ТАТАР

ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР Ә.М.МАЗҺАРОВ

## 3

## К–Л

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ИНСТИТУТЫ
2012

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ҖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

## Баш гыйльми мөхәрририят


Ә.М.Мазһаров (рәис), Р.М.Вәлиев (рәис урынбасары), Р.К.Абдуллин, С.С.Айдаров, А.Г.Әхмәдуллин, Н.М.Вәлиев, З.Р.Вәлиева, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, А.Х.Гыйльметдинов, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, Г.С.Сабирҗанов (җаваплы мөхәррир), К.М.Салихов, М.Х.Сәлахов, М.М.Сәфәров, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Җ.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.

© «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2012.
«Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында»гы РФ Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

ISBN 978-5-902375-08-1

# К

**КАБА́**, 1) татар халкы көнкүрешендә элек киң таралган җеп эрләү җайланмасы. Аның тоташ һәм сүтелмәле төрләре булган. Сүсне, йон, мамыкны тетү өчен югары очында тарагы булган җайланма — «тәрәшле каба», тәрәшсез каба «колга» дип йөртелгән. Эрли




1. Тәрәшсез каба (колга); 2. Тоташ каба (тамыр каба); 3. Тәрәшле каба.

торган механик кабаны «чыгыр» яки «чарык» дип атаганнар. 20 йөзнең икенче яртысыннан көнкүрештә завод-фабрикалар эшләгән җепләр киң таралганнан соң, К.ны куллану кими; 2) агач суканың төбен беркетеп куя торган кисәге («каба агачы»).

*Әд.:* Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек. К., 2007; Татары. М., 2001.

**КАБА́ЕВА** Алина Марат кызы (12.5.1983, Ташкент), спортчы (нәфис гимнастика), РФнең атказ. спорт остасы (2000). Мәскәү сервис ун-тын (2007), Петербург физик культура, спорт һәм сәламәтлек ун-тын (2009) тәмамлый. Гимнастика б-н 1986 елда шөгыльләнә башлый, тренерлары — РФнең атказ. тренерлары В.Н.Шаталина, И.А.Винер (1995 тән, Мәскәү). Игелекле уеннарда (1996), РФ чемпионатларында (1999–2001, 2004) җиңүче; Европа (1998–2000, 2004), дөнья (1999, 2001, 2003) чемпионатларында, Олимпия уеннарында (2004) абсолют чемпион. Олимпия уеннарында бронза медаль (2000) ала. «Бердәм Россия» партиясенең Югары советы (2001–05), РФнең Иҗтимагый палатасы (2005–07) әгъзасы, РФ Федераль Җыены-ның Дәүләт Думасы депутаты (2007 дән). Дуслык, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденнары б-н бүләкләнә.



А.М. Кабаева.

**КАБА́К** (Cucurbita), кабакчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлек; бакча культурасы. Якынча 20 төре бар. Чыгышы — Төньяк һәм Көньяк Америка (б.э.к. 3 меңенче еллардан билгеле). Культурада 3 төре бар: эре җимешле К. (C. maxima), мускат К. (C. moschata), аңардан К.ның төрләре аерылып чыга — чалмасыман, тәме югары сыйфатлы һәм декоратив төрле, каты кабыклы К. яисә гади К. (C. pepo) һәм аның төрле төрләре — ташкабак һәм патиссон. К. — беренче, читтән серкәләнүче, җылылык һәм яктылык яратучан үсемлек, дымлылыкка һәм туфракның уңдырышлылыгына таләпчән. Тамыр системасы көчле, үзәк типта, туфракта 3 *м* га кадәр тирәнгә китә. Сабаклары 4 *м* га кадәр, тармакланып, җиргә ятып үсә. Яфраклары бик күп, эре, озын сабаклы, төкчәсез, төпчек яфраклар юк; формасы һәм төсе б-н аерылалар. Чәчәкләре аерым җенесле, сары төстә. Җимеше — кабакча (ялган сусыл җиләк), каты җимеш тирәлеге (кабыгы) һәм күп санда яссы формалы орлыклары бар, 30–50 көндә формалаша, саклау вакытында да өлгерү сәләтенә ия. К. төрләре үзара серкәләнмиләр. Орлыкларны грунтта яисә үренте итеп үстерәләр, вегетация чоры 80–130 көн. Азык буларак өлгергән җимешләре кулланыла; итчел җимеше — крахмалга, шикәргә, C, B, $B_2$, E витаминнарына, каротин, пектин матдәләргә, ә орлыклары майга бай. Җимешләре кулинариядә, ш.у. төрле хайваннар өчен кыйммәтле сусыл азык буларак кулланыла. К.ның — «Мозолеевская 49», «Зимняя сладкая», «Миндальная 35», «Стофунтовая», «Уфимская», кабакчаның — «Нефрит», «Грибовский 37», «Цукеша» сортлары үстерелә. Илл. к. *Бакча культуралары.*

*Әд.:* Справочник по овощеводству. Л., 1982; Овощеводство. М., 2003.

**КАБАКЧАЛА́Р** (Cucurbitaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. 130 ыругы, 900 төре билгеле, башлыча, Җир шарының тропик һәм субтропик поясларында таралган. Бер- һәм күпьеллык үрмә һәм шуышма сабаклы үләннәр, сирәк кенә куаклар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар: кабак үләне, тладианта, эхиноцистис. Яшелчә буларак, бакча участокларында күбрәк *кыяр*, *кабак*, ташкабак, патиссон, сирәк кенә — карбыз, кавын үстерелә. 1–5 *м* озынлыктагы бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Сабаклары сусыл, суга бай, шуышма яки үрмәле. Яфраклары чиратлашкан, гади, калаксыман яки бармаксыман — теленмә, йөрәксыман нигезле, спираль буенча урнашкан. Серкәчләре 5, күпчелегендә алар парлап үсәләр, берсе ирекле. Җимешлеге бер. Чәчәкләре берле, куентылы яисә себеркәчле чәчәк төркеменә җыйналган, серкәләндерүчеләрне (бал кортлары, шөпшә, төклетура һ. б.) көчле исе б-н түгел, ә ачык сары таҗлары б-н җәлеп итә (мәс., кабакта һәм кыярда). Бөҗәкләр ешрак ата чәчәкләрне үз итәләр, серкәләр исә аларга азык булып тора (100 дән артык файдалы матдәләр, ш. и. аксымнар, май, витаминнар бар). Җимеше — кабакча, җимеш тирәлегенең тышкы катлавы каты, эче — итчел, сусыл, орлыклары күп. Шактый төрләренең җимеше ашарга яраклы. Кабак үләне, тладианта, эхиноцистис — дару, декоратив, баллы үсемлекләр.

**КАБАЛА́Н** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 20 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 21 кеше (татарлар) яши. Клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кабаланов Куст, Бикбулатово исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да почта станциясе урнаша, мәчет, мәдрәсә, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 577,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Черки-Килдураз волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 278, 1897 дә — 455, 1908 дә — 550, 1920 дә — 515, 1926 да — 340, 1938 дә — 333, 1949 да — 271, 1958 дә — 270, 1970 тә — 138, 1979 да — 94, 1989 да — 65, 2002 дә — 32 кеше.

**КАБА́Н АРТЫ́ МӘЧЕТЕ́** (икенче исеме — Ислам дине кабул итүнең меңьеллыгы шәрәфенә салынган мәчет, Юбилей мәчете),



Кабан арты мәчете. Арх. А.Е.Печников. 1926. Хәзерге күренеше.

архит-ра истәлеге. 1919–26 елларда арх. А.Е.Печников проекты буенча шәркый мөселман үрнәгендәге романтик модерн стилендә төзелгән.


Постаучылар бистәсендә, Иске Татар бистәсе каршында Кабан күле ярында урнашкан. Манарасы бина почмагына куелган бер заллы, антресольле җамигъ мәчет. Дүрт кырлы биек манара яктылык тәрәзәләре һәм түгәрәк балконы булган цилиндрга күчә баручы сигез кырлы кәүсәне тәшкил итә. Манара кәрнизе уен бизәк төшерелгән уксыман гөмбәз б-н очланган. Манара ишеге тамбур аша турыпочмаклы, ике рәт тәрәзәле гыйбадәт залына илтә. Әүвәл гыйбадәт залының сул як өлешендәге өч колоннага урнаштырылган балконга вестибюльдәге баскыч алып менгән. Совет чорында зал ике катка бүленә. Хәзер 1 нче катта — гыйбадәт залы, 2 нчесендә уку бүлмәләре урнашкан. Манараны хәтерләтүче уксыман порталлар, тәрәзә архивольтлары, баскычлы һәм кәкре сызыклы тәрәзә йөзлекләре, дивардагы аркатуралы путалар урта гасырлар гарәп-мавритан архит-расының модерн стилендәге үзенчәлекле мәчетне формалаштыралар. Кызыл кирпечле диварның штукатурланган бизәкләр һәм яшел төстәге керәч өстәмәләр б-н ярашуы бинаның гомуми күренешен тагын да тулыландырып җибәрә.

Мәчет 1930 елда ябыла, бина дәүләт учреждениеләренә бирелә, 1991 елда дин тотучыларга кайтарыла. Бинада ш. у. Ислам дине кабул итүнең меңьеллыгы исем. мәдрәсә урнашкан.


*Әд.:* Салихов Р.Р., Хәйретдинов Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр башы). К., 1995; Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КАБА́Н ДУҢГЫЗЫ́** (Sus scrofa), дуңгызлар семьялыгыннан күшәми торган партояклы имезүче хайван. Евразия һәм Төньяк Африкада таралган, Америкада климатлаштырылган. Эре хайван: ана затларның озынлыгы 1,7 *м*, ата затларның 2 *м* тирәсе, биеклеге җилкә калкымында 1 *м* га кадәр; ана затларның авырлыгы 150 *кг* га, аталарның 250–300 *кг* га җитә. Башы зур, чөйсыман озынча, күзләре кечкенә, батынкы. Кискеч тешләре алга, өске һәм аскы казналыкның казык тешләре өскә һәм ян-якка юнәлгән. К.д.ның тешләре гомер буе үсә, зур ата затларда (ата кабаннарда) 8–10 *см* озынлыкка җитә. Гәүдәсе ян-яктан кысылган; алгы өлеше арткысына караганда зуррак һәм шактый калку. Кылы каты, җилкә калкымында сизелерлек ял барлыкка китерә; кышка тупасрак мамык үсеп чыга. Олы хайваннар куе сорыдан көрән яки кара төскә кадәр. 4 айга кадәр балаларының ян-ягында аксыл саргылт төстәге буй сызыклар була. 3–10 арлап (кайвакыт берничә дистә), көтү булып яшиләр. Көтүдәге аерым затлар һәм аерым көтүләр арасында билгеле бер иерархия мөнәсәбәтләре урнашкан. Ана затлардан һәм яшь хайваннардан торган көтүләрдә аеруча көчле ана затларның — берсе, ә ата К.д.лары төркемендә аеруча көчле ата зат өстенлек итә. Җенси активлык чоры ноябрь–гыйнварда. Буазлык чоры якынча 115 көн. Гадәттә, 4–5 (кайвакыт 12 гә кадәр) бала китерә. Балалары тиз үсә, җәй ахырына аларның авырлыгы 20 *кг* һәм күбрәк тә була, кышка кадәр аналары б-н яшиләр. Җенси яктан ана затлар 8–10 айлык вакытта, ата затлар яшәешенең 2 нче елында җитлегә. 10–12 (сирәк кенә 20) ел яши. Төрле азык б-н туклана. Туклануында



1



2

Ата (1) һәм ана (2) кабан дуңгызлары.


үсемлекләр өстенлек итә: үсемлек тамырлары һәм бүлбеләре, үлән, имән чикләвеге, чикләвекләр, агач һәм куак җимешләре. Хайван азыгын яңгыр суалчаннары, туфрак бөҗәкләре һәм аларның личинкалары, төче су һәм җир өсте моллюсклары, тычкансыман кимерүчеләр, кош йомыркалары һәм балалары, бака, кәлтә, еланнар, кайвакыт үләксәләр тәшкил итә. Кышын К.д. кипкән үлән, агач кайрысы һәм ботаклары, агач гөмбәләре, кырда калган иген уңышы б-н туклана. Дошманы — бүреләр, алар аеруча кар күп булган кышларда, яшь хайваннарны бөтенләй диярлек юкка чыгарып, К.д.ларына зур зыян китерәләр. Ата затларга бүреләр сирәк һөҗүм итә, К.д.ның казык тешләренә юлыгып, үзләре үлгән очраклар да бар. Кайвакыт яшь К.д. селәүсен яки аю корбаны була. Татарстан терр-ясендә элек К.д.лары күпләп яши, әмма кырып бетерелә. 1970 тә аучылык оешмалары тарафыннан яңадан үрчетелә һәм кыска гына вакыт эчендә республиканың бөтен терр-ясендә диярлек тарала. Хәзерге вакытта аларның саны 2 меңнән артык. К.д. күп булган р-ннарда аларның зыяны шактый: бәрәңге кырларын һәм чәчүлекләрне «яңадан сөрәләр», кырмыска ояларын туздыралар, туфрак өслегендәге вак хайваннарны юк итәләр, агач токымнарының, бигрәк тә имәннең табигый үсешен зарарлыйлар. К.д.ның баш санын даими көйләп тору зарур. Сунарчылык (ите, тиресе, кылы) объекты. Йорт дуңгызының нәсел башы.

**КАБА́Н КҮЛЛӘРЕ́**, Казан эчендә урнашкан өч күлдән (*Бирге Кабан, Аргы Кабан, Югары Кабан*) торучы күлләр системасы. ТР терр-ясендә иң зур күлләр системасы. Гомуми мәйданы — 186 *га*. Тар бугаз б-н тоташкан Бирге һәм Аргы Кабанның озынлыгы 5575 *м*, Югары Кабанның озынлыгы 1030 *м*. Иң тирән урын 12–13 *м*. Гомуми су күләме 11,8 млн. $м^3$. Күлләр карст упкыннарыннан хасил булган чокырларның катлаулануы нәтиҗәсендә Иделнең элеккеге су юлы урынында барлыкка килгән. Иделнең биек террасасы буйлап төньяктан көньякка сузылып киткән. Бирге һәм Аргы Кабан арасындагы су алмашу зооботаника бакчасы буенда урнашкан Ботаника ермагында (озынлыгы 750 *м*, киңлеге 100–120 *м*, тирәнлеге 2–3 *м*) бара.

Бирге Кабан Болакның табигый ермагыннан бүлеп куелган, ермакта су тигезлеген көйләү максатында аның аша күлдән суны билгеле бер төстә агызалар. Аргы Кабанның Идел б-н бәйләнеше бар. Аның көньяк өлешеннән Монастырь дип аталган инеш үтә, һәм ул күлне Иделнең Подувалье култыгы б-н тоташтыра (риваять буенча инешнең бер өлеше Воскресенский монастыре монахлары тарафыннан казылган; 1960 та канал дәвам иттерелә). Отар посёлогы р-нында инеш дамба б-н ябыла, суны аның аша насослар б-н Куйбышев сусаклагычына җибәрәләр. Югары Кабан — ябык сулык, һәм системаның башка күлләре б-н аның гидрологик бәйләнеше юк. Аргы һәм Бирге Кабаннарга караганда анда су биеклеге 2 *м* га югары.

1950 нең 1 нче яртысында шәһәрнең инженерлык саклау дамбасы төзелгәнче, К.к. Идел һәм Казансу б-н актив су алмаша. Язгы су ташу вакытында Идел Казансуның түбәнге агымнарында су биеклеген югары күтәрә, һәм су, ташкын булып, Болак аша Бирге Кабанга, аннан соң Аргы Кабанга килеп керә. Ташу кимегәннән соң, артык су Бирге Кабаннан Болакка, аннан Казансуга, Аргы һәм Югары Кабан сулары аерым ермаклардан Иделгә агып чыга торган була.

Мең еллар дәвамында К.к. системасы үзенең табигый чисталыгын һәм балыкка байлыгын саклый. Металл эш кораллары барлыкка килгәч, кеше эшчәнлегенең күлләргә, әйләнә-тирә табигать ландшафтына тискәре йогынтысы башлана: яр буйларындагы урманнарны юкка чыгару, җирләрне сөрү ерым эрозиясе көчәюгә һәм алар аша бу күлләргә комсу-балчыксыл китерелмәләр килүгә, ш.у. аларга коючы елга һәм инешләрнең юкка чыгуына китерә. 16 йөздә шәһәр төзелешләре Бирге Кабанга якыная, һәм күл шәһәрне су б-н тәэмин итүче төп чыганакка әверелә. 18 йөз уртасында аның ярларын тулысы б-н диярлек торак йортлар каплап ала. Суы эчү өчен дә, җиләк-җимеш бакчаларын сугару өчен дә тотыла, шул ук вакытта күлнең ярларына (кышларын бозга) тирес һәм чүп-чар түгүләр башлана; сулыкларга төрле пр-тиеләрнең пычрак сулары, ш.у. шәһәр урамнарында яуган яңгыр һәм кар сулары ага башлый. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан күлнең яр буйларында киң колачлы сәнәгать төзелешләре җәелә: постау мануфактура җитештерүе киңәйтелә, бертуган Крестовниковларның стеарин-шәм-сабын кайнату з-ды (к. *Шәм-стеа-*




*рин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы*), хәрби ведомстволары өчен аяк киемнәре җитештерү з-ды, Оскар Петцольдның сыра кайнату з-ды, мамык җебе эрләү, күн һәм аракы пр-тиеләре ачыла. Алардан агып чыккан пычрак су Бирге Кабанга төшә, һәм 19 йөзнең 2 нче яртысында күлдәге су эчәргә яраксыз хәлгә килә. 1875 тә шәһәр җир асты сулары б-н тәэмин ителә башлый, су Казаннан 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Пановка авылы янында урнашкан җир асты чишмәләреннән алына. 19–20 йөзләр чигендә әле Югары Кабанның суы чиста һәм эчәргә яраклы була. Күл шәһәр халкының яратып ял итә торган урыны булып тора. Аның яр буйларында танылган пр-тие хуҗаларының һәм эшмәкәрләрнең (Апанаев, Борнаев, Сәйдәшев, Унженин, Смирновлар) бакчалары һәм утарлары төзелә. Анда су коену өчен махсус урыннар һәм күңел ачу йортлары (1895 тә «*Аркадия*» бакчасы ачыла) эшли. 1868 дә пароходчылыкка нигез салына, аның судноллары Бирге Кабан һәм Аргы Кабан күлләрендә йөзә, пассажирларны Казан пехота уч-щесе хәрби лагерьларына, Архиерей шәһәр яны йортына, кымыз б-н дәвалану йортына, Воскресенский авылына һәм бакчаларга ташый. 17 йөз ахырыннан 18 йөз ахырына кадәр күлләр Воскресенье монастыре биләмәләре булып тора, балык сәүдәсе монастырьның төп керемнәреннән берсе була. 20 йөзнең 1 нче яртысында яңа сәнәгать пр-тиеләре файдалануга кертелгәннән соң (СК, «Искож» з-длары, «Спартак» комб-ты һ.б.), күлләрдә чиктән тыш начар экологик халәт туа. 1928 дә Бирге һәм Аргы Кабаннарны тоташтыручы Ботаника ермагы тимер юл дамбасы өеме б-н ябыла, аның астында бетон а́рка төзелә, һәм 1,5 *м* га якын тирәнлектә ясалма канал үткәрелә. Нәтиҗәдә, күлләр арасындагы су алмашы бозыла, бу аларның табигый хәленә зур зыян китерә. 1957 дә Куйбышев сусаклагычы төзелү хәлне тагын да катлауландыра. К.к. шәһәрнең инженерлык саклау дамбалары б-н Идел һәм Казансуның ташкын суларыннан аерыла, күлләр системасы йомык экосистемага әйләнә. 1957–58 дә комсуыргычлар ярдәмендә 2–3 *м* тирәнлектә күл төпләре, яр буйлары ләмнән чистартыла. Сусаклагычның гидростатик басымы Бирге Кабанга һәм Аргы Кабанга грунт сулары керүен арттыра, һәм аларда су биеклеге күтәрелә. 1960 та күлләрдәге артык су дренаж системасы б-н Иделгә җибәрелә башлый. Күлләрнең төбен чистарту һәм аларны агымлы итү чаралары суның сыйфатын беркадәр яхшырта, ләкин суны пычрату чыганаклары бетерелми. 1970 нең 2 нче яртысында Бирге Кабанда балыклар, хәтта күл төбендә яши торган умырткасызлар да юкка чыга. Аргы Кабанда да 2 *м* тирәнлектә тере организмнар бөтенләй калмый. 1982–83 тә комсуыргыч ярдәмендә чистарту эшләре башлана (ләмне Отар посёлогы янындагы убылган, сазланган участокка суыртып чыгаралар). Бирге Кабан төбеннән 1,5 млн. *т* ләм алына. Төзекләндерү, чистарту чаралары б-н күлнең экологик хәле берникадәр яхшыртыла, пычраткыч матдәләрнең концентрациясе сизелерлек кими, һәм суда балыклар күренә башлый. Комсуыргыч 1988 дә Аргы Кабанга, төбен чистарту эшләрен башкару өчен, яңа урынга күчерелә. 1980 еллар ахырыннан Бирге Кабанның яр буйларын төзекләндерү башлана (Татар акад. театры янында бетон яр буе төзү, Иске Татар бистәсе һәм «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе яр буйларын яшелләндерү, ныгыту, тигезләү эшләре алып барыла, ял итү теплоходлары өчен причаллар төзелә). К.к. системасы исемнәренең килеп чыгышы турында берничә фараз бар. Аеруча киң таралган риваятьләр буенча күлләрнең исеме — элек сулыкны әйләндереп алган имәнлекләрдә, ерымнарны каплаган әрәмәле куаклыкларда кыргый кабаннарның күпләп яшәве б-н, икенче бер риваять буенча күлләрнең исеме Кабанбәк исеме б-н бәйле (Болгар патшасы Габдулланың улы): Болгар шәһәре дошманнар тарафыннан җимерелгәч, ул бу якларга кача һәм биредә торулык төзи. Шулай ук «кабан» сүзе борынгы төрки «каб» («куб») сүзенә барып тоташа һәм ул «чокыр», «казанлык» мәгънәсенә туры килә. Казан ханнарының Кабан күле төбендә яшерелгән хәзинәләре турында күпләгән легендалар яшәп килә.

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф. Казань: Ист. очерк. К., 1952; С е м е н т о в с к и й В.Н. Озеро Кабан // Очерки по географии Татарии. К., 1957; М и н г а з о в а Н.М., К о т о в Ю.С. Казанские озёра. К., 1989; М у с т а ф и н Р.А. Озеро Кабан. К., 1989; ш у л у к. Тайны озера Кабан. К., 1993.

**КАБА́Н-БАСТЫРЫ́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бастырма елгасы буенда. 2010 елда 139 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык, вак һөнәрчелек: көпчәкләр, чана, дуга ясау, киндер сугу, келәм (палас) туку, чыпта, чабата үрү б-н шөгыльләнә; 1773–75 елгы *Крәстияннәр кузгалышында* Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.-Б.та архистратиг Михаил чиркәве (1881 дә төзелә), миссионерлык мәктәбе (1870 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1744 дис. тәшкил итә. 1929 да К.-Б.та Ворошилов исем. к-з оештырыла, 1958 дә, берникадәр үзгәрешләрдән соң, Сталин исем. к-з (1961 дән — Киров исем., 1963 тән — «Игенче», 1998 дән — а.х. товарлары җитештерүче кооператив) составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 462, 1870 тә — 452, 1897 дә — 1075, 1920 дә — 1377, 1926 да — 1175, 1938 дә — 1038, 1949 да — 799, 1958 дә —

785, 1970 тә — 722, 1979 да — 376, 1989 да — 214, 2002 дә — 156 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КАБА́Р АГАЧЫ́**, маржа алкасы (Euonymus), кабарчалар семьялыгыннан яфрак коючан һәм мәңге яшел куаклар яки агачлар ыругы. 200 дән артык төре билгеле, Евразиядә, Америка һәм Австралиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре бар — сөялле К.а. (E. verrucosa). Бөтен республика терр-ясендә киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда, имән урманнарының куаклыкларында үсә. 1–2 *м* биеклектәге күләгәгә чыдам талымсыз куак. Тамыр системасы тирән түгел. Яфраклары гади, каршыдаш, пычкы читле, коңгырт яшел. Ботаклары, тыгыз итеп, көрән яки кара төстәге сөялләр б-н капланган. Чәчәкләре яшькелт-ак яки җете кызыл, яфрак куентыгында урнашкан ярымчатырда. Җимеше — тартмачык, өлгергәч алсу кызыл төскә керә. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм тамыр үргеннәреннән үрчи. Кәүсә кабыгында һәм тамырларында 32% ка кадәр кипмәүче май бар. Барлык өлешләре дә агулы. Халык медицинасында костыру һәм эч йомшарту чарасы, кипкән җимешләре порошогы инсектицид буларак кулланыла. Үзагачы төрле әйберләр ясарга ярый. Декоратив үсемлек буларак, яшел киртәлекләр һәм бордюрлар ясаганда файдаланыла.

**КАБА́Т ҖИТЕШТЕРҮ́**, җитештерү процессының даими, өзлексез кабатлануы. Матди байлыклар һәм хезмәт күрсәтүләрне, эшче көчне һәм җитештерү мөнәсәбәтләрен К.җ. күздә тотыла, аңа ш.у. җитештерү, алыштыру, бүлү һәм куллану процесслары керә. Буыннар өзексезлеген, милли байлыкны саклау һәм арттыруны тәэмин итә. Гади һәм киңәйтелгән К.җ.не аерып күрсәтәләр. Гади К.җ. булганда, җитештерелгән тулаем милли продукт һәм милли табыш күләме артмый, җитештерүне оештыру, аның техникасы һәм технологиясе күпкә үзгәрми. Җитештерү элекке масштабтагы кабатлану б-н генә чикләнә. Гади К.җ.нең аерым бер төре — тарайтылган К.җ., аны икътисади һәм финанс кризислары, оборона сәнәгатендәге конверсия, икътисадка реформалар кертү һәм аны структур үзгәртеп кору, стихияле бәла-казалар һ.б. китереп чыгара. 1990 — 94 елларда ТРда җитештерү ел саен 8,5% ка түбәнәя. Киңәйтелгән К.җ.гә җитештерелә торган продукция һәм хезмәт күрсәтүләрнең үсеше хас, бу үсеш, фән һәм техника казанышларын гамәлгә кертеп, җитештерү факторларын сыйфат ягыннан үзгәртеп, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру хисабына бара. 1995 тән 1999 га кадәр җитештерү күләмнәренең уртача еллык үсеш темпы 4,26% тәшкил итә. 2009 да сәнәгать җитештерүенең гомуми күләме 1995 ел дәрәҗәсеннән — 66,2% ка, машиналар төзелешендә — 62,5% ка, транспорт чаралары һәм җиһазлар җитештерү 9,4 тапкыр арта. Файдалы казылмалар, нефть чыгару 1995–2009 елларда 28,2% ка үсә.

*Әд.:* Современная экономика. Ростов н/Д.–М., 1995; Республика Татарстан: Стат. справ. К., 2010.

*Ф.Г.Газизуллин.*

**КАБИЛӘЛӘ́Р БЕРЛӘШМӘСЕ́**, дошман һөҗүмен (яки һөҗүм янавын) кире кайтару һәм күрше кабиләләргә каршы сугышу өчен, берничә кабиләнең берләшүе. Әлеге максатларда берләшкән кабиләләр күп кенә очракларда, сугышлар беткәннән соң да, шулай яшәп калганнар. Яңа яулап алынган кабилә еш кына К.б.нә яңа халык хокукында кертелгән; К.б. эчендә әгъзалар катлаулары барлыкка килгән (Дунай Болгариясендә — болгарлар һәм славяннар). Берләшмә эчендәге үзара йогынтылар халыкның берлегеН анларга ярдәм иткән. К.б. хакимияттә сугыш җитәкчеләре ныгып калу һәм беренче дәүләтләр-юлбашчылыклар төзелү ягына таба үсеш алган. Идел буенда һәм Урал алдында ананьино, пьянобор, азелино, имәнкискә һ.б. К.б. билгеле.

*Әд.:* История первобытного общества: Эпоха классообразования. М., 1988; Гиренко Н.М. Социология племени. Л., 1991; Крадин Н.Н. Политическая антропология. М., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**КАБУЛХАНӘЛӘ́Р** (гарәп. قبول — ризалык бирү һәм фарсы. خانه — бина), Казан Кремле терр-ясендә. Адм. бинаның беренче проекты 18 йөз ахырында арх. В.И.Кафтырев тарафыннан эшләнә. 19 йөз башында кирпечтән сузынкы ике катлы губерна идарәсе бинасы төзелә. Эчке ишегалдына илтүче ике юлы булган бина үзенең вестибюльләре һәм баскычлары б-н 3 секциягә бүленә. Икенче каттагы секцияләр ян-якларына эш бүлмәләре урнашкан үзәк коридор б-н бәйләнгән. Биек гөмбәзле ярымподвал каты фасадтагы тәрәзәләр аша яктыртыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында бинага өстәп 2 кат салына һәм ике кыеклы түбә б-н ябыла. Яңа катлар бинаның аскы өлешенә тәңгәл итеп төзелә. Кирпеч диварлар штукатурлана һәм агартыла. Фасадлар бизәксез. Ишек өстендәге авыш түбә чүкеп ясалган кронштейнга куелган, бусага алдына чуен баскычлар урнаштырылган. Вестибюльләрдәге баскычларның ян-якларына челтәр бизәкле култыксалар беркетелгән. 21 йөз башында үткәрелгән реконструкция вакытында бина элекке ике катлы рәвешенә кайтарыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КА́БУШКИН** Иван Константинович (15.2.1915, Белоруссия Респ-касы, Брест өлкәсенең Барановичи р-ны Малаховцы а. — 4.2.1943, Минск), Сов. Союзы Герое (8.5.1965, үлгәннән соң), кече лейтенант (1938). Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1938). 1915–35 елларда Казанда яши, трамвай йөртүче булып эшли. 1935 тән Кызыл Армия сафларында. Совет гаскәрләренең Көнбатыш Белоруссия походында (1939) һәм совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында. Әсирлеккә эләгә, качканнан соң, Минскида яшерен оешманың оператив төркеме б-н җитәкчелек итә, 208 нче партизан отрядының разведка башлыгы ярдәмчесе була. Басып алынган Минск каласында фашистларга каршы көрәштә катнаша: сугыш кирәк-яраклары, медикаментлар табыша, лагерьдан качучы хәрби әсирләргә ярдәм күрсәтә, листовкалар бастырып таратуга җитәкчелек итә. 1943 нең 4 февралендә гестапо тарафыннан кулга алына, һәлак була. Ленин ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Минскидагы бер урам, Барановичи шәһәрендәге 12 нче номерлы мәктәп К. исемен йөртә. Туган ягында Геройга һәйкәл куела. «Казгорэлектротранспорт» пр-тиесе каршындагы музейның бер бүлмәсендә К. турында материаллар тупланган. Казанның 3 нче трамвай депосында К. йөрткән трамвай саклана.



И.К. Кабушкин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Люди легенд. М., 1971. Вып. 4; Ракипов Ш.З. По следам Героев. К., 1975; Петраченко Д.М. Именами Героев. Минск, 1978; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КАБЫГАШАРЛА́Р** (Ipidae), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. 3 меңнән артык төре билгеле, Россиядә — 200 дән артык, шуның 50 гә якыны — урман хуҗалыгына һәм бакчачылыкка зарар китерүче корткычлар. Олы коңгызлар 0,8–8 *мм* озынлыкта, цилиндр рәвешендәге озынча гәүдәдән тора, буынлы мыекчыкларның чукмарлары ачык беленә, аяклары кыска һәм юка тәпиле. Күп кенә төрләрнең өске канатлары агач чүбен ташлау өчен җайлашып, очлары батып кергән, читләре тешле булган батынкылыклар барлыкка китерә. Личинкалары ак төстә, аяксыз, С-сыман бөгелгән кыска юан гәүдәле, хитинлашкан зур башлы. Күпчелек төрләре елга 1 буын, сирәк кенә 2 буын бирә. Моногамик гаиләләрдә (ата һәм ана зат) кайрыда аналык юлын ана зат кимереп тишә, аннан соң аның янына ата зат очып керә. Полигамик гаиләләрдә (ата зат һәм берничә ана зат) киң никах камераларын кимереп тишү ата зат өлешенә туры килә, соңыннан анда берничә ана зат керә; кушылудан соң һәрберсе үз аналык юлын кимереп тишә. Аналык юлының стенкасына салынган йомыркалардан личинкалар чыга, алар исә берничә киң камера («курчак бишеге») б-н тәмамланучы үз личинка юлларын салалар. Шулай итеп, «кабыгашар оясы» барлыкка килә, аның формасы буенча һәм зарарланган агачның токымына карап, К.ның төрен ялгышмыйча билгеләргә мөмкин. *Кисмәннәрдән* аермалы буларак, К. зәгыйфь һәм яңа ауган агачларны зарарлый. Яшәү урынына карап, аларны кабыгастлар (төчлегәннәр, юкәрашарлар, типографлар), үзагач (үзагачта юллар сала) һәм урман бакчачыларына (ботакларны кимереп, агач кәүсәләренә һөҗүм итәләр һәм, шул сәбәпле, агачлар нык кына зәгыйфьләнә) аерып йөртәләр. Үзагач К. личинкалары үзагач б-н түгел, ә галереяга ана затлар б-н ияреп керүче гөмбә җепселләре (гифлары) б-н туена.

Татарстан терр-ясендә К. фаунасы аз өйрәнелгән. Аерым агач токымнарының аеруча куркыныч үзенчәлекле корткычлары турын-

да гына мәгълүматлар бар, алар арасында каен төчлегәне (Scolytus ratzeburgi jans.), имән төчлегәне (S. Intricatus), зур нарат юкәрашары (Blastophagus piniperda L.), зур чыршы юкәрашары (Dendroctonus micans Kug.) бар.

*А.К.Жеребцов.*

**КАБЫ́К КҮПЕ́Р** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 21 *км* төньяктарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 157 кеше (руслар) яши. Урта мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, көпчәк ясау, сарык тиресе эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә кәшәнә, земство мәктәбе (1897 дән), 8 җил тегермәне, 3 ярма яргыч, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2121,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 576, 1897 дә — 1005, 1908 дә — 1314, 1920 дә — 1166, 1926 да — 1410, 1938 дә — 656, 1949 да — 497, 1958 дә — 331, 1970 тә — 270, 1979 да — 212, 1989 да — 182, 2002 дә — 198 кеше. Авыл янында *Кабык Күпер комплексы* урнашкан.

**КАБЫ́К КҮПЕ́Р КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Апас р-ны Кабык Күпер авылы янында урнашкан. К.К.к. ядкәрләре археологлар А.Х.Халиков (1960–61 елларда) һәм Р.С.Габәшев (1989–90 да) тарафыннан тикшерелә. Комплекска таш һәм бронза гасырларга нисбәтле өч туктаулык керә. К.К.к.ның I туктаулыгында табылдыклары мезолит чорына караган зур, яртылаш җиргә иңгән торак булганлыгы ачыклана, аның өске катламында мезолит дәверенең таш корал һәм неолит чорыннан калган балчык савыт-саба калдыклары табыла. I туктаулыктан 150 *м* төньяк-көнбатыштарак урнашкан II Кабык Күпер туктаулыгында табылган әйберләр неолит чорына карый дип фаразлана. III Кабык Күпер туктаулыгында (ул I нчесеннән көнбатыштарак) табып алынган әйберләр исә бронза гасырга карый; культура катламы калынлыгы 30–40 *см* га җитә. К.К.к. терр-ясендә ш.у. Бaланово, Кама, Казан яны һ.б. археол. культураларга караган археол. ядкәрләр барлыгы ачыклана.

*Әд.:* Халиков А.Х. Мезолит Среднего Поволжья // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1966. № 126; шул ук. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; шул ук. Приказанская культура // Свод археол. источников. 1980. Вып. 1–24; Бадер О.Н., Халиков А.Х. Памятники балановской культуры // Свод археол. источников. 1976. Вып. 1–25.

*Р.С.Габәшев.*

**КАВА́Л** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 28 *км* көнчыгыштарак, Кибә елгасы бассейнында. 2010 елда 278 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, тимерчелек, киез итек басу һәм сарык тиресен эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1868 дә ачыла), җил тегермәне, тимерчелек, ашлык саклау-сату кибете, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1172 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 557, 1897 дә — 853, 1908 дә — 984, 1920 дә — 1171, 1926 да — 1111, 1938 дә — 1084, 1958 дә — 839, 1970 тә — 924, 1979 да — 721, 1989 да — 544, 2002 дә — 349 кеше.

**КАВА́Л КҮЛЕ́**, *Кавал күлләре* системасындагы аеруча зур күлләрнең берсе. Аның көньяк өлешендә, Лаеш р-ны Комлы Кавал авылыннан көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 91,6 *га*, күләме 3616,4 мең $м^3$. Озынлыгы 1850 *м*, киңлеге 540 *м*. Уртача тирәнлеге



Кавал күле.

4 *м*. Күлнең төбендә 13,11 һәм 6 *м* тирәнлектәге өч карст казанлыгы бар. Күлнең формасы катлаулы, уртасында зур утрау бар, ул көнбатыш яр б-н киңлеге 4–6 *м*, озынлыгы 400 *м* булган дамба б-н тоташкан. Дамба биек түгел, яз көне аның аркылы урыны-урыны б-н су агып чыга. Утрауда хуҗалык бакчалары урнашкан. К.к.нең төньяк өлеше торфлану стадиясендәге зур булмаган күп кенә карст казанлыкларыннан торучы эрозияле уйсулыкларны били. Күл ял итү максатларында һәм суы бакчаларга сибү өчен файдаланыла.

**КАВА́Л КҮЛЛӘРЕ́**, Көнбатыш Кама алды күлләр системасы. Лаеш р-ны Комлы Кавал һәм Столбище авыллары арасында. 3 күлдән гыйбарәт: *Кавал куле, Урта күл* һәм *Зимница* күле; алар тар гына (10–15 *м*) ермаклар б-н тоташкан. Су өслегенең мәйданы 128 *га*, шуның 11 *га* — утраулар, анда хуҗалык бакчалары урнашкан. Күләме 4500 мең $м^3$. Озынлыгы 4207 *м*, иң зур киңлеге 950 *м*, уртача тирәнлеге 3,4 *м*, иң зур тирәнлеге 13 *м* га якын. К.к. карст-суффозия күренешләре нәтиҗәсендә реликт эрозияле үзәндә хасил була. Күлләр системасы калаклар формасында, меридиональ юнәлештә сузылган. Туенуы катнаш, күбесенчә җир асты сулары исәбенә. Суы җиңелчә минеральләшкән (53–67 *мг/л*), бик йомшак (0,3–0,7 *мг-экв/л*), җиңелчә болганчык (үтә күренмәлеге 35 *см*), гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Суда һәм су янында күпчелек җир-су кырлачы, гади кукрак, елга камышы, үткен күрән, камышсыман кушбашак өстенлек итә. Умырткасызларның сирәк төрләреннән су чаяны бар. Күл бакалары, гади тузбаш, кыр үрдәкләре яши. Ял итү урыны. ТР табигать истәлеге (1978).

**КАВАМЕТДИ́Н БОЛГАРИ́** (чын исеме Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла Сабави-Наласави) (18 йөзнең 2 нче яртысы, Казан губ., Мамадыш өязе Байлар Сабасы а. — 1833, Каһирә), язучы, дин эшлеклесе. Нократ губернасының Малмыж өязендәге Мәчкәрә авылы һәм Бохара (18 йөз ахыры) мәдрәсәләрендә укый. Аннан кайтып, Казан өязе Наласа авылында имам-хатип һәм мөдәррис була. 1826 елда Россиядән Төркиягә китә, Мисырда яши, Мәккәгә хаҗ кылырга бара.

Бохарада үзе б-н бергә укыган Г.Курсавиның рационалистик карашлары тарафдары. Татар дин әһелләре Фәтхулла Урави, Фәез Кышкари, Байморат Мәңгәриләр б-н ул заманда кискен төс алган дини мәсьәләләр хакында бәхәсләшә (мәс., Урта Идел буенда кичке (ястү) намазны уку кирәклеге турында). Кульъязма хәлендә сакланган, гарәп телендә язылган «Мәгъдән әл-мәкасыйд» («Максатлар чыганагы») исемле фәлсәфи хезмәт һәм Наласа авылыннан Фәхретдин Баязит ишан турында сатирик шигырьләр (ш.и. Шәмсетдин Кышкари б-н бергә язылганнары да бар) авторы. Р.Фәхретдин К.Б. хезмәтләрен әл-Газали һәм Г.Курсави әсәрләре рәтенә куя.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1904. 1 җилд, 6 җөзья.

*М.В.Гайнетдинов.*

**КАВЕ́РИН** Фёдор Николаевич (1.2.1897, Мәскәү — 20.10.1957, шунда ук), опера режиссёры, педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939, 1948), Татар опера һәм балет театрының беренче опера спектакльләрен куючы. 1922 елда Кече театр мәктәбен (Н.Смирнова һәм В.Пашенная да) тәмамлагач, шул ук театрда режиссёр һәм бер үк вакытта Мәскәүнең башка театрларында спектакльләр куючы булып эшли. 1925 тән укытучылык эшчәнлеге алып бара, Кече театр студиясендә, Дәүләт театр сәнгате ин-тында, Мәскәү театр уч-щесендә (1949 дан проф.) укыта. Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә режиссёр (1934–38). Казанда К. тарафыннан Н.Җиһановның «Качкын», Ш.Гунонның «Фауст» (икесе дә — 1939), М.Юдинның «Фәридә» (1944) опералары куела.

**КАВИ́** Хәмит (1906, Казан губ., Чабаксар өязе Әлмән а. — 15.7.1944), язучы. Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый (1931). 1926 елдан урта мәктәптә биология һәм география фәннәрен укыта. Ил буйлап сәяхәт кыла, күргәннәрен «Кавказ таулары аркылы җәяү» (1930), «Боз диңгезенә таба» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) исемле китап-

ларында тасвирлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Друженополь (Украина ССРның Волынск өлкәсе) авылы тирәсендә барган сугышларның берсендә һәлак була.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**КАВИ́ЕВ** Илгиз Хәмит улы (8.8.1941, Казан), нефтьче-геолог, геол.-минерал. фән. канд. (1972). 1963 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1963–67, 1973–95, 1998–2000 елларда «Татнефть» АҖнең җитештерү һәм фәнни оешмасында эшли (разведка-бораулау конторасы баш геологы, ТатНИПИнефтьтә сектор мөдире). 1967–73 тә ВНИИгеолнерудта, 1955–98 дә файдалы казылма запаслары буенча Татарстан республика комиссиясенең баш белгече. Татар гөмбәзе кристаллик фундаменты тектонмагматик эволюциянең кайбер үзенчәлекләрен ача, нефть табыла торган структураларның хәвефле төзелешен билгели, ТРның аерым районнарында җир тетрәүләрнең куркыныч хәрәкәтләр б-н бәйләнешен ача.

Хезм.: Разломы и горизонтальные движения платформенных областей СССР. М., 1977 (автордаш); Тектоническая предрасположенность к землетрясениям зоны строительства Татарской АЭС. Альметьевск, 1991 (автордаш).


**КАВИ́ЕВ** Мәҗит Сәлим улы (4.1.1908, хәзерге Свердловск өлкәсе, Түбән Тура р-ны Песчанка приискы — 26.1.1966, Казан), гидрогеолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1964). 1932 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, «Татгеолтрест»та эшли (геолог, партияләр башлыгы, баш инженер, фәнни лаб. директоры). 1946 дан СССР ФА нең Казан ф-лы Геол. ин-тында гидрогеология һәм инженерлык геологиясе лаб-ясе мөдире. Идел буенда геол. һәм инженерлык-гидрогеол. тикшерүләр үткәрә. Татарстан, Чуаш һәм Мари АССР терр-яләрендә җир асты суларының урнашуын, химик составын һәм типларын, Идел елгасы үзәгендәге карст күренешләре үсешен билгели; төзелеш материаллары чыганакларын ача, Идел буе һәм Куйбышев ГЭС объектларын төзү өчен урын әзерли. Лёссыман комсыл балчыкларның инженерлык-геол. үзлекләрен лаб. тикшерү методикасын эшли, Идел буе нефть чыганакларының структур карталарын төзү өчен, күп кенә отышлы горизонтларны билгели, гидроминераль чимал (магний, бром, йод һ.б.) эзләүдә перспективалы урыннарны ачыклый, газ һәм нефть чыганакларының килеп чыгу һәм җыелуының гидрохимик шартларын билгели, аларны эзләүнең һәм Татар гөмбәзендә ватылган урыннарны аерып алуның гидрохимик алымнарын эшли, нефть чыганакларын эшкәртүнең гидрогеол. шартларын нигезли, Татарстан терр-ясен су б-н тәэмин итү дәрәҗәсе буенча районлаштыру картасын төзи. Урал һәм Идел буеның Ведомство геоморфологик һәм неотектоник тикшерүләрен координацияләү комиссиясе әгъзасы, Бөтенсоюз география җәмгыятенең Казан бүлегендә карст географиясен һәм геологиясен өйрәнү комиссиясе рәисе. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: К вопросу поисков нефти гидрохимическими методами // Докл. АН СССР. 1948. Т. 61, № 2; Основные итоги изучения подземных вод ТАССР // Изв. КФАН СССР. Сер. геол. наук. 1957. Юбилейный вып.

*Әд.:* Геологи и горные инженеры России. М., 2000; Геологи-нефтяники в становлении и развитии нефтяной промышленности Татарстана. К., 2000.

**КАВИ́ЕВ** (Кавеев) Хәмит Заһир улы (13.9.1955, Әлмәт р-ны Түбән Мактама эшчеләр пос.), радиоинженер, икътисад фән. канд. (1999), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1997). Казан авиация ин-тын (1978), РФ хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (1992) тәмамлый. 1978–79 елларда Казан авиация ин-тында эшли. 1979–84 тә Миңлебай газ эшкәртү з-дында инженер-электрик. 1984–87 дә КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты инструкторы. 1987–92 дә Әлмәт шәһәр халык депутатлары советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, рәисе. 1992–95 тә «Татольпетро» Россия-Франция уртак пр-тиесенең ген. директор урынбасары. 1995–99 да «Татекс» Россия-Америка уртак пр-тиесе ген. директоры урынбасары, ген. директоры (Әлмәт ш.). 1999 дан «Татнефть» АҖдә (бүленеп): ген. директор урынбасары (2005 кә кадәр), идарә башлыгы (2010 га кадәр), идарә башлыгы урынбасары (2010). 2005–07 дә «Татнефть-Регионнар» ҖЧҖ идарә итүче компаниянең ген. директор урынбасары. Дәүләт бүләге, махсус киңәйтелә торган торбалар кулланып, нефть һәм газ скважиналарын ныгыту өчен яңа технологияләр һәм техник чараларны эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**«КАВКА́З ВӘ МЕРКУ́РИЙ»,** Россиядәге пароходчылык акц. җәмгыяте. 1858 елда «Меркурий» Идел елга пароходчылыгы б-н (1849 да В.В.Скрипицын һәм Н.А.Жеребцов тарафыннан булдырыла) «Кавказ» диңгез пароходчылыгы җәмгыяте кушылу нәтиҗәсендә оештырыла (1857). Максаты — Идел, Ока, Чулман һәм аларның кушылдыкларында пароход элемтәсе оештыру, йөкләр ташу. «К. вә М.»ның төп ремонт һәм такта яру остаханәләре, механика з-ды Казан губернасының Спас Затоны авылында була. Идарәсе С.-Петербургта урнаша. Механика з-ды судноларны ремонтлау өчен җиһазлар, пар казаннары һ.б.ны җитештерә. 1913 тә з-дның күчемсез милке бәясе 128 мең сум чамасы (1917 дә — 137 мең сумнан артык), еллык җитештерүчәнлек — 184 мең сум; эшчеләр саны — 346 кеше (1917 дә — 444 кеше). 1913 тә «К. вә М.» «Көнчыгыш товар складлары җәмгыяте» б-н берләшкәч, «КАМВО» («Кавказ, Меркурий, Восточное») фирмасы барлыкка килә. Спас Затонында товар-пассажир пароходлары: «Минин», «Пожарский», «Александр Невский», «Дмитрий Донской», «Пётр Великий», «Екатерина II» (1869–70), «Иоанн Грозный» (1880; Америка тибында, йөк күтәрешлеге 40 мең пот, соңыннан — «Великий князь Владимир»), «Фельдмаршал Суворов» (1882, Идел пароходлары арасында беренче булып электр б-н яктыртыла), «Владимир Мономах» (1886) һ.б. төзелә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында ремонт остаханәләре сугыш кирәк-яраклары җитештерә. 1918 нең гыйнварында җәмгыять национализацияләнә; остаханәләр башлыгы итеп элеккеге җитәкче А.Л.Декенз калдырыла. 1920 дә Спас Затонында 93 судно ремонтлана. 20 нче еллар башында заводка «Красный котельщик» судноләр төзү заводы» исеме бирелә. 1931 дә анда — 150, 1935 тә — 927 кеше эшли. 1935 тән соң остаханәләр



«Кавказ вә Меркурий» җәмгыятенең «Пётр Великий» пароходы.

җирлегендә нефть флотының ремонт-эксплуатация базасы оештырыла. Бөек Ватан сугышы вакытында завод сугыш кирәк-яраклары чыгара. 1957 дә — «В.В.Куйбышев исем. судноләр төзү-судноләр ремонтлау заводы», 1996 дан «В.В.Куйбышев исем. флот ремонт базасы» АҖ исеме бирелә.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; Шубин И.А. Волга. М., 1927; Фурер Л.Н. Проведение национализации Волжско-Камского флота // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1968. Вып. 62, сб. 3; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976; Рабочий класс Татарии (1861–1980). К., 1981.

*К.А.Нәҗипова.*

**КАГА́Н**, югары хаким, патша, дәүләт башлыгы атамасы. 4 йөздән кытай елъязмаларында искә алына (беренче тапкыр жужаннарның — урта гасырлар башында Көнбатыш Маньчжурия, Монголия һәм Төркестан далаларында яшәгән күчмә кабиләләр берлеге юлбашчысының титулы буларак кулланыла). 6 йөз уртасыннан бу титулны Төрки каганлыгы башлыклары йөртә башлый, шуннан соң традицияне башка төрки халыклар (авар, бәҗәнәк, уйгур, хәзәр һ.б.), 13 йөздән монголлар кабул итә; 8 йөз ахыры — 9 йөз башыннан көнчыгыш славяннарда «кенәз» титулы б-н бергә кулланыла башлый. 8–9 йөзләрдә — гарәп-фарсы телле, 11 йөздә төрки телле язма истәлекләрдә «хакан» буларак теркәлә.

*Әд.:* Бартольд В.В. Хакан // Сочинения. М., 1968. 5 т.

**КАГАНБӘ́К ХАН** (Айбәк хан) (?–1376), Алтын Урда ханы (1375–76). Фаразлар буенча, монголларның гаскәр башы Җучи хан улы Тука Тимер нәселеннән. Хаҗичиркәс ханны куып җибәрә, Алтын Урда башкаласы Сарай әл-Җәдид шәһәрен ала. Акча суктыра. Туктамыш хан тарафыннан тәхеттән куыла. Кече Әтрәч хәзинәсендә аның исеменнән

1375/76 елларда Сарайчык шәһәрендә сугылган акча табыла.

*Әд.:* Куликовская битва. М., 1980; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**әл-КАДӘ́Р** (гарәп. القدر — тәкъдир, язмыш), исламда дөньядагы күренешләрнең һәм кеше кылган гамәлләрнең Аллаһ тарафыннан алдан билгеләнгән булуы. «әл-Кадә» һәм «әл-Кадәр» сүзләренең мәгънәсе көндәлек тормышта аерылмый, әмма фәлсәфи системаларда алар төрле дәрәҗәдәге илаһи күренешләр һәм вакыйгаларның закончалыгын сәбәп-нәтиҗәләр бәйләнешеннән чыгып билгеләр: «әл-Кадә»дә вакыт һәм фәзага бәйсез рәвештә алдан билгеләнү — «Аллаһ ихтыяры» (илаһият галимнәрендә) яки «акыл-беренчел» (философларда) төшенчәләре күздә тотыла; «әл-Кадәр» «әл-Кадә»нең вакыт һәм фәзада җәелүен, аның реаль тормышта барлыкка килүе «Аллаһ ихтыяры» б-н яки «галәми рух гамәле» буларак аңлатыла. Илаһият гыйлемендә әл-К.гә нисбәтле 2 юнәлеш барлыкка килә: бөтенесен үз эченә алган тәкъдиргә инану (яһүдиләр фикеренчә) һәм әл-К.нең чикләнгәнлеге, ягъни кешенең күпмедер ирекле ихтыярын тану (кадәриләр фикеренчә).

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**КАДЕ́Р** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зичә елгасы буенда. 2010 елда 320 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710–11 еллардан мәгълүм. Беренче булып монда Дусым авылы кешеләре күченеп килә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, вак һөнәрчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 940 дис. тәшкил итә. 1929 да К.дә «Якты Йолдыз» к-зы (1998 дән — а.х. товарлары җитештерү кооперативы) оештырыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 февраленнән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 295, 1870 тә — 293, 1897 дә — 534, 1920 дә — 807, 1926 да — 566, 1938 дә — 544, 1949 да — 417, 1958 дә — 416, 1970 тә — 609, 1979 да — 449, 1989 да — 361, 2002 дә — 332 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КАДЕ́Р КИЧӘ́**, Рамазан аеның Мөхәммәд пәйгамбәргә *Коръән* иңдерелә башлаган соңгы кичләренең (27 нче) берсе. Бу кичтә Аллаһ һәр мөселманның язмышын билгели, дип санала. Аны мөселманнар мәчетләрдә, Аллаһны зурлап, Коръән укып үткәрәләр.

**КАДЕТЛА́Р**, к. *Конституцион демократлар партиясе.*

**«КАДИ́ЕВКА ПРОЛЕТАРЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Украина КП(б)ның Кадиевка шәһәр ком-ты һәм профсоюзларның шәһәр советы органы. 1931 елның 30 сентябреннән 1934 нең 7 ноябренә кадәр Кадиевка шәһәрендә (Донецк өлкәсе) татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, 254 саны чыга. Кадиевка шахталарында, кокс-химия, химия һәм металлургия заводларында эшләүче татарлар өчен чыгарыла. Газета битләрендә эшче-хәбәрчеләрнең язмалары зур урын ала.

*Т.М.Насыйров.*

**КАДИМЧЕЛЕ́К** (гарәп. قديم сүзеннән — иске, борынгы), дөньяга билгеле бер караш, татар җәмгыяте үсешендә формалашкан дини һәм әхлакый кыйммәтләрне, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне һәм социаль ин-тларны үзгәрешсез калдырып изгеләштерү һәм саклауга юнәлтелгән, традиционализмның җәмгыять үсешендә формалашкан татар варианты. К., 19 йөзнең 2 нче яртысында Россиядә буржуаз мөнәсәбәтләр урнашуга бәйле рәвештә, татар җәмгыятенең социаль-икътисади һәм рухи-идеологик тормышында барлыкка килгән үзгәрешләргә карата реакциясе буларак үсеп чыга. Капиталистик юлдан баручы социаль-икътисади үсешнең гомуми юнәлеше татар җәмгыятендә иҗтимагый аңның үзгәрүенә китерә. К.нең формалашуына һәм таралуына шулай ук татарларның Россия империясендә тоткан социаль-сәяси урыны да этәрә.

16 йөзнең 2 нче яртысында татарлар үз дәүләтчелегеннән, традицион сәяси һәм дини ин-тларыннан мәхрүм ителгәннән соң, К. ислами җәмгыятьтә билгеле бер тотрыклылык урнашуга, дини традицияләрнең саклanып калуына һәм дәвам итүенә булыша, социаль бердәмлекне тәэмин итә.

Дини ин-тларның сакланып калуы төрле социаль-сәяси элементларның берләшүенә һәм уртак тел табуына хезмәт итә һәм татар җәмгыятенә үз-үзен оештырырга шартлар тудыра. 19 йөзнең 2 нче яртысында бары тик дини оешмалары гына булган халык тулы канлы үсү мөмкинлегеннән мәхрүм дигән караш формалаша. Баштарак иҗтимагый тормышның тотрыклылыгына ярдәм иткән ислам, вакыт үтү б-н, җәмгыятьнең артта калуына сәбәпче була. Татарларның иҗтимагый-сәяси тормышында дини компонентның абсолютлаштуы мәдәниятне, идеологияне һәм тормыштагы башка өлкәләрнең үсүен кискен рәвештә чикли башлый (к. *Җәдитчелек, Мөселман ислахчылыгы, Буржуазия, Татар сәүдәгәрләре*). Бер үк вакытта татар халкының билгеле бер өлешендә әлеге яңарышлар гасырлар дәвамында этноконфессиональ бөтенлеген саклаган татар җәмгыятенең традицион нигезләрен какшатуга китермәсме дигән шик тә була. Җәмгыятьнең нигезенә ныклык бирүче, аның фундаментын тәшкил итүче конфессиональ берлек төшенчәсе К.нең теоретик базасына әйләнә. Татарларның этноконфессиональ берлек буларак юкка чыкмавын тәэмин итүче күпгасырлык традицияләрне югалтмау зарурилыгы турындагы тезис К.тә төп элементлардан санала. Традицияләрне яклаган чыгышларында К. тарафдарлары социаль ин-тларның һәм рухи мирасның аерым өлкәләрдә генә түгел, (*мәхәллә*, гаилә, дин, йолалар һ.б.), ә бәлки бербөтен булып саклануын күз алдында тоталар. Шуңа күрә хәтта җәмгыятьтәге өлешчә үзгәрешләр дә аның яшәве өчен куркыныч тудыра дигән караш хөкем сөрә. 1905–07 елгы рев-циядән соң К. идеологиясендә уңай үзгәрешләр күренә башлый. К. вәкилләре кешенең яңа җәмгыятьтә күп кенә әхлакый, социаль-сәяси һ.б. тормыш юнәлешләре алдына куелуын танырга мәҗбүр була; социаль тормышның күптөрлелеген тою аларны традицияләрнең саклануы илдә хөкем сөргән социаль тәртипләрне яклауга түгел, ә бәлки, беренче чиратта, гомуми принципларны үтәүгә (руханиларның абруе, гореф-гадәтләр һәм мәхәллә мәнфәгатьләре өстенлеге һ.б.) нигезләнергә тиеш дигән фикергә китерә. К. идеяләре 1917 елга кадәр киң таралган була, чөнки җәмгыятьнең традицион яшәешен саклау, башка социаль-сәяси ин-тлар һәм аларны оештыру шартлары булмау сәбәпле, үзенең актуальлеген югалтмый. К. идеяләрен кабаттан яңартуда аеруча мөһим чараларның берсе иске ысуллы (кадими) мәдрәсәләр була, арада Кышкар, Мәчкәрә, Мәңгәр, Сатыш, Байлар Сабасы (Казан губ.), Түнтәр (Вятка губ.), Эстәрлебаш, Эстәрлетамак (Уфа губ.) кебек авыллардагы уку йортлары аеруча популярлык казана. К.нең төп идеяләре «*Дин вә мәгыйшәт*» ж-лында һәм «*Бәянелхак*» г-тасында чагылыш таба. Аның күренекле вәкилләре — И.*Динмөхәммәтов*, Г.Мөхетдинов, В.*Хөсәенов*.

*Әд.:* Валидов Дж. Очерки истории образованности и литературы татар (до 1917 г.). М.–П., 1923; Дюдуаньон С.А. Кадимизм: элементы социологии мусульманского традиционализма в татарском мире и в Мавераннахре (конец XVIII – начало XX вв.) // Ислам в татарском мире: История и современность. К., 1997; Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. К., 1998.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**КА́ДНИКОВ** Борис Александрович (20.8.1933, Тула өлкәсенең хәзерге Тепло-Огарёвск р-ны Покровское а.), партия, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, ТАССРның атказ. төзүчесе (1970). 1958 елда Урта Азия политехник ин-тын тәмамлый (Ташкент). 1952 дән, «Гидроводхлопок» Кырым комплекслы экспедициясенең геол. бүлеге техникы. 1957 дән Казан оптика-механика з-дында баш инженер. 1958–65 тә 8 нче төзү-монтаж идарәсендә өлкән прораб, баш инженер, 1965–75 тә «Главтатстрой»ның 2 нче төзү-монтаж тресты управляющие. 1975–88 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында төзелеш бүлеге мөдире. 1989 дан «Татглавснаб» компаниясе» АҖ башлыгы, 1991–2011 дә ген. директоры. Казандагы гражданлык максатлары өчен билгеләнгән күп кенә мөһим объектлар, ш.и. «Татарстан» кунакханәсе, Казан архит-ра–төзелеш ун-тының уку корпуслары һ.б. К.ның турыдан-туры катнашы б-н төзелә. ТАССР ЮС (1971–90), ТССР (1990–92), ТР (1992–95) депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биографии, свершения, надежды. К., 2005.

**КАДО́ШКИН РАЙОНЫ́**, *Мордва Республикасының* үзәк өлешендә урнашкан. 1935 елның 27 маенда оештырыла. Мәйданы — 618,6 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Кадошкино посёлогы (Саранскидан 86 *км* көнбатыштарак). Халкы — 9484 (2004), ш.и. 1760 татар. Татарлар Зур Полянки (736 кеше), Латышовка (734), Насакан-Потьма (56) авылларында район үзәгендә (423) яшиләр. Иң борынгы авыл — Насакан-Потьма (16 йөз уртасында төзелә), 17 йөздә Зур Полянки, Латышовка авыллары барлыкка килә. 1717 гә кадәр район терр-ясендә 5 мәчет һәм 2 мәктәп (Зур Полянки һәм Латышовкада) була. Хәзерге вакытта Зур Полянки һәм Латышовкада үзешчән сәнгать коллективлары эшли, андагы мәктәпләрдә татар теле фән буларак укытыла. К.р.нда а.х. фән. д-ры Ш.И.*Әхмәтов*, мед. фән. д-ры С.Б.*Еналиев* туган.

**КАДРӘ́К** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 70 *км* көньяктарак, Чыкалда елгасы буенда. 2010 елда 495 кеше (марилар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, агач әзерләү, сумала кайнату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә миссионерлык мәктәбе (1888 дә ачыла), тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1710 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Бима волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1762 дә — 47 ир-ат; 1834 тә — 154, 1859 да — 277, 1887 дә — 412, 1920 дә — 677, 1926 да — 757, 1938 дә — 857, 1949 да — 672, 1958 дә — 684, 1970 тә — 704, 1989 да — 535, 2002 дә — 509 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КАДРӘ́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 26 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 241 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1732 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә; алпавыт утарларында көнлекле эштә эшли. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.тә мәктәп (1873 тән) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 914 дис. тәшкил итә. 1930 да К.тә «КИМ» к-зы оештырыла, 1950 дә Молотов исем. к-з (1957 дән — Киров исем.), хәзерге вакытта Калинин исем. к-з составында. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 312, 1870 тә — 374, 1884 тә — 347, 1897 дә — 539, 1906 да — 637, 1913 тә — 782, 1920 дә — 756, 1926 да — 702, 1938 дә — 61, 1949 да — 299, 1958 дә — 320, 1970 тә — 292, 1979 да — 287, 1989 да — 290, 2002 дә — 268 кеше.

**КАДЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Кырыкмас елгасының сул кушылдыгы (Иж елгасы бассейны). Озынлыгы 21,2 *км*, ТР чикләрендә — 13,6 *км*. Бассейнының мәйданы 118 *км*². Сарапул калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе р-нының Девәтернә (Мазарасты) авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 81 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.ның 0,5 тән алып 9,2 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар; иң зурысы — Ары-Казы елгасы (сул). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1*л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 115 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. К. октябрь ахыры – ноябрь башында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 2,6 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАДЫБА́Ш** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 75 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кады елгасы буенда. 2010 елда 482 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, сүс ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәдрәсә, рус-татар земство мәктәбе (1898 дан), тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1829,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостенда. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1834 тә — 349, 1859 да — 561, 1920 дә — 1260, 1926 да — 1077, 1938 дә — 1097, 1949 да — 1092, 1958 дә — 775, 1970 тә — 793, 1989 да — 586, 2002 дә — 491 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КАДЫ́Й**, к. *Казый*.

**КАДЫЙРБИРДЕ́ ХАН** (1395 тирәсе — 1419/20), Алтын Урда ханы (1419/20). *Туктамыш хан* улы. 1419 елдан Идегәй әмир һәм Дәрвиш хан б-н көрәшә башлый, Алтын Урдада хакимиятне үз кулына ала. Акча суктыра. Идегәй б-н бәрелештә һәлак була.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**КАДЫЙРГАЛИ́ БӘК**, (16 йөз уртасы — 17 йөз башы), Себер ханлыгы бәге. Кайбер мәгълүматлар буенча, 1570–80 елларда Себер ханлыгында *карачыбәк* була. Казаклар атаманы Ермак отрядлары б-н сугыша. 1587 дә руслар тарафыннан әсирлеккә алына. 1600 дән Касыйм ханы Уразмөхәммәд сараенда карачыбәк. Уразмөхәммәд биографиясенә багышланган һәм соңрак «Елъязмалар җыентыгы» («Җамигъ әт-тәварих», 1602) дип аталган тарихи хезмәт авторы. Хезмәт татар телендә язылган, аның төп өлеше *Рәшидетдиннең* шул исемдәге фарсыча язылган китабының ирекле тәрҗемәсеннән гыйбарәт. Аның оригиналь керештән («Борис Годуновка мәдхия») һәм кечерәк бүлекләрдән торган, Көнчыгыш Европадагы һәм Себердәге татар ханлыклары тарихының аерым чорларына багышланган йомгаклау кисәкләре зур мәгълүмати кыйммәткә ия. Хезмәттә безнең дәвергәчә сакланмаган борынгырак төрки-татар тарихи әсәрләрендәге мәгълүматлар файдаланылган. Аның күчермәләре Казан һәм Петербург ун-тлары китапханәләре фондларында саклана. К.б.нең хезмәтләрен, беренчеләрдән булып, шәркыятьче галим И.Н.Березин тикшерә.

*Әд.:* Березин И.Н. Библиотека восточных историков: Сб. летописей. К., 1854. Т. 2, ч. 1; Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972.

*М.Г.Госманов.*

**КАДЫЙРГАЛИ́ЕВ** Леонид Иванович (6.11.1925, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Конашак р-ны Нәдер а. — 12.7.1985, Чиләбе ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), өлкән сержант (1945). 1942–43 елларда Чиләбе ремонтлау з-дында токарь булып эшли. 1943 нең гыйнварыннан Кызыл Армия сафларында. 1944 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 107 нче танк бригадасының моторлаштырылган батальоны автоматчылары отделениесе командиры (2 нче танк армиясенең 16 нчы танк корпусы). 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украина, Польшаны азат итү сугышларында, Берлинга һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1944 нең 6 мартында Буки авылы (Черкас өлкәсе Маньков р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: Горный Тикич елгасын беренчеләрдән булып кичеп чыга; дошман траншеясына бәреп кереп, пулемёт расчётын һәм күзәтү-эзәрлекләү барышында дошманның полк байрагы сакланган автомашинасын юк итә. Чиләбе шәһәрендә яши, вагоннар төзек-

ләндерү депосында слесарь булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои — освободители Черкасщины. Днепропетровск, 1980.

*В.А.Шагалов.*

**КАДЫЙРИ́** Габдулла (10.4.1894, Ташкент — 4.10.1938, шунда ук), үзбәк язучысы, журналист. 1912 елда рус-җирле халыклар мәктәбен тәмамлагач, приказчик булып эшли. 1919 дан үзбәк газета һәм журналларында әдәби хезмәткәр, корректор. 1923–24 тә Журналистика ин-тында укый (Мәскәү). Беренче шигырьләре һәм публицистик мәкаләләре 1913–15 тә «Садои Туркистон» («Төркестан авазы»), «Сәмәрканд» үзбәк г-таларында һәм «Айна» («Көзге»), «Муштум» («Йодрык») ж-лларында басыла. Татар периодик матбугаты һәм әдәбияты б-н 1912 дә таныша. Үзбәкләрнең элекке тормышын чагылдырган «Азгынчы» («Жувонбоз», 1915) исемле беренче хикәясен К. татар мәгърифәтчеләренә, аеруча З.Бигиевкә ияреп яза. «Муштум» ж-лы битләрендә урын алган очерк, хикәя, фельетоннарында Г.Тукай, Ф.Әмирханнарның сатирик традицияләре үзен нык сиздерә. «Беркем дә белмәсен» (1921) комедиясе — М.Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» пьесасының өлешчә үзгәртелгән варианты. К.нең төп әсәрләреннән саналган «Үткән көннәр» («Утган кунлар», Ташкент, 1925; татарчага тәрҗемәсе 1959) һәм «Михраб чаяны» («Мехробдан чаён», Ташкент, 1929; русчага тәрҗемәсе «Скорпион из алтаря», М., 1964) романнарында Г.Ибраһимовның романтик прозасы йогынтысы сизелә. «Калфак Мәгъсүмнең хатирә дәфтәреннән» («Калвак Махзумнинг хотира дафтаридан») исемле сатирик хикәясе һәм «Үткән көннәр» романыннан өзекләр Казанда 1930 да «Үзбәк антологиясе»ндә З.Бәшири тарафыннан бастырыла. Әдип Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасын үзбәкчәгә тәрҗемә итә. 1936 да К., үзбәк делегациясе әгъзасы буларак, Казанда, Казан арты авылларында була; К.Нәҗми, Ф.Бурнаш, К.Тинчурин, Х.Туфан б-н очраша. Нахакка репрессияләнә; 1956 елда аклана.

Ә с ә р.: Кичик асарлар. Тошкент, 1969.

*Әд.:* К о ш ч а н о в М. Жизнь. Характеры. Мастерство. Таш., 1963; Т у р д ы е в Ш. Тукай и узбекская литература // Габдулла Тукай. К., 1979; А л и е в А. Абдулла Кодирий. Тошкент, 1967; К у ш ж о н о в М. Кодирий — эрксизлик курбони. Тошкент, 1992.

*Р.К.Ганиева.*

**КАДЫЙРИ́** Закир Хәлим улы (1878, Самара губ., Старополь өязе Абдулла а. — 22.10.1954, Төркия), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, илаһият галиме, журналист. Бохара, Мәдинә, Каһирә (әл-Әзһар ун-ты) уку йортларында белем ала. 1906 елда Россиягә кайткач, «әт-Тилмиз» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә (С.-Петербург). 1907–09 да «*Хөсәения*» мәдрәсәсендә, 1909–13 тә «*Галия*» мәдрәсәсендә философия, гарәп теле һәм әдәбияты укыта. 1914–18 дә «*Тормыш*» г-тасы мөхәррире. 1917 дә Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәте әгъзасы. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (Мәскәү, 1917, май) катнаша, мәдәни-агарту мәсьәләләре буенча милләтнең автономиягә ия булуын күздә тоткан резолюция авторы; гомумтөрки телле югары уку йортлары төзү, рус телле югары уку йортларында махсус төрки кафедралар ачу тарафдары була. 1917 елның августыннан Уфа губернасының Милли Шура Башкарма ком-ты, октябрьдән — президиум әгъзасы. Уфа губернасыннан *Милләт Мәҗлесе* депутаты, төркичеләр фракциясе әгъзасы; Милли Идарә әгъзасы. «Тормыш» г-тасы ябылганнан соң (1919), Финляндиягә китә, мәдрәсәдә укыта. Соңрак Төркиягә күчеп китә.

Илаһият һәм философия, мөселман мәдәнияте тарихы буенча хезмәтләр; тел белеме ярдәмлекләре, Көнчыгыш һәм Европа галимнәре хезмәтләренең татар теленә күпсанлы тәрҗемәләре авторы.

Х е з м.: Куввәт вә рух. Өфө, 1910; Кызлар дөньясы. Уфа, 1911; Низам вә ислам. Уфа, 1911; Тормыш һәм дин. Уфа, 1911; Хәят Мөхәммәд галәйһи сәләм. Уфа, 1911; Гарәп сарыфы, Уфа, 1912; Гарәп нәһүе. Уфа, 1912; Ислам мәдәнияте тарихы: 3 томда. Уфа, 1912–13; Хатын-кыз мәсьәләсе. Уфа, 1915.

*Әд.:* Татар зыялылары: тарихи портретлар. К., 2003; Р а х и м к у л о в а М.Ф. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1975; Х а б у т д и н о в А.Ю. Формирование нации и основные направления развития татарского общества в конце XVIII — начале. XX веков. К., 2001; B e n n i n g s e n A., L e m e r c i e r - Q u e l q u e j a y Ch. La press et le mouvement national ches les Musulmans de Russie avant 1920. P., 1964.

**КАДЫЙРМӘ́ТОВ** Ярмөхәммәд (1721–1775 тән соң), Е.И.Пугачёвның баш күтәрүчеләр гаскәре полковнигы. Казан өязе Ижбулды авылы ясаклы татары. Баш күтәрүчеләр хәрәкәтенә 1773 елның октябрендә кушыла. Баштарак *Б.Канкаев* отрядында хезмәт итә. Кама аръягындагы һәм Кама алдындагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1774 нең июлендә, отряд җиңелгәннән соң, Каманың сулъяк ярына чыга һәм күтәрелеш хәрәкәтен август уртасына кадәр дәвам итә. 1774 нең октябрендә, гаебен танып, Казан яшерен комиссиясенә килә. 1775 нең июненә кадәр төрмәдә була.

Чыг.: Документы ставки Е.И.Пугачёва, повстанческих властей и учреждений. 1773–1774 гг. М., 1975; Воззвания и переписка вожаков Пугачёвского движения в Поволжье и Приуралье. К., 1988.

*Әд.:* Ермухаммет Кадырметов // Оренбургская пушкинская энциклопедия. Оренбург, 1997.

**КАДЫ́ЙРОВ** Абдулла Насрулла улы (Анатолий Николаевич) (1921, хәзерге Владимир өлкәсе Камешково ш. — 19.11.1944, Литва ССРның Кудиркос-Науместис ш.), Дан орденының тулы кавалеры (2.4.1944, 21.8.1944, 24.3.1945, үлгәннән соң), сержант (1944). 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1138 нче укчы полкның җәяүле разведчиклар взводы разведчигы (5 нче армиянең 338 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Ржев-Вязьма, Смоленск (икесе дә — 1943) һәм Белоруссия (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 20 мартында Замушаны торак пункты (Белоруссия ССР, Витебск өлкәсе Лиозна р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: беренче булып,



А.Н.Кадыйров.

дошман урнашкан урынга бәреп керә һәм мөһим документларны кулга төшерә; 1944 нең 16 июлендә Мордасы-Соболишки (Литва ССРның Пренай шәһәреннән 14 *км* көнчыгыштарак) торак пункты тирәсендәге сугышта каты яраланган полк командирын сугыш кырыннан алып чыга; 1944 елның 10 сентябрендә Кункое (Литва ССРның Расейняй шәһәреннән 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак) торак пункты өчен барган сугышта «тел»не кулга төшерергә ярдәм итә. Сугышта һәлак була. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.


*В.А.Шагалов.*

**КАДЫ́ЙРОВ** Альберт Хәмзә улы (3.6.1962, Бөгелмә ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1987). 1979 елдан ТатНИПИнефтьтә эшли, скважиналар эксплуатацияләү һәм ремонтлау бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре (1996 дан). Дәүләт бүләге эшләп торучы колонналарны саклау һәм торгызу өчен техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**КАДЫ́ЙРОВ** Басыйр Габделбари улы (2.12.1957, Чиләбе өлкәсенең Троицк р-ны Искра пос.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2003), подполковник (1991). ТАССР ЮС Президиумы исем. Казан югары танк командирлар уч-щесен (1979), В.И.Ленин исем. хәрби-сәяси академияне (Мәскәү, 1991) тәмамлый. 1980–83 елларда Әфганстан Респ-касында хәрби часть сәяси бүлеге башлыгының комсомол эше буенча ярдәмчесе, 1984 тән Ульянов югары хәрби-техник уч-щесе батальонында партия оешмасы секретаре, 1991 дән Михайловск хәрби артиллерия ун-тының Казан ф-лы укытучысы, 2003 тән Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында (Казан) ватан тарихы каф. мөдире. 1986 да Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша. Хезмәтләре СССРда ике сугыш арасындагы чорда милли мәсьәләнең торышына һәм хәрби тарихка карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Армия и национальный вопрос (1921–1938). К., 2001; Национальная политика Советского государства в межвоенный период (военный аспект). К., 2002.

**КАДЫ́ЙРОВ** Габдрахман Фәйзрахман улы (21.1.1941, Мәскәү өлкәсенең Шатура ш. — 31.7.1993, Сочи ш., Уфа шәһәрендә җирләнә), спортчы, тренер (мотоцикл спорты: мотокросс, спидвей, бозда ярыш), СССРның атказ. спорт остасы (1966), БАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1991), халыкара категорияле судья (1991). 1947 елдан Уфада яши. П.Ф.Лесгафт исем. Ленинград физкультура ин-тын тәмамлый (1970). Команда ярышларында дөнья (1966, 1968–69,



Н.Ж. Кадыйров.

1971–74), Европа (1964–65), СССР (1964–67, 1967–70, 1967–69) чемпионы. Команда ярышларында дөнья (1967, 1970), Европа (1965), СССР (1963–64, 1966–67) чемпионатларында көмеш медальләр; дөнья чемпионатларында (1967, 1974) бронза медальләр ала. СССР җыелма командасының һәм «Башкортстан» командасының өлкән тренеры (1982 кадәр). Башкортстан дәүләт филармониясендә эшли (1981–93). «Почёт билгесе» ордены, Халыкара мотоцикл федерациясенең мактаулы бронза медале б-н бүләкләнә. 1993 тән Уфада ел саен Кадыйров истәлегенә Бөтенроссия ярышлары уздырыла.

Х е з м.: Я выбрал лёд. Уфа, 1974; Трудные кольца спидвея. М., 1976.

*Әд.:* Е р о ш и н А.Е. Первый чемпион // Крутые виражи. М., 1968.

**КАДЫ́ЙРОВ** Нурислам Җиһанша улы (10.10.1926, Буа кантоны Боерган а. — 5.12.1993, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Соц. Хезмәт Герое (1973). Бөек Ватан сугышында катнаша. СССР Азык-төлек әзерләү министрлыгының Югары азык-төлек әзерләү мәктәбен тәмамлый (1952). 1951–55 елларда Будённый р-нында (хәзерге Чүпрәле р-ны) а.х. продуктларын әзерләү системасында эшли. 1955–59 да Буа р-нының Ленин исем. к-зы, 1959–78 дә «Гигант» к-зы рәисе. Бу елларда бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 25 *ц* га, 1 сыердан савым 3100 *кг* га җитә. Хуҗалык ел саен бөртекле ашлык һәм башка а.х. продукциясен әзерләү буенча дәүләт йөкләмәләрен арттырып үти. Терлекчелек фермалары, а.х. техникасына техник хезмәт күрсәтү пунктлары, терлек азыгын эшкәртү цехы, урта мәктәп һ.б. социаль-көнкүреш биналары төзелә. Герой исеме Бөтенсоюз социалистик ярышларда ирешелгән зур уңышлары, фидакарь хезмәте өчен бирелә. 1966–70 тә СССР ЮС депутаты. Өч Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978): Док. очерки. К., 1980.

*И.Н.Афанасьев.*

**КАДЫ́ЙРОВ** Октябрь Халикъ улы (25.10.1935, Чистай р-ны Дүртөйле а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1996). 1958 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1963–70 тә Казан ун-тында; 1970 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында. Хезмәтләре 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар-рус әдәби-сәнгати элемтәләре һәм йогынтыларына; татар әдәбиятында реализм ысулы үсешендә Л.Н.Толстой иҗатының роле, татар әдәбиятының милли үзенчәлекләре мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Л.Н.Толстой сквозь призму татарской мысли. Наб. Челны, 1995; Л.Н.Толстой в татарских переводах советской эпохи. К., 2005.

**КАДЫ́ЙРОВ** Рафаэль Рәшит улы (23.8.1957, БАССРның Гафури р-ны Тугай а.), нәкышьче, график, монументаль сәнгать рәссамы. Башкорт пед. ун-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1979). 1979 елдан — Ишембай шәһәрендә. Башкортстан Респ-касының Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991). Тарихи һәм көнкүреш картиналары, портрет һәм пейзаж жанрларында эшли. К.ның татар авылына, аның кешеләренә багышланган рәсемнәре киң таныла: халык акылын туплаган өлкән буын вәкилләре, аларның шул традицияне дәвам итүче оныклары, көчле батырлары һәм зифа буйлы кызлары — К. картиналарының барлык персонажлары буыннан-буынга тапшырылып килгән яшәеш серләрен, тормышнан карап торучы силуэт фигуралары урнаша.

К. кабатланмас графика эшләрендә (акварельләр сериясе — «Искитәрлек», «Төшләр», икесе дә — 1990 да; пастельләр сериясе — «Портрет», «Пасторальләр», икесе дә — 2001 дә) һәм офорт техникасында уңышлы иҗат итә («Милли көйләр» сериясе, 1996; «Пәри кызы», «Яңа туган ай», икесе дә — 1997 дә; «Юдифь», 1998). «Казан» милли мәдәният үзәгендәге Милли мәдәният музее экспозициясе залында бөтен ян дивар өслеген алып торучы, зурлыгы һәм сюжеты буенча масштаблы «Алтын Урда» монументаль панно (2002) авторы (И.Гаянов б-н бергә).

Республика (конкурс-күргәзмәләр: «Сәнгатьтәге тарих», Уфа, 1999, 2 нче премия; «Яңа меңьеллык», Эстәрлетамак ш., 2000, 3 нче премия), төбәкара («Татарт», С.-Петербург–Казан, 1991; 2 нче Урал станлы графика күргәзмәсе, Уфа, 1998), бөтенроссия (VIII һәм IX акварель күргәзмәсе, Мәскәү, 1987 һәм 1991; «II нче станлы графика күргәзмәсе», Мәскәү, 1989; «Россиянең ерак төбәгендә», Мәскәү, 1992; «Синең исемеңә», Мәскәү, 2000 һ.б.) һәм халыкара (Башкортстан рәссамнарының төркем күргәзмәсе, Зальцбург ш., Австрия, 1995; «АртМәскәү», Мәскәү, 1996) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1991 (Уфа), 1996 (Казан, И.Гаянов б-н бергә; Уфа), 1997 (Уфа, К.Гобәйдуллин б-н бергә), 1998 (Уфа), 2001 (Эльче ш., Испания), 2009 һ.б. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. сәнгать музеенда (Уфа), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Казан), «Казан» милли мәдәният үзәгендәге Милли мәдәният музеенда, Новосибирск. картиналар галереясында, хәзерге заман «Урал», «Сангат» галереяларында (Уфа), Россия һәм чит илләрдәге (Австрия, Германия, Испания, Италия, АКШ, Франция, Төркия һ.б.) шәхси тупланмаларда саклана. БРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1997).

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*





Р.Р. К а д ы й р о в. 1. «Орыну». 1990. «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее; 2. «Көн һәм төн аллегориясе». 1991.

кануннарын аңларга тырышып яшиләр сыман («Бишек җыры», «Кояш нуры шәүләсе», «Чагылыш» триптихы, барысы да — 1987 дә; «Картлык» диптихы, 1988; «Сагыш», 1989; «Тормыш елгасы», «Гаилә», «Кер юу», барысы да — 1990 елларда; 7 картинадан торган «Татар халык җырлары» сериясе, 1991; «Кунакка чакыру» триптихы, 1992; «Аулак өй», 1995). Серияле хезмәтләре («Язмыш», «Көзге», «Көн һәм төн аллегориясе», барысы — 1991 дә; «Ай тотемы», 1992; «Легенда», 1996; «Җеназа», «Ирекле тоткынлыкка омтылу», 1994) кинаяле фәлсәфи мәгънәгә ия, яшьлек һәм картлык, яшәү һәм үлем, ирек һәм ирексезлек коллизияләрен ачып сала. 1990 еллардан К. ислам культурасы темасына, Библия сюжетларына мөрәҗәгать итә («Төнге намаз», 1991; «Рамазан», 1992; «Багдад», 1994; «Иероним төше», 1999; «Нух көймәсе», 2000; «Талчыккан фәрештә», 2001). Аның нәкышенә форманы ачып бирүдә реалистик һәм стильләштерелгән алымнар синтезы, рәсемне үтә күренмәле буяу б-н каплау ысуллары куллану, төсләрнең бер-берсенә охшаш төсмерләрен яраштыру хас. Картиналары образларның гармонияле һәм «аһәңле» тәэсирен тудыручы ачык контурлы рәсемнәр б-н аерылып тора; гадәттә, үзәктә — алгы планда персонажларның характерлы ишарәләре яки башы борылган, тамашачы ягын-

**КАДЫ́ЙРОВА** Нәсифә (Нәзифә) Җәват кызы (13.4.1954, БАССР, Учалы р-ны Ахун а.), җырчы, БАССРның халык (1987), РФнең атказ. артисты (2005). 1971 елдан Башкорт филармониясе солисты, популяр эстрада

җырчысы. К.ның башкару сәнгатенә милли музыка традицияләрен тирән аңлау, бүгенге эстрада музыкасы стиле тенденцияләрен ныклап үзләштерү хас. Җырчының репертуарында башкорт, татар халык җырлары, башкорт (Р.Газизов, Н.Даутов, З.Исмәгыйлев, С.Низаметдинов, Р.Хәсәнов һ.б.) һәм татар композиторларының (М.Имашев, С.Садыйкова, Р.Яхин һ.б.) вокаль әсәрләре бар. Россия шәһәрләрендә һәм Идел буе респ-каларында актив концерт эшчәнлеге алып бара. Башкортстан сәнгать осталары төркеме составында чит илләрдә (Польша, Монголия, ГФР, Венгрия, Дания, Италия, Австрия, Төркия һ.б.) чыгышлар ясый. СССР Үзәк телевидениесенең бөтенсоюз конкурсы («С песней по жизни»,1979) һәм Сочи шәһәрендә үткәрелгән совет җырларын башкаручыларның бөтенсоюз конкурсы (1980) дипломанты. БРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1994).

*Ф.Ш.Салитова, А.Р.Рахмани.*

**КАДЫ́ЙРОВА** Раиса Григорьевна (13.1.1936, Воронеж өлкәсенең Югары-Карачанск р-ны Колтавщина пос.), химик-органик, химия фән. д-ры (1989), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), шунда ук эшли, 1964–67 елларда ин-тның Түбән Кама ф-лы деканы. 1990–2001 дә Казан вет. медицинасы академиясендә нәорганик һәм аналитик химия каф. мөдире, 2001 дән Казан энергетика ун-тында. Хезмәтләре азотлы кушылмалар (фуроксаннар, фуразаннар) химиясенә, ацетиленлы спиртлар, α-кетоспирт нитратлары реакцияләренә карый. Биол. объектларны һәм сәнәгать калдыкларын токсикологик өйрәнү алымнарын, а.х. хайваннары авыруларын башлангыч стадиясендә диагностикалау ысулларын эшли. 160 фәнни хезмәт авторы, уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ – КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**КАДЫ́ЙРОВА** Фәнүсә Заһит кызы (16.9.1951, Әлки р-ны Чуаш Кичүе а.), агроном-селекция белгече, а.х. фән. д-ры (2003), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2004), ТАССРның атказ. агрономы (1991). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1974). 1968 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1983 тән карабодай селекциясе төркеме җитәкчесе, 1997 дән селекция үзәге җитәкчесе, селекция эшләре буенча директор урынбасары, 2002 дән ярма культуралары селекциясе лаб-ясе мөдире. 2007 дән Казан аграр ун-тының селекция һәм орлыкчылык үсемлекләрен саклау каф. профессоры. Хезмәтләре карабодай сортлары селекциясенә һәм аларны игүгә карый. 14 эре бөртекле диплоидлы карабодай сортының автордашы, шуларның 13 сорты («Майская», «Прикамская», «Сокуровская», «Казанская крупноплодная», «Каземка», «Идел», «Каракитән», «Кама» һ.б.) РФнең 35 өлкә һәм республикасында, ш.и. Татарстанда, Башкортстанда, ш.у. Молдавия һәм Украинада районлаштырылган. Карабодай сортларын булдыруы өчен СССР МС бүләге (1986), РФ Дәүләт бүләге (1994) бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм өч көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Результаты селекции и основные хозяйственно-биологические особенности крупноплодных сортов гречихи татарской селекции // Материалы 4-го Междунар. симп. по гречихе. Орёл, 1989; Особенности селекционного процесса при выведении крупноплодных диплоидных сортов гречихи // Селекция и семеноводство. 1995. № 3; Проявление признаков продуктивности и адаптивных свойств у новых сортов озимой ржи и гречихи // Докл. Рос. академии с. х. наук. 2000. № 4; Возделывание гречихи в Республике Татарстан. К., 2002.

**КАДЫ́Ш** авылы, Казанның Авиатөзелеш р-ны составында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* көнбатыштарак, Солонка елгасы буенда. 2002 елда 1610 кеше (руслар – 52%, татарлар – 44%) яши. Халкының төп шөгыле – терлекчелек, яшелчәчелек. Урта мәктәп, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1557 дән – рус авылы. 1565 тә кенәзләр Ю.Засецкий һәм П.А.Булгаковлар хуҗа була, соңрак бу җирләр сарай биләмәсе булып кала. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр – сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тәгәрмәч, юкә кабыгыннан мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 1841 дән К.та Уделлар департаменты мәктәбе (1870 тә Борисоглебскига күчерелә) эшли. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Тихвин чиркәве (1891 дә төзелә), земство мәктәбе (1887 дә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1217,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Каймар волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1927 нең 14 февраленнән – Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан – Юдино, 1958 нең 16 июленнән – Биектау, 1963 нең 1 февраленнән – Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында, 1998 нең 25 ноябреннән Казанның Авиатөзелеш р-ны карамагында. Халык саны: 1646 да – 164, 1782 дә – 240 ир-ат; 1859 да – 567, 1897 дә – 657, 1908 дә – 677, 1920 дә – 801, 1926 да – 939, 1938 дә – 833, 1949 да – 551, 1958 дә – 821, 1970 тә – 1130, 1989 да – 1734 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КАДЫ́Ш** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тәтеш – Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 139 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Урман сәнәгатьчесе М.А.Гурьянов йорты – 19 йөз ахыры архит-ра ядкәре. 1700 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр – сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, балыкчылык, тегүчелек, итек басу, сарык тиресен эшкәртү, чана, мунчала, тәгәрмәч тугымы һәм тырнагы ясау, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та чиркәү, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1635 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда. 1920 дән – ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан – Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан – Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да – 842, 1880 дә – 1004, 1897 дә – 1224, 1908 дә – 1519, 1920 дә – 1500, 1926 да – 1318, 1938 дә – 1239, 1949 да – 907, 1958 дә – 682, 1970 тә – 577, 1979 да – 476, 1989 да – 294, 2002 дә – 185 кеше.

**«КАДЫ́Ш МӘРГӘ́Н»**, Себер татарларының героик-мифологик дастаны. Тылсымлы әкиятләр б-н охшаш яклары шактый. Гайре табигый көчкә, сихер сәләтенә ия булган төп герой исеме б-н атала. Ул җиде башлы өч аждаһаны җиңә, мескен картка урланган өч көтүен кайтарып бирә, кайчандыр геройның урланган үз апалары ук булып чыккан өч хатынын азат итә. Күп кенә батырлыклар күрсәткәннән соң, Кадыш Мәргән хан була. Әсәрнең вариантлары 1860 елларда Томск губернасындагы Тернә авылында яшәүче бараба татарларыннан В.В.Радлов (тулы версия) һәм Күсәкәй авылында Л.В.Дмитриева (кыскача версия) тарафыннан язып алына.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Р а д л о в В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАЕККУЗА́К** (Oxytropis), кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуакчыклар, куаклар ыругы. 400 дән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә 4 төре очрый. Чәчле К. (O. pilosa) ара-тирә барлык районнарда, купшы чәчәкле К. (O. floribunda), Ипполит К. (O. hippolytii), башаклы К. (O. spicata) Кама арьягында очрый. Далаланган сөзәклекләрдә үсәләр. 15–40 *см* биеклегендәге күпьеллык үсемлекләр. Тамырлары үзәк, туфракта тирәнгә китә. Яфраклары чиратлашкан, парсыз каурыйсыман. Тамыр яны яфраклары яфрак таралгысы хасил итә. Чәчәкләре сары, алсу, ак төстә, чуксыман куентылы чәчәк төркемендә. Җимеше – кузак. Май–августта чәчәк аталар. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Декоратив үсемлекләр, бордюрлар ясаганда утыртыла. Купшы чәчәкле К., Ипполит К., башаклы К. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЕКЧӘЧӘ́К** (Corallorhiza), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре – өчкә бүленгән К. (C. trifida) Көнбатыш Кама арьягында очрый. Торфлы мүкле сазлык читләрендә үсә. 7–30 *см* биеклектәге хлорофилсыз үсемлек. Тамырчасы җир астында, аксыл, кораллларга охшаш кыска ботакларга тармакланган. Сабагы туры, нәзек, саргылт-яшел, элпәле 2–4 җиңсәле (җитлекмәгән яфраклар). Яфрак җәймәсе гади. Чәчәкләре күп, куе алсу, тыгыз булмаган чукка җыелган. Җимеше – тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–июльдә өлгерә. Башлыча, орлыктан үрчи. Орлык шытканнан соң, шактый вакыт җир астында: башта бүлбе, соңрак тармаклы тамырча хәлендә була. Халык медицинасын-

да шешенгәндә кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЕ́Н** (Betula), каенчалар семьялыгыннан яфрак коючан агачлар һәм куаклар ыругы. 100 гә якын полиморф төрләре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында, тропикларның тауларында үсә. ТР терр-ясендә 3 төре бар. Иенке К. яки сөялле К. (B. pendula яки B. verrucosa) — 30 *м* га кадәр биеклектәге, ботаклары аска салынып торучан ябалдашлы, ап-ак яки соргылт көүсәле, карт агачларның түбәнге өлешендә исә көүсә тупас кара кабыклы. Яфраклары йомыркасыман ромбтан өчпочмаклы-йомыркасыман формага кадәр. Яшь ботакларында бизле вак төерләр («сөялләр») бар. Бөдрә К. (B. pubescens) күп кенә яфраклы һәм ылыслы токымнар б-н бергә үсә. 20 *м* га кадәр биеклектә, ботаклары өскә таба сузылган, кабыгы шома ак яки соргылт төстә, яшь ботаклары төкчәле. Көүсәсе төбенә кадәр диярлек ак, фәкать картайгач, төбендә бераз чатный. К.ның чәчәкләре аерым җенесле, бер өйле, чәчәк төркем — алка чәчәккә җыйналган. Ата алкалар ботак очларында формалаша. Җимеше — ярылы ике канатчыклы чикләвекчек. Ике төр дә яфрак яру б-н бер үк вакытта диярлек чәчәк ата. Тамыр системасы куәтле, үзәк тамыры юк, киңәеп тирәнгә китә, агачларның җилгә каршы торучанлыгын уңай тәэмин итә, күп кенә ян тамырлары туфрак өслегенә якын булып, горизонталь җәелә. Орлыктан, төп үсентеләреннән үрчи. Суыкка һәм һаваның газлануына чыдамлы булуы б-н аерыла. Төрле туфракларда үсә — ташлы, комсу, торфлы һ.б., башка үсемлекләр үсмәгән урыннарда җиңел үсәләр. ТР терр-ясендә иенке К. һәм бөдрә К. — урман барлыкка китерүче төп токымнар. Каен урманнарының гомуми мәйданы 194,3 мең *га* (урман мәйданының 17,9%ы) тәшкил итә. К. саклагыч полосаларда, бакча һәм паркларда мөһим компонент булып тора. Каен урманнарында ак гөмбә, каен гөмбәсе, ак һәм кара гөреҗдә, кызыл гөмбә, әтәч гөмбәсе үсә. К. үзагачы җиһаз җитештерүдә кыйммәтле чимал санала, аннан фанер, чаңгы, паркет, йорт кирәк-яраклары һәм төрле әйберләр ясыйлар. Каен согында моношикәр, органик к-та, калий тозлары, кальций, тимер; бөреләрендә эфир мае (3,5–6%) бар, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Каен дегете бактерицид үзлеккә ия, Вишневский (җәрәхәтләрне дәвалау өчен) һәм Вилькинсон (корчаңгы һәм гөмбә авыруларын дәвалау өчен) мазьлары составына керә. Кәрлә К. (B. humilis) — бик сирәк, бетә баручы төр. 70–150 *см* биеклектәге куак. Уйсулыклы-торфлы, ш.у. куакчыклар һәм торф мүге таралган сазлыкларда үсә. Әлки р-ны терр-ясендә очрый. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Җимеш алкалы иенке каен ботагы.

*Әд.:* А л е к с е е в Ю.Е. Деревья и кустарники. М., 1997.

**КАЕ́Н ГӨМБӘЛӘРЕ́**, болетачалар семьялыгыннан көпшәле гөмбәләр ыругы. Төньяк ярымшарда таралган. Каен б-н бергә микориза хасил итә, шунлыктан, кагыйдә буларак, аның янында үсә (исеме шуннан). Татарстан терр-ясендә гади К.г. (Leccinum scabrum), алсуланучы К.г. (L. oxydabile), саз К.г. (L. holopus) очрый. Май ахырыннан көз ахырына кадәр үсәләр. Эшләпәсенең диаметры 25 *см* га кадәр, ярымшарсыман яки мендәрсыман, төсе ачык сорыдан куе көрәнгә кадәр. Саз К.г.нең йомшагы бераз сулы. Өслеге җиңелчә ябышучан, шома. Көпшәле катлавы аксыл соры, көпшәләре озын, эшләпә йомшагыннан җиңел аерыла. Споралы порошогы сары-көрән төстә. Споралары орчыксыман. Сабы 20 *см* га кадәр биеклектә, 2–3 *см* юанлыкта, ак төстә, кара тәңкәчекләр б-н капланган. Йомшагы тыгыз, нык, соргылт. Алсуланучы К.г.нең эшләпәсе мәрмәр төстә, сабында эре соры тәңкәчекләр бар, сындырганда йомшагы алсулана һәм, башкалардан аермалы буларак, көз җиткәч кенә күренә башлый. Ашарга яраклы гөмбәләр. Илл. *Гөмбәләр* мәкаләсендә.

**КАЕ́Н ГӨМБӘСЕ́**, к. *Кара каен гөмбәсе.*

**КА́ЕН ҖИЛӘГЕ́** (Fragaria), розачалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 50 төре, БДБ да 7 төре билгеле. Урман К.җ. (F. vesca) һәм яшел К.җ. (F. viridis) киң таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар: бакча К.җ. (F. ananassa), урман К.җ. һәм җир җиләге (F. moschata). Башлыча, бакча К.җ. б-н җир җиләгенең гибридларын үстерәләр.

Бакча К.җ. туфракка таләпчән түгел, ләкин дымлылыкны ярата. Тамырча барлыкка китерүче кыска, тармакланган сабаклы. Күпчелек сортларның чәчәкләре ике җенесле. Җиләкләре эре (40 *г* га кадәр, уртача 15 *г*), төрле төсмерле кызыл төстә, тәме тәмле, хуш исле һәм җимеш йомшагы эреп тора. Составында 5–10 % шикәр, 0,8–1,6 % органик к-талар, 1–1,6 % пектин, 50–80 *мг* % С витамины бар. Җиләкләре яңа өлгергән, туңдырылган һәм эшкәртелгән килеш кулланыла. ТРда җиләкләре июнь уртасында, ә кайбер елларда июнь башында өлгерә. Уңышы 1 *га* дан 60–80 *ц* дан артыграк. Үстерелә торган сортлары: иртә өлгерешле — «Заря»; уртача өлгерешле — «Фестивальная», «Зенга-Прекоза», «Лорд», «Редгонтлит», «Татарстан»; соң өлгерешле — «Зенга-Зенгана», «Рубиновый кулон» һ.б. К.җ. «мыекчалар» ярдәмендә үрчетелә, аларда яфрак таралгысы барлыкка килә. Үрентеләр, нигездә, яз көне (май башында), җәй көне (июль ахыры – август башында) утыртыла. Яз көне утырткannan соң, икенче елда югары уңыш алына. Утырту схемасы — бер сызыклы (рәт араларының киңлеге 70–80 *см*, 1 рәттә 25 *см* аралыкта) һәм ике сызыклы (рәт араларының киңлеге 50–60 *см*, рәттә 30 *см* аша). Плантациядән файдалану вакыты 3 ел (утырткан елны санамыйча). Аннан соң җиләкләре ваклана, уңышы кими, куаклары авырулар һәм корткычлар б-н зарарлана. Махсус җиләк-җимеш хуҗалыкларында К.җ. интенсив технология буенча үстерелә: яхшы сортлар җирле шартлар өчен сайлап алына, культура әйләнеше кулланыла (күпьеллык үләннәр һәм сидератлардан



соң 4–5 кыр К.җ. б-н), тиешле күләмдә ашламалар кертелә, үсемлекләр югары сыйфатлы итеп карала (өстәмә туклandыру, гербицидлар б-н чүп үләннәрен бетерү, рәт араларын эшкәртү-йомшарту, су сибү), уңыш үз вакытында җыеп алына. Татарстанда бакча К.җ. Кайбыч, Арча, Тәмте җиләк-җимеш питомникларында, ш.у. Татарстан а.х. фәнни-җитештерү ин-тында һәм «Татплодоовощпром» концернының махсуслаштырылган хуҗалыкларында үстерелә. Төп корткычлары — К.җ. талпаны, кура-каен җиләге филчеге, К.җ. нематоды; авырулары — җиләкләрдәге соры черек,ончыл чык, яфракларда ак һәм көрән таплар.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КАЕ́Н ЯРЫСЫ́** (каен тузы элпәсе), традицион татар музыка уен коралы. К.я. ясау өчен, К.я.н катламнарга аералар һәм юка элпәнең киңлеген 10–15 *мм*, озынлыгын 60–70 *мм* калдыралар, моның өчен юеш каен тузы файдаланыла. Уйнаганда тасмасыман каен элпәсен, ике кулның баш һәм зур бармаклары б-н тотып, иреннәр б-н кысалар һәм һава сурып алалар. Шушы һава агымында каен элпәсенең үтә юка кыры тирбәлә башлый. Кайбер музыкантлар, уен коралын күп тапкырлар куллану максатыннан, юка каен элпәсен махсус ярыклы агач калыпка урнаштыралар. Каен ярысының тавыш сыйфаты көчле һава агымыннан, тарту көченнән, калынлыгыннан, элпәнең тирбәлеш мөмкинлегеннән, ш.у. башкаручының осталыгыннан тора. Каен тузы элпәсе юка булганга, тавыш та җиңел чыга. Башкаручылар бу турыда: «Яктылык үткәргән каен ярысы гына сандугач булып сайрый», — дип әйтәләр. Уңышлы сайлап алынган К. я. гына 3–4 октавада ачык, көчле аваз чыгара ала. К. я.ның динамик мөмкинлеге — mf-f. Диапазоны терцдецимага җитә. Уен коралының баштагы тон көйләнеше юк. Бу, ансамбльдә көйләнешне алдан әзерләмичә дә, теләсә нинди тональлектә төрле уен кораллары б-н бергә уйнарга мөмкинлек бирә. К.я.нда соло уйнау кошлар сайравына охшый. Ансамбльдә гөслә, гармун, баян б-н бергә уй-

наганда, бию һәм җыр көйләрен дә еш ишетергә мөмкин. Шул сәбәпле, башкаручы үзенең партиясен, алдан әзерләмичә, ярдәмче авазлар (форшлаг), тавышны калтырату (трель) һәм күптөрле ритмик комбинацияләр б-н баета ала.

*Р.Ф.Халитов.*

**КАЕНЛЫ́**, к. *Берёзовка*, Лаеш р-ны.

**КАЕНЛЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Инеш елгасы (Зәйнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 634 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдиният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Зиреклесе исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, төрле төскә әйберләр ману, итек басу, пыяла ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә; Кама пристаньнарында сезонлы эшкә яллана. 20 йөз башында К.да мәчет (19 йөз ахырында төзелә; 1989–90 да реконструкцияләнә; архит-ра истәлеге), 2 мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1335,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарев волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 568, 1870 тә — 578, 1897 дә — 936, 1920 дә — 1223, 1926 да — 657, 1938 дә — 696, 1949 да — 596, 1958 дә — 523, 1970 тә — 562, 1979 да — 353, 1989 да — 662, 2002 дә — 715 кеше.

**КАЕНЛЫ́К** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бидҗады елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 13 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1927 елда нигез салына. 1929 да К.та «Каенлык» к-зы оештырыла, 1950 дә Сталин исем. эреләндерелгән к-з (1960 тан — «Коммунизмга») составына керә; 1994 тән «Богады» а.х. кооперативлары берләшмәсендә. Оештырылган көннән ТАССРның Минзәлә кантоны Байсар волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 195, 1949 да — 169, 1958 дә — 116, 1970 тә — 121, 1979 да — 72, 1989 да — 26, 2002 дә — 22 кеше.

**КАЕНЛЫ́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 18 *км* төньяктарак, Сола елгасы буенда. 2010 елда 377 кеше (татарлар) яши. А.х. техникасы һәм а.х. химиясе пр-тиеләре. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты. 1930 елларда Дөбъяз МТСы посёлогы буларак нигез салына, 1977 нең 22 февраленнән хәзерге исемен йөртә. 1963 нең 1 февраленә кадәр — Дөбъяз, соңрак Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 76, 1949 да — 59, 1958 дә — 127, 1970 тә — 158, 1989 да — 227, 2002 дә — 357 кеше.

**КАЕНЛЫ́К** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Инеш елгасы (Зөяненң уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 232 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Черкен исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәдрәсә, 2 су һәм 5 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 751, 1908 дә — 1416, 1920 дә — 1456, 1926 да — 1158, 1938 дә — 1195, 1949 да — 749, 1958 дә — 646, 1970 тә — 673, 1979 да — 679, 1989 да — 373, 2002 дә — 271 кеше.

**КАЕНЛЫ́К** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 129 кеше (татарлар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек. 1929 да Зур Сәрдек авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Башта ТАССРның Мамадыш кантоны Сәрдек волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 245, 1949 да — 223, 1958 дә — 173, 1970 тә — 167, 1979 да — 144, 1989 да — 138, 2002 дә — 131 кеше.

**«КАЕНЛЫ́К»** («Берёзовая роща»), мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туберкулёз авыруыннан дәвалау санаторие, Казан янындагы нарат урманында урнашкан (Юдино посёлогы). 1937 елда нигез салына, 1978 гә кадәр Зәңгәр күл (Биектау р-ны) ярында урнаша. 240 урынга исәпләнгән, авыр, дәвамлы формадагы авырулар өчен стационар ачыла, ел дәвамында 500 бала дәвалана. Санаторийда рентген, физиотерапия, ингаляция, стоматология, массаж кабинетлары, дәвалау күнегүләре залы, диагноз лаб-ясе бар. Санаторий сулыш юллары, бөерләр һәм буын-сөяк туберкулёзын дәвалау чаралары б-н тәэмин ителгән. Гадәти булмаган, озакка сузылган үпкә авыруларын реабилитацияләү үткәрелә. Казан клиницист-фтизиатрлары өчен фәнни-тикшеренү базасы. Ел дәвамында эшли.

*Әд.:* Берег надежды: к 60-летию детского противотуберкулёзного санатория «Берёзовая роща». К., 1997; Сафиуллина Ф.К. В «Берёзовой роще» // Мед. вестн. 1997. № 22.

*Ф.К.Сафиуллина.*

**КАЕНСА́З** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* төньяктарак, Ык елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 110 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 20 йөз башында Иске Айман авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1920 дә — 383, 1926 да — 396, 1938 дә — 417, 1949 да — 324, 1958 дә — 251, 1970 тә — 238, 1979 да — 207, 1989 да — 147, 2002 дә — 125 кеше.

**«КАЕНСА́З»**, метеорит, күмерле хондрит, III типта, таш, үзгәрмәгән, кара төр. 1937 елда Мөслим р-ны Каенсаз авылы тирәсенә төшеп таркалган метеоритның гомуми авырлыгы 210 *кг* нан артык. «К.» төшкән урынны геолог Л.С.Селиванов тикшерә, ул метеорит кисәкләрен Мәскәү һәм Казан ун-тлары музейларына тапшыра. Метеоритның төп өлеше Мәскәүдә, РФАнең Метеоритлар ком-ты коллекциясендә һәм А.Е.Ферсман исем. Минераллар музеенда. Казан ун-тының Геология-минералогия музеенда 2 данәсе саклана (52,375 *кг* һәм 27 *кг*). Бу кисәкләр почмак рәвешендә, эрү нәтиҗәсендәге тышча б-н капланган, Җир атмосферасында яну нәтиҗәсендә уелган урыннар барлыкка килгән. «К.» ватыклары ш.у. Тау академиясе (С.-Петербург), Латвия ун-ты (Рига ш.), Вашингтон, Чикаго, Австралия һ.б. музейларда саклаканалар. Күмер хондритлар — сирәк метеоритлар төркеменнән, аларны Кояш системасы астероидлары тезелмәсенең тышкы өлешендәге зур булмаган планеталар таркалуы б-н бәйләнгән дип фаразлыйлар.



«Каенсаз» метеориты.

*Әд.:* Тефанова Т.А. Метеориты коллекции Геолого-минералогического музея КГУ // Метеоритика. 1955. Вып. 12.

*Н.Л.Фомичёва.*

**КАЕНСА́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасының (Мишәнең уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 171 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына, 17 йөзнең 1 нче яртысында ташландык хәлгә килгәч, яңадан торгызыла. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 736,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 279, 1897 дә — 392, 1908 дә — 470, 1920 дә — 439, 1926 да — 405, 1938 дә — 432, 1949 да — 353,

1958 дә — 281, 1970 тә — 268, 1979 да — 213, 1989 да — 178, 2002 дә — 186 кеше.

**КАЕНСА́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үртәм елгасы буенда. 2010 елда 119 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1646 елдан мәгълүм. Беренче исеме — Мамкечевская Пустошь. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 385,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 182, 1897 дә — 252, 1908 дә — 360, 1920 дә — 234, 1926 да — 214, 1938 дә — 230, 1949 да — 197, 1958 дә — 184, 1970 тә — 168, 1979 да — 152, 1989 да — 117, 2002 дә — 107 кеше.

**КАЕНСА́Р** авылы, Балтач р-нында, Балтач авылыннан 27 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. 1927 дә нигез салына. Башта ТАССРның Арча кантоны Арбор волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1926 да — 190, 1938 дә — 176, 1958 дә — 110, 1970 тә — 106, 1979 да — 85, 1989 да — 82, 2002 дә — 77 кеше.

**КАЕНСА́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 390 кеше (татарлар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Семён Головино исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында К.да мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1199,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1859 да — 325, 1897 дә — 542, 1908 дә — 718, 1920 дә — 620, 1926 да — 726, 1938 дә — 766, 1949 да — 661, 1958 дә — 593, 1970 тә — 608, 1979 да — 494, 1989 да — 378, 2002 дә — 388 кеше.

**КАЕ́Ш ЯФРА́К** (Pyrola), каеш яфракчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 40 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 4 төре үсә: яшел чәчәкле К.я. (P. chlorantha), кечкенә К.я. (P. minor), түгәрәк К.я. (P. rotundifolia), уртача К.я. (P. media). Күбесенчә ылыслы һәм катнаш урманнарда очрыйлар. 15–30 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырчасы нәзек, тармаклы, шуышма. Сабагы кырлы. Яфраклары калын, түгәрәк яки озынча түгәрәк, еш кына кышлыйлар да. Чәчәкләре ак, ә яшел чәчәкле К.я.ның яшькелт төстә. Җимеше — күп санлы вак орлыклы тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк аталар. Август–сентябрьдә җимеш бирәләр. Орлыктан үрчиләр, тамырында микориза хасил итәләр. Җир өсте өлешләрендә дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында К.я. төнәтмәсе бөрештергеч (эч киткәндә) һәм яра төзәтү чарасы буларак кулланыла. Декоратив үсемлекләр. Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЕШКЫРА́Н**, к о р ы ч т а м ы р (Ononis), кузаклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуаклар яки куаклар ыругы. 70 кә якын төре билгеле, күбесенчә Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Кыр К. (O. arvensis) — көньяк районнарында, арадаш К. (O. intermedia) Көнбатыш Кама аръягында очрый. Болыннарда, куаклар арасында, елга ярлары буенда үсәләр. 30–80 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлекләр, бизсыман төкләр б-н капланган. Тамырчасы үзәк, озын. Сабагы туры, тармаклы, төкләр б-н капланган. Яфраклары чиратлашкан, саплы, аскылары — өчәрле, өскеләре гади. Чәчәкләре алсу төстә, күбәләк чәчәклеләр тибында, эре, 2 шәрләп кыска чәчәк сабында яфрак куентыгында урнашканнар. Җимеше — җиңел ачылучан кузаклар, бөресыман 2–4 орлыгы бар. Июль–августта чәчәк аталар. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Тамырчаларында гликозид, органик к-талар, эфир мае бар. Халык медицинасында тамырларыннан ясалган төнәтмә йөрәк ялкынсынуы, бөер, үт куыгы авырулары вакытында кулланыла. Кыр К. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЕШЧАЛА́Р** (Ligulidae), псевдофилитлар (Pseudophyllidea) отрядыннан паразит тасма суалчаннар семьялыгы. 3 ыругтан 8 төре билгеле; киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 ыруг вәкиле билгеле: лигула (Ligula) һәм диграмма (Digramma). Гәүдәсе каешсыман, 3 *см* дан 2 *м* га кадәр озынлыкта. Үсеше катлаулы. Личинкалар-плероцеркоидлар төче сулыклардагы, күбесенчә карплар семьялыгындагы балыкларның (корбан балык, густера, чабак һ.б.) тән куышлыгында паразитлык итәләр. Балык б-н тукланучы кошларның эчәгесенә эләгеп, берничә көннән алар өлгереп җитәләр. Суда йомыркалардан личинка-корацидияләр чыга, алар б-н ишкәгаяклы кыслачыклар туклана; аларның гәүдә куышлыгында исә личинка-процеркоидлар җитлегә. Паразитлы бу кыслачыклар б-н тукланган балыклар да йогышлана, шул сәбәпле, үсү тоткарлана, эчке органнарның атрофиясе күзәтелә, кайвакыт (сусаклагыч шартларында) балыклар күпләп үләргә дә мөмкин. К. кеше өчен куркыныч түгел.

*О.Д.Любарская.*

**КАЗ**, татар мифологиясендә популяр персонаж; кыргый каз — мәхәббәт, тугрылык, бәхет символы; йорт казы — акылсызлык һәм күп сөйләү билгесе. Соңгы вакытта фольклорда һәм әдәби поэзиядә К. образы башка мәгънәгә ия була башлады: ул ялгызлык, кайгы-хәсрәт, сагыш, газапны гәүдәләндерә («Су өсләрендә бөдрә тал», «Киек каз», «Җил милчә» татар халык җырлары һ.б.).

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Кыска җырлар. К., 1976; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАЗ ӨМӘСЕ́**, татар крәстияннәренең традицион үзара ярдәмләшү чарасы (к. *Өмә*). Йорт кошлары итен алдагы көнгә тизрәк әзерләү, яңа суйган каз һәм үрдәкләрне эшкәртү өчен оештырыла. Көзен, көннәр суытып, аяк асты катыргач, К.ө. яшьләр (нигездә, кызлар) бәйрәме рәвешендә күп кенә авыл өйләрендә уздырыла. Ярдәмгә чакырылган яшьрәк кыз туганнар һәм күршеләр иртәдән көн уртасына кадәр кызык сүзләр сөйләшеп, җырлар җырлап, бергәләшеп каз-үрдәк йолкыйлар, эчләрен чистарталар. Аннары кызлар эшкәртелгән каз түшкәләрен, 2–3 әрләп көянтәләргә элеп, чишмә буена чишмә суы б-н чайкарга алып китәләр. Аларга балалар һәм еш кына матур итеп киенгән егетләр төркеме б-н гармунчы да килеп кушыла. Кызлар әйләнеп кайтуга йорт хуҗабикәсе табын әзерли: каз мае б-н майланган коймак, чәй китерелә; ә кичкә каз һәм үрдәк итеннән, эч-башларыннан пешерелгән ризыклар (каз шулпасы, баш-аяк бәлеше) әзерләнә, өмәдә катнашучылар ашка чакырыла.

*Әд.:* У р а з м а н о в а Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984; ш у л  у к. Семейные обычаи и обряды // Татары. М., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАЗ ЮАСЫ́** (Gagea), лаләчәләр семьялыгыннан суганчалы күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 100 төре билгеле. Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 3 төре бар: сары чәчәкле К.ю. (G. lutea), вак К.ю. (G. minima) барлык районнарда да очрый, суганчалы К.ю. (G. granulosa) — югала баручы төр. Яфраклы урман буйларында, куаклар арасында үсәләр. 5–20 *см* биеклектәге үсемлекләр. Сабагы, нигездә, киң ланцетсыман, тамыр яны бер яссы яфраклы. Чәчәкләре саргылт, шарсыман яки чатырсыман чәчәк төркемендә. Җимеше — өч оялы тартмачык. Апрель–майда чәчәк аталар. Вак К.ю. яшь суганчалары хисабына күп үрчи. Казлар яратып ашый (исеме шуннан). Иртә язгы эфемероидлар, җәен җир өсте органнары корый. Суганчалы К.ю. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЗА́К ҮРТӘМЕ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үртәм елгасы буенда. 2010 елда 94 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре

катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ү.ндә мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 462 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 23 ир-ат; 1859 да — 299, 1897 дә — 320, 1908 дә — 340, 1920 дә — 391, 1926 да — 400, 1938 дә — 480, 1949 да — 80, 1958 дә — 224, 1970 тә — 293, 1979 да — 177, 1989 да — 120, 2002 дә — 107 кеше.

**КАЗАКИ́** (кәзәки), элегрәк татар, рус, украин һәм кайбер башка халыкларда киң таралган язгы-көзге ирләр киеменең бер төре. К. фабрикада җитештерелгән карасу төстәге киҗе-мамык яисә йон тукымадан, әчлек куеп, озын җиңле, озын яки кыска (тезгә кадәр) итәкле итеп тегелә. Гадәттә, билле һәм



Казаки кигән татар. 20 йөз башы. Н.И. Воробьёв фондында саклanучы фоторәсем (ТР Милли музее).

тоташ арттакталы итеп, уңнан сулга ябылулы, ян-якларына кисеп ясалган кесәләр, муен турысыннан каптырмага әләктерелә торган зур булмаган утыртма яка куеп киселә. 20 йөз башында шәһәрдә яшәүче татар интеллигенциясе арасында сәгать йөртү өчен кисеп ясалган түш кесәле кыска йон К. кию киң таралыш ала.

*Әд.:* М у х а м е д о в а Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

**КАЗАКЛА́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 95 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. 1646 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Служилый Муй исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 183,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 142, 1897 дә — 183, 1908 дә — 235, 1920 дә — 272, 1926 да — 275, 1938 дә — 208, 1949 да — 145, 1958 дә — 145, 1970 тә — 165, 1979 да — 136, 1989 да — 100, 2002 дә — 90 кеше.

**КАЗАКЛА́Р** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 19 *км* көнбатыштарак, Шуран елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 171 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. Мәчет. 1647–56 еллардан морза Колай Сабакаев авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Елга, Казаклар Елгалары исемнәре б-н дә мәгълүм. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1882 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 808,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир-ат; 1859 да — 255, 1897 дә — 407, 1908 дә — 465, 1920 дә — 447, 1926 да — 322, 1949 да — 215, 1958 дә — 271, 1970 тә — 277, 1989 да — 192, 2002 дә — 166 кеше.

**КАЗАКЛА́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 40 *км* төньяктарак, Өлә елгасы буенда. 2010 елда 208 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Уразлы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, колмак үстерү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 18 йөз ахырында К.да мәчет, поташ з-ды, 20 йөз башында тимерчелек, җил тегермәне, 1 бакалея һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1855 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 1267, 1897 дә — 1065, 1908 дә — 1176, 1928 дә — 1186, 1938 дә — 1005, 1949 да — 658, 1958 дә — 614, 1970 тә — 550, 1989 да — 449, 2002 дә — 232 кеше.

**КАЗАКЛА́Р** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 5 *км* төньяктарак, Макса елгасы буенда. 2010 елда 163 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Китапханә бар. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Кибәхуҗа исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, баш киеме һ.б. әйберләр тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 2 тегермән, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1747 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда. 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 129 ир-ат; 1859 да — 932, 1897 дә — 898, 1908 дә — 1330, 1920 дә — 910, 1926 да — 827, 1938 дә — 809, 1949 да — 493, 1958 дә — 393, 1970 тә — 302, 1979 да — 255, 1989 да — 185, 2002 дә — 176 кеше.

**КАЗАКЛА́Р** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 209 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1737 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1585,48 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 55, 1816 да — 118 ир-ат; 1859 да — 685, 1897 дә — 757, 1920 дә — 1019, 1926 да — 740, 1938 дә — 658, 1949 да — 468, 1958 дә — 453, 1970 тә — 440, 1979 да — 311, 1989 да — 187, 2002 дә — 188 кеше.

**КАЗАКЛА́Р ЧАЛЛЫСЫ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 45 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы бассейнында. 2010 елда 237 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Казаклар исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, утын кисү, күн эшкәртү һәм тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ч.нда Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1875 тә ачыла), кирпеч һәм май язу з-длары, ярма яргыч, тимерчелек, 1 тукыма, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 672 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ба-



А.А. Казаков.



А.С. Казаков.

лык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1859 да — 339, 1897 дә — 673, 1908 дә — 837, 1920 дә — 725, 1926 да — 729, 1938 дә — 722, 1949 да — 564, 1958 дә — 451, 1970 тә — 433, 1989 да — 336, 2002 дә — 292 кеше.

**КАЗАКО́В** Александр Афанасьевич (28.5.1917, Уфа губ., Минзәлә өязе, хәзер Сарман р-ны Александровка а. — 11.7.1950, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), капитан (1946). Свердловск хәрби пехота уч-щесен тәмамлый (1940). Туган авылында совхозда эшли. 1938–40 елларда һәм 1941 нең июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 787 нче укчы полк батальоны командиры (33 нче армиянең 222 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү шәһәре өчен сугышта (1941–42), Ржев-Вязьма операциясендә (1942), Белоруссияне азат итүдә, Берлин һөҗүм операциясендә катнаша (1945). 1944 нең июнендә Могилёв өлкәсен азат итүдә батырлык күрсәтә (К. җитәкчелегендәге батальон, 23 июньдә Проня, 27 июньдә Днепр елгаларын кичеп, сугыш мәйданында урнаша һәм, аны кулда тотып, дошманның берничә контрһөҗүмен кире кайтара). 1946 дан Азнакай авылында яши, МТС директоры булып эшли. Ленин, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Туган авылы урамы К. исемен йөртә. Шунда ук Геройга һәйкәл куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза- сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Навечно в сердце народном. Минск, 1984.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КАЗАКО́В** Анатолий Семёнович (20.2.1923, Чуаш Респ-касы Урмары а., хәзерге Урмары штп. — 8.9.1986, Казан), Сов. Союзы Герое (15.5.1945), подполковник (1956). Энгельс очучылар хәрби-авиация мәктәбен тәмамлый (1942). 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 235 нче штурм авиаполкының звено командиры (5 нче һава армиясенең 264 нче штурм авиадивизиясе). 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында К. 150 сугышчан очыш ясый, дошманның 19 танкын, 2 бронемашинасын, 83 автомашинасын, ягулык һәм сугыш кирәк-яраклары сакланган 6 складын, 2 паровоз һәм 8 вагонын юк итә. Сугыштан соң Хәрби Һава көчләрендә командирлык вазифаларын башкара (1956 елга кадәр). Казанда яши. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Наши земляки — Герои Советского Союза. Чебоксары, 1980.

*В.А.Шагалов.*

**КАЗАКО́В** Борис Васильевич (5.5.1946, Пермь өлкәсе Лысьва ш. — 2.4.2006, Чаллы ш., Брянск шәһәрендә җирләнә), язучы. Ленинград югары хәрби-диңгез инженерлар уч-щесен (1966), Лениград ун-тын (1970) тәмамлый. 1963–75 елларда СССР Хәрби-диңгез флотында хезмәт итә. 1976 елдан Чаллы шәһәрендә яши. 1976–79 елларда КамАЗның ДОСААФ ком-ты рәисе, 1979–91 дә СССР Автомобиль сәнәгате министрлыгына караган Квалификация үстерү ин-тында укыта, 1991 елдан «КамАЗ» АҖдә. Гражданнар оборонасы буенча фәнни хезмәтләр, уйлап табулар, рационализаторлык тәкъдимнәре авторы. 1996 дан РФ Язучылар берлегенең Чаллы язучылары оешмасы рәисе, 1999 дан РФ Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе. «Диңгез хикәяләре» («Морские рассказы») дип аталган беренче җыентыгы 1967 елда басылып чыга. К.ның жанр һәм язу манерасы төрлелеге б-н аерылып тора, әсәрләре армия һәм флот, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, интернационалист солдатларга багышлана. Әсәрләре катлаулы сюжетка һәм киеренке вакыйгаларга корылган. «Офицерлар вальсы» («Офицерский вальс», А.-А., 1970), «Ракета күкрәве» («Ракетный гром», М., 1974), «Онытылган герой турында повесть» («Повесть о забытом герое», Минск, 1980), «Чаңнар нигә чыңламый» («О чем молчат колокола», М., 1990), «Коммунарлар кыры» («Поле коммунаров», Рига, 1993), «Бу безнең биографиябез» («Это наша с тобой биография», М., 1995), «Орыш-сугышларда» («В боях и сражениях», М., 2000) һ.б. повестьлар авторы. Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә «Сугышчан батырлык өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* На пороге XXI века: Российский автобиобиблиогр. ежегодник. М., 1999. Т. 2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КАЗАКО́В В.Е. БАСМАХАНӘСЕ́**, к. «*Урнәк*».

**КАЗАКО́В** Евгений Петрович (22.10.1934, Түбән Новгород өлкәсенең Бутурлино р-ны Кетарша а., хәзерге Бутурлино штп.), тарихчы, археолог, тарих фән. д-ры (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан ун-тын (1963) тәмамлый. 1967 елдан Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында: 1995 тән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 2001 дән баш фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта, 1995 тән «Finno-Ugrika» ж-лы мөхәррире. 1959 дан Татарстан терр-ясендәге археол. истәлекләрне тикшерүдә катнаша; Такталачык, Олы Тархан, Танкеевка каберлекләрендә, Әҗмәр авыллыгы һ.б. археол. объектларда алып барылган казу эшләренә җитәкчелек итә. *Чиялек культурасын* һәм *Постпетрогром культурасын* беренчеләрдән булып аерып күрсәтә һәм тасвирлый. Хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләте, Идел-Кама төбәгенең таш, бронза һәм тимер гасырлар тарихы һәм археологиясенә, фин-угор халыкларын өйрәнүгә карый. «*Татарстан Республикасының археологик картасы*»н җентекләп өйрәнгән һәм төзүдә катнашкан өчен, ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1994).

Х е з м.: Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978; Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987 (автордаш); Булгарское село 10–13 веков низовий Камы. К., 1991; Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992; Финны, угры и самодийцы в Восточном Закамье (3 в. до н. э. — 14 в. н. э.). Елабуга, 1993 (автордаш); Очерки древней истории Восточного Закамья. Альметьевск, 1999 (автордаш); Le cimetiere de Tankeevka // Les anciens Hongrois et les etnies voisines a Est. Bdpst., 1977 (автордаш).

**КАЗАКО́В** Иван Фомич (18.6.1908, Уфа губ., Минзәлә өязе Кадрәк а. — 2.9.1975, Казан), вет. патофизиологы, вет. фән. д-ры (1967), проф. (1971). 1932 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1932–60 та Казан вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1946 дан патофизиология бүлеге мөдире. 1960–75 тә Казан вет. ин-тының эксперименталь патология һәм физиология лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре йогышлы һәм паразитар авырулар вакытында терлекләрнең канын биохимик тикшерүгә, цито агулы сыркындыларның, прополис препаратларының хайваннар организмына тәэсирен өйрәнүгә, йогышлы авырулар һәм нурланыш алган хайваннарның югары нерв эшчәнлеге патологиясе мәсьәләләренә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нарушение механизма регуляции иммунитета у облученных животных при бруцеллёзе и их компенсации // Ветеринария. 1973. № 7.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КАЗАКО́В** Исхак Мостафа улы (26.12.1876, Казан — 16.10.1939, шунда ук), сәясәт эшлеклесе, педагог. Казан сәүдәгәрләре *Казаковлар* нәселеннән. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый (1897). 1897–1900 елларда Вятка губернасының Сарапул өязендәге Кадыбаш авылында укытучы. 1900–11 дә, 1917–18 дә Казан губернасының Тәтеш шәһәрендә рус-татар мәктәбе мөдире. 1911 дә революцион эшчәнлеге өчен кулга алына, 1912 дә Сембер, аннан соң Оренбург губернасына сөрелә. Беренче бөтендөнья сугышы чорында Россия армиясенә чакырыла, Нарва шәһәре янында хезмәт итә, соңрак Юрьев (Дерпт) гарнизонына күчерелә, анда хезмәте 1917 гә кадәр дәвам итә. 1 нче Бөтенроссия мөселманнар съезды (Мәскәү, 1917), 2 нче Бөтенроссия мөселманнар съезды (Казан, 1917) делегаты. 1918–19 да Үзәк мөселман комис-ты коллегиясе әгъзасы, «Тәтеш хакыйкате» г-тасы мөхәррире. 1919–21 дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең нәшрият бүлеге башлыгы, РКП(б)ның Казан губерна ком-ты каршындагы мөселман бюросы рәисе, Эшче һәм крәстияннәрнең Казан губерна башкар-



И.М. Казаков.

ма ком-ты әгъзасы (1920). 1921–23 тә ТАССР ҮБК Президиумы һәм ХКС рәисе урынбасары, бер үк вакытта Идел буендагы ачларга ярдәм оештыру комиссиясе рәисе урынбасары. 1931 дән ТАССР Социаль тәэминат халык комис-ты идарәсе башлыгы. Хезмәтләре педагогика тарихына һәм ТАССРда соц. төзелеш мәсьәләләренә карый. Нахакка репрессияләнә (1937); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Гимназия: Төрле заведенияләргә хәзерләнүчеләргә үз-үзеннән укырга китап. Оренбург, 1914; Казан — Чулман (Кама) — Идел төбәгенең мәркәзе К., 1923; Татарстан байлыгы. К., 1927; Лучи света в тёмном царстве. История одной школы. Татарский педагогический техникум. К., 1924.

*Әд.:* Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; Х у з е е в а Л. «Мне нужна только свобода и свобода...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2.


*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**КАЗАКО́В** Михаил Владимирович (15.9.1976, Ульянов өлкәсе Димитровград ш.), опера җырчысы (бас), ТРның халык (2003), РФнең атказ. артисты (2008). 2001 елда Казан консерваториясен (Г.Ластовка классы) тәмамлый. 1998 дән Татар опера һәм балет театры, бер үк вакытта, 2001 дән Зур театр (Мәскәү) солисты. Беренче тапкыр Казанда Дж.Вердиның «Реквием» әсәрендә чыгыш ясый. Дөньякүләм танылган опера репертуарында: Борис Годунов, Досифей («Хованщина», М.Мусоргский), Гремин, Рене («Евгений Онегин», «Иоланта», П.Чайковский), Кончак («Князь Игорь», А.Бородин), Захария, Филипп («Набукко», «Дон Карлос», Дж.Верди) һ.б. төп бас опера партияләрен башкара. Вокалистларның М.Г.Глинка исем. 8 нче халыкара (Казан, 1999,«Гран-при» премиясе), Тулуза шәһәрендә үткәрелгән 43 нче халыкара (Франция, 2000, «Гран-при» премиясе), Афинада М.Каллас исем. 25 нче халыкара (Греция, 2001), Мәскәүдә П.И.Чайковский исем. 12 нче халыкара (2002, 1 нче премия), Пекинда вокалистларның 2 нче халыкара (Кытай, 2002, 1 нче премия) һ.б. конкурслар лауреаты. Көнбатыш Европа һәм Американың әйдәп баручы опера театрлары сәхнәләрендә чыгышлар ясый (Вена дәүләт операсы, Бавария милли операсы, Вашингтон милли операсы һ.б.). 2001 дән Казан консерваториясендә укыта. Ирина Архипова фонды бүләге бирелә (2002).

*Ф.Ш.Салитова, А.Р.Рахмани.*

**КАЗАКО́В** Хаҗиморат Исхак улы (1914, Оренбург губ. Тәфкилев хуторы — 13.11.1984, Казан), график, нәкышьче. 1917 елдан — Тәтештә, 1919 дан Казанда яши. А.М.*Кокоревтан* рәсем буенча дәресләр ала. 1934–38 елларда И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тында укый, 1938 дә Киев сәнгать ин-тына күчә. 1941 елда фронтка китә; фронт газетасы рәссамы. 1947–48 дә Казан сәнгать уч-щесе укытучысы. 1949 да Латвия ССР САнең графика бүлеген тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1947). 1950–52 елларда — Фрунзеда, 1952–54 тә — Казанда, 1954–58 дә — Баулыда һәм Бөгелмәдә, 1958 дән Казанда яши. «Шагыйрь», «Мулланур Вахитов» (икесе дә — 1947 дә), «Генерал Я.Җ.Чанышев портреты» (1950), «Кечкенә Тукай», «Шүрәле» (икесе дә 1958 дә), «Автопортрет» (1976); Бөек Ватан сугышы батырлары, тарихи шәхесләрнең график портретлары (линолеумда эшләнгән гравюра), ТРның нефть р-ннарында клублар һәм мәдәният йортлары бизәлеше авторы. «*Зур Идел*» 5 нче төбәк (1980), Мәскәүдә Татарстан рәссамнары әсәрләре (1981) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казандагы Габдулла Тукай музеенда, Яңа Кырлайдагы Габдулла Тукай музей-комплексында саклана. Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.



Х.И. К а з а к о в. «Автопортрет». 1976.



Х.И. К а з а к о в. «Кечкенә Тукай». 1958.
Яңа Кырлай авылындагы Габдулла Тукай музей-комплексы.



Х.И. К а з а к о в. «М.Вахитов портреты».
Линогравюра. 1960 еллар.

**КАЗАКО́В** Хатыйп Шакир улы (4.9.1908, Сембер губ., Буа өязе Тәүгелде а. — 12.11.1991, Казан), биол. фән. д-ры (1956), проф. (1957), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1968, 1973). 1932 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1949–84 тә биол. һәм органик химия каф. мөдире, бер үк вакытта 1960–70 тә биохимия фәнни-тикшеренү лаб-ясе җитәкчесе. СССР ФА Бөтенсоюз биохимия җәмгыятенең Казан ф-лын оештыручы (1963). Хезмәтләре биоген металларның хелат кушылмаларын өйрәнүгә карый. К. металл нигезле йод аксымлы кушылмаларны, биоген макро- һәм микроэлементларның протеид хелатларын ала, аларның коллоид-химик, биохимик һәм иммунохимик үзенчәлекләрен өйрәнә.«Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы белкового питания сельскохозяйственных животных. К., 1960; Хелаты микробиогенных металлов в системе почва-растение-животное. К., 1987.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КАЗАКО́ВА** Элла Хатыйп кызы (14.3.1946, Хабаровск ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1993), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 1995 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре табигый кушылмалар химиясенә, стереохимиягә, супрамолекуляр химиягә карый. К. терпен углеводородларның, аларның модельле аналоглары һәм алардан табылган продуктларның туендырылмаган бәйләнешләренә электрофиль кушылу реакцияләренең стереохимик үзенчәлекләрен, әлеге кушылмаларның фәзаи төзелешләре үзенчәлеген билгели. Селективлыгы РН-көйләнүле каликс[4]резорцинареннар нигезендә молекуляр рецепторлар рәтен эшли һәм өйрәнә, алар өчен металл комплексларның тышкы сферада координациясе механизмын ача. Каликс[4] резорцинареннарга суда эрү үзенчәлекләрен кертүнең югары нәтиҗәле алымын эшли. Шулар нигезендә субстратның бәйләнеше табигатен нечкә көйләргә һәм аның молекула-хуҗа куышлыгында молекуляр хәрәкәте б-н идарә итәргә (тирәлекнең кислота-нигез үзлекләрен, эреткеч составын үзгәртү, күп корылмалы ионнар кертү юллары кулланып) мөмкинчелек бирүче системалар булдырыла. Биологик актив фосфорорганик һәм азоторганик субстратлар б-н яңа



Г.М. Казаков.



Мөхәммәтрәхим Казаков.

молекула-хуҗаларның тотрыклы комплексларын синтезлый. К. җитәкчелегендә өйрәнелгән кушылмалар сенсорлар, экстрагентлар проектлаганда металлкомплекслар һәм органик субстратларны, биомиметикларны бәйләү өчен селектив лигандалар сыйфатында кулланыла.

Х е з м.: Конформации карбоциклических соединений // Конформационный анализ углеводородов и их производных. М., 1990 (автордаш); Фосфорсодержащие каликсарены // Успехи химии. 1998. Т. 67, вып. 11 (автордаш); Исследования в области химии супрамолекулярных соединений каликсаренов // Рос. хим. журн. 1999. Т. 49, № 3–4; Novel Water-Soluble Tetrasulfonatomethylcalix[4]resorcinarenes // Tetr. Lett. 2000. V. 41 (автордаш).

**КАЗАКОВЛА́Р**, Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. **Мөхәммәтҗан Назыйр** улы (1806, Казан губ., Зөя өязе Кече Шырдан а. — 1890, Казан) — Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан. Яшь чагында Казанга китә, бай сәүдәгәрләрдә ярдәмче булып эшли. Әстерханга күченә, 1830 елларда анда чәй, балык, бакалея һ.б. товарлар сату буенча үз эшен ача. 1852–57 дә Әстерхан сәүдәгәре булып исәпләнә. Персия һәм Кавказ б-н сәүдә итә. Казанда Евангелистлар, Екатерининская һәм Захарьевская (хәзерге Татарстан, Габдулла Тукай, Каюм Насыйри) урамнарында күчемсез милек, йортлар, Печән базары мәйданында кибетләр һәм керем йорты тота. 1871–82 дә Казан шәһәр думасы гласные була. 1874 тә Евангелистлар урамында мәчет төзү өчен акча бирә (к. *Казаковлар мәчете*). Хатыны — Бәдыйгылҗамал (1815–78) — сәүдәгәр Йосыповлар нәселеннән. Аның балалары: **Мостафа Мөхәммәтҗан улы** (1835-?) — Әстерхан һәм Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан. Әстерханда гаиләэшен дәвам итә. Аның хатыны Б.Ж.Усмановага (к. *Усмановлар*) этисеннән мираска зур күләмдә байлык кала. 1882 дә Мостафа бөлә һәм этисе химаясендә яши башлый. **Мөхәммәтфәиз Мөхәммәтҗан улы** (11.9.1844 – ?) — Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан. Энесе Мөхәммәтшакир б-н бергә Казанда этисенең сәүдә эшен дәвам итә. 1898 дә гаиләсе б-н мещан катлавына языла. **Мөхәммәтшакир Мөхәммәтҗан улы** (8.10.1848 — 1932) — Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре. Әстерханда этисе эшен дәвам итә: чәйне үлчәү-бүлү һәм төргәкләү ф-касы өчен кирпеч бина төзетә. Әстерханда һәм Казанда чәй сату кибетләре ача. 20 йөз башында Казанга күчеп килә. Керем йортлары төзүгә акча сала. 1906 да сәүдәгәр Ә.Г.Хөсәеновтан «Болгар» номерлары бинасын сатып ала. Евангелистлар, Мәскәү һәм Захарьевская урамнарында таш керем йортлары тота. 1908 дә Әстерханда мәчет (хәзерге Җамигъ мәчет) төзү өчен акча бирә. Аның балалары **Габделхәмит Мөхәммәтшакир улы** (11.9.1877, Казан — 10.2.1938, Мәскәү) һәм **Мөхәммәтрәхим Мөхәммәтшакир улы** (22.1.1874 — 1937) 1908 дә устав капиталы 2,5 мең сумлык «Бертуган Казаковлар һәм К° сәүдә йорты» ширкәтен (1916 да гомуми кереме 450 мең сум тәшкил итә) оештыралар; Берлинда аларның вәкиллеге эшли. 1907–08 дә Габделхәмит *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте* идарәсе рәисе була, 1908 нең августында Вологда губернасына полиция күзәтчелегенә сөрелә, шул ук елның сентябрендә Германиягә китә. Берлинда чимал (башлыча, тиреләр һәм мехлар) сату б-н шөгыльләнгән фирма ача. 1910 да Казанга кайта. Окт. рев-циясеннән соң гаиләсе б-н Мәскәүгә күченә: төрле оешмаларда эре хезмәткәр булып эшли. НЭП елларында Мөхәммәтрәхим Казанда



Мөхәммәтшакир Казаков балалары: беренче рәттә (утырганнар) – Мөхәммәт, Бибирабига, Зөләйха; икенче рәттә (сулдан уңга) – Габделхәмит, Мөхәммәтрәхим. С.Гобәйдуллинның шәхси архивыннан алынган фоторәсем.

Печән базары мәйданында баш киемнәре сату кибете ача. 1935 тә Ватанга хыянәт итүдә гаепләнеп кулга алына, 1937 дә репрессияләнә; үлгәннән соң аклана. **Мөхәммәт Мөхәммәтшакир улы** (24.2.1879 — ?) һәм Фуад Габделхәмит улы (? — ?) Германиягә китеп урнашалар, соңгысы татар эмиграциясенең танылган эшлеклесе була. Ш.у.к. *И.М.Казаков*.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; шулар ук. Казаковы // Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001. Т. 2; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; Г у б а й д у л л и н С. Казаковы // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 2.

*Л.М.Свердлова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**КАЗАКОВЛА́Р МӘЧЕТЕ́**, Казанда. 1876 елда сәүдәгәр М.Н.Казаков иганәсенә Евангелистлар урамындагы (хәзер Татарстан урамы) 12 нче мәхәллә өчен төзелә. Архитекторы билгесез. Бер катлы, ике заллы, ишек өстеннән күтәрелгән 8 кырлы манаралы, татар бизәү сәнгате элементларын кулланып, клас-



Казаковлар мәчете. Казан. 1876. 20 йөз башы фоторәсеме.

сицизм юнәлешендәге эклектик стилендә корылган җамигъ мәчет. Мәчет ишеге бинаның төньяк фасадына тоташкан өч ярусы манара нигезенә урнашкан. 1975 елда Татарстан урамын киңәйткәндә һәм анда биек йортлар төзегәндә сүтелә.

*Әд.:* Х а л и т о в Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991.

*Н.Х.Халитов.*

**КАЗАКЪСТА́Н**, к. *Казакъстан Республикасы*.

**КАЗАКЪСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, Үзәк Азиядә урнашкан. Мәйданы — 2724,9 мең *км*². Башкаласы — Астана шәһәре (1997 елдан; 1929–97 дә — Алма-Ата, казакъча — Алматы). Халкы — 15,73 млн.кеше (2008), ш.и. 228,6 мең татар (1897 дә — 56 мең, 1926 да — 79,8 мең, 1937 дә — 92,1 мең, 1939 да — 106,9 мең, 1959 да — 192 мең, 1970 тә — 287,7 мең, 1979 да — 313,5 мең, 1989 да — 331,2 мең, 1999 да — 320,7 мең, 2001 дә — 245,5 мең, 2007 дә — 229,6 мең кеше). К.Р. терр-ясендә элек-электән төрки халыклар яшәгән (к. *Дәште Кыпчак, Кыпчаклар, Күк Урда, Нугай Урдасы, Сарайчык*). Казакъ далалары аша Урта Идел буе б-н Бохара, Сәмәрканд, Ташкент, Жаркент, Голҗа, Кашгар арасында элемтә урнаштыручы сәүдә юллары уза. 1744 тә Оренбург тирәсендә *Каргалы бистәсе* төзелә башлый, татарларның Казакъстанга икътисади йогынтысы көчәя. Чик буендагы рус кальгаларына (хәзерге Петропавловск, Троицк, Уральск һ.б.) татар сәүдәгәрләре килеп урнаша, мәчетләр һәм кәрвансарайлар төзелә. Көнбатыш Казакъстанның (Кече Жуз) Россиягә кушылуында татар морзасы К.М.*Тәфкилевнең* роле зур була. Салым изүеннән, рекрут җыемнарыннан, милли һәм дини кысулардан качарга омтылган татар крәстияннәре 18 йөзнең 2 нче яртысында Казакъстанның төньяк һәм төньяк-көнбатыш өлкәләренә юнәлә. 1786 да бер төркем татар крәстияннәре һәм һөнәрчеләр Петропавловскидан 40 чакрым көнбатыштарак Мәүлет авылын нигезли (хәзер Мамлютка ш.). 19 йөз башында Петропавловскида татар бистәсе барлыкка килә. Троицк эре йөк күчерү пункты һәм Казан, Түбән Новгород, Уфа губерналары татарларының тартылу үзәгенә әверелә, бирегә сәүдә һәм эшкуарлык б-н шөгыльләнүче кешеләр җыела. 19 йөзнең 2 нче яртысында татарлар Казакъстанга күпләп күченә баш-

лый. Акмола, Павлодар, Әүлия-Атада (Тараз) татар җәмгыятьләре оештырыла. Күкчәтау тирәсенә Саратов губернасыннан татарлар килеп урнаша. Йөзләрчә татар гаиләсе Төньяк-көнчыгыш һәм Көнчыгыш Казакъстанда (Семипалатинск, Аягуз, Лепсы, Капал, Жаркент, Зәйсән һ.б.) төпләнә. 1860 елларда Верный авылында (хәзерге Алма-Ата) татар бистәсе (к. *Алма-Атада татар бистәсе*) барлыкка килә, халкы сәүдә, күн эшкәртү, кирпеч сугу, сабын кайнату, сарык тиресе иләү, бакчачылык, яшелчәчелек б-н шөгыльләнә. 19–20 йөзләр чигендә Петропавловск, Уральск, Семипалатинскида татарлар халыкның күпчелеген тәшкил итә. Татар һәм казакъ эшкуарлары бергәләп сугымчылык, сабын кайнату, туңмай эретү һ.б. пр-тиеләр ача. Кустанай, Актүбә, Петропавловск һ.б. җирләрдә сәүдәгәр Яушевлар, Якуповлар, Абдерәшитовларның кибетләре була. Казакъстанның көньягында атаклы сәүдәгәрләр Бакиров, Габделвәлиев, Каипов, Таҗетдиновлар тукыма, галантерея һ.б. товарлар б-н сәүдә итә. Балхаш буенда Хәмидулла һәм Гөлшат Бикмәтовларның көмеш-кургаш з-ды (завод һәм рудник Гөлшат исемен йөртә) эшли. Казакъстанда татарларның актив икътисади эшчәнлеге милли-мәдәни мохит булдыру б-н бергә кушылып бара: алар төпләнгән урыннарда мәчет һәм мәдрәсәләр калкып чыга. Уральскида атаклы *«Мотыйгия» мәдрәсәсе* була, аның каршында шәкертләрнең *Гыйльми мәҗлес* әдәби түгәрәге эшли, кулъязма журналлар нәшер ителә (мәдрәсә укучылары арасында Г.*Тукай*, Г.*Кариев*, М.*Чулпаный* бар). Күп кенә уку йортлары татар меценатлары иганәсенә төзелә һәм тотыла. Уральскида сәүдәгәр М.Гобәйдуллин акчасына мәдрәсә бинасы салына, Петропавловскида он тарту з-ды хуҗалары Моратовлар 8 сыйныфлы кызлар уч-щесе тота. 1872 дә Семипалатинскида 7 мәдрәсә һәм мәктәп эшли. 20 йөз башына аларның саны 12 гә җитә, шуларның өчесендә кызлар башлангыч белем ала. Казакъстанның төрле өлкәләрендә татарлар оештырган мөселман хәйрия җәмгыятьләре була. Аларның ярдәме б-н Уральск, Семипалатинск, Кустанай, Верный, Күкчәтау һ.б. җирләрдә китапханәләр төзелә. Семипалатинскида «Ярдәм» китап сату ширкәте эшли, ул Оренбург, Уфа, Казаннан татар наширләренең заказын үти. Акмола, Петропавловск, Верныйда татар сәүдәгәрләре кибетләрендә татар китаплары сатыла. Уральск шәһәре татар вакытлы матбугатының үзәге булып китә. 1905 тән соң монда татар телендә *«Фикер»*, *«Яңа тормыш»* г-талары, *«әл-Гаср әл-җәдид»*, *«Акмулла»*, *«Уклар»* ж-ллары нәшер ителә. Аларда Ф.*Әмирхан*, Г.*Тукай*, Р.*Фәхретдин* әсәрләре дөнья күрә. Петропавловскида *«Ишим даласы»* г-тасы чыга. 1917 дән соң Казакъстанда татарларның мәдәни тормышы яңа үсеш ала. 1919 да Верныйда Х.*Уразиков* «Г.Тукай исем. театр» труппасын оештыра. 1920–30 елларда Алма-Атада — татар эшче яшьләр театры, Семипалатинск шәһәрендә («Мәдәният» татар җәмгыяте оештыра), Кустанай, Уральск, Атбасарда татар театр труппалары эшли. Уральскида татар телендә *«Хәбәрләр»* (1917), *«Мөхбир»* (1917–18), *«Ихтилял байрагы»* (1919), *«Кызыл Шәрекъ»* (1919–20), *«Кызыл Шәрекъ яшьләре»* (1920), *«Яңа фикер»* (1920), Петропавловскида *«Маяк»* (1918–19), Семипалатинск шәһәрендә *«Халык сүзе»* (1917–19), *«Эшче халык сүзе»* (1919–20), Кызыл Урдада «Сабан» (1925) г-талары нәшер ителә. 1930 еллар ахырына кадәр Казакъстанда татар гомуми белем бирү мәктәпләре эшли. Совет чорында *индустрияләштерү*, *крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү*, «Сталин репрессиясе» корбаннарын бу якларга сөргенгә җибәрү, Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә пр-тиеләрне эшчеләре б-н бу республикага эвакуацияләү, 1950 елларда чирәм җирләрне үзләштерү, 1960–80 дә сәнәгатьнең нык үсүе К.Р.да татарларның шактый артуына китерә. Хәзерге вакытта татарлар К.Р.ның барлык өлкәләрендә яши. Көньяк Казакъстанда (Алма-Ата, Жамбул, Кызыл Урда, Көньяк Казакъстан өлкәләре; Алма-Ата ш.) — 73,8 мең татар, Көнбатыш Казакъстанда (Актүбә, Атырау, Көнбатыш Казакъстан һәм Мангыстау өлкәләре) — 23,7 мең, Үзәк Казакъстанда (Караганда өлкәсе) — 34,9 мең, Төньяк Казакъстанда (Акмола, Кустанай, Павлодар һәм Төньяк Казакъстан өлкәләре, Астана ш.) — 73,9 мең, Көнчыгыш Казакъстанда (Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе) 22,3 мең татар яши. 1989 дан Алма-Атада татар мәдәни үзәге эшли. Соңрак милли-мәдәни үзәкләр Караганда, Күкчәтау, Павлодар, Петропавловск, Семипалатинск, Талды-Курган, Чимкент, Экибастуз һ.б. шәһәрләрдә барлыкка килә; 1995 тән алар барысы да Казакъстанның Татар һәм башкорт милли-мәдәни үзәкләре ассоциациясенә (президенты — Т.А.Кәримов) карый. 1995 тә Казакъстан халыклары ассамблеясы оештырыла, анда илдә яшәүче барлык милләт вәкилләре, ш.и. татарлар да кертелә. 1990 елларда К.Р.ның барлык өлкә үзәкләрендә диярлек, татар телен өйрәнү максаты б-н, якшәмбе мәктәпләре ачыла. Алма-Ата һәм Петропавловскида татарча радио һәм телевидение тапшырулары алып барыла. Уральскида «Г.Тукайның Уральск үзәге» оешмасы(рәисе Р.А.Әбүзәров) эшли. К.Р.да яшәүче татар язучыларының поэзия һәм проза әсәрләре дөнья күрә. «Фикер» (Алма-Ата) һәм «Ак барс» (Астана) г-талары нәшер ителә. Семипалатинскида татар балалар сәнгать мәктәбе эшли, республиканың төрле шәһәрләрендә татар үзешчән сәнгать ансамбльләре оештырыла. Казакъстанның татар үзешчән артистлары Япония, Финляндия, Швеция, Австрия һәм Төркиядә чыгышлар ясый. ТР һәм К.Р. халкы арасында икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр элек-электән яши. Татар һәм казакъ мәдәниятендә уртак рухи хәзинәләр күп. Татар һәм казакъ телләре *кыпчак теле* төркеменә керә. Татарлар һәм казакъларда *«Идегәй»*, *«Таһир белән Зөһрә»* дастаннарының, *«Чура батыр»* эпик дастанының милли версияләре киң таралган. Татар шагыйре — чичән Г.*Байчугави* үзенең «Кыйссаи әхвали казакъ» поэмасында 19 йөзнең 1 нче яртысында казакъ халкының көнкүрешен һәм милли гореф-гадәтләрен чынбарлыктагыча тасвирлый. Татарлар Казакъстанда агарту эше алып баралар. Педагог-мәгърифәтче М.М.*Бикчурин* Оренбург чик буе комиссиясе каршындагы мәктәптә казакъ балаларына татар теле укыта. *Неплюев кадетлар корпусында* татар һәм казакъ балалары бергә укый. Татар муллалары һәм шәкертләр (Фәхретдин бине Мифтахетдин, Н.*Яушев*), казакъ авылларында йөреп, балаларны укырга-язарга өйрәтә. Татар мәдрәсәләрендә казакъ мәдәниятенең күренекле вәкилләре (А.*Конанбаев)* белем ала. Күп кенә казакълар дөньяви белемне Казан уку йортларында (Казан ун-тында, Казан укытучылар семинариясендә һ.б.) үзләштерә. 1870–81 дә Россиядә казакъ телендә чыгучы беренче төрки телле «Төркестан вилаете газети»ны оештыручы һәм мөхәррире Ш.М.*Ибраһимов* була. Казанда *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәтендә* казакъ телендә китаплар басыла. Татар һәм казакъ әдәбияты классигы булып М.К.*Акмулла* тора; Ә.М.Уразаев (к. *Кормаши*) һәм Й.Ш.*Таңчулаков* үзләренең поэмаларын берьюлы татар һәм казакъ телләрендә иҗат итәләр. Казакъ язучылары М.*Әуэзов*, С.Донентаев, Б.Ж.*Майлин* иҗатына татар әдәбияты йогынты ясый. Казакълар турында К.*Халиди* яза, татар-казакъ әдәби багланышларын өйрәнү б-н Б.*Исхаков* шөгыльләнә.

1917 дән соң татарлар Казакъстанда сов. хакимияте урнаштыру өчен актив көрәшә (К.Б.*Шиһабетдинов*, С.Г.*Габбасов*, Х.Б.*Мәүлутов*, К.Д.*Сутюшев*, С.Ш.*Шәрипов*). 1920 елларда казакъ орфографиясен эшләүдә Г.Х.*Алпаров* катнаша. Татар педагоглары һәм мәгариф хезмәткәрләре казакъ милли интеллигенциясе кадрларын әзерләүгә зур өлеш кертә. Казакъ проф. музыкасына нигез салучыларның берсе — композитор Л.Г.*Хәмиди*. Казакъ опера сәнгате үсешенә ике бертуган М.М.Абдуллин һәм Р.М.Абдуллин күп көч куя. Татарлар республиканың төрле иҗади оешмаларында, фән һәм мәгариф учреждениеләрендә күренекле урын тота, илнең сәнәгый куәтен арттыруда актив катнаша. Татарлар дәүләтнең югары урыннарында (М.А.*Алиев*, Ш.Х.Бикбулатов, Ф.Х.Галимов, В.Г.Ибраһимов,М.С.Мөслимов, Т.Г.Мөхәммәтрәхимов, Х.М.*Пазиков*) эшли, Казакъстан ССР ФАнең академиклары һәм мөхбир әгъзалары (М.А.Алиев, В.М.*Әмербаев*, А.Н.*Иләлетдинов*, С.Р.*Рәфыйков*, С.Ш.*Сәйфуллин* һ.б.) булып сайлана. 1972 дә татар журналисты Ф.Ә.*Иделле* Истамбулда «Казакъ вә татар төрекләре» китабын нәшер итә. 1990 елларда Татарстанның Казакъстан б-н бәйләнешләре яңа рәвешкә керә. Хөкүмәт делегацияләре б-н алмашу җайга салына, икътисад һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү төзелә. К.Р. президенты Н.А.Назарбаев берничә тапкыр Казанда була. ТР ның беренче президенты М.Ш.Шәймиев Алма-Ата һәм Астана шәһәрләренә берничә тапкыр рәсми визит б-н бара. 1997 дә К.Р.да ТРның вәкаләтле вәкиллеге төзелә. 1991 дә Казанда «Казакъстан» җәмгыяте оештырыла, 2000 дә ул ТРда яшәүче казакъларның шул ук исемдәге республика милли-мәдәни автономиясе

(рәисе С.Жаксыбаев) итеп үзгәртелә. Татарстаннан Казакъстанга нефть продуктлары, резина шиннар, йөк автомобильләре, автомобиль җиһазлары, пластмасса чыгарыла; аннан бодай, азык-төлек, текстиль сәнәгате продукциясе, металл кертелә. 1993 тә ТР һәм К.Р. ФАләре арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. 1995 тә Казанда казакъ шагыйре, мәгърифәтче А.Конанбаевның тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни-практик конференция уздырыла. Татар мәдәни үзәкләре вәкилләре Бөтендөнья татар конгрессы эшендә катнаша. Казакъстан татар мәдәни хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләре ТРның дәүләт бүләкләренә лаек була. К.Р.да татар язучылары һәм мәдәният эшлеклеләре б-н очрашулар уздырыла, Казаннан, Татарстан шәһәрләреннән һәм районнарыннан артистлар һәм иҗат коллективлары гастрольләргә чыга. Сов. Союзы Геройлары Г.Б.*Сафиуллин*, З.Л.*Әсфәндияров*, И.С.*Даутов*, Г.З.*Закиров*, Х.Н.*Мөхәммәдиев*, Г.Г.*Рамаев* Р.И.*Кутуев*; Соц Хезмәт Герое Г.Г.*Каюмов*; дирижёрлар Ф.Ш.*Мансуров* һәм Р.С.*Салаватов*; рәссамнар Б.И.*Урманче*, К.В.*Муллашёв*, З.С.*Назыйров*, И.С.*Романов*, Б.Х.*Табиев*, К.М.*Шәяхмәтов*; тарихчылар Р.И.*Нәфыйгов* һәм М.Г.*Госманов*; композитор Н.Г.*Җиһанов*; язучылар З.Ш.*Бәшири*, Х.Р.*Габдүш*, М.Ф.*Гомәров*, И.Н.*Сәлахов*, Г.Г.*Шәрипова*; шагыйрьләр Н.Г.*Арсланов*, М.Х.*Хөсәен*; журналист Ә.Г.*Хәмидуллин*; атказ. спорт остасы Ф.Н.*Җиһангировның* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлеге К.Р. б-н бәйле. Г.Кормаш һәм М.Җәлилнең фашистларга каршы яшерен эш алып барган төркемендә (к. «*Җәлилчеләр төркеме*») Казакъстаннан Ә.Атнашев, С.Бохаров, Г.Кормаш, Ф.Сәйфелмөлеков, Р.Хисаметдинов та була. Казакъстанның фән үсешенә зур өлеш керткән галимнәр: астроном Н.Г.*Ризванов*; тарихчы В.З.*Галиев*; биологлар М.Ф.*Авазбакиева*, Р.Ә.*Гәрәев*, И.Д.*Дәүләтшин*, М.И.*Исмәгыйлев*, Н.Х.*Кармышева*, Г.Г.*Ушбаева*, Н.Җ.*Хөсәенова*; геологлар М.А.Абдулкәбирова, И.Г.*Ганиев*, Ә.М.*Садыйков*; тау инженеры Г.М.*Сиражетдинов*; зоотехник-селекция белгече Ә.Г.*Галиәкбәров*; инженер-метеоролог И.З.*Лотфуллин*; медиклар И.Г.*Дауранов*, М.Г.*Кәримов*, А.Н.*Сызганов*, Г.А.*Ульданов*; педагоглар Р.А.*Әбүзәров* һәм Г.Т.*Хәйруллин*; механика гыйлеме белгече Ә.Г.*Акчурин*; физиклар Ш.Ш.*Ибраһимов* һәм Ш.Х.Ярмөхәммәтов; филолог Х.Х.*Мәхмүдов*; философлар Р.А.Клещеева-Хафизова, К.Х.*Рәхмәтуллин*; электрохимик Р.С.*Вахидов*; хокук белгече К.Җ.*Мөхәммәтшин*.

К.Р.да татар халкының күренекле шәхесләре исемен йөртүче истәлекле урыннар шактый. Уральскида — Г.Тукайга, Петропавловскида — К.Р.Сутюшевка, Алма-Атада Б.Шиһабетдиновка (шәһәрнең бер урамы аның исемен йөртә) һәйкәлләр куела. Алма-Атада бер урамга җырчы бертуганнар М.М. һәм Р.М.Абдуллиннар исеме бирелә, Талды-Курган шәһәрендә укытучылар Ю.Айманов һәм Г.Хәмитов исемен йөртүче урамнар бар. К.Р. ФАнең хирургия фәнни үзәге А.Н.Сызганов исемен йөртә.

*Әд.:* Хайруллин Г.Т. История татар. Алматы, 1997; Хайруллин Г.Т., Хамидуллин А.Г. Татары (Страницы истории и сегодняшний день). Алматы, 1998; Народы Казахстана: Энцикл. справ. Алматы, 2003; Татары на севере Казахстана (история и современность). Петропавловск, 2004; Этнографическая карта Казахстана (этнодемографический аспект). Астана, 2008.

*Г.Т.Хәйруллин, А.И.Ногманов, Ә.В.Әбдрәхимова.*

## КАЗА́Н

I. Гомуми мәгълүматлар.
II. Шәһәр хакимияте.
III. Тарихи очерк.
IV. Икътисади очерк.
V. Мәгариф, фән, мәдәният.
VI. Сәламәтлек саклау.
VII. Планлаштыру һәм архитектура.

### I. Гомуми мәгълүматлар

К. — *Татарстан Республикасының* башкаласы, *Россия Федерациясенең* сәнәгать, фән һәм мәдәният үзәкләреннән берсе. Мәскәүдән 797 *км* көнчыгыштарак, Иделнең сул ярында, Казансу елгасының Иделгә койган тамагында урнашкан. Мәйданы — 425,3 *км*². Зур елга порты, Мәскәү–Екатеринбург юнәлешендәге тимер юл вокзалы, автомобиль юллары үзәге; халыкара аэропорт. К. — халык саны буенча Россиянең иң зур шәһәрләреннән берсе. 2010 ел башына 1136,6, 2008 елда 1130,7 мең кеше (ш.и. ир-атлар — 505,1 мең, хатын-кызлар — 631,5 мең), 80 гә якын милләт вәкиле яши. 2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 524,7 мең (47%), руслар — 538,8 мең (48,8%) кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 2,6 мең кеше.

Шәһәр төньяктан көньякка таба — 28 *км* га, көнбатыштан көнчыгышка таба 30 *км* га сузылган. *Куйбышев сусаклагычы* култыгы — Казансу елгасының түбәнге агымы К.ны 2 гә бүлә: зуррак өлешен тәшкил иткән көньяк-көнчыгыш сулъяк ярга һәм төньяк-көнбатыш уңъяк ярга. Геологик планда шәһәрнең терр-ясе дүртенчел чорга (1,5 млн. еллар элек) караган Идел һәм Казансу елгалары китерелмәләреннән ясалган 5 төрле биеклектәге һәм төрле чордагы террасаларны били. Сусаклагыч яры буенча полоса булып (1,5–4 *км*) шәһәрнең түбәнге өлеше (тимер юл вокзалы р-ны, Болак каналы, Кабан күле h.б.) урнашкан ике түбән терраса зонасы (сусаклагычтан 7–10 *м* биеклектә) сузыла. Бу зона югары террасалардан 25–30 *м* лы киртләч б-н бүленә, һәм ул Юдино посёлогыннан төньяктарак *Казан Кремлен* әйләнеп уза, Бауман һәм Кремль урамнары арасында, Петербург урамы буйлап көньякка — Мирный посёлогына кадәр сузыла. Өч югары терраса зонасы (сусаклагыч тигезлегеннән 30–60 *м* биеклектә, киңлеге 5–6 *км* га кадәр), түбәнге террасалар полосасы кебек, Казан үзәнлеге б-н бүленә. Югары террасалар дүртенчел чорның башында һәм уртасында балчыксыл туфрактан һәм комнан оешкан. Шәһәрнең төньяк-көнбатыш өлешендә югары террасалар комында «Аккош күле» урман паркы урнашкан. Кремль һәм Кремль урамы тирәсендә *Казан ярусы* известьташлары җыерчыкланып торалар, һәм алар өске катлауга якын урнашкан җир асты тау сырты хасил итәләр. Шәһәрнең төньяк-көнчыгышында, Казансуның сул кушылдыклары *Нокса* һәм *Киндерле* елгалары бассейннарында, Югары Пермь токымнары өскә чыга һәм Идел, Казансу үзәннәренең төп сул сөзәклекләрен ясый. Казан ярусының сульфат-карбонатлы токымнары эрү процессы күзәтелгән карст күренешләре б-н бәйле, шул сәбәпле, К.ның төрле р-ннарында упкынлы бүрәнкәләр, казанлыклар, карст күлләре барлыкка килгән (к. *Карст*).

Өске сулар — Куйбышев сусаклагычына, Казансу елгасына, аның кушылдыклары (Нокса, Киндерле, Коры Елга, *Солонка*), күлләр, ш.и. түбән терраса буйлап шәһәрнең үзәк өлешенә кадәр сузылган Кабан күлләре системасы (*Бирге Кабан*, *Аргы Кабан* (Урта Кабан), *Югары Кабан*) керә. К.ның көнбатыш өлешендә карстлы *Тирән күл* һәм дюна арасы күлләр системасы — *Аккош күлләре* бар. Шәһәрнең төньяк читендә уникаль табигатьле тозлырак сулы *Олы Зәңгәр күл* һәм Казансу елгасына кушыла торган *Кече Зәңгәр күлләр* урнашкан. Шәһәр эчендә, табигый сулыклардан тыш, элеккеге сазлыклар урынында ясалма күлләр булдырылган (Яңа Савин р-ны).


К.ның климаты — уртача континенталь. Иң салкын айда (гыйнвар) уртача темп-ра −14 °С, кышкы темп-раның абсолют минимумы −47 °С. Иң җылы ай — июль (+19 °С), иң югары темп-ра — +40 °С. Явым-төшемнең уртача еллык күләме 508 *мм* (күбесе елның җылы вакытына туры килә).

Административ бүленеш нисбәтендә 1917 гә кадәр К.да 6 полиция бүлеге була, 4 се — хәзерге Вахитов, 5 нчесе — Пләтән, 6 нчысы Адмиралтейство бистәсе р-ннары терр-ясендә урнаша. Полиция бүлекләре участок һәм бүлекчәләргә бүленә. 1918 дән шәһәрнең адм. төзелеше РКП(б)ның терр. структураларына, ягъни партия райкомына буйсыну принцибында корыла. Аларның саны, исеме, хокуклары үзгәреп тора. 1920 еллар башында К.да Идел, Шәһәр, Болак аръягы-Пләтән, Кремль, Берләштерелгән бистәләр, Постаучылар бистәсе р-ннары була. 1925 нең октябрендә К.да камилләшкән беренче Елга аръягы р-ны оештырыла, аның б-н шул ук исемдәге райсовет идарә итә. 1930 да, ТАССР районнарга бүленгәнгә кадәр, 1926 да төзелгән Түбән Шәһәр һәм Югары Шәһәр р-ннары б-н партия райкомнары җитәкчелек итә. 1931 дә Югары Шәһәр — Бауман, Түбән Шәһәр — Сталин, Елга аръягы — Пролетар р-ннары итеп үзгәртелә. 1934 тә Пролетар р-нының бер өлешеннән Ленин р-ны оештырыла. 1935 тә Пролетар р-ны Киров р-ны итеп үзгәртелә, Бауман р-ны составыннан Молотов р-ны бүленеп чыга. 1942 нең апрелендә, Бауман, Молотов, Сталин р-ннарын бүлгәләү нәтиҗәсендә, Дзержинский һәм Свердлов р-ннары төзелә. 1956 ның декабрендә Дзержинский р-ны терр-ясе — Бауман р-нына, Свердлов һәм Сталин р-ннары Идел буе р-нына кушыла. 1957 нең октябреннән Молотов р-ны Совет р-ны итеп үзгәртелә. 1973 нең апрелендә К.да 2 яңа район оештырыла: Мәскәү һәм Вахитов р-ннары.

1994 нең декабрендә Ленин р-ны Яңа Савин һәм Авиатөзелеш р-ннарына бүленә, бетерелгән Бауман р-ны терр-ясе Вахитов р-нына кушыла. Хәзерге вакытта шәһәрдә 7 адм. р-н: Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет р-ннары; 1,6 меңләп урам һәм тыкрык исәпләнә.

**II. Шәһәр хакимияте**

Шәһәрдә җирле үзидарәнең югары вәкаләтле органы булып Казан шәһәр думасы исәпләнә, ул 5 елга сайланган 50 депутаттан тора. Аның карамагында: шәһәрнең уставын кабул итү һәм аңа үзгәртүләр, өстәмәләр кертү; үз терр-ясендә һәркем өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне гамәлгә кертү; бюджетны билгеләү һәм аның үтәлеше турында хисап тоту; җирле салым һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару; шәһәрнең үсеш программасын һәм планнар кабул итү; аларның үтәлеше турындагы хисапны раслау;



Казан ратушасы.

җирле үзидарә органнары эшен материаль-техник һәм оештыру ягыннан тәртипкә салу һәм алар эшчәнлегенә контрольлек итү; муниципаль мөлкәт б-н идарә һәм эш итүдә тәртип булдыру; җирле сайлаулар һәм референдумнар үткәрүне билгеләү; ТР Дәүләт Советында кануннар чыгару хокукыннан файдалану һ.б. Шәһәр хакимиятенә муниципаль берәмлек башлыгы — мэр, аның урынбасарлары, президиум; 7 даими комиссия — социаль-икътисади үсеш, эшмәкәрлек һәм муниципаль милек; бюджет-финанс; җирле салымнар һәм җыемнар мәсьәләләре; мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр; шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык; яшьләр эше, физик культура һәм спорт; шәһәр халкының сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклау; законлылык, хокук, җирле үзидарә мәсьәләләре б-н шөгыльләнүче комиссияләр керә. Дума аппараты эшләр б-н идарә итүдән; норматив-хокук идарәсеннән; муниципаль хокук актлары, муниципаль хезмәт эшләре, оештыру эшләре; халыкара һәм муниципалитетара хезмәттәшлек, бүләкләүләр, гомуми бүлек, җәмәгатьчелек һәм массакүләм информация чаралары, мобилизацион хәзерлек бүлекләреннән гыйбарәт.

Җирле үзидарәнең башкарма-җитәкче органы булып шәһәр башкарма ком-ты тора, ул идарә вазифаларын гамәлгә ашыра, К.ның комплекслы социаль-икътисади үсешен тәэмин итә; шәһәр думасына буйсына. Башкарма ком-т җитәкчедән, аның урынбасарларыннан, аппараттан тора. Аңа түбәндәге идарәләр керә: эшләр; оештыру; хокук; кадрлар сәясәте; муниципаль эшчәнлеккә контроль һәм коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру; канцелярия эшләрен алып бару; эчке эшләр; муниципаль архив; ЗАГС; информация технологияләре һәм элемтә; капиталь төзелеш һәм реконструкция; шәһәрдәге төзелеш эшләрен хәл итү; архит-ра һәм шәһәр төзелеше; торак сәясәте; гражданнарны яклау; мәгариф; сәламәтлек саклау; мәдәният; адм.-техник инспекция; халыкны социаль яклау; тышкы реклама һәм информация; адм. комиссия эшен оештыру һәм адм. контрольне координацияләү; ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту; ком-тлар: икътисади үсеш; транспорт; җир һәм милек мөнәсәбәтләре; тышкы бәйләнешләр һәм туризм; торак-коммуналь хуҗалыгы; балалар һәм яшьләр эшләре; физик культура һәм спорт; шәһәрне төзекләндерү; бүлекләр: бухгалтерлык һәм исәп-хисап; район башкарма ком-тларының вәкаләтләрен тәэмин итү; җәмәгатьчелек б-н массакүләм информация чаралары арасында бәйләнешләр, телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар б-н бәйләнеш; дәүләт статистикасы; төзелешне үстерү һәм координацияләү; дирекцияләр: муниципаль торак программалары; шәһәрне үстерүнең бюджеттан тыш программалары; бәйрәм программалары; җир асты транспорты корылмалары төзелеше; Халыкның мәшгульлек үзәге; Иҗтимагый үзәк; наркотикларга каршы көрәш комиссиясе; пр-тиеләр һәм оешмалар: «Казметрострой», «Казжилгражданстрой», «Казан шәһәренең торак-инвестиция компаниясе, «Казэнерго».

К.ның адм. р-ннарында җирле үзидарәнең башкарма-җитәкче органы булып район администрациясе тора. Ул шул районга караган терр-яләрдә шундый ук эшләр башкара, К. шәһәр башкарма ком-тына һәм К. шәһәр думасына буйсына.

**III. Тарихи очерк**

Казансу елгасының түбәнге өлешендәге зур үзәнлек, үсемлек һәм хайваннар дөньясының бай һәм төрле булуы иң борынгы заманнарда ук кешеләргә бу җирләрдә яшәү өчен уңайлы шартлар тудырган. К. терр-ясендә беренче кеше эзләре *мезолит* чорына (Казан Кремле тирәсендә, К. ун-тының ишегалдында, элеккеге Савин посёлогының төньяк читендәге казылмаларда табылган чакматашлар һәм пластиналар якынча б.э.к. 6–5 нче меңьеллыкларга карый) туры килә. Хәзерге шәһәрдә неолит чорының *Идел-Чулман буе культурасы* торулыклары (Новаторлар урамы тирәсендә «Казан II» шәһәрлегендә «Карга Куагы» («Вороний Куст») дип аталган табигый урын), бронза гасырның *Волосово культурасы* (Борисково, Дәрбиш, Займище, Победилово, Савин посёлоклары тирәсендә) һәм *Казан яны культурасы* авыллыклары («Локомотив» су станциясе янында Бакалтай торулыгы, Хуҗамәт, Кукушкино, Дәрбиш посёлоклары тирәсендә һ.б.) табыла. Тимер гасыр башында (б.э.к. 7–5 йөзләр) К. терр-ясендә *Ананьино культурасы* кабиләләре (Новаторлар тимер юл платформасыннан 500 *м* төньяк-көнбатыштарак урнашкан «Казан I» шәһәрлегe, «Казан I» авыллыгы урыны), 3–6 йөзләрдә *Азелино культурасы* кабиләләре (элеккеге К. елга порты тирәсендәге борынгы каберлек, «Казан II» шәһәрлегенең өске катламы) яши.

*Бөек Болгар дәүләте* таркалгач, һәм 653–765 еллардагы *Гарәп-хәзәр сугышларыннан* соң, К. урынына болгар кабиләләре килеп урнаша башлый (к. *Болгарлар*). 10 йөз башында *Идел буе Болгар дәүләте* төзелү, Балтыйк илләреннән Көнчыгышка таба сузылган трансъевразия сәүдә юлларының (Бөек Идел юлы) барлыкка килүе һәм үсүе нәтиҗәсендә, Идел һәм Кама ярлары буйлап сәүдә-һөнәрчелек б-н шөгыльләнүче болгар авыллары барлыкка килә. Шундый сәүдә үзәкләренең берсе буларак, 10–11 йөзләр арасында Казансу елгасының түбәнге өлешендә К. шәһәре оеша. Археологик мәгълүматларга караганда,



Казан Кремле территориясендәге Хан сараеның археол. казылмалар калдыклары.

башта шәһәр Кремль калкулыгының төньяк-көнчыгыш читендә 6 *га* дан артык терр-яне били һәм дошман һөҗүменнән саклану өчен канаулар, урлар системасы, бура рәвешендәге агач диварлар б-н әйләндереп алынган була.

12 йөзнең 2 нче яртысында тышкы куркыныч арту сәбәпле (Владимир-Суздаль кенәзләренең Урта Идел буена һөҗүмнәре), кальга диварлары ныгытыла, агач диварның бер өлеше таш диварга алмаштырыла. 11–12 йөзләрдә К.ның сәүдә-һөнәрчелек бистәсе оеша, Кремльдән түбәндәрәк һәм көньяктарак Кремль калкулыгы буйлап яшәү өчен уңайлы терр-яләрдә кешеләр урнаша башлый. 1236–40 еллардагы монголлар явыннан соң, Чулман аръягы терр-яләреннән таланган качакларның К.га агылуы исәбенә шәһәр халкы күпкә арта. Казансу бассейнында урнашкан җирләрдән Алтын Урда өчен ясак һәм салым җыела, бу, К.ның стратегик яктан уңайлы урнашуы б-н берләштән, аның Урта Идел буенда эре шәһәр үзәкләренең берсенә әверелүенә китерә. Археол. табылдыклар — Җүчи тәңкәләре, кытай фарфоры ватыклары, Урта Азия савыт-сабалары, кургаш мөһерләр, пыяла муенсалар һ.б. К.да икътисади-сәүдә бәйләнешләрының киң үсеш алуын раслый. Аның идарәчеләре 13 йөз ахырыннан «бөек солтан, солтаннарның иң затлы ярдәмчесе, кавем һәм динебезнең горурлыгы булган гыйззәтле ... җиңелмәс әмир, Илаһыбыз шәүләсе» титулларын йөртәләр, *Болгар* идарәчеләре б-н бер үк статуста һәм

Алтын Урда ханнарының вассаллары булалар. 1399 елгы рус елъязмаларында К., Болгар, Җүкәтау, Кирмәнчәк шәһәрләре б-н беррәттән, әмирлек үзәкләренең берсе буларак билгеле. 14 йөз ахыры — 15 йөз башында шәһәрнең башка болгар шәһәрләре арасында абруе зур була. Монда сугылган акчаның кайда эшләнгәнлеге — «*Болгар әл-Җәдид*» («Яңа Болгар») дип күрсәтелә. 1420 еллардан Казан идарәчесе булып Җүчиләр нәселеннән *Гыясетдин* тора. 1431 дә Василий II нең кенәз Фёдор Пёстрый җитәкчелегендәге гаскәрләре тарафыннан Болгар яуланып талангач, Урта Идел буенда К. сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәккә әверелә.

1438 дән К. — мөстәкыйль дәүләт — *Казан ханлыгы* башкаласы. Монда хөкемдарлар династиясе урнаша, аның башында Алтын Урда тәхетеннән бәреп төшерелгән *Олуг Мөхәммәд хан* тора. Сәүдә-һөнәрчелек б-н көнкүреше күпсанлы шәһәр халкы Кремль, ш.у. аннан көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыштарак урнашкан (*Казандагы Богородица хатын-кызлар монастыре* урынында) ныгытылмаган посад терр-яләрендә, алар янәшәсендәге бистә (к. *Күрәеш бистәсе*) һәм авылларда яши. Формасы һәм фактурасы б-н Болгар һәм Алтын Урда чоры үрнәкләрендә эшләнгән корал, чүлмәк, зәркән һ.б. әйберләр ясау, күн эшкәртү үсеш ала. Балта һәм таш кисү эшләре югары осталык б-н башкарыла. 15–16 йөзләрдәге Европа карталарында К. зур шәһәр — мәркәз буларак күрсәтелә. Аның уңайлы җирдә урнашуы төрле ил сәүдәгәрләрен үзенә җәлеп итә, кайберләре монда үзләренең колонияләрен (к. *Әрмән бистәсе*) төзи. К. Мәскәү, Кавказ, Кырым, Төркия, Нугай даласы, Урта Азия, Себер б-н сәүдә итә. Башкорт, мари, мордва, удмурт, чуаш һ.б. халыкларның борынгы бабалары урнашкан Идел буе һәм Урал алдының күп кенә төбәкләре аның б-н икътисади элемтәләр урнаштырырга омтыла. К.нан ерак түгел Сәүдәгәрләр атавында (*Гостиный остров*) халыкара ярминкә эшли. Ярминкәләр шәһәрнең үзендә дә (*Ташаяк* базары) һәм бистәләрдә дә (*Арча кыры*) үткәрелә. Төрки-мөселман мәдәнияте үзәкләренең берсе буларак (Мәгариф, фән, мәдәният бүлекләрен кара), К.ның әһәмияте бик зур була. К. ханлыгының Мәскәү б-н эчке һәм тышкы сәясәте күбесенчә хәрби һәм икътисади көндәшлек (нигездә, сәүдә юлларында хакимлек итү өчен) мөнәсәбәтләреннән чыгып билгеләнә. Рус хөкүмәте К.га берничә тапкыр (1469, 1487, 1506, 1524, 1530 һ.б.) хәрби яулар оештыра. 1487 дә шәһәрне Иван III гаскәрләре яулый. Яулар вакытында таланып беткән посадлар 1530 елларда имән диварлар б-н әйләндереп алына. 1540 еллардан Мәскәү ягыннан көчле яулар (к. *Казанга Рус дәүләте яулары*) башлана, ул Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушу б-н тәмамлана. 1552 нең 2 октябрендә, җиде атналык камалыштан соң, К.ны Иван IV гаскәрләре яулап ала (к. *Казанның яулап алынуы*). Шәһәр тулысынча диярлек җимерелә, халыкның күпчелеге һәлак була, бер өлешен әсирлеккә алып китәләр. К. тарихында яңа чор башлану б-н, милли традицияләр һәм күнегелгән яшәү рәвеше кинәт юкка чыга. Татар мөселман шәһәре рус хәрби, идарә һәм дини үзәгенә, Көнчыгыштагы җирләрне колонияләштерүнең терәк пунктына әверелә. К. б-н башта — наместниклар, 1550 еллар ахырыннан Мәскәү билгеләгән воеводалар идарә итә (к. *Воевода идарәсе*). Җирле үзидарә эшчәнлегенең башында *Казан сарай идарәханәсе* тора. Воеводалар резиденциясе Кремльдәге «Патша йорты»н били. Монда ш. у. хакимият учреждениеләре, азык-төлек, корал складлары, берничә чиркәү, руханилар һәм Казан гарнизоны йомышлы хезмәтчеләре йортлары урнаша. Йомышлылардан тыш, беренче булып, монда башка җирләрдән (1565–68 елгы теркәү кенәгәсе буенча Рус дәүләтенең 40 тан артык төбәгеннән) күчерелгән руслар: һөнәрчеләр, осталар, сатучылар, ямчылар һ.б. посад һәм шәһәр яны бистәләренә килеп төпләнәләр. Татарларга яшәү урыны К.ның читендә, Кабан күле һәм Болак тирәсендә билгеләнә, монда үзенчәлекле бер бистә (к. *Иске Татар бистәсе*) барлыкка килә. 1560 нчы елларда



Казандагы Иске Татар бистәсе. Мәрҗани мәчете манарасыннан төшерелгән 20 йөз башы фоторәсеме.

шәһәрнең мәйданы 110 *га* га якын, 7 урам, 130 дан артык тыкрык була. 1556 да Кремльнең таш диварларын һәм манарасын төзи башлыйлар — элеккеге Хан кальгасының агач ныгытмалары таш диварлар б-н алмаштырыла. 1550 еллардан К. Рус дәүләтенең көнчыгыш өлешендә православие динен тарату үзәгенә әверелә. 1555 тә монда *Казан епархиясе* оештырыла; Елантау (1553, к. *Успение ирләр монастыре*), Спас-Преображение (1556), *Казан Богородица хатын-кызлар монастырьларына* (1591 ел тирәсе) нигез салына. 1579 да К.да могҗизалы *Казан Мәрьям Ана иконасы* табыла, соңрак ул гомумроссия православие чиркәвенең иң абруйлы иконаларыннан берсенә әйләнә. 16 йөз ахырында шәһәрдә 20 дән артык чиркәү исәпләнә. Казан архиерей йортының һәм монастырьларның К. тирәсендә, Идел, Кама буенда бик зур биләмәләре була.

«*Болгавыр заман*» чорында шәһәр В.И.Шуйский хөкүмәтенең терәге була, К. воеводалары баш күтәрүчеләргә каршы җәзалау экспедицияләре оештыра. 1611–12 елларда К.ның гамәлдәге идарәчесе дьяк Н.М.*Шульгин* төбәкне Мәскәүдән аеру һәм мөстәкыйль Казан дәүләте төзү нияте турында чыгыш ясый. 17 йөздә, Болак тамагын шәһәр чикләренә кертү исәбенә, К., башлыча, төньяк-көнбатышка таба киңәя. 1646 елгы халык санын исәпкә алу кенәгәсендә түбәндәге бистәләр теркәлә: Әрмән, Богоявление, Болдырь, Гаврилов, Засыпкин, Мокрый, Татар, Фёдор, Ямчылар бистәләре һәм Пләтән авылы. Шәһәрдә 1652 хуҗалык, 5432 ир-ат исәпләнә. 1654–56 да К.да үләт эпидемиясеннән күп йөзләгән кешеләр үлә. Шушы чорда шәһәрдән китүчеләр *Кизик бистәсен* һәм *Кәҗә бистәсен* төзи. 17 йөздә К.да күп кенә хәрби көчләр туплана. 1661–63 тә шәһәр гарнизонында 287 дворян, 2389 укчы, 43 тупчы, 799 йомышлы татар һәм морза, 337 яңа чукындырылганнар һәм 168 әҗнәби исәпләнә. К. йомышлыларын берничә тапкыр халык кузгалышларын (к. *Җангали хәрәкәте, Крәстияннәр кузгалышы,* 1670–71) бастыру өчен файдаланалар.

1708 дән К. — зур *Казан губернасы* (1781–96 да — наместниклык) үзәге, генерал-губернатор резиденциясе. К.ның беренче губернаторлары — Россиянең атаклы дәүләт эшлеклеләре П.М.*Апраксин* һәм А.П.*Волынский*. 1722 дә Иранга яу чорында шәһәрдә Пётр I була. Ул идарә иткән заманда К. Россия империясенең мөһим адм. һәм сәнәгый үзәгенә әверелә. Монда 1712 дә казна күн з-ды (к. *Помпа каеш-күннәре заводы*), 1714 тә *Казан постау мануфактурасы*, 1718 дә агач әзерләү һәм Азов, Балтыйк, Каспий флотлары өчен корабльләр һәм суднолар төзү б-н шөгыльләнүче *Казан адмиралтействосы* оештырыла. Бу пр-тиеләр янәшәсендә бистәләр калкып чыга (к. *Постаучылар бистәсе*, *Адмиралтейство бистәсе*), аларда төрле һөнәр ияләре, адмиралтейство хезмәткәрләре, солдатлар, матрослар, писарьлар һ.б. яши. Хезмәт шартларының авыр булуы еш кына эшчеләр чуалышларына китерә (к. *Казан постаучылары чуалышлары*). 18 йөздә шәһәр Казансу елгасыннан көнбатыш һәм төньякка таба зурая башлый, хәзерге Киров р-ны терр-ясе үзләштерелә. К. чикләренә көнбатышта *Мокрый бистәсе* һәм *Ямчылар бистәсе*, көнчыгышта Фёдор һәм Подлужный бистәләре керә. 18 йөзнең 1 нче яртысында К.да шәһәр җәмәгатьчелек үзидарәсенә нигез салына, магистрат (1718, к. *Магистрат*), ратуша (1728) төзелә.

1740–50 елларда Казан архиепископы *Лука* (Конашевич) җитәкчелегендә Казан һәм Казан губернасында рус булмаган халыкларны көчләп христианлаштыру, мәҗбүри рәвештә башка җирләргә күчереп утырту, мәчетләрне җимерү эшләре алып барыла. 1749 елгы янгыннан соң Иске Татар бистәсе халкы да шундый күченүгә дучар ителә, аның терр-ясенең бер өлешендә Яңа Чукындырылганнар бистәсе барлыкка килә. Куылган татарлар Поповка авылының сазлыклы җирләрендә *Яңа Татар бистәсен* төзи. Шәһәр тарихының мөһим этабы Екатерина II исеме б-н бәйле. 1767 дә Казанга килгәч, ул болай дип язып калдыра: «Бу шәһәр, һичшиксез, Россиядә Мәскәүдән кала икенче шәһәр ... Казанның бөек дәүләт башкаласы икәнлеге бөтен нәрсәдә чагыла». Мөселман руханилары делегациясен кабул итеп, ул 2 мәчет төзергә рөхсәт бирә («Планлаштыру һәм архитектура» бүлеген кара). Екатерина II үзе Идел

буйлап сәяхәт кылган «*Тверь*» хәрби көймәсен шәһәргә бүләк итеп калдыра. 1781 нең 18 октябрендә ул шәһәрнең гербын раслый: «Алтын Казан таҗын кигән кара елан, канатлары кызыл, кыры ак төстә». Шул ук елны К.да Татар ратушасы (к. *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы*) булдырыла, соңрак, 1785 елгы «Шәһәрләр грамотасы»на нигезләнеп, шәһәр башлыгы җитәкчелегендә 6 гласныйдан торган шәһәр думасы оештырыла.

18 йөзнең 2 нче яртысында К. Россия империясенең иң эре эчке һәм тышкы сәүдә үзәкләренең берсенә әйләнә, Себер, Казакъстан, Урта Азия ханлыклары, Иран, Кытай б-н сәүдә мөнәсәбәтләрендә төп рольне уйный. Шәһәр икътисадының төп тармагы булып икмәк сату тора, ул К. нан югары Идел буе шәһәрләренә, С.-Петербургка җибәрелә. Читкә ш. у. корабльләр ясауга яраклы агач материаллары, бал, балавыз, терлек мае, постау, киндер, комач, *юфть* һ.б. күн әйберләр чыгарыла. *Пётр I һәм Иоанн Алексеевич патшаларның 1685 ел 17 ноябрь Фәрманы* (1698 һәм 1763 тә кабат раслана) нигезендә, төрле ташламалардан файдаланып, Казан бистәләренең йомышлы татарлары сәүдә эшчәнлеген киң җәелдерәләр. Тышкы сәүдәдә Көнчыгыш илләре б-н тыгыз икътисади элемтәдә торучы сәүдәгәрләр Апанаевлар, Әпсәләмовлар, Даутовлар, Мәмәтовлар, Шаһморатовлар, *Юнысовлар* һ.б. мөһим роль уйный. 1797 елгы мәгълүматларга караганда, шәһәрдә 676 рус һәм 595 татар сәүдәгәре була. Төп сәүдә үзәге булып 776 таш һәм агач кибетләре булган Гостиный двор санала. Зур ярминкәләр үткәрелә, даими базарлар эшли (к. *Печән базары*). 1774 нең июлендә К. *Крәстияннәр кузгалышының* (1773–75) үзәгендә кала, һәм аны (Кремльдән башка) Е.И.Пугачёв гаскәрләре яулап ала (к. *Казан өчен сугыш, 1774*). Шәһәр икътисады һәм инфраструктурасына зур зыян килә: янгын 2200 ләп йортны, 28 чиркәү, бөтен кибетләре б-н Гостиный дворны, 10 нан артык заводны юк итә. Бу К.ның күп кенә биналарын таштан төзи башлауга этәргеч бирә. 18 йөз ахырында К. зур Европа-Азия шәһәре буларак билгеле, анда 30 меңләп кеше һәм 150 дән артык пр-тие исәпләнә. 1788 дә казна дары з-ды эшли башлый, аның янында *Дары заводы бистәсе* калкып чыга.

19 йөзнең 1 нче яртысында К. тагын да зурая, халкы да арта (1830 да — 43,9 мең, 1839 да — 51,6 мең, 1859 да — 60,6 мең кеше) һәм мәйданы да киңәя (Адмиралтейство, Кизик, Ягодный бистәләре шәһәр составына керә, халык Арча кырына төпләнә башлый). Тире эшкәртү, сабын-шәм кайнату, киҗе-мамык тукыма тукуда капиталистик җитештерү төре зур үсеш ала, һәм монда татар эшмәкәрләренең роле зур була. Шуның б-н бергә крепостной хезмәткә корылган мануфактуралар (Казан постау мануфактурасы, Адмиралтейство) таркала. Кама (1817) һәм Иделдә (1820) пароходлар йөри башлау К. ның транзит сәүдә үзәге буларак дәрәҗәсен күтәрә. 1850 елларда шәһәрдә буксир һәм пассажирлар суднолары төзү һәм аларга хезмәт күрсәтү б-н шөгыльләнүче берничә сәүдә ширкәте була. Кредит учреждениеләре һәм банкларның ачылуы сәүдә үсешенә этәргеч бирә. 1848 дә шәһәр җәмәгать банкы ачыла, 1853 тән саклау кассалары эшли башлый. Шәһәр халкы сәүдәгәрләр, мещан, һөнәрче, крәстиян, руханилар, хәрби һәм разночинецлардан гыйбарәт була. К.ның Россиянең башка губерна үзәкләреннән аерылып торуы һәм аны Мәскәү, С.-Петербург б-н үзара якынайткан үзенчәлеге — дворяннарның җәмгыятьтә мөһим урын тотуы (1858 елгы мәгълүматларга караганда, 3 меңнән артык дворян яки барлык халыкның 5% ка якыны). Губернаторлар, канцелярия һәм башка губерна дәүләт учреждениеләре башлыклары, шәһәр полициясе, хәрби гарнизон, шәһәр думасының югары дәрәҗәле шәхесләре, өстен хокуклы уку йортлары җитәкчеләре һ.б. дворяннар арасыннан сайлап алына. Дворян аксөякләр К.ның иң төзек, матур өлешендә — Воскресенский (хәзерге Кремль), Грузинский (Карл Маркс), Зур Лядской (Горький) урамнарында зиннәтле йортларда яшиләр. Асраулар тоталар, купшы бәйрәмнәр үткәрәләр.

*Ватан сугышы* (1812) чорында шәһәргә качаклар күп килә, Сенатның Мәскәүдән күчерелгән департаментлары һ.б. учреждениеләр монда урнаша. К.да хәрәкәттәге армия ихтыяҗлары өчен акча җыю оештырыла. *Казан ополчениесе* (5 меңгә якын кеше) Россия терр-ясендәге сугыш хәрәкәтләрендә, рус армиясенең чит илләргә яуларында (аеруча 1813 тә Дрезден шәһәрен алганда батырлык күрсәтә) актив катнаша. 1812–15 тә Кремльдәге корал склады янында туп з-ды эшли, монда ватык коралларны төзәтәләр һәм яңасын коялар, лафетлар, дары әрҗәләре ясыйлар.

1860–70 еллардагы буржуаз реформалар б-н бәйле рәвештә, К. ның административ роле дә үсә. Ул үз губернасы мәйданыннан шактый зуррак булган округларның башында тора. 20 йөз башында Казан хәрби округына — 10 губерна һәм 2 өлкә, су юллары округына — 11, уку округына — 6, почта-телеграфка — 2, мәхкәмә округына 7 губерна керә. Шәһәрдә дәүләт учреждениеләрендә эшләгән 1700 чиновник һәм хезмәткәр, хәрби идарәдәге 700 дән артык генерал, өлкән штаб офицерлары һәм чиновниклар, Казан уку-укыту округының 800 дән артык укытучысы һәм педагогы яши. Реформалардан соңгы чорда шәһәр идарәсе органнарының яңа структурасы формалаша. 1864 тә губерна, өяз земство җыены һәм управасы барлыкка килә. 1870 тә яңа мәхкәмә учреждениеләре: мәхкәмә палатасы, округ мәхкәмәсе, җәмәгать мәхкәмәсе бүлеге ачыла. «Шәһәр кануннары» на нигезләнеп, 1870 тә Казан шәһәр думасына сайлаулар була, думага 72 гласный, ш.и. 8 татар (1908 дә 56 гласныйның 15 е татар) керә. Шәһәрнең эчке эшләрен милек цензы нигезендә сайланылган Казан шәһәр управасы алып бара.

1870–90 да К.да эшкәртү сәнәгатенең төп тармакларында завод-фабрика җитештерүенә куәч төгәлләнә. 1879 да шәһәрдә — 69, 1884 тә — 91, 1890 да — 84, 1903 тә 81 шундый пр-тие исәпләнә. Тора-бара шәһәрнең сәнәгый йөзен билгеләүче берничә эре завод һәм фабрика барлыкка килә: *Алафузовларның завод-фабрикалар һәм җитештерү-сәүдә ширкәте*, бертуган Крестовниковларның *шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы*, *Казан дары заводы*, сәүдәгәр А.Н.Свешниковның механика з-ды (к. «*Урак һәм Чүкеч*»). Сәнәгать җитештерүенең берничә төп тармагы булдырыла: текстиль, химия, азык-төлек, терлекчелек продуктларын һәм минераль чимал эшкәртү, полиграфия. Завод-фабрикаларда эшчеләр саны 1879 да 4081 кеше булса, 1903 тә 8436 кеше исәпләнә. Моннан тыш меңнәрчә эшчеләр һөнәрчелек һәм вак товар җитештерү б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында сәнәгатьтә эшләүче К. халкының 77,8% — руслар, 22%ы татарлар була. Шәһәрнең сәнәгый үсешендә төп рольне рус буржуазиясе (эшмәкәрләр И.И.Алафузов, Крестовниковлар, А.Н.Свешников һ.б.) уйный. Шул ук вакытта татар милли буржуазиясе дә (*Арслановлар*, Борнаевлар, Галиевлар, *Сәйдәшевләр*, Субаевлар, *Үтәмишевләр*, Юнысовлар һ.б.) формалаша һәм ныгый. Татар капиталы Урал буена, Казакъстан, Урта Азия, Себергә үтеп керә һәм анда рус капиталы б-н уңышлы көндәшлек итә. 1866 да К.да сәүдәгәрләр җыены ачыла. 1868 дә Казан сәүдә биржасы оештырыла. Реформалардан соңгы чорда сәүдә әйләнеше даими үсә: 1861 дә аның 5,3 күләме млн. сум булса, 1893 тә 60 млн. сумга җитә. 1897 дә К. пристанена 23,5 млн. пот йөк килә, ә аннан 10,5 млн. поттан артык төрле йөк озатыла (1908 дә 48 млн. пот йөк килә, һәм 14 млн. пот йөк озатыла). Монда Идел, Кама, Агыйдел һәм Вятка елгаларында эш йөртүче барлык пароходчылык җәмгыятьләренең дебаркадерлары була (к. «*Кавказ вә Меркурий*», «*Самолёт*»). 1910 да Казан пристанендә йөкләр ташу күләменең күрсәткече 160 млн. сумга җитә. Сәүдә үсешендә 1893 тә ачылган Мәскәү–Казан тимер юлы зур әһәмияткә ия. 1907 дә К. тимер юл станциясе аша — 10 млн. сумнан артык, грунт юллардан 52 млн. сумнан артык күләмдә товар уза. Шәһәр Россиянең Европа өлешенең Себер, Урта Азия һәм илнең башка төбәкләре б-н сәүдә-икътисад мөнәсәбәтләрендә төп транзит пункты була. К.нан товарлар Түбән Новгород, Ирбет, Сембер ярминкәләренә, ш. у. Мәскәү һәм С.-Петербург шәһәрләренә җибәрелә; шәһәр Кытай, Иран, Хива, Бохара б-н сәүдә итә. К.га агач материаллары, икмәк, нефть, йон, күн эшкәртү сәнәгате өчен чимал килә. К. з-длары ел саен 1 млн. поттан артык шәм җитештерә, ул, башлыча, Россиядә һәм аннан читтә сатыла. К.ның сәүдә үзәгенә әверелүе ислам динен тотучы төрки халыклар өчен әһәмиятле була. Моннан төрле җирләргә татар, гарәп, казакъ һ. б. телләрдәге дини һәм дөньяви эчтәлекле китаплар, кирәк-яраклар: баш һәм аяк киемнәре, сабын, Азия бизәнү әйберләре һ.б. тарала. 20 йөз башында К.да шәһәр җәмәгать һәм сәүдәгәрләр банклары; Дәүләт, Идел-Кама, Петербург халыкара, Рус-Азия, Дон банклары һәм Үзара кредит җәмгыяте бүлекчәләре; берничә банкирның шәхси конторасы эшли.

Бу учреждениеләр губерна үзәгендә сәүдә һәм сәнәгатьнең актив үсүенә булышлык итә. 1900 дә монда 60 млн. сумлык акча әйләнешле 8 меңгә якын сәүдә учреждениесе була. 1897 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, К.ның 130 мең кешелек халкының 86,6 мең халкы (66,6%) сәүдә-сәнәгать өлкәсендә — фабрика, завод, сәүдә фирмалары һәм йортларында эшли.

19 йөздә шәһәр йөзе шактый үзгәрә. 1850 елларга К. тулысынча даими төгәл планлы һәм функциональ структуралы бердәм шәһәр комплексы булып формалаша. К.ның дворяннар, сәүдәгәрләр р-ннары, татар бистәләре, шәһәр читендәге эшчеләр р-ннары шәһәрнең архит-ра үзенчәлекләрен формалаштыра («Планлаштыру һәм архитектура» бүлегеn кара), 1890 елларда шәһәрдә 237 урам һәм тыкрык, 5 меңгә якын торак йорт исәпләнә. 1829 дан К. урамнарын һәм мәйданнарын таш б-н түшәүгә керешәләр. 1840 та урамнар даими яктыртыла башлый, 1860 еллар башында фонарьлардагы киндер мае керосин б-н алмаштырыла. 1872 дә — газ, 1896 да электр б-н яктырту кертелә (к. «*Газ һәм электр*»). 1842–49 да шәһәрне Адмиралтейство бистәсе б-н тоташтыручы дамба төзелә. 1874 тә суүткәргеч кертелә. 1875 тән шәһәрдә атлы тимер юл эшли («конка»), 1899 да беренче электр трамвае йөри башлый (к. «*Казанда Бельгиянең атлы тимер юллар аноним җәмгыяте*»). 1910 еллар уртасында шәһәрдә трамвай 5 юнәлештә — Идел-Проломный (Проломный — хәзерге Бауман урамы), Воскресенский, Грузинский, Екатерининский (Тукай), Божра юнәлешләрендә йөри. Шул ук вакытта извозчиклык та зур роль уйный. 1910 да К.да җәен — 597, кышын эшләүче 1302 извозчик теркәлә. Бәйрәм көннәрендә извозчикларга көндәшләр — шәһәр тормышын үзенчәлекле күренеш б-н баетучы «*барабыз*»лар чыга. К.да су транспорты да була, 1868 дән Кабан күлендә пароходлар даими йөри башлый, алар җәй көне шәһәр халкын «дача»ларга һ.б. ял итү урыннарына ташый. 1904 тә шәһәрдә 9 җәмәгать бакчасы һәм бульвар исәпләнә. Казанлыларның иң яраткан ял итү урыннары — Державин, Лядской, Панаев, «*Рус Швейцариясе*», «*Немец Швейцариясе*», Черек Күл, Эрмитаж бакчалары һ.б. киң таныла. Элемтә чараларында сизелерлек үсеш күзәтелә. 1859 ның декабрендә 1 нче телеграф станциясе файдалануга тапшырыла, 1868 дә Казан–Мәскәү линиясе эшли башлый. 1866 да шәһәр почтасына нигез салына. 1881 дә 1 нче телефон линиясе сафка баса, ул Кремльдәге Казан юнкерлар пехота уч-щесен Воскресенский урамындагы (хәзерге Кремль урамы, 6) офицерлар җыены бинасы б-н тоташтыра. 1888 дә шәһәр телефон станциясе ачыла, ул 70 ләп абонентка (1897 дә 337 гә җитә, 1908 дә 1 меңнән арта) хезмәт күрсәтә. 1911 дә шәһәр урамнарында таксофоннар куела башлый. Ләкин 20 йөз башына кадәр К.ның, башлыча, таза тормышлы халык яшәгән үзәк өлеше генә төзекләндерелә. 1913 тә шәһәр читендәге урамнарның күпчелеге таш б-н түшәлмәгән була, яктыртылмый, суүткәргеч халык ихтыяҗларының 15% ын гына канәгатьләндерә, канализация булмый.

19–20 йөзләрдә К.ның эре дини үзәк буларак әһәмияте саклана. Архит-ра үзенчәлекләренә ия төрле дини корылмалары шәһәргә үзгә төс бирә. 1913 тә К.да 67 православие, 16 мөселман һ.б. диннәр гыйбадәтханәләре (барлыгы 91), 30 дан артык кәшәнә була.

1860 елларда К. Россиянең иҗтимагый-сәяси хәрәкәт үзәкләренең берсенә әверелә. 1861 нең 16 апрелендә монда Рус Бизнәсе авылы крәстияннәре кузгалышы корбаннарын искә алу мәрасиме (к. *Куртина чиркәвендәге панихида*) уздырыла, анда К. ун-ты профессоры А. П.*Щапов* хөкүмәткә каршы нотык сөйли. 1863 тә крәстияннәрнең баш күтәрүләрен оештыру омтылышы (к. «*Казан фетнәсе*») була. 1860 елларда шәһәрдә «Земля и воля» яшерен оешмасы бүлекчәсе эшли. 1870–80 елларда народниклар түгәрәкләре (к. *Народниклык*, *Овчинников түгәрәге*) барлыкка килә. К. Россиядә марксизм идеяләрен таратуда (к. *Федосеев түгәрәкләре*) мөһим роль уйный. 1890 елларда монда марксизм тәгълиматын таратучы түгәрәкләр була; аларны К.К.*Газенбуш* (ш. у. к. *Газенбуш төркеме*), А.М.*Стопани*, Н.Э.*Бауман*, Н.А.*Семашко*, Е.Табейкин оештыра. В.И.*Ленин*, С.М.*Киров*, В.М.*Молотовның* сәяси эшчәнлеге К. б-н бәйле. 1903 тә шәһәрдә РСДРП ком-ты оештырыла, аның башында — В.В.*Адоратский*, Я.М.Свердлов, әгъзалары булып И.А.Саммер, Х.М.Ямашев, В.А.Тихомирнов һ.б. тора.

К.да 1905 нең 16–17 октябрендә эшчеләр һәм студентлар отрядлары полиция һәм казаклар б-н урам сугышлары алып бара. 19–20 октябрьдә шәһәр эшчеләр кулына (к. *Казан шәһәр коммунасы*) күчә. 1905–07 еллар рев-циясе милли мәдәният һәм татар халкының үзаңы үсешенә, милләтләрнең тигез хокуклылыгы һәм иреккә хокукы өчен көрәшкә көчле этәргеч бирә. Беренче гомуммөселман «*Иттифакъ әл-мөслимин*» сәяси партиясе программасының нигезендә шушы таләпләр ята. 1906 да К.да беренче татар китапханәсе ачыла, халык алдында татарча беренче спектакль куела, татар газеталары һәм журналлары нәшер ителә башлый. Беренче бөтендөнья сугышы чорында шәһәр пр-тиеләренең күбесе хәрби заказлар үти. Хәрби киемнәр тегүче Алафузовлар, А.Д.Шабанов ф-каларында, «Кавказ вә Меркурий» җәмгыятенең суднолар төзү һәм А.М.Провоторовның механика з-дында җитештерү шактый арта. Шул ук вакытта халык товарларын эшләп чыгаручы кайбер пр-тиеләр җитештерүне киметә, хәтта арада ябылучылар да була. Хатын-кызлар һәм балалар хезмәтен файдалану зур үсеш ала.

1917 елгы Февр. рев-циясенең беренче көннәрендә үк (2 март) К.да Эшче һәм солдат депутатларының шәһәр советы оештырыла. Губерна хакимияте бетерелә, аның вәкаләтләре Вакытлы хөкүмәтнең К. губерна комиссарына һәм Казан шәһәр думасына тапшырыла. 1917 нең март–апрелендә оешкан төстә «*Мөселманнар комитеты*», *Бөтенроссия мөселманнары* Хәрби *Шурасы* (Хәрби Шура) һәм *Бөтенроссия мөселманнары Милли Шурасының* (Милли Шура) Казан бүлекчәләре рәсмиләштерелә; РСДРП (б) ның Казан ком-ты яңадан торгызыла, ул «Рабочий» г-тасын чыгара башлый. 1917 нең июнендә К.да Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае, Бөтенроссия мөселманнары руханилары корылтае (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*) уздырыла, аларның берләштерелгән утырышында Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының *Милли-мәдәни мохтарияты* игълан ителә һәм *Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе* оештырыла. 1917 нең 24–26 октябрендә, кораллы баш күтәрелеш барышында, шәһәрдә хакимият Эшче һәм солдат депутатларының Казан советы кулына күчә, һәм ул 1918 нең февралендә *Казан совет эшче-крәстиян республикасын* төзү инициативасы б-н чыга.

Казан советы һәм хәрби подразделениеләр көче б-н 1918 нең мартында шәһәрдә җитәкчеләре татар-башкорт дәүләтен — *Идел-Урал штатын* төзүне яклап чыгыш ясаган «*Болак арты республикасы*» таркатыла. 1918 нең язынннан К. Гражданнар сугышы аренасына әверелә, июньнән анда *Көнчыгыш фронтның* штабы һәм РВС (Реввоенсовет) урнаша. 1918 нең 6 августында шәһәрне Чех-словак корпусы һәм *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты* (КОМУЧ) частьләре басып ала. 1918 елның 5–10 сентябрендә *Бишенче армия, Икенче армия* гаскәрләренең Арча төркеме һәм *Идел буе хәрби флотилиясе* көчләре б-н *Казанны азат итү операциясе* нәтиҗәсендә, К.да Совет хакимияте урнаша. Чигенгәндә, ак чехлар Дәүләт банкы подвалларында сакланган *РСФСРның алтын хәзинәсен* шәһәрдән алып китәләр. 1919 ның апрелендә адмирал А.В.Колчак армиясенең һөҗүме вакытында К.га яңадан басып алыну куркынычы яный, шул сәбәпле, шәһәрне һәм Кама Тамагыннан Зөягә кадәрге яр буйларын саклау өчен, Казан ныгытылган р-ны оештырыла. Бу чорда К.ның, Кызыл Армия (күбесенчә милли хәрби частьләр) өчен запас гаскәр әзерләүче эре үзәк буларак, әһәмияте тагын да арта. Бирегә Мәскәүдән *Үзәк мөселман хәрби коллегиясе* күчерелә. 1919 ның сентябреннән шәһәрдә *Республиканың запас армиясе* урнаша, ул 1920 еллар ахырына кадәр 450 меңнән артык кешелек өстәмә гаскәр әзерли, фронтка 2 укчы һәм 2 кавалерия дивизиясен, 26 укчы һәм 4 кавалерия бригадасын, 300 дән артык башка подразделениеләрне озата.

1920 нең 27 маенда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында Декретка кул куела, һәм К. аның башкаласына әверелә. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары чорында шәһәр зур югалтуларга дучар була. Сәнәгать һәм шәһәр хуҗалыгы таркала, бик күп биналар җимерелә, суүткәргечләр эштән чыга, трамвайлар йөрми. Эшләүче пр-тиеләр, башлыча, хәрби продукция (артиллерия снарядлары, дары, хәрбиләр өчен өс-баш һәм аяк киемнәре һ.б.) җитештерә. 1921 дәге сәнәгать җитештерүе 1914 елдагының 29% н гына тәшкил итә. 1917–20 дә К. халкы төрле сәбәпләр ар-

касында (сугышта югалтулар, эпидемия, миграция һәм эмиграция) 206,6 меңнән 146,5 мең кешегә кала. *Ачлык* (*1921–22 еллар*) шәһәр халкының хәлен чиктән тыш авырайта. Игълан ителгән *Яңа икътисади сәясәт* (НЭП) кысаларында хуҗалык җимереклекләрен торгызуда трестлар — хуҗалык исәбендә эшләүче эре пр-тиеләр берләшмәләрен төзү зур роль уйный. 1922 нең башында К.да 10 трест (Урман, Азык-төлек, Татарстан күн, Электр һ.б. трестлар) була. Аларның продукциясен сату өчен, төп үзәкләр — синдикатлар (Таттор һ.б.) оештырыла, җитештерелгән товарлар ТАССР терр-ясендәге кибетләр челтәре аша, ш. у. Түбән Новгород ярминкәсендә, Мәскәү һ.б. шәһәрләрдә сатыла. Шәһәрнең урта һәм вак пр-тиеләренең шактый өлеше дәүләт оешмаларына һәм кооперативларга, 10 % ка якыны аерым шәхесләргә арендага бирелә. Моннан тыш К.да 800 дән артык сәүдә һәм вак һөнәрчелек пр-тиесе эшли, аларның 80% ы аерым шәхесләр кулында була. Кызу темплар б-н пр-тиеләрне торгызу һәм реконструкцияләү, яңа сәнәгать объектлары төзү (ТАССРның 3 еллыгы исем. электр станциясе һ.б.) 1927 нең октябренә К. сәнәгатен сугышка кадәрге дәрәҗәгә җиткерергә мөмкинлек бирә. 1920 елларның 1 нче яртысында Адмиралтейство, Архангельский, Жировка, Ивановский, Калугина Гора, Аскы Әмәт, Дары заводы, Савиново, Удельный бистәләре һәм берничә посёлок шәһәр эченә керә. Шәһәрнең күп кенә мәйданнары һәм урамнары исемнәрен үзгәртә. Аларның исемнәрендә илдәге 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соңгы үзгәрешләр чагылыш таба (Ирек, Революция, Вахитов мәйданнары; Бауман, Дзержинский, Карл Маркс, Межлаук, Комлев, Ленин урамнары һ.б.). 1922 дә трамвай хәрәкәте яңадан торгызыла, Дары Заводы һәм Ягодный бистәләре электрлаштырыла. 1924 тә Казан–Түбән Новгород–Мәскәү һава юлы, 1926 да даими автобус хәрәкәте ачыла. 1920 елларда шәһәрдә милли бәйрәм — Сабан туе (1923 тән Кабан күле буендагы «Аркадия» бакчасында) үткәрелә башлый. Су басулар (иң көчлесе 1926 да була) шәһәр хуҗалыгына зур зыян сала. Идел һәм Казансу елгаларында язгы ташулар нәтиҗәсендә суның биеклеге 14,8 *м* га җитә, К. түбәнлекләре һәм шәһәр читендәге 157 урамның кайберләре — тулысынча, кайсыларының бер өлеше су астында кала; 700 йорт, транспорт дамбалары, күперләр, кайбер сәнәгать пр-тиеләре җимерелә; трамвай линиясенең яртысы диярлек сафтан чыга.

1920 еллар ахыры – 1930 еллар — сәнәгатьнең бик нык үскән чоры (к. *Индустрияләштерү*), бу К.ның сәнәгый йөзе үзгәрүгә китерә. Казансу артында, шәһәрнең үзәк өлешеннән төньякка таба илнең төзелеп килүче иң зур киноплёнка ф-касы (к. *Тасма*), механика з-ды һ.б. тирәсендә яңа сәнәгать районнары калкып чыга. Элеккеге Иске Татар һәм Яңа Татар бистәләре терр-ясендә киез-киез итек басу ф-касы (хәзер «*Валком*»), мех комб-ты (к. «*Мелита*») биналары төзелә, Крестовниковлар з-ды яңартып корыла. 1933 тә ТЭЦ-1 сафка баса, 1936 да *Казан ясалма каучук заводы* беренче продукциясен чыгара, 1938 дә ТЭЦ-2 һәм «Искож» з-длары файдалануга тапшырыла, 1941 дә фотожелатин (к. «*Полимерфото*») з-ды эшли башлый.

Сугыш алды бишьеллыгы чорында К.ны төзекләндерү буенча зур эшләр башкарыла, 20 дән артык мәктәп, 10 югары һәм урта уку йорты өчен биналар салына, торак йортлар төзү киң җәелә, коммуналь хезмәт күрсәтүнең бөтен төрләре үсә, транспорт арта. Күп кенә урамнар, тротуарлар, мәйданнар, юллар, яр буйлары асфальт б-н түшәлә. Мәдәният-көнкүреш һәм мед. учреждениеләре челтәре киңәя. Шәһәрнең гомуми мәйданы тирә-юньдәге посёлоклар кушылу исәбенә зурая (1933 тә 119,6 *км*² булса, 1937 дә 201,2 *км*² га җитә). К.да халык саны да шактый арта (1931 дә — 269 мең, 1939 да — 398 мең кеше). 1930 еллар ахырында «Зур Казан» ген. планы төзелә, шәһәр төньяк һәм көньяк юнәлештә үсә башлый.

К. тарихында Бөек Ватан сугышы чоры аеруча мөһим этап булып тора. Шәһәрдә СССРның көнбатыш р-нналарыннан эвакуацияләнгән дистәләрчә сәнәгать пр-тиеләре (С.П.Горбунов исем. Мәскәү авиация з-ды, 16 нчы Воронеж моторлар төзү з-ды, 230 нчы Мәскәү з-ды һ.б.) урнаша.

Соңыннан алар җирлегендә күп кенә яңа пр-тиеләр оеша: *Казан төгәл машиналар төзү заводы*, *Казан медицина инструментлары заводы*, «*Электроприбор*» һ.б. К. сәнәгате хәрби продукция чыгаруга көйләнә. Эвакуацияләнгән КБларда атаклы галимнәр һәм конструкторлар: В.П.Глушко, С.П.Королёв, И.В.Курчатов, В.М.Петляков, А.Н.Туполев, С.А.Чаплыгин һ.б. эшли. К. фронтны пике ясаучы Пе-2, җиңел У-2 (1944 тән По-2) бомбардировщиклары, авиация моторлары, авиация фотоплёнкалары, фотокәгазь, оптик приборлар, хирургиядә кулланылучы тегү материалы (кетгут), снарядлар, миналар, гранаталар, парашютлар, армия өчен өс һәм аяк киемнәре, җылы эчке киемнәр, маскировка халатлары, колакчын мех бүрекләр, бияләйләр, унтлар, комбинезоннар, шлемофоннар — барлыгы 600 дән артык исемдәге әйберләр б-н тәэмин итә. Шәһәрдә 45 госпиталь оештырыла, аларда йөзләрчә мең яралы һәм авыру сугышчы дәвалана; 11 донорлык пункты эшли. К. дистәләрчә мең эвакуацияләнгән кешене кабул итә: 1941–42 дә халык саны 401 меңнән 515 мең кешегә җитә. Эвакуацияләнгән оешмалар арасында Дәүләт банкы, Хәрби һава флоты баш идарәсе, РВ-84 Үзәк радиостанциясе була. К.да СССР ФАнең Президиумы һәм 33 ин-ты (к. *СССР Фәннәр академиясе оешмаларының Казан төркеме*) урнаша, 93 академик һәм мөхбир әгъза (ш. и. А.И.Абрикосов, С.И.Вавилов, Е.С.Варга, Б.Д.Греков, А.Ф.Иоффе, Е.А.Косминский, Г.М.Кржижановский, С.С.Намёткин, А.Е.Порай-Кошиц, Е.В.Тарле, Е.Н.Чудаков, О.Ю.Шмидт һ.б.), 1650 дән артык фәнни хезмәткәр эшли. Аларның тырышлыгы б-н корабльләрне магнитлы миналардан саклау (А.П.Александров, И.В.Курчатов), Т-34 танклары өчен броня составы (Н.Т.Гудцов, А.М.Бочвар) технологияләре эшләнә, туплардан атканда снарядларның куе булып төшүен һәм очканда тотрыклылыгын саклау мәсьәләләре хәл ителә, илне саклауда әһәмиятле йөзләгән башка фәнни эшләр башкарыла. Сугыш елларында К.нан Кызыл Армиягә 135 меңгә якын кеше хәрби хезмәткә алына. Монда 86 нчы, 18 нче, 334 нче, 146 нчы һәм 120 нче укчы дивизияләр, 91 нче махсус танк бригадасы, махсус инженер-сапёрлар батальоны, 2 авиация дивизиясе, дистәләгән авиация полкы төзелә. К.да туып-үскән һәм



Казандагы Җиңү паркы.

яшәгән 56 кеше Сов. Союзы Герое исеменә лаек була (алар арасында — очучы М.П.Девятаев, Минскидагы яшерен оешма герое И.К.Кабушкин, генерал-полковник М.П.Кирпонос, шагыйрь М.Җәлил; очучы Н.Г.Столяровка бу исем ике тапкыр бирелә), 10 меңнән артык кеше орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Сугыштан соңгы ун елда шәһәр аеруча тиз үсә. Меңнәрчә яңа йортлар, сәнәгать һәм мәдәният объектлары, яңа районнар, транспорт магистральләре төзелә. Мед. хезмәте сыйфаты, хезмәт күрсәтү тармагы, сәүдә үсә. Сууткәргеч, канализация челтәрләре, электр б-н тәэмин итү, элемтә яхшыра. 1948 дә троллейбус юллары ачыла. 1950–51 дә — Болак яр буйлары һәм янәшәдәге урамнар, 1956 да



Казансу елгасы буендагы судан саклагыч дамба.

Кремль һәм Адмиралтейство транспорт дамбалары үзгәртеп корыла, яңа тимер-бетон күперләр (алар шәһәрнең Ленин һәм Киров р-ннары б-н тоташтыра) төзелә. Куйбышев сусаклагычы су б-н тутырылгач, Идел суы шәһәр янына ук килеп җитә. К. «биш диңгез порты»на әйләнә. 1957 дә — елга вокзалы, 1954 тә аэровокзал файдалануга тапшырыла.

К.ның сәнәгать потенциалы кызу темплар б-н үсә. Яңа пр-тиеләр: электр-механика (1949) һәм металл табак прокатлау (1950) з-длары сафка баса. 1951 дә — компрессорлар (к. *Казан компрессор машиналары төзү заводы*), 1952 дә «Теплоконтроль» з-длары беренче продукцияләрен бирә. Казан комбайннар (1951 дән вертолётлар һәм аларга моторлар җитештерү з-ды), Казан механика (1959 дан вакуум техникасы чыгара башлый) з-длары профильләрен үзгәртә, продукциянең яңа төрләрен үзләштерә. Чыгарыла торган продукциянең күп кенә төрләре буенча (җылылык үлчәү приборлары, манометрлар, мех әйберләр, канат юллар, мед. җиһазлары, кетгут һ.б.) К. СССРда алдынгы урыннарны били. 1950 еллар ахырында шәһәр сәнәгать пр-тиеләре продукциясе дөньядагы 40 илгә җибәрелә. Бу чорда төзелеш индустриясенең материаль-техник базасы шактый ныгый. 2 нче һәм 3 нче тимер-бетон әйберләр кою, 70 нче эре панельле йортлар төзү з-дларын файдалануга тапшырылу б-н, К.дагы төзелешләрдә җыелма тимер-бетон конструкцияләр киң кулланылышка керә. Химия сәнәгате пр-тиеләре зур үсеш ала. 1963 тә илдә иң зур органик синтез (к. «*Органик синтез*») з-ды сафка баса. 1960 еллар уртасында К. автоматлаштырылган идарә итү системаларын эшләү һәм производствога кертү буенча төп үзәкләрнең берсенә әйләнә. Машиналар төзелеше, металл эшкәртү, химия, нефть химиясе һәм җиңел сәнәгать зур темплар б-н үсә. 1970 еллар ахырына К.да 150 эре сәнәгать пр-тиесе туплана. Монда берничә мең исемдәге машиналар һәм механизмнар (авиалайнерлар, вертолётлар, электрон-хисаплау машиналары, аеруча төгәл станоклар, язу җайланмалары, автоматлаштыру приборлары һәм чаралары, вакуум насослары һәм агрегатлары, компрессорлар, суыткыч җайланмалар, җылылык үлчәү приборлары, полиэтилен, фенол, ацетон, кинофото тасмалары, хирургия инструментлары һ.б.) җитештерелә.

Сәнәгать, транспорт, төзелеш үсеше халык санының, беренче чиратта, эшче халыкның артуына китерә. 1960 та К.да 692,7 мең кеше яши, сәнәгать пр-тиеләрендә 150 меңгә якын кеше эшли. Халык, башлыча, республика эчендәге авыл (күбесенчә татар) районнарыннан күчеп килүчеләр исәбенә арта. 1957 дән шәһәрдә микрорайоннар — 6 меңнән 12 меңгә кадәрле кешесе булган эре торак массивлар төзелә башлый. 1960–70 елларда корылган микрорайоннар шәһәрнең йөзен шактый үзгәртә. Ленин, Мәскәү, Киров, Идел буе р-ннарында гаять зур торак комплекслары төзелә. 1980 гә К.ның торак фонды 1913 ел б-н чагыштырганда 8 тапкырга арта, мәйданы 29 *км*² дан 300 *км*² га җитә. Торак йортлар төзү б-н беррәттән, планлы рәвештә мәктәпләр, хастаханәләр, мәдәният объектларын, спорт корылмаларын төзү бара. 1955 тә Киров р-ны торак кварталларыннан шәһәргә газ кертелә башлый. Трамвай һәм троллейбус маршрутлары озыная, шәһәр пассажир транспорты паркы камилләшә. Транспорт б-н йөк ташуны яхшыртуда 3 нче транспорт дамбасы һәм Казансу аша күпер (1976) салу һәм файдалануга тапшыру нәтиҗәсендә, Мәскәү һәм Совет сәнәгать р-ннарын бәйләүче иң кыска юл барлыкка килә. 1979 да «Казан-2» халыкара аэропортының беренче бинасы ачылу мөһим вакыйгага әверелә. Шәһәр яңы зонасы да үзгәрә, халыкка ял итү өчен уңай йортлар салына. 1970 еллар ахырында 200 ләп пр-тие һәм оешманың Юдино, Васильево, Боровое Матюшино һ.б. посёлоклар тирәсендәге урман массивлары янында һәм Идел, Казансу яр буйларында ял базалары була.

1979 ның октябрендә К.да халык саны 1 млн. кешедән артып китә. 1980 дә шәһәрдә 13 югары уку йорты, 139 мәктәп, 54 мәдәният сарае һ.б. клуб учреждениеләре, 136 китапханә, 104 стационар кино җайланмасы исәпләнә. 50 дән артык фәнни-тикшеренү институты һәм КБ тикшеренүләр алып бара. 1984 нең 14 маенда шәһәр Ленин ордены б-н бүләкләнә. 1990 ның 30 августыннан К. — Татарстан Совет Социалистик Республикасы, 1992 нең 7 февраленнән Татарстан Республикасы башкаласы.

1999 ның 1 сентябрендә РФ һәм ТР президентлары «Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында»гы Фәрманга кул куя. Бәйрәмгә әзерләнү барышында, К.ның тарихи үзәк өлеше капиталь рәвештә реконструкцияләнә, дистәләгән зур җәмәгать биналары, шәһәр инфраструктурасы объектлары реставрацияләнә, ш.у. метроның беренче чираты төзелә. Шәһәр үзәгенең йөзе тамырдан үзгәрә, халыкка транспорт һәм социаль хезмәт күрсәтү яхшыра. 2000 нең ноябрендә Казан кремле ЮНЕСКО бөтендөнья мирас ядкәрләре исемлегенә кертелә. 2005 тә юбилейны бәйрәм итү халыкара масштаблы вакыйгага әверелә, киң халыкара яңгыраш ала. Юбилей тантаналары кысаларында К.да БДБ илләре дәүләт башлыклары советы саммиты (26–27 август) уздырыла. РФнең 81 субъекты башлыклары, федераль министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре катнашында, РФ Дәүләт Советы утырышы уза. Шәһәр РФнең төрле төбәкләреннән, якын һәм ерак чит илләрдән 20 меңнән артык рәсми кешене һәм кунакны кабул итә. Казанлылар һәм башкала кунаклары өчен дистәләгән массакүләм мәдәният, спорт һ.б. бәйрәм чаралары оештырыла. Тантана барышын 1100 дән артык федераль басманың журналистлары, телевидение, радио каналлары һәм агентлыклары, ш.у. АКШ, Бөекбритания, ГФР, Франция, Чехия, Дания, Польша, Төркия, Япония һәм дөньяның башка илләрендәге массакүләм мәгълүмат чаралары яктырта (ш.у. к. *Казанның меңьеллыгы*).

Күп кенә күренекле язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, галимнәрнең тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге К. б-н бәйле. Алар арасында А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар, Ф.Әмирхан, В.М.Бехтерев, А.М.Бутлеров, А.В.Вишневский, Е.К.Завойский, Н.Н.Зинин, Г.Исхакый, Г.Х.Камай, Н.И.Лобачевский, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Тукай, С.Х. һәм И.И.Хәлфиннәр һ.б. бар. Казан ун-тында С.Т.Аксаков, П.И.Мельников (А.Печерский), Л.Н.Толстой, В.И.Ульянов (Ленин), В.Хлебников, А.И.Рыков, М.Җәлил һ.б. укый. 1833 тә К.га, «Пугачёв фетнәсе» турында мәгълүмат туплау өчен, А.С.Пушкин килә. Шәһәрдә А.Олеарий, А.Н.Радищев, Т.Г.Шевченко, А.И.Герцен, А.Гастгаузен, А.Гумбольдт, А.Дюма-ата һ.б. була. К.да шагыйрьләр Г.Р.Державин, Н.А.Заболоцкий, атаклы җырчы Ф.И.Шаляпин һ.б. туган.

**IV. Икътисади очерк**

**Сәнәгать.** К. — иң мөһим индустриаль үзәкләрнең берсе. 2009 елда монда 5 меңгә якын эре, урта һәм вак сәнәгать пр-тиесе туплана, аларда 105,9 мең кеше эшли. Аннан җибәрелгән сәнәгать продукциясенең, башкарылган эш һәм хезмәт күрсәтүләрнең күләме 139,6 млрд. сумлык (респ-ка күрсәткеченнән 16% ка күбрәк), сәнәгать җитештерүенең алдагы елга карата индексы — 100,9%. Сәнәгатькә шәһәр икътисадының төп өлеше туры килә. Анда эшче халыкның 20% тан артыгы мәшгуль, шәһәрдә тулай терр. продукциянең 45% тан артыгы җитештерелә. Сәнәгать продукциясе структурасында 30% тан артыгы машина төзелеше һәм металл эшкәртү өлкәсенә туры килә. К.да авиатөзелеш — *Казан авиация җитештерү берләшмәсе, Казан моторлар төзү берләшмәсе, Казан вертолёт заводы;* приборлар төзү — «*Элекон заводы*», *Казан оптика-механика заводы, Казан төгәл машиналар төзү заводы*, «*Радиоприбор*», «*Электроприбор*», *Казан медицина инструментлары заводы, Казан газ аппаратлары заводы*, «*Сантехприбор*», «*Теплоконтроль*» эре пр-тиеләре урнашкан. Авыр сәнәгать җиһазлары җитештерүдә «*Казанкомпрессормаш*», «*Вакуummаш*», «*Урак һәм чүкеч*» з-длары специальләшә. Сәнәгать продукциясенең 30% тан артыгын химия һәм нефть химиясе сәнәгате җитештерә. К.да бу өлкәдәге зур пр-тиеләр — «*Казаньоргсинтез*», «*Нәфис Косметикс*», *Казан ясалма каучук заводы*, «*Кварт*», «*Татхимфармпрепаратлар*», *Казан дары заводы*, «*Тасма*», «*Хитон*», «*Аромат*». Азык-төлек сәнәгате 7 икмәк з-дын һәм комб-тын, сөт, ит һәм май комб-тларын, үсемлек мае з-дын, «Кызыл Шәрекъ-Солодовпиво» ҖБн, *Казан ликёр-аракы заводын,* «Эдельвейс-М» ҖЧҖен һ.б.ны үз эченә ала, бу — сәнәгать продукциясенең 12% тан күбрәк өлеше. Җиңел сәнәгатьнең нигезен пр-тиеләр: «*Мелита*» мех, «*Спартак*» аяк киеме, «*Сафьян*» күн, Казан ясалма күн заводы тәшкил итә. Шәһәрнең электр һәм җылылык энергиясенә ихтыяҗын гомуми көче 830 *МВт* һәм 3378 *Гкал/сәг.* булган 1, 2, 3 номерлы *Казан җылылык-электр үзәкләре* канәгатьләндерә. Төзелеш материаллары сәнәгате керамзит, кирпеч, җыелма тимер-бетон конструкцияләр эшләүче, вакташ, чуерташ һ.б.ны чыгаручы пр-тиеләрдә чагыла. Казанда җитештерелгән продукция арасында Ми-8, Ми-17, Ми-38, «Ансат» күпмаксатлы вертолётлары, урта магистральдә очучы Ту-214 пассажир самолётлары, газ турбиналары двигательләре һәм газ суыртып кудыру җиһазлары, югары басым компрессорлары һәм суыту турбиналары техникасы, вакуум насослары, полиэтилен торбалар, ясалма каучук, рентген плёнкала-

ры, күзәтү, радио һәм электр техникасы, электрон, җылылык үлчәү, мед. приборлары, гражданлык һәм оборона җиһазлары, көнкүреш газ плитәләре һ.б. бар. К. пр-тиеләре яктыга сизгер плёнкалар, кетгут (100%), газ турбиналары (95% тан күбрәге), полиэтилен, этилен (40%), одеколон (20% ка якыны) эшләп чыгару буенча Россиядә алдынгы урынны тота. Вертолётлар, этилен полимерлары, ясалма каучук, сәнәгать җиһазлары, приборлар, аларның аерым өлешләре экспортка чыга. К. сәнәгате — тиз үсүчән өлкә. Пр-тиеләрнең күбесе җитештерүнең югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган һәм фәнни булуы б-н аерылып тора, техника паркын яңарта, технологияләр һәм продукциянең яңа төрләрен үзләштерә. Югары технологияле продукция җитештерүгә кече һәм урта эшмәкәрлекне җәлеп итү максатында, «Идея», «Химград» технопарклары булдырыла; шәһәр хакимияте һәм «Казан банкы» ташламалы кредитлау программасын тормышка ашыра (2007 дән). Сәнәгать җитештерү пр-тиеләрен шәһәрнең үзәгеннән читкә чыгару юлы б-н экологик хәлне яхшырту буенча эш башланды.

**Сәүдә**. 2010 да К.да 2900 гә якын стационар ваклап сату пр-тиесе, 22 базар, гомуми мәйданы 1,1 млн. *м*² булган 2400 ләп киоск, 72 мең урынга исәпләнгән 1360 тан артык җәмәгать туклануы пр-тиесе (ш.и. 50 ресторан, 600 кафе, бар, кабымлыкханәләр һ.б.). К.да кулланучылар базарында эшләүче эре пр-тиеләр: «Эдельвейс» сәүдә компаниясе», «Домо» компанияләре төркеме» , «Перекрёсток» сәүдә йорты» («Перекрёсток», «Карусель» кибетләре челтәре), «Тандер» («Магнит» челтәре), «Балалар дөньясы» һ.б. АҖләре; «Бәхетле» сәүдә галереясы», «Ак Барс Торг» («Пятёрочка» челтәре), «Оптовик» («Эссен» челтәре), «Агава», «ИКЕА» (Швеция), «Метро Кэш энд Керри», «Реал-Гипермаркет» (икесе дә — Германия), «Франт» сәүдә-күңел ачу үзәге, «Максидом», «Мой дом» һ.б. ҖЧҖләр, төрле автосалоннар. 2000 еллардан сәүдә өлкәсенә өр-яңа технология һәм сатып алучыларга хезмәт күрсәтүнең инновацион формалары, өстәмә хезмәт күрсәтүләр, Интернет аша электрон сәүдә итү системасы, кулланучыларга кредит бирү, электрон түләү системасы, хәзерге заман сәүдә җиһазлары актив кертелә. Инфраструктура (суыткычлар, складлар, саклау урыннары, автомобиль парклары һ.б.) үсә. Яшәү урынныра якын урнашкан сәүдә пр-тиеләре челтәре төзү буенча эш алып барыла, товарлар «эконом» һәм «люкс» төркемнәренә бүленә. Күп кенә компанияләр кайбер азык-төлек товарларын үзләре җитештерә. 2009 да шәһәрдә ваклап сәүдә итү әйләнеше — 224,8 млрд. сум (азык-төлек товарлары — 50,1%) яки кеше башына 198,3 мең сум; җәмәгать туклануы әйләнеше 9,97 млрд. сум (кеше башына — 8,8 мең сум) тәшкил итә. Бу өлкәләрдә 100 меңнән артык кеше эшли.

**Шәһәр хуҗалыгы.** 1990 елларның 2 нче яртысыннан К.да торак һәм юл-транспорт төзелешенең күләме һәм темплары үсә башлый. 1996–2004 тә Республикада, тузган тораклар фондын бетерү программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, 1,7 млн. *м*² торак төзелә, 29288 гаилә яңа фатирларга күченә. Файдалануга тапшырылган торак мәйданнарының күләме 385,5 мең *м*² дан (1997) 874,7 мең *м*² га (2004) кадәр арта. Уртак һәм индивидуаль рәвештә торак төзү күләмнәре шактый үсә. Зур төзелешләрдән торган яңа кварталлар үсеп чыга. Яңа торак микрорайоннары («Дубрава» экопаркы, «Кояшлы шәһәр»,



Хәзерге Казанның яңа төзелешләре. Торак йорт.

«Казан-XXI гасыр», «Зур Крыловка», «Универсиада авылы» һ.б., ш.у. «Казан йортлары», «Урман шәһәрчеге», «Ореховка» һ.б.) барлыкка килә. Җәмәгать биналары төзелешендә офислар, сәүдә һәм туклану объектлары, кунакханәләр төзү өстенлек ала («Татарстан» банкы, ТРның Теркәү палатасы, «Татэнерго» пр-тиесе, «ГУМ», «Сити-Центр», «ИКЕА», «Бәхетле», «ДОМО» гипермаркетлары, «Савиново» сәүдә комплексы, «Мираж» кунакханәсе биналары һ.б.).




Хәзерге Казанның яңа төзелешләре.
«Сувар Плаза» офислар һәм сәүдә комплексы.

Сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт өчен күп кенә эре объектлар төзелә: Төбәкара клиника-диагностика үзәге, шәһәр йогышлы авырулар хастаханәсе, «Баскет-холл» спорт уеннары сарае, халыкара ат спорты комплексы, «Татнефть-Арена» боз сарае һ.б.; *Спорт сарае*, *Үзәк стадион* реконструкцияләнә. «*Колшәриф*» *мәчете*, мәдәният объектлары — *ТРның Зур концерт залы*, «*Пирамида*» мәдәни-күңел ачу комплексы, «Ривьера» кунакханәсе, «Теннис академиясе», «Ватан» сәламәтләндерү комплексы һ.б. сафка баса. Казан Кремле архит-ра ансамблен, Татар академия опера һәм балет театрын, Казан Зур драма театрын, ТР Милли музеен һ.б. мәдәни-тарихи объектларны реконтрукцияләү гамәлгә ашырыла. Киң колачлы үзгәртүләр нәтиҗәсендә, К.ның үзәк өлеше шактый үзгәрә. Транспорт инфраструктурасын яхшырту буенча эшләр алып барыла. Транспорт өчен төрле биеклектәге юл ачылышлары, эстакадалар төзелә. 2005 тә метрополитенның беренче линиясе (1997 дә төзелә башлый), Казансу аша тимер-бетон күпер (ш.у.к. *Юл-транспорт төзелеше, Күперләр*) файдалануга тапшырыла. 2009 га К. урам-юллар челтәренең (урамнар, юллар, яр буйлары һ.б.) гомуми озынлыгы 1808 *км* (ш.и. камилләштерелгән юл капламы б-н — 1125 *км*) тәшкил итә. Шәһәрдә 85 күпер һәм юлүткәргеч бар. Тышкы яктырту линияләренең озынлыгы 2,1 мең *км* (52 меңнән артык яктырту ноктасы). Шәһәр эчендәге яшел утыртмаларның гомуми мәйданы — 9682 *га*, ш.и. урман-парклар — 3678 *га*, шәһәр урманнары — 810 *га*, гомуми файдаланудагы утыртмалар — 1613 *га*, урам-юллар челтәрен яшелләндерү мәйданы — 2275 *га*.

**Транспорт.** 2009 да К.да транспорт челтәрләре озынлыгы: троллейбусларның — 101,1 *км* (ике линия буларак исәпләгәндә), трамвайларның — 67,3 *км* (ике юлны исәпләгәндә), шәһәр эче һәм шәһәр тирәсе автобус маршрутларының 1900 *км* тәшкил итә. Шәһәр пасс. транспорты паркы 226 троллейбусны, 144 трамвай вагонын, 1200 гә якын автобусны үз эченә ала, 2005 тән метро эшли башлый. (к. *Метрополитен*). Көн саен К.да 0,5 млн.нан артык кеше транспорттан файдалана. Шәһәрдә пассажирларга хезмәт күрсәтү — 98,9%, шәһәр эчендә пассажирлар ташуның гомуми күләме — елга 174,7 млн. кеше (эл. транспорты б-н — 58,8 млн., автобуслар б-н — 115,9 млн. кеше). Пассажирлар коммуналь автопр-тиеләре б-н шәһәр хакимиятенең Транспорт һәм элемтә ком-ты оператив җитәкчелек итә.

**Элемтә.** К. шәһәр телефон станциясе (ГТС) составына барлыгы 257 меңнән артык номерны берләштергән 23 станция һәм подстанция керә. 339 шәһәр таксофоны файдаланыла; «09» белешмә-мәгълүмат хезмәте эшли (1900 еллар башында оештырыла). Төбәктә кәрәзле күчмә автомат телефон элемтәсе челтәре тиз үсә. Кәрәзле элемтә хезмәтен «Вымпелком», «МТС», «МСС-Поволжье», «СМАРТС», «НСС» АҖләре операторлары башкара. Төбәк эчендәге гомуми кулланылыштагы автомат элемтәсенең иң эре операторы — Таттелеком АҖ. Гомуми кулланылыштагы шәһәрара һәм халыкара автомат телефон элемтәсе челтәре хезмәтен «Ростелеком», «Төбәкара Транзит телеком», «Транстелеком компаниясе» һ.б. күрсәтә. Һәр 100 гаиләнең 87,4 е өй телефоны б-н тәэмин ителгән (2009).

**Почта.** К.да традицион һәм өстәмә почта элемтәсе хезмәтен (коммуналь түләүләр кабул итү, пенсияләр һ.б. акчалата пособиеләр түләү) 83 почта элемтәсе бүлекчәсе башкара. Шәһәр эчендә почта аша әйберләр җибәрү

өчен 15 маршрут оештырылган (җыю һәм тапшыру атнага 6 тапкыр башкарыла). Почта хезмәтен 10 оператор башкара, аларның иң зурысы «Татарстан почтасы» — «Россия почтасы» федераль дәүләт унитар пр-тиесе (ФГУП) ф-лы.

**V. Мәгариф, фән, мәдәният**

Татар, чуаш, рус һәм фин-угор халыклары мәдәниятләре тоташкан җирдә урнашканга күрә, К. һәрвакыт аларның үзара тарихи-мәдәни бәйләнешләре төенләнеше булып кала. Татар интеллигенциясенең үзәге бирелдә формалаша, милли мәгариф системасы, татар вакытлы матбугаты, матур әдәбияты, журналистикасы, китап бастыру эше, театры, милли сәнгатьнең төрләре барлыкка килә һәм үсеш ала. Шул ук вакытта элек-электән К. — рус мәдәниятенең эре үзәкләреннән берсе; чуаш, мордва, мари, удмурт, башкорт, казакъ һ.б. халыклар өчен милли кадрлар әзерләү учагы булып танылa. Әлеге тарихи-мәдәни һәм социаль-икътисади факторлар К. һәм анда яшәүче халыкның РФнең башка шәһәрләреннән аерылып торган үзенчәлекле мәдәни синкретизмын билгели.

**Мәгариф.** Мөселман традицияләре буенча К.да элек-электән мәчетләр каршында дини *мәктәп* һәм *мәдрәсәләр* эшләп килә. Шәһәрнең татар халкы арасында гарәп графикасы нигезендә укырга-язарга өйрәнү, җәмгыятьнең югары катламнарында гарәп һәм фарсы телләрен белү киң таралган була. Шәһәрдә беренче рус дөньяви уку йорты булып *Цифирь мәктәбе* (1716) ачыла. 1723 тә Фёдор монастыре каршында дин әһелләре әзерләүче славян-латин мәктәбе ачыла, 1733 тә ул *Казан руханилар семинариясе* (1798–1818 дә Дини академия) итеп үзгәртелә. 1758 дә К.да Сенат фәрманы буенча, Россия провинцияләрендә беренчеләрдән булып, ир балалар гимназиясе (к. *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе)* оештырыла. Ул Мәскәү ун-ты карамагында була, университет аның уставын кабул итә, һәм беренче укытучылары да шуннан килә. 1770 тән гимназиянең уку программасына татар теле дә кертелә, аны танылган татар укытучылары — галимнәр Сәгыйт, Исхак һәм Ибраһим *Хәлфиннәр* укыта. Гимназиядә соңрак Россия фәне һәм мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре: шагыйрь Г.Р.Державин, язучы С.Т.Аксаков, математик Н.И.Лобачевский, астрономия һәм география белгече И.М.Симонов, химик А.М.Бутлеров һ.б. укый. 1786 да шәһәрдә һәркем укый алырлык беренче мәктәп — *Казан халык училищесе* ачыла. 1804 тә *Казан университетына* нигез салына, соңрак ул Россиядә иң зур фән һәм мәгариф үзәкләренең берсенә әверелә. 1835 тә — *Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе,* 1842 дә *Казан руханилар академиясе* эшли башлый. 19 йөзнең 2 нче чирегендә кыз балалар өчен беренче уку йортлары барлыкка килә: *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты* (1841), *Казан дини ведомствосының хатын-кызлар училищесе* (1853), *Казандагы Беренче кыз балалар гимназиясе* (1859).

1860 еллардагы реформалар мәгариф үсешен тизләтүгә китерә. 1870 еллардан шәһәр үзидарәсе органнары башлангыч уч-щеләр (1860 та — 4, 1905 тә — 25, ш.и. — татар-рус) ача башлый. Алар 9 чиркәү-приход һәм 10 хосусый мәктәп б-н бергә күп балага башлангыч белем бирә. Уку йортларын квалификацияле укытучылар б-н тулыландыру өчен, *Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе* (1863), *Казан укытучылар семинариясе*, *Казан халык укытучыларын укыту земство мәктәбе* (1871), *Казан татар укытучылар мәктәбе*, *Казан укытучылар институты* (1876), *Казан чиркәү-укытучылар мәктәбе* (1906) ачыла.

20 йөз башына урта мәктәпләр челтәре киңәя, ул 3 ир балалар, 4 кыз балалар гимназиясеннән (ш.и. 2 се хосусый), Казан реаль һәм епархия уч-щеләреннән тора. Махсус урта уку йортлары барлыкка килә: Казан җир эшләре уч-щесе (1864), Казан земство фельдшерлык мәктәбе (1866), Казан сәнгать мәктәбе (1895), Казан сәнәгать уч-щесе (1897). 1873 тә ветеринария ин-ты (к. *Казан ветеринария медицинасы академиясе*) ачыла, 1876–87 дә *Казан хатын-кызлар югары курслары* эшли.

18 йөзнең 2 нче яртысыннан, татар бистәләрендә мәчетләр төзүне тыюлар бетерелгәч, К. Россиядә ислам динен уку-укытуның иң зур үзәгенә әверелә. Күпчелек мәчетләр каршында мәдрәсәләр ачыла: Ахун (1770), Апанай (1780, к. *«Касыймия» мәдрәсәсе)*, Әмирхан (1780) һ.б. Ислам уку йортларында күренекле дин галимнәре Ш.*Мәрҗани*, И.Хуҗаш, М.*Сәгыйтов,* М.Мөхәммәтрәхимов, Г.*Рахманколый* укыта, атаклы җәмәгать һәм мәдәният эшлеклеләре Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, М.Бигиев, Г.Камал һ.б. укый. 19 йөзнең соңгы чирегендә күп кенә ислам уку йортлары яңа ысуллар кулланып укытуга керешә, Г.*Баруди* җитәкчелегендәге *«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе* дини һәм дөньяви фәннәрне югары дәрәҗәдә укыта торган иң зур ислам уку йортына әйләнә. 1905–07 еллардагы рев-циядән соң К.да дәүләтнеке булмаган 20 дән артык, ш.и. татар кызлары өчен беренче дөньяви уку йортлары (к. *Аитова Фатиха гимназиясе*, *Хөсәения Ләбибә мәктәбе*) ачыла. 1906 да Казан хатын-кызлар югары курслары яңадан эшли башлый. 1917 дә шәһәрдә 4 югары уку йорты, 15 гомуми урта, 9 махсус урта, 50 дән артык тулы булмаган урта һәм башлангыч уку йорты исәпләнә. Совет хакимияте урнашкан елдан ук республикада *культура революциясе* башлана, ул, беренче чиратта, мәгариф һәм мәгърифәт учреждениеләрен колачлый: гимназияләр һәм реаль уч-щеләр бердәм урта мәктәпләр итеп үзгәртелә, яңа башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләр ачыла.

1928 дән К.да гомуми мәҗбүри җидееллык белем бирүгә күчү башлана. Махсус урта уку йортлары (сәнәгать, җир эшләре, коммерция уч-щеләре) берләштерелә һәм *Казан политехник институты* (1919) итеп үзгәртелә, 1922 дә аннан Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык ин-ты (к. *Казан авыл хуҗалыгы академиясе*) бүленеп чыга. 1930 да укытучылар ин-ты һ.б. урта пед. уку йортлары җирлегендә пед. ин-ты (к. *Казан педагогика университеты*) оештырыла. 1919 дан башлап эшче һәм крәстиян яшьләрен К. югары уку йортларына керергә әзерләүне гамәлгә ашыручы *эшчеләр факультетлары* (1934 тә шәһәрдә 13 рабфак эшли) ачыла. Халык хуҗалыгын индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү квалификацияле белгечләр таләп итә, шуның б-н бәйле рәвештә 1930 еллар башыннан К.да күп кенә завод һәм фабрикаларда укыту курслары, техник юнәлештәге 15 махсус урта уку йорты оештырыла. Казан ун-ты һәм политехник ин-ты ф-тлары җирлегендә 1930–31 дә яңа югары уку йортлары ачыла: химия-технол. ин-ты (хәзерге *Казан технология университеты)*, коммуналь төзелеш ин-ты (*Казан архитектура-төзелеш университеты*), мед. ин-ты (*Казан медицина университеты*), юридик ин-т (1952 дә яңадан Казан ун-ты составына кертелә), финанс-икътисад ин-ты (*Казан финанс-икътисад институты*), авиация ин-ты (*Казан техник университеты*). 1940/41 уку елында К.да 14 югары уку йорты (12 мең студент) һәм 53 махсус урта уку йорты (12,9 мең укучы) була. Бөек Ватан сугышы чорында Казан югары уку йортлары җирлегендә эвакуацияләнгән Ленинград химия-технол. һәм финанс-икътисад ин-тлары, Харьков авиация ин-ты эшли. Сугыш нәтиҗәләре авыр булуга карамастан, 1945 тә К.да яңа югары уку йорты — *Казан консерваториясе* оештырыла. 1950 еллар уртасыннан шәһәрдә мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениеләре һәм гомуми белем бирү мәктәпләре саны күпләп арта башлый, җидееллык мәктәпләрнең күпчелеге урта мәктәп итеп үзгәртелә, эшче яшьләр мәктәпләре челтәре, 60 лап һөнәри-техник уч-ще төзелә. Студентлар саны арта, югары уку йортларында белгечлекләр төре киңәя. Хуҗалыкның билгеле бер тармагына караган авиация, химия-технол., төзүче-инженерлар ин-тлары халык хуҗалыгының төрле тармаклары өчен белгечләр әзерләүче политехник ин-тлар итеп үзгәртелә. 1960 елларда К.да Мәскәү энергетика ин-ты ф-лы (хәзерге *Казан энергетика университеты*) һәм Ленинград мәдәният ин-ты ф-лы (*Казан мәдәният һәм сәнгать университеты*) оештырыла. 1970 елларда мәҗбүри гомуми урта белем бирүгә күчү бара. Шул ук вакытта КПССның мәдәният өлкәсендәге идеологик курсы йогынтысында шәһәрдә татар мәктәпләре челтәре кими, 1980 еллар башында К.да бер генә татар мәктәбе кала. Махсус урта һәм югары уку йортларында татар телендә укыту бетерелә. Илдә 1980 еллар ахырында башланган социаль-икътисади мөнәсәбәтләрне үзгәртеп кору һәм 1990 елларның 1 нче яртысында икътисади хәлнең кискенләшүе мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениеләренең, һөнәри-техник уч-щеләрнең кимүенә китерә. Шуның б-н бергә 1990 елларда республика үсешендәге яңа социаль-сәяси шартлар милли мәктәпләр эшчәнлегендә күп кенә уңай күренешләр барлыкка килүгә ярдәм итә. 1990–2000 елларда К.да татар гимназияләре челтәре оештырыла, күп мәктәпләрдә татар сыйныфлары булдырыла, гомуми белем бирү мәктәпләре программаларына татар теле фәне кертелә. Белгечләр әзерләүче махсус

мәктәпләр, гимназия һәм музейлар саны шактый арта, дәүләтнеке булмаган мәктәпләр ачыла. Авиация, химия-технол. һәм энергетика ин-тлары киң профильле югары уку йортлары — университетлар итеп үзгәртелә. 2005 тә Казан пед. ин-ты киңрәк профильле югары уку йорты — Татар гуманитар-пед. ун-ты итеп үзгәртелә. 2010 да Казан (Идел буе) федераль ун-ты оештырыла. 2009 да — Казан техник ун-ты, 2010 да Казан технол. ун-ты фәнни-тикшеренү ун-тлары статусын ала.

Дәүләтнеке булмаган югары уку йортлары ачыла, аларның кайберләре зур уку-укыту үзәкләренә әверелә. *Икътисад, идарә итү һәм хокук институты, Казан социаль-юридик институты, «ТИСБИ» идарә университеты, Татар-Америка региональ институты*. К.да *Казан югары хәрби командирлар училищесе, Казан суворовчылар хәрби училищесе*, дини уку йортлары челтәре (Россия ислам ун-ты, 3 мәдрәсә, Казан руханилар семинариясе һ.б.) бар. 2009 да шәһәрдә 220 гә якын мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениесе, 185 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 36 гимназия, 11 лицей, 9 мәктәбара уку комб-ты, 6 кичке (сменалы) һәм 4 дәүләтнеке булмаган мәктәп эшли. 14 дәүләт һәм 5 дәүләтнеке булмаган югары уку йорты, 19 филиал, *Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институты, Казан медицина академиясе*, 20 һөнәри урта һәм 24 башлангыч һөнәри белем бирү уку йорты эшли.

**Фән.** 1920 елларга кадәр К.да фәнни тикшеренүләр, башлыча, югары уку йортларында, нигездә, Казан ун-тында алып барыла. 19 йөздә — 20 йөз башында университет галимнәре тарафыннан дөньякүләм әһәмияткә ия ачышлар һәм фәнни тәгълиматлар бәян ителә: (математикада — *Лобачевский геометриясе* һәм Н.А.*Васильевның* нәклассик логика системасы, химиядә — *Зинин реакциясе*, К.К.*Клаус* тарафыннан *рутений* элементы ачылу, А.М.Бутлеровның *химик төзелеш теориясе, Марковников кагыйдәсе*, лингвистикада — И.А.*Бодуэн де Куртенэның* фонемалар һәм фонетик чиратлашулар теориясе һ.б. Университетта берничә фәнни мәктәп барлыкка килә: *Казан астрономия фәнни мәктәбе, Казан геология фәнни мәктәбе, Казан геоморфология фәнни мәктәбе, Казан геометрия фәнни мәктәбе, Казан лингвистика фәнни мәктәбе* һ.б. *(к. Казан фәнни мәктәпләре),* медицинада офтальмология, хирургия, гистология һ.б. юнәлешләр билгеләнә (к. *Казан медицина фәнни мәктәбе*). Казан ун-тының *Шәрекъ бүлеге* 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә Шәрекъне өйрәнүдә әйдәп баручы үзәккә әверелә. Казан руханилар академиясендә дә гуманитар фәннәрнең киң даирәсе буенча тикшеренүләр алып барыла, биредә рус чиркәве тарихы, чиркәү хокукы, антропология фәлсәфәсе (В.И.*Несмелов)* һ.б. мәктәпләр формалаша. Казан вет. ин-тында фәнни һәм гамәли тикшеренүләр үткәрелә (к. *Казан ветеринария фәнни мәктәбе*). К.да күп кенә фәнни юнәлешләргә нигез салучы күренекле галимнәр эшли: Е.В.Адамюк, В.М.Бехтерев, В.А.Богородицкий, Н.П.Вагнер, А.В.Васильев, В.И.Григорович, Н.П.Загоскин, А.М.Зайцев, А.О.Ковалевский, Н.О.Ковалевский, М.А.Ковальский, П.Ф.Лесгафт, В.В.Радлов һ.б. Шәһәрдә ш.у. *Казан икътисадчылар җәмгыяте,* Казан табибләр җәмгыяте, *Табигыятьчеләр җәмгыяте, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Казан физика-математика җәмгыяте* уңышлы эшләп килә, һәм алар кысаларында галимнәр б-н бергә гамәли белгечләр, бу фәннәрне сөючеләр дә фәнни эшчәнлек б-н шөгыльләнә.

1920–30 елларда фәнне үстерү дәүләт сәясәтендә өстенлекле юнәлешләрнең берсенә әверелә, һәм шунлыктан финанслау арта, махсус фәнни оешмалар булдырыла, тикшеренү һәм проектлаштыру эшчәнлегенең программалары төзелә. Фәнни тикшеренүләрнең төп үзәкләре электән эшләп килгән һәм яңа төзелгән югары уку йортлары була. Ул елларда *Казан метеорология фәнни мәктәбе,* механикада хәрәкәт тотрыклылыгы теориясе юнәлеше, Н.Г.*Чеботарёвның* — алгебра, Н.Н.*Парфентьевның* — матем. анализ, А.Е.Арбузовның фосфорорганик кушылмаларны өйрәнү мәктәпләре барлыкка килә. Гуманитар фәннәр, бигрәк тә татар халкын өйрәнү гыйлеме өлкәсендә тикшеренүләр яңача үсеш ала, *Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институты, Шәрекъ академиясе, Татар мәдәнияте йорты* әлеге юнәлешнең беренче үзәгенә әверелә. Яңа фәнни оешмалар: *Академүзәк,* Татар икътисади ин-ты төзелә. 1939 да ТАССР ХКС каршында Татарстан тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-ты ачыла (к. *Тел, әдәбият һәм тарих институты*). Фәнни хезмәткәрләрнең саны арта (1926 да — 650, 1940 та 1300 дән артык кеше). Ләкин партиянең идеологик диктаты һәм сәяси репрессияләр фәнни тикшеренүләр үсешенә зур зыян сала. 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында төбәкне өйрәнү эшләре туктатыла, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте* яшәүдән туктый. 1937–38 елларда 50 дән артык галим сәяси репрессияләр корбаны була.

Бөек Ватан сугышы башлану б-н, К. галимнәре оборона бурычларын хәл итүгә күчә, бу эшләр Мәскәү һ.б. шәһәрләрдән эвакуацияләнгән югары уку йортлары һәм фәнни учреждениеләр белгечләре б-н бергә алып барыла. 1944 тә Е.К.*Завойский* тарафыннан *электрон парамагнитик резонанс* күренеше ачыла. Аның тикшеренүләре К. галим-физикларының өстенлекле юнәлешләреннән берсенә әверелә (к. *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбе).* 1945 тә СССР ФАнең Казан ф-лы оештырыла (к. *Россия фәннәр академиясенең Казан гыйльми үзәге*), аңа яңа төзелгән химия ин-ты (к. *Органик һәм физик химия институты*), биология ин-ты (к. *Казан биохимия һәм биофизика институты*), *Казан физика-техника институты,* ш.у. Тел, әдәбият һәм тарих институты керә. К. академик фәннең мөһим үзәгенә әверелә. Югары уку йортларында да фәнни тикшеренүләр дәвам итә, нефть чыгару һәм аны эшкәртүнең үсеше гидроаэродинамика, җир асты механикасы һ.б. тикшеренүләрдә яңа юнәлешләр барлыкка китерә. 1950 еллар уртасына шәһәрнең фәнни учреждениеләрендә һәм югары уку йортларында 50 гә якын фән докторы һәм 500 дән артык фәннәр кандидаты эшли.

К.ның куәтле фәнни потенциалы 1950 елларның 2 нче яртысыннан гамәли фәнни тикшеренүләрнең бик тиз үсүен тәэмин итә. Шуннан соңгы уньеллыкларда ведомство фәнни-тикшеренү ин-тлары, ФҖБләре, проектлау-конструкторлык бюролары һ.б. фәнни-тикшеренү оешмалары төзелә, 1980 елларда аларның саны 98 гә җитә. Югары уку йортларында һәм академик ин-тларда да гамәли эшләр б-н актив шөгыльләнү дәвам итә. 1992 дә *Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе* төзелә, һәм бу К.ның һәм республиканың фәнни потенциалын саклап калуга, гуманитар тикшеренүләрне тагын да үстерүгә, татар халкының тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүгә ярдәм итә. 1994 тә *Татар энциклопедиясе институты* оештырылу фәнни тикшеренүләр үсешенә зур этәргеч бирә. 2010 елга К.да ТР ФАнең 6 ин-ты һәм 5 үзәге, РФА КГҮнең 4 ин-ты һәм 3 институт хокукындагы бүлеге, РМАнең Урта һөнәри белем ин-ты, РАХФАнең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-ты, югары уку йортларында 10 фәнни-тикшеренү ин-ты һәм 100 дән артык үзәк һәм лаборатория (ш.и. Казан (Идел буе) федераль ун-тында — 3, техник ун-тта — 5, технол. ун-тында 2 фәнни-тикшеренү ин-ты), ведомстволарга караган һәм акц. 18 фәнни-тикшеренү ин-ты һәм 20 дән артык башка тикшеренү учреждениесе, ш.и. *Бөтенроссия ветеринария институты*, *Идел буе углеводород чималы институты*, *Гамәли оптика институты*, *Татарстан нефть машиналары төзү институты*, *Казан эпидемиология һәм микробиология институты*, Нефть промыселы химиясе институты, *Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк институты*, Бөтенроссия мед. инструментлары фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-ты эшли. Фәнни учреждение һәм вузларда 8 меңнән артык фәнни хезмәткәр һәм 20 мең тирәсе фәнни-педагогик хезмәткәр, ш.и. РФАнең 4 академигы һәм 5 мөхбир әгъзасы, РМАнең 2 академигы һәм 2 мөхбир әгъзасы, ТР ФАнең 37 академигы һәм 77 мөхбир әгъзасы, 1 меңнән артык фәннәр докторы һәм 11 меңләп фәннәр кандидаты эшли (2010).

**Әдәбият.** Урта гасырларда Казанда әдәби тормыш Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорлары традицияләренең дәвамлы рәвештә Казан ханлыгы чорына күчүе нигезендә формалаша. Бу күренеш әдәби әсәрләрнең формасы, жанры һәм тематик эчтәлегендә чагылыш таба. Шәһәр бай эчтәлекле әдәби тормыш б-н яши. Татар шигърияте тарихында *Мөхәммәдәмин хан* исеме яхшы билгеле. Күренекле татар шагыйре *Мөхәммәдьярның* да тормышы һәм иҗаты К. б-н бәйле. Ул поэмаларының берсендә шәһәрдә «олысы да, кечесе дә үзен шагыйрь саный» һәм әдәбият өлкәсендә дан эзли, дип яза. К. һәм татар әдәбияты тарихында шагыйрь, дәүләт һәм дин эшлеклесе *Колшәриф* исеме ла-

еклы урын алып тора. Монда шагыйрьләрдән Гариф бәк, *Касыйм Шәех* һ.б. яши һәм иҗат итә. Казан ханлыгы чорыннан шактый гына проза әсәрләре сакланып кала. Язучы һәм дәүләт эшлеклесе *Аднаш Хафиз* — «Сираҗ әл-колүб» («Күңелләр нуры», 1553) китабы авторы. Иван IV нең 1549–50 елларда Казанга каршы оештырган уңышсыз яулары турында бәян ителгән «Зафәрнамәи вилаяте Казан» («Казанның җиңүе турында хат», 1550) әсәрендә Шәриф Хаҗитархани: «Дөньяның бер генә җирендә дә Казан кебек чәчәк атучы шәһәр бүтән юк», — дип, сокланып яза. Казан ханлыгы чорында һәркемгә мәгълүм булган мөселман Шәрегы әдәби ядкәрләре тәрҗемә ителә һәм күпсанлы күчермәләрдә тарала. К.ның Иван IV гаскәрләре тарафыннан яулап алынуы, шәһәр халкының күпләп кырылуы, мәчетләр, мәдрәсәләр, китапханәләрнең җимерелүе, януы, көчләп чукындыру сәясәте рухи тормышны, әдәби иҗатны торгынлыкка китерә. Әмма нәфис сүзгә карата мәхәббәт сүрелми, һәм ул халык авыз иҗаты әсәрләрендә көчле чагылыш таба. Казан ханлыгы яшәешенең соңгы еллары б-н бәйле вакыйгалар бәян ителгән әсәрләрнең берсе — «Казан бәете»ндә болай диелә:

«Ике йөз алтмыш ике ел Казан мөселман кулында,
Ахыры — бары соңында кяфир урыс алдыя,
Газилары күп иде, камилләре чук иде,
Галимнәре күп иде, замане Җәдегәр ирдийа.
Бу җиһан мөнәүвәр иде, җәбер-җәфа юк иде,
Мөрид-мөршид күп иде, заманы хуб ирдийа,
Галимнәре дуст иде, мөршидләре хас иде...».

Татар әдәбияты бары 17 йөздә генә кабат торгызыла башлый. Аның беренче чагылышы булып *Мәүла Колый* иҗаты тора. 18–19 йөзләр чигендә шәһәрдә шагыйрь *Колмөхәммәд* иҗат итә. Аның фарсы телендә язылган «Нәсыйхәте Шәһре Казан» исемле дини-дидактик поэмасы сакланып кала. Татар халкының рухият һәм милли мәдәният үзәге буларак, К. сәнгать хәзинәләре тудыручы күп кенә шәхесләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Шагыйрь Гали *Чокрый*, шәһәрдән алган тәэсирләрен яктыртып, «Мәдхе Казан» (1889) исемле шигъри әсәр иҗат итә.

«Иң әувәл: йортлары бик саф,
Икенчесе — ирләре бик саф,
Өченчесе — җырлары бик саф,
Әмерләре нәзар саздыр.
Ләбибләр күплеге берлә,
Әдипләр күплеге берлә,
Табибләр күплеге берлә,
Тәмам илгә гаян саздыр...», — дип яза ул.

19 йөз ахырында К.ның әдәби тормышында сизелерлек җанлану күзәтелә. Беренче татар чәчмә әсәрләре — М.*Акъегетзадәнең* «Хисаметдин менла» (1886), З.*Бигиевнең* «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» («Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә», 1887) романнары; Г.*Ильясиның* «Бичара кыз» (1887) пьесасы; К.*Насыйриның* «Гөлруһ һәм Камарҗан турында хикәйәт» (1896) әсәре һ.б. дөнья күрә. Аларның барлыкка килүе татар әдәбиятының дини-дидактик эчтәлекле традицион әсәрләрдән дөньяви әдәбиятка борылыш алуын билгеләде. 1905–07 еллардагы рев-циядән соңгы чор татар әдәбияты үсеше б-н үзенчәлекле. Бу чорда К.да Г.*Исхакый*, Ф.*Әмирхан*, Г.*Камал*, С.*Рәмиев*, Ш.*Камал*, М.*Фәйзи*, М.*Гафури* һ.б. яши һәм эшли. Алар иҗаты татар әдәбияты тарихында тулы бер дәверне үз эченә ала. Халык шагыйре Г.*Тукайның* таланты да К.да үсә һәм таныла. Ул К.шәһәре турында: «Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур...», — дип яза.

Окт. рев-циясеннән соңгы беренче унъеллыкта К. язучылары үз әсәрләрен хезмәт, яңа тормыш төзү, социаль гаделлек идеяләре өчен көрәш темаларына багышлыйлар. Әлеге чорда К.*Тинчурин*, Т.*Гыйззәт*, Ф.*Бурнаш*, Һ.*Такташ*, М.*Җәлил*, Г.*Кутуй*, Ф.*Кәрим* кебек әдипләр иҗат итә. 1920–30 елларда К.да беренче әдәби түгәрәкләр һәм берләшмәләр — «ТАПП», «ТАТЛОКАФ» барлыкка килә, 1934 тә ТАССР Язучылар берлеге оеша. Бөек Ватан сугышы шәһәрнең рухи тормышына кискен үзгәрешләр алып килә. Күп кенә язучылар фронтка китә, алар дошманга каршы корал һәм нәфис сүз көче б-н көрәшә (А.*Алиш*, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Г.Кутуй, М.*Хөсәен* һ.б.). Сугышта 42 татар язучысының гомере өзелә (барысы да диярлек К.нан). 1950–70 елларда К. татар язучылары авыл тематикасы б-н беррәттән милли интеллигенция, эшчеләр сыйныфы, сәнгать объектлары төзелеше темаларын да яктырталар. Татар әдәбиятында әлеге чорның аеруча күренекле вәкилләре — Г.*Әпсәләмов*, М.*Әмир*, С.*Баттал*, Г.*Бәширов*, Х.*Вахит*, И.*Гази*, Ш.*Галиев*, Н.*Дәүли*, Н.*Исәнбәт*, К.*Нәҗми*, З.*Нури*, Х.*Туфан*, С.*Хәким*, Ф.*Хөсни*, А.*Шамов*, рус әдәбиятында — А.Г.*Бендецкий*, М.С.*Бубеннов*, Б.И.*Зернит*, В.В.*Корчагин*, Г.А.*Паушкин*. Алар иҗатында Бөек Ватан сугышы темасы, чор проблемалары, фәнни-маҗаралы сюжетлар үсеш ала. С.Б.*Радзиевская* балалар өчен әсәрләр иҗат итә, туган як табигате турында яза. 1947–59 да шәһәрдә «Литературная Казань» альманахы чыгарыла. 1980 еллар ахырыннан татар әдәбиятында тарихи темага игътибар көчәя, татар халкының бай мәдәни мирасы сәнгати яктан яңача үзләштерелә, шәрекъ поэтик жанры кире кайтарыла, детектив-маҗаралы һәм мемуар әдәбият үсеш ала, публицистика активлаша төшә (аеруча Г.*Ахунов*, А.*Гыйләҗев*, Ә.*Еники*, М.*Мәһдиев*, Т.*Миңнуллин*, Н.*Фәттах*, М.*Хәбибуллин*, И.*Юзеев* иҗатында). К.ның хәзерге әдәбияты М.*Әгъләмов*, Роберт *Әхмәтҗанов*, Д.*Вәлиев*, Р.*Гатауллин*, *Зөлфәт*, Гәрәй *Рәхим*, Р.*Харис*, Р.*Фәйзуллин*, Ф.*Яруллин* һ.б. исемнәр б-н танылa. 1995 тә татар ПЕН-үзәге төзелә. К.да татар һәм рус язучылары берләшмәләре эшли. «*Казан утлары*», «*Идел*», «*Мирас*» әдәби журналлары чыга. К. рус әдәбиятына Г.Р.*Державинны*, рус романтизмына нигез салучыларның берсе булган Г.П.*Каменевны* бирә. 1806 да Казан ун-ты каршында *Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте* — Идел буе һәм Урал төбәге әдәбиятчыларының беренче берләшмәсе төзелә. Бирегә М.*Горький* да үз «университетлары»н үтә. Е.А.*Боратынский*, Л.Н.*Толстой*, В.*Хлебников* исемнәре дә К. б-н бәйле.

**Китап һәм китапханә эше.** Кулъязма китаплар Казанда Болгар чорында ук кулланылышта була. Казан ханлыгында *Кол Галинең* «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, Мөхәммәдәмин, Мөхәммәдьяр, Колшәриф һ.б. авторларның әсәрләре күчермәләре киң таралыш ала. 16 йөз уртасыннан К.да рус телендәге кулъязма китаплар (дәреслекләр, дини, соңрак дөньяви әдәбият) тарала башлый. Иң беренче китап — Казан архиепископы Гурий (к. *Гурий әлифбасы*) төзегән әлифба. 16 йөзнең соңгы утызъеллыгында Казанга һәм Казан ханлыгының Рус дәүләте б-н көрәшенә, 1552 дә шәһәрнең яулап алынуына багышланган беренче хезмәт — билгесез авторның «Казан патшалыгы турында» («Истории о Казанском царстве») кулъязмасының күп кенә күчермәләре (16–19 йөзләр дәвамында 200 дән артык) барлыкка килә. Дөньяви әдәбият таралуга Пётр I реформалары һәм гражданлык шрифты таралу булышлык итә. 18 йөздән, бигрәк тә император Екатерина II нең 1783 елгы «Ирекле басмаханәләр турында» Фәрманыннан соң, китап сәүдәсе киң таралыш ала. 1800 дә Казанда «*Азия басмаханәсе*» ачыла, анда гарәп, фарсы, татар телләрендә басылган китаплар Россиядәге мөселман халкы арасында тарала. 1805 тә губерна идарәсе басмаханәсе эшли башлый. *Казан университеты басмаханәсе* (1809) ачылу б-н, Казандагы китап басу эше гомумроссия әһәмиятенә ия була. Басылган китаплар саны буенча Казан 19 йөз башында илдә 3 нче урында була (С.-Петербург һәм Мәскәүдән кала). 1831–46 елларда Россиянең провинциаль шәһәрләрендә басылган 77 исемдәге китапның 50 се Казанда чыга. Шәһәрдә беренче хосусый басмаханә 1841 дә ачылган Л.*Щевиц басмаханәсе* була. Китап басу эше 19 йөз ахыры — 20 йөз башында шактый үсеш ала. 1899 да шәһәрдә 16 басмаханә эшли. Китапларны хосусый нәшриятлар (*Кәримовларның китап сату фирмасы*, бертуган Шәрәфләрнең «Мәгариф»е, Идрисов, Галиев вә шөрәкясе, «Сабах» ширкәте), китап кибетләре һәм басмаханәләр хуҗалары (бертуган Башмаковлар, А.А.Дубровин, М.А.Голубев һ.б.), хөкүмәт учреждениеләре, земстволар, шәһәр думасы, сәүдә-сәнәгать пр-тиеләре, фәнни һәм иҗтимагый оешмалар, аерым авторлар бастыра. Казан басмалары китаплары каталоглары, адрес-календарьлар чыга. 1910 да Казанның 26 басмаханәсе 1000 нән артык исемдәге китап (ш.и. 418е татар телендә) бастыра. К.да Россиядә татар телендә чыккан китапларның 85% ка якыны басыла; Р.Фәхретдин, Г.Баттал, М.Рәмзи һ.б. тарихчыларның хезмәтләре, беренче рәсемле татар басмалары нәшер ителә. Басма китапларның югары полиграфия дәрәҗәсе Г.*Камал*, М.И.*Идриси*, И.И.Юзеев исемнәре б-н бәйле, алар яңа шрифтларның 30 дан артык төрен эшли. Окт. рев-циясеннән соң басмаханәләр дәүләтнеке санала башлый, һәм алар эреләндерелә. 1919 да Госиздатның Казан бүлеге (1920 дән Татгосиздат) оеша. (к. *Татарстан*

*китап нәшрияты*); ул Россиядә татар телендә нәшер ителгән китапларның 50% тан артыгын бастыра. 1960 елларда китап басу эше Казанда яңа баскычка күтәрелә, нәшриятлар һәм полиграфия пр-тиеләренең матди-техник базасы шактый ныгый, аларда квалификацияле белгечләр туплана. 1975 тә, Татар газета-журналлар нәшрияты (к. «*Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы*) комплексын сафка бастыру б-н, Казан нәшрият һәм полиграфия сәнәгатенең эре үзәгенә әверелә. Аның учреждениеләре һәм пр-тиеләре 1970–80 елларда ТАССРның гомуми белем мәктәпләре өчен дә, аннан читтә урнашкан татар мәктәпләре өчен дә дәреслекләр чыгара; Урта Азия, Казакъстан респ-калары өчен уку әдәбиятын бастыру буенча заказлар үти. 1990 елларда яңа нәшрият системасы барлыкка килә: нәшриятларны дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар гына түгел, аерым шәхесләр дә оештыра. Бу чорда «*Мәгариф*», «*Фән*», «*Заман*» нәшриятлары барлыкка килә. Полиграфия эшенең техник нигезен яңарту, нәшриятлар саны арту басыла торган китаплар, газета һәм журналларның сыйфаты яхшыруга, аларның тематикасы киңәюгә китерә.

Казанда китапханәчелек эшенең күптәнге традицияләре яши. Казан ханлыгында шәхси китапханәләр, сарай һәм укучы-шәкертләр (мәктәп һәм мәдрәсәләр каршында) китапханәләре, ш.у. мәчетләр каршында, нигездә, дини эчтәлектәге китаплар һәм төрле авырулардан дәвалау буенча трактатлардан (кигәшләрдән) торган китаплар җыелмалары була. Әлеге бай китап тупланмалары 1552 дә Казанны яулап алганда югалып бетә. Мәскәүдә китап басу эше башлану (1564) Казан соборлары һәм монастырьлары китапханәләре оешуга булышлык итә, аларда беренче басма китаплар (аларның кайберләре *Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә* саклана) барлыкка килә. 18 йөздә китапханәләр уку йортларында: руханилар семинариясендә һәм ирләр гимназиясендә булдырыла; соңгысына 1798 дә Г.А.*Потёмкин* һәм В.И.*Полянский китапханәләре* тапшырыла. Казанда шәхси китапханәләр дә була: Ю.И. фон Каниц, Г.П.Каменев, Лихачёвлар һ.б. 1834 тән А.Г.Мясниковның китап кибете каршында җәмәгать китапханәсе (к. *Мясников А.Г. китапханәсе*) эшли. 1850 еллардан — И.А.Сахаров, И.А.Шидловскийның җәмәгатьчелек файдаланган шәхси китапханәләре, 20 йөз башында Г.*Баруди*, С.*Вахиди*, Ә.Максуди китапханәләре киң таныла. 1865 тә И.А.*Второвның* шәхси китаплар тупланмасы нигезендә шәһәр җәмәгать китапханәсе (хәзерге *Татарстан Республикасының милли китапханәсе*) оеша, 1906 дә аның ф-лы — «*Көтебханә-и исламия*» ачыла. Эре китапханәләр Казан ун-тында, руханилар академиясендә, «Мөхәммәдия», «Мәрҗани» мәдрәсәләре каршында, Шәрекъ һәм Шахмат клубларында, Крестовниковлар заводында, Алафузовлар фабрикасында һ.б.да була. 20 йөздә К.да төрле юнәлешләргә һәм максатларга караган китапханәләрнең (к. *Республика балалар китапханәсе, Республика махсус сукырлар китапханәсе, РФА КГҮ Казан физика-техника институты китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе,* ТР ФА фәнни китапханәсе) саны тиз арта. 2010 да К.ның Үзәкләштерелгән китапханәләр һәм Үзәкләштерелгән балалар китапханәләре системалары муниципаль китапханәләрнең бердәм системасына берләшә, анда 2 үзәк китапханә һәм 48 китапханә филиалы керә.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары.** Казанда беренче көндәлек матбугат органы «*Казанские известия*» (1811) г-тасы була. 1821 дә «Казанский вестник» айлык ж-лы басыла башлый. «Заволжский муравей» (1832–34) ж-лы Казан губернасында иң беренче хосусый басма була. Беренче фәнни басма — «*Учёные записки Казанского университета*» (1834). 1838 дә рәсми «*Казанские губернские ведомости*» г-тасы чыга башлый. 1900 дә К.да 21 даими басма нәшер ителә. 1905 тә татар телендә беренче «*Казан мөхбире*» г-тасы, 1906 дан «*әд-Дин вә әл-әдәб*» ж-лы басыла. 1900 дән алып 1917 нең февраленә кадәр К.да рус телендә 36, татар телендә 23 газета һәм журнал чыга. Иң эре татар газеталары — «Бәянелхак», «Кояш», «Йолдыз»; журналлардан — «Аң», «Мәктәп», «Сөембикә», «Тәрбия», «Ялт-Йолт», «Яшен» нәшер ителә. Окт. рев-циясеннән соң шәһәрдә матбугатны, радиотапшыруларны, телевидениене (к. *Газета, Журнал, Радиотапшырулар, Телевидение тапшырулары*) үз эченә алган массакүләм мәгълүмат чараларының яңа структурасы оеша. 1930 елларда, Казанны районлаштырганнан соң, күп кенә шәһәр районнарында җирле хакимият органнары басмалары — «За большевистские темпы» (Шәһәр яны р-ны), «За вторую пятилетку» (Сталин р-ны) г-талары һ.б. басыла башлый. Хәзерге вакытта К.да «*Ватаным Татарстан*», «*Восточный экспресс*», «*Время и деньги*», «*Молодёжь Татарстана*», «*Республика Татарстан*», «*Татарские края — Татар иле*», «*Татарстан яшьләре*», «*Сабантуй*» һ.б. республика газеталары, ш.у. «*Вечерняя Казань*», «*Казанские ведомости*», «*Шәһри Казан*» чыга. К.да чуаш телендә «Сувар» республика г-тасы нәшер ителә. Иң абруйлы һәм яратып укыла торган журналлар: «Идел», «Казан утлары», «Казань», «Мәгариф», «Татарстан», «Сөембикә», «Чаян», «Ялкын». Казанда чыга торган «Научный Татарстан», «Неврологический вестник имени В.М.Бехтерева», «Фән һәм мәктәп» — «Наука и школа», «Вертеброневрология» һ.б. фәнни журналлар бөтен Россиядә билгеле. 1990 елларда Казанда район газеталары яңадан басыла башлый: «Московский район», «Панорама Советского района», «Приволжский район» һ.б. Казанда радиотапшырулар тарихы 1918 нең 20 мартында Казан кабул итү радиостанциясе сафка баскач башлана. 1919 да Кызыл Армиянең *Радиотелеграф оешмаларының Казан базасы* оеша. 1921нең маенда К.да, Россиядә беренче буларак, репродуктор куела.

1928 дән татар һәм рус телендә, 1933 тән чуаш телендә даими радиотапшырулар башлана. Казанда ТРның төп дәүләт радиотапшырулар компанияләре — «*Татарстан*» *дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе* (ДТРК «Татарстан») һәм «*Яңа гасыр*» *телерадиокомпаниясе* (ТНВ) эшли. 1990 елларда шәһәрдә FM диапазонында эшләүче дәүләтнеке булмаган радиостанцияләр оештырыла. Хәзерге вакытта, гомумроссия радиоканаллары б-н бергә, җирле иң популяр радиостанцияләр эшли: «Бим-радио», «Love-радио», «Пульс-радио», «TATAR RADİOSI», «Курай» һ.б. 1959 да К.да телевидение тапшырулары күрсәтелә башлый. Хәзерге вакытта шәһәрдә телевидение тапшыруларын республика компанияләре — «Яңа гасыр» телерадиотапшырулар компаниясенең «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалы, «Татарстан» ДТРК һәм җирле «Эфир», «Вариант», «СТС-Казан», «ТНТ-Казан», «Казан», «Муз-ТВ Казан» каналлары алып бара. Иң зур канал — «Татарстан — Яңа гасыр», ул тамашачыларга телевидение тапшыруларының тулы спектрын — яңалыклар, иҗтимагый-сәяси тапшырулар, телесериаллар, ток-шоулар, спорт матчлары һәм тамаша чараларын — турыдан-туры трансляцияләп күрсәтә. Хәбәрләр Россиянең Европа өлешенә, Урал, Көнбатыш Себер, БДБнең барлык илләренә диярлек һәм ерак чит илләрнең кайберләренә Eutelsat W 4 (көнчыгыш озынлыкның 36 гр.) иярчене аша тапшырыла. 2000 еллар башыннан ТРда кабелле һәм спутниклы телевидение тапшырулары системасы тык үсә, шул сәбәпле, халык РФнең башка төбәкләрендәге каналларны гына түгел, чит ил телекомпанияләре тапшыруларын карау мөмкинлегенә дә ия. 2001 дән кабелле телевидение трансляцияләре башлана, хәзер бу эшне «ТВТ», «Радиосет», «Dom.ru» компанияләре башкара, 2000 еллар ахырыннан алар цифрлы телевидение тапшыруларын күрсәтә. К.да дәүләт информация сәясәтен һәм массакүләм мәгълүмат чаралары эшен координацияләүне «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы башкара. «Татмедиа» агентлыгы Татарстан массакүләм мәгълүмат чаралары порталын (www.tatmedia.com) булдыра, анда К.ның матбугат органнары, радио һәм телевидение редакцияләре шәһәр яңалыкларын урнаштыра. К.да «Интерфакс», «РИА-новости», «ИТАР-ТАСС» гомумроссия мәгълүмат агентлыкларының җирле бүлекләре бар. Татарстан башкаласында «Татар-информ» информация агентлыгы эшли, ул — РФнең 20 иң эре мәгълүмат агентлыкларыннан берсе.

**Сынлы һәм бизәлеш сәнгате.** К. терр-ясендә иң борынгы сәнгать ядкәрләре 10–12 йөзләргә караган әвәләп һәм балчыктан ясалган болгар керәч көнкүреш әйберләре, бронза һәм бакыр бизәнү әйберләреннән торган археол. табылдыклар буларак билгеле (к. *Болгар сәнгате*), Аргы (Урта) Кабан күле буенда Казан аксөякләренең элеккеге зираты табылган җирдә 13 йөз кабер ташларындагы каллиграфия һәм ташка уеп бизәк төшерүнең уникаль үрнәкләре сакланган. Татар гамәли бизәлеш һәм монументаль бизәлеш сәнгатенең, нәфис һөнәрчелекнең чәчәк атуы Казан ханлыгы чорына туры килә. Рус елъязмаларыннан, Казан Кремлендәге табылдыклар-

дан һәм Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы, Мәскәүдәге Дәүләт тарих музее, ТР Милли музее тупланмаларында саклanучы 15–16 йөз истәлекләреннән күренгәнчә, башкалада сәнгатьнең ташка һәм гипска уеп бизәк төшерү, чирәп б-н бизәлгән кирпеч, металл, күнгә бизәк төшерү, укалап чигү, зәркәнчелек (к. «*Казан бүреге*») кебек төрләре зур үсеш ала. Каллиграфия сәнгате К. ханнары Ибраһим һәм Сәхибгәрәй (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*) ярлыкларында һәм кабер ташларындагы эпиграфик язмаларда чагыла. 16 йөз уртасында, К.ны рус гаскәрләре басып алу б-н, татар сәнгате үсеше туктап кала, нәфис сәнгатьнең ташка һәм гипска уеп бизәк төшерү, мозаика һәм майолика, китап бизәү һәм каллиграфия, металлны кыздырып эшкәртү, керәч сәнгате, йөнтәс келәм туку һәм сәнгатьнең башка төрләре юкка чыга. Шәһәр нәфис һөнәрчелеге һәм бизәлеш сәнгате традицияләренең берникадәр үсеше Казан артындагы татар милли-мәдәни учаклары сакланган кайбер авылларда гына дәвам итә. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан К.да рус провинциаль җирле сәнгатьнең үзенчәлекләрен чагылдыручы монументаль чиркәү нәкыше (фрескалы диварлар), икона язу, китапларны рәсем б-н бизәү, чиркәүдә алтын б-н чигү, зәргәрчелек, көнкүреш керамикасы, ялтыравыклы чирәп кирпеч кебек сәнгать төрләре үсә башлый. 18 йөз башыннан К.да рус сәнгате *барокко* стиле йогынтысында була, ул гыйбадәтханәләр һәм дөньяви биналарны бизәүдә (ташны уеп бизәк төшерү, гипстан әвәләп ясау) һәм *иконостасларда* агачка уеп монументаль бизәк төшерүдә үсеш ала.

18–19 йөзләрдә классицизм стиле ныгый, ул җәмәгать һәм гражданлык биналарының эчке һәм тышкы күренешенең архитектур бизәлешендә, Казандагы беренче проф. рәссамнар — нәкышьчеләр Л.Д.*Крюков*, Л.Л.Крюков һ.б.ның иҗатында чагыла. 19 йөзнең 1 нче яртысында шәһәрнең нәкышь һәм график образы *романтизм* стилендә эшләүче пейзажчылар В.С.*Турин*, Э.-П.*Турнерелли*, А.Н.*Ракович* әсәрләрендә гәүдәләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында К. сынлы сәнгать, сәнгать белеме һәм музейлар оештыруның (к. *Музейлар*) эре үзәгенә әйләнә. 1895 тә *Казан сәнгать мәктәбенә* нигез салына, ул талантлы нәкышьче һәм графиклар плеядасын (Н.И.*Фешин*, Д.Д.*Бурлюк*, А.М.*Родченко*, П.П.*Беньков*, П.А.*Радимов* һ.б.) тәрбияли. К. ун-тының нәфис сәнгать теориясе һәм тарихы кафедрасында Россиянең атаклы сәнгать белгечләре Д.В.*Айналов*, Б.П.*Денике*, В.К.*Мальмберг*, А.М.*Миронов*, А.Н.*Смирнов* (к. *Сәнгать гыйлеме*) эшли. К. коллекционерларының шәхси тупланмалары шәһәрдә оештырылган сәнгать күргәзмәләренә куела. 1895 тә археолог А.Ф.*Лихачёв* тупланмалары нигезендә бай картиналар галереясы булган Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музее ачыла. К. коллекционеры һәм библиофил А.Ф.*Мантель* 1912 дә сәнгать китапларын бастыручы «На рассвете» нәшриятын оештыра.

18 йөзнең 2 нче яртысында Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә нәфис һөнәрчелек яңадан торгызыла башлый, һәм татар гамәли бизәлеш сәнгатенең каюлы күн, укалап чигү, зәргәрчелек, ташка уеп бизәк ясау кебек төрләре үсеш ала. 1840 елларда, һөнәрчеләрнең остаханәләре б-н беррәттән, фабрика тибындагы пр-тиеләр күренә башлый, алар күннән бизәкле читекләр (к. *Каюлы күн һөнәре*) тегә. Укалап чиккән баш киемнәре (ирләр түбәтәйләре һәм хатын-кыз калфаклары) Россиядә зур уңыш казана һәм чит илләргә дә чыгарыла. Гарәп язуының проф. хаттатчылык традицияләре һәм китап миниатюралары (М.*Мәхмүдов*) яңадан торгызыла. Коръән аятьләре язылган *шәмаилләр* — нәкышь (майлы буяу б-н пыялага сурәт төшерү) һәм басма (литография һәм типография ысулы б-н) график паннолар барлыкка килә. 19–20 йөзләр арасында К.да хаттатлар Г.*Сәлиев*, М.*Идриси*, М.*Хуҗасәетов* һ.б. эшли. Татар халкының милли мәдәнияте үсеше һәм җәдитчелек идеяләре таралу дулкынында, *сынлы сәнгатьнең* европача төрләрен үзләштергән беренче татар рәссамнары иҗаты формалаша. Алар арасында графиклар, китап һәм журнал бизәүчеләр (Г.*Камал*, И.*Юзеев*, Г.Гомәрев, Г.Табылдиев), театр рәссамнары һәм декораторлары (С.*Яхшыбаев*, Н.Вахитов), татарлардан беренчеләрдән булып югары сәнгать уку йортларын тәмамлаучылар (Х.*Акчурина*, Ш.*Таһиров*, К.Дәүләткилдиев) бар.

20 йөзнең беренче унъеллыгында К.да сынлы сәнгать сизелерлек үсеш ала. 1920 елларда авангард (футуризм, конструктивизм һ.б.), «суллар» (*ТатЛЕФ*, *СУЛФ*, «*Подсолнечник*», «*Всадник*», *КЭМСТ*) һәм реалистик «уңнар» (*ТАТАХРР*, «*Октябрь*») идея-стиль агымнары аеруча күзгә ташлана. К. рәссамнары П.П.Беньков, В.С.*Богатырёв*, В.Э.*Вильковиская*, Ф.П.*Гаврилов*, А.Н.*Коробкова*, В.В.*Кудряшов*, И.А.*Никитин*, А.Г.*Платунова*, И.Н.*Плещинский*, П.А.Радимов, Н.М.*Сокольский*, С.С.*Федотов*, К.К.*Чеботарёв*, Н.С.*Шикалов* һ.б.ның иҗаты үзенчәлекле булулары һәм яңалык алып килүләре б-н аерылып тора. Милли сынлы сәнгатьтә яңа чорны 1920 елларда Б.*Урманче*, Г.Камал, Ф.*Таһиров*, Ш.*Мөхәммәтҗанов*, Г.*Арсланов*, Д.Н.*Красильников* иҗатлары ача. Сынлы сәнгатьне пропагандалауда һәм музей эшләрен оештыруда К.да сәнгать белгечләре П.М.*Дульский* һәм П.Е.*Корнилов* актив эш җәелдерә. Әмма 1920 еллар ахырында мәдәният өлкәсендәге идеологик диктат һәм күп кенә рәссамнарның (П.П.Беньков, А.Г.Платунова, П.А.Радимов, Ф.Таһиров, Б.Урманче, К.К.Чеботарёв һ.б.) К.нан китүе сәбәпле, сынлы, башлыча нәкышь сәнгатендә сыйфатның түбән төшүе күзәтелә. Нәфис һөнәрчелек остаханәләре ябыла, *бизәлеш сәнгатенең* күп кенә традицион төрләре (шәмаил, зәргәрчелек, нәфис туку һ.б.) юкка чыга. 1930 еллар башыннан рәссамнар иҗаты соц. реализм алымы йогынтысында үсә, һәм аның ныгуында 1935 тә К.да оештырылган ТАССР Совет рәссамнары берлеге (к. *Татарстан Республикасының рәссамнар берлеге*) мөһим роль уйный. 1930–40 елларда станлы һәм монументаль скульптура өлкәсендә С.С.*Ахун* актив эшли; рәссам-графиклар Б.М.*Әлминов*, Җ.Г.*Булат*, Ф.З.Ильясов, Г.Я.Мусин «Чаян» ж-лы һәм Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итәләр; театр декорациясе сәнгате яңа талпыныш ала (М.М.Абдуллин, В.С.Никитин, П.Т.Сперанский). Станлы нәкышь сәнгатендә, элеккеге буын осталары (Д.П.*Архипов*, Н.М.*Сокольский*, В.К.*Тимофеев*) б-н беррәттән, реализм мәктәбе традицияләрен Н.К.Вәлиуллин, И.И.*Князьков*, К.Е.*Максимов*, В.А.*Родионов* һ.б. дәвам итә. Бөек Ватан сугышы чорында К.да «Сатира тәрәзәләре»ндә сәяси плакатлар һәм фашизмга каршы юнәлтелгән рәсемнәр басыла (к. *Графика*). 1950 елларда рәссамнар, нигездә, нәкышьчеләр төркеме (Б.М.Әлминов, Н.Г.*Бикташев*, В.И.*Куделькин*, Р.М.*Нурмөхәммәтов*, И.В.*Рәфыйков*, Г.Г.*Рахманкулова*, Э.Г.*Ситдыйков*, Ә.И.*Тумашев*, М.Г.*Усманов*, Б.И.Урманче, Л.Г.*Фәттахов*, Х.Х.*Хәйдәров*, И.М.Хәлиуллов, Х.Г.*Якупов* һ.б.) оеша, һәм соңрак аларның әсәрләрендә милли-төбәк мәктәбенең реалистик традицияләре үсеш ала. 1970–80 елларда бу мәктәп сынлы сәнгатьнең төрле тармакларында иҗат итүче осталар плеядасы б-н тулылана, аларның иҗаты әсәрләрнең милли формасын табуда стиль тенденцияләренең күптөрлелеге б-н аерылып тора (А.Х.*Әбдерәшитов*, У.Н.*Абдуллов*, А.Ә.*Абызгилдин*, Н.И.*Гаделев*, И.К.*Әхмәдиев*, И.Н.Башмаков, З.Ф.*Гыймаев*, Р.Ә.*Госманов*, И.К.*Зарипов*, Э.Я.*Зарипов*, Р.Ш.*Кәримуллин*, Р.Ә.*Килдебәков*, И.К.*Колмогорцева*, В.М.*Маликов*, М.К.*Мавровская*, Ш.Г.*Нигъмәтуллин*, Р.Х.*Нигъмәтуллина*, В.Н.*Скобеев*, М.Г.*Сутюшев*, Ф.Н.*Фәсхетдинов*, В.К.*Фёдоров*, Т.Г.*Хаҗиәхмәтов*, Ш.М.*Шәйдуллин* һ.б.). Монументаль бизәлеш (дивар сурәтләре, мозаика, витраж, гобелен һ.б.) һәм театр декорациясе сәнгате, скульптура зур үсеш ала. 1980 еллар ахырыннан яңа идея-сәнгать агымнары үсеше башлана. Казан рәссамнары иҗатында, реализм традицияләре б-н беррәттән, хәзерге заман сәнгать дөньясына хас стиль юнәлешләре: постмодернизм, неопримитивизм, абстракционизм, концептуаль сәнгать һ.б. (А.М.Артамонов, Н.У.*Әлмиев*, А.В.Бусыгин, Р.М.Вахитов, Р.Х.Гайсин, Б.А.Гильванов, Е.Г.Голубцов, А.И.Дорофеев, А.Р.*Ильясова*, Н.Х.*Кумысникова*, Р.С.*Насыйров*, М.Х.Самакаев, Р.Т.*Сафиуллин*, А.С.Федотов, И.А.*Хәсәнов*, Ф.Ш.*Хәсьянова* һ.б.) үсеш ала. Ислам, бигрәк тә гарәп каллиграфиясе һәм шәмаилләр сәнгате б-н бәйле традицияләр кире кайтарыла (Н.Ф.*Исмәгыйлев* (Нәкъкаш), В.А.*Попов*, Л.Ф.Фәсхетдинова, Р.Г.*Шәмсетдинов*, Р.И.Шәмсутов). Сынлы сәнгатьнең барлык тармакларында тарихи тематика, татар халкының үткәненә яңача караш төп урынны ала башлый (Р.Г.*Заһидуллин*, М.М.*Гасыймов*, К.А.*Нәфыйков*, И.Фәйзуллин, Н.Т.*Хаҗиәхмәтов*, Ф.Г.*Халиков* һ.б.).

Рәссамнарның «Дастан», «Группа 17», «ДД» (к. *Дизайн*), «Тамга» кебек иҗат берләшмәләре барлыкка килә, алар тарафыннан күргәзмәләр оештырыла, фестивальләр («Дизайн дөньясы» һ.б.), конкурслар (С.Сәйдәшев, Б.Урманче һәйкәлләренә, Казанны саклаучыларга, шәһәрнең 1000 еллыгына багышланган проектлар; 1996 дан — боздан

ясалган «Кар барсы» скульптуралар конкурсы) һ.б. акцияләр үткәрелә. Сынлы сәнгать үсешендәге проблемалар, Казанның әйдәп баручы рәссамнары иҗаты төрле фәнни хезмәтләрдә, күргәзмәләр каталогларында, «Казан» әдәби-сәнгать ж-лында һәм вакытлы матбугатның башка басмаларында яктыртыла. Шәһәрдә ТР Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залы, ТР Сынлы сәнгать музее, «Казан» милли мәдәният үзәге каршындагы Милли мәдәният музее, Б.Урманче музее (1999 да аның исем. премия булдырыла), К.А.*Васильев*, И.К.*Зарипов* картина галереялары, шәхси галереялар («Камил», «Зәйнәп» һ.б.) эшли. 2003 тә ТР Халык нәфис һөнәрчелеге үзәге оештырыла. Татар гамәли бизәлеш сәнгате традицияләре «Туран АРТ» (чигү, укалап чигү, каюлы күн), «Традиция» (укалап чигү), «Болгари» (каюлы күн), «Ташбака» (керәч) һ.б. сәнгать остаханәләре фондлары эшләнмәләрендә яңадан торгызыла.

**Театр.** Казан славян-латин мәктәбе укучылары тарафыннан Казанда халык театр тамашаларының 1723 елда куелуы билгеле. 1764 тән Казандагы беренче гимназиядә укучылар һәм укытучылар көче б-н даими рәвештә спектакльләр куела. 1791 дә Казан губернаторы кенәз С.М.Баратаев юлламасы нигезендә Петербург актёры В.С.Бобровский җитәкчелегендә шәһәр халык театры ачыла. 1802 дә Император театрлары конторасы рөхсәте б-н алпавыт П.П.*Есипов* Покров һәм Грузин урамнары кушылган урында (Театр мәйданы, хәзерге Ирек мәйданы) шәһәрдә театр мәдәниятен формалаштыруда зур роль уйнаган агач театр төзи. Аларда спектакльләр даими куела һәм башкарылу дәрәҗәсенең шактый югары булуы б-н аерылып тора. Беренче актёрлар арасында М. һәм Ф. Аникиевлар, А. һәм Н. Комяковлар, Ф.Львов була. 1805 тә әлеге театр сәхнәсендә рус реалистик театр мәктәбенә нигез салучыларның берсе — актёр һәм драматург П.А.Плавильщиков уйный. 1830–40 елларда Казанда Н.И.Иванов, П.А.Соколов җитәкчелегендә труппалар эшли. Әлеге еллар атаклы рус актёрлары П.С.Мочалов, А.Е.Мартыновның Казандагы гастрольләре, М.С.Щепкинның чыгышлары б-н истәлекле. 1836 ның көзендә Казанда аның тарафыннан Н.В.Гоголь пьесасы буенча «Ревизор» спектакле куела. Театрның техник җиһазланышы ягыннан Россиядә иң яхшылардан саналган таш бинасы төзелеше 1849 да тәмамлана. Казанда Н.К.Милославский, П.М.Медведев, М.М.Бородай, Н.И.Собольщиков-Самаринның театр абруен үстерүче иң зур антрепризалары чоры башлана. Казан театры сәхнәсендә В.Н.Давыдов, К.А.Варламов, А.П.Ленский, М.Г.Савина, П.А.Стрепетова, М.В.Лентовский, В.А.Макшеев, М.А.Решимов, А.А.Рассказов, Е.Б.Пиунова-Шмидгоф, М.И.Свободина-Барышева, А.И.Каширин, Н.В.Пальчикова, В.И.Качаловның талантлары ачыла. Соңрак алар рус сәхнәсенең данын үстерәләр. Биредә М.И.Писарев, В.Н.Андреев-Бурлак, М.Т.Иванов-Козельский; Ф.П.Горев, И.М.Шувалов, Е.П.Шебуева, А.П.Двинский, Е.О.Любимов-Ланской, М.М.Тархановлар уйный. К.да В.Ф.Комиссаржевская, М.В.Дальский, Г.Н.Федотова, П.Н.Орленев, Ю.М.Юрьев, 1860 елларда танылган Америка трагик артисты А.Олдридж берничә тапкыр гастрольләрдә була. Казан җәмгатьчелеге тормышында театрның роле 19 йөз ахырында аеруча үсеш ала. Яңа театр биналары төзелә. 1900 дә сәнәгатьче И.И.Алафузов үз пр-тиеләре эшчеләре өчен халык театры («*Алафузов театры*») төзи. Анда һәвәскәрләр төркеме һәм профессиональ труппаларның спектакльләре куела. 1909 да — үзендә театр залы булган Сәүдәгәрләр җыены клубы (хәзерге ТЮЗ), 1912 дә — Яңа театр (хәзерге Татар драма һәм комедия театры), 1914 тә Зур театр ачыла. Спектакльләр ш.у. Постаучылар бистәсендәге Н.В.Гоголь исем. театрда, Евангелистлар урамындагы (хәзерге Татарстан урамы) Шәрекъ клубы, Пушкин урамындагы Приказчиклар клубы сәхнәләрендә, Панаев, «Эрмитаж», «Аркадия» шәһәр бакчаларындагы җәйге театрларда да уйнала. 1906 да «*Шимбәчеләр*» түгәрәгенә йөрүче һәвәскәрләр төркеме тарафыннан татар телендә беренче тапкыр халык спектакле куела. 1907 дә К.да И.Б.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге «Россиядә беренче мөселман драма артистларының күчмә труппасы» гастрольләре була, 1908 дән биредә татар проф. театрына нигез салган «*Сәйяр*» драма труппасы еш кына чыгышлар ясый. Беренче актёрлар арасында Г.Кариев, В.Мортазин-Иманский, Н.Сакаев, З.Солтанов, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Н.Таждарова, К.Шамил, К.Тинчурин, Н.Арапова, бертуган Камаллар, С.Айдаров, Р.Кушловская, Б.Тарханов, Ш.Шамильский, Г.Болгарская, З.Богданова була. 1920–21 елларда күчмә татар труппалары нигезендә Беренче татар дәүләт театры төзелә. 1922 дән ул үз бинасында урнаша (элекке Сәүдәгәрләр җыены клубы), 1926 да аңа *Татар академия театры* дигән рәсми исем бирелә (сәнгать җитәкчесе итеп К.Тинчурин билгеләнә). Зур театр бинасында һәм Елга аръягы Эшчеләр сараенда (элекке «Алафузов театры») эшләп килүче Татар театры һәм рус драма төркемнәре, опера театры күрсәтмә театрлар рәтендә йөри, һәм аларның эшчәнлекләре шәһәр бюджетыннан тәэмин ителә. 1920 елларда Казан Зур драма театрында В.С.Зотов, З.М.Славянова, А.М.Кречетов, С.И.Днепров, П.Л.Вульф, А.Г.Георгиевский, В.В.Белокуров, М.Ф.Астангов, П.И.Герага, М.И.Жаров, М.И.Царёв, А.Л.Грипич, Л.Ф.Лазарев эшли. Бер үк вакытта хосусый антрепренёр театрлар да эшләүләрен дәвам итә. 1923–26 елларда үзенең эстетик принциплары ягыннан В.Э.Мейерхольд һәм С.М.Эйзенштейн театрларына якын торган Б.Н.Симолин җитәкчелегендәге *Хәзерге заман театрының конструктив-тәҗрибә остаханәсе* куйган спектакльләр Казан театр тормышында зур вакыйгага әверелә. 1932 дә Үзәк пионерлар клубы каршында рус һәм татар төркемнәреннән торган Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) төзелә, 1934 тә Беренче дәүләт интернациональ курчак театры эшли башлый. 1935 тә ТЮЗның рус төркеме дәүләт театры итеп үзгәртелә. 1933 тә Татар акад. театры каршында хәзерге Татар драма һәм комедия театрына башлангыч биргән колхоз ф-лы оештырыла. 1930–40 елларда Татар акад. һәм Казан Зур драма театрларында көчле иҗади составтан торган сәнгать коллективлары оеша, иҗат эшчәнлегенең төп принциплары һәм юнәлешләренә нигез салына. Бу күренешләр әлеге театрларның илдә иң яхшы театрлар рәтенә керүенә булышлык итә. К. театр сәнгатенең сәнгати дәрәҗәсен татар театрында Х.Г.Әбҗәлилов, Г.С.Камская, Г.Ф.Булатова, Х.Й.Сәлимҗанов, Камал III, Г.В.Ибраһимова, М.И.Надрюков кебек актёрларның, К.Г.Тинчурин, Г.Г.Исмәгыйлев, С.С.Булатов, Ш.М.Сарымсаков кебек режиссёрларның һәм рус театрында актёрлардан Г.П.Ардаров, Е.Е.Жилина, Ф.В.Григорьев, А.Д.Гусев, И.В.Загорский, Л.П.Милова, Н.И.Якушенко, режиссёрлардан И.А.Ростовцев, Б.С.Великанов, Е.А.Простовларның иҗат эшчәнлекләре билгели. Спектакльләргә Мәскәү һәм Ленинградтан режиссёрлар: В.М.Бебутов, А.Дикий, Е.Гаккель, Л.Прозоровский чакырыла. 1874 тән алып 1920 еллар ахырына кадәр К.да уздырыла торган опера сезоны спектакльләре традицияләрен торгызып, 1939 да опера театры (к. *Татар опера һәм балет театры*) ачыла. Аның труппасының нигезен Татар опера студиясен тәмамлаган У.Г.Әлмиев, М.З.Булатова, Г.М.Кайбицкая, А.С.Измайлова, Ф.Х.Насретдинов тәшкил итә; театрның әдәби бүлеген М.Җәлил җитәкли. Бөек Ватан сугышыннан соң татар театры сәхнәсенә Ш.И.Әсфәндиярова, Ш.Х.Биктимеров, Г.Р.Шамуков, П.Н.Исәнбәт, А.А.Галиева, Х.Б.Җәләлов, В.Е.Минкина, Ф.И.Халитов, Р.А.Тажетдинов, Р.Ш.Шәрәфиев, Ә.Ш.Шакиров, Н.Х.Гәрәева, режиссёрлар Г.Ф.Йосыпов, Р.Р.Тумашев килә; татар театры үсешендә режиссёр М.Х.*Сәлимҗанов* күренекле роль уйный.

Бу елларда рус театрында В.М.Павлова, Н.С.Провоторов, В.И.Улик, Е.А.Кузин, В.В.Кешнер, Л.В.Маклакова, Ю.С.Федотов, В.Г.Остропольский, Л.Б.Кара-Гяур, П.П.Бетев, Г.С.Ишкова, режиссёрлар Л.М.Литвинов, Н.Ю.Орлов эшли. Казан театр коллективларының 1957 дә Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә чыгышлар ясавы, бөтенсоюз һәм бөтенроссия театр фестивальләрендә катнашуы илнең театр тормышында зур вакыйга була. 1990 еллардан Казан театрлары чит илләргә гастрольләр б-н чыга, халыкара театр фестивальләрендә катнаша башлый. К.да Татар акад. театры, Татар опера һәм балет театры, Казан Зур драма театры, Татар драма һәм комедия театры, Казан Рус яшь тамашачылар театры (ТЮЗ), Казан татар яшь тамашачылар театры, «Әкият» татар курчак театры эшли.

**Кино.** 1897 елда К.да беренче тапкыр «җанлы сурәтләр» һәм берничә кыска хроникаль тасма күрсәтелә. 1898 дә шәһәр театры артистлары турында беренче шәхси кинолар төшерелә. 20 йөзнең беренче унъеллыгында кинопрокат эше көчле үсеш ала, кинотеатрлар төзелә, кинозаллар ачыла, трактирлар, ярминкә һәм күргәзмәләрдә киноҗайланма-

лар киң кулланыла һ.б. Бер үк вакытта шәһәрдәге әһәмиятле вакыйгалар турында: «Ослан. Каеклар ярышы», «Казанда ак чәчәкләр көне» һ.б. фильмнар төшерелә. 1921 дә — Гражданнар сугышына багышланган «Казанны алу» фильмы, 1926 да Сабан туен бәйрәм итү турында фильмнар эшләнелә. 1927 дә К.да «*Булат Батыр*» нәфис фильмы төшерелә. Ул 1928 дә дөнья күрә. «Унион», «Электро», «Чаткы», «Рот-Фронт» һ.б. кинотеатрларда үзебездә һәм чит илләрдә төшерелгән фильмнар күрсәтелә (к. *Кинематограф*).



«Мир» кинотеатры.

1932 дән «*Киң Иделдә*» даими киножурналын, документаль-хроникаль кинофильмнар чыгаручы һәм нәфис фильмнарны Идел буе һәм Урал буе халыклары телләренә тәрҗемә итүче Казан кинохроника студиясе эшли. 20 йөзнең соңгы елларында студиядә нәфис фильмнар төшерелә башлый («Күк тау», 2002; «Зөләйха», 2003). 2011 дә К.да 11 кинотеатр эшли.

**Цирк**. 19 йөз ахырына кадәр К.да цирк сәнгате ярминкә кәмитләре рәвешендә яшәп килә, анда традицион Петрушка б-н беррәттән акробатлар, жонглёрлар, фокусчылар катнаша. 1890 елда бертуган Никитиннар К.да беренче стационар цирк төзиләр, аның аренасында күренекле цирк артистлары (Дуровлар, Лазаренко, Кио, Алли-Вад, Кантемировлар, Труцци һ.б.) чыгыш ясый. 1956 да беренче татар цирк коллективы оештырыла (сәнгать җитәкчесе — А.Хәбибуллин). 1967 дә үзенчәлекле проект буенча шәһәрнең истәлекле урыннарының берсе булган *Казан циркы* бинасы төзелә. 1969 да аның каршында Үзәк цирк сәнгате студиясе ф-лы ачыла, 1996 да цирк мәктәбе эшли башлый.

**Музейлар.** Беренче музейлар К.да 19 йөз башында барлыкка килә. 19 йөз — 20 йөз башларында Казан руханилар академиясе каршында этнография музее, Казан сәнгать мәктәбе һәм Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты каршындагы музейлар, Казан епархиясенең тарих-археол. җәмгыяте каршындагы борынгы ядкәрләрне саклау урыны, Казан икътисад җәмгыяте каршында умартачылык (Россиядә беренче), Казан ун-ты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте музейлары, Казан губерна земствосы каршында Үзәк вак сәнәгать һәм һөнәри белем музее оештырыла. 1895 тә Шәһәр фәнни-сәнәгать музее (к. *Татарстан Республикасының Милли музее*) ачыла, ул хәзер Респ-ка башкаласы һәм районнарындагы музейлар өчен фәнни-методик үзәк булып тора. Аның сәнгать коллекцияләре җирлегендә 1958 дә *Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее* оештырыла. 1920–24 тә К.да музей эшләре буенча Россиядә беренче «*Казанский музейный вестник*» ж-лы нәшер ителә. 1930–40 та *Ленин В.И. музей-йорты*, *Горький А.М. әдәби-мемориаль музее* төзелә. 1960–2000 дә музей эшләре б-н идарә итүнең үзәкләштерелүе нәтиҗәсендә, Дәүләт музее җирлегендә яңа музейлар челтәре булдырыла (*Җәлил Муса музей-фатиры, Камал Шәриф музей-фатиры, Боратынский Е.А. әдәби музее, Тукай Габдулла әдәби музее, Сәйдәшев Салих музее, Җиһанов Нәҗип музей-фатиры, Насыйри Каюм музее* һ.б.). Мәктәпләрдә хезмәт һәм сугышчан дан музейларын оештыру хәрәкәте зур колач ала. Югары уку йортлары каршында (мед., техник, технол. ун-тлары, вет. академиясе, *Казан университеты тарихы музее* һ.б.), А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты каршында (*Казан химия мәктәбе музее)*, А.Е.Арбузов исем. Органик һәм физик химия ин-ты каршында (*Арбузовлар А.Е. һәм Б.А. музей-йорты*), ГИДУВ каршында ведомство музейлары булдырыла. Эчке Эшләр министрлыгы, Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе музейлары, ТРның Элемтә министрлыгы каршында элемтә музее оештырыла. Татар акад. театры, Казан Зур драма театры, Татар опера һәм балет театры каршында театр сәнгате музейлары эшли. 20–21 йөзләрдә «*Казан Кремле»* тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы, «Казан» милли мәдәният үзәге музейлар комплексы, *Урманче Бакый музее*, К.А.Васильев картиналар галереясы, И.К.Зариповның галерея-студиясе оештырыла. К. музейлары зур фәнни-тикшеренү, мәгърифәтчелек, туплау һәм методик эшләр алып бара. Алар «Горький», «Шаляпин», «Каменев», «Тукай», «Сәйдәшев» әдәби укулары, «М.Җәлилне искә алу көннәре», фәнни-практик конференцияләр үткәрә. Илнең иң зур музейлары б-н бергә (Россия Дәүләт музее, Третьяков галереясы, Сәнгать академиясе музее, Дәүләт Эрмитажы) масштаблы экспозиция-күргәзмә проектлары тормышка ашырыла. Фәнни мәкаләләр, монографияләр җыентыклары, буклетлар бастырыла. 1995 тән «ТР Милли музееның еллык басмалары» чыгарыла. К.да музей эшләрен үстерүгә А.А.Штукенберг, Н.П.Загоскин, В.П.Васильев, Н.Ф.Катанов, Н.Ф.Высоцкий, Б.Ф.Адлер, П.М.Дульский, А.М.Миронов, М.Г.Худяков, М.Е.Евсевьев, В.М.Дьяконов, Н.И.Воробьёв, Е.Г.Бушканец, М.Н.Елизарова, С.В.Писарева, Ю.И.Петров, Г.А.Могильникова, Л.Г.Вәлиева, Г.С.Муханов зур өлеш кертә.

**Музыка.** Казан ханлыгы чорында К.да зур үсеш алган музыка сәнгате дини-йолалар (кануннарны саклаучы һәм җирле), дөньяви югары катлау (инструменталь һәм вокаль), хәрби, көнкүреш музыкасы һ.б. төрләрдә һәм жанрларда формалаша. Дәүләтчелек бетерелгәннән соң (1552), татар музыка сәнгате озак еллар төшенкелек чоры кичерә, бу музыка иҗатының җәмгыять өчен әһәмиятле төрләрен югалтуда, жанр һәм стильләрнең тараюында чагыла. 20 йөзгә кадәр милли музыка, нигездә, фольклор җырлары формасында яши. К.дагы рус җәмгыятендә музыка б-н шөгыльләнә башлау 1758 дә Казан беренче гимназиясе ачылу б-н бәйле, анда балаларны тәрбияләүдә театраль-муз. тамашалар кулланыла, һәм бу шәһәрнең мәдәни тормышында сизелерлек вакыйгага әверелә. 1804 тән музыка сәнгатен таратуда мөһим үзәк роль Казан ун-тына күчә. Анда 1860 елларга кадәр музыка классы, һәвәскәр оркестрлар, хорлар эшли, муз. кичәләр һәм концертлар оештырыла. Университетта музыка классының беренче җитәкчесе комп. А.В.Новиков була. 19 йөзнең 2 нче яртысында К.да музыка сәнгатенең күп төрләре яши. Беренче музыка уку йортлары — Лежен ир-балалар пансионы каршындагы музыка классы (1864), Л.К.*Новицкий* музыка мәктәбе (1870), В.Н.*Пасхалов* тарафыннан ачылган (1882) түләүсез музыка теориясе һәм хор б-н җырлау мәктәбе, опера һәм симфоник оркестр дирижёры А.А.*Орлов-Соколовскийның* һәркем өчен ачык музыка мәктәбе (1886) барлыкка килә. Шәһәр музыка тормышының үзгәрүенә 19 йөзнең соңгы чирегендә проф. музыкантлар һәм музыка сөючеләрнең берләшүе булышлык итә, аларның беренчесе «*Казан музыка сөючеләр түгәрәге*» (1881) була. Музыкаль кичәләр оештыру б-н Нәфис сәнгать сөючеләр җәмгыяте һәм Ялгыз җырлау түгәрәге шөгыльләнә. 1874 тә П.М.*Медведевның* даими опера труппасын оештыруы Казанның мәдәни тормышында зур вакыйга була. Казанның опера антрепризалары составында Д.А.Усатов, П.А.Агнивцев, Е.П.Кадмина, А.П.Боначич, Ю.Ф.Закржевский, М.К.Максаков, Ф.А.Ошустович, Э.Ф.Боброва-Пфейфер, А.П.Ухтомская-Баронелли, Н.Н.Фигнер, Л.Г.Яковлев, И.В.Тартаков, дирижёрлар У.И.Авранек, А.А.Орлов-Соколовский, В.И.Сук, И.О.Палицын, Я.А.Позен, режиссёрлар Н.Н.Боголюбов, Я.В.Гельрот чыгыш ясый.

К.да музыка сәнгате үсешенең мөһим этабы 19 йөз ахырына — 20 йөз башына туры килә. Бу өлкәдә иң зур башлангычларның инициаторы — Р.А.*Гуммерт*. Ул Император Рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге эшчәнлеге б-н җитәкчелек итә, аның ярдәмендә камера һәм симф. концертлар уздырыла, атаклы музыкантларның (С.В.Рахманинов, А.Н.Скрябин, Л.В.Собинов, А.В.Нежданова, И.Гофман, В.Ландовска, А.Г.Рубинштейн һ.б.) гастрольләре оештырыла. Казанда туып үскән бөек рус җырчысы Ф.И.*Шаляпин* анда берничә тапкыр чыгыш ясый. Р.А.Гуммерт Казан музыка уч-щесен оештыручы һәм аның беренче директоры була (1904), һәм анда академик музыкаль белем бирү системасына нигез салына.

К. — хәзерге заман татар музыка сәнгатен тудыручы һәм үстерүче иң зур үзәк. 20 йөз башында аның башлангыч формалары барлыкка килүгә (әдәби-муз. кичәләр, концертлар, драма спектакльләренә музыка һ. б.) беренче милли драма труппалары һәм Шәрекъ клубы эшчәнлеге ярдәм итә. 1920 елларда

татар проф. музыкасы аеруча тиз үсеш ала. 1925 тә Г.С.*Әлмөхәммәдов*, В.И.*Виноградов* һәм С.Х.*Габәши* иҗат иткән беренче татар «*Сания*» операсы, 1926 да С.*Сәйдәшевнең* «Зәңгәр шәл», 1928 дә «Наёмщик» муз. драмалары, 1930 да «Эшче» операсы куела. Татар музыка сәнгате тарихында мөһим этап булып *Татар филармониясе* (1937) һәм *Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле* (1938), Татар опера һәм балет театры ачылу (1939), ТАССР Композиторлар берлеге (1939) оештырылу тора. Татар мәдәнияте тарихында Казан консерваториясе ачылу (1945) — әһәмиятле күренешләрнең берсе, ул тиздән югары квалификацияле музыкантлар әзерләүче зур үзәккә әйләнә һәм К.ның муз. тормышын җанландыруда көчле фактор була.

Татар музыка сәнгатенең иң күренекле вәкилләренең тормышы һәм иҗаты К. б-н бәйле: композиторлар С.Х.Габәши, С.Җ.Сәйдәшев, М.Ә.*Мозаффаров*, Җ.*Фәйзи*, Н.Г.*Җиһанов*, З.В.*Хәбибуллин*, А.С.*Ключарёв*, Ф.З.*Яруллин*, Ә.З.*Бакиров*, Р.М.*Яхин*, А.З.*Монасыйпов*, С.Г.*Садыйкова*; дирижёрлар Н.Г.*Рахлин*, Ф.Ш.*Мансуров*; җырчы һәм режиссёр Н.К.*Даутов*; җырчылар Р.В.*Ваһапов*, М.З.*Булатова*, А.З.*Аббасов*, Ф.Х.*Насретдинов*, И.Г.*Шакиров*, В.Г.*Шәрипова*, Х.А.*Бигичев*, Р.И.*Ибраһимов*, З.Д.*Сөнгатуллина*, В.Ә.*Ганиева* һ.б.; балет артистлары Н.Д.*Юлтыева*, Р.Ф.*Садыйков*, С.Х.*Хантимерова*, И.Ш.*Хәкимова* һ.б.

К.да музыка сәнгатен үстерү максатында заманча матди-техник база булдырыла: махсус төзелгән опера һәм балет театры бинасы (2005 тә, реконструкцияләнгәннән соң, яңадан ачыла) бар, 1996 да ТР Зур концерт залының орган куелган яңа бинасы файдалануга тапшырыла, 2000 дә Татар филармониясе карамагына элеккеге С.М.Киров исем. Мәдәният сарае бирелә, 2003 тә эстрада-концерт чаралары үткәрү өчен махсус залы булган «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәге төзелә. Хәзерге К.ның муз. тормышы бай һәм күптөрле булуы б-н аерылып тора. Даими үткәрелә торган күпсанлы халыкара акцияләр: *Шаляпин* Ф.И. *исемендәге опера фестивале, Нуриев* Р. *исемендәге классик балет фестивале*, *«Европа-Азия»* хәзерге заман музыка фестивальләре киң таныла. К.да югары профессиональ муз. коллективлар: ТР Дәүләт симф. оркестры (сәнгать җитәкчесе — А.В.Сладковский), «La Primavera» Дәүләт камера оркестры (сәнгать җитәкчесе — Р.Ю.*Абязов*), ТР Дәүләт халык уен кораллары оркестры (сәнгать җитәкчесе — А.И.*Шутиков*), ТР Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле (сәнгать җитәкчесе — А.Ф.*Фәйзрахманов*), ТР филармониясе джаз-оркестры (сәнгать җитәкчесе — А.А.Василевский) һ.б. эшләп килә.

**VI. Сәламәтлек саклау**

Казанда беренче мед. учреждениеләре 18 йөз башында ачыла: табиб пункты, хәрби госпиталь (пехота полкы лазареты), шәһәр хастаханәсе. Шәһәрдә мед. ярдәме күрсәтү эшен үстерүдә Казан ун-тының мед. ф-ты профессорлары һәм укытучылары зур роль уйный, алар ун-т клиникаларында гамәли эш алып бара (к. *Казан медицина университеты клиникалары*). Беренче даруханәләр 1820 елларда күренә башлый, 1837 дә теш табибләре һәм ир-ат фельдшерлар мәктәпләре ачыла. 1869–70 еллардагы реформалар мед. учреждениеләре челтәре киңәюгә, земство һәм завод-фабрика медицинасы үсешенә, сан. хезмәте барлыкка килүгә китерә. 1869 да губерна психиатрия хастаханәсе төзелә, 1874 тә — беренче (Лихачёв) бала тудыру йорты һәм чәчәк салу ин-ты, 1889 да — беренче балалар, 1899 да йогышлы авырулар хастаханәләре эшли башлый. 1900 дә Казан ун-тының клиника корпусы сафка баса (к. *Казан университетының яңа клиникалары*), бактериология ин-ты (хәзерге Казан эпидемиология һәм микробиология ин-ты) ачыла. 1902 дә Казан шәһәренең табибләр җәмгыяте оештырган ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү хезмәте барлыкка килә, 1910 да *Шамов хастаханәсе* сафка баса.

1911 дә Бөтенроссия туберкулёзга каршы көрәш лигасының туберкулёз б-н авыручыларга акча җыю һәм ярдәм итү б-н шөгыльләнүче ф-лына нигез салына. 1913 тә Казанда 1690 урынга исәпләнгән 18 дәвалау учреждениесе, 8 амбулатория, 1600 урынлы Казан округы психиатрия хастаханәсе (Идел буендагы 7 губернага хезмәт күрсәтә) була, 50 гә якын табиб, 40 тан артык фельдшер һәм акушер, доктор Клячкин клиникасы (су-балчык б-н дәвалау), 23 даруханә эшли. Совет хакимияте урнашу б-н, шәһәрдә халыкка мед. хезмәтен күрсәтүне камилләштерү буенча төрле чаралар үткәрелә. 1919 да район башкарма ком-тларында сәламәтлек саклау секцияләре төзелә, дәвалау учреждениеләре берләштерелә, дары заводы лазареты үзгәртеп корыла. Гражданнар сугышы елларында эшчәнлеге туктатылган ашыгыч мед. ярдәме күрсәтү эше яңадан торгызыла; 1922 дә ул мөстәкыйль берәмлеккә әверелә. Акушерлык ярдәме күрсәтүгә, бала тудыру йортлары ачуга зур игътибар бирелә. 1920 дә К.да үзенең дәвалау базасы (2001 дән 3 нче Республика клиник хастаханәсе) булган Клиник ин-т (хәзер Казан дәүләт мед. академиясе), Каменка посёлогында Туберкулёздан дәвалау санаторие ачыла, санитар-эпидемиология хезмәте секциясе төзелә, 9 дәүләт хастаханәсе, 2 НКВД системасы хастаханәсе эшли. 1921 дә Казанда беренче фармацевтика мәктәбе оештырыла (хәзерге Казан мед.-фарм. уч-щесе), туберкулёзга каршы көрәш диспансеры, 1924 тә стоматология поликлиникасы һәм мед. техникумы (к. *Казан база медицина көллияте*) төзелә. 1920 елларда К.да эпидемиология, микробиология, ортопедия, травматология, туберкулёз, трахома авырулары буенча зур фәнни-тикшеренү ин-тлары эшли. 1930 еллар башыннан амбулатор хезмәт, ана һәм баланы саклау хезмәте күрсәтү үсеш ала, балалар һәм хатын-кызлар консультацияләре, пр-тиеләрдә мед.-сан. частьләре ачыла. 1937 дә туберкулёзга каршы көрәш буенча «Зәңгәр күл» балалар санаторие ачыла. 1930 да Казан ун-тыннан мед. ф-ты аерылып чыга, ул дәвалау, сан.-гигиена, педиатрия ф-тлары булган мөстәкыйль уку йортына (хәзер Казан мед. ун-ты) әверелә; мед.-фарм. һәм мед. уч-щеләре эшли. 1930 еллар ахырында К.да сәламәтлек саклауны оештыру, фәнни тикшеренүләр, мед. кадрлары әзерләүнең дәүләт системасы булдырыла.

Бөек Ватан сугышы елларында шәһәрдә 35 мең урынлы 59 эвакуация госпитале эшли. Аларга иң яхшы биналар (мәктәпләр, клублар, институт клиникалары һ. б.) бирелә, урындагы кадрлардан 300 дән артык табиб-травматолог, 13 нейрохирург, дәвалау гимнастикасы буенча 100 дән артык инструктор, 1039 урта мед. персоналы әзерләнә, К. госпитальләрендә акад. А.В.*Вишневский*, профессорлар А.Ф.*Агафонов*, М.П.*Андреев*, И.В.*Домрачев*, Н.Н.*Лозанов*, Р.А.*Лурия*, З.И.*Малкин*, А.Н.*Мурзин*, Ю.А.*Ратнер*, И.И.*Русецкий*, Н.В.*Соколов*, Ә.Г.*Терегулов* һ.б. эшли. Медицина хезмәткәрләренең фидакарь эшчәнлеге нәтиҗәсендә яралылар һәм авыруларның 70% тан артыгы яңадан сафка баса. 1970–80 дә Республика клиник балалар хастаханәсе (1977), Республика клиник хастаханәсенең яңа корпуслары (1982), 6 диспансер (к. *Диспансерлар*) эшли башлый, Регионара, республика, шәһәр мед. үзәкләре (онкология, вертеброневрология, кардиохирургия һ.б.) оештырыла. 1990–2004 тә *Регионара клиник диагностика үзәгенең* 1 нче чираты, Балаларга диагноз кую үзәге, 6 балалар һәм 3 өлкәннәр шифаханәсе, 2 амбулатория, хатын-кызлар консультациясе, Бөек Ватан сугышы инвалидлары өчен госпиталь, микология һәм токсикология лаб-яләре һ.б. файдалануга тапшырыла. 2009 елга К.да 44 дәвалау учреждениесе, 9744 табиб, 14397 урта мед. хезмәткәре исәпләнә; 10 мең кешегә 80 хастаханә урыны туры килә (барысы 7576 урын).

Казанның санаторий-курортлар комплексында — «Казан», «Ливадия» санаторийлары, шәһәрнең эре пр-тиеләреннән — Казан моторлар төзү ҖБ, Казан авиация ҖБ, «Органик синтез», «Кварт» АҖ һ.б.ның санаторий-профилакторийлары эшли.

**Физкультура һәм спорт.** К.да беренче спорт түгәрәкләре, оешмалары һәм берләшмәләре: «Атта чабарга теләүчеләр» (1867), «Шахмат сөючеләр» (1884), «Һәвәскәр велосипедчылар» (1893) оешмалары 19 йөзнең соңгы чирегендә оештырыла; физик тәрбия түгәрәкләре Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә, Казан ун-тында, юнкерлар уч-щесендә эшли. Аеруча фехтование б-н шөгыльләнү (шәһәрдә спорт төре буларак 1805 тән мәгълүм) популяр була. 20 йөз башында спортның берничә тармагын («Бөркет» 1908 дә, «Көч һәм сәламәтлек» 1911 дә) һәм ш.у. техник төрләрен («Яхт-клуб» 1907 дә) үстерүче оешмалар барлыкка килә. 1914 тә «Һавада очучылар» җәмгыяте оештырыла. Беренче рәсми ярышлар велосипед спорты (1894), тимераякта узышу (1899), гимнастика (1908), ишкәкле көймәдә ярышу (1908), грек-рим көрәше (1909), ату, теннис (1910), бокс (1911), җиңел атлетика буенча 10 төр ярыш (1911), футбол (1911), туплы хоккей (1911), йөзү (1912), авыр атлетика (1912), фигуралы шуу (1913) төрләре бу-
































**Казан мәкаләсенә.** 1–2. Шәһәрнең үзәк өлеше панорамасы. 3. Кремль территориясендәге Сөембикә манарасы һәм Президент сарае; 4. Кремльнең бер өлеше; 5. Казан
9. Г. Тукай мәйданы; 10. М. Җәлил һәйкәле; 11. Г. Камал исем. Татар академия театры; 12. Г. Тукай һәйкәле; 13. Болак каналы; 14. Иске Татар бистәсендәге Ш. Мәрҗа
17. Бирге (Түбән) Кабан күленең яр буйлары күренеше (шәһәрнең үзәк өлеше); 18. «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексы; 19. Административ-торак бина (2006); 2



































(Идел буе) федераль университетының төп бинасы; 6. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. ТР Милли музее; 8. М. Җәлил исем. Татар опера һәм балет академия театры;
ни мәчете һәм 19 йөзгә караган торак йорт; 15. «Казан» милли мәдәният үзәге; 16. Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать ин-ты бинасы;
20. Ф.И. Шаляпин һәйкәле; 21. Казансу аръягындагы яңа микрорайоннарның берсе.

енча уздырыла. 1930–80 елларда К.да төрле спорт төрләре буенча СССР һәм РСФСР халыкара спартакиадалары, профсоюзлар, Ирекле спорт җәмгыятьләренең (к. «*Буревестник*», «*Динамо*», «*Зенит*», «*Спартак*», «*Труд*», «*Трудовые резервы*», «*Урожай*») Үзәк һәм Республика советлары беренчелегенә финал ярышлары уздырыла. 2010 да К.да физик тәрбия һәм спорт б-н даими шөгыльләнүче 196 мең кеше (алар ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының физик тәрбия һәм җәмәгать оешмалары коллективлары б-н берләшә, к. *Профсоюзлар физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан Республика Советы*, *Спорт клублары*) исәпләнә. Спортның 38 төре буенча 39 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, ш.и. 17 Олимпия резервы мәктәбе (хоккей, тимераякта фигуралы шуу, самбо, дзюдо, грек-рим һәм ирекле көрәш, авыр атлетика, шахмат, шашка, го уены, туплы хоккей, бокс, баскетбол, футбол, җиңел атлетика, чаңгыда ярышу, су по́лосы, нәфис гимнастика, гандбол, татарча көрәш) эшли, анда 26 меңләп кеше шөгыльләнә. К.ның Россия чемпионатларында катнашучы командалар: премьер-лига (футбол — «*Рубин*»), суперлига (хоккей — «*Ак Барс*», баскетбол — «*УНИКС*», ирләр; «Казан Олимпия Резервы училищесе», хатын-кызлар; волейбол — «Динамо-Казан», хатын-кызлар; «Зенит-Казан», ирләр); югары лига (су по́лосы — «Синтез»; туплы хоккей — «Ракета»; регби — «Стрела», «Энергия»; чирәмдәге хоккей — «Динамо»; мини-футбол — «Приволжанин») составларында уйныйлар. Шәһәрдә 1200 дән артык спорт корылмасы, ш.и. 11 стадион (к. *Стадионнар*), 600 гә якын төрле зурлыктагы спорт мәйданчыклары, 330 спортзал, 16 йөзү бассейны, ш.и. 14 өсте ябык (иң зурлары — «Оргсинтез», «Ак Бүре», «Ак Барс», «Гольфстрим», «Акчарлак» һ.б.), 15 чаңгы базасы, «Казан» тау спорты сәламәтләндерү комплексы, 21 ату тиры, «Татнефть-арена» боз сарае, ясалма бозлы һәм трибуналы *Спорт сарае*, «Баскет-холл» спорт уеннары сарае, Р.Һ.Нәҗметдинов исем. шахмат һәм шашка уеннары сарае, «УНИКС» мәдәният-спорт комплексы, «Казан» халыкара ат спорты комплексы, «Ак Барс» көрәш сарае, «Теннис академиясе», Стендта ату тиры комплексы һ.б. эшли. К.да халыкара ярышлар үткәрү өчен кирәкле спорт корылмалары җитәрлек. Шәһәрдә татар милли Сабан туе бәйрәме спорт чараларының финал өлеше, «Республика Татарстан» г-тасы призына традицион язгы җиңел атлетика эстафетасы (1942 дән), «Казан чаңгы марафоны» (1968 дән), «Казан тынычлык марафоны» (1981 дән), А.П.*Курынов* истәлегенә авыр атлетика буенча халыкара ярышлар (1975 тән), Н.Г.*Жеребцов* истәлегенә гер күтәрү ярышлары (1980 нән, бер үк вакытта 1994 тән — Дөнья кубогына, 1999 дан — озын цикл буенча дөнья чемпионатына) уздырыла.

К.да Россия укучы балаларының 1 нче җәйге спартакиадасы финалы (2003), туплы хоккей буенча дөнья чемпионаты (2005, 2011), билбау б-н көрәш (2005), автокросс буенча Европа чемпионатының 6 нчы этабы (2005), футбол буенча УЕФА Кубогына уеннар, Чемпионнар лигасы, Европа лигасы (2006, 2009–2011 дә «Рубин» командасы катнаша), Россиянең 1 нче Җәйге универсиадасы (2008), «Россия — спорт державасы» 1 нче Бөтенроссия спорт форумы (2009) уздырыла. 2008 дә К. 2013 тә булачак XXVII Бөтендөнья Җәйге универсиаданы үткәрү хокукы ала. Универсиада ярышларын үткәрү өчен, 64 спорт объекты әзерләү планлаштырыла,



«Баскет-холл» спорт уеннары сарае.

шуларның 36 сы — яңа төзелеш, ш.и. 45 мең урынлы футбол стадионы һәм 28 е халыкара таләпләргә туры китереп реконструкцияләнә. 2010 да 10 меңнән артык спортчы бөтенроссия һәм халыкара ярышларда, ш.и. РФ беренчелегенә, Кубогына һәм чемпионатларында (2000 ләп кеше), Европа, дөнья, Олимпия уеннарында (200 дән артык кеше) катнаша. К.ның иң яхшы спортчылары — Европа, дөнья, Олимпия уеннары чемпионнары — Л.А.*Аверьянова*, А.А.*Бозин*, А.М.*Галләмова*, Н.Ф.*Гыйләҗева*, С.А.*Дёмина*, Д.В.*Капустин*, О.Н.*Князева*, Н.А.*Колесников*, А.Н.*Колесникова*, А.П.Курынов, Л.И.*Логинова*, Е.С.Мигунова, В.Г.*Никонова*, О.М.*Рукавишникова*, А.В.*Фадеев*, А.К.*Хамматов*, Д.В.Шкурихина, Л.Е.Шубина. Иң яхшы тренерлар — В.Т.*Глухих*, С.К.*Дёмин*, В.В.*Житлов*, В.В.*Краснов*, Н.И.*Морящичев*, В.А.*Павлов*, О.И.*Павлова*, М.М.*Сәхәбетдинов*, С.М.*Ульянов*, Ә.Ш.*Шәйхетдинов*.

**VII. Планлаштыру һәм архитектура**

Кремль — Казанның тарихи үзәге. 11 йөздән Кремль калкулыгының төньяк өлешенә монгол яуларына кадәрге һәм Алтын Урда чорлары болгар кирмәне урнашкан була. Казан ханлыгы дәверендә кирмәннең мәйданы зурая һәм 16 йөз урталарына ул хәзерге Кремль чикләренә диярлек барып җитә. Тарихи чыганаклар буенча аның эчендә Хан, Нургали, Колшәриф мәчетләре һәм хан төрбәләре (к. *Хан төрбәләре*) булуы мәгълүм. Кирмән диварларының тышкы ягында баштарак көньяк-көнчыгышка таба терр-яне биләп торган сәүдә-һөнәрчелек бистәләре (к. *Казан посады*) урнаша. Соңрак ул күзгә күренеп киңәя. Посадның чикләре 1530 да ахыргача ачыкланып бетә, чөнки ул агач диварлар б-н әйләндереп алына (к. *Казан Кремле*).

Казан 1552 елда яулап алынганнан соң, шәһәр төзелешенең яңа этабы башлана. Ул, рус православие традицияләренә ярашлы итеп, тамырдан үзгәртеп коруга дучар була. Кремльнең кирмән корылмаларын ныгыту өчен, 1555 тә бирегә 200 таш эшкәртүче һәм ташчы китерелә. 1556–64 елларда кирмәннең төньяк һәм көньяк өлешләрендә акташтан диварлар калкып чыга, манаралар үзгәртеп корыла яки аларга өскорма өстәлә. Мөселман архит-расына алмашка православие-христиан төзү стиле килә. 16 йөзнең 2 нче яртысында Кремльдә Спас-Преображение һәм Троица-Сергий монастырьларына нигез салына, Преображение соборы (1596), *Благовещение кафедраль соборы*, Киприан һәм Иустин чиркәве төзелә; посад терр-ясендә — *Казан Богородица хатын-кызлар монастыре*, *Иоанн-Предтеча хатын-кызлар монастыре*, Никола-Кызлар монастыре, Кабан күленең сул ягында Татар бистәсе барлыкка килә. Бу вакытта посад киңәя (Болак тамагының сул ярындагы терр-я хисабына), манаралы агач диварлар б-н тотып алына, анда руслар яши башлый. Шәһәр 3 төп магистральгә ия була: Зур Спас-Воскресенский, Воздвиженский һәм Проломный урамнары. Алар Кремльнең Спас манарасы каршына урнашкан һәм аннан Казансу елгасы суы тулган тирән чокыр б-н аерылып торган Иван мәйданына килеп чыга (*Беренче май мәйданы*). Мәйданда сәүдә итү урыны — *Гостиный двор* төзелә. Посад агачтан төзелгән торак һәм хуҗалык корылмаларыннан формалаша. 17 йөздә Кремльдә Туп йорты, Введение Богородицы чиркәве төзелә, кирмәннең агач диварлары тулысынча кирпечтән корыла, Спас һәм башка манаралар өстәп төзелә. Посад яңадан киңәйтелә һәм агач диварлар б-н уратып алына. Бистә принцибы б-н төзелгән терр-ядә ярымтүгәрәк — дугасыман урамнар челтәре барлыкка килә. Яңа чиркәүләр һәм монастырьлар үсеп чыга: Фёдор монастыре, Иоаким һәм Анна чиркәве, Иоанн-Предтеча монастыреның исемдәш соборы (1649); чиркәүләрнең агач биналары кирпечтән корыла башлый. Шәһәр архит-расында «рус бизәге» («кирпеч бизәге») стиле тарала. Шәһәр яны *Раифа (Богородица) пустыне* һәм *Кизик ирләр монастырена* нигез салына.

17 йөзнең 2 нче яртысында Аргы Кабан күле ярында Казан архиепископларының шәһәр читендәге йортлары (соңрак *Воскресение монастыре*) төзелә. Әлеге чорда кирпечтән беренче торак йортлар барлыкка килә (бердәнбер сакланып калган үрнәге — *Михляев йорты*). 17 йөз уртасы К. күренеше Н.Витзен панорамаларында чагылыш таба.

1708 дә К.га губерна шәһәре статусы бирелгәч, анда тамырдан үзгәртеп реконструкцияләү башлана. Кремльдә элекке Хан сарае урынында Губернатор сарае урнаша, кызыл кирпечтән шәһәр архит-расының доминантасы булган җиде яруслы һәм а́ркалы манара төзелә (к. *Сөембикә манарасы*). Туп сарае урынында Артиллерия сарае урнаша. Шәһәрдә барокко стилендәге *Пётр һәм Павел соборы*, Дүрт Евангелист чиркәве (1769) *Покров чиркәвенең* чаң манарасы калкып чыга. Яңа типтагы җәмәгать биналары (адм., уку, сәнәгать) аерым төркем хасил итә: Казан руханилар семинариясе, Казан тукыма мануфактурасы комплексы, *Адмиралтейство конторасы бинасы* һ.б. А.П.Волынский губернаторлык ит-

кән 1729 елда посадның искергән агач диварлары сүтелә, нәтиҗәдә, посад бистә тирәсендәге корылмалар б-н кушыла. 1730 да инженер А.Сацыпёров К. планын беренче мәртәбә төгәл итеп рәсемгә төшерә. 1739 да шәһәрдә 9 зур, 170 кечкенә урам һәм тыкрыклар, 10 мәйдан һәм сәүдә итү-базар урыннары исәпләнә. 18 йөзнең 1 нче яртысында К.ның үзәк өлешендә элекке агач чиркәүләр урынына таштан яңалары төзелә: *Богоявление чиркәве*, Ярославль могҗиза тудыручылары (чудотворцы) (1737), Воскресение (1741) чиркәүләре. Шул чорда кирпечтән төзелгән чиркәүләрдән сакланып калганнары: Тихвин бистәсендә — *Тихвин Богородицасы чиркәве* (1731), *Евдокия чиркәве* (1734), Постаучылар бистәсендә — Изге Рухның иңүе чиркәве (1735). 1740–50 елларда Иске Татар бистәсе терр-ясендә Яңа чукындырылганнар бистәсе оештырыла, һәм анда Екатерина, Борис һәм Глеб чиркәүләре төзелә.

К. үз тарихында берничә тапкыр һәлакәтле янгыннар кичерә (1579, 1595, 1672, 1684, 1742, 1749, 1754, 1774, 1815, 1842, 1859). Аларның кайберләре шәһәрнең архитектур йөзе үзгәрүдә бер этап була. 1760 еллар уртасында Казан планы 1 нче тапкыр топографик рәсемгә төшерелә. 1768 елда император Екатерина II тарафыннан К.ның җилпәзә рәвешендәге һәм турыпочмаклы планлаштыру системалары чиратлашкан регуляр планы раслана (аны губерна арх. В.И.*Кафтырев* әзерли). План нигезендә посад диварлары урынында 30–40 *м* киңлектәге урамнар (иске урамнарның киңлеге — 10–12 *м* була) барлыкка килә. Яңа урамнар киң җилпәзә рәвешендә Кремль яныннан башланып китә. Воскресенский урамы (хәзерге Кремль) шәһәрнең төп композиция үзәге санала. Радиаль урамнар аркылы урамнар б-н кисешә. Шәһәрнең түбән, көнбатыш өлешендәге төрле якка юнәлгән урамнары план буенча турыпочмаклы урамнарга әверелә. Биредә төп композиция үзәген Проломный урамы (хәзерге Бауман) тәшкил итә. Ромбсыман Балык сәүдәсе мәйданы (хәзерге Г.Тукай мәйданы) иске посад һәм бистәләр чигендә урнаша. Кабан күленең уң яры Георгиевский урамы (хәзерге Петербург урамы) б-н бергә турыпочмаклы урамнар челтәрен тәшкил итә. Кабан күленең сул ярына урнашкан Иске Татар бистәсендә Екатерининский урамы аның композицион үзәге булып тора. Биредә кыек почмаклы урамнар челтәре оеша. К. үзәгендә «үрнәк» проектлар буенча кирпеч йортлар төзелә башлый. 1760–70 елларда, 200 елга сузылган тыюлардан соң, Иске Татар бистәсендә беренче тапкыр 2 таш мәчет төзелә (к. *Апанай мәчете, Мәрҗани мәчете*), алар каршында К.да беренче тапкыр рәсми рәвештә мөселман мәхәлләләре оештырыла. Шулай итеп, шәһәрдә мөселман таш архит-расы яңадан торгызыла башлый. 1774 елда К.ны Е.Пугачёвның крәстиян армиясе басып алганнан һәм көчле янгыннан соң, аның архитектур йөзе зур үзгәрешләр кичерә: шәһәр күләмендә таштан гражданнар төзелеше башлана. 1830 да К.да 429 таш йорт исәпләнә (1774 тә — 56). 18 йөзнең соңгы чирегендә тәртипкә китерелгән Югары һәм Түбән Фёдор бистәләре шәһәр сызыгына кертелә. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында шәһәр архит-расында классицизм һәм *ампир* стильләре киң тарала. Шәһәрдә яңа ансамбльләр һәм биналар салына (Гостиный двор, Казан Богородица хатын-кызлар монастыре, *Университет шәһәрчеге,* Казандагы беренче гимназия, *Рус гаскәриләренә һәйкәл-төрбә* һ.б.). Кабан күленең уң яры тирәсе үзгәртеп корыла, 1816 елга Арча кыры тетерр-ясе йортлар, корылмалар б-н каплана. 19 йөзнең 1 нче чирегендә Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә классицизм формаларында 4 таш мәчет барлыкка килә: Унберенче (1801), Галиев, Иске таш, Зәңгәр. Шәһәр яны бистәләрендә (Адмиралтейство, Дары, Ягодный) агач мәчетләр салу дәвам итә. 1825 елда әлеге бистәләр башкалар (Бишбалта, Гривка, Кәҗә, Кизик) б-н бергә К.га кушыла. 1845 тә Печән базарында, мөселман гыйбадәтханәләре архит-расы үсешендә бер этап булараk, *Печән базары мәчете* корыла. Алга таба аның композицион схемасы буенча Солтан, Борнай, Әҗем, Кызыл мәчетләр төзелә. 1860–70 елларда шәһәрдә башка диннәрнең гыйбадәт кылу йортлары: *Санкт-Катарина кирхасы, костёл* барлыкка килә.

19 йөзнең 1 нче яртысында җәмәгать һәм гыйбадәт кылу биналары, торак йортлар төзелә башлаган Болак ярлары (к. *Болак ярлары*) реконструкцияләнә (Казандагы икенче ир балалар гимназиясе, Казан реаль уч-щесе һ.б.). 1840 елдан К. төзелешләрендә шәһәрнең йөзен төрле стильдәге архит-ра, ш.и. шәрекъ элементлары б-н баеткан *эклектика* кулланыла. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан шәһәрдә сәнәгать күргәзмәләре үткәрелә, һәм алар өчен махсус архит-ра комплекслары төзелә башлый (к. *Казан халыкара күргәзмәсе*).

19 йөз ахырында К.ны төзү кардиналь рәвештә үзгәрә. Анда яңа типтагы таш һәм агач биналар үсеп чыга: тамаша кылу (театрлар, цирк), сәүдә (кибетләр, пассажлар), уку (мәктәп-гимназияләр, ин-тлар), сәнәгать (заводлар, фабрикалар, телефон һәм электр станцияләре, тегермәннәр), торак (табыш йортлары, байлар йортлары) биналар һ.б. Шәһәр панорамасын Богоявление чиркәвенең кыңгырау манарасы аеруча бизәп тора.

1890 елларда эклектикага алмашка *модерн* һәм *неоклассицизм* стильләре килә (*Шамил йорты, Казан хәрби округы командующие йорты, Дәүләт банкының Казан бүлеге* һ.б.). 19 йөзнең 1 нче яртысында шәһәрнең архитектур йөзен формалаштыруга арх. М.П.*Коринфский,* П.Г.*Пятницкий,* Ф.И.*Петонди,* А.К.*Шмидт,* А.И.*Песке*; 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында — Ф.Р.*Амлонг,* В.К.*Бечко-Друзин,* С.В.*Бечко-Друзин,* И.Н.*Колмаков,* К.Л.*Мюфке,* Г.Б.*Руш,* Л.К.*Хрщонович* һ.б. лаеклы өлеш кертә.

Окт. рев-циясеннән соң К. шәһәре төзелешендә яңа этап башлана. 1920 еллар азагыннан *конструктивизм* стиле өстенлек итә башлый. Бу чорда шәһәрнең тарихи шартларда барлыкка килгән мохитендә аңа контраст булган аз санлы яңа җәмәгать биналары төзелә. Мәктәпләр, хастаханәләр, мәдәният сарайлары, клублар, спорт комплекслары корыла. 1926 елда «*Динамо*» стадионы сафка баса (арх. П.Т.Сперанский, 1990 елларда үзгәртелә). 1930 елларда *ТАССРның 10 еллыгы исемендәге мәдәният сарае* (соңрак сүтелә), *Матбугат йорты,* Мехчылар клубы (арх. И.Г.Гайнетдинов, 1935) һ.б. төзелә. 1920–30 еллар дәвамында К.да рационалистик модерн стиле үсүен дәвам итә. Аның элементлары кинотасма ф-касының адм. һәм җитештерү корпусларында (арх. А.Э.Спориус), *Кабан арты мәчете* бинасында ачык чагыла. Совет чорында байтак гыйбадәтханәләр башка максатларда файдаланыла, бу исә, үз чиратында, мәчет манараларының, чаң манараларының җимерелүенә, биналарның эчке төзелеше үзгәрүгә китерә. 1930 елларның 2 нче яртысыннан шәһәр архит-расында «Сталин ампиры» дип йөртелгән зиннәтле стиль өстенлек итә башлый: Казан ун-тының химия ф-ты (башта СССР ФАнең Татарстан ф-лы, арх. М.К.*Игъламов,* 1957), Дәрвишләр бистәсендәге Мәдәният сарае, Казан финанс-икътисад ин-ты бинасы (арх. Ю.Ю.Савицкий, 1938–1951) һ.б. К.дагы Татар опера һәм балет акад. театры бинасы әлеге стильнең аеруча әһәмиятле истәлекләреннән санала. К.да сугыш һәм сугыштан соңгы елларда, сәнәгать пр-тиеләренең яңа терр-яләрне үзләштерүе сәбәпле, халыкка хезмәт күрсәтүче учреждениеләр комплексы булган «социалистик шәһәрчекләр» проектлаштырыла һәм төзелә башлый: кибетләр, ашханәләр, поликлиникалар, мәдәният сарайлары һ.б. (Совет р-нының Дәрвишләр бистәсе, хәзерге Авиатөзелеш р-нының иске өлеше). Аларда классицистик архит-ра элементларын кулланып бизәлгән 2–5 катлы йортлар төзелә. 1948–52 дә «Ленгипрогор» ин-ты тарафыннан К.ны алга таба планлаштыру һәм төзү проекты әзерләнә. Шуңа яраклаштырып, яңа магистральләр үткәрелә (хәзерге Восстание, Декабристлар, Себер тракты, Эсперанто урамнары), мәйданнар корыла (Восстание, Совет һ.б.).

СССР МСның 1955 тә кабул ителгән «Проектлаштыруда һәм төзелештә артыклыкларны бетерү турында»гы һәм «Төзелешләрне алга таба индустриальләштерү, сыйфатын яхшырту һәм бәясен киметү буенча чаралар турында»гы карарларыннан соң К.дагы биналарның архит-расы кырыс-катгый һәм ачык төс ала. Җәмәгать биналарында тимербетон конструкцияләр һәм зур пыяла яссылыклар киң кулланыла: *Казан Елга порты вокзалы,* Ирек мәйданындагы КПСС өлкә ком-ты бинасы (арх. П.А.Саначин, Г.И.Солдатов, инж. О.И.Берим, 1962) һ.б. Күп катлы торак йортлар төзү чоры башлана.

Куйбышев ГЭСы һәм Куйбышев сусаклагычы төзелүгә бәйле рәвештә 1953 елда К.да шәһәрне инженер саклау системасы эшләнә (8 плотина, 25 *км* озынлыктагы 10 саклау дамбасы). 1956 да Казансу елгасының иске үзәне Елантау р-нында ике плотина б-н буып куела, су Иделгә яңа канал буенча ага башлый, нәтиҗәдә шәһәр эчендә, Киров дамбасы р-нында, зур акватория барлыкка килә. Киң

ярлы саклау дамбалары, Киров һәм Ленин күперләре төзелә.

1960 елларда биналар бизәлешендә алюминий, чыныктырылган пыяла, пластмасса, тулысынча завод әзерләгән җыелма элементлар файдаланыла башлый. Әлеге материаллар Спорт сараен (1966), Сәяси мәгариф йортын (арх. А.А.Спориус, П.А.Саначин, 1966), Казан циркын (1967), Актёрлар йортын (арх. В.А.Петров, А.А.Спориус, 1967), Казан консерваториясенең элеккеге концертлар залы бинасын (арх. М.Х.Агишев, И.Н.Агишева, инж. О.И.Берим, С.К.Зәбиров, 1967; 2000 дә үзгәртеп корыла), «Татарстан» кунакханәсен (1970) һ.б.ны төзегәндә киң кулланыла. Шәһәр мәйданнарында яңа скульптура ансамбльләре барлыкка килә: 1 Май мәйданында М.Җәлил һәйкәле, М.Горький исем. Үзәк мәдәният һәм ял паркы янында *Совет власте өчен көрәштә һәлак булганнар һәйкәле* һ.б. К. планы буенча 1965 тән күп катлы йортлардан торган микрорайоннар төзелә башлый. Шәһәрнең күп елларга сузылган үсеш юнәлешен 1969 да «Ленгипрогор» ин-ты төзегән ген. план билгели. Шуның нигезендә К.да җитештерү зоналары, яңа торак р-ннар, җәмәгать үзәкләре, халыкның ял итү урыннары барлыкка килә. Шәһәр яңа кала төзү принциплары буенча корыла: микрорайоннар ирекле планлаштырыла, анда эре комплекслар калкып чыга һ.б. 1972 дә шул ук институт тарафыннан, шәһәрнең тарихи структурасын исәпкә алып, К. үзәген детальләп планлаштыру проекты эшләнә; 1970 еллар ахырында шәһәр микрорайоннары үзәкләренең проекты әзерләнә. К.ның архит-ра һәм төзелеш сәясәтен үстерүгә Ү.Г.*Алпаров*, Ә.Һ.*Бикчәнтәев*, И.Г.*Вәлиев*, И.Г.*Гайнетдинов*, Р.М.*Мортазин*, В.Д.*Панова*, Г.И.*Солдатов*, П.А.*Саначин* һ.б. зур өлеш кертә. 1970–80 елларда К.да, бердәйләштерелгән төзелеш детальләре кулланып, башлыча, үрнәк проектлар буенча торак һәм җәмәгать биналарының зур төзелеше башланып китә. Бу — яңа төзелешләрдә төссез, үз йөзе булмаган районнар барлыкка китерә. Бары тик индивидуаль проектлар буенча төзелгән аерым җәмәгать биналарында гына нииндидер дәрәҗәдә әлеге бертөрлелектән котылу мөмкин була: Чехов урамындагы базар бинасы (арх. Ф.Х.Селецкий, инж. В.В.Цитович, 1971), Казан ун-тының физик һәм гуманитар ф-тлар корпуслары (арх. О.А.Кашинцева һ.б., 1972; 1977), ТР Рәссамнар берлегенең *Күргәзмәләр залы*, В.И.Ленин исем. Үзәк музейның Казан ф-лы, Татар акад. театры. 1980–90 елларда, Горки-1,2, Азино-1,2 микрорайоннарында торак комплекслар, Казансуның уңъяк ярында күпләп яңа кварталлар төзү хисабына, шәһәрнең чикләре шактый киңәя. 1980 еллар ахырыннан, ил үсешендә социаль-икътисади шартлар үзгәрү, архит-ра һәм төзелештә базар икътисады урнашу сәбәпле, К.да мөһим үзгәрешләр була. 1988 дән яңадан мәчетләр һәм чиркәүләр төзү башлана. «*Рамазан*», «*Болгар*», «*Хозәйфә ибне әл-Ямәни* мәчетләре, Серафим Саровскийның храмнар комплексы, католиклар чиркәве шәһәрнең бизәге булып тора. Казан Кремле терр-ясендә шәһәр архит-расы символларының берсенә әйләнгән яңа «*Кол Шәриф*» мәчете салына.

1996 да Тузган торакны бетерү программасы кабул ителеп, 2004 елда ул уңышлы тәгалләнә. Бу вакыт арасында тарихи шартларда барлыкка килгән р-ннарда яшәүче халык шәһәрнең яңа микрорайоннарына күчерелә. К.ның үзәк өлешендә киң күләмдә яңарту эшләре башкарыла. Тузган торак урыннарында заманча офис биналары, югары уңайлылыктагы аз катлы торак йортлар һ.б. калкып чыга. Шәһәрнең яңа ген. планы әзерләнә, аның перспектив үсеш план-схемасы раслана (2004).

К.ның меңьеллык юбилеена (2005) башкалада заманча җәмәгать-күңел ачу һәм сәүдә комплекслары барлыкка килә. К.да «Пирамида», «Кольцо», «Корстон-Казан», «PARK HOUSE», «Тандем», «XL», «Suvar Plaza», «Ривьера» һ.б.; спорт биналары: «Баскет-холл», «Татнефть-арена», «Ракета»; адм.-офис биналары: «ТАИФ» ҖЧҖ, ТРның Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе (ГИБДД) бинасы төзелә. 2005 елда К.да

Казанның меңьеллыгы паркы.



Казансу елгасы аша «Миллениум» күпере салына. «Суворовский», «Магеллан», «Седьмое небо», «Солнечный» һ.б. заманча торак комплекслар Идел һәм Казансу елгаларыннан ачылган К. панорамасының йөзен үзгәртә.

XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада өчен (Казан, 2013) Универсиада авылы һәм 30 дан артык яңа спорт корылмасы: Су спорты сарае, Урта Кабан күлендә ишкәк ишү каналы комплексы, Теннис академиясе, Чирәмдәге хоккей үзәге һ.б. төзелә.

Футбол буенча дөнья чемпионатына (Казан, 2018) әзерлек йөзеннән дөньякүләм дәрәҗәдәге стадион төзелә. Казансу елгасының уңъяк ярында яңа шәһәр үзәге барлыкка килә.

*Әд.:* Рычков П.И. Опыт казанской истории древних и средних времён. СПб., 1767; Фукс К.Ф. Краткая история города Казани. К., 1817; Рыбушкин М.С. Краткая история города Казани. К., 1834; Баженов Н. Казанская история. К., 1847; Шпилевский С.М. Указатель исторических мест достопримечательностей города Казани. К., 1873; Пинегин М. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; Загоскин Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Олеарий А. Описание путешествия в Московию. СПб., 1906; Дульский П.М. Памятники Казанской старины. К., 1914; Худяков М. Очерки истории Казанского ханства. К., 1923; Старая и новая Казань. К., 1927; Казанская история. М.–Л., 1954; Калинин Н.Ф. Казань. К., 1955; Тунаков П.Д. Казань сегодня и завтра. К., 1960; Молодость древнего города. К., 1978; Остроумов В.П. Казань. К., 1978; Айдаров С.С. Казань. К., 1979; Страницы истории города Казани. К., 1981; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Гарзавина А.В., Новицкий А.И. Моя Казань: Исторический и архитектурно-художественный облик. К., 1984; Орденоносная Казань. К., 1987; Халитов Н.Х. Памятники архитектуры Казани XVIII — начала XIX в. М., 1989; шул ук. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; История Казани: В 2 кн. К., 1988–91; Литвин А.Л. Казань: время гражданской войны. К., 1991; Республика Татарстан. Памятники истории и культуры: Каталог-справ. К., 1993; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1994; Амиров К.Ф. Казань: где эта улица, где этот дом?: Справ. улиц города Казани. К., 1995; Древняя Казань глазами историков и современников. К., 1996; Знаменитые люди о Казани и казанском крае. К., 1999; Зорин А.Н. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001; Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г. Средневековая Казань: Краткий библиогр. указ. К., 2002; Султанов Р.И. Историческая география Казани (город и его предместья в XVI–XVII вв.). К., 2004.

**КАЗА́Н**, кече планета № 1316. 1933 елда Кырымдагы Симеиз обсерваториясендә астроном Г.Н.Неуймин тарафыннан ачыла, ТАССР башкаласының исеме бирелә. Планетаның Кояштан ераклыгы 1,6 дан 3,2 а.б. арасында үзгәрә. Кояш тирәли әйләнү периоды 3,7 ел.

**«КАЗА́Н»**, арыш сорты. 1937 елда Казан селекция станциясендә Х.Х.Байчурова һәм Е.Н.Борисова тарафыннан аерып алынган формаларны ирекле серкәләндерү фонында күп тапкыр сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Башагы эре, тыгыз, яхшы бөртекләнгән, ор-

чыксыман формада, турыпочмаклы аркылы киселешле, кылчыгы ярымавыш, бөртеге ярымачык, яшел төстә, сабагы уртача озынлыкта, шактый нык, күп тармаклы. Корылыкка бирешми, кышка чыдам, ләкин бу сорт чиләнүгә һәм кар күгәреге б-н зарарлануга бирешүчән. Он тарту һәм ипи пешерү сыйфатлары югары. 1000 бөртекнең авырлыгы 30,4 *г*, стандарт «Авангард» сортыннан 3,6, «Вятка» сортыннан 4,1 *г* га артыграк. 1937–51 елларда селекция-тәҗрибә станциясендә сорт сынау вакытында уңыш уртача 1 *га* дан 28,93 *ц* тәшкил итә, «Авангард» сортыннан 2,71 *ц* га, «Вятка» сортыннан 1,82 *ц* га югары. 1942 елда Татарстанда һ.б. төбәкләрдә районлаштырыла. Чәчүлекләрдә зур мәйданны биләп 35 ел чәчелә. СССР Дәүләт бүләге бирелә (1950).

*Әд.:* Байчурова Х.Х. Озимая рожь — Казанская. К., 1951.

**«КАЗА́Н»**, болын солычасы сорты. 1975 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Л.А.Киселёва, Ф.М.Киселёв һәм И.Г.Вәлиева тарафыннан җирле популяциядән күпләп сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Көз көне чәчеп үстерелә. Куагы уртача тыгызлыкта, туры басып тора һәм аз үсеш алган. Сабаклары уртача тупаслыкта, төксез, түгәрәкләнгән. Сабагының уртача биеклеге тулысынча чәчәк ату чорында 119 *см*. Яфраклары яссы, яшел һәм ачык яшел төстә. Чәчәк оешмасы — ачык төстәге себеркәч, өлешчә шәмәхә төсле, озын ботаклы һәм ярым кысылган. 1000 орлыкның авырлыгы 2 *г*. Орлыклары яссы, ачык төстә. Тамыр системасы нык үскән. Бу сорт тутык авыруы б-н аз зарарлана, кышка һәм язгы кыраулларга бик чыдам, корылыкка чагыштырмача бирешмәүчән, озак саклана. Ике тапкыр чабып алуга печән уңышы уртача 1 *га* дан 52,2 *ц* тәшкил итә. Сугарган очракта күп тапкырлар чабып алырга мөмкин, печән уңышы 1 *га* дан 83,5 *ц* га җитә. Орлыклык материал югары — 1 *га* дан 3–4 *ц* (иң югары тулы кыйммәтле орлык уңышы җәйге чорда чәчелгәндә алына). Татарстанда районлаштырыла (1976).

**«КАЗА́Н»**, болын тимофеевкасы сорты. 1940 елда Казан селекция станциясендә З.Х.Шәрәф, Ф.М.Киселёв һәм Л.А.Киселёва тарафыннан ирекле сортара серкәләндереп һәм югары агротехник фонда тәрбияләнгән табигый популяциядән күп тапкырлар төркемләп сайлаганнан соң күпләп аерып алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт арадаш экологик типка карый. Куагы уртача тыгызлыкта, аз үсеш алган туры формада. Сабаклары тупас, төксез, цилиндр формасында, куыш эчле, туры, кайбер очракта буынлы. Аларның уртача озынлыгы 105 *см*. Орлыклары вак, озынча-түгәрәк формада, сары-көрән төстә. 1000 орлыкның абсолют авырлыгы уртача 0,568 *г*, 0,3 *г* нан 0,7 *г* га кадәр булырга мөмкин. Тамыр системасы көчле үскән. Гөмбә авырулары б-н аз зарарлана, корылыкка чыдамлылыгы чагыштырмача югары булуы б-н аерылып тора, ләкин корылыклы шартларда уңышы шактый кими. Сугаруны ярата. Югары уңыш бирә. Печән уңышы чиста чәчүлекләрдә сынау елларында 1 *га* дан 26 *ц* дан 54 *ц* га кадәр була. Коры матдәнең иң югары уңышы 1 *га* дан 105 *ц*, орлыгының — 11 *ц*. Протеин 15,8%, шикәр 7,4% тәшкил итә. Татарстанда районлаштырыла (1956), РФнең Урта Идел буе төбәкләрендә игелә.

*Әд.:* к. «*Казанец*».

**«КАЗА́Н»** санаторие. Казан шәһәре үзәгендә, Казансу буендагы урман-паркта урнаша. 1933 елда нигез салына. Санотоpий комплексы үз эченә төп бинаны (7 катлы), уңайлы коттеджлар, дәвалау корпусын, ашханәне ала. Дәвалау факторлары: «Казан» сульфат-магний-кальцийлы шифалы су, бром, ортобор к-тасы, йод б-н баетылган хлорид-натрийлы эремәләр, сульфидлы ләм балчыгы (Зәңгәр күлдән алына). «Казан» минераль суы сидек бүленүне көчәйтә, сидек юлларыннан лайла, комны эретеп чыгаруга ярдәм итә, сидек составын, үт куыгын нормага китерә. Санаторий ашкайнату әгъзалары, сидек-җенес системасы, диабет авыруларын дәвалауга көйләнә; анда ашказаны, уникеилле эчәк җәрәхәтләрен, үт куыгын алу операцияләреннән соңгы авыруларны дәвалау өчен махсус бүлек, йөкле хатын-кызлар сәламәтлеген ныгыту өчен «Фемина» бүлеге. Терренкур йөрү сукмаклары булган парк, сауна, бассейн, күнегүләр залы, китапханә, концерт залы була. Санаторийда клиник-биохимик лаб., УЗИ, ЭКГ, функциональ диагностика, физиотерапия, стоматология кабинетлары бар. Дәвалау комплексында су б-н дәвалау, эчәкләрне минераль су һәм үләннәрдән әзерләнгән су б-н юдыру, минераль ванналар, төрле массажлар (ш.и. су асты), дәвалы душлар, «коры нарзан» ванналары, парафинозокерит һәм ләм б-н дәвалау, спелео-, физио-, гало-, психо- һәм фитотерапия, мануаль һәм рефлексларны дәвалау, дәвалау физкультурасы файдаланыла. 2007 елдан эшчәнлеге туктатыла.

*Л.А.Мартынова.*

**«КАЗА́Н»**, Яшел Үзән р-нындагы бройлер кошчылык ф-касы. 1 нче чираты — 1973 елда, 2 нче һәм 3 нче чиратлары 1975 тә файдалануга тапшырыла. Үзәк утары — Осиново авылы. 1995 тән АҖ, 2003 тән «Ак Барс»




«Казан» кошчылык фабрикасы.

холдинг компаниясе составында. Уңайлыклары булган 400 ләп фатир, тулай торак, көнкүреш хезмәте күрсәтү комб-ты, медпункт, яшүсмерләр клубы һәм башка социаль-көнкүреш биналары төзелә. 2009 да кош итен эшкәртү комб-ты сафка баса. 1990 еллар уртасына фабрика ел саен 1,1–1,2 *млн.* баш тавык асрый; 1997 дә — 13,6, 2011 дә — 15,7 мең *т* тавык ите, 16 млн. данә йомырка житештерелә. Фабрика РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә (1998, 1989). Эшчеләр дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 2 кешегә — РФнең атказ. а.х. хезмәткәре, 4 кешегә ТАССР, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре, 2 кешегә ТРның атказ. механизаторы исемнәре бирелә, 1 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, 2 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Архипов В. Осиновские страницы. К., 2002. *В.А.Архипов.*

**«КАЗА́Н»**, журнал. Казан татарларына теләктәшлек җәмгыяте органы. 1905 елда Истанбулда татар телендә нәшер ителә.

**«КАЗА́Н»** («Kazan»), фәнни-популяр, иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис журнал. Казан төркиләренең Мәдәни һәм үзара ярдәмләшү җәмгыяте органы. 1970–80 елларда кварталга бер Әнкарада, Истанбулда (өзеклекләр




«Казан» журналы.

б-н) төрек телендә нәшер ителә, 23 саны чыга. Журналның химаяче-нашире — Ә.*Мәңгәр*, мөхәррирләре — Р.Мөхтәсиб һәм М.Әллүки. Журналның җаваплы сәркәтипләре, редколлегия әгъзалары һәм төп авторлары — чит илләрдә яшәүче татар галимнәре, язучылары, җәмәгать эшлеклеләре: Р.Аги, Н.Бинарк, Н.Дәүләт, Ә.Курат, Х.Кушай, М.Таһир, А.Тимер, С.Чыгтай һ.б. Текстлар, нигездә, төрекчә, ә татар әдәбияты һәм фольклор әсәрләре оригиналда һәм төрек телендә тәрҗемәдә басыла. Журналда ш.у. төрек, рус, Көнбатыш Европа авторлары язмалары да урын ала. Татарларны өйрәнү тематикасы — татар халкының тарихы һәм бүгенге халәте, аның теле, мәдәнияте, этнографиясе, этносара бәйләнешләр өстенлек ала. Һәр санда татар әдәбияты үрнәкләре, чит илдә яшәүче татар әдипләренең (Х.Габдүш, С.Гыйффәт, Ш.Илдәр, М.Исмәгыйли, А.Ишгәй, Л.Каран һ.б.) әсәрләре тәкъдим ителә. Г.Тукай иҗатын өйрәнүгә, татар мәдәниятенең танылган вәкилләре Й.Акчура, М.Акъегетзадә, Р.Арат, М.Бигиев, И.Гаспралы, М.Гафури, Г.Исхакый, Г.Кариев, С.Максуди, К.Насыйри, Р.Фәхретдин һ.б. тормышы, эшчәнлеге турындагы язмаларга зур урын бирелә. Журнал Төркия,





КАПО. 1. Агрегатлар җыю цехы; 2. Ту-214 самолёты җыю цехында.

Финляндия, Германия, АКШ һ.б. илләрдә яшәүче татарлар арасында киң тарала.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Й. «Kazan» журналы // Кызыл таң. 1992. 10–19 сент.; шул ук. «Казан» һәм «татар» — аерылмас төшенчәләр // Дөньяда сүземез бар. К., 1999; шул ук. Обретёт душа, стремясь к тебе, свободу // Казань. 1993. № 1.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**КАЗА́Н АВИА́ЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́** (КАПО), С.П.Горбунов исемендә, федераль унитар пр-тие, илдә авиация машиналары төзелешенең әйдәп баручы пр-тиеләренең берсе. Хәрби һәм гражданнар самолётлары, халык куллану товарлары җитештерә. 1932 елда төзелеп килүче авиация комб-ты («Казмашстрой») составында завод оеша башлаганда нигезләнә. 1934 тә ул «Серго Орджоникидзе исемендәге 124 нче завод» исемен ала. Аякка басу чорында (1934–36) з-дта дөньядагы иң зур — 8 моторлы АНТ-20 (ПС-124 «Максим Горький») самолёты; спорт-өйрәнү самолётларының бөтенсоюз очышында катнашкан КАИ-1 самолёты; В.Ф.Болховитинов конструкциясе буенча бернича тизлек, очыш биеклеге һәм йөк күтәрү рекордлары куйган ДБ-А бомбардировщиклары эшләнә. 1937 дә СССРдагы беренче югары тизлекле авыр Пе-8 (ТБ-7) бомбардировщигы күпләп җитештерелә башлый, ул 1941 елга кадәр чыгарыла (барлыгы 93 самолёт төзелә). Бу самолётлардан Берлин беренче тапкыр бомбага тотыла (1941 нең августы), аларга утырып сов. дипломатик делегациясе АКШка кадәр оча (1942). Сугыштан соң Пе-8 йөкләр ташу өчен Арктикада файдаланыла. 1940 та Американың «Дуглас» фирмасыннан сатып алынган лицензия буенча пассажир самолёты ПС-84/Ли-2 не җитештерүгә әзерлек башлана (10 машина эшләп чыгарыла). Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан з-д пике ясаучы Пе-2 бомбардировщигын җитештерүне үзләштерә. 1941 нең октябрендә з-д терр-ясенә Мәскәүнең С.П.Горбунов исем. 22 нче авиация з-ды эвакуацияләнә (ул 1927 елда оештырыла, 1933 тә Горбунов исеме бирелә, шул ук елда Ленин ордены б-н бүләкләнә); берләштерелгән з-д С.П.Горбунов исем. Казан 22 нче авиация з-ды дип атала башлый. Кыска вакыт эчендә эвакуация б-н китерелгән җиһазлар гамәлгә кертелә һәм хәрби продукция җитештерү үзләштерелә. Эшләүчеләр саны 30 меңләп кеше исәпләнә. Квалификацияле белгечләр килү кадрлар проблемасын хәл итәргә мөмкинлек бирә. Завод тулысынча техник яктан яңадан җиһазландырыла: салкын ысул б-н штамплау, кайнар штамплар, станок җайланмалары, пресс-формалар, инструментлар цехлары оештырыла; җитештерүне әзерләү хезмәте үзгәртеп корыла. 1942 ел з-д үсешендә борылыш чоры була: тулай продукция күләме сугышка кадәрге 1940 ел күрсәткечләреннән 8 тапкыр арта. Җитештерүнең иң зур күләменә 1944 тә ирешелә (1100 % тан артык). Алдагы елларда да үсеш темплары югары булып кала. Һәр тәүлектә з-дның җыю мәйданчыкларыннан 10–12 Пе-2 самолёты чыга, алар Кызыл Армия Хәрби һава көчләренең төп бомбардировщиклары була (10 меңләп самолёт эшләнә). Хәрби үзгәртеп коруның төп нәтиҗәсе җитештерүнең техник дәрәҗәсе кискен күтәрелүдән һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең гаять зур үсешеннән гыйбарәт була. Пе-2 самолётларын фронтка җибәрү өчен з-дта Кызыл Армия Хәрби һава көчләренең 221 нче аерым күчерү полкы урнаштырыла. Хөкүмәт йөкләмәләрен үрнәк башкаруы өчен 1945 нең сентябрендә з-д Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә; Дәүләт Оборона Ком-тының күчмә Кызыл байрагы з-дка мәңгелек саклауга тапшырыла. 1945 нең 2 нче яртысында, тыныч тормыш таләпләренә яраклашкан рәвештә, җитештерү күләме кискен кимүгә йөз тота. Продукцияне яңасына алмаштыру процессы башлана; 1945 нең ахырында ерак араларга очарга сәләтле авыр Ту-4 бомбардировщигын чыгаруны үзләштерүгә керешәләр. Бу самолёт тактик-техник параметрлары, конструктив-техник күрсәткечләре буенча элек эшләнгән самолётлардан күпкә өстен була. З-д тамырдан үзгәртеп корыла: 3 цех, ш.и. плаза-өлге цехы оештырыла; 7 механика һәм инструментлар, ш.и. 6 агрегатлар цехы яңадан җиһазландырыла; яңа тоташ линияләр гамәлгә кертелә; производство яңа махсус җиһазлар, өлгеләр б-н коралландырыла; яңа технол. процесслар үзләштерелә: шассиларның цилиндрларын күп катламлы дугалы эретеп ябыштыру, бронзадан кою һ.б. кулланыла. 1947 дә Ту-4 бомбардировщигы сериягә салына, з-д бу очкычларны эшләп чыгару буенча төп пр-тиегә әверелә. 1947 нең 3 августында сериядәге өч Ту-4 самолёты һәм Ту-70 самолёты (пассажирлар варианты) Тушино авиация парадында катнашалар. 1951 дә Очу-сынау станциясе, самолётларны аэродромга илтеп җиткерү өчен ангар сафка баса, җир өсте радиолокация җиһазларын ясаучы махсус цех эшли башлый. 1952 дә Ту-4 самолётын чыгару туктатыла (барлыгы 655 машина эшләнә), з-д уникаль очыш-техник күрсәткечләргә ия, ерак арага очарга сәләтле, ракета йөртүче реактив Ту-16 бомбардировщигын җитештерүне үзләштерә башлый. Технологияләр камилләштерелә: беренче тапкыр эре габаритлы электрон коеп (люклар, фонарьлар) эшкәртү, фрезерлауның яңа алымнары, төркемләп пресслап чүкеп беркетү, герметик агрегатлар эшләү; панельләштерү, агрегат аергычларның тоташу өлекләрен һәм тишекләрен механик эшкәртү гамәлгә кертелә, электрожгутлар ясау өчен махсус плазлар эшләнә, плазлар б-н бәйләнешле җайланмалар буенча коммуникацияләр системаларын монтажлау үзләштерелә һ.б. Ту-16 самолётларын җитештерү чорында 10 нан артык модификациядә 799 очкыч эшләп чыгарыла (эре модификацияләрнең берсе пассажирлар самолёты Ту-104Б була; 100 ләп машина эшләнә). Самолётлар Кытайга, Индонезиягә, Мисырга, Гыйракка җибәрелә. Ту-16 самолётын серияләп җитештерү 1963 елда туктатыла. 1957–62 дә з-д куәтләрен күпкә (төп фондларны — 18 % ка, җиһазларны — 13 % ка, мәйданнарны — 8 % ка) үстерә, бу яңа буын самолёт, ерак арага очарга сәләтле, тавыш тизлегеннән югары тизлекле Ту-22 бомбардировщигын төзүне үзләштерү вакытын кыскарту мөмкинлеген бирә. З-д терр-ясендә аны сынау өчен яңа очып күтәрелү-төшү юлы төзелә. 1961 дә өч Ту-22 самолёты Тушино авиация парадында катнаша. 1962 дә самолёт Корallы көчләр составына кабул ителә (барлыгы 300 дән артык машина, ш.и. Гыйракка һәм Ливиягә җибәрү өчен очкычлар чыгарыла). 1962–64 тә, ерак магистральләрдә очучы Ил-62, соңрак аның модификациясе булган Ил-62М пассажирлар самолётларын серияләп җитештерү өчен (1994 ахырына кадәр барлыгы 278 самолёт эшләп чыгарыла, бу самолётлар дөньяның 9 иленә җибәрелә), пр-тиедә барлык база куәтләре камилләштерелә. 1960 еллар ахырында Ту-22М стратегик бом-

бардировщигын эшләү үзләштерелә (яхшыртылган очыш-техник күрсәткечләре б-н Ту-22 схемасы саклана), аның тәҗрибә үрнәге з-дта эшләнә; 1969 да бу самолёт серияләп чыгарыла башлый (төрле модификациядәге 497 очкыч төзелә). Ту-22, Ту-22М самолётлары Әфганстанда сугыш хәрәкәтләре алып бару өчен файдаланыла. 1967 дә Лениногорск шәһәрендә з-дның ф-лы төзелә, анда «Казанка-5» һәм «Казанка-2М» көймәләрен конвейерда җитештерү оештырыла. Бишьеллык планны уңышлы үтәгәне өчен пр-тие Ленин ордены (1971), авиация техникасы җитештерүдәге казанышлары өчен Октябрь революциясе ордены (1977) б-н бүләкләнә. 1978 дән — з-д хәзерге исемдә. 1980 еллар башында коллектив дөньядагы иң зур (озынлыгы — 54,1 *м*; канат җәеме — 55,7/35,6 *м*), шул ук вакытта иң көчле хәрби самолётларның берсе булган, канатлар геометриясе үзгәрешле Ту-160 стратегик бомбардировщигын төзүне үзләштерүгә керешә. Әлеге самолётларны җитештерүгә бәйле рәвештә производство мәйданнарының саны ике тапкыр диярлек арта, технол. җиһазлар паркы яңартыла, аның нигезен санлы программалар б-н идарә итүле станоклар һәм югары җитештерүчәнлекле эшкәртү үзәкләре тәшкил итә. Күп кенә уникаль технол. процесслар, ш.и. дөньяда тиңе булмаган — калын стеналы зур габаритлы титан эретмәсе конструкцияләрен электрон-нурланыш ысулы б-н эретеп ябыштыру үзләштерелә (1992 елга 27 машина эшләп чыгарыла). Ту-160 Россия стратегик көчләренең атом-төш коралын һавада йөртүче төп очкычы булып тора. 1990 еллар уртасында з-дта уртача магистральдә очучы Ту-214 пассажирлар самолётын серияләп чыгару башлана. Берләшмәне техник яктан үзгәртеп кору һәм яңадан коралландыру эшләре дәвам итә. 2000 дә тимерчелек корпусының 1 нче чираты файдалануга тапшырыла. Самолётларның канатларын һәм фюзеляжларын халыкара стандартлар дәрәҗәсендә сыйфатлы җыюны тәэмин итүче заманча чүкеп ябыштыру автоматлары урнаштырыла. 1997 дә Ту-214 самолёты дәүләт сертификациясен уза, 2001 дә КАПОга аның производствосын хуплау турында Таныклык (РФдә бердәнбер) бирелә. Шул ук елда Ту-214 пассажирлар лайнеры 44 нче халыкара «Ле Бурже» аэрокосмик салонында тәкъдим ителә (Франция). Очыш-техник характеристикалары һәм урындагы тавыш күрсәткечләре буенча самолёт Россия һәм халыкара авиация нормаларының барлык таләпләренә җавап бирә. «Россия гражданнар авиациясе техникасының 2002–2010 елларда һәм 2015 елга кадәрге чорда үсеше» Федераль программасы нигезендә КАПО Ту-214 самолёты модификацияләрен эшләү һәм аларны җитештерү буенча төп башкаручы итеп билгеләнә. 1990 еллардан башлап пр-тие, заказчы таләпләренә туры китереп, самолётны берәмләп җитештерүгә күчә. Завод элек төзелгән хәрби һәм гражданнар самолётларын модернизацияләү һәм ремонтлау, ш.у. композицион материаллар, халык куллану товарларын эшләп чыгару б-н шөгыльләнә. 2002 дән С.П.Горбунов исем. Казан авиация җитештерү берләшмәсе (КАПО) — федераль дәүләт унитар пр-тиесе, 2008 дән АҖ. 2009 дан пр-тие Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе составында. Эшләү елларында 20 меңнән артык самолёт төзелә. Пр-тие шәһәр инфраструктурасын үстерүгә зур өлеш кертә. Торак төзелеше темпларын тизләтү максатында авиация берләшмәсе каршында йөртлар төзү комб-ты булдырыла. 1974–93 тә гомуми мәйданы 360,1 мең *м*² тәшкил иткән торак йөртлар, уку-курс комб-ты, ПТУ комплексы, профилакторий, балалар бакчалары, мәктәп, пионер лагере, ял базасы, шәһәр хуҗалыгы объектлары һ.б. төзелә. Пр-тиенең 1 меңнән артык хезмәткәре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 16 кеше — Сов. Союзы Герое, 5 кеше — Соц. Хезмәт Герое, 14 кеше — СССР Дәүләт бүләге лауреаты, 68 кеше — РФ, ТРның атказ. машина төзүчесе, 7 кеше СССР, РФнең атказ. очучы-сынаучысы исемнәренә лаек була; күпләр орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре — К.Д.Кузнецов (1932–34), В.И.Мухин (1934–36), Л.Н.Шаханин (1936–37), С.С.Баринов (1937–39), И.И.Штейнберг (1939–40), М.М.Каганович (1940–41), Ю.Н.Карпов (1941–42), В.А.*Окулов* (1942–49), Л.П.Соколов (1949–53), П.П.Смирнов (1953–60), В.П.Максимов (1960–67), М.Н.Глебов (1967–73), В.Е.*Копылов* (1973–94), Ю.Д.Литвинов (1994–96), Н.Г.Хәйруллин (1996–2007); В.К.Каюмов (2007 дән); Мәскәүнең С.П.Горбунов исем. 22 нче авиация з-ды җитәкчеләре — Ф.С.Малахов (1927–30), С.П.Горбунов (1930–33), В.А.Окулов (1938–41). Ш.у. к. *Авиация*, *Авиация сәнәгате*.

*Әд.:* Гренько в А.И. Отраслевой район авиастроения и проблема планового управления его экономикой. К., 1963; Саукке М.Б. Самолёты Туполева. М., 1995; Кербер Л.Л. Туполев. СПб., 1999; Казань: Спец.вып. 1999. № 3/4; Ригмант В.Г. Самолёты ОКБ А.Н.Туполева. М., 2001; Завод стратегического назначения. К., 2002.

*А.И.Сурская, Г.Я.Мәүлетова.*

**КАЗА́Н АВИА́ЦИЯ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан техник университеты.*

**КАЗА́Н АВИА́ЦИЯ ТЕХНОЛО́ГИЯСЕ ФӘННИ́-ТИКШЕРЕНҮ́ ИНСТИТУТЫ́** (КНИАТ), 1958 елда Мәскәүнең Авиация технологиясе һәм производствоны оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы (КФ НИАТ) буларак нигез салына. 1991 дә — Казан авиация технологиясе һәм производствоны оештыру фәнни-тикшеренү ин-ты, 1995 тә Сәнәгать, бизнес һәм хосусыйлаштыру ин-ты итеп үзгәртелә, 2003 тән хәзерге исемдәге АҖ. Авиация сәнәгате пр-тиеләрендә фәнни-тикшеренүләрне оештыру, фәнни-техник базаны формалаштыру бурычларын оператив хәл итү максатыннан оештырыла: сәнәгать җитештерүе һәм идарә итү проблемалары буенча төп ин-т булып тора.

1959 да җитештерү процессларын комплексலы автоматлаштыру, материаллар белеме һәм икътисад лаб-яләре оештырыла. 1961 дә даими эшләүче тармак технологик күргәзмәсе ачыла. Казан авиация сәнәгате пр-тиеләрендә һәм «Радиоприбор» з-дындагы база лаб-яләре дә ин-тның мөһим бүлекчәләре булып тора, фәнни-тикшеренү эшләренең тулы комплексы аларда үткәрелә. 1960–70 елларда ин-т вертолёт төзү буенча төп фәнни бүлекчәгә әверелә, ш.у. КБлар һәм тармак пр-тиеләренең техника һәм оештыру дәрәҗәсе өчен җаваплы була. Институт җитәкчелек иткән юнәлешләр: яңа вертолётларның технол. конструкцияләрен эшләтеп бетерү; вертолётлар төзелеше өчен технологияләр һәм махсус җиһазлар булдыру; эшләнмәнең параметрларын тикшерүнең автоматлаштырылган системаларын («КАСКАД», «АСОИ» һ.б. типларда) эшләү; ультратавыш һәм өермә токлар методларына нигезләнеп, зыянсыз тикшерүләр өчен приборлар һәм системалар уйлап табу һәм эшләү. Вертолётлар төзелешенә караган эшләрнең күләме ин-ттагы конструкторлык бүлекләре куәтенең 70% ын алып тора; алар арасында — тоташ металл канатлар җитештерү буенча технологияләр, җиһазлар эшләү һәм аларны гамәлгә кертү. Барлыгы 74 яңа фәнни-проектлау эше башкарыла, шуларның 43 е — яңа типтагы махсус һәм махсуслашкан технологик җиһазлар (ССТО), ССТОның 28 моделен эшләп чыгару буенча 55 проект эше гамәлгә кертелә. Илнең төрле з-дларында ССТО нигезендә лонжероннар фрезерлау һәм шомарту, кәрәзле конструкцияләр җитештерү, гидроагрегатларны сынау буенча комплекслы механикалаштырылган 8 производство участогы оештырыла.

1970–80 елларда санлы программалар б-н идарә ителүле станокларда детальләр эшкәртүне автоматлаштыру; идарә итүче программаларны әзерләү чараларын, ш.у. газ турбиналы двигательләрне һәм борт җиһазларын автомат тикшерү системаларын, самолётларның идарә итү системаларын булдыру эше алып барыла. Казан моторлар төзү ҖБндә (КМПО) табаклы титан эретмәләрен, индукцион җылыту кулланып, зур үлчәмле бөкра әзерләнмәләр рәвешенә китерү буенча эшләр гамәлгә кертелә (С.Г.Гомәров, А.Н.Ткаченко), һәм бу — материалдан файдалану коэффициентын 4–5 тапкыр арттыра. Махсуслаштырылган технол. җиһаз һәм җайланмаларның 133 тәҗрибә үрнәге проекты эшләнә; ин-т хезмәткәрләренең проектлары буенча РФ Авиация сәнәгате министрлыгының Баш техник идарәсе пр-тиеләрендә 199 берәмлек җиһаз һәм прибор әзерләнә, шуларның 15 е — лонжероннар фрезерлау өчен ярымавтомат агым линиясе (ППЛ-2, ППЛ-3) үрнәкләре, лонжероннар шомарту станоклары (СШЛН-3, СШЛН-4), АСРН тибындагы агрегат станоклар, программалар әзерләү һәм идарә итүнең техник чаралары (СОРЦ-И һ.б.). Тармак пр-тиеләре ин-тның эксперименталь базасында әзерләнгән 2 меңнән артык автоматлаштырылган тикшерү станогы, приборы һәм җиһазы ала. Алар арасында — зыянсыз тикшерү приборлары (УТ-102, ВДУ-20К, УТ-501), койрык бүлекләре булган лонжерон җыю җайланмасы (УСЛ-5), лонжеронның пыяла-пластик җылыту җайланмасын нығытып беркетү җайланмасы (УПСР-2), эшләнмәләрне авто-

матлаштырылган тикшерү системалары («КАСКАД», «АСОИ-400» һ.б.). 1975–81 дә ин-тта 692 проект эше башкарыла (шуларның 310 ы патент дәрәҗәсендә) һәм алар буенча уйлап табуга 212 авторлык таныклыгы тапшырыла. 2 объект патентлана (сызыкча түгәрәк интерполятор ИЛК-3М һәм шартлагыч тәэсирле югары тизлекле чүкеч), алар буенча 20 чит ил патенты алына; 32 эш СССР ВДНХсының 117 медаленә лаек була, 52 эш төрле күргәзмәләрдә дипломнар, премияләр һәм Мактау грамоталары б-н билгеләнә. 1995 тән ин-тта үсеш алган юнәлешләр: республикада сәнәгать тармаклары икътисадын анализлау, фаразлауларны һәм үстерү программаларын эшләү; финанс-хуҗалык эшчәнлеген анализлау, сәнәгатьне үстерүнең кыска һәм озын вакытлы фаразларын эшләү өчен мәгълүмат булдыру; инвестиция проектларын формалаштыру һәм анализлау өчен методик һәм инструменталь чаралар эшләү; республика күләмендәге җитештерү-хуҗалык бәйләнешләрен үстерү өчен мәгълүматлар базасын төзү. Институт пр-тиеләрнең инженерлык-техник бүлекләре җитәкчеләре өчен производство һәм эшләнмәләрнең сертификациясе буенча дәресләр һәм консультацияләр үткәрә, фәнкатнаш бизнес пр-тиеләре үсешен яклау б-н бәйле хезмәтләр



Казан авиация технологиясе фәнни-тикшеренү институты. Төп административ-инженерлык бинасы.

күрсәтә. Фән, производство һәм эшмәкәрлекнең яңа формаларын үстерү өчен инновацион-технол. үзәк һәм фәнни-сәнәгый парк булдырыла.

Институтның төп структура бүлекчәләре: конструкторлык-технол. комплексы, производствоны автоматлаштыру комплексы; җитештерү-тәҗрибә комплексы; укыту-тикшеренү үзәге; фәнни-сәнәгый парк; инновацион-технол. үзәк, двигательләрнең стенд сынауларының матем., программ һәм метрологик тәэмин ителеше, сыйфаты һәм ышанычлылыгы секторы. Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең иң мөһим юнәлешләре: композицион материалдан эшләнгән төп көч һәм руль винтлары калакларын җитештерү; деталь һәм узелларны вибрацияле-бәрмә һәм вакланган-бәрмә юл б-н чыныктырып ныгыту; композицион материалларны эшкәртү, ш.у. болт-заклёпка, кушыш



Фюзеляж тутыргычын формалаштыру җайланмасы.

стерженьлы заклёпкалар һәм берьяклы ныгыту юлы б-н тоташтырмалар ясау өчен инструментлар эшләү һәм сату; металл һәм металл булмаган деталь һәм узелларны ультратавыш һәм өермә ток нигезендә зыянсыз тикшерү; электростатик кырда порошок сыман полимер композицияләрдән декоратив-саклагыч һәм коррозиягә бирешмәүчән каплаулар ясау; җитештерү процессларын автоматлаштыру (натураль стенд сынаулары, көч җайланмаларын сынау, технол. процессларны көйләү һәм алар б-н идарә итү һ.б.); производствоның технол. әзерлеген автоматлаштыру; табаклы материаллардан теләсә нинди конфигурацияле куыш детальләрне бер күчешле тирәнтен сузу өчен технологияләр эшләү һәм җиһазлар төзү; эшче өслекләрен электролитик формалау кулланып, пресс-формалар әзерләүнең технол. процессларын булдыру; яңа вертолётларны икътисади-техник бәяләү; сәнәгать пр-тиеләрен уртача һәм озак сроклы үстерү фаразларын, дәүләт көйләве алымнарын эшләү; маркетинг мәгълүматының төбәк системасын булдыру; продукцияне, хезмәт күрсәтүләрне, производствоны, персоналны һәм сыйфат тәэминаты системасын сертификацияләү; торак-коммуналь эш кораллары, автоматлаштыру чаралары һәм махсус киемнәр б-н тәэмин итү; патентка лаек тикшеренүләр һәм хезмәт күрсәтүләр үткәрү; сәнәгать пр-тиеләрен реструктуралаштыру һәм аларның реинженерингы буенча методик материаллар эшләү.

Институт хезмәткәрләре тарафыннан 40 тан артык монография бастырып чыгарыла, уйлап табуга 700 тирәсе авторлык таныклыгы һәм патент алына (2010).

Институт илнең 50 дән артык пр-тиесе, фәнни-тикшеренү ин-тлары, вуз һәм учреждениеләре, ш.у. Украина, ГФР пр-тиеләре һәм «AIRBUS» халыкара авиация концерны б-н фәнни-техник бәйләнештә тора.

Институтның директорлары: А.И.Греньков (1959–76), Г.В.Кузнецов (1976–87), Г.И.Карунин (1987–90), В.Д.Шершуков (1990–94), И.М.Закиров (1995–2009), Ф.Г.Шәйхиев (2009 дан).

*Әд.:* Г р е н ь к о в А.И. Планирование научных исследований и разработок. К., 1969; Государственному институту промышленности, бизнеса и приватизации Республики Татарстан 40 лет // Междунар. науч.-практ. конф. «Теоретические, конструкторско-технологические, организационные проблемы и обеспечение качества при создании и освоении новых изделий». К., 1999; З а к и р о в И.М. Казанскому НИАТ 45 лет // Инновационные технологии в проектировании, производстве и испытаниях изделий машиностроения: Сб. материалов науч.-практ. конф. К., 2004.

*И.М.Закиров, В.Г.Товстуха, Р.Г.Усманов.*

**КАЗА́Н АВИА́ЦИЯ-ТЕ́ХНИК КӨЛЛИЯТЕ́**, П. В. Д е м е н т ь е в и с е м е н д ә, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1932 елда, Казанда авиация пр-тиеләре төзелүгә бәйле рәвештә авиация техникумы буларак оештырыла. 2007 дән хәзерге исемендә, шул ук елда П.В.*Дементьев* исеме бирелә. 2010 елга бюджет бүлегендәге белгечлекләр: очу аппаратларын җитештерү; авиация двигательләрен җитештерү; машиналар төзү технологиясе; технол. процессларны һәм производствоны автоматлаштыру; автоматлаштырылган мәгълүмат эшкәртү системалары һәм идарә итү; түләүле бүлекләрдә: хисаплау техникасы чараларына хезмәт күрсәтү технологиясе; икътисад һәм бухгалтерлык исәбе; менеджмент; маркетинг.

Эшләү дәверендә 20 белгечлек буенча 37 меңнән артык белгеч әзерләнә. Техникумда 1932–41 елларда Г.Н.Кутуй әдәбият укыта. Көллиятне тәмамлаучылар арасында производствоны оештыручылар: С.А.*Когогин*, А.М.*Котов*, В.Н.*Иванов*, А.П.*Лаврентьев*, Н.С.*Якубов*, А.М.*Яушев*; галимнәр: авиатөзүче М.Б.*Вахитов*, җылылык техникы А.В.*Фафурин*, СССРның халык артисты А.З.*Аббасов*, Сов. Союзы Герое А.К.*Абдрахманов*, волейбол буенча дөнья чемпионы Н.Ш.*Фәсахов* бар. Укытучылар коллективында якынча 120 кеше, ш.и. 1 РФнең атказ. мәктәп укытучысы, 4 ТРның атказ. мәктәп укытучысы. 2010 да көндезге бүлектә якынча 1250, кичке бүлектә 380, читтән торып уку бүлегендә 230 студент, ш.и. 110 кеше түләүле бүлектә укый. Уку бинасы 1968 дә төзелә, җиһазландырылган 50 кабинет һәм лаб., 2 укыту-производство остаханәсе, музей эшли.

**КАЗА́Н АВТОТРА́НСПОРТ ТЕ́ХНИКУМЫ**, А. П. О б ы д ё н н о в и с е м е н д ә, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1945 елда Мари Респ-касының хәзерге Звенигово р-ны Муш-Мари посёлогында, СССР Юллар халык комис-тының урман техникумы җирлегендә оештырыла. 1951 дә Васильево посёлогына күчерелә. 1954 нең февраленнән СССР Урман һәм кәгазь җитештерү сәнәгате министрлыгы тимер юл транспортының Васильево урман техникасы техникумы, 1954 тән СССР Урман сәнәгате министрлыгының Васильево урман техникумы, 1962 дән Васильево автотранспорт техникумы. 1986 дан Казанда. 2002 дә А.П.Обыдённов исеме бирелә. Белгечлекләр: автомобиль транспортына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, йөк ташуны оештыру һәм транспорт хәрәкәте б-н идарә итү, йөк күтәрү транспортын, төзелеш, юл машиналарын һәм җи-

һазларын ремонтлау һәм алардан файдалану. 2010 да көндезге бүлектә якынча 800, читтән торып уку бүлегендә 450 кеше укый; укытучылар коллективында 67 кеше, ш.и. 5 ТР-ның атказ. мәктәп укытучысы эшли. Эшләү дәверендә 15 меңләп белгеч әзерләнә. Техникумда 4 укыту-лаб. бинасы бар.

*Р.М.Вәлиева.*

**КАЗА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан аграр университеты.*

**КАЗА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ТӘҖРИБӘ́ СТА́НЦИЯСЕ**, 1920 елда оештырыла. Аңа Усад авылындагы (Казаннан 25 *км*) Журавлёвлар утарындагы барлык корылмалар һәм 175 дис. җир, Казанда 126 дис. җир (Казан пехота юнкерлар уч-щесенең хәрби полигоны), Воскресенский монастыреның һәм Архиерей дачасының барлык корылмалары бирелә. Беренче елларда станциядә кырчылык, селекция, болынчылык, а.х. энтомологиясе, умартачылык, бакчачылык, а.х. метеорологиясе бүлекләре, аграр лаб. оештырыла, җитәкчеләре — И.В.Благовещенский, И.И.Штуцер, П.А.Трухин, В.И.Логинов, Ф.В.Чирков. К.а.х.т.с.нең ике — Казаннан 15 *км* ераклыктагы Калинин исем. (Естачинское) һәм 120 *км* ераклыктагы (хәзерге Чистай сорт участогы терр-ясе) тәҗрибә кырлары була, аларда селекция, минераль ашламалар куллану, чиста һәм биләүле парларның ролен өйрәнү, болыннарны җиңелчә яхшырту алымы буенча эшләр алып барыла.

1929 да арышның Е.Н.Борисова тарафыннан булдырылган «*Авангард*» сорты районлаштырыла. 1921 дән К.а.х.т.с. татар һәм рус телләрендә «Казан игенчесе» («Казанский земледелец») ж-лын чыгара; 1929 да бу журналда П.А.Трухинның «Болыннарны тамырдан яхшырту алымнары» («Приёмы коренного улучшения лугов»), «Татарстан болынналарының уңдырышлылыгын күтәрү юллары» («Пути к поднятию урожайности лугов Татарстана») дигән хезмәтләре басыла.

1932 дә Югары Идел селекция үзәге итеп үзгәртелә, аның җирлегендә 1935 тә *Казан селекция станциясе* оештырыла. К.а.х.т.с.нең җитәкчеләре: Н.М.Феофанов (1920–25), Ф.А.Александров (1925–27), К.А.Ходжаев (1927–32), К.Ф.Жданов (1932), А.В.Жаров (1932), К.П.Грибаков (1932), А.П.Водков (1933), М.Ә.*Әхмәтшин* (1934–35).

*Әд.:* Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства — 50 лет. К., 1971.

*А.А.Җиһаншин, И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ һӘМ УРМАНЧЫЛЫ́К ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан аграр университеты.*

**КАЗА́Н АГРА́Р УНИВЕРСИТЕТЫ́**, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының югары уку йорты. 1919 елда *Казан җир эшләре училищесе һәм коммерция училищесе* җирлегендә төзелгән *Казан политехник институтының* а.х. ф-ты ачыла, 1922 нең 22 маенда ул 2 ф-ты булган Казан а. х. һәм урманчылык ин-ты итеп үзгәртелә. 1930 да урманчылык ф-ты аерым ин-т булып Йошкар-Ола шәһәренә күчерелгәннән соң, 1934 тә Казан авыл хуҗалыгы ин-ты А.М.Горький исеме б-н атала башлый. 1995 тә аңа академия статусы бирелә, 2006 да хәзерге исемен ала.



Казан аграр университеты. Төп корпус.

1930–41 дә Казанда кичке, ә Алабугада көндезге бүлеге булган эшчеләр ф-ты эшләп килә. 1933 тә зоотехния ф-ты ачыла. 1936 да ул Ветеринария ин-тына күчерелә (к. *Казан ветеринария медицинасы академиясе*), 1943–48 дә җиләк-җимеш, яшелчә ф-ты, 1949–55 тә агро-урман-мелиорация ф-ты эшли. 1950 дә а.х.н механикалаштыру ф-ты (хәзерге Механикалаштыру һәм техник хезмәт күрсәтү ин-ты) ачыла, 1961 дә икътисад ф-ты (хәзерге Икътисад ун-ты) эшли башлый. 1965–92 дә а. х. хезмәткәрләре һәм җитәкчеләренең квалификациясен күтәрү ф-ты эшли. 2000 нән урманчылык белгечләрен әзерләү эшчәнлеге яңартыла, 2003 тә урманчылык һәм экология ф-ты ачыла. Баулыда (1997), Нурлатта (2000) ф-ллары, Бөгелмә, Буа, Минзәләдә вәкилләре бар. 1997 дә югары уку йортына керергә әзерләү ф-ты оештырыла.

Эшләү дәверендә 30 меңнән артык белгеч әзерләп чыгарыла. Тәмамлаучылар арасында соңыннан дәүләт эшлеклеләре булган Г.И.Усманов, М.Ш.Шәймиев, Р.Н.Миңнеханов һ.б., күп кенә министрлар, ТР р-ннарының хакимият башлыклары, ВАСХНИЛ вице-президенты В.П.Мосолов, СССР ФА академигы Б.А.Арбузов, РАХФА мөхбир әгъзалары А.А.Җиһаншин, Н.К.Мәҗитов, 60 тан артык фән д-ры бар. 2010 елга ун-т составында 2 ин-т һәм 2 ф-т, 36 кафедра исәпләнә, 25 белгечлек буенча белем бирелә. Көндезге бүлектә 2800 дән артык, читтән торып уку бүлегендә 2000 ләп, ш.и. бюджеттан тыш нигездә 1900 студент укый. Пед. коллектив 320 дән артык укытучыдан тора, алар арасында РАХФА мөхбир әгъзасы Н.К.Мәҗитов, ТР ФА мөхбир әгъзалары Җ.И.Фәйзрахманов, Р.А.Сәхапов, Р.И.Сафин, 44 фән докторы һәм 156 фән кандидаты бар.



Казан аграр университеты. Авыл хуҗалыгын механикалаштыру факультеты корпусы.

Ачылган елларыннан ук вузда актив фәнни эшчәнлек алып барыла. Беренче профессорлары — университетның фәнни мәктәпләре вәкилләре: математик Н.Н.Парфентьев, ботаник А.Я.Гордягин, А.П.Пономарёв, агрономнар: В.П.Мосолов, А.К.Вершинин, А.В.Ватагин, П.М.Тихонов, А.А.Җиһаншин, М.Ф.Әмиров, Ф.Ш.Шәйхетдинов, үсемлекләр физиологиясе белгече Ф.Д.Самуилов, агрохимик Б.И.Горизонтов, туфрак фәне белгечләре Н.В.Тюрин, И.В.Үтәй, а.х. механикалаштыру һәм машиналар белеме өлкәсендәге галимнәр Б.В.Шитиков, Ф.С.Завалишин, П.Г.Мудров, И.С.Возовик, а.х. икътисады галимнәре М.И.Куркин, Н.С.Катков, М.Т.Шабаев.

Университетта агрономия һәм үсемлекчелек (В.П.Владимиров, А.С.Салихов, Р.И.Сафин), агроэкология (Ф.Н.Сафиуллин, А.Ш.Шакиров), агрохимия (И.Д.Дәүләтшин, М.И.Гыйләҗев, М.Н.Сафиуллин, И.А.Гайсин), терлекчелек (Г.С.Шәрәфетдинов), туфрак белеме (А.Т.Сабиров), ботаника (В.М.Пахомова), а.х. механикалаштыру (Н.К.Мәҗитов, Р.А.Сәхапов, Н.П.Самойлов, Ю.И.Матяшин, А.Г.Мудров, И.Г.Хәбибуллин, Ә.Х.Җомагылов, Э.Г.Нуруллин, А.П.Мартьянов), хезмәтне саклау (Ф.Х.Ермаков), а.х. икътисады (Җ.И.Фәйзрахманов, Л.М.Рабинович, В.П.Захаров, Д.Ф.Фатихов, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев) буенча тикшеренүләр үткәрелә. 25 белгечлек буенча аспирантура (1961 дән 219 аспирант), а.х. һәм техник фән. докторлары дәрәҗәсендә 2 диссертация советы бар.

Укыту базасын шәһәр үзәгендәге төп корпус (элеккеге *Казан коммерция училищесе* бинасы, архит-ра истәлеге) һәм «Ферма-2» комплексы, аның нигезен элеккеге Казан җир эшләре уч-щесе корпуслары, ш.у. механикалаштыру (1988), урманчылык ф-тлары, спорт комплексы корпуслары тәшкил итә.

Университет карамагында фәнни-тәҗрибә хуҗалыгы, хуҗалык транспорты паркы, фәнни җитештерү үзәге, 5 тулай торак бар, 1925 тән «Вестник» (1947 гә кадәр — «Известия», 2007 гә кадәр «Труды»), 1966 дан «Колос» г-талары нәшер ителә.

Казан аграр ун-ты «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә (1982).

Ректорлары: Н.Н.Парфентьев (1922–24), М.К.Корбут (1925–27), А.И.Луньяк (1927–29), Н.В.Красавин (1929–32), Н.Д.Дадыгин (1933–34), Н.С.Соловьёв (1935–36), М.А.Палькин (1936–38), К.В.Мостафин (1938–40), А.А.Анисимов (1940–41), А.К.Вершинин (1941–43), В.К.Голосов (1943–45), С.Н.Коньков (1946–57), С.В.Гойтанников (1957–64), Р.С.Трикоз (1964–68), С.А.Ильин (1968–71), Н.С.Катков (1971–85), М.Т.Шабаев (1985–96), Җ.И.Фәйзрахманов (1996 дан).

*Әд.:* Казанский сельскохозяйственный институт имени А.М.Горького: Ист. справ. К., 1972; Казанская государственная сельскохозяйственная академия. 80 лет. К., 2002.

**КАЗА́Н АДМИРАЛТЕ́ЙСТВОСЫ**, 1718 елда Пётр I Фәрманы нигезендә судноларны төзү, ремонтлау һәм озак вакыт саклау өчен оештырыла. Казансу елгасы тамагында, Бишбалта авылы янында урнаша. Аңа Әстерхан (1722 гә кадәр), Казан һәм Түбән Новгород верфьләре керә. Эшчеләр сыйфатында Адмиралтействога тирә-яктагы торак пунктлар крәстияннәре, күбесенчә татарлар, чуашлар һәм марилар беркетелә. Корабльләр төзү өчен агач әзерләү эшенә феодаль бәйлелектәге кешеләр һәм йомышлы татарлар (к. *Лашманнар*) җәлеп ителә. 18 йөз ахырына Адмиралтействода эшләүчеләрнең гомуми саны 100 мең кешедән артып китә. К.а. эшләре буенча беренче управляющий итеп Казанның элеккеге воеводасы Н.А.*Кудрявцев* билгеләнә. Беренче елларда ук 7 стапель (аларда судно корпуслары төзелә), төзелеш һәм азык-төлек складлары, сарайлар, казармалар, сызым сызу, брандспойт, фонарь, балта эшләре, җилкән, мичкә ясау, аркан ишү һәм шлюпка остаханәләре, 20 учакка тимерче алачыклары, канцелярия бинасы, чиркәү төзелә. Осталар әзерләү өчен 1718 елда Казанда беренче цифирь мәктәбе ачыла. Адмиралтействоның конторалары шәһәр үзәгендә була (к. *Адмиралтейство конторасы комплексы*). Адмиралтейство терр-ясе капкалы манаралары булган, су тутырылган тирән чокырлы агач ныгытма б-н әйләндереп алына. Суга таш тоз салалар, аннары анда имән яркаларны чылаталар һәм тозландыралар. Верфькә тирән канал тоташа, аның буенча агач материаллары китерелә һәм шунда имән һ.б. төзелеш материаллары тозландырыла. Адмиралтейство б-н янәшә адмиралтейство хезмәткәрләре: осталар, солдатлар, матрослар һ.б. яши (к. *Бишбалта бистәсе*). Стапельләрдән судноларны елына бер тапкыр, майның беренче яртысында, Иделдә һәм Казансуда язгы су ташыганда төшерәләр, һәм ул, гадәттә, шау-шулы тантана б-н үтә. 1722 дә К.а.нда Пётр I була. 4 елда Адмиралтействода 40 лап төрле судно төзелә. Нәкъ менә шуларга утырып Пётр I 100 меңлек гаскәр б-н 1722–23 еллардагы Персия яуларына китә. К.а.нда Азов, Балтыйк һәм Каспий флотлары өчен барлыгы 400 ләп төрле типтагы судно (бомбардир корабльләр, галера, галиот, вельбот, фрегат, корвет, бриг, бригантина, бот һ.б.лар) төзелә. 1829 да Әстерхан порты командующие П.Г.Орловский инициативасы б-н К.а. Әстерханга, Каспий диңгезенә якынгарак күчерелә. Казанда 1860 елга кадәр агач материаллар әзерләү һәм насослар өчен помпа күне эшләү дәвам иттерелә.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**КАЗА́Н АЕКЛА́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, җәмәгать хәйрия оешмасы. 1892 елның 30 июлендә шәһәр халкы арасында спиртлы эчемлекләр кулланугa каршы тору, җәмгыять әгъзаларына матди һәм әхлакый ярдәм күрсәтү, кирәк булганда, эшкә урнаштыруда булышу максатында Казан җәмәгать эшлеклеләре тарафыннан оештырыла. Алыштыргысыз җитәкчесе — А.Т.Соловьёв. Төрле вакытта җәмгыять эшендә актив катнашучылар: А.И.*Александров*, Л.О.*Даркшевич*, И.М.*Догель*, Н.П.*Загоскин*, П.В.*Знаменский*, Н.Ф.*Катанов*, М.А.Кулаев, епископ *Андрей* һ.б. Җәмгыять иганәчеләренең берсе П.А.Столыпин була. Кронштадттагы Андрей соборы протопирее Иоанн (И.И.Сергеев), Грузия экзархы Алексий (А.В.Мочанов), Самара губернаторы А.С.Брянчанинов, Казан губернаторы М.В.Стрижевский һ.б. җәмгыятьнең шәрәфле әгъзалары булып торалар. Казанда исерткеч эчемлекләрсез чәйханәләр, хәйрия кунып чыгу йорты, китапханә-уку йорты, урта уку йортлары укучылары — ир балалар өчен ятимханә тота. 1896 ның мартында җәмгыять эчкечелек б-н авыручылар өчен Россиядә беренче хастаханә ача, 1909 да ул зур дәвалау үзәгенә әверелә. 1900 дә Казанда аның күзәтчелегендә «Бәхетсез хатын-кызларны яклау җәмгыяте» эшли башлый, аның төп бурычы фәхишәлеккә каршы көрәшү була. К.а.җ. аңлату эшләре алып бара, эчкечелеккә каршы, героик-патриотик, дини-әхлакый темаларга язылган китап укулар оештыра. Эчкечелеккә каршы язылган брошюралар («Эчкечелекнең зарары хакында татар үгет-нәсыйхәте» — «Татарское поучение о вреде пьянства», «Эчкечелекнең зарары хакында татар хикәяләре» — «Татарские рассказы о вреде пьянства», «*Деятель*» ж-лы чыгара. Елына бер тапкыр, 29 августта, Казанда аеклык бәйрәме уздыра. 1902 дә К.а.җ.ндә 2073 кеше әгъза булып тора, Казан губернасыннан читтә 40 лап бүлекчәсе эшли. 1905–07 еллардагы рев-ция вакытында җәмгыять сәясиләшә, моңа аның җирлегендә А.Т.Соловьевның карагруһчылар «Русское собрание»сенең Казан бүлекчәсен оештыруы сәбәпче була. 1906–07 дә җәмгыять түләүсез куну йорты, укучы балалар өчен приют, берничә остаханә оештыра, эчкечелек психозлары б-н авыручылар өчен Россиядә беренче махсуслаштырылган хастаханә ача; Мәрхәмәтле Спас хакына чиркәү төзетә. Җәмгыятьнең эшчәнлеге Россиядә һәм чит илләрдә югары бәяләнә (Туриндагы күргәзмәдә аңа иң югары бүләк бирелә). Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, җәмгыять «коры закон» кертүне яклап чыга. 1917 дә үз ихтыяры б-н таркала.

*Әд.:* к. *Казанда православие динендәге рус хатын-кызлары җәмгыяте.*

*И.Е.Алексеев.*

**КАЗА́Н АЗЫ́К СӘНӘГАТЕНЕ́Ң МЕХА́НИКА-ТЕХНОЛО́ГИЯ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты (2006 дан). 1930 елда М.Вахитов исем. 1 нче химия з-ды (к. «*Нәфис Косметикс*») каршында югары технол. уку йортының урта звеносы буларак оештырыла, 1932 дән — Казан май техникумы, 1938 дән — Казан технол. техникумы, 1965 тән — механика-технол. техникумы, 2006 дан хәзерге исемдә. Иң элек май сәнәгате, 1960 тан, башлыча, азык-төлек сәнәгате өчен белгечләр әзерли. Ул буйсынган ведомстволар еш алышына, К.а.с.м.-т.т. СССР Химия сәнәгате, РСФСР Азык-төлек сәнәгате, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыклары карамагында була. Техникум сәнәгать җиһазларын монтажлау һәм технол. эксплуатацияләү; суыткыч-компрессор машиналарын монтажлау һәм технол. эксплуатацияләү, ит һәм ит продуктлары технологиясе; сөт һәм сөт продуктлары технологиясе буенча белгечләр әзерли. 2010 да уку йортында көндезге бүлектә — 450, читтән торып уку бүлегендә — 190, түләүле тәртиптә 171 укучы белем ала.

Укытучылар коллективында 27 кеше эшли. Техникум оешкан вакытыннан алып 19 меңнән артык белгеч әзерләп чыгара. К.а.с.м.-т.т. — азык-төлек сәнәгатенә махсус урта белемле белгечләр әзерләүче бердәнбер уку йорты, аны ТРның бу тармагында эшләүче җитәкчеләрнең күбесе тәмамлый. Техникум бертуган Крестовниковларның (1894) элеккеге завод биналарының берсендә (архит-ра истәлеге) урнашкан.

**КАЗА́Н АРХИЕРЕ́Й СЛАВЯ́Н-ЛАТИ́Н МӘКТӘБЕ́**, 1723 елның 19 мартында Казан һәм Зөя митрополиты Тихон (Воинов) тарафыннан 1721 дәге Дини регламент нигезендә оештырыла. 52 укучы кабул ителә. Беренче укытучы Украинада дини белем алган православиеле Польша шляхтичы Василий Яковлевич Свенцицкий була. Мәктәпне оештыруда митрополит Сильвестр (Холмский) төп рольне уйный, ул җитәкчелек иткән елларда мәктәп Фёдоров монастыре терр-ясендә махсус төзелгән бинада урнаша; матди яктан тәэмин итү өчен аңа ябылган ике монастырьның крәстияннәре беркетелә. 1728 дә тагын 2 укытучы билгеләнә, укучылар саны 180 кешегә кадәр арта. 1720 еллар ахырына Россиядә иң яхшы мәктәпләрнең берсенә әверелә. Дини регламентның славян-латин мәктәпләре бары тик дини катлау балалары өчен генә дигән карары булуына карамастан, Казан мәктәбенә миссионерлык максатларында ел саен әҗнәбиләрдән — чуаш, мари, керәшен татарлардан берничә бала укырга кабул ителә. 1733 тә Казан руханилар семинариясе итеп үзгәртелә.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н АРХИТЕКТУ́РА-ТӨЗЕЛЕ́Ш УНИВЕРСИТЕТЫ́**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының югары уку йорты. Университет тарихы 1919 елдан, *Казан политехник институтының* төзелеш ф-тыннан башлана. Аның нигезендә 1930 ның 23 маенда составында гражданлык корылмалары, юллар төзелеше һәм су канализациясе ф-тлары булган Казан коммуналь төзелеш ин-ты оештырыла. 1932 дә ул Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-ты (ККТИИ) итеп үзгәртелә. 900 дән артык белгеч әзерли, 1941 дә ябыла. 1946 ның 16 февралендә кадрлар составын элеккеге ККТИИ укытучылары һәм аны тәмамлаучылар тәшкил иткән Казан гражданлык корылмалары төзелеше инженерлары ин-ты буларак ачыла. 1952 дән институт СССР Нефть сәнәгате министрлыгы карамагына тапшырыла һәм Казан нефть сәнәгате төзүче инженерлары ин-ты дип үзгәртелә. 1957 дә СССР (1959 дан — РСФСР) Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы карамагына кайтарыла һәм Казан төзүче инженерлар ин-ты (КТИИ) исемен ала. 1995 нең 28 февраленнән — Казан дәүләт архит-ра–төзелеш академиясе, 2005 нең 16 фев-

раленнән Федераль дәүләт югары белем бирү учреждениесе – Казан дәүләт архит-ра–төзелеш ун-ты. 1946 дан институт бер генә төзелеш ф-тыннан торган булса, 1966 да су б-н тәэмин итү һәм канализация (хәзерге инженерлык системасы һәм экология ф-тлары), төзелеш технологияләре, автомобиль юллары (2001 дән Транспорт корылмалары ин-ты) ф-тлары ачыла. 1966 дан архитекторлар әзерли башлый, 1969 да архит-ра-төзелеш ф-ты (1977 дән архит-ра ф-ты) ачыла, 2000 дә ул Архит-ра һәм дизайн ин-ты итеп үзгәртелә. 1999 да икътисад ф-ты ачыла, 2005 тә ул Төзелеш икътисады һәм идарәсе ин-ты дип үзгәртелә.



Казан архитектура-төзелеш университеты. Төп уку корпусы.

Университет 20 меңнән артык белгеч әзерли. Аны тәмамлаучылар арасында хакимият-хуҗалык җитәкчесе П.Д.*Тунаков*, архитекторлар И.А.Вәлиев, П.А.*Саначин*, Г.И.*Солдатов*, А.А.Спориус, төзүче-инженер Ү.Г.*Алпаров* бар.

Укыту 19 белгечлек буенча алып барыла. 2010 да көндезге бүлектә 4900, читтән торып уку бүлегендә 2000 нән артык, ш.и. 3080 студент бюджеттан тыш нигездә белем ала; укытучылар коллективы 552 кешедән (ш.и. Россия Архитектура һәм төзелеш академиясе мөхбир әгъзалары С.С.Айдаров, Р.З.Рәхимов, В.Н.Куприянов, 57 фән. д-ры һәм 247 фән. канд-ты) тора.

49 кафедра, 7 фәнни-тикшеренү лаб-ясендә һәм 5 үзәктә гражданлык һәм юллар корылмалары төзелеше, инженерлык коммуникацияләре, җылылык физикасы, геофизика төзелешендә хезмәт куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча төрле тикшеренүләр алып барыла.

Университетта техник фән. докторлары Л.А.Абдрахманов, А.Б.Гаделшин, Ф.Г.Әхмәдиев, А.И.Брехман, Р.Г.Газизуллин, В.В.Герасимов, В.П.Еремеев, Г.И.Захватов, И.Л.Кузнецов, И.Т.Мирсәяпов, В.Н.Посокин, В.И.Сагадиев, Б.С.Соколов, А.М.Сөләйманов, В.Г.Хозин; архит-ра фән. докторлары – Г.Н.Айдарова, физ.-матем. фән. докторлары В.П.Деревенский, Р.Г.Каюмов, Р.Б.Сәлимов, Б.А.Кац, Д.В.Маклаков, Р.С.Хәйруллин; химия фән. докторлары – В.М.Ланцов, Л.И.Маклаков, В.Ф.Новиков, В.Ф.Строганов, В.Л.Фурер; икътисад фән. докторлары Г.М.Заһидуллина, А.И.Романова; филол. фән. докторлары В.А.Киносьян, В.К.Падерин; пед. фән. докторлары Р.С.Сафин, Н.К.Туктамышев эшлиләр. Төзелеш белгечлекләре буенча аспирантура һәм докторантура бар.

КХТИИ директорлары: З.З.Гыймранов (1930–33), Ф.И.Соболев (1933–38), С.П.Болычевцев (1938–39), И.А.Громов (1939–41) була. Казан гражданлык корылмалары төзелеше, төзүче-инженерлар һәм нефть сәнәгате төзүче-инженерлар ин-ты директоры булып Ф.М.Хәкимов (1946–57) эшли. Соңрак уку йортын җитәкләгән ректорлар: Е.Ф.Камышев (1957–64), В.А.Воскресенский (1964–68), М.Т.Кулеев (1968–88), В.Н.Куприянов (1988–2008), Р.К.Низамов (2008 дән).

*Әд.:* 50 лет Казанской высшей строительной школе (1919–1969): Ист. очерк. К., 1969; Казанской архитектурной школе 30 лет: Каталог. К., 1999.

**КАЗА́Н АСТРОНО́МИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́.** Оешуы 1814 елда И.А.*Литтров* тарафыннан Казан ун-ты каршында беренче шәһәр астрономия обсерваториясенә (к. *Казан шәһәр астрономия обсерваториясе*) нигез салыну б-н бәйле. 1890 елларда К.а.ф.м. Д.И.*Дубяго* эшчәнлегенә нисбәтле үсеш ала; ун-т обсерваториясенең штаты киңәя, астрономия кафедрасына сәләтле яшьләр килә, 1901 дә төп шәһәр яны астрономия обсерваториясенә (1903 тән – Энгельгардт обсерваториясе, 1931 дән – Казан ун-тының В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясе – ЭАО) нигез салына. К.а.ф.м. күзәтүләр б-н бергә, фундаменталь *астрометрия*, күк механикасы, селенодезия, *астрофизика* өлкәсендә теоретик эшләр алып баруы б-н танылa, И.А.Литтровның шәкерте И.М.*Симонов*, Россиядә беренчеләрдән булып (1835), Җирнең магнетизмын өйрәнүгә керешә, Галлей кометасын 440 тапкыр күзәтүгә ирешә (1835). Обсерваториянең яңа бинасын төзегәннән соң (1838), 9 дюймлы рефрактор (1838), меридиан түгәрәге (1847) һәм гелиометр (1874) куелгач, Казан астрономнары дөньяда иң яхшылар рәтендәге күзәтү базасына ия була. 1847–51 дә М.В.Ляпунов Орион томанлыгы йолдызларының торышын билгеләү буенча катлаулы күзәтүләр үткәрә. 1869–76 да Бонн күзәтүе дигән халыкара программа кысаларында М.А.Ковальский 4200 дән артык йолдызның координатлар каталогын төзи. Үзенең шәхси күзәтүләре нигезендә рефракциянең оригиналь теориясен эшли (1866–69). 1892 дә, Россиядә беренче булып, географик киңлекнең үзгәрүчәнлегенә бәйләнгән күзәтүләр башлана. Астроном М.А.Грачёв 8 мең тирәсе киңлекне билгели (1892–1901) һәм беренче булып Җир күчәренең фәзада торышы үзгәрүен тикшерә. Бу тикшеренүләр 1932 дә ЭАОдә яңартыла, хәзерге вакытта да даими үткәрелеп тора. 1988 гә кадәр ЭАО Халыкара полюс хәрәкәте хезмәтенә (Япониянең Мисузава ш.) һәм Халыкара вакыт хезмәтенә (Франциянең Париж ш.) керә. 1984 тән ЭАО Җирнең әйләнүе параметрларын билгеләүнең Дәүләт хезмәтендә (Госстандарт, Мәскәү) катнаша. Рефракцияне өйрәнү буенча М.А.Ковальский башлап җибәргән эшне А.И.Нефедьева дәвам иттерә: 1960–75 тә ул яктылык нурының Җир атмосферасы аша узуы теориясе буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрә һәм рефракциянең яңа теориясен төзи.

Казанда 1890 елларда Д.И.Дубяго тырышлыгы б-н башланып киткән селенодезия юнәлеше яңа үсеш ала. 1895–98 дә астроном А.В.Краснов Россиядә беренче тапкыр Айның әйләнүен өйрәнү максатында гелиометрик күзәтүләр үткәрә, һәм бу эш Казанда 100 ел диярлек дәвам иттерелә (1909 дан ЭАОда). Нәтиҗәдә Айны гелиометрик күзәтүләр буенча дөньяда иң зур күләмле эшчәнлек (1176 күзәтү) башкарыла, бу исә Айның физик либрациясен өйрәнергә (А.А.Яковкин, 1931; И.В.Белькович, 1948), Айның күренмә дискы асимметриясен билгеләргә мөмкинлек бирә (Яковкин эффекты, 1934), гомуми нуленче дәрәҗәдә йөртелгән кырый (чик) зонасының беренче картасы төзелә (А.А.Нефедьев, 1958). 1949–52 дә Ш.Т.Хәбибуллин ЭАОдагы горизонталь телескопта Айның рәсемнәрен төшерә һәм шуның б-н Айның физик либрациясен өйрәнү өчен фотография алымын куллану мөмкинлеген исбатлый, физик либрация параметрын төгәл билгеләү юлын тәкъдим итә (1957). Н.Г.Ризванов җитәкчелегендә 1970–75 тә бөтендөнья астрономия тарихында уникаль рәсемнәр – Айның йолдызлар фонындагы зур масштаблы рәсемнәре алына, алар селенодезиянең күп кенә мәсьәләләрен өр-яңа алымнар б-н чишәргә мөмкинлек бирә. Астроном Р.А.Кащеев, Айның һәм Кояш системасы планеталарының гравитация кырларын өйрәнү өчен, спутниклар куллану методикасын эшли (2000).

Казанда күк механикасы тикшеренүләрен әле М.А.Ковальский башлап җибәргән була: 1852 дә ул Нептун планетасының хәрәкәт теориясен Юпитердан, Сатурн, Ураннан алынган озак вакытлы гравитацион ярсынуларны исәпкә кертеп эшли; 1872 дә куш йолдызларның орбиталарын билгеләүнең шул чордагы иң уңышлы һәм әле хәзер дә әһәмиятен җуймаган юлын күрсәтә. А.Д.Дубягоның күп эшләре дөньякүләм танылу ала: 1921 һәм 1923 тә ул соңыннан үз исеме б-н аталган ике кометаны ача; 1948 дә кометалар хәрәкәтендә гравитация теориясеннән читкә китешнең сәбәпләрен билгели һәм нгравитацион көчләр тәэсирен билгеләү өчен яңа методика тәкъдим итә. Дубяго Кояш системасындагы кече җисемнәрнең хәрәкәтен тикшерү буенча фәнни юнәлешкә нигез сала: 1925 тән башлап, дистәләрчә кометаның һәм алар б-н бәйләнгән метеор күчләренең хәрәкәте өйрәнелә. Ш.Т.Хәбибуллин һәм аның укучылары Кояш системасындагы резонанс күренешләрен тикшерәләр: Юпитер төркеме астероидлары – «троялылар» хәрәкәтенең теориясе (1987), Меркурий һәм Венера планеталарының әйләнү теориясе эшләнелә (1994).

Метеорларны тикшерү эше ш.у. башка исемнәр б-н дә бәйләнгән: К.В.Костылёв метеорларны радиолокация алымы б-н өйрәнүгә нигез сала (1956), О.И.Белькович метеорларның статистик теориясен эшли (1971). М.А.Ковальский Казанда астрономик тикшеренүләрнең тагын бер юнәлешен – Галактиканы өйрәнүне нигезли: 1859 да ул Кояшның фәзадагы хәрәкәтен билгеләү алымын

тәкъдим итә (Ковальский–Эри алымы), беренче булып Галактиканың әйләнүе турында фараз әйтә. Бу фараз 1927 дә үткәрелгән күзәтүләр б-н раслана. Ш.Т.Хәбибуллин Галактикада йолдыз тыгызлыкларының бүленеп урнашуын тикшерә, йолдызларны исәпләүне ике нур буйлап анализлау алымын тәкъдим итә (1949). Галактика структурасын өйрәнү ЭАОда 1990 елларның уртасына кадәр алып барыла.

Казанда астрофизика юнәлеше 19 йөзнең ахырыннан үсеп китә, һәм 1930–40 елларда, Д.Я.Мартынов һәм аның укучыларының хезмәтләре нәтиҗәсендә, Казан тотылышлы куш (затменно-переменные) йолдызларны өйрәнү буенча танылган үзәккә әверелә. Д.Я.Мартынов беренче тапкыр тыгыз урнашкан икеле системаларга карата өч җисемнең чикләнгән мәсьәләсе чишелешен куллану мөмкинлеген күрсәтә (1937). Тыгыз икеле системалар компонентларының тигезләнеш фигураларын В.А.Крат тикшерә (1937). М.И.Лавров куш йолдызларның үлчәмнәрен һәм массаларын билгеләүнең санлы алымнарын эшли.

1960 еллар уртасында йолдызларның физик параметрларын аларның спектрларын санлы модельләштерү юлы б-н билгеләү юнәлеше үсеш ала. Н.А.Сәхибуллин ясалма иярченнәргә (TD-1A, BUSS) урнаштырылган телескоплар ярдәмендә күзәтү буенча халыкара проектларда катнаша (1972); СССРда беренче булып, йолдыз спектрларын анализлауның йолдыз атмосферасы матдәсендәге атом һәм ионнар җыелмаларының локаль термодинамик тигезләнеше фаразына каршы килеп эшләнгән юлын гамәлгә куя. Н.А.Сәхибуллин һәм аның шәкертләре тарафыннан атом һәм ионнарның зур җыелмасының кинетик тигезләнешен анализлауның үзенчәлекле методикасы тәкъдим ителә (1981–2001); Галактиканың гало һәм калын дискы формалашуның кыска фазасы (1 млрд. елдан кимрәк) һәм юка дискы формалашу алдыннан 3 млрд. тирәсе ел дәвамында йолдызлар барлыкка килүнең тоткарлануы турында дәлилләр алына (2000); релятивистик компонентлы куш йолдызларның синтетик спектрларын исәпләүдә үзара нурланышны исәпкә алган методика эшләнә (2000); үтә зур кара тишекләр тирәсендәге аккрецион дискларның югары темп-ралы халәтләре моделе төзелә һәм ул квазарларның рентген спектрларының төп үзлекләрен сурәтли (2001).

Казан астрономнары Россиянең әйдәп баручы обсерваторияләре һәм институтлары галимнәре, ГФР, Финляндия, АКШ, Төркия, Украина астрономнары б-н тыгыз хезмәттәшлек итә. Казан ун-тының ЭАО һәм *Төньяк Кавказ астрономия станциясе* Казан галимнәренең күзәтү базалары булып тора. Төркиядә (Анталья ш. тирәсендә) диңгез тигезлегеннән 2500 *м* биеклектә урнаштырылган, көзгесенең диаметры 1,5 *м* булган АЗТ-22 телескобы төзелеп бетү б-н (1998), К.а.ф.м. өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Анда РФАнең Космик тикшеренүләр ин-ты, Төркия Милли обсерваториясе һәм Казан ун-ты галимнәре тарафыннан күмәк тикшеренүләр алып барыла.

*Әд.:* Воронцов-Вельяминов Б.А. Очерки истории астрономии в России. М., 1956; Колчинский И.Г., Корсунь А.А., Родригес М.Г. Астрономы. Киев, 1986; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

*Л.И.Машонкина.*

**КАЗА́Н АСТРОНО́МИЯ-ГЕОДЕ́ЗИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́** (КАГҖ), 1930 елларда СССР ФА каршындагы Бөтенсоюз астрономия-геодезия җәмгыятенең Казан бүлеге буларак оештырыла; 1922 елдан хәзерге исемендә. Астрономия, геодезия, массакүләм, яшүсмерләр секцияләреннән тора. Җәмгыять б-н башында рәис торган Совет идарә итә. Рәисләр булып танылган галимнәр В.А.Баранов, Ю.В.Евдокимов, А.А.Нефедьев, О.И.Белькович эшли.

Җәмгыятьнең төп бурычы — илебез фәне һәм техникасының казанышларын пропагандалау, астрономия буенча фәнни белемнәрне популярлаштыру. Аның әгъзалары астрономия, геодезия, космонавтика һәм Җирне космостан торып тикшерүләр буенча лекцияләр укый. Яшьләргә түгәрәкләрдә, җәйге астрономия мәктәпләрендә һәм экспедицияләрдә һөнәри юнәлеш бирү эшенә зур игътибар юнәлтелә.

Җирнең ясалма иярченнәрен күзәтүләрне оештыру һәм алып бару буенча шактый эшләр үткәрелә (Ю.В.Евдокимов, М.И.Лавров, М.Ә.Вайсов). 1970 елларда А.А.Нефедьев җитәкчелегендә СССР терр-ясендәге барлык кызыксынган обсерваторияләр һәм оешмалар өчен йолдызларның Ай б-н каплану мизгелләре исәпләп чыгарыла. КАГҖ Казанда, ш.у. Татарстан төбәкләрендә йолдызларның Ай б-н каплануларының аерым төре — орынуларны күзәтү алып бара. Шундый күзәтүләр нигезендә А.А.Нефедьев һәм аның шәкертләре тарафыннан Айның кырый зонасы картасы төзелә.

*Г.В.Жуков.*

**КАЗА́Н ӘСАСЫ́Й ХАЛЫ́К УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, 1786 елның 5 августындагы *халык училищеләре* Уставына нигезләнеп, 1786 ның 22 сентябрендә ачыла. Җәмәгать тәрбиясе приказы карамагында, 1803 тән Халык мәгарифе министрлыгы карамагында була. 1787 дә сәүдәгәрләр җәмгыяте аның файдасына 5 мең сум, дворяннар җыены исәптәге һәр җан башыннан 10 ар тиен күләмендә ярдәм күрсәтә. Училищедә 4 класс (укыту 5 ел) һәм 5 нче пед. класс була, аз санлы халыклар уч-щеләре, соңыннан приход (мәхәллә) уч-щеләре өчен укытучылар әзерли. 1786–98 дә монда сәүдәгәрләр, шәһәрнең гади кешеләре һәм ш.у. дворяннар катлавыннан булган балалар укыйлар, гимназия ачылганнан соң, укучылар составы беркадәр демократияләшә, әмма Казан уч-щесе үзенең ролен югалтмый; 18 йөз ахырында – 19 йөз башында 200 гә якын малай укый. Укытучылары, башлыча, Казан руханилар семинариясен (элеккеге академиядә) тәмамлаучылар була. Җәмәгать тәрбиясе приказы карамагындагы йортта урнаша. Бай китапханәсе була (1815 тә яна). Халык мәгарифе министрлыгының 1828 елгы уку йортлары уставы нигезендә 1834/35 нче уку елы тәмамланганнан соң аның җирлегендә *Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе* ачыла, аңа иң квалификацияле укытучылар, ш.и. директоры П.М.Львов, укучыларның бер өлеше һәм китапханә күчелә, бу исә яңа гимназиядә берьюлы 6 сыйныф ачарга мөмкинлек бирә.

*Әд.:* Рыбушкин М.С. Казань // Заволжский муравей. 1833. Ч. 1, кн. 3; Шулук. Краткая история города Казани. К., 1834. Ч. 2; Толстой Д.А. Городские училища в царствование Екатерины II. СПб., 1886; Харлампович К.В. Материалы для истории Казанской духовной семинарии в XVIII веке. К., 1903.

**КАЗА́Н БАНК МӘКТӘБЕ́** (көллияте), РФ Үзәк банкына караган, күп функцияле уку йорты. 1949 елда РСФСР Финанс министрлыгының финанс-кредит техникумы итеп, Дәүләт банкының Бөек Ватан сугышы елларында эвакуацияләнгән Ленинград исәп-кредит техникумын, РСФСР Сәнәгать банкының Казан финанс-кредит техникумын һәм Татарстан финанс-икътисад техникумын берләштерү юлы б-н оештырыла, 1993 тән К.б.м., 2003 тән көллият. Махсус урта белемле банк эше белгечләре, икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, ш.у. квалификация күтәрү, өстәмә белем бирү бүлегендә РФ Үзәк банк системасы хезмәткәрләрен әзерли. 2010 елда көндезге бүлектә — 685, читтән торып уку бүлегендә 350 студент укый; 45 укытучы, ш.и. 1 фән. д-ры, 16 фән. канд-ты. Мәктәпнең эшләү елларында якынча 23 мең белгеч әзерләнә. Татарстан, Мари, Мордва, Удмурт, Чуаш респ-калары, Киров һәм Кострома өлкәләре банк хезмәткәрләренең яртысыннан артыгы — бу мәктәпне тәмамлаучылар. 12 уку аудиториясе, 5 компьютер классы, спорт-сәламәтләндерү комплексы бар.

**«КАЗА́Н БӘЕТЕ́»**, Казан татарларының 16 йөз тарихи бәете. «Казан тарихы» исеме б-н дә билгеле. Әсәр Болгар шәһәренең Тимер тарафыннан басып алынуы турындагы хәбәрдән башланып китә, ләкин бәеттә кайсы Тимер (Мәңгү-Тимер, Булат-Тимер яисә Аксак Тимер) турында сүз барганлыгын төгәл генә ачыклап булмый: каланы төрлесе төрле вакытта ала. Ядкәр хан (Ядегәр-Мөхәммәд) идарәсе турында әйтелә. Ул патшалык иткән чорда сугышлар булмаган, шәһәр «чәчәк аткан». Аның вафатыннан соң, Шигали (Шаһгали) тәхеттә утырган елларда рус гаскәрләре, басып алу максаты б-н, Казанга берничә мәртәбә яу оештыра. Тычкан елында Чаян аеның 2 нче көнендә, ниһаять, Казан яулап алына. Шәһәр халкы рус гаскәрләре тарафыннан юк ителә, соңрак көчләп чукындырыла башлый. «К.б.»ндә «Аллаһ тарафыннан мөселманнар өчен үч алу көче» бирелгән халык геройлары — Әбүлхаликъ һәм Чура батыр да урын ала. Чура батыр Иван Грозныйны (Явыз Иван) үтермәкче булып карый, әмма уңышсызлыкка тара һәм патша әмере б-н үлем җәзасына хөкем ителә. «К.б.» персонажларының тарихи прототиплары да бар, шулай да аларның тормыш юлларын бәян итү, халык тарихына керткән өлешләренә

бәя бирү еш кына чынбарлыкка туры килеп бетми.

«К.б.» беренче тапкыр 1881 елгы календарьда К.Насыйри бастырып чыгара. 1899 да әлеге бәетнең гарәпчәдән татарчага һәм русчага тәрҗемәсен Н.Ф.Катанов нәшер итә.

*Әд.:* Язучы мөтәрҗим. Казан татарларының тарихи җырлары // Шура. 1911. № 17; Урманчеев Ф.И. Легендалар эзеннән // Казан утлары. 1972. № 8; Катанов Н.Ф. Исторические песни казанских татар. К., 1899.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАЗА́Н БӘКЛЕГЕ́** (әмирлеге), Казансу елгасының түбән агымында. 13–14 йөзләр чигендә *Идел буе Болгар дәүләте* таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Монголлардан Казан тирәсенә качкан болгар бәкләре нигез салган дип фаразлана (13 йөз ахыры кабер ташы сакланган). 1420 елларга кадәр Алтын Урда составына керә. Административ үзәге — Казан. Төп халкы болгар-кыпчак ырулары нигезендә оеша, үзләрен мөселман һәм Казан татарлары дип атаган төрки телле халык. Нигездә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; корал, чүлмәк ясау, тимер әйберләр эшләү, зәркәнчелек, тире-күн эшкәртү һ.б. алга китә (Казанда, Иске Казанда, Чаллыда һ.б. шәһәрләрдә). Балтыйк буе илләре һәм рус кенәзлекләре б-н сәүдә алып бара. Төп дине — ислам. Иң югары хакиме — идарә итүгә Алтын Урда ханнарыннан ярлык алган әмир (аның хакимияте чикләнгән була). 1360 еллардагы *Алтын Урдада тәхет чуалышлары* вакытында җирле бәкләрдә К.б.нең икътисади һәм сәяси бәйсезлеген ныгыту омтылышы туа. Җирле династия барлыкка килгән, дип фаразлана. Алтын Урдадагы үзара даими тарткалашулар Алтын Урда ханнары һәм рус кенәзләре тарафыннан К.б.нә басымны арттыра. 1399 да Болгар бәклегенә һәм К.б.нә Мәскәү кенәзе Юрий Дмитриевич яу б-н килә. 15 йөзнең 1 нче яртысында Казанда Алтын Урда ханнары исемнәре язылган акчалар сугыла (к. *Болгар әл-Җәдид*). 1422 дә К.б.ндә хакимиятне *Гыясетдин* яулап ала һәм 1430 еллар ахырынача (башка мәгълүматларга караганда — 1444–45 кә кадәр) үз кулында тота. 1437 дә *Биләү (Белёв) янындагы сугышта* Василий II не җиңгәч, *Олуг Мөхәммәд* Идел буена басып керә, К.б.н буйсындыра, Гыясетдинне бәреп төшерә һәм *Казан ханлыгының* беренче ханы була.

*Әд.:* Худяков М. Очерки истории Казанского ханства. К., 1923; Материалы по истории Татарии. К., 1948; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

*И.Л.Измайлов.*

**КАЗА́Н БИОХИ́МИЯ ҺӘМ БИОФИ́ЗИКА ИНСТИТУТЫ́**, РФА КГҮ ин-ты, 1946 елда СССР ФАнең (1963–70 тә Казан ун-ты каршында) Казан биология ин-ты буларак оештырыла. 1998 дән хәзерге исемендә. Институт составында: күзәнәк сигнализациясе (оксилипин, сигнал системалар, күзәнәк оксидлашуын көйләү лаб-яләре) һәм биофизика (молекуляр биофизика, синаптик процесслар, транспорт процесслары биофизикасы лаб-яләре) бүлекләре, патогенезның молекуляр нигезләре, үсемлек күзәнәкләренең үсеш механизмы, апопласт биохимиясе, культурадагы күзәнәкләр физиологиясе һәм генетикасы лаб-яләре. Тикшеренүләрнең төп юнәлешләре: үсемлек күзәнәкләрендәге сигнал системалар, адаптациядә һәм иммунитетта аларның роле; үсемлек күзәнәкләренең үсү механизмы һәм дифференциациясе, ферментлар төзелеше, динамикасы һәм функцияләре; күзәнәкара үзара бәйләнешләр, нейромедиация һәм хеморецепциянең молекуляр механизмнары; хайван һәм үсемлек күзәнәкләрендә күчеш-алмашу процессы механизмнары. Институт беренче елларында туфрак белеме һәм агрохимия (М.А.Винокуров, Р.К.Даутов), үсемлекләр физиологиясе (А.М.Алексеев, Н.А.Гусев, А.А.Җәләлев), зоология (В.В.Изосимов, В.А.Попов, В.А.Бойко), хайваннар физиологиясе (А.В.Кибяков) өлкәсендә тикшеренүләр алып бара. *Үсемлекләрнең су режимы* буенча тикшеренүләр киң танылу ала, Идел-Кама төбәгенең флора һәм фаунасын өйрәнүгә өлеш кертелә. 1980 еллар башында биологик системалар оешуның физик-химик нигезләре буенча фәнни юнәлешләр формалаша: биополимерлар һәм мембрана липидлары метаболизмын җайлау, сулыш һәм энергия алмашы (ш.и. *фотосинтез* һәм фотосулау), күзәнәк һәм тукымалар культурасы, күзәнәк инженериясе, микроорганизмнар физиологиясе, үсемлек микоплазмалары генетикасы, аксымнарның структурасы һәм динамикасы. 1993 тә экология бүлеге ТР ФАнең Табигать системалары экологиясе ин-ты составына кертелә.

Мөһим фәнни казанышлар: үсемлек күзәнәкләрендә көйләгеч системаның бердәм сигнал челтәрен өйрәнү, ул исә үсемлекләрнең адаптив реакцияләрен, ш.и. биоген һәм абиоген стрессорларга нисбәттәгеләрен билгели; физиологик актив үсемлек кушылмаларының яңа классларын — липоксигеназа сигнал системаларының интермедиаторларын, күзәнәк тышчасы компонентларын, ш.у. үтә оксид генерацияләүче сигнал системаларының яңа компонентларын ачу һәм сыйфатлама бирү (И.А.Тарчевский, А.Н.Гречкин, Ю.Е.Андрианова, Л.Х.Гордон, Т.А.Горшкова, Ф.Г.Кәримова, В.В.Лозовая, Н.Н.Максютова, В.И.Чиков). Югары төзелешле организмнарда кайбер кабатланучан инфекцияләрнең молекуляр-генетик үсеш механизмы билгеләнә (В.М.Чернов, О.А.Чернова), нерв системасында информация тапшыруның молекуляр механизмы турында яңа мәгълүматлар алына (Е.Е.Никольский). Электростатик үзара бәйләнешләр хисабына аксымнарның үзара ориентлашуы нәтиҗәсендә хасил булган су эремәләрендәге глобуляр аксымнарда ТМР ысулы б-н Броун хәрәкәте анизотропиясе табыла; корреляциянең миллисекундлы диапазонында төп аксым чылбырының гадәттән тыш акрын молекуляр хәрәкәте тикшерелә, аның аксымның гидратация дәрәҗәсенә һәм төзелеше тибына бәйле булуы билгеләнә (В.Д.Федотов). Үсемлекләрдәге су транспорты механизмнары турында (А.В.Анисимов), үсемлек күзәнәкләренең электрик сыйфатламасы ион каналлары һәм көпшәләре б-н бәйләнеше турында (Г.А.Великанов) яңа мәгълүматлар алына.

Институт хезмәткәрләре арасында — РФА һәм ТР ФА академигы (1), РФАнең мөхбир әгъзасы, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, 13 фән. д-ры һәм 76 фән. канд-ты бар. Аспирантурада көндезге һәм читтән торып уку бүлекләре, «үсемлекләр физиологиясе һәм биохимиясе» һәм «биофизика» белгечлекләре буенча кандидатлык диссертацияләрен яклау советы эшли. Институт директорлары: Н.А.Иванов (1946–48), А.В.Кибяков (1949–1953), А.М.Алексеев (1954–60), Н.А.Гусев (1960–75), И.А.Тарчевский (1975–91), В.Д.Федотов (1992–2002), А.Н.Гречкин (2002 дән).

*Әд.:* Казанский институт биохимии и биофизики. К., 2002. *И.Ю.Картилова.*

**КАЗА́Н БОГОРО́ДИЦА ХАТЫ́Н-КЫЗЛА́Р МОНАСТЫРЕ́**, Алабугада. 1856 елда арх. Г.А.Боссе проекты буенча, Алабуга сәүдәгәрләре Г.И., И.И., Д.И.Стахеевлар, П.К.Ушков инициативасы б-н һәм алар акчасына төзелә. Иң элек хатын-кызлар православие җәмәгате оештырыла, 1868 нең сентябрендә монастырь итеп үзгәртеп корыла һәм 10 елдан соң Вятка губернасындагы иң зур һәм төзек бинага әверелә. Төп яшәүчеләрнең



Казан Богородица хатын-кызлар монастыреның Казан Мәрьям Ана иконасы хөрмәтенә төзелгән чиркәве. Алабуга ш. 20 йөз башы фоторәсеме.

саны 250 кешегә җитә, кызлар өчен чиркәү-приход мәктәбе, икона язу, укалап чигү остаханәләре эшли; зират монастырьның төньяк өлешендә урнаша. Монастырьның архит-ра комплексына биш гөмбәзле, өч престоллы, дүрт яруслы, чаң манарасы чиркәү баскычы өстенә урнашкан Казан Мәрьям Ана иконасы чиркәве (кушып салынган корылмалар Иоанн Предтеча һәм изге Параскева Пятница хөрмәтенә изгеләндерелгәннәр), торак һәм хуҗалык корылмалары керә. 1918 дә монастырь рәсми рәвештә ябыла, әмма 1922–29 елларда бер приход чиркәве эшләвен дәвам иттерә, анда монахинялар җәмәгате хезмәт итә. 1930 елларда күпчелек биналар, ш.и. төп чиркәү җимертелә. Совет чорында К.Б. х.-к.м. корылмаларының бер өлеше — Халык Мәгариф комис-тының балалар шәһәрчеге, соңрак авторемонт базасы итеп файдаланыла. 1995 елдан монастырь яңадан ачыла. Өч катлы кызлар корпусы (берсендә











**Казан Богородица хатын-кызлар монастыре**. 1. Гомуми күренеше. 19 йөз ахыры фоторәсеме; 2. Казансу елгасы ягыннан күренеш. 1878 елгы фоторәсем; 3. Казан Мәрьям Ана иконасы хөрмәтенә төзелгән чиркәү (сакланмаган). 20 йөз башы фоторәсеме; 4. Казан Мәрьям Ана иконасы хөрмәтенә төзелгән чиркәү иконастасы (М.Е.Емельянов проекты буенча). 20 йөз башы фоторәсеме; 5. София һәм Крестовоздвижение чиркәүләре. 2002 елгы фоторәсем.

җәфа чиккән Варвара чиркәве эшли), архиерей һәм монастырь башлыгы корпуслары, манаралы диварлар сакланып кала. Казан Мәрьям Ана иконасы чиркәвенең җимерелгән алтаре урынында кәшәнә төзелә. Алабуга р-нының Яңа Анзирка авылында монастырьның чиркәүле скиты (кече монастыре) һәм ярдәмче хуҗалыклары бар.

*Әд.:* Елдашев А.М. Елабужский Казанско-Богородицкий женский общежительный монастырь (1868–2002). К., 2002.

*А.М.Елдашев.*

**КАЗА́Н БОГОРО́ДИЦА ХАТЫ́Н-КЫЗЛА́Р МОНАСТЫРЕ́**, Казансу елгасының биек ярында, Кремльдән төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1590 елда могҗизалы *Казан Мәрьям Ана иконасы* табылу хөрмәтенә патша Фёдор Иоаннович тарафыннан нигез салына. Әүвәл агачтан Рождество Богородицы чиркәве һәм ашханә төзелә. 1594–95 елларда Фёдор Иоаннович әмере буенча Казан изге Мәрьям Ана иконасының пәйда булуы хакына беренче таш собор төзелә. Чиркәүгә Успение Пресвятой Богородицы һәм изге каһарман кенәз Александр Невский хөрмәтенә ике корылма кушып салына. 1739 да таш койма б-н әйләндереп алынган монастырь терр-ясендә берничә чиркәү: изге шәһит Никита хөрмәтенә бинага кушып салынган корылма, җылы Рождество Пресвятой Богородицы һәм капкалар өстенә салынган Иоанн Богослов һәм Мәскәү патшасының улы кенәз Димитрий гыйбадәтханәләре барлыкка килә.

Чиркәү 1774 елда Е.И.Пугачёв кузгалышы вакытында яндырыла. Яңа соборның проектын арх. И.Е.Старов әзерли, ул 1791 дә Екатерина II тарафыннан раслана. 1795 тә «Казан Богородица Соборы төзелеше конторасы» төзелә, төзелешне арх. М.Е.Емельянов җитәкли. 1796 да иске собор сүтелә; 1798 дә яңа бинаның нигезенә беренче таш кую тантанасында Павел I катнаша. Собор 1807 дә төзелеп бетә һәм 1808 нең 30 нчы маенда изгеләндерелә. Казан Мәрьям Ана иконасы соборы катгый классицизм архит-расы үрнәгә санала. Әвернә-гөмбәзе дүрт баганага утыртылган биш гөмбәзле чиркәүдән гыйбарәт. Ионик колонналы 3 зур портик бинаның төньяк, көнбатыш һәм көньяк фасадларында урын алган. Алтарь апсидасы тыштан һәм эчтән коринф пилястралары б-н бизәлгән. Үзәк гөмбәзне 4 юан багана тереп тора. Кече гөмбәзләр бинаның почмакларында урнашкан. Үзәк гөмбәзнең барабаны тышкы яктан коринф ордерлы өч ырмаулы колонналар, ә кече гөмбәзнең барабаннары ионик пилястралар б-н бизәлгән. Барлык барабаннарга биек тәрәзәләр куелган. Иконостаслар арх. М.Е.Емельянов проекты буенча башкарыла, алар өчен иконаларны Казан рәссамы В.С.Турин яза.

1803 тә монастырь терр-ясе шактый киңәйтелә һәм таш койма б-н әйләндереп алына (арх. М.Е.Емельянов проекты). 1808 дә арх. Я.М.Шелковников комплексның яңа ген. планын төзи, ул патша тарафыннан 1809 ның 27 августында раслана. Яңа төзелгән чаң манаралы собор үзәк урынны алып тора. Я.М.Шелковников беренчесе нигезендә монастырьдагы аерым биналарның яңа ген. планын һәм проектларын әзерли (1810 ның 19 мартында раслана). Шул ук елда Никола Тульский җылытылган чиркәвенә (1816 да төзелә) һәм монастырь башлыкларының бүлмәләренә нигез салына. Төзелеш б-н Мәскәү архитекторы Бажанов җитәкчелек итә. Никола Тульский чиркәве — портиклы сигез ионик ордерда колонналар б-н төзелгән күпертмә бизәкләре дә булган «Барысын күрүче күз» сурәте төшерелгән зур фронтонлы бер гөмбәзле чиркәү. Соңрак ишек янына дүрт корылма кушып салына.

1827 дә арх. Я.М.Шелковников әзерләгән корпус проектына үзгәрешләр кертелә, 1832 дә губерна арх. А.К.Шмидт проекты буенча монастырь башлыклары корпусы (игуменьяның ял итү бүлмәләре) җылы чиркәү бинасына кушып төзелә. Комплекс манаралы кирпеч койма б-н әйләндереп алына. Капка өсте чиркәвен үзгәртеп корудан баш тарталар һәм ул әүвәлге хәлендә сакланып кала. 1830 елларда арх. П.Г.Пятницкий монастырьның

яңа койма проектын әзерли. Проект буенча 5 манара калдырыла, койманың көнчыгыш өлеше турайтыла, ә Нагорная урамы буенча ике яклап колонналары булган капка урнаштыру карала. Койма, Кремльгә караган, ату тишекләре уелган манаралы өлешеннән башка, классицизм стилендә корылган. 1850 дән, губерна архитекторы И.П.Бессонов җитәкчелегендә, монастырь биналарын яңарту һәм торгызу эшләре башлана. Аның проекты буенча алты ярусны иске чаң манарасы яңартыла, аның биеклеге 4 саженьга арттырыла (барлыгы 26 сажень).

1814–47 елларда монастырь башлыклары һәм монашкалар өчен ярымтүгәрәк корпуслар төзелә; 1865 тә 1810 ел планында каралган Крестовоздвижение чиркәве салына башлый. Яңа бинаны Изге София чиркәве янәшәсендә төзиләр. Аның иснеме бина төзелгәннән соң (1887) анда Воздвижение Честного и Животворящего Креста Господня чиркәве урнашу б-н бәйле. Чиркәүдән башка бинада аш-су, нәкышь мәктәбе, тегү, кием-салым һәм ашлык саклау, квас әчетү бүлмәләре була.

1895 тә монастырьда император Александр III истәлегенә чиркәү-приход мәктәбе төзелә (1896 да ачыла). Шуннан соңгы елларда монастырьда торак һәм хуҗалык биналары төзү дәвам иттерелә. 1917 елдан соң барлык биналар дәүләткә тапшырыла, аларның күпчелеге хәрби частьләр һәм учреждениеләр карамагына бирелә. Мәктәп бинасына беренче совет мәктәбе, мөсафирлар корпусында шәһәрнең качаклар пункты урнаша. 1929 да монастырьның торак корпуслары педтехникум студентларының тулай торагына әверелә. 1931 дә ТАССР ХКС Казанда киностудия төзү турында карар кабул итә. Элекке монастырь бүлмәләре «Востоккино»ның Татарстан бүлеге карамагына тапшырыла. 1933 ел ахырында аның биләмәсендә кинофабрика өчен үзәк павильон төзелә. 1934 тә «Востоккино» берләшмәсе ябыла һәм «Востокфильм» кинофабрикасы төзелеше туктатыла. 1942 дә Казанга 2 тәмәке ф-касы — Выборг пр-тиесе һәм Мәскәү «Дукат»ы эвакуацияләнә, алар ярымҗимерек монастырь биналарына урнаша. 1958–65 тә берләштерелгән фабрикага реконструкция үткәрелүенә карамастан, комплексның җимерелүе дәвам итә.


Монастырь корылмалары безнең көннәргә кадәр төрле дәрәҗәдәге югалтулар һәм үзгәртүләр б-н килеп җитә. Җылытылган Никола Тульский чиркәве аеруча зур зыян күрә.

Монахиняларның хөҗрәләре торак бүлмәләр итеп үзгәртелә. Крестовоздвижение корпусында, керү а́ркасы эшләнеп, интерьерларга реконструкция ясалганнан соң, Казан пед. ун-тының уку аудиторияләре урнаштырыла (2004 кә кадәр). Чиркәү-приход мәктәбе, аңа 3 нче кат өстәп салынганнан соң, торак йорт итеп үзгәртелә. Пятницкий тыкрыгында монастырьның 2 манарасы, Нагорный урамында койма диварының бер өлеше һәм капкасы сакланып кала. Совет чорында монастырь биләмәсендә яңа биналар: авиация ин-тының тулай торагы, балалар бакчасы, мәктәп, биш катлы торак йортлар калкып чыга. 1995 тә София капка өсте чиркәве Казан епархиясенә тапшырыла, ремонт эшләре башкарыла, әмма керү а́ркасы ачылмаган килеш калдырыла. 2004 нең ахырында Крестовоздвижение чиркәве ш.у. Казан епархиясенә кайтарыла (аңа кадәр биредә Казан пед. ун-тының рус филологиясе ф-ты урнаша), аны реставрацияләү һәм монастырьның башка корылмаларын торгызу буенча эшләр башланып китә. 2005 нең 21 июленнән Крестовоздвижение чиркәвендә моңа кадәр Ватиканда сакланган могҗизалы Казан Мәрьям Ана иконасының күчермәсе урнаштырыла. 2004 нең августында Папа Иоанн Павел II тарафыннан ул Рус Православие чиркәвенә тапшырылган була.

*Әд.:* М а л о в Е.А. Казанский Богородицкий девичий монастырь: История и современное его описание. К., 1879; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Православные памятники Татарстана. К., 1999; Е л д а ш е в А.М. Монастырь Казанского края: Очерки истории. К., 2004.

*С.Г.Персова.*

**КАЗА́Н БОГОРО́ДИЦА ЧИРКӘВЕ́**, Буа р-нының Зур Фролово авылында, архит-ра ядкәре, ТРда иң борынгы һәм иң зур агач чиркәүләрнең берсе. 1780 елларда төзелә, 1820, 1860 елларда яңартыла. 1881 елгы үзгәртеп корудан соң (арх. П.В.Тихомиров), хәзерге рәвешен ала. 1930 елларда ябыла, 1947 дән яңадан эшли башлый. Чиркәүдә 1853 тә Грециянең Афон ярымутравындагы рус монастыреннан алып кайтылган җәфа чиккән Пантелеймон иконасы могҗизалы буларак хөрмәт ителә. Чиркәү дәвалаучы Пантелеймон һәм могҗиза тудыручы Николай чишмәләре православие дине әһелләренең күмәкләп зиярәт кылу урыны булып тора. Үзгәртеп корулардан соң, чиркәүнең тышкы күренеше халык архит-расы һәм барокко формалары б-н төгәлләнгән эклектика стиле сыйфатларын ала. Өч катлы агач чиркәү бүрәнәдән бурап эшләнгән һәм такта б-н тышланган. Бинаның гыйбадәт залы «дүртлек өстенә утыртылган сигезлек» тибыннан гыйбарәт. Ике рәт тәрәзәле дүртлек формасы кубка тартым. Өсте сигез кырлы түбә б-н ябылган, очы гөмбәз б-н төгәлләнә. Апсида биш кырлы, аның өч кырына биек тәрәзәләр уелган. Аш бүлмәсе симметрияле, бер рәт тәрәзәле, биеклеге гыйбадәт залы дүртлеге б-н бертигез, киңлеге бераз кимрәк. Аш бүлмәсе б-н янәшәдә биш ярусны чаң манарасы күтәрелә. Ярусларның зурлыклары астан өскә таба кими бара. Югары ярусларның һәр кырына икешәр тәрәзә уелган. Чаң манарасының дүрткырлы биек гөмбәзенә кырлы, тар муенлы гөмбәз беркетелгән. Кечкенә гөмбәзләр алтарь чыгынтысында һәм чиркәүгә кушып салынган ике корылма түбәсендә дә бар. Чиркәүнең көнбатыш, төньяк һәм көньяк ишекләренә биек баскычлар күтәрелә. Фасадлары ябыштырылган декоратив фигуралар б-н бизәлгән. 1881 дә урнаштырылган иконостас сакланган.



Буа районының Зур Фролово авылындагы Казан Богородица чиркәве.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1; Православные храмы Татарстана: Альбом. К., 2000.

*О.В.Ерёгин.*

**КАЗА́Н БОГОРО́ДИЦА ЧИРКӘВЕ́**, Казанда, рус дини архит-ра ядкәре. 1906–10 елларда иске дин тарафдары сәүдәгәр И.С.Гребенщиков васыять итеп калдырган акчага төзелә. Бер гөмбәзле, чаң манарасы ишек өстендә урнашкан, куб формасындагы зур булмаган чиркәү. Ул кирпеч салуда ясалма рус һәм төрле стильдәге бизәкле формаларның



Казандагы Казан Богородица чиркәве.


бер-берсенә ярашуы б-н аерылып тора. Турыпочмаклы апсиданың киңлеге чиркәү күләменә тигез диярлек. Бинаның төньяк һәм көньяк фасадларында ялган куышлар бар; фасадларның югары өлешендәге тәрәзәләр өстендә Богородица һәм Гайсә пәйгамбәрнең мозаик сурәтләре ясалган. Чиркәү 8 тәрәзәле якты, түгәрәк барабан өстендәге суганбашсыман гөмбәз б-н очланган. Алтарь чыгынтысы өстендәге һәм чаң манарасындагы кечкенә гөмбәзләр тар, сукыр тәрәзәле барабаннарга урнаштырылган. Манараның төрле зурлыктагы 10 чаңын приход халкы монастырь ябылганнан соң да саклап калган. Элек чиркәү Поморлар килешүендәге попсыз иске дин тарафдарлары җәмәгатенә караган. Гыйбадәт кылу 1920 еллар башына кадәр, чиркәү ябылганчы дәвам итә. 1930 еллардан соң бинага төрле оешмалар урнаша. 1989 да ул Рус православиесенең иске дин тарафдарлары чиркәвенә тапшырыла һәм Казан Мәрьям Ана иконасы хөрмәтенә Мәскәү һәм бөтен Русь митрополиты Алимпий (Гусев) тарафыннан изгеләштерелә. Чиркәүгә 1948 дән Ново-Песчаный урамындагы дини җәмәгать-

нең гыйбадәт кылу йортында сакланган борынгы иконалар, китаплар һ.б. чиркәү җиһазлары күчерелә. Шулай ук Покров соборы ябылганнан соң, ТР Сынлы сәнгать музеенда сакланган иконалар кире кайтарыла. Иконостас 1990 елларда борынгы рус традицияләренә туры китереп эшләнә. Хәзер К.Б.ч. *Казан-Вятка епархиясе* кафедраль соборы ролен үти.

*О.В.Ерёгин.*

**КАЗА́Н ВЕРТОЛЁТ ЗАВОДЫ́** (КВЗ), авиация сәнәгате пр-тиесе. *Вертолётлар* (М.Л.Миль исем. тәҗрибә-конструкторлык бюросы эшләнмәләре), күтәрү винты калаклары, вертолётларның запас өлешләрен, җир өсте җиһазлары, халык куллану товарлары җитештерә. Эшләүчеләр саны — 7 меңләп кеше (2010). Казанда 2 сәнәгый мәйданчыгы бар. 1941 елның июлендә Казандагы 169 нчы з-дны (1933 тә арбалар, көпчәкләр, камытлар, дугалар һ.б. җитештерүче Казан олау әйберләре з-ды буларак нигезләнә) һәм аның базасына эвакуацияләнгән, баш конструктор Н.Н.Поликарповның У-2 уку-өйрәнү самолётларын эшләп чыгаруга юнәлтелгән 387 нче з-дны (1940 та Ленинградтагы пр-тиеләр — ОСОАВИАХИМ Үзәк Советының Каракозов исем. 4 нче һәм СССР Гомуми машина төзелеше халык комис-тының «Лентекстильмаш» з-длары җирлегендә төзелә) берләштерү юлы б-н оештырыла. 1935 тә 169 нчы з-дта авиачаңгылар җитештерү буенча реконструкция уздырыла; 1940 тан анда ЛаГГ-3, И-153 самолётлары канатларының нервюрлары һәм лонжероннары, И-15 БИС самолётының запас һәм койрык өлешләре эшләп чыгарыла. Елга уртача эшләүчеләр саны — 778, инженер-техник хезмәткәрләр 109 кеше (ш.и. 29 инженер, 25 техник) тәшкил итә. Заводлар кушылганнан соң, җитештерү мәйданнарын реконструкцияләү һәм җиһазларны монтажлау эшләре уздырыла. 1941 нең сентябрендә эвакуация вакытында китерелгән агрегатлардан, узеллардан һәм детальләрдән беренче У-2 самолётлары җыела. Җитештерү заруриятыннан чыгып, заводка Казан саго з-ды мәйданнары тапшырыла, аэродром төзү өчен 7 *га* участок бүлеп бирелә (хәзер — заводның төп терр-ясе). 1942 дә У-2 самолёты хәрби самолёт — У-2ВС (По-2ВС) итеп үзгәртеп җиһазландырыла һәм сериягә салына. 1942 нең гыйнварыннан 1945 нең мае ахырына кадәр 9746 самолёт эшләп чыгарыла, алар СССР бомбага тоту авиациясендәге гомуми самолёт-очышларның 65%ын башкаралар. 1945 ел ахырына заводның гомуми терр-ясе 22,9 *га* били, җитештерү мәйданы 35 мең $м^2$ дан, эшләүчеләр саны 4,8 мең кешедән арта. Хәрби самолётлар җитештерү буенча хөкүмәт йөкләмәләрен үрнәк дәрәҗәдә башкарганы өчен, СССР ЮС Президиумының 1945 ел 18 август Указы нигезендә, завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Коллектив 15 тапкыр Дәүләт Оборона Ком-тының күчмә Кызыл байрагын яулый, байрак заводта мәңгелек саклауга калдырыла. Бөтенсоюз соц. ярышында заводка 15 тапкыр 1 нче һәм 2 нче урыннар бирелә. 1946 да самолётлар җитештерүне туктатуга юнәлеш алына, 1947 дән завод С-4 комбайннарын чыгаруга күчә. Заводка 16 нчы з-дның (элеккеге «Красный путь» станоклар төзү з-ды) механика производствосы да тапшырыла. 1947–51 дә 10 меңгә якын С-4 комбайны чыгарыла, аларның үрнәкләре 1951 дә Милан һәм Прага күргәзмәләрендә һәм Лейпциг ярминкәсендә күрсәтелә. 1951 дә завод яңадан СССР Авиация сәнәгате министрлыгы карамагына тапшырыла һәм М.Л.Миль конструкциясендәге вертолётлар чыгаруга көйләнә. Шул ук елны пр-тие үзгәртеп корыла һәм Ми-1 вертолётларының беренче партиясе эшләп чыгарыла, алар 1952 дә Тушино авиация һава парадында катнашалар. Бер үк вакытта пр-тиене эре сериядәге вертолётлар җитештерүгә реконструкцияләү бара. 1953 нең ахырында Ми-4 вертолёты төзелә, ул 1954 тә — СССР Һава Флоты көнендә, Тушинодагы парадта, 1955–56 да Димәшкъ һәм Каһирә шәһәрләрендә уздырылган халыкара күргәзмәләрдә катнаша. 1953–65 тә Ми-4 һәм шул ук модификациядәге 3,2 мең вертолёт эшләп чыгарыла; 1963–65 тә күпмаксатлы эшчәнлек өчен билгеләнгән Ми-8 вертолётын күпләп җитештерү үзләштерелә, ул Париждагы авиасалонга куела һәм 1965 тән дөньяда иң киң таралган вертолётка әверелә. Бу чорда заводта Мәскәү Авиация технологиясе һәм производствоны оештыру фәнни-тикшеренү ин-ты б-н бергә җитештерүнең бөтен төрләренең: металл кою, тимерчелек, әзерләү-калыплау, механик эшкәртү, агрегат-җыю, монтаж-җыю һ.б.ның техник дәрәҗәсен кискен күтәрүгә юнәлтелгән эшләр алып барыла. Вертолётларның күтәрү винты калакларының ресурсын арттыру буенча чаралар эшләнә һәм гамәлгә ашырыла. Заводта 6,5 меңнән артык Ми-8 һәм шундый ук модификациядәге вертолётлар төзелә; 3 меңгә якын вертолёт экспортка җибәрелә. 1966 да 387 нче з-д Казан вертолёт з-ды (КВЗ) итеп үзгәртелә. 1970 тә 5-еллык планны уңышлы үтәгәне һәм яңа техника җитештерүне оештырганы өчен СССР ЮСның 1970 ел 31 декабрь Указы нигезендә завод Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә. 1973 тә эзләү-коткару хезмәтләре һәм хәрби-диңгез частьләре өчен билгеләнгән Ми-14 вертолётларын җитештерү үзләштерелә (270 вертолёт эшләп чыгарыла, аларның бер өлеше экспортка куела); 1977 дә Ми-8МТ (экспорт версиясендә — Ми-17, Ми-172) вертолётлары җитештерелә башлый. 1980 елларда пр-тиедә җитештерелгән продукциянең 50% ка якыны чит илләргә чыгарыла. Халыкара сәүдәдә хезмәттәшлекне ныгытуы өчен 1980 дә завод халыкара «Алтын Меркурий» премиясе б-н бүләкләнә. 1979 да Казан вертолёт з-ды Казан вертолётлар ЖБ итеп үзгәртелә. 1993 тән — АҖ. АҖнең структурасына бүлекчә буларак Тәтеш механика з-ды (заводның механика участогы итеп оештырыла, 1968 дән — аның ф-лы, 1979 дан — Тәтеш механика з-ды) керә. 1990 нан башлап базар таләпләренә ярашлы рәвештә КВЗ вертолётларның экспорт вариантларын берәмләп чыгаруга күчә. Вертолётлар дөньяның 38 иленә, ш.и. Финляндиягә, Һиндстанга, Вьетнамга, Пакистанга, Малайзиягә, Африка һәм Латин Америкасы дәүләтләренә җибәрелә. Завод җитештергән вертолётлар дөньяның 85 тән артык илендә файдаланыла. 1997–99 да завод РФнең иң яхшы экспортёры дип таныла. 1990 еллар ахырында пр-тиедә өлешчә реконструкция үткәрелә, файдаланудагы вертолётларга капиталь ремонт башкару үзләштерелә, эшләп чыгарыла торган продукцияне яңача камилләштерү алып барыла. М.Л.Миль исем. Мәскәү вертолёт з-ды һәм «Еврокоптер» француз концерны б-н берлектә урта класслы (яңа буын) Ми-38 вертолёты җыела. 2004 тә ул Мәскәү вертолёт з-дында сынаулар үтә. 1997 дә КВЗ РФдәге серияле вер-









1. Заводның беренче продукциясе – арба тәгәрмәче. 1935; 2. Самолётлар өчен чаңгылар ясау. 1935–40; 3. Коралльы По-2ВС самолёты. 1941–45; 4. Вертолётлар җыю цехы. 2004 елгы фоторәсем.

толётлар төзү заводлары арасында беренче булып вертолёт техникасын эшләп чыгаручы сертификаты ала. Заводта күпмаксатлы эшчәнлек өчен билгеләнгән җиңел «Ансат» вертолётын чыгару җайга салына, ш.у. аеруча җиңел «Актай» вертолёты эшләнә, аның конструкциясендә иң яңа авиатөзелеш технологияләре һәм материаллары файдаланыла. КВЗ — Россиядәге мәгълүмати-техник «Вертолёт» ж-лын оештыручыларның берсе. 1998 дән башлап заводта ел саен Казан вертолётларыннан файдаланучыларның Халыкара конференциясе уздырыла. Заводның 3,9 меңнән артык хезмәткәре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеме — 1 кешегә, РФ һәм ТРның атказ. хезмәткәре — 83, СССР, ТР Дәүләт бүләге — 14; Профсоюзлар советы бүләге — 1; Ленин ордены — 12, Октябрь Революциясе ордены — 8, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 37, Кызыл Йолдыз ордены — 6, «Почёт билгесе» ордены 72 кешегә бирелә. Пр-тие җитәкчеләре: И.В.Федин (1941–45), М.П.Семёнов (1945–48), В.П.Максимов (1948–61), Ф.С.Аристов (1961–75), В.Е.Бивойно (1975–83), А.П.Лаврентьев (1984–2007), В.А.Лигай (2007 дән). Ш.у.к. *Вертолётлар төзү, Авиация сәнәгате*.

*Әд.:* Изаксон А.И. Советское вертолётостроение. М., 1964; Шавров Б.В. История конструкций самолётов в СССР до 1939 года. М., 1969; Морошек Е.М. На вертикальном взлёте. К., 1990; Тематическая подборка, посвящённая авиации // Казань. 1999. № 3/4; Казанские вертолёты: полёт продолжается. К., 2000.

*А.И.Сурская, Б.М.Вәлишев.*

**КАЗА́Н ВЕТЕРИНА́РИЯ МЕДИЦИ́НАСЫ АКАДЕ́МИЯСЕ**, Н.Э.Бауман исемендә, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы учреждениесе. 1873 елның 31 маенда Казан вет. ин-ты буларак ачыла. 1923 тә Н.Э.*Бауман* исеме бирелә. 1995 тән хәзерге исемдә.

Институт ачылган дәвердә аның алдына земство вет. табибләре әзерләү максаты куела. Революциягә кадәр зур булмаган уку йорты, фәкать вет. дисциплиналарын укытучы 8 профессоры була. Биология, химия, фармацевтиканы Казан ун-ты прфессорлары укыта, дәресләр ун-т лаб-яләрендә үткәрелә. Елга 40 лап белгеч әзерләнә. 1896 дан институт каршында махсус урта уку йорты — вет. фельдшерлары мәктәбе эшли башлый. Башта институт арендага алынган бинада, соңрак, 1892–1901 дә, Арча кырында төзелгән институт шәһәрчегендә урнаша (төп уку корпусы, клиника һәм лаб. бинаалары).

Институт Россиядәге 4 шундый уку йортларының берсе була һәм беренче унъеллыктан ветеринариянең төрле юнәлешләрендә — вет. анатомиясе (Л.П.*Третьяков*), иммунология (И.Н.*Ланге*, М.П.*Тушнов*), вет. фармакологиясе (Н.А.*Сошественский*), вет. хирургиясе (Л.С.*Сапожников*), а.х. терлекләре физиологиясе (К.Р.Викторов) буенча эре фәнни тикшеренүләр үзәгенә әверелә. Институтта Себер түләмәсенә каршы профилактика максатында *Ланге вакцинасы* эшләнә.

Күп кенә студентлар демократик катлаулардан (руханилар һәм шәһәр кешеләре, крәс-



Казан ветеринария медицинасы академиясе. Төп корпус.

тияннәр) була, күпләр Казан ун-ты студентлары хәрәкәтендә, народниклар түгәрәгендә, революцион фиркаләр эшчәнлегендә катнашалар. Н.Э.Бауман институтта уку чорында с.-д. фиркасенә керә.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында студентлар саны кимеми, чөнки хәрби вет. табибләренә ихтыяҗ арта һәм аларга хәрби хезмәттән азат ителү мөмкинлеге бирелә.

1917 елдагы рев-ция вакыйгаларында уку өзелми, әйдәп баручы укытучылар һәм студентларның күбесе Казанда кала, элеткәгечә студентларга хәрби хезмәттән вакытлыча ки-чектерү мөмкинлеге бирелә, укуны тәмамлаучылар күбесе фронтка озатыла; 1920 еллар башында хатын-кызларны укыту башлана. 1923–39 да институтта эшчеләр ф-ты, 1925–32 дә Кызыл гаскәрләрнең Ветеринария идарәсенә буйсынган хәрби вет. бүлеге (соңрак Мәскәү вет. академиясенә күчерелә) эшли. Күмәкләштерү һәм колхоз һәм совхозларда терлекчелек үсешенә бәйле рәвештә 1930 да зоотехния ф-ты ачыла, 1931 дә исә ул — Сөт хуҗалыгы ин-ты, 1932 дә яңадан Казан а.х. ин-тының (хәзерге *Казан аграр университеты*) зоотехния ф-ты итеп үзгәртелә, 1936 да вет. ин-тына кайтарыла, 1939 да ябыла.

Бөек Ватан сугышы башлангач, укытучыларның һәм студентларның бер өлеше фронтка китә. Барлык укыту корпуслары һәм башка биналар эвакуацияләнеп килгән хәрби заводка тапшырыла, сугыш тәмамлангач та алар кире кайтарылмый. Шул ук вакытта укыту да тукталмый. 1941–45 тә студентлар саны 170 тән 450 гә җитә. Сугыштан соңгы елларда институт үсешенә биналар җитмәү комачаулый. 1946 да Себер тракты урамында институтның яңа шәһәрчеген төзү эшләре башлана, ул 1960 еллар уртасына кадәр дәвам итә. 1950 дә зоотехния ф-ты яңадан ачыла. 1917 гә кадәр һәм 1920–30 да оешкан фәнни мәктәпләр — вет. паталогоанатомиясе (К.Г.*Боль*), вет. терапиясе (К.М.*Гольцман*, Н.П.*Рухлядев*), вет. акушерлыгы (А.П.Студенцов) һ.б. (к. *Казан ветеринария фәнни мәктәбе*) уңышлы үсеш кичерә, бу исә 1959 да институт җирлегендә фәнни-тикшеренү ин-ты төзергә мөмкинлек бирә, шул чордан Казан вет. ин-ты укыту һәм фәнни-тикшеренү комплексы буларак эшли. 1984 тән фәнни-тикшеренү ин-ты мөстәкыйль учреждение буларак аерылып чыга (к. *Бөтенроссия ветеринария институты*).

2001 дә стандартлаштыру һәм сертификацияләү ф-ты ачыла, 2007 дә зооинженерлар ф-ты б-н берләштерелеп, биотехнология һәм стандартлашу ф-ты булдырыла.

Академиядә 28 меңнән артык белгеч әзерләнә. Академияне тәмамлаучылар арасында ВАСХНИЛның 1 академигы һәм 6 мөхбир әгъзасы бар. 2010 да ветеринария, зооинженерия табибләре, стандартлаштыру һәм сертификацияләү, а.х. продукциясен җитештерү һәм эшкәртү технологиясе буенча белгечләр әзерләнә; көндез 1900 студент, ш.и. 300 студент бюджеттан тыш формада укый. Өстәмә һөнәри белем алу һәм читтән торып уку ф-тларында 700 ләп студент (вет. техникумнарын тәмамлап, белгечлек буенча эшләүчеләр), ел саен 300 дән артык ветеринар, зооинженер, вет. уку йортлары укытучылары белем күтәрү курсларында укый.

Укытучылар коллективында 190 кеше, ш.и. ТР ФА академиклары Л.П.Зарипова, Г.Җ.Идрисов, 40 тан артык фән. д-ры һәм 110 нан артык фән. канд-ты эшли.

Академиянең 35 кафедрасында терлекләрнең продукциясен арттыру һәм йогышлы, инвазион, йогышлы булмаган авыруларны булдырмау ысуллары һәм чараларын эшләү, аларга диагноз кую һәм дәвалау мәсьәләләре буенча киң рәвештә эш алып барыла. 14 белгечлек буенча аспирантура (80 якын аспирант), вет. һәм биол. фән. докторларын әзерләү һәм диссертацияләр яклау буенча 2 совет бар.

Академия Себер трактында үз шәһәрчегендә урнашкан, аның терр-ясен төп уку корпусы, клиникалар һәм лаб-яләр биналары б-н беррәттән тулай торак һәм торак йортлар били. Су тәэминаты, сөт саву машиналары, эл. җиһазлары, азык әзерләү, физиотерапия, ортопедия, рентгенология, электрон микроскоп, хезмәт иминлеге һ.б. махсуслаштырылган кабинетлар һәм лаб-яләр бар; 20 йөз башында төзелгән патологоанатомия, анатомия, паразитология, акушерлык, фармакология уку-укыту музейлары эшли. Академия китапханәсендә 450 меңнән артык китап, әсбаб исәпләнә.

Уку йортында эшләгән директорлар һәм ректорлар: П.Т.Зейфман (1873–1891), И.Н.Ланге (1881–1905), К.М.Гольцман (1905–07, 1910–16), Г.П.Кириллов (1907–10), К.Г.Боль (1919–38), В.Г.Мухин (1938–39, 1943–45), Г.Н.Борисов (1939–43), П.Т.Маширов (1945–47), Е.Н.Павловский (1947–62), Х.Г.Гыйззәтуллин (1963–74), Н.Җ.Хаҗипов (1975–88), Г.Җ.Идрисов (1988–2000); Р.Җ.Корбанов (2000–03), Г.Ф.Кәбиров (2003 тән).

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КАЗА́Н ВЕТЕРИНА́РИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, 19 йөзнең 2 нче яртысында Казан вет. ин-тында оеша.

Фәнни юнәлешләрдән анатомнарны — Л.А.*Третьяков,* патологоанатомнарны — К.Г.*Боль*, микробиологларны — М.П.*Тушнов*, Х.Х.*Абдуллин*, терапевт һәм диагноз куючыларны — К.М.*Гольцман*, Н.П.*Рухлядев*, Г.В.*Домрачев*, фармаколог һәм токсикологларны — Н.А.*Сошественский*, хирургларны Л.С.*Сапожников*, Б.М.*Оливков*, акушерларны — А.П.*Студенцов*, физиологларны — К.Р.*Викторов*, Е.Н.*Павловский*, биохимикларны — С.И.*Афонский*, эпизоотологларны М.Н.*Верещагин*, Х.Г.*Гыйззәтуллин* җитәкли. Анатомия кафедрасына 35 елдан артык (1886 дан) Л.А.Третьяков җитәкчелек итә. Аның шәкертләренең фәнни тикшеренүләре нерв системасын өйрәнүгә багышлана, ул эшләр функциональ якын килү һәм гамәли алып барылу б-н аерылып тора. Бу өлкәдәге мәгълүм галимнәр — Д.М.Автократов, А.Ф.Климов, А.И.Акаевский, Н.А.Васнецов, Ю.Х.Миндубаев, Н.В.Михайлов, Р.Х.Шакиров — хайваннар һәм кошларның периферик нерв системасы морфологиясен өйрәнү б-н шөгыльләнәләр. Бу тикшеренүләрнең нәтиҗәләре әгъзалардагы нерв аппаратларының макро- һәм микроморфологиясен заманча күзаллауны формалашуга китерә.

Ветеринария патологоанатомнары фәнни юнәлеше 1920 еллар башында К.Г.Боль җитәкчелегендә барлыкка килә. Тикшеренүләр комплекслы рәвештә үткәрелә: маңка авыруы (сап), эпизоотик энцефаломиелит, атларда йогышлы анемия, мөгезле эре терлекләрдә паратуберкулёз, дуңгызларда рожа һәм чума, этләрдә чума, котыру һ.б. куркыныч йогышлы авыруларның патологик анатомиясе һәм диагностикасы өйрәнелә. К.Г.Боль тырышлыгы б-н Казанда беренче вет. фәнни-тикшеренү ин-ты ачыла. Тикшеренүләрне дәвам итүчеләр — И.Т.Трофимов, Г.Ж.Идрисов, алар җитәкчелегендә терлекләрнең йогышлы авырулары патоморфологиясе өйрәнелә, яңа вакцина препаратлары кулланганда иммуноморфологик үзгәрешләр анализлана. Иммуноморфологик күзлектән чыгып бруцеллёз, туберкулёз, лептоспироз, листериоз, Себер түләмәсе һ.б. авыруларның киеренке барышы сәбәпләре ачыклана, бу йогышлы авырулар вакытында иммун комплексларның патогенетик әһәмияте билгеләнә (М.С.Ежкова, М.Х.Лотфуллин, И.Н.Җәләлов, Н.С.Садыйков, Д.Ш.Шәрипов, О.Т.Муллакаев һ.б.).

Микробиологлар, вирусологлар һәм иммунологларның эш юнәлеше И.Н.*Ланге*, М.П.Тушнов, М.В.*Рево*, Х.Х.Абдуллин җитәкчелегендә формалаша. И.Н.Ланге Себер түләмәсенә каршы киң кулланыш тапкан вакцина эшли (к. *Ланге вакцинасы*), М.П.Тушнов гистолизатлар турында тәгълиматка нигез сала. Бруцеллёз һәм Себер түләмәсен өйрәнү буенча тикшеренүләр М.В.Рево, Х.Х.Абдуллин җитәкчелегендә үткәрелә. Мөгезле эре терлекләрдә бруцеллёзга каршы вакцина булдырыла (К.М.Салмаков); Себер түләмәсе вакытында бацилла йөртү һәм бацилла бүлеп чыгару күренеше ачыклана (Ш.Х.Харисов); җирле штаммнардан колибактериозга каршы вакцина (В.М.Ибраһимов, К.М.Хәкимова), АУФ штаммыннан (ультрашәмәхә нурлар б-н аттенлашкан) листериозга каршы вакцина (О.А.Котылев) эшләнә; яңа дезинфектантлар (феносмолин һ.б.) табыла, прополисның микробларга каршы тору үзенчәлекләре өйрәнелә (В.П.Кивалкина, А.А.Барсков), Ку бизгәгенә диагноз кую, дәвалау һәм каршы көрәшү буенча чаралар эшләнә (Р.Г.Госманов).

Ветеринария терапевтлары фәнни юнәлешенә 1920 елларда К.М.Гольцман һәм Н.П.Рухлядев нигез сала. Йорт хайваннары һәм кошларның кан морфологиясен нормада һәм патологиядә өйрәнү нәтиҗәсендә а.х. терлекләренең гематологик профиле эшләнә (С.А.Хрусталёв, В.И.Зайцев, Д.Я.Криницын); уникаль гематологик атлас булдырыла (Г.В.Домрачёв, Н.П.Рухлядев); вет. кардиологиясенә нигез салына (Г.В.Домрачёв); фонокардиограф төзелә, вет. фонокардиографиясе нигезе эшләнә (В.Г.Чагин). Йод җитешмәү, остеодистрофия, бозауларда тимер элементлары җитешмәү сәбәпле барлыкка килгән анемия, витаминнар алмашы бозылу (Л.Г.Замарин), хайваннарда матдәләр алмашы бозылу б-н бәйле авырулар, экотоксикология мәсьәләләре (Н.А.Уразаев), яшь терлекләр авырулары, макро- һәм микроэлементлар алмашы бозылу өйрәнелә, аларны булдырмау һәм дәвалау ысуллары эшләнә (К.Х.Попуниди). Бу юнәлеш вәкилләре: И.Г.Шарабрин, С.А.Хрусталёв, П.С.Ионов, Р.М.Восконян, Я.И.Клейнбок, В.И.Зайцев, К.И.Мавсумзаде — төрле елларда СССР һәм РФнең вет. ин-тларында кафедралар б-н җитәкчелек итәләр.

Ветеринария фармакологиясе һәм токсикологиясе юнәлешенә Н.А.Сошественский нигез сала, аның алга таба үсеше П.И.Попов, Д.К.Червяков, В.Н.Локтионов эшчәнлеге б-н бәйле. Яңа паразитларга каршы чаралар, терлекләрнең ашказаны-эчәк авырулары вакытында комплекслы препаратлар куллану (Д.К.Червяков, В.Н.Локтионов, Г.А.Алексеев), тиредә паразит авыруларны дәвалау өчен күкертле органик кушылмалар (В.А.Антипов, Т.В.Гарипов), авыру терлек стресс халәтендә чакта нейролептик матдәләр һәм транквилизаторлар тәэсире (А.И.Шитый, Ф.Г.Нәбиев) өйрәнелә һәм беренче тапкыр гамәлгә кертелә. П.К.Сметов җитәкчелегендә терлекләрнең химик һәм биол. табигатьле агулы матдәләргә тотрыклылыгын арттыру һәрьяклап тикшерелә, агулы матдәләрне индикацияләү, терлекләр агуланганда дәвалау өчен төрле чаралар һәм ысуллар эзләү үткәрелә. Азыклар гөмбә агулары б-н зарарланганда микотоксикология мәсьәләләре, заманча диагноз кую һәм профилактика ысуллары М.Я.Тремасов җитәкчелегендә эшләнә.

Ветеринария хирурглары фәнни юнәлешенә Л.С.Сапожников нигез сала, ул күп шәкертләр тәрбияли (Б.М.Оливков, Т.С.Минкин, В.Г.Зайцев, П.И.Шаталов, И.Д.Медведев, А.С.Макаров), аларның тикшеренүләре асептика, антисептика, авыртуны бастыру, төрле операцияләр техникасы, яралану процессын өйрәнүгә, дәвалауның рациональ ысулларын эшләүгә, очлыклар авырулары патогенезын һәм дәвалау ысулларын өйрәнүгә карый. В.В.Мосин корсактагы нервларга һәм симпатик баганаларга новокаин блокадасын куллануны тәкъдим итә (1948), бу ысулны анатомотопографик яктан нигезли, корсак куышлыгы һәм арт сан әгъзаларын, мускул дистониясе, кастрациядән соң ялкынсыну, киселүләр, арт сан очлыклары параличы вакытында ысулның отышлылыгын исбатлый. Аның җитәкчелегендә бу ысулның балтыр веналары тромбофлебиты, бозаулар һәм дуңгызларда диспепсия, гинекологик авырулар, маститлар, пешү һ.б. авырулар вакытында югары нәтиҗә бирүе исбатлана. М.Ш.Шәкүров хезмәттәшләре б-н гадәти булмаган иммунитетның күзәнәк һәм гумораль факторларына симпатик иннервациянең новокаин блокадасы этәргече тәэсирен ачыклый; вет. практикасында күкрәктәге эчке нервларга новокаин блокадасын эшли һәм гамәлгә кертә (1970). Бу юнәлештә отышлы ысуллар эзләү һәм эшләү хәзер дә дәвам итә.

Ветеринария акушерлары фәнни юнәлешенә А.П.Студенцов нигез сала. Ул шәкертләре б-н җенси цикл турында яңа тәгълимат эшли, терлекләрнең буазлык, тудыру, тудырудан соңгы халәте өйрәнелә (П.И.Шаталов, Г.В.Зверева, В.С.Шипилов, Н.И.Полянцев); үрчемсезлекнең 7 формасы турында тәгълимат булдырыла (тумыштан килгән, картлыкка бәйле, алиментар, климатик, эксплуатацияле, ясалма, симптоматик), терлекләрнең үрчем нормативлары эшләнә һәм үрчемсезлекне булдырмау, дәвалауның комплекслы чаралары оештырыла (О.Н.Преображенский, А.И.Пучковский, М.Г.Миролюбов һ.б.); маститлар классификациясе эшләнә, ана терлекләрдә мастит авыруларын булдырмау һәм дәвалау, диагноз куюның отышлы ысуллары тәкъдим ителә (М.П.Рязанский, Д.Д.Логвинов, А.А.Осетров, Т.К.Трифонова).

К.Р.Викторов җитәкчелегендә вет. физиологлар юнәлеше формалаша, нерв үзәкләренең эшчәнлек шартлары һәм закончалыклары, аларның перифериядәге башкару органнары б-н бәйләнеше өйрәнелә (С.И.Афонский, П.А.Нуждин, Ф.Н.Милованов, Н.В.Иванов, Г.И.Гумилевский); югары сулыш органнары рецепторларының (Е.Н.Павловский, Н.М.Лопатина, Б.Н.Соколов), аутогистолизатлар һәм цитотоксиннарның физиологик роле тикшерелә (Ф.Н.Милованов, А.А.Морозов, И.Ф.Казаков), терлекләр әгъзаларының эшчәнлеге үзенчәлекләре һәм нерв-гумораль көйләнеше өйрәнелә (В.Ф.Лысов, Т.Е.Костина, Е.И.Трутнев, В.А.Берестов, Ю.Н.Зеленов, В.Я.Иванов, В.И.Максимов).

Ветеринария биохимиклары фәнни юнәлешенә С.И.Афонский нигез сала. Ул һәм аның шәкертләре аксымнар, углеводлар һәм липидларның үзенчәлекләрен өйрәнә, шуның нәтиҗәсендә биокомплексlы кушылмалар турында (хелатлар) тәгълимат булдырыла, бioген металларның (бакыр, кобальт, марганец, цинк, йод селиниды) хелат кушылмалары б-н аминокислоталар һәм төрле биолигандаларның синтезы ысулы эшләнә, моның хайван

организмының саклану көченә һәм продукциялелегенә тәэсире өйрәнелә (Х.Ш.Казаков, Э.В.Тен, Н.М.Машковцев, Г.П.Логинов, М.Ю.Метлякова һ.б.). Тилчә вирусының күзәнәк б-н үзара тәэсире; хайваннарда йогышлы авырулар: тилчә, бруцеллёз, туберкулёз, Себер түләмәсе китереп чыгаручыларның антиген төзелеше өйрәнелә, бу йогышлы авырулар вакытында иммунофермент анализ һәм молекуляр генодиагноз куе ысуллары тәкъдим ителә, шул нигездә диагноз куюның тизләтелгән ысуллары эшләнә (Н.Җ.Хаҗипов, А.М.Алимов, В.П.Коксин, Т.Х.Фәизов, Р.П.Тюрикова, Н.К.Кириллов һ.б.).

Академия галимнәре вет. һәм зоотехниянең әйдәп баручы юнәлешләре буенча 200 дән артык дәреслек һәм монография (кайберләре берничә мәртәбә) бастырып чыгаралар, ә кайберләре чит телләргә (кытай, болгар, румын һ.б.) тәрҗемә ителә.

*Әд.:* Студенцов А.П., Сабин И.М. Казанский государственный ветеринарный институт имени Н.Э.Баумана (1873–1953): Материалы к истории ветеринарного образования в СССР // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та имени Н.Э.Баумана. М., 1956. Т. 63; Гизатуллин Х.Г. Казанскому ветеринарному институту — 100 лет // Ветеринария. 1973. № 5; История Казанского ветеринарного института: Очерки. К., 1973; Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993; Казанской государственной академии ветеринарной медицины — 130 лет // Уч. зап. Казан. акад. вет. медицины. 2003. Т. 174.

*Н.Җ.Хаҗипов.*

**КАЗА́Н ВОКЗАЛЫ́**, Мәскәүдәге эре тимер юл станциясе комплексы. 1862 елда нигезләнә. 1894 кә кадәр Рязань вокзалы. Хәзерге рәвешендә 1914–26 да милли романтик юнәлештәге неорус стилендә арх. А.В.Щусевның «Көнчыгышка Мәскәү капкасы» конкурс-проекты буенча (1911) төзелә. Өстәмә төзелешләр 1941 елга кадәр дәвам итә. Вокзалның пассажирлар өчен төзелгән биналары беренче тапкыр юлның хезмәт корылмалары б-н берләштерелә һәм төрле еллар төзелешләренә стильләштерелгән «сарай тибындагы корылмалар» рухында асимметрик композицияле биналарның комплексын барлыкка китерә. Декорацияләрдә төрле тарихи чорларга караган таныш образлар файдаланыла. К.в.ның сәгать манарасы Казан Кремлендәге Сөембикә манарасын шактый ук төгәл чагылдыра. Фасадларны бизәгәндә 17 йөз рус архит-расының «Нарышкин бароккосы» үрнәкләре кулланыла. Пассажирлар залы интерьерында пыялалар б-н бүленгән эре бетон аркалар һәм борынгы рус бизәге элементлары, ресторан интерьерында — барокко стилендәге зиннәтле, эре масштаблы, кабарынкы бизәкләр файдаланыла. 1993–96 да А.В.Щусевның сакланып калган сызымнары буенча яңартыла. Архитектура ядкәре. К.в. көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк юнәлешләрдә хәрәкәт итүче поездларга хезмәт күрсәтә.



Мәскүдәге Казан вокзалы.
Арх. А.В.Щусев. 1914–26 еллар.

*Әд.:* История русской архитектуры. СПб., 1994; Иконников А.В. Историзм в архитектуре. М., 1997. *Х.Г.Надыйрова.*

**КАЗА́Н ВӨҖДА́Н ХӨКЕМЕ́ МӘХКӘМӘСЕ́**, губерна мәхкәмә органы. 1775 елгы Губерна реформасы уздыру барышында оештырыла, 1781 нең 29 декабрендә ачыла. Бәхәсләшүчеләр үзләре үк ачыклык кертүне сораган дәгъваларны, ата-аналар һәм балалар арасындагы милеккә бәйле һ.б. дәгъваларны, үзенең ни кылганын белештермәүчеләр, балигъ булмаганнар һәм сихер б-н шөгыльләнүдә гаепләнүчеләрнең җинаять эшләрен карый. Гражданлык эшләрен тикшерү үзара килештерү тәртибендә гамәлгә ашырыла. Әгәр дәгъваларда катнашучылар һәм арадашчылар килешүгә килмәсәләр, аларның эше гадәти мәхкәмәдә карауга җибәрелә. К.в.х.м. составына судья һәм утырышчы (дворяннардан, шәһәр һәм дәүләт крәстияннәреннән 2 шәр кеше 3 елга сайлана) керә. Үсмер балалар хокукларын яклау: дворяннар өчен — өяз дворяннары башлыгына, алпавыт крәстиннәре өчен — алпавытка, дәүләт крәстиннәре өчен — дәүләт милке стряпчиена, башка катлаулар өчен — казна эшләре буенча губерна стряпчиена йөкләнә. К.в.х.м. наместникка (1796 га кадәр), губерна идарәсенә, Югары вөҗдан хөкеме мәхкәмәсенә һәм Сенатка буйсына. Сенатның 1866 ел 25 ноябрь фәрманы б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание узаконений о губерниях по хронологическому порядку с 1775 по 1817 г. СПб., 1818.

*Әд.:* к. *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасы.* *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГАЗ АППАРАТЛАРЫ́ ЗАВОДЫ́-ВЕ́СТА**, машина төзелеше пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 500 дән артык кеше (2011). 1958 елда Казан «Сантехизделия» з-ды (1956 да нигезләнә) җирлегендә «Газоаппарат» з-ды ларак оештырыла. Шул ук елда беренче продукциясен бирә, ел ахырына 4208 газ плитәсе эшләп чыгара. Баштарак җитештерү башка пр-тиеләрдә ясалган детальләрне җыюдан гыйбарәт була. 1959 да яңа завод төзелә башлый. 1960 та беренче чират сафка баса, 1962 ел алдыннан, эмальләштерүче ярымфабрикат (фритта) коюны да кертеп, завод газ плитәләре эшләүнең тулы циклына күчә. Алдагы елларда төп производство корпусы, заводның үзәк склады, чистарту корылмалары (1970 еллар башы), 9 катлы инженерлык-лаб-я корпусы төзелә. Прогрессив технологияләр һәм уникаль җиһазлар: детальләрне майсызландыручы ультратавыш җайланмалары, эмальләштерү өчен конвейер эл. миче һәм эмальләштерелгән өслекләрне киптерү өчен инфракызыл газ горелкалары, 15 *КПа* гә кадәрге һава басымы астында плитәләрнең герметиклыгын контрольдә тоту стендлары, торбаларны ышкылуга нигезләнеп ябыштыру, гальванизация гамәлгә кертелә. Нигезләнгән чордан башлап завод 15 төрдә 7 млн. нан артык газ плитәсе чыгара. 1968 дә СССРда беренче буларак (ш.и. экспорт өчен), инфракызыл нурланышлы күп функцияле җылыткыч газ горелкаларын җитештерү үзләштерелә. Ш.у. газ б-н су җылыту җайланмалары, суыткычларны эмальләштерү өчен «Серго исемендәге завод» заказы б-н фритта, сантехника һ.б. эшләнә. 1980 еллар ахырында завод табигый газ челтәреннән файдаланып эшләүче «Идел» плитәләре чыгаруга күчә. 1986 да ТАССРда икенче булып аренда пр-тиесенә әверелә, соңрак Россия «Газпром» АҖнең «Газмашаппарат» ассоциациясе составына керә. Газ плитәләре җитештерүнең төрле чорлардагы күләмнәре (мең данәдә): 1960 та — 24,7; 1970 тә — 143,2; 1980 дә — 160; 1990 да — 198,2. 1993 тә мөстәкыйль «Казан газ аппаратлары заводы» АҖ оештырыла, 1999 дан — хәзерге исемдә. Аның составында төп җитештерү (штамплау, өслекләрне эмаль б-н каплау, механика, җыю) цехлары, ярдәмче цехлар һәм хезмәтләр эшли. 2000 елларда җитештерелүче продукция модернизацияләнә, көнкүреш һәм сәнәгать өчен чыгарылучы плитәләрнең яңа үрнәкләре үзләштерелә. Газ һәм катнаш (газ-электр) «Идел», «Веста», «Pozis», «Хазвирт» идән һәм өстәл плитәләре (40 мең данә чамасы, 2009, илдә өченче урын били), инфракызыл горелкалар, эмальләштерелгән металл чирәп чыгара. Эшләнмәләре РФдә һәм БДБ илләрендә сатыла. Завод ТР хөкүмәтенең газлаштыру һәм тузган торакларны бетерү программаларын гамәлгә ашыруда катнаша. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә — СССР МС бүләге; 1 кешегә — ТАССРның атказ. рационализаторы, 2 кешегә — ТАССРның, ТРның атказ. машина төзүчесе, 1 кешегә ТРның атказ. транспорт хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә; 2 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше — «Почёт билгесе», 2 кеше 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары б-н бүләкләнә. Пр-тие директорлары арасында — Л.Г.Гильбург (1958–62), С.Л.Смеркович (1963–68), Л.В.Чистяков (1969–73), Р.К.Мусин (1973–83), В.С.Платонов (1983–98), А.Н.Обозов (1998–99), М.Б.Сәитов (1999–2003), А.В.Песошин (2003–07), А.Ю.Яковлев (2007–08), Э.А.Абайдуллин (2009 дан).

*Әд.:* Советский район Казани: люди, годы, память. К., 2000.

**КАЗА́Н ГАРНИЗОНЫНЫ́Ң МӨСЕЛМА́Н ХӘРБИ́ КОМИТЕТЫ́**, 1917 елның 8 мартында оештырыла. Рәисе — И.С.Алкин. Ком-т эшчәнлегендә Х.Әбелханов, Х.Сафиуллин, Р.Газизов, Б.Әминов, Г.Вәлидов һ.б. актив катнаша. Россия армиясендә тәүге мө-

селман оешмаларының берсе. Комитет мөселман солдатларны берләштерү инициативасы б-н чыга. «Комитетларны ничек оештырырга?» («Как организовать комитеты?», 1917) дигән брошюрада түбәндәгеләр билгеләнә: мөселман хәрби ком-тларының максаты: мөселман сугышчыларын милли һәм сәяси тәрбияләү, мөселман солдатларның белем дәрәҗәсен күтәрү, аларны Учредительләр җыенына сайлауларга әзерләү; ком-тлар составына вәкилләр сайлау тәртибе. «Татар полклары нигә кирәк?» («Зачем нужны татарские полки?», 1917) дигән брошюрада мөселман сугышчылардан аерым милли частьләр оештыру зарурлыгын ком-т милләт мәнфәгатьләре, ирекле ватанга бергә тупланган көч б-н хезмәт итү, татар солдатларының дин тоту иреге алуга омтылышы б-н нигезли. Комитет инициативасы б-н 1917 нең сентябрендә Казан Хәрби округы буенча мөселман солдатларны мөселман роталарына аеру турында боерык игълан ителә. Комитет мөселман солдатларны агарту эше б-н шөгыльләнә. 1917 нең сентябренә гарнизон частьләрендә 10 уку бүлмәсе ачыла. Аларның санын 20 гә җиткерү һәм уку бүлмәсе-мәктәпкә әверелдерү күздә тотыла. 1918 нең мартында бетерелә.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**КАЗА́Н ГЕОЛО́ГИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, 19 йөз уртасында оеша һәм *Пермь системасы* (*чоры*) ачылуга, аның стратиграфиясе һәм минералогиясен өйрәнүгә бәйле. Вәкилләре: Н.А.*Головкинский*, А.А.*Штукенберг*, А.В.*Нечаев*, Б.П. һәм П.И.Кротовлар, М.Э.Ноинский, В.А.*Чердынцев*, Л.М.*Миропольский*, Е.И.*Тихвинская* һ.б. К.г.ф.м.нең үзенчәлеге — геол. күренешләрне өйрәнүгә комплексы тарихи-генетик яктан килү, аларның дөресләлеген һәм әһәмиятен аргументлар б-н исбатлау. Бу принцип геол. процессларның гомуми закончалыкларын ачыклау, минераллар, тау токымнары һәм файдалы казылмаларның (табигый һәм техноген) матди составын, үзенчәлекләрен, ясалу закончалыкларын һәм урнашуларын өйрәнүдә, мохитнең геоэкологик үзенчәлекләре урнашуда чагыла.

Геологик процессларның гомуми закончалыкларын ачу фацияләр корелляциясе законына (К.*Головкинский законы*) һәм циклостратиграфик анализга (М.Э.Ноинский) нигезләнә. К.г.ф.м. дөнья стратиграфик шкаласына *Көнгер ярусы* (А.А.Штукенберг), *Уфа ярусы* һәм *Казан ярусы* (А.В.Нечаев) терминнарын кертә; палеозой, мезозой һәм Урал-Идел кайнозой стратиграфиясе палеонтологик һәм палеоботаник яктан нигезләнә (Б.П.*Кротов*, А.М.Зайцев, А.Д.Архангельский, В.А.Чердынцев һ.б.). Рифей-венд (Л.Ф.Солнцев, С.И.Шевцов, Е.М.*Аксёнов*, Н.С.*Гатиятуллин* һ.б.), палеозой (А.В.Нечаев, Г.Н.Фредерикс, Е.И.Тихвинская һ.б.), мезозой-кайнозой (С.Н.*Никитин*, А.П.Павлов һ.б.) ятмалары төзелеше һәм таралу закончалыклары ачыклана.

Р.Людвиг, Н.А.Головкинский, П.И.Кротов, А.В.Нечаев, А.Н.Замятин, М.Э.Ноинский һ.б. эре тектоник элементларны билгелиләр: Нократ валы, Сок-Шушма, Грахань-Алабуга калку зоналары. Соңрак А.Д.Архангельский, Е.И.Тихвинская, Б.М.Йосыпов һ.б. Татар, Токмов гөмбәзләре һәм аларны аерып торучы уйсулык җентекләп аерым өйрәнелә, бөҗралы һәм шарьяж-хәрәкәтчән өлешләре билгеләнә, тирәндә ятучы җимерелүләр ачыклана; Кама-Кинель бөгелешләре системасы җентекләп тикшерелә.

Гидрогеологик тикшеренүләрне М.Э.Ноинский, С.Г.*Каштанов*, М.С.*Кавиев*, Е.Ф.*Станкевич* һ.б. үткәрә. Алар төче һәм җир асты минераль сулары бүленеше закончалыкларын билгели, Дөнья океаны суларының химик составы эволюциясен һәм җир астында суның парга әйләнүен исбатлый, континенталь галогенезның төп гидрогеол. закончалыкларын ача, нефть-газ горизонтларының гидрохимик күрсәткечләрен, җир асты суларында микроэлементлар бүленеше үзенчәлекләрен ачыклый.

20 йөз уртасыннан Казан ун-ты галимнәре б-н бергә «ЦНИИгеолнеруд», «Татнефтегеофизика» АҖ, «Татнефть» хезмәткәрләре тарафыннан интенсив геофизик тикшеренүләр алып барыла (к. *Геофизика*). Геофизик ысуллар ярдәмендә ТРда җирнең тирән ятмалары төзелеше өйрәнелә, нефть һәм газ ятмалары фаразлана, ТР терр-ясендә 300 дән артык нефть чыганагы билгеләнә, шуның 190 ында нефть барлыгы ачыклана, файдалы казылмаларны табу һәм эзләүнең, скважиналар тикшерүнең яңа ысуллары эшләнелә. Токымнарның физик үзенчәлекләре өйрәнелә, ятмаларның геотермик, гравитацион, магнит, электр, сейсмик закончалыклары билгеләнә; ТР терр-ясенең хәзерге геомагнит кыр вариацияләре һәм сейсмик режимы ачыклана, аның сейсмик халәте фаразлана, ятмаларның сейсмик халәте мониторингы үткәрелә. 20 йөзнең 2 нче яртысында яңа фәнни тикшеренүләр — минераллар палеомагнетизмы һәм тау токымнары магнетизмы темалары үсеш ала (Б.В.Буров, В.П.Боронин, Д.К.Нургалиев һ.б.). Татарстан геофизиклары казанышлары ТР Дәүләт бүләгенә, СССР һәм РФАнең И.М.Губкин исем. бүләгенә лаек була.

Минераллар, тау токымнары һәм файдалы кызылмаларның (табигый һәм техноген) матди составы, үзенчәлекләре, ясалу һәм урнашу закончалыкларын өйрәнү Казан ун-ты төзелүдән һәм минераллар, казылмалар, тау токымнары һәм ташлар коллекциясе булган табигать тарихы кабинеты оешу чорыннан (к. *Геология музее*) башлана. 1840 елда минералогия һәм геогнозия каф. оештырыла (мөдире — проф. П.И.Вагнер), аның хезмәткәрләре Татарстан терр-ясендә һәм күрше өлкәләрдә геол. тикшеренүләр алып баралар. П.И.Вагнер тарафыннан яңа минерал — эпидотның бер төре табыла һәм тасвирлана. 1855–99 елларда Казан геологы Ф.Ф.Сюзен альбит төркеме минералларының химик составы б-н оптик үзенчәлекләре бәйләнеше, корунд кристаллары слюдаларының псевдоморфозалары һ.б. өйрәнелә. 1880–88 дә А.М.Зайцев һәм 1888–1903 тә А.В.Лаврский тарафыннан Идел һәм Кама буеның утырымнардан ясалган ятмалары геологиясе һәм минералогиясе тикшерелә. 1887 дә Г.В.Вульф тарафыннан кристалларны график билгеләүнең «Вульф челтәре» исемен алган ысулы эшләнелә, кристаллографиядә, физика, химия, геодезия һ.б. фәннәрдә ул әле дә кулланыла. 20 нче йөз башында гомуми литогенез теориясе барлыкка килүгә һәм үсешенә, ш.у. литологияне мөстәкыйль фән буларак оештыруга Б.П.Кротов (ятма токымнар петрографиясе, доломитларның, утырма тимер рудаларының генетик табигате) һәм М.Э.Ноинский (литологик-фациаль анализ) өлеш кертәләр. Алга таба Л.М.Миропольский, В.А.Полянин һ.б. тарафыннан минералогик, петрографик, литологик һәм геохимик тикшеренүләр үткәрелә, төрле стратиграфик системалар ятмаларында минераллар һәм токымнарның минералогик үзенчәлекләре һәм таралып урнашу закончалыклары ачыклана, аларны өйрәнүнең яңа ысуллары эшләнелә.

20 йөз уртасында Казан галимнәре катламнарда нефть һәм газ булуның геотермик критерийларын, кузәнәкчел мохиттә авыр нефть һәм битумнарның молекуляр төзелеш үзенчәлекләрен, тау токымнары һәм су ятмаларының җылылык үзенчәлекләрен билгелиләр. Минераллар, файдалы кызылмалар, сулар бүленешенең геохимик закончалыклары билгеләнә, палеобассейннарның геол.-геохимик модельләре эшләнелә һәм металл булмаган токымнар ятмалары һәм казылмалары ясалу шартлары ачыклана. Файдалы казылмалар урнашуның төп закончалыклары өйрәнелә, файдалы казылма чыганаклары барлыкка килүнең төп факторлары ачыла. Минерагеник анализның фәнни-методик принциплары эшләнелеп, ул структур-матди комплекслар үсешенең эволюция процессын, аларның ятмаларга нисбәтле агын ачыклауны үз эченә ала. Татарстан терр-ясе ресурсларын бәяләү буенча фаразлар картасы һәм методик кулланмалар төзелә. Металл булмаган матдәләр ятмалары формалашуда рифтогенез һәм активлаштыру процесслары ролен бәяләүдә принципиаль яңа ысуллар, офиолит комплекслар һ.б. минерагениясен; металл булмаган ятмалар барлыкка килү урыннары формалашуның геол., геол.-генетик һәм геол.-технологик модельләре; конкрет геол.-генетик һәм геол.-сәнәгый төрләр, ш.и. яңа һәм традицион булган төрләрнең (табигый сорбентлар югары темп-ралы керамик чимал, технол. җепләр алу өчен чимал һ.б.) ятмаларын ачыклау, эзләнүләр һәм разведкалауның фәнни нигезләре эшләнелә.

1960 еллар башында табигый матдә һәм каты җисем физикасы фәннәре кушылган урында минералогиядә яңа юнәлеш — *минераллар физика*сы барлыкка килә (В.М.Винокуров, И.Н.Пеньков һ.б.), радиоспектроскопия б-н беррәттән минералларны, ш.и. ясалма тикшерүнең яңа ысуллары — рентгенография, термография, люминисценция, электрон оптик спектроскопия үсеш ала. Күп кенә минералларның электрон төзелеше б-н аларның хасил булуы һәм үзгәреше арасындагы бәйләнеш ачыклана, фазалар күчеше өлкәсендә матдәнең аномаль реакция сәләте һәм хемосорбциясе күренеше ачыла. Атом-төш гамма резонансын (Мёссбауэр эф-

фекты) куллану төрле минералларның кристаллохимик типоморфизмын билгеләүгә китерә. Импульслы атом-төш магнит резонансы ярдәмендә тау токымнарының төп коллектор үзенчәлекләрен билгеләүнең экспресс ысуллары эшләнелә.

Урал-Идел буенда нефть ятмалары булуның фәнни нигезләре эшләнә (А.А.Трофимук, В.И.Троепольский, С.П.Егоров, А.М.Мельников, Р.Х.Мөслимов һ.б.). Җир тышчасында яңа сфера — метаносфера барлыгы билгеле була (Б.М.Йосыпов). Битумлы катламнарның урыннары күрсәтелә, палеозой катламындагы төп табигать резервуарлары һәм битум, нефть билгеләү өчен җайланмалар урнаштыру закончалыклары ачыклана. Девон чорына кадәр һәм кристалл фундаментта нефть, газ чагылмалары булу мөмкинлеге нигезләнә, ш.у. бу урыннардан эшкәртелүче ятмаларга углеводородлар күчеше ачыклана (Р.Х.Мөслимов).

20 йөзнең 2 нче яртысында нефть-газ һәм руда ятмаларының бәйләнешен өйрәнү башлана, кече һәм техноген ятмалар, геол.-икътисади һәм геол.экологик тикшеренүләр рольләре ачыклана. Стратиформалы — цинклы, алтын, терекөмеш, тимер ятмалары, марганец, бакыр комы һәм сланецларның фәзаи урнашуы б-н генетик бәйләнеше билгеләнә; казылмалар нефть ясалу системаларының үсеше утырымнардан ясалган бассейннар эволюциясе барышына бәйләнеше күрсәтелә. Кече ятмалар, бигрәк тә фосфоритларның зур әһәмияте исбатлана. Техноген ятмаларны бәяләү ысулы эшләнелә, анда минераллар һәм тау токымнары бүленеше үзенчәлекләре билгеләнә, техноген чималны эзләү һәм алардан файдалану буенча тәкъдимнәр эшләнелә. Теоретик тикшеренүләр Баулы, Ромашкино, Шөгер һ.б. нефть, цеолитлар һәм пигментлар урыннарын ачуга китерә, бу ачышлар СССР һәм ТР Дәүләт бүләкләре, СССР МС бүләге, СССР ФА һәм РФАнең И.М.Губкин исем. бүләк б-н билгеләнә.

20 нче йөз ахырында яңа фәнни юнәлеш — геоэкология, экогеохимия, экогеофизиканы үз эченә алган мохитнең геоэкологик үзенчәлекләрен билгеләүгә игътибар арта (М.Я.Боровский, И.Х.Газиев, Н.С.Гатиятуллин, У.Г.Дистанов, И.И.Зәйнуллин, В.А.Копейкин, Д.К.Нургалиев, А.А.Озол һ.б.). Геологик мохитнең техноген үзгәрешләрен бәяләү һәм мониторинг үткәрү буенча методик тәкъдимнәр, зарарланган җирләрне экологик һәм икътисади реабилитацияләү эшләнелә. Геологик мохиткә антропоген тәэсир чыганаклары ачыклана, ТР терр-ясен геол. мохитнең табигый иминлек факторларына бәйлелеге буенча типологик районнарга бүлү үткәрелә; геол. мохитне геохимик һәм геофизик саклау ысулларын куллану өчен тәкъдимнәр эшләнелә, Чернобыль һ. б. атом электр станцияләре тирәсендә радионуклидлар таралуны туктатучы геохимик киртәләр өйрәнелә, ТР терр-ясендә геохимик һәм радиацион бәяләү үткәрелә, ТРның биогеохимик картасы төзелә.

Казан геологлары тарафыннан Одесса (Н.А.Головкинский), Пермь (Б.К.Полянов, И.П.Герасимов), Омск (П.Л.Драверт), Киев (А.В.Нечаев, С.И.Субботин), Новосибирск (А.А.Трофимук, В.С.Сурков, А.М.Дымкин), Төмән (А.Н.Кирсанов, В.К.Фёдорцев, М.Ф.Хәсәнов), Уфа (Б.М.Йосыпов. М.Г.Камалетдинов, Ә.Р.Кинзикиев, С.А.Солтанов), Львов (Р.С.Сәйфуллин), Бөгелмә (М.В.Мальцев, Ф.А.Бегишев, Р.Х.Мөслимов, Р.С.Хисамов һ.б.), Лениногорск (Б.А.Яковлев) шәһәрләрендә фәнни үзәкләр булдырыла; галимнәр РФнең геол. фәннәре үсешенә һәм файдалы казылмалар булган урыннарны тикшерүгә зур өлеш кертәләр.

**КАЗА́Н ГЕОМЕ́ТРИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, Казанда геом. тикшеренүләрнең нигезе нәевклид геометрияне төзүче Н.И.*Лобачевский* тарафыннан салына. Россиядә Лобачевский идеяләрен тарату һәм үстерү, аның эшчәнлеген һәм фәнни иҗатын өйрәнү эше 19 йөз ахырында, Казан физика-матем. җәмгыяте оешканнан соң (1890) һәм нәевклид геометрияләр өлкәсендә беренче тикшеренүләр дөнья күргәч башланып китә. Ф.М.*Суворов* өч үлчәнешле риманча фәзаларның дифференциаль инвариантлары теориясе буенча хезмәтләре б-н билгеле. А.П.*Котельников* Евклид һәм нәевклид фәзаларында винтлар теориясе буенча мөһим нәтиҗәләр ала, комплекслы, икеле һәм дуаль саннар алгебраларын куллануга нигезләнеп, сызыкча геометриядә нәевклид фәзаларны күчерү принцибын ача. Д.М.*Синцов*, немец математигы И.Ф.Пфаффның дифференциаль системаларын өйрәнүгә бәйле рәвештә, нәголоном геометрия өлкәсендә тикшеренүләрне башлап җибәрә. Лобачевский фәзасы һәм натурфилософиясе мәсьәләләре турындагы мәкаләләр авторы Н.Н.*Парфентьевның* эшчәнлеге Казан уку йортларында матем. һәм механиканы укыту дәрәҗәсен күтәрергә ярдәм итә.

Геометрик тикшеренүләрнең үсеше һәм К.г.ф.м. барлыкка килү Н.Н.Парфентьевның шәкерте проф. П.А.*Широков* исеме б-н бәйле. Казан ун-тында 1926 елдан аның җитәкчелегендә геом. семинар эшли башлый, һәм анда матем. кафедралары укытучылары, аспирантлар, өлкән курс студентлары катнаша. 1934 тә ун-тта геометрия кафедрасы оештырыла, П.А.Широков анда Лобачевский геометриясе, тензорлы анализ, риманча фәзалар геометриясе, винтлар теориясе, спинор анализ буенча лекцияләр укый; соңыннан киң танылу алган хезмәте «Тензорлы исәпләүләр» («Тензорное исчисление», М.–Л., 1934) дөнья күрә. П.А.Широков К.г.ф.м.нең әйдәп баручы фәнни юнәлешләреннән берсенә — төрле структуралы фәзаларны өйрәнүгә нигез сала. Ул механикада һәм гомуми чагыштырмалылык теориясендә кулланылуы б-н аеруча әһәмияткә ия булган риманча фәзаларны тикшерә. Аны даими кәкрелекле фәзалар, ш.и. Лобачевский фәзасы һәм үзлекләре буенча аңа охшаш фәзалар кызыксындыра; китерелүче фәзалар аерып күрсәтелә һәм тикшерелә; симметрик фәзалар теориясе буенча хезмәтләре үстерелә; комплекслы диярлек структуралы А-фәзалар (Келер–Широков фәзалары) өйрәнелә башлый.

П.А.Широков һәм аның шәкертләре эшчәнлегендә аерым бер урынны Н.И.Лобачевскийның фәнни мирасын тикшерү һәм нәевклид геометрия идеяләрен популярлаштыру, Н.И.Лобачевский исем. премия бирү буенча халыкара конкурслар оештыру (к. *Лобачевский Н.И. исемендәге халыкара премия*) алып тора. Казан геометрлары бөек геометрның тууына 150 ел тулуга багышлап, СССР ФАнең Математика бүлеге б-н берлектә Казан ун-ты тарафыннан оештырылган юбилей конференциясен әзерләүдә һәм үткәрүдә (1943) актив катнашалар. Н.И.Лобачевский хезмәтләренең тулы җыентыгын бастырып чыгару проекты (Т. 1–5, М.–Л., 1946–51) тормышка ашырыла, аны әзерләүдә Казан математиклары да катнаша. Н.И.Лобачевский мирасы буенча йомгаклау материаллары җыентыгы («Научно-педагогическое наследие. Руководство Казанским университетом: Фрагменты Письма», М.–Л., 1976) чыгарыла.

П.А.Широковның шәкертләре — Б.Л.*Лаптев*, И.П.Егоров, А.З.*Петров*, П.И.*Петров*, Г.С.Бархин, В.Г.Копп, А.П.Заборская — К.г.ф.м.нең фәнни тикшеренүләрен дәвам итәләр. Б.П.Лаптев гомумиләштерелгән фәзалар теориясе буенча фундаменталь нәтиҗәләр ала; тензорлы алымнар кулланып, вариатив исәпләүләрне геометрияләштерү б-н бәйле рәвештә кызыксыну тудырган Финслер фәзаларын тикшерә; таяну элементлары фәзалары теориясенә нигез сала, бу фәзаларда Ли дифференциясе аппаратын камилләштерә. 1970 елларда аның шәкерте Б.Н.Шапуков бу нәтиҗәләрне катламлы күптөрлелекләр структурасы теориясе кысаларында тагын да үстерә һәм гомумиләштерә. Б.Л.Лаптев гомумиләштерелгән фәзалар геометриясе өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР ФАнең П.Л.Чебышев исем. медале б-н бүләкләнә (1984). А.З.Петров, тартылу теориясендә инвариант-төркемле алымнар кулланып, Эйнштейн фәзаларын һәм гомуми рәвештәге тартылу кырларын фәза-вакыт кәкрелеге тензорының алгебраик структурасы буенча классификацияли. 1960 та Казан ун-тында ул чагыштырмалылык һәм гравитация теориясе кафедрасына нигез сала. Шәкертләре (В.Р.Кайгородов, А.В.Абдуллин, В.И.Голиков, А.М.Анчиков, А.В.Әминова, Р.Ф.Билалов һ.б.) б-н бергәләп, А.З.Петров тартылу фәзаларын хәрәкәт итү төркемнәре буенча классификацияләүне, бу фәзаларны конформ һәм проектив рәвешүзгәртүне, тартылу кырларын геодезик модельләү мәсьәләләрен тикшерә, соңгысы өчен 1972 дә Ленин бүләгенә лаек була. Ф.М.Суворов һәм П.И.Петров тикшеренүләре барышында ирекле сигнатуралы риманча дүрт үлчәмле фәзаларның дифференциаль инвариантлары теориясе эшләнә; 2 нче тәртип скаляр инвариантларның тулы системасы төзелә.

К.г.ф.м. тарихында мөһим бер чор Мәскәү геометрия мәктәбе вәкиле А.П.*Норден* эшчәнлеге б-н бәйләнгән. 1945 тән ул Казан ун-тының геометрия кафедрасын җитәкли һәм, проектив фәзалар өлекләрен нормальләштерү алымын үстерүен дәвам итеп, аны күбүлчәмле очрак өчен гомумиләштерә. Бу

алым конформ, сызыкчалы, биаксиаль, биаффин һәм проектив төркемнең астөркемнәре б-н билгеләнә торган башка геометрияләрдә күп кенә фундаменталь нәтиҗәләр алырга ярдәм итә, нәевклид геометрияләрне гомумиләштерелгән фәзалар геометрияләре б-н бәйли. Ул геометриядә гиперкомплекслы саннар куллану мәсьәләләрен өйрәнә. А.П.Норден 40 тан артык фән кандидатын һәм докторын, ш.и. А.И.Чахтаури, В.В.Ведерников, Р.Г.*Бохараев*, В.И.*Шуликовский*, А.П.*Широков*, В.В.*Вишневский*, В.В.Шурыгинны әзерли.

Тензорлы тикшеренү элементларын куллану В.И.Шуликовскийга өч үлчәмле Евклид фәзасының челтәрләре һәм конгруэнцияләре теориясенә зур өлеш кертергә мөмкинлек бирә, аның тикшеренү нәтиҗәләре «Классик дифференциаль геометрия» («Классическая дифференциальная геометрия», М., 1963) монографиясендә басылып чыга, ә Пловдив пед. ин-тында эшләү дәверендә Болгария геометрлары б-н Казан галимнәре арасындагы иҗади хезмәттәшлеккә нигез сала, соңыннан бу хезмәттәшлекне Казан математиклары (В.В.Вишневский, Б.Г.*Габделхәев*, А.Д.*Ляшко*) дәвам итә.

А.П.Широков гомуми рәвештәге ассоциатив униталь алгебралар өстендә фәзалар теориясен эшли һәм бу теория б-н ул геометриядә комплекслы структуралар куллану буенча үзенең әтисе идеяләрен логик яктан үстерә. Алгебралар б-н билгеләнә торган структураларның табигый төстә орынма катламнарда, нәевклид фәзаларда барлыкка килүе күрсәтелә. А.П.Широков әтисенең хезмәтләрен төгәлләп бетерә һәм бастырып чыгара, ш.и. «Аффин дифференциаль геометрия» («Аффинная дифференциальная геометрия», М., 1959) монографиясе басыла.

В.В.Вишневский гомуми рәвештәге аффинча структуралы күптөрлелекләрне плюраль саннар алгебралары б-н тыгыз бәйләнештә тикшерә һәм мондый структураларның ярыморынма катламнарда чагылуын күрсәтә.

В.В.Шурыгинның тикшеренүләре локаль алгебраларны югары тәртип агымнарның катламлы күптөрлелегендә куллануга багышланган, когомологияләр теориясе терминнарында кайбер дифференциаль-геометрик структураларның булуына каршылыклар (Атьи-Молино класслары һ.б.) табыла.

К.г.ф.м. галимнәренең төп хезмәтләре төрле типтагы алгебралар һәм билгеләнә торган дифференцияләнүче күптөрлелекләрдә структураларны өйрәнүгә багышлана. Мондый тип структуралар табигый рәвештә нәевклид фәзаларда, катламлы күптөрлелекләрдә, аналитик механика һәм теоретик физика мәсьәләләрендә барлыкка килә. Аларны өйрәнүдә дифференциаль геометрия, төркемнәр теориясе, алгебраик топология, дифференциаль тигезләмәләр теориясе һ.б. хәзерге матем. алымнарының киң арсеналы кулланыла.

1992 елда Казан ун-тында Н.И.Лобачевскийның тууына 200 ел тулуга багышланган конференция уздырыла. Шул елдан башлап, Казан ун-ты һәр 5 ел саен *Лобачевский Н.И. исемендәге медальгә* «Геометрия өлкәсендә күренекле хезмәтләр өчен» конкурс игълан итә.

*Әд.:* Казанский университет. 1804–1979: Очерки истории. К., 1979; Н о р д е н А.П., Ш и р о к о в А.П. Наследие Н.И.Лобачевского и деятельность казанских геометров // Успехи мат. наук. 1993. Т. 48, вып. 2 (290); Механико-математический факультет Казанского университета. 1960–2000: Очерки истории. К., 2000.

*Б.Н.Шапуков.*

**КАЗА́Н ГЕОМОРФОЛО́ГИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, *геоморфология* үсеше б-н бергә 1860–70 елларда оеша башлый. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Урал һәм Рус тигезлегенең көнчыгыш өлешен тикшерү материалларында Казан ун-ты геолог һәм географлары (Н.А.Головкинский, Ф.Ф.Розен, П.И.Кротов, А.В.Нечаев, В.Н.Сементовский һ.б.) рельеф формалашуда тектоник хәрәкәт һәм тектоник структураларның роле, елга террасалары һәм елга үзәннәренең төзелеше һәм килеп чыгышы, борынгы бозлану мәсьәләләрен өйрәнә. 20 йөз уртасында Татарстан рельефы турында беренче җыелма хезмәтләр (В.Н.Сементовский, В.В.Батыр, А.В.Ступишин), беренче геоморфологик карта (А.П.Дедков, М.С.Кавиев һ.б.) барлыкка килә. 20 йөзнең 2 нче яртысында К.г.ф.м. вәкилләре төп игътибарны климатик, динамик һәм экологик геоморфология мәсьәләләренә юнәлтә. Тигезлекләрнең климатик геоморфологиясе буенча (А.П.Дедков, В.И.Мозжерин, А.В.Ступишин, А.М.Трофимов), җир эрозиясе һәм утырма матдәләр агышы (А.П.Дедков, В.И.Мозжерин, А.Н.Шәрифуллин), гумид тигезлекләрнең химик денудациясе (В.И.Мозжерин, А.Н.Шәрифуллин) буенча гаять зур гомуми нәтиҗәләр ясала. Зур төбәкләрдә төрле күренешләрнең гомумтеоретик һәм гомумметодик аспектлары тикшерелә. Урта Идел буенда (А.В.Ступишин) һәм Рус тигезлегенең төньяк өлешендә (Н.П.Торсуев) карст өйрәнелә. Рус тигезлегенең көнчыгыш өлеше киң тикшерелгән: экзотектоник җыерчыклы (А.П.Дедков, Г.В.Бастраков), Куйбышев сусаклагычы ярлары (В.М.Широков, А.В.Ступишин, В.А.Дуглав), плейстоценның перигляциаль морфогенезы (Г.П.Бутаков), ерымнар эрозиясе (Ф.Ф.Бойко, Г.П.Бутаков, А.П.Двинских һ.б.), елга үзәннәренең сөзәклекләре ассиметриясе (Ю.В.Бабанов), елга бассейннарында эрозия пояслары (О.П.Ермолаев). Сөзәклекләр үсешен матем. анализлау (А.М.Трофимов), эре ишелмә материалны күләм ягыннан анализлауның (Г.П.Бутаков, А.П.Дедков) яңа ысуллары эшләнә. Экологик гамәли мәсьәләләрне хәл итүдә, Халыкара геогр. җәмгыяте һәм РФАнең Геоморфология комиссияләре эшендә геоморфологларның катнашуы активлаша бара.

*Әд.:* к. *Геоморфология.*

*А.П.Дедков.*

**«КАЗА́Н ГИПРОНИИАВИАПРОМЫ́»**, авиация сәнәгатенең проектлау һәм фәнни-тикшеренү ин-ты. 1941 елда Казанда, «Гипронииавиапром» үзәкләштерелгән тармак ин-тының махсус проектлау төркеме базасында төзелә (Мәскәү), 1952 дән — аның ф-лы, 1991 дән — хәзерге исемен йөрткән мөстәкыйль ин-т, 1993 тән — АҖ. Эшләүчеләр саны — 330 кеше (2010). Төп эшчәнлеге: авиация сәнәгате, машина төзелеше, төзелеш индустриясе, энергетика, торак һәм мәдәни-көнкүреш объектлары төзелешен, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре объектларын комплекслы проектлау, энергия саклаулы технологияләрне гамәлгә кертү. Институт проектлары буенча тиңдәше булмаган технологияле авиация сәнәгате з-длары һәм объектлары, вертолётлар, авиация двигательләрен сынау станцияләре, Идел буе шәһәрләрендә, Уралда, Украинада, Казанда һәм ТРның башка шәһәрләрендә күчмә эл. станцияләре, ш.у. Казанда гражданлык биналары һәм корылмалары: В.И.Ленин исем. мәдәният сарае (1954–56), НИАТ күргәзмәләр залы (1976), «Казан моторлар төзү» ҖБнең завод идарәсе (1987), «Казан» халыкара аэропорты ярдәмче корылмалары (1999) проектлары эшләнә һ.б.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КАЗА́Н ГРАЖДАНЛЫ́К ЭШЛӘРЕ́ МӘХКӘМӘ́ ПАЛА́ТАСЫ**, Казан губернасының югары мәхкәмә органы. Сенатның 1781 ел 28 сентябрь фәрманы б-н оештырыла һәм 1781 нең 23 декабрендә эшли башлый, 1796 ның 31 декабреннән Казан губерна штатын тәгаенләгәндә, *Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасы* б-н бергә Казан мәхкәмә һәм җәза бирү палатасына берләштерелә, Сенатның 1801 ел 9 сентябрь фәрманы нигезендә К.г.э.м.п. буларак торгызыла. Түбәндәрәк торучы мәхкәмә учреждениеләреннән апелляция буенча һәм тикшерү өчен кергән гражданлык эшләрен карый һәм соңгы карарлар кабул итә. Өяз мәхкәмәләре, губерна һәм шәһәр магистратлары, шәһәр ратушалары һәм 1796 га кадәр — югары земство суды һәм югары җәза бирү өчен югары инстанция булып тора. Палата составына рәис (император билгеләп куя), 2 советник һәм 2 асессор (аларны Сенат билгели), 1802 дән — рәис, рәис иптәше (урынбасары) (1821 дән губерна дворяннар җыены тарафыннан сайланалар), дворяннардан һәм сәүдәгәрләрдән 4 утырышчы керә. Палатага секретарь, өстәл башлыклары һәм аларның ярдәмчеләре, күзәтче, казначей, беркетмә язучы, теркәүче, архивариус (барлыгы 10 кеше; 1869) хезмәт күрсәтә. Сенат һәм 1802 дән Россия Юстиция министрлыгы карамагында була. Сенатның 1871 ел 11 декабрь фәрманы нигезендә бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 20. № 14392; Т. 24. № 17702; Т. 26. № 20004; Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1874. Т. 46, отд. 2. № 50301а.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII в. // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и в раннее новое время. М., 1996; ш у л у к. Органы суда в Казанской губернии в XVIII — начале XX вв. // Правосудие в Татарстане. 2000. № 2/3.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА ЗЕ́МСТВОСЫНЫҢ ВАК СӘНӘГА́ТЬ ҺӘМ ҺӨНӘРИ́ БЕЛЕ́М БИРҮ́ ҮЗӘ́К МУЗЕЕ́**, Казанда. 1910 елның 23 гыйнварында ачыла. Устав буенча

«Музей Казан губернасында вак сәнәгать һәм укыту-һөнәри учреждениеләрнең теге яки бу тармаклардагы хәлен искә алуны, киләчәктә вак һөнәрчеләрне үстерүгә булышлык күрсәтү, бигрәк тә әйберләр сатуны оештыру, вак һөнәрчеләрне материаллар һәм эш кораллары б-н тәэмин итү, һөнәри уку йортларының пед. эшчәнлегенә ярдәм итү максатларын күздә тота». Музей коллекцияләренең төп өлешен 1909 да Казанда булып узган Вак сәнәгать һәм һөнәри белем халыкара күргәзмәсе экспонатлары тәшкил итә.Экспонатлар сайлап алу эшен земство эшлеклеләре А.Н.Боратынский, Н.Н.*Белькович*, В.Н.Белькович, ш.у. рәссам-педагог Н.И.*Фешин* һәм С.М.Григорьев составындагы махсус комиссия башкара, аларга Мәскәү вак һөнәрчелек музее советы әгъзасы С.С.Голоушев ярдәм итә. Музей мөдире М.И.Завалишин, күзәтүчесе П.Ф.Бессонов була. Музей укыту-күргәзмә (аңа кустарь эшләнмәләр үрнәкләре, уку-һөнәрчелек әсбаплары коллекцияләре, китапханә керә) һәм кибет-склад (күпләп-ваклап сату сәүдәсе, заказ кабул итү, вак һөнәрчелек өчен материаллар һәм эш кораллары сатып алу, ш.у. вак сәнәгать эшләнмәләрен арадашсыз сату б-н шөгыльләнә) бүлекләреннән тора. Музей коллекцияләренә Мәскәү губернасы Сергей посады укыту-столярлык остаханәсендә агачтан ясалган эшләнмәләр, Мәскәүнең Строганов һәм Петербургның барон Штиглиц уч-щесенең нәфис сәнгать әйберләре, Екатеринбург нәфис-сәнәгать мәктәбе, Тула нәфис һөнәрчелек-тимерчелек остаханәсе, Кострома губернасының Красный авылындагы зәркән укыту-өйрәтү остаханәсе, Кукарск челтәр бәйләү мәктәбе, Арча туку остаханәсе эшләнмәләре, ш.у. Мәскәү, Вятка, Түбән Новгород һәм Казан губерналары кустарьларының шул замандагы барлык эшләнмә төрләре — *каюлы күн, чигү, нәфис сәнәгать, зәргәрчелек сәнгате* әйберләре керә. 1913 тә музей үзенең коллекцияләре б-н Петербургта 2 нче Бөтенроссия вак һөнәрчелек күргәзмәсендә катнаша һәм Зур көмеш медаль б-н бүләкләнә. 1920 дә музей ябыла, коллекцияләре ТАССРның Үзәк музеена (хәзер ТРның Милли музее) тапшырыла.

*Е.П.Ключевская.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА ИДАРӘСЕ́**, Казан губернасындагы төп адм.-полиция учреждениесе. 1775 елгы губерна реформасын уздыру нәтиҗәсендә оештырыла, 1796 ның 31 декабрендә ачыла. Губернатор каршындагы коллегиаль орган; 1837 дә гамәлгә кергән «Губернаторга күрсәтмә» нигезендә чынлыкта коллегиялекнең юридик хокукларын югалта. Губернаны гомуми идарә итү б-н шөгыльләнә — законнарны, фәрманнарны һәм үзәк хакимиятләр күрсәтмәләрен халыкка җиткерә һәм аларның үтәлешен күзәтчелектә тота; мәхкәмәдә каралмаган эшләрне хәл итә; мәхкәмә чыгарган хөкем карарлары буенча мөлкәт хуҗасы булудан вакытлыча читләштерә; үзенә буйсынудагы учреждениеләргә һәм затларга карата шикаятьләрне тикшерә. Хөкем ителерлек һәм җаваплы эшләр — губернатор б-н берлектә, башкару һәм «2 нче разряд» эшләре К.г.и. бүлекчәләрендә карала. 1865 елгы Нигезләмәдә күрсәтелгәнчә, идарә составына: губернатор (рәис), вице-губернатор, киңәшчеләр, асессор, аерым йөкләмәләр башкаручы чиновниклар, казначей, аның ярдәмчесе, губернаның табиблек инспекторы, губерна инженеры, губерна архитекторы, соңрак губерна төрмә инспекторы һ.б. (1911 дә барлыгы 60 лап кеше) керә. К.г.и. гомуми кабулханәгә һәм канцеляриягә бүленә; канцелярия 4 бүлектән тора. К.г.и. каршында табиблек, төзелеш, төрмәләр һәм җир бүлү бүлекләре, ш.у. типография, архив, регистратура була. Сенатка, 1802 дән Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советларының 2 нче съездының 1917 ел 27 октябрь карары нигезендә бетерелә, 1917 нең 1 декабрендә яшәүдән туктый.

*Әд.:* А н у ч и н Е. Исторический обзор развития административно-полицейских учреждений России. СПб., 1872; Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1; Д о л г о в Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII в. // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и раннее новое время. М., 1996.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА ИДАРӘСЕ́ БАСМАХАНӘСЕ́**, император Александр I нең 1805 елның 7 июнендә Дәүләт казначеена биргән Фәрманы нигезендә оеша. Аны тоту өчен елына 900 сум акча бирелә. Анда басылган беренче басмалар — иеромонах Августинның «Митрополит Амвросийга, аның исем бәйрәменә тирән тәэсирле, ихлас, эчкерсез хисләр бүләге» («Жертва живейшего, нелестного, сердечного чувствования Амвросию, митрополиту в день тезоименитство приносимая», 1805), Д.Н.Зиновьевның «Французлар белән сугыш форсатыннан чаң сугу» («Набат по случаю войны с французами», 1807), әсәрләре, ш.у. аз күләмле табаклы басма продукция: «Казан университеты ачылышы тантанасына чакыру кәгазе» («Листок пригласительный на торжество открытия Казанского университета», 1805) һ.б. 1807 дә басмаханә әдәбиятчы Д.Н.Зиновьев акчасына эшли. 1815 тә янгын вакытында басмаханә янган булса кирәк, чөнки аның эшчәнлеге күпмедер вакытка тукталып тора. Алга таба анда Казан губерна идарәсенә бирелгән император фәрманнары (1818, 1831); «Казанские губернские ведомости» г-тасы (1838 елдан); төрле җәмгыятьләрнең һәм оешмаларның уставлары, хисапнамәләре; Н.А.Иванов, И.Н.Березин, А.П.Щапов. Л.Ф.Камбек, Е.Г.Осокин, А.И.Вицин кебек профессорларның хезмәтләре; «Ваба дип аталган авыруны дәвалау буенча киңәшләр» («Наставление о лечении болезни, называемой холера», 1829), «Терлек үләтен туктату чараларына кагылышлы кагыйдәләр» («Правила о мерах к пресечению скотских падежей», 1852) һ.б. рәсми документлар басыла. 1840 еллардан басмаханә сыйфатлы җиһазларга ия була. Моны, аерым алганда, «Казан губерна идарәсе басмаханәсенең шрифтлар, каймалар һәм политипажлар үрнәкләре» («Образцы шрифтов, бордюров и политипажей типографии Казанского губернского правления», 1848) дә раслый. Полиграфик яктан матур эшләнгән басмалар да шушы вакытка карый, мәс., И.С.Черновның 1840 һәм 1841 елларга «Казан шәһәре күрсәткече» («Указатель города Казани», шагыйрә А.А.Фуксның әсәрләре, «Родионованың Казандагы затлы нәсел кыз балалар институты уставы» («Устав... Казанского Родионовского института благородных девиц», 1838) һ.б.

1860 елларда басмаханәдә, нигездә, губерна идарәсенең рәсми басмалары гына басыла, шәхси заказлар булмый диярлек. Яңа шрифтлар җитешмәү һәм үзләре ясаган буяуның начар булуы нәтиҗәсендә эшнең сыйфаты кими. 1886 га басмаханәнең матди-техник базасы янартыла: 200 гә якын шрифты (1 меңпоттан күбрәк), 4 басмаханә һәм 1 ташбасма машинасы, 8 кул станогы була. Эшчеләр саны 64 кә җитә. Анда, «Казанские губернские ведомости» г-тасыннан тыш, «Волжский вестник», «Казанский биржевой листок» г-талары басыла, ул ш.у. дәүләт оешмалары, вазифаи затлар, земство, хастаханә, даруханә, фабрика, завод, контора, шәхси кешеләрнең заказларын үти.

1918 дә басмаханә конфискацияләнә һәм Дүртенче совет басмаханәсе дип атала башлый; 1919 ның 1 июленә ул национализацияләнә.

*Әд.:* Г а в р и л о в И. Сведения о казанских типографиях, литографиях и словолитнях // Казанское книжное дело. К., 1866. Вып. 1; Л и х а ч ё в Н.П. Книгопечатание в Казани за первое пятидесятилетие существования в этом городе типографий. СПб., 1895; ш у л  у к. Манифесты, указы и другие правительственные распоряжения. СПб., 1895; Д у л ь с к и й П. Книга и её художественная внешность. К., 1921; К у р б а н г а л е е в а Т.С. Книгоиздательское дело в Татарии. К., 1977; М и ф т а х о в З.З. Развитие полиграфической базы в Татарии // Здравствуй, Книга! К., 1989.

*И.А.Новицкая.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасы земство башлыклары һәм өяз съездлары эшчәнлегенә күзәтчелек итүче адм. учреждение. 1889 елның 12 июлендә кабул ителгән «Земство участок башлыклары турындагы нигезләмә» һәм Россия Дәүләт Советының 1891 нең 16 июнендә император Александр III тарафыннан расланган карары нигезендә оештырыла. Составына губернатор (рәис), вице-губернатор, губерна дворяннар башлыгы, округ мәхкәмәсе прокуроры, җирле дворяннардан 2 даими вәкил керә. Аерым эшләрне караганда тавыш бирү хокукы б-н округ мәхкәмәсе рәисе (мәхкәмә эшләре), казна палатасы, җир эшләре һәм дәүләт милке идарәсе управляющийлары, губерна земство идарәсе рәисе (адм. эшләр), губерна земство идарәсенең барлык әгъзалары (азык-төлеккә кагылышлы эшләр) чакырыла. К.г.к. земство башлыклары һәм өяз съездлары чыгарган хөкем карарларына карата белдерелгән шикаятьләрне һәм аларның тәмамланмаган карарларын тикшерә; ревизияләр билгели; крәстиян җәмгыятьләре үзидарәләренең вазифаи затларын эштән азат итү һәм аларны мәхкәмә каравына тапшыру мәсьәләлә-

рен хәл итә; земство участокларының чикләрен үзгәртә һ.б. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 30 июнь карары б-н бетерелә, 1917 нең 1 октябрендә ябыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1894. Т. 11. № 7775.

*Әд.:* Е р о ш к и н Н.П. История государственных учреждений дореволюционной России. М., 1983. *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА КАЗНАЧЕЙЛЫГЫ́**, Казан губернасының дәүләт финанс органы. 1775 елда Губерна реформасы үткәрелү нәтиҗәсендә оештырыла, 1781 нең 13 декабрендә Казан өяз казначейлыгы буларак ачыла; Россия Дәүләт советының 1865 ел 30 ноябрь карарын император Александр II нең раславы нигезендә К.г.к. итеп үзгәртелә. Дәүләт керемнәрен җыю һәм аларны саклау; Дәүләт банкына түләүләр һәм казначейлык арасында акча суммаларының йөрүе; хөкүмәт учреждениеләренең (Изге синодтан тыш) махсус акчаларын һәм депозитларын, император галиҗәнаплары Кабинетының, Җәмәгать тәрбиясе приказының (1867 гә кадәр) һ.б.ларның кайбер суммаларын, ш.у. Финанс министрлыгы б-н аерым килешү нигезендә җәмәгать һәм сословие суммаларын кабул итү, саклау һәм чыгымнарга тоту; герб кәгазьләре, марка, бандероль, бланк, таныкнамәләр сату; сәүдә итүгә һәм сәнәгать б-н шөгыльләнүгә хокук бирүче таныкнамәләр, сәүдә һәм сәнәгать биналарына билетлар һәм паспортлар бирү; кабулханәләр, җәмәгать учреждениеләре һәм вазифаи затларның суммаларын вакытлыча саклауга кабул итү; җирле казначейлыклар аша шәхси акча суммаларын бер шәһәрдән икенчесенә күчерү; К.г.к.ның барлык керемнәре һәм чыгымнары буенча исәп-хисап алып бару, тиешле срокларда *казна палатасына* һәм Россиянең Дәүләт контроле учреждениеләренә отчет бирү эшләрен башкара. 20 йөз башында К.г.к. губерна казначееннан, бухгалтерлар, кассирлар, язу-сызу эшләрен башкаручылар, исәп-хисап алып баручы түрәләр, канцелярия хезмәткәрләре, присяжныйлар, каравылчылардан (барлыгы 60 лап кеше, 1915) тора. Аңа канцелярия һәм бухгалтер, герб, пенсия, хезмәт хакы түләү, хәрби, салым өстәлләре керә. Казна палатасына һәм Финанс министрлыгының Дәүләт казначейлыгы департаментына буйсына. РСФСР ХКСның 1918 ел 31 октябрь Декреты нигезендә бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1867. Т. 40, отд. 2. № 42728.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1. *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА ПРОКУРОРЫ́ КАНЦЕЛЯ́РИЯСЕ**, Казан губернасы учреждениеләре, вазифаи затлары һәм халкы тарафыннан законнарның үтәлүен тикшерүче дәүләт күзәтчелеге органы. 1775 елгы Губерна реформасын уздыру барышында оештырыла, 1781 нең 23 декабрендә ачыла. Административ һәм мәхкәмә учреждениеләренең законнарны дөрес куллануын, казна мәнфәгатьләре саклануын, сак астындагыларга карата ачылган җинаять эшләрен кайгыртуын, мәхкәмәләрдә телсезләр, балигъ булмаганнар һ.б. эшкә сәләтсез гаепләнүчеләрнең мәнфәгатьләре яклануын күзәтә, хезмәт буенча хат язышу, агымдагы документларны төзү б-н шөгыльләнә. Канцелярия составына губерна прокуроры, казна һәм җинаять эшләре буенча 2 губерна стряпчие (Сенат тарафыннан билгеләнә), хат ташучылар, беркетмә язучылар, каравылчы керә. Губерна прокурорына югары земство мәхкәмәсе, губерна магистраты һәм югары җәзалар үтәү оешмасы прокурорлары (1796 га кадәр), өяз һәм шәһәр стряпчийлары буйсына. Аларның эшчәнлеге төрле учреждениеләрнең утырышларында катнашудан, эшләр буенча чыгарылган нәтиҗәләрне тәкъдим итүдән, губерна оешмаларының журналларын һәм карарларын карап чыгудан гыйбарәт була. Барлык ачыкланган законсыз гамәлләр һәм тәртипсезлекләр турында губерна прокуроры губернаторга һәм губерна идарәсенә, аерым очракларда Сенат генерал-прокурорына (1802 дән — юстиция министрына) хәбәр итә, аңа кичектергесез хәбәрләр һәм аерым протестлар җибәрә. К.г.п.к. Сенатның 1869 ел 28 апрель фәрманы нигезендә бетерелә.

Чыг.: Полное собрание узаконений о губерниях по хронологическому порядку с 1775 по 1817 г. СПб., 1818.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII в. // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и в раннее новое время. М., 1996; Н а ф и е в С.Х. Прокуратура Татарстана: история и современность. К., 1997; Прокуратура Татарстана на службе Отечеству и закону: События, факты, люди. К., 2001. *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА РЕКРУТЛА́Р КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасында салым түләүче халыкның рекрутлык бурычын үтәвен оештыручы җирле башкарма орган. 1831 елның 1 июнендә император Николай I тарафыннан расланган «Рекрутлык уставы» нигезендә төзелә. Рекрут участокларын билгеләү б-н шөгыльләнә, рекрутларга азык-төлек җыеп җибәргән өчен халыкка компенсация түләү срокларын контрольдә тота һәм 1853 тән рекрутлыкка алынуның шобага салу тәртибендә баруын да күзәтә. Өяз рекрутлар кабулханәләре эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аларга карата белдерелгән шикаятьләрне карый. Кабулханә составына губернатор (рәис), вице-губернатор, губерна дворяннар башлыгы, казна палатасы рәисе, Дәүләт милке палатасы (1866 дан — губерна дәүләт милке идарәсе) управляющие керә. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. 1874 нең 1 гыйнварында гомуми хәрби бурыч үтәү гамәлгә кертелгәч бетерелә, вазифалары *Казан губерна хәрби хезмәт кабулханәсенә* тапшырыла.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.* *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА УРМА́Н САКЛА́У КОМИТЕТЫ́**, хосусый милектә булган җирләрдәге казна урманнарын саклау буенча губерна органы. 1888 елның 4 апрелендә кабул ителгән «Урманнарны саклау турында нигезләмә» б-н оештырыла. 1888 нең 9 августында ачыла. Комитет составына губернатор (рәис), губерна дворяннар башлыгы, округ мәхкәмәсе һәм губерна земство идарәсе рәисләре, губерна җир эшләре һәм дәүләт милке идарәсе управляющие, губерна кабулханәсенең даими вәкиле, урман ревизоры, җирле урман биләүчеләр вәкиле һәм 1916 дан губерна җир эшләре комиссиясенең даими әгъзалары керә. К.г.у.с.к. түбәндәге вазифаларны башкара: урманнарның сакланулы булуын тәэмин итү һәм аларга карата хуҗалык итү планнарын раслау; елгаларны һәм аларның кушылдыкларын коткарып калу өчен урман массивларын саклау зарурлыгын тану; урман мәйданнарын башка төрле биләмәләргә үзгәртүгә рөхсәт бирү; урман милекчеләренең урманнарның кырылуына китерүче, тамырдан барлык агачларны кисү турындагы күрсәтмәләрен гамәлдән чыгару; агачлары дөрес киселмәгән яки буш калган мәйданнарда урман утыртуның вакытын һәм урынын билгеләү; сакланулы статусы булмаган урманнарда урман хуҗалыгы алып бару планын раслау; урманнарга карата күзәтчелек урнаштыру һәм гаеплеләрне җавапка тарту буенча гамәлләр башкару; урманнарны күзәтчелек итү өчен бүлү; шикаятьләрне мәхкәмәгә юллау һәм мәхкәмәнең хөкем карарын гамәлдән чыгаруны дәгъваларлык вәкаләтләр бирү; күзәтчелек итүче затларга күрсәтмәләр җиткерү һ.б. К.г.у.с.к.ның карарлары барлык урман биләүчеләр өчен мәҗбүри була. Дәүләт милке министрлыгына, 1894 тән Җир эшләре һәм дәүләт милке министрлыгына буйсына. 1918 нең 12 гыйнварында гамәлгә кергән «Губерналарда урманнар белән идарә итү турында вакытлы нигезләмә» б-н бетерелә.

*Әд.:* к. *Казан губернасының земство йөкләмәләре комитеты.* *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНА ХӘРБИ́ ХЕЗМӘ́Т КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасы яшьләрен армиягә чакыруны башкару, оештыру б-н шөгыльләнүче җирле учреждение. Хәрби реформа уздыру барышында император Александр II нең 1874 ел 1 гыйнвар Фәрманы б-н оештырыла. Хезмәткә чакыруның барышын күзәтү, чакырылучыларны барлау, шикаятьләрне карау, губерна буенча гомуми чакыру һәм өстәмә (чакырылудан читләшүчеләр яки хезмәттән вакытлыча калдырылганнар турындагы) исемлекләргә кертелгән затларның исәбе, хезмәткә кабул ителгәннәр хакындагы мәгълүматларны җибәрү, өяз һәм шәһәр хәрби хезмәт кабулханәләренең хисапларын тикшерү, чакырылуның башкарылуы турында гомуми хисап төзү б-н шөгыльләнә. Кабулханә составына: губернатор (рәис), вице-губернатор, губерна дворяннар башлыгы, губерна земство идарәсе рәисе, округ мәхкәмәсе прокуроры һәм генерал керә. Чакырылучыларны барлау чорында кабулханә составы 3 штаб-офицер б-н тулылана. Россия Эчке эшләр министрлыгының Хәрби хезмәт эшләре идарәсенә буйсына. Эчке эшләр халык комис-тының 1918 ел 20 гыйнвар ка-

ралары б-н бетерелә һәм 1918 нең 12 апрелендә эшләүдән туктый.

Чыг.: Устав о воинской повинности. СПб., 1874.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ**, 1708 елда оештырыла. Үзәге — Казан. Губернаның нигезен *Казан сарай идарәханәсенә* караган элеккеге Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары һәм Нугай Урдасы биләмәләре тәшкил итә. Баштарак К.г. Иделнең уңъяк һәм сулъяк ярлары буйлап Түбән Новгородтан Әстерханга кадәр сузылган терр-яләрне колачлый, Әстерхан, Вятка, Казан, Пермь, Пенза, Зөя, Сембер, Уфа һ.б. воеводстволардан тора, 1719 дан алар *провинцияләр* дип атала башлыйлар. 1717 дә К.г.ннан — Әстерхан, 1719 да — Түбән Новгород һәм 1780 дә Вятка, Сембер һ.б. губерналар аерылып чыга. 1781 дә К.г. Казан наместниклыгы (1796 дан яңадан губерна) итеп үзгәртелә, аңа Арча, Казан, Козьмодемьянск, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас, Тәтеш, Царёвококшайск, Цивильск, Чабаксар, Чистай, Ядрин өязләре керә. 1796 да Арча, Спас һәм Тәтеш өязләре бетерелә, 1802 дә соңгы икесе яңадан торгызыла. 1781 дә К.г. һәм өяз шәһәрләре герблары раслана (к. *Герблар*). Мәйданы 55,9 мең кв. чакрымнан артыграк (1897). Халкы 2,85 млн. кеше (1913), ш.и. руслар — 38,9%, татарлар — 31,2%, чуашлар — 22,8%, чирмешләр (марилар) — 5,1%, мордвалар — 1,2%, вотяклар (удмуртлар), — 0,4%. 7272 торак пункт, ш.и. 13 шәһәр (Казан, Арча, Козьмодемьянск, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас, Тәтеш, Царёвококшайск, Цивильск, Чабаксар, Чистай, Ядрин) һәм 2 посад (Мариинск, Троицк); шәһәр халкы — 9% чамасы. Халыкның тыгызлыгы — 1 кв. чакрымга 39 кеше. 1888–92 елларда (елга уртача) туу — 102 мең, үлү 77 мең кеше тәшкил итә; халыкның еллык үсеше — 25 мең кеше. 1862–92 дә К.г. халкы 80%ка арта. Татарлар күпчелек — Казан, Мамадыш, Тәтеш, Чистай, Лаеш, өлешчә Зөя һәм Спас, чуашлар — Козьмодемьянск, Чабаксар, Ядрин, Чистай, өлешчә Тәтеш, марилар — Царёвококшайск, Козьмодемьянск, өлешчә Чабаксар, мордвалар — Спас, Тәтеш һәм Чистай өязләрендә, удмуртлар Мамадыш өязендә яшиләр.

К.г.нда башкарма хакимият император билгеләп куйган губернатор кулында туплана. Аңа адм.-хуҗалык, күзәтчелек, мәхкәмә-полиция эшләре һәм губернадагы башка вазифалар йөкләнә (вазифалар төрле елларда үзгәреп тора). Губернатор үз бурычларын төрле учреждениеләр аша башкара. Бер үк вакытта ул идарә һәм губернадагы башка киңәшү учреждениеләре рәисе була, алар арасында — губернаның төп кабулханәләре: крәстияннәр эшләре, земстволар һәм шәһәрләр эшләре, фабрикалар эшләре, хәрби эшләр, җәмгыятьләр һәм берлекләр буенча кабулханәләр (к. *Кабулханәләр*). 1917 нең мартыннан губернатор Вакытлы хөкүмәтнең губерна комиссары б-н алыштырыла. 1917 нең ноябрь башыннан К.г. б-н *Казан губернасы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы башкарма комитеты* рәисе идарә итә (1918 нең февраль–маенда бүленеп, к. *Казан Совет Эшче-Крәстиян Республикасы*). 1920 нең июнендә аның вәкаләтләре *Вакытлы революцион комитетка* бирелә. Өязләрдә югары адм. хакимият губернатор тарафыннан билгеләнгән һәм аңа буйсынуда эшләүче исправниклар кулында була. 1860 ның уртасыннан К.г.нда земство үзидарәсе (к. *Земство*) һәм губернада җирле үзидарәнең корпоратив органнары (*Дворяннар җыены, Мещаннар идарәсе* һ.б.) эшли. Югары мәхкәмә инстанциясе — Казан округ мәхкәмәсе (к. *Мәхкәмә системасы*).


К.г. Идел һәм Чулман елгалары б-н 3 өлешкә бүленә. 1 нче өлеше — Иделнең уңъяк яры б-н Чулманның сулъяк яры арасындагы киңлекне били; аның көнчыгыш өлешенең яртысы чокырлар б-н бүлгәләнә, аеруча Мамадыш өязендә, ә көнбатыш өлеше Царёвококшайск һәм өлешчә Чабаксар, Козьмодемьянск һәм Казан өязләрендә урманнар б-н капланган тигезлектән тора. 2 нчесе — Иделнең һәм Чулманның сулъяк ярлары арасындагы көньяк-көнчыгыш өлешен тәшкил итә, аның өслеге тигез, фәкать Чистай өязенең төньяк өлешендәге Чулман буендагы урын гына калкулыклы. Иделнең уңъяк ярындагы 3 нче — көньяк-көнбатыш өлеше тирән чокырлар һәм сызалар б-н ергаланган, тау тезмәләре б-н бүлгәләнгән, аларның берсе — Ядрин өязе буйлап, Сура һәм Цивиль елгалары арасыннан, икенчесе — Зөя елгасы тамагыннан түбәнрәк Иделнең уңъяк яры буйлап үтә. К.г. терр-ясе сулыкларның тыгыз челтәре б-н чуарланган; анда 8 мең чамасы елга, ш.и. Идел, Чулман, Нократ, Ветлуга, Казансу, Рутка, Цивиль, Олы һәм Кече Кокшага, Иләт, Бизнә, Ашыт, Утка, Актай, Милёнка, Олы һәм Кече Чирмешән, Мишә, Майна һ.б. елгалар, 400 ләп күл, ш.и. иң зурлары — Юксар, Кабан, Кавал, Архиерей, Сапугали, Казлар, Яльчик.

Губернаның минераль байлыкларыннан чүлмәк ясауда һәм кирпеч сугуда кулланылучы кызыл балчык, башлыча Казан тирәсендә чыгарыла һәм төзелеш тармакларында кулланыла торган известьташ һәм гипс зур хуҗалык әһәмиятенә ия була. Шулай ук Тәтеш өязендә — янучан сланец, Козьмодемьянск өязенең Покровский авылы һәм Чистай шәһәре янындарак кызыл балчыклы тимер рудасы, губернаның төньяк-көнчыгыш өлешендә бакырлы комлыклар, Тәтеш өязе Сөендек авылы тирәләрендә күкерт һәм нефть чыганаклары, асфальт запаслары тикшерелеп табыла. Чистай өязе Черёмуха бистәсендәге күкертле чишмәләр, Казан өязе Щербаково авылындагы күкертле ләмнәр, шул ук өязнең Одинцово авылы янындагы йодлы-тимерле чишмәләр билгеле.

К.г. игенчелек төбәкләренә керә. 1890 елда җир биләмәләренең гомуми мәйданы 5831631 дис., ш.и. сөрүлек җирләре 52,9%, урманнар 29,6%, болынлыклар һәм печәнлекләр 12%, бакчалар, утарлар 1,9%, башка җирләр 4,6% тәшкил итә. Иң күп сөрүлек җирләре Тәтеш (70,6%), Ядрин (66,9%), Казан (64,8%), Зөя (62,7%), Чабаксар (58,9%), Лаеш (58,2%), Мамадыш (56%), Цивильск (50,6%), Спас (53,8%), Чистай (40,2%) өязләрендә була.

Сөрүлек җирләр мәйданы Козьмодемьянск өязендә 21,3%, Царёвококшайскида 18,3% тәшкил итә, әмма урман мәйданнары күләме буенча әлеге өязләр губернада беренче урында тора (66,9% һәм 39,2%), ә Тәтеш һәм Ядрин өязләренә урманнар 13% кына туры килә. Җирбиләүчелек төрләре буенча җир мәйданнары түбәндәгечә бүленә: крәстияннәрнеке — 58,0%, казнаныкы — 21,9%, алпавытларныкы — 18,5%, шәһәрләрнеке — 0,6%, удел җирләре — 0,6%, монастырь һәм чиркәүләрнеке — 0,2%. Игенчелекнең өстенлекле системасын өч басулы чәчү әйләнеше тәшкил итә; туфрак нигездә сука һәм кустарь сабаннар б-н эшкәртелә, катлаулы машиналар (ашлык суккыч, ургыч, иләгеч, сортларга аергыч, чәчкеч һ.б.) бик сирәк кулланыла; ашламалар кулланылмый диярлек. Төп а.х. культуралары арыш һәм солы була, алар бөтен сөрүлек җирләренең 90% чамасын били. Азрак күләмдә арпа, бодай (көзге һәм язгы), бәрәңге, борай, карабодай, ясмык, җитен, киндер һ.б. игелә. 1908–13 елларда губернада ел саен 90 нан алып 120 млн. потка кадәр ашлык җыела, шуның 15–20 млн. поты читкә чыгарыла. Бөртекле культураларның уртача уңышы дисәтинәдән 40–50 пот тәшкил итә. Яшелчә үстерү күбрәк рус һәм чуаш халыкларында, аеруча Казан тирәсендә киң тарала. Бакчачылык б-н, башлыча, Иделнең уңъяк ярында яшәүчеләр шөгыльләнә. Болынлыклар һәм көтүлекләр җитмәү, ш.у. үлән чәчү мәйданнары бик аз булу сәбәпле, терлекчелек, нигездә, бик аз үсә. 1900 елда К.г.нда 2121,2 мең баш терлек, ш.и. 440,6 мең баш ат, 420 мең баш мөгезле эре терлек, 1051,2 мең сарык, 173,7 мең дуңгыз, 35 меңнән артык кәҗә була. Кыш озын һәм кырыс булу сәбәпле, умартачылык артык үсә алмый: чама б-н 70 мең оя умарта исәпләнә. Умартачылык күбрәк Мамадыш һәм Чистай өязләрендә үсеш ала. Балыкчылык, кәсепчелек буларак, Идел һәм Чулман буйларында яшәүчеләр арасында күбрәк тарала: мәрсин, кырпы, укборын (севрюга), чөгә, сөләйман, сыла (судак), кәлчәк, сельд һ.б. балыклар тотыла. 20 йөз башына балык тоту шактый кими: кыйммәтле һәм эре балыклар сирәгрәк очрый башлый. Сунарчылык б-н губернаның төньяк өлешендә яшәүчеләр, нигездә, марилар шөгыльләнә; күпчелек төлке, куян һәм бүре (сирәгрәк соры аю) аулыйлар.

Губернаның фабрика һәм завод сәнәгате аграр характерда була; терлекчелек һәм игенчелек продуктлары (азык-төлек, ярма-он, тире, туңмай, шәраб, сыра кайнату һ.б.) җитештерү һәм эшкәртү өстенлек итә. 19 йөзнең 2 нче яртысында сәнәгатьнең стеарин, химия, урман, тегү, туку, полиграфия, агач һәм тимер эшкәртү һ.б. тармаклары тиз үсә башлый (к. *Индустрияләштерү*). 1913 елга К.г.нда 423 сәнәгать пр-тиесе исәпләнә (җитештерүчәнлекләре елына 1000 сумнан артыграк). Моннан тыш 4,5 мең урта һәм вак


КАЗАН ГУБЕРНАСЫ, 19 ЙӨЗ АХЫРЫ
Губерна шәһәрләре
Өяз шәһәрләре
Штаттан тыш шәһәрләр
Посадлар
Авыллар
Түбән Новгород губернасы
Тимер юллар
Зур юллар
Губерналар чикләре
Өязләр чикләре
Пристаньнәр
Уфа губернасы
Өязләр:
1 Козьмодемьянск
2 Чабаксар
3 Царёвококшайск (Чар)
4 Казан
5 Лаеш
6 Мамадыш
7 Ядрин
8 Цивильск (Чуел)
9 Зөя
10 Тәтеш
11 Спас
12 Чистай
1:2 000 000

кустар җитештерү корылмасы була (җитештерүчәнлекләре елына 1000 сумнан кимрәк). Губерна завод һәм фабрикаларында 40 меңнән артык, ш.и. эре сәнәгать пр-тиеләрендә 17 меңнән артык кеше эшли. Сәнәгать пр-тиеләре, башлыча, шәһәрләрдә, нигездә, Казанда (тире, сабын кайнату, стеарин, туку, агач һәм тимер эшкәртү, сыра кайнату, азык-төлек әйберләре һ.б.) туплана; аларның иң зурлары: *Алафузовларның сәүдә-сәнәгать ширкәте завод-фабрикалары* һәм *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы.* Өязләрдә төрле кустар корылмалар һәм халык һөнәрчелеге формасындагы вак крәстиян сәнәгате өстенлек итә. Царёвококшайск өязендә, Козьмодемьянск һәм Чабаксар өязләренең Идел аръягында, Казан, Цивильск һәм Ядрин өязләренең көньякларында, ш.у. Зөя өязенең төньяк өлешендә халык күпчелек урман кисү һәм такта яру, кап, чыпта сугу, мунчала һәм курыс әзерләү (к. *Урманчылык*), агач савыт-саба ясау (к. *Мичкә-кисмәк кәсепчелеге*), аерым урыннарда дегет һәм сумала куу (к. *Сумала куу кәсепчелеге*), поташ җитештерү б-н шөгыльләнә. Казан, Мамадыш, Лаеш һ.б. кайбер өязләрдә киез басу, тире эшкәртү, тәгәрмәч, арба-чана ясау, йон тетү, тун тегү, бәйләү, тимерчелек, аяк киеме тегү, чүлмәк ясау, кирпеч сугу һ.б. һөнәрчелекләр үсә. 20 йөз башына алар б-н 80 меңнән артык кеше шөгыльләнә. Шулай ук читкә китеп эшләү дә зур үсеш ала. Чабаксар, Козьмодемьянск, Зөя, Цивильск, Тәтеш өязләрендә — Иделдә; Лаеш, Чистай, Мамадыш өязләрендә — Чулманда бурлаклыкка ялланып эшләү киң тарала (к. *Бурлаклар*).

Сәүдә итүнең төп үзәкләре ярминкәләр була: «Язгы базар» (Казан), «Агач ярминкәсе» (Козьмодемьянск), «Кәрван» (Лаеш) һ.б.(барлыгы 90 ярминкә, 9,4 мең сәүдә пр-тиесе). Сәүдәне үстерүдә елга транспорты мөһим роль уйный. 19 йөз уртасында Идел һәм Чулманда, 19 йөз ахырында Нократта пароходлар даими йөри башлый (к. «*Кавказ вә Меркурий*», «*Самолёт*»), алар губернаны Россиянең эре үзәкләре — С.-Петербург, Мәскәү, Рыбинск, Әстерхан һ.б. шәһәрләр б-н тоташтыра. Моннан а.х. һәм өлешчә сәнәгать продукциясе Урта Азиягә (Бохара, Харәзм), Германия, Кытай, Персия һ.б. илләргә җибәрелә. Идел, Чулман, Нократ төп элемтә юллары була. Аларда губернаның төп пристаньнары: Иделдә — Богородский, Югары Ослан, Ильинский, Карташы, Козьмодемьянск, Козловка, Криуши, Лабыш, Мариинск, Моркваш, Тәмте, Тәтеш, Казансу Тамагы (к. «*Бакалтай*»), Чабаксар, Шашкар; Чулманда — Лаеш, Масловка, Монастырь, Мурзиха, Остолопово, Кама Тамагы, Чистай; Нократта — Мамадыш. Идел пароходчылыгының товар әйләнеше елына 5 млн. нан 10 млн. сумга кадәр җитә. Әлеге пристаньнарның иң зурысы булып Казансу Тамагы санала — аның еллык товар әйләнеше еш кына 1 млн. сумга җитә. Чулман пароходчылыгыныкы елына 3 млн. сум тәшкил итә. 1893 елда Мәскәү б-н тимер юл элемтәсе ачыла (к. *Горький тимер юлының Казан бүлекчәсе*). К.г.ннан арыш, солы, тегермән продукциясе (он, ярма һ.б.) һәм химия (дары, сабын, стеарин шәмнәр һ.б.ш.) пр-тиеләре продукцияләре, агач материаллар һәм аннан эшләнгән әйберләр, тире, спирт, туңмай, кыл һ.б. чыгарыла. Машиналар, станоклар, двигательләр, механизмнар, а.х. кораллары, икмәк әйберләре, чәй, төрле чимал, җирле пр-тиеләр өчен ягулык һ.б.ш. кертелә. 1892 дә К.г.нда (мәктәп һәм мәдрәсәләрдән тыш) — 1238, ш.и. Казанда 101, өязләрдә 1137 (аларның 563е — Халык мәгарифе министрлыгы, калганнары православие дине ведомстволарыныкы) уку йорты исәпләнә. Министрлык уку йортларына 8 шәһәр һәм 3 өяз уч-щесе, Чистай хатын-кызлар прогимназиясе һәм 551 башлангыч уч-ще керә. Аларның 34 е өяз шәһәрләрендә, 529 ы авылларда була. Аларда 800 ләп укытучы эшли, 34,6 меңнән артык бала укый (руслар — 70,3%, чуашлар — 16,6%, марилар — 8,7%, татарлар — 2,6%, мордвалар — 1,2%, удмуртлар — 0,6%). Православие ведомствосы уку йортларына түбәндәгеләр керә: 2 ир-атлар рухани уч-щесе, 448 чиркәү-приход мәктәбе һәм башлангыч белем бирү мәктәбе, 124 Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (аларның 12 се шәһәрдә). Аларда 672 укытучы эшли, 20,7 меңнән артык бала укый (руслар — 43%, чуашлар — 39%, татарлар — 9,6%, марилар — 5,3%, мордвалар — 2%, удмуртлар — 1,1%). Мәктәпләр каршында 20 һөнәрчелек сыйныфы, ш.у. 16 уку-тәҗрибә бакчасы, 3 питомник, 12 умартачылык, 50 җиләк-җимеш-яшелчә бакчасы, 3 колмак үстерү кишәрлеге була. Татарлар, нигездә, мәдрәсә һәм мәктәпләрдә укый. 1900 дә алар 814 була, аларда 31 меңләп бала белем ала. Моннан тыш, татар укытучылар мәктәбе (Казан) һәм 12 уч-ще була, аларда 400 ләп ир бала укый. 1913 тә К.г.нда 5 югары уку йорты була (*Казан университеты*, Казан вет. ин-ты (хәзерге *Казан ветеринария медицинасы академиясе*), *Казан югары хатын-кызлар курслары, Казан руханилар академиясе,* Казан укытучылар институты) һәм 3 мең чамасы урта һәм түбән уку йорты, ш.и. 936 мәдрәсә һәм мәктәп (алар арасында: *Казан руханилар семинариясе, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе, Казан татар укытучылар мәктәбе, Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты, «Мөхәммәдия»* мәдрәсәсе). К.г.ның барлык уку йортларында 210 меңләп, ш.и. югары уку йортларында 4 меңнән артык кеше укый. Фәнни җәмгыятьләр (*Казан икътисадчылар җәмгыяте, Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте, Казан табибләр җәмгыяте, Табигыятьчеләр җәмгыяте* һ.б.), китапханәләр (ш.и. «*Көтебханәи исламия*»), Казанда музей учреждениеләре (шәһәр фәнни-сәнәгать музее һ.б.) һәм өяз шәһәрләрендә шәһәр музейлары (берәр), рус һәм татар («*Сәйяр*», *Шәрекъ клубы* һ.б.) театр учреждениеләре эшли. 1906–13 елларда 20 исемнән артык газета һәм журнал, ш.и. «*Казанские губернские ведомости*», «*Йолдыз*», «*Казанский телеграф*», «*Камско-Волжская речь*» г-талары чыга.

1913 тә К.г.нда 5 мең урынга 98 хастаханә (госпитальдан тыш) һәм 50 даруханә, 379 табиб, 251 фельдшер, 99 акушер һәм кендек әбисе, 177 фармацевт, 10 провизор, 73 теш табибе һ.б. исәпләнә. К.г.нда 30 дан артык картлар йорты һәм ятимханә (ш.и. Александра, Мөселман, Николай балалар ятимханәләре) була, аларда 2 меңнән 3 меңгә кадәр бала тәрбияләнә; төрле хәйрия җәмгыятьләре эшли: *Казан шәһәр мөселманнары хәйрия җәмгыяте, Балалар үлеменә каршы көрәш җәмгыяте, Мохтаҗ студентларга ярдәм итү җәмгыяте, Приказчиклар хәйрия җәмгыяте һ.б.*

Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары вакытында К.г. икътисады бөлгенлеккә төшә. Сугышлар икътисади җитештерү механизмының нормаль эшләвен боза, шәһәр б-н авыл, халык хуҗалыгы тармаклары һәм икътисади районнар арасында урнашкан бәйләнешләрне юкка чыгара, тышкы сәүдә элемтәләрен бетерә. Дәүләт финанс учреждениеләренең эшчәнлеге, нигездә, хәрби продукция җитештерүне финанслауга юнәлдерелә. Икътисадта барган процесслар губерна иҗтимагый тормышының күп якларына тискәре тәэсир итә. Алар җәмгыятьнең социаль структурасы, гражданнарның тормыш хәле, аларның аңы кискен үзгәрү б-н бергә туры килә. Губерна халкының төп катлауларында яшәү рәвеше һәм көнкүреш бозыла. Тормыш темпының, аның сыйфатының кискен үзгәрүе, җәмгыятьнең структур яктан үзгәртеп корылуы, мәнфәгатьләр бәрелеше социаль киеренкелек тудыра һәм шәхесне яңа шартларда үз урынын эзләргә этәрә, иҗтимагый-сәяси оешмалар эшчәнлеген активлаштыра. Боларның барысы да социаль кризиска һәм милли мәсьәләнең кискенләшүенә китерә. 1920 дә, татар милли-демократик хәрәкәте лидерларының К.г. терр-ясендә һәм аның янәшәсендәге төбәкләрдә башта Урал-Идел Штаты, аннары Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы төзергә тырышулары уңышсыз тәмамлангач, Татарстан АССР игълан ителә. К.г.ның Казан, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас (Сембер губернасына бирелгән кайбер волостьлардан тыш), Тәтеш, Чистай өязләре һ. б. өязләрнең кайбер волостьлары — Татарстан (к. «*Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы турында» Декрет*), аның Чабаксар, Цивильск, Ядрин өязләре соңрак — Чуаш АССР, Козьмодемьянск һәм Царёвококшайск (1918 дән — Краснококшайск) өязләре Мари АССР составына керә.

К.г. губернаторлары: П.М.Апраксин (1708–13), П.С.Салтыков (1713–19), А.П.Салтыков (1719–24), И.А.фон Менгден (1725), А.П.Волынский (1725–27, 1728–30), В.Н.Зотов (1727–28), М.В.Долгоруков (1730–31), П.И.Мусин-Пушкин (1731–35), А.И.Румянцев (1735–36), С.Д.Голицын (1736–39), А.Г.Загряжский (1741–48), С.Т.Греков (1748–55), Ф.И.Головин (1755–58), В.Б.Тенишев (1758–64), А.Н.Квашнин-Самарин (1764–70), Я.И.фон Брандт (1770–74), П.С.Мещерский (1774–80), И.Б.Бибиков (1780–81); генерал-губернаторлар (наместниклар): П.И.Панин (1774–75), П.С.Мещерский (1780–92), М.И.Кутузов (1793–96), С.И.Маврин (1796),

В.Ю.Соймонов (1822–25), А.Н.Бахметев (1825–28), А.Е.Тимашев (1864–65); наместниклык идарәчеләре: И.Б.Бибиков (1781–83), И.А.Татищев (1783–89), С.М.Баратаев (1789–96); хәрби губернаторлар: П.С.Мещерский (1796–97), Б.П. де Ласси (1797–98), П.П.Пущин (1798–1801); гражданлык губернаторлары: С.М.Баратаев (1796–97), Д.С.Казинский (1797–99), А.И.Муханов (1799–1801), А.А.Аплечеев (1801–02), Н.И.Кацарев (1802–03), Б.А.Мансуров (1803–14), И.А.Толстой (1815–20), П.А.Нилов (1820–23), А.Я.Жмакин (1823–26), О.Ф.Розен (1826–28), И.Г.Жеванов (1829–30), А.К.Пирх (1830–31); гражданлык бүлеге б-н дә идарә итүче хәрби губернаторлар: С.С.Стрекалов (1831–41), С.П.Шипов (1841–46), И.А.Боратынский (1846–50, 1851–57), Е.П.Толстой (1850), П.Ф.Козлянинов (1857–63), М.К.Нарышкин (1863–66); губернаторлар: Н.Я.Скарятин (1866–80), А.К.Гейнс (1880–82), Л.И.Черкасов (1882–84), Н.Е.Андреевский (1884–89), П.А.Полторацкий (1889–1904), П.Ф.Хомутов (1904–05), А.А.Рейнбот (1905–06), М.В.Стрижевский (1906–13), П.М.Боярский (1913–17).

*Әд.:* Казанская губерния // Список населенных мест по сведениям 1859 года. СПб., 1866. Т. 14; Обзор Казанской губернии за ... [1880, 1883–1913] г. К., [1881]–1915; Приволжские города и селения Казанской губернии. К., 1892; Список населенных мест Казанской губернии с кратким описанием их. К., 1893; Казанская губерния // Первая всеобщая перепись Российской империи 1897 г. СПб., 1904. Т. 14; Список начальствующих лиц в городах теперешней Казанской губернии с 1553 г. до образования Казанской губернии в 1708 г., а также губернаторов, наместников, генерал-губернаторов и военных губернаторов, управлявших Казанской губернией с 1708 года по 1908 г. включительно. К., 1908; Описание Казанской губернии. К., 1909; Рабочий класс Татарии (1861–1980 гг.). К., 1981; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма: Соц.-экон. исслед. М., 1984; История Казани. К., 1988. Кн. 1; Зорин А.Н. Уездные города Казанского Поволжья. К., 1989; Республика Татарстан 1920–2000 гг.: Стат. сб. К., 2001; Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ БАЛАЛА́Р ЯТИМХАНӘЛӘРЕ́ ҖӘМӘГА́ТЬ ИДАРӘЧЕЛЕГЕ́ (ПОПЕЧИ́ТЕЛЬЛЕГЕ)**, Балалар ятимханәләре турындагы 1839 ел 27 декабрь нигезләмәсе нигезендә 1843 тә оештырыла. Императрица Мария (Мария Фёдоровна) учреждениеләре ведомствосында тора, Балалар ятимханәләре төп идарәчелегенә буйсына, балалар ятимханәләре б-н үзәкләштерелгән җитәкчелекне гамәлгә ашыра, аларның эшчәнлеген регламентлаштыра. Идарәчелек карамагында ятимханәләр ачу, иганә керүенә һәм тотылуына контрольлек итү, иганәчелек лотереялары оештыру, ятимханәләрнең эш тәртибен раслау мәсьәләләре керә. Вице-губернатор, даими шәрәфле әгъзалар — Казан һәм Зөя архиепископы, гамәли әгъзалар — губерна дворяннар башлыгы, вице-губернатор, дәүләт милке идарәчесе, шәһәр башлыгы; 19 йөз ахырыннан ш.у. халык уч-щеләре директоры һәм губерна земство идарәсе рәисе була. Шәрәфле әгъзалар итеп, гадәттә, иганәчелек эшчәнлеге б-н актив шөгыльләнүчеләр сайлана. Алар арасында В.Ф.Булыгин, Ф.Х.Грахе, В.И.Заусайлов, И.С.Кривоносов, Л.Б.Мандельштам, А.Я.Сәйдәшев, Н.В.Унженин, А.Д.Госманов, Л.К.Хрщонович, А.Г.Хөсәенов, Л.Н.Щербаков була. Идарәчелек утырышлары Губернатор сараенда үтә. 1917 елда бетерелә.

*Әд.:* Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ ҖАВАПЛЫ́ БАШКАРУ́ КОМИТЕТЫ́**, губерна адм. учреждениесе. Россия Дәүләт Советының 1874 елның 10 декабрендә император Александр II тарафыннан расланган карары нигезендә оештырыла. Гаскәрләрне фатир б-н тәэмин итүгә, биналарны хак түләп вакытлыча файдалануга алуга, төзекләндерүгә, төзүгә, җылытуга һәм яктыртуга каралган чыгымнарга кагылышлы мәсьәләләр б-н шөгыльләнә. Составына губернатор (рәис), губерна дворяннар башлыгы, казна палатасы управляющие, Казан шәһәре башлыгы, губерна земство идарәсе рәисе керә. К.г.җ.б.к. исправниклар рәислегендәге өяз җаваплы башкару ком-тлары б-н җитәкчелек итә. Россия Финанс һәм Эчке эшләр министрлыкларына буйсына. 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң эшләүдән туктый.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1876. Т. 49. отд. 2. № 54144.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ ҖӘМГЫЯТЬЛӘ́Р ЭШЛӘРЕ́ КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасында җәмгыятьләр һәм берлекләр эшчәнлеген күзәтчелек итүче адм. учреждение. 1906 елның 7 мартында кабул ителгән «Вакытлы кагыйдәләр» нигезендә оештырыла. Аның составына губернатор (рәис), вице-губернатор, губерна дворяннары башлыгы, губерна земство идарәсе рәисе, губерна земство җыены вәкиле, Казан шәһәр башлыгы керә. Җәмгать оешмаларының программа документларын һәм уставларын терки, аларның эшчәнлеген контрольдә тота. Губернатор кушуы буенча җәмгыятьнең ачылуына кагылышлы эш алдан карала. Рәис кабулханә карарының башкарылуын туктатып торып, эшне эчке эшләр министрына тапшыру хокукына ия була. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 12 апрель һәм 21 июнь карарлары б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1909. Т. 26, отд. 1. № 27479.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ КАЗНА́ ПАЛА́ТАСЫ**, к. *Казна палатасы.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ КАНЦЕЛЯ́РИЯСЕ**, Казан губернасында хакимиятнең адм.-хәрби һәм мәхкәмә-полиция органы. Пётр I нең 1708 ел 1 декабрь Фәрманы нигезендә оештырыла, 1709 ның гыйнварыннан эшли башлый. Губернаның башка учреждениеләре өчен югары инстанция булып тора, хокук тәртибе нормаларын саклауны, халык санын исәпкә алуны, төрле катлауларның бурычларын һәм үзидарәне, салымнарның вакытында керүен, төбәкне төзекләндерү чараларын контрольдә тота, 1727 елдан ш.у. Казанда һәм Казан өязендә мәхкәмә эшләрен алып бара, түбән инстанцияләр карарларына дәгъвалар кабул итә, аларның үлем җәзасы турындагы карарларын раслый. Баштарак — приказ йортлары, обер-комендант һәм земство канцелярияләре, соңрак провинция һәм воеводство канцелярияләре б-н җитәкчелек итә. К.г.к. югары органнарның карарлары нигезендә конкрет күрсәтмәләр эшли, аларның үтәлүен контрольдә тота, Сенат һәм коллегияләр алдында хисап бирә, үз чиратында, буйсынган учреждениеләрдән рапортлар һәм беркетмәләр ала. Моннан тыш, К.г.к. сугыш вакытында яки күчмә халыклар яу б-н килгәндә губернаны саклауны оештыруда, халык чуалышларын бастыруда, эпидемияләргә каршы көрәштә, гадәттән тыш хәлләр б-н бәйле эшләрне җайга салуда төп рольне уйный; рекрутлар җыюда, армияне тәэмин итүдә, дворяннар хезмәтен күзәтүдә, богаулы тоткыннарны озатуда, хөкүмәт комиссияләренә ярдәм итүдә һ.б. төп йөкне тарта. Составы: губернатор (рәис), аның иптәшләре (урынбасарлар), прокурордан торган идарә; сәркәтипләр, беркетмә язучылар, теркәүче, архивариус, канцелярия хезмәткәрләре, канцелярия хезмәткәрләре ярдәмчеләре, төпләүчеләр, өйрәнчек, тәрҗемәче, каравылчылар, палач кергән канцелярия һәм хәрби контингент (барлыгы 130 дан артык кеше). Сенатның 1780 ел 28 сентябрь карары нигезендә 1775 елгы Губерна реформасы үткәрелү уңаеннан бетерелә, аның вазифалары *Казан наместниклык идарәсенә* бирелә.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ КҮЗӘТҮ́-ТИКШЕРҮ́ ПАЛА́ТАСЫ**, дәүләт финанс контроле органы. Россия Дәүләт советының 1865 ел 22 ноябрь карарын император Александр II раславына нигезләнеп оештырыла, 1866 ның 1 гыйнварында ачыла. Дәүләт контролёры һәм Россия Дәүләт контроле советына буйсына. Беренчел финанс документлары буенча хисап бирүне тикшерә, кануннарны дөрес куллануга, губерналардагы дәүләт пр-тиеләре һәм учреждениеләренең акча средстволарын тотуының законлылыгына һәм дөреслегенә күзәтчелек итә, казначейлыкка, кассаларга һәм барлык җирле акча әйләнешләренә ревизия ясый. Кирәк булса, үз вәкилләрен казна палатасының гомуми кабулханәләренә җибәрә, Дәүләт күзәтү-тикшерү үзәк органнары кушуы буенча сметалар һ.б. финанс материалларын карауда катнаша. Түбәндәге бүлекчәләре була: акциз; урман һәм халык мәгарифе; юллар; эчке эшләр, юстиция һәм дәүләт контроле органнары; почта; азык-төлек; Финанс, сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы органнары; артиллерия һәм инженерия; акча;

мөлкәтләр; фактик ревизия; сәркәтиплек бүлеге. К.г.к-т.п.на түбәндәгеләр керә: идарәче, аның ярдәмчесе, өлкән һәм кече ревизорлар, исәп-хисап ясау түрәләре һ.б. (барлыгы 80 кеше, 1913). Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советының 1918 ел 10 март карары һәм РСФСР ХКСның 1918 ел 1 ноябрь Декреты нигезендә бетерелә.

*Әд.:* К о н я е в А. Финансовый контроль в дореволюционной России. М., 1959.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ МАГИСТРАТЫ́**, посад халкы б-н идарә итүче губерна органы, 1781 елдан губерна мәхкәмә учреждениесе. Пётр I нең 1720 ел 15 февраль Фәрманы нигезендә Казан шәһәре магистраты буларак оештырыла, Сенатның императрица Елизавета Петровна раслаган 1743 ел 21 май доклады б-н К.г.м. итеп үзгәртелә. Баштарак түбәндәгеләр б-н шөгыльләнә: посадтан барлык төр салымнар һәм җыемнар керүне тәэмин итә; посад кешеләрен исәпкә ала, аларны йөкләмә-бурычларны, казна һәм гражданлык хезмәтләрен үтәргә мәҗбүр итә; алар өстеннән «мәхкәмә һәм җәза» оештыра, шәһәрне төзекләндерү чаралары үткәрә; җирле сәүдәгәрләрнең күчмә халыклар б-н сәүдә итүен җайга сала һәм 1743 тән провинция һәм шәһәр магистратларына контрольлек итә, аларның мәхкәмә карарларын тикшерә һ.б. Аңа түбәндәгеләр керә: бурмистрлар, ратманнар, сәркәтипләр, беркетмә язучылар, бухгалтерлар, тәрҗемәчеләр, канцелярия хезмәткәрләре, канцелярия хезмәткәрләре ярдәмчеләре, күчермә алучылар, каравылчы, йомышчы, солдатлар (барлыгы 100 дән артык кеше) составындагы идарә һәм канцелярия. Казан губернасы канцеляриясенә һәм Россиянең Баш магистратына буйсына. 1775 елгы Губерна реформасы үткәрү һәм 1781 нең 27 декабрендә «яңа» К.г.м. ачу нәтиҗәсендә бетерелә. Соңгысы губернадагы шәһәр халкының адм.-мәхкәмә, полиция һәм финанс мәсьәләләре, ш.и. өстенлекләр һәм бәхәсле биләмәләр, контрактлар һәм купчийлар, түбән инстанцияләрнең эш-гамәлләренә шикаятьләр, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, мещаннарның башка төрле гражданлык һәм җинаять эшләре б-н шөгыльләнә. Шәһәр магистратлары һәм ратушалары, ятимнәр мәхкәмәләре, 1785 тән шәһәрләр һәм алты тавышлы думалар б-н җитәкчелек итә. Аңа гражданлык һәм җинаять эшләре департаментлары керә (һәрберсенең составында Сенат раслаган рәис, сәүдәгәр һәм мещаннардан 3 елга сайланган наместниклар яки идарәчеләре раслаган 3 утырышчы була). Сессия тәртибендә эшли: 1 нче сессия — 4 ай чамасы, 2 нчесе — 1, 3 нчесе — 2 ай чамасы. Казан губерна идарәсенә, гражданлык һәм җинаятьләр мәхкәмәсе палатасына буйсына. 1796 ның 31 декабрендә бетерелә.

*Әд.:* Д и т я т и н И.И. Устройство и управление городов России. СПб., 1875. Т. 1; К и р и л о в И.К. Цветущее состояние Всероссийского государства. М., 1977; Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ МӨСЕЛМА́Н КРӘСТИЯННӘРЕ́ КОРЫЛТАЕ́**, 1917 елның 3–7 июнендә Казанда эшли. 600 дән артык делегат. Крәстиян депутатларының Казан советы, Мөселман социалистлар ком-ты, Мөселманнар ком-ты, Хәрби Шура тәкъдиме б-н чакырыла. Корылтайда түбәндәге мәсьәләләр карала: җирдән файдалану (крәстиян депутатлары Казан советының шәхси кулланудагы җирләрне крәстиян җәмәгатьләренә бирү турындагы 1917 ел 13 май карарын хуплый), халык мәгарифе (ш.и. Казанда татарлар өчен Халык ун-ты оештыру), мәхәллә муллалары һ.б.; мөселман крәстияннәрне оештыру һәм Казан губерна мөселманнар ком-тына сайлаулар үткәрү өчен махсус башкарма комиссия төзелә.

*Әд.:* Г р а ч ё в Е. Казанский Октябрь. К., 1926; И о н е н к о И.М., Т а г и р о в И.Р. Октябрь в Казани. К., 1967.

*С.И.Ионенко.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ САЛЫ́М КАБУЛХАНӘСЕ́**, губерна финанс учреждениесе. 1885 елның 15 гыйнварында кабул ителгән «Сәүдә һәм сәнәгать предприятиеләренә өстәмә салым салу турында кагыйдәләр», нигезендә оештырыла. Казан губернасына билгеләнгән өстәмә салымны өязләр арасында бүлә һәм аларның өязләрдәге пр-тиеләр буенча бүленүен раслый. Составына управляющий (рәис), казна палатасының махсус кабулханәсе әгъзалары һәм гильдия пошлиналары түләүче 6 кеше (губерна земство җыены, Казан шәһәр думасы һәм сәүдәгәрләр җәмгыяте тарафыннан 3 елга сайланалар) керә. Аңа өяз һәм шәһәр салым кабулханәләре буйсына. К.г.с.к.нең карарларын губернатор раслый, риза булмаган очракта ул үзенең фикерләрен Россия финанс министрлыгына җиткерә. 1898 нең 8 июнендә кабул ителгән Дәүләт кәсәбәчелек салымы турындагы нигезләмә б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1887. Т. 5. № 2664; 1901. Т. 18. № 15601.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ СТАТИ́СТИКА КОМИТЕТЫ́**, Казан губернасының икътисади, хуҗалык һәм мәдәни тормышы турындагы стат. мәгълүматларны җыючы, тикшерүче һәм эшкәртүче адм. орган. Сенатның 1834 ел 20 декабрь фәрманы нигезендә оештырыла һәм 1835 нең 17 сентябрендә ачыла. Статистика мәгълүматларны җыю һәм тәртипкә китерү, исемлекләр төзү, губерна һәм шәһәрләрне топографик, сәнәгый, а.х. һ.б. яктан тасвирлау б-н шөгыльләнә. Төп эше губерна хисапларына теркәлүче күзәтүләр әзерләүдән, белешмә китаплары һәм адрес-календарьлар нәшер итүдән гыйбарәт була. 1860 ның 26 декабрендә кабул ителгән Нигезләмәдә каралганча, составына губернатор (рәис), рәис ярдәмчесе (гомуми җыелышта 3 елга сайлана), секретарь (ком-т эшләрен алып бара), даими әгъзалар — губерна дворяннар башлыгы, вице-губернатор, җирле хакимиятнең төрле тармаклар: финанс, дәүләт милке, аралашу юллары, тау эшләре, уделлар, мед., халык мәгарифе, руханият ведомстволары вәкилләре, ш.у. Казан шәһәре башлыгы (һәрберсенә идарәнең алар карамагындагы өлешләре буенча стат. мәгълүматлар тапшыру йөкләнә), хакыйкый әгъзалар (стат. өлкәсендәге белемнәргә ия, рухани, гыйльми һ.б. дәрәҗәләре булган затлар арасыннан, ш.у. өяз дворяннары башлыкларыннан сайланалар; аларның вазифалары: стат. мәгълүматлар җыю, губерна тасвирламаларын төзү һәм нәшер итү, экспедицияләр оештыру һ.б.) һәм шәрәфле әгъзалар (тумышлары б-н губернадан булган кешеләр, күчемсез милек хуҗалары, ш.у. үзләренең стат. хезмәтләре б-н танылган яки зур күләмдә иганә кылган затлар арасыннан сайланалар) керә. К.г.с.к. эшкә губерна җир үлчәүчеләрен, архитекторларын, топографларын һ.б. белгечләрне җәлеп итә алган. Зарурлык булганда губернатор билгеләве буенча ком-тның җыелышлары һәм башкарылган эше турындагы хисапны тикшерү өчен ел саен гомуми җыелыш уздырыла. Эчке эшләр министрлыгының стат.бүлегенә, 1858 дән — Россиянең Үзәк стат. ком-тына буйсына. РСФСР ХКСның 1918 ел 15 сентябрь Декреты б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1835. Т. 9, отд. 2. № 7685; 1838. Т. 12, отд. 1. № 10303; 1862. Т. 35, отд. 2. № 36453.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫ ЭШЧЕ́, КРӘСТИЯ́Н ҺӘМ КЫЗЫЛА́РМИЯЧЕ ДЕПУТАТЛАРЫ́ СОВЕТЫ́ БАШКАРМА́ КОМИТЕТЫ́**, Казан губернасында дәүләт хакимияте органы. 1917 елның 2 мартында Эшче депутатлары Казан советы, 10 мартында Солдат депутатлары советы һәм 1917 нең 8 маенда Крәстиян депутатлары советы тарафыннан әлеге советларның башкарма ком-тлары сайлана. 1917 нең 16 ноябрендә Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Казан советының, 1918 нең 17 июленнән — Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының бердәм губерна башкарма ком-ты оештырыла. Ул советларның губерна съездлары арасында уртак идарәнең коллектив органы булып тора. Совет хакимиятенең гомумроссия органнары декретларын һәм карарларын тормышка ашыру, агымдагы идарә б-н шөгыльләнә; крәстияннәргә җир бүлеп бирә; Кызыл Армия частьләрен оештыра; халык мәхкәмәләрен булдыра; җитештерү һәм продукциянең бүленешенә эшче контроле кертә; сәнәгать пр-тиеләрен һәм банкларны национализацияли; авыл ярлылары ком-тлары (комбедлар) төзи; губерна терр-ясендәге барлык советлар эшчәнлеген контрольдә тота һ.б. Губерна башкарма ком-ты (25–30 әгъзадан тора) түбәндәге составта эш итә: президент (рәис), рәис урынбасары (урынбасары) һәм 1–3 әгъза; пленум; җирле идарә, юстиция, социаль тәэминат, сәламәтлек саклау, иген-

челек, хезмәт, мәгариф, халык элемтәләре, эшче-крәстиян инспекцияләре, милләтләр эшләре, финанс, ветеринария, коммуналь бүлекләр; ХХС; стат. бюросы; азык-төлек ком-ты; хәрби комис-т; торак-җир советы; дәүләт корылмалары ком-ты һ.б. Советларның губерна съезды каршында, 1919 дан — БҮБК һәм РСФСР ХКС алдында җаваплы була. 1918 нең февраль-маенда үз вәкаләтләрен *Казан Совет Эшче-Крәстиян Республикасына*, 1920 елның 27 маеннан — *Татарстан АССР Советларының Беренче (Оештыру) съезды* чакырылышына кадәр *Вакытлы революцион комитетка* тапшыра.

Рәисләре: Я.С.Шейнкман (1917–1918 нең августы), И.С.Вегер (1918 нең сентябрь–декабре), Д.П.Малютин (1918 нең декабре — 1919 ның декабре), И.И.Ходоровский (1919 ның декабре — 1920).

Чыг.: Татария в борьбе за победу пролетарской революции (февраль–октябрь 1917 г.): Сб. док. и материалов. К., 1957; Образование Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1963; Упрочение Советской власти в Татарии (октябрь 1917 — июль 1918 гг.): Сб. док. и материалов. К., 1964; Деятельность Советов Татарии (1917–1978): Док. и материалы. К., 1983.

*Әд.:* Бродович С.М. Губернские съезды Советов и Губисполкома. М., 1928; Андрианов Н.А. Восстановление Советской власти и укрепление её аппарата в Татарии (1918–1920 гг.). К., 1962; Андрианов Н.А., Толстяков К.А. Становление и упрочение власти Советов в Татарии. К., 1967; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ ЖАНДА́РМНАР ИДАРӘСЕ́**, хәрби оешмасы булган җирле сәяси полиция органы. Император Николай I нең 1827 ел 28 апрель Фәрманы б-н Казан штаб-офицер жандармнар идарәсе буларак оеша; Жандармнар корпусы турындагы 1867 ел 9 сентябрь Нигезләмәсе б-н К.г.ж.и. итеп үзгәртелә. Саклау вазифаларын башкара, революцион һәм оппозицион хәрәкәткә каршы көрәшә, чуалышларны бастыра, дәүләт җинаятьләре турындагы эшләр буенча сорау алулар үткәрә, мәхкәмәнең хөкем карарларын үти, хөкем ителгәннәрне озатып бара, 1871 дән сәяси эшләрне тикшерү б-н дә шөгыльләнә. 1917 елгы инструкция буенча идарәгә ш. у. җирле халыкны үзләренә белдермичә генә күзәтеп тору, губернага башка терр-ядән килгән затларны күзәтү; хакимият әзәрлекләвеннән качып йөргән кешеләрне эзләү; полициягә җәмәгать тәртибен саклауда ярдәм күрсәтү; *Казан саклау бүлегенә* агентура мәгълүматлары бирү һәм сорау алулар уздырганда аның б-н хезмәттәшлек итү; чит ил шпионнарына каршы көрәш йөкләнә. 5 бүлекне үз эченә ала: гомуми җитәкчелек; эзләү, тикшерү, сәяси тотрыклылык, акча. 20 гасыр башында идарә составына башлык, 2 ярдәмче, адъютант, писерләр, вахмистрлар, унтер-офицерлар (барлыгы 46 кеше, 1904) керә. Жандармнарның аерым корпусы штабына һәм Император галиҗәнәпләре канцеляриясенең III бүлекчәсенә, 1881 дән — Полиция департаментына буйсына. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 10 март карары б-н таратыла.

*Әд.:* к. Казан хәрби *округ мәхкәмәсе.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ ҖИР ЭШЛӘРЕ́ ҺӘМ ДӘҮЛӘ́Т МИЛКЕ́ ИДАРӘСЕ́**, җирле адм. учреждение. Император Николай I нең 1838 ел 21 ноябрь Фәрманы нигезендә оештырыла һәм 1839 елның 2 гыйнварында дәүләт милкенең Казан палатасы буларак ачыла; Александр II нең 1866 ел 22 декабрь Фәрманы нигезендә — дәүләт милкенең Казан губернасы идарәсе, император Николай II нең 1902 ел 2 июнь Фәрманы нигезендә К.г.җ.э.һ.д.м.и. итеп үзгәртелә. Баштарак — дәүләт крәстияннәре һәм дәүләт милке б-н, 1866 дан җирләр, урманнар, җир асты байлыклары, урманчылыклар, казна утарлары һәм алардан мөмкин кадәр керем алу б-н идарә итә, ш. у. а.х. өлкәсендәге камилләштерүләргә күзәтчелекне тормышка ашыра. Аның составында идарәче, аның ярдәмчесе, аерым йөкләмәләрне үтәүче түрә, а.х. инспекторлары, урман ревизорлары, эш башкаручылар була. Аңа канцелярия, гомуми, урман, а.х., бухгалтерия, мәхкәмә, инженер-гидротехник бүлекләр керә. 1912 ел 25 июнь Фәрманы б-н Идарә каршында идарәче (рәис), урман ревизорлары һәм урман төзелеше ревизорлары составында Урман советы оештырыла. Ул Дәүләт милке министрлыгына, 1894 тән — Җир эшләре һәм дәүләт милке министрлыгына, 1905 тән — Россия Җир төзелеше һәм җир эшләре баш идарәсенә буйсына. 1918 нең 25 октябрендә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының Казан губернасы башкарма ком-ты карары нигезендә бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1839. Т. 13, отд. 2. № 11754; 1869. Т. 41, отд. 2. № 44024.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения; сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1 .

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ ЗЕ́МСТВО ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕ́ (ҮТӘМӘЛӘРЕ́) КОМИТЕТЫ́**, губерна адм. учреждениесе. 1851 елның 13 июлендә кабул ителгән «Земство йөкләмәләренең яңа тәртибе кагыйдәләре» нигезендә оештырыла. Составына губернатор (рәис), губерна һәм өяз дворяннары башлыклары, казна палатасы, уделлар конторасы һәм дәүләт милке палатасы (1866 дан — губерна идарәсе) управляющийлары, Казан шәһәре башлыгы, дворяннардан, өяз шәһәрләреннән сайланган депутатлар һәм 1867 дән губерна земство идарәсеннән вәкилләр керә. Дәүләт учреждениеләре һәм төрмә биналары корылышы, рекрутлар кабулханәләре өчен хак түләп вакытлыча файдалануга бүлмәләр алу, бүлмәләрне җылыту һәм яктырту, хуҗалык һәм мед. ярдәме күрсәтү һ.б. б-н бәйле земство йөкләмәләренең үтәлеше б-н идарә итә. Гомуми кабулханә керемнәр һәм чыгымнарның исәп проектларын төзи һәм җыемнарны губерна йөкләмәләре буенча бүлә. Аерым җыемнар өязләрдә уза: аларда сәүдә һәм сәнәгать б-н шөгыльләнүгә бирелгән таныклыклар, керем китерүче җирләрнең, урманнар һ.б. биләмәләрнең исәбе, салым түләүчеләрнең катлаулар буенча саны, натураль һ.б. земство йөкләмәләре турында 3 ел эчендә һәр торак пункттан җыелган мәгълүматлар тикшерелә. Аерым кабулханәләр тарафыннан җыелган мәгълүматлар һәм тәкъдимнәр губернаторга тапшырыла, губернатор аларны, җыемнар турындагы хисаплар б-н бергә, тикшерү өчен гомуми кабулханә каравына кертә. Финанс, Эчке эшләр, Дәүләт милке, Патша сарае һәм уделлар министрлыкларына буйсына. Россия Дәүләт Советының 1874 нең 10 декабрендә император Александр II тарафыннан расланган карар б-н бетерелә, вазифалары *Казан губернасы җаваплы башкару комитетына* тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1852. Т. 26. № 25398; 1871. Т. 42, отд. 1. № 44454; 1876. Т. 49, отд. 2. № 54144.

*Әд.:* К. Казан губернасының җир эшләре һәм дәүләт милке идарәсе.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ ЗЕ́МСТВО ҺӘМ ШӘҺӘ́Р ЭШЛӘРЕ́ КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасында җәмәгать үзидарәсенә күзәтчелек итүче адм. учреждение, 1890 елның 12 июнендә кабул ителгән «Земство учреждениеләре турында нигезләмә» б-н Казан губернасының земство эшләре кабулханәсе буларак оештырыла. Земство учреждениеләре гамәлләренең законлылыгын һәм максатка ярашлылыгын күзәтә. Составына губернатор (рәис), вице-губернатор, губерна дворяннар башлыгы, казна палатасы управляющие, округ мәхкәмәсе прокуроры, губерна земство идарәсе рәисе һәм губерна земство җыены вәкиле керә. Законга каршы килгән очракта губернатор земство җыенының теләсә кайсы карарының үтәлешен туктатып торып, аны кабулханә каравына тапшыру хокукына ия булган, кабулханә карарны юкка чыгара яки гамәлгә кертә алган. 1892 нең 11 июнендә кабул ителгән «Шәһәр нигезләмәсе» б-н кабулханә К.г.з.һ.ш.э.к. итеп үзгәртелә. Аның составына Казан шәһәре башлыгы кертелә. Земство һәм шәһәр үзидарәләре күрсәтмәләренең дөреслеген һәм законлылыгын тикшерә; губернатор искәрмәләре һәм аерым затларның шикаятьләре буенча сайлау исемлекләренә төзәтмәләр кертә; сайлауларның дөреслеген, земство җыелышлары һәм шәһәр думалары тарафыннан аерым затларның, җәмгыятьләрнең һ.б. учреждениеләрнең хокуклары бозылу турындагы шикаятьләрне, ш.у. вазифаи затларның җаваплылыгы турындагы эшләрне карый, өяз земство әгъзаларына дисциплинар җәзалар билгели һәм аларны мәхкәмә каравына тапшыра. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 8 июль карары б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1893. Т. 10, отд. 1. № 6927; 1895. Т. 12. № 8708.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ КӘСӘБЧЕЛЕ́К САЛЫМЫ́ КАБУЛХАНӘСЕ́**, губер-

на финанс учреждениесе. 1898 елның 8 июнендә кабул ителгән Дәүләт кәсәбәчелек салымы турындагы нигезләмә б-н оештырыла. Казна палатасының һәм аның дәүләт кәсәбәчелек салымы кабулханәсенең карарларына карата белдерелгән шикаятьләрен карау өчен апелляция инстанциясе булып тора. Кабулханә составына губернатор (рәис), вице-губернатор, казна палатасы һәм акциз җыемнары управляющийлары, округ мәхкәмәсе прокуроры, губерна земство идарәсе рәисе, шәһәр башлыгы һәм 2 эшмәкәр (земство җыены һәм Казан шәһәр думасы тарафыннан 4 елга сайлана) керә. Кабулханәнең утырышларын, зарурлыгына карап, губернатор билгели, эшләр күпчелек тавыш б-н хәл ителә. Финанс министрлыгының Сәүдә һәм мануфактуралар департаментына буйсына. РСФСР ХКСның 1918 ел 1 ноябрь Декреты б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1901. Т. 18. № 15601.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ КРӘСТИЯ́Н ЭШЛӘРЕ́ КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасында 1861 елгы Крәстиян реформасын уздыру буенча адм. орган. 1861 елның 19 февралендә кабул ителгән «Крәстиян эшләре буенча губерна һәм өяз учреждениеләре турында»гы нигезләмә б-н оештырыла. Җәмәгать арадашчылары һәм өяз җәмәгать съездлары гамәлләренә карата белдерелгән шикаятьләрне карый, авылларны волостьлар буенча билгеләү проектларын, алпавытлар һәм вакытлыча бурычлы крәстияннәр арасындагы ирекле килешүләрне, җәмәгать арадашчыларының утар кешеләрен кичекмәстән эштән азат итү турындагы хөкем карарларын раслый, җан башына бирелгән имана зурлыгыннан чыгып, җирләрнең чикләрен билгели, документлар төзүгә күзәтчелек итә, устав грамоталарын һәм ш.у. крәстиян йөкләмәләренең күләмнәре үзгәрү турындагы эшләрне карый һәм раслый. 1861 елгы Крәстиян реформасын гамәлгә ашыру буенча җирле кагыйдәләрне эшли, кагыйдәләр һәм нормалар җыентыгын төзи; җирне сатып алу барышын контрольдә тота; җирләр алмашу һәм чикләү, казна җирләрен крәстиян имана җирләренә алышу буенча килешүләрне раслый. 1874 ел 27 июнь нигезләмәсе буенча өяз крәстиян эшләре кабулханәләрен җитәкли, аларга карата җирле мәхкәмә-адм. органы һәм апелляция инстанциясе статусына ия була. Кабулханә составына губерна дворяннар башлыгы, Дәүләт милке палатасы (1866 дан — губерна дәүләт милке идарәсе) управляющие, губерна прокуроры (1870 тән округ мәхкәмәсе прокуроры), 4 җирле җирбиләүче, казна палатасы (крәстияннәрнең имана җирләрен сатып алуы эшләре буенча) управляющие керә.

Кабулханәгә секретарьлар, эш башкаручылар хезмәт күрсәтә. 1874 тән дворян-җирбиләүчеләр урынына губерна земство идарәсе һәм казна палатасы вәкилләре, ш.у. хөкүмәт тарафыннан билгеләнүче даими әгъза кертелә. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. 1889 ның 12 июлендә кабул ителгән «Земство участок башлыклары турындагы нигезләмә» һәм Россия Дәүләт Советының 1891 нең 16 июнендә император Александр III тарафыннан расланган карары нигезендә бетерелә, вазифалары *Казан губерна кабулханәсенә* тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1863. Т. 36, отд. 1. № 36660; Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1894. Т. 11. № 7775.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ ФА́БРИКА ЭШЛӘРЕ́ КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губерна фабрикаларында һәм заводларында эшчеләргә кагылышлы законнарның үтәлешенә күзәтчелек итүче адм. учреждение. Россия Дәүләт Советының 1897 елның 2 июнендә император Николай II тарафыннан расланган карары нигезендә оештырыла, 1897 нең 1 июлендә ачыла. Эшчеләргә исәп-хисап кенәгәләрен бирү тәртибен бозулар һәм аларны дөрес тутырмау, эшчеләрнең паспортларын саклау һәм аларның һәрберсе күрсәтелгән исемлекләрне төзү, фабрика кибетләре ачылу һәм алардагы сәүдә турындагы эшләрне карый: фабрика инспекциясе б-н җитәкчелек итә; төнге һәм эш вакытыннан тыш хезмәтне законнар нигезендә рәсмиләштерүгә вакытлыча үзгәрешләр кертүгә ризалык бирә һ.б. Кабулханә фабрикантлар һәм эшчеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләүче өстәмә кагыйдәләр чыгарырга хокуклы була, капиталистларның фабрика инспекциясе карарларына карата белдерелгән шикаятьләрен тикшерә. Кабулханә составына губернатор (рәис), вице-губернатор, округның мәхкәмәсе прокуроры, губерна жандармнар идарәсе башлыгы, округ фабрика инспекторы, губерна земство идарәсе рәисе, Казан шәһәре башлыгы, 2 фабрикант керә. Финанс министрлыгына буйсына. ХКСның 1918 ел 18 май Декреты б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1900. Т. 17. № 14232.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕ́РНАСЫНЫҢ ШӘҺӘ́Р ЭШЛӘРЕ́ КАБУЛХАНӘСЕ́**, Казан губернасында шәһәр үзидарә органнарына күзәтчелек итүче адм. учреждение. 1870 елның 16 июнендә кабул ителгән «Шәһәр нигезләмәсе» б-н оештырыла. Шәһәр җәмәгать идарәләре карарларының законлылыгын, аларга карата, ш.у. вазифаи затларның дөрес сайланмавына карата дәгъва белдергән шикаятьләрне карый, җирле полиция идарәләре б-н ике арадагы бәхәсләрне һ.б. хәл итә. Составына губернатор (рәис), вице-губернатор, казна палатасы управляющие, округ мәхкәмәсе прокуроры, җәмәгать съезды һәм губерна земство идарәсе рәисләре, Казан шәһәре башлыгы керә. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. 1892 нең 11 июнендә кабул ителгән «Шәһәр нигезләмәсе» б-н бетерелә, вазифалары *Казан губернасының земство һәм шәһәр эшләре кабулханәсенә* тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1874. Т. 45, отд. 1. № 48498; Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1895. Т. 12. № 8708.

*Әд.:* к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ГУБЕРНА́ТОРЫ КАНЦЕЛЯ́РИЯСЕ**, башкарма орган. 1775 елда Губерна реформасы уздыру нәтиҗәсендә оештырыла, императорлар Павел I нең 1800 ел 18 февраль, Александр I нең 1803 ел 21 апрель Фәрманнары б-н үзгәртеп корыла. Казан губернасының адм., хуҗалык, финанс (1871 гә кадәр мәхкәмә) учреждениеләре эшләренә күзәтчелек итә, хезмәткә кагылышлы язышулар һәм губернаторның агымдагы документларын рәсмиләштерү б-н шөгыльләнә. 19 йөздә — башкару, хисаплау, земство, шәһәр, тышкы эшләр, яшерен эшләр, цензура, гражданнар эшләре, җинаять эшләре өстәлләрен; 20 йөз башында 3 бүлекне (1 нче бүлек — башкару, бүлү, бурычлар, сәүдә, пенсия өстәлләре; 2 нче бүлек — хезмәт хакы, керемнәр салымы, фатирлар, ревизия, герб, мирас өстәлләре; 3 нче бүлек — касса, табышлар, чыгымнар өстәлләре) үз эченә ала. К.г.к. составына: канцелярия идарәчесе, өлкән һәм кече ярдәмчеләр, махсус йомышлар башкаручы чиновниклар, теркәүче, курьерлар һ.б. (барлыгы 20 кеше чамасы; 1915) керә. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 19 сентябрь карары нигезендә бетерелә.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII в. // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и в раннее новое время. М., 1996.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ДАРЫ́ ЗАВОДЫ́**, Татарстан Республикасында хәзергәчә эшләп килүче казна дәүләт пр-тиеләренең иң элеккесе. РФдә пироксилинлы дарылар һәм төрле максатлар өчен билгеләнгән дарылы ату зарядлары әзерләү һәм эшләп чыгару буенча әйдәп баручыларның берсе. Төркия б-н сугышка әзерлеккә бәйле рәвештә, Екатерина II нең Махсус фәрманы б-н, Казан дары з-ды буларак, 1786 елда төзелә башлый. Артиллерия һәм фортификация баш коллегиясе карамагында була, 1804 тән Хәрби министрлыкка карый. Казан янындагы Ягодный авылында 46 дис. җирдә 20 дән артык производство бинасы, ш.и. ат көченә көйләнгән 5 бегун (авыр тегермән ташлары) ф-касы төзелә. 1788 нең 24 июнендә завод тулы көченә эшли башлый, шул ук елда 5,5 мең потка якын дары бирә. Баштарак туп, мушкет һәм винтовка өчен төтенле (кара) дарының 3 сорты чыгарыла. Дарыны бегуннар астында вакланган селитра, күкерт һәм агач күмереннән алалар, анналары алар агач мичкәләрдә катнаштырыла, бөртекләнеп тыгызлана һәм ялтыратыла. Нигездә җирле чимал файдаланыла. Завод бары җәйге чорда гына эшли, чөнки янгын куркынычы булу сәбәпле, агылмый һәм яктыртылмый. Соңрак елларда киңәюен дәвам итә һәм эшләп чыгару күләмнәрен арттыра, сугышлар барганда иң зур күләмгә ирешелә: рус-француз сугышы вакытында (1798–1814) елына 30 мең потка кадәр, Кырым сугышы чорында (1853–56) елына 60 мең потка кадәр дары җитештерелә. 1870 еллар башында рек-

рут бурычын үтәтүгә нигезләнгән мәҗбүри хезмәттән ирекле яллы хезмәт куллануга күчә. 1885–88 дә электрлаштырыла (губерна сәнәгатендә беренче булып), механик җиһазлар б-н тәэмин ителә, барлык производство биналары кирпечтән салына; эшләүчеләр саны 550 кешегә җитә. Заводның 100 еллыгы уңаеннан завод архитекторы И.П.Котелов проекты буенча Баш капка корыла, соңрак ул *Юбилей а́ркасы* («Кызыл капка») атамасын ала. Армия һәм флотны яңартып коралландыруга бәйле рәвештә, 1891–94 тәге тамырдан үзгәртеп корудан соң, завод нитроцеллюлозадан (пироксилиннан) тагын да куәтлерәк төтенсез дары җитештерүгә күчә. Завод составында пироксилин һәм дары бүлекләре оештырыла. Технологик процесс азот кислотасы һәм эфирлар алудан тора. Күкерт кислотасы б-н *Казан химия заводы Ушков П.К. һәм К$^o$* тәэмин итә.

Беренче бөтендөнья сугышы чорында завод Россия армиясе тарафыннан кулланылган дарының иң зур өлешен җитештерә. 1916 да анда 10 меңгә якын кеше эшли, 271 мең пот продукция эшләп чыгарыла. 1915–17 дә проект егәрлеге елына 168 мең пот булган 2 нче завод төзелә. 1917 нең августында иске завод янгын нәтиҗәсендә юкка чыга. Гражданнар сугышы елларында пр-тие Кызыл Армияне дары б-н бердәнбер тәэмин итүче булып кала. 1922 дә ул «В.И.Ленин исемендәге Казан дәүләт дары заводы» исемен ала, 1927 дән — В.И.Ленин исем. 40 нчы завод. Масштаблы төзелеш һәм иң яңа (ш.и. чит илдән кертелгән) югары җитештерүчән җиһазлар нигезендә капиталь үзгәртеп кору заводта 1930 елларда тормышка ашырыла, шунда ук технол. процесслар да шактый камилләштерелә. Целлюлоза алу өчен мамык урынына кәгазь куллана башлый, бөтен дарылар тасма формасыннан 7 каналлы бөртек формасына күчерелә, ул исә бик яхшы баллистик үзлекләргә ия була, чимал (эреткеч) чыгымын 35% ка киметергә һәм хезмәт җитештерүчәнлеген 2 тапкыр күтәрергә мөмкинлек бирә. Предприятиенең к-тага чыдам материалларга ихтыяҗын тәэмин итү максатында, СССРда беренче тапкыр ферросилид (кремнийлы чуен) эшләнмәләр әзерләү цехы оештырыла. 1940 ның башында яңа төр продукция, технологияләр һәм махсус җиһазлар әзерләү өчен завод каршында СССР НКВДсы махсус отрядының 40 нчы Махсус техник бюросы (ОТБ-40) (к. *Химия продуктлары институты*) төзелә. Бу чорда һәм Бөек Ватан сугышы елларында заводта реактив («катюшалар»), зенит, үзйөрешле, диңгез артиллериясе һ.б. иң яңа системаларга дарылар һәм зарядларның күп төрле маркалары җитештерелә. Мобилизация планы нигезендә куәтләрен арттыра барып, завод 1944 тә 28 мең *т* дары эшләп чыгара. Фронтка җибәрелгән зарядларның тулай күләме (млн. данә): реактив снарядлар өчен — 1 дән артык, зенит һәм үзйөрешле артиллерия өчен — 23, гаубицалы артиллерия өчен — 5, туплы кыр артиллериясе өчен — 18, диңгез артиллериясе өчен — 0,6, авиация кораллары өчен — 93, винтовка патроннары өчен — 3924. 1941–43 тә илдәге башка тиңдәш пр-тиеләрне чимал (коллоксилин) б-н тәэмин итә. Дәүләт Оборона Комитеты планнарын даими арттырып үтәп, завод сугыш вакытында СССР сугыш кирәк-яраклары халык комис-ты пр-тиеләренең Бөтенсоюз социалистик ярышында 10 мәртәбә җиңүче була. Сугыштан соңгы елларда пр-тиене модернизацияләү дәвам итә (1949–65 тә исеме — 673 нче п/я (почта ящигы) оешмасы, 1965 тән — В.И.Ленин исем. Казан химия заводы). Тармакта беренче тапкыр азот к-тасы, нитроҗепселләр алу, дары әзерләүнең автоматлаштырылган өзлексез технологияләре эшләнә һәм гамәлгә куела, бу производство циклын 10 тапкыр, чимал чыгымнарын 2,5–5 һәм эшләүчеләр санын 2,5–3 тапкыр кыскартырга



Юбилей а́ркасы («Кызыл капка»).

мөмкинлек тудыра. 1953 тә завод нигезендә яңа оборона пр-тиеләрен проектлаштыру буенча 1 нче союзкүләм махсус дәүләт проект ин-ты ф-лы ачылу б-н, завод тармакның әйдәүче оешмасына әверелә — биредә стандарт булмаган химия җиһазлары эшләнә һәм башка дары заводлары өчен технол. процесслар әзерлек уза, беренче булып чималлар һәм эшләнмәләрнең яңа төрләре үзләштерелә, ш.и. СССРда беренче тапкыр танк артиллериясе өчен янып бетүчән гильзалар эшләү башлана. Оборона максатлары өчен билгеләнгән продукция җитештерү буенча цехлар комплексы күкерт, азот кислоталары, нитроҗепселләр, этил эфиры, спиртларны ректификацияләү, очучан эреткечтәге пироксилинлы дарылар, зарядлар производствосы һәм тутыру җиһазлары цехларын эченә ала. Төп җитештерүне үстерү б-н бер үк вакытта химия продукциясен гражданлык максатларында массакүләм эшләп чыгару цехлары ачыла: нитроэмаль һәм нитролаклар, эреткечләр, келәйләр, целлулоид уенчыклар һәм галантерея, ясалма тукымалар, люминесцентлы яктырткычлар (ш.и. Бразилиягә экспорт өчен), мебель, азык спирты һәм аракы (1966 елга пр-тиедә эшләнгән продукциянең 76% ын халык куллануы товарлары тәшкил итә). 1975 тә завод химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тларының Шостка (Украина) һәм Ташкент шәһәрләрендәге ф-ллары б-н бергә В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү берләшмәсе составына керә һәм баш пр-тие булып китә. Берләшмә оборона продукциясенең яңа төрләрен эшләү һәм җитештерү, автоматлаштырылган технол. процессларны, роботлар техникасын әзерләү б-н шөгыльләнә; 1980 елларда синтетик күн җитештерү буенча зур цех, махсус конструкторлык-технол. бюросы файдалануга кертелә, ярдәмче авыл хуҗалыгы оештырыла, аучылык дарылары, олеин кислотасы, линолеум, идән өчен келәмле каплам (ворсанит), обойлар, җепселле тутыргыч, лаклы коллоксилин җитештерү үзләштерелә. 1990 елларда оборона заказлары кимү сәбәпле, пр-тиене өлешчә конверсияләү гамәлгә ашырыла, халык куллануы товарларының яңа төрләрен: металл түбә ябу материалы, брезент эшләнмәләр, плёнка материаллары эшләп чыгару оештырыла. Ферросилид эшләнмәләрне массакүләм җитештерү җайга салына (насослар, краннар, вентильләр, торбалар, фасонлы эшләнмәләр). 1992 дә завод В.И.Ленин исем. Казан дәүләт фәнни-җитештерү пр-тиесе итеп үзгәртелә, 2002 дә федераль фәнни-җитештерү үзәге статусы ала. 2003 тә аның составыннан хәзерге исемдәге федераль казна пр-тиесе аерылып чыга, аңа оборона эшләнмәләре җитештерү буенча куәтләр тапшырыла (бөтен төп фондларның 90% ы). Төп продукция: ату һәм артиллерия коралларының бөтен төрләре, аучылык, спорт һәм төзелеш-монтаж патроннары өчен пироксилинлы дары һәм зарядлар, нитроцеллюлоза, лаклар, эмальләр, эреткечләр, линолеум, чуен коелмалар, ферросилидтан эшләнмәләр һ.б. Төсле ялкынлы дарылар һәм пиротехник әйберләр эшләп чыгару үзләштерелә. Пр-тие Хезмәт Кызыл Байрагы (1966), Октябрь Революциясе (1976), 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы (1985) орденнары б-н бүләкләнә. Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була; ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеме — 3, Дәүләт бүләге 6 кешегә бирелә. Җитәкчеләре: подполковник, кенәз С.М.*Баратаев* (1786–87), подполковник Баннер (1787–98), генерал-майор Реслейн (1806–26), генерал-лейтенант Табеньков (1836–47), генерал-майор М.М.Свечников (1857–76), С.Ф.Ефимов (1876–82), М.И.Шатилов (1882–85), В.В.*Лукницкий* (1885–1917), В.Шнегас (1918–19), А.Жарко (1919–24), Е.Микитон (1932–36), Д.Равич (1936–37), М.Федосеев (1937–38), А.Якушев (1938–39, 1941–42), К.Иоффе (1931–41), В.Ивченков (1942–44), В.Мосин (1944–47), Н.А.Борисов (1947–52), В.С.Сластников (1952–55), А.В.*Грязнов* (1955–57), С.Г.*Богатырёв* (1967–94), Ф.Ф.*Газизов* (1994–97), С.Э.Межерицкий (1997–2003), Х.З.Гыйниятов (2003 тән).


*Әд.:* Глинский В.С. 100 лет Казанского порохового завода. СПб., 1888; Казаков В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998; Садыков Ф. Заряды для «Катюш» изготовляли девушки Заречья // Эхо веков. 2000. № 1/2. *С.Г.Белов.*

**КАЗА́Н ДЕНДРА́РИЕ**, Казан шәһәренең Вахитов р-ны терр-ясендә. 1948 елда Татарстан урман-тәҗрибә станциясе хезмәткәре Д.И.Морохин инициативасы б-н оештырыла. Мәйданы 1,2 *га*. Төньяк Америка, Европа һәм Азия агач һәм куакларының 105 төре һәм сорты утыртылган. 1955–85 тә күп кенә төрләренең үсеше буенча фенологик күзәтүләр үткәрелә (нәтиҗәләр 1965–85 елларга урман хуҗалыгына багышланган хез-



Дендрарийның гомуми күренеше.

мәтләр җыентыгында басыла). Үсемлекләр үсеше фенофазасы башлануның уртача датасы билгеләнә һәм, шәһәрне яшелләндерүдә файдалану максаты б-н, агач һәм куакларның аеруча чыдам төрләре табыла (Н.В.Напалков). Дендрарий көчле антропоген йогынтыга дучар. Агач һәм куак токымнарының 65, ш.и. 31 җирле һәм 34 интродуицияләнгән төре; ылыслылардан — чыршылар (гади һәм чәнечкеле), көнбатыш туясы, Себер эрбете; яфраклылардан, җирле токымнардан кала — Амур бәрхете, Маньчжур чикләвеге, Маак шомырты, Уссури грушасы, робиния (ак акация), әлүчә, кара балан һ.б. 1981 елда К.д. ТРның табигать истәлеге булып билгеләнә. Станция хезмәткәрләре тарафыннан студентлар һәм мәктәп укучылары өчен экскурсияләр үткәрелә.



Декоратив культуралар участогы.

*Әд.:* Н а п а л к о в Н.В. Озеленение городов и сёл Среднего Поволжья. К., 1974.

*Н.А.Кузнецов.*

**КАЗА́Н ДИНИ́ ВЕ́ДОМСТВОСЫНЫҢ ХАТЫ́Н-КЫЗЛА́Р УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, гомуми урта уку йорты. Документларда һәм әдәбиятта ш.у. Казан хатын-кыз руханилар уч-щесе һәм Казан дини катлаудан булган кызлар уч-щесе буларак билгеле. Дини гаиләдән булган кызлар өчен Россиядә 10 округта уч-ще ачу турында император Николай I нең 1852 ел Фәрманы нигезендә 1853 тә ачыла. Казан, Вятка һәм Пермь губерналарының дин әһелләре кызлары өчен төзелә. Училищегә кабул итү конкурс нигезендә үткәрелә, укый-яза һәм арифметика нигезләрен белү таләп ителә. Башта укыту срогы 5 ел була. 1868 дән училище епархия уч-щеләре уставы буенча эшли башлый, әмма алардан аермалы буларак, Синодка буйсына һәм аерым кешеләрнең акчасы хисабына тотыла (С.А.Браницкая васыяте буенча). 1880 нән уч-ще составында пед. сыйныф эшли. Үз бинасы була.

*Әд.:* Известия по Казанской епархии. 1867–1917; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в пореформенной России. Казанская губерния. К., 1999. *Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ЕЛГА́ ПОРТЫ́**, к. *Татфлот.*

**КАЗА́Н ЕЛГА́ ПОРТЫ́ ВОКЗАЛЫ́**, к. *Татфлот.*

**КАЗА́Н ЕЛГА́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Транспорт һәм элемтә министрлыгының урта һөнәри уку йорты; Татарстанда күптәнге урта һөнәри уку йортларының берсе. 1904 елның



Казан елга училищесе. 20 йөз башы.

октябрендә Казан елга уч-щесе буларак оештырыла. Аны оештыруда төп башлап йөрүчеләрнең берсе — Идел судночылыгының Казан участогы инспекторы М.В.Черепанов, ул уч-щенең беренче директоры була (1904–14). 1924 тән уч-ще Горький су ин-тының эшчеләр ф-ты дип атала, 1932 нең маеннан хәзергечә атала, 2004 тән М.П.Девятаев исемендә. Белгечлекләр: эчке су юлларында судноларйөртүче, механикалаштыру һәм автоматлаштыру чаралары, транспорт эл. җиһазларын һәм автоматикасын эксплуатацияләү, транспортта йөк ташу һәм идарә итүне оештыру, кунакханәләр сервисы, икътисад һәм бухгалтерлык исәбе. 2010 да көндезге бүлектә — 600, читтән торып уку бүлегендә 350 студент укый; педагоглар коллективында 60 кеше эшли; ш.и. 4 се — ТРның атказ. укытучысы. К.е.т. оешуыннан алып 20 меңгә якын белгеч әзерләп чыгара. Тәмамлаучылар арасында — Сов. Союзы Герое М.П.*Девятаев* бар. Училище башта Адмиралтейство бистәсендә аның өчен махсус төзелгән агач (1907 дән таш) бинада урнаша. Техникум Казан шәһәр думасы, Казан, Самара, Сембер губерналары акчасына, ш.у. шәхси су транспорты хуҗаларының иганәсенә төзелә һәм яши. 1969 дан яңа уку корпусы төзелә. Су-спорт лаб-ясе, 2 өйрәнү судносы бар.

*Әд.:* Л о б а н о в а Т.Б. Как перестали стесняться капитаны: первые речные училища на Волге // Казань. 1996. № 3/4; ш у л у к. Школа для капитанов // Казань. 1999. № 12.

**КАЗА́Н ЕПА́РХИЯСЕ**, Рус Православие чиркәвенең адм. бүленеш берәмлеге. 1555 елның 3 нче апрелендә оештырыла. Иң элек Казан ханлыгы терр-иясен һәм Вятка җирләрен үз эченә ала. 1556 да, Әстерхан ханлыгы яулангgranнан соң, К.е.нә барлык Урта һәм Түбән Идел буе җирләре, 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөз башында Урал һәм Себер терр-ияләре керә. Алга таба К.е. мәйданы кечерәя: 1602 дә — Әстерхан, 1620 дә — Тобол, 1657 дә Вятка епархияләре аерылып чыга. 18 йөзнең 1 нче яртысында К.е.нә Казан һәм Уфа губерналары кертелә. 1780 дә К.е. терр-иясе Екатерина II билгеләгән губерна чикләре б-н тәңгәлләштерелә һәм 1790 еллар уртасында Казан һәм Сембер губерналарын гына үз эченә ала (1832 гә кадәр). 1920 елның 1 нче яртысында К.е. чикләре Идел буендагы яңа адм.-терр. бүленешкә яраклаштырып билгеләнә: аның составына Татарстан, Чуаш (1946 га кадәр), Мари (1993 кә кадәр) АССР терр-ияләре тәгаенләнә. Хәзер К.е. составына бары тик ТР терр-иясе керә. 1993 тән К.е.нең идарәче архиерее «Казан һәм Татарстан архиепископы» титулын ала. 1988 дән К.е. б-н архиепископ *Анастасий* (1996 дан) җитәкчелек итә.

*Әд.:* Платон (Любарский). Сборник древностей Казанской епархии и других приснопамятных обстоятельств. К., 1868; Б о г о с л о в с к и й Г.К. Краткий исторический очерк Казанской епархии с приложением биографических сведений о казанских архипастырях. К., 1892; Ж у р а в с к и й А.В. Казанская церковь в эпоху гонений. К., 1994.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ҖИНАЯ́ТЬ ЭШЛӘРЕ́ МӘХКӘМӘ́ ПАЛА́ТАСЫ**, губернаның югары мәхкәмә органы. 1775 елгы Губерна реформасын үздыру барышында оештырыла, 1781 нең 23 декабрендә ачыла, 1796 ның 31 декабреннән Казан губерна штатын тәгаенләгәндә *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасы* б-н берләштерелә, аннан Казан мәхкәмә һәм җәза бирү палатасы составына керә. Сенатның 1801 ел 9 сентябрь фәрманы нигезендә К.җ.э.м.п. буларак торгызыла. Өяз мәхкәмәләреннән, губерна магистратыннан һәм 1796 га кадәр — югары земство мәхкәмәсе һәм югары җәза үтәү учреждениеләреннән кергән җинаять эшләрен карый һәм соңгы карарлар кабул итә; вазифаи җинаятьләрне, шәхси шикаятьләр буенча тикшерү эшләрен беренчел карауны башкара; түбәндәрәк торган мәхкәмә инстанцияләреннән килгән җинаять эшләрен тикшерү б-н шөгыльләнә. Палата составына рәис (император билгеләп куя), 2 советник һәм 2 асессор (аларны Сенат билгели), 1802 дән — рәис, рәис иптәше (урынбасары) (1831 дән губерна дворяннар җыены тарафыннан сайланалар), дворяннар һәм сәүдәгәрләрдән 4 утырышчы керә. Палатага секретарь, өстәл башлыклары һәм аларның ярдәмчеләре, беркетмә язучы, казначей, теркәүче (барлыгы 16 кеше; 1869) хезмәт күрсәтә. Сенат һәм 1802 дән Россия Юстиция министрлыгы карамагында була. Сенатның 1871 ел 11 декабрь фәрманы нигезендә бетерелә.

*Әд.:* к. *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасы.* *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ҖИҢЕ́Л СӘНӘГА́ТЬ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1920 елның маенда Татарстан, Урал һәм Себернең Казан р-ны күн техникумы буларак оештыры-

ла. 1929 дан Казан индустриаль техникумы, 1940 тан Казан технол. техникумы, 1944 тән Казан механика-технол. техникумы, 1955 тән хәзерге исемдә. Мәгълүмат эшкәртү һәм идарә итүнең автоматлаштырылган системалары, тукыма эшләнмәләр технологиясе, күн һәм мех технологиясе, мех һәм сарык тиресеннән тун эшләнмәләр җитештерү, мех эшләнмәләрне модельләштерү һәм конструкцияләү; икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, куллану товарларының сыйфат экспертизасы буенча белгечләр әзерләнә. Техникум Россия киез итек-киез җитештерү һәм мех сәнәгате өчен урта белгеч кадрлар әзерләү буенча бердәнбер уку йорты. 2010 да 690 студент укый (көндезгедә 590 һәм читтән торып уку бүлегендә 100); укытучылар коллективы 48 кешедән тора, ш.и. 4 ТРның атказ. укытучысы, РФнең атказ. махсус урта белем бирү хезмәткәре. К.җ.с.т. оешуыннан башлап 20 меңнән артык белгеч әзерләп чыгара. Тәмамлаучылар арасында СССР Бөтенсоюз мех берләшмәсе башлыгы В.С.Маслов, «Электроприбор» фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, Соц. Хезмәт Герое И.М.*Мостюков*; Мәскәү җиңел сәнәгать ин-ты ректоры, проф. И.Р.Страхов бар. Техникумның төп корпусы — Казан укытучылар семинариясенең элеккеге бинасы, 19 йөз архит-ра истәлеге.


Казан җиңел сәнәгать техникумы бинасы.

*Әд.:* Овчинка стоит выделки. К., 1978; Опыт подготовки специалистов в средних профессиональных учебных заведениях Республики Татарстан. К., 2003.


**КАЗА́Н ҖИР ЭШЛӘРЕ́ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, Дәүләт милке министрлыгы карамагында. 1846 елда Киселёв реформасы барышында дәүләт крәстияннәрен крәстиян яшьләре арасыннан «үрнәк хуҗалар» итеп тәрбияләү максаты б-н Казан укыту фермасы — һөнәри уку йорты булып ачыла. 4 ел эчендә укучылар җир эшләренең алдынгы алымнарыннан гамәли күнекмәләр алалар һәм башлангыч мәктәп курсын үзләштерәләр. Дәүләт милек министрының 1861 ел 13 май боерыгы б-н 1864 ел 15 августында ферма базасы җирлегендә К.җ.э.у. ачыла. Укыту максаты алпавыт һәм дәүләт а.х. утарлары б-н идарә итүчеләр әзерләү була. Беренче устав нигезендә монда башлангыч белемле яшьләр кабул ителә, алар 4 ел укытыла; агрономия һәм вет. фәннәре б-н беррәттән курска матем., химия, сызым, тарих һәм геогр. фәннәре өстәлә. 1867 дә укыту срогы 5,5 елга кадәр озайтыла. 1878 ел 30 май Нигезләмәсе җирлегендә уч-ще алты еллык укыту срогы б-н урта уку йорты итеп үзгәртелә. Абитуриентларга гимназиягә укырга кергәндәге кебек таләпләр куела, аны тәмамлаганда «укымышлы идарәче» квалификациясе бирелә, алар а.х. һәм урман хуҗалыгы югары уку йортларына керергә хокуклы була. Гомуми фәннәр буенча программалар киңәйтелә, немец теле, алгебра, физика һ.б. фәннәр кертелә.

Укытучылар коллективы а.х. академиясен һәм Казан ун-тын тәмамлаучылардан тора. 1904 ел 26 май Нигезләмәсе буенча К.җ.э.у. 1911 нең июленнән Казан урта а.х. уч-щесе итеп үзгәртелә, аны тәмамлаучыларга агроном белгечлеге бирелә. 1917 гә кадәр 650 гә якын белгеч әзерләнә. 19 йөз ахырына кадәр уч-ще тәмамлаучыларның күп өлеше — алпавыт утарлары б-н идарә итүчеләр, соңыннан — земстволарда агрономнар һәм техниклар; калганнары Дәүләт милке министрлыгының а.х. учреждениеләрендә чиновниклар, а.х. уку йортларында укытучылар булып эшлиләр. 50 ләп тәмамлаучы белемнәрен югары уку йортларында дәвам итә. Училище Борисково авылында, 1862–64 тә махсус төзелгән бинада урнаша, 1901 дә киңәйтелә; тәҗрибә кырлары, фермалар, бакчалар, җиләк-җимеш бакчалары, үсемлекләр бакчасы, умарталыклары (хәзер Казан аграр ун-тының укыту-өйрәтү хуҗалыгы) була. 1918 дә Казан а.х. техникумы итеп үзгәртелә, 1919 да аның җирлегендә *Казан политехник институтының* авыл һәм урман хуҗалыклары ф-ты оештырыла.

*Әд.:* Белецкий И. Краткий исторический очерк двадцати пятилетия Казанского земледельческого училища Министерства государственных имуществ. К., 1889; Танеев В.В. Казанское сельскохозяйственное училище. К., 1915.

**КАЗА́Н ҖИРЛӘРЕНДӘ́ АЗАТЛЫ́К СУГЫШЛАРЫ́ (1552–56)**, элеккеге Казан ханлыгында яшәгән төп халыкларның — татар, чирмеш (мари), вотяк (удмурт), чуаш һ.б.ларның рус басып алучыларына каршы азатлык хәрәкәте. Беренче этап 1552 елның декабрендә бер үк вакытта Болын һәм Арча якларында башлана. Тау ягында воевода Б.И.Салтыковның Зөя отряды баш күтәрүчеләрне Цивил елгасы янында тар-мар итә. Арча ягында «Тугай уллары» җитәкләгән җирле халык чыгышларын Казаннан җибәрелгән *Камай морза* һәм Н.Казаринов отрядлары бастыра. 1553 нең кыш ахырында хәл тагын кискенләшә, ул рус хакимиятенең җирле халыктан *ясакны* Казан ханлыгындагы кадәр җыярга тырышуы б-н бәйле була. 1553 нең мартында Арча һәм Болын якларында Сәет Үсәен (Сәет Хөсәен), Туакмыш Шаһзадә, *Сары батыр* җитәкчелегендә халык кузгалышы яңадан кабынып китә. Баш күтәрүчеләр Биектау авылы янында Казаннан җибәрелгән отрядны җиңәләр, 350 стрелецны һәм 450 казакны юк итәләр. Әлеге җиңүдән соң алар Мишә елгасы янында, Казаннан 70 чакрым ераклыкта *Мишәтамак шәһәрчеге* төзиләр, ул баш күтәргән төбәкнең үзәгенә әверелә. Март аенда баш күтәрүләр Тау ягында җәелеп китә, анда Сәет Хөсәен һәм Сары батыр Б.И.Салтыковның Зөя йомышлы кешеләреннән һәм Тау ягында яшәүчеләрдән торган отрядын тар-мар итәләр, воевода үзе әсирлеккә төшә. Яз уртасында баш күтәрүчеләргә ярдәмгә Нугай Урдасы отрядлары килә. Җирле җәза көчләре баш күтәрүне бастырырлык хәлдә булмый. М.М.Щербатов мәгълүматларына караганда, Мәскәүдә хәтта Казанны ташлап китү турында да сүз була. Баш күтәрү зур колач ала, Илләт һәм Уржум елгаларына кадәр барып җитә. Хакимиятләр Тау ягына контрольлек итә алмыйлар, шул сәбәпле Казан тирәсенә Зөядән шактый көчләр китерелә. Шулай ук Рус дәүләтенең төрле төбәкләреннән җәза отрядлары килә. Вятка җирләреннән окольничий Д.Ф.Адашев армиясе килә, ул Нократ һәм Чулман елгалары тирәсен контрольдә тота. Идел буйлап килгән отрядлар Казан воеводасы җитәкчелегенә тапшырыла. Зөядән Казанга полководец кенәз П.И.Шуйский күчерелә. 1553 нең декабрендә төбәккә Мәскәүдән тагын бер отряд килә, аның составында Касыйм, Мещёра, Темниковтан килгән йомышлы татарлар була. 1553–54 нең кышында патша гаскәрләре баш күтәрүләрне бастыра; ихтимал, ул вакытка баш күтәрүчеләрнең җитәкчеләре аз калгандыр. 1554 нең март ахырында рус гаскәрләренең төп көчләре Мәскәүгә әйләнеп кайта.

Баш күтәрүнең яңа этабы 1554 нең җәй ахыры — көз башында башлана. Августта Казан воеводасы М.В.Глинский Болын ягына Көбәнәк бәк һәм Колай морза җитәкләгән отрядны җибәрә, әмма алар баш күтәрүчеләр ягына чыга. 1554 нең октябрендә Казаннан яңадан башында кенәз Е.Чигасов, Е.Маматов, стрелецлар башлыклары А.Бортенев һәм И.Мохнев торган йомышлы татарлар отряды җибәрелә, алар җиңүгә ирешәләр, бәкләр Корман Алины, Көбәнәкне, морзалар Чабак Данин б-н Колайны әсирлеккә төшерәләр. «Казан кешеләренең иң яхшылары» — барлыгы 1560 кеше һәлак була һәм җәзага тартыла. Шуннан соң көчле баш күтәрүләр Иделнең сулъяк ярында, чирмешләр яши торган төбәкләрдә, ш.и. Ветлуга һәм Рутка елгалары бассейннарында була. Баш күтәрүчеләрне «чирмешләр йөзбашы кенәз» *Мамышбирде* (Мәмешбирде) җитәкли. Көз ахырында алар Казанга яный башлыйлар, Иделдәге хәрәкәтне туктаталар. Аларга каршы Мәскәүдән кенәз И.Ф.Мстиславский җитәкчелегендәге армия җибәрелә. Аның составында башында кенәз Арай бәк торган Касыйм татарлары, бәк Е.Тенишев җитәкләгән Темников татарлары да була. Хәрби хәрәкәтләр 1554–55 еллар кышында алмаш уңыш б-н дәвам итә. Мамышбирде хәрби хәрәкәтләрне Тау ягына күчерә, Сундырь тавында *Чалым* кальга-ныгытмасын төзи. Февральдә баш күтәрүчеләр Арча ягына яу б-н баралар, яңа төзелгән ныгытмалардагы стрелецлар һәм йомышлы татарлар аларның һөҗүмнәрен кире кагалар, ә яз уртасында шактый уңышларга ирешәләр. 1555 нең сентябрендә Н.Ф. Мстиславский армиясенә алмашка А.М.Курбский һәм Ф.И.Троекуров җитәкчелегендә яңа көчләр җибәрелә, әмма хәл әлләни үзгәрми. 1556 ның язында П.И.Шуйский патшага «Арча кешеләре һәм государьга якын кешеләр хыянәт иттеләр һәм стрелецларны җиңделәр», дип хәбәр итә.




Баш күтәрүнең үзәге булып элеккечә Казан арты кала. Баш күтәрүчеләрнең җитәкчеләре Тау ягында да актив хәрәкәтләрне дәвам иттерергә тырышалар. Бу вакытта Мамышбирде, хан тәхетен вәгъдә итеп, үзенә нугай морзасы *Гали Әкрамны* чакырган дип фаразлана. 1556 ның яз башында баш күтәрүчеләр (2 мең чамасы кеше) Мамышбирде җитәкчелегендә һәм нугай отрядлары ярдәмендә рус патшасы хакимиятен кабул иткән тау кешеләренә (чуашларга) каршы актив сугышалар. Чуашларның йөзбашы Алтыш җитәкләгән кешеләр Мамышбирдене хәйлә б-н үзләренә чакыралар һәм аны рус хакимиятенә тотып бирәләр. Баш күтәрүчеләр отряды тар-мар ителә, Чалым кальгасы җимерелә. 1556 ның май аенда Мишә елгасы янында хәлиткеч сугыш була, нәтиҗәдә Дәүлек морза җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр җиңелә, башлыклары әсирлеккә төшә. Әлеге җиңүдән соң воевода П.В.Морозов 10 көн дәвамында «барлык Арча якларын яулап ала һәм күп кешеләрне үтерә, күпләрне әсирлеккә төшерә». Җәзалаулар аннан соңгы айларда да дәвам итә. Июнь аенда воеводалар П.В.Морозов һәм Ф.И.Салтыков Арча ягына «Ашыт, Уржум артына һәм Нократка» бөлдергеч яу б-н баралар, «күп сугышлар, була, хатын-кызларны, балаларны әсирлеккә алалар, ә ирләрнең барысын да үтерәләр». Баш күтәрүчеләрнең таркалган төркемнәре юк ителә; анда катнашучыларның барысы да диярлек үтерелә, күпләр Казанга баш иеп бара. 1557 нең язында Казан, Зөя, Чабаксардан, Болын ягыннан халык чуалышлары турында аерым хәбәрләр килә. Әмма өстенлек инде патша гаскәрләре ягында була. Шул вакытта баш күтәрүчеләрнең исән калган башлыкларының берсе Әхмәт батыр әсирлеккә алына. 1557 нең маена баш күтәрү тәмам бастырыла. К.җ.а.с. барышында элеккеге Казан ханлыгының Казан тирәсендәге һәм зур елгаларның яр буйларындагы халык иң күп яшәгән җирләр тәмам ялангачландырыла. 1557 нең маенда Казан һәм Зөя воеводалары әлеге җирләрне Архиерей йортына, монастырьларга, рус алпавытларына өләшә башлый. Сугыш барышында элеккеге Казан ханлыгының барлык аксөякләре диярлек кырып бетерелә, руслар ягына күчкән аз санлы кешеләр инде куркыныч тудырмый. Хәрби хәрәкәтләр барышында 1555 тә Казан Кремленең таш диварлары төзелә башлый, Лаеш, Чабаксар һ.б. кальгаларга нигез салына.

*Әд.:* Ермолаев И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. (Управление Казанским краем). К., 1982; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; шул ук. Тернистый путь борьбы за свободу (Социально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI–XIX вв.). К., 1999.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ҖИТЕ́Н КОМБИНАТЫ́**, к. «*Казан җитене*».

**«КАЗА́Н ҖИТЕНЕ́»** («Казанский лён»), агросәнәгать корпорациясе, җиңел сәнәгать пр-тиесе. Техник максатта житештерелүче бәйләм җебе (сыңарлы һәм җегәрләнгән), җитен һәм ярымҗитен (утка һәм суга чыдам эремә сеңдерелгән) брезентлар, табигый чималдан (җитен, һинд сүсе, Урта Азия киндере, мамык), кәгазьдән һ.б.дан капчык һәм төргәкләү тукымалары, энә үткәрүчән тукылмаган материал эшләп чыгару буенча махсуслаша (2008 елга кадәр). Эшләүчеләр саны — 41 кеше (2010).

1860 елда И.И.*Алафузов* тарафыннан җитен эрләү һәм туку ф-касы буларак нигезлә-

нә. Җитен товарларына ихтыяҗ зур булу пр-тиенең Россия җитен сәнәгате үзәкләренең берсенә әверелүенә китерә. 1891 дән, хәрби кием-салым һәм кирәк-яраклар җитештерүче пр-тие буларак, ф-ка аеруча зур тизлек б-н үсә. 1918 дә национализацияләнә, 1921 дә, 11 пр-тие исәбендә, «Таткожтрест» составына кертелә. 1924 тән В.И.Ленин исемен йөртә. 1925 тә «Татваленки» трестына күчерелә һәм В.И.Ленин исем. текстиль ф-касы итеп үзгәртелә; пр-тиене яңарту буенча зур эш башкарыла. 1933 тән ф-ка В.И.Ленин исем. автономияле дәүләт җитен эрләү, туку ф-касы дип атала башлый һәм ТАССР Текстиль сәнәгате халык комис-ты (1940 тан — СССР Текстиль сәнәгате халык комис-тының Җитен сәнәгате баш идарәсе) карамагына күчә. 1940 та ф-ка В.И.Ленин исем. Дәүләт бөтенсоюз җитен комб-ты итеп үзгәртелә, 1946 дан — В.И.Ленин исем. җитен комб-ты, 1960 тан — В.И.Ленин исем. Казан җитен комб-ты, 1994 тән — «Казан җитен комб-ты» АҖ, 2001 дән хәзерге исемдә.

2008 дән «К.ж.» бары тик энә үткәрүчән тукылмаган материал гына җитештерә (2009 да 73,7 мең *м*). Аның продукциясе элек-электән дөньякүләм танылу ала. 1913 кә кадәр үк иң эре халыкара һәм бөтенроссия сәүдә күргәзмәләренең 13 алтын медале яулана. Беренче бөтендөнья сугышы чорында продукция чыгару 3 тапкырдан да күбрәккә арта. 1926 да постау ф-касы сафка баса, 1934 тә — эрләү ф-касы корпусы, 1964 тә СССРдагы беренче тукылмаган материаллар җитештерүче цех файдалануга тапшырыла. Брезентларны яктылыкка чыдам буяуларга мануны үзләштерү (текстиль тармагында беренче тапкыр, 1956), линолеум астына ябыштырыла торган изоляция катламын эшләп чыгару (1964) СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бәяләнә. 1960 та «К.ж.» 80 нән артык исемдә продукция, ш.и. төрле эрләнгән җепләр, тукымалар, тукылмаган материаллар (брезентлы тукымалардан транспортёр тасмалары һ.б.) эшләп чыгара. 2000 дә автомобиль шиннары эшләүдә кулланыла торган үрелгән тукыма җитештерү үзләштерелә.

2001 дә «К.ж.» тарафыннан җитенне беренчел эшкәртү б-н шөгыльләнүче 2 завод (Казанда һәм Мамадышта, 2005 кә кадәр эшлиләр) төзелә. Төп чимал — җитен, ул Татарстан, Мари, Удмурт Респ-каларында һәм РФнең башка төбәкләрендә, ш.у. Белоруссиядә үстерелә.

«К.ж.»нең продукциясе җиңел сәнәгатьтә, нефть химиясе, автомобиль сәнәгатендә, төзелештә кулланыла, илнең төрле төбәкләренә җибәрелә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 16 кеше РСФСР, ТАССРның атказ. текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре исеменә лаек була, 6 кеше — Ленин ордены, 25 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 29 кеше — «Почёт билгесе», 15 кеше — «Хезмәт даны» орденнары, 48 кеше — медальләр, 9 кеше ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — В.К.Успенский (1953–62), П.П.Филиппов (1962–74), В.М.Анкудимов (1974–80), Э.Г.Ганиев (1980–85), В.И.Мурашов (1985–94), Б.С.Селиваненко (1995–98), А.Е.Голубев (1998–2000), Р.А.Хәкимов (2000–03), И.Ю.Белов (2003–04), Ю.Г.Котляревский (2005–06), Л.Н.Овчинникова (2006–08), Ю.А.Кондаков (2009 дан).

*Әд.:* Анисимов Н.Г. Казанский льнокомбинат. 100 лет. К., 1960; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976.

*И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н ҖЫЛЫЛЫ́К-ЭЛЕ́КТР ҮЗӘКЛӘРЕ́**, (ТЭЦ-1,2,3), эл. энергиясе һәм бер үк вакытта кулланучыларга пар һәм кайнар су рәвешендә җибәрелә торган җылылык эшләп чыгаручы, җылытылган типтагы җылылык-пар эл. станцияләре. Үзәкләшкән хәлдә Казанның энергия ресурсларына булган ихтыяҗларының 50% ка кадәрен тәэмин итәләр, энергиянең бер өлешен респ-ка тирәсендәге торак пунктларга җибәрәләр.



Казан. ТЭЦ-1.

**ТЭЦ-1** Кабан күленең көньяк-көнбатыш ярында урнашкан. 1930 елда Казан ГРЭСы буларак төзелә башлый (1933 тән хәзерге исемдә, 1956 га кадәр — И.В.Сталин исем.). СССРдагы 500 удар төзелеш исәбенә керә. 20 *МВт* куәтле 2 пар турбогенераторы һәм 10,5 атмосфера басымлы һәрберсенең пар җитештерү күләме 53 *т/сәг.* тәшкил иткән, ташкүмер тузаны ягып эшләүче 4 казан-агрегат сафка басканнан соң 1933 нең гыйнварында сынау тогы бирә, июльдә Казанның эре химия, җиңел, азык-төлек сәнәгате пр-тиеләренә эл. энергиясе җибәрә башлый, бу исә аларда хезмәт җитештерүчәнлеген һәм җитештерү күләмен 2 тапкырга арттыру мөмкинлеге тудыра. 1934 тә станция эл. энергиясен Яшел Үзән шәһәренә, Васильево, Юдино, Дербышки эшчеләр посёлокларына һ.б. торак пунктларга, 1938 дә Волжск шәһәренә Мари целлюлоза-кәгазь комб-ты төзелешенә тапшыра башлый. Алдагы елларда ТЭЦта шлактан арындыруның сыек ысулы, турбина конденсаторларында химик юл б-н чистарту өчен су җылыту (ул елга 1 мең *т* дан артык ягулыкны янга калдыра), ягулык бирүне механикалаштыру гамәлгә кертелә. 1972 дә пр-тиеләр һәм халык кайнар су белән тәэмин ителә башлый. 1976–78 дә югары басымга (130 атмосферага кадәр) исәпләнгән пар казаннары куелган 2 нче корпусны файдалануга тапшыру нәтиҗәсендә станция 190 *МВт* эл. энергиясе, 744 *Гкал·сәг.* җылылык энергиясе җитештерү куәтенә ирешә. 1977 дән төп ягулык сыйфатында — мазут, 1981 дән табигый газ файдаланыла башлый. Станциядә 4 турбогенератор, 6 энергетика (пар) һәм 2 су җылыту казаннары эшли. Гомуми куәте 50 *МВт* булган 2 газ-турбиналы җайланма гамәлгә кертелә. Станциянең билгеләнгән эл. бирү куәте — 220 *МВт*, җылылык бирү куәте 630 *Гкал·сәг.* тәшкил итә (2010). Техник су Кабан күленнән алына. Атмосферага экологик яктан куркыныч калдыкларны чыгаруны киметү һәм файдаланылган сулардан зарарлы матдәләрне аерып алу юнәлешендә эшләр башкарыла. Станциянең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 3 кешегә РСФСР, РФнең атказ. энергетигы, 13 кешегә ТАССР, ТРның атказ. энергетигы, 11 кешегә Татарстанның Социалистик Төзелеш Батыры дигән мактаулы исемнәр бирелә; 11 кеше — Ленин ордены, 44 кеше Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. ТЭЦ-1 нең директорлары арасында — Г.С.Билан (1943–45), Г.Ш.Азин (1945–52), К.Г.Вәлитов (1952–56), Р.М.*Мусин* (1956–57), Н.И.Кузовкин (1957–68), Б.В.Козлов (1968–77), И.Г.Галиев (1977–2001), И.Х.Гайфуллин (2001–02), Р.Ә.Бәхтиев (2002–05), Р.З.Гыйззәтуллин (2005–06), Р.Җ.Галиуллин (2006 дан).

**ТЭЦ-2** Казанның төньяк өлешендә урнашкан. 1935 тә Казан авиация комб-тының энергетика цехы буларак төзелә башлый (1942 гә кадәр СССР Авиация сәнәгате халык комис-тына буйсына). 1 нче чираты (400 °С темп-рада пар басымы 33 атмосфера булган 2 пар казаны, җылытылулы турбина, 25 *МВт* куәтле генератор һәм ягулы бойлерлар төркеме) 1938 дә файдаланыла башлый. 1942 дә эвакуацияләнгән Киев ГРЭСының турбогенераторы урнаштырылу нәтиҗәсендә станциянең куәте 2 тапкырга арта. Бөек Ватан сугышы елларында ТЭЦның җитештерү куәтен үстерү буенча алып барылган эшләрдә академиклар Г.М.Кржижановский, К.А.Круг, И.Н.Шефнер катнаша. 1949–50 елларда 140 атмосфера басымлы пар казаннары куела, дистанцион идарә һәм сигнал бирү, резервтагы җиһазларны автоматик рәвештә эшкә кушу системалары гамәлгә кертелә. 1965 тә 50 *МВт* куәтле 9 нчы генераторны һәм 12 нче пар казанын сафка бастыру нәтиҗәсендә станциянең гомуми куәте 325 *МВт* га җитә. 1979–81 дә 2 су җылыту казаны файдалануга тапшырыла, төп ягулык сыйфатында мазут кулланыла башлый. 1989 да техник ресурслары гамәлдән чыккан 4 турбогенератор һәм 2 казан сүтелә. 1993 тә җылылык челтәренә өстәмә куәт бирүче җайланма урнаштырылганнан соң файдаланучыларга җылылык җибәрүдә ышанычлылык дәрәҗәсе арта. Станциядә 5 турбогенератор, 10 энергетика (пар) һәм 2 су җылыту казаннары эшли. 190 *МВт* эл. һәм 851 *Гкал·сәг.* җылылык энергиясе эшләп чыгару куәтенә ия (2010). ТЭЦ-2 директорлары: В.П.Яковлев (1935–38), А.С.Карамян (1938–39), М.И.Ко-

валенко (1939–41), С.Н.Грищенко (1941–42), В.М.Шепелев (1942–43), И.П.Доронин (1943–46), Г.С.Билан (1946–47), Н.П.Чулков (1947–52), А.С.Леднёв (1952–62), В.К.Шибанов (1962–63), А.П.Сысоев (1963–88), Х.Ф.Миннекәев (1988–92), В.В.Шимян (1992–98), Г.К.Филимонов (1998–2000), Р.Р.Хөсәенов (2000–02), Н.П.Дорофеев (2002–04), Р.Ә.Бәхтиев (2005 тән).

**ТЭЦ-3** Казанның көнбатыш өлешендә урнашкан. Үсә барган торак массивларының һәм сәнәгать пр-тиеләренең, башлыча Казан органик синтез з-дының энергия куллану ихтыяҗлары артуга бәйле рәвештә 1966 да төзелә. 1968 дә 4 су җылыту казаны булган котельный эшли башлый. 1971 дә 1 нче энергия блогыннан сәнәгый ток алына. 1973 нең ахырында 1 нче чираты файдалануга тапшырыла; ТЭЦ проектта каралган куәтендә (265 *МВт* эл. һәм 987 *Гкал·сәг.* җылылык энергиясе) эшли башлый. Ягулык сыйфатында мазут кулланыла. 1977 дән «Оргсинтез» ҖБдән килүче нефть газы һәм ташланма газ файдаланыла, 1983 тә, 2 нче чираты сафка басканнан соң, станциянең эл. куәте 440 *МВт* га җитә. 1987 дә, файдалануга 7 нче пар казаны тапшырылганнан соң, станциянең җылылык куәте 1897 *Гкал·сәг.* тәшкил итә. 1991 елга кергәндә станция газ ягуга күчерелә. 1996 да тозсызландырылган су әзерләүдә файдаланыла торган күпбуынлы парга әйләндерү җиһазы гамәлгә кертелә, ул табигый сулыкларга зарарлы матдәләр чыгаруны киметергә мөмкинлек бирә. Станциянең казаннарына һәм төтен торбаларына атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруны автоматик контрольдә тоту җайланмасы урнаштырыла. 1999 да эл. энергиясен Киндерле — Яшел Үзән линиясе буенча тапшыру җиһазы файдалануга тапшырыла. 2009 да ил энергетикасы тарихында беренче тапкыр җыелган суларны комплекслы эшкәртү җайланмасы гамәлгә кертелә, ул су куллануның йомык циклын тәэмин итә. Станциянең төп производствосына — казан-турбина, эл. цехлары, ярдәмче производствога җылылык автоматикасы һәм үлчәүләре, файдаланылган суларны термик эшкәртү, үзәкләштерелгән ремонт, җир асты җылылык коммуникацияләре, химик, ягулык-транспорт цехлары, металлар һәм эретеп ябыштыру лабораториясе һ.б. керә. ТЭЦ-3 директорлары: Ф.М.Шаһиев (1967–78), Р.С.Галиуллин (1978–84), Н.А.Баныкин (1985–86), Ю.А.Потапов (1986–87), И.А.Закиров (1984–85 һәм 1987–2006), И.Ю.Силов (2006 дан).

*С.Г.Белов.*

**КАЗА́Н «ЗАРЯ́» КОНДИ́ТЕР ФА́БРИКАСЫ**, к. *«Заря» кондитер фабрикасы.*

**КАЗА́Н ЗЕ́МСТВО ФЕ́ЛЬДШЕРЛЫК МӘКТӘБЕ́**, 1818 елда Җәмәгать тәрбиясе приказының Казан хастаханәсе каршында нигез салына. 1841 дән — Дәүләт милке министрлыгының Казан фельдшерлык мәктәбе; 1866 да Казан губернасы земствосына күчерелә. 1909 дан Казан земство фельдшер-акушерлык мәктәбе, 1918 дә беренче совет фельдшер-акушерлык мәктәбе итеп үзгәртелә (к. *Казан медицина көллияте*).

Эшли башлавының беренче ун елында К.з.ф.м.дә укучылар саны 10–15 кешедән артмый; алар табиб һәм фельдшерларга ярдәм итеп, һөнәри белем алалар; уку срогы билгеләнми, вакантлы урынга билгеләнгәнгә кадәр укыйлар. Мәктәпне Дәүләт милке министрлыгына күчерү б-н 5 еллык уку срогы билгеләнә, имтиханнар кертелә, ләкин теоретик фәннәрне укыту бик түбән дәрәҗәдә кала. Мәктәпне земствога күчергәннән соң, укучылар саны кискен арта. 1871 дә яңа устав кертелә, аңа туры китереп, мәктәпкә башлангыч белеме булган яшүсмер егетләрне алалар; 4 ел дәвамында алар гомуми һәм мед. фәннәрен өйрәнәләр, укуның бишенче елында практика узалар. Аларны университет тәмамлаучылар һәм югары квалификацияле табибләр укыта. 1871–89 да мәктәпне ел саен 15–20 кеше тәмамлый. 1887 дә яңа устав кертелә, аның буенча кыз балалар өчен бүлекләр ачу һәм белем цензын күтәрү карала: мәктәпкә тулы булмаган урта белем б-н кабул итә башлыйлар, күпчелек ир балалар шәһәр уч-щесен тәмамлаганнан соң, кыз балалар — гимназиянең 4–5 сыйныфын тәмамлаганнан соң керәләр. Фельдшерлыкка уку срогы 3 ел була, күпчелек кыз балалар тагын 1 ел акушерлык эшенә өйрәнәләр.

20 йөз башына кадәр мәктәп Идел буе, Урал һәм Себер губерналарына хезмәт күрсәтә, укучыларның барысы да диярлек хөкүмәт органнары — земство һәм учреждение стипендиатлары була. 1890–1914 тә 173 ир-ат (ш.и. якынча 20 татар) һәм 507 хатын-кыз фельдшер әзерләнә, шуларның 276 сы акушерлык белгечлеген ала (15 тән артыгы — татар хатын-кызлары). Мәктәпне тәмамлаучыларның барысы да диярлек земство һәм башка авыл мед. оешмаларында эшлиләр. Мәктәп Җәмәгать тәрбиясе приказының (соңрак — земствоныкы) Казан хастаханәсендә (*Адмиралтейство конторасы бинасында*) урнаша.

**КАЗА́Н ЗООБОТА́НИКА БАКЧАСЫ́**, мәдәни-агарту оешмасы. 1931 елда Казан ун-тының зоология бакчасы һәм *ботаника бакчасы* коллекцияләре нигезендә оеша. Бирге Кабан һәм Аргы Кабан күлләрен берләштергән Ботаника ермагының көнчыгыш яры буенда урнаша. Мәйданы 8 *га*.

Ботаника коллекциясе 700 дән артык төр үсемлекне берләштерә. Фонд оранжереяның 5 бүлегендә урнаша: 2 бүлектә — субтропик (аларның берсе — пальмалар бүлеге — биек, биредә, зур пальмалардан тыш, ылыслы үсемлекләр экспозициясе урын ала), өченче бүлектә — тропик үсемлекләр, абагалар, бромелиячалар, ароидчалар һ.б.; дүртенчедә — кактуслар һ.б. суккулентлар; бишенчедә (килүчеләр өчен ябык) геснериячәләр, бегонияләр, коммелиначалар һ.б. 60 төр Халыкара Кызыл китапка (IUCN), 20 төр Россиянең Кызыл китабына кертелгән. Су үсемлекләре өчен бассейн, 2 теплица бар, аларда исә үсемлекләр сату өчен үстерелә.

Зоол. коллекциясе хайваннарның 150 дән артык төрен (680 берәмлек) үз эченә ала, аларның исә 22 төре — Халыкара Кызыл китапка, 12 төре СССРның Кызыл китабына кертелгән. К.з.б. ак аюлар һәм ерткыч кошлар үрчетү буенча махсуслаша. Биредә сирәк төрләр: зубрлар, ак тырнаклы аю, леопард, юлбарыслар уңышлы үрчи. 1991 дә үләт бөркете нәсел бирә (әлеге төрнең токтында үрчүе, Познань зоопаркыннан соң, икенче очрак). Хайваннарның сирәк төрләрен (күзлекле аю, кара гриф) үрчетү һәм тоту буенча К.з.б. Европа программасында катнаша.

1806 да проф. К.Ф.Фукс инициативасы б-н оештырылган Казан ун-тының ботаника бакчасы башта ун-т ишегалдында урнаша. 1829 да ун-т тарафыннан Архангел бистәсендә җир участогы алына һәм анда А.А.Бунге җитәкчелегендә яңа ботаника бакчасы төзелә (аңа нигез салучы — П.Я.Корнух-Троицкий). Казанда зоол. бакчасын оештыруда беренче омтылыш 1890 да — Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте тарафыннан, икенчесе — 1920 дә Губерна музее инициативасы б-н ясала. 1925 тә, «Табигать сөючеләр» фәнни түгәрәге студентларының активлыгы б-н Казан ун-ты каршында зоол. почмагы оеша, ул исә К.з.б.ның нигезе була. Аны оештыручылар арасында — түгәрәк әгъзалары А.А.Першаков, И.С.Башкиров (бакчаның беренче директоры), Н.Д.Григорьев (аннан соңгы директоры), В.П.Теплов (соңрак Печора-Илыч һәм Ока саклаулыкларына җитәкчелек итә), ТАССР Үзәк музее директоры Н.И.Воробьёв һ.б. 1968 дә оренжерея яңартып төзелә, аның биеклеге һәм мәйданы арттырыла. Хайваннарны ачык вольерларда тоту өчен зооботаника бакчасын киңәйтү карала. К.з.б. 1996 дан Европа зоопарк һәм аквариумнар ассоциациясе (EAZA), 1997 елдан Евро-Азия зоопарклар һәм аквариумнар төбәк ассоциациясенең (EARAZA) хакыйкый әгъзасы.


Илл. к. 78 нче биттә.

*Әд.:* Башкиров И. Казанский зоологический сад // Тр. студен. науч. кружка «Любители природы» в г.Казани. 1929. Вып. 3; Эсмонт М. Казанский ботанический сад // шунда ук. С. 159–165; Казанский зооботанический сад: Путеводитель. К., 1957; Смирнова В.В. Казанский ботанический сад: Путеводитель. К., 1974; Гильмутдинов Р.Я., Мударисов А.Р., Малёв А.В. Казанский зооботсад: вчера, сегодня, завтра: Путеводитель. К., 2004.

*Р.Я.Гыйльметдинов, А.Р.Мөдәрисов, А.В.Малёв.*

**КАЗА́Н ЗУР ДРА́МА ТЕА́ТРЫ** (Казан Зур рус драма акад. театры, В.И.Качалов исем.). Россиядә иң өлкән драма театрларыннан берсе, рус драма сәнгате тарихында мөһим урын алып тора. Рус провинциаль театры сәхнәсендә революцион-романтик һәм реалистик юнәлешләр урнашуга булышлык итә, Казан ун-ты б-н берррәттән төбәк терр-ясендәге иҗтимагый хәрәкәттә демократик тенденцияләрнең формалашуына, җәмгыятьнең мәдәни үсешенә зур өлеш кертә.


1791 елдан эшли башлый. Император театрлары дирекциясе рөхсәте б-н Казан губернаторы кенәз С.М.*Баратаев* тарафыннан оештырыла; труппаның беренче сәнгать җитәкчесе — актёр В.Р.Бобровский. 1802–1919 елларда шәһәр хакимияте күзәтүе астында хосусый антреприза сыйфатында яшәп килә, 1919 дан — дәүләт театры (Совет Зур театры,



**Казан зооботаника бакчасы мәкаләсенә.** 1. Үзәк керү урыны; 2. 100 яшьлек казак артышы; 3. Иенке саговник; 4. Канар хөрмә пальмасы; 5. Сары пахистахис; 6. 150 яшьлек биек трахикарпус; 7. Ак иңбашлы каракош; 8. Үләт бөркете; 9. Сүрия (Кавказ арты) көрән аюы; 10. Ак аю; 11. Лапундер (дуңгыз койрыклы макак); 12. Барс (ирбис).

Зур драма театры, 1996 дан хәзерге исемдә). 1924–29 да — А.В.Луначарский, 1948 дән В.И.Качалов исемендә. 1919 елгы янгынга кадәр Театр мәйданындагы (хәзер Ирек мәйданы) үз бинасында урнашкан була, 1919 дан — Зур Проломный (хәзер Бауман) урамындагы элекке Г.А.Розернберг Зур театры бинасында (исеме шуннан килә). К.З.д.т. эшли башлаган елларыннан ук алдынгы карашлы, демократик рухлы рус интеллигенциясе идеяләре йогынтысында формалаша. Театрның антрепренёрлары, актёрлары тамашачыны рухи яктан баетуга, киң җәмәгатьчелекнең игътибарын көнүзәк әһәмиятле проблемаларга юнәлдергән югары сәнгати репертуар булдырырга тырышалар; реалистик башкару манерасын алга сөрәләр. Аның сәхнәсендә А.П.Сумароков, В.А.Озеров, Д.И.Фонвизин, Я.Б.Княжнин пьесалары куела. Театрның репертуарына, беренчеләрдән булып (1836 да), А.С.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» («Горе от ума» — спектакльдә катнашучылар арасында яшь башкаручы П.М.Садовский да була), Н.В.Гогольнең «Ревизор» (сәхнәгә куючы — М.С.Щепкин) пьесалары кертелә. А.Н.Островский, А.Ф.Писемский, А.В.Сухово-Кобылин, А.К.Толстой, И.С.Тургенев, Ф.М.Достоевский, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов әсәрләре театрның яшәү дәверендә аның сәхнәсеннән төшми уйнала. Театр ш.у., беренчеләрдән булып, М.Горький («Фома Гордеев», 1902), В.В.Маяковский («Мистерия-буфф», 1923), П.С.Романов («Җир тетрәү» — «Землетрясение», 1924), Б.С.Ромашов («Кабарып пешкән бәлеш» — «Воздушный пирог», 1925; «Криворыльскның бетүе» — «Конец Криворыльска», 1926), М.А.Булгаков («Зойка фатиры» — «Зойкина квартира», 1927) әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә. Аның репертуарында дөнья классикасы әсәрләре дә шактый гына урынны алып тора: У.Шекспир, Ж.Б.Мольер, Ф.Шиллер, К.Гуцков, К.Гольдони, Г.Лессинг, Лопе де Вега, П.Кальдерон, П.Бомарше, Г.Ибсен, Г.Гауптман, Э.Ростан пьесалары. 19 йөздә –20 йөзнең 1 нче яртысында яшәп иҗат иткән күренекле рус актёрларының барысы да диярлек Казан театры сәхнәсендә эшләп ала: П.С.Мочалов, А.Е.Мартынов, Н.К.Милославский, М.Т.Иванов-Козельский, Ф.П.Горев, Н.Х.Рыбаков, П.В.Самойлов, П.М.Свободин, А.Н.Каширин, И.М.Шувалов, Н.А.Никулина, Г.Н.Федотова, В.Ф.Комиссаржевская, М.В.Дальский, И.Н.Певцов, И.А.Слонов, В.С.Зотов; С.-Петербургтагы Александра исем. һәм Мәскәүдәге Кече театрлар сәхнәләрендә уйнаган күп кенә мәшһүр артистлар чыгышлары б-н Казаннан була: М.А.Решимов, А.А.Рассказов, А.И.Стрелкова, Х.И.Таланова, В.И.Виноградов, В.А.Макшеев, В.Н.Давыдов, К.А.Варламов, М.Г.Савина, П.А.Стрепетова, М.И.Писарев, А.П.Ленский; Мәскәү Художество театрына В.И.Качалов б-н Н.Н.Литовцева чакыртып алына. Казанда Н.Н.Синельников, И.А.Ростовцев, Н.Н.Соловцов, А.И.Каниннарның режиссёрлык һәм антрепренёрлык эшчәнлеге башлана. Бередә Ю.М.Юрьев беренче тапкыр Чацкий һәм Хлестаков рольләрен башкара, Казан М.М.Тарханов, Е.О.Любимов-Ланской, Н.И.Собольщиков-Самариннарның иҗат юлларында да мөһим этап булып тора.

Рус актёрлары һәм антрепренёрлары арасында мәшһүрләрдән саналган П.М.*Медведев* 15 ел дәвамында монда антреприза тота, Казан театрының чәчәк ату чоры һәм опера тамашаларының даими күренә башлавы (1874) аның исеме б-н бәйле. Режиссёрлык эшчәнлеге әлеге шәхес иҗатында аерым бер урын алып тора, провинциаль сәхнәдә ул беренче тапкыр спектакль куеп карый, төрле сәхнә алымнарыннан файдалана, актёрлар ансамбле хисабына бербөтен сәнгать әсәре тудырырга омтыла. П.М.Медведев булдырган эстетик принципларга соңыннан М.М.Бородай, Н.И.Собольщиков-Самарин, А.П.Двинский, В.С.Зотов кебек антрепренёрлар һәм режиссёрлар да таяна.



В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры.

1919 елгы янгыннан соң, Казан драма театры хәзерге урынына — элекке Зур театр бинасына күчә. Беренче 5 ел дәвамында театр б-н В.С.Зотов идарә итә. Театр каршында З.М.Славянова җитәкчелегендә Татар театр техникумына (хәзер Казан театр уч-щесе) башлангыч биргән студия (бүленеп, 1961 елга кадәр эшли) булдырыла. Казан театрында беренче театр труппасы оеша, төп составны студияне тәмамлаучылар тәшкил итә. Труппада С.П.Вадова, П.Л.Вульф, А.Г.Георгиевский, В.С.Зотов, А.М.Кречетов, В.И.Окунева, Л.В.Развозжаев, Ю.В.Соболев, Е.А.Степная, В.В.Чарский эшли; студияне тәмамлаучылар арасында В.В.Белокуров, М.М.Белоусов, Е.Е.Жилина, В.В.Кропотов, М.В.Романычева, Н.М.Север бар. Репертуарында А.С.Грибоедов, Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, А.К.Толстой, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, М.Горький, Л.Н.Андреев, А.Н.Толстой, С.А.Найдёнов, А.В.Луначарский, П.С.Романов, В.В.Маяковский пьесалары була.

Алдагы унъеллыкта (1924–34) тормышның актуаль проблемаларын, илкүләм иҗтимагый үзгәрешләрне яктыртуга сәләтле, эшче-крәстиян тамашачы ихтыяҗын канәгатьләндерерлек яңа сыйфатлы театр оешу процессы бара. Заманча драматургияне үзләштерүгә, рев. чоры кешесе, соц. җәмгыять төзүче образларын иҗат итүгә юнәлеш алына. Бу елларда И.Ю.Шлепянов, Р.В.Распопов, В.А.Шестаков, Г.Л.Миллер, С.С.Серёжин кебек рәссамнар б-н бергәләп иҗат иткән режиссёрлар — Л.Ф.Лазарев, Ф.А.Строганов, С.Н.Воронов, В.А.Нелли-Влад, И.А.Ростовцев, А.Л.Грипич, В.А.Чиркин, А.М.Самарин-Волжский — Казан театрының алга таба төп сәнгати үсеш юнәлешен билгеләүче шактый гына спектакльләр куялар. Алар арасында иң уңышлылары: А.М.Файконың «Люль күле» («Озеро Люль», 1925, реж. Л.Ф.Лазарев) һәм «Доцент Янбулатов» («Человек с портфелем», 1928, реж. С.Н.Воронов), Н.Р.Эрдманның «Мандат» (1926, реж. Л.Ф.Лазарев); Б.С.Ромашовның «Кабарып пешкән бәлеш» («Воздушный пирог», 1925, реж. Л.Ф.Лазарев) һәм «Криворыльскның бетүе» («Конец Криворыльска», 1926, реж. Ф.А.Строганов), Б.А.Лавренёвның «Разлом» (1928, реж. С.Н.Воронов); В.М.Киршонның «Рельслар гүләве» («Рельсы гудят», 1929, реж. А.Л.Грипич) һәм «Могҗизалы эретмә» («Чудесный сплав», 1935, реж. А.М.Самарин-Волжский), А.И.Безыменскийның «Ату» («Выстрел», 1929, реж. И.А.Ростовцев), А.Н.Афиногеновның «Сәер кеше» («Чудак», 1930, реж. П.И.Герага), В.В.Вишневскийның «Беренче атлы армия» («Первая Конная», 1930, реж. А.Д.Дикий), Н.Ф.Погодинның «Минем дустым» («Мой друг», 1933, реж. П.П.Сазонов) әсәрләре. В.Э.Мейерхольдның конструктивизм идеяләре, сәхнәгә куюдагы тәҗрибәләре йогынтысында булган Казан театры үзенчәлекле формалар эзли, гадәти булмаган сәхнә чишелешләренә мөрәҗәгать итә, болар классик әсәрләрне сәхнәләштергәндә аеруча ачык чагыла; алар арасында Н.В.Гогольнең «Ревизор» (1933, реж. В.А.Чиркин), А.Н.Островскийның «Яшенле яңгыр», («Гроза», 1928, реж. А.Л.Грипич) һәм «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», 1934, реж. В.А.Чиркин), Л.Н.Толстойның «Мәгърифәт җимешләре» («Плоды просвещения», 1928, реж. А.Л.Грипич), А.П.Чеховның «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», 1929, реж. А.Л.Грипич), М.Горькийның «Мещаннар» («Мещане», 1929, 1932, реж. И.А.Ростовцев) пьесалары буенча куелган спектакльләр аерым бер урын алып тора. 1924/25 еллар сезонында труппаның нигезен Мәскәү «Комедия» (элекке Корш) театры, 1930/31 дә күчмә «Кызыл факел» («Красный факел») театры актёрлары тәшкил итә; Казан театры труппасында М.Ф.Астангов, П.И.Герага, Ф.В.Григорьев, С.И.Днепров, А.В.Емельянов, М.И.Жаров, Е.Е.Жилина, З.Н.Минаева, А.Л.Павлова, Н.Н.Соснин, М.И.Царёв, Е.В.Черник, М.А.Юрьева эшли. 1934 тә адм. җитәкчелекнең башында театрның атаклы оештыручысы Г.Д.*Ригорин* тора. Ул даими труппа, тотрыклы репертуар булдыруны, спектакльне сәхнәгә кую һәм рольне башкару культурасының югары дәрәҗәгә җитүен максат итә. Театрның җитештерү базасы, сәхнә «тартмасы» үзгәрә башлый, сәхнә җиһазы алмашына. Берничә ел дәвамында илнең иң эре сәнгать коллективлары арасында лаеклы урын тоткан труппа оеша. Аның составында Г.П.Ардаров, А.М.Борелин, В.Н.Вешнякова, Ф.В.Григорьев, А.Д.Гусев, Е.Е.Жилина, И.В.Загорский, О.Л.Коханский, Н.Е.Лесная, Е.В.Лисецкая, Д.Р.Любин, А.В.Люлюкин, Я.Б.Мацкевич, Л.П.Милова, И.В.Никулин, П.И.Ососков, М.Н.Преображенская,











**В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры.** Спектакльләрдән күренешләр: 1. В.П. Катаев, «Чишеп булмаслык мәсьәлә турында» (1928) (сулдан икенче – М.И. Жаров); 2. Л.И. Славин, «Интервенция» (1933); 3. А.Н. Островский, «Кайнар йөрәк» (1943); 4. А.Н. Толстой, «Иван Грозный» (1945); 5. А.П. Чехов, «Өч сеңел» (1951); 6. М.А. Шолохов романы буенча «Күтәрелгән чирәм» (1963); 7. У. Гибсон, «Булыргамы, булмаскамы?» (1976) (сэр Томас – Е.А. Кузин, Анна – Л.Б. Кара-Гяур, Уилл – В.В. Кешнер); 8. Н.В. Гоголь, «Ревизор» (1994) (Марья Антоновна – Е.Е. Ненашева, Городничий – А.В. Калаганов, Анна Андреевна – М.В. Кобчикова); 9. Д. Стайн, Д. Бок, «Түбәдәге скрипкачы» (1998).

Н.П.Спиридонов, П.А.Цветаев, М.В.Шейнин, Н.И.Якушенко була. Спектакльне сәхнәгә куюу эшен рәссам В.С.Никитин, музыка өлешен М.И.Климов, Э.Д.Черкасский кебек композиторлар башкара. Репертуарның нигезен рус классикасы һәм совет драматургиясенең аеруча әһәмияткә ия булган әсәрләре тәшкил итә. Сәхнәгә кую эшенә Л.М.Прозоровский («Кремль курантлары» — «Кремлёвские куранты», Н.Ф.Погодин, 1940), В.М.Бебутов («Маскарад», М.Ю.Лермонтов, 1943), А.Д.Дикий («Кайнар йөрәк» — «Горячее сердце», А.Н.Островский, 1943; рәссам А.А.Осмёркин), Е.Г.Гаккель («Ревизор», Н.В.Гоголь, 1944; рәссам К.Ф.Юон) кебек дәрәҗәле режиссёрлар һәм рәссамнар җәлеп ителә. Чынбарлык күренешләрен тирән гәүдәләндерү, романтик пафос һәм күтәренке рух б-н сугарылганлык, күмәк башкару һәм актёрларның искиткеч оста уйнаулары театрның иң уңышлы спектакльләрен аерып күрсәтергә мөмкинлек бирә. Алар арасында В.В.Вишневскийның «Оптимистик трагедия» («Оптимистическая трагедия», 1936, реж. А.Д.Треплев), Л.Н.Рахмановның «Профессор Полежаев» (1938, реж. Г.П.Ардаров), А.Н.Островскийның «Урман» («Лес», 1937) һәм «Соңгы корбан» («Последняя жертва», 1938, икесен дә сәхнәгә куючы Б.С.Великанов), М.Горькийның «Васса Железнова» (1939, реж. Б.Э.Ниренбург), У.Шекспирның «Отелло» (1938, реж. А.Д.Треплев) әсәрләре бар. 1939 ның җәендә Мәскәү һәм Ленинградта театрның гастрольләре зур уңыш б-н уза. Театрның сәнгать җитәкчесе вазифасын башкарган реж. Е.Г.Гаккель Бөек Ватан сугышы елларында В.А.Соловьёвның «Фельдмаршал Кутузов» (1941, төп рольдә Ф.В.Григорьев) һәм А.Е.Корнейчукның «Фронт» (1942) спектакльләрен куя; Г.П.Ардаров К.М.Симоновның «Рус кешеләре» («Русские люди», 1942), Б.Э.Ниренбург Л.М.Леоновның «Ябырылу» («Нашествие», 1943) әсәрләрен сәхнәләштерәләр; Е.А.Простовның «Бик күптәннән» («Давным-давно», А.К.Гладков, 1943) пьесасы буенча куйган спектакле Казан сәхнәсендәге дебюты була (төп рольләрдә Л.П.Милова һәм А.Д.Гусев). Театр сәхнәсендә танылган поляр очучы М.В.Водопьяновның «ДД полкы» («Полк ДД», 1942, реж. Е.Г.Гаккель) һәм «Мәҗбүри рәвештә җиргә төшү» («Вынужденная посадка», 1944, реж. Н.А.Зорин) пьесалары буенча спектакльләр куела. Театр актёрлары концерт бригадалары составында Төньяк-Көнбатыш, Ленинград, Карелия фронтларына хәрәкәт итүче армиягә бара торган булалар.

Аннан соңгы елларда театрның сәнгати юнәлеше Н.А.Медведев, Е.А.Простов, Л.М.Литвинов, И.С.Петровский, Э.М.Бейбутов кебек режиссёрларның эшчәнлегеннән чыгып билгеләнә. Труппа Казан театры ансамблен баеткан Л.С.Шмидт, В.М.Павлова, Г.А.Жарков, В.И.Стебаков, Г.А.Бальян, И.А.Мокеев, П.В.Кормунин, Н.С.Проворотов, Б.В.Лохин кебек актёрлар б-н тулыландырыла. Театр каршында яңадан студия эшли башлый, аны тәмамлаучылар традицияләрне буыннан-буынга тапшыруны тормышка ашырырга тиеш була. Бу елларда уйналган спектакльләр кеше характерларының асылына төшенү, аларны төрле яклап ачарга омтылу, вакыйгаларның масштаблылыгы һәм фәлсәфи тирәнлеге ягыннан аерылып тора: «Иван Грозный» (1945, А.Н.Толстой), «Газап чигеп йөрү» («Хождение по мукам», 1947, А.Н.Толстой), «Анна Каренина» (1948, Л.Н.Толстой), «Тормыш төбендә» («На дне», 1949, М.Горький), «Лейпциг, 1933» (1951, Л.В.Компанейц, Л.И.Кронфельд), «Үле җаннар» («Мёртвые души», 1952, Н.В.Гоголь), «Иделдә йокы» («Сон на Волге», 1953, А.Н.Островский; сәхнәгә куючы Е.А.Простов), «Өч сеңел» («Три сестры», 1951, А.П.Чехов), «Ис әйдә, җил, ис!» («Вей, ветерок!», 1951, Я.Райнис), «Порт-Артур» (1953, А.С.Степанов, И.Ф.Попов), «Урманда» («В лесах», 1958, П.И.Мельников-Печерский; сәхнәгә куючы Л.М.Литвинов), «Үз балаларының әнисе» («Мать своих детей», 1955, А.Н.Афиногенов), «Фабрика кызы» («Фабричная девчонка», 1957, А.И.Володин; сәхнәгә куючы И.С.Петровский), «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» («Юность буревестника», 1955, М.Н.Елизарова), «Үлмәс җыр» («Бессмертная песнь», 1956, Р.Ишморат), «Карт» («Старик», 1956, М.Горький; сәхнәгә куючы Э.М.Бейбутов).

Актёрлар эшенең гаҗәеп байлыгы б-н аерылып торган спектакльләрнең шактые рус театрының күренекле казанышлары була; аларда реж. фикеренең төптән уйланылган һәм анык булуын, сәнгатьчә матурлыкка ирешүдә күптөрле сәхнә чараларыннан файдалануны күздә тоткан режиссурага өстенлек бирелә. Драматургия материалын эзләү дәвам итә, театр еш кына проза әсәрләренә дә мөрәҗәгать итә, Казан, ш.и. татар авторлары (к. *Репертуар*) б-н дә актив эшли. Театрның 1952 елда Мәскәүдәге гастрольләре, ш.у. Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында катнашуы (1957) аның, чыннан да, илнең әйдәүче театрлары исәбендә булуын ачык күрсәтә. 1948 дә театрга СССРның халык артисты В.И.Качалов исеме бирелә, 1957 дә коллектив Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1960–70 елларда Казан театрында актёрлар буыны алышына, өлкән буын осталарына алмашка В.И.Улик, Ю.И.Карева, Г.Е.Егоров, П.С.Маслов, В.Н.Расцветаев, П.П.Бетев, Г.И.Ишкова, Ю.А.Коршок, В.Г.Остропольский, М.В.Кобчикова, С.Е.Ярмолинец, Л.Б. һәм Е.Н.Кара-Гяурлар, студияне тәмамлаучылардан Е.А.Кузин, Л.В.Маклакова, И.И.Чернавина, А.А.Кичигин, В.В.Кешнер, Ю.С.Федотов килә. Театр эстетикасы да үзгәрешләр кичерә, В.С.Никитинның сәнгати-поэтик бизәү рәвеше Э.Б.Гельмс, Т.И.Сельвинская, Д.Л.Бобровскийларның метафорик образлы композицияләре б-н алышына. Репертуарда заманча драматургия әйдәүче урынны били. Әлеге чордагы аеруча әһәмиятле һәм уңышлы спектальләр — «Күтәрелгән чирәм» («Поднятая целина», 1963, М.А.Шолохов романы буенча; реж. О.Э.Лебедев), «Туй көнендә» («В день свадьбы», 1964, В.С.Розов; реж. А.М.Ханович), «Җинаять һәм җәза» («Преступление и наказание», 1965, Ф.М.Достоевский романы буенча; реж. Г.Л.Андреев), «Зыковлар» («Зыковы», 1966, М.Горький), «Варварлар» («Варвары», 1972, М.Горький), «Мунча», «Качу» («Баня», В.В.Маяковский; «Бег», М.А.Булгаков — икесе дә 1967; сәхнәгә куючы Н.Ю.Орлов), «Гадәт буенча җыелу» («Традиционный сбор», 1967, В.С.Розов; реж. В.М.Стрижов), «Караклар балы», «Медея» («Бал воров», 1968; «Медея», 1969, Ж.Ануй; сәхнәгә куючы В.М.Миллер), «Озату» («Проводы», 1975, И.М.Дворецкий), «Булыргамы, булмаскамы?» («Быть или не быть», 1976, У.Гибсон; сәхнәгә куючы В.М.Портнов), ш.у. сәхнәгә куелышы һәм башкарылуы ягыннан Казан театры өчен гадәти булмаган «Ә ничек король буласың?» («А как будешь королём», Т.Новак; сәхнәгә куючы Польша реж. Я.Нычак) спектакле — барысы да иҗтимагый аңдагы үзгәрешләрне һәм чынбарлыкны сәхнә югарылыгында гәүдәләндерүдә яңача карашларны чагылдыралар. К.з.д.т.нда ш.у. татар драматургларының пьесалары да куела («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин, 1969, реж. Ш.М.Сарымсаков; «Әниемнең ак күлмәге», Ш.Хөсәенов, 1978, реж. М.Х.Сәлимҗанов). 1980 еллардагы – 1990 еллар башындагы аеруча уңышлы эшләре арасында «Ак таулар турында төш» («Сон о белых горах», 1982, В.П.Астафьевның «Патша балык» — «Царь-рыба» повесте буенча; сәхнәгә куючы С.Е.Ярмолинец) һәм «Эш» («Дело», 1986, А.В.Сухово-Кобылин; сәхнәгә куючы С.Е.Ярмолинец), «Фёдор патша» («Царь Фёдор Иоаннович», 1988, А.К.Толстой; сәхнәгә куючы Е.Д.Табачников) һәм «Мәрхүмне искә алу догасы» («Поминальная молитва», 1992, Г.И.Горин; сәхнәгә куючы Е.Д.Табачников), «Мастер һәм Маргарита» (1989, М.А.Булгаков романы буенча; сәхнәгә куючы С.В.Таюшев) һәм «Текә маршрут» («Крутой маршрут», 1989, Е.С.Гинзбург; сәхнәгә куючы С.В.Таюшев) спектакльләрен күрсәтергә мөмкин. Сәхнәгә кую эшенә чит ил режиссёрлары да чакырыла: М.Мандель (ГФР) — «Мария Стюарт» (1990, Ф.Шиллер), К.Фётрие (Франция) — «Дон Жуан» (1993, Ж.Б.Мольер).

1990 елларның 2 нче яртысы — Казан театрының иҗади үсеш кичерү чоры. Ул яңадан халыкара һәм бөтенроссия театр фестивальләрендә катнаша, гастрольләргә чыга башлый, театрга карата тамашачының кызыксынуы кискен арта. Үзенең иҗат тарихында беренче тапкыр театр коллективы спектакльләр б-н чит илләргә чыга: Каһирә (Мисыр, 1996) һәм Марсель (Франция, 1997–2001 елгы рус сезоннарында театр ел саен катнашып килә). Бу еллардагы аеруча игътибар үзәгендә булган спектакльләр массакүләм сәхнәләрнең сыгылмалылыгын, зәвыклылыгын, үткен драматизм б-н көчле тамаша күрсәтүнең бергә үрелеп баруын, пространствоны конструктив-метафорик чишелештә хәл итә алуын чагылдыра: «Ревизор» (1994, Н.В.Гоголь), «Банкрот» (1996, А.Н.Островский), «Хәтәр йомыркалар» («Роковые яйца», 1997, М.А.Булгаков повесте буенча), «Түбәдәге скрипкачы» («Скрипач на крыше», 1998, Д.Стайн, Д.Бок мюзиклы; ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2000), «Пики дамасы» («Пиковая дама», 1999, А.С.Пушкин повесте буенча), «Өч тиенлек опера» («Трёхгрошовая опера», 2001, Б.Брехт, К.Вайль), «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», 2004, А.П.Чехов), «Глумов» («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр» — «На всякого мудреца довольно простоты», 2007, А.Н.Островский), «Абзыкай төше» («Дядюшкин сон», 2008, Ф.М.Достоевский повесте буенча), «Бөек комбинатор» («Великий комбинатор», 2009, И.Ильф, Е.Петровның «Унике урындык» («Двенадцать стульев») романы буенча).

1996 да «академия театры» исеме бирелә. 2011 дә театр труппасында РФнең халык артистлары В.В.Кешнер, С.Г.Романова, Г.Н.Прытков; РФнең атказ. артисты Ф.М.Пантюшин; ТРның халык артистлары М.О.Галицкий, ТРның атказ. артистлары А.А.Иванова, Д.А.Огарёва, И.И.Чернавина, Е.И.Галицкая, И.А.Славутский, М.В.Голубев, Э.Ф.Фәрдиева һ.б. була. 1994 елдан театрның баш режиссёры, 2007 дән сәнгать җитәкчесе-директоры — РФнең халык артисты А.Я.Славутский, баш рәссамы — РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе һәм ТРның халык рәссамы А.М.Патраков.

*Әд.:* Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**КАЗА́Н ИЗГЕЛӘРЕ́**, Казан епархиясе терр-ясендә шөһрәт казанып һәм биредә аеруча ихтирам ителеп, Рус Православие чиркәве тарафыннан рәсми рәвештә изгеләштерелгән руханилар. 4 (17) октябрьдә Казан изгеләре бәйрәм ителә; епархия чиркәүләрендә билгеле көннәрдә үткәрелгән гыйбадәт вакытында һәркайсының исемнәре искә алына. 16 йөз ахырында *Гурий, Варсонофий, Герман*, газап чигүчеләрдән Аврамий (Болгарский), *Иоанн, Пётр, Стефан*, 1913 тә *Гермоген* канунлаштырылалар. 1990 елларның 2 нче яртысында изгеләргә тиңләштерелгән *Иона* һәм *Нектарий*, *Гавриил* (Зырянов) һәм совет чорының күпсанлы газап чигүчеләре — Казан митрополиты *Кирилл* (Смирнов), Амбросий (Гудко), *Елантау монастыреның шәһит киткән изгеләре*. *Раифа шәһитләре*, Димитрий Шишокин, *Филарет* (Великанов) канунлаштырылалар.

*Әд.:* Никанор (Каменский). Казанский сборник статей. К., 1910; Месяцеслов казанских святых. К., 2002.

**КАЗА́Н ИКЪТИСАДЧЫЛА́Р ҖӘМГЫЯТЕ́** (Император карамагында), иҗтимагый оешма. Ирекле икътисад оешмасы президенты граф Н.С.Мордвинов инициативасы б-н 1839 елда нигез салына. Оештыручылар арасында — Н.Д.Булыгин, П.И.Еремеев, Н.И.Лобачевский, М.Н.Мусин-Пушкин, А.К.Пирх, С.С.Стрекалов, К.Ф.Фукс. 1879 да җәмгыятьтә 109 әгъза була; төрле елларда: С.Е.Алексацдров, М.М. һәм Х.М.Апанаевлар, И.К.Бабст, А.М.Бутлеров, Н.П.Вагнер, М.Я.Киттары, Д.А.Корсаков, А.А.Крупеников, И.Мостафин, С.В.Пахман, А.С.Унженин, А.К.Чугунов, Г.Юнысов һ.б. Җәмгыять уставы (1868 дә кабул ителә) максатын — Идел-Чулман төбәгендә авыл хуҗалыгын, сәнәгатьне һәм сәүдәне үстерүгә, халык сәламәтлеген саклауга булышлык итү, дип билгели. Җәмгыять әгъзалык взнослары, аерым кешеләр, губерна хакимияте, земстволар, башка учреждениеләр биргән акчалар исәбенә яши. Президент, вице-президент (1869 дан), бүлекчә рәисләре, сәркәтип, казначей составындагы президент советы җитәкли. Баштарак 5 бүлекчәдән тора: эчке идарә, фәнни эшләр; авылда йорт эшләре алып бару һәм җир эшләрен камилләштерү; төрле кул эшләре һәм сәүдә; кеше һәм төрле йорт хайваннары сәламәтлеген саклауны кайгырту; 1868 дән — 3 бүлекчә: а.х., мануфактура-техник һәм мед. 1840 та җәмгыять каршында җир эшкәртү кораллары һәм машиналары депосы, күрсәтмә өйрәнү фирмалары һәм китапханә ачыла, 1894 тә умартачылык һәм бакчачылык буенча гамәли курслар оештырыла. 1845 тә җәмгыять Казан губернасында беренче мәртәбә «авыл хуҗалыгы җитештермәләре» күргәзмәсен ача (аннары Казанда күргәзмәләр — 1852, 1860, 1866, 1880 дә). 1848 дән Рус география җәмгыяте б-н берлектә Казан губернасында метеорология күзәтүләре алып бара. Җәмгыять әгъ-

залары авылдагы хуҗалар (Мәскәү, 1864), табигатьне өйрәнүчеләр (С.-Петербург, 1867) һ.б. съездларда катнашалар. 1880 нән җәмгыять даими рәвештә чәчү орлыклары күргәзмәләре, орлыкларны бушлай бирүне оештыра, күргәзмәләрнең каталогларын чыгара. К.и.җ. көче б-н Казан губернасы а.х. хуҗалары съездлары үткәрелә (1882, 1893), аларда авыл хуҗалыгын үстерү, яңа а.х. техникасын һәм туфрак эшкәртү алымнарын, җир эшләренең яңа формаларын куллануның икътисади нәтиҗәлелеген, крәстиян терлекләрен яхшырту мәсьәләләре тикшерелә, губернада а.х. производствосын камилләштерү өчен өр-яңа агротехник эшләнмәләр тәкъдим ителә. Җәмгыять «Записки Императорского Казанского экономического общества» ж-лын нәшер итә, анда К.и.җ. эшчәнлеге турында отчетлар, утырышларның беркетмәләре, а.х. производствосын камилләштерү, сәнәгатьне һәм сәүдәне үстерү буенча фәнни-практик тикшеренүләрнең нәтиҗәләре басыла, өр-яңа агрономик белемнәр һәм агротехник алымнар пропагандалана һ.б. 1865 тән Казан губернасы эшлекле даирәләренең үзенчәлекле реклама белешмәсе — «Справочная книга для записей предложений и спроса» нәшер итә. Җәмгыять әгъзалары крәстиян хуҗалыклары, җирләрне эшкәртү формалары, авыл һөнәрчелек сәнәгате, авыл хуҗалыгында яллы хезмәттән файдалану, 1891 елгы ачлыкның сәбәпләре турында (Мәскәү а.х. җәмгыяте б-н бергәләп) материаллар җыю һ.б. б-н шөгыльләнә (аларның бер өлеше 1851, 1852, 1853, 1854 елларда «Путевые заметки из поездок по Заволжью»да басыла). 1894 тә К.и.җ. С.-Петербургта үткән халыкара җиләк-җимеш үстерү күргәзмәсендә Казан губернасы исеменнән катнаша. 1866 елда җәмгыять әгъзаларының актив катнашында Казанда халыкка мед. ярдәме күрсәтүче Александров хастаханәсе ачыла. 1900 еллар башында үз эшчәнлеген туктата. К.и.җ. президентлары: С.С.Стрекалов (1839–42), С.П.Шипов (1842–46), П.А.Чертов (1846–47), И.А.Боратынский (1847–58), П.Ф.Козлянинов (1858–64), М.К.Нарышкин (1864–67), Н.А.Скарятин (1867–78), А.Г.Осокин (1878–88), С.Н.Теренин (1888–98), А.П.Мамаев, А.И.Косич.

*Әд.:* Олферьев Н.И. Краткий исторический обзор действий Казанского экономического общества со времени основания до 1853 года // Зап. Казан. Имп. экономического об-ва. 1854. Ч. 1, кн. 1–2; Чугунова А.К. К пятидесятилетию Императорского Казанского экономического общества: Ист. записка. К., 1889; Утехин Н.В. Общие задачи Императорского Казанского экономического общества. К., 1905; Смыков Ю.И. Казанское экономическое общество и проблема сельскохозяйственной техники в Среднем Поволжье (40–90-е гг. 19 в.) // Очерки истории народов Поволжья и Приуралья. К., 1967. Вып. 1; Записки Казанского экономического общества 1854–1861 гг.: Указ. содерж. К., 1990.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КАЗА́Н ИСКЕ́ ДИ́Н ТАРАФДАРЛАРЫ́ ЕПА́РХИЯСЕ**, к. *Казан-Вятка епархиясе.*

**КАЗА́Н ИТ КОМБИНАТЫ́**, азык-төлек сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 650 кеше (2009). 1993 елдан АҖ. 1937 дә Яңа Татар бистәсендә 1892 дә төзелгән шәһәр терлек сую урыны җирлегендә оештырыла. Элек шәһәр читендә эшләп килгән һәм тирәлекне, бигрәк тә эчәргә яраклы суны пычрату чыганакларына әверелгән 10 хосусый терлек сую урыны ябыла. 1950 еллар ахырыннан комб-тның матди-техник нигезен яңарту башлана.

Хәзерге вакытта пр-тие заманча технол. базага ия, ул ТРдагы 10 ит комб-ты арасында иң эресе санала. Казан халкын төп ит һәм ит продуктлары б-н тәэмин итүче. Азык-төлек товарлары б-н бергә техник эшләнмәләр җитештерә. Төп продукциясе — терлекнең барлык төрләре ите һәм субпродуктлары, 100 дән артык исемдә казылык эшләнмәләре, 20 дән артык исемдә ит ярымфабрикатлары, ш.и. фарш, гуляш, пилмәннәр, котлетлар, рагу һәм аш пешерү өчен ашханә ярымфабрикатлары, эретелгән майлар, натураль казылык тышчасы, коры терлек азыклары, техник майлар, тиреләр, мед. сәнәгате өчен махсус һәм эндокрин-ферментлы чимал һ.б. 2009 да җитештерелә (мең *т* ларда): 1 нче категория ит һәм субпродуктлар — 2,6, казылык эшләнмәләре — 5,8, ит ярымфабрикатлары — 0,5, эретелгән майлары — 0,1, коры терлек азыклары — 0,4. 1990 елларга кадәр продукция дөньяның 13 иленә (Кубага, Венгриягә, Франциягә һ.б.) чыгарыла. 2000 елларда продукциясе ТР һәм Мәскәү кулланучыларына җибәрелә.

Җитештерү күрсәткечләре буенча 1968–89 да К.и.к. күп тапкырлар шәһәрдә, республикада һәм тармакта призлы урыннар били. «Алгарыш хакына партнерлык» халыкара программасында катнашуы өчен 1996 да К.и.к.на «Алтын пальма» бүләге һәм призы бирелә. 1999 да «Россиянең иң яхшы 100 товары» Бөтенроссия конкурсында К.и.к. 5 дипломга, «Иң яхшы азык-төлек продукциясе — 2000» конкурсында 3 нче дәрәҗә дипломга һәм бронза медальгә лаек була. Күп кенә хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре, ш.и. 1 кешегә Соц. Хезмәт Герое исеме бирелә, 200 дән артык кеше орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: Н.А.Таркаев (1961–65), В.В.*Кусов* (1965–91), М.Ш.*Хөсәенов* (1991–99), Р.Р.Гайзатуллин (1999 дан).

*И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н КАЙМАСЫ́**, СССР Оборона дәүләт ком-тының 1941 ел 13 октябрь карары нигезендә Казанны немец-фашист гаскәрләренең ихтимал булган һөҗүменнән саклау өчен оештырылган инженерлык ныгытмалары системасы. Төзелеш җитәкчеләре: Ф.М.Ковальский, И.М.Ильина, А.П.Баранников һ.б. Саклану чиге Казан тирәсендә ярымбоҗра булып урнаша. Чуашстан һәм Татарстан терр-яләре буйлап Покровка авылыннан Урмары, Кайбыч, Апас авыллары аша Куйбышев шәһәренә (ТАССР) кадәр сузыла. К.к.ның озынлыгы 331 *км*, ш.и. 151 *км* танк үтмәслек тирән чокырлар, 79,61 *км* эскарплар, 1,96 *км* контрэскарплар тәшкил итә. 392 идарә-командалык һәм күзәтү пункты, 98 яшерен ату ноктасы, танкка каршы ата торган 45 *мм* лы туплар өчен — 44 дзот, 76 *мм* лы туплар өчен 12 дзот, 419 землянка төзелә. Корылмалар бик авыр шартларда (каты салкыннар), нигездә, колхозчылар көче белән төзелә. Анда ш.у. хезмәткәрләр, эшчеләр, мәктәп балалары һәм студентлар да катнаша. Казанны саклау корылмаларында иң күбе 107 мең кеше (1941 нең декабре) катнаша. 1942 нең 11 февралендә К.к. дәүләт комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Немец-фашист гаскәрләре Мәскәү янында тар-мар ителгәч (1941–42), консервацияләнә.

*В.Ф.Телишев.*

**КАЗА́Н КАЛЬГАСЫ́**, к. *Казан Кремле.*

**КАЗА́Н КАНТОНЫ́**, к. *Арча кантоны.*

**КАЗА́Н КАПКАЛАРЫ́**, 15 йөз — 16 йөзнең 1 нче яртысында Казан кирмәненә (Кремльгә) керү юллары-капкалары. Саклану өчен аеруча мөһим урыннарда шәһәр диварлары чатлары булып хезмәт итүче хәрби манаралар эшләнгән. Казан ханлыгы чорында К.к. берничә тапкыр (1505, 1530, 1546, 1551) үзгәртеп корыла. Хан кальгасы (цитадель) капкалары: Нурали, Алабуга, Су капкасы, Көбәк; бистәләр ягындагылар: Хан, Зур, Көрәеш, Арча, Нугай, Төмән, Кырым, Аталык һ.б. *Казанның яулап алынуы* (1552) вакытында җимерелгәннәр. Күп манараларның археол. калдыклары өйрәнелмәгән диярлек. Ш.у. к. *Казан Кремле.*

*Әд.:* Калинин Н.Ф. Казань. К., 1955; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

*И.Л.Измайлов.*


**КАЗА́Н КЕ́ТГУТ ЗАВОДЫ́**, к. «*Татхимфармпрепаратлар*».

**КАЗА́Н КИЕ́З ИТЕ́К-КИЕ́З КОМБИНАТЫ́**, к. «*Валком*».

**КАЗА́Н КИНОХРО́НИКА СТУ́ДИЯСЕ**, хроникаль-документаль характердагы кинофильмнар әзерләүче иҗат пр-тиесе. 1961 елдан үзенең җитештерү базасы булган мөстәкыйль оешма сыйфатында эшли башлый (РСФСР мәдәният министрлыгының 1961 елның 3 июнь 589 нчы приказы нигезендә). «*Таткино*» һәм 1932 дә «Союзкинохроника»ның Татарстан бүлеге итеп үзгәртелгән («Союзкинохроника»ның Татарстан җитештерү базасы) «*Востоккино*» Татарстан бүлегеннән башлангыч ала. 1936 да Татарстан җитештерү базасы К.к.с. дип, 1939 дан СССР ХКС каршындагы Кинематография эшләре ком-тының Хроникаль-документаль фильмнар җитештерү баш идарәсенең Казан хроникаль-документаль фильмнар студиясе дип үзгәртелә. 1942 дән Казан студиясе «Идел буе» («Поволжье») документаль киножурналы өчен сюжетлар төшерү б-н шөгыльләнүче Куйбышев документаль фильмнар студиясенең кинохәбәрче пункты итеп үзгәртеп корыла. «Партизаннарга бүләкләр» («Подарки партизанам», 1942, № 1), «Икмәк — җиңү коралы» («Хлеб — оружие победы», 1943, № 6), «Алар кайттылар» («Они вернулись», 1946, № 8), «Төнлә ашлык сугу» («Ночная молотьба», 1947, № 44), «Идел аша нефтьүткәргеч» («Нефтепровод через Волгу», 1956, № 12), «Сугыш җирләре буйлап» («По местам боёв», 1958, № 37), «Айдагы ракета» («Ракета на Луне», 1959, № 36) һ.б. сюжетлар тө-

шерелә. Казан кинематографистлары, ш.у. «Кадерле кунак» («Дорогой гость», 1943), «Орденлы Чувашия» («Орденоносная Чувашия», 1945), «Мари Республикасы» («Марийская Республика», 1946), «Рак һәм аның белән көрәш» («Рак и борьба с ним», 1947), «Авыл укытучысы» («Сельская учительница», 1948), «Совет Мордовиясе» («Советская Мордовия», 1949), «Казан университетына 150 ел» («Казанскому университету 150 лет»,







1. «Совет Татарстаны» (1930); 2. «Нәҗип Җиһанов» (1969); 3. «Тамырлар» (1999), фильмнарыннан кадрлар.

1954), «Совет Татарстаны сәнгате» («Искусство Советской Татарии», 1957), «Татарстан нефтьчеләрендә» («У нефтяников Татарии», 1959) һ.б.ш. документаль фильмнар төшерә. 1961 дән СССР Мәдәният министрлыгы системасында Казан киностудиясе оеша. Беренче директоры — А.Н.Краев; режиссёрлары — К.Х.Поздняков, Н.И.Лебедев, В.П.Невежин, В.Ф.Савельев, Ю.А.Карамышева, А.С.Стремяков, В.В.Стрелков, Ш.М.Сарымсаков, Х.Ф.Фәхретдинов, Э.Х.Үтәгәнов, Н.К.Вәлитов, М.А.Разбежкина, В.Е.Игнатюк; операторлары — К.Ф.Мотков, В.И.Севастьянов, В.А.Кузьмин, А.Г.Привин һ.б. Киностудия каршында мультучасток булдырыла (мультипликацион сюжетлар һәм фильмнар төшерү б-н шөгыльләнүче бүлекчә), нәфис фильмнарны дубльләштерүче, фильмнарны татар, башк., удмурт, мари һәм мордва телләренә тәрҗемә итүче группа оеша, Йошкар-Ола, Чабаксар, Саранск шәһәрләрендә хәбәрчелек пунктлары булдырыла. «Фуджи» һәм «Кодак» (2000 нән) тибындагы кинопленкаларны кайнар эшкәртү буенча яңа җитештерү-технол. процессы, компьютер монтажы системасы кертелә. Студия «Киң Иделдә» («На Волге широкой») исемле хроникаль-документаль киnож-л (1994 кә кадәр елына 36 номер чыга торган була), «Татарстан» киноелъязмасы ж-лын (1997 дән, елына 12 чыгарыш), «Идел буе округлары: көн артыннан көн» («Поволжские округа: день за днём») киноальманахын (2004 тән) чыгарып килә. Киностудиянең их яхшы эшләреннән — «Эрьзя» (1966), «Габдулла Тукай» (1969), «Җылылык юллары» («Дороги тепла», 1973), «Җәлил. Көрәш сәхифәләре» («Джалиль. Страницы борьбы», 1976), «КамАЗ — ул без» («КамАЗ — это мы», 1977), «Сабан туена барганда» («Дорога на сабантуй», 1980), «Татарстан нефтьчеләре» («Нефтяники Татарии», 1982), «Рәссам Иван Шишкин» («Художник Иван Шишкин», 1982), «Түбән Кама варианты» («Нижнекамский вариант», 1984), «Ялкынланып яныгыз» («Взвейтесь кострами», 1985), «Ә сезнең ишегалдында?», «Исәнме, Лёша!» («А у вас во дворе?», «Здравствуй, Лёша!», 1987), «Бу аңлап булмый торган Галимҗанов» («Этот непонятный Галимзянов», 1988), «Үземне мин кызгана белмим ...» («Себя жалеть я не умею...», 1989), «Терек су» («Вода живая», 2000), татар телендә «Күктау» нәфис фильмы (2002), «Казан планетасы» («Планета Казань», 2003), «Минем Казаным» («Моя Казань»), «Алмаз Монасыйпов — Казаным ... Казаным ...», «Алабуга, яки Марина турында төш» («Елабуга, или Сон о Марине») — барысы да 2005 елда. К.к.с.дә төшерелгән кинофильмнар күп тапкырлар халыкара, бөтенсоюз, бөтенроссия кинофестивальләрендә катнаша, призларга һәм бүләкләргә лаек була.

*Әд.:* А л е к с е е в  И. Рубежи кинодокументалистов Татарии. К., 1974; Казань: Спец. вып. 2001. № 9/10; А л е к с е е в а  Е. Сила традиции. Из истории кино в Татарстане // Казань. 2004. № 7.

*Е.П.Алексеева.*

**КАЗА́Н КОММЕ́РЦИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, уку системасы буенча гимназия һәм реаль уч-щеләргә альтернатив, коммерция юнәлешле дәүләтнеке булмаган урта уку йорты. 1896 елдан коммерция уч-щеләре турындагы Нигезләмә нигезендә Казан шәһәре думасы инициативасы б-н 1905 нең гыйнварында ачыла. Рус һәм татар буржуазиясе вәкилләреннән төзелгән Попечительләр советы җитәкчелек итә. К.к.у. абруйлы уку йорты була, анда, башлыча, хәлле түрәләрнең, профессорлар, эшмәкәрләр, татар сәүдәгәрләренең уллары укый. Училищене тәмамлаучыларның яртысы диярлек коммерция ин-тларына, калганнары университетларга һ.б. югары уку йортларына керә. Тәмамлаучылар арасында Ш.С.*Алкин*, Г.М.*Рәхим* бар. 1918 дә училище урта мәктәп итеп үзгәртелә. Архитекторлар П.П.Голышев һәм В.А.Трифонов проекты буенча 1905–08 дә төзелгән йортта урнашкан (хәзер Казан а.х. академиясе бинасы, архит-ра истәлеге).

*Әд.:* Десятилетие Казанского коммерческого училища. 1905–1915. К., 1916.

**КАЗА́Н КОМПРЕ́ССОР МАШИНАЛАРЫ́ ТӨЗУ́ ЗАВОДЫ́** («Казанькомпрессормаш»), үзәктән кугыч һәм винтлы компрессорлар, суыткыч машиналар һәм алар җирлегендә җайланмалар җитештерү буенча РФнең әйдәп баручы пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 2400 дән артык кеше (2010). Казан компрессорлар з-ды 1946 елда төзелә башлый. 1951 дә завод беренче продукциясен — кислород сәнәгате өчен 220 $кг/см^2$ басымлы, минутка 1,5 $м^3$ кысылган һава бирүче пешкәкле компрессорлар эшләп чыгара. 1955 тә үзәктән кугыч һава компрессорларын җитештерү башлана. 1957 дә завод составында компрессорлар төзү буенча махсус КБ (к. *Үзәктән кугыч һәм роторлы компрессорлар институты*) оештырыла. 1958 гә компрессорлар эшләүнең тулы циклын колачлаган цехлар файдалануга тапшырыла; проектта каралган куәткә (елга 400 ләп компрессор) ирешелә. 1950 еллар ахырыннан завод зур суыту егәрлекле машиналар җитештерүне үзләштерүгә керешә. Киң колачлы үзгәртеп корулар (1959–65) нәтиҗәсендә яңа производство куәтләре булдырыла; гамәлдәгеләрне техник җиһазландыру дәрәҗәсе күтәрелә; төрле типтагы фреон, аммиак, һава (СССРда беренче тапкыр) турбосуыткыч машиналарын, төрле технол. газлар өчен махсус пешкәкле компрессорларны, үзәктән кугыч куәтле циркуляцион компрессорларны күпләп чыгару җайга салына. Җитештерү күләме 4 тапкырга арта. Завод продукциясе СССРның металлургия, химия, нефть химиясе, тау-казылмалар, текстиль сәнәгате пр-тиеләрендә күп кенә технол. процессларны модернизацияләүдә зур роль уйный. Компрессорлар гражданнар һәм хәрбиләр судноларында, су асты көймәләренең күмелү, зур биналарның (Мәскәүдәге «Россия» кунакханәсе, «Останкино» телеүзәге) вентиляция һәм кондиционерлар системаларында һ.б.да кулланыла. Югары дәрәҗәдәге җитештерү җиһазлары эшләүдәге казанышлары һәм 1959–65 еллар 7 еллык планын вакытыннан алда үтәгәне өчен завод коллективы Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1970–80 елларда җитештерү-техник базасын модернизацияләү барышында яңа производство корпуслары, заманча сынау һәм приборлар җиһазлары б-н тәэмин ителгән сынау станциясе төзелә, яңа производстволар оештырыла. Яңартылган технол. паркның югары җитештерүчәнлеген автомат һәм ярымавтомат металл кискеч, тимерчелек-пресслау, эретеп ябыштыру җиһазлары; ш.и. санлы программа б-н идарә ителүче станоклар, бинаның термик шартларын көйләүле аеруча төгәл (тайпылыш чиге микронгача) прецизион металл кисү станоклары тәшкил итә. Автоматлаштырылган проектлау системасы, компрессорларның корыч һәм

титаннан эшләнгән көпчәкләрен эретеп ябыштыру, роторларның эш вакытында әйләнүен махсус «Шенк» станокларында (ГФР) баланслау, табаклы корычны лазер б-н кисү, чуенның бакыр б-н легирланган яңа коелмасын файдалану буенча прогрессив технологияләр эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Бу исә продукцияне күпләп җитештерү өчен күбесе илдә һәм дөньяда беренче булган мөһим техник чишелешләрне табу мөмкинлеге бирә: 1972 дә завод нефть-газ һәм тау-казылмалар сәнәгатендә, эл. станцияләрендә кулланылучы югары басымлы винтлы компрессорларны күпләп җитештерүгә керешә, 1973 тә атм. һавасын файдаланып эшләүче экологик һәм икътисади яктан өстенлекле турбосуыткыч машиналар проектын әзерләп, аларны эшләп чыгара башлый. 1980 еллар башында төрле газлар өчен махсус КБ тарафыннан эшләнгән унификацияләнгән компрессорларның типик үлчәмнәрдәге рәтләре гамәлгә кертелә, бу исә кыска вакыт эчендә зур егәрлекле эре технол. комплекслар һәм җайланмалар булдыру мөмкинлеге бирә. Халык хуҗалыгында бензинны каталитик чистарту җайланмаларында һәм дизель ягулыкларын гидрочистартуда, ш.у. синтез-газ агрегатларында («Дрессер-Кларк» фирмасы лицензиясе буенча, АКШ, 1983) кулланылучы югары басымлы үзәктән кугыч компрессорлар зур әһәмияткә ия, аларны гамәлгә кертү нәтиҗәсендә илдә азот к-тасын һәм азотлы минераль ашламаларны күпләп җитештерү оештырыла. СССРда беренче тапкыр нефтьне газлифт ысулы б-н чыгару (бер үк вакытта 140 скважинадан 6 мең *т/сәг.*, 1981) һәм нефтьнең иярчен газларын һәм сәнәгатьтә файдаланылган газларны җыю буенча эре компрессор станцияләре (1982), нефть газын җыю өчен блок-контейнер рәвешендәге тиз урнаштырыла торган «ТАКАТ» җайланмалары эшләнә (1988). Төрле елларда пр-тие ш.у. газларны суыту һәм бүлү детандерлары, редукторлар, кислород тутыру станцияләре, халык куллануы товарлары (спорт инвентаре, мебель фурнитурасы) чыгара. 1986–91 дә завод ТАССРдагы махсус җиһазлар җитештерүче 6 машина төзү з-дыннан һәм 3 фәнни-тикшеренү ин-тыннан оештырылган «Казанкомпрессормаш» ФҖБнең баш пр-тиесе була. 1996 да хәзерге исемдәге АҖ итеп үзгәртелә һәм үзгәртеп корыла. Составына үзәктән кугыч һәм винтлы компрессорлар з-длары, кою-әзерләү һәм сынау комплекслары, тышкы эшләр хезмәте, «ТАКТ» сәүдә йорты һ.б. бүлекчәләр керә. 1990 елларда «Волга» газ кудыру агрегатлары өчен басым тудыру җайланмалары, агросәнәгать комплексы өчен компрессорлар һәм турбосуыткыч машиналар, 1998 дән космоска очыру җайланмаларының термостатлау системаларына кысылган һава бирү компрессорлары чыгару үзләштерелә. 2000 елларда газ-турбиналы двигательләрнең яну камераларына ягулык газ бирүче төрле үзәктән кугыч һәм винтлы газ җайланмаларын, ш.и. Казандагы ТЭЦ — 1 өчен Россиядә беренче тапкыр ахыргы басымы 4,5 *МПа* булган «ТАКАТ» җайланмасын эшләп чыгару үзләштерелә. «Түбәнкаманефтехим» АҖ өчен бутил-каучук җитештерүдә хлорлы метилны кысучы үзәктән кугыч уникаль җайланма, «ТАИФ-НК» АҖнең бензин з-ды өчен илдә беренче мультипликаторлы үзәктән кугычлы компрессор (җитештерүчәнлеге — 1000 $м^3$/мин.ка кадәр) эшләнә. Кислород, сероводород һ.б. газларны кысу өчен файдаланучы югары нәтиҗәле үзәктән кугыч компрессорларның яңа буынын эшләп чыгару башлана. Пр-тиенең төп продукциясе арасында — һаваны, инерт һәм технол. газларны кысып тутыру өчен 45 *МПа* басымлы һәм 1,5 тән 200 $м^3/мин$ ка кадәр җитештерүчәнлекле, төрле типтагы күчергечле



Казан компрессор машиналары төзү заводы. Административ корпус.

үзәктән кугычлы һәм винтлы компрессорлар; аммиак, пропан, һаваны 40–10000 *Квт* аралыгында –120 °С ка кадәр суытучы турбосуыткыч җайланмалар; 2–16 *МПа* басымда газларны бүлү өчен детандер-компрессор агрегатлары; комплектлау һәм запас частьләр. Пр-тие куллануга җибәрелгән эшләнмәләрен монтажлау һәм аларга хезмәт күрсәтү б-н шөгыльләнә, ш.у. илдә һәм чит илләрдә эшләнгән насос-компрессор җиһазларына экспертиза, диагностика ясау, төзәтү эшләрен башкара. К.к. м.т.з. эшләгән елларда 40 мең берәмлектән артык төрле компрессор һәм суыту техникасы җитештерелә. 1955 тән завод продукциясе халыкара базарга чыгарыла һәм 50 дән артык илдә файдаланыла. Россиядә җитештерелгән компрессор техникасының 20% тан артык өлеше завод тарафыннан эшләп чыгарыла. Продукцияне Россиядә, якындагы чит илләрдә, Кытайда нефть эшкәртү һәм нефть чыгару, машиналар төзү, газ транспортлау, металлургия пр-тиеләре, ш.и. «Сибур», «Татнефть», «Газпром», «Роснефть», «Лукойл», «ТАНЕКО» компанияләре куллана. Пр-тиенең эшләнмәләре Брюссельдәге Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсендә «Гран-при»га (1958) һәм Лейпциг ярминкәсендә Зур алтын медальгә (1979) лаек була, 7 тапкыр СССР ВДНХсында күрсәтелә. Продукциянең югары сыйфаты һәм чит илләрдәге заказчылардан дәгъвалар булмаганы өчен заводка күп кенә халыкара призлар — «Африка призы» (Мадрид, 1993), «Актив коммерция өчен приз» (Париж, 1994) «Алтын глобус» (Копенгаген, 1994), «Продукция сыйфаты өчен» (Женева, 1995), Европа халыкара конвенциясенең «Алтын йолдыз» сертификаты (Париж, 1993) бирелә. 1994–2000 дә ИСО-9001 халыкара сыйфат стандартлары системасын гамәлгә кертү буенча эш башкарыла һәм тиешле сертификат алына. 2005 тә К.к.м.т.з. «Россия Милли Олимпы» дипломы б-н бүләкләнә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 11 кеше — СССР МС бүләге лауреатлары; 3 кешегә — ТАССР, ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе, 15 кешегә — РСФСР, ТАССР, ТРның атказ. машина төзүчесе, 1 кешегә — ТАССРның атказ. сәүдә хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә; 5 кеше — Ленин ордены, 3 кеше — Октябрь Революциясе, 40 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 кеше — Халыклар дуслыгы, 57 кеше — «Почёт билгесе», 33 кеше — «Хезмәт даны», 1 кеше — Дуслык, 1 кеше — «Хезмәт Байрагы» (ГДР), 1 кеше — «Болгариянең Алтын Ордены», 1 кеше — «Грюнвальд хачы» (Польша) орденнары б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: П.Н.Горин (1948–58), А.А.Абецедарский (1958), Т.С.*Ломакин* (1958–70), Р.А.Моратов (1970–73), Ә.М.*Галиев* (1973–96, 1986–91 дә «Казанкомпрессормаш» ФҖБ ген. директоры), Ю.М.Русаков (1986–91), И.Г.*Хисамиев* (1996 дан). Ш.у.к. *Компрессорлар төзү*.

*Әд.:* Тутаев М.З., Худяков В.П. Казанский компрессорный завод. К., 1979; 50 лет ОАО «Казанькомпрессормаш». К., 2001.

*Ә.М.Галиев, С.Г.Белов.*

**КАЗА́Н КОНСЕРВАТО́РИЯСЕ**, Н.Г.Җиһанов исемендә. РФнең Мәдәният һәм кинематография федераль агентлыгы карамагындагы югары уку йорты. РСФСР ХКС карары б-н 1945 елның 13 апрелендә ачыла. 1945–88 дә ректоры Н.Г.*Җиһанов* була, 2001 дә консерваториягә аның исеме бирелә.

Уку йорты ачылганнан бирле фортепиано, оркестр, хор дирижёрлыгы, вокал ф-тлары эшләп килә, 1948 дә теоретик-композиторлык, 1961 дә халык музыка уен кораллары ф-тлары ачыла, 1972 дән органда уйнау өчен әзерлек курслары алып барыла. 1989 да татар музыкасы кафедрасы эшли башлый, 1995 тә татар музыка сәнгате ф-ты оештырыла.

Төрле елларда консерваториядә композиторлар: А.С.Леман, Г.И.Литинский, М.Ә.Мозаффаров, Р.М.Яхин, Л.З.Любовский; опера режиссёрлары Н.К.Даутов, Н.И.Якушенко; вокалистлар: З.Г.Байрашева, В.А.Воронов, Е.Г.Ковелькова, В.А.Лазько, З.Г.Хисмәтуллина, К.Е.Цветов; симф. оркестр дирижёрлары Ф.Ш.Мансуров, Н.Г.Рахлин, Җ.Г.Садриҗиһанов, И.Э.Шерман; хор дирижёрлары: М.А.Юдин, А.Ф.Бормусов, С.А.Казачков; пианистлар: В.Г.Апресов, Г.М.Коган, Л.Г.Лукомский, М.Д.Берлин-Печникова, М.А.Пятницкая, Э.А.Монасзон; кыллы уен кораллары буенча: С.З.Басовский, Н.А.Брауде, А.Б.Броун, Б.В. Каплун, А.М.Лукацкий, Г.Х.Ходжаев; тынлы уен кораллары буенча: Д.К.Антонов, А.П.Баранцев, А.Г.Геронтьев, Н.Г.Зуевич, Е.И.Карпухин, А.П.Колпинский, Ш.Г.Низаметдинов, Л.М.Шлеймович; баянчылар: В.П.Плетнёв, А.В.Тихонов, И.И.Шәрипов, А.И.Шутиков; музыка белгечләре: Х.И.Булатова-Терегулова, Ю.В.Виноградов, Я.М.Гиршман, Г.Я.Касаткина, Ч.Н.Бәхтия-

рова, Г.М.Кантор, Й.Н.Исәнбәт һ.б. укытучылар укыта.


К.к.ндә 1,3 меңнән артык белгеч әзерләнә. Алар арасында композиторлар: Р.З.Ахиярова, Ф.Ә.Әхмәтов, Ә.З.Бакиров, Р.Н.Белялов, Х.В.Вәлиуллин, С.Ә.Гобәйдуллина, Р.Ә.Еникиев, Р.Ф.Кәлимуллин, О.Л.Лундстрем, А.С.Миргородский, А.З.Монасыйпов, Б.Г.Мөлеков, Ш.Х.Тимербулатов, З.Г.Хәбибуллин, М.И.Шәмсетдинова, Ш.К.Шәрифуллин, И.Д.Якупов, М.З.Яруллин; пианистлар: Л.И.Әхмәтова, Т.Г.Әхмәтов, Э.К.Әхмәтова; скрипкачылар: М.Г.Әхмәтов, Ю.Ю.Виват, Г.Н.Крушельницкий, Г.З.Степанов; тромбонист Г.З.Ройтфарб; вокалистлар: Л.Г.Башкирова, Р.Г.Билалова, В.Ә.Ганиева, Р.И.Ибраһимов, Р.З.Ильязов, И.Д.Ишбүләков, М.В.Казаков, Р.Х.Мифтахова, Э.Г.Трескин, А.С.Фадеичева, И.Г.Шакиров; хор дирижёрлары: Н.Г.Җүрәева, Л.Г.Кустабаева һ.б. бар.

*Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры, Татар опера* һәм *балет театры, Татарстан Республикасының җыр* һәм *бию ансамбле,* Татарстан һәм Идел буе республикаларының башка әйдәп баручы коллективларының төп өлешен консерваторияне тәмамлаган белгечләр тәшкил итә.

Укыту — уен коралларында уйнаучылар (фортепиано, орган, клавесин, арфа, кыллы оркестр уен кораллары, тынлы һәм бәрмә оркестр уен кораллары, халык уен кораллары), дирижёрлык итү (опера-симфония, академик хор), вокал сәнгате (академик һәм халык җырларын башкару), композиция, музыка белеме, этномузыкология, балет педагогикасы белгечлекләре буенча алып барыла. 2005 тә көндезге бүлектә — 533, читтән торып уку бүлегендә 71 студент укый, шуларның 52 се бюджеттан тыш нигездә кабул ителә. Студентлар арасында Кытай, Корея, Япония, АКШ вәкилләре дә бар.

К.к.нең 16 кафедрасында 100 гә якын укытучы эшли, алар арасында ТРның 20 дән артык атказ. һәм халык артистлары, 24 профессор һәм 39 доцент, 5 фән. д-ры, 14 фән. канд-ты, ш.и. композиторлар: А.Б.Луппов, Л.З.Любовский, Б.Н.Трубин, А.М.Руденко; дирижёрлар: В.М.Васильев, В.Г.Лукьянов, Р.А.Халитов; вокалистлар: Ю.В.Борисенко, Г.Т.Ластовка, З.Д.Сөнгатуллина; музыка белгечләре: Л.В.Бражник, В.Р.Дулат-Алиев, А.Л.Маклыгин, З.Н.Сәйдәшева, Л.А.Федотова; пианистлар Г.К.Абдуллина, Э.В.Бурнашева, И.С.Дубинина, Е.В.Михайлов, С.Н.Работкин, В.А.Столов, Ю.Ю.Сокольская, В.А.Таганцева; скрипкачылар: М.Г.Әхмәтов, В.А.Афанасьев, Ш.Х.Монасыйпов; альтчы К.Х.Монасыйпов; виолончелистлар А.Ә.Әсәдуллин, А.Н.Хәйретдинов; тынлы уен коралларында уйнаучылар А.Г.Гыйльфанов; органчы Р.К.Абдуллин, баянчылар А.Ю.Протасов, Ә.Ә.Фәйзуллин; думбрачы Г.Ф.Мөхәммәтдинова һ.б. укытучылар бар. Студентларның симф. һәм камера оркестры, халык музыка уен кораллары һәм татар музыкасы оркестры, академик һәм камера хоры, опера студиясе, кыллы квартет һ.б. иҗади коллективлары эшли. 1960 тан консерватория каршында *Махсус урта музыка мәктәбе* эшләп килә.

К.к. музыка сәнгате мәсьәләләрен өйрәнү буенча төбәктә төп фәнни үзәк булып тора. Музыкаль фольклор кабинеты ТР районнарына һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләргә экспедицияләр оештыра. Төп фәнни юнәлешләр: Татарстанның хәзерге музыка мәдәнияте, төрки, фин-угор, славян халыкларының традицион музыка сәнгате һәм аларның үзара йогынтысы, музыка социологиясе, Европа һәм рус музыкасы теориясе һәм тарихы мәсьәләләре, музыка белеме һәм муз. башкару сәнгате проблемалары. 1990 нан редакцияләү-нәшрият бүлеге эшли.



Казан консерваториясе.

«Музыка сәнгате» белгечлеге буенча аспирантура, 2003 тән кандидатлык диссертациясе яклау советы эшләп килә. К.к. китапханәсендә 400 меңнән артык саклау берәмлеге (китаплар, ноталы басмалар, аудио һәм видеоязмалар, ш.и. уникаль кулъязмалар) исәпләнә.

1962 дән консерватория элекке Дворяннар йортына, соңрак КПССның Татарстан өлкә ком-тына караган бинада урнаша (1915–38, арх. С.В.Бечко-Друзин, Р.М.Мортазин); бина архит-ра ядкәре булып тора. 4 концерт залы, 3 орган бар. Укыту базасы сыйфатында *ТРның Зур концерт залы* файдаланыла. 1988 елдан ректоры — Р.К.Абдуллин.

*Әд.:* Казанская государственная консерватория. К., 1998. *Р.К.Абдуллин.*

**КАЗА́Н КООПЕРА́ЦИЯ ИНСТИТУТЫ́**, Россия кооперация ун-ты ф-лы, дәүләтнеке булмаган югары уку йорты. Оештыручысы — РФ Кулланучылар җәмгыяте берлеге үзәге (Центросоюз). 1987 елның октябрь аенда Белгород кооперация ин-тының кулланучылар кооперациясе белгечләре һәм җитәкче хезмәткәрләрнең белемен күтәрү ф-ты булара ачыла. 1989 дан «Мәскәү кооперация институты» кулланучылар кооперациясе фәнни комплексына караган кулланучылар ин-тының Казандагы квалификация күтәрү ф-ты, 1992 дән — Мәскәү кулланучылар кооперациясе ун-тының Казан ф-лы, 1997 дән — институты, 2006 дан — хәзерге исемдә. Кулланучылар кооперациясе өчен бухгалтерлык исәбе һәм аудит, сәнәгать пр-тиесе икътисады һәм идарәсе буенча белгечләр әзерли. 2010 елда уку йортында 1100 ләп студент укый; фәнни-пед. коллективта 50 кеше, ш.и. 6 фән. д-ры һәм 27 фән. канд-ты эшли.

**КАЗА́Н КООПЕРА́ЦИЯ ТЕ́ХНИКУМЫ**, Татарстан кулланучылар берлегенең урта һөнәри уку йорты. 1952 елның июлендә оештырыла. Икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, товар белеме, җәмәгать туклануы продукциясе технологиясе, җәмәгать тукlануында хезмәт күрсәтүне оештыру, кунакханәләр сервисы, икмәк технологиясе, кондитер һәм макарон эшләнмәләр, хокук белеме буенча урта һөнәри белемле белгечләр әзерли. Укыту фәкать коммерция нигезендә генә алып барыла. 2010 да 1100 студент укый (көндезге бүлектә — 720, читтән торып 420). К.к.т. ачылганнан бирле 23 меңгә якын белгеч әзерләп чыгара. Укытучылар коллективында 40 кеше, ш.и. 1 РФнең атказ. укытучысы, 4 ТРның атказ. мәктәп укытучысы эшли. Филиаллары һәм вәкиллекләре Бөгелмә, Буа, Кукмара, Мамадыш, Нурлат шәһәрләрендә урнашкан.

*Әд.:* Баязитов К.С., Шакиров Р.В. Больше века на службе людям (из истории потребительской кооперации Республики Татарстан). К., 1995; Вестергрен И. Партa. Техникум. Профессия // Лидер. 2002. № 6.

**КАЗА́Н КОСТЁЛЫ́** (Католикларның Воздвижение Святого Креста чиркәве). Бина 1855–58 елларда төзелә (арх. П.Т.Жуковский). 1907–08 елларда чаң манарасы һәм элек алтарь урнашкан өлешендә янкорма салына (арх. Л.К.Хрщонович, Л.Л.Хрщонович).

Тәрәзәләре ярымтүгәрәк формада уелган, ал һәм ян-як фасадлары пилястралар б-н нығытылган, түбәсе өчпочмаклы фронтон б-н төгәлләнгән беркатлы бина. Ян-як фасадларга терәлеп, дүртпочмаклы чатыр түбәле, симметрияле, ике катлы, квадрат рәвешендәге ике чаң манарасы урнашкан. Үзгәртеп корганнан соң, костёл Польшадагы католик храмнарга хас типик бинага әйләнә.

1929 елда ябыла. Соңыннан бина Казан авиация ин-тына (хәзер Казан техник ун-ты) тапшырыла һәм хәзер дә аның карамагында. Иске костёлны католиклар җәмгыятенә кабат кайтару мөмкинлеге булмау сәбәпле, 2008 елда Татарстан хөкүмәте акчасына яңа католиклар чиркәве төзелә. Ш.у. к. *Католицизм.*

**КАЗА́Н КӨМЕШЧЕЛӘРЕ́**, 16–19 йөзләрдә кыйммәтле металлардан бизәнү әйберләре җитештерү һәм сату рөхсәт ителгән рус нәфис һөнәрчелек осталары атамасы. Аларга катгый рәвештә Көмешче рәтендә генә сату итәргә рөхсәт ителгән. 18 йөздән аларның эшчәнлеге Көмешче цехы тарафыннан тәртипкә салынган; әйбернең җитештерү урыны күрсәтелгән шәһәр келәймәсе кертелгән, К.к. өчен Елан сурәте — Казан гербы һәм останың инициаллары күрсәтелгән исемле келәймәләр булдырылган. Монастырьлар һәм Архиерей йорты ихтыяҗлары өчен шәһәрнең бистә һөнәрчеләреннән тыш монастырь һәм йорт көмешчеләре дә эшләгән.

1560 елларда Казанда байтак бистә һөнәрчеләре яшәгән. 1566–68 дә төзелгән «Казан һәм өязнең теркәү кенәгәсе» мәгълүматла-

ры буенча, Көмеш рәтендә 17 кибет К.к.неке, ш.и. Мәскәү, Великий Устюг, Владимир, Кострома, башка шәһәрләрдән чыккан Лучка Пахомов, Третьяк Васильев, Рудак Борисов, Угримка Васильев һ.б.ныкы булган, бу исә әйберләрнең сыйфатын һәм стилен дә билгеләгән.

17 йөздә Казан, Зөя шәһәрләрендә, Балык Бистәсе авылында көмеш әйберләр җитештерүче осталарның саны бары Мәскәүдән генә калышкан. Көмешкә уеп бизәк төшерү, каралту һәм аеруча чүкеп бизәк төшерү эше югары сәнгати дәрәҗәдә куелган була. 1652–53 тә патша Алексей Михайлович ярлыгына туры китереп («Мәскәүгә көмешкә уеп бизәк төшерүчеләрне чакырырга һәм дәүләт чиркәве эшенә билгеләргә»), Мәскәү Кремлендәге Успение соборы иконостасы өчен чүкеп бизәк төшерү, алтын йөгертелгән көмеш япмалар әзерләүдә катнашырга Казан һәм Зөядән 9 оста: Афанасий Харламов, Григорий Иванов, Иван Емельянов, Терентий Корнилов һ.б. җибәрелә. Болардан кала, К.к.нең патшага язган үтенеч хатында Казандагы



Шикәр комы өчен чүкеп бизәк төшерелгән савыт. Казан. 1768. Дәүләт Тарих музее. Мәскәү.

митрополит бистәсеннән «үз эшләренең чын осталары» Григорий Семёнов, Родион Андреев һәм Балык Бистәсеннән — Оника Михеев, Степан Васильевның исемнәре дә атала. К.к.нең байтак эшләре хәзер илнең төрле музейларында саклана (Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы, Дәүләт Тарих музее, Дәүләт Рус музее, ТР Милли музее һәм ТР Сынлы сәнгать музее): Казан воеводасы Томила Юдич Луговский өчен эшләнгән көмеш кысалы перламутр чәркә һәм фирәзә б-н бизәлгән көмеш чүмеч (икесе дә — 1630, Дәүләт Тарих музее; көмеш чүмечләр аеруча әһәмияткә ия затлы бүләкләрдән саналган); Казандагы Кизик монастырена нигез салган Казан митрополиты Андриан өчен гравюра ысулында бизәлгән «Кизиктагы 9 газап чигүче» дип язылган көмеш стакан (17 йөз ахыры, Дәүләт Кораллар палатасы). Казанда — Идел буе шәһәрләренең бердәнберендә — үзгә сыйфатлы җепкыр сәнгате үсеш ала: әйберләргә эмаль йөгертелми, стильләре буенча алар Урта Азия яки Греция җепкырына якын тора, мәс., тәхеткә куелган хачның (И.Юркин һәм С.Дмитриев) арты һәм ян-яклары җепкыр б-н башкарылган (1698, Дәүләт Рус музее). К.к.нең 18 йөз әсәрләре арасында — шикәр савыты (1768, Дәүләт Тарих музее), Инҗилнең чүкеп бизәк төшерелгән япмасы (1700, ТР Милли музее), «М.М.» (1790 еллар) һәм «П.М.» (1789–97) монограммалары иярәренең чүкеп бизәк төшерелгән икона япмалары һ.б. бар. Чиркәү китаплары һәм иконалары япмалары рококо стилендәге чәчәкләрдән, җиләк-җимешләрдән һәм үрмә гөлләрдән торган купшы, куе урнашкан калку рельефлы бизәкле күпсанлы фигураларга бай, катлаулы композицияләре б-н аерылып торалар. К.к.нең Дәүләт Тарих музеенда саклана торган стакан һәм кубоклар формаларының тупаслыгы, төшерелгән кеше, кош, җәнлек сурәтләренең примитивлыгы б-н күзгә ташлана.

1839 елда 36 К.к. исәпкә алына, ш.и.: 1821–45 елларда остаханә хуҗасы С.Н.Козлов (эшләнмәләре арасында чүкеп бизәк төшерелгән пута каптырмасы — ТР Милли музеенда); 1824–76 да остаханә хуҗасы Ф.Е.Чернышов (эшләнмәләре арасында — чүкеп бизәлгән икона япмасы — ТР Милли музее тупланмасында); «Е.Ч.» (1837–47) һәм «С.М.О.» (1816) монограммалары иярәре (икесе дә чүкеп бизәлгән икона япмалары аша билгеле).

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Казанда «Казан пробалар тикшерү округындагы алтын һәм көмеш әйберләр б-н эш итүче сәүдә-сәнәгать оешмаларын теркәү китабы» мәгълүматлары буенча, үзенең ялланган эшчеләре һәм өйрәнчекләре б-н эшли торган 60 ка якын көмешче-оста остаханәсе исәпләнгән (Көмеш цехы старшинасы — И.А.Фатьянов). Остаханәләрнең продукция ассортиментында — зәркән эшләнмәләр, аш-су өчен көмеш савыт-саба, дини кирәк-яраклар. Материал (алтын һәм көмеш), башлыча, Мәскәүдән, кайвакыт чит илләрдән, Нюрнбергтан (Германия) алынган. А.Н.Рукавишников (1865–1918, 1890 елда Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсендә «көмеш эшләнмәләрне яхшы җитештергән өчен» Зур көмеш медаль б-н бүләкләнә), И.Е.Разумов (1877–1918, шул ук күргәзмәнең алтын медале), А.А.Прохоров (1898–1915), И.М.Кореньков (1862–?), Ф.М.Павлов (1898–1908), А.Г.Перминов (1898–1918) остаханәләре — аеруча эреләрдән саналган. ТР Сынлы сәнгать музее тупланмасында Ф.С.Козлов хезмәткәрләреннән «Котелмәгән шатлык» һәм «Яхшы хәбәр» иконаларының чүкеп бизәк төшерелгән япмалары, А.И.Кузмичёв хезмәтләреннән «Тихвин Мәрьям Анасы» иконасы оклады саклана.

19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында көмешчеләр остаханәләре өяз шәһәрләрендә дә эшли башлый: Чистайда — 6 (А.П.Мурин — 1909–16, К.Я.Логинов — 1902–07, П.В.Дуванеев — 1903–07 һ.б.), Алабугада — 3 (П.И.Акимов — 1909–16, В.А.Козлов — 1897–1916, А.О.Ситников — 1898–1905), Зөядә — 2 (В.А.Яковлев — 1899–1902, Н.И.Куронов — 1912–15), Тәтештә — 2 (А.Г.Абрамов — 1899–1918, А.А.Абрамов — 1898–1902), Бөгелмәдә — 2 (И.Н.Мосолов — 1899–1902, К.А.Козлов — 1899–1902). К.к. традицияләрен ш.у. *Балык Бистәсе һөнәр-сәнәгать остаханәсе* дә үстерә.

*Әд.:* Постникова-Лосева М.М., Платонова Н.Г., Ульянова Б.Л. Золотое и серебряное дело XV–XX вв. М., 1983; Троицкий В.И. Казанские и свияжские серебряники XVIII в. // Казан. музейный вестн. 1920. № 5/6.

*Е.П.Ключевская.*

**КАЗА́Н КӨ́НКҮРЕШ ХИ́МИЯСЕ ЗАВОДЫ́**, к. *Хитон.*

**КАЗА́Н КРЕ́МЛЕ**, 11–20 йөзләр шәһәр төзелеше истәлеге; 16 йөз уртасы — 20 йөз ахыры архит-ра ансамбле. Казансу елгасы һәм аның сул ермагы — Болак кушылган урындагы биек калкулык борынында чик буе кирмәне буларак барлыкка килә. Соңгы еллардагы археол. казу эшләре хәзерге К.к. терр-ясендә 11 йөздән алып монгол яуларына кадәрге чорда болгар ныгытмалары һәм аннан соң Алтын Урда чоры кирмәннәре урнашканын раслады. 15 йөз башыннан — Казан бәклеге, 1430 еллар ахырыннан — Казан ханлыгы, 16 йөз уртасыннан соң — Казан наместниклыгы, 18 йөз башыннан — Казан губернасы үзәге. Беренче диварлары һәм манаралары агачтан корылган. Археол. мәгълүматлар буенча, 13–14 йөзләрдә ныгытылган мәйданда акташ һәм кирпеч биналар барлыкка килә. Казан бәклеге кирмәне хәзерге К.к.нең төньяк өлешенә урнашкан һәм якынча 400×250 *м* терр-яне алып торган. Көньяктан ул вал өстенә корылган кирмән дивары һәм соңрак Таҗик чокыры исемен алган яр б-н әйләндереп алына. 15 йөз уртасында К.к. кирмәнен яңарту башлана. Кирмән терр-ясен киңәйткәндә аның көнчыгыш дивары — калкулыкның нигезенә, ә көньяк дивары хәзерге чикләренә күчерелә. Казан ханлыгы кирмәне үзенең агач-таш диварлары б-н 13,5 *га* тирәсе терр-яне алып тора; формасы буенча төньяктан көньякка таба сузылган күпкырлы фигураны хәтерләтә. Кремль калкулыгының көнчыгыш сөзәклеге буйлап кирмәннең көнчыгыш өлешен өстәмә ныгыту өчен хезмәт итүче эчке акташ дивар сузылып китә. Аның иң биек ноктасында Хан мәчете, Хан төрбәсе һәм Хан сарае урнашкан була. Археологик казу эшләре нәтиҗәсендә, ханлык чоры кирмәнендә монументаль корылмаларның нинди эзлеклелектә төзелүе ачыкланды. К.к. ныгытмасында беренчеләрдән булып, 15 йөз уртасында, Мәхмүд хан идарә иткән чорда Хан мәчете, 15 йөз ахырында аннан төньяктарак беренче таш Хан төрбәсе, ныгытма үзәгендә Хан сарае төзелгән дип фаразлана. 15–16 йөзләр чикләрендә Хан ныгытмасыннан (цитадель) көньяктарак, Таҗик чокырының төньяк сөзәклеге янында мәдрәсә биналары б-н *Колшәриф мәчете* корыла. Кирмәннең монументаль корылмалар төзелгән төньяк өлеше көньяктан — Таҗик чокыры буйлап, үтеп йөрү манарасы һәм чокыр аша салынган күпере булган акташ дивар б-н тотып алына. 16 йөзнең 1 нче яртысында беренче Хан төрбәсеннән ерак түгел, икенчесе корыла, ш.у. Хан мәчете зурайтыла. 16 йөз уртасында Казанның акташ-агач диварлары, фаразланганча, 6 капкалы кирмәне була. Дүртесенең: Нургали, Сбойливые (татарча исеме билгесез), Алабуга, Хан (Патша) капкаларының исемнәре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Төньяк манарадан кала, капкасыз манараларның саны һәм урнашкан җирләре төгәл билгеле түгел. Хан кирмәнендә, фараз ител-

гәнчә, 12 манара булган. Төньяк-көнбатыштагы Нургали һәм көньяктагы Хан капкаларын бәйләп торучы урам кирмәннең үзәге булып саналган. Археологлар кирмәннең төньяк өлешендә кайбер урамнар һәм тыкрыкларның юнәлешләрен, агач күперләр һәм тыгыз итеп салынган төзелеш нигезләрен ачыклыйлар. Урамнарның киңлеге — 4–5 *м*, тыкрыкларның 2–2,5 *м* тәшкил иткән. Кирмәннең көнчыгыш сөзәклеге итәгендә Алабуга һәм Сбойливые капкаларын бәйләп торган һәм, күбесенчә, күнчеләр, аяк киеме тегүчеләр яшәгән урам урнашкан була. Кирмәндә биек күзәтү манарасы булганлыгы мәгълүм. Аның хан ныгытмасына үтү манарасы яки Таҗик чокыры буендагы күзәтү манарасы булуы ихтимал. Төньяк-көнбатыш сөзәклек өстендә, Нургали манарасына төшә торган урын алдында, ихтимал, хан түрәләренең берсе Нургали бинең сарай комплексы булган. Аның эчендә *Нургали мәчете* урнашкан.

1552 елда Казан Иван IV гаскәрләре тарафыннан яулап алына һәм Казан наместниклыгы үзәгенә әйләнә. 1556 да Казанга Псковтан К.к.нең манараларын һәм диварларын яңадан торгызу өчен И.*Ширяй* җитәкчелегендә 200 ташчы, таш ватучы һәм таш шомартучы җибәрелә. 1556–64 тә арх. И.Я.*Постник* җитәкчелегендә капкалы манаралар, кирмәннең төньяк һәм көньяк өлешләрендә акташтан диварлар төзелә. Рус архит-расы традицияләренә яраклаштырып, кайбер манараларга кечкенә чиркәүләр урнаштырыла һәм аларга яңа исемнәр бирелә. Әйтик, әүвәлге Нургали — Николай (соңрак Тайницкий), Алабуга — Воскресение (Вознесение Христова чиркәве б-н), Сбойливые — Дмитрий (агачтан, Дмитрий Солунский чиркәве б-н), Түбән — Сергий (Сергий һәм Троица чиркәүләре, соңрак Преображение), Хан (Патша) — Спас (Спас Нерукотворный чиркәве б-н) манарасы итеп үзгәртелә. Таштан салынган Никола, Воскресение һәм Сергий манаралары бер яруслы, турыпочмаклы була һәм агач чатыр б-н очлана. *Спас манарасы* кирмәннең төп үтеп йөрү манарасы булып кала. 1552 дән соң, татар кирмәненең мәйданы көньяк диварларны турайту хисабына зурайтыла, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш почмакларында Псков осталары тарафыннан түгәрәк манаралар төзелә. Хан заманындагы квадратлы Төньяк манара нигезендә түгәрәк манара торгызыла. Шул ук вакытта Алабуга һәм Сбойливые манаралары арасындагы көнчыгыш дивар акташтан корылган Көнчыгыш манара б-н ныгытыла. 1565–68 еллардагы Писцовый кенәгә диварның акташтан торгызылган өлеше Хан кирмәненең акташ диварлары калдыкларына 197 имән бура тоташтырылуы турында хәбәр итә. Кирмәннең таш һәм имән диварларының периметры 893 саженьга (1902,1 *м*) җитә. Преображение һәм Никола капкалары арасындагы Көнбатыш түгәрәк манара да агачтан салынган була. Акташ диварлар б-н бер үк вакытта, 1552 нең 6 октябрендә Иван IV тарафыннан нигез салынган беренче агач чиркәү урынына ак таштан *Благовещение кафедраль соборы*, К.к.нең көнбатыш дивары янәшәсендә Никола Ратный чиркәве б-н бергә аш-су палатасы, көнчыгыш диварда тар а́ркалы капка корыла. Таш диварларның өсләре турыпочмаклы тешләр б-н очлана. Кремльнең көньяк-көнбатыш өлешендә 1558 дә нигез салынган Спас-Преображение монастыре урнаша.

16 йөз ахырында Кремльнең агач диварларын кирпечтән яңартырга керешәләр. Кремль терр-ясендә хан заманыннан сакланып калган үзәк урамны тора-бара «Зур урам» дип йөртә башлыйлар. Биредә воеводалар йортлары урнаша. Таҗик чокыры сакланып кала, әмма аның төньягындагы дивар кабаттан торгызылмый. Кремль эчендә Таҗик чокырыннан башка Сергий (Преображение) капкасы янында хан заманындагы саклану системасыннан калган элеккеге ур бар. Спас капкалары каршыннан кайчандыр Кремльне әйләндереп алган урның бер өлеше булган тирән чокыр (Спас исемен ала) уза. Кремльне Иван мәйданы ягыннан әйләндереп алган һәм Казансу елгасы сулары б-н тулган тирән чокырның киңлеге 30 *м*, тирәнлеге 10 *м* була; Спас манарасы каршындагы чокыр аша манаралы зур таш күпер салына. 16 йөзнең 2 нче яртысында К.к. терр-ясендә Зур, Сергий, Дмитрий, Благовещение урамнары һәм күп кенә тыкрыклар барлыкка килә. 1566 да Спас-Преображение монастыренең агач коймасы янында 2 чиркәү: аскы каты таштан салынган агач Преображение һәм аш-су палатасы б-н бергә таш Могҗиза тудыручы Никола чиркәүләре торган. 1596 да аның урынына Преображение соборы төзелә. Спас-Преображение монастыре б-н янәшә 1552 дә Благовещение соборы б-н бер үк вакытта нигез салынган Киприан һәм Иустина чиркәве корыла. Хан кирмәне таш бюналары өлешчә җимерелгән, өлешчә башка максатларда (дары саклау, төрле складлар, казна саклау h.б. сыйфатында) файдаланылган.

16 йөз ахырында агач манаралар һәм диварлар осталар тарафыннан кирпеч һәм ташка алыштырып, осталар К.К.нә куәтле кирмән күренеше өстиләр. Кремль диварларының периметры якынча 1500 *м* тәшкил итә, аларның төрле урыннардагы калынлыгы 4 тән 6 *м* га кадәр үзгәрә, биеклеге 6 дан 8 *м* га кадәр җитә. Дивар өстеннән 0,7–1,2 *м* калынлыгындагы парапетлы 3–5 *м* киңлегендәге хәрби юллар төзелә. Алар ике кыеклы түбә б-н ябыла. Исемсез, Көнбатыш түгәрәк, Көнчыгыш түгәрәк, Дмитрий, Консистория манаралары шул чорга карый. Дүрткырлы 13 манараның 5 се: Спас, Преображение, Никола, Воскресение, Дмитрий манаралары капкалы, ә калган 8 се: Төньяк-көнбатыш, Көньяк-көнбатыш, Көньяк-көнчыгыш, Исемсез, Төньяк, Төньяк-көнчыгыш, Консистория, Күпкырлы манаралар капкасыз була. Әлеге манаралар ату өчен махсус тишекләр уелган 3–5 хәрби ярустан, бойницалардан торган. 17 йөз уртасында Благовещение соборының чаң манарасы төзелә, собор каршында Туп сараена нигез салына. 17 йөздә Хан мәчете урынында Введение Богородицы чиркәве торгызыла.

1708 елда Пётр I фәрманы буенча Казан губернасы оештырыла, Казан губерна шәһәренә әверелә. Кирмәндә шуның б-н бәйле үзгәртеп корулар башлана. Башта калкулык өслегенең чакыр-чокырлы рельефы тигезләнделә. Губернатор сарае элекке Хан сараенда урнаша. Анда кызыл кирпечтән Кремльдән генә түгел, бөтен шәһәрдән дә биегрәк булган җиде яруслы, аркалы манара төзелә. 20 йөз башында аны *Сөембикә манарасы* дип йөртә башлыйлар. К.к.нең якынча төгәл конфигурациясе һәм аның эчендәге биналар һәм корылмалар урнашкан урыннар А.Сацыпёровның 1730 елда натурадан карап ясалган рәсемнәре нигезендә Казан планында чагыла. Кремль калкулыгы бите ул чакта хәзергегә караганда шактый текә була. К.К. аша төньяктан көньякка таба Никола (Тайницкий) манарасыннан Спас манарасына кадәр Зур урам үткән. Воскресение манарасыннан төньяк дивар буйлап аңа таба юл күтәрелгән, алар Введение Богородицы чиркәве янында тоташкан. Көнчыгыштан, Дмитрий манарасыннан Зур урамга таба, Кремль уртасындарак Дмитрий урамы килеп тоташкан. Көнбатыш яктан Преображение капкасыннан Спас-Преображение монастыре коймасының төньяк диварьы буйлап төп урамга таба Преображение урамы якынайган. Планда, алар кисешкән урындарак, коймасыз, бер чиркәүле һәм зур булмаган корылмалары б-н Киприан һәм Иустина монастыре күрсәтелгән. Таҗик чокыры һәм Преображение урамы буйлары күмдерелә. Спас манарасыннан Зур урамның сул ягы буенча Спас-Преображение монастыре, Преображение урамы арьягында — ат абзарлары, йортлар, чиркәүләре һәм мосафирханәләре б-н Троица монастыре комплексы, арырак — Артиллерия йорты урнашкан. Капма-каршы якта, Хан сарае урынында, Дәүләт эшләре сарае һәм Сөембикә манарасы торган. Аңа көньяктан Благовещение соборы һәм Архиерей йорты б-н бергә зур кишәрлек кушылып киткән. Дмитрий урамы аша монастырь приказы бинасы, аннан соң губернатор йорты урнашкан. Ханлык чорындагы күпчелек таш корылмаларны 17–18 йөзләрдә җимерәләр, ә аларның идән асларын күмдерәләр; 1807 дә Хан сарае сүтелә. Введение чиркәве 18 йөз уртасына кадәр эшли, аннары ул дары саклау амбарына әйләнә. 18 йөз башында Спас һәм Тайницкий (Никола) манараларының кирпечтән өске катлары төзелә. Консистория, Преображение манараларының һәм Исемсез манараның өске өлешләре дә кирпеч б-н яңартыла, ату өчен түгәрәк тишекләр ясала. 18 йөзнең 1 нче яртысында Благовещение соборына реконструкция үткәрелә, 18 йөзнең 2 нче яртысында Губерна канцеляриясе, Рухани консистория биналары калкып чыга.

1815 елдагы янгында Кремльдәге консистория, Кабулханә биналары һәм Архиерей йорты янып юкка чыга. Янгыннан соң, юлның уң ягында Кабулханәләр өчен озынча, ике катлы бина корыла. 1812–15 елларда Россиядә иң эре туп кою заводларының берсе урнашкан Артиллерия йорты янына 1840 та арх. П.Г.Пятницкий катнашында ике катлы



**Казан Кремле мәкаләсенә.** 16 йөз уртасы — 20 йөз башы. 1. Казансу елгасы ягыннан Казан Кремле күренеше; 2. Спас манарасы; 3. Никола (Тайницкий) манарасы; 4. Көньяк-көнчыгыш почмак манарасы; 5. Сергий (Преображение) манарасы; 6. ТР Президенты Сарае (элекке Губернатор сарае); 7. Сөембикә манарасы; 8. Благовещение кафедраль соборы; 9. ТР Президенты администрациясенең вәкиллек корпусы; 10. «Хәзинә» музей комплексы (элекке юнкерлар училищесе бинасы); 11. Колшәриф мәчете.

Казан юнкерлар уч-щесе төзелә. Бер үк вакытта К.К.нең көньяк-көнбатыш почмагында, 18 йөздә сугыш кирәк-яраклары сакланган таш склад торган җирдә, Казан гарнизоны гауптвахтасының өч катлы бинасы күтәрелә.

19 йөздә, тузу сәбәпле, Төньяк, Көнчыгыш, Бишкырлы һәм көнбатыш яктагы бер исемсез манара сүтелә, Дмитрий манарасы урынына үтеп йөрү өчен арка ясала, Воскресение манарасының чиркәве сүтелә. 1845 тә Хан сарае торган җирдә *Губернатор сарае*, 1849 да Введение чиркәве урынында — Сарай чиркәве төзелә. 19 йөз ахырында Кабулханә учреждениесе, Консистория корпуслары ике катка күтәрелә, Спас чокыры күмдерелә.

Сов. хакимияте елларында Спас-Преображение монастыреның байтак корылмалары, ш.и. Спас-Преображение соборы, Благовещение соборының чаң манарасы, Спас манарасы чиркәве һәм кәшәнәсе юкка чыгарыла. 1970 еллардан башлап, К.К. корылмалары планлы рәвештә реставрацияләнә һәм баштагы хәленә кайтарыла. 2001 дә ТР Президенты администрациясенең Вәкиллекләр корпусы төзелә (арх. А.Х.Белостоцкая), Туп сарае корылмалары реконструкцияләнә (арх. С.А.Козлова-Мамлиева).

1996 елда К.К.ндә төзеләчәк мәчет проектына конкурс уздырыла. Ул ханнар заманы Казанындагы легендаларга кергән күп манаралы Колшәриф мәчетенең яңадан туу символына әверелә. К.К.ндәге яңа Колшәриф мәчете бер төркем архитекторлар проекты буенча (А.Г.Саттаров, А.В.Головин, А.И.Исхаков, И.Ф.Сәйфуллин, М.В.Сафронов, С.П.Шәкүров) төзелә. 2003–06 елларда ТР Президенты резиденциясе урнашкан Губернатор сараена реконструкция үткәрелә. К.К. — ЮНЕСКО карамагындагы ядкәр (2000 нән).

*Әд.:* А й д а р о в С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1978; О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1981; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Древняя Казань. К., 2000.

*Х.Н.Надыйрова.*

**«КАЗА́Н КРЕ́МЛЕ»**, тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы. ТР Мәдәният министрлыгы карамагында. ТР Президентының 1994 ел 22 сентябрь Указы һәм ТР МКның 1999 ел 31 гыйнвар карары нигезендә оештырыла. «К.К.» музей-саклаулыгы — фәнни-тикшеренү, фәнни-агарту оешмасы, ул Казан Кремле терр-ясендә (13,45 *га*) һәм аның тирәсендә саклана торган зонада (115 *га*) урнашкан тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне саклауны, өйрәнүне һәм пропагандалауны башкара. Музей-саклаулык составына 10–16 йөзләргә караган Кремль шәһәрлегендәге җир, агач һәм таш ныгытмаларның архит-ра-археол. калдыклары, 15–16 йөзләрдәге таш корылмалар, 12–16 йөзләрдәге таш түшәлгән урам өслекләре; 16–18 йөзләрдәге Кремль диварлары һәм манаралары; 16 йөз — 21 йөз башындагы архит-ра корылмалары, музейлар керә. Музей-саклаулык фондында 10 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Аның терр-ясендә археол., геофизик, геол.-инженерлык эзләнүләре алып барыла, археол. объектлар музейлаштырыла. 20 мең $м^2$ дан артык мәйданда 64 урында казу эшләре башкарыла. Алар барышында 12 йөзгә нисбәтле таш кальга, борынгы урамнар һәм аларның таш түшәлгән өслекләре, таш һәм агач биналарның калдыклары табыла.

Кремльдәге эшләр С.С.Айдаров һәм А.Х.Халиков җитәкчелегендә башкарылган һәм ТР МКның 1994 нең 4 августында кабул ителгән карары һәм ТР Президенты тарафыннан хупланган «Казан Кремле ансамблен саклау, яңартып кору һәм файдалану концепциясенең төп юнәлешләре» программасы нигезендә гамәлгә ашырыла. ТР МКның 2006 ел 9 октябрь карары б-н 2010 га кадәрге чорга исәпләнгән «К.К.» музей-саклаулыгын музейлаштыру һәм үстерү концепциясе раслана. Саклаулыкта 4 музей эшли.

**Татар халкы дәүләтчелеге һәм Татарстан Республикасы тарихы музее**. 2006 ның 7 ноябрендә ачыла. Элеккеге сарай чиркәве бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы (9 залны били) 220 $м^2$. Аның «Борынгы төрки дәүләтләр» бүлеге б.э.к. 2 йөздән б.э. 9 йөзенә кадәрге дәверне чагылдыра. Һуннар казаны кисәкләре (4–5 йөзләр), Кубрат хан мөһере төшерелгән йөзек күчермәләре күргәзмәгә куелган. «Идел буе Болгар дәүләте» залында Казан Кремле терр-ясендә табылган (10–11 йөзләр) археол. табылдыклар, тимер йозаклар, кара савытлары, рун язулы сфероконус (12–13 йөзләр) бар. Алтын Урдага һәм Казан ханлыгына багышланган залда 13–14 йөзләрдә яшәгән аксөякнең реконструкцияләнгән костюмы, хан ярлыклары (14–15 йөзләр), ш.у. Казан ханнары Мәхмүд һәм Мөхәммәдәминнең (Т.С. Балуева реконструкциясе) скульптур портретлары, Кремль терр-ясендә табылган кувшин (16 йөз) күргәзмәгә куелган. Музейның аеруча кыйммәтле экспонатлары булып борынгы чех тәңкәсе (929–30), үрдәкле чигә асылмасы (12 йөз), күннән эшләнгән ук савыты (15–16 йөзләр) санала. «Татарлар Россия дәүләте составында» бүлегендә төбәк б-н идарә итү системасын оештыру һәм татар халкы иҗтимагый фикеренең үсеше бәян ителә. Совет чоры тарихы турында бай материал тәкъдим ителә. «Татарстан Республикасының Беренче Президенты» исемле бүлектә Президент М.Ш.Шәймиевнең рәсми визитлары һәм кабул итү вакытларында төшерелгән фоторәсемнәр, аның бүләкләре күргәзмәгә куелган.

**«Эрмитаж-Казан»** — «Казан Кремле» тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы структура бүлекчәсе, күргәзмәләр үзәге, Россиядә беренче Дәүләт Эрмитажы вәкиллеге. ТРда Дәүләт Эрмитажының мәдәни-агарту һәм күргәзмә программасы 2005 нең 23 августында ачыла. Элекке Юнкерлар уч-щесе бинасында урнашкан (19 йөз уртасы, архит-ра истәлеге). Экспозиция мәйданы 870 $м^2$. «Э.-К.» үзәгендә Дәүләт Эрмитажы тупланмасыннан 2005 тә — «Алтын Урда: тарих һәм мәдәният», 2006 да — «Дәүләт Эрмитажы тупланмасыннан XVI–XX йөз башы Көнбатыш Европа чигүе. Интерьер һәм костюм», 2007 дә — «Ат бәрабәренә ярты патшалык... Дөнья мәдәниятендә ат», «Эрмитажда рус сәнгате. XIX йөздә — XX йөзнең башындагы чирегендә күренекле һәм онытылган осталар». 2008 дә — «Кытайдан алып Европага кадәр. Ислам дөньясы тарихы» һ.б. күп кенә әһәмиятле күргәзмәләр уздырыла. «Э.-К.»да Эрмитажның музей-белем бирү программалары буенча мәктәп балалары, яшьләр, музейга килүче аерым кешеләр б-н эшләү һәм актуаль сәнгатьне, дөнья киносы тарихын өйрәнү буенча укыту-белем бирү һәм методик үзәк оештырылган.

**Ислам мәдәнияте музее**. 2006 елның 21 февралендә ачыла. Колшәриф мәчетенең аскы катында 2 залда урнашкан (экспозиция мәйданы 566 $м^2$). Беренче зал төп ислам кагыйдәләренә багышлана, Коръән китаплары төп урынны алып тора, шәмаилләр, намаз укыганда кулланыла торган *намазлык*, кыйбланы (Мәккә юнәлеше) билгеләү өчен компас, тәсбихлар куелган. Экспозициянең икенче залы Урта Идел буенда мәгариф, мәдәният, фән үсеше турында сөйли. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» поэмасының (1825), Мөхәммәдьяр әсәрләренең (18 йөз) кулъязма күчермәләре, Россия терр-ясендәге мәчетләрнең фоторәсемнәре (20 йөз башы) урнаштырылган. Төп урынны татар мәгърифәтчесе кабинетының шартлы интерьеры били. Дин галимнәре, мәгърифәтчеләр Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, Р.Фәхретдин, Г.Буби, З.Камали, Ә.Максуди фотосурәтләре һәм китаплары, мәдрәсә дәреслекләре, совет хакимияте елларында репрессияләргә дучар ителгән дин эшлеклеләре, мәчетләрнең ябылуы турында материаллар куелган. Хәзерге Татарстандагы ислам, яңа мәчетләр һәм уку йортлары төшерелгән фоторәсемнәрдә, мөселман басмаларында күрсәтелә. Аеруча мөһим экспонатлар: Казанда бастырылган Коръәннәр (1816, 1839, 1884), кулъязма Коръән (Урта Азия, 19 йөз), намазлык (19 йөз ахыры), шәмаилләр, шәһәрдә яшәгән татар хатын-кызы костюмы; күлмәк, камзул, калфак (19 йөз ахыры).

**Татарстанның табигыять тарихы музее.** 2008 нең 1 сентябрендә ачыла. Экспозиция-күргәзмә мәйданы — 1096 $м^2$. Музейның гомуми фәнни-экспозиция концепциясе Казан ун-ты, Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү ин-ты, РФАнең Палеонтология ин-ты (Мәскәү), Палеонтология музее (Ундора ш., Ульянов өлкәсе) хезмәткәрләре катнашында Ф.Д.Батырова җитәкчелегендә эшләнә. Сәнгати проектлау һәм төзелеш «Арта-Дизайн» ҖЧҖ һәм ТРның Рәссамнар берлеге сәнгать фонды тарафыннан башкарыла. Ул Идел буендагы бердәнбер музей һәм фәнни-белем бирү үзәге, анда Татарстанның тулы геологик тарихы һәм аның казылмалары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы, минераль-чимал ресурслары турында мәгълүматлар тупланган. Музей экспозицияләре нигезен Казан ун-тының А.А.Штукенберг исем. Геология музее тупланмасы материаллары, ш.у. «К.К.» музей-саклаулыгы фонды коллекцияләре тәшкил итә. Экспозиция 12 залда урнашкан, анда 1000 ләп предмет исәпләнә.

Беренче кат залларында («Җир һәм Галәм», «Җир минераллары», «Юл башы», «Бо-

рынгы яшәеш», «Планетаның кара алтыны», «Җир асты хәзинәләре») астрономия, планетаның минераллар дөньясы төрлелеге турында Җир барлыкка килүдән алып (4,5 млрд. еллар элек) ташкүмер чоры тәмамлануга кадәрге дәвер (300 млн. еллар элек), нефть һәм битум, известьташ һәм гипс, күмер һәм фосфоритлар формалашу һәм аларны казып чыгару турында бәян ителә. Аеруча кызыклы экспонатлар — күк җисемнәрен күзәтергә мөмкинлек бирүче «Интерактив телескоп»; «Галәми үлчәү» ярдәмендә һәр кеше үзенең төрле планеталардагы авырлыгын белә ала, ш.у. оригинал матеоритлар коллекциясе игътибарга лаек.

Икенче катның алты залы («Балыклар һәм җир-су хайваннары патшалыгы», «Казан диңгезе», «Ерткычсыман кәлтәләр дәвере», «Диңгез рептилияләре», «Динозаврлар заманы», «Имезүче хайваннар дөньясы») палеонтологиягә багышлана — беренче балыксыманнар барлыкка килүдән алып хәзерге заман кешесенә кадәрге чорны үз эченә ала. Биредә борынгы балыклар һәм амфибияләр, кәлтәләр һәм рептилияләрне күрсәтүче табигый материаллар, динозаврлар скелетларының күчермәләре, үлеп беткән имезүчеләр һәм мамонтның баш сөякләре куелган.

Саклаулык терр-ясендә Милли сәнгать галереясы (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее ф-лы) һәм Бөек Ватан сугышы мемориал-музее (ТР Милли музее ф-лы) урнашкан.

Музей-саклаулык директорлары: И.М.Вахитов (1994–2007), Р.Р.Хәйретдинов (2007 дән).

*Әд.:* История Казани. К., 1988. Т. 1; Казанский Кремль: Фотоальбом. К., 2005; Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г. Древняя Казань. К., 2005; Ситдиков А.Г. Казанский Кремль: Ист.-археол. исслед. К., 2006.

**КАЗА́Н КРЕ́МЛЕН ТӨЗҮЧЕЛӘ́Р ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. Скульптура төркеме 2 кешедән тора — утырган оста борынгы рус киемендә, аннан сулда басып торганы Казан ханлыгы чоры татар төзүчесе киемендә. Мигъмарлар кулында Казан Кремле планы сызымнары. Һәйкәл — рус монументаль скульптурсы традицияләрендә эшләнгән. Сынның гомуми пластик күренеше һәм образларның психол. бай эчтәлеге аны Казан Кремле биналары ансамблендә башкалардан аерып тора.

Казан Кремле — илдә иң борынгы кальгаларның берсе, ул гасырлар дәвамында төзелә. 16 йөзнең 1 нче яртысында татар төзүчеләре, саклану яруслы манаралары булган 4 *м* калынлыктагы ныклы агач дивар б-н әйләндереп, аны һичкем ала алмаслык итеп коралар. Кальганы берничә тапкыр яулап алырга омтылыш нәтиҗәсез тәмамлана. Аның терр-ясендә Хан сараеның таш биналары, *Колшәриф мәчете*, мәдрәсә, кенәз сарайлары, хан төрбәләре һ.б. җәмәгать биналары була. 1552 елда Иван IV гаскәрләренең Казанга һөҗүме, диварлар шартлавы, көчле янгыннар нәтиҗәсендә, Казан ханлыгы ансамбле архит-расы җимерелә. 16–18 йөзләрдә Кремльдә татар төзүчеләренең кайбер һәйкәлләре сакланып кала (19 йөз башында да Хан сараеның ярымҗимерек бинасын күргәргә мөмкин була). 16 йөз уртасында И.Я.*Постник* һәм И.*Ширяй* җитәкчелегендә Псков осталары тарафыннан Кремльнең диварлары өлешчә торгызыла, өлешчә ташлардан салына; Спас манарасы һәм Благовещение соборына Псков архит-расы үзенчәлекләре хас. Аннан соңгы йөзләрдә Казан архитекторлары Кремльдә адм. биналар, храмнар, торак йортлар төзиләр. Аның тышкы күренеше — губерна үзәге, 1920 дән Татарстанның башкаласы статусына ия булуы б-н аерылып тора. 20 йөз ахырында «Казан Кремле» музей-саклаулыгын булдыру һәм аның ЮНЕСКОның бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе б-н, Казан Кремле корылмаларын



Казан Кремлен төзүчеләр һәйкәле. 2003. Скульпторлар А.В.Головачёв, В.А.Демченко, арх. Р.М.Зәбиров.

үзгәртеп кору һәм реставрацияләү эше алып барыла. Аның архит-ра тарихында иң әһәмиятлеләреннән берсе Колшәриф мәчетен төзү була, ул Кремльнең архит-ра күренешен милли татар мигъмари сәнгате үзенчәлекләре б-н баета.

Композицияне Казан төзүчеләре хөрмәтенә Мәскәү скульпторлары А.Головачёв, В.Демченко һәм Казан архитекторы Р.Зәбиров эшли. Турыпочмаклы формадагы гранит постаментны шәрекъ һәм славян сурәтләре төшкән 2 рельефлы орнаментлы полоса бизи. Уң ягында рус һәм татар телләрендә: «Казан кирмәне мигъмарләренә» («Зодчим Казанского Кремля») дигән язма бар. 2003 нең 18 ноябрендә Кремль үзәгендә Благовещение соборы янындагы кечкенә бакчада ачыла.

*П.И.Новицкий.*

**КАЗА́Н КРЕ́МЛЕНЕҢ СПА́С МАНАРАСЫ́**, к. *Спас манарасы.*

**КАЗА́Н КУЛЛАНУЧЫЛА́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1919 елның декабрендә РСФСР ХКСның эшче-крәстиян кулланучылар җәмгыятьләре турындагы һәм шул ук елның 20 мартында кабул ителгән Декреты нигезендә губерна азык-төлек ком-тының Казан шәһәр азык-төлек бүлеген, гомумшәһәр кооперативын һәм профсоюзларның Казан эшчеләре үзәк кооперативын (к. *Казан эшчеләренең үзәк кооперативы*) берләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килә. К.к.җ.нең идарәсе Казанда була. Эшчәнлек районы — Казан һәм аның бистәләре. Максаты — халыкны азык-төлек һәм беренчел кирәк-яраклар б-н тәэмин итү. Баштарак сәнәгать бүлекләре: а.х. пр-тиеләре, финанс, тәэминат, бүлү, җәмәгать туклануы, утын, транспорт, хуҗалык, оештыру-инструкторлык бүлекләреннән, 1920 дән: әзерләү, бүлү, оештыру, хуҗалык һәм исәп-хисап-финанс бүлекләреннән тора. Союз кулланучылар берләшмәсеннән, хөкүмәт, җәмәгать һәм башка учреждениеләрдән алынган азык-төлекне һәм куллану әйберләрен бүлү, сәнәгать һәм а.х. товарлары әзерләү, бүлү пунктлары аша халыкка азык-төлек һәм сәнәгать товарлары өләшү, халыкның куллану ихтыяҗларын өйрәнү, ш.у. чәйханә, ашханә, дәвалау, шифаханә, мәдәни-агарту учреждениеләре челтәрен оештыру, торак йортлар төзү б-н шөгыльләнә. 1923 нең 25 октябрендә бетерелә.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КАЗА́Н КҮН ГАЛАНТЕРЕ́Я ФА́БРИКАСЫ**, к. *Күн галантерея фирмасы.*

**КАЗА́Н КҮН ҖИТЕШТЕРҮ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́**, к. «*Сафьян*».

**КАЗА́Н ЛИКЁР-АРАКЫ́ ЗАВОДЫ́** (КЛАЗ), азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиесе, «Татспиртпром» АҖ ф-лы. Эшләүчеләр саны — 300 дән артык кеше (2010). Заводны төзү 1971 елда башлана; 1975 тә пр-тие файдалануга тапшырыла һәм беренче продукциясен чыгара. 1998–2003 тә КЛАЗ составына Казан шәраб эшләү з-ды керә (1930 елларда нигезләнә; күбекләнә торган йөзем шәраблары, шәраб, аз алкогольле һәм газландырылган эчемлекләр чыгарыла; 2003 тән «Казанский» шәраб з-ды).

КЛАЗ 2 млн.нан артык декалитр аракы һәм ликёр-аракы эшләнмәләре җитештерә. Ассортиментка 25 тән артык исемдәге (ш.и. 0,05 тән 12 *л* га кадәр сыйдырышлы һәм төрле рәвешле пыяла, фарфор, бәллүр, керамик савытларга тутырылган сувенирлар) продукция керә. Эчемлекләр борынгы рецептлар һәм завод белгечләренең Бөтенроссия азык-төлек биотехнологиясе фәнни-тикшеренү ин-ты, Бөтенроссия шәраб һәм сыра-алкогольсез продукция фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) б-н берлектә эшләгән рецептура буенча әзерләнә. Аракы җитештерү өчен спирт «Татспиртпром» АҖ заводларыннан алына. Шулай ук үсемлек чималы (Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләре терр-ясендә үсә торган артыш җиләге, сары мәтрүшкә, мәтрүшкә, тырнак гөл, юкә чәчәге һ.б.) кулланыла. 1995–2010 тә халыкара һәм бөтенроссия күргәзмәләрендә һәм конкурсларында пр-тие продукциясе 6 «Гран-при» бүләгенә лаек була, 47 алтын, 33 көмеш, 18 бронза медаль, 6 «Продэкспо Йолдызы» медале б-н бүләкләнә. Пр-тие продукциясе РФнең төрле төбәкләренә һәм БДБ илләренә җибәрелә. Заводта берничә реконст-



**Казан ликёр-аракы заводы мәкаләсенә.** 1.Аракы һәм ликёр-аракы эшләнмәләрен шешәләргә тутыру һәм товар рәвешенә китерү линиясе; 2. Йөзем шәрабларын һәм җиңелчә исерткеч эчемлекләрне шешәләргә тутыручы автомат линия; 3. Завод продукциясе үрнәкләре.

рукция уздырыла: дүрт тутыру линиясендә итальян фирмасы «Вир Маури» тарафыннан эшләнгән моноблоклар (тутыру-ябу, этикетка ябыштыручы автоматлар), тутыкмый торган корычтан ясалган сыеклык саклау җиһазлары урнаштырыла. Сәгатькә 12 мең шешә тутыру мөмкинлегенә ия яңа тутыру цехы файдалануга тапшырыла. Сувенир продукция эшләп чыгару өчен 2005 тә «BAROC» фирмасының (Италия) автомат бүлеп тутыру линиясе урнаштырыла. 2007 дә «AMS FERRARI» фирмасының сәгатькә 0,7 *л* сыешлы 6000 шешә һәм 0,5 *л* сыешлы 3000 шешә тутыруга сәләтле ике яңа линиясе куела. Су әзерләү системасы камилләштерелә. 2009 да ачы «Акдов» төнәтмәсе җитештерү буенча яңа цех сафка баса. Пр-тие җитәкчеләре арасында — М.М.Ройтзайд (1971–78), И.М.Зарипов (1981–91), В.Н.Новосельцев (1991–97), В.Е.Савкин (1997–99), В.В.Ходорковский (1999–2004), Р.А.Ихсанов (2004–2007), М.М.Шәрәпов (2007–2010), Н.С.Тимеров (2010 нан). Ш.у. к. *Спирт һәм ликёр-аракы җитештерү сәнәгате.*

*Г.Н.Гаврилина, Г.Я.Мәүлетова.*

**КАЗА́Н ЛИНГВИ́СТИКА ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, 19 йөзнең соңгы чирегендә формалаша. Нигез салучысы — И.А.*Бодуэн де Куртенэ.* Ул Казан ун-тында тел белеме мәсьәләләре б-н кызыксынучы мөгаллим һәм студентларны берләштергән түгәрәк оештыра. К.л.ф.м.нең иң күренекле вәкилләре — В.А.*Богородицкий*, Н.В.*Крушевский,* А.И.*Александров,* А.И.Анастасиев, А.С.*Архангельский*, П.В.Владимиров, А.А.Царевский, Н.С.Кукуранов, В.В.*Радлов,* С.К.Булич һ.б. Казан мәктәбе лингвистлары яшь грамматизм юнәлеше (младограмматизм — Европа тел белемендәге юнәлеш, 1870 елларда Германиядә барлыкка килә) б-н мавыгалар. Алар фикеренчә, телнең сөйләм һәм язма формаларын аерып карау, җанлы сөйләмне тулы һәм төрле яклап өйрәнү, телдәге психологик һәм физиологик үзара бәйләнешләргә анализ, статика һәм динамиканы (синхрония һәм диахрония) аерып карау, тел күренешләренә мөнәсәбәтле тарихилыкның төгәл чагылыш табуы, җанлы телләргә игътибар, барлык телләрнең дә тигез хокуклы булуы һ.б. иң әһәмиятлеләрдән санала. К.л.ф.м. галимнәре үзләренең хезмәтләре б-н тел белеменең эксперименталь фонетика, квантитатив лингвистика, структур лингвистика һ.б. бүлекләренә нигез салалар. К.л.ф.м. галимнәренең төп казанышлары — телгә, даими эш итүче һәм бер үк вакытта һәрчак үсеш, үзгәрештәге феномен буларак, диалектик караш булдыру; телне тарихи (диахрон) һәм тасвирый (синхрон) яктан өйрәнү методикаларын эшләп чыгару. Генеалогик классификация б-н беррәттән алар телләрнең социаль һәм структур типологиясе б-н дә шөгыльләнәләр. Телнең психик дөнья күренеше булуын танучы традицияне хуплап, Казан галимнәре аның иҗтимагый асылына басым ясыйлар, шул рәвешчә, алар француз (А.Мейе) һәм Женева (Ф. де Соссюр) социаль лингвистика мәктәпләреннән дә элгәре, тел белемендә яңа юнәлеш — социолингвистикага нигез салалар. Телнең социаль асылы турындагы фикерне үстереп, К.л.ф.м. вәкилләре барлык телләрнең дә тигез хокуклы булуын тануны зарури саныйлар, җирле халыкларның (татар, мари, чуаш һ.б.) телләрен өйрәнү мөһимлеген ассызыклыйлар. Бодуэн де Куртенэ фикеренчә, Казан ун-ты, Россиянең башка ун-тларыннан аермалы буларак, тарихның үзе тарафыннан гаять уңай шартларга куелган: ким дигәндә өч тел семьялыгы (славян, төрки һәм фин-угор) вәкилләре яши торган өлкәдә урнашкан, шулай булгач, ул әлеге телләрдә сөйләшүче халыкларның телләрен, мәдәниятен, тарихын өйрәнү үзәге булырга тиеш. Ул университетта төрки телләр һәм фин теле кафедрасын кабат торгызуга, факультатив рәвештә булса да, татар телен укытуны кайтаруга ирешә, укучылары арасында татар студентлары да була, аларга ул укуларында актив рәвештә ярдәм итә. В.А.Богородицкий да, остазының идеяләренә ияреп, тюркология мәсьәләләре б-н шөгыльләнә; рус һәм татар телләре акустикасын өйрәнә торган (Г.Шәрәф, М.Х.Корбангалиев хезмәтләре) *Эксперименталь фонетика кабинеты* төзи. Ул ш.у. палатография, лингвография технологиясен һ.б.ны фонетик анализ практикасына кертә. Теоретик һәм гамәли тел белеме методларының К.л.ф.м. вәкилләре тарафыннан әзлекле рәвештә кулланылуы өйрәнелә торган проблемалар төркемен, 20 йөз лингвистикасында закончалыклы дәвамын тапкан лингвистик тикшеренүләрне тагы да киңәйтә (телнең системалылыгы, телләрнең катнашлыгы, лингвометодика мәсьәләләре). Телнең системалы булуына борынгы телче галимнәр үк төшенә, әмма ул бары 19 йөз ахырында гына тел белеменең теоретик проблемасына әверелә: К.л.ф.м. вәкилләре телне катлаулы, һәрвакыт үзгәреп торучы төрле элементлар (фонетик, морфологик, синтаксик һ.б.) системасы буларак күзаллый башлыйлар. К.л.ф.м. идеяләре Бодуэн де Куртенэның Казан ун-тында укыган программа характерындагы лекцияләрендә, «Николай Крушевский, аның тормышы һәм фәнни хезмәтләре» («Николай Крушевский, его жизнь и научные труды», 1888), «Тел белеменең бурычлары турында» («О задачах языкознания», 1889), «Кеше сөйләмендә авазларның ясалу үзенчәлекләре» («Человечение языка», 1893), «Барлык телләрнең дә катнаш булуы турында» («О смешанном характере всех языков», 1901), «XIX гасыр тел белеме, яки лингвистикасы» («Языкознание, или лингвистика XIX века», 1901), «Тел күренешләренең психик нигезләре турында» («О психических основах языковых явлений», 1903) хезмәтләрендә, Н.В.Крушевскийның «Тел турындагы фәннең предметы, бүленеше һәм методы» («Предмет, деление и метод науки о языке», 1880), «Тел турында гыйльми очерк» («Очерк науки о языке», 1883), В.А.Богородицкийның «Тел белеме һәм рус теле буенча очерклар» («Очерки по языковедению и русскому языку», 1910), «Гомуми тел белеме буенча лекцияләр» («Лекции по общему языковедению», 1913), «Рус грамматикасының гомуми курсы» («Общий курс русской грамматики», 1930), «Эксперименталь мөмкинлекләр яктылыгында рус теле фонетикасы» («Фонетика русского языка в свете экспериментальных данных», 1930) һ.б. хезмәтләрендә бәян ителә.

Әлеге идеяләр Россия, Польшада гына түгел, Көнбатыш Европада да тел белеме үсешенә йогынты ясый.

*Әд.:* Богородицкий В.А. Казанская лингвистическая школа (1875–1939) // Тр. Моск. ин-та истории, филологии и литературы. 1939. Т. 5; Березин Ф.М. Русское языкознание конца XIX — начала XX вв. М., 1976; Шарадзенидзе Т.С. Лингвистическая теория И.А.Бодуэна де Куртенэ и её место в языкознании XIX–XX веков. М., 1980; Смирнов С.В., Дмитриев П.А., Сафронов Г.И. Русское и славянское языкознание в России середины XIX — начала XX вв. Л., 1991; Николаев Г.А. Иван Александрович Бодуэн де Куртенэ, 1845–1929. К., 2001; шул ук. Николай Вячеславович Крушевский, 1851–1887. К., 2001; Шарафутдинов З.Т., Шарафутдинова Р.Н. Педагогика научной школы. К., 2001.

*Р.Ә.Колшәрипова.*

**КАЗА́Н МАГНИ́Т ОБСЕРВАТО́РИЯСЕ**, к. *Магнит обсерваториясе*.

**КАЗА́Н МАКАРО́Н ФА́БРИКАСЫ**, азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 150 кешедән артык (2005). 1931 елда чүпрә з-ды җирлегендә оештырыла. Карамагында 9 макарон прессы, пар б-н киптерү шкафлары була. Елга 14 мең *т* га кадәр төрле кушылмалар (йомырка массасы, томат пастасы һ.б.) б-н баетылган макарон эшләнмәләре чыгара. 1977–82 дә уздырылган капиталь яңартып кору вакытында комплекслы рәвештә өзлексез эшләүче һәм автоматлаштырылган линияләр, бүлеп төрү аппаратлары, онны саклау җиһазлары б-н җиһазландырыла; ф-каның тәүлеклек җитештерүчәнлеге 80 *т* га кадәр арта. 1991 дә искергән техника «Брайбанти» итальян фирмасының автомат җиһазлары б-н алыштырыла. 1995 тән — АҖ. Төрле вермишель, макарон, токмач, рожки, фигуралы эшләнмәләр чыгара; продукциянең гомуми күләме 2005 тә 15,5 мең *т* тәшкил итә. 2007 дә ябыла. Пр-тие директорлары арасында — А.А.Плотников, М.М.Фәтхетдинов, В.Е.Барсуков, П.П.Черепнин, А.Х.Ишкуватов, В.Е.Савкин (2003–2007).

**КАЗА́Н МАТЕМА́ТИКА ҖӘМГЫЯТЕ́**, җәмәгать оешмасы. 1992 елда төзелә, беренче исеме — Казан «Математика» фонды. Фондның оештыручылары — Казан ун-тының математиклары һәм механиклары А.П.*Широков*, А.В.*Костерин*, Л.А.*Аксентьев*, Ф.Г.*Әухәдиев*, В.А.*Чугунов*, Д.Х.*Мөштәри*, С.Р.*Насыйров*, А.В.*Лапин*, А.М.*Елизаров* һ.б. Беренче президенты А.П.Широков, вице-президенты А.В.Костерин, башкаручы директоры А.М.Елизаров.

Фондның төп бурычлары — матем. конференцияләр, мәктәпләр, семинарлар һ.б. фәнни чаралар оештыру һәм үткәрү; матем.әдәбият нәшер итү эшчәнлегендә катнашу; халыкара матем. үзәкләр б-н фәнни элемтәләр урнаштыру өчен өр-яңа информацион технологияләрне гамәлгә кертүдә катнашу (ш.и. фәнни алмашу); математик галимнәрнең социаль яклануын күтәрү, талантлы яшь галимнәргә ярдәм итү; иҗади мирасны саклау һәм атаклы галимнәребезнең истәлекләрен мәңгеләштерү. Үз эшчәнлеген фонд Казан ун-ты каршындагы Н.Г.Чеботарёв исем. Математика һәм механика ин-ты (НИИММ) б-н тыгыз бәйләнештә алып бара.

1992 дә фондның тырышлыгы һәм РФА Математика бүлеге булышлыгы б-н Математика һәм механика ин-тында шәһәр галимнәренә халыкара телекоммуникация челтәрләренә тоташу мөмкинлеге бирә торган электрон почта пункты оештырыла. Ул Россия фонды өчен гомумроссия мәгълүмат тапшыру челтәренең Идел буендагы өлешен төзүдә нигез булып тора. Фонд тарафыннан бөтенроссия студентлар олимпиадаларында һәм конференцияләрендә катнашучылар өчен акча бүлеп бирелә, талантлы яшь галимнәрнең чит илләргә фәнни командировкалары финанслана, исемле стипендияләр булдырыла, Америка һәм Франция математика җәмгыятьләре б-н элемтә урнаштырыла, элегрәк Казан математиклары ала алмаган чит ил матем. журналларына язылу оештырыла. 1996 ның октябрендә фонд К.м.җ. исемен ала, шул ук вакытта яңа идарә сайлана, аңа А.В.Лапин (президент), А.М.Елизаров (вице-президент), А.Б.Мазо (башкаручы директор), В.Д.Соловьёв, С.Р.Насыйров, В.А.Чугунов кертелә. К.м.җ.ндә 50 кеше әгъза булып тора (2002). 1995 елда җәмгыятьнең нәшрияты оештырыла (монографияләр, предпринт серияләре һәм төрле конференция материалларын чыгара).

*А.М.Елизаров, А.В.Лапин, В.Д.Соловьёв.*

**КАЗА́Н МӘДӘНИЯ́Т ҺӘМ СӘНГА́ТЬ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан мәдәният һәм сәнгать университеты*.

**КАЗА́Н МӘДӘНИЯ́Т ҺӘМ СӘНГА́ТЬ УНИВЕРСИТЕТЫ́**, РФ Мәдәният министрлыгы карамагында. 1969 елда Н.К.Крупская исем. Ленинград мәдәният ин-тының Казан ф-лы буларак нигез салына. 1974 тән Казан мәдәният ин-ты, 1991 дән Казан сәнгать һәм мәдәният ин-ты, 1995 тән Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе, 2002 дән хәзерге исемдә.

Университетта 8 факультет — мәгълүмат-документлар коммуникациясе (китапханә хезмәткәрләре һәм нәшрият эше буенча белгечләр, архив хезмәткәрләре әзерли), музыка сәнгате һәм хореография сәнгате, социаль-мәдәни эшчәнлек (мәдәният белгечләре, педагог-психологлар, музей эше буенча белгечләр әзерли); икътисад, менеджмент һәм туристлык, кино һәм телевидение, театр, сәнгать культурасы һәм дизайн ф-тлары эшли.

Университетта 15 меңнән артык белгеч әзерләнә. Университетны тәмамлаучылар арасында соңыннан ТР мәдәният министры булып эшләгән И.Г.Тарханов, Мари Респ-касы мәдәният министры М.З.Васютин, артистлардан Р.Ш.Мостафин, С.З.Фәтхетдинов һ.б. бар. 2010 да 28 белгечлек һәм 35 тармак буенча якынча 1900 студент — көндезге һәм




Казан мәдәният һәм сәнгать университеты.


900 дән артыгы читтән торып уку бүлегендә, ш.и. 750 кеше түләүле формада укый. Укытучылар коллективында 260 лап кеше, ш.и. 1 РФнең халык артисты, 2 РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе, 2 ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе, 17 фән. д-ры һәм 88 фән. канд. эшли. Төрле елларда эшләгән укытучылар: М.З.Булатова, К.Т.Гыйззәтов, Җ.Г.Котдусов, Н.Г.Рахлин, Б.Г.Мөлеков, М.Х.Сәлимҗанов, Ш.Д.Сарымсаков, А.И.Шутиков, Н.Д.Юлтыева, В.Ә.Ганиева һ.б. Ике белгечлек буенча аспирантура, кандидатлык диссертацияләре яклау буенча 2 совет эшли.

Университетта зур һәм кече концертлар залы, укыту-өйрәтү театры, видео һәм тавыш яздыру студиясе, китапханә бар; 25 өйрәтү-иҗат коллективы эшли.

Университет ректорлары: Р.А.Шәмсетдинова (1974–87), Р.К.Беляев (1987–96), Р.Р.Йосыпов (1996 дан).

*Әд.:* 25 лет Казанскому государственному институту искусств и культуры. К., 1994; Казанский государственный университет культуры и искусств. К., 2002.

**КАЗА́Н МӘРЬЯ́М АНА́ ИКО́НАСЫ**, Рус Православие чиркәве тарафыннан аерып хөрмәтләнә торган могҗизалы иконаларның берсе. Ул стрелецлар йөзлеге башлыгы Онучинның янган йорты биләмәсендә табыла. Аңа кадәр Онучинның кызы Матронага билге була



Казан Мәрьям Ана иконасы. 16 йөз ахыры – 17 йөз башы. Ярославль могҗиза тудыручылары чиркәве. Казан.

(Мәрьям Ана кызга өч тапкыр күренә). 1591 елда икона могҗизалы дип таныла, аның табылган урынында *Казан Богородица хатын-кызлар монастырена* нигез салына (аның беренче монахинясы Марфа исеме б-н монахлык кабул иткән Матрона була). 1611 дә К.Минин һәм Д.Пожарскийның халык гаскәрендәге Казан отряды поляк интервентларына каршы сугышка киткәндә үзе б-н иконаның күчермәсен ала; иконаның могҗизалы көче Мәскәүне азат итәргә ярдәм иткән, дип санала. Мәскәүгә алып кителгән икона — төп нөсхә, ә күчермәсе Казанда калган, дигән фараз яши.

Интервентларны җиңгәннән соң кенәз Д.Пожарский акчасына Кызыл мәйданда икона өчен агач чиркәү төзелә (1632 дә яңа). 1636 да яңа төзелгән (патша гаиләсе иганәсенә) Казан соборы изгеләндерелә. Казан Мәрьям Ана иконасын Пётр I (1709 дагы Полтава янындагы сугыш), М.И.Кутузов (1812 елгы Ватан сугышы) гаскәренә алалар, Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 нең декабрендә, Мәскәү янындагы рәхимсез сугышлар алдыннан, шушы иконаны тотып

шәһәр тирәли тантаналы хач йөрүе оештырыла.

1904 тә Казандагы икона Казан Богородица монастыреннан урлана (юкка чыгарылуы ихтимал), әмма бу монастырьга гыйбадәт кылырга килүчеләрне туктата алмый. 1910–13 елларда монастырь соборының җир асты куышында, нәкъ икона табылган урында, җир асты чиркәве төзелә. Иконаның күчермәләре Рус Православие чиркәүләренең барлык биналарында, дин тотучыларның йортларында бар. Мәскәү күчермәсе 1934 тә Казан соборы җимертелгәч юкка чыга. Һәр елны 8(21) июльдә (1579 да икона табылган көн) бәйрәм ителә, 22 октябрь (4 ноябрь) — Мәскәүне поляк интервентларыннан азат итү көне билгеләп үтелә (1612 дә кабул ителә). Иконаның бүгенгә кадәр сакланган 9 күчермәсе рәсми рәвештә могҗизалы санала. Казанда җирле халык тарафыннан хөрмәтләнүче 2 күчермә саклана: берсе — Ярославль



Казан Мәрьям Ана иконасы (Ватиканнан кайтарылган күчермә). 18 йөз. Казан Богородица монастыренең Крестовоздвижение чиркәве. Казан.

могҗиза тудыручылары чиркәвендә, икенчесе — Никола соборында. 2004 елның августына кадәр Рим Папасы Иоанн Павел II резиденциясендә сакланган К.М.А.и. 2005 елның 21 июлендә Рус Православие чиркәве епархиясенә тапшырыла; хәзер ул Казан Богородица хатын-кызлар монастыренең Крестовоздвижение чиркәвенә куелган.

*Әд.:* Покровский И.М. Явленная Чудотворная икона Казанской Божьей матери. К., 1904; Зеленецкий А.Ф. Казанский Богородичный первоклассный женский монастырь. К., 1910; Елдашев А.М. Монастыри Казанского края: очерки истории. К., 2004; Москва: Энцикл. М., 1997.

**КАЗА́Н МӘХКӘМӘ́ О́КРУГЫ**, Россия мәхкәмә идарәсенең адм.-терр. берәмлеге. «Мәхкәмә органнарын оештыру турында» 1864 ел 20 ноябрь Нигезләмәсенә таянып барлыкка килә, *Казан мәхкәмә палатасы* каршында 1870 нең 8 ноябрендә ачыла. К.м.о.на Казан, Вятка, Екатеринбург, Пермь, Самара, Сембер һәм Уфа губерналары керә. Аның терр-ясендә гражданлык һәм җинаять эшләре буенча 1 нче инстанция мәхкәмәләре дип исәпләнгән округ мәхкәмәләре урнашкан була. ХКСның «Суд турында»гы 1917 нең 22 ноябрендә кабул ителгән 1 нче Декреты б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1874. Т. 45, отд. 1. № 48517; отд. 2. № 48856, 48926; Декреты советской власти. М., 1957. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н МӘХКӘМӘ́ ПАЛА́ТАСЫ**, мәхкәмә органы. «Мәхкәмә органнарын төзү турында»гы 1864 ел 20 ноябрь Нигезләмәсе б-н оештырыла, 1870 нең 8 ноябрендә эшли башлый. 1 нче инстанция мәхкәмәсе буларак: дәүләткә каршы җинаятьләрне, аеруча авыр җинаять эшләрен, вазифаи җинаятьләр (5–8 класс чиновниклары өчен) һәм матбугатка караган закон бозулар хакындагы эшләрне карый (төрле катлау вәкилләре катнашында тикшерелә); 2 нче инстанция мәхкәмәсе буларак: округ мәхкәмәләре чыгарган хөкем карарларына апелляцияләрне, округ мәхкәмәләре арасында барлыкка килгән хөкемгә тартылу мәсьәләсе буенча фикер каршылыкларын; аерым мәхкәмә карарларына шикаятьләрне, округ мәхкәмәләрендә антлы утырышчылар катнашында каралырга тиешле җинаять эшләрен (гаепләүче актын гаепләүче яки яклаучы файдасына раслый яисә үзгәртә) карый; җәмәгать судьялары һәм җәмәгать судьялары съездлары эшчәнлегенә күзәтчелек итә. Өлкән рәис, 2 департамент рәисе, 10 мәхкәмә әгъзасы составында эшли. Судьялар юстиция министры тәкъдиме буенча император тарафыннан билгеләнә. Гражданлык эшләре, I һәм II җинаять эшләре департаментларына бүленә. Канцелярия, прокуратура, антлы ышанычлылар советын үз эченә ала. Аңа секретарьлар, мәхкәмә приставлары, прокурор күзәтчелеге чиннары (барлыгы 30 га якын кеше; 1915) хезмәт күрсәтә. К.м.п. округына Казан, Вятка, Екатеринбург, Пермь, Самара, Сембер һәм Уфа губерналары керә. Палатаның хөкем карарлары Сенатның кассация департаментларында яңадан карау мөмкинлегенә ия була. ХКСның 1917 ел, 22 ноябрендә кабул ителгән «Суд турында»гы 1 нче Декреты һәм



Казан мәхкәмә палатасы бинасы.

Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы тарафыннан кабул ителгән 1918 ел 10 март карары нигезендә бетерелә.

Өлкән рәисләр: М.Н.Шаховский (1870–71), И.Н.Орлов (1871–77), Н.М.Окулов (1877–83), Н.И.Похвиснев (1883–86), Ф.И.Шмелёв (1886–95), А.Н.Щербачёв (1895–99), Д.Е.Рынкевич (1899–1906), А.Н.Кривцов (1906–10), И.Е.Ильшенко (1910), П.И.Храбро-Василевский (1910–14), Я.М.Затворницкий (1914–16), А.А.Томсен (1916–18).

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1874. Т. 45, отд. 1. № 48517; отд. 2. № 48856, 48926; Правящая Россия: Полный сборник сведений о правах и обязанностях административных учреждений и должностных лиц Российской империи. СПб., 1906. Ч. 3.

*Әд.:* Долгов Е.Б. Органы суда в Казанской губернии в XVIII — начале XX вв. // Правосудие в Татарстане. 2000. № 2/3.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н МӘЧЕТЛӘРЕ́**, Рус елъязмаларында беренче тапкыр 1469 елда искә алыналар. Кирмән эчендә биек таш мәчетләр: Хан сарае янында төрбәләре б-н Хан мәчете, *Нургали мәчете, Колшәриф мәчете*, ш.у. башка шәһәр һәм шәһәр янында Отыч, Басма, Җылкы мәчетләре һ.б. булуы мәгълүм. Казанны яулау походларын бәян иткәндә кенәз А.М.Курбский: «...Патша пулатлары, биек, таш мәчетләре б-н шәһәр басып тора», — дип билгеләп үтә. Таш мәчетләр б-н бергә, агачтан төзелгән гыйбадәт йортлары да бихисап күп була. 16 йөзнең 1 нче яртысы — 18 йөзнең 1 нче яртысында алар юкка чыгарыла, күпчелегенең нигезендә чиркәүләр төзелә. 1767 елдан Иске татар бистәсендә манаралары түбәдә урнашкан таш мәчетләр төзелә башлый. Аларның архит-расында Петербург (*Мәрҗани мәчете*) һәм Мәскәү (*Апанаев мәчете*) бароккосы һәм классицизмы (*Галиев мәчете*; Унберенче мәчет, 1801; *Иске таш мәчет*; *Зәңгәр мәчет*) стильләре чагыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында башка типтагы — манаралары җир өстенә корылган һәм ишекләре аның аскы катында (*Печән базары мәчете, Солтан мәчете, Борнай мәчете, Казаковлар мәчете, Алсу мәчет*) һәм әлеге типның төрдәше — манарасы ишек янында урнашкан (*Әҗем мәчете*) мәчетләр төзелә башлый. Әлеге мәчетләрнең архит-расы милли-романтик юнәлештәге эклектика стиленә карый. Казан бистәләрендә классик юнәлештәге эклектика стилендә (Пороховой бистәсендәге беренче мәчет, 1 нче Бишбалта мәчете, 1820) һәм халык архит-расы формаларында (Пороховой бистәсендәге 2 нче мәчет, 1899; 2 нче Бишбалта мәчете, 1898) агач мәчетләр салына. 1922 елның башында романтик юнәлештәге модерн стилендә манарасы бинаның почмагына урнашкан мәчет төзелә (*Ислам кабул итүнең мең еллыгы шәрәфенә салынган мәчет*).

1917 елда Казанның Иске Татар бистәсендә — 10, Яңа Татар бистәсендә — 3, иске татар зиратында — 1, Елга аръягының Бишбалта, Пороховой, Ягодный бистәләрендә 5 мәчет эшли. 1930 елларда илдә атеизм кертү өчен барган көрәштә, Мәрҗани мәчетеннән кала, барлык мөселман мәчетләре ябыла, манаралары сүтелә, биналары торак йортларга әйләндерелә, учреждениеләргә, пр-тиеләргә тапшырыла. Ярты гасыр узгач, гыйбадәт йортларын кабат яңарту башлана. 1985–88 елларда Казанның Авиатөзелеш р-нында Нур ислам мәчете төзелә. 1990 елларда иҗтимагый тормышны үзгәртеп кору һәм дини оешмалар эшчәнлеген яңадан торгызу б-н бәйле рәвештә тарихи мәчет биналарын мөселман җәмгыятьләренә кайтару, аларны реставрацияләү, яңа мәчетләр: *Болгар, Рамазан, Хөзәйфә ибне әл-Йәмәни, Мәдинә, Колшәриф* һ.б. төзү баш-

лана. Аларда милли архит-раның борынгы традицияләре заманча формалар б-н ярашып торгызыла. Хәзер шәһәрдә 40 ка якын мәчет эшли.

*Әд.:* Халитов Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; Мечети Татарстана / Төзүчеләр: Надыйрова Х.Г., Хәйретдинов Р.Р. К., 2000; Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.


**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА АКАДЕ́МИЯСЕ**, укыту-методик, фәнни-тикшеренү, дәвалау учреждениесе, РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының табибләрне дипломнан соң әзерләүнең иң эре мед. үзәкләренең берсе. 1920 елда Татарстан Сәламәтлек саклау халык комис-тының Казан клиник ин-ты буларак оештырыла, 1925 тән В.И.Ленин исем. дәүләт табибләр белемен камилләштерү ин-ты (ГИДУВ), 1995 тән Казан дәүләт мед. академиясе — Идел буе федераль округының сәламәтлек саклау белгечләре өчен вуздан соң һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча төп учреждениесе. Төп эшчәнлеге: дипломнан соң белем бирү, табибләрнең квалификациясен күтәрү, медицинаның алдынгы юнәлешләре өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләр үткәрү.

1920 дә Казан губерна башкарма ком-ты Табибләр белемен камилләштерү клиник ин-ты булдыру проектын раслый (Петроград ин-тыннан соң икенче). Проектның авторлары һәм башлап йөрүчеләре — В.И.Иорданский, Р.А.*Лурия*. Институтның үзәген аның төп клиникалары — рентгент кабинеты һәм үзәк клиник лаб-ясе булган эчке авырулар клиникасы (мөдире — Р.А.Лурия), нерв авырулары (каф. һәм клиника мөдире — А.В.*Фаворский*), ортопедия һәм травматология (мөдире — М.О.*Фридланд*), тире авырулары һәм венерик авырулар (каф. һәм клиника мөдире — А.А.Хитрово, соңрак М.С.*Пильнов*), акушерлык һәм хатын-кыз авырулары (мөдире — А.И.*Тимофеев*), борын, тамак һәм колак авырулары (мөдире — М.А.Чалусов) клиникалары тәшкил итә. 1921 дә ин-тка су-ләм б-н дәвалау бүлекләре, эл.-яктылык б-н дәвалау кабинетлары булган Физиологик ысуллар б-н дәвалау клиникасы (мөдире — Г.А.*Клячкин*) һәм Балалар авырулары клиникасы (мөдире — Е.М.*Лепский*) кушылалар. Институт директоры итеп мед. д-ры Р.А.Лурия, идарә әгъзалары итеп профессорлар В.П.Первушин, Е.М.Лепский һәм Ф.Г.Мөхәммәдъяров (Татарстан Сәламәтлек саклау халык комис-ты вәкиле) сайланалар.

Губерна башкарма ком-ты һәм республика сәламәтлек саклау органнары карары б-н 1920–22 дә ин-тка берничә бина тапшырыла: Зур Кызыл урамында Кызыл Хач шәфкать туташлары җәмгыяте хастаханәсе лазареты, хәзерге Мөштәри урамында Җир банкы бинасы, Зур Кызыл урамында сәүдәгәр Оконишников утары һәм Бутлеров урамында Е.В.Адамюк исем. Трахоматоз ин-ты өчен дәүләт фондына алынган бина.

1920 дә Казан клиника ин-тында шәфкать туташлары мәктәбе ачыла. Клиникаларда укыту, фәнни-тикшеренү һәм дәвалау эше алып барыла. Институтның беренче этапта үтәгән бурычлары: Казан хастаханәләрендә дәвалау-госпитальләр эшен яхшырту, шәфкать туташлары мәктәпләре эшчәнлеге өчен шартлар тудыру, Казан губернасы, Идел, Кама буе табибләре өчен курслар оештыру. 1921 дә институтка клиника статусы бирелә. Институтны танытуда галимнәрдән А.Ф.*Агафонов*, В.А.*Гусынин*, Г.Н.Бадюл, Т.Д.Эпштейн, М.И.*Мастбаум*, И.И.*Русецкий*, Р.И.*Лепская*, А.Н.*Мурзин*, Я.Д.Печников, Л.М.*Рахлин*, Ю.А.*Ратнер*, Н.Е.*Сидоров* һ.б. актив катнашалар.

1922 дә хирургия (мөдире — В.Л.*Боголюбов*), күз авырулары клиникалары һәм Е.В.Адамюк исем. Трахоматоз ин-ты (каф. мөдире һәм директоры — А.Г.*Агабабов*); топографик анатомия б-н оператив хирургия



Казан медицина академиясе. Төп корпус.

(мөдире — В.А.Гусынин), патология (мөдире — К.Г.*Боль*), бактериология (мөдире — М.П.*Тушнов*) кафедралары оештырыла. Фәнни китапханә ачыла (оештыручылары — табибләр Н.А.Бухалов һәм Е.А.Кривин). Шул рәвешчә, институт 440 урынлы матди базасы булган 14 клиник һәм теоретик кафедрадан тора. 1923 тә Казан клиника ин-ты РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-тының фәнни учреждениеләре исәбенә кертелә һәм РСФСР бюджетына күчерелә. 1920–30 да оештырылган кафедралар: йогышлы авырулар (мөдире — С.С.*Зимницкий*, 1924–28), берләштерелгән социаль һәм эксперименталь гигиена (мөдире — М.А.Дыхно), рентгенология (мөдире — Р.Я.*Гасуль*), туберкулёз (Туберкулёз ин-ты нигезендә, мөдире — М.И.Мастбаум); ашыгыч ярдәм һәм хәрби-кыр хирургиясе клиникасы (мөдире — В.А.Гусынин). 1920–21 дә республиканың Сәламәтлек саклау халык комис-ты юлламасы б-н институтта 22 хәрби табиб (Казан ун-тын тәмамлаучылар) укый башлый. Белем күтәрү һәм аерым белгечлеккә махсуслашу эше, башлыча, ординаторлар һәм экстерн тәртибендә укучы табибләр аудиториясендә алып барыла (бер уку елында 52 ординатор һәм 200 дән артык экстерн укытыла).

1922–30 елларда үз эченә табиблек эшчәнлеге алымнарының бердәмлегенә нигезләнеп оештырылган киң комплекс629 дисциплина-цикллар: хирургия, терапия, офтальмология белгечлеге буенча участок табибләре укытыла. 1930–35 тә табибләрне аерым белгечлеккә әзерләү табиб-белгеч профилендә алып барыла (2–5 айлык курслар). 1941 ел башына ГИДУВта Идел буе, Урал, Себер, Төньяк Кавказ һ.б. төбәкләрдәге республикалардан һәм өлкәләрдән 2 меңгә кадәр табиб укый. Авыллардагы табиб участокларын ныгыту өчен ГИДУВның профессор-укытучылары күче б-н Татарстан, Чуаш, Удмурт, Мордва АССРларның төрле р-ннарында 12 филиал булдырыла, аларда укыту һәм консультация эше оештырыла.

Институт үзенең беренче көннәреннән үк югары фәнни-мед. учреждениесе буларак формалаша. 1920 еллардагы фәнни тикшеренүләр малярия, корсак тифы, висцераль сифилис клиникасы һәм эпидемиологиясе, ашказаны-эчәк тракты авырулары, авитаминозлар, алиментар дистрофия һ.б. актуаль мәсьәләләргә багышлана. Институтның танылуы һәм үсеше, ш.у. зур фәнни юнәлешләр барлыкка килү талантлы клиницист-галимнәр: В.Л.Боголюбов, М.П.Тушнов, А.В.Фаворский, В.С.Груздев, С.С.Зимницкий, В.В.Чирковский, А.И.Тимофеев, А.Ф.Самойлов, М.С.Пильнов, И.П.Васильев, Н.К.Горяев, К.Г.Боль, Е.М.Лепский, И.Ф.Козлов, В.М.Аристовский, А.В.Вишневский, В.К.Трутнев, А.Г.Агабабов, В.Е.Адамюк, Т.И.Юдин, М.О.Фридланд, Р.И.Лепская һ.б. исемнәре б-н бәйле. Кардиологик тикшеренүләрдә йөрәктәге компенсатор күренешләр, электроэнтерография, электрокардиографиянең аерым мәсьәләләре хәл ителә; клиник электрофизиология лаб-ясе төзелә (М.А.Киселёв, Л.М.Рахлин, А.Ф.Самойлов, 1934). Туберкулёзга каршы көрәш хезмәтен Татарстанда институт укытучылары П.А.Дезидерьев, М.И.Аксянцев, М.И.Мастбаум һ.б. җитәкли (1930 еллар). Балалар клиникасында профессорлар Е.М.Лепский һәм Р.И.Лепская җитәкчелегендә матдәләр алмашы бозылуга бәйле авырулар өйрәнелә. Е.М.Лепский һәм аның шәкертләренең (М.Н.Лукъянчикова, Ф.Х.Басыйр, Р.М.Мамиш һ.б.) республикада балаларда рахит барлыкка килү сәбәпләрен һәм шартларын өйрәнү турындагы киң билгеле хезмәтләре языла. Танылган невропатолог И.И.Русецкий хәрәкәт эшчәнлеге һәм вегетологиядәге тайпылышлар мәсьәләләрен өйрәнү буенча фәнни юнәлеш булдыра (1940 еллар). Хирургия профилендәге төрле фәнни юнәлешләр үсешенә танылган хирурглар В.Л.Боголюбов, Ю.А.Ратнер, В.А.Гусынин, М.З.Сигал, Н.В.Соколов һ.б.ның хезмәтләре ярдәм итә. Институтта акушер-гинеколог галимнәрнең фәнни тикшеренүләре өстенлекле урын алып тора. Кафедра хезмәткәрләре (мөдире — А.И.Тимофеев, 1920–28) гинекологик авыруларны консерватив дәвалау һәм операцияләр ясауның яңа оригиналь ысулларын эшлиләр. Клиникада беренче булып акушерлык һәм гинекологик операцияләр вакытында Вишневский ысулы б-н тәннең аерым урынына анестезия гамәлгә ашырыла. Илдә мед. үсешенә И.Ф.Козлова, И.В.Данилов, танылган акушер-гинеколог, СССР МФА академигы Л.С.Персианинов зур өлеш кертәләр. В.В.Чирковский, А.Н.Мурзин һәм А.Г.Агабабов җитәкчелегендә офтальмология кафедрасы хезмәткәрләре Идел буенда таралган трахома авыруына диагноз кую, аны дәвалау, кисәтү буенча тикшеренүләр үткәрәләр; илдә беренче Трахоматоз ин-ты оештырыла, анда республи-

када бу инфекцияне бетерү юнәлешендә эш алып барыла.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән клиникаларда эвакогоспитальләр оештырыла. Хәрәкәттәге армия сафларына һәм тылдагы госпитальләргә ин-тның 267 хезмәткәре чакырыла, Л.М.Рахлин, Н.Н.Спасский, М.И.Мастбаум, В.А.Гусынин, Л.И.Шулутко, Ю.А.Ратнер, М.Х.Фәйзуллин, В.Н.Помосов һ.б. фронт, армия, берләштерелгән госпитальләрдә баш белгечләр буларак эшлиләр. Фронт һәм тыл госпитальләрендәге хезмәтләре өчен ин-тның 160 лап хезмәткәре орден һәм медальләр б-н бүләкләнә. Сугыштан соңгы елларда институтның клиник базалары яңадан торгызыла. Фәнни тикшеренүләрдә сугыш чоры тәҗрибәсе б-н баетылган яңа юнәлешләр барлыкка килә; мед. аппаратурасы эшләү һәм булдыруда яңа технологияләр үзләштерелә; авыруларны дәвалауда заманча әзерләнгән дару препаратлары кулланыла. Бу хәл яңа клиник кафедралар оештыруга, табибләрнең белемен камилләштерү һәм яңа белгечләр әзерләү өчен өстәмә уку цикллары, ш.у. төрле укыту формалары: күчмә цикллар, фәнни конференцияләр, семинарлар һ.б. куллануга китерә.

2010 елда К.м.а.ндә 3 факультетка — терапия, хирургия, мед.-профилактикасы ф-тларына 40 кафедра берләштерелә; академия ш.у. үзәк фәнни-тикшеренү лабораториясен, хастаханәләр аптекасын, клиникалар системасын (хәзерге 3 нче Республика клиник хастаханәсе) һәм клиник кафедраларны (14е — терапия, 14е — хирургия, 4се мед. профилактикасы ф-тына карый), фәнни китапханәне (350 меңләп берәмлектән торган фонд) үз эченә ала. Бирегә һәр елда РФнең 8 меңнән артык табибе — терапия, хирургия, стоматология һәм мед. профилактикасы профилендәге барлык белгечлекләр буенча укый; һәр ел интернатурада, клиник ординатура һәм аспирантурада 200 дән артык белгеч әзерләнә. К.м.а.ндә 6 белгечлек: нурлар б-н диагноз кую һәм дәвалау, нерв авырулары, эчке авырулар, акушерлык һәм гинекология, хирургия, травматология һәм ортопедия буенча 2 махсус диссертация советы эшли. Һәр елда 50 дән артык диссертация яклана. К.м.а. штатында 300 дән артык укытучы-профессор, ш.и. 14 РФА академигы һәм мөхбир әгъзасы, РФ һәм ТРның 18 атказ. фән эшлеклесе, 30 атказ. табибе, 30 сәламәтлек саклау отличнигы, 70 тән артык фән. д-ры, 187 фән. канд. исәпләнә. Академиянең әйдәп баручы галимнәре (И.П.Арлеевский, Л.И.Анчикова, Д.К.Бәширова, Р.Ш.Вәлиев, А.Р.Гайнетдинов, В.Е.Григорьев, Г.А.Иваничев, С.В.Киселёв, С.В.Мальцев, М.К.Михайлов, И.Г.Низамов, Х.З.Гафаров, Р.Г.Сәйфетдинов, Р.М.Таҗиев, Р.Ш.Шәймәрданов һ.б.) республика табибләренең фәнни җәмгыятьләрен җитәклиләр, Бөтенроссия фәнни җәмгыяте идарәсе, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы коллегиясе, шәһәр сан.-эпидемиология күзәтчелеге ком-ты, халыкара оешмалар әгъзалары булып торалар, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының аттестация комиссиясе һәм эксперт советларында эшлиләр (ин-тның 10 нан артык әйдәп баручы белгече).

Дәвалау-консультация эше 20 махсус төбәкара һәм республика мед. үзәгендә үткәрелә. Казанның 60 дәвалау учреждениесендә (К.м.а. базалары) ел саен 15 меңнән артык операция ясала, 10 меңнән артык лаборатор-инструменталь тикшеренү башкарыла. Академия базалары түбәндәге юнәлешләрдә фәнни-тикшеренү эшләре өчен файдаланыла: ана һәм бала сәламәтлеген саклауның мед.-социаль факторлары; яңа дару препаратлары эзләү һәм аларны сәламәтлек саклау өлкәсенә гамәлгә кертү; диагноз кую һәм дәвалауның яңа ысулларын камилләштерү; клиник иммунология һәм аллергология мәсьәләләре; сәламәтлек саклау хезмәткәрләрен дипломнан соң укытуның технологияләрен һәм оештыру-методик нигезләрен камилләштерү. К.м.а. хезмәткәрләре З.Ш.Гыйләҗетдинова, Х.З.Гафаров, И.Е.Микусев, И.Г.Низамов һ.б. Дәүләт бүләкләренә лаек була. Академиянең матди-техник нигезен ныгыту дәвам иттерелә. 1987 елда яңа укыту-лаб. корпусы, 1996 да 1 мең урынлы клиник хастаханә комплексын тәэмин итүче хастаханәләр аптекасы сафка баса. Төрле елларда җитәкче булып танылган фән эшлеклеләре: Р.А.Лурия, М.И.Аксянцев, А.Я.Плещицер, Б.С.Гинсбург, Д.Е.Потехин, И.Ф.Козлов, Г.И.Мөхәммәдъяров, И.В.Данилов, Х.З.Ахунҗанов, И.М.Рәхмәтуллин, М.Ш.Билалов, М.К.Михайлов (1980–2007), К.Ш.Зыятдинов (2007 дән) эшли. Ш.у. к. *Казан медицина академиясе клиникалары*.

*Әд.:* Государственный институт для усовершенствования врачей. 1920–25. К., 1925; Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина. К., 1990; Казанская государственная медицинская академия. 1920–1995. К., 1997. *М.К.Михайлов.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА АКАДЕ́МИЯСЕ КЛИ́НИКАЛАРЫ**, (3 нче Республика клиник хастаханәсе). 1920 елда нигез салына. Клиниканың беренче җитәкчеләре — Р.А.*Лурия*, В.П.Первушин, А.И.*Тимофеев*, Е.М.*Лепский*. Клиниканың төрле еллардагы атамалары: Казан клиник ин-ты клиникалары (1920 елдан), ГИДУВ клиникалары (1925 тән), Республика клиник медицина берләшмәсе (1993 тән), 3 нче Республика клиник хастаханәсе (2004 тән — академиянең укыту базасы).

Клиникалар аерым биналарда урнашкан, 10 бүлектән торалар (терапия, неврология, педиатрия, гинекология, бала тудыру, анестезиология һәм реанимация, нурлар б-н диагноз кую, патологик анатомия, диагноз кую клиник лаб-ясе, физиотерапия).

Терапия клиникасы (90 урынлы) элеккеге Кызыл Хач лазареты бинасында урнаша; анда ин-т клиникаларына хезмәт күрсәткән клиник лаб. була. Биредә С.И.Зотов, Л.С.Бородин, М.Р.Борок, Р.И.*Лепская,* М.И.*Мастбаум*, А.И.Миркин һ.б. танылган табибләр эшли. 1923 тән клиника элеккеге Крестьян җир банкы бинасында урнаша. Лекцияләр курсын төрле елларда профессорлар А.Ф.*Самойлов*, С.С.*Зимницкий*, Р.А.Лурия, Н.К.*Горяев*, Л.М.*Рахлин*, Л.А.*Щербатенко,* И.П.*Арлеевский*, Р.Г.*Сәйфетдинов* укый. Эчке патология, йөрәк авыруларын, матдәләр алмашы бозылуны, бөер һәм бавыр авыруларын дәвалауның гомуми мәсьәләләрен хәл итү юллары эшләнелә. Эдельман кыллы гальванометрының зур моделен сатып алу хезмәткәрләрнең фәнни эш базасына әверелгән клиник электрофизиология лаб-ясен җиһазларга мөмкинлек бирә (к. *Казан медицина фәнни мәктәбе*). 1950 дән клиниканы галим-кардиологлар Л.М.Рахлин, Л.А.Лушникова, И.П.Арлеевский җитәкли. Хәзерге вакытта клиника диагноз кую һәм йөрәк авыруларын дәвалау, ревматология буенча специальләшә. Дәвалау гамәленә аритмия вакытында эл. импульслары б-н дәвалау ысуллары, диагноз кую һәм дәвалау максатында үңәч аша



Казан медицина академиясе. Акушерлык клиникасы (3 нче Республика клиник хастаханәсе бүлекчәсе).

эл. б-н стимул ясау кертелә, коронар авырулардан дәваланучылар өчен интенсив терапия палатасы оештырыла (1972 дән). Клиника терапия профилендәге авыруларны дәвалау эшен план буенча алып бара, тәүлек әйләнәсе кичектергесез кардиологик ярдәм күрсәтә; ел саен анда 2 меңнән артык авыру дәвалана.

Нерв авырулары клиникасы (20 урынлык 3 палаталы неврология бүлеге) беренчеләрдән булып ачыла (1920). Аның тарихы профессорлар В.П.Первушин, А.В.*Фаворский*, И.И.*Русецкий*, А.Н.Смирнов, И.Н.*Дьяконова*, В.П.*Веселовский*, Г.А.*Иваничев* исемнәре б-н бәйле. 1960 еллар башында клиникада урыннар саны 48 гә җитә. Медицинада гальванометрия, хронаксиметрия, кимография кулланыш таба; хәрәкәтләнү системасы патологиясе, рефлектор нерв эшчәнлеге, нерв системасы йогышлы авырулары мәсьәләләре өйрәнелә; умырткалык патологиясе өлкәсендә (умырткалык остеохондрозы вакытында неврологик күренешләр, балалар умырткалыгының туганда ук зарарлануы) тикшеренүләр үткәрелә. Табибләр өчен вертеброневрология курслары оештырыла (1980); энәләр кадап дәвалау ысуллары кулланыла (И.И.Русецкий, Ә.Б.*Терегулов*, Д.М.*Табиева*). 1970 еллар башында стационар һәм поликлиника бүлеге берләштерелә. Анда диагноз куюның заманча ысуллары кулланыла, таралган миофасциаль авыру синдромы патогенезы мәсьәләләренең чишелеш юллары һәм аны дәвалау тактикасы эшләнә, мануаль һәм рефлексларга нигезләнгән дәвалауларны чиратлаштыру гамәлгә кертелә. Клиника ТР һәм Идел буе төбәгендәге авыруларга ярдәм күрсәтә; ел саен 8 меңнән артык авыру дәвалана.

Гинекология клиникасы Кызыл Хач җәмгыятенең Казан шәфкать туташлары оешмасының элеккеге лазаретында оештырыла (1920 дә проф. А.И.Тимофеев нигез сала). Төрле елларда И.Ф.*Козлов*, Н.Е.*Сидоров*, А.З.*Уразаев*, Н.Л.*Капелюшник*, Л.И.*Мальцева* җитәкчелек итә. Анда барлык төр операцияләр (ш.и. эндохирургик, аналыкта һәм аның юлларында), ш.у. аналык көпшәләрен сәламәтләндерү буенча микрохирургик операцияләр, җиңсә һәм аналыкның тотрыксызланган эчке якларына пластик операцияләр үткәрелә; барлык төр ялкынсыну авыруларына, эндометриоз, бала булмау, аналык һәм аның юлларындагы шешләргә диагноз кую һәм дәвалау башкарыла, нейроэндокринология буенча авыру хатын-кызларны дәвалау алып барыла; кичектергесез ярдәм вакытында лазер һәм эндоскопия хирургиясе ысуллары киң кулланыла.

Акушерлык клиникасы б-н төрле елларда И.Ф.Козлов, Н.Е.Сидоров, А.З.Уразаев, Н.Л.Капелюшник, Л.И.Мальцева җитәкчелек итә. Клиника хезмәткәрләре йөклелек өзелү, бала тудыру вакытындагы имгәнүләрне булдырмау мәсьәләләре б-н шөгыльләнәләр. Балага карында чакта авыру йоктыру ихтималы булган, йөклелеге патологияле хатын-кызларны дәвалауга һәм бала тудыру вакытында аларга махсус ярдәм күрсәтүгә аеруча игътибар ителә. Клиника җиһазлары ананы бала тудырганчы, баласы тугач, тулысынча күзәтергә мөмкинлек бирә. Монда ел саен 1,5 мең авыру тикшерү уза һәм дәвалана (2010).

Балалар клиникасын (100 урынлы) оештыручы һәм 30 елдан артык җитәкләүче — проф. Е.М.Лепский (1967 дә клиникага аның исеме бирелә). Клиника сәүдәгәр М.И.Оконишников йортында урнаша, бокслы палаталары, изоляторлары, амбулаториясе, күкрәк балалары өчен консультация пункты була; соңрак биохимия һәм бактериология лаб-яләре ачыла. 1977 дә җитлекмичә туган балалар бүлеге булдырыла. Клиникада төрле елларда Ю.В.*Макаров*, Е.П.Кревер, Р.И.Лепская, Б.Г.Гинсбург, Р.И.Еникиева һ.б. эшли. Зәңгелә, туберкулёз, аксымсыз шешенүләр, рахит, гиповитаминозларны дәвалау юнәлешләрендә фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла. Бөек Ватан сугышы елларында сугыш чоры патологияләре: рахит, пневмония, авитаминозлар, дистрофик балаларның туклануы өйрәнелә. Хәзерге вакытта клиника хезмәткәрләренең фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең төп юнәлешләре: нефрология, гастроэнтерология, йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары, рахитсыман авырулар, матдәләр алмашы бозылу. Монда ел саен 1,9 мең бала тикшерү уза һәм дәвалана. Клиника базасында ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына караган Татарстан Респ-касының Аналар һәм балаларның сәламәтлеген саклау үзәге (1993 тән), шәһәр нефрология үзәге (1977 дән), Республика рахитсыман авырулы балаларны дәвалау үзәге (1977 дән) эшли. Нурлар б-н диагноз кую бүлеге базасында Казан ГИДУВының нурлар б-н диагноз кую каф. булдырыла. Р.А.Лурия тырышлыгы б-н рентгент кабинеты ачыла, соңрак ул рентгент бүлеге итеп зурайтыла (җитәкчесе — М.И.Гольдштейн), 1927 дән рентгент каф. (1967 дән җитәкчесе Г.И.Володина). 1960 еллар башында нурлар б-н лимфогранулематозны ачыклау, онкология, неврология, күз, оториноларингология авыруларына һ.б. диагноз кую мәсьәләләре өйрәнелә.

К.м.а.к. үз эченә лаборатор диагноз кую хезмәтен, бактериология лаб-ясен, табибләрнең тикшеренүләр һәм дәвалау кабинетларын, даруханәне ала. Клиника табибләре гамәли эшләрен пед. һәм фәнни эшчәнлек б-н чиратлаштыралар. Монда 600 дан артык хезмәткәр, ш.и. 12 мед. фән. д-ры һәм канд-ты эшли. Ел саен академия клиникаларында 3 меңгә кадәр авыруга консультатив ярдәм күрсәтелә, 2 меңнән артык операция үткәрелә, стационарда 2 меңгә кадәр авыру дәвалана; РФ һәм ТРның 1200 гә якын табибе һөнәри осталыгын арттыра. 2003–2011 дә баш табиб — А.Р.Абашев.

*Әд.:* Казанская государственная медицинская академия (1920–1995). К., 1997.

*Р.Х.Хәсәенов.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА АКАДЕ́МИЯСЕ ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, 1990 елда фәнни-укыту үзәге буларак төзелә. Академиянең адм. корпусында урнашкан. Музей фондында *Казан медицина академиясе* тарихы материаллары — 3 меңнән артык язма җыйналган; шуларның 1,5 меңнән артыгы махсус урыннарда саклана, ш.и. ГИДУВ турында «Таныш булыгыз, ГИДУВ» («Знакомтесь, ГИДУВ», 1969), «Осталык һәм кешеләрне ярату, хезмәт һәм белем белән» («Искусством и человеколюбием, трудом и знанием», 1990), «Сезгә кешеләр ышаналар» («Вам доверяют люди», 1991) фильмнары. Экспозиция материаллары академиянең үсеш баскычларын тасвирлый. Кыйммәтле экспонатлар арасында академия профессорлары Р.А.*Лурия*, Е.М.Лепский, Л.М.*Рахлин*, А.Ф.*Фаворский*, М.О.*Фридланд*, И.И.*Русецкий*, В.В.*Громов*, Н.Н.*Лозанов*, В.К.*Трутнев*, В.Л.*Боголюбов*, А.Н.*Мурзин*, һ.б. шәхси архивлары; Н.К.*Горяевның* санау камерасы, С.С.Зимницкийның аналитик үлчәү җайланмасы һәм микроскобы, Н.Н.Лозановның инструментлары, И.И.Русецкийның инструмент һәм укыту әсбаплары (нерв үткәрү юллары), Л.М.Рахлинның Челюскин экспедициясен коткарганда файдаланган шәхси әйберләре — стетоскоп, пилотка, плащ-палатка һ.б. бар. Экспозициягә ш.у. РУ-780 рентгент аппараты, ИД-1-ВИ дефибрилляторының күкрәк электроды, Бөек Ватан сугышы елларында табиб В.С.Ефимовның фронтта файдаланган стерильләштерү аппараты һәм хирургия инструментлары куелган. «Хәрби бүләкләр» бүлегендә академия хезмәткәрләренең орденнар һәм медальләре. Экспозиция бүлекләрендә академиянең төрле дәвердәге тормышы һәм Казан галимнәренең мед. фәне һәм сәламәтлек саклау үсешенә керткән өлешен тасвирлаган фотоальбомнар, фотолар бар. Музейның фәнни эшчәнлеге кафедра һәм клиникалар тарихын яктырткан язмаларда, хезмәтләр тупланган җыентыкларда, академиянең юбилеена багышланган «Казан ГИДУВы (1920–90)» («Казанский ГИДУВ (1920–90)»), «Казан дәүләт медицина академиясенә 75 ел (1920–1995)» («Казанская государственная медицинская академия. 75 лет (1920–1995)»), «Нурлар б-н диагноз кую һәм нурлар б-н дәвалау: Үсеш баскычлары. Кафедралар төзелүгә 70 ел» («Лучевая диагностика и лучевая терапия: Этапы становления. К 70-летию организации кафедр»), һ.б. басмаларда күренә.



Казан медицина академиясе тарихы музее. Экспозиция фрагменты.

Музей мөдирләре: И.М.Муравьёва (1990 нан), Г.М.Минһаҗева (2003 тән).

*Ф.Х.Гафурова.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИНА́ ИНСТРУМЕНТЛАРЫ́ ЗАВОДЫ́** (КМИЗ), мед. сәнәгате пр-тиесе. Мед. инструментлары, стоматология, гомуми хирургия һәм микрохирургия, гинекология, акушерлык өчен җиһазлар, урология, офтальмология, оториноларингология һ.б. өчен инструментлар җитештерә. Эшләүчеләр саны — 613 кеше (2009). 1941 елда Казанга Киевтан эвакуацияләнгән теш дәвалау борлары з-ды (1931 дә Американың «Агроджойнт» фирмасы һәм Украинаның «Допомога» хәйрия җәмгыяте ярдәме б-н нигезләнә) җирлегендә Казан теш дәвалау борлары з-ды буларак оештырыла. СССРда 16 типта һәм зурлыкта теш борлары эшләүне үзләштергән һәм күпләп җитештерүне җәелдергән беренче пр-тие. 1960 та КМИЗ итеп үзгәртелә, 1987 дән ЖБ, 1994 тән АҖ. 1992 дән РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, 1996 дан ТРда мед. инструментларының тулы җыелмасын эшләүче, җитештерүче һәм клиникалар челтәрендә гамәлгә кертүче төп оешма. 1941 дә эшләүчеләр саны 180 ләп кеше була, җитештерелгән еллык продукция күләме 3 млн. нан артык теш боры тәшкил итә. 1959 да завод 70 типта һәм зурлыкта 16 млн. теш боры эшләп чыгара. КМИЗ илдә беренче булып стоматологик очлыклар һәм эндоканал инструментлары (илнең теш дәвалау техникасы ихтыяҗларын тәэмин итә, 1959), «Ясалма бөер» аппараты (нефрологик авырулар вакытында кан диализы үткәрү өчен), бөтен дөньяда «медицинада рус иярченнәре» дип аталган «УКБ-40» һәм «УКЛ-60» тегү аппаратлары (торакаль хирургия өчен, 1962), эл. термометрлары (кешенең тышкы һәм эчке тукымаларының, ш.и. баш миенең темп-расын тиз генә билгеләү өчен, 1963) җитештерүне үзләштерә. 1977 дә, заводның беренче чиратын реконструкцияләгәннән соң, 702 исемдә эш-

ләнмәләр чыгарыла, продукция җитештерү күләме — 19 млн. сумга, эшләүчеләр саны 2647 кешегә җитә. 1978 дә илдә беренче тапкыр гинекология һәм нейрохирургия, күз һәм йөрәк микрохирургиясе өчен инструментлар чыгару нигезләре эшләнә һәм үзләштерелә, 1990 елларда алар күпләп җитештерелә башлый. 2000 нән завод стоматология кабинетын коралландыру өчен кирәкле җиһазларның тулы комплектын булдыру, травматик энәләр, ныклы коелмалардан теш борлары җитештерү өстендә эшли.



Микрохирургия инструментлары.

КМИЗ структурасына 5 төрле төп производство: ныклы борлар һәм фрезалар, эндоканал инструментлары, очлыклар һәм пульпоэкстракторлар, хирургия энәләре җитештерү керә. 2 мөстәкыйль бүлендек пр-тиесе бар: «Микрохирургия инструментлары» АҖ (экспортка йөз тоткан әйдәп баручы подразделение, офтальмология, нейрохирургия һәм гомуми микрохирургия өчен продукция җитештерә), «Турбодента» ҖЧҖ (стоматологик очлыклар эшләп чыгара). Производство программалаштырылган станоклар б-н җиһазландырылган, компьютерлы проектлау системасы гамәлгә кертелгән. 2009 да сатылган продукция күләме тышкы базарда 25 млн. нан артык, эчке базарда 376,8 млн. сум тәшкил итә.

Завод танылган фирмалар (Германиядәге «Карл Шторц» һәм «Эскулап») һәм галимнәр (Америка кардиохирургы М. Дебейки, Россия академиклары В.И.Шумаков, Л.А.Бокерия, Е.И.Чазов, Р.С.Акчурин, В.И.Чисов һ.б.) б-н тыгыз хезмәттәшлек иткән, хәзерге вакытта «Сирона» фирмасы б-н элемтәләр җәелдерә. Эшләнмәләр эре серияләр белән, ш.у. заказда каралган кечкенә партияләр (бер генә данә, ягъни махсус сызымнар нигезендә, клиникалар, табибләр үтенече буенча) рәвешендә чыгарыла. 1998 дән җитештерүнең сыйфат күрсәткечләре системасы һәм продукциянең сыйфаты дөнья стандартларына туры килүгә сертификацияләнә. Пр-тиегә төп чимал җибәрүчеләр — «Кировоград ныклы коелмалар заводы» АҖ, «Электросталь», «Златоуст металлургия заводы» АҖләре. Завод продукциясе (3 меңнән артык исемдә) РФнең төрле төбәкләрендәге, БДБ дәге, Балтыйк буе илләре, АКШ, Германия, Израиль, Кытай, Италия, Франция, Греция, Төркия һ.б. илләрдәге 3,5 мең кулланучыга җибәрелә. Завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1976), «Коммерция абруе өчен» (1993), «Иң яхшы сәүдә маркасы өчен» (1994) халыкара дипломнары, «Россиянең иң яхшы экспортчысы» дипломы (РФнең тышкы икътисади багланышларын киңәйтүгә, илнең җитештерүен һәм экспортын үстерүгә керткән өлеше, югары һөнәри культура өчен, 2001) б-н бүләкләнә. КМИЗның күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. СССР, РФ Дәүләт бүләге лауреаты исеме — 7 кешегә, РФ, РТның атказ. машина төзүчесе исеме — 12, ТРның атказ. икътисадчысы исеме — 2, ТРның атказ. энергетигы исеме — 1, Ленин ордены — 3, Октябрь Революциясе ордены — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 13, Халыклар дуслыгы ордены — 1, «Почёт билгесе» ордены — 17, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены — 18, Почёт ордены 1 кешегә бирелә; медальләр б-н 256 кеше, ш.и. 206 кеше СССР ВДНХсының алтын, көмеш, бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: А.П.Бурман (1933–45), А.Х.Акалаев (1945–63), А.П.*Песошин* (1963–77), А.Н.Колемасов (1977–87), Н.Х.Шакиров (1987 дән).

*Әд.:* ОАО «Казанский медико-инструментальный завод». К., 2001.

*И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА КӨЛЛИЯТЕ́**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының махсус база урта уку йорты. Тарихы 1817 елдан башлана, Җәмәгать тәрбиясе приказы хастаханәсе каршында фельдшерлар мәктәбе ачылу һәм аның *Казан земство фельдшерлык мәктәбенә* әверелүе б-н бәйле. 1918 дә бу мәктәп нигезендә 1 нче совет фельдшер-акушерлык мәктәбе, 1924 тән Казан мед. техникумы (Кызыл Хач хәйрия җәмгыятенең Казан шәфкать туташлары җыены каршында 1914 тә оешкан Казан шәфкать туташлары мәктәбе б-н берләштерелгәч), 1929 дан Казан мед.-фармация техникумы (Казан фармацевтика техникумы б-н берләшкәч), 1936 дан Казан фельдшер-акушерлык мәктәбе, 1954 тән 1 нче Казан мед. уч-щесе; 1991 дән хәзерге исемдә. 1996 да көллият составына 1989 да оешкан 2 нче Казан мед. уч-щесе керә.

Училищедә урта мед. хезмәткәрләре әзерләү түбәндәге белгечлекләр буенча алып барыла: дәвалау, акушерлык, шәфкать туташлары, мед.-профилактика эшләре, стоматология, ортопедик стоматология, лабораториядә диагноз кую. 1996 дан урта мед. персоналы һәм урта мед. уку йортлары укытучылары һәм белгечләре белемен күтәрү курслары эшли. 2010 да көндезге бүлектә — 1330, кичке бүлектә — 540, ш.и. 890 студент бюджеттан тыш формада белем ала, 3 меңгә якын кеше белгечлек дәрәҗәсен күтәрә. 130 укытучы эшли, 200 гә якын читтән килеп эшләүчеләр һәм аерым дәресләр алып баручылар, ш.и. 1 фән. д-ры, 7 фән. канд-ты (алар арасында РФнең атказ. табибе, 6 ТРның атказ. табибе, 2 ТРның атказ. укытучысы). 1920 еллар башыннан хәзергәчә 20 меңнән артык белгеч әзерләнә. Тәмамлаучылар арасында Ф.Х.*Чанышева* бар. Төрле еллардагы директорлар: С.В.*Курашов* (1931–36), М.А.Сергеева (1944–72).

70 укыту кабинеты һәм лаб-ясе, спорт-сәламәтләндерү комплексы бар.

**КАЗА́Н МЕДИЦИНА́ УНИВЕРСИТЕТЫ́**, Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш буенча федераль агентлык карамагында. *Казан университетының* табиблек бүлеге буларак оеша (1814 елда ачыла, 1835 тән мед. ф-ты). 1930 дан мөстәкыйль югары уку йорты — Казан мед. ин-ты, 1966 да С.В.Курашов исеме бирелә, 1994 тән хәзерге исемдә.

Башта 2 ф-ттан тора: дәвалау һәм сан.-гигиена (хәзер мед.-профилактика) ф-тлары, 1932 дә педиатрия ф-ты ачыла. 1954 тә *Казан стоматология институты* нигезендә стоматология ф-ты оеша. 1975 тә фарм. ф-ты, 1991 дә социаль хезмәт ф-ты, 1994 тә менеджмент һәм югары белемле шәфкать туташлары ф-ты оештырыла. 1984–2001 елларда кичке факультет эшли.

К.м.у.да 24 меңнән артык белгеч әзерләнә. Тәмамлаучылар арасында 27 академик һәм МФАнең мөхбир әгъзасы бар. Дәвалау, педиатрия, мед.-профилактика эше, стоматология, фармацевтика, шәфкать туташлары эше, социаль хезмәт белгечләрен әзерләү һәм 30 юнәлештәге белгечлек буенча укыту эшчәнлеге алып барыла. 2010 да 5000 студент көндезге һәм 1270 е читтән торып уку бүлегендә укый, ш.и. 700 дән артыгы Азия һәм Африка илләреннән; фәнни-пед. коллективта 560 кеше (ш.и. 1 РМФА академигы, 4 ТР ФА академигы, 4 ТР ФА мөхбир әгъзасы, 141 фән. д-ры, 320 фән. канд.) эшли. Дипломнан соң белем бирү ординатурада (800 кеше, анда 29 белгечлек һәм юнәлеш буенча квалификация күтәрелә, ш.и. мед. уку йортлары укытучылары укый), аспирантурада 25 белгечлек буенча һәм докторантурада алып барыла.

Казан ун-тындагы фәнни-тикшеренү юнәлешләре мед. ун-тында барлык төп дисциплиналар буенча дәвам иттерелә: терапия (Н.К.Горяев, А.И.Бренинг, Ә.Б.Терегулов, В.И.Катеров, З.И.Малкин, К.А.Дрягин, И.Л.Билич, С.И.Щербатенко, В.Е. Анисимов, Я.М.Милославский, Р.Ш.Абдрахманова), йогышлы авырулар (Б.А.Вольтер,

А.Е.Резник), дерматовенерология (Н.Н.Яснитский, Г.Г.Кондратьев), офтальмология (В.Е.Адамюк, А.П.Нестеров, Н.Х.Хәсәнова), оториноларингология (В.К.Трутнев, Н.Н.Лозанов, Л.Г.Сватко), фтизиатрия (Б.Л.Мазур, Ф.Т.Краснопёров), физиотерапия (Ә.Г.Ибраһимова), эндокринология (В.В.Талантов), психиатрия (М.П.Андреев), неврология (Л.И.Омороков, Я.Ю.Попелянский), хирургия (А.В.Вишневский, Н.В.Соколов, С.М.Алексеев, И.В.Домрачев, Б.Г.Герцберг, И.Ф.Харитонов, В.Н.Шубин, Р.А.Вяселев, В.Х.Фраучи, Н.П.Медведев, В.Г.Морозов, А.А.Агафонов, Г.М.Николаев), нейрохирургия (Х.М.Шульман), педиатрия (В.К.Меньшиков, Е.М.Лепский, А.Ф.Агафонов, Ю.В.Макаров, Е.Н.Короваев, П.Н.Булатов, К.А.Святкина, Н.П.Кудрявцева, Е.В.Белогорская), акушерлык һәм гинекология (В.С.Груздев, И.Ф.Козлов, Х.Х.Мещеров, П.В.Маненков, Г.М.Шәрәфетдинов, З.Н.Якубова, Б.Г.Садыйков), балалар хирургиясе (М.Р.Рокицкий), рентгенология (М.И.Гольдштейн, М.Ф.Мусин), нормаль анатомия (В.Н.Терновский, В.Н.Мурат, Х.Г.Вәлиева, А.Г.Коротков), патологик анатомия (В.А.Добрынин, Н.Ш.Шәмсетдинов), гистология (А.Н.Миславский, Г.И.Забусов, Э.Г.Улумбәков), физиология (А.В.Кибяков, И.Н.Волкова, Х.С.Хәмитов), патофизиология (А.Д.Адо, М.А.Ерзин, И.М.Рәхмәтуллин), гигиена (В.В.Милославский, М.Х.Вахитов, А.И.Смирнов, В.П.Камчатнов, А.Т.Гончаров, А.М.Хәкимова), гомуми гигиена (М.Х.Вахитов, Т.Д.Эпштейн), эпидемиология (А.Э.Озол, В.И.Качурец), микробиология (З.Х.Кәримова, Н.Ф.Амфитеатрова), биохимия (В.А.Энгельгардт), стоматология (И.М.Оксман, Г.Д.Овруцкий, Л.А.Кольцова), фармакология (И.В.Заиконникова, И.А.Студенцова).

70 кафедра һәм үзәк фәнни-тикшерену лаб-ясендә терапия (В.Ф.Богоявленский, И.Ә.Лотфуллин, Н.Б.Әмиров, И.Г.Салихов, В.Н.Ослопов, А.С.Галявич, Р.Ә.Хәбиров), йогышлы авырулар (В.Х.Фазылов), иммунология (В.Н.Цыбулькина), дерматовенерология (Р.З.Зәкиев), оториноларингология (В.И.Галочкин), физиотерия (Ю.Е.Микусев), фтизиопульмонология (А.А.Визель), урология (Э.Н.Ситдыйков, М.Э.Ситдыйкова), психиатрия (Д.М.Менделевич, К.К.Яхин, В.Д.Менделевич), неврология (М.Ф.Исмәгыйлев, Т.В.Матвеева, В.А.Исанова, В.И.Данилов, Э.И.Богданов, Д.Р.Хәсәнова), нефрология (О.Н.Сигитова), анестезиология (В.Ф.Жаворонков), нейрорентгенология (И.И.Камалов), хирургия (И.А.Салихов, И.В.Клюшкин, Д.М.Красильников, С.В.Доброквашин), травматология (Р.А.Зөлкарнәев), педиатрия (А.Г.Шамова, А.П.Пигалов, Л.К.Фазлыева, О.И.Пикуза, В.П.Белогорский, В.А.Анохин, С.Я.Волгина), балалар хирургиясе (А.Ә.Ахунҗанов, П.Н.Гребнев), акушерлык һәм гинекология (Л.А.Козлов, А.А.Хәсәнов, И.Ф.Фәткуллин) нормаль анатомия (Э.С.Вәлишин, А.П.Киясов), патологик анатомия (С.Б.Петров, С.В.Петров), гистология (Ю.А.Челышев, В.В.Вәлиуллин), физиология (А.Л.Зефиров, Е.М.Волков), патофизиология (М.М.Миңнебаев, А.М.Девятаев, Ф.И.Мөхетдинова), гигиена (М.М.Гыймадиев, Н.Х.Әмиров, А.В.Иванов, Ш.Ю.Якупов, А.Б.Галләмов, Р.Я.Хәмитова, А.Ә.Имамов), микробиология (О.К.Поздеев, Л.Т.Мусина), эпидемиология (М.Ш.Шәфиев), биохимия (Д.М.Зөбәеров, Р.И.Литвинов, Р.Ф.Байкиев), мед. биология (Г.И.Полетаев, В.В.Семёнов), мәхкәмә медицинасы



Казан медицина университеты. Төп уку корпусы.

(Г.М.Харин), стоматология (Х.М.Сәйфуллина, М.З.Миргазизов, И.И.Гыйниятуллин, Р.З.Уразова), фармакология (Д.А.Вәлимөхәммәтова, Р.С.Гәрәев, Л.А.Поцелуева, Р.Х.Хафизҗанова, А.З.Байчурина, С.Н.Егорова, А.Г.Җиһаншин) буенча тикшеренүләр алып барыла.

Университетның уку базасы 3 уку корпусыннан һәм 4 клиникадан гыйбарәт, нормаль анатомия һәм биол. кафедралары *университет шәһәрчегендә*, махсус кафедралар *Республика клиник хастаханәсендә*, *Балалар медицина үзәгендә*, шәһәр хастаханәләрендә, диспансерларда (барлыгы 4,5 меңнән артык урын), поликлиникаларда урнашкан. Китапханә фондында 700 меңнән артык китап исәпләнә.

*«Казанский медицинский журнал»*, *«Неврологический вестник» имени В.М.Бехтерева»* (ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Казан мед. академиясе катнашында), «Novitas» (1996 дан) ж-лары, «Казанский медик» г-тасы (1934 тән) нәшер ителә.

Университет тарихы (1984 тән), нормаль анатомия, патологик анатомия, нормаль физиология, акушерлык һәм гинекология, ш.у. А.В.Вишневский, Л.О.Даркшевич музейлары эшли.


2 спорт залы, җәйге сәламәтләндерү лагере бар. К.м.у. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнгән. Ун-тның директорлары һәм ректорлары: С.М.Корбангалиев (1930–31), А.А.Диковицкий (1931–32), И.С.Алуф (1932–35), М.И.Аксянцев (1935), С.Б.Еналиев (1935–37), М.В.Нежданов (1937–41), С.В.Курашов (1941–42), Г.Ф.Тихонов (1942–44), В.С.Исупов (1944–45), М.Ф.Мережинский (1945–47), Р.А.Вяселев (1947–63), Х.С.Хәмитов (1963–89), Н.Х.Әмиров (1989–2008), А.С.Созинов (2008 дән).

Ш.у. к. *Казан фәнни медицина мәктәбе*, *Медицина белеме бирү*.

*Әд.:* Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1989; Казанский медицинский институт, 1814–1989: В 2 ч. К., 1989; Амиров Н.Х., Саркин В.Г., Красильников С.Н. Ректоры Казанского медицинского института. К., 1994; Казанский государственный медицинский университет: 1814–1994. К., 1994; Кафедры Казанского медицинского университета. К., 1994; Андреев И.М., Красильников С.Н. Казанский государственный медицинский университет. Стоматологический факультет: История в биографиях. К., 1996; Деканы Казанского медицинского университета (от медицинского факультета до медицинского университета). К., 1997; Казанский государственный медицинский университет. К., 1999; Знаменательные и юбилейные даты истории КГМУ. К., 2002; Казанский государственный медицинский университет 1804–2004 гг. Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА УНИВЕРСИТЕТЫ́ КЛИ́НИКАЛАРЫ**, 19 йөз башында Казан ун-ты каршында оештырылалар. 1930 елдан Казан мед. ин-ты составында, 1953 тән ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, 1994 тән «Медицина университеты клиникалары» муниципаль учреждениесе составында, 2005 тән Казан мед. ун-тының укыту базасы.

1815 тә терапия, акушерлык, хирургия клиникалары, 1840 та «Иске клиника» (аның нигезендә Республика клиник хастаханәсе барлыкка килә), 1872 дә тире-венерология, 1874 тә — офтальмология, 1887 дә — неврология клиникалары, 1890 да балалар клиникасы ачыла. 1900 дә 4 хастаханә корпусы һәм Изге Варсонофий чиркәвеннән торган клиник комплекс (к. *Казан университетының яңа клиникалары*) сафка баса. Ул Идел-Урал төбәгендә клиник мед. һәм мед. фәнни мәктәбе үсеше үзәгенә әверелә. Клиникаларда Е.В.*Адамюк*, А.В.*Вишневский*, В.И.*Разумовский*, А.Г.*Ге*, Н.К.*Горяев*, С.С.*Зимницкий*, М.О.*Даркшевич*, В.С.*Груздев*, Н.А.*Виноградов* һ.б. эшли.



Казан медицина университеты.
В.К.Меньшиков исем. клиника.

Хирургия клиникасын (45 урынлы) В.И.Разумовский җитәкли, аңа дөньякүләм танылуны 1914–34 тә шунда эшләгән А.В.Вишневский китерә (к. *Анестезия*, Вишневский ысулы б-н, *Вишневский мае*). *Акушерлык-гинекология клиникасы* б-н 30 елдан артык В.С.Груздев, Тире-венерология клиникасы (И.И.Алафузов акчасына төзелә) б-н А.Г.Ге җитәкчелек итә (хәзер аның исемен йөртә) (к. *Дерматология*).

Казанда беренче балалар клиникасы (30 урынлы) кенәз П.М.Аргутинский-Долгорукий тырышлыгы б-н төзелә; анда рентген кабинеты, клиника, биохимия һәм бак-

териология лаб-яләре булдырыла. Соңрак клиника б-н В.К.*Меньшиков* җитәкчелек итә. Ул 1912 дә Россиядә беренче булып Европа клиникалары үрнәгендә яңа туган балалар бүлегең ача. Казан педиатрларының фәнни эшчәнлегендәге төп юнәлешләрнең берсе балаларны тукландыру мәсьәләсе була. В.К.Меньшиков тарафыннан



Казан медицина университеты. В.С. Груздев исем. акушерлык-гинекология клиникасы.

балаларны диета б-н дәвалау ысуллары эшләнелә; аның хезмәтләре балаларны тукландыру өчен әче сөт катнашмалары булдыруга этәргеч бирә.

Казан мед. ун-ты клиник базалары 4 меңнән артык урынга исәпләнгән. Клиника кафедралары ш.у. 46 шәһәр һәм республика дәвалау учреждениеләре базаларында, ш.и. Республика клиник һәм Республика балалар клиник хастаханәләрендә, Казан шәһәренең 18 нче, 6 нчы клиник хастаханәләрендә, ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсендә бар. Университетның 1 меңнән артык урынлы базасы Республика клиник хастаханәсендә. Андагы 14 каф. һәм курс хезмәткәрләре елга 9 меңнән артык операция ясый, ТР районнарында һәм эш урынында 120 меңгә якын консультация үткәрә. Татарстан табибләре өчен фәнни-гамәли конференцияләр оештырыла.

Казан мед. ун-ты каршындагы дәвалау учреждениеләре клиникаларында һәм клиника кафедраларында 300 дән артык хезмәткәр, фән докторы һәм кандидаты, ТРның фән һәм техника өлкәсендә 6 Дәүләт бүләге лауреаты эшли. Табибләрнең 89%ы югары квалификация категориясенә ия. 2006 дан баш табиб — Р.Ә.Хәбиров.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1814–2004). К., 2004.

*Э.З.Якупов.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА УНИВЕРСИТЕТЫ́ ПАТОЛО́ГИК АНАТО́МИЯ МУЗЕЕ́**, 1863 елда патологик анатомия кафедрасында фәнни-методик әсбаплар музее буларак оештырыла. Медицинага нисбәтле беренче музей б.э.к. 3 йөз башында Александриядә төзелә. Соңрак Амстердамда голланд табибе һәм анатомы Ф.Рюишның анатомия музее аеруча танылу ала. 1719 да Петербург кунсткамерасы (сирәк очрый торган әйберләр җыелмасы, шуларны саклау урыны, музей) ачыла, шул вакыттан Россия мед. музейлары тарихы башланып китә. Казан коллекцияләренә башлангыч А.В.*Петров* тарафыннан салына (кафедраның беренче мөдире), ул Германия ун-тларында музей эшләре буенча стажировка үткәндә үз кулы б-н 100 дән артык препарат туплый. 1865 тә музей өчен ун-тның *Анатомия театрында* махсус бина бүлеп бирелә. 1930 да, Казан ун-тының мед. ф-ты Медицина ин-ты итеп үзгәртелгәннән соң, музей патологик анатомия каф. б-н бергә Толстой урамындагы уку бинасына күчерелә. Музей фондларында 2 меңнән артык экспонат: патологик анатомиянең гомуми һәм аерым өлешләре буенча уку-өйрәнү макропрепаратлары һәм патологик органнарның барлык төр белгечлекләр буенча табибләрне кызыксындырган уникаль очраклары булган сирәк препаратлар саклана. Экспонатлар Казан губернасында һәм Татарстанда авырулар һәм үлүчеләр санын чагылдыра. Фондларда юкка чыккан һәм сирәк очрый торган авыруларны (махау, чума, чәчәк, түләмә, тимгелле тиф, ваба һ.б.) дәвалау препаратлары бар. Азынган формадагы авырулар: баш сөягенә кушылып үскән инфильтрат җәрәхәтле бит тиресе рагы, 30 *кг* лы аналык фибромиомасы, 15 *см* диаметрлы тире папилломасы, 200 *г* авырлыктагы сидек куыгы ташы, 6 *кг* авырлыктагы кул чугы шеше, бот сөягенең мускул һәм тире капламына кушылып үскән остеосаркома, кызамык вакытындагы нома (бит тукымасы некрозы) һ.б. катлаулы очракларны чагылдырган препаратлар күрсәтелә. Тумыштан килгән гариплек коллекциясе ш.у. уникаль (маңгай уртасында бер күзле «циклоп», түбән очлыклары балык койрыгына охшап үскән «сирена», «ихтиоз» — балык тәңкәсе (тән тиресенең кабырчык б-н каплануы һ.б.). Экспонатлар арасында 69 яшьлек үле хатынның гәүдәсен ярганда табылган «таш яралгы» — известь б-н капланган яшь бала, туберкулёзның барлык формаларын — авыруның беренчел билгеләреннән башлап, бөтен әгъзаларны зарарлап таралганына кадәр — чагылдырган препаратлар; йөрәк-кан тамырларының төрле патологиясен чагылдырган 30 дан артык йөрәк аномалиясе препаратлары; өченчел сифлистан үлгән кешенең макропрепаратлары кебек гадәти булмаган һәм сирәк очрый торганнары бар. Патологик анатомия каф. күп еллар онкология проблемалары б-н шөгыльләнә. Музейда кешеләрдә очрый торган шешләрнең барлык формалары үрнәкләре дә диярлек саклана, арада патологиянең азгын һәм сирәк очраклары макропрепаратлары бар. Казан патологик анатомия музее Россиядә иң уникаль музейларның берсе — препаратларның барысы да диярлек бик сирәк очрый торган әйберләр, коллекция 200 елга якын туплана килә. 19–20 йөзләрдә музей эшен профессорлар Н.М.*Любимов*, Ф.Я.*Чистович*, И.П.*Васильев*, В.С.Подольский, Г.Г.*Непряхин*, В.А.*Добрынин*, Н.Ш.*Шәмсетдинов*, Д.Э.Цыплаков дәвам итә.

*Д.Э.Цыплаков.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА УНИВЕРСИТЕТЫ́ ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, 1984 елда фәнни өйрәнү музее буларак оештырыла. Ун-тның уку-лаб. корпусында урнашкан. Фондта 16 меңгә якын саклау берәмлеге, ш.и. авторлары ун-т укытучылары, рус һәм чит ил галимнәре булган мед. әдәбиятының сирәк нөсхәләре; 19–20 йөзләрдәге уникаль мед. инструментлары һәм мед. җиһазлары; төрле документаль материал; мәшһүр мед. эшлеклеләренең альбомнары, фотосурәтләре, портретлары, рәсемнәре; мед. тематикасына медальләр һәм билгеләр коллекциясе бар. Экспозицияләр «19 йөзнең 1 нче яртысы Казан Император университетының медицина факультеты», «19 йөзнең 2 нче яртысында Европа дәрәҗәсендәге фәнни-медицина мәктәпләре», «Медицина институтын оештыру», «Бөек Ватан сугышы елларында медицина институты», «Совет медицина фәнни мәктәпләре» дигән бүлекләрдән тора. Экспонатлар арасында баш миенең үткәрүче юллары моделе (психоневролог В.М.*Бехтерев* лаб-ясеннән алынган), Татарстан һәм Россиянең танылган мед. эшлеклеләренең: мед. ф-тының беренче деканы, терапевт Ф.Х.*Эрдман*, гигиенист К.Ф.*Фукс*, анатомнар Е.Ф.*Аристов*, В.Н.*Терновский*, гистолог А.Н.*Миславский*,



Казан медицина университеты тарихы музее экспонатлары (психоневролог В.М. Бехтерев лабораториясеннән).

паталогоанатом Н.М.*Любимов*, патофизиолог В.В.*Пашутин*, хирург А.В.*Вишневский*, гигиенист В.В.*Милославский*, СССР сәламәтлек саклау министры С.В.*Курашов* (1966–94 тә институт аның исемен йөртә) һ.б. ның документлары бар. Музейда уникаль мемориаль мебель саклана. Медицина тарихы буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла (мед. тарихы каф. укытучылары һәм студентлар түгәрәге әгъзалары). Казан мед. ун-ты каршында Анатомия театры, Патологик анатомия музее, В.С.*Груздев*, А.В.Вишневский, Л.А.*Даркшевич* музей-кабинетлары бар.

Музей мөдирләре: Е.Ю.Ионова (1984–97), Е.Ю.Поспелова (1997–2003), И.Ю.Артемьева (2004–2011), Ә.Ә.Тутаева (2011дән).

*Э.З.Якупов, А.С.Созинов.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, к. *Казан медицина көллияте.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан ун-тында формалаша башлый. Иң беренчеләрдән булып оешкан һәм хәзерге вакытта аеруча тармакланган фәнни мәктәпләрнең берсе. Ул гомуми танылган 19 фәнни-мед. тикшеренүләре юнәлешен үз эченә ала.

**Анатомия**. Анатомик тикшеренүләрдә (оештыручылар Е.Ф.*Аристов* һәм П.Ф.*Лесгафт*) киң рәвештә эксперименталь ысуллар кулланыла. П.Ф.Лесгафт үз хезмәтләрендә кеше тәне төзелешенең гомуми закончалыкларын бәян итә. В.Н.*Тонков* тамырлар системасы морфологиясен — ангиологияне өйрәнүгә нигез сала (1907), В.Н.*Терновский* нейрологияне өйрәнүгә зур өлеш кертә. 1942 елда В.Н.*Мурат* нерв системасының адаптацион-трофик функциясен морфологик исбатлап күрсәтә; ул һәм аның шәкертләре ашказаны-эчәк юллары парасимпатик иннервациясенең чыганакларын ачыклау өчен адашкан нервка һәм арка-миенең умырткадагы түбән бүлеге нервларына бәйле тикшеренү үткәрәләр. Казан анатомнары Х.Г.*Вәлиева*, М.Т.*Рәкыева*, Э.С.*Вәлишин* тарафыннан төрле органнар һәм системаларның яссы тоташтыргыч тукымалары төзелешен тикшерергә мөмкинлек бирә торган нерв-рецептор аппаратын өйрәнү методологиясе эшләнелә. Алга таба да морфометрик күрсәткечләр эшләнү һәм анатомик эксперимент нәтиҗәләрен анализлау — 1950–90 елларда төрле органнар һәм системалар тамырларында гемодинамика күренешен күзалларга мөмкинлек бирә (Х.Г.Вәлиева, М.Т.Рәкыева, Э.С.Вәлишин һ.б.). Ш.у. к. *Анатомия*.

**Гистология**. Казан ун-тында 1871 дә эмбриология, гистология һәм чагыштырма анатомия (мөдире К.А.*Арнштейн*) кафедрасын ачу нейрогистология (аерым органнарга хас күзәнәкләрне өйрәнү) өлкәсендә фәнни тикшеренүләр активлашуга китерә. Гистологик өйрәнүләр методикасына яшәү чорында нерв элементларын метилен-зәңгәр ярдәмендә буяуны гамәлгә кертү б-н (К.А.Арнштейн, А.Е.Смирнов, А.С.*Догель*) тикшеренүләрнең яңа этабы башлана. 1870–80 дә чәч, тире бизләрендәге нерв очлары тасвирлана, тәмамланган очлардагы нерв аппаратлары төзелеше, мөгез катлам, төсле катлам тышчасы иннервациясе (К.А.Арнштейн, А.Г.*Герберг*), ашкайнату тракты тамырлары, бизләрнең секретор иннервациясе (И.Гоняев), үңәч һәм ашказаны эпителиенда ирекле нерв очлары тикшерелә; периферик нерв системасының соматик бүлеге төзелеше закончалыклары билгеләнә. 1920 елларда А.Н.*Миславский* тарафыннан вегетатив нерв системасына гистологик тикшеренүләргә нигез салына, тиренең эпителиаль тукымасы, бөер күзәнәкләре, ашказаны асты бизе төзелеше өйрәнелә, гистологик тикшеренүләр вакытында көмеш тозлары б-н нейроннарны импрегнацияләү ысулы гамәлгә кертелә. Н.Левандовскийның миокард иннервациясе буенча хезмәте йөрәк органнарының эчке нерв аппараты турындагы тәгълимат үсешенә башлангыч бирә. 1930 елларда сулыш органнары иннервациясен өйрәнү дәвам итә. Г.И.*Забусов*, Н.Г.*Колосов*, Г.А.Поликарпова хезмәтләрендә үткәрүче синтицийнең бер үк җирендә янәшә ятучы ике вазифалы нерв үткәргечләренең терминаль ботаклануы нигезләнә; Б.И.*Лаврентьев* һәм Н.Г.Колосов тарафыннан ашкайнату трактының иннервацион төзелешенең цитоархитектоникасын өйрәнүгә нигез салына. Үзәк цилиндрларның кабельләр булып урнашу системасы турында тәгълимат раслана. Бу тикшеренүләрне Г.И.Забусов, И.Ф.*Иванов*, М.А.Мәкъсудов, В.Н.Мурат, А.П.Маслов (1930–40 та) дәвам итәләр. Гистологик тикшеренүләр үсешендә А.Н.Миславский шәкертләренең зур сеңерләр иннервациясе (Р.А.Чураев), фаллопий көпшәләре иннервациясе турында (М.А.Романов) хезмәтләр зур роль уйный. Казан гистологлары тарафыннан эчке секреция бизләренең микротөзелеше өйрәнелә, кеше һәм хайваннар нерв системасы вегетатив бүлегенең нейрон төзелеше, буй-буйлы аркылы мускулларның симпатик иннервациясе исбатлана, ашкайнату юлының интрамураль нерв үрелмәләрендә сизгер нервлар булуы исбатлана, скелет мускуллары бүленеше һәм сыгылмалыгының гомуми закончалыклары тасвирлап бирелә, мускулларның кыскару күрсәткечләрен көйләү үзенчәлекләре күрсәтелә (Н.П.*Резвяков*). 1970 елларда төрле патологик процесслар вакытында нерв системасының периферик бүлекләре торышын өйрәнүгә башлангыч салына, нерв системасындагы ретоград дегенерация дип аталган күренешләр турында яңа мәгълүматлар алына, сизүчән нейроннарның трофик функцияләре, нерв очларының цитохимиясе (Э.Г.*Улумбәков*) өйрәнелә. 1980 еллардан гистологик кисештәге матдәләрне сан ягыннан бәяләү б-н параллель рәвештә рецепторда матдәләр алмашын бәяләү (Ю.А.*Челышев*) һәм, микрохимия алымнары (Р.Р.Гатауллин) кулланып, гистохимик тикшеренүләр үткәрелә башлый.

**Топографик анатомия**. Казан галимнәренең топографик анатомия өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләре нәтиҗәләре Н.В.*Соколов*, Д.М.Лапковның «Хирургия анатомиясе буенча кыскача кулланма» («Краткое руководство по хирургической анатомии», 1935) исемле монографияләренә нигез итеп алына. 1930–40 та Б.В.*Огнев* тарафыннан иң вак тамырларны нечкә итеп тутыру ысулы эшләнелә һәм ул микроциркуляция турындагы тәгълиматның нигезен тәшкил итә. 1930–60 та клиник анатомия барлыкка килә, лимфология мәсьәләләре өйрәнелә (Я.М.Брускин, А.Н.*Сызганов*, Б.В.Огнев, В.Х.*Фраучи*). Кан һәм лимфа әйләнеше процессларын өйрәнгәндә табылган факторларны анализлау 1990 елларда системаларның төрле халәтен ачыкларга, аларның үсеш стадиясен тасвирларга, дәвалауның төрле методларын куллануны патогенетик яктан нигезләргә (И.Г.*Ибәтуллин*) мөмкинлек бирә. Корсак арты гематомаларына диагноз кую һәм дәвалау мәсьәләләре өйрәнелә, оператив хирургия һәм топографик анатомия буенча күптомлы дәреслек (Ә.Х.*Дәүләтшин*, А.А.*Агафонов*, В.Х.Фраучи, 1990 еллар) нәшер ителә. Топографик һәм клиник анатомиянең фундаменталь нигезләмәләре, төрле авыруларга диагноз куелгач тикшереп карау максатыннан магнитлы резонанс топографиясен нигезләргә һәм мед. гамәленә кертергә мөмкинлек бирә (Ф.С.Бәширов, Ф.Г.Биккиниев, С.В.*Добраквашин*, И.Х.Зарипов, А.В.*Иванов*, М.Ю.Кедрин, А.И.Кормилин һ.б.).

**Патологик анатомия**. 1863 тә Казан ун-тында патологик анатомия каф. ачыла һәм бу үз чиратында патологоанатомик тикшеренүләр башлап җибәрүгә мөмкинлек бирә, анда морфология юнәлешендәге эшчәнлек үсеш ала, туберкулёз, көчле лейкемия вакытында патологик тикшеренүләр үткәрелә (А.В.*Петров*, Н.М.*Любимов*). Гомуми патология И.П.*Васильев* җитәкчелегендә клиника һәм патологоанатомиянең үзара бәйләнеше аша өйрәнелә (1910–20). Атеросклероз, үпкә һәм элпә рагы вакытында ангиология, ганглионевромалар этиологиясен өйрәнүне аның шәкертләре (Г.Г.*Непряхин*, И.Г.Ибәтуллин) дәвам итәләр.

Рак авыруы патологиясе мәсьәләләрен күпьеллык тикшеренүләр нәтиҗәсендә (1970–90) авыру барышын фаразлауга ирешелә, патологик процессларга һәм авыру билгеләренең кабатлануына диагноз кую өчен маркерлар куллану башлана, үпкә ялкынсынуы һәм үпкә рагы авыруы арасындагы үзара бәйләнеш ачыклана, молекуляр патогенез тикшерелә һ.б. эшләр башкарыла (В.А.Добрынин, Н.Ш.*Шәмсетдинов*). 1990 елларда шешләргә алшарт булган (диспластик) процесслар һәм шешнең ракка әйләнүендә цитоскелет (цитокератин) ролен өйрәнү, рак шешләренең үсешен фаразлау, иммуногистохимик диагнозлау һәм дәвалау (С.В.*Петров*) эшләре үсеш ала. Ш.у. к. *Патологик анатомия*.

**Физиология**. 1835 тә Казан ун-тының физиология каф. каршында илдә беренче ачылган физиол. лаб-ясе (мөдире Ф.В.*Овсянников*) эксперим. анатомик-физиол. (нейрофизиол.) тикшеренүләр үткәрергә мөмкинлек бирә. Ф.В.Овсянников шәкерте, фәнни физиологиягә нигез салучы, И.М.Сеченов тәгълиматы тарафдары һәм Россия медицинасында тәҗрибәләр үткәрү юнәлешендә эшләүне дәвам итүче Н.О.*Ковалевский* аксон-рефлекс һәм прессор рефлексларны ача, 1860 елларда физиол. процессларны көйләү механизмнарын (газлар алмашу, кан һәм лимфа әйләнеше) өйрәнә. А.А.Кулябконың эшләре (1900–30 еллар) безнең илнең реаниматологиясе нигезен тәшкил итәләр. Н.А.*Миславский* һәм В.М.*Бехтерев* кан басымына, йөрәк-кан тамырлары системасына, ашказаны-эчәк юлларына, сидек куыгы һ.б. системалар эшчәнлегенә баш мие тышчасының аерым өлешләре тәэсирен өйрәнәләр. Бөер өсте бизләренең секрет иннервациясе үзенчәлекләрен ачыклау эшен Н.А.Миславский һәм М.Н.*Чебоксаров* башкаралар (1910). 20 йөз башында физиол. процессларны көйләү механизмын тикшерү алып барыла. А.Ф.*Самойлов* тарафыннан *электрокардиография* ысулы тәкъдим ителә (1908). Аның бер күзәнәктән икенчесенә ярсынулар тапшырылу идеясе А.В.*Кибяков* тарафыннан гамәлгә ашырыла (1924) һәм хезмәтләре нерв ярсынулары тапшырылуның химик процессларын өйрәнүгә багышлана, 1949 да бу хезмәтләр СССР ФА бүләгенә лаек була. А.В.Кибяков дөньяда беренче булып тәҗрибә ысулы б-н бер гангли-

оз күзәнәктән икенчесенә нейронара синапс ярсынулар күчеше медиатор катнашында булуын исбатлый. Бу тема 1960–80 дә И.Н.*Волкова*, Х.С.*Хәмитов*, Г.И.*Полетаев* хезмәтләрендә дәвам иттерелә. А.Л.*Зефировның* фәнни тикшеренүләре өлкәсе нерв системасы һәм хәрәкәтләнү аппараты физиологиясенә карый. Дөньяда беренче буларак, аның тарафыннан нерв очларыннан медиаторлар бүленеп чыгу механизмнарын тикшерүнең яңа ысуллары эшләнелә, нерв очларының структур-функциональ берәмлекләре (актив зоналар) эшчәнлеге закончалыклары өйрәнелә, нерв очлары формалашу һәм җитлегүе турында уникаль теория төзелә, синаптик тапшыручыларда денервацион-реиннервацион үзгәрешләр механизмы һәм нерв очлары мембранасына ион каналлары урнашу факты ачыла, хәрәкәтләндерүче нерв очларының төп ион агышы һәм ион каналларының нерв очлары буенча бүленеше тасвирлана, нерв очларындагы медиатор секрециясен көйләү механизмының медиаторлар, гормоннар, пептидлар аша башкарылуы ачыклана, синапс фәзан чикләнгән актив зоналарының гетероген, сыгылмалы, интеграль системасы буларак бәяләнә. Е.Е.Никольский, Р.Ә.Гыйниятуллин, А.Х.Уразаев җитәкчелегендә периферик нерв-мускуллар синаптик аппаратының эшчәнлек һәм көйләү механизмнары тикшерелә (к. *Физиология*).

**Патологик физиология**. К.м.ф.м.ндә Россия патологик физиологиясенә һәм патофизиол. тикшеренүләренә нигез салучы булып организмның төрле экстремаль халәтләрдә функциональ үзгәрешләрен өйрәнүче В.В.*Пашутин* санала. Ул беренче калориметр төзи, патологик физиология буенча илдә беренче кулланма яза.

И.Г.*Савченко* иммунобактериология юнәлешенә башлангыч бирә һәм үстерә. Н.Н.*Сиротинин* төрле патологияләр вакытында гипоксия халәте турында мәгълүмат туплый (1900–20). 1930–70 тә Казан галимнәре тарафыннан реаниматология, иммунология (аллергик реакцияләр механизмы һәм аларны классификацияләү) мәсьәләләре өйрәнелә. А.Д.*Адо* аллергология нигезен булдыра, күзәнәк мембраналары эшчәнлеген, ацетилхолинэстераз системаны өйрәнә, бүленеп чыгу иммунитеты мәсьәләләре буенча тикшеренүләр башлый. 1970 елларда М.А.*Ерзин* һәм И.М.*Рәхмәтуллин* скелет мускулларының аллергик реакциясе механизмнарын тикшерүне дәвам итәләр, М.М.*Миңнебаев* аллергия вакытында лимфа системасы патофизиологиясен өйрәнә. Аллергияне дәвалау ысулларын һәм булдырмау чараларын Г.Б.*Толпегина*, Р.Х.*Борнашева*, А.М.*Потёмкина*, Р.С.*Фәссахов* эшлиләр.

**Биохимия.** Казанда биохимик тикшеренүләр үсеше 1963 тә Казан ун-тында биохимия каф. ачылуга бәйле (мөдире — А.Я.Данилевский). Бу өлкәдәге күренекле ачыш булып 1931 дә В.А.*Энгельгардтның* аэроб организмнар яшәешенең энергетик нигезен тәшкил иткән оксидлы фосфорилләнү күренешен ачуы санала. А.А.*Баев* ДНКда аксым алмашының беренчел халәтен тасвирлый. Д.М.*Зөбәеров* әйләнештәге канда булган актив фермент — тромбинны ача, организмда өзлексез кан оешу теориясен эшли (РФ Дәүләт бүләге, 1991). Р.И.*Литвинов* кан оешу биохимиясе өлкәсендә тикшеренүләрне дәвам итә, кан плазмасындагы аксымнарны фракцияләргә бүлү технологиясен эшли; Д.М.Зөбәеров, Р.И.Литвин, О.Д.Зинкевич фибронектин препаратын уйлап табалар (к. *Биохимия*).

**Фармакология**. Казан ун-тының фармакология каф. (1869) нигезендә фармакология мәктәбе формалаша, нигез салучы — М.А.*Алуф*. Яңа дару препаратларын тикшерүне 1950–2000 дә И.В.*Заиконникова*, И.А.*Студенцова*, Р.С.*Гәрәев* һ.б., соңрак Казан мед. ун-ты хезмәткәрләре үткәрәләр (к. *Фармакология*).

**Микробиология**. Микробиология өлкәсендәге фәнни тикшеренүләр үсеше (1910 еллар) И.Г.Савченко, В.М.*Аристовский* һәм аларның шәкертләре исеме б-н бәйле. Беренче тикшеренүләр авыру кузгатучыларны өйрәнүгә, организмның иммун җавап системасын ачыклауга багышлана. В.М.Аристовский спирохетозларны өйрәнә (морфологиясе, дәвалау, иммунологиясе). И.Г.Савченко иммунитет реакциясен өйрәнүдә физик-химик юнәлешкә нигез сала (аның фагоцитозны өйрәнү эшләре классик дип санала); ул җәрәхәт инфекцияләрен өйрәнә һәм аларны дәвалау ысулларын тәкъдим итә. З.Х.*Кәримова*, Г.З.Хәбирова хезмәтләре (1960–70) Идел буе төбәгендә лептоспирозларны өйрәнүгә багышлана: лептоспирларның яңа штаммнары ачыла, аларның үзенчәлекләре өйрәнелә, сыек һәм тыгыз туклану җирлегендә аларны үстерү ысулы эшләнелә. Йогышлы авырулар вакытында фагоцитоз процессларын өйрәнүгә И.Е.*Алатырцева* хезмәтләре багышлана, ютәлгә диагноз кую һәм иммунологиясен ачыклау Н.Ф.*Амфитеатрова* тикшеренүләрендә урын ала. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан микробиологларның тикшеренүләре Казан галимнәре тарафыннан синтезланган фосфорорганик һәм табигый катнашмалардан алынган яңа дару чараларын сынауга, аларның микробларга каршы тотрыклы үзлекләрен өйрәнүгә карый (М.Г.Берим, К.Б.Бруднная, Е.К.Наумова, Ш.З.Туктарова, Р.Г.Исхакова, Э.А.Гозман, Т.Ә.Кәримова һ.б.). Хастаханәдәге йогышлы авырулар, яңа туган бала һәм аналардагы эренле авыруларны булдырмау буенча тикшеренүләрне В.Е.*Григорьев*, Л.А.Генчиков, Л.А.*Козлов* һ.б. үткәрәләр; алар бу авыруларны дәвалау һәм булдырмауның яңа схемаларын һәм ысулларын тәкъдим итәләр.

**Йогышлы авырулар**. Казан йогышлы авырулар белгечләренең фәнни тикшеренүләре йогышлы авыруларга иртә диагноз кую ысулларын эшләүгә, патогенезын, клиникасын өйрәнүгә һәм дәвалауга юнәлтелә. Б.А.*Вольтерның* беренче хезмәтләре (1920 еллар) авыл җирлегендә йогышлы авыруларга диагноз кую һәм аларны булдырмау ысулларын эшләүгә багышлана. Ул кискен йогышлы авырулар клиникасын өйрәнә, серологик реакцияләр үткәрү өчен сыркындылар җыелмасы, зур кан тамчысында лейкоцитлар санауны тәкъдим итә. Аның эшен дәвам итүчеләр тарафыннан 1940–80 дә сыек һәм коры бактериофагларны чагыштырып өйрәнү эшләре башкарыла, дизентерияне дәвалауда сульфидин куллану өйрәнелә (А.Е.*Резник*), дифтериягә диагноз кую һәм дәвалау оптимальләштерелә (В.И.*Качурец*, Н.П.*Кудрявцева*, С.Х.Хәбибуллина, Л.М.Малышева), йогышлы чире булган авыруларда шок вакытында кан әйләнеше бозылу һәм гемостазны булдырмау һәм дәвалау (Д.Ш.*Еналиева*) эшләре башкарыла; рожа кабатлануы вакытында гомеостаз һәм иммунитет бозылулар өйрәнелә, аларны терапия юлы б-н көйләү эшләнелә (В.Х.Фазылов), ш.у. йогышлы авырулар барышына яңа фосфорорганик кушылмалар тәэсире өйрәнелә (Н.А.Булатова, Л.Ч.Самерханова, В.С.Мороков, В.Х.Фазылов, А.С.Созинов). Д.Ш.Еналиева һәм В.Х.Фазылов җитәкчелегендә башкарылган фәнни тикшеренүләр кайбер йогышлы авырулар патогенезында гомеостаз һәм иммуногенез бозылуларының яңа фактларын ачыкларга, глюкокортикостероидлар, димефосфон, ксимедон кебек препаратлар б-н патогенетик дәвалауның авыру барышына уңай тәэсирен билгеләргә мөмкинлек бирә. Соңгы елларда вируслы гепатитлар патогенезы һәм аны дәвалау инфекционистлар һәм эпидемиологларның (Д.К.*Бәширова*, А.С.Созинов, Э.Х.Мамкеев) тирәннән өйрәнү предметы булып тора. А.Д.*Царегородцев* һәм В.А.*Анохин* тарафыннан балаларда көчле респиратор авырулар вакытында патологик синдромнар үсешенең заманча концепциясе тәкъдим ителә.

**Акушерлык һәм гинекология**. Акушерлык һәм гинекология буенча фәнни тикшеренүләр Казанда В.С.*Груздев* җитәкчелегендә башлана. Ул дөньяда беренче булып 1913 тә күкәй сарысының эпителиаль булуын исбатлый, ул ш.у. шешләр һәм яман шешләрне өйрәнә. Н.Н.*Феноменов* акушерлык җиһазларын уйлап таба һәм камилләштерә (1890–1900). И.Ф.*Козлов* операция һәм бала тудыру вакытында тәннең аерым урынына анестезия ясау ысулларын тәкъдим итә (1930). Хатын-кызның баласы булмауны Р.Г.*Бакыева*, З.Н.*Якупова* (П.В.*Маненков* җитәкчелегендә) өйрәнәләр; алар гинекологик операцияләр вакытында аерым урынга анестезия ясау ысулын гамәлгә кертәләр, бала булмауны, акушерлыкта кан китүләрне тиз дәвалау ысулларын тәкъдим итәләр. И.В.*Данилов*, Х.Х.*Мещеров*, З.Ш.*Гыйләҗетдинова* акушерлык-эндокринология ярдәме, эндокринология һәм генетика мәсьәләләрен өйрәнәләр. Л.А.Козлов җитәкчелегендә галимнәр ясалма җинсә булдыру мәсьәләсе өстендә эшлиләр. Б.Г.*Садыйков*, Д.П.Игнатьева яралгы һәм ананың резус-яраклашмау мәсьәләсен (резус-конфликтлы йөклелек) өйрәнәләр, авыру көчәюен булдырмау ысулларын тәкъдим итәләр. Операциядән соңгы авыртуларны булдырмау, акушерлыкта кан китүләргә тикшеренүләр үткәрү, критик халәтне интенсив дәвалау, акушерлык һәм гинекологиядә лазер нурлары һәм югары энергияләр куллану мәсьәләләре Казан мед. ун-ты галимнәренең беренче чираттагы эшләре булып санала.

**Дерматовенерология**. Казан мед. фәнни мәктәбендә дерматология юнәлешенә нигез салучы А.Г.*Геның* фәнни-тикшеренү эшләре сифилиска, тиредә профессиональ авыруларга диагноз кую һәм дәвалауга багышлана. 1900 дә ул тире авыруларын яктылык нуры б-н дәвалау кабинеты ача. Казан мед. ин-ты галимнәре тиредә катлам-катлам була торган авырулар динамикасы (Я.Д.*Печников*, 1950 еллар), тире авырулары патогенезында бактериаль аллергия, аутоаллергиянең роле өйрәнелә (Г.Г.*Нуриев*, 1960 еллар), аларны дәвалау ысуллары эшләнелә. Склеродермия б-н авыручыларны дәвалау өчен димексид препараты тәкъдим ителә (В.П.Сергеев, 1980 еллар). Балаларда псориаз, аллергодерматозлар, озакка сузылган дерматитларны булдырмау ысуллары эшләнелә (Р.З.*Зәкиев*, 1990 еллар).

**Офтальмология**. Казанда офтальмологик фәнни тикшеренүләр үсеше В.Е.*Адамюк* эшчәнлегенә бәйле. 1850 елларда аның шәкертләре (А.Г.*Агабабов*, В.В.*Чирковский*, К.Х.Орлов, В.П.Иванов, А.Н.*Бекетов*) тарафыннан беренче тапкыр катаракта авыруларына операцияләр үткәрелә. Казан ун-ты нәшер иткән 4 томлык «Офтальмология буенча кулланма» («Руководство по офтальмологии», 1890) Казан офтальмологларын Россиядә һәм чит илләрдә таныта. 1922 дә Казанда В.Е.Адамюк исем. Трахоматоз ин-ты ачыла, институт галимнәре тарафыннан трахома классификациясе, авыруга диагноз кую ысуллары тәкъдим ителә, мөгез катламны күчереп утырту гамәлгә кертелә (В.В.Чирковский), тукыманы дәвалап, трахоманы бетерү ысулы эшләнә (В.П.Филатов буенча), СССР Дәүләт бүләгенә лаек булган (1948) «Трахома» хезмәте нәшер ителә. Күзнең төсле катламы һәм мөгез катламына операцияләр ясауга багышланган хезмәтләр авторы А.Н.*Мурзин* тәкъдиме б-н 1933 тә «Вопросы трахомы» ж-лы нәшер ителә башлау инфекция б-н көрәшүдә зур әһәмияткә ия була. 1960 елларда республикада трахоманы бетергәннән соң, глаукома профилактикасы һәм аны дәвалау, һөнәри эшчәнлеккә бәйле күз патологиясе, күрә алмауның көчле үсешен хирургик дәвалау һәм күз тамырлары патологиясе мәсьәләләре актуальләшә (А.П.*Нестеров*, Н.Х.*Хәсәнова*, Д.Г.Камалов, А.Н.*Круглов*). А.П.Нестеров тарафыннан эшләнгән глаукома патогенезы концепциясе дөньякүләм ачыш булып танылa (1975 тә СССР Дәүләт бүләгенә лаек була). М.Б.*Вургафт* күзнең гидродинамик күрсәткечләрен тикшерүнең оригиналь ысулларын эшли, фотоэлектромонограф уйлап табучыларның берсе була. Күзнең алгы камерасының күрү почмагын билгеләүнең ул тәкъдим иткән ысулы (эчке нурлар кисешe феномены) өчен ВДНХ медале бирелә. 1990 елларда яңа юнәлешләр: вертеброофтальмология, көчле күрә карау вакытында энәләр кадап дәвалау эшләнә (җитәкчесе — М.В.*Кузнецова*).

**Гигиена**. Казанда гигиена буенча фәнни тикшеренүләр үсеше сан. медицинасының методологик принципларын эшләгән (1860 еллар) А.И.*Якобий* эшчәнлегенә бәйле. Гигиена дисциплиналарын, диэтиканы укыта башлау гигиена өлкәсендә тикшеренүләргә этәрә. Элегрәк Казан галимнәре тарафыннан гигиена юнәлешендәге тикшеренүләр үткәрелгән була, бу Ф.Х.*Эрдманның* «Россиянең эчке торышын тану» («К познанию внутренней России», 1822); К.Ф.Фуксның «Урал эшчеләренең авырулары» («О болезнях уральских рабочих», 1824), исемле хезмәтләрендә бирелә. К.В.Пупырев, К.Ф.Фукс, И.С.Дмитриевский ваба эпидемиясен һәм аның йогышлылыгын тасвирлыйлар, авыру таралуны чикләү чараларын тәкъдим итәләр. Соңрак В.Д.Орлов, А.Арнольдов, Н.И.Орлов су тәэминаты мәсьәләләрен, Идел елгасы һәм кушылдыклары суы составын тикшерәләр. В.В.*Милославский* эпидемик зоб этиологиясе һәм патогенезында микроэлементлар ролен, су гигиенасы һәм Казанны су б-н тәэмин итү мәсьәләләрен өйрәнә. Н.И.Шулпинов һәм Л.И.Лось республикада су үткәргечләр проектлауны фәнни нигезлиләр. Казандагы суны тикшерү һәм аның сыйфатын бәяләү эшләре б-н гигиенистлар Ф.Д.Клайдович, И.К.Ерохова, И.С.Дмитриевский, Г.И.Блюсфельд шөгыльләнә, тикшеренүләрдә А.М.*Бутлеров* актив катнаша (суны тикшерү өчен тәҗрибә кабинеты ача). Артезиан чыганакларны А.А.*Штукенберг* һәм А.Я.*Щербаков* өйрәнә. Эчү өчен кулланылган суда нитратларның куркынычсыз кушылмалары характеристикасын тикшерүгә Н.И.Петухов, А.В.Иванов, М.М.*Гыймадиевның* хезмәтләре багышланган.

Микроэлементлар ролен өйрәнүне А.Т.*Гончаров* һәм А.М.*Хәкимова* тәкъдим итә (аллергия үсешендә хромның роле). Калкансыман бизнең эшчәнлеге бозылуга китерүче йод җитешмәүне А.М.Хәкимова, А.Н.Юнысова һ.б. өйрәнә. Йод һәм бром алмашы бәйләнеше мәсьәләләре Р.Ш.Таһирова хезмәтләрендә бәян ителә. Казан галимнәре авыл мәктәпләре укучылары сәламәтлеген (В.М.Смирнов, Р.Ш.Якупова, З.З.Мостафина), яшүсмерләр сәламәтлегенең социаль-гигиена аспектларын (А.Х.*Яруллин*, Ф.Ф.*Даутов*, А.Б.*Галләмов*, Ә.Н.Минһаҗева һ.б.) максатчан тикшерү эшен башлыйлар. Мед.-социаль профилактика өлкәсендәге тикшеренүләр ике юнәлештә алып барыла: профилактика чараларын нигезләү (П.Ф.*Капустин*, В.О.Португалов, П.А.Песков, Н.И.Гизяков) һәм төрле төркемнәрдә халык сәламәтлеген өйрәнү; җәмәгать медицинасы, сәламәтлек саклау системасын оештыру (В.В.Милославский, М.М.*Гран*, Н.А.*Семашко*, З.П.*Соловьёв*, Т.Д.*Эпштейн*, С.В.*Курашов*, М.Х.*Вахитов* һ.б.). 20 йөзнең 2 нче яртысында гигиенистларның игътибары кеше һәм аның хезмәт вакытындагы халәтен, нерв-психика бозылу чикләрен (С.М.Шварц, С.М.Арановский, В.П.*Камчатнов*, И.Е.Голубовский, И.В.Чудновская) өйрәнүгә, сәнәгатьнең аерым тармакларында хезмәт шартлары һәм авыруларга бирешүне, хатын-кызлар һәм балалар сәламәтлеген өйрәнүгә юнәлтелә (Н.Х.*Әмиров*, В.Г.Ковязин, В.Н.Краснощёкова, З.М.Берхеева, А.Г.Гарипов, Р.Б.Галләмов, Н.Н.Мәҗитов, Л.А.Никольская һ.б.). ТР районнары һәм шәһәрләрендә авырулар барлыкка килүгә йогынтысы булган экологик куркыныч факторларның хәлиткеч роле билгеләнелә, сәнәгать гигиенасы һәм хезмәт медицинасын өйрәнү юнәлеше булдырыла (җитәкчесе — Н.Х.Әмиров).

**Терапия**. Казанда терапиягә бәйле тикшеренүләрнең үсеше Казан ун-тының мед. ф-ты б-н тыгыз бәйләнгән. Фәнни юнәлешкә нигез салучы Н.А.*Скандовский* «Казанда ваба чире» («Холера в Казани», 1832) хезмәте авторы. Алга таба бу фәннең үсеше Н.А.*Виноградов* (С.П.Боткин шәкерте) исеменә бәйле. Мед. фәне үсешендә терапиянең катлаулы мәсьәләләре турында сөйләшүләр алып барылган «Протоколы», «Труды» һ.б. басма органнары да булган *Казан табибләре җәмгыяте* үзенчәлекле роль уйный. Казан ун-ты диагностика процессының алгоритмик нигезләрен заманча яктырткан оригиналь «Эчке авыруларны тикшерүнең клиник ысуллары буенча кулланма» («Руководство к клиническим методам исследования внутренних болезней», Н.И.Котовщиков, 1880) нәшер итә. Авыруларга гуманистик караш традицияләрен Н.В.*Засецкий*, А.Н.*Казимбәк* һәм В.Ф.*Орловский* (соңрак, 1917–60 та Краков мед. академиясендә терапевтлар мәктәбен җитәкли) дәвам итәләр.

20 йөзнең 1 нче яртысында терапевтик тикшеренүләргә функционист С.С.*Зимницкий*, эндокринолог М.Н.Чебоксаров, гематолог Н.К.*Горяев*, ревматолог З.И.*Малкин*, гастроэнтерологлар Ә.Б.*Терегулов*, К.А.*Маянская*, пульмонолог Р.Ш.*Габдрахманова* хезмәтләре өстәлә. 1920 дә Казанда Клиника ин-ты оештырылгач (соңрак ГИДУВ), терапия буенча тикшеренүләрне Р.И.*Лепская*, Р.А.*Лурия*, Л.М.*Рахлин*, О.С.*Радбиль* үткәрәләр. С.С.Зимницкийның ашказаны секрециясенең төп типларын тасвирлаган тикшеренүләре күпләргә мәгълүм, ул аксымнарның таркалуы-черүе процессына углеводлар тәэсирен өйрәнә, үпкә тукымасы ялкынсыну һәм тараю сәбәпле тын кысылудан һәм бөерләр авыруыннан күкерт б-н дәвалау, бөерләрнең функциональ эшчәнлек сәләтен билгеләү ысулын тәкъдим итә, Н.К.Горяев гематологик анализ ысулларын гамәлгә кертә, канның формалы элементларын санау камерасын эшли (*Горяев санау камерасы*). Ашкайнату системасының функциональ патологиясе, үт юллары дискинезиясе клиникасы һәм аны дәвалау, юан эчәк авырулары, ашказаны җәрәхәте проблемаларын хәл итүгә Ә.Б.Терегулов һәм аның шәкертләренең (К.А.Маянская, И.Л.*Билич*, Д.А.Утикеева һ.б.) тикшеренүләре багышланган. И.Е.*Зимакова*, Д.А.*Вәлимөхәммәтова* җитәкчелегендә клиник фармакология формалаша. Ревматология һәм токсикология мәсьәләләре И.Г.*Салихов*, Р.Ә.*Хәбиров*, Р.М.Газизов тарафыннан тикшерелә. 2000 еллар башында терапевтлар гастроэнтерологик, кардиопульмонологик, ревматологик, эндокринологик тикшеренүләрне дәвам итә. Төрле эчке авырулар вакытында гемокоагуляция — кан бозылу һәм микроциркуляция мәсьәләләрен өйрәнү (Д.М.Зөбәеров, В.А.Люсов, В.Ф.*Бо-*

*гоявленский)* алып барыла; эконефрологиягә нигез салына (Р.Г.Биктимерова). Кардиология мәсьәләләре яңа методик һәм клиник диагноз кую ысуллары нигезендә өйрәнелә (А.С.*Галявич*, В.Н.*Ослопов*, И.Ә.*Лотфуллин*, И.Г.Салихов).

**Педиатрия**. Балалар авыруларын өйрәнү өлкәсендәге фәнни-тикшеренү үсеше П.М.*Аргутинский-Долгорукий* (Казан ун-тының мед. ф-тында балалар авырулары кафедрасын оештыра, 1893); Е.М.*Лепский*, Ю.В.*Макаров*, К.А.*Святкина* (балаларда рахит, авыруларны тукландыру), В.К.*Меньшиков* (ашкайнату бозылу, диатезларны өйрәнү), Е.В.Короваев, А.М.Потёмкин (балалык чоры аллергологиясе), Г.Ф.Солтанова, Е.В.*Белогорская* (неонаталогия, яңа туган балаларда авыруларны булдырмау) эшчәнлекләренә бәйле. Фундаменталь һәм гамәли мед. мәсьәләләре өлкәсендәге киң колачлы комплекслы эшчәнлек яңа фәнни юнәлешләр булдыруга китерә: респиратор юлларда вируслы һәм бактериаль йогышлы авырулар патогенезы һәм дәвалау мәсьәләләрен өйрәнү (О.И.*Пикуза*), гепатобилиар система эшчәнлеге бозылу (В.П.Булатов), ш.и. балалар хирургиясе. Балаларның сулыш органнарында үлекле-деструктив үзгәрешләрне хирургик дәвалау буенча комплекслы эшләр өчен ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге бирелә (М.Р.*Рокицкий*, А.Ә.*Ахунҗанов*, Н.П.Гребнев, 1997). «Сәламәтлек резервы скринингы һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларны «ВИНИБИС» препараты кулланып сәламәтләндерүнең фәнни нигезләмәләре» («Скрининг резерва здоровья и научное обоснование применения препарата «ВИНИБИС» в оздоровление детей дошкольного возраста» (Н.Х.Әмиров, О.И.Пикуза, 1999) исемле хезмәт ш.у. ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була.

**Психоневрология**. Психоневрологик фәнни тикшеренүләргә нигез салучылар булып Л.О.*Даркшевич* һәм В.М.Бехтерев санала. Казан ун-ты галимнәре 19 йөз башында нерв системасы халәтенең авыру барышына тәэсирен өйрәнә башлыйлар (Н.А.Виноградов, Д.М.*Скалозубов*). 1882 дә Казан невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте оештырыла, «Неврологический вестник» ж-лы нәшер ителә башлый, 1887 дән ун-тта Нерв авырулары клиникасы эшли. В.М.Бехтерев тарафыннан яшәү өчен мөһим системалар иннервациясенә ми кабыгындагы үзәкләрнең тәэсирен тикшерү — организмдагы вегатив процессларны ми кабыгы көйләвен тәҗрибә юлы б-н тикшеренүләр башлап җибәрүгә этәргеч була. Л.О.Даркшевич, физиолог Н.А.Миславский, хирурглар В.И.*Разумовский*, А.В.*Вишневскийның* бергәләп тикшеренүләре илдә нейрохирургия юнәлеше үсешенә китерә. 1890 да дөньяда беренче тапкыр Гассер төенен операция юлы б-н алу башкарыла. 20 йөздә арка һәм баш мие шешләре билгеләрен, нерв системасының шешләре һәм тамырлары авырулары патоморфологиясен өйрәнү (А.В.*Фаворский*, 1916–30; Л.И.*Омороков*, 1930–60) актуаль юнәлеш ала. И.С.*Алуф* нейрогистологик һәм цитоархитектоник тикшеренүләр (1920–30) үткәрә, СССРда рефлексотерапиягә нигез салучыларның берсе И.И.*Русецкий* хезмәтләре вегетологияне өйрәнүгә багышлана. Әнәләр кадап дәвалау буенча уникаль атлас һәм ил күләмендәге кулланма хезмәт авторы Д.М.*Табиева*, мануаль терапия һәм акупунктура механизмнары буенча хезмәт авторы Г.А.*Иваничев* аның эшен дәвам итәләр.

**Вертеброневрология**. Нерв системасының вертеброневрологик авыруларын өйрәнү үзәге булып Казан ун-тының (Я.Ю.*Попелянский*) һәм Казан мед. академиясенең (В.П.*Веселовский*) нерв авырулары кафедралары тора. 20 йөзнең 2 нче яртысында нерв системасы бозылуларын — умыртка, муен остеохондрозын (В.П.Веселовский, Ф.Ә.Хәбиров), нерв системасының перинаталь патологиясен (В.Ф.Прусаков), туу вакытында арка миенең зарарлануын өйрәнү һәм дәвалау (А.Ю.*Ратнер*) өстенлекле юнәлеш ала. Балалар нейрорентгенологиясе формалаша (М.К.*Михайлов*), яшькә бәйле вегетологик тикшеренүләр үткәрелә (М.Ф.*Исмәгыйлев*), полимер материаллар кулланып, умырткалыктагы дискларны хирургик юл б-н алыштыру ысулы эшләнелә (Х.М.*Шульман*). Вегетатив функцияләр бозылуның генетик нигезләре (Д.Р.Хәсәнов), бил остеохондрозы вакытында невраль мускулларның бозылышлары (Ф.Ә.Хәбиров) мәсьәләләре, скелет мускулларының регуляция патологиясе вакытында кыскару үзлекләренең үзгәрү закончалыклары, баш миенең кан әйләнеше патофизиологиясе, церебраль паралич авыруларын реабилитацияләү ысуллары (Э.И.*Богданов*) өйрәнелә, функциональ нейрохирургия үсеш ала (В.И.*Данилов*). «Вертеброневрология» ж-лы нәшер ителә (1992 дән), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршында «Вертеброневрология» үзәге оештырыла (1992). Казанда Халыкара вертеброневрологлар ассоциациясе төзелә (нигез салучы В.П.Веселовский, 1990). Арадаш һәм сәнәгый психиатрия мәсьәләләре өйрәнелә (Д.М.Менделевич, К.К.*Яхин*).

**Травматология**. Травматологиянең үсеше ортопедия авырулары өчен беренче лазарет оештырган М.О.*Фридланд* эшчәнлеге б-н бәйле. 1918 дә протезлар әзерләү остаханәсе нигезендә Ортопедия институты ачыла һәм анда сөяк тукымасы регенерациясе, йөрү-хәрәкәт аппаратының тумыштан һәм яшәү дәверендә барлыкка килгән бозылулары патогенезы мәсьәләләре; операциядән соңгы чорда сәламәтләнүнең сыйфатын арттыручы җайланмалар һәм приборларны гамәлгә кертү өйрәнелә. Л.И.*Шулутко* сөякнең ялган буыннарын (пластина урнаштыру, декортикация), остеобластокласт, сколиоз, сөяк ялкынсынуы авыруларын оператив дәвалау ысулларын тәкъдим итә (1937). Ул сынуларны дәвалау өчен функциональ шин уйлап таба (Шулутко-Ципоркин шины). Бөек Ватан сугышы елларында утлы корал яраларын, озакка сузылган җәрәхәтләрне, нерв баганалары яраларын дәвалау ысуллары эшләнелә (Л.И.Шулутко, Л.В.Грубер, Г.С.Книрик). Сугыштан соңгы елларда сәнәгать травматологиясе һәм төрле органнарның эшчәнлеген кабат кайтару өчен җайланмалар төзү юнәлеше алга чыга (Ү.Я.*Богданович*, Д.Г.*Тәхәвиева*, А.И.Гордеева, Е.Н.Громова). Кыйпылчыкларны җыеп электәге позицияне булдыру (Х.С.Рәхимкулов, Ф.Ф.Сафин, А.А.Крылов, А.Л.*Гиммельфарб*), компрессия б-н остеосинтез үткәрү аппаратлары (Ф.С.*Йосыпов*, А.А.Крылов, В.М.Сергеев, Р.А.Шәфигуллина), сөяккә компрессия б-н остеосинтез үткәрүдә эксцентрик бикле пластина куллану (Х.С.Рәхимкулов) белгечләр арасында югары бәяләнә. Түбән очлыкларның торсион деформациясе механизмының оригиналь теориясе төзелә (1980 еллар башы), авыруларны тикшерүнең радиоэлектрон ысуллары эшләнә һәм гамәлгә кертелә, микрохирургик ысуллар б-н дәвалау, буыннарны протезлау башкарыла (А.А.Богов, Х.З.*Гафаров*, А.Л.Гиммельфарб, Р.Г.*Зөлкарнәев*, И.Ф.*Әхтәмов*).

**Хирургия**. Хирургиядә фәнни юнәлешләр 19 йөз башында барлыкка килә (нигез салучылар И.В.*Браун* һәм Ф.Х.Эрдман). Бу вакытта хирургия кафедралары аз бүленешле була, аларның алга таба үсеше И.Х.Ренард, Л.Л.*Фогель*, И.О.Браун, Э.О.*Вердерамо* һ.б. исемнәр б-н бәйле. 1934 тә Казан ун-тының гомуми хирургия кафедрасын бүсерне кисү, литотрипсия, катлаулы яраларны дәвалау эшен башкаручы Ф.О.*Елачич* җитәкли. Ул (А.А.*Китер* б-н бергәләп) Казанда беренче тапкыр эфир наркозы куллана. Клиника Урал буе төбәге өчен табибләр әзерләү үзәге булып китә. 1837 дә П.А.*Дубовицкий* Россиядә пластик хирургиягә (ринопластика) башлангыч сала. Н.Ф.*Высоцкий* һәм Л.Л.*Лёвшин* — беренче рус онкологлары. Н.Ф.Высоцкий 1837 дә онкология буенча беренче хезмәтләрен яза (аскы ирен рагы килеп чыгу сәбәпләре). Ш.у. операция яралары патоморфологиясен тикшеренүләрдә дә аның өлеше зур. Госпиталь хирургиясе кафедрасында А.Н.*Бекетов* хлороформ б-н наркоз ясау клиникасын тирәнтен өйрәнә, аны куллануның катлаулылыгын һәм куркыныч якларын ачыклый (1860–70). Бу чорда антисептика, асептика, авыртуны басу мәсьәләләре өйрәнү стадиясендә булганлыктан, хирургларның ашыгыч ярдәм итү осталыгы хәлиткеч әһәмияткә ия була. Антисептика һәм асептика эшләнешенә бәйле фәнни юнәлеш үсешендә яңа этап госпиталь хирургиясе кафедрасына Л.Л.Лёвшинның килүе (1881) б-н башлана. Аның эшчәнлеге (карбол эремәләр б-н антисептик эшкәртү ысулын гамәлгә кертә, хастаханә һәм кыр шартларында эшләү өчен яраклы асептик стерильләштерү «самовары» куллана) Казанда һәм Россиядә хирургиянең интенсив үсешенә этәргеч була. Л.Л.Лёвшин корсак һәм оча сөяге ялкынсынуы һәм шеш авырулары вакытында лапаротомия үткәрә. Ул Казанда беренче булып аналыктан читтәге йөклелеккә операция ясый, корсак травмаларын операция юлы б-н дәвалый, киләчәктә операцияләрнең органнарны саклап калуны зарурият итәчәген фаразлый, ашказаны трактының кан әйләнешен һәм лимфа системасын өйрәнүдә уникаль тәҗрибә-тикшере-

нүләр үткәрә. Соңрак Л.Л.Лёвшин рак авырулары ин-тын (Мәскәү) оештыручы һәм беренче директоры була. Аның шәкертләре Казанда, Мәскәү, Самара, Саратов, Петербургта мөстәкыйль фәнни юнәлешләр булдыралар (В.М.Зыков, С.И.Спасокукоцкий, Н.А.Геркен, В.И.Разумовский, А.А.Русанов һ.б.). Казанда нейрохирургиягә нигез салучы В.И.Разумовский баш миенә операцияләр ясый. Аның хезмәтләре хирургиядә нейротрофик юнәлеш формалашуга этәргеч бирә. Ул Казанда беренче булып суалчансыман үсентене операция юлы б-н ала, эхинококкэктомия, бөсер пластикасы, корсак ярысының зур дефектлары һ.б. вакытында җөй салуның оригиналь принципларын куллана. И.А.*Праксин* пластик операцияләр (эхинококкэктомия), зоб, озакка сузылган перитонит, актиномикоз, урологик авырулар (Праксин ысулы б-н аралык каналы пластикасы хәзер дә кулланыла) вакытында операцияләр үткәрә. Аның шәкертләре (П.М.*Красин*, М.А.Чалусов, Н.А.Синакевич) оператив хирургия, отиатрия, гомуми хирургия өлкәсендә танылалар. Казанда хирургия үсеше фасциаль җирлектә «күчмә инфильтрат» ысулы б-н новокаин кулланып авыртуны басу ысулына нигез салган А.В.Вишневский исеме б-н бәйле. Бөтен дөньяга мәгълүм булган әлеге ысул Бөек Ватан сугышы елларында уңышлы кулланыла; илдә операцияләрнең 80 проценты аның нигезендә — «рус анестезиясе» б-н үткәрелә (автор 1942 дә СССР Дәүләт бүләгенә, 1955 тә Халыкара Р.Лериш исем. бүләккә лаек була). Тупланган тәҗрибә күп төрле новокаин блокадалары (бил, күкрәк куышлыгы, оча сөяге һ.б.) ясарга һәм аларны морфофункциональ нигезләргә мөмкинлек бирә, алар ярдәмендә авыртуны басу гына түгел, нейротрофик нәтиҗәгә дә ирешелә. Алга таба ысулны камилләштерүдә И.Ф.*Харитонов*, А.А.Вишневский, И.В.*Домрачев*, В.В.Мосин, Г.М.*Николаев*, Т.П.Тихонова, И.Г.*Салихов*, И.Г.Ибәтуллин һ.б. эшлиләр. Казанның беренче нейрохирурглары — В.И.Разумовский, А.В.Вишневский һәм Л.О.Даркшевич. Бу юнәлештәге эшне В.А.*Гусынин*, Р.А.*Вяселев*, Х.М.Шульман, В.И.*Данилов* һ.б. дәвам итәләр. А.В.Вишневский эшләгәндә гепатология һәм урология юнәлешләре алга китә. 1930–40 та онкология, гинекология, хирургиянең хәрби кыр һ.б. тармаклары көчле үсеш ала. В.Л.*Боголюбов* вакытында бавыр, ашказаны асты бизе һәм корсак тирәсе хирургиясе, корсак травмаларын, периферияләге тамырлар авыруларын, герниология, җенси органнар туберкулёзы һ.б. дәвалауда уңышларга ирешелә. Хирургия үсешенә ш.у. аның шәкертләре (А.Н.Сызганов, Б.В.Огнев, М.О.Фридланд, И.А.Цинхес, Ю.А.Ратнер, М.М.Шалагин, В.А.Гусынин, П.Е.Панкратьев һ.б.) зур өлеш кертәләр. Хирургиянең алга китүе физиология, патофизиология, гистология, патологик анатомия һ.б. дисциплиналарның уңышларына бәйле (А.В.Кибяков, Н.Н.Сиротинин, А.Д.Адо, М.А.Ерзин, А.Н.Миславский, И.П.Васильев һ.б.).

1924 тә Н.В.Соколов трансплантология өлкәсендә илдә беренчеләрдән булып «Иммунология күзлегеннән караганда гомотрансплантация» («Гомотрансплантация с точки зрения иммунологии») дигән хезмәтен яза.

1950 елларда үпкә хирургиясе формалаша башлый (Н.В.Соколов, М.М.Шалагин, Ю.А.Ратнер, А.О.*Лихтенштейн,* М.З.*Сигал* һ.б.). Н.В.Соколов шәкертләре — А.М.Сызганов (Алма-Ата шәһәрендә Экспериментальһәм клиник хирургия ин-тына нигез салучы), А.А.Полянцев, Р.А.Вяселев һәм И.Г.Салихов (Волгоград һәм Казанда хиругия кафедралары җитәкчеләре). Р.А.Вяселев Казанда Кан тапшыру станциясен оештыручыларның берсе, канны консервацияләүнең оригиналь ысулы авторы.

1950–60 елларда аеруча катлаулы авырулар патологиясен тирәнтен өйрәнү зарурлыгы туа (перитонит, шок, сепсис һ.б.). И.Г.Салихов беренче булып корсак шешкәндә абдоминаль рецепторларның рефлектор реакциясе характерын һәм динамикасын билгели. Лаб-я хезмәткәрләре аларны көйләү чараларын эшлиләр, перитонит, абдоминаль шок, җепселле тукыма ялкынсынуы көчәюдә организмның аллергик трансформациясенең тискәре роле исбатлана. Ургент абдоминаль патология вакытында бөер өсте бизләре зәгыйфьлегенең сәбәбе һәм характеры күрсәтелә, аны булдырмау һәм дәвалау ысуллары эшләнә.

Перитонит вакытындагы гемодинамик үзгәрешләрнең катлаулы характерын В.А.*Кузнецов* өйрәнә. Гомуми һәм аерым урындагы анестезия, үлекле йогышлы авырулар, сепсис, ялкынсынулы һәм тамырлар авыруларының биохимик аспектлары мәсьәләләре җентекләп өйрәнү предметы булып китә (Б.Г.*Герцберг*, П.Н.Лебедев, Н.П.*Медведев*, В.Н.*Шубин*, В.Г.*Морозов*, Г.А.Измайлов, В.Ю.Терещенко, С.В.Доброквашин). В.Н.Шубин үңәч һәм ашказанының күп кенә авыруларын аңлауда мөһим булган йоткылык-кардиаль рефлекс барлыгын исбатлый. Шәһәр хастаханәләрендә һәм онкология диспансерында (к. *Онкология*) махсус проктология бүлекләре булдырыла, анда О.Ю.Карпухин, И.Г.*Гатауллин*, А.П.Старостин, Н.Н.Молчанов һ.б. эшли. 1972 дә Казанда беренче тапкыр госпиталь клиникасында гастродуоденоскопия үткәрелә (Т.Ф.*Сафин*), ул тиз арада хирургиянең барлык тармакларында кулланыла башлый (Р.Ш.Сафин, В.Ю.*Муравьёв*, А.Н.Чугунов, Е.И.Сигал, И.В.*Фёдоров* һ.б.). Дәвалауда һәм ш.у. диагноз куюда лазер технологияләре киң үсеш ала (махсус аппарат б-н корсакның кискен хирургик патологиясенә диагноз кую, Д.М.*Красильников*). Республика клиник хастанәсе, Травматология һәм ортопедия институты базасында микрохирургия бүлеге төзелә (С.А.Обыдёнов, А.А.Богов), анда очлыкларның фрагментларын күчереп утырту, коррекция-көйләүләр, реплантацияләр һ.б. катлаулы операцияләр үткәрелә.

19 йөз ахырында кардиохирургия үсеше П.И.Тихов исеме б-н бәйле, 20 йөзнең 2 нче яртысында бу өлкәдә фәнни тикшеренүләрне Н.П.Медведев, В.Н.*Медведев*, Р.Х.*Джорджикия*, Л.М.Миролюбов дәвам итә. Тумыштан килгән һәм яшәү барышында барлыкка килгән йөрәк зәгыйфьлеге вакытында операцияләр ясау, аортокоронар шунтлар кую, ясалма клапаннар урнаштыру һ.б. башкарыла.

1970–80 дә микрохирургия техникасы кулланып оператив хирургия буенча тикшеренүләр башлана, бу исә җенси әгъзалар үсеше аномалияләре вакытында клиник үзгәртеп кору анатомиясен нигезләүгә (Л.А.Козлов), ясалма аналык җиңсәсе булдыруга (Н.Л.*Капелюшник),* аналык көпшәләрендә операцияләр үткәрүдә ангиотензиометрия һәм операция микроскобы файдалануга (С.К.*Володин*) китерә. Казанда беренче тапкыр бармак һәм очлыклар сегментларын күчерүдә микрохирургия гамәлгә керә (А.А.Богов), онкохирургиядә сидек куыгы лайлалы тычкасын эчәк кисәге б-н алмаштыру методикасы эшләнелә (Э.Н.*Ситдыйков*). 1990 елларда нейроген сидек куыгын дәвалауда энтеропластика, бөер, күкәйлек күчереп утырту (Р.Х.*Галиев*), хирургия, акушерлык, гинекологиядә лазер б-н җөй салу технологиясе (Д.М.Красильников, И.Ф.*Фәткуллин*, О.Ю.Карпухин), онкологиядә сидек-җенес системасы һәм туры эчәк патологиясе кушылганда юан эчәкне реконструкцияләү б-н энтероцистопластиканы бергә алып бару (И.Р.*Әһлуллин*) операцияләрен үткәрүләр алга чыга.

Лимфа һәм вена тамырларына операцияләрне, коллатераль кан әйләнешен Ф.Ш.*Шәрәфисламов* өйрәнә, ул бавырда кан әйләнешен торгызу өчен кире портоканал анастомозы булдыруның принципиаль мөмкинлеген исбатлый (тикшеренүләре халыкара таныла). Аерым табиблек фәннәре формалашу этапларының берсе булып университетта *урологиядә* беренче хирургик операцияләр үткәрү тора. Ф.О.Елачич, А.Н.Бекетов, М.В.*Никольский*, Л.Л.Лёвшин ташларны алалар, М.В.Никольский литотрипсияне өстен күрә, Н.И.*Студенский* һәм Л.Л.Лёвшин — сидек юлларында ташлар барлыкка килүен, А.В.Вишневский, С.М.*Алексеев*, И.Ф.Харитонов — урология мәсьәләләрен өйрәнәләр.

1960–70 тә Казанда балалар хирургиясе үсеш ала. Беренче балалар хирургы И.Ф.Харитонов үңәчтә, корсак куышлыгы әгъзаларында, урология авыруларына, проктология патологиясе вакытында уңышлы операцияләр үткәрә. *А.Ә.Ахунҗанов,* Н.А.Мифтахов, Н.Н.Молчанов һ.б. — аның шәкертләре. *М.Р.Рокицкий* балаларны дәвалауда үпкә хирургиясе эшен башлый. Кардиохирургиядә Л.М.Миролюбов заманча кардиологик операцияләр үткәрүнең күп төрләрен башкара.

Яңак-бит хирургиясе юнәлеше хирургик клиникаларда үсеш ала (П.А.Дубовицкий, 1840; Н.Ф.Высоцкий, 1904; И.А.Праксин, 1913). Бит хирургиясенең хәзерге этабы утлы коралдан биткә ясалган яраларга беренчел пластика үткәргән Е.А.Домрачев исеме б-н бәйле. Бу юнәлеш Л.А.*Кольцова*, Е.В.*Крешетов*, Т.Т.*Фәизов* тарафыннан үстерелә.

*М.К.Михайлов, Н.Х.Әмиров, В.Ф.Богоявленский, В.А.Анохин, И.Г.Салихов, Р.Г.Исхакова.*

**КАЗА́Н МЕДИЦИ́НА-ФАРМАЦЕ́ВТИКА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш буенча федераль агент-

лыгының урта һөнәри база уку йорты. 1921 елның октябрь аенда Казан фармация мәктәбе буларак ачыла, 1925 тән Казан фармация техникумы, 1929–36 елларда Казан мед.-фармацевтика техникумының (к. *Казан медицина көллияте*) фармацевтика бүлеге, 1936 дан Казан фармацевтика училищесе, 2002 дән хәзерге исемдә. 1990 еллар башында училищенең белгечләр әзерләү юнәлеше киңәя: анда фармация, лабораториядә диагноз кую, шәфкать туташлары эше буенча белгечләр әзерләнә. 2010 елда 550 студент укый, коллективта 39 укытучы, ш.и. 3 фән. канд-ты. Читтән җәлеп ителгән 60 лап укытучының 14 ләбе ш.у. фән канд-ты. Училище ТР, Чуаш, Мари һәм башка республикалар һәм өлкәләрнең сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм фармация хезмәте өчен 8 меңнән артык фармацевт, 500 шәфкать туташы, 500 гә якын фельдшер-лаборант әзерләп чыгарган.

Училищенең 2 бинасы, лабораториясе бар, кайбер дисциплиналар буенча дәресләр Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе кафедралары базаларында үткәрелә, клиник практика һәм һөнәри дәресләр Казанның дәвалау учреждениеләрендә уза.

Училище директорлары: А.А.Казаначеев (1938–45), З.А.Рассыпнинская (1945–67), К.И.Васильева (1967–88), А.Н.Меликьянц (1988 дән).

*Әд.:* Вехи истории фармации Татарстана. К., 2001.
*Р.Г.Исхакова, А.Н.Меликьянц.*

**КАЗА́Н МЕТЕОРОЛО́ГИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, Казан ун-ты каршында метеорологик күзәтүләр оештырылу (1805, И.И.Запольский), *Метеорология обсерваториясе* ачылу (1812), Казан һәм Уралның кайбер пунктлары климаты турында беренче фәнни хезмәтләр чыгарылу (1815–16, Ф.К.Бронер; 1829, 1831, А.Я.Купфер, Н.И.Лобачевский) чорында нигез салына башлый. Идел буе, Кавказ, Урал һәм Себердә табигать күренешләрен, климат шартларын өйрәнү 1830 еллардан алып барыла (Э.А.Кнорр, А.С.Савельев). Метеорологик тикшеренүләр үсешендә Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте (1869) аерым урын алып тора. И.А.Больцани — аэрологик тикшеренүләрне башлап җибәрүче, 1869–70 тә ул үзе төзегән — бәйләп беркетелә торган аэростат ярдәмендә һава басымын, темп-расын һәм дымлылыгын төрле биеклекләрдә үлчи. И.Н.Смирновның «Һава торышының алдан әйтелү мөмкинлеге һәм Россиядәге язгы давыллар турында» («О предсказуемости погоды и о весенних бурях в России», 1870) монографиясе һава торышын алдан әйтү ысулының һәм шуның б-н синоптик метеорологиянең фәнни нигезе булып тора. 1880 елларда актионометрия һәм җылылык балансы тикшеренүләре үткәрелә башлый (Р.А.Колли, Ф.М.Цомакион). Н.П.Слугинов һәм Д.А.Гольдгаммер тырышлыгы б-н 19 йөз ахырыннан «Көнчыгыш Россиянең метеорологик челтәре турында хезмәтләр» чыгарыла. 20 йөз башында Казан ун-ты геофизика (хәзер метеорология, атмосфера климатологиясе һәм экологиясе) кафедрасы хезмәткәрләре (И.А.Картиковский, П.Д.Кушников, Н.Ф.Пушкин) тарафыннан төбәк климаты буенча күп кенә хезмәтләр язылa, К.м.ф.м. вәкилләренең актив катнашында 1930 да Татарстан гидрометеорология хезмәте оештырыла. 1930–60 та атм. циркуляциясе, климаты, сусаклагычларның метеорологик һәм гидрологик режимы, респ-каның агроклиматик ресурслары үсешенә П.Т.Смоляков, О.А.Дроздов, Н.В.Колобов, Е.Д.Федотова h.б. шактый зур өлеш кертәләр. 1970 тән мониторинг, климатны модельләштерү һәм параметрларын алдан әйтү, атм.ның гомуми циркуляциясе, энергетикасы һәм пычрануы турындагы мәсьәләләр һәрьяклап өйрәнелә (Ю.П.Переведенцев, М.А.Верещагин, Р.Р.Хәйруллин, Э.П.Наумов, К.М.Шанталинский h.б.). Төньяк ярымшар тропосферасында климатның хәзерге глобаль җылынуы, ш.у. аның региональ үзенчәлекләре соңгы вакытларда җентекләп анализлана. Урта Идел буе, Татарстан, Казан климаты, әре масштаблы атм. күренешләренең динамикасы һәм энергетикасы, циклоник эшчәнлек, яңартылучан энергия чыганаклары турында, атм. экологиясе h.б. буенча монографияләр басыла. Региональ, Россия һәм Халыкара дәрәҗәдә фәнни семинарлар һәм конференцияләр оештырыла һәм үткәрелә.

*Әд.:* Переведенцев Ю.П. Метеорология в Казанском университете: становление, развитие, основные достижения. К., 2001.
*Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.*

**КАЗА́Н МЕХ КОМБИНАТЫ́**, к. «*Мелита*».

**«КАЗА́Н» МИЛЛИ́ МӘДӘНИЯ́Т ҮЗӘГЕ́**, мәдәни-агарту һәм ял итү, күңел ачу һәм башка мәдәни чаралар үткәрелә торган комплекслы учреждение. 1991 елда оештырыла. 1988 дә архит-ра академигы А.Т.Полянский, арх. Ю.М.Минаев, инженер В.И.Райцын проектлары буенча төзелгән элеккеге В.И.Ленин исем. Үзәк музейның Казан ф-лы бинасында урнашкан. Составында: «К.» м.м.ү. музей комплексы — Казанның меңьеллыгына һәм милли мәдәният тарихына багышланган даими экспозиция, Казандагы *Урманче Бакый музее* (1999), рәссам Ә.Н.Мәҗитов музее (2005), И.К.Зариповның галерея-студиясе (2004); ял итү, күңел ачу комплексы: Казан шәһәр филармониясе (составында «La Primavera», Казан дәүләт камера оркестры, «Казан» бию ансамбле, «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры, «Идел егетләре» халык эстрада-фольклор ансамбле, «Айгөл» балалар вокаль ансамбле), концерт һәм күргәзмә заллары бар. «К.» м.м.ү. төп бинасының гомуми мәйданы 10800 $м^2$. Төп бина каршында скульптуралар паркы комплексы (авторлар — Т.Сөбханкулов, Р.Хәбибрахманов, С.Балашов) һәм «Хөррият» скульптурасы куелган стела (1997, скульп. К.Җәмитов) урнаштырылган. Өч тигезлектәге музей-экспозициясе һәм күргәзмә залларының мәйданы — 3009 $м^2$. Музей комплексы фондларында 34500 экспонат: нәкышь, графика, скульптура, гамәли-бизәлеш һәм халык сәнгате әсәрләре, археол. һәм этнография әйберләре, мемориаль истәлекләр, сирәк китаплар, шәмаилләр, фото һәм документаль материаллар бар. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында: күренекле татар аксөякләре вәкилләре — пр-тие хуҗалары, сәүдәгәрләр, меценатлар Аитовлар, Апанаевлар, Гобәйдуллиннар, Мамлиевлар, Тенишевләрнең гаилә ядкәрләре һәм документлары; Ш.*Мәрҗаниның* шәхси әйберләре, Ф.И.*Шаляпин* һәм Б.И.*Урманченың* төп оригиналь әйберләре һәм документлары. Уникаль әйберләр исәбенә фаразларның берсе буенча «Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән» дип аталган парсуна (якынча 17 йөз ахыры — 18 йөз башы); Алтын Урда чоры Идел буе шәһәрләренең (Болгар, Сарай-Бату) археол. коллекцияләре, Кырым,



«Казан» милли мәдәният үзәге. Гомуми күренеше.

Иран, Урта Азиядә эшләнгән әйберләр, Алтын Урда тәңкәләре хәзинәләре (10 мең бәрәмлек), 8–9 йөзләрдә Көнчыгыш Кама аръягында (Агыйдел елгасы буенда) табылган Чулман хәзинәләреннән көмеш әйберләр; Исмәгыйль хан исеме язылган 16 йөз тимер көбәсе, 18 йөздә Иранда эшләнгән 2 шлем, 19 йөз башына караган кулъязма Коръән һәм Коръән савытлары (ш.и. Төркиядән h.б. илләрдән китерелгән), 1812 елгы Ватан сугышында катнашучы, татар-башкорт полкы командиры полковник Гәрәй Кайбышевның чигелгән билбавы, 18–19 йөзләрдәге татар зәркән бизәнү әйберләре, Н.Челноков, В.Турин, Э.Турнереллиның 18–19 йөзләрдәге Казан күренешләре төшерелгән графика әсәрләре керә. Тарихчы Г.Гобәйдуллинның, күренекле тюрколог С.Моратовның, язучылар Г.Гали, С.Хәким, И.Юзеев, Г.Бакир, Б.Гыйззәт h.б.ның шәхси архивлары зур кыйммәткә ия. Музейның Казанның меңьеллыгына һәм милли мәдәният тарихына багышланган даими экспозициясендә «Татар халкының борынгы һәм урта гасыр мәдәнияте. Б.э.к. 1 нче меңьеллык — 10 йөз»; «Казан, 10–15 йөзләр»; «20 йөздә татар халкы һәм аның мәдәнияте», «Казан — Татарстан Республикасы башкаласы» h.б. бүлекләр бар. Музей комплексының даими экспозициясе материаллары «К.» м.м.ү. дәге музей фондларының, Казан һәм РФнең башка шәһәрләре архивлары һәм музейларының вакытлы күргәзмәләре б-н тулыландырыла. «К.» м.м.ү.нең фәнни, музей-күргәзмә, мәгърифәтчелек гаммәви тамашалар эшчәнлеге татарларның һәм ТРда яшәүче башка халыкларның матди һәм рухи мәдәниятен, һөнәрләрен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен, телләрен саклауга һәм пропагандалауга

юнәлтелгән. Үзәкнең директоры — Р.З.Закиров (1991 дән).

*Әд.:* Сокровищница искусств: Национальный культурный центр «Казань» // Казань. 2002. № 11–12; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004. *И.А.Эделева.*

**КАЗА́Н МИССИОНЕРЛЫ́К КУ́РСЛАРЫ**, Рус Православие чиркәвенең руханилар уку йорты. 1889 елда *Казан руханилар академиясе* каршында оештырыла; 1898–1917 елларда, мөстәкыйль эшләүче уку йорты буларак, Казан Кремленең Спас-Преображение монастырена урнаштырыла. Казандагы әҗнәбиләр приходларына һәм Идел буендагы башка епархияләргә руханилар әзерләү өчен билгеләнә. Анда укучылар Идел буе халыклары телләрен белергә яки уку дәверендә аларны үзләштерергә тиеш булалар. К.м.к.нда татар, чуаш, монгол-калмык бүлекләре оештырыла. Гомуми урта (укытучылар семинариясе, гимназияләр һ.б.) яки пед. белемле һәм башлангыч мәктәпләрдә укыту тәҗрибәсе булган затлар кабул ителә. Уку вакыты — 2 ел, курс тәмамлаучыларга рухани дәрәҗәсе бирелә. Тыңлаучыларның яртысына якынын Идел буе халыклары вәкилләре (шул исәптән керәшен татарлар), Казан укытучылар семинариясен, Сембер чуаш укытучылар мәктәбен, *Казан үзәк керәшен татар мәктәбен* һәм башка пед. уку йортларын тәмамлаучылар тәшкил итә. Яртысы, нигездә, түбән катлау гаиләләрдән чыккан рус тыңлаучыларыннан тора. Алар өчен К.м.к. Россиядә рухани белем алу өчен бердәнбер уку йорты булып санала (руханилар семинарияләрендә дини катлау вәкилләре балалары гына укыган). Курсларда уку *Ильминский системасына* юнәлеш тота — биредә гыйбәдәт кылу һәм вәгазь сөйләү туган телдә алып барыла. Башлыча, Казан руханилар академиясе профессорлары Е.А.*Малов*, М.А.*Машанов*, Н.Ф.*Катанов* һ.б. укыта. Курсларны ел саен 15–20 кеше тәмамлый.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н МОТОРЛА́Р ТӨЗҮ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́** (КМПО), авиация һәм газ-турбина двигательләре, ш.у. алар җирлегендә агрегатлар җитештерү буенча Россиядәге иң эре пр-тиеләрнең берсе. 1932 елда Казанда «Казмаш» авиация комб-ты төзелеше башлана, аның составында 130 нчы (1935 тән — 35 нче) моторлар төзү з-ды корыла. 1938 дә Казан моторлар төзү з-ды М-103 моторы өчен үзәктән куулы авиацион АЦН-2 басым тудыргычы җитештерүгә керешә; М-17, М-25 һәм М-34 двигательләрен төзекләндерү, ш.у. У-2 самолёты өчен детальләр эшләп чыгару б-н шөгыльләнә. 1939 дан мөстәкыйль пр-тие. Составына механика, инструментлар, ремонт-җыю цехлары, сынау станциясе керә. Эшләүчеләр саны 507 кеше тәшкил итә. Техник коралланыу буенча з-д авиамоторлар төзү тармагының иң яхшы пр-тиеләренең берсе була. 1940 та анда пике ясаучы Пе-2 бомбардировщигы өчен В.Я.Климов конструкцияләгән ВК-105 моторларын җитештерүне үзләштерү башлана; җыелган беренче мотор 1941 нең октябрендә сынаулар уза. 1941 нең көзендә з-д терр-ясенә Воронеж шәһәренең 16 нчы моторлар з-ды, 82 нче Мәскәү моторлар з-ды, 219 нчы Мәскәү агрегат-кою з-ды эвакуацияләнә. Берләштерелгән з-д «16 нчы завод» дип атала. 16 нчы Воронеж з-ды 1932–40 та ук С.Кочергин конструкцияләгән ТЩ-2 штурмовиклары, У-2 самолётлары өчен А.Швецов конструкцияләгән һава б-н суытулы М-11 моторлары эшләп чыгара. 1936 дан з-дта 4,6 һәм 12 цилиндрлы МВ-4, МВ-6, М-12 двигательләрен җитештерү башлана. Сугыш елларында 16 нчы з-д төрле модификациядәге ВК-105 моторларын эшләп чыгара; җәмгысе 15 мең мотор, ягъни барлык ВК-105 моторларының яртысы җыела. З-дта моторларны стендта сынау өчен СССРда беренче энергияне эл. тогына әверелдерү җайланмасы урнаштырыла. Сынаулар вакытында авиамотор тарафыннан бүлеп чыгарылган энергиянең 70 % ы эл. энергиясенә әверелдерелә һәм з-дның эл. челтәренә җибәрелә; СССРда беренче тапкыр М-105 блокларын визуаль яктырту өчен рентген җайланмасы эшләнә; моторлар төзү производствосында двигательләр җыю өчен «мәҗбүрләү» конвейеры куела. Һәр 50 *мин* саен аннан әзер двигатель чыгарыла. Механика цехларында механикалаштырылган өзлексез линияләр оештырыла; термик цехта терсәкле валларны ныгыту һәм блоклар гильзаларын чыныктыру өчен мичләр файдалануга тапшырыла.

1945 тә хөкүмәт йөкләмәләрен үрнәк рәвештә үтәгәне өчен з-д Ленин ордены б-н бүләкләнә; сугыш елларында з-д коллективы барлыгы 19 тапкыр Дәүләт Оборона Ком-тының күчмә Кызыл байрагын яулый (байрак з-дка мәңгелек саклауга тапшырыла), 22 тапкыр СССР Авиация сәнәгате халык комис-ты з-длары ярышында 1 нче һәм 2 нче урыннарны били. Сугыштан соң з-д реактив техника эшләп чыгаруга күчә. 1946 да пешкәкле ВК-105 моторын җитештерү туктатыла. Бер үк вакытта пр-тиене С.А.Колосов конструкцияләгән РД-20 турбокомпрессорлы һава-реактив двигателен эшләү өчен реконструкцияләү алып барыла. Яңа производстволар — компрессорлар, турбиналар, яну камералары производстволары оештырыла. СССРда беренче тапкыр 2 елдан да кыскарак вакыт эчендә реактив двигатель эшләп чыгару үзләштерелә. 1947 дә Мәскәүдә РД-20 двигательләре куелган беренче 45 МиГ-9 реактив самолётлары катнашында һава парады уздырыла. 1948 дә Як-23 истребителе өчен В.М.Яковлев конструкцияләгән РД-500С двигателен эшләү башлана. РД-500К двигателенең гадиләштерелгән варианты «һава-җир» классындагы беренче идарә ителүле «Комета» самолёт-снарядларында һәм «җир-диңгез» классындагы «Сопка» системасы ракеталарында кулланыла. 1951 нең ахырында з-дта ерак араларга очучы Ту-16 бомбардировщигы өчен А.А.Микулин конструкцияләгән дөньядагы иң көчле АМ-3 турбореактив двигателен чыгару җайга салына. Аннан соң тагын да камилрәк АМ-5, АМ-9, АМ-11 һәм МиГ-21(15) самолётлы өчен В.Я.Климов конструкцияләгән ВК-1 двигательләрен эшләү үзләштерелә. 1952 дә Ту-16 самолёты һәм аның нигезендә эшләнгән дөньядагы беренче реактив пассажирлар лайнеры Ту-104 өчен А.А.Микулин конструкцияләгән РД-3М-500 двигателен җитештерү оештырыла. 1961 дән з-д Н.Д.Кузнецов конструкцияләгән НК-8–4 (ерак магистральләрдә очучы Ил-62 пассажирлар самолёты өчен), НК-8–2У (уртача ераклыкка очучы Ту-154Б самолёты өчен, 1969), НК-86 (Ил-86 самолёты өчен, 1980) двигательләрен җитештерүгә күчә; реактив двигательләр нигезендә НК-16СТ газ кудыру станциясе һәм аның НК-16–18СТ модификациясе үзләштерелә һәм эшләп чыгарыла. Һәр яңа эшләнмә җитештерүне үзләштерү чорында пр-тиедә реконструкция уздырыла, яңа технологияләр гамәлгә кертелә, прогрессив җиһазлар урнаштырыла. 1969 да Буа шәһәрендә з-дның халык куллану товарлары һәм а.х.нда файдаланулы техника җитештерүче ф-лы төзелә. 1976 да филиал Буа машина төзү з-ды итеп үзгәртелә һәм шул ук елда ике з-д җирлегендә КМПО оештырыла. 1983 тә яңа авиация техникасын эшләү һәм җитештерүдәге казанышлары өчен пр-тие Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә. 1980–85 тә КМПО ф-лы — Яшел Үзән машина төзү з-ды төзелә. 1994 тән — «КМПО» АҖ. 1997 дә анда Ил-96, Ту-204, Ан-70 самолётлары өчен Н.Д.Кузнецов конструкцияләгән НК-93 двигателен, Ту-324, Як-48 самолётлары өчен Ф.М.Муравченко конструкцияләгән АИ-22 двигателен җитештерү оештырыла. 1990 елларның 2 нче яртысыннан берләшмә үсешендәге төп юнәлешләрнең берсен ГПА «Волга» газ кудыру агрегатларын эшләп чыгару тәшкил итә. Пр-тие шәһәр автобуслары җитештерү буенча федераль программада катнаша (аларны автоматик тапшыру тартмалары б-н комплектлау); ш.у. а.х.нда файдаланыла торган продукция чыгара. Детальләрне бик катлаулы эшкәртүдә югары төгәллекле җиһазлар файдаланыла. Эшләнмәләрдә конструкция материалы сыйфатында титан һәм аның кушылмалары, турбиналар калакларын кою өчен юнә-



КМПО. Административ-производство корпусы каршындагы мәйдан.



КМПО. 18 нче цех. Двигатель җыю.

лешле һәм күп кристаллы структуралы, кызуга чыдам яңа материаллар кулланыла. Корпус детальләрен кою, зур диаметрлы эшләнмәләрне җәю, кызуга чыдам һәм термосаклаулы катлам өстәү алымнары б-н ясау технологияләре гамәлгә кертелгән. Җыю цехында стапельләрдә двигательне этаплап җыю өчен өзлексез конвейер линиясе куелган. АҖнең шифаханә-профилакторие, мед.-сан. часте, ял базасы, йөзү бассейны, балаларны сәламәтләндерү үзәге, мәдәният сарае, китапханәсе, спорт клубы бар; физ.-матем. һәм техник лицейлар төзелгән. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 2 кешегә — Сов. Союзы Герое, 6 кешегә Соц. Хезмәт Герое исемнәре бирелә; 36 кеше — Ленин ордены, 26 кеше — Октябрь Революциясе, 4 кеше — 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 186 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 55 кеше — Кызыл Йолдыз, 12 кеше — Халыклар дуслыгы, 281 кеше — «Почёт билгесе», 138 кеше — 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 154 кеше медальләр б-н бүләкләнә. 1942–46 да Махсус двигательләр конструкторлык бюросында С.П.Королёв, В.П.Глушко эшли. Пр-тие җитәкчеләре арасында — С.П.Галкин (1931–36), Г.С.Девдариани (1935–37), М.М.Лукин (1937–39, 1942–46), В.И.Сухоруков (1939–42), В.И.Тарасов (1946–47), А.К.Авраменко (1947–51), И.Т.Борисов (1951–54), Б.А.Чевела (1954–55), А.А.Сибиркин (1955–61, 1966–67), Р.Е.Загребельный (1960–63, 1967–68), П.А.Витер (1968–82), А.Ф.Павлов (1982–2004), Д.З.Кәримуллин (2004 тән). Ш.у. к. *Авиация сәнәгате, Двигательләр төзү.*

*Әд.:* Казань: Спец. вып., посвященный авиац. пром-сти РТ 1999. № 3/4; Фролова Л. Казанскому моторостроительному — 70 лет. К., 2001.

*В.П.Болдырев, Г.Я.Мәүлетова.*

**КАЗА́Н МӨСЕЛМА́Н СОЦИАЛИСТЛА́Р КОМИТЕТЫ́**, 1917 елның апрелендә революцион-демократик татар яшьләре башлангычында оештырыла. Максаты — мөселман пролетариатын һәм хезмәтчел крәстияннәрне оештыру, социалистик идеяләрне тарату. Рәисе — М.Вахитов, әгъзалары — И.Алкин, Ә.Мөхетдинова, Г.Сәйфетдинов, К.Саттаров, М.Солтангалиев һ.б. Составына эшчеләр, хезмәткәрләр, интеллигенция вәкилләре керә. Комиссияләре эшчеләр, җир эшләре, милләт, хатын-кызлар, финанс, юридик һ.б. (барысы — 10) мәсьәләләр буенча төзелә. Комитет инициативасы б-н эшчеләр өчен социаль фәннәр курслары оештырыла, клуб ачыла; Ком-т крайдагы соц. партияләр, ш.и. большевиклар б-н актив хезмәттәшлек итә (РСДРП(б) ҮК һәм эсерлар белән язышулар алып бара). Аның әгъзалары Окт. рев-циясен яклыйлар һәм анда актив катнашалар. Рев-циядән соң мөселман ком-тлары башка шәһәрләрдә дә барлыкка килә. 1918 нең мартында Россия мөселман эшчеләр конференциясе карары нигезендә К.м.с.к. Үзәк мөселман социалистлар ком-ты составына керә, аның рәисе итеп М.Вахитов сайлана. Басма органы — «*Кызыл байрак*» г-тасы. Ш.у. к. *Мөселман социалистлар комитетлары.*

*Әд.:* Нафигов Р.И. Мулланур Вахитов. К., 1975.

*Р.И.Нәфыйгов.*

**«КАЗА́Н МӨХБИРЕ́»**, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета, «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясе органы. Казанда татарча басылган беренче газета. 1905 елның 29 октябреннән 1911 нең 23 мартына кадәр 416 саны нәшер ителә. Башта газетаны татар һәм рус телләрендә чыгару күздә тотыла, әмма оештыручылар һәм Матбугат эшләре буенча баш идарә карары б-н ул бары тик татар телендә генә басыла башлый. Төрле елларда наширләре һәм мөхәррирләре — С.Алкин, Г.Шәрәф, аның бертуганы Б.Шәрәф, Ә.Сәйдәшев, Г.Саинов. 1908 елга кадәр, асылда, мөхәррире Й.*Акчура* була. Татар халкының үзенчәлекләрен саклап калу, мәктәпләрне яңача укытуга (к. *Җәдитчелек*) күчерүгә ярдәм итү, милли әдәбиятның үсешен кайгырту максатлары куела. Авторлар арасында — Г.Баруди, Г.Буби, К.Бикколов, М.Гафури, Х.Габәши, Г.Исхакый, Г.Камал, Ф.Кәрими, Ә.Максуди, Ш.Мөхәммәдев, Ә.Сәгыйди, Ф.Туктаров, Г.Шәрифи һ.б. була. Й.Акчура, З.Бәшири, И.Богданов, М.Гафури, М.Казаков, Н.Думави, Х.Зәбири, С.Иманколый, Ш.Камал, Г.Кышкарый, Р.Рәкыйби, Г.Рахманколый шигырьләре, З.Буранский, Х.Искәндәров, С.Рәмиев, И.Терегулов, М.Шәриф фельетоннары басыла. Газета үзен татар мәнфәгатен, халыкның тигезлеккә һәм ирекkә (дин, сүз, шәхес ирекe һ.б.) омтылуын яклаучы демократик басма дип игълан итә; Россия мөселманнарының рухи бердәмлеген яклый, ислам нигезләрен яктыртуга зур әһәмият бирә. Газетаның беренче битендә Россия законнарындагы үзгәрешләр, хөкүмәт указлары, җирле хакимият күрсәтмәләре турында мәгълүмат бирүче «Система һәм законнар» дигән рубрика була. «Хатын-кызлар рубрикасы» мөһим урын алып тора, анда С.Коләхмәтова, Х.Насыйрия, Ф.Сөләймановалар һ.б.ның язмалары басыла. «К.м.» укучыларны сәяси партияләр программаларының төп нигезләмәләре б-н таныштыра, эчке һәм тышкы сәясәт яңалыкларын, шәһәр һәм земство оешмалары, гыйльми һәм хәйрия җәмгыятьләре утырышлары хроникасын, фәнни-популяр эчтәлекле мәкаләләр, аерым алганда, Россия, мөселман Шәрегы илләре тарихы һәм географиясе буенча язмалар; Россия вакытлы матбугаты, авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать үсеше турында күзәтүләр, биржа яңалыклары, көндәлек (календарь) мәгълүматлар, китапларга анонслар, театр тамашаларының репертуарлары, мәхкәмә хроникасы, некрологлар бастыра. 1909–10 да аңа кушымта рәвешендә юмористик «Без» г-тасы чыга (25 саны басыла). Баштан ук Матбугат эшләре буенча баш идарә тарафыннан газетага рус мәдәнияткен пропагандалау бурычы куела, рус язучыларының (Л.Н.Андреев, В.М.Гаршин һ.б.) әсәрләре татар телендә тәрҗемәдә бастырыла. 1908 дән газетаның форматы кыскартыла, ул атнага 1–2 тапкыр гына чыга башлый. Беренче битне дә кертеп, аның 1/3 өлешен реклама били.


«КАЗАНСКІЙ ВѢСТНИКЪ».

«Казан мөхбире» газетасы.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Әмирхан Р. Иҗтимагый көзгебез // Татарстан. 1995. № 3/4.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**КАЗА́Н МУ́ЗЫКА КӨЛЛИЯТЕ́**, И.В.Әүхәдиев исемендә, Р.А.*Гуммертның* шәхси музыка мәктәбе җирлегендә Император рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге каршындагы музыка уч-щесе буларак, 1904 елда оештырыла. 1919 дан ике баскычлы музыка мәктәбе, 1922 дән (Шәрекъ консерваториясе б-н берләштерелгәннән соң) Шәрекъ музыка техникумы, 1930 дан (Казан сәнгать театр техникумы б-н берләштерелгәннән соң) Татар сәнгать техникумы, 1934 тән ТАССРның ЮС исемендә, 1935 тән Казан музыка техникумы, 1937 дән Казан музыка уч-щесе, 1991 дән И.В.Әүхәдиев исем., 2007 дән хәзерге исемдә.

Казан музыка уч-щесе, оешкан көненнән башлап, Идел буе төбәгендә музыка белеме һәм мәгърифәтчелекнең мөһим үзәгенә әйләнә. 1912 дә Рус музыка җәмгыятенең музыка уку йортлары директорлары съездында Россиянең 4 иң яхшы музыка уч-щесенең берсе булып танылa. Анда Россиянең үзәк шәһәрләре һәм чит ил консерваторияләрен тәмамлаган атаклы музыка эшлеклеләре М.Пятницкая, О.Родзевич, К.Корбут һ.б. укыта, алар яңа буын музыкант-педагогларны (Р.Поляков, А.Бормусов, А.Чернышёва, Н.Шевалина һ.б.) әзерли. Училищенең беренче директорлары: Р.А.Гуммерт, Р.Л.Поляков, А.А.Литвинов, И.В.Әүхәдиев. Училище күп кенә татар сәнгате эшлеклеләренә, композиторларына (С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, Ф.Яруллин,



Казан музыка көллияте.

М.Мозаффаров, А.Ключарёв, З.Хәбибуллин һ.б.), җырчыларына (З.Байрашева, Г.Кайбицкая, М.Рахманкулова, Г.Сөләйманова, М.Булатова һ.б.) проф. музыка дөньясына юл ача. 1920 елларда уч-щедә С.Х.Габәши, Е.Г.Ковелькова һ.б. укыта. Бу вакытта музыка-мәгърифәтчелек эшчәнлегенә беренче татар операсында (С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдов, В.Виноградовларның «Сания» һәм «Эшче» әсәрләре), Көнбатыш Европа һәм рус классик операларында катнашкан уч-ще укучылары һәм укучылары җәлеп ителә. Бөек Ватан сугышы елларында уч-щедә илнең алдынгы музыка уку йортларыннан эвакуацияләнгән укытучылар: М.Ф.Гнесин, В.Д.Конен, С.С.Скребков, Г.И.Литинский, А.С.Леман, М.А.Юдин һ.б. укыта. Шул белгечләр һәм Н.Җиһанов эшчәнлеге нәтиҗәсендә 1945 тә Казан консерваториясе ачыла. 1940 та уч-щене тәмамлаучылар арасында бөтен дөньяга билгеле композитор С.Гобәйдуллина бар. Училищедә төрле елларда танылган музыкантлар, башкаручылар (З.Хисмәтуллина, Р.Билалова, И.Шакиров, Р.Мифтахова, Н.Теркулова, Г.Сәйфуллина, В.Ганиева, А.Хәйретдинов, И.Халитов, О.Бренинг, Э.Әхмәтова, Э.Борнашева, Ш.Монасыйпов, М.Макаров); композиторлар (Х.Вәлиуллин, Ә.Бакиров, А.Монасыйпов, Б.Мөлеков, И.Шәмсетдинов, Ф.Әхмәтов, Р.Еникиев, Р.Белялов, Р.Ахиярова, М.Шәмсетдинова һ.б.) проф. муз. белем ала. 2010 елда 320 дән артык студент укый. Фортепиано, кыллы, халык музыка уен кораллары, тынлы һәм бәрмә уен кораллары, музыка теориясе, академик җырлау, халык җыры, хор дирижёрлыгы буенча бүлекләр бар, 2009 дан эстрада бүлеге ачыла. Укытучылар коллективы составы 40 кешедән артык, ш.и. ТРның халык артистлары Ш.Әхмәтҗанов, В.Гәрәева, М.Имашев, Л.Исмәгыйлева, К.Монасыйпов, Л.Маслова, А.Туишева, К.Хәйретдинова, музыка белгечләре А.Маклыгин, В.Дулат-Алиев эшлиләр.

Педагоглар һәм укучылар актив иҗат-концерт эшчәнлеге алып баралар, радио һәм телевидениедән чыгышлар ясыйлар; уч-щедә симф., тынлы, халык музыка уен кораллары оркестрлары, хатын-кыз һәм катнаш хорлар, вокаль, скрипкачылар, виолончелистлар, гитаристлар, думбрачылар ансамбльләре эшләп килә. Укучылар опера спектакльләре куялар.

Көллият бинасы элеккеге Казан өязе земство управасы бинасында урнашкан (1887, арх. Л.К.Хрщонович). 1887–88 елларда биредә Ф.И.Шаляпин писарь булып эшли. Мемориаль такта куелган.

**КАЗА́Н МУ́ЗЫКА СӨЮЧЕЛӘ́Р ТҮГӘРӘГЕ́** (1881–87), Казанда рәсми расланган беренче музыка-җәмәгать оешмасы. Түгәрәк Казан музыкантлары һәм музыка сөючеләре тырышлыгы б-н барлыкка килә. Түгәрәкне оештыручылар арасында танылган хор дирижёры һәм музыка эшлеклесе С.В.Смоленский, комп. В.Н.Пасхалов, пианист һәм педагог Л.К.Новицкий, Казан ун-ты профессорлары Н.П.Загоскин, Н.Сорокин, Д.С.Ермолаев була. Түгәрәкне оештыруга Казан губернаторы А.К.Гейнс булышлык итә, аның җыелышлары өчен Казан Кремле Губернатор сараеның бер бинасыннан урын бирелә. Түгәрәкнең төп эшчәнлек принцибы аның Уставында бәян ителә. Максаты: «... инструменталь һәм вокаль муз. пьесаларын бергә башкару өчен түгәрәк әгъзаларына җыелырга мөмкинлек тудыру». Музыка сәнгатен пропагандалау өчен, түгәрәкнең җитәкче ком-ты атна саен муз. кичәләр оештыра, анда инструменталь, вокаль, хор музыкасы яңгырый. Концертларда танылган проф. музыкантлар, Европа һәм Россия шәһәрләрендә концерт бирүчеләр: К.Гриняски, И.Аитов, В.Больтерман, С.В.Смоленский, Л.Фуллон, А.И.Панаев һ.б.; нигездә, музыка сөючеләр, Казан ун-ты укытучылары һәм студентлары катнашалар. Түгәрәк каршында М.Мусорин җитәкчелегендә симф. оркестр, Р.Детлов һәм С.В.Смоленский җитәкләгән һәвәскәр хор коллективлары оештырыла. Концерт программасы Көнбатыш Европа һәм рус композиторлары әсәрләреннән тора. Үзенең демократик карашлары б-н билгеле В.Н.Пасхалов Казанда беренче Бушлай эшләүче музыка мәктәбе оештыра. Анда фортепиано, ялгыз җырлау, кыллы һәм тынлы музыка уен коралларында уйнау, хорда җырлау, музыка теориясеннән дәресләр бирелә. Укучылар саны 100 гә кадәр җитә.

*Е.В.Порфирьева.*

**КАЗА́Н МУ́ЗЫКА УЕ́Н КОРАЛЛАРЫ́ ФА́БРИКАСЫ**, 1963 елда Казанның ике фабрикасын — гармун (1934 тә нигезләнә, төрле гармуннар чыгара) һәм пианино (1957 дә Казан шәһәре җирле сәнәгать идарәсенең мебель ф-касы нигезендә оештырыла) ф-каларын берләштерү юлы б-н төзелә. Урта Идел Совнархозының Урман агач эшкәртү сәнәгате идарәсенә (1963–65), ТРның Музыка кораллары сәнәгать-сәүдә берләшмәсенә (1965–95) буйсына. 1995–98 дә АҖ. Эшләүчеләр саны 500 кешегә җитә.


1966 да К.м.у.к.ф.нда реконструкция һәм модернизация уздырыла. Яңа өч катлы корпус файдаланугa тапшырыла, заманча җиһазлар, ш.и. яссы күчерү һәм ялтырату автоматлары, җыю цехында конвейер урнаштырыла, ресурсларны саклаучы технологияләр гамәлгә кертелә, пианино рамнарын эшкәртү автоматлаштырыла, станоклар камилләштерелә.

Фабриканың төп продукциясе: пианинолар, ш.и. «С-5», «Чайка», «Казан» модельләре, аккордеоннар, баяннар, гармуннар, концертина, татар халык музыка уен кораллары — курайлар, сорнайлар, ш.у. музыка уен кораллары өчен футлярлар; музыкантларның шәхси заказлары да эшләнә. Төрле гармуннар ясау һәм сату елга 27 мең данәгә (1965), пианинолар — 4100 данәгә (1984) җитә. 1963–94 тә фабрика тарафыннан 450 меңнән артык гармун һәм 75 мең пианино эшләп чыгарыла. Продукция РСФСР төбәкләренә, Әзәрбайҗан, Әрмәнстан, Грузия, Үзбәкстан, Төркмәнстанга җибәрелә, Болгариягә, Германиягә, Франциягә озатыла.

Чимал б-н тәэмин итүчеләр: Тула «Мелодия» берләшмәсе (тавыш планкалары), Калуга механика з-ды (күрекләр), Татарстан АССР, Төньяк Буковина, Краснодар крае, Пермь өлкәсенең урман сәнәгате хуҗалыклары (агач).

1964 тә Бөтенроссия клавишлы уен кораллары смотрында «Казан» пианиносы РСФСР да иң яхшысы булып танылa. Аккордеон төрендәге татар (милли) гармуны (1973) һәм «Сюита» пианиносы (1981) дәүләт сыйфат билгесенә лаек була. Пр-тие — СССР ВДНХсы дипломанты (1966). Фабриканың 2 хезмәткәре — Хезмәт Кызыл Байрагы ор-







**Казан музыка уен кораллары фабрикасы мәкаләсенә.** 1. «Казан» пианиносы; 2. Татар «Тальян» гармуны; 3. «Беккер-Казан» рояле.

деннары, 4 хезмәткәре СССР ВДНХ сының көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

1990 елларда җитештерү күләме кискен кими, фабрика бөлгенлек хәленә төшә, бу хакта 1998 дә рәсми рәвештә игълан ителә. 2002 дә фабрика юридик зат буларак эшчәнлеген туктата. Мөлкәте сатыла. Пр-тие җитәкчеләре арасында: А.П.Батуров (1963–81), В.Н.Лещуков (1981–95).

*Әд.:* Мифтахов А. Алдынгылар сафы ишәя // Социалистик Татарстан. 1974. 14 февр.; Советский аккордеон // Красная Татария. 1937. 14 февр.; Пианино «Сюита» // Музыкальная жизнь. 1980. № 20.

*М.Ж.Гаитов.*

**КАЗА́Н МУЗЫКА́ЛЬ ФОЛЬКЛО́Р КАБИНЕТЫ́**, ТАССРның Сәнгать эшләре идарәсе каршында, 1937–51 елларда эшли. Татар муз. фольклорын җыю, нотага салу системасын булдыру һәм классификацияләү б-н шөгыльләнә. Кабинет б-н төрле елларда А.А.Эйхенвальд (1937–38), А.С.Ключарёв (1938–50), Ж.Фәйзи (1950–51) җитәкчелек итә; В.И.Виноградов, М.Мозаффаров, М.Садри эшли. ТАССР районнарына һәм РСФСРның татар халкы яшәгән төрле өлкәләренә ел саен кабинет тарафыннан экспедицияләр оештырыла. Бай фольклор материаллары Башкортстанда, Горький, Әстерхан, Оренбург, Куйбышев өлкәләрендә туплана. Касыйм һәм Себер татарларының фольклор әсәрләрен җыю башлана. Кабинетның фольклор язмалары фонды композиторлар, музыкантлар һәм фольклорчыларның, ш.и. И.А.Козлов, Г.Сәйфуллин, Г.Еникиев, И.Мусинның шәхси тупланмаларыннан алынган материаллар б-н дә тулыландырыла. Фонд татар музыкасы фольклоры буенча байтак материалларны үз эченә ала. Кабинет хезмәткәрләре эшенең төп нәтиҗәсе булып басылып чыккан «Татар халык җырлары» җыентыгы санала, аңа кереш сүзне һәм шәрехләүләрне В.И.Виноградов, А.С.Ключарёв һәм М.Садри язалар (1941, Т.1). *Е.В.Порфирьева.*

**КАЗА́Н НАДВО́РНЫЙ МӘХКӘМӘСЕ́**, мәхкәмә органы. Патша Пётр I нең 1719 елның 8 гыйнварында һәм Юстиц-коллегиянең 1719 ның 15 июлендә чыгарылган фәрманнары б-н оештырыла. Үзенә буйсынудагы мәхкәмәләрдә хәл ителгән җинаять (үтерүләр, юлбасарлык, талаулар, урлаулар, өйләнешүгә кагылышлы законнарны бозулар) һәм гражданлык (бурычларны түләмәү, зыян китерү һ.б., милек дәгъваларыннан башка) эшләрен тикшерү һәм яңадан карау, җирле идарә чиновникларының законсыз гамәлләре турындагы эшләрне тикшерү, түбәнрәк дәрәҗәле (1722 гә кадәр), провинцияләрдәге (1722 дән соң) мәхкәмәләрнең һәм милек биләүгә хокукы расланган таныклыклар («крепость») бирүче контораларның эшен контрольдә тоту б-н шөгыльләнә, кайбер адм. һәм полиция вазифаларын башкара. Президент, вице-президент, асессорлардан (судьялардан), 1722 дән прокурордан гыйбарәт була. Кабулханә, канцелярия, канцеляриядән тыш хезмәткәрләрне үз эченә ала. К.н.м. составына секретарьлар, канцелярия хезмәткәрләре, күчермә алучылар, йомышчылар, каравылчылар һәм палач керә; барлыгы 40 лап кеше. Сенатка һәм Юстиц-коллегиягә буйсына. Император Екатерина I нең 1727 ел 24 февраль Фәрманы б-н бетерелә, вазифалары *Казан губернасы канцеляриясенә*, провинция һәм воеводалар канцеляриясенә тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 5. № 3202, 3261, 3269; Т. 7. № 5017.

*Әд.:* Долгов Е.Б. Органы суда в Казанской губернии в XVIII — начале XX вв. // Правосудие в Татарстане. 2000. № 2/3; Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 3. *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н НАМЕ́СТНИКЛЫК ИДАРӘСЕ́**, Казан губернасында югары адм.-терр. хакимият органы. 1775 елгы Губерналар реформасын уздыру нәтиҗәсендә оештырыла, 1781 нең 23 декабрендә ачыла. Губерна б-н гомуми адм. идарә итүне гамәлгә ашыра; үзәк хакимиятләрнең законнарын, фәрман һәм күрсәтмәләрен халыкка җиткерә һәм аларның үтәлешенә күзәтчелек итә; хокук тәртибен саклау б-н шөгыльләнә; мәхкәмә тикшерүе таләп ителмәгән эшләрне карый; мәхкәмә чыгарган хөкем карарлары буенча мөлкәттән файдалануны тыя; буйсынудагы учреждениеләргә һәм затларга карата белдерелгән шикаятьләрне карый. Идарә үзеннән югары органнарның карарлары буенча конкрет күрсәтмәләр чыгара, урыннарга фәрманнар җибәрә, полиция учреждениеләреннән һәм руханият идарәләреннән, магистратлардан һәм ратушалардан, мәхкәмәләрдән һәм җәза үтәүче оешмалардан рапортлар һәм ведомостьлар кабул итә. Составына наместниктан (рәис), идарәчедән (губернатор), 2 губерна киңәшчесеннән гыйбарәт кабулханә; секретарьлардан, беркетмә язучылардан, теркәүчедән, архивариустан, канцелярия хезмәткәрләреннән һ.б. дан торган канцелярия керә. Сенатка буйсына. 1796 ның 31 декабрендә Казан губернасының яңа штатын тәгаенләгәндә бетерелә, вазифалары *Казан губерна идарәсенә* һәм *Казан губернаторы канцеляриясенә* тапшырыла.

Наместниклар (генерал-губернаторлар): П.С.Мещерский (1780–92), М.И.Кутузов (1793–96), С.И.Маврин (1796). Наместниклык идарәчеләре (губернаторлар): И.Б.Бибиков (1781–83), И.А.Татищев (1783–89), С.М.Баратаев (1789–96).

Чыг.: Полное собрание узаконений о губерниях по хронологическому порядку с 1775 по 1817 г. СПб., 1818.

*Әд.:* Долгов Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII в. // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и в раннее новое время. М., 1996.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н НӘФИ́С СӘНГА́ТЬ СӨЮЧЕЛӘ́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, җәмәгать оешмасы, 1895 елда Казанда сәнгать төрләрен тарату һәм популярлаштыруга, сәнгатьнең төрле өлкәләрендә шөгыльләнүче эшлекләләр хезмәттәшлеген җәелдерүгә булышлык итү максатында төзелә. Уставка нигезләнеп, җәмгыять эшчәнлеге музыка, драма, сынлы сәнгать, сәнгать тарихы һәм теориясе, әдәбият өлкәләрен колачлый. Җәмгыятьнең беренче рәисе — шәһәр башлыгы С.Г.Дьяченко, 118 оештыручы әгъза арасында сәнгать тарихчысы Д.В.Айналов, Казан ун-ты профессоры Н.П.Загоскин, сәүдәгәр Д.В.Вараксин, ш.у. җәмәгать эшлекләләре, чиновниклар һ.б. була. Җәмгыять оешкан көннән алып ел ахырына 300 дән артык әгъзаны берләштерә. Драма (җитәкчесе Н.Н.Михайлов), әдәбият (җитәкчесе Н.П.Загоскин), музыка (җитәкчесе Н.П.Купреянов), сәнгать (җитәкчесе О.А.Лебедева, әгъзалары — В.В.Вараксин, А.М.Кокорев, А.И.Пиотровский, Е.Г.Семченко, Л.О.Сиклер, В.Г.Фёдоров) секцияләре барлыкка килә. Җәмгыять Сәүдәгәрләр клубы бинасында урнаша, чараларны үткәрү өчен ш.у. шәһәр думасы залы да файдаланыла. Гнедич пьесалары, Ж. Оффенбах, Ф.Зуппе опереттalары буенча драма секциясе (җитәкчесе һәм режиссёры Н.Н.Михайлов) оештырган һәвәскәр спектакльләр тамашачылар алдында аеруча зур уңыш казана. Музыка секциясе ел дәвамында Казанның танылган музыкантлары Н.Н.Ворошилов, А.И.Панаев, К.И.Гриняски, В.А.Больтерман катнашында, Р.А.Гуммерт җитәкчелегендәге музыка мәктәбе укытучылары, ш.у. һәвәскәр музыкантлар көче б-н 10–12 кичә уздыра. Концертлар, нигездә, муз. аң-белем тарату рәвешендә оештырыла, анда композиторларның биографияләре бәян ителә, муз. әсәрләре башкарыла. Әдәби әсәрләрдән өзекләр уку музыка б-н чиратлаштырып алып барылган әдәби-муз. кичәләр популяр була. Сынлы сәнгать секциясе «җанлы сурәтләр» дип аталган алымны куллана. Рәссамнар мөстәкыйль проф. берләшмә оештыру омтылышы ясыйлар — 1897 дә «Идел буеның теге яки бу дәрәҗәдә билгеле булган барлык шәһәрләре буйлап күргәзмәләр оештыру» максаты б-н «Идел буе рәссамнары җәмгыяте» уставы проекты эшләнә. 1898 дә «Җирле һәм башка шәһәрләрдәге рәссамнарның картиналар һәм этюдлар күргәзмәсе»н (200 гә якын әсәр) рәссам Ю.А.Тиссен Идел буйлап Сембер, Самара, Әстерхан шәһәрләренә озатып бара. Җәмгыять әгъзасы Д.В.Айналов сынлы сәнгать буенча лекцияләр укый. Мәсәлән, 1898 дә музыка мәктәбе бинасында «Кеше яшәешендә сәнгатьнең әһәмияте» дигән темага лекция сөйли. 1900 нең ахырына җәмгыять әгъзаларының саны шактый кими, 1910 да ул ябыла, фонды һәм мөлкәте Казан халык ун-тлары җәмгыятенә һәм Рус Император музыка җәмгыятенең Казан бүлегенә тапшырыла.

Чыг.: Устав Казанского общества любителей изящных искусств. К., 1895; Первый отчёт о деятельности Казанского общества любителей изящных искусств за 1896 г. К., 1897; Второй отчёт о деятельности Казанского общества любителей изящных искусств за 1897 г. К., 1898.

*Әд.:* Северюхин Д.Я., Лейкинд О.Л. Золотой век художественных объединений в России и СССР (1820–1932). СПб., 1992.

*Е.В.Порфирьева, Е.П.Ключевская.*

**«КАЗА́Н» НО́МЕРЛАРЫ**, к. «*Казанское подворье*».

**КАЗА́Н О́КРУГ МӘХКӘМӘСЕ́**, Казан губернасы терр-ясендә беренче инстанция мәхкәмә органы. 1864 елгы Мәхкәмә реформасын уздыру барышында оештырыла, 1870 нең 8 ноябрендә ачыла. Җәмәгать судьялары һәм мәхкәмә палатасы вәкаләтләренә карамаган җинаять (закон буенча барлык дәрәҗәләргә һәм милеккә ия булу хокукларыннан яки барлык махсус хокуклардан һәм өстенлекләрдән мәхрүм ителүгә китергән җинаятьләр турындагы эшләр, алар антлы утырышчылар катнашында тикшерелгән) һәм гражданлык (дәгъваның бәһасе 500 сумнан артканда, сәүдә өлкәсеннән кала) эшләрен, бозылган биләү хокукын (биләмәне) торгызу, бәхәсләр һәм үтенечләр буенча күчемсез мөлкәткә милек хокукын тану, варислык хокукларын раслау һәм язма васыятьләр, уллыкка, кызлыкка алу һәм балаларны законлаштыру, ышаныч кәгазен гамәлдән чыгару, нәсел утарларын сатып алу, биләүгә кертү, дворяннар



Казан округ мәхкәмәсе бинасы.
1900 еллар фоторәсеме.

опекалары һәм *ятимнәр мәхкәмәләре* гамәлләренә карата белдерелгән шикаятьләр, мирас бүлү, раскольникларның хокуклары турындагы эшләрне карый. Составына рәис, рәиснең гражданлык һәм җинаять бүлекләре буенча 2 иптәше (урынбасары), 14 мәхкәмә әгъзасы керә. Судьяларны вазифага губернатор тәкъдим итә, алар император тарафыннан раслана. К.о.м. гражданлык, I һәм II җинаять бүлекләреннән, канцелярия, регистратура, касса һәм архивтан тора. К.о.м.нә секретарьлар, суд тикшерүчеләре, прокурор күзәтчелеге хезмәткәрләре, мәхкәмә приставлары, йомышчылар, нотариуслар, архивариус, антлы ышанычлылар һәм 1874 тән шәхси ышанычлылар хезмәт күрсәтә (барлыгы 190 лап кеше, 1915). Урыннарда округ мәхкәмәсенең өязләрдән сайланган 18 (1889 ның 12 июле Нигезләмәсе б-н гамәлгә кертелә) һәм шәһәрләрдән сайланган 4 әгъзасы (Чистай, Козьмодемьянск һәм Чабаксар шәһәрләрендә) эшли. К.о.м. карарлары б-н риза булмаган очракта алар *Казан мәхкәмә палатасында* һәм Сенатның кассация департаментларында яңадан карала. РСФСР ХКСның 1917 нең 22 ноябрендә кабул ителгән «Суд турында»гы 1 нче Декреты һәм Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының 1918 ел 10 март карары б-н бетерелә.

Рәисләре: А.Е.Лазарев (1870–75), Л.И.Грасс (1875–94), В.Р.Завадский (1894–99), В.К.Кудревич (1899–1903), С.В.Дьяченко (1903–07), Н.Н.Казин (1907–16), В.В.Туношенский (1916–18), А.Н.Нехотяев (1918).

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1874. Т. 45, отд. 1. № 48517; отд. 2. № 48853, 48926; Правящая Россия: Полный сборник сведений о правах и обязанностях административных учреждений и должностных лиц Российской империи. СПб., 1906. Ч. 3.

*Әд.:* к. *Казан мәхкәмә палатасы.*

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н О́КРУГЫ МӨСЕЛМА́Н ХӘРБИ́ КОМИТЕТЫ́**, 1917–18 елларда Казан губернасында эшли. Казан хәрби округы мөселман гаскәрләренең 1917 елның 30 окт. — 21 ноябрендә Казанда үткән 1 нче корылтаенда оештырыла. Аның составына 35 әгъза сайлана. Рәисе — Х.Сафиуллин, рәис урынбасары — Я.Җ.Чанышев, сәркәтибе — К.Л.Якубов. Мөселман хәрби частьләрен туплау, татар һәм башкорт солдатларын өйрәтү һәм тәрбияләү, аларны Бөтенроссия Учредительләр җыенына сайлауларда катнашуга әзерләү б-н шөгыльләнә. РСФСР Милләт эшләре халык комис-тының 1918 ел, 24 март Декреты б-н бетерелә.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**КАЗА́Н ОПОЛЧЕ́НИЕСЕ**, *Ватан сугышы (1812)* вакытында Казан губернасында оештырыла. Халык ополчениеләре император Александр I нең Россиядәге барлык катлауларда яклау тапкан 1812 ел, 6 июль Манифесты нигезендә оеша башлый. 1812 ел, 18 июль Манифестында Александр I рус халкына Ватанны сакларга әзер булуы өчен рәхмәт белдерә. Әлеге документ нигезендә ополчениеләрне терр. төзү 16 үзәк губерна б-н чикләнә, алар 3 округ тәшкил итәргә тиеш була. Түбән Новгород, Пенза, Кострома, Сембер һәм Вятка губерналары б-н бергә Казан губернасы 3 нче резерв округка керә (башлыгы — генерал-лейтенант П.А.Толстой). Ополчение нигездә крепостной крәстияннәрдән тора: махсус развёрстка буенча алпавытлар 100 ревизия җаны башыннан 17 дән 45 кә кадәр яшьтәге 4–5 сугышчы бирә. Сугышчылар бирүдән азат ителгән дворяннар һәр ревизия җаны башы өчен 6 сум 50 тиен кертәләр. Ополчениеләрнең күпмедер өлешен ирекле һөнәрчеләр, мещаннар һәм руханилар катлавы вәкилләре тәшкил итә. К.о. Казан губернасы халкы иганәсенә оештырыла (346 мең сум, ш.и. татарлар 10 мең сум бирә). Ул җәяүлеләр полкыннан һәм татарларның атлы батальоныннан тора (барысы 3 мең кеше). Офицерлары — Казаннан 54 дворян, командирлары — генерал-майор Д.А.Булыгин. Ополчениене оештыру 1812 нең декабрендә тәмамлана. 1813 нең 13 гыйнварында К.о. походка чыга. Ул генерал Л.Л.Беннигсен җитәкчелегендәге поляк армиясе составына керә һәм Польша, Силезия, Богемия, Саксония терр-яләрендәге яуларда катнаша. 1813 нең октябрендә Казан ополченецлары Дрезден шәһәре янында сугыша. Батырлыгы һәм кыюлыгы өчен җәяүлеләр полкы командиры А.П.Селиванов һәм 7 офицер Россия орденнары б-н бүләкләнә, 8 офицер чираттагы дәрәҗәгә тәкъдим ителә (бүләкләнгән татарлар арасында — медаль һәм офицер дәрәҗәсе алган крәстиян Агиев). Шәһәр бирелгәннән соң, К.о.нең бер өлеше Дрезден гарнизоны составына керә һәм сугыш беткәнгә кадәр шунда кала. Атлы батальон Мезербург, Гамбург шәһәрләре өчен барган сугышларда катнаша. 1815 нең 25 февралендә ополченецлар Казанга әйләнеп кайта.

*Әд.:* Апухтин В.Р. Казанское дворянское ополчение 1812–1813–1814 гг. М., 1912; Славин Н.Ф., Лебедева А.И., Кирсанов С.А. Казанцы в Отечественной войне 1812 года. К., 1942; Софинов П., Эпштейн Д., Жибарев П. Народное ополчение Поволжья в Отечественной войне 1812 года. Саратов, 1942; Гарзавина А.В. « ... Отчизне посвятим души прекрасные порывы!» К., 1990.

*С.И.Дашиев.*

**КАЗА́Н О́ПТИКА-МЕХА́НИКА ЗАВОДЫ́** (КОМЗ), оборона һәм гражданлык максатлары өчен оптик-механик һәм оптик-электрон приборлар эшләп чыгаручы пр-тие. 1,9 мең кеше эшли (2011). Башта (1932 елдан) «Вагонстрой» з-ды буларак төзелә, аннары (1937 дән) Ленинград оптика-механика з-дының дублёры буларак эшләп килә. Чит илләрдә җитештерелгән алдынгы технология җиһазлары б-н тәэмин ителә (мәс., эшкәртү озынлыгы 5 тән 20 *м* га кадәр булган токарь станоклары Англия һәм АКШтан кайтарыла). 1940 елда 247 нче з-д буларак сафка баса; 1951 дән 15 нче пр-тие оешмасы. 1966 дан хәзерге исемдә. 1987 дән ҖБ, 1996 да АҖ итеп үзгәртелә.

1941 ел башында беренче продукциясен — «Красное Сормово» з-ды (Горький ш.) өчен перископ торбалар партиясен эшләп чыгара. Бөек Ватан сугышы вакытында эвакуацияләнгән Ленинград пр-тиесе б-н берләшеп, кыска гына вакыт эчендә бинокльләр, артиллерия, танклар, авиация, снайперлар өчен төзәгечләр, перископлар, аэрофотоаппаратлар һ.б. җитештерүне җайга сала. СССР оптика сәнәгатендә беренче тапкыр заводта асылма конвейер кулланыла (1942), ул бинокльләр җитештерүне айга 10 нан 25 мең данәгә кадәр арттырырга мөмкинлек бирә. 1945 тә армия һәм флотны оптик техника белән тоткарлыксыз тәэмин итүгә керткән өлеше һәм җитештерүдәге казанышлары өчен завод Ленин ордены б-н бүләкләнә; 1946 да аңа Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл байрагы мәңгелек саклауга тапшырыла. Сугыштан соң, оборона продукциясе эшләү б-н беррәттән, лупалар, күзәтү торбалары, интраферометрлар, күләгәләү җайланмалары, фотообъективлар, балалар микроскоплары, рәсем ясау аппаратлары һәм гражданлык максатлары өчен башка эшләнмәләр әзерләп чыгару оештырыла. 1950–70 елларда



БМТ-110
бинокуляр диңгез
торбасы.

электроникага һәм автоматикага корылган яңа тип приборларны: спектроскоплар, инфракызыл техника, электрографик, күчерү-күбәйтү һәм микрофильмнар өчен машиналар, «Кама», «Экран» кул кинокамералары, авиация, ракеталар, тирән сулыклар аппаратлары өчен кинофотоаппаратураны күпләп җитештерү үзләштерелә. Завод С.И.Вавилов исем. Дәүләт оптика ин-ты (Ленинград), П.Н.Лебедев исем. Физика ин-ты (Мәскәү), СССР ФАнең Пулково, Бюрокан обсерваторияләре һ.б. учреждениеләр, Мәскәү ун-ты өчен фәнни һәм сәнәгый җиһазларны конструкцияләү һәм эшләү, зур космик тикшеренү комплексларын (стратосфера һәм орбиталь астрофизика станцияләрен) җиһазлау буенча махсус заказлар үти, бик зур җир өсте һәм космик телескопларын әзерләп чыгара. Бу чорда эшләп чыгарылган приборларның саны 80 нән 209 исемгә җитә, КОМЗ һәр юнәлеше гомуми продукция күләменең



Төп продукция үрнәкләре.

8–9% ын тәшкил иткән күп профильле пр-тиегә әверелә. Җитештерүнең үсешенә һәм пр-тиене реконструкцияләүгә бәйле рәвештә, 7 эре производство корпусы һәм берничә ярдәмче корпус төзелә. 1970 елларның 2 нче яртысында завод санлы программа б-н идарә ителә торган һәм эшкәртү комплекслары, автомат технология линияләре булган станоклар б-н җиһазландырыла, лазерлы һәм оптик-җепселле техника, пыялаларны ток үткәргеч б-н каплап ясалган эшләнмәләр җитештерүгә керешә. 1980 елларда «Мир» космик орбиталь станциясе өчен оптик-электрон җиһазлар булдыруны гамәлгә ашыра.

Заводка кою, штамплау-әретеп ябыштыру, полимер материаллардан эшләнгән детальләр, оптик детальләр, механика, җыю, лаклау-буяу һәм гальваник капламнар, автомат-револьвер һәм агач эшкәртү цехлары; ярдәмче производстволар (механика, тимерчелек, инструментлар, ремонт, санитар-техник, эл., төзелеш цехлары) керә. «Фотон» үзәк КБ (1953 тә тәҗрибә-конструкторлык бюросы буларак оештырыла, 1973 тән хәзерге исемдә) пр-тиенең фәнни-техник һәм конструкторлык ягын тәэмин итүне тормышка ашыра. Контроль-сынау үзәгендә эшләнмәләрне космостагы хәрәкәт, кояш нурланышы, төрле климатик шартлар, диңгез тирбәлеше һ.б. имитациясе б-н сынаулар уздырыла. 2003 тә ИСО-9001 халыкара стандартының сыйфат сертификаты алына. КОМЗда бинокльләр, күзәтү торбалары, оптик төзәгечләр, лазерлы ераклык үлчәгечләре, тепловизорлар, күтәрү-мачта җайланмалары (перископлар); караңгыда карау приборлары, авиация һәм диңгез навигацияләре, диагностика һәм лазер хирургиясе өчен медицина приборлары; фәнни-тикшеренү һәм контроль сәнәгый җиһазлар (спектроскоплар, рефрактометрлар һ.б.), электрофотография күчермәсе һәм микрофильмнар өчен аппаратлар әзерләнә һәм эшләп чыгарыла. Кайбер эшләнмәләрнең тиңнәре юк. КОМЗ продукциясе халыкара танылу ала: «Кама» кинокамерасы 1958 дә Брюссельдә уздырылган Бөтендөнья сәнәгать күргәзмәсенә куела, яңа төр призма системасы куелган БКФЦ 7х35 бинокле 1985 тә Кёльн күргәзмәсендә «Гран-при» бүләге ала, ВДНХның алтын медаленә лаек була. КОМЗ приборлары Германиягә, Финляндия, Канада, Кытай, Һиндстан, Берләштерелгән Гарәп Әмирлекләренә һ.б. илләргә (барысы 30 дан артык) чыгарыла (1952 дән).

КОМЗда эшләүчеләр өчен төзелгән торак, социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары Казанның Совет р-нындагы Дербышки посёлогының нигезен тәшкил итә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 3 кешегә — Советлар Союзы Герое исеме, 2 кешегә — Социалистик Хезмәт Герое исеме, 7 кешегә — СССР Дәүләт бүләге, 9 кешегә — СССР МС бүләге, 5 кешегә — Ленин комсомолы бүләге, 4 кешегә — РСФСРның, ТАССРның атказ. уйлап табучысы исеме, 2 кешегә РСФСРның, ТАССРның атказ. рационализаторы исеме бирелә. Завод җитәкчеләре: В.Л.Ольшанский (1940–41), А.Ф.Соловьёв (1941–50), П.А.*Халезов* (1951–61, 1963–68), В.П.Ханин (1961–63), И.Я.Вахрамеев (1969–74), М.А.Вәлитов (1974–77), А.Ф.Кудрявцев (1978–87), Ю.М.Беляков (1987–94), М.М.Нәҗмиев (1994–98), В.Н.Жданов (1998), Н.А.Исаев (1999–2000), Ю.Н.Салаев (2000–02), Х.З.Гыйниятов (2002–03), Р.Н.Шәрипов (2003–07), С.В.Раковец (2007 дән).

*Әд.:* Оружие Победы. М., 1985; Казанский оптико-механический завод. 1940–2000. К., 2000; Советский район Казани: Люди, годы, память. К., 2000.

*С.Г.Белов.*

**КАЗА́Н «ОРГА́НИК СИ́НТЕЗ» АЧЫ́К АКЦИОНЕРЛЫ́К ҖӘМГЫЯТЕ́** («Казаньоргсинтез» ААҖ), химия сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 9 меңнән артык кеше (2010). Россиядә пластмасса, фенол һәм ацетон, синтетик суыту сыеклыклары, нефть чыгару һәм табигый газны корыту өчен реагентлар, полиэтиленнан газ һәм су үткәргеч торбалар, тоташтыру детальләре җитештерү буенча әйдәп бара (170 тән артык төрдә химик продукция, Россиядә чыгарылучы полиэтиленның 30% тан артык өлешен җитештерә). 1958 елда Казан химия з-ды буларак нигезләнә, 1961 дә исеме Казан органик синтез з-ды итеп үзгәртелә. 1963 тә фенол-ацетон җитештерү цехлары (з-дның беренче чираты) файдалануга кабул ителә, беренче продукт эшләнә. Алдагы елларда төзелеш дәвам итә, җитештерү мәйданнары һәм куәтләре зурайтыла. Этилен-пропилен (1965, 1968, 1974, 1981), этилен окисе (1967, 1973), полиэтилен (1966, 1968, 1976,1983), модификаторлар (1970), перекись инициаторлары (1970), полиэтилен торбалар (1980, 1986), тукылган полипропилен капчыклар һәм йомшак «Биг-Бэг» контейнерлары (1996) производстволары файдалануга тапшырыла. Бишьеллык планны һәм соц. йөкләмәләрне вакытыннан алда үтәгәне, химия продукциясе җитештерүдә куәтләрне арттыруда ирешелгән уңышлары өчен 1971 дә завод Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә. 1975 тә — Казан «Полиэтилен» ҖБ, 1976 дан — «Органик синтез» ҖБ. 1987 дә пр-тие б-н идарә итү структурасын камилләштерү өчен гамәлдәге төп производстволар җирлегендә технол. яктан 5 мөстәкыйль завод — этилен, органик продуктлар, югары басымлы полиэтилен, түбән басымлы полиэтилен, полиэтиленны яңадан эшкәртү з-длары төзелә. 1991 дә Казан аренда «Органик синтез» ҖБ оештырыла, 1993 тән — хәзерге исемдә. 2004 тә һаваны таркату цехлары җирлегендә азот, кислород җитештерү һәм суыту (АКХ) з-ды төзелә. Шул ук елда капиталь ремонтлар з-ды оештырыла. 2005 тә түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм пластмассаны кабат эшкәртү з-длары түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм эшкәртү з-дына берләштерелә. Шул елдан ике завод — елга 70 мең *т* бисфенол-А һәм елга 65 мең *т* поликарбонатлар җитештерүгә исәпләнгән з-длар төзелеше алып барыла.

Этилен з-ды составында — этилен, пропилен производстволары, ш.у. фенол һәм ацетон производстволарының 4 чираты. Товарлыклы этилен — этилен кулланучы производстволарга, пропилен фенол-ацетон җитештерүгә җибәрелә. 1998 дә изопропилбензол гидропероксидын гомоген тирәлектә фенолга һәм ацетонга ике баскычлы кислоталы таркату технологиясе эшләнә һәм гамәлгә кертелә. 14 төрдә продукция чыгарыла.

Органик продуктлар з-ды этилен окисе һәм аны эшкәртүдән алынучы продуктлар, трегер катализаторы производстволарын, сыек газ рәвешендәге калдыкларны яңадан эшкәртү һәм утильләштерү цехын үз эченә ала. Чимал сыйфатында этилен кулланыла. Завод 55 төрдә продукция (гликольләр, этаноламиннар, коррозия һәм парафин ингибиторлары, проксанол-проксаминнар, нефть деэмульгаторлары, ярдәмче текстиль матдәләр) эшләп чыгара.

Югары басымлы полиэтилен з-ды составында — түбән тыгызлыклы (югары басымлы) полиэтилен производствосының 3 чираты. Чимал сыйфатында этилен кулланыла. Ел саен кою, кабарту, экструзия һәм плёнка эшләнмәләре җитештерү өчен төрле маркадагы 180 мең *т* композиция чыгарыла. БДБдә тау-казылмалар сәнәгатендә шартлаучан матдәләрне күчергәндә кулланылучы махсус кабельләр һәм торбалар эшләү өчен эл. үткәрүчән полиэтилен композицияләр җитештерүче бердәнбер завод.

Түбән басымлы полиэтилен җитештерү һәм аны кабат эшкәртү з-ды өч цехтан — газларны чистарту һәм этиленны полимерлау, полиэтиленны компаундлау һәм төяп озату, пластмасса эшләнмәләре цехларыннан тора.



«Казаноргсинтез». Предприятиенең гомуми күренеше.

Полиэтилен җитештерүгә чимал сыйфатында этилен, бутен-1, гексен-1, водород куллanыла. 2006 да ике этилен полимерлау реакторы реконструкцияләнә, бу полиэтилен җитештерүнең куәтен елга 510 мең *т* га кадәр арттыру һәм полиэтиленнның яңа маркаларын, ш.и. ныклы төргәкләү плёнкалары өчен тыгызлыктагы түбән полиэтилен һәм ПЭ-100 маркалы торбалар җитештерү өчен бимодаль полиэтилен эшләп чыгару мөмкинлеген тудыра. Пластмасса эшләнмәләр цехы 10–1200 *мм* диаметрлы полиэтилен торбалар, тукылган полимер капчыклар һәм контейнерлар, халык куллануы товарлары чыгара. Еллык җитештерү күләме 30 мең *т* тәшкил итә. Еллык җитештерү куәте — 15 млн. данә тукылган полимер капчык һәм 200 мең контейнер.

Азот, кислород җитештерү һәм суыту з-ды пр-тие подразделениеләрен технол. чаралар б-н тәэмин итә, түбән басымлы полиэтилен эшләү һәм аны кабат эшкәртү з-ды өчен сыек кислород һәм югары ешлыклы азот җитештерә.

Капиталь ремонтка әзерләү һәм ремонт уздыру з-ды технол. җиһазларны ремонтлау б-н шөгыльләнә.

Пр-тие сыйфат менеджменты, экология менеджменты системаларына һәм интеграцияләнгән ИСО халыкара стандартлар менеджменты системасына сертификатлар алган.

Эшкәртү өчен чимал Татарстандагы, Оренбург, Төмән, Самара, Пермь, Ярославль өлкәләрендәге газ чыгару һәм газ эшкәртү з-длары тарафыннан магистраль газүткәргеч буйлап һәм тимер юл транспорты б-н китерелә. Экспортка чыгарылучы продуктлар: югары һәм түбән басымлы полиэтилен, фенол, ацетон, моно- һәм диэтиленгликоль. Экспортлау илләре — БДБ, Финляндия, Польша, Чехия, Словакия, Венгрия, Болгария, Италия, Кытай, Төркия, Корея һ.б.

«Казаноргсинтез» ААҖ 5 нче Бөтенроссия «Югары социаль нәтиҗәлелек предприятиесе 2005» конкурсы нәтиҗәләре буенча катнашкан 800 пр-тие арасында 3 нче урын ала.

Пр-тиедә күптиражлы «Синтез» г-тасы нәшер ителә; Химиклар мәдәният сарае, йөзү бассейны, мед.-сан. часте, шифаханә-профилакторий, 3 ял базасы, траншеялы тир, җәмәгать туклануы комб-ты һ.б. социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары эшли. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәргә лаек була: ш.и. Соц. Хезмәт Герое — 3; ТР Дәүләт бүләге лауреаты — 1, СССР МС бүләге лауреаты — 7 кеше; РФ, РТның атказ. химигы — 44, ТРның атказ. төзүчесе — 11, РФ, ТРның атказ. икътисадчысы — 11, ТРның атказ. юристы — 2, ТРның атказ.транспорт хезмәткәре — 2, ТРның атказ. уйлап табучысы — 1, ТРның атказ. рационализаторы — 12, ТРның атказ. элемтәчесе — 1, ТРның атказ. сәүдә хезмәткәре — 5, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре — 1, ТРның атказ. коммуналь хуҗалык хезмәткәре — 2, ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре — 2, ТАССР, ТРның атказ. табибе — 2, ТРның атказ. физик культура хезмәткәре — 3, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе, — 1, ТРның атказ. артисты — 1, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре — 7 кеше; 7 кеше — Ленин ордены, 4 кеше — Октябрь Революциясе, 54 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 4 кеше — Халыклар дуслыгы, 75 кеше — «Почёт билгесе», 54 кеше — 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 2719 кеше медальләр б-н бүләкләнә.





«Казаноргсинтез». 1. Түбән басымлы полиэтилен заводы;
2. Органик продуктлар заводы. Этилен компрессор станциясе.

Пр-тие җитәкчеләре: В.П.Лушников (1958–82), Ю.Н.Малышев (1982–86), Н.Х.Йосыпов (1986–2003), Л.С.Алёхин (2003 тән).

*Әд.:* Путаев М.З., Айтуганов И.М. Объединение «Органический синтез». К., 1987.

*И.М.Айтуганов, Г.Я.Мәүлетова.*

**КАЗА́Н ӨЙДӘ́ ЭШЛӘҮЧЕЛӘ́Р КОМБИНАТЫ́**, җиңел сәнәгать пр-тиесе. 1974 елда яшьләре буенча пенсионерларны, инвалидларны һәм йорт хуҗалыгында мәшгуль затларны җитештерү өлкәсенә җәлеп итү, ш.у. халык сәнгате кәсепләре эшләнмәләрен чыгаруны арттыру өчен оештырыла. Эшләүчеләр саны — 110 кеше (2010). 1990 га кадәр комб-тның Казанда, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Зеленодольск, Чаллы, Алабуга шәһәрләрендә, Балык Бистәсе, Атабай, Иске Чүпрәле, Питрәч авылларында җитештерү участоклары була. 500 дән артык исемдә тегүчелек, трикотаж, җепкыр эшләнмәләре, агачтан һәм керамикадан сувенирлар җитештерелә. 1986–87 дә комб-т составыннан мөстәкыйль пр-тиеләр булып Казан сәнгать эшләнмәләре ф-касы, өйдә эшләүчеләрнең Чаллыдагы һәм Лениногорскидагы пр-тиеләре аерылып чыга. 1994 тә К.ө.э.к. Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан респ-ка идарәсе милкенә тапшырыла. 1996 да комб-тка яңа җитештерү бүлмәләре бирелә. 2002 дән К.ө.э.к. Казанда һәм Балык Бистәсендә җитештерү участоклары били, төрле тегүчелек эшләнмәләре, сувенирлар, сәхнә костюмнары, эш, спорт, гигиена киемнәре, түбәтәйләр, дөньяның барлык илләре флагларын һ.б. күп төрле әйберләр эшләп чыгара. 2009 да 100 дән артык исемдәге 17,4 млн. сумлык продукция (2002 гә караганда 2 тапкыр күбрәк) сатыла. Комб-т Истанбул шәһәрендә узган Россия милли күргәзмәсендә көндәшлеккә сәләтле экспонатлар өчен РФ МКның дипломы (2000), ш.у. үзара файдалы хезмәттәшлек өчен 1 нче Төбәкара сәнәгать продукциясе күргәзмә-ярминкәсе (Мәскәү, 2000), «Татарстан сәнәгате товарлары» (1999, 2000, 2001, 2002, 2003), «Россиянең иң яхшы 100 товары» (2006), «Халыкара киемнәр һәм аксессуарлар салоны» (2010) күмәртәләп сатып алу күргәзмә-ярминкәләре дипломнары б-н бүләкләнә. Комб-т җитәкчеләре: В.М.Чиленсон (1974–76), К.З.Сигачёва (1977–84), Н.М.Сычёва (1985–96), Л.Н.Никулина (1996–2010), В.А.Мөслимова (2010 нан).

*Әд.:* Гарипова Х. Әниләребез җылы сүзгә сусамасын // Шәһри Казан. 2003. 7 март; Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957. *И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н ӨЛКӘСЕ́**, 1952–53 елларда ТАССРдагы адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — Казан. Терр-ясе — Алабуга, Апас, Арча, Әгерҗе, Әтнә, Балтач, Балык Бистәсе, Биектау, Бондюг, Буа, Будённый, Дөбъяз, Кайбыч, Кама Тамагы, Кызыл Йолдыз, Кызыл Юл, Корноухово, Красный Бор, Кукмара, Лаеш, Мамадыш, Морт, Норлат, Олы Тархан, Питрәч, Подберезье, Саба, Столбище, Тәкәнеш, Тәмте, Тәтеш, Теләче, Чепья, Чүри-

ле, Чүпрәле, Югары Ослан, Юдино районнары һәм Яшел Үзән шәһәре. 1953 тә Алабуга, Бондюг, Кызыл Йолдыз, Мамадыш, Морт районнары *Чистай өлкәсенә* бирелә.

**КАЗА́Н ӨЧЕ́Н СУГЫ́Ш**, 1773–75 еллардагы Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар кузгалышы барышында 1774 нең июлендә хөкүмәт гаскәрләре б-н баш күтәрүчеләр арасында булган бәрелеш. 1774 нең җәендә баш күтәрүчеләр Әгерҗе авылын, Алабуга, Мамадыш, Арча шәһәрләрен алалар. 11 июльдә Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр (20 мең кеше, 12 туп) Казанга киләләр. Аларга гарнизон һәм шәһәр ополчениесе каршы тора (барысы 6 меңгә якын кеше, 50 туп). Аерым участокларда шәһәрне саклауны генерал П.П.Баннер (Арча кыры б-н Казансу елгасыннан Кабан күленә кадәр), генерал-майор Ларионов (Пләтән авылыннан Ямчылар бистәсенә кадәр), полковник Свечин (Ямчылар бистәсеннән Казансу елгасына кадәр) җитәкчелек итәләр. 12 июль иртәсендә баш күтәрүчеләр, Е.И.Пугачёв, И.Н.Белобородов, Минеев, И.Бахмутов, И.*Әхмәтов* җитәкчелегендәге 4 колоннага бүленеп, шәһәрне камый башлыйлар. Сугышып, алар шәһәрне яулап алалар, ә хөкүмәт гаскәрләре Кремльгә кереп яшеренә. Казанда башланган янгын сугышны дәвам иттерергә комачаулый, шунлыктан Пугачёв гаскәрләрне шәһәр читенә чыгара. 12 июль кичендә Арча кырында баш күтәрүчеләр подполковник И.И.Михельсон корпусы б-н сугышка керәләр. 13 июль иртәсендә әлеге корпус шәһәрдәге хөкүмәт гаскәрләре б-н кушылырга юнәлә, ә Е.И.Пугачёв үз гаскәрләрен Коры Елга авылы янына алып китә. 15 июльдә Арча кырында яңадан бәрелеш була. Баш күтәрүчеләр җиңелә: 2 меңнән артык кеше үтерелә, 5 меңгә кадәре әсирлеккә төшә. Е.И.Пугачёв калган сугышчылары б-н Иделнең уңъяк ярына чыга. К.ө.с. барышында Казанда 2190 йорт, 777 вак кибет, 28 чиркәү яна.

*Әд.:* История Казани. К., 1988. Кн. 1; А л и ш е в С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI–XIX вв.). К., 1999.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КАЗА́Н ӨЯЗЕ́**, 1708–1920 елларда Казан губернасының адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — Казан. 16 йөзнең 2 нче яртысында элеккеге Казан ханлыгының күпчелек җирләреннән оештырыла. Төньякта Уржум, Яранск һәм Оса шәһәрләренә кадәр Иделнең сулъяк яр буйларын һәм Иделнең уң ягындагы җирләрне, көньяк-көнчыгышта Кызыл Аланнан Агыйдел елгасына кадәр, көньякта Үләмә елгасының урта агымы һәм Тәтеш шәһәреннән Самара Дугасына кадәр булган терр-яне биләгән. 18 йөзгә кадәр өязнең төгәл чикләре булмаган, 20 йөз башына кадәр терр-ясе берничә тапкыр кечерәйтелгән. 16 йөзнең 2 нче яртысында К.ө.ндә ныгытылган торак пунктлар төзелү нәтиҗәсендә үзәкләре Кокшайск (1573), Царёвококшайск (1584), Царёвосанчурск (1584), Уфа (1586), Яранcктан (1591) торган мөстәкыйль өязләр; үзәкләре Казан тирәсендәге Лаеш (1557), Тәтеш (1558), Малмыж (1584), Минзәлә (1584–86) булган «эчке» өязләр; ныгытылган авыл «шәһәрләре» Усы, Сарапул, Балык Бистәсеннән торган сарай волостьлары оеша. 1708 елда К.ө., үзәкләре «шәһәр бистәләре» Алатырь, Лаеш, Арча, Малмыж, Тәтеш, Усы, Минзәлә, Иске Чишмә, Яңа Чишмә, Тиинск, Биләр, Маинск булган «эчке» өязләргә һәм волостьларга бүленүен саклаган хәлдә, Казан губернасы составына керә. Сарай авыллары Алабуга, Сарапул, Кукар Бистәсе, үз волостьлары б-н Пенза шәһәренә күчерелә. 1719 елда К.ө. Казан губернасындагы Казан провинциясенең төп өлеше була, аның составыннан үз терр-ясе б-н Алатырь бүлеп чыгарыла һәм Түбән Новгород губернасына бирелә. 1781 дә «шәһәр бистәләре» Арча, Лаеш, Тәтеш һәм сарай авыллары Мамадыш, Чистай, Спас шәһәр статусы алалар һәм Казан губернасының мөстәкыйль өязләре үзәкләренә әвереләләр. Шулай ук шәһәр статусы алган «шәһәр бистәләре» Малмыж, Усы, Минзәлә — Вятка, Пермь һәм Уфа наместниклыгы составына кертеләләр. 1796 да Арча, Спас һәм Тәтеш өязләре бетерелә, аларның терр-яләре К.ө. составына кертелә. 1802 дә Спас һәм Тәтеш өязләре яңадан торгызыла. 19 йөз башына кадәр К.ө.н төбәк өчен традицион булган, исемнәре 17 йөз башына ныклап урнашкан Нугай, Җөри, Алат, Гәреч һәм Арча даругаларына бүлү саклана. 19 йөздә К.ө. Казан губернасының төньяк өлешенең уртасын били. Төньяк-көнбатышта — Чабаксар һәм Царёвококшайск өязләре, төньякта — Вятка губернасының Уржум һәм Малмыж өязләре, көньяк-көнчыгышта — Лаеш һәм Мамадыш өязләре, көньякта Зөя өязе б-н чикләнә. Көньяк-көнбатышта өяз Иделгә барып җитә. Өяз терр-ясеннән үзләренең барлык кушылдыклары б-н (Ия, Бирәзә, Аты, Шимяковка, Кырлай, Сола, Сая, Солонка, Кесмәс, Киндерле, Нокса) Сумка һәм Казансу елгалары; Илләт (Ашыт, Симет, Мәмсә, Шура һәм Петьялка елгаларының югары өлешләре) һәм кушылдыклары Нурминкә, Кече Мишә булган Мишә елгалары агып үтә; Вятканың уң кушылдыклары — Шушма, Норма, Хәтнә, Сәрдә, Каманың уң кушылдыгы Әшнәк һ.б. ага. Мәйданы 5012 кв. чакрым. Халкы 350,7 мең кеше, аларның 54,6%ы руслар, 41,8%ы татарлар (1897). 1860 елларның 2 нче яртысына кадәр өяз административ яктан 3 станга (үзәкләре — Арча шәһәре, Пермяк, Югары Бирәзә авыллары) һәм 10 волостька (Мәмсә, Арча, Олы Сәрдек, Мәмдәл, Олы Мәңгәр, Ключи, Рождествено, Алат, Столбище, Кече Лызи) бүленә. Аннары волостьлар саны 20 гә җитә, алар 4 станга бүленә. 1 нче станга (үзәге — Царицыно, соңрак Воскресенский, Клыковская Стройка авыллары) — Воскресенский, Колай, Кощак, Столбище волостьлары; 2 нче станга (үзәге — Чыпчык авылы) — Олы Әтнә, Олы Мәңгәр, Мүлмә, Собакино, Чыпчык волостьлары; 3 нче станга (үзәге — Арча шәһәре) — Арча, Балтач, Кармыш, Мәмсә, Түбән Кишет волостьлары, 4 нче станга (үзәге — Берновый Кавал, аннары Седмиозёрка авылы) — Алат, Ильинский, Каймар, Кавал, Кукмара, Суыксу волостьлары керә. К.ө. халкы башлыча ашлык үстерү (арыш, солы, борчак, тары, ясмык, арпа, борай һәм карабодай), терлек асрау һәм бакчачылык б-н шөгыльләнә. Вак һөнәрчелек кәсепчелеге: агач эшкәртү, киез басу, чүлмәк ясау, чыпта сугу, мунчала эшләү һ.б. К.ө. терр-ясендә завод һәм фабрикалар эшләп килә: Алафузов (туку һәм җитен эрләү ф-калары б-н комплекста), Апанаев, Зальм, Үтәмишев, Щетинкинның — күн, Арсланов, Крестовниковларның — шәм һәм сабын кайнату, Ушковның — химия; казнаның дары, кытай-комач, поташ эшләү, аракы һ.б. заводлары була. 19 йөздә К.ө.ндә 112 рус уку йорты, ш.у. 173 мәдрәсә һәм мәктәп эшли. К.ө. 1920 дә бетерелә, волостьларның күпчелеге *Казан кантоны* (соңрак *Арча кантоны*) составына керә.



КАЗАН ӨЯЗЕ (19 ЙӨЗ АХЫРЫ)

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 4. № 2218; Т. 5. № 3272, 3380; Т. 20. № 15058–15062, 15080, 15085; Т. 21. № 15113, 15241, 15307; Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба. Т. 8. Казанская губерния. СПб., 1861; Памятная книжка Казанской губернии на 1861 год. К., 1861; Список населённых мест по сведениям 1859 года: Казанская губерния. СПб., 1866. Т. 14; Казанский календарь на 1869 год. К., 1868; Адрес-календарь Казанской губернии на 1876 год. К., 1875; Волости и важнейшие селения Европейской России. СПб., 1883. Вып. 4; Иллюстрированный «Волжский календарь» на 1888 год. К., 1887; Материалы для сравнительной оценки земельных угодий в уездах Казанской губернии. К., 1887; Памятная книжка Казанской губернии за 1891–1892 год: В 2 *ч.* К., 1892; Казанская справочная книга на 1894 год. К., 1893; Памятная книжка Казанской губернии на 1895 год. К., 1894; Адресная книжка Казанской губернии на 1900 год. К., 1899; Адрес-календарь Казанской губернии на 1905 год. К., 1905; Адрес-календарь и справочная книжка Казанской губернии на 1915 год. К., 1914.

*Д.Г.Мостафина.*


**КАЗА́Н ПЕДАГО́ГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ́**. Тарихы 1876 елдан, 1918 елда Казан пед. ин-ты итеп үзгәртелгән Казан укытучылар ин-тыннан башлана. 1919 да Казан пед. ин-ты җирлегендә составына Казан ун-ты һәм *Казан югары хатын-кызлар курсларының* тарих-филос. һәм физ.-матем. ф-тлары пед. персоналы һәм студентларның бер өлеше кертелгән *Халык мәгарифе югары институты* оештырыла. 1921 дә Казан пед. ин-ты дип атала башлый, 1922 дә Идел буе респ-каларына пед. кадрлар әзерләү өчен *Шәрекъ педагогия институты* итеп үзгәртелә. 1931 дә, Чабаксар, Йошкар-Ола, Ижевск шәһәрләрендә пед. югары уку йортлары ачылу б-н бәйле рәвештә, исеме Татар пед. ин-ты дип атала башлый. Мари, удмурт, чуаш бүлекләре бетерелә. 1934 тән Казан пед. ин-ты, 1994 тән Казан пед. ун-ты, 2005 тән татар гуманитар-пед. ун-ты.

1932 дә Шәрекъ пед. ин-ты бүлекләре тарих, табигать белеме һәм география, физ.-матем., химия-биол., геогр., мәктәпкәчә белем бирү, филол. (рус һәм татар бүлекләре б-н) ф-тлары итеп үзгәртелә. 1923–37 дә институт каршында эшчеләр ф-ты, 1934–40 та 5 бүлек б-н укытучылар ин-ты (тулы булмаган югары белем бирә) эшләп килә. Бөек Ватан сугышы елларында институт эшчәнлеге тукталмый. 1941–45 тә студентлар саны 170 тән 750 гә кадәр үсә, институтта эвакуациядә булган СССР ФА академиклары һәм мөхбир әгъзалары Б.Д.Греков, Е.А.Косминский, Е.В.Тарле, А.Е.Ефимов, Н.С.Державин, С.П.Обнорский, И.Е.Тамм укыткан.

1946 да мәктәпкәчә белем бирү ф-ты базасында пед. ф-т (башлангыч мәктәп укытучыларын һәм мәктәпкәчә учреждение хезмәткәрләрен әзерли, 1960 ка кадәр эшли) оештырыла. 1947 дә чит телләр ф-ты (әлеге өлкәдә белгечләр әзерләү 1939 дан ук башлана) ачыла. 1955 тә химия-биол. һәм геогр. ф-тлары — табигать белеме һәм география ф-тына, филол. һәм тарих ф-тлары тарих-филол. ф-тына берләштерелә. 1949 дан — физик культура, 1960 тан муз.-пед. ф-ты эшләп килә. 1994 елда тарих-филол. ф-ты тарих һәм филол. ф-тларына бүленә, соңгысы 1995 тә рус һәм татар филологиясе ф-тларына аерыла. Шул ук елда физ.-матем. ф-ты җирлегендә физ. һәм матем. ф-тлары барлыкка килә. 1998 дән — психол. ф-ты, 2001 дән пед. һәм хокук ф-ты (башлангыч мәктәп һәм мәктәпкәчә учреждениеләр педагогларын, педагог-юристлар әзерли) эшләп килә.

К.п.у. тарафыннан 30 меңнән артык белгеч әзерләнә. Аны тәмамлаучылар арасында педагог В.М.Хвостов, тарихчылар С.Х.Алишев, А.М.Җәләлов, Ф.Ш.Хуҗин, артистлар А.Ф.Фәйзрахманов, А.А.Вәлиев, спортчылар Н.Ш.Фәсахов, В.М.Колотов, В.Ф.Маркелов, Н.Ф.Гыйләҗева, В.Н.Никонова, О.В.Данилова, А.В.Плюшкин, А.А.Кузьмин, В.В.Московских, Р.З.Бакиев, Э.Э.Баянов, А.К.Хамматов, Д.В.Капустин, Ю.С.Сотникова, Н.И.Садова һ.б. бар.

2004 тә 11 факультетта 14 белгечлек буенча укытыла. Көндезге бүлектә 6 меңгә якын студент укый, читтән торып — 4,5 меңгә якын, ш.и. бюджеттан тыш нигездә — 2,6 меңнән артык кеше белем ала; пед. коллективта 610 кеше, ш.и. 2 ТР ФА мөхбир әгъзасы, 2 халык артисты (В.С.Федотов, М.В.Галиев) һәм 2 ТРның атказ. артисты, 45 фән. д-ры һәм 244 фән. канд-ты эшли. Квалификация күтәрү ф-ты, әзерлек бүлеге бар.



Казан педагогика университеты. Төп корпус.

Институт беренче елларыннан ук эре фәнни үзәк була, монда атаклы галимнәр: математиклар П.А.Широков, Н.Г.Чеботарёв, биолог А.М.Алексеев, тел белгече В.А.Богородицкий, тарихчылар С.П.Сингалевич, Р.Ш.Таһиров, Е.И.Устюжанин, И.М.Ионенко, этнограф Н.И.Воробьёв, географ һәм педагог В.Н.Кондаков, әдәбият белгече Е.Г.Бушканец һ.б. эшли. Гуманитар һәм табигать фәннәренең төрле юнәлешләре буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла, пед. (М.Г.Әхмәтҗанов, Г.Г.Габдуллин, Җ.Г.Нигъмәтов, В.М.Беркутов, Е.М.Ибраһимова, И.Т.Гайсин, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Р.А.Вәлиева, В.Ф.Габделхаков, Р.А.Фәхретдинова), психол. (И.М.Йосыпов, А.О.Прохоров), биол. (Р.А.Абзалов, Ф.Г.Ситдыйков), мед. (Т.Л.Зефиров, Р.Г.Биктимерова), физ.-матем. (Ф.Г.Мөхлисов, Р.В.Шәйморатов, Ю.Г.Игнатьев, Л.А.Нефедьев, К.Ә.Вәлиев, Р.М.Юльметьев), химия (Ф.Д.Ямбушев, Б.Е.Абалонин), тарих (О.В.Синицын), филос. (Э.М.Хәкимов), икътисад (Ф.Г.Газизуллин) фән. докторлары эшли.

21 белгечлек буенча аспирантура, 2 докторантура, пед., биол., филол. фәннәре буенча 3 докторлык диссертацияләре яклау советы бар.

Шәрекъ пед. ин-ты фәнни эш һәм татар теле, әдәбияты буенча белгечләр әзерләүдә беренче үзәк була. 1922 дә шәрекъ бүлеге, 1927 дә мөстәкыйль татар бүлеге ачыла. 1932 дән ул — филол., 1955 тән тарих-филол. ф-ты составында эшли. 1965 тә аерым татар теле һәм татар әдәбияты кафедралары, 1995 тә татар филологиясе ф-ты оештырыла. 2001 дә татар телен чит телле аудиториядә укыту каф. ачыла.

1920–30 елларда татар бүлегендә М.Ә.*Фазлуллин*, Г.Х.*Алпаров*, М.Х.*Корбангалиев*, Г.Г.*Сәгъди*, Г.Ә.*Нигъмәти*, Җ.Җ.*Вәлиди*, Г.Ш.*Шәрәф*, Н.Г.*Хәким*, Х.Г.*Бәдигый*, Л.Җ.*Җәләй*, Х.Г.*Гыймади* укыта, татар теле белеме, әдәбият белеменең, мәктәптә татар телен укыту методикасының фәнни нигезләре салына. Шуннан соңгы унъеллыкларда укыту эшчәнлеген М.Х.*Гайнуллин*, А.Җ.*Сайганов*, Х.Ф.*Хәйри*, Г.М.*Халит*, Х.Х.*Ярми*, Я.Х.*Агишев*, Г.С.*Кашшаф*, В.Н.*Хангилдин*, М.З.*Зәкиев*, Ф.Г.*Галимуллин* алып бара.

Татар теле бүлеген һәм ф-тын тәмамлаучылар арасында дәүләт эшлеклеләре И.К.*Хәйруллин*, галимнәр Б.Н.*Гыйззәт*, Х.У.*Госманов*, Р.Г.*Фәхретдинов*, Г.Х.*Әхәтов*, С.Ш.*Поварисов*, Г.М.Халит, Х.Х.Ярми, татар язучылары А.Г.*Алиш*, Р.В.*Әхмәтҗанов*, Ә.Ә.*Бикчәнтәева*, Ф.Г.*Гыйльми*, Г.Ш.*Гобәй*, Н.Х.*Дәүли*, Г.Х.*Зәйнашева*, Б.Х.*Камалов*, Г.С.Кашшаф, Р.Г.*Кутуй*, М.С.*Мәһдиев*, М.Г.*Маликова*, Ш.Ф.*Маннур*, Ш.Х.Мөдәррис, И.Н.*Сәлахов*, Һ.Х.*Такташ*, Х.Н.*Камалов*, С.Т.*Хәким*, Р.М.*Харис*, З.З.*Хөснияр*, М.Г.*Шабай*, И.Г.*Юзеев* һ.б.; чуаш язучылары П.Хузангай, П.Афанасьев бар.

Университет ректорлары: С.П.Сингалевич (1922–29), Г.Г.Кудояров (1929–32), М.Р.Йосыпов (1933–35), Г.К.Касыймов (1935–37), И.А.Громов (1937–45), Ю.Ә.Туишев (1945–67), М.З.Зәкиев (1967–86), Р.А.Юсупов (1986–2001), Җ.Г.Нигъмәтов (2001–2005), Р.Р.Җамалетдинов (2005 тән). 2005 елда К.п.у. Татар гуманитар институты һәм Татар-Америка төбәк институты б-н берләштерелеп, Татар гуманитар-педагогика университеты итеп үзгәртелә. 2010 елда Казан (Идел буе) федераль ун-ты составына кертелә.

*Әд.:* Казанский государственный педагогический институт. К., 1974; Казанский государственный педагогический университет — 125: Буклет. К., 2001.

**КАЗА́Н ПЕДАГО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан педагогика университеты*.

**КАЗА́Н ПЕДАГО́ГИЯ КӨЛЛИЯТЕ́**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. Революциягә кадәр Казанда булган берничә пед. уку йортының дәвамчысы. 1919/20 уку елы башыннан *Казан татар укытучылар мәктәбе*, *Казан халык укытучыларын укыту земство мәктәбе*, *Казан укытучылар семинариясе*, Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе өч еллык халык мәгарифе курслары итеп (татар, чуаш, рус, керәшен) үзгәртелә. 1921 дә аларның җирлегендә 4 пед. техникумы оештырыла. 1929 да татар һәм керәшен техникумнары К.Насыйри исем. *Казан татар педагогия техникумына* кушылалар, ул 1930 ның маенда рус һәм чуаш техникумнары б-н Казан пед. техникумына берләшә, 1937 нең гыйнварында Казан пед. уч-щесе итеп үзгәртелә. 1941 дә К.п.к. ябыла, укучылары һәм укытучылары Алабуга пед. уч-щесена тапшырыла. 1945 тә Казанда яңадан ачыла һәм 1956 га кадәр эшли. 1961 дә тагын ачыла. 1980 нән 1 нче Казан пед. уч-щесе. 1990 да татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерли башлый. 1995 нең 7 июненнән РФ мәгариф министры боерыгы б-н уч-ще көллият итеп үзгәртелә. 1920 еллар башыннан 18 меңнән артык белгеч әзерләп чыгарыла. Төрле елларда М.Ә.*Фазлуллин*, В.М.*Горохов*, В.Х.*Хаҗиев* эшлиләр. Директорлары РФнең атказ. мәктәп укытучысы М.Л.Гайнетдинов (1982–2008), А.Г.Җәләлова (2008 дән).

Башлангыч сыйныфлар укытучысы, мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбиячесе, татар теле һәм әдәбияты, чит телләр, социаль хез-


мәтләр, информатика белгечлекләре буенча кадрлар әзерләнә. 2010 да елга 940 студент укый; пед. коллективта 94 кеше, ш.и. 11 фән. канд-ты, 2 РФнең атказ. укытучысы, 8 ТРның атказ. укытучысы эшли.

*Әд.:* М у к м и н ё в Т.Н. Из истории среднего педагогического образования в Татарской АССР // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1958. Вып. 13; Казанскому педагогическому колледжу 125 лет. К., 2001.

**КАЗА́Н ПЕХО́ТА Ю́НКЕРЛАР УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, к. *Казан хәрби училищесе*.

**КАЗА́Н ПОЛИТЕ́ХНИК ИНСТИТУТЫ́**, 1919 елның гыйнварында Казан сәнәгать һәм Казан игенчелек уч-щеләре җирлегендә ачыла. Составында авыл һәм урман хуҗалыклары (1922 дән мөстәкыйль ин-т), химия, механика, төзелеш ф-тлары була. 1924 нең 8 августында югары типтагы Казан индустрия техникумына үзгәртелә, 1929 ның 18 августыннан кабат институт. РСФСР ҮБК һәм ХКСның 1930 ел 23 июнь карары нигезендә 2 мөстәкыйль югары уку йортына аерыла: Казан химия-технол. ин-ты (к. *Казан технология университеты*) һәм Казан коммуналь төзелеш ин-ты (к. *Казан архитектура-төзелеш университеты*). 2 меңнән артык югары һәм махсус урта белемле белгечләр әзерли.

**КАЗА́Н ПОСАДЫ́**, шәһәрнең 15 йөз уртасыннан манаралы агач диварлар б-н әйләндереп алынган, Кремльгә тоташкан торак р-ны. Шәһәр терр-ясе зураю сәбәпле, ул Кремль калкулыгы сырты буенча көньяк юнәлештә киңәя башлый. Казан ханлыгы чорында посадның терр-ясе хәзерге Астрономия урамына кадәр җәелә. Посад көнбатыш яктан Болак урамы б-н чикләнә, көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш яклардан, соңыннан Казан Богородица монастыре барлыкка килгәч, күлләр һәм Казан терр-ясе системасы б-н бергә, Черек күл чокырын үз эченә ала. Хан заманындагы К.п.ның саклану системасы, өстенә агач дивар һәм сугышчылар өчен мәйданчыклар эшләнгән ерымнан һәм туфрак ныгытмадан торган. Саклану өчен әһәмиятле һәм хәтәр урыннардагы диварларга манаралар, ш.и. 7–8 е капкалы манаралар (капкасыз манараларның саны билгесез) урнаштырылган. Казан ханлыгы чорында посад диварлары һәм манаралары, рус елъязмалары хәбәр иткәнчә, берничә тапкыр үзгәртеп корылган һәм яңартылган (1505, 1530, 1546, 1551). Посад диварлары кирмән ансамблен (Кремльне) көньяк-көнбатыш, көньяк, көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш яклардан колачлап алган. Казан ханлыгының посад диварлары буенча төньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка таба Ярыклы, Кайбат, Арча (Арча даругасына алып чыккан), Хан (Казан ун-тының хәзерге физика ф-ты бинасы торган калкулык битендә урнашкан), Нугай (Нугай даругасына алып чыккан), хәзерге Бауман һәм Астрономия урамнары тирәләре Көрәеш, Кырым (Болак буена һәм *Көрәеш бистәсенә* алып чыккан), Аталык (Черек Болакка һәм Ташаяк базарына алып чыккан) капкалары урнашалар. Посадның фәзаи план-структурасы 3 төп юлдан тора. Аларны Болак һәм Казансу сулары б-н тулган тирән ерым аерып торган кирмәннең көньяк диварлары алдындагы сәүдә мәйданы берләштергән. Өч юлның берсе — үзәк юл — кирмәннең Хан манарасы аша узган һәм Кремль калкулыгы сыртыннан Хан капкасына таба (хәзерге Кремль урамы юнәлешендә) дәвам иткән. Икенче олы юл Кремль калкулыгының көнбатыш сөзәклек нигезе буйлап сузылган. Ул Аталык капкасыннан башланган булса кирәк, аннары посадның Нугай капкасы аша үтеп, көньякка — Нугай Урдасына һәм алга таба Кырымга таба юнәлгән. Өченче олы юл — кирмәннең Сбойливые (татарча исеме билгесез) капкасыннан башланган һәм Арча кырына алып чыккан, аннары Казан артына, Арчага таба киткән. Хан посадының якынча мәйданы 80 *га* га якын булган. Болак аръягында, Кабан күле янындарак, *Отыч мәчете* торган Көрәеш бистәсе урнашкан. Хәзерге археол. тикшеренүләр күрсәтүенчә, Болакның урта җирендәге сулъяк ярында, Көрәеш бистәсеннән төньяк-көнбатыштарак, татар авылы урнашкан булган (исеме билгесез).




**Казан посады мәкаләсенә. 16 йөзнең 1 нче яртысы.** План-схема (Х.Г. Надыйрова реконструкциясе): I. Кремль. II. Посад. Посад манаралары: 1 — Капкалы, 2 — Исемсез, капкасыз, 3 — Кайбат, 4 — Арча, 5 — Хан, 6 — Югары Нугай, 7 — Түбән Нугай, 8 — Аталык, 9 — Мунча күле (Югары Черек күл), 10 — Черек, 11 — Ак, 12 — Түбән Черек күлләр; 13 — посад диварлары урнашуы ихтимал урыннар; 14 — әүвәлге посад; 15 — Көрәеш бистәсе; 16 — Исемсез бистә; 17 — хан кәрван-сарае; 18 — мөселман зираты; 19 — Ташаяк ярминкәсе; 20 — Болак; 21 — Кремль ерымы; 22 — посад ерымы. **16 йөзнең 2 нче яртысы.** План-схема (писцовый кенәгәләр һәм Н.Ф. Калинин материаллары буенча): I. Кремль. II. Посад. Посад манаралары: 1 — Сак, 2 — Ярыклы, 3 — Исемсез, капкасыз, 4 — Тула, 5 — Арча, 6 — Спас, 7 — Нугай, 8 — Ермактагы кече капка, 9 — Проломный, 10 — Көрәеш, 11 — Урта Көрәеш, 12 — Ямчылар, 13 — Яшерен, 14 — Никола-Кремль; 15 — Кремль ерымы; 16 — Казан Богородица, 17 — Иоанн-Предтеча, 18 — Никола кызлар монастырьлары; 19 — Параскева Пятница янкормасы б-н могҗиза тудыручы Николай, 20 — Никола Тульский, 21 — Покров, 22 — Крестовоздвижение, 23 — Воскресение, 24 — Никола-Ляпунов, 25 — Покров-Богородица, 25а — Мәскәү могҗиза тудыручылары, 26 — Петропавел, 27 — Владимир-Богородица, 28 — Косьма һәм Дамиан, 29 — Успение, 30 — Борис һәм Глеб, 31 — Ярославль могҗиза тудыручылары, 32 — Никола-Вешняковский, 33 — Никола-Гостиный чиркәүләре; 34 — Гостиный двор; 35 — Мунча күле (Югары Черек күл), 36 — Черек, 37 — Ак, 38 — Түбән Черек күлләр; 39 — посад ерымы; 40 — Татар бистәсе; 41 — Исемсез бистә; 42 — элеккеге Көрәеш бистәсе; 43 — мөселман зираты.

1552 елда, Казанны яулап алганда, посад тулысынча җимерелә һәм яндырыла. Соңрак кала, нигездә, әүвәлге чикләрендә торгызыла. Болакның урта җирендә Көрәеш һәм Исемсез бистәләр биләмәләрен кертү хисабына посад бераз киңәйтелә. 1565–68 еллардагы писцовый кенәгә мәгълүматларына караганда, Казанның әүвәлге рус посадында яшәүчеләр саны гарнизон б-н бергә якынча 5–7 меңгә җиткән. Ханлык чорындагы сәүдә итү урынында *Гостиный двор* барлыкка килгән. 17 йөзгә кадәр Казансу елгасы ярындагы Яшерен (Нурали) манара янында *Даир (Таһир) мунчасы* сакланган. Ханлык чорында төзелгән һәм кирмәнне бәйләүче төп юллар, Гостиный двор һәм шәһәрнең Нугай, Кырым, Арча, Алат, Гәреч юлларына чыга торган үтәли манаралы мөһим урыннары үзгәрешсез калдырылган. Рельеф б-н бәйләнгән әлеге 3 олы юл К.п.ның төзелеш нигезен тәшкил иткән.

Олы юллар Кремль калкулыгы һәм чокырларга аркылы юнәлештәге Черек күл иңкүлеге б-н кисешкән юлларга барып тоташалар. 1565–68 еллардагы писцовый кенәгә рус посадындагы беренче чиркәүләр, манаралар һәм бистәләр турында хәбәр итә. Казанны яулап алганнан соң, 13–15 ел эчендә иң элек рус посадында 12 манаралы кирмән диварлары төзелә, манараларының унысы капкалы була. Капкалы 3 манара Болак аръягында




**Казан посады мәкаләсенә. 17 йөз–18 йөз башы.** План-схема (А. Сацыпёров планы буенча): I. Кремль. II. Посад. Посадның капкалы манаралары һәм капкалар: 1 — Пятницкий, 2 — Ярыклы капка, 3 — Арча, 4 — Воскресение, 5 — Проломный, 6 — Болак күпере капкасы, 7 — Варлаам, 8 — Ямчылар, 9 — Илья (Мокрый), 10 — Болак өстендәге, 11 — Яшерен. Посадның капкасыз манаралары: 12 — Алты почмаклы, 13 — Сигез почмаклы, 14 — Богоявление-Калитошный, 15 — Ярославль; 16 — Кремль ерымы; 17 — Мунча күле (Югары Черек күл), 18 — Черек, 19 — Ак, 20 — Түбән Черек, 21 — Гузиев, 22 — Чыпта күлләре; 23 — посад ерымы; 24 — Паннар бистәсе; 25 — Никола кызлар, 26 — Иоанн-Предтеча, 27 — Казан Богородица, 28 — Фёдор монастырьлары; 29 — Параскева Пятница, 30 — Никола Тульский, 31 — Покров, 32 — Воскресение, 33 — Крестовоздвижение, 34 — Петропавел, 35 — Богоявление, 36 — Вознесение, 37 — Мәскәү могҗиза тудыручылары, 38 — Никола-Вешняковский, 39 — Владимир-Богородица, 40 — Покров (Никола Низский), 41 — Никола-Ляпунов, 42 — Успение, 43 — Иоаким һәм Анна, 44 — Борис һәм Глеб, 45 — Ярославль могҗиза тудыручылары, 46 — Никола-Гостиный чиркәүләре; 46а — немец зираты; 47 — татар зираты; 48 — Татар күпере; 49 — Гостиный двор.

урнаша. Посадта берничә бистә үсеп чыга. Анда Воскресение, Воздвижение, Никола-Гостиный, Никола Тульский, Покров чиркәүләре барлыкка килә.

17 йөз уртасында, 1646 елгы көчле янгыннан соң, К.п. киңәйтелә һәм 25 манаралы агач диварлар б-н әйләндереп алына. Посад дивары Кремль калкулыгының көньяк читендәге Воскресение таучыгын, ш.у. Ярославль могҗиза тудыручылары чиркәве белән Болак тамагы икегә бүленгән җирдәге калкулыкның көнбатыш битен колачлый. Посадтагы 25 манараның 9 ы — Пятницкий, Арча, Воскресение, Проломный, Варлаам (әүвәлге Татар), Ямчылар, Илья, «Болак өстендәге» (төньяк-көнбатыш) манаралары һәм Яшерен манара капкалы була. Посад диварларына манарасыз ике капка: Ярыклы һәм Болак өстендәге (көньяк-көнчыгыш) капкалар уела. Посадта барлыгы 11 үтеп йөрү манарасы төзелә. Калган капкасыз манараларның 2 се Ярославль һәм Ян капкалы Богоявление исемнәрен йөртә. Соңгы манараны 17 йөз уртасында төзелгән Богоявление чиркәве янында ян капка булганга шулай атаганнар. Елдан-ел арта барган монастырьлар һәм чиркәүләр шәһәрне барлыкка китерүдә мөһим роль уйныйлар. Иоанн-Предтеча, Никола-Ляпунов чиркәве б-н Никола кызлар һәм Богородица монастырьлары нык кирпеч диварлар б-н әйләндереп алына. Агач чиркәүләрне кирпечтән үзгәртеп кора башлыйлар. Посадтагы агач төзелешләр арасында күбрәк Ярославль могҗиза тудыручылары, Никола-Гостиный, Богоявление, Крестовоздвижение, Покров, Иоаким һәм Анна, Никола Тульский, Параскева Пятница һәм башка чиркәүләр аерылып тора.

18 йөз башында Кремльнең Спас манарасы каршында адм.-сәүдә мәйданы барлыкка килә, анда үтү өчен ерым аша таш күпер салына. Мәйданның Кремльгә каршы ягында таш койма б-н әйләндереп алынган төрмә урын ала. Төрмәнең төньяк почмагы каршында гарнизон канцеляриясе, төрмә артында — калкулык өстендә таштан Гостиный двор, аның көнбатыш ягында Никола-Гостиный чиркәве төзелә. Коймәләр бушатылган Болактан сәүдә үзәгенә таба калкулык сөзәклеге буйлап кечкенә урамнар, тыкрыклар сузылып китә. Посадта Борисоглебский, Олы Успение, Владимирский, Арча урамнары аерылып тора. Посадтагы төрмә диварлары Болакны ике тапкыр: Кабан күленнән агып чыккан урында һәм елга тамагының көньягында кисеп үтә. Болак буйлап көньякка, Кабан күленә таба, посад чикләреннән өч агач күпер астыннан көймәдә үтәргә мөмкин. Аларның Ямчылар капкасы каршындагы беренчесе — Владимир, өченчесе — Татар күпере дип атала. Посадның төньяк өлешендә Покров, Крестовоздвижение чиркәүләре, Казан Богородица монастыре һәм Никола Тульский чиркәве урнаша. Кирмән диварлары һәм тар чокыр арасында Куликов бистәсе үсеп чыга. 18 йөз башында әүвәлге бистәләр нигезендә үз исемнәре булган, уртак урам һәм тыкрыклар системасыннан торган посад корыла башлый. Казанның ул чор план-схемаларында посадтагы бистәләр төшерелмәгән. Посад диварлары тышында, көньяк-көнбатыш һәм көньякта, шәһәр тирәсендәге уйсу җирдә ярымбоҗра ясап Мокрый, Рогожин, Бутырский, Ямчылар, Сотенный, Паннар (Панский) исемле Болак арты бистәләре үсеп чыга. Болак елгасының уңъяк ярында, Паннар бистәсе каршында, гаять зур Кирпеччеләр бистәсе урнаша. Проломный һәм ян капкалы Богоявление манаралары аша үткән юллар шушы бистәгә чыга. Кирпеччеләр бистәсеннән көньякта, Кабан күленең уң ягында — Гавриил һәм Постаучылар бистәләре, Кабан күленең сулъяк ярында — Татар бистәсе барлыкка килә. Посад диварларын уратып һәм торак төзелешләрен уртада калдырып, Проломный капкасы янынннан төньякка һәм төньяк-көнбатышка таба озын һәм тирән коры

елга сузылып китә. Елганың төбеннән Красный бистәсенә һәм Арча кырына илтүче юл уза. Красный бистәсенең көнбатышында — Патша һәм губернаторның шәһәр яңы сарайлары, төньякта Фёдор монастыре б-н Югары Фёдор бистәсе, Казансуның текә яры астында Түбән Фёдор бистәсе урнаша. 16 йөз ахыры — 18 йөз башында посадның элек немец зираты урнашкан төньяк дивары буенда Засыпкино бистәсе булган. Торак йортлар арасында (күбесенчә агачтан) барокко чалымнары да булган рус бизәү стилендәге таш чиркәүләр калкып чыга. Посадтагы Кремль калкулыгы сырты Никола-Гостиный, Петропавел, Воскресение чиркәүләренең биеклеген ассызыклап торган. 1729 елда саклану әһәмиятен югалткан һәм тузган посад диварлары сүтелә. Посад корылмалары бистә төзелешләре б-н кушыла һәм Казан тоташ фәзаи план-структуралы шәһәр йөзен ала. Рәсеме *Шәһәр төзелеше* мәкаләсендә.

*Әд.:* Калинин Н.Ф. Казань XVIII века (по неизданным картографическим и иконографическим материалам) // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1929. Т. 34, вып. 3/4; Саначин С.П. Эволюция планировки и застройки Воскресенского увала // Казанский посад в прошлом и настоящем. К., 2002.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КАЗА́Н ПОСТА́У МАНУФАКТУ́РАСЫ**, 1714 елда император Пётр I нең Россиядә йон мануфактуралары булдыру турындагы фәрманы нигезендә оештырыла. 1719 да ул 16,9 мең аршын постау тукыма җитештерә, анда 208 кеше эшли, 13 станок була. Шуннан соңгы елларда җитештерү кими, 1724 тә К.п.м. сәүдәгәр И.А.*Михляев* һәм аның ширкәттәшләре — сәүдәгәрләр Б.Пушников, О.Твердышев, М.Иванов, В.Издеберскийлар карамагына бирелә. 1742, 1749 еллардагы янгыннан соң яңа хуҗа И.Ф.Дряблов җитештерү биналарын яңадан төзи. 18 йөз уртасында ул иркен ишегалды периметры буйлап урнашкан берничә бер катлы бинадан тора. 1753 тә төзелгән, гөмбәзле, ун метр биеклектәге, баганасыз түбәле үзенчәлекле бина — 18 йөз уртасы сәнәгать архит-расы истәлеге, ул бүген дә саклана. И.Ф.Дрябловтан соң хуҗа булган сәүдәгәр *Осокиннар* 1816 да пр-тиене яңартып коралар. Анда крепостнойлар хезмәте кулланыла. 1760 елга постау җитештерү 140 мең аршынга җитә. 18 йөз ахырында җитештерү кими, әмма 19 йөз башында үсә башлый (елына 65 мең аршыннан 128 меңгә кадәр). 1812 елгы Ватан сугышы тәмамлангач, казна заказлары нык кимү сәбәпле, җитештерү янә кими. Пр-тие 1881 гә кадәр эшли. Ш.у.к. *Казан постаучылары чуалышлары*, *Постаучылар бистәсе*.

*Әд.:* Из истории Казанской суконной мануфактуры // История пролетариата СССР. М., 1933. Сб. 4(16); Калинин Н.Ф. Казань. К., 1955; История Казани. К., 1988. Кн. 1; Бессонова Т.В. Казанская суконная слобода в XVIII — первой половине XIX вв. Наб. Челны, 2000.

*А.Х.Мәхмутова.*

**КАЗА́Н ПОСТАУЧЫЛАРЫ́ ЧУАЛЫШЛАРЫ́**, *Казан постау мануфактурасы* эшчеләренең 18 йөздә — 19 йөз башында крепостной тәртипләргә каршы чыгышлары. Һөнәри мәнфәгатьләрен кысу (озын эш көне, түбән хезмәт хакы, эшләп чыгару нормасын арттыру, штрафлар һ.б.) һәм 1736 елгы Фәрманнан соң эшчеләрне мануфактураларга беркетү нәтиҗәсендә хокуксыз хәлдә калдыру постаучыларда ризасызлык тудыра.

1737–42 еллардагы чуалышлар тукучыларның (140 кеше) губерна канцеляриясенә мануфактура хуҗасы Афанасий Дрябловка карата шикаять б-н мөрәҗәгать итүеннән башлана. Анда, постауның киңлеге 50 җепкә артуга карамастан, аларга бер аршын постау өчен 6 тиен урынына 5 тиен түләүләре турында әйтелә. Өстәвенә эшчеләрнең хезмәт хакыннан инструментлар, йон калдыклары һ.б. өчен дә тотып калалар.

Җавап итеп, Дряблов үз эшчеләрен «артык оятсызлыкта» гаепли. Хакимиятләр башлап йөрүче 10 кешене кулга алалар. Ризасызлык белдереп, эшчеләр 2 атна эшкә чыкмыйлар. Соңрак императрица Анна Иоанновнадан яклау табарга тырышалар: 1737 елның июнендә эшчеләр Я.Андреев, Г.Васильев,



Казан постаучылары патша Николай I гә шикаять гаризасы тапшыралар. Рәссам И.И. Князьков. 1936 ел тирәсе.

Ф.Ежов, Е.Петров аңа үтенеч җибәрәләр. 1738 нең мартында Коммерц-коллегия Казан губерна канцеляриясенә башлап йөрүчеләрне һәм Дряблов әйткән башка кешеләрне сөргенгә сөрергә боера. Шуннан соң башбаштаклык көчәя: постаучыларны җәзага тарталар, башка эшләрдә эшләтәләр, каторгага җибәрәләр. 1738–40 та 21 кеше сөрелә, 1 кеше солдатка бирелә. Постаучылар көрәшне туктатмыйлар һәм 1740 та Коммерц-коллегиягә яңа шикаять җибәрәләр. Постауның армиягә кирәклеген аңлаган Коммерц-коллегия ташламалар ясый. Дрябловка, үтенечләрне караганга кадәр, эшчеләргә бер аршын постау тукыган өчен 6 тиен түләргә куша. Уңышка ирешкән эшчеләр үзләренең барлык гозерләрен үтәүне таләп итәләр. Чыгышлары 1741 елда иң югары ноктасына җитә. Алар берничә ай эшкә чыкмыйлар. 16 һәм 20 февральдә эшчеләрнең Дрябловларга һәм аның администрациясенә карата ризасызлык белдергән җыелышлары уза. 21 февральдә Постаучылар бистәсенең 1000 ләп кешесе, губерна канцеляриясе бинасы янында җыелып, үз эшләрен тизрәк карауны таләп итә. Март аенда майор Гаринның бистәгә җибәрелгән хәрби командасы бер төркем тукучыны эшкә чыгарга мәҗбүр итә. Әмма аларны тәмам буйсындыра алмыйлар, һәм 21 мартта Дряблов Коммерц-коллегиягә, «фабрика соңгы тукталышка килеп терәлде», дип хәбәр итә.

1742 елда Сенат, Казан постаучыларының шикаятен тикшереп, Дрябловтан алар файдасына 15584 сум акча түләтү, бер аршын постау суккан өчен түләүне 6 тиенгә кадәр арттыру, сөрелгән эшчеләрне кире кайтарту турында карар кабул итә. Ләкин Дряблов Сенат карарын үтәргә ашыкмый: эшчеләргә бары тик 1375 сум гына түләнә, сөргеннән кайтканнар фабрикага эшкә алынмый. Берничә дистә эшчене Дряблов солдатка бирә, каторга эшләренә җибәрә, аңа карата булган күпләгән шикаятьләр җавапсыз кала. Башбаштаклыкка каршы көрәш мануфактураны Дрябловлардан кабул итеп алган Осокиннар заманында да дәвам итә. 1796 да постаучылар сенатор Мавринга хезмәт хакының азлыгына (иң оста эшчеләр айга — 5 сум, калганнары 90 тиен ала) зарланалар, хатыннарын һәм балаларын фабрикада эшләүдән азат итүне сорыйлар. Тикшерү өчен Сенат шикаятьне Коммерц-коллегиягә юллый. Нәтиҗәдә мануфактура хуҗасы эшчеләргә җан башыннан түләүне үз өстенә ала һәм хезмәт хакларын бик азга гына күтәрә (барлык чыгымнар 5 мең сум тәшкил итә). Шул ук вакытта Коммерц-коллегия Казан гражданлык губернаторы Д.С.Казинскийга постаучыларның хәлен ачыклауны һәм аларның хезмәт хакы турындагы фикерләрен язып җибәрүен сорап мөрәҗәгать итә. Казинский постаучыларны хәрбиләрне йортка кертүдән, рекрутлык һәм шәһәр йөкләмәләреннән азат итү турында тәкъдим ясый. Әмма Мануфактур-коллегия гамәлдәге законнарны бозып булмый, моны эшләү мөмкин түгел, дип таба. 1799 да постаучы Шадрин аша император Павел I гә мануфактура хуҗасы һәм идарәчесе өстеннән шикаять җибәрелә, анда «гаиләләрне эшләтеп интектерүләре», эш өчен бик аз түләүләре, каты җәзалары, «фабрикантлар вотчинасы өчен» ф-ка эшчеләре исәбеннән рекрутлыкка бирүләре турында әйтелә. Шикаять Мануфактур-коллегия тарафыннан нигезсез дип табыла. Шуннан соңгы (1800 нең октябре) шикаятьтә, мануфактура хуҗасы хезмәт хакына өстәмә түләмәде («гәрчә ул кәгазьдә күренсә дә»), дип раслана. Постаучылар идарәче Плаксинга карата бирелгән шикаятькә губернатор Казинскийның игътибар итмәвен искәртәләр, 14 гаиләне Иркутск губернасына җибәрергә җыенуга, законсыз-нигезсез рекрутлыкка бирүләргә һ.б.га карата ризасызлык белдерәләр. Алар «үзләренең кемгә буйсынулары — төгәл алпавыт һәм фабрикант Осокингамы, әллә дәүләт крәстияннәре хәлендәме икәнлеге турындагы шикләнүләрен хәл итүне», хезмәт хакын арттыруны, Плаксинны «мануфактурадан алып ташлауны» сорыйлар. 1802 елның июнендә Мануфактур-коллегия, Казанга шикаятьне тикшерергә җибәрелгән комиссия нәтиҗәләренә таянып, аны «нигезсез» дип таба, киләчәктә андый «ялган» шикаятьләрдән тыелуны, «буйсынучанлык күрсәтүне» һәм әлеге таләпләр б-н ризалашуны язмача раслауны таләп итә. Шулай булмаганда, 1736 елгы Фәрман нигезендә постаучыларны «ерак шәһәр-

ләргә яисә Камчаткага эшкә җибәрү белән» яныйлар. Янауларга карамастан, 5 кенә кеше буйсынырга язма рәвештә ризалык бирә. 1803–06 елларда Казан постаучылары даими рәвештә баш күтәрәләр, нәтиҗәдә еллык җитештерүне 80 аршынга кадәр киметүгә һәм үзләре дошман күргән 8 оста ярдәмчесен һәм 1 останы кудыртуга ирешәләр. Хәлнең начарлануы яңа шикаять тудыра, аның б-н 1813 нең гыйнварында император Александр I гә постаучылар Ф.Агапов, И.Енгурин, М.Калашников, Ф.Курятников, Н.Нештин, И.Толмачёв мөрәҗәгать итәләр. Үтенеч җавапсыз кала. Посессион ф-каларның дәүләткә постауны даими бирүенең туктатылуы чуалышларның көчәюенә китерә. Постаучылар үз хәлләренең яхшыруына һәм мануфактура хуҗаларының закон нигезендә эш итмәүләреннән котылуга өметләнәләр. Ләкин администрация эш тәртибенә контрольне көчәйтә, эшчеләрдән берсүзсез буйсыну турындагы документка кул куюны таләп итә. Постаучылар вәкилләре Ф.Курятников б-н И.Хлебников администрация таләпләренә буйсынмаган өчен судка бирелә. Эшчеләр тагын, ш.и. 1817 елда, бөек кенәз Михаил Павловичка шикаять б-н мөрәҗәгать итәләр. Үз зарларын бәян итеп (аз хезмәт хакы, каты җәзалаулар һәм кыерсытулар), алар ирек алуга хаклыбыз, дип белдерәләр. 1820 дә Казан губернасында ревизия үткәргән сенаторлар С.С.Кушников б-н П.Л.Сантига шикаять тапшыралар. Постаучыларның каршылыгын бастырырга тырышып, мануфактура администрациясе һәм җирле хакимият аларның башлыклары Соколов б-н Ефремовны төрмәдә рәхимсез төстә кыйныйлар, башкаларын Себергә сөрәләр. Әмма эшчеләр, нык торып, үзләрен «ирекле», крепостнойлыкта яшәүләрен законсыз дип белдерәләр. Чыгыш ясарга әзерләнәләр, эштән баш тарту һәм хуҗага буйсынмау турында кул куюны оештыралар. Ләкин бу эш ачыла, аның башлап йөрүчеләре (И.Зубарев, Г.Мясников, Г.Недорезов, В.Павлов, И.Скудин һ.б.) 1825 елда камчы б-н суктырыла һәм Себергә озатыла.

Көрәшне дәвам иттереп, 1830 елларда постаучылар үзләрен «коллык изүеннән» азат итүне таләп итәләр, «ирек эзләүдән туктамаячакбыз», дип белдерәләр. 1836 ның августында аларның 1000 ләп вәкиле Казанга килгән Николай I гә шикаять тапшыру өчен Арча кырына җыела. Николай I аны кагарга, әмма ул ялган булса, җәзага тартырга вәгъдә итә. 1837 нең гыйнварында постаучылар җәзага тартыла. Җәзалау өчен 2 рота солдат һәм ярты рота Урал казагы килә. Эшчеләрдән тулысынча буйсыну турында кәгазьгә кул куюны таләп итәләр, ләкин эшчеләр баш тарта. Постаучыларны берничә сәгать дәвамында рәхимсез төстә җәзалыйлар. Меңнәрчә тапкыр чыбык б-н суктырылуларына карамастан, эшчеләр М.Г.Ефремов, Я.С.Добрынин, И.М.Скорняков, Н.А.Костров, В.Л.Шапкин һ.б. кул куймыйлар. Җәзалаганнан соң, эшчеләрнең кайберләрен Себергә сөрәләр, икенчеләрен солдатка бирәләр. Казан постаучылары һәм башка губерна эшчеләренең ныклы көрәше хөкүмәтне 1840 елда посессион эшчеләр ин-тын бетерергә мәҗбүр итә. 1849 да, Казанда әлеге Указ гамәлгә ашырылгач, постаучыларның иң зур күпчелеге шәһәрнең мещаннар катлавына язылар, кайберләре дәүләт крәстияннәре була.

*Әд.:* Ч е р н ы ш ё в Е. Из истории рабочего движения в России в XVIII в.: Борьба казанских суконщиков // Тр. Дома татарской культуры. 1930. Т. 1; Из истории Казанской суконной мануфактуры // История пролетариата СССР. М., 1933. Сб. 4(16); К а л и н и н Н.Ф. Казань. К., 1955; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КАЗА́Н ПО́ЧТА-ТЕЛЕГРА́Ф О́КРУГЫ**, к. *Почта-телеграф округы.*

**«КАЗА́Н ПРОМСТРОЙПРОЕ́КТ»**, проектлау институты. 1969 елда тимер-бетон конструкцияләрне җыю, эре панельле йортлар төзү, юл һәм төзелеш машиналарын ремонтлау з-длары һ.б. төзелеш индустриясе объектларында проектлау-смета документларын эшләү өчен «Гипронефтестрой» дәүләт проектлау ин-тының комплексы проектлаштыру бүлеге буларак Казанда нигез салына. 1987 дә Казан ф-лы итеп үзгәртелә, 1988 дә аның җирлегендә «К.п.» оештырыла; 1993 тән — АҖ. Эшләүчеләр саны — 111 кеше (2010). Төп эшчәнлеге: төзелеш индустриясе пр-тиеләрен һәм объектларын, торак, авыл, автотранспорт биналарын һәм гражданлык корылмаларын комплексы проектлаштыру; шәһәр төзелеше документларын эшләү; инженерлык системаларын һәм челтәрләрен проектлаштыру; инженерлык-геодезия; инженерлык-геология эзләнүләр алып бару б-н бәйләнгән.

**КАЗА́Н ПРОТЕ́З-ОРТОПЕДИ́Я ПРЕДПРИЯ́ТИЕСЕ**, мед. сәнәгате пр-тиесе, илдә иң эреләрдән берсе. Эшләүчеләр саны — 100 дән артык кеше (2011). 1916 елда гарипләнгән сугышчыларның протез остаханәсе буларак нигезләнә. 1919 да национализацияләнә. 1945 тән Казан протез з-ды башта — Варвара чиркәве бинасында, 1960 тан махсус төзелгән бинада урнаша. 1962 дә Йошкар-Ола шәһәрендәге протез з-дын да үз эченә алган ҖБнең төп пр-тиесенә әверелә. 1992 дән хәзерге исемдә, 2003 тән федераль дәүләт унитар пр-тиесе. Составына җитештерү бүлеге (ортопедик аяк киемнәре һәм протез ясау цехлары), мед. бүлеге, катлаулы протезлау өчен 25 урынлы стационар керә, Чаллы шәһәрендә ф-лы бар. Өске һәм аскы очлыклар, күкрәк бизләре протезлары, зарарланган очлыкларны беркетү өчен аппаратлар, туторлар (индивидуаль каты шиннар), ортопедик аяк киемнәре: елга 15 меңләп протез һәм 8,5 мең пар аяк киеме ясый. 1990 еллар башыннан җитештерүдә «Энергия» ракета-космос корпорациясе (Мәскәү өлкәсенең Королёв ш.), «Отто-Бокк» фирмасы (ГФР) тарафыннан эшләнгән технологияләр, җиһазлар, чимал, комплектлау модульләре, узеллар һәм детальләр кулланыла. 2000 дә Россиядә беренче буларак пр-тиедә бала өчен электрон кул протезы эшләнә. Төп заказчы — ТРның Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы, ш.у. күрше төбәкләргә хезмәт күрсәтелә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә РФнең атказ. социаль тәэминат хезмәткәре исеме бирелә; 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 1 кеше «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. Төрле елларда пр-тие б-н З.А.Мифтахов, П.П.Мамаков, З.И.Маслова, В.Т.Урусов, Р.З.Мөхәрәмов, Б.П.Бетеев җитәкчелек итә.

**КАЗА́Н РА́ДИО КАБУ́Л ИТУ́-ТАПШЫРУ́ СТА́НЦИЯСЕ**, даими эшен 1918 елның 20 мартында башлап җибәрә. Почталар һәм телеграфлар халык комис-ты 1918 нең башыннан рәсми радиотапшыруларның радиотелеграф челтәрен төзүгә керешә, текстларны Морзе әлифбасы буенча губерна һәм өяз шәһәрләре радиостанцияләре Царское Село һәм Ходынь радиостанцияләреннән (Беренче бөтендөнья сугышы елларында союздаш илләр: Англия, Франция һәм Италия б-н элемтә өчен Петроград һәм Мәскәү янында төзеләләр) кабул итеп ала. Радио кабул итү җайланмаларының сугыш чоры запаслары файдаланыла, аларга армиядән һәм флоттан кайткан радистлар хезмәт күрсәтә. К.р.к.и.-т.с. Грузинская урамындагы (хәзер К.Маркс ур., 36) почта-телеграф конторасы бинасында урнаша; беренче җитәкчесе булып радио белгече М.И.Петухов эшли. Радиостанция Мәскәүдән җирле хакимият органнары өчен күрсәтмәләр, ш.у. илдәге һәм чит илләрдәге әһәмиятле вакыйгалар турында хәбәрләр кабул итә. Россия телеграф агентлыгы (1918 дә төзелә) радиодан даими тапшырулар өчен мәгълүмат җыя. Бу хәбәрләр ш.у. җирле газеталарда басыла, халык арасында популяр булган плакатлар рәвешендә элеп куела. Радиохәбәрләрне өязләр буенча тарату өчен губерна эчендә эшли торган телеграф һәм телефон челтәре аша тапшыралар. 1918–21 дә Тәтеш, Спас, Бөгелмә, Минзәлә, Чистай, Буа, Алабуга, Лаеш шәһәрләрендә, Биләр авылында радио кабул итү станцияләре булдырыла; 1921 нең октябренә Татарстанда 17 радиостанция эшли. Мәгълүмат өяз һәм волость советларының башкарма ком-тларына тапшырыла, алар аны халык арасында рус һәм татар телләрендә тараталар. 1923 нең июлендә күмәк кулланулы радио кабул итү станцияләрен дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында куюга рөхсәт бирелә. СССР ХКСның «Шәхси радио кабул итү станцияләре турында»гы 1924 ел 28 июль карары буенча аерым затларга да радио кабул иткечләр кую мөмкин була. 1930 еллар ахырында Татарстанда радиоэлемтә кыска радиодулкыннар диапазонын куллануга күчә, яңа радиоаппаратура (илдә җитештерелгән) куела, Мәскәү, ш.у. илнең күп кенә сәнәгать һәм мәдәният үзәкләре б-н тотрыклы радиоэлемтә урнаштырыла. К. *Татар радио-телевидение тапшырулар үзәге.*

**КАЗА́Н РАДИОСПЕКТРОСКОПИ́Я ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, Казан ун-тында 1944 елда Е.К.*Завойский* тарафыннан *электрон парамагнит резонансы* (ЭПР) күренеше ачылу нигезендә формалаша. Шул вакыттан башлап Казан физикларының фәнни программаларында магнит резонансы өлкәсендәге тикшеренүләр әйдәп баручы урынны ала. Мәктәпнең формалашуына 1945 елда СССР

ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-ты төзелү (физика секторы мөдире — Е.К.Завойский, 1947 дән — ул Мәскәүгә күчеп киткәннән соң — Б.М.Козырев), 1957 дә Казан ун-тының физика ф-тында С.А.Альтшулерның квант электроникасының перспективалы эшче матдәләрен эзләү өчен магнит радиоспектроскопиясе лаб-ясе ачуы һәм 1963 тә квант электроникасы һәм радиоспектроскопия кафедрасы (мөдире — Максут М. Зарипов) ачылу ярдәм итә. Казан ун-ты магнит радиоспектроскопиясе өлкәсендә белгечләр әзерләү буенча СССРдагы төп үзәккә әверелә. К.р.ф.м. формалашуга С.А.Альтшулерның шәһәр магнит семинары һәм «Парамагнит резонансы» («Парамагнитный резонанс») җыентыгының даими чыгарылышы (1–25 чыгарылыш 1960–92: 1960–83 тә — С.А.Альтшулер, 1983 тән Б.И.Кочелаев редакциясендә) зур йогынты ясый. ЭПР үсешендә С.А.Альтшулер һәм Б.М.Козыревның «Электрон парамагнит резонансы» («Электронный парамагнитный резонанс», М., 1961) монографиясе мөһим роль уйный, физиканың бу өлкәсендә ул хезмәт беренчеләрдән була һәм соңыннан өстәмәләр б-н кабат бастырып чыгарыла.

Казанда ЭПРның күп кенә махсус методикалары үсеш ала, магнит резонансының кулланылыш өлкәсен күпкә киңәйтә торган җайланмалар төзелә. Алар арасында — СССРда беренче төш спины кайтавызы сигналларын өйрәнү җайланмасы (В.Д.Корепанов, Р.А.Даутов, В.М.Фадеев, 1959), икеләтелгән электрон-төш резонансы спектрометры (Ю.Е.Польский һ.б., 1969), ЭПРның лазерлы поляриметрик спектрометры һәм ионнарның ЭПР спектрларын ярсынган халәтләрендә җылылык импульслары ярдәмендә теркәү методикасы (А.А.Антипин һ.б., 1981), ЭПРны оптик детекторлау җайланмасы (М.Л.Фалин, К.И.Герасимов, 1998). Төш-магнит һәм төшквадруполь резонансларны (ТМР, ТКР) өйрәнү өчен берничә милликельвин төгәллеккә кадәрле уникаль җайланма (М.А.Теплов, А.Г.Володин, М.С.Таһиров, А.В.Егоров, О.Н.Бахарев), магнит кыры градиенты 500 *Тл/м* га кадәр булган импульслы уникаль ТМР спектрометры (Г.Г.Пименов, В.Д.Скирда һ.б.) конструкцияләнә һәм эшләнә, соңгысының аналоглары соңрак төрле фәнни һәм укыту учреждениеләре өчен дә төзелә. ЭПР алымнарын ешлык, фәза һәм вакыт буенча куллану өлкәләре киңәя. Субмиллиметрлар диапазонындагы (65 тән 535 *ГГц* ка кадәр) ешлык буенча көйләнә торган уникаль ЭПР спектрометр (В.Ф.Тарасов һ.б., 1991) һәм тиз уза торган процессларны өйрәнү өчен 80 *нс* вакыт аралыгын билгеләргә сәләтле ЭПР-спектрометр (2002) төзелә. ЭПР-томография юлы б-н беренче тапкыр үткәрүчән объектлардагы скан-катламның сурәте алына (К.М.Салихов һ.б.). Диагноз кую өчен магнит-резонанслы томографлар эшләнә (беренчеләре 1997 елда Казан һәм 2002 дә Чаллы хастаханәләрендә урнаштырыла). К.р.ф.м. галимнәре тарафыннан түбәндәге юнәлешләрдә фундаменталь нәтиҗәләр алына:

**Парамагнитик релаксация**. Сирәк мәгъдән элементлары тозларында беренче тапкыр спин-рәшәткәле релаксация вакытлары исәпләнелә (С.А.Альтшулер, 1953), сыеклыкның парамагнитик релаксациясе механизмы (С.А.Альтшулер, К.Ә.Вәлиев, 1958) һәм *Орбах-Әминов процессы* исемен алган спин-рәшәткәле релаксация механизмы (Л.К.Әминов, 1962) тәкъдим ителә. 1960 еллар уртасыннан релаксацияне үлчәүнең экспериментал резонанслы алымнары үсеш ала (Л.Я.Шекун һ.б.). ЭПР сызыгы очын импульслы туендыру вакытында фононнар системасының артык кызуын һәм фононнар ташкыны барлыкка килүне тәҗрибәдә күзәтү (С.А.Альтшулер, Р.М.Вәлишев, А.Х.Хәсәнов, 1971) һәм бу күренешнең теориясен төзү (Б.И.Кочелаев, Р.Г.Дәминов һ.б.) аеруча зур казанышлар булып санала.

**ЭПР диэлектрик кристалларда**. 1946 елда Е.К.Завойский, тышкы магнит кыры нуль булганда, энергиянең спин дәрәҗәләре таркалуның ЭПРга тәэсир итүен ача һәм бу ачыш ЭПР спектрларының нечкә һәм үтә нечкә структураларын тикшерүгә нигез сала. Казан галимнәренең бу өлкәдәге казанышлары арасында — $^{57}Fe$ изотобы төшенең спины зурлыгын билгеләү (Б.М.Козырев, Н.С.Гарифьянов, Максут М. Зарипов, 1957), рубин кристаллында ЭПР $Cr^{37}$ спектрын ачыклап аңлату, соңыннан бу ачыш мазерлар һәм лазерлар уйлап табуда зур роль уйный (Максут М. Зарипов, Ю.Я.Шамонин, 1956), төрле кристалларда тимер төркеме ионнарын (Максут М. Зарипов, В.А.Уланов һ.б.) һәм сирәк мәгъдән ионнарын (Л.Я.Шекун һ.б.) өйрәнү, рентген нурланышы йогынтысында хасил булган ЭПР-үзәкләрен (парлашмаган s-электронлы) өйрәнү (В.Г.Степанов һ.б.). ЭПР тышкы электр кырларында һәм югары басым астында тикшерелә (М.М.Заитов), тимер төркеме ионнарыннан кластерлары булган катлаулы нәорганик комплекслар өйрәнелә (Ю.В.Яблоков һ.б.). Алмаштыру кластерларын тикшерү нәтиҗәләре Ю.В.Яблоков, В.К.Воронкова, Л.В.Мосинаның «Алмаштыру кластерларының парамагнит резонансы» («Парамагнитный резонанс обменных кластеров», М., 1988) монографиясендә гомумиләштерелә. Парамагнитик үзәкләренең электрон төзелеше теориясе уңышлы үстерелеп килә (Б.З.Малкин, А.М.Леушин, М.В.Ерёмин һ.б.).

**Ван-Флек парамагнетикларында магнит резонансы**. Ван-Флек ионнарының үтә нечкә күчешләрендә магнит резонансын Максут М. Зарипов 1956 елда фаразлый һәм тимер төркеме ионнары төшләрендә (С.А.Альтшулер, В.Н.Ястребов, 1964) һәм сирәк җир ионнары төшләрендә (М.А.Теплов, 1967) ул эксперименталь күзәтелә. С.А.Альтшулер бу матдәләрне адиабатик магнитсызлау юлы б-н үтә түбән темп-ралар алу өчен кулланырга тәкъдим итә (1966). Бу өлкәдәге төп казанышлар: $PrF_3$ тә $^{141}Pr$ нең акустик төш резонансын беренче тапкыр күзәтү (С.А.Альтшулер, А.Х.Хәсәнов, М.А.Теплов һ.б., 1979), тулий этилсульфатындагы $^{169}Tm$ төшләре б-н сыек $^{3}He$ төшләре арасында магнитик резонанслы бәйләнешләр барлыгын ачыклау (М.С.Таһиров, М.А.Теплов, А.В.Егоров, Ф.Л.Әүхәдиев, 1984), TmES монокристаллында субмиллиметрлы ЭПР $Tm^{3+}$ күренешен беренче тапкыр күзәтү (М.С.Таһиров, Д.А.Таюрский, 1996).

**Металларда һәм үтә үткәргечләрдә ЭПР һәм ТМР**. С.А.Альтшулер һәм аның шәкертләре, дөньяда беренче булып, сирәк мәгъдән металларында ЭПР теориясе, ш.и. катышмаларда үткәргеч электроннарның парамагнитик релаксациясе (Н.С.Гарифьянов) теориясе буенча тикшеренүләр үткәрә. Бу өлкәдәге ачышлар: үтә үткәргечтә ЭПР (Т.С.Альтшулер, И.А.Гарифуллин, Э.Г.Харахашьян, 1972) һәм металлардагы үткәргеч электроннарда спин-электрон кайтавазы (Э.Г.Харахашьян һ.б., 1972) күренешләрен ачу, гадәти үтә үткәргечләрдәге ЭПР теориясен төзү (Б.И.Кочелаев, Л.Р.Таһиров, С.Л.Царевский һ.б.). Югары температуралы үтә үткәргечләрнең һәм аларның элгәр буын кушылмаларының магнитик һәм кинетик үзлекләре, ш.у. фазалар буенча катламнарга бүленүе буенча әһәмиятле нәтиҗәләр алына (И.А.Гарифуллин, Н.Н.Гарифьянов, Г.Б.Тейтельбаум, Б.И.Кочелаев, М.А.Теплов, М.В.Ерёмин, Л.Р.Таһиров һ.б.). Мультикатламлы ферромагнетик-үтә үткәргеч структураларында үтә үткәрүчәнлек б-н ферромагнитлылыкның үзара йогынтысы теориясе эшләнә, мондый структураларның принципиаль яңа типтагы микроэлектрон аппаратлар төзү өчен элементлар базасы булу мөмкинлеге күрсәтелә (И.А.Гарифуллин, Л.Р.Таһиров, М.Г.Хөсәенов, Ю.Н.Прошин һ.б.). Металларда үтәли магнит тишекләренең гомуми теориясе төзелә (Ю.Н.Прошин).

**Тәртипкә салынмаган һәм өлешчә тәртипкә салынган тирәлекләрдә радиоспектроскопия**. Беренче тапкыр үтә нечкә үзара тәэсирнең ирекле радикаллар ЭПРы спектрларына йогынтысы ачыла (С.А.Альтшулер, Б.М.Козырев, С.Г.Салихов, 1950). Сыек яки туңган эремәләрдә һәм пыялаларда металл ионнары гадәти булмаган дәрәҗәдә оксидлашкан катнашмаларны да кертеп, составында тимер төркеме, палладий, платина һәм сирәк мәгъдән элементлары ионнары булган комплексы катнашмаларны ЭПР-спектроскопик тикшерү алымы эшләнелә (Н.С.Гарифьянов, Б.М.Козырев, Б.М.Одинцов, Р.С.Абдрахманов һ.б.); эремәләрдәге электрон релаксациясе парамагнитик ионнарның электрон релаксациясе (ш.и. нәрезонанслы йотылуы) процесслары, ш.у. ионнары б-н алмашучы металл катнашкан полимерларның структур оешуы өйрәнелә (Мәхмүт М. Зарипов, Р.М.Юльметьев, Г.П.Вишневская, Б.М.Козырев һ.б.). Парамагнетиклар эремәләренең төзелеше һәм комплекслар барлыкка килү процесслары ТМР алымы б-н тикшерелә (А.И.Ривкинд һ.б.). Өлешчә тәртипкә салынган сыек кристаллы матрицаларда, ш.у. металл катнаш магнитлы сыек кристалларда (беренче тапкыр уйлап табылган) парамагнит комплексларын ЭПР ярдәмендә тикшерү алымы теоретик һәм эксперименталь яктан

үстерелә (И.В.Овчинников, Ю.Г.Галләметдинов һ.б.).

Порошокларда, эремә һәм пыялаларда ирекле радикалларның һәм күптөшле кушылмаларның ЭПР-спектроскопиясен үстерүгә зур өлеш кертелә (Ю.В.Яблоков һ.б.).

**Минералогиядә һәм геохимиядә ЭПР**. 1950 еллар уртасында Казан ун-тында галлоидлар, оксид, фосфат, силикатлар классына керүче минералларда катышмалар күплеген өйрәнүдә ЭПР алымын куллана һәм алынган нәтиҗәләрне минералогия, геология-геохимия мәсьәләләрен хәл итүдә файдалана башлыйлар (В.М.Винокуров, Максут М.Зарипов). Тимер төркеме һәм сирәк мәгъдән элементлары ионнарының изовалентлык һәм гетеровалентлык изоморфлыгы үзенчәлекләре беренче тапкыр 30 дан артык минералда һәм аларның синтетик аналогларында ачыклана. Алынган нәтиҗәләр күп кенә минералларның төсләрен аңлатырга һәм күпсанлы тау массивлары һәм чыганаклары барлыкка килүнең геохимик зоналарын билгеләргә мөмкинлек бирә (В.М.Винокуров, Н.М.Низаметдинов һ.б.). ТКР алымы б-н күп кенә минералларның структурасы өйрәнелә (И.Н.Пеньков), ТРның нефть чыганаклары ЭПР ярдәмендә төрләр составы; катышмалар һәм радиацияле ион-радикаллары буенча тикшерелә; продуктив ятмаларда хәрәкәтсез нефть аралыклары барлыгы ачыклана. Төптәге суларның борынгы һәм хәзерге биеклек зоналары билгеләнә, нефть һәм ярчен сулар б-н бергә чыгарып була торган, радиоактив элементларга бай горизонтлар табыла (В.М.Винокуров, Н.С.Гарифьянов).

**Ирекле радикалларда ЭПР**. Казанда ЭПР алымы б-н ирекле радикалларны ныклап өйрәнү Б.М.Козырев һәм С.Г.Салихов тарафыннан пентафенилциклопентандиенилда парамагнит резонансы сигналын табудан соң (1947) башлана. Беренче тапкыр кислородның һәм эреткечнең ирекле радикалларда ЭПР сызыгы киңлегенә тәэсире беленә (Н.С.Гарифьянов, А.В.Ильясов, Ю.В.Яблоков, 1958), ташкүмердә, пиролиз продуктларында (корымда), нефтьтә һәм табигый керннарда ЭПР сигналлары (Н.С.Гарифьянов, А.В.Ильясов, 1961) алына, ион-радикалларны һәм парамагнит комплексларын электрохимик генерацияләү методикасы тәкъдим ителә (А.В.Ильясов, 1965). Тәҗрибә юлы б-н фосфор төшләренең химик полярлашуы табыла (А.В.Ильясов, Я.А.Левин, 1970), фосфорорганик ирекле радикалларның һәм алар комплексларының күп төрләре өйрәнелә, бу кушылмаларның электрон структурасы үзенчәлекләре һәм әверелешләренең элементар адымнары ачыклана.

**Полимерларда ТМР**. 1963 елдан Казан ун-тында А.И.Маклаков җитәкчелегендә полимерларны ТМР алымнары б-н тикшерүләр башлана. Импульслы ТМР ярдәмендә күп кенә полимерларда молекуляр хәрәкәт, полимерларда кристаллашу процесслары, молекуляр хәрәкәтчәнлек, полимер системаларда фаза күчешләре өйрәнелә (В.Д.Скирда, Н.К.Двояшкин һ.б.); яңа теоретик алымнар эшләнә (Н.Ф.Фәтхуллин).

**Химиядә ТМР һәм ТКР**. Б.А.Арбузов тырышлыгы б-н Казан ун-тында (Й.Ю.Сәмитов, 1958) һәм СССР ФА Казан ф-лының Органик химия ин-тында (1965) ТМР ысулы ярдәмендә физик-химик тикшеренүләр башлана. СССРда беренче тапкыр ТМР-спектрометрлары төзелә (Й.Ю.Сәмитов, Т.В.Зыкова, А.В.Аганов һ.б.), молекулаларның фәзаи структурасы урнашуның теоретик һәм эксперименталь алымнары эшләнә (Й.Ю.Сәмитов, Р.М.Әминова, А.А.Мусина, А.В.Аганов, Т.В.Зыкова, Т.А.Зябликова, Ш.К.Латыйпов, Ф.Х.Каратаева һ.б.), селектив релаксация һәм ике үлчәнешле спектроскопия алымнарын куллануны да кертеп, молекуляр кабат төркемләнүләрнең кинетика һәм динамикалары тикшерелә (Й.Ю.Сәмитов, А.В.Аганов, В.В.Клочков һ.б.). Күпсанлы спектр-структур корреляцияләр төзелә. Беренче тапкыр биологик тукымаларда эрегән инерт газларның төшләрендә тикшеренүләр үткәрелә (Р.К.Мәҗитов, А.В.Ильясов һ.б.). ТКР мәгълүматлары буенча азот кушылмалары молекулаларында электроннар тыгызлыгы бүленеше, ТКР ешлыкларының һәм реакциягә керү сәләте константаларының корреляциясе билгеләнә (И.А.Сафин, Д.Я.Осокин һ.б.). И.А.Сафин һәм Д.Я.Осокинның «Азот кушылмаларында төш квадруполь резонансы» («Ядерный квадрупольный резонанс в соединениях азота», М., 1977) монографиясе бастырып чыгарыла.

**Магнит резонансы биологиядә һәм медицинада**. 1959 да СССР ФА Казан ф-лының Биология ин-тында ТМР алымы б-н биологик объектлардагы суның структур үзлекләре өйрәнелә башлый (Н.А.Мальцев). Соңга таба ике төп юнәлеш үсеш ала: аксымнарның структурасын, динамикасын һәм гидратациясен өйрәнү (В.Д.Федотов һ.б.); үсемлек тукымаларында суны күчерү (А.В.Анисимов һ.б.). Магнит кырының импульслы градиентлары булган ТМР һәм ЭПР алымнары биомедик системалардагы төрле процессларны тикшерүдә кулланыла (А.И.Маклаков, В.Д.Скирда, А.В.Аганов, А.В.Анисимов, Н.И.Силкин һ.б.). Фотосинтезның беренче стадияләрендә бүленгән корылмаларның теләсә нинди вакыт бүлемтегендәге ЭПР-спектроскопиясе теориясе үстерелә (К.М.Салихов). 1990 нан ТМР-томографияне гамәли медицинага кертү башлана (А.В.Ильясов), 1999 дан Казан ун-тында «медицина физикасы» белгечлеге буенча укыту алып барыла.

Казан галимнәренең радиоспектроскопия өлкәсендәге тикшеренүләре фәндә яңа юнәлешләр барлыкка килүгә һәм инде билгеле булган тамырдаш юнәлешләрнең: *акустик парамагнит резонансы*, *фотоннар кайтавазы*, Мессбауэр спектроскопиясенең уңышлы үсүенә ярдәм итә. Соңгысында Мессбауэр спектрларының үтә нечкә структурасын өйрәнү нигезендә, магнитлы кушылмаларның Кюри темп-расында фаза күчеше үзенчәлекләре тикшерелә, катлаулы ферромагнитик кушылмаларның магнит микроструктурасы тәҗрибәдә һәм теоретик яктан өйрәнелә (Ш.Ш.Башкиров, Э.К.Садыйков). Ш.Ш.Башкиров, А.Б.Либерман, В.И.Синявскийның «Ферритларның магнит микроструктурасы» («Магнитная микроструктура ферритов», 1978) монографиясе бастырып чыгарыла. Татарстандагы нефть ятмаларының коллектор-токымнары тикшерелә (Р.А.Маннапов).

Казанда магнит резонансы һәм тамырдаш күренешләрне өйрәнү һәм куллану өлкәсендәге соңгы казанышларга багышланган халыкара һәм бөтенроссия конференцияләре, ш.у. яшь галимнәр укулары даими рәвештә үткәрелә: «Структур тикшеренүләрдә ТМРның яңа казанышлары» (1990 нан), «Магнит резонансының хәзерге заман казанышлары» һәм «Магнит резонансы һәм аны кулланунның актуаль мәсьәләләре» (1991 дән), «Магнит-резонанслы томография һәм спектроскопия; фундаменталь тикшеренүләр, медицинада һәм биологиядә кулланылышы» (2001 дән), «Молекуляр системаларның структуралары һәм динамикасы» (1994 тән). ЭПР ачылуның 25, 50, 60 еллыклары уңаеннан юбилей конференцияләре фән дөньясында иң зур вакыйгаларга әверелә. 1990 нан инглиз телендә халыкара «Applied magnetic resonance» («Магнетик резонансны куллану») ж-лы нәшер ителә. ЭПР үсешендә аеруча зур хезмәтләр өчен *Завойский Е.К. исемендәге халыкара бүләк* (1991) һәм Казанның яшь галимнәре өчен эксперименталь һәм теоретик физикада һәм аны кулланудагы зур казанышлары өчен шул ук исемдәге бүләк (1997) булдырыла. Россиянең күп кенә танылган галимнәре К.р.ф.м.ндә тәрбия алган, шулардан Казанда гына да 60 тан артык галим профессор вазыйфасын башкара (2004). К.р.ф.м. галимнәренең фәнни кадрлар әзерләү өстендә максатчан эшләве фәнгә сәләтле яшьләр килүне тәэмин итә. 1978 елда Казан ун-тының физика ф-тында эшли башлаган физика һәм матем. түгәрәкләре соңрак хезмәткәрләр, аспирант, студентлар, мәктәп укучыларының ун-тның физика ф-ты каршындагы кече физика ф-ты рәвешендәге берләшмәсенә әверелә (1980). Берләшмәнең бурычлары булып мәктәп укучыларына физика-матем. буенча өстәмә белем бирү, алар арасында һөнәри юнәлеш бирү эше, олимпиадаларга әзерләү тора.

*Әд.:* Парамагнитный резонанс. Казанская школа радиоспектроскопии, 1944–1971 гг. М., 1974; Радиоспектроскопия конденсированных сред. М., 1990; Kochelaev B.I. Yablokov Y.V. The Beginning of Paramagnetic Resonance. World Scientific. Singapore-New Jersey–L.–Hong Kong, 1995.

*М.М.Зарипов, Б.И.Кочелаев, К.М.Салихов, Р.Г.Усманов.*

**КАЗА́Н РАДИОЭЛЕКТРО́НИКА ИНСТИТУТЫ́** радиоэлектрон системалар һәм информацион технологияләр буенча, 1949 елда 294 нче Казан авиация радиоаппаратурасы з-ды каршындагы тәҗрибә-конструкторлык бюросы (ОКБ) буларак төзелә. 1957 дә 294 нче тәҗрибә-конструкторлык бюросы (ОКБ), 1962 дә 334 нче фәнни-тикшеренү ин-ты, 1966 да — Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-ты, 1988 дә Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-ты итеп үзгәртелә; 1997 дән «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәге составында, 1998 дән

Федераль «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәге, 2000 нән В.И.Шимко исемендә. Фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең төп юнәлешләре — радиолокацион актив сорау һәм җавап системаларын (САЗО), ш.у. бу системага керүче самолётта, җир өстендә, корабльдә урнашкан аппаратура һәм үлчәү комплексларын эшләү, сынау һәм гамәлгә кертү. ОКБның беренче эше — самолётларны җир өсте маягы урнашкан төбәккә китерүче аппаратлар з-дында производствоны җайга салудан гыйбарәт («Протон» тәҗрибә-конструкторлык эше). «Протон» системасы пр-тиенең профилен һәм моннан соңгы проект эшләрен алдан билгеләүче буларак, илдә беренче радиолокацион САЗОларның берсе санала. Самолёт аппаратурасын конструкцияләгәндә эш һәм эксплуатацияләү шартлары, массасы, үлчәмнәре, кулланудагы ышанычлылыгы, эргономика, массакүләм җитештерүгә яраклылыгы буенча югары таләпләр куела, һәм бу җир өстендә, корабльләрдә урнаштырылган контроль-тикшерүләр һ.б. төрле махсус аппаратура эшләүне үстерүдә ярдәм итә. Модернизацияләнгән «Протон-М» системасында (баш конструкторы Б.А.Веселов) радиодулкыннарның ультракыска диапазоны, алмашынулы билгеле бер ешлык каналлары, сорау һәм җавап буенча вакыт-импульс кодлары кулланыла. «Протон-М» системасы транспорт һәм десант авиациясендә 20 елдан артык эшләтелә. 1950 елларда 294 нче з-дка телевизорлар чыгаруны үзләштерүдә ярдәм итү өчен ОКБда телевизион техника белгечләре коллективы оеша. Йомык телевизион системалар эшләнә: самолётларның алгы туплары өчен — «Зрачок» һәм аның модификацияләре (1958); «очып күтәрелү-утыру» тренажёры өчен — «Полоса» (1961); җиргә төшүнең соңгы стадиясендә пилотны ориентлаштыру өчен — «Посадка» (1961). 1959–61 дә ОКБда «Киловольт», «Киловольт-2», «Киловольт-60» темалары буенча югары вольтлы тоташтыргычлар эшләнә (баш конструкторы А.В.Канцевич) һәм алар күп кенә пр-тиеләрдә озак вакытлар файдаланыла; стратегик ракета очышы траекториясенең башлангыч өлешен тикшергәндә җавап алу өчен «Вымпел» җавап биргече (баш



Казан радиоэлектроника институты.
Радиоэлектрон системалар корпусы.





Казан радиоэлектроника институты.
1. Гибрид-интеграль схемалар цехы;
2. Микроблоклар җыю участогы.

конструктор Н.В.Швецов) төзелә. 1962 дән ин-т — махсус кулланылыштагы радиолокацион САЗОлар буенча илнең баш пр-тиесе.

Тәҗрибә-конструкторлык эшләрен (ОКР) «Радиоэлектроника» фәнни-тикшеренү үзәге коллективы җитәкчелегендә күп кенә фәнни-тикшеренү ин-тлары һәм махсус конструкторлык бюролары алып бара: сорау һәм җавап сигналларының структурасы билгеләнә; махсус эшләнгән методика нигезендә энергетик мөмкинлекләр исәпләнә, антенналар юнәлеше диаграммаларына, югары ешлыклы сигналларның параметрларына, сигналлар кабул итү һәм эшкәртүнең ихтималый характеристикаларына таләпләр куела, сигналларны эшкәртү нәтиҗәсендә карарлар кабул итү буенча импульслы логик җайланмага карата таләпләр аналитик юл б-н билгеләнә. Хәрби операцияләр вакытында гомуми зонада күпсанлы һәм төрле типтагы сорау биргеч һәм җавап алгычларның эшләү шартлары билгеләнә. Институт хезмәткәрләре 330 дан артык фәнни-тикшеренү эшен һәм 340 тәҗрибә-конструкторлык хезмәтен башкарып чыга (2004): почмаклар буенча югары аерымлау сәләтен тәэмин итү өчен миллиметр диапазонындагы дулкыннар куллану; радиолокацион саклау һәм төзәүнең авиация комплексы чараларын эшләү; атом су асты көймәләре өчен САЗО чараларын конструкцияләү; радиосигналлар алмашу б-н электрон идарә ачкычы; тәүлек саен автомат рәвештә радиосигналларның туры килүләрен (тикшерү); самолёт средстволарының берьюлы 2 антеннага эшләвен тәэмин итүче җайланмалар куллану һ.б.

Институт күзәтү астына алынган объектларны тану («үз-чит») чараларын эшли һәм чит илләргә чыгара (Көнбатыш стандартларына туры килә). Серияләп җитештерүне оештыруда илдәге министрлык һәм ведомстволарның 25 идарәсе катнаша, аппаратураны 14 завод чыгара, 53 пр-тие иярешле аппаратураны әзерли.

Яңа радиолокация системасын төзегәннәре өчен баш конструкторлар В.С.Рыжков, Л.М.Махтеев, Г.М.Клибанов, Ю.Г.Рәхмәтуллин Ленин бүләгенә лаек була (1978). Система чараларын файдалануга керткәне өчен ин-т Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1980), 265 хезмәткәр орден һәм медальләргә лаек була. Ген. конструктор И.Ш.*Мостюковка* һәм эшче П.К.Рожковка Соц. Хезмәт Герое исеме бирелә (1980). Баш конструкторлар А.Ф.Пироженко, В.Г.Данилов, Э.К.Әбелханов, С.Н.Медведев СССРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1983).

ОКБ башлыклары: В.А.Веселов (1949–55), Ю.И.Минайкин (1955–60), И.Ш.Мостюков (1960–62). Ин-тның директорлары, ген. конструкторлар: И.Ш.Мостюков (1962–89), Ш.М.Чабдаров (1989–97), В.Л.Сафонов (1997—2005), В.А.Иванцов (2005–09), В.П.Коннов (2009 дан). Ш.у.к. *Радиоэлектроника*.

*С.Н.Медведев, Р.Г.Усманов.*

**КАЗА́Н РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1927 елның 14 февралендә Воскресенский р-ны буларак оештырыла (бу исемне 1927 нең 1 августына кадәр йөртә). Үзәге — Казан шәһәре. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязенә керә, 1920–27 дә ТАССРның Арча кантонында. Оештырылган чорда К.р.нда 66 авыл советы, 133 торак пункт исәпләнә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1930 да кантоннар бетерелгәч, К.р.нда 3 посёлок советы, 72 авыл советы, 166 торак пункт була. 85092 (ш.и. руслар — 83220, татарлар — 610) кеше яши. 1935 тә К.р.ндагы авыл советларның кайберләре яңа оештырылган Биектау р-нына бүленеп чыга. 1938 нең 4 августында район бетерелә, биләмәсе Столбище һәм Юдино р-ннарына бирелә.

**КАЗА́Н РЕВОЛЮЦИО́Н ШТАБЫ́**, Окт. рев-циясеннән соң Совет хакимияте Казанда һәм Казан губернасында оештырган беренче гадәттән тыш орган. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларның Казан Советы тарафыннан 1917 елның 26 октябрендә Совет хакимиятенең гадәттән тыш органы буларак оештырыла. Аңа Казанда тәртип урнаштыру һәм контрреволюцион көчләр һөҗүменнән саклау бурычы йөкләнә. Башта 3/4 өлеше хәрбиләрдән, нигездә большевиклардан тора. Штабны РСДРП(б)ның Казан ком-ты әгъзасы К.Я.*Грасис* җитәкли. Хәрби мәсьәләләрне Н.Е.*Ершов* алып бара. Штаб комиссарларны Дәүләт банкы бүлекчәсенә, почтага, телеграфка җибәрә; корал складына, спирт, азык-төлек запасларына контроль урнаштыра. Кадетлар г-тасы «Камско-Волжская речь» басыла торган типография конфискацияләнә, «Знамя революции» г-тасы чыгарыла башлый. К.р.ш. халыкка хакимиятнең Советларга күчүе турында өндәмә б-н мөрәҗәгать итә. Идел буе һәм Урал гарнизонларының Совет хакимиятенә күчүе турында Казан хәрби округы буенча 3 әмер чыга. Әмма К.р.ш. башка соц. партияләрдә һәм милли оешмаларда киң яклау тапмый. 27 октябрьдә штаб

рәисе итеп М.*Вахитов* сайлана, ул икенче көнне үк аның составыннан чыга. 29 октябрьдә Казан хәрби-округы ком-тыннан 5 делегат К.р.ш.н ташлап китә. 30 октябрьдә хакимият турындагы мәсьәләне РСДРП(б)ның Казан ком-ты, 31 октябрьдә сул эсерлар тикшерә, алар «җавапсыз кешеләр» хакимиятен танымау турында белдерәләр. К.р.ш.ның таянычы булып шәһәр гарнизоны һәм эре пр-тиеләр кала. 4 ноябрьдә эшче һәм солдат депутатларының Казан Советы президиумы яңадан сайлана, аны Я.С.*Шейнкман* җитәкли. Шул ук көнне К.р.ш. аңа үз вәкаләтләрен тапшыра.

*Әд.:* Ионенко И.М., Тагиров И.Р. Октябрь в Казани. К., 1967.

*С.И.Ионенко.*

**КАЗА́Н РЕЗИ́НА-ТЕ́ХНИК ӘЙБЕРЛӘ́Р ЗАВОДЫ́**, к. «*Кварт*».

**КАЗА́Н РУХАНИЛА́Р АКАДЕ́МИЯСЕ**, 1) югары дини уку йорты (Иске Казан руханилар академиясе буларак билгеле). 1798 елда Павел I нең Фәрманы буенча, башта уку срогын 2 югары сыйныфта (филос. һәм дин белеме сыйныфларында) 2 елга озынайту хисабына гына *Казан руханилар семинариясен* үзгәртү юлы б-н оештырыла. Шактый зур һәм төрле төрдәге уку йорты була, башлангыч, урта һәм югары дини белем бирүне берләштерә. Укучылар саны 1 мең кешедән арта, уку вакыты 15 елга җитә. Белем бирү, дини уку йортларына хас булганча, латин-схоластик характерда була, һәр сыйныф белем бирүнең тәмамланган баскычы булып санала. Дин белеменең тулы курсларын ел саен якынча 10 кеше тәмамлый. 1800 дән К.р.а.дә беренче тапкыр татар теле укытыла башлый (1800–18 дә укытучы — А.А.Троянский). Үзенең укыту-фәнни эшләре дәрәҗәсе буенча академия югары типтагы дини семинария булып кала. Казан епархиясенә карата ул дини семинария ролен үтәвен дәвам итә, ә югары уку йорты саналган өлкән сыйныфларга яңадан оештырылган Казан дини уку-укыту округы семинарияләреннән укучылар җибәрелә, бу округка Әстерхан, Вятка, Иркутск, Түбән Новгород, Тамбов, Тобол губерналары уку йортлары керә. 1815 нең 3 сентябрендә булган янгын академия биналарына шактый зыян китерә, китапханәнең зур өлеше юкка чыга. Синодның 1818 дәге Фәрманына туры китереп, К.р.а. яңадан руханилар семинариясе итеп үзгәртелә.

2) 1842–1921 елларда Рус Православие чиркәвенең югары уку йорты. Синодның 1842 ел 25 июне билгеләмәсе буенча оештырыла, 8 ноябрьдә тантаналы рәвештә ачыла. Нигезләнү вакыты буенча Россиядә дини академияләрнең дүртенчесе санала һәм соңгысы була; Киев, Мәскәү, С.-Петербург академияләре үрнәгендә эшли. Кабул ителүченең кайсы катлауга каравы исәпкә алына торган уку йорты була, аңа дини семинарияләрне иң яхшы тәмамлаучылар, башлыча, Идел буе, Себер, Урал, Кавказдан, чорына карап «юллама» («разнарядка») яисә имтиханнар нәтиҗәсендә кабул ителә. Студентларның күпчелеге «казна хисабына» укый, академия бинасында урнашкан тулай торакта яши. 1872 гә кадәр студентлар ике елга бер тапкыр, соңрак ел саен кабул ителә. Чыгарылышы, гадәттә, якынча 30 кешедән тора, иң азы — 17 (1852 дә), иң күбе — 65 кеше (1901 дә). 19 йөз ахыры — 20 йөз башында студентлар арасында Идел буе халыклары вәкилләре — чуаш, мари, керәшен татарлар, ш.у. чит илләрдән — Госманлылар империясеннән, Австро-Венгрия, Болгария, Сербия, Черногория, Япония православие чиркәүләреннән студентлар килә башлый. Академиянең төп максаты дини уку йортлары өчен укытучылар әзерләү була. Академияне тәмамлаучылар 6 ел семинарияләрдә һәм дини уч-щеләрдә эшләргә тиеш булалар, дини һәм ш.у. гомуми белем бирү циклыннан теләсә нинди фәнне укыталар. Уңышлы тәмамлаучыларга — «дин белеме кандидаты» исеме, иң яхшыларына (1870 кә кадәр) — дин белеме магистры гыйльми дәрәҗәсе бирелә (соңрак гыйльми дәрәҗә бирү өчен диссертация якларга кирәк була). К.р.а. советы ш.у. дин белеме, чиркәү тарихы, чиркәү хокукы докторы гыйльми дәрәҗәсен дә бирә. 1842 — 70 тә академия дини уку йортларының 1814 елгы Уставына туры китереп эшли: укыту эшчәнлегенең барлык яклары да Синодның катгый күзәтчелеге астында алып барыла; ректор, профессорлар һәм укытучылар билгеләнеп куела, студентлар кабул итү, уку программалары катгый тикшерелә. Устав студентларның белгечлекләргә бүленүен билгеләми, ләкин 1852 дә К.р.а.дә Россиядә исламга, буддизмга, раскольниклыкка һәм мәҗүсилеккә (чуаш-чирмеш) каршы бүлекчәләр б-н бердәнбер миссионерлык бүлеге оештырыла; соңгысы бары 2 ел гына эшли. 1869 ның 30 июнендә расланган дини академияләр уставы 1863 елгы университетлар уставы йогынтысында төзелгән була һәм киң автономия, ректор, инспектор, профессорларның сайланылуын, студентларның хокуклары киңәюен, аларның өч бүлек буенча (дин белеме, чиркәү тарихы һәм чиркәү-гамәли) белгечлекләр алуын күздә тота. Миссионерлык бүлеге бетерелә, миссионерлык буенча фәннәрне студентлар үзләре сайлап кына өйрәнә башлыйлар. Император Александр III нең контрреформалар рухындагы яңа, 1884 нең 15 августы Уставы катгый административлаштыруны яңадан торгыза; моннан тыш, академия б-н идарә итүдә әйдәп баручы рольне епархия архиерее уйный. Бүлекләр кыскартыла, уку фәннәренең күпчелек өлеше мәҗбүригә әверелә. Белгечлекләр аерымлана, алар бары 4 фәнне үз эченә ала — тел-педагогика һәм дин белеме-канунлаштыру (изгеләштерү), ш.у. монгол-калмык һәм татар-төрек бүлекчәләре б-н миссионерлык бүлеге кертелә. Болар Көнчыгышны өйрәнүнең фәнни потенциалын саклап калырга мөмкинлек бирә, ләкин кадрлар әзерләү дәрәҗәсе түбән була, чөнки махсус фәннәрне укытуга сәгатьләр аз бирелә. 1905 нең 30 ноябрендә дини академияләр өчен автономияне кире кайтаручы (1909 ның 3 февралендә бетерелә) Вакытлы кагыйдәләр кабул ителә. 1910 елгы Устав (1911 дә үзгәртүләр б-н) иң реакцион нигезләмә булып санала, ул дөньяви профессорларны һәм ак руханиларны академиядән кысрыклауга, гомуми белем фәннәрен кыскартуга һәм аларны галим монахлар кулына бирүгә юнәлтелгән була. Бу күрсәтмәләр гамәлгә ашмый, һәм К.р.а. 1917 елга үзенең фәнни потенциалын саклап кала. 1917 нең 8 маенда янә академиянең автономиясен кире кайтаручы Вакытлы кагыйдәләр кертелә. Чиркәүне дәүләттән аеру турындагы декретка туры китереп, академия дәүләт уку йорты статусын югалта, шуңа карамастан ул чиркәү учреждениесе буларак та теркәлми, ләкин 1918–21 дә эшләвен дәвам итә; җитәкчелек хөкүмәтнең дингә каршы сәясәтендәге һәм совет законнарындагы җитешсезлекләрдән уңышлы файдалана. К.р.а. Синодтан зур булмаган субсидия ала, рәсми рәвештә дипломнар (1919–20 дә — якынча 20), гыйльми дәрәҗәләр бирә. 1921 нең апрелендә ректор һәм 32 укытучы кулга алынганнан соң ябыла. Академиянең уку процессы һәм фәнни эшчәнлегенең үсешендә аның ректорлары — Григорий (Митькевич) (1844–51), Агафангел (Соловьёв) (1856–57), Иоанн (Соколов) (1857–64), Никанор (Бровкович) (1868–71), А.П.Владимирский (1871–95) зур роль уйный. Антоний (Храповицкий) (1895–1900) ректор булган елларда академиядә студентлар саны 3 тапкыр арта, хәтта башкала семинарияләрен тәмамлаучылар да килә башлый. Соңгы ректор, Анатолий (Грисюк) (1913–21), 3 елга ирегеннән мәхрүм ителә (законсыз дини эшчәнлеге өчен).



Казан руханилар академиясе. Төп корпус. 19 йөз ахыры фоторәсеме.

К.р.а. оештырылганнан соң тиз арада зур фәнни үзәккә әверелә. Академия галимнәре үз эшчәнлекләрен төрле юнәлешләрдә — дин

белеме (А.М.Бухарев, И.Я.Добротворский, М.И.Богословский, Е.А.Будрин, Н.Я.Беляев, А.Ф.Гусев, Антоний (Вадковский), П.А.Юнгеров, Д.В.Гусев һ.б.), чиркәү хокукы (И.С.Бердников, Н.В.Петров), Библия тарихы (Я.А.Богородский), чиркәү археологиясе (Н.Ф.Красносельцев, А.А.Дмитриевский), византология (Ф.А.Курганов), раскольниклык хәрәкәте (Н.И.Ивановский), философия (В.А.Снегирёв, В.И.Несмелов), филология (И.Я.Порфирьев, А.А.Царевский) буенча алып баралар. 1854 тә академиягә Соловки монастыре китапханәсенең бирелүе тарихи тикшеренүләрнең шактый дәрәҗәдә үсешенә сәбәпче була, анда күп санда иске кульязма һәм басма китаплар, грамоталар саклана. Академияне тәмамлаган А.П.Щапов рус чиркәү тарихының академик мәктәбен төзи; 19 йөзнең 2 нче яртысында П.В.Знаменский мәктәбе нигезләнә (Ф.В.Благовидов, И.М.Покровский һ.б.), Вселенский соборлар эшчәнлеге һәм «Стоглав»ның рус теленә фәнни тәрҗемәләре эшләнә, алардан дин белгечләре һәм тарихчылар хәзерге көндә дә файдаланалар. Миссионерлык бүлекләре, көнчыгыш телләре һәм диннәре кафедраларын оештыру нәтиҗәсендә академия башкаладан читтә дә Шәрекъне өйрәнүче эре үзәккә әверелә, бигрәк тә 1855 тә Казан ун-тының Көнчыгыш разряды С.-Петербург ун-тына күчерелгәннән соң, К.р.а. дә татар телен укыту һәрвакыт югары дәрәҗәдә алып барыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында ислам, татар һәм гарәп тел белемнәре буенча фәнни эшләрне Н.И.Ильминский, Е.А.Малов, М.А.Машанов, Н.П.Остроумов, П.К.Жузе, Я.Д.Коблов һ.б. дәвам итә, аларның ачыктан-ачык миссионерлык, исламга каршы юнәлештәге хезмәтләре югары фәнни дәрәҗәсе б-н аерылып тора. Миссионерлык фәннәрен өйрәнүче студентларның курс эшләре һәм диплом хезмәтләре зур кыйммәткә ия була («Исламга каршы миссионерлык җыентыклары»нда басылалар). 1911 дән Н.Ф.Катанов җитәкчелегендә ислам һәм тюркология буенча тикшеренүләр, башлыча, тел белеме һәм этнографиягә хас төс ала. Академиядә буддизмны, калмыклар һәм бурятлар тарихын һәм этнографиясен өйрәнү мәктәбе зур роль уйный (А.А.Бобровников, Гурий (Степанов), В.В.Миротворцев һ.б.). Академияне тәмамлаучыларның күпчелеге дини уку йортларына укытучылар булып китәләр, иң талантлылары академиянең үзендә доцент һәм профессор дәрәҗәләренә ирешәләр. Нәтиҗәдә аларның күбесе дини дәрәҗә ала, зур шәһәрләрнең приходларында эшли, дөньяви урта һәм югары уку йортларында Илаһи Канун укыта. Калганнары Халык мәгарифе министрлыгы оешмаларына хезмәткә күчә, гимназияләр һәм халык уч-щеләрендә укытучы, инспектор, директор булып эшлиләр. Монахлыкны кабул итүчеләр, кагыйдә буларак, күпмедер вакыттан соң епископ итеп билгеләнә. 20 йөз башында Рус православие чиркәвендә епископлар корпусының биштән бер өлешен К.р.а.н тәмамлаучылар тәшкил итә. Иң күренеклеләре арасында — С.-Петербург митрополитлары Палладий (Раев) һәм Антоний (Вадковский). 1920–30 елларда академия укытучыларының һәм аны тәмамлаучыларның күпчелеге репрессия корбаннары була, соңрак аларның 20 дән артыгы изгеләштерелә. Академия укытучыларының хезмәтләре башлыча, 1855 тән нәшер ителгән «*Православный собеседник*» акад. ж-лында басыла. 1867 дән ш.у. «*Известия по Казанской епархии*», 1911–16 да «*Инородческое обозрение*» ж-ллары чыга. Академия китапханәсендә 20 йөз башында 200 меңләп том исәпләнә. Аның төп фонды 1921 дә Казан ун-ты китапханәсенә, бер өлеше (50 мең томга кадәр) 1995 тә Казан епархия идарәсе китапханәсенә бирелә. 1842 дән К.р.а. Кремльдә Спас-Преображение монастырендә урнаша, аннан соң Зур Проломный урамындагы (хәзерге Бауман урамы) «Казанское подворье» бинасына, 1848 дән — Арча кырында А.И.Песке проекты буенча махсус төзелгән бинага (соңгы классицизм стилендә парадный портик һәм коридорлар системасы б-н махсус төзелгән бинада, хәзер 6 нчы клиник хастаханә бинасы) күчә. 1918 дән дәресләр П хәрефе сыман төзелгән өч катлы бинада, Иоанн-Предтече монастырендә һәм укытучыларның өйләрендә алып барыла.

*Әд.:* Благовещенский А. История Старой Казанской духовной академии. 1797 — 1816. К., 1875; Можаровский А.Ф. Старая Казанская академия. К., 1877; Знаменский П. История Казанской Духовной Академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870 годы): В 3 ч. К., 1891–92; Остроумов Н.П. Воспоминания о миссионерском противомусульманском отделении при Казанской духовной академии // Православный собеседник. 1892. Ч. 1; Терновский С.А. Историческая записка о состоянии Казанской духовной академии после её преобразования. 1870–1892. К., 1892; Загоскин Н.П. Казанские академические пииты и вести начала текущего столетия. К., 1897; Покровский И.М. К столетию кафедры татарского языка в духовных учебных заведениях Казани // Православный собеседник. 1900. Ч. 1; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: источники и развитие (XIX — 20-е гг. XX в). К., 1998; Журавский А.В. Казанская духовная академия на переломе эпох (1884–1921): Дис. ... М., 2000; Исхакова Р.Р. Духовные учебные заведения как фактор создания педагогического образования в регионе. К., 2001.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н РУХАНИЛА́Р АКАДЕ́МИЯСЕ КИТАПХАНӘСЕ́.** 1842 елда ачыла. Фондның нигезен *Казан руханилар семинариясе китапханәсе*, Рухани училище идарәсеннән килгән китаплар тәшкил итә. 1843 ел башына китапханәдә 74 исемдә китап исәпләнә. 1844 кә башка рухани уку йортларыннан (Мәскәү, Петербург, Киев академияләре, Томск уч-щесе һ.б.) килгән шундый ук дублет басмалар исәбенә бу күрсәткеч 894 кә (1785 том) җитә. Алар арасында М.В.Ломоносов, В.Н.Татищев, Н.М.Карамзин хезмәтләре була. 1850 елларда студентлар китапханәсе ачыла. Башта китапханәдә бары тик укучыларның үз хисапларына алынган вакытлы матбугат кына була. Шуның өчен дә ул аларның шәхси китапханәсе санала. Соңга таба ул дәреслекләр б-н дә тулылана һәм фундаменталь китапханә булып санала башлый. Ел саен академия наширләрдән һәм китап сатучылардан 100–200 китап ала. Сирәк китаплар һәм кульязмаларны укытучылар чит илләрдән алып кайта, ш.у. андый басмалар букинистлардан сатып алына. Еш кына төрле оешмалар һәм кешеләр (Вениамин Пуцек-Григорович), (Амвросий Подобедов), (Евгений Болховитинов һ.б.) китапханәгә әдәбиятны бушлай тапшыра. Беренче китаплар академиягә 1844 тә бүләк ителә. 1855 тә С.-Петербург Җәмәгатъ китапханәсеннән 1514 исемдә китап алына. Берничә ел дәвамында китапларны Казан архиепископы Григорий (Постников) та бүләк итә. 1867 дә ул китапханәгә 198 кульязма һәм иске басма китапларын васыять итеп калдыра. 1866 да аннан соң архиепископ булган Афанасий (Соколов) та шундый ук үрнәк күрсәтә: аның 1348 исемдәге китабы (2105 том), геогр. карталары китапханәгә күчерелә. Проф. Г.С.Саблуков, В.И.Григорович, Н.И.Ильминский һ.б. да әлеге матур гамәлне дәвам итәләр. 1855 тә академиягә 1356 данә кульязма һәм иске басма китап Соловки монастыреннан күчә. Шушы вакытка китапханә Россиядә дини китапларга иң бай китапханә була. 1868 дә Изге Синод күрсәтмәсе нигезендә Соловки китапханәсе бөтенләе б-н академия карамагына күчә. Китапханәнең фондлары турындагы беренче тасвирламаны (1839) бакалавр А.И.Лилов яза. Алга таба шуңа охшаш материаллар «*Православный собеседник*» руханилар академиясе ж-лында яктыртылып бара. Академиянең әйдәп баручы галимнәреннән төзелгән комиссия кульязмалар һәм иске басма китапларны системага салалар, исемлекләрен төзиләр. Китапханә фондының күп өлешен 16–18 йөз әсәрләре һәм 13–15 йөз кульязмалары (төп нөсхә һәм күчермәләре) тәшкил итә. Алар арасында: Симеонның «Златоструй», «Георгий Арматол хроникасы» («Георги Арматол»), «Стоглав», И.Дамаскин һәм М.Грек әсәрләре, болгар һәм серб язма ядкәрләре, С.Полоцкийның «Алексей Михайловичның үлеме хәсрәте» («Плачъ на кончину Алексея Михайловича»), «Мамай сугышы турында хикәят» («Сказание о Мамаевом побоище»), М.В.Ломоносовның «Бөек Пётр» («Пётр Великий») әсәре, арифметикалар, хронографлар, травниклар һ.б. бар. 1916 елга китапханәдә рус, Европа, шәрекъ телләрендә 46393 исемдәге китап (103880 том), 4 меңнән артык кульязма исәпләнә, күп газета һәм журналлар алдырыла («Вопросы философии», «Русский архив», «Вестник Европы», «Книжные вести» һ.б.). Даими басылган системалы, алфавит тәртибендәге, хронологик, топографик каталоглар алып барыла. Академия яңа бинага (Арча кырында) күчкәннән соң, китапханә бина кырыена тоташтырып салынган таш йортның (флигель) икенче катына урнаша.

1917 дән соң китапханә таратыла. Әдәбият төрле оешмаларга, ә Соловки монастыре китапханәсе Үзәк тарихи архивка бирелә. 1928 елга аның төп өлеше җәмәгать китапханәсенә (хәзерге Россия Милли китапханәсе) күчерелә. Аерым басмалар Казан ун-ты, Ка-

зан пед. ун-ты фәнни китапханәсе фондларында һ.б., ә кульязмалар ТР Милли архивында саклана. Фондның бер өлеше 1990 елларда Казан епархия идарәсенә бирелә.

*Әд.:* З н а м е н с к и й П. История Казанской духовной академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870 годы): В 3 ч. К., 1891–92; Т е р н о в с к и й С. Историческая записка о состоянии Казанской духовной академии после ее преобразования. 1870–1892. К., 1892; С л у х о в с к и й М.И. Русская библиотека XV–XVII вв. М., 1973; Христианство: Энцикл. словарь. М., 1993. Т. 1.

*Г.Г.Габделганиева.*

**КАЗА́Н РУХАНИЛА́Р СЕМИНА́РИЯСЕ**, 1) Рус Православие чиркәве уку йорты. 1723 елда Казан архиерей славян-латин мәктәбе буларак ачыла, 1733 тә К.р.с. итеп үзгәртелә. 1868 гә кадәр дини катлау балалары өчен генә була, соңрак та укучыларның күп өлешен дини катлау балалары тәшкил итә. Урта дини белем бирә. 18 йөздә укыту украин дини мәктәпләре өчен 17 йөздә эшләнгән система буенча алып барыла. 18 йөзнең 2 нче яртысында Россиядә иң яхшы семинарияләрнең берсе булып санала. 1798 дә *Казан руханилар академиясе* итеп үзгәртелә, 1818 дә яңадан семинария буларак оештырыла. Дини мәктәпләр реформасы нигезендә 1808 дә укыту программалары гомуми белем бирү характерында була, 1842 елгы реформа барышында алар тагын да нығытыла.

1890 нан К.р.с.нә ел саен Казан укытучылар семинариясен тәмамлаган берничә керәшен татар, чуаш һәм мари кабул ителә башлый. К.р.с.нең төп бурычы Казан епархияләре өчен дин әһелләре әзерләү була, семинарияне иң яхшы тәмамлаучыларны дини академияләргә җибәрәләр, күпчелеге университетларга укырга керә һәм гражданлык хезмәтендә эшли башлый. Алар арасында медицина белгечләре А.А.Соколовский, М.Ф.Кандаратский, геолог А.В.Нечаев, механика белгече Н.Г.Четаев, чуаш тарихчысы, этнограф, җәмәгать эшлеклесе Н.В.Никольский, мари этнографы, тарихчы, тел белгече В.М.Васильев, кытайлар тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче белгеч Палладий (Кафаров) һ.б. була. К.р.с. 1918 нең гыйнварында чиркәүнең дәүләттән аерылуы һәм бинасы конфискацияләнү сәбәпле эшен туктата. Башта Фёдор монастыренда урнаша, 1735 тән Воскресенский урамындагы (хәзерге Кремль урамы, Казан ун-тының геология ф-ты) бинаны били. К.р.с.нең биналар комплексы — классицизм архит-расы истәлеге. Шәһәрнең үзәк өлешендә, Петропавел соборына якын урнашкан. Ике катлы кирпеч корпуслар аркалар б-н тоташтырылган ябык ишегалды системасын тәшкил итә. Бинаның беренче катлары 1740 елларда төзелә, комплексның заманча тышкы күренеше 1867 елгы үзгәртеп корулардан соң арх. П.А.Солнцев проекты буенча яңадан торгызыла. 2000–04 елларда семинария комплексы реконструкцияләнә. 2) Рус Православие чиркәвенең дәүләтнеке булмаган югары уку йорты. 1997 елда ачыла, 80 ләп укучы укый, 30 укытучы, ш.и. 5 фән. д-ры, 11 фән. канд-ты эшли.



Казан руханилар семинариясе. 20 йөз башы фоторәсеме.

*Е.В.Липаков, С.Г.Персова.*

**КАЗА́Н РУХАНИЛА́Р СЕМИНА́РИЯСЕ КИТАПХАНӘСЕ́**. Фундаменталь, укучылар һәм уку китапханәләрен үз эченә ала. Беренчесенең төп өлешен 1733 елда Л.Канашевич семинариягә бүләк иткән дини тәгълимат әсәрләре җыелмасы тәшкил итә. Башта китапханә иганәчелек хисабына тулылана. Алга таба китаплар сатып алына башлый. Алар китапханәгә ш.у. хөкүмәт кушуы буенча да җибәрелә. 1792 дә китапханәдә рус, латин, грек, немец, француз телләрендә 1370 исемдәге, 1818 дә — 3500 дини, тарихи, фәлсәфи һ.б. 16–18 йөзләр китаплары исәпләнә. Алга таба фондлар кыскартыла: архиепископ Филарет боерыгы б-н китапларның эчтәлеге тикшерелә һәм «яраксыз» әсәрләр (Вольтер һ.б.) юк ителә. 1842 дә Казан руханилар академиясе китапханәсенә 52 исемдәге китап (286 том) тапшырыла. 1850 дән укуда яңа дәресләр кертелү сәбәпле, аларны әдәбият б-н тәэмин итү максатында китапханә фондын баету өчен акча күбрәк бирелә башлый. 1854 тән рус расколы (Россиядә 17 йөздә барлыкка килгән һәм чиркәүгә каршы булган дини-иҗтимагый хәрәкәт) тарихы укытыла башлагач, раскольниклардан тартып алынган китап һәм кульязмалар да китапханәгә тапшырыла. 1898 дә китапханәдә 4819 исемдә кульязма һәм басма хезмәт (11956 том) исәпләнә, аларның 4526 сы — китап, 52 се Львов, Вильно, Киев, Мәскәү һ.б. шәһәрләрдә басылган «Острог библиясе» («Острожская библия», 1851), «Псалтырь» (1598, 1652, 1657), «Апостол» (1623), «Требник» (1647), «Инҗил» («Евангелие», 1648, 1651), «Часослов» (1652) кебек иске басма китаплар; 107 се журнал (аларның 30 ы дини һәм 77 се дөньяви, 13–16 йөзләргә караган 78 кульязма; 56 сы — атлас һәм карталар. Җыелмадагы әсәрләрнең 1645е — дини китаплар, 1082 се тарихи , 246 сы — фәлсәфи, 196 шары — математикага һәм географиягә караган, 674 е — әдәби әсәрләр һ.б. Иң борынгы китап — Э.Роттердамский мөхәррирлегендәге «Яңа гаһед» («Новый завет», Базель, 1516) китабы. Китаплар 6 бүлеккә таратыла: фәнни-дини, фәлсәфи, тел, тарихи, филол., тел белеме. Өстәмә 7 нче бүлектә химиягә, мед., хокук һ.б. фәннәргә караган әдәбият туплана.

Казан руханилар семинариясе һәм Гостиный дворның бер өлеше. 1830 еллар. В.С.Турин офорты.



Укучылар китапханәсе бары тик уку китапларыннан гына җыела, һәм ул өч бүлектән: түләүсез, пансионерлар һәм сату өчен булган әдәбияттан тора. Аның беренчесе *Казан архиерей славян-латин мәктәбендә* барлыкка килә, аңа китаплар Изге Синод боерыгы б-н җибәрелә. Сату китапханәсе 1797 дә оеша. Китаплар семинариянең җитеш тормышта яшәүче укучыларына, дини оешмаларга (Казан епархиясенең чиркәү китапханәләренә һ.б.) сатыла. Пансионерлар китапханәсе 1886–87 уку елында ректор Н.Т.Каменский тәкъдиме б-н оеша. Әдәбият пансиондагы укучылар акчасына сатып алына. 1886 да анда 58 исемдәге китап (623 том) исәпләнә. Уку китапханәсен 1808 дә архиепископ П.Зернов оештыра. Семинария укучылары һәм укытучыларыннан тыш, акча (40 сумнан 100 сумга кадәр) түләп шәһәр кешеләре дә йөри. Фондлар сатып алынган китаплар һәм иганә ярдәме б-н тулылана. 1818 гә китапханәдә рус телендә 522 исемдә китап исәпләнә. Алар арасында М.В.Ломоносов хезмәтләре, Н.И.Новиковның «Борынгы вивлиофика» («Древняя вивлиофика») әсәре, «Россия дәүләте география сүзлеге» («Географический словарь Российского государства»), «Дөнья сәяхәтчесе» («Всемирный путешественник») һ.б. була. 1821 дә китапханә ябыла. 1834 тә яңадан оештыру омтылышы уңышсыз тәмамлана.

Китапханә семинариянең төп бинасының икенче катында урнаша. Китапханәче һәм аның ярдәмчеләре семинария укытучылары арасыннан билгеләнә. 1871 гә кадәр хезмәт хакы түләнә. Семинария ябылганнан соң китапханә фондлары төрле оешмаларга таратыла. Аерым китаплар Казан ун-ты фәнни китапханәсендә саклана.

*Әд.:* Б л а г о в е щ е н с к и й А. История старой Казанской духовной академии (1797–1818). К., 1875; Библиотека при Казанской духовной семинарии: Краткий ист. очерк. К., 1889; Систематический каталог фундаментальной библиотеки Казанской духовной семинарии. К., 1889.

*Г.Г.Габделганиева.*

**КАЗА́Н САКЛА́У БҮЛЕГЕ́**, Казан губернасында яшерен полиция органы. Полиция департаментының 1902 ел, 12 август циркуляр

күрсәтмәсе нигезендә Казан эзләү бүлеге булара оештырыла, шул ук департаментның 1903 ел 13 февраль циркуляры б-н К.с.б. итеп үзгәртелә. Дәүләт иминлеген тәэмин итү һәм җәмәгать тәртибен саклау максатында сәяси эзәрлекләү б-н шөгыльләнә. К.с.б. тарафыннан җыелган материллар буенча *Казан губернасының жандармнар идарәсе* аерым революционерларны һ.б. ышанычсыз затларны кулга ала, сәяси оешмалар турында сорау алулар уздыра. Бүлек канцеляриядән, яшерен һәм эзләү бүлекләреннән тора. «Шикле затларны читтән күзәтүче» махсус агентура: «тикшерелә торган тирәлектәге» шымчылар һәм яшерен агентлар — хәбәр итүчеләр һәм провокаторлар тота. Россия Эчке эшләр министрлыгының Полиция департаментына буйсына. Шул ук департаментның 1913 нең 9 маенда чыгарылган циркуляры б-н бетерелә.

*Әд.:* Е р о ш к и н Н.П. История государственных учреждений дореволюционной России. М., 1983; П е р е г у д о в а З.И. Политический сыск в России (1880–1917 гг.). М., 2000.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н САРА́Й ИДАРӘХАНӘСЕ́** (Казан сарае, Казан һәм Мишәр сарае), 16 йөзнең 2 нче яртысында — 18 йөз башында Рус дәүләтенең хөкүмәт учреждениесе. Элеккеге Казан, Әстерхан һәм Себер ханлыклары җирләре б-н идарә итү өчен оештырыла. Шулай ук Түбән Новгород өязе һәм Мишәр җирләре дә (1587 елга кадәр) идарәханә карамагында була. Адм., финанс һәм мәхкәмә эшләре б-н идарә итә, җирле хакимиятне күзәтчелектә тота, рус булмаган халыклардан ясак җыю һ.б. б-н шөгыльләнә. 17 йөздә элеккеге Әстерхан ханлыгы шәһәрләре — Илчелек, Себер терр-ясе — Себер (1637) идарәханәләре карамагына күчә. Урта һәм Түбән Идел буйлары төбәкләре б-н Казан, Урал алды К.с.и. нә буйсынуда кала. Казан губернасы төзелгәннән соң бетерелә (1708).

*Әд.:* С а д и к о в П.А. Очерки по истории опричнины. М.–Л., 1950.

**КАЗА́Н СӘНӘГА́ТЬ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, Х а л ы к  м ә г а р и ф е  м и н и с т р л ы г ы  к а р а м а г ы н д а г ы уку йорты, 1897 нең 10 сентябрендә Николай II нең 1896 ел 23 май Фәрманы нигезендә ачыла. Урта махсус белем биргән урта химия-технол. уч-щесен һәм «түбәнге» (һөнәри) механика, химия-технол. (1898 дән), төзелеш (1899 дан) уч-щеләрен үз эченә ала. Урта уч-щегә реаль уч-щенең 5 сыйныфын тәмамлаган малайлар кабул ителә; уку срогы 4 ел тәшкил итә, тәмамлап чыгучыларга инженер ярдәмчесе квалификациясе һәм технол. ин-тына укырга керү хокукы бирелә. «Түбәнге» (һөнәри) уч-щегә өяз уч-щесенең һәм шәһәр башлангыч мәктәбенең ике классын тәмамлап керәләр; өч еллык укудан соң, призводствода мастерлар, техниклар, десятниклар, прорабләр булып эшлиләр. Уку түләүле була, шулай да күп укучылар земство һәм шәһәр идарәсе стипендиясе алалар. 1899–1918 дә 1 меңнән артык белгеч әзерләнә, шәхси эшмәкәрләрдә ялланып, земство һәм шәһәр учреждениеләрендә техниклар булып эшлиләр; 100 дән артык кеше белем алуны югары уку йортларында дәвам итә. 1901–04 тә «түбәнге» химия-технол. уч-щесендә С.М.*Киров* укый. К.с.у.нең укытучылар персоналы югары белемле тәҗрибәле белгечләрдән тора (С.В.*Бечко-Друзин*, И.И.*Брюно*, К.С.*Олешкевич*, Н.М.*Пауткин* һ.б.). 1917 дә К.с.у. Казан политехник уч-щесенә үзгәртелә. 1918 дә Казан коммерция уч-щесе б-н Казан политехник техникумына кушыла; 1919 да аның җирлегендә Казан политехник ин-ты оеша. Училище арх. К.С.Олешкевич проекты буенча 1897–1901 дә төзелгән бинасының комплексында урнашкан (хәзер Казан технол. ун-ты корпусларының берсе).



Казан сәнәгать училищесе бинасы.
Арх. К.С.Олешкевич. 1901. Хәзерге күренеше.

**КАЗА́Н СӘҮДӘ́-ИКЪТИСА́Д ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Икътисад һәм сәүдә министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1971 елда Казан совет сәүдә техникумы буларак оештырыла. 1992 дән хәзерге исемдә. Җәмәгать туклануы пр-тиеләренә, сәүдә оешмаларына кадрлар әзерли. Белгечлекләр: коммерция, менеджмент; җәмәгать туклануында хезмәт күрсәтүне оештыру; җәмәгать туклануы продукцияләре технологиясе; куллану товарларының сыйфат экспертизасы; икътисад һәм бухгалтерлык исәбе. Укыту көндезге һәм читтән торып уку формасында алып барыла; өстәмә белем бирү бүлеге бар. 2010 да 1100 дән артык кеше (көндезге бүлектә — 900, читтән торып уку бүлегендә — 250, ш.и. түләүле тәртиптә 430 студент укый); укытучылар составы 49 кешедән тора. Техникум ачылганнан бирле 10 меңнән артык белгеч әзерләп чыгарыла. 23 уку бүлмәсе һәм 3 лаб-ясе булган уку бинасы, тулай торагы бар.

**КАЗА́Н СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ́ СТА́РОСТАЛЫГЫ**, Казан губернасы сәүдәгәрләренең үзидарә органы. 1727 елда хөкүмәт вазифаларын башкаручы Сенат тарафыннан 1724 нең 30 декабрендә кабул ителгән фәрман нигезендә оештырыла. Старосталар ел саен сәүдәгәрләр җәмгыятьләре әгъзаларыннан, русларда һәм татарларда аерым сайлана. Татар һәм рус сәүдәгәрләре җәмгыятьләре фәкать үз җәмгыятьләре эшләре б-н генә шөгыльләнәләр. Аларның вазифасына сәүдәгәрләрнең гаилә исемлеген төзү, Сәүдәгәрләр җәмгыятенә кабул итү һәм аннан чыгару, казнага кергән салым-җыемнарны бүлү, ятимнәр мәхкәмәсендә әгъза буларак катнашу керә. Кандидатураларны губернатор раслый. Сәүдәгәрләр старостасы вазифасы 1918 дә БҮБК һәм ХКСның 1917 ел 10 ноябрь Декреты нигезендә бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 7; Собрание узаконий и распоряжений рабочего и крестьянского правительства. П., 1917. № 3.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАЗА́Н СӘҮДӘГӘРЛӘРЕНЕ́Ң Ү́ЗАРА ЯРДӘМЛӘШҮ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, иганәчелек оешмасы. 1898 елның мартында оештырыла. Әлеге җәмгыятьне булдыру мәсьәләсе берничә тапкыр күтәрелә: 1889 да Казан сәүдәгәрләре җәмгыяте җыелышында Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре И.Я.Поплавский белдерүе буенча, 1894 тә И.В.Рябчиков тәкъдиме б-н тикшерелә (мәсьәләне тагын да җентекләбрәк тикшерергә карар кылына). Җәмгыять составына оештыручы, хокукый, шәрәфле һәм иганәче әгъзалар керә. Максаты — җәмгыять әгъзаларына матди һәм мед. ярдәме күрсәтү, картайган һәм бөлгенлеккә төшкән әгъзаларга, ятим балаларга ярдәм итү. Җәмгыять акчасы әгъзалык кертеме һәм иганә исәбенә туплана. 1917 дән соң таркала.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАЗА́Н СЕЛЕ́КЦИЯ СТА́НЦИЯСЕ**, 1935 елда Югары Идел селекция үзәге б-н Татарстан агрохимия станциясен берләштерү нәтиҗәсендә оеша. 1937 дә СССР ХКСның «Авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын яхшырту буенча чаралар турында» карары нигезендә ТАССР Игенчелек халык комис-тының Казан дәүләт селекция станциясе итеп үзгәртелә. Агротехника һәм селекция өлкәсендә тикшеренүләр б-н, ш.у. район орлыкчылык хуҗалыкларының орлыкчылык участоклары өчен төп кыр культуралары — бөртекләләр, бөртекле-кузаклылар, майлы, күпеллык үләннәрнең элита орлыкларын җитештерү б-н шөгыльләнә. к. *Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты*. Станциядә 1935–36 да язгы бодайның «Альбидум 04749», «Альбидум 04815» (Г.И.*Попов*) сортлары, «Эритросперум 01630», «Ферругенеум 02055» (З.Г.Рязанова) сортлары үрнәкләре булдырыла. 1936 да клеверның «*Казан 1*», 1937–42 дә люцернаның «*Казан 36*», «*Казан 64/95*» (Ж.Х.*Шәрәф*), карабодайның «Казан» (А.Ф.*Шубина*), тарының «*Казан 506*» (Е.П.Ивенина), мәкнең «Татарстан» (А.А.Абдулганиев), арышның «*Казан*» (Е.Н.Борисова, Х.Х.*Байчурова*), 1945–46 да тарының «*Казан 176*», «*Казан 430*» (Г.И.Попов), арпаның «*Казан 6/4*» (Ш.В.*Вәлиев*, П.С.Зубков), бәрңгенең «Казан» (А.Ф.*Демидович*, З.А.Лапаева), тимофеевканың «*Казан*» (Ж.Х.Шәрәф, Ф.М.Киселёв), чиянең «*Минзәлә*» (А.М.Тверетинов, А.С.Вологина, Г.И.*Розанова*), алмагачның «*Волжское*», «Казан», «Урожайное» (Г.И.Розанова) сортлары районлаштырыла. Икееллык виканың селекциясе буенча эшләр алып барыла (печән уңышы 1 *га* дан 90 *ц*).

К.с.с.ндә А.П.*Мосолов*, П.М.*Тихонов*, Г.И.Попов, А.С.Кротов, С.С.*Ильин*, А.А.*Җиһаншин* эшлиләр, соңыннан алар Татарстан а.х. фәне үсешенә нигез салалар; а.х. культуралары агротехникасы буенча һ.б. тикшеренүләр дәвам иттерелә. «Кыр культураларын ашлау» («Удобрение полевых культур», С.С.Ильин, 1940), «Татарстан АССР да кыр культуралары агротехникасы» («Агротехника полевых культур в Татарской

АССР», 1952), «Бөртекле-кузаклы культураларны игү» («Возделывание зернобобовых культур», А.А.Җиһаншин, В.З.Шәкүров, 1953), «Май культуралары» («Масличные культуры», Н.П.Косов, Х.Х.Рәмиев, З.А.Лапаева, 1952) китаплары басыла. 1956 да яңа оештырылган Татарстан республика а.х. тәҗрибә станциясенә кушыла.

К.с.с. җитәкчеләре: М.Ә.*Әхмәтшин* (1935–36), Соколов (1936–37), Н.К.Родыгин (1937–38), А.А.Косушкин (1938–46), П.С.Зубков (1946–50), С.З.Әхмәров (1950–53), М.Я:Кәримов (1954–56).

*Әд.:* Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства — 50 лет. К., 1971.

*А.А.Җиһаншин, И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н СОВЕ́Т ТӨЗЕЛЕШЕ́ ИНСТИТУТЫ́**, РСФСР ҮБК югары уку йорты. 1931 елның 6 маенда Казан ун-тының совет төзелеше һәм хокукы ф-ты җирлегендә ачыла. Идел һәм Урал буе, Кырым, Казакъстан республикаларындагы совет учреждениеләре өчен кадрлар әзерли. Уку вакыты — 3 ел, ел саен 100–150 кеше тәмамлый. Ин-тны тәмамлаучылар 3 төрле белгечлек нигезендә сәнәгать, авыл хуҗалыгы б-н идарә итү органнарына, партия һәм совет кадрлары системаларына эшкә җибәрелә.

РСФСР ҮБКның 1936 ел 26 июнь карары нигезендә ябыла, студентлар һәм укытучылар Казан юридик ин-тына күчерелә.

**КАЗА́Н СОВЕ́Т ЭШЧЕ́-КРӘСТИЯ́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, Казан губернасындагы вакытлы дәүләт берләшмәсе. 1918 елның феврале ахырында Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан Советы тарафыннан 1918 нең 1 мартында Казан губернасы һәм аның күршесендәге өлкәләр территориясендә татар милли дәүләте — *Идел-Урал Штатын* булдыру турында игълан итәргә ниятләгән татар милли-демократик хәрәкәт башлыкларына каршы көрәш барышында оештырыла. Казан Советы 1918 нең гыйнварында *Идел-Урал төбәге Советлары съездын* чакыра һәм халыкларның Идел-Урал Совет Республикасы формасындагы үзбилгеләнүе турындагы резолюция б-н килешмичә, Идел-Урал Штатына каршы К.С.Э.-К.Р. оештырырга тәкъдим итә (к. *Болак арты республикасы*). Аның адм. үзәге Казан була. Казан Советына кергән партияләрнең килешүе буенча, республиканың дәүләт структуралары — Халык Комиссарлары Советы һәм халык комиссариатлары оештырыла, ХКС рәисе итеп Я.С.Шейнкман сайлана, халык комиссариатлары җитәкчеләре раслана: эчке эшләр — В.И.Мохов, җир эшләре — К.М.Шнуровский, азык-төлек — Я.С.Шейнкман, юллар — И.О.Аносов, сәүдә һәм сәнәгать — А.И.Карпов, финанс — В.Н.Скачков, хезмәт — С.М.Брауде, милләт эшләре буенча — С.С.Сәетгалиев һ.б. Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы турында нигезләмә игълан ителгәч (март) һәм гомум-мөселман оешмалары эшчәнлеге тыелгач (апр.-май), бу республиканың кирәге калмый. И.Р.Таһиров фикеренчә, Казан Советы җитәкчеләре Россиянең төзелеш принцибын күз алларына китерә алмыйлар һәм федерация идеясен кабул итмиләр, әмма ничек кенә булса да Штат идеясен башка бер милләтсез идея — бары тик кәгазьдә генә яшәүче К.С.Э.-К.Р. б-н алыштырырга телиләр. 1918 нең 16 маенда Казан губерна Советы башкарма ком-ты карары б-н бетерелә («Совет властеның бер генә органы да андый республиканы игълан итмәде»), аның хакимият вәкаләтләре Казан Советына тапшырыла.

*Әд.:* Тагиров И.Р.История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КАЗА́Н СОЦИА́ЛЬ-ЮРИ́ДИК ИНСТИТУТЫ́**, дәүләти булмаган югары уку йорты. (2004 елдан социаль белем бирү академиясе). 1993 тә Урта һөнәри белем бирү фәнни-тикшеренү ин-ты җирлегендә оеша. Аның б-н берлектә бердәм фәнни һәм укыту комплексы төзи. Укыту юриспруденция, социаль хезмәт, маркетинг, җәмгатьчелек б-н бәйләнешләр, психол., пед. һәм психол., махсус психол., культурология, социаль эш, персонал б-н идарә итү белгечлекләре буенча алып барыла. Институт каршында көллият — урта һөнәри уку йорты эшли. 2010 да көндезге бүлектә якынча 1,5 меңләп, читтән торып уку бүлегендә 3,4 мең чамасы; көллияттә 200 гә якын студент (барысы да — түләүле формада) укый; укытучылар коллективында 150 кеше, ш.и. 12 фән. д-ры һәм 59 фән. канд-ты, аспирантура эшли. Ректоры Г.В.Мөхәммәтҗанова (1993 тән).

**КАЗА́Н СӨЛГЕСЕ́**, Казан татарларының укалап чигелгән традицион йола сөлгесе. Гадәттә туйларда бүләк ителгән һәм, кадерле, затлы әйбер буларак, башлыча, бай шәһәр татарлары көнкүрешендә киң таралган. Формасы һәм бизәге буенча катлаулы һәм ачык төсле К.с. татар йортының интерьерын баеткан, аларны йортларның бүлмә такталарына һәм тәрәзә араларындагы диварларга элгәннәр. Алар Казан (Иске һәм Яңа татар бистәләре) һәм якын-тирә авыллардагы осталар тарафыннан, башлыча, сорау буенча эшләнгәннәр; югары сәнгатьле сыйфатлары булу сәбәпле киң танылганнар һәм татарлар яшәгән төбәкләрдә таралганнар (Идел буе — Урал, Себер). Сакланып калган үрнәкләренең эшләнү вакыты 18 йөз ахыры — 20 йөз башы б-н күрсәтелә. Очлары киң, озынлыгы 3 *м* га якын ак, тыгыз, ефәксыман сөлге тукымасы алтын һәм көмеш җеп б-н чигү (к. *Укалап чигү*), ак һәм төрле төстәге җепләр б-н тамбурлап һәм шома чигү (к. *Чигү*) б-н бизәлә; еш кына баш-башларына яки тешле каймалы чит-читләренә чуклар, чачаклар, ефәк, ука тасмалар, басма бизәкле аеллар (к. *Басма*), металл җептән үрелгән пружина ялтыравыклар һәм бизәкнең башка элементлары өстәлә. Соңрак кәнитил (спираль рәвешендә үрелгән алтын яки көмеш җеп) б-н чигү популярлаша, күбрәк кыйммәтле ефәк (сирәк кенә киҗе-мамык) җепләр б-н (мулинә, гәрес) чигәләр. К.с.нең борынгы үрнәкләрендә оч бизәкләре ян-ягында ике тар кайма, уртада киң буй рәвешендә урнашкан. Аларга уңыш һәм муллык символы — «тормыш агачы» мотивы б-н бәйле чәчәк бәйләме хас. 19 йөз уртасыннан К.с. очларындагы ян-як каймалар бетерелә, чәчәк бәйләмнәре тагын да катлаулана, детальләштерелә, төсләр төрле төсмерләр палитрасы б-н баетыла. Букет геральдикасыннан башка берничә чәчәк бәйләменнән торган композицияләр дә файдаланыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында традицион чәчәк бәйләмнәре композицияләрен сөлге очларының барлык мәйданын алып торучы чәчәк-үсемлек бизәкләре алмаштыра; асиметрия барлыкка килә, кош, күбәләк, умарта корты, сурәтләре бизәк рәвешендә кулланыла. 20 йөз башыннан К.с. әкренләп көнкүрештән төшеп кала, аларның урынын кызыл-ак төстәге өйдә сугылган йола сөлгеләре ала. К.с. бүләк һәм сувенир эшләнмә буларак җитештерү 1980 елларда Казан тегү ф-касында һәм Халык нәфис кәсепчелеге комбинатында, 1990 елларда «Туран Арт» милли мәдәният үзәге фонды остаханәләрендә (Казан), «Казан өйдә эшләүчеләр комбинаты» ҖЧҖ дә, халык осталарының һәм проф. рәссамнар әсәрләре үрнәкләрендә яңара (М.З.*Бикбулатова*, Ф.Калмурзина, А.Кудряшова, С.Д.*Кузьминых*, Л.Фәсхетдинова, Т.Чудовичева һ.б.). К.с.нең югары зәвыклы сәнгать үрнәкләре Россия халыкларының этнография музеенда (С.-Петербург), ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Уфа, Касыйм, Чистай, Сарапул һ.б. шәһәрләр музейларында саклана.





Казан сөлгеләре. Үрнәкләр. Киндер. Ефәк, ука, алтын һәм көмеш җепләр. Укалап чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; шул ук. Татарский народный орнамент. К., 2002; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х гг.). К., 1995.

*Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАЗА́Н СӨТ КОМБИНАТЫ́**, азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиесе. Тарихы 1929

елдан, Казан үзәк сөт пункты (Островский урамы) төзелә башлаган чордан килә; пункт 1932 дә файдалануга тапшырыла, 1935 тә Казан шәһәр сөт з-ды итеп үзгәртелә. Үзәк сөт пунктының төп инвентаре товар үлчәүләре, кабул итү баклары һәм металл ванналар, агач чаннар, 2 кул сепараторы, пастеризаторлар, май язгыч һәм май эшкәртү җайланмасыннан гыйбарәт була; пар казаны куела. Сөт пункты тәүлеккә 15 *т* сөт эшкәртү куәтенә ия булып, беренче чиратта хастаханәләрне һәм балалар учреждениеләрен продукция б-н тәэмин итә (сөтнең бер өлешеннән май языла, каймак һәм эремчек эшләнә). Технологик процесс, башлыча, кул көче б-н башкарыла. Чимал республиканың тирә-яктагы 8 районыннан китерелә. 1936 да завод нәтиҗәлерәк җитештерү җиһазлары б-н коралландырыла, күп көч таләп ителгән эшләр механикалаштырыла; Горький шәһәр сөт з-дыннан кайтарылган 2 эремчек ваннасы һәм 2 яссы суыту җайланмасы урнаштырыла; электрлаштырыла. Бөек Ватан сугышы елларында завод (1942 дә аның терр-ясенә Брянск шәһәр сөт з-ды эвакуацияләнә) хәрби пр-тиеләр, госпитальләр һәм балалар учреждениеләре ихтыяҗлары өчен эшли: ацидофил пастасы, кесәл, суфле, сыер маеннан һәм көнбагыш маеннан кайнатылган май җитештерелә; җитештерү калдыкларыннан сабын кайнаталар. 1950 еллар башында пр-тиедә суыту һәм пластинкалы пастеризацияләү-суыту җайланмалары, яңа буын сепараторлар, шешәләргә бүлеп салу машинасы эшкә җигелә. 1953 тә сөт продукциясе җитештерү сугышка кадәрге күрсәткечләрдән 10 тапкыр күбрәк күләмгә җитә һәм 60 мең *т* дан арта. 1959 да тәүлеккә 100 *т* сөт эшкәртү куәтенә ия яңа сөт з-ды төзелә һәм файдалануга тапшырыла (акад. Арбузов ур.). 1960 та Казан шәһәр сөт з-ды К.с.к. итеп үзгәртелә, 1960–70 елларда анда 426 берәмлек нәтиҗәлерәк җитештерүле технол. һәм энергетик җиһаз, ш.и. пастеризацияләү-суыту җайланмалары, флягаларга бүлү машинасы, суыту җайланмалары, сөтне шешәләргә бүлеп салу линияләре, каймакны һәм эремчекне савытларга салу-төргәкләү автоматлары, пар казаннары гамәлгә кертелә. Яңа техника һәм технол. куллану, цехларны реконструкцияләү нәтиҗәсендә комб-тның куәте сменага 140 *т* га кадәр сөт эшкәртерлек дәрәҗәгә җиткерелә. Продукция төрләре дә күбәя. Белгечләр татар милли ачы сөт продуктлары — катык, сөзмә, кулинария өчен корт, коры сөт ярымфабрикаты җитештерү технологиясен эшләп, аны призводствода файдалануга кертәләр; бу продуктлар 1968 дә СССР ВДНХсында Сөт продуктларының яңа төрләре павильонында күрсәтелеп, 3 нче урынга лаек була. 1964 тә чәй сыры эшләп чыгару, кефирны резервуар ысулы б-н җитештерү технологияләре гамәлгә кертелә. 1970–90 елларда пр-тие шактый гына киңәйтелә (2 җитештерү корпусы, котельный, склад биналары, аертылмаган сөт алыштырылмасын җитештерү цехы төзелә), куәте тәүлеккә 700 *т* га кадәр сөт эшкәртерлек дәрәҗәгә җиткерелә. Ачы сөт продуктларын резервуар ысулы б-н җитештерү ысулы, эремчекне аерым эшләп чыгару алымы гамәлгә кертелә, сөт продуктларының яңа төрләре — «Коломенский» эчемлеге, баетылган сыворотка һ.б. үзләштерелә. Каймак-эремчек продукциясе (1988) һәм сырлар (2001) җитештерү корпусында реконструкция уздырыла. Сөт продуктларын эшләп чыгару, аларның төрләре, бигрәк тә озак саклауга исәпләнгән төрләре арттырыла. Төргәкләү материалын камилләштерү һәм аның дизайнын яхшырту буенча эшләр башкарыла. 1990 да К.с.к. — аренда пр-тиесе, 1994 тә структурасына 2 түбәнге завод (Питрәч, Биектау з-длары) һәм 40 тан артык кибетне үз эченә алган сәүдә фирмасы кергән АҖ итеп үзгәртелә.

2002 дән комб-т — «Татарстан сөте» АҖнең (2006 да «Вамин-Татарстан» АҖ итеп үзгәртелә) ф-лы. Эшләүчеләр саны — 1 меңнән артык кеше (2009). 4 җитештерү корпусы бар. 2008 дә асептик савытларга салынган стерилләштерелгән сөт җитештерү линияләре урнаштырыла. 2009 дан ультрапастеризацияләнгән «Мой милок» сөте һәм кайнатылган сөт, 2010 нан шул ук исемдә полиэтилен стаканнарга тутырылган каймак эшләп чыгарыла. Төп продукциясе: пастеризацияләнгән сөт, эремчек продуктлары, ачы сөт продукциясе, каймак, майсызландырылган коры сөт, йогуртлар, сырлар, атланмай. Продукциянең яңа төрләре арасында — шикәр диабеты б-н авыручылар өчен «Тонус» ачы сөт продукты, биойогуртлар, диетик йомшак эремчек, «Голландский», «Российский», «Витязь», «Фаворит», «Сусанинский» сырлары.

К.с.к. Бөтенроссия сөт фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү), Алтай сыр фәнни-тикшеренү ин-ты, «Углич» фәнни-тикшеренү берләшмәсе (Ярославль өлкәсе) б-н хезмәттәшлек итә. Эшкәртү өчен чимал республиканың 14 районыннан китерелә. Продукция Казанга (700 дән артык сәүдә һәм җәмәгать туклануы пр-тиеләренә) һәм ТРның башка шәһәрләренә чыгарыла, ш.у. Мәскәүгә, С.-Петербургка, Екатеринбург, Түбән Новгород, Самара, Чиләбе, Киров шәһәрләренә, Казакъстанга җибәрелә.

Комбинатның күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 18 кешегә ТРның атказ. азык-төлек индустриясе хезмәткәре һәм ТРның атказ. авыл хуҗалыгы хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә; 1 кеше — Ленин ордены, 1 кеше — Октябрь Революциясе, 2 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — «Почёт билгесе» орденнары, ш.у. 19 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре арасында — И.А.Арефьев (1932–41), А.Х.Хәлиуллин (1941–?), П.П.Черзер (1950–59), А.М.Мачихин (1959–61, 1965–71), И.Г.Мирошниченко (1971–92), В.Ф.Верещагин (1992–98), Ә.М.Гатауллин (1998–2008), И.М.Зәкиев (2008 дән).

Ш.у.к. *Сөт һәм сыр-май җитештерү сәнәгате.*

*Әд.:* Донбулатов М.Ш., Закиров Т.З. Молочная промышленность Татарии. К., 1974; ОАО «Казанский молочный комбинат»: От прошлого — в будущее. К., 2002.

*И.Ф.Алиуллов, Г.Я.Мәүлетова.*

**КАЗА́Н СТОМАТОЛО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, югары уку йорты. 1936 елда Казан мед. ин-тының стоматология кафедрасы һәм стоматология клиникасы нигезендә ачыла. Институтта 26 кафедра, ш.и. 3 се профильле (терапия, стоматология ортопедиясе һәм хирургиясе, клиника һәм поликлиника) була. Күренекле галим стоматологлар С.И.*Вайс*, И.М.*Оксман*, И.М.*Утробин* һ.б. эшлиләр; гомуми мед. дисциплиналарын Казан мед. ин-тының әйдәп баручы профессорлары укыта. Һәр елда 100 студент кабул ителә. Барлыгы 1 меңгә якын белгеч әзерләнә. 1954 тә К.с.и. Казан мед. ин-тының стоматология ф-ты итеп үзгәртелә (к. *Казан медицина университеты*).

*Әд.:* Тихонов Г.Ф. Казанский государственный стоматологический институт к 30-летней годовщине Великой Октябрьской социалистической революции // Тр. Казан. гос. стоматологического ин-та. 1949. Вып. 2.

**КАЗА́Н СТУДЕНТЛАРЫ́ ҖЫЕНЫ́** (1887), Казан ун-ты һәм вет. ин-ты студентларының патша хөкүмәтенең халык мәгарифе өлкәсендәге сәясәтенә каршы чыгышы. Җыенда 300 гә якын кеше катнаша, аеруча актив катнашучылар: К.Гладков, А.Орловский, В.Ульянов (В.И.*Ленин*), С.Ферапонтов (Казан ун-ты), А.Борецкий, Н.Мотовилов, Н.Мышкин, Г.Серебренников, Л.Скворцов, К.Тихановский (вет. ин-ты). 1887 елның 4 декабрендә көндезге 12 ләр тирәсендә студентлар университетның актлар залын биләп ала. Алар ком-т сайлыйлар, аннан соң петиция һәм «Җәмгыятькә» дигән мөрәҗәгать укыла. Петициядә студентларның җыеннарга хокукы, үз китапханәләренә һәм уку залларына хокукы, уку йортларына керүне кыенлаштыра торган сословиечел һ.б. чикләүләрне бетерү, үз хокукларын яклау максатындагы





Казан сөт комбинаты. 1. 1 нче производство корпусының аппаратлар цехы; 2. Аертылмаган сөттән эшләнгән продукция.

чыгышлары өчен укудан чыгарылган барлык студентларны кире уку йортына кайтару турында таләпләр куела. Петиция университет ректоры Н.А.Кремлёвка тапшырыла. Гаскәр кертелү куркынычы булганлыктан, җыен 15 сәг. 45 минутта оешкан төстә туктатыла. 99 студент үзләренең студент билетларын ректорга калдырып чыга. Иң актив катнашучылар кулга алына, соңрак административ тәртиптә Казаннан сөрелә (алар арасында В.Ульянов та бар). Университеттан 164 студент, вет. ин-тыннан 33 студент чыгарыла. Аларның күбесе соңыннан Россиянең иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә актив катнашуларын дәвам итә һәм төрле сәяси партияләр әгъзалары була.

*Әд.:* Нафигов Р.И. Первый шаг к революции. К., 1970; Бурнашева Ю.В., Нафигов Р.И. В.И.Ленин в Казанском университете. К., 1987. *В.А.Шагалов.*

**«КАЗА́Н СТУДЕНТЛАРЫ́ КИТАПХАНӘСЕ́»**, Мәскәү ун-ты студентларының 1856–62 еллардагы иҗтимагый-сәяси оешмасы. Казан ун-тыннан күчкән студентлар тарафыннан рәсми якташлык китапханәсе буларак оештырыла, көндәлек рус басмалары, ш.у. Көнбатыш Европа фикер ияләре (П.Ж.Прудон, Л.Блан һ.б.) хезмәтләре б-н тулыландырыла, үзлектән белем күтәрү буенча студентлар түгәрәкләре үзәкләренең берсе була. Җитәкчесе — А.Ф.Маккавеев. 1859 елда китапханә канаты астында 50 дән артык кешене берләштергән яшерен оешма барлыкка килә. Җитәкчеләре: Ю.М.Мосолов, Н.М.Шатилов һ.б. «К.с.к.» составына студентларның Заичневский-Аргиропуло түгәрәге әгъзалары (алар тыелган әдәбиятны литографта бастыру һәм тарату б-н шөгыльләнә), ш.у. Мәскәү гарнизонының берничә офицеры керә. «К.с.к.» Казан һәм С.-Петербургтагы студентлар түгәрәкләре, полякларның Мәскәүдәге «Огул» җәмгыяте б-н элемтәдә тора. 1862 дә «Земля и воля»ның Мәскәү бүлекчәсе составына керә. Түгәрәкнең берничә әгъзасы 1863 тә Андрущенко эше б-н бәйле рәвештә Себергә сөрелә. Шуннан соң оешма яшәүдән туктый.

*Әд.:* Нечкина М.В. «Земля и воля» 1860-х гг. (По следственным материалам) // История СССР. 1957. № 1; Революционная ситуация в России в 1859–1861 гг. М., 1965; Эпоха Чернышевского. Революционная ситуация в России в 1859–1861 гг. М., 1978; Революционная ситуация в России в середине XIX в.: Деятели и историки. М., 1986.

**КАЗА́Н СУ ТӘЭМИНАТЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Петербург АҖ бүлекчәсе. Россия МКның 1873 елның 28 декабрендә император Александр II тарафыннан расланган Нигезләмәсе б-н төзелә. Оештыручылары — П.И.Губонин, М.П.Козлянинов, инженер-технолог А.Ф.Буров. Төп капиталы — 900 мең сум, әйләнеш капиталы — 450 мең сум. Казанның казна, җәмәгать һәм аерым затлар йортларында суүткәргеч челтәре кору һәм аны файдалануга яраклы хәлдә тоту б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында суүткәргеч челтәренең озынлыгы 68 чакрым тәшкил итә, 22 сулыктан файдаланыла. Суүткәргечтән тәүлеккә 400 мең чиләк чамасы чистартылмаган су җибәрелә, ул чүлмәк һәм чуен торбалар буйлап чишмәләрдән килә. Су җыйгычлардан алынган 100 чиләк су өчен 17 тиен, шул ук күләмдә урамнарга сиптерү өчен 10 тиен түләнә. Йортларда суның күләме су үлчәгеч б-н билгеләнгән яки тулаем еллык түләү б-н һәр кешегә көнгә 3 чиләк күләмендә бирелгән.

Суүткәргеч корылмаларның бәясе 1,6 млн. сум тәшкил иткән, аларны еллык файдалануга 48 мең сум чамасы акча сарыф ителгән. Эшчәнлеге 1875 тә башланып, 1878 гә кадәр җәмгыять зыянга эшли һәм бик аз керем ала. Акрынлап су сатудан керем арта башлый һәм 20 йөз башында елга якынча 40 мең сум тәшкил итә. Эшче һәм солдат депутатларының Казан губерна советының 1918 ел 28 март карары б-н җәмгыятьнең пр-тиеләре национализацияләнә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1876. Т. 48. № 52950; Сборник сведений о настоящем состоянии городского хозяйства в главнейших городах России. Самара, 1889.

*Әд.:* Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921 гг.). М., 1976. *Е.Б.Долгов, Г.Р.Заманова.*

**КАЗА́Н СУВО́РОВЧЫЛАР ХӘРБИ́ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, РФ Оборона министрлыгының хәрбиләштерелгән гомуми урта уку йорты. 1944 елда оештырыла. Югары хәрби уку йортларына керергә әзерли. Уку вакыты өч ел (8 сыйныф базасында). 2010 да 650 укучы белем ала; коллективта 51 кеше, ш.и. 1 — РФнең атказ. укытучысы, 6 — ТРның атказ. мәктәп укытучысы. Училищене 13 меңнән артык кеше тәмамлый. 1974–84 тә уч-щенең башлыгы Сов. Союзы Герое ген.-майор Н.К.*Горбанёв* була. Уку йортын тәмамлаучылар арасында Сов. Союзы Герое, ген.-майор А.Л.Солуянов, РФ Геройлары Р.В.Игошин, В.В.Макаров, С.З.Тулин, В.А.Чебанов бар. Училище элеккеге *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты* бинасында урнашкан (1841 дә төзелә, архит-ра истәлеге). Клуб, спорт комплексы (стадион, спорт шәһәрчекләре һәм заллары, бассейн, тирлар) эшли.

*Әд.:* Белов А. Мы из Казанского суворовского. М., 1999.

**КАЗА́Н СЫНЛЫ́ СӘНГА́ТЬ МӘКТӘБЕ́**, урта махсус уку йорты. Петербург СА каршындагы «Россиянең рәсем ясау мәктәпләренә кагылышлы мәсьәләләрне тикшерүче комиссиясенә» Казан шәһәр думасы һәм бер төркем рәссамнарның (Н.Н.*Белькович*, Х.Н.*Скорняков*, Г.А.*Медведев*, Ю.И.*Тиссен*, И.А.*Денисов*, Л.В.Шервуд) үтенече нигезендә оештырыла. СА нең игътибары нәкъ менә Казанга юнәлә, чөнки ул — «Россиядәге бөтен Шәрекънең төп агарту үзәге. Халыкка сәнгать белемнәрен әкренләп шуннан бирә башлау лязим, башта Идел-Чулман ягына, ә аннары Себергә күчәргә», — диелә.

Гамәлгә куелучы мәктәпнең максатлары аның уставының беренче параграфында да әйтелә: «җирле халыкның сәнгать үсешенә һәм аларның СА каршындагы Югары сәнгать училищеларына укырга керүләрен күздә тотып, нәкышьче-рәссам, гравёр, сынчы, архитекторларга әзерлек белемнәре бирүдә ярдәм итү». 1895 елның 9 сентябрендә ачыла. СА карамагында тора, җитәкчелек Попечительләр ком-ты (төрле елларда аның әгъзалары арасында губернатор П.А.Полторацкий, шәһәр башлыгы С.В.Дьяченко, Казан ун-ты профессорлары Д.В.*Айналов*, А.М.*Миронов* һ. б. була) һәм укытучылардан торган пед. совет тарафыннан башкарыла. Мөдирне 3 елга сайлап куялар, аңа рәссам-педагоглар Н.Н.Белькович (1895–98), К.Л.*Мюфке* (1898–1901), Г.А.Медведев (1901–04, 1908–16), Ю.И.Тиссен (1904–08), И.А.Денисов (1917) сайлана. Устав нигезендә мәктәптә 4 махсус бүлек: нәкышь (1895 тән), гравёрлык (1896–1908), архит-ра (1897 дән), скульптура (1904 тән) бүлекләре ачыла. Махсус фәннәр укытучылары югары сәнгать белеменә ия була һәм дәүләт хезмәтендәгеләрнең барлык хокукларыннан файдалана. Мәктәпне тәмамлаучыларга урта уку йортларында рәсем укытучысы дәрәҗәсе, ә беренче, югары дәрәҗә б-н тәмамлаучыларга СА каршындагы Югары сәнгать уч-щесенә укырга керү хокукы бирелә. Махсус бүлекләргә башлангыч рәсем ясау курслары үткәннән соң алганнар. Мәктәптә укыту укучыларның алга таба сайлаячак белгечлегенә бәйсез рәвештә гомумсәнгать әзерлеге дәрәҗәсенең көчле



Казан сынлы сәнгать мәктәбе. Арх. К.Л.Мюфке. 1901–02. 20 йөз башы фоторәсеме.

игътибар үзәгендә булуы б-н аерылып тора. Рәсемгә, сурәтләү сәнгатенең нигезе буларак, аеруча зур игътибар бирелә һәм ул, вакытлар үтү б-н, уку йортының үзенчәлекле традициясенә әверелә.

Укучылар арасында нәкышь бүлеге аеруча популярлык казана. Бүлекнең оештыручылары һәм педогоглары — Н.Н.Белькович, Х.Н.Скорняков,И.А.Денисов, Г.А.Медведев, 1908 дән — Н.И.*Фешин*, П.П.*Беньков*, П.С.Евставьев укучыларның проф. әзерлегенә һәм идея-иҗади формалашуына зур йогынты ясыйлар. Мәктәпне тәмамлаучылар арасында — рәссам-педагоглар К.М.Лепилов, А.М.Соловьёв, танылган осталар М.Спиридонов, Н.Сверчков, Р.Либерт, Д.Д.*Бурлюк*, А.М.*Родченко,* А.Григорьев, К.К.*Чеботарёв*, А.Г.*Платунова*, Н.М.*Сапожникова* һ.б. бар.

Укучылар саны ягыннан икенче урында торган архит-ра бүлегендә аның оештыручысы һәм җитәкчесе К.Л.Мюфке (1897–1912), шушы вазифаны дәвам иттерүче П.И.Абрамычев, ш.у. Ф.Р.Амлонг (1900–03), А.Горохов (1905–08), М.С.Григорьев (1912–15) укыта. Бүлек 19 — 20 йөзләр чигендә төбәктә төзелеш эшләре киңәю һәм технологияләр катлаулану сәбәпле ихты-

яҗ артканга күрә, архит-ра-төзелеш өлкәсе өчен урта квалификацияле кадрлар әзерли. Бүлектә күренекле Казан (П.Т.*Сперанский*, Ф.П.*Гаврилов*, М.С.Григорьев, Д.М.Фёдоров), ш.и. сов. чоры архитекторлары (А.М.Рухлядев, С.О.Овсянников, Э.Я.Штальберг һ. б.) укып чыга.

Мәктәпнең скульптура бүлеге төбәктә сәнгатьнең иң аз үскән төре — сыннар ясау тармагы үсешендә хәлиткеч роль уйный. Бүлекне оештыручы — П.В.*Дзюбанов* (1904–08). Аның дәвамчысы В.С.*Богатырёв* (1908) мәктәпнең талантлы педагогы буларак кына түгел, әсәрләре «җирле һәм башка шәһәрләрдән килгән рәссамнарның периодик күргәзмәләрендә» даими куелып килүче актив, иҗади эшләүче сынчы буларак та таныла. Укучылары — күренекле сынчылар Г.Козлов, Я.Кац, К.Ф.*Зале*, сынчы-педагог О.В.Витман (Арбузова).

Гравёрлык бүлеге, сәнгатьнең мөстәкыйль төре буларак, графиканың алга таба үсешенә булышлык итә; кискеч б-н эшләнүче гравюра һәм офорт укытыла. Бүлекне оештыручы һәм аның җитәкчесе — Ю.И.Тиссен (1896–1908). Укучылары арасында күренекле рәссам-графиклар Л.Ф.Овсянников, П.М.*Дульский* һ. б. бар.

Мәктәптә ш. и. һәркем укырга керә алырлык бушлай якшәмбе рәсем класслары, музей һәм сәнгать буенча махсус китапханә эшли. СА каршындагы «Провинция музейларына әсәрләр җибәрү комиссиясе» музейны оештыруда төп чыганак була. Мәктәп музеенда Б.Микеланжело, А.Канова, Б.Торвальдсен, Э.М.Фальконе, С.С.Пименов, С.И.Гальберг әсәрләреннән югары сыйфатлы гипс күчермәләре, Ф.И.Иордан, А.Г.Ухтомский, В.В.Матэ гравюралары, И.Е.Репин, И.Н.Шишкин, А.П.Боголюбов һ. б. ның нәкышь картиналары урын ала.

1896 дан мәктәп «төбәктә сәнгать белеме дәрәҗәсен күтәрүне һәм укучыларның зәвыгын үстерүне кайгыртып, ш.у. моның югары тәрбияви әһәмиятен күздә тотып», ел саен «Җирле һәм читтән килгән рәссамнарның периодик күргәзмәсе»н үткәрә. Күренекле осталар — И.Е.Репин, И.И.Шишкин, В.В.Матэ, В.Е.Маковский, К.Я.Крыжицкий, Г.Г.Мясоедов һ.б. катнашында барысы 15 күргәзмә уздырыла. Шуларның иң зурларыннан — «Хәзерге заман рус сәнгате» күргәзмәсендә (1909) Россиянең күп кенә әйдәп баручы сәнгать берләшмәләреннән — Күчмә нәкышь күргәзмәләре ширкәте, «Рус рәссамнары берлеге», «Рәссамнарның яңа җәмгыяте», «Салон», «Язгы күргәзмә» һ.б.ның әсәрләре тәкъдим ителә. Мәктәп катнашында Казанның сәнгать тормышы тарихында вакыйга булган «Казанның сәнгать хәзинәләре» исемле зур шәхси тупланмалар күргәзмәсе оештырыла (1916). 1900 да мәктәп каршында хәйрия максатларында «Укучыларга ярдәм итү җәмгыяте» төзелә һәм ул сәнгать әсәрләренә заказлар кабул итү, хәйрия максатында спектакльләр һәм костюмлы баллар оештыру б-н шөгыльләнә.

Мәктәп эшчәнлеге сәнгать практикасының педагогика һәм тәрбиягә, һөнәрчелек сәнгатенә, полиграфиягә, актив үтеп керүенә музейлар төзелешен һәм күргәзмә эшчәнлеген интенсивлаштыруга, сәнгати тәнкыйть һәм сәнгать белемен үстерү өлкәсенә юл ача. Анда илнең 30 га якын губернасы вәкилләре һәм чит ил гражданнары (болгарлар, австриялеләр) белем ала. Эшчәнлеге дәверендә мәктәпне 348 укучы һәм 1526 ирекле тыңлаучы тәмамлый. Анда тәрбия алган сәнгать әһелләре Казан төбәгендә генә түгел, Башкортстан, Чувашия, Мордва, Удмуртия, Үзбәкстан, Ерак Көнчыгыш, Латвия һәм илнең башка төбәкләрендә сәнгатьне аякка бастыруда һәм үстерүдә әйдәүче көч булып әвереләләр. 1918 дә илнең сәнгать белемендә гомуми реформа үткәрелү һәм СА бетерелү сәбәпле, мәктәп Дәүләт ирекле югары сәнгать остаханәләре (к. *Казан сынлы сәнгать училищесе*) итеп үзгәртелә.

1895–1900 елларда мәктәп Вагнер йортының аренда бүлмәләрендә урнаша. К.с.с.м.нең үз бинасы 1901–02 елларда арх. К.Л.Мюфке проекты буенча төзелә. Ул өч катлы, кирпечтән, Н-рәвешле бина һәм аңа кушып салынган бер катлы йорттан тора, 300 укучыга исәпләнә, 6 гомуми кичке рәсем классын, төньяк фасадында түбәдә зур тәрәзәләре булган 2 нәкышь, 6 гомуми белем бирү, рәсемнәр бастыру бүлмәсе булган архит-ра һәм гравюра классларын, актлар залын һәм 2 музей һәм күргәзмәләр залын сыйдыра. Төп фасад композициясе өч өлештән тора: ян-якларын ризалитлар б-н бүленеп алынган, үзәк өлешендә — ике колонналы, портиклы, антаблементлы төп ишек биек пьедесталга урнаштырылган. Ишек өстендәге а́рка тәбәнәк капительле, шомартылган мәрмәр колонналарга таяна (Мюфкеның мәктәпкә бүләге). Портик уеп бизәкләнгән ярым парапетлы кәрниз б-н төгәлләнә. Үзәк өлеш 2 нче кат биеклегендә, капительле, өч чирекле колонналар б-н аерылып тора. Ишек өстенә шлем рәвешендәге фонарь беркетелгән. Фасадларны бизәү өчен Ананьино известьташы, Кукар ак ташы кулланылган. Бинаның үзәк өлешендә тимер бәпкәләр файдаланылган, интерьерда — күпертмә бизәкләр, «КХШ» эмблемасы һәм сәнгать атрибутлары (кыл-каләм, палитра, циркуль һ. б.). Байтак алымнар Мюфке тарафыннан конкурста катнашкан «Хәрби-тарихи музей» диплом проектыннан күчерелгән. Бина төзегәндә Мюфке җитәкчелегендә аның укучылары — Караулов, Парашин, Рогозин, Латышев, Штальберг, Смирнов катнаша. 1941 дән К. с. с. м.ндә Казан техник ун-тының уку корпусы урнаша. 2004 тә бина Казан сынлы сәнгать училищесенә тапшырыла.

*Е.П.Ключевская.*

**КАЗА́Н СЫНЛЫ́ СӘНГА́ТЬ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, Н.И.Фешин исемендә. ТР Мәдәният министрлыгының урта һөнәри уку йорты. Тарихы 1895 елдан *Казан сынлы сәнгать мәктәбеннән* алып барыла, ул 1918 дә Казан ирекле сәнгать остаханәләре итеп үзгәртелә, 1920 дә Казан югары сәнгать-техника остаханәләре, 1921 дән Казан сәнгать ин-ты, 1922 дә Казан архит-ра-техника ин-ты, 1926 да Казан сәнгать-пед. техникумы. 1927 дән сәнгать белгечлекләре буенча махсус урта белем бирү Казанның берләштерелгән сәнгать-театр техникумында, 1932 дән Татар сәнгать техникумында тормышка ашырыла. 1935 тә аннан К.с.с.у. аерылып чыга. Н.И.Фешин исеме 2006 елда бирелә.

Төрле елларда танылган рәссамнар: Н.И.Фешин, К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, Н.С.Шикалов, И.Н.Плещинский, Б.И.Урманче, В.С.Богатырёв, Ф.С.Быков, В.К.Тимофеев, А.Н.Кашаев, С.С.Ахун, М.М.Васильева, Н.Н.Ливанова, П.Т.Сперанский, В.И.Куделькин, С.А.Ротницкий, Е.В.Зуев, Т.А.Зуева, Ә.И.Тумашев укыталар.

1918 дән 1,5 меңгә якын белгеч әзерләнә. Уку йортын тәмамлаучылар арасында: — У.Н.Абдуллов, А.Ә.Абызгилдин, Н.И.Адылов, Н.С.Артамонов, И.Н.Башмаков, Д.Г.Булат, К.А.Васильев, З.Ф.Гыймаев, Р.Ә.Госманов, И.К.Зарипов, В.П.Игнатьев, Р.Ф.Имашев, В.В.Карамышев, И.И.Князьков, Н.Д.Кузнецов, С.О.Лывин, Ю.Б.Лысогорский, Ә.Н.Мәҗитов, В.М.Маликов, К.А.Нәфыйков, С.В.Неустроев, В.А.Попов, И.В.Рәфыйков, Г.Г.Рахманкулова, Р.Т.Сафиуллин, Е.А.Симбирин, В.Н.Скобеев, Н.М.Сокольский, Л.Л.Сперанская, М.Г.Сутюшев, Ә.И.Тумашев, М.Г.Усманов, Л.Г.Фәттахов, В.К.Фёдоров, Т.Г.Хаҗиәхмәтов, Ф.Ш.Хәсьянова, Х.Г.Якупов бар.

Укыту нәкышь сәнгате (60 ка якын студент), скульптура (10 лап), дизайн (60), декоратив-гамәли бизәлеш сәнгате һәм халык промыселлары (30) белгечлекләре буенча алып барыла.

2010 да 160 ка якын укучы; укытучылар коллективында 20 кеше, ш.и. 1 — ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе, 2 — ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре, 1 ТРның атказ. укытучысы эшли. Әзерлек бүлеге бар. 1941 дән училище Мөштәри урамында, элеккеге Осокиннар йортында урнаша, архит-ра истәлеге (арх. И.П.Бессонов, 1849).

**«КАЗА́Н ТАҖЫ́»,** Казан ханнарының баш киеме, якынча 15 йөз —16 йөзнең беренче яртысы; Казан ханлыгы чорындагы татар *зәргәрчелек сәнгате* истәлеге. Риваятьләр буенча, 1552 елда Казан ханлыгы яулангannan соң Мәскәүгә алып кителә һәм рус патшалары таҗына әверелә. Татар баш киемнәренә хас формада башкарылган: кыйммәтле мех (кеш) салынган ярымшар сыман таҗ (*тәкия*). «К.т.» на сузынкы формалы гәрәбә 1552 дән соң сакланмаган элеккеге бизәге урынына өстәлә. Алтын түбәсенең каралтылган нигезенә (к. *Каралту*) юка рельефлы бизәк төшерелгән; түбә өслегенә катлаулы арабеска бизәге стилендә тирән уемланган тукранбаш үсемлеге формасында төгәлләнгән алтын аеллар урнаштырылган. «К.т.» ның асылташлар б-н корлау системасы һәм төсләр сайланышы татар зәргәрчелек сәнгатенә хас (к. *Корлау*): алсу зәңгәр альмандиннар һәм кызыл гранат б-н яраштырылган зәңгәр-күк фирәзә, яшел яшма һәм кызыл топаз — татарлар могҗиза көчкә ия дип санаган саклагыч ташлар. Сәнгать белгече Ф.Х.*Вәлиев*, «К.т.» ның бизәлеш элементларына, сыйфатларына, асылташлар б-н корлау системасына анализ ясаганнан соң, аны татар зәргәрчелек сәнгате әсәре дип атый («Казан татарлары бизәге» —



«Казан таҗы» (хан таҗы). Алтын, асылташлар. Уеп бизәкләү, каралту. 15–16 йөзнең 1 нче яртысы. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы.

«Орнамент казанских татар». К., 1969). «К.т.» ның Мәскәүгә алып кителгән татар зәргәрчеләре тарафыннан эшләнүе турындагы фикер («Рус сәнгате тарихы» — «История русского искусства», М., 1959, Т. 4) яклау тапмый. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында саклана. 1990 еллар ахырында «К.т» ның күчермәсе эшләнә (зәргәрчеләр Ш.Латыйпов һәм Ш.Хәялиев). Татар халкының мөкатдәс истәлеге буларак, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее экспозициясенә куела. Ш. у. к. *Гамәли бизәлеш сәнгате*.

*Әд.:* Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г. Ф. Древнее искусство Татарстана. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАЗА́Н ТАТА́Р ПЕДАГО́ГИЯ ТЕ́ХНИКУМЫ**, элеккеге *Казан татар укытучылар мәктәбе* җирлегендә 1921 елда ачыла. 1929 да аңа керәшен пед. техникумы кушыла һәм К.*Насыйри* исеме бирелә. 1930 да чуаш һәм рус техникумнары б-н бердәм Казан пед. техникумына берләштерелә, хәзер *Казан педагогия көллияте*.

1921–30 елларда 1 меңнән артык башлангыч сыйныф укытучылары һәм мәктәпкәчә учреждение тәрбиячеләре әзерләп чыгара. Техникум башлангыч татар мәктәпләре өчен методик ярдәмлекләр, әсбаплар, укыту программалары төзү өчен төп нигез булып тора. Анда М.Ә.*Фазлуллин*, В.М.*Горохов* һ.б. укыта.

*Әд.:* Мукминёв Т.Н. Из истории среднего педагогического образования в Татарской АССР // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1958. Вып. 13.

**КАЗА́Н ТАТА́Р УКЫТУЧЫЛА́Р МӘКТӘБЕ́**, 1876 елда ачыла. *Рус-татар училищеләре* укытучылары әзерләү өчен оештырыла. К.т.у.м.нең эше Татар укытучылар мәктәпләре турындагы 1872 ел, 27 март Нигезләмәсе б-н билгеләнә. Казан уку-укыту округының татар мәктәпләре инспекторы В.В.*Радлов* инициативасы б-н ачыла.

Мәктәпкә рус-татар уч-щеләрендә, мәдрәсәләр каршындагы рус сыйныфларында рус теленнән башлангыч белем алган яшүсмерләр кабул ителә. Алар барысы да диярлек дәүләт хисабына укый, тулай торакта яши, туклану, форма киеме б-н тәэмин ителә. 1876 да расланган уку планы буенча, уку срогы 4 ел була, ул 40 ел дәвамында үзгәрми. Төп фәннәргә — рус теле, педагогика һәм дидактика, пед. практикага зур урын бирелә, соңгысы мәктәп каршындагы үрнәк рус-татар уч-щесендә уздырыла (1881 дә ачыла). Матем., тарих, геогр., табигать белеме, рәсем дәресләре *шәһәр училищеләре* программасы буенча укытыла. Ислам дине тәгълиматын өйрәнүгә күп сәгатьләр бирелә. Аңардан кала, барлык фәннәр дә рус телендә укытыла. Беренче унъеллыкта мәктәпкә ел саен 10–15 кеше кабул ителә, 20 йөз башына бу күрсәткеч 20 кешегә җитә.

Мәктәпнең инспекторлары: М.*Мәхмүдов* (1876–81), Ш.И.*Әхмәров* (1881–1900), М.Н.*Пинегин* (1900–07), В.П.Брюханов (1907–11), В.А.Зеленецкий (1911–12), И.М.Крестников (1912–17). Эшли башлавының беренче елларыннан ук мәктәп югары дәрәҗәдәге уку йортына әверелә, аны тәмамлаучылар рус телендә иркен сөйләшә торган квалификацияле белгечләр була. Рус телен барлык инспекторлар, ш.у. атаклы педагоглар А.И.*Анастсиев*, В.А.*Богородицкий*, М.А.*Васильев* укыта. Пед. практика б-н үрнәк уч-щенең тәҗрибәле укытучылары җитәкчелек итә. Укучылар ш.у. мөселман дин белемен дә өйрәнәләр. Аның беренче укытучысы Ш.*Мәрҗани* була (1876–84). Аны Т.Г.*Яхин* (1885–1909) алыштыра, ул үзе дә К.т.у.м. тәмамлый, үзләре төзегән уку ярдәмлегенә таянып, дин белеме нигезләрен укытуның яңа алымлы курсын эшли.

Табигать белемен 1880–1906 да И.В.*Терегулов* укыта. Аның инициативасы б-н мәктәпкә физ., химия, биол. буенча иң яхшы күрсәтмә уку ярдәмлекләре алына. Рәсем дәресләрен татарлардан иң беренче дипломлы рәссам Ш.Ә.*Таһиров* (1885–1917) алып бара, тарих, география, математиканы университет белеме булган тәҗрибәле укытучылар, ш.и. П.В.*Траубенберг*, А.В.*Васильев* укыта. 1905 тән соң укыту сыйфаты түбәнәя башлый.

Татар җәмәгатьчелегенең мәктәпкә карата мөнәсәбәте баштан ук тискәре була. Ш.Мәрҗанине миссионерлыкта гаеплиләр, мәктәпне руслаштыру һәм христианлаштыруның бер коралы итеп бәялиләр. Кадимчеләр дөньяви фәннәрнең рус телендә укытылуына ризасызлык белдерә, җәдитчеләр исә хөкүмәт контроле, ана теле һәм әдәбияты, тарих укытылмау б-н килешми. 20 йөз башында М.Н.Пинегин, И.В.Терегулов, С.Ш.*Алкинның* мәктәптә ана теле һәм әдәбияты укытуны кертергә тырышулары тормышка ашмый кала. Мәктәп попечительләре арасында сәүдәгәрләр М.И.*Галиев*, М.Г.Мусин, М.М.*Галикәев*, юрист С.Ш.Алкин мәктәпкә зур матди ярдәм күрсәтәләр.

Ш.Мәрҗанинең мәктәп милли зыялыларны әзерләү үзәге булыр дигән өметләре акланмый. Укучылар арасында мәдрәсәдә тәрбияләнүчеләр өстенлек иткән беренче ике елдан соң, мәктәпкә дини белеме булмаган крәстиян балалары күпләп килә башлый; мәктәпне тәмамлаганнан соң алар бары тик рус телен генә укыта ала. Шул сәбәпле Ш.Мәрҗани мәктәптән китә. 19 йөз ахырында хәл үзгәрә, К.т.у.м.нә яңадан мәдрәсә тәмамлаучылар килә башлый, алар өчен мәктәптә уку белем алуның соңгы баскычы яисә югары уку йортына керү өчен мөһим этап була. Татар җәмәгатьчелегенең мәктәпкә карата мөнәсәбәте яхшыга таба үзгәрә башлый, ул тар профильле уку йорты буларак карала. Мәктәп татарлар арасында рус теленең таралуында әһәмиятле роль уйный. Мәктәпне тәмамлаучылар һәм аның укытучылары төп дәреслекләрнең авторлары булалар, укыту методикасын төзиләр, рус-татар уч-щеләрендә генә түгел, ә иң яхшы мәдрәсәләрдә дә («Буби», «Мөхәммәдия», «Касыймия», «Госмания» һ.б.) укыталар, яңа типтагы татар мәктәбе формалашуда мөһим роль уйныйлар. Рус мәдәнияте б-н танышу нәтиҗәсендә мәктәп һәм аның укучылары аша татар җәмәгатьчелегенә Россиядә таралган радикаль идеяләр үтеп керә. Укучылар яшерен әдәбият б-н танышалар (ш.и. яшерен «Тәрәккый» түгәрәгендә). 1905 тә алар рев-ция вакыйгаларында катнашалар; мәктәпнең үзендә дә укучыларның җитәкчелеккә актив каршылыгы була, 24 кеше мәктәптән куыла, 3 кеше кулга алына, 3 кеше сөргенгә җибәрелә. Күпләр с.-д. һәм эсерлар, милли радикализм, ш.у. нигилизм идеяләрен таратучылар булып китә.

К.т.у.м.ндә күп кенә милли хәрәкәт җитәкчеләре, хәрби җитәкчеләр, галимнәр, мәгърифәтче һәм педагоглар, язучылар, мәдәният эшлеклеләре белем ала. Алар арасында партия һәм дәүләт эшлеклеләре, коммунизм идеяләрен пропагандалаучылар, ш.у. большевизмга каршы көрәштә актив катнашучылар, сәяси репрессияләр корбаннары да бар: Г.Х.*Алпаров*, Г.Н.*Әхмәров*, Х.Г.*Бәдигый*, Р.С.*Газизов*, Н.С.*Еникеев*, Г.Г.*Исхакый*, И.М.*Казаков*, Г.Х.*Камай*, Г.Ю.*Коләхмәтов*, М.Х.*Корбангалиев*, И.Б.*Кудашев-Ашказарский*, Ә.Н.*Максуди*, С.Н.*Максуди*, Х.Б.*Мәулетов*, Ш.З.*Мөхәммәдьяров*, Н.К.*Мөхетдинов*, М.Т.*Мөштәриев*, Н.С.*Надиев*, Г.Җ.*Сәйфетдинов*, Ф.К.*Сәйфи-Казанлы*, Г.Ш.*Сәйфуллин*, М.Х.*Солтангалиев*, С.Х.*Сүнчәләй*, Г.Х.*Терегулов*, Ф.Ф.*Туктаров*, М.Ә.*Фазлуллин*, К.Г.*Хәкимов*, К.Г.*Хәсәнов*, Я.Җ.*Чанышев*, Х.М.*Ямашев* һ.б.

1917 дә К.т.у.м. — Татар укытучылар семинариясе, 1919 да пед. курслар итеп үзгәртелә, 1921 дә аның җирлегендә Казан татар пед. техникумы булдырыла (к. *Казан педагогия көллияте*). 1876 дан мәктәп Бутягин йортында урнаша (хәзер Тукай урамы), 19 йөз башы архит-ра истәлеге.

*Әд.:* Гайнетдинов М.Г. Татар башлангыч мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү (XIX–XX гасырлар). К., 2002; Траубенберг П.В. Татарская учительская школа в Казани. К., 1980; Хакимов Х.Х. Роль Казанской татарской учительской школы в развитии и распространении прогрессивной педагогической мысли среди татар // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1972. Вып. 105; Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса, 1861–1917 гг.). К., 1982; Рахимов С.Г. Ш.Марджани и Казанская татарская учительская школа // Марджани. Наследие и современность: Материалы междунар. науч. конф. К., 1998; Исхакова Р.Р. Казанская татарская учительская школа и её роль в формировании и становлении национального образования. К., 2002.

*Р.Р.Исхакова, Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ТАТА́Р ЯШЬ ТАМАШАЧЫЛА́Р ТЕА́ТРЫ**, Г.Кариев исем. проф. театр; 1991 елда ТР МК карары б-н оеша.

Спектакльләрне балалар өчен татар телендә куючы махсус проф. театр беренче тапкыр 1918–19 елларда Казанда булдырыла: Алафузов театры каршында балалар татар драма коллективы төзелә. 1923–24 тә Казансу аръягындагы фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбе каршында балалар татар театр төркеме эшли. 1924–30 да Татар дәүләт театры (хәзер Татар акад. театры) каршында Касыйм Шамил җитәкчелегендә балалар һәм яшүсмерләр өчен спектакльләр әзерләүче актёрлар коллективы оеша. Төркемдә Г.Арсаев, Г.Бикмуллин, А.Вәлиева, Гәрәева, Зарипов I, Зарипов II, Ишморатов, А.Камал, Кәримова, Кыямов, Р.Корманаева, Котдусов, Латыйпов, Мәҗитов, К.Мөхәммәтҗанов, И.Нуриев, Р.Самусова, Х.Фәйзуллина, Э.Шамил, Ф.Юнысов һ.б. була. «Тычканга үлем — мәчегә көлке» (К.Шамил), «Ялкау Гали» (И.Казаков), «Пәрәмәч», «Йорт күсесе» (Г.Бакиров), «Парикмахер» (Т.Ченәкәй), «Әтәчләр кычкырганда» (Э.Шамил), «Шүрәле», «Хәйләкәр Таз» (К.Шамил, Г.Тукай әкиятләре буенча) һ.б. спектакльләр куела. 1932 дә Үзәк пионерлар клубы каршында Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) төзелә; аның составында К.Шамил җитәкчелегендә татар төркеме оеша. Төркем 1934 кә кадәр яши һәм шәһәр пр-тиеләре театрны акча б-н тәэмин итүдән туктау сәбәпле таркала.

1944 тә Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршында Татар театр студиясе ачыла, 1949 да Казан ТЮЗы каршында аны тәмамлаучылардан торган татар төркеме оеша. Репертуарына О.И.Пыжова тарафыннан диплом эшләре буларак куелган спектакльләр керә: «Васса Железнова» (М.Горький), «Болан-Патша» («Король-Олень», К.Гоцци), «Козы-Көрпеш һәм Баянсылу» (Г.Мөсрәпов). Төркемнең баш режиссёры итеп билгеләнгән К.Тумашева «Илдус» (Д.Аппакова), «Үги кыз» (А.Әхмәт), «Маякчы кызы» (Г.Гобәй повесте буенча) спектакльләрен куя. Төркем составында Ш.Әсфәндиярова, Р.Әхмәрова, Р.Бикчәнтәев, А.Галиева, Х.Гыйматдинов, Д.Ильясов, П.Исәнбәт, Г.Камалова, Х.Кумысников, Р.Сакаев, А.Хәйруллина, Г.Хөсәенов эшли. Финанс кытлыгы туу сәбәпле, 1950 дә төркем таркатыла, актёрларның бер өлеше Татар акад. театры труппасына кабул ителә.

1987 дә нәни һәм яшүсмер тамашачылар өчен ТАССР Халык мәгарифе министрлыгы каршында Ф.Ә.*Хәбибуллин* җитәкчелегендә татар театр студиясе оеша. Куелган спектакльләр: «Намус хөкеме» (Д.Вәлиев), «Мәхәббәт моңы» (А.Айдар), «Сандугачлар килгән безгә» (И.Юзеев), «Уеннан уймак» (З.Шаһиморат), «Атылган йолдыз» (Ф.Бәйрәмова). 1991 дә студия Казан татар яшь тамашачылар театры итеп үзгәртелә. Ул башта Островский урамындагы 12 йортта урнашкан була, аннан аңа Елга аръягындагы элекке Алафузов театры бинасы бирелә, театр хәзер дә шунда урнашкан. Труппа составында РФнең атказ., ТРның халык артисты Н.В.Сафин, ТРның халык артисты Ф.А.Галиев, ТРның атказ. артистлары Г.Э.Габитова, Ф.Х.Кәлимуллин, И.Д.Камалиев, Х.М.Сөнгатуллина, артистлардан М.З.Мәхмүтов, И.З.Низамиев, Г.Ф.Фазылҗанова һ.б. эшли. Баш режиссёры — Р.М.Әюпов. Театрның репертуарында: «Сак-Сок» (Р.Батулла), «Килмешәк» (Х.Ибраһим), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин), «Тапкыр егет» (Д.Аппакова), «Алтынбәк һәм Су кызы» (М.Гыйләҗев), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Король Лир» (У.Шекспир) һ.б. әсәрләр.

*Ю.А.Благов.*











Казан татар яшь тамашачылар театры. Спектакльләрдән күренешләр: 1. «Сандугачлар килгән безгә», И. Юзеев (1989); 2. «Бер көрешү — үзе бер гомер», Ф. Яруллин (1996); 3. «Кызлар — йолдызлар», Ш. Рәкыйпов (1998); 4. «Тапкыр егет», Д. Аппакова (2003); 5. «Сак-Сок», Р. Батулла (2003).

**КАЗА́Н ТАТАРЛАРЫ́**, татарлар (үзатама), Идел-Урал төбәгендәге татарларның субэтник төркеме. Идел-Урал татарларының төп өлешен (2/3 тирәсе) тәшкил итә. Берничә этник төркемгә бүленә: үзәктә яшәүче татарлар, нократ татарлары, Пермь татарлары, типтәр-башкортлар. Халыкның сөйләм теле — татар теленең урта диалекты. Ислам динен (мөселман-сөнниләр), зур булмаган төркеме христиан динен тоталар (к. *Керәшен татарлар*). Фәнни әдәбиятта кулланыла торган «К.т.» термины ачылып җитмәве б-н аерылып тора, ул Казан татарларына карата да, барлык Идел-Урал татарларына карата да кулланыла. Башта әлеге төшенчәнең мәгънәсе рус елъязмаларында Казан ханлыгы дәүләтен барлыкка китерүче этносны аңлатучы буларак теркәлә («татары казанские», «казанские татаровя», «казанцы»). Соңга таба, 16 йөзнең 2 нче яртысыннан, татарлар Казан ханлыгының үзәк районнарыннан читкә тарала башлагач, К.т. төшенчәсе киңрәк бергәлекне аңлата (мәс., Себер татарлары Идел-Урал төбәгеннән күченеп килүчеләрне шулай атыйлар, Урал ягында да шундыйрак хәл күзәтелә). К.т.ның формалашуына фәндә бердәм караш юк, аларның этник тарихы җитәрлек өйрәнелмәгән. Аларның болгарлардан, Алтын Урда төркиләреннән («татар») һәм кыпчаклардан килеп чыгуы турындагы фаразлар бар, ике арада яшәүче карашлар да яши. Тулаем алганда, К.т.ның барлыкка килүендә болгар компонентының роле зур. Әмма әлеге компонент этник яктан бик катлаулы була — төрлечә килеп кушылган төркиләр, угорлар, финнарның кайбер төркемнәре. Идел Болгары составында, монголлар заманында феодаль халык буларак туплану процессы кичереп (төбәкнең кайбер этник аерымлыклары сакланса да), төрле кабиләләрдән элекке феодаль болгар халкы формалаша. Идел буе Болгар дәүләте терр-ясен Алтын Урдага кушу сизелерлек этносәяси үзгәрешләр китереп чыгара. Идел Болгары халкының этник мохитенә кыпчаклашкан, соңрак кыпчак-нугай төркемнәреннән шактый зур масса үтеп керә. 14–15 йөзләрдә болгар халкы яшәгән районнарда үзәкләре Болгар, Җүкәтау, Казан (Иске Казан) булган берничә бәклек билгеле. Фәкать Казан ханлыгы — К.т.ның милли дәүләте чорында гына (1438–1552 еллар) 2 этник компонент — болгар һәм татарлардан, шактый ишле феодаль халык буларак, яңа этнос — К.т. тәмам формалашып бетә. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөздә барган таралу вакытындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә К.т.ның *мишәрләр* һәм *Касыйм татарлары* б-н үзара бәйләнешләре арта. Идел буе татарларының төрле этник бергәлекләренең янәшә һәм полоса аша таралуы аларның этник, тел һәм мәдәни яктан берләшүенә ярдәм итә (к. *Татарлар*). Нәтиҗәдә К.т. 18 йөзгә субэтноска әверелү процессы кичерә, ә 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында, кайбер субэтник аерымлыкларын югалтып, фактта Идел-Урал төбәге татарлары составында этник төркемгә әверелә (19 йөз ахырына халык саны — 1,7 млн. чамасы кеше).

Казан ханлыгы чорында К.т.ның игенчелеккә нигезләнгән, Идел буе Болгар дәүләте



Казан татарлары. 19 йөз фоторәсеме.

һәм Алтын Урда чорларына барып тоташкан алга киткән мәдәнияте була (ш.и., рус һәм Көнбатыш Европа чыганакларында билгеләп үтелгәнчә, шәһәр мәдәнияте дә). Көтүдә йөртү һәм ябып асрауга нигезләнгән терлекчелек икенчел роль уйный. Авыл хуҗалыгы б-н берләттән, агач эшкәртү, киез-киез итек басу, туку, тире эшкәртү, ювелирлык эше кебек промысел һәм һөнәрчелекләр мөһим урын тота. Казан ханлыгын басып алганнан соң (1552), К.т.ның мәдәнияте ярлылануга, ш.и. демографик югалтуларга (16 йөз уртасында халык саны 1/3 өлешкә кими), татарларны шәһәрләрдән тулысынча кууга карамастан, халык яшәвен дәвам иттерә. К.т.ның үз этник терр-яләрен шактый күләмдә саклап калуы аларның традицион мәдәниятенең күп элементларын (бәйрәмнәрне, йолаларны һ.б.), ш.у. җыен системасын (к. *Җыен*) саклап калырга ярдәм итә. К.т.ның кайбер мәдәни үзенчәлекләре уникаль һәм Казан арты районнарында аеруча ачык чагыла. К.т.ның урта гасырлар шәһәр мәдәнияте нәкъ менә шунда саклана. Колониаль шартларда яшәргә күнегүнең авыр чорыннан соң, 18 йөзнең 2 нче яртысыннан К.т.ның икътисады һәм мәдәнияте тизрәк үсә башлый. Казан артында булган һөнәрчелек базасында 18–19 йөзләрдә — киез-киез итек, тире эшкәртү, туку, читек, алтын б-н тегү мануфактуралары, 19 йөздә күн, постау һ.б. заводлары эшли башлый. Күп крәстияннәр тегү, йон тетү, йон-тукыма ману, балта эшләре һ.б. б-н шөгыльләнә. Сәүдә-арадашчылык эшчәнлеге киңәя. Гәрчә әле 20 йөз башында К.т.ның төп массасы авыл җирләрендә яшәсә дә, 19 йөзнең 2 нче яртысыннан шәһәр халкының саны арта бара. Шулай да шәһәрләшү һәм 30 нчы еллардагы индустрияләштерү К.т.ның традицион мәдәнияте төп элементларының тиз югалуына китерә. К.т.ның халык сөйләм теле бүгенге татар әдәби теле барлыкка килүдә төп рольне уйный, ә аларның традицион мәдәнияте милли мәдәниятне формалаштыруда төп чыганак була (мәс., халык бәйрәме *Сабан туе*, кием-салымнар — *калфак, читек* һ.б., аерым ашлар — *чәкчәк, өчпочмак* һ.б.).

*Әд.:* З н а м е н с к и й П. Казанские татары. К., 1910; В о р о б ь ё в Н.И. Материальная культура казанских татар. К., 1930; ш у л  у к. Казанские татары: Этнографическое исследование материальной культуры доoктябрьского периода. К., 1953; З а л я й Л. Средний диалект татарского языка: Автореф. дис. ... К., 1954; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; В а л е е в Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; И с х а к о в Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени: Этнологической взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв. К., 1998; Татары. М., 2001.

*Д.М.Исхаков.*

**«КАЗА́Н» ТА́У СПОРТЫ́ СӘЛАМӘТЛӘНДЕРУ́ КО́МПЛЕКСЫ**, Зөя елгасының күтәренке уң як яры буенда урнашкан, Казаннан 35 *км*, Казан–Мәскәү автомобиль юлыннан 2 *км* ераклыкта. Комплекста 800 дән 1800 *м* озынлыкта төрле катлаулылыктагы 160 тан 190 *м* га кадәр биеклектәге, ясалма кар ясау системасы булган 9 яктыртылган чаңгы трассасы бар. 3 утыргычлы 4 урынлы күтәргечләр эшли: балалар шәһәрчеге, транспорт ленталары, бебилифт, шугалак, чаңгы, сноуборд, сноублейд һ.б. спорт инвентарьлары б-н җиһазландырылган. Комплекста кунакханә, бөтен уңайлыклары булган йортлар, кухня, ванна, сауналары б-н «альп» йортлары бар. Комплекс киңәйтелә бара — яңа чаңгы трассалары, ябык шугалаклар, теннис кортлары, бассейннар, аквапарк, мунчалар һ.б. төзелә.



«Казан» тау спорты сәламәтләндерү комплексы. 1. Кунакханә; 2. Күтәргечләр.

**КАЗА́Н ТЕА́ТР УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, урта һөнәри уку йорты. Тарихы 1919 елдан Казан Зур драма театры каршындагы театр студиясеннән башлана, 1923 тән Татар театр техникумы. Беренче педагоглары — драматург К.Тинчурин, язучы Ф.Әмирхан, реж. З.Солтанов, комп. С.Сәйдәшев, актёрлар З.М.Славянова, Е.М.Лидова, А.М.Кречетов, В.В.Белокуров, М.В.Романычева, балетмейстер Ю.А.Муко, театр тарихчысы М.Д.Прыгунов. Иң элек техникум «Идел» («Волга») номерларында



Казан театр училищесе.

урнашкан була, соңрак аны элекке Мария исем. хатын-кызлар гимназиясе бинасына күчерәләр. Укыту методикасы нигезе итеп рус реалистик театр сәнгате мәктәбе алына. 1924 тә мөгаллимлек һәм җитәкчелек эшенә Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсенең (к. *КЭМСТ*) «сул» юнәлеш театры эшлекләләре Б.Н.Симолин, Я.П.Гамза, И.Г.Ингвар чакырып алына, укыту практикасына В.Э.Мейерхольд «биомеханика»сы элементлары кертелә; ритмика, сәхнә хәрәкәте алымнарын үзләштерүгә зур игътибар бирелә. Беренче чыгарылыш 1926 да була (чыгарылыш укучылары арасында — Г.Ф.Булатова, Р.Ф.Ишморат, Г.Н.Нигъмәтуллина, Х.Й.Сәлимҗанов, К.З.Тумашева). 1927 дә Татар театр техникумы Казан сәнгать-пед. техникумы б-н берләштерелә һәм Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы төзелә, ул элекке сәнгать мәктәбе бинасында урнаша. 2 нче чыгарылыш (1928) шәкертләре арасында Б.Д.Галиуллина, Г.Г.Исмәгыйлев, Г.Таһиров була. 1930 да сәнгать-театр техникумы Шәрекъ музыка техникумы б-н берләштерелеп, Татар сәнгать техникумы оештырыла (1930 еллар ахырына кадәр эшли). 1944 нең мартында Татар. театр уч-щесе ачыла (1952 гә кадәр эшли). Директоры һәм сәнгать җитәкчесе С.С.Булатов була; укытучылары — Ш.М.Сарымсаков, К.З.Тумашева, Г.Р.Шамуков, К.Ш.Шамил (чыгарылыш укучылары арасында — А.Г.Арсланов, Г.Н.Әхмәтҗанов, Ш.Х.Биктимеров, Г.И.Нуруллин). 1958 дә — Казан Зур драма театры җирлегендә татар һәм рус актёрлары төркемнәреннән торган студия, 1960 та Казан рус яшь тамашачылар театрында студия, 1962 дә кабат К.т.у. ачыла. Баштарак биредә рус һәм татар театрлары өчен актёрлар әзерләнә (уч-щенең беренче педагоглары — Е.А.Простов, А.Д.Гусев, М.Х.Сәлимҗанов, Р.Ә.Бикчәнтәев, Н.В.Алексеева, А.Ф.Гацулина, Н.Ф.Смирнова һ.б.). Соңга таба курчак театры актёры, рәссам-бутафор (җитәкчеләре — Т.А.Зуева, М.И.Кәримова), рәссам-гримёр, сәхнә күренешләрен яктыртучы рәссам белгечлекләре булдырыла.

2011/12 уку елында К.т.у.ндә 216 укучы белем ала; белгечлекләр: актёрлык сәнгате, эстрада сәнгате, театр-бизәлеш сәнгате, яктылык режиссурасы. Укытучылары арасында ТАССР һәм РФнең халык артисты В.В.Кешнер; ТАССРның халык, РФнең атказ. артис-

ты И.З.Хәйруллин, ТРның халык артисты Е.Е.Ненашева, ТРның атказ. артисты, ТРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе Ю.И.Карева, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре Р.М.Фәткуллин, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе М.Г.Имашев, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәрләре М.А.Данилов, Е.П.Моисеева, Мари Респ-касының атказ. сәнгать эшлеклесе Т.В.Лядова, педагоглар М.Д.Вәлиев, И.А.Григорьянц һ.б. бар. 1963тән уч-ще Александров-Чемесовның дворян хатын-кызлар өчен ачылган элекке хәйрия йорты бинасында (хәзер Гоголь урамы) урнаша, архит-ра истәлеге (1886–95, арх. Л.К.Хрщонович). Директоры — ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре Г.Х.Мөбарәкшин.

*Әд.:* Иляловa И. Школа лицедеев // Казань. 2002. № 10. *Ю.А.Благов.*

**«КАЗА́Н ТЕКСТИЛЕ́»**, җиңел сәнәгать пр-тиесе. Атлас, капрон, эластик, бандаж, техник тасмалар; шнурлар, аяк киеме шнурлары, полипропилен капчыклар эшләп чыгара. 80 гә якын кеше эшли (2012). 1941 елның августында, Казан тасмалар туку һәм шнурлар үрү ф-касы буларак, Казанның сәдәф, гармун ф-калары һәм Мәскәүдән, Мәскәү өлкәсенең Клин, Кунцево, Ногинск шәһәрләреннән эвакуацияләнгән берничә пр-тие нигезендә оештырыла. 1942 дә тасмалар туку һәм шнурлар үрү ф-каларына бүленә, 1962 дә алар яңадан Казан текстиль-галантерея ф-касына берләштерелә. Пр-тие үсә һәм модернизацияләнә: 345 яңа тасма туку станогы урнаштырыла, капрон һәм эластик тасмалар эшләү технологияләре үзләштерелә (1945–46); яңа җитештерү корпуслары төзелә, буяу-бизәкләү һәм тегү цехлары ачыла (1952–57), Румыния һәм Швейцариянең алдынгы җиһазлары гамәлгә кертелә (1974–75), искергән шүреле тасма туку станоклары югары җитештерүчән шүресез станоклар б-н алыштырыла (1980–83), бау-тасма үрү машиналары (1993), полипропилен җеп әзерләү линиясе, полипропилен тукыма эшләп чыгару буенча 12 эре туку станогы һәм капчыклар тегү буенча автомат (2000) сафка баса. 1992 дә пр-тие куәтләренең бер өлеше мөстәкыйль «Чулпан» ф-касына бүлеп бирелә. 1996 да Казан текстиль-галантерея ф-касы хәзерге исемендәге АҖ итеп үзгәртеп корыла. Төп (тегү, текстиль-галантерея эшләнмәләре, буяу-эшләп чыгару, полипропилен капчыклар җитештерү буенча цехлар) һәм ярдәмче (ремонт-механика, эл., ремонт-төзелеш цехлары, котельный) производстволарны үз эченә ала. Елга 19 мең *т* дан артык тукылган тасма һәм 243 мең *т* үрелгән шнур эшләнмәләр җитештерә (2011). Продукциясе РФгә һәм БДБ илләренә куллануга җибәрелә. Чималны төп гамәлгә куючылар: «Евромастер» АҖ (Түбән Кама ш.), «Уфаоргсинтез», «Химволокно» (Саратов өлкәсе Балаково ш.), «Млекта» (Мәскәү), «Химволокно» (Белоруссия, Могилёв ш.). Пр-тие җитәкчеләре: В.Ф.Ясмон (1941–43), Я.И.Рохлин (1943–45), Р.С.Саттаров (1945–54), А.Ф.Калмыков (1954–60), Филиппов (1960–62), Н.П.Андреев (1962–76), Ф.Я.Гыймадиев (1977–87), В.С.Кузьмин (1987–95), Н.Ф.Балешев (1995–2002), Д.Н.Балешев (2000–10), Ә.К.Шәйдаров (2011 дән).

**КАЗА́Н ТЕКСТИ́ЛЬ-ГАЛАНТЕРЕ́Я ФА́БРИКАСЫ**, к. *«Казан текстиле»*.

**КАЗА́Н ТЕ́ХНИК УНИВЕРСИТЕТЫ́**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының югары уку йорты. Казан ун-тының 1930 елда төзелгән аэродинамика бүлеге җирлегендә Казан авиация ин-ты буларак 1932 дә оештырыла. 1973 тән А.Н.*Туполев* исемендә, 1992 дән хәзерге исемдә. 2010 да милли-тикшеренү ун-ты статусы бирелә. Беренче елларда институт очу аппаратларын конструкцияләү һәм төзү буенча инженерлар әзерли. 1939 дан «очу аппаратлары двигательләре» белгечлеге буенча укыту башлана. 1945 тә В.П.*Глушко* инициативасы б-н СССРда беренче ракета техникасы каф. ачыла. 1951 дән институт авиация приборларын төзү, 1952 дән самолётлар радиотехникасы һәм радио җиһазлары буенча белгечләр әзерләүгә керешә. 1970 тә автомобильләр төзү ф-ты ачыла (1982 дә Кама политехник ин-тына күчерелә). 1972 дән ЭВМ һәм кибернетика буенча инженерлар әзерләүгә нигез салына. 1970 еллар уртасыннан радио һәм приборлар төзү ф-тлары авиация сәнәгате өчен генә түгел, халык хуҗалыгы һәм фәннең башка тармаклары өчен дә белгечләр әзерли башлыйлар. Совет чорыннан соң дәүләт идарәчелеге һәм менеджмент (1991), электрон физ. һәм гамәли матем., икътисади теория һәм хокук (2003), психол. (2003) һ.б. белгечлекләр буенча белгечләр әзерләү башлана, автомобиль транспорты буенча белгечләр әзерләү яңартыла (1999).

Университет составында 6 уку-укыту ин-ты эшли: авиация, җир өсте транспорты һәм энергетика; автоматика һәм электрон приборлар төзелеше; техник кибернетика һәм информатика; радиоэлектроника һәм телекоммуникацияләр; инженерлык-икътисад ин-ты (икътисадчылар, гамәли информатика буенча белгечләр әзерли); социаль технологияләр (оешмалар менеджерлары, җәмәгатьчелек б-н элемтә буенча белгечләр әзерли); эшмәкәрлек һәм инновацион технологияләр (юристлар, психологлар, дөнья икътисады, персонал б-н идарә итү буенча белгечләр әзерли), ш.у. физ.-матем. ф-ты эшли. Чистай, Әлмәт, Бөгелмә, Волжск, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә филиаллары бар. Белгечләр әзерләү 71 белгечлек буенча алып барыла, көндезге бүлектә — 10003, кичке бүлектә — 1500, читтән торып 3000 студент укый. Ел саен РФнең югары һәм урта һөнәри уку йортларыннан килеп 2,5 меңләп укытучы квалификациясен күтәрә.



Казан техник университеты. Беренче уку бинасы.



Казан техник университеты. Жиденче уку бинасы.

Укытучылар коллективында 1400 чамасы кеше, ш.и. 1 РФА академигы, 4 ТР ФА академигы, 5 ТР ФА мөхбир әгъзасы, 168 фән. д-ры һәм 800 дән артык фән. канд-ты эшли.

52 меңнән артык белгеч әзерләнә, алар арасында «Энергия-Буран» системасының баш конструкторы Б.И.Губанов, П.О.Сухой исемендәге ОКБ ген. конструкторы М.П.Симонов, СССРның авиация сәнәгате министры, РФ МК рәисе булып эшләгән И.С.Силаев һ.б. бар.

Университет беренче елларыннан ук эре фәнни үзәк була. Н.Г.Четаев җитәкчелегендә вузда алга таба И.Г.Малкин, Г.В.Каменков, С.Г.Нужин, Х.М.Мөштәри, П.А.Кузьмин, А.С.Галиуллин, Ю.В.Кожевников, В.М.Матросов, В.Н.Скимель-Оше, И.И.Әхмәтгалиев, А.Ш.Әминов, Н.В.Куршев, К.П.Персидский хезмәтләрендә үсеш алган Казан хәрәкәт тотрыклыгы теориясе фәнни мәктәбе оеша. Ныклылык өлкәсендәге тикшеренүләр Ю.Г.Одиноков, Ю.А.Радциг, М.Б.Вахитов, В.Г.Шатаев тарафыннан алып барыла. А.В.Болгарский, С.В.Румянцев, Г.С.Жирицкий, С.Ф.Лебедев башлаган очу аппаратлары двигательләренең физ.-техник проблемаларын тирәнтен тикшерү В.Е.Алемасов, В.И.Локай, А.В.Талантов, В.К.Щукин, И.Н.Дятлов, М.К.Максутова, В.М.Янковский, Б.С.Виноградов тарафыннан дәвам ителә. Авиация техникасын проектлау һәм җитештерүне конструктор-технол. тәэмин итү буенча фәнни-тикшеренүләр М.И.Лысов, Г.Н.Воробьёв, А.Ф.Әхмәров, Ф.С.Юнысов җитәкчелегендә алып барыла. Мәгълүмати-үлчәү приборлары һәм системалары өлкәсендәге эшләргә Р.Ш.Нигъмәтуллин, В.И.Поповкин, Ш.М.Чабдаров, Я.С.Урецкий җитәкчелек итә.

Университет составында 5 фәнни-тикшеренү ин-ты: физ.-химик процесслар, транспорт проблемалары, «Прометей» тәҗрибә эстетикасы (ТР ФА б-н бергәләп), авиация техникасы һәм технологиясе, энергоактив технологияләр, ш.у. 10 фәнни-техник үзәк, 57 тармак һәм проблемалы лаб.; 360 ка якын фәнни хезмәткәр эшли.

Университет галимнәре тарафыннан фундаменталь һәм гамәли теоретик, тикшеренү эшләре һәм тәҗрибәләр алып барыла. Алар түбәндәге юнәлешләрдә бара: тотрыклылык һәм хәрәкәт б-н оптималь идарә итү теориясе (Т.К.Сиражетдинов, Г.Л.Дегтярёв, А.С.Земляков, А.И.Маликов, К.Г.Гәрәев, А.А.Балоев, Ш.И.Галиев), формасын үзгәртүчән каты җисемнәр механикасы, очу аппаратлары ныклыгы һәм матем. модельләштерү (В.Н.Паймушин, В.А.Павлов, И.Х.Сәитов, В.А.Фирсов, А.С.Кретов, А.М.Арсланов, Р.Т.Сиражетдинов), җылылык двигательләре һәм энергетик җайланмаларның физик-техник проблемалары (А.Ф.Дрегалин, Г.А.Глебов, В.И.Наумов, В.Г.Крюков), авиация двигательләре һәм энергия җайланмаларында яну һәм газ динамикасы (В.А.Костерин, Б.Г.Минһаҗев), интенсивлаштырылган җылылык-масса алмашу (Ю.Ф.Гортышов, С.А.Тарасевич, Р.З.Алимов, В.М.Молочников, Б.Е.Байгалиев), сыеклык һәм газ механикасы (В.Г.Павлов, В.Н.Игнатьев, З.Х.Ногманов), турбомашиналарда эш процесслары (Л.В.Горюнов, А.В.Щукин), авиация техникасының юка стеналы детальләрен пластик формалаштыру (И.М.Закиров, Ю.П.Катаев, В.И.Хәлиуллин), алынма материаллы деталь өслекләрен формалаштыру (Ф.С.Юнысов, А.Х.Кәримов, А.Н.Лунёв, З.Б.Садыйков), түбән температуралы плазма физикасы һәм техникасы (Г.Ю.Даутов, Ф.М.Гайсин, Б.А.Тимеркәев), радиоэлектрон, квант җайланмалары һәм системалары (Ю.Е.Польский, Г.И.Ильин, В.И.Воронов), электрохимик әверелдергечләр кулланылган, электрон мәгълүмати-үлчәү техникасы (М.Р.Вяселев, Ю.К.Евдокимов, Ф.А.Карамов), очу куркынычсызлыгын инструментлар б-н тәэмин итү алымнары һәм чаралары, мәгълүмати-үлчәү приборлары һәм системалары (В.А.Ференц, В.М.Солдаткин), микроэлектрон аппаратура һәм аны җитештерү технологиясе (Ю.П.Ермолаев, И.К.Насыйров, Н.З.Сафиуллин, О.Ш.Даутов), радиотехник системалар һәм җайланмалар анализы һәм синтезы (Г.И.Щербаков, Г.А.Морозов, Ю.Е.Седельников, А.Ф.Надеев), югары җитештерүчән исәпләү системалары, гамәли математика һәм информатика (А.П.Тунаков, В.А.Песошин, Н.Е.Роднищев, В.С.Моисеев, Р.И.Әдһәмов, Л.М.Шарнин), электр җиһазлары, электрик микромашиналар һәм микрокүчергечләр (В.С.Терещук, А.Ю.Афанасьев), икътисад теориясе һәм пр-тиеләр икътисады (А.П.Тунаков, С.И.Шәрәпов, Р.К.Мәҗитова, А.Ш.Хәсәнова, Г.Ф.Мингалиев), фәлсәфә (В.Д.Евстратов, В.В.Лузгин, Н.М.Солодухо, Р.К.Мөрсәлимов), психология (Р.В.Габдриев), социология һәм политология Л.Ш.Шәрәпов, Д.К.Сабирова, Т.Г.Исламшина). 38 белгечлек буенча 375 аспирант (2011), 9 белгечлек буенча докторантлар әзерләнә, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрен яклау советлары эшләп килә. 1937 дән институт актив халыкара багланышларда тора.

1947–55 тә институтта 8 соц. илдән килгән студентлар укый. 1996 дан чит илләрдән килгән белгечләрне әзерләү яңадан башлана, хәзерге вакытта Европаның 11 иленнән, Азия, Америкадан студентлар һәм аспирантлар укый.

Бразилия, Германия, Испания, Кытай, Ливия, АКШ, Франция һ.б. илләрнең ун-тлары, фәнни оешмалары б-н фәнни һәм белем бирүдәге элемтәләр үстерелә.

Университетның 7 уку бинасы бар (элекке Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе, Казан католиклар чиркәүләре биналары — архит-ра истәлекләре). Фәнни-техник китапханәдә 1,5 млн. нан артык саклау берәмлеге исәпләнә. Нәшрияты бар, 1933 тән «Труды Казанского авиационного института», «Вестник Казанского государственного технического университета» (1998 дән), «Авиационная техника» (1958 дән), «Вертолёт» (1998 дән) ж-ллары, «Крылья» г-тасы, «Актуальные проблемы авиационных и аэрокосмических систем» (2001 дән), «Проблемы нелинейного анализа в инженерных системах» халыкара җыентыклары нәшер ителә. 1982 дән КДТУ тарихы музее эшләп килә. Университет Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә. К.т.у. ректорлары: Н.З.Векслин (1932), С.П.Гудзик (1932–36), И.П.Богданов (1936–38), И.С.Шохов (1938–42), П.И.Ильин (1942–44), Г.В.Каменков (1944–49), С.В.Румянцев (1949–53), Ю.К.Застела (1953–67), Р.Ш.Нигъмәтуллин (1967–77), Ю.В.Кожевников (1977–87), Г.Л.Дегтярёв (1987–2007), Ю.Ф.Гортышов (2007–11), Н.Р.Абруков (2011 дән ректор вазифаларын башкаручы).

*Әд.:* Казанский авиационный институт: Сб. статей. К., 1982; Казанский авиационный институт. К., 1992; Коняхина В.И. Выпускники — гордость университета: Краткий биогр. справ. К., 2002.

*Г.Л.Дегтярёв.*

**КАЗА́Н ТЕХНОЛО́ГИЯ УНИВЕРСИТЕТЫ́** (КТУ), РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының югары уку йорты. 1930 елда ҮБК һәм РСФСР ХКС карары нигезендә Казан политехник ин-тының һәм Казан ун-тының химия ф-тлары җирлегендә ачыла. Башта Казан химия ин-ты дип йөртелә, 1933 тән А.М.Бутлеров исем. Казан химия-технол. ин-ты (КХТИ), 1935 тән — С.М.Киров исем. КХТИ, 1992 дән хәзерге исемдә. 2010 да милли-тикшеренү ун-ты статусы бирелә.

К.т.у.на нигез салынган вакыттан оборона сәнәгате белгечләрен әзерләүче инженерлык, химия-технол. ф-ты (2001 дән институт) эшләп килә. 1930 дан тикшеренү һәм технол. ф-тлары ачыла. 1931 дә алар нигезендә нәорганик химия, органик химия һәм химия-технол. бүлекләре оештырыла. 1933 тә алар факультетлар итеп үзгәртелә, 1946 да технол. ф-тына берләштерелә (1992 дән химик технологияләр ф-ты; 2002 дән нефть һәм химия ин-ты составына кертелә). 1939 да механика ф-ты ачыла (2002 дән Нефть һәм химия машиналары төзү ин-ты составында). 1941–43 тә институтка эвакуацияләнгән Ленинград технол. ин-ты кушыла. ТАССРда нефть табу һәм эшкәртү үсеш алу б-н бәйле рәвештә, 1954 тә нефть ф-ты ачыла (2002 дән Нефть һәм химия ин-ты), 1970 тә энергетика машиналары төзелеше һәм технол. җиһазлары ф-ты, 1971 дә — полимерлар ф-ты (1999 дан — институт), 1982 дә химия-технол. процессларын автоматлаштыру һәм җиһазлау ф-ты (хәзерге идарә һәм автоматлаштыру ф-ты) эшли башлый. 1987 дә Бөтенсоюз текстиль һәм җиңел сәнәгать белеме читтән торып уку ин-тының гыйльми-консультация пункты базасында җиңел сәнәгать технологияләре ф-ты ачыла.

1990 елларда укыту эшчәнлегендә яңа юнәлешләр үсеш ала; химия сәнәгате һәм аңа бәйле тармаклар өчен кадрлар әзерләү үзәгеннән ун-т икътисад, дәүләти һәм муниципаль идарә, фән һәм сәнгатьнең төрле тармаклары өчен белгечләр әзерләп чыгаруга юнәлеш тоткан киң профильле югары уку йортына әверелә.



Казан технология университеты. «А» корпусы.

2010 га К.т.у. составында 8 институт исәпләнә: энергия сыйдырышлы материаллар һәм эшләнмәләр экологиясе ф-ты, технол. һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы ф-тларыннан торган Инженерлык химия-технол. ин-ты; нефть һәм нефть химиясе, химик технологияләр (нәорганик технологияләр буенча белгечләр әзерли), наноматериаллар һәм нанотехнологияләр ф-тлары б-н Нефть, химия һәм нанотехнологияләр ин-ты; механика ф-ты, энергетика машиналары төзү һәм технол. җиһазлар ф-тлары булган Химия һәм нефть машина төзелеше ин-ты; каучук һәм эластомерлар эшкәртү технологиясе ф-ты һәм пластмассалар, композитлар эшкәртү технологияләре, сертификацияләү ф-тларын берләштергән Полимерлар ин-ты; җиңел сәнәгать технологияләре, мода, дизайн һәм программалаштырылган инженерия ф-тлары кергән җиңел сәнәгать технологияләре, мода һәм дизайн ин-ты; идарә итү һәм мәгълүматлаштыру, мәгълүмат технологияләре ф-тлары б-н Идарә, мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат технологияләре ин-ты; идарә, икътисад һәм хокук, социаль һәм гуманитар технологияләр ф-тлары б-н Идарә, икътисад һәм социаль технологияләр ин-ты; азык-төлек технологияләре, азык-төлек инженериясе ф-тлары б-н Азык-төлек әзерләү ин-ты; Хәрби хезмәткә өйрәтү ин-ты. 2007 дә ачылган Корпоратив ун-т КТУның бүлекчәсе булып тора (логистика буенча белгечләр әзерли).

1963 тән Түбән Кама шәһәрендәге ф-лы 1995 елда *Түбән Кама химия-технология институты* итеп үзгәртелә (ш.у. КТУның ф-лы хокукында). 1995 тә Бөгелмә, Волжск (Мари Респ-касы) шәһәрләрендә дә ф-лары ачыла.

79 белгечлек буенча укыту алып барыла, 31 бакалаврлык, 57 магистрлык юнәлешендә барлыгы 90 нан артык белгечлек буенча белем бирелә. 2010 елга КТУда көндезге бүлектә 10830, кичке бүлектә — 1425, читтән торып уку бүлегендә 8043, ш.и. 10300 студент түләүле нигездә белем ала. Моннан тыш, Түбән Кама ин-тында — 4320, Бөгелмә ф-лында — 320, Волжск ф-лында 344 студент исәпләнә. КТУда Әзәрбайҗан, Әфганстан, Бангладеш, Вьетнам, Мисыр, Замбия, Гыйрак, Иран, Йәмән, Казакъстан, Кытай, Кыргызстан, Литва, Намибия, Нигерия, Палестина, Сүрия, Судан, АКШ, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Украина һ.б., барлыгы 26 илдән 400 ләп студент белем ала.

Университет барлыгы 80 меңнән артык белгеч әзерләп чыгара. Уку йортын тәмамлаучылар арасында 6 СССР ФАнең һәм РФАнең мөхбир әгъзасы һәм академигы, ш.и. В.В.*Кафаров*, С.Р.*Рәфыйков*, И.В.*Торгов*, П.А.*Кирпичников*, сәнәгать оешмалары җитәкчеләре С.Г.*Богатырёв*, Н.Х.*Йосыпов*, Ленин һәм Дәүләт бүләкләре лауреатлары Р.С.*Гайнетдинов*, Ф.П.*Мадякин*, ТР ФА президенты Ә.М.*Мазһаров* бар. Укытучылар коллективында 1100 дән артык кеше исәпләнә, ш.и. ТР ФА академиклары С.Г.*Дьяконов*, Р.С.*Сәйфуллин*, ТР ФА мөхбир әгъзасы В.П.*Барабанов*, Ф.Ә.*Гарифуллин*, Г.С.*Дьяконов*, В.А.*Иванов*, Н.Ф.*Кашапов*, В.А.*Максимов*, И.Г.*Хисамиев*, И.Ш.*Хәснетдинов* — барлыгы 186 фән. д-ры һәм 650 фән. канд-ты.

КТУ — өстәмә белем бирү үзәге дә. 1966 да квалификация күтәрү ф-ты ачыла. 1998 дә ул 58 белгечлек буенча квалификация күтәрү, 2 нче югары белем бирү һәм яңа һөнәр үзләштерү программаларын гамәлгә ашыручы Өстәмә һөнәри белем бирү ин-ты дип үзгәртелә. Аның составында 8 югары мәктәп (икътисад, идарә, менеджмент һәм маркетинг, чит ил телләре, бизнес, социаль технологияләр, модель бизнесы, сәнгать мәктәпләре), укытучыларның белемен күтәрү ф-ты (КТУ укытучылары өчен), укытучыларның квалификациясен күтәрү үзәге (Россия югары уку йортлары укытучылары өчен) һәм тагын гуманитар-психол., өстәмә белем бирү (КТУ студентлары өчен) ф-тлары бар. Ел саен анда 4 меңләп кеше белем ала.

1990 елда К.т.у.на әзерләү ф-ты ачыла, 2005 тә мәктәп укучыларына һөнәри юнәлеш бирүне оештыручы, аларны укырга керергә әзерләүче Әзлексез белем бирү үсеше ин-ты дип үзгәртелә. Аның карамагында урта һөнәри уку йорты — Казан технол. көллияте эшли, анда 5 белгечлек буенча 500 ләп укучы белем ала.

Хәрби хезмәткә өйрәтү ин-ты (2008 дә ачыла) студентларны запастагы офицер белгечлегенә өйрәтүне тәэмин итә, аның карамагында ун-тның спорт командалары һәм секцияләре, 2 чаңгы базасы, спорт лагере бар.

КХТИда фәнни тикшеренүләрне башлап җибәрүчеләр — Казан ун-тының химия фәнни мәктәбе вәкилләре: А.Е.*Арбузов*, Б.А.*Арбузов*, А.Я.*Богородский*, А.М.*Васильев*, Г.С.*Воздвиженский*, А.Ф.*Герасимов*, Г.Х.*Камай*, А.И.*Луньяк*, А.И.*Разумов* һәм механика мәктәбе вәкилләре: Г.К.*Дьяконов*, Х.М.*Мөштәри*, Н.М.*Пауткин*. Шуннан соңгы унъеллыкларда Б.Л.*Кондрацкий*, С.М.*Кочергин*, А.Г.*Усманов*, П.А.*Кирпичников*, Н.А.*Холево* һ.б. эшли.

Хәзерге вакытта КТУ, фәнни үзәк булarak, фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләрне түбәндәге юнәлешләр буенча алып бара: нефть химиясе җитештерү технологияләре (А.Г.*Лиакумович*, И.Н.*Дияров*, И.Ш.*Хәснетдинов*), ясалма каучук технологиясе (С.И.*Вольфсон*, Л.А.*Зенитова*), электрохимик процесслар технологиясе (Б.Л.*Журавлёв*, Р.Г.*Кайдриков*), химик һәм технол. процесслар кинетикасы (Х.Э.*Харлампиди*), органик һәм нәорганик полимерлар технологиясе (Р.Я.*Дебердиев*, В.Ф.*Сопин*, А.В.*Косточко*), конструкцион һәм композит материаллар



Казан технология университеты. «Б» корпусы.

технологиясе (Н.Ф.Кашапов), биотехнология (В.М.*Емельянов*, В.С.*Гамаюрова*), җиһазлар проектлаштыру методологиясе (И.И.*Поникаров*), химик технологияләр процессын математик модельләштерү (С.Г.Дьяконов, Г.С.Дьяконов, Ф.Ә.Гарифуллин), җылылык һәм авырлык алмашы (Ә.Ә.Тәрҗеманов, Ф.М.*Гомәров*), механика (В.А.Иванов, В.А.Максимов), экология (А.Ф.*Махоткин*, С.В.*Фридланд*), мәгълүмати технологияләр (А.В.*Фафурин*, А.П.*Кирпичников*), элементоорганик кушылмалар химиясе (П.А.*Гуревич*, М.Б.*Газизов*), физик химия (В.П.Барабанов), теоретик химия (А.М.*Кузнецов*), махсус химия һәм махсус технология (В.Я.*Базотов*, И.Ф.*Фәләхов*), социаль-икътисади, сәяси һәм фәлсәфә мәсьәләләре (Р.С.*Цейтлин*, В.И.*Курашов*), югары техник белем бирү педагогикасы (Л.И.*Гурье*, А.М.*Кочнев*, В.В.*Кондратьев*).

КТУ 7 фәнни үзәкне һәм 20 лабораторияне үз эченә ала. 1997 дән КТУ составында эшләгән «Союзхимпроект» (500 хезмәткәр) иң эре фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру үзәкләреннән берсе булып санала. 14 диссертация советы эшләп килә (ш.и. 7 се докторлык диссертацияләрен яклау буенча), 55 белгечлек буенча аспирантура (техник, химия, биол., тарих, сәясәт, социол., икътисад, фәлсәфә, пед., психол., фарм. фәннәре), барлыгы 580 аспирант, 9 белгечлек буенча 40 тан артык докторант бар. Университет 20 дән артык илнең югары уку йортлары һәм пр-тиеләре б-н фәнни һәм тикшеренү элемтәләре җәелдерә.

Университетның уку биналары 3 шәһәрчектә урнашкан. Башта институт шәһәр үзәгендәге элеккеге *Казан сәнәгать училищесе* бинасын (хәзерге «Б» корпусы) били. Шунда ук 1936 да ректор корпусы төзелә («А» корпусы), ике бина да архит-ра истәлеге исәпләнә. 1960–70 елларда Себер трактында яңа биналар комплексы төзелә, Инженерлык химия-технол. ин-тының үз шәһәрчеге бар. Фәнни-гыйльми мәгълүмат үзәге (китапхана) 2 млн. саклау берәмлеген тәшкил итә. 1997 дә үз нәшрияты ачыла, анда «Химия и компьютерное моделирование. Бутлеровские сообщения», «Вестник технологического университета» ж-ллары, «Технологический университет» г-тасы чыгып килә. 1970 тән А.Е.Арбузов, Г.Х.Камай, П.А.Кирпичников мемориалларын туплаган музей эшли.

Университетның бөтен уңайлыклары булган 7 тулай торагы, Яшь галимнәр һәм укытучылар йорты, «Яшел наратлык» («Зелёный бор») спорт-сәламәтләндерү лагере, профилакторие, спорт һәм студентлар клубы бар.

1980 дә ун-т Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. К.т.у.ның ректорлары: Б.Н.Выропаев (1930–31), Г.Б.*Баһаветдинов* (1931–37), А.М.Васильев (1937), Н.П.Воскобойников (1937–38), З.Б.Шубин (1938–39), И.В.Суриков (1939–41), И.И.Курочкин (1941–42), А.Е.*Переверзев* (1942–44), Г.Х.Камай (1944), Л.М.*Козлов* (1944–58), С.М.Кочергин (1958–59), А.Г.Усманов (1959–62), А.И.Милютин (1962–64), П.А.Кирпичников (1964–88), С.Г.Дьяконов (1988–2007), Г.С.Дьяконов (2007 дән).

*Әд.:* Казанский химико-технологический институт: Материалы к истории возникновения и развития КХТИ им. С.М.Кирова (1930–1955). К., 1955; Несмелов В.В. Казанский химико-технологический институт им. С.М.Кирова. 1919–1969: Ист. очерк. К., 1969; Казанский химико-технологический институт вчера, сегодня, завтра: В 2 ч. К., 1990; Лозовой А.С., Кириченко А.В., Денисенко Н.Н. Казанский химико-технологический институт в годы войны. К., 1995; Логинова Л.Н. История Казанского химико-технологического института: Послевоенный период (1946–1960). К., 1995; Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ-КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000; Мухаметзянов Г.М. Казанский химико-технологический институт. Механический факультет. 60 лет. К., 2000; Переломное десятилетие. Казанский государственный технологический университет (1991–2000): Ист. очерк. К., 2000; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**КАЗА́Н ТИМЕ́Р ЮЛ ТРА́НСПОРТЫ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Горький тимер юлы урта һөнәри уку йорты. 1985 елда оештырыла. Техникум тимер юл транспорты өлкәсендә эшләү өчен тимер юл төзелеше, юл һәм юлларны төзү, хәрәкәттәге тимер юл составын техник файдалану; тимер юл транспортында йөк ташу һәм идарә итүне оештыру; тимер юл транспортында телемеханика (ерактан торып идарә итү һәм көйләү) һәм автоматика юнәлешләре буенча белгечләр хәзерли. 2010 да 720 гә якын кеше, (ш.и. көндезге бүлектә — 440, читтән торып уку бүлегендә 275 студент укый); укытучылар коллективы

40 кешедән тора. 2 меңнән артык белгеч әзерләнә. Техникумда 64 бүлмәле укыту корпусы һәм лаб., өйрәтү полигоны, стадион, спорт залы бар.

**КАЗА́Н ТӨБӘГӘ́ КРЕДИ́Т КООПЕРАТИВЛАРЫ́ БЕРЛЕГӘ́**, 1918 елның маенда Казан губернасының үзара кредитлашу, ссуда бирү-саклау ширкәтләре берлеге җирлегендә оештырыла. Максаты — Казан губернасындагы, Вятка һәм Сембер губерналарының 7 өязендәге кооперативларны һәм аларның берләшмәләрен кредитлау һәм һөнәрчелек промыселларын үстерү өчен шартлар тудыру юлы б-н ярдәм итү. 1919 да *Казан төбәге кредит кооперативлары һәм хезмәт артельләре берлеге* дип үзгәртелә.

**КАЗА́Н ТӨГӘ́Л МАШИНАЛА́Р ТӨЗҮ́ ЗАВОДЫ́**, оборона сәнәгатенең федераль казна пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 890 кеше (2010). 1941 елда Казанда, июль–август айларында эвакуацияләнеп, Казан мех комб-ты корпусларында урнаштырылган М.И.Калинин исем. Ленинград машиналар төзү з-ды җирлегендә «Искож» һәм «Пишмаш» з-длары, 4 нче һөнәр уч-щесе, трамвай паркының төзелеп бетмәгән биналарында, Казан химия-технол. ин-ты остаханәләрендә урнашкан Предприятие п/я 421 буларак оештырыла. 1941 нең 7 ноябрендә заводтан фронтка оборона эшләнмәләренең беренче партиясе җибәрелә. Заводны оештыру-торгызу эшләре, нигездә, 1942 нең мартында тәгәлләнә. 1942 нең апрелендә аның үз металлургия базасын төзү башлана. 1943 тә пр-тиенең инструменталь базасы 1941 гә карата 3 тапкыр, продукция җитештерү, 1942 ел күрсәткечләре б-н чагыштырганда, 2 тапкыр арта. 1943–45 тә завод детальләрне механик эшкәртү технологиясен интенсив рәвештә камилләштерүне автомат ысулларга («АКМЭ», «КОН-123», «КОН-126» һәм «Питлеры» автоматларында) күчү юнәлешендә дәвам итә. 1944 тә өзлексез эшләүче 22 линиягә (гомуми озынлыклары 336 *м*) тагын 18 линия (760 *м*) өстәлә; аларда эшчеләрнең 65%ы эшли, җитештерү циклы 26 тапкыр кыскара. 1945 тә, 1944 ел б-н чагыштырганда, җитештерү 30% ка арта; халык хуҗалыгында кулланылучы продукция — тракторлар, комбайннар һ.б. а.х. машиналары өчен запас частьләр, беркеткеч эшләнмәләр, саву һәм кырку аппаратлары, дизель ягулыгы аппаратурасы, бакча тракторлары һ.б. эшләп чыгара. 1966 дан — Казан төгәл машиналар төзү заводы (1975–2008 дә М.И.Калинин исемендә), 1998 дән — дәүләт унитар пр-тиесе, 2000 нән — федераль дәүләт унитар пр-тиесе, 2008 дән — федераль казна пр-тиесе.

1990 елларда завод тарафыннан эл. б-н йөри торган арбалар өчен җиһазлар, яктылык кайтаргычлар, авто- һәм аэровентильләр, янгын турында хәбәр бирүче җайланмалар, көнкүрештә кулланылучы «Фонтан» насослары, газ басымын көйләүче РДГ-80 җайланмасы һ.б. җитештерелә. 1996 да суыткыч машиналар, сөт салкынайткычлар, һава-спиральле, майсыз спиральле компрессорлар чыгарыла. Завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1981). Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 5 кешегә — СССРның Дәүләт бүләге лауреаты, 12 кешегә — РСФСРның, ТАССРның атказ. машина төзүчесе, 1 кешегә — РСФСРның атказ. рационализаторы, 1 кешегә — РСФСРның атказ. икътисадчысы дигән мактаулы исемнәр бирелә; 5 кеше — Ленин ордены, 2 кеше — 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 5 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 24 кеше — «Почёт билгесе», 2 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 5234 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Завод җитәкчеләре: Р.А.Стролинович (1941), Г.Н.Брук (1941–42), М.А.Лупандин (1942–43), Е.Д.Бердичевский (1943–45), В.М.Мачинский (1945–54), К.Н.Кононов (1954–57), К.А.*Сергиевский* (1957–73), Е.Н.Попов (1973–77), О.В.Филиппов (1977–85), Р.Б.Ибраһимов (1985–95), Я.Н.Гайнетдинов (1995–2003), Л.Ф.Самай (2003–06), А.И.Хисамиев (2006 дан).

*Әд.:* С т е п а н о в А.Н. Наш Точмаш. К., 1995.

*И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н ТӨЗЕЛӘ́Ш КӨЛЛИЯТӘ́**, РФ Торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш буенча Федераль агенство уку йорты. 1955 елда Казан технол. техникумы буларак оештырыла, 1961 дән Казан төзелеш техникумы, 1991 дән хәзерге исемдә. Көллият йортлар һәм корылмалар төзү һәм файдалану; шәһәр төзү кадастры, металл булмаган төзелеш конструкцияләре һәм эшләнмәләре җитештерү; икътисад, бухгалтерлык исәбе һәм контроль; җир-милек мөнәсәбәтләре; хокук белеме буенча белгечләр әзерли. 1964–70 тә Әлмәт шәһәрендә филиалы эшли (хәзер Әлмәт политехник техникумы). 2010 да 1250 кеше, ш.и. көндезге бүлектә — 990 һәм читтән торып — 250 студент укый; укытучылар коллективы составы 61 кешедән тора, ш.и. 2 ТРның атказ. мәктәп укытучысы, 1 фән. канд-ты. Көллият оешканнан алып 22 мең белгеч әзерли. Көллияттә 40 аудиторияле 2 уку корпусы, 7 укыту-производство остаханәсе бар.

**КАЗА́Н ТӨЗҮЧӘ́ ИНЖЕНЕРЛА́Р ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан архитектура-төзелеш университеты.*

**КАЗА́Н УКУ́-УКЫТУ́ О́КРУГЫ** (19 йөз — 20 йөз башы), Россиядәге 6 (соңрак 10) уку-укыту округының берсе. Халык мәгарифе министрлыгы карамагында. 1803 елның 20 июнендә уку йортлары б-н идарә итү һәм дәреслекләр бастыруны җайга салу өчен оештырыла. Башта аның составына Идел буе һәм Урал алдының 14 губернасы, 1836 дан (Губерналар реформасыннан соң) — 9 губерна, 1845 тән (Пенза губернасын Мәскәү уку-укыту округы карамагына күчергәннән соң) — 8 губерна, 1873 тән (К.у-у.о.ннан мөстәкыйль Оренбург уку-укыту округы аерылып чыкканнан соң һәм 1918 дә К.у.у.о. ябылганга кадәр) — 6 губернаның (Казан, Әстерхан, Вятка, Самара, Саратов, Сембер) уку йортлары керә. К.у-у.о. попечителе император тарафыннан билгеләнә, ул үзенең вәкаләтләре б-н халык мәгарифе министры иптәшенә (урынбасарына) туры килә. Аның вазифаларына округ терр-ясендәге барлык дәүләт (дини уку йортларыннан башка) уку йортлары б-н җитәкчелек итү һәм дәүләтнеке булмаган (19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында земство һәм шәһәр уку йортлары) уку йортларын тикшерү керә. Попечитель карамагында чиновникларның зур аппараты була (ярдәмчеләр, округ инспекторлары, канцелярия). Попечительләр университет б-н даими җитәкчелек итә, ел саен гимназияләргә инспекция б-н киләләр. Уку йортларын түбәнрәк дәрәҗәдә агымдагы тикшерү попечительгә буйсынучы халык уч-щеләре директорларына тапшырыла. Хөкүмәт сәясәтен мәгариф өлкәсендә таратучылар буларак, попечительләр кайбер очракларда аны формалаштыруда үзләре дә актив катнашалар (М.Л.*Магницкий*, П.Д.*Шестков*). К.у-у.о.ның попечительләре: С.Я.Румовский (1803–12), М.А.Салтыков (1812–18), М.Л.Магницкий (1819–26), М.Н.Мусин-Пушкин (1827–45), вакытлыча Н.И.Лобачевский (1845–47), В.П.Молоствов (1847–57), Ф.Ф.Веселаго (1857 нең май–ноябре), Е.А.Грубер (1857–59), кенәз П.П.Вяземский (1859–62), Ф.Ф.Стендер (1862–65), П.Д.Шестаков (1865–83), П.Н.Масленников (1883–89), В.А.Попов (1889–94), Г.А.Потапов (1895–99), М.М.Алексеенко (1899–1901), С.Ф.Спешков (1901–05), А.Н.Деревицкий (1905–12), Н.К.Кульчицкий (1912–13), И.А.Базанов (1913–15), М.М.Ломиковский (1915–17).

Чыг.: Начальственные распоряжения по Казанскому учебному округу. К., 1827–64; Отчёты по Казанскому учебному округу. К., 1841–56; Циркуляры по Казанскому учебному округу. К., 1866–1916.

*Әд.:* В л а д и м и р о в В.В. Материалы для истории образования в Казанском учебном округе. К., 1866; Р о ж д е с т в и н А.С. Пётр Дмитриевич Шестаков: Очерк жизни и педагогической деятельности. К., 1907; П а в л о в а Г.Е. Степан Яковлевич Румовский. 1734–1812. М., 1979.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н УКЫТУЧЫЛА́Р ИНСТИТУТЫ́**, 1876 елда ачыла. *Шәһәр училищеләренә*, 1912 дән *Казан уку-укыту округы* өчен *югары башлангыч училищеләргә* укытучылар әзерләү максатында оештырыла. Пед. һәм гомуми белем дәрәҗәсе тәмамланмаган югары белем алуга тиң була. Институтка шәһәр уч-щеләрен бик яхшыга тәмамлаучылар һәм, укытучылар семинариясен тәмамлап, ике ел башлангыч мәктәптә эшләп килүчеләр кабул ителә. Уку срогы 3 ел, ел саен 60–70 кеше алына һәм тәмамлый. Идел буе регионында югары дәрәҗәдәге бердәнбер махсус пед. уку йорты буларак, институт эре методик үзәккә әверелә. Укытучылар коллективында тәҗрибәле белгечләр, ш.и. Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе профессорлары һәм доцентлары (А.И.*Дружинин*, Н.К.Невзоров, М.Н.*Пинегин)* эшли. Укытучыларның күпчелеге — институт һәм шәһәр уч-щеләре өчен дәреслекләр авторлары. 1896–1902 дә К.у.и.ның директоры күренекле педагог А.И.*Анастасиев* була. Институтта педагогика, дидактика теориясен өйрәнүгә, пед. практикага (институт каршындагы шәһәр үрнәк уч-щесендә узалар) зур игътибар бирелә. 1917 гә кадәр институтка бары тик православие динендәгеләр генә кабул ителә, программада Илаһи Канун (Закон Божий) мөһим



Казан укытучылар институты.

урын алып тора. Институтны тәмамлаучылар математика, гуманитар, табигыять фәннәрен тулы булмаган урта мәктәптә укытырга сәләтле киң профильле укытучылар була, гимназия укытучылары, Халык мәгарифе министрлыгы ведомствосы чиновниклары булып эшли. Институтта чуаш, мари һәм мордвалар укый, аларның күпчелеге милли хәрәкәт һәм мәгариф эшлеклеләренә әверелә, ш.и. совет чорында да (педагоглар — чуашлар О.А.Андреев, Я.З.Захаров, мордвалар Ф.Ф.Советкин, И.Ф.Прокаев, марилар — И.Т.Матюков, М.И.Веткин). 1918 дә К.у.и. Казан пед. ин-ты — югары уку йорты итеп үзгәртелә, шуннан *Казан педагогика университеты* тарихы башлана.

*Әд.:* Т р о и ц к и й С.М. Историческая записка о Казанском учительском институте за 25 лет его существования. К., 1901; Казанский государственный педагогический институт. К., 1974; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001.

**КАЗА́Н УКЫТУЧЫЛА́Р СЕМИНА́РИЯСЕ**, ир балалар урта уку йорты. 1872 елда Н.И.*Ильминский* башлангычында ачыла. 1872–84 тә Казан әҗнәби укытучылар семинариясе. Идел буе халыклары вәкилләреннән педагог-миссионерлар әзерләү өчен оештырыла, ләкин шул заманның тел мохите ихтыяҗларын тәэмин итү өчен семинариядә укучыларның кимендә өчтән бер өлеше руслар булырга тиеш була. Казан уку-укыту округына кергән губерналардан земство һәм башка башлангыч мәктәпләрне тәмамлаучылар, Төньяк һәм Себер халыкларының балалары кабул ителә. Уку, туклану һәм яшәү түләүсез була. Уку срогы 4 ел (әзерлек сыйныфын кертеп, анда укырга керүчеләрнең барысы да диярлек укый).

Илаһи Канун (Закон Божий), рус теле, тарих, география, арифметика һәм геометрия, чиркәү хорында җырлау укытыла. Педагогиканы укытуга зур әһәмият бирелә. Пед. практика уздыру өчен 1874 тән семинария каршында чуаш, мари, мордва, удмурт башлангыч мәктәпләре булдырыла (руслар практиканы — шәһәр башлангыч мәктәпләрендә, ә керәшен татарлар *Казан үзәк керәшен татар мәктәбендә* узалар). К.у.с. *Ильминский системасын* формалаштыру һәм үстерү үзәге була. Укытуда миссионерлык характеры ачык күренә. Семинариягә бары тик православие динендәгеләр генә кабул ителә. Укучылар һәм укытучылар Библия һәм христиан әдәбиятын аларның үз ана телләренә тәрҗемә итүдә актив катнашалар. Укытучылар, нигездә, югары квалификацияле белгечләр була: В.Н.Витевский, Н.И.Ашмарин, С.В.Смоленский, Н.В.Никольский, Никанор (Каменский) һ.б.

К.у.с. 1918 дә ябыла; аны 1500 кеше тәмамлый, ш.и. руслар — 686, керәшен татарлар — 243, чуашлар — 179, марилар — 128, мордвалар — 110, удмуртлар — 70, коми һәм коми-пермяклар — 36, 100 ләп кеше — калмыклар, казакъләр, якутлар, хакаслар, алтайлылар, шор, кореялылар һ.б. Семинарияне тәмамлаучылар Идел буе халыкларының формалашып килүче милли интеллигенциясе нигезен тәшкил итә. Аларның зур күпчелеге земство мәктәпләрендә эшли (ана телендә укыталар): 200 дән артык кеше дин әһеле булып китә. Семинарияне тәмамлаучылар арасында — Т.Е.*Егоров*, Р.П.Даулей, В.М.*Горохов* (керәшен татарлар), мордва мәдәнияте эшлеклеләре — А.Ф.*Юртов*, М.Е.*Евсевьев*, удмуртлар — И.С.*Михеев*, И.В.Яковлев, марилар — Ф.Е.Егоров, С.Г.Чавайн, В.М.Васильев һ.б.

Беренче елларда семинария Казан үзәк керәшен татар мәктәбе биналарында, 1874 тән Кабан күле буенда арх. В.К.Бечко-Друзин проекты буенча төзелгән махсус бинада урнаша (хәзер *Казан җиңел сәнәгать техникумы*; архит-ра истәлеге).

К.у.с.нең директорлары: Н.И.Ильминский (1872–91), А.В.Бобровников (1892–1906), А.А.Воскресенский (1906–14), В.В.Беляев (1914–16), А.М.Неунывалов (1916–18).

*Әд.:* В и т е в с к и й В.И. Николай Иванович Ильминский — директор Казанской учительской семинарии. К., 1892; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001.

*Р.Р.Исхакова.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́**, илнең иң борынгы югары уку йортларының берсе. Император Александр I нең 1804 елның 5 ноябрендә кул куйган Устав һәм Раслау грамотасы нигезендә 1805 нең мартында ачыла. Хәзерге Россия терр-ясендә Мәскәү ун-тыннан кала икенче ун-т. 1917 гә кадәр император ун-ты, 1925 тә В.И.Ульянов-Ленин исеме бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы (1955), Ленин (1979) орденнары б-н бүләкләнә. РФ Президенты Б.Н.Ельцинның 1996 ның 30 июль Указы б-н Россия тарихи-мәдәни мирасының аеруча кыйммәтле объектлары дәүләт җыелмасына кертелә.

*Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе* җирлегендә оештырыла, аның иң яхшы укытучылары (И.Ф.Яковкин, И.И.Запольский, И.И.Эрих) — ун-т укытучылары, ә өлкән сыйныф укучылары студентлары булып китәләр (ш.и. С.Т.Аксаков). К.у.нда Мәскәү ун-тыннан, Мед.-хирургия академиясеннән, руханилар академияләреннән, Германия һ.б. илләрдән чакырылган профессорлар эшли башлый. Баштагы 10 елда укыту планнары һәм программалары эшләнү стадиясендә була, Устав тарафыннан каралган бүлекләр оештырылмый, студентлар саны 45 тән артмый.

1814 тә ун-т рәсми төстә ачыла, составында — әхлакый һәм сәяси фәннәр, физика һәм матем., дәвалау, тел фәннәре бүлекләре була. 1819 да студентлар саны 169 га кадәр арта. К.у. өчен 1819 да *Казан уку-укыту округы* попечителе М.Л.*Магницкий* тарафыннан уздырылган ревизия авыр сынау була. Ул уку-укыту эшенең торышын бик түбән бәяли, ун-тны дәһрилек, сәяси фикер хөрлеге, әхлаксызлык приюты («Анда дәһрилек һәм фетнә орлыклары чире хөкем сөрә») дип атый һәм аны ябарга тәкъдим итә. Магницкий эшләгән елларда (1819–25) күп кенә профессорлар ун-ттан эштән җибәрелә (Г.И.Солнцев, И.Е.Срезневский, Е.В.Врангель һ.б.), укыту программасыннан рәсми идеологиягә туры килмәгән бүлекләр төшереп калдырыла, китапханәдән күп китаплар алына; эчке тәртипләрнең катгыйлануы нәтиҗәсендә студентларның саны 110 га кадәр кими. Шул ук вакытта ун-тның бюджеты сизелерлек арта, төп бина төзелә, фәнни тикшеренүләр өчен кыйммәтле җиһазлар булдырыла. Шул елларда талантлы яшь галимнәр Н.И.Лобачевский, И.М.Симонов, Ф.Х.Эрдманның эшчәнлеге башлана. 1825–35 тә 1804 елгы Устав рәсми рәвештә гамәлдә кала, ләкин император Николай I заманында идарәне бюрократлаштыру нәтиҗәсендә ун-т, асылда, автономиясен югалта.

1835 елгы Устав буенча Халык мәгарифе министрлыгы һәм уку-укыту округлары попечительләре тарафыннан ун-тлар өстеннән күзәтчелек итү көчәя, ректорлар һәм гыйльми советларның хокуклары чикләнә, сайлау башлангычлары кыскартыла, катгый дисциплина кертелә. Шуның б-н бергә уку йортының статусы билгеләнә һәм ярдәмче базаны (китапханәләр, обсерваторияләр, лабораторияләр, кабинетлар, клиникалар, типографияләр) финанслау арта. К.у.да 3 ф-т эшли: философия (тел белеме һәм физика-матем. бүлекләре б-н), юридик, мед. 1835 тә тел белеме бүлеге составында *Шәрекъ бүлеге* (1855 тә Петербург ун-тына күчерелә), 1844 тә юридик ф-тның *Камераль разряды* ачыла, ул дәүләт милке б-н идарә итү буенча белгечләр әзерли. Фәнни мәктәпләр оештырыла, ләкин ун-тның мәгариф үсешендәге роле ясалма рәвештә түбәнәйтелә. 1840–50 елларда студентлар саны артмый, 300 дән 380 гә кадәр тирбәлә. 1850 елларның 2 нче яртысында ун-т тормышын либеральләштерүгә күчеш сизелә, студентлар кабул итүдә чикләүләр бетерелә, аларның саны тиз арта башлый (1863 тә 600 дән артык кеше), төрле катлау вәкилләренең өлеше 40% ка кадәр арта; студентларның социаль составы буенча К.у. Россиядә иң демократик уку йорты була.

1863 елгы Устав ун-тларның киң автономиясенә башлангыч бирә, советларның хокуклары киңәя, аларның составына барлык профессорлар керә, профессорлар ректор, деканнарны сайлый, фәннәрнең бүленешен, аларны укыту тәртибен раслый. Яңа Уставка туры китереп, К.у. юридик, мед., физика-матем. һәм тарих-филол. ф-тларыннан тора. Кафедралар һәм укытучылар саны 2 тапкырдан да артып китә. Университетка барлык урта белемле кешеләр керә ала, дәресләргә ирекле йөрү һәм имтиханнарның уңайлы гра-

фигы рөхсәт ителә. Шуның б-н бергә студентларның үзешчән берләшмәләре һәм коллектив рәвештә каршылык күрсәтү акцияләре катгый тыела. 1860–70 елларда К.у. уңышлы үсешкә ирешә, студентлар саны 1884 елга 900 кешедән арта, фәнни тикшеренүләр активлаша.

1873 тә К.у. җирлегендә вет. ин-ты ачыла (к. *Казан ветеринария медицинасы академиясе*). 1876 дан ун-т каршында *Казан югары хатын-кызлар курслары* эшли. Иҗтимагый тормышның либеральләшүе фәнни оешмалар — *Табигыятьчеләр җәмгыяте* (1869), Казан табибләре җәмгыяте (1877), *Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең* (1878) эшчәнлеге үсешенә этәргеч бирә. Шуның б-н бергә 1860 еллар ахырыннан автономияне чикләү сәясәте уздырыла. Попечитель П.Д.*Шестаковның* ун-т тормышының барлык якларын катгый күзәтүе дә либераль профессорлар арасында ризасызлык тудыра. Конфликтлар нәтиҗәсендә 1868 дә А.М.Бутлеров Петербург ун-тына күчә; 1871 дә П.Ф.Лесгафт эшеннән азат ителә, моңа каршы протест белдереп, профессорлар Н.А.Головкинский, А.Я.Данилевский, В.Г.Имшенецкий, В.В.Марковников, А.И.Якобий, А.Е.Голубев, П.И.Левитский отставкага китәләр; 1878 дә ун-т инспекциясе өчен инструкция, 1882 дә студентлар өчен кагыйдәләр кертелә, 1863 елгы Уставның кайбер кагыйдәләре шулар нигезендә бетерелә.

1884 елгы Устав автономияне юкка чыгара һәм яңадан идарәнең үзәкләштерелгән структурасын булдыра. Ректорлар император фәрманнары б-н, деканнар халык мәгарифе министры әмерләре б-н билгеләнә. Уку-укыту округы попечителенең йогынтысы кими, ләкин ректорның хакимлеге кискен арта, профессорлар аның әмере б-н билгеләнә. Абитуриентларга карата булган таләпләр катгыйлана, барлык укырга керүчеләрдән гимназия курслары өчен имтиханнар тапшыру таләп ителә, руханилар семинарияләрен тәмамлаучылар өчен укырга керү чикләнә. Студентларның тәртипләрен күзәтү яңадан кертелә (дәресләр вакытында гына түгел, укудан тыш вакытта да). Чынлыкта ун-тта инспекторлар һәм аларның ярдәмчеләреннән полиция оештырыла. Яңа Уставка каршы протест 1887 елгы сходкада чагыла. Студентлар саны 20 йөз башына кадәр артмый диярлек (1898 дә — 938 кеше). Шуның б-н бергә университетны финанслау арта, яңа биналар төзелә, укытуның дәрәҗәсе күтәрелә. Фәнни мәктәпләр яңа үсеш ала. *Казан физика-математика җәмгыяте* (1890) һәм Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте (1891) оештырыла.

1884 елгы Уставка һәм студентларны солдатка бирүгә каршы бөтенроссия студентларының 1899 елгы забастовкасы хөкүмәтне ташламалар ясарга мәҗбүр итә.

Халык мәгарифе министры күрсәтмәләре һәм Студент учреждениеләрен оештыруның вакытлы кагыйдәләре (1901) дисциплина режимын йомшарта: инспекциянең җәза бирү функцияләре бетерелә, сәяси булмаган студентлар җәмгыятьләрен, оешмаларын булдыру рөхсәт ителә. *Россиядә 1905–07 еллар революциясе* көчәйгән вакытта кабул ителгән 1905 елгы Вакытлы кагыйдәләр ун-тка автономияне кайтара. Кабул итү кагыйдәләре җиңеләю сәбәпле, студентлар саны 1903 елда 968 дән 1905 елда 1225 кә кадәр арта. Шул ук елны ун-тка, беренче тапкыр ирекле тыңлаучылар буларак, 200 дән артык хатын-кыз кабул ителә. 1906 да тарих-филол. ф-ты җирлегендә яңадан Казан югары хатын-кызлар курслары ачыла. Рев-ция бастырылганнан соң, 1907 нең ноябрендә, автономия чикләнә, хатын-кызларны кабул итү туктатыла. 1908 нең ноябрендә Хакимлек итүче сенат фәрманы б-н 1884 елгы Устав яңадан торгызыла, ләкин ректорлар һәм деканнарның сайланып куелуы саклана. 1905 тән соң студентлар саны тиз артуын дәвам итә, 1910 да 3 мең кешегә җитә, ләкин 1914 елга 2 меңгә кадәр кими, моңа 1909 да Саратов ун-ты ачылу сәбәп була, Түбән Идел буе урта уку йортларын тәмамлаучыларның күпчелеге шунда укырга керә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында барлык ф-т студентларын (мед. ф-тыннан тыш) хәрби хезмәттән вакытлыча азат итү туктатыла, шуңа күрә 1915 елга аларның саны 500 гә кадәр кими. Шул ук елны ун-тка яңадан хатын-кызлар кабул ителә башлый.

1917 елга кадәр К.у. илнең иҗтимагый тормышында әһәмиятле роль уйный. 1861–63 тә аның каршында «Җир һәм ирек» революцион оешмасының Казан бүлеге эшли, 1863 тә студентлар *Казан фетнәсендә*, 1874 тә «халык арасына чыгуда» катнашалар. Студентлар Россиядә марксизмны тарату башында торган *Федосеев түгәрәкләренең (1888–90)*, 20 йөз башларында с. д. җирле оешмаларының һәм социалист-революционерлар партиясенең күпчелек өлешен тәшкил итәләр. Университетның элеккеге студенты Д.А.Каракозов 1866 да император Александр II гә беренче тапкыр һөҗүм ясый. Университетта студентларның күмәк чуалышлары 1882, 1887, 1902, 1904, 1905 елларда була. Университет профессорлары 1860 еллардан земство һәм шәһәр үзидарә органнарының актив өлешен тәшкил итәләр. Профессор Э.П.Янишевский — шәһәр башлыгы, 5 профессор — 1–4 нче Дәүләт Думалары депутатлары, Н.П.Загоскин — Дәүләт советы әгъзасы, М.Я.Капустин — 3 нче Дәүләт Думасы рәисе урынбасары, И.В.Годнев Вакытлы хөкүмәт министры була.

1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң ун-тның автономиясе 1905 елгы Вакытлы кагыйдәләр күләмендә яңадан кайтарыла. Кабул итү шартларының либеральләшүе нәтиҗәсендә, 1917 дә ун-тка 1885 кеше укырга керә (шуларның яртысыннан артыгы — хатын-кызлар). К.у. советы 1917 нең 9 декабрендә большевикларның хакимияткә килүен гаепли; 1917–18 дә дәресләр иске программа буенча дәвам ителә, совет власте органнары ун-т тормышына катнашмыйлар. Университет советы һәм профессорларның күпчелеге 1918 нең августында Чех-словак корпусы гаскәрләре һәм КОМУЧның халык армиясенең Казанны алуын хуплый һәм *Учредительләр җыены әгъзалары комитетына* күндәмлек күрсәтә. 100 дән артык укытучы һәм студентларның шактый өлеше чигенүче акгвардиячеләр б-н шәһәрдән китә. Аларның бер өлеше 1919–20 елларда кире кайта.

1918 нең көзеннән югары мәктәпне актив рәвештә үзгәртеп кору башлана (адмистратив үзгәртү, аеру һәм берләштерү), ул 15 ел дәвам итә. 1918 дә урман ф-ты булдырыла, 1919 ның мартында юридик ф-т кыскартыла, аның урынына юридик-сәяси, икътисад һәм тарих бүлекләре б-н иҗтимагый фәннәр ф-ты оештырыла, анда марксизм идеологиясе актив өйрәнелә. Шул ук елда ун-тка Казан югары хатын-кызлар курсларын кушалар. Студентларны пролетарлаштыру башлана; эшче һәм крәстиян яшьләрен ун-тка керергә әзерләү өчен 1919 да К.у.ның *эшчеләр факультеты* оештырыла (1920 еллар башыннан 1930 еллар уртасына кадәр аны тәмамлаучылар студентларның 35% ын тәшкил итә). 1921 дә тарих-филол. ф-ты, 1922 дә иҗтимагый фәннәр ф-ты ябыла, укытучылар һәм студентларның күпчелеген *Шәрекъ педагогия институтына* күчерәләр. Урман ф-ты 1922 дә Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык ин-ты составына күчерелә (к. *Казан аграр университеты*). 1922 дә, СССР югары уку йортлары укытучыларының протест акциясендә («профессорлар забастовкасы»нда) катнашкан өчен, математик А.А.Овчинников, тарихчы И.А.Стратонов, психиатр Т.Я.Трошин чит илгә сөрелә. 1922–23 уку елы башына бары тик физика-матем., мед. ф-тлары һәм эшчеләр ф-ты гына кала. 1928 дә — Совет хокукы ф-ты, 1930 да геол.-биол. һәм икътисад ф-тлары ачыла, химия бүлеге яңа оештырылган Казан химия-технол. ин-тына бирелә (к. *Казан технология университеты*). 1930 да мед. ф-ты Казан мед. ин-ты итеп үзгәртелә (к. *Казан медицина университеты*), 1931 дә совет хокукы һәм икътисад ф-тлары җирлегендә совет төзелеше һәм совет хокукы ин-тлары булдырыла (к. *Казан юридик институты, Казан финанс-икътисад институты*). Нәтиҗәдә ф-тлар саны яңадан кыскартыла (физика-матем., геол.-биол. һәм эшчеләр ф-тлары). Университетны таркату һәм аның җирлегендә махсус югары уку йортлары булдыру күздә тотыла. Шуның өчен 1931 дә факультетлар һәм кафедралар урынына механика-матем., астрономия-геодезия, физика, геофиз., геол.-минерал., геогр., туфрак-агрохим., зоол., ботаника, физиол., химия, аэрономика бүлекләре ачыла. Соңгысы 1932 дә авиация ин-ты итеп үзгәртелә (к. *Казан техник университеты*).

СССР ҮБКнең 1932 ел 19 сентябрь карары буенча 1930–31 дәге реформалар хата санала, белгечлекләрне бүлгәләү, югары белемгә утилитар караш, ун-тларны бетерү гаепләнә. Югары белем бирүнең традицион системасына кире кайту башлана. 1932 нең көзендә кафедралар, 1933 тә факультетлар яңадан булдырыла: физика-матем., химия, биол., геол.-туфрак-геогр. 1939 да геогр. һәм тарих ф-тлары (1940 тан — тарих-филол.) ачыла. 1930 елларда илдә репрессияләр көчәйгән шартларда, К.у. профессорлары В.Н.*Слепков*, М.К.*Корбут*, Н.Н.*Эльвов*, Н.-Б.З.*Векс*-

*лин,* С.П.*Сингалевич*, Г.Х.*Камай*, күп кенә башка укытучылар, хезмәткәрләр, студентлар кулга алына һәм хөкем ителә.

1940 та ун-тта 2 меңнән артык студент исәпләнә. 1941 дә, Бөек Ватан сугышы башлангач, укытучыларның һәм студентларның күп өлеше фронтка китә, ләкин ун-т кадрлар әзерләвен дәвам итә. 1941/42 уку елының беренче семестрыннан тыш, чөнки ул вакытта барлык укытучы һәм студентлар сакчылану корылмалары төзелешендә эшлиләр, дәресләр гадәттәгечә уздырыла. Студентлар саны 1943 кә 406 кешегә кадәр кими, ләкин сугыш ахырына 700 гә кадәр арта. К.у. җирлегендә СССР ФАнең эвакуацияләнгән фәнни бүлекчәләре эшли (к. *СССР Фәннәр Академиясе оешмаларының Казан группасы*), ун-тта күп кенә атаклы галимнәр укыта: академиклар Б.Д.Греков, Н.Е.Кочин, С.Л.Соболев, Е.В.Тарле, мөхбир әгъза Л.И.Иванов һ.б. Университетның 90 нан артык хезмәткәре һәм студенты фронтта һәлак була.

Сугыш беткәннән соң, ун-тның укыту һәм фәнни эшчәнлеге киң үсеш ала. 1946 да 1089 студент исәпләнә, 1954 кә аларның саны 3111 гә кадәр арта. 1949 да геол. ф-ты оештырыла, туфрак белеме каф. биол.-туфрак ф-ты дип атала башлый. Нигездә, нефть чыгару һәм эшкәртү б-н бәйле яңа белгечлекләр кертелә. 1952 дә юридик ф-т яңадан булдырыла. Шуның б-н бергә, галимнәр буыны алмашу сәбәпле, профессорлар, фән д-рларының саны кими. Фәнни тикшеренүләрнең үсешенә идеологик компанияләр каршылык күрсәтә (космополитизм б-н көрәш, «лысенковщина»). Хаксыз тәнкыйтькә һәм адм. репрессияләргә филолог А.И.Вознесенский, туфрак белгече М.А.Винокуров, биолог Н.А.Ливанов, тел белгече Р.А.Хәкимова һ.б. дучар була.

К.у.ның 1950 еллар уртасыннан 1980 еллар ахырына кадәр ныклы үсешенә фән-техника рев-циясе шартларында фәннең роле арту сәбәпче була. 1954 елга ун-тта 50 каф., 3,1 мең студент, 300 дән артык укытучы исәпләнсә, 1980 еллар уртасына — 72 каф., 11 меңнән артык студент, 800 дән артык укытучы санала. Университетның матди базасы да шактый ныгый. 1973 тә физика корпусы файдалануга тапшырыла, 1977 дә 2 нче уку корпусы, 1978 дә китапханәнең яңа бинасы эшли башлый.

1966 да К.у. илдәге дүрт база ун-ты санына кертелә, СССР югары һәм урта махсус белем бирү министрлыгы карамагына күчерелә, 1967 дә югары уку йортлары укытучылары квалификациясен күтәрү ф-ты ачыла. 1960 та физика-матем. ф-ты физика һәм механика-матем. ф-тларына бүленә, соңгысыннан 1978 дә хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-ты аерылып чыга. 1980 дә тарих-филол. ф-ты тарих һәм филология ф-тларына бүленә. 1989 да татар филологиясе һәм тарихы, экология ф-тлары, 1990 да журналистика ф-ты ачыла.

СССРның таркалуы, 1990 еллар башындагы икътисади һәм сәяси кризис, бер яктан, фән һәм югары мәктәпләрне финанслауның кинәт кимүенә китерә. Икенче яктан, совет чорында формаль генә булган ун-т автономиясе чынлыкка аша. Структур бүлекчәләрдәге, уку-укыту процессының эчтәлегендә һәм аны оештырудагы, фәнни эшчәнлекләрдәге реформалар профессор-укытучылар коллективы һәм җитәкчелекнең карарына нигезләнеп уздырыла. Белгечлекләр номенклатурасы киңәя, бюджеттан тыш финанслау шактый үсеш ала.

1990–2000 елларда уку-укыту бүлекчәләре структурасында күп төрле үзгәрешләр була. 2010 елга: Көнчыгышны өйрәнү ин-ты (Көнчыгышны өйрәнү, көнчыгыш телләр, халыкара мөнәсәбәтләр буенча белгечләр әзерли), А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты (2003 тә фәнни-тикшеренү ин-ты химия ф-ты б-н берләштерелә); биология-туфрак, хисаплау математикасы һәм кибернетика, география һәм экология, геол., журналистика һәм социология, тарих, психология, татар филологиясе һәм тарихы, физика, филология (рус филологиясе, роман-герман филологиясе, лингвистика), философия (философия, дин белеме, сәясәт белеме, культурология), икътисад ф-тлары эшли.

Эшләү дәверендә ун-т 90 меңнән артык белгеч әзерли. Рев-циягә кадәр чорда аның студентлары һәм ирекле тыңлаучылары: дәүләт эшлеклеләре А.М.Княжевич, М.И.Галкин-Враский, А.П.Ахматов, язучылар С.Т.Аксаков, П.И.Мельников (А.Печерский), Л.Н.Толстой, П.Д.Боборыкин, комп. М.А.Балакирев, мөфти М.Солтанов, татар иҗтимагый хәрәкәте һәм мәгарифе эшлеклеләре Г.Ә.Ваһапов, Ш.И.Әхмәров, С.Ш.Алкин, Х.М.Ямашев, Ә.Г. һәм И.Ә.Әхтәмовлар, Ф.Ф. Туктаров, Россия халыклары мәгърифәтчеләре — чуаш И.Я.Яковлев, мари В.М.Васильев, мордва М.Е.Евсевьев, бурят Д.Банзаров; совет чорында — партия һәм дәүләт эшлеклеләре Г.Б.Баһаветдинов, Ф.Ә.Табеев, В.Н.Лихачёв, К.Ш.Исхаков, Н.В.Фёдоров, мәдәният эшлеклеләре М.Х.Сәлимҗанов, С.С.Говорухин, Р.Г.Кутуй.

2010 елга укыту 44 белгечлек буенча алып барыла. Көндезге бүлектә якынча 10 мең, кичке бүлектә 600, читтән торып уку бүлегендә 3000, ф-лларында якынча 3500 студент укый. Университет каршында әзерләү бүлеге (1966 дан), укытучыларның квалификациясен күтәрү ф-ты (1967 дән), әзерләү бүлекләре һәм студентларга өстәмә белем бирү бүлекчәләре б-н өзлексез белем бирү бүлеге эшли.

К.у. эшчәнлегенең беренче унъеллыгында башланган фәнни мәктәпләрнең үсеше нәтиҗәсендә 19 йөз уртасына ун-т Россия фәненең иң эре үзәкләренең берсенә әверелә.

Математика өлкәсендә ун-тта беренче проф. М.Ф.Бартельс була, Н.И.Лобачевскийның нәевклид геометриясе матем. фәненә зур үсеш бирә. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында матем. фәне буенча тикшеренүләрне В.Г.Имшенецкий, П.С.Назимов, А.В.Васильев, Н.Н.Парфентьев һ.б. алып бара. Механика белеменең үсешендә П.И.Котельников, И.С.Громека, А.П.Котельниковның хезмәтләре мөһим роль уйный. Физика фәнен Ф.К.Броннер укыта башлый. И.А.Больцани ярдәме б-н ун-т физика буенча тикшеренүләр


1


2


3


4

Казан университеты. 1. Төп бина һәм студент В.И.Ульянов һәйкәле; 2. Химия факультеты бинасы; 3. Икенче уку корпусы; 4. Физика факультеты корпусы.

өчен матди база ала, бу тикшеренүләрне 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында А.С.Савельев, Р.А.Колли, Н.П.Слугинов, Д.А.Гольдгаммер алып бара. Астрономия буенча башлап атаклы галим И.А.Литтров шөгыльләнә, аның эшчәнлеген И.М.Симонов, М.А.Ковальский, Д.И.Дубяго дәвам итәләр, астрономия буенча тикшеренүләрнең уңышлы үсешенә 20 йөз башында В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе ачылу булышлык итә.

1830 еллардан ун-тта *Казан химия фәнни мәктәбе* оеша, химия профессорларының (Н.Н.Зинин, К.К.Клаус, А.М.Бутлеров, В.В.Марковников, А.Н.Попов, А.М.Зайцев, Ф.М.Флавицкий) хезмәтләре дөнья химия фәненә зур өлеш кертә. М.Я.Киттары, А.М.Зайцев, И.И.Канонников химия технологиясе проблемалары өстендә эшлиләр. Геология буенча тикшеренүләрне П.И.Вагнер башлый, 19 йөзнең 2 нче яртысында *Казан геология фәнни мәктәбе* һәм *Казан геоморфология фәнни мәктәбе* булдырыла (Н.А.Головкинский, Ф.Ф.Розен, А.А.Штукенберг, П.И.Кротов, Б.К.Поленов, А.В.Нечаев). Метеорология буенча тикшеренүләрне А.Я.Купфер башлый. И.Н.Смирнов синоптик метеорологиягә нигез салучыларның берсе була.

19 йөз уртасыннан табигыять-матем. һәм мед. ф-тлары кысаларында биология фәннәре үсеш ала. Кеше һәм хайваннар физиологиясе (Н.О.Ковалевский, Н.М.Мельников, Н.А.Миславский, А.Ф.Самойлов), зоология (Н.П.Вагнер, Э.А.Эверсман, М.М.Усов, М.Д.Рузский, И.П.Забусов, Н.А.Ливанов), ботаника, геоботаника һәм үсемлекләр физиологиясе (А.А.Бунге, П.Я.Корнух-Троицкий, Н.Ф.Леваковский, С.И.Коржинский, В.А.Ротерт, А.Я.Гордягин, Б.А.Келлер, В.В.Лепёшкин) буенча тикшеренүләрдә әһәмиятле фәнни нәтиҗәләргә ирешелә. К.у.да Россия биохимия фәненең үсеше башлана (А.Я.Данилевский, А.Я.Щербаков, А.А.Панормов).

Медицина фәненең башында И.О.Браун, К.Ф.Фукс тора, аларның эшчәнлеген А.А.Китер, Ф.О.Елачич, А.Н.Бекетов дәвам итә. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында фәнни тикшеренүләр медицинаның төрле өлкәләрендә алып барыла: эчке авырулар буенча (Н.А.Виноградов, А.Н.Казим-Бәк, С.С.Зимницкий, М.Н.Чебоксаров), балалар авырулары (Б.А.Аргутинский-Долгоруков, В.К.Меньшиков), гистология (К.А.Арнштейн, А.С.Догель, Ф.В.Овсянников), офтальмология (Е.В.Адамюк, А.Г.Агабабов, В.В.Чирковский, В.Е.Адамюк), невропатология һәм психиатрия (В.М.Бехтерев, А.И.Фрезе, Л.О.Даркшевич, А.В.Фаворский), венерология (А.Г.Ге, В.Ф.Бургсдорф), акушерлык һәм гинекология (В.С.Груздев), хирургия (Л.Л.Лёвшин, Н.А.Геркен, Н.Ф.Высоцкий). 1900 дә Париждагы Пастеров ин-тына охшаш Бактериология ин-ты ачыла. (к. *Казан медицина фәнни мәктәпләре, Казан медицина университеты клиникалары, Казан медицина академиясе клиникалары, Казан эксперименталь микробиология фәнни-тикшеренү институты*).

К.у. эшчәнлегенең беренче елларыннан ук анда юридик фәннәр укытыла. Атаклы галимнәр — хокук белгечләре Д.И.Мейер, Н.П.Иванов, Г.Ф.Шершеневич, В.В.Ивановский, А.А.Пионтковский, С.В.Пахман, С.М.Шпилевский, В.Ф.Залесский. Россия тарихын өйрәнүнең башында С.В.Ешевский, А.П.Щапов тора. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында Россия тарихы буенча тикшеренүләрне тарих-филол. ф-тында Н.А.Фирсов, Д.А.Корсаков, Н.Н.Фирсов, юридик ф-тта Н.П.Загоскин алып бара. Шул ук вакытта гомуми тарих мәктәбе барлыкка килә (Н.А.Осокин, М.М.Хвостов, В.К.Пискорский, Н.Н.Грацианский һ.б.). Славян филологиясе буенча тикшеренүләргә В.И.Григорович башлангыч бирә, аның эшчәнлеген М.П. һәм Н.М.Петровскийлар дәвам итә. 1870 елларда И.А.Бодуэн де Куртенэ *Казан лингвистика фәнни мәктәбен* оештыра (Н.В.Крушевский, В.А.Богородицкий, А.И.Александров, Е.Ф.Будде һ.б.). Шәрекъ бүлеге Россиядә иң зур тикшеренү үзәгенә әверелә, аны Петербург ун-тына күчергәннән соң, көнчыгыш тикшеренүләре традицияләрен И.Ф.Готвальд, Н.И.Ильминский, Н.Ф.Катанов дәвам итәләр.

Окт. рев-циясе күп фәнни традицияләрне туктата, ләкин профессорларның төп өлеше үзләренең укыту һәм фәнни эшчәнлекләрен дәвам итәләр (математик Н.Н.Парфентьев, астроном В.А.Баранов, физиклар Д.А.Гольдгаммер, В.А.Ульянин, геолог М.Э.Ноинский, зоологлар Н.А.Ливанов, А.А.Остроумов, ботаник А.Я.Гордягин, физиологлар А.Ф.Самойлов, Н.А.Миславский, Д.В.Полумордвинов, биохимик А.А.Панормов, медиклар А.Н.Миславский, А.В.Вишневский, В.С.Груздев, А.Г.Агабабов, В.В.Чирковский, С.С.Зимницкий, М.Н.Чебоксаров, В.Ф.Бургсдорф), бу фәнни мәктәпләрнең буыннан-буынга күчә баруын тәэмин итә. Казанда тел белгече В.А.Богородицкий, тарихчылар М.М.Хвостов, Н.Н.Фирсов, М.В.Бречкевич, С.Б.Сингалевич һ.б. кала, ләкин ун-тның тарих-филол. ф-ты ябылганнан соң гуманитар фәнни мәктәпләр шәһәрнең башка югары уку йортларында һәм акад. үзәкләрдә үсеш ала, К. ун-тында аларның яңадан эшли башлавы 1940 елларга туры килә.

Рев-циягә кадәр үк формалашкан алгебра (Н.Г.Чеботарёв һәм аның укучылары И.Д.Адо, Л.И.Гаврилов; Н.Н.Парфентьев һәм аның укучылары Б.М.Гагаев, Н.М.Мейман, А.В.Дороднов, Л.И.Чибрикова, А.В. Сульдин, М.С.Матвейчук, Б.Г.Габделхаков), геометрия (П.А.Широков, П.В.Яблоков, А.З.Петров, А.П.Норден, Б.Л.Лаптев, В.В.Вишневский, Б.Н.Шапуков) мәктәпләре үз эшләрен дәвам итә.

Механиканың үсеше А.П.Котельников укучысы Д.Н.Зейлигер һәм Г.И.Четаев исемнәре б-н бәйле; соңгысы хәрәкәт тотрыклылыгы теориясе мәктәбен оештыра, соңрак бу теория авиация ин-тында үстерелә (хәзер Казан техник ун-ты). 1940 еллардан механика буенча яңа фәнни юнәлешләр барлыкка килә: гидроаэромеханика һәм кайтма кырый мәсьәләләр (Г.Г.Тумашев, М.Т.Нужин, С.Г.Нужин, Ф.Д.Гахов, А.В.Саченков, В.В.Клоков, А.В.Кузнецов), эластиклыкның нәсызыкча теориясе (Х.М.Мөштәри, К.З.Галимов, А.И.Голованов, Ю.П.Жигалко), җир асты гидромеханикасы (Г.Г.Тумашев, С.Ф.Сайкин, М.А.Пудовкин, Һ.С.Салихов, А.Н.Чекалин). 1934 тән ун-т каршында *Математика һәм механика институты* эшли.

Е.К.Завойскийның 1947 елда *электрон парамагнит резонансы* (ЭПР) күренешен ачуы физика тарихында мөһим вакыйга була, бу физика үсешендә яңа юнәлешкә башлангыч сала (Й.Ю.Сәмитов, М.А.Теплов). Электрон парамагнит резонанс ачылу *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбенең* үсешенә этәргеч бирә (С.А.Альтшулер, Б.М.Козырев, М.М.Зарипов, Н.Н.Непримеров, С.Һ.Салихов һ.б.), радиофизика (И.М.Романов), оптика (И.С.Поминов), каты җисем физикасы (Ш.Ш.Башкиров), гравитация теориясе (В.Р.Кайгородов) буенча тикшеренүләр алып барыла. *Казан астрономия фәнни мәктәбе* традицияләрен В.А.Баранов, И.А.Дюков, А.Д.Дубяго, А.А.Яковкин, И.В.Белькович, Д.Я.Мартынов, Ш.Т.Хәбибуллин, К.В.Костылёв, О.И.Белькович дәвам итә.

К.у.нда формалашкан Казан химия фәнни мәктәбе совет чорында төрле югары уку йортларында һәм фәнни-тикшеренү ин-тларында үсеш ала, ләкин ун-т иң зур тикшеренүләр һәм фәнни кадрлар әзерләү үзәге булып кала (А.Е.Арбузов, А.Я.Богородский, А.М.Васильев, А.Ф.Герасимов, В.Ф.Торопова, А.А.Попель, Л.Г.Берг, А.Н.Пудовик һ.б.). 1929 дан ун-т составында А.М.Бутлеров исем. химия фәнни-тикшеренү ин-ты эшли.

К.у.ның геол. ф-тында Казан геол. һәм геоморфология фәнни мәктәпләре (Б.П.Кротов, Е.И.Тихвинская, Л.М.Миропольский, С.Г.Каштанов, В.И.Троепольский, М.Г.Солодухо, И.С.Муравьёв, В.И.Игнатьев, В.Г.Халымбаджа, В.П.Боронин, А.П.Дедков, В.И.Мозжерин, В.М.Винокуров, Б.В.Буров һ.б.) тагын да үстерелә. Совет чорында ун-тта *Казан метеорология фәнни мәктәбе* барлыкка килә (В.А.Ульянин, П.Т.Смоляков, Н.В.Колобов һ.б.), геофизика үсеш ала физик (В.Н.Сементовский, А.В.Ступишин һ.б.) һәм икътисади (Н.-Б.З.Векслин, Н.И.Блажко) география буенча тикшеренүләр алып барыла.

Ботаника (С.И.Коржинский, А.Я.Гордягин, В.И.Баранов, В.С.Порфирьев һ.б.), үсемлекләр физиологиясе (А.М.Алексеев), зоол. (Н.А.Ливанов, М.Е.Макушок, А.Я.Недошивин, М.Х.Корбангалиева, В.Л.Вагин, А.В.Лукин), микробиология (М.И.Беляева, И.Б.Лещинская, биохимия (В.Г.Винтер) фәнни мәктәпләренең үсеше дәвам итә. Генетика юнәлешенең үсеше 1937 дә проф. В.Н.Слепков кулга алынганнан соң өзелә. 1970 тән экология проблемалары өстендә эшләү башлана (В.А.Попов).

1920 елларда университетның мед. ф-тында мед. фәнни мәктәпләре үсеше дәвам итә, 1930 дан аларның эшчәнлеге медицина ин-тында һәм табибләрнең белемен күтәрү ин-тында (хәзер Казан мед. академиясе),

ә физиология буенча тикшеренүләр К.у.ның биол. ф-тында үсеш ала.

Сугыштан соңгы елларда гуманитар фәннәр мәктәпләре: философия (М.И.Абдрахманов), хокук (Д.И.Фельдман һ.б.), тарих (А.С.Шофман, В.Д.Жигунин), Россия, СССР тарихы (И.М.Ионенко, Г.Н.Вульфсон, Р.И.Нәфыйгов), археология (А.Х.Халиков); политэкономия (А.Б.Харитонов, В.Ф.Семёнов), Казанның лингвистика (Н.А.Широкова, Э.М.Ахунҗанов, Л.В.Златоустова, В.М.Марков), әдәбият белеме (А.Н.Вознесенский, Н.А.Гуляев, В.Н.Коновалов, Л.С.Ачкасова һ.б.) фәнни мәктәпләре традицияләре үсеш ала.

1990–2000 елларда факультетларда һәм фәнни-тикшеренү оешмаларында традицион фәнни юнәлешләр үстерелә, яңа фәнни проблемалар өстендә эшлиләр. Механика-матем. ф-тында, Хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-тында, Н.Г.Чеботарёв исем. Математика һәм механика ин-тында профессорлар, фән д-рлары: математиклар В.В.Вишневский, И.И.Сахаев, Л.А.Аксентьев, В.И.Жегалов, М.М.Арсланов, Д.Х.Мөштәри, И.А.Бикчәнтәев, Ф.Г.Әүхәдиев, В.В.Шурыгин, И.Б.Ившина, С.Р.Насыйров, Ю.В.Обносов, А.Н.Шерстнёв, Н.Д.Якимов, Н.Б.Плещинский; механика белгечләре Н.Б.Ильинский, Ю.Б.Артюхин, Ю.Г.Коноплев, Н.Г.Гурьянов, А.В.Костерин, А.Г.Егоров, Э.В.Скворцов, В.А.Чугунов, А.Н.Саламатин, А.В.Поташёв, М.Г.Храмченков; хисаплау һәм гамәли матем., математик статистика, кибернетика, информатика буенча белгечләр Я.И.Заботин, Н.К.Замов, М.М.Карчевский, А.В.Лапин, В.Д.Соловьёв, Р.Х.Латыйпов, Ф.М.Аблаев, А.М.Елизаров, И.Б.Бәдриев, Р.З.Даутов, И.В.Коннов, М.Ф.Павлова, Е.М.Федотов, Р.Р.Шәһидуллин, В.Р.Фазылов, М.Д.Миссаров, О.А.Задворнов, В.Д.Соловьёв эшли. Физика ф-ты кафедраларында һәм фәнни тикшеренүләр лаб-ясендә, В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясендә физиклар Ш.Ш.Башкиров, А.И.Маклаков, Б.И.Кочелаев, В.Р.Кайгородов, Л.К.Әминов, Б.З.Малкин, А.В.Аганов, В.Д.Скирда, А.И.Фишман, А.Б.Балакин, А.Х.Гыйльметдинов, Д.А.Таюрский, Р.Р.Нигъмәтуллин, Ю.Н.Прошин, Л.Р.Таһиров, С.Л.Царевский, Н.Ф.Фәтхуллин, Э.Г.Садыйков, В.М.Ларионов; оптиклар М.Х.Сәлахов, Р.Х.Гайнетдинов, В.В.Самарцев; радиофизиклар В.В.Сидоров, Г.М.Тептин, А.М.Насыйров, М.В.Ерёмин, М.С.Таһиров, О.Н.Шерстюков, Э.А.Ибатуллин, М.Н.Овчинников; химик-физиклар К.М.Салихов, Р.М.Әминова, В.В.Клочков; астрономнар Н.А.Сәхибуллин, Н.Г.Ризванов, А.И.Нефедьева, А.Д.Акчурин, Р.А.Кащеев хезмәт куя.

А.М.Бутлеров исем. химия ин-тының кафедра һәм бүлекләрендә тикшеренүләрне нәорганик химия буенча Ю.И.Сальников, Ф.В.Девятов, С.С.Бабкина, В.В.Чевела; органик химиядән — А.И.Коновалов, Г.Н.Чмутова, И.С.Антипин, А.Н.Ведерников, Ф.Х.Каратаева; аналитик химиядән — Г.К.Будников, Н.А.Улахович, Э.П.Медянцева, физик химиядән — А.В.Әминова, Б.Н.Соломонов, В.В.Горбачук, А.В.Захаров, В.Д.Киселёв; югары молекуляр һәм элементорганик кушылмалар химиясе буенча И.В.Коновалова, Р.А.Черкасов, В.И.Галкин, стереохимия буенча Я.А.Верещагина алып бара.

Геология ф-тында геол. һәм минералогия проблемалары хәл ителә (В.М.Винокуров, И.Н.Пеньков, Б.В.Буров, Р.Х.Мөслимов, А.И.Шевелёв, А.И.Бахтин, В.Т.Изотов, Н.М.Низаметдинов, Б.В.Успенский, Р.Р.Хәсәнов), геофизика (Г.Е.Яковлев, З.М.Слепак, Д.К. Нургалиев, А.С.Борисов).

Биология-туфрак ф-ты һәм Биология фәнни-тикшеренү ин-тының алты кафедрасы һәм биш лаб-ясендә генетика (Б.И.Барабанщиков), биохимия (З.И.Абрамова, Д.Г.Ишмөхәммәтова), үсемлекләр физиологиясе (Л.П.Хохлова, Н.А.Чернов), кеше һәм хайваннар физиологиясе (И.Н.Плещинский), микробиология (Р.П.Наумова, Б.М.Куриненко, Т.В.Багаева, О.Н.Ильинская, С.Ю.Егоров), умырткасызлар зоологиясе (А.И.Голубев, Ә.Б.Халидов, Ф.М.Соколина), умырткалылар зоологиясе (В.А.Кузнецов), ботаника (А.Б.Ситников, Е.Л.Любарский), туфрак белеме (Г.Ф.Копосов, А.А.Шинкарёв) мәсьәләләре буенча эш алып барыла. Фәнни мәктәпләрнең геогр. һәм экология ф-тларында физика (И.Н.Плотников), икътисади география (А.М.Трофимов, В.А.Рубцов), метеорология (Ю.П.Переведенцев) буенча белгечләр эшли, гамәли (В.З.Латыйпова, Н.М.Минһаҗева, Г.А.Евтюгин, Т.В.Рогова, А.А.Савельев, С.Ю.Селивановская, В.В.Сироткин) һәм ландшафтлы (О.П.Ермолаев) экология проблемалары өйрәнелә. Тел белеме ин-тында һәм гомуми ун-т бүлекчәләрендә шул исемдәге ф-тларда философлар — В.Н.Комаров, М.Д.Щелкунов, политологлар М.Х.Фарукшин, Г.В.Морозова, О.И.Зазнаев, Т.Т.Сидельникова, психологлар Л.М.Попов, Н.Й.Хөсәенова, Б.С.Алишев, педагоглар В.И.Андреев, Г.А.Петрова, В.Г.Каташёв, Л.А.Казанцева, Ф.Л.Ратнер эшли.

Юридик ф-т кафедраларында хокукның күп тармаклары буенча тикшеренүләр алып барыла: дәүләт хокукы (Ю.С.Решетов), җинаять (М.Л.Лысов, Ф.Р.Сундуров, И.Г.Тарханов, Б.В.Сидоров, М.В.Талан), җинаять-процессуаль (Б.Л.Железнов, Н.Г.Моратова), гражданлык (В.И.Романов, З.Д.Сафин), хезмәт (А.К.Безина), халыкара хокук (Р.М.Вәлиев, Г.И.Курдюков, Л.Х.Минһаҗев).

Тарих фәнни мәктәпләре традицияләрен Ватан тарихы (И.П.Ермолаев, И.Р.Таһиров, Р.К.Вәлиев, Р.В.Шәйдуллин, Р.А.Циунчук, С.Ю.Малышева) һәм гомуми тарих (Я.Я.Гришин, О.Л.Габелко), тарихи чыганаклар һәм историография (А.Л.Литвин, И.И.Шарифҗанов, Г.П.Мягков, Р.Н.Имангалиев, А.А.Сальникова), көнчыгышны өйрәнү тарихы (Р.М.Вәлиев), этнология (Г.Р.Столярова), археология (Ә.Г.Мөхәммәдиев), дин белеме (Р.Ә.Нәбиев) белгечләре дәвам итәләр.

Филология ф-тында Казан лингвистика фәнни мәктәбенең үсеше дәвам итә (Г.А.Николаев, Э.А.Балалыкина, К.Р.Галиуллин, А.Ю.Чернышёва, Э.Х.Хәбибуллина, Е.Ф.Арсентьева, О.Ф.Жолобов, Г.М.Николаева, Л.Р.Габделхакова); милли мәктәпләрдә рус теле укыту (Н.А.Андрамонова, Л.К.Бәйрәмова, Ә.Ә.Әминова), әдәбият белеме (Й.Г.Нигъмәтуллина, Г.А.Фролов, О.О.Несмелова) проблемаларын өйрәнү алып барыла. Журналистика һәм социология ф-тында шәхесне социальләштерү (Э.С.Рәхмәтуллин), ТРда мәгълүмат чаралары һәм журналистика тарихының үсеше (Е.С.Дорощук, А.А.Роот, С.К.Шәйхетдинова) мәсьәләләре өйрәнелә. Икътисад проблемалары икътисад ф-тында һәм хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-тында (С.В.Мокичев, Е.М.Разумовская, Г.А.Сульдина) тикшерелә.

К.у.да 76 белгечлек буенча аспирантура (2010 елга 615 аспирант) һәм 9 белгечлек буенча докторантура эшли. Докторлык диссертациясе яклау буенча 18 совет һәм кандидатлык диссертациясе яклау буенча 6 совет эшли.

К.у.нда татар теле укыту Шәрекъ бүлегендә үк башлана. 1812–29 да дәресләрне И.И.Хәлфин, 1829–46 да — А.К.Казимбәк, 1846–55 тә — И.Н.Березин алып бара, татар каллиграфиясен 1842–55 тә М.Мәхмүдев укыта (аны тәмамлаучылар арасында — тел белгече С.Б.Күкләшев бар). Шәрекъ бүлеге Петербург ун-тына күчерелгәннән соң татар телен өйрәнү туктатыла, бары тик 1862–72 дә генә төрки телләрне укыту һәм татар тел белеме буенча тикшеренүләр б-н Н.И.Ильминский шөгыльләнә. 1894 тә татар телен укытуны Н.Ф.Катанов яңадан башлап җибәрә, төрки телләр, шулай ук әдәбият белеме буенча фәнни эшне җәелдерә, ләкин ун-т татар теле буенча белгечләр әзерләми.

1858–1900 дә К.у.нда якынча 30 татар һәм башкорт укый. 1905–07 еллардагы рев-ядән соң татар студентларының саны арта бара, ел саен 10 лап кеше укырга керә.

Совет властеның беренче елларыннан ук татар яшьләре арасыннан студентлар күбрәк кабул ителә. 1920 елларда –1930 ның беренче яртысында татар студентларының барысы да диярлек ун-тка эшчеләр ф-тларын тәмамлаганнан соң керә, 1930 елларда татарлар студентларның 28% ын тәшкил итә, соңрак бу сан тагын да арта.

1924/25 уку елында татар телен (һәм татарлар өчен татар әдәбиятын) өйрәнү — эшчеләр ф-тында, 1930 да — барлык студентлар өчен дә мәҗбүри була; 1931 елга татар теле кафедрасында 7 укытучы ш.и. М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов эшли. 1933 тән татар теле факультатив курс булып кала, 1937 дә кафедра ябыла. Татар филологиясе бүлеген ачу 1941–42 уку елы башына билгеләнә, ләкин Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, бүлек 1944 тә ачыла (оештыручысы — Р.А.Хәкимова). Ул акрынлап татар тел белеме буенча фәнни тикшеренүләр алып баручы, кадрлар һәм югары квалификацияле милли интеллигенция әзерләүче үзәккә әверелә; 1960 та аерым татар теле һәм татар әдәбияты кафедралары булдырыла. Анда тел белгечләре М.Н.Ногман, Ү.Ш.Байчура, М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, В.Х.Хаков; әдәбиятчылар Я.Х.Агишев, Г.С.Кашшаф, Х.Г.Госманов,

И.З.Нуруллин, М.С.Мәһдиев, Н.Г.Юзиев укыта.

Бүлекне тәмамлаучылар арасында галимнәр М.Х.Хәсәнов, Ф.Ә.Ганиев, М.И.Әхмәтҗанов, Н.Ш.Хисамов, Р.Г.Юсупов; язучылар Р.Х. Әхмәтҗанов, Г.А.Ахунов, Ә.Ф.Баян, Р.В.Вәлиев, М.Х.Вәлиев, Р.К.Гатауллин, С.Г.Гәрәева, Гәрәй Рәхим, Ә.Г.Гаффар, А.М.Гыйләҗев, Җ.Х.Дәрзаманов, Зөлфәт, Э.С.Касыймов, Г.С.Кашапов, Р.Г.Мингалим, Р.М.Миңнуллин, Ф.М.Миңнуллин, Р.Ә.Мостафин, Р.С.Мөхәммәдиев, В.Н.Нуруллин, К.З.Тимбикова, Р.Г.Фәйзуллин, Н.С.Фәттах, Я.М.Халитов, М.Х.Хөсәен, С.Ф.Шакир, Ф.Г.Яруллин һ.б. бар. Тарих ф-тында татар халкы тарихы проблемаларын М.Г.Госманов, Р.И.Нәфыйгов, С.М.Михайлова өйрәнә.

1989 да татар филологиясе бүлеге татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр ф-ты итеп үзгәртелә, 2000 нән татар филологиясе һәм тарихы ф-ты; аның составына татар халкы тарихы, татар теле, татар әдәбияты, татар телен укыту методикасы аны чит телле аудиториядә укыту методикасы кафедралары керә. Анда тел белгечләре Ф.М.Хисамова, Г.Ф.Саттаров, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Й.Йосыпов, Ф.Ш.Нуриева; әдәбиятчылар Х.Й.Миңнегулов, А.Г.Әхмәдуллин, Р.К.Ганиева, М.Х.Бакиров, Т.Н.Галиуллин, Д.Ф.Заһидуллина; тарихчылар М.Г.Госманов, И.А.Гыйләҗев эшли.

Татар теле һәм әдәбияты, татар халкы тарихы проблемалары К.у.ның башка уку-укыту бүлекләрендә дә: тарих ф-тында (Д.М.Госманова), Шәрекъ ин-тында (Г.Г.Зәйнуллин), журналистика һәм социология ф-тының татар журналистикасы кафедрасында (В.З.Гарифуллин) өйрәнелә.

К.у.ның уку-укыту базасының биналар комплексында: *университет шәһәрчеге*, геол. корпусы (элеккеге *Казан руханилар семинариясе*) (архит-ра истәлеге саналалар), химия корпусы, заманча ике биек корпус керә. Казаннан читтә обсерватория, ботаника бакчасы, ике биостанция, Ак диңгездә биол. тикшеренүләр базасы, *Төньяк Кавказ астрономия станциясе*, Төркиядә телескоп урнашкан.

Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәдә 5 млн. саклау берәмлеге исәпләнә.

К.у.ның вакытлы матбугат басмалары — «*Казанские известия*» (1811–20, Казанда беренче журнал), «*Казанский вестник*» (1821–33), «Ученые записки Казанского университета» (1834 тән) ж-ллары, «Казанский университет» (1927 дән, 1990 га кадәр «Ленинец») г-тасы. Шулай ук «Известия высших учебных заведений. Математика» (1957 дән), «Георесурсы. Научно-технический журнал» (1999 дан), «Environmental Radioekology and Applied Ecology» (2000 нән) ж-ллары басыла, 5 электрон ж-л чыгарыла.

Университет тарихы (1979 дан), геол., археол., этнография, ботаника, зоол., Казан химия фәнни мәктәбе музейлары эшли.

1804–13 елларда К.у.ның директоры И.Ф.Яковкин була. Ректорлары: И.О.Браун (1813–19), Г.И.Солнцев (1819–20), Г.Б.Никольский (1820–23), К.Ф.Фукс (1823–27), Н.И.Лобачевский (1827–46), И.М.Симонов (1846–55), О.М.Ковалевский (1855–60), А.М.Бутлеров (1860–63), Е.Г.Осокин (1863–72, 1876–80), Н.А.Кремлёв (1872–76, 1885–89), И.О.Ковалевский (1880–82), Н.Н.Булич (1882–85), К.В.Ворошилов (1889–99), Д.И.Дубяго (1899–1905), Н.М.Любимов (1905–06), Н.П.Загоскин (1906–09), Г.Ф.Дормидонтов (1909–17), Д.А.Гольдгаммер (1917–18), Е.А.Болотов (1918–21), А.А.Овчинников (1921–22), М.Н.Чебоксаров (1922–23), В.В.Чирковский (1923–26), А.И.Луньяк (1926–28), П.Н.Ганланза (1928–29), М.И.Сегаль (1929–30), Г.Б.Баһаветдинов (1930–31), Н.-Б.З.Векслин (1931–35), Г.Х.Камай (1935–37), К.П.Ситников (1937–51), Д.Я.Мартынов (1951–54), М.Т.Нужин (1954–79), А.И.Коновалов (1979–90), Ю.Г.Коноплёв (1990–2001), Н.К.Замов (2001–02), М.Х.Сәлахов (2002–10), И.Р.Гафуров (2010 ның апреленнән). РФ Хөкүмәте карары б-н 2010 елның 2 апреленнән Казан ун-ты җирлегендә *Казан (Идел буе) федераль университеты* оештырыла.

*Әд.:* Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета (1804–1904): В 4 т. К., 1902–06; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904): В 2 ч. К., 1904; Корбут М.К. Казанский государственный университет имени В.И.Ульянова-Ленина за 125 лет. (1804/05–1929/30): В 2 т. К., 1930; История Казанского государственного университета им. В.И.Ульянова-Ленина. К., 1954; Верхунов В.М. История физики в Казанском университете. К., 1963; Мазитова Н.А. Изучение Ближнего и Среднего Востока в Казанском университете (первая половина XIX в.). К., 1972; Казанский университет. 1807–1979: Очерки истории. К., 1979; Марков М.В. Ботаника в Казанском университете за 175 лет. К., 1980; Ионенко И.М., Попов В.А. Казанский университет в годы Великой Отечественной войны. К., 1985; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета, 1905–1917. К., 1986; Вульфсон Г.Н., Нуриева Ф.Ф. Братья по духу: Питомцы Казанского университета в освободительном движении 1840–1870-х гг. К., 1989; Факультет, на котором учился Ленин. К., 1990; Михайлова С.М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России. К., 1991; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. — 20-е гг. XX в.). К., 1998; Емельянова И.А. Юридический факультет Казанского государственного университета. 1805–1917 год: Очерки. К., 1998; Факультет географии и геоэкологии Казанского университета: История становления и основные достижения. К., 1998; Механико-математический факультет Казанского университета: очерки истории. 1960–2000. К., 2000; Очерки истории Казанского университета. К., 2002; Изучение и преподавание отечественной истории в Казанском университете. К., 2003; История экономической и философской мысли в Казанском университете. К., 2003; Вишленкова Е.А. Казанский университет Александровской эпохи. К., 2004; История Казанского университета. 1804–2004. К., 2004.

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́ БАСМАХАНӘСЕ́**, 1809 елда ачыла. Үз керемнәре хисабына эшли. Җитәкчесе һәм җаваплы оештыручысы (фактор) турыдан-туры ректорга һәм ун-т идарәсенә буйсына. Ялланып эшләү һәм эш күләменнән түләү карала. Басмаханә җитәкчесе итеп ун-т профессорлары һәм укытучылары, факторлар сыйфатында чит ил кешеләре билгеләнә (1815 елдан 10 елга якын гравёр Л.Кальмон эшли). Хезмәткәрләр саны заказларның күләменә һәм катлаулылыгына, җиһазларның җитенкелек дәрәҗәсенә бәйле була. 1819 да басмаханәдә штат буенча — 16 кеше, 1829 да — 34, 1844 тә — 17, 1850 елларда — 18 дән алып 25 кә кадәр, 1883 тә — 48, 1898 дә — 96, 1901 дә 133 кеше исәпләнә.

Кадрлар басмаханәнең үзендә әзерләнә, еш кына әтиләренең һөнәрләрен уллары дәвам итә (мәс., хәреф җыючы Әхмәтовлар династиясе). В.Әхтәмов, Г.Мозаффаров, Я.Муравьёв, С.Аничкин һ.б. басмаханәдә берничә дистә ел эшлиләр. 1850 дән 1884 кә кадәр басмаханәне проф. И.Ф.Готвальд җитәкли. 1847 дән М.Ветошкин басмаханәдә эшли башлый, 1865–93 тә ул фактор була, 1893 тә нәселдән күчмә мактаулы граждан исемен ала.

Заказчыларны җәлеп итү өчен, гамәлдәге шрифтларның үрнәкләре һәм прейскурантлары басыла (1834, 1843, 1884, 1891, 1896).

Дөнья күргән басмалар ун-тның комиссионерлары (мәс., сәүдәгәр Суханов, 1811 дән) кибетләрендә сатыла. Басмаханә ачылган вакытта 2 басу, 1 фигуралар станы, 55,5 пот шрифт, ш.и. математика һәм календарь билгеләре һәм цифрлары була. Алдагы 3 елда пуансоннар, матрица һәм хәреф кою җайланмасы сатып алына. 1819 да тагын 2 стан китерелә, әмма шрифтлар саны күпкә артмый — 58 потка гына җитә.


1829 да ун-т һәм Азия басмаханәләре кушыла. 1828–29 да ректор Н.И.Лобачевский (1827–46) һәм Казан укыту округы попечителе М.Н.Мусин-Пушкин тырышлыгы б-н яңа җиһазлар алу өчен 20 мең сум акча бүленеп бирелә, җиһазларны Мәскәүдә һәм Петербургта сатып алалар.

К.у.б.ндә башкаланың иң яхшы басмаханәләре тәҗрибәсе кулланыла. 1834 елга әлеге басмаханә Россия провинцияләре басмаханәләре арасында иң яхшы өйрәнү мәктәбе буларак танылa; эшне оештыру Н.И.Лобачевскийның даими контроле астында бара.

1840–70 елларда шрифтлар — ФА һәм Лазарев чит телләр ин-ты басмаханәләреннән, Берлинның сарай басмаханәсеннән, Петербургтагы Ж.Ревильон фирмасыннан, татар шрифтлары Казан хәреф кою ширкәтчесе Фәизовтан һ.б.дан сатып алына.

1842 елгы янгында җиһазларның 2/3 өлеше юкка чыга. 1850 дә басмаханә бурычка алынган акчага (1860 та ул 16,5 мең сум тәшкил итә, 1861 дә император указы б-н гамәлдән чыгарыла) торгызыла. 1852 дән аның үз бинасы була; 1885 тә газ б-н яктыртыла башлый. 1869 да һәм 1885 тә басмаханәнең барлык шрифтлары эретеп яңадан коела (1890 га 1,5 мең пот шрифт исәпләнә).

1809–18 дә китаплар рус, татар, латин, немец, француз һәм итальян телләрендә басыла. 1829 да — грек һәм гарәп хәрефләренең матрицалары һәм пуансоннары, 1832 дә төрек һәм фарсы шрифтлары сатып алына. 1834 тән читтән шрифтларны коеп ясауга заказлар кабул ителә башлый. 1835 елгы Устав нигезендә ачылган гарәп һәм фарсы, төрек-татар телләре кафедралары, үз хезмәтләрен бастыру




Казан университеты басмаханәсе басмалары. 1–3. Аерым китапларның титул битләре;
4–5. «Басмаханә һәм хәреф кою ширкәтенең язулар, бизәкләр һәм билгеләр үрнәкләре». 1884.

өчен, шрифтлар б-н тәэмин ителәләр, ә 1842 дә оештырылган әрмән теле, санскрит һәм тибет теле кафедраларына хәрефләр алдагы елда алына. Ул елларда басмаханәдә монгол телен белгән эшчеләр булмау сәбәпле, «Монгол хрестоматиясе»н («Монгольская хрестоматия» 1–2 т., 1836–37) нәшер иткәндә, проф. О.М.Ковалевскийга хәреф җыю һәм корректор эшләрен үзенә башкарырга туры килә.

1830 еллардан Н.И.Лобачевский тырышлыгы белән Шәрекъ телләрендә китаплар күпләп басыла башлый. Хәреф җыю, шрифтларны эретеп коюның күп хезмәт таләп итүе һәм тиражы күп булу сәбәпле, әлеге заказларның бәяләре рус һәм башка Европа телләрендә басылган китапларга караганда 3–4 мәртәбә югарырак була (һәр форманы 2 шәр мәртәбә җыю, 1,2 мең данә).

Шәхси заказлар, бигрәк тә татар наширләренеке, басмаханәгә шактый зур табыш китерә (1833 тә — 3512 сум, 1843 тә — 5510 сум, 1864 тә — 2118 сум, 1866–68 дә 25 мең сум чамасы). Әлеге керемнәр җиһазларны яңартуга тотыла.

Басмаханә каршында аның үз басмаларыннан торган китапханә эшли (1842 елгы янгында юкка чыга). Азия басмаханәсе басмаларын кертеп, «Император Казан университеты басмаханәсендә 1800 елдан 1896 елга кадәр басылган китаплар каталогы» («Каталог книг, отпечатанных в типографии императорского Казанского университета с 1800 по 1896 год », төзүчесе А.Т.Соловьёв, 1896) һәм «1896 елдан 1899 елга кадәр... каталогы» («Каталог... с 1896 по 1899», төзүчесе Н.Ф.Катанов, 1899) сакланган.

1896 елга басмаханәдә 1 мең пот шрифт, 7 тиз баса торган машина, 3 хәреф кою җайланмасы исәпләнә, шул сәбәпле Казан ун-ты басмаханәсе башка провинцияләр басмаханәләрен узып китә, башкаланың иң яхшы басмаханәләре дәрәҗәсенә күтәрелә. 1892 дә Н.Д.Даниловның ташбасмаханәсе сатып алына. 1897 дә ул «басмаханә, ташбасмаханә, хәреф кою ширкәте» исемен ала. Эшнең сыйфаты күзгә күренеп яхшыра, заказларны үтәү вакыты кыскара. 20 йөз башына җиһазларның бәясе 62 мең сумга җитә. Басмаханә хисабына университет өчен кирәкле хезмәтләрнең күп итеп бушлай басылуы (1890 да 5438 сумлык, 1900 дә — 12388 сум), җиһазлар өчен чыгымнарның артуы (1892 дә 50763 сум, 1900 дә 64421 сум), идарәнең бюрократлашуы (ун-т идарәсе һәм советы рөхсәтеннән башка бернәрсә дә эшләнми), арзан бәягә нәшер итүче хосусый басмаханәләр саны арту нәтиҗәсендә басмаханәнең чыгымнары керемнәрдән артып китә, бу исә басмаханәгә мөрәҗәгать итүче заказчыларның кимүенә китерә. 1909 га ул аяныч хәлдә кала, әлеге вазгыять Окт. рев-циясе башланганда да үзгәрми.

1918 дә басмаханә национализацияләнә һәм губерна халык мәгарифе бүлеге карамагына тапшырыла, аннары Казан губерна халык хуҗалыгы советының полиграфия секциясенә күчә (1919 ның гыйнвар-феврале) һәм 5 нче дәүләт басмаханәсе дип атала башлый.

1886 да Казан сәнәгый күргәзмәсендә — зур көмеш медаль, 1889 да Екатеринбург күргәзмәсендә — алтын медаль, 1890 да Казан күргәзмәсендә мактаулы бәяләмә ала. Ш.у.к. *Казан университеты нәшрияты.*

*Әд.:* к. «*Казан университеты нәшрияты*».

*И.А.Новицкая.*

**«КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́ ЗООСТА́НЦИЯСЕ»** (Дачный урман массивы), табигать истәлеге, Югары Ослан р-ны терр-ясендә Пустые Моркваши авылыннан көнбатыштарак урнашкан. 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 300 *га*. Куйбышев сусаклагычы акваториясен һәм тугайлы болын, урман («тау иманлекләре» дип аталучы) өлешләре сакланган утраулар һәм Идел елгасының уңъяк ярындагы далаланган участокларны били. Имән һәм аңа хас үсемлекләр б-н юкәлекләр, нигездә, икенчел, элеккеге урманнар урынында барлыкка килгән; аерым наратлар очрый. Сирәк үсемлекләрдән каеш яфракның төрле төрләре, Роберт өер абагасы, Браун күпрәтлеге, кара җимешле кызылча, хуш исле зубр кыягы үсә. Фаунада балыклар (43 төр, ш.и. подуст (түбәнавыз), тупалакбашлар, амфибияләр (4), рептилияләр (4, ш.и. бакыр кәлтә, гади кара елан), кошлар (88, ш.и. кыр, болын карчыгалары, бөркет, тавышлы зур каракош, шөпшәашар, балыкчы карчыга, сапсан, төн лачыны, яшел һәм өч бармаклы тукран, урман тургае), имезүчеләр (25 төр, ш.и. тимгелле йомран, ас, таш сусары, гади шолган).

Табигать истәлеге терр-ясендә 1916 да Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте карары (А.А.Остроумов) нигезендә оешкан зоология станциясе урнаша. Ул Зөя елгасының уңъяк ярында тамагыннан 3 *км* читтә фаунаны тикшерү һәм фәнни өйрәнүләр үткәрү максаты б-н оештырыла. 1918 дә эшен туктата. Станция 1950 еллар башында үзенең эшчәнлеген яңадан торгыза: матди-техник база булдырыла, уку лаб-яләре җиһазландырыла. Соңрак су организмнары экологиясе лаб-яләре оештырыла. 2000 дә Казан ун-тының биология-туфрак ф-ты каршындагы Биология фәнни-тикшеренү ин-ты составында зоол. станциясе студентларның кыр һәм махсуслашкан практика үтүе өчен база булып тора. Куйбышев сусаклагычы үрнәгендә үзгәртеп корылган сулык экосистемалары формалашуын, аларның аерым компонентларын (бактерио-, фито-, зоопланктон, бентос һәм балыклар) һәм төрлелеген, ш.у. яр буе биоценозлары фаунасын һәм флорасын өйрәнү буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла.

*Әд.:* И в а н о в И.И. Энтомологические наблюдения // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1925. Т. 49, вып. 3; Ш м и д т о в А.И. Кафедра зоологии позвоночных // Уч. зап. Казан. ун-та. 1960. Т. 120, кн. 3.

*В.А.Кузнецов.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́ КАРШЫНДАГЫ́ КАЗА́Н ТАБИБЛӘРЕ́ ҖӘМГЫЯТЕ́ КИТАПХАНӘСЕ́.** 1868 елда оеша. Аның фондын җәмгыятьнең үз хезмәтләре, мед. газеталары һәм журналлары редакцияләреннән, мед. мөнәсәбәте булган учреждениеләрдән килгән һ.б. оешмалардан алмаштырып алынган әдәбият тәшкил итә. Китапханәне төрле елларда табибләр А.В.Петров (1868–74), В.П.Иванов (1874–77), В.Д.Орлов (1877–83), А.Н.Арнольдов (1883–86), А.А.Панормов (1886–89), М.В.Казанский (1889–1913), В.П.Неболюбов (1913 елдан) җитәкли. 1892 гә китапханәдә 3754 берәмлек китап исәпләнә; ул Россия табибләр җәмгыяте китапханәләре арасында иң яхшылардан санала.

Китапханә фонды иганәчелек ярдәмендә дә баеган, мәс., 1885 һәм 1886 елларда — табиб Гросс, проф. А.У.Фрезе (544 том), 1895 тә җәмгыятьнең шәрәфле әгъзасы проф. И.И.Гвоз-

дев, проф. А.Н.Бекетов (477 том) һәм С.С.Зимницкий варислары үзләренең китапларын тапшыралар.

Казан ун-тының мед. ф-ты мөстәкыйль мед. ин-ты булып аерылып чыкканнан соң китапханә шунда күчерелә (1930), аның фондын 20 меңгә якын басма тәшкил итә (к. *Казан медицина университеты*).

*Н.А.Антонова.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́ НӘШРИЯТЫ́**. Революциягә кадәрге Россиядә иң эре нәшриятларның берсе. *Казан университеты басмаханәсе* барлыкка килгән вакыттан эшли башлый. Нәшрият сәясәтен күбесенчә Казан ун-ты каршындагы цензура ком-ты (1807–27), Халык мәгарифе министрлыгы каршындагы Баш цензура идарәсе (1828–62), Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Матбугат эшләре буенча баш идарә (1865–1917) билгели; татар телендәге китаплар өстәмә цензура уза. Аерым басмаларны редакцияләү һәм аларның полиграфик бизәлеше «Казанские известия»нең нәшрият ком-ты (1811–20), Н.И.Лобачевский җитәкчелегендәге «Кырым ханнары тарихы»н бастыру өчен оештырылган ком-т (1828–29), Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең редакция ком-ты тарафыннан билгеләнә.

19 йөзнең 1 нче яртысында басма продукциянең 57% ын гуманитар фәннәр буенча басылган китаплар һәм брошюралар тәшкил итә, 19 йөзнең 2 нче яртысында табигыять фәннәре һәм төгәл фәннәр буенча чыгарылган басмалар өстенлек ала. 1808–50 елларда — 591, 1851–1900 да — 1700, 1907–15 тә 126 басма дөнья күрә. Басмаханәдә иң беренчеләрдән булып нәшер ителгән басмаларның берсе — И.Хәлфиннең «Татар теле әлифбасы һәм грамматикасы» («Азбука и грамматика татарского языка», 1809). 1812 дә Ватан сугышы башлангач, Сенатның Казан шәһәренә эвакуацияләнгән Мәскәү департаментлары фәрманнары да басыла. 1813 тән латин телендә басмалар чыгарыла башлый.

Басмаханәдә ш. у. дәрес расписаниеләре, хисаплар, юбилей нотыклары, җыентыклар, «Казанские известия» (1811–20), «Казанский вестник» (1821–33), «Учёные записки Казанского университета» (1834–1918) ж-лары һ.б. дөнья күрә.

Казан ун-ты профессорлары А.М.Бутлеров, Н.Н.Зинин, К.К.Клаус, Н.И.Лобачевский, И.М.Симонов, Э.А.Эверсман хезмәтләре нәшер ителә. 1830–40 елларда Россия һәм җирле төбәк тарихы мәсьәләләренә багышланган 15 хезмәт басыла. Басылган китапларның күбесе — дәреслекләр. А.К.Казимбәкнең немец теленә тәрҗемә ителгән «Төрек-татар теле грамматикасы» («Грамматика турецко-татарского языка», 1839; 2 нче басма, 1846) Европа ун-тлары студентлары өчен берничә дистә ел дәвамында кулланма булып хезмәт итә. Түбән һәм урта уку йортлары саны арту сәбәпле, дәреслекләр берничә тапкыр нәшер ителә. Мәсәлән, «Татар әлифбасы» 1830–80 елларда 33 тапкыр басыла. Казан Шәрекъне өйрәнү мәктәбе И.Н.Березин, А.К.Казимбәк, О.М.Ковалевский, П.Я.Петров, Х.Д.Френ, Ф.И.Эрдман һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба. И.Хәлфиннең татар телендә язылган, русча исемләнгән «Чыңгыз хан һәм Аксак Тимернең тормышы» («Жизнь Джингиз хана и Аксак Тимура», 1819) хезмәте уку йортлары өчен, татар-рус һәм рус-татар сүзлекләрендә бирелгән кушымта б-н басыла (1821), ул тюркологларның югары бәясен ала. Археограф граф Н.П.Румянцев тырышлыгы б-н Әбелгазый Бахадур ханның чагатай телендә язылган, И.Хәлфин тарафыннан басмага әзерләнгән, исеме латин телендә бирелгән «Шәҗәрә-и төрек» («Төркиләр шәҗәрәсе», 1825) кулъязмасы һәм аның француз, немец, рус телләрендәге тәрҗемәләре югары сыйфатлы басма булarak дөнья күрә.

1809–50 елларда гарәп шрифтында — 220, 1851–1900 елларда 1500 гә якын китап — фольклор, матур әдәбият, гарәп һәм фарсы әдәбиятлары классиклары, борынгы төрки әдәбияты ядкәрләре, сүзлекләр, дәреслекләр, календарьлар, ислам кануннары гыйлеме буенча хезмәтләр, Коръән, догалыклар басыла. 19 йөзнең 2 яртысында нәшер ителгән китапларның яртысын диярлек татар китаплары тәшкил итә, бу татарларны агартуда зур роль уйный. Шәрекъ телендәге басмалар Россиянең башка өлкәләренә, Кавказга, Урта Азиягә, Якын Шәрекъ илләренә җибәрелә. 20 йөз башыннан нашир-мәгърифәтче К.Насыйри, язучылар Р.Әмирхан, Г.Фәезханов, Ә.Максуди тарафыннан чыгарылган татарча басмалар арасында тираж буенча дини эчтәлекле әдәбият өстенлек ала.

Казан ун-ты нәшрияты басмалары 20 йөзнең күп дистә еллары дәвамында Казан китап басу эшенең фәнни йөзен билгели, Идел буе, Урал, Себер халыкларын агартуда булышлык итә.

СССР югары белем бирү министры В.П.Елютин тарафыннан 1957 нең 25 декабрендә чыгарылган боерык нигезендә Казан ун-тында китап нәшрияты яңадан оештырыла. Башта нәшриятның үз басмаханәсе була. 1992 гә кадәр «Союзкнига» һәм «Международная книга» нәшриятлары б-н хезмәттәшлек итә. Күп кенә басмалар, мәс., «Гамәли математика буенча тикшеренүләр» («Исследования по прикладной математике»), «Ихтималлык алымнары һәм кибернетика» («Вероятностные методы и кибернетика») җыентыклары чит телләргә тәрҗемә ителә. Фәнни тикшеренүләрнең югары дәрәҗәдә алып барылуы нәшриятның аерым урынын билгели. 1987 нең 28 сентябреннән нәшрият (илнең төбәкләрдәге нәшриятлары арасында бердәнбер) СССР Югары белем бирү министрлыгына һәм СССР Дәүләт нәшрият эшләре ком-тына буйсынган хәлдә үзәк нәшрият статусын ала. РФ хөкүмәтенең 1994 ел 10 февраль карары нигезендә нәшрият дәүләт унитар пр-тиесе итеп үзгәртелә. Хуҗалык исәбендә эшли һәм үз чыгымнарын үзе каплый. Нәшрият монографияләр, фәнни хезмәтләр җыентыклары, дәреслекләр, журналлар, фәнни-популяр һәм матур әдәбият әсәрләре чыгара. 2010 да 500 ләп басма дөнья күрә.

*Әд.:* П а р а м о н о в а Н.Б. Книгоиздательская деятельность Казанского университета в первой половине XIX века: Дис. ... Л., 1977; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992; Г а б д е л ь г а н и е в а Г.Г. Книгоиздательская и типографская деятельность Казанского университета второй половины XIX века: Дис. ... К., 1994.

*И.А.Новицкая.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́ СТУДЕНТЛАРЫ́ КИТАПХАНӘЛӘРЕ́**. 1850 елларда шәхси уку китапханәсе буларак оешалар. Беренчесен филолог-студентлар оештыралар; 1858 дә инде алар башка ф-тларда да барлыкка килә. Аларга өстәмә итеп якташлык китапханәләре ачыла, шуларның беренчесе һәм иң оешканы — Себер якташлыгыныкы. Әдәбият иганәчелек, шәһәр кешеләре ярдәмендә туплана, анда легаль һәм легаль булмаган басмалар да була. Китапханәче итеп ышанычлы казанган студент сайлана. Китапханәдән, күпмедер акча түләп, шәһәрнең башка уку йортлары студентлары да файдалана. 1860 еллар башында аерым якташлык китапханә фондлары бергә кушыла һәм бердәм китапханә булып эшли башлый, кайберләре мөстәкыйль эшләүләрен дәвам итә. Студентлар үтенече б-н ун-т бинасында бирләштерелгән китапханә өчен махсус бүлмә бирелә. Аларның берсендә эшчәнлеге ун-тка А.П.Щапов килгәч активлашкан легаль булмаган китапханә оеша (1861 дә аны хакимиятләр яба). 1862 дә «Студентлар клубы» китапханәсе оештырыла, анда легаль һәм легаль булмаган китаплар да була. Китапларны студентлар алдыра, алар ш.у. төрле кешеләрдән, ш.и. сөргендәге кешеләрдән дә килә. Мәсәлән., «Колокол», «Искра», «Современник», «Русский вестник» һ.б. ж-лар, В.Г.Белинский, Н.А.Добролюбов, Н.Г.Чернышевский, Д.Юм, Дж.Локк, Г.Спенсер, Дж. Милль әсәрләре, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, А.Н.Плещеев һ.б.ларның тыелган әсәрләре. 1863 тә хакимият бу китапханәне япканнан соң, студентлар фондларны саклап калалар. Алар күп кенә шәхси китапханәләрнең нигезен тәшкил итә (доцент М.А.Хомяков, мед. д-ры А.Н.Соловьёв (1864 тән), проф. А.А.Штукенберг (1879 дан), Казан мәхкәмә палатасының антлы вәкиле Н.В.Рейнгардт (1882 ел уртасыннан) китапханәләре). Әлеге шәхесләр китапханәнең бары тик кәгазьдәге хуҗалары гына, чынлыкта алар б-н язылган басмалар исемлеген билгеләүче студентлардан оешкан сайлау ком-ты идарә итә. Китапханәләрдән шәһәр кешеләре дә файдалана. 1884 тә китапханәне хакимиятләр яба. Студентлар фондны өлешләп үз фатирларына ташыйлар, һәм алар яңа китапханәләр, ш.и. марксистик түгәрәкләр каршында ачылганнарының нигезе булып торалар. Китапларның шактый өлеше *Федосеев түгәрәге* китапханәсенә күчә. 1850–60 еллардагы якташлык китапханәләренең кайберләре 1880 елларда оешкан легаль булмаган якташлык китапханәләре нигезен тәшкил итә.

*Әд.:* Б и р ю к о в А.А. Университет и студенчество в 60-е годы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1930. Кн. 5; В у л ь ф с о н Г.Н., Б у ш к а н е ц Е.Г. Общественно-политическая борьба в Казанском университете в период революционной ситуации (1859–1801). К., 1952; ш у л у к. Из истории разночинного движения в Поволжье и на Урале. К.,

1963; Каримуллин А.Г. Книги и люди: Исслед. К., 1985.

*Г.Г.Габделганиева.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫ́ ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, 1979 елның 30 ноябрендә университетның 175 еллыгы уңаеннан ачыла. Аның төп бинасында, элеккеге Крестовоздвиженский чиркәве бинасында урнашкан. Музей мәйданы — 247 $м^2$, коллекцияләр 20 меңнән артык саклау берәмлеген тәшкил итә. Экспозиция авторлары — С.В.Писарева (фәнни җитәкче), И.В.Жизневская, Н.В.Пельникевич; сәнгати бизәү авторлары — А.А.Крылов, Б.М.Салосин, В.Ф.Зиновьев. Музей составына мемориаль комплекслар: элеккеге хокук ф-ты аудиториясе (реставрациядән соң, 1970), актлар залы (реставрациядән соң, 1987; проф. Г.Н.*Вульфсон* җитәкчелегендә яңадан торгызыла), Н.И.*Лобачевскийга* багышланган зал (1992 дә ачыла) керә. Музей экспозициясе Россиядәге иң өлкән ун-тларның берсенең тарихына, аның фәнни мәктәпләре уңышларына, рус һәм дөнья фәннәре үсешенә зур өлеш керткән күренекле галимнәренә, укытучыларына һәм ун-тны тәмамлаган шәхесләргә багышлана. Экспонатлар арасында галимнәрнең шәхси әйберләре, документлары, кулъязмалары, үзләре исән чагында басылып чыккан хезмәтләре һәм китаплары, приборлары, эш кораллары, профессор мундиры һәм ун-тның 19 йөздәге швейцарының махсус парад киеме һ.б. бар. Экспозициянең махсус бүлекләре *студентлар җыеннарында* (1887) катнашучыларга, 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларына, ун-тның эшчеләр ф-ты (рабфак) тарихына багышлана. Аеруча кыйммәтле булган экспонатлар арасында җир шары тирәли 1 нче рус экспедициясендә катнашкан И.М.*Симоновның* астрономия приборлары; мәшһүр галим-химиклар Н.Н.*Зинин*, А.М.*Бутлеров*, В.В.*Марковниковның* препаратлары һәм хезмәтләре; Шәрекъне өйрәнүчеләр О.М.*Ковалевский*, В.П.*Васильев*, Н.Ф.*Катановларның* Себергә, Ерак Көнчыгыш, Монголия, Кытайга экспедицияләреннән алып кайткан коллекцияләреннән әйберләр; В.И.*Разумовский*, А.В.*Вишневскийның* хирургия кораллары; Россиядә А.Ф.*Самойлов* тарафыннан 1 нче электрокардиограмма язуда кулланылган кыллы гальванометр; А.Е.Арбузовның пыяладан өреп ясау б-н шөгыльләнү өстәле; 1944 тә, электрон парамагнит резонансын ачканда, Е.К.*Завойский* кулланган магнит; геол. һәм геогр. профессоры П.И.*Кротовның* мундиры; ботаника профессоры В.И.*Барановның* рәсемнәре; матем. профессоры Н.Н.*Парфентьевның* цитрасы (кыллы музыка уен коралы); этнография белгече, профессор Е.П.*Бусыгинның* скрипкасы; тәүге рабфакчыларның берсе А.Шамовның кыек якалы ирләр күлмәге, үреп ясалган кәрзине; физик Р.Б.Таһировның фронт шинеле; ректор М.Т.*Нужинның* кыр сумкасы һәм хәрби бүләкләре; фехтование буенча 1986 елгы дөнья чемпионы — ун-т студенты О.Б.*Вощакинаның* спорт кирәк-яраклары һәм бүләкләре бар. Музейның 2 ф-лы: Е.К.Завойский музей-лаб-ясе һәм *Казан химия мәктәбе тарихы музее* бар.






Казан университеты тарихы музее. 1. Экспозициянең гомуми күренеше; 2. Актлар залы; 3. Н.И.Лобачевский залы; 4. Юридик факультетның 7 нче аудиториясе.

2001 дән музей Россия Музейлар берлеге әгъзасы булып тора.

*Әд.:* По музеям университета: Буклет. [У.к.], [Е.к.]; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004.

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ГЕОЛО́ГИЯ-МИНЕРАЛО́ГИЯ МУЗЕ́Е**, к. *Геология музее*.

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ИНФОРМАЦИО́Н ТЕХНОЛО́ГИЯЛӘР ҮЗӘГЕ́** (ЦИТ). 1957 елда университет ректоры М.Т.Нужин һәм проф. В.В.Морозов тырышлыгы б-н матем. анализ һәм җир асты гидромеханикасы проблемалы лаб-ясе базасында Хисаплау үзәге (ВЦ) буларак төзелә; 1985 тән Казан ун-тының информатика һәм хисаплау техникасы үзәге (ЦИВТ), 2001 дән хәзерге исемдә. Үзәк ун-т информацион инфраструктурасының үсешен һәм эшләвен, төбәк һәм бөтендөнья информацион пространстволары б-н элемтәне тәэмин итә; уку-укыту процессын, фәнни-тикшеренү эшләрен, идарә итүне мәгълүматлаштыруның программ-техник чараларын эшли һәм гамәлгә кертә, яңа информацион технологияләр өлкәсендә фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен алып бара. 1958 дә ВЦда илнең иң беренче электрон-исәпләү машиналарының (ЭВМ) берсе — УРАЛ-1 (баш конструкторы Б.И.Рәмиев) урнаштырыла, һәм анда СССР ФА Казан ф-лының, вузлар, фәнни-тикшеренү институтлары, заводларның махсус КБлары һәм шәһәрнең башка оешмалары заказлары буенча исәпләү эшләре башкарыла. 1950 еллар ахырына ВЦ секундка 20 мең операция егәрлекле өч адреслы М-20 машинасы (Казан матем. машиналар з-дында эшләнә) б-н җиһазландырыла, һәм ул УРАЛ-1 дән 200 тапкыр куәтлерәк була. 1965 тә ВЦ Алгол-60 алгоритмик программалаштыру теленнән трансляторларны үзләштерә: ТА-1 (җитәкчесе С.С.Лавров, СССР ФАнең Төгәл механика һәм хисаплау техникасы ин-ты) һәм ТА-2 (җитәкчесе М.Р.Шура-Бура, СССР ФАнең Гамәли математика ин-ты). 1969 да ВЦ өчен бина төзелә, шул вакыт өчен бик зур тизлеккә, оператив һәм тышкы хәтергә, периферия җайланмаларына, техник һәм программа чараларына ия булган икенче буын ЭВМнар (М-220, М220М, М-222) куела. Бу уңышлар ЭВМ ресурслары б-н дистанцион бүленгән эшләрне оештыру өчен илдә беренчеләрдән вакыт бүлү системасын (җитәкчесе А.В.Сульдин) булдырып гамәлгә кертү мөмкинлеге бирә. Республикада беренче тапкыр ЭВМ исәпләү максатларында гына түгел, идарә итүдә дә кулланыла башлый. 1960 еллар ахырында ВЦда ун-т б-н автоматлаштырылган идарә итү системасын (АСУ) эшләү өчен төркем төзелә (җитәкчесе — И.И.Мальцева). Беренче АСУ «Абитуриент» системасы була; 1971 дә ун-т хезмәткәрләренә хезмәт хакын һәм студентларга стипендия исәпләүнең автоматлаштырылган системасы гамәлгә кертелә. 1980 елларда ВЦга ЕС сериясе машиналары (ЕС-1033, ЕС-1045, ЕС-1046) һәм берничә мини-ЭВМ (СМ һәм МИР) алына, алар 12 терминал классының эшләвен тәэмин итә. ЭВМнар челтәрен төзүгә караган проектлар эшләнә һәм аларның ресурсларын берләштерү буенча беренче тәҗрибәләр үткәрелә.

1990 елларда Казан ун-ты локаль исәпләү челтәренә берләштерелгән һәм глобаль челтәрләргә чыга торган персональ компьютерлар б-н җиһазландырыла. 1993 тә ун-тның компьютерлар паркы SUN Microsystems компаниясенең югары җитештерүчән техникасы (RISC процессорлар базасында) б-н тулыландырыла; 1994 тә ун-тның Интернет б-н эшли ала торган информацион-хисаплау челтәре булдырыла. Аның нигезендә төрле оеш-

маларны берләштергән коммерциячел булмаган шәһәр челтәре эшли башлый. Бу челтәрнең әбүнәчеләре булып вузлар, академик ин-тлар, дәүләт идарәсе органнары, әйдәп баручы китапханәләр, медицина учреждениеләре, мәктәпләр һ.б. тора (1995 кә аңа 200 тирәсе оешма керә). Казан ун-ты челтәре төзелү б-н ЦИВТда челтәрнең мәгълүмат базасын һәм белемнәр базасын эшләүгә керешелә, ТРның беренче мәгълүмат системасы оештырыла, анда респ-каның тарихы, мәгариф системасы, сәнгате буенча рус, татар һәм инглиз телләрендә белешмәләр урнаштырыла. Бердәм информацион системаның компонентлары: информацион-аналитик идарә системасы, Web-сайт, китапханә системалары, электрон укыту ресурслары эшләнә һәм гамәлгә кертелә.

1991–2000 елларда «Компьютер лингвографиясе» проекты кысаларында ЦИВТ (җитәкчесе — Н.А.Обносова) һәм филол. ф-ты (җитәкчесе — К.Р.Галиуллин) хезмәткәрләре коллективлары IBM PC өчен «RussianExpert» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын эшлиләр, система АКШ һәм Канаданың күп кенә ун-тларында танылу ала.

Казан ун-тының компьютер челтәренә 2 меңнән артык компьютер станциясе керә; югары тизлекле челтәр ун-тның барлык корпусларын һәм тулай торакларын, Яшел Үзән шәһәрендәге ф-лны берләштерә; видео- һәм аудиотрансляцияләр, конференцияләр даими үткәрелә. 2007 елда илнең сайтлар конкурсында ун-тның www.ksu.ru порталы Идел буе төбәгендә беренче урынны яулый. ЦИВТ базасында ТРның мәктәпара методик үзәкләр системасының Төбәк координация советы булдырыла. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү порталы проектын эшләп, ЦИВТ РФнең милли бүләген ала (2006). Казан ун-ты гомумроссия операторларына, ш.у. ТРның барлык коммерциячел элемтә операторларына (Таттелеком, Телесет, Татинтелком, Интелсет, ТРК ТВТ һ.б.) үзен ялгый ала.

ВЦ–ЦИТның төрле еллардагы җитәкчеләре: В.В.Морозов (1957), В.Я.Булыгин (1958–61), Я.И.Заботин (1961–67), А.Н.Чекалин (1967–80), А.В.Лапин (1980–84), А.В.Таркаев (1984–92), В.А.Шевченко (1992–2000 ); В.А.Чугунов (2000–11). 2011 елда ЦИТ Казан (Идел буе) федераль ун-тының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә департаменты итеп үзгәртелә.

*Әд.:* Вычислительные методы и математическое обеспечение ЭВМ. К., 1980; Формирование и использование сетевых информационных ресурсов в Казанском государственном университете // Новые информационные технологии в университетском образовании: Междунар. науч.-метод. конф. Новосиб., 1998.

*В.А.Шевченко.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң НӘФИ́С СӘНГА́ТЬ ҺӘМ БОРЫНГЫ́ ИСТӘЛЕКЛӘ́Р МУЗЕЕ́**. Кафедралар каршында ярдәмче уку учреждениеләре, ш.и. сәнгать теориясе һәм тарихы кафедрасы каршында Борынгы истәлекләр һәм сәнгать (борынгы һәм яңа сәнгать әсәрләренең күчермәләре) музеен оештыру кирәклеге ун-тның 1864 еллгы Уставында әйтелә. Музей эшен алып бару өчен ел саен махсус акча бүлеп бирелә. 1880 еллар уртасына кадәр тарих-филол. ф-тында составында элеккеге рәсем классындагы сынлы сәнгать, графика әсәрләре, скульптуралар коллекциясе сакланган этнография, борынгы истәлекләр һәм нәфис сәнгать музее эшләп килә. 1887 дә өч мөстәкыйль музейга — ватанны өйрәнү гыйлеме, нумизматика һәм үзендә 4726 сум 57 тиенлек 174 төрле әйбере булган нәфис сәнгать һәм борынгы истәлекләр музеена бүленә. Музей б-н төрле елларда ф-т деканы Д.Ф.Беляев (1894–97), Д.В.*Айналов* (1897–1903), проф. А.М.*Миронов* (1903–20) җитәкчелек итә. Музей, сатып алудан тыш, ректор Н.П.Загоскиннан, профессорлар Д.Е.Образцов, Д.А.Корсаков, Д.Ф.Беляев, Д.И.Дубяго, Зөя Успение монастыре архимандриты Афанасий атакайдан бүләк сыйфатында әйберләр ала. Д.В.Айналов музейны беренче тапкыр үзгәртеп кору эшләрен үткәрә (3 бүлек оеша: антик скульптураларның күчермәләре, борынгы истәлекләр, китапханә); «Казан Император университеты каршындагы Сәнгать һәм борынгы истәлекләр музее китаплары каталогы»н («Каталог книг Музея искусств и древностей при Императорском Казанском университете», 1990) бастыра; чит илләрдә командировкаларда сатып алган 800 гә якын төрле архит-ра һәм сәнгать истәлекләре фоторәсемнәрен бүләк итеп тапшыра. Музейны оештыруның беренче башлангыч этабында төп игътибар китапханәне сәнгать тарихына караган уку әсбаплары б-н тәэмин итүгә бирелә. 1920 ел башында китапханәдә Шәрекъ, борынгы Греция һәм Рим, христиан һәм Византия сәнгате һәм археологиясе, урта гасырлар, Яңарыш чоры, рус борынгы истәлекләре һәм сәнгате, мәдәниятнең, дин һәм көнкүрешнең гомуми тарихы, география, картография һәм юлкүрсәткечләр, эстетика, сәнгатьнең гомуми тарихына кагылышлы күрсәтмә әсбаблар саклана, яңа сәнгать бүлекләрендә 2 меңнән артык басма хезмәт исәпләнә, журналлар туплана. Китапханәдә рус һәм чит ил классикларының һәм хәзерге сәнгать тикшеренүчеләренең (Б.А.Тураев, Н.П.Кондаков, В.В.Стасов, О.Г.Филимонов, А.Л.Погодин, Н.В.Покровский, Н.П.Лихачёв, А.Н.Бенуа, Винкельман, Гиро, Масперо, Куиньи, Лессинг, Байе, Верман, Дж.Рёскин һ.б.) хезмәтләре була. В.К.Мясоедов, Б.П.Денике, Д.В.Айналов, А.А.Сидоров, П.М.Дульский, А.М.Миронов һ.б.дан автографлары б-н бүләккә бик күп китаплар кабул ителә. Китаплардан тыш Микеланджело, Рафаэль, Рембрандт, Веласкес, Мурильо, Леонардо да Винчи, Брейгель һ.б. әсәрләренең фоторәсемнәре, зур форматлы гелиогравюралары — репродукцияләре сатып алына. Вакытлы басмалардан «Старые годы», «Пропилен», «Аполлон», «Столица и усадьба», «Русский библиофил», «Художественные сокровища России», «Искусство и художественная промышленность» ж-ллары игътибарга лаек. Әдәбият китаплары Берлин, Париж, Лейпциг, Дорнах, Рига, С.-Петербург шәһәрләреннән яздырып китерелә һәм Казан китап сатучылары Дубровин һәм Башмаковтан сатып алына. 20 йөз башында музей китапханәсе Казанда сәнгатькә караган махсус басмалар тупланган бердәнбер урын була. Музей коллекцияләрендә археология, гамәли-бизәлеш сәнгате әйберләре, иконалар, нәкышь, уемлау һәм ташбасма ысулы б-н төшерелгән рәсемнәр (ел саен 20 дән 50 гә кадәр экспонат сатып алына) бар. Төрле чорларга, шул чорларның мәдәниятенә һәм стиленә нисбәтле булган археол. һәм гамәли бизәлеш сәнгате әйберләре күптөрле: сасанилар көмеше, фарсылар һәм кыргызларның фирәзә һәм ахаклы зәркән үрнәкләре, борынгы Рим чоры предметлары, Кытай фарфоры, Кырымда казу эшләре вакытында табылган борынгы Греция ядкәрләре, 1812 елгы Ватан сугышы темасы буенча Ф.П.Толстойның медальоннар күчермәләре, Мисырның борынгы истәлекләре (саркофаг һәм 9 сын) — Мисыр хәлифәсенең император Александр III гә биргән бүләгенең бер өлеше; Микены шәһәре халкының борынгы ядкәрләренең (алар Г.Шлиман тарафыннан табылган) гальванопластикада эшләнгән коллекцияләре күчермәләре; А.С.Пушкинның үлгәннән соңгы битлеге һ.б. Коллекцияләр арасында күпчелекне иконалар һәм гыйбадәтханә җиһазлары: бакырдан коеп ясалган әйберләр, җыелма иконалар, ефәк б-н чигелгән рәсемле иконалар, хачлар, панагияләр, патша ишеге һ.б. тәшкил итә. Христос, Мәрьям-Ана һәм изгеләр, христиан дини бәйрәмнәре сурәтләнгән әсәрләр күпләп тәкъдим ителә. Сынлы сәнгать коллекцияләре рус һәм чит ил рәссамнарының рәсем, графика һәм скульптура әсәрләрен үз эченә ала. Сәнгать академиясеннән антик сынлы әсәрләрнең гипстан әвәләп ясалган күчермәләре керә; ун-т идарәсе музейга элек ун-тның төрле биналарында сакланган Гомер, Питтак, Гораций, Демосфен, Овидий, Кант, Барклай де Толли, Кутузов бюстларын тапшыра. Сынлы сәнгать бүлегендә 17–19 йөзләрдә немец, француз, фламанд, итальян (шул чор билгеләре буенча), ш.у. рус осталарының аерым әсәрләре күрсәтелә. П.А.Радимов үзенең картиналарын, ш.и. Казанда «Хәзерге заман рус сәнгате» (1909) күргәзмәсендә күрсәтелгән «Казанда бәйрәм көнендә саескан базары» картинасын бүләккә бирә. А.М.Миронов сәнгать әсәрләренең даими иганәчесе була; 1919 да ул музейга таныш булмаган рус рәссамнарының киндергә төшерелгән «Бөек Пётрның портреты», «Хатын-кыз портреты», «Патшаның үтерелгән улы Дмитрийның анасы Мария Фёдоровна портреты» исемле картиналарын тапшыра. Шул ук елда музей Л.О.Сиклердан картиналар һәм аларның күчермәләрен бүләк итеп ала. Музей тупланмаларында графика әсәрләре арасында акварель б-н ясалган портретлар (Россия патриархлары Иов, Гермоген, Филарет, Иосиф, Иосаф портретлары), Мәскәү һәм Казан күренешләренең ташбасма ысулы б-н төшерелгән рәсемнәре, 18–19 йөзләрдәге рус һәм чит ил осталарының уемлау ысулы б-н эшләгән картиналарының күчермәләре һәм оригиналь әсәрләре бар. 1920 дә, тарих-филол. ф-ты бетерелүгә бәйле рәвештә сәнгать теориясе һәм

тарихы каф. һәм музей эшләүдән туктый. Хәзер аның коллекцияләренең аерым әйберләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана.

*Әд.:* Сыченкова Л.А. История Музея изящных искусств и складывание нового стиля культурной жизни в Казани // Казанский посад в прошлом и настоящем. К., 2002; Назипова Г.Р. Университет и музей: исторический опыт губернской Казани. К., 2005.

*Е.П.Ключевская.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ФӘННИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**, Н.И.Лобачевский исемендә, РФдә иң борынгы фәнни китапханәләрнең берсе. Фондның зурлыгы буенча университет китапханәләре арасында өченче (Мәскәү һәм С.-Петербург ун-тларыннан кала). 1969 елдан — Югары Идел буе зонасындагы, ә 1983 тән ТР, БР, Удмурт Респ-касы югары һәм махсус урта уку йортлары китапханәләре өчен методик үзәк. Китапханә Казан ун-ты Уставы нигезендә оеша (1804 нең 5 ноябрендә император Александр I Уставка кул куя). Иң элек аның вазифаларын Казан гимназиясе (ун-т шуның базасында оештырыла) китапханәсе башкара. Университетның мөстәкыйль бүлекчәсе буларак, китапханә 1806 ның 8 ноябреннән, Казан ун-тының беренче китапханәчесе итеп грек теле һәм әдәбияты профессоры М.Л.Сторль билгеләнгәч, эшли башлый. Ярдәмчесе П.С.Кондырев б-н ул гимназия китапханәсеннән ун-т өчен кирәкле булган 4022 томлык 1737 китапны сайлап ала. Г.А.Потёмкин һәм В.И.Полянскийның элек гимназиянеке саналган китаплар җыелмасы китапханәнең иң беренче фондының нигезен тәшкил итә (к. *Потёмкин Г.А. шәхси китапханәсе, Полянский В.И. шәхси китапханәсе*).

1825–35 елларда Н.И.*Лобачевский* Казан ун-ты китапханәчесе була, ул китапханә үсешенә үзеннән зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә махсус бина төзелә, китап фондын туплауның нәтиҗәле системасы булдырыла. Китапханәдән шәһәр кешеләре дә файдалана (берничә ел дәвамында ул Казандагы бердәнбер җәмәгать китапханәсе булып тора). Китапханәче буларак, Лобачевский эшен дәвам итүчеләр: К.К.*Фойгт* (1835–50) һәм И.Ф.*Готвальд* (1850–97). Китапханәче ярдәмчеләре: Н.И.Второв (1838–43), А.И.*Артемьев* (1842–50), И.А.Буссе (1897–1909) һ.б. 1916 ның 1 гыйнварына китапханә фондында 323449 берәмлек исәпләнә. 1932 дә ун-т китапханәсе (фонды 700 мең берәмлек) Казанның икенче эре китапханәсе — фонды (1 млн. берәмлектән артык) Окт. рев-циясеннән соң национализацияләнгән, 1920 еллардагы үзгәртеп кору нәтиҗәсендә үзләренең элеккеге хуҗаларын югалткан дистәләрчә китап җыелмаларыннан торган Татарстан Республика фәнни китапханәсе б-н берләштерелә. Әлеге җыелмаларның иң эресе — Казан руханилар академиясе китапханәсе. 1934 тә берләштерелгән китапханә республика китапханәсе статусын ала һәм Казан ун-ты каршындагы Татарстан Республика фәнни китапханәсе дип атала башлый. Китапханәнең яңа статусы 1940 еллар уртасына кадәр саклана, шул вакыттан ул Казан ун-тының фәнни китапханәсе исемен ала. 1953 тә аңа Н.И.Лобачевский исеме бирелә. 1931–46 елларда ул башка югары уку йортлары студентларына да, Бөек Ватан сугышы вакытында СССР ФА оешмаларыннан Казанга эвакуацияләнгән хезмәткәрләргә дә хезмәт күрсәтә. 1922 дән китапханә РСФСРда чыгучы китап һәм журналларның бушлай дәүләт данәсен ала башлый, 1928 дән — СССР, 1932 дән — РСФСР, 1941 нең август аеннан 1959 ның сентябрь аена кадәр — СССР, соңрак ун-т профиле буенча мәҗбүри түләүле данә. 1990 еллар башыннан, акча б-н тәэмин итү җитәрлек булмау сәбәпле, китапханә фондын үзебездә чыккан китаплар б-н тулыландыру эше өзелә. Китапханәдә дөньяның күп телләрендә басылган 15–21 йөзләрнең фәнни, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби әсәрләреннән зур тупланма барлыкка килә. 2011 нең 1 гыйнварына аның фондында — 4936737 берәмлек, алмашты-ру-резерв фондында 187704 берәмлек исәпләнә. Рус телендәге басма китаплар арасында 19–20 йөзләр басмалары күбрәк тупланган, 18 йөз китаплары һәм журналлары да күп җыелган, иске басмалар да бар (1564 тә Иван Фёдоров һәм Пётр Мстиславец тарафыннан басылган «Апостол» дигән — датасы күрсәтелгән иң беренче китаптан башлап). Китапханәдәге тупланмаларның күп өлешен 19–21 йөзләр Казан басмалары, татар телендә чыккан китапларның илдәге иң эре җыелмалары, газета һәм журналлар алып тора. Күп сандагы Көнбатыш Европа басмаларыннан — инкунабулалар, палеотиплар һәм атаклы басмаханәләр, фәнни үзәк басмалары. Атаклы галимнәр, язучылар, җәмәгать эшлеклеләренең үзләре исән чакта басылган басмалары; легаль булмаган һәм тыелган китаплар, ш.и. махсус фондта булган совет чоры басмалары һ.б. сакланган. Китапханә фондына тарихчылар Н.С.Арцыбашев, Н.А.Осокин, А.С.Шофман, әдәбият белгече Н.Н.Булич, Шәрекъне өйрәнүче белгечләр И.Ф.Готвальд, А.Б.Халидов, педагог А.И.Анастасиев, театр эшлеклесе П.М.Медведев, сәнгать белгече П.М.Дульский, галим-табибләр И.П.Франк, Н.А.Толмачёв, А.Г.Ге, коллекционер Г.И.Мешков һ.б.ның китап тупланмалары кергән. Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә рус, төрки, гарәп, фарсы һ.б. телләрдә 9–21 йөзләр кульязмалары һәм кульязма китаплар бирелгән. Әлеге б-н кульязмалар бүлеге күпкырлы. Анда 16–18 йөзләр Россия эш башкару документлары, Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте архивыннан башка документлар, Н.И.Лобачевский, И.М.Симонов, А.М.Бутлеров, төбәкне өйрәнүче Н.А.Агафонов архивлары; Казан ун-ты студентларының 1917–25 еллардагы шәхси эшләре һ.б. саклана. Бүлекнең Шәрекъ секторында — гарәп графикасындагы татарча кульязмалар, И.Ф.Готвальдның Шәрекъ телләрендәге кульязмалар коллекциясе, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Баруди, С.Вахиди, Х.Габәши, Г.Буби, М.Түнтәри, М.Фәйзи һ.б. татар галимнәре, язучылары, педагогларының архивлары һәм тупланмалары. 1963 тән китапханәгә Шәрекъ телләрендәге китаплар керү чыганагы — Казан ун-тының сектор хезмәткәрләре катнашкан археогр. экспедицияләр. Китапханәдә ун-т челтәренә һәм Интернетка тоташкан локаль компьютер челтәре булдырылган. Мәгълүматлар базасы: китапханәдәге китаплар каталогы (1992 дән), гуманитар фәннәр буенча мәкаләләр (1994 тән), ун-т галимнәре хезмәтләре (1999 дан), ун-тта якланган диссертация авторефератлары, мәгълүматларының, фәнни-тикшерү эшләре турындагы хисапларның тулы базасы һ.б. Китапханә «Ачык җәмгыять. Булышлык итү фонды» ин-тының финанс ярдәмендә 2002 дә оешкан Казанның корпоратив китапханәләр челтәре б-н җитәкчелек итә. Китапханә ун-тның барлык кешеләренә, ш.у. Казанның башка югары уку йортлары һәм оешмаларының фәнни хезмәткәрләренә дә хезмәт күрсәтә. Анда барысы 11 уку залы (аның берсе татар һәм Шәрекъ әдәбияты бүлеге каршында), 2 компьютер классы бар. Китапханәнең барлык бүлекчәләрендә 1100 дән артык утыру урыны исәпләнә.

Фәнни эшнең иң борынгы юнәлеше — китапханәнең китаплар һәм кульязмалар фондын, аның тарихын өйрәнү. А.И.Артемьев китапханәгә 19 йөзнең 1 яртысында кабул ителгән рус һәм Көнбатыш Европа телләрендәге кульязмаларның тасвирламасын әзерли. 20 йөзнең 2 яртысында рус һәм Шәрекъ кульязмалары тасвирламасының — 19, ш.и. татар телендә 9 чыгарылышы, китапханәдә саклана торган китап истәлекләренең каталогы (инкунабулалар, кириллицада басылган китаплар, 18 йөзнең 1 чирегендәге рус китаплары), кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең рус секторындагы кульязмалар фонды буенча юлкүрсәткечләр (1999) басыла. Казан ун-тының ректоры һәм китапханәчесе буларак, Н.И.Лобачевский эшчәнлеге турындагы документлар аның «Фәнни-педагогик мирас» («Научно-педагогическое наследие», М., 1976) китабында, 1820 дә Антрактиданы ачкан, Җир шары тирәли рус экспедициясендә катнашкан И.М.Симоновның язмалары нәшер ителә. Китапханә хезмәткәрләре Казан ун-тының 175 һәм 200 еллык тарихына багышланган китапларны, «Казан университеты, 1804–2004» («Казанский университет, 1804–2004». Т. 1–3, 2002–04) биобиблиографик сүзлеген, ш.у. 18 йөз һәм 1918–26 еллар рус китапларының җыелма каталогын әзерләүдә дә катнашалар («1918–26 еллар рус китабы халыкара җыелма каталогы» — «Международный сводный каталог русской книги 1918–26 гг.», Т. 1–2, СПб., 2002–03). Татарстан тарихы, татар әдәбият белеме, хезмәт хокукы, халыкара хокук буенча хезмәтләр, геологик өйрәнүләр, үсемлекләр дөньясы, республика туфрагы турындагы әдәбият күрсәткечләре, Казан ун-тының «Гыйльми язмалары», башка вакытлы басмалар эчтәлеге күрсәткечләре һ.б. басыла. 1998 дән китапханә Россия китапханәләр ассоциациясе әгъзасы, 2002 дән — Өлкә китапханә консорциумнар ассоциациясе әгъзасы. Китапханә директорлары арасында — Н.С.Ва-

сильев (1909–32), Н.Н.Парфентьев (1933–36), М.К.Андреев (1942–50), А.С.Гурьянов (1955–84), Ж.В.Щелыванова (1984–2000), Г.А.Әүхәдиева (2000–07), Җ.С.Миңнуллин (2007–11), Е.Н.Струков (2011 дән). Китапханәдә С.П.Шестаков, М.А.Васильев, Г.А.Скопин, С.Б.Радзиевская, Ә.Г.Кәримуллин, Д.Г.Абдуллина, А.С.Фәтхиев, В.В.Аристов һ.б.

Китапханәнең төп бинасы (1834–38, арх. М.П.Коринфский, янкорма — 1891–94, арх. В.Бернгардт) — 19 йөз архит-ра истәлеге, ун-т шәһәрчегенең бер өлеше. Китапханәнең яңа бинасы (1978 дә төзелә, арх. О.А.Кашинцева) — ун-тның 2 нче уку корпусы элементы. Беренче уку залы төп бинада урнашкан, дүртенче һәм бишенчесе — ун-тның уку корпусларында һәм тулай торакларында.

*Әд.:* Аристов В.В., Ермолаева Н.В. История Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского (1804–1850). К., 1985; Библиотека Казанского университета: фонды, раритеты, история...: Сб. статей. К., 1989; Аухадиева Г.А. Путь длиною в два столетия // Научный Татарстан. 2002. № 3/4; Университетские библиотеки в глобальном информационном и культурном пространстве: Материалы Всерос. науч.-практ. конф. К., 2004.

*Г.А.Әүхәдиева.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ХИСАПЛА́У ҮЗӘГЕ́**, к. *Казан университетының информацион технологияләр үзәге.*

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ЭТНОГРА́ФИЯ МУЗЕЕ́**, 1815 елда университетның *Шәрекъ бүлеге* каршында сирәк очраучы әйберләр кабинеты буларак оештырыла. 19 йөзнең 1 нче яртысы дәвамында кабинет ун-т галимнәренең Тын океан утраулары, Монголия, Тибет, Кытай сәфәрләреннән алып кайткан көнкүреш әйберләре б-н тулыландырыла. 19 йөз уртасыннан Шәрекъ бүлеге Петербург ун-тына күчерелү сәбәпле, этнография коллекцияләре рус тарихы кафедрасына тапшырыла һәм шуның нигезендә Ватанны өйрәнү музее булдырыла. Ул Россиянең төрле, бигрәк тә Себер һәм күп милләтле Идел буе халыкларының мәдәниятен һәм көнкүрешен чагылдырган этнографик әйберләр өстәлеп тулылануын дәвам итә. 1878 дән Казан ун-ты каршында төзелгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә этнография коллекцияләре булдырыла. 1888 дә ун-тта геогр. һәм этнография каф. ачыла, ул Австралия, Океания, Африка, Төньяк һәм Көньяк Америка халыкларының көнкүрешен өйрәнү әсбаплары сыйфатындагы коллекцияләрне Гамбургта (Германия) Умляуф музееннан сатып ала. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында каф. каршындагы этнография кабинеты Казанда 1890 һәм 1912 дә Бөтенроссия сәнәгать күргәзмәсен оештыру һәм үткәрү вакытында Идел буе терр-ясендә җыелган әйберләр б-н тулыландырыла. 1913 тә эшләп килгән музейлар проф. Б.Ф.Адлер җитәкчелегендәге музейга берләштерелә. Аның өчен күмәкләшеп махсус бина җиһазландырыла, анда барлык периметр буенча экспозиция шкафлары эшләнә. Б.Ф.Адлер ун-ттан киткәннән соң, 1922 дә туплау эше туктатыла, бары тик коллекцияләрне саклау дәвам итә. 1946 дан Н.И.Воробьев җитәкчелегендәге К.у.э.м. эшчәнлеге яңадан торгызыла. 1960 ның урталарыннан этнография музее этнография һәм археол. каф. лаборантлары карамагында була. Музей Казан ун-тының төп бинасының көнбатыш ягындагы икенче катта урнашкан. Хәзерге экспозиция мәйданы — 280 $м^2$, фондында 5 меңнән артык саклау берәмлеге бар. Экспозициянең фәнни концепциясе авторы — О.А.Масалова, рәссамы — В.А.Ткаченко.

Музей директорлары: И.Т.Щербакова (1999–2000), О.А.Масалова (2000 дән).

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ЭШЧЕЛӘ́Р ФАКУЛЬТЕТЫ́**, 1919 елның 1 ноябрендә ачыла. Гомуми һәм милли (татар, мари, чуаш, удмурт) бүлекләрдән тора. Беренче елларда уку срогы — индивидуаль, 1931 дән — 3 ел, милли бүлекләрдә 4 ел итеп билгеләнә. 1920 елларда укыту гомуми программа буенча алып барыла, бу факультетны тәмамлаучылар төрле югары уку йортларына укырга керә ала. 1930 дан укучыларны максатлы юнәлештә Казан ун-тының аерым ф-тларына һәм аерым белгечлекләр буенча укырга керергә әзерлиләр. 1928 дә татар бүлегеннән тыш милли бүлекләр, шул республикаларда эшчеләр ф-тлары ачылу сәбәпле, ябылалар. 1931 дә көндезге бүлек Чистайга күчерелә, Казанда кичке бүлек кала. 1936 да К.у.э.ф.на кабул итү туктатыла, 1938 дә Казан бүлеге, 1939 да Чистай бүлеге ябыла. Эшләү елларында югары уку йортларына якынча 1800 кеше, ш.и. якынча 40% эшчеләрдән, 50% крәстияннәрдән, 26% татарлар арасыннан әзерләнә. 1925–36 елларда ун-т студентларының 30 дан 40% ка кадәрен эшчеләр ф-тын тәмамлаучылар тәшкил итә. Алар арасында галим-геолог Б.М.Йосыпов, селекция белгече Х.Х.Байчурова, язучы А.Ш.Шамов бар.

*Әд.:* Морозова С.В. Роль рабочих факультетов в подготовке кадров национальной интеллигенции (на материалах рабфака Казанского университета) // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1973. Вып. 118; Из истории рабфака Казанского университета. К., 1976.

**КАЗА́Н УНИВЕРСИТЕТЫНЫ́Ң ЯҢА́ КЛИ́НИКАЛАРЫ** (архит-ра комплексы). 1896–1901 елларда арх. К.М.Быковский проекты буенча арх. И.Н.Колмаков катнашында төзелә. Хәзерге Толстой, Бутлеров, Госпиталь урамнары, Исемсез тыкрык б-н чикләнгән, дөрес булмаган дүртпочмаклы участокта урнашкан. Хирургия, тире-венерология, акушерлык-гинекология, офтальмология һәм балалар авыруларын дәвалау биналарын; адм. һәм лаб. корпусларын, изге Варсонофий Казанлы чиркәвен (акушерлык-гинекология клиникасына кушып салына) үз эченә ала. К.М.Быковский проектлаган терапия һәм неврология клиникалары биналары, хезмәткәрләр өчен торак йорт төзелми кала, чиркәү К.М.Быковский проекты урынына И.Н.Колмаков проекты буенча, тагын да масштаблырак итеп, сәүдәгәр И.И.Алафузов акчасына төзелә. Клиника биналары яшел зона итеп файдаланылган эчке ишегалды периметры буенча урнашкан. Проектлау вакытында корылмаларны ирекле урнаштыру принцибы кулланыла, бу исә ансамбльгә үзенчәлекле, кабатланмас ямь бирә. Биналар симметриясез, төзелешнең кызыл сызыгыннан беркадәр эчкәрәк кертеп урнаштырыла.

Һәр бинаны планлаштырганда анда нинди клиника урнаштырылачагы алдан билгеләнә. Төгәл функциональ зоналарга бүлү ш.у. фасадларның симметриясез композицияләрендә дә сизелә: үзәктәге ял итү һәм вестибюль зоналары махсус блоклар б-н аерыла (тире-венерология клиникасы) яки участокның бер ягына куела (хирургия клиникасы). Һәр бинаның кабатланмас фәзаи күләмле композициясе бар, аларны төзү өчен архитекторлар берничә төрле күләмдәге, биеклеге һәм формасы буенча төрле, зур булмаган блокларны берләштергәннәр. Барлык биналар тышкы яктан штукатурасыз, кызыл кирпечтән төзелгән, бердәй стильле, архит-ра-бизәкләү элементлары еш кабатлана: стильләшкән пилястралар аркалы һәм киль рәвешендәге төрле куышлар, баскычсыман элементлар б-н бизәлгән; беренче катлары рустланган, баскыч рәвешендә төгәлләнгән; уксыман тәрәзә уемнары уксыман тоташтырмалар һәм тәрәзә асларындагы Т-рәвешле баскычсыман элементлар б-н баетылган; кат арасындагы борыслар — «тешләр», кәрнизләр стильләшкән консольләр һәм сталактитлар б-н бизәлгән; икенче каттагы үзәк вестибюль аркалы уемнар б-н аерылып тора, ике кыеклы түбә б-н төгәлләнгән (хирургия һәм тире-венерология клиникалары). Һәр бина бизәлешендә үзенчәлекле, башка корылмаларда кабатланмаган элементлар бар, мәс., акушерлык-гинекология клиникасы бинасындагы эркер һәм ярдәмче баскычлары булган манаралар. Комплексның төп биналары эклектиканың кирпеч стилендә, 19 йөз уртасында Бөекбританиядә төзелгән «кызыл кирпечле» ун-т комплекслары йогынтысында проектлаштырылганнар. Клиника чиркәве рус-византия стилендә, туры сызыклы композиция буенча төзелгән һәм бер катлы ашханәдән, почмаклары киселгән һәм зур булмаган апсидалы төп залдан тора. Төп залны беренче катта ике турыпочмаклы тәрәзә, икенче катта киль рәвешендәге аркалы тәрәзә яктырта. Бина зур булмаган сугансыман гөмбәз б-н төгәлләнгән. Ашханә диварларына киль рәвешендәге куышлар һәм хачсыман элементлар б-н бизәлгән киң, вертикаль чыгынтылар урнаштырылган. Алар арасына а́ркалы тәрәзәләр уелган, кильсыман архивольт шуларга таяна. Тәрәзәләр ике яктан колонналар б-н бизәлгән. Биналар Казан мед. ун-ты клиникалары буларак файдаланыла, элекке хирургия клиникасында нефрология кафедрасы урнашкан. Клиника чиркәве 2010 елда яңадан эшли башлый.

*Е.В.Липаков, Л.М.Мортазина.*

**КАЗА́Н УТАРЛАРЫ́** (Казан дачалары), 1) Казан воеводасы карары б-н дәүләт хезмәтендәге кешеләргә бүлеп бирелгән җир-утарлар; 2) Казан сарай идарәханәсе тарафыннан йомышлы кешегә утар биләргә рөхсәт бирү грамотасы; 3) утарга бирелгән чәчүлек җирләре, печәнлек һ.б. файдалы җирләр тасвирланган теркәү кенәгәсе.

*Әд.:* Каштанов С.М. Земельно-иммунитетная политика Русского правительства в Казанском крае в 50-х годах XVI века (по актовому материа-




**«Казан утлары» мәкаләсенә.** Журналлар: 1–2. «Безнең юл»; 3. «Атака»; 4. «Яңалиф»; 5–6. «Совет әдәбияты»; 7–8. «Казан утлары».

лу) // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1970. Вып. 80; Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов. К., 1978.

*Д.Г.Мостафина.*

**«КАЗА́Н УТЛАРЫ́»**, айлык әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси журнал. Оештыручысы — «Татмедиа» ААҖ. 1922 елның маеннан татар телендә Казанда нәшер ителә. 1930 га кадәр «Безнең юл» исеме б-н басыла; 1930 да журнал бүленә (1930–32 дә 2 журнал чыга: «*Атака*» — Татар пролетар язучылары ассоциациясе органы; «*Яңалиф*» — ТАССР Мәгариф халык комис-ты һәм Татар совет язучылары җәмгыяте органы); 1933 тән «Совет әдәбияты» исемен ала, 1965 тән — «Казан утлары». ТАССР ҮБК һәм ХКС органы буларак чыга башлый, 1923 нең мартыннан ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы була, 1925 тән ул — РКБ(б)ның Татарстан өлкә ком-ты агитация һәм пропаганда бүлеге, 1928 дән — Татар мәдәният йорты, 1934 тән — ТАССР Язучылар берлеге органы. Язучылар берлеге оешканга кадәр (1934) журнал татар әдипләрен, журналистларын һәм галимнәрен берләштерүче үзәк булып тора. Журнал чыга башлаган еллардан алып, анда әдәби әсәрләр өстенлек итә. Гарәп графикасында басылган «Безнең юл» ж-лы укучыларны К.Әмири, Г.Газиз, М.Гафури, Ш.Камал, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Толымбай һ.б. танылган язучыларның әсәрләре б-н таныштыра. Редакция ш.у. М.Әмир, Ә.Фәхри, М.Җәлил, Г.Кутуй, М.Максуд, К.Нәҗми, Һ.Такташ, Х.Туфан, Ш.Усманов, Д.Фәтхи кебек яшь авторларның прозасы һәм поэзиясенә дә урын бирә. Журнал битләрендә үзләренең мәкаләләре б-н Ф.Бурнаш, Г.Гали, Г.Ибраһимов, Г.Нигъмәти, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, Г.Толымбай һ.б. күренекле әдипләр, әдәби тәнкыйтьчеләр һәм сәнгать белгечләре чыгыш ясый. Театр, рәсем һәм музыка сәнгате үсешенә һәм татар мәдәнияте тарихын өйрәнүгә кагылышлы мәсьәләләр, башлыча, шушы журналда яктыртыла. Язучылар берлеген оештыру буенча ком-т төзелгәннән соң, 1933 тә «Атака» һәм «Яңалиф» урынына, Берлек органы буларак, «Совет әдәбияты» ж-лы чыга башлый. Редакция аны әдәбият, сәнгать, тәнкыйть һәм публицистика журналы сыйфатында тәкъдим итә, 1948 дән ул әдәби һәм иҗтимагый-сәяси басмага әверелә. 1939 га кадәр латин графикасында басыла. Беренче көннәрендә үк журнал социалистик реализм методы үсешенә зур игътибар юнәлтә, ТАССР Язучылар берлегенең 1 нче съезды материалларын бастыра. Бу чорда Г.Гали, Г.Кашшаф, Г.Нигъмәти, К.Тинчурин, Х.Хәйри актив языша. Г.Бәширов, А.Әхмәт, Г.Галиев һ.б.ның күпсанлы мәкаләләре татар авылы тормышына багышлана. Бөек Ватан сугышы елларында журнал укучыларны фронтовик язучылар һәм журналистларның язмалары б-н таныштырып бара. Сугыш тәмамлангач та, аңа багышланган күләмле әсәрләрне бастыруны дәвам итә: Г.Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Газинур» романнары, «Ак төннәр» повесте, М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ннән шигырьләр, Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» повесте, Ш.Маннурның «Муса» романы, С.Хәким, З.Нури поэмалары һ.б. дөнья күрә. Журналда басылган әсәрләрдән Г.Бәшировның «Намус», К.Нәҗминең «Язгы җилләр», И.Газиның «Онытылмас еллар», Г.Гобәйнең «Без үскәндә», М.Әмирнең «Ялантау кешеләре», «Саф күңел», Ә.Еникинең «Йөрәк сере», Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек ут», Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Г.Ахуновның «Хәзинә», А.Расихның «Ике буйдак» әсәрләре һәм Х.Вахит пьесалары, Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арсланов һ.б.ның поэмалары, шигырьләре сугыштан соң илне

төзекләндерү, гади эшчеләрнең хезмәт энтузиазмы, татар халкы тарихының фаҗигале һәм якты сәхифәләренә багышлана. «К.у.» һәрвакыт күренекле һәм яшь татар әдипләренең әсәрләрен, ТРның танылган тәнкыйтьчеләренең һәм журналистларның актуаль аналитик, публицистик мәкаләләрен бастыручы, әйдәп баручы журнал.

Журнал кыен шартларда да татар мәнфәгатьләрен яклау, халыкның милли аңын үстерү юлын эзли. Р.Сабировның «Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык» (1922), Г.Алпарның «Латин түгел, гарәп» (1926) мәкаләләре, ВКП(б) Үзәк ком-тын 1944 елда махсус карар чыгарырга этәргән «Идегәй» дастаны (Н.Исәнбәт җыйнамасы, 1940), Н.Фәттахның «Әтил суы ака торур» тарихи романы (1970) шушы басмада чыга. 1990 нчы елларда журналда Татарстанның мөстәкыйльлеген яклап күп кенә әсәрләр һәм саллы мәкаләләр басыла. 2006 елның февралендә, Россия әдәби журналлары арасында беренче булып, «Казан утлары»ның 1000 нче саны дөнья күрә. Шул уңайдан редакция «Сүнмәс утлар балкышы. Мең санлы хәзинәдән» дигән уникаль антология нәшер итә. Төрле елларда баш мөхәррирләр булып татар әдәбиятының күренекле эшлеклеләре — Г.Мансуров, М.Борындыков, Ф.*Сәйфи-Казанлы,* Г.*Нигъмәти,* Г.*Гали,* К.*Нәҗми,* Г.*Бәширов,* Г.*Иделле,* Г.*Кашшаф,* А.*Гомәров,* Г.*Мөхәммәтшин,* Р.*Мостафин,* Г.*Ахунов,* З.*Нури,* Р.*Харис,* Р.*Фәйзуллин* (1989 дан) эшли.

*Әд.:* Сафина Р. Журналыбызны кемнәр җитәкләгән? // Казан утлары. 1992. № 5; Мәрдиева М. Рухи тормыш көзгесе // Тонус. 1996. № 1; Фәйзуллин Р. Бу гасырда да балкыр! // Казан утлары. 2002. № 5.

*Р.А.Айнетдинов.*

**КАЗА́Н ҮЗӘ́К КЕРӘШЕ́Н ТАТА́Р МӘКТӘБЕ́**, миссионер һәм педагогик уку йорты. 1863 елда *Казан руханилар академиясенең* татар теле практиканты В.Т.*Тимофеев* керәшен татарларның балаларын укыта башлый. Рәсми рәвештә мәктәп 1864 нең 3 сентябрендә Н.И.Ильминскийның тырышлыгы б-н, шәхси уку йорты буларак, 1864 елгы башлангыч халык уч-щеләре турындагы Нигезләмәгә туры китереп ачыла. 1878 — дән Халык мәгарифе министрлыгының ике класслы уч-щеләре, 1899 дан *ике класслы мәктәпләр* программасы буенча эшли. Мәктәп дәүләтнеке булмый, ләкин укытучыларга 1881 дән, бу министрлыкның хезмәткәре буларак, пенсия һәм дәрәҗәсе (чины) буенча эшләгән хезмәт еллары өчен түләү карала. 1867 дән мәктәпне *Изге Гурий борадәрлеге* финанслый. Мәктәпнең попечителе сәүдәгәр П.В.*Щетинкин* зур ярдәм күрсәтә (1871–1917). Беренче елларда укый-яза белмәүче балалар кабул ителә, 1871 дән Казан, Вятка, Уфа, Оренбург губерналарыннан миссионерлык башлангыч мәктәпләрен яхшы тәмамлаучылар алына. Укучылар арасында керәшен татарлардан кала татар телен белүче удмурт, мари, чуашлар була. Ир балалар мәктәбе итеп раслана, ләкин анда башыннан ук кыз балалар да укый. 1874 тә кыз балалар бүлеге ачыла, дәресләр, нигездә, бергә уздырыла. Казан губернасыннан булган укучылар түләүсез, калганнары земство һәм *Православие миссионерлык җәмгыяте* стипендиясенә укый.

Уку срогы 3–5 ел, укучының әзерлек дәрәҗәсенә карап билгеләнә. Мәктәптә үзенә бертөрле «фәннәргә бүленмәгән» укыту системасы барлыкка килә. Төп дәресләр укытучы җитәкчелегендә, рус китапларын җентекләп уку һәм тикшерү формасында бара, әсәрләр татар теленә тәрҗемә ителә. Илаһи Канун (Закон Божий), рус һәм татар телләре, әдәбияты укытыла, тарих һәм география буенча башлангыч мәгълүмат бирелә. Арифметика буенча аерым дәресләр үткәрелә. 19 йөз ахырында гадәти класслар-фәннәр системасы кертелә. Мәктәпнең директорлары: В.Т.Тимофеев (1863–95), Т.Е.Егоров (1895–1917). Укытучылар коллективының нигезен иң яхшы авыл укытучылары арасыннан сайлап алынып, шушы мәктәпне тәмамлаучылар тәшкил итә. Казан руханилар академиясен тәмамлаучылар өлкән сыйныфларда дин белемен һәм изге тарихны укыталар. Татар һәм славян телләрендә чиркәүдә җырлауга һәм музыкага зур урын бирелә. Мәктәп *Ильминский системасының* беренче уку йорты һәм «сынау кыры» була.

1867 дән мәктәпне тәмамлаучылар, укытучы итеп, борадәрлек һәм миссионерлык мәктәпләренә җибәреләләр.

1870 еллар уртасыннан яшүсмерләр *Казан укытучылар семинариясенең* 3 нче сыйныфына укырга керәләр, кыз балалар укытучылыкка экстерн рәвештә имтиханга әзерләнәләр. Мәктәпне тәмамлаучыларның күпчелеге мед., техн., җир үлчәү һ.б. махсус уку йортларына керә.

1913 елга мәктәпне 2 меңнән артык кеше тәмамлый, 896 сы — укытучы, 242 се — берничә ел пед. эшчәнлектән соң дин әһеле, ш.и. 80 нән артыгы рухани булып китә; 4 се Казан руханилар академиясен тәмамлый.

Мәктәпне тәмамлаучылар арасында дин эшлеклесе Иннокентий (Никифоров), шагыйрьләр Я.Е.Емельянов, Д.С.Аппакова, медицина галиме В.А.Кибяков, икътисадчы А.П.Харитонов, педагоглар В.М.Горохов, И.С.Михеев, Н.С.Соловьёв, мордва мәгърифәтчесе А.Ф.Юртов, хакимият-хуҗалык эшлеклеләре Н.В.Петров, И.М.Шпаков, Бөек Ватан сугышы геройлары П.М.Гаврилов, А.Г.Новиков, А.Е.Яковлев һ.б. бар.

1866–71 дә П.В.Щетинкин һәм башка сәүдәгәрләр иганәсенә 11 бинадан торган шәһәрчек төзелә. Төп уку бинасы сакланган (хәзер Ершов урамы).

1918 дә мәктәп Керәшен пед. курслары итеп үзгәртелә, 1921 дә мәктәп җирлегендә Керәшен пед. техникумы оештырыла.

*Әд.:* Казанская центральная крещёно-татарская школа: Материалы для истории христианского просвещения крещёных татар. К., 1887; Воскресенский А.А. Николай Иванович Ильминский о системе просвещения инородцев в Казанской центральной крещёно-татарской школе. К., 1913; Глухов-Ногайбек М.С. Судьба гвардейцев Сююмбеки. К., 1993; Исхакова Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001.

*Р.Р.Исхакова.*

**КАЗА́Н ҮЗӘ́К ТЕЛЕГРАФЫ́**, к. *Телеграф.*

**КАЗА́Н ФАРМАЦЕ́ВТИКА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, к. *Казан медицина-фармацевтика училищесе.*

**КАЗА́Н ФӘННИ́ МӘКТӘПЛӘРЕ́**, фәндә төп карашларның берлеге, принцип һәм алымнарның уртаклыгы яки буыннан-буынга күчеше б-н бәйле булган юнәлешләр.

19 йөздә Казан ун-тында формалаша башлый. Беренчеләрдән булып, Н.И.*Лобачевский* хезмәтләрен нигез итеп алган Казан фәнни геометрия мәктәбе булдырыла. Иң билгеле фәнни мәктәпләр: *Казан астрономия фәнни мәктәбе, Казан ветеринария фәнни мәктәбе, Казан геология фәнни мәктәбе, Казан геометрия фәнни мәктәбе, Казан геоморфология фәнни мәктәбе,* Казан зоология фәнни мәктәбе (к. *Зоология*), *Казан лингвистика фәнни мәктәбе, Казан медицина фәнни мәктәбе, Казан метеорология фәнни мәктәбе,* Казан үсемлекләрнең су режимы фәнни мәктәбе (к. *Үсемлекләрнең су режимы*), *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбе,* Казан физиология фәнни мәктәбе (к. *Кеше һәм хайваннар физиологиясе*), *Казан химия фәнни мәктәбе.*

**КАЗА́Н ФӘННИ́-ҖИТЕШТЕРҮ́ ПРЕДПРИЯ́ТИЕСЕ**, В.И.Ленин исемендә, к. *Казан дары заводы.*

**КАЗА́Н (ИДЕ́Л БУЕ́) ФЕДЕРА́ЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ́ (КФУ)**. РФ хөкүмәтенең 2010 елның 2 апрелендәге карары б-н *Казан университетының, Татар гуманитар-педагогия университетының, Казан финанс-икътисад институтының, Алабуга педагогия университетының,* 2012 дән *Кама инженерлар-икътисади академисенең* профессорлар-укытучылар коллективын, студентларын, матди базаларын берләштерү юлы б-н Казан ун-ты җирлегендә оештырыла.

2012 ел башына КФУ составында: Экология һәм география ин-ты, Геология һәм нефть-газ технологияләре ин-ты, Тарих ин-ты, Н.И.Лобачевский исем. математика һәм механика ин-ты, Физика ин-ты, А.М.Бутлеров исем. химия ин-ты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмат технологияләре ин-ты, Филология һәм сәнгать ин-ты (татар, рус, роман-герман филологиясе, чит телләр укытучылары, музыка һәм сынлы сәнгать буенча белгечләр әзерли), Идарә итү һәм территориаль үсеш ин-ты (Казан ун-тының элеккеге икътисад ф-ты җирлегендә булдырыла), Икътисад һәм финанс ин-ты (элекке Казан финанс-икътисад ин-ты), Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр ин-ты, Педагогика һәм психология ин-ты (мәктәпкәчә учреждениеләр өчен психологлар, педагоглар, дефектологлар, башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар әзерли); юридик, биология-туфрак, журналистика һәм социология, филология ф-тлары эшли; ун-т ф-ллары Алабуга, Яшел Үзән, Чаллы шәһәрләрендә бар. КФУ составына ш.у. *Чеботарёв Н.Г. исемендәге математика һәм механика институты* керә.

2011 ел ахырына ун-тның барлык бүлекчәләрендә 30 меңнән артык студент, ш.и. ф-лларда 7,8 мең. студент, 1200 аспирант укый. Укытучылар коллективында 2662 кеше эшли. Ректоры — И.Р.Гафуров (2010 нан).

**КАЗА́Н ФЕТНӘСЕ́**, 1863 елның язында Идел буенда крәстияннәрнең баш күтәрүен оештыру омтылышы. 1863 нең гыйнварында поляк азатлык хәрәкәте әгъзасы И.Ф.Кеневич Вильно баш күтәрү ком-тына Идел буенда чыгышлар оештыру тәкъдиме б-н мөрәҗәгать итә. Максаты — Россиянең хәрби көчләрен поляк халкы күтәрелешеннән читкә җәлеп итү була. Кеневич планы Вильно ком-ты әгъзаларының бер өлеше, Польшадагы рус офицерлары ком-ты, «Җир һәм ирек» («Земля и воля») революцион оешмасының Мәскәү ком-ты тарафыннан хуплана, ләкин «Җир һәм ирек» ҮК аны кире кага. 1863 нең мартында Кеневич кушуы буенча Казанга М.А.Черняк килә. Ул К.ф.нә Казан губернасында хәрби хезмәттә булган поляк офицерлары Н.К.Иваницкий, Р.И.Станкевич, А.Е.Мрочекны җәлеп итә. «Җир һәм ирек»нең Казан ком-ты вәкилләре И.М.Краснопёров, В.М.Полиновский һ.б. б-н элемтә урнаштырыла. Алар б-н сөйләшүләр вакытында күтәрелеш планнары тикшерелә. Баштарак Казанны кулга төшерү һәм крәстияннәрне коралландыру күздә тотыла. Ләкин студент И.Глассон тарафыннан фетнә турында искәртелгән хакимиятләр шәһәрне саклауны көчәйтәләр. Мрочек тәкъдим иткән башка план буенча Казан губернасы авылларында баш күтәрү, Ижевск з-дындагы коралларны басып алу күздә тотыла. Крәстияннәрне күтәрелешкә җәлеп итү өчен ялган патша манифесты әзерләнә, анда Россиянең барлык подданныйларына ирек, крәстияннәргә һичнинди түләүсез җир бирелүе белдерелә. К.ф.ндә катнашучылар арасында бердәмлек булмый. «Җир һәм ирек»нең Казан ком-ты вәкилләре ялган манифестны таратудан баш тарталар, агитация алып бару өчен «Туганнар, сезне бик озак изделәр» («Долго давили вас, братцы») прокламациясен файдаланырга тәкъдим итәләр. Анда К.ф.ндә катнашучыларның башкалары алга сөргән идеяләр (кичекмәстән баш күтәрү, патша исемен куллану) урынына «патша сүзенә» ышанмаска, «барысы да изге эш, азатлык хакына күтәрелергә әзер булгач» оешкан төстә күтәрелеп чыгу турында өндәмәләр яңгырый. 1863 нең апрель ахыры — май башында К.ф.ндә катнашучылар кулга алына. 40 кеше тикшерүгә тартыла. Фетнәдә төп катнашучылар — И.Ф.Кеневич, М.А.Черняк, Н.К.Иваницкий, А.Е.Мрочек, Р.И.Станкевич Казанда җәзалап үтерелә. Башкалар (И.М.Краснопёров, В.М.Полиновский, С.Я.*Жеманов*, К.В.*Лаврский*, М.К.*Элпидин* һ.б.) төрле срокларга каторгага хөкем ителә.

*Әд.:* К о з ь м и н Б.П. Казанский заговор 1863г. М., 1929; В у л ь ф с о н Г.Н. Разночинно-демократическое движение в Поволжье и на Урале в годы первой революционной ситуации К., 1974; В у л ь ф с о н Г.Н., Н у р е е в а Ф.Ф. Братья по духу: Питомцы Казанского университета в освободительном движении 1840–1870-х гг. К.,1989.

**КАЗА́Н ФИ́ЗИКА-МАТЕМА́ТИКА ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1890 елда Казан ун-ты каршындагы Табигатьне өйрәнүчеләр җәмгыятенең физика-матем. секциясе базасында төзелә. Җәмгыятьнең уставы Россиянең көнчыгыш өлешендә физика-матем. гыйлемен таратуны, фәнни хезмәтләрне цензура тикшерүенә кадәр үк бастырып чыгаруны («Известия физико-математического общества» ж-лы.), бүләкләр, премияләр билгеләү хокукын күздә тота. К.ф.-м.җ. әгъзалары арасында Россиянең күп кенә башка шәһәрләреннән дә галимнәр була. Аның беренче рәисе — проф. А.В.*Васильев*, ул эшләгән чорда җәмгыять, үз хезмәтләре һәм басмаларына алмашып, физика-матем. фәннәре буенча периодик әдәбият ала, Европа, Азия, Америка һәм Австралиянең фәнни үзәкләреннән түләүсез 90 лап периодик басма алдыра.

Җәмгыять Россиядә һәм чит илләрдә Н.И.*Лобачевский* идеяләрен тарату буенча чараларда катнаша. 1893 нең 22–24 октябрендә Казан ун-ты һәм К.ф.-м.җ. тантаналы төстә галимнең 100 еллыгын үткәрә. Казан шәһәр думасының соравы буенча, ун-т урнашкан урамга һәм аның алдындагы скверга галимнең исеме бирелә. 1896 ның 1 сентябрендә ун-тның актлар залында Н.И.Лобачевскийның бюсты (скульпторы М.Л.Диллон) урнаштырыла. *Лобачевский Н.И. исемендәге халыкара бүләк* өчен 3 елга бер тапкыр халыкара конкурслар үткәрү турында карар кабул ителә.

Окт. рев-циясеннән соң җәмгыятьнең рәисе Н.Н.*Парфентьев* һәм әгъзалары А.П.*Котельников*, Д.Н.*Зейлигер*, П.А.*Широков*, Н.Г.*Чеботарев*, В.А.*Яблоков* тырышлыгы б-н 7 нче (1927) һәм 8 нче (1937) халыкара конкурслар үткәрелә. 1943 тә Казан ун-ты СССР ФАнең Математика бүлеге б-н берлектә, Н.И.Лобачевскийның тууына 150 ел тулуга багышлап, юбилей конференциясен оештыра. Юбилейны уздыруда Н.Г.Чеботарев, П.А.Широков, Б.Л.Лаптев актив катнаша. Бөек Ватан сугышыннан соң К.ф.-м.җ. үз эшен дәвам иттерә. Казан һәм илнең башка фәнни үзәкләре галимнәренең докладлары тыңлана. Б.Л.Лаптев Н.И.Лобачевский истәлегенә багышланган укулар оештыра, укучылар өчен матем. олимпиадалар үткәрелә (башлап йөрүче В.В.*Морозов*), 1946–51 дә җәмгыять әгъзаларының актив тырышлыгы б-н Н.И.Лобачевский хезмәтләренең тулы җыентыгы (5 томда) нәшер ителә. 1949 да «Известия физико-математического общества» ж-лының соңгы томы чыгарыла һәм ул бер үк вакытта «Учёные записки Казанского университета» басмасының 109 нчы томының 4 нче китабы була. Журнал фәннең төрле бүлекләре буенча тематик җыентыклар б-н алыштырыла. 1950 дән җәмгыять б-н А.П.*Норден* җитәкчелек итә. 1951 дә Казан ун-ты һәм К.ф.-м.җ. Н.И.Лобачевский тарафыннан нәевклид геометрия ачылуның 125 еллыгын билгеләп үтә. 1970 елларда җәмгыятьнең эшчәнлеге туктала, аның җирлегендә Казан физика (1989) һәм Казан математика (1992) җәмгыятьләре оеша.

*Әд.:* Собрание протоколов секции физико-математических наук Общества естествоиспытателей Казанского университета. К., 1890. Т. 8; Празднование 125-летия открытия неевклидовой геометрии. К., 1952; История отечественной математики. Киев, 1967. Т. 2; И з о т о в Г.Е. Казанское физико-математическое общество. К., 2003.

*Г.Е.Изотов.*

**КАЗА́Н ФИ́ЗИКА-ТЕ́ХНИКА ИНСТИТУТЫ́** (КФТИ), Е.К.З а в о й с к и й и с е м е н д ә, 1945 елның августында СССР ФАнең Казан ф-лы составында оештырыла (1963 тән СССР ФА, 1973 тән СССР ФА Казан ф-лы, 1990 елдан СССР ФА КГҮ, 1991 дән РФА КГҮ составында), 1984 елдан Е.К.Завойский исемендә. Институтның беренче директоры итеп СССР ФАнең мөхбир әгъзасы Н.Г.Чеботарёв билгеләнә.

Башта ин-т СССР ФА Казан ф-лы бинасында (Лобачевский урамы) урнаша, 1971 дән ин-тның төп өлеше аерым бинага (Себер тракты урамы) урнаштырыла.



РФА КГҮ Казан физика-техника институты.

Институт составында 4 сектор — матем. (сектор мөдире Н.Г.Чеботарёв), астрономия һәм геофизика (А.Д.Дубяго), физика (Е.К.Завойский), механика (Х.М.Мөштәри) секторлары оештырыла. 1951 дә астрономия һәм геофизика секторы ябыла.

КФТИдагы физика тикшеренүләренең уңышлы үсешенә Казан ун-тында Е.К.Завойский тарафыннан *электрон парамагнит резонансы* (ЭПР) күренешенең ачылуы (1944) зур этәргеч бирә. Галим 1947 нең көзенә кадәр КФТИның физика секторы б-н җитәкчелек итә, эшчәнлекнең төп юнәлеше сыйфатында куе тирәлекләрне радиоспектроскопия алымнары б-н өйрәнүне билгели.

Радиоспектроскопия өлкәсендә КФТИ галимнәре тарафыннан ирекле радикалларда ЭПР күренеше ачыла (Б.М.Козырев, С.Г.Салихов, 1947), ЭПР спектрларында үтә нечкә тәэсир итешүләр барлыгы ачыклана (С.А.Альтшулер, Б.М.Козырев, С.Г.Салихов, 1948), $^{57}$Fe изотобы төшенең спины билгеләнә (Б.М.Козырев, Н.С.Гарифьянов, М.М.Зарипов, 1957).

1960 еллар башында, ин-т хезмәткәрләре У.Х.Копвиллем һәм В.Р.Нагибаров *яктылык кайтавазы* күренешен фаразлаганнан соң, КФТИда оптик когерент күренешләр һәм квант акустикасы өлкәсендә тикшеренүләр уңышлы җәелдерелә. 1970 тә А.Р.Кессель һәм И.А.Сафин *полярлашкан кайтаваз* күренешен ачалар. Башка казанышлар арасында — күпканаллы *фотон кайтавазы* сигналларын алу һәм антиферромагнетикларда гаять көчле магнитик акустика эффектын ачу һәм теоретик тасвирлау.

Фәнни-тикшеренү ин-тының мөһим юнәлеше булып ярымүткәргечләрнең ионлы һәм лазерлы модификацияләренә таянып, мик-

роэлектрониканың физик нигезләрен эшләү тора. И.Б.Хәйбуллин, Е.И.Штырков, М.М.Зарипов, М.Ф.Галәветдинов һәм Р.М.Баязитов тарафыннан тәртибе үзгәргән ярымүткәргечләрнең импульслы рекристаллашуы күренеше ачыла (1973), бу күренеш *лазер нурында чыныктыру* буларак танылу ала. Ярымүткәргечләр өлкәсендә яңа фазаларның субмикронлы элпәләрен ион нурланышлы синтезлау алымнары үстерелә, ярымүткәргечләрдә электрик актив катнашмалар иң югары концентрациядә булган катламнар ясауның яңа ион импульслы алымнары, ш.у. адгезияне ионлы-индукцияле күтәрүнең һәм оптик материаллар модификацияләүнең яңа юллары эшләнә.

1950 еллардан башлап күзәнәкле тирәлектә сыеклыкларны фильтрлау теориясе матем. секторының фәнни юнәлешенә әверелә. Басым куучы һәм нефть чыгаручы скважиналар эшләгән вакытта нефть бирүчән контурны билгеләүнең аналитик һәм санлы алымнары эшләнә.

Механика өлкәсендә сүрүләрнең нәсызыкча теориясе буенча фәнни юнәлеш билгеләнә (Х.М.Мөштәри). Эластик һәм эластик-пластик сүрүләр деформациясен тикшерүнең югары нәтиҗәле санлы һәм вариатив алымнары эшләнә, мондый сүрүләрнең тотрыклылыгы буенча күп кенә мәсьәләләр хәл ителә. 1970 елларда аэрогидроэластиклык буенча фәнни юнәлеш формалаша (М.А.Илһамов). Конструкцияләрдәге юка стеналы элементларның сыеклык, газ, эластик тутырыгыч б-н үзара тәэсиренең нәсызыкча теориясе үстерелә. Тикшеренү нәтиҗәләре нефть чыгару сәнәгатендә, авиация, ракета һәм суднолар төзелешендә, химия сәнәгате машиналары төзүдә, каты ягулыклы двигательләр, торба үткәргеч һәм парашют системаларын проектлаштыруда кулланыла. Эшләү дәверендә ин-тның структурасы шактый үзгәрешләр кичерә. Төрле чорларда аның составына төрдәш тематикалы лаб-ләрне берләштергән фәнни лаб-ләр һәм бүлекләр керә. 1989 да җылылык энергетикасы бүлеге төзелә (җитәкчесе В.Е.Алемасов), 1991 дә аның нигезендә СССР ФА КГҮнең ин-т хокукындагы Энергетика бүлеге оештырыла, ә КФТИның фильтрлаштыру процессларын матем. модельләү, тоташ тирәлекләр механикасы, сүрүләр механикасы бүлекләре һәм технол. процессларны модельләү лаб-ясе нигезендә СССР ФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзелеше ин-ты төзелә (1991).

КФТИда 3 бүлек: молекуляр фотохимия, физика һәм өслекләр химиясе лаб-ләре кергән химик физика бүлеге; материалларга радиацион тәэсирләр бүлеге — аңа радиацион физика, интенсив радиацион тәэсирләр, радиацион химия һәм радиобиология лаб-ләре керә; мед. физикасы бүлеге — аңа мед. физикасы алымнары, биофизика лаб-ләре керә. Лабораторияләр: магнитик акустика, диэлектриклар радиоспектроскопиясе, молекуляр радиоспектроскопия, нәсызыкча оптика, перспектив материаллар физикасы, физик-механик процессларны һәм системаларны модельләштерү.

1946 да — китапханә, 1955 тә — матем. секторы каршында хисаплау бюросы, 1960 та — газ сыеклагычларын карап тоту төркеме, 1962 дә эксперименталь остаханә, 1970 тә — монокристаллар үстерү төркеме, 1997 дә телекоммуникацион технологияләр бүлеге оештырыла.





1. КФТИ тарафыннан эшләнгән ТМР-0,06-КФТИ магнит резонанслы медицина томографы; 2. Молекуляр фотохимия лабораториясендә.

Матдәнең куерган халәтен өйрәнү өчен радиоспектроскопия алымнарын куллану тикшеренүләрнең төп юнәлешләреннән берсе булып кала. КФТИда магнит резонансының заманча алымнарын кулланып табылган иң әһәмиятле ачышлар арасында — дөньяда беренче булып магнитлы сыек кристаллар синтезлау һәм тикшерү, үтә үткәргечләрдә электрон спин резонансын һәм үткәрүчәнлек электроннарында спин кайтавазын күзәтү. Гадәти һәм югары температуралы үтә үткәрүчәнлек өлкәсендәге казанышлар, ш.и. $YBa_2Cu_3O_7$ нигезендә югары температуралы үтә үткәргечләрнең гетерогенлыгын ачыклау, критик халәтне тикшерү өчен хәрәкәтчән спин зонды алымын кулланылышка кертү, критик темп-ра б-н халәтләр тыгызлыгының универсаль бәйләнешен билгеләү, күп катламлы үтә үткәргеч-ферромагнетик гетероструктураларын тикшерү дөньякүләм танылу ала. 1998 дән башлап ин-тта химик һәм фотохимик процессларда магнит һәм спин эффектларын теоретик яктан тикшерүләр үсеш ала. К.М.Салихов реакцион фотосинтетик үзәк ЭПРының вакытка бәйле спектрларының аномаль үзлекләрен теоретик яктан фаразлый (квантлар тибеше, «псевдокайтаваз», спин кайтавазы сигналлары фазасының аномальлеге).

КФТИда тикшеренүләрнең яңа юнәлешләре уңышлы үсеш алган: ЭПРны оптик детекторлау, югары ешлыклы ЭПР-спектроскопия, тиз узучан процессларны тикшерергә мөмкинлек бирә торган вакытка бәйле ЭПР алымнар, ТМР- һәм ЭПР-томография, тиз узучан процессларны өйрәнү өчен фемтосекундлы лазер спектроскопиясе; каты җисемнәрнең өслекләрен тикшерү өчен сканирлаучы (төшереп алучы) туннельле, атом-көч һәм магнит микроскопиясе; конструкцияләрдәге көч куелу системаларын ныклыкка сынауны һәм нефть катламнарын фильтрлау динамикасын компьютерда модельләштерү алымнары, яңа физик принципларга нигезләнгән яңа буын мед. приборларын эшләү. Магнит резонансы методлары буенча югары квалификацияле белгечләр әзерләү өчен, КФТИ каршында ин-тның лаб-ләре базасында Радиоспектроскопия үзәге оештырылган (1992).

Институтта эшләнгән гамәли эшләр арасында магнит резонанслы ТМР-0.02-КФТИ һәм ТМР-0.06-КФТИ томографлары бар; алар ТРның үзәк район хастаханәләрен һәм эре диагностик үзәкләрен чагыштырмача арзанлы диагностика аппаратлары б-н тәэмин итә ала.

Ин-т РФАнең фәнни оешмалары, Казан, Мәскәү, Новосибирск ун-тлары, тармак ин-тлары, ГФР, Италия, Польша, Швейцария һ.б. илләрнең фәнни оешмалары б-н тыгыз фәнни бәйләнештә тора. 1994 тә Казанда ЭПР ачылуның 50 еллыгына багышланган халыкара 27 нче «Ampere» конгрессы үткәрелү — Казан галимнәренең магнит резонансы өлкәсендәге казанышларының киң танылуына ачык дәлил. Конгресс эшендә БДБ һәм ерак чит илләрнең 500 ләп галиме катнаша. 1969–90 да КФТИ «Сүрүләр теориясе һәм тоташ тирәлекләр механикасы буенча семинар эшләре» («Труды семинара по истории оболочек и механике сплошных сред») басмасын чыгарып килә.

1990 да «Springer Wien New York» нәшрияты б-н берлектә ин-т, магнит резонансының физикада, химия, биология, медицинада һ.б. кулланылышына багышлап, халыкара фәнни «Applied magnetic resonance» ж-лын нәшер итә.

2001 дән башлап, ин-т «Казанский физико-технический институт имени Е.К.Завойского» дигән еллык басмасын чыгара.

КФТИ тәкъдиме б-н *Завойский Е.К. исемендәге халыкара бүләк* булдырылган, ул, 1991 дән башлап, ел саен магнит резонансы өлкәсендәге тикшеренүләре өчен әйдәп баручы чит ил һәм Россия галимнәренә тапшырыла.

Ин-тта төрле елларда эшләп, КФТИда физик тикшеренүләрне үстерүгә зур өлеш керткән атаклы галимнәр: С.А.Альтшулер, Р.З.Бариев, Б.М.Козырев, Н.С.Гарифьянов, У.Х.Копвиллем, В.Р.Нагибаров, А.И.Ривкинд, И.А.Сафин, Э.Х.Харахашьян.

Ин-тның директорлары: Н.Г.Чеботарев (1945–46), Х.М.Мөштәри (1946–72), М.М.Зарипов (1972–88), К.М.Салихов (1988 дән).

*В.Ф.Тарасов.*


**КАЗА́Н ФИЗИОЛО́ГИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, к. *Физиология.*

**КАЗА́Н ФИНА́НС-ИКЪТИСА́Д ИНСТИТУТЫ́**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының югары уку йорты, РСФСР Үзәк башкарма ком-тының 1931 ел 13 август карарына туры китерелеп, Казан ун-тының 1929 дан эшләп килгән икътисад бүлеге җирлегендә оештырыла. 1936–91 елларда В.В.Куйбышев исемен йөртә. Финанс һәм кредит ф-тлары, рабфак (1939 га кадәр) эшләп килә. Бөек Ватан сугышы елларында вакытлыча эвакуацияләнгән Ленинград финанс-икътисад ин-тының пед. ф-ты б-н берләштерелә; СССР ФАнең 1 академигы һәм 14 мөхбир әгъзасы (И.А.Трахтенберг, А.М.Ляндо һ.б.) укыта. 1946 да ин-тны Финанс министрлыгыннан РСФСРның Югары һәм урта махсус белем бирү министрлыгына тапшыру кадрлар әзерләү юнәлешләрен киңәйтергә булышлык итә. 1946 да халык хуҗалыгының төрле тармаклары өчен икътисадчылар әзерли торган хисап-икътисад ф-ты (хәзерге гомум икътисади ф-т) ачыла; элек эшләп килгән ф-тлар финанс-кредит ф-тына берләштерелә. 1955 тә — читтән торып уку ф-ты, 1966 да сәнәгатьне планлаштыру ф-ты (хәзерге пр-тиеләр икътисады ф-ты) ачыла. 1990 еллар уртасыннан менеджерлар әзерләү башлана, 2003 тә менеджмент ф-ты ачыла. Институт составында дистанцион укыту, югары белемле кадрларны яңадан әзерләү ф-тлары, финанс-кредит даирәсе эшчеләренең, дәүләт һәм идарә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, икътисади белем бирү, аудиторлар, кризиска каршы идарә һәм банкротлык буенча белгечләр әзерләү үзәкләре, хисапчыларны аттестацияләү буенча укыту-методик үзәк эшли. 2011 дә укыту финанс һәм кредит, хезмәт икътисады, бухгалтерлык исәбе, кризиска каршы идарә, оешма менеджменты, маркетинг, персонал б-н идарә итү белгечлекләре буенча алып барыла; көндезге бүлектә — 3290 га якын, кичкедә 2300 студент укый.

2010 да ин-тта 21 кафедра, 300 гә якын укытучы, ш.и. 26 фән. д-ры, алар арасында ТР ФАнең мөхбир әгъзасы В.В.Иванов, фән д-рлары, профессорлар: С.Н.Абдуллина, К.И.Азизов, С.И.Андреев, Й.И.Әҗимов, А.И.Банников, Ш.М.Вәлитов, К.М.Гарифуллин, Ф.С.Зыятдинов, В.Б.Ивашкевич, В.А.Мальгин, И.Ш.Рахманкулов, Н.М.Сабитова, М.Р.Сафиуллин, Э.Р.Таһиров, Н.М.Якупова; ш.у. 178 фән. канд-ты эшли. Кафедраларда һәм лаб-яләрдә икътисади фәннең төрле юнәлешләре, ш.у. социология, философия, тарих буенча фәнни эш алып барыла.

7 белгечлек буенча — аспирантура, 3 белгечлектә докторантура (барысы 90 га якын аспирант), докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрен яклау буенча 2 совет эшли. 39 меңнән артык белгеч әзерләнә. Чыгарылыш студентлары арасында — атаклы галим-икътисадчылар Л.П.Блинов, И.А.Бахтин, М.Ф.Лучинский, Ф.Г.Хәмидуллин, дәүләт эшлеклеләре М.Җ.*Азизов*, С.Г.*Батыев*, икътисад учреждениеләре җитәкчеләре В.П.*Бухина*, Е.Б.*Богачёв* һ.б. бар.

Институтның төп корпусы 1937–41 елларда арх. Ю.Ю.Савицкий проекты буенча төзелгән, архит-ра истәлеге булып тора. 1970–80 елларда 2 уку корпусы, 2 тулай торак, ял базасы корыла. Институт «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә. 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-ты составында.




Казан финанс-икътисад институты.

Институтның директорлары һәм ректорлары: Ш.Х.Сакаев (1931), Г.Х.Әбделмәнов (1932–33), Л.А.Вашеров (1933–35), В.М.Стам (1935–38), А.Д.Арнаутов (1938–41), И.Д.Тихомиров (1941–47), П.Ф.Бунин (1947–57), В.Ф.Павленко (1957), П.В.*Абрамов* (1957–62), С.А.Люшин (1962–72), Н.З.Җәләлетдинов (1972–80), Ф.Г.*Хәмидуллин* (1980–90), Н.Г.*Хәйруллин* (1990-2007), Ш.М.*Вәлитов* (2007–11).

*Әд.:* Казанский финансово-экономический институт имени В.В.Куйбышева. 1931–1981: Очерки истории. К., 1981.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КАЗА́Н ФОТО́ГРАФЛАР ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1895 елда Казанда һәвәскәр фотограф П.Д.Викторов башлангычында оеша. Җәмгыятьнең максаты — фотографиягә кагылышлы сәнгати һәм техник белемнәрне таратуга булышу, фотографларга тарихи истәлекләрне, атаклы архит-ра корылмаларын, матур урыннарны һ.б.ны фотога төшерүдә ярдәм итү. Җәмгыятьнең беренче рәисе — Казан ун-ты ботаника профессоры Н.В.Сорокин, аннары — Н.М.Любимов, М.А.Пикеринг. Җәмгыятьнең төрле вакыттагы хакыйкый әгъзалары — Казан ун-ты профессоры М.Н.Капустин, һәвәскәр фотографлар В.В.Аганчиков, И.Н.Аристов, П.В.Баранов, М.С.Мастрюков, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре М.Әҗимов, И.Айтуганов, С.Усманов, фототоварлар б-н сәүдә итүчеләр В.М.Ключников һәм Г.А.Герингслаке, юристлар С.В.Манассеин һәм И.А.Котелов, суд палатасы әгъзалары Р.К.Краус һ.б. Шәрәфле әгъзалары: Казан губернаторы П.А.Полторацкий, шәһәр башлыгы С.В.Дьяченко һ.б. Иң яхшы әсәрләргә бүләкләр бирелгән фотография күргәзмәләре, фәнни әңгәмәләр, хәйрия кичәләре үткәрелә, техник тәҗрибә уртаклашулар оештырыла. Җәмгыять әгъзалык взносларына, үзе оештырган җыелышларга, күргәзмәләр, концертлар, кичәләр, спектакльләр, төрле укуларга халык түләп кергән акчага, хезмәтләрне бастырудан килгән табышка, иганәчелек акчасына яши. К.ф.җ. хәйрия чараларына да шактый күләмдә чыгымнар сарыф итә. Аның әгъзаларының мәкаләләре чит илләр һәм Россия фотография журналларында да басыла. «Казан фотографлар җәмгыяте хезмәтләре» (*«Труды Казанского фотографического общества»*) нәшер ителә. К.ф.җ. Казан губернасының фәнни-техник һәм сәнгать тормышына зур өлеш кертә. 1900 елларда яшәүдән туктый.

*Әд.:* Гольдшмидт И.П. Корифеи Казанской фотографии // Казань. 1997. № 8/9.

*Г.Р.Заманова.*

**КАЗА́Н ФОТОМАТЕРИАЛЛА́Р ИНСТИТУТЫ́**, 1956 елда Бөтенсоюз кинофото фәнни-тикшеренү ин-тының (Мәскәү) Казан ф-лы буларак оештырыла. 1967 елдан — Химия-фотография сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-тының Казан ф-лы, 1969 дан — СССР Химия сәнәгате министрлыгының Казан химия-фотография сәнәгате фәнни-тикшеренү технол. һәм проект ин-ты; 1992 дән хәзерге исемдә; шул ук елдан — АҖ. Институт составында 4 фәнни-тикшеренү лаб-ясе һәм тәҗрибә-сәнәгать производствосы бар (2003). Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: галогенкөмеш фотоматериалларга яктылыкның һәм ионлаштыргыч нурланышларның фотохимик тәэсирен тикшерү; көмеш галогениды микрокристалларын идарә итүле синтезлау, аларны химик һәм иң зур сизгерлек һәм мәгълүматлылык б-н тәэмин итүче спектраль сенсибилизация ысулларын өйрәнү; галогенкөмеш фотоматериалларның сенситометрик характеристикаларын яхшырту өчен яңа химикатлар, ш.у. аларны химик-фотографик эшкәртү процессларын эзләү һәм өйрәнү; чимал һәм продукция сыйфатын тикшерү ысулларын, сәнәгать зонасының экол. мониторингы мәсьәләләрен камилләштерү. Тикшеренүләр нигезендә медицина, полиграфия, дефектоскопия һ.б. өчен аклы-каралы һәм төсле фотоматериаллар җитештерү технологияләре, яңа фотохимикатлар, дару субстанцияләре җитештерү технологияләре эшләнә. Тәҗрибә-сәнәгать производствосында технологияләрне эшкәртү, технол. параметрларны оптимальләштерү, химия-фотография һәм фарм. сәнәгате ихтыяҗлары өчен фотохимикатлар һәм дару субстанцияләренең модульле җайланмаларын төзү һәм тәҗрибә-сәнәгый партияләрен чыгару гамәлгә ашырыла. 1950–60 елларда төсле һәм аклы-каралы кинофототасмалар, кинофотоматериаллар, желатинны камилләштерү өчен органик кушылмалар һәм полимерлар синтезы технологияләре, яктыга сизгер тасмалар җитештерү, ш.у. сыйфатын тикшерү приборлары һәм аппаратлары бүлекләре оештырыла. Институт кинематография, телевидение һәм фотографияләр өчен төсле тасмалар, полиграфия, репрография, фототелеграф, астр. өчен фототехник

тасмалар, сәнәгый радиография һәм мед. диагностика өчен рентген тасмалары, көмешсез материаллар, фотографияләр өчен нечкә органик синтез химикатлары һәм полимер материаллар эшләү; технол. процессларны аппаратура б-н тәэмин итү һәм үтә сизгер материаллар җитештерү өчен махсус технол. җиһазлар булдыру б-н шөгыльләнә. 1960 еллар ахырында механика цехы, полиэтилентерефталь нигезләре җитештерү, фотографияләр өчен нечкә органик синтез продуктлары һәм полимер продуктлар цехлары булган тәҗрибә з-ды төзелә. Фәнни эшләнмәләрне җитештерүгә кертүдә төп оешма — «Тасма-Холдинг» АҖ. Медицина һәм техника өчен рентгенографик тасмалар комплекты, үтә сизгер рентгеномед. тасма, магистраль нефть- һәм газүткәргечләрнең эретеп ябыштырылган җөйләрен тикшерү өчен рентгенографик тасма, полиграфия һәм газета битләрен тиз тапшыру өчен фототехник тасмалар комплекты технологияләре эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. Телевидение, һәвәскәр һәм проф. фотография өчен төсле һәм кабат кулланылулы фотоматериаллар, микрофильмнар төшерү һәм астр. тикшеренүләр өчен уникаль тасма комплектлары булдырыла, спектраль һәм химик сенсибилизаторлар синтезлана, фототасмаларны стабильләштерү һәм саклау шартлары билгеләнә. Фотография желатинын өйрәнү буенча хезмәтләр дөньяга таныла. Фәнни һәм гамәли тикшеренүләр үсешенә өлеш кертүчеләр: А.В.Борин, В.М.Гороховский, Л.Г.Гросс, Е.А.Зимкин, В.О.Иванов, Г.А.Кутырев, В.А.Кухтин, П.В.Мейкляр, И.А.Новиков, А.Н.Пудовик һ.б.

Институт директорлары: Н.Н.Сомов (1956–74), В.О.Иванов (1974–87), Б.А.Воробьёв (1987–2001), Г.А.Кутырев (2001–05), Ә.З.Әхтәмов (2005 тән).

*В.А.Абзалова.*


**КАЗА́Н ХАЛЫ́К УКЫТУЧЫЛАРЫ́Н УКЫТУ́ ЗЕ́МСТВО МӘКТӘБЕ́**, Россиядә беренче земство пед. уку йортларыннан. 1871 елның 7 ноябрендә аны Казан губернасының земство идарәсе ача. Башлангыч земство мәктәпләрен 5 легә тәмамлаган һәм өяз земство идарәсе юлламасы һәм имтиханнар нәтиҗәсе буенча, нигездә, крәстиян кыз балалары кабул ителгән. Уку, яшәү урыны һәм туклану өяз земстволары тарафыннан түләнгән, шуңа күрә мәктәпне тәмамлаучылар 6 ел үзләренең өяз мәктәпләрендә эшләргә тиеш булалар. Казан земство ятимнәр йортында тәрбияләнүчеләр дә губерна земствосы хисабына укыйлар. Мәктәпнең программасы даими рәвештә камилләшә, мәктәптә белем бирү дәрәҗәсе тулысынча *кыз балалар гимназияләре* дәрәҗәсенә туры килә, ләкин чит телләр өйрәнелми; алар урынына а.х. нигезләре һәм чуаш яисә чирмеш (мари) телләре (сайлау буенча) укытыла. Соңгы уку елында практика уздырыла, аның өчен 1874 тә үрнәк башлангыч мәктәп ачыла. Әмма, сыйфатлы белем алуга карамастан, мәктәпне тәмамлаучыларның укуны дәвам итәргә мөмкинлекләре булмый. 1876 дан мәктәп махсус төзелгән бинада урнаша. 1901 дә уку срогы 4 елдан 5 елга кадәр арттырыла, программага педагогика, психология, дидактика кертелә. Мәктәп халык мәгарифе үсешендә әһәмиятле роль уйный. 1874–1917 дә аны 850 кыз бала тәмамлый, 20 йөз башында алар Казан губернасының башлангыч мәктәпләрдәге укытучыларның чирегеннән артыгын тәшкил итәләр, совет чорында да авыл мәктәпләрендә эшләүләрен дәвам итәләр. 1918 ел башында земстволарны бетерү һәм финанслау туктатылу сәбәпле ябыла. 1919 да аның җирлегендә рус пед. техникумы ачыла (к. *Казан педагогия көллияте*).

*Әд.:* Е р ш о в А.Ф. Двадцатипятилетие Казанской земской школы для образования народных учительниц. 1871–1896. К., 1896; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX–XX веков. К., 2001.

*Р.Р.Исхакова.*

**КАЗА́Н ХАЛЫ́КАРА КҮРГӘЗМӘСЕ́**, 1909 елда Казанда кулланучыларны Россия һәм чит илләрдә җитештерелгән сәнәгать, а.-х. продукцияләренең иң яхшы үрнәкләре б-н таныштыру максатында үткәрелә. Бөтенроссия Түбән Новгород күргәзмәсеннән соң (1896) Идел буендагы беренче эре күргәзмә. Аны оештыру өчен Казан губернаторы М.В.Стрижевский җитәкчелегендә күргәзмә ком-ты төзелә. Күргәзмәдә Россиянең 30 дан артык губернасыннан 2316 кеше катнаша, шуларның 1308 е кече сәнәгать вәкилләре була. Казан губернасы пр-тиеләреннән И.Арслановның сәнәгать ширкәте, Үтәмешев һәм К°ның Казан мануфактуралары, А.Н.Лоскутов з-ды, Алафузов ф-калары һәм з-дларының сәүдә-сәнәгать җәмгыятьләре, П.В.Щетинкинның сәүдә йорты һ.б. бик күпләр үзләренең товарларын тәкъдим итәләр. Россиянең күргәзмәләр үткәрү эшендә беренче тапкыр һөнәри белем бирү бүлеге оештырыла. Күргәзмәдә Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы һәм Халык мәгарифе министрлыгының барлык һөнәри уку йортлары диярлек катнаша. Германия, Швеция, Япония кебек 40 лап чит ил фирмасының продукцияләре кулланучылар хозурына тәкъдим ителә.





Казан халыкара күргәзмәсе. 1909.
1. Гомуми күренеше; 2. О.Э.Петцольдның сыра кайнату заводы павильоны.





Казан халыкара күргәзмәсе. 1909.
1. Төп капка; 2. «И.В.Александров варислары» сәүдә йорты павильоны.

Һөнәри белем бирү бүлегеннән тыш, кече сәнәгатьне, авыл хуҗалыгы сәнәгатен, эре сәнәгать товарларын, утка чыдам төзелеш материалларын, янгынга каршы тору эшләрен эченә алган экспозицияләр оештырыла. К.х.к. «Рус Швейцариясе» паркында һәм шуңа тоташып торган терр-ядә урнаша. Күргәзмә комплексының баш архитекторы — П.В.Ладыгин, ярдәмчесе арх. Г.Башмаков була. Комплексның төп павильоннары урнашкан көнчыгыш һәм көнбатыш өлешләргә бүлгән трамвай юлы аның күчәрен тәшкил итә. Комплекска барлыгы 63 корылма керә. Киртә б-н тотып алынган терр-ягә керү юлы күп ярусль, озынча өчпочмак формасындагы агач манара аша үтә. Павильонның вестибюле рус тарихына багышланган темага рәссам Е.П.Фирсов тарафыннан бизәлә. Базиликаль композицияле эре сәнәгать павильоны аңа заманына хас индустриаль төсмер биреп торган. Пермь земствосы павильоны стильләштергән Төньяк Русе формаларында эшләнә. Мөселман архит-расы темасы М.Рам фирмасы һәм И.В.Александров варислары павильоннарында чагылыш таба. Алафузов ф-калары һәм з-дларының сәүдә-сәнәгать җәмгыятьләре павильоннары күләмнәренең гомумиләштерелүе б-н аерылып тора (мөселман архит-расының традицион формала-

рын стильләштерү хисабына). Павильон фасадларында һәм гөмбәзләрендә металл конструкцияләр актив кулланыла. Конструктивлык идеяләре В.Ю. фон Денфферн павильоннарының архитектур чишелешләрендә чагылыш таба. К.х.к.нең күп кенә корылмаларында реклама идеяләре ачык чагыла: О.Э.Петцольдның шешә формасындагы сыра кайнату з-ды павильоны, И.Арслановның тоташ төрле төсле сабыннан эшләнгән Казан сабын кайнату ширкәте павильоны шундыйлардан. Күргәзмә терр-ясендә ш.у. кафешантан, тиз төшерүче фотография, бильярд һәм кегельбан, эстрада, цирк, кинематограф эшли. Күргәзмәне 247 меңгә якын кеше карый.

*Әд.:* Д у б и н А., К у з н е ц о в а О. К 90-летию Международной выставки в Казани // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4.


*Г.Н.Айдарова.*

**КАЗА́Н ХАНЛЫГЫ́**, Урта Идел һәм Чулман буйларында 1438 (кайбер чыганаклар буенча 1445) — 1552 елларда яшәгән феодаль дәүләт. Идел буе Болгар дәүләте терр-ясендә (*Болгар бәклеге, Җүкәтау бәклеге, Казан бәклеге*) *Алтын Урда* таркалган чорда барлыкка килә. Нигезләүчесе — *Олуг Мөхәммәд хан.* Ул Казанда тәхеткә җирле аксөякләр ярдәмендә утыра. Олуг Мөхәммәд һәм аның якын нәселдәшләре идарә иткәндә ханлык биләмәләре Чулман буе һәм Көньяк Урал яны җирләрен кушу исәбенә киңәя. Иң куәтле чорында — 15 йөзнең 2 нче яртысында К.х. көнбатышта — Сура, көнчыгышта — Идел елгалары бассейннарына, көньякта — Самара Дугасына, төньякта Чулман буе һәм Вятка җирләренә кадәрге терр-яне үз эченә ала.

Адм. төзелеше урта гасырлар төрки-татар дәүләтләренә хас рәвештә була, К.х. үзенә бәйле өлкәләрне берләштерүче эре вилаятьләр — *даругалардан* тора. Башта дүрт: *Алат* (Төньяк Казан арты), *Арча* (Төньяк-көнчыгыш Казан арты), *Гәреч* (Төньяк-көнбатыш Казан арты һәм, ихтимал, *Тау ягы* — Тауиле), *Җөри* (Үзәк Чулман алды) даругалары була. Соңрак, нугайларны «туендыру» өчен, *Нугай даругасы* (Көньяк Казан алды һәм Казан ягы, өлешчә Тау ягы) оештырыла. Даругалар б-н, гадәттә, *карачыбәкләр* яки танылган *әмирләр, бәкләр* идарә итә. Даругалар берничә торак пунктларны берләштергән *олысларга* (йөзлекләргә) бүленә. Кагыйдә буларак, алар терр. җәмәгатьләргә — *җыеннарга* туры килә (мәс., Ашыт, Байтирәк, Кирәм, Кушкапка, Мукшы, Тукташ, Чабыр). К.х. биләмәсендә 700 дән артык торак пункт була. Олыслар башында олыс, йөзлек әмирләре (*хакимнәр*), *морзалар*, старшиналар һ.б. тора, алар салымнар җыю, мәхкәмә эшләрен башкару, хәрби ополчениеләр туплау һәм алар б-н җитәкчелек итү б-н шөгыльләнә. Ханлык башкаласы — Казан. К.х.ның башка шәһәрләре: *Алат, Арча, Кашан, Болгар, Иске Казан,* Лаеш, Тәтеш, Чаллы — даругаларның, халык тормышының, икътисади, дини һәм мәдәни үзәкләре була. Аларның башында әмирләр тора.

К.х. җирләрендә төрки телле (татарлар, нугайлар, чуашлар һәм башкортлар) һәм фин-угор (марилар, удмуртлар, мордвалар) халыклары яшәгән. Аксөякләр үзләрен татар дип, ә күпчелек халык ешрак дин билгесе буенча — мөселманнар дип атаган. К.х.нда иң киң таралган тел (сөйләм һәм рәсми) төрки тел (*Идел буе төрки теле* формасында) була, шул телдә барлык эшләр башкарыла, дипломатик язышу алып барыла. Халыкның төп шөгыле — игенчелек (өч басулы система һәм өлешчә дала җирләрен эшкәртү), терлекчелек, чолыкчылык, балыкчылык була. Шәһәрләрдә, бигрәк тә зурларында, тимерчелек, корал ясау, чүлмәкчелек, зәргәрчелек, тире, агач эшкәртү һ.б. һөнәрчелек үсә. Җирле сәүдә — Югары Чулман һәм Көньяк Урал буенда, халыкара сәүдә — Русь, Урта Азия һәм Кавказ илләре б-н багланышлар — хуҗалык итүнең мөһим тармагын хасил итә. Читкә чыгарыла торган кыйммәтле товарлар — мех, күн әйберләр, бал, икмәк; кертелә торганнары — бизәнү әйберләре, кыйммәтле кораллар, тукымалар, тәмләткечләр, терлек һ.б. Танылган ярминкәләр — *Ташаяк, Сәүдә атавында, Арча кырында уткәрелә.*

КАЗАН ХАНЛЫГЫ (1438–1552 еллар)




К.х.нда югары хакимият Җүчи нәселеннән чыккан ханнар кулында була: 1518 гә кадәр ханнар булып *Олуг Мөхәммәд*, соңрак *Кече Мөхәммәд*, 1518–52 дә (бүленеп) — Гәрәй, 1521–51 дә (бүленеп) — Шибан, 1552 дә — *Әхмәд* нәселләре вәкилләре тора. Фәкать ислам динен тотучы *чыңгызыйлар* гына хан була ала. Формаль яктан ханнар хакимиятне бер кулда тоталар, аларның исеме мәчеттә дога укыганда әйтелә (мәс., *хөтбәдә*), алар барлык канунннарга үз мөһерләрен сугалар, дәүләтнең бөтән вазифаларын башкаралар. Чынлыкта исә К.х.нда хакимият *диван* кулында була. Ул югары татар аксөякләре вәкилләреннән тора; анда хәлиткеч рольне *Ширин, Аргын, Барын* һәм *Кыпчак* идарәче ыруларыннан чыккан карачыбәкләр уйный. Югары адм. һәм хәрби хакимият олуг карачыбәк кулында була, ул күбрәк Ширин ыруы вәкилләреннән (мәс., *Булат Ширин*, аның улы *Нурали*) билгеләнә.

К.х.нда аксөякләрнең социаль бүленеше җир биләүгә (яки билгеле бер күләмдә салым җыюга) хокук б-н бәйле иерархик система тәшкил итә, җирбиләүче җир өчен үзенең хуҗасына хезмәт итәргә тиеш була. Җир биләү ике төргә: шартлы — *суйургал* һәм шартлы булмаган яки өлешчә шартлы булмаган — *тархан* (барлык яки өлешчә салым һәм җыемнардан азат ителү) төрләренә бүленә. Аксөякләрнең иң югары катлавын Җүчи нәселе вәкилләре — *угланнар, солтаннар,* бәкләр, ш.и. карачыбәкләр һәм әмирләр, аннары морзалар, *чуралар* — баһадурлар (*батырлар*) һәм казаклар тәшкил итә. Дәүләттә иң мөһим эшләр (ханны тәхеткә утырту, аны төшерү, сугыш игълан итү, солых төзү һ.б.) аксөякләр җыенында — *корылтайда* тикшерелә.

Халыкның төп массасын ханга һәм феодалга салым түләүче *кара халык* тәшкил итә. Төп салым *ясак* (ясак-калан) була. Аннан тыш җир һәм керем салымнары, җыемнар (салыг муссама, тамга-тырнак, хараҗ һ.б.) булган, төрле йөкләмәләр — гаскәрләргә, хакимиятләргә азык-төлек бирү (амбар малы, олыф — шүсүн һ.б.), ямчылык (илче-кунак) һ.б. бурычлар гамәлдә яши. Шулай ук мөселманнар руханилар файдасына салымнар (*гошер, зәкят*), мөселман булмаган бәйле халык та ясак һәм салым түли. Салымнар һәм йөкләмәләр саны 16 га җитә; аларны җыюны 10 нан артык төрдәге чиновниклар оештыра. К.х.на бәйле өлкәләрдә яшәүчеләр дә хан һәм аерым феодаллар файдасына салымнар һәм ясак түли, төрле бурычлар башкара (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*).

К.х.ның гаскәрен төрле даруга һәм шәһәрләрдән җыелган халык, хан һәм аксөякләрнең шәхси отрядлары, ш.у. аркадаш өлкәләр, илләр сугышчылары (30–50 мең кеше) тәшкил итә. Армиянең төп терәге аксөякләр була, гаскәр башлыклары һәм проф. сугышчылар, нигездә, авыр кораллы атлылардан (5–10 мең кеше) тора. Сугышта җәяүлеләр ярдәмче рольне үти. Кырдагы сугышларда һәм ныгытмаларны саклаганда утлы корал кулланыла. Елгаларда сугышканда хәрби һәм транспорт-сәүдә флотыннан файдаланалар. Оператив һәм тактик хәрби сәнгать шактый үсеш ала, манёврлар һәм дошманны чолгап алулар, актив саклану, сугыш кырында дошман сафларына үтеп керү һәм аны камап алу өчен укчыларның һәм авыр кораллы җайдакларның һөҗүмен чиратлаштыру кулланыла. Казан ханнары күрше, ш.и. рус җирләренә зур яулар оештыралар (1445, 1448, 1505, 1521, 1523, 1536).

К.х.нда дәүләт дине *ислам* була. Дин әһелләре зур җир биләмәләре — *вакыфлар* били. К.х.ның дин башлыгы булып *сәед* санала. Иң танылган сәедләр: Бараш (1491–1507),

Шәех Хөсәен (1512–16), *Боерган Сәет* (1546), *Мансур* (1546) һәм *Колшәриф* (1552). Аларның барысы да зур шөһрәт һәм хөрмәт казана, дәүләт б-н идарә итүдә һәм Казан ханнарының дипломатик сөйләшүләрендә катнаша.

*Шәех, казый, мулла, имам, хафизлар* һәм башка руханилар гыйбадәт кылуны оештыралар, ш.у. илдә гражданлык эшләрен карауда катнашалар. Ханлыкта суфичылык (*Нәкышбәндийә* борадәрлеге) таралу турындагы мәгълүматлар да бар.

Мәктәп һәм мәдрәсәләр дин әһелләре карамагында була. Казанның Җамигъ мәчете каршында 1552 дә Колшәриф җитәкләгән зур мәдрәсә һәм китапханә булуы турында мәгълүматлар сакланган.

Күп кенә мәдрәсәләрдә кульъязма китаплар туплана һәм китапханәләр оештырыла, аларда күчереп язучы хаттатлар эшли. Халыкның укый-яза белүен, мәдәни дәрәҗәсен сакланып калган көнкүреш әйберләрендәге, кабер ташларындагы һ.б. язулар раслый. Татар әдәбияты үсеш ала: *Мөхәммәдьярның* «Төхфәи мәрдан» (1539–40) һәм «Нуры содур» (1542) поэмалары, Шәрифи Хаҗитарханиның (Колшәриф) «Зафәрнамәи вилайәте Казан» («Казан төбәгендәге җиңүләр китабы») (1550) әсәре, Колшәриф, *Мөхәммәдәмин*, Гарифбәк һ.б.ларның аерым шигырьләре билгеле. Аерым шәҗәрәләр рәвешендә һәм фольклор традицияләрендә сакланган үзенчәлекле тарихи язмалар булган («Елъязмалар җыентыгы», «Дәфтәре Чыңгызнамә»). Төзелеш эшләре һәм архитектура (ш.и. ак таштан), үсемлек бизәкләре уеп кабер ташлары ясаучыларның осталыгы югары дәрәҗәгә җиткән. (к. *Эпиграфика ядкәрләре*).

Ул чорның архит-ра ядкәрләре сакланмаган, әмма кайбер монументаль биналар — *Даир (Таһир) мунчасы, Колшәриф мәчете, Отыч мәчете, Нургали мәчете* һ.б. турында безгә язма чыганаклардан (рус елъязмалары, А.М.Курбскийның «Мәскәүнең бөек кенәзе турында тарих» — «История о великом князе Московском», 1573) һәм соңгы елларда Казан Кремлендә үткәрелгән археол. казу материаллары буенча билгеле. Казанда һ.б. торак пунктларда археол. казу эшләре вакытында биналарның декоратив бизәлешләре (бизәкләп ясалган алебастр плитәләр, архит-ра бизәкләре кисәкләре), керамика әйберләре (*хумнар,* кувшиннар, ялтыравык йөгертелгән язулы касәләр, тәлинкәләр), күн аяк киемнәре калдыклары табыла (к. *Казан ханлыгы сәнгате*).

К.х. актив тышкы сәясәт алып бара. Эчке хәлләрне ныгыткач, Олуг Мөхәммәд хан Мәскәү кенәзлегенә яулар б-н бара (1439, 1444). 1445 тә аның уллары *Мәхмүд* б-н Якуб Суздаль янында Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II гаскәрен тар-мар итәләр, үзен әсирлеккә төшерәләр. Ул килешүгә барырга, зур йолым һәм ел саен ясак түләргә мәҗбүр була (к. *Суздаль янындагы сугыш*). Якынча шул вакыттан соң Олуг Мөхәммәднең исеме чыганакларда искә алынмый. 1445 тә аның улы Мәхмүд үз туганнары Якуб б-н *Касыймны* Казаннан куа, тәхеткә утыра һәм 1467 гә кадәр идарә итә. Ул идарә иткән чорда Рус дәүләте б-н тыныч мөнәсәбәтләр урнаша һәм К.х.да адм.-сәяси структура барлыкка килә. Мәхмүд үлгәч (1467), аның улы *Хәлил* тәхеткә утыра, шул ук елда тәхетне *Ибраһим* ала, әмма аңа каршы аксөякләр тарафыннан яшерен фетнә оештырыла, һәм тәхеткә Мишәр җиреннән удел кенәзе Касыйм чакырыла. Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III яклавына таянып, Касыйм Казанга яу б-н бара, әмма җиңелә (1467). Мәскәү-Казан сугышы (1467–69) солых төзү б-н тәмамлана, яклар арасында әсирләр алмашу була. 1470 елларда К.х.ның эчке хәле ныгый, ул Югары Чулманда һәм Нократ төбәгендә үз биләмәләрен киңәйтә башлый (1478 дә Хлынов шәһәренә яу оештырыла). Рус гаскәрләренең һәм *ушкуйникларның* җавап һөҗүмнәре кире кагыла (1478). Ибраһим үлгәч (1479), К.х.нда үзара көрәш башлана, анда Илһам җиңә (1479–87), тәхеткә дәгъва кылучы солтан Мөхәммәдәминне куа. Соңгысы Мәскәү ярдәмендә Илһамга каршы сугыш башлый (1482 елгы яу). Якынча 1484–85 тә Мөхәммәдәмин Казанны ала, ләкин озакламый бәреп төшерелә. Илһам хакимиятенең көчәюенә җавап йөзеннән, рус гаскәрләре Казанга яу оештыралар (1487), озак камап торганнан соң, аны алалар һәм ханны тәхеттән төшерәләр. Мөхәммәдәмин хан идарә иткән чорда (1487–95) К.х., нигездә, *Мәскәү протектораты* басымы астында була һәм Мәскәү б-н бер тышкы сәясәт алып бара, аерым алганда, Зур Урдага каршы сугыша (1493). Мөхәммәдәмин диван хакимиятен чикли, бу исә 1495 тә аксөякләрнең ризасызлыгын соңгы чиккә җиткерә. Ул тәхеттән куыла. Карачыбәкләр *Колмөхәммәд*, Урак, Садыр һәм Агиш тәхеткә Шибан нәселеннән Себер ханы улы Мамыкны утырталар. Әмма карачыбәкләрне ул да канәгатьләндерми, 1496 да хан тәхетенә Мөхәммәдәминнең кече туганы — Русьта яшәгән Габделлатыйф утыртыла. Ул да аксөякләрнең сәяси йогынтысын чикләргә тырыша (1499 да карачыбәк Урак җитәкләгән фетнәне бастыра), бу исә аксөякләр б-н каршылык китереп чыгара. 1502 дә олуг карачыбәк Колмөхәммәд Габделлатыйфны бәреп төшерә һәм рус илчеләре ярдәмендә Казанга Мөхәммәдәминне кайтаруга ирешә (1502). Ул эре аксөякләрнең сәяси (1502 дә Колмөхәммәдне җәзалау) һәм икътисади (җирбиләүчелек системасындагы үзгәрешләр) йогынтысын киметә һәм югары хакимиятне ныгыта. 1505–07 елларда Мөхәммәдәмин Казан янында Мәскәү гаскәрләрен ике тапкыр тар-мар итә, Мәскәү б-н берничә солых төзи (1507, 1508, 1512, 1516), К.х. б-н Рус дәүләте арасында тигез хокуклылык һәм яхшы күршелек мөнәсәбәтләре урнаштыра. Мөхәммәдәмин үлгәч (1518 нең декабре), олуг карачыбәк Булат Ширин җитәкчелегендәге диван Казан тәхетенә аксөякләрнең өстенлеген сакларга вәгъдә иткән Касыйм ханы *Шаһгалине* утырта. Әмма ханлыкта рус киңәшчеләренең йогынтысы арту һәм карачыбәкләр хакимиятен чикләргә тырышу аксөякләрнең яңа фетнәсен тудыруга һәм ханны куУга китерә. 1521 дә Казан тәхетенә үги анасы — ханбикә *Нурсолтан* — ярдәмендә Кырым солтаны *Сәхибгәрәй* утыртыла. Яңа хан, Кырым б-н дуслыкка таянып, Рус дәүләтенә каршы актив хәрби хәрәкәтләр башлый: Мәскәүгә җиңү б-н тәмамланган яу б-н бара (1521) һәм аны К.х.на ясак түләргә мәҗбүр итә. 1523 тә Сәхибгәрәй яңадан Мәскәү һәм Әстерхан б-н сугыш башлый, ләкин, Кырым ханы үлгәч, 1524 тә К.х. тәхетенә үзенең туганы *Сафагәрәйне* утыртып, кинәт кенә Кырымга кайтырга мәҗбүр була. Аксөякләр (Булат Ширин, әмир Отыч, аталык Талыш һ.б.) ярдәмендә 1524 тә ул яу б-н килгән рус армиясен куып җибәрә, 1526–28 дә Мәскәү б-н солых төзи. 1530 да Мәскәү хөкүмәте солых килешүен өзә һәм Казанга яу б-н килә. Әмма казанлылар нугай һәм әстерханлылар гаскәре ярдәмендә рус полкларын җиңә. Хан хакимиятенең яңадан көчәюе Мәскәү яклы аксөякләрнең фетнәсен тудырып, 1531 дә Сафагәрәй куыла, аның тарафдарлары үтерелә. Башында Мәскәү тарафдары ханбикә *Гәүһәршат*, Булат Ширин һәм Кече Гали морза торган диван 1531 дә Казан тәхетенә Касыйм ханы *Җангалине* чакыра. Ул Мәскәү хөкүмәте ризалыгы б-н нугай морзасы Йосыф кызы *Сөембикәгә* өйләнә. Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III үлгәч (1533), Мәскәүнең К.х.на йогынтысы нык кими, бу исә аксөякләрнең ханга һәм аның тарафдарларына каршы фетнәсен китереп чыгарып, Булат Ширин б-н Гәүһәршат 1535 тә Җангалине бәреп төшерәләр, тәхеткә яңадан Сафагәрәй утыртыла, Җангали үлгәч, ул Сөембикәгә өйләнә. Мәскәүдәге үзара көрәш-талаштан файдаланып, Сафагәрәй Руська уңышлы яу оештыра (1536–37). Аның хакимияте ныгыган саен, аксөякләрнең ризасызлыгы арта, алар ханны алыштыру турында Мәскәү б-н сөйләшүләр алып баралар (1541 һәм 1545). Моңа җавап итеп, Сафагәрәй аксөяк казанлыларның бер өлешен үтертә, шуның б-н Казан аксөякләрен үзенә каршы куя; яңа фетнә нәтиҗәсендә (башында *Нарыйк улы Чура бәк*, Боерган Сәет һәм Кадыш бәк тора) хан бәреп төшерелә. Фетнәчеләр тәхеткә яңадан Шаһгали ханны чакыралар (к. *Казанда тәхет чуалышы*, 1545–46). Сафагәрәй нугай бәге Йосыф янына кача, аннан гаскәр алып, Казанга әйләнеп кайта һәм Шаһгали ханны тәхеттән төшерә. Сафагәрәйнең идарә итүе (1546–49) дошманнары Нарык улы Чура бәкне, Кадышны һ.б.ларны үтертүдән һәм хакимияткә Кырым һәм нугай бәкләре килүдән башлана. Сафагәрәй үлгәч (1549 ның марты), хакимият аның Сөембикәдән туган яшь улы *Үтәмешгәрәйгә* күчә. Хакимият Сөембикә кулында була һәм ул *Кошчак* углан җитәкләгән Кырым гвардиясенә таяна. Казан аксөякләре арасындагы низаглардан һәм хан хакимиятенең көчсезләнүеннән файдаланып, 1545–52 елларда *Казанга Рус дәүләте яулары* оештырыла. Иван IV-нең Казанга турыдан-туры яулары уңышсыз төгәлләнгәч, 1551 дә Зөя елгасы тамагында, шәһәргә якын урында, Зөя кальга-ныгытмасы төзелә. Бу исә кырымлылар җәберенә ризасызлык белдергән Тау ягы җирле халыкларының патша ягына күчүенә китерә. Сөембикә хөкүмәте яклаучысыз кала. Кош-

чак углан һәм аның кешеләре үтерелә, Сөембикә б-н Үтәмешгәрәй Мәскәүгә озатыла. 1551 дә Казан аксөякләре: *Ходайкол* углан, карачыбәк Нурали, Колшәриф, әмир Бәйбарс (Раст бәк улы) һ.б. ярдәмендә тәхеткә яңадан Шаһгали утыра. Ханның Тау ягын Рус дәүләтенә бирү турындагы карары аксөякләрнең ризасызлыгын тудыра. Зур корылтай (1551 нең 14(24) сентябре) ханнан ул җирләрне кире кайтаруны таләп итә. Рус гарнизоны яклавына таянып, Шаһгали бу таләпне үтәүдән баш тарта, аксөякләргә каршы җәза чаралары үткәрә башлый (Раст бәк уллары һәм тагын 70 бәк үтерелә). 1552 дә Шаһгалине төшергәннән соң, казанлылар Иван IV кә ант кабул итү өчен илчелек сайлыйлар. Бу эш аксөякләрнең бер өлешендә һәм халыкта нык ризасызлык тудыра. Шуннан файдаланып, бәкләр *Ислам бәй, Кибәк* һәм *Галикәй* (Нарыйк улы) русларга каршы баш күтәрәләр. Казанлылар гарнизонны юк итәләр һәм, тәхеткә Әстерхан солтаны *Ядегәр Мөхәммәдне* чакырып (1552), Мәскәү дәүләте б-н сугыш башлыйлар. 1552 дә рус гаскәрләре Казанга зур яу оештыра. 49 көн камалып торганнан соң, шәһәр штурм б-н алына (1552 елның 2(13) октябре), Казан ханы әсир төшерелә һәм Мәскәүгә озатыла (к. *Казанның яулап алынуы*). Әмма К.х. халкы үз дәүләтчелеген югалту б-н килешә алмый һәм басып алучыларга ныклы каршылык күрсәтә (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары*, 1552–56). 1557 елга каршылык күрсәтүнең соңгы учаклары бастырыла. К.х. тәмам яшәүдән туктый, ә аның терр-ясе Рус дәүләте составына керә һәм Казан сарай идарәханәсе карамагына тапшырыла. Ләкин төп халыкларның азатлыкка омтылышын тәмам бастыру мөмкин булмый, һәм алар берничә тапкыр (1572–73, 1581–84 тә) үз дәүләтләрен торгызырга омтылып карыйлар (к. *Казан ханлыгы яулап алынганнан соңгы фетнә-чуалышлар*). К.х. чоры татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә мөһим баскыч булып тора. Ханлык халкы бүгенге Идел буе һәм Урал яны татар халкы формалашу өчен этник нигез хасил итә; мәдәният казанышлары (тел, дини традицияләр, фольклор һәм язма әдәбият әсәрләре) татар халкының мәдәни-тарихи мирасының төп өлеше булып кереп калалар (к. *Татарлар*).

Ханнар: Олуг Мөхәммәд (1438–45), Мәхмүд (1445–62), Хәлил (1463–67), Илһам (1479–84, 1485–87), Мөхәммәдәмин (1484, 1487–95, 1502–18), Мамык (1495–96), Габделлатыйф (1496–1502), Шаһгали (1519–21, 1546, 1551–52), Сәхибгәрәй (1521–24), Сафагәрәй (1524–31, 1535–45, 1546–49), Җангали (1531–35), Үтәмешгәрәй (1549–51), Ядегәр Мөхәммәд (1552).

*Чыг.:* История о Казанском ханстве. СПб., 1791; Полное собрание русских летописей. СПб., 1859. Т. 8; 1901. Т. 12, 13; 1910. Т. 23; М.–Л., 1949. Т. 25; М., 1962. Т. 27; 1963. Т. 28; Л., 1982. Т. 37; Рахим А. Татарские эпиграфические памятники XVI в. К., 1930; История Татарии в документах и материалах. Л., 1937; Казанская история. М.–Л., 1954; Сказание о царстве Казанском. М., 1959; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; шул ук. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Герберштейн С. Записки о Московии. М., 1988; Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой. 1489–1549 гг. Махачкала, 1995.

*Әд.:* Атласов Һ. Казан ханлыгы. К., 1913; Гобәйдуллин Г.С. Татар тарихы. К., 1922; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984; Баженов И. Казанская история. К., 1848; Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах: В 2 ч. СПб., 1863–64; Перетяткович Г.И. Поволжье в XV-XVI вв. М., 1877; Загоскин Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Рычков Н.И. Опыт Казанской истории древних и средних времен. СПб., 1907; шул ук. История татар. М., 1994; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Калинин Н.Ф. Казань. К., 1955; Мухамедьяров Ш.Ф. Земельные правоотношения в Казанском ханстве. К., 1958; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; Валеев Ф.Х. К истории архитектуры казанских татар XV — первой половины XVI вв. // Вопр. истории, филологии и педагогики. К., 1967. Вып. 2; Чернышёв Е.И. Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Археология и этнография Татарии. К., 1971. Т. 1; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Халиков А.Х. Татарский народ и его предки. К., 1984; Исхаков Д.М. Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. К., 1997; шул ук. От средневековых татар к татарам нового времени. К., 1998; Халитов Н.Х. Архитектура ханской Казани. К., 2000; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Искусство Казанского ханства: раритеты и методика их изучения // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования. К., 2002; Измайлов И.Л. Завоевание Казанского ханства: причины и последствия // Татарский народ после 1552 года: потери и приобретения. К., 2003; Keenan E. Moscow and Kazan. 1445–1552: A Study in steppe politics: Ph. D. diss., Harvard University, 1965; Pelenski J. Russian and Kazan: Conquest and Imperial Ideology (1438–1560). P., 1974.

*И.Л.Измайлов.*

**КАЗА́Н ХАНЛЫГЫ́ СӘНГАТЕ́**, Идел буе Болгар дәүләте (к. *Болгар бизәлеш сәнгате*) һәм Алтын Урда (к. *Алтын Урда сәнгате*) сәнгатьләре нигезендә барлыкка килә. Шәрекъ, яки мөселман бароккосы стиле, ислам эстетик кануннары йогынтысында, Госманлылар Төркиясе, Кырым, Иран, Әзәрбайҗан мәдәнияте тәэсирендә үсеш ала. Казан Кремле һәм Иске Казан шәһәрлегендәге археол. табылдыклар: биналарның декоратив бизәк фрагментлары, ш.и. гарәп стилендәге бизәк төшерелгән алебастр плитәләр, рәсемле чынаяк кирпечләр һәм төрле таш кисү үрнәкләре, ш.у. уеп ясалган орнаментлар һәм ялтыравык йөгертелгән, нәкышьле керәч әйберләр (зур хумнар (чүлмәкләр), кувшиннар, табаклар, кара савытлары һ.б.), зооморф мотивлар — этәч, тәкә, ат башлары, бизәкле комганнар (к. *Керәч сәнгате*), басма бизәкле һәм ефәк б-н чигеп бизәлгән көн аяк киеме калдыклары — барысы да К.х.с. шаһитлары. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы, С.-Петербургтагы Россия халыклары дәүләт этнография музее, ТР Милли музее тупланмаларында торевтиканың тиңдәшсез үрнәкләре: чүкеп ясалган, гарәп стиле б-н язылган шигъри юллар һәм сабына «Әмин-хан бакырчысы — Насыйр» (Мөхәммәдәмин хан 1484, 1487–95, 1502–18 елларда тәхеттә була) дип уеп язылган җиз шәраб кувшины, атаклы «Казан таҗы», Казан аксөякләре өс киемнәренең алтын җепкырлы бил каптырмалары һәм бизәкле төймәләре, Коръән тартмачыклары, укалап чигелгән япмалар һ.б., декоратив сәнгатьнең югары зәвыклы башка әсәрләре саклана. Рус елъязмаларында һәм башка документаль чыганакларда Казан яулаганнан соң «дәүләт казнасына» алып кителгән (1552) ханлык билгеләре, кыйммәтле бизәнү әйберләре һәм йорт кирәк-яраклары, алтынланган тукымадан тегелгән өс киемнәре һәм кораллар турында мәгълүматлар бар: «Бихисап алтын һәм көмеш, һәм энҗе, һәм кыйммәтле асылташлар, һәм күз явын алырлык укалы кием-салым, һәм кыйммәтле ефәк тукыма, һәм көмеш һәм алтын савыт-саба, һәм һөнәрчелек әйберләре алынды, ганимәт малының исәбе-хисабы юк иде» («Казан патшалыгы турында риваять» — «Сказание о царстве Казанском»). Борынгы татар зиратларындагы кабер ташларында ташка уеп бизәк төшерү сәнгате традицияләре чагыла. Аларның аерым үрнәкләре (2,5 *м* га кадәр биеклектә) уеп бизәкләү техникасының камиллеге, рельефының калкулыгы, орнаментлы бизәкләргә һәм «Шәрекъ бароккосы» сыйфатларына бай булуы б-н аерылып тора. К.х.с. нә кабер ташының арткы ягына еш кына гөл чүлмәгендә утырган купшы чәчәк бәйләме рәвешендә бөтен буена уеп ясалган бизәкләр; кабер ташларының башларына ярымтүгәрәк чәчәк-розеткалар — үсемлек орнаментлы нәкышь композицияләрләр эшләнә; гарәп стилендәге бизәкләр һәм гарәп шрифтындагы («сөлес» имлясы) матур язулар еш очрый. К.х.с. архит-ра, тукыма, зәргәр бизәкләрендә, ш.у. татар орнаменты төшерелгән рус комганы кебек көнкүрештә куллану әйберләрендә чагылыш таба (лотос, лалә, чәчәк букетлары һ.б.), бу исә К.х.с.нең рус осталары иҗатына да билгеле бер күләмдә йогынты ясавы турында сөйли. Татар йогынтысы 16–17 йөз рус боярларының өс-башы, аяк киеме атамаларында (кәзәки, япанча-чапан; тафья, башлык; читек, башмак һ.б.) аеручa нык чагыла.


К.х.с. урта гасырлар иҗатының проф. формада үсешенә йомгак ясау булып тора. Казан яулап алынганнан соң, ул дәүләтчелеген югалтуга бәйле сыйфат үзгәрешләре кичерә. Сәнгатьнең монументаль архит-ра һәм аңа бәйле бизәлеш сәнгате (ташка һәм гипска уеп бизәк төшерү, мозаика, майолика), керәч сәнгате, металлны кайнар ысул б-н эшкәртү кебек югары сыйфатлы затлы төрләре юкка чыга. К.х.с. традицияләре Казан татарларының халык иҗатында, соңгы гасырларның *бизәлеш сәнгатендә* һәм *гамәли-бизәлеш сәнгатендә* дәвам итә.

*Әд.:* Костомаров Н.И. Очерк домашней жизни и нравов великорусского народа в XVI–XVII столетиях. СПб., 1860; Калинин Н.Ф. Раскопки в Казанском Кремле в 1953 г. // Изв. КФАН СССР. Сер. гуманитарных наук. 1955. Вып. 1; Валеев Ф.Х. К истории архитектуры казанских татар XV – первый половины XVI вв. // Вопр. истории, филологии и педагогики. К., 1967. Вып. 2; Халиков А.Х. Происхождение татар Поволжья и Приуралья. К., 1987; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство







**Казан ханлыгы сәнгате мәкаләсенә.** 1. Олуг Мөхәммәд ханның төрек солтаны Морад II гә язган хаты. 1428. ТР Милли архивы; 2. Кабер ташының арткы ягына уеп төшерелгән бизәк. 16 йөзнең 1 нче яртысы. Саба р-нының Пановка авылы; 3. Кабер ташындагы уеп төшерелгән кайма бизәк. 16 йөзнең 1 нче яртысы. Биектау р-нының Кече Солабаш авылы (Ф.Х. Вәлиевнең 2 нче һәм 3 нче реконструкциясе); 4. Балчыктан ясалган кувшиннар. 15 йөз –16 йөзнең 1 нче яртысы. «Казан Кремле» Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы; 5. Итек фрагментлары. Күн, ефәк. Чигү. 15 йөз –16 йөзнең 1 нче яртысы. ТР Милли музее; 6. Шәраб кувшины. Җиз. Чүкеп бизәк төшерү, уеплау, кою. 16 йөзнең 1 нче яртысы. ТР Милли музее; 7. Декоратив төймәләр. Көмеш, алтын йөгертү, асылташлар. Җепкыр, бөртекләү. 16 йөзнең 1 нче яртысы. ТР Милли музее; 8. Бил каптырмасы. Алтын җепкыр, бөртекләү. 16 йөзнең 1 нче яртысы. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы; 9. Япма. Тукыма, алтын җеп. Чигү. 16–17 йөзләр. ТР Милли музее.

Татарии. К., 1987; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Искусство Казанского ханства: раритеты и методика их изучения // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАЗА́Н ХАНЛЫГЫ́ ЯУЛАНГАННА́Н СОҢГЫ́ ФЕТНӘ́-ЧУАЛЫШЛА́Р**, Идел буе һәм Урал алды халыкларының патша хакимияте алып барган социаль-икътисади, милли һәм дини изүгә каршы кораллы чыгышлары.

**1572–73 еллардагы кузгалышка** салым изүенең көчәюе, 1558–83 тәге Ливон сугышына халыкны күпләп мобилизацияләү сәбәпче була. Ул 1572 нең җәендә Болын ягында башлана. Көзгә Казанга кадәр тулысынча Болын ягын, сәүдәгәр Строгановлар җирләренә кадәр Арча ягын колачлый, Чабаксар шәһәре тирәсендә Тау ягына да күчә. Рус хөкүмәте тарафыннан баш күтәрүчеләргә каршы җибәрелгән гаскәр 1572 нең ахырында тар-мар ителә. 1573 нең көзендә Муром шәһәрендә яңа зур гаскәр туплана, ләкин ул яуга кузгалмый, чөнки баш күтәрүчеләр үз гаепләрен танып хакимияткә мөрәҗәгать итәләр. Кузгалыш җитәкчеләренең исемнәре һәм аның нечкәлекләре тикшеренүчеләргә мәгълүм түгел. Баш күтәрүчеләргә каршы көрәштә бирелүчеләрне һәм хөкүмәт ягына чыгучыларны кичерү турында вәгъдә бирүләр киң кулланыла. Кузгалышның тукталуына Кырым татарлары явының 1572 нең 26 июлендә Молоди янында (хәзер Мәскәү өлкәсенең Чехов р-ны) җиңелүе сәбәпче булуы ихтимал. Яңа кузгалышларны булдырмау өчен Болын ягында Кокшайск шәһәре нигезләнә (1574).

**1581–84 тәге кузгалыш** «чирмеш сугышы» буларак мәгълүм. Анда татарлар да актив катнаша. Хакимиятләрнең салымнар җыйгандагы рәхимсезлеге һәм көчләп христианлаштыру сәбәпче була. 1581 нең көзендә башлана. Болын ягының зур өлешен колачлый, ш.у. Тау ягына да күчә. 1582–84 тә рус хөкүмәте баш күтәрүчеләргә каршы Ф.М.Лобанов-Ростовский, И.М.Воротынский, И.С.Туренин, Ф.В.Шереметев, Д.П.Елецкий, Г.П.Засекин, И.А.Ноготков җитәкчелегендә 7 армия җибәрә. Үзәктән килгән гаскәрләрдән тыш, кузгалышны бастыруда Түбән Новгород, Арзамас, Казан, Зөя воеводаларының отрядлары катнаша. Ике якның да гамәлләре аеруча аяусыз була, сугыш хәрәкәтләре зур колач ала. Баш күтәрүчеләргә каршы көрәш барышында Царёвосанчурск (хәзер Санчурск), Царёвококшайск (хәзер Йошкар-Ола), Малмыж, Уржум шәһәр-кальгалары нигезләнә. Ихтимал, кузгалышның 1584 нең ахырында басылуы җирле халыкның патша Фёдор Иоанновичның амнистия игълан итүенә өмет баглавы б-н бәйле булгандыр.

**1606–10 дагы кузгалыш** тәхеткә «законлы патша» Дмитрий Ивановичны кайтару лозунгы астында «*Болгавыр заман*» чорында була. Аны рус аксөякләре һәм дворяннары, казаклар вәкилләре җитәкли; кузгалышта йомышлылар һәм крәстияннәр — татарлар, чуашлар, чирмешләр, мордвалар актив катнаша. Күтәрелешкә 1606 ның июнендә Зөя шәһәре янында И.И.Болотниковның аркадашы «патша улы Петр» гаскәрләре тору этәргеч бирә. Болотников хәрәкәте башлангач, кузгалыш үзе Арзамас шәһәренә күчә. 1606 ның көзендә җирле дворяннар И.Б. һәм М.Б.Доможировлар, яңа чукындырылган йомышлы А.Б.Казаков, мордва старшиналары Москов һәм Варгадин җитәкчелегендә баш күтәрүчеләр Курмыш, Алатырь, Цивильск шәһәрләрен алалар, Түбән Новгород шәһәрен камыйлар. 1606 ның декабрендә — 1607 нең гыйнварында алар Г.Г.Пушкин һәм С.Г.Ододуров армиясе тарафыннан тар-мар ителәләр. 1608 нең көзендә Ялган Дмитрий II нең Тушинодагы хөкүмәте ярдәме б-н янә активлашалар. Арзамас шәһәре яңадан кузгалыш үзәгенә әверелә. Күтәрелешләр Түбән Новгород, Алатырь, Ядрин, Козьмодемьянск, Чабаксар, Зөя, Яранск, Царёвосанчурск, Царёвококшайск өязләрен колачлый. Василий Шуйскийга тугры воеводалар контролендә Уржум, Малмыж, Арча, Алат шәһәрләре б-н Казан өязе

һәм 1608 нең ноябрендә баш күтәрүчеләр штурм б-н алырга омтылган Түбән Новгород шәһәре генә кала. 1609 ның гыйнварында Әстерханнан килгән Ф.И.Шереметев гаскәре Казан отрядлары б-н бергә баш күтәрүчеләрне Зөя янында тар-мар итә. Февральдә баш күтәрүчеләр Царёвококшайск, Яранск һәм Царёвосанчурск шәһәрләреннән куыла. 1609 ның мартында О.Зюзин һәм А.Хохлов җитәкчелегендә Казаннан килгән отрядлар аларны Борындык авылы тирәсендә (Зөя өязе) зур җиңелүгә дучар итә. 1609 ның җәе ахырында һәм көзендә сугыш хәрәкәтләре яңадан башлана. Тау ягында баш күтәрүчеләр Чабаксар, Ядрин, Курмыш, Алатырь һәм Козьмодемьянск шәһәрләрен билиләр, Зөя шәһәрен камыйлар. Болын ягында алар Кокшайск һәм Яранск шәһәрләрен алалар. 1610 ның ахырында баш күтәрүчеләр йомышлы татар кенәз К.Смиленев җитәкчелегендә Казанны штурмларга омтылалар, ләкин җиңеләләр. Ялган Дмитрий IIнең үлеменнән соң көрәш тәмамлана. Ш.у. к. *Җангали хәрәкәте*.

*Әд.:* Ермолаев И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. К., 1982; Димитриев В.Д. Чувашия в эпоху феодализма. Чебоксары, 1986; Бахтин А.Г. XV – XVI века в истории Марийского края. Йошкар-Ола, 1998.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ ГО́СПИТАЛЕ**, хәрби хезмәткәрләрне стационар дәвалау, хәрби медицина экспертизалары һәм фәнни тикшеренүләр үткәрү өчен иң әүвәлге медицина учреждениеләреннән берсе. Госпиталь күп тапкырлар үзгәртеп төзелә, хәзерге вакытта 19 йөз рус архит-расы истәлеге булып саналган биналарда урнаша. Бу комплекска бер катлы ике турыпочмаклы корпус (1809, арх. Я.М.Шелковников), классицизм стилендәге ике катлы турыпочмаклы корпус (1822, арх. П.Г.Пятницкий), икенче катлар буйлап соңгы классицизм стилендәге ябык галерея б-н тоташкан икешәр катлы ике турыпочмаклы корпус (1842, арх. П.Г.Пятницкий; 1872, арх. Л.К.Хрщонович) керә.

Казанда хәрби госпиталь 1809 елда ачыла һәм ул Польшадан китерелгән пехота полкы лазаретын (240 урын) алыштыра. Тулысынча Казан коменданты карамагына бирелә һәм Арча кыры тирәсендә урнаштырыла. 100 елдан артык ул Россиянең көнчыгыш өлешендә иң зур хәрби-дәвалау учреждениесе булып санала. 1820 дә элекке Богырыслан өязенең Сергиев минераль суларында Казан госпиталенең авыру солдат һәм офицерларын күкертле водород ванналары б-н дәвалау бүлеге ачыла, 1870 тә ул хәрби-санитар станция итеп үзгәртелә; 1871 дә Барабаш Аланында (Самара шәһәреннән 15 чакрым ераклыкта) К.х.г.нең кымыз б-н дәвалау станциясе ачыла. Идел буенда ваба эпидемиясе (1830 еллар) чорында К.х.г. бу авырудан интегүчеләрне кабул итә.

1838 дә К.х.г. каршында 75 кешегә исәпләнгән өчьеллык фельдшерлар мәктәбе оештырыла; дәресләрне госпитальнең табибләре — Казан ун-тын һәм Петербург хәрби-диңгез академиясен тәмамлаган П.Я.Сергеев, М.А.Нечаев, И.И.Зедерштедт һ.б. алып бара. Госпитальдә профессорлар А.И.Белов, В.С.Бронников, Л.Х.Вагнер, А.А.Генрици, Ф.О.Елачич, И.И.Зедерштедт, А.А.Китер, Н.Я.Теплов, К.П.Турино, Э.А.Шарбе эшли. 1864 тән К.х.г. үз эченә Казан, Сембер, Саратов, Әстерхан, Урал, Тургай губерналарын, ш. у. Бүки Урдасын алган Казан хәрби округының округ дәвалау учреждениесе функцияләрен үти. 1869 да Казан округы хәрби-медицина идарәсе каршында — хәрби-медицина җәмгыяте (аны П.И.Савостьянов җитәкли), 1871 дә К.х.г. каршында монастырь тыңлаучылары өчен шәфкать туташлары бүлекчәсе ачыла. Госпиталь Казан ун-тының мед. ф-ты студентлары өчен уку базасы булып тора.

К.х.г. эшчәнлегенә П.С.Новицкий зур өлеш кертә, аның хезмәтләре «Врач» ж-лында (1890) һ.б. мед. басмаларында нәшер ителә.

Рус-төрек кампаниясе (1877–78) вакытында К.х.г. табибе М.Я.*Капустин* кыр шартларында дезинсекция һәм дезинфекция үткәрү өчен пар б-н эшли торган мичкә-камера уйлап таба (соңрак аны «Капустин мичкәсе» дип атыйлар).

1892–93 тә В.С.Бронников җитәкчелегендәге мед. хезмәткәрләре төркеме Казан хәрби округында ваба эпидемиясен бетерүдә катнаша. 1903 тә К.х.г. штатында 7 табиб, 13 фельдшер эшли, госпиталь 423 урынга исәпләнә. 1914 тә анда 1160 койка була, соңрак койкалар саны 2 меңгә җитә.

Фронтта мед. хезмәткәрләрен күпләп югалту аркасында фельдшерлар мәктәбендә укыту сроклары кыскартыла. К.х.г. 1915 тә — 150, 1916 да 281 фельдшер укытып чыгара. Гражданнар сугышы елларында К.х.г. илнең көнчыгышында иң зур госпиталь була.

Окт. рев-циясеннән соң госпитальдә 1740 урын исәпләнә. 1918 дә туберкулёз бүлеге эшли башлый, корсак тифы эпидемиясенә бәйле рәвештә 5 йогышлы авырулар бүлеге ачыла. 1910–20 дә госпитальдә А.В.*Вишневский*, Л.П.Левшин, С.С.*Зимницкий*, Г.А.*Клячкин*, И.И.Колгин, С.Н.Рукавишников, Н.С.Охотин һ.б. эшлиләр.

1919 да дәвалау корпуслары төзекләндерелә, медикаментлар, азык-төлек б-н тәэмин итү яхшыртыла. 1936–39 да капиталь реконструкция үткәрелә. 1941 нең җәенә К.х.г.ндә 1000 урын була.

Бөек Ватан сугышы елларында К.х.г. «361 нче эвакогоспиталь» дип йөртелә. Анда хирургия, оториноларингология, нейрохирургия, дәвалау, травматология, күз авырулары, рентген бүлекләре, лаб-яләр эшли, урыннар саны 2320 гә җиткерелә. К.х.г. базасында мед. хезмәткәрләрен кабаттан әзерләү курслары ачыла, аларны 300 табиб-травматолог, 13 нейрохирург, 1039 шәфкать туташы тәмамлый.

1944 тә Казанда Идел буе хәрби округы госпитальләре табибләренең фәнни конференциясе үткәрелә, анда гамәли һәм фәнни-тикшеренү эшләре тәҗрибәсенә йомгак ясала. Сугыш чорында госпиталь табибләренең күмәк хезмәте нәтиҗәсе булган 40 фәнни эш басылып чыга (200 дән артык фәнни-тикшеренү эше Ленинград һәм Мәскәүдән эвакуацияләнгән фәнни-тикшеренү ин-тлары табибләре б-н берлектә эвакогоспитальләр базасында үткәрелә). Сугыштан соң К.х.г.нең штаты кыскартыла, урыннар саны 1200 дән 400 гә (1959) кадәр кими. Госпитальдә дәвалау, физиодәвалау, кардиология, гастроэнтерология, пульмонология, хирургия, эренле хирургия, урология, неврология, психиатрия, анестезиология һәм реанимация, күзләрне дәвалау, оториноларингология, травматология, тире-венерология авырулары бүлекләре эшли. Баш табиб — Л.Э.Ахмедянов (2008 дән).

*Әд.:* Очерки истории Казанского военного госпиталя. К., 1991; Большая медицинская энциклопедия. М., 1977. Т. 6.

*Л.Э.Ахмедянов, Д.Р.Нуретдинова.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ О́КРУГ МӘХКӘМӘСЕ́**, хәрби коры җир көчләренең округ идарә системасындагы хәрби юстиция органы. Император Александр II тарафыннан расланган, 1871 елның 15 сентябрендә кабул ителгән «Казан хәрби округы гаскәрләрендә хәрби-мәхкәмә уставын гамәлгә кертү турында нигезләмә» буенча оештырыла. Хәрбиләр, запастагы хәрбиләр, ш.у. округның хәрби хәлдә дип белдерелгән терр-ясендә яшәүче гражданнар тарафыннан кылынган җинаятьләрне тикшерә. Даими (мәхкәмә рәисе һәм хәрби судьялар) һәм вакытлы (хәрби округ гаскәрләре командующие тарафыннан 4 айга билгеләнгән 4 штаб һәм обер-офицерлар) әгъзалардан тора. К.х.о.м. аппаратына өлкән тикшерүче һәм аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче керә. Өязләр һәм округ тикшерү участоклары хәрби тикшерүчеләре мәхкәмәгә турыдан-туры буйсыналар. Эш башкару мәхкәмәнең канцеляриясе тарафыннан алып барыла. Прокурор күзәтчелеге хәрби округ прокуроры һәм аның ярдәмчеләренә ышанып тапшырыла. Округның ерак р-ннарындагы эшләрне хәл итү өчен К.х.о.м. кул астындагы вакытлы хәрби мәхкәмәләр чакырыла (елга 2 мәртәбәдән дә ким булмый). 1898 елда Казан хәрби округы терр-ясе 7 хәрби тикшерү участогына (Казан, Самара, Саратов, Пермь, Уфа, Оренбург һәм Әстерхан) бүленгән була. К.х.о.м. Казан хәрби округы гаскәрләре командующиена һәм Россиянең Баш хәрби мәхкәмә идарәсенә буйсына. ХКСның 1917 елның 22 ноябрендә кабул ителгән «Суд турында»гы 1 нче Декреты һәм Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларның Казан советы кабул иткән 1917 ел 30 ноябрь карары нигезендә 1918 нең мартында Россия армиясен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә юкка чыгарыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1874. Т. 46. № 49905.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1996. Кн. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ О́КРУГЫ**, хәрби-адм. төзелеш һәм гаскәрләр б-н идарә итү органы. 1864 елның 6 августында «Хәрби округ идарәләре турындагы нигезләмәләр»гә туры китереп оештырыла. Россия империясендәге иң зур округларның берсе. Хәрби хезмәткәрләрнең гомуми саны кайчак 800 мең кешедән артып китә. Башта аңа Казан (округ үзәге),

Сембер, Пенза, Самара, Саратов, Әстерхан, Вятка һәм Пермь губерналары терр-яләре керә. 1881 дә Оренбург хәрби округы бетерелгәч, К.х.о. составына Уфа һәм Оренбург губерналары, Урал һәм Тургай өлкәләре кушыла. Гомуми мәйданы — 2 млн. *км*² диярлек, халкы 25 млн. чамасы кеше тәшкил итә. 1917 нең 1 гыйнварына К.х.о. гаскәрләре 98 торак пунктта урнаша. Зур гарнизоннар Казан, Самара, Екатеринбург, Царицин шәһәрләрендә була. Идел буенда 60 гарнизон исәпләнә, алар составына 53 запастагы пехота, 4 артиллерия, 2 пулемёт полкы, 1 казаклар гаскәре, 8 аерым казаклар йөзлеге, 3 запас кавалерия полкы, 9 ополчение дружинасы, ш.у. дистәләрчә башка хәрби учреждение керә; алар составында 500 меңнән артык солдат һәм офицер (округтагы шәхси составның 70% ы чамасы) була. Уралда 38 гарнизон: 26 запас пехота полкы, Себер укчы полкы, 2 казаклар гаскәре, 8 ополчение дружинасы, 180 башка хәрби подразделениеләр керә; хәрби хезмәткәрләрнең гомуми саны 250 меңнән артык кеше тәшкил итә. Округ терр-ясендә 30 дан артык хәрби завод, 20 дән артык госпиталь һәм лазарет була. К.х.о.ның төп вазифалары: матди һәм кеше ресурслары әзерләү, стратегик коммуникацияләрне тиешле хәлдә тоту, илдәге революцион хәрәкәтне бастыруда катнашу. Соңгысын гамәлгә ашыру өчен округта 16 тыл часте тотыла. Округ б-н идарә итү структурасы 1860–74 еллардагы хәрби реформа нигезендә корыла. Округ башында командующий тора (беренче командующий генерал-лейтенант Кнорринг була). Округ б-н Округ советы һәм Округ штабы идарә итә. Соңгысы түбәндәге идарә һәм бүлекләрдән тора: 1) ген.-квартирмейстер идарәсе (бүлекләре — строевой, мобилизацияләү, язу-сызу эшләрен башкару, хәрби-дежур комиссия), 2) округның дежур генералы идарәсе (бүлекләре — инспекторлык итү, хуҗалык, казаклар гаскәрләре, эвакуация, уку йортлары б-н идарә итү, хәрби-юл, канцелярия), 3) интендант идарәсе (әйбер складлары, остаханәләр, заводлар), 4) артиллерия, 5) инженерлык, 6) квартир б-н тәэмин итү, 7) мәхкәмә, 8) хәрби прокурор күзәтчелеге, 9) хәрби-ветеринария, 10) хәрби госпитальләр һәм лазаретлар, 11) хәрби уку йортлары. Шул рәвешле К.х.о. идарәсе 25 генералдан, 105 өлкән офицердан, 100 дән артык гамәли һәм яшерен советниктан тора. К.х.о. төрле төрдәге барлык фронтларны ресурслар, барыннан да бигрәк кеше ресурслары б-н тәэмин итүче гомумроссия базасы була. 1 нче Бөтендөнья сугышының беренче 3 елында хәрәкәттәге армиягә 7950 маршттагы рота (2,4 млн. чамасы солдат һәм офицер) озатыла. К.х.о.нда оештырылган 24 нче армия корпусы ген. А.А.Брусиловның 8 нче армиясе дан казана. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң армиядә таркалу башлана. Дистәләрчә мең солдат үз частеннән кача. 1917 нең марты башында солдатларның революцион чыгыш дулкыны җәелеп китә, аның барышында командованиенең 100 вәкиле, ш.и. округ командующие ген. А.Г.*Сандецкий* кулга алына һәм вазифасыннан читләштерелә. Солдат һәм офицерлар советлары һәм ком-тлары барлыкка килә. 1917 нең июленә 59 гарнизонда — эшче һәм солдат депутатларның берләштерелгән советлары, 14 ендә — солдат депутатлар советлары һәм гарнизон ком-тлары, 7 сендә башка типтагы оешмалар (аларның составына 37 меңнән артык солдат һәм офицер керә) эшли. Болардан тыш, 50 дән артык полк һәм бригада, 800 дән артык рота ком-ты барлыкка килә. Кайбер гарнизоннарда милли ком-тлар оеша (барлыгы 15 мең чамасы солдат һәм офицер). К.х.о.нда илдә беренче *Казан хәрби округы комитеты* оештырыла, ул хәрби частьләр б-н коллектив идарә итүгә дәгъва белдерә. Округ солдатларының революцион чыгышлары тыл частьләре өчен типик формада була: фронтка җибәрүгә массакүләм протест белдерү, а.х. эшләре вакытында ялга җибәрүне таләп итү, 40 яшьтән узган хезмәткәрләрне хезмәттән азат итү, кораллларны контрольдә тоту, милли частьләр оештыру, команда составының хакимиятен чикләү. Дизертирлык гадәти күренешкә әверелә. Армиянең таркалуына солдатларның шактый өлеше крәстияннәрнең аграр чыгышларына каршы көрәшкә җәлеп ителүе дә этәрә, бу эштә 50 меңнән артык кеше катнаша. К.х.о. җитәкчелегенең солдатларның революцион чыгышларын туктатырга сәләтсезлеге командующийларны еш алыштыруга китерә (1917 дә 5 кеше алышына). Солдатларның революцион чыгышларын киметергә тырышып, округ командованиесе 1917 нең 1 маеннан 1 августына кадәр 220 меңнән артык солдат һәм офицерны фронтка җибәрә. Округ солдатлары ген. Л.Г.Корнилов фетнәсенә каршы сугышалар, тыл полкларын күпләп фронтка җибәрүне өзәләр, 1917 нең сентябрендә Казан советы солдатлар секциясенең командующий б-н каршылыкка килүен оештыралар. Окт. рев-циясе көннәрендә К.х.о. солдатлары күпчелек гарнизоннарда Совет хакимиятен урнаштыруда хәлиткеч роль уйныйлар, меңнәрчә солдат кызылармиячеләр отрядларына кушыла, атаман А.И.Дутов һәм ген. А.М.Каледин гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша. Округ командующие итеп прапорщик Н.Е.*Ершов* билгеләнә, соңрак идарә итү комиссарлар советына күчә. 1917 нең декабренә К.х.о. составында 200 мең чамасы хәрби хезмәткәр кала. 1918 нең язында иске армия таркатылу һәм Кызыл Армия оештырылу сәбәпле К.х.о. бетерелә. К.х.о.ның төрле еллардагы командующийлары: генераллар — Кнорринг, К.Р.Семякин, Б.Г.Глинка-Маврин, А.О.Бруннер, Г.В.Мещеринов, А.Г.Сандецкий, Ф.Н.Добрышин, А.З.Мышлаевский; полковниклар В.А.Коровиченко, Н.А.Караулов, М.Н.Архипов; прапорщик Н.Е.Ершов.

*Әд.:* Общий состав управлений местных войск Казанского военного округа. К., 1868; Е ж о в Н. Военная Казань в 1917 году. К., 1927; И о н е н к о И.М., Т а г и р о в И.Р. Октябрь в Казани. К., 1967; И о н е н к о И.М. Солдаты тыловых гарнизонов в борьбе за власть Советов. К., 1976; ш у л у к. Солдатские массы в Октябрьской революции: По материалам Поволжья и Приуралья. К., 1982; Ц е й т л и н Р.С. В борьбе за солдатские массы. К., 1987.

*Р.С.Цейтлин.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ О́КРУГЫ БАШКАРМА́ КОМИТЕТЫ́**, *Казан хәрби округы комитетының* дәвамчысы (1917 елның ноябре – 1918 нең феврале). Казан хәрби округы солдат советларының 2 нче округ съезды карары б-н оештырыла. Аның составына моңарчы Казан хәрби округы ком-ты составында булган большевиклар, сул эсерлар, ш.у. мөселман оешмалары вәкилләре, барлыгы 68 кеше керә. Рәисе — А.К.Евлампиев, әгъзалары — Н.Е.Ершов һ.б. Ком-т составында хуҗалык, хәрби, медицина, ветеринария, контроль-техник, төзелеш, элемтә, гамәлдән чыгару, бюджет-финанс, редакция, агитация комиссариатлары оештырыла. Иске армияне үзгәртеп кору, кызылгвардиячеләр отрядлары оештыру, хәрби-округ элемтәсен юлга салу, солдат депутатлар советлары составын яңарту һ.б. б-н шөгыльләнә. Ком-т атаман А.И.Дутов һәм ген. А.М.Каледин фетнәсен бастыруда булыша, Кызыл Армиянең беренче подразделениеләренә нигез сала.

*Әд.:* Е ж о в Н. Военная Казань в 1917 году. К., 1927.

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ О́КРУГЫ КОМА́НДУЮЩИЕ ЙОРТЫ́** (Сандецкий йорты), архитектура истәлеге. Казанның югарыгы өлешендә Карл Маркс һәм Мөштәри урамнары кисешкән почмакта урнашкан. Бина 1906 елда, фаразлар буенча, архитекторлар К.Л.Мюфке һәм Ф.Р.Амлонг проекты буенча Казан хәрби округы командующие резиденциясе буларак төзелә. 1907–17 дә анда генерал А.Г.Сандецкий яши. Йорт янәшәсендә флигель, төрле хезмәт корылмалары, бакча урнаша.

Г-рәвешле ике катлы кирпеч бина романтик юнәлештәге модерн стилендә төзелгән, сарайларга хас катлаулы, зур күләмле композициягә ия. Урам ягындагы зал бүлмәләре анфилада системасы буенча урнашкан, тәрәзәләре урам ягына карый; торак бүлмәләрен алардан коридор аерып тора. Төп ишек йортның көнчыгыш тарафында урнашкан (хәзерге Мөштәри ур.). Ордеры катлаулы, портигы пар колонналы, өстенә импостлар куелган, уксыман фронтон тимпанына герб урнаштырылган. Ишек өсте сәнгатьле итеп чүкелгән түбә б-н бизәлгән. Төньяк фасад сәнгатьчә эшләнгән дүрт колонна һәм түгәрәк тәрәзә б-н бизәлгән. Түбәнге катның диварлары тирән рустлау ысулы б-н эшкәртелгән. А́ркалы тәрәзәләр архивольтлар б-н каймаланган, алар арасындагы дивар аралыгына пилястралар урнаштырылган. Тәрәзәләре туры почмаклап эшләнгән, югары кат диварлары штукатурланган. Ярымротонда формасындагы залларның берсе бакча ягына чыга. 2 нче каттагы ярымротонда нәфис баганаларга беркетелгән култыксалы балкон б-н уратып алынган. Түбә кыеклары челтәрле металл рәшәткә б-н бизәлгән. Түбә кәрнизе бизәкле кронштейннарга терәлеп тора. Түбә почмакларына вазалар куелган. Йортның тышкы бизәлеше — тулысынча, интерьеры өлешчә сакланган. Сандриклар б-н әйләндереп алынган, ишекләре, челтәрләп эшләнгән үзәк баскыч, урам якның катлаулы һәм матур тышкы күренеше, чүкеп эшләнгән рәшәткәләре б-н аерылып торган таш баскычы, агач кронштейннарны хәтерләткән түшәме, кирпечтән чы-




Казан хәрби округы командующие йорты. Казан. Архитекторлар К.Л. Мюфке, Ф.Р. Амлонг. 1906.
1. 20 йөз башы фоторәсеме; 2. Хәзерге күренеше.

гарылган төрле зурлыктагы мичләре һәм каминнары б-н бина игътибарны җәлеп итә.

Утарның төньяк-көнбатышында урнашкан ярдәмче блок төп бина б-н бер үк вакытта төзелгән. Ул Г-рәвешле ике өлештән тора. Йорт биләмәсенең көньяк чигендә арбалар куюя сарае, ат абзары, кар базы, төньягында төп фасады Грузин урамына (хәзер К.Маркс ур.) караган торак флигель урнашкан. Аның фасадлары эклектиканың классик юнәлешендә төзелгән. Кәрниз икеле кронштейннар б-н бизәләнгән. Фасадны чүкеп эшләнгән рәшәткәләр төгәлли. Утарның коймасы башка корылмалар б-н бер үк вакытта төзелә. Койманың кирпеч баганалары штукатурланган. Чабакса осталары эшләгән чуен рәшәткәгә үсемлек бизәкләр төшерелгән. Утарның төньякта һәм көнчыгышта капкалары бар.

1920 еллар башыннан бинада — Беренче Советлар Йорты, Казан шәһәр советы башкарма ком-ты президиумы, 1924 тән туберкулёз диспансеры урнаша. 1967 дән биредә *ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее* эшли.

*Әд.:* Остроумов В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. К., 1993.

*Л.М.Мортазина, Г.И.Середа.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ О́КРУГЫ КОМИТЕТЫ́**, Казан хәрби округы гаскәрләре командующие карамагындагы аерым киңәшмә органы. Казан хәрби округы составында беренче хәрби округ ком-ты Саратов шәһәрендә 1 нче хәрби округ конференциясе (1917 елның марты) карары буенча Саратов гарнизоны хәрби ком-ты һәм солдат депутатларның Самара советы инициативасы нигезендә оештырыла. Казанда хәрби округ 10 апрельдә оештырыла, аның составына Казан хәрби округының 98 гарнизоны вәкиле керә. К.х.о.к. б-н җитәкчелек итү өчен башкарма ком-т һәм башкарма бюро сайлана. Җитәкчеләре: А.Орлов, С.Всесвятский, В.М.Михайловский, Г.Ф.Никитин, А.К.Евлампиев. 1917 нең12 апрелендә К.х.о.к.ның хокуклары һәм вазифалары турында нигезләмә («Казан хәрби округы комитеты конституциясе») кабул ителә һәм ул раслату өчен хәрби округ командующие А.З.Мышлаевскийга җибәрелә. Командующий үзенең хакимиятен чикләүгә һәм округта ике хакимиятлелекне раслауга каршы була. К.х.о.к. эшче һәм солдат депутатларның Казан советы башкарма ком-ты тарафыннан да яклау тапмый. К.х.о.к. Россия армиясенең тыл частьләрен демократияләштерүдә, командирлар составын чистартуда һ.б.да катнаша. К.х.о.к. башлангычында 2 нче хәрби округ конференциясе чакырыла (Казан, 1917 нең 28 мае). Комитет җитәкчелеге баштарак күпчелекне тәшкил иткән эсер-меньшевиклар карашларын яклый һәм Вакытлы хөкүмәткә теләктәшлек белдерә. Илдә кризисның тирәнәюе һәм ком-т составында сул эсерлар позициясенең ныгуы 1917 елның җәендә аның карарларын кискенләштерүгә китерә: ком-т әгъзалары фронтта үлем җәзасы кертүгә каршы чыгалар, ген. Л.Г.Корнилов фетнәсен якламыйлар (1917 нең августы). Окт. рев-циясе вакытында хакимиятнең Советларга күчүенә каршы булалар. 2 нче хәрби округ съезды карары нигезендә 1917 нең ноябрендә К.х.о.к. таркатыла һәм Казан хәрби округы башкарма ком-ты оештырыла. Ул «Известия Казанского военно-окружного комитета» г-тасын чыгара башлый.

*Әд.:* Ионенко И.М., Цейтлин Р.С. Казанский военно-окружной комитет (апрель–октябрь 1917 г.) // Общественно-политическое движение и классовая борьба на Средней Волге (конец XIX — начало XX века). К., 1972.

*Р.С.Цейтлин.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ О́КРУГЫ ШТАБЫ́ БАСМАХАНӘСЕ́**. 1864 елның сентябрендә Казан хәрби округы барлыкка килгәч үк оеша. 1880 еллар уртасында басмаханәдә — 16 кеше, 1890 еллар ахырында 30 га якын кеше эшли. 1890 еллар башында тиз баса торган өч машина, 3 — ташбасмаханә һәм 2 ташбасма станогы б-н җиһазландырыла, 412 поттан артык шрифты була. Басма продукция хәрби частьләр һәм хәрби уку йортлары өчен әзерләнә, һәр елны 2 меңнән алып 5 мең сумга кадәрге шәхси заказлар да кабул ителә. 1901–17 еллар арасында 397 басма дөнья күрә, алар арасында рәсми-ведомство материаллары, уку-укыту, хәрби хезмәт буенча белешмәлекләр һәм гамәли кулланмалар була. 1918 дән ул Идел буе хәрби округы басмаханәсе дип йөртелә башлый. 1919 да аның базасында 11 нче дәүләт басмаханәсе оеша.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Становление и развитие татарской советской книги. К., 1989; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

*Г.Г.Габделганиева.*

**КАЗА́Н ХӘРБИ́ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, хәрби уку йорты. 1866 елның 1 сентябрендә Казан пехота юнкерлар уч-щесе буларак ачыла, штатта 200 юнкер була (1870–300, 1876–400), Казан хәрби округы дивизияләре өчен офицерлар әзерли. Беренче башлап уку вакыты 2 ел итеп билгеләнә, 1901–07 дә — 3 ел (2 махсус сыйныф, 1 гомуми). Училищегә яшүсмерләрне тулы урта белем б-н имтихансыз кабул итәләр. 1903 нең 27 гыйнварыннан Хәрби министр фәрманы б-н уч-ще байрак б-н бүләкләнә. 1909 да К.х.у. итеп үзгәртелә. Белем бирү дәрәҗәсе буенча Россия хәрби уку йортларының 2 төркеменә керә (Петербург, Мәскәү һәм Киев уч-щеләре б-н беррәттән). Яхшы китапханә, манеж була; тәҗрибәле укытучылар эшли. Тәмамлаучыларның күбесе Россиянең югары хәрби бүләге — Изге Георгий ордены б-н бүләкләнә (капитан К.А.Моисеев, подполковник А.С.Полянский, полковник Н.И.Тихомиров, поручик К.В.Тхоржевский һ.б.).

*А.В.Гарзавина.*

**«КАЗА́Н ХИ́МИЯ ЗАВОДЫ́** Ушков П.К. һәм К°», 1893 елда «П.К.Ушков һәм К° химия заводлары ширкәте» тарафыннан төзелә, 1883 тә тупланган пай нигезендә барлыкка килә. Идарәсе Мәскәүдә була, аның б-н И.П., А.И. һәм К.К.Ушковлар идарә итә. Җитештергән төп әйберләре — күкташ мае, сульфат, күкерт һәм тоз кислоталары (кулланучысы — Казан дары з-ды). Эшләүчеләр саны 1910 дә — 150 кеше, 1913 тә — 180, 1916 да — 369, 1917 дә янгынга кадәр — 250, янгыннан соң — 165, 1920 дә — 220 кеше. Елга уртача 344245 пот күкташ мае, 122958 пот сульфат җитештерелә. 1917 елгы янгын нәтиҗәсендә завод корылмаларының шактый өлеше җимерелә. Шул ук елда Мәскәүдә «П.К.Ушков һәм К° ширкәте предприятиеләренә үзәк эшче контроле» оештырыла. 1918 елның апрелендә булып узган П.К.Ушков ширкәте химия заводлары, пр-тиеләре эшчеләре һәм хезмәткәрләре делегатлары съездыннан соң, май аенда завод — дәүләт карамагына, 1919 да «Төп химия сәнәгатенең дәүләт заводлары берләшмәсе»нә күчә, завод «Казанның элеккеге Ушков химия заводы» исемен ала (директоры — И.В.Шпади). Хәрби сәнәгать ихтыяҗлары нәтиҗәсендә 1919 ел ахырына ул тулаем диярлек торгызыла, 1920 дә планны үтәү йомгаклары буенча Россия химия пр-тиеләре арасында 2 нче урынны ала. 1921 дә икътисади кризис аркасында ябыла.

*Әд.:* Белялов У.Б. Руководство хозяйственным строительством в Татарии в годы гражданской войны (1918–1920). К., 1963; Петрова А.А., Лифшиц И.М., Цитрина Л.Н. Большая химия Татарии. К., 1967; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976.

*К.А.Нәҗипова.*

**КАЗА́Н ХИ́МИЯ ИНСТИТУТЫ́**, фәнни-тикшеренү учреждениесе, 1964 елда 405 нче дәүләт фәнни-тикшеренү ин-ты (Ленинград) базасында оештырыла. 1966 дан Казан химия фәнни-тикшеренү ин-ты (1999 дан дәүләт унитар пр-тиесе, 2005 тән АҖ). Институт составында (2012) — 17 фәнни-тикшеренү лаб-ясе һәм бүлеге, 4 цехы булган тәҗрибә-сәнәгать производствосы. Фәнни-тикшеренү эшчәнлеге кешенең тире катламын массакүләм юк итү кораллары

тәэсиреннән, сәнәгатьтә файдаланыла торган күп кенә агулы һәм зарарлы матдәләрдән саклау чаралары булдыруга юнәлдерелгән. 1980 еллар уртасына кадәр тикшеренүләрнең тагын бер юнәлеше — төрле тирәлекләрдә агулы һәм зарарлы матдәләрне табу (индикацияләү) ысулларын эшләү гамәлдә була. 1968 дән Казан химия ин-ты — РФ хәрби-сәнәгый комплексының төп ин-ты, илнең фәнни, конструкторлык һәм сәнәгый оешмалары б-н оештыру һәм фәнни-методик җитәкчелекне тәэмин итә. Кешене әйләнә-тирә мохитнең тискәре факторларыннан саклауның нәтиҗәле чараларын эшләү өчен төрле ситуацияләрдә «кеше – саклау чаралары – әйләнә-тирә мохит» системасында нигезле тикшеренүләр үткәрелә. Күп катлаулы күзәнәкчел полимер системалар б-н нурланыш энергиясенең көчле импульслы агымнары тәэсир итешүе процессларын өйрәнү, тәэсир итүче яктылык ташкыннарын көчсезләндерү факторларын ачу РФ Кораллы көчләренең шәхси составына, авария-коткару бүлекләренә, янгын сүндерүчеләргә, атом-төш коралы шартлаганда көчле яктылык нурланышыннан шәхси саклану чаралары булдыруга ярдәм итәләр. Квазидинамик режим шартларында күп катлаулы күзәнәкле системалар аша сыек һәм газсыман агулы матдәләр үтү процессларын тикшерү нигезендә яхшы эргономик сыйфатка һәм югары саклау үзлекләренә ия булган саклагыч киемнәр булдырыла. Саклагыч кием кигән кешенең эшләү сәләтенә йогынты ясаучы факторлар ачыклана һәм алар б-н идарә итү ысуллары эшләнә, шуның нәтиҗәсендә сыек һавалы һәм күчмә һава тапшыру — чистарту системалары төзергә мөмкин була, алар әйләнә-тирә мохиттән тулысынча аерылган авария (һәлакәт) шартларында озак эшләүне тәэмин итәләр. Көчле агулы матдәләрне, инсектицидларны, төрле тирәлектә (һава, су, туфрак, азык-төлек) авыр металл тозларын һәм пестицидларны билгеләү өчен югары сизгерлекле һәм үзенчәлекле ысуллар эшләнә. 1980 еллар башында җирлек мониторингы, су б-н тәэмин итү һәм вет. хезмәтләре өчен стационар һәм күчмә лаб-яләр оештырыла. 2006 га кадәр 40 лап төрдәге саклагыч материаллар, аеруча агулы матдәләрне индикацияләү яки саклау чараларының ышанычлылыгын һәм сыйфатын бәяләү буенча 26 методика эшләнә; РФ Кораллы көчләренә 41 гомумигаскәри һәм махсус саклау чаралары комплекты һәм индикацияләр тапшырыла. Сәнәгый саклау чараларын эшләүгә шактый әһәмият бирелә. Хлордан, аммиактан, көчле агулы аминнар һәм аларның кушылмаларыннан, куертылган к-та һ.б. агулы һәм агрессив химик продуктлардан саклану өчен махсус комплектлар булдырыла. 40 лап төрдәге саклагыч эшләнмә сәнәгать җитештерүенә тапшырыла. Химик коралны юк итү заводларында хезмәт итүчеләр өчен саклау чаралары эшләнә һәм җитештерелә. Тикшеренүләрнең яңа юнәлешләре — ионлаштыргыч һәм электромагнит нурланышлардан, вибрацияләрдән саклану чараларын эшләү; азык-төлек, җиңел сәнәгать продукциясен, табигый һәм сәнәгать материалларын, халык куллану товарларын радиологик сынау һәм контрольдә тоту һ.б. Институт РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты, Технол. фәнни-тикшеренү ин-ты (Электросталь ш.), Химия фәнни-тикшеренү ин-ты (Тамбов ш.), РФ Оборона министрлыгының Радиация, химик һәм биол. саклану хәрби ун-ты (Мәскәү) һ.б. фәнни оешмалар б-н элемтәдә тора. 6 кешегә ТР Дәүләт бүләге, 8 кешегә РСФСР, ТАССР, ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе исеме бирелә; 50 хезмәткәр СССР һәм РФ орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә. Институт хезмәтләре ВДНХның, Бөтенроссия күргәзмә үзәгенең алтын, көмеш, бронза медальләре, дипломнары б-н билгеләнә. Фәнни тикшеренүләргә В.С.Абрамов, П.В.Дубилей, Г.П.Шарнин, Г.Г.Жиляев, И.Н.Зарипов һ.б. зур өлеш кертә. Институт директорлары — А.Ш.Вәлиуллин (1964–82), Г.П.Шарнин (1982–97), Р.Х.Фәтхетдинов (1998 дән).

*В.Г.Абзалова.*

**КАЗА́Н ХИ́МИЯ КОМБИНАТЫ́**, к.«*Нәфис Косметикс*».

**КАЗА́Н ХИ́МИЯ МӘКТӘБЕ́ МУЗЕЕ́**, *Казан университеты* каршындагы *Бутлеров А.М. исемендәге Химия институты* карамагында, 1837 елда арх. М.П.Коринфский проекты б-н ун-тның махсус физ.-химия лаб-ясе өчен төзелгән бинада урнашкан. Музей коллекцияләре 19 йөз уртасыннан *Казан химия фәнни мәктәбе* үсеше тарихын чагылдыра. Музей



Казан химия мәктәбе музее.
19 йөз экспонатларын саклау залы.

мәйданы — 310 *м*², фондлар 6 меңнән артык саклау берәмлеген үз эченә ала. Лаб-ядә эшләүче һәм рутенийны — платиналар төркемендәге 6 нчы элементны һәм платинасыман металларның кайбер кушылмаларын беренче булып ачкан галим К.К.*Клаус* музей коллекцияләрен төзү-оештыру эшен башлап җибәрә. Музейда саклаучы хезмәткәрләр булып күп кенә танылган галимнәр (А.Н.Попов, С.Н.*Реформатский*, И.И.Канонников, И.В.Сорокин һ.б.) эшли. Музейда 19 йөзгә караган интерьерлар, мебель һәм лаб. җиһазлары; уку аудиториясе, А.М.Бутлеровның кабинеты һәм фәнни китапханәсе, лаб. китапханәсе саклanган. Экспонатлар арасында — беренче тапкыр Казан галимнәре тарафыннан алынган синтетик *анилин* (Н.Н.*Зинин*), беренче өченчел спирт классыннан триметилкарбинол (А.М.Бутлеров), Казан химия фәнни мәктәбенең танылган вәкилләре (В.В.*Марковников*, М.М.*Зайцев*, Е.Е.*Вагнер*, Ф.М.*Флавицкий*, С.Н.Реформатский, А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар һ.б.) тарафыннан синтез юлы б-н китереп чыгарылган һ.б. препаратлар бар. Музей тупланмасында Казан химикларының шәхси автографлары язылган китаплары, аларның бюстлары һәм портретлары, 1837 дән 1900 гә кадәр булган лаб. документлары, тәҗрибәләр өчен А.Е.Арбузов тарафыннан үз кулы б-н эшләнгән пыяла химия савыт-сабалары саклана. 1929 да 5 нче Менделеев съезды карары б-н галимнең 100 еллык юбилее уңаеннан ачылган, Бутлеров А.М. исем. Химия институтын оештыру һәм ин-т эшчәнлеге тарихына багышланган даими экспозиция киңәйтелә. Органик химия тарихына багышланган экскурсияләр үткәрелә. Музей химия һәм фармация тарихы буенча Европа музейлары юлкүрсәткече исемлегенә кертелгән. Аның бинасында Казан химия фәнни мәктәбе галимнәре хөрмәтенә 9 мемориаль такта урнаштырылган. 20 йөз уртасыннан музей мөдире вазифаларын Бутлеров А.М. исем. Химия ин-ты хезмәткәрләре В.М.Зороастрова (1950–80), В.С.Виноградова (1980–92), А.В.Фуженкова (1992–98) башкаралар; 1999 дан мөдир — Т.Д.Сорокина.

*Әд.:* По музеям университета: Буклет. (У. к.), (Е. к.). *Т.Д.Сорокина.*

**КАЗА́Н ХИ́МИЯ ФӘННИ́ МӘКТӘБЕ́**, Казан ун-тында 19 йөздә К.К.*Клаус*, Н.Н.*Зинин* һәм А.М.*Бутлеровларның* гыйльми эшләре җирлегендә барлыкка килә. Мәсьәләләргә теоретик яктан тирән якын килү, җитештерү б-н бәйләнеш, мәгариф һәм фәнни-агарту эшчәнлеге, буыннар эзлеклелеге б-н характерлана. К.х.ф.м. 1830 еллар уртасында барлыкка килгән дип фаразлыйлар, бу Казан ун-тында химия лаб-ясенең махсус корпусы (хәзер *Бутлеров А.М. исемендәге Химия институты*) төзелеше тәмамлану, ш.у. Н.Н.Зинин һәм К.К.Клаусның укыту эшчәнлеге башлану б-н аңлатыла. Шул заман өчен аппаратлар һәм приборлар б-н яхшы җиһазландырылган, җитәрлек күләмдә платина һәм пыяла савытлар б-н тәэмин ителгән бу лаб-ядә Н.Н.Зинин ароматик нитрокушылмаларның аминокушылмаларга кайтарылу реакциясен ача (*Зинин реакциясе*) һәм синтетик *анилин* алу ысулын таба (1842), бензидин кушылмаларын барлыкка китереп, яңадан төркемләнүне гамәлгә ашыра; К.К.Клаус Урал чыганагының платина рудалары калдыкларында рутений элементын ача (1844) (Россиядә ачылган бердәнбер табигый элемент, аның исеме б-н атала). Аларның шәкерте А.М.Бутлеров органик кушылмаларның *химик төзелеш теориясен* тәкъдим итә, шуның б-н матдәләрнең физик һәм химик үзлекләре атомнар табигатенә һәм органик кушылмаларның молекулалары төзелешенә бәйле булуын дәлилли. Теория изомерия күренешенә логик аңлатма бирә, шуның нәтиҗәсендә таутомерия турындагы тәгълиматка нигез салына; химиклар органик молекулаларны конструкцияләү һәм лаб-ядә синтезлау мөмкинлеге ала. Теоретик нигезләрнең дөреслеге А.М.Бутлеров тарафыннан экспериментал ь яктан дәлилләнә: химик төзелеш теориясе нигезендә өчле спиртларның билгесез

классы вәкиле — өчле бутил спирты (1864), изобутан (1866), изобутилен (1867) һ.б. алына, полимерлашу гамәлгә ашырыла. А.М.Бутлеровның шәкертләре — В.В.*Марковников*, А.Н.*Попов,* А.М.*Зайцев* — аның теоретик һәм эксперименталь эшләрен дәвам итәләр. В.В.Марковников химик төзелеш теориясен химик кушылмаларда атомнарның үзара тәэсирләшү тәгълиматы б-н тулыландыра, бу тәгълимат реакцияләрнең соңгы продуктлары төзелешен аңлата, химик реакцияләр барышының төгәл фәнни фаразлау юлларын ача (1869, *Марковников кагыйдәсе*); аның тарафыннан циклоалканнар рәтендә изомер әверелешләр өйрәнелә, органик кушылмаларның яңа классы — нафтеннар ачыла (1883), фән буларак *нефть химиясенә* нигез салына. А.Н.Попов структур органик химия үсешенә өлеш кертә, кетоннарның оксидлашу кагыйдәсен тәгъбирли (1869, *Попов кагыйдәсе*). А.М.Зайцев органик кушылмаларның төрле классларын — икеле һәм өчле спиртлар (1875), оксикислоталар, күп атомлы спиртлар һ.б. синтезлау ысулларын эшли (ш.у. к. *Зайцев кагыйдәсе, Зайцев–Вагнер реакциясе*). Ул К.х.ф.м.н таныткан шәкертләр йолдызлыгын тәрбияли (исемлек 72 исемнән тора), алар арасында: Е.Е.*Вагнер* — кабатлы бәйләнеше булган органик кушылмаларның оксидлашу реакциясен ача (1887, *Вагнер реакциясе*), беренче төр камфенлы яңадан төркемләү ысулын (1899, *Вагнер-Меервейнның яңадан төркемләү ысулы*), төрле терпеннарның төзелешен билгели; С.Н.*Реформатский* — β-оксикислоталарны синтезлау ысулын ача (1887, *Реформатский реакциясе*), өчле спиртларның кайтарылуын өйрәнә, күбатомлы спиртлар ала; И.И.*Канонников* — органик кушылмаларның оптик активлыгын өйрәнеп, органик химиядә тикшеренүләрнең физик ысуллар башлангычына нигез сала; Ф.М.*Флавицкий* — терпеннар, амиленнар, төрле тоз гидратларын өйрәнүгә, эремәләрнең химик теориясе үсешенә өлеш кертә.

**Органик химия**. Органик химиянең алга таба үсеше 20 йөз дәвамында К.х.ф.м. б-н идарә иткән аталы-уллы А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар исемнәре б-н бәйле. А.Е.*Арбузов* (А.М.Зайцев шәкерте) *фосфорорганик кушылмалар* химиясенә нигез салучы, фосфорит к-тасы төзелешен ачыклый, аның эфирларын таба, фосфорит к-тасы урта эфирларының алкилфосфин к-талары эфирларына каталитик изомерлашуын ача (1905, *Арбузов реакциясе*) — бу фосфорлы кушылмалар синтезының универсаль ысулы булып тора. Химия өлкәсендә фосфорорганик кушылмалар буенча этисенең тикшеренүләрен Б.А.*Арбузов* дәвам итә. Ул терпеннар һәм диеннар химиясенә зур өлеш кертә, полимерлар химиясе башлангычына нигез сала. Аның фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә Казан органик һәм *элементорганик кушылмаларның* нечкә төзелешен өйрәнү үзәгенә әверелә. Б.А.Арбузов һәм аның шәкертләре кислород, күкерт, фосфор, мышьяк һ.б. элементларның циклик кушылмалар стереохимиясен өйрәнүдә зур уңышларга ирешәләр. В.С.*Абрамов* тарафыннан альдегид һәм кетоннарның карбониль группаларына өчвалентлы фосфор к-таларының тулы булмаган эфирларын кушу реакциясе ачыла (1950, *Абрамов реакциясе*), бу фосфорорганик кушылмаларның синтетик химиясе үсешендә мөһим роль уйный. А.Е.Арбузов шәкерте Г.Х.*Камай* — *мышьякорганик кушылмалар* химиясенә нигез салучы. Фосфор- һәм мышьякорганик кушылмаларны (к. *Камай реакциясе*), ш.и. төрле координацион саннарда мышьякның кислородлы кушылмаларын синтезлау ысулларын, ш.у. катнаш фосфор-мышьякорганик кушылмалар классын ача, төрле фосфорорганик кушылмаларның реакциягә керү сәләтен өйрәнә (Б.Д.*Чернокальский*, В.А.*Кухтин* һ.б. б-н бергәләп). Б.А.Арбузов шәкерте А.Н.*Пудовик* тарафыннан фосфор к-таларының тулы булмаган эфирларын чикләнмәгән бәйләнешле кушылмаларга кушу реакциясе (1947, *Пудовик реакциясе*) — фосфонат к-талары эфирлары синтезының гомуми һәм гади ысулы ачыла. Әлеге реакция нигезендә молекулада фосфор атомы б-н бергә башка элементлар: азот, күкерт, кремний, германий, селен булган сызыкча һәм циклик кушылмаларның яңа класслары алына. А.И.*Коновалов* җитәкчелегендә циклкушу реакциясе закончалыклары, эремәләрдә органик кушылмалар һәм органик реакцияләр сольватлашуның термодинамикасы өйрәнелә. Полимерлар химиясе өлкәсендә билгеләнгән үзлекләре буенча полимерларны, ш.у. полисульфид һәм уретан эластомерларын синтезлау, модификацияләү һәм эшкәртү буенча (А.В.*Воскресенский*, Е.В.*Кузнецов,* Б.Е.*Иванов* һ.б.) тикшеренүләр үсеш ала. Мономерлар һәм полимерларны стабильләштерүнең фәнни нигезләре эшләнә (П.А.*Кирпичников*). Озонны сәнәгать технологиясендә һәм нечкә органик синтезда куллану буенча, югары молекуляр кушылмалар һәм катнаш динамик термоэластопластлар реологиясе, нәорганик полимерлар буенча фәнни юнәлешләр формалаша (В.В.Берестнев, С.И.Вольфсон, О.С.Сироткин).

**Нәорганик химия**. Казанда *нәорганик химиянең* үсешенә Ф.М.Флавицкийның эвтектиклар составы закончалыкларын, каты халәттәге реакцияләрне өйрәнү буенча хезмәтләре китерә. Аның мәктәбе традицияләре А.Я.*Богородский* (эретелгән тозларның физика-химиясе), А.М.*Васильев* (нәорганик кушылмаларның төзелеше һәм эвтексиясе), А.Ф.*Герасимов* (коллоид системалар химиясе) хезмәтләрендә дәвам ителә. Л.Г.*Берг* тозлы һәм ярымүткәргечле системаларны өйрәнә, дифференциаль-термик анализ ысулын эшли. Комплекслар ясалу реакцияләрен һәм эремәләрдә химик алмашуны өйрәнүдә А.А.*Попель* төш магнит-релаксация ысулын үстерә, катлаулы тигез көчле системаларны матем. модельләштерә. А.Е.Арбузов һәм А.А.*Гринберг* хезмәттәшлеге затлы металларның фосфорорганик лигандалар б-н комплекслы кушылмаларын тикшерүгә нигез сала, бу эшне А.Д.*Троицкая* җитәкли. Затлы металл комплексларын лигандалар сыйфатындагы фосфор, мышьяк һәм сөрмә булган кушылмалар б-н фундаменталь тикшерүләр үткәрелә.

**Аналитик химия**. Платина рудаларын яңадан эшләү һәм анализлауның К.К.Клаус тәкъдим иткән методик алымнары *аналитик химия* үсешенә башлангыч бирә. Ф.М.Флавицкий төсле реакцияләр ярдәмендә каты халәттә металл тозларын тану ысулын (Флавицкийның кесә лаб-ясе) эшли, А.М.Васильев бергә утырымга төшү күренешенә нигезләнеп, эзле матдәләр микъдарын куерту ысулын өйрәнә, А.А.Попель нәорганик кушылмаларны анализлауның магнит-релаксация ысулын уйлап таба. Эремәләрдә металл комплекслары полярографиясе, амперометрия, кулонометрия өлкәсендәге тикшеренүләр *электроаналитик химия* үсешенә китерә, органик реагентлар, экстракцияләп куерту, химик сенсорлар, ш.и. *биосенсорлар* (А.М.Васильев, В.Ф.*Торопова*, Г.К.*Будников* һ.б.), газ һәм сыеклык хроматографиясе буенча тикшеренүләр үсеш ала.

**Электрохимия**. А.М.Бутлеровның үз тикшеренүләрендә Кольбе углеводородларын электрохимик синтезлау ысулын, А.Е.Арбузовның гидразоннар һ.б. азометиннар таутомериясен өйрәнү өчен полярографик ысул куллануын *электрохимия* буенча эшләр башлану дип санарга була. Коллоидлар электрохимиясе (А.Ф.Герасимов), утлы-сыек халәттәге нәорганик кушылмалар электрохимиясе буенча (А.Я.Богородский) эшләр башкарыла. Түбәндәге фәнни юнәлешләр формалаша: кристаллоэлектрохимия (Г.С.*Воздвиженский*), композицион нәорганик һәм полимер электрохимик капламнар булдыру (Р.С.*Сәйфуллин*); полимер электролитларның сулы һәм сусыз эремәләре электрохимиясе (В.П.*Барабанов*), электроорганик синтез (Ю.М.*Каргин*). Металлар һәм комплекслы кушылмалар электрохимиясе, электр ярдәмендә кайтарылган металлар текстурасы, электрокатализ, корылган өслекләрдә адсорбцион һәм кинетик процесслар буенча тикшеренүләр үткәрелә, металларның электрохимик капламнары технологиясе буенча тикшеренүләр үсеш ала (А.Ф.*Богоявленский*, Н.В.*Гудин*, С.М.*Кочергин*, Г.А.*Добреньков* һ.б.).

**Техник химия**. 1930 елларда Казан химия-технол. ин-тында махсус техник химия буенча эшләр башлана (И.Е.*Мойсак*, Л.И.*Захаров*, Б.Л. *Кондрацкий*), соңрак сизгерлек (Н.А.*Холево*), энергия б-н туендырылган системалар кристаллографиясе (В.М.*Бочков*) буенча тикшеренүләр алга китә. Энергия б-н туендырылган компонентлар һәм материаллар синтезы (А.Д.*Николаева*, Г.П.*Шарнин*), физика-химиясе өлкәсендә (А.В.*Косточко*, А.И.*Петров*), пиротехник составларны эшкәртү теориясе һәм технологиясе (М.М.*Арш*, Ф.П.*Мадякин*); энергия б-н туендырылган материалларны табу, аларның яну һәм шартлау физикасы буенча фәнни юнәлешләр формалаша. Фейервейкларда кулланыла торган периодик нурланышлы пиротехник составлар («җемелдәүче йолдызлар»); теләсә нинди киселештәге озын эшләнмәләр өчен тыгызландыру ысулы б-н эшкәртелә торган төрле

максатларда кулланылучы термопластик составлар; целлюлоза нитратлары һәм утильләштерелгән дары нигезендә шартлаучан составлар эшләнә.

**Нефть химиясе**. 1950 елларда нефть чыгаруның артуы нефть химиясе үсешенә китерә. Түбәндәге тикшеренү юнәлешләре формалаша: төп органик һәм нефть химиясе синтезы (А.Г.*Лиакумович*, Б.Р.*Серебряков*, А.Ш.*Зыятдинов*, Х.Э.*Харлампиди*); углеводород чималын күкертле кушылмалардан чистарту, нефть һәм табигый битумнарны эшкәртүнең теоретик нигезләрен һәм технологияләрен эшләү (Ә.М.*Мазһаров*, И.Н.*Дияров*, Г.В.*Романов*); нефть сәнәгате өчен эффектив химик реагентлар синтезлау (И.М.*Шермергорн*, С.В.*Крупин*, А.Ш.*Газизов*); нефть чыгаруның экспресс-технологияләрен булдыру (И.Ф.*Садыйков*).

Химия һәм медицина өлкәсендәге уртак тикшеренүләр нәтиҗәсендә эффектлы дарулар булдырыла. Алар арасында пирофос, армин, нибуфин, *димефосфон*, лепрозга каршы һәм иммун тәэсирле препарат диуцифон, пешүгә каршы *ксимедон*, югары эффектлы гипотензив дарулар, периферик миорелаксантларның яңа классы (А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов, А.И.*Разумов*, А.Н.Пудовик, А.О.*Визель*, В.С.Резник һ.б.) бар. Бирелгән тәэсир итү механизмлы дару препаратларын максатчан эзләү методологиясе эшләнә. Химиклар һәм биологларның уртак тикшеренүләре нәтиҗәсендә үсемлекләр һәм хайваннарны химик саклау чаралары булдырыла.

Казан ун-тының «иске» химия лаб-ясе рус органик химиясенең бишеге булып санала. А.М.Бутлеровтан К.х.ф.м.нең — Петербург, В.В.Марковниковтан — Мәскәү, А.А.*Альбицкийдан* — Харьков, С.Н.Реформатскийдан — Киев, Е.Е.Вагнердан Варшава тармаклары башлана. 20–21 йөз чикләрендә К.х.ф.м. вәкилләре: химик-тикшеренүчеләр һәм химик-инженерлар коллективлары, фәнни-тикшеренү эшләре институтлары челтәре (Казан ун-тының Бутлеров А.М. исем. Химия ин-ты, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты, Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-ты, Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты, Казан химия фәнни-тикшеренү ин-ты һ.б.), химия өлкәсендә белгечләр әзерләүче югары уку йортлары (Казан технол. ун-ты, Казан ун-тының Бутлеров А.М. исем. Химия ин-ты), химия пр-тиеләре һәм лаб-яләре («Түбәнкаманефтехим», «Татнефть», «Органик синтез» АҖләре, «Киров исем. ясалма каучук заводы», Ленин В.И. исем. Казан фәнни-җитештерү берләшмәсе; «Татхимфармпрепаратлар» химия-фармацевтика җитештерү берләшмәсе һ.б.). К.х.ф.м. галимнәренең фәнни ачышлары Россия һәм бөтендөнья химия сәнәгатен үстерүгә ярдәм итә. Зинин реакциясе анилин буяу, фармакология сәнәгате, хуш исле матдәләр, *шартлаткыч матдәләр* сәнәгате башлангычларына нигез сала. К.К.Клаус аффинаж сәнәгате өчен саф платиналы металлар алу ысулын тәкъдим итә. А.М.Бутлеровның изобутиленның полимерлашу сәләтен ачуы төрле югары молекуляр кушылмаларны, ш.и. безнең ил галимнәре алган ясалма *каучукны* синтезлауга ачкыч булып тора. Аның тарафыннан синтезланган уротропин медицинада, а.х.нда, химия, азык-төлек сәнәгатендә, шартлаучан матдәләр технологиясендә файдаланыла. М.Я.*Киттары* төп химик җитештерү технологияләренә фәнни нигез сала, шәкертләр — химик-технологлар тәрбияли. В.В.Марковниковның нафтен кушылмалы Кавказ нефте һәм химиясе составын өйрәнүгә караган хезмәтләре нефть эшкәртү сәнәгате үсешенә ярдәм итә. М.Я.Киттары һәм А.М.Зайцев бертуган Крестовниковлар з-дында шәм һәм сабынны бер үк вакытта эшләү технологиясен камилләштерәләр. Ф.М.Флавицкий, А.Е. һәм Б.А.Арбузовларның ылыслы агачлардан сагыз алу буенча тәҗрибәләре Россиядә сагыз-сумала табуны алга җибәрә, скипидар һәм канифоль җитештерүне хәл итәләр. К.х.ф.м. галимнәре синтетик каучук химиясен өйрәнүгә һәм аны җитештерүне камилләштерүгә, нефть химиясен өйрәнүгә зур өлеш кертәләр (Б.А.Арбузов, А.Н.Пудовик, П.А.Кирпичников, А.Г.Лиакумович). Яңа технологияләр үстерүгә Р.С.Сәйфуллин, В.П.Барабанов, Ф.А.Гарифуллин, Б.Е.Иванов, Ф.П.Мадякин, Г.Н.Марченко шактый зур өлеш кертәләр. Химик технологияләрнең теоретик нигезләрен булдыру, җылылык һәм масса алмашу кинетикасын һәм катализын, процессларын өйрәнү, физик һәм матем. модельләүдән файдаланып җиһазларны оптималь проектлау методологиясен куллану химия, нефть химиясе, нефть эшкәртү өчен югары эффектив машиналар һәм аппаратлар эшләүдә нигез булып тора (А.М.*Николаев*, А.Г.*Усманов*, С.Г.*Дьяконов* һ.б.). Казан технол. ун-ты галимнәре синтетик каучук өчен мономерлар җитештерүнең интенсив яңа ысулын; ташландык газларны азот, күкерт оксиды, серкә к-тасы, формалин, фталь ангидриды, нитроксилол, тузан, азот һәм күкерт к-талары томаннарыннан чистартуның дулкынлы, үзәктән куулы-өермәле, каталитик технологияләрен эшлиләр (А.Ф.*Махоткин*).

К.х.ф.м. галимнәре традицион тикшеренү юнәлешләрен үстерә баралар; чиксез кушылмалар химиясе өлкәсендә — циклкушу реакцияләре механизмы, яңа органик һәм элементорганик кушылмалар һәм алар нигезендәге реакция продуктларын синтезлау, чиксез табигый кушылмаларның төзелешен һәм реакциягә керү сәләтен өйрәнү; фосфорның органик химия өлкәсендә — гамәли яктан файдалы үзенчәлекле матдәләр булдыруның яңа ысулларын эшләү (пестицидлар, үстерү көйләгечләре, полимер материал компонентлары, экстрагентлар, аналитик реагентлар); яңа кушылмаларның реакция механизмнарын, төзелеше, реакциягә керү мөмкинлекләре һ.б. үзлекләре арасындагы үзара бәйләнешне бәяләүнең микъдари ысулларын өйрәнү; органик һәм элементорганик химия теориясе үсеше (Казан ун-ты, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты, Казан технол. ун-ты һ.б.).

Б.А.Арбузов, А.Н.*Верещагин*, Ю.Ю.*Сәмитов*, В.А.*Наумов* (шәкертләре б-н бергәләп) хезмәтләре төрле класс һәм типтагы кушылмаларның конформацион эффектларын өйрәнүнең эксперименталь һәм теоретик базасын булдыралар, бу исә органик һәм элементорганик кушылмаларның стереохимиясе өлкәсендә тикшеренүләрне үстерүгә нигез сала. Казанда беренче тапкыр органик ирекле радикалларны, ш.и. фосфорлыларны да ЭПР ысулы б-н өйрәнүләр башлана (Н.С.Гарифьянов, А.В.Ильясов). К.х.ф.м.дә төрле агрегат халәттә һәм эремәләрдә матдә (фәзаи һәм электрон) төзелешен өйрәнүнең заманча физик ысулларының бай фәнни базасы: масс-спектрометрия, газлы электронография, структур рентген анализы, ТМР, ЭПР, төш квадруполь резонансы, инфракызыл, комбинацион яктылык таралу, ультрашәмәхә, фотоэлектрон спектроскопия; диполь моментлар, электр һәм магнит кырларында икеләтә нур сыну һ.б. ысуллары бар. Казанда структур рентген анализы ысулларын файдаланучы Региональ үзәк төзелә. Квант химиясе ысуллары б-н органик һәм нәорганик кушылмаларның төзелеше һәм реакциягә керү мөмкинлеге (Р.М.*Әминова*, М.С.*Шапник* һ.б.) өйрәнелә. Стереоселектив синтез, аерым конформацияләрнең бериш булмаган конформацион кушылмалар б-н гомуми реакциягә керү мөмкинлеген билгеләү буенча эшләр алып барыла. Химиянең заманча өлкәләрендә — бионәорганик, супрамолекуляр химия, металлкомплекслы катализ; югары молекуляр кушылмалар химиясе (полимер һәм композицион материалларны синтезлау һәм эшкәртү); биополимерлар һәм түбән молекуляр *табигый кушылмалар* химиясе; нефть һәм битумнар химиясе, геохимиясе һәм эшкәртүнең фәнни нигезләре; фуллереннар химиясе; яңартылучан үсемлек чималы химиясе; катлаулы молекуляр системаларның *физик химиясе*; энергия сыешлы кушылмалар химиясе; комплекслы кушылмалар һәм металлар химиясе һәм электрохимиясе, модификацияләнгән электродлар нигезендә химик сенсорлар; мышьякорганик кушылмалар химиясе; дару препаратлары, үсемлек һәм хайваннарны саклау чараларын эшләү; әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик-химик контроль, ташландыксыз, энергия саклаулы технология системалары булдыру буенча тикшеренүләр алып барыла. Фәнни тикшеренүләрне оештыруда РФА КГҮнең һәм ТР ФАнең Химия һәм химик технология бүлегенең роле зур.

К.х.ф.м. галимнәренең фәнни кадрлар әзерләүдәге максатчан эшчәнлеге фәнгә талантлы яшьләр килүгә ярдәм итә. Казан химия-технол. ин-тында (1948), Казан ун-тында (1950 еллар уртасы) яшь химиклар клубы эшли, 1969 елдан яшь химикларның читтән торулы олимпиадалары үткәрелә, читтән торып укулы химия мәктәпләре эшли. 1970 елда П.А.Кирпичников һәм П.А.Гуревич тарафыннан олимпиадаларда җиңүчеләр өчен «Орбиталь» җәйге балалар химия мәктәбе оештырыла. 1975 тә Казан ун-тында бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларда призлар яулаган мәктәп укучылары б-н индивидуаль эшләү буенча беренче төркем формалаша. 1994 тән РФ Мәгариф һәм фән ми-

нистрлыгы Бөтенроссия методик комиссиясе б-н берлектә Казан ун-тының химия ф-ты һәм Казан технол. ун-ты базасында мәктәп укучыларының химия буенча халыкара олимпиадалары өчен РФ җыелма командасы кандидатлары б-н кышкы уку-өйрәнү дәресләре үткәрә.

Традицияләрнең дәвамчанлыгы барлык буын Казан химикларының галимнәр истәлегенә сакчыл мөнәсәбәте б-н ялганып бара. Бутлеров А.М.исем. Химия ин-ты диварларында 8 мемориаль такта — биредә эшләгән Н.Н.Зинин, К.К.Клаус, А.М.Бутлеров, В.В.Марковников, А.М.Зайцев, Ф.М.Флавицкий, А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов истәлеген һәм берсе аларның күренекле шәкертләре исемнәрен мәңгеләштерә. 1978 елда Казанның үзәгендә А.М.Бутлеровка һәйкәл куела. Химиклар музейлары: Бутлеров А.М. исем. Химия ин-тында (*Казан химия мәктәбе музее*), Казан технол. ун-тында (А.Е.Арбузов музее, П.А.Кирпичников кабинет музее), *Арбузовлар А.Е. һәм Б.А. музей-йорты* оештырыла. Бутлеров, Арбузов, Верещагин, Кирпичников укулары, конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр уздырыла. А.Е.Арбузовның 120 еллык юбилеена (1997) А.И.Коновалов башлангычында А.Е. һәм Б.А.Арбузовларның исемен мәңгеләштерү максатыннан ТР Президенты М.Ш.Шәймиев Указы б-н фосфорорганик химия өлкәсендә күренекле ачышлар, фәнни хезмәтләр һәм уйлап табулар өчен *Халыкара Арбузов бүләге* булдырыла. Казанда ике халыкара форум: гомуми һәм гамәли химия буенча 5 нче һәм 17 нче Менделеев съездлары үткәрелү (1928, 2003) К.х.ф.м.нең казанышларын, Татарстан башкаласының эре фән, сәнәгать һәм мәдәният үзәге булуын тану факты булып тора. 5 нче Менделеев съезды карары буенча, А.М.Бутлеровның тууына 100 ел тулу уңаеннан Казан ун-ты каршында А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты ачылып, аның исеме мәңгеләштерелә (1929). 17 нче Менделеев съездын үткәрү химия тарихындагы истәлекле даталар: А.М.Бутлеровның тууына 175 ел, Б.А.Арбузовның тууына 100 ел, биохимик М.С.Цвет тарафыннан хроматография ачылуга 100 ел, Россия химия җәмгыятенең 135 еллык юбилее б-н бәйле; съезд эшендә бөтен илдән күренекле галимнәр һәм белгечләр катнаша. Химия фәне тарихын өйрәнүдә А.Е.Арбузов, А.С.Ключевич, Н.П.Гречкин һ.б.ның өлешләре зур.







КПО ВС.
1. ЭВМ М–20 (лампалы) идарә пульты;
2. ЭВМ М–222 (ярымүткәргечле) идарә пульты.

*Әд.:* А р б у з о в А.Е. Казанская школа химиков. К., 1971; ш у л у к. Избранные работы по истории химии. М., 1975; Химия в Татарстане: наука, промышленность, образование // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3/4; Переломное десятилетие. Казанский государственный технологический университет (1991–2000). К., 2000.

*Т.Д.Сорокина, В.Г.Абзалова.*

**КАЗА́Н ХИ́МИЯ-ТЕХНОЛО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан технология университеты.*

**КАЗА́Н ХИ́МИЯ-ТЕХНОЛО́ГИЯ ТЕ́ХНИКУМЫ**, 1939 елда СССР Оборона халык ком-ты боерыгы б-н 40 нчы завод каршында (элеккеге Казан дары заводы, хәзер Казанның В.И.Ленин исем. фәнни-тикшеренү пр-тиесе) оештырыла. Баштарак шартлаучан матдәләр җитештерә, 1960 тан ш.у. полимерлар, кинофотоматериаллар җитештерү һәм нефть эшкәртү сәнәгате өчен кадрлар әзерли. 6 меңгә якын белгеч әзерләнә. 1998 елда Казан технология көллияте — *Казан технология университеты* бүлекчәсе итеп үзгәртелә.

**КАЗА́Н ХИСАПЛА́У СИСТЕ́МАЛАРЫ ҖИТЕШТЕРУ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́** (КПО ВС), электрон сәнәгать пр-тиесе. ЭВМ машиналарын эшләү, җитештерү б-н шөгыльләнә, аларны программалар б-н тәэмин итә. 1954 елда Матем. машиналар з-ды буларак нигезләнә. 1957–58 дә 2 җитештерү корпусы файдалануга тапшырыла. Эшләүчеләр саны 280 кеше тәшкил итә. 1958 дә беренче продукция — инфратүбән ешлык приборлары чыгарыла (приборларның төрле модификациясе 1968 гә кадәр җитештерелә). Бер үк вакытта яңа җитештерү куәтләрен төзү бара. Өч сәнәгый мәйданда барлыгы 100 мең $м^2$ тан артык күләмдә заманча техника һәм технол. җиһазлар (ш.и. 2 меңнән артык станок) б-н коралландырылган төп һәм ярдәмче производство цехлары (төп мәйданда — 13 корпус, 2 нчесендә — 22 корылма, 3 нчесендә — 1 корпус), махсус КБ, пар казаннары бинасы, гараж, складлар төзелә. 1960 та з-д беренче буын зур универсаль (лампалы) М-20 электрон машинасын эшләүне үзләштерүгә керешә. 1963 тә Казан электрон — хисаплау машиналары з-ды итеп үзгәртелә. 1964–65 тә аның тарафыннан ВУ-700 хисаплау машиналары өчен тиз эшләүче тышкы җайланмаларны һәм беренче алфавитлы-санлы басу җайланмасын (АЦПУ-128) җитештерү үзләштерелә. Киләчәктә завод алфавитлы-санлы басу машиналарын эшләүче төп пр-тиегә әверелә. 1964–74 тә ул икенче буын ярымүткәргечле М-220 (модификацияләр б-н), «Сетунь», «Наири», «Гранит», «Урал-11» машиналарын чыгара. Бишьеллык планны уңышлы үтәве һәм яңа техниканы җитештерүне оештыруы өчен 1971 дә з-д Октябрь Революциясе ордены б-н бүләкләнә. 1970 еллар башында өченче буын машиналарын (интеграл схемаларда) — ЕС-1030 (1972–46), ЕС-1033 (иң күп таралган ЭВМ; 1974–76 да з-дта эшләнә; баш конструкторы В.Ф.*Гусев*; 1976–80 дә сериялэп чыгарыла), ЕС-1045 (1979 дан), ЕС-1046 (1984 тән) ЭВМ нарын сериялэп чыгара башлыйлар. 1960–90 елларда КПО ВС җитештерелгән ЭВМнар галәмне үзләштерү буенча эре программаларны гамәлгә ашыру, илнең оборона сәләтен ныгыту б-н бәйле катлаулы исәпләүләр башкару өчен файдаланыла. ЕС-1030, ЕС-1033, ЕС-1045, ЕС-1046 электрон-хисаплау машиналары җирлегендә ике һәм күп машиналы ВК-1010, УК-1010, ВК-1033, ВК-2М45, ВК-2П45, ВК-2М46, ВК-3М46 комплекслары төзелә. Эшләүчеләр саны 14 мең кеше тәшкил итә (1985). 1986 да терминаль ЕС-1007 машинасын җитештерү җайга салына (баш конструктор А.У.Ярмөхәммәтов). Барлыгы 7425 ЭВМ чыгарыла. ЕС машиналары техник чаралар б-н комплектлана. Завод тарафыннан ЕС-7032 (1973), ЕС-7036 (1982) алфавитлы-санлы басу җайланмаларын, ЕС-8375 мәгълүматларны телеэшкәр-






КПО ВС. 1. ЕС-1033 «1-рәт» универсаль электрон цифрлы хисаплау машинасы процессоры стойкасы;
2. ЕС-1045 «2-рәт» универсаль электрон цифрлы хисаплау машинасы.

тү процессорын (1986) сериялəп җитештерү үзлəштерелə. 1970–80 еллар уртасында заводның еллык җитештерү күлəмнəре 1 млрд. сумнан арта. 1988 дə Казан ЭВМ з-ды (төп пр-тие) һəм Казан хисаплау системалары фəнни-тикшеренү ин-ты (НИИ ВС, шул ук елда з-дның махсус КБсы җирлегендə оештырыла) КПО ВС га берлəштерелə, 1991 дə аның составында Британиянең «International Computers Limited» компаниясе б-н берлектə *АЙ-СИ-ЭЛ–КПО ВС* (ICL КПО ВС) пр-тиесе төзелə. Пр-тие, башлыча, РФнең Оборона һəм Эчке эшлəр министрлыклары заказларын үти. Продукция зур күлəмдə (319 ЭВМ) Чехословакиягə, Һиндстанга, Венгриягə, Болгариягə, Монголиягə, Кореягə һ.б. иллəргə җибəрелə. Пр-тие ш.у. халык куллану товарларын да чыгара. Завод шəһəрнең инфраструктурасы үсешенə өлеш кертə. 28 торак йорт, 9 балалар комб-ты, поликлиника, конференц-зал, пионерлар, хезмəт лагерьлары, 2 ял базасы, аучылык хуҗалыгы, шəһəр хуҗалыгы объектлары төзелə. Пр-тиенең күп кенə хезмəткəрлəре дəүлəт бүлəклəренə лаек була, ш.и. 1 кешегə — Сов. Союзы Герое, 1 кешегə — Соц. Хезмəт Герое, 6 кешегə — РФ, ТРның атказ. машина төзүчесе исемнəре, 4 кешегə — СССР Дəүлəт бүлəге, 2 кешегə — Əрмəнстан ССР Дəүлəт бүлəге, 8 кешегə Ленин комсомолы бүлəге бирелə; 400 дəн артык кеше орденнар һəм медальлəр, ш.и. 5 кеше — Ленин ордены, 7 кеше Октябрь Революциясе ордены б-н бүлəклəнə. 1994 тə КПО ВС Казан «*Терминал*» хисаплау техникасы чаралары ҖБ составына керə.

Пр-тие җитəкчелəре: К.Е.Минеев (1954–66), В.Н.Иванов (1966–79), И.З.Гыйззəтуллин (1979–94).

*Əд.:* Казанский завод ЭВМ (КЗММ, КЗЭВМ, КПО ВС). К., 2004.

*М.Ш.Бəдретдинова, Г.Я.Мəүлетова.*

**КАЗА́Н ХИСАПЛА́У ТЕ́ХНИКАСЫ ИНСТИТУТЫ́**, фəнни-тикшеренү һəм технология ин-ты (КНИТИ-ВТ). 1973 елда Үзəк технол. фəнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы (1971 дə нигез салына) җирлегендə төзелə, 2002 дəн ДУП Эшчəнлегенең төп төрлəре — хисаплау техникасы җитештерү эшлəнмəлəрен һəм аларның технологиялəрен эшлəү. Ин-тның төп эш юнəлешлəре — басма платалар (печатные платы) эшлəү технологиялəрен булдыру; ЭВМ панельлəрен үткəргечле монтажлау өчен монтаж эшлəрен автоматлаштыру; радиоэлектрон узеллар җитештерүендə контрольне һəм монтажны автоматлаштыру; магнит дисклар җитештерү һəм тикшерү өчен тикшерү-үлчəү аппаратлары эшлəү; ЭВМнарның магнитлы туплагычларын җыю, көйлəп урнаштыру һəм тикшерү технологиясен эшлəү; порошоклы металлургия алымын кулланып, аеруча катлаулы детальлəр җитештерү өчен технологик процесслар булдыру; зур һəм үтə зур сыешлы оптик хəтер җайланмаларын эшлəү; технологик процессларны автоматлаштыру. Институт структурасындагы фəнни-техник бүлеклəр: технологик процесс б-н идарə итүнең автоматлаштырылган системалары һəм тикшерү-үлчəү аппаратурасы, стенд аппаратурасы; югары химик технология, прогрессив форма ясау, адм.-идарə бүлекчəлəре һəм ярдəмче бүлеклəр (фəнни-техник мəгълүмат, метрология, баш механик һəм энергетик бүлеклəре, адм.-хуҗалык, матди тəэминат).

Фəнни-техник тикшеренүлəрнең юнəлешлəре: монтажы югары тыгызлыкта булган басма платалар əзерлəүнең төп технологиясен һəм тикшерү-үлчəү аппаратурасын эшлəү; хисаплау техникасы чараларының элементлəрын җитештерүнең мəгълүмати технологиялəрен булдыру; икенчел ресурслардан товар продукциясе җитештерүгə нигезлəнгəн химик технологиялəр; алдан яки кредитка түлəүле электр куллануның автоматлаштырылган шəхси исəп һəм контроль системасы; электр казаннары горелкасында ялкын фронтының булу-булмавын автомат тикшерү системасы; даими магнитлар өчен югары энергияле магнит материалы алу технологиясе; су чыгымын һəм сыйфатын автомат тикшерү системасы.

Авыл хуҗалыгын химиялəштерү, икътисадның төрле тармаклары өчен автоматлаштырылган идарə итү системаларына приборлар уйлап табу, мед. җиһазларын эшлəү, гамəлгə кертү һəм аларга хезмəт күрсəтү эшлəре алып барыла. Уйлап табуга 210 нан артык авторлык таныклыгы һəм патент алынган. Институт хезмəткəрлəре дəүлəт бүлəклəренə лаек була; СССР ВДНХсы медале б-н билгелəнгəн хезмəтлəр бар.

Ин-тның директорлары: В.М.Юдин (1973–75), Д.Б.Хөсəенов (1976–95), А.Г.Субботин (1996 дан).

*А.Г.Субботин, Р.Г.Усманов.*

**КАЗА́Н ХИСАПЛА́У ТЕ́ХНИКАСЫ МУЗЕЕ́**, Казанда, 1982 елның ноябрендə Казан электрон хисаплау машиналары заводының (1988 дəн *Казан хисаплау системалары җитештерү берлəшмəсе*) структур бүлекчəсе буларак ачыла. 2003 нең сентябрендə *АЙ-СИ-ЭЛ–КПО ВС*ның структур бүлекчəсе сыйфатында яңадан торгызыла һəм яңартыла. Экспозиция мəйданы 50 $м^2$, саклау фонды 45 $м^2$. 5,5 меңнəн артык экспонат исəплəнə. Төп экспозициядə 690 экспонат урын



Казан хисаплау техникасы музее. Экспозиция фрагментлары.

алган, алар: хисаплау техникасы чаралары, алфавитлы-санлы язу җайланмалары, блоклар, узеллар, макетлар; хисаплау системаларының Казан ҖБдə чыгарылган М-20, М-20, М-220, М-220А, М-222, Сетунь, Наири, ЕС-1030, ЕС-1045, ЕС-2700, ЕС-1046, ЕС-1007 ЭВМнарының 4 буыны үрнəклəре күрсəтелə, ЭВМга нигезлəнгəн хисаплау комплекслары буенча мəгълүмат бирелə. Шулай ук Бөек Ватан сугышында җиңүнең 40 еллыгы һəм ТАССР төзелүнең 50 еллыгы уңаеннан пр-тиегə соц. ярышта җиңүче буларак тапшырылган истəлекле байраклар, СССР Дəүлəт, Əрмəнстан ССР, Ленин комсомолы бүлəклəре лауреатларының, Бөек Ватан сугышы һəм Соц. Хезмəт Геройларының, Ленин ордены кавалерларының һ.б. югары Дəүлəт бүлəклəре иялəренең, пр-тие җитəкчелəренең портретлары куелган. Махсус стенд «ICL-КПО ВС» АҖ эшчəнлегенə багышлана. Татарстан студентлары һəм мəктəп укучыларының ел саен үткəрелə торган программистлар турнирлары программасында музей б-н танышу каралган. Ел саен Җиңү бəйрəме (9 май), Халыкара музейлар көне (18 май), Татарстан Республикасы (30 авг.), өлкəннəр көннəре (1 окт.) билгелəп үткəрелə.

Директорлары: В.Н.Ерохин (1979–86), Н.В.Романова (1986–95), М.Ш.Бəдретдинова (1998 дəн).

**КАЗА́Н ХИСАПЛА́У ТЕ́ХНИКАСЫ ҺƏМ ИНФОРМА́ТИКА ФƏННИ́-ҖИТЕШТЕРУ́ БЕРЛƏШМƏСЕ́** (КНПО ВТИ). 1987 елда Казан фəнни-укыту үзəген (төп пр-тие; 1976 да «Модуль» махсус фəнни һəм укыту-җитештерү берлəшмəсенең Казан өйрəнү үзəге буларак төзелə (1977 дəн «Алгоритм» махсус фəнни-җитештерү берлəшмəсенең Казан фəнни-укыту үзəге). Хисаплау техникасына хезмəт күрсəтү һəм аны ремонтлау з-дын, Казан программа чаралары җитештерү комб-тын бергə кушу юлы б-н оештырыла (1991 дə завод һəм комбинат берлəшмə составыннан чыгалар). Эшлəүчелəр саны — 150 лəп кеше (2005). Пр-тие тарафыннан хисаплау техникасы һəм информатика өлкəсендə кадрлар əзерлəү һəм яңадан əзерлəү башкарыла; компьютерлы офис технологиялəре, локаль һəм корпоратив челтəрлəр б-н эшлəргə əзерлəү өчен укыту-методик тəэминат системасы (əсбаплар, материаллар, өйрəтү программалары) эшлəнə; дистанцион укытуны оештыру һəм алып бару буенча инструменталь программа чаралары эшлəнə һəм гамəлгə кертелə; ТРның дəүлəт хакимияте һəм идарə органнарының мəгълүматлар тапшыру корпоратив челтəрен, сəүдə һəм транспорт пр-тиелəрендəге мəгълүматлар һəм гамəли программалар б-н тəэмин итү базаларын, финанс-бухгалтерлык компьютер системаларын үстерү һəм аларга хезмəт күрсəтү буенча эшлəр алып барыла; янгыннан саклану һəм сак сигнализациясе системаларын проектлау һəм монтажлау, хисаплау техникасына, автоматлаштыру чараларына һəм оргтехникага техник (сервис) хезмəт күрсəтү һəм аларны ремонтлау башкарыла (контроль-касса машиналарына һəм үлчəү чараларына хезмəт күрсəтү үзəге эшли); полиграфия һəм кунакханə хезмəте күрсəтелə. 2005 елга кадəр берлəшмəдə 60 меңнəн артык инженер-электроник, программист, мəгълүмати технологиялəр б-н файдаланучылар укытып чыгара. 1995 тə ТРның барлык районнарында «Сайлаулар» системасы өчен

җиһазлар, модем элемтәсе гамәлгә кертелә һәм персонал әзерләнә. 1996 да республиканың күп кенә уку йортларында чукрак һәм начар ишетүче, терәк-хәрәкәт системасы бозылган балалар өчен махсус укыту һәм һөнәри әзерләү программа-методик комплекслары эшләнеп файдалануга кертелә һ.б. КНПО ВТИ — системалы интеграция, мәгълүмат һәм идарә системалары өлкәсендә эшләүче эре пр-тиеләрне берләштергән бөтенроссия «Сириус» ассоциациясен оештыручы. Автоматлаштырылган укыту системаларын (1984) һәм халык хуҗалыгында хисаплау техникасы чараларын кулланучы белгечләр әзерләүнең тармакара системасын (1986) булдырган һәм гамәлгә керткән өчен пр-тиенең 5 хезмәткәре СССР МС бүләгенә лаек була.

Пр-тие җитәкчеләре: Н.В.Кузнецов (1976–82), К.Ш.Исхаков (1982–88), Н.Ф.Домашов (1988–2010), Г.Ш.Исхаков (2010 нан).

*Әд.:* Воронин А. Алгоритм выживания: Традиции и перспективы КНПО ВТИ // Казань. 1999. № 1/2. *Н.Ф.Домашов.*

**КАЗА́Н ХОРЕОГРА́ФИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Мәдәният министрлыгының һөнәри урта уку йорты. 1993 елның гыйнварында Казан музыка уч-сенең хореография бүлеге җирлегендә ачыла. К.х.у. «балет артисты», «халык биюләре ансамбле артисты» квалификацияләре буенча белгечләр әзерли. 2010 да 60 кеше укый. Алар арасында халыкара конкурслар лауреаты А.Белов, халыкара конкурслар дипломантлары Е.Бортякова, Е.Сафронова, А.Давыдов бар. Укытучылар коллективы 40 кешедән тора; шулар арасында ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе С.С.Юнысова, РФ һәм ТРның халык артисты И.Ш.Хәкимова, ТРның халык артистлары В.Н.Бортяков һәм С.Х.Хантимерова, Е.Н.Щеглова. Училищенең сәнгать җитәкчеләре РФ һәм ТРның атказ. артисты В.А.Яковлев (1993–98), РФ һәм ТРның халык артисты Н.Д.Юлтыева (1998 дән). 6 балет һәм 5 уку залы, костюмерлар, театр спектакльләре куюга бүлмәләре бар.

**КАЗА́Н ҺӘМ ӘСТЕРХА́Н ГУБЕ́РНАЛАРЫНЫҢ ИСӘ́П АЛУ́ ЭШЛӘРЕ́ КАНЦЕЛЯ́РИЯСЕ** (Казан һәм Әстерхан губерналарында кешеләрне таныклау һәм полклар урнашу канцеляриясе, Казан һәм Әстерхан губерналарының сан алу канцеляриясе, И.А.Фамендин карамагындагы ир затларны таныклау канцеляриясе), 1719–21 елларда уздырылган халык саны алу нәтиҗәләрен тикшерү учреждениесе. 1722 нең 5 февралендә император Пётр I тарафыннан расланган «Генералитетка һәм штаб-офицерларга күрсәтмәләр, яки Боерык» нигезендә оештырыла, 1722 нең җәендә ачыла. Казанда эшли, Әстерхан, Саратов шәһәрләрендә һ.б. торак пунктларда бүлекчәләре була. 1719–21 дә халык санын алганнан соң җан башыннан салым түләргә сәләтле кешеләр һәм аларга күпме күләмдә пехота һәм кавалерия «туры килүе» турындагы мәгълүматларны тикшерү һәм анықлау б-н шөгыльләнә. «Кешеләрне барлау»ның таралыш алуы чынлыкта яңадан халык санын алу чарасына әверелә. Аны уздыру барышында канцелярия халыкның исәбен ала, җан башына тиешле салым күләмен ачыклый яки аны сыза, салым түләүчеләрне билгеле бер яшәү урынына терки һәм «качакларны асрауда», аларны үзләрендә «яшәүгә беркетүдә һәм яшерүдә» гаеплеләргә җәза бирү чаралары турында карар чыгара; җирле чиновникларның адм. закон бозуларына карата белдерелгән шикаятьләрне тикшерә, уңыш булмау нәтиҗәләренә каршы чаралар күрә һ.б. Казан губернасы терр-ясендә барлыгы 684 меңләп кешегә салым күләмнәрен билгели һәм полкларны урнаштыру планын төзи. К.һ.Ә.г.и.а.э.к. ген. ревизор җитәкли, кабулханәне (рәис, 5 штаб һәм обер-офицер), канцелярия һәм аннан тыш эшләүче хезмәткәрләрне үз эченә ала. Составына секретарь, канцелярия хезмәткәрләре һәм аларның ярдәмчеләре (подканцеляристлар), күчермә алучылар (барлыгы 36 кеше; 1727) керә. Канцеляриянең хәрби командасында 25 унтер-офицер, драгун һәм солдат исәпләнә. Сенатка буйсына. Император Екатерина I нең 1727 ел 9 февраль Фәрманы б-н бетерелә, 1728 нең апрелендә яшәүдән туктый.

Ген. ревизоры — И.А. фон Менгден (Фамендин).

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 6. № 3720; Т. 7. № 4977, 5010.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 3; Бабич М.В. Государственные учреждения XVIII века: Комиссии петровского времени. М., 2003. *Е.Б.Долгов.*

**КАЗА́Н ҺӘМ БИСТӘЛӘРЕ́ ҺӨНӘРЧЕЛӘРЕ́ ҺӘМ КӘСЕПЧЕЛӘРЕ́ КОМИТЕТЫ́**, к. *Казан вак һөнәрчеләр һәм кәсепчеләр җәмгыяте.*

**КАЗА́Н ҺӨНӘРИ́-ПЕДАГО́ГИЯ КӨЛЛИЯТЕ́**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының урта махсус уку йорты. 1947 елда индустриаль-педагогия техникумы буларак ачыла. 1998 дә үзгәртелә һәм хәзерге исемдә атала башлый. Һөнәри уку йортларында производствога өйрәтү осталары һәм урта мәктәптә технология укытучылары әзерләү өчен оештырыла. Белгечлекләр: һөнәри укыту (тегү эшләнмәләре технологиясе, төзелеш, бина һәм корылмаларны файдалануга тапшыру), технология (хезмәт күрсәтү, техник хезмәт), икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, тегү әйберләрен модельләштерү, биналарны һәм корылмаларны төзү һәм файлану, социаль эш. 2010 да 800 гә якын студент укый; пед. коллективта 76 кеше эшли, ш.и. РФнең атказ. мәктәп укытучысы — 1, ТРның атказ. мәктәп укытучысы — 10, ТРның атказ. төзүчесе — 1, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре — 1 кеше.

**КАЗА́Н ҺӨНӘРЧЕЛӘ́Р ИДАРӘСЕ́**, 1785–1917 елларда Казанда цехларга берләшкән һөнәрчеләрнең катлау үзидарәсе. Сайланып куелган һөнәрчеләр башлыгыннан (ел саен Казан һөнәрчеләре җәмгыяте җыелышында сайлана), цех старшиналарыннан һәм антлы һөнәрче маклердан тора. Казан шәһәр магистратына буйсына. Идарәнең вазифалары: һөнәрчеләрнең осталыгын бәяли; осталарга өйрәнчекләр билгели һәм ала; дисциплинар хакимияткә ия булган хәлдә, цехларга терки һәм алардан чыгара; Казан һөнәрчеләр җәмгыятендә акча җыюга һәм җәмгыять әгъзаларының үз йөкләмәләрен үтәүләренә күзәтчелек итә; һөнәрчеләрнең ятим балаларына һәм тол хатыннарына ярдәм күрсәтә; өйрәнчекләргә һәм оста ярдәмчеләренә күзәтчелек итә һәм аларның хуҗалар б-н үзара мөнәсәбәтләрен җайга сала. Идарә карамагында ш.у. Казан һөнәрчелек цехларының гаилә исемлеген төзү дә була: 1873 тә анда 1733 гаилә теркәлә. Казанда К.һ.и.нә барлыгы 7 цех: икмәк пешерү (1887 дә аның составына 133 оста, 430 эшче, 124 өйрәнчек керә; еллык товар әйләнеше 683 мең сум тәшкил итә); көмешчелек (85 оста, 230 эшче, 142 өйрәнчек; 212 мең сум); аяк чолгавы тегү (183 оста, 754 эшче, 413 өйрәнчек; 409 мең сум); итек тегү (100 оста, 480 эшче, 183 өйрәнчек; 210 мең сум); балта эшләре (110 оста, 589 эшче, 231 өйрәнчек; 280 мең сум); тимерчелек (80 оста, 286 эшче, 153 өйрәнчек; 134 мең сум); мич чыгару (31 оста, 132 эшче, 80 өйрәнчек; 44 мең сум) цехлары була. 1887 елда 7 цехта барлыгы 722 оста (1893 тә — 989), 2921 эшче (3088), 1326 өйрәнчек (1223) эшли. Гомуми товар әйләнеше 1973 мең сум (1893 тә — 1576 мең сум) була. *Л.М.Айнетдинова.*

**КАЗА́Н ЦИ́РКЫ**, сәнгатьнең билгеле бер төренә караган тамашалар оештыру өчен билгеләнгән пр-тие. Ярминкә тамашаларыннан (Казанда 18 йөздән Николай мәйданында, Гостиный двор чиркәве тирәсендә оештырыла торган була), шәһәр бакчаларындагы җәйге циркларлардан һ.б.дан башлангыч ала. 1883–84 елларда цирк тамашалары Италия антрепренёры Максимилиан Труцци тарафыннан махсус оештырыла, вакытлыча кулланылыштагы агач йортта уздырыла. 1890 да бертуган *Никитиннар* Мунча күле урынында агачтан даими цирк бинасы төзиләр (ачылу тантанасы 1890 ның 20 маенда була), 1928 дә ул үзгәртеп төзелә һәм аңа «ТАССРның 8 еллыгы исемендәге Казан циркы» исеме бирелә; анда тамашалар 1961 гә кадәр уздырыла. 1967 дә заманча бина булдырыла.

1924 кә кадәр К.ц. үзенең эшчәнлеген хосусый антреприза хокукында тормышка ашыра, 1924 тән — Дәүләт муз., эстрада һәм цирк пр-тиеләре берләшмәсе системасында (1936 дан — Цирклар баш идарәсе, 1957 дән — Союзгосцирк, 1992 дән — Росгосцирк), 1993 тән — ТР Мәдәният министрлыгы карамагындагы мөстәкыйль пр-тие.

К.ц. аренасында цирк сәнгатенең күп кенә мәшһүр вәкилләре, ш.и. В.Труцци, аталы-уллы Лазаренколар, Н.Г.Жеребцов, И.М.Поддубный, цирк җайдаклары Кантемировлар, кыргый хайваннарны өйрәтүче Запашныйлар, Дуровлар, Филатовлар, М.Золло, И.Н.Бугримова, М.П.Назарова, иллюзионистлар Алли-Вад, Кио, Клео Доротти, клоуннар Карандаш, О.Попов, Ю.В.Никулин









1. Казанда бертуган Никитиннар циркы; 2. Казан циркының хәзерге бинасы. Архитектор Г.М. Пичуев. Инженерлар О.И. Берим, Е.Ю. Брудный, В.Д. Панова. 1967; 3. Татар цирк коллективы. 1970; 4. Цирк аренасында — Д.Х. Гыйбадуллин житәкчелегендәге жонглёрлар төркеме.

һ.б. эшли. 1956 да Казанда беренче татар цирк коллективы оеша (директоры — М.Гыйсмәтуллин, сәнгать җитәкчесе һәм реж. — А.Хәбибуллин; труппаның составында — муз. эксцентриклар һәм акробатлар Гали Җәмлиханов һәм Хәмит Бакиров, акробатлар Тәскирә һәм Абдулла Хәбибуллиннар, көч жонглёры Йосыф Рәфыйков, гимнаст Мансур Хәбибуллин, куплетлар башкаручы Фатих Колбарисов, иллюзионист Габделхәй Мушинский, акробатлар Хәмит Сәйфетдинов, Заһит Вафин, Сания Гыйниятуллина, клоун Ярулла Әхмәдуллин). Коллектив Казанның мәдәният сарайлары сәхнәләрендә чыгышлар ясый.

1969 да К.ц. каршында икенче татар цирк коллективы булдыру өчен Үзәк цирк сәнгате студиясе ф-лы ачыла (студиянең җитәкчесе — цирк директоры Н.К.Панов, педагоглар — Н.А.Лазарев, К.Б.Кох, И.В. һәм В.М.Файертакилар, Э.Б.Аберт, И.А.Кантемиров, А.Д.Маншилина). 1970 нең 23 июнендә әлеге коллективның дебюты була. Төрле елларда анда эшләүчеләр: акробат, ТАССРның атказ. артисты З.Васильева; каеш гимнасты, ТАССРның атказ. артисты Н.Казыльский; тимер чыбыкта биюче, ТАССРның атказ. артисты Р.Хөсәенова; клоуннар — ТАССРның атказ. артистлары Рамазан Әбдикиев һәм Замир Мостафин, мәчеләр өйрәтүче, ТАССРның атказ. артисты В.Анисимов, көч жонглёрлары Н.Бәдретдинов, В.Берчанский, Ш.Хәйретдинов, акробат-эксцентриклар Р.Асанов һәм В.Котников, рәссам-моменталист И.Зарипов, мичкәләрдә сикерүче акробатлар А. һәм И.Рәхмәтуллиннар, РФнең атказ. артисты, ТАССРның халык артисты Д.Гыйбадуллин җитәкчелегендәге жонглёрлар төркеме, аю өйрәтүчеләр, РФнең халык артистлары Р. һәм Г.Ибраһимовлар, ТАССРның атказ. артисты А.Шайкин җитәкчелегендәге һава гимнастлары, дрессировщик, Мари АССРның халык артисты Г.Гыйбадуллин, акробат С.Мәҗитова, иллюзионист Л.Сиразҗетдинова һ.б. Коллективны оештыруга һәм аның алга таба эшчәнлегенә Б.М.Гыйззәтуллин зур өлеш кертә. Коллектив 19 ел эшли. 1996 да К.ц. каршында Республика балалар цирк мәктәбе ачыла, анда цирк сәнгатенең әйдәп баручы осталары белем бирә. Цирк каршында музей төзелә. Уникаль конструкцияле К.ц. бинасы (арх. Г.М.Пичуев, инженерлар О.И.Берим, Е.Ю.Брудный, В.Д.Панова) 2 корпустан тора: төп (тамашачы) һәм производство (артистлар өчен) корпуслары. Төп корпус яссы түбәле вестибюль һәм фойены, тамаша залының алардан биегрәк урнашкан, гөмбәз б-н капланган 2,4 мең урынлы амфитеатрын үз эченә ала. Производство корпусы — йомык эчке утар хасил иткән 2 блоктан торган турыпочмаклы корылма. Блокларның берсендә — адм. һәм артистлар бүлмәләре, өйрәнү аренасы, икенчесендә хайваннар өчен бина урнашкан. Циркның төп бинасы 62 *м* диаметрлы тәлинкәсыман ике монолит тимер-бетон тышчалы конструкциядән гыйбарәт. Аскы тышча әйләндереп куелган кисек конус формасында, аның эчке өслегенә тамашачылар өчен урыннар урнаштырылган. Өске тышча 5 *см* калынлыктагы сферасыман тимер-бетон гөмбәз рәвешендә эшләнгән. СССР МС бүләгенә лаек була (1972).

К.ц. директорлары — Н.К.Панов (1967–73), Б.М.Гыйззәтуллин (1973–76), М.Ф.Боголюбов (1976–93), Д.М.Шәфигуллин (1993 тән).

*Әд.:* Ш н е е р А.Я., С л а в с к и й Р.Е. Цирк. М., 1973; К у д р я в ц е в а Е. Смотри на «нижнего»!: Из летописи казанского манежа // Казань. 2005. № 11; Цирковое искусство России: Энцикл. М., 2000.

*В.Н.Анисимов, Х.Г.Надыйрова.*

**КАЗА́Н ЦИФИ́РЬ МӘКТӘБЕ́**, Казанда беренче уку йорты. Пётр I нең 1714 елгы Фәрманы нигезендә 1716 да ачыла. Бу Фәрман буенча Россиянең барлык зур шәһәрләренә 2 шәр гардемарин җибәрелеп, аларга «төрле чиндагы балаларны» җыярга һәм аларны «цифирьга, ш.у. геометриянең кайбер өлешләрен — циркуль б-н эшләү, яссылыктагы тригонометрия, тангенслар алымнарын өйрәтергә» кушыла. Якынча 2 ел уку срогы булган иң гади башлангыч мәктәп. Указ буенча цифирь мәктәпләре өчен биналар архиерей йортларында бүленеп бирелә, ә укучылар руханилар, подъячий һәм солдат балаларыннан җыела. Беренче укытучылар — гардемарин Семён Куницын һәм Иван Дунаев була. 1718 дән мәктәп Казан адмиралтействосы карамагында була. 1726 да мәктәптә 60 приказлылар һәм солдат баласы, 47 рухани баласы укый. 1740 та К.ц.м. нигезендә солдат һәм матрос балалары өчен гарнизон мәктәбе оештырыла.

*Әд.:* З н а м е н с к и й П.В. Духовные школы в России до реформы 1808 года. К., 1881; Л и п а к о в Е.В. Очерки истории казанских духовных школ // Семинарский вестн. 2003. № 4.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ЧИРКӘ́Ү ТАРИ́Х-АРХЕОЛО́ГИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́** (Казан епархиясенең чиркәү тарих-археол. җәмгыяте). 1906 елда архиепископ Димитрий (Самбикин) башлангычы б-н оештырыла. Җәмгыять әгъзалары — Н.Ф.Катанов, В.А.Нарбеков, Н.В.Никольский, И.М.Покровский, К.В.Харлампович, А.П.Яблоков һ.б. Максаты — «чиркәү-дин тормышын өйрәнү, ... җирле борынгы чиркәүләр һәм тарихи истәлекләрне, кульязма һәм басма китапларны, тарихи документларны өйрәнү һәм туплау». Айлык җыелышларда «Известия по Казанской епархии» һәм «Православный собеседник» ж-лларында, аерым китапларда басылган материаллар тикшерелә. Җәмгыять Казан һәм Зөя архит-ра истәлекләренә, чиркәү тарихына, Казан өязе тарихи чыганакларына багышланган җыентыклар бастыра. Епархиядәге барлык чиркәүләр һәм приходлар тасвирланган һәм алар турында язылган тарихи очерклар басмага әзерләнә (Казанга, Казан һәм Мамадыш өязләренә багышланган 3 том дөнья күрә; башка өязләр турындагы 10 томның кульязмалары югала). Башлыча, җәмгыять тырышлыгы аркасында Казан руханилар консисториясе архивы сакланып кала, чиркәү һәм волость архивларында сакланып калган чыганаклар фәнни әйләнешкә кертелә. Җәмгыять үз архивын булдыра, тарихи һәм сәнгати кыйммәткә ия борынгы чиркәү әйберләрен туплый, музей ачарга әзерләнә. Окт. рев-циясеннән соң яшәүдән туктый. 1918 дә архив талана; китаплар һәм кульяз-

маларның бер өлеше Казан ун-тының Фәнни китапханәсе фондларында саклана.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ЧИРКӘ́Ү-УКЫТУЧЫЛА́Р МӘКТӘБЕ́**, ир балалар педагогик уку йорты, чиркәү-приход мәктәпләре өчен укытучылар әзерли. Синодның Чиркәү-укыту ведомствосы карамагында була. 1907 елда ачыла. Махсус төзелгән үз бинасында урнаша. Укыту процессы 1902 елдагы Чиркәү-укытучылар мәктәбе уставы б-н килешенеп оештырыла. Бирегә икенче баскыч мәктәпләрне яисә аларга тиңдәшле земство ике классы мәктәпләрен тәмамлаган крәстиян балалары кабул ителә. Уку вакыты 3 ел була. Илаһи Канунга (Закон Божий), чиркәү хорына, дидактикага зур игътибар бирелә. К.ч.-у.м. каршында пед. практика өчен база булып торган үрнәк чиркәү-приход мәктәбе эшли. 1918 ел башында ябыла.

*Әд.:* С а н а ч и н С.П. Красный дом на Декабристов // Казан. телеграф. 1997. № 103; И с х а к о в а Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001. *Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н ЧУКРА́К-ТЕЛСЕЗЛӘ́Р ИНСТИТУТЫ́**, Е.Г.Ласточкина исемендә, уку-укыту йорты һәм фәнни-методик үзәк. 1881 елдан эшләп килгән Казан чукрак-телсезләр уч-щесе җирлегендә 1922 дә Е.Г.*Ласточкина* оештыра. Ласточкина исеме 1926 да бирелә. Ул эксперименталь интернат-мәктәпне, педагог-дефектологларның квалификациясен күтәрү һәм белемен арттыру курслары системасын, укыту программалары һәм әсбаплар эшләнелә торган методика кабинетын үз эченә ала. Ласточкина җитәкчелегендә 1920 дә чукрак-телсезләрне татар телендә укыту оештырыла, акылы зәгыйфь чукрак-телсезләрне укыту методикасы булдырыла һәм сынала, 300 дән артык белгечләр хәзерләп чыгарыла. 1943 тә чукрак-телсезләр өчен интернат-мәктәп итеп үзгәртелә. Чукрак-телсезләр уч-щесе өчен 1905 тә төзелгән бинада урнашкан була (арх. И.Н.Колмаков, архит-ра истәлеге), хәзер анда 1 нче номерлы балалар музыка мәктәбе.

*Е.В.Липаков.*


**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р АСТРОНО́МИЯ ОБСЕРВАТО́РИЯСЕ**, Казан ун-тының фәнни-укыту учреждениесе, Казан ун-ты терр-ясендә урнашкан. Физика ф-тының астрономия кафедрасын, астрофотометрия, йолдызлар атмосферасы, күзәтүләр астрономиясе лаб-яләрен үз эченә ала. 1814 елда И.А.*Литтров* тарафыннан Казан астрономия обсерваториясе буларак төзелә, 1901 дән хәзерге исемдә.

Обсерватория өчен телескоп 1835 тә Фраунгофер остаханәсендә төзелә башлый, 1837 нең августында И.М.*Симонов* аны С.-Петербургта кабул итеп ала һәм Казанга кайтара. 1838 нең августында телескоп агач материалга беркетеп урнаштырыла. 1850 дә аны чуен б-н беркетәләр. Рефракторының көпшәсе агач булып, аңа микрометр һәм 1000 тапкыр зурайта ала торган окулярлар куела. Соңыннан телекскоп берничә тапкыр үзгәртелә. 1930 елларда инструмент астрофизик күзәтүләргә яраклаштырып көйләнә һәм 1990 елларга кадәр шуңа хезмәт итә.

Төгәл вакытны саклау өчен И.М.Симонов 1823 тә Парижның Брегет фирмасыннан беренче маятникдлы сәгатьне, 1838 дә С.-Петербургта Гаут остадан икенчесен сатып ала. Аларга обсерватория тәрәзәсенә 1885 нең 23 февралендә циферблат көйләп куела һәм сәгатьләр 50 елдан артык эшләп торалар, казанлылар шуннан карап төгәл вакытны белгели.

И.М.Симонов тарафыннан алынган (1847) соңгы зур инструмент — Репсольд (Гамбург ш.) эшләгән меридиан түгәрәге, ул яктырткычларның күк сферасындагы торышын һәм координаталарын югары төгәллек б-н билгеләргә мөмкинлек бирә. 1902 дә Репсольд фирмасы башкарган яңартулардан соң, меридиан түгәрәге шәһәр читендәге астрономия обсерваториясенә тапшырыла.

К.ш.а.о.н инструментлар б-н тәэмин итү 1855–84 елларда обсерваторияне җитәкләгән М.А.Ковальский чорында төгәлләнә. (Аңа кадәр директор булып Орион томанлыгын тасвирлаган М.В.Ляпунов эшләп ала, 1850–55). М.А.Ковальский 1861 дә — компенсацион маятникдлы Tiede № 268 йолдызлар сәгатен, ә 1874 тә Репсольд тарафыннан эшләнгән гелиометрны алдыра, соңгысы планеталар, Ай, Кояшның почмакча үлчәмнәрен һәм алар дискындагы детальләрнең үлчәмнәрен төгәл билгеләргә мөмкинлек бирә.



Казан шәһәр астрономия обсерваториясе бинасы.

Казанда яшәвенең беренче унъеллыгында М.А.Ковальский күбрәк теоретик мәсьәләләр б-н шөгыльләнә, аерым алганда, Кояш системасының фәзадагы хәрәкәтен билгеләү алымын эшли һәм Галактиканың әйләнүе турында фараз әйтә (1859), Нептун планетасы хәрәкәтенең теориясен эшли (1852). 1860 еллар башында ул йолдызларның меридиан түгәрәгендәге торышын даими күзәтүгә керешә. 1869 да К.ш.а.о. 9,5 йолдызча зурлыктан яктырак булган барлык йолдызларның координатларын билгеләү буенча халыкара программага кертелә (Бонн күзәтчелеге); обсерваториядә төньяк авышлыкның 75–80 нче градуслары зонасында күзәтүләр алып барыла. Гомеренең соңгы елларын М.А.Ковальский алынган нәтиҗәләрне эшкәртүгә багышлый. 1884 тә обсерваториянең директоры, астрономия һәм геодезия кафедралары профессоры итеп Д.И.*Дубяго* билгеләнә. Ул эшләгәндә обсерваториянең штаты арттырыла, К.ш.а.о.нең фәнни хезмәтләрен даими нәшер итү (1893 тән) башлана. Обсерватория китапханәсе өчен китаплар алуга акча булмаганлыктан (1884 тә анда төрле-төрле 875 том исәпләнә), Д.И.Дубяго бөтен дөнья обсерваторияләренә басма хезмәтләре б-н алмашырга тәкъдим итә. Бу тәкъдимнән аларның берсе дә баш тартмый, һәм 1917 елга обсерваториядә 9 мең том хезмәт була. Хезмәтләр алмашу хәзерге вакытта да дәвам итә.

Д.И.Дубягоның теоретик хезмәтләре, ш.и. Диана астероиды хәрәкәте теориясе, аңа Дрезден шәһәрендә (Германия) шәхси обсерватория төзегән В.П.*Энгельгардт* б-н хат алышу (соңыннан дуслашу) мөмкинлеге бирә. Соңрак В.П.Энгельгардт үзенең инструментларын Казан ун-тына бүләк итә, һәм шул сәбәпле Д.И.Дубяго шәһәр читендә астрономик обсерватория төзүгә, 1901 дә аны ачуга ирешә. 1903 тән — Энгельгардт обсерваториясе; 1931 дән В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе (АОЭ) дип атыйлар.

К.ш.а.о.нең күп кенә инструментлары АОЭга тапшырыла. Шәһәр обсерваториясе шуннан соң АОЭ б-н тыгыз һәм үзара файдалы хезмәттәшлектә үсә.

Обсерватория инструментларын кулланып, Д.И.Дубягоның шәкертләре дөньякүләм әһәмиятле тикшеренүләр үткәрә. Астроном М.А.Грачёв 1893–1901 дә халыкара программа буенча киңлекнең үзгәрүчәнлеген күзәтә һәм шуның өчен ике медаль, премия б-н бүләкләнә. 1890 елларда В.А.Краснов Ай либрациясен өйрәнә башлый, бу эшне 1910–16 да АОЭда Т.А.Банахевич, соңрак А.А.Яковкин дәвам итә. Күзәтүләрнең эшкәртмәләре Яковкинга Айның төньяк һәм көньяк ярымшарлары асимметриясен ачарга мөмкинлек бирә. В.А.Баранов (1918–41 дә К.ш.а.о. директоры) 1900 елларда Идел буе һәм Кама алды буйлап күпсанлы экспедицияләрдә гравиметрик тикшеренүләр үткәрә.

Инструментларның күп өлеше АОЭга бирелүгә карамастан, 1920 елларда да К.ш.а.о.да актив күзәтү эшләре алып барыла. А.Д.*Дубяго* 6 дюймлы (162 *мм*) Мерц комета эзләгече ярдәмендә 2 комета ача (1921 һәм 1923 тә). Бу ачышлар Казанда кометаларны тикшерү эшенә нигез сала, соңыннан ул теоретик характер ала (комета орбиталарын исәпләү). А.Д.Дубяго югалган дип исәпләнгән күп кенә кометаларның орбиталарын исәпләп таба, алар хәрәкәтенә гравитацион булмаган тәэсирләрне исәпләү методикасын эшли. 1920 елларда А.Д.Дубяго һәм Д.Я.Мартынов — астероидлар һәм кометаларны, 1920 еллар уртасыннан тотылучан-куш йолдызларны актив күзәтәләр. Бу тикшеренүләрнең үсеше Д.Я.Мартыновка әлеге йолдызларны өйрәнү буенча дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни юнәлеш тудырырга мөмкинлек бирә; соңыннан бу юнәлеш аның шәкертләре тарафыннан Казанда һәм Мәскәүдә тагын да үстерелә.

1930 елларда шәһәр күгенең яктыртылуы аркасында обсерваториядә актив күзәтүләр ясап булмый башлый. К.ш.а.о. нигездә студентларны укыту үзәгенә һәм АОЭнең күзәтү эшләре б-н тыгыз бәйләнештә алып барыла торган күпсанлы теоретик тикшеренүләр үткәрү урынына әверелә.

Бөек Ватан сугышы елларында Казанга Мәскәүнең академик учреждениеләре эвакуацияләнә; шәһәр обсерваториясе бинасында күп кенә танылган галимнәр, ш.и. акад. О.Ю.Шмидт яши. Ул үзенең Кояш системасы барлыкка килү турындагы фаразын Казан ун-ты галимнәренең семинарында бәян итә.

1957 дә К.ш.а.о. директоры итеп Ш.Т.Хәбибуллин билгеләнә (1987 гә кадәр), ул АОЭда йолдызлар астрономиясе эшләренә нигез сала, АОЭның горизонталь Ай телескобында Айның либрациясен өйрәнә һәм 1957 дә Айның физик либрациясе теориясен төзи. Аның шәкертләре планеталар, аларның иярченнәре һәм астероидларның резонанслы хәрәкәтләрен өйрәнү өстендә эшлиләр. Алар тарафыннан Юпитер төркеме астероидлары — «троялылар»ның (1987), Венера планетасының (1994) резонанслы хәрәкәте теорияләре, Айның физик либрациясенең хәзерге яримааналитик теориясе (1995) эшләнә. Р.А.Кащеев Айның, Марс һ.б. планеталарның гравитация кырларын өйрәнү алымнарын эшли һәм үстерә.

Космик эраның башыннан К.ш.а.о.ндә Җирнең ясалма юлдашларын күзәтү буенча СССР Астросоветы станциясе оештырыла (1957). Станциянең мөдире итеп кометалар хәрәкәтен (аерым алганда Джакобини-Циннер кометасының) һәм аларның метеор тупланмалары б-н бәйләнешен тикшерүләре буенча танылган галим Ю.В.Евдокимов билгеләнә. Иярченнәрне оптик тикшерү эшчәнлеге станциядә 10 елдан артык дәвам итә.

1950–60 елларда обсерваториядә астрофизик тикшеренүләр башлана. Д.Я.Мартыновның шәкерте М.И.Лавров тотылучан-куш йолдызлар җемелдәве кәкреләрен компьютерда модельләү алымнарын эшли, һәм бу АОЭда күзәтелгән бик күп йолдызларның үлчәмнәрен һәм массаларын табарга, төрле спектраль класстагы йолдыз дискларының кырыйга таба караңгылануын өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Ш.Т.Хәбибуллин шәкерте Н.А.*Сәхибуллин* (1987 дән К.ш.а.о. директоры) йолдыз атмосфераларын анализлауның заманча алымнарын эшли (1972). Кайнар йолдызлар атмосферасындагы һәм алар өслегеннән купкан җилләрдәге физик шартларны тикшерә, бу йолдызлар спектрындагы икеләтә йонлашкан углерод сызыгының эмиссиясен аңлатып бирә. Н.А.Сәхибуллин шәкертләренең бу алымнарны үстерүе нәтиҗәсендә аларны тыгыз куш йолдызларны һәм компактлы релятивистик объектлар (1992 дән), йолдызларның химик составы буенча мөһим тикшеренүләр үткәрүдә, Галактиканың химик һәм физик эволюциясенең монотон түгеллеге турында нәтиҗәләр чыгаруда (2000) куллану мөмкин була.

Казан зонасында күзәтүләр өчен астроклиматик шартларның начараюы аркасында АОЭда астрономик күзәтүләр кыенлаша. 1970 еллардан К.ш.а.о. һәм АОЭ биек тауларда заманча күзәтү базалары төзи. 1975 тә *Төньяк Кавказ астрономия станциясе* сафка баса, аңа диаметры 40 *см* булган Цейсс астрографы куела. 1998 дә Анталья (Төркия) шәһәре тирәсендәге Бакерлетөп тавында (диңгез өстеннән 2,5 мең *м*) куелган һәм көзгесе 1,5 *м* диаметрлы Казан телескобы эшли башлый.

К.ш.а.о., оешкан көненнән башлап, төгәл вакытны саклау һәм тарату үзәге була. 1930 еллардан обсерваториядә актив төстә астрономогеодезия тикшеренүләре үсеш ала, хезмәткәрләр Идел буе һәм Урал алды терр-ясендә күпсанлы астропунктлар координаталарын төгәл билгелиләр. К.ш.а.о. Татарстан һәм күрше төбәкләр икътисадын үстерүдә зур әһәмияткә ия булган спутникълы навигация системаларын (GPS) өйрәнү һәм куллану буенча региональ үзәк ролен үти.

К.ш.а.о.нең директорлары булып, традиция буенча, Казан ун-тының астрономия каф.



Казан шәһәр астрономия обсерваториясе. Лекцияләр залы.

мөдирләре эшли. Студентлар ике белгечлек — «астрономия» һәм «астрономогеодезия», аспирантлар — «астрофизика һәм радиоастрономия», «астрономия һәм күк механикасы» белгечлекләре буенча әзерләнә.

К.ш.а.о.нең хәзерге бинасы — классицизм архит-расы истәлеге, арх. М.П.Коринфский проекты буенча ун-тның төп корпусына бик якын итеп төзелә. Бинага 1833 нең 5 октябрендә нигез салына, 1838 дә ул төзелеп бетә. Аның структурасы астрономик күзәтүләр өчен яраклаштырып эшләнә. Батынкы төп фасады көньяк-көнбатышка каратылган һәм террасалар б-н әйләндереп алынган. Бинаның көнчыгыш һәм көнбатыш өлешләреннән яктырткычлар меридианда һәм беренче вертикальдә күзәтелә. Ярымтүгәрәкнең уртасында 9 дюймлы (объективының диаметры 23 *см*) телескоп-рефрактор (обсерваториянең төп инструменты) өчен манара урнаштырылган; бинаның ике читендә астрономия инструментлары өчен манаралар эшләнгән. 1842 елгы янгын вакытында бина шактый зыян күрә, соңыннан әүвәлге рәвешендә яңадан төзелә. 2000 еллар башында капиталь ремонт һәм реставрация ясала.

*Әд.:* Б а р а н о в В.А. Энгельгардтовская обсерватория, её возникновение и развитие (1901–1935 гг.) // Изв. Астрон. Энгельгардтовской обсерватории Казан. ун-та. 1937. Т. 1, вып. 1; М а р т ы н о в Д.Я. Астрономия в Казанском университете в 20-е годы // Ист.-астрон. исслед. 1983. Вып. 16.

*В.Ф.Сөләйманов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р ДУ́МАСЫ**, Казан шәһәр үзидарәсенең башкарма органы (1870 елның 21 декабре – 1918 нең 28 гыйнвары). Шәһәрне төзекләндерү, сәламәтлек саклау, мәгариф, иганәчелек һ.б. мәсьәләләр б-н шөгыльләнә. Шәһәр башлыгы җитәкчелек итә. Башкарма органы: алты гласныйлы Дума (1785 тән), Казан шәһәр идарәсе (1870 тән). 1870 елгы реформа нигезендә К.ш.д.нда гласныйлар саны — 72 кешедән, 1892 елгы реформа нигезендә 80 кешедән артмый; алардан тыш, утырышларга тавыш бирү хокукы б-н Казан өязе земство идарәсе рәисен һәм рухани ведомство депутатын чакыралар. К.ш.д.нда сәүдәгәрләр һәм дворяннар вәкилләре гласныйларның гомуми санының 65% ыннан да күбрәген тәшкил итә. Дума утырышларында барлык мәсьәләләр күпчелек тавыш б-н хәл ителә, тавышлар тигез булганда рәис тавышы өстенлек бирә. Дума утырышлары айга 1–2 мәртәбә үткәрелә. Алар шәһәр башлыгы карары, губернатор таләбе яисә гласныйларның кимендә 20% ның теләге б-н чакырыла. Дума карарларын губернатор расларга тиеш була. 1892 елдан соң шәһәр идарәсе гласныйлардан бәйсезрәк була, шәһәр башлыгының хокуклары шактый киңәйтелә. Хезмәт хакын бары тик идарә канцеляриясе әгъзаларына һәм анда эшләүчеләргә, ш.у. шәһәр башлыгына (төрле елларда 4,2 меңнән 7 мең сумга кадәр) гына түләнә. Дума үткәргән чаралар шәһәрне төзекләндерүгә, аның абруен күтәрүгә, шәһәрдә яшәүчеләрнең тормыш эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар булдыруга юнәлдерелә. 1870 елларда салым салу системасы һәм идарә итү механизмнары тәртипкә кителә; 1880 елларда — халык мәгарифен һәм иганәчелек учреждениеләрен яхшырту, 1890 елларда Казанны гомумроссия тимер юллары б-н тоташтыру мәсьәләләре карала; 1990 еллар башында гласныйларның игътибары шәһәрнең медицина-санитария хәлен яхшырту мәсьәләләренә юнәлтелә. Шәһәрнең санитария хәлен яхшырту өчен дума китерелә торган азык-төлеккә санитария тикшерүен оештыра, аз керемлеләр өчен шәһәр дәвалау учреждениеләре челтәрен булдыра, чәчәк авыруына каршы гомумкүләм прививка ясау программасын гамәлгә ашыра, аның инициативасы б-н ел саен эпидемиология чаралары үткәрелә. Дума гласныйлары тырышлыгы нәтиҗәсендә Казанда сууткәргеч, шәһәр мал сую урыны, альбумин — эчәк з-ды, газ һәм эл. б-н яктырту, трамвайлар, шәһәр музее барлыкка килә, уку йортлары челтәре киңәя. Шәһәр өчен фәнни-сәнәгать күргәзмәсе (1890–91) зур әһәмияткә ия була. К.ш.д.ның шәһәрне икътисади үстерү планында Шәһәр җәмәгать банкы, шәһәр ломбарды һәм шәһәр хезмәт сөю йорты оештырыла. Шәһәрне төзекләндерү өчен Лядской, Мокринский, Черек күл, Юныс, Николай, Театр, Фукс, Андреев исемле бакчалар һәм скверлар, Александр II һәм Н.И.Лобачевский һәйкәлләре янында чәчәк түтәлләре булдырыла. Халык мәгарифен яхшырту өчен дә күп нәрсәләр эшләнә. Шәһәр думасы фәнни һәм урта уку йортлары турында кайгыртырга, югары уку йортларына мөмкин кадәр ярдәм итәргә тиеш була. Дума гласныйлары уку йортлары ихтыяҗлары өчен шәһәр җиренең иң яхшы кишәрлекләрен бирергә тырышалар. Шәһәр бюджетыннан шәхси, земство һәм дәүләт уку

йортларына пособиеләр түләнә, халык китапханәсе, фәнни-сәнәгать музее, түләүсез уку залы кебек гомуми файда китерүче йортларга акча бүлеп бирелә, ш.у. шәхси китапханә һәм уку залларына ярдәм күрсәтелә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында дума җыены тылны оештыру чаралары күрә: шәһәрдәге финанс һәм товар әйләнешен тотрыклыландыру мәсьәләләре хәл ителә, икмәк, утын, керосин һәм иң кирәкле башка товарлар сатып алына. Дума Хәрби-сәнәгать ком-ты оештыра, фронттан яралыларны кабул итү өчен госпитальләр булдыра. 1914 елдан К.ш.д. Гомумшәһәр берлегенә керә. Шәһәр үзидарә органнарының актив хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә 20 нче еллар башына төзеклек ягыннан Казанның тышкы кыяфәте шактый үзгәрә. Кайбер казанлылар өчен (С.Ш.*Алкин*, И.В.*Годнев*, Г.Ф.*Шершеневич* һ.б.) думада эшләү иҗтимагый-сәяси карьера ясау өчен чыныгу урыны була.

Казан шәһәр башлыклары: И.Ф.Дряблов (1767–69), В.Т.Поярков (1770–72), П.Г.*Каменев* (1773–75), А.Б.Аникиев (1776–81), И.И.Кобелев (1782–84), П.И.Богдановский (1785–87), А.И.*Квасников* (1788–90), П.И.Комаров (1791–93), П.Д.Смирнов (1794–96), О.С.Петров (1797–99), А.И.Квасников (1800–02), И.С.Жарков, И.Д.Хамов (1803–05), И.А.Варнавин (1806–08), Л.Ф.Крупенников (1809–11), Ф.И.Хворов (1812–14), П.С.Суханов (1815–17), Ф.Ф.Золотарёв (1818–20), Ф.И.Хворов (1821–23), К.И.Котелов, В.Я.Заусайлов (1824–26), В.С.Потехин (1827–29), Н.О.Чижов (1830–32), Г.С.Мельников (1833–35), М.С.Верин (1836–38), В.С.Матвеев, И.С.Ососов, А.Л.Крупенников (1839–41), С.Е.Александров (1842–44), А.С.Унженин (1854–56), А.К.Месетников, А.К.Подуруев, И.Я.Тихонов (1857–59), Я.Д.Соколов (1860–62), П.А.Прибытков (1863–65), И.Я.Тихонов (1866–68), Д.И.Вараксин (1869–70), К.И.Романов (1871), Э.П.Янишевский (1872–82), А.А.*Лебедев* (1883–88), С.В.*Дьяченко* (1888–99), А.А.Лебедев (1899–1903), Р.Ф.Николаи (1903–05), А.П.Попрядухин (1905–08), С.А.Бекетов (1909–12), В.Д.Боронин (1913 – 8.11.1917), С.М.Ефимов (8.11.1917 — гыйнвар 1918).

1835 тән Дума Иван мәйданында (хәзер 1 Май мәйданы) арх. Ф.И.Петонди проекты буенча сәүдәгәр Евреиновның соңгы классизм стилендә үзгәртеп корылган өч катлы торак йортында урнаша. Күләме буенча симметрик, төп фасадында почмаклары түгәрәкләнгән бина 1842 елгы янгын вакытында зыян күрә. 1846 да арх. Х.Крамп бина интерьерларын үзгәртеп кора, төп фасадның ишеге өстенә металл кронштейннар куеп балкон эшли. 19 йөз ахырында төп ишек дүрт баганалы а́ркалы портик б-н бизәлә. 2000–01 дә бинада конференц-зал булдырыла, ишегалды фасады үзгәртеп корыла. Хәзерге вакытта биредә халык депутатларының Казан шәһәр советы һәм Казан муниципаль берәмлеге башлыгы урнашкан. Бина — архит-ра истәлеге.

Чыг.: Алфавитный указатель постановлений Казанской Городской Думы. [Б. м.], 1883; Сборник обязательных для жителей г.Казани постановлений Казанской Городской Думы. 1872–1913 гг. К., 1914; Достойны памяти пютомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* Краткий очерк деятельности Казанского городского самоуправления за 25-летие (1871–1895). К., 1896; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Г о н ч а р е н к о Л.Н. Города Среднего и Нижнего Поволжья во второй половине XIX века: Соц.-экон. исслед. Чебоксары, 1994; С а л и х о в Р.Р. Представительство татар-мусульман в выборных органах местного самоуправления в Казани на рубеже XIX-XX вв. // Ислам в татарском мире. История и современность: Материалы междунар. симп. К., 1997; З о р и н А.Н. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

*Г.Р.Заманова, Х.Г.Надыйрова.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р ҖӘМӘГА́ТЬ БА́НКЫ**, 1848 елның 2 гыйнварында Казанда ярлы, өлкән яшьтәге һәм гарип гражданнар өчен Ятимнәр йорты ачылу уңаеннан Шәһәр думасы башлангычында оештырыла. Максаты — шәһәр җәмәгать хуҗалыгына һәм аерым кешеләргә күчемсез милек һәм кыйммәтле кәгазьләр исәбенә бурычка акча (кредит) биреп тору, фонд базарында финанс операцияләре үткәрү һ.б. Алынган табыш Ятимнәр йортын тотуга бирелә. Банк вексельләрне исәпкә ала; дәүләт процент кәгазьләре, акцияләр һәм облигацияләр, күчемсез милек һәм кыйммәтле әйберләрне амәнәткә салу исәбенә акча бирә; банк капиталы исәбенә процентлы кәгазьләр сатып ала. Аның агымдагы хисабы була. Кертемнәр кыска сроклы, сроксыз һәм даими сроклы саклаулы була. Илле елда (1848–98) аларның гомуми суммасы 45102 мең сум тәшкил итә; шул ук чорда кертемнәр буенча 4053 мең сумлык процент түләнә. К.ш.җ.б. әйләнешендә түбәндәге капиталлар була: төп (1897 дә — 858 мең сумнан күбрәк, 1911 дә — 1279 мең сум, 1914 тә 1343 мең сум тәшкил итә), резерв, запас (1897 дә — 294 мең сум, 1911 дә — 426 мең сум, 1914 тә — 447 мең сум), Ятимнәр йорты капиталы (287 мең сум) һәм Коммерция уч-щесе капиталы. Илле елда К.ш.җ.б. операцияләре буенча әйләнештә булган барлык капиталның гомуми суммасы — 133099 мең сум, 1911 дә капитал әйләнеше 31034 мең сум тәшкил итә. Банк б-н гомуми идарә итүне Шәһәр думасы, Банк идарәсе, Күзәтчелек советы, директор гамәлгә ашыра. Төрле елларда директорлар: А.К.Месетников (1848–51; 1957–58), С.Е.Александров (1851–54), А.С.Унженин (1854–57), А.К.Подуруев (1958–59), И.Я.Тиханов (1859–60), Я.Д.Соколов (1860–63), И.П.Карпов (1863–71), В.Н.Никитин (1871нең 15 мартыннан до 22 ноябренә кадәр), В.Е.Соломин (1871–73), А.П.Алексеев (1873–84), И.В.Галкин (1884–92), А.Н.Чарушин (1892–1900). 1917 елның декабрендә Совет хөкүмәте карары б-н национализацияләнә.

*Әд.:* Отчёт о деятельности Казанского городского общественного банка за пятьдесят лет (с 1848 по 1898 год). К., 1898.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р КОММУ́НАСЫ**, Казанда 1905 елның 19–21 октябрендәге революцион үзидарә органы. 1905 нең 17 октябрендә җирле хакимиятләр митингка җыелган тыныч халыкны бастыралар. С.-д. һәм эсерлар массаларны губерна хакимиятенә каршы чыгарга һәм идарә итүне үз кулларына алырга чакыралар. 19 октябрьдә халык вәкилләре катнашында шәһәр думасының ашыгыч утырышы була. Канлы вакыйгаларны тикшерү, аның төп гаепләләрен хөкем итүгә тапшыру, казакларны шәһәрдән куу, полиция булдырудан баш тарту, аның урынына шәһәр милициясе оештыру һ.б. өчен дума гласныйлары һәм округ мәхкәмәсе прокуроры составында комиссия төзү турында карар кабул ителә. Әлеге таләпләрне тормышка ашырырга митинглар, манифестацияләр ярдәм итәргә тиеш була. 19 октябрьдән 20 сенә каршы төндә К.ш.к. төзелә. Ул с.-д. һәм буржуаз партияләр, крәстияннар берлеге һәм башка оешмалар вәкилләреннән тора. Аның әгъзалары арасында большевиклар — И.А.Саммер, С.А.Лозовский, И.И.Дамперов, Н.Н.Накоряков; меньшевиклар — И.С.Алуф, А.А.Мизовский; эсерлар — Т.Л.Драверт, М.Якобсон; кадетлар — А.Г.Бать, Т.Г.Тельберг була. К.ш.к. 17 октябрьдә һәлак булганнарны җирләүне оештыра; халык милициясе б-н җитәкчелек итә һәм шәһәрдәге тәртипне күзәтә, ләкин барлык революцион көчләрне берләштерү чаралары күрелми, алда торган эшләрнең төгәл планы булмый. Бу чорда революционерларның төп таянычы булып фәкать укучы яшьләр һәм радикаль фикерле интеллигенция генә кала. Нәтиҗәдә 21 октябрьдә К.ш.к. җирле хакимиятләр ярдәмендә карагруһчылар тарафыннан тар-мар ителә. 130 милиционер, ш.и. И.А.Саммер, И.И.Дамперов, С.А.Лазовский, Г.Ю.Коләхмәтов, Ф.Ф.Туктаров, Ш.З.Мөхәммәдьяров кулга алына.

*Әд.:* С ә й ф и - К а з а н л ы Ф. Беренче революциядә Казанда һәм губернасында эшче-крәстиян хәрәкәте. К., 1931; А р о с е в А. Казанские очерки о революции 1905 г. К., 1925; Л и в ш и ц С. Казань в годы первой революции. К., 1930; Х а с а н о в Х.Х. Революция 1905–1907 гг. в Татарии. М., 1965; ш у л у к. Казань в годы первого штурма царизма. К., 1985.

*Р.Г.Әмирханов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р ПО́ЧТАСЫ**. Хатларны, визит карточкаларын, вакытлы матбугатны шәһәрдә тарату, ш.у. Россиянең башка шәһәрләренә җибәрү максатында 1866 елда Губерна почта конторасы каршында оештырыла. Казанда 13 почта тартмасы куела, 3 хат ташучы эшли, 6 хезмәткәр чит шәһәрләрдән килгән хатларны тарату б-н шөгыльләнә. Шәһәр почтасына хезмәт күрсәтү өчен атлы транспорт (почта экипажлары, кареталар, дилижанслар) файдаланыла. Җәйге вакытта почта көненә — 4, шәһәр читенә 3 тапкыр илтелә. 1920 елга Казанда почта тартмалары саны 70 кә җитә, 25 почта участогы була. Почта конторасында сортларга аеру өчен урыннар оештырыла, көненә 20 мең данәгә кадәр почта корреспонденциясе эшкәртелә. 1930 елларда хезмәт күрсәтү төрләре арта: элемтәнең почта бүлекчәләре аша заказлы корреспонденцияләр алына һәм бирелә, газета-журналларга язылу кабул ителә, пенсия һәм пособиеләр түләнә һ.б. 1950 елларда почтаны шкафларга (терәк пунктларга) машиналарда илтә башлыйлар, торак йортларда кор-

респонденцияләр өчен абонент почта тартмалары куела. 1964 тә Казан почтамтында элемтә хезмәтләре өчен клиентлар б-н исәп-хисап ясауны үзәкләштерелгән рәвештә исәпләү һәм эшкәртү өчен машина — исәп-хисап бюросы оештырыла. 1970 тән вакытлы матбугат иртән китерелә башлый. 1970–80 елларда матди база ныгытыла, төп почта операцияләре механикалаштырыла. Посылка, хат, бандероль, газета-журналларны эшкәртү өчен алты билгеле индексация нигезендә хатларны аеру, төргәкләрне бәйләү, ал ягына штемпель сугу машиналары, корреспонденцияләр тутырылган капчыкларны, газета төргәкләрен, посылкалы контейнерларны производство эчендә йөртү һәм эшкәртү урыннарына аерып тарату өчен тасмалы һәм чылбырлы конвейерлар кулланыла башлый, открытка, конверт, газета-журналлар сатучы ярымавтоматлар барлыкка килә. 1980 елларда Казанда, Россиядә беренчеләрдән буларак, вакытлы басмаларны кабул итү һәм заказлар эшләү ЕС-1030 хисаплау машинасында башкарыла. 2001 дә почта аша акча күчерүләрнең бердәм системасы (ЕСПП) гамәлгә кертелә, шуның нәтиҗәсендә электрон почта акча күчерү һәм түләү арасындагы вакыт 72 сәгатькә кадәр кыскара.

2003 тә «Почта салоны» ачыла. Операторларның эш урыннары персональ компьютерлар, контроль-касса аппаратлары б-н җиһазландырыла. 13 элемтә почта бүлекчәсендә, «Россия электроникасы» федераль максатчан программаны тормышка ашыру кысаларында, Интернетка коллектив керү пункты ачыла. Шәһәр эчендә почта күчермәләрен алмашу буенча 15 маршрут булдырыла (җыю һәм илтеп тапшыру атнасына 6 тапкыр башкарыла). 2005 тә Казанда 81 почта бүлекчәсе эшли; 111 номерлы почта бүлеге базасында Татарстанда беренче юридик затлар б-н эшләү бүлекчәсе ачыла.

1998 дән 2005 нең июленә кадәр К.ш.п. «Татарстан почтасы» почта элемтәсе идарәсе» дәүләт унитар пр-тиесе составында була. 2006 дан К.ш.п. «Казан почтамты» дигән аерым структур подразделение булып бүленеп чыга. 2005 тә 15 нче почта элемтәсе бүлекчәсе каршында Почта элемтәсе музее ачыла. Ш.у.к. *Почта*, *Телеграф*, *Элемтә*.

*Әд.:* Орлова А.Ф. Время и связь. К., 1988; Веками вместе с вами: 115 лет Казанской ГТС. К., 2003; Людей связующая нить. К., 2003.

*Г.Я.Мәүлетова, Т.С.Янькова.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р ПСИХОНЕВРОЛО́ГИЯ ХАСТАХАНӘСЕ́**, акад. В.М.Бехтерев исемендә, клиник дәвалау-профилактика учреждениесе. 1885 елда Казан округының «Барлык хәсрәт чигүчеләр юанычы Мәрьям Ана» рухына аталган хастаханә (хәзерге Республика психиатрия хастаханәсе) каршында акылга зәгыйфь авыруларны дәвалау клиникасы оештырыла (мөдире — проф. В.М.*Бехтерев*). Клиникада Россиядә беренче психоневрологик лаб. ачыла; хәзерге чорда да бераз үзгәртелгән рәвештә медицинада кулланылышта булган гипноз ярдәмендә эчкечелек авыруын кумәк психик дәвалау эше башлана. Акылга зәгыйфь авыруларны дәвалау клиникасы өчен яңа бина 1912 дә төзелә башлый. В.М.Бехтерев һәм В.П.*Осипов* проектлау, финанс һәм төзелеш мәсьәләләрен хәл итүдә катнашалар. Махсус дәвалау учреждениесе буларак, клиника бинасы проекты (арх. И.И.Брюно) Берлин психиатрлар конгрессында (1911) алтын медальгә лаек була; клиника 1914 нең июль аенда ачыла. Беренче бөтендөнья сугышы башында клиникада госпиталь оештырыла; сугыштан соң — акылы зәгыйфь авырулар өчен клиника, ш.у. Казан ун-ты мед. ф-тының психиатрия кафедрасы базасы була. Казанда фәнни һәм гамәли психиатрия үсешендә яңа этап Т.И.Юдин (1904 тән Округ психиатрия хастаханәсе директоры) эшчәнлеге б-н бәйле: психиатрик ярдәм эше үзгәртелә (тәрбияләү эше дәвалауга алмаштырыла), авыруларны тирәнтен өйрәнү һәм шул чор өчен алдынгы дәвалау ысуллары кулланылган дәвалау-диагноз кую бүлекләре оештырыла. Хастаханә гамәлендә элек кулланылган ирексезләү чаралары, дуамал авыруларны ябып кую бетерелә. Мед. хезмәткәрләре өчен яңа таләпләр (сан. белгечлеге минимумын, хезмәт иминлеге кагыйдәләрен белү) куела. ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика психиатрия хастаханәсе һәм акылы зәгыйфьләр өчен клиник хастаханә (психик авыруларның киеренке формалары һәм эчкечелек мәсьәләләренә аеруча игътибар бирелгән психоневрологик санаторий буларак) арасында эшчәнлекләре буенча төгәл бүленеш булдырыла. Авыруларны амбулатор кабул итү оештырыла, шәһәрнең балалар поликлиникаларында балалар стационарлары, психотерапия бүлекләре һәм кабинетлары ачыла. 1950–60 елларда К.ш.п.х., психоневрология бүлеге буларак, ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе составына керә. 1960 елда зур үзгәрешләр үткәрелә, яңадан амбулатор психиатрия хезмәте булдырыла. 1984 тән хастаханә акылы зәгыйфьләр өчен клиника буларак эшли; психиатриягә карамаган бүлекләр аерып чыгарыла; диспансер 250 урынлы итеп зурайтыла. Хастаханә хәзерге исеме б-н атала башлый (350 хезмәткәр). Хастаханә карамагында 100 урынлы көндезге һәм төнге стационарлар, 100 урынлы дәвалау-хезмәт остаханәләре, сәнәгать предприятиеләрендә психик авырулар һәм инвалидлар өчен махсус цехлар ачыла. 1990 елларда К.ш.п.х. төп бинасына үзгәртеп кору һәм капиталь төзекләндерү үткәрелә. 2004 тә хастаханә үз эченә диспансер-поликлиника бүлеген, 455 урынлы көндезге стационар, шәһәр поликлиникаларында кабинетлар челтәре булган Шәһәр психотерапия үзәген, суицидологик ярдәм кабинетын ала, Казан мед. ун-тының психиатрия каф. базасы булып тора. Табибләр һәм урта мед. хезмәткәрләр коллективы 500 кеше тәшкил итә. Клиниканың төрле еллардагы баш табибләре: В.М.Бехтерев, В.П.Осипов, Т.И.Юдин, Н.А.Авдонина, В.И.Казаков, В.А.Евплов (2002 дән). 2007 дән К.ш.п.х. Республика психиатрия хастаханәсе составына кертелә.


*Әд.:* Осипов В.П. Клиника душевных заболеваний Казанского Императорского университета. К., 1914; Болотовский И.С. Развитие научной психиатрии и состояние психиатрической помощи в г.Казани, бывшей Казанской губернии и Татарской АССР. К., 1966.

*В.А.Евплов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘ́Р ТЕЛЕФО́Н ЧЕЛТӘРЕ́** (Казан ГТСы), элемтә пр-тиесе. Казанда беренче телефон линиясе 1881 елда барлыкка килә. Ул Кремльдә урнашкан Казан пехота юнкерлар уч-щесен Воскресенская урамындагы офицерлар җыены бинасы (хәзер Кремль ур., 6 йорт) б-н бәйли һәм бары тик хәрби ихтыяҗлар өчен генә хезмәт итә. 1888 нең 27(15) ноябрендә Казан ГТСы рәсми рәвештә ачыла. Телефон челтәренең беренче башлыгы — А.А.Бабановский. Үзәк телефон станциясенә 70 ләп абонент тоташтырыла. Россиядә беренче булып, Казан ГТСында Швециянең «Эриксон» фирмасының МБ (җирле батарея) системасындагы шнурлы бер үткәргечле коммутаторы урнаштырыла. 1897 елга ГТС 337 абонентка хезмәт күрсәтә. Шәхси телефоннар өчен елына 60–70 сум (2 чакрымга кадәр ара булганда) һәм, шуңа өстәп, һәр чакрым өчен 15 әр сум түләнә. 1902 дә Үзәк телефон станциясендә реконструкция уздырыла — ЦБ (үзәк батарея) системасындагы шнурлы ике үткәргечле коммутаторлар куела. 1908 дә телефон челтәренең сыешлыгы 1 мең абоненттан артып китә. 1900 еллар башыннан белешмәләр бюросы (соңга таба белешмә-мәгълүмат хезмәте) эшләп килә. 1920 елларның 2 нче яртысында телефон челтәрендә киңәйтү, реконструкция, төзелешләр башлана. Һава челтәрен кабельле җир асты челтәренә алыштыру эшләре алып барыла. 1936 да ГТСның монтажланган сыешлыгы 4350 номер тәшкил итә. 1935–36 да Казанда телефон-автоматлар (таксофоннар) куела башлый. 1942 дә — сыешлыгы 2 мең номер булган, машина системалы беренче автомат телефон станциясе (АТС), 1951 дә — декадалы-адымлы системалы АТС (4,2 мең), 1954 тә — Ленин р-ны АТСы (дүртурынлы нумерация б-н 1 мең номер), 1963 тә Совет р-ны АТСы (3,2 мең) җиһазландырыла. Шул ук елда челтәрне бердәм бишурынлы нумерациягә күчерү эшләре башлана. 1978 дә координата системалы чыгарылма подстанция (ПСК-1000) монтажлана. 1983 тә ГТС та этаплап алтыурынлы нумерациягә күчү башлана, шул ук елда «Горки» торак массивында сыешлыгы 9,2 мең номер булган координаталы станция (АТСКУ) монтажлана һәм файдалануга тапшырыла. 1988 дә АТС-35 б-н АМТС (шәһәрара автомат телефон станциясе) арасында гомуми озынлыгы 6775 *м* булган



«Эриксон» телефон аппараты. 1896.



Декадалы-адымлы система станциясе.

беренче оптик-җепселле линия сафка баса. 1990 да — МТ тибындагы беренче электрон АТС-42 (ЭАТС), 1993 тә — ЭАТС-43, 1994 тә цифрлы станцияләр АТС-62/63, АТС-64 файдалануга тапшырыла. 1997 нең ахырыннан синхрон цифрлы STM-4 иерархиясенең беренче транспорт челтәре (SDH) «SINFONET» эшли башлый. 1999 дан шәһәрнең декада-адымлы системалы үзәк АТСы электрон — DX-200 тибындагы ЭАТС-92/93 б-н алыштырыла. Элемтә чараларына ихтыяҗ арта бару сәбәпле, ел саен шәһәр һәм посёлокларда гамәлдәге АТСлар киңәйтелә. 2002 дә STM-16 дәрәҗәсендәге синхрон цифрлы иерархиянең оптик-җепселле яңа транспорт челтәре гамәлгә кертелә (уздыру сәләте 2,5 *Гбит/с* ка кадәр), һәм ул челтәр трафигындагы барлык төрләрнең үсә баручы ихтыяҗларын тәэмин итә. 2006 ның 1 гыйнварына Казан ГТСы гомуми сыешлыгы 257 мең номер булган 23 станцияне һәм подстанцияне бергә берләштерә. Казан ГТСы шәһәр терр-ясендә 33 бинаны били. Шәһәр челтәрендә номерлар сыешлыгын арттыру б-н бергә телефон аппаратурасын сыйфат ягыннан яхшырту — заманча электрон җиһазлар һәм хисаплау техникасы чараларын куллану бара. Телефон станцияләрен программалаштыру 2001 дә җирле сөйләшүләргә вакытка бәйле тариф кертергә һәм берничә өстәмә



АТСК-56 автоматлар залы.

хезмәт күрсәтү оештырырга мөмкинлек тудыра. 2005 тә Казан Россиядә заманча цифрлы телекоммуникация челтәренә кучкән миллион кешелек беренче шәһәр була. 100% цифрлаштыру яңа төр инфокоммуникация хезмәтләрен гамәлгә кертү мөмкинлеге бирә. 2005 нең сентябрендә Казан ГТСы телефоннарның җидеурынлы нумерациясенә күчә, нәтиҗәдә яңа абонентлар кертү мөмкинлеге һәм яңа ресурслар барлыкка килә. 2002 дә элемтәнең сыйфат системасы ГОСТ Р ИСО 9001–2001 (ИСО 9001–2000) таләпләренә туры килә дигән сертификат алына.

1994 нең июлендә Казан ГТСы АҖ итеп үзгәртелә (аңа кадәр «Связьинформ» элемтә һәм мәгълүмат пр-тиесенең структур подразделениесе). 2000 дә автомат телефоннарга хезмәт күрсәтү өчен «Таксофон» ААҖ оештырыла, һәм 2003 тә «09» белешмә-мәгълүмат хезмәте дә аңа күчерелә. 2006 да «Казан шәһәр челтәре» АҖ «Таттелеком» АҖгә кушыла. Җитәкчеләр арасында: З.Ф.Курмашев (1960–68), Л.Х.Рәхмәтуллин (1968–71), М.М.Мусин (1971–77), В.Ф.Четверик (1977–86), Р.Т.Җәләлов (1986–93), Д.Н.Салихов (1993–99), А.М.Фәхриев (1999–2006).

Ш.у. к. *Земство телефон элемтәсе, Шәһәрара телефон элемтәсе, Элемтә, Телефон челтәре.*

*Әд.:* О р л о в а А.Ф. Время и связь. К., 1988; 100 лет Казанской городской телефонной сети. К., 1988; Веками вместе с вами: 115 лет Казанской ГТС. К., 2003; Людей связующая нить. К., 2003.

*В.Н.Богданов, С.Г.Белов, Г.Я.Мәүлетова.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ БАЛАЛА́Р ИҖА́Т САРАЕ́** (КШБИС), А. А л и ш и с е м е н д ә, Казан шәһәре мәгариф идарәсе карамагында, ТРдагы иң эре күппрофильле өстәмә белем бирү учреждениесе. 1934 елда шәһәр Пионерлар йорты буларак ачыла; 1961 дән А.Алиш исем. Пионерлар сарае, 1991 дән Балалар иҗат үзәге; 2001 дән хәзерге исемдә. Мәктәптән тыш белем бирү, спорт-техника, милли мәдәният һәм төбәкне өйрәнү, музыка-театр, сәнгать-эстетика бүлекләрендә, ш.у. хореография студиясендә белем бирүнең 95 программасы гамәлгә ашырыла. 2004 тә 384 төркемдә 6 мең бала шөгыльләнә, «Йолдызчык» балаларны сәламәтләндерү лагеренда КШБИС тан 900 гә якын укучы ял итә. Күп кенә иҗат коллективлары — хезмәт этләре асраучылык клубы, «Алишевец» хореография ансамбле, «Ак калфак» татар фольклор студиясе, Татар театр мәктәбе һ.б. — Россия һәм халыкара конкурсларда, ярышларда җиңү яулый һәм бүләкләнә. КШБИС бүлекләре һәм студияләре шәһәр һәм республика массакүләм чаралары оештыра: конкурслар, фестивальләр, конференцияләр, чемпионатлар. Аларда ел саен 50 мең тирәсе кеше катнаша. КШБИС методик эш һәм өстәмә белем бирү, музыка мәктәпләре, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен белем һәм тәрбия бирү йортларында хезмәт күрсәтүче педагогларның квалификацияләрен күтәрү үзәге булып тора. Методик һәм башка бүлекләрдә 26 методик берләшмә һәм 7 семинар эшли; уку ярдәмлекләре, репертуар җыентыклары һ.б. әдәбият басыла. КШБИС пед. коллективында 152 кеше, ш.и. 1 фән д-ры һәм 7 фән канд., 1 ТРның халык артисты һәм 1 ТРның атказ. артисты, 3 ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе һәм 11 ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре; 1 ТРның атказ. укытучысы һәм 1 ТРның атказ. табибе, РФнең республика категорияле 3 судьясы (2004) эшли.

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ ЙОГЫШЛЫ́ АВЫРУЛА́Р КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, А. Ф. А г а ф о н о в и с е м е н д ә (1947), йогышлы авыруларны дәвалау һәм кисәтү буенча күп профильле клиник учреждение (берләшмә). 1899 елда Ярлы һәм авыру балаларны кайгырту җәмгыяте тарафыннан 40 урынлы хастаханә буларак ачыла, 1901 дә аның каршында амбулатория оештырыла. Ел саен 300–400 бала стационар дәвалау үтә, 2 меңнән артык авыру амбулаториядә кабул ителә. 1916 да агач бина төзелеп бетә (кабул итү бүлеге), хастаханә б-н рәттән аның хезмәткәрләре өчен торак биналар урнаша. Хастаханәнең ярдәмче хуҗалыгы була.

1918 дә ул бюджеттан тәэмин ителә башлый һәм Совет балалар хастаханәсе дигән исем ала, 1920 дән — 1 нче балалар хастаханәсе. 1923 тә аның җирлегендә Казан ун-тының проф. Б.А.Вольтер җитәкчелегендәге йогышлы авырулар каф. оештырыла, 1924 тә хастаханәнең йогышлы авырулар каф. (мөдире — С.С.Зимницкий) ачыла. Кафедралар һәм хастаханә хезмәткәрләре тимгелле тиф, корсак тифы һәм кайтма тиф, бизгәк, скарлатина, дифтерия б-н көрәштә актив катнашалар. 1931 дә баш табиб Е.М.Идельсон җитәкчелегендә 235 урынлы хастаханә өчен яраклаштырылган агач бина төзелеп бетә. Бөек Ватан сугышы елларында кафедралар һәм хастаханә табибләре эвакуация госпитальләрендә һәм хәрби әсирләр лагерьларында консультацияләр, табибләр өчен йогышлы авыруларны булдырмый калу һәм дәвалау буенча семинарлар үткәрәләр; 1960–70 елларда ТАССР һәм Идел буе р-ннарында грипп, авыр клиник характердагы менингококк инфекциясенең, бөер синдромлы геморрагик бизгәкнең зур эпидемик таралышларын бетерүдә катнашалар.

1979 да хастаханәдә реанимация бүлеге булдырыла һәм анестезиолог-реаниматолог табиб вазифасы кертелә, штатта табибләр саны арттырыла (7 бүлек мөдире, 18 табиб-инфекционист, 6 табиб-ординатор, 98 урта мед. персоналы). Халыкка мед. ярдәме күрсәтүне яхшырту максатыннан респ-каның барлык р-ннары хастаханә һәм кафедралар табибләренә аерып беркетелә, ш.у. эпидемия ачыкланган төбәкләрдә консультацияләр оештырыла.

2006 да К.ш.й.а.к.х. составына 1 нче, 2 нче йогышлы авырулар хастаханәләре, балалар йогышлы авырулары хастаханәсе кертелә, 2010 га хастаханәдә 220 балалар, 85 олылар һәм 6 реанимация койка-урыны, дисбактериозларга диагноз кую һәм дәвалау үзәге, җиһазландырылган лаб-яләр (клиник, бактериологик, биохимик), рентгеноскопия, УЗИ, эндоскопия кабинетлары исәпләнә. Йогышлы авырулар клиникасы Казан мед. ун-тының йогышлы авырулар (1930 дан), балалар инфекцияләре (1933 тән), Казан мед. академия-

сенең йогышлы авырулар (1925 тән) кафедраларының укыту базасы булып тора. 2011 дән — Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе.

Ел саен берләшмәдә 10 меңнән артык авыру дәвалау курсы үтә. 10 меңнән артык кешегә кичектергесез ярдәм күрсәтелә. Хастаханәдә 500 дән артык мед. хезмәткәре эшли.

*Әд.:* Саматов В.А., Шигабутдинов Ф.М., Зуфарова А.В. Городской инфекционной больнице № 1 им. А.Ф.Агафонова 100 лет // Актуальные проблемы инфекционной патологии. К., 2000.

*В.Х.Фазылов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ КЛИ́МАТЫ**. Шәһәрдә метеорологик күзәтүләр 1733 елдан өзеклек б-н, 1828 дән даими рәвештә алып барыла. К.ш.к. «җылылык учаклары» (шәһәр үзәгендә) һәм «суыклык учаклары» (Казансу үзәнендә, Иделнең беренче тугай өсте террасасында һәм Кабан күлләре тирәсендә) булу б-н үзенчәлекле. Тыныч аяз һава торышы булганда иртәнге сәгатьләрдә алар арасында темп-ра сикерешләре 5 °С ка җитәргә мөмкин. Һаваның уртача еллык темп-расы 3,1 °С (абс. макс. 38 °С, абс. миним. −47 °С); уртача айлык макс. темп-ра 19,1 °С (июль), миним. темп-ра −13,5°С (гыйн.). 1887–1992 еллар эчендә глобаль җылыну процесслары һәм шәһәр терр-ясенең киңәюе йогынтысында уртача еллык темп-ра 1,27 °С ка үсте. Уртача еллык темп-раның әлеге үсешендә «шәһәр» өлешенә — 0,74 °С (58%), табигый һәм глобаль антропоген факторларга 0,53 °С (42%) туры килә. Җылы көннәр 209, салкыннары 156 көн дәвам итә. Уртача еллык явым-төшем 508 *мм* (миним. 305 *мм* 1920 елда, макс. 829 *мм* 1978 дә), җылы вакытта 373 *мм*. Кар якынча 27 октябрьдә ята, 13 апрельдә китә. Коры көннәр 23 (һаваның чагыштырмача дымлылыгы 30 %), дымлы көннәр 116 (дымлылык 80% тан артыграк). Яз башында, аяз көннәр булганда, «җылылык учакларында» һаваның чагыштырмача дымлылыгы «суыклык учакларына» караганда 25–30% ка түбәнрәк булырга мөмкин. Җилнең уртача еллык тизлеге 3,9 *м/с* (көчәйгәндә 40 *м/с* ка җитә). Җир өстенең уртача еллык темп-расы 4 °С, уртача айлык макс. темп-ра 23 °С (абс. макс. 60 °С, 1972), миним. темп-ра −14 °С (абс. миним. −46 °С, 1979); туңның уртача тирәнлеге 11 *см* (38–154 *см*).

*Әд.:* Климат Казани. Л., 1990.

*М.А.Верещагин, Э.П.Наумов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ КӨ́НКҮРЕШ ӘЙБЕРЛӘРЕ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́ БЕРЛЕГЕ́** («Казгорбытпромсоюз»), РСФСР ХКС каршындагы Һөнәрчелек кооперациясе идарәсенең 1944 елгы 1 апр. һәм ТАССР ХКСның 22 апр. боерыклары нигезендә Казан шәһәре ремонт-көнкүреш һөнәрчелеге берлеге буларак оештырыла, 1951 нең 8 гыйнварыннан — хәзерге исемдә. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советы* карамагында була. Төп максаты — җитештерүне оештыру һәм тармактагы кооператив артельләренең финанс эшчәнлеге б-н идарә итү. 13 артельне берләштерә. Производство-техника, финанс-хисап, план, тәэминат һәм сәүдә, оештыру-масса һ.б. бүлекләрдән тора. 1954 нең декабрендә бетерелә, аңа караган артельләр *Татарстан көнкүреш кәсепчелеге берлеге* составына тапшырыла.

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, ярдәм күрсәтүче оешма. 1898 елда татар сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать һәм дин эшлеклеләре тәкъдиме б-н оештырыла. Җәмгыятьне оештыручылар һәм аның Уставын эшләүчеләр — Казан сәүдәгәрләре М.И.*Галиев,* А.Я.Сәйдәшев, юрист С.Ш.*Алкин*. Җәмгыять, массакүләм җәмәгать оешмасы буларак, милли, конфессиональ, катлауларга бәйле һәм башка чикләүләрдән азат була. Шәрәфле, гомерлек һәм хакыйкый әгъзалардан тора. Беренчеләренә әлеге исем оешманың барлыкка килүе һәм үсешенә аеруча зур кертемнәре һәм эшчәнлекләре өчен гомуми җыелыш карары нигезендә бирелә. 60 сум һәм аннан күбрәк суммада ярдәм күрсәтүчеләр гомерлек әгъза булып исәпләнә, ел буена 5 сум күләмендә кертем кертүчеләр исә хакыйкый әгъзаларга санала. 1904 елның 28 мартындагы гомуми җыелыш карары нигезендә һәм Уставның 7 нче параграфына яраклы рәвештә Казанның барлык указлы муллалары ш.у. Җәмгыять әгъзалары дип саналалар. 1900 дә Җәмгыятьтә 9 шәрәфле, 46 гомерлек, 49 хакыйкый әгъза була, 1911 дә шул тәртиптә, — 15, 48, 233. Губернатор П.А.Полторацкий, шәһәр башлыгы С.В.Дьяченко, меценатлар О.С.Александрова-Гейнс һәм Д.В.Вараксин; медиклар С.С.Надель-Пружанская, А.И.Захарьевский; татар җәмәгать эшлеклеләре Г.Баруди, Г.А.Ишморатов, С.М.Аитов, С.Ш.Иманколов, И.В.Терегулов, З.М.Шамил, А.Я. һәм М.А. Сәйдәшевләр Җәмгыятьнең әгъзалары булып торалар. Идарә итүче органнары — гомуми җыелыш һәм 6–12 кешедән торган идарә. Идарә ай саен, ә гомуми җыелыш елга 2–3 мәртәбә җыела. Беренче идарә рәисе итеп М.Ш.Шамил, урынбасары — Ш.И.Әхмәров, секретаре — С.Ш.Алкин, казначие — И.И.Айтуганов сайланалар. Идарә составына ш.у. З.М.Шамил, С.С.Гобәйдуллин, И.Г.Үтәмешев, К.Г.Гыймадетдинов, А.М.Әҗемов, С.Д.Усманов керә. Идарә рәисләре: Ш.И.Әхмәров (1898–99), И.И.Айтуганов (1899–1902), Г.Г.Апанаев (1902–07), Г.М.Казаков (1907–08), А.Г.Мөсәлимов (1908–10), М.Г.Апанаев (1910–17) була. Оешманың түбәнге структурасына 15 участок попечительлеге карый, аларның вазифасына үз участокларында яшәүче фәкыйрьләрнең матди хәле турында мәгълүматлар җыю һәм аларга ярдәм күрсәтү керә. Попечительлек башлыкларын идарә сайлый. Җәмгыятьнең оешу вакытына аның карамагында гомуми күләме 39902 сумлык процент кәгазьләре, күчемсез милек һәм акча исәпләнә (аның 24 мең сумы мөселман картлар һәм гарипләр йорты ачу өчен бүлеп куела, 10 %ы Җәмгыятьнең запас капиталы итеп күчерелә), 1914 тә капитал 80589 сум тәшкил итә. Җәмгыять үз хисабына мәдрәсәләр, мәктәпләр, мәчетләр, мөселман зиратлары тота, шәкертләргә, Казанда яшәүче һәм читтән килгән ярлы мөселманнарга матди ярдәм күрсәтә, урта һәм югары уку йортларындагы талантлы укучыларның укуы өчен түләү кертә. Җәмгыять каршында ятимханәләр эшләп килә — ике мәктәпле балалар ятимханәсе (1905 тән) һәм бала тудыру йорты (1914 тән), ирләр һәм хатын-кызлар рус-татар уч-щеләре (1909 дан), амбулатория (1902 дән), мөселман хатын-кызларга бала тудыруда ярдәм итү, дәвалау йорты (1912 дән). Җәмгыять татар, рус сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре иганәсе, зәкят, әгъзалык кертемнәре, Казан шәһәр думасы субсидияләре, төрле күңел ачу чараларын үткәрүдән кергән акчалар хисабына яши. Ярдәм җыйнау өчен ш.у. һәвәскәрләр спектакльләре һәм сәнгать кичәләре дә уздырыла. 1911 гә оешма активларының зур өлеше (58300) күчемсез милектән гыйбарәт була. Җәмгыятькә Евангелистлар урамындагы (хәзер Татарстан ур.) табыш йорты карый, ул ел саен 1500 сум табыш китерә. Россиядәге шуңа охшаш 87 мөселман хәйрия җәмгыятьләре арасында капиталының күләме ягыннан җәмгыять 1 нче урында тора. 1917 нең октябренә кадәр яши.

*Әд.:* Салихов Р.Р.Татарская буржуазия Казани и национальные реформы второй половины XIX — начала XX в. К., 2000.

*Л.М. Айнетдинова.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ ТАТА́Р БИСТӘЛӘРЕ́ РА́ТУШАСЫ**, 1781–1855 елларда Казанда татар бистәләренең үзидарә органы. Ратуша составына ныклы тормышлы сәүдәгәрләр һәм эшмәкәрләрдән 30 яшьтән ким булмаган, «намуслы һәм тәртипле» кешеләр сайлап куела. Ратуша әгъзаларының вәкаләт срогы 3 ел була. Бер үк вакытта ратуша каршында ятимнәр һәм гапләшү мәхкәмәләре оештырылган. Ратушага беренче сайлаулар 1784 нең 10 декабрендә үткәрелә. Сайланалар: шәһәр башлыгы — Я.Солтангалиев, бургомистрлар — М.Хәлфин, М.Әсәнов, ратманнар — М.Килмәмәтов, И.Апанаев, А.Саинов, М.Рахманкулов. Ратуша утырышлары, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, һәр көнне 8 дән 14 сәгатькә кадәр була. Канцелярия эшләре рус телендә алып барыла. Ратушада тикшерелгән мәсьәләләр беркетмәләр рәвешендә теркәлә. Россия законнары буенча, татар ратушасының үз инициативасы б-н җинаять һәм гражданлык эшләрен тикшерү хокукы булмый. Шәхси кешеләрнең шикаятьләре һәм дәгъвалары, ш.у. җирле адм. учреждениеләре (губерна идарәсе, казна палатасы, гражданлык мәхкәмәсе палатасы һ.б.) боерыклары буенча эшләр карала. Ратуша сәүдәгәрләр һәм мещаннар катлауларына язуны формалаштыру, сәүдә итәргә бару өчен паспортлар бирү, бурычларны эзләп алу, банкротлык эшләре, салымнар җыю, варислар арасында милек бүлү, корабльләр төзү өчен агач әзерләүгә җибәрү, рекрутлар җыю б-н шөгыльләнә. 1788 дә Уфа Мөхәммәд дине кануннары Җыены оештырылгач, ратушага аңа әгъзалар сайлау йөкләнә. Ратуша аның карамагындагы гаиләләр акчасына тотыла. Дәүләт Советының 1854 ел 27 октябрь фәрманы нигезендә таратыла. Рекрутлар җыю сәбәпле, ратушага ул эш тәмамланганчы эшләргә рөхсәт ителә. Ратушаның соңгы утырышы 1855 нең 16 мартында була. Ратуша шәһәрнең татар җәмәгатьчелеген туплауда, татар сәүдәгәрләре һәм сәүдә капиталлары булдыруда мөһим роль уйный.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар-фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

*И.А.Гыйләҗев.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ ТЕГҮ́, КҮН ЭШКӘРТҮ́, КИЕ́З БАСУ́ ҺӨНӘРЧЕЛЕКЛӘРЕ́ БЕРЛЕГЕ́** (Казгоршвейкожвалпромсоюз), 1945 елда оештырыла, *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советы* карамагында була. Төп максаты — тегү, галантерея, күн аяк киеме, трикотаж, киез аяк киеме, мех әйберләр, уенчыклар җитештерү һ.б. пр-тиеләрне оештыру һәм җитештерү-хуҗалык эшчәнлеге б-н идарә итү. 14 артельне, 2 кибетне, тәэминат һәм сату конторасын берләштерә. Адм.-хуҗалык, производство, финанс-хисап, план-икътисад, сәүдә, әзерләүләр һәм тәэминатны оештыру, кадрлар, мәдәният-массалар б-н эшләү һ.б. бүлекләре була. 1951 нең 2 мартында бетерелә.

**«КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ УРТА́ МӘКТӘПЛӘРЕ́ УКУЧЫЛАРЫНЫ́Ң БЕРЛӘШКӘ́Н ТӨРКЕМЕ́»**, укучы яшьләрнең сәяси-иҗтимагый оешмасы (1904–07). Революцион хәрәкәтнең күтәрелеше чорында төзелә һәм шунда ук революцион оешмалар б-н бәйләнешкә керә. Аның түгәрәкләре сәнәгать, җир эшләре, реаль уч-щеләрдә, теш табибләре, фельдшерлар, татар укытучылар мәктәпләрендә, укытучылар ин-тында, гимназия, мәдрәсәләрдә һ.б. эшли. Әгъзалары: В.А.Тихомирнов, И.С. һәм М.С.Кадомцевлар, А.Я.Аросев, М.М.Вахитов, М.М.Золина-Вилонова, М.К.Бубнова һ.б. 1905 елның 15–16 гыйнварындагы сөйләшүләр нәтиҗәсендә төркем РСДРПның Казан ком-тының идея җитәкчелеген таный; яшьләр б-н даими бәйләнешләр урнаштыру өчен төркемдә ком-тның вәкиле эшли. Төркемнең эшчәнлеге самодержавиегә каршы, демократик характерда була. С.-Петербург, Варшава, Түбән Новгород, Саратов, Уфа һ.б. шәһәрләрнең мәктәп берләшмәләре б-н элемтәдә тора. «Искорки» һәм «Ученик» дигән кульъязма ж-ллар чыгара, гектографта хөкүмәткә каршы брошюралар һәм өндәмәләр бастыра. Өндәмәләрнең берсе шундый шигарь б-н тәмамлана: «Пролетариат белән берләшегез! Самодержавиенең тузган ныгытмаларын яуларга барыгыз!». 1907 елның 2 нче яртысында эшчәнлеге туктый.

*Р.Г.Әмирханов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ 1 нче КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, Ә.Б.Терегулов исемендә (Шамов хастаханәсе), күп профильле дәвалау-клиник учреждениесе. 1 нче гильдия сәүдәгәр Я.Ф.Шамов акчасына төзелә. 1908 елда Казан шәһәр думасы хастаханәнең 75 урынга исәпләнгән яңа бинасын төзү өчен Осокин урманында урын билгели. Модерн стилендә өч катлы Ш хәрефе сыман бина проектлана (арх. К.С.Олешкевич). Думага хастаханә проектын ун-т профессоры Н.А.Горлен тәкъдим итә. Я.Ф.Шамовның вафатыннан соң (1908) төзелешне аның хатыны А.Х.Шамова дәвам иттерә.

Хастаханә тантаналы төстә 1910 ның 25 апрелендә ачыла. Хирургия, дәвалау, гинекология, күз бүлекләре шунда ук эшли башлый, лаб-ясе, рентген кабинеты, даруханә, амбулатор кабул итү өчен кабинетлары була. Хастаханәдә 10 табиб; 7 фельдшер, шәфкать туташлары эшли. Хастаханә б-н аның мед. бүенча попечителе В.В.Владимиров җитәкчелек итә. Дәвалау өчен Казан һәм Казан өязе кешеләре кабул ителә, амбулатория хезмәте бушлай, хастаханәдә дәвалану түләүле була. 1918 дән ул Беренче шәһәр хастаханәсе дип йөртелә башлый. Гражданнар сугышы елларында бирелә тимгелле тифтан дәвалау госпитале җәелдерелә. Эшли башлавының беренче елларыннан ук хастаханәнең штатына галимнәр: проф. В.Л.Боголюбов, А.Н.Вишневский һ.б. кертелә. 1919 да аның җирлегендә Казан ун-ты мед. ф-тының дәвалау-госпиталь клиникасы (каф. мөдире — С.С.Зимницкий) оештырыла. 1919 да клиникага Ә.Б.Терегулов исеме бирелә. 1921 дән хастаханә Казан ун-ты мед. ф-тының клиник базасына әверелә. Бирелә М.Н.Чебоксаров, Н.К.Горяев, Ә.Б.Терегулов, Н.В.Соколов, А.И.Бренинг, К.А.Доягин, Р.Г.Вяселев һ.б. эшлиләр.

1950 елларда клиник хастаханә җирлегендә 1 нче дәвалау-профилактика берләшмәсе төзелә, аның стационары 250 урынга исәпләнә, хирургия, дәвалау, туберкулёзны дәвалау бүлекләре була.

1971 дә дәвалау бүлеге җирлегендә мед. ин-тының госпиталь хирургиясе каф. б-н берлектә консультацияләр өчен гастроэнтерология кабинеты (мөдире — И.Г.Салихов) ачыла, соңрак ул гастроэнтерология үзәгенә әверелә. Бирелә республикада беренче тапкыр фиброгастроскопия алымы (Т.Ф.Сафин, 1971) гамәлгә кертелә. 1987 дә поликлиника бүлеге 2 нче шәһәр поликлиникасы итеп үзгәртелә (баш табибе — Ф.Я.Халитов).

Хастаханәдә планлы һәм кичектергесез хирургия, гастроэнтерология, ревматология, токсикология (агулану очракларын ашыгыч дәвалау өчен), интенсив терапия һәм реанимация, физиотерапия бүлекләре була. Токсикология бүлеге базасында республика һәм шәһәр токсикология үзәкләре, ревматология бүлеге базасында — шәһәр ревматология үзәге эшли, аларның эшчәнлегендә традицион алымнар б-н бергә дәвалауның эфферент ысуллары — плазмофорез, гемодиализ, гемосорбция, ультрафиолет нурлар, канны магнит ярдәмендә эшкәртү һ.б. кулланыла. Ел саен бирелә 9 мең пациент дәвалана, 10 меңнән артык пациентка ашыгыч ярдәм күрсәтелә. Хастаханәдә 300 дән артык мед. хезмәткәре эшли.

2009 дан хастаханә капиталь ремонтта.

*Әд.:* Халитов Ф.Я. История городской клинической больницы № 1 // Актуальные вопросы внутренних болезней. К., 2000.

*И.Г.Салихов, Ф.Я.Халитов.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ 7 нче КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, күп профильле клиник дәвалау-диагноз кую дәүләт учреждениесе. Хастаханә «Оргсинтез» ҖБнең мед.-сан. часте буларак төзелә. 1964 елда поликлиника сафка кертелә, 1986 да хастаханә комплексы төзелеше төгәлләнә (беренче баш табибе — И.С.Абдуллин, 1991 — дән Г.М.Сафин, 2008 дән — М.Н.Садыйков). Хастаханә Казан мед. ун-тының һәм Казан мед. академиясенең клиник базасы булып тора; аның составында кабул итү, хирургия, кичектергесез хирургия, терапия, неврология, аллергология, анестезиология һәм реанимация, оториноларингология, эндокринология, диагностика һәм параклиника бүлекләре, неврологик авырулар өчен көндезге стационар эшли.

Диагностика бүлеге (1993 тә булдырыла) заманча җиһазландырылган; 1999 да РФА КГУ Физика-техника ин-ты тарафыннан эшләнгән магнит-резонанслы томограф файдалануга кертелә; гипербарик оксигенация бүлегендә барокамера урнаштырыла (1994). 1992 дә — үт чыгару системасы һәм ашказаны асты бизендә авыртулары булган хирургик авыруларга диагноз кую һәм дәвалау өчен аллергология үзәге булдырыла.

Хастаханә ел саен 27 меңнән артык авыруга хезмәт күрсәтә, поликлиникада шәһәрнең һәм республиканың 190 меңнән артык кешесе дәвалану уза. Хастаханәдә 1200 дән артык мед. хезмәткәре эшли.

*Г.М.Сафин.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ 12 нче КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, күп профильле клиник дәвалау-профилактика учреждениесе. 1936 елда төзелә. 1949 да — хирургия корпусы, 1973 тә терапия корпусы сафка кертелә. 1992 дән поликлиника эшләп килә. Әлеге клиник хастаханә Казан мед. ун-тының һәм Казан мед. академиясенең клиник базасы булып тора, алты махсус корпуста урнашкан, аның составына хастаханә, поликлиника, травмпункт, хатын-кызлар консультациясе, районара диагностика, биохимия, бактериология һәм патологик анатомия лаб-яләре, кан алу бүлеге керә. Хастаханәнең бүлекләре: интенсив дәвалау палатасы булган кардиология; эндоскопия, ультратавыш, тепловизион диагностика, криолазеротерапия, биохимия кабинетлары булган гастроэнтерология; торакаль хирургия, спонтан пневмоторакс һәм бронхология кабинетлары б-н пульмонология; кан юллары бозылган авырулар өчен неврология (интенсив дәвалау палаталары б-н); колак, борын, тамак авырулары өчен планлы һәм кичектергесез хирургия, аудиология кабинеты булган ике бүлек, Тернәкләндерү травматологиясе һәм ортопедия ин-ты б-н бергә эшләүче травмотология һәм ортопедия; функциональ диагностика кабинеты һәм махсус лаб-ясе булган профпатология. Бирелә ашказаны җәрәхәтенә, гениталийлар патологиясенә органнарны саклап калулы оригиналь операцияләр, үт юлларында таш булганда барлык төр операцияләр (ш.и. эндоскопик), ашказанындагы, эчәклектәге һ.б. шешләргә радикаль операцияләр, ш.у. сидек юлындагы ташларга, бөерләр, сидек юллары, бөер өсте бизе һ.б. эшчәнлеге бозылганда планлы һәм кичектергесез операцияләр үткәрелә.

Хастаханәдә ш.у. рентгенология, криолазеротерапия, физиотерапия, дәвалау физкультурасы, массаж, бальнеологик дәвалау бүлекләре; су астында дәвалау, психотерапия, энәләр б-н дәвалау кабинетлары бар. 250 дән артык мед. хезмәткәре исәпләнә. Ел саен 15 меңнән артык кеше дәвалану уза (планлы һәм кичектергесез), 300 меңнән артыгына

хастаханә белгечләре консультация үткәрә, 25 меңнән артык авыруның өйләренә барып хезмәт күрсәтелә. Баш табиб — Т.Ф.Сафин (1989 дан).

*Т.Ф.Сафин, Р.Г.Исхакова.*

**КАЗА́Н ШӘҺӘРЕ́ 18 нче КЛИ́НИК ХАСТАХАНӘСЕ́**, күп профильле клиник дәвалау-диагностика учреждениесе. Хастаханә комплексы «Радиоприбор» з-дының 1943 елда ачылган мед.-сан. часте җирлегендә төзелә. 1970 тә — поликлиника (Тукай урамындагы бинада), 1988 дә хастаханә комплексының яңа бинасы (Мәүлетов урамындагы амбулатория) сафка баса. 1990 да стационар эшли башлый (1994 тән баш табиб Р.С.Бакиров). Комплекс «Радиоприбор» ЖБ хисабыннан төзелә һәм җиһазландырыла. К.ш.к.х. Казан мед. ун-тының һәм Казан мед. академиясенең клиник базасы булып тора; бүлекләре: терапия б-н бергә кардиология, неврология, психоневрология, хирургия, оториноларингология, интенсив дәвалау палатасы булган анестезиология һәм реанимация, өч бүлектән торган балалар стационары (пульмонология, психоневрология, педиатрия). Поликлиника хезмәтенә нурлар ярдәмендә диагноз кую бүлекләре (ультратавыш, рентген б-н тикшерүләр, компьютерлы томография), функциональ диагноз кую, физиотерапия, дәвалау физкультурасы, массаж кабинетлары, клиник диагностика лаб-ясе керә.

1992 дә оториноларингология бүлеге нигезендә югары сулыш юлларын тернәкләндерү хирургиясе үзәге ачыла. Хирургия бүлеге җирлегендә 1993 тән эндохирургия үзәге эшли. 1996 дан район клиника-диагностика үзәге эшли башлый. Ел саен 9 меңнән артык авыруга стационар ярдәм күрсәтелә. Хастаханәдә 500 дән артык кеше эшли. Баш табиб — Р.С.Бакиров (1994 тән).

*Р.С.Бакиров.*

**«КАЗА́Н ШӘҺӘРЕНЕ́Ң КЫСКА́ЧА ТАРИХЫ́»**, К.Ф.*Фукс* әсәре. Казан тарихы буенча иң беренче хезмәтләрнең берсе. 100 дән артык чыганакка нигезләнеп (елъязмалар, татар тарихы әсәрләре, риваятьләр, нумизматик мәгълүмат) язылган.

Беренче кисәге 1811 елда «Казанские известия» г-тасында басыла (№ 67, 68, 80). Аерым китап булып 1822 дә Казан ун-ты басмаханәсендә нәшер ителә (титул битендә 1817 ел — цензура рөхсәте алынган ел күрсәтелгән). Китап сатуга чыгарылмый, автор аларны дуслары һәм танышларына тарата. 20 йөз башына аның проф. Н.П.Загоскинда, тарихчы, библиофил Н.П.Лихачёвта (2 данә), коллекционер Ф.Т.Васильевта (К.Ф.Фукс автографы б-н) булган барлыгы 4 нөсхәсе сакланып калган.

Бәян итү борынгы заманда бу төбәктә яшәгән кабиләләрне хикәяләүдән башлана. Автор Казанга нигез салынган вакытны — 14 йөз ахыры, дип билгеләп үтә, ханнарның исемнәрен санап күрсәтә (ш.и. гарәп транскрипциясендә дә) Казанны Явыз Иван гаскәре алуны сурәтли, өлкә б-н идарә итүне оештыру хакында, җирле халыкның баш күтәрүләре, Казан губернасы оешу турында яза. Соңыннан 1821 дә 1552 елда Казанны алганда һәлак булган рус сугышчылары истәлегенә һәйкәлгә нигез салыну турында әйтелә. Кушымтада К.Ф.Фуксның үзендә булган татар тарихи кулъязмаларыннан өземтәләр бирелә: *Гостиный двор* терр-ясеннән табылган кабер ташларындагы гарәп язулары, Мәскәүнең Архангел соборында һәм Симонов монастыренда җирләнгән Казан ханнары каберләре өстенә куелган ташлардагы язулар, синодиктан өземтә, Пётр I нең Казан сәүдәгәре И.Михляевка язган хаты күчерелеп бирелгән.

Китап зур кызыксыну уята, аны шәхси китапханәләр өчен дә күчереп алалар. Аның бер күчермәсен Г.З.Кунцевич Мәскәүнең Җәмәгать китапханәсеннән табып ала. 1899 елда Н.Ф.Катанов Петербург антиквары В.И.Клочковтан алынган кулъязма нөсхә буенча «Кыскача тарих»ны («Краткая история...») яңадан бастыра. Өченче басмасы 1905 елда Ф.Т.Васильевта сакланган нөсхәсе буенча Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте тарафыннан басыла. 1914 елда кабат басылган басмасы да бар.

К.Ф.Фуксның китабын М.С.*Рыбушкин* һәм Н.К.*Баженов* үз хезмәтләрен язганда кулланалар.

*Әд.:* Л и х а ч ё в Н. Краткая история города Казани, сочинённая профессором Фуксом. СПб., 1903.


**КАЗА́Н ЭЛЕ́КТР-ЭЛЕМТӘ́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1932 елның августында Казан элемтә техникумы буларак оештырыла, 1940 тан хәзерге исемдә. К.э.-э.т.: элемтә челтәре һәм коммутация системасы; күпканаллы телекоммуникация системалары; радиоэлемтә, радиотапшырулар һәм телевидение; радиоэлектрон техникага техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт; почта элемтәсе; икътисад һәм бухгалтерлык исәбе; элемтә чараларын эксплуатацияләү буенча белгечләр әзерләп чыгара. 2010 елда 1570 студент исәпләнә (көндезгедә — 1150, читтән торып уку бүлегендә — 420 укучы); укытучылар составы 86 кешедән тора, ш.и. 4 ТРның атказ. укытучысы. Техникум оешканнан бирле 26 меңнән артык белгеч әзерләнә.

**КАЗА́Н ЭЛЕКТРО́Н ХИСАПЛА́У МАШИНАЛАРЫ́ ЗАВОДЫ́**, к. *Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе.*

**КАЗА́Н ЭНЕРГЕ́ТИКА ИНСТИТУТЫ́**, к. *Казан энергетика университеты.*

**КАЗА́Н ЭНЕРГЕ́ТИКА ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Энергетика министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1956 елда оештырыла. К.э.т. оешканнан алып, икътисад ихтыяҗларына бәйле рәвештә, анда белгечлекләр еш алмашына. 1990 га кадәр укуны тәмамлаучыларның күп өлеше — машиналар төзелеше пр-тиеләренә, хәзерге вакытта, башлыча, электр энергетикасы системасына җибәрелә. Электр станцияләре, челтәрләре һәм системалары, җылылык электр станцияләре, релелы саклау һәм автоматика, энергетикада икътисад һәм бухгалтерлык исәбе буенча белгечләр әзерләп чыгара. 2010 елда көндезгедә — 800, читтән торып уку бүлегендә 100 студент укый. Укытучылар коллективы 81 кешедән тора, ш.и. 1 пед. фән. канд., ТРның атказ. укытучысы, ТРның атказ. энергетигы эшли. 11 меңнән артык белгеч әзерләнгән.

**КАЗА́Н ЭНЕРГЕ́ТИКА УНИВЕРСИТЕТЫ́**, Р Ф М ә г а р и ф һ ә м ф ә н м и н и с т р л ы г ы к а р а м а г ы н д а. 1968 елда Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лы буларак ачыла. 1999 дан Казан энергетика ин-ты, 2000 нән хәзерге исемендә. Беренче елларда инженер-энергетиклар гына әзерли, 1990 еллар уртасыннан укыту 10 белгечлек буенча алып барыла, 1996 дан икътисад һәм менеджмент буенча белгечләр әзерләү башлана, 2000 нең беренче яртысыннан — күппрофильле югары уку йорты. 2010 га ун-т составында — җылылык энергетикасы ин-ты;



Казан энергетика университеты.

электр энергетикасы, икътисад һәм социаль технологияләр (икътисадчылар, менеджерлар, социологлар, политологлар, архивистлар әзерли), ф-тлар: энергомашина төзелеше; кичке (җылылык энергетикасы, электр энергетикасы), читтән торып уку, укытучыларның квалификацияләрен күтәрү. 13 меңнән артык белгеч әзерләнгән.

2010 елга укыту 45 белгечлек буенча алып барыла, 6300 студент укый. Көндезге бүлектә — 3300, кичке бүлектә — 1260, читтән торып уку бүлегендә 3300; ш.и. түләүле формада 5346 студент. Укытучылар коллективында — 576 кеше, ш.и. 1 РФА мөхбир әгъзасы, 1 ТР ФА мөхбир әгъзасы, 73 фән. д-ры һәм 327 фән. канд-ты, 232 аспирант. Фәнни эш 37 кафедрада, Энергетика проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тында, 19 проблемалы лаб-ядә 9 төп юнәлеш буенча алып барыла. Җылылык-масса алмашы һәм җылылык энергетикасы буенча Ю.Г.Нәҗмиев җитәкчелегендәге, ш.у. электроника һәм электротехника өчен перспектив каты материаллар һәм приборлар буенча В.А.Голенищев-Кутузов җитәкчелегендәге тикшеренү эшләре халыкара танылу ала. Ун-тта профессорлар, техник фән. д-рлары, энергетиканың төрле юнәлешләре (ТР ФА мөхбир әгъзасы Г.Н.*Марченко*, В.Н.*Подымов*, А.И.*Гурьянов*, В.Г.*Олимпиев*, А.Б.*Шиһапов*, Р.Г.*Идиятуллин*, М.А.*Таймаров*, А.И.*Федотов*, К.Х.*Гыйльфанов*), И.М.*Вәлиев*, Ф.Г.*Халитов*, Ю.Г.*Володин*, Р.Г.*Миңнуллин*, Р.С.*Габрахманов*, Ю.И.*Солуянов*, В.А.*Уланов*, А.В.*Карпов*, А.А.*Наумов*, А.М.*Маклецов*, Т.Ш.*Ильясов*, И.Х.*Саитов*, С.А.*Лаптев*, И.А.*Копахина*, Е.К.*Вачагина*, И.К.*Фәйзуллина*, А.Я.*Мутрисков*, Н.Х.*Зиннәтуллин*, Ә.И.*Абдуллаҗа-*

*нов*), төрле техник фәннәр (В.Н.*Шәрифуллин*, О.С.*Сироткин*, А.Г.*Лаптев*, Ю.В.*Ваньков*, Ф.И.*Гарифҗанов*, Р.Ш. *Гыймадиев*, А.Я.*Чилап*), физика-матем. (С.А.*Григорян*, Б.П.*Смоляков*, И.М.*Сөләйманов*, В.А.*Белавин*, Н.И.*Москаленко*, А.Р.*Мөхетдинов*, Ф.М.*Гомәров*, Н.Д.*Якимов*, В.Л.*Матухин*, Ю.Г.*Кубарев*, Ю.Я.*Петрушенко*, В.К.*Козлов*, В.Ю.*Белашов*, А.В.*Голенищев-Кутузов*), химия (А.А.*Чичиров*, Н.Д.*Чичирова*), экология (Р.Х.*Тукшаитов*), гуманитар фәннәр (Э.Ә.*Тайсина*, Г.У.*Матушанский*, Н.М.*Мөхәррәмов*, М.А.*Нугаев*, Ю.Р.*Хәйруллина*) буенча белгечләр эшли.

1995 тән аспирантура һәм 2002 дән докторантура (230 аспирант), 3 диссертация яклау советы эшли. Университет китапханәсендә 300 меңнән артык саклау берәмлеге бар. Нәшрият эшли, «Известия вузов. Проблемы энергетики» дигән айлык журнал чыгарыла (1999 дан). Музей (2003 тән), Спорт комплексы, «Шеланга» спорт-сәламәтләндерү лагере бар. Директорлары һәм ректорлары: Ф.З.Тинчурин (1976–94), Ю.Г.Нәҗмиев (1994–2005), Ю.Я.Петрушенко (2005–2011), Э.Ю.Абдуллаҗанов (2011 дән).

*Әд.:* Казанский государственный энегетический университет. К 40-летию вуза. К., 2008. Т. 1–2.

**КАЗА́Н ЭПИДЕМИОЛО́ГИЯ ҺӘМ МИКРОБИОЛО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, Р Ф Сәламәтлек саклау министрлыгының фәнни-тикшеренү институты (КНИИЭМ), Россиядә беренчеләрдән булып йогышлы авыруларга каршы көрәш өчен махсуслаштырып төзелгән гамәли учреждение. 1900 елда Казан ун-тының мед. ф-ты каршында Бактериология ин-ты буларак, Парижда Л.Пастерның бөтен дөньяда мәгълүм ин-ты үрнәгендә оештырыла. 1925 тән Төбәк микробиол. ин-ты. Алга таба институтның исеме һәм ул буйсынган ведомстволар үзгәрә: 1935 тән Казан эпидемиология һәм микробиол. ин-ты, 1942 дән Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-ты, 1952 дән Казан вакцина һәм сыркындылар фәнни-тикшеренү ин-ты, 1956 дан Казан эпидемиология һәм гигиена фәнни-тикшеренү ин-ты, 1966 дан хәзерге исемдә. 1965 тән институтта хуҗалык исәбендәге берәмлек оештырыла — махсус иммуноглобулиннар, кан препаратлары, бактериаль аллергеннар һ.б. препаратлар җитештерүче Казан бактериаль препаратлар җитештерү пр-тиесе (директоры Р.Г.Мөхетдинова), 1996 дан мөстәкыйль пр-тие. 1975 тә КНИИЭМ каршында ТР һәм Идел буе халыклары өчен йогышлы аллергик авыруларга диагноз кую һәм дәвалау махсус поликлиникасы ачыла. Институт составындагы лаб-яләр: аллергеннар эшләү; микробиология, иммунология һәм биохимия; йогышлы авыруларның табигый чыганаклары; ш.у. консультатив диагноз кую поликлиникасы, фәнни китапханә бар.

19 йөз ахырында Россиядәге авыр эпидемиологик хәл йогышлы авырулар б-н көрәш өчен фәнни үзәкләр булдыру зарурлыгын тудыра. Ел саен Идел буе, Урал, Себер терр-ясендә үлем б-н тәмамланган 40 меңгә кадәр авыру теркәлә; чәчәк, дифтерия, ваба һ.б. эчәк инфекцияләре, паразит тифлар, бизгәк, полиомиелит тарала. 1896 елның маенда Казан ун-ты каршында Н.Ф.Высоцкий (ин-тның беренче директоры) җитәкчелегендәге махсус комиссия тәкъдиме б-н Идел-Кама төбәгенең 14 губернасы земство вәкилләре һәм табибләр администрациясе съездында институт төзү проекты раслана. 1898 дә өч катлы корпусы төзелә (арх. Л.К.Хрщонович); институт 1900 нең 10 февралендә ачыла, өч бүлектән тора: фәнни, пастерлау һәм сыркындылар; штатта 13 хезмәткәр була. Институт бактериологиянең гамәли микробиологиягә караган мәсьәләләрен хәл итә, дәвалау-профилактика препаратлары (бактериаль антитоксиннар, вакциналар, агуларга каршы сыркындылар) эшләп чыгара. 1905 елга институт фәнни-җитештерү юнәлеше ала. И.Г.*Савченко* җитәкчелегендә Россиядә беренче тапкыр бактериолог-иммунологларның фәнни юнәлештәге эше башлана. Казан галимнәре тарафыннан бактериологик тикшеренүләрнең иң яңа ысуллары үзләштерелә, кайбер тикшеренүләр Пастер ин-тында башкарыла (И.Г.Савченко, Ф.Я.Чистович, М.Я.Капустин, Н.М.Любимов, А.В.Вишневский), Пастерның оригиналь ысулы б-н антирабик вакцина әзерләнә. И.Г.Савченконың иммунология өлкәсендәге эш нәтиҗәләре һәм идеяләре (фагоцитозның ике фазалы булуын ачу һәм аның махсус антитәнчек-иммунизиннар тирәлегендә көчәюе), И.И.Мечников тарафыннан фагоцитар теорияне нигезләүдә (1902) файдаланыла. И.Г.Савченко скарлатинага каршы дәва сыркындысын — гемолитик стрептококкның махсус скарлатина агуын таба, аларны җитештерү ысулын һәм технологиясен эшли; Д.К.Заболотный б-н берлектә вабага каршы вакцина таба һәм аны үзләрендә сынап карый. 1904 тә Ф.Я.Чистович иммунологиядә, мәхкәмә медицинасында, биологиядә һ.б. файдаланыла торган күп кенә преципитацияләрнең (сыеклыктагы матдәнең төпкә утыруы) диагностик реакцияләре өчен фәнни нигез булган күренеш — чит аксымның төпкә утыруы феноменын (Чистович-Уленгут феноменын) ача.

Институтның беренче буын вәкилләрен бактериолог-иммунолог В.А.Барыкин, иммунолог П.Ф.Здродовский, офтальмолог В.В.Чирковский; 1922 елда бөер эшчәнлегенә тикшеренүләр үткәрү ысулын эшләгән С.С.*Зимницкий* (*Зимницкий пробасы*), фундаменталь тикшеренүләре тимгелле һәм кайтма тифлар, сифилис, туберкулёз, йогышлы аллергия мәсьәләләренә, бактериаль препаратларны камилләштерүгә багышланган В.М.*Аристовский* тәшкил итә.

Институт революциянең беренче елларында да, Гражданнар сугышы һәм сугыштан соңгы төзекләндерү чорында да Идел буенда көчле таралган йогышлы авыруларны бетерү өчен эшли. Дифтериягә һәм скарлатинага каршы сыркындылар, вабага һәм күсе тифына каршы антирабик (1917), скарлатиноз (Габричевский ысулы, 1922), стафилококк һәм стрептококк (1924) авыруларына каршы вакциналар эшләп чыгарыла һәм кулланышка тапшырыла. Казан галимнәренең тикшеренүләре гамәли эпидемиологик аспектта кулланыш таба: төбәктәге чәчәк эпидемиологиясе, дифтерия, скарлатина, бактериаль дизентерия, корсак тифы проблемалары хәл ителә. 1930 елларда Татарстанда чәчәк авыруы бетерелә.

Бөек Ватан сугышы елларында институт эшчәнлеге эпидемияләр булдырмауга юнәлдерелә. Фәнни эшләр сугыш чорының эпидемиологик торышын исәпкә алып үткәрелә һәм йогышлы авыруларны дәвалау зарурлыгына, аларны булдырмау чараларына бәйле була. Тимгелле тиф һәм дифтериягә каршы төбәктә эпидемиологик чаралар үткәрелә (А.Э.Озол). 1941 дән институтта Н.Ф.Гамалея исем. Үзәк эпидемиология һәм микробиология ин-ты белгечләре (Мәскәү, җитәкчесе В.Л.Троицкий) һәм Казанга эвакуацияләнгән Ленинград галимнәре эшли. Бердәм коллективта тимгелле тифка каршы вакцина (Т.М.Кокушкина, П.Н.Кашкин), гангренага каршы сыркынды эшләнелә (И.Е.Алатырцева) һәм аларны җитештерү үзләштерелә, дизентериягә каршы тире астына җибәрелә торган вакцина, дивакцина, пентавакцина эшләнелә (В.Л.Троицкий, А.М.Полтинникова, Г.Г.Әхмәдуллина, К.С.Зобина), чәчәктән детрит әзерләүнең интенсив ысулы гамәлгә кертелә (Л.А.Сергеева), грамицидин һәм мицетин җитештерү (П.Н.Кашкин) үзләштерелә. Дәвалау сыркындысының анафилактик үзенчәлекләрен өйрәнү алга таба иммунитет һәм аллергия механизмнарын өйрәнүгә, аллергик халәттә нерв системасының ролен ачыклауга (А.Д.Адо) китерә. 1943 тә йогышлы авыруларны кисәтү һәм дәвалау өчен 6,5 млн. кешелек дозада бактериаль препаратлар җитештерелә (17 исемдә); 1945 тә бу препаратларны җитештерү сугышка кадәрге күләмнән 20 тапкырга арта.

1950–80 дә көчле һәм озакка сузылган дизентерияне булдырмау һәм дәвалау өчен җирле штаммнарга яраклаштырылган дизентерия бактериофагын җитештерү үзләштерелә, югары сыйфатлы дифтерия анатоксины җитештерелә, дифтериягә, столбнякка, ютәлгә каршы иммунитет булдыру өчен даруларны борынга салу ысулы эшләнелә.

А.Д.Адо һәм И.Е.Алатырцева тарафыннан (1964) яңа фәнни юнәлеш — йогышлы аллергияне өйрәнү башлана. Илдә беренче булып, диагноз кую өчен бактериаль аллергеннар фәнни лаб-ясе ачыла, соңрак ул шартлы патоген микрофлорага нисбәтле сиземләүгә диагноз кую өчен аллерген препаратлар эшләү, аларның клиникасын өйрәнү һәм җитештерү буенча фәнни-җитештерү комплексы итеп үзгәртеп корыла, махсус поликлиника ачыла (1975). 1977 дә бактериаль аллергияне өйрәнү буенча иммунология һәм биохимия лаб-ясе төзелә (мөдире А.Н.Маянский). Тукландыру тирәлекләре бүлегендә нейссерияләрнең тәңгәллеген ачыклау өчен тирәлекләр эшләнелә. Дифтерия агуы һәм аның табигате (митотик агу) өйрәнелә, үз чиратында, бу дифтерия патогенезын аңлату мөмкинлеген тудыра, авыруны дәвалау өчен яңа

эзләнүләргә юл ача. 1950–70 тәге грипп пандемиясе чорында диагноз кую сыркындылары һәм грипп диагностикумнары чыгарыла. Талпан энцефалитының Идел буенда табигый чыганаклары ачыклана һәм өйрәнелә, Татарстан, Удмурт, Чуаш, Мари Респ-ларында, Ульянов һәм Пенза өлкәләрендә бөер синдромлы геморрагик бизгәкнең табигый чыганаклары булуы раслана, бу йогышлы авыруның һава-тузан б-н күчеп йөрүе исбатлана (Т.А.Башкирёв, В.А.Бойко). Бу хезмәтләр «Урта Идел буенда бөер синдромлы геморрагик бизгәк» («Геморрагическая лихорадка с почечным синдромом в Среднем Поволжье», 1989) исемле монографиядә тупланып бирелә. 1980–90 да әлеге авыруны булдырмау һәм дәвалау өчен иммуноглобулин (В.С.Потапов), гөмбә аллергеннары табу технологиясе эшләнә, күгәрек гөмбәләрдән беренче чират аллергеннар җитештерелә, 20 исемдәге аллергенга документ төзелә (җитәкчесе В.М.Лукашков); нейтрофилларда фибронектинга рецепторлар булуы ачыклана һәм аның нейтрофиль фагоцитоз реакцияләрендәге роле күрсәтелә; каннан дару препараты — фибронектин һәм аның нигезендә «Күз тамчылары-фибронектин» алына (җитәкчесе О.Д.Зинкевич); шартлы патоген микрофлора антигеннарына карата антитәнчекләрнең санын билгеләү өчен иммунофермент тест-система эшләнә, ул организмның реакциясен бәяләү һәм иммун статусының аерым күрсәткечләрен билгеләү өчен файдаланыла, бу исә авыруның ничек тәмамлануын фаразларга һәм оптималь дәва ысулларын сайлап алырга мөмкинлек бирә. Фагоцитоз реакцияләре өчен стандарт вакциналар, гамәли киң кулланыш тапкан НСТ-тестлар җитештерү җайга салына. Институтта традицион темалар буенча тикшеренүләр уздырыла: диагностика үткәрү һәм дәвалау препаратлары (бактерияләр һәм гөмбәләрдән аллергеннар, иммуноглобуллиннар), антигеннар һәм антитәнчекләр билгеләү өчен иммунофермент системалар эшләү, йогышлы авыруларга диагноз кую ысулларын камилләштерү, йогышлы эчәк авырулары һәм табигый чыганаклы йогышлы авыруларның эпидемиологиясен һәм микробиологиясен өйрәнү, бу авыруларны киметү чараларын эшләү; ТР һәм Идел буе төбәгендәге халыкка консультация-диагноз кую, дәвалау ярдәме күрсәтелә. 2010 да институт штатында 100 дән артык кеше исәпләнә, ш.и. 10 фән д-ры, 30 фән канд-ты. Институтта эшләгән танылган галимнәр арасында: Н.М.Любимов, М.Я.Капустин, Ф.Я.Чистович, Б.А.Барыкин, П.Ф.Здродовский, Н.П.Кашкин, А.Д.Адо һ.б. бар. Төрле еллардагы институт җитәкчеләре: Н.Ф.Высоцкий (1900–04), И.Г.Савченко (1904–18), В.М.Аристовский (1918–32), С.В.Немшилов (1932–37), П.А.Вершилова (1941–43), А.Р.Конова (1943–45), А.М.Борзунина (1945–54), Н.А.Немшилова (1954–61), И.Е.Алатырцева (1961–70), Т.А.Башкирёв (1970–83), В.И.Курочкин (1983–85), И.З.Мөхетдинов (1986–90), В.З.Камалов (1990–96), В.М.Лукашков (1996–2000); Р.С.Фәссахов (2002 дән).

*Әд.:* Казанский научно-исследовательский институт эпидемиологии и микробиологии (1900–1975). К., 1975; Казанский научно-исследовательский институт эпидемиологии и микробиологии: Юбилейная конф. КНИИЭМ (1900–2000). К., 2000.

*С.Х.Исхакова, Р.Г.Исхакова, Р.С.Фәссахов.*

**КАЗА́Н ЭШЧЕЛӘРЕНЕ́Ң ҮЗӘ́К КООПЕРАТИВЫ́**, 1918 елның 25 октябрендә Казанда сәнәгать һәм а.х. товарларын бүлеп бирүче оешма буларак оештырыла. 1920 нең сентябренә кадәр Профсоюзларның Казан үзәк эшчеләр кооперативы дип атала. 1919 ның декабреннән *Казан кулланучылар җәмгыяте* составында. Казан халкын азык-төлек һәм чимал развёрсткасы барышында, ш.у. сәнәгать пр-тиеләре һәм крәстиян хуҗалыклары арасында турыдан-туры продуктлар алмашу процессында алынган азык-төлек һәм иң кирәкле әйберләр б-н тәэмин итә (башлыча, карточка системасы буенча). 1923 нең 3 апрелендә бетерелә, мөлкәте һәм матди базасы Татарстан эшчеләр секциясенә бирелә. 1925 нең 2 апрелендә яңадан торгызыла. Максаты — азык-төлек һәм иң кирәкле әйберләр әзерләү һәм алар б-н Казан халкын тәэмин итү, җәмгыять тукланиуын оештыру, торак, дәвалау һәм клуб учреждениеләре төзү, мәдәни-агарту эшләре алып бару. 1932 нең гыйнварында — Казан шәһәр эшчеләр кооперативы, 1934 нең августында Казан шәһәр кулланучылар берлеге дип үзгәртелә (1936 ның 16 гыйнварында эшчәнлеге туктатыла).

**КАЗА́Н ЮГАРЫ́ АРТИЛЛЕ́РИЯ КОМАНДИРЛАРЫ́ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, М.Н.Чистяков исемендә, РФ Оборона министрлыгының югары уку йорты. 1941 елның 23 февралендә Авиамеханикларның Чиләбе хәрби авиация мәктәбе буларак ачыла, 1944 тән Кызыл Армия Хәрби Һава Көчләренең Чиләбе хәрби-авиация техник уч-щесе. 1947 дән Казанда (Ерак арага очучы авиациянең Хәрби авиация техник уч-щесе), 1959 дан Казан артиллерия техник уч-щесе, 1963 тән Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесе, 1980 нән артиллерия маршалы М.Н.Чистяков исем. Казан югары хәрби инженерлар уч-щесе, 1983 тән ракета гаскәрләренең Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесе, 1994 тән Югары артиллерия инженер-командирлар уч-щесе, 1998 дән Хәрби артиллерия ун-ты (филиал), 2002 дән Михайлов хәрби артиллерия ун-тының Казан ф-лы, 2004 тән Казан артиллерия уч-щесе (филиал). 2008 дән *Казан югары хәрби командирлар училищесе* бүлекчәсе, 2011 дә ябыла.

Эшләү елларында 26 меңнән артык белгеч әзерләнә. Тәмамлаучылар арасында — 24 генерал, 1 ике тапкыр Сов. Союзы Герое (генерал-майор А.К.Недбайло) һәм 4 Сов. Союзы Герое.

*Әд.:* Долгов Е.В. История и тенденции Казанского высшего артиллерийского командно-инженерного училища (1941–1996). К., 1996; 60 лет на службе Отечеству: История и тенденции Казанского филиала Высшего артиллерийского университета (1991–2001). К., 2001.

**КАЗА́Н ЮГАРЫ́ ПА́РТИЯ МӘКТӘБЕ́**, югары уку йорты. 1946 елда ВКП(б) ҮКның «Партия һәм совет җитәкче кадрларын әзерләү һәм өстәмә белем бирү турында»гы карары буенча ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты каршында Партия мәктәбе буларак ачыла, башта икееллык, 1953 тән өчьеллык тулы булмаган югары уку йорты. 1956 да югары уку йорты, КПСС ҮКның Казан дүртьеллык югары партия мәктәбе итеп үзгәртелә, Татарстан, Чуаш, Мари АССРлардан тыңлаучылар өчен билгеләнә. 1958 дән К.ю.п.м. программаларына фәлсәфә, икътисад, хокук, пед. фәннәре кертелә. Тыңлаучылар партия органнары тарафыннан, партия һәм совет органнары эшендә үзләрен уңай яктан күрсәткән КПСС әгъзаларыннан җыела (1956 дан тулы урта белем таләп ителә). Мәктәпнең эшләү елларында көндезге бүлектә 1400 дән артык кеше белем ала. Мәктәпне тәмамлаучылар эшкә район ком-тларына, район башкарма ком-тларына, зур предприятиеләргә партоешма секретарьлары итеп җибәреләләр. К.ю.п.м. каршында югары белемлеләр өчен читтән торып уку бүлеге һәм кыска сроклы квалификация күтәрү курслары булдырыла. КПСС ҮКның 1960 елның 10 май карары буенча партия һәм дәүләт аппаратын кыскарту кампаниясе һәм партия эшенә югары белемле кадрларны тарту күрсәтмәсе нигезендәге 1961 нең августында ябыла.

*Әд.:* Уланов В.И. Подготовка руководящих партийных и советских кадров в Татарской АССР за годы Советской власти // Сб. статей преподавателей и научных сотрудников (Института истории партии при Татар. обкоме КПСС). К., 1958.

**КАЗА́Н ЮГАРЫ́ СӘНГА́ТЬ-ТЕ́ХНИКА ОСТАХАНӘЛӘРЕ́**, к. *Казан сынлы сәнгать училищесе*.

**КАЗА́Н ЮГАРЫ́ ХАТЫ́Н-КЫЗЛА́Р КУ́РСЛАРЫ**, 1) урта белем бирү җирлегендәге 2 еллык иҗтимагый уку йорты (Петербург һәм Мәскәүдән соң өченче). 1876 елның 3 октябрендә Казан ун-ты каршындагы табигыятьчеләр җәмгыяте инициативасы б-н 1873 тән уздырылган лекцияләр нигезендә ачыла. Халык мәгарифе министры тарафыннан 1876 ның 8 маенда расланган Нигезләмә, һәм 1879 ның 12 июлендә кабул ителгән яңа Кагыйдәләр нигезендә эшли, оештыручысы — Казан ун-тының ботаника профессоры Н.В.Сорокин исемен йөртә. Укытучылары, нигездә, ун-т профессорлары, ш.и. В.А.*Богородицкий*, Н.Н.*Булич*, А.В.*Васильев*, Н.П.*Загоскин* була. Пед. һәм уку-укыту эшчәнлеге б-н пед. совет җитәкчелек итә, аның рәисләре: Н.А.Фирсов (1876–77), Н.А.Осокин (1877–80), С.М.Шпилевский (1880–83), Н.В.Сорокин (1883–87). Курсларга гимназия, епархия уч-щеләре, Затлы нәсел кыз балалар ин-тын тәмамлаучылар, башлыча, Казан уку-укыту округы губерналарынан килгән кыз балалар кабул ителә. Курсларның төп вазифасы кыз балалар гимназияләре өчен укытучылар әзерләү була (диплом бирмичә). Уку срогы 2 ел, программалар гомуми белем бирү өчен төзелә. Күптөрле фәннәр укытыла: Россия тарихы һәм гомуми тарих, немец, инглиз, латин телләре, рус, немец, француз әдәбияты, алгебра, геометрия, табигыять белеме, физика, химия; математика, физика, фәлсәфә буенча махсус курслар алып бары-

ла. Баштарак тыңлаучылар бергә укытыла, 1880/81 дән тарих-филология һәм физика-математика бүлекләренә аерылалар. Укыту процессының оештырылуы бик гади була: китапханә һәм лаб-яләр булмый, дәресләр көннең икенче яртысында ун-тның 2–3 аудиториясендә (алар түләүсез бирелгән) уздырыла. Уку түләүле була, курсларда тыңлаучыларның якынча өчтән бере ярлылык сәбәпле уку өчен түләүдән азат ителә. Беренче елларда ел саен 40–50 кеше кабул ителә, 1879 да бу сан кинәт кыскара, чөнки Кагыйдәләр буенча курсларга Казанда яшәүче гаиләләрдән яисә даими эше булган кыз балаларны гына



Казан югары хатын-кызлар курслары. 1913 елгы фоторәсем.

кабул итәргә рөхсәт бирелә. 1880 еллар уртасына тыңлаучыларның саны яңадан арта башлый. 1886 ның июнендә халык мәгарифе министры боерыгы б-н Россиянең барлык югары хатын-кызлар курсларына кабул итү тыела, һәм 1887 нең язында Казан курслары үзенең эшчәнлеген туктата. 11 ел эшләү дәверендә биредә 300 ләп хатын-кыз белем ала, аларның шактые кыз балалар гимназияләрендә, урта һәм башлангыч мәктәпләрдә укытучы булып эшли. 2) Иҗтимагый югары уку йорты, Казан ун-тының бер төркем профессорлары (К.А.Арнштейн, А.В.Васильев, Н.В.Сорокин, М.М.*Хвостов*, Г.Ф.Шершеневич) инициативасы б-н оештырыла, шәһәр думасы һәм губерна земство идарәсе химаясендә тора. Халык мәгарифе министрлыгының 1906 ел 26 июль карарына нигезләнеп, курслар шул ук елның 26 октябрендә ачыла. Казан уку-укыту округы попечителе тарафыннан расланган Нигезләмә буенча эшли. Урта белемле кыз балалар кабул ителә; укыту ун-тларның тарих-филология ф-тлары программалары нигезендә «тарих» һәм «рус теле» белгечлекләре буенча алып барыла. Курсларны тәмамлаучылар — кыз балалар, 1911 дән ир балаларда урта уку йортларында укыту хокукына ия булалар. Уку-укыту процессын оештыру б-н барлык укытучылар кергән совет җитәкчелек итә. Ул директорларны һ.б. вазифаи затларны сайлап куя, уку-укыту планнарын һәм программаларын раслый. Курсларның директорлары: Е.Ф.Будде (1906–11) һәм С.П.Шестаков (1911–19).

Бердәнбер финанслау чыганагы — уку өчен түләү. Укучылар санының күплеге аркасында, курсларның матди хәле яхшы була; тыңлаучыларның чиреге түләүдән азат ителә, күп өлеше шәһәр һәм земство идарәсе стипендиясенә укый. Аз күләмдәге иганә акчасы тыңлаучыларга матди ярдәм итүгә генә тотыла.

Укыту эшчәнлеге югары дәрәҗәдә алып барыла, укытучыларның күпчелеге — ун-т профессорлары, ш.и. А.И.*Александров*, А.Н.*Боголюбов*, В.А.Богородицкий, Н.А.*Васильев*, Д.И.*Нагуевский*, Н.М.*Петровский*, С.П.*Сингалевич*, А.В.*Смирнов*, М.М.Хвостов, башка укытучылар да тоташ диярлек гыйльми дәрәҗәгә ия була; кайбер фәннәрне Руханилар академиясе профессорлары (В.А.*Керенский*, Н.В.*Петров*) укыта. Фундаменталь китапханә эшли, 1917 елда анда якынча 14 мең том исәпләнә. Курслар баштан ук зур уку йорты булып санала, беренче елны 242 кеше кабул ителә, 1916 га 504 кә кадәр арта. 1910–19 елларда 3 меңнән артык кеше тәмамлый. 1911–17 дә курсларда 19 татар кызы укып чыга, ш.и. М.С.Гобәйдуллина, А.Ф.*Мөхетдинова*, З. һәм Р.Габитовалар, Г.*Әхмәровның* һәм А.М.*Казаковның* кызлары. Курс тәмамлаганнар урта уку йортларында эшли, ләкин аларның күп өлеше үз белгечлекләре буенча эш таба алмый, чөнки Казан уку-укыту округының кыз балалар уку йортларында тарих һәм рус теле укытучыларына якынча 300 урын гына бирелә. 1906 дан дәресләр — өченче кыз балалар гимназиясе бинасында, 1909 дан кич б-н Казан биржасы бинасында уздырыла. 1910–13 тә курсларның директор ярдәмчесе И.А.*Стратонов* җитәкчелегендә арх. В.А.*Трифонов* проекты буенча үз биналары төзелә (хәзер Казан (Идел буе) федераль ун-тының К.Маркс урамындагы уку бинасы). 1919 да курслар ябыла, тыңлаучылары Казан пед. ин-тының тарих-филол. ф-тына күчерелә, бинасы да аңа бирелә.

Чыг.: Отчёты о состоянии Казанских высших женских курсов за 1906–1916 гг. К., 1907–16.

*Әд.:* Исхакова Р.Р. Педагогическое образование в пореформенной России: Казанская губерния. К., 1999; Афонина Е.В. Казань — первый в провинции центр высшего женского образования // Казанский посад в прошлом и настоящем. К., 2002. *Е.В.Афонина.*

**КАЗА́Н ЮГАРЫ́ ХӘРБИ́ КОМАНДИРЛА́Р УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, РФ Оборона министрлыгының югары уку йорты. Беренче мөселман пехота командирлар курсларыннан башлангыч ала, 1919 елның февралендә *Казан хәрби училищесе* җирлегендә булдырыла. 1919 ның июнь аеннан — Икенче мөселман командирлар курслары. 1920 нең июнь аенда Петроградка күчерелә, Бишенче Петроград пехота курслары составында. 1920 нең октябреннән Уналтынчы мөселман пехота командирлары курслары, 1923 нең гыйнварыннан (9 нчы кавалерия курслары б-н берләштерелгәннән соң) Берләштерелгән Казан мөселман командирлар курслары, 1924 тән Алтынчы берләштерелгән татар-башкорт хәрби командирлар мәктәбе, 1935 нең декабреннән ТАССР ҮБК исем. Татар-башкорт хәрби пехота мәктәбе, 1937 дән ТАССР ҮБК исем. Казан пехота уч-щесе, 1941 нең мартыннан ТАССР ЮС Президиумы исем. Казан танк уч-щесе. 1947 дә, хәрби көчләр кыскартылу сәбәпле, уч-ще таратыла. 1963 тә Казан танк уч-щесе буларак яңадан торгызыла, 1966 дан ТАССР ЮС Президиумы исем. Казан Кызыл байраклы югары танк командирлары уч-щесе, 1998 дән Чиләбе танк ин-тының Казан ф-лы, 2005 тән К.ю.х.к.у. 2010 нан Коры җир гаскәрләренең «РФ Кораллы көчләренең гомумгаскәри академиясе» хәрби укыту-фәнни үзәге (Казан ф-лы). Командирлар һәм инженерлар составы өчен белгечләр әзерли.

Тәмамлаучылар арасында — 50 дән артык генерал, 39 Сов. Союзы Герое, 8 РФ Герое. Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә (1944).

**КАЗА́Н Ю́НКЕРЛАР УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, к. *Казан хәрби училищесе*.

**КАЗА́Н ЮРИ́ДИК ИНСТИТУТЫ́**, РСФСР Юстиция министрлыгы карамагындагы югары уку йорты. 1931 елның 6 маенда Казан ун-тының совет төзелеше һәм хокукы ф-ты җирлегендә Казан совет хокукы ин-ты буларак ачыла. 1935 тән Казан хокук ин-ты, 1936 дан, Казан совет төзелеше ин-ты б-н кушылганнан соң, К.ю.и. 1952 дә Казан ун-тының юридик ф-ты дип үзгәртелә. Институтта 10 каф., аспирантура, 2 белгечлек (студентларны юстиция, прокуратура, адвокатура органнарында эшләү, ш.у. барлык Идел буе республикалары һәм өлкәләрендәге совет учреждениеләрендә эшләү өчен әзерләү) була. Институтны ел саен 300–350 кеше тәмамлый. Шәкертләре арасында Р.С.Әҗимов, Б.С.Волков, Н.С.Захаров, Ф.Н.Фәткуллин һ.б. кебек хокук белгечләре бар.

**КАЗА́Н ЯГЫ́**, элекке *Казан ханлыгы* биләмәләренең бер өлеше — 1550–60 елларда Иделнең сулъяк яры буенда урнашкан җирләр. Элек Казан ханлыгы биләмәләрен Идел агымы буйлап 2 якка (Казан һәм Зөя) рәсми рәвештә бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килә. К.я. атамасы элекке «Арча ягы», «Болын ягы», «Яр буе ягы» атамаларын алыштыра. *Казан өязе* биләмәсенә керә.

*Әд.:* Ермолаев И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. (Управление Казанским краем). К., 1982.

*Д.Г.Мостафина.*

**КАЗА́Н ЯЗУ́ МАШИНАЛАРЫ́ ЗАВОДЫ́**, к. «*Терминал*».

**КАЗА́Н ЯҢЫ́ КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), бронза дәверендә (якынча б.э.к. 16–9 йөзләр) Идел-Чулман буйларында яшәүчеләргә нисбәтле археол. культура. К.я.к. ядкәрләре 19 йөзнең 2 нче яртысыннан өйрәнелә (А.А.Штукенберг, Н.Ф.Высоцкий, Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков һ.б.). 1950 елларда мөстәкыйль археол. культура сыйфатында А.Х.Халиков тарафыннан нигезләнә. 1960 елларда ул К.я.к. үсешен хронологик этапларга бүлә — Займище (б.э.к. 16–15 йөзләр), Балым-Карташиха (б.э.к. 14–13 йөзләр), Атабай (б.э.к. 12–11 йөзләр), Маклашеевка (б.э.к. 10–9 йөзләр) чорларын аерып күрсәтә. Кайбер галимнәр Балым-Карташиха этабының күп кенә ядкәрләре *Чиркәскүл культурасы* б-н бәйле, соңгы этап ядкәрләре К.я.к.ның Атабай этабы этник төркемнәреннән үзгә, читтән килгән халык тарафыннан калдырылган мөстәкыйль *Маклашеевка культрасына* карый дип исәплиләр. Атамасы бу культураның яхшырак өйрәнелгән ядкәрләре тупланган урыннан Идел буенең Казан төбәге исеменнән алынган. К.я.к. составына А.Х.Халиков 500 ләп археол. ядкәрне кертә. Тук-

таулыклар, шәһәрлекләр калдыклары, чокырлы һәм курганлы каберлекләр табылган. Иделнең Чулман буе төбәгендәге ядкәрләр — элеккеге Займище авылы (*Займище комплексы*), Олы Утар авылы (*Балым комплексы*), Атабай авылы (*Атабай торулыгы*) янындагы туктаулыклар, Олы Утар авылы, элеккеге Яңа Мордово авылы, Луговой посёлогы янындагы каберлекләр яхшырак тикшерелгән. К.я.к. кабиләләре терлекчелек, сунарчылык, балыкчылык, игенчелек б-н көн күргәннәр, бронзадан әйберләр ясый белгәннәр (бронзадан эшләнгән хезмәт, сугыш кораллары һ.б. табылган). А.Х.Халиков фикеренчә, терлекчелек хуҗалыкта асрау-көтүчелек рәвешендә булган, кышкы чорда терлекләр аранда тотылгын. Күбесенчә мөгезле эре терлек һәм атлар, ш.у. мөгезле вак терлек һәм дуңгызлар үрчеткәннәр. Урман зонасындагы туктаулыкларның культура катламнарында табылгын сөякләрнең 30–70% — кыргый хайваннарныкы. Торак йортлар яртылаш җиргә казылып салынган, алар бер-берсенә канаулар б-н тоташтырылган. К.я.к.на балчыктан ясалган яссы яки йомры төпле, калын кырлы чүлмәксыман савытлар хас. Мәетләр буйга сузылган яки бөгәрләнгән хәлдә җирләнгән, кайбер очракларда каберләр өстенә кечерәк курганнар өелгән. Каберләрдә үзенчәлекле җирләү әйберләре (балчык савыт-саба, таштан һәм сөяктән эшләнгән хезмәт кораллары, бронза бизәмәләр, кием предметлары һәм йорт кирәк-яраклары, пычак-хәнҗәрләр һ.б.) очрый. Кайбер торулыкларда (Займище III, Балым торулыкларында һ.б.да) учак эзләре һәм корбан бирү әйберләре сакланган йола урыннары өйрәнелгән.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Приказанская культура и её роль в формировании ананьинской культуры // Уч.зап. Перм. гос. ун-та. 1967. № 148; ш у л  у к. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; ш у л  у к. Приказанская культура // Археология СССР: Эпоха бронзы лесной полосы СССР. М., 1987. *Е.П.Казаков.*

**«КАЗА́Н ЯРМИНКӘСЕ́»**, күргәзмә-мәгълүмат сәүдә-коммерция пр-тиесе. 1991 елда ТАССР ВДНХсы җирлегендә күргәзмә-мәгълүмат коммерция берләшмәсе (ВИКО) буларак оештырыла. 1997 дән хәзерге исемдә. 1998 дән АҖ. 1993 тән Россия күргәзмәләре һәм ярминкәләре берлеге әгъзасы, РФнең әйдәүче күргәзмә операторлары бишлегенә керә. 1997 дән Бөтендөнья күргәзмәләр индустриясе ассоциациясе (UFI) әгъзасы, 2 күргәзмәсе аның билгесенә лаек була. Төп бурычлары: халыкара һәм региональ күргәзмәләр һәм ярминкәләр, презентацияләр, семинарлар, симпозиумнар, конференцияләр оештыру һәм уздыру; Россиядә һәм чит илләрдә милли экспозицияләр оештыру; реклама-нәшрият һәм коммерция-арадашчылык эшчәнлеге; ТРның социаль-икътисади инфраструктурасын үстерүдә катнашу. Төрле тематикалы һәм юнәлешле күргәзмәләр эшендә Германия, Греция, Испания, Франция, Төркия, Украина, Казакъстан, Белоруссия һ.б. ның компанияләре, фирмалары һәм пр-тиеләре катнаша. 2007 дә Халыкара сыйфат стандартларына яраклылык билгесе (ISO 9001:2008) бирелә. Даими эшләүче күргәзмә үзәге (КҮ) буларак, «К.я.» ТР товар җитештерүчеләре продукциясен Лейпциг, Салоники, Измир, Будапешт шәһәрләрендә узучы халыкара күргәзмә-ярминкәләрдә тәкъдим итә. Уздырылучы күргәзмәләрнең тематикасы ТРда бара торган икътисади үзгәртеп корулар б-н тыгыз бәйләнгән. «К.я.»ндә ТР пр-тиеләре катнашында Казанның коммуналь хезмәтләре кулланучыларының, Татарстан товар җитештерүчеләренең даими күргәзмәләре һәм «Шәһәр заказы» күргәзмәсе эшли. Күргәзмәләр Татарстанның министрлыклары һәм ведомстволары, әйдәп баручы пр-тиеләре һәм фирмалары тарафыннан оештырыла. КҮ гомуми мәйданы 6,5 мең $м^2$ булган 3 павильонны һәм 5 мең $м^2$ лык ачык экспозиция мәйданын, конференц-залы һәм офислары булган бизнес-үзәкне, 20 мең $м^2$лык мәйданлы ял паркын били. «К.я.»нең күргәзмәләр (күргәзмәләр һәм ярминкәләр оештыру), тышкы икътисади элемтәләр (эшлекле бәйләнешләр һәм багланышлар, чит ил фирмаларын һәм җирле товар җитештерүчеләрне җәлеп итү), коммерция бүлекләре, ш.у. хезмәт күрсәтү төркеме, маркетинг һәм реклама хезмәте (семинарлар, презентацияләр, пресс-конференцияләр оештыру, мәгълүмат һәм реклама әзерләү) бар. К.Ү. ел саен 70 тән артык төрле күргәзмә-конгресс чаралары уздыра, 40 ка якын проектны гамәлгә кертә. Күргәзмәләргә йөрүчеләр саны 200 мең кешедән арта.

*В.А.Наумов.*

«Казан ярминкәсе». 1. Үзәк капка; 2. Төп павильон.



1


2

**КАЗА́Н Я́РУСЫ**, р у с  ц е х ш т е й н ы, *Пермь системасы (чоры)* бүлегенең аскы өлешендәге тау токымнары катламнары. 1915 елда А.В.Нечаев тарафыннан билгеләнә, исеме Казан губернасы атамасыннан алына. Көнчыгыш һәм Төньяк-Көнчыгыш Европа платформасында киң таралган. К.я. аналоглары Тунгус свитасы (Көнчыгыш Себер) күмерле ятмалары составына керә, ш.у. Көнбатыш Европаның (цехштейн) Пермь ятмалары арасында бар.

ТРда, К.я. көньяк һәм үзәк өлештән тыш, барлык терр-яне алып тора, Уфа (Көнбатышта) һәм Сакмар ярусында, татар катламы б-н, ә ерак Көньяк-Көнбатышта юра утыртмалары б-н ябылган. 2 асъяруска бүленә. Түбәнгесе соры известьташтан тора һәм анда мергель, балчык һәм комлык катламнары була.



Югары Казан асъярусы комлыклары.
Алабуга районы Покровский авылы янында.

Көнбатышта аны доломитлар алыштыра, Көнчыгышта кызыл төстәге (кайбер җирдә битумлы) токымнар күбрәк. Калынлыгы 85 *м* га җитә. Югары асъярус — доломитлы (кайчак битумлы) катлау известьташ, балчык, комлы катламнардан, гипс яки ангидрит линзаларыннан; Көнчыгышта күбрәк кызыл төстәге комлы-балчыклы ятмалардан тора (к. *Бәләбәй свитасы*). Калынлыгы урыны б-н 100 *м* га җитә, К.я.ның гомуми тирәнлеге 200 *м* га җитә. Килеп чыгышы б-н К.я. токымнары яр буе — континенталь һәм сай диңгез утырымнары. К.я. эре елгалардан Идел, Кама, Нократ һәм аларның кушылдыклары Чишмә, Зәй, Минзәлә, Казансу һ.б. ярлары буенда өскә чыга. Иделнең уң ярында Югары Ослан р-ны Печище авылы янында югары Казан асъярусы стратотибы күренә (к. *Печище геологик киселеше*). К.я. ятмаларына ташлы төзү материаллары, гипс, битум, мәрмәрле оникс һ.б. керә, 19 йөз уртасына кадәр алардан бакыр алына. ТРның кайбер районнарында карст чоңгыллары К.я. б-н бәйле (к. *Карст*).

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Ю.В.Сементовский.*


**КАЗА́Н ЯСАЛМА́ КАУЧУ́К ЗАВОДЫ́**, химия сәнәгате пр-тиесе. Дөньяда беренчеләрдән булып 1928 елда акад. С.В.Лебедев тарафыннан эшләнгән ысул буенча ясалма каучук җитештерә башлаган заводларның берсе. 1700 дән артык кеше эшли (2009). Завод 1931 нең ноябрендә төзелә башлый. 1936 ның октябрендә беренче каучук алына. Завод 1936 дан — С.М.Киров исем. 741 нче з-д, 1952 дән — п/я 974 оешмасы; 1966 дан — С.М.Киров исем. К.я.к.з.; 1988 дән — ФҖБ

(з-дны һәм С.В.Лебедев исем. Бөтенсоюз ясалма каучук фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лын берләштерү юлы б-н төзелә), 2000 елдан АҖ. Завод махсус максатларга билгеләнгән каучуклар һәм алар нигезендә натрий-бутадиен каучугы, полисульфид олигомерлар һәм герметика, силикон каучуклар һәм алар нигезендә төрле резина катнашмалары, герметиклар һәм силикон компаундлар, полиэфирлар, полиуретан каучуклар, үзлегеннән ябышучан силикон материаллар, автогерметика, төзелеш максатларындагы продукция чыгара. Бөек Ватан сугышы елларында Казанда Воронеж һәм Ефремов ясалма каучук з-длары, Ленинградтан Бөтенсоюз ясалма каучук фәнни-тикшеренү ин-ты эвакуацияләнгәннән соң, Казан з-ды илдә ясалма каучук җитештерүче бердәнбер пр-тиегә әверелә. Фригит (1941), мипорсепараторлар, «Эджрайт» антиоксиданты, винилиденхлорид латексы (1942), ДА тиоколы (1946) җитештерү үзләштерелә. 1950 еллар ахырыннан завод интенсив үсештә. Яңа полимер материаллар: полисульфид каучуклар (1959), кызуга чыдам силикон каучуклар (1962), полиэфирлар (1964), уретан каучуклар (1966), кызуга чыдам резина катнашмалары (1967), радиацион вулканизация ысулы б-н җитештерелүче үзлегеннән ябышучан электр изоляцияләү материаллары (1970), силикон герметиклар һәм компаундлар (1972), өзлексез технологияләр нигезендә уретан каучуклар (1982), ике яклы резина катнашмалары (1986), төзелеш мастикалары һәм ябу материаллары (1994), азотлы ашламалар һәм викель резина катнашмалары (1995), олифа



Казан ясалма каучук заводы.
Резина катнашмалар цехы.

һәм алкидлы лак (1996), торак түбәләрен ябу материалларының яңа төре — «Тэлкров» һәм сополимер күкерт (2000), катлаулы ТЭФД полиэфиры, ДВХБ-Ш шин латексы, ачыкландырылган төстәге тиокол (2004), тиокол нигезендә төзелеш мастикалары (2005), Р-5 резина катнашмалары, Maxsil герметиклары (2006), уретан мастика һәм пластификатор (2008), тиокол нигезендә төзелеш герметигы (2009), санитар герметик (2010) производстволары булдырыла, силикон, ышкылу һәм май-бензин тәэсиренә чыдам резина катнашмаларының ассортименты киңәйтелә. К.я.к.з. — Россиядә СКБ маркалы бутадиен каучук, үзлегеннән ябышучан, кызуга чыдам «ЛЭТСАР» эл. изоляцияләү тукымасы җитештерүче бердәнбер пр-тие. Полисульфид каучуклар (алар дөньяда 3 илдә, ш.и. АКШта, Япониядә җитештерелә) эшләп чыгару буенча Россиядә һәм БДБ илләрендә заводка тиңнәр юк. Җитештерелүче продукция (150 исемнән артык күләмдә) сәнәгатьнең төрте тармакларында файдаланыла, РФндәге 5 меңнән артык кулланучыга һәм дөньядагы 20 ләп илгә, ш.и. Германиягә, Италиягә, Польшага, Бөекбританиягә, Кытайга, Латвиягә, Төркиягә, Һиндстанга, Украинага, Молдавиягә, Белорусиягә, Казакъстанга, Үзбәкстанга, Кыргызстанга җибәрелә. К.я.к.з.-ның читкә чыгарылучы төп продукциясе — полисульфид олигомерлар (барлык экспортның 90% тан артык өлеше).



Казан ясалма каучук заводы. Төргәкләү цехы.

2001 дә Франкфурт-Майн шәһәрендә (Германия) узган 29 нчы халыкара конкурста пр-тие продукциясе сыйфат призына лаек була. 2002 дә «Шиннар, резина-техник эшләнмәләр, каучуклар» конкурсында (Мәскәү) «Иң яхшы каучуклар, резина-техник материаллар һәм алардан җитештерелгән эшләнмәләр» номинациясендә силикон каучуклар, резина катнашмалары һәм шулар нигезендә эшләнгән герметиклар өчен завод алтын медаль б-н бүләкләнә, шул ук конкурста 2003 тә аңа НВБ-2 тиоколы өчен — алтын медаль, автогерметик прокладка өчен бронза медаль, 2005 тә электротехника сәнәгатендә кулланылучы «Силикон» резина катнашмалары өчен — алтын медаль, 32 маркалы сыек полисульфид полимерлары өчен көмеш медаль, 2006 да КФ-05 маркалы «ЛЭТСАР» тасмасы өчен — алтын медаль, РССО-6П резина катнашмасы өчен көмеш медаль бирелә.

К.я.к.з. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1985). Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеме — 1 кешегә, Ленин ордены — 10, Октябрь Революциясе ордены — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 170, Халыклар дуслыгы ордены — 5, «Почёт билгесе» ордены — 43, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены 24 кешегә бирелә; медальләр б-н 3143 кеше бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: Ф.В.Егоров (1931–37), П.С.Назаров (1937–40), И.П.Карташов (1940–44), М.М.Бондаренко (1944–46), М.С.Поздняков (1946–65), З.З.*Сафин* (1965–94), М.М.Хаснуллин (1994–2000), Р.Т.Бикмуллин (2000–02), Ф.М.Палютин (2002–07), А.В.Контуров (2007 дән).

*Әд.:* Зрелость: страницы истории Казанского завода синтетического каучука им. С.М.Кирова. К., 1986; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001; На стыке тысячелетий: Энцикл. социально-деловой элиты. Наб. Челны, 2001. Т. 1.

*И.Н.Афанасьев.*

**КАЗА́Н ЯСАЛМА́ КҮН ЗАВОДЫ́**, («Искож»)җиңел сәнәгать пр-тиесе. Аяк киемнәре тегүдә кулланыла торган һәм техник картоннар, синтетик плёнка материаллары, аяк киемнәре пластикатлары чыгара. Эшләүчеләр саны — 500 ләп кеше (2010). 1933 елда «Кожсуррогат» ф-касы буларак нигезләнә. Дөньяда әлеге профильдәге дүртенче пр-тие була. 1938 нең маенда «Искож» з-ды итеп үзгәртелеп файдалануга тапшырыла һәм СССРда беренче булып күпләп натураль күн алмаштыргыч — С-1 картон олтырагы җитештерә башлый. Алдагы елларда илдә аяк киемнәренең 50% тан артыгы завод продукциясен файдаланып чыгарыла. 1938–69 да завод 1 млрд. 638 млн. пар аяк киеме тегүгә тотылган 131 мең *т* төрле күн алмаштыргыч эшләп чыгара. 1965–70 елларда пр-тие техник картон һәм аннан автотрактор прокладкалары эшләүче Италия җиһазларын кулланышка кертү юлы б-н үзгәртеп корыла һәм киңәйтелә. 1972 дә Япония технологик линияләрен урнаштыру нәтиҗәсендә синтетик плёнка материалларын җитештерү җайга салына, киләчәктә ул зур үсеш кичерә. 1991 дә завод җирлегендә — Казан «Искож» коллектив аренда пр-тиесе, 1995 тә «Казан ясалма күн заводы» АҖ оештырыла. Аның составында аяк киемнәре тегү өчен кулланыла торган һәм техник күн картоннары (продукциянең гомуми күләменең 55%ы), кайнар ысул б-н поливинилхлоридпластикаттан эшләнмәләр (45%) җитештерү производстволары, 7 ярдәмче цех эшли. Заводның төп продукциясе: картоннар, аяк киемнәре җитештерү өчен коелган пластикат, төрле плёнкалар, тарттырма түшәмнәр, линолеум, электрдан изоляцияләү әйберләре, каплар һ.б. Гомумроссия күләмендә күн алмаштыргычлар җитештерүнең 80%ы АҖ өлешенә туры килә, эшләнмәләр РФ һәм БДБ илләренең төрле профильдәге 150 дән артык пр-тиесенә җибәрелә. ТРда продукцияне төп кулланучылар (барлык эшләнмәләрнең 55%ы): «Спартак», «Сафьян», «Кварт», «Тылсым» АҖләре, ТРның «Полиграфия-нәшрият комбинаты» дәүләт унитар предприятиесе һ.б., «КАМАЗ», «Казан вертолёт заводы», «Казан моторлар төзү ҖБ» АҖләре б-н хезмәттәшлек җәелдерелә. К.я.к.з. — югары технологияле пр-тие, үзе эшләнмәләрне проектлый, прогрессив чит ил җиһазларын гамәлгә кертә. Аның күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 24 кешегә — РФнең, ТРның атказ. текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре, 3 кешегә — ТРның атказ. икътисадчысы, 1 кешегә ТРның атказ. энергетигы дигән мактаулы исемнәр бирелә; 1 кеше — Ленин ордены, 8 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 13 кеше — «Почёт билгесе», 12 кеше 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре: Л.З.Каган (1934–38), М.А.Миронышев

(1938–39), А.А.Медведев (1939–43), И.А.Врублевский (1943–51), Я.А.Матанцев (1951–54), А.Е.Хохлов (1954–56), Л.Л.*Ластин* (1956–85), В.П.*Дмитриев* (1985–2006), Ф.Г.Нигъмәтуллин (2006–08), Г.В.Схиртладзе (2009 дан).

**КАЗА́Н ЯШЬ ТАМАШАЧЫЛА́Р ТЕА́ТРЫ** (ТЮЗ), проф. театр, рус дәүләт драма театры. ТАССР Мәгариф халык комис-ты, ВКП(б)ның Казан шәһәр һәм ВЛКСМның өлкә ком-тларының уртак карары нигезендә 1932 елда Үзәк пионерлар клубы каршында оеша. «Яшьтәшләр» («Ровесники») дип аталган беренче спектакль 1932 нең 30 ноябрендә куела. 1935 тән РСФСР ХКС карары нигезендә дәүләт театры; 1955–91 елларда Ленин комсомолы исемендә, 1991–2000 елларда афишаларда «Казан яшьләр театры» дип күрсәтелә. 1932–34 тә Профсоюз урамындагы 15 нче йортны били; 1935 тән — Островский урамындагы 10 нчы йортта, элекке Сәүдәгәрләр җыены бинасында урнаша.

Балалар өчен спектакльләр («утренниклар») 19 йөз уртасыннан Казан шәһәр театрында куела башлый. Рус классик әдәбиятының танылган әсәрләреннән («Акыллылык бәласе» — «Горе от ума», А.С.Грибоедов; «Ревизор», Н.В.Гоголь) тыш, яшь тамашачыга этнографик характердагы спектакльләр («XVI йөз ахырындагы рус туе» — «Русская свадьба на исходе XVI столетия», П.П.Сухонин), чит ил язучыларының балалар өчен язылган, сәхнәләштерелгән әсәрләре («Робинзон Крузо», Д.Дефо; «Капитан Грант балалары» — «Дети капитана Гранта», Ж.Верн һ.б.), әкиятләр тәкъдим ителә. Спектакльләрне сәхнәгә куючы танылган режиссёрлар: П.М.Медведев, Н.И.Собольщиков-Самарин, В.В.Образцов, А.И.Канин. Казан Зур драма театры каршында оешкан студиянең җитәкчесе З.М.Славянова 1919 да анда укучы яшьләр тарафыннан балалар өчен спектакльләр әзерләүне уку-укыту планына кертә, үзе дә пьесалар яза («Явыз король» — «Злой король», 1922 һ.б.), студиядә укучы яшьләрне дә пьесалар һәм сценарийлар язу эшенә җәлеп итә («Итекле мәче» — «Кот в сапогах», Н.М.Север, 1923 һ.б.). Спектакльләрнең зур уңыш б-н баруы балалар өчен махсус театр булдыру идеясе туугa этәргеч була. 1932 дә, Бөтенсоюз пионер оешмасының 10 еллыгын билгеләп үтү уңаеннан, ТАССР Мәгариф халык комис-ты коллегиясе татар һәм рус төркемнәре булган ТЮЗ оештыру турында карар кабул итә. Рус төркеме Казан Зур драма театры студиясен тәмамлаучылардан һәм һәвәскәрләрдән туплана. Режиссёрлары — Е.Иванов, Н.Кроль. Театр шәһәр пр-тиеләре акчасына эшли. 1934 тә акча б-н тәэмин итү туктатыла, театр таркала, әмма 1935 тә РСФСР ХКС карары нигезендә кабат дәүләт театры буларак оеша. Режиссёрлары — А.Ю.Вилинский-Боголюбов, Н.А.Гаголкин, Б.Ф.Логинов, директор — Ф.Н.Зәйни. 1941/42 еллар сезонында театр эшләми: Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, составның барлык ир-ат актёрлары диярлек үз теләкләре б-н фронтка китә. 1942 дә башында сәнгать җитәкчесе С.П.Силаев торган Сталинград ТЮЗының



Казан яшь тамашачылар театры бинасы (1995–2001 елларда яңартып төзелгәннән соң).

актёрлар төркеме Казанга күчерелә. Төркемнең составында актёрлардан С.М.Болтунов, В.И.Володин, Ф.А.Дембицкая, Д.А.Дросси, П.А.Мулярчик, Б.З.Роскин, А.И.Терентьев, А.П. һәм М.П.Неменко-Бабковский, А.М.Пешкова, А.В.Попова, Л.А.Тюрина, рәссам А.А.Поздняков, комп. Д.А.Говорухин була. Үсеп килүче буынга әхлакый, рухи, патриотик тәрбия бирүне күздә тотып, Казан ТЮЗы эшли башлаган елларында ук заманча драматургиянең турыдан-туры балалар һәм яшүсмерләргә кагылышлы мәсьәләләрен күтәреп чыгу б-н генә чикләнеп калмый, ә тамашачыны киң иҗтимагый яңгыраш алган проблемаларны да чагылдыручы әһәмиятле әсәрләр б-н дә таныштыра торган репертуар булдыра. А.А.Кронның «492116 номерлы винтовка» («Винтовка № 492116», 1932, реж. Е.Иванов), А.Бондиның «Уйлап табучылар» («Изобретатели», 1933, реж. Е.Иванов, Н.Кроль), А.Я.Бруштейнның «Дәвамы бар» («Продолжение следует», 1935, реж. А.Ю.Вилинский), В.А.Любимованың «Сережа Стрельцов», Н.А.Островский романы буенча «Корыч ничек чыныкты» («Как закалялась сталь», 1937, реж. А.В.Цвиленёв), К.А.Тренёвның «Любовь Яровая» (1938, реж. А.В.Цвиленёв), А.Н.Арбузовның «Шәһәрдә таң ата» («Город на заре», 1961, реж. Н.И.Басин), А.В.Вампиловның «Июньдә хушлашу» («Прощание в июне», 1973, реж. Ф.Г.Григорьян), А.П.Гайдар әсәрләре буенча «Бумбараш» (1975, реж. Л.И.Верзуб), А.М.Володинның «Сөйгәннәрегез белән аерылышмагыз» («С любимыми не расставайтесь», 1980, реж. Л.И.Верзуб), Е.Л.Шварцның «Аждаһа» («Дракон», 1988, сәхнәгә куючы Б.И.Цейтлин), Б.Л.Васильев повесте буенча «Җимерү» («Погром», 1990, РФ Дәүләт бүләге; сәхнәгә куючы Б.И.Цейтлин) һ.б. спектакльләр зур иҗтимагый яңгырашка ия була. Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы елларда репертуарда халыкның сугыштагы рухи һәм әхлакый батырлыгын, югары патриотизм хисен данлаган, яшь кешенең әхлакый, рухи үсеш кичерүен чагылдырган «Финист Ясный Сокол» (Н.Я.Шестаков; 1942, реж. С.П.Силаев), «Полк улы» («Сын полка», В.П.Катаев; 1946, реж. Д.А.Дросси; 1961, реж. С.Бурман; 1972, реж. Л.И.Верзуб), «Дөреслек турында әкият» («Сказка о правде», М.И.Алигер; 1946, реж. Д.А.Дросси; төп рольдә — М.П.Неменко-Бабковская), «Ике капитан» («Два капитана», В.А.Каверин; 1947, реж. С.П.Силаев), «Кызчык әтисен эзли» («Девочка ищет отца», Е.С.Рысс; 1948, реж. Е.А.Простов), «Минем өйгә кайтасым килә» («Я хочу домой», С.В.Михалков; 1949, реж. Л.А.Брошкевич), «Воробьёв таулары» («Воробьёвы горы», А.Д.Симуков; 1949, реж. В.В.Тан), «Хәерле иртә» («В добрый час», В.С.Розов; 1955, реж. В.А.Стояновская), «Чын кеше» («Настоящий человек», Б.Н.Полевой повесте буенча; 1956, реж. Л.Г.Щеглов), «Анюта күзләре» («Анютины глазки», Т.Г.Ян; 1956, реж. Л.Г.Щеглов), «Безнең шәһәр егете» («Парень из нашего города», К.М.Симонов; 1963, сәхнәгә куючы М.Х.Сәлимҗанов), спектакльләре һ.б. яшь Казан ТЮЗы сәхнәсендә ышан-



Казан яшь тамашачылар театры. Спектакльләрдән күренешләр: 1. «Корыч ничек чыныкты», Н.А. Островский романы буенча. 1937; 2. «Анюта күзләре», Т.Г. Ян. 1956; 3. «Пеппи Озыноек», А.Линдгрен. 1973; 4. «Принц һәм теләнче», М. Твен повесте буенча. 1977; 5. «Сид», П. Корнель 1986.

дырырлык гәүдәләнеш таба. «Замана балалары» («Современные ребята», М.Ф.Шатров; 1963, реж. М.Х.Сәлимҗанов), Л.И.Верзуб куйган «Ә Воробьёв тәрәзә ватмады» («А Воробьёв стекла не выбивал», Ю.Я.Яковлев, 1971), «Пеппи Озыноек» («Пеппи Длинныйчулок», А.Линдгрен, 1973), «Малаховны туктатыгыз!» («Остановите Малахова!», В.А.Аграновский, 1977), «Гуманоид күктә оча» («Гуманоид в небе мчится», А.Г.Хмелик; 1982, реж. Е.М.Долгина), «Бойкот» (В.К.Железников; 1984, реж. Ю.А.Благов) һ.б. спектакльләрдә яшүсмерлек чорына хас проблемалар ачык чагылыш таба.

Рус һәм дөнья драматургиясенең классик әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, театр аларда күтәрелгән проблемаларның тирәнлеген, әһәмиятен тамашачы игътибарына җиткерергә омтыла. У.Шекспирның «Ялгышлар комедиясе» («Комедия ошибок», 1956, реж. Л.Г.Щеглов), «Җәйге төндә күргән төш» («Сон в летнюю ночь», 1982, реж. Л.И.Верзуб) һәм «Давыл» («Буря», 1993, реж. Б.И.Цейтлин, РФнең «Алтын битлек» Милли бүләге), В.Гюго романы буенча «Хокуксызлар» («Отверженные», 1951, реж. В.В.Тан), Ф.Шиллерның «Юлбасарлар» («Разбойники», 1935, реж. А.Ю.Вилинский; 1954, реж. М.И.Каширин) һәм «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь», 1957, реж. Л.Г.Щеглов), Н.В.Гогольнең «Ревизор» (1936, реж. А.Ю.Вилинский; 1958, реж. Л.Г.Щеглов) һәм «Өйләнү» («Женитьба», 1970, реж. В.Бейлис), И.С.Тургенев романы буенча «Бер көн элек» («Накануне», 1949, реж. В.В.Тан), А.Н.Островскийның «Яшенле яңгыр» («Гроза», 1971, реж. Ф.Г.Григорьян) һәм «Бирнәсез кыз» («Бесприданница», 1964, реж. М.Х.Сәлимҗанов), А.П.Чеховның «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», 1947, реж. С.П.Силаев), «Өч сеңел» («Три сестры», 1960, реж. Д.М.Каплан-Александрова) һәм «Ваня абзый» («Дядя Ваня», 2003, реж. Г.З.Цхвирава), М.Горькийның «Мещаннар» («Мещане», 1953, реж. М.И.Каширин) һ.б. спектакльләре режиссёр һәм актёрларның зур осталык күрсәтүләре б-н аерылып торалар. 1983 тә Казан ТЮЗында Кече сәхнә ачыла.

Соңгы елларда куелган аеруча игътибар үзәгендә булган спектакльләр: А.Казанцевның «Ашыгучы юлаучылар» («Бегущие странники», 2006), М.Макдонахның «Минем сөекле баш сөягем» («Череп мой любимый», 2006), М.Ладоның «Бик гади вакыйга» («Очень простая история», 2007), Э.-Э.Шмидтның «Оскар һәм Алсу Әни» («Оскар и Розовая Мама», 2007), Н.В.Гогольнең «Уенчылар» («Игроки», 2008), Ш.Диленинның «Бал тәме» («Вкус мёда», 2008), А.Поярковның «Кечкенә татар кешесе» («Татарин маленький», 2008), У.Шекспирның «Отелло» (2011) әсәрләре; барысын да сәхнәгә куючы — В.Б.Чигишев.

Казан ТЮЗы сәхнәсендә В.Е.Горюнов, М.П.Неменко-Бабковская, В.А.Чернецкий, П.А.Мулярчик, С.М.Болтунов, Б.З.Роскин, А.М.Пешкова, В.В.Близнова, Ю.А.Максимов, В.А.Глушков, Н.И.Калаганова, А.В.Калаганов, А.В.Кокурин, З.А.Петрова, Е.С.Царьков, Н.М.Кочнева, А.И.Купцов, В.А.Фейгин, Р.В.Хәйруллина тирән эчтәлекле, мәгънәле, тәэсирле образлар иҗат итәләр. Төрле елlардагы режиссёрлар арасында: Е.Иванов (1932–34), С.П.Силаев (1942–48), В.В.Тан (1948–52), Л.Г.Щеглов (1955–59), Н.И.Басин (1959–62), М.Х.Сәлимҗанов (1963–66), Ф.Г.Григорьян (1968–73), Л.И.Верзуб (1974–87), Б.И.Цейтлин (1987–95), Г.З.Цхвирава (2002–04), В.Б.Чигишев (2005 тән) исемнәре киң таныла.

Театрның гастрольләре Мәскәү (1959, 1961), Ленинград (1958), Ярославль, Калуга, Иваново, Запорожье, Новгород, Караганда һәм илнең башка күп кенә шәһәрләрендә уза; театр күп тапкырлар Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия балалар театрлары, милли драматургия фестивальләрендә катнаша һәм лауреат була; спектакльләре еш кына Үзәк телевидениедән күрсәтелә.

Труппаның составында (2010) ТРның халык артистлары Р.В.Ерыгин, Е.Е.Ненашева, Г.Ю.Юрченко, Н.М.Кочнева, А.И.Купцов, М.А.Меркушин, С.В.Мосейко һ.б. бар; баш реж. — РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе В.Б.Чигишев, директоры — ТР һәм РФ нең атказ. мәдәният хезмәткәре Ф.Ш.Шәмсиев.

*Әд.:* Б л а г о в Ю.А. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**«КАЗА́Н 1»**, болын клеверы сорты. 1936 елда Казан селекция станциясендә З.Х.Шәрәф, Л.А.Леденцова һәм Н.А.Кащеева тарафыннан җирле клевердан күп тапкырлар һәм күпләп сайлап, семья тәртибендә аерып алу ысулы б-н чыгарыла. Бер тапкыр чабып алына торган төргә карый. Популяциядә көзге типтагылары өстенлек алган, язгы күпьеллыклары аз. Язгы үсә башлаудан беренче чабып алуга кадәр 70 — 100 көн, тулысынча өлгерүгә — 135–150 көн. Тармаклануы аз. Сабаклары юан, куыш эчле, биеклеге 65–90 *см.* Өске өлештә ботакланган. Буын арасының саны 9. Яфраклары озынча, очланып килгән. Яфраклануы югары. Башы уртача зурлыкта, чәчәкләре ачык-алсу төстә. Тармаклануы яхшы. Яз көне һәм чабып алганнан соң акрын үсә. Соң өлгерешле, чәчәк атуы тишелеп чыкканнан соң беренче елда 104–113 көннән башлана. Икенче елда июльнең 1 яртысында чәчәк ата. 1000 орлыкның авырлыгы 1,5–1,8 *г.* Кышка чыдамлылыгы уртача, корылыкка бирешүчән. Тутык авырулары б-н нык, антракноз б-н уртача зарарлана. Коры матдәсенең иң югары уңышы 1 *га* дан 145 *ц*, орлыгы — 7 *ц*, печән уңышы — 70,5 *ц.* 1938 дә Татарстан һәм Чуаш АССРларда районлаштырыла, Урта Идел буе төбәкләрендә игелә.

*Әд.* к. «*Казанец*».

**«КАЗА́Н 2»**, тары сорты. 1956 елда Казан селекция станциясендә М.Н.Шумкова һәм Г.И.Попов тарафыннан «Казан 176» сорты табигый гибридының иң яхшы токымыннан сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт суббокцинеум астөренә карый. Себеркәче эре, җәенке формада, антоциан төстә. Бөртеге ачык-кызыл төстә, озынча-түгәрәк формада. 1000 бөртекнең авырлыгы 6,5–7 *г*, элпәлелеге югары — 20–25%, ярма чыгышы — 70–75%, тишелеше — 65–75%, беренчел протеин — 12–14%. Иртә өлгерешле, вегетация чоры 80–90 көн. Сөрлегүгә чыдам, бөртек коелуы уртача. Брянск һәм Орёл өлкәләрендә районлаштырыла (1962).

*Әд.* к. «*Казанская местная*».

**«КАЗА́Н 6/4»**, сабан арпасы сорты. 1940 елда Казан селекция станциясендә Ш.В.Вәлиев һәм П.С.Зубков тарафыннан чыгарыла. Уртача өлгерешле, вегетация чоры якынча 80 көн. Яхшы уңыш бирә, корылыкка чыдам. 1942 елда РСФСРның 9 өлкәсендә һәм автономияле республикаларында районлаштырыла. Якынча 30 ел чәчелә.

*Әд.:* Татарскому научно-исследовательскому институту сельского хозяйства — 50 лет. К., 1971.

**«КАЗА́Н 36»**, люцерна сорты. 1938 елда Казан селекция станциясендә З.Х.Шәрәф тарафыннан «Грим» сорты б-н җирле сары люцерна сортын ирекле серкәләндерүдән булган гибридлардан күпләп сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Уртача өлгерешле, акрын үсә. Кышка чыдамлылыгы югары, яфраклануы 60% тәшкил итә. Авырулар б-н зарарлануы уртача. Сынау елларында печән уңышы 1 *га* дан 45–55 *ц* була; 2–3 тапкыр чабып алырга мөмкин. ТАССРда районлаштырыла (1938).

*Әд.* к. «*Казанская местная*».

**«КАЗА́Н 38»**, борчак сорты. 1963 елда Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясендә В.З.Шәкүров тарафыннан «Казан 104» һәм «Казан 4999» гибридларыннан күп тапкырлар индивидуаль сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Вульгатум астөренә карый. Шытымнары ачык-яшел. Сабагы 60–90 *см* биеклектә һәм биегрәк. Буын арасының гомуми саны 20–25, беренче чәчәк атуга кадәрге буын арасы — 10–14. Төпчек яфраклары йөрәк формасында, эре. Яфраклары 2–3 парлы йомыркасыман ачык-яшел төсле тоташ яфракчыклардан тора, очлары өчләтә мыекчалар б-н. Чәчәкләре ак, чәчәк сабагында 2–3 чәчәге бар. Кузаклары туры, тупа башлы, киңлеге 1,5, озынлыгы 7 *см.* Кузагында уртача 4–5 орлык була (1 дән 8 кадәр). Орлыгы ачык-алсу төстә, түгәрәк, шома, уртача эрелектә, тәмле һәм тиз пешә, аксым микъдары 22–27% тәшкил итә. 1000 орлыкның авырлыгы 239–244 *г.* Бу сорт уртача иртә өлгерешле, вегетация чоры 75–84 көн, стандарт «Торсдаг» сортыннан 2–3 көнгә иртәрәк өлгерә. Аскохитоз авыруыннан стандарт сорт б-н тигез дәрәҗәдә зыян күрә, җимешашар һәм гөбләләр зарарлавына бирешми. Югары уңышлы, сынау елларында Татарстан сорт участокларында орлык уңышы 1 *га* дан 16,3–23,7 *ц* тәшкил итә, бу стандарт «Торсдаг» сортыннан 1,3–3,5 *ц* га югарырак. Актаныш р-ны хуҗалыкларында («Октябрьнең 12 еллыгы») 1 *га* дан 30 *ц* һәм аннан да артыграк уңыш алына. 1966 да Татарстанда һәм РСФСРның күп өлкә һәм республикаларында районлаштырыла.

*Әд.* к. «*Казанская местная*».

**«КАЗА́Н 61»**, тары сорты. 1961 елда Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясендә М.Н.Шумкова тарафыннан «Казан 176» һәм «Долинское 86» сортларын серкәләндерүдән

булган гибридларның иң яхшы токымнарын популяциягә берләштерү юлы б-н чыгарыла. Бу сорт Виктория астөренә карый. Себеркәче кысынкы-бөгелгән формада, озын асылынып торган куе-сары төстәге сабаклы. Бөртеге түгәрәк, ачык-сары төстә, кызыл кырыйлы, эре. 1000 орлыкның авырлыгы 7–7,5 *г*, элпәлелеге — 17–21%, тишелеше — 65–75%, ярма чыгышы — 75–80%, беренчел протеин — 13–14% тәшкил итә. Югары уңыш бирә, сөрлегүгә чыдам, бөртеге яхшы технологик сыйфатка ия. Уңыш бирүе 1 *га* дан 40–45 *ц* (стандарттан 3–4,8 *ц* га югары). Иртә өлгерешле; вегетация чоры 80–85, кайбер очракта 90 көн. 1961 дә дәүләт сорт сынавына тәкъдим ителә, 1966 да Курган һәм Чиләбе өлкәләрендә районлаштырыла.

**«КАЗА́Н 64/95»**, люцерна сорты. 1938 елда Казан селекция станциясендә З.Х.Шәрәф, М.С.Новосёлова тарафыннан люцернаның сары Себер сорты б-н Азия һәм Европа сортларының ирекле серкәләнүеннән алынган гибрид популяциядән күпләп сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт чуар-гибрид сорт тибына карый. Тармаклануы уртача, ярым егылган һәм таралып тора. Сабаклары 45–54 *см* биеклектә, уртача юанлыкта, яхшы ботакланган. Яфраклары озынча-эллиптик, ланцетсыман, аскы яктан кыска төкле. Яфраклануы 43,6–48,8%. Чәчәк оешмасы — цилиндрик формадагы (сирәгрәк башча) чук, уртача озынлыкта һәм тыгызлыкта. Чәчәкләрнең күпчелеге шәмәхә-чуар төстә, ачык-зәңгәр һәм ачык-сары төсләләре дә очрый. Кузаклары 0,5–3 бөтеркәле, эре. 1–2 тапкыр чабып алырга мөмкин, кышка чыдам, корылыкка бирешми. Сынау елларында Курган өлкәсенең Белозёрск сорт участогында яшел массасының уртача уңышы 1 *га* дан 119 *ц*, печәне — 43,7 *ц* чыга; 1942 дә Татарстан һәм Бурят АССРларда районлаштырыла, Курган һәм Пермь өлкәләрендә коры үзәнлекле болыннарда печәнлек һәм көтүлекләр өчен файдаланыла.

*Әд.:* к. «*Казанская местная*».

**«КАЗА́Н 84»**, уҗым бодае сорты. 1990 елда «Татарстан кыры» ФҖБдә Э.Ф.Ионов, У.Х.Вәлиуллин, Л.А.Семахина, Т.А.Гусева тарафыннан рекомбинация һәм мутация үзгәрешләре туры килү нәтиҗәсендә һәм экстремаль начар шартлар фонында үсемлекләрнең кышкы вегетация чорында элиталы төрне сайлап алу ысулы б-н чыгарыла.

Уртача өлгерешле, вегетация чоры 320–335 көн, корылыкка бирешми, кышка чыдамлылыгы югары. Язгы үсеше интенсив булганда корылыклы елларда да югары уңыш бирә: Уртача уңышы 1 *га* дан 35 *ц*. 1000 бөртекнең авырлыгы 36–38 *г*, элпәлелеге 70%, беренчел протеин 13,79%, гомуми икмәк пешерү бәяләмәсе 4,2 балл. Яфракта була торган көрән гөмбә һәм ончыл чык авырулары б-н зарарлануы уртача. 1992 дә Урта Идел буе регионы буенча дәүләт селекция казанышлары реестрына кертелә.

*Әд.:* к. «*Казанец*».

**«КАЗА́Н 176»**, тары сорты. 1941 елда Казан селекция станциясендә Г.И.Попов тарафыннан җирле үрнәктән ике тапкыр сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт субкокцинеум астөренә карый, яфраклары, сабаклары, башагының тәңкәләре антоциан төстә, җәенке формада. Бөртеге кызыл, уртача эрелектә. 1000 бөртекнең авырлыгы 6–6,8 *г*, ярма чыгышы 75–77%. Тиз өлгерешле (вегетация чоры 70–80 көн), вегетация чорының башында тиз үсеше б-н аерылып тора. Салкынга чыдам, начар һава шартларына бирешми. Уңышы 1 *га* дан 28–30 *ц* (стандарт «Новоуренское 241» сортыннан 2 *ц* га артык). 1945–47 дә Татарстан, Чуаш, Мари АССРларда һәм Горький өлкәсендә районлаштырыла. 20 елдан артык игелә.

*Әд.:* к. «*Казанская местная*».

**«КАЗА́Н 285»**, көзге бодай сорты. 1996 елда «Татарстан кыры» ФҖБдә Э.Ф.Ионов, Н.П.Капитонова, У.Х.Вәлиуллин, П.П.Дёмкин, И.Л.Максимов тарафыннан Hadmeslebner 15080 (Германия) сортын «Мишә 2» сорты б-н ирекле рәвештә җил ярдәмендә серкәләнүдән булган гибридтан аерым семьяlыкларны сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Уртача өлгерешле, вегетация чоры 314–330 көн. Кышка һәм корылыкка чыдамлылыгы югары булуы б-н аерылып тора, азотлы ашламалар кертелгәндә яхшы уңыш бирә. 1999 дан ТР буенча җитештерүдә куллануга тәкъдим ителә.

**«КАЗА́Н 430»**, тары сорты. 1946 елда Казан селекция станциясендә Г.И.Попов тарафыннан Мари АССРның җирле популяциясеннән сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт субфлявум астөренә карый. Себеркәче җәенке, асылынып тора, антоциан төстә. Бөртеге караңгы төсмерле ачык сары төстә, формасы — озынча түгәрәк. 1000 бөртекнең авырлыгы 6,5–7 *г*, элпәлелеге 20–25%, ярма чыгышы 70–78%, тишелеше 60–70%, беренчел протеин 12–13% тәшкил итә. Бу сорт түбән темп-рага, сөрлегүгә, бөртек коелуга чыдам. Тиз өлгерешлелеге б-н аерылып тора: вегетация чоры 65–70 көн. Уңышы 1 *га* дан 20–25 *ц*. 1948 дә Пермь, Рязань өлкәләрендә, Мари һәм Башкортстан АССРларда районлаштырыла.

*Әд.:* Шумкова М.Н. Селекция, семеноводство и агротехника проса // Тр. Татар. реп. с. х. опытной станции. К., 1969. Вып. 2.

**«КАЗА́Н 506»**, тары сорты. 1934 елда Югары Идел буе селекция үзәгендә И.И.Штуцер, Е.И.Ивенина тарафыннан җирле үрнәктән аерым сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт флявум астөренә карый, себеркәче эре җәенке, антоциан төстә түгел. Бөртеге сары, уртача эрелектә. 1000 бөртекнең авырлыгы 6,5 *г*, элпәлелеге 18–24%, ярма чыгышы 76–77%, тишелеше 60–70%, беренчел протеин 12–12% тәшкил итә. Вегетация чоры 70–82 көн. Сыгылмалылыгы б-н аерылып тора. Бөртегенең сыйфаты буенча кыйммәтле сортлардан санала. Салкынга чыдам, тиз өлгерешле. Уңышы 1 *га* дан 28–30 *ц*. Сорт сынавы Татарстан дәүләт сорт участокларында 1934 тә башлана, рәсми рәвештә Дәүләт комиссиясенә 1937 дә тапшырыла. 1938 дә Красноярск һәм Алтай крайларында, Иркутск, Кемерово, Томск, Төмән һәм Новосибирск өлкәләрендә районлаштырыла.

*Әд.:* к. «*Казанская местная*».

**КАЗА́Н-ВЯ́ТКА ЕПА́РХИЯСЕ**, Рус православие иске дин тарафдарлары чиркәвенең башында епископ торган чиркәү-административ бүленеш берәмлеге. 1856 елда, Белокриница иерархиясендәге Мәскәү иске дин тарафдарлары архиепископы Антоний (Шутов) фатихасы б-н, беренче Казан-Вятка епископы *Пафнутийны* (Шикин) изге дәрәҗәгә күтәрү йоласы үткәрелгәч оештырыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Казан-Вятка терр-яләрен үз эченә ала. 1905 елның 17 октябрь Манифесты игълан ителгәнгә кадәр епископлар рәсмиләштерелмәгән хәлдә яшиләр. Аларның төп җыелу урыны Саратов губернасының Хвалынск шәһәре янындагы Черемшан монастыре була: Казанда аларның резиденцияләре булып иске дин тарафдарлары чиркәве урнашкан Карповлар йорты (Бауман урамы, 64) хезмәт итә. 1905 елның апреленнән Епархия идарәсе рәсми рәвештә эшли башлый, 1909 дан *Покров чиркәве* кафедраль собор итеп билгеләнә. Епархиядә уннарча, ш.и. Казан губернасы терр-ясендә 20 дән артык иске дин тарафдарлары приходлары оеша. Епархия б-н епископлар: Пафнутий (1856–90), *Иоасаф* (Зеленкин) (1890–1912), Филарет (Удалов) (1912–31) идарә итә. 1930 еллар башында динне эзерлекләү нәтиҗәсендә иске дин тарафдарлары иерархиясе структурасы яшәүдән туктый, 1997 дә кабаттан торгызыла. 2001–04 тә аны Казан һәм Вятка епископы Андриан (Четвергов), 2005 тән епископ Корнилий (Титов), 2011 дән епископ Евфимий (Дубинов) җитәкли. Хәзер епархиягә Татарстан, Мордва, Мари, Чуаш һәм Удмурт Респ-калары терр-ясе; Киров һәм Ульянов өлкәләре, Пермь өлкәсенең Чайковский шәһәре керә.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗА́Н-КАВКА́З МӨСЕЛМА́Н АРТИСТЛАРЫ́ ШИРКӘТЕ́**, хосусый антреприза. 1908 елның апрелендә Тифлис (хәзер Тбилиси) шәһәрендә Г.Кариев җитәкчелегендәге татар һәм Г.Араблинский җитәкчелегендәге әзәрбайҗан труппалары актёрларының үзара килешүе буенча театр сәнгатенең максат һәм бурычларына карата булган уртак карашлар нигезендә оеша. Төрек язучысы Н.Кәмалның «Кызганыч бала» пьесасы буенча бергә куйган беренче спектакле Шәфыйка ролен башкарган С.*Гыйззәтуллина-Волжскаяның* бенефисы буларак уза; Г.Араблинский Гата ролен башкара. Икенче спектакль әзәрбайҗан драматургы Н.Вәзировның «Мөсыйбәте Фәхретдин» трагедиясе буенча куела, анда С.Гыйззәтуллина-Волжская Сәгадәт ролендә уйный. Июньдә ширкәт Әстерхан шәһәренә күчә, анда Н.Наримановның «Надир шаһ» әсәре, С.Ганизадәнең «Дурсунәли вә баллы бады» водевиле буенча куелган һәм алдан әзерләнгән спектакльләр күрсәтелә. Июльдә ширкәтнең гастрольләре Казанда узарга тиеш була, әмма шәһәр хакимиятләре тарафыннан каршылыкка очрау сәбәпле, бер генә спектакль күрсәтелә. Түбән Новгород

ярминкәсендә Н.Наримановның «Надир шаһ», А.Ахвердовның «Милләт достлары», Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем», Г.Камалның «Беренче театр», «Бәхетсез егет» пьесалары буенча спектакльләр куела (Г.Араблинский — Закир, Г.Кариев — Кәрим бай, С.Гыйззәтуллина-Волжская — Гайни рольләрендә). 1908 нең августында, гастрольләре тәмамланганнан соң, ширкәт аерыла: Г.Кариев труппасы Казанга кайта, Г.Араблинский труппасы Бакуга китә. Бергә эшләү тәҗрибәсе татар һәм әзәрбайҗан театрларының алга таба үсешенә уңай йогынты ясый (репертуар һәм сәнгатьчә чараларга баетыла). Тормышчан көнкүреш драма һәм комедияләр б-н беррәттән татар театры репертуарында героик-романтик характердагы спектакльләр дә барлыкка килә. Шул ук вакытта Г.Кариев мәктәбенең тормышчанлыгы һәм ышандыру көче әзәрбайҗан актёрлары сәнгатен дә баета.

*Әд.:* Иллялова И. Межнациональные связи татарского театра. К., 1985.

*И.И.Иллялова.*

**КАЗА́Н-КИ́РОВ БӨГЕЛЕШЕ́**, Казан бөгелеше, Казан–Кажим күмелгән бөгелеш-авлакогены, Казан–Киров авлакоген-иңкүлеге, девон чорындагы меридиональ урнашкан, күмелгән тектоник катлам, Идел Кама антеклизасының бер өлеше. Борынгы (венд) ятма, күпсанлы тирән җимерелүләр б-н катлауланган. Казаннан Кажим посёлогына (Коми Респ-касы) кадәр сузыла (800 *км* дан артык). Кристал фундаменттагы токымнар өслеге көньяктан (–1850 *м*) төньякка (–2800 *м*) түбәнәя, бөгелеш амплитудасы 150 *м* дан 900 *м* га кадәр. К.-К.б.енең үзәк өлешен тар тектоник структура — Казан–Кажим авлакогены алып тора; тирәндәге өлеше, 211 *м* га кадәр тирәнлектәге комлы-балчыклы урта девон чоры утырмаларыннан тора, аларның сыртында бөгелеш яссы рәвеш ала, өелмәләр (Зөя, Казаклар һ.б.) һәм локаль калкулыклардан тора. Девонның югары горизонтында бөгелеш күренми, әмма кече өлешләрдә бөгелешләр еш кабатлана һәм яңа тектоник структуралар хасил була: *Кама-Кинель бөгелешләр системасы, Вятка өелмәсе* (*валы*) һ.б.

К.-К.б. чикләрендә, югары девон катламында нефть (Киров өлкәсе) бар, ТР терр-ясендә Пермь һәм антропоген чор катламнары — күпсанлы төзелеш материаллары казылмалары, минераль пигментлар, туфракны известь б-н баету өчен карбонат токымнар, җир асты минераль сулары һ.б. бар.

*Әд.:* Войтович Е.Д., Гатиятуллин Н.С. Тектоника Татарстана. К., 1998; Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999. Ч. 1.

**КАЗАНБА́ЕВ** Шәрифҗан Габдрахман улы (1916, хәзер Пермь крае, Барда р-ны Сараш а. — 1944 нең апреле), Сов. Союзы Герое (13.9.1944, үлгәннән соң), гв. старшинасы (1944). Колхозда эшли. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 14 нче гв. һава десанты полкының комендант взводы отделениесе командиры (4 нче гв. армиясенең 6 нчы гв. һава десанты дивизиясе). Воронеж һәм 2 нче



Ш.Г.Казанбаев.

Украина фронтлары гаскәрләре составында Белгород-Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Украина һәм Молдавияне азат итүдә катнаша. 1944 елның 1 апрелендә Чолтяны авылы (Молдавия ССР Оргеев р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: полк дошманның көчле контратакасын кире кайтарганда совет гаскәрләре кыен хәлгә тарганда, штаб башлыгы К. отделениесенә часть байрагын саклап калырга боера. К. берүзе кала, приказны үтәгәндә каты яралана һәм яралардан үлә. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Коренев А.А. Пароль — подвиг. Киш., 1968; Золотые звёзды Прикамья. Пермь, 1974.

*В.А.Шагалов.*

**КАЗАНБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 541 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1617 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кармыш-Казанбаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, күн эшкәртү һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 1866 елгы мәгълүматларга караганда, К.та мәчет була; 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, 2 мәчет, кредит бирү ширкәте, тегермән, тимерчелек, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1869,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 161 ир-ат; 1859 да — 877, 1897 дә — 1074, 1908 дә — 1178, 1920 дә — 1256, 1926 да — 1183, 1938 дә — 948, 1949 да — 793, 1958 дә — 697, 1970 тә — 695, 1979 да — 628, 1989 да — 596, 2002 дә — 549 кеше.

**«КАЗАНВТОРЦВЕТМЕ́Т»,** икенчел металлургия пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 300 ләп кеше (2010). 1936 елда «Цветметлом» (1938 дән — «Вторцветмет») трестының Казан бүлекчәсе буларак нигезләнә. 1942 дән «Главвторцветмет» идарәсенең Казан республикаара җитештерү-хәзерләү конторасы, 1958 дән «Росглаввтормет»ның Татарстан җитештерү-хәзерләү идарәсе, 1965 тән Казан «Вторцветмет» республикаара аренда пр-тиесе оештырыла, ул 1994 тә «К.» ҖЧҖ итеп үзгәртелә. 1997 дән — АҖ. Аның составында — ТРның р-ннарындагы һәм шәһәрләрендәге 30 ф-л (чимал әзерләү б-н шөгыльләнәләр) һәм Казандагы төп җитештерү цехлары (җиз, бакыр һәм алюминий ватыкларын сортларга аералар һәм эшкәртәләр). Пр-тиенең химия лаб-ясендә чималның һәм эшләнә торган продукциянең химик составы анализлана. 2000 нән эретү производствосы актив үсеш кичерә, алюминийны кисү станоклары, бакыр һәм алюминий ватыкларын эретү мичләре гамәлгә кертелә, 2001 дән маркалы җиз һәм алюминий коелмаларын чыгаручы куәтләр эшкә җигелә. Пр-тиедә җитештерү күләме 35% ка арта; гамәлдәге куәтләр елга 100 мең *т* га кадәр төсле метал калдыкларын эшкәртү мөмкинлеген бирә.

«К.»ны чимал б-н тәэмин итүче эре пр-тиеләр — Казан моторлар төзү берләшмәсе, Казан авиация ҖБ, «Казанкомпрессормаш», «КамАЗ» АҖләре. РФнең 2 меңнән артык пр-тиесе, ш.и. «Вторцветмет»ның Мценск, Каменск-Уральский, Подольск шәһәрләрендәге металлургия з-длары, «Сухоложский «Вторцветмет» заводы АҖ, «ВМС» з-ды (Мценск), «Латуни» фәнни-техник үзәге (Мәскәү) «К.» продукциясен кулланалар. Татарстандагы төп кулланучылар — «Сантехприбор», «Элекон», «Теплоконтроль», «Электроприбор» з-длары, нефть-газ сәнәгате пр-тиеләре һ.б. 1990 еллар уртасыннан продукциянең 50%ы чамасы Япониягә, Бөекбританиягә, Латвиягә һ.б. илләргә җибәрелә. Пр-тиенең эше икътисади кризис шартларында җитештерүне уңышлы үстерү өчен Халыкара бизнес академиясенең «Бирмингем факелы» призына (1995), икенчел ресурсларны җыю һәм эшкәртү өлкәсендәге пр-тиеләр һәм оешмаларның 1 нче Бөтенроссия конкурсының 1 нче дәрәҗә дипломына (2003) лаек була. Пр-тие җитәкчеләре арасында — В.М.Гаделшин (1951–85), В.Г.Никитенко (1985–94), И.В.Пивнюк (1994–2003), А.И.Пивнюк (2003 тән).

**КАЗАНГА́ РУС ДӘҮЛӘТЕ́ ЯУЛАРЫ́**, 1545–51 елларда Рус дәүләтенең Казан ханлыгына каршы алып барган яулап алу сугышлары. 1545 елның язында Глинскийлар хөкүмәте Казанга 3 зур отряд: иң зурысын — Идел буйлап Түбән Новгород шәһәреннән, кечерәкләрен — Вятка җиреннән Нократ елгасы һәм Пермьнән Чулман елгасы буйлап җибәрә. Беренче 2 отряд Казан тирәсендә очраша һәм «күпләгән казанлыларны үтерә». Төп көчләр киткәннән соң Казан янына килеп җиткән Пермь отряды тар-мар ителә. Бу яу *Казанда тәхет чуалышына* (1545–46) сәбәпче була, аның нәтиҗәсендә Мәскәү ялчысы Шаһгали Казан тәхетенә утыртыла. 1546 да Шаһгали казанлылар тарафыннан бәреп төшерелгәч, Глинскийлар Казанга кенәз А.Б.Горбатый-Шуйский җитәкчелегендәге гаскәрне җибәрәләр. Идел буйлап хәрәкәт итеп, ул Зөя тамагына кадәрге җирләрне талап йөри, күп әсирләр ала. 1547 дә башка хөкүмәт — «Сайлама рада» («Избранная рада», Боярлар җыены) Казанга яңа һөҗүм оештыра. Кенәз Д.Ф.Бельский җитәкчелегендәге гаскәр Түбән Новгородтан чыга, ләкин Иделдә боз эрү аркасында зур югалтуларга дучар була. Цивиль елгасы тамагында ул Шаһгали отрядлары б-н кушыла. Гаскәрләр Казанга килеп җитәләр һәм аның тирә-ягын талыйлар. 1548 нең мартында Бельский гаскәре Түбән Новгородка әйләнеп кайта. Чираттагы яу Сафагәрәй ханның үлеме һәм тәхет өчен барган көрәшкә бәйле рәвештә оештырыла. Аңа әзерлек 1549 ның ноябрь башын-

да башлана. Яуга Шаһгали һәм Бельский белән бергә Иван IV җитәкчелек итә. Бик зур гаскәр кышын Муром, Суздаль, Кострома, Ярославль шәһәрләрендә җыела. 1550 нең 14 февралендә гаскәрләр Казан янына килеп җитәләр һәм шәһәргә һөҗүм башлыйлар. Әмма көннәр җылыну, азык-төлек һәм сугыш кирәк-яраклары җитмәү аркасында 2 атнадан соң Иван IV чигенергә һәм Мәскәүгә кайтып китәргә мәҗбүр була. 1551 нең язында чираттагы яу оештырыла. Шаһгали һ.б. җитәкчелегендәге гаскәр Зөя елгасы тамагына терәк кальга төзү өчен җибәрелә (к. *Зөя*). Гаскәрләр берничә яктан — Мещёрадан (кенәз Д.И.Хилков), Түбән Новгородтан (кенәз П.С.Серебряный), Нократ буйлап (Б.Зюзин) хәрәкәт итә. Зөягә беренче булып килеп җиткән П.С.Серебряный 18 майда Казан тирәсенә һөҗүм оештыра. 24 майда башка гаскәрләр дә килеп җитә. Яуның төп нәтиҗәсе Тау ягы чуаш һәм чирмешләренең Мәскәү хакимиятенә буйсындырылуы, Казанда *Сөембикә ханбикә* хөкүмәтенең бәреп төшерелүе һәм аны кече яшьтәге улы *Үтәмешгәрәй хан* б-н бергә Иван IV кулына тапшыру, Казан тәхетенә Шаһгалинең кабат кайтуы була. Ш.у. к. *Казанның яулап алынуы*.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Д и м и т р и е в В.Д. Чувашия в эпоху феодализма. Чебоксары, 1986; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; С а б и р з я н о в Г.С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1995; Б а х т и н А.Г. XV–XVI века в истории Марийского края. Йошкар-Ола, 1998.

*Е.В.Липаков.*

**«КАЗАНДА́ БЕ́ЛЬГИЯНЕҢ АТЛЫ́ ТИМЕ́Р ЮЛЛА́Р АНОНИ́М ҖӘМГЫЯТЕ́»**, акционерлык җәмгыяте. 1892 елда оештырыла (Россия Министрлар Кабинетының 1894 ел 18 гыйнвар нигезләмәсе б-н раслана). 1892 нең 25 февралендә Казан шәһәр думасы б-н атлы тимер юл («конка») төзү турында килешү төзи. 1890 еллар ахырына шәһәрдә 5 атлы тимер юл линиясе эшли: Идел — Толчоктан Идел буендагы пароход пристаньнарына кадәр; Проломный — Зур Проломный урамыннан Постаучылар бистәсенә кадәр; Черек күл — Черек күлдән Грузинский урамы аша Арча кырына кадәр; Үзәк — Югары Фёдоровский урамыннан Балык рәтләре мәйданына кадәр; Екатерининский — Мәскәү урамы буйлап бертуган Крестовниковлар заводына кадәр. Линияләр бер рәтле була, ике ат вагонны сәгатенә 2 чакрым тизлек б-н тарта. Түбән Кабан күле янында эл. трамвайлары үзәк станциясе төзелгәч (1898), трамвайлар эл. ярдәмендә хәрәкәткә китерелә башлый, хәрәкәт 1899 ның 18 ноябрендә ачыла. 1913 кә гомуми озынлыгы 26 *км* булган 6 трамвай линиясе эшли, аларда елына 250 меңнән артык пассажир йөртелә. БҮБК һәм Россия ХКСның 1918 ел 26 июнь декреты б-н национализацияләнә.

*Әд.:* История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**КАЗАНДА́ МОНА́РХИЯ ЯКЛЫ́ РУС ЯШЬЛӘРЕ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, иҗтимагый оешма. 1908 елда «Монархия яклы рус яшьләре түгәрәге» (1907 нең декабрендә оештырыла) базасында булдырыла. Уставы 1912 дә раслана. Төп максатлары: Казандагы һәм Казан губернасындагы монархия яклы яшьләрне берләштерү, яшьләрнең милли үзаңын үстерү, рус тарихи башлангычларын саклау («православие, самодержавие һәм халыкчанлык»), фетнәгә каршы тыныч чаралар белән көрәшү. Җәмгыятькә әгъза итеп университет, вет. ин-ты, руханилар академиясе студентлары, Казан югары хатын-кызлар курслары тыңлаучылары һәм балигъ булган 30 яшьтән артмаган кешеләр алына. Җәмгыять б-н составына рәис, 2 иптәш (рәис урынбасары), секретарь, казначей һәм сайланып куелган берничә әгъза кергән совет җитәкчелек итә. Төрле елларда рәисләре: П.Я.Полетика, Н.И.Мамонтов, Н.В.Сергиевич, Н.А.Александров. Пропаганда эшчәнлегеннән тыш, җәмгыять фәнни-тикшеренү һәм спорт-патриотик эшләр б-н дә шөгыльләнә. 1908 дә аның каршында гимнастика һәм спорт сөючеләр түгәрәге — «Беркут» ачыла (1913 тән «Сокол» гимнастика җәмгыяте), массакүләм спорт ярышлары һәм кичәләр үткәрелә (күбесенчә Казан пехота юнкерлар уч-щесе манежы терр-ясендә), ш.у. оешма гомумроссия ярышларында һәм тантаналарында актив катнаша. 1910 да түгәрәк каршында спортчы И.Г.Корибут-Кубитович җитәкчелегендә хатын-кызлар бүлекчәсе ачыла. 1917 дә үз ихтыяры б-н тарала.

Әд. к. «*Казанда православие динендәге рус хатын-кызлары җәмгыяте*».

*И.Е.Алексеев.*

**КАЗАНДА́ О́ПЕРА СЕЗОННАРЫ́**, опера труппасының 1874–1929 елларда даими формалашкан, тулы театр сезоны яисә ярты сезон дәвамында уйналган спектакльләре. 1874 кә кадәр Казанда опера спектакльләре гастрольдә йөрүче итальян труппалары яисә аерым солистларны чакырып эпизодик төстә һәм өлешләп (хор күренешләрен төшереп калдырып) драма труппалары көче б-н куела. 1874 тә антрепренёр П.М.*Медведев* үз хисабына беренче тапкыр солистлар, хор һәм оркестр б-н опера труппасының тулы составын оештыра. 1874 нең 26 августында М.И.Глинканың «Патша хакына корбан китү» («Жизнь за царя») операсының беренче тулы составтагы спектакле куела. Опера партияләрен Ф.К.Львов (Сусанин), З.А.Рунич-Давыдова (Антонида), К.А.Алелеков (Собинин) башкаралар; Ф.Вальнер дирижёрлык итә. Сезон дәвамында А.Н.Верстовскийның «Аскольд кабере» («Аскольдова могила»), А.С.Даргомыжскийның «Су кызы» («Русалка»), Ш.Гуноның «Фауст»ы, Д.Вердиның «Трубадур» опералары куела. 1917 гә кадәр Казан шәһәре театры сәхнәләрендә опера труппасы көче б-н рус һәм чит ил композиторларының 130 дан артык операсы куела. Иң яхшы солистлар буларак танылган җырчылар З.И.Эйбоженко, Э.Ф.Боброва-Пфейфер, А.П.Ухтомская-Баронелли, Е.П.Кадмина, А.Фострем, А.Верни, А.П.Боначич, Ю.Ф.Закржевский, И.В.Тартаков, С.К.Ильяшевич, А.М.Давыдов, М.К.Максаков, А.И.Мозжухин, Д.Х.Южин, Д.А.Усатов, Л.Г.Яковлев, Н.Н.Фигнер, Ф.И.Шаляпин чыгыш ясыйлар. Спектакльләрдә У.И.Авранек, В.И.Сук, И.О.Палицын, А.П.Асланов, Л.П.Штейнберг, М.М.Голинкин, А.А.Эйхенвальд, А.А.Орлов-Соколовский, Я.А.Позен дирижёрлык итә; Н.В.Унковский, Я.М.Любин, Н.Н.Фигнер, А.М.Давыдов антрепризага иганә ярдәме күрсәтәләр; режиссёрлык эше б-н Н.Н.Боголюбов, Н.А.Шухмин, Я.В.Гельрот шөгыльләнә. Күп кенә спектакльләргә махсус программалар чыгарыла, ш.и. татар телендә дә; аларда операның эчтәлеге генә түгел, аның куелу тарихы, композиторлар турында кыскача мәгълүматлар бирелә. 1901 нең җәендә Мәскәүдә Казан опера труппасының гастрольләре зур уңыш б-н уза. 1917 дән опера спектакльләре тулы театр сезонында үткәрелә башлый, 1919–22 дә опера театры «*үрнәк театрлар*» исәбенә керә. 1923–29 да матди мөмкинлек булмау сәбәпле, Казанда опера сезоны очраклы рәвештә генә үткәрелә.

*Әд.:* К а н т о р Г.М. Музыкальный театр в Казани XIX — начала XX в. К., 1997; Б л а г о в Ю.А. «... получил прозвище Казанский». К., 2001; ш у л у к. Казанская антреприза Собольщикова-Самарина. К., 2004.

*Ю.А.Благов.*

**КАЗАНДА́ ПРАВОСЛА́ВИЕ ДИНЕНДӘГЕ́ РУС ХАТЫ́Н-КЫЗЛАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, 20 нче еллар башында Казанда иҗтимагый хәйрия җәмгыяте, карагруһчыларның «Рус җыены» («Русское собрание») оешмасының Казан бүлекчәсе тырышлыгы б-н «Рус хатын-кызлары берлеге» («Союз русских женщин», С.-Петербург) дигән уң монархик сәяси берләшмә үрнәгендә оештырыла. Җәмгыятьнең әгъза-оештыручылары — В.С.Булыгина, Е.В.Семёнова, Л.Л.Соловьёва, М.П.Перова, К.В.Черепанова һ.б. Устав (1908) нигезендә оешманың максаты Казандагы православие рус хатын-кызларын җәмгыятьтә православие карашларында тәрбияләү, патриотизмны үстерү һәм рус халкының әхлакый нигезләрен ныгыту өчен берләштерү була. Оешма мәктәпләр, ашханә, ятимханә, уку өйләре ачу, әхлакый-патриотик эчтәлектәге китап һәм брошюралар тарату, укулар, әңгәмәләр һәм кичәләр оештыру, мохтаҗларга ярдәм итү хокукларына ия була. Әгъза булып бары тик православиеле рус хатын-кызлары гына керә, ә ир-атлар ярышучы әгъзалар гына (тавыш бирү хокукыннан башка) булып саналалар. Җәмгыять б-н башында рәис торган ком-т җитәкчелек итә (төрле елларда рәисләр — М.М.Соколова, В.С.Булыгина, О.Н.Терновская). Оешма акчасына Казанда караучысыз калган балалар өчен ятимханә ачыла, аларны өс һәм аяк киеме тегү, ювелирлык һөнәрләренә өйрәтү өчен остаханәләргә урнаштыралар. Җәмгыятькә *А.Н.Боратынский*, Н.А.Ильяшенко, И.С.Перов, И.И.Восторгов һ.б. матди ярдәм күрсәтәләр. Җәмгыять әгъзалары спектакльләр һ.б. агарту-хәйрия эшләре оештыралар; 1912 дә болгар һәм серб армияләренә күп кенә әйберләр җибәрәләр. Беренче бөтендөнья сугышы елларында җәмгыять Россия солдатлары өчен акча җыюда актив катнаша. 1917 дә үз ихтыяры б-н тарала.

*Әд.:* А л е к с е е в И.Е. Черная сотня в Казанской губернии. К., 2001.

*И.Е.Алексеев.*

**КАЗАНДА́ СӘНӘГА́ТЬ КҮРГӘЗМӘЛӘРЕ́**, 19 йөзнең 2 нче яртысында таралыш алалар. Тәүгеләренең берсе — 1886 елдагы һөнәрчелек һәм а.х. күргәзмәсе, анда экспозиция бүлекләре өязләргә багышлана. 1890 да Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсе була, аның бүлекләре төбәкләр (Себер-Урал, Азия, Әстерхан, Казан һ.б.), продукция җитештерү рәвеше (фабрика-заводлар, сәнәгать-вак һөнәрчелек, сәнгать, а.х., фотография) буенча оештырыла. Күргәзмә комплексы Николай мәйданында (хәзерге Ленин бакчасы) төзелә (арх. М.Н.Литвинов). Ул эклектика стилендә халык төзү сәнгате һәм Ренессанс архитектурасы мотивлары катнашында корылган берничә бер катлы агач павильоннан гыйбарәт була. 1909 ның җәендә *Казан халыкара күргәзмәсе* уздырыла.

*Әд.:* Казанская ремесленная и сельскохозяйственная выставка 1886 г. К., 1886; Каталог Казанской научно-промышленной выставки. К., 1890; Заключительный отчёт Казанской губернской земской управы по устройству Казанской Международной выставки 1909 года. К., 1915.

*Г.Н.Айдарова.*

**КАЗАНДА́ ТАТА́Р БИСТӘСЕ́**, к. *Иске Татар бистәсе*.

**КАЗАНДА́ ТӘХЕТ́ ЧУАЛЫШЫ́** (1545–46), Казан аксөякләре вәкилләренең *Сафагәрәй ханны* тәхеттән бәреп төшерүе һәм күпләгән Казан кешеләренең Мәскәүгә, Нугай Урдасына качып китүе. Аксөякләрнең баш күтәргән вәкилләре һәм шәһәр халкы 1546 елда Сафагәрәйне яңадан бәреп төшерәләр, аңа якын Кырым тарафдарларының шактый өлеше юк ителә. Вакытлы хөкүмәтне күтәрелешне оештыручылар — өлешчә Мәскәү яклы бәкләр *Чура бәк*, Кадыш, Баубәк җитәклиләр. Алар тәхеткә Мәскәү тарафдары Шаһгалине утырталар һәм аның хакимиятен чикләүче кайбер таләпләр куялар. Мәсәлән, русларның Казандагы даими илчеләре Кремль эчендә түгел, ә посадта яшәргә тиеш булалар. 13 июньдә Шаһгали Казанга килә, ләкин бер айдан соң качарга мәҗбүр була, Сафагәрәй яңадан тәхеткә утыра. Күтәрелеш җитәкчеләрен җәзалый, Казандагы 75 аксөяк, ш.и. Колыш, Терегол, Борнаш бәкләр Иван IV кә хезмәткә күчәләр. Күтәрелеш нәтиҗәсендә Казан ханлыгында хакимият йомшый һәм Мәскәү — Казан каршылыклары кискенләшә.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗАНДА́ ТЕА́ТР БЕЛЕМЕ́**. 20 йөз башына кадәр проф. театр актёрлары тарафыннан оештырылган хосусый дәресләр, курслар, мәктәпләр сыйфатында яши. Дәресләр һәр укучы б-н аерым уздырыла, аларда сәнгать әсәрләрен халык алдында башкару күнекмәләренә өйрәтү һәм төшендерү күздә тотыла; драма сәнгатенең танылган педагоглары арасында — М.Н.Белина-Белинович, вокаль сәнгатьтә — Л.Н.Люценко, Н.А.Преображенский, Ю.Ф.Закржевский, Е.Г.Ковелькова; балет сәнгатендә — Ф.Ф.Виттиг. 1906 елда Император Рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге тарафыннан оештырылган музыка уч-щесе каршында драма классы ачыла, аның б-н Император театрының элекке актрисасы Н.В.*Пальчикова* җитәкчелек итә. Сөйләм техникасы (Н.С.Кривоносов), театр тарихы (Б.В.Варнеке), драма сәнгате укытыла. Уку 3 еллык була, һәр уку елы сәнгатьле уку һәм актёрлык осталыгы буенча халык алдында имтихан тоту б-н тәмамлана; А.Н.Островский («Бәхетле көн» — «Счастливый день», «Гел май да бал түгел» — «Не всё коту масленица», «Хезмәт икмәге» — «Трудовой хлеб», «Читтән кергән байлык файда китерми» — «Чужое добро впрок не идёт», «Гаепсездән гаеплеләр» — «Без вины виноватые»), Ж.Б.Мольер («Жорж Данден»), Э.Золя («Жак д'Амур») һ.б.ның пьесалары буенча спектакльләр күрсәтелә. Чыгарылыш укучылары арасында А.И.Баева, К.Н.Яхонтов (соңрак Казан Зур драма театрында эшлиләр) бар. Н.В.Пальчикова вафат булганнан соң, музыка уч-щесе каршындагы драма классы ябыла. 1918 дә — Грузинская урамындагы (хәзер Карл Маркс) ирекле сәнгатьләр студиясе каршында, 1919 да Кызылармеец сарае һәм Совет Зур театры (хәзер Казан Зур драма театры) каршында драма курслары булдырыла. Алдагы елларда К.т.б. күбесенчә студияләрдә (к. *Театр студияләре*) тормышка ашырыла, аларда уку һәм иҗат эшчәнлекләре үзенчәлекле рәвештә бергә үрелеп бара. Татар театры актёрлары әзерләү өчен 1922 елда Татар театр техникумы төзелә (хәзер Казан театр уч-щесе), монда уку төгәл уйланылган система буенча проф. дәрәҗәдә алып барыла, һәм тар белгечлеккә караган фәннәрне гамәли үзләштерү дә, ш.у. тарихи-мәдәни юнәлештәге күптөрле предметларны өйрәнү дә каралган була. К.т.б.н *Казан мәдәният һәм сәнгать университеты* каршындагы Театр ин-тында да алырга мөмкин.

**КАЗАНДА́ ФӘННИ́ МЕДИЦИ́НА ҖӘМГЫЯТЬЛӘРЕ́**, ТРда медицина һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүче галимнәр, укытучылар, табибләрне берләштерәләр. Җәмгыятьләрнең максатлары: мед. теориясе һәм гамәле мәсьәләләрен карау, фәнни белемнәрне тарату һәм аны мед. гамәленә кертү, халыкка мед. хезмәте күрсәтү сыйфатын күтәрү һәм профилактик чараларда ярдәм итү, Бөтенроссия һәм Халыкара фәнни мед. җәмгыятьләре б-н бәйләнешне көйләү. 1960–70 елларда К.ф.м.җ. Бөтенсоюз мед. җәмгыятьләре, 1990 нан Бөтенроссия җәмгыятьләре ф-ллары итеп үзгәртелә. Казан табибләр җәмгыяте 1868 дә төзелә, 1877–1930 да Казан ун-ты каршында эшләгән *Табибләр җәмгыяте* 1931 дә Мед. ин-ты каршындагы Татарстан төбәк фәнни-мед. ассоциациясе итеп үзгәртелә.

1892 дә Казанда В.М.Бехтерев төзегән Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте Россиядә иң әүвәлге оештырылган җәмгыятьләрнең берсе була, ул нерв системасын өйрәнүче белгечләрне берләштерә. Анда анатомия-физиол. мәсьәләләре карала, авыруларны дәвалауның һәм аларга диагноз куюның теоретик һәм гамәли мәсьәләләре чишелеш таба, көнкүреш афәте буларак аеруча зур игътибар эчкечелеккә каршы көрәшкә бирелә. Җәмгыять нәшрият, сан. мәгърифәте эшчәнлеге һәм оештыру-методик эш алып бара, «Неврологический вестник» ж-лын нәшер итә (1893–1918, мөхәррире В.М.Бехтерев). Төрле еллардагы җәмгыять җитәкчеләре: Н.М.Попов (1893–1903), Н.А.*Миславский* (1903–05), Л.О.*Даркшевич* (1905–17), А.В.Фаворский (1917–29), Т.И.Юдин (1929–32), М.П.*Андреев* (1932–34), И.И.*Русецкий* (1934–41, 1945–64), Л.И.*Омороков* (1941–45), В.М.Андреев (1964–67), В.С.*Чудновский* (1967–73), И.Н.*Дьяконова* (1973–83), Д.Г.*Еникиев* (1983–90). 1990 елда җәмгыять ТР невропатологлары фәнни-методик җәмгыятенә (рәисе М.Ф.Исмәгыйлев) һәм ТР психиатрлар фәнни методик җәмгыятенә (рәисләре — 1990–96 да Д.Г.Еникиев, 1996–2000 Д.М.Менделеевич, 2000 нән К.К.Яхин) бүленә. Казанда 7 нче Пирогов съезды (1899), 3 нче Бөтенроссия табибләре җәмгыяте съезды (1974), Бөтенсоюз табибләр җәмгыяте идарәсе пленумы (1979), 8 нче Бөтенроссия неврологлары съезды (2004) үткәрелә, 4 тапкыр «Россиянең яшь психиатрлары мәктәбе» (1997, 2000, 2002, 2004) җыела, В.М.Бехтеревка 150 яшь тулуга багышланган Бөтенроссия конгрессы (2004) уздырыла. 2004 тә ТР Невропатологлары җәмгыятеннән ТР Табиб-нейрохирурглар ассоциациясе бүленеп чыга һәм теркәлә (70 тән артык белгеч, рәисе В.И.Данилов).

Казанда хирург табибләр җәмгыяте 1886 да төзелә, җитәкчеләре Н.Ф.Высоцкий һәм А.Н.Бекетов. 1890–1900 да программаның төп мәсьәләләре — бөердә ташлар җыелу авыруын (Л.Л.Лёвшин, Н.А.Геркен, Н.И.Студенский), эндемик зоб (Н.Ф.Высоцкий, М.Ф.Кондаратский, М.В.Казанский, В.И.Разумовский, П.И.Тихов һ.б.), актиномикоз (И.А.Праксин, В.И.Разумовский, П.И.Тихов һ.б.) авыруларын дәвалау була. Антисептика һәм асептика, хлороформлы һәм эфирлы наркоз (Ф.О.Елачич, А.А.Киттер, А.Н.Бекетов) үсеше буенча фәнни эшләргә, аерым урын анестезиясе (Н.А.Геркен, А.Н.Опохин), ш.и. аны корсак куышлыгы органнарында куллануга (А.В.Вишневский, М.П.Жаков, Л.Б.Блитштейн, П.А.Глушков һ.б.), «ОХ» Рентген нурларына, хирургиядә аларны куллануга (А.Д.Гольдгаммер, П.И.Тихов, М.А.Чалусов) зур игътибар бирелә. Хирургик тикшеренүләрең төп темалары: утлы корал зыяныннан килгән яраларны дәвалау, нейрохирургия, травматология һәм ортопедия мәсьәләләре (1918–24), аерым урын анестезиясе (1927, А.В.Вишневский), кичектергесез хирургия ярдәме күрсәтү (1932 дән, В.А.Гусынин, Г.М.Новиков, Б.Г.Герцберг, И.В.Домрачев, Н.В.Соколов, В.М.Осиповский, П.В.Кравченко, Х.З.Ахунҗанов һ.б.). 1923 тә 1 нче Идел буе табибләре съезды була. 1926 дан табиб хирургларның аерым секциясе эшли башлый (җитәкчесе В.Л.Боголюбов, 1926–32). Җәмгыятьне 1932–34 тә проф.

А.В.Вишневский, 1935–63 тә Н.В.Соколов, 1963–65 тә И.Ф.Харитонов һ.б. җитәкчеләр.

Табиб-офтальмологлар җәмгыяте 1907 дән Казан ун-ты каршындагы Табибләр җәмгыятенең күз авырулары түгәрәге буларак эшли, 1924 тән Татарстан табиб-офтальмологлары җәмгыяте секциясе, 1955 тән мөстәкыйль җәмгыять. Төрле елларда җәмгыять җитәкчеләре: А.Г.Агабабов (1907–18), В.Е.Адамюк (1918–22), В.В.Чирковский (1922–33), А.Н.Мурзин (1933–54), А.П.Нестеров (1964–73), М.Б.Вургафт (1973–86), Н.Х.Хәсәнова (1987–90) һ.б.

Акушер-гинеколог табибләр җәмгыяте 1908 дә Казан табибләр җәмгыятендәге түгәрәк буларак эшли башлый, 1923 тән җәмгыятьнең секциясе, 1935 тән Татарстан акушер-гинекологларының мөстәкыйль җәмгыяте. Төрле елларда җитәкчеләре: В.С.Груздев (1923–35), И.Ф.Козлов (1935–48), В.П.Маненков (1948–75), Л.А.Козлов (1975–77), Б.Г.Садыйков (1977–2000); 2002 дән И.Ф.Фәткуллин.

Гигиена һәм сан. табибләре җәмгыяте 1926 да төзелә. Илдә беренче башлап сан. һәм чәчәк авыруына каршы прививка ясау учреждениеләре, микробиол. лаб-яләре төзүне тәкъдим итә һәм соңрак ача (А.Н.Серебряков, 1873; Э.Ю.Витте, Н.И.Студенский, 1872; Н.В.Сорокин, 1883). Төрле елларда җитәкчеләре: В.В.Милославский (1926–61), В.П.Камчатнов (1963–88), М.М.Гыймадиев (1988–90); 1990 нан Н.Х.Әмиров.

Табиб-фтизиатрлар җәмгыяте 1931 дә оеша. 1937 дә аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә республикада туберкулёзга каршы вакцинация кертелә, шифаханәләр, диспансерлар ачыла, амбулаториядәге авыруларны антибактериаль препаратлар б-н бушлай тәэмин итү оештырыла, ш.у. туберкулёзны бетерү буенча 6 программа эшләнә һәм тормышка ашырыла. Төрле елларда җитәкчеләре: М.И.Мастбаум (1931–39), Б.П.Левенштейн (1940–49), В.Я.Садогурский (1950–55), Б.Л.Мазур (1955–60), Г.А.Смирнов (1966–92), Е.М.Галков (1993–95); 1995 тән А.А.Визель.

Татарстан балалар табибләре җәмгыяте Казан табибләр җәмгыятенең педиатрлар секциясе нигезендә 1935 тә оештырыла, 1937 дән СССР балалар табибләре җәмгыятенең Татарстан бүлеге буларак эшли, 1994 тән Россия педиатрлар берлегенең республика бүлеге. Җәмгыять җитәкчеләре: В.К.Меньшиков (1935–45), Е.М.Лепский (1945–55), Ю.В.Макаров (1955–70), К.А.Святкина (1970–80); 1980 нән С.В.Мальцев.

Патологоанатомнар җәмгыяте 1963 тә төзелә, 2004 тән Бөтенроссия патологоанатомнар җәмгыятенең Республика бүлеге. Җәмгыятьнең төрле еллардагы җитәкчеләре: Г.Г.Непряхин (1963–69), В.А.Добрынин (1969–89), Н.Ш.Шәмсетдинов (1989–2003); 2003 тән С.В.Петров.

1950–80 елларда анатомнар, гистологлар, эмбриологлар (1953), онкологлар (1955), ортопедлар, травматологлар, мәхкәмә табибләре (1957), мед. тарихчылары, (патологоанатомнар, 1963), урологлар (1967), клиника лаборантлары (1969), эндокринологлар, анестезиологлар, реаниматологлар (1970), кардиологлар (1972), ревматологлар (1984), иммунологлар, аллергологлар (1986) оешмалары барлыкка килә. 1960 та Татарстанда 77 фәнни мед. җәмгыяте эшли. 1968 дә — 26, 1972 дә — 33, 2007 дә — 40 тан артык. ТРның К.ф.м.җ. 2 меңнән артык галим, укытучылар, гамәли табибләрне берләштерә.

*Әд.:* Основные положения проекта Устава «Всероссийского общества врачей в память Н.И.Пирогова» // Казан. мед. журн. 1908. Т. 8; Груздев В.С. 60-летие Общества врачей при Казанском университете // Казан. мед. журн. 1928. Т. 1.

*А.С.Созинов, Р.Г.Исхакова.*

**КАЗАНДА́ ФӘННИ́-СӘНӘГА́ТЬ КҮРГӘЗМӘСЕ́**, 1890 елда уздырылган өлкә күргәзмәсе. *Табигыятьчеләр җәмгыяте* башлангычында оештырыла. 1888 дә ком-т төзелә, аның составына Җәмгыятьтән, земстводан һәм Казан шәһәр думасыннан вәкилләр керә; рәисе итеп — шәһәр башлыгы С.В.*Дьяченко*, аның иптәше (урынбасары) итеп — Табигыятьчеләр җәмгыяте рәисе проф. А.А.*Штукенберг*, шәрәфле секретаре итеп проф. Н.Ф.Высоцкий сайлана. Күргәзмәнең химаячесе тәхет варисы Николай Александрович




Профессор А.А. Штукенбергның Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсенең алтын медале белән бүләкләнүе турындагы таныклык. 1890. ТР Милли музее.

була. Төп бурычы — Идел-Кама төбәген төрле яклап таныту: «аның туфрагын, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын, халкының төрледән-төрле составын», авыл хуҗалыгын, фабрика-заводларын, һөнәрчелекне, кустарчылык һәм сәнгать үсешен, җәмәгать үзидарәләре эшчәнлеге нәтиҗәләрен, ш.у. Себер, Ташкент, Бохара, Хива һәм Кавказның икътисади үсеш манзарасын күрсәтү. Оештыручылар ниятләгәнчә, күргәзмә, таныл-белү шартлары тудыру б-н генә чикләнмичә, төбәкнең барлык халкы өчен файда китерергә тиеш була, чөнки халыкның иң «сыйфатлы товарлар» б-н танышуы, җитештерүчеләрнең исә үз производстволарын яхшыртуы һәм сату базарларын җәелдерү мөмкинлегенә ирешүе күздә тотыла. 1890 ның 15 маеннан 15 сентябренә кадәр уза. Күргәзмә павильоннары Николай мәйданы, «*Рус Швейцариясе*», Театр мәйданы (хәзер Ирек мәйданы), Черек күл терр-яләрендә урнаша. Күргәзмәнең фасады һәм планы шәһәр архитекторы М.Н.*Литвинов* тарафыннан эшләнә. К.ф.-с.к.ндә 2,5 меңнән артык экспонент катнаша, алар арасында төрле учреждениеләр, фирмалар вәкилләре, Әстерхан, Вятка, Екатеринбург, Мәскәү, Самара, Сембер, Саратов, Оренбург, Пермь губерналарыннан һәм Россиянең башка төбәкләреннән килгән аерым затлар, чит илләрдәге 7 шәһәрдән вәкилләр була. Күргәзмәгә 125 меңнән артык кеше килә. 12 бүлек — фән, мәктәп, мед-санитария, фабрика-заводлар, кустарлык-кәсепчелек, а.х., сәнгать, Себер, Урта Азия, Кавказ һәм читтән кертелгән әйберләр бүлекләре эшли. Фән бүлегендә археология, геология, туфрак белеме, зоология, тарих һәм этнография буенча экспонатлар куела. Казан ун-ты җәмгыятьләре һәм учреждениеләре, Урал табигыять фәннәрен сөючеләр җәмгыяте, Петр исем. Әстерхан төбәген өйрәнүчеләр җәмгыяте һ.б. бу бүлекнең экспонентлары булалар. Музейлар, фәнни җәмгыятьләр, статистика һәм земство учреждениеләре үз коллекцияләрен урнаштыралар. Мәктәп бүлеге экспозициясендә Казан, Пермь, Вятка, Түбән Новгород губерналарыннан һ.б. төбәкләрдән кителгән уку ярдәмлекләре һәм укучыларның эшләре куела. Балалар һәм мед.-сан. бүлекләрендә мәктәпкәчә тәрбия һәм медицинаның гамәли үсеше турында мәгълүмат бирелә. Фабрика-заводлар бүлегендә азык-төлек җитештерү, химия һәм җиңел сәнәгать экспонатлары өстенлек итә. 1522 бүләк, ш.и. күргәзмә химаячесенең 4 алтын медале (алар б-н С.В.Дьяченко, А.А.Штукенберг, И.И.Алафузов, бертуган Крестовниковларның сәүдә йорты бүләкләнә), ком-тның 30 зур алтын, 80 зур көмеш медальләре, Император табигыять фәннәрен сөючеләр җәмгыятенең 7 медале, Казан Император икътисадчылар җәмгыятенең — 15, Техниклар җәмгыятенең — 7, Дәүләт ат заводлары идарәсенең — 9, Рус сәнәгатенә һәм сәүдәсенә булышлык итү җәмгыятенең — 15, Рус Император бакчачылык җәмгыятенең — 3, Игенчелек һәм авыл сәнәгате департаментының 28 медале тапшырыла. Күргәзмәдән кергән гомуми табыш 86 мең сум тәшкил итә, нәтиҗәдә аны оештыруга тотылган чыгымнар каплана. Күп кенә экспонатлар Казан шәһәр музеена тапшырыла. Ш.у.к. *Сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы күргәзмәләре*.

Чыг.: Общественное значение предстоящей Казанской научно-промышленной выставки 1890 года. К., 1889; Положение и программа Казанской научно-промышленной выставки 1890 г. К., 1890; История Казани в документах и материалах. XIX век: Промышленность, торговая, финансы. К., 2005.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАЗАНДА́ ЧИТ ИЛ КОММУНИСТЛАРЫ́ ШӨГЪБӘСЕ́**, 1918–20 елларда РКП(б)ның Казан губерна ком-ты составындагы чит ил коммунистлары төркемнәре берләшмәсе. Югослав, венгр, немец, поляк һәм төрек коммунистларыннан (элеккеге хәрби әсирләрдән) тора. Төркем б-н Арнольд Гофман, Шандор Апати, Георг Гандшу һ.б. җитәкчелек итә. Чит ил хәрби әсирләре арасында . хакимиятен якларга өндәп, агитация эшләре алып бара, ике интернациональ рота оештыра, Республиканың запас армиясендәге чит ил солдатлары һәм коммунистлары арасында сәяси эш җәелдерә. Интернационалистлар Интернациональ батальон, 1 нче, 2 нче Казан совет полклары, Гинцбург исем. берләштерелгән Казан полкы һ.б. составын-

да сугышалар. РКП(б)ның Казан губерна ком-ты каршында венгр, немец, поляк һәм югослав секцияләре эшли. 500 коммунисты булган венгр секциясе иң активлардан санала. Германия һәм Австро-Венгриядәге 1918 нең ноябрендәге рев-циядән соң шөгъбә Казанда эшче һәм солдат депутатларының Австро-Венгрия советын оештыру өчен махсус комиссия төзи. Шөгъбә әгъзалары Коминтерн конгрессы эшендә катнашалар. Чит ил секцияләре тырышлыгы б-н Казанда К.Либкнехт исем. интернациональ клуб ачыла; венгр телендә «Уй элоре» («Кабат алга»), немец һәм венгр телләрендә «Коммунист» г-талары нәшер ителә. Шөгъбә 1920 дә таратыла.

*Әд.:* Субаев Н.А. Иностранные секции Казанского губкома РКП(б) в 1920-м году // Вопросы истории Татарии. К., 1962; шул ук. Иностранные интернационалисты в Татарии (1918–1920 гг.) // Интернационалисты в боях за власть Советов. М., 1965.

**КАЗАНДА́ 1917 ЕЛГЫ́ ОКТЯ́БРЬ КОРАЛЛЫ́ БАШ КҮТӘРЕЛЕШЕ́,** эшчеләр һәм солдатларның массакүләм кузгалышы. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында һәм 1917 елгы Февр. рев-циясе барышында социаль-икътисади, сәяси һәм милли каршылыкларның кискенләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Аерым сул радикаль офицерлар һәм Казан хәрби округы командованиесе арасындагы конфликттан башлана. Коткы таратучыларның берсе Саранскида 1917 нең 28 июнендә 101 нче пехота запас полкының полк ком-ты тарафыннан кулга алынган һәм Казанга хөкем ителергә озатылган подпоручик Гроздов була. Ул сак астыннан кача һәм Арча кырында урнашкан артиллерия казармаларында яшеренеп яши. Үзен солдатларга сугышны дәвам итүнең катгый дошманы дип белдерә. 12 октябрьдә аның башлангычында гарнизонда күп кешелек митинг җыела, анда Вакытлы хөкүмәткә буйсынмаска һәм кичекмәстән Россия һәм Германия арасында солых төзергә чакырган өндәмәләр яңгырый. Казан хәрби округы командованиесе Гроздовны кулга алырга әмер бирә. 2 нче артиллерия бригадасы солдатлары моны гамәлгә ашыруга комачаулыйлар; 21 октябрьдә алар бригада командиры Седлецкийны сак астына алалар. Казан хәрби округы командующие полковник М.Н.Архипов йорты янына П.Поплавский җитәкчелегендәге Финляндия артиллерия бригадасының 6 нчы батареясы һәм берничә юнкерлар бригадасы китерелә. Округ командующие әмере б-н шул көнне кичен 2 нче артиллерия бригадасын коралсызландыру омтылышы уңышсыз тәгамәлләнә. Нәтиҗәдә, 20–21 октябрьдә юнкерлар һәм солдатлар арасында киеренке мөнәсәбәтләр урнаша. 22 октябрьдә хөкем сөргән вазгыятьне тикшерү өчен Казан хәрби округының Революцион штабы (к. *Социалистик оешмалар берлеге*) башлангычында Вакытлы хөкүмәт комиссары капитан Е.П.*Калинин* җитәкчелегендә гарнизон җыены чакырыла (хәрби табиб Израилович рәислек итә). Җыенда чыгыш ясаган Н.Е.*Ершов*, К.Я.*Грасис*, барлык бәлаләрдә дә хәрби округ командующиен, округ хәрби комиссарын һәм гарнизон башлыгын гаепләп, аларны аңлатма бирү өчен чакырырга тәкъдим итәләр. Ләкин гаепләнүчеләрнең берсе дә җыенга килми. Җыен хакимиятне һәм коралларны Эшче һәм солдат депутатлары Советына тапшыру, юнкерлар б-н килгән броневикларны фронтка җибәрү таләбе куелган резолюция кабул итә. «Буржуазия хакимиятенә һәм революцион штабка ышаныч күрсәтмәскә» дигән сүзләр аерым пункт буларак ассызыклана. 23 октябрь кичендә Советның гомуми җыелышы була, анда 1899 да хәрби хезмәткә чакырылган солдатларны тарату төп мәсьәлә буларак карала. Хәрби министрлык б-н киңәшкәннән соң Казан хәрби командованиесенә солдатларны таратуның катгый тыелуы турындагы күрсәтмә килә. Карар Советка җиткерелә. Җыелышта Ершов хакимиятне Вакытлы хөкүмәт түгел, Советлар гәүдәләндерә, зарурият туган очракта алар башка елларда чакырылган солдатларны да тарата-чаклар дип белдерә. Яклап бирелгән 230 тавыш б-н резолюция кабул ителә (социалист-революционерлар һәм меньшевиклар партияләре вәкилләре протест йөзеннән җыелыштан чыгып китәләр). 24 октябрьгә каршы төндә хәрби округ командующие һәм хәрби округ комиссары катнашындагы Революцион штаб Грасисны һәм Ершовны кулга алу турында карар кабул итә. Грасисның кулга алынуы турында белгәч, Ершов Каргополь казармаларында 2 нче дивизион тупчылары арасында яшеренә һәм барлык батареяларны митингка җыя. П.Поплавскийга митингта катнашучыларны куып таратырга һәм Ершовны кулга алырга әмер бирелә. Моңа җавап йөзеннән Поплавскийның үзен һәм 6 нчы батареяның барлык офицерларын кулга алу турында карар кабул ителә. Шулвакыт Поплавский чакырткан броневик килеп җитә һәм һавага ата. Солдатлар таралалар. Тиздән бәрелеш урынына юнкерлар взводы һәм 6 нчы батарея тупчылары килә. Нәтиҗәдә, 2 нче дивизион тулысынча коралсызландырыла. Ершов, солдат киемнәрен киеп, 2 нче артбригаданың Арча кырында урнашкан 1 нче дивизионына китә. Анда ул митингка җыелучыларга 2 нче дивизиондагы вакыйгалар турында сөйли (соңгы хәбәрләрне башка хәрби частьләргә дә җиткерү турында карар чыгарыла). Хәрби округ командующие М.Н.Архипов һәм Вакытлы хөкүмәтнең хәрби округ комиссары Калинин Ершовны тотып бирүне таләп итәләр. Солдатлар баш тарталар. Атышлар башлана, алар 25 октябрьгә каршы төндә тына. Юнкерлар чигенергә мәҗбүр булалар. 25 октябрь төнендә шәһәрдә атышлар сирәгәя, иртән баш күтәргән частьләр шәһәрне тупка тота башлыйлар. Казан заводлары эшчеләре солдатларга теләктәшлек белдерәләр; 25 октябрьдә алар тупчыларны коралсызландыруга протест йөзеннән гомуми забастовка игълан итәләр. Хакимиятләр 24 октябрь иртәсендә үк шәһәр һәм аның бистәләрен камалыш хәлендә дип белдергән булалар. 25 октябрьдә Калинин Петроградка: «Казанда икенче көн буе хөкүмәткә тугры гаскәрләр һәм фетнәчел частьләр арасында урам сугышы бара», — дип хәбәр җибәрә. Шул ук көнне Совет тарафдарларының хәрби округ командованиесе б-н сөйләшүләре булып уза. Баш күтәрүчеләр вәкилләре барысына да коралсызланырга, коралларны Советка тапшырырга тәкъдим итәләр. Командующий баш тарта. Шул ук вакытта Ершов тарафыннан 240 нчы запас полк каршында оештырылган революцион штаб үзенең эшчәнлеген башлый. 25 октябрьдә эшче отрядлары ярдәмендә солдатлар Казан хәрби округы командующие йортын басып алалар; Казан Кремлендәге Вакытлы хөкүмәткә тугры гаскәрләрне һәм юнкерларны камыйлар. 26 октябрьдә, Петроградтан Вакытлы хөкүмәтнең бәреп төшерелүе турында телеграмма алынгач, Казандагы хөкүмәт гаскәрләре корал ташлый.

Вакыйгаларның дәвам итүенә бәйле рәвештә гаеплеләрне эзләү башлана. 26 октябрьдә иртәнге сәгать 2 дә башка хәрби частьләрнең вәкилләре катнашында 240 нчы пехота запас полкының полк һәм роталар ком-тларының берләштерелгән җыелышы була; анда соңгы көннәрдәге вакыйгаларны тикшерү комиссиясе оештыру турында карар кабул ителә. 30 октябрьдә А.И.*Карпов* рәислегендә большевикларның Казан ком-ты утырышы булып уза. А.И.Карпов: «...соңгы көннәрдәге вакыйгалар түнтәрелеш (Петроградта) турындагы хәбәрләр алынганчы комитет җитәкчелегендә түгел, аның аерым әгъзалары җитәкчелегендә, сәяси җирлектә түгел, бәлки хәрби җирлектә булып узды», — дип билгеләп үтә. Ком-т әгъзаларының күпчелеге бу фикер б-н килешәләр, Г.Ш.*Ольkеницкий* һәм Грасис каршы чыгалар. 29 октябрьдә Ершов:«Көрәш буржуазиянең провокаторлык коткысы белән башланды. Беренче булып солдат каны акты, сугышка без түгел, безне тартып керттеләр, һәм без аны кабул иттек», — дип язып чыга. Алга таба Поплавскийны мәхкәмә утырышында тикшерәләр, аны 24–25 октябрь вакыйгаларында гаепле дип табалар. 26 октябрь кичендә полклар, роталар һәм фабрика-заводлар ком-тлары вәкилләре катнашында Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советының тантаналы утырышы ачыла. Ершов кораллы баш күтәрелеш турында доклад б-н чыгыш ясый. Аның тәкъдиме б-н Грасис җитәкчелегендә *Казан революцион штабын* төзү турында карар кабул ителә. Штаб составына ш.у. Ершов, Масальский, Фролов, Ольkеницкий, Конюшкин, Милх, Кортов, Казакевич, Венецианов, Бадаев, Карпов, Жестянников, Пономарёв, Гинсбург (арадан 9 кеше — хәрбиләр), хәрби частьләрдән тагын 4 кеше һәм дары з-дыннан 1 кеше кертелә. Гарнизонның хәрби ахуны Г.Баһаветдинов революцион ком-т составына милли оешмалар вәкилләрен кертергә тәкъдим итә (Хәрби Шурадан, Мөселман социалистлар ком-тыннан Я.Ж.Чанышев, К.Л.Якубов, М.М.Вахитов һ.б. керә). Штаб округ гаскәрләре командующие сараенда эшли. Революцион штаб гражданнарга Петроградта һәм Казанда кораллы баш күтәрелешнең җиңүе һәм сов. хакимияте урнашуы турындагы өндәмә б-н мөрәҗәгать итә. Тынычлык саклау һәм яңа хакимияткә теләктәшлек күрсәтү тәкъдиме алга сөрелә. Шулай ук округ съезды чакырылганчы хәр-

би округның вакытлы командующие — Ершов, аның ярдәмчесе — подполковник Руанет, милиция башлыгы булып Бухов сайлануы турында хәбәр җиткерелә. Шул ук вакытта башта ук революцион штабта үзләренең шәхси хакимиятләрен урнаштырырга омтылган Ершов б-н Грасис тарафдарлары, ш.у. штабның башка әгъзалары арасында көрәш бара; Грасис һәм Вахитов арасында аеруча кискен бәрелешләр була. *Казан хәрби округы комитеты* һәм губерна крәстияннәр Советы хакимиятне үзләштерүгә каршы чыгалар. 4 ноябрьдә Советның *Дворяннар җыены бинасында* булып узган берләштерелгән утырышында Революцион штаб хакимиятне Эшче һәм солдат депутатлары Советына тапшыра. Тиздән узган округ съездында Ершов хакимияттән читләштерелә. Казанда хакимият өчен әчке көрәш бару сәбәпле, Ершовка каршы булган губерна крәстияннәр Советы Казандагы вакыйгалар турында өязләргә һәм волостьларга хәбәр җибәрергә ашыкмый. 4 ноябрьдә, хакимият Эшче һәм солдат депутатлары Советы кулына тәмам күчкәч кенә, Крәстияннәр Советы өязләрдә һәм волостьларда яңа хакимият органнарын оештыру эшчәнлеген җәелдерә. 6 ноябрьдә, ягъни Казандагы кораллы баш күтәрелештән соң 8 көн узгач, өязләргә Казанда хакимият алмашу турындагы хәбәр җиткерелә.

Чыг.: Татария в борьбе за победу пролетарской революции: Сб.док. и материалов. К., 1957; Документы по истории Октября в Татарии (март 1917 – март 1918 гг.). К., 1973.

*Әд.:* Ионенко И.М., Тагиров И.Р. Октябрь в Казани. К., 1967; Валеев Р.К. Революционная борьба в Среднем Поволжье (июль–октябрь 1917 года). К., 1972; Ионенко И.М. Солдаты тыловых гарнизонов в борьбе за власть Советов (по материалам Поволжья и Урала). К., 1976; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*И.Р.Таһиров.*

**КАЗАНДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ ДӘҮЛӘ́Т СӘНГА́ТЬ ҺӘМ ФӘН КҮРГӘЗМӘСЕ́**, 1920 елның 28 маенда Казан дәүләт сәнгать остаханәләре бинасында ачыла. Запастагы армиянең сәяси бүлеге, Казан губернасы халык мәгарифе бүлеге, Үзәк сынлы сәнгать бүлеге һәм Бөтенроссия музейлар эшләре коллегиясе ярдәмендә Бөтенроссия музейлар эшләре, сәнгать истәлекләре һәм борынгы әйберләр коллегиясенең Казан бүлекчәсе тарафыннан оештырыла. Күргәзмә Казанның мәдәни тормышында күренекле вакыйгага әйләнә, ТАССР Үзәк музееның (хәзерге ТР Милли музее) сәнгать тупланмасын оештыру зур әһәмияткә ия була. Анда 2 меңгә якын эшләнмә, ш.и. Е.Д.Мясниковның Казанга һәм Чистайга бүләк итеп биргән тупланмасыннан (нәкышь, гамәли-бизәлеш сәнгате, этнография әйберләре һ.б.) сәнгать әсәрләре куела. РСФСР Дәүләт музее фонды үзенең 25 еллыгын билгеләп үтүче ТАССР Үзәк музеена 100 дән артык әсәр җибәрә. Күргәзмә ком-ты мөрәҗәгатендә: «Казанда кызылармиячеләр һәм эшчеләр өчен ачылучы күргәзмә иң реалистик әсәрләрдән алып, яшь рәссамнарның өр-яңа тәҗрибәләренә кадәрге төрле юнәлештәге сынлы сәнгать әсәрләрен хезмәт ияләренә күрсәтүне максат итеп куйды. Күргәзмә материалларының байлыгы һәм төрлелеге буенча Казан төбәгендә беренче урынны алып тора һәм, һичшиксез, халык өчен киң агарту һәм тәрбияви мәгънәгә ия», — диелә. Төбәк сәнгате б-н бергә 19 йөз ахыры — 20 йөз башы Мәскәү һәм Петроград рәссамнарының әсәрләре, ш.и. «Сәнгать дөньясы» сәнгать берләшмәсе осталарының (Л.С.Бакст, А.Н.Бенуа, К.Ф.Богаевский һ.б.), Рус рәссамнары берлеге әгъзалары (К.А.Коровин, С.Т.Конёнков, С.В.Малютин һ.б.) һәм нәкышьнең авангард агымнары әгъзалары (Н.С.Гончарова, П.П.Кончаловский, А.В.Лентулов, М.Ф.Ларионов, О.В.Розанова, А.М.Родченко һ.б.) картиналары тәкъдим ителә. Классик рус һәм Көнбатыш Европа сәнгатен Казан губернасының музейлар эшләре, сәнгать истәлекләре һәм борынгы әйберләрне саклау бүлекчәсе музее фонды тупланмалары: 17 йөзнең голланд, фламанд, итальян нәкышь мәктәбе, шәхси тупланмалардагы 19 йөз нәкыше җыелмасы (А.М.Миронова, А.Н.Тришевский, А.Д.Иенидуния, Б.Залкинд) һәм Казан дәүләт сәнгать остаханәләре музее әсәрләрен тәкъдим итә. Күргәзмәгә Саксония, Севр, Вена, Берлин з-длары фарфоры һәм ш.у. Император з-дында, Гарднер, Попов, Софонов, Тереховлар һәм Киселёв, Фомин, Храпунов-Новый ф-каларында җитештерелгән рус фарфоры үрнәкләре куела. Экспозициядә борынгы гобеленнар, бронза, декоратив тукымалар, келәмнәр бизи. Анда Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте, география һәм этнография кабинетлары тупланмалары, ш.и. нефрит, фил сөягеннән эшләнмәләр, кызыл лак б-н капланган 18 йөз Кытай әйберләре, Идел буе халыклары тукымалары, чигүләре, басма бизәкләренең зур җыелмасы куела. Күргәзмәдә катнашкан Казан рәссамнары арасында П.П.Беньков, В.С.Богатырёв, В.Э.Вильковиская, Г.А.Козлов, А.М.Кокорев, Г.А.Медведев, А.Г.Платунова, П.А.Радимов, В.К.Тимофеев, Н.И.Фешин кебек зур осталар була. Күргәзмә эшләгән вакытта сәнгатьнең әһәмиятле мәсьәләләренә багышланган диспутлар, җирле шагыйрьләр катнашында шигъри кичәләре үткәрелә. В.Т.Дитякин, П.М.Дульский, А.М.Миронов, А.Тришевский, Б.Ф.Адлерның сәнгать белеме турындагы мәкаләләре кергән күргәзмә каталогы басылып чыга.

*Әд.:* Денникe Б.П. Художественная выставка 1920 года в Казани // Казан. музейный вестн. 1920. № 5–6; Первая Государственная выставка искусств и науки в Казани. К., 1920.

*Е.П.Ключевская.*

**КАЗАНДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ ИР БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ**, 1788 елга кадәр Казан гимназиясе, 1835 кә кадәр Император Казан гимназиясе. Сенатның 1758 ел 21 июль фәрманы нигезендә ачыла, Россиядә Мәскәү һәм С.-Петербург гимназияләреннән соң өченче гимназия була. 1774 тә гимназистлар һәм укытучылар Казанда Е.И.Пугачёв гаскәренә каршы урам сугышларында катнашалар, 6 гимназист һәм 2 укытучы һәлак була. К.Б.и.б.г. 1785 нең 27 августына кадәр Мәскәү ун-ты карамагында. 1788 дә *Казан әсасый халык училищесе* ачылу һәм финанслау туктатылу сәбәпле ябыла. Император Павел I нең 1797 ел 31 октябрь Фәрманы б-н кабаттан ачыла; 1798 дә махсус аның өчен устав раслана; укулар 1799 да башлана. 1804 тә гимназия җирлегендә *Казан университеты* ачыла (1835 кә кадәр гимназия аның структур бүлекчәсен тәшкил итә). 1835/36 уку елыннан 1828 дә чыккан гадәти гимназияләр Уставына күчерелә. 1769 да Казан гимназиясендә, Россия уку йортларында беренче булып, татар телен укыту кертелә. 1824 кә кадәр аны Сәгыйть, Ибраһим, Исхак *Хәлфиннәр*, соңрак М.*Мәхмутов* укыта. 19 йөзнең 1 нче яртысында башка көнчыгыш телләре дә укытыла: гарәп, фарсы, монгол, әрмән; күп кенә укучылар Казан ун-тының *Шәрекъ бүлегенә* укырга керәләр. Шәрекъ бүлеген Петербург ун-тына күчерү сәбәпле, 1857 дә көнчыгыш телләрен укыту туктатыла.

Гимназияне 5 меңнән артык кеше тәмамлый. Алар арасында — күп кенә атаклы галимнәр һәм мәдәният эшлеклеләре: Г.Р.*Державин* (беренче чыгарылышта), С.Т.*Аксаков*, Н.И.*Лобачевский*, Д.*Банзаров*, А.М.*Бутлеров*, А.В.*Попов*, В.И.*Тимьянский*, К.К.*Фойгт*, А.Е.*Арбузов*, Ә.Ә.*Ваһапов*, С.Ш.*Алкин* һ.б.

Башта гимназия — Кольцов йортында (урыны билгеле түгел), 1762 дән Грузинский урамында (хәзерге К.Маркс урамы) урнаша. 1774 тә, Е.И.Пугачёвның Казанны алуы вакытында, биналарны янгын юкка чыгара. Зур булмаган таш флигель сакланып калган, ул арх. В.И.*Кафтырев* проекты буенча төзелгән дип күздә тотыла (хәзер *Бөтентатар иҗтимагый үзәге* бинасы, архит-ра истәлеге). 1775 тән 1788 дә ябылганга кадәр Покровский урамындагы үз бинасында була. 1798 дә кенәз Тенишевтан сатып алынган йортны



Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе бинасы. 1820 еллар. В.С.Турин офорты.



Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе бинасы. 20 йөз башы фоторәсеме.

били. Шунда ук 1804 тән университет та урнаша, ә гимназия 1807 дә Покровский урамындагы Х.Л.Молоствовтан сатып алынган йортка күчерелә, 1918 дә ябылганга кадәр шунда була. Казан гимназиясенең бинасы 1788 дә арх. М.Е.Емельянов проекты буенча төзелә, 1811 дә архитекторлар В.А.Смирнов һәм Я.М.Шелковников проектлары буенча реконструкцияләнә. Алты колонналы коринф стилендәге портик, терәк балкон өстәп төзелә, йортның урта өлеше зал урнаштыру өчен тагын бер катка күтәртелә һәм гөмбәз б-н каплана. 1932 дән биредә *Казан техник университетының* 1 нче бинасы эшләп килә. 1939 да архитекторлар Ә.Һ.Бикчәнтәев һәм В.А.Дубравин проекты буенча балконлы портиксыз һәм гөмбәзсез генә итеп реконструкцияләнә. Реконструкция нәтиҗәсендә урта өлештә — парадный баскыч һәм актлар залы, ә ян-яктагы канатларында — коридорның ике ягында уку аудиторияләре урнаштыру хисабына, бина симметрияле рәвештә киңәя. Төп фасад алты колонналы үзәк портик һәм Коринфский ордерының 6 өччирекле колонналары булган ян ризалитлары б-н бүлгәләнгән. Фасадны бизәүдә классицизм архит-расы элементлары (пилястралар, медальоннар һ.б.) кулланыла. Архит-ра истәлеге.

*Әд.:* Владимиров В.В. Историческая записка о Первой Казанской гимназии: В 3 ч. К., 1867–68; Артемьев А. Казанская гимназия в XVIII столетии. СПб., 1874; Нагуевский Д.И. Казанская гимназия накануне основания Казанского университета (1804–1805). К., 1900; Горталов Н.К. Из прошлого Казанской Первой гимназии. К., 1910; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Е.В.Липаков, Х.Г.Надырова.*

**КАЗАНДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ ПЕДАГО́ГИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, к. *Казан педагогия көллияте.*

**КАЗАНДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ РЕА́ЛЬ УЧИ́ЛИЩЕ**, табигыять-техник юнәлешле гомуми урта уку йорты (к. *Реаль училищеләр*). Өч сыйныфлы уку йорты буларак, 1875 елда ачыла. Беренче чыгарылышы 1879 да була. Халык мәгарифе министрлыгы карамагында була, әмма Казан шәһәре бюджетыннан финанслана. Башлангыч белемле малайлар кабул ителә, уку срогы 6–7 ел була. Алты классны тәмамлаучылар техник һәм махсус югары уку йортларына, ә җиденчедән соң ун-тның физика-матем. һәм мед. ф-тларына керергә хокуклы булалар. 1881 дә хәзерлек классы ачыла. Училищене 2 меңнән артык студент тәмамлый. Ул 1879 дан реаль уч-ще укытучысы Х.Г.*Пашковский* проекты буенча төзелгән үз бинасында урнаша (хәзерге вакытта — Казан (Идел буе) федераль ун-тының уку бинасы). Беренче директоры И.А.*Износков* була (1875–1909). Тәмамлаучылар арасында М.*Вахитов*, В.М.*Молотов*, В.А.*Тихомирнов* бар.

**КАЗАНДАГЫ́ ИКЕНЧЕ́ ИР БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ**, 1835 елның 17 маенда *Казан әсасый халык училищесе* җирлегендә ачыла. Укучылар арасында вак чиновниклар, дин эшлеклеләре, шәһәрнең төрле катлау балалары өстенлек итә. Укыту процессы шактый югары дәрәҗәдә була, Казан ун-ты профессорлары укыта. 1850–70 елларда укыту пед. юнәлештә алып барыла, гимназияне тәмамлаучыларның күбесе өяз уч-щеләрендә укыта. 1918 дә гимназия урта мәктәп итеп үзгәртелә. Гимназияне тәмамлаучылар арасында — филолог Н.Н.*Булич*, зоологлар Н.П.*Вагнер*, Н.П.*Мельников*, химик А.М.*Зайцев*, медиклар А.Н.*Казимбәк*, И.В.*Домрачев*, тарихчылар Н.П.*Лихачев*, медик һәм Казан шәһәр башлыгы Э.П.Янишевский, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Н.Я.*Агафонов*, төбәкне өйрәнүче һәм халык мәгарифе эшлеклесе И.А.*Износков*, хокук белгече һәм сәясәт эшлеклесе Г.Ф.*Шершеневич*, татар мәгарифе эшлеклесе Ш.*Әхмәров*, революционер-большевиклар В.В.*Адоратский*, Н.Э.*Бауман*. Гимназияне барлыгы 4 меңнән артык кеше тәмамлый.



Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе.
1870 еллар башы фоторәсеме.

Беренче вакытта элекке халык уч-щесе бинасында урнашкан була. 1838–40 та Болак яры буенда арх. И.П.Бессонов проекты буенча соңгы классицизм стилендә яңа бина төзелә. Хәзерге вакытта ул ике катлы, почмаклары түгәрәкләнгән турыпочмаклы бина, класслары яктыртылган озын зал буенча бер яклап урнашкан, бу зал 3 ишегалды чыгынтысын һәм өстәмә ишекләрне баскычлар б-н тоташтыра. Бинаның уртасында, киң фронтонлы төп фасадта ризалит б-н аерымланган урында өч өлешле баскычлы төп керү урыны һәм вестибюле урнашкан. Фасадтагы башка баскычлар таррак ризалитлы, аларның бизәлешендә пилястралар һәм өзелгән фронтон кулланыла.

Үзәк ризалит пилястралар, яссы аркатура һәм тәрәзә асты филёнкалары б-н бизәлгән. Ризалитлар арасындагы беренче кат стеналары рустлар б-н бизәлгән. 1874 тә бинаның сулъяк ягына арх. В.К.Бечко-Друзин проекты буенча ике катлы чиркәүле бина өстәп төзелә. Беренче каттагы бүлмәләр һәм икенче катта урнашкан чиркәү гимназиянең төп бинасы класслары б-н коридорлар аша тоташкан. Болак ягына караган турыпочмаклы апсида өстендә зур булмаган ярым түгәрәк гөмбәз урнаштырылган, ул гөмбәзе барабанга утыртылган дүрткырлы чатыр б-н ябылган. Апсиданың фасады икеләтелгән ярымколонналар, аркатура, өч катламлы фронтон, почмакларда аттик тумбалар б-н бизәлгән. Арка тәрәзәләре ярымколонналарда почмаклы архивольтлар б-н каймаланган.

Чиркәүнең фасады тулысынча псевдорус юнәлешендәге эклектика стилендә классицистик архит-ра элементларын кулланып эшләнгән. Совет хакимияте чорында бу бинада 2 нче мәктәп урнаша (хәзер — Казан шәһәренең А.Алиш исемендәге балалар иҗаты сарае).

*Әд.:* Гвоздев П.П. Историческая записка о Второй Казанской гимназии. К., 1876; Львов Д.М. Историческая записка о Казанской второй гимназии с 1876 по 1885 год. К., 1885.

*Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.*

**КАЗАНДАГЫ́ ИКЕНЧЕ́ ПЕДАГО́ГИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, к. *Татар гуманитар институты.*

**КАЗАНДАГЫ́ КСЕ́НИЯ (ИКЕНЧЕ́) КЫЗ БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ**, кыз балалар гимназиясе. 1880 елда ачыла, император Александр III нең кызы бөек княгиня Ксения исеме б-н атала. Уку вакыты 7 ел булган кыз балалар гимназияләре уставлары нигезендә эшли. 1886 да гимназия каршында өстәмә 8 нче пед. сыйныф, 1890 да әзерлек сыйныфы ачыла; 2 шәр параллель сыйныф эшли. Ел саен якынча 80 кеше тәмамлый. Укытучылары Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе профессорлары була. Гимназияне тәмамлаучылар (алар арасында М.В.*Нечкина*) шәһәр һәм земство башлангыч мәктәпләрендә укыталар, Казан хатын-кызлар югары курсларында укуларын дәвам итәләр. Сәүдәгәр И.И.Аппаковтан сатып алынган бинада урнаша (архит-ра истәлеге; хәзер РФА КФҮ бинасы).



Казандагы Ксения (икенче) кыз балалар
гимназиясе. 20 йөз башы фоторәсеме.

*Е.В.Липаков.*

**КАЗАНДАГЫ́ МАРИ́Я (БЕРЕНЧЕ́) КЫЗ БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ,** кыз балалар өчен гомуми белем бирүче урта уку йорты. 1859 елда Казан шәһәр думасыннан килгән һәм халыктан җыелган акчага, Казан губернаторы П.Ф.Козлянинов һәм халык уч-щеләре директоры О.А.Имшеник башлангычында, 1 нче разрядлы кыз балалар уч-щесе буларак ачыла. 1869 дан Мария гимназиясе. 1870 тә *Кыз балалар гимназияләре* турындагы кагыйдәгә туры китереп үзгәртелә. 1870 тә 7 нче сыйныф, 1871 дә — 8 нче пед. сыйныф ачыла. Казанда иң эре урта уку йорты санала, 1879 да укучылар саны якынча 900 кеше, 20 йөз башында мең кешедән арта. Халык укытучыларын әзерләүдә әһәмиятле роль уйный. 20 йөз башында Казан шәһәр башлангыч мәктәпләрнең һәм земство мәктәпләренең укытучыларының күпчелеге бу гимназияне тәмамлаучылар була. 1918 дә урта мәктәп итеп үзгәртелә. Беренче елларында Воскресенский урамында (хәзерге Кремль урамы) Крупенников йортында вакытлыча алынган бинада, 1873 тән — үз



Казандагы Мария (беренче) кыз балалар гимназиясе.

бинасында Петропавел соборы каршында (арх. Л.К.Хрщонович; архит-ра истәлеге) урнаша.

*Әд.:* Смирнов П. Исторический очерк Казанской Мариинской женской гимназии за 25 лет её существования (1859–1884). К., 1884; Траубенберг П.В. Казанская Мариинская женская гимназия: её современное состояние и деятельность. К., 1900.

**КАЗАНДАГЫ́ ТИМЕ́Р ЮЛ ВОКЗАЛЫ́**, пассажирлар өчен бина, архит-ра истәлеге. 1895–96 елларда арх. Г.Б.Руш проекты буенча, эклектика формаларында традицион рус кирпеч бизәге төшерү ысулы кулланып төзелә. Вокзалның төп бинасы тимер юлның бер ягында урнашкан, вестибюль, көтү заллары, ресторан һәм хезмәт күрсәтү бүлмәләре бар. Бинаның үзәк композициясе чатыр түбә б-н капланган, тар һәм тәбәнәк түшәмле аралыклар б-н тоташкан куб рәвешендәге 3 өлештән тора. Үзәк өлеш 4 кырлы ике гөмбәз б-н тәгәлләнгән. 1992 елгы янгыннан соң бинаның барлык фасадлары һәм интерьерлары әүвәлге рәвешендә торгызыла (1997): әвәләп ясау сәнгате үрнәкләре һәм Мәскәү-Казан тимер юлы үткән Россия губерналары герблары б-н бизәлгән.





Казандагы тимер юл вокзалы.
Фоторәсемнәр: 1. 20 йөз башы; 2. 1997.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

**КАЗАНДАГЫ́ ЯНГЫННА́Р**. Шактый еш һәм корылмаларның (башлыча, агач) тыгыз урнашканлыгы аркасында һәлакәтле булалар. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан алып 20 йөзгә кадәр Казанда шәһәргә аеруча зур зыян китергән 12 көчле янгын теркәлгән. 1579 елның 23 июнендәге янгын Никола-Тула чиркәве приходында стрелец Онучин йортында башлана, Кремльдәге Патша сарае һәм Спас-Преображение монастыре, төньяк һәм төньяк-көнбатышта урнашкан бистәләр янып бетә. Берничә көннән янгын башланган йорт урынында *Казан Мәрьям Ана иконасы* табыла. 1672 дә һәм 1684 тә Кремль янындагы — Проломный б-н Болак арасындагы һәм икенче яктан Кремль калкулыгыннан Казансу елгасына кадәр урнашкан йортлар яна. 1742 нең 3 нче апреленә каршы төндә янгын ш.у. Кремль янында, руханилар семинариясе бинасы тирәсендә башлана, шәһәрнең үзәк өлешендәге йортлар, Кремльдә протоиерей йорты һәм кафедраль Благовещение соборы янып бетә. 1749 да Татар бистәсендә башланган (к. *Иске Татар бистәсе*) янгын шәһәрнең үзәгенә күчә, губернатор һәм комендант йортлары, Кремльдәге губернатор канцеляриясе янып юкка чыга, Казансудан Болакка сузылган урамдагы корылмаларны ялкын урап ала; Болактагы бөтен күперләр, суднолар һәм агач складлар күмер хәленә килә. 1757 елгы янгын вакытында шәһәрнең Кремль һәм Гостиный двор тирәсендәге өлеше яна. 1774 нең 12 июлендә бөтен яклап ут чолгаган шәһәр көлгә әйләнә, Постаучылар һәм Татар бистәләрендәге корылмалар гына өлешчә сакланып кала. 1815 нең 3 сентябрендәге янгын Ямчылар бистәсендә Варлаам чиркәве тирәсендә чыга, 3 айга сузылган корылык утның бик тиз җәелүенә китерә. Казанны 8 чакрымлык божралы янгын чорнап ала; 1,5 мең йорт янып бетә. 1842 дәге янгын 24 августта Проломный урамында сәүдәгәр Щербаков йортында чыга. Өермәле җилдә ут зур мәйданга тарала. 2 көн эчендә шәһәрнең үзәк өлеше, Радионов затлы кыз балалар ин-тына кадәрге утарлар, (Дворяннар җыены һәм хәрби губернатор йортларыннан кала), ш.у. Болак аръягындагы йортлар юкка чыга. 1309 бина янып бетә, килгән зыян миллион сумнар б-н исәпләнә. Шулай ук 1847 дә, 1848 дә һәм 1859 да шәһәрдә көчле янгыннар булып уза. 1917 нең 14 августында Казан дары з-дындагы янгын аркасында шәһәрнең шактый өлешенә шартлау һәм һәлакәт яный. Заводның башлыгы генерал-лейтенант В.В.*Лукницкий*, үз гомерен кызганмыйча, янгынны туктатуга ирешә.

Күпсанлы янгыннар халык арасында уттан зыян күрүчеләргә карата теләктәшлек тудыра, аларга ярдәм күрсәтелә. 1815 тәге янгыннан соң туганнарын, йорт-җирләрен һәм мал-мөлкәтләрен югалткан Казан халкына ярдәм йөзеннән бөтенроссия подпискасы ачыла. С.-Петербургтан Казанга афәтнең сәбәпләрен һәм күләмен ачыклау өчен сенатор С.С.Кушников килә. 1842 дәге янгыннан соң шәһәр идарәсе җәмәгать ашханәләре оештыра; сакланган биналарда йортсыз-җирсез калганнар урнаштырыла. Император Николай I Казанга 1 млн. сум ссуда бирә һәм шәхсән 50 мең сум иганә кыла. Янгыннан зыян күрүчеләргә аерым кешеләр акчалата, мал-мөлкәт һәм яшәргә урын бирү б-н дә ярдәм итәләр. Шәһәрдә таш биналар арта һәм янгыннан саклану эшләре камилләшә бару аркасында янгыннар локаль күренешкә әйләнә, ләкин шулай да сизелерлек зыян салуны дәвам итә. 1919 да Театр мәйданында Казанның элеккеге театры янып бетә, 1987 дәге зур янгын ТАССР Дәүләт музее биналарына шактый зыян китерә, 1996 да ТЮЗ бинасы яна. Янгыннарны булдырмауга юнәлтелгән чараларны ТР Эчке эшләр министрлыгының Янгыннан саклау идарәсенә караган оешмалар гамәлгә ашыра. Янгыннар турындагы хәбәрләр бердәм диспетчерлык пунктына килә, ул сигналлар бирү һәм янгыннарны сүндерүне идарә итү системасы б-н җиһазландырыла.

*Әд.:* Загоскин Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Систематический сборник постановлений Казанской городской думы за 22 года (с 1871 по 1892 гг.). К., 1898; Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1898. Т. 2.

*И.А.Новицкая.*

**«КАЗА́НЕЦ»**, борчак сорты. 1987 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Т.Г.Евдокимова, А.Н.Фадеева, И.Н.Федотова, Н.В.Афиногентова, И.П.Еряшева тарафыннан «Орёл 86/3» сорты үрнәгендә аерым сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Уртача өлгерешле. Вегетация чоры 72–84 көн, сөрлегү һәм коелуга бирешми. Орлыклары саргылт-алсу, почмаклы-түгәрәк. Яхшы тигезләнеш булганда (83%), 1000 орлыкның авырлыгы 233 *г*. Борчакның кабыксыз өлеше 87,3%. Протеин 22–24%, пешергәндә таралуы уртача, пешерү вакыты 135 *мин* (коэф. 2,6). Тәме 3,5 балл. Азык-төлек һәм бөртекле терлек азыгы буларак кулланыла. Интенсив типта үстерелә. Чәчүнең иң оптималь нормасы 1,2–1,4 млн. орлык. Бер фазалы уңыш җыю мөмкинлеге бар. Уңыш стандартлардан уртача 2,8 *ц* га югары, 1 *га* дан 50 *ц* (1994 тә Түбән Новгород өлкәсе сорт участокларында). ТРда иң югары уңыш 1 *га* дан 39,1 *ц* була (1997).

*Әд.:* Научно-производственное объединение «Нива Татарстана». К., 1997.

**КАЗА́НКА** авылы, Арча шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 159 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 81, 1949 да — 109, 1958 дә — 102, 1970 тә — 131, 1979 да — 107, 1989 да — 117, 2002 дә — 172 кеше.

**КАЗА́НКА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 11 *км* көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 192 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 73%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлан-

гыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Черемшанский Косогор, Хорватка исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1549 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Югары Кармалы волостенда. 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1886 да — 580, 1889 да — 712, 1910 да — 837, 1920 дә — 750, 1926 да — 661, 1949 да — 411, 1958 дә — 454, 1970 тә — 494, 1979 да — 181, 1989 да — 181, 2002 дә — 208 кеше.

**«КАЗА́НКА»**, карабодай сорты. 1985 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында И.Н.Петелина, Ф.З.Кадыйрова, В.М.Галактионова тарафыннан морфологик һәм хуҗалык өчен кыйммәтле сыйфатлары буенча эре бөртекле диплоидлы карабодай селекция материалыннан кабаттан индивидуаль-семья тәртибендә сайлап алу ысулы б-н чыгарыла.

Уртача өлгерешле сорт, вегетация чоры 75–84 көн, эре бөртекле. Яхшы тигезләнеш булганда (95–98%) 1000 бөртекнең авырлыгы 32–34 *г*. Ярма чыгышы (74%) һәм аксым микъдары (18–27%) буенча стандарт «Майская» һәм «Казанская крупноплодная» сортлары дәрәҗәсендә. Алыштыргысыз һәм үзенчәлекле аминокислоталар күп булуы б-н аерылып тора, шуңа бәйле рәвештә карабодай ярмасының туклыклылык һәм диетик бәясе күтәрелә. «К.» — интенсив типтагы сорт, начар климат шартларына чыдам, уңай шартларда яхшы үсә, минераль ашламаларны күп нормада кертсәң сөрлекми, бер вакытта чәчәк ата һәм өлгерә. Югары дәрәҗәдә орлыклык материал бирә. Сынау елларында «К.»ның уңышы стандарт «Казанская крупнозерная» сортыннан 1,2 *ц* га, «Майская» сортыннан 3,2 *ц* га арта. Иң югары уңыш — 1 *га* дан 34,5 *ц* — 1986 да Белгород өлкәсенең Ракитянск сорт участогында була. «К.» 1989–90 да Саратов, Тамбов өлкәләрендә һәм Молдавиядә районлаштырыла, Рязань, Волгоград өлкәләрендә һәм Башкортстан Респ-касында өстенлекле дип танылa.

*Әд.:* Крупяное поле Татарии. К., 1979; Крупноплодные диплоидные сорта гречихи. К., 1991.

**КАЗА́НКА БОТА́НИКА ТЫЮЛЫГЫ́** («Юрочка чокыры»). Бөгелмә р-нының Иске Казанка авылы янында. 1991 елда язгы адонисның популяциясен саклау максатында оештырыла. Мәйданы 5 *га*. Бөгелмә Зәе елгасы үзәненең уңъяк битендәге сызаны били, үзән төбе буенча зур булмаган инеш ага. Үсемлекләрнең 150 дән артык төре үсә. Карбонат токымнарыннан торучы сыза сөзәкләрендә ТРның Кызыл китабына кертелгән дала төрләре очрый. Цингер мәче борчагы, Гмелин тәңкәяфрагы, матур кылган, рус күкебашы, садә оносма һ.б. Язгы адониснең уртача урнашу тыгызлыгы — 1 $м^2$ га 1,6 данә. Даpу үсемлекләре резерваты буларак, тыюлык фәнни-гамәли әһәмияткә ия.


Казанка ботаника тыюлыгы.

**КАЗА́НКИН** Александр Фёдорович (15.4.1900, Буа ш. — 20.3.1955, Мәскәү), генерал-лейтенант (1950). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне тәмамлый (1934). 1918 елдан Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышы елларында Урта Азиядә советларга каршы оештырылган хәрби көчләр б-н сугышта катнаша. 1934 тән Белоруссия хәрби округында. 1936 дан һава десанты гаскәрләрендә. Совет-фин сугышында 214 нче һава десанты бригадасы составында сугыша. Бөек Ватан сугышында корпус (дивизия) б-н җитәкчелек итә. Сугыштан соң һава десанты гаскәрләре командующие урынбасары, соңрак СССР Оборона министрлыгы аппаратында эшли. Ике Ленин ордены, биш Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.


**«КАЗАНКОМПРЕССОРМА́Ш»**, к. *Казан компрессор машиналар төзү заводы.*

**КАЗАННЫ́ АЗА́Т ИТҮ́ ОПЕРА́ЦИЯСЕ**, 1918 елның 5–10 сентябрендә Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе һәм 2 нче армиясенең Арча төркеме составындагы Кызыл Армия сугышчыларының Идел буе хәрби флотилиясе б-н берлектә алып барган сугышлары. Максаты — КОМУЧ халык армиясе, Чех-словак корпусының Идел буе армиясе Казан төркемнәрен тар-мар итеп, Казанны кулга төшерү. Һөҗүм өч юнәлештә җәелдерелә. Төп һөҗүмне көнбатышта Зөя шәһәреннән Иделнең уңъяк һәм сулъяк ярлары буйлап, Идел буе хәрби флотилиясенең (командующие Ф.Ф.Раскольников) 17 корабле булышлыгында 5 нче армия (командующие П.А.Славин) өстәмә һөҗүмне төньяк-көнбатыштан Биектау станциясеннән Арча төркеме (командующие В.М.Азин) ясый. Һөҗүм алдыннан Казанда эшчеләр баш күтәрә, ләкин күтәрелеш бастырыла. 7 сентябрьгә 5 нче армиянең Уңъяк яр төркеме (3,5 мең кеше), Югары һәм Түбән Ослан авылларын алып — Иделгә, ә Сулъяк яр төркеме (4 мең кеше) Казансу елгасына чыга. Арча төркеме (3,5 мең кеше) Киндерле һәм Кече Клыки авылларын басып ала. 10 сентябрь иртәсендә Яңа Татар бистәсе тирәсендә Идел буе флотилиясе (комиссары һәм командующий ярдәмчесе Н.Г.*Маркин*) десант төшерә. Бер үк вакытта Сулъяк яр һәм Арча төркемнәре сугышчылары һөҗүмгә күчәләр, шәһәрне ярымбоҗрага алалар. Казанны штурмлауда Югары Ослан авылы биеклегеннән 15 нче туп батареясы уты, хәрби кораблләр, бронепоездлар һәм авиация катнаша. Бергәләп штурмлау нәтиҗәсендә Кызыл Армия сугышчылары Казанны алалар. Дошман Лаеш — Чистай — Сембер шәһәрләре юнәлешендә чигенә. Трофейлар, ш.и. 12 туп батареясы, 2 бронепоезд кулга төшерелә. Операция Көнбатыш фронтта стратегик инициативаның Кызыл Армиягә күчүен тәэмин итә.

*Әд.:* История Казани. К., 1991. Кн. 2.

**КАЗАННЫ́Ң ЯУЛА́П АЛЫНУЫ́** (22.8 (2.9.) — 2 (13).10.1552), *Казанга Рус дәүләте яуларының* соңгы этабы. К.я.а. алдыннан «Мәскәү — Өченче Рим» доктринасы тирәсендә тупланган күп кенә нигезләмәләрне («чын рус җирләре», «Казан — рус кенәзләре вотчинасы» һ.б.) үз эченә алган идеологик әзерлек алып барыла. К.я.а.ның алшартлары — Зөя кальгасы төзелү, Сөембикә хөкүмәтен бәреп төшерү һәм тәхеткә *Шаһгали ханны* утырту (1551). Ләкин Шаһгалинең аксөякләрне кыру һәм ханлыкны Рус дәүләтенә кушу сәясәте җирле аксөякләрнең аңа каршы күтәрелүенә һәм аны тәхеттән төшерүгә китерә (1552). Баш күтәрүчеләр *Чапкын бәк Отыч улы, Ислам, Кибәк* бәкләр, сәет *Колшәриф* җитәкчелегендә рус гаскәрләренә каршы сугыш хәрәкәтләре башлыйлар һәм 1552 елның язында тәхеткә Әстерхан ханзадәсе Ядегәр Мөхәммәдне утырталар. Бу исә рус гаскәрләренең яңа явы башлануга сәбәп була. Кырым ханлыгы һәм Төркиянең аны өзәргә омтылышы 1552 нең 23 июнендә Тула янында рус армиясе тарафыннан туктатыла. Русларның төп гаскәрләре ике колонна булып 1 июльдә Коломнадан Казанга яуга кузгалалар, алар, Сура елгасы буенда кушылып, 13 августта Зөя янына килеп җитәләр. Ял иткәннән соң гаскәрләр Иделне кичә башлыйлар һәм, каршылыкка очрамыйча, 20 августта лагерь булып Казан диварлары буенда урнашалар. Рус гаскәрләре б-н патша Иван IV, воеводалар — кенәзләр *А.М.Курбский, А.Б.Горбатый-Шуйский*, И.М.*Воротынский*, дьякон *И.Г.Выродков* һ.б. җитәкчелек итәләр. Рус гаскәрләре (50–60 мең чамасы, кайбер мәгълүматлар буенча, 150 меңләп кеше) составына биләмәләрдән тупланган атлы гаскәр, җәяүле сугышчылар отрядлары, стрелец полклары (5 мең), артиллерия, Шаһгалинең татар атлы гаскәре (3 меңгә кадәр кеше), хан гаскәре составына *Ядегәр Мөхәммәд* ханның нугайлар атлы гаскәре (3 мең), халык ополчениесе (10 меңгә кадәр) керә (кайбер мәгълүматлар буенча, барлыгы 33 мең чамасы сугышчы). Арча кыры ягыннан рус гаскәрләре тылында Япанча морзаның атлы гаскәре (3–5 меңләп кеше) хәрәкәт итә. 22 августта рус гаскәрләре шәһәрне камый башлыйлар һәм шунда ук Казанны саклаучылар һөҗүменә дучар булалар. Бу һөҗүмне кире кайтарганнан соң, рус полклары шәһәрне чолгап алалар һәм 23 августта шәһәрне планлы рәвештә камалышта тота башлыйлар. Алгы һәм Олы полклар — Арча кырында, уң кул полкы җиңелчә коралланган атлылар б-н — Ка-

зансуның уңъяк ярында, сакчы полк — Болак елгасы тамагы янында; сул кул полкы — Болак елгасы буйлап бистә диварлары тирәли, Шаһгали отрядлары — Зур полк янында, резерв (Патша) полкы сул кул полкы артында хан болынында урнаша. Рус армиясенең алгы отрядлары башлаган камау эшләре күп тапкырлар казанлылар һөҗүмнәре б-н туктатыла. 29 августта урлар өелә һәм алар өстенә туплар урнаштырыла. Урлар өстендәге 150 ләп туптан, биек агач корылмаларга куелган 10 лап туптан һәм 50 *тофәңнән* шәһәрне утка тоту аның диварларына һәм саклаучыларга зур зыян китерә. Моңа җавап итеп, казанлылар күп тапкырлар шәһәрдән чыгып һөҗүмнәр оештыралар, аларга Япанчаның атлы гаскәре ярдәм итә. Аның һөҗүмнәреннән саклану өчен русларның Горбатый-Шуйский җитәкчелегендәге 30 мең кешелек гаскәре 30 августта татар атлыларына каршы яу башлый. Татарларның атлы гаскәре җиңелә, Япанча Арчага таба чигенә, әмма көчләр туплап яңадан рус лагерена һөҗүм ясый. Шуннан соң рус гаскәрләре Арча тарафына юнәләләр, 6–8 сентябрьдә татар атлы гаскәрен тар-мар итәләр, шәһәрчекне штурм б-н алалар (шул вакытта Япанча һәлак була). Шәһәрчекләрне һәм авылларны талап, аларның халкын кырып, рус отрядлары *Арча даругасы* аша узалар. Тылдан янаган куркынычны бетереп, рус гаскәрләре Казанны тулысынча боҗрага алалар, камау эшләрен һәм даими штурмлауны дәвам иттерәләр. Алар Казансуны шәһәр диварлары яныннан боралар, 4 сентябрьдә шәһәрнең төп коесын шартлаталар һәм шул рәвешле камалыштагыларның су б-н тәэмин ителүе катлаулана. Бу вакытта урлар һәм туплар диварларга тагын да якыная, диварлар астына дарылы шартлаткычлар куела. Камалыштагылар ярсып контрһөҗүмнәргә ташланалар, еш кына урларны кулга төшерәләр, тупларны юк итәләр һәм камау корылмаларын яндыралар




(Зәйнаш морзаның 26 сентябрьдәге һөҗүме). 30 сентябрьдә Арча һәм Хан капкалары янында диварларны шартлатканнан соң Казанга каршы хәлиткеч һөҗүм башлана. Диварларның бер өлеше шартлатылу нәтиҗәсендә Олы һәм Алгы полкларның сугышчылары шәһәргә бәреп керә. Казанлылар гайрәтләнеп каршы торалар, контрһөҗүмгә күтәреләләр һәм русларны шәһәрдән кысрыклап чыгаралар. Рус полклары чигенәләр һәм чираттагы һөҗүмгә әзерләнәләр. Төндә камалыштагылар җимерелгән дивар урынына яңасын төзергә һәм аның өстенә сакланып калган тупларны урнаштырырга омтылалар. Иван IV шәһәр халкына ультиматум куя, тик ул кире кагыла. 2 октябрь тирәсендә шәһәрне барлык яктан штурмлау башлана (Аталык һәм Нугай капкалары янында тагын бернчә урында дивар шартлатыла), шәһәр тупка тотыла. Дивар сызыгы өзелә һәм сугышлар Казан урамнарында дәвам итә. Шәһәр халкы көрәшенең соңгы үзәге хан сарае урнашкан хисарда (цитадель) була, кальганы саклаучылар шунда чигенәләр. Рәхимсез сугыштан соң хисарның диварлары җимерелә һәм көрәш эчтә дәвам итә. Биредә, сугышып, сәет Колшәриф һәм ул җитәкләгән мәдрәсә шәкертләре һәлак булалар. Каршылык күрсәтүнең өметсезлеген күреп, Ядегәр Мөхәммәд Зәйнаш морза б-н әсирлеккә биреләләр. Шәһәрне саклаучыларның калган төркеме, Алабуга капкасы аша үтеп чыгып, урманга китә. Казан халкының күпчелеге кырып-үтерелеп бетерелә, өлешчә әсир ителә, шәһәр яндырыла һәм талана. Казанны саклау 40 көннән артык бара, ул сан ягыннан өстен һәм яхшы коралланган рус армиясенә каршы көрәшкән татарларның югары дәрәҗәдәге хәрби-инженерлык сәнгатенә ия булуларын күрсәтә. К.я.а. нәтиҗәсендә татар халкының каршылык күрсәтүе тукталмый, ләкин бу көрәш инде бердәм үзәктән алып барылудан һәм хәрби-техник чаралардан (дары, туплар һ.б.) мәхрүм ителә. К.я.а. Рус дәүләтенең Көнчыгышта яңа терр-яләр басып алуы, империя төзү, самодержавиенең һәм дәүләт эчендәге золымның (опричнинаның) көчәюе юнәлешендә ясалган мөһим адым була. Ул Иван IV нең реформалар сәясәте тәгәлләнүне һәм самодержавиеле идарәгә күчүне күрсәтә.

*Әд.:* Б о г д а н о в с к и й М. Инженерно-исторический очерк осады Казани (1552). П., 1897; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Б а х р у ш и н С.В. Взятие Казани // За родную землю. М., 1949; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

*И.Л.Измайлов.*



К.Б. В е н и г. «Казанны буйсындыру». Эскиз. 19 йөзнең 2 нче яртысы. Дәүләт Рус музее.

**«КАЗА́НСКАЯ ВЕЧЕ́РНЯЯ ПО́ЧТА»** («Казан кичке почтасы»), көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. 1909 елның 5 маеннан 1910 ның 17 маена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 283 саны чыга («*Вечерняя почта*» саннарын исәпкә алып). Нашире һәм мөхәррире — М.А.Малашенко.

«К.в.п.» битләрендә Петербург телеграф агентлыгының иҗтимагый-сәяси һәм икътисади әһәмияткә ия телеграммалары, башкалада чыгучы һәм җирле газеталардан мәкаләләр күчереп басыла. Газетада төп урынны «Казан тормышы» бүлеге били, аның «Казан губернаторыннан», «Дума темалары», «Театр һәм музыка», «Казан халыкара күргәзмәсе кайтавазы», «Төрлесеннән», «Кечкенә фельетон» дигән даими рубрикалары була.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКАЯ ГАЗЕ́ТА»** («Казан газетасы»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. Казан губерна земствосы идарәсе органы. 1902 елның 10 ноябреннән 1914 нең 25 декабренә кадәр рус телендә Казанда нәшер ителә, барысы 632 саны чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — В.В.*Марковников*, П.И.Геркен, Н.А.*Мельников*. Башлыча, Казан губерна һәм өяз земстволары идарәләре рәисләре, әгъзалары һәм хезмәткәрләре язмалары басыла. Газета Казан губерна земствосы хисабына чыгарыла, аны волость идарәләре һәм авыл китапханәләре, земство хезмәткәрләре (укытучылар, табибләр, ветеринарлар), газетада язмалары басылган авыл руханилары һәм крәстияннәр бушлай алдыра. Басмада Россия телеграф агентлыклары телеграммалары, авыл хуҗалыгына кагылышлы хөкүмәт указлары, карарлары һәм боерыклары басыла;


Воскресенье, 10-го ноября 1913 года
Казанская Газета.
Общій подъемъ народнаго хозяйства.

кабул ителгән законнар һәм Дәүләт Думасының закон чыгару тәкъдимнәренә аңлатмалар урнаштырыла. Столыпин аграр реформасын әзерләү һәм уздыруга зур игътибар бирелә, хутор хуҗалыкларының өстенлекләре пропагандалана. «К.г.» редакциясе аеруча зур кызыксыну б-н җәмәгать үзидарә органнары эшен яктырта; укучыларын Казан губерна земствосы карарлары, комиссияләр һәм өяз идарәләре докладлары б-н таныштыра; Казан шәһәр думасы утырышларының отчётлары, җәмәгать эшләре, Казан губернасында башлангыч белем бирү торышы, хәйрия җәмгыятьләре, дәвалау һәм белем бирү оешмаларының хәле, кооперативлар, артельләр, ширкәтләр оештыру турында язмалар бастыра. Газета авыл хуҗалыгын алып баруның алдынгы алымнарын пропагандалый; мед., ветеринария, умартачылык буенча файдалы мәгълүматлар, крәстияннәр тормышын һәм хезмәтен яхшыртуны оештыру турында киңәшләр бирә. «К.г.» ны укучылар губернаның барлык өязләре буенча а.х. статистикасы мәгълүматлары алалар. Ш.у.к. «*Земская неделя*».

*Әд.:* С т а р о с т и н В.А. «Казанская газета» как печатный орган губернского земства // Казанский посад в прошлом и настоящем. М., 2002.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКАЯ ГАЗЕ́ТА - КОПЕ́ЙКА»** («Казан газетасы — бер тиен») (колонтитулда: «Казанская копейка»), көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. 1912 елның 3 маеннан 1914 нең 2 февраленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 583 саны чыга. Төрле елларда наширләре һәм мөхәррирләре — Д.З.Горностаев, К.Н.Тимофеев. Редакция газетаны бернинди дә сәяси төркемгә бәйле булмаган, прогрессив юнәлешле басма дип тәгаенли. Ул «кыска күләмдәге язмада да күп мәгълүмат бирүне, яшәү урыныннан, дәүләт эчендә һәм чит илләрдә барган вакыйгаларны мөмкин кадәр тулырак чагылдыруны» төп бурыч итеп куя. Газета битләрендә шәһәр үзидарә органнары утырышларының хисаплары басыла, Казан шәһәр думасының хуҗалык-икътисади, ш.и. Идел аркылы тимер юл күпере төзүгә кагылышлы мәсьәләләр җентекләп яктыртыла. Соңгы битендә шәһәрнең дәвалау учреждениеләре адреслары урнаштырыла. Петербург телеграф агентлыгы телеграммалары, Балкан сугышы, Россиянең Атланта илләре б-н мөнәсәбәтләре турындагы үз хәбәрчеләре хәбәрләре, Россия һәм чит ил басмаларыннан күчерелгән язмалар бастырыла. Арзан бәясе, аңлаешлы гади телдә нәшер ителүе аркасында газета халык арасында абруй казана.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКАЯ ЖИЗНЬ»** («Казан тормышы»), рәсемле кечке иҗтимагый-сәяси һәм әдәби көндәлек газета. 1914 елның 19–21 октябрендә (3 сан) һәм 28 октябреннән 9 декабренә кадәр (36 сан) Казанда рус телендә нәшер ителә. Нашир-мөхәррире — Н.А.Скворцов. Язмаларның күбесе шул елда башланган Беренче бөтендөнья сугышына багышлана. Хәрби хәбәрләр, Югары Башкомандующий штабы мәгълүматлары, Петроград телеграф агентлыгы һәм шәхси телеграф бюролары телеграммалары, хәрби-патриотик темага караган мәкаләләр басыла. «Сугыш театры», «Сугыш көндәлеге», «Дуслар һәм союздашлар», «Казан һәм сугыш», «Казан лазаретлары буйлап», «Сугыш һәм җәмәгать үзидарәсе» кебек даими рубрикаларда сугыш хәрәкәтләре барышы, фронтлардагы хәлләр, Россия армиясенең тәэмин ителешен оештыру, земстволарның һәм шәһәрләрнең бөтенроссия берлекләрен төзү турындагы мәгълүматлар бирелә. Сугыш шартларында Казанның хуҗалык-иҗтимагый халәтен, сугыш заказларын үтәүче җирле сәнәгать, ш.и. Казан завод-фабрикалары торышын анализлауга зур игътибар юнәлтелә; Казан хәрби госпиталендә дәваланучы яралылар турында мәгълүматлар басыла. Газета битләрендә Казанны азык-төлек һәм көндәлек товарлар б-н тәэмин итү, бәяләр үсешен тоткарлау, спекуляциягә каршы көрәш алып бару буенча шәһәр һәм земство үзидарәләренең эшчәнлеге яктыртыла. Авыру һәм яралы сугышчыларга ярдәм итү шәһәр ком-ты утырышлары турында даими рәвештә хәбәрләр басыла. 1914 елның 17 октябрендә (газета оештырылганчы) һәм 22–25 октябрендә газетага иртәнге кушымта рәвешендә «Телеграммы вечерней газеты» Казанская жизнь» чыгарыла. Кушымта — «*Жизнь*» ж-лы.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКАЯ КООПЕРАТИ́ВНАЯ ЖИЗНЬ И ИЗВЕ́СТИЯ ГУБЕ́РНСКОГО ПРОДОВО́ЛЬСТВЕННОГО КОМИТЕ́ТА»** («Казан кооператив тормышы һәм губерна азык-төлек комитеты хәбәрләре»), журнал. Казан кооператив ком-ты органы. 1917 елның маеннан августына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, 5 саны чыга. «Өмид» басмаханәсендә басыла. Баштагы 3 саны «Казанская кооперативная жизнь» исеме б-н чыга. Мөхәррире — И.Шадрин. Даими авторлары арасында — А.Хабачёв («Журнал Казанского общества пчеловодства» — «Казан умартачылык җәмгыяте журналы» мөхәррире), Г.Беляков, К.Соловьёв, С.Строителев, В.Полканов. Төп бүлекләре: «Хөкүмәт гамәлләре һәм боерыклары», «Россия буйлап», «Губерна буйлап», «Иҗтимагый тормыш», «Кооператив хәрәкәте», «Азык-төлек хроникасы». Басылган язмаларның төп темасы — Казан губерна кооператив берләшмәләренең эшчәнлеген камилләштерү. Журнал Учредительләр җыенын чакыру идеясен пропагандалый, халыкны «Ирек заёмы»на («Заём свободы») язылырга өнди. Редакция большевиклар эшчәнлеген тәнкыйтьли.

*Т.М.Насыйров.*

**«КАЗА́НСКАЯ КООПЕРА́ЦИЯ»** («Казан кооперациясе»), айлык журнал. Кулланучылар җәмгыятьләренең Казан берлеге органы. 1919 ның гыйнварыннан 1920 нең декабренә кадәр рус телендә Казанда барлыгы 36 саны нәшер ителә. 1919 да Казан губерна кооператив съездлары советы органы буларак айга 2 мәртәбә басыла (24 сан). «Рабочее дело» басмаханәсендә нәшер ителә. Мөхәррире — К.В.Харлампович. Журналда җирле һәм Мәскәү кооператорлары, галимнәр, журналистлар катнаша. Үзәк һәм җирле идарә органнарының кооперация буенча эшчәнлекләре яктыртыла; иҗтимагый-сәяси тормыш, кооперация һәм аның аерым тармакларының гомуми мәсьәләләре буенча материаллар басыла. Шулай ук «К.к.» кооперациянең Россиядә һәм чит илдәге эшчәнлеген яктырта, кулланучылар җәмгыятенең агымдагы эшчәнлеге, кредит мәсьәләләре, хезмәт артельләре турында журнал укучыларның сорауларына җавап бирә. Икътисад, медицина, библиография бүлекләре эшләп килә. Әдәби бүлектә фельетоннар, поэзия (ш.и. рәссам һәм шагыйрь П.А.Радимовның 10 нан артык шигыре) басыла. Редакция «Икътисади тормыш» (Мәскәү), «Кооператив сүзе» (Смоленск), «Казан игенчесе» һ.б. үзәк һәм җирле матбугат органнары материалларын күчереп бастыра.

*Т.М.Насыйров.*

**«КАЗА́НСКАЯ КРУПНОЗЁРНАЯ»**, карабодай сорты. 1981 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Н.Н.Петелина, Ф.З.Кадыйрова, В.М.Галактионова һәм Л.С.Нижегородцева тарафыннан эре бөртекле тиз өлгерешле диплоидлы «Троянда» карабодай сортыннан кыска сабаклы һәм сөрлегүгә чыдам булган сортны ике тапкыр сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Бу сорт уртача өлгерешле, вегетация чоры 76–82 көн, бер вакытта чәчәк ата һәм өлгерә. Уртача биеклектә, нык калын сабаклы, яфраклары яхшы үскән. 1000 бөртекнең авырлыгы 30–33 *г*, элпәлелеге — 23%, тишелеше 97–100%, эре ярма бөртекләренең чыгышының күп булуы б-н аерылып тора (87%, стандарт «Богатырь» сортының — 44%). Бу сорт интенсив типка карый, аеруча кыйммәтле санала, үрчү коэффициенты югары, сөрлегүгә һәм коелуга чыдам, уңышы 1 *га* дан 12–20 *ц*. Сынау вакытында 1 *га* дан уңышы стандарт «Майская» сортыннан 1,2 *ц* га, «Богатырь» сортыннан 2,6 *ц* га югары була. Татарстанда, Түбән Новгород һәм Курган өлкәләрендә районлаштырыла. Самара өлкәсе һәм Башкортстан Респ-касының күп мәйданарында игелә. СССР ВДНХсының алтын медале бирелә (1983).

*Әд.:* Крупяное поле Татарии. К., 1979; Крупноплодные диплоидные сорта гречихи. К., 1991.

**«КАЗА́НСКАЯ МЕ́СТНАЯ»**, карабодай сорты. 1938 елда Казан селекция станциясендә А.Ф.Шубина һәм Т.В.Тихонова тарафыннан крәстиян чәчүлекләрендә булган борынгы карабодай сортыннан чыгарыла. (Юдино р-нының «Авангард» к-зы). Иртә өлгерешле, корылыкка чыдам, бөртеге югары технол. сыйфатларга ия. Бу сортның кимчелекләре: иртә була торган кырауларга бирешүчән, вак бөртекле (1000 бөртекнең авырлыгы 21–23 *г*), сөрлегүгә бирешә. Конкурс сынаулары күрсәткечләре буенча «К.м.» сортының уңышы ул елларда киң таралган «Богатырь» сортыннан уртача 18% ка (1 *га* дан 1,2 *ц*) югары була. Ярославль, Иваново, Новгород, Кострома, Владимир, Киров өлкәләрендә, Красноярск краенда, Татарстан, Мари, Удмурт АССРларда районлаштырыла. Бу сорт 1970 еллар башына кадәр, якынча 30 ел чәчелә.

*Әд.:* Районированные и перспективные сорта сельскохозяйственных культур селекции Татарского НИИ сельского хозяйства. К., 1990.

**«КАЗА́НСКАЯ РАБО́ЧАЯ ГАЗЕ́ТА И ИЗВЕ́СТИЯ СОВЕ́ТА СОЛДА́ТСКИХ И РАБО́ЧИХ ДЕПУТА́ТОВ»** («Казан эшчеләре газетасы һәм солдат һәм эшче депутатлары советы хәбәрләре»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. Казан РСДРП бюросының берләштерелгән органы. 1917 елның 2 апреленнән 7 октябренә кадәр рус телендә Казанда 151 саны нәшер ителә. «Өмид» басмаханәсендә басыла. Мөхәррирләре — Ю.П.*Деникe*, Б.Н.Нелидов, П.С.Розовский, П.С.Голанов, С.М.Ефимов. Газета «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг астында чыга. Россиядә һәм чит илләрдә барган сәяси хәлләрне, халыкара эшчеләр хәрәкәте тарихын яктырта. Нигездә, сугышның дәвам ителүен хуплаган Вакытлы хөкүмәт мәнфәгатьләрен, аның эчке сәясәттәге күпчелек гамәлләрен яклый, «Заём Свободы» г-тасын чыгарырга ярдәм итә. Редакция большевикларның 1917 елгы Петроград вакыйгаларындагы гамәлләрен тәнкыйтьли, Учредительләр җыенын чакыру һәм бөтен хакимиятне аңа тапшыру, күппартиялелек нигезендәге власть органы оештыруны яклый. Казан шәһәр думасына сайлаулар алдыннан (1917 нең 8 октябрендә үткәрелә) эсер, меньшевик, латыш һәм поляк социаль-демократлары, Бунд һәм Берләшкән яһүд соц. эшчеләр партиясе тарафыннан төзелгән. Аның дәвамчысы булып «*Рабочее дело*» г-тасы кала.

*Т.М.Насыйров.*

**«КАЗА́НСКАЯ РЕЧЬ»** («Казан сүзе»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. Партиясез, демократик орган. Казанда рус телендә 1918 елның 11 гыйнварыннан 16 гыйнварына кадәр бары 3 саны гына нәшер ителә. «Казанская речь» нәшрияты тарафыннан «Труд» басмаханәсендә басыла. Газетаның барлык саннары да басмага редколлегия тарафыннан имзаланып тапшырыла һәм 1918 елның гыйнвар башында большевикларның Учредительләр җыенын куып таратуын тәнкыйтьләүгә багышлана («Учредительләр җыены әгъзаларын кулга алу», «Большевиклар властьта» һ.б. мәкаләләр). «К.р.» битләрендә совет хакимиятенең җирле органнары тарафыннан демократик басмаларның репрессияләнүе дә кискен тәнкыйть ителә («Студенческая речь», «Народное дело» г-талары ябылу). Илдәге сәяси хәлләрне шәрехләп, газета болай дип яза: «Большевиклар илне эндәшмәскә мәҗбүр итмәкче. Тик сүз ирегe һәм уй беркайчан да көчләүгә бирешми». «К.р.» басмаханәдәге кәгазь запаслары хакимиятләр тарафыннан тартып алынгач чыгудан туктый.

*Т.М.Насыйров.*

**«КАЗА́НСКАЯ СЕЛЬСКОХОЗЯ́ЙСТВЕННАЯ ГАЗЕ́ТА»** («Казан авыл хуҗалыгы газетасы»), «*Волжский вестник*» г-тасына кушымта буларак чыга. Казанда рус телендә 1897 елның 25 мартыннан 1903 нең 23 мартына кадәр елына 1 тапкыр барлыгы 7 саны нәшер ителә. Мөхәррире — Н.В.Рейнгардт. Газета авыл хуҗалыгы эшмәкәрләре өчен чыгарыла, шуңа күрә язмаларның авторлары күпчелек а. х. белгечләре була: М.П.Давыдов, О.И.Ивашкевич, Н.В.Морозов, И.П.Окулич һ.б. Төп игътибар Казан губернасында а.х. буенча белем бирүне киң җәелдерүгә бирелә, вак һөнәрчелек, а.х. кредиты мәсьәләләре күтәрелә, төрле елларда аз уңыш алуның сәбәпләре тикшерелә. Губерна һәм өяз земстволарының аграр белемне җәелдерү буенча эшчәнлеге яктыртыла. Бакчачылык, җимеш агачлары үстерү, яшелчәчелек, умартачылык, урман үстерү һәм үлән чәчү хакында мәгълүматлар бирелә. «Авыл хуҗалыгы матбугатыннан» рубрикасында а.х. техникасына кагылышлы вакытлы матбугат язмаларына күзәтү ясала.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКАЯ СЦЕ́НА»** («Казан сәхнәсе»), әдәби-нәфис һәм театр газетасы. Рус телендә Казанда 1913 елның 1 октябреннән 5 октябренә кадәр 2 саны нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — М.Л.Премиров. Басманың төп максаты «укучыда театр һәм музыка б-н кызыксыну уяту» була. Газетада театраль күзәтүләр, либретто һәм спектакльләргә рецензияләр, Казан театрларының программалары басыла. Фельетон һәм язмаларда «замана сәхнәсе мәсьәләләре» яктыртыла.

**«КАЗА́НСКИЕ ВЕ́ДОМОСТИ»** («Казан хәбәрләре»), көндәлек шәһәр газетасы. Оештыручысы: «Татмедиа» ААҖ. 1991 елның 15 мартыннан рус телендә нәшер ителә. Баш мөхәррире — Л.В.*Агеева*, В.А.Якупова (1995 тән). Казанның иҗтимагый-сәяси, иктисади һәм мәдәни тормышын яктырта, танып-белүгә караган һәм төрле күңел күтәргеч язмалар басыла.

**«КАЗА́НСКИЕ ВЕ́ДОМОСТИ. ИЗВЕ́СТИЯ УПРАВЛЕ́НИЯ ОСОБОУПОЛНОМО́ЧЕННОГО КОМИТЕ́ТОМ ЧЛЕ́НОВ ВСЕРОССИ́ЙСКОГО УЧРЕДИ́ТЕЛЬНОГО СОБРА́НИЯ ПО КАЗА́НСКОЙ ГУБЕ́РНИИ»** («Бөтенроссия учредительләр җыенының Казан губернасы буенча аерым вәкаләтле әгъзалары комитетының Казан хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси газета. *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты* (КОМУЧ) органы. Казанда рус телендә 1918 елның 24 августыннан 5 сентябренә кадәр 5 саны нәшер ителә. Газетаның беренче санында «барлык дәүләт органнары һәм учреждениеләргә кичекмәстән үзләренең барлык боерык, күрсәтмәләрен, рәсми белдерүләрен бастыру өчен басмага хәбәр итәргә» дигән әмер басылып чыга. Казан акгвардиячеләр кулында булганда газета 130 дан артык рәсми документ бастырып чыгара. Алар буенча иҗтимагый-сәяси, мәдәни-агарту, хуҗалык эшләрен, дини һәм милли мөнәсәбәтләрне, җирле власть һәм идарә органнарының ниятләрен һәм эшчәнлеген эзлекле рәвештә күзәтеп барырга мөмкин. Газетада ш.у. Ак армиянең Казан янындагы сугыш хәрәкәтләре яктыртыла.

*Т.М.Насыйров.*

**«КАЗА́НСКИЕ ВЕ́СТИ»** («Казан хәбәрләре»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм сәүдә газетасы. 1890 елның 11 декабреннән 1892 нең 31 декабренә кадәр рус телендә Казанда барысы 622 саны нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — Н.А.Ильяшенко. Газетада күренекле Казан галимнәре, җәмәгать эшлеклеләре һәм әдәбиятчылар: Н.А.Агафонов, А.Н.Бараков, А.И.Богданович (псевд. Зри-


КАЗАНСКІЯ ВѢСТИ.

Г. КАЗАНЬ.

«Казанские вести» газетасы.

тель), Н.Ф.Высоцкий, А.А.Дробыш-Дробышевский (псевд. Уманьский), А.М.Дохман, Н.П.Загоскин, Н.А.Осокин, А.А.Павлов (псевд. Ишилов), М.Н.Пинегин, А.С.Рождествин, И.Н.Смирнов, Н.Н.Траубенберг, Е.Н.Чириков, Г.Ф.Шершеневич һ.б. языша. Төп бүлекләре: «Хөкүмәт әмерләре һәм гамәлләре», «Телеграммалар», «Чиркәү хәбәрләре», «Казан хроникасы», «Өлкә бүлеге», «Библиография», «Биржа», «Белешмәләр». Басмада хөкүмәтнең күрсәтмәләре һәм гамәлләре турында хәбәрләр, Россия телеграф агентлыклары телеграммалары, Казан һ.б. Идел буе епархияләре буенча «чиркәү хәбәрләре» басыла. Казан губернасы һәм өяз земство җыелышлары, Казан шәһәр думасы, галимнәр, хәйрия җәмгыятьләре утырышлары отчётлары урын ала. «К.в.» ш.у. суд утырышларында тыңланган эшләрне шәрехли, алар буенча резолюцияләр бастырып чыгара. Сәүдә-сәнәгать хәбәрләренә, биржа сводкаларына да җитәрлек урын бирелә. 1891 дә «К.в.» г-тасында, Казанда ваба таралу сәбәпле, аның масштаблары турындагы хәбәрләр «Эпидемиология бите» дигән рубрикада алып барыла. «Зыян күрүчеләр файдасына» рубрикасы укучыларны Казан губернасы халкын ачлыктан саклап калу чаралары б-н таныштыра. Газетаның кайбер саннарына кушымта булып чит ил авторларының повесть һәм хикәяләре басыла.

*Әд.:* С а м о т у ч и н а А.Р. Общественно-культурная жизнь татар на страницах газеты «Казанские вести» (1890–1893) // Сб. материалов итоговых конференций молодых учёных и аспирантов за 1999–2000 гг. К., 2001.

*Р.Г.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЕ ГУБЕ́РНСКИЕ ВЕ́ДОМОСТИ»** («Казан губернасы хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. 1838 елның гыйнварыннан 1917 нең мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә; 1838 дә атнага 1 тапкыр, 1867 дән — 2, 1884 тән — 3, 1908 дән — 2 тапкыр чыга. Губерна идарәсе органы, иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормыш мәсьәләләре буенча хөкүмәт карашларын чагылдыра. Дәфтәр формасында чыга, 1865 елда күләме икеләтә зурая, 1873 тән киңәйтелгән форматы тулы биттә басыла башлый. 1843 тә рәсми һәм рәсми булмаган бүлекләре чыга. Рәсми бүлегенең мөхәррире, гадәттә, вице-губернатор була, газета басмага губернатор имзасы б-н бирелә. Информацион характерда була. Аның программасы берничә дистә ел дәвамында үзгәрешсез кала. Боерыклар, циркулярлар, хөкүмәт, җирле администрация фәрманнары һәм сәүдә, сату итү, подрядлар һ.б. турында белдерүләр урнаштырыла. Рәсми булмаган бүлегенең мөхәррирләре губернатор билгеләгән затлар була: И.А.Соколов, Н.И.Второв, А.И.Артемьев, И.Н.Березин, С.С.Немиров, А.Ф.Михайлов, Н.Н.Вечеслав, С.М.Шпилевский, Н.Ф.Юшков, А.П.Гесс, А.Н.Розенштейн, А.П.Молостов, А.М.Никитин, И.К.Мосцицкий, А.Петров, Ф.Иванов. «К.г.в.» формалашуда газета б-н актив хезмәттәшлек итүче Казан ун-ты укытучылары, профессорлары мөһим роль уйный. Шулай ук газетага Казан губернасының танылган публицистлары, хәбәрчеләре, фән, мәдәният, мәгариф хезмәткәрләре, руханилар, җирле җәмәгать үзидарәсе органы хезмәткәрләре, гласныйлар яза. 1871 дәге хөкүмәт карары буенча «К.г.в.» сәяси, юридик һ.б. материалларның бары тик рәсми чыганаклардан алынганнарын гына бастырып чыгарырга хокуклы була. Мәкаләләрнең тематикасы илдәге иҗтимагый-сәяси тормышның үзгәрүе, цензура режимының көчәюе яки кимүе, җирле администрация тарафыннан «күзәтү»нең ни дәрәҗәдә булуыннан һ.б. факторлардан тора.

Даими рубрикалар, ш.и. «Җирле бүлек», «Эчке хәбәрләр», «Статистика» «Өяз хәбәрләре», «Юридик бүлек» (1871 дән), «Белдерүләр», «Библиография» чыгып килә. 1860 елларның 2нче яртысыннан газетаның «Кушымта»сы чыга. Ул земство һәм шәһәр бюджеты турында мәгълүматлар, җирле үзидарә органнары күрсәтмәләре, сайлаулар буенча кагыйдәләр, Казан губернасының торак пунктлары исемлеге, крәстиян эшләре буенча алып барылган журналлар һ.б. турында мәгълүматлар бастыра. «К.г.в.»да губернаның хуҗалык тормышы хәбәрләре, төбәк тарихы һәм этнографиясе турында мәкаләләр мөһим урын алып тора. Этнографик һәм тарихи язмалардан өзекләр, фельетоннар, мәкаләләр, К.Ф.Фуксның «Казан татарлары статистик һәм этнографик нисбәттә» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях») китабыннан өзекләр, ш.у. аның Казан губернасының удмурт, мордва, чуаш авылларында йөрүен тасвирлаган язмалар басыла. А.С.Пушкинның А.Фукска адресланган хаты да газетада урын ала. 1838–42 елларда әчтәлеге базар бәяләренә күзәтү, библиографик белешмәләр һәм шәхси белдерүләр б-н чикләнгән «Прибавления к Казанским губернским ведомостям» чыга. Ш.у.к. «*Известия Казанского губернского комиссариата*».

*Әд.:* В а с и л ь е в П.П. Казанское книжное дело: Материалы по местной книжно-литературной деятельности. К., 1866. Вып. 1; А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1907. Ч. 2; А й п л а т о в Г.Н. «Губернские ведомости» как исторический источник: По материалам неофициальной части «Казанских губернских ведомостей» // Герценовские чтения: Межвуз. конференция Ист. науки. Л., 1968; Д е й ч Г.М. «Губернские ведомости» как исторический источник // Вспомогательные исторические дисциплины. Л., 1978. Т. 9; Б у р м и с т р о в а Л.П. Провинциальная газета в эпоху русских просветителей. К., 1985; Указатель статей по археологии, истории и этнографии, помещённых в неофициальной части «Казанских губернских ведомостей» (1878–1891) // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, вып. 1.

*Л.П.Бурмистрова, Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЕ ИЗВЕ́СТИЯ»** («Казан хәбәрләре»), иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби газета; Казан губернасында беренче вакытлы матбугат басмасы. 1811 елның 19 апреленнән 1820 нең 29 декабренә кадәр Казанда рус телендә — атна саен, 1815 тән соң — атнага 2 тапкыр нәшер ителә. И.И.*Запольский* тырышлыгы б-н басыла башлый. Нашире — Д.Н.*Зиновьев*, аннан соң Казан ун-ты (19 нчы саннан башлап). Мөхәррирләре — Г.Н.*Городчанинов*, В.М.Перевощиков. Газетада В.Я.Баженов, Н.М.Ибраһимов, М.В.Полиновский, М.С.Рыбушкин, П.А.Словцов, К.Ф.Фукс һәм Казан әдәбият сөючеләр җәмгыятенең башка әгъзалары язмалары бастырыла. «Сәхифәләремдә гамәлләрне бәян итәм, укучыларымны ялган б-н аздырмыйм» дигән эпиграф б-н чыга. Басманың максаты 1812 елга газетага язылырга чакырган белдерүдә болай


КАЗАНСКІЯ ГУБЕРНСКІЯ ВѢДОМОСТИ.


КАЗАНСКІЯ ГУБЕРНСКІЯ ВѢДОМОСТИ.


КАЗАНСКІЯ ГУБЕРНСКІЯ ВѢДОМОСТИ.


КАЗАНСКІЯ ГУБЕРНСКІЯ ВѢДОМОСТИ

«Казанские губернские ведомости» мәкаләсенә.

дип билгеләнә: «Җирле Казан губернасы һәм аның б-н чиктәш һәм элемтәдә торган башка губерналар һәм илләр халкы файдасына». Газета үзенең укучыларына Россиядәге мөһим иҗтимагый-сәяси яңалыклар турында хәбәр итә, тарих, статистика һәм этнография турында мәкаләләр бастыра. «К.и.»нең беренче саннарының эчтәлеген шәхси һәм рәсми белдерүләр, Идел-Кама төбәге буенча статистик мәгълүматлар, мәзәкләр, төрле хәбәрләр, ш.и. крепостной кешеләрне сату-алу яки яллау хакындагы язмалар алып тора. «К.и.»




«Казанские известия» газетасы.

халык мәгарифе министры тарафыннан берничә мәртәбә тәнкыйтьләнә, ул «кайбер мәкаләләрнең эчтәлеге әдәпсез» дип белдерә, аңарда «типографик хаталар гына түгел, ә телгә һәм стильгә каршы килү дә бар» дип саный. Тиздән Казан ун-ты «К. и.»не нәшер итү өчен махсус ком-т оештыра, аның составына Ф.К.Броннер, П.С.Кондырев, Г.Б.Никольский, К.Ф.Фукс, Ф.Х.Эрдман керә. Газетаның программасы киңәйтелә, әмма шул ук министр боерыгы буенча хокук белеме, фәлсәфә, мед. хәбәрләре турындагы бүлекләр ябыла. Сәнәгать үсеше, сәүдә, Идел-Кама төбәгенең мәдәни тормышы, тарих, этнография, икътисад турында күзәтүләр, Россия империясенең эчке һәм тышкы сәясәте турындагы төрле мәкаләләр басыла башлый. 1812 елгы Ватан сугышы вакыйгаларына, гаскәр башлыкларының уңышларына, халык патриотизмына, ополчение төзүгә зур урын бирелә. «К.и.»дә рус тарихының героик сәхифәләрен яктырткан мәкаләләр, Г.Н.Городчаниновның мәдхияләре һәм кантаталары, Н.М.Ибраһимов шигырьләре басыла. Бераз вакыттан соң газета абруй казана, шулай да Казан уку-укыту округы попечителе итеп сайланган М.Л.Магницкий аны яптырырга ирешә. Ш.у.к. «*Казанский вестник*».

*Әд.:* С м ы ш л я е в Д.Д. Указатель статей о Пермской губернии, помещённых в «Казанских известиях» (1811–1820) // Пермский сборник. Повременное издание. М., 1860. Кн. 2; П о н о м а р ё в П.А. Полный систематический указатель статей местно-областного содержания, напечатанных в «Казанских известиях», издававшихся при Казанском университете с 1811 по 1821 г. К., 1880; К у р а н о в К.Н. Особенности формирования жанров публицистики в казанской прессе первой трети XIX века // Жанры журналистики. К., 1972; М и х а й л о в а С.М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока России (XIX век). К., 1991.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЕ НО́ВОСТИ»** («Казан яңалыклары»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. «*Городской листок*» г-тасының дәвамчысы. 1885 елның 10 июненнән 1886 ның 29 декабренә кадәр Казанда рус телендә атнага 4 тапкыр нәшер ителә, барлыгы 226 саны чыга. Наширләре — С.А.Гисси, В.М.Ключников, мөхәррире — М.В.Ключников. Хөкүмәт карарлары турында телеграммалар, яңалыклар, төрле җәмгыятьләрнең (мәхкәмә, фәнни һәм хәйрия) утырышлары турында хисаплар басыла. Казан шәһәр хуҗалыгы торышына,халыкның тормыш хәленә, шәһәрдәге яшәү шартларына зур игътибар бирелә, җирле үзидарә органнарының бу юнәлештәге эшләре кискен тәнкыйтьләнә. Газетаның «Казан елъязмасы», «Театраль күзәтүләр», «Белешмәләр сәхифәсе», «Белдерүләр» һ.б. даими рубрикалары була. Дөньяви хроникага аерым урын бирелә.Мөхәррире авырып китү сәбәпле, газета басылудан туктый.

*Г.Р.Заманова.*

**КАЗА́НСКИЙ** (Ибраһимов) Гыйләҗетдин Ибраһим улы (1891, Казан губ. Казан өязе, хәзерге Арча р-ны Өчиле а. — 1938, Минзәлә ш.), драма актёры, режиссёр. Татар проф. театрына нигез салучыларның берсе. Сәхнә эшчәнлеген 1908 елда Уфа шәһәрендә башлый, 1912 дән «*Нур*» труппасында эшли. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия фронт театры бригадаларында катнаша. 1920 дә Уфа күрсәтмә татар-башкорт труппасын оештыручыларның берсе (1922 дән — Татар-башкорт драма театры). 1930–34 тә Татар акад. театрында, 1934 тән Минзәлә колхоз-совхоз театрында. Киң диапазонлы артист: сәхнәдә яшь герой образларын югары романтик рухта гәүдәләндерә, гадәти тормыш-көнкүреш хәлләрен ышандырырлык итеп күрсәтә белә; җырлау сәләтенә ия булганга, муз. спектакльләрдәге баш рольләрне башкара. Уйнаган рольләре — Закир («Бәхетсез егет», Г.Камал), Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Таһир («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Гали («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов), Сөләйман («Яшә, Зөбәйдә, яшим мин», С.Рәмиев), Мулла («Кем гаепле?», Ф.Нурмави), Фәхретдин («Мөсыйбәте Фәхретдин», Н.Вәзиров), Борис («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Фердинанд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Жан Рено («Хөкем хатасы», А.Деннери).

*И.И.Илялова.*

**«КАЗА́НСКИЙ БИБЛИОФИ́Л»** («Казан китап сөючесе»), тәнкыйди-библиографик, иллюстрацияле журнал. Библиографларның Казандагы «*Китап дуслары*» түгәрәге, ә 1922 елдан — *Татгосиздат* органы. 1921–23 тә рус телендә Казанда нәшер ителә, барысы 4 саны чыга. Редколлегия төркеменә сәнгать белгече галиме П.М.Дульский, Татгосиздатның Казан бүлеге җитәкчесе И.П.Кочергин, Казан ун-ты укытучылары — физик Б.И.Смирницкий, тарихчы М.К.Корбут, әдәбият белгече Г.Ф.Линсцер керә. Журналда Казан, Мәскәү, Петроград, Самара, Сембер библиографлары, әдәбиятчы һәм тарихчыларыннан В.Я.Адарюков, Н.П.Андреев, Н.Ф.Бельчиков, Б.С.Боднарский, Л.К.Ильинский, А.И.Малеин, М.В.Нечкина, А.С.Поляков, Г.И.Поршнев, Н.Н.Столов, Е.И.Шамурин һ.б. хезмәттәшлек итә. Басманың беренче санында библиография бүлеге каршында оешкан түгәрәк уставы һәм журналның тәфсилле программасы басылып чыга. Редакция фикеренчә, бу басма Татарстанда китап эше барлыкка килү һәм аны өйрәнү мәсьәләләрен хәл итү өчен кирәк була. «К.б.»ның 1 нче санына Мәскәүнең «Печать и революция» (1922, № 1), «Народное просвещение» (1921, № 84) ж-лларында, Петроградның «Книга и революция» ж-лында (1921, № 12) чыккан рецензияләрне күчереп бастыралар. «К.б.»ның төп бүлекләре: «Гомуми бүлек»,«Библиография», «Хроника» һәм «Рәсми бүлек». «Гомуми бүлек»тә кайчакта очраклы гына сайлап алынган тарихи-әдәби һәм фәнни мәкаләләр басыла. Күләме б-н журналның яртысын алып торган «Библиография» бүлегендә фәлсәфә, дин, тел һәм әдәбият, сәнгать, тарих, география, табигать фәннәре, китап белеме, китап тарихы буенча бәяләмәләр, рецензия, рефератлар, китап, брошюра, журнал мәкаләләренә аннотацияләр урнаштырыла. Матбугат эше турында мәкаләләр басыла (В.Я.Адарюков, И.П.Кочергин, Г.Ф.Линсцер, И.Д.Рождественский һ.б.). «Гомуми бүлек» рубрикасында библиографик матбугатка, әдәбият күрсәткечләренә, белешмә басмалар һәм календарьларга рецензияләр һәм библиографик күзәтүләр урын ала. «Сәнгать» бүлегендә В.Я.Адарюков, Б.П.Денике, А.А.Захаров, П.Е.Корнилов үзләренең мәкаләләре б-н чыгыш ясыйлар; Б.М.Кустодиев, З.Е.Серебрякова, В.Д.Фалилеев, А.Г.Платунова һ.б. иҗатына күзәтүләр ясала. Журналда уеплап бизәүчеләр, илл. осталары һәм китап бизәү сәнгате турында материаллар чыга (авторлары — П.М.Дульский, Н.Н.Столов, П.Е.Корнилов). Казан ханлыгы чоры кулъязмалары, Казан тарихы турында мәкаләләр басыла (авторлары — М.А.Васильев, Б.П.Денике, П.Е.Корнилов, Е.И.Нелидов, А.И.Никифоров, Н.М.Петровский һ.б.).




«Казанский библиофил» журналы.

*Әд.:* Очерки истории русской советской журналистики (1917–1932). М., 1966; Б е р к о в П.Н. История советского библиофильства (1917–1967). М., 1971; А р и с т о в В.В., Е р м о л а е в а Н.В. Всё началось с путеводителя... К., 1975; Б у г а р о в а О.Л. «Казанский библиофил» // Советская библиография. 1985. № 2; Книга: Энцикл. М., 1999. *Р.А.Айнетдинов.*

**«КАЗА́НСКИЙ БИРЖЕВО́Й ЛИСТО́К»** («Казан биржа сәхифәсе»), иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм сәүдә эшләре газетасы. Казан сәүдәгәрләре биржасы органы. 1868 елның 1 декабреннән 1892 гә кадәр чыга (1882 гә кадәр — атнага 2, 1886 елга кадәр — атнага 3 тапкыр, 1886 дан көн саен нәшер ителә). Төрле еллардагы мөхәррирләре — А.К.Чугунов, А.И.Миропольский, М.В.Ключников, Н.Я.Агафонов, Д.А.Соколовский, Н.А.Ильяшенко, С.А.Гисси һ.б. Газета сәнәгать, сәүдә


КАЗАНСКІЙ БИРЖЕВОЙ ЛИСТОКЪ.

«Казанский биржевой листок» газетасы.

һәм финанс даирәләре мәнфәгатьләрен чагылдыра. Хөкүмәт күрсәтмәләре, биржа хәбәрләре, банк, сәүдә корреспонденцияләре, Россия һәм чит илләрнең төрле шәһәрләреннән хәбәрләр, статистика мәгълүматлары, фельетоннар, Казан губернасы тарихы буенча мәкаләләр һәм отыш тиражлары басыла. Башкала газеталарыннан күчереп басылган язмаларга зур урын бирелә. *Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЙ ВЕ́СТНИК»** («Казан хәбәрчесе»), айлык журнал. «*Казанские известия*» г-тасының дәвамчысы. Казан ун-ты басмаханәсе тарафыннан 1821 елның гыйнварыннан 1833 нең декабренә кадәр рус телендә нәшер ителә. 39 кисәктән торган 84 китапта чыга. Журнал б-н составы үзгәреп торган «Нәшрият комитеты» идарә итә. Аның актив әгъзалары арасында Казан ун-ты укытучылары В.Я.*Баженов*, В.Я.*Булыгин*, Г.Н.*Городчанинов*, И.И.*Дунаев*, И.Ф.Краузе, Н.И.*Лобачевский*, В.М.Перевощиков, В.И.*Тимьянский*, М.А.*Пальмин*, М.С.*Рыбушкин* була. Танылган язучылар һәм галимнәр: Н.С.Арцыбашев, В.Я.Булыгин, А.К.Казимбәк, О.М.Ковалевский, А.Я.Купфер, И.М.Симонов, К.Ф.Фукс, Э.А.Эверсман, Ф.И.Эрдман һ.б. язмаларын бастыра. «К.в.»ны башлап чыгаручы Казан фәнни округы попечителе М.Л.Магницкий була. Аның мәгариф өлкәсендә үткәргән реформаларын исәпкә алып, ком-т журналның программасын эшли. «Җитәкчелек күрсәтмәләре» бүлегендә Казан фәнни округы буенча Халык мәгарифе министрлыгы указлары, күрсәтмә һәм боерыклары басыла. «Әсәрләр һәм тәрҗемәләр» бүлеге үгет-нәсыйхәт һәм фатиха бирү характерындагы мәкаләләрне, ком-т әгъзаларының язмаларын, Казан ун-ты студентларының «чиркәү әдипләре һәм грек, латин классикларыннан» тәрҗемәләрен үз эченә ала. Цензура эшен М.Л.Магницкий үзе башкара. «Халык тәрбиясе рухы һәм дини тәрбиянең мөһимлеге» турында мәкаләләр урнаштырыла. Библиядән алынган сюжетларга, беренче христиан эшлеклеләре тормышы турындагы язмаларга, тәкъва тормыш рәвешен пропагандалауга зур урын бирелә. М.Л.Магницкий Казан фәнни округы попечителе вазифасыннан азат ителгәч (1826 ел, май), «К.в.»ның дини юнәлештән читкә тайпылуы күзәтелә. Шигырьләр, география, төбәкне өйрәнү һәм этнография турындагы язмалар, юлъязмалар, фәнни, фәнни-популяр, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре басыла башлый. Н.И.Лобачевскийның бернечә хезмәте, ш.и. «Геометрия башлангычлары турында» («О началах геометрии»), «Иң мөһим тәрбия чаралары турында» («О важнейших предметах воспитания») әсәрләре басыла. Журналда ун-т профессорларының еллык хисаплары, нотыклары, иганәчелек турында хәбәрләргә урын бирелә. 1832 дә басманың 2 бүлеге ирекле рәвештә чыгып килә, 1833 тә бары тик «Җитәкчелек күрсәтмәләре» генә дөнья күрә. «К.в.» казанлыларның иҗтимагый-сәяси характердагы хәбәрләргә ихтыяҗын канәгатьләндерми. Журнал язылучылар арасында абруен югалта, аның тиражы даими рәвештә азая бара һәм 1833 тә бары тик 200 данә генә тәшкил итә (1821 дә 500 данә). «К.в.»ка кушымта буларак, «*Прибавление к «Казанскому вестнику»*» исемле атналык г-та чыга башлый. 1833 ел ахырында Казан фәнни округы попечителе М.Н.Мусин-Пушкин Казан ун-ты каршында әдәби журнал чыгаруны кирәксез дип таба һәм журнал ябыла. Ш.у.к. «*Учёные записки Казанского университета*».


КАЗАНСКІЙ ВѢСТНИКЪ,

издаваемый при Императорскомъ Казанскомъ Университетѣ.

ЧАСТЬ ПЕРВАЯ.

КНИЖКА I.

ГЕНВАРЬ.

1821 года.

Печатано въ Университетской типографіи.

«Казанский вестник»журналы.

*Әд.:* Л и х а ч ё в Н.П. «Казанский вестник» // Книговедение. 1894. № 2–12; П о п о в Н. Общество любителей отечественной словесности и периодической литературы в Казани // Рус. вестн. 1859. Сент; К у р а н о в К.Н. Публицистика в «Казанском вестнике» (1821–1833) // Сб. аспирантских работ. Гуманитарные науки. Литературоведение. Языкознание. Журналистика. К., 1971; ш у л у к. Особенности формирования жанров публицистики в казанской прессе первой трети XIX века // Жанры журналистики. К., 1972; «Казанский вестник», 1821–1833 гг.: Указ. содерж. К., 2003. *Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЙ ВЕ́СТНИК»**, газета; к. «*Казан мөхбире*».

**«КАЗА́НСКИЙ ВЕ́ЧЕР»** («Казан киче»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби көндәлек газета. Кадетлар партиясе органы. Казанда 1906 елның 29 июленнән 1907 нең 30 ноябренә кадәр рус телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — Н.А.Скворцов, аңардан соң Н.П.Гусев. Газетаны чыгаруда кадетлар партиясенең күренекле вәкилләре И.И.Бабушкин, А.В.Васильев, П.Д.Долгорукий, И.А.Котелов, И.В.Мандельштам, А.А.Симолин, М.М.Хвостов, Г.Ф.Шершеневич, А.И.Шингарёв һ.б. катнаша. Редакция газетаны чыгаруга матди ярдәм итүче кадетлар партиясе карашларын пропагандалый. *Выборг өндәмәсеннән* соң һәм хөкүмәт кадетлар партиясен рәсмиләштерүдән баш тарткач, газетага элеккеге юнәлешен саклау куркыныч була башлый, г-та үзен «партиясез-прогрессив» дип билгеләп. «К.в.» сәхифәләрендә сайлауларга әзерлек, 2 нче чакырылыш Дәүләт Думасының эшчәнлеге киң яктыртыла. Кадетлар һәм программалары б-н аларга якын торган партияләр эшчәнлеге аеруча игътибарга алына. Басма җирле үзидарә ин-тының киң җәелүе өчен көрәшә, аның сәхифәләрендә җирле һәм шәһәр иҗтимагый идарә органнарының эшчәнлеге анализлана, Казан халкының яшәү шартлары уңайлылыгы һәм шәһәр хуҗалыгы мәсьәләләре күтәрелә. Шәһәр читендәгеләрнең хезмәт һәм көнкүреш мәсьәләләре газетаның игътибар үзәгендә була. Ш.у. к. «*Волжско-Камская речь*». *Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЙ ЗЕМЛЕДЕ́ЛЕЦ»** («Казан игенчесе»), журнал; к. *Вестник Казанской областной с.-х. опытной станции.*

**«КАЗА́НСКИЙ ЛЕТОПИ́СЕЦ»** («Казан елъязмачысы»), 16 йөзнең 2 нче яртысында язылган тарихи-публицистик әсәр. Төп нөсхәсе сакланмаган. Хәзерге вакытта башлыча 16 йөз ахыры — 17 йөзнең 1нче утызъеллыгына караган 300 дән артык күчермәсе мәгълүм. Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә 16–19 йөзләргә нисбәтле 7 күчермәсе саклана.

«К.л.»ның язылу вакыты — 1554–55 (Г.Н.Моисеева) яки 1564–66 еллар (Г.З.Кунцевич). Авторның Казанда әсирлектә яшәве, мөселманлыкка күчүе, Казан ханлыгы тормышының соңгы 20 елындагы (1532–52) вакыйгаларның турыдан-туры шаһиты һәм укымышлы кеше булуы, рухани һәм дөньяви әдәбиятны белүе текстта чагылыш таба. Тарихчы В.Н.Татищев «К.л.»ның авторы рухани Иоанн Глазатый булган, дип фаразлый.

Кыйссаның нигезен Казан һәм Казан ханлыгының барлыкка килү чорларыннан башлап, аларның 1552 елда рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынуына кадәрге тарихы тәшкил итә. «К.л.»ка Казан татарларының көнкүреше турындагы мәгълүматлар, риваятьләр һәм легендалар (Казанның нигезләнүе турында һ.б.) кергән. «К.л.»ның төп идеяләренең берсе — Казанның яулануын аклау. Бу максат б-н автор хикәяләүгә уйдырма эпизодлар кертә, тарихи вакыйгаларны тенденциоз рәвештә тасвирлый, Казан ханлыгы һәм казанлылар турында тискәре фикерләр әйтә. Аның тарафыннан Казанның буйсындырылуы Ходай җәзасы һәм гамәле тормышка ашу буларак күрсәтелә.

«К.л.»ның чыганаклары — Никон елъязмасы, 1479 елгы Мәскәү бөек кенәз елъязмалары тупланмасы (Мәскәү елъязмачылыгы), ш.у. Новгород елъязмалары, Воскресение елъязмасы, 1517 елгы редакциядәге Рус Хронографы, «Патша һәм бөек кенәз Иван Васильевич патшалык итә башлаган чор елъязмачысы» («Летописец начала царства царя и великого князя Ивана Васильевича»), разряд китаплары, илчелек хатлары, җирле эшләр турындагы документлар, шәҗәрә китаплары, «Дәрәҗәләр китабы» («Степенная книга»), Иван IV нең 1551 елгы Стоглав соборындагы нотыгы, Иван IV нең Курбскийга хаты, сугышчылар хикәятләре, аерым затларның тормышы турындагы язмалар, Нестор-Искәндәрнең «Царьград турындагы хикәят»е («Повесть о Царьграде»), «Рус җиренең һәлакәте хакында сүз» («Слово о погибели Русской земли»), «Мамай явы турында хикәят» («Сказание о Мамаевом побоище»). «К.л.» авторы ш.у. үзенең шәхси күзәтүләренә һәм татарлар сөйләгәннәргә дә таянган.

«К.л.» күчермәләреннән 18–19 йөзләрдә тарихчылар А.И.Лызлов, В.Н.Татищев, М.М.Щербатов, Н.М.Карамзин, Н.С.Арцыбашев файдаланганнар. Акад. Г.Ф.Миллер Себергә экспедиция б-н барганда (1733–43) Казанда «К.л.»ның иң тулы нөсхәләренең берсен күчереп ала һәм үз күчермәсен «Борынгы һәм урта заманнар Казан тарихы тәҗрибәсе» («Опыт Казанской истории древних и средних времян», СПб., 1767) китабын язу өчен П.И.Рычковка бирә.

Ядкәр беренче тапкыр 18 йөздә басылып чыга («Ике борынгы күчермә буенча XVI йөздә яшәгән билгесез язучының Казан патшалыгы турындагы тарихы» — «История о Казанском царстве неизвестного сочинителя XVI столетия по двум старинным спискам», СПб., 1791). Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы Ф.Т.Васильев кулындагы күчермә аның акчасына Казанда факсимиль басма «Казан патшалыгы барлыкка килү турында хикәят» («Сказание о зачатии царства Казанского», 1902, проф. Н.Ф.Катанов кереш сүзе) буларак нәшер ителә. «К.л.» текстының беренче фәнни басмасы (152 күчермә файдаланыла) С.-Петербург ун-ты магистры Г.З.Кунцевич тарафыннан әзерләнә һәм «Рус елъязмалары җыелмасы» («Полное собрание русских летописей», СПб., 1903, т.19) составында дөнья күрә. «К.л.» хәзерге рус теленә күчерелгән («Казан патшалыгы турында хикәят» — «Сказание о царстве Казанском», М., 1959). «К.л.»ның күчермәләре филологлар һәм тарихчылар Г.Н.Моисеева, Т.Ф.Волкова, Л.А.Дубровина һ.б. тикшеренүчеләр тарафыннан өйрәнелә. Соңгы тапкыр 2000 дә Мәскәүдә басылып чыга.

Чыг.: Казанская история. М.–Л., 1954; Казанская история // Памятники литературы Древней Руси. Сер. XVI в. М., 1985. Вып. 7; История о Казанском царстве (Казанский летописец). М., 2000.

*Әд.:* Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве, или Казанский летописец: Опыт ист.-лит. исслед. СПб., 1905; Моисеева Г.Н. Автор «Казанской истории» // Тр. Отд-ния древнерус. лит. М.–Л., 1953. Т. 9; Кокорина С.И. К вопросу о составе и плане «Казанской истории» // Тр. Отд-ния древнерус. лит. М.–Л., 1953. Т. 12; Волкова Т.Ф. Казанская история // Словарь книжников и книжности Древней Руси. Л., 1988. Вып. 2, ч. 1; Дубровина Л.А. История о Казанском царстве (Казанские летописи): Списки и классификация текстов. Киев, 1989.

*И.Л.Измайлов, И.А.Новицкая.*

**«КАЗА́НСКИЙ ЛИСТО́К ДЛЯ СПРА́ВОК И ИЗВЕ́СТИЙ»** («Казанның белешмә һәм хәбәрләр сәхифәсе»), к. «*Городской листок*».

**«КАЗА́НСКИЙ МЕДИЦИ́НСКИЙ ЖУРНА́Л»** («Казан медицина журналы»), табибләр өчен фәнни-гамәли журнал. «*Дневник Казанского общества врачей при Императорском Казанском университете*» ж-лының дәвамчысы. Казанда рус телендә 1901 елдан нәшер ителә (1925 елда — айга бер, 1957 дән 2 айга бер тапкыр чыга). 1917 нең гыйнварыннан 1921 гә һәм 1941 нең июненнән 1957 нең июленә кадәр чыгудан тукталып тора. Оештыручылары: «Татмедиа» ААҖ, Казан медицина ун-ты. Төрле елларда мөхәррирләре — Л.О.*Даркшевич*, А.Н.*Казимбәк*, Н.А.*Геркен*, Ф.Я.*Чистович*, Н.А.*Миславский*, В.С.*Груздев*, Т.И.*Юдин*, И.С.*Алуф*, В.Л.*Боголюбов*, М.И.*Мастбаум*, Е.М.*Лепский*, А.Б.*Терегулов*, Н.Н.*Лозанов*, А.П.*Нестеров*, Д.М.*Зөбәеров*, А.С.Созинов (2011 дән).

Журналның авторлык активын галимнәр генә түгел, ә сәламәтлек саклауны оештыручылар һәм табиб-практиклар да тәшкил итә. Журналда төрле елларда А.Г.Агабабов, Е.В.Адамюк, В.М.Бехтерев, В.Л.Боголюбов, Н.Д.Бушмекин, К.М.Быков, Н.А.Виноградов, Н.О.Ковалевский, Н.И.Котовщиков, Н.М.Любимов, В.А.Обух, И.П.Павлов, В.Н.Парин, В.Н.Первушин, А.В.Петрова, И.П.Разенков, В.И.Разумовский, Н.А.Семашко, З.П.Соловьёв, А.В.Фаворский, В.П.Филатов һ.б. язмалары бастырыла. Редакция мед. өлкәсендәге фундаменталь һәм гамәли белемнәрне таратуны, укучыларны мед. фәнендәге яңа уңышлар б-н таныштырып баруны басманың төп бурычы итеп саный. «К.м.ж.» медицинаның иң мөһим тармаклары: терапия, хирургия, акушерлык, гинекология, гигиена, социаль медицина, дерматовенерология һәм сәламәтлек саклауны оештыру буенча язмалар бастыра. Фәнни-тикшеренү үзәге ролен үтәп, журнал теоретик һәм гамәли медицинаның төрле өлкәләрендә үткәрелгән экспериментал, клиник тикшеренүләргә багышланган язмаларга зур урын бирә, чит илләрдә һәм үзебезнең илдә чыгып килүче журналларда басылган мәкаләләргә рефератлар, фәнни мед. җәмгыятьләре эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр урнаштыра, Россиядә һәм чит илләрдә узган медицина съездлары һәм конференцияләре турында мәгълүмат бирә, яңа чыккан китапларга рецензияләр, докторлык диссертацияләре яклау турында хәбәрләр бастыра. «К.м.ж.» Россия сәламәтлек саклау системасында үткәрелгән чараларны яктырта, яңа дарулар турында белешмә бирә, дәвалау учреждениеләре эшчәнлегенең хисапларын, вакансияләр турында белдерүләр, табибләр конкурслары, хастаханәләр ачылу турында хәбәрләр, укучы хатлары һ.б. бастырып бара.


КАЗАНСКІЙ
МЕДИЦИНСКІЙ ЖУРНАЛЪ.
Томъ I.
ЯНВАРЬ-ФЕВРАЛЬ
1901 г.

«Казанский медицинский журнал».

*Әд.:* Окулов А.М. Статьи об учёных Казани в «Казанском медицинском журнале» за 40 лет (1921–1960) // Казан. мед. журн. 1960. № 2; Харитонов И.Ф. Отражение деятельности хирургов в «Казанском медицинском журнале» // Казан. мед. журн. 1976. № 1; Альбицкий В.Ю., Шарафутдинова Р.М. История медицины на страницах «Казанского медицинского журнала» // Казан. мед. журн. 1976. № 2; Зубаиров Д.М., Закирова А.Ш. Сто лет на службе научной медицины // Науч. Татарстан. 2000. № 4; Яхонтов К.М. Указатель статей, помещённых в «Казанском медицинском журнале» за 1896–1913 гг. К., 1914.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКИЙ МУЗЕ́ЙНЫЙ ВЕ́СТНИК»** («Казан музей хәбәрчесе»), фәнни-нәфис журнал; Россиядә музейлар өчен беренче махсус матбугат басмасы. ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршындагы музейлар, сәнгать истәлекләрен һәм борынгы ядкәрләрне саклау эшләре Бөтенроссия коллегиясенең Казан бүлекчәсе, соңрак Казан губернасы халык мәгарифе бүлегенең мәктәптән тыш бүлекчәсе, аннан соң ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы. 1920–24 елларда Казанда рус телендә 17 саны нәшер ителә. Мөхәррире — П.М.*Дульский*, редколлегия төркеменә Б.Ф.Адлер, Г.С.Гобәйдуллин, М.И.Лопаткин, К.В.Харлампович керә. Журналда музей хезмәткәрләре, музей эше буенча җитәкче белгечләр Казан, Мәскәү, Ленинград, Ярославль, Себер шәһәрләре галимнәре: Д.Н.Анучин, Ю.Бахрушин, Н.Ф.Высоц-




кий, И.Э.Грабарь, Э.Ф.Голлербах, В.В.Егерев, Н.Ф.Катанов, П.Е.Корнилов, С.Ф.Ольденбург, Н.Н.Фирсов, М.Г.Худяков һ.б. язмаларын бастыралар. Басманың төп эчтәлеген музей эшчәнлегенең тарихы, теориясе буенча язмалар, музейларның мәдәни һәм тәрбияви роле турында мәкаләләр били. Журналның игътибар үзәгендә яңа җәмгыять шартларында музейлар үсешенең теоретик һәм гамәли проблемалары тора. «К.м.в.» ш.у. беренчә бәхәсле теоретик мәкалә бастырып чыгара: Б.Ф.Адлерның «Милли музей» («Национальный музей», 1921, № 1–2), Э.Ф.Голлербахның «Музей апологиясе» («Апология музея» — Н.Ф.Фёдоров тәгълиматы буенча музейлар төзүнең роле) һ.б. Басмада музей эшчәнлеген оештыруның төрле аспектлары, музейның мәгърифәтчелек эшчәнлеге (экскурсия эше, мәктәп музейлары һ.б.) анализлана. Мәскәү, Ленинград, Новгород, Пермь, Сембер, Ярославль шәһәрләрендәге, Себер һәм Кавказдагы музей эшчәнлеге турында язмалар басыла. Татарстандагы археол., тарихи, этнографик тикшеренүләрнең нәтиҗәләренә зур урын бирелә. Кызыклы коллекцияләрне тасвирлауга һәм экспедицияләргә багышланган мәкаләләр сериясе басыла. Урта гасырлар Болгар шәһәре терр-ясендә табылган истәлекләр җыелмасына багышланган язмаларга; Татарстан терр-ясендә борынгы рус сынлы сәнгатен табу буенча И.Э.Грабарь җитәкчелегендәге Мәскәү галимнәре экспедициясе язмаларына; Казан рәссамнарына, сынлы сәнгать галереясына, аерым картиналарны тасвирлауга зур урын бирелә. Журнал РКП(б) ҮКның «Ведомство басмаларын кыскарту турында»гы карары нигезендә чыгудан туктый (1924).

*Әд.:* Синицына К.Р. «Казанский музейный вестник» (1920–1924 гг.). К., 1963.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«КАЗА́НСКИЙ ПЕДАГОГИ́ЧЕСКИЙ ЖУРНА́Л»** («Казан педагогик журналы»), фәнни-гамәли басма. 1995 елның октябреннән Казанда рус телендә нәшер ителә. Оештыручылары — РМАнең Проф. белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-ты, Социаль белем бирү академиясе. Исеме өстәмә рәвештә «Методология, теория, практика» аныкламасы б-н тулыландырыла. 2003 кә кадәр «Профессиональное образование» дигән исем б-н чыга. Төрле еллардагы мөхәррирләре — П.Н.*Осипов*, Г.В.*Мөхәммәтҗанова*. Журналда өзлексез проф. белем бирү системасының барлык бүлекләрен дә үстерү, гомуми һәм проф. белем бирү бергәлеге, гомумдөнья стандартларына туры килгән заманча белгечләр тәрбияләү мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр басыла. Төп бүлекләре: «Теория һәм методология», «Профессиональ белем бирү», «Югары белем», «Социаль тәрбия», «Педагогика һәм психология», «Чит илләр тәҗрибәсе», «Мәгариф тарихы» һ.б.

**«КАЗА́НСКИЙ ТЕЛЕГРА́Ф»** («Казан телеграфы»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм сәүдә газетасы; 19–20 йөзләр чигендә Идел-Кама өлкәсендәге иң эре провинция басмаларының берсе булып санала. 1893 елның 11 апреленнән 1917 нең 11 мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 7103 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — А.Г. һәм Н.А.Ильяшенколар. 1903 тә Н.А.Ильяшенко Матбугат эшләренең баш идарәсенә газетаның татарча тәрҗемәсен чыгаруны сорап мөрәҗәгать итә, ләкин аның үтенече кире кагыла. Төрле елларда газетада күренекле иҗтимагый-сәяси һәм дин эшлеклеләре, педагоглар һәм Казан дәүләт ун-ты галимнәреннән Н.Я.Агафонов, епископ Андрей, А.С.Архангельский, Н.Ф.Высоцкий, Е.Ю.Геркен, Н.П.Загоскин, Н.Ф.Катанов,


КАЗАНСКІЙ ТЕЛЕГРАФЪ

«Казанский телеграф» газетасы.

П.А.Пономарёв, А.С.Рождествин, И.Н.Смирнов, И.И.Степанов, П.П.Траубенберг, Н.Н.Фирсов, Н.Ф.Юшков һ.б. хезмәттәшлек итәләр. «К.т.»ның беренче санында ук газетаның бәйсез характерда булуы күрсәтелә, ә максаты «Идел-Кама төбәге һәм Казан халкының ихтыяҗларын гадел, дөрес чагылдыру» дип белдерелә. Газета материаллары тема һәм жанр төрлелеге б-н аерылып тора. Хөкүмәт карарлары, рәсми циркулярлар, Россия телеграф агентлыгы телеграммалары басыла. Төрле партияләрнең, аеруча октябристларның һәм Дәүләт Думасының эшчәнлегенә һәм сайлау алды кампанияләренә зур игътибар бирелә. Дини-әхлакый, сентименталь-мещан һәм дини характердагы проблематикага караган язмалар, хикәя, повесть, романнар басыла. Күп өлешен сәүдәгә кагылышлы белдерүләр алып тора. 1900 еллар башында редакция үзенең партиясезлек принципларыннан тайпыла; «бердәм һәм бүленмәс Россия» лозунгын яклап чыга башлый, монархик, антисемит карашларда тора.

*Әд.:* Хайрутдинова Л.Ф. «Казанский телеграф»: Литературно-критическое наследие (1893–1917 гг.). К., 2000.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКОЕ КОРМОВО́Е»**, тары сорты. 1987 елда «Татарстан кыры» ФҖБдә Л.Г.Сәгъдиева, М.М.Маликов, И.А.Шурина, Н.С.Мөхәммәтова, Ф.М.Никитина тарафыннан «Кормовое 1» һәм «Казан 506» гибрид популяциясеннән индивидуаль сайлап алу ысулы б-н чыгарыла. Соң өлгерешле; вегетация чоры тишелүдән яшел массаның уңышын җыюга кадәр 50–60 көн, орлыгының тулысынча өлгерүенә кадәр 85–100 көн. Үсемлекнең биеклеге 130–145 *см*. Саламы нечкә, яфраклануы тигез. Яфраклары эре, озынлыгы 35–50 *см*, киңлеге 1,5–2 *см*. Себеркәче җәенке, эре, көпшәк, озынлыгы 30–42 *см*; төсе ачык яшел. Бөртеге вак, озынча-түгәрәк формада, ачык төстә. 1000 бөртекнең авырлыгы 6–6,2 *г*. Азык массасында беренчел протеин 10–14% тәшкил итә. Бу сорттан печән һәм ярма-бөртек алына, яшел массасы (1 *га* дан 350 *ц* га кадәр) һәм ярмасы (1 *га* дан 45 *ц* га кадәр) буенча югары уңышлы.

Яшел массасының шикәр-протеин чагыштырмасы — 1,62. 1 *га* дан шикәр җыелмасы 463 *кг*, протеинныкы 286 *кг*. Стандарт «Кама» сорты б-н чагыштырганда тузанлы кисәү гөмбәсе һәм некротик меланоз авыруына чыдам. Терлек азыгы чәчүлекләрендә яшел азык, печән, үлән оны, сенаж һәм силос буларак файдалану өчен үстерергә тәкъдим ителә. 1991 дә РФнең 9 төбәге буенча Дәүләт реестрына кертелә.

*Әд.* к. «*Казанская местная*».

**«КАЗА́НСКОЕ ПОДВО́РЬЕ»** (Щетинкин номерлары», «Казан кунакханәсе»), Казанда архит-ра ядкәре. Кунакханә комплексына «Казанское подворье», Щетинкин номерлары һәм Мыльников йорты керә. 1843–48 елларда арх. Ф.И.Петонди тарафыннан әүвәлге корылмаларны реконструкцияләү нәтиҗәсендә соңгы ампир стилендәге бердәм фасад б-н берләштерелә. Пландагы Г-рәвешле бинаның беренче катында кибетләр, икенче һәм өченче катларында коридор системалы номерлар урнаша. Чуеннан коелган колонналы матур чыгынтылы төп ишек арх. М.П.Коринфский проекты буенча эшләнгән ордерның дүрт пилястралы портиклары б-н бизәлгән бинада үзәк өлешне алып тора. Гөмбәз б-н төгәлләнгән ярымтүгәрәк йортның дүрт катлы почмак өлешендәге икенче катында



«Казанское подворье». Арх. Ф.И.Петонди. 1843–48. 20 йөз башы фоторәсеме.

ресторан эшли. Ул 1902 елда арх. Л.К.Хрщонович тарафыннан эклектик формаларда реконструкцияләнә. 1965–66 елларда ресторан һәм кунакханәнең интерьерлары арх. А.А.Спориус һәм М.С.Артамонов проектлары буенча яңартыла. 2002 дән «К.п.» га капиталь реконструкция ясала. Совет чорында кунакханәдә А.В.Луначарский, В.В.Маяковский, А.М.Горький һ.б. туктала.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

**«КАЗА́НСКОЕ СЛО́ВО»** («Казан сүзе»), иҗтимагый-сәяси көндәлек газета. «*Город Казань*» г-тасының дәвамчысы. 1917 елның 16 апреленнән 1918 нең июненә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 317 саны чыга. Наширлары Ю.А.Еленев, Н.А.Макаров һәм журнал коллективы була; мөхәррирләре — Ю.А.Еленев, В.С.Андреев, Г.П.*Деника*. Газетада көн саен «Петроград телеграф агентлыгы телеграммалары» басыла. Редакция газетаны «партиясез-демократик» дип атый. «К.с.» Вакытлы хөкүмәт эшчәнлеген һәм сугыш хәрәкәтләрен яктыртып бара, Казан хәрби округы штабының эшчәнлеге турында белешмәләр бирә. Казандагы иҗтимагый тормышның төрле аспектларына кагылышлы мәкалә һәм белешмәләр басыла; шәһәр думасы, идарә һәм аның оештыру комиссияләре утырышлары турында хәбәрләр урын ала. Казан шәһәр үзидарә органнарының эшлексезлеге һәм шәһәр хуҗалыгының канәгатьләнмәслек торышы тәнкыйтьләнә. Гаугалы хәбәрләргә һәм булып үткән хәлләр турындагы белешмәләргә зур урын бирелә.

*Г.Р.Заманова.*

**«КАЗА́НСКОЕ У́ТРО»** («Казан иртәсе»), атналык иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Казанда рус телендә якынча 1915 елның 7–19 октябрьләрендә 7 саны нәшер ителә. Нашире — Ю.А.Еленев, мөхәррире — Л.К.Медведев. Газета материалларының күпчелеген Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында барган хәрби хәрәкәтләр турында мәгълүмат бирүче һәм Петроград хәрби округы җитәкчелеге эшчәнлеген яктыртучы үзәк матбугаттан күчереп басылган язмалар били. Редакциянең игътибар үзәгендә Дәүләт Думасы эшчәнлеге тора. Эшчеләр сыйныфы мәсьәләләре буенча материалларга аерым урын бирелә. «Казан эшчеләре арасында» рубрикасы Алафузовлар ф-касы һәм з-длары эшчеләренең авыр хезмәт һәм тормыш шартлары турында мәгълүмат бирә. 15 сентябрьдә чыккан 2 нче санында И.М.*Гаспринский* истәлегенә багышланган мәкаләләр басыла.

*Г.Р.Заманова.*

**КАЗАНСУ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 140 *км*, бассейнының мәйданы 2600 *км*². Елга башы Арча р-ны Бимәр авылыннан төньяктарак, Биектау р-ны терр-ясеннән ага; түбәнге агымы һәм тамагы Казан эчендә. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Куйбышев сусаклагычы 53 *м* билгесенә кадәр тулганнан соң, К.ның түбәнге агымнары Олы Дербышкидан башлап су басудан саклану зонасына керә һәм Казан эчендә елга участогы суднолар йөрерлек киң култыкка әверелә.





Казансу елгасы. 1. Биектау районы Коркачык авылы янында; 2. Троицкий урманы ягыннан күренеш.

Сусаклагыч һәм инженерлык дамбалары төзелгәнгә кадәр, К.ның иң түбәнге агымында елга юлы башка юнәлештә була: ул көнчыгыш, төньяк һәм көнбатыштан Елантау тавын урап узган һәм Игумный посёлогы б-н Бишбалта бистәсе арасында Иделгә койган. 1950 еллар уртасына кадәр К. тамагында пароход пристаньнары урнашкан була. 1955–57 дә шәһәр үзәгеннән Елга аръягына Киров исем. транспорт дамбасы төзелә, һәм аның астыннан К.ның яңа юлы салына. Иске юлның елга б-н гидрологик элемтәсе юкка чыга һәм агымсызга әйләнә.

Елганың су җыелу мәйданы күпсанлы кушылдыкларның (күбесенчә уңъяк) үзәннәре б-н бүлгәләнгән җиңелчә дулкынсыман асимметрик тигезлектән гыйбарәт. К. бассейнының гомуми авышлыгы көньяк-көнбатышка таба. Су җыелу мәйданының уртача киңлеге бөтен озынлыгында диярлек 17–18 *км*. К. бассейнының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш өлешендә рельефта Вятка Увалының абс. биеклекләре 150–210 *м* га җиткән көньяк тау тармаклары бар. Су җыелу мәйданы ерымлы-сызалы көчле эрозиягә дучар ителгән; кайбер урыннарда ярыклы, упкынлы, бүрәнкәле карст үсеш алган (Арча р-ны Төбәк-Чокырча авылыннан көнчыгыштарак тирәнлеге 3 тән алып 7 *м* га кадәр булган 20 гә якын шундый түбәнәюләр бар); *Зәңгәр күлләр*, Биектау р-ның Семиозёрка авылы, Якты Күл посёлогы һ.б. тирәсендә күлләр барлыкка килү ш.у. карст күренеше б-н бәйле. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%, сөрүлекләр 75%, күлләвекләр 5%.

К. үзәнлеге трапеция формасында, киңлеге 0,2–1,2 *км*, шактый өлеше асимметрияле: югары агымында Щербаково авылына кадәрге урыннарда күбесенчә уң ягы текә, Олы Дербышки авылыннан түбәндәрәк — сул ягы текә. Тугае тоташ, ике яклы, киңлеге 1 *км* га кадәр; өслеге тигез, урыны б-н сазлыклы. Казан эчендә тугае Куйбышев сусаклагычы сулары астында, рельефта тугай өсте террасасы күренә. Елга юлы бөтен озынлыгына диярлек бормалы, югары агымында киңлеге 1,8–2,5 *м*, түбәнге агымында — 30–40 *м* га кадәр. 2–3 *км* га кадәр озынлыктагы борылмалары бар. Урта агымында ярлары, нигездә, текә; урыны б-н биеклеге 2–5 *м* га кадәр җиткән киртләч, түбәнге агымында ярлар сөзәгрәк. Елга агымының уртача тизлеге җәйге саегу вакытында 0,1–0,3 *м/с*, ташу чорында — 0,7–0,8 *м/с*. Төбе тигез, күбесенчә ләмле, югары агымында — урыны б-н ташлы.

К.ның 41 кушылдыгы бар, иң зурлары: Ия (21,9 *км*), Бирәзә (19,2 *км*), Аты (20,1 *км*), Кызылсу (25,7 *км*), Шәмәк (27,6 *км*), Сола (27,3 *км*), Солонка (25,8 *км*), Коры Елга (20 *км*) — уң; Кесмәс (35 *км*), Киндерле (26 *км*), Нокса (42 *км*) — сул. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*². Уң кушылдыкларның шактые (Кызылсу, Шәмәк, Сола, Солонка) күбесенчә меридианнар юнәлешендә. Туенуы катнаш, җәйге челләдә җир асты сулары исәбенә тотрыклы. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–5, түбәнге агымында — 10 *л/с·км*² га кадәр. Елга режимын күзәтү



Казансу елгасы. Казан Кремле тирәсендәге яр буе күренеше.

1–5 тән алып 27 елга кадәрге периодлар б-н 11 постта өйрәнелгән. Хәзерге вакытта күзәтү-тикшерү эшләре Арча шәһәре янындагы суүлчәгеч постта алып барыла (1934 тән). Гидрологик режимы су биеклеге интенсив рәвештә арта барган югары су муллыгы һәм аның чагыштырмача тиз кимүе, саегу вакытының озакка сузылуы б-н характерлана. Су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре Арча шәһәре янында 4,8 *м* (макс. 5,5 *м*), Олы Дербышки авылы тирәсендә 5,4 *м* (макс. 7,2 *м*). Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана һәм 30 көн тирәсе дәвам итә. Аерым елларда ташу башлану вакыты уртачадан 15–20 көн аерма б-н булырга мөмкин. Шул чорда еллык су агымының 70–80% ы уза. Суның иң күп чыгымнары: Арча шәһәре янында 266 $м^3/с$, Олы Дербышки авылы тирәсендә 310 $м^3/с$. Җәйге саегу вакыты дәвамлы һәм тотрыклы. Яңгырдан ташулар күп түгел, ел саен күзәтелә, аларның уртача дәвамлылыгы 1–3 көн. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 4,8 $м^3/с$. Минималь чыгымнар август–сентябрь айларында күзәтелә. К. елгасында кышкы саегу, гадәттә, ноябрьнең беренче яртысына туры килә һәм 140–150 көн дәвам итә. Суының уртача күпьеллык чыгымы Арча шәһәре янында 3,7 $м^3/с$, Олы Дербышки авылы тирәсендә — 12,9 $м^3/с$. Елгада боз кату, гадәттә, ноябрьнең беренчеункөнлеге ахырында башлана. Боз капламы елганың күпчелек өлешендә тотрыклы, тоташ. Бозның калынлыгы кыш азагына 56 *см* (Олы Дербышки авылы) — 78 *см* га (Арча шәһәре) җитә; макс. калынлыгы — 165 *см*. Елганың кайбер урыннарында боз капламы тотрыксыз, кыш җылы булганда боз кату күзәтелми. Бу җир асты суларының елга юлына күпләп чыгуы (Зәңгәр күлләр, Олы Дербышки авылы тирәсендә) һәм сай урыннарда агымның көчле булуы б-н бәйле. Елга суының күп өлеше сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы; Арча шәһәре тирәсендә, Кызылсу һәм Сола елгалары тамаклары арасында — гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы. Гомуми минеральләшүе Арча шәһәре янында ташу вакытында 100–300 *мг/л*, җәйге саегу вакытында — 600 *мг/л*; Олы Дербышки авылы янында саегу вакытында ул 1500–1750, кайвакыт 2200 *мг/л* га җитә. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (Арча шәһәре янында 9 *мг-экв/л* дан алып Олы Дербышки авылы янында 23 *мг-экв/л* га кадәр). К. бассейнында суның гомуми күләме 16,4 млн. $м^3$ булган 26 буа төзелгән. Су ресурслары сугару (елына 12 млн. $м^3$), торак пунктларын су б-н тәэмин итү (елына 5 млн. $м^3$), балык үрчетү (балык үрчетү буаларының күләме 5 млн. $м^3$ тирәсе) өчен файдаланыла.

Елга ТРның табигать истәлеге буларак билгеләнә (1978). К. бассейнында *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы*, *Зәңгәр күлләр* табигать тыюлыгы, ш.у. *«Казансу башы»*, *Курса соры челән колониясе, Эстачи* (*Остачы*) *сөзәклеге, Семиозёрка урманы, Карьер чокыры, «Терлек таулары»* («Швейцария») табигать истәлекләре урнашкан.


*О.Н.Урбанова.*

**«КАЗАНСУ́ БАШЫ́»**, табигать истәлеге. Арча р-ны терр-ясендә, Казансу елгасының сулъяк ярында, аның югары агымында урнашкан. 1972 елда билгеләнә. Мәйданы 678 *га*. Арча урман хуҗалыгының Сорнар урманчылыгындагы урман массивының көнбатыш чиген били. Себер чыршысы, Себер ак чыршысы һәм сабакчалы имән ареаллары чиге тирәсендә көньяк тайга урманнары типларын берләштергән уникаль табигать комплексы. Көньяк юнәлештә абс. биеклекләренең күтәрелүе б-н бергә урманның составы да үзгәрә: караңгы ылыслы чыршылы-ак чыршылыдан — юкә һәм өрәңге катнаш караңгы ылыслы киң яфраклыга — имән катнаш киң яфраклы урманнарга күчә. Биредә Россиянең Европа өлешендәге урман зонасы формациясенең киң зональлеген кабатлаучы «вертикаль зональлек» күзәтелә. Төньяктагы иңкүлекле участокның рельефы тирән булмаган чокырлар б-н бүлгәләнгән, алар буенча Казансу елгасын туендыручы таш төпле инешләр ага. Уйсулык сөзәклекләре һәм алар арасындагы кәсле-көлсу туфраклы яссы сыртларны чыршы һәм ак чыршы катнаш караңгы ылыслы урманнар били. 150 яшьлек чыршыларның биеклеге 30–35 *м* га, кәүсә диаметры 60 *см* га җитә, урманнарның 1 нче ярусын тәшкил итә. Урман буйларында Себер ак чыршысыннан торучы урман участоклары бар. Бу урманнарның үлән составында кымызлык, ике яфраклы май чәчәге, Европа талакдары, эре чәчәкле сыңар чәчәк, яшел чәчәкле, уртача һәм түгәрәк каеш яфраклар, башка тайга төрләре; абаганың сирәк төре — Линней өер абагасы өстенлек итә. Яшел мүкләрнең тоташ капламы барлыкка килә. Территориянең күп өлешен чыршы һәм ак чыршы б-н беррәттән юкә, өрәңге, элмә, карама катнаш урманнар били. Агачлар астында урман зелпесе, миләш, сөялле кабар агачы, балан үсә. Үлән составында киң үләнле неморал төрләр өстенлек итә: сәрдә, күпьеллык зибык уты, кыр наратбашы, чәчсыман күрән, ланцетсыман йолдызак. Мүк капламы үсеш алмаган яки бөтенләй юк. Пермь утырмаларындагы кәсле-карбонатлы туфраклы көньяк калкулыклы участокларны имәнлекләр били. 1 нче яруста 25 *м* биеклектәге имәннәр, сирәк кенә чыршы; 2 нче ярусniкта очлы яфраклы өрәңге, элмә, карама. Куаклыкларда чикләвек куагы өстенлек итә. Үләннәрнең күләгәгә чыдам төрләре: исле сырмавык, Европа тайтоягы, күпьеллык зибык уты; эфемероидлар — казаяксыман җилдәк, фикария һ.б. үсә.

Табигать истәлеге терр-ясендә ак куян, тиен, төлке, бурсык, селәүсен, поши һ.б. хайваннар, кошлардан — кызылтүш, яшел нарат чыпчыгы, чытырдавык нарат чыпчыгы, зур песнәк, урман тургае, сары чәперчек, гади солы чыпчыгы яши. Типик тайга төрләре булган суер, боҗыр (чуар көртлек), өч бармаклы тукран һәм чукрак күке б-н беррәттән киң яфраклы урманда яшәүче кошлар — урман күгәрчене, күкшә, шәүлегән очрый; Татарстанда беренче тапкыр су тургае теркәлә (оялау чорында).

*Әд.:* Памятники природы Татарии. К., 1977; П о р ф и р ь е в В.С. Южно-таёжные памятники природы: Сурнарское лесничество // Охрана природы и биогеоценология. К., 1979. Вып. 2.

*Ф.Г.Борһанов.*



В.В. Казанцев.

**КАЗА́НЦЕВ** Валерий Васильевич (4.2.1945, Орёл өлкәсенең Верховье р-ны Верховье а.), гобойчы, ТССРның халык артисты (1991). 1970 елда Казан консерваториясен гобой буенча (М.Г.Зуевич классы) тәмамлый. ТР Дәүләт симф. оркестры артисты (1966 дан), 1973 тән гобойчылар төркеме концертмейстеры, бер үк вакытта 1973 тән Казан музыка уч-щесе, 1998 дән Казан консерваториясе







«Казансу башы». 1. Казансу елгасы башы; 2–3. Ак чыршы һәм чыршы урманнары.



Г.А. Казанцева.

укытучысы. К., ансамбль башкаручысы буларак, тәэсирле, матур тембрлы техникасы, югары проф. дәрәҗәдәге башкару осталыгы б-н аерылып тора.

**КАЗА́НЦЕВА** Галина Александровна (3.2.1953, Тукай р-ны Керәшен Мәҗьны а.), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано), ТР-ның халык артисты (2000). 1978 елда Казан консерваториясен (З.Г.Хисмәтуллина классы) тәмамлый. 1978–98 дә Татар опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Микаэла («Кармен», Ж.Бизе), Мюзетта («Богема», Дж.Пуччини), Алтынчәч (шул исем. опера, Н.Җиһанов), Галимә («Кара йөзләр», Б.Мөлеков), Сәрвәр («Башмагым», Ж.Фәйзи) һ.б. Киң, тулы диапазонлы, көчле һәм матур тембрлы тавышы, ачык чагылышлы иҗади индивидуальлеге, табигый сәхнә мөлаемлылыгы, югары проф. осталыгы б-н аерылып тора. К.ның концерт репертуарына классик, халык һәм эстрада вокаль әсәрләр керә. Концерт программаларының музыка җитәкчесе һәм төп башкаручысы, ш.и. «Бөтероссия керәшен татарларның фольклор музыкасы фестивале»н (1996) оештыручы буларак, керәшен татарлар муз.-фольклоры мирасын саклау һәм үстерүгә ярдәм итә, әлеге традицион көйләр җырчы репертуарының мөһим өлешен били. Россия шәһәрләрендә концертлар б-н чыгышлар ясый.

**КАЗА́НЦЕВА** Людмила Александровна (1.7.1955, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1999), проф. (2000). 1977 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1977 дән Казан һәм Биектау р-ны мәктәпләрендә химия һәм биология укыта. 1979 дан ПФА (РМА) Проф.-техник пед. фәнни-тикшерену ин-тында, 1995 тән Казан ун-тының пед. кафедрасында. Хезмәтләре урта һәм югары мәктәпләрдә заманча белем бирү процессының теориясе һәм методологиясе мәсьәләләренә карый.


Х е з м.: Исследовательский метод в условиях гуманизации образования. К., 1999.

**КАЗАНЧЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 19 *км*, бассейнының мәйданы 125,3 *км*². Мөслим р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Үрнәк авылыннан көньяктарак, тамагы Метрәй авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 205 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 34%. К.ның 1,4 тән алып 6,8 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 120 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. К. ноябрьнең беренче унконлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,173 *м*³*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 2,9 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАЗАНЧЫ́ БИГӘНӘ́Й** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 14 *км* көньяктарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 143 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә-19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, киез итек басу, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б. дә мәчет, тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 725,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 306, 1897 дә — 503, 1908 дә — 538, 1920 дә — 516, 1926 да — 428, 1938 дә — 375, 1949 да — 281, 1970 тә — 238, 1979 да — 211, 1989 да — 149, 2002 дә — 157 кеше.

**КАЗАНЫ́Й** Габдрәшит бине Гаид (18 йөз), дин эшлеклесе, язучы. Казанның Яңа Татар бистәсендә Алтынчы мәчет каршында мәдрәсә тота, үзе дин дәресләре бирә. Эпистоляр жанрда язылган «Васыятьнамә» (1769) авторы. Әсәрдән өзекләр Ш.Мәрҗани тарафыннан «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (1–2 кит., 1885–1900) хезмәтенә кертелгән.

**«КАЗА́НЬ»** («Казан»), айлык иҗтимагый-сәяси, тарихи-публицистик һәм әдәби-нәфис, рәсемле-бизәлешле журнал. Оештыручысы — «Татмедиа» ААҖ. 1993 елның октябреннән рус һәм татар телләрендә, ә 1998 дән бары рус телендә генә нәшер ителә. Төп эчтәлеге Казанның үткән һәм хәзерге мәдәни тормышына, Татарстан тарихына, әдәбиятына, музыкасына, театрына, сәнгатенә, архит-расына багышлана. Күп кенә саннары тематик эчтәлекле, юбилей даталарына туры китереп басыла, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре, шәһәрнең иҗади интеллегенциясенең күренекле вәкилләре хакында сөйли. Казанлылар һәм төбәктә яшәүчеләр хакында мемуар һәм очерклар урнаштырыла. Журнал шәхси коллекцияләрдәге сирәк очрый торган фотосурәтләр, рәссамнар әсәрләре, репродукцияләре б-н мул итеп бизәлә. Баш мөхәррире — Ю.А.Балашов.




«Казан» журналының беренче саны.

**КАЗАЧИ́НСКИЙ РАЙОНЫ́**, *Красноярск краеның* үзәк өлешендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 5,8 мең *км*². Үзәге — Казачинский авылы (Красноярск шәһәреннән 213 *км* төньяктарак). Халкы — 11,2 мең кеше, (2010) 613 татар (2002). Татарлар, нигездә, Отношка, Гамурино һәм Дементьевка авылларында яшиләр. Алар К.р. терр-ясендә 20 йөз башында күренә башлыйлар. 1911 дә Казан губернасыннан чыккан кешеләр Яңа Төркеш (хәзер Отношка) авылына нигез салалар. 1917 гә кадәр мәчет, мәктәп эшли. Хәзерге вакытта Отношка авылында татар теле — фән буларак, Гамурино авылында факультатив рәвештә укытыла. Отношка авылында фольклор клубы һәм халык драма коллективы бар, ел саен Сабан туе бәйрәме үткәрелә; 1999 дан мәчет эшли.

**КАЗАЧКО́В** Семён Абрамович (5.6.1909, Чернигов губ., Новозыбков өязе Перевоз а. — 2.5.2005, Казан), хор дирижёры, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1980), сәнгать фән. канд. (1955), проф. (1970). 1940 елда Ленинград консерваторисен хор һәм симф. дирижёрлыгы буенча (В.Степанов һәм И.Мусин класслары) тәмамлый. 1940–42 дә Чуаш АССРның Җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе, (1942–45 тә Бөек Ватан сугышында), 1945–47 дә Балтыйк флоты җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе. 1947–91 дә Казан консерваториясе укытучысы (1948–89 да хор дирижёрлыгы каф. мөдире). Репертуарына чит ил һәм рус композиторларының мәшһүр әсәрләре — И.С.Бах кантаталары, С.Танеевның «Иоанн Дамаскин»ы, И.Стравинскийның «Псаломнар симфониясе» («Симфония псалмов»), Г.Свиридовның «Патетик оратория»се («Патетическая оратория») һ.б. керә, 1947 дә үзе оештырган Казан консерваториясе хор капелла-



Профессор С.А. Казачков.
Рәссам З.Ф. Гыймаев. 1990.

сы б-н башкару эшчәнлеге алып бара. Капелла татар композиторларының (Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Ш.Шәрифуллин һ.б.) күпләгән хор әсәрләрен беренче башкаручы. Коллектив Мәскәү, Ленинград, Таллин һәм илебезнең башка шәһәрләренә гастрольләргә бара. Фәнни хезмәтләренең төп өлеше хор башкаруы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Дирижёрский аппарат и его постановка. М., 1967; От урока к концерту. К., 1990; Дирижёр хора — артист и педагог. К., 1997.

*Әд.:* К а с а т к и н а Г.Я. На хоровых репетициях // Советская музыка. 1991. № 12; Дирижёрско-хоровой факультет // Казанская государственная консерватория (1945–1995). К., 1998; К а н т о р Г.М. Музыковеды Казани. К., 2000.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КАЗАЯ́К** (Ranunculus), казаякчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 600 дән артык төре билгеле, бөтен Җир шары буенча таралган, күбрәк Төньяк ярымшарның уртача поясында. ТР терр-ясендә 11 төре бар. Зәһәр К. (R.acris), алтынсыман К. (R.auricomus), күп чәчәкле К. (R. polyanthemos), үрмәле К. (R.repens) киң таралган. Болында, сазлык, су буйларында үсә. Кыска тамырчалы 5 тән 100 *см* га кадәр биеклектәге үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, бармаксыман яки каурыйсыман бүленмә, теленмә яисә бөтен читле. Чәчәкләре берле яки аз чәчәкле чәчәк төркемендә. Чәчәк тирәлеге ике катлы, 5 аерым таҗ яфракчыклы. Дымлы көндә һәм төнгә чәчәкләре ябыла һәм иелә. Җимеше — күпчикләвекчек. Апрельдән сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Орлыктан, сирәк кенә шуышма тамырчадан үрчи. Барлык төрләрендә дә агулы очучан матдә (анемона камфарасы) бар, ул исә тиредә һәм күз, борын, бугазның лайлалы тышчаларында көчле ялкынсыну, әчеттерү тудыра (кычыту, кызару, куыклар барлыкка килә). Зәһәр К. һәм үрмәле К.та гликозид, алкалоид, сапонин, С витаминнары бар. Халык медицинасында ревматизм вакытында кулланыла, үлекле шешләргә куялар. Күп кенә төрләре баллы. Алтынсыман К., күп чәчәкле К., үрмәле К., агулы К. (R. sceleratus) җимешләре кошлар өчен азык. 5 төре, ш.и. чаккыч К. (R. flammula), Гмелин К. (R. gmelinii), озын яфраклы К. (R. lingua) ТРның Кызыл китабына кертелгән.



1. Зәһәр казаяк; 2. Үрмәле казаяк.

**КАЗАЯКЧАЛА́Р** (Ranunculaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. 60 тан артык ыруг, 2 меңгә якын төре билгеле; башлыча, Төньяк ярымшарның урта һәм салкын поясларында таралган. Күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләннәр, ярымкуаклар яки лианалар, сирәк кенә зур булмаган агачлар. Татарстан терр-ясендә 17 ыругка караган 38 төре очрый. Күбесенчә күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, гади, теленмә яки бармаксыман-бүленмә. Чәчәкләре ике җенесле, еш кына дөрес формалы, спираль-циклик рәвешле, ике катлы яки гади чәчәк тирәлекле, ачык төстә. Серкәч һәм җимешлекләре күп. Җимеше — күптабакча яки күпчикләвекчек, сирәк кенә җиләк (бүре бөресе). Алар арасында дару (башаклы бүре бөресе, саз тавык үләне, язгы адонис, аю табаны һ.б.), декоратив (алтын туй чәчәге, суҗыяр, җилдәк, зәрдә, испәрәк), баллы (испәрәк, казаяк, алтын туй чәчәге), агулы (бүре бөресе, зәрдә, җилдәк, йокы үләне һ.б.), чүп (испәрәк) үләннәр. 16 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**эл-КАЗВИНИ́** (القزوىى) Хәмдуллаһ Мостафави (1281 — 1349), фарсы тарихчысы һәм географы. Һулагу хан варислары сараенда вәзир *Рәшидеддин* җитәкчелегендә хезмәт итә. «Гомуми тарих» («Тарих-и гозидә», 1330) китабын яза, анда монгол илханнары һәм кайбер фарсы династияләре тарихы буенча кыйммәтле мәгълүматлар, атаклы кешеләрнең биографияләре бар. Ә.*Фирдәүсинең* «Шаһнамә» поэмасы дәвамы буларак уйланылган һәм 1331–32 елларга кадәр җиткән «Җиңү китабы» («Зафәрнамә») шигъри хроникасы авторы. Анда Алтын Урда тарихына кагылышлы мәгълүматлар бар. 13–14 йөзләрдәге Персия һәм аңа күрше дәүләтләрнең икътисади тарихы буенча кыйммәтле чыганак булган «Күңел нәзәкатьләре» («Нөзһәт эл-колүб», 1340) космографик-геогр. хезмәтне төзүче.

*Әд.:* П е т р у ш е в с к и й И.П. Хамдаллах Казвини как источник по социально-экономической истории Восточного Закавказья // Изв. АН СССР. Отд-ние обществ. наук. 1937. № 4.

**КАЗГОРБЫТПРОМСОЮ́З**, к. *Казан шәһәре көнкүреш һөнәрчелеге берлеге.*

**КАЗГОРКООПИНСОЮ́З**, к. *ТАССР инвалидлар кооперациясенең Казан шәһәре берлеге.*

**КАЗГОРШВЕЙКОЖВАЛПРОМСОЮ́З**, к. *Казан шәһәре тегү, күн эшкәртү, киез басу һөнәрчелекләре берлеге.*

**«КАЗГРАЖДАНПРОЕ́КТ»**, проектлау институты. 1977 елда шәһәр төзелеше объектларын проект-смета документлары б-н тәэмин итү өчен, баш проектлар төзү оешмасы буларак, Казанда оештырыла. 1990 нан — аренда пр-тиесе, 392 кеше эшли (2006). Төп эшчәнлеге — Казанның ген. планын, районнарының, инфраструктура объектларының, торак микрорайоннарының һ.б. объектларның планын, проектларын җентекләп эшләү. Институт проектлары буенча «Таулар», «Азино», «Көнчыгыш Елга Аръягы», «Клыки» торак микрорайоннары; Яшьләр үзәге, Үзәк универмаг, «Сувар» АҖ офисы бисалары; Казан метрополитены, Төбәкара клиник-диагностика үзәге (ТКДҮ) төзелә; ратуша, шәһәр думасы, Татар акад. театры бинаFлары реконструкцияләнә. Институтка нигез салынганнан бирле эшләүчеләр арасында М.А.Кафиатуллин, И.Д.Галанин, Х.Г.Сөнгатуллин, А.С.Коряковалар бар. Хезмәткәрләрдән А.А.Насыйров, Г.И.Солдатов, Р.Г.Вахтель, Ф.Ш.Палей, Р.Г.Сафин «Татарстанның атказ. төзүчесе» исеменә лаек булалар.

**КАЗИЛЕ́** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 33 *км* көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 106 кеше (руслар) яши. Клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 1640 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә, Самара губернасына барып эшли. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе урнаша. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 684,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волосте үзәге. 1921 дән ТАССРның Алабуга кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 249, 1887 дә — 361, 1905 тә — 391, 1920 дә — 424, 1926 да — 384, 1938 дә — 396, 1949 да — 343, 1958 дә — 250, 1970 тә — 212, 1979 да — 170, 1989 да — 109, 2002 дә — 119 кеше.

**КАЗИЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 133 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 20 йөз башында К.дә мәчет, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1277,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 147 ир-ат; 1859 да — 521, 1897 дә — 668, 1908 дә — 930, 1920 дә — 890, 1926 да — 840, 1938 дә — 650, 1949 да — 567, 1958 дә — 375, 1970 тә — 276, 1979 да — 215, 1989 да — 157, 2002 дә — 148 кеше.



Казиле авылы. Мәчет. 1899.

**КАЗИЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 27 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Благовещенский, Түбән Казиле исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элеккеге крепостнойлар) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, киез-киез итек басу, пыяла ясау, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе, Благовещение чиркәве, земство хастаханәсе, земство мәктәбе (1869 да ачыла), 2 май язу з-ды, 2 тегермән, ярма яргыч, тимерчелек, йон-тукыма ману остаханәсе, 2 сыраханә, 1 казна шәраб, 7 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе саен базар, 6 декабрь һәм 9 май көннәрендә ярминкәләр эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1463 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волосте. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 291 ир-ат; 1859 да — 874, 1897 дә — 1062, 1908 дә — 1223, 1920 дә — 1187, 1926 да — 912, 1949 да — 411, 1958 дә — 385, 1970 тә — 261, 1979 да — 112, 1989 да — 31, 2002 дә — 12 кеше.

**КАЗИЛЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оргыды елгасы буенда. 2010 елда 95 кеше (татарлар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1920 дә — 36, 1926 да — 119, 1938 дә — 73, 1958 дә — 263, 1970 тә — 312, 1979 да — 203, 1989 да — 103, 2002 дә — 74 кеше.

**КАЗИМБӘ́К** Алексей Николаевич (2.3.1859, Саратов губ. — 25.6.1919, Томск ш.), терапевт, мед. д-ры (1887). Г.К.*Казимбәк* улы. Н.А.*Виноградов* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлагач (1883), шунда ук терапия клиникасында эшли, табиблек диагностикасы (1894 тән), факультет терапиясе (1904 тән) кафедралары мөдире. Хезмәтләре тумыштан килгән һәм барлыкка килгән йөрәк зәгыйфьлеге иннервациясенә, аневризмаларына һәм бу авыруга диагноз куюга, йөрәк зәгыйфьлеген строфантин б-н дәвалауга, үпкә рагына, бизләр эшчәнлеге бозылуга, подагра, корсакта су җыелу һ.б. авыруларга диагноз куюга карый. Беренче булып йөрәкнең сул карынчыгы патологиясе билгеләрен тасвирлый (Казимбәк симптомы). Бактериология ин-тын, «Каменка» туберкулёздан дәвалау санаториен нигезләүдә башлап йөрүчеләрнең берсе, Казанда Александр хастаханәсе попечителе. Бөтенроссия туберкулёзга каршы көрәш лигасын җитәкли (1912–18), бер үк вакытта лиганың Казан бүлеге рәисе (1911 дән) була.


Х е з м.: Клинические наблюдения действия антидифтерийной сыворотки. СПб., 1885; Материалы к иннервации. К., 1887; О происхождении первого тона сердца. К., 1889; К вопросу о механическом лечении подкожной водянки надрезами кожи. К., 1904.

*Әд.:* Профессора Томского университета: Биогр. словарь. Томск, 1998. Т. 2.

**КАЗИМБӘ́К** (Мирза) Габдесаттар Касыйм улы (1816, Дербент ш. — 5.6.1888, Казан), педагог, тәрҗемәче. М.К.*Казимбәкнең* энесе, А.Н.*Казимбәкнең* әтисе. 1839–55 елларда Казан ун-тында төрек-татар телләре, бер үк вакытта 1840–48 дә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә татар теле укыта. Физули шигырьләрен һәм Унсур әл-Мәгалинең «Кабуснамә»сен фарсы теленнән татар теленә тәрҗемә итә. 1855 тә православие кабул итә һәм Николай исемен ала (рухи атасы — император Александр II). 1860 та С.-Петербург урман ин-тын тәмамлый, 1881 дә Саратов һәм Казан губерналарында урманчы булып хезмәт итә.

*Әд.:* В л а д и м и р о в В.В. Историческая записка о Первой Казанской гимназии: В 3 ч. К., 1867–68.

**КАЗИМБӘ́К** Мирза Мөхәммәтгали Касыйм улы (Александр Касимович) (22.7.1802, Решт ш., Иран — 27.11.1870, С.-Петербург, Павловск шәһәрендә җирләнә), филолог, шәркыятьче галим, шәрекъ телләре д-ры (1869), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1835). Король Азия җәмгыяте хакыйкый әгъзасы (1829, Лондон). Россия шәркыять гыйлеменә нигез салучыларның берсе. 1811 елдан Дербент шәһәрендә яши, ислам белеме ала. 1823 тә инглиз миссионерлары йогынтысында христианлаша, яһүд һәм инглиз телләрен өйрәнә, 1826–49 елларда Казан ун-тында: лектор, шәрекъ телләре адъюнкты (төрек-татар теле каф. мөдире), проф. (1836). 1849 дан С.-Петербург ун-тында: фарсы теле һәм әдәбияты каф. мөдире (1855–58), шәрекъ телләре ф-ты деканы (1860–70). Әзәрбайҗан телен фәнни яктан тикшерүне башлап җибәрә, төрки-татар телләрен, иранлылар һәм гарәпләр телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Аның «Төрек-татар теле грамматикасы» («Грамматика турецко-татарского языка», 1839) исемле хезмәте бөтен дөньяга таныла. Алга таба ул кабат эшкәртелә, тулыландырыла һәм «Төрек-татар теленең гомуми грамматикасы» («Общая грамматика турецко-татарского языка», 1846) дигән исем б-н басылып чыга. Хезмәтләре ислам, Кавказ, Иран, Урта Азия, Кырым тарихларына карый; Шәрекъ илләрендәге иҗтимагый-сәяси хәрәкәткә, ш.и. мөритлеккә багышланган хезмәтләре дә бар. Гарәп, фарсы, төрек һәм Урта Азия авторларының мәдәниятқә, филологиягә, шәригать белеменә караган күп кенә хезмәтләрен өйрәнә һәм фәнни әйләнешкә кертә. К. Казан ун-тының махсус комиссиясе кушуы буенча Сәед Ризаның «Әс-сәбга әс-сәйәр» («Җиде сәяхәт») исемле кулъязма әсәрен төрек теленнән рус теленә тәрҗемә итә («Семь планет») һәм басмага әзерли. Ул Кырым ханнарының 1466 дан 1737 гә кадәрге тарихына багышлана. К. православие гыйбадәт китапларын татар теленә тәрҗемә итүдә



М.К. Казимбәк.

катнаша. Мөселман халыклары вәкилләреннән шәркыятьче галимнәр әзерләү эшенә күп көч куя; югары шәркыять белемен укыту (беренче чиратта, тел белеме) методикасының төрле аспектларын эшли, студентларны укыту һәм тәрбияләү эшендә прогрессив формалар һәм алымнар куллануны яклап чыга. К. тарафыннан эшкәртелгән, камилләштерелгән дәреслекләр, уку ярдәмлекләре һәм программалар Казан, Петербург һ.б. уку йортларында кулланылыш таба. Аның хезмәтләре рус, фарсы, гарәп, төрек, инглиз, француз, әзәрбайҗан һ.б. телләрдә басылып чыга.

Х е з м.: Распределение преподавания арабского, персидского и турецко-татарского языков в I Казанской гимназии. К., 1836; Исследования об уйгурах // Журн. Мин-ва нар. просвещения. 1841. Авг.; Мюхтесерюль-Вигкает. К., 1845; Мифология персов по Фирдоуси // Северное обозрение. 1848. Т. 3; Мюридизм и Шамиль // Рус. слово. 1859. № 12; Баб и бабиды. Религиозно-политические смуты в Персии в 1844–1852 гг. СПб., 1865; Избр. произведения. Баку. 1985.

*Әд.:* Р з а е в А. Мирза Казем-Бек. Баку, 1965; Г у л и е в В. Мирза Казем-Бек. Баку, 1987; Мирза Казем-Бек и отечественное востоковедение. К., 2001.

**КА́ЗИН** Николай Нилович (26.5.1856, Казан — 10.1.1916, шунда ук), хокук белгече, хакыйкый статский советник (1905). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1882). 1883–90 елларда Казан губернасы Лаеш өязендә, 1890–92 дә Лифляндия губернасында мировой судья. 1899–1902 дә Екатеринбург округ мәхкәмәсе прокуроры. 1893–99 да Казан округ мәхкәмәсенең өяз әгъзасы, 1902–07 дә — прокуроры, 1907 дән — рәисе.

*Әд.:* У ш а к о в С. Памяти Н.Н.Казина // Камско-Волжская речь. 1916. 13 янв.; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеал. словарь. К., 2001.

*Е.Б.Долгов.*

**КА́ЗИН** Фёдор Нилович (14.7.1857, Казан губ., Лаеш өязе Байтирәк а. — 1913), җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. Икенче Казан гимназиясен тәмамлый. Крәстияннәр эшләре буенча өяз кабулханәсенең даими әгъзасы, Казан губернасы Тәтеш өязенең 1 нче участогы земство башлыгы. 4 нче Дәүләт Думасы депутаты (1912–17), җир һәм җирле үзидарә комиссиясе әгъзасы.

**КА́ЗИНСКИЙ** Дмитрий Степанович (12.5.1759 — 9.11.1804, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1797). Дворяннар нәселеннән. 1776 елдан хәрби хезмәттә. 1794–96 да — Екатеринослав, 1796–97 дә Новороссийск вице-губернаторы. 1797–99 да Казан гражданнар губернаторы. Казанны төзекләндерүне кайгыртa, Богородица монастыре соборын һәм шәһәрнең башка биналарын төзетүдә катнаша. 1797 дә *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен* торгызуга ярдәм күрсәтә: Воскресенский урамындагы губернатор йортын аның карама-

гына тапшыра, казна хисабына Г.А.Потёмкин китапханәсен һәм минераллар коллекциясен сатып алуны тәэмин итә. Аның заманында Казан руханилар академиясе оештырыла (1797), Арча, Спас һәм Тәтеш өязләре бетерелә (1799).

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗКА́Ш** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 28,4 *км*, бассейнының мәйданы 216 $км^2$. Саба р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Сабабаш авылыннан 3 *км* төньяктарак, тамагы Мамалай авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 11%. К.ның 0,4 тән алып 4,5 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,20 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен



Казкаш елгасы югары агымында.

нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 150 *мм*, ташу агымы катламы 103 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. К. ноябрьнең 2 нче яртысында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,35 $м^3/с$. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,7 млн. $м^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАЗЛА́Р**, үрдәк кошлар семьялыгыннан суда йөзүче кошларның берничә ыругының гомуми исеме. Европа, Азия, Төньяк Америка һәм Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә өч ыругка караган 7 төр яши. Ак яңаклы казарка (Branta leucopsis) һәм кара казарка (B. bernicla) — сирәк очып килүче төрләр; ындыр казы (Anser fabalis), ак маңгайлы каз (A. albifrons), чыелдык каз (A. erythropus), кызыл түшле казарка (Rufibrenta ruficollis) — күчмә төрләр; соры каз (A. anser) — аз сандагы оя коручы төр, *йорт казларының* бөтен токымнарының диярлек нәсел башы. Коры җирдә яки сай сулыкларда яшиләр. Гәүдәсенең озынлыгы 60 тан (ак маңгайлы каз) 100 *см* га (соры каз) кадәр, авырлыгы 2–6 *кг*. Аяклары чагыштырмача озын, йөзүгә караганда йөрүгә күбрәк җайлашкан. Томшыгы зур, кайбер К.ның төптән үк калын. Башлыча үсемлекләр б-н туклана. Парлар бөтен үрчү чорында бергә була. Ояларын җирдә ясый. 5–8 йомырка сала. Ана кош утыра, әмма атасы һәрвакыт оя янында була. Кош балаларын икесе дә ияртеп йөри. Соры каз, ак маңгайлы каз, ындыр казы — аучылык төрләре. Ак яңаклы казарка, кызыл түшле казарка ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЗМА́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 112 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кощакова исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 899,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 419, 1897 дә — 678, 1908 дә — 803, 1920 дә — 787, 1926 да — 760, 1938 дә — 480, 1949 да — 390, 1958 дә — 314, 1970 тә — 307, 1979 да — 316, 1989 да — 184, 2002 дә — 146 кеше.

**КАЗНА́ ПАЛА́ТАСЫ** (Казан губернасы казна палатасы), губерна финанс учреждениесе. 1775 елда Губерна реформасын уздыру нәтиҗәсендә оештырыла, 1781 нең 23 декабрендә ачыла. Баштарак салым түләүче халыкны исәпкә алу, хисапларга ревизия ясау, тоз кәсепчелеге, шәраб сату буенча түләүләр һәм подрядлар, казна төзелешләре һ.б. б-н шөгыльләнә, 19 йөздән — ведомствога буйсына торган казначействоларда акча керемнәрен һәм чыгымнарын исәпкә алу һәм хисап тоту, салым түләүче халыкны исәпкә алу, подряд буенча китерелгән товарлар б-н сәүдә итү, рекрут эшләре (1874 кә кадәр), милекнең бәясен һәм табышлылыгын күрсәтү (1885 тән), пенсияләр билгеләү б-н мәшгуль була. 18–19 йөзләрдә вице-губернатордан (1837 дән рәис, 1866 дан управляющий), экономия директоры, киңәшче, асессорлар, губерна казначее, казна эшләре стряпчийлары, секретарь, теркәүче, бухгалтерлар, архивариус, канцелярия эшчеләреннән тора; экспедицияләргә бүленә: 1 нчесе — казна фабрикалары, җирләре, урманнары, икмәк саклау-сату кибетләре һ.б.; 2 нчесе — казна һәм шәхси биналар; 3 нчесе — тоз кәсепчелеге һ.б.; 4 нчесе — шәраб сату буенча түләү һәм подрядлар, рекрутлар җыю һ.б.; 5 нчесе — акча керемнәре һәм чыгымнарын контрольдә тоту; 6 нчысы — казна корылмалары, күперләр салу, йөк күчерүләр б-н идарә итә. 20 йөз башында К.п.на управляющий, аның ярдәмчесе, губерна башкару ком-ты әгъзалары, өстәл башлыклары, бухгалтерлар, эш башкаручылар, секретарь, аерым эш үтәүче чиновниклар, хөкем эшләре буенча чиновник, архивариус, экзекутор, журналист, хисапчылар, теркәүчеләр (барлыгы 100 гә якын кеше, 1912) керә. Бүлекләре: 1 нче (башкару, яисә гомуми кабулханә) — өстәлләр: башкару, бүлгәләү, салым, сәүдә, пенсия; 2 нче (ревизия) — өстәлләр: түләү, табыш, фатир, ревизия, варислык, герб; 3 нче (казначейство) — өстәлләр: касса, керем, ссуда, чыгым, бухгалтерлык. К.п. идарәчелегендә губерна һәм өяз казначействолары, губерна салым кабулханәсе (1885–98), шәһәр һәм өяз салым инспекторлары (1885 тән), шәһәр һәм өяз кәсәбәчелек салымы кабулханәләре (1898 дән) була. Сенатка, Камер-коллегиягә, 1802 дән Финанс министрлыгына буйсына. РСФСР ХКСның 1918 ел 1 ноябрь Декреты нигезендә бетерелә.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 1999. Кн. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЗНА́ ЭШЕНӘ́ БЕРКЕТЕЛГӘ́Н КРӘСТИЯННӘ́Р**, 17 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә феодаль бәйле кешеләр. Алар җан башына һәм имана салымы түләү урынына казна яки хосусый пр-тиеләрдә эшләргә тиеш булалар, ягъни аларга беркетеләләр. Үсә баручы сәнәгатькә булышлык күрсәтү һәм аны эшче көчләр б-н тәэмин итү өчен ирекле ялланган эшчеләр җитмәгәнлектән, хөкүмәт дәүләт крәстияннәрен мануфактураларга беркетүне киң куллана (гадәттә, вакыты күрсәтелмичә, ягъни гомерлеккә беркетеләләр). Формаль яктан К.э.б.к. дәүләт милке саналалар, ләкин чынлыкта, алпавытлар крепостной крестияннәргә ия булган кебек, аларга сәнәгатьчеләр ия булалар. 18 йөздә — 19 йөз башында Казан губернасының Мамадыш, Чистай һәм Спас өязләре крәстияннәре Вятка һәм Пермь төбәкләрендәге казна тау з-дларына беркетелгән була. Мәсәлән, 1798 елда Ижевск тимер эшләү һәм Вознесенск бакыр кою з-дларында 2635 К.э.б.к. эшли. Эш һәм яшәү шартлары авыр булу аркасында К.э.б.к. качалар, баш күтәрәләр. 18 йөз ахырында хөкүмәт крәстияннәрне заводларга яңадан теркәүне туктата. К.э.б.к. категориясе 1861 дә крепостнойлык хокукы бетерелгәч юкка чыгарыла.

*Әд.:* П а н к р а т о в а А.М. Формирование пролетариата в России. М., 1963.

*Р.Х.Хәйретдинов.*

**КАЗНИИХП**, к. *Химия продуктлары институты.*

**КАЗНИИТЕХФОТОПРОЕ́КТ**, к. *Казан фотоматериаллар институты.*

**КАЗПЕЧА́ТЬ**, к. *Татпечать.*

**КАЗУЧЫ́ ШӨПШӘЛӘ́Р** (Sphecoidea), шөпшәләр өссемьялыгы. Бердәнбер сфецидлар семьялыгыннан 6,6 мең төре билгеле, киң таралган; Россиядә — 1 меңгә якын төр, Татарстан терр-ясендә — 70 төр тирәсе. К.ш.нең күбесе бер яки берничә бүлемле ояларын җирдә (исеме шуннан) ясый, анда алар олы бөҗәкләрдән (цикадалар, саранчалар, коңгызлар, чебеннәр, хальцидлар һ.б.), күбәләк гусеницалары, кисмән личинкалары, сирәк кенә үрмәкүчләрдән торган азык запасы әзерлиләр. Төрле вак гөбләләрне аулыйлар, кайберләре а.х. корткычларының энтомофаглары, әмма ТР шартларында, саны аз булу сәбәпле, хуҗалык өчен әһәмияте юк. Республика терр-ясендә гади умарта корты бүресе (Philanthus triangulum) һәр җирдә (әмма күп санда түгел) очрый. Ана затлар личинкаларын бал кортлары б-н туендыралар. Умарталыкка якын урнашып, умартачылыкка зыян китерергә мөмкиннәр. Казанда (М.Горький исем. Үзәк мәдәният һәм ял паркында, Дербышки бистәсендәге паркта) үткен тешле шөпшә (Sphex maxillosus) очрый — бу кызыл корсаклы, кара төстәге шактый зур шөпшә, июльдән август урталарына кадәр оча; бик сирәк төр. Зур борынлы бембикс һәм үткен тешле шөпшә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Ф а б р Ж.А. Инстинкт и нравы насекомых. М., 1993. Т. 1; Красная книга Республики Татарстан. К., 2006.

*Е.А.Сапаев.*

**КАЗХИМНИ́Й**, к. *Казан химия институты.*

**КАЗЫ́Й** (гарәп. قاضى, сүзгә-сүз — билгеләүче, хөкем чыгаручы), хөкемдарның мөселман илләрендә кабул ителгән исеме. *Шәригать* кануннары нигезендә хөкем итүче. Беренче К.лар Гомәр хәлифә тарафыннан Мәдинә, Басра, Куфр шәһәрләренә билгеләнә. Соңрак К.лар эре шәһәрләрдә, өлкәләрдә һәм хәрби яу вакытында гаскәрләрдә *хәлифәләр* тарафыннан куела башлый. Бары тик хәлифәләр генә К.ларны билгели һәм аларның карарларын үзгәртә алган. 8 йөзнең 2 нче яртысында баш К. вазифасы булдырылган, ул хәлифә исеменнән башка К.ларны билгеләгән, аларның карарларын үзгәрткән. Бәйсез мөселман дәүләтләре оешкач, әлеге мәсьәләләрне дәүләт башлыклары үзләре хәл итә башлый, ләкин аларны хәлифә тарафыннан раслау 12 йөзгә кадәр дәвам итә. Мисырда Фатимилар (909–1171) һәм Әюбиләр (1171–1250) династиясе заманында баш К.лар һәр *мәзһәбтән* тәгаенләнәләр, солтанга киңәшче буларак чакырылалар. Госманлы төрекләр дәүләтендә К.ларны солтаннар билгели, ә баш К. вазифасын баш мөфти башкара. К. вазифасын эшкә сәләтле, шәригать гыйлемен тиешле дәрәҗәдә белгән һәм физик кимчелекләре булмаган теләсә кайсы мөселман башкара алган (тәкъва һәм зирәклегенә карап, укый-яза белмәүче мөселманнарның билгеләнүе дә мәгълүм). К. бөтен җәмәгать алдында хезмәткә алынган дип саналган һәм, аның мөстәкыйль фикер йөртүен тәэмин итү өчен, казна хисабына тотылган. К. вазифасын башкарган хәлле кешеләр, гадәттә, хезмәт хакын дәүләт хисабыннан алудан баш тартканнар. Еш кына бәйсезлек саклау йөзеннән, кайбер К.лар бер үк вакытта нинди дә булса башка эш б-н дә шөгыльләнгәннәр (мәс., сәүдә).

К. шәһәр һәм төбәкләрдә ритуаль, әхлак, гаилә өлкәсендәге гражданлык һәм җинаять эшләрен хәл иткән. Зарурлык туганда К. кешеләргә яки милеккә вәсый (опекун) билгели, вакыф милкенә, җәмәгать биналарын, юл, урам һәм мәйданнар төзү һәм файдалануга, мирасны бүлү һәм васыятьләрне саклауга, хөкем чыгару һәм җәза бирүгә күзәтчелек итә, төрмәләрне тикшерә; *зәкәт, сәдака* бирү һәм башка җәмәгать чаралары үтәлешен контрольдә тота.

Гаскәри К.лар шундый ук вазифаларны башкарудан тыш, патша, хәлифә исеменнән *җиһад* игълан иткәннәр, ганимәт малының дәрәҗәсенә бәя биргәннәр һәм аны бүлүдә катнашканнар. Аларның төрле эчке гаскәри эшләрдә дә катнашы булган. К.лар еш кына *фәкыйһләрдән* билгеләнгәннәр, шул сәбәпле дәрәҗәләре дә еш кына нәселдән нәселгә күчеп килгән. 8 йөздән фәкыйһләр дә, мөфтиләр кебек, махсус киемнәр киеп йөргәннәр (бу гадәт хәзер дә саклана). Зур шәһәрләрдә К.лар берләшмәләргә тупланганнар (коллегияне хәтерләткән, әмма рәсми статусы булмаган), 19 йөздә — 20 йөз башында мөселман илләрендә гражданлык мәхкәмәсе эшләрен башкару үсешенә бәйле рәвештә, К.лык вазифалары гаилә, дин һәм кайвакыт мирас хокукын хәл итү б-н чикләнә башлый. Кайбер мөселман илләрендә (Мисыр, Тунис, Төркия) шәригать мәхкәмәсен бетерү б-н бергә (Төркиядә 1930 елларда, Мисыр һәм Туниста 1950 елларда), К.лык ин-ты да юкка чыгарыла.

Татарстан терр-ясендә К.лар Идел буе Болгар дәүләте чорыннан ук билгеле; Казан ханлыгы яулап алынганнан соң (1552), К.лык бетерелә, 1788 дә Уфа Мөхәммәд дине кануннары Җыены оештырылгач, кабат торгызыла (1918 гә кадәр яши). 1994 тә ТР Мөселманнары Диния нәзарәтендә К.лык кертелә. Республика мөселманнарының берләштерелгән корылтаенда (1998) 4 ел вакытка 1 нче Баш К. сайланып куела. Аның вазифаларына исламга дөрес аңлатма бирүгә күзәтчелек итү, имам-хатиблар, имам-мөдәррисләрнең һәм мөселман уку йортлары ректорларының эшчәнлеген, мөселман әхлагы һәм дианәтлелеген тикшерү керә. Аның җитәкчелегендә ТРның Үзәк, Көнчыгыш, Көньяк-көнчыгыш, Көньяк-көнбатыш, Төньяк һәм Көньяк төбәкләренең казыятләре эшчәнлек алып бара.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Республика Татарстан. Свобода совести и религиозные объединения: Словарь-справ. К., 2001.

**КАЗЫ́Й** (Газый) бәк (?-1577), Кече Нугай Урдасына нигез салучы. Рус дәүләте б-н якынаю сәясәтенә каршы була. 1550 елларда үз олысы б-н Кавказ алдының көнбатышына һәм Дон тамагына күченә һәм үзен Кече Нугай Урдасы бәге дип игълан итә. Кырым ханлыгы һәм Госманлылар империясе йогынтысында була. 1560–70 елларда Рус дәүләтенә һәм Кавказ алды тау халыкларына каршы сугышларда катнаша. Кабардага яу вакытында һәлак була.

*Әд.:* Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2001.

*И.Л.Измайлов.*

**КАЗЫЛМА́ КҮЛ**, Көнчыгыш Кама аръягында. Актаныш р-ны Чишмә авылыннан көньяктарак Сөн елгасы бассейнында. Су өслегенең мәйданы 0,5 *га*. Күләме 4,4 мең $м^3$. Озынлыгы 110 *м*, иң зур киңлеге 50 *м*. Уртача тирәнлеге 0,84 *м*, иң зур тирәнлеге 4,5 *м*. Ясалма (казылма) күл. Формасы турыпочмаклы. Күбесенчә явым-төшем б-н туена. ТРның табигать истәлеге (1978).

**КАЗЫЛМА́ КҮМЕРЛӘ́Р**, үсемлек калдыкларыннан хасил булган януgreat чан каты тау токымнары, составында минераль катнашмалар 50 % тан кимрәк. Утырма токымнар катлам (пласт) яки калын катламсыман һәм линзасыман ятмаларда ята. Текстурасы җирсыман, авыр, катламлы һәм бөртекле. Төзелеше бертөрле, буй-буй. Төсе көрәннән соры-карага, ялтыравыгы тоныктан металлсыманга кадәр. Катылыгы 1–3, тыгызлыгы 0,92–1,7 $г/см^3$. Метаморфизм дәрәҗәсе буенча көрән күмер, ташкүмер һәм антрацитларга бүленә. К.к.нең 3 меңнән артык чыганагы һәм бассейны билгеле. Аеруча зур ресурслар Кытай, АКШ, Һиндстан, Австралия, Россиядә (дөнья ресурсларының 30% тан артыгы). РФнең 24 субъектында 300 млн. *т* га якын күмер чыгарыла, яртысыннан артыгы Кузбасста. ТР терр-ясенең көнчыгышы Кама күмер бассейнының шактый өлешен били (Төньяк-Татар, Көньяк-Татар һәм Мәләкәс күмер төбәкләре). 105 ятма ачыкланган, ш.и. девон утырмаларында — 1, карбонда — 95, Пермьдә — 9 һәм неогенда 4. Девон күмерләренең Казан тирәсендә барлыгы билгеле, яше 370 млн. елдан артык. Катламнарның юка (0,1–0,6 *м*) булуы һәм тирәндә (1342–1379 *м*) ятуы сәбәпле, аларның гамәли әһәмияте юк. Карбон утырмаларында ятучы ташкүмер катламнары (330–340 млн. яшь) сәнәгати игътибарга лаек, аларның калынлыгы 40 *м* га җитә, яту киңлеге 3 *км* га, озынлыгы 60 *км* га кадәр. Төп катлам (Нурлат һәм Яңа Чишмә р-ннары) аеруча әһәмияткә ия. Күмер — уртача көлле (26 %), уртача күкертле (күкерт составы уртача 3,36 %), яну җылылыгы (33,9 *Мдж/кг* га кадәр) һәм газ чыгышы (1 *кг* күмергә 3,26 $м^3$ ка кадәр) чагыштырмача югары. Ятмалар 880–1440 *м* тирәнлектә урнашкан, күмер тыгызлыгы 1,4–12,8 млн. $т/км^2$, ресурсларның торышы 2,7 млрд. *т* тирәсе ($P_2+P_1$ категориясе), $C_2$ категориясе буенча — 0,7 млрд. *т* (2007). Күмерләр составында микроэлементлар бар, алар арасында германий (күмер көлендә 400 *г/т* га кадәр) һәм сирәк руда элементлары аеруча гамәли әһәмияткә ия. Көрән күмер ятмалары Төньяк-Татар һәм Көньяк-Татар күмер төбәкләренең (Минзәлә һәм Алабуга р-ннары) Пермь (250 млн. яшь тирәсе) һәм неоген (2 млн. яшьтән артык) утырмаларында 26 *м* га кадәр тирәнлектә ята. Аерым катламнар Кама елгасының сулъяк ярында һәм Покровский, Танай авыллары (Алабуга р-ны) һ.б. тирәсендәге известьташ чыганаклары карьерларында очрый. Пермь күмерләре югары көлле (уртача 45–48 %), уртача һәм югары күкертле (күкерт 4 % ка кадәр), дымлылык 20–25 %; урыны б-н металлы: көлдә Ag — 34 *г/т* га, Au — 18,6 *мг/т* га, Pd — 4,2 *мг/т*,

Pt — 1,18 *г/т* га кадәр. Неоген күмерләренең сыйфаты: дымлылык 34,3–53,8, көллелек 8,7–74,6 %, очучан матдәләр 67,6% ка, кокс һ.б. 40 % ка кадәр, чагыштырма яну җылылыгы 24,6–25,74 *Мдж/кг*, күкерт 1,1–5,0 %. Көрән күмер ресурслары берничә йөз мең тонна. ТР терр-ясендә К.к.не эшкәртү җир астын газлаштыру (ташкүмер) яки штольня һәм кечкенә шахталар (көрән күмер) ярдәмендә мөмкин. К.к. энергетикада сыек һәм газсыман ягулык алу өчен каты ягулык буларак, металлургиядә (кокс), химия сәнәгатендә (300 дән артык исемдә товар), төзелеш материаллары һ.б. җитештерүдә файдаланыла. ТР терр-ясендә ташкүмер, янучан газ буларак, көрән күмер ашламалар, Ag, Ge һ.б. металлар алуда кулланылырга мөмкин.

*Әд.:* Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твердых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999. Ч. 1; Петрографические типы визейских углей Камского бассейна: Атлас. К., 2001; Геологическое изучение земных недр Республики Татарстан. К., 2002. *Р.Р.Хәсәнов.*

**КАЗЫЛЫ́К** (казы́), өй шартларында, соңрак сәнәгый производствода чи иттән каклап җитештерелә торган ризык. Традицион технология буенча татарлар К.ны ат яисә сыер эчәгесенә тапалган ат яки сыер ите б-н вакланган корсак маен аралаштырып ясалган эчлек тутырып әзерлиләр. Тоз һәм борыч салынган эчлек башта салкында тотыла. Әзерләнгән К.лар берничә көн кояшта каклана, аннары 2–2,5 айга караңгы салкынча урынга элеп куела. К. ярты елга кадәр куллануга яраклылыгын саклаганлыктан, суыткычлар булмаган шартларда әлеге рецепт авыл җирләрендә итне әзерләп куюның арзан һәм гади ысулы буларак яши. Табынга кабымлык рәвешендә һәм пешереп бирелә.

*Әд.:* Ахметзянов Ю.А. Татарские блюда. К., 1970. *Ф.Ф.Гулова.*

**«КАЙ-ТАТЦИ́Т»**, гандбол командасы. 1993 елда Казан техник ун-тының гандбол клубы каршында оештырыла (1994 кә кадәр «АвиК», 1999 дан «КАИ-Зилант»). 1994–96 да Россия чемпионатының 2 нче, 1996–97 дә 1 нче, 1997–98 дә югары лигаларында, 1999 дан суперлигасында. 2008 дә команда юридик зат буларак яшәүдән туктый. Россия чемпионатларында көмеш (1995–97, 1999), бронза (1998) медальләр ала, Европа Чакыру кубогына ярышларда (2001–02) катнаша. 1994 тән баш тренеры — Р.Г.Газимов. Иң яхшы уенчылар — С.В.Белоусов, О.Г.Бухаров, Р.Г.Газимов, А.Н.Мокришин, В.Н.Мокришин, В.В.Натаров, Г.Б.Попов, В.В.Телышев, В.В.Уткин, Д.В.Яровой. «КАИ-Зилант-2» командасы Россия чемпионатының югары лигасында (2000 нән). Баш тренеры А.П.Исаев. Спортчылар Р.Ш.Гатауллин һәм К.И.Сабаев — гандбол буенча РФ яшьләр җыелма командасы әгъзалары (2002 дән). Әзерлек базасы — «Маяк» спорт комплексы (Яшел Үзән ш.).

**КАЙ́НКИ** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы тамагы буенда. 2010 елда 50 кеше (руслар) яши. Башлангыч мәктәп. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1550 еллардан — рус авылы. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Воздвиженское исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (К.ның беренче хуҗаларыннан кенәз А.И.Катырев-Ростовский була) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1868 дә чиркәү-приход мәктәбе, 1871 дә ул земство мәктәбе итеп үзгәртелә. 20 йөз башында К.да Крестовоздвижение чиркәве (1890–1903 тә төзелә; архит-ра истәлеге), Халык мәгарифе министрлыгы уч-щесе, җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 836 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Зөя өязе Клянчино волостена керә. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 44, 1782 дә — 115 ир-ат; 1859 да — 491, 1897 дә — 697, 1908 дә — 758, 1920 дә — 735, 1926 да — 719, 1938 дә — 526, 1949 да — 394, 1958 дә — 405, 1970 тә — 289, 1979 да — 208, 1989 да — 73, 2002 дә — 78 кеше. К.да астроном И.М.*Симонов*, математик А.В.*Васильев*, шәркыятьче галим В.П.*Васильевлар* яшәгән; 1904–06 да сәясәт эшлеклесе А.Ф.Керенский (җирле чиркәүдә никахлашкан) булган.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый ... К., 2001; Бажанов В.А. Каинки: Из истории одного поволжского села // Казань. 1998. № 9/10.

**КАЙ́П** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 23 *км* төньяктарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 468 кеше (руслар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рус халкы анда 1550 елларда күренә башлый. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә. 1630–1760 та К. авылының бер өлеше Казан Спас-Преображение монастыре милкендә була. Халык, нигездә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та Вознесение чиркәве (1766 да төзелә), земство мәктәбе (1892 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 136 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 25 ир-ат; 1859 да — 378, 1884 тә — 439, 1897 дә — 411, 1908 дә — 478, 1920 дә — 385, 1926 да — 532, 1938 дә — 256,1949 да — 285, 1958 дә — 258, 1970 тә — 256, 1979 да — 219, 1989 да — 369, 2002 дә — 493 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**КАЙБИ́ЦКАЯ** Галия Мотыйгулла кызы (21.5.1905, Уральск ш. — 16.5.1993, Казан), артист, җырчы (колоратуралы сопрано), ТАССРның халык артисты (1939). 1932 елда Татар сәнгать техникумын вокал буенча (Е.Ковелькова классы), 1938 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен (Д.Белявская классы) тәмамлый. Драма артисты буларак, сәхнә эшчәнлеге 1921 дә Уральск шәһәре татар театры труппасында башланып китә.



Г.М. Кайбицкая.


1923–33 тә Татар академия театры артисты, 1939–58 дә Татар опера һәм балет театры солисты. Вокаль һәм драматик сәләткә ия синтетик пландагы артист татар драма сәхнәсендә милли муз.-драматик репертуарны башкаручы буларак чыгыш ясый. Муз.-драма спектакльләрендәге төп рольләре: Мөршидә, Сәрвәр, Мәйсәрә, Гөләндәм («Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе» муз. драмалары, К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшев), Гөлйөзем («Наёмщик», Т.Гыйззәт һәм С.Сәйдәшев) һ.б. Татар операсы сәхнәсендә беренче тапкыр Дж.Россининың «Севилья чәчтарашы»нда Розина,



Г.М. Кайбицкая Дж. Вердиның «Травиата» операсында Виолетта ролендә (Альфред ролендә — Ф.Н. Насретдинов).

Дж.Вердиның «Травиата», «Риголетто»сында Виолетта, Джильда, Н.Римский-Корсаковның «Патша кәләше»ндә Марфа һ.б. партияләрне башкара. Татар композиторлары опералрында Рәйхан («Качкын», Н.Җиһанов), Алтынчәч (шул исем. опера, Н.Җиһанов), Галиябану (шул исем. муз.драма, М.Мозаффаров) һәм муз. комедияләрдә Сәрвәр («Башмагым», Җ.Фәйзи) һ.б. төп партияләрне беренче башкаручы. Җиңел, йомшак тембрлы тавышка ия, сәхнәдә җитез, елгыр, матур, хәрәкәтчән булуы б-н аерылып тора. Эстрада концертлары б-н чыгышлар ясый. Татар театр-музыка сәнгатенең мәшһүр эшлеклеләре турында истәлекләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. 1998 дә Кайбыч р-ны Олы Кайбыч авылында *Кайбицкая Галия музее* ачыла.

Әсәр.: Истәлекләр // Азат хатын. 1963. № 3; Ситдыйк Айдаров // Казан утлары. 1975. № 10; Якты йолдыз белән янәшә: истәлек. (Салих Сәйдә-



1. Г.М. Кайбицкая музее бинасы; 2. Музейның мемориаль экспозиция фрагменты.

шев тууына 75 ел) // Казан утлары. 1975. № 12; Бөек иҗатчы рухы // Казан утлары. 1986. № 5.

*Әд.:* И ш м о р а т Р. Татар халык артисткасы Галия Кайбицкая // Дусларым — остазларым. К., 1988; Л а т и ф у л л и н М. Галия Кайбицкая. К., 1957; Народные артисты. К., 1980; Тематическая подборка, посвящённая Г.Кайбицкой // Казань. 2002. № 5; Музыкальная энциклопедия. М., 1974. Т. 2.


*Ф.Ш.Салитова.*

**КАЙБИ́ЦКАЯ ГАЛИЯ́ МУЗЕЕ́**, Кайбыч р-ны Олы Кайбыч авылында, мемориаль һәм этнография музее. 1996 елда оеша, 1998 дә ачыла. ТР Милли музее ф-лы. Махсус бинада урнаштырыла, аның проектын төзүдә Г.М.*Кайбицкаяның* улы арх. С.С.*Айдаров* катнаша. Музейның гомуми мәйданы — 110 *м*², экспозиция мәйданы — 93 *м*², фондларда 575 саклау берәмлеге исәпләнә. Даими ике: мемориаль, этнография экспозиция заллары һәм музыка салоны эшләп килә. Җырчының шәхси әйберләре: җиһазлар, китаплар, ноталар, театр костюмнары һәм гаиләсенең истәлекле ядкәрләре һ.б. куелган. Кыйммәтле экспонатлар арасында сәхнә костюмнары, метроном (музыкада темпны һәм вакытны күрсәтә торган механик прибор); җырчының фотосурәтләре б-н кулъязма мемуарлары, хатлары, әтисе (М.Төхфәтуллин) шәҗәрәсе язылган дини эчтәлектәге кулъязма китап (1791); Уральск шәһәрендә җырчының өлкән абыйсы К.Мотыйгый редакторлыгында чыккан «Әлгасрелҗәдид» ж-лы (1906, май) бар. Этнография бүлегендә татарлар, руслар, чуашларның, керәшен татарларның көнкүреш әйберләре, костюмнары куелган. Музей Кайбыч р-ны оешкан көнне (19 апр.), Г.Тукай туган көн Шигърият бәйрәме (26 апр.), Халыкара музейлар (18 май), Г.Кайбицкая туган көндә — Музыка көннәре (21 май) үткәрә. 1996 елдан музей директоры М.С.Шәфигуллина.

**КАЙБЫ́Ч** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 581 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. К. ка 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халыкның күпчелеге — дәүләт крәстияннәре, бер өлеше удел (элеккеге сарай) крәстияннәре катлавына керә, лашманлыкта эшли, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, балта эше, арба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та 2 мәчет, мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1742 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 209 ир-ат; 1859 да — 788, 1880 дә — 967, 1897 дә — 1192, 1911 дә — 1343, 1913 тә — 1636, 1920 дә — 1331, 1926 да — 1110, 1938 дә — 970, 1949 да — 992, 1958 дә — 1861, 1970 тә — 968, 1979 да — 974, 1989 да — 599, 2002 дә — 636 кеше.

**КАЙБЫ́Ч АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, комплекслы. Кайбыч р-нының төньяк-көнбатышында Гөбенә һәм Бәрле елгалары арасында урнашкан. Мәйданы 20,2 мең *га*, ш.и. урманнар 3,4 мең *га* җир били. 1963 елда оештырыла. Поши, кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе, ак куян, үр куяны, төлке, сусар, соры кыр тавыгы, көртлек саклана.

**КАЙБЫ́Ч ИМӘНЛЕКЛӘРЕ́**, табигать истәлеге, Кайбыч р-ны терр-ясендә. 1981 елда аерып билгеләнә. Мәйданы 140 *га*. «Казан тау имәнлекләре» дип аталучы табигый имән урманнары сакланып калган ике участоктан тора, Кайбыч урманчылыгы составында. Рельефы калкулыклы-тигезлекле, күп санлы ерымнар б-н телгәләнгән. Имәннәр юкә, өрәңге, ара-тирә карама б-н бергә үсә, биредә корычагач ареалының табигый чиге үтә; беренче ярусның биеклеге 25–26 *м* тәшкил итә. Аерым агачларның яше 100 (Урсак урманчылыгының 4 нче кварталында) һәм 150 гә (Бәрлебаш урманчылыгының 73 нче кварталында) җитә. Вак агачлардан урман зелпесе, сөялле кабар агачы, миләш һәм чикләвек куагы таралган. 1978/79 елдагы кышкы каты суыклар, олы яшьтәге имәнлекләрнең шактый өлешенең бетүенә һәм агачлар төбендәге яктылык шартларының кинәт үзгәрүенә китерде. Үлән капламында неморал флора вәкилләре өстенлек итә: сәрдә, зибык уты, төкле күрән; сирәк төрләрдән бүре җиләге, ике яфраклы төн миләүшәсе. Кошларның 100 дән артык төре, яши, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәре: кыр карчыгасы, сапсан, балобан, колаклы ябалак, сазлык ябалагы, соры ябалак, чал тукран, яшел тукран, сары корташар; ш.у. соры гөберле бака, гади кара елан, болан коңгыз, зур имән кисмәне; күбәләкләр — махаон, адмирал, төсен үзгәртүчән күбәләк. К.и. сабакчалы имәннең генетик резерваты булып тора һәм урман орлыкчылыгында файдаланыла. Фәнни һәм эстетик әһәмияткә ия.



Кайбыч имәнлекләре.

**КАЙБЫ́Ч РАЙОНЫ́**, ТРның көнбатыш өлешендә, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. Идел алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 995,4 *км*². 17 авыл җирлеген, 57 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Олы Кайбыч авылы. Халкы — 15,2 мең кеше (2010; 2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 66,5 %, руслар — 27,4 %). Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 15,2 кеше. 1927 елның 14 февралендә *Ульянково районы* буларак оештырыла. Район үзәге Ульянково авылыннан Олы Кайбычка күчү сәбәпле (1927 нең 1 авг.), районның исеме К.р. дип үзгәртелә. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Тәтеш һәм Зөя өязләрендә, 1920–27 дә ТАССРның Зөя кантонында. Оештырылган чорда К.р.нда 45 авыл советы, 76 торак пункт исәпләнә, аларда 56905 кеше (татарлар — 31043, руслар — 24649, башка милләтләр — 1213 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1184 *км*², халкы — 56,7 мең кеше, 40 авыл советы, 91 торак пункт була. 1944 нең 19 февралендә К.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Подберезье районына* бүленеп чыга (1956 ның 14 маенда кире кайтарыла). 1960 та районның мәйданы — 1185,3 *км*², аңа 20 авыл советы, 84 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә К.р. таркатыла, биләмәсе Буа р-нына, 1964 нең 4 мартында Апас р-нына бирелә. 1991 нең 19 апрелендә район яңадан торгызыла.

К.р.ның рельефы — елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлек (биеклеге — 150–200 *м*). Район җирлегеннән Зөя елгасы һәм аның кушылдыклары Бәрле, Гөбенә елгалары ага. Җирләре күбесенчә соры, аксыл-соры һәм карасу-соры урман, селтесезләнгән кара туфраклы. Урманлылыгы — 16,6 %. Мергель, известьташ, доломит, комташ, балчык, балчыксыман туфрак, ком ятмалары бар. Табигать саклаулыклары: Бәрле, Зөя елгалары, *Кайбыч аучылык тыюлыгы*; табигать истәлекләре: *Зур Күл, Кайбыч имәнлекләре*, *Турминка урман дачасы*. К.р.нда 60 тан артык археол. истәлек (бронза гасырдан Болгар һәм Алтын Урда чорларына кадәр) табыла. Күп кенә археол. табылдыклар 19 йөздә үк *Заусайловлар коллекциясенә* кертелә.

Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык үрчетү зур үсеш алган. А.х. 66,1 мең *га* җир били, ш.и. 56,4 мең *га* сөрүлек җир (2009). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, карабодай, борчак иге-



КАЙБЫЧ РАЙОНЫ
1:1 000 000
1 Яшел Үзән районы, 2 Югары Ослан районы, 3 Апас районы

лә. 2010 да К.р.нда 8 а.х. пр-тиесе, эшли. Сәнәгать пр-тиеләре Олы Кайбыч авылында урнашкан. Районда урман хуҗалыгы, балык эшкәртү хуҗалыгы, икмәк кабул итү пр-тиесе (Колангы тимер юл станциясе поселогында) бар. К.р. жиреннән Ульянов–Зөя тимер юлы, Казан–Ульянов автомобиль юлы уза. 32 гомуми белем бирү мәктәбе (2010/11 уку елында 1880 укучы укый), ш.и. 14 башлангыч, 2 тулы булмаган урта, 16 урта һәм 1 балалар сәнгать мәктәбе; 29 китапханә (1 се балалар өчен), 19 мәктәпкәчә яшьтәгеләр һәм 41 клуб учреждениесе, 87 урынлы хастаханә (2010) бар. *Кайбицкая Галия музее* (Олы Кайбыч а.) эшли. Татар һәм рус телләрендә «Кайбыч таңнары» – «Кайбицкие зори» район г-талары нәшер ителә.

**КАЙБЫ́Ч УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, орлыкчылыкка махсуслашкан, сабакчалы имән орлыкчылыгы, әһәмиятле генофонд табу һәм сайлап алу, даими эшләүче урман орлыкчылыгы участоклары булдыру б-н шөгыльләнә. Кайбыч, Апас һәм Яшел Үзән р-ннары терр-ясендә урнашкан. 1931 елда 20524 *га* мәйданда Төрләмә, Күгәй, Подберезье, Кайбыч, Балтай һәм Коллар урман дачалары составында оештырыла. 1940 та җирле әһәмияткә ия урманнар кушыла. К.у.х.ның гомуми мәйданы 24569 *га*, ш.и. урман мәйданы 23961 *га*. Бәрлебаш (10144 *га*), Урсак (9635 *га*), Күгәй (4790 *га*) урманчылыкларыннан тора. Урман хуҗалыгы дирекциясе Кайбыч р-ны Федоровский авылында урнашкан. Эшләүчеләр саны 205 кеше.

К.у.х.ның урман массивлары Идел буеның типик таулык имәнлекләреннән тора, әдәбиятта «Казан тау имәнлекләре» буларак билгеле. Үзенең югары җитештерүчәнлеге һәм әһәмияте буенча иң яхшылардан исәпләнә, әле 18 йөз башында саклаулы корабль урманнары составына кергән. 1 нче төркем урманнар 7550 *га* мәйданны били, ш.и. аеруча саклаулы табигать терр-яләре – 196 *га*, эрозиягә каршы утыртылган урман – 329 *га*, автомобиль һәм тимер юллары буенда саклаучы полосалар – 365 *га*, сыза урманнары – 4037 га, елга ярлары буенда тыюлык полосалары – 2623 *га*. Җирле әһәмияткә ия 2 нче төркем урманнар 17019 *га* тәшкил итә. Урман культураларының мәйданы 9093 *га*. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшьләре (36%), урта яшьтәгеләре (44%), өлгереп килүчеләре (8%), өлгергәннәре һәм картайганнары (12%). Имәнлекләр 14198 *га* мәйданны били, аларның 95% ка якыны – яшь һәм урта яшьтәге агачлар. Өрәңге-юкә катнаш имәнлекләр өстенлек итә. Утыртылган юкә агачлары мәйданы 4511 *га*, 80–90 яшьтә, агач запасы 1199 мең $м^3$; алар умарта тоту зоналарына кертелгән. Усаклыклар аерым участоклар булып таралган, нигездә, сырмавыклы, гомуми мәйданы 1924 *га*, агач запасы 271 мең $м^3$. Нарат урманнары 1259 *га* мәйданда үсә, аларның 78% ка якыны – яшь, күбесенчә кулдан утыртылган. Каен (1,4%), өрәңге (1,3%), чыршы (0,9%), карагай (0,7%) аз санда таралган. Гади корычагач утыртмалары, 1978/79 дагы кышкы салкыннардан зыян күргәннән соң, табигый ареалының төньяк-көнчыгыш чигендә торгызыла башлады.

К.у.х. терр-ясендә табигать истәлекләре билгеләнгән: 1981 дән – *Кайбыч имәнлекләре*, 140 *га* мәйдан биләүче олы яшьтәге 2 имәнлек участогы; 1989 дан – *Турминка урман дачасы*, 56,3 *га* мәйдан биләүче югары җитештерүчәнлекле нарат утыртмалары, алар фәнни һәм мәдәни-тарихи әһәмияткә ия. Югары бонитетлы имән һәм катнаш урман үскән 743 га мәйданда (Бәрлебаш урманчылыгы) сабакчалы имәннең генетик резерваты формалаша (1997).

Төп кулланылыш өчен еллык урман кисү күләме 12,7 мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 1400 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 10 мең $м^3$ чамасы эшкә яраклы агач әзерләнә. 170–200 *га* мәйданда урман торгызу эшләре (яшь урман утырту) алып барыла. Урман хуҗалыгының даими эшләүче питомникларында ел саен 10 төрле агач-куакның 4,5 млн. үсентесе үстерелә. 955 *га* мәйданда имән, 165 *га* мәйданда юкә орлыкчылыгы буенча даими эшләүче урман участоклары бар. 2 млн. нан артык сумлык халык товарлары (агач-такта материаллары, буралар, койма такталары, әрҗәләр һ.б.) җитештерелә. Урман хуҗалыгы үсешенә зур өлеш кертүчеләр: РФ һәм ТРның атказ. урманчысы И.Х.Хаффазов, ТРның атказ. урманчысы Ф.А.Хәйруллина, Күгәй урманчылыгы урманчысы Н.Г.Георгиев һ.б.

**КА́ЙБЫШЕВ** Оскар Әкрам улы (28.3. 1939, Мәскәү), материаллар белеме өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1974), БР ФА академигы (1991), БАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1979). 1962 елда Мәскәү корыч һәм эретмәләр ин-тын тәмамлый. 1967 дән Уфа авиация ин-тында, металлар белеменең гомуми технологиясе каф. мөдире (1969 дан), проф. (1977). 1980–87 дә «Тантал» махсус конструкторлык-технол. бюросы директоры (Уфа ш.), 1987–2005 тә РФА Уфа Гыйльми үзәгенең Металларның үтә сыгылмалылыгы проблемалары ин-ты директоры. 1991–94 тә БР ФА президенты. Хезмәтләре югары тизлекле деформация тәэсирендә металларның рекристаллашуы механизмнарына, металларның төзелешен һәм үзлекләрен өйрәнүгә карый. Төп хезмәтләре материалларның ныклылык һәм сыгылмалылык физикасына багышлана. К. металл, композицион һәм керамик эшләнмәләрнең форма ясалышы технологиясенең фәнни нигезләрен үстерә. Теләсә нинди сәнәгый металл эретмәләрендә, ш.и. авыр деформацияләнүчән эссегә чыдам һәм титанлы интерметаллидларда, ш.у. керамикада үтә пластик агымнарга шартлар тудыру мөмкинлеген билгели. Үтә пластиклыкның физик теориясен эшли. Металл физикасы һәм материаллар белеме буенча Уфа фәнни мәктәбен төзи. Поликристалларда йотылу яки рәшәткәле дислокацияләр очрагында бөртекләрнең бертөрле булмаган чикләре барлыкка килү күренешен ачучыларның берсе. Уйлап табуга 150 дән артык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пластичность и сверхпластичность металлов. М., 1975; Сверхпластичность промышленных сплавов. М., 1984; Границы зёрен и свойства металлов. М., 1987 (автордаш).

**КА́ЙБЫШЕВЛАР**, татар бәкләре. Нәселне башлап җибәрүче – Карачурин улы, 17 йөзнең 2 нче яртысында Уфа өязе Сабай авылында яшәгән ясаклы татар Кайбыш Үзәев. Ул 1681–84 елларда татар-башкортлар баш күтәрүендә актив катнаша. 19 йөздә К. Сабай, Карагош, Рәсмәкәй, Чыршы-Тартыш авылларында (БРның хәзерге Кушнаренко р-ны) яшиләр. Чыршы-Тартыш К.ы, кантон түрәләре буларак, 19 йөздә нәселдән килгән дворян дәрәҗәсе алалар. 1874 тә Мөхәммәдгәрәйнең Уфа губернасы, Бөре өязе Түбән Сухояш авылы тирәсендә 1598 дис. җире була.

Чыг.: Акты исторические, собранные и изданные археографической комиссией. 1676–1700 годы. СПб., 1842. Т. 5.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Ш а р и п о в а Э. Башкирское шежере из рукописного фонда ИИЯЛ БФАН СССР // Письменные памятники Башкирии. Уфа, 1982.

*Р.Р.Габдуллин.*

**КАЙГОРО́ДОВ** Владимир Романович (24.12.1936, Свердловск өлкәсенең Тура р-ны Яңа Слобода а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1982), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук чагыштырмалылык һәм гравитация теориясе кафедрасында эшли, каф. мөдире (1975–2000), проф. (2001). Хезмәтләре гравитация кыры теориясенә һәм инвариант төркемләү ысулларын тикшерүгә карый.

Х е з м.: Алгебраически специальные поля тяготения с однопараметрической группой движений // Изв. вузов. Физика. 1966. № 5 (автордаш); Обобщённые решения класса Кундта для уравнений Эйнштейна с космологической постоянной // Изв. вузов. Физика. 1966. № 10 (автордаш); Курс аналитической геометрии и линейной алгебры. К., 1986.

**КАЙГЫЛЫ́ КҮБӘЛӘ́К** (Nymphalis antiopa), нимфалидалар семьялыгыннан күбәләк. Татарстанның бөтен районнарында һәм Казан терр-ясендә очрый. Канат җәеме 55–75 *мм*, карасу-кызыл төсмерле бәрхетсыман кара төстә, сары ак каймалы, аның алдында зәңгәр тимгелләрдән торучы рәт, алгы канатларында сары ак төстәге 2 шәр зур тимгел бар. Июль–сентябрьдә оча. Кышкы йокыдан соң, йомыркаларын язын каен, тополь, тал

яфракларына сала. Зур кызыл көрән таплы чәнечкеле кара гусеницалары, арткы өлеше б-н теләсә нинди каты нигезгә берегеп, башлары б-н аска асылынып курчакланалар. Бер атнадан соң хитинлы кабык астыннан булачак күбәләкнең билгеләре ачык күренә. Елга бер, кайвакыт 2 тапкыр үрчи. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*С.Г.Гордиенко.*

**КА́ЙДРИКОВ** Рөстәм Гали улы (3.3.1946, Казан), электрохимик, химия фән. д-ры (1988), проф. (1989), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2004). 1969 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1988 дән электрохимик производстволар технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре металл һәм эретмәләрне хәрәкәтчән электродларга электр тәэсирендә утырту кинетикасын һәм механизмын өйрәнүгә карый. К. төрле типтагы вак детальләргә металлик капламнар төшерү җайланмасын эшли. Коррозион халәттәге металл мониторингының электрохимик технологияләрен, агрессив тирәлекләр тәэсире шартларында конструкцион материалларны фаразлау һәм саклау ысулларын тәкъдим итә. К. житәкчелегендә аз файдаланылган яки халыкара килешүләр б-н тыелган материалларны (кадмий, хром, никель һ.б.) тулысынча алмаштыруны тәэмин итүче электрохимик технологияләр, металл һәм эретмәләрне электр ярдәмендә селектив утыртуның экологик технологияләре, нефтехимик җиһазлар узелларының металлик өлеләкләрен локаль яңадан торгызу, вак детальләрне прецизион ныклы хромлауның технол. процесслары, шиннарны вулканлаштыру, нефть резервуарлары һ.б. өчен пресс-формаларны коррозиядән саклау ысуллары эшләнә. Фәнни эшкәртмәләре Казан оптика-механика з-дында, «Мединструмент» ФҖБдә, Рузаевка химия машиналары төзү з-дында, «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин» АҖләрендә һ.б.ларда гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Особенности электроосаждения гальванических покрытий на подвижные электроды // Защита металлов. 1989. Т. 25, № 3; Влияние условий перемешивания деталей в барабане на равномерность гальванических покрытий // шунда ук. С.312–314 (автордаш); Электроосаждение цинк-никелевых покрытий из щелочных электролитов с добавками аминосоединений // Электрохимия. 2001. Т. 37, № 7 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**КАЙМА́НОВ** Никита Фадеевич (24.9.1907, Уфа губ. Минзәлә өязе, хәзер ТРның Түбән Кама р-ны Прости а. — 18.2.1972, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (26.8.1941), полковник (1958). «Выстрел» курсларын (1940), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1948, Мәскәү) тәмамлый. 1929 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, НКВД гаскәрләренең чик буе отряды штабында бүлек башлыгы. 1941 нең июнь ахыры — июль башында батырлык күрсәтә: 19 тәүлек дәвамында отряды б-н совет-фин чигендә дошманның күпсанлы атакаларын кире кайтара; чигенүгә әмер алып, К. җитәкчелегендәге отряд чолганыш боҗрасын өзә һәм, 160 *км* ара узып, төп частьләр б-н кушыла. Сугыштан соң хезмәтен чик буе гаскәрләрендә дәвам итә (1958 гә кадәр). Мәскәүдә яши. Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Геройга туган ягында Музей-йорт төзелә.




Н.Ф. Кайманов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ч е р н ы ш ё в Т.А. Застава Кайманова. Петрозаводск, 1975; С ч е р е в с к и й В.С., Д р ы г а н Ю.Д. Застава в огне. Петрозаводск, 1982; Бессменные часовые. М., 1983; Героям Родины — слава. Петрозаводск, 1985.

*В.А.Шагалов.*

**КАЙМА́Р** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,5 *км*, бассейнының мәйданы 33,8 *км*². Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы булып зур булмаган урман массивында урнашкан чишмә тора, Каймар авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Дачный поселогыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 57 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 12%. К.ның 1,4 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 148 *мм*, ташу агымы катламы 109 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. К. ноябрьнең 2 нче яртысында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*³*/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада су күләме 0,3 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару һәм балык үрчетү өчен файдаланыла.

**КАЙМА́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 9 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 19 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1565–67 елларда Кече Пустошь-Каймар исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (К. хуҗалары Н.А.*Кудрявцев* һәм аның улы — М.Н.*Кудрявцев*, шагыйрь Е.А.Боратынский гаиләсе һ.б. була) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киез-киез итек басу б-н шөгыльләнә. 1722 дә авылда Пётр I була. 20 йөз башында К.да Кирилл-Белозёрский чиркәве (1723 тә төзелә; архит-ра истәлеге), картлар йорты, земство мәктәбе (1870 тә ачыла), китапханә, халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек оешмасы, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2788 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Каймар волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 451 ир-ат; 1859 да — 1480, 1897 дә — 1158, 1908 дә — 1510, 1920 дә — 1437, 1926 да — 1592, 1938 дә — 1008, 1949 да — 765, 1958 дә — 478, 1970 тә — 221, 1989 да — 60, 2002 дә — 42 кеше.



Каймар авылы. Кирилл-Белозёрский чиркәве. 1723.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КАЙНОЗО́Й ЭРАТЕ́МАСЫ (Э́РАСЫ)**, к а й н о з о й (грек. kainós — яңа һәм zoe — яшәү), өске иң яшь эратема (төркем) — геологик тарихның иң яңа эрасы, җир кабыгы катламнарының гомуми стратиграфик шкаласында иң өске (яшь) төркем. 65 млн. ел элек башланган, хәзер дә дәвам итә. Палеоген, *неоген* һәм *дүртенчел система (чор)* — антропоген дәверләренә бүленә. К.э. көчле таулар ясалу б-н характерлана, Тын океан периферриясендә, Көньяк Европада һәм Азиядә биек таулар барлыкка килә. Неоген чоры ахыры — дүртенчел чор башында табигать кискен үзгәрә, Евразия (ТРдан төньяктарак) һәм Төньяк Америка материклары бозлана. Органик мохитта имезүчеләр өстенлек ала, приматлар барлыкка килә.

К.э. ТР терр-ясендә Идел һәм Кама болынлыкларында үсеш алган неоген һәм дүртенчел системаларның утырмалары б-н билгеләнә.

ТРда кайнозой геологиясен Г.Н.Бурба, Г.П.Бутаков, А.П.Дедков, У.Г.Дистанов, Н.Н.Малышева һ.б. өйрәнә.

**КА́ЙРЕВО** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 15 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 39 кеше (татарлар) яши. Клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1675 елда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Спас, Ягодный исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, слесарьлык һөнәре, тегү, вак-төякләр сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1367,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынга волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 835, 1879 да — 1086, 1897 дә —

1195, 1911 дә — 1287, 1913 тә — 1549, 1920 дә — 1092, 1926 да — 1053, 1938 дә — 562, 1949 да — 310, 1958 дә — 166, 1970 тә — 143, 1979 да — 113, 1989 да — 46, 2002 дә — 60 кеше.

**КАЙТМА́ КЫРЫ́Й МӘСЬӘЛӘЛӘ́Р** (ККМ), ниндидер дифференциаль тигезләмәне яки дифференциаль тигезләмәләр системасын — бирелгән шартларда, ә аның чикләрендә туры кырый мәсьәләләргә караганда бер берәмлеккә зуррак шартларда канәгатьләндерә торган өлкәне һәм функцияне яки функцияләр системасын табу мәсьәләләре. Аналитик функцияләр өчен мәсьәлә болай куела: өлкәне һәм андагы аналитик функцияләрне бу функцияләрнең өлкә чигендәге кыйммәтләре буенча билгеләргә. Шул ук вакытта эчке һәм тышкы мәсьәләләр шактый аерыла.

Аналитик функцияләр өчен ККМ теориясе, саф математик юнәлеш буларак, Казан ун-тында булдырыла һәм үсеш ала; теориягә нигез салучылар — Г.Г.Тумашев һәм М.Т.Нужин. Ике үзгәрешленең гармоник функциясе өчен кайтма кырый мәсьәләне, саф математик мәсьәлә буларак, 1929 елда Д.Рябушинский куя (контурны гармоник функциянең һәм аның нормаль чыгарылмасының анда бирелгән кыйммәтләре буенча табу). 1933 тә Б.Демченко әлеге мәсьәләне чишәргә омтылыш ясый, тик ул гармоник функциянең һәм аның нормаль чыгарылмасының кырый кыйммәтләре контурда түгел, ә ниндидер әйләнәдә бирелгән дип ала һәм бу мәсьәләне шактый гадиләштерә (мондый куелыш Рябушинский куелышыннан күпкә аерыла). Соңрак Рябушинский һәм Демченко ККМга әйләнеп кайтмыйлар. ККМ гамәли мәсьәләләрне — аэрогидродинамика мәсьәләләрен чишкәндә (Ф.Вейниг, 1929; А.Бетц, 1934; В.Манглер, 1938) килеп чыга. 1942–45 тә Тумашев аэрогидродинамика ККМен (АККМ) чишүнең оригиналь алымын тәкдим итә. Бу алымның үзәк өлешен агымның комплекслы потенциалы яссылыгындагы аерым өлкә тәшкил итә, шуның аркасында сыеклыклар һәм газлар механикасында яңа мәсьәләләр кую һәм чишү мөмкинлеге туа. Әлеге эшләрнең әһәмияте гамәли мәсьәләләр кысасыннан чыга һәм матем. физикада яңа юнәлешкә — ККМ теориясенә нигез булып тора. 1947 дә Нужин ККМнең гомуми куелышын билгели һәм аны аналитик функцияләр теориясе мәсьәләсе дип атый (өлкәне һәм аналитик функцияне аның шушы өлкә кырыендагы кыйммәтләре буенча табу). Мондый куелыш эзләнелә торган аналитик функция яссылыгында ККМне үз эченә алган контур кертү, ш. у. эчке һәм тышкы ККМне тикшерү мөмкинлеге бирә. Гармоник функция өчен аларның Нужин тәкъдим иткән классификациясе, чишелүчәнлекләрен тикшерү һәм чишелешләрен табу аналитик функция өчен ККМ теориясенең нигезен тәшкил итә. ККМнең саф математик проблемалары буенча Ф.Д.Гахов мөһим нәтиҗәләр ала (1952–55).

20 йөзнең 2 нче яртысында ККМ буенча теоретик һәм гамәли тикшеренүләр Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты һәм Казан ун-тының механика, дифференциаль тигезләмәләр һәм матем. анализ кафедралары галимнәре тарафыннан бергәләп алып барыла. Күплекләр теориясе һәм топология характерындагы катлаулы сорауларны тикшерүдә, риманча өслекләрдә, күп бәйләнешле өлкәләр өчен ККМ чишүдә, эзләнелә торган чишелешләрнең бер битлелек билгеләрен табуда мөһим теоретик нәтиҗәләр алына (С.Н.Андрианов, В.С.Рогожин, Ю.М.Крикунов, Л.А.*Аксентьев*, Р.Б.Сәлимов, М.И.Хайкин, В.Н.Монахов, Ф.Г.*Әухәдиев*, С.Р.Насыйров). Гамәли ККМдә аэродинамика проблемаларына — аерымланган канат профильләрен, ирекле өслек астында һәм экран өстендә хәрәкәт итүче бипланнарның канат профильләрен, турбомашиналарның профильләрен төзүгә аерым игътибар бирелә. ККМнең яңа юнәлешләре фильтрация теориясе һәм шартлау теориясе б-н бәйләнгән.

1980 еллардан төп игътибар аэрогидродинамиканың кайтма кырый мәсьәләләрен (АККМ) чишүгә юнәлтелә. Канат профильләрен проектлаштыру һәм оптимальләштерүнең нәтиҗәле юлларыннан берсе АККМне чишүгә нигезләнә, аның асылы профиль формасын тизлек һәм басымның бу профильнең контуры буйлап бүленеше буенча эзләүдән гыйбарәт. Нәкъ менә шундый бүленешләр аша төп аэродинамик характеристикалар — күтәрү көче, каршылык көче, аэродинамик сыйфат билгеләнә дә. АККМ буенча күпсанлы хезмәтләр Н.Е.Жуковский исем. Үзәк аэродинамика ин-ты (Мәскәү) һәм Казан ун-ты галимнәре тарафыннан эшләнгән. Тематикасы буенча моңа якын тикшеренүләр ш.у. Мәскәү ун-тының Механика ин-тында, РФА Себер бүлеге Теоретик һәм гамәли механика ин-тында (Новосибирск ш.), Казан техник ун-тында, С.П.Королев исем. Самара аэрокосмик ун-тында, П.И.Баранов исем. Үзәк авиация моторлары төзү ин-тында (Мәскәү), А.Н.Крылов исем. Үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында (С.-Петербург) да үткәрелә. Канат профильләренең аэродинамик сыйфатларын яхшырту максатыннан чик катлам б-н суырту яки кабарту алымы ярдәмендә идарә итү, күп элементлы канат профильләре өчен аэродинамиканың кире мәсьәләләрен чишү, геометрик чикләмәләр бирелгәндә профильләрне аэродинамик проектлаштыру һәм оптимальләштерү кебек перспектив юнәлешләр үсеш ала. 1980 елларда Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында нәкорректив АККМ куелышын регулярлаштыру һәм аларның квазичишелешләрен табу юлы эшләнә, бу юл бирелгәннәрне минималь коррекцияләү хисабына чишелешләрнең физик гәүдәләнешен табарга мөмкинлек бирә.

Хезмәтләрнең 1 нче сериясе тышкы агымны модельләштерүнең төрле вариантлары б-н бәйләнгән, бу, аерым алганда, суыртуга кагыла, чөнки ул чик катлам б-н идарә итүнең канат профиленең аэродинамик характеристикаларын яхшыртуга юнәлтелгән бер юлы булып тора. 2 нче серия хезмәтләр очкыч аппаратларның төп элементларын, күп элементлы профильләрне проектлаштыру, гомуми куелыштагы АККМне, аналитик-кисәкле мәсьәләләр чишү б-н бәйле. Мондый катлауландырулар шактый ук математик кыенлыклар тудыра. 3 нче серия хезмәтләр оптималь аэродинамик проектлаштыру мәсьәләләре б-н бәйләнгән. Оптималь аэродинамик проектлаштыруның яссылык мәсьәләләрен чишүдәге бер алымы вариацион АККМ теориясенә нигезләнә. Бу алым кысаларында күп кенә оптимальләштерү мәсьәләләре тикшерелгән. Гамәли ККМ чишүдә Тумашев һәм Нужинның шәкертләре һәм дәвамчылары Л.Л.Лебедев, Р.М.Насыйров, М.Ф.Мөхәммәтҗанов, А.М.Казбан, Н.Б.*Ильинский*, О.М.*Киселёв*, Н.Б.Сәлимов, Н.Д.*Якимов*, А.М.*Елизаров*, А.Б.*Поташёв*, Д.А.*Фокин*, Д.Ф.Әбҗәлилов зур өлеш кертәләр.

*Әд.:* Тумашев Г.Г., Нужин М.Т. Обратные краевые задачи и их приложения. К., 1965; Теория обратных краевых задач для аналитических функций и их приложения // Итоги науки и техники. Мат. анализ. 1980. Т. 18; Аксентьев Л.А., Ильинский Н.Б. История развития обратных краевых задач в Казани: Очерки истории НИИ математики и механики имени Н.Г.Чеботарёва. К., 1989; Елизаров А.М., Ильинский Н.Б., Поташёв А.В. Обратные краевые задачи аэрогидродинамики. М., 1994; шулар ук. Развитие исследований по обратным краевым задачам аэрогидродинамики // На рубеже веков: Науч.-исслед. ин-т математики и механики им. Н.Г.Чеботарёва Казан. гос. ун-та. 1998–2002 гг. К., 2003.

*Н.Б.Ильинский.*

**КАКА́ЛИЯ** (Cacalia), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. ТР терр-ясендә бер төр — сөңгесыман К. (C. hastata), сирәк очрый. Сирәкләнгән яфраклы һәм катнаш урманнарда үсә. Туры сабаклы, горизонталь тамырчалы, 120 *см* биеклеккә җитүче үсемлек. Яфраклары сабакчыл, сөңгесыман киң. Чәчәкләре аксыл, сабак очында себеркәчле чәчәк төркеме хасил итә. Җимеше — озын очкаклы орлыкча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Үсемлектә алкалоид, флавоноид, C витамины, каротин бар. Халык медицинасында җир өсте өлешләре төрле йогышлы авыруларны, үлекле яра һәм җәрәхәтләрне дәвалау өчен кулланыла. Баллы үсемлек.

**КАКЛАВЫ́Ч**, каты билчән (Cirsium), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә икееллык үсемлекләр ыругы. 200 дән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралган. ТР терр-ясендә 8 төре бар. 2 *м* га кадәр биеклектәге чәнечкеле үсемлекләр. Яфраклары озынча, бөтен яки каурыйсыман бүленмә. Чәчәкләре яшькелт-сары, аксыл шәмәхә, җете кызыл, көпшәле, кәрзингә җыйналган. Җимешләре — каурыйсыман төкчәле очкак орлыкча. Июнь ахырыннан сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Тамыр үргеннәреннән, тамыр өземтеләреннән, сирәк кенә орлыктан үрчи. Гади К. (C. vulgare), бакча К. (C. oleraceum), кыр К. (C. arvence), төрле яфраклы К. (C. heterophyllum) республиканың һәр җирендә таралган. Аланнарда, урман кисенделәрендә, юл буйларында, ташландык җирләрдә, чүплекләр тирәсендә үсәләр. Вак тешәүле К. (C. serrulatum), сары К. (C. esculentum),



Кыр каклавычы.

соры К. (C.canum) болыннарда, ш. у. Кама аръягының яткын һәм ташландык җирләрендә, ак төкле К. (аксыл К.) (C. incanum) — зур елгаларның (Кама, Агыйдел) тугайларында очрый. Кыр К. яки алсу (каты) билчән — тамыр үргеннәрен юкка чыгару кыен булган чүп үлән, барлык а.х. культураларын, бакча чәчүлекләрен чүпли. Бакча, гади кыр К.ының яшь яфраклары ашарга яраклы. Халык медицинасында кыр К.ының сулы төнәтмәсе тире авыруларын дәвалаганда кулланыла. К.ның күп кенә төрләре баллы. Сары К. — декоратив, ак төкле К., бакча К., төрле яфраклы К. — терлек азыгы.

**КАКУ́К** (Kakuk) Жужа (1925 елда туа), венгр шәркыятьче галиме, Будапешт ун-ты профессоры (1970 елдан). «Көнчыгышны өйрәнү» ж-лы мөхәррире (1986 дан); Венгрия ФАнең ориенталистика ком-ты рәисе (1985 тән). Венгрия тюркологиясе тарихы, татар теле һәм татар фольклоры, төрек диалектлары буенча хезмәтләр авторы. И.Кунош тарафыннан тупланган татар фольклоры фәнни җыентыкларын немец телендә нәшер итә: «Казан татарларының халык җырлары» («Kasantatarische Volkslieder», Bdpst, 1980), «Казан татарларының халык әкиятләре» («Kasantatarische Volksmärchen», Bdpst, 1989).

*И.Н.Надиров.*


**КАКЫ́** (Bunias), әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ырыгы. 6 төре билгеле, Евразиянең уртача һәм субтропик поясларында, Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — көнчыгыш К. (B. orientalis) барлык районнарда да очрый. Болыннарда, тау битләрендә, сызаларда, кырларда, чүплекләр тирәсендә үсә. 25–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры үзәк. Сабагы туры, ботаклы, аска караган кыска төкчәле һәм кара сөялләре бар. Аскы яфраклары каурыйсыман бүленмә, өскеләре — ланцетсыман, тешле читле. Чәчәкләре ачык сары, күп чәчәкле себеркәчле чәчәк төркемендә. Җимеше — бер орлыклы ачылмаучы кузакчык. Май ахырыннан июльгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июль ахыры — август башында өлгерә. Нигездә орлыктан үрчи. Яшь ботак һәм яфракларында эфир майлары, С витамины, тимер, бакыр, орлыкларында 10 % ка кадәр май бар. Халык медицинасында зәңгеләгә каршы чара буларак кулланыла. Баллы үсемлек. Терлек азыгы.

**КАКЫЛЫКҮ́Л** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 7 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 101 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1920 дә — 201, 1926 да — 185, 1938 дә — 241, 1949 да — 235, 1958 дә — 216, 1970 тә — 193, 1979 да — 160, 1989 да — 104, 2002 дә — 106 кеше.

**КАЛАГА́НОВ** Александр Викторович (10.3.1947, Украина ССРның Каменец-Подольск ш. — 22.2.2001, Түбән Тагил ш.), драма актёры, ТРның халык артисты (1995). И.А.Слонов исем. Саратов театр уч-щесен тәмамлый (1969). 1969–70 елларда Калининград өлкәсенең Советск шәһәре драма театрында, 1970–81 дә — Казан, 1981–83 тә Киров яшь тамашачылар театрларында. 1983–99 да Казан Зур драма, 2000 нән Түбән Тагил драма театрлары актёры. Казан яшь тамашачылар театры сәхнәсендә Кудряш («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Букин, Сильва («Июньдә хушлашу», «Шәһәр читендә очрашу», А.В.Вампилов), Бумбараш (А.П.Гайдарның шул исем. әсәре буенча), Малахов-эти («Малаховны туктатыгыз», В.А.Аграновский), Смелянский («Казан университеты», Д.Н.Вәлиев) кебек әһәмиятле образлар тудыра. Аның башкаруында табигыйлек, гадилек, сәхнәдә чагылыш тапкан тормыш дөреслеге, психологик анализның тирәнлеге, гәүдәләндерелгән персонажның төгәл социаль характеристикасы б-н бергә үрелеп бара. Казан Зур драма театры сәхнәсендә дә шактый образлар иҗат итә: Тарелкин («Эш», А.В.Сухово-Кобылин), Шариков («Табиб Борментальнең көндәлек дәфтәре», М.А.Булгаковның «Эт йөрәге» повесте буенча), Шейлок («Венеция сәүдәгәре», У.Шекспир), Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь). Актёр, геройлар кичергән каршылыклар тәэсиренең драматизмын көчәйтеп, характерларның һәм иҗтимагый көрәнешләрнең фаҗигале асылын ача. Шул ук вакытта аның геройлары, кайсы гына тарихи чорга карасалар да, үз-үзләрен тотышы, дөньяга карашлары, уйланырга, фикер йөртергә этәрүләре б-н тамашачы



А.В.К а л а г а н о в Шариков («Табиб Борментальнең көндәлек дәфтәре», М.А.Булгаковның «Эт йөрәге» повесте буенча) ролендә.



А.В.Калаганов.

өчен һәрвакыт заманча булып кала. Бөтенләй диярлек грим кулланмыйча, К. рухи яктан яңача гәүдәләндерелгән, тормыш дөреслегенә туры килә торган, ышандырырлык образлар иҗат итә. К.Тинчурин исем. 2 нче Республика театр фестивале лауреаты.

*Әд.:* Б л а г о в Ю.А. Казанский театр юного зрителя. К., 1986; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**КАЛА́ЙДА** Марина Львовна (13.6.1957, Литва ССРның Шяуляй ш.), гидробиолог, эколог, биол. фән. д-ры (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли, 1998 елдан умырткалылар зоологиясе каф. профессоры. 2002 дән Казан энергетика ун-тында, инженерлык экологиясе каф. профессоры. Хезмәтләре сулыклар экосистемасын, Урта Идел буендагы балык ресурсларын ясалма җитештерү һәм рациональ файдалануны өйрәнүгә, экосистемага антропоген йогынтыны бәяләүгә карый. К. комплекслы сулыкларның продуктив потенциалын өйрәнә һәм көтүлекле аквакультура алымы б-н төбәкләрдәге балык хуҗалыгын үстерү концепциясен эшли. Зәй ГРЭСнең суыту сулыгында личинка стадиясеннән ташмаңгай һәм аның гибридларын җитештерү мөмкинлеген күрсәтә. Зур төзелешләрнең (Кама елгасы аша күпер, Кече Казан бөҗрасы, Зур Казан бөҗрасы) һәм Казанның үзәк өлешен үзгәртеп коруның әйләнә-тирә мохиткә негатив йогынтысын экологик бәяләү эшләрен җитәкли.

Х е з м.: Водоёмы комплексного назначения как основа рыбного хозяйства в Среднем Поволжье // Проблемы развития рыбного хоз-ва в аридных регионах. М., 2001; История и перспективы развития рыбного хозяйства Татарстана. К., 2001; Экологическая оценка Куйбышевского водохранилища в условиях антропогенного воздействия. К., 2003.

**КАЛАМКА́РОВА** Люция Исхак кызы (27.5.1937, Кыргызстан ССР, Фрунзе ш.), сан.-гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1988), проф. (1990). Алма-Ата мед. ин-тын тәмамлагач (1962), Төбәк патология фәнни-тикшеренү ин-тында (Алма-Ата) эшли, 1975 елдан Казакъстан Респка-сы Мәгариф һәм фән министрлыгының Тукландыру ин-ты хезмәткәре, ризыкларның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын контрольдә тоту бүлеге мөдире. Тикшеренүләре сан. һәм клиник микробиол. өлкәсенә: ризыкларның химик һәм биол. куркынычсызлыгы, эчәклек дисбактериозы этиологиясе мәсьәләләрен өйрәнүгә, аны булдырмау һәм дәвалауга карый. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Использование отечественных штаммов лактобацилл при лечении детей, страдающих упорной диареей // Биотехнология: теория и практика. 1998. № 4.

**КАЛА́Н**, Җүчи олысы һәм татар ханлыкларындагы салымнарның бер төре. «К.» атама-

сының мәгънәсе аны куллану вакытына һәм урынына карап үзгәрә. Кайбер очракларда бу атама б-н аулап алынган җирдән җан башыннан яки җирдән алына торган салымнарны атаганнар. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында ул кайчак «ясак-калан» мәгънәсендә йөргән һәм төп салымны аңлаткан. «К.» атамасы Алтын Урда һәм 15–16 йөзләрдәге татар ханлыклары ханнарының барлык ярлыкларында очрый.

*Әд.:* Березин И.Н. Внутреннее устройство Золотой Орды. К., 1850; Федоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975; Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*И.Л.Измайлов.*

**КАЛАНХО́Е** (Kalanchoe), кантибәрчәләр семьялыгыннан суккулент сусыл ярымкуаклар яки үләнчел үсемлекләр ыругы. 200 гә якын төре билгеле. Чыгышы — Америка һәм Африканың тропик һәм субтропиклары. ТРда бүлмә гөле буларак үстерелә; аеруча таралганнары: киезсыман К. (K. tomentosa) — очлары көрән төстә булган куе төкчәле көмешсыман соры яфраклы; Федченко К.сы (K. fedtschenkoi) — тонык күгелҗем яфраклы һәм түбәнге өлешендә һава тамырлары барлыкка китерүче күп сабаклы; Кьюс К.сы (K. kevensis) — сусыл, үзенчәлекле теленмә яфраклы; Блоссфельд К.сы (K. blossfeldiana) — кара яшел яфраклы, сары, кызыл, алсу төстәге вак чәчәкләре куе чатырсыман чәчәк төркемендә; каурыйсыман К. (K. pinnata). Соңгы төр бүлмә женьшене, тормыш агачы исеме б-н билгеле.

Яфраклары бөтен, зур, түгәрәкләнгән тешле читле һәм үзәк сеңерчәле. Өскеләре — катлаулы парсыз каурыйсыман, аскылары — гади озынча түгәрәк. Чәчәкләре иенке, таҗ көпшәсе яшькелт ак, таҗ яфракчыклары кирпечсыман кызыл. Фәнни медицинада кулланыла. Согы яра һәм җәрәхәтләрне үлә баручы тукымалардан чистарта, яра төзәтүдә көчле чара буларак тәэсир итә. Кайбер күз авырулары, рожа ялкынсынуы вакытында кулланыла. Барлык төрләре дә яктылык яратучан. Сабактан һәм яфраклы чыбыкчадан үрчетелә.

**КАЛАТА́У** посёлогы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 69 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Саба р-нында. Халык саны: 1938 дә — 125, 1949 да — 120, 1970 тә — 149, 1979 да — 99, 1989 да — 87, 2002 дә — 78 кеше.

**КАЛА́ШНИКОВ** Анатолий Степанович (23.10.1922, Казан — 25.6.1985, Минск), Сов. Союзы Герое (26.10.1944), подполковник (1960). Очучыларның Ульянов хәрби авиация мәктәбен (1943), Н.Е.Жуковский исем. Хәрби һава инженерлары академиясен (Мәскәү, 1949) тәмамлый. Чистай шәһәре аэроклубында очучы-инструктор булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 637 нче штурм авиациясе полкында эскадрилья командиры урынбасары (2 нче һава армиясенең 227 нче авиация штурм дивизиясе). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында 1944 нең маена 107 сугышчан очыш ясый, дошманның 27 танкын, 100 автомашинасын юк итә, һава сугышында дошман истребителен бәреп төшерә. Сугыштан соң хезмәтен Совет Армиясендә дәвам итә (1960 ка кадәр). Минск шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Чистай шәһәренең 1 нче мәктәбе бинасына Герой исемен мәңгеләштергән мемориаль такта эленә.



А.С.Калашников.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*В.А.Шагалов.*

**КАЛА́ШНИКОВ** Михаил Анатольевич (3.5.1935, Казан), приборлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), проф. (1995). 1963 елда Горький политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Авиация технологиясе фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1972 дән Казан химия-технол. ин-тында (бүлекнең, 1975–78 дә Бөтенсоюз физик-техник һәм радиотехник үлчәүләр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында). 1988–95 тә Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында, электр күчергечләрен һәм сәнәгать җайланмаларын һәм технол. комплексларны автоматлаштыру каф. мөдире (1991–95). Хезмәтләре зыянсыз электромагнитик контрольгә, автоматикага һәм метрологиягә карый. Адымлы электр күчергечләре куелган пешкәкле прецезион дозаторлар теориясен, прецезион дискрет электр күчергечләренең ялгышларын автомат рәвештә төзәтү өчен программ һәм техник чаралар эшли.

Хезм.: Переменно-частотные электромагнитные дефектоскопы. К., 1994; Прецезионные поршневые дозаторы с шаговым электроприводом. К., 1994; Средства и системы контроля управления и автоматизация в энергетике: В 2 кн. К., 1994.

**КАЛА́ШНИКОВ** Николай Григорьевич (6.8.1929, Саратов өлкәсенең Терновский р-ны Квасниковка а. – 19.7.2009, Казан), төзүче инженер, РСФСРның атказ. төзүчесе (1989), техник фән. канд. (1996). Саратов автомобиль юллары ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Кемерово өлкәсе «Араничевскстрой» төзелеш идарәсендә өлкән механик булып эшли. 1953–60 елларда «Омскстрой» идарәсенең Машина юллары идарәсе башлыгы, 4 нче төзелеш р-ны баш механигы. СССР ХХСның 6 нчы Омск тресты (1960–62), «Омскнефтепроводстрой» тресты (1962–69) төзелеш идарәләре башлыгы. 1969–70 тә «Татнефтепроводстрой» тресты баш инженеры, 1970–79 да — управляющие. 1979–91 дә «Татстрой» терр.-төзелеш берләшмәсе башлыгы, 1991–99 да «Татстрой» АҖ ген. директоры. К.ның турыдан-туры катнашы б-н һәм аның җитәкчелегендә газ һәм нефть үткәргечләре, нефть һәм химия сәнәгате, сәнәгать, торак, мәдәни-көнкүреш, а.х. б-н бәйле объектлар төзелә һәм файдалануга тапшырыла. 1981–94 тә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, Кызыл Байрак, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КАЛА́ШНИКОВА** Галина Сергеевна (25.8.1940 (башка чыганакларда 1936), Владивосток ш. — 23.6.1988, Казан), балет артисты, педагог, ТАССРның халык артисты (1964). 1956 елда Ленинград хореография уч-щесен (педагогы — О.Г.Иордан) тәмамлый. 1956–76 да Татар опера һәм балет театры солисты, бер үк вакытта шунда ук балалар балет студиясе педагогы (1961–64) һәм балет труппасы педагогы-репетиторы (1968–76). Хореографик партияләре арасында — Жизель (шул исем. әсәр, А.Адан), Одетта-Одиллия («Аккош күле», П.Чайковский), Маша («Щелкунчик», П.Чайковский), Никия («Баядерка», Л.Минкус), Асель (шул исем. әсәр, В.Власов), Мехмене Бану («Сөю турында легенда», А.Меликов), Зарема («Бакчасарай фонтаны», Б.Асафьев), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин), Гаймә («Алтын тарак», Ә.Бакиров) һ.б. Көчле актёрлык сәләтенә ия, бертигез дәрәҗәдә классик һәм характерлы бию техникасы остасы булуы б-н аерылып тора.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980.

*В.Н.Горшков.*

**«КАЛӘ́М»**, Уфа губернасы Эстәрлетамак шәһәрендәге нәшрият. Аны 1906 елда имам Мөхәммәтгариф Рәмиев һәм шәхсән мактаулы гражданин Бәдретдин Гыйбадуллин ача, башлап йөрүчесе III Дәүләт Думасы әгъзасы Ш.Мәхмүдов. Нәшрият татар китапларын нәшер итү һәм сату б-н шөгыльләнә. Башта үзенең заказларын Уфаның Электр губерна басмаханәсенә, аннары Орск шәһәренең «Шәрекъ» татар басмаханәсенә урнаштыра. 1910 да нәшрият Эстәрлетамакта «Нур» басмаханәсен ачу инициаторы һәм аның күмәк пайчысы була. Филиалы 1912 дә Мәләвез авылында ачыла. «К.»дә Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның беренче варианты, татар мәктәпләре өчен шигырьләр, хикәяләр, тәрҗемәләр, дәреслекләр, уку ярдәмлекләре, Ә.Биктимеров, З.Ярмәки, Х.Кәримов, Ш.Мәхмүдов, С.Яхшыгулов, М.Ибраһимов, Б.Гыйбадуллин, М.Хәнәфи, Х.Сатлыков һ.б. әсәрләре; Г.Алпаров төзегән «Кесә календаре» («Карманный вечный календарь»), И.Некрасовның М.В.Ломоносов турындагы (М.Ибраһимов тәрҗемәсендә) очеркы һ.б. китаплар басыла. 1918 елдан соңгы язмышы билгесез.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**КАЛЕНДА́РЬ** (лат. calendarium — бурычлар кенәгәсе — calendae сүзеннән. Рим календаренда — айның беренче көне; бурычлыларның процент түләү көне), бәйрәм көннәре, тарихи вакыйгалар, зур булмаган әдәби әсәрләр, хронологик мәгълүматлар урнаштыручы белешмә басма. К.лар исәпләү тибына (кояш, ай); вакыт сыйдырышлылыгына (сезонлы, еллык, «мәңгелек»); кулла-














1. «Казан шәһәре белешмәлеге», 1840; 2. «1869 елгы Казан календаре»; 3. К. Насыйриның татар телендәге «Казан календаре», 1871; 4. Татар телендәге «Заман календаре», 1900; 5. Удмурт телендәге «Удмуртлар өчен календарь», 1907; 6. «Мари календаре», 1911; 7. Татар телендәге дивар календаре, 1938; 8. «Татар календаре», 1994.

ну сферасына (дини, дөньяви); мәгълүмат бирү характерына (универсаль, махсус); билгеле бер максатны күздә тотуына (гомуми кулланылышлы, популяр, фәнни, реклама ясаучы, өйрәтү характерында); төзелешенә (табаклы, ертып алына торган) карап төрле була.


Беренче рус басма К.е булып И.Ф.Копиевский нәшер иткән «Изгеләр, яки Календарь» («Святцы, или Календарь»; Амстердам, 1702) санала. Ел саен чыгучы басма К.лар сериясен нәшер итү Мәскәүдә 1709 елдан, ә С.-Петербургта 1713 тән башлана. 1724 тән К. чыгару хокукына бары Петербург ФА генә ия була; К. чыгарудан җыелган керемнәр китапханә һәм Кунсткамера тотуга сарыф ителә. К.ларны ФА академиклары, профессорлары, адъюнктлары төзи; шуңа да беренче басмаларда ук шул чор К.ларына хас булган астрологик күзаллауларга урын кими төшә. К.га өстәмә рәвештә тарих, геогр., астрономия, мед. буенча фәнни-популяр мәкаләләр, сәяси хәбәрләр басыла. Мәсәлән, «Календарь, яки 1773 ел өчен тарихи Месяцеслов» («Календарь, или Месяцеслов исторический, на 1773 год», 1772); анда «Патшалар китабы» («Царственная книга», 1769) һәм П.И.Рычковның «Борынгы һәм урта чорлардагы Казан тарихы тәҗрибәсе» («Опыт казанской истории древних и средних времян», 1767) буенча И.М.Стриттер тарафыннан төзелгән «Патша Иван Васильевич заманында Казан каласын басып алу һәм Казан патшалыгын бөлдерү тарихы» («История о взятие города Казани при царе Иване Васильевиче и разорении Казанского царства») бәян ителә.

1801 нең 19 декабрь Фәрманы буенча провинция К.ларын алар бары тик электән үк нәшер ителгән шәһәрләрдә чыгарырга рөхсәт бирелә. Ә 1865 тән Россиядә К. чыгару теләге булган һәркемгә, ш.и. провинциялеләргә дә рөхсәт ителә башлый. Россиядә танылган К. чыгаручылар: А.С.Суворин, И.Д.Сытин һ.б., ә Казанда — М.В.Шимановский була. С.-Петербургта А.Н.Суворов редакциясендә чыгып килгән «Иллюстрацияле рус календарьлары» («Русские иллюстративные календари») сериясенең бер чыгарылышы — «Казан губернасының 1893 елга иллюстрацияләнгән календаре» («Иллюстрированный календарь Казанской губернии на 1893 год», 1892) — Казан губернасына багышлана.

Казан губернасында К. характерындагы беренче басма — «Казан шәһәре белешмәлеге» («Указатель города Казани») (хәрби губернатор И.С.Чернов күрсәтмәсе буенча төзелә) — 1840 та Казанда рус телендә басыла, 1841 дә төзәтмәләр б-н яңадан чыгарыла. Ул үз эченә гомум мәгълүматлар; белешмәләр (дини бәйрәмнәр исемлеге, мөселман К. һ.б.); хөкүмәт һәм җәмәгать йортларының адреслары, сәүдәгәрләр, сәнәгать йортлары, төрле һөнәрчеләр исемлеге, ш.у. шәһәрдә яшәүчеләр саны, йортлар исәбе, уңайлылык, яшәү шартлары, санитар тормыш, шәһәр бюджеты һ.б. турында белешмәләрне ала. 1869 дан Казанда губерна турында кыскача статистик мәгълүмат бирүче, үз эченә тарихи күзәтүләр, атаклы урыннар турында белешмә, ел эчендә булып узган мөһим вакыйгалар, некрологлар, Казанда чыккан китаплар исемлеген туплаган К.лар (даими булмаган) чыгарыла башлый. Шундый төр басмаларның төзүчеләре һәм наширләре арасында П.П.Васильев, И.Гаврилов, А.А.Дубровин, В.М.Ключников, Н.Редников, К.А.Тилли булуы мәгълүм. Аерым бер тармак буенча гына махсуслаштырылган «Юристлар өчен календарь һәм белешмәлек китабы» («Календарь и справочная книжка для юристов», 1874) һәм ярдәм итү максатындагы хәйрия («Календарь-лилипут», 1882; кешелекне яратучылар җәмгыяте ашханәсе файдасына В.И.Заусайлов чыгара) К.лары чыгарыла. Рев-циягә кадәр китап бастыру эшендә Идел-Кама төбәге турында гомуми белешмәләр һәм тарихи мәкаләләренең күптөрлелеге б-н аерылып торган «Волжский вестник» календаре» («Календарь «Волжского вестника»), ш.у. «Казан биржа сәхифәсе календаре» («Календарь «Казанского биржевого листка») (икесе дә 1888 дә чыга) аерым урын биләп тора.

Татарлар 1917 гә кадәр «К.» төшенчәсен билгеләү өчен «горрәлек», «горрәнамә», «тәкъвим», «салнамә», «рузнамә» кебек гарәп-фарсы алынмаларын кулланып килгәннәр. Татар теленә «К.» термины К. Насыйри тарафыннан кертелә. Аның беренче чыгарган К.лары «Казан календаре» дип атала, 1878 дән — бары «Календарь» дип йөртелә. Сакланып калган татар кулъязма К.лары үрнәкләре 18 йөз башына карый. Алар кулъязма җыентыкларга керәләр, ш.у. аерым К. үрнәкләре дә очрый. Татар кулъязма К.ларында берьюлы берничә ел исәбе системасы кулланыла: гарәп ай (*һиҗри*) һәм кояш К., христиан кояш һәм 12 еллык Шәрекъ К.е. Китап басу барлыкка килү б-н кулъязма К.лар басма аналоглары тарафыннан кысрыклап чыгарылалар.

Төрки-мөселман халыклары һәм россиялеләр арасында татарлар беренчеләрдән булып К. чыгара башлыйлар. Беренче басма татар К. — «Горрәлек» 1841 дә Казанда мәгърифәтче Р.Әмирханов тарафыннан чыгарыла. 1905 кә кадәр татар басма К.лары билгеле бер дәрәҗәдә вакытлы матбугат ролен үтиләр һәм иҗтимагый-сәяси тематикалы мәгълүмат бастыралар. 19 йөзнең икенче яртысында — 20 йөз башында К. чыгару аеруча киң тарала. Мәсәлән, 1870–98 елларда (1886, 1887, 1895 елларны исәпкә алмаганда) К.Насыйри төрле фәннәрдән энциклопедия ролен үтәүче һәм гади аңлаешлы телдә язылган К.лар чыгара. Алар үз эченә мед., тәрбия, татар һәм рус халкы тарихы буенча (мәс., «Шигали ханның үз вәзирләре турында җыры» яки «Рус тарихыннан истә калырлык вакыйгалар» хронологик таблицасы) мәгълүматларны туплыйлар. Татарча К.лар чыгаручылар арасында тагын Ш.Рәхмәтуллин (1891–1901 һәм 1914 ел К.лары), Ф.Халиди (1893–1912, 1894, 1895, 1908–10 елларны исәпкә алмаганда), Г.Фәезханов (1893), иң популяр календарьлардан берсе «Заман» («Эпоха», 1900–17) К.ының төзүчесе һәм мөхәррире Ш.Шәгыйдуллин, «Мөшавәрәт» («Киңәш», 1914–17) К.е мөхәррире М.Кадерməти, «Шәрекъ» (1915–17) К.ен нәшер итүче К.Бәширов һ.б. бар. 1917 гә кадәр чыгып килгән 200 ләп татар басма К.е билгеле. Алар поли-







К. Б ә ш и р о в. «Шәрекъ» календаре. 1915.

график үтәлешләренә карап: өстәл К.ларына; брошюра тибындагыларга; дивар К.ларына һәм плакат формасындагыларга; ертып алынучы дивар К.ларына; кесә К.ларына бүленәләр. Беренче басма К.лар брошюра рәвешендә булалар. Китап басу техникасы камилләшү барышында К.ларның башка төрләре дә барлыкка килә, ертып алына торган дивар К.лары киң таралыш ала. Шул төрдәге иң беренче К. — «Тәкъвими дивари календарь» («Бүленгән дивар календаре»), ул Ә.Максуди тарафыннан 1898 дә төзелә. Тора-бара куен дәфтәре рәвешендәге кесә К.лары да чыга башлый (Ш.Шәгыйдуллин К.е, 1910; Г.Алпаров, 1911; К.Бәширов, 1915). Гадиләре б-н беррәттән татарноширләре әдәби, фәнни-әдәби, сәүдә-сәнәгать К.ларын да бастыралар.

1905–07 елгы рев-циядән соң хөкүмәт Россиядә милли телләрдә китап басуны рөхсәт итә. Милли интеллигенция Идел-Агыйдел төбәге халыкларын мәгърифәтле һәм мәдәниятле итү өчен көрәшкә керешә. Казан губернасында яшәүче халыклар телендә К.лар чыгарыла башлый. Мәсәлән, Казан укытучылар семинариясе мөгаллиме И.Михеев 1904–09 да үз хисабына удмурт телендә «Удморт кылын календарь» («Удмуртлар өчен календарь») исемле белешмә өстәл К.е чыгара. Анда статистик белешмәләр, хуҗалык алып бару, мал-туарны дәвалау турында файдалы киңәшләр, белешмә эчтәлекле язмалар туплана. Удмурт халкы укый алырлык уку йортлары исемлеге бирелә, публицистик язмалар, матур әдәбият үрнәкләре урын ала. Бердәм мари әдәби теле үсешенә ярдәм иткән «Мари календаре» (1907–13) зур әһәмияткә ия. Ләкин бу еллык милли К.лар даими басылмый. Аларның нәширләре сәяси идеяләр тарату б-н шөгыльләнмәсәләр дә, демократик эчтәлекле язмалар урнаштыралар; шуның нәтиҗәсендә К. тиражы еш кына кыскартыла.

1917 елдан соң «Соцәкгиз» һәм «Политиздат» нәшриятлары һәм ш.у. хәрби, а.х., театр өлкәләренә караган проф. нәшриятлар, региональ-җирле нәшриятлар, мәс., «Татарстанның билгеле һәм истәлекле даталары календаре» (1969 елдан), универсаль К.лар чыгаралар. 1990 еллардан башлап Татарстан китап нәшрияты, «Раннур» нәшриятлары һ.б.лар рус, татар телләрендә Татарстан тарихы, күренекле галимнәрнең, язучыларның тормышы, иҗаты турында мәгълүмат һәм танылган җәмәгать эшлеклеләренең биографияләрен туплаган К.лар чыгарып киләләр.

*Әд.:* Дивари календарь // Тәрҗеман. 1906. 1 дек.; К ә р и м у л л и н Ә.Г. 90 ел түгел, ә 120 ел // Совет әдәбияты. 1961. № 3; ш у н д а у к. Каюм Насыйри календарьлары // Әйдә халыкка хезмәткә! К., 1985; Д ә у л ә т ш и н Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Ә х м ә т җ а н о в М. Татар кульязма китабы. К., 2000; М и ң н у л л и н а Л. Татар календарьлары тарихыннан // Казан утлары. 2001. № 7; П а в л о в А. Казанские календари: 1840–1891. Ист.-библиогр. заметка // Казанские вести. 1892. 11–12 янв.; К а т а н о в Н.Ф. Обзор казанско-татарских отрывных календарей за последние 3 года (1902–1904) // Деятель. 1904. № 6; Б е р к у т о в В.М. Народный календарь и метрология булгаро-татар. К., 1987; Удмуртская Республика: Энцикл. Ижевск, 2000.

*Л.Ж.Миңнуллина, И.А.Новицкая.*


**КА́ЛИЙЛЫ АШЛАМАЛА́Р**, минераль матдәләр, үсемлекләрне тукландыру өчен калий чыганагы буларак кулланыла. Калий матдәләр алмашында актив катнаша, уңышны арттыра, үсемлекләрнең кышка чыдамлылыгын күтәрүгә, сөрлегүгә һәм ончыл чык б-н зарарлануга каршы торучанлыгына ярдәм итә. К.а. тәэсирендә бәрәңге бүлбеләрендә крахмал, шикәр чөгендерендә шикәр, кайбер җимеш һәм яшелчә культураларында моносахаридлар туплану көчәя. Калий, нигездә, табигый калий тозларыннан алына. Беренче чыганагы Германиядә (Штасфурт шәһәре янында) 1840 елларда ачыла. Соңрак калий тозлары ятмалары Франция, Канада, АКШта табыла. Калий хлориды, калий селитрасы, калий сульфаты һ.б. калий тозларын җитештерү башлана. Россиядә калий сәнәгате 1929 да Төньяк Уралда (Соликамск, Березники) калий чыганакларын ачканнан соң үсеш ала. К.а. эшкәртелмәгән калий тозларына (сильвинит, карналлит һ.б.), концентрацияле ашламаларга (калий хлориды, калий сульфаты һ.б.), җитештерү калдыкларына (көл) бүлеп йөртелә. Кагыйдә буларак, аларны фосфорлы һәм азотлы ашламалар б-н бергә барлык туфракларда кулланалар, ләкин алар торфлы, су баса торган, комсыл һәм азрак балчыксыл кәсле-көлсу туфракларда, көлсуланган һәм селтесезләнгән калий аз булган кара туфраклы җирләрдә нәтиҗәлерәк. К.а.ның роле җиңел һәм известьләнгән туфракларда югарырак. К.а.ның дозасы, башлыча, туфрак шартларына, ашлама кертеләчәк культураның биологик үзенчәлекләренә карап билгеләнә. Татарстан туфракларының алмаш калий б-н чагыштырмача яхшы тәэмин ителгән булуына карамастан, К.а.ны дөрес куллану тамыразыклар, яшелчә һәм бөртекле культуралар, күпьеллык үләннәр үстерүдә яхшы нәтиҗә бирә. Бөртекле һәм техник культуралар чәчүлекләренә калийны азотлы-фосфорлы ашламалар, ә кузаклылар чәчүлекләренә фосфорлы ашламалар б-н кертү файдалы. Комсыл һәм комлы туфракларда К.а.ны яз көне, ә балчыклы һәм балчыксыл туфракларда көз көне — туңга сөрелгән җиргә кертү нәтиҗәлерәк. Аерым очракларда К.а.ны берникадәр микъдарда рәтләргә чәчү вакытында яисә өстәмә тукландыру вакытында кертәләр. 1 *га* га 10–15 *кг* исәбеннән рәтләп ашлау туфракта калий запасы аз булганда һәм калийга таләпчән культуралар чәчүлекләрендә башкарыла. 1 *га* га 30–40 *кг* исәбеннән тукландыру калийга ярлы туфракларда һәм К.а. чәчүгә кадәр кертелмәгән очракларда кулланыла. Татарстанда 2000, 2001, 2010 елларда К.а. 1 *га* чәчүлеккә 12,6; 15,3; 13,3 тәэсир итүче матдә исәбеннән, нигездә, калий хлориды, калий тозлары һәм калий сульфаты формасында кертелә.

*Әд.:* Влияние удобрений на урожай сельскохозяйственных культур в условиях Волго-Вятского района. К., 1974; Система земледелия Татарской АССР. К., 1988; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992.

*М.З.Гайнетдинов.*

**КАЛИ́НИН** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәләкәс елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 89 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кошчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 118, 1949 да — 177, 1958 дә — 148, 1970 тә — 175, 1979 да — 136, 1989 да — 58, 2002 дә — 94 кеше.

**КАЛИ́НИН** Ариан Павлович (1.3.1927, Мордва АССРның Ардатов ш.), хирург, мед. фән. д-ры (1967), РМФАнең мөхбир әгъзасы (1995). 1947 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук хирургия кафедрасында эш-



Н.Ф. Калинин.

ли. 1950 дән Казан ГИДУВының гомуми хирургия кафедрасында. 1960 тан СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Бөтенсоюз эксперименталь эндокринология һәм гормоннар химиясе ин-тының хирургия бүлегендә (Мәскәү). 1967 дән М.Ф.Владимирский исем. Мәскәү өлкә фәнни-тикшеренү ин-тының клиник хирургия бүлегендә, 1972 дән проф., хирургик эндокринология бүлеге җитәкчесе. Хезмәтләре бөер өсте бизләре хирургиясенә карый. Мәскәү өлкәсе эндокринологлары ассоциациясе рәисе, Россия эндокринологлар фәнни җәмгыяте идарәсе, хирург-эндокринологлар интернациональ ассоциациясе әгъзасы. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хирургия надпочечников. М., 2000; Доступ к надпочечникам. М., 2003; Послеоперационный период в эндокринной хирургии. М., 2003.

**КАЛИ́НИН** Евгений Павлович (1887–1920), сәясәт эшлеклесе. 1905–07 еллардагы рев-циядә катнаша. 1917 дә Петроград эшче һәм солдат депутатлары советы әгъзасы, А.Ф.Керенский канцеляриясендә эш башкаручы, 16 августтан Казан хәрби округында Вакытлы хөкүмәт комиссары. Социалистик оешмалар берлеген оештыручыларның һәм аның җитәкчеләренең берсе. 1917 нең августыннан совет хакимиятенә каршы көрәшә. Алдагы язмышы билгесез.

**КАЛИ́НИН** Николай Филиппович (24.5.1888, Саратов ш. — 16.6.1959, Казан), тарихчы, археолог. Татарстан терр-ясен тоташ археол. тикшерүне, Татарстан һәм Урта Идел буе археол. ядкәрләрен картага төшерүне оештыручыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлый (1910). Царёвококшайск, Сембер, Тәтеш, Казан шәһәрләрендәге уку йортларында тарих укыта. 1924–44 елларда ТАССРның Үзәк музеенда тарих бүлеге мөдире. 1944 тән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Татарстанны өйрәнү җәмгыяте, Тәтеш, Мамадыш шәһәрләре һ.б. торак пунктлардагы төбәкне өйрәнү җәмгыятьләре эшендә актив катнаша. 1923–37 дә Казан шәһәрендә археол. тикшеренүләр алып бара. Болгар (1938 дән), Иске Казан (1945, 1956 да) шәһәрлекләре һәм Рус Урматы авыллыгы (1956–57) терр-яләрендә башкарылган археол. казу эшләренә җитәкчелек итә. Аның тарафыннан таш, бронза һәм тимер гасырлар ядкәрләре ачыла. *Казан яны культурасын* аерып күрсәтә (А.Х.Халиков б-н бергә). Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1923 тән). Хезмәтләре Казан, Урта Идел буе тарихына һәм археологиясенә карый.

Х е з м.: Где был дворец казанских ханов? К., 1926; Спасская башня Казанского кремля. К., 1926; Археологические наблюдения на улицах Казани // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1927. Т. 33, вып. 4; Казань: Ист. очерк. К., 1955.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. История археологического изучения г.Казани // Средневековые археологические памятники Татарии. К., 1983; С и т д и к о в А.Г. Н.Ф.Калинин — исследователь средневековой Казани // Археологическое изучение булгарских городов. К., 1999.

*П.Н.Старостин.*

**КАЛИ́НИН** Юрий Павлович (2.11.1939, Мәскәү — 6.12.2003, Казан), спортчы (академик ишү), СССРның спорт остасы (1961); патологоанатом, мәхкәмә медицинасы экспертлы, мед. фән. канд. (1990), ТАССР, РФның атказ. табибе (1991, 1996), Сәламәтлек саклау отличнигы (1982). 1967 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Мамадыш р-ны үзәк хастаханәсе баш табибенең 1 нче урынбасары булып эшли. 1984 тән ТР сәламәтлек саклау министрлыгының Республика мәхкәмә мед. экспертизасы бюросы башлыгы. Хезмәтләре мәхкәмә мед. экспертизасы, лаб-ядә тиз арада диагнозлау, стенокардиягә диагноз кую мәсьәләләренә карый.

Спорт б-н 1955 тән «Спартак» ирекле спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый (Казан), тренеры — В.Т.Глухих. Россия чемпионатларында (1957–67), РСФСР халыклары спартакиадасында (1956, 1963, 1967, ТАССР җыелма командасы составында); СССР чемпионатында (1959, яшьләр); «Спартак» үзәк советы беренчелегендә (1965, 1967), халыкара регаталарда (1961, 1966) җиңүче; СССР команда беренчелегендә (1961, РСФСР җыелма командасында) көмеш медаль ала.

Х е з м.: Этапы и перспективы развития судебно-медицинской службы в Республике Татарстан // Казан. мед. журн. 1994, № 4. Клинико-морфологические параллели нестабильной стенокардии с депрессией сегмента ST на ЭКГ // Проблемы экспертизы в медицине. 2003. Т. 3, № 1.

**КАЛИ́НИН РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә оештырыла. Үзәге — Пучы авылы. 1920 гә кадәр К.р. терр-ясе Уфа губернасының Минзәлә өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Минзәлә кантонына, 1930–35 тә Актаныш, Минзәлә, Мөслим р-ннарына керә. 1940 та районның мәйданы — 1086 *км*², халкы — 37,7 мең кеше, 31 авыл советы, 66 торак пункт була. К.р.ның адм. бүленеше бернинчә тапкыр үзгәрә (1948 дә — 25, 1956 да 22 авыл советы исәпләнә). ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1959 ның 12 октябрендә К.р. таркатыла, биләмәсе Актаныш һәм Мөслим р-ннарына бирелә.

**КАЛИ́НИНО** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 7 *км* көнчыгыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2010 елда 552 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 56%, руслар — 43%) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Терлекчелек, кирпеч заводы. Казан ханлыгы чорыннан Янчурино авылы буларак билгеле, 18 йөздән 1933 кә кадәр Собакино исемен йөртә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек алпавыт Бекетовлар крепостнойлары) катлавына керә, төп шөгыле — К. аша уза торган Себер трактында юлаучылар йортлары тоту (1878 дә 61 крәстиян хуҗалыгына 23 юлаучы йорты туры килә). 20 йөз башында К.да почта станциясе урнаша; почта бүлекчәсе, телефон, земство мәктәбе (1885 тә ачыла), 2 тимерчелек, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 160,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 411, 1897 дә — 411, 1908 дә — 387, 1926 да — 562, 1938 дә — 508, 1949 да — 416, 1958 дә — 388, 1970 тә — 379, 1989 да — 284, 2002 дә — 435 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КАЛИ́НОВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 1 кеше (чуаш) яши. 1930 елларда Калинин исем. посёлок буларак нигез салына. Оештырылган көннән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 168, 1949 да — 156, 1958 дә — 148, 1970 тә — 105, 1979 да — 71, 1989 да — 15, 2002 дә — 9 кеше.

**КАЛИ́НОВКА** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы (Каманың сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 60 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1656 дан Калинов Пучинкәсе исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2241,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 556, 1897 дә — 791, 1920 дә — 995, 1926 да — 578, 1938 дә — 511, 1949 да — 217, 1958 дә — 109, 1970 тә — 67, 1979 да — 47, 1989 да — 28, 2002 дә — 40 кеше.

**КАЛИ́НОВКА** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Калинино. Башта ТАССРның Чистай кантоны Иске Чаллы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 34, 1938 дә — 107, 1949 да — 73, 1958 дә — 56, 1989 да — 8, 2002 дә — 5 кеше.

**КАЛИПСО́** (Calypso), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Евразия һәм Төньяк Американың салкын һәм уртача поясларында таралган.

ТР терр-ясендә бер төр — бүлбеле К. (C. bulbosa) очрый. Күләгәле мүкле-ылыслы (сирәк кенә катнаш) урманнарда үсә. Кыска тамырчалы үсемлек, җир өстендә бүлбеле үсенте хасил итә. Сабагы 10–15 *см* биеклектә, озын саплы йомыркасыман киң яфраклы. Чәчәге берле, эре, алсу, иенке, үзенчәлекле исле. Таҗ яфракчыгы башмак рәвешендә. Җимеше — тартмачык. Май–июнь башында чәчәк ата. 1967 елга кадәр сирәк кенә Көнбатыш Кама алдында очрый. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЛИСТРА́ТОВ** Геннадий Григорьевич (2.8.1953, Казан), спортчы (судно моделе спорты), СССРның атказ. спорт остасы (1983). Спорт б-н 1969 елда Казанның Мәскәү р-ны Пионерлар йортында судно моделе түгәрәгендә шөгыльләнә башлый. Тренерлары — Н.Ф.Васильев, К.Д.Головин. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1975). Радио б-н идарә ителүле модельләр классында СССР (1971–90), Европа (1975, 1977), дөнья (1979, 1981, 1986) чемпионы. 1975–78 дә «Вакуум-маш» фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире, 1978 дән ДОСААФның Татарстан өлкә ком-тында инструктор-методист, 1991 дән ТР оборона-спорт оешмасында. Шәкертләре арасында халыкара класслы спорт остасы С.В.Титов, Д.Н.Шахурдин, Э.В.Балалыкин бар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**КА́ЛКА ЕЛГАСЫ́ БУЕНДАГЫ́ СУГЫ́Ш**, 1223 елның 31 маенда рус кенәзләре һәм кыпчак ханы Котянның Җәбә һәм Сөбедәй җитәкчелегендәге монгол гаскәрләре белән беренче сугышы. Калка елгасы буенда (хәзерге Кальмиус елгасы кушылдыгы Кальчик елгасы) була. Монголлар тарафыннан тар-мар ителгән кыпчаклар ярдәм сорап рус кенәзләренә мөрәҗәгать итәләр. Киевтагы кенәзләр съездында кыпчаклар б-н бергә яу чыгарга карар кылына. Яуда кенәзләр Мстислав Киевский, Мстислав Черниговский, Мстислав Удалой, Всеволод Мстиславович, Михаил Всеволодович, Даниил Романович һ.б.ның дружиналары катнаша. 1223 нең мае башында рус гаскәрләре Днепрның сулъяк ярына чыгалар. Монголлар, юри чигенгән булып, аларны үзләренең төп көчләре һөҗүме астына алдап кертәләр. 31 майда кыпчаклар һәм Мстислав Удалой, Мстислав Черниговский һәм Даниил Романович җитәкчелегендәге рус дружиналарының бер өлеше Калканы кичеп чыга, монгол отрядлары тарафыннан тар-мар ителә. Монголлар кенәз Мстислав Киевский лагерын берничә көн камап торалар, аннары рус дружинасын ялган вәгъдәләр б-н алдап чыгаралар һәм тар-мар итәләр. Монголлар каршы якның калган отрядларын Днепр елгасына кадәр куып бара, аннары Идел буе Болгар дәүләте тарафына юнәләләр (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). Сугыш нәтиҗәсендә кыпчаклар *Дәште Кыпчакта* тоткан сәяси рольләрен югалталар.

*Әд.:* Насонов А.Н. Монголы и Русь. М.–Л., 1940; Каргалов В.В. Внешнеполитические факторы развития феодальной Руси. М., 1967; Пашуто В.Т. Внешняя политика Древней Руси. М., 1968.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**КАЛКА́Н**, сугышчының гәүдәсен саклау ярагы. Төсле күн яки тукыма б-н тышланган төрле материаллар (агач, күн һ.б.) җыелмасыннан гыйбарәт корпус рәвешендә эшләнә. К.ның тышкы ягы еш кына металл өслек б-н каплана. Идел буенда б.э.к. 1 меңьеллыкта барлыкка килә. Болгарлар 8–9 йөзләрдә күн яки агач К.нар, кайчакта тимер өслекле, 12–15 йөзләрдә зур булмаган кабарынкы түгәрәк һәм бадәмсыман К.нар кулланалар. 16 йөздә кулланылыштан чыга.

*И.Л.Измайлов.*

**КАЛКАНКЫСЛАЧЫКЛА́Р** (Notostraca), *яфрагаяклы кысласыманнар* отрядыннан умырткасыз хайваннар асотряды. 9 төре билгеле, Россиядә — 5, Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: язгы калканкыслачык (Lepidurus apus) һәм җәйге калканкыслачык (Triops cancriformis). К., аеруча гади төче су кысласыманнары, башында, күкрәгендә һәм корсагының алгы өлешендә яссы калканы бар. Гәүдәсе 4–5 *см* озынлыкта, кара көрән төстә. Күзләре калканның алгы кырые тирәсендә урнашкан. Озын мыекчаларның ике пары да редукцияләшкән. Күкрәге 10 сегменттан тора, аларның һәркайсы 6 калактан торучы бер пар аяклы. Еш кына аяк парларының гомуми саны 10–70 кә җитә (кысласыманнар арасында иң зур сан). Язгы калканкыслачык кар суларында, җәйге калканкыслачык яңгыр суларында очрый. К.ның ата затлары бик сирәк, шунлыктан кибүне, туңуны һәм 8 °С ка җылынуны кичерергә сәләтле аталанмаган йомыркалар ярдәмендә үрчиләр. Йомыркалар яшәү сәләтен 7–9 ел саклый. К. грунт кисәкчекләре б-н тукланалар, саңакаяклы башка умырткасыз хайваннарга, чукмарбашларга һәм балык маймычларына һөҗүм итәләр, буа балыкчылыгына зур зыян китерәләр. Ике төре дә саклауга мохтаҗ. Язгы калканкыслачык ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель фауны России. СПб., 1996. Т. 2.

*В.А.Яковлев.*

**КАЛКАНЛЫ́ АБАГА́** (Dryopteris), калкан абагачалар семьялыгыннан абагалар ыругы. 150 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында таралган, башлыча, уртача пояста. Татарстан терр-ясендә 5 төре бар. Ата К.а. (ата абага) (D. filix-mas), Картузиус К.а. (D.carthusiana) барлык районнарда очрый; Амброзен К.а. (D. ambroseae), охшаш К.а. (D. assimilis), тараксыман абага (D. cristata) — сирәк төрләр. Ылыслы һәм катнаш урманнарда, куаклар арасында, сазлыклы болыннарда үсәләр. 30–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлекләр. Тамырчасы куәтле, күпсанлы үткән елгы яфрак саплары калдыкларыннан тора. Яфрак пластинкасы куе яшел, икешәр каурыйсыман теленмә. Яфрак өлешләренең аскы ягында ике рәткә спорангийлар өеме урнашкан, алар исә бөресыман элпәле япма б-н капланган. Чәчәкләр хасил итми, чәчәкле ботагы юк, спoралардан һәм тамырчалардан үрчиләр. Споралары июнь–июльдә өлгерә. Ата абаганың тамырчаларында органик к-талар, флавоноидлар, дуплау матдәләре, эфир мае бар. Суалчанга каршы экстракт (сыгынты) алу өчен кулланыла. Халык медицинасында төнәтмәсе ревматизм вакытында кулланыла. Декоратив үсемлек. Охшаш К.а. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЛКАНЛЫ́ КАНДАЛАЛА́Р** (Pentatomidae), кандалалар семьялыгы. Гәүдәсе 2–40 (ешрак 7–15) *мм* озынлыкта, озынча түгәрәк, нык калын тышчалы. Башы өстән яссы яки азмы-күпме кабарынкы калкан рәвешендә (исеме шуннан), түшенең өчтән бер өлешен яки тулысынча каплый. Күпчелеге үсемлек б-н туклanучы, бары тик Asopinae ассемьялыгы вәкилләре генә ерткычлар. (Америка кандаласы Perilus үз төбәгендә колорадо коңгызын юк итә; әлеге корткыч б-н биологик көрәш максатларында Европада бу кандаланы климатлаштыру эшләре үткәрелә.) Гадәттә, олы затлар, сирәк кенә личинкалары яки йомыркалары кышлый.

Дөньяда К.к.ның 4 меңгә якын төре билгеле, киң таралган; Россиядә 300 дән артык, Татарстан терр-ясендә 30 га якын төр билгеләнгән. Әвернә чәчәклеләр яки бакча эвридема (Eurydema) ыругы кандалалары (гәүдәсе чуар һәм шактый үзгәрүчән рәсемле) яшелчә культураларын нык зарарлый. Кәбестә кандаласы (Eu.ventralis) һәм рапс кандаласы (Eu.oleracea) яхшы билгеле. Кыяклы культураларга очлы башлы элиа (Aelia acuminata) зур зыян китерә. Санап кителгән корткычлардан тыш, җиләк кандаласы (Dolycoris baccarum), Италия калканлы кандаласы (Graphosoma lineatum), яшел калканлы кандала (Palomena prasina) иң гадәтиләре булып тора.

*С.М.Шәфигуллина.*

**КАЛКУЛЫ́К**, әйләнә-тирәдәге башка терр-яләргә караганда чагыштырмача өстәрәк ятучы җир өсте участогы. Шартлы рәвештә 200 *м* дан артык абс. биеклектә билгеләнә һәм түбәнлеккә каршы була. Татарстан терр-ясендә К.лар түбәнлекләрдән күбрәк. Төп К.лар: *Идел буе калкулыгы* (төньяк-көнчыгыш өлеше), *Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы* (көнбатыш өлеше), *Можга калкулыгы* (көньяк өлеше), *Вятка увалы* (көньяк-көнчыгыш өлеше). Аларның барлыкка килүендә төп рольне өр-яңа тектоник хәрәкәтләр уйнаган. Барлык К.лар да яше һәм составы буенча төрле булган тау токымнарын кисүче, 200–240 *м* биеклектәге эрозион-денудацион өслеккә ия. *Бөгелмә яссы калкулыгы* иң биеге, бирердә, түбәнгеләр б-н беррәттән югарыгы денудацион өслекләр (280–360 *м*) яхшы сакланган, аның үрләренә исә ТР рельефының иң биек нокталары туры килә.

**КАЛЛИГРА́ФИЯ**, к. *Хаттатчылык.*

**КАЛМА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Шилнә елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,3 *км*, бассейнының мәйданы 43,5 *км*$^2$. Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Новый посёлогының көнчыгыш чигендә, тамагы Әҗмәкәй авылыннан 3 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 86 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. К.ның 0,3 тән алып 2,1 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,54 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбе-

сенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 117 *мм*, ташу агымы катламы 91 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрь башында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,027 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К. бассейнында су күләме 0,5 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАЛМА́Ш** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 23 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 70 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1731 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, төрле һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет (беренче мәртәбә 1813 тә телгә алына), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1690 дис. тәшкил итә. 1929 да К.та Фрунзе исем. к-з оештырыла, 1950 дә «Алга» к-зына, төрле үзгәртүләрдән соң «Агыйдел» к-зына (2006 дан «Наратлы» ҖЧҖ) керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 238, 1834 тә — 255, 1859 да — 381, 1870 тә — 423, 1884 тә — 511, 1908 дә — 495, 1920 дә — 419, 1926 да — 253, 1938 дә — 266, 1949 да — 191, 1958 дә — 171, 1970 тә — 152, 1979 да — 131, 1989 да — 79, 2002 дә — 77 кеше.

**КАЛМА́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 22 *км* көнчыгыштарак, Шилнә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 1148 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1656 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, урман кисү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәктәп, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2715,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макар волостенда 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 423, 1897 дә — 1174, 1920 дә — 1538, 1926 да — 1367, 1938 дә — 1061, 1949 да — 664, 1958 дә — 563, 1970 тә — 509, 1979 да — 700, 1989 да — 959, 2002 дә — 930 кеше.

**КАЛМОРЗА́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 25 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 181 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1706 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр, дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә. 20 йөз башында К.да мәчет (беренче тапкыр 1836 да телгә алына), су тегермәне, 3 ашлык киптергеч, ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1087 дис. тәшкил итә. 1930 да К.да «Калморза» (1935 тән — «Кызыл Яр») к-зы оештырыла, 1950 дә — «Корыч» (1956 дан — «Победа», 1961 дән — «Гигант»), 1988 дә «Кызыл Курган» к-зына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 46, 1859 да — 157, 1870 тә — 197, 1884 тә — 177, 1906 да — 285, 1913 тә — 297, 1920 дә — 317, 1926 да — 337, 1938 дә — 372, 1949 да — 317, 1958 дә — 333, 1970 тә — 334, 1979 да — 256, 1989 да — 124, 2002 дә — 203 кеше.

*Әд.:* Ю с у п о в Ю. Калморза — морзалар ягы. Минзәлә, 2003.

**КАЛМЫКО́В** Анатолий Николаевич (1.1.1946, Столбище р-ны Сапуголи а. — 4.11.1996, Казан), зоотехник-селекционер, а.х. фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1968 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый, 1969–70 тә шунда ук эшли. 1970–73 тә Бөтенсоюз ат асраучылык фәнни-тикшеренү ин-тында (Рязань өлкәсе). 1973 тән Казан вет. ин-тында, 1993–96 да зоотехния каф. мөдире. Хезмәтләре аутбрид һәм инбрид үрчетү ысулларын куллану нәтиҗәсендә төрле линиядәге үгезләрнең токымнарында файдалы үзгәрешләр һәм төрле семьялыктагы сыерларның сөт бирүе артуы, сөтнең сыйфаты яхшыруы закончалыкларын өйрәнүгә карый. К. сыерларның сөт бирүчәнлеген иртә бәяләү һәм фаразлау ысулын эшли, хайваннарны инбрид нигездә үрчетү нәтиҗәсендә сөтчелек терлекләрен селекцияләү ысулын тәкъдим итә.

Х е з м.: Управление процессами совершенствования дойного стада и технологии производства молока. К., 1977 (автордаш); Айрширская порода скота в условиях Татарской АССР. К., 1985 (автордаш); Ранняя оценка и прогнозирование молочной продуктивности коров. К., 1991.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов, М.А.Сущенцева.*

**КАЛМЫЯ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Сөн елгасының (Агыйдел елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 39,9 *км*, бассейнының мәйданы 237,2 *км²*. Елга башы Мөслим р-нының Горбуновка авылы янында, тамагы Актаныш р-нының Чуракай авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 31%. К.ның 4 тән алып 12,4 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар; иң зурысы — Дусай елгасы (уң). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрь башында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,18 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 3,6 млн. *м³* булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАЛМЫЯ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Игәт елгасы буенда. 2010 елда 423 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1747 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н, чана, арба, утын чанасы ясау, кәрзин үреп сату б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.да мәчет (беренче мәртәбә 1870 дә телгә алына), мәктәп (1821 дән), 3 тимерчелек, җил тегермәне, ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2205,4 дис. тәшкил итә. 1912 дә земство мәктәбе эшли башлый. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 637, 1897 дә — 1034, 1906 да — 1314, 1920 дә — 1543, 1926 да — 1202, 1938 дә — 1223, 1949 да — 1091, 1958 дә — 977, 1970 тә — 915, 1979 да — 753, 1989 да — 542, 2002 дә — 450 кеше.

**КАЛТА́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ташъелга буенда. 2010 елда 335 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1719 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, юкәдән мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.та Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1152 дис. тәшкил итә. 1929 да К.та «У корно» («Яңа юл») к-зы оештырыла, 1959 дан — «Марс» к-зы составында (1975 тән — «30 лет Победы», 1990 нан үзенең беренче «У корно» исемен йөртүче мөстәкыйль хуҗалык). 1918 гә кадәр — Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы, 1918–20 дә Әтрәкле волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Калинин, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1747 дә — 86, 1795 тә — 175, 1811 дә — 204, 1834 тә — 162 ир-ат; 1859 да — 513, 1884 тә — 696, 1897 дә — 837, 1906 да — 892, 1920 дә — 724, 1926 да — 711, 1949 да — 408, 1958 дә — 393,

1970 тә — 505, 1979 да — 430, 1989 да — 319, 2002 дә — 359 кеше.

**КАЛТАСЫ́ РАЙОНЫ́**, БРның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1564 *км*². Үзәге — Калтасы авылы (Уфадан 202 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 28202 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 6612, 1979 да — 6203, 1989 да — 5855, 2002 дә — 4569 кеше. Районда 78 торак пункт, ш.и. 17 сендә татарлар яши. Иң зур татар авыллары (2009): Күчәш (304 кеше), Күгәрчен (242), Чумар (160). Татарларның күпчелеге шәһәр тибындагы Красный Холм посёлогында (2720) һәм район үзәгендә (1803) яши. Иң элеккеге авыллар: Күчәш (1695 ел) һәм Куян (1787). Хәзерге вакытта районда 16 башлангыч татар мәктәбе (ш.и. Күгәрчен авылында 1914 елда ачыла) эшли. 2004/05 уку елында 3 мәктәптә укыту татар телендә бара, 2 сендә татар теле фән буларак өйрәнелә. 1997 дә районда Татар башкарма комитеты советы оештырыла; 1999 да Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. К.р.нда тарих фән. д-ры Р.М.Рәимов, физика-матем. фән. д-ры Р.Т.Таһиров, БАССРның эш һәм мәшгульлек министры (1982–92) К.Н.Галиуллин, СССР Журналистлар берлеге әгъзасы В.И.Хуҗин туган.


*Әд.:* Сторона моя Калтасинская. Уфа, 1993.

**КАЛТЫРАВЫ́К БАШАҠ́** (Briza), кыяклылыр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, Евразиядә, Көньяк Америкада, Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — урта К.б. (B. media) Кама алдында очрый. Дымлы болыннарда, урман аланнарында үсә. 20–60 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы кыска. Сабагы туры. Яфрак пластинкалары кыяк, яссы, өске ягы кытыршы; яфрак җиңсәсе төбенә кадәр ачык, шома; яфрагының вак телләре элпәле, кыска. Чәчәк төркеме — җәенке себеркәч. Башакчыклары түгәрәк-йөрәксыман, ян-яктан кысылган, яшькелт ак яки шәмәхә төстә, нәзек сапта утыралар. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Нигездә, орлыклардан үрчи. Терлек азыгы. Кипкән букетлар ясау өчен кулланыла.

**КАЛФА́К** (фарсы. قالپاق), Урта Идел буе һәм Урал яны татарларының традицион хатын-кызлар баш киеме. Бәйләнгән яисә тукымадан (ешрак бәрхеттән) тегелгән. 19 йөзнең 2 нче яртысында кызлар арасында «ак калфак» кию аеруча киң тарала — озынлыгы 70 *см* га кадәр булган конус рәвешендәге К.лар ак киҗе-мамык җептән бәйләнә. Аны маңгай бәйләвече — чуклы укалы тасма («укачачак») б-н йөртәләр, К.ны чачаклы очын артка җибәреп яки кырын салып кияләр. 19–20 йөзләр чигендә ул кулланылыштан чыга, әмма әле авылларда яшәп килә. 19 йөз уртасыннан шәһәр хатын-кызлары читтән китерелгән, төрле төстәге буй сызыклар төшкән ефәк трикотаж тукымадан тегелгән К.ны артыграк күрәләр. Конус рәвешендәге традицион форманы саклаган хәлдә, бу К.лар кыскарак була (50 *см* тирәсе), әмма бай бизәлеше б-н аерылып тора: чуклы укалы тасма баш киеменең кырыйларына да тегелә, аның өслегенә аппликация тегеп чыгу, төсле җепләр һәм чук җебе б-н тигез чигү ысулларында үлән-чәчәк бизәкләре төшерелә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан ука б-н тигез чигү (укалы К.), сәйлән һәм энҗе тезеп чигү (энҗеле К.), тәңкәле аппликация (тәңкәле К.) б-н бизәлгән каты кырпулы бәрхет К.ларның популярлыгы арта; аларны кызлар да, кияүдәге хатыннар да, эчтән киелә торган баш киеме буларак, яратып кияләр, гадәттә, К. өстеннән фабрикада эшләнгән яулык ябалар. Казанда һәм Казан артында К.лар тегү һөнәрчелеге алга китә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында зур бәрхет К.лар урынына кечкенә кадама калфаклар (мөгез К.) кулланыла башлый, алар да яулык яки җиңелчә япма, ефәк шәл астыннан кадап калдырыла. Бүгенге көндә милли хатын-кызлар киеменең бер этнографик элементы буларак сакланып калган.



Калфаклар. 19 йөз — 20 йөз башы. ТР Милли музее.



*Әд.:* М ө х ә м м ә д о в а Р.К. Татар теленең һөнәрчелек лексикасы. К., 1983; Г у л о в а Ф.Ф. Татарская народная вышивка. К., 1980; З а в ь я л о в а М.К. Татарский костюм. К., 1996.

*Ф.Ф.Гулова.*


**КАЛЫ́М**, күп кенә Шәрекъ халыкларында ата-бабаларның тормыш рәвешеннән сакланып калган йола: кияү ягыннан кәләшнең ата-анасына бирелә торган түләү. Татарларда ешрак «калым малы» яисә «мәһәр» атамалары б-н йөртелә. Кагыйдә буларак, К. мәсьәләсе кодалау вакытында хәл ителеп куела. Җирле туй йолаларына, милекнең күләменә карап, яклар К.ның күләме һәм түләү вакыты турында килешәләр. К.га түбәндәгеләр керә: киемнәр салынган сандык (тун яки пальто, затлы камзул, бернича йон, ефәк, ситсы күлмәк), аяк киемнәре (читекләр, туфлиләр, галошлар), кәләшнең баш киемнәре (шәлләр, калфаклар, мех кырпулы бүрек, калфак), ш.у. түшәк, ястык, йорт хайваннары (бозау, сыер, ат һ.б.). Моннан тыш, кияүнең туганнары билгеле бер күләмдә акча (тарту, баш акча) б-н һәм туй табынын азык-төлек (бал, май, он, чәй, ит һ.б.) б-н тәэмин итүне үз өсләренә ала. Асылда, татарларда К., кәләшнең ата-анасыннан бигрәк, яңа кияүгә чыккан кызның үзенә билгеләп куела. Ире йортына күчкәндә яшь килен атасы йортыннан үзенең *бирнәсен* дә, аның милкенә әйләнгән К.ны да алып китә. Гадәттә, К.ны өлешләп түлиләр. Акчаның һәм бүләкләрнең бер өлеше сүз куешу — кыз ярәшү вакытында бирелә. Пермь татарлары, мишәрләр яшәгән кайбер р-ннарда кияүнең туйга кадәр үк ирле-хатынлылык хокукларыннан файдалану мөмкинлеге булган. К.ның төп өлеше кәләш өендә уздырылган никах туенда тапшырыла. Кияүгә чыккан кыз ире янына бары тик К. тулысынча түләнеп беткәннән соң гына күчә. Кайчак яшь киленнең беренче баланы ире йортына күченгәнче үк тапкан очраклары да була.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; У р а з м а н о в а Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984; ш у л у к. Семейные обычаи и обряды // Татары. М., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАЛЬГА́-КИРМӘ́Н ДИВАРЛАРЫ́**, торулыкларның инженерлык-саклану ныгытмалары. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы шәһәрләрендә (Биләр, Җукәтау, Ашлы, Болгар, Үкәк, Казан, Иске Казанда һ.б. шәһәрләрдә) К.-к.д., гадәттә, бер яки күп (өчкә кадәр) рәтле булган, чокырлардан һәм биеклекләре 1,5 *м* дан 3 *м* га кадәр җиткән, өсләренә 2–3 *м* биеклектәге диварлар корылган урлардан торган. Эчләренә туфрак һәм ташлар тутырылган биек агач буралар рәвешендә, кайбер очракларда таш блоклардан һәм кирпечләрдән (Казан) төзелгәннәр. Дивар өстендә торулыкны саклаучылар өчен мәйданчык булдырылган, шунда ыргыту-ату кораллары (арбалетлар), 14 йөздән — туплар урнаштырылган. Явым-төшемнәрдән, дошман укларыннан, пулялардан һәм ядрәләрдән саклану өчен чатырсыман түбә б-н капланган. 10–14 йөзләрдә К.-к.д. дәүләт куәте символы булып хезмәт итәләр, 17–18 йөзләрдә үзләренең элеккеге әһәмиятләрен югалталар. Татарстан терр-ясендә Казан Кремленең К.-к.д. сакланган.

*И.Л.Измайлов.*



Буралар рәвешендәге кальга-кирмән дивары. Идел буе Болгар дәүләте. 12–13 йөзләр. А.М.Гобәйдуллин, И.Л. Измайлов реконструкциясе.



Биләр шәһәрлеге урлары калдыклары. Идел буе Болгар дәүләте. 12-13 йөзләр.

**КА́ЛЬКА** (фр. calque, сүзгә-сүз — тәрҗемә итеп күчерү, копия), лингвистикада — башка бер телдәге сүзләрнең, сүзтезмәләр һәм җөмләләрнең сүз ясагыч, синтаксик, семантик структураларын башка телләрдән тел чаралары ярдәмендә турыдан-туры тәрҗемә итеп күчерү (сүз ясау). Үзгәрешсез, ягъни сүзгә-сүз тәрҗемә итү юлы б-н ясалган (төгәл К.), ш.у. чыганак телдәге структур берәмлекләрдән күпмедер читкә тайпылыш күзәтелгән (төгәл булмаган К.) күчермә дә булырга мөмкин. Телдәге лакуналарны (бушлык) тутыру чарасы буларак кулланыла һәм турыдан-туры алынмаларга альтернатива булып хезмәт итә. Татар телендә К.ның зур күпчелеге рус теле тәэсирендә барлыкка килә. Сүз ясаучы К. — башка телдәге сүзнең морфемалы тәрҗемәсе: татар сүзе «бозваткыч» рус сүзе «ледокол»дан калька буларак барлыкка килгән («боз» — «лёд», «ват» (ватарга) — «кол» (колоть), «кыч» аффиксы үзе ялганган сүзгә эш яки хәрәкәт өчен хезмәт итә торган машина, корал, җайланма мәгънәсен бирә). Фразеологик К. — фразеологизмнарның компонентлы (өлешле) тәрҗемәсе: «печән өстендәге эт» («собака на сене» дигән рус фразеологизмының калькалы тәрҗемәсе), «сары йорт» (русча «жёлтый дом» фразеологизмының калькалы тәрҗемәсе). Семантик К. — сүзнең башка телдәге күчерелмә мәгънәсен алу: татарның «койрык» сүзе рус телендәге «хвост» сүзеннән турыдан-туры тәрҗемә ителеп, күчерелмә мәгънәләрендә (кемдер артыннан бер дә калмый йөрүче; калдык; нәрсәнең дә булса үтәлми калган өлеше) кулланыла.

Ярымкалька — башка бер телдән өлешчә күчерү, ярымтәрҗемә. Татар телендә сүз ясаучы (лексик) ярымкалькалар («бизнесчы» — «бизнесмен», «микродулкынлы» — «микроволновая»), ш.у. үзендә милли һәм алынма компонентларны тәшкил итүче фразеологик, терминологик ярымкалькалар киң таралыш алган («сыгып ташланган лимон» — «выжатый лимон», «Морзе әлифбасы» — «азбука Морзе»). Күпчелек К.лар татар әдәби теле фондына да керә. Шулай да аларның кайберләре әдәби нормаларга туры килеп бетми һәм хата буларак кабул ителә. Мәсәлән, «Табигатьтә бар күренешләр, кайсыларын читен аңларга» җөмләсе синтаксик К. булып тора, ягъни «В природе есть явления, которые трудно понять» дигән рус җөмләсенең синтаксик структурасын үзгәртмичә сүзгә-сүз бирү, һәм ул үзенең төзелеше буенча татар телендәге сүзләрнең урнашу тәртибенә туры килеп бетми, дөресе — «Табигатьтә аңлавы читен булган күренешләр бар».

*Әд.:* А х у н з я н о в Э. Русские кальки в татарском литературном языке // Вопросы татарского языка. К., 1965; Ш а н с к и й Н.М. Лексикология современного русского языка. М., 1972; М а к с и м о в Н.В. Калькирование в татарском языке. К., 1999.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**КАЛЬМЕ́ТОВ** Сәет Гани улы (20.4.1918, хәзерге БРның Яңавыл р-ны Яңавыл пос. — 4.5.1992, Әлмәт ш.), драматург. Хезмәт эшчәнлеген бизәүче-рәссам буларак Ташкент (1937–38) һәм Чиләбе (1939–41) татар театрларында башлый, бер үк вакытта Ташкент сәнгать студиясендә белем ала. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945 елдан башта Ютазы, соңрак Буа колхоз-совхоз театрларында режиссёр булып эшли. «Безнең кияү» дигән беренче пьесасы 1947 дә сәхнәгә куела. Татар акад. т-ры тарафыннан сәхнәләштерелгән «Тын алан шаулый» (1951) пьесасы К.ны халыкка таныта. 1955 тән К. Әлмәттә яшәп иҗат итә, һәм драматургның алдагы иҗат эшчәнлеге Әлмәт татар драма т-ры б-н бәйле. Аның сәхнәсендә К.ның «Нуриянең дуслары» (1953 тә сәхнәләштерелә), «Ышанычлы юлдаш» (1957 дә сәхнәләштерелә), «Уйланырсың, кодагый» (1962 дә сәхнәләштерелә) комедияләре, «Соңгы очрашу» (1956 да сәхнәләштерелә), «Зәкия» (1959 да сәхнәләштерелә), «Тайгак тау» (1968 дә сәхнәләштерелә) драмалары зур уңыш белән бара. Пьесаларында беренче чиратта заманның әхлак, тәрбия мәсьәләләрен яктыртырга тырыша. Әсәрләре «Шулай да була» (1972), «Тын алан шаулый» (1978) җыентыкларына тупланган.

*Әд.:* А х у н о в Г. Усал телле драматург // Казан утлары. 1968. № 5.

**КАЛЬМЕ́ТОВ** Фәтхелкадыйр (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче чиреге), хаттат, ташка уеп язу остасы. Казанда яши. К.ның хәлле һәм атаклы кешеләр өчен (мәс., Дәминовлар нәселе) эшләгән Олы Мәңгәр (хәзерге Әтнә р-ны), Казанчы Бигәнәй (хәзерге Саба р-ны) авыллары зиратларында сакланып калган кабер ташлары аның тирә-юньдә танылган эпитафияләр язучы оста булуы турында сөйли. Зур үлчәмле һәйкәлләр (90×40×20 *см*) ак таштан эшләнгән, өске өлешләре ярымтүгәрәк арка б-н төгәлләнгән; эшкәртелгән алгы өслекләренә (тирәнтен уеп кисү алымы кулланып) татар телендә язулар төшерелгән (гадәттә, гарәп каллиграфиясенең «сөлес» имлясында). Текст калку итеп эшләнгән сызыклар б-н турыпочмаклы кайма эченә алынган. Кабер ташларына үз исемен автор «Кятиб Фәтхелкадыйр әл-Казани» яки «Кятиб Калметов Казанлы» дип уеп язган.

*М.И.Әхмәтҗанов.*


**КАЛЬЦИ́Т**, известьле шпат (лат. calx, calcis — известь), карбонатлар классындагы минерал, $CaCO_3$. Җир кабыгында таралуы буенча өченче урында. Табигатьтә күптән мәгълүм, хәзерге исемен 1845 елда немец галиме Гайдингер тәкъдим итә. Химик яктан ешрак саф, кайвакыт химик (Mn, Mg һ.б.) һәм механик (пирит, гётит, гипс һ.б. минераллар, күмер, битум һ.б.) кушылмалары була. Кристаллга нисбәтле ныклыгы 2,5–3,5, уртача 3; тыгызлыгы 2,7–2,8 *г/см*$^3$. Пыяласыман ялтыравыклы. Яктылык К. аша үткәндә ике тапкыр үзгәрә (исланд шпаты). Үтә күренмәле, ешрак тонык төстә. Ак, соры, сары, кызылсу, көрән, зәңгәрсу һәм яшькелт төстә була. Сызыклары ак яисә төсле. Сындырганда кабырчыксыман яки баскыч-баскыч киселешле, сыегайтылган (3–5%) хлорид к-тасында кайный. Кристаллары тригональ сингонияле, кайвакыт ромбоэдрик габитус, скаленоэдрик, призматик; рәвеше таблеткасыман, таякка, энәгә охшаш, еш кына парлы һәм өчле була. ТРда ромбоэдрик кристаллар Әлмәт (Кичүчат, Мәмәт, Чупай а-лары) һәм Кама Тамагы р-ннарындагы (Сөйке а.) Казан ярусының карбонат токымнарында очрыйлар. К.ның полиморф (ромблы) модификациясе булып арагонит санала.

К. күп очракларда, ш.и. ТР терр-ясендә карбонатлы токымнар, аерым алганда, известьташлар, известьле доломитлар, мергельләр ясалышында катнашучы төп минерал, алар составында кристаллы, бөртекле, тыгыз, җирле (акбур), тишекле (известьле туф) агрегат массалар ясый. Кайбер очракта известьле шарсыман матдәләр («борчак ташлар») туплый. Перламутр, энҗеләр, кайбер коралларның минерал өлешен төзи. Цемент сыйфатында (утырма токымнар) яисә состав өлеше буларак күп кенә метаморфик токымнарда, гидротермаль руда юлларында; бушлыкларда — агып төшкән сыеклыкның катып калган формасында (мәгарәдәге сталактитлар һәм сталагмитлар) була. Эре кристаллар (бернечә тоннага җитә) ярыкларда һәм бушлыкларда очрый. Төрле геол. һәм физик-химик шартларда хасил булалар.


Кристалларның электр, магнит, люминесцент һ.б. үзенчәлекләрен өйрәнү өчен кулланыла. Исланд шпаты оптика сәнәгатендә кулланыла. Ш.у.к. *Известьташ, известьле туф, Акбур, Мәрмәр оникс.*

*В.А.Тимесков.*

**КА́МА** (югары агымында борынгы төрки исеме Чулман) елгасы, Иделнең иң зур сул кушылдыгы. Удмурт Респ-касы (елга башы һәм урта агымында), Киров һәм Пермь өлкәләре, ТР (түбәнге агымында) буйлап ага. Озынлыгы 1805 *км* (ТР чикләрендә 360 *км*), бассейнының мәйданы 507 мең *км*$^2$ (ТР чикләрендә 38 мең *км*$^2$). Югары Кама калкулыгыннан 331 *м* биеклектән башлана. Беренче




**Кальцит мәкаләсенә.** 1. Кальцит кристаллары. Сөйке авылы; 2. Кальцит кристаллары (друзасы) агрегаты. Сөйке авылы; 3. Кальцит. Кама Тамагы посёлогы.



Кама елгасы (1) һәм Иске Кама ермагы (2), Түбән Кама шәһәре янында.

100 *км* төньяк юнәлештә ага, аннан калкулыкны урап узып, юнәлешен көньякка үзгәртә. Урал сыртыннан агып төшүче Вишера һ.б. елгалар койганнан соң, К. зур сулы елгага әйләнә. Су агымының шактый гына өлеше Кама (Пермь), Воткинск һәм *Түбән Кама ГЭС*лары буалары тарафыннан үзгәртелгән, алардан өстәрәк шул ук исемдәге сусаклагычлар төзелгән (к. *Түбән Кама сусаклагычы*). Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәр К., урыны б-н киңлеге 20 *км* га кадәр җиткән зур тугай хасил итеп, Иделгә шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы янында койган; хәзерге вакытта елганың 200 *км* дан күбрәк озынлыктагы түбәнге агымы сусаклагычның терәк зонасында. Елга үзәне асимметрик: уңъяк тау бите ягы бар яктан диярлек текә һәм биек; урыны б-н югары Пермь токымнарыннан тора; сул ягы сөзәгрәк, аллювиаль террасалар комплексы б-н аерылып тора. ТР терр-ясендәге төп кушылдыклары: Агыйдел, Ык, Зәй, Чишмә (сул); Иж, Вятка, Мишә (уң). Күбесенчә кар сулары, ш.у. җир асты һәм яңгыр сулары исәбенә туена. Еллык су агымының уртача күләме 130 *км*$^3$; еллык су агымының 58% язгы чорга туры килә. Сусаклагычлар төзелгәнче, су биеклеге тирбәнешләре 5,5–10,9 *м*, уртача 8,5 *м* тәшкил иткән . Суның уртача күпьеллык чыгымы (*м*$^3$/*с*): ТР чикләрендә — 1770, Чаллы шәһәре янында — 2810, Чистай шәһәре янында — 4100 (Иделнең К. б-н кушылганга кадәрге күләменнән (3500) күбрәк); суның иң зур чыгымы (елга тамагы янында) — 36000 тирәсе, иң азы — 400. Елганың боз б-н каплануы ноябрьнең 3 нче ункөнлегендә башлана һәм апрель уртасына кадәр дәвам итә. Язын боз китү берничә көннән алып 2 атнага кадәр сузыла. Вишера тамагына кадәр суднолар йөри. Навигация 6,5 ай тирәсе дәвам итә.

К. ярларында беренче торулыклар таш гасыр чорында барлыкка килә (к. *Идел-Чулман буе культурасы, Чулман буе культурасы*). 10–13 йөзләрдә монда Идел буе Болгар дәүләте, Җукәтау, Кашан һ.б. шәһәрләр була. Борынгы чорларда ук К. үз бассейнына килеп урнашкан халыкларның хуҗалык тормышында, аларның Рус тигезлеге, Урта диңгез, Якын Көнчыгыш, Скандинавия ярымутравы халыклары б-н сәүдә мөнәсәбәтләрендә (Идел һәм Каспий аша) зур әһәмияткә ия була. 16 йөз ахырында К. Рус дәүләтен Себер б-н бәйләүче төп юлның мөһим буыны булып тора. 1815 елда беренче пароход төзелү К.да пароходчылык үсешенә башлангыч бирә. Индустрияләштерү елларында Кама буе илнең мөһим икътисади үзәгенә әверелә: агач материалларын эшкәртү һәм читкә чыгару күләме арта; К.ның транспорт әһәмияте үсә. Төп йөкләр — урман, икмәк, тоз, нефть, күмер, руда, химия һ.б. сәнәгать продукцияләре. Бер үк вакытта пристань хуҗалыгын яңадан җиһазландыру һәм механикалаштыру, судноләр ремонтлау һәм төзү заводларын кору эше алып барыла. Татарстан терр-ясендә Алабуга, Чистай эре пристаньнардан санала. К.да комплекслы гидроузеллар төзелү (1949–57 дә Пермь шәһәре янында — Кама; 1955–57 дә Пермь өлкәсе Чайковский шәһәре янында — Воткинск; 1972–79 да — Чаллы шәһәре янында — Түбән Кама ГЭСы) аңа чиктәш регионнардагы сәнәгатьне һәм шәһәрләрне эл. энергиясе, су б-н тәэмин итү мөмкинлеге бирә; суднолар йөртү шартларын яхшырта. Чаллы, Түбән Кама, Менделеев, Алабуга шәһәрләре сәнәгать пр-тиеләре җирлегендә Түбән Кама территориаль-җитештерү комплексы оеша. 1950 еллар ахырында ТРның Кама буе төбәкләрендә нефть чыгару эшләре алып барыла. К.да комлы-вак чуерташлы чыганаклар бар. 2002 дә К. аша автомобиль күперенең 1 нче чираты эксплуатациягә тапшырыла. К. үзәне ландшафты күптөрле булуы б-н аерылып тора. Монда аеруча сакланулы табигый урыннар челтәре төзелгән, алар арасында Идел-Кама саклаулыгының Саралан участогы (к. *Саралан урманы*), *Түбән Кама милли паркы, Игим наратлыгы,* «*Соколка урманы*», *Ивановский наратлыгы* кебек табигать истәлекләре дә бар. ТР чикләрендә К. елгасының уңъяк яры буенда Пермь системасының стратотипик әһәмияткә ия булган Казан һәм Уфа яруслары утырмаларының чыганаклары табыла (к. *Геологик табигать истәлекләре*). К. һәм аның кабатланмас матур ярлары И.И.Шишкин («Нарат урманы. Вятка губернасында мачта урманы», 1872; «Камада ак чыршы урманы», 1877; «Кама», 1882; «Алабуга янындагы изге чишмә», 1886; «Корабльләр ясау өчен агачлык», 1898), В.В.Мешков («Кама киңлекләре»,«Кама», 1950) һ.б. рәссамнарның картиналарында гәүдәләнеш таба. К. ярларында бальнеологик максатларда җир асты минераль сулары («Иж минераль сулары», «Жемчужина» һ.б.) файдалана торган шифаханәләр һәм профилакторийлар урнашкан. Елгада, нигездә, корбан балык, сазан, судак, чөгә, җәен, синец, густера, кәлчәк һ.б. балыклар тотыла.

*Әд.:* Кама: Путеводитель. Молотов, 1953; Очерки по географии Татарии. К., 1957; Кама. Волга. Дон: Путеводитель. Пермь, 1967; Бассейн реки Камы // Гос. вод. кадастр: многолетние данные о режиме и ресурсах поверхностных вод суши. Л., 1988. Т. 1, вып. 25.

**КА́МА** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Урсалы елгасының (Дала Зәе елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 21,1 *км*, бассейнының мәйданы 138,3 *км*$^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага, Әлмәт р-нында. Елга башы Кама-Елга авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Яңа Нәдер авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 109 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 36%. К. елгасының 1,4 тән алып 6,6 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,51 *км*/*км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л*/*с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 109 *мм*, ташу агымы катламы 62 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,224 *м*$^3$/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв*/*л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв*/*л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг*/*л*, кышын һәм җәен 1000 *мг*/*л* дан күбрәк.

**КА́МА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 49 *км* көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 43 кеше (руслар) яши. Клуб, китапханә. 1930 ның 1 нче яртысында Кама Урман хуҗалыгы посёлогы буларак нигез салына. Оештырылган көннән Балык Бистәсе р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1970 тә — 573, 1989 да — 144, 2002 дә — 68 кеше.


**КА́МА** посёлогы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы яры буенда. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Балык Бистәсе р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1970 тә — 67, 2002 дә — 8 кеше.

**КА́МА** посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаллы-Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 292 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 68%) яши. Башлангыч мәктәп. Төзү пр-тиеләре. 1950 елларда нигез салына, торак пункт буларак 1959 да теркәлә. Оештырылган көннән — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1970 тә — 447, 1979 да — 510, 1989 да — 318, 2002 дә — 283 кеше.

**КА́МА** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Уратма елгасы бассейнында. 2010 елда 240 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 67%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Новосёлки. 1930 еллардан «Прикамский» с-зы үзәк утары. 1960 еллар ахырыннан хәзерге исемдә. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 66, 1949 да — 573, 1958 дә — 804, 1970 тә — 750, 1979 да — 406, 1989 да — 348, 2002 дә — 357 кеше.

**КА́МА**, кече планета № 1387. 1935 елда Кырымдагы Симеиз обсерваториясендә ачыла, Кама елгасы исеме б-н атала.

**КАМА́** (Lutra lutra), сусарсыманнар семьялыгыннан имезүче ерткыч җәнлек. Европа, Азия, Төньяк Америка һәм Төньяк-көнбатыш Африкада очрый. ТРда даими тереклек итү урыны Әгерҗе аучылык тыюлыгы (Кырыкмас елгасы һәм аның кушылдыклары). Аз санда ш.у. төньяк төбәкләрдәге Иллэт, Шора, Шушма елгалары буенда очрый. Гәүдәсе сузынкы, сыгылмалы, озынлыгы 85 *см* га кадәр. Авырлыгы 10 *кг* га җитә. Ана К. ата заттан кечкенәрәк. Койрыгының озынлыгы 45 *см*



тирәсе, очланган һәм төптән юан, руль урынына хезмәт итә. Бармаклары йөзгеч элпә б-н тоташкан. Чумганда колак һәм борын тишекләре аерым тиречел үсентеләр б-н томалана. Мехы тыгыз, чагыштырмача кыска, кара коңгырт, корсагы көмешсыман төстә, су б-н юешләнми һәм һаваны тоткарлый. Ярымсу яшәү рәвеше алып бара. Керү юлын аста калдырып, агач һәм куакларның асылынып торган тамырлары астында оя ясый. Әңгер-меңгер вакытта һәм төнлә актив. Нигездә, балыклар, ш.у. бакалар, вак кимерүчеләр б-н туклана. Балаларын (2–5), гадәттә, язын тудыра. 15 елдан артык яши. 1930 елдан К.га ау тыелган, саны акрын арта. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Колонок, горностай, выдра. М., 1977.

**«КА́МА»**, агрофирма, ҖЧҖ, Балык Бистәсе р-нында. 2008 елда бер үк исемдәге а.х. җитештерү кооперативы җирлегендә оештырыла. 2001 гә кадәр 1932 дә төзелгән «Кызыл йорт өсте» колхозы, 1959 дагы эреләндерүдән соң — «Кама». 2009–10 да хуҗалыкка «Рус Әшнәге» һәм «Ырга» а.х. кооперативлары берләштерелә. Олы Елга (үзәк утар), Казаклар, Рус Әшнәге һәм Югары Ырга авылларын үз эченә ала. А.х. җитештерүендә эшләүчеләр саны — 174 кеше (2010). А.х. файдалану җирләренең мәйданы 5842 *га*; 3500 баш мөгезле эре терлек, ш.и. 1200 баш сыер асрала. Төп юнәлеше — бөртекле ашлык, сөт җитештерү. Бөртекле культураларның уңышы: 1980 елларда уртача 1 *га* дан 20 *ц* дан, 1990 елларда — 40 *ц* дан артык, 2001–05 тә — 47 *ц*. 2009 да 100 га а.х. файдалану җирләренә 357 *ц* сөт җитештерелә. Хуҗалык үсешенә зур өлеш керткән җитәкчеләр: Х.Х.Кәримуллин (1983–95), Г.Н.Әлмиев (1985–2006), К.Г.Садыйков (2008 дән).

**«КА́МА»**, Совет-Германия танк мәктәбе. Казанда ОСОАВИАХИМның техник курслары исемендә ачыла. Мәктәпне оештыру турындагы шартнамә 1926 елның 2 октябрендә Мәскәүдә Германия һәм СССР вәкилләре тарафыннан имзалана. Аның буенча, 1926–28 дә Германия өйрәнү кыры, класслар һәм остаханәләр төзи, моның өчен 2 млн. марка чамасы акча сарыф итә. 1928 нең ахырында — 1929 ның башында мәктәп сугыш һәм өйрәнү техникасы б-н җиһазландырыла башлый. Танк мәктәбендә алты 23 тонналы (75 *мм* лы туп) һәм өч 12 тонналы (37 *мм* лы туп) танк файдаланыла. Шулай ук Англиядә эшләнгән җиңел танклар да була. Мәктәп башлыклары — подполковник В.Мальбрандт (1929), Людвиг Риттер фон Радльмайер (1929–32), полковник Йозеф Харпе (1932–33). Совет ягыннан «К.»га Кызыл Армиянең автомобиль инспекциясе күзәтчелек итә. Мәктәптә дәресләр 1929 ның мартыннан башлана. Анда даими (4 ай) һәм үзгәрүчән (6 ай) составлар курсантлары укый. Курсантларның составы: 50% — Эшче-Крәстияннәр Кызыл Армиясе, 50% — рейхсвер вәкилләре. 1929–33 тә Кызыл Армия өчен 100 ләп курсант (башлыча, танк һәм мотопехота подразделениеләренең команда составы) укытыла. «К.»ның эшчәнлеге катгый яшерен рәвештә алып барыла. Мәктәпкә җибәрелгән немец офицерлары иң элек армия хезмәтеннән азат ителәләр. Алар уйдырма фамилияләр теркәлгән паспортлар б-н СССРга Польша аша киләләр. 1933 нең августында бетерелә. Җиһазлар өлешчә Германиягә кайтарыла, аларның бер өлеше түләүсез Кызыл Армиягә калдырыла.

*Әд.:* Д ь я к о в Ю.Л., Б у ш у е в а Т.С. Фашистский меч ковался в СССР: Красная Армия и рейхсвер. Тайное сотрудничество. 1922–1933: Неизвестные документы. М., 1992; П ы х а л о в И. Великая Оболганная война. М., 2005.

*В.А.Шагалов.*

**«КА́МА»**, тары сорты. 1975 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.Н.Шумкова, Л.Г.Сәгъдиева тарафыннан «Казанское 430» сорты б-н «Казан 176» һәм «Долинское 86» гибридларының серкәчләрен парлы изоляцияләп рәт аралаш чәчкәндә табигый серкәләндерү һәм индивидуаль сайлап алу юлы б-н чыгарыла. Үсемлек уртача биеклектә, яхшы тармакланган. Серкәче кысынкы, уртача озынлыкта (22–25 *см*), аның ботаклары озын, нәзек, бөртекләре өлгергәндә бер якка салынып төшә. Бөртекләре өлгерү чорында серкәче көпшәкләнә, башагының тәңкәләре, яфраклары һәм сабаклары антоциан ачык-яшел төстә. Серкәче яхшы бөртекләнгән, бөртеге уртача эрелектә, түгәрәк формада, ачык төстә. Технологик һәм ярма сыйфатлары яхшы. 1000 бөртекнең авырлыгы 6,8–7,2 *г*, элпәлелеге түбән — 17–18%, ярма чыгышы 78–80%, тишелеше 65–75%, беренчел протеин 14–15% тәшкил итә. Бу сорт иртә өлгерешле, салкынга чыдам, вегетация чоры 80–90 көн. Сөрлегүгә һәм бөртеге коелуга бирешми, сыгылмалылыгы б-н аерылып тора. Уңышы 1 *га* дан 40–45 *ц* (сорт участокларында «Казан 176» сортыннан 4,7–6,3 *ц* га югары). ТАССРда (1978), БАССРда (1979) һәм Рязань өлкәсендә (1979) районлаштырыла. Тары чәчүлекләренең 27,3%ын били (7,7 мең *га*). СССР ВДНХсының бронза медале бирелә (1980).

*Әд.:* к. «*Казанская местная*».

**КА́МА АВТОМЕХА́НИКА ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Фән һәм мәгариф министрлыгы уку йорты, Чаллы шәһәрендә. 1973 елда респ-ка автохуҗалыклары һәм Кама автомобиль з-ды өчен квалификацияле кадрлар әзерләү максаты б-н оештырыла. 2003 тә Кама машина төзүчеләр техникумы (1993 тән эшләп килә) б-н берләштерелә. ТРдагы зур урта һөнәри уку йорты, үзенең эшләү елларында 30 меңнән артык белгеч әзерли. 2011 дә укыту — автомобиль һәм трактор төзлеше; машина төзелеше технологиясе; автомобиль транспортын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү; сәнәгать җиһазларын монтажлау һәм техник хезмәт күрсәтү; кою производствосы; электр җиһазларын монтажлау, көйләү һәм файдалануга тапшыру; хисаплау техникасын программалар б-н тәэмин итү, икътисад һәм бухгалтерлык исәбе; иминият хезмәте; банк хезмәте белгечлекләре буенча алып барыла. Көндезге бүлектә 1600, читтән торып уку бүлегендә 750 студент укый. Коллективта 70 укытучы эшли.

**КА́МА АЛАНЫ́**, шәһәр тибындагы посёлок, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасының сулъяк ярында. 2010 елда 15795 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 48%, татарлар — 43,7%) яши. 4 урта һәм 1 музыка мәктәбе, татар гимназиясе, һөнәр уч-щесе, мәдәният үзәге, 2 китапханә. Мәчет. Чиркәү. Автоагрегат, механика, эре панельле йортлар төзү з-длары, трикотаж һәм тегү ф-калары. 18 йөздә Полянки авылы буларак нигез салына, 20 йөз башыннан хә-




Шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогы. «Чулман су» мәдәният үзәге.



Шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогы. «Рамазан» мәчете һәм Бөек Ватан сугышында җиңүгә багышланган һәйкәл.

зерге исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиләннәре катлавына керә һәм Ижевск корал з-дына беркетелә; игенчелек, терлекчелек, йон-тукыма дану б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында пароходлар пристане (ел саен 300 мең потлап төрле товар, нигездә, икмәк һәм утын озатыла), Богоявление чиркәве, земство мәктәбе, 3 тегермән, 3 тимерчелек, 1 казна шәраб, 2 сыраханә, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2128 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр К.А. Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. 1982 елда Татарстанда АЭС төзелә башлау (1990 да туктатыла) уңае б-н, К.А. авылы шәһәр тибындагы посёлок итеп үзгәртелә. Халык саны: 1782 дә — 112 ир-ат; 1859 да — 1997, 1897 дә — 2097, 1908 дә — 2137, 1920 дә — 2137, 1920 дә — 2279, 1926 да — 2170, 1938 дә — 1533, 1949 да — 1050, 1958 дә — 1203, 1970 тә — 976, 1979 да — 545, 1989 да — 12200, 2002 дә — 15049 кеше.

**КА́МА А́РЪЯГЫ ИСКЕ́ ЧИК СЫЗЫГЫ́**, Кама аръягы терр-ясендәге саклану ныгытмалары системасы. 1652–56 елларда төзелә. Атлы отрядлар бәреп кергән очракта ачык калу ихтималы булган урыннарда корылган кальгалардан, урлардан һәм чокырлардан, урманнарда аркылы-торкылы аударылган агачлардан гыйбарәт. К.а.и.ч.с.н кору б-н Казан воеводасы Н.И.Одоевский җитәкчелек итә. Аны төзүгә Казан өязеннән 6 хуҗалыктан 1 хезмәтче исәбеннән «морҗа кешеләре» («подымные люди», «төтен», ягъни морҗа — хуҗалык исәбеннән салым түләүчеләр) тартыла. Кальгалар төзелүгә, аларда гарнизоннар урнаштырыла (мәс., Акъяр гарнизоны Лаештан күчерелгән казаклардан туплана, Зәй кальгасының гарнизоны Чаллы кальгасыннан китерелгән стрелецлардан һәм поляк шляхтичларыннан тора, Кичү кальгасында чиратлашып Казан стрелецлары хезмәт итә). К.а.и.ч.с. Чирмешән елгасы тамагы янындагы Акъяр кальгасыннан башланып, Зирек-легә кадәр аркылы-торкылы аударылган агачлар рәте сузыла, аннан соң ныгытмалар Чирмешән елгасының уң яры буйлап Тия кальгасына кадәрге аралыкта урнаштырыла. Шул урында К.а.и.ч.с. юнәлешен үзгәртә, субүләр буенча Чишмә елгасына кадәр төзелә, анда Яңа Чишмә кальгасы корыла (Яңа Чишмә урлары хәзергәчә сакланган). Тия һәм Яңа Чишмә кальгалары арасында, болгар шәһәре *Биләрнең* сакланып калган ныгытмалары да файдаланылып, Биләр кальгасы төзелә. Алга таба ныгытмалар һәм аударылган агачлар рәте Чишмә һәм Кичү елгалары арасындагы субүләр буйлап сузыла, ул елгалар кушылган җирдә Кичү кальгасы урнаша. Аннан ары ныгытмалар Кама елгасына параллель рәвештә дәвам иттерелеп, Ык елгасына кадәр җиткерелә; анда, Минзәлә елгасы тамагы янында, Яңа Минзәлә кальгасы корыла. К.а.и.ч.с.н төзү нәтиҗәсендә Рус дәүләте Кама аръягының көнбатыш һәм үзәк өлешләрендә үз контролен урнаштыра һәм ул төбәкләрне колонияләштерә башлый. 17 йөзнең 2 нче — 18 йөзнең 1 нче яртысында К.а.и.ч.с. нугайлар, башкортлар һәм кыргыз-кайсаклар отрядлары һөҗүмнәренә дучар була (мәс., 1707 дә — Зәй, 1717 дә Яңа Чишмә кальгалары басып алына һәм яндырыла). «Идел аръягындагы түбәнге шәһәрләрне яхшырак саклау» һәм халыкны «дошман һөҗүмнәреннән» яклау өчен 1731–36 да К.а.и.ч.с.ннан көньяктарак *Кама аръягы чик буе* төзелә.

*Әд.:* П е р е т я т к о в и ч Г.И. Поволжье в XVII и начале XVIII века (Очерки по истории колонизации края). Одесса, 1882; Я к о в л е в А.И. Засечная черта Московского государства в XVII веке. М., 1916; Б у к а н о в а Р.Г. Города-крепости юго-востока России в XVIII веке: История становления городов на территории Башкирии. Уфа, 1997; А м и р х а н о в Р.Х. Закамские засечные линии — восточные границы России // Әлмәт- Альметьевск. К., 2003.

*И.Л.Измайлов.*

**КА́МА А́РЪЯГЫ ҺӘМ НУРЛА́Т ШӘҺӘРЕ́ ТӨБӘК ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, 1977 елда җәмәгатьчелек тәртибендә 61 нче тимерьюлчылар мәктәбе укытучысы И.Л.Сандлер тарафыннан оештырыла. 2002 дә төбәк тарихы музее буларак ачыла, 2003 тән хәзерге исемдә. 2003–2005 тә ТР Милли музее ф-лы, 2006 дан муниципаль музей. Мәдәният сараенең 2 нче катында урнаштырыла. Экспозиция мәйданы — 800 $м^2$, фондында 6 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозицияләр 6 залда урнаштырыла. «20 йөз башында Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы үсеше» бүлегендә иң эреләреннән берсе булган Бөгелмә — Нурлат тимер юл станциясе төзелеше, Октябрь (хәзер Нурлат) р-ның оешуы турындагы материаллар; Нурлат станциясенең беренче биналары һәм торак йортлары, тимерьюлчылар фотосурәтләре, станциянең беренче чаңы һәм станцияне тыштан яктыртучы электр лампасы, вагон фонарьлары күргәзмәгә куела. «Гражданнар сугышы һәм колхозлар оешу» бүлеге районның 1917 дән соңгы тарихын ача. «Истәлекләр залы»нда 3 нче дәрәҗә Дан ордены кавалеры П.Е.*Михеевның* ордены, Сов. Союзы Геройлары Н.А.*Козлов*, А.И.*Кузнецов*, М.Е.*Сергеев*, Н.К.*Синдряковның* документлары һәм фотосурәтләре, сугыш вакытындагы азык-төлек карточкалары, фронттан килгән хатлар, Мәскәүдән эвакуацияләнгән хәрби з-дның мина һәм снарядлар чыгаруы турындагы материаллар урын алган. «1950–80 елларда Нурлат һәм район» экспозицияләр залы сәнәгать, а.х., мәгариф, сәламәтлек саклау һәм мәдәният үсеше тарихы б-н таныштыра. Аерым зал район нефтьчеләренә багышлана, анда Соц. Хезмәт Геройлары Г.К.*Гыйматдинов*, З.Т.*Тимерҗанов* һ.б.ның документлары һәм фотосурәтләре куелган. «Бүгенге Нурлат» бүлеге соңгы елларда р-ндагы үзгәрешләр турында сөйли. Экспонатлар арасында — 20 йөз башы телефон аппараты, «Кызыл Октябрь» з-дының 1937 елда чыгарылган мотоциклы һ.б. бар.

Ел саен Җиңү бәйрәме (9 май), Халыкара музейлар көннәре (18 май) үткәрелә.

Музей директоры Ф.З.Морзаханова (2002 елдан).

**КА́МА А́РЪЯГЫ ЧИК СЫЗЫГЫ́**, Кама һәм Самара елгалары арасындагы саклану корылмалары системасы. 1731–36 елларда төзелә. *Кама аръягы иске чик буеннан* көньяктарак урнашкан. «Идел аръягында түбәндә урнашкан шәһәрләрне яхшырак саклау» һәм халыкны «дошман һөҗүмнәре»ннән аралау максатында корыла. К.а.ч.с. төзелеше б-н җитәкчелек итү яшерен советник Ф.В.Наумовка йөкләнә; инженерлык эшләрен капитан



Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре төбәк тарихы музее. Экспозиция фрагментлары.

И.А.Бибиков җитәкли. К.а.ч.с. төзелешенә Казан губернасы крәстияннәре җәлеп ителә. 1731 дә аны төзүгә 3 мең «Кама аръягы өязләре кешеләре»н, 1733 тә 15 мең «бөтен Казан губернасыннан эшләүчеләр» җибәрү турында күрсәтмә бирелә. К.а.ч.с.ның саклану системасы кальгалардан, кырдагы ныгытмалардан — редутлардан һәм фельдшанецлардан, урлардан, чокырлардан, аркылы-торкылы аударылган агачлардан (засекадан) тора. К.а.ч.с.нда яшәү һәм аны саклау өчен 4 ландмилиция полкы (4 меңнән артык кеше) — 1 пехота полкы (Алексеев) һәм 3 атлы полк (Чишмә, Биләр, Сергиевский) оештырыла. Чик буе Алексеев бистәсе, Зур Кинель (Самара елгасы кушылдыгы) тамагы янында башлана. Красный редуты аша ул Кондырча елгасы тамагына кадәр Сок елгасына таба сузыла. Сок елгасының сул ярында Красноярск кальгасы (хәзер Самара өлкәсенең Красный Яр авылы) төзелә. Сок елгасын сулда калдырып, берничә редутны һәм Чернореченск фельдшанецын үз эченә алып, К.а.ч.с. Сергиевский кырыена кадәр дәвам итә. Сок елгасын кисеп, ул Липовка елгасы башына таба сузыла, анда редут корылган була. Редуттан Боровка елгасы башына кадәрге араны аркылы-торкылы аударылган агачлар каплый, аннары чик буе дәвам итә, шул тирәдә редут урнаштырылып, ул Сурыш елгасы башына һәм бер фельдшанецы булган Кондырча елгасына таба сузыла. Кондырча фельдшанецы яныннан ары тагын агачлар аударыла, аннан соң Тархан редуты ясала. К.а.ч.с. Чирмешән елгасын кисеп чыга, елга ярында Чирмешән кальгасы төзелә. Кальгадан чик буе Чишмә елгасының сул ярындагы Чишмә фельдшанецына таба сузыла. Уң ярда К.а.ч.с. Баграж елгасы башына таба дәвам итә. Биредә саклану участогы уналты чакрымга сузылган аркылы-торкылы аударылган агачлардан гыйбарәт була. Чик буе Кичү елгасы янында тәгәлләнә, анда фельдшанец корыла. 1730–40 елларда Оренбург ныгытылган сызыгы төзелгәннән соң К.а.ч.с.ның стратегик әһәмияте югала. ТР терр-ясендә чик буеның калдыклары Чирмешән р-нының Чирмешән авылы, Әлмәт р-нының Кичү авылы янында бар, ш.у. Чишмә кальгасы сакланган.

*Әд.:* Иванин М.Г. Описание Закамских линий // Вестн. Имп. Рус. геогр. об-ва. 1851. Ч. 1, кн.1; Дубман Э.Л. Новая Закамская линия: Судьба, проект, строительство. Самара, 2005.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КА́МА ИКЪТИСАДИ́-ИНЖЕНЕРЛА́Р АКАДЕ́МИЯСЕ**, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында. 1980 елның 1 апрелендә Чаллы шәһәрендә Казан төзүче инженерлар ин-тының 1979 дан гамәлдә булган кичке ф-ты җирлегендә, төзелеш һәм машиналар төзелеше (хәзер автоматлаштыру һәм прогрессив технол.) ф-тлары составында ачыла. 1983 тә машиналар төзелеше ф-тыннан автомеханика ф-ты аерылып чыга, 1987 дә механика-технол. (1996 да читтән торып һәм кичке уку ф-ты дип үзгәртелә) ф-ты булдырыла, 1997 дә икътисад ф-ты ачыла (2005 тән институт), 2003 тән — халыкара бизнес институты (дөнья икътисады һәм чит телләр буенча белгечләр әзерли). 2005 кә кадәр Кама политехник ин-ты. 2005 тән — К.и.-и.а. 2012 нең апреленнән Казан (Идел буе) федераль ун-ты составында. Укыту 31 техник, 6 менеджер, 9 икътисад, 2 төзелеш, 1 экология, 2 лингвистика, 2 сәнгать белгечлекләре буенча алып барыла. 2010 да якынча 11 мең студент, 130 аспирант укый. 1997 дән урта һөнәри белем б-н белгечләр әзерләнә, 2010 га көллиятләр эшли: автомеханика, төзелеш, икътисад, автоматлаштыру һәм прогрессив технологияләр, дизайн; барлыгы якынча 2,5 мең укучы. Укытучылар коллективында 400 тирәсе укытучы эшли, шулардан 43 фән д-ры һәм якынча 170 фән канд.; ш.и. профессорлар, техник (Ә.Х.Хәйруллин, С.В.Дмитриев, М.С.Колесников, Б.Л.Кузнецов, М.П.Соколов, В.Г.Шибаков), физика-матем. (Л.М.Котляр, Э.М.Сибгатуллин), химия (Ф.Д.Бәйрәмов), икътисад (Д.С.Садриев, Ю.В.Тёмный), фәннәре д-рлары бар. Институтта 29 каф., 10 белгечлек буенча аспирантура (якынча 100 аспирант), техник фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе өчен диссертация яклау советы эшли. 1999 дан «Информационные и социально-экономические аспекты создания современных технологий» («Заманча технологияләр булдыруның мәгълүмати һәм социаль-икътисади аспектлары»), 2003 тән «Социально-экономические и технические системы» («Социаль-икътисади һәм техник системалар») дигән интернет-журналлар чыгарыла. 4 уку бинасы бар. Ректорлары — Ә.Х.Хәйруллин (1996–2007), 2007 дән В.Г.Шибаков.

**КА́МА МАШИНА́ ТӨЗЕЛЕШЕ́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, к. *Кама автомеханика техникумы.*

**КА́МА ПОЛИТЕ́ХНИК ИНСТИТУТЫ́**, к. *Кама икътисади-инженерлар академиясе.*

**КА́МА ТАМАГЫ́**, шәһәр тибындагы посёлок, Кама Тамагы р-ны үзәге. ТРның көнбатышында, Каратун тимер юл станциясеннән (Ульянов–Зоя линиясе) 57 *км* көнчыгыштарак, Идел елгасының уңъяк ярында (Кама тамагына каршы) урнашкан. Казаннан 117 *км* читтә. 2010 елда 4482 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 58,9%, руслар — 37,5%) яши. Сөт з-ды, агрохимия, а.х. техникасы һәм төзү пр-тиеләре. Урта, тулы булмаган урта һәм музыка мәктәпләре, 3 китапханә. 2 мәчет. Чиркәү. Район мәдәният йорты. Район тарихы музее. Пристань. 17 йөз башында балыкчылар посёлогы буларак ни-



Шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы. Лобач тавыннан күренеше.



Район хакимияте бинасы.

гез салына. Беренче исеме — Богородский. Халкы Казан архиерей йортыныкы булып исәпләнә, 1764 тә секуляризациядән соң икономик (1743 тән — дәүләт) крәстияннәре катлавына күчерелә, бакчачылык, елга судноларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, таш, известь, алебастр, күкерт табу б-н шөгыльләнә. Богородский авылы эре сәүдә үзәге була. 19 йөздә ел саен авыл пристаненнан 500 мең потлап йөк, нигездә, ашлык җибәрелә. 1845–53 елларда Дәүләт милке министрлыгы мәктәбе эшли, 1867 дә — земство мәктәбе, 1892 дә кыз балалар өчен чиркәү-приход мәктәбе ачыла. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Богородица-Рождественская чиркәве (1802 дә төзелә), 2 кәшәнә, земство хастаханәсе. Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек оешмасы, кредитлау ширкәте, почта-телеграф бүлекчәсе, 1 казна шәраб һәм 16 вак-төякләр кибете, 3 сыраханә, 8 тегермән, 2 тимерчелек, пароход пристане эшли; шимбә саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4520,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Богородский — Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1925 тән хәзерге исемен йөртә. 1927 нең 14 февраленнән — Кама Тамагы р-ны үзәге. 1939 да шәһәр тибындагы посёлок итеп үзгәртелә. 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан — яңадан район үзәге. Халык саны: 1646 да — 80, 1782 дә — 557 ир-ат; 1859 да — 1581, 1897 дә — 1819, 1908 дә — 2082, 1920 дә — 2530, 1926 да — 2536, 1938 дә — 3225, 1979 да — 4005, 1989 да — 5000, 2002 дә — 4451 кеше.

**КА́МА ТАМАГЫ́ ГИПС ЧЫГАНАГЫ́**, ТРда иң зур чыганаклар. Шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 6–8 *км* төньяк-көнбатыштарак Иделнең уң ярында урнашкан. Геологик эзләнүләр эше 1929–80 елларда (бүленеп) үткәрелә. Файдалы ятмалар өске Казан асъярусы (Пермь) өлешендә, составы һәм биеклеге җитәрлек булган һәм доломит пачкалары б-н бүлгәләнгән 2 горизонталь гипс катламыннан тора (биеклеге 14–15 *м*). Өске катламның биеклеге 3–7,05 *м*, аскысының — 9,8–14,2 *м*. Катламнар ак-сыл-соры һәм соры вак кристаллик гипстан тора, сирәк кенә буй-буй булып соры доломит, аскы катламда зәңгәрсу ангидрит сузыла. Файдалы ятма астан соры доломит, өстән мергельләр, доломитлар, балчык (гомуми ка-

лынлыгы 24–100 *м*) б-н капланган. A+B+C категориясендәге гипс запаслары 58 млн. *т* дан артык (1997 елның 1 гыйнварына). Сәнәгый запаслары буенча К.Т.г.ч. ТРдагы 84 гипс ятмасы арасында 11 нче урында, 21 эшкәртелү урыннары арасында 5 нче урында тора. 100 елга якын эшкәртелә, 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башында еллык макс. чыгару 500–700 мең *т* га җитә, 1990 еллар ахырында 7–10 тапкыр кими. Ятмалар 130 *м* га якын тирәнлектә штольнялар ясап эшкәртелә. Кама Тамагы гипс руднигында 50 елдан артыкка җитәрлек гипс запаслары бар.

Гипс барлык төрдәге төзү әйберләрен ясауда, мед. максатларында, портландцементка өстәмә буларак кулланыла. Гипс ташы су юлы б-н Идел буе һәм Урал цемент з-дларына һәм төзү материаллары комб-тларына озатыла. 1980–90 елларда Финляндия һәм Швециягә чыгарыла.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

**КА́МА ТАМАГЫ́ РАЙОНЫ́**, ТРның көнбатыш өлешендә урнашкан. Идел алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1198,8 *км*². 3 шәһәр һәм 17 авыл җирлеген, 53 торак пунктны, ш.и. шәһәр тибындагы 3 посёлокны (Кама Тамагы, Куйбышев Затоны, Тенеш) берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы. 2010 елда 16,9 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 53,6 %, руслар — 43,2 %) яши. Шәһәр халкы — 7,9 мең, авылларда 8,9 мең кеше яши. Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 14 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязендә, 1920–27 дә ТАССРның — Тәтеш, 1927–30 да Буа кантонында.



КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫ

Оештырылган чорда К.Т.р.на 35 авыл советы, 50 торак пункт керә, аларда 34860 кеше (ш.и. татарлар — 21358, руслар — 11849) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 842 *км*², халкы — 31,5 мең кеше, 1 посёлок һәм 25 авыл советы, 51 торак пункт була. 1958 нең 16 июлендә К.Т.р. составына бетерелгән *Тәмте районының* бер өлеше кушыла. 1960 та районның мәйданы — 1194,4 *км*², 2 посёлок һәм 15 авыл советы, 66 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, К.Т.р. таркатыла, 1963 нең 1 февралендә биләмәсе Тәтеш р-нына бирелә. Кабат торгызылганнан соң (1965 нең 12 гыйнвары) районның мәйданы — 1197 *км*², халкы — 31,5 мең кеше, 2 посёлок һәм 15 авыл советы, 63 торак пункт була.

К.Т.р.ның рельефы — чокыр-сызалар б-н телгәләнгән һәм Идел яры буйлап сузылган текә, киртләч калкулыклы тигезлек (биеклеге 170–190 *м*). Гипс, доломит, балчык ятмалары бар. Идел (Куйбышев сусаклагычы), кушылдыклары б-н Коры Үләмә, Ишем, Карамалы, Мордвасу елгалары ага. Җирләре күбесенчә соры, аксыл соры һәм карасу соры урман, көрән соры һәм кәсле-карбонатлы туфраклы. Урманлылыгы — 8,7 %. Саклаулы табигать терр-яләре: табигать истәлекләре — *Антоновка чокырлары*; *Байкүл* күле, *Урман күле*; *Юрьев мәгарәсе*, Зимовье мәгарәсе, *Тәмте кылган даласы*; табигать тыюлыклары — *Лобач тавы*, *Лабыш таулары*. К.Т.р. терр-ясендә археол. истәлекләр (югары палеолит чорыннан башлап) табыла. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә, шәһәр тибындагы Куйбышев Затонында («Флотның В.Куйбышев исем. судноларремонтлау базасы» ЯАҖ) һәм Тенеш посёлокларында (Кама Тамагы гипс чыгару руднигы ААҖ), Красновидово авылында (икмәк кабул итү пр-тиесе) урнашкан. Кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау, бакчачылык зур үсеш алган. Сабан бодае, көзге бодай, арыш, арпа, борчак игелә; шикәр чөгендере үстерелә. А.х. 70,3 мең *га* җир били, ш.и. 55,1 мең *га* сөрүлек җир (2010). 2010 да районда 3 а.х. пр-тиесе, 37 фермер хуҗалыгы эшли. К.Т.р. җиреннән Югары Ослан – Кама Тамагы, Апас – Кама Тамагы, Тәтеш – Кама Тамагы автомобиль юллары уза. Кама Тамагында, Куйбышев Затоны, Красновидово, Тенеш, Тәмтедә пристаньнәр бар. Районда 32 гомуми белем бирү мәктәбе (2010/11 уку елында 1822 укучы укый) ш.и. 8 башлангыч, 7 тулы булмаган урта, 10 урта мәктәп, 7 мәктәп-балалар бакчасы, 2 музыка мәктәбе; һөнәр уч-щесе; 26 китапханә, хастаханә, 3 амбулатория, 35 фельдшер-акушерлык пункты бар (2010). Төбәк тарихы (Кама Тамагы) һәм М.Горький (Красновидово) музейлары эшли. Татар һәм рус телләрендә «Идел таңнары»–«Волжские зори» район г-талары нәшер ителә.

**КАМА́ ТАМАГЫ́ СПЕЛЕОЛО́ГИЯ СИСТЕ́МАСЫ**, Кама Тамагы р-ны чикләрендә Идел елгасының уңъяк яр буендагы карст мәгарәләре төркеме. Пермь системасы югары Казан асъярусының доломит һәм доломитлашкан известьташлар б-н бүлгәләнгән гипс катламнарына (калынлыгы 14 *м* га кадәр) туры килә. Мәгарәләрнең формалашуы һәм үсеше доломитлардагы субвертикаль ярыклар буенча су агымнарының сульфат токымнары өслегенә килеп чыгуы нәтиҗәсендә элеге токымнарның (башлыча, гипсның) селтәсезләнүе б-н бәйле. Мордва Каратае авылы янындагы гипс мәгарәләре (Сөйке), ш.у. Антоновка (Юрьев) мәгарәләре 17 йөздән билгеле. Аларның үлчәмнәре турында кайбер мәгълүматлар Е.Ф.Зябловский хезмәтендә китерелә (1810).

Күкертле-водородлы минераль су чыганаклары Сөйке мәгарәләренең танылуына китерә, халык исә аны дәвалану максатларында куллана (19 йөзнең 2 нче яртысында зур булмаган курорт эшли). 1838 елда рус рәссамнары Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар Сөйке мәгарәләренең рәсемнәрен ясыйлар (1955 тә А.В.Ступишин тарафыннан басылып чыга). Мәгарәләр Идел елгасы агымы буенча, түбәндәге тәртиптә урнаша: «Безымянная», «Змеевая», «Отвай-Камень», «Девичья», «Сухая», «Ледяная», «Удачинская». Аеруча зур «Девичья» мәгарәсенең (Ступишин аны Зур Сөйке дип атый) гомуми озынлыгы 250 *м* га кадәр; ул 5 залдан тора, ш.и. сталактитлар һәм сталагмитлардан торган «Гипс», 90 *м* озынлыктагы һәм 12 *м* киңлектәге, суының даими темп-расы 6,8 °С булган җир асты күлле «Озёрный» заллары. Куйбышев сусаклагычы төзелгәч, Сөйке мәгарәләре су астында кала.

Юрьев мәгарәләре (элекке исеме буенча Антоновка чокырлары) Кама Тамагы гипс руднигыннан көньяктарак, Кама Тамагы посёлогыннан 6 *км* югарырак (Идел елгасы агымы буенча). Ерым түбәнлекләренә тоташа, исемнәре исә аларга ярашлы рәвештә алынган. Төньяктан көньяк юнәлешкә таба урнашалар: Рудничная (озынлыгы 80 *м*), Коннодол — 1, 2, 3 (320, 120 һәм 32 *м*), Богородск — 1,2 (40 һәм 36 *м*), Үзәк ерымдагы Зимовье мәгарәсе (30 *м*) һәм *Юрьев мәгарәсе* (410 *м*) Урта Идел буенда иң зурлары. Гипс чыганагының көнбатыш чигендә Мочилки мәгарәсе (16×10 *м*) билгеле. Мәгарәләрнең биеклеге 6,5–7 *м*, иң зур биеклек 12 *м* (Юрьев мәгарәсендәге «Яңгырлар куышы»). 1986 елда табигать истәлеге булып билгеләнә.

*Әд.:* Ступишин А.В., Мухитдинова Д.Х. Сюкеевские пещеры. К., 1950; Максимович Г.А. О первом описании ледяных пещер // Изв. Всесоюз. геогр. об-ва. 1952. Т. 84, вып. 1; Ступишин А.В. Материалы по истории отечественного карстоведения (феодальный период 1689–1861) // Уч. зап. Казан. ун-та. 1955. Т. 115, кн. 2; шул ук. Равнинный карст и закономерности его развития на примере Среднего Поволжья. Гл. 12. Карстовые пещеры. К., 1967; Ишмуратов Р.Р., Лаптева Н.Н., Ступишин А.В. Юрьевская пещера // Экзогенные процессы в Среднем Поволжье. К., 1972; Станкевич Е.Ф., Ступишин А.В., Субботин Р.С. Камско-Устьинская спелеологическая система и некоторые вопросы сульфатного карста // Экзогенные процессы и эволюция рельефа. К., 1983.

**КА́МА ТАМАГЫ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогында, 1987 елның 27 ноябрендә җәмәгатьчелек тәртибендә оештырыла, 1992 дән ТРның Берләштерелгән дәүләт музее (2001 дән ТР Милли музее) ф-лы; 2007 дән муниципаль музей. Ике катлы кирпеч бинаның беренче катында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 210 *м*², төп фонд 5600 саклау берәмлеген тәшкил итә. Җиде залда урнашкан экспозицияләр 17 йөздән алып бүгенгәчә төбәк тарихын чагылдыра. «Богородский — Кама Тамагы» бүлегендә 1692 елда төзелгән Богородский авылы тарихы күрсәтелә. Идел пароходчылыгының үсеше, 20 йөз башында пароходларны сыек ягулык б-н тәэмин итү өчен нефть бак-



Кама Тамагы төбәк тарихы музее. Экспозиция фрагменты: 20 йөз башы татар һәм рус өйләре интерьерлары.

лары төзелеше, рудник гипсын эшкәртү турындагы һ.б. документлар күргәзмәгә куела. 2 залда «Сугыш даны» бүлеге Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашларның, ш.и. Сов. Союзы Герое М.А.*Чирковның* документлары, фотосурәтләре, шәхси әйберләре, орденнары һәм медальләре б-н таныштыра. «Татарлар һәм русларның көнкүреше», «Халык һөнәрләре һәм кәсепләре» бүлекләрендә өс киемнәре, көнкүреш әйберләре, төбәк халкының хезмәт кораллары күрсәтелә. 19–20 йөзләрдәге экспонатлар арасында — чүлмәкчелек һәм тимерчелек эшләнмәләре, агач савыт-саба, туку станогы, агач «швейка» (1836), татарларның һәм русларның өйдә тукылган сөлгеләре һ.б. урын алган. Аеруча кыйммәтле коллекцияләргә — нумизматика, 19 йөз ахыры — 20 йөз башына караган өс киемнәре һәм көнкүреш әйберләре (100 саклау берәмлеге), 20 йөз башындагы җирле чүлмәкчеләрнең эшләнмәләре (30 саклау берәмлеге), самоварлар (15 саклау берәмлеге) керә. Ел саен Ватанны саклаучылар (23 февр.), Җиңү бәйрәме (9 май), Халыкара музейлар (18 май), Хәтер (22 июнь), Татарстан Респ-касы (30 авг.) көннәре үткәрелә.

**КА́МА УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, комплекслы урман пр-тиесе, Мамадыш, Балык Бистәсе һәм Чистай р-ны терр-яләрендә кабат утырту, саклау, чимал ресурсларын нәтиҗәле файдалану буенча урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. Кама механикалаштырылган урман хуҗалыгын (1936–54 тә Кама урман хуҗалыгы) һәм Кама урман сәнәгате хуҗалыгын (1936 да бетерелгән Яр Чаллы урман сәнәгате хуҗалыгы базасында) берләштерү юлы б-н 1960 елда Кама урман сәнәгате хуҗалыгы буларак оештырыла. 1992 дә Кама урман хуҗалыгына үзгәртелә. 2002 гә урман хуҗалыгының гомуми мәйданы 49801 *га*, ш.и. урман мәйданы 47845 *га*. К.у.х. составына түбәндәге урманчылыклар керә: Бөрсет (8448 *га*), Үсәли (11546 *га*), Кама буе (8841 *га*), Шомбыт (9959 *га*), Кама (5714 *га*), Чистай (5293 *га*); 3 урман эшкәртү һәм 1 агачларны читкә чыгару пункты. Эшләүчеләр саны 650 кеше.

К.у.х. урманнарының төп массивы Кама елгасының уңъяк яр буенда (Бөрсет һәм Шомбыт елгалары бассейнында) урнашкан. 1 нче төркем урманнар 32262 *га* мәйданны били, ш.и. кыйммәтле кәсәбәчелек балыкларының уылдык чәчү урыннарын саклаучы тыюлык урман полосалары — 6788 *га*, елга, сусаклагыч ярлары буенча тыюлык полосалары — 15789 *га*, яшел зона урманнары — 2578 *га*, әйләнә-тирә табигать мохите өчен әһәмияткә ия урманнар — 6533 *га* һ.б. 2 нче төркем, ягъни файдаланыла торган урманнар 17539 *га* мәйданны алып тора. Урман культураларының мәйданы 15342 *га*. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 38%, урта яшьтәгеләр — 30%, өлгереп килүчеләр — 15%, өлгергәннәре һәм картайганнары 17 % тәшкил итә. Ылыслы агачлар 13026 *га* мәйданда таралган, ш.и. нарат — 9269 *га*, чыршы — 3541 *га*, карагай 216 *га*. Имән урманнарының мәйданы — 7922 *га*, шуның 70% ка якынын биек кәүсәлеләр били. Йомшак яфраклы токымнардан: каен — 11114 *га*, усак — 4198 *га*, юкә — 6221 *га*. Табигый ареалның көньяк чиге буйлап Себер ак чыршысы, өрәңге, элмә, карама, зирек, соры һәм кара топольләр, талларның төрле төрләре үсә. Өлгергән утыртмаларда агач запасы түбәндәгечә ($м^3$/*га*): наратлыкларда — 325, чыршылыкларда — 278, биек кәүсәле имәнлекләрдә — 126, каенлыкларда — 213, усаклыкларда — 261, юкәлекләрдә — 240. Типлары буенча юкәле һәм мүкле наратлыклар, юкәле чыршылыклар, өрәңге-юкәле имәнлекләр, сырмавыклы каенлыклар, күрәнле һәм сырмавыклы усаклыклар, төрле үләнле юкәлекләр өстенлек итә. К.у.х. терр-ясендә табигать истәлекләре билгеләнгән: 1972 дә — *Бөрсет акчыршылыклары*, 1987 дә — *Карагай урман культуралары*. Төп кулланылыш өчен еллык урман кисү 54 мең $м^3$ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 1500 *га* мәйданда чистарту эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 34 мең $м^3$ тан артык эшкә яраклы агач әзерләнә. Ел саен 300–400 *га* мәйданда яшь урман утырту эшләре башкарыла, ерым һәм сызалар буенда саклагыч утыртмалар (40 *га*), юл буе урман полосалары (30 *га*) булдырыла. Даими эшләүче 6 питомникта 25 төрле агач-куак токымнарының 4 млн. га кадәр үсентесе һәм чәчкене үстерелә. К.у.х. елына 12 млн. нан артык суммага товар (агач-такта материаллары, фанера, паркет, әрҗә, буралар һ.б.) җитештерә. Югары хезмәт күрсәткечләре өчен 1976 да Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1966–92 елларда урман хуҗалыгын Соц. Хезмәт Герое, ТАССРның атказ. урманчысы И.З.Иванов җитәкли. К.у.х. үсешенә зур өлеш кертүчеләр: ТРның атказ. урманчылары В.Н.Волостнов, Р.Ф.Таҗетдинов, А.К.Мингалиев, А.Н.Михайлов, А.П.Чернов. 2007 ел ахырында шул ук исемдәге урманчылык дип үзгәртелә.

**КА́МА УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 60 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 1425 кеше (татарлар) яши. Урман хуҗалыгы, агач эшкәртү пр-тиеләре. Мәдәният йорты. 1936 да нигез салына. Оештырылган көннән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 448, 1970 тә — 1677, 1979 да — 1588, 1989 да — 1476, 2002 дә — 1499 кеше.

**КА́МА ФИ́ЗИК КУЛЬТУ́РА ИНСТИТУТЫ́**, РФнең физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-ты карамагында. 1975 елда Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лы буларак ачыла. 1986 да Чаллы шәһәренә күчерелә, 1997 дә мөстәкыйль ин-т буларак үзгәртелә. Эшләү дәверендә 3 меңнән артык белгеч әзерләнә. Институтны тәмамлаучылар арасында танылган спортчылар — Л.А.Аверьянова, С.А.Дёмина, Г.И.Сәмитова һ.б. бар. Укыту физик культура һәм спорт, адаптив физик культура белгечлекләре буенча алып барыла. 2010 елга көндезге бүлектә якынча 1 мең, читтән торып уку бүлегендә якынча 500 студент, ш.и. 400 кеше түләүле формада укый; укытучылар коллективында — 75 кеше, аларның 30 ы фән канд. һәм 5 се фән д-ры (ике эштә эшләүчеләр б-н бергә), ш.и. профессорлар — биол. фән. д-ры Г.С.Чинкин, психол. фән. д-ры А.И.Фукин, химия фән. д-ры Ш.В.Сәдетдинов, пед. фән. д-ры А.С.Кузнецов. Ректоры — Г.С.Чинкин (1996–2010). 2011 елда Идел буе физкультура һәм спорт академиясе итеп үзгәртелә.

**КА́МА-ЕЛГА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кама елгасы (Дала Зәе бассейны) буенда. 2010 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Бөгелмә кантоны Габдрахман волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 225, 1938 дә — 255, 1949 да — 232, 1958 дә — 187, 1970 тә — 131, 1979 да — 116, 1989 да — 48, 2002 дә — 60 кеше.

**КА́МА-ИСМӘГЫ́ЙЛЬ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 18 *км* көнчыгыштарак, Кама елгасы (Урсалының сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 659 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; газ-нефть чыгару, урман хуҗалыгы. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр, дәүләт крәстияннәре катлауларына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 20 йөз башында К.-И.дә 3 җамигъ мәчет, 3 мәктәп, 2 икмәк саклау-сату кибете, 4 су тегермәне, 5 бакалея һәм тукымалар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3260 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе — Әлки, 1918 дән Урсалы волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 47, 1795 тә — 328 ир-ат; 1859 да — 1016, 1897 дә — 1849, 1910 да — 2324, 1920 дә — 2319, 1926 да — 2425, 1938 дә — 2045, 1949 да — 1702, 1958 дә — 1666, 1970 тә — 1501, 1979 да — 1168, 1989 да — 639, 2002 дә — 681 кеше.

**КА́МА-КИНЕ́ЛЬ БӨГЕЛЕШЛӘРЕ́ СИСТЕ́МАСЫ**, Идел-Кама антеклизасының көнчыгыш өлешендәге структур-фациаль зона. Өске девонның доманик горизонты төбеннән түбәнге карбонның бобриково горизон-

ты түбәсенә кадәр күзәтелә. Девонның фамен ярусы карбонатлар токымы түбәсе буенча һәм Идел аръягы карбон горизонтында аеруча ачык күренә. ТР терр-ясендә 4 бөгелеш билгеле: көнбатышта Чирмешән Тамагы, төньякта Можга һәм Түбән Кама, көнчыгышта Актаныш-Чишмә. Девон катламнары буенча 25–100 *км* киңлектә, түбе тигез, кырыйлары ачык билгеләнгән, үзәгендәге өлеше 400 *м* га кадәр түбән төшкән батынкылыклардан тора. Бөгелеш кырыйларында — күпсанлы риф структуралар, башка катламнары (терриген девоны) — аз амплитудалы күтәренке өлешләрдән, рифлар өстендәге катламнар гөмбәзләрдән тора.

К.К.б.с., урта-франс чорында барлыкка килгән батынкылыкларда явым-төшем җитеп бетмәве нәтиҗәсендә ясала, бобриков чоры ахырында сыгылмалыклар явым-төшем б-н тула. Хәзерге рельеф буенча бөгелешләргә, кайбер тайпылышлар б-н, Чирмешән Тамагына — Идел, Түбән Камага — Кама, Актаныш-Чишмәгә — Ык һәм Агыйдел, Можгага — Ижау елгаларының болынлыклары һәм елга үзәннәре керә. Бөгелешләрнең барлыкка килүе һәм үсеше кристалл фундаментның тирәндә җимерелүләре аркасында кантарлы хәрәкәтле механизмга бәйле (мәс., Актаныш-Чишмә һәм Түбән Кама бөгелешләре Кама алды җимерелүләре өлешенә керә). К.К.б.с.нда күп кенә нефть ятмалары бар: Акан, Енорус, Алабуга, Актаныш һ.б.

*Әд.:* Войтович Е.Д., Гатиятуллин Н.С. Тектоника Татарстана. К., 1998.

**КА́МА-ЫК АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, комплекслы, Актаныш һәм Минзәлә р-ннары терр-ясендә, Кама елгасы һәм Ык култыгы (Түбән Кама сусаклагычы) арасында урнашкан. 1963 елда түбәндәге сунарчылык җәнлекләре төрләрен саклау өчен оештырыла: поши, кәҗәболан, янутсыман эт, Европа чәшкесе, ас, ондатра, суда йөзүче кошлар. Мәйданы 18,6 мең *га*, ш.и. урманнар 2,8 мең *га*. Тыюлык терр-ясендә *Игим наратлыгы* һәм *Көләгеш сазлыгы* урнашкан. Соры торна, ысылдавык аккош, елга каракошының оялау урыны.

**КАМА́ЕВА** Гайшә Нургали кызы (23.12.1912, хәзерге Алексеев р-ны Юеш Көрнәле а. — 16.1.2009, Мәскәү), җырчы (лирик сопрано). 1930–41, 1944–48 елларда Татар радиосы солисты. 1949 дан Мәскәүдә яши. К.ның киң репертуарына татар һәм башкорт композиторларының әсәрләре һәм халык җырлары керә. Европа һәм рус композиторларының вокаль музыкасы әсәрләрен татар телендә башкарып пропагандалауга шактый өлеш кертә. Концерт эшчәнлеге алып бара.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КАМА́З** (Кама автомобиль заводы), РФдә һәм БДБдә зур йөк автомобильләре, дизель двигательләре, автотехника, тракторлар һәм аларны комплектлаучы детальләр җитештерү, сату, сервислы хезмәт күрсәтү пр-тиеләренең иң эре комплексы. Авыр йөк машиналары җитештерү буенча дөньядагы әйдәп баручы 16 компаниянең берсе, дизель двигательләре эшләп чыгару күләме буенча дөньяда 8 нче урынны били. Эшләүчеләр саны — 50 меңнән артык кеше (2012). Төп җитештерү куәтләре Чаллы шәһәрендә урнашкан.

КПСС ҮК һәм СССР МСның 1969 елның август карары нигезендә Кама автомобильләр з-ды буларак төзелә башлый. 1973 тән Кама зур йөк автомобильләре җитештерү з-длары комплексы, 1976 дан Кама зур йөк автомобильләре җитештерү берләшмәсе («К.» ЖБ), 1990 нан «К.» АҖ (СССР пр-тиеләре арасында беренче).

Генераль подрядчик итеп «*Камгэсэнергострой*» төзелеш идарәсе билгеләнә. Завод төзелеше, бөтенсоюз төзелеше буларак игълан ителеп, 1969 ның декабрендә башлана.

Предприятиеләрне технол. җиһазлар б-н коралландыру 1974 нең маенда башлана. Комплексның заводларында 30 меңләп берәмлек технол. җиһаз урнаштырыла, шуларның 80% тан артык өлеше автомат һәм ярымавтомат режимда эшли, ш.и. 700 автомат һәм өзлексез-механикалаштырылган линияләр. Барлык системалар конвейерларының озынлыгы 300 *км* га җитә.

К.ны төзүдә һәм җиһазландыруда 2 меңнән артык пр-тие, илнең 85 төбәгеннән килгән белгечләр һәм эшчеләр (100 меңләп кеше), 700 чит ил фирмасы катнаша.

1976 ның 29 декабрендә — заводлар комплексының 1 нче, 1981 нең 12 февралендә 2 нче чираты файдалануга кабул ителә. Автомобильләр, двигательләр (хәзер «КАМАЗ-Дизель» АҖ), пресс-рам («Кама пресс-рам з-ды» АҖ), тимерчелек һәм кою («КАМАЗ-Металлургия» АҖ), ремонт-инструментлар («КАМАЗ инструмент-спецмаш» АҖ) з-длары гамәлгә кертелә. Бер үк вакытта шәһәр тибындагы Зәй посёлогында мөстәкыйль пр-тие буларак көпчәкләр җитештерү з-ды (хәзер «КАМАЗ автотехника» АҖ) төзелә. Заводлар комплексына хезмәт күрсәтү өчен автомобиль юллары һәм тимер юллар, аэропорт, елга порты, төзелеш индустриясенең җитештерү базасы, сәнәгый-коммуналь зона, ТЭЦ, тораклар төзелә, шәһәрнең социаль инфраструктурасы һ.б. булдырыла.

1973 нең декабрендә К. конструкторлары б-н берлектә И.А.Лихачёв исем. Мәскәү автомобиль з-дында эшләнгән (баш конструктор А.М.Кригер) беренче база моделе — «КАМАЗ-5320» автомобиле һәм аның 3 модификациясе җитештерүгә кабул ителә. 1973 нең ноябрендә «КАМАЗ» двигателенең Ярославль моторлар төзү з-дында эшләнгән (баш конструктор Г.Д.Чернышёв) беренче моделе сериялап җитештерүгә тәкъдим ителә. Мытищи машиналар төзү з-ды белгечләре — автомобиль кузовын, Одесса автоҗыю з-ды белгечләре тагылмаларны проектлый. Элегрәк чыгарылган автомобильләрдән аермалы буларак, «КАМАЗ» тагылма б-н даими файдалана торган йөк тарту автомобиле сыйфатында эшләнә, нәтиҗәдә аның җитештерүчәнлеге 2 тапкыр арта. Яңа машиналарны конструкцияләүдә илнең автомобиль төзелеше өчен прогрессив техник алымнар — башка йөк автомобильләрендә һәм автобусларда («ЗИЛ», «УралАЗ», «ЛАЗ», «ЛиАЗ») файдаланыуга яраклаштырылган югары тизлекле 150–210 ат көчле дизель двигателе; 10 баскычлы тапшырулар тартмасы; төрле тапшыру мөмкинлекләре булган 2 баскычлы төп тапшыргычлар; радиаль конструкцияле шиннар; халыкара таләпләргә туры килгән күпконтурлы тормоз системасы; двигатель өстенә урнаштырылган өч урынлы кабина (2 типта); заманча яктырту техникасы һ.б. кулланыла.

1975 нең 4 декабрендә беренче дизель моторы җыела. 1976 ның 16 февралендә төп конвейердан беренче автомобиль — бортлы «КАМАЗ-5320» төшерелә. 1980 гә кадәр 8 модификациядә 202,3 мең автомобиль чыгарыла. 1980–82 дә яңа база моделе — югары үтүчәнлеккә ия булган тулы күчергечле, бортлы платформалы «КАМАЗ-4310» тягачы һәм аның төрле модификацияләре эшләнә, аларны җитештерү үзләштерелә.

1980 еллар уртасына К.ның тулай продукциясе республикадагы сәнәгый җитештерүнең 17% ын, СССР автомобиль сәнәгате җитештерүе күләменең 10% тан артык өлешен тәшкил итә. 1988 дә продукция чыгаруның иң зур күрсәткеченә ирешелә — 126,6 мең йөк автомобиле һәм 200 меңләп дизель двигателе җитештерелә; эшләп чыгарылган автомобильләрнең гомуми саны 1 млн. нан арта.

1987 дә аз литражлы автомобильләр производствосы (1991–2005 тә «Аз литражлы автомобильләр заводы», 2005 тә «К.» АҖдән чыга) оештырыла; 21 декабрьдә конвейердан беренче «ВАЗ-1111» «Ока» автомобиле төшерелә, 2006 да аны эшләп чыгару туктатылганга кадәр, 300 мең тирәсе автомобиль җитештерелә.

1993 нең 14 апрелендә Двигательләр з-дында чыккан янгын төп корпусны бөтенләй диярлек юкка чыгара. Шуның аркасында продукция күләме кискен кими. Двигательләр з-ды дәүләт ярдәме б-н өр-яңа технол. җиһазлар нигезендә яңадан торгызыла һәм 1996 да эшли башлый.

Күп кенә үзгәртеп корулардан соң 2011 нең башына К.оешмалары төркеменә автомобиль техникасын һәм компонентларын эшләү, җитештерү, җыю, әзер продукцияне сату б-н шөгыльләнүче 150 дән артык бүлендек һәм бәйле компания, ш.и. Чаллы шәһәрендәге 7 эре махсус завод керә.

Төп продукциясе — йөк автомобильләре, а.х. техникасы, дизель двигательләре һәм көч агрегатлары, автобуслар, махсус техника (йөк күтәрүчәнлеге 4 тән 30 *т* га кадәр булган 30 дан артык модель). 1990 еллар ахырында сериядәге агрегатларны киң күләмдә заманчалаштыру һәм унификацияләү нәтиҗәсендә тулы булмаган күчергечле «КАМАЗ-65111» үзбушаткычы нигезендә 15 *т* га кадәр йөк күтәрешле транспорт автомобильләре төркеме (тулы күчергечле үзбушаткыч, иярле тягач, бортлы тягач) һәм 10 *т* га кадәр йөк күтәрешле тулы күчергечле автомобильләр төркеме эшләнә һәм чыгарыла башлый. Шулай ук (РФ Оборона заказы буенча) юлсыз шартларда йөрергә сәләтле күпмаксатлы «Мустанг» автомобильләре («КАМАЗ-4350», «КАМАЗ-5350», «КАМАЗ-6350») эшләнә. «КАМАЗ-6520» шассие һәм үзбушаткычы нигезендә 20 *т* лы йөк



1



2





3



4

5



6



7



8



9



10



11

**КАМАЗ мәкаләсенә.** 1. Төп җыю конвейеры; 2. Кабиналар җыю линиясе; 3. Бортлы «КАМАЗ-4308» автомобиле; 4. «КАМАЗ-740.75» семьялыгыннан 440 а.к. егәрлекле дизель двигателе («Евро-4» стандарты); 5. Дизель двигательләрен җыю конвейеры; 6. «КАМАЗ-5460» магистраль тягач; 7. Югары йөк күтәрүчәнлекле «КАМАЗ-6540» үзбушаткычы; 8. «КАМАЗ» янгын сүндерү автомобиле; 9. «КАМАЗ-5289» шассие нигезендәге «НЕФАЗ» автобусы; 10. Тулы приводлы «КАМАЗ-43118» автомобиле; 11. «КАМАЗ Т-215» тракторы.

күтәрешле автомобильләр төркеме, уртача авырлыктагы йөк күтәрешле «КАМАЗ-4308» нигезендә 5,5 *т* лы йөк ташуга исәпләнгән автомобильләр, җиңел йөк күтәрешле «КАМАЗ-4307» нигезендә 3,2 *т* лы йөк ташу автомобильләре булдырыла.

2000 елларда автомобильләрнең перспектив модельләр рәтен яңарту, киңәйтү һәм төзү алып барыла. Аларның техник характеристикалары һәм куллану үзлекләре дөньяның әйдәп баручы пр-тиеләрендә, ш.у. үзендә эшләнгән автокомпонентлар куллану хисабына яхшыртыла.

1990 еллар ахырында автомобиль двигательләренең 360 *а.к.* егәрлегенә җиткерелгән, «Евро-1», «Евро-2» экологик стандартлары таләпләренә җавап бирүче яңа төркеме эшләнә, әлеге двигательләр ш.у. комбайннар, тракторлар, суднолар һәм көч тудыру җайланмалары составында файдаланылырга мөмкин; 2001 дә — «Евро-1», 2002 дә «Евро-2», 2008 дә «Евро-3» стандартлары таләпләренә туры килүче двигательләр куелган автомобильләр чыгарыла башлый. 2005 тә газ двигательләре төркемен серияләп җитештерүне гамәлгә кертү төгәлләнә. Тулысынча «Евро-3» стандарты таләпләренә җавап бирүче двигательләр урнаштырылган автомобиль техникасы җитештерүгә күчәләр, шул ук вакытта «Евро-4» стандартына туры килүче двигательле йөк машиналарының тәҗрибә-сәнәгать үрнәкләрен чыгару башлана.

2005 тән башлап дөньякүләм дәрәҗәдә югары технологияле продукция җитештерүче чит ил фирмалары б-н берлектә уртак пр-тиеләр төзелә: тапшырулар тартмалары, электрон идарәле двигательләр, тормозлау механизмнары, цилиндр-пешкәк детальләре, ш. у. Fuso Canter җиңел йөк һәм Mercedes-Benz авыр йөк машиналары, а. х. һәм төзелеш техникасы пр-тиеләре.

2008 дә 61956, 2010 да 45844 йөк автомобиле, ш.у. тиңдәшле рәвештә 62573 һәм 28395 двигатель һәм көч бирү агрегаты җитештерелә. 2012 елга кадәр К.да 2 млн.нан артык йөк автомобиле, 2,6 млн.нан артык двигатель чыгарыла.

К. — киң күләмдә диверсификацияле җитештерүгә нигезләнгән компания. Ул ш.у. махсус автомобиль өстәмәләре һәм җиһазлары (янгыннан саклану техникасы, автоцистерналар, урман ташу машиналары), тагылмалар, көч куллану ведомстволары өчен броняле автомобильләр, йөк машиналары һәм җиңел машиналар, автобуслар һәм троллейбуслар өчен көпчәкләр, а.х. техникасы өчен запас частьләр, зур ассортиментта инструментлар, металлургия производствосы әйберләре (чүкелмәләр, штамповкалар, чуен һәм төсле металл коелмалары) һ.б. эшләп чыгара.

«НЕФАЗ» АҖ бүлендек пр-тиесендә (Нефтекамск ш., Башкортстан Респ-касы) «КАМАЗ» шассие нигезендә автоүзбушаткычлар, автобуслар һәм автоцистерналар, ш.у. тагылма һәм ярымтагылма техника чыгаручы куәтләр эшли. Автобусларның төрле модельләрен (шәһәр яны, шәһәр арасы, кече классны, уңайлыклары арттырылган «Турист» автобуслары һ.б.) эшләп чыгару үзләштерелә, еллык җитештерү күләме 3 мең тирәсе (2010). «Автотагылма-КАМАЗ» («Автоприцеп-КАМАЗ») АҖ (Ставрополь ш.) автотагылма техника — 16 *т* га кадәр йөк күтәрешле бортлы ике һәм өч күчәрле тагылмалар, 8 *т* га кадәр йөк күтәрүгә исәпләнгән үзбушаткыч тагылмалар, 14,5–32 *т* йөк күтәрешле ярымтагылмалар, 22 *т* дан 39 *т* га кадәр йөк күтәрүгә исәпләнгән контейнерлы ярымтагылмалар җитештерә.

2004 тә кече һәм урта эшмәкәрлек б-н хезмәттәшлекне киңәйтү кысаларында, автомобиль техникасын һәм запас частьларны җыю өчен комплектлаучы детальләр җитештерүдә чыгымнарны азайту, заманча автомобиль техникасын чыгаруда яңа техник алымнарны һәм ысулларны сынау һәм яңа эш урыннары булдыру максатында «Мастер» Кама индустриаль паркы» АҖ оештырыла.

Автомобильләрнең, дизель двигательләренең модельләр рәтен формалаштыру һ.б. эшләрне К.ның Фәнни-техник үзәге башкара. 1999 да кабул ителгән автомобиль техникасын яңарту концепциясе экология һәм куркынычсызлык буенча халыкара таләпләрнең үтәлешен тәэмин итүче агрегатларны, системаларны һәм узелларны этаплап гамәлгә кертүне күздә тота. Предприятие продукциянең кулланылу үзлекләрен яхшыртуга, эшләнмәләрнең яңа төрләрен үзләштерүгә, производстволарны модернизацияләүгә юнәлтелгән ике федераль программада катнаша. К.ның барлык предприятиеләрендә халыкара ИСО 9001–2008 стандартлары нигезендә сертификацияләнгән сыйфат системалары гамәлгә кертелә. Пр-тие РФ Оборона министрлыгы өчен продукция эшләү һәм җитештерү хокукы биргән «Хәрби регистр» сертификатына ия.

1983 тә «КАМАЗ» автомобиль техникасына гарантияле һәм сервис хезмәте күрсәтүче «КАМАЗавтоцентр» җитештерү фирмасы (1995 тән «КАМАЗтехобслуживание» АҖ) оештырыла. 2010 да аның составында 109 дилерлык пр-тиесе һәм 100 дән артык фирма сервис автоүзәге исәпләнә, алар РФнең барлык төбәкләрендә һәм ш.у. Белоруссия, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Украина респ-каларында һ.б. җирләрдә эшлиләр; 500 меңнән артык автомобильгә техник хезмәт күрсәтелә.

Дилерлык челтәре, фирма автоүзәкләре һәм сәүдә йортлары аша җитештерелгән продукциянең 70% тан артык өлеше сатыла. Россия базарында сатылган шул класстагы йөк автомобильләренең 35% тан артыгы К. продукциясенә туры килә (2011). К. Россиядә лизинг схемалары буенча автомобиль техникасы сату лидерларының берсе (2008 дә лизингка 4315 берәмлек, 2009 да 1998 берәмлек техника тапшырыла).

Продукцияне экспортка чыгару 1977 дә йөк автомобильләрен Польшага җибәрүдән башлана. Барлыгы 130 меңнән артык автомобиль экспортлана, әлеге продукция Европа, Азия, Африка һәм Латин Америкасының 83 илендә файдаланыла. Төп сату базарлары: Венгрия, Словакия, Сербия, Кытай, Һиндстан, Иран, Гыйрак, Вьетнам, Әфганстан һ.б. (барлыгы 40 тан артык ил). 2011 дә экспортка 6 мең берәмлектән артык йөк автомобиле чыгарыла. К.ның җыю производстволары Казакъстанда, Иран, Пакистан, Һиндстан, Вьетнамда эшли (2011).

«КАМАЗ» автомобильләре күптапкырлар халыкара ярминкәләрдә, күргәзмәләрдә һәм автосалоннарда күрсәтелә: Мәскәү, Лейпциг шәһәре (Германия), Брно шәһәре (Чехословакия), Пловдив шәһәре (Болгария). «КАМАЗ» автомобильләре — күп тапкырлар халыкара ралли-марафоннарда җиңүчеләр һәм призёрлар (к. *Автоспорт*). 2006 да К. РФ хөкүмәтенең сыйфат өлкәсендәге бүләгенә, 2007 дә «Россия сәүдә олимпы» бүләгенә лаек була.

К. — шәһәр төзүче пр-тие һәм Чаллы шәһәре төзелешенең төп заказчысы (з-д төзелеше башланыр алдыннан шәһәрдә 27 мең кеше яши, беренче елларда аның халкы ел саен 30–40 мең кешегә арта бара һәм 1990 еллар уртасына 530 мең кеше тәшкил итә; 2011 дә 513,8 мең кеше яши). 2001 дә киң колачлы социаль, мәдәни, гуманитар, яшьләр һәм спорт программаларын гамәлгә ашыруы өчен К.га ЮНЕСКОның «Тынычлык пальмасы ботагы» алтын медале бирелә.

К. Ленин ордены б-н бүләкләнә (1984). Аның 4,5 меңнән артык хезмәткәре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 8 кеше — Соц. Хезмәт Герое, 17 кеше — СССР, РФ, ТРның Дәүләт бүләкләре лауреаты; 114 кешегә — РФ, ТРның атказ. машина төзүчесе, 16 кешегә — РФ, ТРның атказ. төзүчесе, 8 кешегә — РФнең атказ. технологы, 8 кешегә — РФнең атказ. металлургы, 11 кешегә — РФнең атказ. конструкторы, 14 кешегә — РФ, ТРның атказ. энергетигы, 6 кешегә — РФнең атказ. икътисадчысы, 21 кешегә — РФ, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре, 6 кешегә — РФ, ТРның атказ. торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре, 2 кешегә РФнең атказ. табибе дигән мактаулы исемнәр бирелә; 30 кеше Ленин ордены, 1500 тирәсе кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: Л.Б.*Васильев* (1969–81), В.А.*Фаустов* (1981–87), Н.И.*Бех* (1987–97), И.М.*Костин* (1997–2002), С.А.*Когогин* (2002 дән).

*Г.Я.Мәүлетова, С.Г.Белов, Ф.С.Җиһаншин, А.С.Тайбинский.*

**«КАМА́З-ЧАЛЛЫ́»**, футбол командасы (Чаллы ш.). 1981 елда оештырыла (1988 гә кадәр — «Труд», 1990 га кадәр — «Торпедо», 1995–2000 дә — «КамАЗ — Чаллы» 1990–94 тә һәм 2001 дән — «КамАЗ»). 1988–91 дә СССР чемпионатының 2 нче лигасында, 1992–93 тә Россия чемпионатының 1 нче, 1993–97 дә югары лигасында, 1999–2003 тә 2 нче, 1997–98 һәм 2003 тән Россия чемпионатының 1 нче дивизионында. Татарстан кубогы иясе; производство коллективлары арасында Россия физик культура чемпионатында 2 нче урын (1987), Россия беренчелегендә 1 нче (1990, 2 нче лига; 1992, 1 нче лига) һәм 6 нчы (1994, югары лига), урыннар ала. «Интертото» УЕФА Кубогында катнаша (1996). Баш тренерлары —


В.В.Четверик (1988–97, 2001–02), И.Н.Буталий (1998–2000), П.Е.Шубин (2000–01), Ю.Ф.Газзаев (2002–2009), Р.Е.Евдокимов (2010 нан). Команданың иң яхшы уенчылары — Е.Варламов, Р.Евдокимов, П.Захарчук, Н.Колесов, Р.Нигъмәтуллин, В.Панченко, Б.Тропанец, А.Цвейба, И.Яремчук.

**КАМА́Й** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 85 кеше (руслар) яши. Башлангыч мәктәп. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы* бар. Казан ханлыгы чорыннан *Иске Казан* шәһәре, 1557 дән — рус авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кенәз Камаев исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (алпавытлар арасында Энгельгардтлар, Боратынскийлар, Траверслар, Чемодуровлар һ.б. була) катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тимерчелек һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да полиция үрәтниге фатиры урнаша, земство уч-щесе (1887 дә ачыла), 4 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1085,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 142 ир-ат; 1859 да — 675, 1897 дә — 685, 1908 дә — 748, 1926 да — 523, 1938 дә — 578, 1949 да — 484, 1958 дә — 355, 1970 тә — 220, 1979 да — 421, 1989 да — 141, 2002 дә — 87 кеше. К. янында *Камай шәһәрлеге* урнашкан.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КАМА́Й** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 14 *км* төньяктарак, Бужай елгасы буенда. 2010 елда 414 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, авылдан читкә китеп эшләү һәм агач сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәктәп (1839 дан), икмәк саклау-сату кибете, су тегермәне, пәнҗешәмбе саен базар, 21–22 ноябрьдә ярминкә (атлар сату) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2860 дис. тәшкил итә. 1914 тә земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр — Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1795 тә — 167 ир-ат; 1859 да — 669, 1897 дә — 1096, 1911 дә — 1291, 1920 дә — 1517, 1926 да — 1363, 1938 дә — 1044, 1949 да — 767, 1958 дә — 704, 1970 тә — 573, 1979 да — 471, 1989 да — 399, 2002 дә — 394 кеше.

**КАМА́Й** Гыйлем Хәйри улы (23.2.1901, Казан губ. Тәтеш ш. — 17.3.1970, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1941), проф. (1931), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1944, 1961). А.Е.*Арбузов* шәкерте. Мышьякорганик кушылмалар химиясе буенча фәнни юнәлешкә нигез салучы. 1926 елда Томск ун-тын тәмамлый. 1926–29 да Татар коммунистлар ун-тында эшли. 1930 да квалификациясен күтәрү өчен Тюбинген ун-тына (Германия) җибәрелә. 1931–37 дә Казан ун-тында (1935 тән директор). Бер үк вакытта Казан химия-технол. ин-тында: арадаш продуктлар һәм буягычлар каф. мөдире (1931–37), директор урынбасары (1944–45), төп органик синтез каф. мөдире (1946–70), мономерлар һәм полимерлар комплекслы лаб-ясе җитәкчесе (1958–70). 1945–52 дә СССР ФАнең Казан ф-лында гыйльми сәркәтип. Хезмәтләре элементорганик һәм нитрокушылмалар химиясенә карый. Д.И.Менделеев периодик системасындагы 5 нче төркем элементларының органик кушылмалары реакцияләрен, синтез ысулларын ача. Бөек Ватан сугышы елларында Оборона Дәүләт ком-ты йөкләмәсе буенча А.Е.Арбузов җитәкчелегендәге әйдәп баручы химиклар төркеме б-н заринны ресинтезлауда катнаша. Мышьякорганик кушылмалар буенча өйрәнүләрне К. немец химигы Я.Мейзенгеймер лаб-ясендә башлый. Катнаш фосфор-мышьякорганик кушылмаларның яңа төркемен ачуы әлеге эшләрнең дәвамы булып тора, анда мышьяк атомы фосфор атомы б-н турыдан-туры бәйләнгән. Мышьякның кислородлы к-та эфирлары меркаптаннар б-н реакциягә җиңел кереп, өч валентлы мышьякның тиокислота эфирларын барлыкка китерүен исбатлый, гөмбәчеккә каршы актив кушылмалар ала. Өчалкилфосфитларның дүртхлорлы углерод б-н үзара тәэсир итешү реакциясен ача (к. *Камай реакциясе*), реакция продуктлары — фосфорның төрле к-талары өчхлорлы метил кушылмаларының — гербицид һәм фунгицид активлыкка ия булуын күрсәтә. Фосфор к-тасының аллил эфирларын синтезлый (В.А.*Кухтин* б-н берлектә), аларның полимерлашуын һәм сополимерлашуын өйрәнә, бу мәсьәлә аның тарафыннан (В.С.*Цивунин* б-н берлектә) фосфорның алкенил кушылмаларында да чишелә. Өч валентлы фосфор к-тасы эфирларының чиксез к-талар һәм аларның кушылмалары б-н реакцияләрен эшли (бергәләп). Өч һәм биш валентлы фосфор хлоридларының төрле чиксез һәм галогенлы углеводородлар б-н реакциягә керү сәләтен өйрәнә (бергәләп). К.ның нитрокушылмалар (югары энергияле кушылмалар) өлкәсендәге хезмәтләре оборона сәнәгате өчен зур әһәмияткә ия була. Төп органик һәм нефтехимик синтез технологиясе буенча хезмәтләр, Казан химия фәнни мәктәбе вәкилләре турындагы фәнни-популяр мәкаләләр авторы. Татарлар арасында химияне һәм химик технологияләрне популярлаштыруга өлеш кертә, русча-татарча химия терминнары сүзлеген төзи, химия дәреслеген татар теленә тәрҗемә итә. 1920 елларда К. республиканың Революция хәрби советы сәяси идарәсенең Көнчыгыш бүлеге агитатор-пропагандисты, РКП(б) ҮК каршындагы Тюркбюро татар-башкорт секциясе интернационал бүлеге лекторы, авылларда комсомол ячейкаларын оештыручы була. Кызыл Армия сафларында генерал-лейтенант Г.М.Семёнов, адмирал А.В.Колчак гаскәрләренә каршы сугышларда катнаша. 35 авторлык таныклыгы бар. Фәнни-тикшеренү һәм җәмәгать эшләрендәге казанышлары өчен Татарстанның Соц. Төзелеш Батыры исеме бирелә (1932). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). Ике Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 1937–39 елларда репрессияләнә. 1994 тә ТР ФА химия һәм химик технол. өлкәсендәге иң яхшы хезмәтләр өчен Г.Х.Камай исем. бүләк булдыра. Казанның бер урамы аның исемен йөртә.



Г.Х. Камай.

Х е з м.: О реакции получения фосфонуксусного и фосфонмалонового эфира // Журн. общей химии. 1947. Т. 17, вып. 12 (автордаш); Методы синтеза и реакции эфиров кислот мышьяка // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1964. Кн. 13 (автордаш); Стереохимия органических соединений фосфора и мышьяка // Успехи химии. 1966. Т. 35, вып. 8 (автордаш); Мечте навстречу. М., 1970.

*Әд.:* Гильм Камай. К., 1982; В а л е е в а Н.Ш., В ь ю г и н а С.В. Научно-педагогический потенциал химической школы Г.Х.Камая. К., 2005.

*В.Г.Абзалова.*

**КАМА́Й МОРЗА́** (16 йөз), Казан аксөякләренең Мәскәүгә йөз тоткан вәкилләренең берсе. 1552 елда Казанны Иван IV гаскәрләре камалышта тотканда (к. *Казанның яулап алынуы*) аның ягына чыга. Чыганакларда күрсәтелгәнчә, К.м. патшага «Казан патшасының барлык уйларын һәм хәйләләрен» җиткерә һәм аңа тагын 200 кешенең руслар ягына чыгарга әзер булулары хакында әйтә. 1552 дә, *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56)* башлангач, рус гаскәрләренең К.м. һәм Н.Казаринов җитәкчелегендәге отрядлары Арча ягында «Тугай балалары» күтәрелешен бастыра.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КАМА́Й РЕА́КЦИЯСЕ**, өчвалентлы фосфор к-тасы эфирларының, дүртхлорлы углерод б-н үзара тәэсир итешеп, өчхлорлы метилфосфон эфирлары хасил итүе:

$$(AlkO)_3P + CCl_4 \rightarrow (AlkO)_2\,P(O)CCl_3 + AlkCl$$


Әлеге схема буенча дүртхлорлы углерод б-н катнаш триалкилфосфитлар, алкил (арил) фосфонит һәм фосфинит к-таларының тулы алкиллы эфирлары реакциягә керәләр. К.р. кайбер очракта төп эфирларның пропорциясе бозылу, изомерлашу һәм оксидлашу процесслары б-н бергә бара. Дүртхлорлы углерод б-н реакцияләр барышына өчвалентлы фосфор к-талары эфирларының галогенофиль табигате йогынты ясый. Эфир төзелешенә һәм тирәлекнең полярлыгына бәйле ре-

вештә реакция гомолитик һәм гетеролитик юл буенча бара ала. 1946 елда Г.Х.*Камай* тарафыннан ачыла, теоретик һәм практик яктан әһәмиятле төрле класс фосфорорганик кушылмаларны (пестицидлар, дарулар, полимер материалларның модификаторлары, майлау материалларына өстәмәләр һ.б.) синтезлау ысулы булып тора. Алга таба К.р. нигезендә төрле ил тикшеренүчеләре тарафыннан фосфорорганик кушылмаларны синтезлауның яңа процесслары эшләнә.

*Әд.:* К а м а й Г.Х. Действие четырёххлористого углерода на эфиры фосфористой и фенилфосфонистой кислот // Докл. АН СССР. 1947. Т. 55, № 3; Х а р р а с о в а Ф.М. Четырёххлористый углерод в реакции с эфирами кислот трёхвалентного фосфора // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2001. № 1.

*Ф.М.Харрасова, В.И.Гаврилов.*

**КАМА́Й ШӘҺӘРЛЕГЕ́** (Иске Казан шәһәрлеге), археол. ядкәре; урта гасырлар (14–16 йөзләр) торулыгы калдыклары. Биектау р-ны Камай авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы* составына керә. Тикшеренү эшләрен П.С.Паллас, И.Г.Георги, П.И.Рычков һ.б.; Д.Н.Зиновьев, И.Ф.Яковкин, М.С.Рыбушкин, Н.Н.Кафтанников, Н.И.Второв һ.б. (19 йөз); П.А.Пономарёв, М.М.Хомяков (20 йөз башы); П.И.Бороздин (1928), Н.Ф.Калинин (1945, 1956), А.П.Смирнов (1960), Р.Г.Фәхретдинов (1972–91), А.Ә.Борһанов (1990 еллар) һ.б. алып бара. Казанка елгасының биек сул ярында урнашкан. Мәйданы 61200 $м^2$. Кала саклау ныгытмалары (валлар, күзәтү каланчасы нигезләре), гарнизон казармасы калдыклары, ш.у. манара һәм капкаларның, ак таш йортлар, агач торак һәм хуҗалык корылмалары (ш.и. тимерче остаханәсе, сугыш кораллары һәм хезмәт кирәк-яраклары ясый торган остаханәләр), шәһәрлекне әйләндереп алган диварларның нигез калдыклары, кыпчак каберлекләре һ.б. тикшереп өйрәнелә. Күпсанлы тимер (утлы корал өчен зур булмаган ядрәләр, төрле кылыч сыныклары, ук һәм сөңге очлыклары, көбә кием кисәкләре һ.б.) һәм зәркән (алтын йөгертелгән, көмеш һәм бакыр йөзекләр, бронза көзге һәм бакыр беләзекләр, гәрәбә һәм пыяла муенсалар, бизәкләп эшләнгән пычак һәм хәнҗәр саплары, төрле бизәмәләр һ.б.) эшләнмәләр, монголларга кадәрге болгар һәм Алтын Урда чорына нисбәтле төс йөгертелгән, чынаяк кирпечтән эшләнгән балчык савыт-саба ватыклары һ.б. табыла. Очканда сызгыра торган уникаль балчык туп ядрәсе табып алына. Күп кенә тарихчылар һәм археологлар фаразлавынча, әлеге торак пункт Алтын Урданың таркалу чорында (14 йөз ахыры — 15 йөз башы) Җүчи тәңкәләре сугу үзәкләренең берсе була. К.ш. терр-ясендә шунда сугылган күпсанлы тәңкәләр һәм алар өчен әзерләнмәләр, ш.у. Алтын Урда ханнары Барак, Дәрвиш, Дәүләтбирде, Олуг Мөхәммәд, Чокрый, Казан идарәчесе Гыяседдин исеменнән чыгарылган тәңкәләр табыла. К.ш. тирәсендә 15–16 һәм 18 йөзләргә нисбәтле эпиграфик ядкәр калдыклары булган Иске Казан зираты урнашкан. Кайбер тикшеренүчеләр (А.П.Смирнов һ.б.) К.ш.н *Иске Казан шәһәрлеге* б-н бәйләп карыйлар. Мондый фикер 16 йөз уртасына караган рус язма кенәгәләрендә дә, 17–18 йөзләр татар тарихи чыганаклары һәм фольклор әсәрләрендә дә теркәлеп калган. Казан ханлыгы чорында шәһәр дәүләтнең төньяк-көнчыгыш хәрби форпостларының берсе булган. Биредә православие динендәге әсирләр тотылган: эчтән киелә торган тимер һәм бакыр тәреләр, уникаль гәрәбә тәре-энколпион табыла, әмма рус халкының көнкүрешенә хас әйберләр очрамый.








1. Камай шәһәрлеге. Р.Г.Фәхретдинов төзегән план; 2. Аккургаш аел. 15–16 йөзләр; 3. Көмеш йөзек. 15–16 йөзләр.

*Әд.:* Ш п и л е в с к и й С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ (1945–1952 гг.). К., 1954; Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; ш у л у к. Исследования в Старой Казани (Итоги раскопок 1970-х гг.) // Советская археология. 1984. № 4; К о к о р и н а Н.А. Керамика в кипчакских традициях с Камаевского городища // Татарская археология. 2000. № 1.

*Р.Г.Фәхретдинов.*

**КАМА́Л** (Камалетдинов) Әгъзам Камалетдин улы (21.1.1918, Казан губ., Тәтеш өязе Үтәмеш а. — 16.5.1943, ?), шагыйрь. Казан финанс-икътисад техникумын тәмамлый (1937). 1938–39 елларда «Чаян» ж-лында һәм «Кызыл Татарстан» г-тасында әдәби хезмәткәр. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Җилфердә, байрак!» (1938, Ә.Галиев б-н берлектә), «Һәйкәл янында җыр» (1939) исемле шигъри җыентыклар авторы. Сугыш елларында фронт газеталарында һәм республика вакытлы матбугатында патриотик шигырьләрен бастыра. Аның әдәби мирасыннан кайбер сугыш еллары шигырьләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) күмәк җыентыкларга кертелгән. Сталинград янындагы сугышларда һәлак була.

*Әд.:* Ш а к и р С. Әгъзам Камал // Совет әдәбияты. 1956. № 8; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КАМА́Л** (Камалетдинов) Әнәс Галиәсгар улы (20.2.1908, Казан — 18.3.1978, шунда ук), драматург. Г.*Камалның* улы. Татар сәнгать техникумын тәмамлый (1931). 1931–35 елларда Минзәлә колхоз-совхоз театрында директор һәм сәнгать җитәкчесе, 1935–55 тә Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1921–26 елларда беренче драма әсәрләре — «Хуҗа Насретдин әфәнде», «Җизнәкәй», «Чегән егете белән качкан мулла кызы Хәмидә» комедияләрен иҗат итә. «Биш меңле Гайнетдин» (1928) комедиясе авторның иң зур уңышы санала. Аның «Давыл» (1930), «Ике көч» (1931), «Туй» (1939), «Март бураннары» (1955) пьесалары буенча куелган спектакльләре авыл клублары сәхнәләрендә уңыш б-н бара. Әтисе турында истәлек язмалары һәм биографик очерклары тупланган «Халык драматургы Г.Камал» (1950), «Гүзәл тормыш сәхифәләре» (1958) җыентыклары берничә тапкыр басылып чыга. К. Татар дәүләт курчак т-ры өчен, Г.Тукайның мәшһүр поэмасына таянып, «Кисекбаш» (1951) комедиясен дә яза. Ул ш. у. — бер пәрдәлек пьесалар, скетчлар, инсценировкалар, интермедияләр авторы; А.Гайдарның «Школа» («Мәктәп», 1956) повестен татарчага тәрҗемә итә.

Ә с ә р.: Комедияләр һәм скетчлар. К., 1966; Беренче тургайлар. К., 1978; Март бураннары. К., 1988.

*Әд.:* З ә й н и Ш. Драматург үткән юл // Казан утлары. 1968. № 3.

**КАМА́Л** (Камалетдинов) Галиәсгар Галиәкбәр улы (25.12.1879, Казан — 16.6.1933, шунда ук), күренекле драматург, публицист, театр сәнгате һәм җәмәгать эшлеклсе, Хезмәт Батыры (1924), ТАССРның халык драматургы (1926). Милли журналистикага һәм татар проф. театрына нигез салучыларның берсе. 1880 елларда — «Госмания» һәм «Халидия», 1890 елларда «Мөхәммәдия» мәдрә-

сәләрендә укый, бер үк вакытта өчьеллык рус мәктәбендә башлангыч белем ала. Улын мулла итеп күрергә теләгән атасының ихтыярына каршы килеп, К. үзен халыкны агарту эшенә багышлый. 1901 дә ул китап бастыру һәм тарату эше буенча «Мәгариф көтебханәсе» дигән җәмгыять оештыра һәм 1905 кә кадәр аның б-н җитәкчелек итә. 1905 тә — «Казан мөхбире» дип аталган беренче татар г-тасында, 1906 да «Азат» г-тасында эшли, соңгысының фактик җитәкчесе була; шул ук елны — «Азат халык» дигән яңа исем б-н чыга башлаган әлеге газетаның нашире һәм мөхәррире. 15 саны чыкканнан соң, революцион эчтәлекле материаллар бастырган өчен



Г. Камал һәм Г. Кариев.

газета ябыла, ә К.га штраф салына. 1908–09 да ул «Яшен» сатирик ж-лын чыгара һәм аның нашире була, 1917 гә кадәр — «Йолдыз» (1912–13 елгы Балкан сугышы вакытында — Төркиядә үзхәбәрче), 1917 дән соң «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия» г-таларында эшли. К.ның башлангыч әдәби тәҗрибәсе «Бәхетсез егет» (1900, 2 нче варианты — 1908), «Өч бәдбәхет» (1900, башка исеме — «Уйнаш», 1910) әсәрләре һәм Н.Кәмал язган «Кызганыч бала» пьесасының тәрҗемәсеннән башлана (1900). К. — драматург мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятындагы сәнгатьчә традицияләрнең гомуми юнәлешендә иҗат итә. Әлеге әсәрләрнең лейтмотивы — татар гаиләләрендә өстенлек алган патриархаль тәртипләрне тәнкыйтьләү. Алдагы елларда К.ның комедиограф буларак та таланты ачыла. Ул милли драматургияне һәм театр сәнгатен «Беренче театр» (1908), «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) комедияләре б-н баета. Аларда К. XX йөз башы татар җәмгыяте тормышын сатира күзлегеннән чыгып гәүләндерә, аталар һәм балалар, ир б-н хатын, гаилә-көнкүреш мөнәсәбәтләре проблемаларын күтәреп чыга; патриархаль рухта тәрбияләнгән милли сәүдәгәр — мещаннар мохите вәкилләренең истә калырлык образларын иҗат итә. Иҗат тематикасының төп юнәлеше — патриархаль тәртипләрнең җимерелүен, яңа мөнәсәбәтләр, карашлар тууны, искелек б-н яңалык арасындагы каршылыкларны, көрәшне яктырту. К. пьесаларында персонажлар «җәмгать» һәм «мәдәният» эшләре б-н мәшгуль (Фатих, Насыйр, Гариф, Кәрим — «Безнең шәһәрнең серләре»), һәр яңалыкка каршы (Хәмзә бай — «Беренче театр»), үзләренең комсыз теләкләрен һәм ихтыяҗларын бар нәрсәдән дә өстен куялар (Хәмидә «Бүләк өчен»), кешеләр арасындагы эшлекле мөнәсәбәт һәм әдәплелек кагыйдәләрен бозалар (Сираҗетдин — «Банкрот»). Г.Тукай югары бәяләгән «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасында шәһәрдә яшәүче татар халкының барлык катлаулары да (зыялылар, руханилар, чиновниклар, хезмәтчеләр һ.б.) гәүдәләнеш таба. К. комедияләре конфликтларның үткенлеге, вакыйгаларның хәрәкәтчәнлеге, бай эчтәлекле булуы б-н аерылып тора; аларда геройларның рухи дөньясы оста яктыртыла, милли йолалар, гореф-гадәтләр, көнкүреш детальләре (йорт җиһазлары, аларның урыны, чисталык, тәртип; милли аш бүлмәсе һ.б.) ачык сурәтләнә. Автор үзен диалог остасы буларак та күрсәтә, аның комедияләренең теле халык юморына бай. К.ның поэтик иҗаты татарның иҗтимагый тормышында 1905–07 елгы Рев-ция чорында барлыкка килгән уй-фикер һәм халәтләрне чагылдыра. Ул милләтнең ихтыяҗлары, ирекккә омтылуы, өмет-хыяллар б-н яшәве хакында, милли мәгариф, мәдәният һәм фән үсеше турында яза («Азатлык», «Өндәү», 1905; «Безнең кирәк», «И, мөселман, йокламагыл!», 1906 һ.б.). К. публицистика өлкәсендә дә күп темаларны яктырта: 1905 елгы Дәүләт думасы һәм манифестка мөнәсәбәт («3 нче ноябрь манифесты ни бирә?»; «Дума, дума, дума», 1906; «Депутатлар озату», 1907 һ.б.), татар иҗтимагый тормышы мәсьәләләре («Кем гаепле?», 1905; «Искелек сакчыларына ачык хат», 1906; «Ачларга ярдәм эшләре», 1907; «Иван Николаевич Харитонов», 1909; «Кыз сату», 1912 һ.б.). Хикәяләрендә К. бушка, юкка вакыт сарыф итүне тәнкыйтьли, халыкка һәм җәмгыятькә файдалы эшләр башкарырга чакыра («Сабир хәзрәт яки гыйбрәт», 1903; «Күгәргән алтыннар», 1909). К. татар әдәбияты һәм театры үсешен игътибар б-н күзәтә, күп санда әдәби-тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр бастырып чыгара («Татарча театр», «Габдулла Тукаев шигырьләр», 1907; «Ачлык кушты», 1908; «Яңа әсәрләр», 1909; «Саран» пьесасы хакында», 1915 һ.б.). Ул, революцион эчтәлекне традицион поэтик формаларда сурәтләп, гражданнар сугышы елларында илдә һәм республикада барган вакыйгаларны яктырта («Декламацияләр», 1921). К.ның 1917 дән соңгы иҗаты сәнгатьчәлеге ягыннан Октябрьгә кадәрге чор иҗатыннан шактый калыша. Алга таба аның драматургиясендә җәмгыятьне соц. үзгәртеп кору идеяләре яңгыраш таба. Совет органнары хезмәткәрләре һәм алар тарафдарлары уңай геройларга әверелә, ә үзгәрешләргә каршы булучылар көлкегә алына («Хафизәләм иркәм» комедиясе, 1922; «Өч тормыш» драмасы, 1930 һ.б.). К. күп кенә рус һәм чит ил драматургларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә: «Өйләнү» — «Женитьба» һәм «Ревизор», Н.В.Гоголь; «Яшенле яңгыр» — «Гроза», А.Н.Островский; «Саран» — «Скупой» һәм «Ирексездән табиб булу» — «Лекарь поневоле», Ж.Б.Мольер; «Һинд кызы» — «Индианка», Г.Хәмид һ.б. К. рәсем ясау остасы да була. Ул Г.Тукай әсәрләренә беренче иллюстрацияләр ясый, ш.у. «Яшен» (1907–08), «Ялт-Йолт» (1908–10) ж-лларындагы актуаль иҗтимагый һәм сәяси темаларга сатирик рәсемнәр авторы да. Рәссам-график буларак, Татарстанда нәшрият эше үсешенә зур өлеш кертә: Казандагы И.Н.Харитонов басмаханәсе өчен татар шрифтларының (хәрефләренең) яңа рәсемнәрен ясый, беренче театр афишалары иҗат итә. Татар театрында шактый спектакльләрнең сәнгатьчә бизәлеше аның тарафыннан эшләнә. 1920 елларда К. татар каллиграфиясен камилләштерә, «Чаян» ж-лы, «Кызыл байрак» г-тасы өчен шрифтлар эшли.


Ә с ә р.: Әсәрләр: 3 томда. К., 1978–81.



Г. Камал.



«Казан бае Мәкәрҗә ярминкәсендә».
Г. Камал карикатурасы.
1908.



Г. К а м а л. 1. «Банкрот» пьесасы кергән театраль җыентык тышлыгы. Казан, 1912; 2. «Ялт-Йолт» журналы тышлыгы. 1914. Икесе дә — ТР Милли музее.



Г. Камал пьесасы буенча куелган «Беренче театр» спектакленнән күренеш. Татар акад. театры. 1978.

*Әд.:* Г а й н у л л и н М. Галиаскар Камал // Татарская литература XIX в. К., 1975; А х м а д у л л и н А. Основоположник татарской драматургии // Горизонты татарской драмы: Лит.-крит. статьи. К., 1983.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**КАМА́Л** (чын фам. Байгилдиев) Шәриф Камалетдин улы (27.2.1884, Пенза губ., Инсар өязе Татар Пешләсе а. — 22.12.1942, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1940). Башта авыл мәдрәсәсендә укый, 1900–03 елларда Төркиядә белем ала. Укуын тәмамларга матди хәле мөмкинлек бирмәгәнгә, ватанына әйләнеп кайта. Донбасс шахталарында, Каспийдагы балыкчылар артельләрендә, Одессада, Кырымда, Кавказда эшли. 1905 кә кадәр мөгаллимлек итә, «Нур» г-тасы (Петербург) редакциясендә эшли. 1907–10 да туган авылы мәдрәсәсендә укыта. 1917 дән Оренбург шәһәрендә яши, укыта, «Шура» ж-лында, «Вакыт» г-тасында язышa. 1918–19 да «Эшчеләр дөньясы», «Кызыл йолдыз», «Юксыллар сүзе» (Оренбург ш.) газеталары редакцияләрендә эшли. 1920–21 дә Оренбург өлкәсе Чебенле авылында коммуна оештыруда катнаша, 1924 кә кадәр Оренбургның төрле оешмаларында эшли, «Юл» г-тасы мөхәррире була. 1925 нең көзеннән К. Казанда: «Кызыл Татарстан» г-тасы редакциясендә; 1928 дә Татар мәдәнияте йортында гыйльми сәркәтип; 1929–32 дә ТАССРның Әдәбият һәм нәшрият эшләре буенча баш идарә (Главлит) хезмәткәре, 1933–35 тә Татар акад. театрында әдәби бүлек мөдире. 1934 тә СССР язучыларының 1 нче съездында катнаша.

К. ның беренче әдәби тәҗрибәләре 1905 елга карый. «Нур» г-тасында, эшчеләр хокукын яклап, шигырьләр һәм мәкаләләр бастыра. 1906 да «Сада» («Аваз») исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә. Хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләсенә багышланган «Уяну» новелласы 1907 дә «Шура» ж-лында басыла һәм җәмгыятьтә киң яңгыраш таба. Хатын-кыз хокуксызлыгы темасы «Буранда» (1909), «Күңелсез эш» (1910), «Эч пошулы» (1912) исемле хикәяләрендә дәвам итә. К. хикәяләре тулылыгы, кыскалыгы һәм аныклыгы, детальләрнең төгәллеге, пейзажларның матурлыгы, гүзәллеге б-н аерылып тора. Аларда билгеле бер дәрәҗәдә А.П.Чехов һәм М.Горький новеллалары тәэсире сизелә. К. татар әдәбиятында беренчеләрдән булып хезмәт кешесе образларын тудыра, шахтёрлар, балыкчылар, сезонлы эшчеләр, сукбай-зимагурлар тормыш-көнкүрешен тасвирлый. Каспий балыкчылары тормышына багышланган «Акчарлаклар» (1941) автобиографик повесте хезмәт кешесенең рухи дөньясын реалистларча сурәтли. Дистәләрчә еллар алдан К. татар әдәбиятында «кечкенә» кешенең рухи асылын ачып салу юлларын дөрес билгеләгән. Аның традицияләре замандашлары һәм киләчәк буын язучылар әсәрләрендә үсеш ала. К.ның мөһим сәнгати ачышларыннан берсе — кеше һәм табигать арасындагы үзара тыгыз бәйләнешне дөрес һәм оста күрсәтә белү.

Окт. рев-циясен К. хезмәт кешесенә чын ирек бирүче яңа эра башы дип кабул итә. Язучының рев-циядән соң язылган әсәрләрендә чынбарлык киң колачлы итеп тасвирлана. Җәмгыятьтә барган зур социаль үзгәрешләрне аңларга теләп, К. зур әдәби формаларга мөрәҗәгать итә. Беренче «Таң атканда» (1927) романында ул геройлар язмышын («Акчарлаклар»да да шулай) тарихның хәлиткеч мизгелләрендә, 1917 нең Февр. рев-циясе тудырган социаль һәлакәт барышында күзәтә. 1930 еллар башында К. биш томнан торачак эпик әсәр турында уйлана башлый, ләкин аның бу нияте тормышка өлешчә генә аша. 1937 дә әдипнең 1920–30 еллар авыл тормышына багышланган «Матур туганда» романы басылып чыга. Әсәр булачак эпопеяның беренче китабы сыйфатында авылда барган катлаулы, каршылыклы социаль үзгәрешләрне күрсәтергә тиеш була. Роман сюжетын Оренбург тирәсендәге авыл хуҗалыгы коммунасы тормышындагы вакыйгалар тәшкил итә. 1921 дә К. үзе шул коммунаны оештыручыларның берсе була. Кешеләр арасында яңа мөнәсәбәтләр һәм мораль нормалар тууга багышланган романның исеме дә символик мәгънәгә ия. Эпопеяның «Ныклы адымнар» исемле икенче китабы язылып бетми кала. 1930 елларда К. драматургия өлкәсендә актив эшли: «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1932), «Габбас Галин» (1934) пьесаларын яза. Алар характерларның аныклыгы һәм үзенчәлеклеге, конфликтның кискенлеге, тематиканың актуальлеге б-н аерылып торалар. Бөек Ватан сугышы башлангач, К. иҗатында публицистик юнәлеш үсеш ала.

Татар әдәбиятында К. исеме соц. реализм үсеше, гуманизм традицияләре, хезмәт кешесенә хөрмәт күрсәтүне раслау б-н бәйле. Новеллист буларак, ул татар әдәбиятында, бу жанрның классик үрнәкләрен тудырып, үзеннән зур өлеш кертә. К.ның алдагы чор иҗатында сов. хакимияте казанышларына дан җырлау өстенлек ала. Ул еш кына яңа тормышны, җәмгыятьне идеаллаштыра, кайвакыт уңай геройлар образын тудырганда схемачылыкка бирелә. Шуңа да карамастан, К.ның совет чоры иҗаты, татар әдәбиятының якты бер сәхифәсе булып кала, аны шактый гына баета. Ленин ордены б-н бүләкләнә (1940). 1950 дә Казанда К.ның Музей-фатиры ачыла.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1952–56; Избр. произведения: В 2 т. К., 1983–84.



Ш. Камал.



Камал III.

*Әд.:* К а ш ш а ф Г. Шәриф Камал. К., 1940; Н у р у л л и н И.З. Шәриф Камал иҗаты. К., 1963; Х и с м а т у л л и н Х. Шариф Камал // История татарской советской литературы. М., 1965.

*В.Х.Ганиев.*

**КАМА́Л III** (чын фамилиясе һәм исеме Сәләхетдинов Камал Ситдыйк улы) (5.1.1899, Әстерхан ш. — 27.7.1968, Казан), драма актёры, ТАССР, РСФСРның халык артисты (1943, 1957). Сәхнә эшчәнлеген 1918 елда Әстерханда татар һәвәскәрләре труппасында башлап җибәрә. Әстерхан театр студиясен тәмамлаганнан соң (1919), Әстерхан татар драма театрына кабул ителә. Башта Сакмарский кушаматы б-н чыгышлар ясый. 1924 елда Татар дәүләт театрына (хәзер Татар акад. театры) чакырып алына. Монда ул Камал III псевдонимы б-н эшли башлый. Искиткеч матур тышкы кыяфәткә ия актёр беренче елларда, нигездә, романтик рухтагы яшь герой рольләрен башкара: Хәлил, Бакый, Шәрәф («Галиябану», «Ак калфак», «Сөйгән яр», М.Фәйзи), Галимҗан («Башмагым», Х.Ибраһимов), Шаһзадә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш) — шундыйлардан. Казанда уйнаган әһәмиятле тәүге рольләреннән берсе — Н.В.Гогольнең «Ревизор» комедиясендәге гипербола, гротеск алымнарыннан оста файдаланып башкарган Хлестаков образы. К. III — замандаш драматургларның пьесаларындагы төп рольләрне башкаручы: Саттаров («Гудок», М.Җәлил), Камил (Г.Кутуйның шул исем. әсәре), Ногман, Әсфан («Мактаулы заман», «Изге әманәт», Т.Гыйззәт), Луконин, Сабуров («Безнең шәһәр егете», «Көннәр һәм төннәр», К.М.Симонов), Максимов («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв). Актёр үз чорының кыю һәм үз бурычына тугры булган җыелма герое образын иҗат итә. Классик драма-





1. Ш. Камал дуслары белән (уртада — К. Нәҗми, уңда — Ф. Туишев); 2. Ш. Камал пьесасы буенча куелган «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакленнән күренеш. Татар акад. театры. 1959.



М.Г. Камалетдинов.



Ф.Г. Камалетдинов.

тургиядә аның геройлары югары хисләргә ия, кичерешләргә бай булулары б-н аерылып тора: Ромео, Эдгар, Отелло («Ромео һәм Джульетта», «Король Лир», «Отелло», У.Шекспир), Герман, Фердинанд («Юлбасарлар», «Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Теодоро («Печән өстендәге эт», Лопе де Вега), Незнамов, Жадов, Борис («Гаепсездән гаеплеләр», «Төшемле урын», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский). Башкаруда гадилек һәм эчкерсезлек, теге яки бу рольнең тышкы яктан шомартылган, ягъни тиешле дәрәҗәгә җиткереп эшләнгән булуы, хисләр тирәнлеге — татар театр сәнгатендә романтик юнәлешнең иң үрнәк традицияләрен дәвам итүче һәм үстерүче К.Ш ижатының төп үзенчәлекләре.

Башка рольләре: Мәхмүт («Козгыннар оясында», Ш.Камал), Гали («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов), Хәмит («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин), Мулланур Вахитов (Н.Исәнбәтнең шул исем. әсәре), Сәлим («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Шәмгун («Рәүфә», Ә.Фәйзи), Актёр («Тормыш төбендә», М.Горький), Чибисов («Мылтыклы кеше» Н.Ф.Погодин).

*Әд.:* Илялова И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им. Г.Камала: Биографик белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980.


*И.И.Илялова.*

**КАМА́Л ШӘРИ́Ф МУЗЕ́Й-ФАТИРЫ́**, Казанда, әдәби-мемориаль музей. РСФСР ХКСның 1944 ел 2 июнь карары нигезендә оештырыла, 1950 дә ачыла. ТР Милли музее ф-лы. 19 йөз ахырында төзелгән, 1928–42 дә Ш.К.*Камал* яшәгән йортта урнашкан. Йортка мемориаль такта эленгән. 155,7 $м^2$ лы музей мәйданы язучының мемориаль фатирын һәм лекция-күргәзмә залын үз эченә ала. Фонд 1 меңнән артык саклау берәмлеген тәшкил итә. Фатирының мемориаль җиһазлары язучының шәхси әйберләре нигезендә яңадан торгызыла(аларны Ш.Камал кызы З.Ш.Байгилдиева музейга тапшыра). Экспозициядә Ш.Камалның Оренбург шәһәрендә сатып алган керосин лампасы, язу өстәле; К. шул өстәлдә Октябрьгә кадәрге чорда барлык әсәрләрен һәм ш.у. 1927 дә Казанда сатып алган язу өстәлендә «Таң атканда», «Матур туганда» романнарын, ш.у. драма әсәрләрен дә иҗат итә; бүлмәдә рус әдәбияты классиклары Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, М.Горький әсәрләре һәм белешмәлекләр, энциклопедик басмалар, үзенең шәхси китаплары куелган китап шкафы; ТАССРның халык артисты Г.П.*Ардаров* бүләк иткән карета сәгате, шул ук кичәдә Зеленодольск фанера ф-касы хезмәткәрләре бүләк иткән әйләнмәле этажерка һ.б. урнаштырылган. Экспозициядә ш.у. Ш.Камал йортында еш булган язучылар һәм шагыйрьләр Ф.Вольф, А.Фадеев, М.Җәлил һ.б. ның портретлары куелган. Музей тупланмасының иң кыйммәтле экспонатлары исәбенә Ш.Камалның «Сада» шигырьләр җыентыгы («Аваз», СПб., 1906), Ш.Камал портреты (1949) һәм аның «Акчарлаклар» повестена рәссам Х.Якуповның иллюстрациясе эскизлары (1951); язучы тарафыннан кызы өчен 1938 дә сатып алынган, С.Сәйдәшев һ.б. танылган татар композиторлары уйнаган рояль керә. Музей ел саен 22 декабрьдә Ш.Камалны искә алу көнен билгеләп үтә.

*Әд.:* Шәриф Камалның Казандагы музей-фатиры — Музей-квартира Шариф Камала в Казани. К., 2000.



Шәриф Камал музей-фатиры. Экспозиция фрагменты.



Ш. Камал музей-фатиры. Экспозиция фрагменты: Язучының кызы өчен сатып алынган рояль.

**КАМАЛЕТДИ́НОВ** Морат Габделхак улы (18.7.1928, Томск ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1979), БР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1991), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). Уфа геотектоника мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), БАССРның җитештерү оешмаларында (геол.-төшереп алу экспедициясе башлыгы, геол.-эзләнү конторасының баш геологы). 1969 елдан РФА Башкортстан гыйльми үзәгенең Геология ин-тында, директор (1974–91), тектоника лаб-ясе мөдире (1991 дән), проф. (1981). Структур геология, формацион анализ, офиолит комплекслар геологиясе, магнитизм, метаморфизм, метамоматизм, нефть һәм руда геологиясе өлкәсендә яңа идеяләр һәм гамәли нәтиҗәләр барлыкка килүгә этәргән теория — литосфераның шарьяж-шуышмалы теориясе автордашы. Башкортстан нефть-газ чыганакларын (Табын, Тейрух һ.б.) ачуда катнаша. Татарстанда һәм Башкортстанда АЭСлар төзүне туктатуның мөһимлеген теоретик яктан нигезли. РФА Тектоника ком-ты әгъзасы, халыкара геол. карталар төзү буенча геол. конгресслар комиссиясе әгъзасы. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Покровные структуры Урала. М., 1974; Шарьяжно-надвиговая тектоника литосферы. М., 1991 (автордаш).

*Әд.:* Тимергазин К.К., Тимергазин А.К. Уфимская геотектоническая школа. Уфа, 1992.

**КАМАЛЕТДИ́НОВ** Фәррах Гыймади улы (25.5.1914, хәзерге Томск өлкәсенең Кривошеин р-ны Нөркәй а. — 28.8.1989, Казакъстан ССР, Караганда ш.), Сов. Союзы Герое (27.8.1943), өлкән лейтенант (1946). Мәскәү пехота уч-щесен тәмамлый (1940). Колхозда тракторчы, Көнбатыш Себер елга пароходчылыгында механик-моторист булып эшли. 1934 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында, Хәсән күле буенда япон милитаристларына каршы сугышта катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 410 нчы укчы полкта автоматчылар взводы командиры (13 нче армиянең 81 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш, Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Смоленск (1941), Курск (1943), Днепр елгасы өчен барган сугышларда (1943), Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлин һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 5 июль төнендә Малоархангельск шәһәре (Орёл өлкәсе) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: взвод б-н дошманның һөҗүмен кире кайтара, 6 авыр һәм 1 җиңел танкны сафтан чыгара; яралы хәлендә взвод б-н җитәкчелек итә. 1946 дан Тимертау шәһәрендә (Казакъстан Респ-касы Караганда өлкәсе) яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Их имена никогда не забудутся. Ставрополь, 1969. Кн. 2; Ветераны в строю. М., 1981; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*В.А.Шагалов.*

**КАМАЛЕТДИ́НОВА** Эллионора Шәйхетдин кызы (17.7.1937, Украина ССР, Кривой Рог ш.) философ, филос. фән. д-ры (1991), проф. (1993). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1960). 1956–58 елларда Казанның ВЛКСМ райкомында, 1958–61 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире урынбасары. 1964–70 тә Мәскәү-

дә ВЛКСМ ҮК инструкторы. 1970–94 тә — Яшьләр ин-тында. 1994–2000 дә РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы ком-тында балалар һәм яшьләр эшләре секторы мөдире, ком-тның аппарат киңәшчесе. 2000–02 дә Мәскәү гуманитар-социаль академиясендә яшьләр проблемаларын фәнни-тикшеренү үзәге директоры урынбасары, директор вазифаларын башкаручы. 2002 дән Мәскәүдәге һәм Мәскәү өлкәсендәге дәүләтнеке булмаган вузлар берлеге директоры, бер үк вакытта, 2004 тән Россия дәүләтнеке булмаган вузларның милли берлеге директоры. Хезмәтләре балалар һәм яшьләр тәрбиясе, балалар һәм яшьләр хокукын яклау проблемаларына карый.

Х е з м.: Воспитание в комсомоле (теоретико-методологические проблемы). М., 1988; От мечты к реальности: О концепции государственной политики Российской Федерации в интересах детей. М., 2002; Положение молодежи и реализация государственной молодежной политики в Российской Федерации: 2000–2001 годы. М., 2002 (автордаш).

**КАМАЛИ́** Зыя (Камалетдинов Пәрвазетдин Җамалетдин улы) (9.12.1873, Уфа губ., Уфа өязе Келәш а. — 1942, Самара ш.), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог. *«Госмания»* мәдрәсәсендә белем алганнан соң, 1898 елда хәйрия җәмгыяте тарафыннан Истанбулга укырга җибәрелә, соңрак — Мәдинәдә, аннары Каһирәдәге әл-Әзһар ун-тының филос. ф-тында укый, Мөхәммәд *Абдуның* шәкерте була. 1904 тә Уфага кайта. «Госмания» мәдрәсәсендә ислам фәлсәфәсен һәм Коръән тәфсирен укыта. 1906 да Уфаның либераль мөселман элитасы ярдәмендә *«Галия»* мәдрәсәсенә нигез сала, мөдәррис, директор вазифаларын башкара (1919 га кадәр). 1906–17 дә «әл-Галәм әл-Ислами» («Мөселман дөньясы») г-тасының редколлегия әгъзасы. 1909 дан — 2 нче җамигъ мәчет имамы. Муллалар һәм мөгаллимәләр өчен еллык пед. курслар оештыруда башлап йөри. 1915 тә «Анасия» хатын-кызлар мәдрәсәсен оештыручыларның берсе. 1909–10 да К. «Фәлсәфәи Ислам» (1–3 өлешләр, Уфа), 1913 тә «Дини тәдбирләр» (Уфа) хезмәтләрен бастыра, ислам догматикасын фәлсәфи карашлар аша нигезли, заман ихтыяҗларына туры килгән реформаларны хуплап чыга (аерым алганда, хатын-кызларның тигез хокуклыгы турындагы фикерне яклый). К.ның мөселман руханилары хупламаган радикаль идеяләре күпчелек түбән һәм урта катлаулардан чыккан яшь буын шәкертләр тарафыннан кабул ителә.

1917 нең мартында Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния Нәзарәтенең вакытлыча тәгаенләнгән казые булып сайлана. 1917 нең апрелендә Р.Ибраһимов б-н бергә Учредительләр җыены чакырылганчыга кадәр Эчке Россия мөселманнары корылтаен үткәрергә тәкъдим итә; Россия мөселман руханиларының 2 нче Бөтенроссия корылтаенда (Казан, июль, 1917) руханиларның ролен чикләүгә каршы чыга. 1917 нең октябрендә Уфа губернасы мөхтәсибе, Милләт Мәҗлесе депутаты, төбәк һәм мәгариф комиссияләре әгъзасы булып сайлана. 1918 дә — Милли Идарәнең тикшерү комиссиясе әгъзасы. 1923 тә Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния Нәзарәтенең казые итеп сайлана (1926 да кабаттан сайлана). Мөселманнарның милли яңарышын, җәмәгать тормышын, ш.и. динне демократияләштерүне яклый, җәдидчелектәге радикаль агым тарафдары. 1920 елларда радикаль характердагы күп кенә мәкаләләр бастыра, җәннәткә, җәһәннәмгә, Ахырзаманга ышануны, изгеләргә табынуны кискен тәнкыйтьли. Шулай итеп, «исламны социальләштереп», тоталитар режим шартларында аны саклап калырга омтыла. 1936 да К. кулга алына һәм хөкем ителә. Төрмәдә вафат була; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* К у д а ш С. Незабываемые минуты. Уфа, 1962; Д а в л е т ш и н Т. Советский Татарстан: Теория и практика ленинской национальной политики. Лондон, 1974; К а м а л о в Т. Зия Камали. К., 1997; Ю н у с о в а А.Б. Ислам в Башкортостане. Уфа, 1999; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1998. Вып. 1; B e n n i n g s e n A., Lemercier-Quelguejay Ch. La presse et le mouvement national ches les Musulmans de Russie avant 1920. P., 1964.

*А.Ю.Хәбетдинов.*

**КАМАЛИ́ЕВ** Әмир Аман улы (псевд. Аманулла) (29.5.1960, Апас р-ны Шыгай а.), актёр, язучы. М.С.Щепкин исем. театр уч-щесен (Мәскәү, 1988) тәмамлый. 1988–95 елларда Татар акад. театры актёры. 1995–2000 дә «Казан» милли мәдәният үзәгендә режиссёр, 2000 нән Казан татар яшь тамашачылар театры баш режиссёры. Аның тарафыннан Татар акад. театры сәхнәсендә башкарылган Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи, 1991), Закир («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов, 1989), Сәлимҗан ( «Зөләйха», Г.Исхаки, 1992), Парис («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир, 1991), телевизион спектакльләрдә уйналган Муса («Уяну», Ш.Камал, 1993), Рамай бай («Хан кызы Нурсолтан», Н.Сәйяр, 1999) рольләрен аеруча уңышлы дип бәяләргә мөмкин. К. пьесалары буенча сәхнәләштерелгән «Җәйге кырау» (1992), «Әлепле әртисләре» (1994), «Кылый Кирам балдагы» (1996), «Әле кичә генә яз иде» (1998), «Кыйбла кая?» (1998), «Мактанчык әтәч» (1996), «Моңлы ядкәр» (2002) спектакльләре Татар акад., Чаллы, Әлмәт татар драма, Уфа «Нур», Казан татар яшь тамашачылар театрларында зур уңыш б-н бара. «Кайсыгызның теше сызлый?» (2003) исемле хикәяләр һәм шигырьләр, «Әле кичә генә яз иде» (2003) һәм «Моңлы ядкәр» (2005) дип исемләнгән пьесалар җыентыклары дөнья күрә.

*Әд.:* З а к и р җ а н о в Ә. «Моңлы ядкәр» // Казан утлары. 2007. № 9.

**КАМАЛИ́ЕВ** Галимҗан Камали улы (15.7.1919, Казан губ., Лаеш өязе Апакай а. — 13.6.1993, Казан), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), сержант (1943). Питрәч р-ны «1 Май» к-зында эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 248 нче укчы полкның миномёт ротасында миномёт расчёты командиры (46 нчы армиянең 32 нче укчы дивизиясе). Дала, 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен (1943) сугышта, Украина, Болгария һәм Румынияне азат итүдә, Будапешт (1944–45), Вена һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 27 сентябрендә Сошиновка (Днепропетровск өлкәсе Верхнеднепров р-ны) авылы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып Днепр елгасын кичеп чыга, плацдарм өчен барган сугышта миномёт уты б-н дошманның станоклы пулемётын юк итә, укчы подразделениеләр составында мөһим биеклекне алуда, берничә контрһөҗүмне кире кайтаруда катнаша. 1946 дан запаста, Ленино-Кокушкино (Питрәч р-ны) авыл советы рәисе булып эшли. 1971–80 дә Чирмеш авылында (Питрәч р-ны) өлкәннәр һәм инвалидлар интернат-йорты директоры. 1962–66 да РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.



З.П.Камали.



Г.К.Камалиев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*В.А.Шагалов.*

**КАМАЛИ́ЕВ** Гыймади Камали (Камалетдин) улы (2.7.1912, Минзәлә өязе Түбән Суыксу а. — 1982, Казан), журналист, тәрҗемәче, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1969). Алабуга пед. техникумын (1930), Казан пед. ин-тын (1950) тәмамлый. 1930 елдан ТАССРның Мамадыш р-ны мәктәпләрендә эшли, 1931–32 дә Мамадыш шәһәрендә р-н газетасы сәркәтибе. 1932–33 тә Чаллы газетасында мөхәррир урынбасары, мөхәррир. 1933–34 тә Шөгер авылында район газетасы мөхәррире урынбасары. Казанда армия хезмәте узгач (1934–35), ВКП(б) ҮК каршындагы Массакүләм читтән торып уку ин-тының Татарстан бүлегендә радиолекцияләр тәрҗемәчесе һәм дикторы, 1937 дән СССР Дәүләт планы Үзәк стат. идарәсенең Дәүләт стат. нәшрияты Татарстан конторасында тәрҗемәче, 1941–48 дә контораның управляющие. ВКП(б) өлкә ком-ты каршындагы Республика партия мәктәбен тәмамлаганнан соң (1950), «Совет Татарстаны» г-тасының әдәби хезмәткәре, әдәби сәркәтибе, 1954–60 та — КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы Партия тарихы ин-тында В.И.Ленинның әсәрләрен нәшер итү буенча өлкән фәнни хезмәткәр. Институт ябылу сәбәпле, «Совет Татарстаны» г-тасына (1960 тан «Социалистик Татарстан») пропаганда бүлеге мөдире итеп җибәрелә, соңыннан шунда ук — мөхәррир урынбасары (1960–63). 1963–73 тә Татарстан китап нәш-

рияты директоры. Тәрҗемәләре иҗтимагый-сәяси әдәбиятка карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**КАМАЛИ́ЕВ** (чын фамилиясе Камалетдинов) Тәүфикъ Салих улы (3.2.1940, Буа р-ны Ташкичү а. — 13.2.1980, Казан), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлый (1966). «Ялкын» ж-лы (1966–76), «Социалистик Татарстан» г-тасы (1976–78) редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, ТАССР МС каршындагы Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында өлкән мөхәррир (1973–75) булып эшли. Лирик шигырьләре тупланган «Ромашкалар эзлим» исемле беренче җыентыгы 1967 елда басыла. «Сабыр канатлары сынмый» (1968), «Сезгә генә сөйлим» (1970), «Хәләл көчем белән» (1972), «Яшьлеккә кайту» (1978), «Ак өметләр» (1986) җыентыкларына яшьлек, дуслык турындагы шигырьләре кергән. К. әсәрләре туган җиргә һәм кешеләргә мәхәббәт белән сугарылган.

*Әд.:* М а н н а п о в Ш. Яшел килеш яфрак коелды // Казан утлары. 2000. № 2.

**КАМАЛЛА́Р** (Камаловлар, Камалетдиновлар), татар театр сәнгате тарихында зур роль уйнаган мәдәният эшлеклеләре гаиләсе. Гаиләнең татар проф. театры башында торучы беренче вәкилләре театрга нигез сала, алдагы буыннар тарафыннан үстерелгән, башка актёр һәм драматурглар сәнгатендә расланган принцип һәм традицияләрен булдыра: 1) **Галиәсгар Галиәкбәр улы *Камал***, драматург. 2) **Габдулла Галиәкбәр улы** (*Камал I*) (20.10.1893, Казан — 23.6.1933, шунда ук), драма актёры, реж., Галиәсгар К.ның энесе. Сәхнә эшчәнлеген 1912 елда «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия частьләрендә фронт театрлары эшендә катнаша. 1920 дә Оренбург Шәрекъ театрын оештыручылардан һәм иҗади эшлеклеләрдән берсе. 1921–26 да Ташкентта Үзбәк үрнәк труппасында актёр һәм реж., 1926–29 да Ашхабадта төрекмән театры режиссёры. 1929–33 тә, нигездә, реж. вазифасын үти; Әстерхан, Оренбург татар театрларында спектакльләр куя, Казанда радиотапшырулар алып бара. Татар драматурглары пьесаларындагы рольләрне беренчеләрдән булып башкаручы — Кара фикер («Ике фикер», Г.Коләхметов), Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Идрис («Ачлык кушты», Я.Вәли). Шулай ук Ильяс («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин), Хөсәен («Надиршаһ», Н.Нариманов), Әлмансур (Һ.Һейненың шул исем. әсәре буенча), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Осип («Ревизор», Н.В.Гоголь), Дикой («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Константин («Ванюшин балалары», С.А.Найдёнов) һ.б. рольләрдә уйный. «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь», Ф.Шиллер), «Җинаятьче гаиләсе» («Семья преступника», П.Джакометти), «Комарбазның хәяте» («Жизнь игрока», В.Дюканж), «Өйләнү» («Женитьба», Н.В.Гоголь), «Фәрһад һәм Ширин» (Хәршид), «Канлы урман» («Кровавый лес», А.Каушутов) спектакльләрен сәхнәгә куя. 3) **Габдрахман Галиәкбәр улы** (*Камал II*) (10.5.1896, Казан — 24.2.1948, шунда ук), драма актёры. Галиәс-



Камал I.



Камал II.

гар һәм Галиәкбәр К.ның энесе. Сәхнә эшчәнлеген 1915 тә «Сәйяр» труппасында башлый. Соңыннан Пермь, Уфа, Троицк, Петропавловск татар театрларында эшли. 1924–34 тә Татар акад. театры актёры. Төп рольләре — Гомәр («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Хәмит («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин), Вәли («Яшь гомер», Г.Коләхмәтов), Тахмасхан («Надиршаһ», Н.Нариманов), Бобчинский («Ревизор», Н.В.Гоголь), Муров («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Алексей («Ванюшин балалары», С.А.Найдёнов). 4) **Зәйнәп Галиәкбәр кызы *Камалова*** (1899, Казан — 1977, шунда ук), драма актрисасы, ТАССРның атказ. артисты (1957). Галиәсгар, Габдулла һәм Габдрахман К.ларның сеңеле. Сәхнә эшчәнлеген 1917 дә «Сәйяр» труппасында башлый. 1920 дә Урта Азиягә китә, Ташкент, Сәмәрканд үзбәк театрларында, аннан соң Әстерхан татар театрында чыгышлар ясый. 1940 та Буа шәһәрендә эшләүче Республика күчмә театрына урнаша. Ныклы характерлы, үзенчәлекле актриса, нигездә, гадәти көнкүрештә өлкән яшьтәге кешеләр рольләрен башкара. Ул иҗат иткән образлар — Мәрбуга («Тормыш җыры», М.Әмир), Җиһан («Башмагым», Т.Гыйззәт), Гыйльминиса, Яучы («Күңел дәфтәре», «Яшел эшләпә», Г.Насрый), Ана («Тормыш юлында», Р.Ишморатова). 5) **Фатыйма Хәйрулла кызы** *Камалова*, драма актрисасы. Габдулла К. хатыны. 6) **Әнәс Галиәсгар улы *Камал***, драматург. Галиәсгар К.ның улы. 7) **Гәүһәр Габдулла кызы *Камалова***, драма актрисасы. Габдулла һәм Фатыйма К.лар кызы.

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им. Г.Камала: Биографик белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986.

*Д.Ә.Гыймранова, И.И.Илялова.*

**КАМА́ЛОВ** Абрик Закир улы (12.1.1943, БАССРның Кыйгы р-ны Түбән Кыйгы а.), механика өлкәсе галиме, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2009), физика-матем. фән. канд. (1971). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), СССР ФАның Казан ф-лы Физика-техника ин-тында эшли. 1975 елдан Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, теоретик механика каф. мөдире (1977–78), проф. (1997 дән). Хезмәтләре конструкцияләрдәге юка стеналы элементларның ныклыгы, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләре мәсьәләләренә карый. Теоретик механика буенча укыту-методик әдәбиятның тулы комплексын татар телендә эшли. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасы мәгариф системасында татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә ашыруның фәнни, укыту-методик һәм мәгълүмати-программ тәэмин ителеше» дигән хезмәте өчен бирелә. «Фән һәм тел» ж-лы редакциясе мөхәррире (1997–2010).

Х е з м.: Теоретик механика. К., 1996; Свободные и параметрические колебания цилиндрической оболочки бесконечной длины в акустической среде // Авиац. техника. 1966. № 4 (автордаш); Обтекание упругой оболочки вращения // Исследования по теории пластин и оболочек. К., 1973. Вып. 10.

**КАМА́ЛОВ** Барлас Хәмит улы (17.1.1930, Чистай ш. — 5.2.2004, Казан), язучы, ТАССРның, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1980, 1992). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1953). 1959–62 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында җаваплы мөхәррир, 1962–64 тә «Социалистик Татарстан» г-тасы һәм «Чаян» ж-лында бүлек мөдире, әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара. 1964–66 да ТАССР МС каршындагы Радио һәм телевидение дәүләт ком-тында эшли. «Гомер иткәндә» исемле беренче хикәяләр җыентыгы 1959 да басыла. К.ның «Сыналыр чак» (1965), «Күршеләр» (1970), «Күңел кыңгыраулары» (1971; русчага тәрҗемәсе «Колокольчики души», 1976), «Йөрәк давыллары» (1980), «Ярсөяр әрәмәсе» (1983) исемле повесть һәм хикәяләр җыентыклары гомумкешелек кыйммәтләренә, тарихка мөрәҗәгать итүе, публицистик язу стиле белән аерылып тора. «Өметең өзелмәсен» (1986), «Җир күчәре» (1990) романнары авыл кешеләренең авыр хезмәтенә һәм яшь буынны тәрбияләү проблемаларына багышланган. «Мирхәйдәр Фәйзи» (1987) повестенда күренекле татар драматургының тормышы һәм иҗат юлы бәян ителә.

Ә с ә р.: Язмыш сәхифәләре. К., 1990.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КАМА́ЛОВ** Владимир Гали улы (2.8.1951, Комсомольск-на-Амуре ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). 1974 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук «Союзхимпромпроект» ин-тында эшли: бүлек башлыгы (1990 нан), техник директор урынбасары (2001 дән), техник директоры (2005 тән). Хезмәтләре махсус продуктлар технологиясенә карый. Дәүләт бүләге Казан дары з-дында көндәшлеккә сәләтле продукция эшләп чыгаруның диверсификацион технологияләрен булдырганы өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КАМА́ЛОВ** Глеб Хафиз улы (7.5.1929, Казан — 14.12.2009. Казан), вет. вирусологы, вет. фән. д-ры (1982), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). 1954 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1954–59 да Пенза өлкәсе районара вет. лаб-ясенең өлкән вет. табибе, директоры, 1959–62 дә Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү эксперименталь ин-тында (Мәскәү), 1962–65 тә Бөтенсоюз тилчә авырулары фәнни-тикшеренү ин-тында (Владимир ш.). 1965 тән Казан вет. ин-тының биопрепаратлар эксперименталь технологиясе лаб-ясе мөдире, 1984 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре терлекләрне иммунлаштыру өчен вируслы һәм бактерияле препаратлар җитештерү техно-

логиясенә, эксперименталь инфекцияләр вакытында терлекләргә гормональ тәэсирләрнең йогынтысы мәсьәләләренә карый. Дуңгызларда Ауески авыруына каршы БУК-628 штаммыннан чыгарылган коры вакцинаны һәм мөгезле эре терлекләрдә некробактериозга каршы формалин эмульсиясе вакцинасын гамәлгә кертә. СССР МСның Дәүләт бүләге лауреаты (1977).

Х е з м.: Изучение вирусовакцин из штамма БУК против болезни Ауески для жвачных и плотоядных животных // Материалы конф. молодых учёных, посвящённой XXIV съезду КПСС. К., 1971 (автордаш); Изменения в организме свиней при иммунизации их вакцинами против болезни Ауески // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1977. Т. 126 (автордаш).

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993.


**КАМА́ЛОВ** (Камалетдинов) Җамалетдин Сираҗетдин улы (1883, Уфа губ., Шадрин өязе Түбән а. — 1937, Чиләбе ш.), җәмәгать һәм пед. эшлеклесе. Шадрин шәһәр уч-щесен тәмамлый (1904). Чиләбе пед. ин-тында укый (1937). Төркиядә белем ала. 1917 елга кадәр — Шадрин өязе земство идарәсе секретаре. Гражданнар сугышы елларында Идел-Урал Штатын төзү идеясен яклый. 1920 еллар башында Түбән авылында беренче татар-башкорт башлангыч мәктәбен ача. 1932 гә кадәр — Урал өлкәсе мөселман мәктәпләре инспекторы. 1932 дә Түбән авылында Усть-Багряк башлангыч-урта мәктәбен ача, аның беренче директоры була. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

*А.Ә.Борһанов.*

**КАМА́ЛОВ** Җәүдәт Габдрахман улы (5.9.1940, Чистай р-ны Әҗи а.), офтальмолог, мед. фән. канд. (1983), ТРның атказ. табибе (2000). 1971 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук офтальмология кафедрасында эшли, 1990 нан каф. мөдире (бүленеп, 1972–73 тә Чистай р-н хастаханәсе офтальмологы). Хезмәтләре офтальмология өлкәсенә, авыруларны хирургик реабилитацияләү, мөгез катламын катламлы кератопластика өчен консервацияләүгә карый. К. офтальмологиядә беренче тапкыр иммунокомпонент күзәнәкләрнең махсус реакциясен өйрәнүдә «тире тәрәзә» ысулын файдалана. Бу хезмәт вируслы һәм үлекле бактериаль йогышлы авыруларны дәвалау максатында, ш.у. авыруларны хирургик реабилитацияләүдә катламлы һәм үтәли кератопластика куллануда нигез була. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Послойная и периферическая пересадка обезвоженной роговицы при рецидивирующих и обширных первичных птеригиумах // Офтальмол. журн. 1975. № 3; Способ получения чистых нейтрофилов человека // Лабораторное дело. 1980. № 2; Модификация антиглаукоматозных операций выкраиванием конъюктивального лоскута от лимба // Микрохирургия глаза. СПб., 1991 (автордаш); Медицинская и профессиональная реабилитация больных с травматическими катарактами // Офтальмол. журн. 1992. № 4 (автордаш).

**КАМА́ЛОВ** Зыя Камал улы (23.8.1920, ТАССРның Тәтеш кантоны Багыш а. – 13.2.2006, Казан), Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Каршылык хәрәкәтендә (Франция) катнашучы. Мед. уч-щесен тәмамлый (Иске Константиновка ш., Украина ССР). 1940 елда Кызыл Армиягә чакырылганчы Багыш-та колхоз бригадиры булып эшли, фельдшерлык курсларын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша (хәрби фельдшер). 66 нчы артиллерия полкы составында сугыша. 1942 дә әсирлеккә эләгә, Украина, Польша терр-яләрендәге фашист концлагерьларында була. 1943 нең ахырында Франциягә күчерелә. 1944 тә әсирлектән кача һәм Каршылык хәрәкәтенә кушыла. Лимож һәм Сен-Жюньен шәһәрләре (Югары Вьенна департаменты) р-нында сугыша, француз армиясе капитаны дәрәҗәсе ала. Батырлыгы һәм сугышчан хезмәтләре өчен Франция орденнары һәм медальләре («Маки» партизаннар ордены, Корал кардәшлеге байрагы ордены, Добровольский ордены, 1939–40 елларның Сугышчан хач, Лимож шәһәре оборонасы өчен медаль һ.б.) б-н бүләкләнә. Франциядә сугыш хәрәкәтләре тәмамланганнан соң, Сов. Армиясендә хезмәт итә (1945–47). 1948 дә репрессияләнә (1955 кә кадәр Колымадагы концлагерьда була); 1992 дә аклана. 1955 тән Казанда. 1955–60 та тимер юл хастаханәсендә фельдшер, 1960–92 дә Казан ГИДУВында рентгенотехник. 1997 дән Франция Каршылык хәрәкәте ветераннарының Төбәкара хәйрия «Комбатан волонтёр» ассоциациясенең Идел буе–Урал секциясе рәисе. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



З.К. Камалов.

**КАМА́ЛОВ** Илдар Исхак улы (25.4.1939, Казан), нурлар б-н диагноз кую белгече, хирург, мед. фән. д-ры (1984), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1962), ТАССР мед. учреждениеләрендә эшли, 1969 елдан Казан ГИДУВында, ин-тның гыйльми сәркәтибе. 1971 дән Казанда Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1985 тән Целиноград, Башкорт мед. ин-тларында рентгенология, сөяк патологиясе һәм радиацион мед. кафедралары мөдире. 1994 тән Казан мед. ин-тының нурлар б-н диагноз кую һәм нурлар б-н дәвалау каф. мөдире, бер үк вакытта, 1990 нан стоматология ф-ты деканы. 1990–93 тә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика мед. диагноз кую үзәге җитәкчесе. Хезмәтләре нейрорадиологиягә карый: баш сөяге, баш мие, умырткалык, арка миенең тумыштан яки барлыкка килгән патологиясе; баш сөягенең һәм баш миенең механик зарарлануы. К. баш сөяге чатнауларының төзәтү закончалыкларын, баш сөяге-ми җәрәхәтенең морфологик чагылыш билгеләрен ачыклый, бу, үз чиратында, җәрәхәтнең дәрәҗәсен ачыкларга һәм дәвалауны фаразларга мөмкинлек бирә; сөяк патологиясе вакытында депосинометрия технологиясен эшли; ТРда беренче тапкыр баш мие тамырларының контрастлы булмаган магнит-резонанс ангиографиясен гамәлгә кертә. Уйлап табуга 31 авторлык таныклыгы бар, монография авторы.

Х е з м.: Рентгенодиагностика закрытой позвоночно-спинальной травмы и её последствия. К., 1992; Рентгенологическая характеристика отдалённого периода травматических повреждений черепа и головного мозга. К., 1999.

**КАМА́ЛОВ** Кәрим Шәйсолтан улы (20.7.1950, Пермь ш.), генерал-майор (1994). Ракета гаскәрләренең Сов. Союзы Маршалы В.И.Чуйков исем. Пермь югары хәрби команда-инженерлык уч-щесен (1973), Ф.Э.Дзержинский исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1981) тәмамлый. 1973 елдан Урал, Урта Азия, Карпат буе хәрби округы ракета гаскәрләрендә. 1986 дан Белоруссия хәрби округында полк командиры, 1989 дан Мәскәү хәрби округы берләшмәсенең штаб башлыгы. 1993–98 дә Себер хәрби округы стратегик бурыч башкаручы ракета гаскәрләре берләшмәсе командиры. 1998 дән Новосибирск өлкәсенең гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр идарәсендә. Кызыл Байрак, «Хәрби казанышлары өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КАМА́ЛОВ** (Габделваһапов) Мөхәммәтзакир (1804, Казан губ., Малмыж өязе Сасна а. — 28.5.1893, Чистай ш.), дин эшлеклесе, Мәчкәрә мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1846 елда Чистай мәчете имам-хатибы. Дини эшчәнлек б-н бергә сәүдә, хәйриячелек б-н дә шөгыльләнә: 1847 дә Чистайда аның акчасына җәдиди ысуллы «Камалия» мәдрәсәсе төзелә, К. бирәдә мөдәррислек итә (1847 дән). *Нәкышбәндийә* суфичылык борадәрлеге вәкилләренең берсе (Закир ишан буларак та мәгълүм).

*Р.Г.Әмирханов.*

**КАМА́ЛОВ** Рашат Җиһангир улы (2.6.1946, Казан), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1969), ТРның атказ. юристы (1999). «Динамо» физкультура спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Тренерлары — А.Д.Кузьминых (1959–61), Г.М.Кондратьев (1961). Казан ун-тының биология ф-тын тәмамлый (1971). СССР (1963, яшүсмерләр арасында), 1969 (команда), «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы беренчелегендә (1965) чемпион, «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы кубогы иясе (1967), К.Петров истәлегенә багышланган Европа турнирында — алтын медаль (1969), профсоюзларның Бөтенсоюз үзәк советы беренчелегендә бронза медаль (1968) ала. 1973 тән РФ Эчке эшләр министрлыгы Юридик ин-тының Казан ф-лында укытучы, 1999 дан Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында җинаять эше процессы һәм хокук каф. профессоры (Казан).

**КАМА́ЛОВ** Фәйзрахман Гафур улы (20.4.1960, Башкортстан АССРның Чакмагыш р-ны Нариман а.), дизайнер, нәкышьче, график, кинематографист. С.-Петербургтагы В.Мухина исем. Югары сәнгать-сәнәгать уч-щесенең дизайн бүлеген тәмамлый (1993), Уфа авиация-техник ун-тының фәнни-техник үзәгендә баш дизайнер булып эшли.



Х.Ә. Камалов.



Х.Н. Камалов.

1997 елдан — С.-Петербургта, станлы нәкышь өлкәсендә актив иҗат б-н шөгыльләнә, академик мәктәп традицияләренең дизайн б-н иҗади принциплары синтезы нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңа юнәлеш — «саф реализм б-н абстракционизмны бәйләп торучы үзенчәлекле күпер» (К. манифестыннан) — «трансформация сәнгате» идеясен алга сөрә. «Мистика», «Фәрештә», «Мистерия», «Супрематик төшләр» (барысы да — 1997), «Уяну» (2001), «Су анасы» (2002), «Вәсвәсә» (2004), «Барадж» (2005) һ.б. картиналарында ритмлы абстракт формаларның сынлы сурәтләр б-н тәңгәллеге, экспрессив төсләр тулылыгы кискен хәрәкәтле фәза, бер образдан икенчесенә күчү иллюзиясе тудыралар. Нәкышь тәҗрибәләрен К. «Диологлар» халыкара күргәзмәсенә тәкъдим итә (С.-Петербург, 1997). Бер үк вакытта реалистик алымда эшләнгән татар мәдәнияте эшлеклеләренең портретлар сериясе авторы: С.Садыйкова (2006); Г.Айдарский, Р.Яхин (икесе дә 2010), Г.Рәхим (2011) һ.б. К.ның графикасы китап бизәлешендә һәм илл. («Штучки-дрючки», «Артель» шәхси нәшрияты, С.-Петербург, 2000), станлы рәсемнәрдә (карандаш, тушь) — «Тормыш сызыгы» сериясендә (2011) һ.б. чагыла.

2004 елдан С.-Петербургта төшерелгән док. фильмнарда куючы-оператор һәм рәссам: адмирал С.О.Макаровның һәлак булуына 100 ел тулуга багышланган «Бака яфрагы» («Подорожник»), 2004; «Кешегә хат» («Послание к человеку») 14 нче халыкара кинофестивальнең дипломына лаек була (С.-Петербург, 2005), «Әнвәр Либабов. Кеше, актёр, клоун» (2004, реж. В.А.Наумов), Казанның 1000 еллыгына багышланган «Бөек кала тормышыннан 1000 мизгел» (2005) һ.б.

2007 елдан — Казанда, «Faiz» шәхси киностудиясенә нигез сала (улы И.Камалов б-н бергә) «Биләр, диләр...», «Кырык кыз риваяте», «Безнең Рональдинолар» (барысы да — 2007) фильмнары авторы, «Татарстан — Яңа гасыр» телестудиясе өчен «Яралы язмышлар» (реж. И.Сираҗиев) док. фильмнар сериясенең куючы-операторы һәм рәссамы (барысы — 7 фильм, арада — «Ф.Яруллин», «Х.Туфан», «С.Садыйкова», «Ф.Әхмәдиев» һ.б., 2009).

Аудио-дисклар («Казанның 1000 еллыгына багышлана», 2005; «С.Садыйкованың 146 җыры», 2006; «С.Садыйкованың 100 еллыгына фильм-концерт», 2005; «Ил кызы», 2009), видеоклиплар (10 нан артык клип дөнья күргән) чыгаруда дизайнер сыйфатында уңышлы катнаша. Башлыча С.-Петербургта яшәүче татар рәссамнарыннан торган, хезмәтләре бер үк исемдәге виртуаль галереяда (1999 дан) һәм С.-Петербургтагы төркемле күргәзмәләрдә күрсәтелгән «АртЭль» иҗат төркеменә нигез сала (төркемдәге 12 рәссам арасында — Ф.Әминов, М.Гафиятуллин, Н.*Кугушев*, Р.Тимергалиев һ.б.). «Җисем» Халыкара балалар һәм яшьләр кинофестивале проектының авторы (Казан, 2008–09).

1985 елдан С.-Петербургтагы шәһәр күргәзмәсендә, Экспоүзәктәге (1994, Мәскәү), «Диалоглар» (1997, С.-Петербург) халыкара күргәзмәләрендә, Тампереда (Финляндия), Париждагы Мадам Пежо салонында (2008) узган күргәзмәләрдә һ.б. катнаша.

*Әд.:* Шакирова Л. Полёт Бараджа во сне и на яву // Петербург национальный: Ежегодник. 2007.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАМА́ЛОВ** Хәмит Әскәр улы (9.11.1958, Кыргызстан ССР Кок-Янгак ш.), генерал-полковник (1995), РФнең атказ. төзүчесе (1993). Ленин комсомолы исем. Вольск югары хәрби тыл уч-щесен (1980), Хәрби тыл һәм транспорт академиясен (Ленинград, 1991), РФ Кораллы Көчләре Генштабы Хәрби академиясен (Мәскәү, 2001) тәмамлый. 1980 елдан батальон, полкның хезмәт башкару башлыгы. 1986 дан Вольск югары хәрби тыл уч-щесендә: хәрби хезмәт башкару башлыгы, тыл башлыгы урынбасары, башлыгы. 1992 дән РФ тимер юл гаскәрләре тыл башлыгы урынбасары, 1 нче урынбасары. 1994 тән тыл башлыгы — РФ тимер юл гаскәрләре башлыгы урынбасары. РФ Дәүләт Думасы депутаты (2007 дән). «Хәрби казанышлары өчен», «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КАМА́ЛОВ** Хисам Нуретдин улы (14.4.1926, Әлмәт р-ны Кама-Исмәгыйль а.), язучы, ТРның халык язучысы (2001). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли. Әдәбиятка шагыйрь буларак килә. «Яңадан сафта» дигән беренче шигъри җыентыгы 1955 елда басыла. «Чияле тау» (1956; рус. тәрҗемәсе «Вишнёвая гора», М., 1963), «Язмыш» (1967), «Тормыш дулкыннары» (1968), «Каен суы» (1972), «Күңел» (1976) җыентыкларына тупланган шигырь һәм поэмалары гражданлык хисе, оптимизм белән сугарылган. К. поэзиясенең төп темалары — Бөек Ватан сугышы, ул китергән кайгы-хәсрәт, илдә барган социаль-икътисади үзгәрешләр, өмет, бәхет, мәхәббәт турында фәлсәфи уйланулар. 1970 еллардан К., нигездә, проза өлкәсендә эшли. «Һәркемнең гомере бер генә» (1975; рус. тәрҗемәсе «У каждого жизнь — одна», 1983), «Безне өйдә көтәләр» (1985; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1986), «Үлгәннән соң яздым» (1989), «Түләнмәгән күз яше» (1995) романнарында, ш. у. «Бердәнбер ул» (1982) җыентыгындагы повесть һәм хикәяләрендә әдип сугыш чоры вакыйгаларын яктырта, фронт һәм тыл тормышын чынбарлыктагыча тасвирлый, совет кешеләренең батырлыгын, фидакарьлеген, намуслылыгын гәүдәләндерә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 2004.

*Әд.:* Фәйзи Ә. Әдипнең эрудициясе. К., 1973; Маннапов С. Тормыш үзәненнән // Казан утлары. 1980. № 3; Вәлиев М. Утны күчер! // Гамәл дәфтәре. К., 2003.

**КАМА́ЛОВА** Гәүһәр Габдулла кызы (29.9.1922, Ташкент — 6.4.1990, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык (1976), РСФСРның атказ. (1983) артисты. Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате ин-ты (ГИТИС) каршындагы Татар театр студиясен тәмамлый (1949). 1949–50 елларда Казан Яшь тамашачылар театрының (ТЮЗ) татар төркеме актрисасы, 1950 дән Татар акад. театрында. Студент елларында уйнаган беренче рольләреннән үк (Васса Железнова, М.Горькийның шул исем. пьесасы; Кунакай — «Козы көрпеш һәм Баянсылу», Г.Мөсрәпов) үзен көчле драматик темпераментка ия актриса буларак таныта. К.ның Татар акад. театры сәхнәсендә тудырган образлары характерның асылына төшеп бөтен тирәнлеге б-н ачылуы, социаль характеристиканың төгәллеге, форма ныклыгы, ачыклыгы ягыннан аерылып тора: Соколова, Софья, Полина («Соңгылар», «Дошманнар», М.Горький), Галиябану (М.Фәйзинең шул исем. пьесасы), Гайнавал, Ханзафа («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Мәргидә («Хөррият», М.Әмир), Камилә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Зөләйха («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Гашия («Ир-егетләр», Т.Миңнуллин), Тулганай («Анам кыры» телевизион спектакле, Ч.Айтматов повесте буенча) һ.б. Сурәтләүдә әһәмиятлелек һәм масштаблылыкка ирешеп, актриса тыйнак, әмма ышандырырлык төгәл чаралар ярдәмендә көчле характерлы хатын-кыз образларын иҗат итә: Хәят («Мәхәббәтең чын булса», Х.Вахит), Диаконисса («Сукыр», Э.Альт). К.ның комедиячел таланты Шәмсия, Бибигайшә («Күк капусы ачылса», «Ике





Г.Г. Камалова: 1. Эмилия («Отелло», У. Шекспир); 2. Рауза («Монда тудык, монда үстек», Т. Миңнуллин) рольләрендә.

килен-килендәш», Х.Вахит), Фәүзия («Әнә килә автомобиль», Ф.Яруллин), Гөлбану («Назлы кияү», К.Тинчурин), Әйшә, Гөлбану («Зифа», «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Камилә («Кыз урлау», М.Кәрим) рольләрендә ачыла. Әлеге образларга теге яки бу күренешләрне гротеск дәрәҗәсенә җиткереп сурәтләү, тормыш дөреслеге хас.



Г.Г.Камалова.

*Әд.:* Иллялова И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им.Г.Камала: Биографик белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; Иллялова И. Театр имени Камала. К., 1986.

*Д.Г.Гыймранова.*

**КАМА́ЛОВА** (чын фамилиясе Хәлиуллина) Фатыйма Хәйрулла кызы (12.12.1903, Оренбург ш. — 9.1.1974, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык (1954), РСФСРның атказ. артисты (1957). Сәхнә эшчәнлеген 1918 елда Оренбургта татар-башкорт яшьләр секциясенең драма коллективында башлап җибәрә, 1919–22 дә Оренбург Шәрекъ театры актрисасы. 1922–23 тә — Казанда Татар дәүләт театрында (хәзер Татар акад. театры), 1923–25 тә — Әстерхан татар, 1925–27 дә — Ташкентта үзбәк муз.-драма, 1933–36 да — Оренбург татар драма, 1927–28 һәм 1939–63 тә Татар акад. театрларында. Көчле комедия актрисасы; аның башкаруына тормышчанлык, персонажларына дөреслек һәм ышандыру көче, образ иҗат иткәндә үзенчәлекле һәм мәгънәле детальләр сайлый белү хас. Милли характерны гәүдәләндерүче шактый гына тирән эчтәлекле рольләр башкара. Рольгә керүнең виртуоз техникасы, искиткеч сөйләү осталыгы, алымнар байлыгы һәм төрлелеге актрисаның һәр чыгышын уңышлы театраль күренешкә әверелдерә. Ул башкарган рольләр — Биби, Гөлҗиһан («Бәхетсез егет», «Банкрот», Г.Камал), Мәрфуга («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Гайнавал, Ханзафа, Сәхибә («Ташкыннар», «Изге әманәт», Т.Гыйззәт), Маймүнә, Сәлимә («Миңлекамал», «Тормыш җыры», М.Әмир), Әйшә («Зифа», Н.Исәнбәт), Ниса («Югалган матурлык», Һ.Такташ), Җиһан («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Кабаниха, Пелагея Егоровна («Яшенле яңгыр», «Ярлылык гаеп түгел», А.Н.Островский), фрау Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Харитонова («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв).



Ф.Х.Камалова Елизавета («Сүнмәс ялкын», Б.Н.Полевой әсәре буенча) ролендә.

*Әд.:* Иллялова И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им.Г.Камала: Биографик белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; Иллялова И. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Иллялова.*

**КАМА́ЛОВЛАРНЫҢ ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́.** Чистай шәһәре җамигъ мәчетенең имам-мөдәррисләре Закир Камалов (1818–93) һәм аның улы Ибраһимның (1876–1930) шәхси китапханәсе. Китапханәдә татар, төрек, фарсы, гарәп телләрендәге кульязмалар һәм басма китаплар, мөселман хокукы буенча хезмәтләр, хәдисләр, *тәфсирләр* һ.б. дини әдәбият, ш.у. гарәп теле грамматикалары, сүзлекләр, тарих, геогр., мед., матем., логика дәреслекләре һ.б. тупланган. 17–19 йөзләргә караган кульязма китаплар арасында 17 йөз татар хаттатлары башкарган Коръән күчермәләре, Мөхәммәд Садыйкның мөселман хокукы буенча әсәрләр күчермәсе (1742), үзбәк шагыйре Мәшрәбнең шигырьләр җыентыгы, «Кавагыйде-вә гыйлем әт тәгъриф» гарәп теле грамматикасы һ.б. бар. Китапларга Закир һәм Ибраһим Камаловларның шәхси мөһерләре сугылган. Аларның вафатыннан соң китапханәнең бер өлеше Чистай шәһәре җамигъ мәчетендә саклanып кала; кайбер китаплар 1968 һәм 1985 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тының Чистай р-нына оештырылган археографик экспедицияләре вакытында М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан табыла һәм институт каршындагы борынгы кульязмалар мирасханәсенә тапшырыла.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**КАМАЛТЫ́НОВ** Юрий Земельевич (11.3.1957, Казан), дәүләт эшлеклесе, ТРның атказ. халыкны социаль яклау хезмәткәре (2001). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) (1980), Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. академиясе) (1994) тәмамлый. 1980–86 елларда Казан «Органик синтез» ҖБдә: смена башлыгы (1981 гә кадәр), ВЛКСМ (1981–84), КПСС (1984 тән) ком-ты секретаре урынбасары. 1986–90 да Казанда КПССның Мәскәү райкомында бүлек мөдире. 1990–92 дә Татарстан укытучылар белемен камилләштерү ин-тының социол. тикшеренүләр лаб-ясе башлыгы. 1992–94 тә Казанның Мәскәү р-ны хакимияте башлыгы урынбасары. 1994–95 тә ТР социаль тәэминат министры урынбасары. 1995–96 да ТР Дәүләт Советы аппаратының бүлек башлыгы. 1996–2004 тә ТР социаль яклау министрының 1 нче урынбасары. 2004–05 тә ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары. 2005 тән ТР Президенты аппараты җитәкчесе. 2004–05 тә ТР халык депутаты. Медаль б-н бүләкләнә.

**КАМА́ЧКОВ** Хәсән Йосыф улы (? — 1919), революцион хәрәкәттә катнашучы. 1905–07 еллардагы рев-ция вакытында Әстерхан шәһәрендә татар с.-д. төркемен оештыра. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Әстерхан бистәләрендә аның тырышлыгы б-н эшче мөселманнар ком-ты оештырыла. 1917–18 дә Вакытлы мөселман хәрби-революцион ком-т рәисе урынбасары. 1918–19 да Әстерхан крае мөселман комис-тында хезмәт комиссары. Гражданнар сугышында катнаша, Царицын (хәзерге Волгоград) шәһәре оборонасы вакытында һәлак була.



Ф.Х.Камалова.



Ю.З.Камалтынов.

*Р.Г.Хәйретдинов.*

**КАМБА́РКА РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 611 *км*². Үзәге — Камбарка шәһәре (Ижевскидан 116 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 20,4 мең кеше (2010), 1789 татар (2007). Татарлар, нигездә, Кама (900 гә якын кеше), Шолья (636) посёлокларында, район үзәгендә (300) яшиләр. 1991 дән К.р.нда Удмурт Респ-касы Татар иҗтимагый үзәге бүлекчәсе эшли. Кама посёлогы мәдәният йорты каршында — «Җидегән чишмә» ансамбле, китапханә каршында Татар мәдәни үзәге оештырыла. Кама (1991 дән) һәм Шолья (2001 дән) посёлокларында мәчет эшли; мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә татар телен өйрәнү төркемнәре бар. 1990 еллар башыннан К.р.нда Сабан туе, Җыен, Нәүрүз бәйрәмнәре үткәрелә.

**КА́МБЕК** (Cambecg) Логин Фёдорович (6.1.1796, Германия, Дрезден ш. — 30.5.1859, Лифляндия губ., Дерпт ш.), хокук белгече, юридик фәннәр д-ры (1852), статский советник (1847). Кёнигсберг ун-тын тәмамлый (1820). 1824–27 елларда Перновск магистраты секретаре (Лифляндия губ.), 1827–31 дә Дерпт магистраты әгъзасы, 1931–36 да синдигы (чиновник). 1836–37 дә Түбән Новгород гимназиясе инспекторы. 1837–53 тә Казан ун-ты хокук белеме адъюнкты, 1853–55 тә Рим хокукы каф. экстраординар профессоры; бер үк вакытта, 1838–52 дә Казандагы беренче ир балалар гимназиясе укытучысы. Хезмәтләре Рим хокукын, Россиядә мәхкәмә эшләрен башкаруны өйрәнүгә карый.

Хезм.: Каким образом римское право сделалось в важнейших европейских государствах господствующим и вспомогательным правом. К., 1838; Конспект преподавания пандексов. К., 1838; Опыт начертания гражданского судопроизводства по российским законам. К., 1848.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**«КАМГЭСЭНЕРГОСТРО́Й»**, Татарстандагы иң эре төзелеш оешмасы. Төп куәтләре Чаллы шәһәрендә урнашкан. Эшләүчеләр саны: 2,7 мең (1964), 54 мең (1979), 4,6 мең (2010) кеше. 1964 елда Кама елгасы бассейнында энергетика һәм сәнәгать объектларын төзү өчен «Воткинскэнергострой» һәм

«Татэнергострой» трестларының дүрт төзелеш-монтаж идарәсе җирлегендә «К.» төзелеш идарәсе буларак оештырыла. 1973 тән ҖБ, 1990 нан дәүләт концерны, 1994 тән АҖ. 1990 елларның 2 нче яртысында, составындагы төзелеш идарәләре бүлендек акц. җәмгыятьләренә әверелеп, пр-тие күп профильле төзелеш-инвестиция холдинг компаниясе итеп үзгәртелә.

«К.» тарафыннан Татарстанда гомуми куәте 6180 *мВт* тәшкил иткән эл. станцияләре, ш.и. *Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГЭСы,* Казанда, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә җылылык-эл. үзәкләре төзелә. «К.» шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогында, Агыйдел посёлогында (Башкортстан Респ-касы), Курск шәһәрендә атом эл. станцияләрен, Уфа, Самара, Тверь, Экибастуз (Казакъстан) шәһәрләрендә энергетика объектларын, Кояш энергиясен файдалану буенча Кырым экспериментал ь станциясен төзүдә һәм реконструкцияләүдә катнаша. 1969 дан пр-тие — КамАЗ төзелешенең ген. подрядчигы. «К.»ның инженерлык хезмәте тарафыннан прогрессив технол. процессларның проектлары эшләнә һәм гамәлгә кертелә: СССРда беренче тапкыр нигез салуда субай сугу-бораулау корылмасы кулланыла; биналарны тулы әзерлектәге күләмле блоклардан җыю һәм монтажлауның конвейерлы ысулы (төп фермаларны монтажлап, әзер түбә, пыяла кую, технол. торба үткәргечләр салып һәм югары көчәнешкә исәпләнгән кабельләр б-н), бетон идәннәрне җәюдә һәм җиһазлар урнаштыруда өзлексез алым куллану оештырыла. Нәтиҗәдә җир эшләренең күләме, объектларны тапшыру вакыты, хезмәт чыгымнары ике тапкырга кими, җитештерүчәнлек арта. Заводның 1 нче һәм 2 нче чиратлары төзелеше өчен пр-тие Ленин ордены б-н бүләкләнә (1980). Бер үк вакытта «К.» 500 мең кешегә исәпләнгән Чаллы шәһәрен комплексы төзү б-н шөгыльләнә. «К.» тарафыннан ш.у. «Татэлектромаш» ҖБ, «АлАЗ», Чаллы картон-кәгазь комб-ты, Чистай сәгать, Зәй шикәр з-дларының, Казан «Заря» кондитер ф-касының яңа корпуслары, компрессорлы газ кудыру станцияләре комплексы (Чуаш Респ-касының Можга пос.), Мәскәүдә — 1980 елгы Олимпиада объектлары һәм АПН («Яңалыклар» матбугат агентлыгы) биналары комплексы, Мәскәү өлкәсенең шәһәр тибындагы Голицино посёлогында автобуслар з-ды, «Ижминводы» шифаханәсе (Менделеев р-ны) һ.б. төзелә. Чаллы шәһәр яны зонасында агросәнәгать комплексы пр-тиеләре корыла. ТРда һәм РФнең башка төбәкләрендә 10 млн. $м^2$ дан артык мәйданда торак, 110 мәктәп, 210 балалар бакчасы, 40 хастаханә һәм поликлиника, 30 кинотеатр, 200 кибет, 100 көнкүреш хезмәте күрсәтү объекты төзелә. 1988 дә «К.» Әрмәнстанда җир тетрәү нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша, Ленинакан шәһәрендә посёлок төзи. «КамАЗ» АҖнең двигательләр з-дында 1993 тә булган янгыннан соң 420 мең $м^2$ мәйданда биналарны торгызу эшләрен башкара.

«К.» РФнең төрле төбәкләрендә (ТРдан читтә 50% тан артык), ш.и. аерым геол., климатик, сейсмик шартларда, экологик һәлакәтләргә дучар булган зоналарда төзү-монтаж инженерлык хезмәте күрсәтә, ремонт, консервация һәм торгызу эшләре башкара. Пр-тиенең төзелеш материаллары җитештерүче үз куәтләре металл конструкцияләре, бетон, күзәнәкле бетон, эре панельле йортлар төзү, керамзитлы гравий, силикат һәм балчык кирпеч, тышлыкта кулланылучы ташларны кисү, авторемонт з-длары; агач эшкәртү комб-ты, линолеум һәм металлургия производстволары бар. «К.» ТРда Тузган торакны бетерү дәүләт программасында катнаша. «К.» төзегән объектлар арасында «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-длары комплексы, «Алабуга» аерым икътисади зонасындагы җитештерү мәйданнары, Универсиада-2013 спорт корылмалары, Казандагы торак йортлар, Удмурт Респ-касындагы сәнәгать объектлары һ.б. бар.

Пр-тие җитәкчеләре: А.В.Эгенбург (1964–71), Е.Н.*Батенчук* (1971–72, 1979–89), Н.М.*Иванцов* (1972–75), В.А.Фоменко (1975–79), В.Н.*Ельцов* (1989–2003), А.С.Евдокимов (2003 тән).

**КА́МЕНЕВ** Гаврила Петрович (3.2.1772, Казан — 1803, шунда ук), язучы. Рус романтизмының башлангыч чоры вәкилләреннән берсе. Казандагы бай сәүдәгәрләр нәселе варисы. 1800 елдан Мәскәү язучылары даирәсенә керә, 1802 дә Петербургтагы Тел, фәннәр һәм сәнгать сөючеләр иреккле җәмгыятенә алына. Казан һәм аның тирәсе б-н *«Громвал»* (Зилант-елан турында легенда) балладасы мотивлары, «Төш» («Сон») элегиясе (Кизик монастыре, Хижица телгә алына), «Казаннан өч чакрымда» («В трёх верстах от Казани») әсәре тыгыз бәйләнештә. Тулаем алганда К. иҗаты (элегия, баллада, юллама, сентиментал ь повестьлар) романтик характерда. Аның балладалары В.А.Жуковский иҗатына зур йогынты ясый. К. — әдәби тәрҗемәләр авторы. Аның әдәби мирасын А.С.Пушкин югары бәяли.

*Әд.:* Б о б р о в Е. Первый русский романтик Г.П.Каменев // Ист. вестн. 1903. Т. 43, № 8; Чтения, посвящённые 225-летию со дня рождения Каменева... К., 1997; В а л е е в Э. Судьбою прерванный полёт... К., 2001.

*А.Н.Пашкуров.*

**КА́МЕНЕВ** Пётр Григорьевич (28.8.1740, Казан — 12.10.1776, шунда ук), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Татар бәкләре *Макуловлар* нәселеннән. Ике таш (Черек күл һәм Воскресенская урамнарында) һәм 1 агач йорт (Болак ермагы артындагы Тихвин приходында), Болак буендагы 19 вак кибет һәм таш амбарлар хуҗасы. Россиядә һәм Германиядә тукылган ефәк һәм постау товарлар, Әстерхан балыгы һәм уылдагы б-н сәүдә итә. 1767–71 елларда Казан шәһәр магистраты бургомистры, 1773–75 тә шәһәр башлыгы. 1775 тән Казан губерна магистраты президенты. 1767 дә Казанда император Екатерина II не кабул итә (Екатерина аны шпага б-н бүләкли).

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Кн. 1; ш у л у к. Из казанской истории. К., [Е.к.].

*Л.М.Свердлова.*

**КА́МЕНЕВ Г.П.НЫҢ ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́.** Шагыйрь Г.П.*Каменевның* шәхси китапханәсе. Китапханә Казанда аның өендә сакланган. Китапларның күбесе 18 йөз басмалары: Г.Р.Державин, А.Д.Кантемир, Н.М.Карамзин, М.В.Ломоносов, В.К.Тредиаковский, М.М.Херасков, Г.П.Каменев әсәрләре басылган «Иппокрена...», «Аониды...» әдәби ж-лары; чит ил авторлары Л.Ариосто, Ф.Вольтер Ж.-Ф.Мармонтель, Д.Мильтон, Ш.Монтескьё, Т.Тассоның русчага тәрҗемә ителгән әсәрләре, драматург А.Коцебуның Г.П.Каменев тәрҗемәсендәге әсәрләре, мистик һәм масон басмалар һ.б. Китапханәдә ш.у. Н.И.Новиковның «Шәһәр һәм авыл китапханәсе» («Городская и деревенская библиотека...», 1782–86), «Балаларның күңелен һәм акылын үстерү укулары» («Детское чтение для сердца и разума», 1785–89), «Россия язучылары турында тарихи сүзлек тәҗрибәсе» («Опыт исторического словаря о российских писателях...», 1772), А.П.Сумароковның «Барлык әсәрләрнең тулы җыелмасы» («Полное собрание всех сочинений...», 1787) басмалары һ.б. булган.

1803 елда төзелгән исемлек буенча, Г.П.Каменев үлгәннән соң китапханәдә 489 том китап исәпләнә, шуларның 296 сы — рус телендә. Г.П.Каменев тупланмаларыннан өч китап — А.Д.Кантемирның «Сатиралар һәм башка шигъри әсәрләр»е («Сатиры и другие стихотворческие сочинения», 1762), Ш.Ролленьның «Мисырлыларның борынгы тарихы» («Древняя история о египтянах», 1749–62), Г.Гейнзиусның «1744 нче ел башында күренгән кометаны тасвирлау» («Описание в начале 1744 года явившейся кометы», 1744) дигән әсәре — Казан ун-тының фәнни китапханәсендә саклана. Китапларның беренче битендә «Г.Каменев» дигән язу һәм аларның тәртип номерлары бар. Чит ил китапларының исемлеге сакланмаган.

*Әд.:* З а л к и н д Г. Г.П.Каменев: Опыт имущественной характеристики первого русского романтика. К., 1926.

*И.А.Новицкая.*

**КА́МЕНКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Түбән Ямаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 8 кеше (руслар) яши. 1910 елларда нигез салына. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1920 дә — 89, 1926 да — 84, 1949 да — 243, 1958 дә — 227, 1970 тә — 131, 1979 да — 34, 1989 да — 12, 2002 дә — 12 кеше.

**КА́МЕНКА** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Дала Зәе елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 5 кеше (руслар) яши. 1910 елларда нигез салына. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Ха-

лык саны: 1912 дә — 23, 1926 да — 49, 1938 дә — 36, 1949 да — 36, 1958 дә — 35, 1970 тә — 119, 1979 да — 63, 1989 да — 28, 2002 дә — 5 кеше.

**«КА́МЕНКА»**, Казан шәһәр туберкулёз авыруын дәвалау хастаханәсе. Биектау р-нындагы нарат урманында урнашкан («Каменка» санаторие пос.). Туберкулёзга каршы көрәш санаториена 1914 елда нигез салына. Төзү өчен акчаны (50 мең сум) Бөтенроссия туберкулёзга каршы көрәш лигасының Казан бүлеге җыя (А.Н.*Казимбәк* рәислегендә). Төзелеш 1920 дә тәмамлана. Беренче дәвалануучылар Кызыл Армиядә туберкулёзның ачык формасында авыручы хәрбиләр була. Казан халкы арасында туберкулёз аеруча көчле таралган чорда (1914 тә 100 мең кешегә — 53,8, 1927 дә — 175 кеше), Казан ГИДУВының туберкулёз каф. галимнәре, «К.» хастаханәсе, «Обсерватория» балалар санаторие табибләре, Казан фтизиатрлар җәмгыяте әгъзалары Татарстанда һәм Идел буенда туберкулёзга каршы көрәш оештыралар. Республикада туберкулёзны дәвалау буенча диспансер булдырыла. 1939 елга «К.» санаторие стационарында 200 урын исәпләнә, санаторийда клиник диагноз кую лаб-ясе, рентген һәм пневмоторакс кабинетлары, физик күнегүләр б-н сәламәтләндерү, теш дәвалау кабинетлары була. Дәвалауның төп ысуллары: санаторий режимын үтәү, тулы рациональ туклану, дәвалау (сулыш алу) физкультурасы, физиотерапия (электр һәм яктылык б-н дәвалау, парафин аппликацияләре), ясалма пневмоторакс һәм пневмоперитонеум ябу, кефир һәм кымыз б-н дәвалау (В.Д.Дунаев гамәлгә кертә, 1930–40). Бөек Ватан сугышы елларында Казанда 2 махсус хастаханә (госпитальләр) эшли: «К.» базасында (1941), 237 нче з-д каршында (1943), РСФСРның атказанган табибе Н.С.Вәлиев бу хастаханәләрнең җитәкчесе итеп билгеләнә.

1966 да хастаханә карамагына «Пугачёвка» туберкулёзга каршы көрәш санаторие тапшырыла, автоматлаштырылган биол. чистарту корылмасы төзелә. 2010 да хастаханә составында 400 урынлы 4 бүлек — үпкә туберкулёзының җиңел формалары һәм рецидивлары б-н авыручылар, озакка сузылган туберкулёз авырулары, яңа ачыкланган һәм таралган авыру, деструктив үпкә туберкулёзлылар (махсус бүлек), сөяк-буын туберкулёзы, ш.у. үпкәдән тыш (лимфоденитлар, мезоденитлар, сидек-җенес системасы) авырулар бүлекләре эшли. Хастаханәдә штатта 200 дән артык кеше исәпләнә. Хастаханә коллективы һәм төбәк Кызыл Хач җәмгыяте тарафыннан 1998 дән «Ак ромашка» шәфкатьлелек акциясе үткәрү торгызыла, хастаханәгә шул кысаларда ярдәм күрсәтелә. Иң яхшы табиб-фтизиатрларга проф. А.Н.Казимбәк исемендәге ел саен тапшырыла торган премияләр, мед. ун-ты студентларына, булачак фтизиатр табибләргә исемле стипендияләр оештырыла. 1980 еллар башыннан «К.» Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе галимнәре өчен фәнни тикшеренүләр базасына әверелә. «К.»ның баш табибләре — В.Д.Дунаев, Т.М.Хәкимов, Г.Ф.Гришин, В.В.Тидген, С.С.Митракова, М.М.Фәрхетдинов, В.М.Вәлитов, Р.Ә.Җәләлиев (1996 дан).

*Әд.:* Река времени. К., 2001.

*Р.Ә.Җәләлиев.*





Казан шәһәр «Каменка» хастаханәсе.
1. Физиотерапия кабинеты;
2. Бактериология лабораториясе.

**«КА́МЕНКА»** шифаханәсе посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 2 *км* көнчыгыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2010 елда 133 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50%, татарлар — 46%) яши. Туберкулёз авыруын дәвалау шифаханәсе эшли. Посёлокка 1930 елларда нигез салына. Башта Казан авыл р-нына керә. 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 183, 1949 да — 136, 1958 дә — 281, 1970 тә — 284, 1989 да — 182, 2002 дә — 142 кеше.

**КА́МЕНКА РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* үзәк өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 2200 *км*². Үзәге — Каменка шәһәре (Пенза шәһәреннән 75 *км* көнбатыштарак). 2010 елда 21,6 мең кеше (38,9 мең кеше Каменкада) яши. 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 9223 кеше. Районда татарлар тупланып яшәгән 5 авыл бар: Кабылкин (1563 кеше), Ятмис (740), Мачали (1138), Кикин (1732), Тәлөтен (263). Татарларның күпчелеге район үзәгендә (2488) яши. Алар район терр-ясендә 18 йөздә күренә башлыйлар. Беренче күченүчеләр Керенский өязенең Мачали авылыннан (хәзер Пенза өлкәсенең Вадинск р-нына керә) чыккан кешеләр була. 1917 гә кадәр К.р.нда 3 мәчет (Кабылкин һәм Тәлөтен а.), 2 мәдрәсә була. 1918 дә Ятмиста мәктәп ачыла, анда 1946 га кадәр укыту татар телендә алып барыла. К.р.нда Каменка һәм Кикинда милли-мәдәни үзәкләр, Ятмиста «Миләшләр», Кикинда «Яшьлек», Ятмиста «Ак каен» фольклор коллективлары һәм Каменкада «Бәйрәм» халык коллективы эшли (2004). Районның берничә мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Каменкада (1999), Тәлөтен, Кобылкинда мәчетләр бар.

**КАМЕНКО́В** Георгий Владимирович (12.1.1908, Мәскәү-Казан тимер юлының Ночка ст. — 9.10.1966, Мәскәү), математика һәм механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1937), проф. (1938). 1930 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли, 1937 дән директор урынбасары, 1944 тән директоры. 1949 дан Мәскәү авиация ин-тында: директор урынбасары, 1956 дан директоры, бер үк вакытта аэродинамика каф. мөдире. Хезмәтләре аэродинамика өлкәсенә, хәрәкәтнең тотрыклылыгы һәм нәсызыкча тирбәнешләр теориясенә карый. К. Ка́рманның өермәле чылбырлары хәрәкәтенең тотрыклылыгына теоретик тикшеренүләр үткәрә, чиктән тыш хәвефле һөҗүм итү почмаклары буенча канатның күтәрү көче турындагы мәсьәләнең чишелешен таба. Ляпунов алымнарын үстерә барып, хәвефлелек туган һәм аңа якын очракларда хәрәкәт тотрыклылыгы, ш.у. соңгы вакыт аралыгындагы хәрәкәт тотрыклылыгы буенча фундаменталь нәтиҗәләргә ирешә. Нәсызыкча тирбәнешләр проблемасын тикшереп, периодик чишелешләр булу һәм аларның тотрыклылыгы шартларын билгели, тирбәнешләрнең формаларын тикшерә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Мәскәү авиация ин-тының аэродинамика корпусы, Казан техник ун-ты биналарында мемориаль такта куелган; 1970 елдан башлап, К. истәлегенә фәнни укулар үткәрелә.

Х е з м.: Избр. труды: В 2 т. М., 1972.

**КА́МЕНСК-УРА́ЛЬСКИЙ** шәһәре, *Свердловск өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә (Екатеринбургтан 100 *км* көньяк-көнчыгыштарак) урнашкан. Халкы — 179061 кеше (2010), ш.и. татарлар — 7659 кеше (2002). К.-У.га татарлар күпләп 1960 елларда күчеп киләләр, бу шушы чорда шәһәрдә сәнәгать һәм торак төзелешенең нык үсүе б-н бәйле. 1998 дән татар-башкорт мәдәни үзәге, «Дуслык» җыр үзешчән ансамбле эшли. «Күпмилләтле Каменск-Уральскийның сәнгать көзгесендә чагылышы» төбәк программасы нигезендә квартал саен Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. «Каменск-Уральский шәһәренең үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль учреждениесенең 16 нчы ф-лы фондында татар телендә 10 мең данәдән артык басма (китаплар, вакытлы матбугат) бар. 2002/03 уку елында Лингвистика көллиятендә татар телен өйрәнү төркеме булдырыла. Шәһәрдә мөселманнарның «Азан» һәм «Рамазан» дини оешмалары бар. 1994 тән мәчет эшли.

**КАМЕ́НСКИЙ** Иван Петрович (1773, Полтава ш. — 6.8.1819, Харьков ш.), хирург, анатом, мед. д-ры (1802). Мәскәү мед.-хирургия академиясен тәмамлагач (1797), хәрби госпитальдә эшли, 1799 елдан Мәскәү мед.-хирур-

гия академиясендә анатомия каф. проректоры, 1804 тән С.-Петербургта табиб. 1806 дан Казан ун-тында проф., анатомия, физиол. һәм мәхкәмә табиблеге каф. мөдире, беренчеләрдән булып, физиол. һәм анатомия укыта башлый. 1810–19 да Харьков ун-тында акушерлык осталыгы каф. мөдире.

Х е з м.: Опенетрирующая язва желудка. К., 1796; Краткое начертание наблюдений и опытов о вредности молочной и о пользе хлебной, мясной и другой пищи для детей. СПб., 1805.

**КА́МЕРА МУ́ЗЫКАСЫ**, башкаручылар составы зур булмаган инструменталь яисә вокаль музыка. Татарстан композиторлары иҗатында шактый зур үсеш ала. Камера-вокаль (җырлар, романслар, солистлар һәм зур булмаган ансамбльләр өчен җырлар, романслар, вокаль цикллар) һәм камера-инструменталь (төрле составлар өчен программалы пьесалар цикллары, сонаталар, сюиталар, квартетлар, камера ансамбльләре) жанрлар керә. 20 йөз башы татар. музыкасында башкаручы-музыкантлар иҗатында беренче тапкыр скрипка, фортепиано, думбра, зур булмаган инструменталь ансамбльләр өчен инструменталь миниатюралар барлыкка килә; Г.Зайпин, И.Козлов, З.Яруллин, Х.Әхмәдуллин, С.Габәши әлеге камера әсәрләренең беренче авторлары һәм башкаручылары булалар. Проф. татар композиторларының К.м. иҗаты үсеше 1930–40 елларга туры килә. Башта В.Виноградов, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, З.Хәбибуллинның татар халык көйләренә эшкәртмәләре, аннан соң вокаль миниатюралар, фортепиано өчен әсәрләр (М.Мозаффаров һәм Н.Җиһанов сонатиналары), Ф.Яруллинның виолончель өчен сонатасы, З.Хәбибуллинның Скрипка һәм фортепиано өчен поэмасы иҗат ителә. Яңа буын композиторлар (Ф.Әхмәтов, Р.Еникиев, А.Леман, А.Монасыйпов, М.Яруллин, Б.Трубин) К.м. өлкәсенә өстенлек биргәнлектән, К.м. жанрлары 1950–60 елларда аеруча нык үсә. Композиторлар күбрәк Европа классик традициясе жанрларында (сонаталар, партиталар, квартетлар, квинтетлар) эшлиләр. Алар ш.у. соло уен кораллары өчен әсәрләр дә (Р.Яхинның фортепиано өчен пьесалары, А.Ключарёвның фортепиано өчен язылган «Туган як күренешләре» циклы, Н.Җиһановның «12 музыкаль сурәт» һәм «Матюшино эскизлары», А.Монасыйповның «Биш лирик картина һәм марш»ы, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин, Ә.Бакировларның скрипка өчен поэмалары, Р.Еникиевнең «Вальс-поэма»сы, Р.Яхин һәм Л.Хәйретдиновның Виолончель өчен элегияләре һ.б.) иҗат итәләр. Р.Яхинның татар музыкасын яңа хисләр гаммасы (соклану, омтылыш, зарыгу, патетика, дәрт) б-н баеткан романслары камера-вокаль музыкасы үсешенә зур йогынты ясый.

А.Монасыйпов иҗатында да вокаль лирика (еш кына джаз катнашында) сизелерлек урын алып тора. Ф.Әхмәтов, А.Ключарёв, Р.Еникиев, И.Якупов, Р.Еникиева әсәрләре арасында ш.у. камера-вокаль характердагы әсәрләр бар.

1970–90 елларда К.м. Татарстанда беренче планга чыга. Бүгенге көндә иҗатның шушы шактый бай өлкәсе А.Луппов, Л.Любовский, Р.Белялов, А.Миргородский, Ш.Шәрифуллин, Ш.Тимербулатов, Л.Блинов, И.Якупов, Б.Четвергов, Р.Әхиярова, Ф.Шәрифуллин, М.Шәмсетдинова, Р.Кәлимуллин, А.Руденко, С.Беликов һ.б.ның әсәрләрендә көчле яңгыраш ала. Композиторлар муз. гәүдәләндерү чараларының киң спектрыннан, композиторлык техникасының яңа алымнарыннан файдаланалар. Аларның иҗаты, урта гасыр татар әдәбияты темалары һәм образларын, мөнәҗәт һәм бәет жанры үзенчәлекләрен кулланып, Шәрекъ мөселман халыклары мәдәниятенә һәм татар халкының этник төркемнәре фольклорына игътибарны юнәлтү б-н бергә традицион музыка материалына карата яңа мөнәсәбәте ягыннан аерылып тора. Р.Беляловның фольклор сюиталары, Ш.Шәрифуллинның камера цикллары, А.Монасыйповның солистлар ансамбле өчен язылган «Керәшен көйләре» һәм «Борынгы Болгар кыйссасы» әсәрләре, Р.Кәлимуллинның фортепиано фантазияләре һәм тавыш, 2 флейта, виолончель һәм фортепиано өчен «Риваяте», 2 флейта, фортепиано һәм бәрмә уен кораллары өчен язылган «Пальмира күренеше», М.Шәмсетдиновaның «Пәйгамбәрнең тууы» вокаль-инструменталь композициясе шундыйлардан. Композиторлар иҗатына күбесенчә республиканың югары проф. башкаручы көчләре стимул бирә. 1972 дә Зур концерт залына орган куелу Ф.Әхмәтов, Ш.Шәрифуллин, Л.Блинов, Р.Кәлимуллин, Р.Салиховларның махсус әсәрләр иҗат итүенә этәргеч бирә. 1992 дән «Европа-Азия» заманча музыка халыкара фестивален уздыру Татарстанда К.м. үсешенә шактый йогынты ясый. Бу музыка форумының Евразия компоненты төрле илләрдәге башкаручыларны һәм композиторларны үзенә җәлеп итә, хәзерге муз. культураның киң панорамасын һәм үсеш динамикасын күрсәтә, бер үк вакытта Татарстан композиторлары музыкасын дөнья музыка җәмәгатьчелегенә тәкъдим итә.

*Г.Б.Гобәйдуллина.*

**КАМЕРА́ЛЬ РАЗРЯ́Д**, Казан университеты юридик ф-тының уку бүлекчәсе. 1844 елда ачыла. Дәүләт милке һәм финанслар министрлыгының техник һәм махсус учреждениеләре өчен чиновниклар, казна пр-тиеләре идарәчеләре әзерләү өчен билгеләнә. К.р.та укучылардан юриспруденция (дәүләт, гражданлык, финанс, хокук), ш.у. а.х. (ботаника, ветеринария, агрономия), сәнәгать (химия, технология), икътисад өлкәләре (сәяси икътисад, статистика) белгечләрен әзерләү күздә тотыла. Н.Н.*Зинин*, А.М.*Бутлеров*, К.К.*Клаус*, М.Я.*Киттары*, И.К.*Бабст*, Е.Г.*Осокин*, Д.И.*Мейер* һ.б. укыта. 1850 елларда К.р. университетта иң зур бүлекчә була, ел саен чыгарылышны 15–25 кеше тәшкил итә. Фәнни юнәлешләрнең (*Казан химия фәнни мәктәбе*, технол., ботаника мәктәпләре), икътисади фәннәрнең үсешенә ярдәм итә. К.р.ны тәмамлаучылар арасында А.К.*Чугунов*, В.В.*Марковников*, А.М.*Зайцев* бар. 1865 тә университетта 1863 елгы Устав кертелү сәбәпле ябыла, бу Уставта факультетларны разрядларга бүлү каралмаган була. Техник һәм а.х. фәннәренең үсеше физика-матем. ф-тында дәвам итә.

*Әд.:* Р ы с а е в а Г.Р. Подготовка инженерно-технических кадров в Казанском университете в XIX — начале XX вв.: Дис. ... К., 1987.

**КАМЗУ́Л**, арттактасы билләп эшләнгән, төймәләмичә киелә торган, элегрәк татарлар арасында киң таралган кыска өс киеме. К.ны җиңле күлмәк өстеннән бәйрәм киеме сыйфатында ирләр дә, хатын-кызлар да кия. Аны тукыма аслык, сирәгрәк — мех б-н әчләп, тезгә кадәр озынлыкта, җиңсез яки кыска җиңле (терсәккә кадәр) итеп, затлы тукымалардан (бәрхет, парча, хәтфә, постау, ефәк) тегәләр. Ирләр К.ының тегелеше хатын-кызларныкыннан зур булмаган утыртма яка һәм билендә бөрмәләр булмау б-н аерыла. Гадәттә, хатын-кызлар К.ының билгә кадәр өлешен, гәүдәгә сыланып торырлык итеп, ян-ягына ялгаулар өстәп тегү исәбенә, киң чабулар калдырып кисәләр. Ялгауларның санына карап, өч җөйле («өч билле») һәм биш җөйле («биш билле») К.лар була. Хатын-кызлар К.ының алгы кырыйларына, итәк һәм җиң төбенә укалы тасма, тукылган тасма, аккош мамыгы тотыла. 19–20 йөзләр чигендә Европа киеме



Камзул. 19 йөз уртасы. РФАнең Бөек Пётр исем. Антропология һәм этнография музее. С.-Петербург.

тәэсирендә яшьләр арасында җиңсез күлмәк рәвешендәге кыска К.лар кию киң тарала: егетләр — жилет кебек К., кызлар билен нык бөреп эшләнгән, түше ачык, чабулары капламасыз, бил турыннан матур прәшкә — *каптырма* б-н эләктерелә торган К. киеп йөри башлыйлар. Элеккеге өлге б-н тегелгән озын итәкле, алды ябылган К.лар («әдәп камзулы») керәшеннәрдә яшь хатыннарның көндәлек киеме сыйфатында яшәвен бик озак дәвам итә; кагыйдә буларак, аны кияүгә чыгуның беренче елында кияләр, бу тыйнаклык һәм тәрбиялелек билгесе санала.

*Әд.:* Р ә х и м о в а Р.К. Татар теленең һөнәрчелек лексикасы. К., 1983; З а в ь я л о в а М.К. Татарский костюм. К., 1996; М у х а м е д о в а Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАМИ́НСКИЙ** Валерий Наумович (24.6.1939, Мәскәү), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1985), проф. (1987). 1961 елда Мәскәү автомобиль юллары ин-тын тәмамлаганнан соң, Дәүләт тракторлар фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәс-

кәү) эшли: перспектив двигательләр лаб-ясе мөдире, двигательләр бүлеге мөдире (1978 гә кадәр), 1978–86 да КамАЗда (Чаллы ш.): турбоөрдерүле двигательләр бүлеге башлыгы, Кама зур йөк автомобильләре җитештерү берләшмәсе идарәсенең двигательләр буенча баш конструкторы урынбасары, бер үк вакытта Кама политехник ин-ты профессоры (1985 тән). 1986–89 да Алабугада: Кама тракторлар з-дының конструкторлык-технол. үзәге баш конструкторы — директоры (1988 гә кадәр); Алабуга автомобильләр з-дының баш конструкторы – ген. директор урынбасары (1989 га кадәр). 1989 дан «Турботехника» ФҖБнең ген. директоры (Мәскәү өлкәсенең Протвино ш.), бер үк вакытта Мәскәү автомеханика ин-ты профессоры (1989–97). Хезмәтләре автомобиль һәм трактор двигательләрен, өрдерү агрегатларын проектлаштыруга карый. Трактор, комбайн; судно двигательләре өчен турбоөрдерү системаларын һәм зур йөк автомобильләре өчен дизель двигательләре; БТР-80 бронетранспортёры өчен турбоөрдерүле «КАМАЗ» двигательләре төркеменең конструкцияләрен эшли. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Турбонаддув высокооборотных дизелей. М., 1976; Оптимизация некоторых конструктивных параметров системы воздухоснабжения 8-цилиндровых V-образных дизелей с турбонаддувом // Двигателестроение. 1983. № 10; Создание унифицированных агрегатов наддува и охлаждения наддувочного воздуха для автомобильных дизелей // Высокий наддув поршневых двигателей и роторные двигатели. М., 1984; Турбонаддув — путь к повышению технико-экономических и экологических параметров тракторных и комбайновых двигателей // Тракторы и сельхозмашины. 2001. № 4.

**КАМКАЛА́Р** (Coccinellidae), коңгызлар семьялыгы. Дөнья фаунасында 4 меңгә якын, Урта Идел буенда 60 ка кадәр, ТРда 45 тән артык төре исәпләнә. Зурлыгы 0,5 *мм* дан (Scymnus ыругы) 10 *мм* га (Anatis ыругы) кадәр. Гәүдәсе кабарынкы, түгәрәк яки озынча түгәрәк. Канат өслеге һәм аркасының алгы өлеше кара, еш кына аксыл фонда кара нокталы сары, кызыл-сары, кызыл, көрән төстә. Канат өслегендәге рәсемнәрнең үзгәрүчәнлеге хәтта күз күремендә дә ачык сизелә. Тәпиләре 4 буынлы, мыекчалары чукмарсыман. Йомырка салып үрчи. Сезонда бер яки берничә буын бирә. Личинкалары озынча, кыска мыеклы, йөгерә торган тәпиле, бик актив, төрле төстә. Гәүдәсе кабарынкы, төкле сөялләр сибелеп урнашкан. Курчаклары аксыл, үсү б-н караңгырак төстә, эллиптик-тамчысыман, арттан субстратка береккән, алгы өлеше аз хәрәкәтчән. К.ның курчакларын ялгышлык б-н еш кына колорадо коңгызы личинкалары урынына юк итәләр. Коңгыз стадиясендә К. табигатьнең төрле урыннарында кышлый. Татарстан терр-ясендә һәр җирдә очрый, урман, болын, дала һ.б. табигый бергәлекләрдә гадәти яшәүче; агроценозларда 30 га якын төре яши. К.ның күп кенә төрләре ерткычлар (коңгызлар һәм личинкалар). Гөбләә, яфрак борчалары, калканчыкларны юк итүче буларак, үсемлекләрне биологик саклауда әһәмияткә ия. Үсемлекләр б-н тукланучылар арасында люцерна К.ы гына билгеле; 4 төре күгәрек б-н туена. ТР өчен игътибарга лаек К.: тимгелле К. (Stethorus punctillum Ws.), үз ареалының төньяк читләрендә яшәүче бердәнбер камка — акарифаг; колорадо коңгызының күкәй салгычын юкка чыгарырга сәләтле унөч нокталы хиподамия К. (Hippodamia tredecimpunctata L.); ТРда иң зур камка — күзле К. (Anatis ocel-lata L.) ылыслы урманнарда яши; җиде нокталы К. (Coccinella septempunctata L.) үләнчел һәм куакчыл яруста таралган. Җайдакларның 3 һәм чебеннәрнең 2 төре җирле К.ның паразиты булып тора. Русча халык исеме («божьи коровки») аларның күккә — «аллага» очарга талпынуы һәм саргылт төстәге гемолимфа — «сөт» тамчысы (тиренең һәм лайлалы тышчаның ялкынсынуын китереп чыгарырга мөмкин, куркыту исенә ия) бүлеп чыгаруы б-н бәйле. Гөбләә (үлән бете) — аларның төп туклану объекты. Тимгелле К. ТРның Кызыл китабына кертелгән. Илл.не к. *Коңгызлар* мәкаләсендә.

*Әд.:* С а в о й с к а я Г.И. Кокцинеллиды: систематика, применение и борьба с вредителями сельского хозяйства. А.-А., 1983; К а п и т о в В.Д. Характеристика кокцинеллофауны люцерны в условиях Татарской АССР // Защита растений и охрана природы в ТАССР. К., 1986; ш у л у к. Какцинеллиды посевов картофеля в условиях ТАССР // Защита растений и охрана природы в Татарской АССР. К., 1989. Вып. 4.

*В.Д.Капитонов, О.В.Краснов.*

**КАМОДЗА́ВА** (Kamozawa) Ивао (1924, Токио ш.), тарихчы, икътисади география галиме. Токио ун-тын тәмамлый (1954). 1965 елдан проф., 1970 тән Хосей ун-тының гуманитар ф-ты деканы (Япония); бер үк вакытта, 1954–90 да Токио, Хитосубаший ун-тлары укытучысы. Япония икътисад-геогр. җәмгыяте әгъзасы (1965 тән). 1991–95 тә «Мирас» ж-лы редколлегиясе әгъзасы. Хезмәтләре төрки халыкларның икътисади географиясенә, Япониядәге татар диаспорасына, Көнбатыш Германиядәге төркиләргә багышлана. Инглиз телендә «Төрки эмигрантлар — Рус бассейны шахтёрлары» (1979), «Төркиләр Көнбатыш Германиядә» (1991), япон телендә «Татарлар Япониядә» (1984) хезмәтләре басылып чыга.


**КА́МСКАЯ** (ире буенча Ильясова) Гөлсем Сәйфулла кызы (25.3.1901, Казан — 9.12.1975, шунда ук), драма актрисасы, ТАССРның халык (1951), РСФСРның атказ. артисты



Г.С. Камская Сәхилә («Хуҗа Насретдин», Н. Исәнбәт) ролендә.



Г.С. Камская.



Г.Р.Камский.

(1957). Сәхнә эшчәнлеген 1919 елда Кызыл Октябрь исем. Татар театрында (хәзер Татар акад. театры) башлап җибәрә. 1922–26 да — Әстерхан татар драма, 1927–33 тә — Мәскәү Үзәк татар яшьләре, 1933 тән Татар акад. театрларында эшли. 100 дән артык роль башкара, аларның күбесе татар сәхнә сәнгате тарихына кереп кала. Яңача гәүдәләндерү остасы буларак, К. төгәл детальләр, хәрәкәтләр, башкару рәвеше, сөйләү манерасы ярдәмендә ышандырырлык характерлар иҗат итә. Хатын-кызларны, аеруча гади халык кызларын, ш.у. алар характерына хас милли үзенчәлекләрне гәүдәләндергән вакытта, К. иҗатының халыкчанлыгы ачык чагыла. Аеруча игътибарга лаек рольләре — Нәгыймә, Мәгъри («Банкрот», «Бәхетсез егет», Г.Камал), Сабира («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов), Ишанның беренче хатыны («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Гөлниса, Фәрхәнә («Ташкыннар», «Чаткылар», Т.Гыйззәт), Маһинур («Миңлекамал», М.Әмир), Сәхилә, Кәләмзә («Хуҗа Насретдин», «Зифа», Н.Исәнбәт), Сихерче («Үги кыз», А.Әхмәт), Галчиха, Кукушкина, Акылдан язган байбичә («Гаепсездән гаепләләр», «Төшемле урын», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский).

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары: Биографик белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980.

*Д.Ә.Гыйльманова.*

**КА́МСКИЙ** Гата (Гатаулла) Рөстәм улы (2.6.1974, Новокузнецк ш.), шахматчы, хокук белгече, халыкара гроссмейстер (1990). СССР (1987, яшүсмерләр арасында), АКШ (1992), дөнья (1992, команда ярышларында) чемпионы. Халыкара шахмат федерациясе (ФИДЕ) версиясе буенча дөнья беренчелегендә финалист. Дөньяның көчле гроссмейстерлары халыкара шахмат турнирында 2 нче приз ала (София, 2006), Дөнья кубогы иясе (2007). 1989 елдан АКШта яши. 2004 тә Аризона ун-тының юридик ф-тын (АКШ) тәмамлый, үзенең шәхси юридик конторасын ача.

**«КА́МСКО-ВО́ЛЖСКАЯ ГАЗЕ́ТА»** («Кама-Идел газетасы»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Казанда рус телендә 1874 елның 4 гыйнварыннан 25 гыйнварына кадәр атнага — 2, ә 1873 тән — 3 тапкыр нәшер ителә. Нaширләре — Н.Я.*Агафонов* һәм К.В.*Лаврский*, мөхәррире — Н.Я.Агафонов. «Берни булмауга караганда, нидер булу яхшы» девизы астында чыга. Газета тирәсенә демократик юнәлешле эре иҗтимагый-сәяси һәм әдәби көчләр туплана. А.С.Гацисский,

Г.Н.Потанин, Н.Н.Булич, С.М.Шпилевский һ.б. хезмәттәшлек итә. Басмага Идел-Кама төбәгенең иҗтимагый-сәяси һәм икътисади тормышын яктырту бурычы йөкләнә. Аеруча мөһим социаль мәсьәләләр, ш.и. крәстияннәр, эшчеләрнең авыр тормышы һәм хезмәт


№ 1. КАМСКО-ВОЛЖСКАЯ ГАЗЕТА. № 1.

ПОЛИТИЧЕСКАЯ И ЛИТЕРАТУРНАЯ

шартлары турында язмалар, сәяси күзәтүләр басыла. Земстволар эшчәнлегенә, халыкка белем бирүнең торышына, реаль уч-щеләргә аеруча зур игътибар бирелә. Казанның 1870 елгы Шәһәр нигезләмәсен тормышка ашыру, шәһәрдә яшәүчеләрнең яшәү шартларын яхшырту буенча үзидарә органнары чаралары турында күзәтүләр, мәхкәмә хроникалары басыла. Тарихи, этнографик, статистик язмаларга урын бирелә.

*Әд.:* Пивоварова Л.М. С жизнью рядом // Из истории казанской прессы. К., 1977.

*Г.Р.Заманова.*

**«КА́МСКО-ВО́ЛЖСКАЯ РЕЧЬ»** («Кама-Идел сүзе»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. «*Волжско-Камская речь*» г-тасының дәвамчысы. Революциягә кадәрге әйдәп барган Казан газеталарының берсе, кадет юнәлешле либераль-демократик басма. Казанда рус телендә 1908 елның 1 октябреннән 1917 нең 14 декабренә кадәр һәм 1918 нең 21 августыннан 7 сентябренә кадәр барлыгы 2391 саны нәшер ителә. Төрле елларда наширләре — И.И.Бабушкин, М.М.Шерстенников, П.А.Дубровин, мөхәррирләре — А.Ф.Музовский, М.М.Шерстенников, Н.П.Гусев, К.Н.Тимофеев, Е.Д.Титова, В.К.Самсонов. 1915 тә кушымта рәвешендә «Телеграммы «Камско-Волжской речи», 1917–18 елларда «Телеграммы Петроградского телеграфного агентства» чыгарыла. Редакция 3 нче һәм 4 нче Дәүләт Думасы эшчәнлеген яктырта, Дума әгъзалары һәм Казан депутатларының чыгышларын бастыра, кадетлар башлангычы б-н Думада «Прогрессив блок» (1915) төзелүне хуплый. П.А.Столыпинның аграр реформасын кискен тәнкыйтьли, крәстиян җәмгыятьләрен саклау, җирләрне көчләп тартып алу һәм бертигез кулланунгы яклап чыга. Газета «Идел буе төбәгендә мөселман татарларның йогынтысына каршы чаралар күрү өчен җыелган махсус киңәшмә» (С.-Петербург, 1910) турындагы күрсәтмәләргә үзенең шиген белдерә. Кадетлар партиясе программаларының максатларына, аның Казан губернасында Үзәк һәм Җирле ком-тлары эшчәнлегенә, съезд материалларына зур игътибар бирелә. Басмада кадетлар партиясенең Казан ком-ты әгъзаларыннан А.Г.Бать, А.В.Васильев, Н.П.Гусев, П.А.Дубровин, Н.А.Макаров, А.А.Симолин, В.Д.Смолин, Г.Г.Тельберг, М.М.Хвостов, Г.Ф.Шершеневич, Н.Н.Юшков һ.б. хезмәттәшлек итә. «Шәһәр думасы» рубрикасында Казан думасы утырышлары һәм шәһәр үзидарәсе органнары эшчәнлеге турында язмалар басыла, Казанның көндәлек тормышы җентекләп тасвирлана. Газетаның башкалада һ.б. шәһәрләрдә, ш.и. губернаның барлык өяз үзәкләрендә дә үз хәбәрчеләре була; аларның мәкаләләре «Кама-Идел төбәге» рубрикасында басыла. Әйдәп баручы Россия һәм чит ил вакытлы матбугатына күзәтүләр, барыннан да элек кадет юнәлешле басмаларга («Речь», «Русское слово», «Русские ведомости», «Современное слово» һ.б.) күзәтүләр басыла. Татар басмаларыннан («Вакыт», «Шура», «Юлдаш») — тәрҗемәләр, әдәби бүлектә матур әдәбият әсәрләреннән өзекләр һәм шигырьләр бирелә. Басманың даими бүлекләре һәм рубрикалары: «Россия буйлап», «Соңгы хәбәрләр», «Мөселман дөньясыннан», «Суд», «Театр һәм музыка», «Университет тормышыннан», «Библиография», «Спорт». Газета Беренче бөтендөнья сугышының җиңеп чыкканчы дәвам итүен яклый, «Сугыш», «Сугыш һәм Казан» рубрикаларында сугыш хәрәкәтләрен, Казанның фронтка ярдәм итүен яктырта; 1917 елгы Февр. рев-циясен шатланып каршылый, Вакытлы хөкүмәтне һәм Учредительләр җыенының чакырылуын яклап чыга. Редакция 1917 нең июлендә булган Петроград вакыйгалары өчен большевикларны гаепли, совет хакимиятенә урнашуга каршы чыга. Казан губернасы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы тарафыннан 1917 нең октябрь ахыры— ноябрь башында 2 атнага чакыру туктатыла. Шулай да 8 ноябрьдән яңадан басыла башлый һәм, кадетларны якларга чакырып, Учредительләр җыены сайлаулары уңаеннан кампания җәелдерә. 1917 нең 14 декабрендә, большевикларга каршы пропаганда алып барган өчен, хакимиятләр тарафыннан ябыла. Казанны чехлар һәм КОМУЧ халык армиясе алгач, үзенең эшчәнлеген вакытлыча торгыза: КОМУЧның Вәкаләтле вәкиле эшчәнлеген һәм җирле хакимият органнары оешуны яктырта, Казан тирәсендәге сугыш барышын, «кызыл террор»ны җентекләп тасвирлый. Соңгы саны «Барыбыз да туган шәһәребез өчен көрәшкә!» дигән өндәү б-н чыга, мөхәррир В.К.Самсонов «Дәһшәтле вакыт» («Грозный час») мәкаләсендә казанлыларны якын көннәрдә Кызыл Армиянең шәһәргә һөҗүм итәчәге турында кисәтә.


КАМСКО-ВОЛЖСКАЯ РѢЧЬ

газета общественно-литературная и политическая.

«Камско-Волжская речь» газетасы.

*Т.М.Насыйров.*

**«КА́МСКО-ВО́ЛЖСКИЙ КОРРЕСПОН-ДЕ́НТ ДЛЯ ДЕЛОВЫ́Х ЛЮДЕ́Й»** («Эшмәкәрләр өчен Кама-Идел хәбәрчесе»), сәүдә газетасы. Казанда рус телендә 1897 елның 15 октябреннән 1901 гә кадәр (1899 ның ахырында чаклы атнага 3 тапкыр, соңыннан төрлечә) нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — П.И.Кидалинский. 1898 нең 3 июленә кадәр (№ 103) «Бөтен Россия буенча сату-алу, утарлар, җир, заводлар сату турында белдерүләр басмасы» исемендә чыга, һәм анда бары тик рекламалар гына урын ала. Кидалинскийның шәхси басмаханәсе ачылганнан соң, газетаның тематикасы киңәя һәм форматы зурая. Үзен «сәүдә һәм Кама-Идел төбәге публикацияләре, белешмәләр органы» дип игълан итеп, басма күчемсез милек сату-алулар, сәүдә, аукцион, подряд, базар, ярминкә, биржа килешүләре (бигрәк тә Казан һәм Түбән Новгородта) турында белдерүләр һәм куллану товарларына бәяләрне бастырып бара. Аның сәхифәләрендә хөкүмәт карарлары, төрле оешма утырышларында каралырга тиешле эшләр исемлеге, поезд һәм пароход расписаниеләре, календарьлар, метеорологик бюллетеньнәр, игъланнар урын ала.

*Г.Р.Заманова.*

**«КА́МСКО-ВО́ЛЖСКИЙ КРАЙ»** («Кама-Идел төбәге»), көндәлек иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Казанда рус телендә 1895 елның 28 декабреннән 1898 нең 1 февраленә кадәр 651 саны нәшер ителә. Төрле елларда наширләре — Н.А.*Фирсов*, В.Н.Марченко, С.Г.Дьяченко, мөхәррирләре — Н.А.Фирсов, Н.П.*Загоскин*. Газета төбәкнең иҗтимагый тормышын яктырту буенча программа игълан итә. Фән, әдәбият, сәнгать, театр, музыкага багышланган бүлекләре була. Агымдагы вакыйгалар арасында земство медицинасы, халыкны укыту, крәстияннәр арасында мәдәни-агарту эшләре алып бару мәсьәләләренә аеруча игътибар ителә. Идел буе халыкларының көнкүреше һәм гореф-гадәтләре турындагы этнографик материалларга зур урын бирелә.

*Г.Р.Заманова.*

**КАМЧА́ТНОВ** Владимир Павлович (19.7.1920, Васильево пос. — 30.10.1988, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1964), проф. (1966). ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1970). 1950 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1957–81 дә хезмәт гигиенасы һәм профпатология каф. мөдире. 1953–57 дә Кытайда, хезмәт гигиенасы мәсьәләләре буенча киңәшче. Хезмәт гигиенасы китаплары авторы. К. химия, мебель, нефть эшкәртү, мех, киез-итек, киез сәнәгате, кино-фотоплёнка җитештерү пр-тиеләрендә хезмәт шартларын тикшерә. 1969 дан Бөтенроссия гигиена белгечләре һәм сан. та-

библәре җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сравнительная характеристика содержания марганца в пищевых продуктах в эндемических и неэндемических районах по зобу. К., 1953; Вопросы гигиены труда в производстве кинофотоплёнки. К., 1969; Гигиена труда в химизации сельского хозяйства. К., 1970.

**КАМЧЫЛЫЛА́Р** (Mastigophora), иң түбән төзелешлеләр, аларның хәрәкәтләнү органнары булып җепселләр (камчылар) хезмәт итә, саны бер яки берничәдән алып (гәүдәнең алгы полюсыннан башлангыч алалар) берничә меңгә кадәр (бөтен гәүдәне каплыйлар) була ала. Күп кенә К. колонияләр (вольвокс) хасил итә. Иң түбән төзелешлеләр таксономиясе турында Халыкара комитет (1980) системасы буенча К. Sarcomastigophora тибының астибы булып тора һәм 2 класска бүленә: үсемлек К. (Phytomastigina) һәм хайван К. (Zoomastigina). Беренчеләре — автотрофларны (фотосинтез юлы б-н углеродны үзләштерә) һәм миксотрофларны (матдәләр алмашының катнаш тибына ия), икенчеләре гетеротрофлар (әзер органик матдәләрне куллана), ш.и. паразит формаларны берләштерә. К. шулкадәрле төрле: тикшерүчеләр бер күзәнәкле организмнар (протистлар) системасын гына түгел, ә, гомум алганда, эукариотларны да яңадан карарга мәҗбүр булалар. Яңа систематик төзелеш буенча К.ны берничә типка бүләләр. К.ның гомуми саны — 7 меңнән артык төр, ш.и. 5 меңнән артыгы — ирекле яшәүчеләр. ТРда К. аз өйрәнелгән, берничә йөзгә кадәр ирекле яшәүчеләр, симбиотик һәм паразит төрләре билгеле.

Бер күзәнәкле ирекле яшәүче формалар арасында К. иң ваклары булып торалар. Зурлыгы 3 тән 300 *мкм* кадәр, уртача 50 *мкм* тәшкил итә. Гәүдә формасы шарсыманнан орчыксыманга кадәр. Хәзерге К.ның күбесендә 2 шәр камчы бар. Ихтимал, борынгы мастигофоралар ике камчылы булган (казылма планктон К. билгеле), күп һәм бер камчылылар икенчел булып барлыкка килгән. Төрле камчыларның эшләү механизмы төрлечә, әмма, нигездә, винтсыман хәрәкәт ясала; иң түбән төзелешлеләр әйләнә-тирә мохиттә борылып йөргән шикелле. Кагыйдә буларак, күзәнәкнең төше бер. Сирәк кенә ике төшле (лямблияләр) һәм күп төшле (опалиннар) формалар очрый. Хлорофиллы хроматофорларга ия К.ның автотроф формаларында фотосинтез өчен уңай яктылык зонасын сайларга мөмкинлек бирүче кызыл яки кызыл-сары төстәге күз таплары бар. Осмокөйләүче функцияне кыскару вакуольләре үти, алар исә диңгез һәм паразит формаларда юк. Үрчүе, гадәттә, җенессез (буенча икегә бүленә). Төгәлләнмәгән җенессез үрчү вакытында колонияләр барлыкка килә. Гаметалар копуляциясе (изогамия, гетерогамия) тибы буенча җенси үрчү билгеле.

Ирекле яшәүче К., башлыча, төче сулыкларда киң таралган һәм табигатьтә матдәләрнең өзлексез әйләнешендә мөһим роль уйный. ТРда К. су катламнарында һәм сулык төпләрендә (хризомонадиналар, перидинияләр, евгленачалар, бодонидлар), чистарту корылмалары аэротенкларының актив ләмендә, грунт суларында, туфракта яши, әйләнә-тирә мохитнең пычрану дәрәҗәсен күрсәтүче биол. индикаторлар булып тора. Гипермастигиннардан булган К.ның күбесе күшәүче партояклыларның ашказаны картасында, аларга зыян китермичә, әмма үзенә файда алып (комменсализм) яши. К.ның әлеге группадагы төрләре үзагач б-н тукланучы бөҗәкләрнең эчәклегенә урнаша һәм целлюлозаны тарката (симбиоз). Күп кенә К. умырткасыз һәм умырткалы хайваннарның, кешеләрнең паразитлары (трихомонадалар — сидек-җенес органнары системасында, контакт юлы б-н күчә; лямблияләр — нечкә эчәктә һәм үт юлында, цисталар ярдәмендә таралала) булып тора. ТР чикләрендә лейшманияләр (тирене һәм эчке органнарны зарарлый. Кавказ арты һәм Урта Азиядә очрый) һәм трипаносомалар (канда, лимфа һәм арка мие сыекчасында паразитлык итәләр, нигездә, тропикларда очрый) куркынычы бар, алар кан суыручы парканатлы бөҗәкләр тешләгәндә күчә.

*Әд.:* Д о г е л ь В.А. Зоология беспозвоночных. М., 1981; С е р а в и н Л.Н. Простейшие: что это такое? Л., 1984; Ж у к о в Б.Ф., К а р п о в С.А. Пресноводные воротничковые жгутиконосцы. Л., 1985; Международный кодекс зоологической номенклатуры. Л., 1988; Х а у с м а н К. Протозоология. М., 1988; Б у р у к о в с к и й Р.Н. Зоология беспозвоночных. Ч. 1. Простейшие. Калининград, 1999; Протисты: Рук. по зоологии. СПб., 2000; К а р п о в С.А. Строение клетки протистов. СПб., 2001. *Р.М.Сабиров.*

**КАМЫ́Л СЫБЫЗГЫ́**, салам сабагыннан ясалган бер телле традицион татар музыка уен коралы. Гади һәм җиңел эшләнгәнгә һәм тавыш чыгарганга, балалар арасында киң кулланыла. К.с. ясау өчен, салам сабагының ныклы, чыдам өлеше файдаланыла. Аның буе 70–100 *мм*, диаметры 3–4 *мм*, очлары 40–45° б-н кисеп алына. Барлыкка килгән көпшәнең очыннан 10–12 *мм* ара калдырып, үткен пычак яисә лезвие б-н 20–25 *мм* озынлыкта, 2,5–3 *мм* киңлектә тел уела. Телнең очы иркен ителсен өчен, тирбәнүче телнең бер өлеше 1–2 *мм* га көпшәнең өстеннән чыгып тора. Тавыш чыгару өчен көпшәне иреннәр арасына куялар һәм өрәләр. Көпшәнең очын тел б-н авыз куышлыгына урнаштыргач, башкаручының теле аның иркен тирбәнешенә комачауламаска тиеш. Уен коралының тембры йомшак, безелдәвекле. Динамик мөмкинлеге — pp-mf. К.с. оста музыкантлар кулында шактый зур сәнгати мөмкинлеккә ирешә, балалар өчен мавыктыргыч уенчык санала. *Р.Ф.Халитов.*

**КАМЫЛЛЫ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 39 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 59 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 елларда Иске Тәрбит авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Башта ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1926 да — 385, 1938 дә — 327, 1949 да — 286, 1958 дә — 223, 1970 тә — 261, 1979 да — 145, 1989 да — 82, 2002 дә — 50 кеше.

**«КАМЫ́Р БАТЫ́Р»**, каһарманнар турындагы әкиятләр циклыннан татар халык әкияте. Балалары булмаган карт б-н карчык камырдан ир бала әвәлиләр һәм аңа Камыр батыр исеме кушалар. Малай бик тиз үсеп җитә, гайре табигый көчкә ия була, әмма яшьтәшләрен кыерсыта, кулларын, аякларын сындыра торган була. Авылдашлары һәм картның таләбе буенча Камыр батыр өйдән чыгып китә. Юлда ул ике каһарманны очрата. Үзара сугышып алганнан соң, алар дуслашып китәләр. Өчесенең дә дошманы — «Үзе бер карыш, сакалы биш карыш» кушаматлы явыз карт-җен була. Камыр батыр, сугышып, аны җиңә, соңыннан үзе чибәр бер кызга өйләнә. «К.б.»да баласызлык һәм могҗиза б-н дөньяга килү кебек әкияти мотивлар каһарманнар сугышы һәм явыз көчләрне җиңү кебек эпик мотивлар б-н үрелеп бара.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; У р м а н ч е Ф. Әкиятләр // Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2002.


*Ф.И.Урманчеев.*

**КАМЫ́Ш** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 13 *км* көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 12 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Арча кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1926 да — 165, 1949 да — 181, 1958 дә — 169, 1970 тә — 65, 1979 да — 32, 1989 да — 16, 2002 дә — 6 кеше.

**КАМЫ́Ш** (Scirpus), күрәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 дән артык төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап таралган, күбрәк Төньяк ярымшарның уртача поясында. ТР терр-ясендә 5 төре: К. (S. sylvaticus), күл К.ы, яки куга (S. lacustris), һәм Табернемонтан К.ы (S. tabernaemontani) — һәр җирдә; каты К. (S. radicans) — Көнбатыш Кама алдында; киң ябалдашлы К. (S. supinus) Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычы яр буйларында һәм утрауларында очрый. Су буйларында, сай сулыкларда, сазлыклы болыннарда, урманнарда, куаклыклар арасында үсә. 40–250 *см* биеклектәге үсемлекләр. Күл К.ы шуышма калын тамырчалы һәм цилиндрсыман шома сабаклы; урман К.ы — өч кырлы сапта урнашкан киң кыяк яфраклы. Чәчәкләре ике җенесле, башча яки себеркәч чәчәк төркемендә. Җимешләре — өч кырлы вак чикләвекләр. Июнь–июльдә чәчәк ата. Башлыча, тамырчадан, ш.у. орлыктан үрчиләр. Тамырчасында крахмал һәм шикәр матдәләре бар. Күл К.ының яшь сабаклары — ондатра, су тычканнары, су кошлары, урман К.ы сабаклары боланнар өчен азык булып тора. Күл К.ы — торф барлыкка китерүче үсемлек.

**КАМЫ́Ш ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Acrocephalus), әрәмә чыпчыклары семьялыгыннан сайрар кошлар ыругы. Европа, Азия, Африка,

Австралиядә очрый. ТР терр-ясендә 5 төре бар. Саз шәфәкъ чыпчыгы (A.palustris) һәм бурсык чыпчык (A.schoenobaenus) — һәр җирдә; миләш чыпчыгы сыман К.ч. (A. arundinaceus), бакча шәфәкъ чыпчыгы (A.dumetorum) — сирәк төрләр; әйләнчек камыш чыпчыгы (A.paludicola) очып китү, кайту чорларында очрый. Республика терр-ясе буенча миләш чыпчыгы сыман К.ч.ның оялау ареалының төньяк чиге үтә. Күчмә кошлар. Май



Саз шәфәкъ чыпчыгы.

аенда очып киләләр. Зур сазлыкларда, елга тугайларында, сулык ярлары буенда оялыйлар. К.ч.ның озынлыгы 10–20 *см*, авырлыгы 30 *г* га кадәр. Сыртында каурыйлары кызгылт-көрән, түше кызгылт-ак. Томшыгы чагыштырмача нечкә. Күп кенә төрләренең авыз почмагында кыллар бар. Түгәрәкләнеп килгән койрыклы. Ояларын берничә вертикаль сабакка асып, тирән касә яки кәрзин рәвешендә куе булып үскән куаклар, камыш, курак арасында ясыйлар. Кара таплы аксыл 4–6 йомырка сала. Бөҗәкләр, үрмәкүчләр вак моллюсклар б-н туклана. Кышлау өчен сентябрьдә очып китәләр.

**КАМЫШЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,6 *км*, бассейнының мәйданы 99,4 *км*$^2$. Сарман р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Имән авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Яхшыбай авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 133 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 8%. К.ның 3,6 дан алып 9,9 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 126 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,055 *м*$^3$/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада су күләме 0,25 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАМЫШЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 12 *км*, бассейнының мәйданы 42,6 *км*$^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага, Лениногорск р-нында. Елга башы Лениногорск шәһәрендә, тамагы Воздвиженка посёлогыннан 2 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 138 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 26%. К.ның 3 һәм 4 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 138 *мм*, ташу агымы катламы 87 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрь башында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м*$^3$/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**КАМЫШЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 12 *км*, бассейнының мәйданы 22,2 *км*$^2$. Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Степановка авылыннан көньяктарак, тамагы Иске Александровка авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 64 *м*. К. елгасының су җыелу терр-ясе урмансыз диярлек. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,54 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, яртысы диярлек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәйге саегу вакытында елга еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 101 *мм*, ташу агымы катламы 51 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*$^3$/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л* дан күбрәк.

**КАМЫШЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,8 *км*, бассейнының мәйданы 48 *км*$^2$. Идел арьягы түбәнлегеннән ага, Нурлат р-нында. Елга башы Кече Камышлы авылыннан көньяктарак, тамагы Абләскино авылыннан 1 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 110 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. К. елгасының су җыелу терр-ясе урмансыз диярлек. К.ның 4,1 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен яңгыр озак яумый торса, елга бөтен озынлыгына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 80 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,008 *м*$^3$/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КАМЫШЛЫ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 30 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 138 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1930 елларда нигез салына. Башта Тымытык р-нына керә. 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 331, 1949 да — 308, 1958 дә — 290, 1970 тә — 303, 1979 да — 205, 1989 да — 144, 2002 дә — 137 кеше.

**КАМЫШЛЫ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәрәпәле елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1730 елларда отставкадагы солдатлар нигез сала. Беренче исеме — Яңа Камышлы бистәсе. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киез итек басу, чүлмәк, агачтан савыт-саба ясау һ.б. б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 609 дис. тәшкил итә. 1929 да К.да «Искра» к-зы оештырыла, 1950 дә — «Родина» к-зына, 1973 тә — район хуҗалыкара берләшмәсенә, соңрак Зәй с-зына (1998 дән — «Заман» а.х. товарлары җитештерүче кооператив) керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 140, 1917 дә — 396, 1920 дә — 360, 1926 да — 299, 1938 дә — 295, 1949 да — 243, 1958 дә — 189, 1970 тә — 175, 1979 да — 85, 1989 да — 41, 2002 дә — 49 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КАМЫШЛЫ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 10 *км* көньяктарак, Оштырма елгасы буенда. 2010 елда 293 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Оштырма-Камышлы исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, тимерчелек, 2 тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1269,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 488, 1897 дә — 914, 1908 дә — 1010, 1920 дә — 911, 1926 да — 782, 1938 дә — 563,

1949 да — 405, 1958 дә — 361, 1970 тә — 417, 1979 да — 360, 1989 да — 308, 2002 дә — 286 кеше.

**КАМЫШЛЫ́ КҮЛ** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Чалпаймас елгасы буенда. 2010 елда 37 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 184, 1949 да — 250, 1958 дә — 78, 1970 тә — 99, 1979 да — 71, 1989 да — 31, 2002 дә — 22 кеше.

**КАМЫШЛЫ́ РАЙОНЫ́**, *Самара өлкәсенең* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1991 елда оештырыла. Мәйданы — 832 $км^2$. Үзәге — Камышлы авылы (Самара шәһәреннән 200 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 11,4 мең кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 9,6 мең кеше. Районда 10 татар авылы: Камышлы (4941 кеше), Иске Ермаково (1637), Яңа Усманово (1478), Балыклы (666), Иске Усманово (550), Яңа Ермаково (501), Чулпан (331), Татар Байтуганы (293), Бузбаш (174), Дәүләкул (151) бар. 1931 дә Камышлы авылында 2 мәчет була. 1935 тә татар мәктәбе ачыла. Хәзерге вакытта К.р.ның 7 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла, халык драма театры, вокаль-инструменталь ансамбль (Камышлы а.), «Ак каен» фольклор коллективы (Иске Ермаково а.) эшли. К.р.нда Сов. Союзы Герое Ф.Ә.*Сабиров*, Дан орденының тулы кавалеры Х.М.*Миңнекәев* туган.

**«КАМЭНЕРГОСТРОЙПРО́М»**, Түбән Кама шәһәрендәге төзелеш материаллары җитештерүче пр-тие. Эшләүчеләр саны — 1,5 мең кеше (2010). Түбән Кама тимер-бетон конструкцияләр һәм эшләнмәләр з-ды (төп пр-тие, 1960 елда нигезләнә; җитештерү куәте — елга 250 мең $м^3$ җыелма тимер-бетон) һәм керамзитлы гравий з-ды (1966 да нигезләнә; елга 266 мең $м^3$ гравий эшләп чыгара) җирлегендә ЖБ буларак оештырыла. Соңрак аның составында автотранспорт хуҗалыгы (1970), Алабуга р-ны Котловка авылында вак чуерташ һәм сортларга аеру ф-касы (1971; эшкәртү күләме — навигация сезонына 605 мең $м^3$ чуерташлы масса), Түбән Кама р-ны Олы Аты авылында балчык чыгару карьеры (1971), пыяла плиткалар з-ды (1978; елга 550 мең $м^2$ тышлау плиткасы) төзелә. 1960–80 елларда «К.» «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин», КАМАЗ, Яңа Менделеев минераль ашламалар з-ды, Смоленск, Курск, Чернобыль шәһәрләрендә атом эл. станцияләре, Татарстанда һәм СССРның башка төбәкләрендә җылылык һәм гидроэл. станцияләре, гражданнар объектлары, ш.у. Улан-Батыр шәһәрендә җылылык-эл. үзәге төзелешләрен материаллар б-н тәэмин итә. 1996 да ЖБ унитар пр-тие итеп үзгәртелә; 2003 тән ҖЧҖ. Бетоннан һәм тимер-бетоннан 100 дән артык исемдә конструкцияләр һәм 3000 ләп маркада эшләнмәләр, товарлыклы бетон һәм измә, металл формалар һәм конструкцияләр, төзелеш комы, чуерташ һәм вак таш, керамзит җитештерә. Төзелеш конструкцияләрен, инженерлык челтәрләрен, стандарт булмаган корылмаларны проектлау б-н шөгыльләнә, төзелеш-монтаж һәм бизәлеш эшләрен, автотранспорт б-н йөкләр ташуны башкара. Продукцияне кулланучы эре пр-тиеләр арасында «Татэнерго», «Түбәнкаманефтехим», ТАИФ-НК, «Татнефть», «КамАЗ», «Түбәнкамашин» АҖләре, Пермь, Мәскәү, Сургут, Ижевск шәһәрләрендәге пр-тиеләр бар. «К.» тарафыннан Спорт сарае, балаларны сәламәтләндерү лагере, теплица хуҗалыгы һ.б. төзелә. Төрле елларда пр-тие б-н В.Г.Панин, Г.И.Уралов, Р.С.Шиһабетдинов, В.Ә.Яһүдин, В.З.Хәйруллин, Р.С.Хәйруллин җитәкчелек итә.

**КАНА́ВКА** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Сөлчә елгасының (Олы Сөлчә, Олы Чирмешән елгалары бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 10 *км*, бассейнының мәйданы 30,5 $км^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән ага, Аксубай р-нында. Елга башы Аксубай урман заводы посёлогы тирәсендәге урман массивында, тамагы — Түбән Баланда авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. К.ның 3,8 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 94 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,004 $м^3/с$. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КАНА́РСКИЙ** Альберт Владимирович (17.1.1946, Мари АССРның Волжск ш.), биотехнология өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (2000). 1975 елда Ленинград урман техникасы ин-тын тәмамлый. 1964 тән Красноярск урман эшкәртү пр-тиесендә эшли. 1965 тән Мари целлюлоза-кәгазь комбинатында, производство башлыгы (1975 тән). 1979–95 тә Мари целлюлоза-кәгазь сәнәгате ин-тында: лаб. мөдире, директор урынбасары (1987 дән). 1995–2001 дә Волжск гидролиз-чүпрә з-ды директоры. 2001 дән Казан технол. ун-тында, биотехнологияләр сәнәгате каф. профессоры. Хезмәтләре биотехнология, мед., азык-төлек сәнәгатьләре өчен фильтрлаучы материаллар булдыруга карый. К. махсус материалларның структур һәм функциональ үзлекләренең үзара бәйлелеген өйрәнә; ашлык бөртекләре калдыкларын эшкәртү нигезендә, терлек азыгы аксымы алуның биотехнологиясен булдыра. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Фильтровальные виды бумаги и картона. М., 1991; Адгезионная и адсорбционная способность фильтровальных видов бумаг и картона // Хим. пром-сть. 1996. № 4; Микробиологи — комбикормщикам // Комбикорма. 1999. № 6; Перспективы биохимической переработки древесного сырья // Изв. вузов. Пищевая технология. 2001. № 1.

**КАНАТЛЫ́ СҮЗЛӘ́Р**, җанлы сөйләмдә киң таралган тапкыр образлы тәгъбирләр, цитаталар һәм афоризмнар. Мәкаль һәм әйтемнәр б-н бергәттән сөйләмне матурлыйлар, дидактик функция үтиләр; халык сөйләменнән лексика, стиль, ритмикасы б-н аерылалар. Татар теленең күп кенә К.с.ен фольклор әсәрләреннән, Кол Гали, С.Сараи, Мөхәммәдъяр, Г.Утыз Имәни, Акмулла, Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан һ.б. шагыйрь һәм язучыларның әсәрләреннән алынган цитаталар тәшкил итә; мәс.: «Йимәс эт саркытын килеп арыслан» — эттән калганны арыслан ашамас («Китабе Гөлестан бит-төрки»), «Иң мөкатдәс нәрсә — эш» (Г.Тукай). Татар К.с.нең шактые — алынма сүзләр (калькалаштыру һәм ярымкалькалаштыру юлы б-н ясала), шулар исәбендә Шәрекъ (аеруча гарәп һәм фарсы) фольклорыннан һәм әдәбиятыннан, Коръән һ.б. дини китаплардан күчкәннәре бар: «Җенне кувшиннан чыгару» (фарсы, «Балыкчы турында әкият»), «ләм-мим дәшмәү» (Коръән); К.с.нең бер өлеше борынгы мифологиядән һәм әдәбияттан кергән: «Сизиф михнәте», «Дамокл кылычы»; Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятыннан алынган: «Җил тегермәннәре б-н сугышу» («Дон Кихот», М.Сервантес), «Базда (савытта) дары бар әле» («Тарас Бульба», Н.В.Гоголь).

*Әд.:* М ә х м ү т о в Х.Ш. Канатлы сүз — хикмәтле сүз. К., 1999; А ш у к и н Н.С., А ш у к и н а М.Г. Крылатые слова. М., 1966; Г о н ч а р о в а Н.А., Щ е р б а к о в а И.М. Из античной мудрости. Минск, 1995; М а х м у т о в Х.Ш. Афористические жанры татарского фольклора. К., 1995.

*Х.Ш.Мәхмүтов.*

**КАНАТНЫ́ ЯГАЛА́П АГУ́ ТЕО́РИЯСЕ**, гамәли аэродинамика бүлеге, хәрәкәт итүче канатның газ (һава) б-н үзара тәэсир итешү законнарын өйрәнә. К.я.а.т.сен үстерүгә Казан ун-ты һәм Казан техник ун-ты галимнәре зур өлеш кертә. 1940 еллар башында аэродинамиканың кире мәсьәләсе — басымның канат өслеге буенча бүленеше бирелгәндә, канат профильләрен төзү мәсьәләсе куела һәм чишелә (Г.Г.Тумашев). 1950–60 елларда йөртүче өслекләрне ягалап агуны исәпләү алымнары, чикләнгән озынлыктагы канатларның аэродинамик көчләрен һәм моментларын, аз озынаючы канатларны, тирбәлүчән канатларны, ук сыман канатларны зур һәм критик чиктән артык булган атака почмакларында исәпләү юллары эшләнә (Г.В.Каменков, С.Г.Нужин, Т.К.Сиражетдинов, Г.Г.Тумашев, Н.М.Монахов һ.б.); канат профиленең аэродинамик характеристикалары үзлелекне исәпкә алып тикшерелә (З.Х.Ногманов); канат профильләрен кысылмаучан һәм үзле булмаган сыеклыкның яссы-параллель агымы, тавыш тизлегенә кадәрге кысылучан (С.Г.Нужин) һәм тавыш тизлеге тирәсендәге (А.И.Богомолов) агымнарның ягалап агу теорияләре эшләнә; әйләнмә җисемне кысылмаучан сыеклык агымының ягалап агуы мәсьәләсе чишелә (О.П.Сидоров); профиль рәшәткәләрен ягалап агу һәм канат профилен ягалап агуга Җир өслегенең якынлыгы тәэсире теориясе төзелә (М.Х.Бикчәнтә-

ев, Г.И.Костычев). 1970 елларда, һава ташкынын өрдереп кертү һәм чыгару юлы б-н, сыеклык һәм газның чик катламы б-н оптималь идарә итү мәсьәләләре куела һәм чишелә (Т.К.Сиражетдинов, А.А.Афанасьев, О.Г.Диваков һ.б.). Чик катлам теориясе өлкәсендә тикшеренүләр Казан техник ун-тында һәм тармак фәнни-тикшеренү ин-тларында дәвам иттерелә (В.Г.Павлов, К.Р.Караев һ.б.).

*Әд.:* Х р и с т и а н о в и ч С.М., Ю р ь е в И.М. Обтекание профиля при докритической скорости потока // Прикладная математика и механика. 1947. Т. 11, чыг. 1; А р ж а н н и к о в Н.С., М а л ь ц е в В.Н. Аэродинамика. М., 1955; Н у ж и н С.Г. Труды по аэродинамике. К., 2002.

*Т.К.Сиражетдинов.*


**КАНА́У** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 25 *км* көньяктарак, Чилчә елгасы буенда. 2010 елда 43 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 20 йөз башында нигез салына. Беренче исеме — Артель Канава. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостена керә. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1920 дә — 155, 1926 да — 154, 1938 дә — 178, 1949 да — 125,1958 дә — 123, 1970 тә — 139, 1979 да — 135, 1989 да — 71, 2002 дә — 54 кеше.

**КАНА́Ш** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәрәпәле елгасы буенда. 2010 елда 93 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, кошчылык, терлекчелек. Клуб. 1928–29 елларда Сәрәпәле авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Башта ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 367, 1949 да — 367, 1958 дә — 285, 1970 тә — 275, 1979 да — 143, 1989 да — 77, 2002 дә — 91 кеше.

**КАНА́Ш** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 56 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәми елгасы буенда. 2010 елда 110 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1924 ел тирәсендә Барыш авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Башта ТАССРның Зөя кантонына керә, 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 281, 1949 да — 341, 1958 дә — 270, 1970 тә — 268, 1979 да — 218, 1989 да — 141, 2002 дә — 138 кеше.

**«КАНА́Ш»** («Киңәш»), газета; к. *«Хыпар»*.

**КАНӘФЕ́Р ЧӘЧӘ́К** (Dianthus), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр яки ярым куаклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Америка һәм Африкада таралган. ТР терр-ясендә 9 төре бар. Чуар К.ч. (D. versicolor), канәфер үләне (сандугач тәпие) (D. deltoides) барлык районнарда очрый; Андржеевский канәфер үләне (күгәрчен тәпие) (D. andrzejowskianus), Барбаш (D. borbasil) — Идел алдында һәм Кама аръягында; болын канәфере (D. pratensis), комлык канәфере (D. arenarius), купшы К.ч. (D. superbus), Фишер канәфере (D. fischeri), инә яфраклы К.ч. (D. acicularis) — сирәк төрләр. Сирәкләнгән урманнарда, урман буйларында, болыннарда, ташлы далаларда үсә. 10–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы шуышма. Сабагы буынлы, гади яки тармаклы. Яфрагы кыяк яки ланцетсыман. Чәчәге тешәүле, катмарлы яки гади таҗ яфраклы, хуш исле, алсу, җете кызыл, ак төстә, берле яки чук себеркәчкә җыелган. Җимеше — тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Комлык, чуар канәфер, үлән канәфере, Фишер канәфере халык медицинасында кан туктату чарасы буларак кулланыла. Купшы канәфер үләне — баллы үсемлек. К.ч. элек-электән культуралаштырылган. Кайбер төрләре бакча сортларын тудыру өчен материал нигез буларак хезмәт итә. Теплицаларда үстерелә. Купшы К.ч. һәм инә яфраклы К.ч. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Канәфер үләне.

**КАНӘФЕРЧӘЛӘ́Р** (Caryophyllaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Үләннәр, сирәк кенә куаклар һәм зур булмаган агачлар. 80 гә якын ыругы, 2100 дән артык төрне берләштерә. Җир шарының барлык континентларында таралганнар. Аеруча Төньяк ярымшарның уртача поясында киң таралыш алган. ТР терр-ясендә 22 ыругтан 60 төре билгеле, ш.и. *канәфер чәчәк, йолдызак, җил үләне, шартлавык чәчәк, кырлык* һ.б. Яфраклары каршыдаш, сирәк кенә чиратлашкан, гади, бөтен, еш кына тар (кыяк яки кыяк-ланцетсыман), тәңкәсыман төпчек яфраклы яисә төпчек яфраксыз. Чәчәкләре себеркәч, чуксыман чәчәк төркемендә, кайвакыт ялгыз, еш кына ике катлы чәчәк тирәлекле. Һәрвакыт диярлек бөҗәкләр ярдәмендә серкәләнә. К.нең җимеше — капкачлар яки тешчекләр б-н ачылучы, гадәттә, сабак очында урнашкан күп орлыклы тартмачык. Составында сапониннар булганлыктан, К. медицинада кулланыла. Дәвалау максатларында, башлыча, дарулы сабын үләнен һәм яфраксыз бүсер үләнен кулланалар. Кайбер берьеллык төрләре — чүп үләннәр (чәчү кырлыгы, гади бакра үләне, урта йолдызак һ.б.). Канәфер чәчәкләр — декоратив үсемлекләр һәм хуш исле, һәм таҗының ачык төстә булуы аркасында үстерелә. Декоратив үсемлек сыйфатында ш.у. дүңгәләк, дарулы сабын үләнен һ.б.ны да кулланалар. Баллы үсемлекләр (гади чыпчык җилеме, күке үләне, купшы канәфер). 12 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАНДАЛА́ ҮЛӘНЕ́** (Lepidium), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үлән, сирәк кенә — ярымкуакчыклар ыругы. 150 гә якын төре билгеле, поляр иләрдән кала бөтен Җир шары буенча таралган, тропикларда — бары тик тауларда гына. ТР терр-ясендә 5 төре үсә. Киң яфраклы К.ү. (L. latifolium), чүплек К.ү. (L. ruderale) барлык районнарда да очрый; тишек яфраклы К.ү. (L. perfoliatum) һәм куе чәчәкле К.ү. (L. densiflorum) — республикада сирәк очраучы төрләр; чәчүле К.ү. яки кресс-салат (L. sativum) яшелчә культурасы буларак (бакча кишәрлекләрендә) үстерелә. 10–100 *см* биеклектәге үләнчел үсемлекләр. Яфраклары зәңгәрсу яшел, тамыр яны яралгысындагылар — сабакчыл, каурыйсыман бүленмә яки аерчалы, өскеләре — утырма, кыяк, бөтен. Чәчәкләре вак, яшькелт, калкансыман себеркәчкә җыелган. Җимеше — тар бүлгеле һәм бер орлыклы оядан торучы кузакчык. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Июньнән җимешләре өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Халык медицинасында зәңгелә авыруына каршы кулланыла. Чүп үлән. Баллы үсемлек. Чүплек К.ү. — тәмсез исле, кандалалардан саклану чарасы буларак кулланыла (исеме шуннан).

**КАНДАЛАЛА́Р**, я р ы м к а т ы к а н а т л ы л а р (Hemiptera), бөҗәкләр отряды. 50 семьялыктан 30–40 мең төре билгеле, Европада аларның 430 ыругы һәм 1,2 меңнән артык төре бар. Татарстан терр-ясендә якынча 250–300 төре исәпләнә. Авыз органнары чәнчеп суыруга җайлашкан, хортумчыгы башының алгы өлешенә тоташкан, мыекчыклары 3–5 буынлы. Тыныч халәттә өске канатлары яссы җыелган, очы элпәле, нигезләре калын; аяклары йөгерүгә, сирәк кенә йөзүгә (арткылары) яки эләктереп алуга (алгылары) җайлашкан. Күп кенә төрләрнең арткы күкрәгендә ис бизләре бар, аларның сыекчасы исә саклагыч әһәмияткә ия һәм бер төр затларының очрашуын тәэмин итүче химик сигнал ролен уйный. Үсеше тулы булмаган әверелешле. Күп кенә төрләре елга бер буын бирә. Йомыркаларын үсемлек өслегенә яки башка субстратка яисә үсемлек тукымаларына батырып (Miridae) сала. Личинкалары олы затлар б-н охшаш яшәү рәвеше алып бара, гадәттә, 5 тапкыр кабык сала. Йомыркалары, личинкалары яисә олы затлары кышлый. Су, су асты һәм җир өсте төрләре бар, соңгылары арасында ачык, ш.у. яшерен: түшәлмәдә, туфракта, кайры астында һ.б. яшәүчеләр. К.ның күпчелеге үсемлек б-н туклана. Генератив органнарыннан һәм орлыкларыннан сокны суырып, а.х. һәм урман үсемлекләренә зыян китерә. Кайбер төрләре үсемлекләрнең вируслы авыруларын тарата. Ерткычлар да бар, аеруча суда яшәүчеләр арасында (уылдык һәм балык маймычларын юк итә). К.ның җир өсте ерткычлары (Anthocoridae, Nabidae, кайбер Miridae) зарарлы бөҗәкләрнең санын

киметүдә әһәмиятле роль уйныйлар. Cimicidae семьялыгыннан булган К. кошлар имезүчеләр һәм кеше каны б-н туеналар (ш.и. *ятак кандаласы*).

*С.М.Шәфигуллина.*

**КАНДАЛЫ́Й** Габделҗәббар Габделмәҗит улы (1797, Самара губ., Ставрополь өязе Иске Кандал а. — 1860, шунда ук), шагыйрь. Татар һәм гарәп телләрендә яза. «Кандалый» тәхәллүсе туган авылы исеменнән алынган. Мулла гаиләсендә туа. 17 ел дәвамында Казан губернасының Казан, Тәтеш, Чистай өязләре, ш.у. Самара губернасының Ставрополь өязе мәдрәсәләрендә белем ала. Мәдрәсәләрне еш алыштыру — шигырьләрендә алардагы тәртипләрне һәм уку системасын тәнкыйтьләү нәтиҗәсе. Укуга сәләтле булганы өчен, аны шәкертлек чорында ук мәдрәсәнең түбән баскычларында гарәп телен укытуга тарталар. 1824 елда руханилык вазифаларын башкарырга рөхсәт алып, К. туган авылына кайта, имам-хатип булып тора. Шигырьләрендә мөселман руханиларын көлке утына алганы, хатын-кыз образларына мәдхия җырлаганы (традицияләргә каршы чыгу), кайбер шәригать нормаларын бозганы өчен, 1840 та авылның мөселман мәхәлләсе җыелышы К.ны руханилык дәрәҗәсеннән мәхрүм итәргә тәкъдим ясый. Бу тәкъдим тиешле тавыш санын җыя алмаса да, К. эшеннән китәргә мәҗбүр була. 1843 тә ул үзенең фикердәшләре тарафыннан оештырылган 2 нче мәхәллә б-н җитәкчелек итә. 1848 дә аның мәхәлләсенә җитәкче руханилар тарафыннан яңа имам һәм мөдәррис куела. Шулай итеп, К.ны эшеннән читләштерәләр, мәхәлләдә аның йогынтысы сизелерлек кими. 2 елга якын төрмәдә утырып чыга (кулга алуның төгәл вакыты һәм сәбәбе билгесез).

К. күпкырлы белем иясе була. Мәдрәсәдә өйрәнгән гарәп һәм фарсы телләреннән тыш, үзлегеннән рус, мордва һәм чуаш телләрен үзләштерә. Ул төрле эшләр б-н шөгыльләнә: китап төпли, сабын кайната, мич чыгара, йозак төзәтә. Беренче «Рисаләи-әл-иршад» («Тугъры юлга күндерүче китап», 1815/16 тирәсе) әсәрен К. мәдрәсәдә укыган чорда яза. Бу дини-дидактик әсәр кереш сүз, 28 бүлек һәм *мөнәҗәт* формасында язылган йомгактан тора. Автор укучыны мөселман дине кысаларында гына мөмкин булган дөреслеккә өнди. Поэмада җир тормышының фанилыгы турында мотивлар яңгырый, бакый дөньяга үзеңне әзерләү зарурлыгы ассызыклана. Моның өчен К. фәннәр өйрәнү, изге гамәлләр кылу, золым, хәйлә, мәкерлекне кире кагу, хискә артык бирелмәү, түземле булу кирәклеген әйтә. Гыйлемлелекне югары бәяләп, К. крәстиянгә карата беркадәр һавалылык (тәкәбберлек) күрсәтә. Аныңча, укымышлы кешегә игенчелек хезмәте килешми.

К.ның ш. у. уку чорында язылган дип фараз ителгән «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» этик-фәлсәфи поэмасы зур күләмле әсәрнең бер өлешен тәшкил итә (тулаем күләмдә сакланмаган). Поэманың исеме шартлы рәвештә төп геройларның берсе исеменнән алынган. Аның прототибы реаль тарихи шәхес — Бәлх солтаны Ибраһим Әдһәм (874/875 дә үлә). Хакыйкать эзләп, ул, тәхетен ташлап, дәрвиш киемендә юлга чыга. Акылы һәм диндарлыгы б-н Ибраһим Әдһәм Һарун әр-Рәшид хәлифәгә ошый (763/766 — 809), һәм ул аңа үзенең сараенда киңәшче булып калырга тәкъдим ясый. Ләкин Ибраһим Әдһәм, дәрвиш тормышына тугры калып, Аллаһка хезмәт итү юлын сайлый. Поэманың башка бүлекләрендә сүз «Болгар иле»нең белем эзләп сәяхәткә чыккан Кәндиле авылы егете турында бара. Шушы урында поэма өзелә. Сакланып калган текстның күп өлеше урта гасырлар әдәбияты рухында, нәсыйхәт характерында язылган.

Заманасына күрә новаторлык рухында иҗат ителгән «Сәхипҗамал» поэмасы К.ның соңгы иҗат чорына карый. Ул эпистоляр жанрда язылган, анда хәрәкәт тә, сюжет та юк. Анда татар әдәбиятында беренче мәртәбә хатын-кызга карата мәхәббәт җырлана:

Сәңа, җаным, дога иттем, дога илә сәлам иттем,
Сәламнәрнең соңы, җанкәм, язып гозер каләм иттем.
Сәхипҗамал, чибәрем лә, и матурым, сөярем лә!..

К. гади крәстиян кызының сөйкемле образын тудыра, авыр физик хезмәт һәм күңел газапларына дучар булган татар хатыны тормышының күңелсезлеген күрсәтә. Шагыйрьнең кызларга сөйгәннәрен үзләре сайларга тиеш булулары турындагы мөрәҗәгате искелек кануннарына каршы чыга, шуңа күрә мөселман руханилары тарафыннан тәнкыйть утына алына.

Төрмәдә утырганда К. *Аллаһияр Суфиның* «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк») поэмасына гарәпчә комментарийлар яза.

К.ның башлангыч чор әсәрләренең теле катлаулы һәм архаик, үз эченә гарәп-фарсы, угыз, чыгытай лексика һәм морфологиясе элементларын ала. Соңгы чор иҗатында халык теленә бераз якыная. Аның шигърияттендә сөйләм теле элементлары, эпик әсәрләрдән өзекләр, җырлар, әйтемнәр, мәкальләр, фразеологизмнар күп.

Үзе исән вакытта К.ның әсәрләре кульязма рәвешендә тарала. С.Кукләшевнең 1859 да чыккан «Диване хикайәте татар» китабына беренче тапкыр шагыйрьнең, исеме аталмыйча гына, 8 юлы керә. Тагын 200 юлы «Император география җәмгыятенең Оренбург бүлеге язмалары»нда («Записки Оренбургского отделения Императорского географического общества», 1870, кн. 1) басыла, алар анда «татар һәм башкорт халык җырлары» дип атала. 1881 дә күбесенчә К. шигырьләреннән торган «Мәгъшукнамә» («Сөеклемә») китабы басылып чыга, ләкин шагыйрьнең исеме тагын күрсәтелми. Беренче тапкыр К. исеме К.Насыйриның «Фәвакиһел җөләсә»сендә («Мәҗлесләрнең җимеше») 1884 тә бирелә, китапта шагыйрьнең 1 меңнән артык шигъри юлы урын ала. 1920 елларда ТАССР Мәгариф халык комис-ты Академүзәге К.ның иҗади мирасын өйрәнергә һәм системага салырга дигән карар чыгара. Ләкин шагыйрьнең беренче «Шигырьләр» җыентыгы Х.Госман редакциясендә 1960 та гына дөнья күрә. Шагыйрьнең бүгенге көндә кулланышта йөргән иң тулы «Шигырьләр һәм поэмалар» басмасы 1988 дә фәнни комментарийлар б-н М.Госманов редакциясендә нәшер ителә. 1999 да «Сәхипҗамал» поэмасы аерым китап булып чыга.

*Әд.:* Р ә х и м Г., Г а з и з Г. Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. К., 1922. 1 җилд; И р т у г а н К. Шагыйрь Г.Кандалыйның кыскача тәрҗемәи хәле һәм шәхси хәяты // Безнең юл. 1927. № 8; Б ә х т и е в И. Шагыйрь Г.Кандалый турында // Яңалиф. 1929. № 13; Г о с м а н Х. Г.Кандалыйның яңа табылган әсәрләре // Совет әдәбияты. 1960. № 5; К у р б а т о в Х.Р. Г.Кандалый шигырьләрендә метрика һәм строфика // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 кит.; Т а з ю к о в Х. Г.Кандалый турында кайбер мәгълүматлар // Совет мәктәбе. 1978. № 6; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Г о с м а н о в М. Кандалый мирасын барлау юлында // Казан утлары. 1987. № 7; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

*А.М.Ахунов.*

**КАНДАРА́ТСКИЙ** Валериан Сергеевич (1894, Казан — 3.11.1959, шунда ук), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1956). 1916 елда Казан ун-тын тәмамлагач, хәрби мед. хезмәтендә. 1922 дән Казан мед. ин-тында фәнни-пед. хезмәттә. Хезмәтләре аналык муентыгында яман шеш нейрогистологиясе һәм патогенезына карый. К. аналыкта яман шешләрнең үсүе яман шеш тукымасындагы нерв үсентеләре катнашында баруын; бластома үсеше б-н бергә яңа нерв җепселләре барлыкка килүен һәм шеш үсү барышында нерв элементы үзгәрешләре муентык-җиңсә ганглиясенең вегетатив үзәкләренә таралуын (даими дегенератив тайпылышлар) ачыклый. К. сары тәнчек үсешен һәм әһәмиятен өйрәнә.

Х е з м.: Искусственное развитие жёлтых тел в яичнике кролика. К., 1956; Состояние периферического отдела иннервационного аппарата матки при раковом поражении шейки последней. К., 1956.

**КАНДАРА́ТСКИЙ** Михаил Фёдорович (7.11.1854, Казан губ. Зөя ш. — 29.10.1912, Казан), хирург, мед. д-ры (1888), проф. (1905). 1881 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук фәнни-пед. эштә, 1883–86, 1888–1912 дә оператив хирургия һәм топографик анатомия кафедрасында. 1885 тә чит илгә командировкага җибәрелә. 1886 дан мед. департаментының штаттан тыш мед. чиновнигы, бер үк вакытта 1892–1905 тә Казандагы Александровлар хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире. 1904 тә Маньчжуриядә Кызыл Хач җәмгыяте сан. отряды б-н җитәкчелек итә. Хезмәтләре кискен анемия турында газ алмашы, эндемик зоб, топографик анатомия мәсьәләләренә карый. К. Шамов хастаханәсен төзүдә (Казан шәһәренең 1 нче клиник хастаханәсе) катнаша. 2 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, Кызыл Хач медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Газообмен при острой анемии. К., 1910.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**КАНДАУ́РОВА** Галина Фёдоровна (20.10.1945, Оренбург өлкәсенең Бозаулык р-ны Редкодуб пос.), нефтьче-геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), ТР, РФнең атказ.

геологы (1993, 1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), «Татнефть» АҖдә эшли, 1981 дән «Лениногорскнефть» НГДУда баш геолог һәм идарә башлыгы урынбасары. Татарстан нефть чыганакларын ачуда, эзләнүдә, запасларны исәпләп чыгаруда һәм эшкәртү процессларын камилләштерүдә катнаша. Дәүләт бүләге авыр чыгарыла торган нефть ятмаларын эшкәртүнең югары нәтиҗәле комплекслы системасын эшләгәне өчен бирелә.

*Әд.:* Геологи-нефтяники в становлении и развитии нефтяной промышленности Татарстана. К., 2000.

**КАНДИ́ЛОВ** Валерий Петрович (1.8.1952, Питрәч р-ны Питрәч а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация (хәзер Казан техник ун-ты) (1975), Ташкент политехник (1978) ин-тларын тәмамлый. 1978–82 елларда Бөтенсоюз насослы машина төзелеше технол. фәнни-тикшеренү проектлары ин-тының бүлек мөдире урынбасары (Казан). 1982–86 да КПССның Идел буе райкомы инструкторы, КПССның Казан шәһәр ком-ты оештыру бүлеге мөдире урынбасары. 1986–91 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тының оештыру-партия эшләре бүлегендә мәгълүмат секторы мөдире. 1991–93 тә ТР Президенты Аппаратының мәгълүмат үзәге секторы мөдире. 1993–95 тә ТР ЮС секретариатының мәгълүмати тәэмин итү, 1995–98 дә ТР Дәүләт Советы аппараты эшләре идарәсенең Дәүләт Советы эшчәнлеген мәгълүмати-технол. тәэмин итү, 1998–2000 дә ТР Дәүләт Советы Аппараты эшләре буенча идарәнең эшчәнлеген мәгълүмати-техник тәэмин итү бүлекләре мөдире. 2000 нән ТР Статистика буенча дәүләт ком-ты, 2003–04 тә ТР Дәүләт стат. ком-ты рәисе. 2004–05 тә Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең ТР буенча җирле органы җитәкчесе. 2005 тән ТРның социаль-икътисади мониторинг ком-ты рәисе.

**КАНДЫ́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 64,2 *км*, ТР чикләрендә — 34 *км*. Бассейнының мәйданы 804,4 *км*$^2$. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап ага. Елга башы Оренбург өлкәсе терр-ясендә, тамагы Баулы р-нының Яңа Зареченский посёлогыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 119 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.ның 14 кушылдыгы бар, шуларның 6 сы ТР терр-ясендә, иң зурлары: Сула (33,6 *км*), Куй елгасы (11,4 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,24 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, яртысына якынын кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–10 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 170 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакыттагы уртача күпьеллык чыгымы 2,5 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Су ресурслары җирле хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**КАНЕ́ТОВ** Нурлан Исмәгыйль улы (12.3.1975, Казакъстан ССР, Уральск ш.), балет артисты, ТРның атказ. артисты (2003). 1993 елда Алма-Ата хореография уч-щесен тәмамлый. 1993–96 да Абай исем. Казакъстан дәүләт акад. театрында солист, 1996 дан Татар опера һәм балет театрында әйдәп баручы солист. Төп рольләре: Альберт («Жизель», А.Адан), Джеймс («Сильфида», Х.Левенсхольд), Зигфрид, Ротбарт («Аккош күле», П.Чайковский), Ромео («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Йосыф («Кыйссаи Йосыф», Л.Любовский), Красс («Спартак», А.Хачатурян), Арман («Камелияле ханым», Дж.Верди музыкасы) һ.б. Россия һәм чит илләр буйлап гастрольләрдә йөри (ш.и. Көнчыгыш һәм Үзәк Европа илләрендә Татар опера һәм балет театры труппасы составында, Израильдә һәм Испаниядә «Рус империя балеты» труппасы б-н). Хәзерге заман балет артистларының иң күренеклеләренең берсе. Югары бию хәрәкәтләренең нәфислегенә ия. Биючене зур осталык, хис, үзенчәлекле дәртлелек б-н башкару аерып тора. Л.Любовскийның «Кыйссаи Йосыф » балетында, хәзерге шартларда төп партияне башкаручы буларак, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә милли эпос традицияләре үсешенә өлеш керткән өчен РФ Дәүләт премиясе (2005) б-н бүләкләнә. («Восходящая звезда» номинациясендә «Балет», «Душа танца — 2003» ж-ллары призына лаек була).

*Ф.Ш.Салитова.*

**КА́НИЦ** Юлий Иванович, фон (якынча 1730 — 6.3.1781, Казан), педагог, төбәк тарихын өйрәнүче, әдәбиятчы, коллегия советнигы (1779). Остзея дворяннары нәселеннән. Шляхта кадетлар корпусын армия прапорщигы дәрәҗәсендә тәмамлый (1751); 1751–52 елларда хәрби хезмәттә. 1752 дән надворный советник чинында, подпоручик (1753 тән), Юстиц-коллегиянең Эстляндия һәм Лифляндия эшләре секретаре.

1764 тән Казан гимназиясендә директор (командир), аны оештыруга һәм үсешенә зур өлеш кертә: ул эшләгәндә гимназистларны тоту өчен акча арттырыла (1767 дән), директор хокуклары киңәйтелә; татар теле укытыла башлый (1769 дан); укучылар саны арта. К. укучыларның әхлакый тәрбиясенә игътибар бирә. «Файдалы китаплар уку турында, күңелләрне һәм гамәлләрне тәртипкә китерү турында» фәннәр кертелә. Гимназистлар катнашында театраль тамашалар — «Язмыш, Россия һәм Казан» прологы, А.П.Сумароковның «Синав һәм Трувор» трагедиясе (1765), «Ялганлы бирнә» (1771) һ.б. күрсәтелә. Җырлаучылар хоры булдырыла. Укытучыларның белемен һәм укыту осталыгын үстерү өчен ай саен әдәби-пед. әңгәмәләр уздырыла (1765–74, 1778–81). Ел саен тантаналы «нотык җыелышлары» оештырыла. К. берничә тапкыр гимназиядә укытуны камилләштерү проектларын тәкъдим итә, ләкин алар үтәлми. Бары тик гимназиянең устав һәм штат проектлары гына 1798 дә гимназиянең эшен яхшыртуда өлешчә нигез итеп алына.

К. «гимназия корпусын» (74 кеше — өлкән сыйныф укучылары, укытучылар һәм хезмәткәрләр) җитәкли һәм Е.И.Пугачёв гаскәрләреннән шәһәрне саклаганда яралана. Гимназияне яңадан элекке хәленә кайтарганда аеруча активлык күрсәтә: дәресләр 3 айдан соң ук башлана. Шушы вакыттан тарих буенча халык алдында лекцияләр укый башлый. 1777 дә гимназистлар җыенында «Казан губернасындагы табигый табылдыклар турында» — Кама елгасы буенда табылган билгесез хайванның мөгезе турында сөйли; бу хезмәте өчен аңа (гимназиянең эше һәм уңышлары турындагы хисабы б-н) Мәскәү ун-ты рәхмәт белдерә.

К. ярдәме б-н Венераның Кояш дискы аша узуын астрономик күзәтүләр башкарыла, аларның нәтиҗәләре «Московские ведомости»да басыла (1769, № 146, Өстәмәләр).

1778 дә риваятьләр, кулъязмалар һәм үз күзәтүләре нигезендә К. «борынгы Казан шәһәренә кыскача аңлатмалар һәм 1552 елда аны камау һәм яулап алуны тасвирлау» б-н шәһәрнең планын төзи, аннан тарихчылар Н.Г.Устрялов «Кенәз Курбский хикәятләре» («Сказания князя Курбского», СПб., 1833) һәм М.С.Рыбушкин «Казан шәһәренең кыскача тарихы» («Краткая история города Казани», 1834) хезмәтләрен язганда файдаланалар.

Немец телендә М.М.Херасковның «Россияда» (М., 1779) поэмасына тәнкыйди күзәтү ясый һәм 1779 да аны «Рижский журнал»да бастыра. Г.Р.Державин б-н актив языша. К.ның Казандагы Көчек-Кайнарҗир солыхы төзелү тантанасына багышланган кулъязмасы сакланган.

Х е з м.: Описание и изъяснение картин и эмблем на триумфальных вратах, в Казани построенных, для всевысочайшего прибытия Е.И.В.Екатерины Второй. М., 1767; Слово в публичном собрании при казанских гимназиях по восстановлении общего покоя говоренное 1775 года. М., 1775.

*Әд.:* О состоянии учебных в Казани заведений с 1759 по 1805 г. // Казан. вестник. 1828. № 39–50. Прибавление; В л а д и м и р о в В. Историческая записка о 1-й Казанской гимназии. Ч. 1. XVIII столетие. К., 1867; А р т е м ь е в А. Казанская гимназия в XVIII столетии. СПб., 1874.

*И.А.Новицкая.*

**КАНКА́ЕВ** Бәхтияр (? — ?), Е.И.Пугачёвның көрәштәше, баш күтәрүчеләр гаскәрләренең өлкән полковнигы. Күтәрелеш башланганчы Уфа өязенең Ака авылында яши. 1773 елның ноябрь–декабрендә баш күтәрүчеләр хәрәкәтенә кушыла. Башта — Красноуфимск кальгасы тирәсендә (Уфа өязе), 1774 нең апрель–маенда Көңгер өязендә хәрәкәт итә. Уфа һәм Көңгер өязләрендә баш күтәрүчеләр отрядларын җитәкли. 1774 нең июнь–июлендә Пугачёвның төп гаскәренең Красноуфимск кальгасыннан Казанга килүендә мөһим роль уйный; отрядлар туплый, Кама аша салынган кичүләрдә контроль урнаштыра, русларның җәза отрядларын күзәтүне оештыра. Казан өчен барган сугышлар вакытында К. отрядлары Пугачёв гаскәрләренең тылын саклый. 1774 нең 27 июлендә аның отряды

Җөри авылы (хәзер Мамадыш р-нында) янында тар-мар ителә. К. яңадан Келәүш авылы (хәзер Мамадыш р-нында) янында отряд туплый, әмма шунда тулысынча җиңелә. Берничә баш күтәрүче б-н кача. Алдагы язмышы билгесез.

*Әд.:* А л и ш е в С.Х. Бәхтияр Канкаев // Казан утлары. 1968. № 1; ш у л у к. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973.

**КАНЛУ́Т** (Chelidonium), мәк чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бердәнбер төре — зур К. (C. majus). Төньяк ярымшарның субарктик һәм уртача поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә барлык районнарда очрый. Буш җирләрдә, кисенделәрдә, ерганак буйларында, чүп үлән буларак паркларда, бакчаларда һәм торак яннарында үсә. 30–90 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры үзәк, кыска тамырчалы. Сабагы туры, тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, каурыйсыман бүленмә, өсте яшел, асты күксел.



Чәчәкләре сары, чатырсыман чәчәк төркемендә. Җимеше — кара көрән төстәге күпсанлы вак орлыклы кузаксыман тартмачык, сусыл үсентесе кырмыскалар өчен азык булып тора, алар исә, орлыкларны ташып, К.ның таралуына булышлык итә. Үсемлекнең бөтен өлеше дә кызгылт-сары сөтле сыекчалы. Июньнән сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июльдән өлгерә башлый. Үләнендә алкалоид, флаваноидлар, органик к-талар, дуплау матдәләре бар. Бәвел кудыру чарасы һәм бактерицид үзлекләргә ия. Халык медицинасында сөтле сыекча сөялләрне бетерү, җәрәхәт, яраларны, кайбер тире авыруларын дәвалау өчен кулланыла. Үләне инсектицид үзлеккә ия, яшелчә һәм бакча культуралары корткычларына каршы кулланыла. Агулы үсемлек.

**КАНОНЕ́РКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 34 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөздә нигез салына. Халкы башта алпавыт крәстияннәре катлавына керә, 1830 елларда дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. Игенчелек, терлекчелек, йөк ташу б-н шөгыльләнә, алпавыт утарларында көнлекчелектә эшли. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 578 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән — ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә р-нында. Халык саны: 1870 тә — 135, 1884 тә — 194, 1906 да — 378, 1913 тә — 413, 1920 дә — 534, 1926 да — 480, 1944 тә — 433, 1949 да — 303, 1958 дә — 211, 1970 тә — 143, 1979 да — 85, 1989 да — 46, 2002 дә — 31 кеше.

**КАНО́ННИКОВ** Иннокентий Иванович (16.5.1854, Иркутск ш. — 2.3.1902, Казан), химик-органик, химия д-ры (1884). А.М.*Зайцев* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1875), шунда ук эшли (бүленеп, 1884–86 елларда Мәскәү ун-ты профессоры), 1886 дан технол. каф. мөдире. Хезмәтләре органик химиягә, химик кушылмаларның оптик активлыгын өйрәнүгә карый. К. ацетилхлоридның бозлы серкә к-тасына тәэсире б-н серкә ангидридын ала. Матдәләрнең яктылыкны сындыру сәләте б-н аларның төзелеше арасындагы бәйләнешне өйрәнә. Эремәнең чагыштырма рефракциясе эреткеч һәм эрегән матдәләрнең чагыштырма рефракцияләре суммасына тигез булуын күрсәтә. Кайбер терпеннарның циклик төзелешен, малеин к-тасында икеләтә бәйләнеш, камфора һәм борнеол молекулаларында бициклик структура булуын ачыклый. Химик кушылмаларның оптик активлыгын һәм яктылыкны сындыру сәләтен өйрәнгән вакытта полярлашу яссылыгының әйләнү почмагы б-н сынган нурның иң кечкенә авышу почмагы арасындагы бәйләнешне таба. Катнашманың чагыштырма әйләнүе аның компонентларының чагыштырма әйләнү зурлыклары уртасы икәнлеген билгели.

Х е з м.: О соотношениях между вращательной и светопреломляющей способностью химических соединений // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Ч. хим. 1888. Т. 20, вып. 6, 9; 1890. Т. 22, вып. 2; Об удельном вращении виннокаменной кислоты и её солей // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. Ч. хим. 1890. Т. 22, вып. 5; Об истинной плотности химических соединений и её отношениях к их составу и строению. СПб., 1903.

*В.Г.Абзалова.*

**КАНСАУ́ әл-ГАУРИ́** (тулы исеме әл-Мәлик әл-Әшраф Байбарди әд-Дин Әбү ән-Насыйр Кансау әл-Гаури) (1440–1517), шагыйрь, дәүләт эшлеклесе. Төрки һәм гарәп телләрендә яза. 1501–17 елларда мәмлүкләр Мисыры хөкемдары. «Диван» («Җыентык»), «Әл-кәүкәб әд-дорри фи Әвҗибат әл-Гаури» («Гаури мәсьәләләренең якты йолдызлары»), «Әл-мөнакках әл-зариф әла мөвашшаһ» («Изге билгеләрне эченә алган ачык төзәтмәләр») исемле тезмә һәм чәчмә әсәрләр һ.б. авторы.

Х е з м.: И с л а м о в Р.Ф. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар. К., 1998; Z a j a c z k o w s k i A. Poczja stroficzne muvassah mameluckiego sultan Qansuh (Qansav) // Rocznik Orientalistyczny. Warsz., 1964.

*Р.Ф.Исламов.*

**КАНТО́Н** (франц. canton — округ), ТАССРда 1920–30 елларда адм.-терр. берәмлек. 1920 дә Татарстан терр-ясендә *өязләрне* алмаштыра. Башта 10 К.: *Арча кантоны* (Казан өязе җирләрендә), *Бөгелмә кантоны* (Бөгелмә өязе), *Буа кантоны* (Буа өязе), *Мамадыш кантоны* (Мамадыш өязе), *Минзәлә кантоны* (Минзәлә өязе), *Зөя кантоны* (Зөя өязе), *Спас кантоны* (Спас өязе), *Тәтеш кантоны* (Тәтеш өязе), *Чистай кантоны* (Чистай өязе җирләрендә) оештырыла. 1921 дә *Алабуга кантоны* (өлешчә Алабуга һәмм Сарапул өязләре волостьлары) төзелә; 1922 дә Алабуга К.ыннан *Чаллы кантоны* аерып чыгарыла. К. волостьларга бүленә. К.нар 1927–30 да ТАССРны районлаштыру барышында бетерелә (к. *Район*).

**КА́НТОР** Георгий Михайлович (20.6.1930, Рязань ш.), музыка белгече, педагог, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). 1955 елда Казан консерваториясен, бер үк вакытта Рязань пед. ин-тының тарих ф-тын читтән торып укып тәмамлый. 1955–59 да Рязань, 1959–60 та Казан музыка уч-щесендә, 1960–76 да Казан пед. ин-тында (1963–76 да музыка теориясе тарихы һәм музыка уен кораллары каф. мөдире), 1977–95 тә Казан консерваториясендә (1984–87, 1990–95 тә музыка тарихы каф. мөдире) укыта. Хезмәтләре төбәк музыкасына, музыка педагогикасына, фәнни библиография өлкәсенә карый. Фәнни җыентыклар төзүче һәм аларның мөхәррире. Музыка сәнгате тәнкыйтьчесе һәм публицист буларак чыгышлар ясый. Шулай ук лектор һәм концерт программаларын алып баручы буларак танылa. 1995 тән Израильдә яши.

Х е з м.: Казань музыкальная. К.-Йошкар-Ола, 1994; Татарский академический театр оперы и балета им. М.Джалиля. К., 1994 (автордаш); Музыкальный театр в Казани в XIX — начале XX веков. К., 1997; Литература о татарской музыке: Библиогр. указ. К., 1984; Музыковеды Казани: Библиогр. словарь. К., 2000.

*Әд.:* Ш а х н и н а Т. Георгий Кантор // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КАНТЮКО́В** Рәфкать Габделхәй улы (23.8.1953, БАССРның Эстәрлетамак р-ны Аллагуват а.), «Газпром» АҖнең «Трансгаз Казан» ҖЧҖ ген. директоры (1998 дән), техник фән. канд. (1999). Уфа нефть ин-тын (1986) һәм С.-Петербург халыкара менеджмент ин-тын (2001) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1970 елда Салават ремонт-механика з-дында (БАССР) токарь булып башлый. 1973–82 дә Салават нефть химиясе комб-тында автомобиль транспорты һәм механикалаштырылган эшләр цехы башлыгы урынбасары. 1989–98 дә «Ямбурггаздобыча» ҖБдә (Төмән өлкәсе): инженер, транспорт бүлеге башлыгы, ген. директор урынбасары (1991 дән). Ямбург һәм Заполярье конденсатлы нефть һәм газ чыганакларын файдалануны җайга салуда турыдан-туры катнаша. ТРда газ хуҗалыгын үстерүгә шактый зур өлеш кертә (шәһәр һәм авылларны газлаштыру программасы гамәлгә ашырыла; Уренгой-Ужгород, Казан–Түбән Новгород газүткәргечләре арасында технол. тоташтыру җайланмасы сафка баса). «Ел җитәкчесе» респ-ка бәйгесенең «Иң яхшы транспорт һәм юл хуҗалыгы җитәкчесе» номинациясендә җиңүче (2002). 1999 дан ТР халык депутаты. «Дуслык» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Компьютерное моделирование полей температуры и давления нестационарных турбулентных газовых течений в технологических трубопроводах // Хим. пром-сть. 1998. № 7 (автордаш); Применение вихревого аппарата для интенсификации процесса регенерации насыщенного раствора абсорбента // Хим. пром-сть. 1998. № 8 (автордаш).

*Әд.:* Солнце греет и ночью. К., 2000; Добрый след на земле. К., 2002.

**КАНУННА́Р МӘҖМУГАСЫ́** (1649) (патша Алексей Михайлович Мәҗмугасы), 17 йөз юридик ядкәре; рус феодаль хокукы кодексы. Мәскәүдә һәм Россиянең башка шәһәрләрендә булып узган халык күтәрелешләреннән соң 1648–49 елларда Земство соборы тарафыннан кабул ителә. К.м.н башында бояр кенәз Н.И.Одоевский торган махсус комиссия төзи. Россия дәүләтчелеге тарихында беренче тапкыр илнең иҗтимагый-сәяси һәм икътисади тормышының барлык даирәләрен колачлаган гамәлдәге бөтен хокукый нормаларның бердәм җыентыгын төзү омтылышы ясала. Мәҗмуганың чыганаклары сыйфатында Судебник (1550), Җирле, Земство, Юлбасарлык һ.б. приказларның фәрман кенәгәләре, патша фәрманнары, дума карарлары, Земство соборлары карарлары, Мәскәү һәм провинция дворяннарының, посад кешеләренең күмәк үтенечләре, Византия хокукы, Литва статуты (1588) һ.б. хезмәт итә. 1648–49 да Земство соборында Казан Спас-Преображение монастыре архимандриты Никон, Казан воеводасы бояр Г.И.Морозов, Казан дворяннары С.Змеев, С.Аристов, посад кешесе М.Ермолин, Зөя дворяннары У.Молоствов, И.Колодьин, посад кешесе О.Ульянов; Козьмодемьянск, Чабаксар, Царёвококшайск, Царёвосанчуринск, Цивильск һәм Урта Идел буеның башка шәһәрләреннән йомышлы һәм посад кешеләре җыела. Земство соборында рус булмаганнардан Рязаньнан килгән яңа чукындырылган (татар булуы мөмкин) В.Моратов кына катнаша. 1649 ның 29 гыйнварында Мәҗмуга текстын төзү һәм төзәтүләр тәмамлана, шул ук көнне ул патша һәм Земство соборы тарафыннан раслана.

Тарихи чыганак буларак К.м.ның әһәмияте шунда: ул бердәм Россия дәүләтенең кануннар җыелмасын булдыру процессына йомгак ясый. К.м. 17 йөздәге Россиянең иҗтимагый-икътисади һәм сәяси тарихы буенча мөһим мәгълүмат бирә. Мәҗмугада сословиеле-вәкиллекле монархиядән абсолютизмга күчү процессы чагыла; дәүләттә чиркәүнең роле билгеләп куела; дәүләт мөстәкыйльлеге, куркынычсызлыгы, гражданлык, хәрби бурыч, сәяси дәүләт җинаятьләре төшенчәләренә билгеләмә бирелә; матди һәм процессуаль хокук һәм мәхкәмә эшләрен башкару мәсьәләләре эшләнә. Мәҗмуга 25 бүлектән (һәрберсендә билгеле бер хокук бозу объекты карала), 957 маддәдән тора. Россия дәүләтенең күпмилләтле һәм күптөрле динле характеры кодексның дини даирәне һәм җир-хокук мөнәсәбәтләрен көйләү бүлекләрендә күбрәк чагыла.

К.м. Россиядә православие диненә рәсми дәүләт дине статусы билгеләп аны ныгыта, рус чиркәвенә миссионерлык эшчәнлеге алып баруда монополия бирә. 22 нче бүлекнең 24 нче маддәсе (нинди гаепләр өчен үлем җәзасы бирелүен, ә нindиләре өчен бирелмәвен билгели) рус кешеләрен ислам диненә күндерүче мөселманнарга карата яндырып үтерү җәзасын билгели. 20 нче бүлекнең 70 нче маддәсе (холоплар турында хөкем) рус кешеләренең чукынмаган чит ил кешеләрендә мәҗбүри рәвештә дә, үз теләге б-н дә холоплыкта булырга тиеш түгеллеген күрсәтә. Шул ук вакытта Мәҗмуга ислам динен билгеле бер юридик нормаларга нигезләнгән дини тәгълимат буларак таный. 10 нчы бүлекнең 161 нче (мәхкәмә турында) һәм 14 нче бүлекнең 3 нче (хач үбү турында) маддәләре мөселманнарның шәригать буенча ант итү хокукын таный һәм терки. 16 нчы бүлекнең 41–45 маддәләре (урыннардагы җирләр турында) Урта Идел буе халыклары: татар, мордва, чуаш, мари, удмуртлар җирләренең хокукый статусын билгели. Канун рус йомышлы кешеләренең боярлардан башлап барлык разрядларына да, рус булмаган феодалларның җирләрен төрле юллар б-н (сатып алу, алыштыру, аренда һ.б.) үзләренә алуны тыя; ясаклы халыкның җирләрен тартып алу да тыела. Нәтиҗәдә, Мәҗмуга элеккеге Казан ханлыгы халыклары яшәгән терр-ягә патша милке статусын беркетә. Патша хөкүмәте рус булмаган феодаллар катлавын төбәктә үзенең таянычы итеп күрергә омтыла. Морзаларда һәм йомышлы татарларда, дәүләт хезмәтен дәвам иттерү шарты б-н, аларга элегрәк бүлеп бирелгән бушап калган борынгы рус җирләре кабат калдырыла; үз җирләрен тәртиптә тотарга, башка шәһәрләргә һәм авылларга качмаска, хезмәтләрен ташламаска, үз җирләрендә һәм вотчиналарында яшәргә кушыла (дәүләт хезмәтен кире кагу, качу, җирләрне сату, биреп тору һ.б. юллар б-н алардан котылырга тырышу очракларында гаепплеләр җәзага тартыла).

К.м.да Урта Идел буе халыкларына карата 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөзнең 1 нче яртысындагы законнар гомумиләштерелә һәм системалаштырыла. Гомумән алганда, патша хөкүмәте сәясәте буенча аларның шул ук катлаудагы рус кешеләренеке кебек үк хокуклары булуы таныла, әмма берәр ситуациягә дини фактор йогынты ясаган очракта закон православие динендәге кешене яклый. Яңа чукындырылганнар самодержавиенең аерым мәрхәмәтенә лаек була: христианлыкны кабул итү гамәле җинаятьләр һәм гаепләр өчен җәзадан котылып калу, җир һ.б. милекне саклап калу мөмкинлеге бирә.

Мәҗмугада берничә маддә дәүләттә холоплар категориясен тулыландыруның бер чыганагы булып саналган Себер һәм Түбән Идел буе татарларына багышланган. 20 нче бүлекнең 117–118 маддәләре (холоплар турында) Себердә һәм Әстерхан төбәгендә «татарларны һәм татар улларын» сатып алуны рөхсәт итә (воеводалар һәм анда хезмәт итүче приказлы кешеләр генә бу хокуктан мәхрүм ителә). Сатып алынган татарлар б-н эш итү хокукы бик киң була: аларны васыять итәләр, бүләккә, бирнәгә бирәләр, саталар. Әгәр татарга ия булган кеше үз холопын чукындырса, ул аны сату хокукын югалта (үз холопын акчасыз гына бирү яки васыять итү хокуклары саклана). Кануннар б-н христиан булмаган холопларның хокукый хәле христиан холопларныкыннан азрак көйләнә, һәм бу канун бозу ихтималлыклары тудыра.

К.м. 17 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башы дәвамында бик күп аңлатмалар, үзгәрешләр б-н тулыландырыла, ш.и. татар халкына кагылышлы кануннар да үзгәртелә. Мәҗмуга 1832 гә кадәр илнең төп канун кодексы булып кала, М.М.Сперанский җитәкчелегендә Россия кануннарын кодификацияләү кысаларында шул елда Россия империясенең Кануннар җыелмасы эшләнә.

*Әд.:* Тихомиров М.И., Епифанов П.П. Соборное уложение 1649 г. М., 1961; Маньков А.Г. Уложение 1649 года — кодекс феодального права России. Л., 1980; Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002; шул ук. Татары Среднего Поволжья в Соборном уложении 1649 г. // Источники и исследования по истории татарского народа: Материалы к учеб. курсам. К., 2006.

*А.И.Ногманов.*

**КАНЧУ́РИН** Әсәд Хөсәен улы (1928), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1963), проф. (1964). А.Д.*Адо* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1953), Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1968–74 елларда СССР МФАнең И.И.Мечников исем. микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). Хезмәтләре аллергологиягә карый (йогышлы һәм аутоаллергологик этиология). К. мөһим аллергеннар төркемен (тузан, серкә, азык, бактерияле, вируслы һ.б.) өйрәнә һәм җитештерү технологиясен эшли, алар гамәлгә кертелә һәм авыруларга диагноз куюда, дәвалауда кулланыла.

**КАНЭЧКЕ́Ч ОЗЫНБОРЫННА́Р** (Culicidae), парканатлылар отрядының чын озынборыннар семьялыгы. 3 ассемьялыкны үз эченә ала: Anophelinae, Culicinae, Toxochynclitinae. 2,5 меңгә якын төре билгеле, Россиядә 82 төре бар. Татарстанда К.о.ның 35 төре һәм 3 астөре яши; 2 төр — Anophelinae ассемьялыгына, калганнары Culicinae ассемьялыгына керә.

Гәүдәсенең озынлыгы 4 тән 12 *мм* га кадәр. Сары, соры, коңгырт төстә. Авыз аппараты — чәнчеп суыра торган хортумчык. Башында бер пар фасетлы күзләр. Корсагы 10 сегменттан тора, күкрәге киңрәк. Аяклары озын. К.о.ның үсеше тулы әверелешле (йомырка, личинка, курчак һәм олы бөҗәк фазалары). Ата затлар — үсемлек согы, аталанган аналар кан б-н туклана. Кан суырган ана зат агымсыз яки акрын агучы сулыкларга: күл, сазлык, буа, су үсемлекләре күпләп үскән аз сулы елгаларга һәм сусаклагычларга 120 дән 400 гә кадәр йомырка сала. Йомыркалардан чыккан личинкалар органик калдыклар, бактерияләр, микроскопик суүсемнәр б-н туклана; үсү дәверендә 3 тапкыр кабыгын сала. Соңгы стадиясендә личинкалар хәрәкәтчел курчакка әверелә; ул су өслегенә күтәрелә, тышча ертыла һәм аннан олы озынборын чыга. К.о. эңгер-меңгердә актив: активлыкның 1 нче «пигы» таң атканда, 2 нчесе (иң күбе) кич б-н күзәтелә. Олы озынборыннарның гомер озынлыгы 2–3 атнадан (ата затлар) алып 2 айдан күбрәккә (ана затлар) сузыла. Шушы вакыт эчендә ана затлар 1 дән 4 кә кадәр гонотрофик цикл үтәргә мөмкин, хуҗасына һөҗүм итеп, һәрбер кан суырудан соң йомыр-

ка сала. Шулай итеп, майдан сентябрьгә кадәр сезонлы активлык чоры дәвам итә. К.о.ның күпчелеге аталанган ана зат яки йомырка фазасында кышлый. Үзәктән җылытылучы күпкатлы биналарда озынборыннар кышкы чорда да активлыкны югалтмый. Су саркып тору яки грунт сулары фильтрациясе нәтиҗәсендә подвалларда күлләвекләр хасил була, анда исә озынборыннарның личинкалары үрчи. Җилләтү системасы буенча Culex pipiens molestus озынборыннарының ана затлары кешеләр торагына очып керәләр. Татарстан терр-ясендә К.о. парканатлы паразитлар арасында черкиләрнең төп компонентын (80%) тәшкил итә. ТРда 4 сусаклагыч төзелү озынборыннарның төр составын үзгәртми, әмма аларның саны шактый арта. К.о. вируслы, бактериаль, протозой, гельминтоз авыруларын һ.б. тарата. Кешегә авыру йоктыра торган озынборыннарның эчке сәбәпләр аркасында 50 дән артык вирус б-н агулануы ачыкланган. ТР галимнәре тарафыннан талпан энцефалиты вирусы циркуляциясендә, сусаклагычлар барлыкка килгәннән соң, Көнбатыш Нил һәм Синдбис йогышлы бизгәк вируслары учакларының формалашуында К.о.ның катнашы барлыгы исбатлана.

*Әд.:* Практическая паразитология. Л., 1977; Л ь в о в Д.К., К л и м е н к о С.М., Г а й д а м о в и ч С.Я. Арбовирусы и арбовирусные инфекции. М., 1989; Паразитология и инвазионные болезни животных. М., 2000; Природные очаги зооантропонозов трансформированных ландшафтов Республики Татарстан во второй половине XX века. К., 2001. *В.А.Бойко.*

**КАНӘЧКЕЧЛӘ́Р** (Hippoboscidae), парканатлылар отрядыннан түгәрәк бөҗралы кыска мыеклы чебеннәр семьялыгы. Дөнья фаунасында 200 дән артык төр исәпләнә, Россиядә 40 ка якын. Кошларда һәм имезүчеләрдә яши, аларның каны б-н туклана. Олы бөҗәкнең гәүдәсе 3–12 *мм* озынлыкта, яссы, тыгыз; аякларындагы тырнаклары хуҗаның йонына һәм каурыйларына ябышып торырга ярдәм итә. К.нең күбесе канатлы, әмма канатлары үсеш алмаган, канатсыз төрләре дә очрый. Ана чебеннәр берәр зур личинка сала, ул исә хуҗасы тәненнән башка гына курчаклана. Татарстан терр-ясендә кошларның 100 дән артык төрендә паразитлык итүче К.нең 4 төре билгеләнгән. Аеруча күп санлы төре — Ornithomya avicularia; майдан октябрьгә кадәр кошларда күренә, июльгә «пик» саны туры килә. Атларда, сирәк кенә мөгезле эре терлектә ат К. (Hippobosca equina), поши, кәҗәболаннарда болан К. (Lipoptena cervi), сарыкларда канатсыз йонкояр (Melophagus ovinus) паразитлык итә.

К. терлекчелеккә зыян китерә: мәс., сарыкларның күпләп (бер сарыкка 100 дән артык паразит) зарарлануы уртача көнлек артымны 13,4% ка, йон алуны 20% ка киметә. К.нең тешләве хайваннарны тынычсызлый. А.х. терлекләре арасында К.нең бруцеллёз, түләмә авыруларын йоктыру ихтималы хакында хәбәрләр бар. *В.А.Бойко.*

**КАПЕЛЮ́ШНИК** Нина Лазаревна (5.11.1925, Белоруссия ССРның Витебск ш.) акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1981), СССР сәламәтлек саклау отличнигы (1978), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). 1948 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе) акушерлык-гинекология клиникасында эшли, 1980–97 дә акушерлык һәм гинекология каф. мөдире, 1997 дән 1 нче каф. профессоры. Хезмәтләре хатын-кыз җенси әгъзалары зәгыйфьләгән һәм хатын-кызларның бала тудыру сәләте бозылуын дәвалауга карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Табибләр өчен уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Гинекология детского возраста. К., 1976; Хирургические методы лечения трубного бесплодия. Л., 1989.

**КАПИТАЛИ́ЗМ** (лат. capitalis — төп), хосусый милеккә һәм базар икътисадына нигезләнгән җәмгыять тибы. Иҗтимагый фикернең төрле агымнары тарафыннан ирекле эшмәкәрлек системасы, индустриаль җәмгыять үсеше этабы, ә хәзерге К. сыйфаты — «катнаш икътисад», «постиндустриаль җәмгыять» һ.б. билгеләмәләр б-н аңлатыла; марксистик-ленинчыл историографиядә К. — җитештерү чараларына хосусый милеккә һәм яллы хезмәтне файдалануга нигезләнгән иҗтимагый-икътисади формация дип аңлатыла.


Россиядә рев-циягә кадәрге К. үсешендә 2 төп чор аерып күрсәтелә: 1) 17 йөз башыннан 1861 елга кадәр — капиталистик мөнәсәбәтләр урнашу, капитал туплану; 2) 1861–1917 еллар — җитештерүдә капиталистик ысулның ныгып урнашуы һәм хакимлек итүе. Башлангыч чорда, крепостнойлык хокукы өстенлек итү нәтиҗәсендә, Россиядә К. акрын үсә. К. барлыкка килү өчен товар җитештерүнең һәм эчке базарның чагыштырмача киң үсеш алуы алшарт булып тора. 17 йөз башында капиталистик җитештерү ысулына нигезләнгән беренче пр-тиеләр — гади капиталистик кооперация тибындагы остаханәләр һәм *мануфактуралар* оеша. 17 йөз ахырында Россиядә 40 лап мануфактура исәпләнә, К. үсеше өчен Петр I реформалары зур әһәмияткә ия була. Шул чорда ирекле эшче куллар җитмәү проблемасы өлешчә чишелә. 1721 елгы Фәрман б-н пр-тиеләрдә эшләү өчен сәүдәгәрләргә крепостной крәстияннәрне сатып алырга рөхсәт бирелә. (к. *Посессион крәстияннәр*). Эшче куллар кытлыгы крәстияннәрнең *хуҗалыктан читкә китеп эшләве* арту хисабына да хәл ителә. 18 йөзнең 2 нче яртысында феодаль-крепостнойлык мөнәсәбәтләре хөкем сөргән шартларда капиталистик тормыш рәвеше барлыкка килә.

17 йөздә Казан губернасында вак товар җитештерү үсеше күзәтелә: Казанда, Кукмарада, Спаста һ. б. авылларда беренче мануфактуралар оеша. Казанның Мәскәү, Урал, Себер, Урта Азия б-н багланышлар алып барган зур төбәкнең үзәге булуы биредә капиталистик мөнәсәбәтләр үсешенә этәргеч бирә. 1646 елгы халык санын алу кенәгәсендә Казанда ялланып эшләүчеләр хезмәте файдаланылган 30 остаханә булуы күрсәтелә. 18 йөздә капиталистик мөнәсәбәтләр а. х. нада үтеп керә. Алпавытлар аракы з-длары, киндер, постау, он тарту пр-тиеләре һ. б. ны ачалар. 18 йөздә Казан губернасында сәнәгать үсеше үзенчәлеге — эре мануфактура пр-тиеләренең (к. *Казан Адмиралтействосы, Казан постау мануфактурасы, Помпа каеш-күннәре заводы*) дәүләт тарафыннан нигезләнүенән гыйбарәт. Төбәк сәнәгате өчен бакыр кою тармагы (к. *Бакыр кою заводлары*) зур әһәмияткә ия була, аның продукциясе казна тарафыннан хәрби максатларда сатып алына. Сәүдәгәр һәм крәстиян пр-тиеләре, кагыйдә буларак, яллы хезмәт куллана. Сәүдәгәрләр (И.А.Михляев, И.Ф.Дряблов, Л.Ф.Крупеников һ.б.) актив рәвештә сәнәгый җитештерүгә акча кертәләр һәм шул юл б-н төбәктә сәнәгать буржуазиясе барлыкка килүгә этәргеч бирәләр.

19 йөз уртасына игенчелек элеккечә үк төбәк халык хуҗалыгының төп тармагы булып кала бирә; Казан губернасы халкының 95,7% ын крәстияннәр тәшкил итә, ел саен губернадан 20–30 млн. пот икмәк чыгарыла. Алдынгы карашлы алпавытлар — Геркеннар, Чертовлар, Дадьяннар, Лебедевлар, Тилле, Молоствовлар һ.б. хуҗалыкларның товарлыклылыгын күтәрү максатында капиталистик җитештерү ысулларына күчәләр, яңа чәчү әйләнешләрен гамәлгә кертәләр, сортлы орлыклар кулланалар, нәселле терлекләр үрчетәләр. Авыл хуҗалыгы, аның товарлыклылыгы һәм көндәшлеге үсешенә ярдәм итү өчен *Казан икътисадчылар җәмгыяте* оештырыла. Товар-акча мөнәсәбәтләре үсеше авылда крәстияннәрнең катлауларга бүленү процессын көчәйтә. Ел саен төбәктә хуҗалыктан читкә китеп эшләүче крәстияннәрнең саны 100 мең кешедән артып китә, һәр ел Иделгә генә дә 20 меңләп крәстиян бурлаклык хезмәтенә килә (к. *Бурлаклар*). 19 йөздә губерна авылларында яллы хезмәттән файдаланучы остаханәләр күбәя. Еш кына авыл тулысынча берәр төрле әйбер җитештерү б-н шөгыльләнә: мәс., Чабакса авылында — тарантаслар, Балык Бистәсендә зәргәрчелек эшләнмәләре ясыйлар һ. б. (к. *Халык нәфис кәсепчелеге*). Сәнәгатьтә 19 йөздәге мөһим үзгәрешләр 1830–40 елларда башланган сәнәгать борылышы б-н бәйле: кул хезмәтенә нигезләнгән мануфактураны фабрика-завод производствосы алыштыра башлый (к. *Индустрияләштерү*).Сәнәгать борылышы җитештерүнең төрле тармакларында төрле вакытта башлана. Җиңел сәнәгатьтә ул аеруча киң колач җәя. Казан губернасында машина техникасы беренче чиратта химия сәнәгате пр-тиеләрендә, аерым алганда, бертуган Крестовниковларның сабын кайнату з-дында кулланыла (1855). 1865 тә И.И.Алафузов Казанда заманча машиналар б-н җиһазландырылган эрләү-туку ф-касы, ш.у. күн эшкәртү з-ды ача. 1860 елларда «Кавказ вә Меркурий» җәмгыяте пароходлар төзи башлый. Хезмәт базары да үсә: 1850 еллар ахырында Казанда гына да 3764 ирекле яллы эшче, 12448 хуҗалыкта эшләүче һәм көнлекче крәстиян исәпләнә; өязләрдәге мануфактураларда — 2 меңләп, урман кисү-әзерләү тармагында — 30 мең чамасы эшче, суднолар төзүдә һәм суднолар йөртү эшендә 40 меңнән артык кеше эшли; губернаның барлык эшче көчләр базары 100 меңнән артык кеше тәшкил итә. Ләкин,



Н.М. Капитонов.



П.Л. Капица.

Россиянең үзәк районнары б-н чагыштырганда, төбәкнең сәнәгый үсеше түбәнрәк темпларда бара: 19 йөз башында сәнәгый продукция җитештерүдә Казан губернасы Россия буенча — 7 нче, 1860 еллар тирәсендә 14 нче урынны били. Казан губернасының өяз шәһәрләреннән Чистайда гына берничә эре пр-тие була, анда 100 дән артык кеше эшли (сәүдәгәр Лаврухиннарның, мещан Жокеевның, ш.у. Е.П. һәм А.Я.Логутовларның капчык-чыпта сугу з-длары).

1860–70 еллардагы буржуаз реформалар Россиядә К. ның үсешенә этәргеч бирә. Крепостнойлык хокукы бетерелү б-н *эшчеләр сыйныфы* формалашу өчен алшартлар туа. Бу чорда К. үсешенең үзенчәлеге — крепостнойлыкның кайбер калдыклары сакланган шартларда икътисадның күп укладлы булуы. Сәнәгатьтә К. ның чагыштырмача үсеш алган формалары илнең гомуми икътисади артталыгы б-н бергә бара. Күп кенә авыл районнарында К. га кадәрге мөнәсәбәтләр өстенлек итә. Җитештерүнең һәм капиталның туплануы монополистик капитал оешуга китерә, капиталистик кредит системасы барлыкка килә. 1870–90 елларда Казан эшкәртү сәнәгатенең әйдәп баручы тармакларында фабрика-завод җитештерүенә күчеш төгәлләнә. Ирекле яллы хезмәткә нигезләнгән машина индустриясе примитив кул хезмәтен һәм бәйле хезмәтне кысрыклап чыгара. 1879 да Казанда гына да фабрика-завод тибындагы — 69, 1884 тә 91 пр-тие исәпләнә. Аларның саны арту сәбәпле, сәнәгать пролетариаты ишәя бара. 1879–1903 тә Казанда эшчеләр саны ике тапкыр — 4081 кешедән 8436 кешегә кадәр арта. Нәселдән килгән пролетарийлар катлавы барлыкка килә. 19 йөзнең 1 нче яртысыннан губернада банк капиталы да үсеш ала. Бер үк вакытта диярлек берничә эре банк (*Казан шәһәр җәмәгать банкы*, Дәүләт банкының Казан бүлекчәсе, *Сәүдәгәрләр банкы*, *Идел-Кама банкының* Казан бүлекчәсе), ш.у. күп кенә хосусый банклар һәм конторалар ачыла. 19–20 йөзләр чигендә җитештерү аерым кулларда һәм үзәкләрдә туплана, ул банк капиталы б-н тыгыз бәйләнештә була. Төбәктә монополистик К. ның төп чагылышларының берсе буларак, төрле типтагы күпсанлы АҖлар барлыкка килә. Казанда шундый җәмгыятьләр реформалар чорында нигезләнә («Бертуган Крестовниковларның фабрика-сәүдә ширкәте», «П.К.Ушковның химия заводлары ширкәте», «Алафузовлар фабрикаларының сәүдә-сәнәгать җәмгыяте», «Иван Стахеев һәм Ко»). Татар буржуазиясе арасында да капиталларның үзара бәйләнеше киң колач ала, эре акц. җәмгыятьләреннән пайларга нигезләнгән «Әхмәтҗан Сәйдәшев уллары белән һәм Бакый Субаев» сәүдә-сәнәгать ширкәте (устав капиталы 500 мең сум, Казанда чәй һәм шикәр сату буенча монополист), «И.Арслановның сабын кайнату һәм глицерин заводы ширкәте», «Казан мануфактурасы ширкәтенең бәз ману фабрикасы һәм Үтәмишевның сабын кайнату заводы һәм Ко» аерылып тора. Сәүдәгәрләр һәм сәнәгатьчеләр еш кына эре банклар әгъзалары һәм аларны оештыручылар булалар. Тимер юллар төзелү һәм Казанның 1893 елда тимер юллар челтәренә кертелүе икътисадның тиз үсеше өчен шартлар тудыра. 1900 да Казан губернасында — 234, 1904 тә 326 пр-тие исәпләнә. Пролетариатның саны ишәя: 1900 дә — 13937, 1904 тә — 15018 кеше. Хезмәт җитештерүчәнлеге сизелерлек арта; 1900 дә капиталның гомуми суммасы — 16488151 сум, 1904 тә 21644274 сум тәшкил итә. Россиядә К. үсеше Окт. рев-циясе һәм *«хәрби коммунизм»* сәясәтен гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә туктала. Базар икътисадының кайбер элементлары кыска гына вакытка *яңа икътисади сәясәт* (НЭП) елларында торгызыла, ләкин 1930 еллар башына НЭП бетерелә.

20 йөз башында дөньяның үсешкә ирешкән илләрендә тотрыклы социаль структура оеша, анда, эре милекчеләр һәм яллы хезмәтчеләр б-н бергә, урта сыйныф та зур үсеш ала. Базар көндәшлегенең хәзерге формалары дәүләтнең җайга салу механизмнары аша тулыландырыла. 1980–90 елларда Россиядә базар икътисадына күчеш гамәлгә ашырыла.

*Әд.:* Обзор Казанской губернии за 1900. К., 1901; Обзор Казанской губернии за 1904. К., 1905; Х а с а н о в  Х. Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; История Казани. К., 1988. Кн. 1; С в е р д л о в а  Л. М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991; З о р и н  А. Н. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

*И.М.Мөлеков.*

**КАПИТО́НОВ** Николай Михайлович (14.12.1927, хәзерге Теләче р-ны Шармыш а. — 5.1.2009, шунда ук), авиация техникы, слесарь-җыючы, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1 нче Вольск хәрби техник уч-щесен тәмамлый (1956). 1943–47 елларда Теләче р-нының Шармыш авылы сәнәгать комб-тында тимерче булып эшли. 1948–58 дә Совет Армиясендә хезмәт итә. Авиация техникасына хезмәт күрсәткәне өчен исемле сәгать б-н бүләкләнә, бүләкне аңа өч тапкыр Сов. Союзы Герое, дивизия командиры И.И.Кожедуб тапшыра (1954). 1958–90 да Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсендә слесарь-җыючылар бригадиры. Бөтенсоюз уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыятенең үзәк советы әгъзасы (1978–88). 100 рационализаторлык тәкъдиме авторы, аларны гамәлгә кертү хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруны, югары икътисади нәтиҗәгә ирешүне тәэмин итә. Герой исеме бишьеллык планны (1966–70) үтәгәндәге казанышлары һәм яңа эшләнмәләр җитештергәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КАПИТО́НОВА** Нина Петровна (16.1.1938, Мордва АССРның Сысов кордоны), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Ленинград а.х. ин-тын тәмамлый (1960). 1961–73 елларда һәм 1974 тән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, үсемлекләрне саклау лаб-ясе мөдире (1962 гә кадәр). 1973–74 тә Республика үсемлекләрне саклау станциясендә баш агроном. Салкынга һәм корылыкка чыдам көзге «Казан 84», «Мишә 2» (Дәүләт бүләге), «Казан 285» һәм язгы «Керба» бодай сортлары авторларының берсе. Хезмәтләре а.х. культураларының вируслы авыруларга һәм селекция ярдәмендә бодайның биотик стрессларга чыдамлылыгын арттыру мәсьәләләренә карый.

**КАПИ́ЦА** Пётр Леонидович (8.7.1894, Кронштадт ш. — 8.4.1984, Мәскәү), физик, түбән темп-ралар физикасына һәм көчле магнит кырлары физикасына нигез салучылардан берсе, филос. д-ры (1923), физика-матем. фән. д-ры (1928), СССР ФА академигы (1939; 1929 елдан мөхбир әгъза), ике тапкыр Соц. Хезмәт Герое (1945, 1974). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Политехник ин-тны тәмамлаганнан соң (Петроград, 1918), шунда ук эшли. 1921 дә Бөекбританиягә фәнни командировкага җибәрелә һәм анда физик Э.Резерфорд җитәкчелегендә тикшеренүләр үткәрә; 1924–32 дә Кембридж ун-тының Кавендиш лаб-ясендә директор урынбасары, 1930–34 тә Монд исем. лаб. директоры. 1935–46 да һәм 1955 тән СССР ФАнең үзе нигез салган Физик проблемалар ин-ты директоры. Фәннәр академиясенең эвакуациясе чорында (1941–43) Казан ун-тында эшли. Бу елларда К. җитәкчелегендә һәм аның турыннан-туры катнашы б-н металлургия, химия сәнәгате һәм энергетика тармакларына зур күләмнәрдә кислород табу өчен сәнәгый җайланмалар төзү буенча күп кенә мөһим эшләр башкарыла. 1947 дән Мәскәү физика-техника ун-ты профессоры.

1924 тә үтә көчле магнит кырлары булдыруның импульслы алымын тәкъдим итә һәм 320 *кГс* ка кадәрле кырлар тудырыла торган җайланма төзи. 1928 дә көчле магнит кырларында күп кенә металларның электр каршылыгы кырның көчәнешлелеге б-н сызыкча бәйлелектә икәнлеген (Капица законы) ача. 1938 дә сыек гелийның үтә агучанлыгын ачып (СССР Дәүләт бүләге, 1943), каты җисемнән (мәс., көпшә стеналарыннан) сыек гелийга җылылык күчергәндә бүленеш чигендә темп-ра сикереше барлыкка килүне (Капица темп-ра сикереше) күрсәтә. 1939 да югары нәтиҗәле турбодетандерда түбән басымнар циклы ярдәмендә һава сыегайтуның яңа алымын эшли (СССР Дәүләт бүләге, 1941), бу алым зур күләмнәрдә газ халәтендә һәм сыек кислород табуда киң кулланыла. 1950–55 тә яңа типтагы үтә югары ешлыклы генераторлар — 300 *кВт* ка кадәр егәрлекле (өзлексез

режимда) планотрон һәм нитотрон уйлап таба һәм эшли; тыгыз газларда югары ешлыклы бушану вакытында тотрыклы плазма шнур хасил булуын һәм анда электроннарның темп-расы $10^5$-$10^6$ К булырга тиешлеген ачыклый. Әлеге хезмәт (1969 да басыла) идарә ителүле термотөш синтезын гамәлгә ашыру өлкәсендә яңа юнәлеш ача. Түбән темп-ралар физикасы өлкәсендә фундаменталь тикшеренүләре өчен Нобель бүләгенә лаек була (1978). «Журнал экспериментальной и теоретической физики» басмасының баш мөхәррире (1955 тән). Пагуош хәрәкәтенең Милли ком-ты советы әгъзасы. Лондон король җәмгыяте (1929), АКШ Милли фәннәр академиясе (1946), Дания корольлеге (1946), Польша (1963), Швеция корольлеге (1966) академияләре һәм күп кенә башка чит илләрнең фәнни җәмгыятьләре әгъзасы. Биш Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең М.В.Ломоносов исем. алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электроника больших мощностей. М., 1962; Жизнь для науки. М., 1965; Теория, эксперимент, практика. М., 1966; Физические задачи. М., 1972.

*Әд.:* Академик Пётр Леонидович Капица (к 60-летию со дня рождения) // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1954. Т. 27, вып. 3; А л е к с е е в с к и й Н.Е. Пётр Леонидович Капица (к 70-летию со дня рождения) // Успехи физ. наук. 1964. Т. 83, вып. 4.

*М.С.Таһиров.*

**КАПКА́** (утар капкалары). Татарлар яшәгән утарларда, шәһәрләр һәм авылларда, гадәттә, урам ягындагы такта койма уртасына, 3–4 биек баганага беркетелеп, ике якка ачыла торган такта капкалар куела. Кечкенә К.ны зур К. б-н янәшә итеп яки ике якка ачылмалы К.ның бер ягын тишеп ясыйлар. Традицион татар капкасы баганаларының өске өлешен ачык калдыралар яисә а́рка рәвешендәге борыс б-н тоташтыралар. 18 йөз ахырыннан руслар үрнәгендәге (рус капкасы) — өсте ике кыеклы итеп ябылган К.лар кую гадәткә керә. 19 йөздә К.ларның бизәлешенә, йорт, коймалар һәм К.ны бер стильдә эшләүгә зуррак игътибар бирелә башлый. Уентылы һәм тоташ уеп бизәкләүне контурлы уеп бизәкләү техникасы кысрыклап чыгара; К. баганаларына һәм капкачларына ромблар, өлешчә һәм тулы соляр фигуралар (кояш рәвешендә) һ.б.ны ябыштырып бизәү таралыш ала. 19 йөз ахырыннан К.ларны йорт фасады төсләренә туры китереп, төрле төсләргә буяу (ак, зәңгәр, кызыл, сары, яшел), «балкыш» сурәтләре, чәчәксыман бизәкләр б-н нәкышьләү киң җәелә. Татар авылларында 1960 елларның уртасына кадәр авылга кергәндә бик биек булмаган К.лар — киртәләрдән эшләнгән кысалы рәшәткәле капкалар («җил капка», басу капкасы, кыр кабагы) очрый. Заманча төзелгән утарларга керү юлында еш кына рус К.лары куела, аларны уеп бизәкләү, рәсемнәр төшереп бизәү (чәчәк-үсемлек композицияләре) кулланыла. Татар К.лары кую да дәвам итә, биек һәм тәбәнәк, кайчак металл кысаларга тарттырып, баганалары урынына металл торбалар куеп яисә кирпеч өеп, төрле төстәге һәм чүкеп ясалган бизәкләр кулланып эшләнгән К.лар игътибарны җәлеп итә. Татар халкының тарихи төзелеш һәм һөнәрчелек үзәкләре — Арча, Әтнә, Балтач, Яшел Үзән, Кукмара р-ннарындагы утар К.лары милли бизәлеш сәнгатенең иң камил үрнәкләре булып санала.



Татар йорты капкасы үрнәге. Казан арты. 20 йөзнең 1 нче яртысы. Ф.Х.Вәлиев реконструкциясе. Кәгазь, акварель. 1960 еллар.



Авыл йорты капкасы. Залесный посёлогы (хәзер Казанның Киров р-ны). 1970 еллар.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; В а л е е в Ф.Х. Архитектурно-декоративное искусство казанских татар (сельское жилище). Йошкар-Ола, 1975.

**КАПКА́ЕВ** Радик Абдулла улы (9.11.1928, Ташкент), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1973). проф. (1974), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). 1953 елда Ташкент мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, курслар мөдире (1974 тән), 1976 дан тире һәм венерик авырулар каф. мөдире, 1970–80 дә декан, 1987–90 да проректор. Хезмәтләре сифилис эпидемиологиясенә, клиникасына һәм аны дәвалауга карый. К. тәҗрибә юлы б-н сифилис авыруын өйрәнә (иммунология, патоморфология), экземалар, аллергик дерматитларны дәвалау ысулларын эшли. СССР Дерматологлар җәмгыяте әгъзасы. РФ Дерматологлар җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1993).

Х е з м.: Экзема. Таш., 1979; Диспансеризация кожных и венерических больных. Таш., 1989; Справочник дерматовенеролога. Таш., 1992.


**КА́ППЕЛЕР** (Kappeler) Андреас (20.9.1943, Швейцария, Винтертур ш.), тарихчы, филос. фән д-ры (1969), проф. (1982). Цюрих һәм Вена ун-тларын тәмамлый (1969). Цюрих (1970–82) һәм Кёльн (1982–98) ун-тларында эшли, 1998 елдан Вена ун-тында (Көнчыгыш һәм Көньяк-көнчыгыш Европа ин-ты директоры). Хезмәтләре — немец чыганаклары буенча Россиянең Иван IV чорына, борынгы заманнардан алып 19 йөз уртасына кадәр Урта Идел халыклары тарихына, Россиядәге милләтләр һәм милли мәсьәләләргә, Украина тарихына, Россия-Украина мөнәсәбәтләренә, Украинадагы милли хәрәкәтләргә карый. Урта Идел халыклары тарихына багышланган түбәндәге хезмәтләре бар: «Совет фәнни-тикшеренү хезмәтләрендә Урта Идел халыклары (татар, чуаш, мари, удмуртлар) этногенезы» («Cahiers du monde russe et sovetigue» ж-лы, Париж, 1976), «Совет тикшеренүләрендә X йөздән алып XIX йөзнең 2 нче яртысына кадәр Урта Идел халыклары тарихы» («Jahrbücher für Geschichte Osteuropas», Мюнхен-Висбаден еллык ж-лы, 1978), «Россия империясе мөселманнарына карата патша сәясәте» («Die Muslime in der Sowjetunion und in Jugoslawien» җыентыгы, Кёльн, 1989). «16 йөздән 19 йөзгә кадәр Россиянең беренче милләтләре: Патша империясе һәм Урта Идел халыклары» («Russlands erste Nationalitäten: Das Zarenreich und die Völker der Mittleren Wolga vom 16 bis 19 Jahrhundert», Köln–W, 1982) монографиясе К.ның иң зур хезмәтләреннән санала.

Х е з м.: Regionalismus und Nationalismus in Russland. Baden-Baden, 1966; Ivan Groznyj im Spiegel der auslandischen Druckschriften seiner Zeit: Ein Beitrag zur Geschichte der westlichen Russlandbildes. Bern–Fr./M., 1972; Kleine Geschichte der Ukraine. Munch., 1994; Russische Geschichte. Munch., 1997; Der schwierige Weg zur Nation. Beitraage zur neueren Geschichte der Ukraine. W.–Köln–Weimar, 2003; Россия — многонациональная империя: Возникновение. История. Распад. М., 2000.

*Әд.:* Д и м и т р и е в В.Д. О трудах швейцарского историка А.Каппелера по истории народов Среднего Поволжья с древних времён до середины XIX в. // Из истории дореволюционной Чувашии. Чебоксары, 1992.

*И.А.Гыйләҗев.*

**КАПТЫРМА́**, элмәк һәм эләктергечтән торган төймәләү җайланмасы, ш.у. элегрәк татарларда популяр булган эләктергеч прәшкә рәвешендәге зәркән бизәмә. К. татар милли киеменең иң таралган бизәнү әйберләреннән санала. Формасы һәм бизәлеше буенча төрле К.лар хатын-кыз күлмәге изүен (изү каптырмасы), камзул чабуларын (камзул каптырмасы), путаларны (камәр каптырмасы) беркетү өчен хезмәт итә, ш.у. кайбер зәркән



1. Яка каптырмасы. Көмеш. Кою, штамповкалау, уеплау. 17–18 йөзләр. ТР Милли музее; 2. Камәр каптырмасы. Көмеш, ярымасылташлар. Уеплау. 19 йөзнең 1 нче яртысы.


эшләнмәләр — беләзекләр муенсаларның аерым бер өлеше дә булып тора.

*Әд.:* С у с л о в а С.В. Татарские ювелирные украшения. К., 1980; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф., Ш а г е е в а Р.Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАПУ́СТИН** Денис Викторович (5.10.1970, Казан), спортчы (җиңел атлетика, өчләтә сикереш), РФнең атказ. спорт остасы (1999). Профсоюзларның физкультура — спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Тренерлары — А.А.Семагин (1987 гә кадәр), Г.А.*Мөхәммәдов* (1996 га кадәр), Е.П.Загорулько (1996 дан). Казан пед. ун-тын тәмамлый (1995). Россия (1992, яшьләр арасында; 1994, 2000), Европа (1989, яшүсмерләр арасында; 1994) чемпионы, Европа кубогы иясе (1994, 1999). Европа чемпионатларында (1994, кышкы; 1998), Европа кубогына ярышларда (1997), дөнья чемпионатында (1998) — көмеш медальләр, Олимпия уеннарында (2000) бронза медаль ала. 1991 дән ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгында спортчы-инструктор.

**КАПУ́СТИН** Михаил Яковлевич (23.12.1847, Омск ш. — 1920, Мәскәү), гигиена белгече, мед. д-ры (1879), җәмәгать-сәясәт эшлеклесе. Статский советник (1898). Дворяннар нәселеннән. С.-Петербург мед. академиясен тәмамлый (1870). 1871–72 елларда земство медицинасы, 1873–79 да хәрби мед. хезмәтендә. Рус-төрек сугышы чорында (1877–78) Кавказда вакытлы хәрби госпитальләрнең берсенә җитәкчелек итә. 1879 дан Мед.-хирургия академиясендә, бер үк вакытта Рус халык сәламәтлеген саклау җәмгыяте советы секретаре (мөхбир әгъзасы). Корылыктан зыян күргән җирләрне өйрәнү өчен аларның статистик карталарын эшли. 1880–84 тә Воронеж һәм Курск шәһәрләре сан. табибе. 1885 тән Варшава ун-тының гигиена һәм мед. полициясе кафедрасы экстраординар профессоры. 1887 дән Казан ун-ты профессоры, 1907 дә мед. ф-ты деканы. Тикшеренүләре җәмәгать медицинасына карый: крәстияннәргә бушлай мед. ярдәме күрсәтүне хуплый, беренчеләрдән булып системалы стационар земство медицинасы оештыруның өстенлеген исбатлап, земство медицинасы тәҗрибәсе тупланган «Земство медицинасының төп мәсьәләләре» («Основные вопросы земской медицины», СПб., 1889) хезмәтен чыгара, участок земство табибе хезмәтен, даруханәләр эшен оештыруны җентекләп анализлый, сан. статистикасының максатын һәм ысулларын билгели. К. хезмәтләре земство табибләре өчен кулланма була. Гигиена мәсьәләләренә: су б-н тәэмин итүне оештыруга һәм дезинфекцияләүгә, чистарту корылмалары эшенә зур игътибар бирә. Хезмәтләренең бер өлеше эпидемияләр б-н көрәшкә багышланган. Ул «Капустин мичкәсе» исеме бирелгән дезинфекцияләү мичкәсен уйлап таба. 1897 дә чума б-н көрәшү һәм аны кисәтү чараларын оештыру комиссиясенә җәмәгать гигиенасы белгече буларак кертелә (принц А.П.Ольденбургский җитәкчелегендә). Феодосия, Керчь, Севастополь, Евпатория шәһәрләрендә тикшеренүләр үткәрә; аның нәтиҗәләре эпидемиягә каршы чаралар оештыруда файдаланыла. Иҗтимагый, сәяси эштә актив катнаша. Казан ун-тының табибләр җәмгыяте әгъзасы (1891 дән рәисе). 1890 еллар башында ачлыктан интегүчеләргә ярдәм итүдә катнаша, рус-япон сугышы елларында (1904–05) яралы һәм авыру сугышчыларга ярдәм ком-тында эшли. Табибләрнең 7 нче Бөтенроссия Пирогов съездын оештыручыларның берсе (Казан, 1899), земство һәм шәһәр медицинасы секциясен җитәкли. 1894 тән земство хәрәкәтендә катнашуы өчен полиция күзәтүе астында була. 1905 тә «*Унҗиденче октябрь берлеге*»нең Казан губерна бүлеген төзүчеләрдән (1905 тән рәисе), 1906 елның 10–12 сентябрендә Казанда октябрьчеләрнең Идел буе корылтаен оештыручылардан, программалар төзү комиссиясенә керә. «*Унҗиденче октябрь берлеге*»нең Мәскәү ҮК әгъзасы. Казан губернасыннан 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думасы (1907–12) депутаты. 2 нче Думада китапханәләр һәм халык мәгарифе буенча комиссияләр әгъзасы; 3 нче Думада рәис ярдәмчесе, бюджет, халык мәгарифе, иске дин тарафдарлары, Финляндия эшләре комиссияләре әгъзасы (рәис ярдәмчесе). 2 нче Думада октябристлар фракциясен җитәкли. Сәяси карашлары буенча октябрьчеләрнең сул канаты тарафдары, кадетлар б-н хезмәттәшлек итә. Еш кына үз фиркасенең төп фикерләренә каршы булган чыгышлар ясый. 1906 ның март аенда төбәкләр автономиясен яклый, әмма алар Россия үзәгендә дә булырга тиеш ди: «һич югы Казан, Саратов губерналарында автономия булмаган килеш Польшага автономия бирү сәер хәл». Россия милләтчелегенә каршы, крәстияннәр мәсьәләсен тизрәк чишү ягында була. Дәүләт Думасын халык өчен файдалы дип исәпли һәм аңа зур өмет баглый. Танылган рус монархисты В.М.Пуришкевич К.ның Дәүләт Думасындагы чыгышларыннан соң «Капустин маркалы октябрист» кушаматын гамәлгә кертә, октябристларның шундыйларын «конституция принципларын резина кебек туктаусыз сулга тартучылар» дип атый. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Эчке эшләр министрлыгы (С.-Петербург) Медицина советы әгъзасы, бер үк вакытта Петербург ун-тында укыта. 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 һәм 2 дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.



М.Я. Капустин.

Х е з м.: Главные основания проекта сельской земской больницы. СПб., 1874; Борьба с дифтеритом // Рус. начальный учитель. 1880. № 4–6; Калинкинская городская больница в Санкт-Петербурге. СПб., 1885; Один из простейших типов паровой дезинфекционной камеры // Дневник Казан. об-ва врачей. 1892. Вып. 3; Задачи гигиены в сельской России. М., 1902; Речи казанского октябриста. К., 1907.

*Әд.:* Члены 2-й Государственной Думы. СПб., 1907; У с м а н о в а Д.М. Профессора и выпускники Казанского университета в Думе и Госсовете России, 1906–1917. К., 2002; А й н у т д и н о в а Л.М. Либеральное движение в Казанской губернии. К., 2003.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАПУ́СТИН** Николай Федорович (12.11.1936, Лаеш р-ны Астраханка а. — 5.2.2006, Казан), инженер-механик, «Вакууммаш» АҖ ген. директоры (1994 тән), РФнең атказ. машина төзүчесе (1993). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1964). 1958–61 елларда Казандагы 3 нче техник уч-щедә эшли. 1961–2006 да «Вакууммаш» АҖдә: инженер-конструктор, цех башлыгы, баш технолог урынбасары, серияле КБ башлыгы, ФҖБ ген. директорының 1 нче урынбасары, бер үк вакытта Казан механика з-ды директоры (1989 дан), ФҖБ ген. директоры (1991–94). К. җитәкчелегендә пр-тие техник яктан торгызыла, вакуумлы җиһазларның яңа төрләре барлыкка килә, җитештерү күләмнәренең тотрыклы үсеше гамәлгә ашырыла. Халыклар дуслыгы, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Казанскому предприятию «Вакууммаш» 50 лет // Вакуумная техника и технология. 1993. Т. 3, № 3/4; Золотая Звезда «Вакууммаша» // Науч. Татарстан. 1996. № 4.

*Әд.:* Выпускники — гордость университета: Краткий биогр. справ. / КАИ. К., 2002.

**КАПУ́СТИНА** Татьяна Васильевна (15.6.1949, Казан), математик, педагог, физика-матем. фән. канд. (1981), пед. фән. д-ры (2001), проф. (2002). Алабуга пед. ин-тын (хәзер ун-т) тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук алгебра һәм геометрия кафедрасында эшли, 1983–96 елларда каф. мөдире. Хезмәтләре геометрия һәм топология, матем. укытканда компьютер технологияләрен куллану мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Голоморфно-конформное соответствие в касательных расслоениях риманова пространства // Тр. геометр. семинара. К., 1981. Вып. 13; Компьютерная система Mathematica 3.0 в вузовском образовании. М., 2000.

**КАПУСТИ́НСКИЙ** Анатолий Фёдорович (16.12.1906, Житомир ш. — 26.8.1960, Мәскәү), физик-химик, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1939). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1929), Бөтенсоюз гамәли минерал. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү) эшли (1941 гә кадәр); бер үк вакытта, 1933–37 елларда Горький ун-ты профессоры, 1937–41 дә Мәскәү корыч ин-тының физик химия каф. мөдире. 1941 дән СССР ФАнең Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында термохимия лаб-ясе мөдире (Бөек Ватан сугышы елларында Казанда), Казан ун-тының физик химия каф. мөдире (1943 кә кадәр); бер үк вакытта, 1943 тән Мәскәү химия-технол. ин-тында гомуми һәм нәорганик химия каф. мөдире, 1945–49 да Мәскәү ун-ты профессоры. Хезмәтләре кристаллохимия, термохимия, химик термодинамикага һәм металлургия процессларының физик химиясенә карый. К. молекулада ионлы бәйләнеш энергиясен исәпләү өчен тигезләмә ала (Капустинский формуласы). Кристалл энергиясенең изотоп составына бәйлелеген билгели (литий гидриды һәм дейтериды мисалында).



А.Ф. Капустинский.

Эремәнең энтропиясен исәпләү тигезләмәсен тәкъдим итә. Эремәләрдә ионнар җылысыешлыгы теориясен киңәйтә. Нәорганик кушылмалар термохимиясе һәм термодинамикасы буенча тикшеренүләр үткәрә, аларның барлыкка килү җылылыгын билгели, нәорганик матдәләрнең термодинамик константаларын системага сала. Контакт ысулы б-н сульфат к-тасы алу процессы теориясенә зур өлеш кертә. Судагы эремәләрдә ионнарның координацион саннарын билгеләүнең термохимик ысулын эшли (бергәләп). Электролитларның судагы эремәләренең җылы үткәрүчәнлеген өйрәнә. Югары басым астында атомнарда электрон конфигурацияләрнең үзгәреп корылуын һәм җир шары төзелешенең оригиналь геохимик теориясен фаразлый. Россиядә химия фәне барлыкка килү тарихы, төрле химия фәнни мәктәпләре эшчәнлеге турында хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Физическая химия металлургических процессов. М.–Л., 1933. Т. 1; Химические равновесия в неорганических системах. М.–Л. 1936; Очерки по истории неорганической и физической химии в России. М., 1949.

*Әд.:* Анатолий Фёдорович Капустинский // Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1958. Вып. 26.

*В.Г.Абзалова.*

**«КАР ДЕСАНТЫ́»** («Снежный десант»), хәрби-патриотик эзләнүләр хәрәкәте. Татарстанда аның барлыкка килүе 1960 елларның 2 нче яртысында ВЛКСМ ҮК башлангычында революцион, сугышчан һәм хезмәт даны урыннары буйлап яшьләрнең бөтенсоюз походы үткәрелү б-н бәйле. Беренче «К.д.» 1968 дә Казан ун-тының геогр. ф-тында (соңрак — Казан театр уч-щесенда (1969), Казан ун-тының тарих-филол. (1971), физика (1972), юридик (1973) ф-тларында, Казанның башка уку йортларында һәм пр-тиеләрендә) оештырыла. Беренче походларга студентлар кышкы каникул чорында чыгалар — атама шуңа нисбәтле. «К.д.» эзтабарлары агитация-пропаганда һәм фәнни-эзләнү эшләре алып баралар; 18 нче, 120 нче, 146 нчы, 147 нче, 334 нче, 352 нче укчы һәм 86 нчы мотоукчы дивизияләрнең, Фастов танк бригадасының һ.б. хәрби берләшмәләрнең тарихы, фронт газеталары эшчәнлеге, Татарстан милициясе тарихы һ.б. өйрәнелә. Тупланган материаллар республика архивларына һәм музейларына тапшырыла, тикшеренүчеләр тарафыннан Бөек Ватан сугышы тарихына багышланган хезмәтләрдә (ш.и. 120 нче һәм 334 нче укчы дивизияләрнең сугышчан юллары турындагы китапларда) файдаланыла. Татарстаннан меңнәрчә егет һәм кыз «К.д.» мәктәбен уза. Аларның остазлары — Казан ун-ты профессорлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар И.М.Ионенко, М.Т.Нужин, И.М.Романов һ.б. 1980 еллардан «К.д.» эшчәнлегендә төп юнәлеш буларак Бөек Ватан сугышында һәлак булган совет солдатларының җәсәдләрен эзләү, аларның шәхесләрен ачыклау һәм җирләү эшләре үзәккә чыга. 1981 дән «К.д.» (башта — Казан ун-тының филол. ф-ты десанты) бу эшләрне «Үлем үзәне»ндә (Новгород өлкәсенең Мясной Бор авылы тирәсе) алып бара (анда 1942 дә Волхов фронтының 2 нче удар армиясе чолганышта кала). Татарстанның «К.д.»нда катнашучылар тәкъдиме б-н, 1988 дә Новгород өлкәсендә «Долина» эзләү экспедициясе» оештырыла, аның әгъзалары тарафыннан 2011 елга кадәрге чорда Кызыл Армиянең 98 меңнән артык солдаты һәм офицеры сөякләре табыла һәм җирләнә. 1983 тән «К.д.»лары агитация эшләре алып бару һәм Икенче бөтендөнья сугышында һәлак булган, хәбәрсез югалган татарстанлылар һәм Татарстанда туып-үскәннәрнең исемлеген туплаучы республика «*Хәтер-Память*» китабы өчен мәгълүматлар җыю максатында Татарстан р-ннары буйлап Хәтер маршларында катнашалар. 1993 тә «К.д.» җирлегендә ТРның «Ватан» берләшмәсе» яшьләр иҗтимагый оешмасы төзелә, аның составына Казан, Алабуга, Түбән Кама, Чаллы, Чистай, Яшел Үзән шәһәрләренең һәм республиканың аерым р-ннарының эзләнү отрядлары, хәрби-тарихи, хәрби-спорт клублары әгъзалары керә. «К.д.» яшьләрне хәрби-патриотик рухта тәрбияләүдә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның батырлыгын мәңгеләштерүдә, Татарстан халыкларының сугышчан һәм хезмәт данын пропагандалауда әһәмиятле роль уйный.

*Әд.:* В походах за памятью. К., 1995; М и л ю к о в И.И. «Ходили мы походами...». К., 2002; Ч е р е п а н о в М.В. Зачем живым «Долина смерти?» К., 2006.

*В.Ф.Телишев.*

**КАР КАПЛАМЫ́**, кар яву нәтиҗәсендә җир яки боз өстендә барлыкка килгән кар катламы. Карның биеклеге, тыгызлыгы һәм андагы дым запасы б-н характерлана. 1 ай һәм аннан да күбрәк ятучы К.к.н тотрыклы, азрак ятса — вакытлыча диләр. Татарстан терр-ясендә К.к. уртача 20–31 октябрьдә күренә башлый, 15–22 ноябрьдә хасил була, 140–150 көн ята, 6–16 апрельдә эри башлый, 10–20 апрельдә эреп бетә. К.к. ятуында уртача даталардан — 30–40, эрүендә — 15–20 көнгә аерма була. К.к.ның калынлыгы ачык кыр участокларында — 35–45 *см*, ышык урыннарда — 50–75 *см*. К.к.нда су запасы 100–150 *мм*, ул еллык явым-төшемнең 20–30% ын тәшкил итә. К.к.ның хасил булуы, ятуы һәм эрүе күп кенә факторларга — кояш радиациясе режимын билгеләүче гомуми циркуляциягә, явым-төшемнәргә, темп-ра һәм җилгә, физ.-геогр. җирлеккә (рельеф, үсемлекләр дөньясы һ.б.) бәйле. К.к. үсемлекләр һәм хайваннар тормышына зур йогынты ясый, туфракны тирән туңудан, көзге уҗымнарны өшүдән саклый. Язгы ташуның муллык дәрәҗәсе су запасы тәэсиренә бәйле.

*Әд.:* Б а т р ш и н а С.Ф., П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Динамика снежного покрова на территории Татарстана во второй половине XX столетия. К., 2005.

*Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.*

**КАРА́ БАЛЫ́К** (Tinca tinca), карплар семьялыгыннан төче су балыгы. Европа һәм Азиянең барлык сулыкларында диярлек очрый. ТР терр-ясендә киң таралган. К.б. аз хәрәкәтләнә. Су төбендә йөзә, үсемлекләргә бай ләмле күл һәм елгаларны өстен күрә, суда кислородның аз булуына түзә. Гәүдәсенең озынлыгы 60 *см* га кадәр, авырлыгы, гадәттә, 1 *кг* нан артык түгел. Сырты кара-яшел, ян-яклары алтынсу зәйтүнсыман төстә. Гәүдәсе калын, лайлалы, шактый киң. Тәңкәсе вак һәм тыгыз. Йөзгечләре түгәрәкләнгән. Авыз кырыйларында берәр кыска мыекча бар. К.б. өчен җенси диморфизм хас. 2–3 яшендә җенси җитлегә. Уылдыкны өлешләп, май ахыры – июнь башында чәчә. Үрчемлелеге — 300–400 мең уылдык бөртеге. Бөҗәк личинкалары, вак моллюсклар, кысласыманнар б-н туклана. Кәсәбәчелек әһәмияте зур түгел. Буаларда үрчетүле балыкчылык объекты.

**КАРА́ БОЛЫ́Н ТУФРАКЛАРЫ́**, туфрак тибы, болын-дала һәм яфраклы урманнарда өстәмә юешләнү шартларында хасил була. К.б.т. өчен профильнең шактый ук тирәнлектә юешләнүе һәм түбәнге горизонтларның туфрак-грунт сулары б-н даими туенуы вакытында дымны өслеккә якынрак тарту периодларының чиратлашуы хас. Морфологик билгеләре буенча К.б.т. *кара туфракларга* якын, алардан гумус горизонтының карарак төстә булуы һәм югары гумуслык, түбәнге горизонтларда глейлану билгеләре булуы б-н аерыла. Кара туфраклар арасында таплар рәвешендә, нигездә, рельеф түбәнлекләрендә җиңелчә кәсле яссы субүләрләрдә һәм елгаларның тугайасты террасаларында таралган. 2 астипны билгелиләр: карасу болын туфраклары (өстән вакытлыча дымлану шартларында формалаша) һәм кара болын туфраклары (туфрак-грунт суларының даими тәэсир итеп торуы нәтиҗәсендә).

К.б.т. профилендә кара төстәге көпшәк төзелешле, бөртекле структуралы гумус горизонтын (А) билгелиләр. Гумуслы горизонтның аскы өлешендә (АВ) төсе коңгыртлана, псевдомицелий хәлендәге карбонатларның күренүе мөмкин. Гумуслы горизонтларның гомуми калынлыгы — 70, кайвакыт 120 *см* га кадәр. Икенче күчеш горизонты (В яки Bg) бер төстә генә түгел, коңгырт, тирәнгә сузылган күп санлы гумус эзләре бар; чикләвек сыман призматик структуралы; бу туфракларның кара болын астибында глейлану билгеләре күренә башлый. Ана токым (Cgk) — күгәрек-көрән төстәге таплар рәвешендә глейлану эзләре булган карбонатлы утырманы тәшкил итә.

ТРда К.б.т. 141 мең *га* (барлык мәйданның 2,1% ы) тәшкил итә. Бу туфракларның 2 төре таралган: селтесезләнгән (В горизонтында карбонатлар юк) һәм тозланган (профильнең түбәнге өлеше җиңел эрүчән тозлар б-н баетылган). К.б.т.ның механик составы балчыклы һәм авыр балчыксыл. Суга чыдам бөртекле структурага, югары көпшәклеккә һәм су тота алу сәләтенә ия. Алмаш

магний күп булуы (алмаш нигезләре суммасының 30–50%) хас, бу исә грунт суларының тәэсире б-н бәйле. Мохит реакциясе нейтральгә якын. Кара туфракларга караганда гумус запасы зур, шунлыктан, дым б-н яхшырак тәэмин ителү сәбәпле, уңдырышлылык та югары, бу аеруча коры елларда сизелә. Бу тип туфраклар а.х.да киң кулланыла. Бөртекле һәм техник культуралар игелә. Туфракларның бер өлешен печәнлек һәм көтүлек җирләр били.

*Ф.Г.Борһанов.*

**КАРА́ БОРНА́Ш** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Бола елгасы буенда. 2010 елда 116 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б. та мәчет, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 459,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Черки-Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 10 ир-ат; 1859 да — 111, 1897 дә — 312, 1908 дә — 390, 1920 дә — 436, 1926 да — 449, 1938 дә — 417, 1949 да — 285, 1958 дә — 379, 1970 тә — 317, 1979 да — 246, 1989 да — 179, 2002 дә — 131 кеше.

**КАРА́ БӨРЛЕГӘ́Н**, күгелҗем кура җиләге (Rubus caesius), розачалар семьялыгыннан ярымкуаклар төре. Туры үсә торган, дугасыман яисә түшәлмә сабаклы; күп яктан кура җиләгенә охшаш. Аерым билгеләре — көчле кырлы үрентеләре бар, кызыл шәмәхә төстә һәм эләктереп алучан бөгелгән чәнечкеле; чәчәкләре ике җенесле, эре, күпчелеге ак, озын чукларга җыелган; җимешләре — кара яисә шәмәхә төстә, катлаулы каты җимеш. Татарстан терр-ясендә кыргый төре су баса торган болыннарның дымлы туфракларында, сулыкларның яр буйларында, чокырларда, һәм урман кисентеләрендә очрый, тоташ үтеп чыкмаслык куаклыклар барлыкка китерә.



К.б. йорт яны кишәрлекләрендә үстерелә, 4–8 % шикәр, 0,8–1,4 % кислота, С витамины, каротин булган эре, тәмле җимешләр бирә. Яңа өлгергән һәм киптерелгән килеш, эшкәртү өчен (кайнатма, джем һ.б.) кулланыла. К.б. тамыр үргеннәре һәм үрентеләрдән үрчи. Якынча 300 сорты билгеле, Татарстан шартларына туры сабаклы — «Агавам», «Чероки», «Эльдорадо», «Уфимская местная»; түшәлмә сабаклы «Лукреция», «Гималайя», «Торнлесс Логан», «Максвелл Эрли» сортлары туры килә. К.б. кышка чыдам, туфракка таләпчән түгел, элгәреге культураларга органик ашламалар кертү һәм сугаруны ярата. Яз һәм көз көне кыраулар башланганчы утырталар. Рәт аралары 1,5–2 *м*, рәтләрдә үсемлекләр арасы 0,75 *см* була. Вегетация чорында плантацияне чүп үләннәрдән чистартып, ашламалар кертеп һәм сугарып торалар. ТР шартларында К.б. үсентеләрен кыш көне өшемәсен өчен җиргә бөгеп калдыралар. Уңышы 1 *га* дан 50–70 *ц*. К.б. плантацияләрен хуҗалыкта файдалану вакыты 12–15 ел.

*Әд.:* И в а н о в а Р.Г. Дикорастущие съедобные растения Татарии. К., 1988; К а з а к о в И.В. Малина. Ежевика. М., 2001.

*Г.Е.Осипов.*

**КАРА́ ЕЛАННА́Р** (Vipera), кара еланнар семьялыгындагы агулы еланнар ыругы. 25 төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә 2 төре яши. Гади кара елан (V. berus) республиканың барлык җирләрендәге урманнарда, урманлы тугайларда очрый, әмма һәр җирдә саны кими бара; дала кара еланы (V. ursini) — Спас р-ның җылы якка караган далаланган сөзәклекләрендә (к. «*Спас*»), Кама аръягы дала инешләре үзәннәрендә, Куйбышев сусаклагычы утрауларында очрый. Гади кара еланның озынлыгы 90 *см* га кадәр, кара яки соры төстә. Башы яссы ромб рәвешендә, вертикаль бәбәкле. Өске казналыкның алгы читендә хәрәкәтчел көпшәсыман агу тешләре урнашкан. Дала кара еланы кечерәк (65 *см* га кадәр)



Дала кара еланы.

һәм ачыграк төстә. Гади кара еланның койрык очы күбесенчә саргылт яки кызгылт төстә. Борын тишеге гади кара еланда борын калканчыгының урта, ә дала кара еланында аскы өлешендә урнашкан. К.е. апрель ахыры — май башында уяна, кушылу чоры 15–20 көннән соң. Августта ана К.е. йомырка (14 кә кадәр) сала, балалары шунда ук чыга. Төнге яшәү рәвеше алып бара. Тычкансыман кимерүчеләр, бака, сирәк кенә кәлтәләр, яшь К.е. бөҗәкләр б-н туклана. Туң җир чигеннән түбәндәрәк, җир асты сыену урыннарында, кайвакыт берничә дистәгә җыелып, сентябрьдә кышкы йокыга талалар. Тынычсызланган вакытта елан тиз генә бөгәрләнә, ысылдый һәм ачык авызы б-н чагар өчен алга ыргыла. К.е.ның чагуы кеше өчен куркыныч. Агуы медицинада елан чагуыннан сывороткалар һ.б. кыйммәтле препаратлар (випралгин, випраксин, випратоксин һ.б.) әзерләү өчен кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАРА́ ҖИЛӘ́К** (Vaccinium), арчанчалар семьялыгыннан куаклар яки куакчыклар ыругы. 100 гә якын төре билгеле, Евразиянең уртача һәм салкын поясларында, Африка һәм Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади К.җ. (V. myrtillus) барлык районнарда бар. Ылысլы һәм катнаш урманнарда үсә. 15–30 *см* биеклектәге, кышка яфракларын коючы куакчык. Тамырчасы озын, шуышма, күпсанлы тамырлары нык тармаклы. Сабагы туры, очлы кабыргалы ялангач ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, озынча йомыркасыман, вак пычкы читле, кыска сапта. Чәчәкләре берле, алсу, яфрак куентыгына урнашканнар. Җимеше — сусыл күксел-кара татлы җиләк. Орлыклары бик вак. Майда чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. 4–5 елдан җимеш бирә башлый. Күбрәк тамырчалардан үрчи. Җиләкләрендә органик к-талар, углеводлар, флавоноидлар бар. Халык медицинасында җиләк төнәтмәсе әчелек түбән булганда ашказаны ялкынсынуыннан, бөер-таш авырулары вакытында, матдәләр алмашы бозылганда кулланыла. Яфракларында дуплау матдәләре, гликозидлар, органик к-талар, эфир мае, минераль тозлар бар. Яфракларыннан ясалган чәй бәвел капчыгы ялкынсынуы, ашказаны чәнчүләре вакытында файдаланыла. Җиләкләре яңа җыелган һәм эшкәртелгән килеш кулланыла; әчемлекләргә төс кертү өчен ликёр-аракы сәнәгатендә файдаланыла; нарат урманы киекләре өчен азык булып тора. Баллы үсемлек.

**КАРА́ КАЕ́Н ГӨМБӘСЕ́**, ч а г а, кара каты төерсыман кытыршы күпьеллык үсентеләр, яфраклы агач токымнарының кәүсәләрендә үсәләр; кыек агач гөмбәләре (Inonotus abliquus) — паразит агач гөмбәсенең үрчемсез формасы. Татарстан терр-ясенең күп кенә районнарында, ешрак каеннарда, сирәк кенә зирек, өрәңге, корычагач һ.б. яфраклы токымнарда, башлыча, дымлы урыннарда очрый. Гөмбә, нигездә, кәүсәне, әмма һәрвакыт сәламәт агачларны зәгыйфьли. Җәрәхәтләнү нәтиҗәсендә (кәүсәләрдә юнылган урыннар, кайры ярыклары, кәүсәләрнең кояшта пешүе һ.б.) агачлар К.к.г. б-н зарарлана һәм кәүсәләрдә ак черек авыруы үсеш ала. Үсентеләр, гадәттә, черек авыруы киң үсеш алган урында барлыкка килә; акрынлап үсеп, аның үлчәме зурая (диаметры 50 *см* га, авырлыгы 3–5 *кг* га җитәргә мөмкин). Черек авыруы ныграк сузылган очракта, агачның үсүе тоткарлана, эшкә яраклы шактый агачны юкка чыгарырга мөмкин. Кыек агач гөмбәсе, кагыйдә буларак, агач корыганнан соң, К.к.г.нән капма-каршы яктагы кайры астында формалаша. Түгәрәк, күпчелеге кыек көпшәчекләр б-н капланган, кайтарылган читле кара көрән яки коңгырт төстәге калын элпәле. Кайры астыннан чыккан гөмбә споралар бүлеп чыгара. К.к.г. ялкынсынуга каршы чара, авыртуны басу һәм тонусны күтәрү үзлекләренә ия, дару чималы буларак әзерләнә (аннан бефунгин дарусы ясала).

**КАРА́ КАРГА́** (Corvus frugilegus), чыпчыксыманнар отрядындагы карга кошлар семьялыгындагы кош. Үзәк Европа һәм Азиядә таралган. Ареалның төньяк чиге Архангельск–Якутск линиясе буенча уза. Игенчелек



алга киткән районнарда аеруча күп. Гәүдәсенең озынлыгы 44 *см* тирәсе. Каурый капламы шәмәхә-зәңгәр төсмерле кара төстә. Томшыгы озын, төбендә каурыйсыз, орлык, суалчан һәм бөҗәкләрне казып алырга җайлашкан. Күчмә кош. Көньяк-көнчыгыш Европа тигезлекләрендә һәм Урта Азиядә кышлый. Язның беренче хәбәрчеләре. Татарстан терр-ясенә, гадәттә, мартның 2 нчеункөнлегендә кайта. Козгын һәм чәүкәләр б-н төркем булып яши. Март ахырында К.к. иске ояларын яңартырга һәм яңаларын төзергә керешә. Урман буйларында, агачлыкларда, парклардагы биек агачларда оялый. Октябрь ахырында — ноябрь башында очып китә. Зарарлы бөҗәкләрне, кимерүчеләрне юк итә. Орлык һәм шытымнарны чукып зыян китерә.


**КАРА́ КУРА́ ҖИЛӘГЕ́**, к. *Кара бөрлегән.*

**«КАРА́ КҮКЕ́Л»**, бараба татарларының героик дастаны. Баш герой исеме б-н аталып йөртелә. Эчтәлеге, образлар системасы һәм стиль үзенчәлекләре ягыннан «К.К.»нең бараба татарларының башка дастаннары б-н уртаклыклары күп («Йәстәй Мөнке», «Кадыш Мәргән», «Мәшак алып»). Борынгы сюжетка нигезләнгән. 70 яшьлек картның күптән көтеп алынган беренче ир баласы туа. Әкият персонажларына хас булганча, малай бик тиз үсеп җитә һәм баһадир була. Кыргый атны тотып, алты потлы кылыч һәм сөңге чүкеп ясап, Кара Күкел сәяхәткә чыгып китә. Әсәрдә геройның максаты анык кына күрсәтелмәгән; гайре табигый көчен кая куярга белмичә, ул я үзенә лаек дошман, я кәләш эзләп йөри дигән фаразлар бар. Юлда ул бер-бер артлы мәҗараларга юлыга, борынгы эпик батырларга хас булганча, урман җәнлекләре б-н аралаша. Ниһаять, Кара Күкел тау зурлыгындагы мәһабәт Тимер батырны очрата. Сүзгә килгәннән соң алар арасында җиде көн һәм җиде төнгә сузылган рәхимсез сугыш башлана. Дошманын җиңгәч, Кара Күкел аны үтерергә тели. Тимер батыр аннан исән калдыруын үтенә һәм үзенең кызын хатынлыкка бирергә вәгъдә итә. Баһадирлар сугышы кебек традицион мотив «К.К.»дә үзгәреш кичерә: эпик традиция каршы якларның бер-берсенә лаек булуларын таләп итә, ә Тимер батыр дастан героеннан көчсезрәк булып чыга. Икенче дошманы Чуен алып була (Чуен баһадир), аның б-н көрәшкән батырларның сөякләреннән тау хасил булган («барса — кайтмас» мотивы). Дастанда әлеге баһадирның куәте, кодрәте шуның б-н дәлилләнә. Кара Күкел Чуен алыпны да җиңә, соңыннан аның кызына өйләнә (күп хатынлылык мотивы). Геройның соңгы дошманы — Яшь алып аның үзен җиңә. Үлемнән Кара Күкелне Тимер батыр кызыннан туган улы Кучкар алып коткара. Үзе Яшь алып кызына өйләнә. Герой туган якларына әйләнеп кайта. Аның 8 хатыны, 28 баласы була. Кара Күкел, туган җиренең сакчысы буларак, тагын бик күп батырлыклар кыла. Дастанда Тимер батыр сүзләрендә каргышның борынгы формасы яңгыраш таба: «Үз әниеңә өйләнергә насыйп булсын». 1860 елларда В.В.Радлов тарафыннан язып алына һәм нәшер ителә.

*Әд.:* Әхмәтова Ф.В. Татар халык дастаннары // Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАРА КҮ́Л**, Көнбатыш Кама алдында. Биектау р-ны Каракүл авылыннан көньяктарак Ашыт һәм Питиал елгалары субүләре янында. Су өслегенең мәйданы 10 *га*. Күләме 400 мең $м^3$. Озынлыгы 820 *м*, иң зур киңлеге 220 *м*, уртача тирәнлеге 4 *м* га якын, иң зур тирәнлеге 10 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Катлаулы, озынча формада. Ермак б-н тоташкан ике күл плёсы системасын тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туенуы тотрыклы. Суы җиңелчә минеральләшкән (153 *мг/л*), катылыгы 7,8 *мг-экв/л*, гидрокарбонат-хлорлы-кальцийлы типта. Үтә күренмәлелеге 200 *см* га кадәр. Күлнең көнчыгыш яры калкулыклы һәм киң яфраклы урман б-н капланган. ТРның табигать истәлеге (1978).



Биектау районындагы Кара күл.

**КАРА́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-ны Урта Девятово авылыннан 3 *км*, Брысса һәм Мишә елгалары субүләрендәге урман массивында. су өслегенең мәйданы 4,32 *га*. Су күләме 170 мең $м^3$ тирәсе. Озынлыгы 345 *м*, Иң зур киңлеге 170 *м*. Уртача тирәнлеге 4,8, иң зур тирәнлеге 8 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст-суффозия күренеше б-н бәйле. Формасы озынча. Ярлары тәбәнәк, куаклыклар б-н капланган, яр буйлары зонасында су үсемлекләре үсә. Явым-төшем һәм грунт сулары б-н туена. Суы гидрокарбонат-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән, саргылт төстә. Үтә күренмәлеге 230 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).



Урта Девятово авылы тирәсендәге Кара күл.

**КАРА́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Архиерей күленнән көньяктарак, Лаеш р-ның Никольский авылыннан 1 *км* көнбатыштарак, Идел елгасының сулъяк яр террасасы буенда. Нармонка авылы янында Мишә елгасы б-н кушылган Кавал күлләреннән көньяк һәм көньяк-көнчыгыш юнәлешләрендәге сазлы һәм куаклык үскән иңкүлектәге күл. Су өслегенең мәйданы 3,92 *га*. Күләме 100 мең $м^3$.




Никольский авылы тирәсендәге Кара күл.

Озынлыгы 507 *м*, иң зур киңлеге 123 *м*. Уртача тирәнлеге 3 *м*, иң зур тирәнлеге 4 *м*. Күл казанлыгы карст эшчәнлеге нәтиҗәсендә хасил булган. Формасы озынча. Ярлары тәбәнәк, сөзәк. Су буе зонасы сазлы. Күлнең төбе суүсемнәр б-н капланган, шунлыктан су кара төстә кебек күренә (исеме шуннан). Күлдә сары төнбоеклар үсә. Зур Никольский күленең (озынлыгы 6 *км* тирәсе, су өслегенең мәйданы 223 *га*, киңлеге 65 *м* дан алып 830 *м* га кадәр булган, Казан буе сулыкларының иң зурларыннан берсе) кибеп бетүе һәм берничә вак күлгә таркалуы нәтиҗәсендә К.к. барлыкка килә. Язгы ташу вакытында күлдән Мишә елгасы ягына елга агып чыга. ТРның табигать истәлеге.

*Әд.:* Тайсин А.С. Озёра Приказанского района, их современные природные и антропогенные изменения. К., 2006.

**КАРА́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Яшел Үзән р-ны Бело-Безводный авылының көньяк-көнчыгыш чигендәге Ак күл янында, Сумка елгасының сулъяк ярында, Идел елгасының биек террасасында. Идел-Кама саклаулыгы зонасына керә. Су өслегенең мәйданы 1,8 *га*. Күләме 27 мең $м^3$. Озынлыгы 170 *м*, иң зур киңлеге 145 *м*. Уртача тирәнлеге 1,5 *м*, иң



Бело-Безводный авылы янындагы Кара күл.

зур тирәнлеге 3,5 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Формасы түгәрәк. Явым-төшем һәм грунт сулары б-н туена. Ярлары тәбәнәк, сөзәк, күп кенә урыннарда таллар үскән. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта һәм карасу төстә. Үтә күренмәлелеге 50–70 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла.

**КАРА́ КҮЛ**, Идел алдында. Зөя елгасының уңъяк тугаенда, Югары Ослан р-ныңдагы Чулпан авылының төньяк чигендә. Су өслегенең мәйданы 1,36 *га*. Озынлыгы 210 *м*, иң зур киңлеге 85 *м*. Формасы сузынкы.

**КАРА́ КҮЛ** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 35 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Чулпан волостенда. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 131, 1938 дә — 198, 1949 да — 200, 1958 дә — 177, 1970 тә — 175, 1979 да — 122, 1989 да — 74, 2002 дә — 80 кеше.

**КАРАКҮ́Л**, Көнбатыш Кама алдында. Балтач р-нының Ярак-Чурма авылыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак Шушма елгасы үзәненең сулъяк яры буенда. Су өслегенең мәйданы 1,6 *га*. Күләме 136 *мең м*$^3$. Озынлыгы 200 *м*, иң зур киңлеге 130 *м*, уртача тирәнлеге 8 *м*, иң зур тирәнлеге 18 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Озынча



Балтач районындагы Каракүл.

түгәрәк формада. суы уртача минеральләшкән (340 *мг/л*), йомшак, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Үтә күренмәлелеге 100 *см*. Җир асты сулары б-н туенуы тотрыклы. Ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

**КАРАКҮ́Л**, Көнбатыш Кама арьягында. Элеккеге су юлында сакланып калган. Олы Чирмешән елгасының сулъяк яры тугаенда, Нурлат р-ны Каракүл посёлогының көньяк-көнчыгыш чигендә урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,5 *га*. Күләме 49 мең *м*$^3$. Озынлыгы 480 *м*., иң зур киңлеге 30 *м*, уртача тирәнлеге 3 *м*. Суы уртача минеральләшкән (281 *мг/л*), бик йомшак, гидрокарбонат-хлорлы-кальцийлы типта. Үтә күренмәлелеге 60 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

**КАРА́ МИЛӘ́Ш**, арония (Aronia Pers), роза чәчәклеләр семьялыгыннан яфрагын коючан куакчыл үсемлекләр ыругы; җимеш культурасы. Биеклеге 2 *м* га кадәр, җимешләре кара, түгәрәк, 0,6–1 *см* диаметрлы. К.м.не И.В.Мичурин культуралаштыра. Татарстанда селекция эшләрен Казан а.х. ин-тында Я.М.Петров уздыра. Республика терр-ясендә сентябрьдә өлгерә. 1 *га* дан 120 *ц* уңыш алына. Җитештерү хуҗалыкларында һәм коллектив бакчаларда, йорт яны участокларында тамырландырылган ботактан, яшь үренте, чыбыкча һәм орлыклардан үрчетәләр. Кышкы суыкларга чыдам, мул уңышлы, җимешләре тиз һәм даими өлгерешле булуы, авыруларга һәм корткычларга бирешмәүчәнлеге б-н аерылып тора. Туфракка һәм үсү урынына талымсыз. Җимешләрендә шикәр, күп күләмдә Р, Е, С витаминнары, каротин, йод, никотин һәм фолий кислоталары, флавоноидлар бар. К.м. склероз, йөрәк-кан авыруларыннан саклану, гипертонияне дәвалау өчен кулланыла.

**КАРА́ ПУЛА́Т**, хәзерге Болгар шәһәре янында Алтын Урда дәвере болгар архит-расы истәлеге. 14 йөз уртасында урта гасырлар шәһәренең үзәгендә, Җамигъ мәчет комплексыннан 400 *м* көньяктарак төзелгән. Башта әйләнәсендә ике ярусль, үзәгендә зал урнашкан бина була. Бинаның сакланып калган үзәк күләменең тышкы үлчәмнәре — 10×10 *м*, сакланмаган тышкы күләме — 15×16 *м* зурлыкта булган. Эчке үлчәмнәре 7×7 *м* зурлыктагы калын дүрткырлык рәвешендәге үзәк зал өстән тәрәзәле, сигез кырлы барабан б-н яктыртыла. Барабан өстенә ярымтүгәрәк гөмбәз б-н тәмамланган сигез өлешле тоташ көймә урнашкан. Гөмбәз очына түгәрәк тишек уелган.

Беренче кат тәбәнәк (2,2 *м*), яктыртылмый һәм үзәк залның өч якты тәрәзәле төп өлешеннән бүрәнә өрлекләргә җәелгән агач идән б-н аерыла. Беренче ярусның залны урап алган бүлмәләре цилиндрлы көймә б-н ябылган һәм штукатурланган. Урта бүлмәнең көнчыгыш өлешендәге идәнендә тыштан үзәк бүлмәгә кергән һәм суүткәргеч балчык торбалар үткәрү өчен билгеләнгән канал табылган. Беренче каттагы бүлмәләрнең файдаланылу максаты мәгълүм түгел. Икенче ярусның көнчыгыш һәм көньяк өлешендә — кечкенә бүлмәләр, төньяк һәм көнбатышында ябык галереялар урнашкан, төньяк һәм көнчыгыш яктагы бүлмә идәннәренең тигезлек аермасы 0,65–0,75 *м* га җитә. Бинаның көнбатыш ягында галереяга алып керүче порталлы һәм таш баскычлы төп ишек урнашкан. К.п.ның үзәк өлешенә үтүче төп ишек галереяның төньяк ягында. Көньяк фасадның үзәгендә икенче ишекнең тирән порталлы куышы уелган.

К.п.ның диварлары акташтан, гөмбәзе җиңел туфтан төзелгән. Тышкы дүрткырлы диварлар — эре, сигезкырлылары — ваграк туф плитәләр б-н тышланган. 9,5 *м* биеклектәге үзәк залның һәр ягында ишек уемнары эшләнгән. Дүрткырлыктан сигезкырлыкка тромплар аша күчелгән К.п.ның интерьерындагы диварлар штукатурланган һәм төрле зурлыктагы розеткалар, капительле колонна-



Кара пулат. 14 йөз уртасы. Болгар шәһәрлеге. Гомуми күренеш.

лар, тромплардагы сталактитлар һ.б. б-н бизәлгән.

Хәзерге вакытта ян бүлмәләр, галерея, агач түшәмнәр һәм баскычлар сакланмаган. Бинаның почмак-тромплар аша сигезкырлыкка әверелүче дүрткырлык рәвешендәге үзәк өлеше ярымтүгәрәк гөмбәз б-н ябылган. Әүвәлге сигез өлешле тоташ көймә рәвешендәге түбәсе сакланмаган. Фасадлары турыпочмак куышлар рәвешендә эшләнгән сигезкырлыкның ян-якларына уксыман тәрәзәләр уелган. Бинадагы ишек һәм тәрәзә уемнары да уксыман формада.

Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, К. п. мәхкәмә йорты булып хезмәт иткән. Үзенең атамасын 18 йөздә корым б-н капланган кара диварлары аркасында алган, бина монахларның ит-балык ыслау урыны булып хезмәт иткән.

1870 елларда Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте К.п.та борынгы әйберләр музее оештыра. Монда кабер ташлары, архит-ра үрнәкләре кисәкләре һ.б. туплана. 1884–1926 да бина реставрацияләнә, җитешмәгән өлешләре кызыл кирпечтән торгызыла.

1938 елда арх. Р.М.Мортазин К.п.ның үлчәмен ала, 1957 һәм 1966 елларда К.п.та археол. тикшеренүләр үткәрелә.

1956–57 дә гөмбәз яңартыла. 1977–87 елларда арх. С.С.Айдаров һәм Р.В.Билалов җитәкчелегендә һәйкәлгә консервация ясала һәм өлешләп реставрация үткәрелә: сыланган куышлар ачыла, интерьерның дивар өлеше ят катламнардан чистартыла һәм кабаттан агартыла, сылап ябыштырылган бизәкләр, агач идәннәр һәм баскычлар кабаттан торгызыла. К.п.ның реставрацияләү проекты нигезен К.п.ны фәнни яктан тикшерүләр һәм С.С.Айдаровның Болгар шәһәрлеге истәлекләрен реставрацияләү һәм консервацияләү буенча методик эшләнмәләре тәшкил итә.

*Әд.:* Мортазин Р.М. Чёрная палата. К., 1953; Айдаров С.С., Аксёнова Н.Д. Великие Булгары: Путеводитель по Булгар. ист.-архит. заповеднику. К., 1983; Айдаров С.С. Исследование и реставрация памятников монументального зодчества Болгара // Город Болгар: Монументальное строительство, архитектура, благоустройство. М., 2001.

*Х.Г.Надыйрова.*

**«КАРА́ РЕ́ЙХСВЕР»**, к. *«Немецларның совет хакимиятенә каршы фетнәчел оешмасы»* эше.

**КАРА́ СОЛЫ́** (Helictotrichon), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 90 га якын төре билгеле, башлыча, Евразиядә, Африкада, 2–3 төре Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Куян К.с.сы (H.pubescens) сирәк кенә барлык районнарда да, чүл К.с.сы (H.desertorum) һәм Шелли К.с.сы (H.schellianum) Кама аръягында очрый. Далаланган сөзәклекләрдә, куаклар арасында үсә. 20–100 *см* биеклектәге куакчыл үсемлек. Сабаклары туры, нәзек. Яфраклары тар, кыска төкчәле. Чәчәк төркеме — кысынкы яки җәенке себеркәч. Җимеше — бөртекчә. Май–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Терлек азыгы. Чүл К.с.сы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАРА́ ТИЕ́Н АЛЫ́П**, «*Идегәй*» дастаны персонажы; кеше һәм *пәридән* туган зат, гаять олы гәүдәле, гайре табигый көчкә ия, хәтәр дошман һәм шул ук вакытта Идегәйнең кан кардәше (туганнан туган абыйсы).

К.Т.а. бар кешедә курку уята. «Ярты дөньяны үзенә буйсындырып тотучы» кодрәт ияасе Шаһ Тимернең кызын урлавы аның куәтен раслаучы дәлил булып тора. Әсәрдә К.Т.а.ның тышкы кыяфәте җентекле тасвирлана: әгәр ул басса, йолдызлардан да биегрәк була, утырса, кыяга охшый, аның күкрәге — күпер, куллары — бура, колаклары калкан кебек. Халык иҗатында (фольклор әсәрләрендә) персонажларны мондый төгәллек б-н тасвирлау сирәк очрый. К.Т.а.ның мистик үзенчәлекләре һәм гайре табигый мөмкинлекләре турында да тәфсилле бәян ителә: ул искиткеч көчле, алдан күрә белү сәләтенә ия, аны ук та, кылыч та алмый, күз карашына түзеп торып булмый, аны бары үзенең коралы б-н генә юк итәргә мөмкин. Әлеге сыйфат үзенчәлекләре күпчелек эпик геройларга хас (гомумтөрки Алпамыш, казакъларның Алмамбәт, Кобланды батыры, кыргызларның Манасы һ.б.). Бу халык иҗаты геройларының тамырлары уртак булуны раслый. Шуңа да карамастан, мифология персонажына хас күп кенә сыйфатларга ия булган К.Т.а. башка төрки-татар фольклоры әсәрләрендә очрамый, бары «Идегәй» һәм аның милли версияләрендә генә урын ала. Каракалпак версиясендә ул — дию нәселеннән булган дәү Каратиен. Монда аның эпик герой б-н көрәше дастанның татарча версиясендәгегә караганда, киңрәк һәм төгәлрәк сурәтләнә.

*Әд.:* Татар халык дастаны «Идегәй» // Совет әдәбияты. 1940. № 11/12; Идегәй: Татар халык дастаны. К., 1988; Татарский народный эпос. К., 1990; Иҙеүкәй менән Мораҙым: Тарихи ҡобайыр. Өфө, 1994. *Ф.И.Урманчеев.*

**КАРА́ ТИЛГӘ́Н** (Milvus korschun), карчыга кошлар семьялыгындагы ерткыч кош. Евразия, Африка һәм Австралиядә таралган. ТР терр-ясендә зур күлләр һ.б. сулыклар янында, еш кына авыллар тирәсендә яши. Озынлыгы 45–60 *см*, канат җәеме 1 *м* га кадәр. Авырлыгы 700–1100 *г*. Аркасында каурый капламы көрән, корсак асты буй-буй чуарлы көрән-кызгылт, башы аксыл төстә. Томшыгы озын ыргаклы, борын тишеге ярыксыман. Томшыгы һәм тырнаклары кара, томшык өсте һәм аяклары сары. Койрыгында зур булмаган өчпочмаклы уем бар. Аягы кыска, тәпиләре көчсез. Апрель башында очып кайта. Ялгыз, парлы, төркем булып яши. Оясын агачта кора. Көрән яки шәмәхә тимгелле 2–4 ак йомырка сала. Ана кош балаларын ай дәвамында утырып чыгара. Тычкансыман кимерүчеләр, үләксә, калдык-постык, үле балыклар б-н туклана. Кимерүчеләрне юк итеп файда китерә. Сентябрь башында К.т.нәр төркемгә җыела һәм кышлау өчен очып китә.



*Әд.:* Рахимов И.И., Павлов Ю.И. Хищные птицы и совы Татарстана. К., 1999.

**КАРА́ ТУКРА́Н** (Dryocopus martius), тукран кошлар семьялыгындагы кош. Европа һәм Азиядә таралган. ТРда К.т. яшәгән ареалның төньяк чиге уза. Катнаш һәм ылыслы карт урманнарда яши. Аз санлы, өлешчә күчеп йөрүче төр. Гәүдәсенең озынлыгы 45 *см* га кадәр, авырлыгы якынча 300 *г*. Каурый капламы тонык кара, ата кошта башының — өсте, ана кошта баш арты куе кызыл, күзнең төсле катлавы акка якын ачык сары төстә. Томшыгы зур, озын һәм туры, штыксыман кырлы. Ояларын шома кәүсәле биек агачларда кора. Куышының тишеге турыпочмаклы диярлек. Парлашу чоры мартта башлана. Ялтыравыклы 3–5 ак йомырка сала. Мыеклач коңгыз, кабыгашарлар, алтын коңгызлар, кырмыскалар, үрмәкүчләр, күбәләкләр, аларның личинкалары һәм курчаклары б-н туклана. Урманга зур файда китерә.

**КАРА́ ТУФРАКЛА́Р**, туфрак тибы, күп дәверләр дәвамында болын-дала һәм дала үсемлекләре калдыкларының гумуслану процессы барышында бөтенләй юылмау яки периодик юылу режимы шартларында хасил була. Төп токымнар — лёсслар, лёссыман балчыклар һәм комсыл балчык туфраклар, известьташларның җимерелү продуктлары. К.т. гумуслы-аккумулятив горизонтта органик матдәләрнең шактый тупланышы, бөртекле һәм бөртекле-төерле структурасы, югары үңдырышлылыгы б-н аерылып тора. Гумуслы матдәләр, нигездә гумин к-талары, туфракка кара (исеме шуннан) төс бирә. Гумус б-н бергә туфракка катлаулы органик-минераль кушылмалар формасында үсемлекләрнең туклану элементлары (азот, фосфор, күкерт, тимер һ.б.) керә. Алар гумус к-таларының туфракның минераль өлеше б-н үзара тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә. Туфракта һәм үсемлек калдыклары составында нигезләрнең, аеруча кальцийның күп булуы, аларның гумуслы матдәләр б-н туенуына һәм өске горизонтларда нейтраль яки аңа якын реакцияләрнең саклануына булышлык итә.

Профиленең төзелеш үзенчәлекләренә (гумуслы горизонтның калынлыгы, гумус күләме, карбонат тирәнлеге һ.б.) бәйле рәвештә, К.т.ны 5 астипка бүләләр: көлсуланган, селтесезләнгән, типик, гади һәм көньяк. Шуның беренче 3 се — урман-дала зонасында, ш.и. Татарстан терр-ясендә дә, калганнары дала зонасының төньяк өлешендә барлыкка килгән. ТРда К.т.ның гомуми мәйданы 2153,6 мең *га* яки 31,7%. Идел алдының көньяк өлешендә, Көнбатыш Кама аръягы (үзәк өлешләрдән кала) һәм Көнчыгыш Кама аръягында (төньяк-көнбатыш өлешләр) туфрак капламының төп фонын тәшкил итә. Көлсуланган К.т. 294,7 мең *га* мәйданда (К.т. мәйданының 13,7%) таралган. Нигездә, Көнбатыш Кама аръягында кара соры урман һәм селтесезләнгән К.т. арасында зур булмаган участокларда очрый. Күбесенчә сары-коңгырт делювиаль балчыкларда һәм балчыксыл туфракта барлыкка килә. Башлыча гумуслы горизонтның түбәнге өлешендәге аерым структураларны каплаган кремнезёмның ончыл аксыл сибелмәсе б-н аерылып тора. 30–70 *см* калынлыктан гумуслы горизонт (А+А), кара соры яки соры кара төстә, дарысыман-бөртекле структуралы. Түбәндәрәк көрән төстәге, кара таплар һәм гумус эзләре булган чикләвексыман призматик структуралы иллювиаль горизонт билгеләнә. Карбонатларның яту тирәнлеге 130–150 *см*. Гумус күләме 5–8%. Реакциясе җиңелчә әче (pH 5,5–6,5). Гидролитик әчелеге югары (5–7 *мг-экв*/100 *г* һәм артыграк та). К.т. арасында селтесезләнгән К.т. аеруча зур мәйданны (1217,2 мең *га* яки К.т. мәйданының 56,5% ы) били. Буа, Чүпрәле, Чистай, Алексеев, Яңа Чишмә, Минзәлә, Мөслим, Сарман, Актаныш р-ннарында аларның зур массивлары тупланган. Елга үзәннәренең сөзәк битләрендә, субүләр платоларда урнашкан. Алар өчен ана токымнар булып лёссыман, сары-көрән делювиаль, кызгылт көрән элювиаль балчыклар һәм комсыл балчыклар, көньяк-көнбатышта — соры һәм куе соры мезозой балчыкларының җилләнү продуктлары хезмәт итә. Морфологик үзенчәлекләре: гумуслы катлам астында карбонатлардан селтесезләнгән коңгырт төстәге горизонт, ш.у. аерым структуралар чикләрендә элпәле һәм кара тар гумус эзләре булу. Гумус составы 6–10%, реакция нейтральгә якын (pH 6,5–6,8), йоту комплексы тулысы б-н диярлек кальций һәм магний б-н туенган. Типик К.т. 641,7 мең *га* мәйданны били (К.т. мәйданының 29,8% ы). Күбрәк Көнчыгыш Кама аръягында, сирәк кенә Идел алдында субүләр платода һәм үзәннәрнең сөзәк битләрендә таралган. Алар өчен ана токымнар булып элювиаль, элювиаль-делювиаль утырмалар, Пермь системасы известьле-мергель токымнарының җилләнгән продуктлары тора. К.т. барлыкка килүнең аеруча тулы чагылган билгеләре: гумус (9–12% ка кадәр), азот һәм көл элементлары күпләп тупланган, карбонатлар тирәнгә юылмый, ләм фракциясе составы буенча элювиаль-иллювиаль өлешләргә бүленми (көлсуланган һәм селтесезләнгән К.т.дан аермалы буларак), тимер һәм алю-

миний оксидлары булмый. Республиканың көньяк-көнчыгышында плитәле известьташларда барлыкка килгән типик К.т.ның беренчә төре билгеле: тулы үсеш алмаган, калдык-карбонатлы һәм карбонатлы. Аларның үзенчәлеге — кыска профиль (40–60 *см*), гумуслы горизонт калын түгел (40 *см* дан азрак), известьле вакташ (еш кына өстә үк) булу. Карбонатлы К.т., су режимының корылыкка бирешүчәнлеге аркасында, күп кенә а.х. культураларын (шикәр чөгенере, кукуруз һ.б.) үстерү өчен бик үк уңай түгел.

Татарстан терр-ясендәге К.т.ның гумуслы катламы калынлыгы буенча, нигездә, уртача (40–80 *см*), сирәк кенә аз калынлыкта (40 *см* дан азрак), гумуслылык дәрәҗәсе буенча — уртача (6–9%), урыны б-н аз гумуслы (6% тан азрак).

К.т. югары дәрәҗәдәге табигый уңдырышлылыкка ия. ТРда алар а.х. җирләренең 48% ын били, ш.и. 57,6% ы сөрүле җирләр. Аларда бөртекле һәм техник культуралар (уҗым һәм сабан бодае, карабодай, шикәр чөгендере) игелә, җиләк-җимеш һәм яшелчә үстерелә. К.т.ны үзләштерү һәм озак еллар дәвамында кулланганга күрә, туфрак структурасы начарая, гумус һәм азот составы кими, эрозия процесслары көчәя. Туфракта дымның туплануы һәм саклану системасы (кыр ышыклау урман полосалары утырту, кар тоту һ.б.), су һәм җил эрозиясеннән туфракны саклау, дөрес чәчү әйләнешен, туфрак эшкәртү системасын үтәү, органик һәм минераль ашламалар куллану, әче туфракны известьләү (1970 еллардан ТРда көлсуланган һәм селтесезләнгән К.т.ны известьләү эше үткәрелә башлый) К.т. өчен зур әһәмияткә ия.

*Әд.:* Винокуров М.А., Колоскова А.В. Черноземы Татарии. К., 1976.

*Ф.Г.Борһанов.*

**КАРА́ УРМА́Н**, күп кенә халыкларда мифологиясендә киң таралган гыйбарә; билгесезлек һәм хәвеф-хәтәр билгесе. К.у. — күпчелек тылсымлы татар әкиятләрендә, җырлар, бәетләр һәм кайбер әдәби әсәрләрдә теге яки бу хәлләрнең башкарылу урыны. Анда еш кына мөһим вакыйгалар була, геройлар көтелмәгән үзгәрешләр кичерә, тылсымлы җимеш бирә торган агачлар үсә, серле затлар яши (шүрәле, аждаһа, дию һ.б.). К.у. аша герой башка бер дөньяга килеп чыга, еш кына К.у. үзе икенче бер дөньяны гәүдәләндерә. К.у.да була торган барлык сихри хәлләрнең классик үрнәкләре «Ак бүре» татар халык әкиятендә, «Лашманнар», «Лашман бәете» кебек халык бәетләрендә һ.б. фольклор әсәрләрендә чагылыш таба. Лирик җырларда К.у. образы гади халыкның авыр тормышын символлаштыра.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1978. 2 кит.; Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«КАРА́ УРМА́Н»** («Иске кара урман»), борынгы татар халык җыры. Көенә карағанда — озын татар көйләре рәтенә керә. Җырның үзәк образы — авыр тормыш сынауларын гәүдәләндерүче *кара урман*:

Кара да гына урман, караңгы төн, / Нинди юллар белән үтәрбез?

Җырда рефрен рәвешендә «тормыш юлыннан — кара урмандагы кебек — ялгыз гына атлап булмый; кешегә тугры дуслар, якын кешеләр кирәк, бары бергә булганда гына барлык авырлыкларны җиңеп, теләгән максатка ирешергә мөмкин» дигән фикер уздырыла. Җыр халык арасында популяр, проф. җырчылар репертуарына керә. Беренче тапкыр 1913 елда басылып чыга.

*Әд.:* Җырлар китабы. К., 1972; Урманче Ф. Татар халык иҗаты. К., 2002.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАРА́ ХАЛЫ́К**, 13–16 йөзләрдә Алтын Урда, Әстерхан, Казан, Себер һ.б. татар дәүләтләрендәге феодаль бәйле халыкның шартлы атамасы. Күпчелек ясаклы халыктан (авыл җәмәгате әгъзалары, һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр һ.б.; кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, коллар-полонянниклар) тора. Ясак һ.б. төрле салымнар түлиләр, ш.у. төрле йөкләмәләр үтиләр. Татар ханлыкларын Рус дәүләтенә кушкач, К.х.ның күпчелеге *ясаклыларга* языла.

**КАРА́ ЧИШМӘ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 28 *км* төньяктарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 577 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ч.дә мәчет, мәдрәсә, ашлык саклау-сату кибете, 2 бакалея кибете эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостенда, 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән — Чаллы, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1897 дә — 1240, 1906 да — 1421, 1920 дә — 1571, 1926 да — 680, 1949 да — 876, 1958 дә — 931, 1970 тә — 1195, 1979 да — 1011, 1989 да — 648, 2002 дә — 542 кеше.

**КАРА́-ГЯУ́Р** Людмила Борисовна (1.5.1936, Ростов өлкәсе Шахты ш.), драма актрисасы, ТАССРның һәм Украина Респ-касының халык артисты (1982, 1995). Одесса ун-тын тәмамлый (1962). Бер үк вакытта Актёрлар йорты каршындагы театр студиясендә укый, 1959–61 елларда Одесса драма театрында эшли. 1961–72 дә һәм 1987 дән Севастополь рус драма театрында. 1972–87 дә Казан Зур драма театры актрисасы. Казан театр уч-щесендә укыта. Үзенчәлекле талант иясе, гадәти булмаган киң диапазонлы шәхес, комик характерга да драматизм билгеләре өсти алучы, сәхнә күренешләрен гаҗәеп ышандыру көче б-н башкаручы, форма б-н виртуозларча эш итә белүче актриса. Казан Зур драма театры сәхнәсендә шактый гына тирән эчтәлекле образлар иҗат итә. Беренче роленнән үк (Руца — «Безнең яшьлек кошлары», И.П.Друцэ) К.-Г. иҗат юнәлешенең үзәк принцибын — үзен тулысынча сәхнә дөньясына багышлау-



Л.Б. Кара-Гяур.

га әзер булуын күрсәтә. Аның героинялары — тынгысыз, бер чиктән икенчесенә ташланучан натуралар, үз-үзләрен тотышлары кайвакыт сәер, килешсез һәм көлкеле дә була. Аларның күп төрле мәгънәгә ия төс-кыяфәтләре, рухи дөньяларының бай, күңел кичерешләренең тирән булуы тамашачының игътибарын җәлеп итә, кызыксыну уята. Аның героинялары шәхеснең үзкыйммәте, нинди генә тормыш шартларында да кешелек сыйфатларын югалтмау зарурлыгы турындагы фикерләрне расслый. Алар — Клементина («Геростратны онытыргамы?!», Г.И.Горин), Эмма («Пунтила әфәнде һәм аның хезмәтчесе Матти»,



Л.Б. Кара-Гяур Анна («Булыргамы, булмаскамы», У. Гибсон) ролендә; Уилл ролендә — В.В.Кешнер.

Б.Брехт), Цыренжапова («Озату», И.М.Дворецкий), Лидия Жербер («Модадан төшкән комедия», А.Н.Арбузов), Анна («Булыргамы, булмаскамы», У.Гибсон), Мария («Изгеләрдән изге», И.П.Друцэ), Демчиха («Юл чаты», В.В.Быков), Беттина («Цилиндр», Э.де Филиппо), Линда («Астория» кунакханәсе», А.П.Штейн), Кручинина («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Песочинская («Сагыш», А.М.Галин), Серафина («Роза чәчәге татуировкасы», Т.Уильямс), Софья



Л.Б. Кара-Гяур Песочинская («Сагыш», А.М. Галин) ролендә.

(«Соңгылар», М.Горький), Марья («Иван һәм мадонна», А.Н.Кудрявцев), Нелли («Колея», В.К.Арро), Шарлотта («Фон Штайн гаиләсендәге сөйләшүләр», П.Хакс). Соңгы елларда Севастополь рус драма театры сәхнәсендә Аэлита («Тәрәзәләре төньякка караган, чәчәк тоткан мөлаем ханым», Э.С.Радзинская), патшабикә Елизавета («Сезнең апагыз һәм әсир кыз», Л.Н.Разумовская), миссис Гоффорт («Сөт машинасы монда бүтән туктамый», Т.Уильямс), Ганна («Кич», А.А.Дударев), Люси Купер («Алда — тынлык», В.Дельмар) һ.б. рольләрне башкара. Украина Респ-касының иң яхшы актрисасы дигән исемгә лаек була; М.Заньковецкая исем. Бөтен Украина бүләге бирелә (1998).

*Әд.:* Иляловa И. Корни жизни // Театральная жизнь. 1973. № 8; Ингвар И., Иляловa И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**КАРА́-ЧУА́Р ТОКЫМЛЫ́ МӨГЕЗЛЕ́ ЭРЕ́ ТЕРЛЕ́К**, сөт җитештерү өчен асрала. СССРда китереп чыгарыла. 1959 елда рәсми теркәлә. Россиянең төньяк-көнбатышында, Украина, Белоруссиядә, Балтыйк буе респ-каларында, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себердә, Ерак Көнчыгышта үрчетелә. Токым төрле климат шартларында, ш.у. тукландыру шартларындагы төрле төркем терлекләрен кушып һәм беренчел ана формаларының төрле төрләрен файдаланып чыгарыла. Сөт бирүче махсус токымнар арасында К.-ч.т.м.э.т. гәүдә төзелеше һәм продукциялелеге б-н аерылып тора. К.-ч.т.м.э.т.нең күрсәткечләре: биеклеге 128–132 *см*, озынлыгы 150–170 *см*, күкрәк әйләнәсе 170–190 *см*, чук әйләнәсе 18–22 *см*, ит сыйфаты канәгатьләнерлек. Интенсив үстерү чорында авырлыгы тәүлеккә уртача 800–1000 *г* га арта, симертүдәге 15–16 айлык үгезләрнең тере авырлыгы 420–480 *кг*. Сугым терлегеннән 50–55% ит алына. Бу токымның берничә төре һәм тибы бар.

Россиядә К.-ч.т.м.э.т.нең 3 зур популяциясе исәпләнә, алар үзенчәлекле билгеләре һәм сыйфатлары (экстерьер үзенчәлек, сөт бирү, сөтнең майлылыгы) б-н аерыла: Үзәк (Урта Россия), Урал, Себер токымнары.

Россиянең үзәк районнарындагы К.-ч.т.м.э.т. Голландия токымын җирле Холмогор һәм Ярославль токымнары б-н кушып чыгарыла. Өлешчә швиц һәм симменталь токымнары файдаланыла. Терлекләр эре (үгезләр 900–1000 *кг*, сыерлар 550–600 *кг*), күп сөт бирә. Еллык уртача савым — 4000 *кг*, нәсел совхозларында — 6000 *кг*, әмма майлылыгы башка төрләр б-н чагыштырганда түбән, 3,6–3,7%.

Себер популяциясендәге К.-ч.т.м.э.т.нең авырлыгы — 450–550 *кг*, елга 3,7–4% майлылыктагы 4500–5000 *кг* сөт бирә, күрсәткечләре башка популяцияләргә караганда түбәнрәк.

Урал популяциясе продукциялелеге һәм экстерьер ягыннан Россиянең Үзәк һәм Себер популяцияләре арасында югары урын алган. 1980 еллар ахырыннан токымның конституциясен һәм сөт бирүен арттыру өчен каплатуда голштин токымы файдаланыла. Кайбер очракларда кушудан соң сөтнең майлылыгы һәм үрчем кимү күзәтелә. Кушудан соңгы начар күрсәткечләр түбән дәрәҗәдәге селекция-үрчем эше б-н бәйле: үгезләрнең токымы начар булу, үрчемнең сыйфатын тикшермәү, асрау шартлары түбән булу һәм сыйфатсыз азык.

ТРда бу токым 31 районда үрчетелә. 2000 дә 171 мең баш исәпләнә (республикадагы барлык мөгезле эре терлекләрнең 48,2%), 2008 дә 231,2 мең баш (57,6%). Шуларның 43,3 меңе (18,7%) элита-рекорд, 54,6 меңе (23,6%) — элита, 102,8 меңе (44,5%) — 1 нче класс, 13,2 меңе — 2 нче класс. 2000 дә елга 1 сыердан уртача — 2834 *кг* сөт, ш.и. беренче бозаудан соң — 2669, өченче лактациядән соң һәм өлкәнрәк яшьтә 2877 *кг* сөт алына. 2008 дә бу күрсәткечләр 4411, 4258 һәм 4391 *кг*. 2000–08 дә сөтнең майлылыгы 3,66–3,8%, терлекнең авырлыгы 455–517 *кг*. 2008 дә К.-ч.т.м.э.т. үрчетүдә танылган хуҗалыклар: Актаныш р-ны «Нигез» ҖЧҖ (бер сыердан елга 6921 *кг*) һәм «Киров» ҖЧҖ (7389 *кг*), Алексеев р-ны «Родина» к-зы (6098 *кг*), Әлки р-ны «Кызыл Шәрекъ Агро» АҖ (8041 *кг*), Нурлат р-ны «Заман» ҖЧҖ (7559 *кг*), Чирмешән р-ны «Таң» ҖЧҖ (7777 *кг*).


*Әд.:* Трибулкин П., Храмов А. Чёрно-пёстрый скот Сибири. Новосиб., 1967; Скотоводство. М., 2007; Современное состояние селекционно-племенной работы в хозяйствах Республики Татарстан и пути её улучшения. К., 2009.

*Ә.Х. Фазылҗанов, Т.И. Благовещенская.*

**КАРАБА́Й** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үләмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Йомралы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1002,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 84 ир-ат; 1859 да — 403, 1897 дә — 627, 1908 дә — 688, 1920 дә — 675, 1926 да — 503, 1938 дә — 632, 1949 да — 375, 1958 дә — 412, 1970 тә — 443, 1979 да — 335, 1989 да — 267, 2002 дә — 202 кеше.

**КАРАБАЙЛА́Р**, сорокопутлар (Lanius), карабайчалар семьялыгыннан кошлар ыругы. 24 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада һәм Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Гади карабай (жулан) (L. collurio) — барлык районнарда, кара маңгайлы карабай (L. minor) — Кама аръягында, соры карабай (L. excubitor) Кама алдында һәм Кама аръягының көньяк-көнчыгышында очрый. Оя коручы, күчмә һәм кышлаучы төрләр. Куаклы елга үзәннәрендә, урман буйларында, бакча һәм паркларда яшиләр. Гәүдәсенең озынлыгы 16–36 *см*. Каурый катламы йомшак, еш кына соры, ак һәм кара, сирәк кенә җирән төсләр б-н бергә кушыла. Томшыгы зур, ыргаксыман аска бөгелгән, өске томшыгы очлы теш б-н тәмамлана. Канатлары кыска, түгәрәкләнгән. Койрыгы озын, киртләч-киртләч. Тәпиләре көчле, бөгелгән үткен тырнаклы. Оясын куакларда һәм агачларда кора. Көрән-тимгелле 5–7 йомырка сала. Бөҗәкләр, үрмәкүчләр, тычкансыман кимерүчеләр б-н туклана. К. очлы ботакларга, чәнечкеле үсемлекләр, ешрак гөлҗимеш чәнечкеләренә кадап запас азык әзерлиләр. Августның 2 нче яртысы — сентябрьдә очып китәләр. Кара маңгайлы карабай һәм соры карабай ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАРАБАЛЫ́К КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Яшел Үзән р-ны Садовый посёлогыннан 2 *км* көнчыгыштарак, Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогындагы урман массивында. Сумка елгасы бассейнына карый. Су өслегенең мәйданы 7,2 *га*. Күләме 171 мең *м*³. Озынлыгы 540 *м*, иң зур киңлеге 180 *м*, уртача тирәнлеге 2,4 *м*, иң зур тирәнлеге 6 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Формасы озынча түгәрәк.



Карабалык күле.

Аның аша Сер-Болак елгасы ага; елга тамагында комлы пляж урыны барлыкка килгән. Күл акрынлап ләмләнә һәм үсемлекләр б-н каплана.

**КАРАБА́Ш** (Prunella), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 нан артык төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади К. (P. vulgaris) барлык районнарда очрый. Дымлы болыннарда, урман кырыйларында, сулык ярларында, юл буйларында үсә. Сабагы туры, дүрт кырлы, 15–35 *см* биеклектә. Тамырчасы шуышма, озын. Яфраклары каршыдаш, озынча йомыркасыман. Чәчәкләре шәмәхә, сирәк кенә ак, ике иренле, сабак очындагы бождралы башаксыман чәчәк төркемендә. Һәрбер чәчәк киң чәчәк яны яфрагы куентыгында урнашкан. Җимеше — күп чикләвекчек. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Үсемлекнең җир өсте өлешләрендә флавоноид, сапонин, органик к-талар, микроэлементлар, эфир мае бар. Халык медицинасында ялкынсынуга каршы, тән кызышканда, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Баллы үсемлек.

**КАРАБА́Ш**, шәһәр тибындагы посёлок (1957 елдан), Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәрен-



Карабаш тавы һәм Карабаш сусаклагычы. Гомуми күренеш.

нән 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасының Дала Зәенә койган урынында урнашкан. 2010 елда 5005 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 80,3%) яши. 2 урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Нефть чыгару сәнәгате («Лениногорскнефть» НГДУ). К. янында Карабаш сусаклагычы бар. 1748 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре, асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 20 йөз башында К.та почта станциясе, 2 мәчет, 2 су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7080 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Каратаевка волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 12 октябреннән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1317, 1897 дә — 1912, 1910 да — 2326, 1920 дә — 2957, 1926 да — 2083, 1989 да — 4300, 2002 дә — 5139 кеше.

**КАРАБА́Ш СУСАКЛАГЫЧЫ́**, Бөгелмә Зәе елгасында, Бөгелмә р-ны Карабаш посёлогы тирәсендә. 1957 елда барлыкка килә. Гадәти биеклегендә (140 *м*) су өслегенең мәйданы 7,3 *км*², тулы күләме 52,4 млн. *м*³, уртача тирәнлеге 7,1 *м*; озынлыгы 8,7 *км*, иң зур киңлеге 1,2 *км*. Республиканың көньяк-көнчыгышында нефть чыганакларын су б-н тәэмин итә. Фаунада балыкларның 15 кә кадәр төре бар: чабак, корбан балык, җилем, алабуга, густера, кыртыш, судак, опты һ.б. Сусаклагыч ярлары буенда ял итү зоналары урнашкан.

**КАРАБА́Ш ТАВЫ́**, табигать истәлеге. Бөгелмә р-ны терр-ясендә шәһәр тибындагы Карабаш посёлогы тирәсендә урнашкан. 1959 да билгеләнә. Мәйданы 50 *га*. Көньяк, көнбатыш һәм көнчыгыш сөзәклекләрдә ташлы, болынлы, куаклы дала элементлары б-н урман-дала үсемлекләренең күп кенә төрләре һәм төньяк сөзәклектәге киң яфраклы урманнарның уникаль кушылмасын хасил иткән калкулык. Югары төзелешле көпшәле үсемлекләрнең 170 тән артык төре, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән 60 төр үсә: көдрәч куак (ареалның төньяк чигендә), матур, Коржинский, Лессинг, Сарепта һ.б. кылганнар, Трансильвания ярмабашы, биек гониолимон, сары һәм күпьеллык җитен, Австрия, испан һ.б. татлы тамыры, чал һәм тау сирениясе, биек, озын яфраклы, украин тургай тарысы, мәче борчагы, ялмача, тәңкәяфракның сирәк төрләре. Чукмармыеклы тәңкәканатлылар яши: махаон, мнемозина, бәрхетканатлылар (дриада, Галатея чуар күзчек), алтынсыман сары күбәләк, күк күбәләкләр (чабыр үләне, мәче борчагы, куян туканбашы, эспарцетлар б-н трофик бәйләнешле Мелеагр һ.б. төрләр), автоной, аретуза, бризеида, ферула. Территориясе көчле антропоген йогынтыга дучар ителгән (көтүләр йөртелә, төзелеш ташы чыгарыла).

*Әд.:* Марков М.В., Папченков В.Г., Ситников А.П. Новые и редкие виды флоры Татарии // Бот. журн. 1988. Т. 73, № 1; Ситников А.П. Atraphaxis frutescens (L.) на северной границе ареала в Заволжье // Самарская Лука. 1993. № 4.

*В.Г.Марфин.*

**КАРАБАЯ́Н** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 26 *км* көньяктарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 33 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау, тимерчелек, киез итек басу, тегүчелек, агач эшкәртү б-н шөгыльләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында берара Карабаян волосте үзәге. 20 йөз башында К.да Казан Богородица чиркәве (18 йөз башында салынган агач чиркәү янган урында 1899 да төзелә), земство мәктәбе (1868 дә ачыла), су тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек, 2 сыраханә, 1 шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете була; җомга саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1019,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 499, 1897 дә — 687, 1908 дә — 783, 1920 дә — 763, 1926 да — 670, 1938 дә — 460, 1949 да — 353, 1958 дә — 306, 1970 тә — 191, 1979 да — 142, 1989 да — 74, 2002 дә — 44 кеше.

*Әд.:* Туган ягым — Теләче. К., 2003.

**КАРАБЛИ́НОВ** (Кораблинов) Яков Минич (1789–1837 дән соң), тарихчы, филолог, магистр (1821), сарай киңәшчесе (1833). Рухани улы. Воронеж руханилар семинариясен (1803), Петербург руханилар академиясен (1821) тәмамлый. 1811–17 елларда Воронеж руханилар семинариясе укытучысы, 1821–23 тә Волынск руханилар семинариясе профессоры. 1824–37 дә Казан ун-тында: политэкономия һәм дипломатика каф. (1825 кә кадәр), латин теле каф. (1825–34) экстраординар профессоры; бер үк вакытта 1825–26 да әхлакый сәясәт бүлекчәсе деканы.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904); В 2 ч. К., 1904.

*Е.Б.Долгов.*

**КАРАБОДА́Й** (Fagopyrum), карабодайчалар семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр ыругы, төп ярма һәм бал культурасы. Бер- һәм күпьеллык төрләре очрый. Культурада берьеллык төре — чәчүле К. яисә гади К. (F. sagittatum). Ватаны — Һиндстанның биек таулы төньяк районнары. Европа (Польша, Чехия, Словакия, элекке Югославия, РФ, Украина, Белоруссия), Көнчыгыш Азия (Кытай, Корея, Япония, Непал), Төньяк Америка (Канада) илләрендә киң таралган. Россиядә урман-дала һәм дала зоналарында игелә. БДБда Татарстан карабодайның эре бөртекле сортларын игүче төп үзәкләрнең берсе санала. Карабодай — гадәти (традицион) культура, ул Идел буе Болгар дәүләте чорыннан ук игелә. ТРда 1970–80 елларда ел саен 60–75 мең *га* мәйданда үстерелә. Дым һәм җылылык ярата. Вегетация чоры 60–90 көн. Умарта кортлары һәм кыргый серкәләндерүчеләр ярдәмендә серкәләнә. Тирәнгә китми торган аз үсешле, ләкин үзәк типтагы актив тамыр системасына ия. Сабагы буынлы, куыш, кабыргалы, ялангач, биеклеге 50 *см* дан 100–120 *см* га кадәр. Озын үсканнәре сөрләгә. Яфрагы уксыман һәм түгәрәк-йөрәксыман формада. Чәчәге — ачык чәчәкле, ике җенесле һәм гетеростилье. Чәчәк оешмасы башлыча калкансыман, ярымчатыр һәм чуксыман формада. Җимеше — өч кырлы чикләвекчек. К. җиңел һәм уртача механик составлы кара туфракларда яхшы үсә. Иң яхшы элгәрләре — чиста пардагы уҗымнар, бөртекле-кузаклылар, шикәр чөгендере, бәрәңге, күпьеллык үләннәр катламын әйләндерү. Төп агротехник эшләр: районлаштырылган сортларның яхшы орлыкларын киң рәтләп чәчү; тишелеп чыккач тырмалау һәм рәт араларын эшкәртү; умарта кортлары б-н серкәләндерү (1 *га* га 2–3 умарта семьясы); уңышны үз вакытында аерып җыеп алу.

ТРда К.ның еллык уңышы 1 *га* дан 5 *ц* дан 14,4 *ц* га кадәр үзгәрә, алдынгы хуҗалыкларда 20–25 *ц*, иң югары уңыш — 38–43 *ц*. Бал чыгышы 1 *га* дан якынча 60 *кг* тәшкил итә.

К. ярмасының туклыклылык, диетик һәм дәвалау үзлекләре югары бәяләнә. Терлек азыгы сыйфатында саламы, кибәге, кабыгы кулланыла, ләкин аларның азык буларак кыйммәте түбән.

Ярма итеп эшкәртү өчен К. житештерү б-н башлыча Азнакай, Бөгелмә, Әлмәт, Сарман, Лениногорск, Мөслим, Спас, Ютазы р-ннары а.х. оешмалары шөгыльләнә. ТРда К. җитештерүнең уртача еллык күләме

30–50 мең *т* тәшкил итә. ТРда чәчәргә тәкъдим ителгән сортлар: «Каракитә» (1991), «Саулык» (1997), «Чирмешән» (2001), «Чатыр Тау» (2005), «Батыр» (2008). Чәчүлек К. азотлы (30–45 *кг/га* N), ярлы туфракларда фосфорлы (40–60 *кг/га* $P_2O_5$) һәм калийлы (60 *кг/га* $K_2O$) минераль ашламаларга таләпчән. Тиешенчә җылынган туфракка гадәти рәтләр һәм тар рәтле ысуллар б-н чәчәләр, орлыкларның чәчү нормасы тиңдәшле рәвештә 80–100 һәм 40–50 *кг/га*, чәчү тирәнлеге 4–7 *см*. Уңышны аерым уру ысулы б-н җыялар. ТРда К. үстерүнең һәм уңышын җыеп алуның чәчүлекләрне иң яхшы элгәрләрдән соң урнаштыру, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты селекциясенең югары уңыш бирә торган сортларын үстерү, планлаштырылган уңыш алу исәбеннән үсемлекләрне яхшы тукландыруны тәэмин итү һ.б. агротехник алымнар комплексын үтәүдән гыйбарәт интенсив технологияләре эшләнә һәм кулланыла.

*Әд.:* Крупяное поле Татарии. К., 1979; Каргальцев Ю.В., Труцков Ф.М. Гречиха. М., 1986.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КАРАБОДАЙЧАЛА́Р** (Polygonaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, куаклар һәм лианалар, кайвакыт зур булмаган агачлар. 30 га якын ыругы, 1000 нән артык төре билгеле, бөтен Җир шары буенча, әмма нигездә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 4 ыруг, 27 төр, ш.и. *кырлач, карабодай, кодрәч, кузгалак* үсә. Яфракларының шактый өлеше чиратлашкан, бөтен. Семьялыкка хас билге — төпчек яфраклардан барлыкка килгән кушуч яфраклар булу. Чәчәкләре вак, күп чәчәкле чәчәк төркемендә. Бер катлы чәчәк тирәлеге, калучы һәм еш кына җимешләрдә рәвешләрен үзгәртүче, 3–6 яшел, ак яки кызыл өлешләрдән тора. Җимеше — өч кырлы чикләвекчек. Орлыктан үрчи. Үсемлекнең барлык органнарында, аеруча җир асты өлешләрендә дуплау матдәләре бар. Составында аксым, углевод, май, органик к-талар булган чәчүлек карабодай кыйммәтле ярма культурасы булып санала. Атеросклероз һәм гипертонияне дәвалау өчен карабодайдан сәнәгать ысулы б-н рутин алалар. Карабодай, кабызлык — баллы үсемлекләр. Халык медицинасында кузгалак, рәвәҗ, кырлач кулланыла. Кузгалак, рәвәҗнең кайбер төрләре культуралаштырылган. Кодрәч куак, рәвәҗнең кайбер төрләре — декоратив. 3 төре (кодрәч куак, кабызлык, яр кузгалагы) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАРАВА́ЕВО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 172 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кызыл Яр, Спас исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Спас чиркәве (1793 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе, 1 су һәм 6 җил тегермәне, йон-тукымаману остаханәсе, тимерчелек, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1858,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Левашёво волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 355 ир-ат; 1859 да — 964, 1897 дә — 1230, 1908 дә — 1533, 1920 дә — 1142, 1926 да — 863, 1938 дә — 632, 1949 да — 375, 1958 дә — 412, 1970 тә — 443, 1979 да — 335, 1989 да — 244, 2002 дә — 227 кеше.

**«КАРАВО́Н»** (иске рус телендәге каравод — хоровод сүзеннән), Лаеш р-ны Никольский авылында яшәүчеләрнең фольклор бәйрәме. 16 йөздән билгеле. Баштарак христианнарның дини бәйрәме буларак, изгеләндерүче һәм могҗиза тудыручы Николайның (Никола Вешнийның) сөякләрен күчерү көненнән башлап, иске стиль б-н 9 майда һәм яңа стиль б-н 22 майда 3 көн дәвамында уздырыла. Әлеге бәйрәмгә үзләренең яклаучысына табынырга, туганнары һәм авылдашлары б-н күрешеп сөйләшергә дип, элегрәк төрле якларга таралган шушы авыл кешеләре җыела. 1950 еллардан атеизмның һәм дингә каршы көрәшнең яңа дулкыны җәелә башлау сәбәпле, бәйрәм үткәрелми; 1988 дән яңадан торгызыла. 2003 нең маенда «К.» бәйрәмен уздыру турында ТР МК карары кабул ителә; шул ук елда ул «ТРда бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр турында» ТР Законы нигезендә республикадагы рәсми бәйрәмнәр исемлегенә кертелә, анда татар халкының милли бәйрәме *Сабан туен* һәм «К.» бәйрәмен үткәрү вакыты һәр елда ТР Президенты Указы б-н билгеләнүе күрсәтелә; шуның б-н бәйрәм гомумреспублика чарасы дәрәҗәсендә раслана. 2003 тә «К.» бәйрәме «Россия мәдәнияте (2001–2005 еллар)» федераль максатчан программа кысаларына кертелә.

Хәзер «К.» — халыкның күмәк күңел ачу бәйрәме һәм ТРда яшәүче русларның фольклор вокаль һәм этнографик коллективлары фестиваленә әверелде. Соңгы елларда «К.» бәйрәменә РФнең Татарстан б-н күрше республика һәм өлкәләреннән (Мари, Чуаш Респ-калары, Киров, Омск өлкәләре һ.б.) дә фольклор коллективлары килә. «К.»ны үткәрү нәтиҗәсендә Никольский авылында һәм Лаеш р-нында гамәли-бизәлеш сәнгате традицияләре яңара; «К.» уздырылган көннәрдә авылда «Русское подворье» дип аталган тарихи-этнографик күргәзмә оештырыла, 2011 дә «К.» бәйрәме тарихы музее ачыла. 1988 дән биредә «Каравон» үзешчән башкаручылар ансамбле эшләп килә; аның репертуарында — йола, лирик һәм биюле халык җырлары (җитәкчеләре — Сергей Алексеевич һәм Светлана Алексеевна Трусовлар). «К.» бәйрәме чараларында катнашу өчен күпсанлы фольклор һәм вокаль ансамбльләр җыела. 2006 елның маенда «К.» бәйрәмендә ТРның 25 р-ныннан 61 фольклор коллективы һәм вокаль ансамбле, ш.у. Казан («Коляда»), Ижевск («Ладушки», Удмурт Респ-касы) һ.б. шәһәрләрдән килгән халык ансамбльләре катнашса, 2011 дә бәйрәм 100 дән артык сәнгать коллективы катнашында уза.

*Г.С.Сабирҗанов.*



«Каравон» бәйрәмендә катнашучыларның зур әйлән-бәйлән түгәрәге.



«Каравон» бәйрәменең башламы.

**КАРАВЫ́Л ТАВЫ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 604 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер үстерү; кирпеч з-ды. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1710 нан мәгълүм. Беренче исеме — Клявлино. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч ясау, сарык тиресен эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Т.нда тимерчелек, 2 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1984 дис. тәшкил итә. 1912 дә земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат; 1859 да — 529, 1897 дә — 858, 1908 дә — 917, 1920 дә — 1066, 1926 да — 963, 1938 дә — 942, 1949 да — 848, 1958 дә — 1037, 1970 тә — 1046, 1979 да — 859, 1989 да — 629, 2002 дә — 624 кеше.

*Әд.:* Е н д и р я к о в В.А. История Егоркинской волости Чистопольского уезда Казанской губернии (с середины XVII в. до 1930 г.). К., 1994.

**КАРАГА́Й** (Larix), наратчалар семьялыгыннан ылыслы агачлар ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Американың салкын һәм уртача өлкәләрендә таралган. ТР терр-ясендә интродукцияләнгән 3 төре: Даурия К.е (L. dahurica), Европа К.е (L. decidua), Себер К.е (L. sibirica) очрый. Урман хуҗалыкларында һәм торак пунктларда үстерелә. 30–40 *м* биеклектәге, диаметры 1 *м* булган бер өйле агачлар, ябалдашы конуссыман (яшь агачларда), цилиндрсыман яки киң конуссыман (картларында). Тамыр системасы тирән, тармаклы, үзәк тамыры яхшы үскән. Ылысы кыяк, йомшак, ефәксыман, иртә язда ачыла, яфраклы агачлар б-н беррәттән саргая. «Чәчәкләре» ылыслылар б-н бер үк вакытта, язын күренә. Ата «чәчәк төркемнәре» (башаклар) шарсыман диярлек, саргылт, күбесенчә яфраксыз кыска сабакларда, ботакның аскы ягында урнашкан. Ана «чәчәк төркемнәре» (күркәчекләр) озынча, кызыл, алсу, яшел, вертикаль урнашкан, бөтен үзәгендә спиральсыман утыручы кабырчыклардан тора. Җил б-н серкәләнә. Орлыктан үрчи. Тиз үсүче, яктылык яратучы, суыкка чыдам токым, туклыклы матдәләргә бай туфракта яхшы үсә. К.ның үзагачы кызгылт зур үзәкле һәм тар гына ачык төчлегәнле (нарат һәм чыршы үзагачыннан аермалы буларак), каты, нык, дымлылыктан череми. Татарстанда Себер К.е уңышлы яраклашкан, урман хуҗалыкларында үзагачы кыйммәтле токым буларак үстерелә. Себер К.еның карт утыртмалары ТРның табигать истәлекләре итеп билгеләнгән (*Карагай урман культуралары, 1906*; *Чыршы һәм карагай урман культуралары, 1910–13 еллар*). 300–400 ел яшиләр. Ылысында С витамины, минераль матдәләр, эфир мае бар. К. яшелләндерү һәм саклагыч урманнар сыйфатында файдаланыла.


**КАРАГА́Й** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 47 *км* көньяк-көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 139 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1921 дә Туктар Урдалысы авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1929 да «Маяк» к-зы оештырыла, 1958 дә «Кызыл орден» к-зы (Туктар Урдалысы а.) б-н берләштерелә, хәзер — М.Җәлил исем. күмәк пр-тие. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Шөгер волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 354, 1938 дә — 505, 1949 да — 397, 1958 дә — 282, 1970 тә — 285, 1979 да — 224, 1989 да — 136, 2002 дә — 186 кеше.



Себер карагае.

**КАРАГА́Й УРМА́Н КУЛЬТУ́РАЛАРЫ**, 1906 елда утыртылган ландшафтлы табигать истәлеге. Кама елгасының уңъяк ярында Балык Бистәсе р-ны Кама урман хуҗалыгы посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 1987 елда билгеләнә. Мәйданы 27 *га*. Республикада иң карт һәм уникаль, югары продукцияле, утыртылган гади нарат, Себер карагае һәм гади чыршы (Шомбыт урманчылыгының 116 нчы кварталы) урманнары. Пермь мергельләреннән торучы комсу утырмаларда формалашкан. Төрле составлы агачларның 4 бүлемтегеннән тора: 40–70% ын нарат били, 10–30 ар % чыршы һәм карагай, аз санда — каен, юкә, усак. Утыртмаларның бонитет классы 1а, сирәк кенә 1, агачның гомуми запасы 450–800 $м^3/га$. 95 яшьлек нарат агачлары 30–31 *м* биеклеккә җитә, кәүсә диаметры 44–48 *см*, чыршы — тиңдәшле рәвештә 27–28 *м* һәм 36–40 *см*, карагай — 30–31 *м* һәм 40 *см*.

*А.Х.Газизуллин.*



Чыршы һәм карагай урман культуралары. 1910–13 еллар.

**КАРАГРУҺЧЫЛА́Р**, 1905–17 елларда Россия империясендә уң монархиячел иҗтимагый-сәяси оешмалар вәкилләренең, ш.у. консерватив, революция һәм либеральләштерү идеяләренә каршы яклыларның атамасы. К. «Православие. Самодержавие. Халыкчанлык» дигән өч өлештән торган принципка нигезләнгән идеологиягә таянып эш итәләр. Православие һәм патша самодержавиесен саклау һәм аларның һәр җирдәге хакимлеге, Россия империясенең бердәмлеге, рус халкының өстен хәлен ныгыту турындагы лозунглар б-н чыгыш ясыйлар. Милли мәсьәләдә әҗнәбиләргә (бигрәк тә яһүдләргә) карата чикләүләр саклануын таләп итәләр. К.ның беренче оешмасы булып 1900 ел ахыры — 1901 нең башында төзелгән «Рус җыены» санала, ул нигездә С.-Петербург христиан руханиларын, рус интеллигенциясен, дворяннарны һәм чиновникларны берләштерә. Массачыл К. хәрәкәте 1905–07 елларда Россия җәмгыятен революцион-либераль үзгәртеп кору омтылышына җавап буларак башлана һәм халыкның барлык катлауларын үз эченә ала. К.ның иң зур оешмалары: «Рус кешеләре берлеге» (1905 нең мартыннан), «Рус монархия партиясе» (1905 нең язынннан, 1907 дән — «Рус монархия берлеге»), «Рус халкы берлеге» (СРН, 1905 нең ноябреннән), «Михаил Архангел исемендәге рус халык берлеге» (РНСМА, 1908 дән), «Рус халкының бөтенроссия Дубровин берлеге» (ВДСРН, 1912 дән).

Казан губернасында К. оешмалары башкала оешмалары б-н параллель рәвештә формалаша. 1904 нең ахырында Казанда Казан аеклар җәмгыяте базасында беренче оешма — «Рус җыены»ның Казан бүлеген (КОРС) оештыру карары кабул ителә, 1905 нең ноябре–декабрендә ул тулысынча формалашып бетә (бүлек советының рәисе — А.Т.*Соловьёв*). 1905 тә КОРС матбугатта актив контрреволюцион уң монархиячел пропаганда җәелдерә, әмма баштарак үзен К.дан күпмедер дәрәҗәдә читтәрәк тота. 1905 тә 17 октябрь Манифесты басылганнан соң, Казанда бер-бер артлы революцион бәрелешләр башлана, алар исә Казан шәһәр думасын контрольдә тоткан соц. һәм либераль партияләр вәкилләре, ш.у. аларның «милициясе» һәм «патриотик манифестация», юнкерлар һәм полиция арасындагы бәрелеш б-н тәмамлана, бер уңайдан яһүдләргә каршы һөҗүм оештырыла — бу вакыйгалар К. оешмаларының рәсми формалашуын тизләтә. 1905 тә ноябрьнең беренче яртысында Арча шәһәрендә һәм Чистай өязендә революцион агитаторларны җәзалау очраклары була. Казанның барлык рев-циягә каршы көчләрен берләштерү «Хокукый тәртипне саклау комитеты»н (соңрак «Хокукый тәртипне саклау партиясе») төзүгә китерә, бераздан аннан урталык монархистлары аерылып чыгалар һәм «Казан 17 октябрь Манифесты партиясен» төзиләр. Калган уң элементлар җирлегендә мөстәкыйль К. оешмасы — «Казан шәһәрендә патша-халык рус җәмгыяте» (ЦНРО, совет рәисе — В.Ф.*Залесский*) төзелә. Аның әгъзалары, беренчеләрдән булып, үзләренә карагруһчылык атамаларын алырга карар кылалар. 1905 нең декабрендә уң монархик караштагы «Казан шәһәренең чиркәү старосталары һәм приход попечительләре җәмгыяте» (ОЦСПП, совет рәисе — А.И.Кукарников, 1910 ның 3 июненнән Л.А.Матвеевский) төзелә. Төзелүнең беренче елында К.ның Казан оешмаларында 2,7 мең кеше исәпләнә. Казанда мөстәкыйль оешма барлыкка килүнең төп сәбәпләреннән берсе — бирedә башкала К.ы исәпкә алмаган үзенчәлекләр булу. Аграр өлкәдә бу крәстияннәрнең аз җирлелеге мәсьәләсен хәл итүдә тормышчанрак таләпләр куюда һәм

крәстиян җәмәгатьләрен бетерү мәсьәләсенә саграк килүдә чагыла. ЦНРО эре һәм урта күләмдәге җирбиләүчеләр җиренең 1/3 нә кадәр өлешен билгеләнгән хакны түләп тартып алу мөмкинлеген таный, ш.у. җир биләүнең үзенчәлекле «җәмәгать-хутор» моделен тәкъдим итә; милли һәм дини мәсьәләләрдә әҗнәбиләргә һәм православиедән аерылып торган дин тотучыларга (ш.и. консерватив карашлы татар-мөселманнарга карата да уңай мөнәсәбәттә) карата сыгылмалырак тактика алып барыла. 1 нче Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында ЦНРО Казаннан «мөселманнар өчен махсус» 2 нче депутатны тәкъдим итүне сорый. 1908 нең 9 декабрендә Чистай өязендә мөселман татарлардан торган уң монархик «Патша-халык мөселман җәмгыяте» теркәлә. Бу оешманың максаты — «татар халкының хокукы чикләнмәгән патшага Коръән б-н ант иткән тугрылыгын һәм патриотик рус җәмгыятьләре б-н ныклы бергәлекне саклау» була (Баш совет рәисе — Х.Фәйзуллин). ЦНМОның 18 бүлеге ачыла, анда 240 кеше әгъза булып тора. 1909 ның 30 декабрендә ЦНМО Казан губернаторы М.В.Стрижевский таләбе б-н ябыла. Болардан тыш, Лаеш өязе исправнигының 1916 ел февраль рапортына караганда, Кече Нырты, Сауыш һәм Балыклы авылларында ЦНРОның бүлекләре эшли, аларда 38 әгъза исәпләнә (совет рәисләре — М.Гыйлаҗетдинов, З.Хисаметдинов, Я.Халиков). Бер үк вакытта җирле К. татарлар арасындагы либераль һәм соц. агымнарны, Дәүләт Думасының мөселман фракциясен кискен тәнкыйтьлиләр. «Яһүдләр мәсьәләсендә» Казан К.ы иң кискен карашларда торалар. Рус милли һөнәри берләшмәләрен һәм хәйрия җәмгыятьләрен төзүгә аеруча зур игътибар бирелә. 1908 нең 16 июлендә КОРС каршында Төзелеш эшләре һөнәриләре җәмгыяте (рәисе — А.М.Тюфилин), 1908 нең 21 октябрендә ЦНРОның Портнов бүлекчәсендә түләүсез гомуми белем мәктәбе (җитәкчесе — Н.А.Петров) ачыла. Казан К.ы күзәтчелегендә торган иң зур иҗтимагый хәйрия-агарту оешмасы Казан аеклар җәмгыяте була. 1908 дә КОРС тырышлыгы б-н «Казан рус христиан хатын-кызлары җәмгыяте», 1912 дә Казанда «Ярлыкаучы Спас исем. кече яшьтәге акылга зәгыйфьләр һәм гарипләрне тәрбияләүче җәмгыять» оештырыла. К. традицион рус рухында белем бирүне таләп итәләр, университетларга автономия бирүгә каршы чыгалар, вузлардан либераль һәм сул карашлы профессоларны куып чыгару, студентларны сәяси һәм милли карашлардан чыгып сайлап алу өчен көрәшәләр. Студентлар арасында 1907 нең декабреннән Монархистик яшьләрнең рус түгәрәге (1908 дән Рус монархиячел яшьләрнең Казан җәмгыяте), 1912 дән Казан шәһәре югары уку йортларының партиясез студент — академистлар түгәрәге эшли. 1908 дә Рус монархиячел яшьләрнең Казан җәмгыяте каршында «Беркут» гимнастика һәм спорт сөючеләр түгәрәге (1913 тән «Сокол» гимнастика җәмгыяте) ачыла. Казан ун-тында «уң профессорлар төркеме» эшли (җитәкчеләре — профессорлар Н.А.Засецкий, Н.Ф.Высоцкий), аңа уң һәм уртача карашлы монархистлар керә. Казанда К.ның иң югары сәяси активлыгы аларның берләшеп эшләү чорына туры килә. 1906 ның ноябрь башында СРН ның Казан губерна бүлеге (КГО СРН) ачыла (совет рәисе һәм бер үк вакытта ЦНРО советы рәисе — В.Ф.Залесский). Шуннан соң барлык Казан губернасында СРН, РНСМА, ВДСРНның бүлекләрен төзү башланып китә. 1907 нең 18 декабренә Казан губернасында СРНның 97 бүлеге (әгъзаларның гомуми саны 7 мең тирәсе) эшли. СРН, РНСМА һәм ВДСРН бүлекләренең 15%ы тирәсе чуашлар яшәгән торак пунктларда исәпләнә. 1906 ның декабрендә Казанда Залесский, Кукарников, Соловьёв, архимандрит Андрей (кенәз А.А.Ухтомский) катнашындагы «Берләшкән рус халкының өлкә идарәсе» оештырыла (ул барлык Идел-Кама төбәген үз эченә алырга тиеш була), әмма ул кәгазьдә генә оешып кала. К. барлык 4 чакырылыштагы Дәүләт Думасына сайлауларда катнаша, тик кандидатларның берсе дә сайланмый. 1 нче һәм 2 нче Дәүләт Думаларына сайлауларда алар КЦНРО, КОРС һәм ОЦСППның Берләштерелгән советыннан сайлаучыларның гомуми исемлеге һәм «Дәүләт Думасына рус кешеләреннән сайлаучылар исемлеге» күрсәткән блоклар буларак чыгыш ясыйлар. 3 нче Дәүләт Думасына сайлауларга әзерлек барышында һәм сайлаулардан соң Казанның төп К. оешмалары арасында җитди каршылыклар туа, бу исә башкала СРН җитәкчелегендәге таркалыш б-н бәйле була. 1908 нең 21–25 ноябрендә КГО СРН һәм ЦНРО Казанда Беренче Идел-Кама өлкә патриотик съездын үткәрәләр, анда СРНның 57 «провинция» бүлегеннән, ш.у. Казан һ.б. губерналар К.ының башка оешмаларыннан вәкилләр катнаша. Залесский тарафыннан съездда катнаштырылмаган КОРС һәм ОЦСПП, СРНның Соловьев контролендәге бүлекләре 1908 нең 21,23 һәм 25 ноябрендә альтернатив «гомуми җыелышлар» үткәрә. 1908–11 дә Залесский (мөстәкыйль юнәлеш) һәм Соловьев (СРН лидеры А.И.Дубровинны яклый) арасында дәвам иткән каршылык Казанда К. хәрәкәтенең үзеген какшатуга һәм сүлпәнәюгә китерә. Казан К.ы арасындагы бәхәскә аларның башкала җитәкчеләре дә җәлеп ителә (И.И.Восторгов, Дубровин һәм В.М.Пуришкевич). 4 нче Дәүләт Думасына сайлауларга әзерлек вакытында Казан К.ның бер өлеше «Казан рус сайлаучылары комитеты»на һәм «Казан рус милли клубы»на күчә. Әмма Залесский һәм ЦНРОның күп кенә әгъзалары «милләтчеләргә» каршы чыга һәм үз кандидатларын күрсәтә. Соловьёв та үз тарафдарлары б-н бергә алардан аерыла, һәм бу хәл Казанда «милләтчеләрнең» дә, К.ның да җиңелүенә китерә. Монархизм идеясенең Беренче бөтендөнья сугышы барышында тагын да көчәеп киткән кризисы К. хәрәкәтенә тискәре йогынты ясый. 1916 ның гыйнвар–мартында Казан губернасында К.ның 55 оешмасыннан 5 се генә кала. 1917 елгы Февр. рев-циясе җиңгәннән соң аларның эшчәнлеге тыела, ә оешма әгъзалары репрессияләргә дучар ителә. К.ның периодик басмалары: «Деятель», «Казанский раёшник» ж-ллары, *«Газета» правых»*, *«Казанский телеграф»*, «Русь православная и самодержавная», *«Сошники»*, *«Черносотенец»* г-талары.

*Әд.:* С о к о л о в с к и й С.А. »Революционеры и «Чёрная сотня». К., 1906; А л е к с е е в И.Е. Чёрная сотня в Казанской губернии. К., 2001; Чёрная сотня: Ист. энцикл., 1900–1917. М., 2008.

*И.Е.Алексеев.*

**КАРАГУЖА́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 44 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда, 2010 елда 469 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Никола чиркәве (1887–89 да төзелә, архит-ра истәлеге, 1990 еллар ахырында яңадан эшли башлый). 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 1867–73 тә К.да чиркәү-приход мәктәбе була, 20 йөз башында земство мәктәбе (1876 да ачыла), 12 җил тегермәне, тимерчелек, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5297 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Зөя өязе Ивановский волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 566 ир-ат; 1859 да — 1122, 1897 дә — 1595, 1908 дә — 1900, 1920 дә — 1780, 1926 да — 991, 1938 дә — 992, 1949 да — 716, 1958 дә — 789, 1970 тә — 888, 1979 да — 818, 1989 да — 645, 2002 дә — 544 кеше.

К.да генерал-лейтенант Г.А.Макаров туган.

**КАРАДУГА́Н** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 7 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 536 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек; мебель ф-касы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. М.Җәлил, *«Себер тракты тарихы» музейлары*. Сәүдәгәр М.М.Мөлекев йорты — 19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, тимерчелек, тире иләү, туку, тегүчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 18 йөз ахырында К.да сәүдәгәр М.Рахмандиевның зур күн эшкәртү з-ды, 2 су тегермәне эшли. 20 йөз башында К.да почта станциясе, арестантларны төн кундыру йорты урнаша, мәчет (1866 да төзелә), мәдрәсә, юлаучылар йорты, почта бүлекчәсе, 4 вак-төякләр кибете, су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 881 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 февраленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйн-

варыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 244, 1897 дә — 549, 1908 дә — 617, 1920 дә — 591, 1926 да — 474, 1938 дә — 408, 1949 да — 344, 1958 дә — 312, 1970 тә — 479, 1979 да — 496, 1989 да — 468, 2002 дә — 577 кеше.

**КАРАДУЛЕ́** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 39 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 111 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, агач эше, тимерчелек, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә Вознесение чиркәве (1766 да төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), аек яшәү рәвеше попечительлеге уку залы, 2 җил тегермәне, 2 тимерчелек, ярма яргыч, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2854 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 212 ир-ат; 1859 да — 844, 1897 дә — 1343, 1908 дә — 1589, 1920 дә — 1715, 1926 да — 1973, 1949 да — 743, 1958 дә — 677, 1970 тә — 481, 1979 да — 376, 1989 да — 209, 2002 дә — 144 кеше. К.дә академик Н.Г.*Четаев* туган.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**КАРАЕЛГА́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 18 *км* көньяктарак, Кара Елга елгасы буенда. 2010 елда 113 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1724 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, төзү эшләре, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Вознесение чиркәве (1860–67 дә төзелә; архит-ра истәлеге), уч-ще, 2 тегермән була; дүшәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2820 дис. тәшкил итә. 1929 да К.да «Кызыл Октябрь» к-зы оештырыла, ул 1959 да берләштерелгән «Искра» хуҗалыгы составына керә; 1998 дән — «Саваллеево» а.х. товарлары җитештерү кооперативы. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда, 1920 дән — ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 713, 1897 дә — 1426, 1917 дә — 1562, 1920 дә — 1548, 1926 да — 1169, 1938 дә — 762, 1949 да — 513, 1958 дә — 389, 1970 тә — 388, 1979 да — 203, 1989 да — 126, 2002 дә — 138 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КАРАЕЛГА́** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Борбаш елгасы буенда. 2010 елда 82 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөз уртасына кадәр нигез салына. 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдебаш волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1873 тә — 43, 1884 тә — 75, 1920 дә — 107, 1926 да — 117, 1938 дә — 123, 1949 да — 99, 1958 дә — 37, 1970 тә — 80, 1979 да — 102, 1989 да — 126, 2002 дә — 96 кеше.

**КАРАЕ́Ш** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 75 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1550 елларның 2 нче яртысыннан Казан архиерей йорты вотчинасы була. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, балыкчылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та чиркәү-приход мәктәбе, 1 тукыма һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1439 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 89 ир-ат; 1859 да — 468, 1897 дә — 620, 1908 дә — 782, 1926 да — 1009, 1949 да — 688, 1958 дә — 634, 1970 тә — 486, 1979 да — 372, 1989 да — 180, 2002 дә — 128 кеше.

**«КАРАКИТӘ́»**, карабодай сорты. 1987 дә «Татарстан кыры» ФҖБдә Н.Н.*Петелина*, З.Ю.Азизов, В.М.Галактионова, Л.С.Нижегородцева, Ф.З.*Кадыйрова* тарафыннан Марс урта мәктәбенең (Чүпрәле р-ны Югары Каракитә а.) уку-җитештерү бригадасы катнашында чыгарыла. Питомникның корылыкка каршы торучанлык формалаштыру материалыннан орлыкларны индивидуаль-семьялык ысулы б-н аерып алу нәтиҗәсендә булдырыла. Уртача өлгерешле сорт, вегетация чоры 70–76 көн. Интенсив үсеше б-н характерлана, бер вакытта чәчәк ата һәм өлгерә, корылыкка, коелуга һәм сөрлегүгә чыдам, ш.и. үсемлекләрне интенсив тукландыру фонында да. Орлыкларның тигезлелеге 99,7%. Бөртегенең эрелеге 85,7%. Ярманың диетик һәм кулинар үзенчәлекләре бик яхшы. Сынау елларында уңыш 1 *га* дан 24,7 *ц* (стандарттан 2,5 *ц* га югары). 1000 орлыкның массасы — 36–39 *г*. Потенциаль уңышы — 1 *га* дан 40 *ц*. Иң яхшы уңыш урта һәм җиңел гранулометрик составлы кара туфраклы һәм соры урман туфраклы җирләрдә алына. К. — иң иртә язгы срокларда чәчелә торган, туфракның оптималь җылынуына һәм чәчү алдыннан чүп үләннәрне бетерүгә ориентлашкан сортларның берсе. Киң рәтләп чәчкәндә орлыкларның чәчү нормасы 1 *га* 1–1,3 млн., тоташ чәчүдә — 1,5–1,8 млн. данә. ТРда 1991 дә районлаштырыла, Россиянең селекция казанышлары реестрына кертелә, Идел-Вятка һәм Урта Идел төбәкләрендә чәчүгә тәкъдим ителә. 2005 тә ТРда карабодайның бу сорты чәчелгән җирнең 6,8 мең гектарын яисә 25,5% мәйданын били. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә (1991).

**КАРАКОРЫ́М** (монгол. Хара-Хорин), урта гасырлардагы (13–16 йөзләр) шәһәр, Монгол империясе башкаласы (14 йөзгә кадәр), Урхун елгасының югары агымында урнашкан. 1220 елда Чыңгыз хан тарафыннан нигезләнә. 13 йөздә анда *Плано Карпини*, Марко Поло, В. де *Рубрук* һ.б. Көнбатыш Европа сәяхәтчеләре була. 1940 елларда археол. казу эшләре вакытында шәһәрнең көньяк-көнбатыш өлешендә калган Үгәдәй сарае, сәүдә-һөнәрчелек кварталлары калдыклары, гыйбадәтханә харәбәләре, сабан төрәне, тегермән ташы, чуен казаннар, тәңкәләр һ.б. табыла. Шәһәрдән ерак булмаган басуларның каналлар б-н сугарылуы ачыклана.

*Әд.:* Ядринцев Н.М. Путешествие на верховья Орхона к развалинам Каракорума // Изв. Рус. геогр. об-ва. СПб., 1890. Т. 26, вып. 4; Позднеев А. Монголия и монголы: В 2 т. СПб., 1896–98.

**КАРАКО́Ш**, төрки-татар мифологиясе персонажы, сары томшыклы һәм шундый ук тырнаклы зур кара кош, бөркетнең читләтеп әйтелгән атамасы. Татар әкиятләрендә К. патша кызына өйләнә, бик матур егеткә әверелә. Кыргыз һәм казакъ эпосында К.ның аңа охшаш тиңе бар. Ул — геройны үз канаты астына алучы гаять зур Алыпкаракош.

Язма татар әдәбияты әсәрләрендә К. атамасы еш кына тискәре мәгънәдә кулланыла. Мәсәлән, Ф.Бурнашның «Сабак булсын» шигырендә К. — Гражданнар сугышы чорында чит ил интервенциясе символы, Ф.Бурнашның «Сахра каны» поэмасында, Х.Әюпнең «Туры сүзгә» шигырендә һ.б.да К. — Россия империясенең колониаль сәясәте символы. Үзенең беренчел фольклор мәгънәсендә дә кулланыла (мәс., Ф.Бурнашның «Мөкаррәмә» поэмасында туган як азатлыгы өчен көрәшүчеләр К. б-н тиңләштерелә).

*Әд.:* Бурнаш Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1959; Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Казахский фольклор в собрании Г.Н.Потанина. А.-А., 1972.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАРАКОШЛА́Р** (Aquila), карчыга кошлар семьялыгындагы ерткыч кошлар ыругы. 9 төре билгеле, Евразия, Африка, Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. *Бөркет* (A. chrysaetus) — урманнарда яшәүче гадәти төр, 10 пардан артык оялямый. Тавышлы зур каракош (A. clanga) — оялаучы сирәк төр, саны оялаучы 5–7 пардан артмый, уртача һәм зур елга үзәннәрендә очрый. *Үләт бөркете* (A. heliaca) — оялаучы күчмә кош, барлык районнарда да, күбрәк Кама аръягында күренә. Дала каракошы (A. rapas), кәрлә каракош (Hieraaetus pennatus), тавышлы кечкенә каракош (A. pomarina) — сирәк очып керүче төрләр. Гәүдәсе 90 *см* га, авырлыгы 7 *кг* га кадәр. Канатлары киң, канат җәеме 2 *м* га кадәр. Ана һәм ата кошлар бер үк, башлыча, көрән төстә, кайбер төрләренең (бөркет, үләт бөркете) башы һәм җилкәсе аксыл. Барлык кошлар да зур томшыклы, көчле тәпиле, шүре сөяк-

ләре каурыйлы, тырнаклары очлы. Агачларда (дала каракошы җирдә) оялыйлар, бер үк ояны еллар буе файдаланалар. Сары-көрән таплы 1–2 ак йомырка сала, алар өстендә исә ана һәм ата кош — икесе дә утыралар. Вак (йомраннар, тиеннәр, су тычканнары) һәм уртача зурлыктагы имезүчеләр (сөркәләр), ш.у. кошлар һәм сөйрәлүчеләр (еланнар, кәлтәләр) б-н тукланалар; дала каракошы һәм бөркет үләксәләр б-н тукланырга мөмкин. Бөркет, үләт бөркете, тавышлы зур каракош ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАРАКУ́Л** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 45 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 205 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Апак исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1884 тә ачыла), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 834 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 8 июненнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 533, 1897 дә — 634, 1908 дә — 783, 1920 дә — 743, 1926 да — 656, 1938 дә — 329, 1949 да — 465, 1958 дә — 563, 1970 тә — 548, 1979 да — 439, 1989 да — 333, 2002 дә — 274 кеше.

**КАРАКУ́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 44 *км* көнбатыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 117 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Айбаш исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тегүчелек, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Түбән Айбашта мәчет (1876 да төзелә), мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 592,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 363, 1897 дә — 527, 1908 дә — 593, 1926 да — 500, 1938 дә — 440, 1949 да — 413, 1958 дә — 324, 1970 тә — 336, 1989 да — 135, 2002 дә — 128 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КАРАЛТУ́**, йөгертү, зәргәрчелек сәнгатендә каралтылган бизәк чыгару өчен металл (көмеш, сирәк кенә — алтын) эшләнмәләрне бизәү техникасы. Эшләнмә өслегендә тирән уемлау техникасы б-н төшерелгән бизәк көмеш, бакыр, кургаш һәм күкерт эретмәсеннән әзерләнгән махсус порошок — К. б-н каплана.

Урта гасырларда К. б-н, гадәттә, көмешче уеп чыгарган бизәк фонын каплаганнар — Болгар һәм Алтын Урда сәнгате әсәрләре (бөти тартмачыклары, кечкенә йозаклар, беләзекләр, алкалар, йөзекләр), «Казан таҗы» (15–16 йөзләр) һ.б. К.ның мондый ысулында тирән уемланган фон өслегендә каралтылган бизәкләр кабарынкы булып, ялтырап торган. 18–19 йөзләрдә фонны К. ысулы тирән уелган бизәкләрне К. алымы б-н алмаштыра һәм К. шома, кайвакыт уемланган башлыча көмеш фонда сурәтләр иҗат итү чарасына әйләнә. Беркадәр зиннәтлерәк бизәкләрдә К. алтын б-н башкарылган яки эшләнмәгә алтын йөгертелгән. Мондый очракта бизәкләр, К. ны бозмас өчен, лак яки үзле балчык б-н капланган.

К. татар беләзекләрен, йөзекләр, сирәк кенә — алка, бил каптырмаларын, хәситә, изү, чәч чулпылары тәңкәләрен бизәгәндә киң кулланылган. Татарларда 19 йөз уртасыннан чәчәк-үсемлек сабаклары формасындагы каралтылган сызылмалы бизәк төшкән яки гарәп графикасында хикмәтле Коръән сүзләре, изге теләкләр, ияләренең исемнәре язылган көмеш яссы беләзекләр аеруча популярлык казанган. Йөзекләрдә, гадәттә, чәчәк бәйләме яки сабак рәвешендәге бизәк-калканчык К. б-н зиннәтләнгән. Мондый йөзекләр болгар чорында ук таралган була, ләкин аларда бизәк әйләнәсендә уеп алынган фон каралтыла. 19 йөз ахырыннан көмеш яки алтын йөгертелгән беләзекләрне еш кына ул вакытта Дагстанда әзерләнгән (Кубачы авылы) модалы үрнәкләрне күчереп эшләүче Балык Бистәсе зәркән осталары җитештерә башлый.

Татар зәркәнчеләре иҗатында К. Дагстан һәм Үзәк Азия үрнәкләреннән шактый аерыла: бизәкләр контурлы, аерым детальләргә игътибар бирелми, каралтылган урыннар каралтылмаганнары б-н аралашып килә, күбрәк шартлы рәвештә генә стильләшә.

К.да бизәкләр тирәнрәк уела, читләре тигез һәм бизәкнең бөтен рәсеме чүкеп бизәлгән фонда кабарынкы булып чыгып торучы тар, шома тасма б-н каймалана. Көмеш яки алтын йөгертелгән эшләнмәләр, аерым алганда, беләзекләр, башкорт, казакъ, кыргызларда аеруча киң тарала, татар зәркәнчеләре әлеге халыклар өчен аларны махсус җитештерә. К. сәнгате югары зәргәрчелек һөнәри традицияләре булган өлкәләрдә үсеш ала.

Казан каралтылган эшләнмәләрне җитештерүче эре үзәк була. 18 йөздән К. Казан арты (Байлар Сабасы, Тенәки, Килдебәк, Йосыф-Алан), Бөгелмә өязе авылларында (Иске Әлмәт, Елхово), Оренбург өлкәсенең Каргалы бистәсендә, Башкортстанның Кырмыскалы авылында һ.б. үсеш ала. Ул халык осталары иҗатында хәзерге заманнарга кадәр саклана: Әлмәт авылында (хәзерге Әлмәт ш.) 19 йөз ахырыннан 1940 елларга кадәр хәзерге Саба р-ны Тенәки авылы кешесе Йосыф бабай нигез салган Йосыповларның гаилә артеле эшли; аның эшен хатыны һәм өч улы дәвам иттерә. Әлеге алым б-н 1970 елларга кадәр Әлмәт р-ны Түбән Абдул авылыннан Миңсафа Мифтахова эшли, ул К.га Елховода яшәүче әтисе Габдерәүфтән өйрәнә; Самара өлкәсенең Камышлы р-ны Яңа Усман авылы кешесе зәркәнче Нәбиулла К.га Каргалы бистәсендә өйрәнеп кайта (бизәк фонын К.) һ.б. 1960 елларда Шәмәрдән авылында зәркән остаханәсе ачыла (1967 дә ябыла), анда якын-тирә авыллардагы осталар эшли. Тенәки авылыыннан зәргәрче Х.*Ганиев* 1990 елларга кадәр әлеге техникада эшләвен дәвам иттерә.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАРАМА́**, к. *Элмә.*

**КАРАМАЛЫ́** (Алгама, Амгамка) елгасы, Идел алдында, Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 41,3 *км*, бассейнының мәйданы 421 *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан ага, Кама Тамагы р-нында. Елга башы Антоновка авылы янында, тамагы Заовражный Каратай авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 7%. К.ның 1 дән алып 6 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы б-н характерлана, суның биеклеге шактый арта; җәйге саегу вакытында елга кибә. Ташу вакытында су агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында гомуми күләме 1,95 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары 1,1 мең *га* сугарулы җирне су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла. К. үзәнендә Карамалы күле (Байкүл), ТРның табигать истәлеге урнашкан.

**КАРАМАЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,9 *км* бассейнының мәйданы 37,8 *км*. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Карамалы посёлогыннан 1,5 *км* көнбатыштарак, тамагы — Зәй шәһәре чигендә; Зәй сусаклагычына коя. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 70%. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$ Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 65 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга

тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,007 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**КАРАМАЛЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 13 *км*, бассейнының мәйданы 56 *км*². Сарман р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Александровка авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Рантамак авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 91 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 14%. К.ның 1 дән алып 3 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елганың югары өлеше җәйге саегу вакытында еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 65 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**КАРАМАЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 8,2 *км*, бассейнының мәйданы 28,1 *км*². Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Мордва Кармакасы авылының көньягындарак, тамагы Сарабиккол авылында. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 28%. К.ның 3 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, яртысыннан күбрәген кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 135 *мм*, ташу агымы катламы 73 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында су күләме 0,26 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАРАМАЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бөрсет елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 7,4 *км*, бассейнының мәйданы 31,4 *км*². Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Рәхмәтулла Аланы посёлогыннан 2,5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Урманчы авылыннан 1,2 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 58 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 95%. К.ның 0,4 тән алып 1,6 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан күбрәге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 166 *мм*, ташу агымы катламы 97 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,16 *м*³/*с*. Язын суы елганың югары өлешендә йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), тамагы янындагы урында чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*); кышын һәм җәен елганың бөтен озынлыгына суы каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КАРАМАЛЫ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сарсаз елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 509 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөзнең 2 нче чирегендә Әсәй авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Карамалы Елга исеме б-н билгеле. Халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тегү, балта эшләре, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, К.да мәчет, 2 су тегермәне; 20 йөз башында 2 бакалея кибете, ярма яргыч була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3315 дис. тәшкил итә. 1910 да 2 нче мәчет ачыла. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароков волостена керә. 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 150, 1841 дә — 222, 1859 да — 321, 1889 да — 810, 1897 дә — 1045, 1908 дә — 1084, 1920 дә — 1394, 1926 да — 1317, 1938 дә — 1127, 1949 да — 844, 1958 дә — 807, 1970 тә — 743, 1979 да — 543, 1989 да — 485, 2002 дә — 528 кеше.

*Әд.:* К ә р и м о в Т. Карамалы авылы // Аргамак. 1999. № 2.

**КАРАМАЛЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы бассейнында. 2010 елда 204 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Беренче исеме — Исәмбай. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1200 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1945 нең 3 апреленнән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 63 ир-ат; 1859 да — 755, 1897 дә — 1174, 1908 дә — 1057, 1920 дә — 1216, 1926 да — 757, 1949 да — 694, 1958 дә — 602, 1970 тә — 621, 1979 да — 394, 1989 да — 290, 2002 дә — 279 кеше. К. — язучы Ф.К.*Сәйфи-Казанлының* туган авылы.

**КАРАМАЛЫ́** посёлогы, Зәй шәһәре карамагында, Зәй тимер юл станциясеннән 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Карамалы елгасы (Дала Зәенең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 265 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 52,5%, руслар — 45%) яши. Халкының төп шөгыле — агач әзерләү һәм эшкәртү. Башлангыч мәктәп, клуб. 1956 да Зәй урман-агач эшкәртү хуҗалыгы булarak нигез салына. 1959 ның 18 ноябрендә торак пункт булып теркәлә. 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. 1978 нең 5 апреленнән Зәй шәһәре составында. Халык саны: 1979 да — 341, 1989 да — 303, 2002 дә — 284 кеше.

**КАРАМАЛЫ́ ЕЛГА́** (Чалпаймас) авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 16 *км* көньяктарак, Чалпаймас елгасы буенда. 2010 елда 27 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Бөгелмә кантоны Азнакай волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 136, 1938 дә — 241, 1949 да — 253, 1958 дә — 92, 1970 тә — 126, 1979 да — 84, 1989 да — 38, 2002 дә — 21 кеше.

**КАРАМАЛЫ́ КҮЛЕ́**, к. *Байкүл*.

**КАРАМАЛЫ́ ТА́У**, шәһәр тибындагы посёлок, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 6 *км* көнбатыштарак, Идел елгасының уң ярында (Куйбышев сусаклагычы буенда) урнашкан. Мәскәү–Казан тимер юлындагы Зөя станциясе. 2010 елда 8048 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 78,5%, татарлар — 14,5%) яши. Тире эшкәртү ф-касы, ит комб-ты бар. Урта һәм тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Троица чиркәве (1735 тә төзелә; архит-ра истәлеге). Хәзерге исемен 1646 дан бирле йөртә. Башта Зөя Успение-Богородица монастыреныкы була. 1764 тә Экономия коллегиясе карамагына, халкы экономик (соңрак дәүләт) крәстияннәр катлавына күчерелә. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек, Идел буйлап сал агызу, елга корабльләре һәм пароходларда матрос булып эшләү. К.Т. халкы күрше Вязовые (Югары Вязовые) авылының Троица чиркәве приходына карый, шунда ук крәстиян балалары земство мәктәбендә белем ала. 1893 тә К.Т. Мәскәү–Казан тимер юлындагы станция булып китә, бу тирә-юньдәге хуҗалык тормы-

шын җанландырып җибәрә. 1913 тә Романов күпере (к. *Күперләр*) ачылганчы елга аша паром б-н чыкканнар, анда Идел буйлап паровозлар һәм вагоннар озатылган. 20 йөз башында К.Т.да 2 тегермән, 2 чәйханә, 1 казна шәраб һәм 9 вак-төяк кибете, сыраханә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 253 дис. тәшкил итә. Гражданнар сугышы чорында авыл *Казанны азат итү операциясе (1918)* б-н бәйле вакыйгалар үзәгендә була.

**КАРАМАСА́Р** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 33 *км* төньяктарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 271 кеше (татарлар) яши. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кармаса исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1317 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Иваново волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир-ат; 1859 да — 573, 1897 дә — 972, 1908 дә — 1148, 1920 дә — 983, 1926 да — 782, 1938 дә — 803, 1949 да — 643, 1958 дә — 624, 1970 тә — 570, 1979 да — 519, 1989 да — 299, 2002 дә — 317 кеше.

**КАРАМЗИ́Н** Николай Михайлович (1.12.1766, Казан губ., Сембер провинциясе Михайловка а. — 22.5.1826, С.-Петербург), язучы, тарихчы, публицист, Петербург ФА-нең шәрәфле әгъзасы (1818), хакыйкый статский советник (1824). Татар морзалары нәселеннән. Сембердә, Мәскәүдә белем ала. 1789–90 елларда Көнбатыш Европа буйлап сәяхәттә була. Әдәби-публицистик «Московский журнал» (1791–92), «Вестник Европы» ж-лларын (1802–03) нәшер итә. Рус сентиментализмына нигез салучы. Күпләгән әдәби һәм фәнни әсәрләр авторы («Бичара Лиза» — «Бедная Лиза», 1792; «Рус сәяхәтчесе хатлары» — «Письма русского путешественника», 1801; «Борынгы һәм яңа Россия турында язма» — «Записка о древней и новой России», 1811 һ.б.). 1803 тә император Александр I аны рәсми историограф итеп билгеләде. К. тарихка рациональлек һәм прагматик карашлар тарафдары була, узган вакыйгаларны өйрәнгәндә тарихи-чагыштыру алымы куллана. Аның карашынча, самодержавие, дәүләт б-н идарә итү формасы буларак, Россиягә органик рәвештә туры килә. Шул карашка нигезләнеп, ватан тарихын периодларга бүлүне кертә (борынгы, урта, хәзерге чорларга бүлә). «Борынгы һәм яңа Россия турында язма»да ук К. «Россия урта гасырларда ук инде Европага славяннар китергән һәм... озак еллар дәвамында монголлар белән элемтәбез аркасында ныгытылган борынгы Көнчыгыш гадәтләр кушылмасыннан гыйбарәт», дип билгеләп үтә, Көнчыгыш гореф-гадәтләренең һәм традицияләренең ил тарихына һәм мәдәниятенә йогынтысын ачып бирә. Төп хезмәте — «Россия дәүләте тарихы» («История государства Российского», т. 1–12; СПб., 1816–29) тулылыгы, нигезлелеге, фактлар һәм чыганаклар б-н дәлилләнгәнлеге ягыннан аерылып тора. К. татарларны Россиянең үсешен тоткарлауда гаепли, барыннан да бигрәк Батый хан явының һәм изүенең рус мәдәниятенә, рус дәүләтчелеге үсешенә бик зур зыян салуын билгеләп үтә. Аның фикеренчә, татарлар йогынтысы нәтиҗәсендә Борынгы Руська билгеле булган ирек һәм гражданлык хокуклары юкка чыга. Урда ханнарының хакимлек итүендә К. уңай сыйфатлар да күрә: «шәһәрдәге артык иркенлекне бетерү һәм самодержавие урнаштыру». Ул изү астында да рус халкының православиесе кагылгысыз калуы турындагы фикерне әйтә.



Н.М. Карамзин. Рәссам В.А.Тропинин. 1818.

К. «Тарих»ка бирелгән искәрмәләрдә бик күп документаль материаллардан өзекләр китерә, алар тарихи чыганакларның киң һәм күптөрле җыелмасы булып тора. Анда Урта Идел буеның дәүләт булып оешканга кадәрге хәле, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм татар ханлыклары турында кыйммәтле мәгълүматлар бар. К. ватан тарихының гомуми барышын аңлауга да, аерым тарихи вакыйгаларны бәяләүгә дә күп яңалык кертә. Хезмәтнең мөһим сюжет линиясе — рус кенәзләре һәм патшаларының тышкы сәясәтен тасвирлау. Хезмәттә Россиянең хәрби яулары һәм Көнчыгыш илләре б-н илчелек элемтәләре энциклопедик характер ала; галим бу элемтәләрне гасырлар дәвамында тасвирлый. К.ның матур әдәби тел б-н вакыйгаларны ачык һәм образлы итеп сурәтләп язган «Тарих»ы киң катлау укучыларга да аңлашыла һәм Россия историографиясе үсешендә яңа этап була. Казан ун-тының (1814) һәм Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте (1815) әгъзасы.

*Әд.:* П о г о д и н М.П. Н.М.Карамзин по его сочинениям, письмам и отзывам современников: В 2 ч. М., 1866; Б е с т у ж е в - Р ю м и н К.Н. Биографии и характеристики. СПб., 1882; Л о т м а н Ю.М. Сотворение Карамзина. М., 1998.


**КАРАМЫ́Ш** елгасы; к. *Сөлчә.*

**КАРА́МЫШЕВ** Валентин Валерьевич (11.12.1928, Казан — 13.9.2004, шунда ук), график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970), ТАССР-ның халык рәссамы (1979). Харьков сәнгать ин-тын тәмамлый (1954), И.А.Дайн җитәкчелегендә китап графикасы өлкәсендә специальләшә. 1954 елдан Казанда яши һәм эшли. Татарстан китап нәшрияты, «Чаян» ж-лы, «Агитплакат» остаханәсе б-н хезмәттәшлек итә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1960). Иҗат диапазоны киң булган рәссам (китап һәм журнал графикасы, иллюстрация, плакат, карикатура, станлы һәм монументаль нәкышь). К. иҗаты республикада китап графикасы сәнгатенең проф. үсешенә этәргеч бирә, рәссам заманның полиграфик мөмкинлекләрен һәм эстетикасын исәпкә алып эшли, башлыча, акварель, тушь, темпера б-н башкарылган, төсле яки аклы-каралы рәсемнәр б-н бизәлгән полосалы (бит, сәхифә) иллюстрацияләр иҗат итә (У.Шекспир, А.Пушкин, М.Лермонтов, Г.Тукай, Э.Багрицкий, А.Гайдар, В.Шишков, Ф.Хөсни, М.Әмир, Г.Әпсәләмов, З.Нури, С.Шакир әсәрләренә). К.ның иҗатына реалистик төгәллек, детальләрнең тормышчан чынбарлыгы, рәсемнәрнең табигый булуы, осталык б-н эшләнү хас. Рәссамның график иллюстрация ясау алымы һәр циклда әдәби текстның эчтәлегенә тәңгәл була һәм бөтен иҗаты дәвамында үсә бара. Аның балалар өчен чыгарылган китаплардагы, ш.и. әкиятләр, мәсәлләр җыентыкларындагы, фольклор әсәрләрендәге иллюстрацияләре (Т.Янның «Ай кызы» әкият-пьесасы, 1954; Г.Тукайның «Су анасы» әкият-поэмасы, 1969; А.Пушкинның «Поп һәм аның ялчысы Балда турында әкият»е, 1996 һ.б.) буяуларның ачыклыгы, эпизодларның кызыклы, фантастик булуы б-н аерылып тора. К.ның станлы нәкышь һәм график әсәрләре сизгер күзәтүчәнлек, йомшак юмор һәм лиризм б-н иҗат ителгән. Байтак еллар дәвамында аның тематик цикллары: балаларга багышланган жанрлы серияләр, табигать күренешләре серияләре, Казанга багышланган серияләр: «Музейда» (темпера,



В.В. Карамышев.




В.В. К а р а м ы ш е в. 1. Г. Тукайның «Су анасы» китабы тышлыгы. Эскиз. Акварель, гуашь. 1969; 2. Шул ук китапка иллюстрация. Акварель, гуашь. 1969.



В.В.К а р а м ы ш е в. «Әмәт».
Акварель, гуашь. 1979.

1964), «Беренче чирәм» (темпера, 1964), «Басу капкасы» (акварель, гуашь, 1978), «Ветлуга» (киндер, майлы буяу, 1999) кебек яңа әсәрләр б-н тулыланып тора. К.ның монументаль-бизәлеш әсәрләреннән «Балалар дөньясы» кибетенең сәүдә залындагы (1970), күмәртәләп сәүдә итү базасының күргәзмә залындагы бизәк-рәсемнәре (1972), Төзүчеләр мәдәният сараеның тамашачылар залындагы төрле төстәге ясалма ташлардан эшләнгән мозаикасы (1972) (барысы да рәссам Р.Ә.Кильдебәков б-н бергә) аерым игътибарга лаек. Республика (ТАССРның Сынлы сәнгать декадасы алды күргәзмә-смотры, 1957; «Бердәм гаиләдә», 1983; Бәйсезлек көненә һәм Татарстан рәссамнарының XI съездына багышланган сынлы сәнгать күргәзмәсе, 1999 һ.б.), төбәк («Зур Идел», 1964, 1969, 1974 һ.б.), бөтенроссия (2 нче бөтенсоюз эстамп күргәзмәсе, 1962–63 һ.б.) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт шәһәре Картиналар галереясында, ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*О.Г.Вербина.*

**КАРА́МЫШЕВА** Йолдыз Ариф кызы (4.6.1933, Мәскәү), кинорежиссёр. 1962 елда Бөтенсоюз кинематография ин-тының режиссёрлык ф-тын (А.П.Довженко остаханәсе) тәмамлый, 1962–81 дә Казан кинохроника студиясендә эшли, анда ул М.Җәлилгә багышланган «Тормыш — җыр» («Жизнь — песня») документаль-публицистик фильмын (диплом эше) төшерә (1964 тә — «милли герой образын эмоциональ яктан көчле гәүдәләндерүе» өчен Ленинградта узган Бөтенсоюз кинофестивале дипломы, 1965 тә — иң яхшы режиссура һәм фильмның иң яхшы муз. чишелеше өчен Куйбышев шәһәрендә узган Идел буе студияләренең зона кинофестивале призлары). Нәфис фильмнарны татар һәм башкорт телләрендә дубляж ясау б-н шөгыльләнә, «Киң Иделдә» («На Волге широкой») киножурнал-лының 28 тематик махсус чыгарылышын, кыска метражлы документаль һәм фәнни-популяр фильмнар, ш.и. Казан мех берләшмәсендә планлаштыруның яңа системасы турында «Уйларга, эзләнергә, өйрәнергә» («Думать, искать, учиться», 1967), «Нәҗип Җиһанов» («Назиб Жиганов», 1969), «Чуаш риваяте» («Чувашская легенда», 1970), «Казан» (табигать күренешләре турында, 1973), «Нефть катламнары штурманнары» («Штурманы нефтяных недр», 1977) фильмнарын төшерә. Үзе төшергән күп кенә фильмнарның сценарий авторы да. 1981 дән Мәскәүдә яши. 1986 да Үзәк телевидениедә Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган «Мин дә якты эз калдырырмын» («И я оставляю светлый след») дип аталган тулы метражлы төсле фильм төшерә; 1992 дә Г.Тукай исем. Гуманитар фонд оештыра.

*Әд.:* К о л и н а С. Казанские москвичи // Казань. 2001. № 9–10.

*Е.П.Алексеева.*

**КАРА́МЫШИХА** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 51 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, балта эше, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, 4 җил тегермәне, йон тетү остаханәсе, 5 май язу з-ды, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 790 дис. тәшкил итә. 1912 дә земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 22 ир-ат; 1859 да — 302, 1897 дә — 485, 1908 дә — 511, 1920 дә — 565, 1926 да — 436, 1938 дә — 453, 1949 да — 203, 1958 дә — 198, 1970 тә — 207, 1979 да — 146, 1989 да — 87, 2002 дә — 84 кеше.

**КАРА́Н-АЗИ́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 67 кеше (чуашлар, татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1762 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чуаш Караны, Пустошь-Искемунча исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-А.та земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1152 дис. тәшкил итә. 1930 да авылда «Каран-Азик» (1935 тән — Киров исем.) к-зы оештырыла, 1957 дә — «Урожай», 1988 дә «Юшадинский» (хәзер а.х. товарлары җитештерүче кооператив) с-злары составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богдановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 197, 1859 да — 250, 1870 тә — 320, 1884 тә — 345, 1908 дә — 444, 1920 дә — 505, 1926 да — 321, 1938 дә — 352, 1949 да — 234, 1958 дә — 241, 1970 тә — 246, 1979 да — 203, 1989 да — 101, 2002 дә — 91 кеше.

**КАРАНТИ́Н** (итал. guarantena, guaranta giorni — кырык көн), эпидемик яисә эпизоотик чыганаклардан йогышлы авыруларның үтеп керүен, таралуын кисәтү, авыру барлыкка килгән урыннарны чикләү һәм бетерү чаралары системасы. Беренче карантин Италиядә 14 йөздә кертелә, көймәләрнең чума авыруы булган җирдән кайтуы ачыкланганда, аларны рейдта 40 көнгә тоткарлыйлар; соңрак К. башка куркыныч йогышлы авырулар булганда да кулланыла. 19 йөздә карантин чараларын берләштерү өчен халыкара килешүләр төзүгә омтылыш ясала, 1851 елда Парижда бу кагыйдәләрне эшләү буенча халыкара конференция үткәрелә. Россиядә К., Псков, Тверь һ.б. елъязмаларына караганда, 15–16 йөзләрдә күренә башлый. Эпидемия б-н көрәшүнең бердәнбер реаль чарасы заставалар һәм кордоннар була. 1521 дә чумадан саклану өчен Псковта, 1572 дә Новгородта К. үткәрелә. 1656 да чума таралу куркынычына бәйле рәвештә Мәскәүдә радикаль чаралар үткәрелә. К. эшләре буенча 1712 дә — гомуми, ә 1728 дә төгәлрәк инструкция төзелә, 1800 дә «Чик буе һәм портлар карантины уставы» кабул ителә. Гадәттән тыш карантин чаралары 1887 дә Одессада, 1878–79 да Әстерхан губернасында үткәрелә. 20 йөз уртасыннан К. чаралары халыкара сан. кагыйдәләре буенча көйләнә. Хәзерге Татарстан терр-ясендә К. берничә мәртәбә кертелә.

Казанда беренче зур эпидемия турында мәгълүмат 1654–56 да Россиядә, ш.и. Идел буенда таралган үләт җәрәхәте яисә чума вакыйгасына бәйле. Казан тирәсендә К. билгеләнә һәм заставалар куела; үткәрелгән чараларга карамастан, 1654 тә 45 мең кеше кырыла, 1737–39 һәм 1771 дә Россиянең төньяк-көнчыгышын биләп алган чума эпидемиясе нәтиҗәләре бигрәк тә һәлакәтле була. Оренбург губернасында 1829 ның көзеннән котырган ваба 1830 да Казанга үтеп керә. Губернатор И.Г.*Жеванов* карары б-н халык җыела торган урыннар, базарлар ябыла, К. кертелә; мед. д-ры К.Ф.*Фукс* халыкка мед. ярдәме оештыра. И.Г.Жеванов үзе дә бу авыруның корбаны була. 19 йөз барышында Казанда — 1847–48, 1853, 1859, 1866, 1870–71, 1884, 1893 тә эпизодик рәвештә ваба эпидемиясе калкып чыга, авыру б-н көрәшүдә профилактика һәм терапия чаралары тагын да камилләшә. Соңгы (1961–72) ваба пандемиясе 50 илне били, 1970 тән Украина, Идел буе шәһәрләрендә теркәлә.

**Ветеринария карантины**, беренчел эпизоотик чыганак чигеннән авыруның читкә таралу билгеләре күренә башлауга куела һәм түбәндәге авыруларга кагыла: тилчә, Себер түләмәсе, сап, чәчәк, эмфиземалы чуан, йогышлы үпкә пәрдәсе ялкынсынуы авыруы, кәҗәләрдә йогышлы үпкә ялкынсынуы авыруы, Ауэски авыруы, чума (ш.и. Африка дуңгыз һәм атлар чумасы, ерткычлар чумасы) мөгезле эре терлектә нодуляр дерматит, Рифта үзәне бизгәге, Тешень авыруы, дуңгызларда везикуляр авыру, эпизоотик лимфангоит, йогышлы анемия, йогышлы энцефаломиелит, грипп (ш.и. кош гриппы), Ньюкасл авыруы, үрдәкләрдә вируслы гепатит, куяннарда микосоматоз. Карантин чараларының характеры авыруның эпизоотик үзенчәлекләренә

бәйле һәм а.х. өлкәсендә җитәкчелек итүче дәүләт органнары күрсәтмәләре б-н билгеләнә.

Вет. К. районның (шәһәрнең) баш вет. табибе тәкъдиме б-н район администрациясе башлыгы карары буенча билгеләнә һәм гамәлдән чыгарыла. Карарда К. зонасы чикләре күрсәтелә (К.га кергән һәм эпидемия куркынычы булган), ул чикләр авыру таралган иисә аның б-н чиктәш урыннарны үз эченә ала. Авыруга бирешүчән хайваннарны кертү, чыгару һәм төркемнәргә бүлү тыела, терлек продукциясе һәм чималы әзерләү, азык ташу туктатыла. Тилчә яисә мөгезле эре терлектә чума кебек кизүләр вакытында авыру терлек вакытлыча аерым тотыла, ш.у. йогышлы авыру чыганагына якынаю һәм керү тыела (хезмәт күрсәтүче персоналдан тыш), әйләнеп үтү юлларын хәбәр итүче билгеләр куела, саклау постлары оештырыла. К. бетү алдыннан терлекчелек биналары һәм фермалар терр-ясе тирестән чистартыла, җентекләп дезинфекция үткәрелә. Кайбер тыю чаралары К. беткәч тә гамәлдә була. Чит илләрдән терлек кертү вакытында, профилактик карантин, терлекләрнең сәламәтлеген контрольдә тоту ысулы буларак, чик буе контроль пунктлары белгечләре тарафыннан махсус күрсәтмәләрдән файдаланып үткәрелә.

ТР территориясендә вет. К., дуңгызларда чума авыруына бәйле рәвештә 1970, 1973, 1974 тә Чирмешән, 1971 дә — Норлат һәм Алексеев, 1972 дә Бөгелмә, 1984 тә Зәй р-нnарында; 1991 дә мөгезле эре терлекләрдә Себер түләмәсе авыруы булу сәбәпле, Яшел Үзән р-ны «Уразлы» с-зында (Никольский а.), 1992 дә Әгерҗе р-ны Кандыбаш авылында, 1995 тә Лениногорск р-ны «Зеленая роща» с-зында, 2003 тә Яшел Үзән р-ны Күгеш авылында, мөгезле вак терлекләрдә Себер түләмәсе авыруына бәйле рәвештә Кайбыч р-ны «Уңыш» к-зында; 1971 дә тилчә авыруына бәйле Югары Ослан р-ны «Зөя» с-зында, 1986 да Әлмәт р-нында кертелә.

**Үсемлекләр карантины**, зарарлау чыганакларыннан чүп үләннәрнең, а.х. үсемлекләре өчен куркыныч корткычларның һәм авыру китереп чыгаручыларның үтеп керүләрен кисәтү, ш.у. бу чыганакларны чикләү һәм юк итү буенча дәүләт чаралары системасы. К. — *үсемлекләрне саклау* гомуми системасының мөһим өлеше. Бу хезмәт куркыныч корткычларның бер сорттан һәм бер төр үсемлекләрдән башкаларга күчүен, башка сортларга, төрләргә яраклашып, яңа раса һәм формалар барлыкка китерүен, ш.у. карантиндагы үсемлекләрнең хуҗалыкларга үтеп керүен булдырмый торган әчке фитосанитария чаралары б-н тыгыз бәйләнгән. Яңа төр корткычлар, авыру тудыручылар, чүп үләннәрнең үтеп керү куркынычы илләр арасында сәүдә киңәю б-н арта. К. турында беренче канун Франциядә 1660 елда сабак күгәреге эпифитотиясенә бәйле кабул ителә.

АКШта шундый канун 1881 дә гамәлгә керә һәм филлоксера б-н көрәшкә бәйле. Россиядә үсемлекләр К. турында беренче закон 1873 тә кабул ителә, 1931 дә К. хезмәте булдырыла.

Татарстанда К. инспекциясе 1934 тә ТАССР Җир эшләре халык комис-ты боерыгы б-н өлкә һәм районара карантин инспекторлары составында оештырыла (беренче җитәкчесе С.В.Муллин). 1922 дә ТРда үсемлекләр карантины буенча Дәүләт чик буе инспекциясе оештырыла һәм Бөгелмә, Буа, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә, Кукмара посёлогында, Питрәч авылында 6 районара пункт булдырыла. Инспекциянең кирәкле җиһазлары, заманча элемтә чаралары һәм транспорты бар. ТРда К. чаралары б-н гомуми җитәкчелекне Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы башкара. 2001 дә ТР дәүләт инспекторлары тарафыннан Россия төбәкләреннән 82 мең тонна, чит илләрдән кертелгән 106 мең тонна продукциягә икенчел күзәтү үткәрелә, 400 фитосанитария һәм 2600 карантин сертификатлары бирелә, 500 мең *га* чәчүлек тикшерелә.

ТРда 2 төр К. объекты таралган: алтынсу бәрәңге нематодасы (Globodera rostocnienisis) — 9 районның 37 торак пунктындагы шәхси хуҗалыкларга караган 242 *га* мәйданда һәм өч өлешле амброзия (Ambrosia trifida) — Аксубай р-нының «МЮД» с-зында. Бу объектларның чыганагын чикләү һәм аларны бетерү өчен ел саен план буенча эш алып барыла.

*Әд.:* Ветеринарное законодательство. М., 1972. Т. 1; П о с п е л о в С.М. Основы карантина сельскохозяйственных растений. Л., 1978; Руководство по общей эпизоологии. М., 1979; Сельское хозяйство: Большой энцикл. словарь. М., 1988.

*Н.П.Капитонова, М.Г.Сафин, Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КАРАНЫ́Й** Сәлах (псевд. Әбү Хәҗиб) (19 йөз), язучы. «Тәнбиһ әл-кәмал» («Талант уянуы») дини-дидактик шигырьләр, «Иказәт әт-төҗҗар» («Сәүдәгәрләргә нәсыйхәт») хикәяләр җыентыгы авторы. Аларда 19 йөзнең 1 нче чиреге татар әдәбиятына хас булган традицион дини мәсьәләләр, мөселман руханиларына карата мөнәсәбәт проблемалары яктыртыла. К. Оренбург Мөхәммәд дине кануннары Җыены б-н хезмәттәшлек итүгә каршы чыга, указлы муллаларны һәм *абызлар хәрәкәте* вәкилләрен тәнкыйтьли, мөселманнарны чәй б-н шикәрдән тыелырга чакыра. К. әсәрләренең кулъязмалары ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты каршындагы кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсендә һәм Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар бүлегендә саклана.

*М.В.Гайнетдинов.*

**КАРАСЁВ** Станислав Николаевич (2.6.1948, Кама Тамагы р-ны Кама Тамагы штп.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1995). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан оптик механика з-дында. 1973 тән Казан ун-тында, 1978 дән Казан энергетика ин-тында. Хезмәтләре деформацияләнүчән каты җисем механикасына карый. К. Фредгольмның 2 нче буын интеграль тигезләмәләрен чишә һәм аларны механика мәсьәләләренә карата куллана. Гомумиләштерелгән функцияләр нигезендә математик физиканың кырый мәсьәләләрен чишүнең яңа алымнарын эшли.

Х е з м.: Теория оболочек с учётом поперечного сдвига. К., 1978.

**КАРАСУ́** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Кече Сөлчә елгасының (Олы Сөлчә, Олы Чирмешән елгалары бассейннары) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11 *км*, бассейнының мәйданы 43,1 *км*². Идел арьягы түбәнлегеннән ага, Аксубай р-нында. Елга башы урман массивында, Трудолюбово авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы — Карасу авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 179 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. К.ның 1,1 һәм 3,7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 93 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,004 *м*³*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада су күләме 0,35 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАРАСУ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 550 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710 нан мәгълүм. 1920–1960 еллар башындагы рәсми чыганакларда 2 мөстәкыйль торак пунктка бүленә: Татар Карасуы (татарлар) һәм Рус Карасуы (чуашлар). 1965 нең 17 маеннан хәзерге исемен йөртә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау, дегет кайнату, агач эше, тимерчелек, йөн-тукыма ману — бизәк төшерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 мәчет, земство вет. хастаханәсе, тегермән, 3 ярма яргыч, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2796 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 1053, 1897 дә — 1800, 1908 дә — 2307, 1920 дә — 2446, 1926 да — 2044, 1938 дә — 1724, 1949 да — 1109, 1958 дә — 443, 1970 тә — 1317, 1979 да — 1127, 1989 да — 676, 2002 дә — 629 кеше.

**КАРАТА́ЕВ** Робиндар Николаевич (20.8.1937, Казан), метрология һәм системаларның ышанычлылыгы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), РФнең атказ. метрологы (2006). Мурманск югары диңгез уч-щесен (1961) һәм Казан ун-тын (1967) тәмам-

лый. 1961–64 елларда Актив диңгез балыкчылыгы идарәсендә (Приморье краеның Находка ш.) эшли. 1965 тән Бөтенсоюз нефть һәм газ сәнәгатен комплекслы автоматлаштыру фәнни-тикшеренү һәм проектлау-конструкторлык ин-тының Казан ф-лында. 1968–97 дә Бөтенсоюз чыгым үлчәү фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1989 дан), фәнни-тикшеренүләр бүлегенең сектор башлыгы (1993 тән), бер үк вакытта Казан техник ун-тында (1971 дән), стандартлаштыру, сертификация һәм технол. менеджмент каф. профессоры һәм Мәскәү энергетика ун-тының Казан ф-лында (1996 дан), кечкe электроэнергетика ф-ты деканы (1996–99). 2000 нән Россия сәүдә-икътисад ун-ты Казан ин-тының (ф-лының) коммерция эшчәнлеге каф. профессоры. Хезмәтләре чыгымнар үлчәү техникасына, метрологиягә һәм стандартлаштыруга карый. К. үзенең үзлекләре буенча стандарт градуирланучан тирәлекләрдән (су, һава) аермалы булган сыеклыклар һәм газларны үлчәү теориясен һәм алымнарын үстерә. Чыгым үлчәгечләрнең метрологик характеристикаларын сыек һәм газсыман тирәлекләргә яраклаштырып исәпләү алымнарын эшли. К. гамәлгә керткән яңа реологик зурлык көч үлчәнешенә ия, ул агучан тирәлекләрнең каршылыгын характерлый, газларны физик үзлекләре буенча тәртипкә салырга, газ һәм сыеклык хәрәкәте б-н бәйле процессларны модельләштергәндә газ алыштыргыч сайлап алырга мөмкинлек бирә. К.ның хезмәтләре ТР, РФ һәм чит илләр пр-тиеләрендә һәм фәнни-тикшеренү ин-тларында гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Расходомеры постоянного перепада давления (ротамеры). М., 1980 (автордаш); Метрологические аспекты измерений артериального давления и частоты сердечных сокращений. К., 2003 (автордаш); Измерение малых и микрорасходов жидкости и газа в промышленности. К., 2004.

**КАРАТА́ЕВА** Фәридә Хәйдәр кызы (6.2.1948, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (2000), проф. (2008). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре ТМРның бер- һәм ике үлчәмле спектроскопиясе ысулларына карый. К. N-(тио)фосфорил(тио)амидларның эчке молекуляр төзелешен һәм хәрәкәтчәнлеген өйрәнә, C-N һәм P-N бәйләнешләр тирәсендәге әйләнүне, прототропияне, фосфорилтропияне, ацилтропияне һәм P=S→P=O яңадан төркемләнүне кертеп, молекула эчендәге көчешләрнең гомуми схемасын билгели. Фосфорлы циклларны тикшерүләрдән алынган дәлилләр нигезендә күбесенчә яңа молекулаларның конформацияләрен билгеләүдә файдаланылучы спин-спин тәэсир итешүнең вициналь константалары өчен стереохимик корреляцияләр ала. РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (2006).

Х е з м.: Структура и внутримолекулярная подвижность N-(тио)фосфорил(тио)амидов. VI. Интерпретация методом спектроскопии ЯМР H, C и P фосфорилотропной перегруппировки в N,Ń-бис(диизопропокситиофосфориламидокарбонил)-1, 10-диаза-18-краун-6-эфире в растворе ДМСО // Журн. общей химии. 1999. Т. 69, вып. 7 (автордаш); Структура и внутримолекулярная подвижность N-(тио)фосфорил(тио)амидов. VI. Интерпретация методом спектроскопии ЯМР H, C и P N-беноил(ацетил)амидотиофосфат-N-тиобензоил(ацетил)амидофосфатной перегруппировки P=S→P=O // Журн. общей химии. 2002. Т. 72, вып. 10 (автордаш); Dynamic NMR H, C, P spectroscopy of the crown containing N-(thio)phosphoril(thio)ureas // Applyed Magnetic Resonance. 1998. V. 14, № 4 (автордаш).

**КАРАТА́ЕВКА** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 40 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасы тамагы буенда. 2010 елда 40 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920 еллар башында нигез салына. ТАССРның Чистай кантонына керә. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән Чистай р-нында. Халык саны: 1926 да — 288, 1938 дә — 316, 1949 да — 333, 1958 дә — 220, 1970 тә — 201, 1979 да — 139, 1989 да — 85, 2002 дә — 60 кеше.

**КАРАТА́Й** (Ч ү т е) елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,4 *км*, бассейнының мәйданы 56,5 *км*². Лениногорск р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чүте авылы янында, тамагы Мөэмин-Каратай авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 97 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 18%. К.ның 1,7 дән алып 4,2 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 93 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,04 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КАРАТА́Й** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 38 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басу, чыпта сугу, урман кисү, балта эше, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 792,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 56 ир-ат; 1859 да — 367, 1897 дә — 499, 1908 дә — 590, 1920 дә — 477, 1926 да — 388, 1938 дә — 361, 1949 да — 269, 1958 дә — 186, 1970 тә — 164, 1979 да — 150, 1989 да — 144, 2002 дә — 117 кеше.

**КАРАТА́Й** Шамил Сәгыйть улы (18.2.1947, Казан — 5.5.2008, шунда ук), социаль гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1996), ТРның атказ. табибе (1994). 1970 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый. 1971–77 дә Казанда Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1977 дән Казан шәһәре башкарма комитетының сәламәтлек саклау идарәсендә, 1982 дән бүлек мөдире. 1985–91 дә ГИДУВта һәлакәтләр медицинасы каф. мөдире. 1991 дән Республика һәлакәтләр медицинасы үзәге директоры; 1995 тән ТР гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары. Фәнни тикшеренүләре гадәттән тыш хәлләрдә яралanучыларга диагноз кую, аларны дәвалау һәм реабилитацияләүгә карый. РФ Гражданнарны саклау эшләре, Гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының республика реабилитацияләү үзәген оештыручыларның берсе (1996).

Х е з м.: Экология и здоровье населения. К., 1997 (автордаш); Актуальные проблемы медицины катастроф. К., 2000; Хирургия медицины катастроф. К., 2002 (автордаш).

**КАРАТА́Л** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кыярмәт елгасы буенда. 2010 елда 217 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1651 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Казый-Каратал исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, мич чыгару, урманчылык, балта эше, йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 2 җил һәм 1 су тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 йон-тукыма ману остаханәсе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 762,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 38 ир-ат; 1859 да — 375, 1897 дә — 682, 1908 дә — 795, 1920 дә — 756, 1926 да — 341, 1938 дә — 511, 1949 да — 407, 1958 дә — 377, 1970 тә — 381, 1979 да — 306, 1989 да — 221, 2002 дә — 214 кеше.

**КАРАТАМЫ́Р** (Cynoglossum), кыярчалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 70 кә якын төре билгеле, уртача һәм субтропик поясларда һәм тропикларның таулы районнарында үсә. Татарстан терр-ясендә бер төре — дару К.ы (C. officinale) барлык районнарда очрый. Даlaланган сөзәклекләрдә, буш җирләрдә, юл буйларында үсә. 50–100 *см* биеклектәге икееллык үсемлек. Тамыры калын, үзәк. Сабагы туры, берле, өске өлеше тармаклы, озын йомшак ак төкчәләр б-н капланган. Яфраклары соры киезсыман, бөтен, чиратлашкан. Чәчәк-

ләре кара кызыл, җете кызыл, бөтеркәдә, себеркәчле чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше ыргаксыман чәнечкеле 4 җәлпәк чикләвекчек. Май–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Тәмсез исе кипкәч бетә. Барлык өлешләрендә алкалоид, сумала, эфир майлары бар. Халык медицинасында тамыр һәм яфраклары тамак йомшарту, авыртуны басу, тынычландыру чарасы буларак кулланыла, ревматизм вакытында, пешкән урыннарга, чуаннарга куялар. Баллы. Агулы. Инсектицид үсемлекләр.

**КАРАТМӘ́Н** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта-капчык сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 402,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 207, 1897 дә — 301, 1908 дә — 339, 1920 дә — 364, 1926 да — 512, 1938 дә — 498, 1949 да — 276, 1958 дә — 301, 1970 тә — 294, 1979 да — 254, 1989 да — 202, 2002 дә — 265 кеше.

**КАРАТУ́З РАЙОНЫ́**, *Красноярск краеның* көньягында урнашкан. Мәйданы — 10236 *км*². 1924 елда оештырыла. Үзәге — Каратуз авылы (Красноярск шәһәреннән 760 *км* көньяктарак). Халкы — 16,8 мең кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 84 кеше. Татарлар Каратуз һәм Өҗәй авылларында яши. К.р.на алар Идел буенда 1921–22 еллардагы ачлык чорында күчеп килә. 1930 елларда Өҗәй авылында милли мәктәп була; хәзерге вакытта «Замандаш татарлар» милли-мәдәни оешмасы эшли.

**КАРАТУ́Н** посёлогы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 16 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 40 кеше (татарлар) яши. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иванаево Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да су тегермәне, тимерчелек, казна шәраб кибете, 3 ашханә, юлаучылар йорты була; дүшәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 128 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда. 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1859 да — 56, 1897 дә — 193, 1908 дә — 254, 1920 дә — 174, 1926 да — 144, 1938 дә — 117, 1949 да — 57, 1958 дә — 78, 1970 тә — 80, 1979 да — 60, 1989 да — 47, 2002 дә — 40 кеше.

**КАРАТУ́Н** тимер юл станциясе посёлогы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 1116 кеше (татарлар) яши. Нефть базасы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1942 дә нигез салына. Оештырылган көннән — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1958 дә — 258, 1970 тә — 489, 1979 да — 715, 1989 да — 894, 2002 дә — 1156 кеше.

**КАРАТУ́Н АШЛЫ́К КАБУ́Л ИТУ́ ПУ́НКТЫ** посёлогы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 437 кеше (татарлар) яши. Май з-ды, а.х. химиясе пр-тиесе, элеватор. Мәчет. 1943 тә нигез салына. Оештырылган көннән Апас р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1958 дә — 133, 1970 тә — 243, 1979 да — 295, 1989 да — 245, 2002 дә — 431 кеше.

**КАРАЧУ́РИН** Хәсән Айбулат улы (?–?), 1670–71 еллардагы Крәстияннәр кузгалышы җитәкчесе С.Т.Разинның көрәштәше. Кадом өязе йомшылы татары. Кадом һәм Керенск өязләрендә җирләр (146 чет һәм чирек), ш.у. умарталыклар, печәнлекләр, балык тоту урыннары, крәстияннәр (40 лап кеше) били. Воевода кенәз Ю.Н.Барятинский полкында хезмәт итә. 1670 нең сентябрендә, Сембер шәһәре өчен барган сугышлар вакытында, Разин ягына чыга. К., татарлар ярдәм итәчәк дип ышандырырга тырышып, аны Казанга яу б-н барырга өнди. Разин исеменнән К. «өндәү хаты» б-н Казан һәм Казан өязе татарларына мөрәҗәгать итә һәм аларны күтәрелешкә кушылырга чакыра, баш күтәргән крәстиян отрядларын җитәкли. 1670 нең декабрендә Алатырь шәһәре янында хөкүмәт гаскәрләре б-н бәрелештә катнаша, баш күтәрүчеләр анда җиңеләләр, К. бер мордва авылында яшеренә. Соңрак аны тоталар һәм воевода Ю.А.Долгоруков әмере б-н ботарлап үтерәләр, башка мәгълүматлар буенча К. «хәбәрсез югала». Аның биләмәләре Мәскәү стрелецлары башлыгы Г. Вешняковка тапшырыла.

Чыг.: Крестьянская война под предводительством Степана Разина: Сб. док. М., 1957. Т. 2, ч. 1; 1962. Т. 3.

*Әд.:* Алишев С. Х. Каһарман бабайлар. К., 1976; шул ук. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. (II половина XVI–XIX вв.). К., 1999.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КАРАЧУ́РИН КАГА́Н** (Кара Журин Төрк Биягу, Дянгу Дату-каган, Тарду) (?–604), төркиләр каганы (7 йөз башыннан). *Истәми каганның* улы. Урта Азияне, Харәземне яулауда (566), эфталитлар б-н сугышларда, Көнчыгыш Европага яу чабуда (568–71) катнаша. 567 елда Төрки каганлыкның үзәге Җидесуда урнашкан көнбатыш өлешенең идарәчесе (тардуш хан) була. Кытай (582) һәм Иран (589) б-н Бөек ефәк юлын үз контроленә алу өчен сугыша. Кытай гаскәрләре б-н сугышта (604) һәлак булганнан соң, каганлык 2 өлешкә — Көнчыгыш һәм Көнбатыш каганлыкларга бүленә.

*Әд.:* Гумилёв Л.Н. Древние тюрки. М., 1967.

*И.Л.Измайлов.*

**КАРАЧЫ́ БӘК**, төрки-монг. дәүләтләрендә *диван* әгъзасы, югары катлау аксөякләр вәкиле. «К.б.» төшенчәсе 13 йөз башында Монгол империясендә, соңрак чыңгызыйлар нигезләгән барлык дәүләтләрдә, ш.и. Җүчи Олысында, Казан, Кырым һәм Касыйм ханлыкларында барлыкка килә. К.б.ләр мөһим дәүләт эшләрен карау һәм хәл итү б-н шөгыльләнәләр, алар карамагына финанс-адм. эшләр, җир фондының бер өлеше, гражданнар мәхкәмәсе эшләре, тышкы сәясәт, хәрби мәсьәләләр һ.б. керә. Алар дәүләт актларын һәм ярлыкларны имзалау хокукына ия була. Хан диванына, гадәттә, илнең барлык терр-ясен иңләгән 4 зур олыс б-н җитәкчелек иткән 4 төп идарәче ыругтан (Җүчи Олысында — Аргын, Барын, Кыпчак, Ширин) берәр К.б. сайланган. К.б.ләр арасыннан *бәкләр бәкләре* һәм вәзирләр күрсәтелгән. Аксөякләр һәм хан йогынтысына бәйле рәвештә К.б.ләрнең ил б-н идарә итүдәге роле һәм әһәмияте төрлечә булган. 14 йөз уртасында таба аксөякләр позициясе көчәя төшү һәм ханнар хакимияте йомшару нәтиҗәсендә Алтын Урдада К.б.ләрнең йогынтысы арта. К.б.ләрнең вазифасы тора-бара варислы һәм алыштыргысыз дәрәҗәгә әверелә. К.б.ләрнең кайберләре чынлыкта ил б-н идарә итә (*Мамай*, *Идегәй*). Казан, Кырым һәм Себер ханлыкларында К.б.ләр зур кодрәткә ия булалар, алар барлык дәүләт эшләре б-н җитәкчелек итеп кенә калмыйча, ханнарны билгеләр яки тәхеттән төшерәләр. 15–16 йөзләрдәге татар ханлыкларында (бигрәк тә Казан һәм Кырым ханлыкларында) К.б.ләр арасында Ширин ыругы вәкилләре төп рольне уйныйлар, кагыйдә буларак, аларны бәкләр бәкләре итеп билгелиләр.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Т. 2; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1975.

*И.Л.Измайлов.*

**КАРАЧЫБӘ́К** (?–1587), Себер ханлыгы *карачы бәге*. Үзәге Иртеш елгасы буенда урнашкан шәһәрчекле (Кашлык шәһәре янындагы Карачын кала) олыс идарәчесе, *Күчем ханның* киңәшчесе һәм яубашы була. 1582–85 елларда казаклар атаманы Ермакка каршы көрәш алып барган җитәкчеләрнең берсе. 1584 тә Кашлыкны камый, җиңелә. 1585 тә Күчем хан б-н бергәләп Ермакка каршы сугышу турында килешү төзи. Әмма аларның гаскәрләре Бигеш шәһәрчеге янында тар-мар ителә. Ермакның үлеменнән соң Күчем хан Кашлыкны ала һәм дәүләт б-н үзәкләштерелгән идарә итү системасын торгызырга омтыла. К. фетнә күтәрә, Күчем ханны Кашлыктан куа (1586) һәм хан тәхетенә Сә-

едне утырта. Фаразлар буенча, Д.Чулков һәм М.Мещеряк җитәкчелегендәге рус отрядлары б-н бәрелештә һәлак була. Тарихчылар (мәс., М.Госманов) К.не *Кадыйргали бәк* б-н тиңлиләр.

*Әд.:* М и л л е р Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; У с м а н о в М.Г. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; С к р ы н н и к о в Р.Г. Сибирская экспедиция Ермака. Новосиб., 1982.

*И.Л.Измайлов.*

**КАРАША́Й-САКЛА́У** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 36 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 358 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Авыл тарихы музее. 1735 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Саклау, Каршы Саклау исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-С.да мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1065,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 303, 1897 дә — 680, 1926 да — 826, 1938 дә — 927, 1949 да — 590, 1958 дә — 516, 1970 тә — 580, 1979 да — 468, 1989 да — 330, 2002 дә — 347 кеше.

**КАРАШӘ́М** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 149 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, балта эше, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 918 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир-ат; 1859 да — 420, 1897 дә — 639, 1908 дә — 1031, 1920 дә — 734, 1926 да — 692, 1938 дә — 718, 1949 да — 396, 1958 дә — 395, 1970 тә — 342, 1979 да — 273, 1989 да — 214, 2002 дә — 175 кеше.

**КАРАШӘ́М ХӘЗИНӘСЕ́**, 14 йөзгә — 15 йөз башына нисбәтле болгар зәркән эшләнмәләре хәзинәсе. 1950 елда Яшел Үзән р-ны Карашәм авылы янында *Н.Ф.Калинин* һәм *А.Х.Халиков* археол. экспедициясе тарафыннан табыла. 158 предметтан, ш.и. 14–15 йөзләр башы Җучи тәңкәләреннән, алтын һәм көмеш бизәнү әйберләреннән (алкалар, уеплап бизәкләнгән тоташ беләзекләр, йөзекләр, зооморф детальләр б-н бизәлгән кадамалар, бәллүр һәм пыяла сәйләннәр), ш.у. Корьән савытыннан тора. Алар югары проф. дәрәҗәдә җепкыр, бөртекләү һәм каралту ысулларын кулланып эшләнгән (охшаш үрнәкләр Алтын Урда чорына нисбәтле башка истәлекләрдә, мәс., Болгар шәһәрлегендә очрый). Тәңкәләр буенча, К.х.нең күмелү вакыты якынча 15 йөз башына карый. К.х. турындагы материаллар 1954 тә Н.Ф.Калинин һәм А.Х.Халиков тарафыннан бастырыла. Хәзинәнең нумизматик өлешен Г.А.Фёдоров-Давыдов өйрәнә. ТРның Милли музеенда саклана (К.х. әйберләренең күп өлеше югала).

*Әд.:* К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. К., 1954.

*К.А.Руденко.*

**КАРАШИРМӘ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 180 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет (1863 тә төзелә), су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1299,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1859 да — 462, 1897 дә — 577, 1908 дә — 615, 1920 дә — 577, 1926 да — 510, 1938 дә — 512, 1949 да — 218, 1958 дә — 296, 1970 тә — 333, 1979 да — 264, 1989 да — 212, 2002 дә — 202 кеше.

**КАРБО́Н**, к. *Ташкүмер системасы (чоры).*

**КА́РБЫШЕВ** Дмитрий Михайлович (26.10.1880, Омск ш. — 18.2.1945, Австрия), фортификация өлкәсе галиме, инженерлык гаскәрләре генерал-лейтенанты (1940), хәрби фән. д-ры (1941), проф. (1938), Сов. Союзы Герое (1946, үлгәннән соң). *Нагайбәкләр* нәселеннән — керәшен татар. Себер кадетлар корпусын (1898, Омск ш.), Николаев хәрби инженерлык академиясен (1911, С.-Петербург), Генштаб Хәрби академиясен (1938, Мәскәү) тәмамлый. 1904–05 елларда рус-япон сугышында катнаша. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Көньяк-Көнбатыш фронтта инженерлык эшләре б-н җитәкчелек итә. 1918 дән Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышы вакытында Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясендә инженерлар башлыгы, Көньяк фронтның инженерлар башлыгы ярдәмчесе. 1923–26 да Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе Баш хәрби-инженерлар идарәсенең Инженерлык ком-ты рәисе. 1926 дан М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиядә каф. башлыгы, 1938 дән Генштаб Хәрби академиясендә каф. башлыгы ярдәмчесе. Хезмәтләре хәрби-инженерлык сәнгате һәм хәрби тарихка карый. Бөек Ватан сугышы башында каты контузия алган хәлдә әсирлеккә эләгә. Концлагерьларда фашистларга каршы агитация алып бара. Маутхаузен (Австрия) лагеренда гитлерчылар тарафыннан җәзалап үтерелә. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Мәскәү, Омск, Таллин һәм Маутхаузен шәһәрләрендә К.ка һәйкәлләр куела. Казанның бер урамы К. исеме б-н атала һәм мемориаль такта урнаштырыла.



Д.М.Карбышев.

Х е з м.: Избр. науч. труды. М., 1962.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Д а в ы д о в Л.Д. Верность. М., 1984; П о з н а н с к и й В.С. Д.М.Карбышев. Новосиб., 1985; Р е ш и н Е.Г. Генерал Карбышев. М., 1987; Г р и ш и н Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д. На службе Родине. К., 2005.


**КАРГА́ БОТКАСЫ́** (дәре боткасы, зәре боткасы), татар халкының *Сабан туе* бәйрәме б-н бәйле йоласы. Иртә язда, әлеге бәйрәмгә әзерлек барышында (баштарак ул чәчү эшләренә кадәр уздырылган), Казан татарларында балаларны йола боткасы б-н сыйлау гадәте булган. Өлкәннәр билгеләгән көнне шушы йоланы үтәр алдыннан балалар өйдән өйгә йөреп, төрле әйтемнәр әйтеп, хуҗалардан төрле азык-төлек җыйганнар. Болында яки тау буенда инде кардан ачылган урында зур казан асылган. Өлкән яшьтәге берничә хатын-кыз ярдәме б-н бөтен авылдан җыелган ярма, сөт, майдан К.б. пешерелгән, йомыркаларны аерым пешергәннәр. Бәйрәм итү төрле уеннар, кызыклы ярышлар, ш.у. авыру, өлкән яшьтәге һәм ялгыз авылдашларны сыйлау б-н үрелеп барган. Татарлар таралып яшәгән көнчыгыш төбәкләрдә, керәшен авылларында йола Бәрмәнчек боткасы (Кызыл тал боткасы) буларак билгеле: анда аны Олы көн (Пасха) бәйрәменә бер атна кала, Кызыл тал якшәмбесе (Вербное воскресенье) алдыннан уздырганнар. Балалар, өйдән өйгә йөреп, хуҗаларга урманда сындырып алынган кызыл тал ботаклары бүләк итәләр һәм моның өчен аларга нәрсә булса да бирәләр (гадәттә, йомыркалар); юлда очраганнарны алар, кызыклы сүзләр әйтеп, кызыл тал чыбыклары, саламнан үрелгән баулар б-н сыдыргалап китәләр. Кайбер авылларда Бәрмәнчек боткасы йоласында бала-чага түгел, ә яшьләр һәм яшь ир-атлар актив катнаша. Формасы һәм эчтәлеге ягыннан йоланың бу төре *Сөрән* йоласына туры килә. К.б. җәй коры килгәндә яңгыр яудырсын өчен дә үткәрелә.

*Әд.:* Б а я з и т о в а Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; У р а з м а н о в а Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX — нач. XX вв.). К., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАРГА́ КОШЛА́Р** (Corvidae), чыпчыксыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 100 дән артык төре билгеле, бөтен Җир шары буенча диярлек таралган. ТР терр-ясендә 8 төре бар: *козгын*, ала карга, *кара карга*, чәү-


кә (Corvus monedula), *саескан*, кукшә (Garrulus glandarius), куккош (Cractes infaustus), *әрбетче*. Урман, агачлык, торак пунктларда яшиләр. Әре яки уртача зурлыкта, тыгыз тәнле. Томшыгы нык, шактый озын, туры яки җиңелчә бөгелгән, еш кына томшык өсте кабарынкы. Борын тишекләре куе төкләр б-н капланган: тик олы кара каргаларда бу төкләр ышкылып бетә, шунлыктан томшык төбендә ялангач тире барлыкка килә. Канатлары киң; койрыгы туры, түгәрәкләнгән яки киртләч-киртләч, кайберләрендә (саескан, кукшә) озын. Төсе еш кына металлсыман кара, соры, коңгырт, кайвакыт ак яки зәңгәр урыннары да була. Парлап, сирәк кенә төркем яки колония булып оялыйлар, botаклардан ясалган ачык (козгын, ала карга, кара карга, кукшә, куккош) яки түбәле (саескан) ояларын агачларда һәм куакларда урнаштыралар, чәүкә агач куышларында һәм каралтыларда оялый. Елга бер тапкыр, иртә язда үрчиләр, ана кош кара тимгелле 2–8 зәңгәрсу-яшел йомырка сала. Утрак һәм күчмә кошлар. Төрле азык б-н тукланалар. Күп кенә төрләре файдалы — тычкансыман кимерүчеләрне һәм зарарлы бөҗәкләрне юк итәләр; кайберләре аучылык хуҗалыкларына һәм чәчүлекләргә зыян китерергә мөмкин. К.к. кышын, нигездә, үләксә б-н тукланалар. Әрбетче ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Карга кошлар. 1. Козгын; 2. Ала карга.

*Әд.:* Птицы Волжско-Камского края. Воробьиные. М., 1977.

**КАРГА́ КҮЗЕ́** (Paris), лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — дүрт яфраклы К.к. (P. quadrifolia) үсә. Бөтен районнарда урманнарда, куаклар арасында очрый. 15–30 *см* биеклектә, озын, ак, шуышма тамырчалы үсемлек. Сабагы туры, гади. Яфраклары киң эллипссыман, челтәрсыман сеңерчәле, такыя рәвешендә урнашалар. Чәчәкләре берле, сабак очында, саргылт яшел төстә. Җимеше күп орлыкчалы күксел кара җиләк, карга күзен хәтерләтә (исеме шуннан). Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм тамырчалардан үрчи, тамырында микориза хасил итә. Үсемлек составында гликозид, алкалоид, кумарин, сапониннар бар. Гомеопатиядә кулланыла. Халык медицинасында яңа җыелган үлән төнәтмәсе туберкулёз, матдәләр алмашы бозылган вакытта кулланыла; җиләкләренең согы яра төзәтү чарасы булып тора. Үсемлек тулысы б-н агулы, тәмсез исле. Хайваннар ашамый.


Дүрт яфраклы карга күзе.

**КАРГАЛЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Талкыш елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 24,7 *км*, бассейнының мәйданы 254,7 *км²*. Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Каргалы авылы янында, тамагы Олы Талкыш авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 118 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 3%. К.ның 3 тән алып 19,9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар; иң зурысы — Артъелга (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км²*. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 112 *мм*, ташу агымы катламы 108 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,033 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,9 млн. *м³* булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАРГАЛЫ́** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 11 *км* төньяктарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 423 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 5 тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төяк-ләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2386 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостенда, 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 163 ир-ат; 1859 да — 815, 1897 дә — 296, 1908 дә — 1369, 1920 дә — 1436, 1926 да — 869, 1938 дә — 893, 1949 да — 718, 1958 дә — 663, 1970 тә — 727, 1979 да — 618, 1989 да — 511, 2002 дә — 466 кеше.

**КАРГАЛЫ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 79 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Можарово, Яңа Троицкий исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да волость идарәсе урнаша; чиркәү, земство мәктәбе, тегермән, 2 вак-төякләр, 1 казна һәм 1 шәраб кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 909 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Тояба волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 22 ир-ат; 1859 да — 478, 1897 дә — 575, 1908 дә — 865, 1920 дә — 514, 1926 да — 556, 1938 дә — 536, 1949 да — 324, 1958 дә — 229, 1970 тә — 172, 1979 да — 128, 1989 да — 96, 2002 дә — 99 кеше.

**КАРГАЛЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 26 *км* төньяктарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 49 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Шыя исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Яңа Шыяда 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 978,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152 ир-ат; 1859 да — 417, 1897 дә — 561, 1908 дә — 688, 1920 дә — 417, 1926 да — 100, 1938 дә — 168, 1949 да — 120, 1958 дә — 138, 1970 тә — 165, 1979 да — 131, 1989 да — 83, 2002 дә — 64 кеше.

**КАРГАЛЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1884 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Нефть кудыру һәм газ-компрессор станциясе, яшелчә киптерү з-ды, кошчылык ф-касы эшли. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, мич чыгару, балта эше, йон тетү һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да волость идарәсе урнаша, почта станциясе, полиция үрәтниге фатиры урнаша; мәктәпләре булган 2 мәчет, 2 тимерчелек, 3 җил тегермәне, 10 бакалея кибете эшли; пәнҗешәмбе саен базар үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5391 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында.

1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия р-ны үзәге, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 193 ир-ат; 1859 да — 1479, 1897 дә — 2075, 1908 дә — 2398, 1920 дә — 2342, 1926 да — 1500, 1938 дә — 2209, 1949 да — 1839, 1958 дә — 1932, 1970 тә — 2103, 1979 да — 2148, 1989 да — 2092, 2002 дә — 2240 кеше.

**КАРГАЛЫ́ БИСТӘСЕ́** (Сәет бистәсе; хәзер Оренбург өлкәсенең Сакмар р-ны Татар Каргалысы а.), 1744 елда Оренбург шәһәреннән 18 чакрым төньяктарак Каргалы елгасы (Сакмар елгасының уң кушылдыгы) буенда Оренбург крае наместнигы И. И. Неплюевның Урта Азия һәм Шәрекъ илләре б-н сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салу һәм үстерү максатындагы үтенече буенча нигезләнә. Сәүдәгәр татарлар — Казан губернасыннан килүчеләр (салымнардан һәм хәрби бурычтан азат ителгән 200 ләп гаилә) килеп утыра. Башта бистәне нигезләүче Сәет Хәялин исеме б-н атала. 1787 дән бистә. 18 йөз ахырында анда 1,5 мең, 1835 тә — 5 мең тирәсе, 1897 дә 13 меңнән артык кеше (башлыча, татарлар) яши. К.б. кешеләре тарафыннан Оренбург губернасында 30 дан артык авылга нигез салына. 18 йөздә — 19 йөз башында Россия һәм Урта Азия арасында эре транзит сәүдәсе үзәге була. К.б.нең төп халкы һөнәрчелек (22 төрле сәнәгать оешмасы, 20 ләп су тегермәне), сәүдә, игенчелек б-н шөгыльләнә. Оренбург төбәгендәге татар мәдәнияте үзәге: 20 йөз башында К.б.ндә мәдрәсәләре һәм мәктәпләре булган 10 нан артык мәчет исәпләнә. К.б.ндә күренекле татар шагыйрьләре Ә.Каргалый, Г.Утыз Имәни, сәүдәгәр Хөсәеновлар — «Хөсәения» мәдрәсәсен нигезләүчеләр һ.б. яши. 1917 дән соң анда сәүдә-сәнәгый эшчәнлек сүлпәнәя, мәчетләрнең һәм мәдрәсәләрнең күбесе ябыла. Сәүдәгәрләрнең һәм руханиларның бер өлеше репрессияләргә дучар ителә, аларның кайберләре К.б.ннән китәргә мәҗбүр була. 2002 елдагы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча Татар Каргалысы авылында 3497 кеше яши.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н о в Р. Сәид шәһәре. К., 1897; Оренбург сәүдәгәрләре. Оренбург, 1996; И с к а н д а р о в А., И с к а н д а р о в Р. Сеитов посад: Очерки по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. К., 2005.

*Р.Н.Имангалиев.*

**КАРГАЛЫ́Й** Әбелмәних (псевд., чын исеме Габдессәлам Әбелмәних Әбелфәез угылы) (1782, Оренбург губ. Каргалы бистәсе — 1833 тән соң), шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Шагыйрь *Габдессәлам бине Урай* оныгы. Бохара мәдрәсәсендә белем ала. 1816–17 елларда Бохара әмире сараенда дипломат хезмәтендә. 1816 ның июнендә дипломатик миссия әгъзасы буларак (илчелек имамы һәм илчелек җитәкчесе Мөхәммәдйосыф бәк киңәшчесе сыйфатында) Төркиягә бара, соңрак Мисыр һәм Гарәбстанда булып кайта. Мисырда танылган җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Гали паша б-н очраша. Хаҗ кыла, Гарәбстанның изге урыннарында була. 1817 дә Истанбулга кайта. Шул ук елда, хезмәтеннән китеп, Каргалы бистәсенә кайта һәм Оренбург Мөхәммәд дине кануннары Җыенына каршы булган *абызлар хәрәкәтенә* кушыла. Абызлар карашын уртаклашып, К. рухани дәрәҗә алыр өчен имтиханнар бирүдән баш тарта, игенчелек б-н шөгыльләнә башлый. 1833 тә хаҗ кылу сылтавы б-н иленнән китә.

К. — *суфичылык әдәбияты* вәкиле (к. *Суфичылык*). Ул *мөнәҗәт*, *сәяхәтнамә*, фәлсәфә-мәхәббәт лирикасы жанрларында иҗат итә. Аскет дәрвишләр, суфи-шәехләр тормышына багышланган күпсанлы шигырьләр авторы. Шигърият б-н мәдрәсәдә укыган чордан бирле шөгыльләнә. К.ның безнең көннәргә килеп җиткән мирасы 2200 юл чамасы тәшкил итә. Язылган вакыты күрсәтелгән беренче «Шәфәгать, йа рәсулуллаһ!» исемле шигыре 1816 да хаҗ кылганда, «Тәшәккер» шигыре 1817 дә Истамбулда Бохара әмире илчесе Мөхәммәдйосыф бәк үтенече б-н языла.

Фаразланганча, 19 йөзнең 1 нче чирегендә «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди» (1845 тә басыла) җыентыгы иҗат ителә. Аңа оригиналь характердагы, сюжетлары Шәрекъ авторлары әт-Табариның (839–923) «Тәфсир әл-кәбир»еннән («Тулы тәфсир»), әл-Газалиның (1058/59–1111) «Мишкәт әл-әнвәр»еннән («Нур чыганагы») һ.б. алынган 10 шигъри хикәясе керә. Аннан тыш китапта К.ның Якын Көнчыгышка кылган сәяхәте турында автобиографик хикәясе, дини-этик эчтәлекле өч ода һәм элегияләре урын ала. К. танылган суфичылык вәкилләренә — Басрадан мистик Хәсән Басрыйга (642–723), суфи-шагыйрь Рабига Годувига (713–801), суфиларның кадыйрия борадәрлеген оештыручы Абдел-Кадыйр Гиләнигә (1166 да вафат) мәдхия җырлый һәм аларны идеаллаштыра. К. суфилар *тарикате* нигезендә абызларны берләштерү турында хыяллана, югары әхлаклы суфилар тормышыннан мисаллар китерә, хикәяләрен фәлсәфи-этик характердагы фикерләр б-н тулыландыра, җәмгыятьтә хөкем сөргән әхлаксызлыкны тәнкыйтьли.

Тормыштан күңел кайту мотивлары, дөньядан ваз кичү идеяләре К. шигърияgreтендә шактый урын ала; әсәрләрендә байлар һәм түрәләрнең комсызлыгы аркасында гаделлек мөмкин булмаган нәрсә булып кала. К. фикеренчә, оптимистик мотивлар бары тик Аллаһ, аның кодрәте һәм изгелеге б-н генә бәйле булырга мөмкин.

К. иҗаты, тулаем алганда, социаль төсмергә ия түгел, аңа көндәлек-көнкүреш темалары хас. Ләкин аерым шигырьләрендә (мәс., «Кибәй (Гобәйдулла) байга») шагыйрь үз ватанында аның тормыш тәҗрибәсе һәм талантының кирәге булмаганы өчен күңел төшенкелегенә бирелә. Охшаш мотивлар «Хаҗи Мөхәммәд байга» шигырендә дә очрый: шагыйрь Мөхәммәд байны наданлыкта, тәкәбберлектә, җәмгыять ихтыяҗларыннан читләшүдә гаепли; ул акыл хезмәте б-н шөгыльләнүче кешеләрне санга сукмаган, иске фикерле кеше образын мыскыллы көлү аша тасвирлый. Юллама формасында язылган шигырьләре шагыйрьгә фикерләрен ачыктан-ачык белдерергә, замананың чынбарлык күренешләрен чагылдырырга мөмкинлек бирә. К. хәйләгә бармаска, байлыкка кызыкмаска өнди. Борынгы суфи шагыйрьләр кебек ул саранлыкны, комсызлыкны, көнчелекне тәнкыйтьли (мәс., «Җиһанның җаһы...» шигырендә).

К. — Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган күпсанлы мөнәҗәтләр, мәдхияләр (шулар арасында «Мөнаҗәте әл-Хаҗи Әбелмәних», 1898) авторы. Аның зирәк күзәтүчәнлеге табигать һәм мәхәббәткә багышланган шигырьләрендә аеруча нык сизелә. К. — новатор-шагыйрь: татар әдәбиятында беренче тапкыр лирик әсәрнең темасы булып аерым бер кешенең эчке кичерешләре тора. Ул дөньяның төсмерләргә бай булуына, кеше хисләренең һәм үзара мөнәсәбәтләрнең тирәнлегенә төшенә. Аның поэзиясе музыкаль аһәңгә һәм эмоциягә бай. Әсәрләренең телендә гарәп-фарсы сүзләре өстенлек итә, аңа образлылык, сурәтләү байлыгы һәм төгәллек хас.

К.ның кайбер шигырьләре М.Ивановның «Татар хрестоматиясе»ндә («Татарская хрестоматия», 1842) урын алган, тагын берсе С.Кукляшевнең «Диване хикәяте татар» (1859) җыентыгына кергән, 10 шигыре «Өммикамал китабы»нда (1884) кушымта рәвешендә бирелгән. Шигырьләренең бер өлеше Р.Фәхретдиннең «Сәгыйд» (1897) китабында урын алган, кабат аның «Асар» (1903) китабының 4 нче кисәгендә басылган. К.ның аерым әсәрләре «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» (1982) хезмәтенә кертелгән. Аеруча тулы шигырьләр җыентыгы М.В.Гайнетдинов тарафыннан 2002 елда бастырыла. К. кулъязма мирасының күп өлеше Казан, С.-Петербург, Ташкент архивларында саклана.

Ә с ә р.: Мөнәҗәтләр. Хикәятләр. К., 2002.

*Әд.:* С а д р е т д и н о в Ш., Г а й н е т д и н о в М.Ә. Каргалый: Студентлар өчен ярдәмлек. К., 1978; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

*М.В.Гайнетдинов.*

**КАРГА́Н**, к. *Шикша*.

**КАРГА́Т РАЙОНЫ́**, *Новосибирск өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 5,6 мең *км*². 1925 елда оештырыла. Үзәге — Каргат шәһәре (Новосибирск шәһәреннән 177 *км* көнбатыштарак). Халкы — 19,3 мең кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, 500 гә якын татар. Татарлар, күбесенчә, Муса авылында (230 кеше), Теренино (169), Шибаки (41) посёлокларында яши. 1917 гә кадәр Муса авылында мәчет була, 1930 елларга кадәр җирле мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. 1995 тән Теренино посёлогында «Чишмә» татар вокаль ансамбле эшли.

**КАРГИ́Н** Рафаил Габдрахман улы (28.11.1931, Казан), инженер-механик, «Хитон» АҖ ген. директоры (1997–2003), ТАССРның атказ. химигы (1991). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1956). 1947–51 елларда Казан промторгында эшли. 1956–68 дә Казан ясалма каучук з-дында мастер, цех механигы, директор урынбасары. 1968–97 дә «Хитон» АҖ директоры.

К. җитәкчелегендә пр-тиене реконструкцияләү үткәрелә. Сыек һәм паста хәлендәге югычлар, лак-буяу һәм аэрозоль әйберләр җитештерү оештырыла. 149 төрдәге яңа товар җитештерелә башлый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КАРГИ́Н** Юрий Михайлович (24.11.1931, Түбән ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1985). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1954–61 дә һәм 1972–2000 дә шунда ук эшли, 1972–97 дә физик химия каф. мөдире. 1961–72 дә һәм 1986 дан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында (1986–96 да электрохимия лаб-ясе мөдире). Хезмәтләре электрорганик химиягә карый. Органик кушылмаларның электрохимик кайтарылу механизмын, аларның электрохимик реакцияләргә керү сәләте б-н химик төзелеше арасындагы бәйләнешне, электрон күчерү нәтиҗәсендә беренчел продуктлар, башлыча, ион-радикаллар табигатен өйрәнә. Электрохимик реакцияләрдә ирекле энергияләрнең сызыкчалылык принцибын киңәйтә. Элементар стадиядәге электрон күчерү һәм химик әверелешләрнең реакцион константалары зурлыгын үлчәү юлларын тәкъдим итә. Ион-радикалларны электрохимик генерирлау ысулларын электрохимик параметрларны контрольдә тотып эшли. Электрорганик синтез буенча фәнни юнәлешкә нигез сала, фосфорорганик һәм нитрокушылмалар электросинтезын эшкәртү б-н шөгыльләнә. К. катнашында ун-тның физик химия кафедрасында «Полимер» фәнни-тикшеренү тармак лаб-ясе һәм тармак белгечләрен кабаттан әзерләү ф-ты оештырыла. СССР МС бүләге (1989), ТР Дәүләт бүләге (1994) лауреаты. 2001 дән Канадада яши.

Х е з м.: Спектры ЭПР органических ион-радикалов. М., 1980 (автордаш); Электрохимия элементоорганических соединений. Группы I, II, III периодической системы. М., 1985 (автордаш); Очерки истории электрохимии органических соединений в Казани. К., 2006 (автордаш).

**КАРГЫ́Ш**, фольклор прозасының кече жанры. Ерак үткәннәргә барып тоташа; сүзнең сакраль-сихри мәгънәсенә нигезләнә. Гадәттә, кемнеңдер рәхмәтсезлеге аркасында рәнҗетелгән, явызлыгыннан зыян күргән кешенең аңа карата үпкәсе, ачуы, аннан үч алу теләге чагылышы. Татар фольклорында К.ның торыклы тезелмәләре күзәтелә: «Кулы череп аккыры», «Ашаткан ашларым, иткән яхшылыкларым тотсын» һ.б. Гадел булмаган К.ларны кире кагу сүзләре дә бар: «Авызыңнан җил алсын, илтеп куеныңа салсын», «Каргышыңа — каргышым», «Каргышың казык башына» һ.б. Кайвакыт кемгә дә булса килгән афәтләрне нәкъ менә К.лар б-н аңлаталар. Кайбер әкият һәм риваятьләрдә сый-хөрмәт күрсәтелмәгән иясә үпкәләтелгән юлаучы К.ы («Алтмыш өйле Котернәс алты өйгә калса иде»), Шүрәле К.ы («Шүрәле каргаган авыл») аркасында кешесез калган авыллар турында бәян ителә. Ана К.ы иң авырлардан һәм котылгысызлардан санала («Сак-Сок» бәете). К. жанры Х.Ш.Мәхмүтов тарафыннан өйрәнелә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАРДАШЕ́НКО** Юрий Борисович (8.8.1923, хәзерге Саратов өлкәсе Дергачи а. — 28.4.1989, Чаллы ш.), Сов. Союзы Герое (27.2.1945), гв. өлкән сержанты. Саратов политехник ин-тын тәмамлый (1951). 1941 елның октябреннән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 54 нче гв. кавалерия полкында пулемёт взводы командиры ярдәмчесе (7 нче гв. кавалерия корпусының 14 нче гв. кавалерия дивизиясе). 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Варшава-Познань һөҗүм операциясендә катнаша (1945). 1945 нең 29 гыйнварына каршы төндә Альткессель авылы (Иске Киселин, Зелёна-Гура шәһәреннән көнчыгыштарак, Польша) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга; плацдармны яулап алуда һәм аны кулда тотуда катнаша. 1945 тә демобилизацияләнә. Идел-Дон суднолар каналы һәм В.И.Ленин исем. Идел ГЭСы, 1971 дән Чаллы шәһәре КамАЗ төзелешләрендә эшли. 1973–79 да «Камгэсэнергострой» (Чаллы) берләшмәсендә баш инженер. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Р у м я н ц е в Н.М. Люди легендарного подвига. Саратов, 1968; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.; К а з а к о в Б.В. На службе Отчизне. Наб. Челны, 2002.

*М.З.Хәбибуллин.*



Ю.Б. Кардашенко.

**КАРДИОЛО́ГИЯ** (грек. kardia — йөрәк һәм *...логия*), мед. бүлеге (эчке авырулар): йөрәк-кан тамырлары системасы төзелешен һәм функцияләрен, авыруларның сәбәбен һәм көчәю-үсеше механизмын, йөрәк-кан тамырлары патологиясенең клиник күренешләрен өйрәнә, авыруларга диагноз кую ысулларын, аларны дәвалау һәм булдырмау юлларын эшли. К. фән буларак 1870 елларда формалаша. Моңа кадәр кан әйләнеше күренеше ачыла (У.Гарвей, Англия, 1628), перкуссия — йөрәкне тән өслегенә суккалап тыңлау ысуллары (Л.Ауэнбруггер, Австрия, 1761) һәм аускультация — йөрәк тибешен тыңлау (Р.Лаэннек, Франция, 1819), күкрәк бакасы — стенокардия тасвирлана (У.Геберден, 1768). К.нең алга таба үсешенә электрокардиограф уйлап табу (В.Эйнтховен, 1903); артериаль басымны үлчәүнең аускультатив ысулын эшләү (Н.Н.Коротков, 1905); йөрәк куышлыкларын тикшерү ысуллары (В.Форсман, Германия, 1929; Д.Ричардс, АКШ; А.Ф.Курнан, АКШ, 1941); йөрәк артериясенә контраст матдә кертеп, коронароангиография ысулын эшләү (А.Кастельянос, Р.Перейрас, А.Гарсия, Куба, 1938) һәм эхокардиография — йөрәкне ультратавыш б-н тикшерү (И.Эдлер, Г.Герц, Швеция, 1954); йөрәк артерияләрен ясалма киңәйтү (А.Грюнтциг, 1977) эшләре нигез була. Клиник К.гә нигез салучылар булып Дж.Макензи (Бөекбритания), П.Д.Уайт (АКШ) санала. 1950 дә Европа кардиологлары җәмгыяте, 1962 дә Бөтенроссия кардиологлары фәнни җәмгыяте төзелә.

Россиядә йөрәк-кан тамырлары авыруларын өйрәнү б-н С.П.Боткин, Р.А.Остроумов, В.П.Образцов, М.В.Яновский, Д.Д.Плетнёв, Г.Ф.Ланг, Н.Д.Стражеско, В.Ф.Зеленин, А.Л.Мясников шөгыльләнә. 1967 дә СССР МФАнең Кардиология ин-ты төзелә, 1975 тә шул нигездә СССР МФАнең Бөтенсоюз кардиология фәнни үзәге оештырыла (хәзер РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Россия Кардиология фәнни-җитештерү комплексы).

Казанда 19 йөздә йөрәк-кан тамырлары авырулары системасын өйрәнү эчке авыруларның гомуми бурычлары кысаларында үткәрелә. Терапевт галимнәр тарафыннан йөрәк-кан тамырлары авыруларының аерым мәсьәләләре тикшерелә. Н.В.*Виноградов* (1870 еллар башы) йөрәк гликозидлары тәэсире механизмнарын, йөрәк-кан тамыры системасына югары һәм түбән температураларның тәэсирен тикшерә. Ул аорта зәгыйфьлеге вакытында ят тавышның җилкә һәм бот артерияләренә үтү фактын ачыклый. А.Н.*Казимбәк* сул карынчык аневризмасы билгеләрен тасвирлый — йөрәк тибешенең өске ноктада көчле булуы б-н беррәттән нур артериясендә зәгыйфь тибешен билгели. Россиядә мед. гамәленә яңа дәвалау чарасын — строфантинны кертүдә төп рольне уйный. А.Ф.*Самойлов* Россиядә беренче тапкыр клиника шартларында электрокардиограмма (ЭКГ) яздыра (Казан, 1906; к. *Физиология*). С.С.*Зимницкий* яшьләрдә атеросклероз күренешен беренче тапкыр тасвирлый; күкрәк бакасын сальварсан препараты б-н дәвалауның оригиналь ысулын эшли; артериаль гипертониянең үзенчәлекләрен, аның «үзгәрүчән» һәм «даими» факторларын ачыклый. Л.М.*Рахлин* йөрәк мускулларында компенсаторлы үзгәрешләр вакытындагы электрокардиографик күрсәткечләрне өйрәнә; электрокардиография лаб-ясен (1934), ТАССРның кардиологлар фәнни җәмгыятен (1955) оештыра.

Татарстанда К. 20 йөзнең 2 нче яртысында актив үсеш ала. 1971 дә Казанның 7 нче шәһәр хастаханәсе нигезендә кискен йөрәк инфарктлы авыруларны дәвалау өчен 1 нче махсуслаштырылган бүлек төзелә, 1972 дә Н.П.*Медведев* тарафыннан йөрәк-кан тамырлары хирургиясе үзәге (к. *Хирургия*), 1985 тә шәһәр кардиология диспансеры ачыла. 1983 тә диспансердагы инфаркт бүлеге 15 нче шәһәр хастаханәсенә күчерелә; йөрәк авыру-

ларына диагноз куюны шактый уңай якка үстергән ике төрле үлчәмдәге эхокардиография һәм допплер-эхокардиография ысулы гамәлгә кертелә (А.С.*Галявич*, 1988); беренче коронароангиография башкарыла (2 нче Респ. клиник хастаханәсе, В.В.Коробов, 1993); йөрәк ритмының катлаулы тайпылышларына диагноз кую һәм дәвалау өчен махсуслаштырылган аритмологик үзәк төзелә (1 нче Республика клиник хастаханәсе, 1993). Л.А.*Щербатенко* атеросклероз патогенезында гипоталамо-гипофизар система ролен тәҗрибәдә һәм клиник шартларда өйрәнә; йөрәк инфарктына алдан диагноз кую ысулын, аның көчәюенә каршы профилактика үткәрүне, кискен йөрәк инфаркты кичергән авыруларны физик реабилитацияләү ысулларын эшли (1950–80). Я.М.*Милославский* гипертония авыруы вакытында бөер өсте бизләре элпәсенең функциясен өйрәнә. И.П.*Арлеевский* Казанда беренче электр импульслары б-н дәвалауны гамәлгә кертә (1966). И.Ә.*Лотфуллин* йөрәкнең кан җитешмәү авыруының төрле формаларына диагноз кую һәм дәвалауны, көчле йөрәк инфаркты мәсьәләләрен өйрәнә. А.С.Галявич озакка сузылган йөрәк зәгыйфьлеге мәсьәләләрен хәл итү буенча эшли.

Татарстан галимнәре түбәндәге фундаменталь хезмәтләрне нәшер итәләр: И.Ә.Лотфуллин — «Йөрәкнең ишемик авыруы: төп куркыныч факторлары, дәвалау» («Ишемическая болезнь сердца: основные факторы риска, лечение», 1977) һәм «Йөрәк инфаркты» («Инфаркт миокарда», 1998); А.С.Галявич — «Артериаль гипертония (диагноз кую, дәвалау)» («Артериальная гипертония (диагностика и лечение)», 1998), «Артериаль гипертонияләргә диагноз кую һәм дәвалау» («Диагностика и лечение артериальных гипертоний», 2000), «Артериаль гипертензияләр» («Артериальные гипертензии», 2002) һ.б.

*Әд.:* Богоявленский В.Ф. Профессор Семён Семёнович Зимницкий — врач, учёный, патриот. К., 1970; Анисимов В.Е., Альбицкий В.Ю. Профессор Николай Андреевич Виноградов. К., 1972; Кардиология в СССР. М., 1982; Бородулин В.И. Очерки истории отечественной кардиологии. М., 1988; Арлеевский И.П. История кафедры терапии. К., 2001; Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004; Acierno L.J. The Hystory of Cardiology. L.–N.Y., 1994.

*А.С.Галявич.*

**КА́РЕВА** (чын фамилиясе Каражеляскова) Юнона Ильинична (7.7.1933, Харьков ш.), драма актрисасы, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1973), ТР, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1997, 2005). Кинодокументалист С.С.Говорухинның әнисе. М.С.Щепкин исем. Мәскәү югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1955), Казан Зур драма театрына кабул ителә һәм анда 1993 елга кадәр эшли. К. башкаруында Надя («Фабрика кызы», А.М.Володин), Майя («Петрарка сонеты», Н.Ф.Погодин), Лиля Брегман, Лика («Ерак юл», «Минем бичара Маратым», А.Н.Арбузов), Татьяна, Ирина («Сезгә 22, картлачлар!», «Мәхәббәт турында 104 бит», Э.С.Радзинский) рольләре сәхнәдәге мөлаемлекләре б-н аерылып тора; актрисага героиняларының рухи дөньяларын гәүдәләндергәндә психологик мизгелне сизгер тоемлау, аларның хис-кичерешләрен бөтен нечкәлекләре б-н күрсәтә белү хас. Агния («Гадәт буенча җыелу», В.С.Розов), Цыренжапова («Озату», И.М.Дворецкий) рольләрендә әхлакый һәм иҗтимагый конфликтлар башлангычын чагылдыра. Рус классикларының пьесалары буенча куелган спектакльләрдә шактый гына күренекле, мәгънәле образлар, ш.и. Татьяна, Лидия Павловна («Карт», «Варварлар», М.Горький), Клеопатра («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский) образларын да иҗат итә. К. Татар филармониясе сәхнәсендә барган спектакльләрдә, героинялары характерларының асылына, катлаулы рухи дөньяларына тирәнтен үтеп кереп, Надежда фон Мекк («Мәңгелек өчен яшәү», Ю.А.Оснос) һәм Лиза Тураева («Күзге алдында», В.А.Каверин) рольләрен гаҗәеп оста башкара. 1971 елдан Казан театр уч-щесендә укыта (аның укучылары арасында Р.*Заһидуллин, Ч.Хамматова,* ТРның атказ. артисты Г.*Юрченко* да бар). Кинога төшә («Очрашу урынын үзгәртергә ярамый» — «Место встречи изменить нельзя»; «Онытыла барган темага сочинение» — «Сочинение на уходящую тему»). Актив рәвештә иҗтимагый, мәдәни-агарту эшчәнлеге б-н шөгыльләнә.



Ю.И.Карева.

*Әд.:* Колина С. Прозвище как титул // Казань. 2000. № 1; Сальтина Н. Судьбой дарованные встречи // там же. С. 65–68.

*Ю.А.Благов.*

**КАРЕ́ЙША** Пётр Степанович (1796–1830), анатом. 1816 елда Мед.-хирургия академиясен тәмамлый (С.-Петербург), хәрби-кыр госпиталендә ординатор вазифасын башкара. 1820 дән Казан ун-тында адъюнкт һәм прозектор, 1824 тән анатомия кафедрасының экстраординар профессоры һәм мөдире. 1821 дән гамәли һәм теоретик анатомия курсын алып бара (анатомия укыта башлаучыларның берсе). Казан ун-тының Анатомия музеена нигез салучы. 1830 дагы ваба эпидемиясе вакытында табиблык бурычын үтәгәндә һәлак була.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**КАРЕ́ЛИЯ РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, РФнең Төньяк-көнбатыш Европа өлешендә урнашкан, Төньяк-көнбатыш федераль округка керә. 1920 елның 8 июнендә элеккеге Олонец һәм Архангельск губерналары терр-яләрендә Карелия хезмәт коммунасы буларак оештырыла; 1923 нең 25 июленнән — Карелия АССР; 1991 нең ноябреннән — К.Р. Мәйданы — 180,5 мең *км*². Үзәге — Петрозаводск шәһәре. Халкы — 684,2 мең кеше (2010). 2002 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, татарлар — 2628 кеше (1897 дә — 61, 1926 да — 198, 1939 да — 3088, 1959 да — 2692, 1970 тә — 2603, 1979 да — 2608, 1989 да — 2992 кеше). 1920 еллар ахырына кадәр Карелиядә татар җәмгыяте сан ягыннан кечкенә була, 1930 еллардан, республикада яңа сәнәгать пр-тиеләре төзелү б-н, ул кинәт кенә үсә башлый. Бөек Ватан сугышыннан соң татарлар монда оешкан төстә күченәләр; 1950 елларның 1 нче яртысында ТАССРдан күчеп килүчеләр, башлыча, агач әзерләү сәнәгате пр-тиеләренә урнаша; 1960–70 ләрдә К.Р.на эшкә билгеләнгән Татарстан югары һәм урта махсус уку йортларын тәмамлаучылар килә; 1980 елларда республика халкы Костомукша шәһәрен һәм җирле тау казылмаларын баету комб-тын төзүдә катнаша. Хәзерге вакытта татарлар Петрозаводск, Костомукша, Питкяранта, Суоярви, Сортавала шәһәрләрендә тупланып яши. Карелия «Дуслар» татар мәдәни җәмгыяте» төбәк иҗтимагый берләшмәсе 1997 дән, К.Р. мөселманнары Диния нәзарәте, мәчет эшли. 1998 дән Петрозаводск шәһәре янында ел саен Сабан туе бәйрәме уздырыла, анда Татарстан артистлары һәм иҗат коллективлары катнаша. 2005 нең 10 июлендә Беломорск шәһәрендә «Татарстан һәм Карелия уллары һәм кызларына, Ватанны саклаучыларга (1941–1945)» һәйкәле ачыла, аны ТР хөкүмәте һәм Россия мәдәният фонды ярдәме б-н Россия мәдәният фондының Карелия ф-лы куйдыра.

Техник фән. д-ры Р.И.*Аюкаев*, армия генералы Р.Г.*Нургалиевның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Карелия б-н бәйле.

*В.Н.Бирин.*

**КАРИ́** (Кариев) Әнәс Кари улы (1920, Бөгелмә кантоны Уразай а. — 4.4.1954, Теләче р-ны Саурыш а.), шагыйрь. 1937 елдан Үргәнеч шәһәрендә (Үзбәкстан) яши. Шунда Укытучылар ин-тын тәмамлый (1939) һәм 1941 гә кадәр институтка әзерләү курсларында, 1941–42 дә Азнакай р-ны мәктәпләрендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша: Орёл шәһәре янындагы сугышларның берсендә каты яралана. 1945 елдан башта Арча пед. уч-щесендә, аннары Теләче р-ны Янсуар урта мәктәбендә укытучы булып эшли. «Балаларга бүләк» (1947), «Гөлбакча» (1948; 2 нче басмасы 1996), «Күңелле ел» (1951), «Дуслык» (1953), «Сыналган мәхәббәт» (1956), «Тамчы тамганда» (1957; 2 нче басмасы 1990) исемле шигъри җыентыклар авторы. Кайбер әсәрләре «Татар балалар поэзиясе антологиясе»нә (1980) кертелгән.

*Әд.:* Нур Г. Үсү юлында // Совет әдәбияты. 1950. № 2.

**КАРИДЕ́Л (КАРАИДЕ́Л) РАЙОНЫ́**, БРның төньяк өлешендә урнашкан. 1932 елның 20 февралендә оештырыла. Мәйданы — 3664 *км*². Үзәге — Караидел авылы (Уфадан 217 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 27,5 мең кеше (2010). Татарлар: 1970 тә — 17358, 1979 да — 14155, 1989 да — 11109, 2002 дә — 8000 кеше. Районда 102 торак пункт, ш.и. 27 татар, 10 татар-башкорт, 1 татар-рус авылы бар. Иң зур татар авыллары (2009): Байкыбаш (1346 кеше), Кызыл Үреш (568), Кирзә посёлогы (491), Тайкаш (559), Байкы-Юныс (438), Подлубов (459), Тигермән (472). 2004/05 уку елында районның

24 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. Татар телендә «Караидел» г-тасы нәшер ителә. К.р.нда Сов. Союзы Герое Н.М.*Миңнеәхмәтов*, Россия Геройлары В.Р.Алимов, Р.М.Риянов, РФнең атказ. укытучысы Н.К.Йосыпов туган.

**КАРИ́ЕВ** Габдулла (чын фамилиясе һәм исеме Хәйруллин Миңлебай Хәйрулла улы) (8.5.1886, Казан губ., Чистай өязе Күлбай Мораса а., хәзерге Нурлат р-ны Күлбай Мораса а. — 28.1.1920, Казан), драма актёры, режиссёр; татар проф. театрына нигез салучы. Башта Такталы авылы мәдрәсәсендә, аннан соң Уральск шәһәрендә белем ала, анда ул Г.Тукай б-н таныша. Сәхнә эшчәнлеген 1907 елның августында И.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге «Россиядә беренче күчмә мөселман драма артистлары труппасы»нда башлый (Түбән Новгород ш.). 1908 дән «Мосафир артистлар җәмгыяте» (соңрак «Сәйяр») дип аталган үз труппасын оештыра. К., рус театры тәҗрибәсенә таянып, рус режиссёрларын коллектив эшенә тарта, шул рәвешчә аларны пьесаларны сәхнәгә кую, укыту-өйрәтү эшләренә җәлеп итеп, татар актёрлары өчен психологик реализм мәктәбе булдыра. Г.Тукай, Г.Камал, Г.Исхакый, Г.Коләхмәтов, Г.Терегулов кебек татар әдәбияты һәм мәгарифенең алдынгы карашлы зыялылары б-н күп еллар арадашлык итү һәм элемтәдә тору, Г.Араблинскийның әзәрбайҗан труппасы б-н бергә хезмәттәшлек итү, К.С.Станиславский һәм Мәскәү Художество театры актёрлары б-н очрашып тору аның карашлары формалашуга көчле йогынты ясый. К. репертуарга аеруча зур игътибар бирә. Цензура тыюларын һәм дини фанатикларның каршылыгын җиңүгә күп көч сарыф итеп, Г.Камалның «Бәхетсез егет», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», «Беренче театр» әсәрләрен, Г.Исхакый, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, К.Тинчурин пьесаларын беренчеләрдән булып сәхнәләштерә, татар тамашачысын әзәрбайҗан драматургиясе, рус һәм дөнья классикасы б-н (башта үзгәртеп эшләнгәннәре б-н, аннары тәрҗемәләрдә) таныштыра. К. эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар театры репертуарында Н.В.Гоголь, А.Н.Островский, М.Горький, Ф.Шиллер, Н.Нариманов пьесалары да күренә башлый. Актёр татар сәхнәсенең классик



Г. Кариев (утыра) татар театр эшлеклеләре белән (сулдан уңга – К. Тинчурин, З. Солтанов, Г. Мангушев).



Г. Кариев.

үрнәгә булган Кәрим һәм Хәмзә байлар, Сираҗетдин, Хафиз («Бәхетсез егет», «Беренче театр», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», Г.Камал), Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Юныс хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь), Юсов («Төшемле урын», А.Н.Островский), Бессеменов («Мещаннар», М.Горький) кебек шактый гына тирән эчтәлекле образлар иҗат итә. Аның яңача гәүдәләндерү принцибына нигезләнгән башкаруы сәнгатьчә детальләрне төгәл һәм җентекле сайлый белүе, сәхнә персонажының һәрбер гамәлен психологик яктан дәлилләве, үткен иҗтимагый юнәлешле һәм теге яки бу характер тибының халык аңына якын булуы б-н аерылып тора. К.ның чыгышлары тамашачылар тарафыннан һәрвакыт хуплана, ә реакцион матбугатның, киресенчә, рәхимсез гаепләүләренә дучар була. Режиссёр буларак, К. куйган спектакльләрендә тормыш дөреслегенә омтыла, чынбарлык күренешләрен сәхнә югарылыгында гәүдәләндерүгә ирешә, шуның б-н бергә драматургның төп фикерен, әсәрнең төп идеясен тамашачыга җиткерергә тырыша, актёрлардан башкару барышында ансамбльлекне (берничә кешенең бергәләп уйнавын) таләп итә, күмәк иҗатка басым ясый. Актёрлар б-н эшләүгә, ш.и. сәхнә теленә зур игътибар бирә, беренче татар актёрларының һәм профессиональ, рухи остазлары була. К.Тинчурин билгеләп үткәнчә, татар мәдәнияте тарихында яңа сәхифә ачкан Г.Кариев театрның башлангыч чорында, дөрестән дә, аның бердәнбер җитәкчесе була, «ул беренчеләрдән булып татар театрына форма бирә, беренчеләрдән булып татар типларын башкара һәм аларга дөрес бәя бирә, татар театрын рухи яктан халыкка якынайта». 1988 дә Күлбай Мораса авылында Г.Кариевның мемориаль музее ачыла.

*Әд.:* Габдулла Кариев турында истәлекләр. К., 1967; Г.Кариев: Мәкаләләр, истәлекләр, документлар. К., 1976; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары: Биогр. белешмәлек. К., 2005; С а р ы м с а к о в Ш. А.Кариев. К., 1957.

**КАРИ́ЕВ Г. МУЗЕЕ́,** Нурлат р-ны Күлбай Мораса авылында, ТРның Милли музее ф-лы. 1988 елда ачыла. Музей мәйданы — 224 *м*², коллекциясендә 1 мең саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозициядә Г.*Кариев*ның мемориаль әйберләре (документлар, китаплар, афишалар), авыл тарихына багышланган бүлектә Г.Кариев, шагыйрьләр Г.*Кандалый*, Г.*Утыз Имәни* тәмамлаган мәдрәсә турында, ш.у. 18–19 йөзләрдәге китап коллекцияләре, сәүдәгәрләр Шабанов һәм агалы-энеле Сәйфуллиннарның шырпы ф-касы тарихына караган материаллар, этнография бүлегендә хезмәт кораллары, өс-баш киемнәре, көнкүреш әйберләре һәм татар халкының 19 йөзнең 2 нче яртысыннан алып 20 йөз башына кадәрге декоратив-гамәли сәнгате әсәрләре урын алган. Экспозициянең махсус бүлеге шушы авылда туып-үскән кешеләрнең язмышларын — репрессия чоры корбаннары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар тарихын чагылдыра. Аеруча кыйммәтле коллекцияләр арасында — артист Г.Р.*Шамуковның* шәхси китапханәсеннән Г.Кариев иҗаты б-н таныштыра торган документлар; 19 йөз ахыры — 20 йөз башында өйдә тукылган сөлгеләр һәм эскәтерләр; 18–19 йөзләргә караган гарәп һәм татар телләрендәге китаплар бар. 1996 елда музей К.ның туган авылы мәдәният йортында «Бөтен тормыш — театр» дигән даими эшләүче күргәзмә оештыра. Музей ел саен (октябрь аенда) Татар акад. театры б-н бергәләп «Кариев укулары» уздыра.





1. Г. Кариев музее; 2. Экспозиция фрагменты; 19 йөзгә караган халык көнкүреше әйберләре.

*Әд.:* На родине Г.Кариева: Буклет. К., 1996; Музей Г.Кариева: Буклет. Нурлат, 2003.

**КАРИЛЕ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 4 *км* көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 1287 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Поскан Котаймас, Яңа Норма исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1367,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 17 ир-ат; 1859 да — 654, 1897 дә — 636, 1908 дә — 684, 1920 дә —

750, 1926 да — 785, 1938 дә — 846, 1949 да — 623, 1958 дә — 658, 1970 тә — 764, 1979 да — 1196, 1989 да — 1445, 2002 дә — 1341 кеше.

**КА́РИН ТАТАРЛАРЫ́**, к. *Нократ татарлары.*

**КА́РИХ** Феликс Гансович (19.6.1934, Свердловск өлкәсенең Егоршино а.), физик, техник фән. д-ры (2005), проф. (2007). 1957 елда Кыргыз ун-тын (Фрунзе ш.) тәмамлаганнан соң, Фрунзе политехник ин-тында эшли. 1961–73 тә Кыргызстан ССР ФАнең Физика һәм математика ин-тында. 1973–87 дә КамАЗ лаборатор-тикшеренү эшләре идарәсенең үзәк спектраль лаб-ясе башлыгы. 1987 дән Кама инженерлар академиясендә, кою производствосы машиналары һәм технологиясе каф. профессоры. Хезмәтләре плазма һәм квант генераторларының эш программаларын тикшерүгә һәм оптимальләштерүгә карый. Руда һәм минералларны эмиссион спектраль анализлау методикасын; металларны эретүнең физик-химик параметрларын спектраль анализ нигезендә билгеләү методологиясен эшли. Уйлап табуга 27 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лазеры и их применение в науке и технике. Фрунзе, 1964 (автордаш); Производство чугунов многоцелевого назначения: разработка составов и управления технологическими процессами. М., 2009.

**КАРЛ ЛИ́БКНЕХТ** исемендәге авыл, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 23 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 9 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Мөслим р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 245, 1949 да — 204, 1958 дә — 111, 1970 тә — 104, 1979 да — 66, 1989 да — 16, 2002 дә — 12 кеше.


**КА́РЛИКОВ** Дмитрий Васильевич (1.10.1941, Чистай р-ны Керәшен Ялтаны а.), генетик, а.х. фән. д-ры (1983), проф. (1991). Керәшен татар. 1963 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1968–72 дә Кыргыз терлекчелек фәнни-тикшеренү ин-тында (Фрунзе) эшли. 1972 дән Бөтенроссия терлекчелек ин-тында (Мәскәү), 1982–2005 тә кара-чуар токымлы мөгезле эре терлекләр селекциясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре мөгезле эре терлекләрнең авыруларга бирешмәүдә генетик тотрыклылыгына һәм кара-чуар токымлы мөгезле эре терлекләр селекциясенә карый. Терлекләрнең лейкозга бирешмәүдә нәселдән килгән тотрыклылык концепциясе авторы.

Х е з м.: Селекция скота на устойчивость к заболеваниям. М., 1984; Естественный и искусственный отбор при совершенствовании высокопродуктивного скота // Зоотехния. 1990. № 1 (автордаш); Новая линия чёрно-пёстрой породы // Молочное и мясное скотоводство. 1991. № 2.

**КА́РЛОВА** Тамара Сергеевна (25.3.1932. Казан — 20.9.1989, шунда ук), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1981), проф. (1984). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1958 дән шунда эшли. Хезмәтләре Л.Н.Толстой, Ф.М.Достоевский, К.И.Чуковский иҗатларына, журналистика мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Достоевский и русский суд. К., 1975; Лев Толстой в движении истории. К., 1978; Слышу зовущий звук. К., 1992.

**КАРЛЫ́** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 88,4 *км*, ТР чикләрендә — 63,2 *км*. Бассейнының мәйданы 1005 *км*$^2$. Идел буе түбәнлегеннән ага. Елга башы һәм югары агымы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, тамагы Буа р-нының Степановка авылыннан 1 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 65 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. К.ның 24 кушылдыгы бар, иң зурлары (уң): Олы Карлы (28 *км*), Чепкас (13 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*$^2$. Елга режимы Теңкәш авылы (1976 елдан) янындагы суүлчәгеч постта өйрәнелә. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$.



Карлы елгасы. Буа шәһәре янында.

Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 71 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,48 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 5,9 млн. *м*$^3$ булган 7 буа бар.

**КАРЛЫ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 3 *км* көньяктарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 794 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек; урманчылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1662 елдан мәгълүм, 1859 га кадәр Байбулат исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (элеккеге йомышлы татарлар кебек лашманчылыкта эшли), игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1350,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 215, 1859 да — 557, 1880 дә — 707, 1897 дә — 835, 1910 да — 1018, 1913 тә — 1250, 1920 дә — 916, 1926 да — 1012, 1938 дә — 990, 1949 да — 921, 1958 дә — 932, 1970 тә — 990, 1979 да — 912, 1989 да — 747, 2002 дә — 843 кеше.

**КАРЛЫГА́Н** (Ribes), крыжовникчалар семьялыгыннан үсемлекләр ыругы. Якынча 150 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк һәм Көньяк Америка, Африкада таралган. Культурада кара К., кызыл К. (ак һәм кызыл җимешле сортлар), алтынсыман К. үстерелә. Татарстанда К.сазлык буйларында, елга ярлары буенда, куаклыклар арасында, (башлыча, Актаныш, Минзәлә, Әгерже р-ннарында) үсә. К. — 1,5–2,5 *м* биеклектәге тармакланып үсә торган куаклык. Тамыр системасы тирән түгел. Яфраклары гади, 3–5 калаклы (кара К. яфрагының аскы ягында эфир майлары булган бизләр урнашкан, алар үзенчәлекле исле була). Чәчәкләре вак, чуклы, күбесенчә ике җенесле, сирәгрәк аерым җенесле һәм икеөйле, үзлегеннән серкәләнүче (үрчемсез сортлары да очрый). Уңышы, башлыча, югары рәтләрдәге берьеллык ботакларында формалаша. Җимеш сабакчасы (уңыш формалаша торган кыска ботакчыклар) бер елдан биш елга кадәр яши (кара К. — 1–3, кызыл К. — 3–4, алтынсыман К. — 4–5 ел). 4–5 ел җимеш биргән ботакларны кисәләр. Чукларында 2 дән 18 гә кадәр җиләк үсә. Җимеше — кара, кызыл, аксыл, сары, алтынсыман һ.б. төсләрдәге җиләк, тәме әчкелтем. Үсүе һәм үрчеме өчен иң яхшы темп-ра — 18–20 °С. Кайбер сортлары — 40 °С салкынга түзә. Кышка иң чыдам төрләре — кызыл К. һәм алтынсыман К. Туфракның уңдырышлылыгына һәм дымга таләпчән. Туклыклылыгы һәм дәвалау үзенчәлекләре буенча кара К. иң кыйммәтле җиләк культураларыннан санала.



Кара карлыган.

Җимешләрендә 5–12% шикәр (глюкоза, фруктоза һәм сахароза), 2–4% кислоталар (лимон һәм алма кислотасы), С (100 *г* га 80–100*мг*), $B_1$, Р витаминнары, каротин, пектин һәм дуплау матдәләре бар. Җиләкләре яңа өлгергән, туңдырылган һәм эшкәртелгән килеш кулланыла. ТРда үстерергә тәкъдим ителгән сортлар: кара К. — «Багира», «Вологда», «Белорусская сладкая», «Минай Шмырёв»; кызыл К. — «Красный крест», «Голландская красная», «Красная Андрейченко», «Голландская белая», «Версальская белая». Алтынсыман К.ның төп сортлары: «Сеянец Крандаля», «Золотистая Ранняя», «Плотномясая» һ.б. Алтынсыман К.ны ш.у. декоратив куак буларак, урман саклау поло-

саларында, крыжовник һәм карлыганның штаммлы формаларын алу өчен ялганма сыйфатында да кулланалар. К.ны чыбыкча һәм үсентеләрдән үстерәләр. К.ның уңышы 1 *га* дан 6–10 *т*, күп булганда 20–30 *т* тәшкил итә. К. корткычлары: яфрак, бәбәк һәм бөре галлицалары (оры чебеннәре), карлыган пыялач күбәләкләре, крыжовник утчыллары, җиләк кисмәннәре, гөбләләр, калканчык күбәләкләр; авырулары: антракноз, тутык авыруы һ.б.

*Әд.:* Плодоводство. М., 1979.

**КАРЛЫГА́Н КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Илләт һәм Ашыт елгалары субүләрендә урнашкан. Биектау р-нының Гәр авылыннан 1,4 *км* көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 1,44 *га*. Су күләме якынча 30 мең $м^3$. Озынлыгы 250 *м*, иң зур киңлеге 70 *м*. Уртача тирәнлеге 2 *м* тирәсе, иң зур тирәнлеге 4,5 *м*. Күл карстсуффозия күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Озынча түгәрәк формада. Ярлары күтәренке. Туенуы тотрыклы, күбесенчә җир асты сулары исәбенә. Ял итү урыны.

**КАРЛЫГАЧЛА́Р** (Hirundinidae), чыпчыксыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 80 гә якын төре билгеле, Арктика, Антарктида, Яңа Зеландия һәм Океаниядәге вак утраулардан тыш, бөтен җирдә диярлек таралганнар. ТР терр-ясендә 3 төре яши: яр карлыгачы (Riparia riparia), авыл карлыгачы (Hirundo rustica), шәһәр карлыгачы (Delichon urbica). Республиканың бөтен терр-ясендә очрый. Тиз һәм озак очарга яраклашкан зур булмаган күчмә кош. Яр карлыгачы ерым, карьерларның текә ярларына, еш кына елга ярларына диаметры 4–5 *см* тишекле тирән оялар чокып ясый. Дистәләрчә һәм йөзләрчә оядан торган колонияләр хасил итә. Гәүдәсе сузынкы, озынлыгы 12–14 *см*, авырлыгы 11–17 *г*. Канатлары озын, муены кыска. Гәүдәсенең өске өлеше соргылт-күк, түбәнге өлеше ак, түшендә аркылы кара тасма бар. Койрыгы җиңелчә уемтылы. Авыл карлыгачы чынаяксыман оясын авыл җирлегендәге агач корылмаларның түбәләре астында балчык б-н ябыштырып ясый. Озынлыгы 16–20 *см*, авырлыгы 14–24 *г*. Гәүдәсенең өске өлеше, бүксәсендәге аркылы тасма, канат һәм койрыгы — металлсыман зәңгәр кара, аскы өлеше тутыксыман көрән төстә. Койрыгы тирән уемтылы озын чәч үргече сыман тырпаеп тора. Шәһәр карлыгачы шәһәр һәм зур посёлоклардагы таш корылмаларда, шоссе һәм тимер юл күперләрендә оялый. Яннан керү тишеге булган ярымшар формасындагы оясын, корылмаларга (торак йортларның кәрнизләрендә, балконнар астында) беркетеп, балчыктан ябыштырып ясый. Гәүдә озынлыгы 13 *см* га кадәр, авырлыгы 14–25 *г*. Гәүдәсе озын, канатлары сузынкы. Каурый капламы тыгыз, өсте зәңгәр-кара, корсак тирәсе ак. Койрыгы җиңелчә икегә аерылган. К. оча торган бөҗәкләр (парканатлылар, коңгыз, күбәләк, энә караклары) б-н туклана. Май ахыры — июнь башында оя ясауга керешә. 4–8 ак йомырка сала. Балаларын июньнең 2 нче яртысы — июль башында чыгара. Кышлау өчен август ахыры — сентябрьдә очып китәләр.



Шәһәр (1), яр (2) һәм авыл (3) карлыгачлары.

**«КАРМА́К»**, әдәби-сәяси, бизәлешле сатирик-юмористик журнал. 1915 елның гыйнварыннан 1917 нең сентябренә кадәр айга 2 тапкыр Оренбургта татар телендә барысы 60 саны нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — М.*Галәү*. Журналда Ш.Бабич, Ш.Камал, А.Максуди һ.б.ның язмалары басыла. Алдынгы идеяләрне пропагандалый һәм дини догматизмны тәнкыйтьли. Татар әдәбиятында реализм принцибын алга сөрә; әдәби яктан көчсез әсәрләрне (мәс., Ф.Сәйфи-Казанлының «Күрексез тормыш» пьесасы), авторларның социаль-сәяси пассивлыгын (ш.и. Дәрдемәнд, С.Сүнчәләй, Н.Думави, З.Бәшири) һәм аларның әсәрләрендәге персонажларны тәнкыйтьли. «К.» татар шагыйрьләре, әдип һәм публицистлары тормышына, иҗатына кагылышлы язмаларга (Ф.Әмирхан, Ш.Әхмәдиев, Ә.Вәлиди, Х.Кәрими, С.Рәмиев һ.б.) зур урын бирә. З.Бәшири, М.Гафури, С.Сүнчәләй, В.Хәлил, Г.Харис, Г.Шәрифи һ.б.ның шигырьләре басыла. Ай саен татар мәдәнияте вакыйгаларына (китаплар һәм вакытлы матбугат басмалары чыгу, яңа спектакльләр куелу һ.б.) күзәтү ясала. «Кармак» агентствосы телеграммалары» бүлегендә мәзәк хәлләр, кызыклы язмалар урын ала.

*Әд.:* Г и м а д и е в У.И. Сатира, её жанры и художественные средства, Уфа, 1980; ш у л у к. Сила сатирического слова. К., 1987.

*А.Ә.Хәсәвнех.*


**КАРМАЛЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 73 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 576 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1990 елларда Архангел Михаил чиркәве (1882–91 дә төзелә, архит-ра истәлеге) яңадан эшли башлый. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да чиркәү, земство мәктәбе (1870 тә ачыла), тимерчелек, 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2868,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 655, 1897 дә — 1365, 1908 дә — 1395, 1920 дә — 1380, 1926 да — 1144, 1938 дә — 1102, 1949 да — 749, 1958 дә — 693, 1970 тә — 753, 1979 да — 660, 1989 да — 449, 2002 дә — 661 кеше.

**КАРМА́Н** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 23 *км* төньяктарак, Аулаш елгасы буенда. 2010 елда 139 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Беләксу исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киез-киез итек басу, мичкә, тәгәрмәч ясау, балта эше, тегүчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, К.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне; 20 йөз башында 2 су тегермәне, 2 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1117 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1870 тә — 384, 1897 дә — 689, 1912 дә — 901, 1920 дә — 942, 1926 да — 739, 1938 дә — 678, 1949 да — 572, 1958 дә — 493, 1970 тә — 462, 1979 да — 305, 1989 да — 184, 2002 дә — 147 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КАРМА́НКОВО** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 6 *км* төньяктарак, Юраш (Туйманың уң кушылдыгы) елгасы буенда. 2010 елда 78 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1719 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, К.да икмәк кибете була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 619,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1781 дә — 20 ир-ат; 1836 да — 82, 1859 да — 124, 1887 дә — 166, 1905 тә — 199, 1920 дә — 200, 1926 да — 219, 1938 дә — 207, 1949 да — 160, 1958 дә — 130, 1970 тә — 124, 1979 да — 103, 1989 да — 64, 2002 дә — 63 кеше.

**КАРМӘ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Сөлчә елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 22 *км*, бассейнының мәйданы 231,6 $км^2$.



А.П. Карпеев.

Идел аръягы түбәнлегеннән ага, Аксубай р-нында. Елга башы Иске Кармәт авылыннан 2,8 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Түбән Баланда авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 157 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. К.нең 5 кушылдыгы бар, иң зурысы (уң) — Шәрбән елгасы (13 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м*³*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 0,7 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КАРМЫ́Ш** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 29 *км* төньяктарак, Сөлчә елгасы (Олы Кәминкәнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 372 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, йон-тукыма ману — бизәк төшерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәктәп, ярма яргыч, 5 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1200 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 676, 1897 дә — 1305, 1908 дә — 1543, 1920 дә — 1559, 1926 да — 1000, 1949 да — 650, 1958 дә — 589, 1970 тә — 687, 1979 да — 551, 1989 да — 390, 2002 дә — 381 кеше.

**КА́РМЫШЕВА** Бәлкыйс Хәлил кызы (13.7.1916, Кытай, Голҗа ш. — 9.10.2000, Мәскәү), этнограф, тарихчы, тарих фән. д-ры (1977). Урта Азия ун-тын (Ташкент) тәмамлый (1946). 1945–56 елларда Таҗикстан ССР ФАнең Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында. 1956 дан Россия ФАнең Н.Н.Миклухо-Маклай исем. Этнология һәм антропология ин-тында, 1986 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре Урта Азия халыкларының этногенезын һәм этник тарихын өйрәнүгә карый. К. үзенең әнисе Г.Ш.Кармышеваның 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Кытайдагы Уйгыр автономияле р-ны — Җидесу һәм Шөнҗанда яшәүче татар диаспорасы тормышын тасвирлауга багышланган истәлекләрен басмага әзерли («Татар интеллигенциясе тарихына (1890–1930 еллар)» — «К истории татарской интеллигенции (1890–1930 годы)», М., 2004).

Х е з м.: Узбеки-локайцы Южного Таджикистана: Историко-этнографический очерк животноводства в дореволюционный период. Сталинабад, 1954; Очерки этнической истории южных районов Таджикистана и Узбекистана. М., 1976.

**КА́РМЫШЕВА** Нурания Хәлил кызы (17.2.1913, Кытай, Голҗа ш. — 4.12.1985, Алма-Ата ш.), геоботаник, биол. фән. д-ры (1976). 1939 елда Урта Азия ун-тын (Ташкент) тәмамлаганнан соң, Аксу-Җабаглы саклаулыгында (Казакъстан ССР), директор (1945–51). 1959 дан Казакъстан ССР ФАнең Ботаника ин-тында. Хезмәтләре флористикага, үсемлекләр систематикасына, геоботаникага карый. К. дәвамлы тыюлык режимының үсемлекләр дөньясына тәэсирен тикшерә, Көнбатыш Тянь-Шаньның арча (артыш) урманнары типологиясен эшли.

Х е з м.: Материалы по растительному питанию белокоготного медведя в заповеднике Аксу-Джабаглы // Тр. Ин-та зоологии АН Казах. ССР. 1963. Т. 20; Флора и растительность заповедника Аксу-Джабаглы. А.-А., 1973; Флора и растительность западных отрогов Таласского Алатау. А.-А., 1982.

*Әд.:* Заповеднику Аксу-Джабаглы 50 лет. А.-А., 1976.

**КАРПЕ́ЕВ** Александр Порфирьевич (22.2.1957, Казан), курчак театры актёры, ТРның халык артисты (2005). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1979), «Әкият» татар курчак театрына кабул ителә. Шактый гына зур рольләр башкара, шулар арасында Батыр («Апушның тылсымлы төшләре», Р.Бохараев), Мөгезборын («Мөгезборын һәм жираф», Х.Гюнтер), Принц («Золушка», Ш.Перро), Падишаһ, Алып («Падишаһ кәләше», «Казан турында риваять», М.Гыйләҗев), Нихати («Елан күзләре», И.Зиннуров), Рама («Рамаяна», Л.А.Кожевников), Щелкунчик (Э.Т.А.Гофман повесте буенча) рольләре дә бар. Курчак уйнату остасы буларак, К. сәнгать чараларын мул куллана, шул рәвешчә гаять үзенчәлекле характер яки типик образ тудырырга омтыла. Тамашачы б-н тиз арада уртак тел табып, «тере план»да да чыгышлар ясый. Брауншвейг, Ботроп (ГФР, 1994, 2002), Измир (Төркия, 1999), Канн (Франция, 2000), Стара-Загора (Болгария, 2001), Рязань, Оренбург (2003) шәһәрләрендә уздырылган халыкара театр фестивальләрендә катнаша.

**КАРПИ́ЛОВ** Юрий Соломонович (21.3.1931, Чуаш АССРның Алатыр ш. — 21.9.1977, Мәскәү өлкәсе Пущино ш.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1973), проф. (1977). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1953). 1953–54 елларда ТАССРның яшьләр газеталары хәбәрчесе, 1954–56 да ВЛКСМның Тәтеш райкомы 1 нче секретаре. 1957–62 дә Казан а.х. ин-тында. 1962–72 дә Сугарулы игенчелек һәм яшелчәчелек фәнни-тикшерену ин-тының (Тирасполь ш., Молдавия ССР) изотоплар һәм фотосинтез биохимиясе лаб-ясе мөдире. 1972 дән СССР ФАнең Фотосинтез ин-тында (Пущино ш.), углерод метаболизмы лаб-ясе мөдире (1974 тән). Хезмәтләре фотосинтез һәм сулау механизмын өйрәнүгә карый. К., беренчеләрдән булып (1960), фотосинтез процессында кукурузда углерод әверелешенең аның тарафыннан «кооператив фотосинтез» дип аталган бөтенләй яңа юлын ачыклый. Соңыннан фотосинтезның бу тибы ачыш булып таныла һәм дөньякүләм фәндә $C_4$ фотосинтезы дип атала. (1966 да Австралия галимнәре М.Хетч һәм К.Слэк мәкаләләреннән соң алар фотосинтезның бу күренешен шикәр камышы мисалында раслыйлар). К. тарафыннан кайбер тропик үсемлекләрнең фотосинтез аппараты төзелеше һәм аның барышы үзенчәлекләре ачыла, $C_4$ фотосинтезы концепциясе формалаштырыла (1969).

Х е з м.: Распределение радиоактивного углерода $C^{14}$ среди продуктов фотосинтеза кукурузы // Тр. Казан. с.-х. ин-та. 1960. Т. 41, вып. 1; Особенности функций и структуры фотосинтетического аппарата некоторых видов тропического происхождения // Тр. Молд. НИИ орошаемого земледелия и овощеводства. 1969. Т. 11; Фотосинтез ксерофитов (эволюционные аспекты). Киш., 1970.

*Әд.:* М о к р о н о с о в А.Т., К а р п и л о в а И.Ф. Проблемы фотосинтеза в исследованиях Ю.С.Карпилова (1931–1977 гг.) // Физиология растений. 1992. Т. 39, № 4; Б и л ь К.Я. Юрий Соломонович Карпилов: Человек, учёный первооткрыватель кооперативного фотосинтеза (1931–1977 гг.) // Физиология растений. 2000. Т. 47, № 4.

*С.Н.Неуструева.*

**КАРПИ́НИ** (Carpini Joannes del Plano Carpine) Джованни де Плано (1182–1252), монах-францискан, сәяхәтче. Германиядә, Польшада дини эшчәнлек алып бара, Богемия, Венгрия, Данияда монастырьлар ачуда катнаша. 1245 елда Рим папасы Иннокентий IV аны Монголиягә бөек каган янына монголлар турында мәгълүматлар җыярга җибәрә. Ул анда көньяк рус кенәзлекләре, Идел буе далалары, Харәзем, Җидесу аша бара. К. Алтын Урдада Бату хан ставкасында, Монгол империясе башкаласы Каракорымда була. Анда бөек каган Үгәдәй улы Гөекне тәхеткә утырту тантанасында катнаша (1246). Үзенең сәяхәте турында «Libellus historicus» дигән хезмәтендә язып калдыра. Анда, Монгол империясе турында кыйммәтле мәгълүматлардан тыш, аларның киемсалымы, тораклары, ризыклары, диннәре, гореф-гадәтләре, йолаларының антропологик һәм этнографик тасвирламалары бирелгән.

*Әд.:* Собрание путешествий к татарам. СПб., 1825; Древняя Казань глазами историков и современников. К., 1996.

**КА́РПЛАР** (Cyprinidae), карпсыманнар отрядыннан балыклар семьялыгы. 1700 дән артык төрне берләштерә, Евразия, Төньяк һәм Үзәк Америка, Африканың төче һәм тозлы суларында таралган. ТР терр-ясендә 26 төре бар. Барлык сулыкларда диярлек — зур елга һәм сусаклагычлардан алып, сай сулы күлләргә кадәр очрый. Сузынкы һәм ян-яктан

кысынкы гәүдәсе шактый эре циклоид сыман тәңкәләр б-н капланган. Койрык йөзгеченең арткы чите уемтылы. Күпчелек төрләрнең казналыкларында тешләр юк, алтынчы саңак дугачыгында йоткылык тешләре урнашкан. Йөзү куыгы сөяк капсула б-н әйләндереп алынмаган. Нигездә, планктон һәм бентосның вак умырткасызлары б-н, кайбер төрләре (ташмаңгай, ак амур, кызылканат) күбесенчә үсемлекләр б-н туклана, ерткычлар да бар (опты). К.ның күпчелеге уылдыкны берьюлы, вак балыклар (ташбаш, кыртыш) өлешләп, җәйге чорда үрчүче төрләр (табан балыклар, карабалык) җәйдә берничә тапкыр чәчә. К. — җылылык яратучы балыклар. К. арасында күп кенә кыйммәтле кәсәбәчелек төрләре (корбан балык, чабак, бәртәс, сазан, табан балык, кәлчәк һ.б.) бар. Кайберләре (мәс., карп, табан балык, сазан) буа хуҗалыгында үрчетелә. Ак амур, гади ташмаңгай һәм чуар ташмаңгай — климатлаштыру объектлары. Гади горчак, елга ләргесе, гади подуст ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КА́РПОВ** Александр Иванович (август, 1890, Казан губ. Тәтеш ш. — 1937), партия һәм профсоюз эшлеклесе. Казан ун-тында укый. Эсерлар оешмалары эшендә катнаша. 1917 елның маеннан РСДРП(б) сафларында, 1917 нең октябрендә Революцион Хәрби Совет составына, Вакытлы революцион ком-т әгъзасы итеп сайлана. 1918 дә Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касы ХКСның сәүдә һәм сәнәгать комиссары. Гражданнар сугышында катнаша, бригада комиссары, Көнчыгыш һәм Көньяк фронтларда сугышларда полк командиры вазифасында була. 1921–22 дә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1922 дән Уралда, Украинада профсоюз эшендә. 1931–33 тә Тау-руда сәнәгате эшчеләре союзы ҮК секретаре (Мәскәү). 1933 тән Украинада партия эшендә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* А н д р и а н о в Н. Карпов Александр Иванович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

*Ф.С.Хәбибуллин.*

**КА́РПОВ** Анатолий Михайлович (23.3.1950, Казан), психиатр, фармаколог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1998). 1973 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1983 тән Казан мед. академиясендә, 1996 дан психиатрия, наркология һәм психотерапия каф. мөдире. Хезмәтләре психик авыруларны дәвалау ысулларын камилләштерүгә карый. К. фармакологик, психик, ш.у. хезмәт б-н дәвалау ысулларын эшли, психотроп дару препаратларын клиник бәяләү һәм аларга сынау үткәрә; психик авыруларның үз-үзләренә ярдәм күрсәтү мәсьәләләрен өйрәнә. Авыруларны дәвалауның системалы гуманистик концепциясен эшли. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Самозащита от наркомании: Образовательно-воспитательные основы профилактики и психотерапии наркомании. К., 2001.

**КА́РПОВ** Виктор Васильевич (27.5.1927, Ульянов өлкәсенең Сенгилей р-ны Тушна а. — 3.1.1997, Яшел Үзән р-ны Осиново а.), а.х. җитештерүен оештыручы, СССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), а/я 157 оешмасында инженер-конструктор булып эшли. 1952 елдан баш инженер, 1956–62 дә Минзәләдә МТС директоры, 1962–63 тә Минзәлә р-н башкарма ком-тының җитештерү идарәсе башлыгы урынбасары, 1963–65 тә Яшел Үзән «Сельхозтехника» берләшмәсендә управляющий. 1965–69 да ТАССР а.х. министры урынбасары. 1969–72 дә «Татколхозстрой» берләшмәсендә рәис урынбасары. 1972–88 дә Яшел Үзән р-нының «Майский» с-зы директоры. К. җитәкчелегендә 49 *га* мәйданда кышкы теплица, 6 *млн.* шартлы банкага исәпләнгән яшелчә эшкәртү цехы, 49 торак йорттан торган посёлок, 640 урынлы мәктәп, 280 урынлы балалар комб-ты, аптека, амбулатория, мәдәният йорты, сәүдә үзәге һ.б. мәдәният-көнкүреш биналары проектлана һәм төзелә; ябык грунтта яшелчә җитештерү 1988 дә 13 мең *т* га җитә, 1 $м^2$ дан 31–35 *кг* уңыш алына. К. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Свежие овощи — круглый год. К., 1980; Овощной цех Казани. К., 1987.

*Әд.:* А р х и п о в В.А. Осиновские страницы. К., 2002.

*В.А.Архипов.*

**КА́РПОВ** Лев Яковлевич (30.4.1879, Киев — 6.1.1921, Мәскәү), химик-технолог, сәясәт эшлеклесе. 1910 елда Мәскәү югары техник уч-щесен тәмамлый. 1915–17 дә Бондюг химия з-ды (хәзер Карпов исем. Менделеев химия з-ды) директоры, 1918 дән РСФСР Халык Хуҗалыгы Югары Советында Химия сәнәгате бүлеген җитәкли. К. җитәкчелегендә химия сәнәгатен оешкан төстә үзгәртүләр уздырыла, яңа химик производстволар булдырыла. Скипидар һәм канифоль алуның экстракция ысулын эшли, җиһазлауны проектлауда катнаша, үзе эшләгән технологияләрдән файдаланып, канифоль һәм скипидар җитештерү буенча Россиядә беренче пр-тиеләр төзелешен җитәкли. Бондюг химия з-дында мед. һәм техник хлороформ, сыек хлор һ.б.ны җитештерүне оештыра. РСФСР Халык Хуҗалыгы Югары Советы каршындагы Үзәк химия лаб-ясенә (хәзер К. исем. Физика-химия ин-ты) нигез салучы (1918). 1920–24 тә К. башлангычы б-н рус химия сәнәгатенең аерым тармаклары буенча белешмәлек бастырыла. «Төньяк эшчеләр берләшмәсе» җитәкчеләренең берсе, РСДРП ҮК әгъзасы (1904–05), РСДРПның Мәскәү ком-ты секретаре (1906–07), 1905–07 еллардагы рев-циядә катнаша.

*Әд.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**КА́РПОВ** Михаил Васильевич (6.11.1923, Чистай кантоны Кубас а.), слесарь-җыючы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1941–88 дә Казан моторлар төзү ҖБдә эшли, җыю бригадасы бригадиры (1959 дан). Цехта беренче булып шәхси сыйфат келәймәсе кую хокукын ала. Продукция сыйфатын күтәрү һәм технол. процессларны камилләштерү буенча 90 нан артык рационализаторлык тәкъдимен гамәлгә кертә. Герой исеме 7 еллык планны (1959–65) үтәгәндәге һәм яңа техника булдырудагы уңышлары өчен бирелә. 1967–71 дә РСФСР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



М.В.Карпов.



П.А.Карпов.

*Әд.:* Т о л с т о й И. Карпов Михаил Васильевич // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–78 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КА́РПОВ** Павел Алексеевич (12.7.1924, Спас кантоны Павловка а. – 1.11.2008, Болгар ш.), Дан орденының тулы кавалеры (17.7.1944, 15.3.1945, 29.6.1945), гв. старшинасы. Куйбышев р-ны Кузнечиха МТСында комбайнчы булып эшли. 1942 елның августыннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1336 нчы укчы полкның туп расчёты командиры (22 нче һәм 43 нче армияләрнең 319 нчы укчы дивизиясе). Калинин, 1 нче һәм 2 нче Балтыйк буе, 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Калинин (1941–42), Ржев-Вязьма (1943), Ленинград-Новгород, Рига (икесе дә — 1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 25 гыйнварында Слободка авылы (Псков өлкәсе Новосокольнический р-ны) янында дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда (каты яралана, әмма сафта кала), 1945 нең 23–24 гыйнварында Лабиау шәһәре (хәзер Калининград өлкәсе Полесск ш.) өчен сугышта (туп уты б-н 4 дошман пулемётын сафтан чыгара), 1945 нең 8 апрелендә Кёнигсберг шәһәренең (хәзер Калининград ш.) көнбатыш чигендәге сугышта (дошманның танкка каршы атучы тубын һәм берничә пулемётын юк итә) батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. 1956–61 дә шахтада (Воркута ш.) катлам нигытучы булып эшли. Болгар шәһәрендә яши. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Мәскәүдә Җиңү Парадында катнаша (1995).

*Әд.:* Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды славы. К., 1969; Солдатская слава. Свердловск, 1985; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1986; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КА́РПОВКА** посёлогы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 272 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 53%, татарлар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. «Карповка кошчылыкхуҗа-

лыгы. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1950 елларда нигез салына. Халык саны: 1970 тә — 303, 1979 да — 161, 1989 да — 204, 2002 дә — 249 кеше.

**КАРПУ́ХИН** Евгений Васильевич (17.3.1943, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1998), ТАССР, РФнең атказ. табибе (1985, 1995), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2002). 1966 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Чистай шәһәренең мед. учреждениеләрендә эшли: балалар табибе, районның балалар табибе, үзәк район хастаханәсендә балалар сәламәтлеге һәм бала тудыру вакытында ярдәм буенча баш табиб урынбасары. 1971 дән Республика клиник хастаханәсе баш табибе урынбасары. 1975 тән Республика балалар клиник хастаханәсендә, 1978 дән баш табиб. 1987–88 дә, бүленеп, ТАССР Сәламәтлек саклау министры урынбасары. К. республикада демография процессын, балалар авырулары торышын өйрәнә; авыл җирендә балалар үлеме сәбәпләрен, педиатрия уронефрологиясе мәсьәләләрен ачыклый. Дәүләт бүләге «Онкогематологик авыруларны дәвалау» исемле хезмәте өчен бирелә. К. 2010 да «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Алгоритмы этапного лечения детей с хирургическим заболеванием. К., 1998; Репродуктивно-демографические процессы в РТ. К., 1998; Здоровье населения РТ на пороге третьего тысячелетия. К., 1999.

**КАРПУ́ХИН** Евгений Иванович (10.8.1926, Мәскәү өлкәсенең Можайск р-ны Семёновский а. — 16.7.2007, Казан), валторначы, педагог, проф. (1981), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1998). 1956 елда Горький консерваториясен (В.Шведов һәм С.Янкелевич классы) тәмамлый. 1956–69 да Чуаш филармониясе симф. оркестры солисты, бер үк вакытта Чабаксар музыка уч-щесе укытучысы. Чуаш композиторларының беренче опера, балет, симф. әсәрләрен башкаруда һәм радиога яздыруда катнаша. Ф.Лукин, А.Токарев, В.Ходяшев, А.Асламасның валторна өчен язылган әсәрләрен башкарып, Чуаш композиторлары берлеге пленумы концертларында чыгыш ясый. 1967 дән Казан консерваториясендә укыта, 1977–93 тә тынлы һәм бәрмә уен кораллары каф. мөдире. Актив башкару эшчәнлеге алып бара. 100 дән артык музыкант-валторначы шәкертләр әзерли. Алар арасында РФнең халык артисты В.Галкин, ТРның халык артистлары Ю.Самарский, А.Митюков, БРның атказ. сәнгать эшлеклесе З.Хәмәтдинов, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәрләре И.Алмазов, Е.Жирков, М.Чекменёв һ.б. бар. Аның күп кенә укучылары бөтенсоюз, бөтенроссия, халыкара конкурслар лауреатлары булалар.

К., тынлы уен кораллары өчен берничә хрестоматия һәм әсәрләр җыентыгы бастырып, пед. репертуарны шактый баета: «Валторна һәм фортепиано өчен рус пьесалары» («Русские пьесы для валторны и фортепиано», М., 1984); «Элекке сонаталар» («Старинные сонаты», М., 1986); «Классик пьесалар» («Классические пьесы», М., 2001) һ.б. Шулай ук Казан һәм Чабаксар шәһәрләре музыкантлары турында энциклопедик белешмәлек, муз. сүзлекләр өчен мәкаләләр, тынлы уен коралларында әсәрләр башкаруга караган фәнни-методик әсбаплар авторы. К.ның иҗади йөзе, башкаручы буларак, стильне, форманы төгәл сиземләве, башкарыла торган әсәр образларының эчтәлеген дөрес һәм ихлас җиткерә белүе, интонациянең чисталыгы, авазларның ачык булуы, моңлылыгы, башкару техникасының камиллеге б-н аерылып тора. К.га, беренче башкаручы буларак, чуаш һәм татар композиторларының валторна өчен язылган әсәрләре багышлана.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КАРПУ́ХИН** Олег Юрьевич (15.1.1961, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2005). 1984 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук 1 нче хирургия һәм онкология кафедрасында эшли, бер үк вакытта Казан мед. ун-тының белгечләрнең квалификациясен үстерү һәм яңа һөнәри белем бирү ф-ты деканы. Хезмәтләре онкология хирургиясендә нур технологияләре, онкологик авыруларны дәвалау һәм аларга диагноз куюның яңа ысулларын куллануга карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Эндоректальная эхография в диагностике опухолях прямой кишки и в неорганных опухолей малого таза // Эхография. 2003. Т. 4, № 1 (автордаш); Современные методы лечения геморроя // Практическая медицина. 2003. № 4; К лечению распространённой формы болезни Хиршспрунга у взрослого // Казан. мед. журн. 2005. № 5 (автордаш).

**КАРСТ**, к а р с т к ү р е н е ш л ә р е, тау токымнарының җир өсте һәм җир асты сулары тәэсирендә эрүе б-н бәйле процесслар: карбонатлы (известьташлар, доломитлар), сульфатлы (гипс, ангидрит), хлоридлы (таш тоз). Нәтиҗәдә рельефның җир өстендәге (бүрәнкәләр, каррлар, казанлыклар) һәм җир астындагы формалары (юллар, куышлар, мәгарәләр) барлыкка килә. К. термины Әдрән диңгезенең төньягында урнашкан Истрия ярымутравындагы известьташ плато исеме б-н бәйле, биредә К. күренешләре интенсив бара һәм беренче тапкыр җентекләп өйрәнелә.

Татарстан терр-ясендә, һәр җирдә үсеш алмаса да, К. күренешләре киң таралган. Бу барыннан да бигрәк геологик шартлар: Пермь системасы югары Казан ярусы һәм түбәндә яткан сульфат-карбонатлы токымнарның җир өслегенә якын актив су алмашу зонасында булуы б-н билгеләнә. Бу токымнар катламнарның антиклиналь күтәрелмәләре өслегендә яталар. Тектоник бөгелешләрдә алар актив су алмашу зонасыннан түбәндәрәк, нык минеральләшкән тирән җир асты суларында аларның эрүе көчле түгел. К. үсешенең тау токымнары катламнарының зур антиклиналь күтәрелешләре б-н закончалыклы бәйләнеше Урта Идел буе терр-яләренә, ш.и. Татарстанга да хас. Республика чикләрендә К. таралышының 3 зонасын билгелиләр: көнбатыш, көньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш.

Көнбатыш К. зонасы Идел елгасы үзәнен һәм Тәтеш шәһәренең аңа тоташучы төньяк киңлекләрен алып тора. К. формалары — тирәнлеге 20 *м* га, диаметры 150 *м* га кадәр булган төрле формадагы (конус-, касә-, тәлинкә-




Карст упкыны. Яшел Үзән районы.

сыман) бүрәнкәсыман упкыннар. Идел алдында, Сөйке авылы һәм шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы тирәсендә алар аеруча күп (1 *км*$^2$ га 110–120 гә кадәр бүрәнкә). Биредә үк Казан ярусының гипс катламында Сөйке һәм Юрьев карст мәгарәләре барлыкка килгән (к. *Кама Тамагы спелеология системасы*). Казан яны төбәкләрендә, Идел елгасының сулъяк яр буендагы комсыл террасаларда карст күлләре урнашкан: Раифа, Ильинка, Тирән, Ковал, Архиерей һ.б. Шулай ук К. Кабан күле төбен катлауландыра. Комсу террасаларда К. формаларының барлыкка килүе Пермь токымнарында карст куышлыкларына ком юылу б-н бәйле. Казансу елгасының түбәнге агымында һәм аның уң кушылдыгы Солонка елгасы үзәннәрендә К. түбән Пермь катламындагы сульфат-карбонат басымлы (*Зәңгәр күлләр* «чоңгыллары») су чыгышлары б-н бәйләнгән. Казан терр-ясендә дә К. күренешләре һәм аның б-н бәйле иңүләр күзәтелә.

Көньяк-көнбатыш К. зонасы Татар тектоник гөмбәзенең көньяк өлешендә урнашкан, рельефта аңа Бөгелмә яссы калкулыгы туры килә. Биредә К. түбән Пермь һәм түбән Казан асъярусларының карбонат-сульфатлы токымнарында бара. Карст бүрәнкәләре Чишмә, Зәй, Ык, ш.у. Минзәлә елгасының югары агымы үзәннәрендә очрый. 1939 елда Дала Зәе елгасы үзәненең сулъяк сөзәклегендә 52 *м* тирәнлектә *Акташ упкыны* хасил була.

Төньяк-көнчыгыш К. зонасы Вятка елгасы тамагыннан өстәрәк, Каманың уң һәм сулъяк ярларын били, монда исә Иж елгасы түбәнлекләрендә, Салауш елгасы үзәнендә һ.б. урыннарда карст бүрәнкәләре билгеләнгән.

Неоген чорында түбән Пермь һәм Казан ярусларының калын катламнары актив су



Урман белән капланган карст бүрәнкәсе. Казанның төньяк-көнчыгыш чиге.

алмашу зонасына керү сәбәпле, үзәннәрнең нык телгәләнүенә бәйле рәвештә, К. куәтләрәк барган. Бу турыда неоген катламнары астында калган күпсанлы карст формалары сөйли. Карст күренешләре а.х. һәм инженерлык корылмалары төзелешендә һ.б.да җитди кыенлыклар тудыра.

*Әд.:* К а в е е в М.С. Общие закономерности развития карстовых явлений в центральной части Волго-Камского бассейна // Изв. КФАН СССР. Сер. геол. наук. 1959. № 7; С т у п и ш и н А.В. Равнинный карст и закономерности его развития на примере Среднего Поволжья. К., 1967.

*А.П.Дедков.*

**КАРСУ́Н РАЙОНЫ́**, *Ульянов өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 1768 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Карсун посёлогы (Ульянов шәһәреннән 100 *км* көнбатыштарак). Халкы — 25,3 мең кеше (2010), 3020 татар (2002). Районда 4 татар авылы: Нагаево (673 кеше), Татар Голышевкасы (321), Уразовка (438), Татар Горенкие (350); 6 катнаш: шәһәр тибындагы Карсун посёлогы, Сухой Карсун, Беловодье, Сосновка, Языково, Прислониха авыллары бар. Татарлар К.р.на 16 йөз ахырында килеп урнаша. 17 йөз уртасында, Карсун-Сембер чик сызыгы төзелү б-н бәйле рәвештә, татарлар күпкә арта. Курмыш өязеннән йомышлы татарлар, хезмәт итү өчен, монда күчерелә. 1917 гә кадәр Нагаево (1840 тан), Татар Горенкие (1867) һәм Уразовка (1897 дән) авылларында мәктәпләр була. Һәр татар авылында мәчетләр эшли (Сов. хакимияте чорында ябылалар). 1932 дә Нагаево авылында җидееллык татар мәктәбе ачыла, 1962 дә ул — сигезьеллык, 1988 дә урта мәктәп итеп үзгәртелә, татар теле фән буларак өйрәнелә. Хәзерге вакытта Татар Голышевкасы (1986 дан), Нагаево (1997 дән), Татар Горенкие (1998 дән) авылларында мәчетләр эшли. Нагаево авылында вет. фән. д-ры М.Г.*Хәбибуллов* туган.

**КАРТ** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 27 *км* көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы астында калган зона чигендә урнашкан. 2010 елда 136 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек һ.б. б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 968,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1834 тә — 132, 1859 да — 205, 1870 тә — 180, 1884 тә — 245, 1906 дә — 527, 1913 тә — 340, 1920 дә — 275, 1926 да — 307, 1938 дә — 329, 1949 да — 234, 1958 дә — 259, 1970 тә — 280, 1979 да — 236, 1989 да — 174, 2002 дә — 160 кеше.

**КАРТАЛЫ́ РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көньягында урнашкан. Мәйданы — 4737 *км*². 1965 елда оештырыла. Үзәге — Карталы шәһәре (Чиләбе шәһәреннән 275 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 50,1 мең кеше (2010), 1224 татар (2002). Татарлар, башлыча, Карталы шәһәрендә яши. К.р.на алар 19 йөз ахырында күчеп килә, һәм бу Уралда яңа җирләр үзләштерү б-н бәйле. Карталыда һәм Еленинки авылында төбәк тарихы музейлары эшли. Төбәкне өйрәнүче И.Х.Үтәшевнең тормышы һәм эшчәнлеге К.р. б-н бәйле.

**КАРТАШЁВ** Валентин Александрович (4.3.1936, Аксубай р-ны «Большевик» с-зы), генерал-лейтенант (1987). Новосибирск хәрби уч-щесен (1958), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1969), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (Мәскәү, 1978) тәмамлый. 1958–66 елларда Балтыйк буе хәрби округының махсус вазифа башкаручы частендә хезмәт итә. 1969–76 да СССР Кораллы Көчләре Генштабының разведка идарәсендә: отряд (батальон) командиры, штаб башлыгы, махсус вазифа башкаручы бригада отделениесе командиры. 1978–84 тә Ленинград Хәрби Округында: башлык урынбасары, разведка башлыгы. 1984 тән разведка башлыгы урынбасары — Көнбатыш юнәлеш штабы башлыгы урынбасары (Легница ш., Польша), 1997 дән Төньяк-Көнбатыш регионда Спецназ «РОСА» җәмәгать оешмасы идарәсе рәисе. Кызыл Йолдыз, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**КАРТАШЁВ** Валерий Борисович (21.1.1937, Пермь ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1990). 1961 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «Казан вертолет заводы» АҖдә: өлкән инженер, цех башлыгы урынбасары, очу-сынау станциясе башлыгы, баш инженер урынбасары, ген. директорның җитештерү буенча урынбасары (1985–2007). Күп функцияле җиңел «Ансат» вертолётын төзү проекты җитәкчесе. Дәүләт бүләге «Ми-8МТВ-1, Ми-8МТВ-2, Ми-8МТВ-3, Ми-8МТВ-5, Ми-172 камилләштерелгән вертолётларын һәм аларның модификацияләре гаммасын сериялап җитештерүгә кую» хезмәте өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КАРТАШО́В** Пётр Николаевич (22.12.1890, Уфа губ. Чаллы ш. — ?, Саратов ш.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1938). 1914 елда Казан ун-тын тәмамлагач, рус армиясендә табиб хезмәтен үти. 1918–20 елларда Казан губернасында район хастаханәсе табибе; 1921–27 дә Пермь ун-тында һәм госпитальләрдә проф. (1926). 1927–48 дә (бүленеп) Саратов, 1936–38 дә Воронеж мед. ин-тларында. 1949–55 тә Казан ГИДУВында, стоматология каф. мөдире. Хезмәтләре яңак-бит хирургиясе алымнарын камилләштерү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: О кистовидном растяжении гайморовой полости. Пермь, 1925.

**КАРТАШО́ВА** Ирина Вячеславовна (19.4.1931, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1984), проф. (1986). 1953 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1957 дән Казан ун-тында, 1972 дән Тверь ун-тында (1987–91 дә каф. мөдире). Хезмәтләре Н.В.Гоголь иҗатына, романтизм теориясенә, романтизм юнәлешендәге рус һәм чит ил әдәбиятларының үзара багланышлары мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Гоголь и романтизм. Калинин, 1975: Введение в теорию романтизма. Тверь, 1991 (автордаш).



В.А.Карташёв.

**КА́РЦЕВА** Лидия Валерьевна (2.7.1955, Томск өлкәсенең Кривошеино р-ны Кривошеино а.), социолог, филос. фән. канд. (1983), социол. фән. д-ры (2002), проф. (2002). Казан ун-тының журналистика ф-тын (1977), ш.у. ф-тның психология бүлеген (1996), Казан мед. ин-тының социаль хезмәт ф-тын тәмамлый (1994). 1977 дән Казан ун-тының журналистика ф-тында. 1987–91 дә СССР ПФА проф.-техн. педагогика фәнни-тикшеренү ин-ты фәнни хезмәткәре (Казан). 1994–2002 елларда Казан мәдәният һәм сәнгать академиясенең педагогика һәм психология кафедрасында. 2002 дән Казан энергетика ун-ты профессоры. Хезмәтләре социаль психология, идарә итү психологиясе, фамилистика (гаилә белеме) һәм мәгариф өлкәсендәге психол.-пед. мәсьәләләргә карый.

Х е з м.: Социальная работа с семьёй: психолого-педагогический анализ. К., 1998; Российская семья на рубеже двух веков. К., 2001; Семья в трансформирующемся обществе. К., 2003; Социология культуры. К., 2004 (автордаш); Этика и психология управленческого труда. К., 2004.

**КАРЧЕ́ВСКИЙ** Евгений Михайлович (10.8.1970, Казан), математик, физика-матем. фән д-ры (2007). 1992 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре дифракция теориясендәге спектраль мәсьәләләрне матем. модельләштерүгә һәм чишү алымнарын эшләүгә карый. Интеграль тигезләмәләр алымы нигезендә диэлектрик дулкын йөрткечләр теориясенең спектраль мәсьәләләрен тикшерә.

Х е з м.: Численный метод поиска дисперсионных кривых и собственных волн оптических волноводов // Вычисл. математика и мат. физика. 2005. № 12 (автордаш); Спектральные задачи теории диэлектрического волновода // Уч. зап. Казан. ун-та. 2008. Т. 150, кн.4; Метод интегральных уравнений и точные нелокальные граничные условия в теории диэлектрических волноводов. К., 2009.

**КАРЧЕ́ВСКИЙ** Михаил Миронович (26.2.1944, Баулы р-ны Ютазы ст.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1990). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, хисаплау математикасы каф. мөдире (1988 дән). Хезмәтләре нәсызыкча механикада тоташ тирәлекләрне ма-

тем. модельләштерүгә карый. Матем. физиканың нәсызыкча мәсьәләләрен төзү юлларырын һәм аларны чишүнең челтәр алымнарын эшләде; бу эшкәртелмәләре фильтрлаштыру теориясе мәсьәләләрендә, юка сыгылгычлар теориясендә, фильтрлаштыруның гидродинамика теориясендә кулланыла.

Х е з м.: Разностные схемы для нелинейных задач математической физики. К., 1976 (автордаш); Нелинейные задачи теории пластин и оболочек и их сеточные аппроксимации // Изв. вузов. Математика. 1985. № 3; Методы вычислений (численные методы алгебры). К., 1986 (автордаш); Методы двойственности в прикладных задачах. К., 1987 (автордаш).

**«КАРЧЫГА́»**, айлык сатирик-юмористик, иҗтимагый-сәяси журнал. Оренбург шәһәрендә татар телендә 1906 елның 25 сентябреннән 1907 нең июненә кадәр барлыгы 9 саны нәшер ителә. Казан, Эстәрлетамак, Орск, Троицк, Петропавловск, Верный шәһәрләрендә тарала. Нашире һәм мөхәррире — Ш.Мөхәммәдов. Актив язучы авторлары — М.Бәдәйли, Х.Габдүшев, Б.Ишемгулов, С.Кудаш, Г.Сабиров, Т.Ченәкәй, Г.Шәрифи. «К.» революцион-демократик идеяләрне пропагандалауны үзенә максат итеп куя. Журналның идея-тематик эчтәлегенә *«Урал»* г-тасы мөхәррире Х.Ямашев зур йогынты ясый. «К.» редакциясе эшче-крәстиян мәнфәгатьләрен, хатын-кызларның тигез хокуклылыгын һәм *җәдидчелек* идеяләрен яклап чыга. Бюрократлык, дәүләт милкен урлау, ришвәтчелек, башбаштаклык кебек социаль бозыклыклар тәнкыйтьләнә. Мәгариф, икътисад, мәдәният, эчке һәм тышкы сәясәт турында язмалар басыла. Журналга килгән хатлар анда басылган фельетон, сатирик цикллар, эпиграммалар өчен материал булып тора.

*Әд.:* Г и м а д и е в У.И. Сатира, её жанры и художественные средства. Уфа, 1980; ш у л у к. Сила сатирического слова. К., 1987.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**КАРЧЫГА́ КОШЛА́Р** (Accipitridae), лачынсыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 220 якын төре билгеле, киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә 10 ыругтан 22 төре бар: шөпшәашарлар, тилгәннәр, *карчыгалар, елак карчыгалар*, елан карчыгалары, *каракошлар*, елга каракошлары, кара грифлар, сиплар һ.б. Урманнарда, ш.у. ачык урыннарда яшиләр. Күпчелек төр утрак яшәү рәвеше алып бара, кайберләренә сезонлы күчүләр хас, сирәк очып керүче төрләр дә бар. Төрле зурлыктагы кошлар. Кара грифтан кала, барлык төрләрнең дә ана кошлары аталарына караганда зуррак. Томшыклары ян-яктан кысылган, өске томшыкның аскы читендә мөгез тешләре, томшык асты кырыенда тиешле булган уемтык юк. Күзләре зур, алга юнәлгән, бу исә зур бинокуляр күрү кырын тудыра. Кешегә караганда 8 тапкыр яхшырак күрәләр. Тавыш мускуллары яхшы үскән, ерак араларга ишетелерлек югары тембрда төрле тавышлар чыгарырга мөмкиннәр. Яхшы ишетәләр, колак куышлыгы зур, кайвакыт аның тирәсендә тиреле җыерчыклар формалаша, колак каурыйлары тавыш тоткыч хасил итә. Каурый катламы каты. Канатлары киң, очы түгәрәкләнгән, озак очу өчен җайлашкан. К.к., гадәттә, ялгыз яшәү рәвеше алып баралар, әмма алар оя кору вакытыннан тыш, азык тупланган урында күпләп җыелырга мөмкин. Парларын озак вакытка, еш кына сыңарының үлеменә кадәр саклыйлар. Ояларын агачларда яисә җирдә ясыйлар. Елга бер тапкыр үрчиләр. 1–6 ак яки тимгелле йомырка салалар. Умырткалы хайваннар, үләксә, моллюсклар, бөҗәкләр б-н тукланалар. 15 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.


**КАРЧЫГА́ УТЫ́** (Hieracium), оешма чәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 1000 нән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә 22 төре бар. Кырлы яфраклы К.у. (H. calodon), Онега К.у. (H. onegense), төкле К.у. (H. pilosella), чатырсыман К.у. (H. umbellatum) һ.б. барлык районнарда да очрый; кәс ле К.у. (H. caespitosum), калкулык К.у. (H. collinum), Циц К.у. (H. zizianum) һ.б. — сирәк төрләр. Нарат урманнарында, урман буйларында, аланнарда, сөзәклекләрдә, ерганакларда үсәләр. 15–150 *см* биеклектә, сабагы гади яки тармаклы. Яфраклары озынча түгәрәктән кыяк-ланцетсыманга кадәр, чиратлашкан яки тамыр яны яфрак таралгысында. Чәчәкләре кәрзиндә, берле яки сабак очындагы чатырга, яки себеркәчкә җыйналган. Җимеше — орлыкча. Үсемлек тулысы б-н бизле һәм ялтыравыклы гади төкчәләр б-н капланган. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Төкле К.у. һәм чатырсыман К.у. — терлек азыгы.

**КАРЧЫГАЛА́Р** (Circus), карчыга кошлар семьялыгыннан ерткыч кошлар ыругы. 9 төре билгеле, Арктика һәм Антарктидадан тыш, бөтен дөнья буенча таралган. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Кыр карчыгасы (C. cyaneus) барлык районнарда да очрый. Кыр, болын, кечкенә куаклыкларда, ерымнарда оялый. Күзләре, томшык төбе һәм аяклары — сары, томшыгы һәм тырнаклары кара төстә. Башка төрләрдән канат һәм койрыгының чагыштырмача озын, койрыгының киң ак һәм канат очының кара төстә булуы б-н аерыла. Болын карчыгасы (C. pygargus) респ-каның бөтен терр-ясендә таралган. Елга үзәннәрендә, әрәмәлекләрдә яши. Ата кошлар аксыл төстә. Аркасы соры, корсагыннан җирән буйлар сузыла. Канат очлары кара, канат уртасыннан аркылы кара буй уза. Башка төрләргә караганда канатлары тар һәм очлы. Дала карчыгасы (C. macrourus) Кама аръягында очрый. Елга тугайларында, дымлы болыннарда, сыза кырыйларында һ.б. ачык урыннарда яши. Ата кошларның аркасы күксел соры, корсагы ак. Ана кошлар җирәнрәк кара көрән төстә, корсаклары кызыл, буй-буй җирән-көрән чуар рәсемле. Койрык өсте соры. Канат очы кара. Саз карчыгасы (C. aeruginosus) респ-каның бөтен терр-ясендә бар. Курак, җикәнбаш үскән урмансыз дымлы, сазлыклы җирләрдә, елга тугайларында яши. Аркасы көрән яки коңгырт, башка төрләргә караганда башы ачыграк төстә. К. — оя коручы күчмә кошлар. Гәүдәләренең озынлыгы 45–55 *см*, авырлыгы 260–700 *г*. Апрельдә очып киләләр. Ояны җирдә ясыйлар. Көрән тимгелле 3–5 ак йомырка салалар. Тычкансыман кимерүчеләр, кечкенә кошлар, бака, бөҗәкләр б-н тукланалар. Август ахырында очып китәләр. Кыр карчыгасы, дала карчыгасы, болын карчыгасы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Р а х и м о в И.И., П а в л о в Ю.И. Хищные птицы и совы Татарстана. К., 1999.

**КАРЫ́К-СЕРМА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Көшкәт елгасы буенда. 2010 елда 112 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Турья исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 620,4 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1763 тә — 24 ир-ат; 1795 тә — 120, 1850 дә — 182, 1859 да — 195, 1876 да — 195, 1884 тә — 210, 1905 тә — 250, 1920 дә — 334, 1926 да — 360, 1938 дә — 394, 1949 да — 290, 1958 дә — 300, 1970 тә — 275, 1979 да — 218, 1989 да — 134, 2002 дә — 143 кеше.

**КАРЫШЛАВЫКЛА́Р** (Geometridae), төрле мыеклы күбәләкләр семьялыгы. 15 меңгә якын төре билгеле, киң таралган. Канатлары нәфис, җәеме 13–50 *мм*, кайвакыт 80 *мм* га кадәр, шактый киң, гадәттә, аркылы буйлар төшкән көрән соры яки саргылт төстә, ачык һәм чуар булырга мөмкин, тыныч халәттә чагыштырмача җәелгән, еш кына вертикаль рәвештә өскә күтәрелеп тора. Мыекчыклары сырлач, җепсыман, сирәк кенә каурыйсыман. К.ның кайбер төрләрендә ана затлар канатсыз, яисә канатлары җитлекмәгән була. Хортумчыгы гадәти. Гәүдәсе нечкә, аяклары шома. Гусеницаларның корсагында ике пар аягы бар, хәрәкәте үзенчәлекле: гәүдәнең алгы өлешен күтәреп, аны алга күчерә һәм шул ук вакытта арткы өлешен тартып китерә, ягъни юлны карышлап үлчәүне хәтерләтә (исеме шуннан). Хәрәкәтсез гусеница коры ботак яки сабакка охшатып сузыла, шунлыктан аны күрү мөмкин түгел. Мондый халәттә алар фәкать арткы аяклары б-н генә тотынып тора. Хәрәкәтсезлек торышы түбәнге иреннән үсемлеккә сузылган пәрәвез җебе хисабына ирешелә. 2 нче буын гусеницалары кышлый. Семьялык үз эченә берничә ыругны ала, Татарстан терр-ясендә аеруча таралганнары: язгы К. (каен К. — Archiearias parthenias), хиппархус (яшел К. — Hipparchus papilionaria), анаитис (мәтрүшкәле К. — Anaitis plagiata), лигрис (сары К. — Lygris populata), абраксас (крыжовник К. — Abraxas grossulariata), селения (ай К. — Selenia lunaria), канаткойрык (аю баланы К. — Urapteryx sambucaria), бистон (Biston betularius), бупалюс (нарат К. — Bupalus piniarius). К.ның күпчелеге



Карьер чокыры.

агаччыл һәм куакчыл үсемлекләрнең яфраклары, кайберләре үләнчел үсемлекләр б-н туклана. Күпләп үрчегәндә, урман, сирәк кенә җимеш культураларына, парк үсентеләренә куркыныч тудыралар.

*С.Г.Гордиенко.*

**КАРЬЕ́Р КҮЛЕ́**, к. *Юдино күле*.

**КАРЬЕ́Р ЧОКЫРЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Казан шәһәренең Совет р-нындагы Карьер посёлогы тирәсендә. 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 5 *га*. Урман үсемлекләре б-н капланган тирән чокыр. Сөзәклекләрдә Пермь системасы Казан ярусының җилләнгән доломитлары күренә. Карст бүрәнкәләре үсеш алган. Сирәк очрый торган үсемлек төрләре үсә: чын башмакчәчәк, саз тавык чәчәге, сарана лалә, ике яфраклы төн миләүшәсе һ.б. Ак кашлы миләш чыпчыгы, миләш чыпчыгы, деряба, көнчыгыш сандугачы, күктүш, әрәмә чыпчыклары оялый. Бурсык очрый.

**«КАРЬЯ́Т БАТЫ́Р»**, Себер татарлары *тарихи җыры*. Себер татарларының башка тарихи җырлары кебек («Камбар батыр», «Тавыш Мәргән») кайчандыр кулланылышта йөргән эпик хикәятнең бер өзеге булуы ихтимал. Күләме чикләнгән булу сәбәпле, җырның сюжетына һәм тарихи нигезенә анализ бирү мөмкин түгел. Гомумтөрки элементларны үзендә саклаучы (лексика, шигъри үлчәм, композиция) «К. б.»ның поэтик стиле зур кызыксыну уята. Тикшеренүчеләр җыр персонажы б-н башка героик-эпик әдәби ядкәрләрдәге геройлар арасында охшашлык табалар. Әсәрдә тарихи җырлар һәм героик эпос элементлары бергә үрелеп бара. «К. б.»ның текстлары һәм ноталары беренче тапкыр 1955 елда А.А.Ключарёв тарафыннан бастырып чыгарыла. Проф. җырчылар репертуарына керә.

*Әд.:* Ключарёв А.А. Татар халык җырлары. К., 1955; Урманчеев Ф. Тарихи җырлар // Казан утлары. 1969. № 3; шул ук. Историческая песня // Героический эпос татарского народа. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАРЯ́КИН** Василий Александрович (28.1.1851, Рыбинск ш. — 14.10. 1913), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Мещаннар катлавыннан. Өяз уч-щесен тәмамлый (Рыбинск). 1864 елда сәүдә эшчәнлеген башлап җибәрә. 1877 дә Казанга күчеп килә, каенатасы П.Г.Сусловның икмәк белән сату итү фирмасында эшли (каенатасы үлгәч, фирма аңа кала, 1886 дан — «В.Карякин һәм Г.Рахманов сәүдә йорты»). 20 йөз башында Казан губернасы Мамадыш өязендә ике тегермәне, Казанда йортлары, Курляндия губернасының Калкуны авылында чүпрә һәм кирпеч з-длары, ярма яргыч тегермән кергән утары, Ярославль губернасында 11752 дис. урманы була. Иҗтимагый-сәяси һәм иганә эшчәнлеге б-н актив шөгыльләнә. Казанда 1905 елгы октябрь вакыйгалары вакытында Хокук тәртибен яклау буенча Казан ком-ты рәисе була, аның нигезендә «Унҗиденче октябрь берлеге» партиясенең Казан бүлекчәсе оештырыла (1906). «Унҗиденче октябрь берлеге» партиясенең 2 нче Бөтенроссия съезды делегаты, Казан губернасыннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907–12), октябристлар фракциясе әгъзасы, азык-төлек комиссиясе рәисе, финанс, дәүләт керемнәрен һәм чыгымнарын барлау, эчүчелеккә каршы көрәш комиссияләре әгъзасы. Православие иске дин тарафдарларының 1 нче Бөтенроссия съезды делегаты (С.-Петербург, 1912, гыйнвар). 1890 нан берничә тапкыр Рыбинск биржа ком-тында төрле вазифаларга сайлана (1905–09 да рәис). 1895–1911 дә Дәүләт банкының Рыбинск бүлекчәсе исәп-хисап ком-ты әгъзасы, 1894–1903 тә Казан биржа ком-ты рәисе урынбасары, 1896–1913 тә Казан шәһәр думасы гласные, Ярлы һәм авыру балаларны кайгырту буенча Казан ком-ты әгъзасы (1896–1913) һәм рәисе (1913), Казан сәүдәгәрләренең үзара ярдәмләшү җәмгыяте рәисе (1898–1913), Рыбинск коммерция уч-щесе попечительләр советы әгъзасы (1902–13), 2 нче Рыбинск югары башлангыч уч-щесенең шәрәфле попечителе (1903–13), Сембер коммерция уч-щесенең шәрәфле попечителе (1907–13), Казан коммерция уч-щесенең попечительләр советы әгъзасы (1904–13). К. портреты Казан шәһәр думасында, Ярлы һәм авыру балаларны кайгырту ком-тында, коммерция уч-щесендә куела. Рыбинскида аның акчасына шәһәр уч-щесе бинасы төзелә, бакча төзекләндерелә. Станислав, Александр һәм Анна тасмаларында өч «Тырышлык өчен» алтын медале, Изге Александр Невский ордены тасмасында көмеш медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р., Хайрутдинова Л.Ф. Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000; Айнутдинова Л.М. Либеральное движение в Казанской губернии (1900–1917 гг.). К., 2003.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КАСА́Й** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 78 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кады елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 105 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1722–23 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Көек, Илморза, Иске Тугыз исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, урман кисү б-н шөгыльләнә; көнлекче булып эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.да мәчет, 2 тегермән, 20 йөз башында мәктәп, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1380,4 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостена керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1927 дән — Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1816 да — 144, 1859 да — 217, 1890 да — 579, 1905 тә — 837, 1920 дә — 727, 1926 да — 524, 1938 дә — 518, 1949 да — 286, 1958 дә — 307, 1970 тә — 758, 1989 да — 146, 2002 дә — 177 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КАСИ́МОВ** Дмитрий Иванович (1888, Казан губ., Лаеш өязе Керәшен Казысы а. — 1937, Казан), сәясәт эшлеклесе. Керәшен татар. 1917–19 елларда Керәшен милли җәмгыятен җитәкли, 1919–23 тә РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты Үзәк керәшен бүлеге каршындагы Югары коллегия рәисе. Нахакка репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Глухов М. Tatarica: Энцикл. К., 1997.

**КА́СЛИНА** Роза Григорьевна (12.6.1957, Мари Респ-касы Покровское а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2005), проф. (2006), РФнең атказ. югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007). 1978 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1978–80 дә Казан язу җайланмалары з-дында. 1984 тән Казан финанс-икътисад ин-тында, идарә исәбе һәм контроле каф. профессоры (2005 тән), бер үк вакытта шул ук ин-тның икътисади үсеш һәм инновацияләр үзәге директоры. Төп хезмәтләре корпоратив хисапчылык, идарә исәбе һәм финанс хисапчылыгының халыкара стандартлары мәсьәләләренә карый. Корпоратив хисапчылык концепциясе эшләнә, диверсификацияле холдингларда гамәлгә кертелүче инсорсинг системасы сайлап алына. Европа бухгалтерлар ассоциациясе, РФ Финанс министрлыгы каршындагы Аудиторлык эшчәнлеге советы эшче органының аудиторларны аттестацияләү һәм аларның квалификациясен күтәрү комиссиясе әгъзасы.

Хезм.: Бухгалтерская отчётность в системе корпоративного управления. М., 2004; Практическое применение международных стандартов финансовой отчётности в Росии: Уч. пособие. М., 2006; Финансовый отчёт и отчётность в условиях инфляции: Уч.пособие. М., 2008 (автордаш).

**КАСЫЙДӘ́** (гарәп. قصيدة — максат, ният, теләк), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Урта һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия, Көнчыгыш Европа халыклары әдәбиятында таралган лирик поэзия жанры. Эчтәлеге ягыннан К. — кемгә дә булса (гадәттә түрәләргә, олы дәрәҗәдәге шәхесләргә, меценатларга) яки нәрсәгә дә булса (әһәмиятле вакыйгага, истәлекле датага) мәдхия җырлау, артык мактау. К. ш.у. элегик, дини-фәлсәфи, сатирик характерда

да була. Классик К. тотрыклы структурага ия һәм 3 өлешкә бүленә: лирик керештә (нәсиб) мохит, пейзаж тасвирлана, төп эчтәлекне үзләштерү өчен фон, рух тудырыла; аннан төп өлешкә күчелә; ахыргы өлештә макталган затка авторның теләге белдерелә (мәдех). Күләме ягыннан 12 дән алып 200 *бәйткә* кадәр булырга мөмкин. К.гә *гаруз* б-н язылу, моноримфа, рәдиф (шигъри юл ахырында бер яки берничә сүздән торган кабатлау) һәм тәхәллүс (авторның поэтик псевдонимы) булу хас. К.нең классик үрнәкләрен Мәгарри, Рудаки, Нәвои иҗатларында күрергә мөмкин. Төрки-татар поэзиясендә К. жанрын Харәзми, Өмми Камал, Ә.Каргалый, Г.Чокрый, Г.Кандалый, Г.Тукай һ.б. иҗади үстерәләр. Аерым очракларда К. атамасы ода, зур күләмле шигъри әсәргә карата да кулланыла.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Миңнегулов Х.Й. Гасырлар өнен тыңлап. К., 2003.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**КАСЫ́ЙМ** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Сола елгасының (Казансу елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,4 *км*, бассейнының мәйданы 47,8 $км^2$. Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Торнаяз авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Әблә авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 2%. К.ның 0,8 *км* дан алып 2 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,52 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 132 *мм*, ташу агымы катламы 92 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,14 $м^3/с$. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**КАСЫ́ЙМ ПАТШАЛЫГЫ́**, к. *Касыйм ханлыгы.*

**КАСЫ́ЙМ РАЙОНЫ́**, *Рязань өлкәсенең* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1929 елда оештырыла. Мәйданы — 2925 $км^2$. Үзәге — Касыйм шәһәре (Рязань шәһәреннән 156 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 63,7 мең кеше (2010), 876 татар (2002). Татарлар, башлыча, Касыйм шәһәрендә (421 кеше), Подлипки посёлогында, Әхмәт авылында яши. Хәзерге К.р. терр-ясендә татарларның яши башлавы *Касыйм ханлыгы* оештырылу (1450 еллар) б-н бәйле. 1917 гә кадәр район терр-ясендә берничә татар уч-щесе, мәдрәсә, 9 татар мәктәбе, ш.и. кызлар өчен беренче татар мәктәбе (1909) эшли. Касыйм шәһәрендә — 2, Касыйм өязендә 10 лап мәчет була. 1898 дә *Касыйм шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте* оештырыла, аның ярдәме б-н 1910 да татар китапханәсе ачыла, анда рус һәм татар телләрендә 10 мең данәгә якын китап исәпләнә (1919 да ябыла). 1908 дә Касыйм шәһәрендә яңалык тарафдарлары мөселманнары җәмгыяте теркәлә. 19 йөз уртасында сәүдәгәр Х.С.Шакуловның күн эшкәртү з-ды һәм сәүдәгәрләр А.Х.Кастров, А.М.Ишимбаевларның бәрән тиресе эшкәртү з-длары була. Өяздә татар сәүдәгәрләре 16 кибет тота (1912). 1918 дә Касыйм шәһәрендә «Чулпан» татар театры (1930 елларда Н.Н.Нариманов исем. татар яшьләре клубы итеп үзгәртелә; 1940 еллар башына кадәр эшли) оештырыла. Хәзерге вакытта шәһәрдә мөселман җәмгыяте (2000 нән) бар, «Динем» г-тасы нәшер ителә. 1768 һәм 1835 елларда реставрацияләнгән Хан җамигъ мәчете (15 йөз; хәзерге вакытта бу бинада төбәк тарихын өйрәнү музееның Касыйм татарлары этнографиясе бүлеге урнашкан), ак таштан салынган Яңа җамигъ мәчет (1906), манаралы Шаһгали хан тәкиясе (1556) һәм кирпечтән салынган Әфган-Мөхәммәд солтан тәкиясе (1649) сакланган. К.р.нда дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Г.*Баязитов*, җәмәгать эшлеклесе, педагог С.Х.*Булатова*, математик, педагог С.К.*Шакулова*, Сов. Союзы Герое В.В.*Альбетков* туган. Мәгърифәтче әдип, педагог З.Һ.*Һадиның* тормышы һәм хезмәт юлы К.р. б-н бәйле.

*Әд.:* Акимов В.В. Касимовские татары: между прошлым и будущим. М., 2004.

**КАСЫ́ЙМ ТАТАРЛАРЫ́** (үзатамалары: качим татарлары, качим халкы), Идел-Урал төбәге татарларының этнотерр. төркеме. Касыйм шәһәрендә һәм, кечерәк тупланган төркемнәр булып, Рязань өлкәсенең Касыйм районында яшиләр. 1979 елгы халык исәбе буенча — 1040 кеше, 2002 елгы мәгълүматлар буенча 876 кеше тәшкил итәләр. К.т.ның шактый өлеше Россия (С.-Петербург, Мәскәү, Рязань, Казан), Урта Азия, Казакъстан, Балтыйк буе шәһәрләрендә яши. К.т.ның сөйләме татар теленең урта диалектына карый, ләкин кайбер фонетик үзенчәлекләре бар. Диннәре — ислам. К.т.ның формалаша башлавы 15 йөз башында Мәскәү дәүләте терр-ясендә үзәге Городец Мещерский булган *Касыйм ханлыгы* барлыкка килү б-н бәйле. Соңрак шәһәр Царевич городок, Ханкирмән, *Касыйм* (ханлыкның беренче идарәчесе, *Олугъ Мөхәммәднең* улы *Касыйм* хан исеменнән) буларак мәгълүм. Касыйм ханлыгы хуҗаларының хокуклары чикләнгән удел тибындагы бәйле кенәзлек була. Йомышлы татарлары Рус дәүләтенең эчке һәм тышкы бурычларын хәл итүдә актив катнашалар. К.т. Алтын Урда ханнарына, шведларга, ливон рыцарьларына каршы сугышларда рус гаскәрләре составына кушылалар, Русьның көньяк чикләрен күчмә халыклар һөҗүмнәреннән саклауда мөһим роль уйныйлар. К.т. тыныч хезмәттә дә актив катнашалар: аларны татар ханлыкларына илчеләр, тәрҗемәчеләр итеп җибәрәләр. Хәрби хезмәтләре өчен бүләк итеп җирләр — еш кына соңыннан мирас булып калган утарлар бирәләр. Хакимлек итүче сыйныф төрле дәрәҗәдәге феодаллардан — ханнардан, солтаннардан, аларга якын аксөякләрдән (карачылар, даруга бәкләре, казначылар), хәрбиләрдән (кенәзләр, бәкләр, морзалар, угланнар), дин әһелләреннән (сәедләр, абызлар) гыйбарәт була.



Касыйм татарлары. 19 йөз ахыры.

Халыкның шактый өлеше түбән феодаль катлауга (казаклар) керә. Ханлыкта феодаль-бәйле крәстияннәр була, кечерәк катлауны хәрби әсирләр тәшкил итә. Касыйм ханлыгы халкының этник составы төрле була. Аның терр-ясендә фин, славян һәм төрки халыклар вәкилләре яши. Ханлыкта Казаннан, Кырым, Себердән, кыргыз-кайсакъ урдасыннан чыккан кешеләр килеп төпләнә. К.т. этнотерр. төркем сыйфатында формалашуда иң актив компонентларның берсе нугайлар була: аларның йогынтысы сөйләмдә, рухи һәм матди мәдәнияттә сизелә. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан соң төрки халыкларның килүе кими башлый. Бу 1552 дә Казан ханлыгын Рус дәүләтенә кушканнан соң Касыйм ханлыгының Казан ханлыгына карата «буферлык» роле кимү б-н бәйле. Рус хөкүмәте Касыйм ханлыгына ышанычсыз Казан татар феодалларын җибәрә. 1681 дә, соңгы идарәче *Фатыйма Солтан* үлгәннән соң, идарә итү тулысынча Россия патшасы кулына күчә. Йомышлы татарларга өстенлекләр бетерелгәч, кү-



Касыйм татарлары. 20 йөз башы.

чеп китү активлаша: 1719 һәм 1744 еллар арасында татар халкының Касыйм өязеннән күчеп китүе 18% тәшкил итә (5797 дән 4880 кеше кала). Күченүнең төп юнәлешләре — көнчыгыш, Идел аръягы һәм Урал буйлары. К.т.ның бер өлеше С.-Петербургка, Мәскәүгә (Татар бистәсенә, татарлар 14–16 йөзләрдә үк Мәскәү елгасы аръягына урнаша башлыйлар) күчеп утыра. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында К.т., яшәү өчен шартлар эзләп, Россиянең Казан, Сембер, Түбән Новгород һәм Оренбург губерналарының эре шәһәрләренә һәм авыл районнарына, ш.у. Урта Азиягә юнәләләр һәм шунда төпләнеп калалар. Җир җитмәгәнлектән, Рязань губернасының Касыйм өязе терр-ясендә яшәгән татарлар сарык тиресе, күн эшкәртү, Россиядә генә түгел, Германия, Америка базарларында да тире, мех, алардан эшләнгән әйберләр сату б-н шөгыльләнәләр. Читкә чыгып эшләү дә аларга хас күренеш була: игенчелек эшеннән бушагач, ир-атларның яртысыннан күбрәге шәһәрләргә эшкә китә. Берәүләр приказчиклар, официантлар, ялчылар, кучерлар, ат карауучылар, ишегалды җыештыручылар була, башкалары трактирлар, буфетлар тота. К.т.ның торулыклары ике төрле — шәһәр һәм авыл тибында була. Касыймның Татар бистәсе — шәһәр тибының бер мисалы. Анда феодаль аксөякләрнең утарлары урнашкан. Хан сарае каршында манаралы ак таш мәчет була (1467 дә төзелә). 19 йөз ахырында К.т.ның төп массасы авылларда (авыл, сала, ил) яши, алар 3 терр. төркемгә бүленә: Ука елгасының сул ярында баштарак ак аймакка керүче (Касыйм шунда урнашкан) 4, аннары 5 авыл, кара аймакка керүче 38 авыл, уң ярда кешеләре «кара зыбыннар» дип аталучы 8 авыл урнашкан. К.т.ның утарлары торак йорттан һәм хуҗалык корылмаларыннан гыйбарәт була. Йортларны күбесенчә бүрәнәләрдән, баерак гаиләләр таштан ике катлы итеп төзегәннәр. Йортка керү урынын кечерәк кенә дүрт яки алты почмаклы тамбур рәвешендә ике якка ачыла торган, төсле пыяла тәрәзәләр куелган ишекле итеп эшләгәннәр. Традицион йортта шактый урынны икмәк пешерә торган һәм казан урнаштырылган мич алып торган. Ишек каршында бөтен дивар буйлап киң сәке сузылган, ул йоклау, ашау, ял итү урыны булып хезмәт иткән. Күп кенә өйләрдә сәндерәләр булган. Киез келәмнәр һәм сандыклар, диварлар буйлап эленгән тукылган һәм чигелгән сөлгеләр йортка татар төсмере биргәннәр. К.т.ның традицион киеме Казан татарларыныкыннан аз аерыла; төрле сәбәпләр аркасында К.т. шәһәрдәге кием-салымнарның яңа стилен чагыштырмача тиз кабул иткәннәр. Ашау-эчү традицион рәвештә ит-сөт һәм камыр ризыкларыннан торган. К.т.ның укымышлылыгы югары булган: өлкәннәрнең 57%ы ана телендә укый-яза белгән. Касыймда «Аң», «Чалгы» г-талары нәшер ителгән. К.т.ннан татар халкы тарихында беренче хатын-кыз математик, Сорбонна университетын тәмамлаган *С.К.Шакулова* (1887–1964), Сов. Союзы Герое В.В.*Альбетков* (1917–84), җырчы, педагог З.Г.*Байрашева* (1906–84) чыккан. Ш.у. к. *Касыйм районы.*

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды // Уч. зап. Мордов. гос. ун-та. Саранск, 1960. Вып. 11; Ш а р и ф у л л и н а Ф.Л. Касимовские татары. К., 1991.

*Ф.Л.Шәрифуллина.*

**КАСЫ́ЙМ ХАН** (? — 1469, Касыйм ш.), *Касыйм ханлыгының* беренче идарәчесе (ханы) (15 йөз уртасыннан). *Олуг Мөхәммәднең* улы. 1437 елда *Кече Мөхәммәд* тарафыннан хан тәхетеннән куылган Олуг Мөхәммәд ир туганнары б-н Биләү (Белёв) шәһәренә кача. *Биләү* (Белёв) *шәһәре янындагы сугышта* катнаша (1437). Суздаль тирәсендәге сугыштан соң (1445) К.х. абыйсы Якуб б-н, Мәскәү бөек кенәзе Василий II тарафыннан ясак түләүнең үтәлешен тикшерү өчен, Мәскәүгә килә. Соңыннан Василий II гә хезмәткә күчә. Аңа Дмитрий Шемяка б-н көрәштә актив булышлык күрсәтә. 1448–49 да Звенигород шәһәренә күчерелә, Алтын Урда гаскәрләре һөҗүмнәрен кире кайтаруда катнаша. 1449 да К.х. Пахра елгасы буенда Сәед Әхмәд хан гаскәрен тар-мар итә. Касыйм ханлыгының үзәгенә әверелгән Городец-Мещерский (соңрак Касыйм ш.) шәһәрен мирас биләмәсе буларак ала. Әлеге удел өчен К.х. атлы гаскәр тотарга, Рус дәүләтенең көнчыгыш чикләрен сакларга һәм Мәскәү бөек кенәзләренең яуларында катнаштырга йөкләмә ала. Мәскәү гаскәрләре б-н Новгородка яу чаба (1456), Ука елгасы буенда татарларның һөҗүмнәренә каршы тора (1461). Казанда хан тәхетенә утырырга омтылыш ясый, әмма аның 1467 елгы явы уңышсыз тәгәлләнә. Казанга каршы оештырган яңа һөҗүме вакытында яки аннан соң вафат була. Ш.у. к. *Касыйм хан мәчете.*

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1; З и м и н А.А. Витязь на распутье. М., 1991. *И.Л.Измайлов.*

**КАСЫ́ЙМ ХАН** (?–1500 еллар тирәсе), Әстерхан ханы (1470 еллардан). *Мәхмүднең* улы, *Кече Мөхәммәднең* оныгы. Атасы үлгәч, тәхеткә утыра. Олы Урда ханы Әхмәд белән сугыша. Аның вакытында Әстерхан ханлыгы терр-ясенә Югары Каспий буе кертелә.

*Әд.:* М е х о в с к и й М. Трактат о двух Сарматиях. М., 1935; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**КАСЫ́ЙМ ХАН** (?–1532), Әстерхан ханы (?–1532). *Сәед Әхмәд хан* улы, *Әхмәд хан* оныгы. Нугайлар ярдәмендә Хаҗитархан шәһәрендә хакимиятне яулап ала. Үзәк хакимиятне ныгыту сәясәте уздыра. Кырым ханлыгын дәгъвалаган Исламгәрәй отрядларына каршы көрәшә. Төркия солтаны Сөләйманга атап язылган хат авторы буларак мәгълүм (1531–32). Аккүбек хан тарафыннан тәхеттән төшерелә һәм үтерелә.

*И.Л.Измайлов.*

**КАСЫ́ЙМ ХАН МӘЧЕТЕ́**, 16–19 йөзләр архит-ра истәлеге. Касыйм шәһәренең (Рязань өлкәсе) борынгы өлешендә, элекке Хан сарае терр-ясендә урнашкан. 16 йөз башында *Касыйм хан* хөрмәтенә төзелә. 1702 елда җимерелә. Зур нигезгә салынган уксыман гөмбәзле, кыска цилиндр рәвешендәге ике



Касыйм хан мәчете. 16 йөз — 19 йөз башы. Хәзерге күренеше.

ярусы манарасы сакланып калган. 1768 дә мәчет яңадан торгызыла (иске нигездә төзелгән, түбәсе дүрт кыеклы итеп эшләнгән бер катлы, бер заллы бина), 1835 тә 2 нче каты төзелә (архитекторы билгесез). Мәчетнең кирпеч бинасы гөмбәз б-н тәгәлләнә һәм измә б-н сылап шомартыла. Фасадлары һәм интерьеры классицизм стилендә бизәлгән. Таш манара — шундый типтагы урта гасырлар татар архит-расының бердәнбер сакланып калган элементы. 1930 дан биредә музей эшли. *Х.Г.Надыйрова.*

**КАСЫ́ЙМ ХАНЛЫГЫ́** (Касыйм патшалыгы), 15 йөз уртасында рус җирләрендә татар ханнары һәм бәкләре биләмәсе буларак барлыкка килә, 1445 елның октябрендә *Суздаль шәһәре янындагы сугышта* җиңелүе нәтиҗәсендә Мәскәү бөек кенәзе Василий II моңа ризалык бирергә мәҗбүр була. Кенәз тарафыннан *Касыйм ханга* (ханлыкның һәм башкаланың исеме дә шуннан) бүләк ителә. 16 йөз уртасына кадәр рус кенәзләреннән, ш.и. Мәскәү бөек кенәзләреннән дә Касыйм идарәчеләре файдасына ясак түләнә. Үзәге — *Касыйм шәһәре.* Ука елгасы буена урнашкан (хәзерге Рязань өлкәсе терр-ясенең төньяк-көнчыгыш өлеше). Халкы: татарлар, мордвалар, руслар. Төп шөгыльләре — игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек. Идарә итүче төп нәселләр — Мангыт, Аргын, Җәлаир, Кыпчак. Рус дәүләте көчәюе нәтиҗәсендә К.х. мөстәкыйльлеген югалта бара. Ханнар Мәскәү хөкүмәте тарафыннан Казан, Кырым, Себер һ.б. ханлыкларның идарәче династияләре вәкилләреннән билгеләп куела. Касыйм ханнары берничә тапкыр Мәскәү ягыннан торып Казанга каршы сугышларда катнашалар (1467–69, 1487, 1552). Шаһгали өч тапкыр Казан ханы була (1519–21, 1546–51, 1551–52). Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан соң, К.х.нда хакимият әкренләп Мәскәү воеводалары кулына күчә бара, ханнар һәм бәкләр хезмәткә ялланган җирбиләүчеләр хәлендә калалар. «Болгавыр заман»да К.х. Ялган Дмитрий II ягында була. Сәед Борһан чорында халыкны христианлаштыру башлана, бу татарларның күтәрелешенә китерә (1656). Соңгы идарәчесе Фатыйма Солтанның үлеменнән соң (1681) К.х. яшәүдән туктый.

К.х. идарәчеләре: Касыйм хан (1440 еллар ахыры — 1469), Данияр (1469–86) — Казан ханнары нәселеннән; Нурдәүләт (1486–91),

Сатылган (1491 тирәсе — 1506), Җанай (1508 тирәсе — 1512 тирәсе) — Кырым ханнары нәселеннән; Шәех Аллаһияр (1512–16 тирәсе), Шаһгали (1516–19, 1540 тирәсе — 46, 1546–51, 1552–67), Җангали (1519–32), Сәин Булат (1573 тән — Симеон Бикбулатович); (1570 тирәсе — 73), Мостафа Гали (1580 тирәсе — 1600) — Алтын Урда ханнары нәселе, чыгышлары б-н, башлыча, Әстерхан ханлыгыннан; Уразмөхәммәд (1601–10) — казакъ ханнары нәселеннән; Арслан (1614–27), Сәед Борһан (1627–79), Фатыйма Солтан (1679–81) — Себер ханнары нәселеннән. К.х.ның идарәчеләре арасында турыдан-туры варислар булмаган очракта нәселләр алышына.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах: В 4 ч. СПб., 1863–87; Шишкин Н.И. История города Касимова с древнейших времён. Рязань, 1891; Шарифуллина Ф. Касимовские татары. К., 1991.

**КАСЫ́ЙМ ХАННАРЫ́ ЙОРТЫ́**, фараз ителгәнчә, 15 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөздә Мәскәүдә Касыйм ханнары вәкиллеге. Мәскәү кремле янында (хәзерге Мясницкая урамында) урнашкан була. 1483 елда рус елъязмаларында Мәскәүдә Касыйм ханы Даниярның якыннары Каракоч бәк һәм аның улы яшәве турында искә алына. 1638 дә халык санын алу мәгълүматларында («Предтеча монастыреннан Варвара капкасына кадәрге җирдәге Ак шәһәрдә» бүлегендә) «Касыйм ханзадәсе Сәет Борһан Арслан улы» йорты теркәлгән. К.х.й. 1 *га* чамасы җир били, ул Касыйм ханнары улларына нәселдән күчә. 17 йөздә, Татар бистәсе һәм Кырым ханнары йорты б-н бергә, Мәскәү мөселманнары һәм Касыйм татарлары өчен туплаучы үзәк булып хезмәт итә. 1681 дә бетерелә.

18 йөз башында утарны Касыйм ханзадәсе Иван Васильевич били, аннан соң ул А.Г.Долгорукийга, 1730 елларда император Анна Иоанновнаның кардәшләре — Салтыковларга күчә; ханзадә, әлеге нәсел вәкиленә өйләнеп, алар б-н туганлаша. 18 йөз ыгыгакларында утарда таш йорт булуы турында әйтелә. 1822–34 еллар арасында аны танылган библиофил А.Д.Чертаков, 1873 тә Н.А.Гагина сатып ала; 1880–1914 тә йортны К.Н.Обидина били. 20 йөз башында, 1917 гә кадәр, К.х.й.нда мөселманнарның гыйбадәт бүлмәсе булуы турында мәгълүматлар бар.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В. В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Росписной список города Москвы 1638 года // Тр. Моск. отдела Имп. Рус. Военно-ист. об-ва. 1911. Т. 1; Сытин П. В. Из истории московских улиц. М., 1958; Розенберг Л. И. Татары в Москве XVII — середины XIX века // Этнические группы в городах Европейской части СССР (формирование, расселение, динамика культуры). М., 1987; Памятники архитектуры Москвы: Белый город. М., 1989.

*Д.З.Хәйретдинов.*

**КАСЫ́ЙМ ШӘЕ́Х** ибне Ибраһим әл-Казани (?-1589/90), шагыйрь, дин эшлеклесе. Урта гасырлар татар поэзиясендә суфичылык юнәлешенең күренекле вәкилләреннән берсе. Кайбер мәгълүматлар буенча, Казанны Иван Грозный гаскәрләре яулап алганнан соң (1552) Урта Азиягә кача. К.ш. шигырьләренең бер өлеше «Бакырган китабы»на кертелгән (1847).

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1885; Фәхретдин Р. Асар. 1900. 1 җилд, 1 җөзья; Таһирҗанов Г. Тарихтан — әдәбиятка. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**КАСЫ́ЙМ ШӘҺӘРЕ́** (Городец Мещерский, Ханкирмән), хәзерге Рязань өлкәсендә, Ока елгасының сул ягында урнашкан шәһәр. 1152 дә кенәз Юрий Долгорукий тарафыннан Городец Мещерский буларак нигезләнә. 1376 да Алтын Урда гаскәре тарафыннан җимертелә, соңрак кабат торгызыла. 15 йөз уртасында Мәскәү кенәзе Василий II Тёмный *Суздаль янындагы сугышта* җиңелгәннән соң әсирлеккә төшә һәм шуннан коткарганнары өчен Городецны *Олуг Мөхәммәд ханның* улы *Касыйм ханга* биләмә итеп бирә. Городец *Касыйм ханлыгының* үзәгенә әверелә; 1471 дә К.ш. исеме ала һәм 1681 гә кадәр ханлыкның башкаласы була. 17 йөздә К.ш. 3 өлешкә бүленә: Касыйм ханнары һәм бәкләре биләмәсе (Татар бистәсе һәм Иске бистә); Мәскәү карамагындагы ямчылар бистәсе; шәһәрнең калган өлеше (ш.и. Марфа бистәсе) б-н Касыйм воеводасы идарә итә. 17 йөз уртасында — Казан сарай идарәханәсе карамагына, 1681 дән соң сарай волостьларына бирелә, Касыйм татарлары Воронеж корабльләр төзү верфенә теркәлә. 1708 дән — Казан губ., 1719 дан Азов губернасының Шацк провинциясе составында. 1778–95 елларда Рязань наместниклыгының өяз шәһәре, 1796 дан Рязань губернасында. К.ш. татарлары башлыча С.-Петербург, Мәскәү һәм Россиянең башка үзәк шәһәрләрендә сәүдә б-н шөгыльләнәләр, шул уңайдан 19 йөздә — 20 йөз башында татарларның башка шәһәрләргә күпләп күченүе башлана. К.ш.ндә сәүдәгәр Кастровларның һәм Мусяевларның каракүл тиреләре эшкәртүче берничә һөнәрчелек остаханәсе була (сарыкларны Урта Азиядә үрчетәләр, мехларны Мәкәрҗә ярминкәсендә, Мәскәүдә, С.-Петербургта, ш.у. чит илләрдә саталар). 19 йөз ахырында К.ш.ндә 14 ләп күн ф-касы һәм 20 дән артык башка пр-тие була. Окт. рев-циясеннән соң сәүдәгәрләрнең социаль катлавы яшәүдән туктый, күпләгән татар нәселләре ярлылана. Мөселманнарны туплап торучы дини берләшмәләр дә бетерелә, нәтиҗәдә шәһәрнең мөселман халкы сизелерлек кими. 1910 елда К.ш.ндә 17 мең (ш.и. 2 мең татар), 2000 дә 38 мең кеше (ш.и. 500 татар) яши. 19 йөз ахырында К.ш.ндә 1 ирләр һәм 1 хатын-кызлар гимназиясе, 4 ирләр һәм 2 хатын-кыз мәхәллә уч-щесе; берничә шәхси һәм чиркәү-приход мәктәбе, 10 православие чиркәве, 1 монастырь була. Манаралы мәчет (1467), Шаһгали (1556) (*Шаһгали хан тәкиясе*) һәм Әфган-Мөхәммәд (1658) (*Әфган-Мөхәммәд солтан тәкиясе*) төрбәләре сакланган. Ш.у.к. *Касыйм татарлары, Касыйм ханнары йорты, Касыйм хан мәчете.*



Касыйм шәһәренең гомуми күренеше.
20 йөз башы фоторәсеме.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2; Шишкин Н.И. История города Касимова с древнейших времён. Рязань, 1891; Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1895. Т. 7; Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары. К., 1991; Аминов Д.А. Татары в старом Петербурге. СПб., 1994.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**КАСЫ́ЙМ ШӘҺӘРЕ́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1897 елның октябрендә оештырыла. Рязан губернасының Касыйм шәһәрендә һәм аның тирәсендә эшчәнлек алып бара. Оештыручылары — Х.Акбулатов, А.Әлбәтков, К.Әлбәтков, Х.Байбәков, Н.Бикбулатов, А. Виргазов, Н.Дуймакаев, М.Ишембаев, А.Кастров, С.Лашев, А.Мусин, Х.Мусаев, Х.Танкачиев, А.Тубакаев, К.Х.Шакулов, М.Юшинский. Төп максаты — мохтаҗ мөселманнарга матди ярдәм күрсәтү, мөселман мәдәни-агарту оешмалары үсешенә булышлык итү. Җәмгыять каршында китапханә — уку өе эшли. 1917 дән соң яшәүдән туктый.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**«КАСЫЙМИЯ́»**, Казандагы мәдрәсә. Мөхәмметкасыйм *Салихов* (1899–1918) исеме б-н атала (20 йөз башыннан). Шулай ук Апанай, Күл буе мәдрәсәсе исемнәре б-н дә билгеле. 1770 елларда *Апанай мәчете* каршында ачыла. Мәдрәсә җитәкчеләре белемле дин белгечләре һәм күренекле педагоглар булалар: Салих Сәгыйтов (1820 елларга кадәр), Исхак Сәгыйтов (1831–38), М.Мөхәммәтрәхимов (1836–61), Сәләхетдин Сәгыйтов (1861–75); соңгысының вафатыннан соң Бохара традицияләренең әзлеклелеге өзелә. Гарәп һәм фарсы телләрен, мантыйк, дин белемен, *фикъһ* укыту югары дәрәҗәдә алып барыла. Мәдрәсәнең китапханәсе бик бай була, һәм ул иң яхшы татар уку йорты санала. Шәкертләр санын 1870 елларга якынча 300 кеше тәшкил итә, башлыча Идел буе һәм Урал алды төбәкләреннән киләләр. Мәдрәсә мөдәррисләренең урта гасырлар укыту формасын саклап калырга тырышулары Ш.*Мәрҗанидә* һ.б. алдынгы татар иҗтимагый фикер ияләрендә ризасызлык уята. Т.Бәширов (1875–79) һәм А.Салихов (1879–99) мөдәррислек иткәндә, мәдрәсәдә укыту кадими формада саклана (к. *Кадимчелек*), шуңа карамастан, 1876 да рус телен укыту кертелә. *Җәдидчелек* үсеше нәтиҗәсендә, бигрәк тә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачылганнан соң, «К.» мөселман укыту системасында алдынгылыгын югалта. Соңгы мөдәррис — Г.*Баруди* шәкерте М.Салихов укытуга яңа алымнар кертә. 20 йөз башында бу мәдрәсәдә татар әдәбиятының күренекле эшлеклеләре — Ә.*Максуди* (гарәп теле), Г.*Коләхмәтов* (рус теле),



«Касыймия» мәдрәсәсе бинасы. Хәзерге күренеше.

Ә.*Вәлиди* (төрки тарих һәм гарәп әдәбияты) укыта.

Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында К.*Насыйри*, Г.Баруди, М.*Бигиев*, З.*Бигиев*, Ә.Вәлиди, С.*Максуди*, Г.*Исхакый*, Г.*Камал*, К.*Мотыйгый*, М.*Гали*, А.*Шамов* һ.б. бар.

Башта «К.» агач бинада урнаша, соңрак ул урында Борнай мәчете төзелә, 1877 дән Кабан күле буенда, сәүдәгәр Ә.*Рәхмәтуллин* акчасына төзелгән йортта була (арх. П.И.Романов; архит-ра истәлеге).

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; С а л и х о в Р.Р. Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; В а л и д и Д. Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). К., 1998.

**КАСЫ́ЙМОВ** Габделбәр Касыйм улы (10.12.1940, Кукмара р-ны Ядегәр а.), урман белгече, а.х. фән. д-ры (1999), проф. (2002). Урал урман-техник ин-тын (Свердловск ш.) тәмамлый (1964). 1967–74 елларда «Удмуртгражданпроект» ин-тында (Ижевск ш.) эшли. 1975–89, 1994–99 да Пермь ун-тында, урманчылык һәм урман экологиясе лаб-ясе мөдире (1994), 1990–93 тә Мари политехник ин-тында (Йошкар-Ола ш.). 2000 нән Ижевск а.х. академиясендә: урман культуралары (2006 га кадәр), урманчылык һәм урман культуралары кафедралары мөдире (2007 дән). Хезмәтләре техноген ландшафтларны торгызуга карый. Камбарка, Чернов чыганакларында нефть (Башкортстан), торф (Удмуртия), чәчелмә минераллар (Пермь өлкәсе) һ.б.ны чыгару вакытында үзгәргән җирләрне рекультивацияләү алымнарын эшли һәм гамәлгә кертә.

Х е з м.: Фитопродуктивность техногенных ландшафтов. Пермь, 1999; Экологические аспекты лесовосстановления отработанных россыпей Прикамья. Екатеринбург, 2002 (автордаш); Восстановление ельников Предуралья. Екатеринбург, 2007 (автордаш).

**КАСЫ́ЙМОВ** Галиулла Сөнгатулла улы (18.7.1893, Вятка губ., Глазов өязе Кистем а. — 1942), сәясәт эшлеклесе. 1915–17 елларда Россия армиясендә хезмәт итә, Шадрин шәһәрендәге 139 нчы пехота полкы рядовое. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң полк ком-ты әгъзасы, взвод командиры. 1918–20 дә Гражданнар сугышы фронтларында: Уралда, Урта Азиядә, Казакъстанда. 1920 дә ТАССР Эшче-крәстияннәр инспекциясе халык комиссары. 1921–23 тә Симферополь округы башкарма ком-ты рәисе. 1923 тән Казанда, Сембердә, Үзбәкстанда партия, хуҗалык эшендә. 1931–33 тә Эшче-крәстияннәр инспекциясе халык комис-ты әгъзасы, 1933 тән РСФСР Игенчелек халык комис-ты әгъзасы (Мәскәү). Татар милли хәрәкәте, пантюркизм тарихы буенча хезмәтләр авторы. Сталинның милли сәясәтен яклый, милли мәсьәлә буенча М.Солтангалиев карашларына каршы чыга. Нахакка репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Татар-башкортлар Кызыл Армия сафларында. К., 1925; Пантюркистическая контрреволюция и её агентура «султангалеевщина». К., 1931; Идеология национал-фашистов (султангалеевщина и иттихадисты). Таш.-Самарканд, 1932; О контрреволюционной деятельности татаро-башкирской националистической буржуазии (идеология национал-фашистов). Таш.-Самарканд, 1932.

*Әд.:* С а й д а ш е в а М. Касимов Галиулла Сынгатуллович // Борцы за счастье народное. К., 1967; ш у л у к. Велением сердца // Вечерняя Казань. 1987. 19 марта.


**КАСЫ́ЙМОВ** Мөхәммәдйосыф (17–18 йөзләр), Россия дипломаты. 1666 елда Иранда була. Александрия патриархы Папсийга һәм Антпохия патриархы Макарийга күрсәткән хезмәтләре өчен патша Алексей Михайлович К.ка Әстерханда һәм Мәскәүдә пошлина түләмичә сәүдә итәргә рөхсәт бирә. 1675 тә Моголлар империясе хакиме шаһ Аурангзебкә, дипломатия һәм сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштыру өчен, илче итеп җибәрелә. Аңа ш.у. Һиндстанга үтеп керү юлларын (коры җир, судан, таулар аша) белү йөкләнә. К. су юлына аеруча игътибар итәргә тиеш була. Аннан Аму-Дәрья елгасы (аның башлануы һәм озынлыгы), аның ярлары тирәли яшәгән кешеләр, аларның хуҗалык эшчәнлекләре һ.б. турында мәгълүматлар көтәләр. Башта ул анда илче итеп билгеләнгән В.Даудов белән Бохарага, аннары Кабулга (шаһ Аурангзеб биләмәсе) китә. Шаһның Кабулдагы башлыгы К.ның килүе турында хәбәр иткәч, шаһ аны кире борырга куша. Бу карар Һиндстанда борынгы заманнардан ук рус илчеләренең булмавы б-н аңлатыла. Шулай да К.ның үзенә Аурангзебкә хезмәткә калырга тәкъдим итәләр, ләкин ул баш тарта. К. шаһка дигән бүләкләрне сата, шуннан кергән акчага рус әсирләрен тоткынлыктан йолып ала һәм Мәскәүгә кайта.

*Әд.:* Б а р т о л ь д В. История изучения Востока в Европе и России. Л., 1925.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КАСЫ́ЙМОВ** Наил Васил улы (20.8.1955, Арча р-ны Ашытбаш а.), шагыйрь. Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1977). 1992 елга кадәр Казанның төзелеш оешмаларында өлкән инженер булып эшли. 1992–97 дә «Татарстан» ДТРКсында мөхәррир, соңрак өлкән мөхәррир. 1997–99 да Казан шәһәр советы мәдәният идарәсе башлыгы урынбасары, 1999 дан юл төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары. «Су буенда учак яна» (1992), «Күңелем каршында тезләнде» (1996), «Күңелем кояшы» (2004) лирик шигырьләр җыентыклары; «Ак яулыклы әнием» (Л.Батыр-Болгари көе), «Туй күлмәге» (Р.Ахиярова көе), «Су буенда учак яна» (З.Хәйретдинов көе) кебек популяр җырлар текстлары авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.



Г.С. Касыймов.



С.С. Касыймов.

**КАСЫ́ЙМОВ** Рафаил Габделхәй улы (1.7.1947, Слупск ш., Польша), композитор, педагог, БРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). 1973 елда Уфа сәнгать ин-тын фортепиано (Л.Франк классы) һәм композиция буенча (З.Исмәгыйлев классы) тәмамлый. 1972–79 да Башкорт филармониясендә сәнгать җитәкчесе, 1979 дан Уфа шәһәренең 1 нче балалар музыка мәктәбендә фортепиано һәм композиция укытучысы.

К. күбесенчә симф. һәм камера-инструменталь музыка жанрында эшли. Композиторлык иҗаты техникасын яхшы белә. Үзенең киң масштаблы симф. әсәрләрендә хәзерге актуаль проблемаларны һәм яшәүнең мәңгелеге темасын күтәреп, тормыш күренешләрен фәлсәфи югарылыкта гомумиләштерергә омтыла. Бер үк вакытта К. әсәрләрендә драматик һәм фаҗигале образлар шактый урын алып тора. Аның иҗат стилистикасы заманча яңгырашлы интонация һәм ритмнарның киң палитрасына нигезләнгән. Композиторның музыкасы татар һәм башкорт муз. мәдәниятенең классик традицияләрен тирән аңлавын күрсәтә. К. балалар музыка мәктәбе өчен вокаль һәм инструменталь пед. репертуар булдыру өстендә актив эшли. Аның әсәрләре бик күп илләрдә башкарыла. БРның С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2004).

Төп әсәрләре: Симф. оркестр өчен 1, 2, 3, 4, 5 нче симфонияләр (1984, 1997, 1999, 2000, 2002); оркестр б-н фортепиано өчен концерт (1973), Диптих (1992), Увертюра (1995); камера оркестры өчен — Диптих (1980) һәм Концертино (1987); хор өчен — М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре» шигырьләренә а́ capella 5 хор әсәре (1973); Орган өчен каприччио (1987); камера-инструменталь әсәрләр — Фортепиано өчен квинтет (1984), Фортепиано өчен 6 сюита (1971–1986), Фортепиано өчен 2 соната (1971–1977); балалар өчен җырлар, фортепиано пьесалары һ.б.

*Әд.:* С к у р к о Е., Х а б и р о в а С. Рафаил Касимов // Композиторы и музыковеды Башкортостана: Очерки жизни и творчества. Уфа, 2002.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КАСЫ́ЙМОВ** Сәмигулла Сөнгатулла улы (1897, Вятка губ., Глазов өязе Кистем а. — 1968, Казан), сәясәт эшлеклесе. 1916 елның маеннан Россия армиясендә, декабрьдә солдатлар арасында сугышка каршы пропаганда алып баруы өчен төрмәгә ябыла. Гражданнар сугышында катнаша. 1924–25 тә Үзбәкстан ССР хөкүмәте әгъзасы. 1925–27 дә Татар-башкорт хәрби мәктәбе комиссары, 1930–32 дә ТАССР Госпланы рәисе, аннан

ТАССР ХКС каршындагы Татарстан радиолаштыру һәм радиотапшырулар республика ком-ты рәисе, ОСОАВИАХИМ ның Татарстан бүлекчәсе рәисе. Нахакка репрессияләнә, 1956 да аклана.

*Әд.:* С а й д а ш е в а М. Касимов Самигулла Сынгатуллович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2; ш у л у к. Велением сердца // Вечерняя Казань. 1987. 19 марта.

*М.А.Сәйдәшева.*

**КАСЫ́ЙМОВ** (чын фамилиясе Исрафилов) Хатип Касыйм улы (15.11.1932, Ширәмәт, хәзер Түбән Кама р-ны Болгар а.), шагыйрь. Чистай а. х.н механикалаштыру техникумын тәмамлагач (1969), Түбән Кама р-ны «Память Ильича» с-зында механик, куркынычсызлык техникасы инженеры, партия оешмасы секретаре булып эшли. 1983–90 елларда «Түбәнкаманефтехим» берләшмәсенең 6 нчы йортлар идарәсе инженеры. 1990–95 тә «Туган як» г-тасында (Түбән Кама ш.) бүлек мөдире. Шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1988) күмәк җыентыгында урын ала. «Ак чишмә» (1991), «Кичке моң» (2001), «Мин җирдә калам» (2004) исемле шигъри җыентыклар авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КАСЫ́ЙМОВ** Эдуард Салихҗан улы (8.11.1930, Киров өлкәсенең Слободский р-ны Нократ а. — 21.3.1986, Чаллы ш.), язучы, филол. фән. канд. (1966). Казан ун-тын тәмамлагач (1953), Азнакай эшчеләр посёлогында, соңыннан Киров өлкәсе Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн авылында укытучы булып эшли. 1957 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында фәнни хезмәткәр. 1965–67 дә Алабуга пед. ин-тында татар фольклорын һәм әдәбиятын укыта. 1980–81 дә ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җаваплы сәркәтибе. Беренче хикәя һәм очерклары 1950 еллар башында күренә башлый. Аның төп әсәре — илдә барган катлаулы тарихи вакыйгаларны бер гаилә үрнәгендә тасвирлаган «Гомер ике килми» (1964) автобиографик романы. Бондюг химия з-ды эшчеләре коллективының хезмәтен чагылдырган «Томан аша» (1968) һәм «Һаваларда тургай» (1971) романнары дилогия тәшкил итә. Рус телендә «Чулман — оныкларыбыз елгасы» («Чулман — река внуков», М., 1976) исеме б-н басылып чыккан бу дилогия 1978 дә эшчеләр темасына язылган проза әсәрләре Бөтенроссия конкурсында ВЦСПС һәм Язучылар берлеге бүләгенә лаек була. «Шиңмәсен гөлләрең» (1986), «Кама елгасында» («На Каме-реке», М., 1979) исемле очерк җыентыкларында сүз авылда КамАЗ төзелеше белән бәйле социаль-икътисади үзгәрешләр турында бара. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С а ф и н Ф. Еллар яктысы // Казан утлары. 1980. № 11; С а л и х о в Р. Кояш томанны тарата. Алабуга, 2003.

**КАСЫЙМУ́ЛЛИН** Шәмсулла Мөхибулла улы (18.5.1952, Чирмешән р-ны Кармыш а.), а.х. пр-тие җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1994). 1978 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Зәй р-ның «Нива» а.х. җитештерү кооперативында (1998 гә кадәр «Заветы Ильича» с-зы) эшли: агроном, 1982 дән директор. К. җитәкчелегендә товарлыклы-сөтчелек комплексы реконструкцияләнә, дуңгыз фермаларына капиталь ремонт ясала. 8721 *м*² мәйдан торак йортлар, ике ашханә, кибет, гараж, 18 *км* лы каты өслекле юл төзелә; Поповка, Налим авылларына газ кертелә. 2001–2005 тә хуҗалыкта бөртекле ашлык җитештерү 1996–2000 еллар б-н чагыштырганда 28,2% ка, ит — 79,7% ка, сөт 6,4% ка арта. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**КАСЬЯ́НОВ** Владимир Ибрагимович (5.6.1946, Казан), математик, физика-матем. фән д-ры (2002). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1968 дән ГНИПИ ВТда эшли. 1976–79 да «Известия вузов. Математика» ж-лы редакторы. 1979–86 да Казан пед. ин-тында, 1986–92 дә ГИПОда, 1992–93 тә Казан а.х. ин-тының кибернетика кафедрасында. 1993 тән Әлмәт нефть ин-тында, югары матем. каф. профессоры (2002 дән). Хезмәтләре кырый мәсьәләләргә һәм аларның матем. физикадагы нәрегуляр мәсьәләләрдә кулланылышына, фильтрлаштыру теориясенә карый. К. бисингуляр интеграль тигезләмәләрне чикләнмәгән өлкәләрдә чишүнең турыдан-туры алымнарын эшли; ярым бисссылыкта матем. физика мәсьәләләренә эквивалент булган Риман мәсьәләләре классын ачыклый; чикләнмәгән өлкәләрдә функцияләрнең конструктив теориясе буенча нәтиҗәләр ала; компьютерларның кертү-чыгару интеграль-оптик җайланмаларын исәпләү алымнарын эшли.

Х е з м.: О численной реализации интегрального метода в теории дифференциальных решёток // Оптика и спектроскопия. 1992. Т. 72, вып. 4 (автордаш); Оптимизация прямых методов решения сингулярных интегральных уравнений в неограниченных областях // Изв. вузов. Математика. 1995. № 5.

**КАТА́**, татарларда кыска кунычлы итек рәвешендәге традицион күн яисә йоннан басып (киез ката) эшләнгән аяк киеме. Кәҗә тиресеннән эшләнгән К.ны, гадәттә, каты аслыкта, киң үкчәле (кадаклап) һәм киң яки береаз тарайтылган башлы итеп тегәләр. К.ны бәйләнгән оек яки тула оек, яисә йомшак табанлы читек өстеннән тышкы аяк киеме буларак кияләр. Ш.у. к. *Кәвеш.*

*Әд.:* М у х а м е д о в а Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

**КАТА́ЕВ** Владимир Евгеньевич (7.5.1951, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1997), проф. (2009), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1973), РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, директор урынбасары (1991–96), табигый кушылмалар химиясе лаб-ясе мөдире (1994–2008), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2008). Хезмәтләре органик, элементорганик һәм табигый кушылмаларның структур химиясенә карый. Органик кушылмаларның төрле функциональ төркемле һәм берничә эчке әйләнү күчәре булган молекулалары төзелешенең конформацион закончалыкларын ача. Азотлы гетероциклик кушылмаларның, аларның химик төзелешенә, структур һәм конформацион факторларына биол. активлыгының бәйлелеген билгели, аларның ацетилхолинэстераза б-н тәэсир итешү моделен тәкъдим итә. Изостевиол дитерпеноиды кушылмалары рәтендә яңа реакцияләр ача һәм аның ароматик кушылмаларны селектив бәйләү сәләте барлыгын ачыклый (бергәләп).

Х е з м.: Конформационный анализ замещённых этанов // Конформационный анализ углеводородов и их производных. М., 1990 (автордаш); Исследования Б.А.Арбузова в области изомеризации и стереохимии бициклических монотерпенов // Б.А.Арбузов — учёный, педагог. К., 2003; Синтез, структура и свойства соединений молибдена. К., 2003 (автордаш).

**КАТА́ЕВ** Владислав Евгеньевич (18.10.1957, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1979), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1996 дан). Хезмәтләре металларда һәм металл-оксидлы кушылмаларда магнит резонансын эксперименталь тикшерүләргә карый. К. магнит кырының югары темп-ралы үтә үткәргечләр б-н гадәти булмаган тәэсир итешүләрен ачыклый (бергәләп, 1991), аеруча үткәрүчән яңа материаллар физикасында кристаллик структура, магнит һәм электрон үзлекләренең үзара бәйләнешендәге яңа аспектларны билгели (бергәләп, 1993).

Х е з м.: Paramagnetic Meissner effect in Bi-high temperature superconductors // Phys. Rev. Letters. 1992. V. 68, № 12 (автордаш); Coupling constant versus density of states in $La_{2-x}Sr_xCuO_4$ as reveafed by EPR of Gd spin probes // Phys. Rev. B. 1993. V. 48, № 17 (автордаш); Slow antiferromagnetic dynamics in the low temperature tetragonal phase of $La_{2-x}Sr_xCuO_4$ as reveafed by EPR of Gd spin probes // Phys. Rev. B. 1976. V. 56, № 6 (автордаш).

**КАТА́ЕВ** Юрий Павлович (27.9.1936, Свердловск өлкәсенең Ирбит ш.), авиация технологияләре өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1971), проф. (1972), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2005). 1960 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, металларны басым б-н эшкәртү (1972–83), машиналар төзелеше, металл эшкәртү станоклары һәм инструментлары технологияләре (1983–2006) кафедралары мөдире. Хезмәтләре металларның статик һәм динамик деформациясенә, очкыч аппаратлар детальләрен пластик деформация һәм югары тизлекле механик эшкәртү алымнары б-н формага салу процессларына карый. К. табаклы детальләрнең химик каплау вакытында кәкрәюе теориясен һәм аны исәпләү алымнарын эшли (С.П.Горбунов исем. Казан авиация з-дында гамәлгә кертелә). Ирекле аркылы кисемле очкыч аппаратларның куыш элементларын пластик борып әйләндерү процессы өчен технол. параметрларны исәпләү алымнарын тәкъдим итә (Мәскәү авиация технологияләре фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында һәм Казан вертолётлар з-дында гамәлгә кертелә). Детальләрне термовибрацион эшкәртүдә югары темп-раларда материалларның шуышуын киметә торган алымнарны; металларны пластик деформацияләүнең магнит-гидроимпульслы алымын; металларны

кисүнең матем. теориясен эшли. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пластическое кручение полых элементов летательных аппаратов. М., 1985; Пластичность и резание металлов. М., 1994 (автордаш); Магнитно-гидроимпульсное пластическое деформирование металлов. М., 1994 (автордаш).

**КАТА́ЛИЗ**, химик реакцияләрнең тизлеген үзгәртү яки аларны реакциядә катнашып та азаккы продукт составына кермәүче матдәләр (катализаторлар) б-н көчәйтү. Реагентларга караганда катализаторлар саны шактый аз. Катализаторлар катнашындагы реакцияләр каталитик дип атала. Аларны уңай К. (реакциянең тизләтелүе) һәм тискәре К. (реакциянең акрынаюы), яки ингибирлауга аералар. Гадәттә, «К.» терминын уңай К.га карата кулланалар. Гомоген К. булганда, катализатор һәм реагентлар бер үк фазада, гетероген булганда, төрле фазада булалар. Коллоид кисәкчекләре сыек фазада арадаш халәттә була. Шулай ук гетероген-гомоген К.да бар, ул вакытта реакция, каты катализатор өслегендә башланып, барлык күләмдә дәвам итә. Катализаторның химик табигатенә карап К. кислота-нигездәге К., металлар, оксидлардагы К. һ.б. төрләргә аерыла. Каталитик процессларның аерым төркемен биол. катализаторлар — ферментлар б-н китереп чыгарыла торган ферментатив реакцияләр тәшкил итә. Реагентлар молекулаларына керүче элементларның оксидлашу дәрәҗәсе үзгәрү б-н, реакциянең тизләтелүен оксидлашу-кайтарылу К.ына кертәләр. Мөмкин булган стереоизомерлардан фәкать берсен генә хасил итә торган реакцияләрне стереоселектив К.да тикшерәләр. Катализатор, туры һәм кире реакцияләр тизлегенә тигез дәрәҗәдә тәэсир итеп, реагирлашучы системаларда химик тигезләнешкә тәэсир итми, ләкин аның нәтиҗәсен тизләтә, бу вакытта каталитик булмаган реакциягә караганда, каталитик реакциядә активлаштыру энергиясе Е азрак тотыла. Мәсәлән, $NH_3$ нең $N_2$ һәм $H_2$ гә каталитик булмаган таркалуы вакытында Е=330 *кДж/моль*, платина булганда Е=160 *кДж/моль*. Каталитик әверелеш стадияле механизм буенча була ала, ул вакытта бер каталитик булмаган реакция А+В→ С+Д һәрбер стадиядә активлаштырылган комплекс А+К=(АК)* → АК; АК+В → (АВК)* → С+Д+К хасил итеп, катализатор б-н реагентларның берничә стадиядә бер-бер артлы тәэсир итешүләр җыелмасы б-н алыштырыла, яки тоташ (ассоциатив, синхрон) механизм буенча, бер үк вакытта катализатор б-н барлык реагентлар тәэсир итешә һәм бер активлаштырылган комплекс [А+В+К → (АВК)* → С+Д+К] хасил була. Катализаторлар еш кына сайлау тәэсиренә ия булалар, ягъни термодинамик мөмкин булган реакцияләрнең берсен генә тизләтәләр. Мәсәлән, $Bi_2O_3{\cdot}MoO_3$ булганда пропилен акролеинга кадәр, $Co_3O_4$ булганда $CO_2$ гә һәм $H_2O$ га кадәр оксидлаша.

К. турында беренче фәнни мәгълүматлар 19 йөз башына карый. 1806 елда француз химиклары Н.Клеман һәм Ш.Дезорм сульфат к-тасы алуның камера процессында азот оксидларының күкерт газы оксидлашуга каталитик тәэсирен ачалар. 1811 дә рус химигы К.С.Кирхгоф сыегайтылган к-таларның крахмалны шикәргә (глюкозага) әверелдерүен күрсәтә. 1818 дә француз химигы Л.Ж.Тенар күпсанлы каты җисемнәрнең водород пероксиды эремәләрен таркатуны тизләтүен билгели, инглиз химигы Г.Дэви спирт һәм эфир парларының платинада кислород б-н оксидлашу мөмкинлеген ачыклый. 1822 дә немец химигы И.В.Дёберейнер водород һәм кислородның платинада гадәти температурада кушылуын билгели. Матдәләрнең химик реакцияләр тизлегенә яки аларның булу мөмкинлегенә уңай тәэсире ачылу немец химигы Э.Мичерлих тарафыннан — контактлы (1833), швед химигы Й.Я.Берцелиус тарафыннан каталитик (1835) дип аталучы аерым төр күренешләрне аерып өйрәнүгә китерә. Проф. М.Г.Кучеров, ацетиленнан серкә альдегиды алу өчен, сәнәгатьтә киң кулланылучы терекөмеш тозларының каталитик тәэсире астында ацетиленлы углеводородларны гидратлау реакциясен ача (1881). Акад. В.Н.Ипатьев беренче тапкыр гетероген К.га югары басымны кертеп, басым астындагы К. га нигез сала. Алга таба каталитик реакцияләрнең бик күп саны ачыла, 20 йөзнең 2 нче яртысыннан К. сәнәгатьтәге химик реакцияләрнең әйдәп баручы алымына әйләнә (аммиак синтезы, сульфат һәм нитрат к-таларын алу, нефть дистиллятлары крекингы, риформингы һәм изомерлаштыру һ.б.). К. теориясе үсешенә Россия галимнәре А.А.Баландин (К.ның мультиплет теориясе), Н.Н.Кобозев (аггравация теориясе), Ф.Ф.Волькенштейн (адсорбциянең электрон теориясе һәм ярымүткәргечләрдә К.), Г.К.Боресков, Х.М.Миначев, С.З.Рогинский (гетероген К.), С.Н.Хаҗиев (цеолитларда К.) зур өлеш кертәләр.

Органик К. уңышлары органик кушылмаларның химик төзелеш теориясе үсеше б-н нык бәйле. 1869–74 тә А.М.Бутлеров, сульфат к-тасы булганда су кушу юлы б-н олефиннарны спиртка әверелдереп, гидратацион К.га нигез сала; $H_2SO_4$, $H_3PO_4$, $BF_3$ һ.б. катализаторлар булганда туендырылмаган углеводородларны каталитик полимерлаштыруны ача. Һәр ике реакция дә сәнәгатьтә киң кулланылыш таба. 1871 дә М.М.Зайцев беренче тапкыр нитрокушылмаларны аминнарга кайтару реакциясен водород б-н каталитик гидрирлауны (палладий булганда) куллана. С.А.Фокин сыек фазада гидрогенлаштырылган К.ны үстерә, һәм 1909–10 елларда аның җитәкчелегендә бертуган Крестовниковларның Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия з-дында (Казан) Россиядә беренче сыек үсемлек майларын гидрогенлаштыру җайланмасы төзелә. А.Е.Арбузов, гомоген тирәлектә каталитик процесслар механизмын өйрәнгәндә, арадаш реакцияләр теориясенә таяна, «Фосфорның кайбер кушылмалары әверелешләре өлкәсендә катализ күренешләре» («О явлениях катализа в области превращений некоторых соединений фосфора») дигән докторлык диссертациясендә (1914) өч валентлы фосфорның биш валентлы кушылмаларга изомерлашуның барлык реакцияләре дә арадаш продуктлар хасил итеп үтүен күрсәтә.

Татарстан галимнәре К.ның теоретик һәм гамәли аспектларын өйрәнүгә шактый зур өлеш кертәләр. Углеводородларның изомерлаштыру, гидрирлау һәм дегидрирлау (водород аеру) процессларында гетероген К. буенча (Р.И.*Измайлов*); углеводородларны каталитик дегидрирлау һәм мономерлар аерып чыгару (А.Г.Лиакумович, В.А.Курбатов, П.А.Кирпичников); углеводородлар һәм күкертле кушылмалар оксидлашу процесслары, углеводородларны гидрирлау, эпоксидлау һәм дегидратлаштыру өчен гетероген һәм гомоген К. (Н.М.Лебедева, Х.Э.Харлампиди); күкертле кушылмаларның металл комплекслы һәм гетероген катализаторлар б-н сыек фазалы оксидлашу реакцияләрендә К. (Ә.М.*Мазһаров*, А.Ф.*Вилданов*; ТРның Дәүләт бүләге, 1998); ацетилен һәм олефинсыман углеводородлар гидрирлау процессларында, этилбензолны эпоксидлау, дегидрирлау, изобутиленны гидратлаштыру һ.б. процессларда К. (Б.Р.*Серебряков*, А.Ш.*Зыятдинов*); этиленны этилен оксидына оксидлаштыруның каталитик процесслары нәтиҗәлелеген күтәрү буенча хезмәтләр (М.С.*Габетдинов*), алюминийның актив оксидын электрохимик синтезлау һәм углеводородларны кабаттан гидроэшкәртү процесслары өчен катализаторлар табу (А.А.Ламберов) буенча эшләр башкарыла. Каталитик процессларны төпле һәм гамәли тикшерүләр РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан технол. ун-тында, Бөтенроссия углеводород чималы ин-тында, «Түбәнкаманефтехим» АҖнең фәнни-технол. үзәгендә, Казан ун-тында, «Казаноргсинтез» АҖдә үткәрелә. Тикшеренү нәтиҗәләре ТР һәм БРның ясалма каучук з-дларына, «Түбәнкаманефтехим», «Казаноргсинтез» АҖләренә, РФ пр-тиеләренә, «Тенгизшевройл» Россия-Америка уртак пр-тиесенә (Казакъстан Респ-касы) кертелә. Бөтенроссия углеводород чималы ин-ты тарафыннан эшләнгән газлы конденсатны һәм газолинны күкертле кушылмалардан чистартуның каталитик технологияләре Иранга 20 сәнәгый корылма төзү өчен сатыла (2003).

*Әд.:* Б о р е с к о в Г.К. Катализ: В 2 ч. Новосиб., 1971; Т о м а с Ч. Промышленные каталитические процессы и эффективные катализаторы. М., 1973; Г е й т с Б., К е т ц и р Дж., Ш у й т Г. Химия каталитических процессов. М., 1981.

*Ә.М.Мазһаров.*

**КАТА́НОВ** Николай Фёдорович (6.5.1862, Изюм (Узюм) даласы, хәзерге Хакас Респ-касы Аскиз р-ны — 10.3.1922, Казан), төрки телләр галиме, этнограф, филол. фән. д-ры (1903), чагыштырма тел белеме д-ры (1907). 1888 елда Петербург ун-тының шәрекъ ф-тын тәмамлый. 1889–92 дә Рус география җәмгыятенең һәм Петербург ФАнең Себер, Монголия, Җуңгария, Кытай, Төркестан экспедицияләрендә катнаша; җирле төрки халыкларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, телен, фольклорын өйрәнү б-н шөгыльләнә. 1893 тән Казан ун-тының төрек-татар шивәләре кафедрасында экстраординар проф. 1896–98 дә Уфа губернасының көнбатыш өязләрендә башкорт теле диалектларын өйрәнә; «Башкорт теле әлифбасы»н («Азбука башкирского языка») төзи (басылмаган).



Н.Ф. Катанов.



Н.А. Катин.

Соңрак *Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетында* шәрекъ, ш.и. татар басмалары цензоры һәм әҗнәбиләр өчен дәреслекләр мөхәррире. 1907 дән Тәрҗемә комиссиясе рәисе. 1911 дән Казан руханилар академиясендә Идел буендагы христианлык тарихыннан лекцияләр укый, татар теле укыта. «Кыскача татарча-русча сүзлек» («Краткий татарско-русский словарь», 1912), академия тыңлаучылары өчен татар телендә хрестоматия бастырып чыгыра (1913). Бер үк вакытта этнография музее б-н җитәкчелек итә, «Православный собеседник» ж-лының кушымтасы «Инородческое обозрение»ның мөхәррире була. 1917 дән соң кабат Казан ун-тында (1921 дән проф.). Лекцияләрендә К. төрки телләрнең таралу географиясе һәм классификациясе, төрки язу тарихы буенча мәгълүматлар бирә. Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм этнография, Югары халык мәгарифе ин-тларында да укыта. Төрки тел белеме һәм этнография буенча хезмәтләре бар. «Урянхай телен өйрәнү тәҗрибәсе...» («Опыт исследования урянхайского языка...», т. 1–2, 1903) хезмәтендә урянхай (тува) теленең грамматик төзелеше башка төрки телләрнеке б-н чагыштырып карала; анда халык авыз иҗаты үрнәкләре дә, сүзлек тә бирелгән. Ул ш.у. Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы һәм Казан тарихлары б-н кызыксына: археол. казу эшләре вакытында табылган акчаларны, болгар эпиграфик истәлекләрен, матди мәдәният калдыкларын өйрәнә. Рус география җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1894), Рус археол. җәмгыяте әгъзасы (1894).

Казандагы бер урамга һәм Хакас ун-тына К. исеме бирелә.

Х е з м.: Материалы к изучению Казанско-татарского наречия: В 2 ч. К., 1899; Наречия урянхайцев, абаканских татар и карагасов // Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён. СПб., 1907. Ч. 9.

*Әд.:* И в а н о в С.Н. Николай Фёдорович Катанов: Очерк жизни и деятельности. М., 1973; Катановские чтения: Доклады, прочитанные в Казан. ун-те, посвящённые 135-летию со дня рождения Н.Ф.Катанова. К., 1998; Ю д а к и н А. Урало-алтайское (тюрко-монгольское) языкознание: Энцикл. М., 2001; В а л е е в Р.М. Классик отечественного востоковедения // Науч. Татарстан. 2002. № 2. *В.Х.Хаков.*

**КАТАСТРО́ФАЛАР МЕДИЦИ́НАСЫ**, мед. бүлеге һәм сәламәтлек саклау тармагы; гадәттән тыш хәлләр вакытында һәлакәткә дучар булганнарга ярдәм итү һәм аның нәтиҗәләрен бетерү эшләрен фаразлауга һәм оештыруга юнәлтелгән фәнни һәм гамәли эшчәнлек б-н шөгыльләнә. К.м. мөстәкыйль тармак буларак 20 йөзнең соңгы чирегендә формалаша. Катастрофалар бүленеше Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы тарафыннан тәкъдим ителә. Аларга стихияле: метеорологик, технологик, теллурик, тектоник һәлакәтләр; антропоген фаҗигаләр; корабльләр, поездлар һәлакәте, су тәэминатындагы сулар пычрану һ.б. керә. К.м. хәрби мед. б-н тыгыз бәйләнештә.

Татарстанда К.м. 1970 еллар ахырында формалаша. 1990 да Республика К.м. үзәге төзелә, 1994 тә ул ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына керә. Халыкка мед. ярдәмен оештыру нигезен ике яисә өч этаплы дәвалау-эвакуация эшләре тәшкил итә. Экстрен ярдәм системасы Республика К.м. үзәгеннән һәм 9 районара үзәктән тора. Аларга юл-транспорт һәлакәте вакытында ашыгыч трасса хезмәте, тиз хәрәкәтле мед. отряды (1998), экстрен мед. ярдәме оештыруның аналитика бүлеге (2000), һәлакәттә имгәнгән һәм травма алганнарны реабилитацияләү өчен «Ливадия» санаториендагы поликлиника (1996) керә; Чернобыль АЭСы һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларның сәламәтлеген күзәтү һәм диспансер хезмәте оештырыла. Гадәттән тыш хәлләр вакытында кичектергесез ярдәм күрсәтү өчен авиамедотряд һәм күчмә дәвалау диагностика комплекслары нигезендә эш итү технологияләре эшләнә. Катастрофаларны булдырмау һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү буенча максатчан республика программасы бар (1991). Ел саен ТР К.м. хезмәте 1000 нән артык очракта һәлакәткә дучар булганнарга ярдәм итүне оештыра.

Республика К.м. үзәге җитәкчеләре: Ш.С.Каратай (1990–95), Н.И.Галиуллин (1995–98), Ф.Р.Әхмәров (1998 дән).

**КАТА́Ш-КАРА́Н** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 397 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-К.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 ярма яргыч, 3 ашлык киптергеч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2315,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәтмулла волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1834 тә — 121, 1870 тә — 837, 1897 дә — 1019, 1913 тә — 1243, 1920 дә — 1196, 1926 да — 1173, 1938 дә — 980, 1949 да — 673, 1958 дә — 664, 1970 тә — 646, 1979 да — 494, 1989 да — 377, 2002 дә — 402 кеше.

**КАТАШЁВ** Валерий Георгиевич (23.5.1941, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1997), проф. (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Казан мәктәпләрендә физика укытучысы, директор урынбасары, директор булып эшли. 1976 елдан ТАССР Мәгариф министрлыгында укыту-тәрбия эшләре буенча инспектор. 1978 дән СССР ПФАнең Проф.-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында фәнни хезмәткәр. 1985 тән Казан пед. ин-тында. 1992 дән Казан ун-тының пед. кафедрасында. Хезмәтләре шәхеснең проф. үзаңын формалаштыру, профильле укыту мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Актуализация знаний учащихся в процессе обучения физике. К., 1989; Формирование профессионального самосознания школьников. К., 1993; Профессиональное самосознание учащихся: Дидактический аспект. К., 1994; Педагогика высшей школы. К., 2002.

**КА́ТЕРОВ** Василий Иванович (20.1.1891, Самара ш. — 2.6.1960, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1939), проф. (1935), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). 1915 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, шунда ук терапия клиникасында эшли (1918–21 дә хәрби мед. хезмәтендә). Бер үк вакытта (1921–29) «*Обсерватория*» туберкулёз санаторием оештыра һәм аның директоры була. 1930–60 та Казан мед. ин-тында, 1935 тән 2 нче госпиталь терапиясе каф. мөдире. 1943–46 да ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының эвакуация госпитальләре баш терапевты. Хезмәтләре туберкулёзны дәвалау һәм булдырмауга, ш.и. кымыз б-н дәвалауга карый. К. курортлар эшен, «Иж минераль сулары», «Бәкер» санаторийларының бальнеология ресурсларын өйрәнә. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О клинике первичного рака лёгких // Казан мед. журн. 1930. № 12; Общие основы лечения малярии // Казан. мед. журн. 1936. № 3; К методике собирания анамнеза // Казан. мед. журн. 1938. № 10.

*Әд.:* Э п ш т е й н Т.Д. Памяти профессора В.И.Катерова // Казан. мед. журн. 1960. № 4.

**КА́ТИН** Николай Андреевич (21.12.1924, Арча кантоны Ильинский а. — 7.4.1945, Калининград өлкәсенең, Зеленоград р-ны Волошино пос.), Сов. Союзы Герое (19.4.1945, үлгәннән соң), өлкән лейтенант. Ярославль пулемётчы-миномётчылар уч-щесен тәмамлый (1943). 1942 елның маеннан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 68 нче укчы полкның пулемёт ротасы командиры (43 нче армиянең 70 нче укчы дивизиясе). Калинин, 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Демидов шәһәре янындагы оборона сугышларында, Смоленск, Белоруссия һәм Балтыйк буе һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1944), Курляндия ярымутравында дошман группировкасын камауда катнаша (1944–45). 1945 нең март–апрель айларында Көнчыгыш Пруссиядә — 3 нче марттан 4 нче мартка кадәр Побетен (хәзер Калининград өлкәсе Романово пос.) һәм 7 апрельдә Фридрихсберг (хәзер Калининград ш. Зелёный пос.) торак пунктлары өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: сугышчылар төркеме б-н йортны кулга төшерә һәм аны 3 *сәг.* буе кулда тота; танкка каршы кулланыла торган граната б-н үзен һәм аны чолгап алган дошманнарны шартлата. Ленин ордены, ике Кызыл Йолдыз ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Калининград шәһәрендә обелиск куела һәм Герой

һәлак булган йортка мемориаль такта эленә. Калининград һәм Яшел Үзән шәһәрләренең бер урамы К. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Слава бессмертна. Калининград, 1963; Д р и г о С.В. За подвигом — подвиг. Калининград, 1984; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КАТКО́В** Николай Семёнович (18.12.1928, Киров өлкәсенең Нолинск р-ны Мошата а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1983), проф. (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). РСФСРның, Мари Респ-касының атказ. икътисадчысы (1982, 2003), РФнең мактаулы югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1962 елда К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый. 1948–50 дә 320 нче з-дта (Казан) эшли. 1962–63 тә Татарстан республика а.х. тәҗрибә станциясендә өлкән фәнни хезмәткәр, 1963–68 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1965–85 һәм 1987–90 да Казан а.х. ин-тында, кибернетика каф. мөдире (1970 тән), ректор (1971–90 да). 1985–87 дә Куба Респ-касында а.х. ин-ты ректоры киңәшчесе (Баямо ш.) һәм совет белгечләре төркеме җитәкчесе. 1990 нан Мари ун-тында (Йошкар-Ола ш.), кибернетика каф. мөдире, проф. (2003 тән). Хезмәтләре терлек азыгы базасын оештыруга һәм аның икътисадына; а.х. производствосын специальләштерүгә һәм туплауга карый. Татарстанда беренче булып а.х. тикшеренүләрендә модельләштерү куллана башлый. К. «КамАЗның шәһәр яны зонасы» проектын төзү төркеме җитәкчесе. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Корма и экономика. К., 1974; Кормовая база промышленных комплексов. К., 1978; Экономика и организация кормопроизводства. К., 1980; Пригородное сельское хозяйство Татарии. К., 1982; Проблемы приватизации и государственное регулирование в аграрном секторе. Нью-Йорк–М., 1996; Совершенствование интеграционных процессов в отраслях АПК. Йошкар-Ола, 2003.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КАТМЫ́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 55 *км* көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 491 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиәннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та 2 мәчет, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1340,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сөн волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 103 ир-ат; 1859 да — 700, 1897 дә — 872, 1908 дә — 1127, 1920 дә — 1077, 1926 да — 1056, 1938 дә — 1037, 1949 да — 782, 1958 дә — 758, 1976 да — 778, 1979 да — 652, 1989 да — 496, 2002 дә — 500 кеше.

**КАТМЫ́Ш** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 194 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вәрәш-Катмыш исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 463,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирек волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 135, 1913 тә — 233, 1920 дә — 267, 1926 да — 206, 1938 дә — 244, 1949 да — 268, 1958 дә — 224, 1970 тә — 222, 1979 да — 210, 1989 да — 187, 2002 дә — 203 кеше.

**КАТНА́Ш АЗЫ́К**, вакланган терлек азыгыннан фәнни нигезләнгән рецепт буенча төзелгән әзер катнашма. Терлекләрне тукландыру өчен кулланыла. Терлекләрнең яше буенча бүленгән һәм хуҗалык төркемнәренең һәрберсе өчен (бозаулар, сөт бирүче сыерлар, симертелә торган терлек һ.б.) махсус К.а. чыгарыла. Бөртекле ашлык, бодай көрпәсе, түбе, терлек азыгы (балык яисә ит-сөяк оны) һәм тупас азык (үлән һәм ылыс оны), тозлар, витаминлы препаратлар, ш.у. техник производстволар, химия һәм микробиология сәнәгате продуктлары калдыклары төп чимал булып тора. Катнаш азык пр-тиеләрендә һәм цехларында хайваннарга кирәкле барлык туклыклы матдәләр булган тулы рационлы К.а. эшкәртәләр (башка азык өстәмичә ашатыла), бигрәк тә кошлар, дуңгызлар, куяннар, балыклар өчен, чикләнгән күләмдә — атлар өчен җитештерелә; рационда төп туклыклы матдәләр җитешмәгәндә кулланыла торган концентратлар; баланслаучы терлек азыгы өстәмәләре (аксымлы-витаминлы, аксымлы-витаминлы-минераллы премикслар) җитештерелә. Премикслар рационны биологик актив матдәләр б-н баету өчен К.а.ка кертелә. Аларга профилактика һәм дәвалау көченә ия булган витаминнар, микроэлементлар, ферментлар, кайбер аминокислоталар, антибиотиклар, антиоксидантлар һ.б. матдәләр керә. Татарстанда сибелүчән (вак, уртача һәм эре тартылган), ш.у. онлы катнашма, ярма, гранула, брикет (барлыгы 30 дан артык исемдә) рәвешендәге К.а. ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгы раслаган рецептлар буенча Казан, Чаллы, Бөгелмә икмәк продуктлары комб-тларында, Чистай һәм Нурлат элеваторларында җитештерелә. Гомуми җитештерү күләме 700–800 мең *т*.

ТРда 1986–2003 тә К.а. җитештерү (уртача елына мең *т*): 1986–90 да — 715; 1991–95 — 774; 1996–2000 — 383; 2001 — 212; 2005 — 286,4; 2008 — 518,8. Ш.у. к. *Ашлык хәзерләү һәм эшкәртү.*

*И.Н.Афанасьев, Н.Н.Мөхәммәтгалиев.*

**«КАТНА́Ш НАРАТЛЫ́К»**, ландшафтлы табигать истәлеге. Әгерҗе р-нының Балтач авылыннан төньяктарак Барҗы елгасының сулъяк сөзәклегендә урнашкан. 1987 дә билгеләнә. Мәйданы 49 *га*. Көньяк сөзәклектәге урман участогы (Әгерҗе урманчылыгының Шаршады участок урманчылыгының



«Катнаш наратлык» ландшафтлы табигать истәлеге.

108 нче кварталы). Көньяк тайга тибындагы, нарат, чыршы, ак чыршыдан торучы ылыслы урманнарның типик фрагменты; урта яшьтәгеләр, 2–3 ярuslы, куаклыклар куе булып яхшы үскән. Ареалның көньяк чигендә экосистемалар мониторингы объекты.

**КАТНА́Ш УРМАННА́Р**, ылыслы һәм яфраклы агачлардан торган урманнар. Агачларның катнаш составы б-н генә түгел, ә бәлки үсемлек һәм хайваннарның күптөрлелеге, мозаикалы төзелеше, әйләнә-тирәнең төрле тәэсирләренә чыдамлыгы б-н аерыла. Үсү шартлары бертөрле булганда, *ылыслы агачлар урманнарына* һәм *яфраклы урманнарга* караганда К.у.ның продуктлылыгы югары.



Катнаш урман. Яшел Үзән районы.

К.у.ны ылыслы-вак яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарга аерып йөртәләр. Татарстанда беренчеләренә чыршылы-каенлы, чыршылы-усаклы, наратлы-каенлы утыртмалар керә. Алар озак яшәмиләр, вак яфраклы урманнарның (каенлыклар, усаклыклар) төп ылыслы урманнарга (наратлык, чыршылык) яки киң яфраклыларга (имәнлекләр) алышынуында арадашчы буын булып торалар. Нарат һәм чыршы агачлары урманнары составында 20–30% ка кадәр каен, усак һәм ак зирекнең катнашуы агачларның гөмбә авыруларына һәм корткычларга каршы чыдамлыгын арттыра, туфрак шартларын яхшырта. Ылыслы-киң яфраклы урманнар К.у.ның көньяк асзонасында үсә һәм Кама алды урманнарының төп зональ тибын хасил итә. Европа һәм Себер чыршысыннан һәм аларның гибридларыннан, урыны б-н

Себер акчыршысыннан торалар. Яфраклы токымнардан юкә, имән, очлы яфраклы өрәңге, элмә агачлары үсә. Коңгырт-көрән һәм соры урман комсыл балчыклы туфракларда продуктлылыгы югары булган чыршылыклар очрый. Алар составында Себер ак чыршысы, имән һәм өрәңге, чикләвек куагы, үлән капламы яхшы үсә. Җиңелчә кәсле һәм дымлы участокларда, кагыйдә буларак, каен, ак зирек, сирәк кенә усак үсә. Татарстан терр-ясендә чыршы һәм ак чыршы югары продуктлылыгы б-н характерлана, күпчелек агачларның бонитет классы 1. Чыршылыклар һәм юкәле ак чыршылыклар, сирәгрәк кенә ак чыршылы-юкәле һәм яшел мүкле чыршылыклар өстенлек итә. К.у.ның көньяк чиге ТР чикләрендә Казан–Арча–Теләче линиясе буенча, аннары Мамадыш р-ны терр-ясе буенча Ишки–Тау иле–Көек-Ерыкса–Гурьевка линиясеннән үтә. Бу линиядән көньяктарак киң яфраклы урманнар үсә.

*Әд.:* Г о р д я г и н А.Я. Растительность Татарской Республики // Географическое описание Татарской Республики. К., 1921. Ч. 1; М а р к о в М.В. Растительность Татарии. К., 1948; К у р н а е в С.Ф. Лесорастительное районирование СССР. М., 1973. *А.Х.Газизуллин.*

**КАТОЛИЦИ́ЗМ** (грек. katholikós — дөньякүләм, гомум, бөтен), *христиан* динендә *православие* һәм протестантизм б-н беррәттән төп юнәлешләрнең берсе; Рим-католик чиркәвендәге догматлар, кануннар, йолалар, учреждениеләр системасы 4–5 йөзләрдә барлыкка килә, тулысынча 11 йөздә формалаша. Гомумхристиан тәгълиматы нигезләренә таяна, әмма шактый гына аермалыклары да бар, шул сәбәпле К. б-н православие бер-берсеннән аерыла. Аларга Изге Рухның Илаһ-Атадан гына түгел (башка чиркәүләрдәге кебек), Илаһ-Улдан (filique) да иңүе һәм 1870 елда инану һәм әхлак мәсьәләләрендә папаның гөнаһсызлыгы турында 1 нче Ватикан соборы тарафыннан кертелгән догматлар да кагыла. К., формаларын һәм асылларын беркадәр камилләштереп, 7 христиан йоласын (чукындыру, чукындырганда хуш исле май — миро сөртү, ак күмәч б-н шәраб йоту, тәүбәгә килү, никах, зәйтүн мае сөртеп изгеләндерү, руханилык дәрәҗәсе бирү) таный. Барлык католик руханилары целибат — буйдак (ялгыз) яшәү рәвеше алып бара. К.да йолалар башкаруда төрле аермалыклар бар: дин тотучылар латин (98,4% ка якын) һәм көнчыгыш йолаларын үтәүче католикларга бүленәләр. Оешу структурасы түбәндәгечә: югары чиркәү мәхкәмәсе исеменнән хакимлек итү хокукы бирелгән чиркәү башлыгы — Рим папасы (резиденциясе — Ватикан шәһәр-дәүләте); кардиналлар (курия оештыралар һәм папаны сайлау хокукына ия булалар); конгрегацияләр (чиркәү эшләре б-н идарә итәләр); архиепископлар һәм епископлар (епархияләр-диоцезалар б-н җитәкчелек итәләр); деканатларга берләштерелгән приход (парафия) ксёндзлары. Католикларның гомуми саны 1 млрд. кешегә якын, шуларның якынча 600 меңе Россиядә яши (РФ Юстиция министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2004 тә 248 католик дине оешмалары эшли). Казанда беренче католиклар, башлыча, Балтыйк буе дворяннарыннан һәм эшчеләреннән торган немецлар, 18 йөздә күренә башлыйлар. 1815 тә Польша корольлеген Россиягә кушканнан соң, Казанда Идел буе хәрби частьларында хезмәт итүче поляклар һәм латышлар, ш.у. 1830 да Польша баш күтәрүчеләрен бастырганнан соң, Казанга сөрелгәннәр хисабына католиклар саны арта башлый. 19 йөзнең 1 нче чирегендә Казан, Вятка, Түбән Новгород, Пермь һәм Себер губерналарында 4 меңгә якын католик яши: 2 шәр мең хәрби һәм граждан затлар (башлыча, сөргенгә җибәрелгәннәр). 1833 тә император Николай I Фәрманы буенча Рим-католик динендәге гаскәри руханилар (капелланнар) хезмәте булдырыла, 1835 тә Казанга католик солдатларның дини ихтыяҗларын үтәү өчен католик рухани В.Усаковский (Ушанский) җибәрелә (1855 тә «гражданнар» ксёндзлары хезмәте барлыкка килә). Баштарак католик гыйбадәтләр Казан шәһәр хакимияте биргән йортларда үткәрелә, 1858 дә «Воздвижение креста Господня» костёлы төзелә (арх. П.Т.*Жуковский*, А.И.*Песке* проекты, 1907–08 дә үзгәртеп корыла). Аннан башка Арча кыры зиратында кәшәнә эшли. 1897 елгы гомуми халык санын алу мәгълүматлары буенча, Казан губернасында католик динен тотучы (күпчелеге поляклар, латышлар, немецлар) 1591 ир-ат һәм 433 хатын-кыз (ш.и. Казанда 1760 кеше) яши. Католиклар җәмгате чиновниклар, мәдәният, фән, мәгариф эшлеклеләре (И.А.*Бодуэн де Куртенэ*, М.Ф.*Бартельс*, И.О.*Браун*, И.О.*Готвальд*, И.М.*Догель*, О.М.*Ковалевский*, М.А.*Ковальский*, И.И.*Литтров*, Д.И.*Нагуевский*, Л.К.*Хрщонович* һ.б.), һөнәрчеләрдән тора. Казандагы католиклар җәмгате шәһәр тормышында актив катнаша, хәйриячелек б-н шөгыльләнә (1897 дә «Ярлыларга ярдәм итүче Казан Рим-католик приходы җәмгыяте», соңрак балалар приюты оештырыла). Казан губернасындагы барлык гимназияләрдә һәм һөнәр уч-щеләрендә белем алучыларга католикларның Илаһи канун дәресләре бирелә. Беренче бөтендөнья сугышы башланганда Казан губернасында католиклар саны арта: 1914 нең октябрендә Казан хәрби гарнизонында католик динен тотучы 5–6 мең кеше була, губернага 1 меңгә якын католик немец һәм австрияле күчерелә; 1917 нең җәенә 20 меңгә якын хәрби әсир китерелә (аларның 2/3 се — католиклар). 1915 тә Казан губернасында 30 мең качкын-католик исәпләнә. Окт. рев-циясеннән соң костёлның бинасы һәм милке дәүләткә тапшырыла, 1918 дән аларда юлламалы ксёндзлар хезмәт итә. 1923 тә католик руханилар эшчәнлеге туктатыла, 1927 дә собор ябыла. 1938 дә католиклар җәмгате яшәүдән туктый, җитәкчеләре нахак гаепләүләр б-н хөкем ителә. Хәзерге вакытта ТРда Изге Климент епархиясенә керүче (үзәге — Саратовта) 2 католик дине оешмасы: Чаллыда (1994 тән) һәм Казанда (1996 дан, шул елда Арча кыры зиратындагы кәшәнә католикларга кайтарыла), ш.у. «Каритас» хәйрия оешмасы (барлыгы 250 гә якын кеше) эшли. 2008 елда Казанда католиклар өчен яңа чиркәү төзелә.

*Әд.:* Л и п а к о в Е.В., Н у г у м а н о в а Г.Г. История католического прихода в Казани. К., 1997; Народы и религии мира: Энцикл. М., 2000; Л о б ь е д е П. Три Града, Социальное учение христианства. М., 2001; История II Ватиканского Собора: Формирование соборного сознания: В 2 т. М., 2003–04; Религии и религиозные объединения в Республике Татарстан. К., 2004; Современная религиозная жизнь России. М., 2004. Т. 1. *Е.В.Липаков.*

**КАТРА́Н**, к р а м б е (Crambe), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләннәр, кайвакыт куаклар ыругы. 30 га якын төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре бар — татар К. (C. tataria) Идел аръягында очрый. Ташлы сөзәклекләрдә үсә. 30–50 *см* биеклектәге күпьеллык үләнчел үсемлек. Тамыры озын, орчыксыман. Сабагы туры, ботаклы, эре соры-яшькелт, итчел тамыр яны яфраклы. Чәчәкләре вак, күп санда, күбесенчә ак. Җимеше — ике буынлы ачылмаучан кузакчык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Яфракларында С витамины, каротин, тамырларында шикәр, крахмал, орлыкларында май бар. Тамырларыннан әзерләнгән төнәтмә балалар өчен гомуми ныгыту чарасы буларак кулланыла. Декоратив, терлек азыгы, баллы үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАТЫ́ КАБЫКЛЫ́ ТАЛПАННА́Р**, о р и б а т и д л а р (Oribatei), акариформалылар отрядыннан талпаннар семьялыгы (140 кадәр) төркеме. 6,5 меңгә якын төре билгеле, киң таралган; РФ — 1000гә якын төр, Татарстан терр-ясендә — 100 дән артык төр. Озынлыгы 0,1–0,5 *мм*. Туфракта, кайберләре үсемлекләрдә яши. Үзенчәлекле билгесе — олы бөҗәкләрнең каты кабыклы булуы (исеме шуннан) һәм трахеялы сулау. Башка талпаннардан аермалы буларак, К.к.т., туфрак кипкәннән соң да, шактый озак вакыт тере кала. Моның б-н аларның киң таралуы һәм күпсанлы булуы аңлатыла. Личинка һәм нимфаларында трахея һәм каты кабык юк, шунлыктан алар дымлы һавада һәм субстратның калын катламында яшәргә мәҗбүр. Мул микрофлоралы чери торган үсемлек калдыклары б-н туклана, шул сәбәпле туфрак барлыкка килү процессында, аларның әһәмияте зур. Күп кенә төрләре — йорт һәм кыргый хайваннары гельминтларының арадаш хуҗалары; кайберләре агачларны зарарлаучы фитопатоген микроорганизмнарны һәм гөмбәләрне (гөмбә авыруларын) таратучылар. *Н.В.Шулаев.*

**КАТЫ́ КАНАТЛЫЛА́Р**, к. *Коңгызлар*.

**КАТЫ́ КУРА́** (Lythrum), каты курачалар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләннәр, биек булмаган куаклар ыругы. 30 га якын төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар: тал яфраклы К.к. (L. salicaria) һәм чыбыксыман К.к. (L. virgatum); бөтен республикада очрый. Дымлы болыннарда, сулык яфраклары буенда, сазлыкларда үсә. 60–125 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тал яфраклы К.к. туры яки өске өлеше тармаклы булган йөнтәс сабаклы. Чыбыксыман К.к.ның сабагы чыбыксыман тармаклы. Яфраклары озынча яки озынча

ланцетсыман. Чәчәкләре алсу яки җете кызыл, башаксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — тартмачык. Июньнән сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Тамырларында һәм яшел өлешләрендә дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе кан китү вакытында кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**КАТЫ́К**, аертылмаган кайнаган сөтне яисә өсте алынган майсызландырылган сөтне оетып ясала торган ризык. Татарлар аны мөстәкыйль ашамлык рәвешендә дә, шулпаларга һәм икенче ашларга тәмләткеч буларак та кулланалар. К.ны ш.у. кызыл чөгендер яки җиләк-җимешләр белән дә әзерлиләр, аларны кайнар сөтне оетырга куйганчы салалар. Сөзелгән К.тан эремчекнең бер төре — сөзмә, К.ны су б-н кушып әйрән эчемлеге әзерләнә. К. элек-электән чәчләрне юу һәм ныгыту өчен гигиена чарасы да булып исәпләнә.

*Әд.:* Б у ш к о в Р.А., М а з и т о в а Ф.Г. Букет напитков Татарстана. К., 1993; Х а й р у т д и н о в а Т.Х. Названия пищи в татарском языке. К., 1993.

**КАТЫ́Р ТУФРАКЛА́Р**, тозлы туфрак типлары, юылмаучы су режимы шартларында башка төр туфраклар б-н бер комплекста хасил булалар. Катырлану (тозлану) процессы нәтиҗәсендә туфрак эремәсеннән яки грунт суларыннан керүче натрийның (йотылу күләменең 10–15 тән 70% ына кадәр) туфрак-йотылу комплексында туплануыннан барлыкка килә. К.т. профилендә кара көрән төстәге, кырлары ялтыравыклы чикләвексыман бүлемтекләргә җиңел таркалучы баганасыман төзелешле катыр горизонт $B_1$ билгеләнә; үзле,ябышучан һәм дымлы халәттә күперүчән, коры халәттә үтә тыгыз һәм каты булуы б-н аерыла. Татарстан терр-ясендә кара туфраклар б-н бер комплекста, башлыча, Кама аръягы р-ннарында, Көньяк-көнчыгыш Идел алдында очрый. Гомуми мәйданы 3,2 мең *га*. Калын булмаган гумуслы горизонт, гумус, азот, көлле элементларның аз булуы б-н характерлана, реакциясе селтеле. К.т.да соданың булуы үсемлекләргә зыян сала. Тулы мелиорация үткәргән очракта (гипслау, органик һәм минераль ашламалар кертү) а.х. культураларын үстерергә мөмкин.

*Ф.Г.Борһанов.*

**КАТЮ́ШИНО** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Үтәк елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 24 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөз башына кадәр нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 221 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 563, 1897 дә — 614, 1908 дә — 788, 1920 дә — 883, 1926 да — 654, 1938 дә — 416, 1949 да — 352, 1958 дә — 389, 1976 да — 301, 1979 да — 199, 1989 да — 104, 2002 дә — 56 кеше.

**КАУРЫ́Й ТАЛПАННАРЫ́** (Analgesoidea), акариформалылар отрядыннан паразит талпаннар ассемьялыгы. 2 меңгә якын төре билгеле, киң таралганнар; Россиядә 500 гә якын төре яши. Гәүдәсе 0,3–0,5 *мм* озынлыкта. Кошларның тышкы паразитлары; тәннәрендә һәм каурыйларында яшиләр, каурый капламы мае, каурый һәм эпидермис кисәкчекләре б-н туклана. Кошларның тән тукымасын бозып, личинкалар кайвакыт тире астына керәләр. К.т.ның кайбер төрләре тире авырулары һәм каурыйларның коелуын китереп чыгарырга мөмкин.

Илл. к. *Талпаннар* мәкаләсендә.

**КАУЧУ́К**, үсемлекләрдән алынган (табигый К., ТК) яки ясалма юл б-н табылган (ЯК) югары эластиклыкка ия материал; резина, шин, җилем алу өчен файдаланыла. «К.» термины «каучу» (кау — агач, чу — агу, елау, агач яше) сүзеннән алынган, Бразилиядә яшәүчеләр гевея агачыннан алынган продуктны шулай атыйлар. ТК каучуклы үсемлекләрнең сөтле үлән согында (латекста) була, аны Бразилия гевеясы агачы латексын коагулирлап табалар. ЯКны нефтьнең җиңел фракцияләрен эшкәртүдән калган продуктларыннан, ш.у. табигый газлардан аерып алынган яки синтезланган төп кушылмаларны (мономерларны) полимерлаштырып җитештерәләр. ЯКны шартлы рәвештә 2 төркемгә бүләләр: гомуми кулланылыштагы каучуклар (бутадиен — БЯК һәм ДЯК, изопрен — ИЯК, бутадиенстирол һәм бутадиенметилстирол — СЯК һәм МСЯК), аларны резинаның төп үзенчәлеге — гадәти темп-раларда югары эластиклык һәм механик ныклык таләп ителгән төрле әйберләр (шиннар, резинатехник әйберләр, конвейер тасмалары һ.б.) җитештерүдә кулланалар; махсус кулланылыштагы каучуклар (бутадиеннитрил — НЯК, этиленпропилен — ЭПЯК һәм ЭПТЯК, хлоропрен, бутилкаучук — БК, уретан — УЯК, полисульфид-тиокол, силикон — ТЯК) гомуми кулланылыштагы каучукларга хас күрсәткечләр комплексыннан тыш, озонга, атмосферага, майга, ягулыкка, җылылыкка, салкынлыкка һәм тузуга чыдамлык кебек махсус үзлекләргә ия. ЯКның аерым төркеме — синтетик латекслар, сыек каучуклар, термоэластопластлар. К. вулканлаштырып алынган продуктлар — резиналар — гадәти һәм түбән темп-раларда югары эластиклыкка ия булган механик нык материаллар. Резиналар (резиналы катнашмалар) алу өчен композицияләрдә, К.тан тыш, вулканлаштыру агентлары (күкерт, металл оксидлары, органик пероксидлар һ.б.), вулканлаштыруны тизләткечләр (дифенилгуанидин, каптакс, тиурам һ.б.), тутыргычлар, пластификаторлар, стабилизаторлар (антиоксидантлар, антиозонантлар, яктылык һәм төс стабилизаторлары, аруга каршы матдәләр, антирадлар) бар. Кайбер катнашмаларга буягычлар (охра, ультрамарин һ.б.), одорантлар, пластмассалар (термоэластопластлар), резина регенератын кертәләр. К.ның вулканлашу дәрәҗәсен вулканлаштыру агенты б-н сызыкча макромолекулалар тәэсир итешүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән аркылы бәйләнешләр саны билгели. Вулканлаштыручы матдә күләме арту б-н (К. массасының 5 тән алып 100% кадәр), резинаның эластиклыгы кими, аның өлеше артканда (К. массасының 25% тан артыгы), каты резина, яки эбонит хасил була. Вулканлашуны тизләткечләр процессның вакытын кыскарталар һәм температурасын түбәнәйтәләр. Тутыргычлар (актив, инерт) — югары дисперс нәорганик һәм органик кушылмалар, резина катнашмасында аларның өлеше К. составыннан да арта ала. Актив (көчәйткеч) тутыргычлар (техник углерод, кремнийның синтетик диоксиды, силикатлар, металлар) резиналарның механик күрсәткечләрен үзгәртәләр, инерт тутыргычлар (каолин, акбур) эшкәртүне җиңеләйтәләр, аларга специфик үзлекләр (җылытуга, майга һәм яктылыкка чыдамлык, янмаучанлык) өстиләр, үзкыйммәтне түбәнәйтәләр. Искерүгә каршы матдәләр, вакыт үтү б-н, резинаны физик-химик үзлекләре үзгәрешеннән саклый. Пластификаторлар һәм йомшарткычлар К. һәм резина катнашмаларының үзлелеген түбәнәйтәләр, ингредиентларны кушканда энергия тотылуны киметәләр, резиналарның эластиклыгын һәм салкынга чыдамлылыгын яхшырталар. Резина катнашмасына элек кулланылган резинаны махсус эшкәртүдән алынган пластик продукт — регенерат өстәү җитештерүне арзанайта һәм пластиклыкны бераз арттыра. ИЯК нигезендәге резиналар югары механик ныклыкка һәм эластиклыкка ия, ДЯК нигезендәге резиналар югары динамик үзлекләргә ия, НЯК нигезендәге резиналар югары җылылыкка, майда, ягулыкта, нефть продуктларында бүртүчәнлеккә чыдам. СЯК һәм МСЯК куллану механик нык, тузуга чыдам, җылылыктан һәм табигый искерүгә нык каршы торучы резина алу мөмкинлеге бирә. БК тан эшләнгән әйберләр агрессив тирәлеккә, җылылыкка, үтә озакка чыдам булуы һәм һава үткәрүчәнлеге б-н ТК эшләнмәләрдән 8–10 тапкыр өстен тора. Галобутилкаучуклар югарырак адгезиягә ия, алардан резинаны металлга беркетү өчен җилем алалар. ЭПЯК һәм ЭПТЯКлардан эшләнгән резиналарда исә югары атмосферага, озонга, җылылыкка, салкынга чыдам эреткечләр һәм агрессив тирәлек тәэсиренә чыдамлык кебек югары механик һәм эластик үзлекләр кушыла. Радиациягә чыдам (рентген саклагыч) резиналарны фторкаучук, кургаш һәм барий оксидлары б-н тутырылган НЯК, СЯК нигезендә алалар. А.М.Бутлеровның изобутиленның полимерлашу мөмкинлеге ачуын һәм өчизобутилен табуын синтезлау ачкычы һәм ЯКны хәзерге химик җитештерүгә фундамент итеп санарга була. Россиядә беренче тапкыр ЯК җитештереп чыгару 1932 елда, этил спирты нигезендә акад. С.В.Лебедев эшләгән алым б-н тормышка ашырыла. 1936 да Казанда *Ясалма каучук заводы* (ЯК җитештерү буенча СССРда 4 нче завод) төзелә. Татарстан галимнәре ЯК химиясен өйрәнүгә һәм аны җитештерүне камил-

ләштерүгә зур өлеш кертәләр. Бөек Ватан сугышы елларында ЯКның салкынга каршы торучанлыгын арттыру бурычы хәл ителә (Б.А.Арбузов), элементорганик кушылмалар нигезендә гетероатом тиоколлар, тиоколларга пластиклык өстәүче структуралаштыручы өстәмәләр синтезлана (В.С.Абрамов). 1950 елларда полимерларны модификацияләү, стабильләштерү буенча фәнни юнәлешләр формалаша (В.А.Воскресенский, П.А.Кирпичников, В.Г.Хозин, Н.А.Мукменёва), өстәмә реакцияләрне булдырмый калу, полимерлашуны, термополимерлашуны, үзлегеннән полимерлашуны ингибирлау ысуллары эшләнә (А.Г.Лиакумович, Д.Г.Победимский, Н.П.Борейко, Н.В.Лемаев, Я.А.Левин), ЯК өчен мономерлар җитештерүдә каталитик системалар (Б.Р.Серебряков, А.А.Петухов, В.А.Курбатов, А.Ш.Зыятдинов), полиуретаннар алуның изоцианатларсыз алымнары тәкъдим ителә (В.В.Михеев); радикаль полимерлаштыруның кинетикасы һәм механизмы (В.Ф.Куренков), изоцианатларның циклик полимерлаштыру закончалыклары (М.И.Бахитов), изоцианатларны гомополимерлаштыру (В.П.Архиреев), эмульсион полимерлашу, радикаль процессларны ингибирлау өйрәнелә (П.А.Кирпичников); янмый торган фосфорлы полимерлар (Б.Е.Иванов), функциональ төркемнәр б-н олигомерлар (В.В.Береснев), полимер композицион материаллар — динамик термоэластопластлар алына (С.И.Вольфсон). Этиленпропилен каучуклар (Р.Я.Дебердеев), челтәрсыман полиуретаннар (В.П.Дорожкин), эластик күбек уретаннар, уретан лаклар, җилемнәр, капламнар (Л.А.Зенитова), олигомер кушылмалар, нефтькә бәйләнешле сумалалар — лак-буяу материаллары өчен элпә хасил иткечләр, резина катнашмасы модификаторлары һ.б. композицияләр (Т.И.Лонщакова), махсус үзлекле силоксан каучуклар, резина катнашмалары, силикон герметиклар, компаундлар, силоксан каучук стабилизаторлары (Е.П.Лебедев), катыру композицияләрен һәм җилемнәрен герметиклаштыручы сополимер тиоколлар (Л.А.Аверко-Антонович), полиэфирлар технологиясен (Ю.О.Аверко-Антонович) эшләүгә шактый өлеш кертелә; изопрен (Р.А.Әхмәтҗанова), бутилкаучук (А.Ш.Зыятдинов) технологияләре камилләштерелә. ЯК һәм полимерлар буенча фәнни тикшеренүләр РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан технол. ун-тында (ш.и. Полимерлар һәм махсус каучуклар ин-тында), Казан ун-тында, «Түбәнкаманефтехим» АҖнең фәнни-технол. үзәгендә алып барыла. ТРда төп ЯК җитештерүчеләр (җитештерү берләшмәләрен шин, резина техник әйберләр һәм полимер композицион материаллар б-н тәэмин итәләр): «Түбәнкаманефтехим» АҖ (ИЯК, ДЯК, БК һәм галобутилкаучук, ЭПЯК, төп кулланучы — «Түбәнкамашина» АҖ), «Казан ясалма каучук заводы» АҖ (махсус КБ, уретан, силикон, полисульфид олигомерлар, бутадиенвинилиденхлорид латекс һ.б.), «Кварт» АҖ (термоэластопластлар).

*Әд.:* Кирпичников П.А., Аверко-Антонович Л.А., Аверко-Антонович Ю.О. Химия и технология синтетического каучука. Л., 1987; Агаянц И.М. Пять столетий каучука и резины. М., 2002.

*Л.А.Зенитова.*

**КАФ ТАВЫ́**, төрки халыклар мифологиясендә һәм фольклорында җир читендәге иң зур һәм иң биек тау. К.т. артында кешеләргә дошман иблис затлар — *аждаһа*, *дию*, *пәри* яши. Алар миф геройларын К.т. артына алып китәләр (иң борынгы версияләрдә). Мондый геройлар тере килеш әйләнеп кайтмыйлар («барса — кайтмас» мотивы). Соңгырак чордагы фольклор әсәрләрендә (халык әкиятләрендә) герой, гадәттә, дошман көчләрне җиңә һәм исән-имин әйләнеп кайта. Мифологик һәм фольклор әсәрләрдә К.т.ның урнашкан урыны күрсәтелми. Кайбер тикшеренүчеләр аны Кавказ тауларына, кайберәүләре Гыйрак терр-ясендә урнашкан Куфи-Каф тавына охшаталар. Казакъ Кәп Тавы, кыргыз Кәйкабы, Кәйкоф, Каф-Каплар татар К.т.ның аналоглары булып торалар. Мифология һәм фольклор әсәрләрендә К.т. урта гасырларның элгәреге чорларыннан алып безнең көннәргә кадәр очрый.

*Әд.:* Әмирханов Х. Тәварихы Болгария. К., 1883; Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. К., 1999; Казахский фольклор в собрании Г.Н.Потанина. А.-А., 1972; Башҡорт халыҡ ижады. Т. 3. Эпос. Өфө, 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАФА́РОВ** Виктор Вячеславович (5.6.1914, Шавли ш., Литва — 11.10.1995, Мәскәү), химик-технолог, техник фән. д-ры (1952), РФА академигы (1991; 1979 елдан СССР ФА академигы, 1966 дан мөхбир әгъза), СССРның мактаулы химигы (1976), СССРның мактаулы нефтехимигы (1980). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1938). 1929–38 елларда 40 нчы номерлы заводта (хәзер В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесе), Бөек Ватан сугышы елларында — СССР ФА ин-тларында (Мәскәү). 1944 тән Мәскәү химия-технол. ин-тында, проф. (1953), үзе тарафыннан СССРда беренче оештырылган химик-технол. процесслар кибернетикасы каф. мөдире (1960–91), бер үк вакытта СССР ФА Бөтенсоюз фән һәм техника информация ин-тының химик технологияләрнең төп процесслары секторы мөдире (1952–80). 1967–91 дә СССР Халык мәгарифе дәүләт ком-тының химик технологияләр аппаратлары һәм процесслары, химик кибернетика секциясе башлыгы, СССР ФА Химик технологияләрнең теоретик нигезләре буенча фәнни совет башлыгы урынбасары, 1990 нан Фәнни-нәшрият советының химик-технол. әдәбият секциясе башлыгы, РФА Нәорганик матдәләр физик химиясе һәм технологиясе бүлегенең академик-сәркәтип урынбасары. Хезмәтләре химия технологиясенең теоретик нигезләренә карый. К. — химик технол. процесслар кибернетикасына нигез салучы. Ул ин-тта укыган елларында А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар лаб-ясендә фәнни эш б-н шөгыльләнә башлый. Фундаменталь тикшеренүләре химик-технол. процессларны матем. модельләштерү, оптимальләштерү һәм проектлау мәсьәләләренә багышлана. Фазалар инверсиясе режимында газ һәм сыеклык фазалары арасындагы җылылык һәм масса алмашының сикерешле арту күренешен ача (бергәләп). Масса күчерү теориясен үстерә, күчерүнең турбулентлыгын һәм өслекнең динамик халәт факторын исәпкә алып, охшашлыкның яңа критерийларын кертә. Химик процессларны матем. модельләштерүнең системалы принципларын нигезли. Охшашлык теориясе нигезендә химик реакторларда гидродинамик, җылылык һәм диффузион процессларны модельләштерү мәсьәләләрен өйрәнә һәм химик процессларны модельләштерү өчен аларның җитәрлек булмавын күрсәтә. Химик-технол. процессларны системалы анализлау стратегиясе нигезләрен тәгъбир итә (бергәләп). Хезмәтләр сериясе һәм «Химик технология процессларын системалы анализлау» («Системный анализ процессов химической технологии», М., 1986) монографиясе өчен СССР ФАнең Д.И.Менделеев исем. бүләгенә лаек була (1978). Ресурс саклаучы экол. куркынычсыз химик-технол. системаларны синтезлау, аларның ышанычлылыгын тәэмин итү һәм оптимальләштерү, югары эффектлы химик-технол. процесслар б-н оптималь идарә итү, аларны камилләштерү өчен эксперт системалар булдыруны хәл итү ысулларын һәм принципларын эшли. К. җитәкчелегендә илдә беренче автоматлаштырылган проектлауның тармак системалары (САПР-ХИМ, САПР-НЕФТЕХИМ) эшләнә. «Биохимик җитештерүләрне модельләштерү һәм системалы анализлау» («Моделирование и системный анализ биохимических производств») монографияләре циклы өчен СССР Халык мәгарифе дәүләт ком-тының 2 нче дәрәҗә бүләге бирелә (1988); «Калдыксыз химик җитештерүләр булдыру принциплары» («Принципы создания безотходных химических производств», М., 1991) китабы өчен РФАнең Д.И.Менделеев исем. алтын медале б-н бүләкләнә (1991). Уйлап табуга 140 авторлык таныклыгы бар. Икътисади ярдәмләшү советының СССРдагы даими вәкиле (1960–90), Химик җитештерүләрне автоматлаштыру комиссиясе рәисе урынбасары (1973 елдан); Мәскәү химия-технол. ин-ты каршында химиядә һәм химик технологиядә кибернетика ысуллары буенча Бөтенроссия консультатив-методологик үзәк җитәкчесе 1965–95); «Фән һәм химия технологияләре нәтиҗәләре» («Итоги науки и химической технологии») җыентыгында «Химик технология процесслары һәм аппаратлары» («Процессы и аппараты химической технологии»; 1973 тән) сериясенең фәнни мөхәррире, Бөтенроссия фән һәм техник мәгълүматлар ин-тының «Химик җитештерүләр һәм химик кибернетика процесслары һәм аппаратлары» («Процессы и аппараты химических производств и химическая кибернетика»; 1973 тән) һәм «Ресурс саклаучы техно-



В.В. Кафаров.

логияләр» («Ресурсосберегающие технологии»; 1989 дан) экспресс-мәгълүмат сериясенең фәнни җитәкчесе; РФАнең «Теоретические основы химической технологии» ж-лының баш мөхәррире (1988–95). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1982). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, 1 нче дәрәҗә Кирилл һәм Мефодий ордены (Болгария); медальләр (ш.и. Чехословакия, Кытай Халык Респ-касы, Болгария) б-н бүләкләнә. Веспрем техн. ун-ты (Венгрия), К.Шорлеммер Югары техник мәктәбе (Германия), Генуя ун-ты (Италия), Казан технол. ун-тының шәрәфле докторы.

Х е з м.: Основы массопередачи. М., 1979; Методы кибернетики в химии и химической технологии. М., 1985; Анализ и синтез химико-технологических систем. М., 1991 (автордаш).

*Әд.:* Виктор Вячеславович Кафаров: Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1991. Вып. 90; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**КАФА́РОВ** Пётр Иванович (монахлыкта Палладий) (16.9.1817, Казан губ., Чистай өязе Иске Чишмә бистәсе — 6.12.1878, Марсель ш., Франция), шәркыятьче галим, филолог, географ, архимандрит (1848). Руханилар катлавыннан. 1827–32 елларда Чистай руханилар уч-щесе, 1832–37 дә Казан руханилар семинариясе студенты. Петербург руханилар академиясен тәмамлый (1838). 1840–47 дә Пекиндагы Россиянең рухани миссиясе башлыгы. 1860–64 тә Римда Россия илчелеге каршындагы чиркәү башлыгы. Кытай б-н Россия арасында Тяньцзинь килешүен әзерләүдә катнаша (1858). 1840 ның гыйнварында, 1847 нең августында, 1849 ның гыйнварында Казанда булып, В.П.Васильев б-н бергә ун-ттагы будда дине китапларын тәрҗемә итә; Казан руханилар академиясенә Н.Я.Бичуринның кулъязмалар һәм карталар коллекциясен, ш.у. үзендәге материалларны тапшыра. Тикшеренүләре Кытай, Үзәк Азия һәм Ерак Көнчыгыш халыклары, ш.и. маньчжурлар, киданнар һ.б. күчмә кабиләләр тарихын, географиясен һәм мәдәниятен өйрәнүгә карый. Монголлар тарихы буенча кытай ядкәрләре тәрҗемәләре: «Даос монахы Чан Чуньның көнбатышка сәяхәте» («Путешествие даосского монаха Чан Чуня на запад», СПб., 1866), «Чыңгыз хан турында борынгы монгол хикәяте» («Старинное монгольское сказание о Чингисхане», СПб., 1866), «Чыңгыз хан турында борынгы кытай хикәяте» («Старинное китайское сказание о Чингисхане», СПб., 1872) К.ка зур танылу китерә. Кытайдагы диннәр тарихына (будда, христиан, ислам диннәре), Кытайның башка илләр б-н сәүдә һәм мәдәни багланышларына, аеруча рус-кытай мөнәсәбәтләре тарихына (14 һәм 17 йөзләрдә Пекинда рус колонияләре турында язмалар, Марко Поло язмаларына аңлатмалар һ.б.) багышланган хезмәтләре билгеле. 1870–71 дә Уссурийск төбәгенә җибәрелгән археол.-этнографик экспедицияне җитәкли; бу хакта очерк яза (1879 да басыла). К.ның фундаменталь хезмәте — П.С.Попов б-н берлектә төзегән «Кытайча-русча сүзлек» (1–2 кис., Пекин, 1888). Монголиягә һәм Кытайга сәяхәтләре вакытында К. көндәлекләр алып бара, аларның бер өлеше басылып чыга һәм әлеге илләрнең тарихы һәм географиясе буенча кыйммәтле чыганак булып тора.

Х е з м.: Исторический очерк древнего буддизма // Тр.членов Российской духовной миссии в Пекине. СПб., 1853. Т. 2; Исторический очерк Уссурийского края // Зап. Имп. Рус. геогр. об-ва. 1879. Т. 8, вып. 2; Китайская литература магометан. СПб., 1887; Дорожные заметки на пути по Монголии в 1847 и 1859 гг. СПб., 1892.

*Әд.:* П.И.Кафаров и его вклад в отечественное востоковедение (к 100-летию со дня смерти): Материалы конф.: В 3 ч. М., 1979; Д о л г о в Е.Б. «Нет другого человека, лучше и точнее знающего Китай и китайские дела» // Из истории Татарстана и татарского народа. К., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**КАФИАТУ́ЛЛИН** Марат Абдулла улы (25.7.1934, Горький өлкәсе Уразовка ш.), төзүче инженер, ТАССР, РСФСРның атказ. төзүчесе (1977, 1986). 1958 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый. 1958–71 дә «ГипроНИИавиапром»ның Казан ф-лында инженер, өлкән инженер, төркем җитәкчесе, төзелеш бүлеге башлыгы булып эшли. 1971 дән «Татгражданпроект» ин-тында баш инженер. 1977 — 2009 да — «Казгражданпроект» ин-ты директоры. 2009 дан шунда ук директорлар советы рәисе. Казандагы күп кенә сәнәгать, торак һәм җәмәгать биналары проектларының авторы һәм җитәкчесе. К. җитәкчелегендә шәһәрнең тарихи өлешендә эре Сәүдә үзәге (1968–73), Яшьләр үзәге (1970–73) проектлаштырыла. Ул КПССның Вахитов райкомы бинасын проектлауда (1974–75), Ибраһимов проспектындагы, Татарстан урамындагы 14 катлы кирпеч йортлар сериясен, 38 нче микрорайондагы 111–90 (1977–79), 53 нче микрорайондагы 111–121 серияләрендәге (1977–78) торак йортларның проектларын әзерләүдә һәм төзүдә катнаша. К. эре панельле прокат ысулы б-н ясалган стеналар эшләү з-ды бинасының (1958), металл конструкцияләрдән әзерләнгән 300 $м^2$ мәйданлы җитештерү корпусының (1959–60), «Казгражданпроект» ин-ты җитештерү бинасының (1975–76), компрессорлар з-ды мәдәният йортының (1977), В.И.Ленин исем. Республика китапханәсе бинасының (1978–80), Тамбов шәһәрендәге 14 катлы торак йортлар төркеменең (1978–80) һ.б. биналарның конструктив нигезләрен эшли. Бер үк вакытта 1973–77 дә Казан төзүче инженерлар ин-тында укыта. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Л.М.Мортазина.*

**КАФТА́ННИКОВ** Николай Николаевич (1790–1841), беллетрист, рәсем ясаучы, гравёр, һәвәскәр археолог. Казан ун-тында укый (1811–14), Казан студентлары арасында беренчеләрдән булып магистрлык диссертациясе яклый. Университетны тәмамлаганнан соң Оренбург халык уч-щесендә табигыять тарихын укыта. 1830 дан яңадан Казанда. Татар һәм башкорт телләрен белә, татар телендә борынгы кулъязмалар туплый, аларны тәрҗемә итә, соңрак аларның өзекләрен А.Кавелин үзенең Идел буе болгарлары турындагы «Борынгы болгарлар (Кафтанников язмаларыннан)» — «Древние болгаре (из бумаг Кафтанникова)» («Библиотека для чтения», СПб., 1847, Т. 82) исемле хезмәтендә файдалана. К. «Заволжский муравей» ж-лы нашире М.С.Рыбушкин б-н хезмәттәшлек итә, анда үзенең «Арыслан Бабр» повестен һәм заманына күрә шактый җитди «Болгарлар, яки шул халыкның хәрабәләре» тикшеренүләрен һәм шул әсәрләре буенча офорт ысулы б-н төшерелгән гравюраларының иллюстрацияләрен — «Успенский авылы һәм Бөек Болгар хәрабәләре күренеше», «Беренче манара», «Кара пулат, яки Хөкем сарае» (1832, № 11, 16, 19); «Башкортлар көрәше», «Башкортлар»ны (1833, № 5; 1834, № 14) бастыра. Ф.И.Эрдманның «Оренбург губернасына бару» («Поездка в Оренбургскую губернию») мәкаләсенә «Алабуга шәһәре янындагы Шайтан каласы манарасы күренеше» гравюрасын ясый («Заволжский муравей», 1834, № 6). К.ның «Елантау монастыре күренеше» гравюрасы архимандрит Гавриилның «Елантауда Казанны алу вакытында үтерелгән сугышчылар истәлегенә салынган һәйкәлне тарихи тасвирлау» («Историческое описание памятника, сооружённого в воспоминание убиенных при взятии Казани воинов на Зилантовой горе») очеркында урнаштырыла (1833). К.ның гравюралары Казан вакытлы матбугатында беренче китап һәм журнал иллюстрацияләре булып санала; алар табигый хисләрнең җанлылыгы, авторның альбом графикасына якын торган ышандыручан интонациясе б-н аерылып торалар.



Н.Н.К а ф т а н н и к о в. «Шайтан каласы манарасы күренеше... Шайтан каласы манарасы урыны планы». Офорт. «Заволжский муравей» журналындагы иллюстрация. 1834. №6.

*Әд.:* П о н о м а р ё в П.А. Казанская периодическая пресса: «Заволжский муравей» // Казанский литературный сборник. К., 1878; А г а ф о -

н о в Н.Я. Женитьба Кафтанникова // Из казанской истории. К., 1906; Д у л ь с к и й П.М. Книга и её художественная внешность. К., 1921; Ф а х р у т д и н о в Р. Мелодия камней. К., 1986; К л ю ч е в с к а я Е.П. У истоков казанской графики // Художник. 1990. № 6.

*Е.П.Ключевская.*

**КА́ФТЫРЕВ** Василий Ильич (1731/1733, Мәскәү — 1807, Казан), Казанның беренче проф. архитекторы. 1748–53 елларда Д.В.Ухтомский мәктәбендә (Мәскәү) укый. 1753–67 дә — Мәскәү Сарай канцеляриясендә. 1767 дән — Казан архитекторы, 1783–91 дә — Казан губернасы архитекторы. К. — Казанның беренче регуляр планын төзүче. Ул Кремльдән сузылган төп юлларның әүвәлге юнәлешләрен шул килеш калдырып һәм аларны тоташтыручы зур тыкрыкларны өлешчә кулланып, шәһәрнең яңа, төгәлрәк функциональ структурасын формалаштыра. Үзендә шәһәр төзүче таланты ачылганнан соң, ул алга таба үзен тәҗрибәле проектлаштыручы итеп тә таныта (Казанда берничә дистә административ, дини һәм торак корылма проектларын эшли). Автор биналарның сәнгатьчә эшләнүенә барокко стиленә хас пластик чаралар куллану нәтиҗәсендә ирешә. Аеруча билгеле җәмәгать корылмалары — Казан руханилар уч-щесе бинасы (1770), *Адмиралтейство конторасы комплексы,* Кремльдәге урам буенча сузылган ике катлы *Кабулханәләр* бинасы (1783), шәһәр магистраты идарәсе (1788). Аның проектлары буенча таштан Дүрт Евангелист чиркәве төзелә (1769, сов. чорында юкка чыга). Фаразлаулар буенча, К. — *Мәрҗани мәчете* һәм *Апанай мәчетенең* авторы да (1770). Шәһәр проектын тормышка ашыра барып, архитектор аны 18 йөз ахырына хас таш торак утарлар төзеп тулыландыра. Шул исәптән, 1767 елда ул Постаучылар бистәсендәге ике катлы йорттан, төп йортның ике ягына кушып салынган ике флигельдән һәм хезмәт урынналары корпусыннан торган торак утарны проектлый, аларны элегрәк салынган корылмаларга камил рәвештә яраштырып тоташтыра. К. ш.у. Кремль урамы чатындагы ике катлы, түгәрәк почмаклы Л.Н.Урванцев йорты (1770); ике катлы, турыпочмаклы, таш эргә биеклегендәге каты, ишегалды ягыннан ризалиты булган Г.П.Каменев йорты (1774); Иноземцевның квадрат рәвешендәге ике катлы, аркалы тәрәзәләре классик рустлы стильдә бизәлгән аерым таш йорты (1774) проектларының авторы. 1775 тә К. проекты буенча Г-рәвешле ике катлы, фасадлары профильле кәрниз б-н бизәлгән (бинаны бизәгәндә бароккодан классицизм стиленә күчү сизелә) Чекмарёв йорты төзелә. 1786 да кенәз Тенишевның зур булмаган ике катлы таш йорты һәм утары төзелә, соңрак ул Казан ун-тының төп бинасы составына керә. К.ның Казандагы соңгы төзелешләренең берсе Петропавел соборы тирәсендәге тыкрыкта салынган Дворяннар җыены кунакханәсе була.

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань. К., 1978; К у з н е ц о в С.В. Классицизм в казанском зодчестве: Дис. ... М., 1989; Республика Татарстан: памятники истории и культуры: Каталог-справ. К., 1993; М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Х.Г.Надыйрова, Л.М.Мортазина.*

**«КАҺАРМА́Н КИТАБЫ́»**, төрки-татар әдәби ядкәре, дастан. Кайбер мәгълүматларга караганда, «Каһарманнамә» (11–12 йөзләр) фарсы героик эпосына барып тоташа. Төп герой — кыю һәм кодрәтле Каһарман баһадир. Аның тууына кадәр 70 ел алдан *диюләр* Каһарманның аларны юк итәсен белеп алалар. Бу хәлне булдырмас өчен, алар яңа туган баланы урлап, үз илләренә алып китәләр. 7 елдан соң Каһарман, көтмәгәндә туганнарын очратып, үзенең урланганын белә һәм үч алырга була. Күп төрле сынаулар үтеп, Каһарман үзен урлаучыларны җиңә, диюләрне исламга тарта, алар илендә мәчет-мәдрәсәләр төзетә; аннан соң туган иленә әйләнеп кайта. Татарлар арасында ядкәрнең сөйләм һәм язма версияләре 14 йөздән тарала башлый. Беренче тапкыр 1879 елда Казанда басылып чыга, соңыннан кабат басыла. 1900 дә И.Лаптев әсәрнең казакъ версиясен русчага тәрҗемә итә. Дастанның тулы тексты хәзерге татар графикасында М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан бастырыла. Дастан кучермәләре Казанда һәм Ереванда саклана; иң элгәрегесе 18 йөзгә карый (ТРның Милли музее фондында саклана).

Чыг.: Кыйссаи Каһарман. К., 1879; Каһарман Катил дастаны. К., 1998; Лаптев И. Материалы по казак-киргизскому языку // Тр. по востоковедению, издаваемые Лазаревским институтом восточных языков. М., 1900. Вып. 2.

*Әд.:* К а т а н о в Н. Кыссэ-и Кагырман (повествование о Кагырмане) // Деятель. 1901. № 1.

*М.И.Әхмәтҗанов.*









В.И.К а ф т ы р е в. 1. Дүрт Евангелист чиркәве. 1769. 20 йөз башы фоторәсеме; 2. Казан магистраты. Рәсем. 18 йөз ахыры; 3. Казан архиереенең җәйге резиденциясе. 1781. Хәзерге күренеше; 4. Шәһәр магистраты. Казан. 1788. 20 йөз башы фоторәсеме.

**КАҺАРМА́НОВ** Нурулла Фәрит улы (10.2.1928, БАССРның Әлшәй р-ны Әсләк а. — 1998, Уфа ш.), нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның атказ. нефтьчесе (1967), БАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978). 1952 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң Башкорт нефть сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында эшли, директор урынбасары (1970–80, 1985–88), директор (1980–84), проф. (1986), алмаз б-н һәм колонкалы бораулау лаб-ясе мөдире (1988 дән). Хезмәтләре нефть һәм газ скважиналарын бораулау һәм эксплуатацияләү техникасына һәм технологиясенә карый. Уйлап табуга 100 дән артык авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бурение скважин малого диаметра. Уфа, 1959; Алмазное бурение. Уфа, 1962; Новые методы бурения скважин. Уфа, 1973; Справочник инженера по бурению. М., 1973; Индустриально-комплексный метод разработки нефтяных месторождений. Уфа, 1980 (автордаш); Новые методы бурения скважин в Башкирии. Уфа, 1982.

**КАЦ** Борис Александрович (3.1.1952, Мәскәү), математик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1995). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1976 дан Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, бер үк вакытта (2000 нән) Казан ун-тының матем. анализ кафедрасында эшли. Хезмәтләре фракталь чикле өлкәләрдәге кырый мәсьәләләргә һәм комплекслы анализга карый. К. төзәймәс кәкреләр буенча интеграллау теориясен төзи, комплекслы анализдагы кырый мәсьәләләрнең чишелүчәнлеге б-н өлкә чикләренең фракталь үлчәнешләре арасындагы бәйләнешне билгели.

Х е з м.: The Riemann Boundary Value Problem on Nonsmooth Arcs and Fractal Dimensions // St. Peterburg Math. J. 1995. V. 6, № 1; The Stieltjes Integral along Fractal Curve // Le Matematiche. Fascicle 1. 1999. V. 54; The Inegualities for Polynomials and Integration Fractal Arcs // Canadian Math. Bull. 2001. V. 44 (1).

**КА́ЦАРЕВ** Николай Иванович (6.12.1747, С.-Петербург — 9.5.1815, шунда ук), дәүләт эшлеклесе, яшерен советник (1800). Дворяннар нәселеннән. 1756 елдан хәрби хезмәттә. 1768–74 тә рус-төрек сугышында катнаша. 1779 дан прокурор, 1796–1802 дә Коммерц-коллегия әгъзасы (С.-Петербург). 1802–03 тә Казан гражданнар губернаторы. С.-Петербургны азык-төлек б-н тәэмин итүне оештыру б-н шөгыльләнә. Аның заманында Казанда *Есипов П.П. театры* (1802) һәм тәрбия йорты (1803) ачыла. Адм. тәртип бозулар һәм хакимияттән үз максатларында файдаланганы өчен вазифасыннан читләштерелә.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы-главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б. Долгов.*

**КАЧА́ЛОВ** (чын фамилиясе Шверубович) Василий Иванович (30.1.1875, Вильно ш. — 30.9.1948, Мәскәү), драма актёры, СССРның халык артисты (1936). Санкт-Петербург ун-тының юридик ф-тында укый, В.Н.Давыдов җитәкчелегендәге студентлар драма түгәрәге спектакльләрендә катнаша, бер үк вакытта, 1896–97 елларда Суворин театрында штаттан тыш актёр булып эшли. 1897 дә М.М.Бородайның Казан–Саратов ширкәтенә



В.И. Качалов. Казан. 1897.

кабул ителә һәм шул ук елның 9 сентябрендә К.А.Тарновскийның «Ул белгән булса» комедиясендәге зур булмаган барон Раццель роле б-н беренче тапкыр Казан сәхнәсенә чыга. А.И.Каширин, А.А.Агарёв, Е.П.Шебуева, Е.Я.Неделин һ.б. осталар б-н берлектә эшләү аның иҗат биографиясендә мөһим этап булып тора. К. сәләтенең әһәмиятле яклары: рольнең зәвыклы (филигрань) тәмамланыш алуына омтылу, образның сөйләм нигезенә үтеп керү, сүз б-н тәэсир итә белү, персонажны романтик рухта гәүдәләндерү, үз героен тормыш-көнкүреш ваклыкларыннан өстен куярга тырышу, аның рухи асылын ачу нәкъ менә Казан сәхнәсендә формалаша һәм алга таба Мәскәү Художество театры сәхнәсендә үстерелә. Өч сезон дәвамында К. Казанда 150 дән артык төрле рольләр башкара. Алар арасында Муров, Дудукин, Досужев, Кнуров, Прибытков, Митя, Борис, Несчастливцев («Гаепсездән гаеплеләр», «Төшемле урын», «Бирнәсез кыз», «Соңгы корбан», «Ярлылык — гаеп түгел», «Яшенле яңгыр», «Урман», А.Н.Островский), Нелькин («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Неизвестный («Маскарад», М.Ю.Лермонтов), Ракитин («Авылда бер ай», И.С.Тургенев), кенәз Шаховской («Фёдор патша», А.К.Толстой), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Эдгар, Кассио, Горацио («Король Лир», «Отелло», «Гамлет», У.Шекспир) рольләре дә бар. Кассий («Юлий Цезарь», У.Шекспир) һәм булачак патшаның исәп-хисап б-н эш йөртүен, аек акыллы һәм тәхет яратучан булуын гәүдәләндерә алган Борис Годунов («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой) рольләре өчен Казан вакытлы матбугатының иң югары бәясенә лаек була. Һәр күренеше тиешле дәрәҗәдә эшләнгән кимчелекләрсез форма — грим, костюм, үз-үзеңне тоту рәвеше, һәрбер әйткән сүзнең, һәр кыланыш, ишарәнең тирән уйланылган, мәгънәле булуы — туып килүче талантның башкаларга охшамаганлыгын, үзгәлеген раслый. Казанда яшәгән елларында К. җәмәгать чараларында — хәйрия концертларында, студентлар кичәләрендә актив катнаша; А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов шигырьләрен сәнгатьле укуы, А.С.Грибоедов, У.Шекспир пьесаларыннан монологларны оста башкаруы б-н дан казана. 1900 елның гыйнварында ул К.С.Станиславский һәм В.И.Немирович-Данченко тарафыннан Мәскәү Художество театрына чакырып алына, монда эшләгән елларында аның иҗаты бөтен дөньяга танылa. 1948 дә Казан Зур драма театрына К. исеме бирелә. 1973–93 тә театрда «Качалов бүлмәсе» экспозициясе ачыла (К.ның Казанда яшәве б-н бәйле документлар һәм материаллар тупланган), иң яхшы актёрлык һәм режиссёрлык эше өчен В.И.Качалов исем. бүләк булдырыла, «Качалов көннәре» уздырыла. Казан урамнарының берсе К. исемен йөртә. 1897–99 елларда Лобачевский урамындагы К. яшәгән 3 нче номерлы йортка (элекке «Михайлов номерлары») мемориал такта куела. 2005 елда К.ның тууына 130 ел тулу уңаеннан Казан Зур драма театрының ишегалдында (атриумда) аңа һәйкәл ачыла (скульп. А.М.Миңнуллина, арх. Г.А.Бакулин).



В.И. Качалов кенәз Шаховской («Фёдор патша», А.К.Толстой) ролендә. Казан. 1898.



Казан Зур драма театры ишегалдында В.И. Качалов һәйкәле (скульп. А.М. Миңнуллина, арх. Г.А. Бакулин).

*Әд.:* В.И.Качалов: Сб. статей, воспоминаний, писем. М., 1954; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Т а л а н о в А. Качалов. М., 1962; В и л е н к и н В. Качалов. М., 1976.

*Ю.А.Благов.*

**КАЧА́ЛОВ** Николай Николаевич (7.6.1883, Германиянең Дрезден ш. — 19.6.1961, Ленинград), химик-технолог, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1933), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1935). 1911 елда Петербург тау ин-тын тәмамлаганнан соң Петроград фарфор з-дында (хәзер М.В.Ломоносов исем. з-д) эшли. 1923 — 30 елларда Ленинград оптик пыяла з-дының техник җитәкчесе, бер үк вакытта директор урынбасары (1920–30), Ленинград керамика тикшеренү ин-тының гыйльми коллегиясе рәисе (1929 дан), Бөтенсоюз оптика-механика сәнәгате берләшмәсенең фәнни секторы башлыгы (1930–32). 1930 дан Ленинград технол. ин-тында: проф., пыяла каф. мөдире, директор урынбасары (1937 — 39); бер үк вакытта Ленинград оптик пыяла ин-тында директор урынбасары (1932–46), лаб. башлыгы (1932–37); 1948 дән СССР ФАнең Силикатлар химиясе ин-тында. 1941–44 тә Казан химия-технол. ин-тында пыяла технологиясе каф. мөдире. К. — Россиядә оптик пыяла җитештерүгә нигез салучыларның берсе. Пыяла җитештерүдәге мөһим технол. процессларның физик-химик нигезләрен беренче булып тулысынча сурәтли. Аның тарафыннан пыяланың өске катлавының механик үзлекләренә фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә. К. оптика-механика сәнәгате үсешенә, рус сәнгате нәфис фарфорын җитештерүгә, кызыл балчыктан йомшак һәм техник фарфор, җирле материалдан пыяла алу технологияләрен эшләүгә өлеш кертә. Пыяланы шомарту һәм ялтырату процессларын теоретик һәм эксперименталь тикшеренүләре 2 нче дәрәҗә Сталин бүләгенә лаек булган (1947) «Пыяланы шомарту һәм ялтырату процесслары ни-

гезләре» («Основы процессов шлифовки и полировки стекла», М., 1946) монографиясендә гомумиләштерелә. К. җитәкчелегендә төсле пыяланы кыздырып беркеттерү методикасы, элегрәк кулланылмаган буягычлар, яңа төсле гаммалар б-н баетылган мозаика смальталарын ясау технологиясе, азык-төлек сәнәгате өчен химик яктан чыдам эмальләр, төсле металлар өчен ювелир эмальләр, газ аппаратурасы өчен эмальләр, нечкә катламлы һәм нык титанлы эмальләр алына. Барлык төр силикат материаллар җитештерү өчен чимал базасын булдыруда катнаша. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.Н. Качалов.

Х е з м.: Фарфор и его изготовление. М.–Л., 1927; Основы производства оптического стекла. Л., 1936 (автордаш); Основы технологии стеклоизделий (формирование стекла) // Технология стекла. Т. 2. Технология стеклоизделий. М.–Л., 1939 (автордаш).

*Әд.:* Николай Николаевич Качалов: Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1953. Вып. 18; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**КАЧКЫ́Н** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 53 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 258 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, клуб. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1728 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, төрле кәсеп б-н шөгыльләнә, Себер, Пермь губерналарына эшкә йөри. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.да этап йорты урнаша, мәчет (1831 дә беренче тапкыр телгә алына), ир һәм кыз балалар өчен мәктәпләр, 2 җил тегермәне була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1516 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 50, 1816 да — 73, 1834 тә — 134 ир-ат; 1870 тә — 471, 1897 дә — 755, 1913 тә — 892, 1920 дә — 880, 1926 да — 649, 1938 дә — 477, 1949 да — 253, 1958 дә — 282, 1970 тә — 326, 1979 да — 298, 1989 да — 237, 2002 дә — 265 кеше.

**«КАЧКЫ́Н ХӘМИДУЛЛА́»**, татар халкының качкыннар турындагы җырлары циклыннан *тарихи җыр*. Татар-мишәрләр арасында киң таралган. Җырның нигезенә 19 йөз уртасында хәзерге Мордва Респ-касының Ләмбрә р-ны терр-ясендә яшәгән Хәмидулла Вескин биографиясендәге хакыйкатькә туры килә торган фактлар салынган. Җирле байларның берсендә хезмәт итүче Вескин бервакыт утар управляющиен шәһәргә алып бара. Юлда барганда чана әйләнеп каплана, һәм управляющий кулын авырттыра. Байның рәхимсез җәзасыннан соң Вескин аны үтерә һәм авылдан кача. Башка качкыннар б-н бергә землянкаларда яши. Шул вакыттан алып реаль кеше җыр героена әверелә. Җырда аның «намуслы юлбасар» тормышын чагылдыручы куркыныч маҗаралар б-н тулы язмышы бәян ителә. Хәмидулла байларны талый, ярлыларга булыша, урманнардан-урманнарга йөри, Дон, Харьков һәм Орёл төбәкләрендә яшеренә. Аны тотып алып килгән кешегә зур бүләк билгеләнә. Качкынны тоталар, әмма ул кача, кабат тотыла. Хәмидулланы хөкем итәләр һәм Себергә сөрәләр. Мордвалар җирендәге кара урманнар, киң Дон далалары, Агыйдел елгасының гүзәл ярлары, чиксез Себер киңлекләре «К.Х.»да драматик күренешләрнең сәнгатьчә фоны булып хезмәт итә.

Җыр 1957 елда Мордва АССРның Ләмбрә р-ны Ләмбрә авылында Х.Х.Гатина тарафыннан язып алына; беренче тапкыр «Татар халык җырлары» (1965) җыентыгында басылып чыга. Җырны башкаручыларның сүзләреннән чыгып төзелгән искәрмәләрдә Себергә сөрелгән Х.Вескинның 90 яшенә кадәр яшәгәнлеге әйтелә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988; У р м а н ч е е в Ф. Исторические песни // Героический эпос татарского народа. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КАЧУРЕ́Ц** Вера Ивановна (23.8.1921, Украина ССР, Проскуров ш. — 19.9.1983, Казан), эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТАССРның атказ. табибе (1972). 1942 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1968 дән эпидемиология каф. мөдире. Хезмәтләре эпидемиологиягә, йогышлы авырулар (ш.и. балаларда дифтерия) клиникасы һәм авыруларны булдырмау мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Длительность и напряжённость противодифтерийного иммунитета привитых различными видами вакцин. К., 1954; Заболеваемость дифтерией в Казани и основные этапы её ликвидации. К., 1967; Профилактика особо опасных инфекций в мирное время. К., 1976.

*Әд.:* Профессор Вера Ивановна Качурец: Некролог // Казан. мед. журн. 1984. № 4.

**КАЧЫ́Р ҮЛӘНЕ́** (Oenothera), кырлыганчалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразиядә, Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Икеellык К.ү. (O. biennis) сирәк кенә барлык районнарда очрый, кисек яфраклы К.ү. (O. laciniata) һәм кызыл сабаклы К.ү. (O. rubricaulis) — сирәк төрләр. Чүпле урыннарда, тимер юллар һәм гадәти юл буйларында үсә. 30–100 *см* биеклектәге икеellык үсемлек. Сабагы туры, өске өлешендә азрак кырлы. Кызыл сабаклы К.ү. сабагының кызыл төстә булуы б-н аерыла. Яфраклары чиратлашкан, уемтылы-тешле яки каурыйсыман-теленмә. Чәчәкләре эре, аксыл сары, хуш исле, озын чәчәк сапларында, чуксыман чәчәк төркеменә җыелган, ешрак кич б-н ачыла; төнге күбәләкләр б-н серкәләнә. Җимеше — цилиндрик формадагы дүрт оялы тартмачык. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре сентябрь–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Икеellык К.ү.ндә дуплау һәм минераль матдәләр, органик к-талар, крахмал бар; халык медицинасында тамыр төнәтмәсе туберкулёзны дәвалаганда, ш.у. яраларны юдыру өчен кулланыла; яфракларыннан ясалган төнәтмә күзән җыеру вакытында ярдәм итә. Барлык төрләре дә декоратив, баллы үсемлек.

**КАШ УТЫ́** (Herminium), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — бер бүлбеле К.у. (H. monorchis) үсә. Биектау, Яшел Үзән, Мөслим һәм Тукай р-ннарында очрый. 8–30 *см* биеклектәге урман-болын үсемлеге, сирәкләнгән якты урманнарда, урман аланнарында, болыннарда таралган. Күбесенчә известьле туфракларда үсә. Эре бүлбеле, сабакның түбәнге өлешендә 2 озынча эллипссыман яфрак, урта өлешендә вак тар яфракчыклар бар. Чәчәк төркеме — чук; чәчәкләре вак, саргылт яшел, көчле бал исле. Июнь–июльдә чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Дару үсемлеге. К. у. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАШАГА́**, традицион татар авыл йортының эчендә хәзер дә файдаланыла торган зиннәтләү әйбере. Гадәттә, фабрикада җитештерелгән киҗе-мамык тукымадан, озын буй итеп алып тегелә; элек өйдә тукылган материал киң кулланылган. К. чигү, чук (чуклы К.), бөрмә (бала итәкле К.) б-н бизәлә; өйнең төрле урыннарында түшәмгә — дивар буйлап (озын К., түр буе), матча (матча итәге), мич (мич корма) буена, ишек (ишек К.сы), чаршау (чаршау кашы) өстенә һ.б. җирләргә бүленә.



Кашага. Авыл йорты интерьеры. 19 йөз ахыры. Яшел Үзән Олы Ачасыр авылындагы К.Насыйри музее. Реконструкция.

*Әд.:* В о р о б ь ё в Н.И. Казанские татары. К., 1953; Х а л и к о в Н.А. Сельские поселения и жилища // Татары. М., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАША́ЕВ** Александр Николаевич (1889–1976, Казан), график, нәкышьче, Казан сәнгать мәктәбен (1915), Казан архит-ра-сәнгать остаханәләрен (1924) тәмамлый. Тат-



А.Н. К а ш а е в. «Кызыл Армия». Плакат эскизы. Кәгазь, акварель. 1923. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

ЛЕФ әгъзасы һәм рәисе (1925–27), Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1929–39). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1937). 1920 елларда рев-цион темаларга монументаль, символик-аллегорик паннолар — «РЛКСМ» (1924), «Ленинизм» (1925) һәм «Пролетарий Татарстана» ж-лы өчен карикатуралар (1925–26) иҗат итә; күргәзмәләр, сәнәгать объектларын, киң халык манифестацияләрен уздырy урыннарын бизәү һ.б. б-н шөгыльләнә. ТЮЗ спектакльләренә декорацияләр ясый (1935). Бөек Ватан сугышы елларында Казан «Сатира тәрәзәләре»н («Окна сатиры») оештыра. 1940–50 елларда пейзаж, натюрморт жанрларында эшли: «Тәтеш янындагы Идел» (1946), «Тәрәзә янында», «Натюрморт» (икесе дә — 1947 дә), «Навигация ачылыр алдыннан» (1950) һ.б. әсәрләр иҗат итә.

Кахутеинның 3 нче конкурс күргәзмәсендә, КАХУТЕМАС күргәзмәсендә, «Казан — алга!» сәнгать күргәзмәсендә (барысы да 1924 тә, Казан), ЛЕФ лаборатор-җитештерү эшләренең 2 нче сәнгать күргәзмәсендә (1925, Казан), «СССР халыклары сәнгате» бөтенсоюз күргәзмәсендә (1927, Мәскәү) катнаша. К.ның әсәрләре ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990.

*О.Л.Улемнова.*

**КАША́ЕВ** Әнвәр Шакир улы (22.3.1949, БАССРның Фёдоров р-ны Акбулат а.), нәкышьче, график. Морза Еникеев-Кашаевлар нәселеннән. Дүшәнбе сәнгать уч-щесендә укый, Уфа сәнгать уч-щесен педагог В.Н.Баскаковта тәмамлый (1974). 1987 дән Уфадагы балалар сәнгать мәктәбендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1993). К.ның нәкышьче буларак таланты Ватан темасын фәлсәфи ачуда («Бодай кыры пейзажы», 1983; «Моңсу көн», 1995; «Авыл иртәсе», 1996; «Әнкәй турында хатирәләр», 2004; «Балачак каеннары», 2005), рәссамның остаханә тәрәзәсеннән күзәткәндә яки ил буйлап сәяхәт иткәндә истә калдырган шәһәрләр («Уфа урамы», 1979; «Ялгызлык», 1987; «Судактагы мәчет», 1987; «Кар ява», 1988 һ.б.) күренешләрен сурәтләгән пейзажларында ачык чагыла. К.ның жанрлы картиналарында аның әхлакый идеаллары, яшәеш гармониясе һәм камиллеге турындагы хыяллары гәүдәләнә («Тынлык», 1995; «Дуслар җыелган кичә (Тарковский, Высоцкий, Шукшин)», 1994; «Кайту», 2004 һ.б.)

К.ның нәкышенә җемелдәп торган рельефлы фактура, якты колоритны зәңгәр, күк, кызгылт сары һ.б. төсләр б-н яраштыру хас. Аның каләм, тушь, төсле һәм кара карандаш б-н эшләнгән станлы график әсәрләре символик эчтәлеккә ия булулары, форма һәм фәзаны сыек томан эффекты бирүче вак штрихлар ярдәмендә махсус модельләштерүе б-н аерылып торалар. Еш кына әсәрләрнең композициясендә төп игътибар К.ның үзе иҗат иткән шигырь юлларына бирелә («Тукай хастаханәдә», 1983; «Кар өстендәге шигырьләр», 1990; «Рамай җыры», 1995; «Автопортрет», «Минас Аветисян», икесе дә — 1997 дә һ.б.). Аның иллюстрацияләре б-н бизәлгән китаплар — Р.Идиятуллинның «Хәерле көн» (Уфа, 1997), Э.Кәшфуллинның «Иман нуры» һәм «Мин язларда калам» (Уфа, 1997 һәм 1998) һ.б.



Ә.Ш. К а ш а е в. «Ялгызлык». Картон, майлы буяу. 1987.

1983 тән — бөтенроссия («Рәсем һәм акварель күргәзмәсе»), 1985 тән төбәк («Социалистик Урал»), төбәкара («Татарт», С.-Петербург-Казан, 1991–92) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1988, 1993, 1994, 1999, 2004 тә (Уфа) оештырыла. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, В.С.Высоцкий (Мәскәү) музеенда саклана.

*Әд.:* Анвар Кашаев. Живопись. Графика: Каталог выставки. Уфа, 1999.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАША́ЕВ** Габбас Сөләйман улы (15.8.1912, Саратов губ., Кузнецк өязе Верхозим а. — 27.3.2005, Казан), партия, хуҗалык хезмәткәре. Партия оештыручылар югары мәктәбен (Мәскәү, 1946) тәмамлый. 1934–37 елларда Минзәлә р-ны Воровский исем. с-з комсомол оешмасының сәяси бүлегендә. КПСС-ның Юдино райкомының 2 нче (1940), Баулы (1941–44), Чистай (1944–45), Кукмара (1947–53), Әлмәт (1953–56) район һәм шәһәр ком-тларының 1 нче секретаре. 1965–76 да «Татнефтестрой» ҖБнең башлык урынбасары. 1951–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Почёт билгесе орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**КАША́ЕВ** Рөстәм Солтанхәмит улы (11.5.1949, Казан), физик, техник фән. д-ры (2001). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында, 1975 тән Казан химия-технол. ин-тында эшли. 1985 тән «Нефтепромавтоматика» махсус проектлау-конструкторлык бюросының (Казан) әйдәп баручы конструкторы. 1993 тән Казан ун-тының акад. көллиятендә, бер үк вакытта Резонанс комплекслары конструкторлык бюросы директоры (Казан). 1995–2002 дә Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә; 2002 дән Казан энергетика ун-ты профессоры. Хезмәтләре нефтьле дисперс системаларны импульслы ТМР алымы ярдәмендә тикшерүгә карый. К. кечкенә үлчәмле автомат ТМР релаксометрын төзи (1992), протонлы системаларның структур-динамик анализы (СДА) нигезләрен эшли. Беренче булып чимал нефть параметрларын билгеләү өчен агымлы ТМР-анализатор тәкъдим итә (1996), СДА кулланып, нефтьле дисперс системаларны (углеводородлар, нефтьләр, мазутлар, гидроннар, битумнар, карбоидлар, кокс) тикшерә. К.ның кечкенә үлчәмле ТМР-релаксометры чимал нефть параметрларын тикшерү максатында фәнни-тикшеренү ин-тларында, вузларда һәм пр-тиеләрдә кулланыла.

Х е з м.: Применение импульсного ЯМР в нефтехимии и нефтедобыче. К., 1999; Структурно-динамический анализ нефтяных дисперсных систем. К., 1999; Информационные системы. К., 2001; Импульсная спектроскопия ЯМР структурно-динамического анализа нефтяных дисперсных систем. К., 2002.

**КАША́ЕВЛАР**, татар морзалары нәселе. Касыйм татарларыннан. Фаразланганча, 1629 елда крепостной крәстияннәре булган морзалар арасында искә алынган Ишәй Кашаевтан башлана. Мәскәүне Польша короле улы Владислав гаскәрләреннән азат итүдә катнашуы өчен (1612) аңа Темников өязендәге Аксел, Адай һәм Митрәле авыллары янында 120 чиреклек мәйданда җирләр бирелә. 17 йөзнең 2 нче яртысында К. нәселеннән Исәкәй Тимралиев искә алына. 18 йөз башында К. Касыйм һәм Кадом өязләрендәге Иванково, Яңа һәм Иске Мансур, Кожбухта, Шильно авылларында, Алатырь өязенең Кызыл Яр авылында яшиләр. 1779 да морза К. Бөгелмә өязе Габдулла авылыннан (хәзер Азнакай р-ны Илбәк а.) Оренбург губернасы Нугай даругасының Юрматы волостена күченеп китәләр. Сенатның 1796 ел 1 декабрь фәрманы б-н К. нәселеннән морзалар Сәфәр Ижбулатов һәм Вәлиша Казбулатов дворяннар катлавына кертелә. 19 йөздә — 20 йөз башында аларның варислары Акбулат һәм Батыр авылларында (хәзер БРның Фёдоров р-ны) гомер кичерәләр. К. нәселенең дәүләт крәстияннәре катлавында калган өлеше Югары Аташ, Яңа һәм Иске Калмаш (хәзер БРның Чакмагыш р-ны), Кормаш (хәзер БРның Кушнаренко р-ны), Сарайлы Моталлап (хәзер БРның Благовар р-ны) авылларында яши.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**КАША́Н**, урта гасырларда (12–15 йөзләр) Чулманның уңъяк яры буендагы болгар шә-


З.К.Кашапов.

һәре. 12–13 йөзләрдә — Түбән Чулман буе, 14 йөздә *Кашан бәклегенең* эре сәүдә-икътисад үзәге. Чулман тамагында һәм аның аша кичүдән ерак булмаган уңайлы географик урында урнаша, бу исә калага елга һәм коры җир сәүдә юлларын контрольдә тоту мөмкинлеге бирә. 1391 елда рус ушкуйниклары һәм 1399 да Мәскәү гаскәре тарафыннан яулап алына һәм талана. Соңрак К. үз әһәмиятен югалта, *Казан бәклеге*, аннары *Казан ханлыгы* составына кертелә. Археол. калдыклары Лаеш р-нының Шуран авылы тирәсендә (к. *Кашан шәһәрлекләре*).

*Әд.:* Пономарёв П.А. Данные о городах Камско-Волжской Булгарии. Булгарский город Кашан // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1893. Т. 11, вып. 2; Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

*И.Л.Измайлов.*

**КАША́Н БӘКЛЕГЕ́**, болгар бәклеге (13–15 йөзләр). Монголлар яулап алганнан соң, *Идел буе Болгар дәүләте* терр-ясендә оеша. Алтын Урда составында вассал буларак яши. Үзәге — *Кашан* шәһәре. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек; эре авыл һәм шәһәрләрдә тимер кою, чүлмәк ясау, бакыр кою һ.б. һөнәрчелек төрләре, сәүдә үсеш ала. 1391 елда — Новгород ушкуйниклары, 1399 да Мәскәү гаскәрләре тарафыннан талана. 1430–40 елларда *Казан ханлыгына* керә.

*Әд.:* к. *Кашан.*

*И.Л.Измайлов.*

**КАША́Н ШӘҺӘРЛЕКЛӘРЕ́**, археол. ядкәрләр; урта гасырлардагы болгар шәһәрләре калдыклары. 19 йөздән башлап Н.А.Толмачев (1850), С.М.Шпилевский (1877), П.А.Пономарёв (1878–79), Н.Ф.Калинин (1948), К.А.Руденко (1995–99) һ.б. тарафыннан тикшерелә. Шпилевский һәм Пономарёв К.ш.нең берсен Кашан шәһәренә тиңлиләр. Атамасы «Кашан тарлавыгы» дигән чокыр исеменнән алынган. К.ш.нең барлык терр-ясе диярлек сөрелгән.

**Кашан I шәһәрлеге** Каманың биек уң ярында (биеклеге 90 *м* га кадәр) Лаеш р-ны Шуран авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак урнашкан. Мәйданы 17,1 *га*. Якынча 11–12 яки 13–15 йөзләргә карый. Шәһәрлекнең терр-ясе трапеция рәвешендә, төньяк-көнбатыштан — «Гремячий ключ», көнчыгыштан — «Рыжный овраг» чокырлары, көньяктан Кама яры б-н чикләнә; культура катламы бик юка. Археол. казулар вакытында кыр һәм елга ягындагы, валдан һәм чокырдан торган нығытмалары, шәһәрлек эчендәге культура утырмалары өйрәнелә. «Гремячий ключ» чокыры янында Ананьино археол. культурасына нисбәтле балчык савыт-саба ватыклары табыла. Казу мәйданчыкларында табылган әйберләр металл эшләнмәләрдән (тимер ук очлыклары, ачкыч, кечкенә гер, кадаклар, тишкеч, каптырма, асылма йозаклар һәм ат дирбиясе детальләре, бакыр савыт-саба ватыклары, бронза шөлдер һ.б.), әвәләп ясалып, һөнәрче түгәрәгендә төзәтелгән, 11–12 йөзләргә караган керамик савыт-саба, сфероконуслар ватыкларыннан, балчык орчык башларыннан һ.б.дан гыйбарәт. Шәһәрлек терр-ясендә Алтын Урда тәңкәләре хәзинәсе һәм 11–12 йөзләргә нисбәтле берничә болгар әйберләре хәзинәсе табыла.

**Кашан II шәһәрлеге** Каманың уң ярында Балык Бистәсе р-ны Саескан Тавы авылыннан көнбатыштарак урнашкан. Мәйданы 30,2 *га*. Якынча 12–13 йөзләргә карый. Терр-ясе дүртпочмаклык рәвешендә, көньяктан Каманың текә яры (биеклеге 25 *м* га кадәр), көнчыгыштан — «Долгий», көнбатыштан «Кашан тарлавыгы» чокырлары б-н чикләнә; культура катламы бик юка. Шәһәрлек көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш яклардан вал һәм чокырдан торган икешәр рәтле, төньяктан бер рәтле саклану системасы б-н киртәләнгән; нығытмалар өч җирдән капкалар б-н бүленә.

Шәһәрлек терр-ясендә алтын тамгалы кылыч, кәкре кылыч, балталар, яфрак рәвешендәге сөңге очлыгы, бизәнү әйберләре һ.б. табыла. Н.Ф.Калинин фикеренчә, шәһәрлек *Кашан* шәһәре кальгасы һәм гаскәр башлыгы урнашкан урын булган.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Пономарёв П.А. Данные о городах Камско-Волжской Булгарии. Булгарский город Кашан // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1893. Т. 11, вып. 2; Калинин Н.Ф., Халиков А.Х. Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. К., 1954; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Руденко К.А. Итоги исследования городища Кашан I в Татарстане: к вопросу о формировании булгарских городов и протогородов // Новые исследования по средневековой археологии Поволжья и Приуралья. Ижевск–Глазов, 1999.

*К.А.Руденко.*

**КАША́ПОВ** Газиз (Газизҗан) Салих улы (псевд. Газиз Кашшаф-Үзиле) (21.8.1942, Аксубай р-ны Яңа Үзи а. — 30.8.1991, Чаллы ш., туган авылында җирләнә), язучы, Благовещенск хәрби уч-щесен, Казан ун-тын (1979) тәмамлый. 1974–82 елларда Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге инспекторы, «Хезмәт байрагы» (Әлмәт ш.), «Социалистик Татарстан» г-талары хәбәрчесе вазифаларын башкара. 1987–89 да ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җаваплы сәркәтибе. Беренче әсәрләре 1974 тә «Ялкын» ж-лында басылып чыга. «Сәмум җиле» (1978) автобиографик повесте чик сакчыларына багышлана, «Җир җылысы» (1983) повесте һәм «Язмышыңа ышан» (1987) романы эре сәнәгать объектлары һәм яңа шәһәрләр төзүчеләр турында. К. ш.у. — замана яшьләре проблемаларын яктырткан «Еллар тыныч иде» (1983), «Вөҗдан хәтере» (1989) кебек повестьлар, шагыйрь Х.Туфанга багышланган «Киек каз юлы» (1992) документаль роман; публицистик мәкаләләр, популяр җыр текстлары авторы да. 1992 дә К.ның туган авылында бюст куела һәм музей ачыла.

*Әд.:* Нәҗмиев Т. Үзи авылының Газизҗаны // Казан утлары. 2002. № 8; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КАША́ПОВ** Заһир Баһаветдин улы (3.5.1930, Азнакай р-ны Югары Әстәрле а.), а.х. пр-тие җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1990). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1970). 1948–93 елларда Азнакай р-нының Мичурин исем. к-зында эшли: колхозчы, тракторчы, бригадир, колхоз рәисе урынбасары, колхоз рәисе (1967 дән). К. җитәкчелегендә колхоз а.х. продукциясен җитештерү һәм сату буенча югары күрсәткечләргә ирешә, алдынгы агротехникасы һәм югары үскән терлекчелеге булган зур табышлы хуҗалыкка әверелә. 1975–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КАША́ПОВ** Зәкәрия Кәшшаф улы (14.3.1923, Минзәлә кантоны, хәзерге Мөслим р-ны Баланлы а. — 21.3.2000, шунда ук), механизатор, Соц. Хезмәт Герое (1966). Тракторчылар курсын тәмамлый (1941). 1941–83 елларда Мөслим р-нының «Михайловский» с-зында эшли: тракторчы, тракторлар бригадасы бригадиры, комбайнчы. 1958 дә К. 418 *га* мәйданнан — 6179 *ц*, 1965 тә 479 *га* дан — 6175 *ц*, 1966 да 393 *га* дан 6237 *ц* ашлык суктыра. Герой исеме терлек азыгы культураларын һәм ашлык җитештерүдә ирешелгән уңышлары һәм техникадан югары җитештерүчәнлекле итеп файдаланганы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Мөслим р-нының Мөслим авылында К.ка бюст куела (2003).

*Әд.:* Мастер своего дела. К., 1966; Гайнуллин Х., Галиев Р. Кашапов Закария Кашапович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КАША́ПОВ** Наил Фаикъ улы (8.11.1960, Казан), физик-химик, техник фән. д-ры (2001), проф. (2005), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008) ТРның атказ. уйлап табучысы (2005). 1983 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли, 1987 дән лаб. мөдире. 1992 дән «Нур» Татарстан яңа технологияләр үзәгендә директор урынбасары, 1999–2002 дә Суыргыч машиналар төзү технологияләре фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, бер үк вакытта, 2000 нән Казан технол. ун-тында, 2002 дән мед. һәм җиңел сәнәгать технологик җиһазлары каф. мөдире, 2004 тән — вузга кадәр хәзерлек ф-ты деканы, 2010 нан — проректор. Хезмәтләре плазма физикасына карый. Газ агымында түбән температуралы плазманың тотрыксызлыгы, тигезсез плазманың каты җисемнәр өслеге, аларның плазмалы модификациясе, капламнар ясау б-н тәэсир итешүе проблемаларын өйрәнә. К. түбән басымлы югары ешлыклы плазма агымының эшкәртү һәм сип-

терең каплау процессларын бергә кушу хисабына «каплам — төп материал» системасының яңа үзлекләр алу мөмкинлеген билгеле. Металларның, диэлектрикларның, ярымүткәргечләрнең һәм юка элпәле капламнарның өске катлаулары үзлекләрен инерт һәм актив газлар һәм аларның катнашмаларының югары ешлыклы плазмасы тәэсирендә үзгәртү технологияләрен эшли. «КамАЗ», «Радиоприбор», «Мединструмент» һ.б. пр-тиеләрдә, Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында, Казан технол. ун-тында өслекне әзерләү һәм капламнарны югары ешлыклы плазмотрон б-н каплау өчен технологияләр һәм җиһазлар гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 35 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Высокочастотная плазменно-струйная обработка материалов при пониженных давлениях. Теория и практика применения. К., 2000 (автордаш); Нанесение тонкоплёночных покрытий с помощью высокочастотной плазмы пониженного давления // Физика и химия обработки материалов. 2000. № 2 (автордаш); Основные результаты исследований в области низкотемпературной плазмы и её применений в 2002 году // Исследование и применение низкотемпературной плазмы. М., 2003.

**КАША́ПОВ** Равил Исхак улы (15.11.1956, Чиләбе өлкәсенең Увельский р-ны Красногорск пос.) спортчы (җиңел атлетика, марафон), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1987). Профсоюзларның Физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренерлары — Х.М.*Мортазин*, М.Н.*Чинкин*. Казан ун-тының биология ф-тын тәмамлый (1979). СССР (1987, марафон; 1988, кросс), дөнья (1998, команда беренчелегендә 100 *км* га йөгерүдә) чемпионы, Европа кубогы иясе (1988, марафон); дөнья чемпионатында (1998, шәхси беренчелектә 100 *км* га йөгерүдә) бронза медаль ала, Олимпия уеннарында катнаша (1988, марафон). 1979–83 елларда Казан ун-тында укытучылык эшендә, 1983–89 да Волгоград физкультура ин-тының Казан ф-лында, 1989 дан «КамАЗ» спорт клубында (1992–95 тә футбол клубында) тренер-инструктор, 1995 тән Кама физкультура ин-тында укытучы (Чаллы ш.).

**КАШАФЕТДИ́НОВ** Гайфи Әбрар улы (25.1.1931, Арча р-ны Мирҗәм а. — 12.10.2002, Казан), вет. фармакологы, токсиколог, вет. фән. д-ры (1989). 1955 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, Сарман р-ның баш вет. табибе булып эшли. 1957 дән Казан вет. ин-тының фармакология кафедрасында. 1985 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1990–93 елларда вет. хезмәте камиллеге лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре инсекторепеллентлар сыйфатында кулланылучы фосфор һәм күкерт органик кушылмаларын тикшерүгә карый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сравнительное изучение действия армина и нибуфина на общее состояние и холинэстеразную активность плазмы крови // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1964. Т. 92; К вопросу противогрибкового действия метилацетонохлорофосов // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1970. Т. 104 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КАШБА́У** (кашпау), татар хатын-кызларының йомшак башлык рәвешендәге, кабырчыксыман итеп көмеш тәңкәләр, сәйлән, мәрҗәннәр тегеп бизәлгән борынгы баш киеме. К.ның өстәмә бизәге рәвешендә баш киеменә беркетелгән тәңкәле колак асмалары (колакчалар), муенса (тамакча) һәм тәңкәләрдән тезелгән чылбыр яки тукыма тасмага тоташ тутырып тегелгән мәрҗәннәр, энҗе, тәңкәләр, ялтыравыклы чәч баулары санала. К. башлары ш.у. бик бай итеп бизәкләп тукылган яки чигелгән *тастар* өстеннән киелә. 20 йөз башына кадәр К. Ләмбрә мишәрләре,



Кашбау.

Мәлки керәшеннәре (кашпу) арасында таралыш ала. Ул ш.у. анатри-чуашлар (хушпу), бисерманнар (кошпу), башкортларга (кошмау) да хас була.

*Әд.:* З а в ь я л о в а М.К. Татарский костюм: Из собрания Государственного музея Республики Татарстан. К., 1996; М у х а м е д о в а Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КАШГАРИ́** Мәхмүд, к. *Мәхмүд Кашгари.*

**КАШИ́РИН** (чын фамилиясе Благушин) Александр Иванович (1862, Харьков ш. — 3.12.1925, Лаеш кантоны Шиланка а.), драма актёры; рус реалистик театры мәктәбенең күренекле вәкилләреннән берсе. Сәхнә эшчәнлеген 1881 елда Воронеж театрында К.И.Бессонов антрепризасында башлап җибәрә, 1902 дә С.-Петербургтагы Александра исем. театрга чакырыла, монда ул ике сезон эшли, 1904 тә В.Ф.Комиссаржевская театрына күчә, 1914–15 тә С.-Петербургтагы А.С.Суворин Кече театры актёры; шулай да күпчелек рольләрен провинциядә башкара. 1893–1901, 1909–10, 1916–23 елларда Казан шәһәр театрында эшли; 1910, 1919 да Яңа (1919 да — Кызыл Армия) театрда эшләүче труппаның сәнгать җитәкчесе. 1923 тә Елга аръягы Эшчеләр сараенда Казан күн комбинатында эшләүче һәвәскәр актёрлардан торган труппа оештыра, театрның тәрбия эшенә аеруча зур игътибар бирә. Казанга еш кына гастрольләр б-н килә. Казанда үз йорты һәм Зөя өязе Шиланка авылында утары булган нәселле Казан дворян кызы Е.П.Костливцевага өйләнә. Утар крәстияннәре арасында К. хәйрия эше алып бара. Рус репертуарында шактый рольләре б-н танылу тапкан күренекле башкаручы К. Казан театр сәнгатенә зур өлеш кертә. Актёрның Ананий («Ачы язмыш», А.Ф.Писемский), Рогожин («Идиот», Ф.М.Достоевский романы буенча), Никита («Караңгылык патшалыгы», Л.Н.Толстой), Иоанн Грозный («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой; «Василиса Мелентьева», А.Н.Островский) рольләре аеруча игътибарга лаек. Аның В.С.Зотов, В.И.Качалов, И.А.Слонов, Д.Р.Любин, ш.у. Казан сәхнәсендә эшләүче башка актёрлар



А.И. Каширин.

иҗатына да йогынтысы зур була. Персонаж тормышының бөтен нечкәлекләре, психологик тирәнлеге К. башкаруында гадилек һәм сәхнәдәге табигыйлек, геройның үз-үзен тотышы б-н бергә үрелеп бара. Теләк-омтылышларында, ачу-нәфрәтендә тыелгысыз һәм аяусыз, хәтта куркыныч Иван Грозныйны ышандырырлык һәм темпераментлы итеп гәүдәләндерә, шул ук вакытта аның алдан күрүчән сәясәтче, зур масштаблы дәүләт эшлеклесе булуына да басым ясый. К.ны Л.Н.Толстойның «Караңгылык патшалыгы» пьесасындагы Никита ролен бөтен сәхнә тарихында «иң оста башкаручы» дип табалар. Геройның вөҗдан газаплары, әхлакый кичерешләре актёр тарафыннан гадәттән тыш эмоциональ һәм әчкерсез башкарыла. Халыкчан характерлар К.га аеруча якын. Андрей Белугин, Безсудный, Краснов, Любим Торцов («Белугинның өйләнүе», «Кеше күп җыелган җирдә», «Адәм баласы хатадан хали түгел», «Ярлылык — гаеп түгел», А.Н.Островский), 1 нче мужик («Мәгърифәт җимешләре», Л.Н.Толстой), Алексей, Андрей Колгуев («Алтын», «Яңа эш», В.И.Немирович-Данченко) һ.б. геройлар, рус милли характерының типик үзенчәлекләрен, үзләренең әхлакый принципларын, намуслылыкларын, «дөреслек буенча яшәргә» омтылуларын гәүдәләндереп, тамашачыда кызгану, теләктәшлек хисләре уяталар. К. иҗатының нәкъ менә демократик юнәлештә үсүе тамашачының хөрмәтен казана һәм аның тарафыннан танылу таба. К. җәмәгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, хәйрия концертларында актив катнаша.

*Әд.:* С м и р н о в а Н.А. Воспоминания. М., 1947; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Ш е б у е в Г. Актёрское счастье. Куйбышев, 1964; Б л а г о в Ю. «Казанский помещик» Александр Каширин. К., 2006.

*Ю.А.Благов.*

**КА́ШКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 11 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 71 кеше (руслар, чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1921 дә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Тәтеш кантоны Колунец волостенда, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 160, 1938 дә — 220, 1949 да — 220, 1958 дә — 272, 1970 тә — 268, 1979 да — 180, 1989 да — 125, 2002 дә — 83 кеше.

**КАШКАЛА́К** (Fulica arta), көтүче кошлар семьялыгындагы кош. Евразия, Төньяк-көн-

батыш Африкада, Австралиядә киң таралган. ТР терр-ясендә аз сулы күл, буа, аеруча балык хуҗалыкларында еш очрый. Кошларның саны күбәя бара, бу сай сулыкларда үсемлекләр күпләп үскән мәйданнарның артуы һәм сусаклагычлар төзелү б-н бәйле. Ата кошларның авырлыгы 700–1200 *г*, ана кошларның 550–800 *г*. Төсе тонык кара, корсагы соргылт-кара; маңгаенда калын тиречел ак тап бар. Тәпиләре телле-телле йөзгеч элпәле. Томшыгы конуссыман, кыска, ак төстә. Аяклары соры. Яхшы йөзә һәм чума, начар оча. К. — оя ясаучы күчмә кош. Апрельдә очып килә. Камыш, курак, күрәннең сабак һәм яфракларыннан ясаган яссы оясын турыдан-туры су өстендә яки су кырыенда ук куе үскән үсемлекләр арасында урнаштыра. Көрән яки шәмәхә тимгелле 6–10 аксыл соры йомырка сала. Кош балалары июнь ахырында чыга. Йомшак су үсемлекләре, бөҗәк, моллюсклар, вак балыклар б-н туклана. Октябрьнең 1 нче яртысында очып китәләр. Ау спорты объекты.

**КАШКАРА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 20 *км* көньяктарак, Оштырма елгасының уң кушылдыгы Кенә бассейнында урнашкан. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 18 йөз ахырында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да чиркәү-приход мәктәбе (1892–97 дә укырга-язарга өйрәтү мәктәбе), тимерчелек, 3 вак-тәяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 876 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 436, 1897 дә — 741, 1908 дә — 772, 1920 дә — 778, 1926 да — 937, 1938 дә — 465, 1949 да — 492, 1958 дә — 273, 1976 тә — 112, 1979 да — 65, 1989 да — 11, 2002 дә — 5 кеше.

**КАШКАРЫЙЧАЛА́Р** к. *Оешма чәчәкләләр*.

**КА́ШКИН** Николай Дмитриевич (27.11.1839, Воронеж ш. — 15.3.1920, Казан), музыка тәнкыйтьчесе, музыка белгече, педагог, проф. (1875). Фортепианода уйнарга һәм музыка теориясенә шәхси педагогларда, ш.и. А.Дюбюкта өйрәнә. 1863 елдан Рус музыка җәмгыятенең Мәскәү бүлеге музыка классларында, 1866–1906 да Мәскәү консерваториясендә (фортепиано классы, музыка һәм теория тарихыннан дәресләр алып бара) укыта. К., музыка тәнкыйтьчесе буларак, Россия музыка сәнгате тарихына мөһим өлеш кертә. «Московские ведомости», «Русские ведомости» г-талары; «Артист», «Русская музыкальная газета», «Музыка», «Музыкальный современник» ж-ллары һ.б. хезмәттәшлек итә. Үзенең тәнкыйть мәкаләләрен, нигездә, композиторлык һәм башкару иҗаты проблемаларына багышлый, Россия музыка сәнгатенең аеруча мөһим күренешләренә реаль чынбарлыктан чыгып бәя бирә. К.ның П.Чайковский, М.Глинка, Н.Римский-Корсаков, М.Балакирев, С.Танеев, А.Скрябин, С.Рахманинов һ.б. композиторлар турында рус язмаларында композиторлык мәктәбе казанышлары пропагандалана. Шулай ук К. публицистик язмаларын муз. агарту проблемаларына багышлый («Рус консерваторияләре һәм сәнгатьтә заман таләпләре» — «Русские консерватории и современные требования искусства», 1906 һ.б.). К. музыка теориясе буенча уку әсбаплары авторы һәм Мәскәү консерваториясенең беренче историографы. Л.Буслер, Х.Рихман һ.б. Европа авторларының музыка-укыту әдәбияты басмаларын рус теленә тәрҗемә итә. 1918 дән Казан дәүләт ике баскычлы музыка мәктәбен (элеккеге Рус музыка җәмгыятенең Казан музыка уч-щесе базасы җирлегендә) оештыруда актив катнаша һәм шунда ук музыка тарихы курсларын алып бара.

*Әд.:* Глущенко Г.С. Н.Д.Кашкин. М., 1974; Вайда-Сайдашева Г.К. Звуки времени. К., 1991.

**КА́ШКИН** Павел Николаевич (4.1.1902, Кострома губ. Салигадич ш. — 1991, Ленинград), миколог, мед. фән. д-ры (1937), проф. (1938), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1957). 1926 елда Ленинград мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1928 дән Ленинград ГИДУВының дерматовенерология кафедрасында, 1935 тән 1 нче Ленинград мед. ин-тының микробиология каф. мөдире, 1936 дан Ленинград фарм. ин-тының шул исемдәге каф. мөдире. 1943–45 тә Казан мед. ин-тының микробиология каф. мөдире, бер үк вакытта Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары, антибиотикларны өйрәнү тәҗрибә лаб-ясе җитәкчесе. Ленинградта Антибиотиклар ин-тын оештыручы (1945); 1950 дән Ленинград ГИДУВының микробиол. каф. мөдире; 1950 дән Ленинград химия-фармакол. ин-тында инженерия-микробиология ф-тын оештыручы, деканы. Хезмәтләре антибиотиклар (грамицидин С, мицитин) булдыруга, гөмбә антигеннарын тикшерүгә карый. К. беренче булып җепселле гөмбәләр, ш.и. дерматомицетлардан антибиотик матдәләр ала; тирән микозлар һәм дерматомикозлар мәсьәләләрен өйрәнә. 1931 дә Россиядә беренче дерматомицетларны тикшерү буенча кулланма нәшер итә (акад. О.Н.Подвысоцкая б-н берлектә). 1950 еллар ахырында ул оештырган микология лаб-ясе СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Бөтенсоюз тирән микозлар һәм микоген аллергия үзәгенә әверелә (хәзер С.-Петербургта П.Н.Кашкин исем. Микология мед. фәнни-тикшеренү ин-ты). Уйлап табуга таныклыклары бар. 1951 дә «Дерматомикозы: этиология, лабораторная диагностика и эпидемиология» (Л., 1950) китабы өчен СССР Дәүләт бүләге бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Антибиотики и их практическое применение. Л., 1952; Антибиотики. М., 1970.

*Әд.:* П.Н.Кашкин (к 80-летию со дня рождения) // Вестн. дерматологии и венерологии. 1982. № 1; Елинов Н.П. 100 лет со дня рождения П.Н.Кашкина // Тез. докл. науч.-практ. конф. по медицинской микологии (Кашкинские чтения). СПб., 2002.

**КАШЛЫ́К** (Искәр, Сибир), Иртеш елгасының уң яры буендагы урта гасырлар (14–16 йөзләр) татар шәһәре (бүгенге Тобол шәһәре янәшәсендә). 15 йөз ахырыннан *Себер ханлыгы* башкаласы. Иң куәтле үсеш чоры 16 йөз башына, ханлык терр-ясе *Мөхәммәд Тайбуга* хан тарафыннан берләштерелгән дәвергә туры килә. 1582 елда атаман Ермак отрядлары тарафыннан җимертелә.

*Әд.:* Миллер Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; Материалы по истории Сибири. Улан-Удэ, 1964.

*И.Л.Измайлов.*

**КАШТА́НОВ** Нәкыйп Фәсхетдин улы (8.1.1942, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кыр Бикшеге а.), табиб, язучы. Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1971), Чистай үзәк район хастаханәсендә эшли, 1974–80 дә — Казан медицина оешмаларында. 1981 дән Республика клиник хастаханәсе табибе. «Үпкә гангренасы. Үпкә эмболиясе. Тромбоз. Үпкә инфарктлары» («Гангрена лёгких. Эмболия лёгких. Тромбоз. Инфаркт лёгких», 2001) монографиясе авторы.

Беренче шигырьләре һәм хикәяләре 1970 еллар ахырында басыла башлый. Балалар өчен язылган «Төлке» операциясе» (1995), «Айгөлнең туган көне» (1997), «Тылсымлы курай» (2001), «Канатлы чәчәкләр» (2004), «Күчтәнәч» («Гостинец», 2007) китаплары фантазиягә бай, юмор б-н сугарылган. Шигырьләре «Язмыш орчыгы» (2002), «Күкләргә кунмый тузан» (2004), «Кыйссаи Йосыфка»ка сәяхәт» (2005), «Сәйлән» («Бисеринки», 2007) җыентыкларына тупланган.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КАШТА́НОВ** Сергей Георгиевич (8.10.1905, Казан губ., Спас өязе Берёзовка а. — 10.3.1985, Казан), геолог-гидрогеолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1953), проф. (1953). 1991 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, гомуми геол. һәм гидрогеол. каф. мөдире (1952–77), бер үк вакытта проректор (1955–60). К. Татарстан терр-ясе һәм күрше төбәкләр гидрогеологиясен өйрәнә. Кама елгасы үзәнендә җир асты суларының гөмбәзсыман урнашуын ача (М.С.Кавиев һ.б. б-н берлектә), бу Идел-Кама артезиан бассейнындагы җир асты суларын чыгару шартларын күзалларга ярдәм итә. Татарстан терр-ясенең палеогидрогеологик шартларын өйрәнә, һәм бу нефть чыганаклары формалашу һәм саклау үзәнчәлекләрен аңлатуда мөһим роль уйный. Республика терр-ясен гидрогеол. районлаштыруның беренче схемасын эшли. Казанда гидрогеохимик аномалияне билгели. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Подземные воды Казани. К., 1979; Подземные воды Татарии. К., 1987 (автордаш).

*Әд.:* Королёв М.Е., Есаулова Н.К. Сергей Георгиевич Каштанов. К., 2003.

*М.Е.Королёв.*

**КАШТА́НОВ** Сергей Михайлович (29.1.1932, Ленинград), тарихчы, тарих фән. д-ры (1968), РФА мөхбир әгъзасы (1997). Мәскәү тарих-архив ин-тын тәмамлый. 1956 елдан РФАнең Тарих ин-тында (Мәскәү),

1992 дән баш фәнни хезмәткәр. Бер үк вакытта 1995 тән Россиянең урта гасырлар һәм яңа заманның әлгәре чоры тарихын өйрәнү үзәге җитәкчесе, 1987 дән Россия гуманитар ун-тының (Мәскәү) чыганакларны өйрәнү һәм ярдәмче тарихи дисциплиналар каф. профессоры. Хезмәтләре 10–19 йөзләр Россия тарихына, историографиясенә, чыганакларны өйрәнүгә, дипломатия, палеография, кодикология, филигранология, археография, тарихи географиягә карый. Урта Идел крәстияннәре историографиясе (16–19 йөзләр), Рус дәүләтенең Казан төбәге, Вятка һәм мордва җирләре б-н үзара мөнәсәбәтләре, Рус дәүләте сәясәтендә Алтын Урда традицияләренең күчүчәнлегенә караган хезмәтләр авторы. Казан епархиясе архивындагы грамоталарны беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертә.

Х е з м.: О внутренней политике Ивана Грозного в период «Великого княжения» Симеона Бекбулатовича // Тр. Моск. гос. ист.-архивного ин-та. 1961. Т. 16; Социально-политическая история России конца XV — первой пол. XVI в. М., 1967; Земельно-иммунитетная политика русского правительства в Казанском крае в 50-х годах XVI века (по актовому материалу) // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1970. Вып. 80; Очерки русской дипломатики. М., 1970; Акты Русского государства 1505–1526 гг. М., 1975 (соавт.) Актовая археография. М., 1998.

**КАШША́Ф** (Кашшафетдинов) Гази (Миргази) Солтан улы (15.4.1907, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Арсланбәк а. — 9.12.1975, Казан), әдәбият тәнкыйтьчесе, әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1960). Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1929), укытучы булып эшли. 1937–42 елларда Татарстан китап нәшриятында (Татгосиздат), 1942–45 тә «Совет әдәбияты» ж-лында; 1945–47 дә ТАССР Язучылар берлегендә референт-консультант, 1947–50 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1950–58 дә «Казан утлары» ж-лында баш мөхәррир. 1961 дән Казан ун-тында. Милли театр мәсьәләләренә, татар язучылары (Г.Тукай, Г.Камал, М.Гали, Ш.Камал, Ә.Фәйзи, К.Нәҗми, М.Галәү һ.б.) иҗатына караган мәкаләләр б-н чыгышлар ясый, урта мәктәп өчен хрестоматияләр төзүдә катнаша. М.Җәлил иҗатын һәм тормышын өйрәнә: «Моабит дәфтәре»нә фәнни искәрмәләр яза, шагыйрьнең әсәрләрен басмага әзерләгәндә текстологик яктан эшкәртә, аның фотоальбомын төзи, шагыйрь турында замандашларының истәлекләр җыентыгын әзерли (Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге). Повестьлар һәм хикәяләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Күңел көзгесе. К., 1975; Муса Джалиль. К., 1961; По завещению Мусы Джалиля. К., 1984.

*Әд.:* А х у н җ а н о в И. Остаз // Художник һәм аның сүзе. К., 1978; Ю з и е в Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. К., 1978.

**КАШЫКЛЫ́К АБАГА́** (Athyrium), чын абагачалар семьялыгыннан абагалар ыругы. 200 гә якын төре билгеле, күбесенчә ике ярымшарның уртача поясларында таралган. ТРда бер төре — ана К.а. (ана абага) (A. filix-femina) һәр җирдә, күбрәк төньяк районнарда очрый. Ылыслы һәм яфраклы урманнарның күләгәле урыннарында, куаклар арасында, болыннарда, елга ярлары буйларында үсә. 30–100 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска, юан. Яфраклары зур, озынча-эллипссыман; үсемлеккә декоратив матурлык бирүче киң ябалдашлы бәйләмгә җыелган. Тупас яфраклы калканлы абага (ата абага) б-н чагыштырганда, нәфис телгәләнгән каурый яфраклары аркасында «ана абага» исеме алган. Июнь–июльдә споралардан үрчи. Күләгә һәм дым яратучан. Суыкка чыдам. Дару үләне. Яфрак һәм тамырларында дуплау матдәләре, органик к-талар бар. Халык медицинасында тамырларыннан әзерләнгән төнәтмә какырык куптару чарасы буларак кулланыла.

**КАШЫКТОМШЫ́К** (Platalea leucorodia), ибис кошлар семьялыгындагы кош. Евразия һәм Төньяк-көнчыгыш Африкада яши. Гәүдә озынлыгы 90 *см* тирәсе, авырлыгы 1,5 *кг* га кадәр. Каурый капламы ап-ак, башында сары төстәге бүреге бар (яшь кошларда юк). Томшыгы кара, очы сары, озын һәм яссы, түгәрәкләнгән калак кебек киң. Канатлары һәм койрыгы кыска. Аяклары озын, кара. Челәннән яшәеш рәвеше б-н аерыла. ТР терр-ясенә сирәк очып керә. Идел алдында очрый. Яр буйларында, күл һәм елга сайлыкларындагы камышларда оялый. Су бөҗәкләре, суалчаннар, балык һәм бака уылдыклары б-н туклана. Азыкны ләмле сай сулыкларда таба. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КАЩЕ́ЕВ** Рафаэль Александрович (2.8.1951, Казан), астроном, физика-матем. фән. д-ры (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли, астрономия каф. профессоры (2002). Хезмәтләре Җир, Ай һ.б. күк җисемнәренең гравитация кырларын өйрәнүгә карый. К. фәзаның аерым нокталарында төрле төрдәге үлчәү нәтиҗәләре буенча күк җисемнәренең гравитация кырларын билгеләү теориясен төзи һәм универсаль алымнарын эшли. Астрономия һәм геодезия мәсьәләләрен чишү өчен җир өстендә һәм орбиталь базаларда урнаштырылган оптик интерферометрлар куллану алымнарын тәкъдим итә, шулай ук Җир төркеме планеталарының гравитация кырлары параметрларын бәяләү юлларын билгели.

Х е з м.: Перспективы интегративного подхода в селенодезии // Селенодезия и динамика Луны. Киев, 1990; Моделирование распределения вторых производных гравитационных потенциалов Луны и Марса на спутниковых высотах // Кинематика и физика небесных тел. 1994. Т. 10, № 5; Перспективы космической интерферометрии // Науч. Татарстан. 1996. № 1 (автордаш); Определение гравитационных полей небесных тел по разнородным спутниковым данным // Изв. вузов. Геодезия и аэрофотосъёмка. 1998. № 3.

**КАЮКО́ВА** Галина Петровна (20.1.1944, Владимир ш.), нефтехимик, химия фән. д-ры (2000). 1967 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, машиналар төзү з-дында (Киров ш.) эшли. 1970 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 2000 нән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (бүленеп: 1981–88 дә «Союзнефтепромхим» ФҖБдә). Хезмәтләре нефть һәм битумнар химиясе һәм геохимиясенә, экологиягә карый. Битумнарның химик составы һәм үзлекләре формалашуның төп закончалыкларын ачыклый, битумнарның технол. үзлекләрен алдан бәяләү алымнарын эшли һәм аларны углеводород чималы альтернативасы сыйфатында файдалану мөмкинлекләрен билгели. Биотамгаларны сыйфат һәм микъдари анализлау нигезендә ТР терр-ясендә нефть б-н пычрануның экологик мониторингы системасын булдыра.


Х е з м.: Химия и геохимия пермских битумов Татарстана. М., 1999 (автордаш); Закономерности состава и особенности распределения углеводородных биомаркеров Бавлинского участка Южно-Татарского свода // Нефтехимия. 2004. Т. 14, № 6 (автордаш); Особенности состава нефтей и битумов из трещиноватых зон продуктивных участков Матросского месторождения // Геология нефти и газа. 2004. № 5 (автордаш); Органическая геохимия осадочной толщи фундамента территории Татарстана. М., 2009 (автордаш).

**КАЮЛЫ́ КҮН**, кулдан каеп бизәү техникасында төрле төстәге күн кисәкләрен ялгап, нәфис эшләнмәләр ясау ысулы (бизәкле аяк киемнәре — читек-кәвешләр; келәмнәр, мендәрләр һ.б.); татар гамәли-бизәлеш сәнгате төре. К.к. йомшак *сафьян*, бераз катырак *юфть* күненнән әзерләнә, кайвакыт салават күперенең барлык төсләренә буялган шигрин күне кулланыла (ешрак яшел, зәңгәр, кызыл, көрән, сары һәм аларның төсмерләре). К.к. бизәкләре орнаментлы трафаретны бернечә катка төрелгән төрле төстәге күн өстенә куеп, буйга киселә. Бизәкнең күптөсле композициясе төсле ефәк, кайвакыт алтын һәм көмеш җепләрдән чигелә торган чылбырны түшәп калдыручы каты кыл һәм без ярдәмендә махсус станда тегелгән кисәкчекләрдән тора. Каюлы бизәкне берләштерүче һәм контурлаучы җеп, кагыйдә буларак, үзе дә күптөсле (гадәттә 2–3 төстә). Мондый чигү җөйләре техник алымнары, аяк киеме җепләрен яшереп торучы каюлы бизәкләрнең урнашуы б-н аерылып торган читекләр һәм аларның бизәкләре К.к.не дөньяга таныта (к. *Каюлы күн кәсепчелеге*). Традицион чи-

гү җөйләре һәм хәзерге заман сәнгатендә теркәлмәгән. К.к. рус телле әдәбиятта татарларның һәм казанлыларның «каю эшләре» дигән исем алган. Ул Казан татарлары тарафыннан уйлап чыгарыла һәм соңрак Касыйм, Себер һәм Кырым татарлары, ш.у. Урта Азия осталарында очрый. Торжок шәһәрендә эшләгән рус осталары үз итекләрен «татар итекләре» сыман каеп теккәннәр.

Күнне нәфис эшкәртү традициясе, читек тегү кебек үк, Идел болгарлары мәдәниятенә барып тоташа. Моңа рус елъязмалары һәм эшкәртелгән күннең бүгенгәчә сакланган исемнәре шаһит булып тора: Урта Азия халыкларында — «болгари», алтайлылар һәм калмыкларда — «пулгайры», венгрларда — «багария». Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән әүвәлге К.к. үрнәкләре 18 йөз ахыры — 19 йөз башы читекләре бизәкләрендә күренә. И.Виткевичның «1835–36 елларда Бохарага бару турында язмалар»ында бизәкле һәм төсле аяк киемнәре җитештерү б-н шөгыльләнүче татар итекче осталары турында белешмәләр бар. Нәкъ менә чигү осталыгы һәм чигү җөйләренең техник алымнары, аяк киеме җепләрен яшереп торучы каюлы бизәкләрнең урнашуы б-н аерылып торган читекләр һәм аларның бизәкләре К.к.не дөньяга таныта (к. *Каюлы күн кәсепчелеге*). Традицион чи-








**Каюлы күн мәкаләсенә.** 1. Читекләр. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы. ТР Милли музее; 2. С.Д. Кузьминых. «Алсу» мендәре. 1988. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. Н.Х. Кумысникова. «Сак белән Сок» дивар панносы. 2003; 4. С.Ю. Гарбузова «Семирамида бакчасы» панносы. 1998; 5. «Заман ритмнары» панносы. «Арча аяк киемнәре» АҖ эшләнмәсе. 2000 еллар; 6. И.Х. Гайнетдинов. Декоратив панно. 2004.

текләрнең үрнәкләре кунычның вертикаль күчәре буенча урнашкан Шәрекъ һәм Үзәк Азия орнаментына хас архаик бизәкләр (лотос, пальметталар, таҗ яфракчыклы розеткалар, йөрәк мотивлары һ.б.), ш.у. аларның алгы өлешен ачып торучы болытлар, спираль, лалә һәм яфрак сыман формадагы бизәкләр б-н бизәлгәннәр. Бөтеркәле кәкре сызыклардан гыйбарәт бизәкләрнең урнашу рәвеше бизәлештә зур әһәмияткә ия. Читекләрдәге борынгы Шәрекъ үрнәкләрен куллану гади алынма түгел, ул К.к. сәнгатенең буыннан-буынга күчә баручанлыгын чагылдыра (Алтайдагы Пазырык курганыннан табылган бизәкле аяк киеме үрнәкләре, Монголиядәге Ноинулин курганнарыннан чыккан келәм мотивлары, болгар орнаменты һәм Бурятия, Монголия, Кытай халык сәнгате орнаментлары). К.к. бизәкләренә кәкре сызыклар, йомык һәм күләмле формалар, контурларның, фактуралы һәм төсле контрастлар тудырып, төсле бөтерелмә җепләрдән рельефлы җөйләр б-н ачык тасвирлануы хас. Читекләрдәге К.к.нең гомуми колоритлы чишелешен төсләр палитрасын киметә яки көчәйтә баручы бизәк һәм фон төсләренең гармонияле нисбәте тудыра. Еш кына табигый буяулардан әзерләнгән йомшак һәм төсмерләре б-н бер-берсенә якын торган төсләр файдаланыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында К.к.нең борынгы бизәкләре яфрак һәм чәчәк характерындагы, гадәттә, букет композициясендәге стильләшкән яңа мотивлар б-н алмашына. Хәзерге заман модасына ияреп аерым бизәкләр, читекләрнең бөтен бизәлеше гадиләшә бара. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында К.к. үзенең югары сәнгать кыйммәтләрен югалта: гармонияле үсешне күзгә ташланучан чуарлык һәм вакланган бизәкләр алыштыра, милли традицияләрне җимерүче эклектик стиль урнаша.

20 йөздә К.к. сәнгате Казан арты р-ннарындагы авыл артельләренең кәсепчелек эшләнмәләрендә (1920–30 елларда) һәм аяк киемен сәнәгый җитештерү кысаларында (1950–2000 елларда), ш.и. аз серия б-н бизәкле читекләр чыгаручы Арча ф-касында (к. *Милли аяк киеме*), К.к. традицияләрен хәзер дә дәвам иттерүче проф. һәм үзешчән рәссамнар иҗатларында үсеш кичерә (С.Д.Кузьминых, Н.Х.Кумысникова, И.Х.Гайнетдинов, С.Ю.Гарбузова, А.Артемьева, А.А.Җәмилова, Ф.А.Калмурзина, Л.Чубукова һ.б.).

К.к. эшләнмәләре (читекләр, туфлиләр, сумкалар, бил каешлары, мендәрләр, келәмнәр һ.б.) Дөбъяз авылындагы «Экоскин» берләшмәсендә, «Туран» фондының Казан остаханәләрендә һәм ф-лларында — Биектау р-нының Ямаширмә авылында, «Презент» АҖдә һ.б. җитештерелә. Иҗади фикернең үзенчәлеге бизәлештә яңа үрнәкләр, төсле чишелешләр, эшләнмәләрнең заманча күренешләрен эзләүдә чагыла. К.к. өс киемнәрен һәм костюм аксессуарларын бизи, интерьерларны дивар паннолары һәм картиналар б-н зиннәтләгәндә (Н.Х.Кумысникова, С.Ю.Гарбузова), йорт җиһазларын тышлаганда һәм истәлек бүләкләре әзерләгәндә кулланыла. К.к., *монументаль-бизәлеш сәнгате* төре буларак, интерьерларны бизәгәндә дә кулланылыш таба. Казан консерваториясендәге Актлар залының кунаклар бүлегендә тышланган кечкенә декоротив колонналар беренче тәҗрибә була (арх. М.Х.*Агишев*, Арча милли аяк киемнәре ф-касы осталары башкара, 1967). Соңрак Казандагы Татар ашлары йортының банкетлар залы диварлары (арх. М.Х.Агишев, рәссамнар Н.С.Артамонов, В.И.Охотин, А.А.Спориус, С.Ш.Мостафин, 1968), «Татарстан» кунакханәсе ресторанының банкетлар залы үзәк диварлары (арх. М.Х.Агишев, рәссам Р.Ә.Килдебәков, 1970) вертикаль панно рәвешендәге К.к. б-н тышлана. 2006 да ТР Мәдәният министрлыгы бинасы вестибюленең интерьеры дивар панносы б-н бизәлә (рәссам Н.Х.Кумысникова). К.к. осталыгы Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының гамәли-бизәлеш сәнгате кафедрасында (2000 дән), Казан сәнгать уч-щесендә (2002 дән, «күнне нәфис эшкәртү» белгечлеге буенча) укытыла. К.к. әсәрләре этнография һәм антропология музеенда (С.-Петербург), Дәүләт Тарих музее (Мәскәү), ТР Милли музее, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, «Казан» милли мәдәният үзәге музее, Казан ун-тының этнография музее, Бөтенроссия гамәли-бизәлеш һәм халык сәнгате музеенда (Мәскәү), Касыйм шәһәрендәге крайны өйрәнү музеенда, Торжоктагы Тарихи-этнография музеенда, Сергиев Посадтагы Тарихи-сәнгать музеенда, Оффенбах шәһәренең (Германия) Күн музеенда, Анкарадагы Этнография музеенда (Төркия) һ.б.да саклананалар.

*Әд.:* Дульский П.М. Искусство казанских татар. М., 1925; Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы в Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; шул ук. Татарский народный орнамент. К., 2002; Гулова Ф.Ф. Татарская национальная обувь. К., 1983; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Саттарова Л. Казанская узорная кожа. М., 2004.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАЮЛЫ́ КҮН КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, традицион нәфис кәсепчелек; күннән татар халкының милли бизәкле аяк киемнәрен — итек (*читек*) һәм туфлиләрне (башмак, чүәк) күпләп җитештерү; татар халык сәнгатендә хезмәтне оештыру формасының бер төре. К.к.к. күнне «каюлы күн» (к. *Каюлы күн*), сирәгрәк — басма техникасында нәфис эшкәртүгә нигезләнгән. 18 йөз ахырына кадәр читек чигү б-н күбесенчә авыл җирләрендә, өй шартларында шөгыльләнгәннәр. 1840 елларда Казанда вак һөнәрчелек остаханәләре б-н берәттән, өйдә эшләүчеләр, башлыча, авыл җирендә яшәүче хатын-кыз осталар хезмәтен файдаланучы эре мануфактуралар (сәүдәгәрләр Абдуллин һәм Фәйзуллиннар) барлыкка килә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан милли аяк киемнәре җитештерү Казанда һәм Казан артындагы зур авылларда (Арча, Дөбъяз, Олы һәм Кече Кавал, Мәмдәл, Колачы, Мүлмә, Урта Аты, Әтнә, Субаш, Өнсә, Урта Сәрдә, Тимерче, Ямаширмә), ш.у. Казан губернасының Чистай, Тәтеш, Мамадыш һәм Спас өязләрендәге кайбер авылларда дәвам итә. К.к.к. алга таба милли бизәкле аяк киемнәреннән тыш, каюлы күн һәм чигү техникасында укалап бизәлгән хатын-кыз калфаклары һәм ир-ат түбәтәйләре җитештерү формасында да үсеш ала.




Каюлы күн эшләнмәләре үрнәкләре: читекләр, диван мендәрләре, япма. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее экспозициясе.

19 йөз ахырында Казанда 2 меңләп, якын-тирә авылларда 10 меңгә якын читек тегүче осталар эшли. Милли аяк киемнәрен иң күпләп җитештерүче һәм алар б-н сәүдә итүче сәүдәгәр Галиев була. Аның фирмасы эшләнмәләре Россия һәм чит ил бүләкләренә, ш.и. Париждагы Европа фәннәр җәмгыятенең Зур алтын (1883) һәм Бронза (1886) медальләренә, Бөтендөнья Париж күргәзмәсенең Көмеш медаленә (1889) лаек була. 1910 елда Казанда 34 җитештерүче фирманың каюлы күн товарлары сатучы 43 сәүдә кибете була. Эшләнмәләр Көнбатыш Европа, Идел буе, Урал һәм Себер шәһәрләренең эре ярминкәләренә, ш.у. Урта Азиягә җибәрелә. Нәкъ менә шуңа да аяк киеменең бу төре «Азиянеке» дип йөртелә башлый. Читекләр йомшак һәм каты табанлы итеп чыгарыла. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан хатын-кыз читекләренең аерым модельләре руслар өчен махсус тегелә башлый; 19 йөз ахырыннан аларга биек үкчәләр куела. Татар милли бизәкле аяк киемнәре 18 йөз ахырында — 20 йөз башында Оренбург (Сәет бистәсе), Торжок, Касыйм, Тобол, Томск, Бохара шәһәрләрендә дә тегелә. 20 йөзнең беренче унъеллыгында К.к.к.ндә яуланган казанышлардан артка чигенү сизелә. Ләкин 1920 елларның 2 нче яртысында яңа икътисади нигездәге эре ширкәт артельләре Казанда («Шәрекъ аяк киеме», «Кызыл кустарь», «Эш»), Арчада (Г.Тукай исем.), Питрәч һәм Дөбъяз р-ннарында («Суыксу» берләштерелгән артеле), Лаеш р-нында («Татар Кабаны» артеле) оештырыла. Аларда милли бизәкле аяк киемнәреннән башка, күннән диван мендәрләре, келәм, альбом тышлыклары чыгарыла. Артельләр продукцияләре Франциягә, Бельгиягә, Германиягә, Англиягә, Италиягә җибәрелә (1932 дә К.к.к. җитештергән 300 мең пар аяк киеменең яртысы экспортка китә). 1940–50 елларда К.к.к. системасында милли аяк киемнәре җитештерү кискен кими (аяк киемнәренең гомуми күләменең 5–6 %). 1961 дә ширкәт артельләре Арча һәм Дөбъяз ф-калары итеп үзгәртелә, 1972 дә алар Арча милли аяк киемнәре ф-касына берләштерелә (к. *Милли аяк киеме*). Анда халык кия торган заманча аяк киемнәре җитештерү җайга салына, К.к.к.нең традицион продукциясе (читекләр) аз серияләрдә һәм куллланучылар заказлары буенча гына әзерләнә. Фабрикада проф. рәссамнардан С.Кузьминых, И.Гайнетдинов, әйдәп баручы осталардан Ф.Кадыйров, Р.Сәфәров, З.Сабиров, Р.Мөхәммәтҗанова, З.Надфуллина һ.б. эшли. 2002 дә фабрика шәхси кулга күчә (җитәкчесе И.М.Минхәеров), 2006 да ябыла.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Гулова Ф.Ф. Татарская национальная обувь. К., 1983; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КАЮ́МОВ** Габдерәүф Габделхак улы (13.12.1926, Бөгелмә кантоны Сарабиккол а.), механизатор, слесарь-инструментчы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1940 елда Яңа Писмән (1955 тән Лениногорск) р-нының «Магнит» к-зында башлый, 1950–53 тә шул ук колхозның рәис урынбасары. 1943–50 дә Совет Армиясендә. Бөгелмә механикалаштыру мәктәбен тәмамлаганнан соң (1953), шул ук районның Шөгер МТСында механик-комбайнчы булып эшли. 1957–87 дә Казакъстанның Кустанай өлкәсе Боровский р-ны Будённый исем. с-зында: комбайнчы, бригадир ярдәмчесе, а.х. машиналарын ремонтлау буенча механик, терлекчелектә авыр хезмәт процессларын оештыру буенча инженер (1966 дан). Герой исеме терлек азыгы культуралары һәм бөртекле ашлык җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешелгән казанышлары һәм техникадан югары җитештерүчәнлекле файдаланганы өчен бирелә. «Сәнәгать нигезендә терлек азыгы әзерләү буенча комплекс» дигән новаторлык проекты авторы (1975). 1987–97 дә «КамАЗ» АҖнең агрегат з-дында слесарь-инструментчы. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм 5 бронза медале б-н бүләкләнә.



Г.Г. Каюмов.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КАЮ́МОВ** Гафур Шәкүр улы (2.3.1959, Арча р-ны Яңа Сәрдә а.), актёр, драматург. Казан театр уч-щесен тәмамлый (1983). 1983–90 да (бүленеп) Татар драма һәм комедия театры актёры, 1990–97 дә — Татар акад. театрында. 1997–99 да ТР Мәдәният министрлыгында театр сәнгате белгече. 1999 дан Татар акад. театрында сәхнәгә куючы режиссёр. 2000 нән «Татарстан» ДТРКда әдәби тапшырулар мөхәррире. 2005 тән Әлмәт татар драма театры режиссёры. Аеруча мөһим рольләре: театр сәхнәләрендә — Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи, 1991), месье Таккарель («Тол ханымда тукталыш», Э.Лабиш, 1993), Сәйяр («Әни килде», Ш.Хөсәенов, 2001); телевизион спектакльләрдә — Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи, 1995), Сәлимҗан («Зөләйха», Г.Исхакый, 2004). К.ның «Мирас» (1990), «Һинд кызы» (1993), «Әрнү» (1999), «Юбилей» (1992), «Соң инде...» (1998), «Сарык Арыслан» (1997) пьесалары буенча куелган спектакльләре Татар акад., Татар драма һәм комедия, Чаллы, Минзәлә, Әлмәт татар драма театрлары, «Нур» татар драма театры (Уфа ш.) сәхнәләрендә зур уңыш б-н бара. «Упкын өстендә» (2003) пьесалар җыентыгы авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КАЮ́МОВ** Дамир Каюм улы (8.12.1936, Әлки р-ны Югары Әлки а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре

(2001). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1967). 1958–82 елларда Әлки р-нында: ВЛКСМның Рус Салманы авылы ком-ты секретаре (1960 ка кадәр), 1960–62 дә ВЛКСМның район ком-ты 1 нче секретаре, 1962–64 тә КПССның «Правда» с-зы, 1964–66 да «Салман» с-зы ком-тлары секретаре. 1967–70 тә «Энергетик» с-зы директоры, 1970 тән КПСС райкомының 1 нче секретаре. 1982–88 дә КПССның Арча райкомының 1 нче секретаре. 1988–96 да ТРның Хезмәт һәм социаль мәсьәләләр буенча дәүләт ком-ты рәисе. 1996–99 да ТР Дәүләт Советының Экологик куркынычсызлык мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе. 1999 дан орлыкчылык буенча баш дәүләт инспекторы, «Дәүләт орлыкчылык инспекциясе» федераль дәүләт учреждениесенең ТР буенча башлыгы. 1975–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1995–99 да ТР халык депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**КАЮ́МОВ** Илгиз Рифат улы (4. 12.1971, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (2007). 1994 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, бер үк вакытта дифференциаль тигезләмәләр кафедрасында (2005 тән). 2000–2002 дә Вюрцбург математика ун-тында (Германия), Миттаг-Люффлер ин-тында (Швеция), 2006–07 дә Иллинойс Урбана-Шампань (АКШ) ун-ты профессоры. Хезмәтләре матем. физикага, кырый мәсьәләләргә, функцияләрнең геометрик теориясенә карый. Кабарынкы функцияләрнең интеграль уртасын бәяләүне тәкъдим итә, шулай ук өч класс өчен интеграль урталарны төгәл бәяли. Х.М.Мөштәри исем. бүләк иясе (2004).

Х е з м.: Об одном неравенстве для универсального спектра интегральных средних // Мат. заметки. 2008. Т. 84, № 1; Сходимость рядов наипростейших дробей в Lp(R) // Мат. сборник. 2011. Т. 202, № 10; Lolez Estimates For Integral Means of Univalent Functions // Arc. Mat. 2006. V. 44, № 1.

**КАЮ́МОВ** Малик Шәфыйк улы (10.8.1952, Әлмәт р-ны Мәмәт а.), тау эшләре инженеры, техник фән. канд. (2003), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), ТРның атказ. нефтьчесе (2002). Октябрь нефть техникумын (1971), Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1980) тәмамлый. 1973 елдан «Татнефть» АЖдә эшли: «Әлмәтнефть» НГДУ цехында өлкән инженер-топограф (1976 га кадәр), инженер-технолог, өлкән геолог, цех, үзәк технологик хезмәт күрсәтүләр башлыгы, «Елховнефть» НГДУда баш геолог (1998 дән), баш инженер (2001 дән), «Җәлилнефть» НГДУда идарә башлыгы (2005 тән). Дәүләт бүләге авыр алына торган нефть запасларын чыгаруда нәтиҗәлелекне күтәрү өчен яңа технологияләр һәм жайланмалар комплексын эшләгәне һәм сәнәгатькә кертәне өчен бирелә. Уйлап табуга 30 патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

**КАЮ́МОВ** Марат Каюм улы (18.1.1937, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Пошат а. — 2006, шунда ук), галим агроном, а.х. фән. д-ры (1987), проф. (1989). РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). 1956–60 елларда Псков һәм Горький өлкәләрендә агроном хезмәтен башкара. 1967 дә Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый, шунда ук эшли. 1971–81 дә ВАСХНИЛның гыйльми секретаре. 1981 дән Бөтенсоюз а.х. читтән торып белем бирү ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Балашиха ш.), ботаника һәм үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1987 дән). Хезмәтләре а.х. культуралары уңышын программалаштыруда теоретик нигезләрне һәм гамәли алымнарны эшләүгә карый.

Х е з м.: Программирование урожаев: Справ. М., 1977; Программирование продуктивности полевых культур: Справ. М., 1989.

**КАЮ́МОВ** Рәшит Габделхак улы (6.2.1951, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1997). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. 1977 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тының материаллар каршылыгы, эластиклык һәм пластиклык теориясе нигезләре кафедрасында (1995 тән). Хезмәтләре композицион материаллар халәтен матем. модельләштерүгә һәм алардан эшләнгән конструкцияләрне исәпләү алымнарына карый. К. армирланган композицион материаллар тибындагы анизотроп җисемнәр өчен билгеләгеч нисбәтләр теориясен үстерә. Цилиндрик сүрүләр эшен анализлау нигезендә, бер юнәлешле армирланган композицион материалның нәсызыкча-эластик характеристикаларын идентификацияләү алымнарын теоретик нигезли. Чик йөкләнешне эзләп табу алымының (чик тигезләнеш теориясенә нигезләнгән) теоретик нигезләрен эшли; конструкцияләрнең чыдамлылык сәләте турындагы мәсьәләләрнең аналитик чишелешен таба һәм санлы чишелешләр табу юлларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Об оценке несущей способности конструкций при произвольных условиях текучести // Прикладная механика и техн. физика. 1993. № 1; Связанная задача расчёта механических характеристик материалов и конструкций из них // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 1999. № 6; Расчёт конструкций по теории предельного равновесия. К., 2003 (автордаш).

**КАЮ́МОВ** Фаварис Кадыйр улы (1.1.1930, БАССРның Миякә р-ны Тимәш а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1978), проф. (1978). 1953 елда Сәмәрканд совет сәүдәсе ин-тын тәмамлый. 1957–87 дә Урта Азия а.х. икътисады фәнни-тикшеренү ин-тында (Сәмәркканд ш.) эшли: бүлек башлыгы, 1975 тән директор урынбасары. 1988 дән СССР Дәүләт бәяләр ком-ты Бәяләр кую буенча фәнни-тикшеренү ин-тының Урта Азия ф-лы директоры (Ташкент). Хезмәтләре сугарулы а.х. җирләре зонасында капитал салуларның нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә карый. К. тарафыннан чыгымнар һәм нәтиҗәлелек нисбәтен билгеләгәндә җирләрнең бәяләү хакын кертеп исәпләү методикасы эшләнә; средстволар җибәргәндә, диспропорция булдырмауга һәм комплекслылыкны төгәл үтәүгә нигезләп, капитал салуларның нәтиҗәлеген күтәрү юллары билгеләнә. Аның хезмәтләрендә яңа җирләрне үзләштерүнең нәтиҗәлелеге, производствоны урнаштыру, хуҗалык итүнең икътисади механизмын камилләштерү, бәяләр билгеләү проблемалары шактый зур урын алып тора. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эффективность капитальных вложений в освоение новых земель. Таш., 1968; Эффективность капитальных вложений и основных фондов в хлопкосеющих хозяйствах Узбекистана. Таш., 1974; Интенсификация сельского хозяйства хлопковой зоны СССР. М., 1985 (автордаш); Резервы повышения производительности труда в хлопководстве. Таш., 1986.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КАЮ́МОВА** Нурия Самат кызы (7.11.1931, Ленинград), гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы. Фарфор эшләнмәләр бизәү б-н шөгыльләнә. Керәч осталары нәселеннән. К.ның бабасы — Халик Мәҗитов (1843–1943) чыгышы б-н Буа өязе Каенлык авылыннан, 1917 елга кадәр Император фарфор з-дында яндыручы булып эшли. М.В.Ломоносов исем. Ленинград фарфор з-ды каршындагы сәнгать-һөнәр уч-щесен тәмамлаганнан соң, К. 1995 кә кадәр заводның сәнгать лаб-ясендә эшли. Алтын йөгертү кулланып, ялтыравыклы бизәк алымын үзләштергән танылган осталарның берсе (бүләк вазалары, сервизлар, бизәкле савыт-сабаның башка төрләре). 1949 да фарфордан И.В.Сталинга 70 яшь тулу уңаеннан җитештерелгән истәлек вазасын бизәүдә катнаша; 1994 тә К. тарафыннан бизәлгән истәлек вазасы Бөекбритания королевасы Елизавета II гә (С.-Петербургка сәфәре вакытында) бүләк ителә. Истәлек вазаларына «Петербург күренешләре» темасына сюжетлы бизәкләр сериясен эшли (2000); 2000 дә Казан мериясенә Казанның 1000-еллыгы хөрмәтенә шәһәрнең архит-ра күренешләре һәм гербы төшерелгән зур күләмле ваза бүләк итә. К. әсәрләре Ленинград фарфор з-дында саклана.

*Әд.:* Каюмова Н.С. // Петрова Н.С. Ленинградский фарфоровый завод им. Н.В.Ломоносова. Кн. 2. 1944–2004. СПб.–М., 2006.

*Р.И.Шәмсутов.*

**КАЮ́МОВА** Сания Каюмҗан кызы (8.5.1954, Казан), курчак театры актрисасы, ТРның халык артисты (2005). 1973–74 елларда һәм 1980 нән «Әкият» татар курчак театры актрисасы. Махсус белеме булмаса да, практик эш барышында курчаклар б-н эш итү чараларыннан оста файдалана, гадилек һәм табигыйлеккә ирешә, лирик һәм үткен характердагы рольләрне башкару серләрен үзләштерә. К. иҗат иткән образлар арасында аеруча сәнгатьлеләре — Будур («Гәләветдиннең тылсымлы лампасы», Н.Гернет), Дюймовочка (Г.Х.Андерсенның шул исем. әсәре буенча), Принцесса («Иткәле мәче», Ш.Перро), Нәни юлбасар кыз («Кар патшабикәсе», Е.Л.Шварц), Айсылу («Патша кәләше», М.Гыйләҗев), Чегән карчыгы («Чегәннәр», А.С.Пушкин поэмасы буенча). «Паппет-шоу» эстрада программасында К. иҗат иткән образлар сыгылмалы, нәфис, музыкаль булулары, характе-



С.К. Каюмова.

ристикаларының төгәллеге б-н аерылып торалар. Актриса курчак театры сәнгатен пропагандалау буенча тамашачылар б-н һәрвакыт актив эшли. Стара-Загора (Болгария, 2001), Ботроп (ФРГ, 2002) шәһәрләрендә халыкара театр фестивальләрендә катнаша.

**КӘБЕСТӘ́** (Brassica), кәбестәчәләр (әвернә чәчәклеләр) семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үсемлекләр ыругы. 35 төре билгеле. Евразиядә һәм Төньяк Африкада таралган, күпчелеге Урта диңгез һәм Кытайда килеп чыккан. Татарстанда 5 төре бар: кыр К.се, сарепта К.се, яисә сарепта горчицасы, май К.се (*рапс*, гәрәнкә), шалкан (турнепс), бакча К.се. Бу төрләр 4 мең ел элек формалашкан, вегетация органнары буенча шактый аерымлыклары булса да, үрчү органнары буенча бик охшаш. Беренче булып культурага К.нең яфраклы формалары кертелә. К.нең культуралы



Кәбестә: 1 — чәчәкле кәбестә; 2 — ак башлы кәбестә; 3 — кызыл башлы кәбестә.

формалары — салкынга чыдам, яктылык, югары уңдырышлы туфрак яратучы үсемлекләр, сазлыклы һәм ачы туфракта уңышны киметәләр. Башлы К. (ак һәм кызыл формалары) — Татарстанда иң төп яшелчә культураларының берсе — үрентеләрдән үстерү ысулы б-н барлык районнарда игелә, ел саен 2800–2900 *га* мәйданда үстерелә. Уңышы 1 *га* дан 400–500 *ц*.

Бакча кишәрлекләрендә К.нең ш.у. савойя, Брюссель, чәчәкле, шалкан (яисә кольраби) һ.б. төрләрен үрчетәләр. ТРда җитештерүдә файдалану өчен тәкъдим ителгән ак башлы сортлары: иртә өлгерүче — «Золотой гектар» (1953), «Номер первый грибовский 147» (1953), «Июньская» (1986), «Казачок» (1997), «Трансфер» (1999), «Малахит» (1999), «Старт» (2001); уртача вакытта өлгерешле — «Надежда» (1975), «Слава 1305» (1987), «Лосиноостровская 8» (1987), «Экстра» (2001), «СБ-3» (2003); уртача соң вакытта өлгерешле — «Подарок» (1960); соң өлгерүче — «Зимовка 1474» (1986), «Харьковская зимняя» (1990), «Амагер 611» (1991), «Крюмон» (1993), «Колобок» (2002); кызыл башлы К.ләр: «Каменная головка 447» (1961), «Гако» (1996), «Михнёвская (1996); савойя К.ләре: »Юбилейная 2170« (1992), »Вертю 134« (1996); чәчәкле К.ләр: »Ранняя грибовская 1355 (1953 кә кадәр), «Гарантия» (1988), «Мовир 74» (1988), «Отечественная» (1997); Брюссель К.се: «Геркулес» (1996); кольраби К.: «Венская белая 1350» (1965); Пекин К.се: «Хибинская» (1996).

Орлыкка К. икееллык культура итеп үстерелә. Бер үсемлектән 40–50 *г* орлык (1 *га* дан 5–6 *ц*) җыела. Уңышка җир борчалары, кәбестә чебене, кәбестә көясе, кәбестә ябалакчыгы, кәбестә гөбләсе, кәбестә кандаласы, рапс чәчәкашары һ.б. корткычлар зур зыян китерә. Киң таралган авырулар: әвернә чәчәклеләрдәге кила авыруы, кара аяк, альтернариоз, ялган ончыл чык, сары һәм ак черек. Көрәш чаралары: чәчү әйләнешен дөрес саклау, кырларны чүп үләннәрдән чистарту, ашламаларны фәнни нигезләнгән дозада кертү, дөрес күләмдә сугару, орлыкларны инкрустацияләү, чәчүлекләрне инсектицидлар һәм фунгицидлар б-н үз вакытында эшкәртү.

*Әд.:* Бакин О.В., Рогова Т.В., Ситников А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000; Сельское хозяйство: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

*И.Н.Афанасьев.*

**КӘБЕСТӘЧӘЛӘ́Р**, к. *Әвернә чәчәклеләр.*

**КӘБИ́РОВ** Галимҗан Фазылҗан улы (12.1.1957, Буа р-ны Кече Шыгырдан а.), терлекчелек технологиясе белгече, вет. фән. д-ры (2000), проф. (2001). 1984 елда Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. мед. академиясе) тәмамлагач, шунда ук эшли, 2000 нән терлекчелек технологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта зооинженерия ф-ты деканы, 2003 тән ректор. Хезмәтләре бакыр хелат кушылмаларның ашкайнатуга, матдәләр алмашына һәм яшь сарыклар продукциялелегенә тәэсирен өйрәнүгә, сарыкларда, дуңгызларда гипомикроэлементозларны булдырмау һәм дәвалау чараларын эшләүгә карый.

Хезм.: Рекомендация по использованию хелатокомплексных соединений в овцеводстве. К., 1997; Практический курс скотоводства. К., 2002.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КӘБИ́РОВ** Фирдәүс Зариф (19.5.1961, Чаллы ш.), спортчы (автомобиль спорты), РФнең халыкара класслы спорт остасы (1997), ТР, РФнең атказ. спорт остасы (1999, 2003). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1984). 1987 дән «КамАЗ-Мастер» командасында штурман, 1992 дән пилот; «Ельч» 1988, «Обжектив сюд 1989», «Париж-Дакар 1991», «Мастер-Ралли 1996», «Байконур-Мәскәү 1997», «Париж-Каһирә 2000», «Бажа-Италия 2000», «Телефоника-Дакар» 2003, 2004, «Дезерт Челендж 2004», «Лиссабон-Дакар 2006», «Маршрут 1000» 2008, «Дакар. Аргентина-Чили» 2009, 2010, 2011, «Ефәк юлы»-«Дакар» сериясе 2010, 2011 раллиларында призлар ала. «Оптик 2000» 1997, «Мастер-Ралли 1997», «Дезерт Челендж 2000», «Пор Лас Пампас 2001», «Хәзәр далалары 2003», «Телефоника-Дакар 2005», «Ефәк юлы»-«Дакар» сериясе 2009 раллиларында, Дөнья кубогына ралли-марафоннарда (1997, 2011) җиңүче. 1984–86 да «Автовазтехобслуживание» республика үзәгендә (Казан), 1986–87 дә Кама трактор з-дында (Алабуга ш.) эшли, 1987 дән «КамАЗ» АҖнең фәнни-техник үзәгендә (1995 тән йөк автомобильләре КБ җитәкчесе). РФ Дәүләт бүләге лауреаты (2000). 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Хезмәт Кызыл Байрагы, Почёт, Дуслык, Батырлык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2002).

*Әд.:* Якубова О. Мой финиш — горизонт. Крань (Словения), 1998.

**КӘВЕ́Ш** (гарәп. كفش), татарларда резин галошлар барлыкка килгәнче кулланылган аяк киеме. Күп төрләре булуы билгеле — күн (ката), йөннән басылган (киез ката), юкәдән агач табан куеп эшләнгән (чабата, юкә башмак) К.ләр. Күн К.ләр тирәнрәк (тирән кунычлы К.) һәм сайрак (сай К.) итеп эшләнгән. Урал яны төбәкләрендә сай К.ләрнең кыска, әмма киң киндер яки постау кунычлы итеп эшләнеп, баулар б-н тарттырып куела торганнары да файдаланылган. Тирән эчле К.ләр һәрвакыт үтемле булган; хәзерге вакытта фабрикада җитештерелгән тирән эчле резин галошларга ихтыяҗ зур.

*Әд.:* Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

**КӘГЪБӘ́** (гарәп. ألكعبة — куб), Кәгъбәтуллаһ, исламның төп изге урыны, мөселманнар намазны шул тарафка карап укыйлар (к. *Кыйбла*). Ел саен К.гә *хаҗ* кылырга бару — ислам ритуалындагы төп элементларның берсе. К. *Мәккә* шәһәрендәге җамигъ мәчет әл-Мәсҗид әл-Хәрам үзәгендә урнашкан һәм 10×12×15 *м* зурлыктагы таш бинадан гыйбарәт. Төзелгән вакыты билгесез. К.нең почмаклары дөньяның дүрт тарафына карап тора. Көнчыгыш яктагысы «кара почмак» дип атала: аның куышына Аллаһ тарафыннан Җиргә төшерелгән һәм аның кодрәтен чагылдырган көмеш кысалы «кара таш» — хәҗәре әсвәд урнаштырылган. Ул кара-кызыл төстәге бергә кушылган өч кисәктән тора. Мөселман риваятьләренә караганда, ул Аллаһ тарафыннан Адәмгә *җәннәттән* куылганнан соң тапшырылган, соңрак бу ак төсле якут таш кешеләр кылган гөнаһлардан каралган, дип фараз ителә. К.нең төньяк почмагы «Гыйрак», көнбатышы — «Сүрия», көньягы «Йәмән» дип атала. Гадәттә, К. Коръән *айәтләре* чигелгән кара япма (кыйсва) б-н ябыла. Риваять буенча, төньяк-көнчыгыш диварының тышкы ягында *Исмәгыйль* пәйгамбәр һәм аның әнисе Һаҗәр җирләнгән. Диварда 2 *м* биеклектә К. ишеге урнашкан. Изге бинаның эчендә өч колонна, күпсанлы лампалар, бүләк ителгән *Коръән* күчермәләре бар. К. тирәли таш җәелгән. Хаҗ кылучылар, гадәт буенча, шушы изге бина тирәли әйләнәләр (тәваф). «Кара таш» каршында изге *Зәмзәм* чишмәсе чыга. Мөселман риваятьләре буенча, аның өстендәге беренче бинаны — Адәм, К.нең үзен аның улы Шис (Библиядәге — Сиф) төзегән. Туфан вакытында К. һавага күтәртел-

гән. Вакытлар узу б-н К. җимерелә. Ибраһим пәйгамбәр улы Исмәгыйль б-н Мәккәгә күчеп килгәч, Аллаһ аңа К.нең нигезен торгызырга боера. Ибраһим Аллаһның әмерен үти һәм барлык мөселманнарга К.гә хаҗ кылырга васыять әйтеп калдыра. Ул — бөтен дөнья мөселманнары бердәмлегенең мөһим символы һәм үзәге. Аның изгелеген һәм аеруча әһәмияткә ия булуын исламдагы барлык агымнар да таный.

*Әд.:* Пиотровский М.Б. Коранические сказания. М., 1991; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**КӘДЕ́К** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 40 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сармаш елгасы буенда. 2010 елда 38 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Зирекле, Елантау исемнәре б-н дә билгеле. Беренче булып монда марилар килеп урнаша. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киндер сугу, чабата үрү, агач савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышы* (1773–75) чорында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.тә су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 566 дис. тәшкил итә. 1929 да К.тә «Кызыл Кәдек» к-зы оештырыла, 1950 дә ул Чапаев исем. к-з б-н берләшә (1998 дән — «Сармаш» а.х. товарлары житештерү кооперативы). 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1972 нең 1 февраленнән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 98, 1884 тә — 166, 1920 дә — 402, 1926 да — 223, 1938 дә — 309, 1949 да — 285, 1958 дә — 251, 1970 тә — 223, 1979 да — 166, 1989 да — 26, 2002 дә — 50 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**«КӘҖӘ́ БЕЛӘ́Н САРЫ́К»**, хайваннар турындагы әкиятләр циклыннан татар халык әкияте. Сюжеты күп кенә халыклар фольклорында киң таралган. Кәҗә б-н Сарык, хуҗаларының суеп ашауларыннан куркып, өйдән чыгып китә. Юлда алар бүре башы табалар һәм капчыкларына салып куялар. Бу вакыт урман читендә берничә бүре ботка пешереп ята торган була. Кәҗә б-н Сарыкны күргәч, алар, боткага ит тә була, дип куанышалар. Әмма Кәҗә б-н Сарык капчыктагы башны чыгаргач, бүреләр куркып калалар һәм әкренләп качып бетәләр. Кәҗә б-н Сарыкның хәйләкәрлегe һәм тапкырлыгы бүреләрнең ахмаклыгыннан өстен чыга. Татар фольклорында әкият берничә вариантта билгеле. Әкият сюжетына нигезләнеп, Г.Тукай шул ук исемдәге поэма иҗат итә.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Ахметова Ф.В. О татарских бытовых сказках // Фольклор народов РСФСР. Уфа, 1976.


*Ф.И.Урманчеев.*

**КӘҖӘ́ БИСТӘСЕ́**, революциягә кадәрге Казанның төньяк читендә, Казансу елгасының уң ягында 17 йөзнең 2 нче яртысында оеша (хәзерге Чистай, Декабристлар, Эшче, Яңа авыл урамнары). Шәһәр б-н Хижицкая (хәзерге Ленин) дамбасы аша тоташа. К.б.нә 1654–56 еллардагы чума эпидемиясе вакытында Казаннан күчеп килгән кешеләр нигез сала. К.б.ндә бау-аркан ишү, шәм кою үсеш ала; ул дару үләннәре җыючылары б-н дан тота. Урыны язын су баса торган үзәннәргә бай була, аларда кәҗәләр көтәләр. 19 йөз ахырыннан шәһәр терр-ясенә керә.

*Әд.:* Бикбулатов Р., Мустафин Р. Казань и её слободы. К., 2001.

**КӘҖӘ́ САКАЛЫ́** (Tragopogon), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 дән артык төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә 5 төре үсә. Зур К.с. (T. major), көнчыгыш К.с. (T. orientalis), болын К.с. (T. pratensis) бөтен районнарда да очрый; чәнечке борынлы К.с. (T. dasyrhynchus), Подольск К.с. (T. podolicus) — республика флорасы өчен сирәк төрләр. Болыннарда, урманнарда, чәчүлек җирләрдә, елга буйларында үсә. 20–120 *см* биеклектәге икеellык үсемлек. Сабагы гади яки ботаклы, шома яки төкчәле. Яфраклары кыяк, бөтен читле. Чәчәкләре сары, телсыман, бер рәттән торучы чәчәкләр төргечле эре кәрзиннәрдә урнашкан. Җимеше — бүрекчәле орлыкча. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Болын К.с. бәвел кудыру һәм яра төзәтү үзлекләренә ия, халык медицинасында кулланыла. Терлек азыгы. Баллы үсемлек.

**КӘҖӘБОЛАННА́Р**, кыр кәҗәләре (Capreolus), боланнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 2 төре билгеле, Евразиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — Себер К.ы (C. pygargus) бар. Кама аръягында һәм Идел-Кама саклаулыгында очрый. Зур аланлы, кисенделе якты һәм катнаш урманнарда яши. Озынлыгы 1,5 *м* га, биеклеге җилкә калкымында 1 *м* га кадәр; ата К. 60 *кг* га кадәр авырлыкта, аналары кечерәк. Җәен — кызгылт, кышын көрән яки кызгылт төсмерле соры төстә; балалары — тимгелле. Кечкенә башлы, озын муенлы төз хайван. Ата затларның зур булмаган, туры диярлек 3–5 тармаклы мөгезе бар. Ул төптән үк озынча чыгынтылы һәм төерле. Колаклары зур, очлаеп тора, койрыгы кыска, йон астына яшеренгән. Аяклары озын һәм нечкә. Җәен К., гадәттә, гаилә булып яши. Көзен, мөгезләрен салгач, 20–30 башка җиткән катнаш көтүләр барлыкка китерә, кышын 2–4 зат булып төркемнәргә бүленә. Февральдә ата К.ның яңа мөгезләре үсеп чыга. Кушылу вакыты июльдән сентябрьгә кадәр. Буазлык чоры 9 ай тирәсе. Язын 1–2 бала китерә. 2–3 яшьтә җенси яктан өлгерәләр. Үлән, куак һәм агач ботаклары, җиләкләр, лишайниклар б-н туклана. Ана К. 11–12 ел, ата К. 16 яшькә кадәр яши. К. өчен селәүсен, бүре, сукбай этләр куркыныч тудыра. Сунарчылык объекты.


1 2

1. Ата кәҗәболан; 2. Ана кәҗәболан.

*Әд.:* Европейская и сибирская косули: систематика, экология, поведение, рациональное использование и охрана. М., 1992.

**КӘЗКӘ́Й** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, БР б-н чиктәш. 2010 елда 304 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кадыкеево, Кадыпеево исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек б-н шөгыльләнә, печән әзерләү пунктларында һәм Агыйдел елгасы буендагы пристаньнарда эшли. 20 йөз башында К.дә мәчет (беренче мәртәбә 1844 тә телгә алына), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2970 дис. тәшкил итә. 1929 да К.дә «Яңа тормыш» к-зы оештырыла, 1955 тә «Изаил» к-зы (1965 тән Ленин исем.; хәзерге вакытта — «Аеш» ЖЧЖ) составына керә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостенда. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 80 ир-ат; 1884 тә — 839, 1897 дә — 818, 1908 дә — 828, 1920 дә — 951, 1926 да — 855, 1949 да — 577, 1958 дә — 463, 1970 тә — 585, 1979 да — 475, 1989 да — 351, 2002 дә — 335 кеше.

**КӘКРЕ́ АТА́У** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 497 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1782 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Абдрахманово, Русское Озеро исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, балта, токарьлык эше, паркет ясау, аяк киеме һәм бияләйләр тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.А.да мәчет (1889–90 да төзелә, архит-ра истәлеге), мәдрәсә, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1121 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1859 да — 496, 1897 дә — 970, 1908 дә — 1110, 1920 дә — 1303, 1926 да — 689, 1938 дә — 665, 1949 да — 710, 1958 дә — 687, 1970 тә — 880, 1979 да — 607, 1989 да — 558, 2002 дә — 524 кеше.

*Әд.:* Е н д и р я к о в В.А. История Егоркинской волости Чистопольского уезда Казанской губернии (с середины XVII в. до 1930 г.). Елабуга, 1994.

**КӘКРЕ́ ЕЛГА́**, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,9 *км*, бассейнының мәйданы 92,7 *км*$^2$. Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Куәтле Елга авылыннан (даими яшәүчеләр юк) 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Мәсгут авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 120 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 23%. К.Е.ның 0,3 тән алып 11 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,51 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 79 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К.Е. ноябрьнең 2 нче яртысында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*$^3$/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. К.Е. бассейнында күләме 8 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КӘКРЕ́ ЕЛГА́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кәкре Елга елгасы буенда. 2010 елда 671 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1748 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Е.да мәчет, мәктәп, башка җирләргә күчерү пункты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5334 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мәсгут волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 266 ир-ат; 1859 да — 1001, 1890 да — 1496, 1910 да — 1794, 1920 дә — 2029, 1926 да — 1489, 1938 дә — 1242, 1949 да — 777, 1958 дә — 493, 1970 тә — 749, 1979 да — 743, 1989 да — 721, 2002 дә — 709 кеше.

**КӘКРЕ́ КҮ́Л**, Идел алдында. Элеккеге су юлында сакланып калган. Буа р-ны Аккүл авылыннан көнбатыштарак Зөя елгасының уңъяк яры тугаенда. Су өслегенең мәйданы 1,72 *га*. Озынлыгы 530 *м*, иң зур киңлеге 60 *м*.

**КӘКРЕ́ КЫЛЫ́Ч**, салкын коралның чаба торган төре; саплы кылыч, бөгелгән корыч йөзенең тышкы ягы үткен була. 6 йөздә Көнчыгыш Европа һәм Урта Азиядәге күчмә төркиләрдә барлыкка килә. Аның киң кулланылышы кәкре йөзенең көчле чабу көченә бәйләнгән. Соңга таба кискечнең кәкрелегеn һәм кисү өлешен арттыру юлы б-н камилләштереlә; 13–17 йөзләрдә кайбер К.к.ларның кисү өлешендә уентык һәм оч тирәсенең киңәюе күзәтелә. Урта Идел буенда бу төр коралны Идел буе болгарлары беренче тапкыр 8–9 йөзләрдә кулланугa кертә. 9–16 йөзләрдә К.к. төрки халыкларда иң киң таралган кискеч коралга әверелә. Әлгәре урта гасырларда аны башлыча авыр коралланган атлы сугышчылар кулланса, яңа чорда җиңел кавалерия (гусарлар, казаклар) куллана. Кайбер Үзәк Азия кылычларында — рун хәрефләре очрый, Идел буе Болгар дәүләтендә 13 йөздә әрмән язулары булган кылычлар эшләнә. Рус телендәге «сабля» сүзен (саплы) күп кенә белгечләр (Ф.Е.Корш, И.Г.Добродомов, Н.А.Баскаков һ.б.) төрки телләрдән алынма дип исәплиләр.

*Әд.:* М е р п е р т Н.Я. Из истории оружия племён Восточной Европы в раннем средневековье // Советская археология. 1955. Т. 23; Х у д я к о в Ю.С. Вооружение средневековых кочевников Южной и Центральной Азии. Новосиб., 1986; И з м а й л о в И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII вв. Магадан — К., 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**КӘКРЕ́ ЧИШМӘ́** елгасы; к. *Пакшин.*

**КӘКРЕКҮ́Л** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 401 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә, тәгәрмәч ясау, балта эше, тимерчелек, йон-тукыма ману, бизәк төшерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе урнаша; София чиркәве, авыл банкы, земство мәктәбе (1872 дә ачыла), хастаханә, 3 тимерчелек, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2253 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 767, 1897 дә — 1319, 1908 дә — 1660, 1920 дә — 1504, 1926 да — 1244, 1938 дә — 1280, 1949 да — 891, 1958 дә — 701, 1970 тә — 707, 1979 да — 707, 1989 да — 490, 2002 дә — 469 кеше.

**КӘЛӘ́Й** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 1638 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Катнаш терлек азыгы з-ды. 1727 дә Рус Акташы авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1875 тә К.дә мәктәп ачыла, ул миссионерлык оешмасы (1878 дә земствоныкы итеп үзгәртелә) хисабына яши. 20 йөз башында 2 су тегермәне, 2 бакалея һәм 2 икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2591,8 дис. тәшкил итә. 1915 тә агачтан Дмитриев чиркәве төзелә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Акташ волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1747 дә — 82, 1782 дә — 97 ир-ат; 1841 дә — 482, 1859 да — 629, 1870 тә — 752, 1897 дә — 1158, 1900 дә — 1272, 1920 дә — 1448, 1926 да — 1125, 1938 дә — 1073, 1949 да — 952, 1958 дә — 943, 1970 тә — 941, 1979 да — 931, 1989 да — 1310, 2002 дә — 1675 кеше.

**КӘЛӘ́Й** т и м е р ю л с т а н ц и я с е п о с ё л о г ы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 13 *км* көнбатыштарак, Әгерҗе-Акбаш тимер юлы буенда. 2010 елда 1944 кеше (татарлар — 50%, руслар — 39%) яши. А.х. товарлары җитештерүчеләрне ашламалар, төзү материаллары һәм җиһазлар б-н тәэмин итү пр-тиеләре. Урта мәктәп. Мәдәният йорты. Китапханә. Чиркәү. 1954 тә Кәләй тимер юл станциясе посёлогы буларак нигез салына. 1960 та тимер юл файдалануга тапшырыла. Халык саны: 1989 да — 1922, 2002 дә — 2010 кеше.

**КӘЛӘ́Й УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Әлмәт, Яңа Чишмә һәм Зәй р-ннары терр-ясендә урманчылык эшләрен алып бара. 1931 елда Шөгер урман хуҗалыгы буларак оештырыла, 1958 дән Шөгер урман сәнәгате хуҗалыгы, 1968 дән Кәләй урман сәнәгате хуҗалыгы, 1991 дән хәзерге исемендә. Территориясе берничә тапкыр үзгәртелә. 2002 ел башына К.у.х.ның гомуми мәйданы 40951 *га*, ш.и. урман мәйданы 38690 *га*. Түбәндәге урманчылыкларны үз эченә ала: Чишмә № 1 (14249 *га*), Бота (9157 *га*; 1991 гә кадәр Әлмәт урман хуҗалыгы составында), Иске Ялан (8117 *га*; 1991 га кадәр Әлмәт урман хуҗалыгы составында) һәм Рокашево (9428 *га*; 1992 гә кадәр Зәй урман хуҗалыгы составында). Урман хуҗалыгы дирекциясе Әлмәт р-ны терр-ясендә, Кәләй тимер юл станциясе посёлогында урнашкан. Эшләүчеләр саны 130 кеше.

1 нче төркем урманнар 4296 *га* мәйданны били, ш.и. әйләнә-тирә мохитне саклау өчен әһәмиятле урманнар — 4161 *га*, эрозиягә каршы утыртылган урманнар — 83 *га*, тимер юл буйларындагы саклагыч полосалар — 52 *га* һ.б. 2 нче төркем, ягъни җирле файдалануда әһәмиятле урманнар 36665 *га* мәйданны алып тора. Урман культуралары мәйданы 4943 *га*. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 31%, урта яшьтәгеләре — 36%, өлгереп килүчеләре — 13%, өлгергәннәре һәм картайганнары 20% тәшкил итә. Нарат урманнары 2352 *га* мәйданны биләп тора, аны кулдан утыртылган яшь һәм урта яшьтәге агачлар тәшкил итә. Юкәле һәм чикләвек агачлы наратлыклар аеруча киң таралган. Чыршылыклар аерым участок булып, ш.у. кулдан утыртылганнары 1289 *га* мәйданда үсә. Юкә урманнарының мәйданы 11520 *га*, агач запасы 1625 мең *м*$^3$; күбесенчә үсентеләрдән барлыкка килгән каен һәм усак, өрәңге катнаш төрле үләнле юкәлекләр өстенлек итә. Каенлыклар (4047 *га* мәйданда; агач запасы 472 мең *м*$^3$)



Ә.М. Кәлиев.

һәм усаклыклар (31712 *га* мәйданда; агач запасы 1910 мең *м*³) элеккеге урманнар урынында барлыкка килгәннәр һәм чагыштырмача чиста массив булып утыралар. Имәнлекләр чикле күләмдә, Рокашево һәм Чишмә № 1 урманчылыгы терр-яләрендә аерым участокларда үсәләр; тәбәнәкләр, үсентеләрдән барлыкка килгәннәр, гомуми мәйданы 2517 *га*. Чишмә урманчылыгында 1987 дә табигать истәлеге буларак билгеләнгән *Чыршы һәм карагай урман культуралары* участоклары бар.

Һәр ел саен 250 *га* мәйданда урман торгызу эшләре алып барыла, күбесенчә яшь урман утыртыла. Урман хуҗалыгының даими эшләүче базис питомнигында 5–6 төрле агач-куак токымнарының 1,3 млн. үсентесе һәм чәчкене үстерелә. Халык хуҗалыгы товарлары җитештерелә. 2007 ел ахырында шул ук исемдәге урманчылык итеп үзгәртелә.

**КӘЛӘПҮ́Ш**, к. *Түбәтәй.*

**КӘЛИ́ЕВ** Әнвәр Мәди (Мәһди) улы (8.3.1921, Түбән өлкәсе, хәзер Яркәү р-ны Тархан а. — 1997, Үзбәкстан Респ-касының Ташкент өлкәсе Курганча пос.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), старшина (1946). Колхозда эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 326 нчы аерым разведка ротасы разведчигы (65 нче армиянең 246 нчы укчы дивизиясе). Дон, Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Украина һәм Белоруссияне азат итүдә, Көнчыгыш Пруссия (1945) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 16 сентябрендә Мезино авылы (Чернигов өлкәсе Короп р-ны) тирәсендә һәм 1943 нең 19 октябрендә, Лоев посёлогы (Гомель өлкәсе) янында разведка операцияләре үткәргәндә батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып Днепр елгасын кичеп чыга һәм дошманның ут нокталары урынын тәгаенли. 1946 елдан Ташкент өлкәсенең Галәбә р-ны Курганча посёлогында яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Җиңү юлы. К., 1946; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои земли Тюменской. Свердловск, 1975; Ветераны в строю. М., 1981; Днепр — река героев. Киев, 1983.

*В.А.Шагалов.*

**«КӘЛИЛӘ́ ВӘ ДИМНӘ́»**, урта гасырлар фарсы һәм гарәп әдәбияты ядкәре. 6 йөздә фарсы теленә «К. вә Д.» дип (беренче 2 бүлек персонажлары — 2 шакал исеме б-н) тәрҗемә ителгән борынгы һинд фольклор китабы «Панчатантра»га нисбәтле. Әсәрнең бердәм тоташ сюжеты юк, ул аерым бүлекләрдән — гыйбрәтле хикәяләрдән тора. Әсәрнең нигезен Дабшалим патша б-н акыл иясе Бәйдаба арасында барган әңгәмә тәшкил итә. Һәр бүлек башында аның темасы билгеләнә, аннары патша үтенече б-н аның асылы аңлатыла. Һәр бүлек ахырында күтәрелгән мәсьәләләргә нәтиҗәләр ясала. Шул рәвешчә, җыентык тәгәл системага салынган структурадан гыйбарәт.

«К. вә Д.»дәге вакыйгалар һәм хәлләр төрле урыннарда бара: җирдә, су астында, һавада. Хикәяләрдә катнашучылар — игенчеләр һәм һөнәрчеләр, акыл ияләре һәм руханилар, ирләр һәм хатын-кызлар, балалар һәм олы яшьтәге кешеләр. Алар б-н беррәттән әсәрдә төрле җәнлекләр (хайваннар), кошлар, мифик затлар да урын ала. Алар да кешеләр кебек сөйләшәләр, уйланалар, эшлиләр, яраталар, канәгатьсезлек күрсәтәләр. Аларда кеше табигатенә хас сыйфатлар, язмышларында кешеләр арасында очрый торган катлаулы мөнәсәбәтләр чагылыш таба. Бу тереклек ияләре еш кына үзләрен кеше дип исәплиләр.

8 йөз уртасында Ибне әл-Мукаффа (723/724 тә туган) тарафыннан гарәпчәгә тәрҗемә ителгән бу әсәр төрле версия һәм вариантларда Шәрекъ мөселман дөньясында киң тарала. 13 йөздә гарәп версиясе испан һәм борынгы яһүд телләренә, аннары латин (14 йөз), немец (1470), төрек (16 йөз), соңыннан француз, инглиз һәм рус телләренә тәрҗемә ителә. Әсәрнең төрки-татар теленә тәрҗемә ителгән 10 га якын варианты билгеле, иң борынгылары 15–16 йөзләргә карый. Г.Фәезханов тарафыннан тәрҗемә ителгән (Казанда 1889–91 дә басылып чыга) вариант татарлар арасында аеруча киң тарала. «К. вә Д.»нең мотив һәм сюжетлары татар әдәбиятында да еш файдаланыла (Кол Гали, Мөхәммәдьяр һ.б.ның әсәрләрендә).

Чыг.: Ибн аль-Мукаффа. Калила и Димна / Пер. с араб. Б.Шидфар. М., 1986; Кәлилә вә Димнә: Хикәятләр / Төз. Җ.Г.Зәйнуллин. К., 1996.

*Әд.:* З ә й н у л л и н Җ. Ибне Фазлан сәяхәтнамәсе һәм «Кәлилә вә Димнә» турында // Казан утлары. 1986. № 11; М и н н е г у л о в Х.Ю. Татарская литература и восточная классика: Вопросы взаимосвязей и поэтики. К., 1993.

*Җ.Г.Зәйнуллин.*

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Айдар Миңнемансур улы (19.6.1969, Алабуга ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2006), проф. (2009). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1991), шунда ук эшли, 1996–2000 елларда тарих һәм гомумтарих каф. мөдире, 2000–08 дә тарих-филол. ф-ты деканы, 2008–11 дә ректор. 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-тының Педагогика һәм психология ин-ты директоры. Тарих фәненең яңа юнәлешен — экологик тарих тармагын булдыруга зур өлеш кертә. Хезмәтләре Татарстан сәнәгать үзәкләренең экологик тарихларына, табигатьне саклау мәсьәләләренә карый. РФ Төбәк тарихын өйрәнүчеләр берлеге (2006), Европа экологик тарих җәмгыяте (Бөекбритания, 2003) әгъзасы. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007).

Х е з м.: Природно-охранные проблемы в контексте индустриального развития Татарстана (1960 — нач.1990). К., 2005; Историческое исследование региональных экологических проблем. М., 2006; Экологическая история промышленного города 2-й пол. 20 в. К., 2011.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Амил Камил улы (14.5.1950, Мәскәү), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), ТРның атказ. химигы (2006). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, «Россия» химия комб-тының полимерлар җитештерү цехында мастер, инженер-технолог, участок башлыгы (Ростов өлкәсенең Каменск-Шахтинский ш.). 1978–89 да, 1999–2004 тә «Түбәнкаманефтехим» АҖдә: смена башлыгы, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, этилен з-дында баш инженер (1986 дан), олигомерлар з-дында баш технолог (1999 дан). 1989–97 дә «Тобол нефть-химия комбинаты» АҖнең бутилкаучук з-дында баш инженер. 1997–98 дә «Спирт-аракы заводы»ның кече пр-тиесендә ген. директор урынбасары (Казакъстанның Кустанай ш.). 1998–99 да «Сибирячка» АҖдә ген. директор урынбасары (Тобол ш.). 2004 тән «ТАИФ-НК» АҖнең бензин з-ды директоры. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2008).

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Әхмәт Закир улы (10.6.1919, хәзерге Питрәч р-ны Тау Иле а. — 1967, Казан), балет артисты, балетмейстер, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1965). Проф. сәхнәгә үзешчән сәнгать коллективыннан килә. 1938–40 елларда ТАССРның Җыр һәм бию төркеме артисты. 1940–41 дә Татар опера һәм балет театрында балет артисты (бер үк вакытта театрның балет мәктәбендә укый). 1941–46 да хәрәкәттәге армиядә була (флотта хезмәт итә, Япониягә каршы сугышта катнаша). 1946–54 тә Татар опера һәм балет театры артисты. 1954–67 дә Казанның Халык иҗаты йортында хореография бүлеге мөдире һәм, бер үк вакытта, 1958–62 дә ТАССР Җыр һәм бию ансамбле балетмейстеры. Ансамбльдә куйган хореографик күренешләре һәм биюләре: «Ялда», «Әпипә», «Ак бүрек», «Көтүче биюе», «Баламишкин», «Егетләр», «Сөмбел», «Кызлар лирик биюе» һ.б. Ф.Ә.*Гаскәров* традицияләрен дәвам иттерүче. 1937 дән 1960 ел урталарына кадәр (бүленеп) Казанда «Хезмәт резервлары» җыр һәм бию ансамблендә бии һәм яшьләр хореография коллективы б-н җитәкчелек итә.

*В.Н.Горшков.*

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Бари Гыйбәт улы (10.4.1907, Уфа губ., Златоуст өязе Дуван-Мәчетле а. — 21.7.1989, Уфа ш.), архитектор, сәнгать фән. д-ры (1976), Төзелеш һәм архит-ра академиясе мөхбир әгъзасы (1957), РСФСРның атказ. архитекторы (1976), БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1947). Новосибирск төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1935) «Башпрогор» трестының шәһәрләр планлаштыру секторын җи-

тәкли. 1951–63 елларда СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында фәнни хезмәткәр. 1966 дан — Казан төзүче инженерлар ин-тының архит-ра каф. мөдире, проф. (1976). Хезмәтләре шәһәр төзелеше, башкорт халык архит-расы, авылларны планлаштыруга карый. БАССРның Архитекторлар берлеген оештыручыларның берсе (1935), аның беренче рәисе. Уфада Җиңел сәнәгать халык комис-ты (1936–37, хәзер К.А.Тимирязев исем. Башкорт пед. ин-тының 3 нче бинасы), Башкорт пед. ин-тының төп бинасы (1950, хәзер Башкорт ун-тының төп бинасы), Советлар йорты (1950, хәзер Уфа авиатехник ун-тының төп бинасы) һ.б. җәмәгать биналары проектларының автордашы. Ишембай (1939), Белорецк (1939), Баймак (1940), Эстәрлетамак (1942–46) шәһәрләренең ген. планнарын әзерләүдә катнаша.

Х е з м.: Планировка и застройка башкирских деревень. Уфа, 1959; Башкирское народное зодчество. Уфа, 1978; Деревянная резьба в народной архитектуре. Уфа, 1984.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Илгиз Нурулла улы (20.3.1929, Апас р-ны Болын-Балыкчы а. — 1.7.1989, Казан), шагыйрь, тәрҗемәче. Рус телендә иҗат итә. Бала чактан ук инвалид. Беренче шигырьләре 1950 еллар башында «Комсомолец Татарии» г-тасында, Мәскәүдә чыга торган «Смена», «Юность» ж-лларында басыла башлый. Шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Сафта» («В строю», 1956), «Дуслар белән бергә» («Вместе с вами, друзья», 1959), «Кояш, безнең җырга кушыл!» («Солнце, влейся в песню!», 1966), «Бәхет магистралендә» («На магистрали счастья», 1969), «Изге чакыру» («Священный зов», 1975), «Кешеләргә табан...» («Дорога к людям», М., 1978), «Таңнар миннән агыла...» («Плывут рассветы сквозь меня...», 1979), «Туачак көнгә ышанам» («Верю в день восходящий», 1983) исемле җыентыклар авторы. К.ның әсәрләре тормыш турында фәлсәфи уйланулар, югары гражданлык сыйфатлары б-н аерылып тора. К. шигырьләрендә нык ихтыярлы, батыр ир-егетләргә, бөек төзелешләрдә илһамланып эшләүче яшьләргә дан җырлана, шагыйрь аларның ашкынулы мәхәббәтен, хезмәт героикасын романтик күтәренкелек б-н гәүдәләндерергә омтыла. 1977 дә К.ның шигырьләре, татар теленә тәрҗемә ителеп, «Җиргә мәдхия» исеме б-н басылып чыга. К. ш.у. Х.Туфан, М.Хөсәен һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә.

Ә с ә р.: Стихи и поэмы: Избр. К., 1989.

*Әд.:* П а у ш к и н Г. Сафка кайту // Совет мәктәбе. 1956. № 7; К у т у й Р. Перед бедою не поник // Волга. 1968. № 9.


**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Рафаэль Гомәр улы (18.12.1942, Кемерово өлкәсенең Белово ш.), генерал-майор (1991). Кемерово тау ин-тын (1965), СССР Дәүләт иминлеге ком-ты Югары мәктәбен (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1966–67 елларда Кемерово шәһәрендә ВЛКСМның Үзәк р-н ком-ты, 1967–69 да шәһәр ком-ты секретаре. 1971–85 тә Кемерово өлкәсе Дәүләт иминлеге ком-ты идарәсендә. 1985–87 дә СССР Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе (Мәскәү) хезмәткәре, бүлек башлыгы урынбасары. 1987–93 тә ТР Дәүләт иминлеге ком-ты рәисе. 1993 тән Мәскәүдә Федераль иминлек хезмәте органнарында. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Рәшит Фәһим улы (6.5.1957, Яшел Үзән ш.), композитор, педагог, ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1990, 1996), ТР һәм РФнең халык артисты (2003, 2007), РФ Хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге бүләге (2005), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2007) лауреаты. 1985 елда Казан консерваториясен (Б.Трубин классы) тәмамлый. 1989 дан ТР Композиторлар берлеге рәисе. 1987–2001 дә Казан консерваториясендә (1992–2001 дә композиция каф. мөдире) укыта. Хәзерге татар композиторлар мәктәбенең иң көчле вәкилләреннән берсе. К.ның иҗади үзенчәлеген борынгыдан килгән милли муз. фикерләүне заманча гәүдәләндерүе, яңача алымнар куллана белүе билгели. 20 йөз ахыры — 21 йөз башы композиторлык техникасы чаралары б-н иркен эш итә, аны үзенең иҗатында интонацион һәм милли эчтәлекле җирлектә табигый һәм нәтиҗәле куллана. К.ның иҗатында төп урынны камера оркестры, хор, орган, аерым башкара торган уен кораллары өчен язылган әсәрләр алып тора. Аның әсәрләре Россиядә, ш.у. Япония, Люксембург, АКШ һ.б. илләрдә киң яңгыраш ала; ТР Дәүләт квартеты, Р.Абязов җитәкчелегендәге «La Primavera» камера оркестры, органчы Р.Абдуллин, япон пианисты А.Такахаши, Америка музыкантларының «Signus» хәзерге заман музыкасы ансамбле, пианист Р.Поллок, кларнетчы Ф.Башор һ.б.ның репертуарларына керә.

К.ның иҗат тематикасы татар халкы тарихының эпохаль вакыйгаларына һәм мәшһүр шәхесләренә мөрәҗәгать итүе б-н аерылып тора. К. киеренке иҗат эшен пед. һәм муз.-җәмәгатьчелек эшчәнлеге б-н бәйләп алып бара. 1992 дән «Европа-Азия» хәзерге заман музыкасы халыкара фестивален оештыру ком-ты директоры һәм рәисе. Бер үк вакытта С.С.Прокофьев исем. Яшь композиторларның халыкара конкурсы (Мәскәү) жюри әгъзасы, ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге бирү ком-ты әгъзасы. К.М.Вебер исем. халыкара конкурс (Германия, 1987), «Вена-Модерн-Мастер» халыкара конкурсы (Австрия, 1994), РФ Композиторлар берлегенең Д.Д.Шостакович исем. бүләге (1998) лауреаты.

Төп әсәрләре: И.Юзеев либреттосына «Ерактагы кәккүк авазы» (1989) рок операсы; симф. әсәрләр: «Болгар» симф. поэмасы (1982, 2 нче редакциясе, 1986), Р.Мингалимов шигырьләренә язылган «Тынлык һәм тынычлык» вокаль-симф. поэмасы (1987); акапелла хор өчен язылган әсәрләр: «Ходай алдында без җаваплы», «Әлвидаг» хор әсәрләре; камера-вокаль әсәрләре: Н.Арсланов шигырьләренә тавыш һәм фортепиано өчен «Тынычлык турында» һәм «Бәхет турында» поэмасы (1985), тавыш һәм 2 флейта өчен Р.Мингалимов шигыренә «Риваять» поэмасы (1987), тавыш, флейта, виолончель һәм фортепиано өчен музыка (1991), вокаль квартет өчен П.Поупның «Виндзор урманыннан» шигыренә музыка (2001); камера-инструменталь әсәрләре: фортепиано өчен 2 соната (1985, 1987), виолончель-соло өчен 2 соната (1986, 1990), Г.Тукай истәлегенә 3 нче кыллы квартет (1986), фортепиано өчен «Истанбулда иртә» фантазиясе (1993), флейта, фортепиано һәм бәрмә уен кораллары өчен «Пальмира күренеше» триосы (1993), флейта-соло өчен соната-фантазия (1995), 2 саксофон өчен дуэт (2000), 4 саксофон өчен «Франкфурт-Люксембург поезды» (2002), баян һәм скрипка өчен «Инсайт» (2002); орган өчен: «Онытылган аваз» фантазиясе, 2 нче «Муенга элмәк» фантазиясе; скрипка, бәрмә уен кораллары һәм магнитофон өчен (бер башкаручы өчен) «Теләкләр көзгесе»; виолончель, магнитофон һәм ике биюче өчен соната-фантазия (1998), «Үргән дөге турында төш»; виолончель, бәрмә уен кораллары һәм магнитофон өчен муз. хәрәкәтләр (2000); катнаш хор һәм оркестр өчен «Казанны сагыну» концерт-поэмасы (2004); оркестр б-н фортепиано өчен концерт (2006), симф. оркестр өчен «Минем Татарстаным» увертюрасы, симф. оркестр өчен «Илем даны» әсәре (2007), симф. оркестр өчен «Татар халык җырлары темасына фантазия» (2007), оркестр өчен концерт (2008), оркестр-гитара өчен концерт (2009, «21 гасырда классик гитара» Халыкара фестивале, премьера-Казан), симф. оркестр өчен «Фанфаралар» (2009), гитара өчен дуэт (2009).

*Р.Г.Усеинова.*



Р.Ф. Кәлимуллин.



Р.К. Кәлимуллин.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Рифкать Кәлимулла улы (5.4.1927, Буа кантоны Борындык а. — 16.8.1993, Чүпрәле р-ны Борындык а.), инженер-механик, техник фән. канд. (1967), Соц. Хезмәт Герое (1951), ТАССРның атказ. а.х. механизаторы (1967). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1958). 1942 елда Мөрәле МТСында комбайнчы булып эшли. Герой исеме уңыш җыюда иң яхшы сыйфатка ирешкәне өчен бирелә. 1958–60 та КПССның Татарстан өлкә ком-тының а.х. бүлегендә инструктор. 1960–62, 1966–69 да Казан а.х. ин-тында укытучы, доцент. 1962–66 да «Сельхозтехника»ның Татарстан берләшмәсе машина-трактор паркының ремонт эшләре идарәсендә баш инженер. 1969–87 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшерү ин-тында механикалаштыру бүлеге мөдире.

Хезмәтләре ашлык җыюда операцион технология, авыр хезмәт процессларын механикалаштыру мәсьәләләренә карый. К. бөртекле культураларны суктыруның яңа технологиясен һәм ашлык җыюның операцион тех-



М.С. Кәлимуллина.

нологиясен эшли, бу технологияләр уңыш җыйганда ашлык югалуны 2–3% ка киметергә һәм комбайннарның көндезге эш җитештерүчәнлеген 3–4 *га* га арттырырга мөмкинлек бирә. Республикада беренчеләрдән булып комбайнга ЖБА-3,5 ургычын (борчак җыю өчен) тагуны тәкъдим итә. Бөртекле ашлык комбайнына күп режимлы суктыру-аеру җайланмасын эшли. Өч Ленин ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә. К. истәлегенә «Елның иң яхшы комбайнчысы» дигән билге һәм ел саен бирелә торган бүләк булдырыла.

Х е з м.: Регулировка зерноуборочных машин. К., 1968; Машины и их использование в полеводстве // Система ведения сельского хозяйства в ТАССР. К., 1974 (автордаш); Особенности уборки хлебов в условиях Татарии. К., 1976.

*Әд.:* З и я т д и н о в Ф.С. Комбайнёр, герой, учёный // Наши земляки. К., 1978; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Салихҗан Минсабир улы (10.12.1945, Әлки р-ны Татар Чиябашы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. инженеры (1984), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1968). 1968–79 елларда Әлки р-ның «Коммунизм юлы» к-зында инженер, 1973–78 дә Питрәч р-ның «Шигали» с-зында баш инженер, директор урынбасары. 1978–85 тә Питрәч р-ны «Сельхозтехника» берләшмәсе управляющие. 1985–87 дә Халык депутатларының Питрәч район советы башкарма ком-ты рәисе. 1987–91 дә «Татагропромхимия» АҖ рәисе, 1991–95 тә «Татсельхозхимия» дәүләт кооператив берләшмәсендә. 1995 тән «Татагрохимсервис» Холдинг компаниясе» (1998 дән «Трастовая компания») АҖ президенты, 1997 дән ген. директоры. К. җитәкчелегендә «Сельхозтехника» һәм «Татагрохимсервис» район берләшмәләренең җитештерү базалары ныгытыла, агрохимия эшләренең күләме һәм а.х. культураларының күләме арта. Дәүләт бүләге күп максатларда кулланыла торган хелатлы комплекслы микроашламаларны эшләгәне һәм җитештерүгә кerтkәне өчен бирелә. 1990–2000 елларда ТР ЮС депутаты. Халыклар дуслыгы ордены; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Сәмигулла Мәсифулла улы (1914, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Бакал а. — 1989, Уфа ш.), театр рәссамы, Башкорт АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1955). Уфа сәнгать техникумының сәнгать бүлеген тәмамлый (1935). 1935–74 елларда М.Гафури исем. Башкорт акад. драма театрында куючы-рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1954). Башкортстанда театр декорациясе сәнгатенә нигез салучыларның берсе. 30 дан артык спектакльне бизи. М.Гафуриның «Кара йөзләр» (1954; 1955 тә Г.Имашева б-н берлектә), И.Абдуллинның «Генерал Шәйморатов» (1959), Ә.Мирзаһитовның «Авыл көйләре» (1965), К.Даянның «Таңчулпан» (1965) һ.б. спектакльләргә эшләнгән декорация эскизлары авторы. К. декорацияләренә 1960 еллар башы нәкышь сәнгатенең стильләшкән тенденцияләр йогынтысы: катгый гомумиләшкән формалар, монументаль образлылык, тәэсирле чараларны сайлаудагы ачыклык, татар сәнгате колоритына нигезләнгән контрастлы төсләр ярашуы хас.



1



2

С.М. К ә л и м у л л и н. 1. К.Даян пьесасы буенча куелган «Таңчулпан» спектакленә декорация эскизы. Киндер, гуашь. 1965. М.В. Нестеров исем. Башкорт сәнгать музее; 2. Ә. Мирзаһитов пьесасы буенча куелган «Авыл көйләре» спектакленә декорация эскизы. Киндер, гуашь. 1965. М.В. Нестеров исем. Башкорт сәнгать музее.

Республика (1938–78), төбәк (Пермь, 1967; Чиләбе, 1969), бөтенроссия (Мәскәү, 1956, 1957, 1961; Уфа, 1961), бөтенсоюз (Мәскәү, 1956) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1964, 1973 (Уфа). Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда саклана. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К у ш н е р о в с к а я Г.С. Изобразительное искусство БАССР. М., 1974; Е в с е е в а С.В. Выставка произведений художников-сценографов Республики Башкортостан: Каталог. Уфа, 2000; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Хәлиулла Кәлимулла улы (7.1.1924, Чистай кантоны Иске Кыязлы а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Бөек Ватан сугышында катнаша. Колхоз рәисләре әзерләү буенча Татарстан урта а.х. мәктәбен (1952) һәм Минзәлә совхоз-техникумын (1973) тәмамлый. Аксубай р-ның «Правда» (1950–53), Вахитов исем. (1953–64) к-зларында, Октябрь р-ның В.И.Ульянов исем. (1964–78) к-зында рәис булып эшли; 1978–82 елларда Норлат элеваторы директоры. К. җитәкчелек иткән елларда В.И.Ульянов исем. к-зда бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 6 *ц* дан 22 *ц* га, 1 сыердан савым 500 *кг* нан 3200 *кг* га кадәр арта, терлекчелек фермалары, социаль-көнкүреш объектлары төзелә, торак фондның 70% яңартыла. Авылның көнкүреш культурасы өчен хуҗалыкка ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байрагы бирелә (1972). Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КӘЛИМУ́ЛЛИН** Юныс Нәгыймулла улы (5.9.1939, Буа р-ны Наратбаш а. — 4.9.2002, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1971 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, Чистай р-ны «Чишмә» с-зының баш зоотехнигы булып эшли. 1973 тән Казан вет. медицинасы академиясендә, 1990–2000 елларда терлекчелек каф. мөдире. Хезмәтләре хелат кушылмаларның а.х. терлекләре продукциялелегенә һәм үрчем функцияләренә тәэсирен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Металлохелаты — стимуляторы иммунохимических и репродуктивных функций сельскохозяйственных животных. К., 1984; Хелатокомплексные стимуляторы продуктивности крупного рогатого скота. К., 1990.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КӘЛИМУ́ЛЛИНА** Мәгъсүмә Садри кызы (15.6.1913, хәзерге Апас р-ны Болын-Балыкчы а. — 30.8.1970, шунда ук), колхозчы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Апас р-ның «Ракета» к-зында сарык карауччы, сыер савучы, бозау караучы булып эшли. Герой исеме 7 еллык план (1959–65) йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г а л и е в Г. Геройларыбызга дан! // Азат хатын. 1966. № 5; Тормышның кадерен белегез // Сердәш. К., 1969; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КӘЛТӘЛӘ́Р** (Lacerta), чын кәлтәләр семьялыгыннан сөйрәлүчеләр ыругы. 200 гә якын төре билгеле, Евразиядә, Африкада таралган. Татарстанда 2 төре бар: житез кәлтә (L. agilis) һәм терелэй тудыручы кәлтә (L. vivipara). Җитез кәлтә барлык районнарда, аеруча Кама арьягында һәм Идел алдында күп очрый. Кояшта яхшы җылынучан урыннарны: сирәкләнгән нарат урманнарын, коры кисентеләр һәм урман буйларын, урман полосаларын, елга тугайларындагы биек ком сөзәкләрен үз итә. Апрельдә күренә башлый.



Җитез кәлтә.

Олы К.нең озынлыгы 250 *мм* га кадәр һәм озынрак, шуның 60% ы койрыкка туры килә. Яшь К.нең сырты аксыл буйлы, коңгырт соры яки көрән төстә, олыларда үзгәрә: буйлар юыла, көрән, коңгырт яки кара таплар барлыкка килә. Ата затлар, кабык салганнан соң, ачык яшел («туй киеме») төс ала, аналарда соры төс саклана. Парлашу май аенда. Июньдә ана зат җиргә тиречел йомшак тышчалы 6–13 йомырка сала. Августта яшь К. (озынлыгы 40 *мм* га кадәр) чыга. Тереләй тудыручы кәлтә җитез кәлтәгә караганда сирәгрәк очрый. Дымлы урманнарда, сазлыкларда, үсемлекләр үскән ерганакларда, иске бакча һәм паркларда очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 120 *мм* га кадәр җитә. Ана зат аталарга караганда зуррак. Сырты кара таплы яки тапларсыз гына чикләвексыман, ачык көрән яки соры төстә. Арка сөяге буйлап тар полоса уза. Күзләре аша гәүдәсенең ян-ягына койрык төбендә тоташучы киң полосалар сузылган. Ана затларның корсагы аксыл сары, аталарның ачык (кызгылт сарыга кадәр) төстә. Яхшы йөзәләр һәм чумалар, сулык төбеннән чабарга һәм куркыныч янаганда ләмгә күмелергә мөмкин. Парлашу апрельдә (ата затларның сугышулары б-н бергә була). Бу К., исеменнән күренгәнчә, тереләй тудыралар. Июль ахыры – август башларында 3–11 бала китерә. Балалар ярым үтә күренмәле юка тышчада туалар, аны исә шунда ук ерталар һәм качу урыннарына үрмәләп кереп китәләр. К., куркыныч килгәндә, койрыкларын өзәргә мөмкин, соңыннан ул яңадан үсә. Күбрәк бөҗәкләр һәм аларның личинкалары үрмәкүч, моллюсклар, суалчаннар б-н тукланалар. Качу урыны булып ташлар арасындагы бушлыклар, агач куышлары, коелган яфрак һәм чыбык-чабык өемнәре, өннәр хезмәт итә. Дошманнары — бакыр елан, гади һәм дала кара еланнары, торымтай, карчыгалар, елак карчыгалар, бурсык.



Тереләй тудыручы кәлтә.

*Әд.:* Павлов А.В., Замалетдинов Р.И. Животный мир Республики Татарстан. Амфибии и рептилии. Методы их изучения. К., 2002.

**КӘЛЧӘ́К**, чехонь (Pelecus cultratus), карплар семьялыгындагы балык. Балтыйк, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре бассейннарында, күлләрдә һәм сусаклагычларда таралган. Татарстанның барлык районнарында очрый. Зур елгаларда һәм сусаклагыч плёсларында яши. Гәүдәсенең озынлыгы 50 *см* га кадәр, ян-яктан кысылган; авырлыгы 1 *кг* га кадәр. Сырты туры, корсагы кабарынкы. Корсагында очлы киль бар, тәңкәсез. Өсте зәңгәрсу-соры, ян-яклары һәм корсагы — көмешсыман соры. Сырт йөзгече кыска, артка этәрелгән, аналь һәм күкрәктәгеләре — озын. Башы зур түгел. Авызы өскә караган. Гәүдәсе җиңел коелучан ялтыравыклы вак таплар б-н капланган. Төркем булып яши. 3–4 елдан җенси җитлегә. Май–июньдә уылдык чәчә. Гәүдә авырлыгына һәм зурлыгына бәйле рәвештә, 6,2 меңнән алып 94,4 меңгә кадәр уылдык бөртеге чәчә. Күбрәк бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, ш.у. суалчаннар һәм вак балыклар б-н туклана. Кәсәбчелек объекты. Рәсеме к. *Балыклар*.

**КӘЛӘ́М** (гарәп. كلام — сүз, сөйләм), урта гасырлар мөселман әдәбиятында дини-фәлсәфи темага һәртөрле фикер йөртү; дин галимнәре өйрәтмәләренә (*тәкълидкә*) таянмыйча, дини догмаларга акыл нигезендә аңлатма бирүне алга сөргән илаһият гыйлеме. К. 8 йөзнең 2 нче яртысында исламда барлыкка килгән төрле дини-сәяси төркемнәр арасындагы бәхәсләр, ш.у. төрле милләт вәкилләре б-н алып барылган диспутлар вакытында туа. Бу — К.дә проблемалар (һәм К.нең фикерләү ысуллары): ихтыяр иреге һәм тәкъдир, кешенең мөселман, динле яки динсез буларак билгеләмәсе, илаһи атрибутларның үзара бәйләнеше, Коръәннең асылы, җитәкче мөселманга кирәкле сыйфатлар тупланган чор. К.нең ысуллары һәм проблемаларын әл-Җәд ибне Дирхәмнең (742/43 тә вафат) Коръән аятьләрендәге акылга каршы килүче символик-аллегорик аңлатмалар һәм акылга таяныч булырдай таләпләр күтәреп чыккан иҗатында күп очратырга мөмкин. Аның шәкерте Җәһем ибне Сафван (745 елда җәзалап үтерелә), ш.у. Җәһемнең шәкерте Дирар ибне Әмер К.нең беренче зур мәктәбе — *мөгътәзилиләр* идеяләренә нигез салалар. Соңрак башка мәктәпләр (мәс., матуридиләр, әшгариләр) барлыкка килә. К. яңа һәм соңгы тарихи дәвердә (иң элек аның мөгътәзилиләр юнәлешендәгесе) дини тәгълимат нигезләре (мәс., Җ. әл-Әфгани, М. *Абду*, либераль фикер ияләре, «сул» исламчылардан Х.Хәнәфи) б-н низагка кермәскә омтылган рационалистлар өчен нигез булып тора.

*Әд.:* Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте. К., 2002; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**КӘМИНКӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 7,5 *км*, бассейнының мәйданы 17,8 $км^2$. Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Биектау авылыннан көнчыгыштарак урманлы сызада; Ивановка һәм Яңа Мамонино авыллары арасында К. Казансу елгасының иске юлында сакланган элеккеге күлгә ага. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагынныкы — 56 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. К. елгасының югары агымында 2 зур булмаган кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 148 *мм*, ташу агымы катламы 109 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. К. ноябрь уртасында туңа. Тамагында суының иң аз вакытлардагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 $м^3/с$. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К.ның югары агымында буа бар. Су ресурслары җирле хуҗалык-көнкүреш максатларда файдаланыла.

**КӘРА́М** (чын фамилиясе Рәхмәтуллин) Габдрахман Хәбибулла улы (25.6.1878, Казан — 24.6.1947, шунда ук), журналист, театр тәнкыйтьчесе һәм әдәби тәнкыйтьче, тәрҗемәче. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен, Истанбул ун-тының сәнгать ф-тын тәмамлый. Әдәби тәнкыйть эшчәнлеген 1906 елда «Казан мөхбире», «Йолдыз» г-таларында, соңрак «Аң» ж-лында башлый. Ул даими рәвештә тарих, әдәбият, сәнгатькә караган мәкаләләр, татар театрлары труппаларының агымдагы репертуарында урын алган спектакльләргә төгәл анализ бирелгән рецензияләр бастыра. «Сәйяр» труппасы спектакльләренең беренче проф. театр рецензентларыннан берсе. К.ның тәнкыйди күзәтүләре һәм рецензияләре беренче проф. татар актёрларының башкару осталыкларын һәм татар тамашачысының гомуми театраль культурасын камилләштерүгә ярдәм итә. 1917 дән соң «Татарстан хәбәрләре», «Эш», «Кызыл Шәрекъ яшьләре» г-таларында татар театры тарихы буенча мәкаләләр, татар сәхнәсе осталары турында очерклар бастыра. М.Горькийның «Мещаннар» (1916), У.Шекспирның «Отелло» (1920), «Король Лир» (1925) пьесаларын; В.М.Керженцевның «Иҗади театр» исемле теоретик хезмәтен татарчага тәрҗемә итә. 1920 еллар ахырында Пролеткульт идеологлары тарафыннан «буржуаз-милләтчелек»тә гаепләнә һәм публицист эшчәнлегеннән читләштерелә.

*А.Р.Габәши.*

**КӘРАМИ́** (Кәрамиев) Рәфкат Кәрами улы (18.2.1942, Сарман р-ны Рангазар а.), язучы, ТАССР, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1989, 2005). Казан ун-тын (1970) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курслар тәмамлый (Мәскәү, 1979). 1979–93 елларда ТР Язучылар берлегенең Матур әдәбиятны пропагандалау бюросында әдәби консультант, вәкаләтле вәкил, директор вазифаларын башкара. 1994–2001 дә Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) директоры. 1967 елда үзенең «Дүрт кешелек каюта» исемле беренче детектив повестен, байлык артыннан гына куучы тар карашлы кешеләрне тәнкыйть объекты итеп алган «Кичке уйлар» (1970) повестен бастыра. «Капитан Хәкимов» (1974), «Сагышлы кояш» (1983), «Йөрәгемне ут алган» (1987), «Ындыр тулы кибән» (1992) повестьларында һәм «Өзелгән чәчәк» (2002) җыентыгындагы хикәяләрендә, тормыштагы рухи һәм әхлакый проблемаларны үзәккә алып, замандашлары образларын гәүдәләндерә. Өч кисәктән торган «Очар кошлар белән янәшә» (1999) романы яшь төзүчеләргә, «Каргышлы этаплар» (1995) романы репрессия елларында хаксызга рәнҗетелгән якташлары истәлегенә багышлана. «Яратуың чынмы?» пьесасын Минзәлә татар драма театры 1982 елда сәхнәләштерә. Күп кенә әсәрләре рус, әзәрб., кыргыз, мари һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (1999).

*Әд.:* Б ә д и г ы й Х. Ындыр тулы кибән // Мирас. 2002. № 2; В ә л и е в М. Чынлык көче // Казан утлары. 2002. № 2.

**КӘРА́МОВ** Фидүс Әхмәди улы (22.6.1953, Актаныш р-ны Актаныш а.), эл. энергетикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (2003). 1975 елда Казан ун-тын тәмамлый. Казан техник ун-тында эшли, электрон приборлар төзү каф. мөдире (1999 дан), бер үк вакытта — Федераль «Казан приборлар төзү конструкторлык бюросы» ДУПта (2001 дән), фәнни эшләр буенча директор урынбасары (2003–2004). Хезмәтләре суперион үткәргечләрне тикшерүгә, алар нигезендә функциональ электроника элементларын эшләүгә, җылылык техникасында электрон үлчәүләр системаларын, мәгълүматны микроэлектрон беренчел үзгәрткечләр төзүгә карый. К. электр б-н идарә ителүле бериш һәм бериш булмаган параметрлы резистив һәм резистив-сыйдыргычлы структуралар тәкъдим итә. Түбән һәм үтә түбән ешлыклар өлкәсендә тикшеренүләр үткәрү методикасын һәм суперион үткәргечләр нигезендә ике һәм өч электродлы элементлар һәм гетероструктуралардан торучы үлчәүләр системасын эшли. К. җитәкчелегендә фракталь үлчәнешләр очрагы өчен электрод-суперион үткәргеч гетероструктурасын модельләштерү һәм исәпләү эшләре үткәрелә. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Низкочастотный импеданс границ раздела Pt, Au, Ni, Ti — электродов с суперионным проводником // Электрохимия. 1994. Т. 30. № 2; Суперионные проводники. Гетероструктуры и элементы функциональной электроники на их основе. М., 2002; Investigations of Reversible and Polarised Interfacial Surface Properties by Electrochemical Impedance Method // Electrochemical Methods in Corrosion Research. V. 289–292. P. 871–878.

**КӘРАМУ́ЛЛИН** Газизулла Хикмәтулла улы (17.10.1927, Бөгелмә кантоны Югары Әстәрле а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Казанда Югары партия мәктәбен тәмамлый (1960). 1952–56, 1960–62 елларда партия эшендә. 1969–72 дә Азнакай район башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1962–69 һәм 1972–87 дә «*Авангард*» к-зы рәисе. К. җитәкчелек иткән елларда бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 26 *ц* га, кукурузның яшел массасы 1 *га* дан 80 *ц* га кадәр арта, шикәр чөгендерен үстерүне механикалаштыру гамәлгә кертелә, колхоз икътисади яктан нык хуҗалыкка әверелә. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**КӘРӘКӘ́ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогында, Яшел Үзән р-ны Садовый посёлогында. Су өслегенең мәйданы 0,6 *га*. Күләме 33 *мең м*³ га якын. Озынлыгы 100 *м*, иң зур киңлеге 60 *м*, уртача тирәнлеге 5,5 *м*, иң зур тирәнлеге 11,6 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Суы гидрокарбонат-хлорлы-кальцийлы типта, бик йомшак. Үтә күренмәлелеге 60 *см*. Күл аша Сәр-Болак елгасы ага.

**КӘРӘКӘ́ КҮЛЕ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 42 *км* көньяктарак, Чистай-Нурлат автомобиль юлы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1930 елларда нигез салына.



Кәрәкә күле.

Башта Чистай р-нына керә, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 123, 1949 да — 145, 1958 дә — 112, 1970 тә — 104, 1979 да — 63, 1989 да — 36, 2002 дә — 5 кеше.

**КӘРӘКӘЛЕ́ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Биектау р-ны Кече Рәс авылыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт, Питиал һәм Казансу елгалары субүләрендә урнашкан. Су өслегенең мәйданы 10,56 *га*. Күләме 360 *мең м*³. Озынлыгы 700 *м*, иң зур киңлеге



Кәрәкәле күле.

250 *м*, уртача тирәнлеге 3 *м*, иң зур тирәнлеге 4,3 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Формасы катлаулы. Җир асты сулары б-н туенуы тотрыклы. Суы җиңелчә минеральләшкән (146 *мг/л*), йомшак, гидрокарбонат-хлорлы-кальцийлы типта.

**КӘРӘКӘ́С** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяктарак, Аулаш елгасы буенда. 2010 елда 205 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 916,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонас волостенда, 1920 дән ТАССРның Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1870 тә — 425, 1897 дә — 718, 1913 тә — 946, 1920 дә — 897, 1926 да — 723, 1938 дә — 580, 1949 да — 562, 1958 дә — 555, 1970 тә — 548, 1979 да — 453, 1989 да — 253, 2002 дә — 222 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КӘРӘКӘШЛЕ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2010 елда 739 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Төбәк тарихы музее. 1765 тән мәгълүм. 18- 19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр, дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, сату б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә мәчет, 7 су тегермәне була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3614 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1795 тә — 213, 1859 да — 803, 1886 да — 1261, 1889 да — 1335, 1897 дә — 1676, 1920 дә — 1958, 1926 да — 2080, 1938 дә — 1532, 1949 да — 1501, 1958 дә — 1021, 1970 тә — 1466, 1979 да — 1269, 1989 да — 977, 2002 дә — 869 кеше.

**КӘРӘКӘШЛЕ́** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы п о с ё л о г ы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 26 *км* көнбатыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда урнашкан. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 1940 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1979 да — 61, 1889 да — 14, 2002 дә — 11 кеше.

**КӘРИ́М** (Кәримов) Мостай (Мостафа) Сафа улы (20.10.1919, Уфа губ., Уфа өязе Келәш а. — 21.9.2005, Уфа), язучы, Башкорт АССРның халык шагыйре (1963), Соц. Хезмәт Герое (1979), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982), Башкортстан ФАнең хакыйкый әгъзасы (1992). Башкорт телендә яза. Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1941). Беренче шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә 1935 елда күренә башлый. «Отряд ҡуҙғалды» (Уфа, 1938, автордаш), «Язғы тауыштар» (Уфа, 1941) җыентыкларына кергән шигырьләре тормышка гимн буларак яңгырый. «Таныш булмаған ҡунаҡ» (1940) поэмасында Гражданнар сугышының фаҗигале вакыйгалары тасвирлана. К. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронтка киткәндә язылган «Мин һуғышҡа китәм, иптәштәр!» исемле шигыре ватанны яклаучы сугышчы анты булып яңгырый. «Минең атым» (Уфа, 1943), «Шиғырҙар» (Уфа, 1945) җыентыкларына кергән шигырьләрендә, «Декабрь йыры» (1942), «Үлмәсбай» (1943) поэмаларында шагыйрь сугышның фаҗигалелеген, совет солдатының батырлыгын, аларның фашизмга каршы алып барылган сугышта гуманлылык миссиясен үтәүләрен күрсәтә. Яралланган-

нан соң (1942), «За честь Родины», «Советский воин» фронт г-талары хәбәрчесе булып эшли. «Ҡайтыу» (Уфа, 1947) җыентыгына кергән шигырьләрендә кичә генә сугыштан тыныч тормышка әйләнеп кайткан солдатларның хисләрен һәм өметләрен чагылдыра. Сугыштан соң үзен иҗади һәм иҗтимагый эшчәнлеккә багышлый: 1951–62 елларда Башкортстан АССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе. Сугыштан соңгы поэзиясе яңа төсмер ала: тематикасы киңәя, аналитик сәләте көчәя, тормыш турындагы фәлсәфи уйланулары тирәнәя; оптимизм б-н сугарылган пафоска халыклар язмышы турында уйланулар өстәлә: «Европа — Азия» (Уфа, 1953), «Вьетнам яҙмалары» (Уфа, 1957), «Каштан сәскә аткан ерҙә» (1959), «Болгар дәфтәре» (1960), «Кабардин-Балкар дәфтәреннән» (1962) цикллары; «Яҙғы ер» (Уфа, 1951), «Йылғалар һөйләшә» (Уфа, 1961), «Торналар ҡайтҡанда» (Уфа, 1964), «Мәхәббәттең дүрт миҙгеле» (Уфа, 1978), «Заманалар» (Уфа, 1982) һ.б. җыентыклар. 1950 еллардан К. узган сугыш темасына кабат әйләнеп кайта. Аның фаҗигалелегенә, совет кешеләренең бөек ватанпәрвәрлелеген тирәнтен аңлый: «Өҫ көн тоташ ҡар яуа» (1955) шигыре, «Ҡара һыуҙар» (1961) поэмасы һ.б. Драматургия өлкәсендә дә актив эшли: сугыш башлану сәбәпле өзелгән тыныч тормышка яңадан кайту турындагы «Туй дәуам итә» (1947), сугыштан соңгы авыл колхозы турында «Яңғыз ҡайын» (1950) пьесаларын яза. «Ҡыҙ урлау» (1958) лирик комедиясендә, «Айгөл иле» (1968) романтик драмасында авыл тормышының көлкеле һәм кайгылы яклары тасвирланган. «Йырланмаған йыр» (1961), «Йәйәүле Мәхмүт» (1986), «Киҫкә табын» (1993) пьесалары кешенең халык һәм җәмгыять алдында торган җаваплылыгы турындагы фәлсәфи уйланулар б-н сугарылган. Риваятьләргә, тарихи фактларга нигезләнеп язылган «Ай тотолған төндә» (1963), «Салауат» (1971), «Ташлама утты, Прометей!» (1975) трагедияләре ирекле кешенең бөеклеге, идея хакына корбан булырга әзер торуы темалары күтәрелә. «Оҙон-оҙак бала сак» (Уфа, 1976) повестенда кешенең яшәү рәвешен фәлсәфи тирәнлектә яктыртырга омтыла. Әсәрнең логик дәвамы булып «Ауыл адвокаттары» (Уфа, 1989) һәм «Тормош миҙгелдәре» (Уфа, 1997) китаплары языла. «Ярлыҡау» (Уфа, 1986) повестенда сугышның кешелексезлеге бәян ителә. Балалар һәм яшүсмерләр өчен язылган «Беҙҙең өйҙең йәме» (Уфа, 1951), «Өҫ таған» (Уфа, 1962) әсәрләрендә авыр сугыш һәм сугыштан соңгы елларда башкорт авылының тормышы балалар күзлегеннән чыгып яктыртыла; кешелеклелек, кешеләргә карата мәрхәмәтлелек, яхшылык кылуга омтылыш раслана. К. китаплары Россия һәм дөнья халыкларының телләренә тәрҗемә ителә. 1955–90 елларда РСФСР ЮС депутаты. Башкортстан АССР Салават Юлаев исем. (1967), РСФСРның К.С.Станиславский исем. (1967), СССР Дәүләт (1972), Ленин (1984) бүләкләре лауреаты. Ике Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», 3 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары б-н бүләкләнә.


Ә с ә р.: Әҫәрҙәр: 5 томда. Өфө, 1971–73; Әҫәрҙәр: 4 томда. Өфө, 1987–88; Собрание сочинений: В 3 т. М., 1983.

*Әд.:* К и л ь м у х а м е т о в Т. Драматургия Мустая Карима. Уфа, 1979; Хөсәйенов Ғ. Мостай Кәрим. Өфө, 1994.

*С.Г.Сафуанов.*

**КӘРИ́М** (Кәримов) Фатих Әхмәтвәли улы (9.1.1909, Уфа губ., Бәләбәй өязе Ает а. — 19.2.1945, Калининград өлкәсе Багратионовск ш.), шагыйрь. 1922–24 елларда Бәләбәй пед. техникумы каршындагы әзерлек курсларында, 1925–29 да Казан Җир эшләре техникумында укый. 1933 кә кадәр «Кечкенә иптәшләр» (Мәскәү) ж-лында, «Яшь ленинчы», «Крестьян газеты», «Кызыл армеец» г-талары, «Атака», «Азат хатын» ж-ллары редакцияләрендә эшли. 1933–37 дә Татарстан китап нәшриятында балалар әдәбияты секторын җитәкли. Беренче әсәрләре матбугат битләрендә 1920 еллар ахырында күренә башлый. Иҗатының башлангыч чорында ул елларга хас кычкырып торган гражданлык, лозунгка тартым публицистлык, Һ.Такташ, Х.Туфан, В.Маяковскийлар кебек новатор шагыйрьләр стилистикасы йогынтысы күзәтелә («Безнең һәйкәл», 1932; «Еллар каршысында», 1932). «Җиденче мич» (1931), «Яшен яктысы», (1932), «Тавышлы таң» (1933), «Аникин» (1936) поэмаларының тематикасы ш.у. замана рухын чагылдыра: алар Гражданнар сугышы, сыйнфый көрәш, хезмәт кешеләре тарафыннан төзелә торган матур киләчәк турында. Иҗатына лирик-романтик интонация («Зәйтүнә», 1932; «Көтәм сине», 1935; «Дулкынланып китте ак болыт», 1935; «Таныш бу күзләр», 1936), жанр төрлелеге (шигырь, эпиграмма, җыр, баллада, поэма, хикәя, повесть, драма, фельетон) хас. 1938 дә К., милләтчелектә гаепләнеп, кулга алына һәм 10 елга лагерьга хөкем ителә, 1941 дә ирекkә чыга. К. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1942–45 тә ул иҗади үсеш кичерә. Бу елларда әдип татар шигъриятендә үзенчәлекле бер күренешкә әверелгән шигырь һәм поэмаларын иҗат итә. Сугыш еллары шигырьләренең лирик герое — Ватаны өчен үз-үзен аямыйча көрәшкән батыр сугышчы («Теләк», «Ант», «Ак күгәрчен», «Бездә яздыр», «Ватаным өчен», «Кошлар», «Юл» барысы да — 1942). Автор сугышчыларның барлык кичерешләрен чагылдырырга омтыла: якыннарына («Газиз әнкәй», 1943; «Һөҗүм», 1943; «Бизәкле ал яулыгың», 1945), туган як табигатенә («Шомырт куагы», «Соңгы тапкыр карыйм Иделгә» икесе дә — 1942) мәхәббәтен, сугышның кешегә һәм тереклеккә аяусыз булуын тасвирлый. «Кыңгыраулы яшел гармун» (1942) поэмасы К. иҗатының иң югары ноктасы булып тора. Әсәрнең төп герое Фазыл образында совет солдатының батырлыгы һәм җиңүгә ныклы ышанычы гәүдәләнә. Кызыл Йолдыз, 1нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Сугышта һәлак була.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 3 томда. К., 1979–81; Кыр казы. К., 2004; Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 2009; Избранные стихи и поэмы. К., 1957.



М. Кәрим.



Ф. Кәрим.

*Әд.:* М ә җ и т о в З. Фатих Кәрим // Татар әдәбияты тарихы. К., 1989. 5 том; ш у л у к. Поэзия Фатиха Карима. К., 1955.

*Н.М.Йосыпова.*

**КӘРИ́М** (Кәримов) Хөсни (Хөснетдин) Минһаҗетдин улы (15.12.1887, Уфа губ., Бөре өязе Тайморза а. — 25.12.1965, Казан), язучы, педагог, җәмәгать эшлеклесе. «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач (1911), бер үк вакытта, үзлегеннән әзерләнеп, Царицын шәһәрендәге реаль уч-щедә рус теле мөгаллимлегенә имтихан тота. 1914 елга кадәр Әстерхан шәһәре рус-татар мәктәбендә укыта, җирле «Идел» г-тасында актив хезмәттәшлек итә: хикәяләр, фельетоннар яза, халык мәгариф системасындагы җитешсезлекләр турында тәнкыйть мәкаләләре бастыра. К.ның журналистлык эшчәнлеге полиция күзәтчелеге астына алына, һәм ул Уфа шәһәренә, аннан Бөре өязе Богдан авылына күчеп китәргә мәҗбүр була. 1917 дән соң Бөре өязе халык мәгарифе бүлеген җитәкли. 1919–24 елларда Уфа шәһәре мәгариф бүлегенең мөселман әдәбияты секциясе мөдире, Идел буе хәрби округы каршында татар-башкорт гаскәриләре өчен ачылган курсларда лектор һәм сәяси җитәкче, аннары РКП(б)ның Уфа губерна ком-ты каршындагы татар-башкорт нәшрияты бүлеге мөдире булып эшли. 1924 тән Казанда: 1926–36 да Главлит җитәкчесе, Татарстан ҮБКның читтән торып уку бүлеге мөдире һәм Татарстан радио ком-тының әдәби-муз. тапшырулар секторы мөдире вазифаларын башкара. Крәстияннәр тормышыннан алып язылган «Атна кич, яки Шакир хәлфә» (1910) драмасы, «Җан исәбен алганда» (1927), «Ертылган приказ» (1929), «Октябрьгә чаклы» (1935) повестьлары авторы.

Ә с ә р.: Ике дус. К., 1969.

*Әд.:* К ә р и м о в а З. Онытылмас хатирәләр // Казан утлары. 1968. № 9.


**КӘРИМБИРДЕ́ ХАН** (?-1413), Алтын Урда ханы (1412 елдан). Туктамыш хан улы. Атасы ягыннан торып Идегәй әмиргә каршы көрәшә. 1406 да Туктамыш үтерелгәннән соң, бертуганы Җәләлетдин б-н бергә Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II гә хезмәткә күчә. 1408 дә Литвага кача. 1411 дә Җәләлетдингә *Тимер ханны* тар-мар итәргә һәм Алтын Урдада тәхеткә утырырга булыша. Җәләлетдин хакимияте ныгуга риза булмыйча, Идегәй котыртуы нәтиҗәсендә фетнә оештыра һәм идарәчене үтерә. Үз исеменнән акча суктыра. *Кибәк хан* тарафыннан үтертелә.

*Әд.:* к. *Кибәк хан* мәкаләсе.

*И.Л.Измайлов.*

**КӘРИМИ́** (Кәримов) Фатих (Мөхәммәтфатих) Гыйльман улы (17.3.1870, Самара губ., Бөгелмә өязе Миңлебай а. — 27.9.1937, Мәскәү), язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе. Г.*Кәримов* улы. Башлангыч белемне өйдә атасыннан ала. 1892 елга кадәр «Камалия» (Чистай ш.) мәдрәсәсендә укый; бер үк вакытта рус теле һәм әдәбияты дәресләренә дә йөри, моның өчен (ш.у. шәкертләр арасында «Тәрҗеман» г-тасы идеяләрен тараткан өчен) мәдрәсәдән куыла. 1892–96 да чиновниклар тәрбияли торган «Мәктәп мөлкия-шаханә» (Истанбул) югары уку йортында укый. Гарәп, фарсы, төрек, француз телләрен өйрәнә. 1896–98 дә Таврия губернасы, Ялта өязендә, җәдит мәдрәсәсендә укыта. Бакчасарайда мөгаллимнәр әзерләү курсларына җитәкчелек итә. 1899 ның февраль-маенда алтын приисклары хуҗасы М.Рәмиев б-н бергә Европаның берничә иленә сәяхәт кыла; шул ук елда Мәскәүдә нәшрият эшен һәм немец телен өйрәнә. 1899 ның июлендә гаиләсе б-н Оренбург шәһәренә күчеп килә. Җәен Каргалы бистәсендә җәдитчә белем бирүче мәктәпләр өчен укытучылар әзерләү курсларында укыта. 1900 дә С.-Петербургта И.М.Бораганский нәшриятында практика үтә. 1902 дән, атасы вафатыннан соң, *«Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе* б-н җитәкчелек итә. 1906 да мөселманнар әдәби түгәрәген оештыра. 1906 дан «Иттифак әл-мөслимин» партиясе Үзәк Комитеты әгъзасы була, 1906–17 дә — «*Вакыт*» г-тасы баш мөхәррире, 1917 дә — Оренбург мөселманнары Бюросы рәисе. Бөтенроссия мөселманнары корылтайларына (1905, 1906, 1914, 1917), 1917 нең маенда 1 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда Оренбург делегатларыннан Милли Шура әгъзасы итеп сайлана. 1917 нең 1 ноябреннән «*Яңа вакыт*» г-тасын нәшир итә башлый. 1917–24 тә Оренбургның төрле уку йортларында укыта. 1919 дан «Эшчеләр дөньясы», «Юл» г-таларында язышa һәм аларның редколлегияләрендә әгъза була. 1925 тән Мәскәүдә яши, СССР халыклары Үзәк нәшриятының татар бүлегендә эшли, Көнчыгыш ин-тында төрек теле укыта, «Эшче» г-тасында язышa. 1937 нең августында кулга алына һәм «Төркия файдасына шпионлык кылуда һәм партия җитәкчеләренә каршы террор актлары оештыру»да гаепләнә. Шул ук елның сентябрендә СССР Югары суды Хәрби коллегиясе тарафыннан үлемгә хөкем ителә; 1959 да аклана.

К. иҗатының төп идеясе — искечә укыту ысулларын тәнкыйтьләү, татар мәктәбендә реформалар үткәрү өчен көрәш. Авыл мәдрәсәсен тасвирлаган «Җиһангир мәхдүм» (СПб., 1900) хикәясе — К.нең беренче әсәрләреннән. Автор мәдрәсә шартларының фәкыйрьлеген, укыту ысулларының кадимилеген тасвирлый. «Салих бабайның өйләнүе» (1901) хикәясе герое — умартачы Салих бабай — авыл балаларына әкиятләр, үз тормышыннан төрле вакыйгалар сөйли. К. геройның бай рухи дөньясын ачып сала, «гади» кешеләр б-н аралашуның рәхәтлеген күрсәтә. «Бер шәкерт илә бер студент» (1899) повестенда язучы гротеск ярдәмендә кадимче муллаларның наданлыгын сурәтли. Вакыйга шәрекъне өйрәнүче рус студентының Бохарада белем алган татар мөдәррисе б-н пароходта корган әңгәмәләре тирәсендә бара. Мөдәррис студентның гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә биргән гади сорауларын да аңламый. Кадимчелек дошманы буларак, К. аларның наданлыгын күпертеп күрсәтә һәм шуның аркасында мөселман руханиларының катгый тәнкыйтенә дучар була. «Нуретдин хәлфә» (1899; нәшер ителүе 1996) повестенда да К. кадими мулла образына мөрәҗәгать итә. Мәгърифәтчелек романтизмы рухында язылган «Морза кызы Фатыйма» (1901) повестеның төп героинясы, бакчачыга булган мәхәббәте хакына өен ташлап, сөйгәне б-н чит илгә китеп бара. Качып киткән яшьләрне куып җитеп, кызның әти-әнисе никахка ризалыкларын бирәләр. Язучы саф мәхәббәт тантанасын күрсәтә, укучыны кешенең дәрәҗәсе аның чыгышына карап түгел, ә рухи сыйфатларына карап билгеләнергә тиеш икәненә инандыра. «Хыялмы? Хакыйкатьме?» (1908) повестенда 2 нче Дәүләт Думасы депутаты б-н мәгърифәтле татар хатыны арасында барган әңгәмә аша милләт язмышы мәсьәләләре яктыртыла. Язучы әңгәмә темасына тирән кызыксыну күрсәткән булып, асылда, бу кызны ничек итеп икенче хатынлыкка алырга икән дип уйлап утырган депутатны ирония б-н тасвирлый. К. — *сәяхәтнамә* жанрында язылган берничә китап авторы да. «Аурупа сәяхәтнамәсе» (СПб, 1902) китабында ул 1899 дагы сәяхәте турында яза, татар һәм Европа халыклары көнкүрешен һәм мәдәниятен чагыштыра, соңгыларының уңышларына сокланып карый. Татарның артта калуын уку системасын үзгәртергә, укыту программаларына дөньяви фәннәрне кертергә теләмәү б-н аңлата. Шундый ук фикерләр 1903 тә Бакчасарай шәһәренә «Тәрҗеман» г-тасының 20 еллыгын бәйрәм итәргә барганда алган тәэсирләре чагылыш тапкан «Кырымга сәяхәт» китабында да (Оренбург, 1904) урын ала. 2 нче Балкан сугышы вакытында «Вакыт» г-тасында басылган хат-язмалар җыентыгы «Истанбул мәктүбләре» (Оренбург, 1913) исеме б-н аерым китап булып нәшер ителә һәм К. иҗатында әһәмиятле урын ала. Хатлар рәвешендәге бу очеркларда К.нең Төркиянең икътисадына, сәясәте, мәдәнияте, мәгарифе, тарихына караган фикерләре урын ала. Төркиянең икътисади уңышсызлыклары, хәрби потенциалы түбән булу сәбәбен ул укыту системасының артта калганлыгы б-н аңлата. К. рус, француз, төрек фәнни-популяр әдәбияты тәрҗемәчесе булып та танылa. Ул ш.у. Польша язучысы Ф.Ф.Пуцековичның дөньядагы 30 халыкның тормышы һәм көнкүрешенә багышланган берничә брошюрасын, 1917 дән соң В.И.Ленин, шәркыятьче В.В.Бартольд хезмәтләрен тәрҗемә итә. К. тарих, география, педагогикага караган дәреслекләр авторы: «Мөхтәсар җәгърафия» («Географиянең кыскартылган курсы», 1899), «Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә» («Укытучылар вә тәрбиячеләр өчен кулланма», Оренбург, 1902), «Мөхтәсар тарихе гомуми» («Кыскартылган гомум тарих», Оренбург, 1911) һ.б. К.нең иҗаты һәм тормышына караган мәгълүматлар ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты фондларында, ТР Милли архивында, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда саклана. Әлмәт р-нындагы Миңлебай авылында 1998 дән Кәрими музее эшли.


Ф. Кәрими.

Ә с ә р.: Мәрхүм Гыйльман ахунд. Оренбург, 1904; Аннан-буннан. Оренбург, 1907; Ф.Кәрими әсәрләре. К., 1925; Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860–1905). К., 1979; Морза кызы Фатыйма: Сайланма әсәрләр. К., 1996; Istanbul mektuplari. Ist., 2001.

*Әд.:* Г а й н е т д и н о в М. Мәгърифәтче әдип // Мирас. 1995. № 7/8; А б д у л л и н Я. Җәдитчелек хәрәкәте һәм Ф.Кәрими // Татарстан. 1996. № 6; Ә х м ә т җ а н о в М. Ф.Кәрими мирасына яңа сәхифәләр // Казан утлары. 1999. № 6; Фатыйх Кәрими: Фәнни-биогр. җыентык — Фатих Карими: Науч.-биогр. сборник. К., 2000; Г а й н е т д и н М. Гасырлар мирасы. К., 2004; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Р а х и м к у л о в а М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997; Я м а е в а Л.А. Мусульманский либерализм начала XX в. как общественнополитическое движение. Уфа, 2002; А х у н о в А. Запечатлённое слово Ф.Карими // Татарский мир. 2004. № 5.

*А.М.Ахунов.*

**КӘРИМИ́ ФАТИ́Х МУЗЕ́Е**, Әлмәт р-ны Миңлебай авылында, мемориаль музей. 1998 елның 17 сентябрендә ачыла. 2001–06 да ТР Милли музее ф-лы; 2007 дән муниципаль музей. Авыл җирлеге советының ике катлы кирпеч бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 77 *м*², төп фонд 450 саклау берәмлегеннән тора. Экспозиция бер залда оештырыла. Күргәзмәдә Ф.Г.*Кәриминең* китаплары, документлары, мемориаль әйберләре, аның әнисе Мәгъсүмә абыстайның фотосурәтләре, шәхси әйберләре һәм әтисе Г.*Кәримовның* документлары, Р.*Фәхретдин* турындагы материаллар бар. Мөхәррире Ф.Кәрими булган «Вакыт» г-тасы төпләмәсе (1909) күргәзмәгә куелган. Экспозиция бүлегендә авыл тарихына багышланган документлар, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар халкының гамәли бизәлеш сәнгате һәм көнкүреш әйберләре; 20 йөз башы крәстиян агач йортының эчке күренеше күрсәтелә. Ел саен Ф.Кәриминең туган көне (30 март), Халыкара музейлар көне (18 май), Г.Кәримовның туган көне (1 окт.) билгеләп үтелә.

**«КӘРИ́МОВ, ХӨСӘЕ́НОВ ВӘ ШӨРӘКЯСЕ́» БАСМАХАНӘСЕ́,** Оренбург шәһәрендә. 1899 елда Бөгелмә өязенең Миңлебай авылыннан Оренбург шәһәренә килгән һәм Б.Бреслинның төрки телләрдә китаплар бастырган басмаханәсе б-н кызыксынган Г.И.*Кәримов* басмаханәсеннән башлангыч ала. 1900 дә Г.И.Кәримов ул басмаханәдән гарәп шрифтлары сатып ала, һәм 1901 дә яңа басмаханә үз эшен башлап җибәрә. Шул ук елның 15 мартында беренче китап — «Мәгъ-

лүмат нәгрия» («Файдалы киңәшләр») дөнья күрә. Кәримов татар телендә 52,4 мең данә тираж б-н 27 исемдә китап бастыра. 1902 дә басмаханә аның улы Ф.Г.*Кәримигә* күчә. Рус, Шәрекъ, Көнбатыш Европа телләрен белүе, белемле булуы, Германия, Австрия, Италия, Төркия, Мәскәү, Санкт-Петербург басмаханәләре эше б-н таныш булуы Кәримине югары дәрәҗәле белгеч итеп танытa. 1905 елда басмаханәләр кушыла һәм яңа басмаханә «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» ширкәтенә әверелә, әмма 1906 ел буе диярлек китаплар әле «М.- Ф.Кәрими» грифы б-н чыга. 1908 дә Уфада ф-лы ачыла. 1914 кә кадәр басмаханә б-н, асылда, Ф.Кәрими идарә итә.

Ул эшләгән елларда ширкәт составына Мировецкийның зур басмаханәсе дә керә, яңа машиналар сатып алына, Казандагы бертуган Кәримовлар басмаханәсеннән татар шрифтлары китерелә. Басмаханәдә басылган югары сыйфатлы китаплар наширләрне дә җәлеп итә, һәм ул Оренбургта иң яхшы басмаханәгә әверелә. Анда Оренбург губернасының көндәлек зур күләмле газета һәм журналлары, татар вакытлы матбугат басмалары — «Чүкеч», «Икътисад» ж-ллары, «Вакыт» г-тасының һәм «Шура» ж-лының беренче саннары дөнья күрә.

Басмаларның репертуары күптөрле була: Шәрекъ фәлсәфәсе буенча китаплар, дөнья халыклары тарихы буенча хезмәтләр, законнар җыелмалары, әдәбият белеме буенча тикшеренүләр, фәнни-популяр китаплар, татар мәдрәсәләре өчен дәреслекләр. Ширкәт үз хисабына казакъ мәктәпләре өчен дә китаплар чыгара. Кәриминең 100 гә якын үз хезмәте басыла. Татар драматургиясе классигы М.Фәйзи пьесалары, күренекле мәгърифәтчеләр, язучылар һәм тарихчылар Р.Фәхретдин, Н.Думави, Ш.Мәрҗани әсәрләре, татар шагыйрьләре З.Бәшири, С.Сүнчәләй, Г.Хәйдәров һ.б.ның шигырь җыентыклары, Л.Н.Толстой хикәяләре һәм Г.Бичер-Стоу романнарының тәрҗемәләре дөнья күрә. 1906 ел ахыры — 1907 ел башында с.-д. рухындагы басмалар, мәс., Б.Самойловичның Х.Ямашев тәрҗемәсендәге «Эшчеләрне азат итү — эшчеләрнең үз эше булырга тиеш» («Освобождение рабочих должно быть делом самих рабочих») дигән хезмәте дә шунда нәшер ителә. Әлеге хезмәт аркасында 1908 елда ширкәттән 51 исемдә тыелган татарча китаплар һәм 7,5 меңгә якын татарча с.-д. брошюралар тартып алына. Елдан-ел басмаханә басмаларны чыгаруны арттыра бара: 1901–12, 1902 дә — 18, 1903 тә — 31, 1904 тә — 18, 1905 тә — 35 һәм 1906 да 41 исемдә басма дөнья күрә. Беренче рус рев-циясе җиңелгәннән соң, цензура эзәрлекләве нәтиҗәсендә тиражлар кими: 1907 дә — 16, 1908 дә 2 генә басма чыгарыла; аннары басмаханә эше тагын җанланып китә: 1912 дә — 23, 1914 тә — 10, 1915 тә — 6 басма. 1901 — 1917 дә 182110 данә гомуми тираж б-н 384 татар китабы басыла. 1917 елда басмаханәнең эшчәнлеге туктала.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; ш у л у к. Из истории татарской дореволюционной книги // Здравствуй, книга! К., 1989.

**КӘРИ́МОВ** Альберт Хәмзә улы (1.8.1935, Казан), гамәли электрохимия өлкәсе галиме, физик, техник фән. д-ры (1983), проф. (1986), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан авиация ин-тын (1959), Казан ун-тын (1966) тәмамлый. 1959–70 елларда Казан моторлар төзү з-дында эшли, 1969–70 тә эшкәртүнең электрохимик алымнары һәм сәнәгать электроникасы эксперименталь-конструкторлык бюросы башлыгы. 1970 тән Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты) гамәли физика каф. мөдире (1983–2001). Хезмәтләре авиация төзелешендә материалларны үлчәмләп электрохимик эшкәртүгә карый. К. фасонлы өслекләрне үлчәмләп электрохимик эшкәртү процессының матем. моделен, ш.у. формалар ясауның бер, ике һәм өч үлчәнешле мәсьәләләрен бер үлчәнешле локаль якынчалаштыру нигезендә чишү алымнарын эшли. Катод инструментларның профильләрен исәпләү һәм профильләү алымнарын, фасонлы өслекләрне үлчәмләп электрохимик эшкәртү процессының технол. күрсәткечләрен күтәрү юлларын тәкъдим итә. Конструкцион һәм инструменталь корычларның һәм эретмәләрнең төрле электролитларда электрохимик эшкәртелә алучанлыгын тикшерә. Авиация төзелеше детальләре өчен К. тарафыннан уйлап табылган электрохимик җайланмалар һәм технол. процесслар ТР пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Электрофизические и электрохимические методы обработки материалов» дигән вузара җыентыкның җаваплы мөхәррире (1985–93). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996). РФ Космонавтика федерациясенең акад. В.П.Макеев исем. медале, СССР ВДНХсының көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә. Тимераякта узышу буенча ТАССРның биш тапкыр җиңүчесе һәм рекордчысы була (1954–60).

Х е з м.: Технология электрохимической обработки деталей в авиастроении. М.,1986 (автордаш); Методы расчёта электрохимического формообразования. К., 1990 (автордаш); Исследование вибрационных характеристик деталей и узлов двигателей методом голографической интерферометрии при их диагностике. К., 1998 (автордаш); Технология лазерной обработки. К., 1999 (автордаш).

**КӘРИ́МОВ** Ахим Кәрим улы (5.12.1917, Уфа губ., Минзәлә өязе Качкын а.), нефтьче-геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1969), проф. (1973), рәссам. Сәмәрканд ун-тын тәмамлый (1939). 1947–50, 1954–59 елларда Уфа нефть фәнни-тикшеренү ин-тында, 1950–54 тә — Бөтенсоюз нефть геология-разведка ин-тында (Ленинград) эшли, 1959–75 тә Ташкент нефть чыганаклары геологиясе һәм эзләнү фәнни-тикшеренү ин-тында геохимия бүлеге мөдире. Уфа нефть (1975–80) һәм Башкорт пед. (1980–88) ин-тларында химия кафедралары мөдире. Татарстан, Башкортстан, Каспий буеның төньяк-көнчыгышында һәм Үзбәкстан терр-яләрендә нефть составы үзгәрүнең үзенчәлекләрен ачыклый, Татарстанның аерым районнарында һәм чиктәш районнарда углеводородлар булуын нигезли. 150 дән артык картина иҗат итә, аларның иң яхшылары Казан музейларында саклана. Бөтенсоюз рәсем сәнгате күргәзмәләре лауреаты (1982, 1985, 1987). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефти Башкирии. Уфа, 1960 (автордаш); Задачи и упражнения по органической химии. Уфа, 1988.

*Әд.:* З ы я т д и н о в Ф.С. Авылдашның авыр юл башы // Казан утлары. 2012. № 6–7.

**КӘРИ́МОВ** Әлтаф Хөснимәрдан улы (19.9.1939, Мәскәү ш.), авиаконструктор, техник фән. д-ры (1984). 1962 елда Мәскәү авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, А.Н.Туполев исем. тәҗрибә КБда (хәзер А.Н.Туполев исем. авиация фәнни-техник комплексы, Мәскәү), әйдәп баручы конструктор (1970 тән). 1973–95 тә В.М.Мясищев исем. эксперименталь машиналар төзү з-дында (Мәскәү өлкәсенең Жуковский ш.): әйдәп баручы конструктор, ныклылык һәм аэросыгылмалылык бүлеге башлыгы (1974–87), проектлар бүлекчәсе башлыгы (1987–90), пилотсыз очкыч аппаратлар буенча баш белгеч. 1995 тән А.Н.Туполев исем. авиация фәнни-техник комплексының фән буенча директоры. 1997 дән «П.О.Сухой исем. тәҗрибә КБ» АҖнең баш конструкторы урынбасары (Мәскәү). Хезмәтләре очкыч аппаратларның аэродинамикасына, ныклыгына һәм аларны проектлауга карый. К. очкыч аппаратның аэродинамик характеристикаларын исәпләү алымнарын, конструкциясенә бәйле рәвештә йөкләнешләр дәрәҗәсен киметү юлларын эшли (югары биеклекләрдә оча торган М-17, М-55 самолётларын, пилотсыз «Орёл», «Ромб», «Чиж-К» комплексларын проектлаштырганда кулланыла). Ту-144, Ту-154, Ту-22М һ.б. самолетларны төзүдә катнаша. К. җитәкчелегендә күпсанлы пассажирларны сыйдыручан КР-860 магистраль самолёты һәм пилотсыз С-62 самолёты (очыш биеклеге 20 *км* га, очу дәвамлылыгы 24 сәгатькә кадәр) проектлары эшләнә. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Определение аэродинамических характеристик упругого стреловидного крыла в дозвуковом потоке // Изв. вузов. Авиац. техника. 1970. № 3; Матрица аэродинамических коэффициентов влияния для крыла произвольной формы в плане при сверхзвуковых скоростях // Изв. вузов. Авиац. техника. 1971. № 4; Беспилотные самолёты: Максимум возможностей // Наука и жизнь. 2002. № 6.

**КӘРИ́МОВ** Гыйльман Ибраһим улы (1.10.1841 — 6.6.1902), дин эшлеклесе, нашир. Самара губернасы Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы авылы мәдрәсәсендә укый, 1867 елда Чистай мәдрәсәсен тәмамлый. 1870–99 елларда Бөгелмә өязе Миңлебай авылы мәдрәсәсенең мөдәррисе һәм мәчетнең имам-хатибы. Урта Идел буенда җәдит мәдрәсәләре оештыручыларның берсе, дәреслекләр авторы. 1899 да дини эшчәнлектән ераклашып, китап басу эше б-н шөгыльләнә баш-

лый. 1900 елда Оренбург шәһәрендә зур булмаган басмаханә сатып ала. Гомуми тиражы 52,4 мең данә булган 27 исемдә китап бастыра. К.ның наширлек эшчәнлеген аның улы Ф.Г.*Кәрими* дәвам итә.

*Әд.:* Кәрими Ф. Мәрхүм Гыйльман ахун. Оренбург, 1904; Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**КӘРИ́МОВ** Җәүдәт Хәлил улы (1914–84), генерал-майор (1962). Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Урал, Воронеж, Кавказ арты һәм Одесса хәрби округларында җитәкче вазифалар башкара, 1965–74 елларда Идел буе хәрби округында командующий урынбасары.

**КӘРИ́МОВ** Камил Әдһәм улы (1.7.1950, Питрәч р-ны Шәле а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан мәдәният ин-тын тәмамлагач (1980), «Яшь ленинчы» г-тасы хәбәрчесе булып эшли. 1982–88 елларда «Идел» альманахында җаваплы мөхәррир, 1988–2000 дә «Чаян» ж-лында җаваплы сәркәтип. 2000 нән «Казан утлары» ж-лының проза бүлегендә мөхәррир булып эшли. К. беренче хикәяләреннән үк («Уңдүрт яшьтә» җыентыгы, 1981) лиризм белән юморны оста бәйләүче, үзенчәлекле язу стиленә ия автор буларак танылa. Соңрак язылган әсәрләрендә дә, юмористик интонация тагы да көчәеп, сатирик мотивлар өстенлек ала бара («Бәхетле кеше», 1984; «Вәгъдә», 1985; «Күләгәдә төлке бар», 1990; «Үзеңне бел», 1997; «Өй артында шомыртым», 2003). Мелиораторлар тормышы һәм аларның хезмәтенә багышланган дилогиянең беренче китабы — «Ком сәгате» (2000) романы — тәнкыйтьчеләр һәм укучылар тарафыннан югары бәяләнә. 2003 тә дилогиянең икенче өлеше «Сакау күке» исеме б-н «Казан утлары» ж-лында басылып чыга. «Уен» романы («Казан утлары», 2007, № 6–7) авторы. К. 1988–2000 елларда телевизион юмористик тапшырулар авторы һәм алып баручысы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**КӘРИ́МОВ** Марат Нәби улы (9.1.1930, Башкортстан АССРның Зианчура р-ны Күгәрчен а.), язучы, БРның атказ. мәдәният хезмәткәре, халык шагыйре (1994, 2003). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый (1961). 1954–56 елларда КПСС ҮК каршындагы Үзәк (Югары) комсомол мәктәбендә укый. 1956–57 дә «Ленинчы» г-тасында әдәби хезмәткәр, 1958 дән (бүленеп) «Һәнәк» ж-лында (1968–78 дә баш мөхәррир); 1964–68 дә «Пионер» ж-лының баш мөхәррире. «Бөреләр» (Уфа, 1956; русчага тәрҗемәсе «Весенние почки», М., 1961), «Йәшлегем йәшнәр көнөм» (Уфа, 1965), «Тормыш — ғашиҡтарға» (Уфа, 1969), «Ете көнем — ете моң» (Уфа, 1981), «Тәгәрәй гүмерем йомғағы» (Уфа, 1994) кебек шигъри җыентыклар, «Алланың ҡашҡа тәкәһе» (Уфа, 1968), «Ялган һуҡмаҡ» (Уфа, 1987), «Адәм көлкесе» (Уфа, 1998) исемле сатирик һәм юмористик хикәяләр җыентыклары авторы. Уфа шәһәрендә яши.

Ә с ә р: Һайланма әҫәрҙәр. Шиғырҙар. Өфө, 2000.

**КӘРИ́МОВ** Морат Габделхәй улы (18.4.1931, Казакъстан АССРның Джамбейты р-ны Джамбейты пос.), физиолог-онколог, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1973). 1954 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1960 тан Казакъстан онкология һәм радиология фәнни-тикшеренү ин-тында (Алма-Ата); эксперименталь онкология лаб-ясе (1961 дә төзелә, соңрак тышкы мохитнең канцероген агентлары лаб-ясе), диагноз кую лаб-ясе мөдире (1985 тән). ТРның Казакъстан Респ-касындагы тулы вәкаләтле вәкиле (1997–2005). Хезмәтләре әйләнә-тирә мохитнең нефть һәм нефть продуктлары б-н пычрануы дәрәҗәсен, нефтьнең агулылыгын һәм канцерогенлыгын, эндо- һәм экзоагулардан дәвалау һәм аларны булдырмауны өйрәнүгә карый. К. тарафыннан шешләр штаммнары (Эрлих яман шешенең осцит һәм солид формалары, саркома, $C_{37}$, Уокер карциносаркомасы, $C_{45}$, ЛИО-1 микросаркомасы һ.б.) булдырыла. Казакъстан Респ-касы халкы сәламәтлеген, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча норматив документлар, нефть эшкәртү сәнәгатендә гигиена нормативларын эшләүдә катнаша. Казакъстанда Татар һәм татар-башкорт җәмгыятьләре һәм мәдәни үзәкләре ассоциациясе президенты, Арал диңгезе, Балхаш күле, Казакъстан экологиясе проблемалары буенча халыкара ком-т президенты. «Дуслык» ордены (Казакъстан), медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: О значении нефти, нефтепродуктов, курения, алкоголя и водного режима в генезе рака мочевого пузыря. Алматы, 2000; Рак — проблема XXI века. Алматы, 2000.

*Әд.:* Мурат Абдулхаевич Каримов (к 70-летию со дня рождения) // Онкология и радиология Казахстана. 2001. № 11.

**КӘРИ́МОВ** Мөхәммәтша Зариф улы (28.7.1910, Чиләбе ш. — 28.4.1990, Мәскәү), реставратор, график, гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, коллекционер, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982). 1930 елда Казан сәнгать-пед. техникумының сәнгать бүлеген (П.*Беньковта*, В.*Тимофеевта*) һәм графика остаханәләрен (Ф.Быковта) тәмамлый; Б.*Урманче* нигез салган Керәч остаханәсе шәкерте. 1928 дә К. милли бизәкләр төшерелгән керәч сәнгате үрнәкләре б-н Парижда уздырылган Гамәли-бизәлеш сәнгате күргәзмәсендә катнаша. В.И.Ленинның К. башкаруындагы миниатюр портреты (ксилография, 1929) АКШның зур шәһәрләрендә узган «СССРның хәзерге заман сәнгате» күргәзмәсендә куела (1933). К.ның 1920 еллар ахырында эшләнгән график миниатюраларыннан «Билгесез кеше портреты» (литография) һәм «Кепкалы автопортрет» (ксилография, кара фонда ак контур б-н башкарылган) әсәрләре П.М.*Дульскийның* «Революция чорында татар китабы бизәлеше» («Оформление татарской книги за революционный период», 1930) китабында басыла. 1930–34 елларда К. ТАССР Милли музее каршындагы картиналар галереясы б-н җитәкчелек итә; репрессияләнгән Б.Урманченың әсәрләрен конфискацияләнүдән саклап кала. 1931 дә музей тарафыннан Урта Азиягә сәнгать белгече П.Е.*Корнилов* җитәкчелегендә оештырылган экспедиция эшендә катнаша. Урта Азия темасына рәсемнәр сериясе иҗат итә. 1935 тә Мәскәүгә күчә: 1937 гә кадәр Третьяков галереясында баш саклаучы ярдәмчесе, өлкән фәнни хезмәткәр; 1937–44 тә Керәч музееның (Кусково) өлкән фәнни хезмәткә-










М.З.К ә р и м о в. 1. «Автопортрет». Линогравюра. 1928; 2. «Соңарган кичке аш». Литография. 1929; 3. «Хәсән Урманов портреты». Ксилография. 1930; 4. «Рәссам Мөнүрә Газизова портреты». Кәгазь, карандаш. 1931. Барысы да — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

ре, баш саклаучысы; 1944–45 тә А.С.Пушкин исем. Сынлы сәнгать музееның реставрацияләү остаханәсе мөдире; 1947–49 да Мәскәү гамәли һәм бизәлеш сәнгате ин-ты хезмәткәре булып эшли. Шул ук елларда сугыш вакытында зыян күргән экспонатларны ачыклау буенча РСФСР музейларында хезмәт итә. 1950 еллар азагына кадәр Дәүләт трофей фондыннан һәм Дрезден галереясыннан кайтарылган берничә мең антик керамика, скульптура әсәрләрен, картина рамнарын реставрацияли. Бер үк вакытта 1962 гә кадәр СССР ФАдә, Кремльнең Зур сараенда, Шәрекъ мәдәнияте музеенда, Бахрушин исем. Театр музеенда, Кече акад. т-рында, СССР Сәнгать фондының Мәскәү бүлеге сынлы сәнгать-җитештерү комбинатында, Мәскәү сәнгать-сәнәгать уч-щесе (элекке Строганов) остаханәләрендә һ.б.ларда керамика, гамәли-бизәлеш, скульптура, нәкышь сәнгате әсәрләрен, җиһазларын реставрацияли. 1962–71 дә Революция Үзәк музеенда — рәссам-реставратор. 1971–74 тә РСФСР Сәнгать музеенда эшли, тарихи-рев-ция музейлары өчен кабатланмас ядкәрләр: документлар, байраклар, бүләкләр (орденнар, медальләр һ.б.), В.И.Ленин, М.И.Калинин, Ф.Э.Дзержинский, Я.М.Свердловның шәхси әйберләре күчермәләрен, муляжларын әзерли. Реставрация эшләре барышында көмеш, эмаль, кытай лагы, таш, агач һ.б.ш. материалларның 10 меңнән артык реставрацияләү рецептларын һәм яңа алымнарын, ысулларын булдыра. К. 1920 еллар татар рәссамнарының (Б.Урманче, Ш.*Мөхәммәтҗанов*, К.*Чеботарёв*, А.*Платунова* һ.б.) уникаль нәкышь һәм графика әсәрләре коллекциясен туплый, аларның бер өлешен ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музеена тапшыра.

К.ның графика мирасын карандаш, акварель б-н язылган эшләр; литографияләр, линогравюралар: «Кухняда», «Казан сәнгать техникумында графика түгәрәге» (икесе дә — 1929), «Урта Азия сериясе» (1931), «Ф.Дзержинский портреты» (1936) һ.б. тәшкил итә. Шәхси күргәзмәсе Казанда оештырыла (1982). К.ның әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда саклана.

Х е з м.: Реставрация и консервация серебряных и посеребрённых предметов. М., 1949.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990.

*Р.Г.Шаһиева, О.Л.Улемнова.*

**КӘРИ́МОВ** Салават Хәким улы (15.9.1914, Казан губ., Зөя өязе Янгилде а. — 11.5.1986, Казан), Сов. Союзы Герое (5.5.1942), майор. «Выстрел» югары офицерлар курсларын (Мәскәү өлкәсе Солнечногорск ш., 1942), М.В.Фрунзе исем. Хәрби акад. каршындагы тизләтелгән пехота курсларын (Мәскәү, 1944) тәмамлый. Хәрби хезмәткә чакырылганчы, Свердловск шәһәрендә заводта слесарь булып эшли. 1936–38, 1939–40 елларда һәм 1941 нең июненнән Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 709 нчы укчы полкның укчы батальоны командиры (22 нче армиянең 178 нче укчы



С.Х. Кәримов.

дивизиясе). Калинин, Төньяк-Көнбатыш һәм 2 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Смоленск сугышында (1941), Ржев-Вязьма (1943), Ленинград-Новгород, Старорус-Новоржев, Режица-Двинск һәм Рига (барысы да — 1944) һөҗүм операцияләрендә, Курляндия ярымутравындагы сугышта (1944–45) катнаша. 1942 нең 26 гыйнварыннан 5 февраленә кадәр Харино, Струйский һәм Фролово (Калинин өлкәсе Ржев р-ны) авыллары янындагы сугыш операцияләрендә батырлык күрсәтә: алдан уйлап хәрәкәт итүе нәтиҗәсендә К. җитәкчелек иткән батальон дошманның күпсанлы хәрби техникасын юк итә. 1947 дән запаста. Казанда яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; В боях за Ржев. М., 1973; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.


*М.З.Хәбибуллин.*

**КӘРИ́МОВ Ф. БАСМАХАНӘСЕ́**, к. «*Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе.*

**КӘРИ́МОВ** Фәхразый Шәмсемөхәммәт улы (16.9.1932, Азнакай р-ны Чалпы а.), механизатор, Соц. Хезмәт Герое (1981). 1949 елда Бөгелмә механикалаштыру уч-щесен тәмамлаганнан соң, Азнакай р-нының «Коммунизмга» к-зында (1990 нан «Чалпы» а.х. җәмгыяте) тракторчы булып эшли. 1976 да К. җитәкчелегендәге звено 50 мең *ц* дан артык ашлык суктыра һәм республикада ашлык җыю-транспортлау звенолары арасында иң югары күрсәткечкә ирешә. К. язгы культураларны тиз чәчүнең инициаторы була. Герой исеме 10 нчы бишьеллык (1976–80) йөкләмәләрен һәм игенчелек продукциясен җитештерүне арттыруда һәм дәүләткә сатуда ирешелгән уңышлары өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Азнакай шәһәрендә Геройлар аллеясында К.ка бюст куела (2002).

*Әд.:* Д у д н и к Г. Каримов Фахрази Шамсумухаметович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КӘРИ́МОВ** Хәниф Зәки улы (9.1.1948, Азнакай р-ны Мәлбагыш а.), галим-агроном, а.х. фән. д-ры (2001), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Азнакай р-нының Ленин исем. к-зында икътисадчы, баш агроном (1973) булып эшли. 1978 елдан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1988 дән беренчел орлыкчылык бүлеге мөдире. 2006 дан Казан аграр ун-тының җир эшләре һәм агроэкология каф. профессоры. Хезмәтләре күпьеллык үләннәр орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. К. люцерна һәм башка культуралар орлыгын игүнең



Ф.Ш. Кәримов.



Г.Г. Кәримова.

фәнни нигезләнгән алдынгы технологияләрен эшли. Люцернаның «Айсылу», язгы бодайның «Әмир» һәм «Казанская юбилейная», арпаның «Нур» сортларының автордашы. Уйлап табуга 3 патенты бар. Дәүләт бүләге ТРда терлек азыгы җитештерү системасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Люцерна на семена в Татарстане. К., 2003 (автордаш); Козлятник восточный в Татарстане. К., 2004 (автордаш).

**КӘРИ́МОВА** Гөлбикә Гали кызы (15.9.1938, Теләче р-ны Караширмә а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1971), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). 1953–93 елларда Теләче р-нының В.И.Ленин исем. тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында сыер савучы. 1968 дә һәр сыердан савым уртача 5549 *кг* тәшкил итә һәм К.га «ТАССРның иң яхшы сыер савучысы» дигән исем бирелә. 1971–75 тә һәр сыердан елына 5 мең *кг* нан артык сөт ала, 1973 тә районда беренчеләрдән булып машина б-н савуны үзләштерә, 1984 тә 2 сменалы эшкә күчә. Герой исеме хезмәттә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. СССР ВДНХсында катнаша. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Теләче р-нының Үзәк поселогында бер урамга К. исеме бирелә (1999).

*Әд.:* М а т в е е в а Е. Каримова Гульбика Галеевна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КӘРИ́МОВА** Дания Йосыф кызы (7.11.1946, Казан), педиатр, гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1993). 1970 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм Казанда 6 нчы балалар шифаханәсе табибе булып эшли. 1974 тән Казан мед. ин-тының социаль гигиена һәм сәламәтлек саклауны оештыру каф. мөдире, 1984 тән Казан ГИДУВының шул ук исемдәге кафедрасында. 1995 тән Халыкара экология һәм яшәү куркынычсызлыгы академиясендә (С.-Петербург). Хезмәтләре ана һәм бала сәламәтлеген саклауга, мед. тарихына карый. РФ Дәүләт Думасы депутаты (1995–99).

Х е з м.: Здоровье, счастье, красота. К., 1992.

**КӘРИ́МОВА** Зәйнәп Хәбибулла кызы (22.2.1909, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Аллагуат а. — 22.9.1995, Казан), микробиолог, мед. фән. д-ры (1968), проф. (1969). 1931 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли, 1942–74 тә микробиол. каф. мөдире.



С.С. Кәримова.

Хезмәтләре бактериофаглар алу ысулларын эшләү һәм аларны йогышлы авыруларны дәвалауда куллануга, лептоспироз авыруларына диагноз кую һәм дәвалауга карый. К. авырулар каныннан спирохетлар алу ысулын эшли, туберкулёзны дәвалау өчен прополистан дәвалау препаратлары ала, Татарстанда лептоспирозларның этиологик төзелешен ачыклый, яңа төрләрен ача (берсе аның исеме б-н «Кәримова штаммы» дип йөртелә). «Почёт билгесе» ордены, медаль, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Использование прополиса в медицине // Пчеловодство. 1960. № 8; Лептоспирозные заболевания людей, вызванные Leptospira rattus // Материалы юбилейной науч. конф., посвященной 150-летию со дня основания мед. ин-та. К., 1964; Прополис в комплексном лечении лёгких и бронхов. Бухарест, 1972.

**КӘРИ́МОВА** Саимә Сафа кызы (31.10.1926, Фрунзе ш.), геолог, РСФСРның атказ. геологы (1973), Соц. Хезмәт Герое (1976). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1982). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1950), Көньяк Якутия геол.-эзләнү экспедициясендә эшли, баш геолог (1968–88). Көньяк Якутиянең геол. төзелешен һәм файдалы казылмаларын өйрәнү буенча геол.-эзләнү эшләре комплексы б-н җитәкчелек итә. Күмер (ш.и. Россиядә иң эреләрдән саналган Эльгин һәм Нерюнгри), алтын, флогопит, төзелеш материаллары, җир асты суларының чыганакларын һ.б. эзләүдә һәм ачуда катнаша. Көньяк Якутиянең беренче геол.-сәнәгый картасын төзи. Көньяк Якутия терр.-җитештерү комплексының күмер минерал-чимал базасын булдырганы өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була. 1976–88 елларда Якутия АССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Саха Респ-касы (Якутия, 1997) һәм Нерюнгри шәһәренең (1982) мактаулы гражданы.

Х е з м.: Стратиграфия мезозойских угленосных отложений // Тр. Всесоюз. геол. ин-та. 1979. Т. 6.

**КӘРИ́МОВА** Фатыйма Габдуллаҗан кызы (5.4.1941, Балык Бистәсе р-ны Биектау а.), биолог, биол. фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1970 елдан РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, баш фәнни хезмәткәр (1994–2000), сигнал системалары лаб-ясе мөдире (2001 дән). Хезмәтләре тере күзәнәктә барган физиологик-биохимик процессларның сигнал системалары ярдәмендә көйләнү механизмнарын өйрәнүгә карый. К. үсемлек күзәнәкләрендә су һәм кальций транспортын, генетик аппаратның метаболизмын һәм активлыгын көйләүче сигнал системаларының үзара бәйләнеш активлыгын, үсемлекләрнең үзгәреп торучы тереклек шартларына реакциясен тикшерә. Аның тарафыннан үсемлекләрдә цАМФ-сигнал (циклик аденозинмонофосфат) системасының төп буыннары эшчәнлеге өйрәнелә. А.х. үсемлекләренең түбән темп-раларга һәм патогеннарга чыдамлыгында фитогормоннар, гидроксидодецен һәм салицил к-таларының тәэсире вакытында үсемлек күзәнәкләрендәге аденилатциклаз, тирозинкиназ һәм кальцийлы сигнал системаларының катнашуын күрсәтә. Үсемлекләрнең әйләнә-тирәлекнең уңайсыз һава шартларына чыдамлыгын арттыра торган төп көйләгеч аксымнар ачыклана.

Х е з м.: К вопросу о роли $Ca^{+2}$ в транспорте воды в растительных тканях // Физиология и биохимия культурных растений. 1985. Т. 17, № 6; $Na^{+}/Ca^{+2}$ — обмен в клетках растений // Докл. РАН. 1999. Т. 366, № 6 (автордаш); The oppositely directed $Ca^{+2}$ and $Na^{+}$ transmembrane transport in algal cells // Protoplasma. Austria, 2000. V. 213 (автордаш).

**КӘРИ́МОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре, китаплар б-н сәүдә итүчеләр, наширлар. Чыгышлары б-н Саратов губернасы Зур Черкиле авылыннан. **Шәрифҗан** (1850–?), **Мөхәммәтҗан** (25.8.1853–?), **Хәсән** (1872–?) **Минһаҗетдин** уллары галантерея товарлары һәм китаплар б-н сәүдә итәләр. 1897 елда 2 нче гильдия Казан сәүдәгәрләре булып язылалар. 1898 дә «Бертуган Кәримовлар сәүдә йорты» ширкәтен оештыралар, 1900 дә басмаханә һәм хәреф кою йорты ачыла, анда дини-дидактик, фәнни-популяр һәм матур әдәбият, дәреслекләр һ.б. басыла. К.ның китап басу комплексы галантерея товарларын һәм китапларны күпләп сату кибетеннән (еллык сәүдә әйләнеше 300 мең сум) һәм басмаханәдән (еллык сәүдә әйләнеше 100 мең сум) тора. Россиядә татарлар тупланып яшәгән барлык төбәкләрдә дә К. сәүдә йортының ф-ллары эшли. К. Ш.Мәрҗани идеяләрен дәвам иттерүчеләр, либераль үзгәртеп корулар тарафдарлары булалар. 1912 дән алар «*Кояш*» г-тасы чыгара башлыйлар. Ш.у.к. *Кәримовларның китап сату фирмасы*; *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәте.*

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII начало XX веков). К., 1994.

*Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.*

**КӘРИ́МОВЛАР БАСМАХАНӘСЕ́, ТАШБАСМАСЫ́ ҺӘМ ХӘРЕ́Ф КОЮ́ ШИРКӘТЕ́.** Казандагы беренче шәхси татар басмаханәсе. Хуҗалары — китап б-н сәүдә итүчеләр, наширләр — бертуган Шәрифҗан, Мөхәммәтҗан һәм Хәсән *Кәримовлар.* 1899 елда *Кәримовларның китап сату фирмасы* эшчәнлеге кысаларында М. һәм Ш.Кәримовлар тарафыннан нигезләнә. 1900 дән эшли башлый. Басмаханәдә 3 тиз баса торган басмаханә машинасы, 2 басмаханә станогы, татар һәм рус телләрендәге 96 пот 36 кадак хәрефләр була. Шул ук елда хәреф кою ширкәте эшли башлый. 1901 дә ташбасма да ачыла һәм бертуган Кәримовлар басмаханәсе «Кәримия



Шәмаил. Ташбасма. Билгесез рәссам. 1907. Кәримовлар басмаханәсе.

матбагасы» исемен ала. Башта басмаханәдә 11 кеше, 1902 дә — 32, 1902–05 тә — 34–35, 1915 тә 50 кеше эшли. 1917 дә анда 3 зур басмаханә машинасы (1 «американка», 2 «бостонка») һәм 2 ташбасма машинасы исәпләнә. Хәреф кою ширкәтендә 65 пот хәреф файдаланыла, айга 15 пот хәреф коела. Әлеге хәреф кою ширкәте, «Идрисов», «Мәгариф» хәреф кою ширкәтләре һәм 1 нче дәүләт басмаханәсе җирлегендә эре дәүләт хәреф кою ширкәте оеша. Ул Казан басмаханәләрен генә түгел, губерна, Идел буе, Себер, Төркестан, Әзәрбайҗан, Украина басмаханәләрен дә хәрефләр б-н тәэмин итеп тора.

Беренче басмалары — «Мәҗмәгел ләтаиф» («Мәзәкләр җыентыгы», 1900), Г.Камалның «Бәхетсез егет» (1900) пьесасы һ.б. 1900 нең 10 аенда татар телендә 433,1 мең данә тираж б-н 36 исемдәге китап басыла. Алга таба ел саен якынча 1,5 млн. данә тираж б-н 130 лап исемдә, 1901–17 дә 20 млн. нан артык тираж б-н 1763 исемдәге китап чыгарыла.

20 йөз башында Казанда татар телендә чыккан китапларның яртысы Кәримовлар басмаханәсендә нәшер ителә. Барлык басмаларны да диярлек Кәримовлар үз китап кибетләрендә саталар; алар арасында урта гасырлар авторлары әсәрләре, татар җәдит мәктәпләре өчен дәреслек-әлифбалар, үзөйрәткечләр, грамматика буенча ярдәмлекләр, арифметика, география дәреслекләре бар (Ш.Рәхмәтуллинның «Руслар өчен — татар теленнән һәм татарлар өчен рус теленнән үзөйрәткеч»енең 10 га якын басмасы чыга). Басмаханәнең монохром төсләрдә мәктәп атласлары, географик карталар чыгару мөмкинлеге дә була. Ислам тәгълиматына һәм йола, гореф-гадәтләренә, Коръән уку кагыйдәләренә багышланган китаплар, үгет-нәсыйхәт характерындагы китаплар, Коръән (17 басма), догалыклар һ.б. дөнья күрә. Басмалар арасында зур урынны мед., а.х., һөнәрчелек буенча фәнни-популяр әсәрләр, Ватан тарихы буенча китаплар алып тора. Шулай ук татар халык җырлары, әкиятләре, табышмаклары җыентыклары, Хуҗа Насретдин мәзәкләре һ.б. нәшер ителә. Басмалар арасында төп урынны М.Гафури, М.Фәйзи, Н.Думави, Ф.Кәрими, Г.Коләхмәтов һ.б. авторлар әсәрләре били. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.С.Тургенев, Л.Н.Толстой әсәрләре, рус халык әкиятләре; М.Твенның «Принц һәм теләнче», Д.Дефоның «Робинзон Крузо», Ж.Вернның «Һава шарында биш атналык

сәяхәт» повестьлары, Х.К.Андерсенның «Шыксыз үрдәк бәбкәсе» әкиятенең һ.б. татарчага тәрҗемәләре дә әлеге басмаханәдә дөнья күрә. Бертуган Кәримовларның китап сату каталоглары (1890, 1897, 1914), «Сабах» нәшриятының китап каталоглары (1908) була. «Бәянелхак» (1907), «әл-Ислах» (1908–09), «Тавыш», «Йолдыз» (1909, 1912), «Кояш» (1912, 1914, 1915) г-талары, «Яшен» ж-лы һ.б. басыла.

Кирәкле җиһазларның барысы да булуы нәтиҗәсендә бертуган Кәримовларның китап басу йорты башка басмаханәләргә бәйле булмый; басмаларның күптөрле булуы, күп тиражда чыгулары, кәгазь һәм нәфис бизәлеш чыгымнарын киметү аларның китап продукциясен арзанлы һәм табышлы итә.

Нәшрият эше юнәлешләрен билгеләүдә Кәримовларның шәхси элемтәләре зур роль уйный. Татар с.-д. даирәсеннән Г.Камал, Ә.Хәсәни б-н танышлык нигезендә басмаханәдә РСДРП(б)ның Казан ком-тының «Рабочий» г-тасы (1917), Мөселман соц. ком-ты материаллары, 1919 ның апрелендә рус, татар, чуаш, мари телләрендә «Красный воин» г-тасы басыла. Листовкалар, өндәмәләр б-н бергә татар телендә китаплар басылу да дәвам итә. 1919 ның июнендә басмаханә национализацияләнә һәм «Мәгариф» басмаханәсе б-н кушылып, 6 нчы дәүләт басмаханәсе дип атала башлый. Шул ук елда китап төпләү машиналары Көнчыгыш фронтка тапшырыла.

*Әд.:* «Правила внутреннего распоряжения...». К., 1900; К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; М и ф т а х о в З.З. Развитие полиграфической базы в Татарии (октябрь 1917–1927 гг.) // Здравствуй, книга! К., 1989.

**КӘРИ́МОВЛАРНЫҢ КИТА́П САТУ́ ФИ́РМАСЫ**, 1898 елда Казанда «Бертуган Кәримовлар сәүдә йорты» ширкәте ачыла. Кәримовларның этиләре Казан сәүдәгәре Минһаҗетдин Кәримов 1892 елда үзенең Тихвин урамында урнашкан шәхси йортында басмаханә оештыра (аның эшчәнлеге турында мәгълүматлар юк). Әлеге хуҗалык б-н җитәкчелек итү аның улына — 1900 дә басмаханә һәм хәреф коюю ширкәтен нигезләгән 2 нче гильдия сәүдәгәр М.М.Кәримовка күчә (1909 да ул әлегә кадәр этисенең басмаханәсе урнашкан Тихвин урамындагы йортка күчерелә). Ширкәт эше б-н М.М.Кәримов җитәкчелек итә. Аның составында ш.у. һәрберсе 7 мең сум өлеш керткән бертуган Ш.М. һәм Х.М.*Кәримовлар* да була. Ширкәт китаплар һәм башка, ш.и. галантерея товарлары б-н сату итү өчен оештырыла. Ширкәттә Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабының ике басмасы (1885, 1897) дөнья күрә. Ш.Мәрҗанинең гарәп илләренә сәяхәте вакытында алып барган язмалары да бертуган Кәримовлар хисабына басыла («Рихләт әл-Мәрҗани», 1897 — Р.Фәхретдин тарафыннан төзелә). Әлеге басмаларны нәшер итү өчен заказлар шәһәрнең төрле басмаханәләренә бирелә. 1900 еллар башында китап сату фирмасы Печән базары мәйданындагы Усмановлар корпусында 2 бүлмә били. Китаплар Мәкәрҗә, Ирбет, Минзәлә һәм Сембер ярминкәләрендә сатыла. Сәүдә йортының бүлекчәләре Оренбург һәм Уфа шәһәрләрендә дә була (управляющие — Х.Кәримов). Үз басмаларын Кәримовлар Һиндстанда, Төркиядә, гарәп илләрендә дә тараталар. Китап сату һәм наширлек эшчәнлеге кыйммәтчелеге шәхси басмаханә булдыруны таләп итә. Ш.у. к. *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәте*.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; С а л и х о в Р. Мастера печатного дела // Время и деньги. 2004. 17 марта.



Кәримовларның китап сату фирмасы. Бертуган Кәримовларның нәшрият-сәүдә комплексы бинасы. Арх. П.И.Романов. 1883.




Кәримовларның китап сату фирмасы. «Сәүдә-сәнәгать альбомы» китабындагы реклама. 1909–10.

**КӘРИМУ́ЛЛИН** Әбрар Гыйбадулла улы (29.5.1925, Мамадыш кантоны Чәбия-Чүрчи а. — 19.9.2000, Казан), филолог, китап белеме галиме, библиограф, публицист, филол. фән.д-ры (1978), ТР ФА академигы (1992), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1941 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, башта колхозчы, аннары Нырты хастаханәсендә хисапчы, башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. 1943 елда Кызыл Армиягә чакырыла, 1947 дә демобилизацияләнә. 1953 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1953–64 елларда — Казан ун-тының фәнни китапханәсендә, 1964–92 дә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, шул ук вакытта, 1991–2000 дә ТР Милли китапханәсендә баш фәнни хезмәткәр булып эшли. Татар халкы тарихын өйрәнә. Төп хезмәтләре татар басма китабының барлыкка килү һәм үсү тарихын өйрәнүгә, филология һәм библиографиягә багышлана. «Татар китабының чишмә башы» («У истоков татарской книги», 1992) трилогиясе өчен Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә (1991) лаек була. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар тел белеме библиографиясе (1786–1956). К., 1958; Татар матур әдәбияты библиографиясе (1917–1966). К., 1964; Татарлар: Исемебез һәм җисемебез. К., 1991; Из истории печатного слова. К., 1984. Книги и люди: Исследование. К., 1985; Становление и развитие татарской советской книги. 1917–1932. К., 1989.

*Әд.:* Академия наук Татарстана. К., 1994; Абрар Гибадуллович Каримуллин: Биобиблиогр. указ. Уфа-К., 1995.

*Җ.С.Миңнуллин.*




Ә.Г. Кәримуллин.




Ә.Г. Кәримуллин хезмәтләре.

**КӘРИМУ́ЛЛИН** Миңнулла (1913, хәзерге Кукмара р-ны Байлангар а. — ?), татар фольклоры әсәрләрен җыючы. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тына 30 га якын татар халык әкиятләре текстларын җыеп тапшыра (күбесе «Татар халык иҗаты» җыентыгына кертелә).

**КӘРИМУ́ЛЛИН** Рәфкат Шәйхулла улы (23.3.1935, Теләче р-ны Күкчә а.), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2003). Казан сәнгать уч-щесендә укый (1951–54). Слесарь, аннан соң Казан вертолёт з-дында рәссам-бизәүче (1954–61), Казан телестудиясендә (1961–65), Казан киностудиясендә рәссам, «Казан утлары» ж-лында рәссам-бизәүче (1966–67) булып эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1993). К. иҗатының җитлегү чоры 1980 еллар ахырына туры килә. Бу чорда аның иҗатында яктылыкны импрессионистик рухта бирүче нәкышьләү алымнары образлар төзелешендәге экспрессионистик, сәнгати темпераментны билгеләгән ысуллар б-н берләшә. Пейзажлы нәкышь, лирик натюрморт, портрет остасы К. буыннарның күчә бару темасын чагылдырган сюжетлы-тематик картиналар авторы буларак та билгеле: «Яңгырдан соң» (1995), «Яңа пейзаж» (1995–96), «Җир» триптихы (1995–2005),





Р.Ш. К ә р и м у л л и н.
1. «Натюрморт». 1997;
2. «Көз». 2000;
3. «Сагыш». 2003.

«Авыр еллар» (1996), «Ятим» (1996–2005), «Кичке көйләр», «Хатирәләр», «Натюрморт» (барысы да — 1997), «Көз», «Җәйге җил», «Эссе көн» (барысы да — 2000), «Кышкы әкият» (2001), «Күңел ялкыны» (2002), «Сугыш балалары» (2004). Төбәкара («Татарт», С.-Петербург-Казан, 1991), төбәк («Зур Идел», 1974, 1980, 1991, 1998), бөтенроссия («Хезмәткә дан!», Мәскәү, 1976), бөтенсоюз (Җиңүнең 30 еллыгына багышлана, Мәскәү, 1975; «Хезмәт һәм спорт», Мәскәү, 1976; «Җир һәм кешеләр», Мәскәү, 1977; «Портрет», Мәскәү, 1989) күргәзмәләрендә катнаша, Шәхси күргәзмәләре 1995, 1996, 2000, 2003, 2005, 2010 елларда (Казан, Ульяновск, Чаллы, Димитровград ш.) оештырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Каунастагы М.К.Чюрлёнис Милли музеенда (Литва), Оренбург сәнгать музеенда, Франция, Бөекбритания, Төркиядәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Ш а г е е в а Р., М а м а е в а Т. Равкат Каримуллин: Проспект. К., 1996; Ш а г е е в а И. Лики бездны // Казань. 2002. № 11/12.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**КӘРКӘҮ́Ч** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Аллаук елгасының (Вятка (Нократ) елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 15 *км*, ТР чикләрендә — 13 *км*. Бассейнының мәйданы 171,6 $км^2$. Елга башы Кукмара р-ның Югары Шөн авылыннан 2,3 *км* көнбатыштарак, тамагы Киров өлкәсе терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 67 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 2%. К.ның 0,7 дән алып 4,4 *км* га кадәр озынлыктагы 12 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 115 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 $м^3/с$. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,1 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КӘРКӘҮ́Ч** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кәркәүч елгасы буенда. 2010 елда 354 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710–11 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, тегермән, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 990,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 362, 1897 дә — 675, 1908 дә — 779, 1920 дә — 776, 1926 да — 739, 1949 да — 669, 1958 дә — 559, 1970 тә — 527, 1979 да — 448, 1989 да — 375, 2002 дә — 400 кеше.

**КӘРЛӘ́Ч** (Sedum), кантибәрчәләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, кайвакыт ярымкуаклар һәм куаклар ыругы. 600 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында, башлыча, Евразиядә, берничә төре Көньяк Африкада һәм Көньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — зәһәр К. (S. acre) ара-тирә барлык районнарда очрый. Болыннарда, комлы һәм вак ташлы коры тау битләрендә, ташландык җирләрдә үсә. 5–15 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы нәзек, шуышма. Сабагы төбеннән үк тармаклы; чәчәксез сабаклары ятып, чәчәк атучылары — күтәрелеп тора. Яфраклары чиратлашкан, калын, озынча яки озынча түгәрәк. Чәчәкләре сары, очлы таҗ яфракчыклы, җәенке чәчәк төркемендә. Чәчәк ату чорында сары келәм хасил итә. Җимеше — күптабакча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре җәй ахырында өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Җир өсте өлешләрендә алкалоид, флавоноид, органик к-талар, кальций бар. Согы әче, зәһәр исле. Агулы. Халык медицинасында үләне бәвел кудыру, костыру чарасы, ш.у. йогышлы җәрәхәтләрне дәвалау өчен кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**КӘСКЕ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 55 *км* көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 17 кеше (руслар) яши. 1762 дән чуаш авылы буларак билгеле, 1830–40 елларда руслар килеп урнаша. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Смысловка, Берёзовка исемнәре б-н мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, урман промыселы, көл әзерләү б-н шөгыльләнә; көнлекчелектә эшли. 20 йөз башында К.дә земство мәктәбе (1900 ләр тирәсендә ачыла), икмәк һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 335 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1859 да — 182, 1870 тә — 203, 1884 тә — 254, 1913 тә — 276, 1920 дә — 384, 1926 да — 438, 1938 дә — 497, 1949 да — 445, 1958 дә — 308, 1970 тә — 167, 1979 да — 92, 1989 да — 41, 2002 дә — 12 кеше.

**КӘСЛЕ́-КАРБОНАТЛЫ́ ТУФРАКЛА́Р**, туфрак тибы, гумид климат һәм юыла торган су режимы шартларында үлән капламы мул үскән киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда карбонат токымнарда формалаша. Аларның эволюциясе нигезендә кальций карбонатының акрынлап селтесезләнүе һәм профильнең балчыклануы ята. Әлеге процессның стадияләренә бәйле рәвештә К.-к.т.ның түбәндәге астипларын билгелиләр: типик, селтесезләнгән һәм көлсуланган. Типик К.-к.т. калынлыгы 10–15 тән 30–40 *см* га кадәр булган, кара соры төстәге гумус горизонтыннан (А) тора, ул исә кисәк түшәлмә токым (D) б-н алышына. Селтесезләнгән туфрак профилендә көрән-коңгырт төстәге, калынлыгы 35–50 *см* булган, еш кына карбонат кушылмалары б-н көчеш катламы (В) билгеләнә. Көлсуланган туфракларда элювиаль-иллювиаль тип буенча профильнең дифференциациясе билгеләре: гумуслы катламның структурасы тузанлану, көчеш катламында кремнеземның аксыл сибелмәсе булуы ($A_1A_2$), иллювиаль катламда туфракның тыгызлануы күренә. 10% лы HCl тәэсирендә типик К.-к.т. өслегеннән, В катламы башында — селтесезләнгән һәм В катламы соңында — көлсуланган өлешләрдә туфрак кайнау күзәтелә.


ТР терр-ясендә К.-к.т. ике елга арасындагы, известьташ, доломит, мергель һәм аларның җилләнү продуктларыннан торган калкулыклы зур булмаган участокларда, аеруча Көнбатыш Кама алдында (Кукмара, Балтач, Мамадыш, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба р-ннары), Көнчыгыш Кама аръягының төньяк-көнбатыш р-ннарында (Зәй, Түбән Кама, Сарман) һәм Идел алдының көнчыгыш р-ннарында (Кама Тамагы, Югары Ослан, Апас) таралган. Рельефның биек һәм кабарынкы элементларына туры киләләр; гомуми мәйданы 175,6 мең *га* (ТР терр-ясенең 2,5%). Профильнең югары өлешендә — җиңелчә әче яисә нейтраль, түбәнге өлешендә аз селтеле тирәлек реакцияләре, туфрак йотылу комплексының нигезләр б-н югары туенганлыгы, суга чыдам бөртекле яки чикләвексыман бөртекле структура, туклану матдәләре запасының (фосфор, калий һәм азот) шактый булуы б-н характерлана. Түбәндәге төрләргә бүленә: гумус микъдары буенча — черемәле (12% тан артык), күп гумуслы (5–12%), урта гумуслы (3–5%), аз гумуслы (3% тан аз), гумуслы катламның калынлыгы буенча — аз (15 *см* дан ким), уртача (15 *см* дан күбрәк); төрчәләре: механик составы буенча — балчыклы, балчыксыл, комсу, ташлылык дәрәҗәсе буенча — көчле, уртача, җиңелчә ташлы. К.-к.т. мәйданының 60% ка якынын сөрү җирләре алып тора: бөртекле культуралар һәм күпьеллык үләннәр үстерелә. Печәнлек һәм көтүлек буларак кулланыла, К.-к.т.ның 18% ын урманнар били.

*Әд.:* Почвы Татарии. К., 1962; Шакиров К.Ш., Арсланов П.А. Почвы широколиственных лесов Предволжья. К., 1982.

*Ф.Г.Борһанов.*

**КӘСЛЕ́-КӨЛСУ́ ТУФРАКЛА́Р**, к. *Көлсу туфраклар*.

**КӘТӘҖИ́**, 19 йөз ахыры — 20 йөз башында татар кыз балалар баш киеме. Кәләпүш (тигез өслекле түбәтәй) формасында була. Төсле ефәк яисә бәрхеттән эшләнә. К.нең маңгай өлешендәге каты кашны, гадәттә, алтын яисә көмеш җепләр, яки энҗе, сәйлән б-н чигелгән чәчәк бизәкләре төшереп бизиләр. Баш



Кәтәҗи. Бәрхет. Укалап тигез чигү, сәйлән б-н чигү. 19 йөз ахыры.

киеменең өске ягы күп вакытта овал формасында була, җиңелчә генә фигуралы сырлар б-н бизәлә, кырпуга тоташкан сызыгы тар гына бөрмә б-н каймалана. Кечкенә кыз балалар К.не ялан башка, үсмер кызлар яулык өстеннән кияләр.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Завьялова М.К. Татарский костюм: Из собрания Государственного музея Республики Татарстан. К., 1996.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КӘТЕ́М** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кәкре Елга буенда. 2010 елда 147 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1755 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Карыколан исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2046 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мәсгут волостена керә. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 98 ир-ат; 1889 да — 581, 1908 дә — 825, 1920 дә — 949, 1926 да — 818, 1938 дә — 672, 1949 да — 402, 1958 дә — 356, 1970 тә — 294, 1979 да — 260, 1989 да — 181, 2002 дә — 183 кеше.

**КӘТИ́Б** (гарәп. كاتب), күчереп язучы, чиновник. Иң башта Мөхәммәд пәйгамбәргә иңгән вәхиләрне һәм аның боерыкларын язып баручыны, аннары мөселман илләрендәге дәүләт идарәсе оешмаларында чиновник — эш башкаручыларны шулай атап йөрткәннәр; К.ләр югары (салым-финанс ведомствосы — диван составына кергәннәр), урта һәм түбән катламнардан торган. Гадәттә, К. титулы нәселдән килгән. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында «К.» атамасы «*битикче*», «*бакши*» төшенчәләренә туры килгән (13–14 йөзләр), соңрак, ислам факторы көчәйгәч, «хафиз» мәгънәсен алган. Беренче тапкыр «К.» сүзе 1485 елда, өстенлекләрдән файдалану өчен җучиләр тарафыннан бирелгән ярлыкларда теркәлгән, аны актив куллану *Сәхибгәрәй хан* идарә иткән чорда башлана (16 йөзнең 1 нче яртысы), бу чорда *Кырым ханлыгы* һәм Госманлы империясенең үзара мөнәсәбәтләре торган саен якыная бара. К.ләр ин-ты татар әдәбиятында рәсми — эш стиленең үсешенә булышлык иткән.

*Әд.:* Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**КӘТҮ́К СЫБЫЗГЫ́** (шүре, агач кәтүк сыбызгы), традицион татар милли музыка уен коралы. Тар итеп киселгән тасмалы вибратор агач кәтүккә беркетелә. К.с. түбәндәгечә әзерләнә: аның бер башын турыпочмаклы итеп кисәләр. Эшкәртелгән өлешенә тар, нәзек каен элпәсе яки резина тасма тарттырып беркетәләр. Вибрация вакытында тасмага иркен йөреш тәэмин итү өчен астына 1–1,5 *мм* калынлыгындагы кечкенә агач кисәкләре кыстыралар. Кәтүкнең икенче башы көпшәнең тышкы диаметры калынлыгында калдырыла яисә бөтенләй эшкәртелми. Уйнаганда уен коралын иреннәргә кысалар һәм өрәләр. Үтеп кергән һава, ярык аша узып, киселә һәм тасмага тирбәнү хәрәкәте бирә. Тавышның югарылыгы һәм тембры һава кискечне ясау өчен кулланылган материалның озынлыгыннан һәм калынлыгыннан, ш.у. сыйфатыннан тора. Уен коралы кискен тавышы, чикләнгән обертоннар (өстәмә тон) тембры б-н аерылып тора. К.с.ның динамик мөмкинлеге — mp-ff, даими диапазоны — квинта. Башкаручының ирен хәрәкәте, ш.у. тасмага һава өрүе нәтиҗәсендә төрле тавышларны чыгарырга мөмкин. Бүгенге көндә дә күп кенә татар авылларында К.с. ясый белүче халык музыкантлары һәм аның ярдәмендә җыр, бию көйләрен башкаручылар бар. Киң диапазонлы көйләрне башкару өчен музыкантлар тарафыннан төрле тоннарга көйләнгән репертуар нигезендә ике К.с. кулланыла. Еш кына икенче уен коралының түбәнге тавышы (башлангыч тон) беренчесенә караганда квартага югарырак көйләнә. К.с.да, чиратлаштырып, әле берсендә, әле икенчесендә көйләрне амбитус б-н октавага кадәр яки аннан да югарырак уйнап була.

*Р.Ф.Халитов.*

**КӘТҮКЛӘ́Р** (Planorbidae), үпкә моллюсклары асклассыннан корсагаяклылар семьялыгы. Һәркайда таралган. Берничә йөз төре билгеле, Европада — 35 тән күбрәк төр. Татарстан терр-ясендә, нигездә, Gyraulus, Planorbis, Anisus һәм Planorbarius ыругларыннан булган 20 гә якын төре очрый. Еш очраучы төрләр: мөгезсыман кәтүк (Planorbarius corneus), гадәти К. (Pl. planorbis) һәм бормалы К. (A. contortus). Төп үзгәлеге — бер яссылыкта спиральсыман бормалы кабырчык булу. Мөгезсыман кәтүктә ул аеруча зур — кызгылт-көрән төстәге кабырчыгының диаметры 32 *мм* га кадәр җитә. Кайбер К. 7–8 әйләнешле кабырчыктан (Pl. complanatus) тора. Күп кенә төрләрендә кабырчык бормаларының уртасыннан үтүче киль бар. P. vortex кәтүге үтә күренмәле диярлек юка кабырчыклы, аның аша эчке органнарны да күрергә мөмкин. Башында парлы юка кармавычлары бар, алар төбендә күзләр урнашкан. Аяклары яссы киң булганлыктан, су асты предметлары буенча хәрәкәтләнергә сәләтле, суда — өске каплану пәрдәсе буенча йөриләр. Һаваны мантия тышчаларыннан барлыкка килгән үпкә куышлыгына җыеп, атм. һавасын сулыйлар. Кайбер төрләрендә аеруча һава җитмәгәндә сулыш алуда катнашучы гади саңаклар сакланган. Үсемлек һәм хайван азыгы б-н тукланалар, су үсемлекләре һәм ташлар өслегеннән вак хайван һәм бактерияләр б-н бергә яшел кунакны кыра яки үсемлек өлешләре б-н туена. К. бентос б-н тукланучы балыклар өчен азык булып тора. Күп кенә төрләре аквариумнарда үрчетелә. Кан имгеч суалчан яки шистозомалар (Schistosomum bovis) кеше паразитының арадаш хуҗалары булып яши.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977; Limnofauna Europea. Stuttg., 1978.

*В.А.Яковлев.*

**КӘҮҖИЯ́К** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 19,1 *км*, бассейнының мәйданы 135,9 $км^2$. Елга башы Сарман р-нының Кәүҗияк авылыннан 1,5 *км* төньяктарак, тамагы Мөслим р-нының Ташлыяр авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгышта-

рак. Елга башының абс. биеклеге 143 *м*, тамагыныкы — 79 *м*. Үзәне каньонсыман сузылган, урыны б-н текә сөзәклекле. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 3%. К.нең 7,5 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,2 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 67 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. ноябрь башында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,034 *м*$^3$*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,3 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КӘҮҖИЯ́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 16 *км* көнчыгыштарак, Кәүҗияк елгасы буенда. 2010 елда 509 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. 1744 елдан мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр, ясаклы татарлар катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә 3 мәчет, 4 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2141,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәтмулла волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 175, 1870 тә — 894, 1897 дә — 1212, 1920 дә — 1232, 1926 да — 1227, 1938 дә — 1211, 1949 да — 1021, 1958 дә — 901, 1970 тә — 916, 1979 да — 718, 1989 да — 590, 2002 дә — 551 кеше.

**КӘЧЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 869 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1602–03 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балык тоту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 6 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2082 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 213 ир-ат; 1859 да — 1109, 1897 дә — 1713, 1908 дә — 1951, 1920 дә — 1780, 1926 да — 1923, 1938 дә — 1678, 1949 да — 1214, 1958 дә — 1074, 1976 да — 991, 1979 да — 930, 1989 да — 885, 2002 дә — 900 кеше.

**КӘЧИМИ́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 5 *км* көнчыгыштарак, Оштырма елгасы буенда.



Кәчимир авылы. Мәчет. 1899.

2010 елда 364 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, мәчет (1899 да төзелә; архит-ра истәлеге). 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, ярма яру тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 965,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 54 ир-ат; 1859 да — 438, 1897 дә — 642, 1908 дә — 682, 1920 дә — 580, 1926 да — 617, 1938 дә — 928, 1949 да — 407, 1958 дә — 426, 1976 да — 402, 1979 да — 401, 1989 да — 349, 2002 дә — 351 кеше.

**КӘШФЕЛӘСРА́Р** Ваһаб (1858, Вятка губ., Малмыж өязе Пыжмара Пүчинкәсе а., хәзер Балтач р-ны Пыжмара а. — 29.3.1957, Голҗа ш., Кытай), дин эшлеклесе. Казан, Әстерхан, Бохара мәдрәсәләрендә укый. 1899 елда Голҗа татар мәхәлләсенә имам-хатиб һәм казый итеп чакырыла. К.нең турыдан-туры катнашуында мәчет һәм мәктәп салына (1900), Г.*Буби* (1913–14) тарафыннан җәдит ысулы б-н эшләүче «Нур» уку йорты итеп үзгәртелә. К. шәһәрнең татар җәмәгате тормышында актив катнаша; аның тырышлыгы б-н Мусабаевларның күн з-дында җомга ял көне итеп билгеләнә.

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Ябылмаган китап, яки Чәчелгән орлыклар: Шәркый Төркестан турында тарихи очерклар. К., 1996.

**КӘШШАФЕТДИ́Н** Минзәләви, к. *Минзәләви Кәшшафетдин.*

**КВАНТ ХИ́МИЯСЕ**, квант механикасы, стат. физика, матем. физика һәм хисаплау математикасы ысуллары б-н атом-молекуляр дәрәҗәдә матдә төзелешен, үзлекләрен һәм әверелешләрен теоретик өйрәнүче дисциплинаара фән. К.х., фән буларак, квант механикасы ысуллары б-н атомнар һәм аерым молекулаларның электрон төзелешен исәпләү нигезендә формалаша. Соңрак молекулаларның физик-химик үзлекләрен аңлату өчен (молекулалар спектры, химик реакцияләр механизмы, электр һәм магнит кырларында молекулаларның үз-үзен тотышы, сыек һәм каты халәттә матдә төзелеше һ.б.) ш. у. матем. һәм стат. физика, хисаплау математикасы алымнары да кулланыла башлый. Квант-химик ысулларны уңышлы куллану нәтиҗәле матем. алгоритмнар, исәпләү алымнары һәм компьютер техникасы үсеше б-н бәйле. Иң беренче квант-химик өйрәнүләрдә хисаплауның якынча, ярымэмпирик алымнары файдаланыла. Немец физигы Э.А.Хюккельның ярешле молекуляр системалар үзлекләрен яхшылап аңлату өчен кулланылган π-электрон якынчалыкны исәпләвен әлеге эшләрнең башлангычы итеп санарга кирәк. К.х.нең эмпирик булмаган алымнары чикле төп җыелмаларны кулланып һәм бер детерминант якынчалыкта барлык интегралларны җентекләп исәпләп, алга таба электрон корреляция эффектларын исәпкә алып, Хартри-Фока-Рутан тигезләмәсен чишүгә нигезләнгән була. К.х. фәнни молекуляр системаларның тәҗрибә өчен мөмкин булмаган үзлекләре турында мәгълүмат бирергә сәләтле (химик реакцияләрдә күчеш халәтләре һәм интермедиатлар төзелеше, тәэсирләндерелгән халәттә молекуляр системалар энергиясе һәм төзелеше). К.х. алдан фаразлау мөмкинлекләренә ия, шул сәбәпле молекулалар төзелешен, үзлекләрен һәм реакциягә керү сәләтен өйрәнүнең нәтиҗәле инструментына әйләнә (фуллереннар, гиперлитийлы һәм гипернатрийлы молекулалар, углерод атомы валентлыгы дүрттән артыграк булган молекуляр структуралар һ.б.ш.).

Казанда К.х. алымнарын куллану 1950 елларда металлкетилларда — металларның кетоннар б-н тәэсир итешү продуктлары булган органик анион-радикалларда ЭПР спектрлары интерпретациясен һәм спиннар тыгызлыгы бүленешен исәпләүләрдән башлана (СССР ФАнең Органик химия ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре И.Д.Морозова, Казан). Казан ун-тының органик кушылмалар төзелешен өйрәнүнең проблемалы лаб-ясендә Й.Ю.Сәмитов җитәкчелегендә илдә беренчеләрдән булып протоннарда югары мөмкинлекле ЯМР-спектрометрлар булдырыла (1960). Шул вакыттан катлаулы молекуляр системаларда төш-магнит экранлашу константаларын исәпләү, ТМР спектрлары нигезендә молекулаларның фәзаи төзелеше һәм химик үзгәрешләрнең конформацион бәйлелеге турында мәгълүмат алу өчен К.х. һәм квант механикасы ысуллары кулланыла башлый (Р.М.Әминова). Бу максатлар өчен нәтиҗәле вариацион ысуллар эшләнә, молекулалар структур элементларыннан изоэкранлау диаграммалары төзелә, 5-, 6- һәм 7-буынлы гетероциклик молекулаларның структур рәтләре өчен ТМР параметрлары үзгәрү закончалыклары билгеләнә. 1970–80 елларда Казан технол. ун-тында яңа фәнни юнәлеш — К.х. ысуллары һәм электрод өслегенең кластер моделе нигезендә электрохимик процессларны модельләү формалаша (М.С.Шапник). Гетероген катализның табигатен өйрәнү, күчемле металлар ионнары катнашында электрод процесслары механизмын ачыклау өчен квант-химик модельләү кулланыла (А.Н.Кузнецов). 1990 еллар башыннан корылма күчерү, К.х.нең заманча ысуллары, компьютер

ярдәмендә модельләү һәм фәнни тәҗрибә ясау өлкәсендәге казанышларга нигезләнеп фәнни юнәлеш — квант электрохимиясе үсеш ала (Р.Р.Нәҗметдинов); электрод процессларын тасвирлауга микроскопик алымнар эшләнә. C-,N-,O-нитрокушылмаларның кинетикасын һәм термик таркалу механизмын өйрәнү өчен квант-химик алымнарны куллану органик кушылмаларның реакциягә керү сәләтенең гомуми закончалыкларын ачыкларга, ш.у. кинетик процесслар теориясе, яну һәм шартлау теориясе үсешенә ярдәм итә (А.Г.Шамов, Г.М.Храпковский). Әлеге хезмәтләр нитрокушылмалар һәм алар нигезендә төрле композицияләр алу һәм эшкәртүнең куркынычсыз шартларын билгеләү өчен гамәли әһәмияткә ия. Фемтосекундлар эчендәге тәҗрибә мәгълүматларына һәм яктылык б-н тәэсирләндерелгән молекулаларның потенциаль энергиясе өслекләрен квант-химик исәпләүгә нигезләнгән фемтохимия ысуллары эшләнә (Р.М.Әминова, А.Г.Шамов, С.А.Моисеев). К.х. ысуллары фотоэлектрон спектрларны интерпретацияләү, фармакофор төркемнәре булган яңа фуллерен кушылмалары төзелешен һәм үзлекләрен өйрәнү өчен (В.В.Зверев), ароматик һәм гетероциклик кушылмаларның кислород-, күкерт- һәм селенлы кушылмаларын өйрәнгәндә эксперим. нәтиҗәләрен аңлату өчен, ш.у. төзелеше ягыннан якын молекулаларның яңа үзлекләрен фаразлау өчен кулланылыш таба (Г.А.Чмутова). Диэлектрик тирәлекнең полимер калыптагы хромофор төркемнәрнең электрон гипер поляризлаучанлыгына тәэсирен исәпкә алып, перспективалы полиен хромофорларның молекуляр дизайны өчен квант-химик модельләр эшләнә (М.Б.Зуев, М.Ю.Балакина). К.х. ысулларын кулланып структур өйрәнүләр Казан ун-тында, Казан технол. ун-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында уңышлы үткәрелә.

*Әд.:* Слэтер Дж. Методы самосогласованного поля для молекул и твёрдых тел. М., 1978; Степанов Н.Ф., Пупышев В.И. Квантовая механика молекул и квантовая химия. М., 1991; Минкин В.И., Симкин Б.Я., Миняев Р.М. Теория строения молекул. Ростов н/Д. 1997.

*Р.М.Әминова.*

**«КВАРТ»**, химия сәнәгате пр-тиесе. Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 1700 чамасы кеше (2010). 1941 елның июлендә эвакуацияләнгән «Красный богатырь», «Каучук» (Мәскәү), «Красный треугольник» (Ленинград), Олтан-регенерат (Ярославль ш.) һәм Казанда төзелүче Регенерат-резина з-длары җиһазлары җирлегендә Казан резина-техник эшләнмәләр (РТИ) з-ды булачак нигезләнә. Ярымкустарь цехларда (әзерләү, формалы техника, җиңсәләр цехларында) 46 кеше эшли. Беренче продукция 1942 нең гыйнварында чыгарыла. Завод оборона пр-тиеләре өчен дюрит һәм тормоз шланглары, авиадетальләр, төрле көпшәк эшләнмәләр, техник пластиналар һәм бөгелүчән кушылмалар җитештерә. 1950–60 елларда завод корпуслары төзелеше җәелә, эшләүчеләр саны 3,7 мең кешегә җитә, җитештерү 30 тапкыр арта. Завод илдә төрле максатларда, ш.и. тирән бораулауда һәм нефть чыгаруда кулланыла торган җиңсәләр, тимер юл һәм метрополитен поездлары өчен тормоз эшләнмәләре җитештерүче әйдәп баручы пр-тиеләрнең берсенә әверелә. СССРда беренче тапкыр шарлы-очу һәм радиозонд сүрүләре, герметиклар эшләп чыгару оештырыла. 1970 еллар башыннан пр-тиенең үсеше гамәлдәге җитештерү көчләрен индивидуаль җиһазларны конвейерлы-механикалаштырылган җиһазларга алмаштыру нигезендә тамырдан үзгәртү һәм техник яктан яңартып кораллану юлы б-н алып барыла. Җитештерүне үстерүнең заводта эшләнгән алымнары республика һәм СССР химия сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертү өчен тәкъдим ителә. 1984 тә завод җирлегендә «Казанрезинотехника» ЖБ (1990 нан аренда берләшмәсе) оештырыла, 1992 дән — хәзерге исемдәге АҖ. 1990 елларда АҖдә структур подразделениеләр: Менделеев шәһәрендә автомобиль сәнәгатенең комплектацияләү өчен елга 1100 *т* формалы эшләнмәләр чыгаручы резина-техник эшләнмәләр з-ды, Түбән Кама шәһәрендә тимер юл транспорты өчен резина һәм пластмасса эшләнмәләр производствосы файдалануга тапшырыла.

«К.» — инновацияләр нигезендә эшләүче югары технологияле пр-тие. Җитештерү процессларының механикалаштырылуы 83% тәшкил итә. Пр-тиенең үз фәнни-техник комплексы продукциянең яңа төрләрен эшли, производстволарны реконструкцияләүне конструкторлык һәм технол. яктан тәэмин итә. Эшләнмәләрне җыюда файдаланыла торган махсус станоклар һәм агрегатларның, сынау стендларының, үлчәп төрүче машиналарның һәм кучергеч җайланмаларның күп өлеше механика бүлекчәләре тарафыннан әзерләнә. 2004 тә Халыкара сыйфат стандартларына яраклылык сертификаты (ISO 9001:2000) бирелә.

«К.» продукциясе 7 меңнән артык исемдәге эшләнмәләрне (аларның күпчелеген пр-тие белгечләре проектлый) колачлый: 1,5 меңнән артык төрдә төрле конструкцияле җиңсәләр (кордлы, трослы, кургашлау ысулы б-н ясалучы дорнлы һәм дорнсыз, үрелгән металл челтәрле эшләнмәләр һ.б.); химик һәм кызуга-салкынга чыдам резиналардан техник пластиналар; хлоропрен һәм натураль каучук җирлегендә җилемнәр; эластик идән һәм түбә япмалары; динамик вулканлаштыру ысулы б-н ясалган термопласт эшләнмәләре; тимер юл һәм трамвай юлы аша чыгу урыннарына түшәлә торган резина плитәләр, формалы һәм формасыз резина эшләнмәләр һ.б. АҖдә җитештерелә торган ашалуга чыдам, су астында һәм тирән бораулауда кулланыла торган җиңсәләргә, герметикларга, радиозонд һәм шарлы-очу сүрүләренә БДБдә тиңнәр юк. «К.» — РФ дә динамик вулканизация термо-эластопластларын җитештерүче бердәнбер пр-тие. Анда даими рәвештә резина катнашмаларының һәм эшләнмәләренең яңа төрләре үзләштерелә. «К.» продукциясе автомобиль, нефть чыгару сәнәгатьләре, а.х. машиналарын төзү пр-тиеләре тарафыннан файдаланыла, төзелештә, мелиорациядә, агросәнәгатьтә һ.б.да кулланыла. Төрле илларда ул дөньяның 40 тан артык иленә чыгарыла. 1992 дә, җиңсә эшләнмәләрнең югары сыйфатлы һәм конкурентлыкка сәләтле булуы өчен, «К.»ка халыкара «Европаның Алтын Йолдызы Аркасы» бүләге бирелә. Пр-тие тарафыннан 2 поликлиниканы, хастаханә, шифаханә комплексын, ял йорты һәм базасын, техника һәм көнкүреш йортын, балалар уку-күңел ачу комплексы һәм ял лагерен, кунакханәне үз эченә алган социаль инфраструктура объектлары челтәре төзелгән.

Пр-тиенең 550 дән артык хезмәткәре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 2 кешегә — СССР Дәүләт бүләге лауреаты, 17 кешегә — РСФСРның, ТАССРның атказ. химигы, 1 кешегә — РСФСРның атказ. рационализаторы, 4 кешегә — ТАССРның атказ. төзүчесе, 2 кешегә — ТАССРның атказ. икътисадчысы, 1 кешегә ТАССРның атказ. энергетигы дигән мактаулы исемнәр бирелә; 5 кеше Ленин ордены б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре арасында — А.Т.Скобелев (1941), И.П.Вайнштейн (1941–46), И.М.*Диденко* (1946–63), В.Д.*Григорьев* (1970–2005), М.Г.Хәйретдинов (2005 тән).

**КВА́СНИКОВ** Алексей Иванович (1745, Казан — 6.11.1819, шунда ук), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, коммерция советнигы (1801). Борынгы сәүдәгәрләр нәселеннән. Казан янындагы — Плетән авылындагы сабын кайнату з-ды (1812 елда 5 казаны була, 7 мең пот сабын җитештерә), Казандагы өч йорт (Болак буендагы йортында ашханә эшли, икенче йорты — Проломный урамында, 8 кибетле һәм 20 лавкадан торган галереясы икмәк базары янында була, флигельле өченче таш йорты — Воздвижение приходында урнаша), Болак буендагы 2 таш амбар хуҗасы. Актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара, сәүдә кешеләре арасында ихтирам казана. 1770–73, 1777 дә Балык Бистәсе авылында казна тозы төяп җибәрүче ларёчный булып сайлана. 1774–75 тә Казан вөҗдан мәхкәмәсе судьясы. 1779–82 дә — Казан губерна магистраты, 1782–83 тә Казан шәһәр магистраты бургомистры. 1788–90, 1800–02 дә Казан шәһәре башлыгы. 1790 да К.ка хезмәтләре өчен шәһәр җәмәгатенең мактау кәгазе б-н бергә «хезмәттә танылган граждан» исеме бирелә; 1801 дә император Александр I гә таҗ кидерү тантанасында катнашкан Казан губернасы делегациясе составына керә.

Чыг.: Достойны памяти потомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* Агафонов Н. Казань и казанцы. К., 1907. Кн. 2; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**КВАШНИ́Н-САМА́РИН** Андрей Никитич (1716–1776), дәүләт эшлеклесе, сенатор (1773), яшерен советник (1773). Дворяннар нәселеннән. 1736 елдан — хәрби, 1760 тан дәүләт хезмәтендә. 1756–60 елларда Җидееллык сугышта (1756–63) катнаша. 1764–70 тә Казан губернаторы. К.-С. заманында губернада Яңа чукындырылганнар эшләре контора-

сы ябыла (1764), почта хезмәте үзгәртеп корыла (1765), Казанны төзү планы раслана (1768), *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә* театр тамашалары күрсәтелә башлый (1760 елларның 2 нче яртысы). Петербург ФАнең Себергә һәм Оренбург краена оештырылган экспедицияләренә булышлык итә (1765, 1768). Казанда ярлылар өчен шәһәр якшәмбе мәктәбе ачуга ярдәм күрсәтә (1766); Мәрҗани (1766–70) һәм Апанай (1768–71) мәчетләрен салырга рөхсәт бирә. 1770–73 тә Түбән Новгород губернаторы. 1773 тән Сенат департаментларында.

*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1857. Ч. 4; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**КЕ́ДРОВА** Неонила Ивановна (15.1.1875, Калуга губ. Ново-Александровское а. — 13.11.1964, Калуга ш.), акушер-гинеколог, РСФСРның атказ. табибе (1943). Калуга хатын-кыз руханилар уч-щесен, 1901 елда С.-Петербург Клиник акушерлык (повивальный) ин-тын тәмамлый. 1902 дән Петербург хатын-кызлар мед. ин-тында, 1906 дан Казан ун-тында. 1907 дә Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаган беренче биш хатын-кыз арасында беренчеләрдән булып лекарь-отличник исемен ала, ун-ттагы акушерлык-гинекология клиникасының штаттан тыш ординаторы итеп билгеләнә, проф. В.С.*Груздев* җитәкчелегендә эшли. 1913 тә Самара губернасы Богырыслан шәһәрендә. 1914–15 тә Рязань һәм Калуга өяз хастаханәләрендә гинекология һәм хирургия бүлекләре оештыра. 1916 дан Калугада; 1932 дә аның тырышлыгы б-н гинекология бүлеге базасында бала тудыру йорты ачыла, үзе 1950 гә кадәр шунда эшли, бер үк вакытта фельдшер-акушерлар мәктәбендә укыта. Хезмәтләре хатын-кыз җенес системасында гигант яңа шешләрне өйрәнүгә карый. К. гигант шешләрнең этиологиясе, патологик анатомиясе, клиникасы, диагноз кую һәм дәвалау (рентген- һәм радиотерапия) мәсьәләләрен өйрәнә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт разработки учения о гигантских опухолях женской половой сферы. К., 1913.

**КЕ́КИН ЙОРТЫ́**, Казанда романтик юнәлештәге модерн стилендә төзелгән 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 1903–05 елларда сәүдәгәр Л.В.Кекин акчасына арх. Г.Б.*Руш* проекты буенча төзелә. Горький һәм Галактионов урамнары кисешкән трапеция рәвешендәге почмакта урнашкан, подваллары гөмбәз формасында эшләнгән (1903) дүрт катлы таш йорт. Бинаның ике катлы ягы Галактионов урамына карый (1905). Өч һәм ике өлешле баскыч мәйданчыклары һәм Казанда электр б-н эшләүче беренче күтәргеч йорт катларындагы коридорларны тоташтыра. Йортның өске катларында бүлмәләр бер яки ике яклап, коридор системасы буенча тоташкан. Бинаның ике ягы тоташкан урында кат саен урамнар кисешкән чатка караган зур зал бүлмәләре бар. Кирпеч диварлар штукатурланган. Тәрәзәләре беренче каттан дүртенче кат-




Л.В.Кекин йорты. Казан. 1905.
20 йөз башы фоторәсеме.

ка таба төрле стильдә үзгәрә бара. Мавритания, готика һәм һинд архитектурасына хас үрнәкле чуар рельефлы кәрнизләре, декоратив детальләре бинага кабатланмас төс бирә.

Окт. рев-циясенә кадәр К.й.нда В.И.Ряхинаның шәхси гимназиясе, Педагогика җәмгыяте гимназиясе, Н.А.Беневскаяның әзерлек уч-щесе, Казан округының элемтә юллары идарәсе, С.Я.Пальчинская китапханәсе, Л.Ф.Гросс басмаханәсе, П.В.Шаталовның китап кибете, А.В.Афанасьевның шәраб-бакалея кибете, М.Р.Төхвәтуллинның галантерея кибете, өске катларда җиһазланган кунакханә бүлмәләре урнашкан була. Хәзерге вакытта аскы катларны, кибетләр, югарыдагыларын учреждениеләр били.

2002–04 елларда К.й. үзгәртеп корыла һәм яңартыла. Үзгәртеп кору проекты «Казан Гипро фәнни-тикшеренү ин-ты» АҖдә (проект авторы — арх. Р.М.Шәмсетдинов), реставрация проекты «Зәбир» ҖЧҖдә (җитәкчесе — Ф.М.Зәбирова) эшләнә. Архитектура бизәкләре, акташтан салынган нигез катлары,



Л.В.Кекин йорты. Фасад детальләре.
Хәзерге күренеше.

баскычларның металл култыксалары яңартыла. Фасадлар баштагы үз төсләренә — кызгылт-көрән, өлешчә ак төскә буяла. Үзгәртеп кору барышында бина нигезләре ныгытыла, агачтан ясалган этаж аралары һәм подвалның гөмбәзләре тоташ тимер бетоннан эшләнә. Бинада сәүдә-офис үзәге урнашкан.

*Әд.:* З а б и р о в а Ф.М. Дом — метафора, дом — загадка // Дизайн и новая архитектура. 2004. № 17; М и т р о ш и н а М. Дом Кекина: Опыт реставрации // шунда ук. Б.10–16.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КЕКОВА́Т**, 16–17 йөз башында Нугай Урдасының сул канаты (көнчыгыш өлеше) идарәчесенең (гаскәр башлыгының) титулы. Атама Идегәйнең улы, 15 йөздә Идел аръягында олысы булган Кей-Кобадка бәйле дип фаразлана. Кагыйдә буларак, К. дип идарәче бәк нәселенең кече вәкилләре аталган. К. титулына ия булган идарәчеләр арасында Шәех Мамай (1520 еллар – 1548), Уразгали (1549–55), Ырыс (1561–63) билгеле. 16 йөзнең 2 нче яртысында Нугай Урдасы титуллары иерархиясендә К.ның әһәмияте кими. *Нурадын* титулы мөһимрәк була бара. К. сул канатның хәрби отрядлары өстеннән хакимиятен саклап кала, Идел аръягы биләмәләреннән салым җыю да аның карамагында була. 17 йөз башында Нугай Урдасының көнчыгыш канаты көчсезләнгән саен, К.ның әһәмияте кими: ул *тәйбугадан* түбәнрәк урынга чыга. Нугай Урдасында канатлар системасы беткәч, К. титулы үз әһәмиятен бөтенләй югалта.

*Әд.:* Н о в о с е л ь с к и й А.А. Борьба Московского государства с татарами в первой половине XVII века. М.–Л., 1948; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**КЕЛӘМЧЕЛЕ́К**, гамәли-бизәлеш сәнгате төре; торакны җылыту һәм интерьерны бизәү өчен билгеләнгән нәфис тукыма эшләнмәләр — келәмнәр һәм паласлар җитештерү. Алар йон, ефәк һәм киҗе-мамык җептән, күн һәм ясалма материаллардан әзерләнә; кулдан һәм машина б-н тукылган (19 йөз уртасыннан — механик станнарда), чигелгән һәм бәйләнгәне, киездән басылганы, мех тиреләрдән тегелгәннәре була. К. — борынгы нәфис сәнгать төрләренең берсе, нигезләре хуҗалыкның борынгы терлекчелек һәм игенчелек чорларыннанан башлана; үсемлек сүсләрен (житен, киндер, кычыткан) һәм йонны (башлыча, сарык йоны) эшкәртүгә нигезләнгән. К. үсешенә көнкүреш гореф-гадәтләренең үзенчәлекләре, ш.у. келәм җитештерү ысуллары һәм технологиясе, туку станнары конструкциясе һ.б. йогынты ясый. Җепләр ачык төстәге үсемлек, соңрак ясалма буяуларга маныла һәм күптөрле бизәкле композиция тәшкил итә.

Келәмнәр татар көнкүрешендә зур урын алып торганнар, аларны өй түрендәге *сәкегә* һәм идәнгә җәйгәннәр, еш кына кәләш бирнәсенең бер өлешен тәшкил иткәннәр, туйда кияүгә һәм аның әти-әнисенә бүләк иткәннәр. Урта Идел буенда яшәүче рус һәм башка халыклар мәдәниятендә К. үсеш алмый; гадәттә, алар көнкүрешендә корама келәмнәр файдаланыла; 19 йөз уртасыннан рус авылларында бер генә төсле киез паласлар — кошмалар (к. *Киез*) киң тарала, кайбер авылларда, мәс., Урта Идел буеның көнчыгыш районнарында, алар кәләш бирнәсенә кергән.

Татарларда К. б-н, башлыча, хатын-кызлар шөгыльләнгән (ир-ат келәм өчен киез баскан). Ул йорт һөнәрчелегенең бер формасы булган, хәлбуки, киезләрне, паласларны кулланучылар соравы буенча да җитештергәннәр. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан 20 йөз башына кадәр Казан губернасындагы татар авылларында (Минзәлә, Мамадыш өязләре) тукылган келәмнәр, идән паласлары һәм



**Келәмчелек. Киез.** 1. Намазлык. Киез. 19 йөз ахыры. Республика Кырым-татар сәнгать музее. Симферополь ш.; 2. «Тормыш агачы» дивар панносы. Киез. Рәссамнар Д.Г. Рәхмәтуллин, Р.Х. Рәхмәтуллина. 1984; 3. «Коралл» дивар панносы. Киез. Рәссам Д.Г. Рәхмәтуллин. 1983; 4. Келәм. Фрагмент. Йон. Йөнтәс булмаган туку. 19 йөз. Бакчасарай музее; 5. Йөнтәс булмаган келәм үрнәге. Казан арты. 19 йөз ахыры. Ф.Х. Вәлиев реконструкциясе; 6. Келәм. Йон, киҗе-мамык җепләр. Кулдан йөнтәс булмаган туку. 20 йөз уртасы. Бөгелмә р-ны Кодаш авылы мәктәбе музее; 7. Келәм. Йон. Кулдан йөнтәс булмаган туку. Халык остасы М. Ганиева. 1960 еллар. Әлмәт р-ны Яңа Нәдер авылы мәктәбе музее; 8. Палас. Йон. Кулдан йөнтәс туку. Халык остасы А. Дәүләтшина. Алабуга ш. 1980 еллар; 9. Келәм. Йон, киҗе-мамык һәм синтетик җепләр. Кулдан йөнтәс булмаган туку. Халык остасы Н. Гәрәева. 1960 еллар. Самара өлкәсе Ярмәк авылы; 10. Келәм. Йон, киҗе-мамык җепләр. Кулдан йөнтәс булмаган туку. 1950 еллар. Самара өлкәсенең Татар Байтуганы авылы мәчетендә саклана; 11–12. Келәм. Йон, киҗе-мамык һәм синтетик җепләр. Кулдан йөнтәс булмаган туку. Халык остасы М. Османова. 1970 еллар. Кырымның Судак р-ны Весёлое пос. (элеккеге Кутлак авылы); 13. Келәм. Йон. Кулдан йөнтәс булмаган туку. Рәссам М. Чурлу. 2005.

утыргыч өчен кечкенә, яссы мендәрләр — ястыклар әзерләү җайга салынган.

Күчмә тормышның байтак сыйфатларын туплаган К.нең тарихи тамырларын гасырлар түреннән эзләргә кирәк. Аның сакланып калган сирәк үрнәкләре 19 йөз ахырына — 20 йөз башына карый. Җеп һәм йон эрләү кабалары, ш.у. тукылган келәмнәр әзерләүдә кулланылган махсус эләктергеч кебек табылдыклар К.нең Идел буе болгарлары арасында киң таралган булуын дәлилли. Татарларда йөнтәс К. тармагы 1552 елда Казан ханлыгы яуланганнан соң һәр җирдә дә диярлек юкка чыга, чөнки ул аңа кадәр хан сарае остаханәләрендә үскән булса кирәк. Йөнтәс К., халык иҗаты төре буларак, Пермь өлкәсендәге Урал буе татарларының аерым авылларында (озын йөнтәс келәмнәр) һәм Башкортстанда 20 йөзнең 2 нче яртысына кадәр саклана. Ул Кырым татарлары мәдәниятендә дә үсеш ала, ләкин 20 йөз башында бары тик асылмалы «әйбә» сумкалар әзерләүгә кайтып кала.

Татар халык К.гендә кулдан туку станнарында йоннан әзерләнгән келәмнәр — келәм, палас, «асалы палас», Себер татарларында — «үрмәк», «җәймә», Кырым татарларында — «атма килим» (буйлы), «кыбрыз килим» (бизәкле) аеруча киң тарала; алар бизәкләренең үзенчәлеге, буяу төсләренең оста сайлануы, мәһабәтлелеге, тантаналылыгы б-н аерылып тора. Келәмнәр, гадәттә, 50–60 *см* киңлектәге 2–3 тукыманы ялгап әзерләнгән. Аның иң гади төрләре тар һәм киң буйларда кабатланып килгән төрле төстәге буй-буй (сирәгрәк шакмаклы) бизәкләр б-н бизәп тукылганнар. Һәр келәмдә кара төстән башка барлык төсләр дә — алтынсу-сары, җирән, яшел, зәңгәр, шәмәхә, алсу, миләүшә һ.б. — кулланылган. Бизәкләре катлаулырак келәмнәр «асалап сугу» яки палас туку техникасында (к. *Сәнгати туку* ) әзерләнгәннәр. Келәм-паласлар махсус эшләнгән тар кайма б-н каймаланганнар. Келәм бизәкләрен керенте ромблар, дүрткелләр һ.б. төрле фигура мотивлары тәшкил иткән, алар келәм кырында бер-берсенә охшаган эрерәк фондагы фигуралар эченә кереп, ритмлы сафлар рәтен барлыкка китергәннәр. Келәмнең «аламыч» дигән борынгы төрен Томск өлкәсендә яшәүче Себер татарлары кычыткан сүсеннән тукыганнар. Мондый келәмнәр ике өлешне бергә ялгап әзерләнгәннәр һәм өчпочмак һәм түгәрәк мотивлары б-н бизәлгәннәр.

К.нең 20 йөз башына кадәр киң таралган икенче төре — киез К., бер генә төсле һәм бизәкле паласлар — *киез* әзерләү. Элек ш.у. каелган (к. *Каюлы күн*) яки рәсемле бизәк төшерелгән күн келәмнәр дә җитештерелгән; кулдан яки станда камыштан чыпталар сугылган. Чыпта сугу (бараба татарларында — «йөгән», «әчерге») Себер татарларында киң тарала; аның б-н сәке өсләрен япканнар (Томск татарларында — «урынтык», «тур»). Алар, гадәттә, шома камыш һәм карасу үлән сабакларыннан үрелгәннәр һәм ромбсыман каймалы нигезгә дүрткел челтәрле гади геом. бизәк б-н бизәлгәннәр; читләрен киндер һәм йон җепләр б-н ураганнар. Камыштан һәм җикәнбаштан сугылган чыпталарны 20 йөз башына кадәр Урал буе татарлары һәм Казан губернасының көньяк-көнчыгышында яшәүче татарлар, «җикән» камыштан сугылганнарын Әстерхан татарлары әзерләгән.

Күп кенә халыкларның К.гендә мәгълүм корама — тукыма кисәкләреннән тегелгән келәмнәр татар авылларында киң тарала. Татар корама келәмнәре бизәкләренең эре геом. фигураларга охшатып ясалуы б-н аерылып торган. Корамаларны төсләре һәм зурлыклары буенча сайлап алганнар; бер-берсенә ялгап, алардан озын тасмалар теккәннәр һәм соңыннан бергә берләштергәннәр. Катлаулы бизәк әзерләү өчен тукыма кисәкләрен аппликация ысулы б-н күпкатлы итеп тә теккәннәр. Татар К.генең һәр төре гамәли һәм эстетик әһәмияткә ия булган. Бизәкле — «асалы палас»ларны сәкедәге бер төсле киезләр өстенә япсалар, буйлы келәмнәрне идәнгә җәйгәннәр. Этнографлар Себер татарларының келәмнәрне көнкүрештә куллануының борынгы очрагын теркәгәннәр. Биредә яшәүче халык келәмнәрне сәкегә берничә кат җәйгән (иң аска камыш чыпта, аннары киез, аңа буйлы йон келәм — «аламыш» җәелгән, иң өскә бизәкле келәм ябылган. Йола буенча, кәләш 3 келәм — кияү һәм аның әти-әнисенә бүләк өчен буй бизәкле 2, кунаклар каршылау өчен бизәкле 1 келәм суккан.

Хәзерге шартларда К.тәге бик күп традицияләр югалган. Тукылган келәмнәрне өйдә җитештерү очракларын Татарстанның Минзәлә, Зәй, Әлмәт, Апас һ.б. кайбер район авылларында, Самара, Ульянов өлкәләрендә, Көнбатыш Себердә күзәтергә мөмкин. 1970 елларда келәм җитештерүне сәнәгый нигезгә көйләү омтылышлары була. 1974 тә Казандагы «Таттрикотаж» берләшмәсе каршында кулдан һәм механик юл б-н йөнтәс келәмнәр туку цехы оештырыла; шундый ук цех Алабуга тегү ф-касында ачыла. Милли бизәкле йон паласларны кулдан тукуны 1970 еллар ахырында Алабуга остасы А.Дәүләтшина, традицион киез келәмнәр әзерләүне Бөгелмә рәссамнары Д. һәм Р.Рәхмәтуллиннар яңартып җибәрә (к. *Киез*).

Хәзерге заман К.гендә сюжетлы-тематик рәсемнәр һәм бизәкләр чигү, бәйләү һәм аппликация алымы б-н әзерләнгән келәмнәр киң үсеш алды. К.нең *гобелен* төре үзләштерелә, коллаж, макраме, колаксыман аппликация — «тырнак алмалау» (к. *Аппликация*) техникасында эшләнгән, ш.у. ясалма киезне механик пресслап (рәссам Л.Кальюрандның авторлык техникасы) дивар өчен әзерләнгән тукыма паннолар һ.б. барлыкка килә. Татар К.ге хәзерге вакытта «Һөнәрчелекләрне яңарту» халыкара программасы буенча Кырымда яңарыш ала. К. һәм гобелен тармагы б-н осталар М.*Чурлу*, Н.Решатова, З.Мусаева, Л.Уста һ.б. шөгыльләнә.

*Әд.:* Б у с ы г и н Е.П. Русское население Среднего Поволжья. К., 1966; Б о г о м о л о в В.Б. Ткачество декоративных ковров у барабинских татар // Духовная культура народов Сибири. Томск, 1980; ш у л у к. Узоры сибирских татар Омского Прииртышья // От Урала до Енисея: Народы Западной и Средней Сибири. Томск, 1995; В а л е е в Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; М у х а м м е т ш и н Ю.Г. Этнографический обзор поселений, усадеб и построек Астраханской области // Астраханские татары. К., 1992; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1996; Ф а т к у л л и н а Ф.М. Тарские татары: традиции орнаментации изделий из бересты и тростника // Тюркские народы: Материалы V Сибирского симп. «Культурное наследие народов Западной Сибири». Тобольск-Омск, 2002; З а а т о в И. Крымско-татарское декоративно-прикладное и изобразительное искусство. Симферополь, 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КЕЛӘНЧЕ́** елгасы, Идел алдында, Сөлчә елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,3 *км*, бассейнының мәйданы 75,3 *км²*. Идел буе калкулыгыннан ага, Югары Ослан р-нында. Елга башы — Карамышиха авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Рус Макылы авылы тирәсендә. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. К.нең 0,2 дән алып 6 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км²*. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 104 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КЕЛӘНЧЕ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 33 *км* көнбатыштарак, Олы Шаһиян елгасы буенда. 2010 елда 421 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, балта эше, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, 3 су һәм 1 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1997 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 160 ир-ат; 1859 да — 859, 1897 дә — 2012, 1908 дә — 2211, 1920 дә — 2040, 1926 да — 1034, 1938 дә — 1177, 1949 да — 925, 1958 дә — 784, 1970 тә — 789, 1979 да — 653, 1989 да — 471, 2002 дә — 466 кеше.

**КЕЛӘНЧЕ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Келәнче елгасы буенда. 2010 елда 176 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек ас-

рау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 1646 дан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, пыяла ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе урнаша; Смоленск Богородица чиркәве (1848 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1869 да ачыла), 2 җил тегермәне, йон тетү, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 889 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 24, 1782 дә — 191 ир-ат; 1859 да — 498, 1897 дә — 602, 1908 дә — 618, 1920 дә — 588, 1926 да — 556, 1938 дә — 431, 1949 да — 328, 1958 дә — 283, 1970 тә — 227, 1979 да — 145, 1989 да — 153, 2002 дә — 195 кеше.

**КЕЛӘ́Р** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 16 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 1 нче яртысында дворян Косяковскийлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кляри-Архангельское, Кирели исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә агач Архангел Михаил чиркәве (1775 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), җил тегермәне, тукыма-бакалея кибете була; пәнҗешәмбе саен базар эшли, һәр елның 28–30 сентябрендә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 575,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1646 елда — 75, 1763 тә — 124 ир-ат; 1834 тә — 369, 1859 да — 284, 1897 дә — 331, 1908 дә — 389, 1920 дә — 406, 1926 да — 235, 1938 дә — 164, 1949 да — 143, 1958 дә — 96, 1970 тә- 53, 1979 да — 37, 1989 да — 22, 2002 дә — 15 кеше.

**КЕЛӘТЛЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 7 *км*, бассейнының мәйданы 14,5 $км^2$. Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Келәтле авылыннан 2,5 *км* көньяктарак, тамагы — Бөреле җәнлек совхозы посёлогыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 100 *м*, тамагыныкы — 57 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Җәйге челләдә елга еш кына кибә. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елганың югары агымында су күләме 0,2 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЕЛӘТЛЕ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 9 *км* көнчыгыштарак, Келәтле елгасы буенда. 2010 елда 46 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Казан ханлыгы чорында нигез салына, 1550 еллардан — рус авылы. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә земство мәктәбе (1887 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1088 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 93 ир-ат; 1859 да — 577, 1897 дә — 548, 1908 дә — 565, 1920 дә — 575, 1926 да — 617, 1938 дә — 467, 1949 да — 367, 1958 дә — 318, 1970 тә — 228, 1989 да — 55, 2002 дә — 43 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕЛӘТЛЕ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 8 *км* көньяктарак, Алан елгасы буенда. 2010 елда 60 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 су тегермәне, тимерчелек, май язу йорты була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 801,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 280, 19313 тә — 638, 1920 дә — 671, 1926 да — 696, 1938 дә — 478, 1949 да — 433, 1958 дә — 368, 1970 тә — 458, 1979 да — 230, 1989 да — 116, 2002 дә — 91 кеше.

**КЕЛӘҮЛӘ́Р**, мәҗүси потка (келәүлек, теләүлек, сын) табыну, ягъни агачтан уеп ясалган, баганага утыртылган ат башына мөрәҗәгать итеп, теләк теләү. К. — шигъри формадагы тәүбә (теләү) сүзләре, көйләп сөйләнә. Алар арасында табигать көчләренә һәм күренешләренә рәхим-шәфкать, мәрхәмәт, ярдәм сорап мөрәҗәгать итү К.е («Яңгыркаем, яу, яу», «Җир, җир, көчең бир») һ.б. бар. К.нең күпчелеге билгеле йолаларга бәйле, әчтәлекләре дә шуннан чыгып билгеләнә: *Карга боткасы* — татарларның яңгыр сорау йоласы, Иран календарендагы Яңа ел бәйрәменә бәйле *Нәүруз* — йорт хуҗаларына яхшы теләкләр әйтүгә корылган.

*Әд.:* Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. К., 1977. Т. 1; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КЕЛӘҮ́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 45 *км* төньяктарак, Юкәче елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 192 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 67%, татарлар — 27%) яши. Җиһаз ф-касы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Лыябаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә волость идарәсе урнаша; Троица чиркәве, земство мәктәбе (1870 тә ачыла), фельдшерлык пункты, 7 тимерчелек, 2 сыраханә, 1 казна шәраб, 1 зур һәм 3 кечкенә вак-төякләр кибете була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1218 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 368, 1897 дә — 757, 1908 дә — 811, 1920 дә — 776, 1926 да — 797, 1949 да — 637, 1958 дә — 738, 1970 тә — 704, 1979 да — 515, 1989 да — 304, 2002 дә — 270 кеше.

**КЕЛӘ́Ш** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 25 *км* көнбатыштарак, Буа — Тәтеш автомобиль юлы буенда. 2010 елда 403 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Кырлангы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиyннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1567,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 481, 1897 дә — 869, 1908 дә — 1058, 1920 дә — 1020, 1926 да — 967, 1938 дә — 678, 1949 да — 608, 1958 дә — 612, 1970 тә — 628, 1979 да — 530, 1989 да — 430, 2002 дә — 427 кеше.

**КЕЛЕ́РИЯ**, к.*Нечкә сабак*.

**КЕ́ЛИНА** Татьяна Игоревна (17.3.1944, Иваново ш. — 11.9.2006, Казан), педиатр-иммунолог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1996). 1967 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, Казан ГИДУВында эшли, 1980 нән педиатрия

кафедрасында балалар табибе. 1970–80 дә Е.М.Лепский исем. клиникада. 1996 дан Казан мед. академиясенең педиатрия каф. профессоры. Хезмәтләре иммунология, валеологиягә, вакциналау ярдәмендә балалар авыруларын кисәтүгә карый. К. вакытыннан алда туган балалар авыруларын (иммунитет торышы, иммунитет зәгыйфьлеге) өйрәнә. К. балаларның еш авыру сәбәпләрен ачу ысулын тәкъдим итә, дәвалау ысулларын эшли.

Х е з м.: Анемии недоношенных детей: Метод. рекомендации для врачей. К., 1982 (автордаш); Актуальные проблемы вакцинопрофилактики у детей. К., 1995; Роль нейроэндокринных взаимоотношений в формировании иммунологической реактивности у часто болеющих детей // Педиатрия. 1995. № 6.

**КЕМА́ЛОВ** Алим Фәйзрахман улы (5.8.1951, Ставрополь краеның Нефтекумск пос.), нефтехимик, техник фән. д-ры (2005). 1980 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре югары үзлелеккә ия нефтьләрне һәм битумнарны чыгару, ташу, эшкәртү һәм фракцияләрен сыек фазада оксидлаштыруны көчәйтү процессларының фәнни нигезләрен, нефть һәм нефть продуктлары б-н пычранган грунтларны рекультивацияләү технологияләрен, товарлыклы продукция җитештерү өчен нефть химиясенең күп тонналы калдыкларын һәм икенчел продуктларын (ш.и. күкертне) комплекслы куллану технологияләрен эшли. Нефть битумнарын (калдык, оксидлашкан, компаундлашкан) һәм алар нигезендә киң ассортиментлы битумлы продукция җитештерү өлкәсендә тикшеренүләр үткәрә. Мотор ягулыкларына, минер. майларга, юллар һәм гражданлык төзелеше өчен үзле материалларга катионлы актив утырткычлар, эмульгаторлар һәм модификаторлар тәкъдим итә. Уйлап табуга 65 тән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Пути повышения качества окисленных битумов // Изв. вузов. Нефть и газ. 1997. № 7 (автордаш); Влияние активирующих добавок на получение окисленных битумов // Химия и технология топлив и масел. 2003. № 1/2; Улучшение свойств лакового специального битума на стадии его получения // Химия и технология топлив и масел. 2003. № 5 (автордаш).

**КЕМА́ЛОВ** Руслан Алим улы (2.4.1978, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), техник фән. канд. (2003). 2001 елда Казан технол. ун-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли, табигый битумнар лаб-ясе мөдире (2004 тән), «Табигый битумнар» фәнни-техник үзәге директоры урынбасары (2008 дән). Бер үк вакытта, 2005–2006 да «Кровля» фәнни-җитештерү үзәге директоры урынбасары, «Нефтехимпродукт» фәнни-укыту үзәге җитәкчесе (2010 нан). Хезмәтләре үтә авыр нефтьләрне һәм табигый битумнарны комплекслы эшкәртүгә; нефть химиясе сәнәгате өчен ультратавыш ешлыклы кырда электромагнитик, акустик дулкыннар генерацияләү нигезендә эшләүче энергия җайланмалары һәм аппаратлары төзүгә карый. Дәүләт бүләге авыр нефть чималын табу һәм эшкәртүдә интенсив парга әйләндерү һәм электромагнитик активлаштыруның инновацион энергия саклаулы технологияләрен эшләгәне өчен бирелә.

Х е з м.: Защитные лакокрасочные покрытия на основе продуктов нефтехимического сырья. К., 2008 (автордаш); Научно-практические аспекты процессов коррозии и способов защиты. К., 2008 (автордаш); Производство окисленных битумов. К., 2010 (автордаш).

**КЕ́МБРИЙГАЧА ЧОР**, Җир кабыгының кембрий чоры алдыннан барлыкка килгән иң борынгы калын катламнары һәм Җирнең геол. тарихының 6/7 сы чамасын тәшкил иткән вакыт аралыгы. К.ч.ның дәвамлылыгы 4 млрд. ел чамасы. *Архей* һәм *протерозойга* бүленә. Борынгы платформаларның нигезен төзи (к. *Кристаллик нигез*). К.ч. — күбесенчә әче составлы тау токымнары (гранит һ.б.) массивы керү б-н бергә барган югары тектоник активлык дәвере. К.ч. катламнары зәңгәр-яшел суүсемнәрнең күпсанлы калдыкларын һәм аларның тереклек эшчәнлеге әзләрен үз эченә ала. К.ч. утырмалары б-н файдалы казылмаларның күп төрле комплексы бәйләнгән: 99% Co, 73% Cr, 70% Fe; Көньяк Африкада К.ч. конгломератлары үз эченә эре алтын чыганакларын, РФдә — К.ч. карбонатлары нефть чыганакларын (Иркутск өлк.) ала. ТР терр-ясендә К.ч. токымнарында углеводород, графит һ.б. чагылмалары ачыкланган.

**КЕ́МЕРОВО ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Себернең көньяк-көнбатышында урнашкан. Үзәге — Кемерово шәһәре. 1943 елның 26 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 95,5 мең *км²*. Халкы — 2821 мең кеше (2010), 51 мең татар (2002). Татарлар, башлыча, Анжеро-Судженск (4168 кеше), Кемерово (8071), Новокузнецк (6361), Прокопьевск (9342), Междуреченск (1820), Юрга (2315) шәһәрләрендә һәм күпләп Ижморский р-нының Нижегородка, Тёплая Речка, Кемерово р-нының Умантай, Мариинский р-нының Тундинка, Куркули, Юрга р-нының Олы Ылыс, Зимник авылларында яши. К.ө.ндә Татар милли мәдәни үзәге (1991 дән, Кемерово ш.), Себер һәм БДБ илләренең Европа өлеше мөселманнары Диния нәзарәте мөхтәсибәтенең мөселман дини берләшмәсе (1993 тән, Анжеро-Судженск ш.), «Нур» мөселман җәмгыяте (1999 дан, Междуреченск ш.) эшли. 2003 тә Кемерово шәһәрендә ТР Сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрлыгы ярдәме б-н «Татарстан сәүдә йорты» ҖЧҖ төзелә. ТР К.ө.н «Нефаз» автобуслары б-н тәэмин итә. Соц. Хезмәт Геройлары Ф.Тәхәвиев, Ш.Зәйнетдинов, Г.Идрисов, РСФСРның атказанган шахтёры Г.Т.*Фазалов*, генерал-майор Р.Г.*Кәлимуллин*, физика-матем. фән. д-ры С.Г.*Вәлиев*, мед. фән. д-ры М.З.*Миргазизовларның* тормышы һәм хезмәт юлы К.ө. б-н бәйле.

**КЕ́МПЕР** Михаэл (Michael Kemper) (8.11.1966, Хаген ш., ГФР), тарихчы, шәркыятьче галим, фән. д-ры (2003). Бохум шәһәрендәге Рур ун-тын тәмамлый (1994). 1998–2004 елларда «Фольксваген» фонды һәм Немец тикшеренүләр җәмгыяте матди ярдәмендә фәнни-тикшеренү эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 2005 нең гыйнварыннан АКШ-та, Сент Лоренс ун-ты (Нью-Йорк штаты) профессоры. Төп тикшеренүләре Россиядә ислам тарихы, татарлар арасында суфичылык таралу мәсьәләләренә, мөселман хокукы б-н гадәти хокукны чагыштырып өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Между Бухарой и Средней Волгой: Столкновение Абд ан-Насра ал-Курсави с улемами традиционалистами // Мир ислама. 1999. № 1/2; Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: Der Islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. B., 1998.

**КЕНӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Оштырма елгасының (Вятка елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,4 *км*, бассейнының мәйданы 69,2 *км²*. Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Чигайка авылының көньягындарак урнашкан чишмәләрдән башлангыч ала, тамагы — Камышлы авылыннан 1 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. К.нең 1,1 дән алып 5,7 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 129 *мм*, ташу агымы катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында су күләме 0,3 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЕНӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бөре елгасының (Вятка елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,8 *км*, бассейнының мәйданы 70 *км²*. Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Каенсар авылыннан 1,2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы — Яңил авылыннан 1,5 *км* көнчыгыштарак. Елганың абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. К.нең 1,8 дән алып 2,5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 91 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,065 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**КЕНӘБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 15 *км* көнбатыштарак, Хәтнә елгасы буенда. 2010 елда 344 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 1920 елларга кадәрге рәсми чыганакларда Иске Кенәбаш һәм Яңа Кенәбаш авылларына бүленә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәдрәсә, 2 су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 809,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 1 февраленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 30 ир-ат; 1859 да — 507, 1897 дә — 677, 1908 дә — 750, 1920 дә — 776, 1926 да — 864, 1938 дә — 581, 1949 да — 531, 1958 дә — 525, 1970 тә — 539, 1979 да — 535, 1989 да — 323, 2002 дә — 329 кеше.

**КЕНӘБА́Ш** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 18 *км* көньяктарак, Кенә елгасының (Оштырманың уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 339 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 730,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 275, 1897 дә — 380, 1908 дә — 456, 1920 дә — 494, 1926 да — 512, 1938 дә — 932, 1949 да — 738, 1958 дә — 531, 1970 тә — 500, 1979 да — 397, 1989 да — 361, 2002 дә — 367 кеше.

**КЕНӘ́Ж**, к. *Княжа*, Питрәч р-ны.

**КЕНӘРИ́ ҮЛӘНЕ́**, кушбашак (Phalaroides), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Африка һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — камышсыман кушбашак (Ph. arundinacea) бар; бөтен республикада очрый. Сулык ярлары буенда, сазлыклы болыннарда үсә. 1,5–2 *м* биеклектәге, озын шуышма тамырчалы, кышка чыдам, дым яратучан үсемлек. Күпсанлы сабагы киң кыяклы, очлы тешәүле яфраклар б-н капланган. Башакчыклары бер чәчәкле, аксыл шәмәхә, бер яклы тармаклы себеркәчтә. Җимеше — бөртекчә. Июньдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Туфракка талымсыз, озак вакыт дәвамында суда калуны һәм ләмләнүне җиңел кичерә, суыкка һәм корылыкка чыдам. Артык дымлы болыннарда печәнлек җирләр булдыру өчен тәкъдим ителә.

**КЕРАМЗИ́Т**, ясалма куыш гранулалы күзәнәк төзелешле материал. Җиңел бетоннарны тутыруда кулланылучы ясалма куыш матдәнең аеруча киң таралган төре. Шулай ук төрле максатларда төзелгән биналарның конструкцияләрендә җылылык саклаучы катлам буларак та файдаланыла. Бөртекләренең зурлыгы 5–40 *мм*. К. әйләнеп торган мичләрдә эри, кабара торган балчыктан яндырып эшләнә. Структурасы буенча К. бөртеге ябышып каткан юка тышча б-н капланган пыяласыман куыш массадан гыйбарәт. Күбрәк вак чуерташ рәвешендә ясала. Татарстанда К. җитештерүче беренче завод 1957 елда Казанда төзелә. К. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрендәге, Биектау р-ны Коркачык посёлогындагы пр-тиеләрдә эшләп чыгарыла. Җитештерү күләме (мең $м^3$): 1970 тә — 193, 1980 дә — 688, 1990 да — 776, 2000 дә — 353, 2002 дә — 147, 2004 тә — 110, 2008 — 150,5. Ш.у. к. *Бетонитлар*.

*Р.З.Рәхимов.*

**КЕРАСИ́НОВО** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кырлай елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше яши. Казан ханлыгы чорыннан Кече Сайра исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сухая Сайра, Красенский буларак мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 тимерчелек, су тегермәне, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 149,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир-ат; 1859 да — 170, 1897 дә — 176, 1908 дә — 178, 1920 дә — 189, 1926 дә — 204, 1938 дә — 253, 1949 да — 228, 1958 дә — 140, 1970 тә — 89, 1989 да — 11, 2002 дә — 6 кеше.


**КЕРӘ́Н** (Armoracia), кәбестәчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; яшелчә культурасы. Килеп чыгышы — Көньяк-Көнчыгыш Европа. Ике төре билгеле. ТРда гади К. яисә авыл К.е үстерелә (A. rusticana). Тамыры юан, итчел, бөтен буена күп бөреләр бар, туфракка бик тирәнгә китә, сабагы туры, тармаклы. Яфрак таралгылары тоташ, эре, озынча, каяу кырыйлы; сабак яфракларының түбәнгеләре — каурыйсыман аерым; уртадагылары — озынча-ланцетсыман; югарыдагылары — сызыкча. Вак ак чәчәкләре чуксыман чәчәк төркеменә җыела. Үсемлек читтән серкәләнә. Җимеше — озынча яисә шарсыман кузакчык. Орлыклары сирәк ясала. Вегетатив юл б-н тамыр чыбыкчаларыннан үрчетәләр. Бер- яки икееллык культурада, дымлы, балчыксыл, уңдырышлы туфракларда үстерәләр. Азык буларак, нигездә, тамыры кулланыла; яфраклары яшелчәләр тозлаганда һәм консервлаганда тәмләткеч итеп файдаланыла. К. зәңгелә авыруына каршы яхшы чара, фитонцид үзлеккә ия, яфраклары һәм тамырлары аскорбин кислотасына һәм эфир майларына бай; аппетитны ача, ашамлыкның тәмен арттыра, азык эшкәртелүгә булыша. Составында горчица глюкозиды булу сәбәпле, бик әче. ТРда чәчәргә рөхсәт ителгән сортлары: «Суздальский», «Ростовский», «Рижский», «Атлант» һ.б. Халык хуҗалыкларында үстерелә.

*Әд.:* Справочник по овощеводству. Л., 1982; Овощеводство. М., 2003.

**КЕРӘНЛЕ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 147 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, киез итек басу һәм тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1087,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 419, 1897 дә — 671, 1908 дә — 693, 1920 дә — 673, 1926 да — 568, 1938 дә — 599, 1949 да — 655, 1970 тә — 545, 1979 да — 387, 1989 да — 171, 2002 дә — 190 кеше.

**КЕРӘ́Ч СӘНГАТЕ́**, *гамәли-бизәлеш сәнгате* һәм *монументаль-бизәлеш сәнгате* өлкәсе; яндырылган махсус кушылмалы балчыктан төрле нәфис эшләнмәләр ясау төре. К.с.нең төп төрләре — чүлмәк ясау, терракота, майолика, мозаика, фаянс, фарфор — савыт-саба, вазалар, сыннар, дивар паннолары, архитектур чынаяк кирпечләр, уенчыклар, бизәкләр һ.б. әйберләр иҗат итү өчен файдаланыла. Татарларда К.с. «керәч» исеме б-н мәгълүм һәм нәфис һөнәрчелектә традицион төрләрнең берсе.

Татарстан терр-ясендә керәч эшләнмәләрнең иң әүвәлге табылдыклары неолит дәверенә карый (зигзаглар, ромблар, өчпочмаклар, тараксыман штамп, үрелгән шнур рәвешендәге һәм иң гади геом. бизәкләр б-н сырланган чүлмәк савытлар; к. *Балахна культурасы, Идел-Чулман буе культурасы*). Бакыр һәм бронза гасырларда савыт формалары тагын да төрләнәлә бара, орнамент мотивлары катлаулана (бизәк төрле киңлектәге кайма рәвешендә төшерелә), өсләкләр шомартыла, ялтыратыла (к. *Буралы курган культурасы, Казан яны культурасы*). Б.э. к. 8–3 йөзләр К.с. (*Ананьино культурасы*) археол. калдыклары: балчыктан ясалган вак пластик хатын-кыз сыннары, геом. бизәкләр һәм стильләшкән җәнлек сурәтләре б-н каймаланган (мәс., чабып баручы атлар төркеме) соры һәм кызгылт-көрән төстәге түгәрәк төпле савыт фрагментлары рәвешендә билгеле. Алдагы меңьеллыкта чүлмәк ясау техникасы камилләшә;



**Керәч сәнгате.** 1. Савыт. Үзле балчык. Ялтырату, чәнечкеләп-сызып төшерелгән бизәк. Буралы курган культурасы. Б.э.к. 2 нче меңьеллык уртасы; 2. Тоткасы җәнлек башы рәвешендәге савыт. Ф.Х. Вәлиев реконструкциясе. Рәссам Б.А. Шубин; 3. Савыт. Үзле балчык. Чәнечкеләп-сызып төшерелгән бизәк, штрихлау. Идел буе Болгар дәүләте. 10–11 йөзләр. Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы; 4. Кечкенә шәмдәл. Ялтыравык йөгертелгән керәч. Идел буе Болгар дәүләте. 10–11 йөзләр. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. Касә. Төсле ялтыравык. Алтын Урда. 14 йөз. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 6. Керәч дивар бизәге калдыгы. Майолика. Болгар шәһәре. 13–14 йөзләр. ТР Милли музее; 7. Керәч дивар бизәге калдыклары. Майолика. Болгар шәһәре. 13–14 йөзләр. ТР Милли музее; 8. Җәнлек рәвешендәге савыт. Әвәләп ясалган керәч. Казан. 16–17 йөзләр. ТР Милли музее; 9. Балчыктан ясалган керәч үрнәкләре. Ялтырату, шомарту. Казан. 16–17 йөзләр. ТР Милли музее; 10. Питрәч һөнәрчелеге үрнәкләре. Үзле балчык. Бизәк. 1980 еллар. ТР Милли музее; 11. Казан сәнгать-педагогика техникумының керәч остаханәсе эшләнмәләре үрнәкләре. 1928. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. «Батыр» дивар тәлинкәсе. Үзле балчык. Эмаль, төсле ялтыравык. Рәссам Б.А. Шубин. 1967; 13. Декоратив керәч эшләнмәләре җыелмасы. Үзле балчык. Уеп ясалган бизәк. Рәссам Н.В. Кузьминых. 2000 еллар; 14. Шәмәрдән балчык уенчыклар ясау остаханәсе әзерләгән сувенир эшләнмәләр. Рәссам Р.К. Сафина. 2000 еллар; 15. «Елан патша» декоратив скульптурасы. Шамот. Рәссам Х.Н. Латыйпов. 1992.

7–8 йөзләрдә Идел-Чулман буйларында әлгәреге болгарлар таралып яши башлагач, чүлмәк ясау тәгәрмәче барлыкка килә. К.с.нең җитлеккән вакыты 10–13 йөзләргә — форма бирү, бизәк төшерү культурасының югары дәрәҗәгә ирешкән чорына карый. Бер яки ике саплы амфора рәвешендәге кувшиннар, коштабаклар, хумнар, чүлмәкләр, *комганнар* һ.б. савыт-сабалар, шәмдәлләр, кара савытлары, уенчыклар кул б-н әвәләп тә, чүлмәк ясау тәгәрмәче б-н дә эшләнә. Алар үлчәвенә туры килә торган пропорцияләре, буяуларның ачыклыгы (якты сарыдан, томанлы сорыдан кызыл һәм куе кызгылт көрән төскә кадәр) һәм бизәкле (үрмәләр, үсемлек сабаклары, каймалар, каннелюрлар, штрихланган өчпочмаклар, «йөгерек дулкын» мотивлары, интеграль спираль һ.б.) композицияләре б-н аерылып торалар. Эшләнмәне ангоб б-н каплау (ак, кызыл, соры балчык), үтә күренмәле чүлмәк лагы б-н каплау (сыек яшелдән кара төскә кадәр) һәм буйлы сызыклар рәвешендә шомарту алымы киң тарала. Пыяласыман ялтыравык йөгертелгән К.с. еш кына контррельефлы бизәк б-н яраша. Болгар К.с.нең формалары да үзенчәлекле — сылап ясалган киек-җәнлек гәүдәләре (алгы өлеше) һәм башлары (үгез, ат, сарык, эт, поши, үрдәк, әтәч һ.б.) эшләнмәләрнең түгәрәк өлешен тәшкил иткән һәм әйбернең сапларын, борыннарын бизәгән. Кайбер очракта табыну һәм саклау мәгънәсенә ия булган җәнлек һәм кош сурәтләре шартлы рәвештә ярымтүгәрәк чыгынты формасы б-н алмаштырылган.

*Алтын Урда сәнгатендә* майоликаның килеп чыгуы һәм архит-ра бизәлешендә киң кулланылуы К.с. үсешенә яңа импульс бирә. Рельефлы һәм ялтыравык чынаяк кирпеч рәвешендәге бизәкле майолика, уеп бизәлгән майоликалы мозаика кулланыла. Алтын Урда шәһәрләрендә (Иске Сарай, Яңа Сарай, Болгар һ.б.) хосусый җитештерү җәйга салына һәм зәңгәр, фирәзә, ультра зәңгәр, сары, кызыл тондагы чәчәк-үсемлек бизәкләре, кайбер очракта алтын йөгертелгән өстәмәләр (ябыштырылган алтын фольга кисәкләре яки алтын буяулы лак өсте бизәкләре) һәм ак, җиңелчә рельефлы гарәп язулы купшы бизәкләр б-н аерылып торган архит-ра керәче стиле булдырыла. Мозаика еш кына ялтыравык бизәкле (фирәзә төсле ялтыравыклы һәм кара бизәкле) майолик плиткалар кебек махсус ак измәдә — «кашин»да әзерләнә. Кабер һәм төрбә диварлары (Болгардагы Хан каберлеге, Үргәнечтәге Түрәбәк ханым төрбәсе), торак йортлар, ш.у. мичләр һ.б. тышлана. Тоташ яки өлешчә ялтыратылган (күк, зәңгәр), уеп бизәлгән терракота — сирәк очрый торган архит-ра бизәге төре. Алтын Урда чорында ялтыравык көнкүреш савытлары (коштабаклар, касәләр), шәмдәлләр һ.б. киң кулланыла башлый. Ялтыравыксыз керәчнең киң күләмдә җитештерелә башлавы монголларга кадәрге Идел буе Болгар дәүләте традицияләренең дәвам итүенә юл ача, эшләнмәләрнең яңа төрләре (рәсемле, язулы, тамгалы осталар билгеләре булган сфероконуслар), ш.и. рельефлы бизәкләр төшерелгән эпиграфик орнаментлы абстракт мотивлар, штампланган керәч (савытлар) барлыкка килә. Алтын Урда К.с.нең бизәкләү формалары һәм ысулларында, эшләнмәләрне гарәп язулары б-н бизәү традицияләрендә, аларның төсләр палитрасында урта гасырлар *мөселман сәнгатенең* гомуми тенденцияләре чагыла.

15 йөздә — 16 йөзнең 1 нче яртысында (к. *Казан ханлыгы сәнгате*) К.с. узган гасырларның төрлечә кулланылган бизәкле чүлмәк ясау сәнгате традицияләрен саклый. Кирпеч төсендәге кызыл һәм сары-кызыл савытлар кулдан һәм аяк б-н әйләндереп эшли торган чүлмәк ясау тәгәрмәчендә әзерләнә; осталарның савытлардагы келәймәләре чүлмәк ясау остаханәләренең гамәлдә булуы турында сөйли (аларның берсе *Иске Казан* шәһәрлегендә табыла). Казан Кремле терр-ясендәге археол. табылдыклар арасында бизәкләре фирәзә, куе һәм сыек-яшел, ш.у. ак фонга зәңгәр төстәге ялтыравык йөгертелгән керәч фрагментлары очрый. Савыт-саба (кувшиннар, комганнар) бизәлешендә савытларның борыннарын бизәү өчен ат, сарык, әтәч формасындагы әвәләп ясалган күпертмә бизәкләр куллану дәвам итә. Әтәч башлы эшләнмәләрне тарихчылар (Н.Ф.Калинин) «борынгы Казан формасы» дип исәплиләр (Казандагы казу эшләре вакытында 13–14 һәм 15–16 йөзләр катламнарында табыла).

Казан ханлыгы яуланып, татарларны чүлмәк ясау эшенә яраклы балчык ятмалары булган (хәзерге Питрәч авылы, Алабуга, Чистай шәһәрләре, Кукмара ш.т.п. янындагы карьерлар) зур елга буйларыннан сөргәннән соң, К.с. яшәүдән туктый. Рус булмаган халыклар өчен металлны утта кыздырып эшкәртү һәм, шул рәвешле, яндырып чыныктыру мичләре куллану патша тарафыннан тыела. Татар халкы, башлыча, руслар җитештергән керәч савытларны куллана, кайбер авылларда (Татарстанның көньяк-көнчыгышы) файдаланырга яраклы табигый балчыктан (әвәләп ясалган) гади савыт-сабалар җитештерелә, кирпеч сугыла.

Казан Кремле терр-ясендә үткәрелгән казу эшләре нәтиҗәләреннән күренгәнчә, шәһәрдә яшәүче рус халкы читтән кайтартылган, 16–17 йөзләрдә рус керәченә хас һәм биналарның бизәлешендә кулланылучы рельефлы чынаяк кирпеч рәвешендәге, пыяласыман ялтыравык катлам йөгертелгән, бер төсле һәм бизәкле майоликадан киң файдалана. 18 йөздән башлап, читтән кайтартылган (башлыча, Мәкәрҗә ярминкәсеннән) һәм, гадәттә, җирле осталар тарафыннан бизәлгән һәм яндырып чыныктырылган чынаяк кирпечләр күбрәк Казандагы торак йортлар мичләре бизәлешендә файдаланылган, алар сәнгатьнең әлеге төрендәге гомумрус традицияләренә тәңгәл килгән. Балчыктан ясалган савытлар һәм борынгы көнкүреш кирәк-яраклары вак һөнәрчелек б-н көн иткән Питрәчтә һәм аның янәшәсендәге авылларда җитештерелгән. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан биредә бизәлгән һәм ялтыравык б-н капланган нәфис эшләнмәләр (савытлар, камин тышлыклары һ.б.) әзерли башлыйлар. 1890 елда Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсенә әзерләнү уңаеннан керамик эшләнмәләрне җирле җитештерү киңәйтелә һәм камилләштерелә. Бизәк эскизларын *Казан сәнгать училищесе* укытучылары эшли. 1911 дә кәсепчелек базасында *Питрәч нәфис-һөнәрчелек остаханәсе* ачыла (1918 дә ябыла). 1927 дә остаханә җирлегендә Б.И.*Урманче* башлангычы б-н Казан сәнгать уч-щесенең керәч остаханәсе эшли башлый. Яндырып чыныктыру миче ясала, кыру станоклары, һ.б. җиһазлар китерелә, ангоб бизәкле, ялтыравык йөгертелгән керәч савытлар эшләүгә юл ачыла. К.с. үрнәкләре остаханә җитәкчесе (Б.Урманче) һәм студентлар эскизлары буенча иҗат ителә, алар урта гасырлар мөселман керәченә хас формалары, татар орнаменты стилендәге күптөсле бизәкләре б-н аерылып тора.

Остаханәдә рельефлы ялтыравык керәчтән Татарстанның беренче гербы эшләнә (авторлары — Б.Урманче, Ш.Усманов). 1929 да остаханә ябыла һәм шул вакыттан алып проф. керәчче-рәссамнар Г.А.Зяблицев һәм Б.А.*Шубин* иҗатларында яңарганчы, ягъни 1960 елларга кадәр, К.с. үсеше өзелеп тора. Алар тарафыннан уникаль күргәзмә үрнәкләре (декор. савытлар, сервизлар, вак сыннар һ.б.) б-н бергә серияле, тиражлы эшләнмәләр дә иҗат ителә. 1963 тә Шубин Казан төзелеш материаллары комб-ты каршында керәч цехы оештыра һәм күпләп җитештерүне җайга сала. Җитештерелүче әйберләр үрнәкләрендә, керәч формаларында һәм мотивларында ул Болгар һәм Алтын Урда чоры традицияләренә таяна, татар фольклоры сюжетларын, татар гамәли-бизәлеш сәнгатенең төсле һәм орнаментлы композицияләрен файдалана, керәч төрләренең технологиясен камилләштерә һәм диапазонын киңәйтә (фаянс, майолика, шамот, люстр һәм ангоб бизәкләре, вак сыннар һ.б.). 1970 елларда рәссамнарның иҗат төркеме (А.Симбирин, А.Горев, А.Маяков) ярдәмендә монументаль-бизәлеш керәче (җәмәгать биналарының фасадларын һәм интерьерларын бизәүче шамоттан эшләнгән дивар паннолар, рельефлар, сыннар: Казан яшьләр үзәге, Казан технол. ун-ты ашханәсе һ.б.) яңарыш кичерә башлый. Панно, декоратив өстәмәләр, идән вазалары, вак сыннар рәвешендәге интерьер керәче 1980–90 елларда төрле җәмәгать биналарын: Чаллы, Түбән Кама, Алабуга һ.б. шәһәрләрдәге мәктәпләрне, балалар бакчаларын, мәдәният сарайларын, сәүдә учреждениеләрен бизәгәндә (рәссамнар Р.Вахитов, Р.Круглякова, Х.*Латыйпов*, Г.Миргалимов, З.Низаметдинов, Р.*Сәлахов*, О.Суняев һ.б.) киң кулланыла. 1986 да Казанда ТАССРның Сәнгать фонды каршында керәч остаханәсе ачыла. Рәссамнар А.Абызгильдин, Н.Кузьминых, И.Макарова, А.Миңнуллина, Ф.Фәсхетдинов һ.б. шамотны, сюжетлы ялтыравык бизәкле керәчне киң кулланып, уникаль күргәзмә әсәрләре иҗат итәләр (дивар тәлинкәләре, вазалар, коштабаклар, сыннар һ.б.). 1980 еллар ахырында республикада К.с.нең фарфор төре үсеше өчен мөмкинлек туа. *«Бөгелмә фарфоры»* з-ды базасында нәфис эшләнмәләр һәм сувенирлар эшләү җайга салына (рәссамнар Р.һәм З.Мәхмүтовлар, Т.Слободе-

нюк, Г.Маргулис һ.б.). Фарфорның бисквит кебек төреннән (кобальт, люстр, перламутр һәм алтын б-н бизәлгән, ялтыравыксыз ак фарфор) сервизлар, шәмдәлләр, штофлар, декоратив сыннар иҗат итәлә. Р.Мәхмүтовның татар фольклоры мотивлары буенча кобальттан эшләнгән ялтыравык бизәкле, жанрлы композицияләре («Чәй эчкәндә», «Гайбәтче хатыннар», 1980 еллар), милли орнаментлы кофе сервизлары һ.б. югары сәнгать дәрәҗәдә башкарылулары б-н аерылып торалар.

1990 елларның 2 нче яртысында К.с. шәхси иҗат остаханәләре (В.Әйбәтова, Л.Сафина — «Тере балчык», «Ташбака» һ.б.) һәм Казан төзелеш материаллары комб-ты каршында аерым һәм серияле эшләнмәләр чыгаручы керәч цехы кебек сәнгати җитештерү кысаларында үсә. Азнакай р-нының шәһәр тибындагы Актүбә посёлогында бер үк вакытта уку-укыту үзәге булган «Актүбә уенчыгы» дигән яңа нәфис кәсепчелек пр-тиесе барлыкка килә. Биредә И.Сәлахова җитәкчелегендә балчыктан татар уенчыкларының сувенир үрнәкләре күпләп җитештерелә башлый. Саба р-нының Шәмәрдән авылындагы җирле мәктәп остаханәсендә традицион формадагы балчыктан эвәләнгән уенчыклар эшләү үзләштерелә (рәссам Р.Закирова). Керәч сәнгатен укыту беренче тапкыр Казан сәнгать уч-щесенең керәч бүлегендә, *Казан мәдәният һәм сәнгать университетының* гамәли-бизәлеш сәнгате ф-тында гамәлгә ашырыла башлый.

*Әд.:* Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; шул ук. Искусство художественной керамики // Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Носкова Л.М. Мозаики и майолики из средневековых городов Поволжья. М., 1976; Фёдоров-Давыдов Г.А. Искусство кочевников и Золотой Орды. М., 1976; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; шул ук. Художник Борис Шубин: Искусство керамики Татарстана. К., 1999.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КЕРӘ́Ш ШУРА́Н** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* төньяктарак, Ык елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 134 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1762 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1406 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1859 да — 106, 1870 тә — 262, 1884 тә — 239, 1920 дә — 436, 1926 да — 516, 1938 дә — 489, 1949 да — 344, 1958 дә — 314, 1970 тә — 273, 1979 да — 208, 1989 да — 155, 2002 дә — 145 кеше.

**КЕРӘШӘЛӘ́Р**, аерыкойрыклылар (Apodidae), керәшәсыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 80 гә якын төре билгеле, поляр өлкәләрдән кала, киң таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре бар — кара керәшә (Apus apus). Бөтен районнарда очрый. Май уртасында очып килә. Гәүдәсенең озынлыгы 18 *см* га, канат җәеме 40 *см* га җитә, авырлыгы 95–110 *г*. Каурый капламы яшькелт металлсыман көрән төстә. Томшык асты-муенында ак тап бар. Канатлары озын, ураксыман бөгелгән. Койрыгы кыска, сәнәксыман. Томшыгы киң. Тәпиләре көчсез, йөрү өчен җайлашмаган, барлык 4 бармагы да алга юнәлгән. Очуы тиз, канатларын еш җилпи. Вакытның күп өлешен азык эзләп һавада үткәрә. Колонияләр булып оялыйлар, ояларын агач куышларында, текә кыяларда, түбә асларында, бина ярыкларында ясыйлар. Канатлы бөҗәкләр (чебен, озынборыннар) б-н туена, аларны исә ул очканда аулый. Очкан вакытта парлаша. 2–4 ак йомырка сала. Августта кышларга очып китә.

**«КЕРӘШЕ́Н ГАЗЕТЫ́»**, керәшеннәрнең үзәк ком-ты басмасы. 1918 елның гыйнвар–июль айларында Казанда татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Григорьев А.Н. Кряшенский вопрос в Татарии и его разрешение Советской властью: Дис. ... М., 1945; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975.

**КЕРӘШЕ́Н КАЗЫСЫ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 30 *км* төньяктарак, Казылы елгасы (Мишәнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 104 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Керәшен Казысы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умарта ясау, йон тетү, өс-баш киемнәре тегү, тимерчелек һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.нда Троица чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 2 җил тегермәне, ярма яргыч, май язу з-ды, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 964 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 320, 1897 дә — 706, 1908 дә — 819, 1920 дә — 812, 1926 да — 778, 1949 да — 315, 1958 дә — 351, 1970 тә — 232, 1989 да — 125, 2002 дә — 133 кеше.

**КЕРӘШЕ́Н НАРАТЛЫСЫ́**, к. *Сосновый Ключ*, Чистай р-ны.

**КЕРӘШЕ́Н ПАКШИНЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Пакшин елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.П.нда чиркәү-приход мәктәбе (1900 дә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 343 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троица-Сәкинәс волостенда, 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 112, 1897 дә — 240, 1908 дә — 304, 1920 дә — 269, 1926 да — 263, 1938 дә — 204, 1949 да — 695, 1958 дә — 190, 1970 тә — 273, 1979 да — 177, 1989 да — 115, 2002 дә — 106 кеше.

**КЕРӘШЕ́Н СӘРДӘСЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 22 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 401 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Никольский чиркәве. 1565–67 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Керәшен Сәрдәсе буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.С.ндә земство мәктәбе (1868 дә ачыла), 3 ярма яргыч, тимерчелек, 2 тукыма һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1479 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 553, 1897 дә — 989, 1908 дә — 1144, 1920 дә — 1259, 1949 да — 864, 1958 дә — 862, 1970 тә — 882, 1979 да — 791, 1989 да — 594, 2002 дә — 477 кеше.

**«КЕРӘШЕ́Н СҮЗЕ́ – СЛО́ВО КРЯ́ШЕН»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1993–2001 елларда Чаллы шәһәрендә нәшер ителә, текстлары татар һәм рус телләрендә бирелә. Өзлексез чыга. Оештыручылары — Н.П.Антонов, Н.К.Колчерин. Төрле еллардагы мөхәррирләре — А.Н.Малов, Л.Д.Белоусова. *Керәшен татарларны* бергә туплау һәм аларның үзаңын ныгытуны максат итеп куя. Татарстан һәм Россиядәге керәшен татарлар тормышын яктырта. Керәшен татарларның тарихы, гореф-гадәтләре, этник үзенчәлекләре турындагы материаллар басыла. Газета керәшен татарларның күренекле мәдәният эшлеклеләре һәм әдипләре иҗаты б-н таныштыра.

**КЕРӘШЕ́Н ТАТАРЛА́Р** (үзатамалары — керәшен), Идел буе — Урал яны татарлары составындагы этноконфессиональ төркем. К.т. православие динен тота. Татарстанда (18,76 мең кеше), зур булмаган төркемнәре Удмуртиядә (650 кеше), Башкортстанда (4,51 мең кеше), Чиләбе өлкәсендә (*нагайбәкләр*) яши. 1926 елгы халык исәбен алу мәгълүматлары буенча, К.т. һәм нагайбәкләр мөстәкыйль этник берәмлек буларак карал-

ган чакта, К.т. 104,4 мең, нагайбәкләр 11,2 мең кеше тәшкил итә; 2002 елгы халык исәбен алу буенча, К.т. саны 24,67 мең кеше исәпләнә. К.т. составына Мәлки, Чистай, Көнбатыш Кама алды, Алабуга, Минзәлә, Бакалы, Нагайбәк этнографик төркемнәре керә. Телдә 5 сөйләшне: нагайбәкләр, Түбән Кама яны К.т., Казан арты, Чистай һәм Мәлки К.т. сөйләшләрен аерып күрсәтергә мөмкин. Нигездә, К.т. татар теленең урта диалектында сөйләшәләр (көнбатыш диалектка якын Мәлки К.т. сөйләше бераз аерылып тора). К.т.ның мөстәкыйль гомумилек буларак оешуы берничә этапны үтә; бу процесста фин-угор, ш.у. төрки, ш.и. соңгырак чор төрки-кыпчак-нугай компонентлары катнаша. 15 йөздә — 16 йөзнең 1 нче яртысында православие динен кабул иткән К.т. бик тиз руслашалар. 17–18 йөзләрдә руслашу татар аристократиясе арасында да күзәтелә, аның күп кенә вәкилләре (мәс., Беговатовлар, Бигловлар, Енгалычевлар, Урусовлар, Ширинскийлар) үз биләмәләрен



Керәшен хатын-кызы.

саклап калу өчен 16 йөздә — 18 йөз башында христианлыкка күчәләр. Тулаем алганда, К.т.ның формалашуы 16 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөздә Идел буе татарларының бер өлешен *христианлаштыру* процессында бара. Әлеге төркем (18 йөз башына якынча 17 мең кеше исәпләнә) «баштарак чукындырылган татарлар» исемен ала. 18 йөзнең 1 нче яртысында хөкүмәт Идел буенда яшәүче рус булмаган халыкларны күпләп христианлаштыру сәясәте алып бара. Татарларны православие диненә күчерергә тырышу каршылыкка очрый (1755–56 елгы *Батырша хәрәкәте*, 1773–75 елларда Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге *Крәстияннәр кузгалышы*) һәм гомумән алганда уңыш китерми. Бу чорда татарларның православие динен кабул иткән яңа төркеме (якынча 12,8 мең кеше) «яңа чукындырылганнар» дип йөртелә башлый. 1760 елларга К.т.ның Идел буе һәм Урал яны татарлары составындагы чагыштырма күләме иң югары күрсәткечкә — 7,6% ка җитә. 19 йөздә, аеруча 1860 еллардан башлап, К.т. арасында, барыннан да элек яңа чукындырылганнарда, мөселманлыкка кайту хәрәкәте башлана. К.т.ның, ш.и. баштарак чукындырылганнарның да, христианлыктан күчүе 1906–07 елларда көчәя. 20 йөз башында мөселманлыкка К.т.ның 40% ка якыны күчә.

К.т. саны 18 йөздә — 20 йөзнең 1 нче чирегендә түбәндәгечә була: 1719 да — 17 мең кеше, 1744 тә — 23 мең, 1762 дә — 30,3 мең, 1795 тә — 40 мең, 1833 тә — 68,7 мең, 1857 дә — 86,3 мең, 1897 дә — 110 мең, 1911 дә — 123 мең, 1926 да — 120,7 мең кеше.

20 йөз башында К.т.ның этноконфессиональ гомумилеге керәшен үзатамасы (кайберләрендә, мәс., нагайбәкләрдәге кебек, башка этнонимнар) ныклап берегеп калган төркемнәрне тәшкил итә. Әлеге гомумилекнең тотрыклылыгына аның 1920 һәм 1926 еллардагы халык исәбен алу вакытында мөстәкыйль этник берәмлек — халык сыйфатында аерып күрсәтелүе дәлил булып тора. Окт. рев-циясеннән соң Татарстанда «керәшен мәсьәләсе» килеп туа, аны хәл итүнең ике төрле исулы билгеләнә: К.т.га аерым автономия бирү яисә аларның башка татарлар б-н акрынлап рухи якынаюы. Кискен көрәштә урта линия дип аталган як җиңүгә ирешә, К.т.га билгеле мәдәни автономия бирелгән очракта, К.т. һәм мөселман татарлар арасында аерманы юкка чыгару сәясәтен алып бару күздә тотыла. 1990 елларда К.т.ның православие традицияләренә корылган рухи тормышын яңарту омтылышы күзәтелә; 1990 да «Керәшеннәрнең этнографик мәдәни-агарту берләшмәсе» төзелү, 2001 дә К.т.ның конференцияләрен, съездларын («Керәшеннәрнең этнос буларак үзбилгеләнүе турында декларация» дә кабул ителә) уздыру моны ачык күрсәтә. Әмма К.т.ның радикаль карашлы әйдәүчеләре тарафыннан күтәрелгән үзбилгеләнү хакындагы лозунглар 2002 елгы халык исәбен алу барышында К.т.ның 1/10 өлешендә генә яклау таба. Хәзерге шартларда да К.т.ның мәдәни-дини үсешендә билгеле проблемалар кала килә.

К.т.ның мәдәнияте шактый үзенчәлекле. Мөселман татарларның гомуми массасыннан аерымлану шартларында традицион мәдәниятнең аерым элементлары консервацияләнә, тора-бара христиан мәдәнияте б-н кушылып китә. Нигездә, К.т. Казан татарларына якын, тик аларның кайбер төркемнәре (Чистай, Мәлки) мишәр-татарлар б-н дә бәйле. К.т. хуҗалыгында элек-электән бөртеклеләр (арыш, бодай, борай, солы, карабодай, арпа, борчак, ясмык һ.б.) буенча махсуслашкан игенчелек төп роль уйный. Техник культуралардан киндер, сирәк кенә — җитен игелә. 20 йөз башына кадәр сука төп сөрү коралы булып исәпләнә. Яшелчәчелек үсеше мөселман татарлардагы кебек үк түбән дәрәҗәдә була (бәрәңге, суган, кайчак кәбестә, кабак үстерелә). Терлекчелек ярдәмче тармак булып санала, ат, сыер, сарык, кәҗә, дуңгыз асрала (дуңгызчылыкның соңрак килеп чыгуын әлеге хайваннарның традицион ритуалларда файдаланылмавы һәм аларның итен йола ризыгы буларак кулланмау аң раслый). Кошчылык (тавык, каз, урыны б-н үрдәк, күркә) киң кулланылышта була. Умартачылык, бакчачылык, аучылык үсеш ала. Кәсепләр шактый төрле: тегүчелек, чабата үрү, агач, йон, күн эшкәртү, чыпта сугу һ.б. Авыллар һәм салалар, нигездә, чокырлы-елгалы һәм үзәнлекле типта, 19 йөздә авылларны планлаштыруның сызыксыман рәвеше өстенлек итә. Бердәм комплекс тәшкил итүче утар каралтылары бүрәнә өйләрдән (күбесенчә өй-өйалды тибындагы ике яклы тораклар) һәм хуҗалык корылмаларыннан (келәт, амбар, абзар, мунча, баз һ.б.ш.) тора. Торак түбәләре такта һәм салам б-н, хуҗалык корылмалары, болардан тыш, кабык һәм камыш б-н ябыла. Өйне ике өлешкә: ак (ак өй) һәм кара (кара өй) якларга бүлү традициясе яши. К.т.да түр як б-н бергә (түр — ишеккә каршы урнашкан изге урын) икона куела торган урын да кадерле саналган (кояш почмак, тәре почмак). Өйнең яши торган өлеше, мөселман татарлардагы кебек үк, такта яки чаршау б-н ике якка (ир-ат һәм хатын-кыз яклары) бүленә. Йортның эчен җиһазлауда өйдә тукылган төсле башлы сөлгеләр, тастымаллар һ.б. кулланыла. Сәке, сәндерә, эскәмияләр (ян сәке) төп җиһаз булып тора.



Керәшен татарларның традицион хатын-кыз костюмы вариантлары.

19 йөз ахырында шәһәр көнкүрешенә хас кайбер детальләр килеп керә (өстәл, буфет, көзге, сәгать һ.б.ш.). К.т.ның төрле төркемнәренең киемендә аерымлыклар бар. 19 йөзнең 2 нче яртысында алар киндер һәм алачадан тегелә, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында исә фабрикада җитештерелгән тукымалар, гәрчә алар күбесенчә бәйрәм киемнәрен әзерләүдә кулланылсалар да, популярлашып китә. К.т.да, мөселман татарлардан аермалы буларак, өйдә тукылган киемнәр путалы (әзәр) булуы б-н аерыла, ул кулланылыштан шактый тиз төшә, әмма аерым төркемнәр киемендә саклана. Ак киндер тукымадан иңбашлары җөйсез, туника рәвешендәге өлгеле (ирләр һәм хатын-кызлар өчен бер үк төрле өлге) күлмәкләр киң кулланылышта йөри. Хатын-кыз күлмәгенең икенче тибы киселмә билле итеп, күкрәк уемын (изү) бизәкләп, итәкләренә бөрмәләр ясап тегелә. Шәһәрчә киемнәргә күчү дә нәкъ менә шул типтагы киемнәр нигезендә килеп чыга: кокетка һәм кайбер башка элементлар өстәлә. Кияүдәге хатын-кызлар күлмәк астыннан тамбур чигүле яисә төрле төстәге ситсы кисәкләреннән торган аппликация б-н бизәлгән *күкрәкчә* ки-

еп йөриләр. Ирләр күлмәгенең җиң очлары, итәге, кияү күлмәгенең изү кырыйлары чигеп бизәлә. Ыштаннар киң итеп, ике җенес затлары өчен дә бер үк өлге б-н тегелә. 20 йөз башында ирләр арасында шәһәр тибындагы ыштаннар — чалбарлар кулланылышка керә. Ирләрдә дә, хатын-кызлар арасында да алъяпкычлар популяр була. Хатын-кызларда алъяпкыч ш.у. бәйрәм киеменең бер өлеше дә булып тора. 19 йөзнең уртасына кадәр хатын-кызлар һәм ирләрнең тышкы киеме буларак *камзул* (хатын-кызларныкы билле була) кулланыла. Бәйрәм камзуллары, аеруча яшь кызларныкы, төсле тукымалардан аппликация, тасмалар, көмеш укалы тасма һ.б. б-н бизәлә. Яшь кызларның гына түгел, яшь хатыннарның да җәйге киеме *киндер җилән* санала. Соңрак аны ш.у. фабрикада җитештерелгән тукымалардан да тегәләр. Бәйрәм җиләннәре, аеруча кәләшләр кия торганнары, бизәлә. Элекке заманда К.т.да халат рәвешендәге башка кием — *чыба* да гамәлдә булган. Ирләр арасында иң киң кулланылган өс киеме *кәзәки* исәпләнгән. Язын һәм көзен ирләр — туры арттакталы, хатын-кызлар — билле постау чикмәннән йөргәннәр; хатын-кызлар ш.у. билләп тегелгән кара постау армяк (чикмән) дә кигәннәр. *Бишмәт,* тун, кыска тун, толып ирләр һәм хатын-кызларның тышкы киемнәре саналган. Кызлар кия торган туннар төсле бизәкләр тегеп яки аппликация (аның киң кулланылуы б-н К.т. киеме мөселман татарларныкыннан аерылып тора) б-н купшыландырыла. Татар үрнәгендәге *чабаталар*, тула оек һәм бәйләнгән оеклар, итекләр (ш.и. чәрек башмак), *киез итекләр* аяк киемнәре булып хезмәт итә. Ирләрнең баш киеме, нигездә, башка татарларныкы кебек үк — сарык тиресеннән тегелгән кышкы бүрек, кайчак кырыйларына мех куеп тегелә; рус малахай бүрекләре дә киң кулланыла. Җәй көне кара һәм соры киез эшләпә кияләр. Соңрак шәһәрчә фуражкалар килеп керә. Мөселман татарлар кия торган баш киемнәре (түбәтәй, кәләпүш, бәрхет калфак, кәтәҗи) К.т.да кулланылмый. Кызлар, гадәттә, яланбаш йөри, бары бәйрәмнәрдә генә башлык рәвешендәге такыя яки маңгай бәйләвече һәм ука чәчәкле ак калфак кияләр. Хатын-кызлар сүрәкә (русларның «сороки» тибындагы баш киеме), кайбер төркемнәре тастар җыелмасы (к. *Тастар*) киеп йөри. Бизәмәләр бик күп төрле була — көмеш тәңкәләр, сәйлән, вак мәрҗәннәр һ.б.ны файдаланып ясалган зәркән эшләнмәләр (баш киемнәрендә, чулпыларда, алкаларда, муен асмаларында, беләзекләрдә һ.б.)

К.т.ның төп ризыклары — камыр һәм ярма әйберләр. Ит продуктларыннан сарык, бозау, сыер итенә өстенлек бирелә, ат һәм дуңгыз ите кайбер җирләрдә генә, тавык, каз, үрдәк ите исә һәркайда кулланыла. Мөселманнардан аермалы буларак, К.т. гөмбә һәм ш.у. хайван канын (кан тәбәсе) киң кулланалар. Сөт продуктларының төрлесе: сөт, каймак, май, *катык*, эремчек файдаланыла, кайбер районнарда сырның аерым төре — чыгыр эшләнә. К.т.ның төп эчемлеге — чәй, ш.у. *әйрән*, квас, сыра (туйларда мәҗбүри эчемлек), баллы эчемлекләр (ш.и. алкогольле), самогон (көмешкә).

К.т.ның көндәлек яшәү рәвешенә хас күп кенә үзенчәлекләр күптән юкка чыккан. Традицион кием-салым фәкать гаилә ядкәре буларак кына сакланып калган. К.т.ның көнкүреше хәзерге шәһәр мәдәниятенең көчле йогынтысына дучар була. Шуңа да карамастан, К.т. христианлыкның православие дине б-н бәйле этномәдәни үзенчәлекләрен саклап киләләр.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967. Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. М., 1977; Исхаков Д.М. Этнографические группы татар Волго-Уральского региона: Принципы выделения, формирование, расселение и демография. К., 1993; Татары. М., 2001.

*Д.М.Исхаков.*

**КЕРӘШЕ́Н ЯЛТАНЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 34 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1710–11 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Наратлы Елга елгасы буендагы Починок исеме б-н билгеле. 1860 ларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Я.нда Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1900 дә ачыла), 2 тегермән, тимерчелек, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 585 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 64 ир-ат; 1859 да — 296, 1897 дә — 517, 1908 дә — 617, 1920 дә — 678, 1938 дә — 397, 1949 да — 350, 1958 дә — 325, 1970 тә — 249, 1979 да — 177, 1989 да — 58, 2002 дә — 11 кеше.

**КЕРӘШЕННӘ́Р**, к. *Керәшен татарлар, Нагайбәкләр*.

**КЕ́РЕНСКИЙ** Владимир Александрович (13.12.1868, Сембер губ., Карсун өязе Троицкое-Куроедово а. — ?), тарихчы, илаһиятчы, илаһият гыйлеме д-ры (1903). Вакытлы хөкүмәт башлыгы А.Ф.Керенскийның туганнан туганы. Сембер руханилар семинариясен, Казан руханилар академиясен тәмамлый (1893). 1894 елда Сембер руханилар семинариясе укытучысы. 1895 тән Казан руханилар академиясендә, тарих һәм көнбатыш дини тәгълиматларын фаш итү каф. профессоры (1901–21). Рус православие чиркәвенең Поместный соборы делегаты (1917–18). 1921 дә законсыз дини эшчәнлек алып барганы өчен бер елга ирегеннән (шартлы рәвештә) мәхрүм ителә. Алга таба язмышы билгесез. Хезмәтләре католик, англикан, лютеран, иске католиклар, американ епископлык чиркәүләре тарихын һәм дини тәгълиматларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Старокатолицизм. К., 1894; Школа ричлианского богословия в лютеранстве. К., 1903; Американская епископальная церковь. К., 1908; С Запада: Очерки западно-церковной жизни. К., 1913.

*Е.В.Липаков.*

**КЕ́РЖНЕВ** Таһир Кәлүк улы (15.3.1922, хәзерге Пенза өлкәсе, Городище р-ны Түбән Әләзән а. — 28.1.1992, Мари Респ-касының Йошкар-Ола ш.), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. өлкән сержанты. Куяр (Мари АССР Медведев р-ны) урман хуҗалыгында урман кисүче булып эшли. 1942 елның февраленнән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 17 нче гв. механикалаштырылган бригадасының разведка ротасында отделение командиры (42 нче гв. танк армиясенең 6 нчы гв. механикалаштырылган корпусы). Көнбатыш, Брянск һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Орёл (1943), Проскурово–Черновцы, Львов–Сандомир (икесе дә — 1944), Сандомир–Силезия, Түбән Силезия, Югары Силезия, Берлин һәм Прага (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 25 гыйнварында Одер елгасын Кёбен (Хобеня, Польша) торак пункты янында кичеп, шул сугышта батырлык күрсәтә: разведчиклар төркеме б-н чик сызыгын басып алып, аны 6 сәгать буе кулда тота һәм дошманның берничә контрһөҗүмен кире кайтара. Сугыштан соң Йошкар-Ола шәһәрендә яши, Мари машина төзү з-дында слесарь булып эшли. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Йошкар-Ола шәһәрендә ул яшәгән йортка мемориаль такта элenә.



Т.К. Кержнев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Разведчики в боях за Родину. М., 1967; Герои и подвиги. Саратов, 1976. Кн. 3; Наши герои. Йошкар-Ола, 1985.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КЕРКӘЛЕ́** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2010 елда 854 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; «Керкәле карьеры» ҖЧҖ, катнаш азык з-ды, урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1748 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә мәчет, дүшәмбе саен базар була. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 су тегермәне, 2 ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4242 дис. тәшкил итә. 1911 дә земство мәктәбе ачыла, 1917 дә дүртенче мәчет төзелә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спиридоновка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 15 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1889 да — 1621, 1908 дә — 2256, 1920 дә — 2362, 1926 да — 1761, 1938 дә — 1407, 1949 да — 1335, 1958 дә — 1247, 1970 тә — 1254, 1979 да — 1042, 1989 да — 919, 2002 дә — 844 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**КЕРКӘЛЕ́** (Ибрай Каргалы) авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 18 *км* төньяктарак, Олы Кәминкә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 259 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, кошчылык. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет һәм мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 925 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат, 1859 да — 325, 1897 дә — 773, 1908 дә — 904, 1920 дә — 749, 1926 да — 454, 1949 да — 501, 1958 дә — 494, 1970 тә — 583, 1979 да — 439, 1989 да — 308, 2002 дә — 288 кеше.

**КЕРКӘЛЕ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 23 *км* көнбатыштарак, Ульянов — Уфа тимер юлы буенда. 2010 елда 40 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Ютазы р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 314, 1949 да — 257, 1958 дә — 151, 1970 тә — 101, 1979 да — 75, 1989 да — 61, 2002 дә — 41 кеше.

**КЕРКӘЛЕ́ КИСМӘТА́Ш ЧЫГАНАГЫ́**, Лениногорск р-нындагы Керкәле авылы янында. Запасы — 26,5 мең *м*³. 1959 елдан үзләштерелә. Пермь системасының Казан ярусы известьташларына туры килә. Известьташның 2 продуктив катламы ярусның түбәнге өлешендә: өске — калынлыгы 1,3–1,7 *м* һәм түбәнге (үзләштерелүче) — калынлыгы 2,4–12,3 *м*. Катламнар 0,7–5,6 *м* калынлыктагы комташ һәм мергель катлаулары б-н аерылган. Каплаучы токымнар 1,2–14 *м* калынлыкта. Оолит, органоген, урыны б-н кристаллик известьташлар; соры, аксыл сары, тыгыз; составында казылма организм һәм үсемлек скелетларының известьле калдыклары бар. Известьташларның җиңелчә ярыклы булуы һәм яту шартлары турыдан-туры забойда урнаштырылган таш кисү станоклары ярдәмендә кисмәташ әзерләргә мөмкинлек бирә. Известьташларның физик-механик үзлекләре ГОСТ 400–84 таләпләренә туры килә. Чыгару күләме 6 мең *м*³ (2003). Кисмә стена блоклары һәм бут ташы әзерләү өчен кулланыла.


*Әд.:* Геология твёрдых и полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕРКӘЛЕ́ ТУКМАГЫ́** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 34 *км* көнбатыштарак, Инеш елгасы буенда. 2010 елда 36 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Шөгер волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 412, 1938 дә — 397, 1949 да — 344, 1958 дә — 281, 1970 тә — 222, 1979 да — 133, 1989 да — 50, 2002 дә — 39 кеше.

**КЕРПЕБА́Ш** (Sparganium), керпебашчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, күбесенчә төньяк ярымшарның субарктик, уртача һәм субтропик поясларында таралган. ТР терр-ясендә 3 төре бар. Гади К. (S. simplex) һәм туры яки ботаклы К. (S. erectum) — бөтен респ-када, вак К. (S. minimum) — күбесенчә төньяк районнарда очрый. Елга, күлләрнең сазлыклы ярларында, күрәнле сазлыкларда үсә. 10–100 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы нәзек, шнурсыман. Сабагы туры, тармаклы. Яфраклары сусыл, тар кыяклы. Чәчәкләре вак, шарсыман башчаларда. Җимеше — төшчә, тишекле коры чәчәк тирәлеге б-н әйләндереп алынган. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре көзен өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Декоратив үсемлек. К.ның яшь сабаклары һәм тамырчалары нутрия, ондатра, кондыз һәм су кошлары өчен азык булып хезмәт итә.

**КЕРПЕЛӘ́Р** (Erinaceidae), бөҗәк ашаучылар отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 20 төрне үз эченә ала. Европада, Азиядә, Һиндстанның уртача киңлекләрендә, Африкада таралган. Гәүдәсенең озынлыгы 20–25 *см*, авырлыгы 700–800 *г*, аркасы 3 *см* тирәсе озынлыктагы энәләр б-н капланган, танавы һәм гәүдәсенең аскы өлеше (корсагы) каты тупас мехлы. К.дә бөҗрасыман тире асты мускуллары бар, алар кысылганда гәүдә шар кебек йомарлана. ТРда 3 төре: гади керпе (Erinaceus europaeus), актүшле керпе (E. concolor) һәм колаклы керпе (Hemiechinus auritus) очрый.

Гади керпе, башлыча, республиканың төньяк-көнбатыш районнарында очрый. Куаклар үскән яфраклы урманнарны өстен күрә, ш.у. агачлыкларда, урман буйларында һәм аланнарда, кисенделәрдә, куаклыкларда, кыр ышыклау урман полосаларында, бакчаларда яши. Эңгер-меңгер һәм төнге яшәү рәвеше алып бара. Бөҗәкләр, аларның личинкалары, сөйрәлүчеләр, җирдә оялаучы кошларның йомыркалары б-н туклана. Үсемлек азыклары (җимеш, җиләк һәм орлыклар) аның туклануында икенчел роль уйный. Октябрь–ноябрьдән апрель ахырына кадәр йокыда (өндә, агач тамырлары астында яки башка качу урыннарында) булалар. К. ялгыз кышлый. Уянып бернечә көннән соң кушылу чоры башлана. Балалары (3–6, кайвакыт 8 гә кадәр) җәй башында туа. Туганда керпе балалары сукыр, ялангач, 10–15 *г* авырлыкта була, әмма бернечә сәгатьтән соң йомшак ак энәләр барлыкка килә, 5–6 нчы көндә тулысынча энәле каты каплам формалаша, 16–18 нче көндә азыкны үзләре таба башлый, җәй уртасыннан мөстәкыйль. Иң куркыныч дошманы — байгыш, кайвакыт төлке корбаны була. Май коңгызлары яшәгән каенлык һәм наратлыкларда, ш.у. бакчаларда зарарлы бөҗәкләрне юк итеп шактый файда китерә.



Гади керпе.

Актүшле керпе яшәү рәвеше һәм тышкы кыяфәте буенча гади керпегә охшаш, фәкать корсагындагы йоны гына аксылрак (кайвакыт бөтенләй ак диярлек) төстә. Татарстанның һәр җирендә очрый.

Колаклы керпе Татарстан терр-ясендә сирәк төр, ареалының төньяк чиге биредә уза. Чүпрәле, Буа, Апас р-ннарының далаланган җирләрендә очрый. Гади керпедән озын колаклары, йомшак кыска йоны, башының аксылрак, корсагының ак төстә булуы б-н аерыла. Җитезрәк, көндезен дә актив. Бөҗәкләр, вак умырткалылар б-н туклана. Өннәрдә яши. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Аськеев И.В., Аськеев О.В., Беляев А.Н. Млекопитающие Республики Татарстан. К., 2002.

**КЕСМӘ́С** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 35 *км*, бассейнының мәйданы 311,9 *км*². Арча р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Пүчинкә-Поник посёлогыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Арча шәһәренең көнчыгышындарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 89 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.нең 0,7 дән алып 8,9 *км* га кадәр озынлыктагы 19 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 143 *мм*, ташу агымы катламы 102 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,45 *м*³/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми мине-



Кесмәс елгасы.

ральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елганың түбәнге агымында гомуми күләме 5 млн. *м*³ булган Арча балык үрчетү хуҗалыгы буалары төзелгән. Елга үзәненең сулъяк сөзәклегендә *Курса соры челән колониясе* табигать истәлеге урнашкан.

**КЕ́ССЕЛЬ** Александр Рахмиэлевич (20.11.1935, Одесса ш. — 23.6.2003, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1981), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, теоретик физика секторы мөдире (1975–83), магнит күренешләре физикасы бүлеге мөдире (1983–93), резонанслы күренешләр лаб-ясе мөдире (1993 тән). Хезмәтләре магнетизмның квант теориясенә, теоретик физика алымнарына карый. И.А.Сафин һ.б. б-н бергәләп пьезоэлектрик кристалларда электроакустик кайтаваз күренешен ача (1970). «Акустик төш резонансы» («Ядерный акустический резонанс», М., 1969) монографиясе авторы. Акустик дулкын кырында акустик спин кайтавазын һәм спиннарның квантлашуын алдан әйтә. Каты җисем теориясе мәсьәләләрен чишүнең төгәл алымнарын үстерә. Статик физикадагы спин темп-расы булу һәм статик сурәтләүне кыскарту турындагы фаразларны төгәл аналитик дәлилли. Нефть катламнарын фильтрлауның динамик модельләрен статик физиканың яңа казанышлары нигезендә үстерә. Квант механикасы парадоксларын өйрәнү өчен бер фотонның фотон кайтавазы эффектын, квантлы компьютер эшчәнлеге өчен яңа тирәлек тәкъдим итә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Медальләр, ш.и. СССР Космонавтика федерациясенең М.С.Рязанский исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Магнитный резонанс изинговских магнетиков. М., 1982 (автордаш); Кинетика перколяционной решётки как модель фильтрации нефтяного пласта // Докл. АН СССР. Матем. моделирование. 1991. Т. 321, № 3 (автордаш); Время — задержанная самоинтерференция фотонов // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1993. Т. 58, № 2 (автордаш); Вариационное вычисление NN-потенциалов в простой полевой модели // Ядерная физика. 1994. Т. 57, № 1 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**КЕСТӘРӘ́**, б е т у н и к а (Betonica), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Дөнья флорасында 30 га якын төре бар. ТР терр-ясендә бер төр — эре чәчәкле К. (ак шалфей) (B. peraucta). Урманда, урман буйларында үсә. 50–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, дүрт кырлы. Яфраклары саплы, йомыркасыман, төбендә йөрәксыман. Чәчәкләре аксыл-җете кызыл, башаксыман цилиндрик боҗракта урнашкан. Җимеше озынча 4 көрән чикләвекчектән тора. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Үзенчәлекле көчле исле. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Үләнендә һәм тамырларында эфир мае, дуплау матдәләре, органик к-талар, шикәр һ.б. бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе сулыш юллары ялкынсынуы, бавыр һәм ашказаны авырулары вакытында тынычландыру чарасы буларак кулланыла; кайбер үлән җыелмалары составына керә. Кипкән үсемлекнең порошогы кимерүчеләргә каршы кулланыла.

**КЕЧЕ́ АККО́Ш КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. *Аккош күлләре* системасына керә. Казан — Яшел Үзән автомобиль юлына якын, Казанның Киров р-ны терр-ясендәге «Аккош күлләре» урман паркында. Суының биеклеге сезонлап бик нык үзгәрә (мәс., 1991 нең көз аенда күл мәйданы 5 тапкыр кими, күләме язгы ташу б-н чагыштырганда 22 тапкыр кечерәя). Су иң аз вакыттагы өслек мәйданы 3 *га*, күләме 27 мең *м*³, озынлыгы 360 *м*, иң зур киңлеге 140 *м*, уртача тирәнлеге 1 *м* тирәсе, иң зур тирәнлеге 3,9 *м*. Күлнең барлыкка килүе



Кече Аккош күле.

эрозия — карст-суффозия күренеше б-н бәйле. Өчпочмак рәвешендә, катлаулы формада. Ярлары сөзән, наратлыклар б-н капланган. 1990 еллар ахырында күлне төзекләндерү эшләре башкарыла. Ял итү урыны.

**КЕЧЕ́ АКСУ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Яклы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 241 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең ахырында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.А.да мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 634 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда , 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 344, 1897 дә — 631, 1913 тә — 839, 1920 дә — 867, 1926 да — 940, 1938 дә — 791, 1949 да — 638, 1958 дә — 719, 1970 тә — 654, 1979 да — 586, 1989 да — 278, 2002 дә — 271 кеше.

**КЕЧЕ́ АКСУБА́Й** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 74 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Аксубай р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 217, 1949 да — 187, 1958 дә — 183, 1970 тә — 196, 1979 да — 110, 1989 да — 81, 2002 дә — 69 кеше.

**КЕЧЕ́ АКТА́Ш** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 15 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 29 кеше (чуашлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Яңа Әдәм волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 128, 1949 да — 125, 1958 дә — 147, 1970 тә — 149, 1979 да — 118, 1989 да — 51, 2002 дә — 42 кеше.

**КЕЧЕ́ АЛА́Т** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 32 *км* төньяктарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 54 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1602–03 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез басу, бау ишү, арба, мичкә ясау, кирпеч сугу, мич чыгару, тимерчелек, тегү, йон тетү, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.А.та земство мәктәбе, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1384,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир-ат; 1859 да — 545, 1897 дә — 713, 1920 дә — 798, 1926 да — 980, 1949 да — 781, 1958 дә — 475, 1970 тә — 287, 1989 да — 126, 2002 дә — 62 кеше.

**КЕЧЕ́ АЧАСЫ́Р** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Буа елгасы буенда. 2010 елда 70 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.А.да мәчет, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 504,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 341, 1897 дә — 573, 1908 дә — 749, 1920 дә — 751, 1926 да — 745, 1938 дә — 728, 1949 да — 440, 1958 дә — 274, 1970 тә — 290, 1979 да — 257, 1989 да — 147, 2002 дә — 113 кеше.

**КЕЧЕ́ ӘТНӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 55 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез-киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ә.дә вак-төякләр

кибете, 2 юлаучылар йорты була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 83,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 28, 1897 дә — 66, 1908 дә — 91, 1920 дә — 81, 1926 да — 85, 1938 дә — 86, 1949 да — 100, 1958 дә — 140, 1970 тә — 88, 1979 да — 59, 1989 да — 30, 2002 дә — 11 кеше.

**КЕЧЕ́ ӘТНӘ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 2 *км* көньяктарак, Әтнә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 256 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ә.дә мәчет, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 968 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 94 ир-ат; 1859 да — 572, 1897 дә — 1002, 1908 дә — 1164, 1920 дә — 1033, 1926 да — 858, 1938 дә — 974, 1949 да — 608, 1958 дә — 506, 1970 тә — 433, 1979 да — 412, 1989 да — 334, 2002 дә — 252 кеше.

**КЕЧЕ́ ӘТРӘ́Ч** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 19 *км* төньяктарак, Шоңгаты елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 252 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1647–51 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Починок Мертюбяков исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, җил тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1277,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифорово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 93 ир-ат; 1859 да — 711, 1897 дә — 1246, 1908 дә — 1510, 1920 дә — 1273, 1926 да — 753, 1938 дә — 851, 1949 да — 693, 1958 дә — 570, 1970 тә — 602, 1979 да — 484, 1989 да — 338, 2002 дә — 293 кеше.

**КЕЧЕ́ ӘШНӘ́К** авылы, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 280 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1617 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ә.тә мәчет, мәдрәсә, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1289,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 167 ир-ат; 1859 да — 1028, 1897 дә — 1133, 1908 дә — 1363, 1920 дә — 1234, 1926 да — 877, 1949 да — 743, 1958 дә — 742, 1970 тә — 694, 1989 да — 419, 2002 дә — 323 кеше.

**КЕЧЕ́ БАГРА́Ж** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 52 *км* көнбатыштарак, Баграж суы (Чишмә елгасының уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Баграш Курень Малый һәм Николаевский Курень Баграш исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тегермән, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 293,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 23, 1859 да — 54, 1870 тә — 69, 1913 тә — 160, 1926 да — 180, 1938 дә — 162, 1949 да — 195, 1958 дә — 115, 1970 тә — 70, 1979 да — 49, 1989 да — 13, 2002 дә — 6 кеше.

**КЕЧЕ́ БАКЫРЧЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 23 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 67 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 636 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 елда — 60 ир-ат; 1859 да — 242, 1897 дә — 444, 1908 дә — 556, 1920 дә — 491, 1926 да — 312, 1938 дә — 294, 1949 да — 122, 1958 дә — 183, 1970 тә — 160, 1979 да — 127, 1989 да — 81, 2002 дә — 93 кеше.

**КЕЧЕ́ БАХТА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Бахта елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,3 *км*, бассейнының мәйданы 96,6 $км^2$. Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яуширмә авылыннан 4 *км* көньяктарак, тамагы Үтәк (Өтәк) авылының төньяк чигендә. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 59 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 2%. К.Б.ның 0,6 дан алып 2,7 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,017 $м^3/с$. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада су күләме 0,73 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЕЧЕ́ БИСӘ́Р** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак. Бисәр елгасы буенда. 2010 елда 140 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.дә чиркәү-приход мәктәбе, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 558 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән — Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 170 ир-ат; 1859 да — 253, 1897 дә — 376, 1908 дә — 455, 1920 дә — 510, 1926 да — 418, 1938 дә — 478, 1949 да — 545, 1958 дә — 490, 1970 тә — 453, 1979 да — 356, 1989 да — 210, 2002 дә — 175 кеше.

**КЕЧЕ́ БИТАМА́Н** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 204 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Агач эшкәртү пр-тиесе бар. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.да мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 693,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшай (1919 дан — Краснококшай) өязе Сотнур волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 210, 1897 дә — 298, 1908 дә — 363, 1920 дә — 481,

1926 да — 436, 1938 дә — 539, 1949 да — 474, 1958 дә — 454, 1970 тә — 464, 1989 да — 217, 2002 дә — 226 кеше. К.Б.да язучы Р.*Корбан* туган.

**КЕЧЕ́ БОЕРГА́Н** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Чилчә елгасы буенда. 2010 елда 92 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Борындык волостенда. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 60, 1938 дә — 242, 1949 да — 246, 1958 дә — 105, 1970 тә — 285, 1979 да — 180, 1989 да — 117, 2002 дә — 101 кеше.

**КЕЧЕ́ БОЛГАЕ́Р** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 23 *км* көнчыгыштырак, Олы Шәһиян елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 310 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.да мәчет, 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 943 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифорово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 елда — 73 ир-ат; 1859 да — 447, 1897 дә — 790, 1908 дә — 1020, 1920 дә — 948, 1926 да — 732, 1938 дә — 727, 1949 да — 580, 1958 дә — 493, 1970 тә — 509, 1979 да — 472, 1989 да — 377, 2002 дә — 337 кеше.

**КЕЧЕ́ БОРТА́С** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 32 *км* төньяк-көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 96 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урманчылык, балта эше, агачтан төрле әйберләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.та мәчет (1875 тә төзелә), мәктәп, 5 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1072 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 елда — 103 ир-ат; 1859 да — 504, 1897 дә — 1060, 1908 дә — 1075, 1920 дә — 1040, 1926 да — 634, 1938 дә — 633, 1949 да — 422, 1958 дә — 373, 1970 тә — 246, 1979 да — 206, 1989 да — 153, 2002 дә — 99 кеше.

**КЕЧЕ́ БӨГЕЛМӘ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 7 *км* көнчыгыштарак, Зәй елгасы (Дала Зәенең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1788 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 79 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1730 елларда нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, таш вату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.дә чиркәү һәм земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3890 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 785, 1889 да — 1097, 1910 да — 1425, 1920 дә — 1442, 1926 да — 1439, 1938 дә — 1002, 1949 да — 788, 1958 дә — 627, 1970 тә — 1056, 1979 да — 931, 1989 да — 1062, 2002 дә — 1438 кеше.

**КЕЧЕ́ БӨРЕЛЕ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2010 елда 43 кеше (руслар) яши. 1840 та алпавыт И.В.Доленго-Грабовский нигез сала, шунда Бөреле авылы крәстияннәрен күчерә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ильинка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 169,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 145, 1897 дә — 120, 1908 дә — 140, 1920 дә — 154, 1938 дә — 187, 1949 да — 146, 1958 дә — 110, 1970 тә — 40, 1989 да — 29, 2002 дә — 28 кеше.

**КЕЧЕ́ БҮСЕРӘ́К**, к. *Яңа Бүсерәк*, Зәй р-ны.

**КЕЧЕ́ ДЕРБЫ́ШКИ** авылы, Казанның Совет р-ны составындагы бистә, Казан тимер юл станциясеннән 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 1565–67 еллардан Кузьмино Займище исеме б-н билгеле. Халкы башта Казан Богородица хатын-кызлар монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 407,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. 1998 нең 25 ноябреннән Казанның Совет р-ны составында. Халык саны: 1782 елда — 91 ир-ат; 1859 да — 308, 1897 дә — 305, 1908 дә — 316, 1920 дә — 341, 1926 да — 326, 1938 дә — 362, 1949 да — 450, 1958 дә — 421, 1970 тә — 534, 1989 да — 377 кеше.

**КЕЧЕ́ ЕЛГА́** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 25 *км* көнчыгыштарак, Шуран елгасы буенда. 2010 елда 780 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1648–50 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Е.да мәчет, тимерчелек, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2069 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 елда — 202 ир-ат; 1859 да — 838, 1897 дә — 1168, 1908 дә — 1427, 1920 дә — 1488, 1926 да — 1114, 1938 дә — 1011, 1949 да — 967, 1958 дә — 920, 1970 тә — 1150, 1979 да — 1083, 1989 да — 874, 2002 дә — 875 кеше.

**КЕЧЕ́ ЕЛГАЛА́Р**, озынлыгы 100 *км* дан кимрәк һәм су җыелу мәйданы 2 мең $км^2$ га кадәр булган тигезлек *елгалары*. Гадәттә, бер географик зона чикләрендә урнашалар. Елгаларны классларга бүлү критерийлары сыйфатында кайвакыт гидрологик режим күрсәткечләрен кулланалар: уртача күпьеллык су чыгымы, туклану режимы һ.б. Су агымының ел дәвамында даими яки җир асты су запаслары кимүе сәбәпле, К.е. кыска вакытка кибеп торалар.

Татарстанда, Идел, Кама, Вятка һәм Агыйдел елгаларыннан кала, чагыштырмача суы даими, ш.и. вакытлыча кибә торган кече агымлы сулар, озынлыкларына бәйсез рәвештә, К.е.га кертелә. 250 *км* дан озынрак 4 елга (Ык, Зөя, Олы Чирмешән, Кондырча) һәм 100–250 *км* озынлыктагы 16 елга (Иж, Дала Зәе, Чишмә, Сөн, Илләт, Мишә, Кече Чирмешән, Гөбенә, Минзәлә, Казансу, Туймә, Бола, Олы Сөлчә, Кичү, Кырыкмас, Шушма), уртача еллык су чыгымының чагыштырмача зур булмавы аркасында, К.е. категориясенә керә. Республикада якынча берничә йөз метрдан берничә йөз километрга кадәр озынлыктагы 4 мең К.е. исәпләнә. Күпчелек елгаларның озынлыгы 10 *км* дан кыскарак. Барлык К.е.ның гомуми озынлыгы 20 мең *км* га якын. Елга челтәренең тыгызлыгы уртача 0,25–0,35 *км/км²* тәшкил итә һәм 0,09–0,14 *км/км²* дан (Лаеш, Спас р-ннары) 0,4–0,45 *км/км²* га (Лениногорск, Аксубай, Зәй, Әгерҗе р-ннары) кадәр үзгәрә. Суның уртача еллык чыгымы 50 $м^3/с$ булган Зөя, Ык, 10–20 $м^3/с$ — Казансу, Мишә, Дала Зәе, Чишмә, Сөн, Иж, 1–10 $м^3/с$ — Бөрсет, Гөбенә, Дим, Минзәлә, Кичү һ.б. К.е.ның 50% тан артыгының су чыгымы 0,01 $м^3/с$ һәм, нигездә, зур елгаларның сулъяк ярлары буенда урнашканнар. Елгаларның күбесендә еллык агымның 80% ка якыны язгы ташу чорына туры килә. Җәйге һәм кышкы чорда елгалар күбесенчә җир асты су горизонтларыннан

туена. Әмма су иң аз вакытта күп кенә елгаларда су режимы тотрыклы түгел һәм шунлыктан алар нык кына саегалар. Казансу, Иж, Ашыт, Мишә, Гөбенә, Олы Сөлчә һәм кайбер башка елгаларга югары тотрыклы су режимы хас. К.е.да ташу башлануның уртача вакыты Идел алды төбәгендә март ахырында һәм ТР-ның калган терр-ясендә апрель башында. Ташуның иң көчле вакыты апрель уртасына туры килә; кайбер елларда, яңгыр ташкыннары б-н катлауланып, июнь ахырына кадәр дәвам итә. Аннан соң елгаларда су биеклеге акрынлап кими. Февраль ахырында, кагыйдә буларак, иң түбән су биеклеге урнаша. Бу чорда К.е.ның шактый өлеше суның минеральләшүе югары (500–1000 *мг/л*) булу б-н характерлана.

Су б-н тәэмин итү чыганагы буларак, К.е. халык хуҗалыгы өчен зур әһәмияткә ия. Элек-электән аларда буалар, су тегермәннәре төзелгән. 1930 еллар ахырыннан, аеруча 1950 елларда, нигездә, колхоз һәм совхоз ихтыяҗлары өчен егәрлеге зур булмаган гидроэлектростанцияләр төзелә. 1960 еллар башында Зөя елгасында Дәвеш (Апас р-ны), Кыят (Буа р-ны) гидроэлектростанцияләре эшли. 1960 еллар ахыры — 1970 еллар башында К.е. бассейнында буалар һәм ирригация системалары күпләп төзелә башлый. Ул елларда сугарыла торган җирләрнең гомуми мәйданы 230 мең *га* тәшкил итә. Татарстанда күп кенә кече елга тугайларындагы болыннар печәнлек һәм көтүлек җирләре буларак файдаланыла.


Гомумән алганда, елгалар системасы торышында К.е.ның халәте чагыла, чөнки алар зур елгаларны туендырып тора. Антропоген тәэсирләрнең көчәюе К.е.ның саегуына, пычрануына, кайбер вакытларда бетүенә китерә. Су саклау зоналарында җир өсте сулары агышының шактый артуына китерүче (тиңдәшле рәвештә елгаларны туендыручы җир асты сулары агышы кими) һәм туфрак эрозиясен барлыкка китерүче җир сөрү эшләре (тиңдәшле рәвештә каты агымнарның елга юлына керүе) аеруча куркыныч. К.е.да су торышы аның ярларында хуҗалык эшчәнлеге алып баруның санитар-экологик нормаларын үтәве б-н бәйле. К.е.ның су ресурсларын нәтиҗәле файдалану сәнәгать суларының, терлек фермалары агынтыларының, кырлардан юылган ашламаларның һ.б.ның тискәре йогынтысын бетерүне таләп итә. К.е.ның деградация процессын акрынайту, аларда су күләменең кимүен бетерү, фәкать, комплекслы дәүләт чаралары үткәргәндә генә мөмкин. 30 К.е. (ш.и. Ык, Дим, Кече Чирмешән, Чишмә, Дала Зәе, Зөя, Үләмә, Сөлчә, Казансу, Мишә) — ТРның табигать истәлеге (1978).

*Әд.:* Причины и механизмы пересыхания малых рек. К., 1996; Длины малых рек Республики Татарстан: Справ. К., 2003.

*О.Н.Урбанова, Ф.Г.Борһанов.*

**КЕЧЕ́ ЗӘҢГӘ́Р КҮЛЛӘ́Р**, Биектау р-ның Щербаково авылыннан төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасының (Казанның төньяк-көнчыгыш чигендә) уңъяк ярында зур булмаган ике карст күле. Көнчыгыштагы күл өслегенең мәйданы 0,17 *га*, күләме 2,4 мең $м^3$, озынлыгы 150 *м*, иң зур киңлеге 20 *м*, уртача тирәнлеге 1,4 *м*. Күлнең көнбатыш һәм көнчыгыш өлешендә 4 *м* тирәнлектә ике бүрәнкә аерылып тора, аларның төбендә җир асты сулары чыгу юллары бар. Күлнең ике ягыннан Казансу елгасы ягына таба ермаклар китә һәм агым барлыкка килә. Күлнең калку ярында чишмәләр бар. Суның төсе зәңгәрсу-яшелдән алып ачык зәңгәргә кадәр. Күлнең су алмашу коэф. тәүлегенә 2,4 мең $м^3$.

Көнбатыштагы күл тар сай сулыктан тора, су өслегенең мәйданы 0,23 *га*, күләме 2,8 мең $м^3$, озынлыгы 170 *м*, иң зур киңлеге 20 *м*, уртача тирәнлеге 1,2 *м*. Көнбатыш ягында 2 *м*, 3,3 *м*, 3,5 *м* тирәнлекләрендә өч бүрәнкә бар. Суның төсе зәңгәрсу-яшел. Күлнең көнбатыш өлешеннән ермаклар аерыла, һәм су агымы Казансуга кушыла. Су алмашу коэф. тәүлегенә 0,94 мең $м^3$. К.З.к.дә су темп-расы ел дәвамында 6-8 °С тәшкил итә. Күлләр туңмый. 1990 еллар уртасында Казансудан күлне аерып торучы дамбаны ныгыту буенча чаралар үткәрелә һәм сулыкларның ярлары төзекләндерелә. Күл төбеннән алынган грунт дәвалану максатларында кулланыла. Ял итү урыны. К.З.к. *Тирән күл* табигать тыюлыгы составына керә (1994).



Кече Зәңгәр күл.

*Әд.:* Уникальные экосистемы солоноватоводных карстовых озёр Среднего Поволжья. К., 2001.

**КЕЧЕ́ ЗИРЕКЛЕ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Инеш елгасы (Зәйнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 133 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, К.З.дә су тегермәне була, 1893 тән миссионерлык мәктәбе эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1340 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1858 елда — 324, 1870 тә — 395, 1912 дә — 909, 1920 дә — 972, 1926 да — 548, 1938 дә — 483, 1949 да — 448, 1958 дә — 421, 1970 тә — 483, 1979 да — 339, 1989 да — 187, 2002 дә — 172 кеше.

**КЕЧЕ́ ИРНӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Урман Зәе елгасының (Дала Зәе елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 21,3 *км*, бассейнының мәйданы 206 $км^2$. Елга башы Әлмәт р-нының Салкын Алан авылы янында, тамагы Зәй р-нындагы Ирнә авылының көнбатыш чигендә. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 92 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. К.И.нең 1 дән алып 14,5 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар, иң зурысы — Сарман елгасы (уң). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,076 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. К.И. бассейнында гомуми күләме 1,1 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Елга бассейнында *«Бохарай наратлыгы»* табигать истәлеге урнашкан.

**КЕЧЕ́ ЙОРТ** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 1565–67 еллардан мәгълүм. Халкы башта монастырь крәстияннәре катлавына керә, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Й.та 4 тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 406 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 елда — 87 ир-ат; 1859 да — 476, 1897 дә — 503, 1908 дә — 347, 1920 дә — 280, 1926 да — 302, 1938 дә — 281, 1949 да — 246, 1958 дә — 100, 1970 тә — 27, 1979 да — 16, 1989 да — 4 кеше.

**КЕЧЕ́ КАБА́Н** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 481 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 73 %, татарлар — 24 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары* (1552–56) чорында авылда яшәүчеләр калмый, бу җирләр Казан Спас-Преображение монастырена бирелә. 17 йөз ахырында Олы Кабан авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кычей Кабан исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында

К.К.да чиркәү-приход мәктәбе, 6 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1624,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 132 ир-ат; 1859 да — 460, 1897 дә — 769, 1908 дә — 767, 1920 дә — 872, 1926 да — 940, 1938 дә — 676, 1949 да — 741, 1958 дә — 870, 1970 тә — 755, 1979 да — 360, 1989 да — 825, 2002 дә — 454 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**КЕЧЕ́ КАВА́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Солонка елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 30 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1617 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, он тарту, башмак һәм киемнәр тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.да мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 378 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 318, 1897 дә — 284, 1908 дә — 370, 1920 дә — 298, 1926 да — 299, 1938 дә — 193, 1949 да — 123, 1958 дә — 126, 1970 тә — 137, 1989 да — 62, 2002 дә — 42 кеше. К.К.да дин һәм җәмәгать эшлеклесе *Г.Баруди* туган.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕЧЕ́ КАДРӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 36 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасы бассейнында. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. 1840 елларда нигез салына. 1917 гә кадәрге стат. чыганакларда К.К.нең халкы, җире, сәүдә-сәнәгать һ.б. оешмалары турындагы мәгълүматлар Кадрәк (к. *Зур Кадрәк*) авылын кертеп исәпләнә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1920 дә — 339, 1926 да — 405, 1938 дә — 320, 1949 да — 70, 1958 дә — 68, 1970 тә — 23, 1979 да — 88, 1989 да — 25, 2002 дә — 13 кеше.

**КЕЧЕ́ КАЙБЫ́Ч** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 4 *км* көньяктарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 441 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер игү. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.та мәчет, мәдрәсә, 2 су һәм 1 җил тегермәне, 1 тукымалар һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1094 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 594, 1897 дә — 1052, 1908 дә — 1273, 1920 дә — 1101, 1926 да — 980, 1938 дә — 1127, 1949 да — 814, 1958 дә — 711, 1970 тә — 766, 1979 да — 673, 1989 да — 543, 2002 дә — 501 кеше.

**КЕЧЕ́ КАМЫШЛЫ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 8 *км* төньяктарак, Чистай–Нурлат автомобиль юлы буенда. 2010 елда 218 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1794 тән мәгълүм. Чияле Алан авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Камышлы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.да җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 916 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 227, 1897 дә — 336, 1908 дә — 395, 1920 дә — 483, 1926 да — 437, 1938 дә — 416, 1949 да — 419, 1958 дә — 374, 1970 тә — 480, 1979 да — 402, 1989 да — 220, 2002 дә — 231 кеше.

**КЕЧЕ́ КАРАГУҖА́** (Кече Карауҗа) авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 45 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1653 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү, мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 181 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 22 ир-ат; 1859 да — 126, 1897 дә — 174, 1908 дә — 196, 1920 дә — 137, 1926 да — 159, 1938 дә — 156, 1958 дә — 100, 1970 тә — 73, 1979 да — 67, 1989 да — 50, 2002 дә — 48 кеше.

**КЕЧЕ́ КАРАМАЛЫ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 7 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы бассейнында. 2010 елда 163 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөздә Олы Карамалы авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Карманов исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1869 да төзелә), мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 482,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 200, 1897 дә — 553, 1908 дә — 638, 1920 дә — 745, 1926 да — 567, 1938 дә — 623, 1949 да — 567, 1958 дә — 438, 1970 тә — 401, 1979 да — 326, 1989 да — 246, 2002 дә — 210 кеше.

**КЕЧЕ́ КАРИЛЕ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 28 *км* көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 16 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә мәчет, мәктәп, рус-татар мәктәбе, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 470 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 333, 1897 дә — 608, 1908 дә — 698, 1920 дә — 602, 1926 да — 475, 1938 дә — 686, 1949 да — 405, 1958 дә — 339, 1970 тә — 373, 1979 да — 283, 1989 да — 144, 2002 дә — 105 кеше.

**КЕЧЕ́ КИБӘХУҖА́** (Түбән Авыл) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 7 *км* төньяктарак, Макса елгасы буенда. 2010 елда 61 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны:

1859 да — 167, 1897 дә — 277, 1908 дә — 330, 1920 дә — 301, 1926 да — 178, 1938 дә — 232, 1949 да — 191, 1958 дә — 147, 1970 тә — 119, 1979 да — 76, 1989 да — 63, 2002 дә — 71 кеше.

**КЕЧЕ́ КИБӘЧЕ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 33 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нысы елгасы буенда. 2010 елда 204 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 546,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 124, 1897 дә — 243, 1908 дә — 295, 1920 дә — 353, 1926 да — 316, 1938 дә — 383, 1949 да — 315, 1970 тә — 386, 1979 да — 367, 1989 да — 289, 2002 дә — 214 кеше.

**КЕЧЕ́ КИЗӘ́Й**, күл, Көнчыгыш Кама аръягында. Азнакай р-нының Чәкән авылыннан 7,3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 2,16 *га*. Күләме 24,3 мең *м*³. Озынлыгы 370 *м*, иң зур киңлеге 100 *м*. Уртача тирәнлеге 1,13 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча. Явым-төшем һәм грунт сулары б-н туена. Суы уртача каты (5,4 *мг-экв/л*), гидрокарбонат-хлорлы-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 179,1 *мг/л*. Үтә күренмәлелеге 55 *см*. Күл суы хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**КЕЧЕ́ КИРМӘ́Н** (Кирмәнбаш) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 25 *км* көнбатыштарак, Омар елгасы бассейнында. 2010 елда 439 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, агач әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә волость идарәсе урнаша, 3 мәчет, мәдрәсә, 3 тимерчелек, тегермән, йон-тукыма ману остаханәсе, кирпеч сугу бинасы, 12 вак-төякләр кибете була; якшәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2455 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 127 ир-ат; 1859 да — 1139, 1897 дә — 2219, 1908 дә — 2574, 1920 дә — 2195, 1926 да — 2086, 1938 дә — 1237, 1949 да — 963, 1958 дә — 821, 1970 тә — 912, 1979 да — 734, 1989 да — 553, 2002 дә — 480 кеше.

**КЕЧЕ́ КЛЫКИ́** авылы, Казан шәһәренең Совет р-ны составында, Казан тимер юл станциясеннән 9 *км* көнчыгыштарак, Нокса елгасы буенда. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1550 еллардан Казан Спас-Преображение монастыреныкы булып исәпләнә. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, яшелчә үстерү һәм умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.да 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 895,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Воскресенский волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау, 1998 нең 27 ноябреннән Казанның Совет р-ны составында. Халык саны: 1646 да — 114, 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 268, 1897 дә — 388, 1908 дә — 443, 1920 дә — 595, 1926 да — 656, 1949 да — 678, 1958 да — 732, 1970 тә — 949, 1989 да — 778 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕЧЕ́ КЛЮЧИ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 21 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1870 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 376, 1926 да — 419, 1938 дә — 366, 1949 да 304, 1958 дә — 202, 1970 тә — 133, 1979 да — 51, 1989 да — 31, 2002 дә — 23 кеше.

**КЕЧЕ́ КОЛАҢГЫ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 17 *км* көнчыгыштарак, Колаңгы елгасы буенда. 2010 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1651–54 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 296 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 104, 1897 дә — 245, 1908 дә — 306, 1920 дә — 305, 1926 да — 282, 1938 дә — 221, 1949 да — 139, 1958 дә — 211, 1970 тә — 105, 1979 да — 74, 1989 да — 63, 2002 дә — 44 кеше.

**КЕЧЕ́ КУЯ́Н КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-нының Столбище авылыннан көньяктарак, Идел елгасының биек террасасында. Су өслегенең мәйданы 3,84 *га*. Күләме 96 мең *м*³. Озынлыгы 530 *м*, иң зур киңлеге 120 *м*. Уртача тирәнлеге 2,5 *м*, иң зур тирәнлеге 7,5 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Озынча түгәрәк рәвешендә. К.К.К. элек *Куян күленең* бер өлеше була. Казан–Атабай автомобиль юлы төзелеше вакытында аннан дамба б-н бүленә һәм үзе бер аерым сулыкка әверелә. Суы йомшак (3 *мг-экв/л*), җиңелчә минеральләшкән (100 *мг/л* га кадәр), үтә күренмәле, гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Ял итү урыны.



Кече Куян күле.

**КЕЧЕ́ КУККУ́З** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 267 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә мәчет, су тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 905 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 79 ир-ат; 1859 да — 259, 1897 дә — 586, 1908 дә — 699, 1920 дә — 752, 1926 да — 561, 1938 дә — 567, 1949 да — 495, 1958 дә — 556, 1970 тә — 525, 1979 да — 466, 1989 да — 327, 2002 дә — 321 кеше.

**КЕЧЕ́ КҮЛБА́Й-МОРАСА́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 58 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мораса елгасы буенда. 2010 елда 60 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Мураса исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тимерче алачыгы, шәраб һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 116 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир-ат; 1859 да — 304, 1897 дә — 376, 1908 дә — 584, 1920 дә — 522, 1926 да — 399, 1938 дә — 347, 1949 да — 192, 1958 дә — 168, 1970 тә — 159, 1979 да — 145, 1989 да — 93, 2002 дә — 89 кеше.

**КЕЧЕ́ КҮЛГӘ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Суша елгасы бассейнында. 2010 елда 39 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 226 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 елда — 166, 1897 дә — 262, 1908 дә — 298, 1920 дә — 217 (Ивановка авылын да кертеп), 1926 да — 235, 1938 дә — 257, 1949 да — 149, 1958 дә — 141, 1970 тә — 134, 1989 да — 81, 2002 дә — 51 кеше.

**КЕЧЕ́ КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы буенда. 2010 елда 210 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.да фельдшерлык пункты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 297 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кызылъяр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 елда — 35 ир-ат; 1859 да — 465, 1897 дә — 611, 1908 дә — 653, 1920 дә — 683, 1926 да — 644, 1938 дә — 415, 1949 да — 247, 1958 дә — 246, 1970 тә — 235, 1979 да — 197, 1989 да — 173, 2002 дә — 267 кеше.

**КЕЧЕ́ ЛЫЗИ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 4 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 409 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, удмуртлар — 60 %, руслар — 23 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, урманчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710–11 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сергеевка исеме б-н дә билгеле. Башлыча, Алан Биксер һәм Топкино авылларыннан күчеп килгән руслар К.Л.да 18 йөз ахырында күренә башлый. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, юлаучылар йортлары тота. 20 йөз башында анда волость идарәсе урнаша; чиркәү (1878 дә төзелә), земство мәктәбе (1872 дә ачыла), 7 тимерче алачыгы, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2573 дис. (Югары Ушма, Урта Ушма, Түбән Ушма а.ларын кертеп) тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 елда — 235 ир-ат; 1859 да — 520, 1897 дә — 291, 1908 дә — 318, 1920 дә — 339, 1926 да — 363, 1938 дә — 380, 1949 да — 242, 1958 дә — 224, 1970 тә — 271, 1979 да — 286, 1989 да — 326, 2002 дә — 397 кеше.

**КЕЧЕ́ МАНАРА́**, *Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгындагы* Алтын Урда дәвере болгар дини архит-ра ядкәре, Болгар шәһәрлеге терр-ясендәге Җамигъ мәчет үзәк комплексыннан көньякка таба 500 *м* ераклыкта урнашкан. 14 йөзнең 1 нче яртысында, риваятьләр буенча, «изге болгарлар» җирләнгән урында төзелгән. Чатырыннан башка — 12, конуссыман чатыры б-н — 16 *м* биеклектә. Төрбәләр б-н әйләндереп алынган һәм мәчеткә тоташкан була. «Кече манара» атамасы б-н 18 йөздә йөртелә башлый. Җамигъ мәчетнең Олы манарасыннан аермалы буларак, ул ике төрле биеклектәге цилиндрлар һәм кубсыман нигезле таш манараны тәшкил итә. Куб кисек почмаклар — тромплар аша кыска сигезкырлыкка, ә ул, үз чиратында, пальметталар б-н бизәлгән тромплар аша манараның кечерәк диаметрлы һәм өскә таба тарая барган цилиндрик кәүсәсенә барып тоташа. Манара чатыры астында азан әйтү өчен парапеты аркатура б-н бизәлгән түгәрәк балкон урнаштырылган. Манара эчендәге 45 басмалы бормалы баскыч балкондагы а́ркалы ишеккә алып менә, манара ишеге аның төньягында урнашкан. А́ркалы ишек уеп бизәкләнгән «үрмә бау» б-н каймаланган. Түбән ярусның көнбатышка караган ягында ишек б-н бер биеклектә яссы, уксыман уемга батырылган, киль рәвешендәге куышы бар. Уемның кечерәге элек — тәрәзә, ә зуррагы ташка уеп бизәк төшерү техникасында эшләнгән үсемлек һәм геометрик орнаментлар б-н бизәлгән кайма булган дип фаразлана. Ишек һәм куышларны каймалаган бизәкләрнең аерым өлешләре генә сакланган. Манарага зур булмаган, йөзлексез, уксыман тәрәзәләр уелган. Тышкы яктан пөхтә итеп шомартылган туф һәм известьташ блоклар б-н тышланган, эчтән бераз штукатурланган. 1968–71 елларда реставрацияләнә.

*Әд.:* Айдаров С.С., Аксенова Н.Д. Великий Булгар. К., 1978.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КЕЧЕ́ МӘМИ́** (Күлбаш) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 23 *км* көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 2,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 380 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.М.дә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1883 тә ачыла), 2 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 858 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 25 ир-ат; 1859 да — 279, 1897 дә — 575, 1908 дә — 714, 1920 дә — 805, 1926 да — 713, 1938 дә — 745, 1949 да — 728, 1958 дә — 542, 1970 тә — 516, 1979 да — 578, 1989 да — 388, 2002 дә — 410 кеше.

**КЕЧЕ́ МӘРӘТХУҖА́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 185 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.М.да мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 808 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 321, 1897 дә — 630, 1908 дә — 783, 1920 дә — 876, 1926 да — 604, 1938 дә — 875, 1949 да — 663, 1958 дә — 490, 1970 тә — 444, 1979 да — 317, 1989 да — 257, 2002 дә — 226 кеше.

**КЕЧЕ́ МИРӘТӘ́К** (Бичер) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 25 *км* көньяктарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 133 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән Мирәтәк Пүчинкәсе исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү һәм мунчала ясау, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.М.тә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1874 тә ачыла), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 299,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 17 ир-ат; 1859 да — 174, 1897 дә — 247, 1908 дә — 351, 1920 дә — 326, 1926 да — 288, 1938 дә — 286, 1949 да — 563, 1958 дә — 238, 1970 тә — 244, 1979 да — 210, 1989 да — 167, 2002 дә — 155 кеше.

**КЕЧЕ́ МИШӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 44,5 *км*, бассейнының мәйданы 728 *км²*. Саба р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Кырбаш авылыннан 1,5 *км* төньяктарак, тамагы Теләче авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы —



Кече Мишә елгасының түбән агымы.

80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 22%. К.М.нең 27 кушылдыгы бар; иң зурлары: Мишә (31,5 *км*) — сул; Макса (24,1 *км*) — уң. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 $км/км^2$. Туенуы катнаш, зур күпчелеге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 126 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,47 $м^3/с$. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К.М. бассейнында суның гомуми күләме 6,8 млн. $м^3$ булган 15 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЕЧЕ́ МӨХӘММӘ́Д** (Мөхәммәд хан) (1395–1450 еллар тирәсе), Алтын Урда ханы (1437 дән). Тимер ханның улы. Фаразлар буенча, 1419 елга кадәр Идегәй әмир сараенда тәрбияләнә. 1420 елларда Барак ханга хезмәт итә, аның Мавәраәннәһергә хәрби яуларында катнаша. 1436 дан Олуг Мөхәммәд ханга каршы көрәш башлый, Идегәйнең улы бәкләр бәге Нәүрүз б-н бергәләп аны Рус дәүләте чикләренә (Биләү шәһәре тирәсенә) куа. Алтын Урданың көнбатышында ныгып алган Сәед Әхмәд б-н үзара сугышлардан соң, К.М. Дон һәм Идел буйларын басып ала. 1440 та аның хакимияте шактый ныгый. 1442–43 тә Руська яу б-н бара. Алтын Урданы берләштерүгә омтыла.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; З и м и н А.А. Витязь на распутье. М., 1961.

*И.Л.Измайлов.*

**КЕЧЕ́ МУКЛЕ́ КҮЛ**, Көнчыгыш Кама арьягында. Азнакай р-нының Чәкән авылыннан 1,3 *км* көньяктарак. Су өслегенең мәйданы 0,36 *га*. Күләме 2,88 мең $м^3$. Озынлыгы 180 *м*, иң зур киңлеге 35 *м*. Уртача тирәнлеге 0,8 *м*, иң зур тирәнлеге 1,21 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча. Суы йомшак (2,2 *мг-экв/л*), гидрокарбонат-хлорлы-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 189,1 *мг/л*. Үтә күренмәлеге 47 *см*. Яр буе зоналары сазлы. Күл акрынлап сазлана бара.

**КЕЧЕ́ НУГА́Й УРДАСЫ́** (Казый олысы, Кече нугайлар), 16 йөзнең 2 нче яртысында Нугай Урдасыннан Иделнең уңъяк ярына һәм Азов диңгезе буйларына күчеп утырган *нугайларның* дәүләти берәмлеге. Нигез салучысы — *Казый бәк* (?–1577). Кабарда б-н Дон елгалары арасындагы далаларда күчмә тормыш алып баралар. 18 йөз уртасына кадәр Кырым ханлыгы б-н Төркиягә бәйле булалар. Күп тапкырлар кырымлыларның рус җирләренә яуларында, адыгыйлар б-н кабарда бәкләренең үзара сугышларына катнашалар. 17 йөзнең 1 нче чирегендә К.Н.У. ярым мөстәкыйль дүрт олыска — Касай, Мамай, Урак, Шәйдәк олысларына бүленә. 1634 елда калмыклар *Олы Нугай Урдасын* җиңгәч, Олы һәм Кече Нугай Урдалары берләшә. Идел б-н Дунай елгалары арасындагы киңлекләрдә берничә урда (Буджак, Едисан, Едишкүл, Җамбайлүк, Кубан һ.б.) күченеп йөри. 18 йөзнең 2 нче яртысында Кырым ханлыгы һәм Төркия көчсезләнеп, Россия Кара диңгез буйларында ныгыганнан соң, Едисан һәм Буджак урдалары Россиягә буйсына, башка урдалар 19 йөз башында Төркия җирләренә күченә.

*Әд.:* Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002.

**КЕЧЕ́ НЫРСЫ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 22 *км* көньяктарак, Нырсы елгасы бассейнында. 2010 елда 151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1710 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тау Иле исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 495,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 316, 1897 дә — 418, 1908 дә — 438, 1920 дә — 468, 1926 да — 388, 1938 дә — 438, 1949 да — 247, 1958 дә — 329, 1970 тә — 284, 1979 да — 255, 1989 да — 184, 2002 дә — 160 кеше.

**КЕЧЕ́ ӨТӘ́К** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 39 *км* көньяктарак, Зөя елгасыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 68 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1647–52 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кече Утяково исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1887 дә төзелә), мәдрәсә, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 433 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 190, 1897 дә — 280, 1908 дә — 344, 1920 дә — 292, 1926 да — 203, 1938 дә — 381, 1949 да — 196, 1958 дә — 140, 1970 тә — 148, 1979 да — 110, 1989 да — 53, 2002 дә — 44 кеше.


**КЕЧЕ́ ПӘЛЧЕКӘ́Ү** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Имәнле елгасы Зәй елгасына койган төбәктә. 2010 елда 19 кеше (руслар) яши. 19 йөз башында Пәлчекәү авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский Пучинкәсе, Пәлчекәү Пучинкәсе исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч ясау һәм вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 503 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Токмак волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 февраленнән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 261, 1913 тә — 264, 1920 дә — 299, 1926 да — 193, 1949 да — 201, 1958 дә — 130, 1970 тә — 63, 1979 да — 33, 1989 да — 16, 2002 дә — 11 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КЕЧЕ́ ПЛАНЕ́ТАЛАР** (астероидлар), Кояш системасында диаметрлары 1 *км* дан 1000 *км* га кадәр булган күк җисемнәре. Барлык К.п.ның суммар массасы Җир массасының 1/700 өлешенә тигез. Күпчелек К.п.ның орбиталары Марс һәм Юпитер орбиталары арасында (астероидлар поясы дип йөртелә) урнашкан. К.п. исем һәм номер б-н билгеләнәләр: Волга (№ 1149), Дубяго (№ 1167), Изергин (№ 1271), Казан (№ 1316), Кама (№ 1387), Лобачевский (№ 1858), Мартынов (№ 2376), Дибай (№ 2389), Татария (№ 2668), Крат (№ 3036), Җәлил (№ 3082), Сөембикә (№ 27849). Иң билгеле К.п.: Церера (№ 1), Паллада (№ 2), Юнона (№ 3), Веста (№ 4).

*Р.Г.Усманов.*

**КЕЧЕ́ ПОДБЕРЕ́ЗЬЕ** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 25 *км* көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 140 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Успение-Богородица чиркәве



Кече Подберезье авылы.
Успение-Богородица чиркәве. 1902–10.

(1902–10 елларда төзелә; архит-ра истәлеге). 19 йөз башында Олы Подберезье авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Пүчинкә, Лямочкино исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, башлангыч белем мәктәбе (1886 да ачыла), җил һәм су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1026 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 324, 1897 дә — 532, 1908 дә — 729, 1920 дә — 696 (Озерки посёлогын да кертеп), 1926 да — 615, 1938 дә — 499, 1949 да — 391, 1958 дә — 328, 1970 тә — 358, 1979 да — 274, 1989 да — 205, 2002 дә — 186 кеше.

**КЕЧЕ́ ПОЛЯ́НКА** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 24 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Полянки, Кече Чытырчы исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 386,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 79, 1897 дә — 209, 1908 дә — 243, 1920 дә — 264, 1926 да — 222, 1949 да — 161, 1958 дә — 157, 1970 тә — 114, 1979 да — 83, 1989 да — 47, 2002 дә — 27 кеше.

**КЕЧЕ́ ПРЕДПРИЯ́ТИЕЛӘР**, сәнәгатьтә, төзелештә һәм транспортта эшләүчеләр саны 100 кешегә кадәр, а. х.да һәм фәнни-техник даирәләрдә — 60 ка, күпләп сату сәүдәсендә, башка тармакларда һәм эшчәнлекнең бүтән төрләрендә 50 гә кадәр кеше эшли торган пр-тиеләр. «Россия Федерациясендә кече эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме» турындагы закон нигезендә кече эшмәкәрлек субъектларына коммерция оешмалары — устав капиталларында РФ һәм аның субъектларының дәүләт милке, муниципаль, иҗтимагый һәм дини оешмалар һ.б. милке 25% тан артмаган юридик затлар керә. Юридик зат булып теркәлмичә эшмәкәрлек эшчәнлеге б-н шөгыльләнүче физик затлар, ш.и. уртак хезмәт эшчәнлеге алып баручы гаилә әгъзалары һ.б. затлар да К.п. субъекты булып санала. Бернигә төрле эшчәнлек алып барган күппрофильле пр-тиеләр продукция (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр) сатудан суммар керемнең зуррак өлешен тәшкил итүче эшчәнлек төре буенча К.п. булып тора.

К.п. өчен алда күрсәтелгән Закон нигезендә өстенлекләр каралган (эшмәкәрлек б-н шөгыльләнүнең башлангыч чорында салымнан азат ителәләр, аларга карата бер генә төр — керемгә кертелгән салым гына кулланыла).

2003–09 да кече предприятиеләр эшчәнлегенең төп күрсәткечләре

| Күрсәткечләр | 2003 | 2005 | 2009 |
|---|---|---|---|
| Кече предприятиеләрнең саны, мең | 16,9 | 18,6 | 44,6 |
| Эшләүчеләрнең уртача саны, мең кеше | 89,8 | 146,5 | 1287,2 |
| Кече предприятиеләрдә акча әйләнеше, млн. сум | 26175,5 | 146330,4 | 357821,8 |

К.п.нең күбесе сәүдә һәм җәмәгать туклануы тармакларында. Сәүдә системасындагы шәхси эшмәкәрләрнең 3/4 енә барлык К.п.нең базар сәүдәсендәге 71% һәм күпләп сату сәүдәсендәге 41% акча әйләнеше туры килә (2006).

**КЕЧЕ́ ПУРГА́ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньягында урнашкан. Мәйданы — 1223,2 *км*². Үзәге — Кече Пурга авылы (Ижевскидан 37 *км* көньяктарак). Халкы — 30979 кеше (2010); 749 татар (2007). Алар, башлыча, Әбделмән, Кече Пурга авылларында, Яган һәм Пугачёво посёлокларында яши. К.П.р. терр-ясендәге иң борынгы татар авылы — Әбделмән, аны 1875 тә Ижевск Заводы посёлогыннан күчеп килүчеләр нигезли. Халкы игенчелек һәм аучылык, Ижевск корал-металлургия з-ды өчен агач күмере әзерләү б-н шөгыльләнә. 1920 елларның 2 нче яртысыннан 1970 еллар башына кадәр Әбделмән авылында татар мәктәбе эшли. 1991 дә Кече Пурга авылында «Ләйсән» татар ансамбле оештырыла. Яган посёлогында мәчет эшли (2001 дән); мәктәптә татар теле факультатив дәресләрдә укытыла; Сабан туе бәйрәме үткәрелә. К.П.р. б-н Сов. Союзы Герое З.*Солтановның* тормышы бәйле.

*Әд.:* Зорина В.С. Малопургинская земля — моя родина. Ижевск, 2002.

**КЕЧЕ́ ПҮЧИНКӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* төньяктарак, Шуман елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Келәтле исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында кәшәнә, чиркәү-приход мәктәбе (1898 дән), 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1375,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 391, 1897 дә — 424, 1908 дә — 531, 1920 дә — 477, 1926 да — 518, 1938 дә — 517, 1949 да — 214, 1958 дә — 187, 1970 тә — 98, 1979 да — 41, 1989 да — 11, 2002 дә — 7 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕЧЕ́ ПҮЧИНКӘ́** посёлогы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сула елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 10 кеше (руслар) яши. 1649 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шигали Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстиннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киндер туку, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.П.дә су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 170 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир-ат; 1859 да — 96, 1897 дә — 142, 1908 дә — 119, 1920 дә — 186, 1926 да — 195, 1949 да — 79, 1958 дә — 78, 1970 тә — 54, 1979 да — 41, 1989 да — 23, 2002 дә — 15 кеше.

**КЕЧЕ́ РӘС** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 190 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Р.тә мәчет (1882 дә төзелә), мәктәп, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1284,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 88 ир-ат; 1859 да — 781, 1897 дә — 928, 1908 дә — 884, 1920 дә — 772, 1926 да — 819, 1938 дә — 702, 1949 да — 525, 1958 дә — 390, 1970 тә — 388, 1989 да — 216, 2002 дә — 202 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕЧЕ́ САЛТЫ́К** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Карамалы елгасы бассейнында. 2010 елда 211 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, он тарту һәм йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.С.та 2 мәчет, 4 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 йон-тукыма ману остаханәсе, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1670,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Яңасала волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш,

1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 119 ир-ат; 1859 да — 853, 1897 дә — 723, 1908 дә — 1497, 1920 дә — 1637, 1926 да — 1250, 1938 дә — 979, 1949 да — 707, 1958 дә — 609, 1970 тә — 478, 1979 да — 372, 1989 да — 300, 2002 дә — 244 кеше.

**КЕЧЕ́ СОЛАБА́Ш** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 28 *км* төньяктарак, Сола елгасының (Казансуның уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 181 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1653 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тенивраг Солабаш, Кече Шолабаш исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 819,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 445, 1897 дә — 652, 1908 дә — 896, 1920 дә — 719, 1926 да — 726, 1938 дә — 617, 1949 да — 418, 1958 дә — 295, 1970 тә — 228, 1989 да — 167, 2002 дә — 222 кеше. К.С.та дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог Х.*Габәши*, композитор С.Х.*Габәши* туган.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КЕЧЕ́ СОН** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 37 *км* көнбатыштарак, Сон елгасы буенда. 2010 елда 352 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Композитор Ф.З.*Яруллин* музее. 1680 нән Байгильдин Починок исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кулущи, Покровский исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет һәм мәдрәсә (19 йөз ахырында — 20 йөз башында төзеләләр; архит-ра истәлеге), су тегермәне, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1375,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 95 ир-ат; 1859 да — 862, 1897 дә — 1207, 1908 дә — 1327, 1920 дә — 1468, 1926 да — 1383, 1938 дә — 963, 1949 да — 812, 1958 дә — 684, 1970 тә — 648, 1979 да — 558, 1989 да — 404, 2002 дә — 379 кеше. К.С.да композиторлар З.Я. һәм М.З.Яруллиннар туган.

**КЕЧЕ́ СӨЛЧӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Олы Сөлчә елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 66,2 *км*, бассейнының мәйданы 809,7 *км*². Идел арьягы түбәнлегеннән ага. Елга башы урман массивында, Яңа Чишмә р-нының Сөлчәбаш авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Аксубай р-ның Карасу авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. К.С.нең су җыелу мәйданы ерым, сызалар челтәре б-н җиңелчә генә бүлгәләнгән, биек булмаган тигезлектән гыйбарәт; елга челтәре уемы тирән түгел. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Елга үзәне җиңелчә асимметрияле: уңъяк тау сөзәклекләре күпкә текәрәк. Елга юлы бормалы, киң тармаклы түгел, киңлеге 5–9 *м*. Су агымы тизлеге 0,1–0,3 *м/с*. К.С.нең 29 кушылдыгы бар; иң зурлары: Киса (11,2 *км*), Уеш (11,3 *км*), Кармәт (22 *км*), Карасу (11 *км*) — уң; Канавка (10 *км*), Киса (10 *км*) — сул. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы катнаш, зур күпчелеге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен



Кече Сөлчә елгасы.
Шәһәр тибындагы Аксубай посёлогы янында.

нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 95 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К.С. ноябрьнең беренче унконлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,14 *м*³*/с*, югары агымнарында — 0,03 *м*³*/с*. Суы язын гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы, каты (6–12 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–1000 *мг/л*. К.С. бассейнында суның гомуми күләме 9,9 млн. *м*³ булган 12 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. К.С. — ТРның табигать истәлеге (1978).

*О.Н.Урбанова.*

**КЕЧЕ́ СӨНЧӘЛӘ́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 123 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Сунчелеева исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 вак-төякләр кибете, ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 677 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 63 ир-ат; 1859 да — 278, 1897 дә — 421, 1908 дә — 515, 1920 дә — 566, 1926 да — 685, 1938 дә — 589, 1949 да — 485, 1958 дә — 399, 1970 тә — 448, 1979 да — 320, 1989 да — 179, 2002 дә — 148 кеше.

**КЕЧЕ́ ТАЛКЫ́Ш** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 21 *км* көнчыгыштарак, Талкыш елгасы буенда. 2010 елда 232 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авылның архит-ра истәлекләре: волость идарәсе бинасы (20 йөз башында төзелә), Троица чиркәве (1890–1916). 1710 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сергеевский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек Демидовлар з-дларына беркетүле булалар) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, чиркәү, земство мәктәбе (1873 тә ачыла), фельдшерлык пункты, 2 тимерчелек, 2 җил тегермәне, 2 сыраханә, 2 бакалея һәм 1 казна шәраб кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4163,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 158 ир-ат; 1859 да — 943, 1897 дә — 1717, 1908 дә — 1753, 1920 дә — 1829, 1926 да — 1922, 1938 дә — 1449, 1949 да — 904, 1958 дә — 587, 1970 тә — 522, 1979 да — 414, 1989 да — 295, 2002 дә — 263 кеше.

**КЕЧЕ́ ТИРӘ́Н КҮЛ** (Й о м ы к  к ү л), Көнбатыш Кама алдында. Казанның Киров р-ны терр-ясендәге «Аккош күле» урман паркында. Су өслегенең мәйданы 1,7 *га*. Күләме 26,1 мең *м*³. Озынлыгы 240 *м*, уртача киңлеге 60 *м*. Уртача тирәнлеге 1,5 *м*, иң зур тирәнлеге 4,5 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст-суффозия күренеше б-н бәйле. Элек *Тирән күл* б-н бер сулыкны тәшкил иткән, хәзер йөзмә «үлән-утрау» б-н аерылган. Өчпочмак рәве-



Кече Тирән күл.

шендә, озынча. Ярлары калку, катнаш урман б-н капланган. Күбесенчә явым-төшем исәбенә туена. Акрынлап күл саега бара. Төбендә бик калын органик ләм (сапропель) катламы бар. Ял итү урыны.

**КЕЧЕ́ ТОРМЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тормы елгасы буенда. 2010 елда 60 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1647–51 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Т.да мәчет, җил һәм су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 437,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 184, 1897 дә — 326, 1908 дә — 414, 1920 дә — 422, 1926 да — 344, 1938 дә — 233, 1949 да — 271, 1958 дә — 207, 1970 тә — 184, 1979 да — 164, 1989 да — 102, 2002 дә — 73 кеше.

**КЕЧЕ́ ТӨРНӘЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 74 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Төрнәле Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 307,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 51, 1897 дә — 137, 1908 дә — 106, 1920 дә — 192, 1938 дә — 233, 1949 да — 238, 1958 дә — 200, 1970 тә — 161, 1979 да — 108, 1989 да — 97, 2002 дә — 86 кеше.

**КЕЧЕ́ УКМА́С** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 14 *км* төньяктарак, Укмас елгасы буенда. 2010 елда 181 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1615–16 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.У.та мәчет, мәдрәсә, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1085 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 360, 1897 дә — 562, 1908 дә — 672, 1920 дә — 762, 1926 да — 547, 1938 дә — 547, 1949 да — 482, 1958 дә — 449, 1970 тә — 446, 1989 да — 251, 2002 дә — 219 кеше.

**КЕЧЕ́ УРСА́К** (Имәнле Башы) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Имәнле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 111 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 61 %, чуашлар — 36 %) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.У.та мәчет, мәдрәсә, 3 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 734 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 349, 1897 дә — 631, 1908 дә — 764, 1920 дә — 745, 1926 да — 663, 1938 дә — 777, 1949 да — 600, 1958 дә — 498, 1970 тә — 461, 1979 да — 426, 1989 да — 236, 2002 дә — 170 кеше.

**КЕЧЕ́ УРЫССУ́** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 8 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 470 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1924 тә Иске Урыссу авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 287, 1938 дә — 351, 1949 да — 365, 1958 дә — 311, 1979 да — 563, 1989 да — 437, 2002 дә — 474 кеше.

**КЕЧЕ́ ҮБИ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 22 *км* көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 373 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Тархан Убеи, Служивые Убеи исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, итек басу, балта эше һәм такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1298,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 531, 1897 дә — 799, 1913 тә — 1025, 1920 дә — 1043, 1926 да — 1143, 1938 дә — 1184, 1949 да — 1065, 1958 дә — 1035, 1970 тә — 995, 1979 да — 747, 1989 да — 460, 2002 дә — 416 кеше.

**КЕЧЕ́ ҮЛӘМӘ́** елгасы, Идел алдында, Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,7 *км*, бассейнының мәйданы 116,4 *км²*. Идел буе калкулыгы буйлап ага, Тәтеш р-ны терр-ясендә. Елга башы — Монастырский авылыннан 2 *км* төньяктарак, тамагы — Зеленовка авылында. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. К.Ү.нең 1,1–7,2 *км* озынлыктагы 11 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км²*. Туенуы катнаш, якынча өчтән бер өлешен кар сулары алып тора. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 143 *мм*, ташу агымы катламы 87 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,065 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада күләме 0,77 млн.*м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. К.Ү. бассейнында ландшафтлы табигать истәлеге — *«Таштау»* ерым-сызалар системасы урнашкан.

**КЕЧЕ́ ФРОЛО́ВО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тормы елгасының югары агымы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ф.да 3 җил тегермәне, май язу йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1191,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 503, 1908 дә — 1133, 1920 дә — 1035, 1926 да — 803, 1938 дә — 849, 1949 да — 421, 1958 дә — 337, 1970 тә — 195, 1979 да — 89, 1989 да — 31, 2002 дә — 11 кеше.

**КЕЧЕ́ ЧИРМЕШӘ́Н** елгасы, Көнбатыш Кама арьягында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 188,1 *км*, бассейнының мәйданы 3190 *км²*. Идел арьягы түбәнлеге буйлап ага. Елга башы Покровка табигый ызанында, Яңа Чишмә р-нының Татар Алкины посёлогыннан 4,3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, алга таба Чистай, Аксубай, Алексеев һәм Әлки р-ннарыннан ага. Түбән агымнары һәм тамагы — Ульянов өлкәсе терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагыныкы — 56 *м*. К.Ч. елгасының су җыелу мәйданы кушылдык үзәнлекләре, ерымнар һәм сызалар б-н җиңелчә бүлгәләнгән дулкынсыман тигезлектән гыйбарәт. Үсемлекләр дөньясы тугайлы болыннардан һәм катнаш урманнардан тора. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 22%. Үзәне беленер-беленмәс, киңлеге югары агымнарында 0,2–0,4 *км*, түбән агымында 2–4 *км* га кадәр. Тугае ике як-

лы, киңлеге 2–3 *км*, уйсулыклар һәм ерганаклар б-н бүлгәләнгән, сазлыклы, урыны б-н таллы; түбәнге агымында борынгы күлләр бар. Елга юлы чагыштырмача бормалы, тармакланмаган, киңлеге 20–30 *м* га кадәр. Ярлары урыны б-н текә, биеклеге 2–6 *м*. Плёсларда тирәнлеге 6 *м* га кадәр җитә, сайлыкларда — 20–30 *см*. Агым тизлеге 0,2–0,4 *м/с*. К.Ч.нең 37 кушылдыгы бар, аларның күбесе зур түгел һәм аз сулы, ш.и.: Изгар (12,4 *км*), Баганалы (14,7 *км*), Вәлүл (9 *км*), Бәрән (17,3 *км*), Мәүләшә (10,5 *км*), Ата (23,3 *км*), Шыя (15,3 *км*), Юхмачы (15,7 *км*), Путак (15,4 *км*) — уң; Чабаксар (20,9 *км*), Саурыш (20,5 *км*), Әдәм (20,8 *км*), Биләр (11,8 *км*), Мораса (39,6 *км*), Тумба (9,9 *км*) — сул. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–3 *л/с·км*$^2$. Елга режимын күзәтү Алексеев р-ның Абалдуевка авылы янындагы гидрологик



Кече Чирмешән елгасы.

постта үткәрелә (1940 тан). Су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 6,5 *м* (макс. — 8 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 82 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу уртача 30–35 көн дәвам итә, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Абалдуевка авылы янында макс. су чыгымы 702 *м*$^3$*/с* тәшкил итә (1979). Җәйге саегу тотрыклы, яңгыр ташкыннары сирәк күзәтелә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,86 *м*$^3$*/с*, Абалдуевка авылы янында — 0,27 *м*$^3$*/с*. Җәен яңгыр озак яумый торса, югары агымнарында елга тулысынча кибеп бетә, урта һәм түбән агымнарында урыны б-н плёслы күлләргә бүлгәләнә. К.Ч., гадәттә, ноябрь уртасында туңа, елгада боз каты уртача 140–145 көн дәвам итә. Кыш ахырында бозның калынлыгы 55 *см* га җитә. Суы гидрокарбонат-кальцийлы, язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К.Ч. елгасы бассейнында суның гомуми күләме 6,8 млн. *м*$^3$ булган 13 буа исәпләнә. Су ресурслары хуҗалык-көнкүреш һәм а.х. максатларында файдаланыла. Елга ярларында җирле кирпеч з-дларында куллану өчен яраклы балчык чыганаклары бар. К.Ч. — ТРның табигать истәлеге (1978). Аның бассейнында *Биләр тарих, археология һәм табигать музей-саклаулыгы*, ш.у. *«Татар Әхмәте торфлы сазлыгы»* табигать истәлеге урнашкан.

*О.Н.Урбанова.*

**КЕЧЕ́ ЧЫГТА́Й** посёлогы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 101 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ч.да су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 219 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 40, 1889 да — 68, 1910 да — 74, 1920 дә — 86, 1926 да — 68, 1949 да — 97, 1958 дә — 117, 1970 тә — 156, 1979 да — 137, 1989 да — 107, 2002 дә — 111 кеше.

**КЕЧЕ́ ЧЫНЛЫ́** елгасы, Идел алдында, Чынлы елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 54 *км*, бассейнының мәйданы 386,8 *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Чүпрәле р-нының Чуаш Чүпрәлесе авылыннан 1,3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Буа р-ның Новосёлки авылы янында. Түбән агымының зур булмаган өлеше Ульянов өлкәсе терр-ясеннән ага. Елга башының абс. биеклеге 218 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Елганың су җыелу мәйданы урмансыз диярлек. К.Ч.ның 1,3 *км* дан 9,9 *км* га кадәр озынлыктагы 19 кушылдыгы бар. Иң зурысы — Пакерлы елгасы (сул). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,12 *м*$^3$*/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К.Ч. бассейнында суның гомуми күләме 2,5 млн. *м*$^3$ булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЕЧЕ́ ЧЫНЛЫ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 28 *км* көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 1641 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1674 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ч.да 8 мәчет, 3 мәдрәсә, поташ з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7296,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Яңа Кәкерле волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 2485, 1897 дә — 3495, 1913 тә — 4701, 1920 дә — 5303, 1926 да — 4214, 1938 дә — 3438, 1949 да — 2888, 1958 дә — 2927, 1989 да — 2091, 2002 дә — 1835 кеше. К.Ч.да актёр Р.А.*Таҗетдинов* туган.

**КЕЧЕ́ ШӘЙМОРЗА́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 36 *км* көнчыгыштарак, Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 54 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1905 тә нигез салына. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Олы Чынлы волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1913 тә — 267, 1920 дә — 275, 1926 да — 308, 1938 дә — 358, 1949 да — 305, 1958 дә — 328, 1970 тә — 307, 1979 да — 198, 1989 да — 95, 2002 дә — 74 кеше.

**КЕЧЕ́ ШӘМӘ́К** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тормы елгасы буенда. 2010 елда 317 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ш.тә Никола чиркәве (1889 да ачыла), чиркәү-приход мәктәбе, 6 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1945,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 851, 1897 дә — 1333, 1908 дә — 1549, 1920 дә — 1413, 1926 да — 1181, 1938 дә — 1091, 1949 да — 720, 1958 дә — 653, 1970 тә — 584, 1979 да — 468, 1989 да — 352, 2002 дә — 333 кеше.

**КЕЧЕ́ ШӘҺӘРЧЕ́К**, археол. ядкәр; *Болгар* шәһәренең көньяк өлешендә, 13–14 йөзләргә караган кечерәк саклану корылмасы. *Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы* составына керә. Беренче тапкыр К.ш. атамасы 1712 елда дьяк Михайлов тасвирламасында теркәлә. Шәһәрчекнең ядкәрләре 1893 тә А.Н.Смирнов, А.И.Александров, 1946 да О.С.Хованская, 1981–84 тә Л.А.Беляев һ.б. тарафыннан тикшерелә.

К.ш. планда трапеция рәвешендә, төньяктан көньякка сузылган; периметры буенча урлар һәм чокырлар эзләре сакланган 2 рәт ныгытмалары булган. Тышкы зурлыгы: көнчыгыш ягы — 290 *м*, көнбатышта — 330 *м*, төньякта — 300 *м*, көньякта 150 *м*. Ныгытмаларның икенче, эчке рәте тагын бер дүртпочмаклы мәйданчык хасил итә (ур чокыры буенча зурлыгы: төньяк һәм көнчыгыш яклары 105 әр *м*,

көньякта — 90 *м*, көнбатыш ягы — 106 *м*). Комплексның төньяк өлешендә (шәһәр уры каршында) урнашкан, 4 *м* дан артык киңлектәге ике манаралы монументаль капка ансамбльнең композицион үзәген хасил иткән. Пилон манаралар керү урынын симметрик рәвештә чикләгәннәр, планда алар турыпочмаклык формасында (8x9 *м*). Манараларның эченә керү өчен, тыштан аларның капкаларына кадәр тар юллар сузылган. Көнбатыш манара эчендә бормалы баскыч эшләнгән. Көнчыгыш манара гөмбәз түбәле заллы корылмадан гыйбарәт булган. К.ш.нең икенче монументаль корылмасы да чокыр сызыгында, капкага капма-каршы — эчке мәйданчыкның көньяк чигендә урнашкан. Планда ул чокыр юнәлеше буенча (көнчыгыштан көнбатышка) сузынкы турыпочмаклык рәвешендә (19×13 *м*). Бина эчтән ике бүлмәгә бүленгән. Тикшеренүләр нәтиҗәсендә төзелеш эшләренең төгәлләнмәве ачыклана. Өченче корылма зур түгел (5,2×5,3 *м*), аның көнчыгышка караган ягында киң (2,7 *м*) керү урыны булган. Бина ике саклану рәте арасында, эчке мәйданчыкның төньяк-көнчыгыш почмагына капма-каршы урнашкан. Ян-яклардагы диварлар буенда таш эскәмияләр (суфалар) куелган, керү урынына капма-каршы диварда *михраб* корылган, ул бинаның тышыннан контрфорс б-н терәтелгән. Аның каршындагы каналлы сулык тәһарәт алу, юыну өчен файдаланылган. К.ш.нең өйрәнелгән барлык корылмалары, ак ташларның шома өслеген алга чыгарып, алебастр измәсе кулланып төзелгән, соңыннан аларның диварлары штукатурланган. Элегрәк сүтелгән ядкәрләрнең материалларын кабат файдалану эзләре дә бар. Археологлар фаразынча, төзелеш эшләре бер үк план буенча 1–2 сезон дәвамында башкарылган. Табылдыклар (14 йөзнең 1 нче яртысына карыйлар) бик аз очрый, бу ш.у. төзелешнең кыска вакытлы булуын күрсәтә. К.ш.нең нинди максатларда корылуы турында тикшеренүчеләрнең бердәм фикере юк, аны төзү, ихтимал, шәһәрнең 1361 дә *Булат Тимер бәк* тарафыннан яулап алынуы сәбәпле туктала. Истәлек төзелеп бетмәгән тантаналар үткәрү комплексы яки кәрвансарай калдыклары дип исәпләнә.

*Әд.:* Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Беляев Л.А. Новый архитектурно-археологический памятник XIV в. на Болгарском городище // Архитектурное наследие и реставрация. М., 1986; шул ук. Малый городок как памятник архитектуры и строительного искусства Великого Болгара XIV века // Город Болгар: Монументальное строительство, архитектура, благоустройство. М., 2001.

*Р.Ф.Шәрифуллин.*

**КЕЧЕ́ ШИЛНӘ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шилнә елгасы буенда. 2010 елда 995 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50 %, татарлар — 45 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан Шилнә, Яңа Усад исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык һәм урман кисү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2175,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макар волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 620, 1897 дә — 691, 1920 дә — 703, 1926 да — 627, 1938 дә — 495, 1949 да — 260, 1958 дә — 277, 1970 тә — 236, 1979 да — 482, 1989 да — 783, 2002 дә — 849 кеше.

**КЕЧЕ́ ШОМБЫ́Т** елгасы. Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 20,8 *км*. Бассейнының мәйданы 172 *км²*, Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга Шомырбаш авылыннан 2 *км* төньяктарак урман буенда башлана, тамагы Тәберде Чаллысы авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 162 *м*, тамагыныкы 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. К.Ш.ның 9 кушылдыгы бар. Аеруча зурысы Су елга (14,4 *км*) — уң кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,27 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле бассейнының төрле өлешләрендә 1 дән 10 *л/с·км²* га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 127 *мм*, ташу агымы катламы 110 *м*. Язгы ташу, кагыйдә буларак, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,1 *м³/с*. Суының катылыгы елганың бөтен озынлыгында үзгәрә: язгы ташу вакытында югары агымында йомшак (1,5 — 3 *мг-экв/л*), урта агымында һәм тамагында чагыштырмача каты (3 — 6 *мг-экв/л*); җәйге һәм кышкы челләдә елганың бөтен озынлыгында каты (6 — 9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200 — 300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700 — 1000 *мг/л*.

**КЕЧЕ́ ШУГА́Н** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 14 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Акташ волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 104, 1938 дә — 94, 1949 да — 76, 1958 дә — 50, 1970 тә — 186, 1979 да — 107, 1989 да — 36, 2002 дә — 13 кеше.


**КЕЧЕ́ ШЫГЫРДА́Н** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 44 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 20 йөз башында К.Ш.да мөселманнар өчен гыйбадәт йорты була. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1897 дә — 89, 1910 да — 104, 1913 тә — 93, 1920 дә — 113, 1926 да — 124, 1938 дә — 152, 1949 да — 160, 1958 дә — 138, 1970 тә — 213, 1979 да — 147, 1989 да — 98, 2002 дә — 61 кеше.

**КЕЧЕ́ ШЫҢА́Р** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 16 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 377 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Мәдәният йорты. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ш.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1159 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 116 ир-ат; 1859 да — 575, 1897 дә — 713, 1908 дә — 939, 1920 дә — 864, 1926 да — 724, 1938 дә — 805, 1949 да — 702, 1970 тә — 611, 1979 да — 548, 1989 да — 424, 2002 дә — 403 кеше.

**КЕЧЕ́ ШЫРДА́Н** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәкел елгасы буенда. 2010 елда 105 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ш.да 2 мәчет, 5 тегермән, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1024 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 244 ир-ат; 1859 да — 1703, 1897 дә — 1740, 1908 дә — 1406, 1920 дә — 1365, 1926 да — 1385, 1938 дә — 1110, 1949 да — 825, 1958 дә — 612, 1970 тә — 495, 1979 да — 336, 1989 да — 211, 2002 дә — 130 кеше. К.Ш.да татар мәгърифәтчесе К.*Насыйри* туган.

**«КЕЧКЕНӘ́ ИПТӘШЛӘ́Р»**, айлык рәсемле балалар журналы. ВЛКСМ ҮК каршындагы татар-башкорт бүлеге органы. СССР халыклары үзәк нәшрияты тарафыннан 1924 елның мартыннан 1928 нең апреленә кадәр Мәскәүдә татар телендә барлыгы 47 саны нәшер ителә. «Октябрь баласы», «*Ялкын*» балалар ж-ларының башлангычы булып тора. Төрле елларда мөхәррирләре — Х.Курмаев, М.*Җәлил* (1927 нең ноябреннән). Журнал үзенең максаты итеп укучы яшьләр тормышын төрле яклап яктыртуны куя. Редакция пионерлар, комсомол эшчеләр, укытучылар арасында хәбәрчеләр челтәре төзү буенча актив эшчәнлек алып бара. Ил буенча басманың

барлык саннары турында фикер алыша торган «К.и.» ж-лы дуслары түгәрәкләре барлыкка килә; аның битләрендә яшь хәбәрчеләр җибәргән язмалар даими урын ала. «К.и.»нең эшчәнлеген бәяләп, ВЛКСМ ҮК «журнал үзенең эшчәнлегенә татар-башкорт эшче һәм крәстиян балаларын актив җәлеп итә», дип яза. Күп кенә яшь татар әдипләре журналда үзләренең иҗади эшчәнлекләрен башлап җибәрәләр. Актив авторлар арасында З.Бәширова, Н.Гыйбадуллин, А.Мөхтәров, М.Парсин, Н.Рубцова, Х.Садыйков, Т.Салихов, М.Уразмөхәмматов, Ю.Усманов, И.Юманкуловлар була.



«Кечкенә иптәшләр» журналы.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Фәсәхов К. Тормыш көзгесе // Ялкын. 1973. № 3; Мәңге яшә, орденлы «Ялкын»! // Ялкын. 1984. № 3; Хамматов Ш.Х. Муса Җәлил, аның каләмдәшләре. К., 1986; Мустафин Р. Муса Джалиль: Жизнь и творчество в довоенный период. К., 1986.

*Т.М.Насыйров.*

**КЕШ** (Martes zibellina), ерткыч имезүчеләр, сусарлар семьялыгыннан җитез, матур хайван. Гәүдә озынлыгы 32–58 *см*, авырлыгы 870–1800 *г*, очлыклары кыска, койрыгы йонлач, 9–17 *см* озынлыкта, ана затлар аталардан кечерәк. Кышын К.нең йон катламы куе, ефәксыман, кылы ялтыравык. Төсе аксылдан сумаладай карага кадәр. Җәйге йоны кышкыдан караңгы. Урман зонасында Уралдан Камчаткага кадәр, Япониядә, Төньяк Кореяда, Кытайда, Монголиядә таралган. Яшәү төбәгенә карап зурлыгы, йонының төсе, йомшаклыгы һәм куелыгы б-н аерыла. Карарак төсләләре Байкал аръягы, Якутиядә, аксыллары Көнбатыш Себер, Приморье һәм Сахалинда, иң эреләре Алтай һәм Камчаткада яши. К. тайга урманнарында күп таралган. Яшәү урыны — агач тамырлары куышлыгы, таш аралары, ауган агач куышлары. Гадәттә, вак кимерүчеләр, кошлар, эрбет чикләвеге, җиләкләр б-н туклана. Июнь–июльдә аталана, буазлык 245–298 көн дәвам итә. Бер тудыруда 1–7 (гадәттә, 3–4) бала китерә, апрель–майда туган балалар августта зур К.ләрдән аерылмый. 2 яшьтә җенси өлгерә. Читлектә 15–18 ел яши, йон һәм тире өчен үстерелә. РФ хуҗалыкларында һәм Кытай, Дания фермаларында үрчетелә. ТРда К. үрчетү б-н 1970 елдан Биектау р-ны «Бөреле» җәнлекчелек с-зы (хәзер АҖ) шөгыльләнә. 2008 ел башына — 2200 баш, 2009 да 2660 баш җәнлек исәпләнә, 1 анага уртача 1,1 һәм 1,5 бала туры килә.

*Әд.:* Звероводство. СПб. — М. — Краснодар, 2004.

*Ф.Б.Вәлиев, Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КЕШЕ́ ИСЕМНӘРЕ́**. Хәзерге татар исемнәре чыгышы б-н берничә төркемгә бүленә: 1) гомумалтай (Алтынчура, Алтынбай, Алтынчәч); 2) борынгы төрки (Байтимер, Уразбикә, Тимерхан); 3) борынгы татар (төрки К.и. дә үз эченә ала — Актай, Таңсылу, Ханбәк; болгар-татар — Атлас, Туктар, Туйбикә; кыпчак — Айдар, Байтирәк, Сөембикә; уйгыр — Абас, Даиш, Гильде); 4) гарәп (Асия, Габдулла, Гомәр, Мөхәммәт) — 922 елда ислам дине кабул ителгәч үтеп керә башлыйлар һәм хәзерге көндә дә актив кулланылышта; 5) фарсы (Бану, Гөлнара, Зифа, Рөстәм) — Болгар дәүләтенең Урта Азия һәм Көнчыгыш дәүләтләре б-н сәүдә һәм мәдәни багланышларына бәйле рәвештә кулланыла башлыйлар; 6) рус һәм Көнбатыш Европа кеше исемнәре катламы (Светлана, Венера, Альберт, Клара, Рафаэль, Роберт, Регина) — 1917 дән соң популярлашып китәләр; 7) яңа татар исемнәре (Айгөл, Алсу, Илдус, Ирек, Илназ) — 1917 елдан соң. Ш.у.к. *Атасы исеме*. *Фамилия*.

*Әд.:* Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. К., 1981; шул ук. Татар исемнәре ни сөйли? К., 1998.

**КЕШЕЛЕКЛЕЛЕ́К ИМПЕРА́ТОР ҖӘМГЫЯТЕНЕ́Ң КАЗА́Н ЯРЛЫЛАРГА́ ЯРДӘ́М ИТҮ́ КОМИТЕТЫ́**, хәйрия оешмасы. Россиядә Кешелеклелек император җәмгыяте 1802 елдан эшли. 1816 да Романовский (рәис) башлангычында Казанда аның бүлекчәсе ачыла. Максаты — мохтаҗларга ярдәм итү: «хәерчелектә яшәве ачыкланган һәм ярдәм кирәклеге расланган һәркемгә, балаларны тәрбияләү өчен, дәрәҗә классларына карап, елга 36 сумнан 180 сумга кадәр акча, 24 пот арыш оны, 25 аршын постау, 20 аршын киндер бирү» күздә тотыла. Устав буенча ярлыларга бушлай мед. хезмәте күрсәтү һәм аларны дарулар б-н тәэмин итү, ш.у. кече яшьтәге ятим балаларны һөнәр уч-щеләренә урнаштыру, эшкә урнашканда ярдәм итү карала. Тәрбиягә алынучыларның саны җыелган иганәләр күләменә бәйле була (1817 дә — 39, 1850 еллар ахырында — 128 гаилә). Җәмгыятьнең капиталы аның әгъзаларының даими хәйрияләреннән һәм аерым бирелгән иганәләрдән туплана (1833 тә — 137 мең сум). Даими әгъзаларның күпчелеген сәүдәгәрләр (Т.Е.Аникин, И.И.Осокин, И.Н., К.И. һәм М.И.Котеловлар, И.И.Калашников һ.б.) тәшкил итә. 1870 еллардан җәмгыять башлангычында мохтаҗларга кыйммәт булмаган бәягә фатирлар биреп торыла, арзанлы ашханәләр һәм чәйханәләр, ачлык елларында вакытлыча түләүсез ашханәләр ачыла (1891 дә Пләтән бистәсендәге Ә.Я.Сәйдәшев йортында 300 кешелек ашханә, Толчоктагы Щербаков йортында 1 мең кешелек чәйханә һ.б. эшли). 1917 дә эшчәнлеге туктала.

*Әд.:* Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.


*Л.М.Свердлова.*

**КЕ́ШНЕР** Вадим Валентинович (22.3.1937, Казан), драма актёры, педагог, ТАССР, РФнең халык артисты (1982, 1997). Казан Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлый (1961), танылган режиссёрлар Э.М.Бейбутов, Е.А.Простов, А.Д.Гусевта белем ала; 1961 елдан әлеге театрда актёр. Аның сәхнәсендә 100 дән артык роль башкара, шуларның күбесе театр сәнгатендә күренекле урын тота. Максимов («Хезмәттәшләр», В.П.Аксёнов повесте буенча), Владик («Мәхәббәт турында 104 бит», Э.С.Радзинский), Борис («Ленинград проспекты», И.В.Шток), Прокофьев («Хатын-кызлар монастыре», В.А.Дыховичный, М.Р.Слободской), Леонидик («Минем бичара Маратым», А.Н.Арбузов) кебек беренче рольләрендә үк актёр талантына хас булган сыгылмалылык, музыкальлек, рольнең тышкы бөтенлеге, тәгаллеккә омтылыш, ачык темперамент күзгә ташлана. К.ның «Гадәти вакыйга» (И.А.Гончаров романы буенча В.С.Розов пьесасы, 1968) спектаклендәге кече Адуев ролен башкаруы театр тормышында зур вакыйга була. Әйләнә-тирә чынбарлык гаделсезлекләре б-н тигезсез көрәштә әҗәлен тапкан романтик рухның драматик тарихын, якты идеалларга ышанган ялкынлы егетнең рәхимсез, прагматик чиновникка әверелүен актёр ышандырырлык итеп, характерның һәм социаль күренешнең иҗтимагый асылына төшеп сурәтли. Актёрның Пушкин («Барлыгы 13 ай», Ю.З.Дынов, 1970) һәм Чайковский («Мәңге-



В.В.Кешнер.







В.В.Кешнер 1. Пушкин («Барлыгы 13 ай», Ю.З.Дынов; кенәз хатыны Вяземская ролендә — Л.В.Маклакова); 2. Александр Адуев («Гадәти вакыйга», И.А.Гончаров); 3. Уилл («Булыргамы, булмаскамы?», У.Гибсон) рольләрендә.

лек өчен яшәү», Ю.А.Оснос, 1970) рольләре сәнгати казанышы булып тора: әйләнә-тирә җәмгыять таләпләреннән аерылыбрак торган башка бер дөньяда яшәүче һәм шуңа күрә аның б-н һәрдаим рухи һәм әхлакый конфликтта торучы иҗат кешесенең катлаулы һәм бай эчке дөньясын К. оста сурәтли. Әлеге рольләрдә гәүдәләнеш тапкан иҗат әһеле б-н җәмгыять арасындагы үзара мөнәсәбәтләр темасын актёр Уилл («Булыргамы, булмаскамы», У.Гибсон, 1976) ролендә ача. Иҗади сәләт, дөресен сөйләү хокукы, иҗат өчен мөһим алшарт булып торган рухи ирек ихтыяҗы башкаручы тарафыннан, аның гражданлык һәм әхлакый позициясеннан чыгып, шәхсән үз кичерешләре аша ялкынлы һәм темпераментлы рәвештәраслана. Горчаков, Челознов («Озату», «Урман эчендәге веранда», И.М.Дворецкий), Рощин («Бердәнбер шаһит», А.С. һәм П.Л.Тур), Брызгалов («Кафедра», В.В.Врублёвский), Шабельников («Күрегез, кем килгән!», В.К.Арро) һ.б. шундый замандашларының образларын иҗат иткәндә К., кайвакыт кискенлек кебек сыйфатны өстен куеп, тышкы сурәткә кырыслык биреп, үз героеның, беренче чиратта, әхлакый асылын, аның җәмгыятьтә тоткан урынын күрсәтергә омтыла. Нияз («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Атташе («Пунтила әфәнде һәм аның хезмәтчесе Матти», Б.Брехт), Иван Иванович («Мунча», В.В.Маяковский) һ.б. рольләре аша актёр форма б-н виртуозларча эш итә белүен, теге яки бу образны ачканда үтемле, мәгънәле, тәэсирле детальләр таба белүен күрсәтә. Актёрның проф. Преображенский, Персиков («Табиб Борментальнең көндәлек дәфтәре», 1988; «Хәтәр йомыркалар», 1997, М.А.Булгаковның шул исем. повесте буенча), Серебряков («Ваня абзый», А.П.Чехов, 1993), Дус («Барысы да бетте», Э.Олби, 1994) рольләре психол. картинаның төгәллеге, бер үк вакытта кырыслыгы б-н аерылып тора. «Театр-99» сәхнәсендә К. тарафыннан башкарылган Хамперт («Лолита», В.В.Набоков романы буенча, 1994) һәм Звонарёв («Sorry» («Гафу»), А.М.Галин, 1995) рольләре театр сәнгатендә зур вакыйга була. Актёрның әлеге рольләрендә әхлакый эчтәлекнең күпкырлылыгы, образларның психол. яктан тирән ачылышы тышкы күренешләрнең сәнгатьчә байлыгы б-н тыгыз үрелеп бара.

1976 дан К. Казан театр уч-щесендә пед. эшчәнлек алып бара, Россиянең төрле театрларында эшләүче берничә буын актёрлар тәрбияли. Концерт эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты (2011).

Ә с ә р.: Начало // Казань. 1997. № 1/2; Всплески памяти // Актуальное национально-культурное обозрение. 2001. № 3–5.

*Әд.:* Р о м а н о в и ч И. Большие ожидания // Театр. 1970. № 9; Б л а г о в Ю. И в сотый раз — преодоление // Татарстан. 1996. № 12; ш у л у к. Кешнер и К°. К., 2001.

*Ю.А.Благов.*

**КИБА́РДИН** Александр Михайлович (24.5.1948, Әгерҗе р-ны Красный Бор а. — 30.1.2001, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1994). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, 1996 дан фосфорорганик кушылмалар химиясе һәм технологиясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. К. сызыкча һәм циклик төзелешле фосфорның N-виниламид кушылмалар к-талары химиясе буенча фәнни юнәлеш тудыра. 2 дән алып 5 кә кадәрле координацияле фосфор атомы булган бер һәм күп циклы төзелешле азафосфациклannar классын таба; аларның төзелеш үзенчәлекләрен күрсәтә һәм химик үзлекләрен өйрәнә. Көч җитәрлек һәм арзанлы органик субстратлар нигезендә ветеринариядә файдалану өчен алмаштырылган арилметансульфон к-таларының биол. актив аммоний тозларын синтезлауның гади һәм уңайлы ысулларын ача. Химик коралны юк итү мәсьәләләрен хәл итү юлларын эшли. Ипритның һәм аның эфирлы аналогының югары нигезле тирәлекләрдә реакциягә керү мөмкинлеген өйрәнә, ипритны утильләштерүнең бик отышлы ысулларын тәкъдим итә (бергәләп). Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Синтез и молекулярная структура 2-хлор-1, 3-дициклогексил-4-хлор-1, 3, 2-диазафосфолена. Необычно длинная связь P-Cl // Докл. АН СССР. 1988. Т. 298, № 2 (автордаш); Реакции хлорангидридов кислот фосфора с иминами // Журн. орган. химии. 1993. Т. 63, вып. 11 (автордаш); Взаимодействие галогенфосфинов с сопряжёнными гетеродиенами // Успехи химии. 1999. Т. 68, вып. 2 (автордаш).

**КИБА́РДИНА** Надежда Николаевна (8.2.1956, Чаллы ш.) спортчы (велосипед спорты — шосседа һәм тректа узыш), СССРның атказ. спорт остасы (1980). Спорт б-н 1971 елдан «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә (Чаллы ш.) шөгыльләнә башлый, тренеры — Б.С.Головин. СССР (1980–85, 3 *км* га шәхси узыш; 1987–89, 50 *км* га команда узышы), Бөтендөнья студентлар уеннарында (1983, шосседа узыш) чемпион, Милләтләр кубогы иясе (1989, 1992). 1980 еллар ахырыннан Самара шәһәрендә яши. 1994 тән Идел буе округының эчке гаскәрләрендә тренер-инструктор (тау велосипеды).

**КИБӘ́К БӘК** (? — 1552), карачыбәк. Чыгышы б-н Себер ханлыгыннан. Казанга *Сафагәрәй хан* идарә иткәндә, ихтимал, 1530 елларда кенәз Бәйбарс Растов б-н бергә килгәндер. Аның сәясәтен яклый, 1551 дә Шаһгали ханга тәхеткә утырырга булыша. Шаһгали хан оппозициядә торучыларны тар-мар иткәндә кулга алына һәм Зөя кальгасына озатыла. Башка бәкләр б-н бергә рус әсирлегеннән кача һәм Казанда баш күтәрү оештыра. 1552 дә Чапкын бәк Отыч хөкүмәте әгъзасы. 1552 дә Казанны саклаучыларның берсе. Шәһәр камалышта вакытта һәлак була.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Л.Измайлов.*

**КИБӘ́К ИЛӘ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Җирә елгасы буенда, 2010 елда 242 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.И.ндә мәчет, ашлык саклау-сату кибете, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 693 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 228, 1897 дә — 338, 1908 дә — 409, 1920 дә — 420, 1926 да — 436, 1949 да — 433, 1958 дә — 351, 1970 тә — 365, 1979 да — 355, 1989 да — 283, 2002 дә — 283 кеше.

**КИБӘ́К ХАН** (Күбек, Кубал) (?–1413), Алтын Урда ханы (1413). *Туктамыш хан* улы. Әтисе ягында Идегәй әмиргә каршы сугыша. Туктамыш хан үлгәч, Сыгнак шәһәренә кача. Җәләлетдин хан идарә иткәндә Алтын Урдага кайта. 1413 елда үз туганы Кәримбирдене үтереп, литвалылар ярдәмендә тәхеткә утыра. Акча суктыра. Идегәй әмир тарафыннан үтерелә.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**КИБӘЧЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 14 *км*, бассейнының мәйданы 162 *км*$^2$. Питрәч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Кавал авылыннан 4 *км* төньяктарак, тамагы Кибәче авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 64 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 16%. К.нең 8,3 һәм 16,1 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар; иң зурысы (уң) — Сеин елгасы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 149 *мм*, ташу агымы катламы 127 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башларында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,12 *м*$^3$/*с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,3 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КИБӘЧЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 23 *км* көнчыгыштарак, Кибәче елгасы буенда. 2010 елда 365 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1565–67 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә чиркәү-приход мәктәбе (1872 дә ачы-

ла), тимерчелек, ярма яргыч, кибет, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана жире 1167 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 504, 1897 дә — 1022, 1908 дә — 1224, 1920 дә — 1432, 1926 да — 1350, 1938 дә — 1241, 1949 да — 1062, 1958 дә — 1015, 1970 тә — 1156, 1979 да — 806, 1989 да — 533, 2002 дә — 467 кеше.

**КИБЕРНЕ́ТИКА** (грек. kybernētikḗ — идарә итү сәнгате), катлаулы (техник, биол., социаль һ.б.) системаларда идарә итү, элемтә һәм мәгълүмат эшкәртү турындагы фән. «К.» терминын беренче тапкыр француз математигы А.Ампер куллана (1834), 1948 елда Америка галиме Н.Винер тарафыннан яңартыла: ул аны кибернетика фәненең төп концепцияләре бәян ителгән китабының исемендә күрсәтә («Кибернетика, или Управление и связь в живом и машине», М., 1983). 1956 да К. идеяләренең системалы аңлатмасын Англия галиме У.Эшби бирә; фәннең шуннан соңгы үсеше Америка инженер-математигы К.Шеннон, күренекле сов. галимнәре А.А.Ляпунов, А.И.Берг, В.М.Глушков һ.б.ның хезмәтләре б-н бәйләнгән. Совет иленең рәсми фәнни даирәләре ягыннан А.Н.Колмогоров аның фәлсәфи аспектларына зур өлеш кертә. Илнең матем. К. фәнни мәктәбе үсешенең нигезенә дискрет функциональ системаларның структур катлаулылыгын бәяләү нәтиҗәләре (С.В.Яблонский, О.Б.Лупанов) салына. К. идеяләре б-н баетылган хисаплау техникасының үсеше гамәли машина алгоритмнары теориясен эшләү, информатика фәне барлыкка килү б-н бергә бара. К., фән буларак, таррак мәгънәдә машиналар һәм тере организмнар арасындагы аналогияләрне, ясалма интеллект һәм филос. проблемаларын тикшерүче фән булып кала.

1950 еллар уртасыннан Казан ун-тында К. өлкәсендә интенсив тикшеренүләр башлана. 1957 дә В.В.*Морозов* инициативасы буенча алгебра кафедрасында матем. анализ лаб-ясе төзелә, һәм ул 1960 та (беренче «Урал-1» электрон хисаплау машинасы куелу б-н) хисаплау үзәге (ВЦ) статусын ала. Шул ук елда Казан ун-ты каршындагы Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында К. бүлеге ачыла. 1971 дә ун-тының механика-матем. ф-тында теоретик К. каф. ачыла, 1978 дә шул ук ф-тның дүрт кафедрасы базасында исәпләү математикасы һәм К. ф-ты оештырыла. 1962 дән башлап, ихтималый автоматлар теориясен һәм ихтималый процессорларны конструкцияләү төп фәнни тема булып кала (Р.Г.*Бохараев*, В.М.*Захаров*, Ф.М.*Аблаев*, Н.Н.Нурмиев һ.б.). 1990 елларда алгоритмик алгебраларны өйрәнү өлкәсе — «тулылык проблемасы»н тикшеренүләр үсеш ала (Ю.В.*Голунков*, В.Б.Соловьев). Кибернетик функцияләрнең катлаулылыгын бәяләү теориясенә Р.Г.*Нигъмәтуллин* зур өлеш кертә. Керүче һәм чыгучы мәгълүматны кыскарту (кысу) нигезендә интеграль схемаларны автоматик тикшерүнең (тест үткәрүнең) эффектив теориясе эшләнә (Р.К.Латыйпов). 2000 еллар башыннан квантлы автоматларны тикшерүдә (Ф.М.Аблаев), матем. логика өлкәсендә алгоритмик тулылык проблемасын чишүдә (М.М.Арсланов) ихтималый автоматлар проблемасын өйрәнү дәвам иттерелә.

1968 дә Казан ун-ты каршында Мәскәү электрон идарә итү машиналары ин-тының матем. тәэмин ителеше бүлеге (МО ИНЭУМ) оештырыла, ул ЕС ЭВМ һәм СМ ЭВМ тибындагы сов. ЭВМнарын матем. яктан коралландыра. 1984 тә бүлек нигезендә ИНЭУМның ф-лы булдырыла, соңрак ул ТР ФАнең *Информатика институты* итеп үзгәртелә. 1993 тә ясалма интеллект проблематикасы яңа үсеш ала: аерым алганда, татар компьютер лингвистикасы барлыкка килә, ул теоретик К. каф. каршындагы ясалма интеллект лаб-ясендә ТР ФА катнашы б-н эшләнә, бу тикшеренүләрнең прагматик методологиясе, башлыча, Җ.Ш.*Сөләйманов* тарафыннан башкарыла (2001). Исбатлаулар һәм логик программалаштыру теорияләре Н.К.*Замов* һәм В.И.Шаронов тарафыннан үстерелә; предикатлар исәпләүдә теоремаларны исбатлауның машинага яраклашкан эффектив алымнары эшләнә, алар предикатлар исәпләүнең чишелешле классларының күпчелеген һәм модаль логикалар өчен исбатлауларны автоматик эзләүнең тулы стратегиясен төзү мөмкинлеге бирә (Н.К.Замов); оптимальләштерү теориясендә һәм ЭВМның икътисади исәпләүләрендә кулланыла торган алымнар — квазикабарынкы функционалларны минимальләштерү алымнары эшләнә (Я.И.*Заботин*). Ихтималый машиналарның төрле типларын конструкцияләү өлкәсендә Казан авиация ин-ты (хәзер Казан техник ун-ты) галимнәре теоретик һәм практик нәтиҗәләргә ирешәләр (Б.Ф.*Кирьянов*, В.А.*Песошин*, В.И.*Глова*); алар очраклы кодларның идарә ителүле генераторының беренче серияле моделен эшлиләр, фильтрлаштыруның аппаратуралы алымнарын һәм очраклы процесслар теориясенең радиотехника аппаратларындагы вибросынагычлар төзелешендә куллану мөмкинлекләрен үстерәләр (Ш.М.*Чабдаров һ.б.*).

*Әд.:* Энциклопедия кибернетики. Киев, 1974.

*Р.Г.Бохараев.*

**КИБЯКО́В** Алексей Васильевич (27.9.1899, Казан губ., Мамадыш өязе Шомырбаш а. — 30.5.1985, Ленинград), физиолог, мед. фән. д-ры (1939), СССР МФАнең мөхбир әгъзасы (1948). Н.А.Миславский һәм А.Ф.Самойлов шәкерте. 1927 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1930–56 да Казан мед. ин-тында, 1936 дан нормаль физиол. каф. мөдире, профессоры; бер үк вакытта 1948–53 тә СССР ФАнең Казан ф-лы Казан биол. ин-ты директоры, экспериментал ь биол. секторы мөдире. 1957 дән И.П.Павлов исем.1 нче Ленинград мед. ин-тының нормаль физиол. каф. мөдире. Хезмәтләре нервлар эшчәнлегендә медиаторларның физиол. роле мәсьәләләренә карый. К. дөньяда беренче булып нейронара синапстагы ярсынулар тапшырылуда медиатрлар катнашын исбатлый, аларның үзәк нерв системасы һәм периферик органнарның функциональ торышын көйләүдәге ролен ачыклый (1933). СССР ФАнең И.П.Павлов исем. бүләге (1949) бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



А.В.Кибяков.

Х е з м.: О гуморальных факторах во взаимоотношении между нейронами в симпатическом ганглии: Дис. ... К., 1939; О природе регуляторного влияния симпатической нервной системы. К., 1950.

*Әд.:* Творческий путь А.В.Кибякова (к 60-летию со дня рождения) // Физиол. журн. СССР им. И.М.Сеченова. 1960. Т. 46, № 2.

**КИВА́ЛКИНА** Вера Поликарповна (25.9.1918, Казан губ., Козьмодемьянск өязе Коротки а. — 28.6.1990, Казан), микробиолог, биол. фән. д-ры (1964), проф. (1966), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1973). 1936 елда Казан ун-тын тәмамлый, «Ижминводы» АҖдә эшли. 1940 тан Казан вет. ин-тында, 1969–87 дә микробиол. һәм вирусология каф. мөдире. Хезмәтләре Себер түләмәсен китереп чыгаручының үзгәрүчәнлеген өйрәнүгә карый. К. прополисның микробка каршы көрәшү үзенчәлекләрен ачыклый. Прополисның дару төрләрен эшли һәм сыный, аның иммуннарны үзгәртү тәэсирен ачыклый (иммунитетның махсус булмаган һәм барлыкка килгән факторларын стимуллаштыру). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пчела и здоровье человека. М., 1962; Биологическая активность прополиса и перспективы его применения // Фитонциды. Киев, 1981.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*А.И.Ибраһимова.*

**КИГӘВЕННӘ́Р** (Tabanidae), парканатлылар семьялыгыннан кыска мыеклы туры җөйле кан суыручы бөҗәкләр семьялыгы. Гәүдәсе җыйнак, кыска, озынлыгы 7–30 *мм*. Канатлары киң, көчле. Башы зур, төсле ялтыравык зур күзле һәм мыекчасының өченче буыны бөҗралы. Хортумчыгы кадап суыручан типта. 3,5 меңнән артык төре бар, киң таралган. Россиядә 200 гә якын төре билгеле; Татарстан терр-ясендә 15 ләп төре бар. Аеруча билгеле төрләр: *соры чебеннәр,* К. үзләре (Tabanus), яңгыр кигәвеннәре (Haematopota). Гадәттә, елга һәм күл ярлары буенда яши. Чебен-черки компонентларының берсе, ачык һавада эссе кояшлы көндә хайваннарга, сирәк кенә кешеләргә һөҗүм итә. Канны ана зат эчә (ата затлар нектар б-н туклана). Бер суырганда 300 *мл* га кадәр (озынборыннарга караганда 70 тапкыр күбрәк) кан эчә. Яшәү дәверендә үсемлекләрнең су өсте өлешләренә 3,5 мең гә кадәр күкәй сала. Личинкалары суда яки аның тирәсендә үсә, башка бөҗәкләрнең личинкалары, яңгыр суалчаннары һ.б. б-н туклана. Олы затлар да дымлы урын-

нарны ярата, шунлыктан терлекләргә су эчертү урыннарында аеруча күп очрыйлар. К. түләмә, түләрәмә һ.б. авыруларны таратучылар булырга мөмкиннәр. К. фаунасы төрләр комплексы хасил итә: тайга урманы (төп төрләр — бизәкле чуар коңгыз, төшке кигәвен, иртәнге кигәвен), Европа-Себер урманы (төп төрләр — үгез кигәвене, гади һәм Италия яңгыр кигәвене) һәм урман-дала (реликт чуар коңгырт коңгыз, соры кигәвен, көзге кигәвен). Климатның глобаль үзгәрешләре б-н бәйле рәвештә урман-дала төрләренең ареалы акрынлап киңәя бара.

*Әд.:* Гоголев В.Б., Лотфуллин М.Х., Камилов Н.К. Кровососущие двукрылые Среднего Поволжья Волго-Вятского региона. К., 2002.

*Р.М.Зелеев.*

**КИЕ́З**, татар гамәли сәнгатендә киез келәм, кошма. Бизәкле һәм бизәксез төрләре билгеле.Гадәттә, К. өчен көзен алынган табигый ак, соры, сирәк кенә кара төсләрдәге һәм кызыл, зәңгәр һәм көрән төскә буялган сарык йоны файдаланыла. Киез келәм басу юлы б-н әзерләнә. Бизәү өчен келәмнең төп фонына буялган йон кушыла; бизәкләр К.не басканда ук алдан билгеләнгән урынга беркетелә. Икенче төрле алым да кулланыла: К. бизәкләр бер төстәге (ак яки соры) К. фонга төсле җепләр б-н тегеп куела, аннары өстәмә рәвештә чигүләр һәм чәмчәле җөйләр б-н бизәлә. К.не, гадәттә, җәй көне ишегалдында әзерләгәннәр. Башта ак, тыгыз тукыма җәелгән, аның өстенә 5–8 *см* калынлыктагы таралган һәм чистартылган йон түшәлгән. Йон өслегенә җепләр ярдәмендә рәсеме еш кына тукымага төшерелгән бизәкләр урнаштырылган. Өстән башка тукыма ябылган һәм кайнар су б-н чылатылган. Аннары К.не төргәкләгәннәр һәм махсус катокта су сиптереп тыгызлаганнар. К.нең озынлыгы 1,6 дан 2 *м* га, киңлеге 1,4 тән 1,6 *м* га җиткән; чит-читлары төрле төстәге тукыма б-н каймаланган. К. әзерләүдә ирләр дә, хатын-кызлар да катнашкан. Хатын-кызларга, гадәттә, бизәү эше йөкләнгән. К.нең бизәкләре йөнтәс келәм композицияләреннән кәкре сызыклы фигуралары, йомык контурлы формалары (күчмә кабиләләрнең дала культурасына барып тоташа), 2–3 төрле төстән төзелгән гади төсләр гаммасы б-н аерылып торалар. К.нең бер-берсенә сабаклары б-н тоташкан эре чәчәкле бизәкләре, башлыча, кайма читләренә урнаштырыла. Себер татарлары К.ләрендәге бизәкләр борынгылыгы һәм байлыгы б-н күзгә ташлана. Келәм үзәгендәге тигез үлчәмле сигез канатлы йолдызлар, «тәкә мөгезләре» б-н тулыландырылган эре, түгәрәк чәчәкләр һәм келәм буеның ике ягындагы давыл чәчәкләренә охшаган кайма бердәм композицияне тәшкил итә. К.не көндәлек тормышта әзерләү һәм куллану гомумтөрки культурага хас күренеш. Аның гасырлар буенча сакланып килгән күркәм традицияләре хәзер дә татар йорты бизәлешендә дәвам итә. Һәр К.нең йорт бизәлешендә үз урыны булган: бизәкле келәмнәр такта сәкеләргә, бер төслеләре идәнгә җәелгән. Кырым татарлары (башлыча, дала р-ннарында яшәүчеләр) К.дән *намазлыклар* да әзерләгәннәр. К. татарлар көнкүрешендә кулдан тукылган келәмнәр б-н чагыштырганда азрак таралган. 19 йөзнең 2 нче яртысында К. акрынлап кулланыштан чыга, шулай да Татарстанның аерым р-ннарында (Әлмәт, Бөгелмә, Азнакай һ.б.) һәм аннан читтә (Самара, Оренбург өлкәсе, Төньяк Себер, Урал буе) бер төсле К. җитештерү 20 йөзнең уртасына кадәр дәвам итә.

Татарстанның хәзерге заман мәдәниятенә К. келәмнәрнең яңадан кайтуы 1980 еллар башыннан К.нең технологияләре, төр һәм жанр бердәмлеген камилләштерү б-н шөгыльләнүче проф. рәссамнар Д. һәм Р.Рәхмәтуллиннар (Бөгелмә) иҗаты б-н бәйле. Алар тарафыннан җәмәгать биналары һәм шәхси йорт интерьерларын бизәү өчен К.дән орнаментлы һәм тематик-сюжетлы дивар келәмнәре иҗат ителә. К. композицияләре татар фольклоры мотивлары («Сабантуй», «Шүрәле», «Бәйрәм белән» — барысы да 1982; «Кубыз», 1983; «Карга боткасы», 1984 һ.б.), болгар һәм татар орнаментлары нигезендә («Тормыш агачы», 1984; «Күбәләк», «Тузганак», 1980 еллар), еш кына К. бизәкләренә стильләшкән кеше фигуралары, зооморф мотивлар кушылган тематик триптихлар рәвешендә («Ак йон», 1981) төзеләләр. Рәссамнарның хезмәтләре югары бәяләнә, күргәзмәләргә куела. Р.Рәхмәтуллина Казандагы татар гимназиясендә балаларга К. басарга өйрәтү өчен дәресләр бирә. Ш.у. к. *Келәмчелек.*

*Әд.:* Вәлиев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; Богомолов В.Б. Узоры сибирских татар Омского Прииртышья // От Урала до Енисея: Народы Западной и Средней Сибири. Томск, 1995; Вәлиева-Сөләйманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920–90 гг.), К., 1995; Заатов И. Крымскотатарское декоративно-прикладное изобразительное искусство. Симферополь, 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КИЕ́З ИТЕ́К**, итек формасындагы йоннан басылган аяк киеме. Озын кунычлы К.и. (яки пима) — татарларның традицион кышкы аяк киеме. Элегрәк кыска кунычлы К.и.ләр (киез ката) еш кулланылган, алар кышкы галош рәвешендә — читек яки тула оек өстеннән киелгән. Татарларда итек басу һөнәре киң таралыш ала, 19 йөз уртасыннан Казан губернасының Казан һәм Мамадыш өязләре, Вятка губернасының Малмыж өязе, Сембер губернасының Буа өязе халкы өчен читкә китеп эшләү кәсебе була. Аеруча Мамадыш өязенең Кече Әтнә һәм Кукмара авыллары осталары дан казана. Читкә китеп эшләүчеләр заказчының утарында (гадәттә, мунчада) үз кирәк-яракларын кулланып эшлиләр. К.и.не заказчы материалыннан басалар: йонны язалар, төсе, сыйфатына карап сортларга аералар, аннары тетәләр: йон арасына арыш оны сибә-сибә, чыбыктан үрелгән рәшәткәдә (дырындык) бәрән эчәгесеннән эшләнгән кыллы җәя б-н, яисә киндергә төрелгән йонны су яки эремчек суы б-н чылатып, идәндә тәгәрәтәләр. К.и.не агач калыпта тиешле формага китереп, известьлы эремәдә кайнаталар, аннары киптергәннән соң, пемза яки акбур б-н ышкып тигезлиләр. Кукмарада махсус технология буенча бизәкле К.и.ләр җитештерелә: К.и.нең җиңелчә генә төргәкләнгән ак киез өслегенә тышкы яктан тамбур чигүе яки кыек җөй б-н, гадәттә, кызыл һәм зәңгәр йон җепләр б-н эшләнгән чигеш үрнәге тәгәрәтеп кертелә; чигүдәге төп бизәкләр — дулкынсыман, тешле-тешле, кыек полосалар, ромблы чылбыр, мөгезсыман фигуралар. 19 йөз ахырында Кукмарада һәм Казанда К.и.ләрне фабрикада җитештерү җәйга салына. Йоннан басылган аяк киеменә бүген дә ихтыяҗ зур, аны төп җитештерүче — «*Кукмара киез итек-киез комбинаты*». Ш.у. к. *Киез итек–киез җитештерү.*



Кукмара киез итекләре. 21 йөз башы.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Халиков Н.А.Хозяйство татар Поволжья и Урала. К., 1995; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

**КИЕ́З ИТЕ́К–КИЕ́З ҖИТЕШТЕРУ́**, җиңел сәнәгатьнең киез, басылган аяк киеме, йон һәм мамык баш киемнәре, киез детальләр эшләп чыгаручы тармагы. Киез һәм басып эшләнгән аяк киеме җитештерү өчен сарык, кәҗә, сыер һ.б. хайваннар йоны, кыйммәтле мех, сарык тиресеннән туннар тегү һ.б. йон эшкәртүче производство калдыклары, йон корама кисәкләре кулланыла; киез эшләнмәләрнең кайбер төрләре өчен йон б-н катнашмада мамык, ясалма (штапель) тукыма файдаланыла. Йон баш киемнәре бары тик нечкә сарык йоны һәм аңа сыйфаты б-н туры килә торган таралган йоннан җитештерелә. Фетр эшләнмәләр, башлыча, куян һәм йорт куяны мамыгыннан әзерләнә. К.и.-к.җ. технол. процессының төп элементларына түбәндәгеләр керә: чимал әзерләү, катнашма булдыру, тарау, киез салу, тыгызлау (киезләндереп басу), тәгәрәтү, буяу, киптерү, бизәкләү, сыйфатын тикшерү, маркалау һәм төреп кую.

Хәзерге Татарстан терр-ясендә К.и.-к.җ. 18 йөздә, вак һөнәрчелек кәсепчелеге буларак, Мамадыш, Буа, Минзәлә, Чистай, Казан өязләрендә киң таралыш ала. 19 йөз башында губернада шактый күләмдә киез эшләпәләр, кисәкле киезләр җитештерелә. Беренче пр-тиеләр 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Казанда Е.Е.Сафроновның остаханәсе (1864 елда нигезләнә) һәм шул ук хуҗаның басылган аяк киеме ф-касы (1895 тә нигез салына); Кукмара авылында бертуган Н.В. һәм С.В.Комаровларның киез һәм тула аяк киеме механик ф-касы (1870 тә нигез салына) һәм Г.П.Войдиновның басылган аяк киеме ф-сы (1880 дә оештырыла); Жилой Рудник посёлогында (Кукмара р-ны) бертуган Родыгиннарның фабрика-сәүдә ширкәте (1897 дә нигезләнә) аларның иң эреләреннән исәпләнә. 1918–21 дә барлык К.и.-к.җ. пр-тиеләре национализацияләнә. 1923 тә алар базасында механикалаштырылган зур

пр-тие — Кукмара «Красный текстильщик» киез итек-киез ф-касы оештырыла (к. «*Кукмара киез итек-киез комбинаты*»). 1932 дә Казан киез итек-киез ф-касы (к. «*Валком*») сафка баса. 1930 елларда басылган аяк киемнәре һәм киез әйберләр цехлары һәм производстволары Җирле сәнәгать, сәнәгый кооперация министрлыгы карамагында була. Бөек Ватан сугышы елларында республиканың К.и.-к.ж. пр-тиеләре фронт ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен эшли. 7 млн. пардан артык киез итек басыла, 11 млн. пардан күбрәге яңадан торгызыла; оборона сәнәгатенең авиация, танклар һ.б. тармаклары өчен 1000 *т* дан артык киез һәм 20 млн. киез детальләр җитештерелә. 1950 елларда, К.и.-к.ж. пр-тиеләрен реконструкцияләгәннән соң, продукция эшләп чыгару 2 тапкыр арта, ел саен 4 млн. пар аяк киеме басыла, 4–4,5 мең *т* төзелеш киезе, сәнәгать ихтыяҗлары өчен 1 млн. нан артык киез детальләр әзерләнә. 1970–80 елларда К.и.-к.ж. пр-тиеләрендә күп көч таләп итә торган процесслар, өзлексез эшләү линияләре, конвейерлар механикалаштырыла, яңа җиһазлар куела, станоклар паркы яңартыла. Яңа производство мәйданнары төзелә, булганнары үзгәртеп корыла. 1980 еллар ахырына җитештерүне механикалаштыру дәрәҗәсе 85–87% ка җитә. 25 төргә якын басылган аяк киеме, 10 төр киез, ш.у. сәнәгать, төзелеш һәм транспорт оешмалары өчен 1,5 мең исемдәге киез детальләр эшләп чыгару үзләштерелә. Продукция дөньяның 19 иленә җибәрелә. 1990 еллар башында җитештерүнең түбәнәюе күзәтелә. 1995 тән башлап продукция эшләп чыгару күләмнәре арта, чимал б-н тәэмин итүчеләр һәм продукцияне кулланучылар б-н сәүдә-икътисади бәйләнешләр торгызыла. 2009 да ТРның К.и.-к.ж. пр-тиеләрендә 1000 нән артык кеше эшли, җитештерү күләме 784,6 меңнән күбрәк пар аяк киеме, 400 *т* дан артык киез тәшкил итә.

*Әд.:* Б е л я л о в У.Б. Руководство Коммунистической партии социалистической индустриализацией в национальных республиках Среднего Поволжья. К., 1978; Рабочий класс Татарии (1946–80): Док. и материалы. К. 1981; Казанскому валяльно-войлочному комбинату 60 лет. К., 1992; География Кукморского района. Кукмор, 1996.

*К.Ф.Фәсхетдинов, Г.Я.Мәүлетова.*

**КИЕ́К КАЗ ЮЛЫ́**, к. *Галактика.*

**КИЕ́К МӘТРҮШКӘСЕ́** (Acinos), иренчәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм сирәк кенә күпьеллык үсемлекләр ыругы. 10 га якын төре билгеле, күбесенчә Урта диңгез буе зонасында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — кыр К.м. (A. arvensis) ара-тирә барлык районнарда очрый. Сирәкләнгән урманнарда, куаклар арасында үсә. 10–30 *см* биеклектәге берьеллык төкчәле үсемлек. Яфраклары ланцетсыман яки йомыркасыман озынча, кыска саплы. Чәчәкләре зәңгәрсу аксыл-шәмәхә, кыска чәчәк сапларында, 2–6 шар булып куе булмаган боҗракка урнашкан, ул исә өске яфракларның куентыгында. Аскы иреннәре өскеләренә караганда ике тапкыр озынрак. Җимеше — чикләвекчек. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре җәй дәвамында һәм көзен өлгерә. Составында витаминнар һәм эфир мае булган яфраклары тәмләткеч буларак кулланыла. Декоратив үсемлек.

**КИЕКЛЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 26,5 *км*, бассейнының мәйданы 134,3 *км*$^2$. Идел аръягы түбәнлеге буйлап ага, Нурлат районында. Елга башы 3 нче Съезд исем. посёлоктан 3 *км* көнчыгыштарак, тамагы Киекле авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагынык ы— 74 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. К.нең 2 дән алып 4 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,27 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,5 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КИЕКЛЕ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 1090 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Киклы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек, тукыма ману б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә мәчет була. 20 йөз башында 3 мәчет, 3 мәктәп, тимерче остаханәсе, ярма яргыч, тегермән, 11 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3463 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 1626, 1897 дә — 2454, 1908 дә — 2684, 1920 дә — 2830, 1926 да — 2301, 1938 дә — 1981, 1949 да — 1548, 1958 дә — 1571, 1970 тә — 1953, 1979 да — 1740, 1989 да — 1304, 2002 дә — 1242 кеше.

**КИҖЕ́-МАМЫ́К ҖИТЕШТЕРҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, текстиль сәнәгатенең кием-салым, аяк киемнәре, оеклар һәм оекбашлар җитештерү, ш.у. йорт җиһазлары ясау, машиналар төзү һ.б. тармаклар өчен пахтадан мамык, эрләнгән җеп һәм тукымалар (ситсы, сатин, бәз һ.б.) эшләп чыгару тармагы. Үзенең үсеше дәверендә К.-м.ж.с. мануфактура һәм машина индустриясе этапларын уза. 18 йөздә җитен *тукучылыгы* җирлегендә *комач мануфактуралары* барлыкка килә. 1812 елда Казан губернасында елга 514 мең аршын комач һәм яулыклык тукымалар эшләп чыгаручы шундый 9 пр-тие була, аларда 534 эшче һәм 307 стан исәпләнә. Барлык пр-тиеләр читтән, башлыча Бохарадан, китерелгән чималны кулланалар. Тукымаларның күп өлеше Россиянең төрле шәһәрләренә, ш.у. Украинага, Урта Азиягә, Кытайга, Персиягә җибәрелә.

1820 дә кытай тукыма (киҗе-мамыктан тыгыз тукыма) җитештерүче пр-тиеләр оештырыла башлый; 1835 кә аларның саны 10 га җитә, продукция күләме 4,5 млн. аршын тәшкил итә. 19 йөз уртасында Мәскәү һәм чит ил җитештерүчеләре б-н ярыша алмаган комач пр-тиеләре кытай тукыма җитештерүгә күчә, тукыманың бу төре ярминкәләрдә тиз сатыла. Әлеге чорда, башлыча Казан, Мамадыш, Лаеш, Царёвококшайск өязләрендә тупланган вак кәсепләр элеккечә үк зур роль уйныйлар.

1840 елларда машиналар ярдәмендә җитештерү башлана: Казанның 3 мануфактура пр-тиесендә Англиядән һәм Бельгиядән кайтартылган эрләү һәм туку станоклары урнаштырыла. 1845 тә сәүдәгәр В.Л.Кекин Чистай шәһәрендә пар машинасы куелган зур мамык эрләү ф-касы оештыра (эшләүчеләр саны — 325 кеше; 1881 дә Казан эшмәкәрләре Ә.Рәхмәтуллин һәм Б.Субаев тарафыннан сатып алына, 1900 дә ябыла).

1857 дә Казан губернасында 13 киҗе-мамык пр-тиесе 3,6 млн. аршын кытай тукыма һәм 2 мең пот мамык җитештерә, аларда 603 кеше эшли. 1870 кә кытай тукыма җитештерү — 24,8 млн. аршынга, мамык эшләп чыгару 5 мең потка җитә. Чимал буларак Бохара һәм Хива пахтасы кулланыла. Продукция Казанда, Түбән Новгород, Эрбет, Сембер, Карсун ярминкәләрендә, Иркутскида сатыла.

19 йөз ахырында илнең башка төбәкләрендә тармак үсеше алга китү нәтиҗәсендә Казан губернасында К.-м.ж.с. таркалу хәленә килә: нибары 4 киҗе-мамык җитештерү (160 эшләүче) һәм 1 мамык тарау (5 эшләүче) пр-тиесе кала. Аларның иң эреләре Казанда урнаша: М.М.Әҗемов варисларының туку һәм ману ф-калары гомуми исәпләгәндә 2,3 млн. аршын кытай тукыма һәм бәз эшләп чыгаралар; «Үтәмешев һәм К°» бәз ману ф-касында елга 176 мең аршын чамасы бәз манула.

Беренче бөтендөнья сугышы чорында тармак пр-тиеләре фронт ихтыяҗлары өчен эшли. Окт. рев-циясеннән соң фабрикалар национализацияләнә. Гражданнар сугышы елларында продукция, башлыча, Кызыл Армиягә җибәрелә.

1920 дә Татарстанда 23 кеше эшләгән 2 пр-тие айга 800 аршын киҗе-мамык тукыма, 500–600 пот мамык җитештерә. 1929 да Казан мамык ф-касы ачыла (эшләүчеләр саны — 115 кешедән артык, иң зур җитештерү күләме 5 мең *т* га җитә, 1985 кә кадәр эшли). 1940 та республиканың К.-м.ж.с. продукциясе 28 *т* эрләнгән җеп, 50 мең *м* тукыма, 2100 *т* мамык тәшкил итә.

1942 дә ТАССРга Калинин өлкәсеннән Вышний Волочёк киҗе-мамык комб-ты җиһазлары һәм белгечләре эвакуацияләнә. 1943 тә алар җирлегендә Алабуга, Мамадыш һәм Чаллы шәһәрләрендә сугыш чорында башлыча фронт ихтыяҗлары өчен эшләгән

киҗе-мамык ф-калары оештырыла. 1963 тә бу ф-калар Алабуга киҗе-мамык ҖБнә берләштерелә. Төп пр-тие — Алабуга киҗе-мамык ф-касы, эрләнгән җеп, агартылмаган җеп, бәз җитештерә, эшләүчеләр саны — 940 кешегә, еллык тукыма эшләп чыгару күләме 8,6 млн. *м* га җитә; 700 ләп кеше эшләгән Мамадыш мамык эрләү ф-касы елга 400 *т* чамасы эрләнгән җеп һәм 3,3 млн. *м* тукыма җитештерә; 50 эшчесе булган Чаллы киҗе-мамык эрләү-туку ф-касы мамык, марля, бәз эшләп чыгара, барлык эшчәнлек чорында анда 82 млн. *м* тукыма җитештерелә (1971 дә Түбән Кама сусаклагычы астында калганнан соң бетерелә). Берләшмә пр-тиеләре киңәйтелә һәм модернизацияләнә: Мамадыш мамык эрләү ф-касында яңа җитештерү корпусы төзелә, илдә чыгарылган автомат станоклар, ш.у. түгәрәк эрләү машиналары урнаштырыла. Нәтиҗәдә тукучы 3–4 станок урынына 25 станокка, эрләүче 600 ләп орчыкка хезмәт күрсәтә башлый. Алабуга киҗе-мамык ф-касында яңа эрләү машиналары куела. 1970–80 елларда фабрикаларда зур модернизация уздырыла: югары җитештерүчәнлекле эрләү, тарау, урау машиналары гамәлгә кертелә, бәзнең яңа төрләрен эшләп чыгару үзләштерелә. 1970 тә тармак пр-тиеләре 2604 *т* эрләнгән җеп, 8,9 млн. $м^2$ тукыма, 2911 *т* мамык эшләп чыгаралар. 1975 тә Буа мамык ф-касы оештырыла (эшләүчеләр саны — 40 кеше, җитештерү күләме — айга 30 *т* га кадәр). 1970 елларның 2 нче яртысыннан тармакның җитештерү күләме кими бара. 1990 да продукция эшләп чыгару: эрләнгән җеп — 1511 *т*, ,тукымалар — 3 млн. $м^2$, мамык — 811 *т* тәшкил итә.

1990 елларда чимал җитмәү, аңа бәяләр арту, чит илләрдән кертелгән арзанлы продукция б-н ярыша алмау 1992 дә — Алабуга, 1994 тә — Мамадыш, 1995 тә Буа ф-каларының бөлгенлеккә төшүенә һәм ябылуына китерә.

*Әд.:* З а й ц е в К. Очерк развития и настоящего положения китаечного производства. К., 1858; А б з я н о в М.Д., Л а п ш и н Н.П., М о т р о х и н Ю.В. Здравствуй, Елабуга. К., 1980; История Казани: В 2 т. К., 1988–91; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана: В 2 т. К., 2001.

*М.Ж.Гаитов.*

**КИ́ЗЕЛ**, *Пермь өлкәсендәге* шәһәр (Пермьнан 200 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 29,8 мең кеше (2010), 4481 татар (2002). К.дә татарлар 19 йөздә күренә башлый, 1940 елларның 2 нче яртысында алар күпләп күченә, башлыча фәкыйрь авыллардан К. шахталарына эшкә урнашу нияте б-н килә. Хәзерге вакытта Татарстан б-н берлектә мәдәният һәм икътисад өлкәсендәге проектлар тормышка ашырыла. 2001 дән мәчет эшли. Шәһәрдә Сов. Союзы Герое М.Р.*Хәсәншин*, Соц. Хезмәт Герое Г.Г.Габдерәхимов яшәгән.

**КИЗИ́К БИСТӘСЕ́**, Казанның төньягында, Казансуның уң ярында 17 йөзнең 2 нче яртысында Кәҗә бистәсеннән (хәзер Декабристлар урамының бер өлеше) ерак булмаган урында барлыкка килә. 1654–56 еллардагы чума эпидемиясе вакытындаКазаннан күчеп утырган шәһәр халкы нигез сала. Исеме *Кизик ирләр монастырена* (17 йөз ахырында нигез салына) нисбәтле. Гади халык арасында әлеге урын «хижица» дип йөртелә. 1825 тән шәһәр составында.

*Әд.:* Б и к б у л а т о в Р., М у с т а ф и н Р. Казань и её слободы. К., 2001.


**КИЗИ́К ИРЛӘ́Р МОНАСТЫРЕ́**, Казандагы 17–20 йөзләр рус дини архит-ра ядкәре. Казан Кремленең төньягында, Казансу елгасының уңъяк ярында (хәзерге Мәскәү р-ны терр-ясендә) урнашкан. 1688–89 елларда митрополит *Адриан* тарафыннан Седмиозёр монастыреннан ел саен тантаналы төстә Седмиозёр Мәрьям Ана иконасын күтәреп бару һәм очрашу урынында нигез салына. Баштарак Введение монастыре дип йөртелә. Хәзерге исемен 1692 дә патриарх Адриан монастырьга Кизик газап чигүчеләренең (Кизик ш. исеменнән, Кече Азия) изге сөякләрен тапшырганнан соң ала. Беренче төзелешләр монастырь башлыгы Стефан Сахаров җитәкчелегендә башлана. Агач чиркәү 1688 дә салына, 17–18 йөз ахырында тагын берничә таш чиркәү һәм корылма калкып чыга. Корабсыман итеп төзелгән, 16–17 йөзләр чиркәүләре өчен типик барокко стилендә бизәлгән 9 Кизик газап чигүчесе өчен янкорма (17 йөз ахыры) Введение Пресвятой Богородицы чиркәвенә кушып салына. Барокко стилендәге Изге апостолларга тиң кенәз Владимир чиркәве (17 йөз ахыры) таш капка өстенә корыла; архидьякон Стефан чиркәве (18 йөзнең 1 нче яртысы) монастырьның почмагындагы дивар янында төзелә (хәзер юк); дивар эчендә таштан кәшәнә корыла (соңрак сүтелә).

1835–36 да Введение Пресвятой Богородицы чиркәвенә арх. Ф.И.Петонди проекты буенча дорик ордер элементлары кергән классицизм стилендәге һәм квадрат шәкелендәге дүрт яруслы чаң манарасы кушып салына (сакланмаган). 1840 та аның өчен сәүдәгәр П.И.Котелов акчасына 157 пот 17 фунт авырлыктагы чаң коялар. 1882 дә сәүдәгәр М.Н.Вениаминов-Башаринов иганәсенә псевдовизантия стилендәге Успение Пресвятой Богородицы чиркәве төзелә (сакланмаган).

19 йөз ахырында монастырь дивары артында арх. С.В.Бечко-Друзин проекты буенча кәшәнә корыла. Ул 1891 нең 28 апрелендә (9 Кизик газап чигүчесен искә алу көне) Отсу шәһәрендә (Япония) тәхет варисы Николай Александровичның һөҗүм вакытында үлемнән котылып калу истәлегенә төзелә.



Казандагы Кизик ирләр монастыре.
17 – 20 йөз башы. 1870 еллар фоторәсеме
(фотограф Е.А.Аршаулов).



Кизик ирләр монастыре. Кенәз Владимир чиркәве. 1691. Хәзерге күренеше.

Безнең көннәргә кадәр 2 бина сакланып калган. Изге апостолларга тиң кенәз Владимир чиркәве барокко стилендәге дүрткырлыкка утыртылган сигезкырлы колоннасыз дини корылма үрнәген гәүдәләндерә. Чиркәү зур итеп кызыл кирпечтән салынган һәм измә б-н шомартылган. Бер-берсе б-н тоташтырылган төрле зурлыктагы дүрт залдан тора. Дүрткырлы төп залга туры почмаклы аш бүлмәсе кушып салынган, аш бүлмәсенең почмагына кечерәк бүлмә кушылып тора. Гыйбадәт залының икенче ягына апсида рәвешендәге дүрткырлы, эчке диварлары түгәрәкләп эшләнгән бина тоташкан. Гыйбадәт залы уң яктагы биек а́рка (элек үтеп йөри торган) өстенә урнашкан. Түбәнрәк урнашкан сул як а́рка аш бүлмәсе астына туры килә. Үзәк бина суганбашлы гөмбәз б-н очланган. Чиркәү капкаларының порталы зиннәтле фронтон, чыгынтылар б-н төгәлләнгән, стена яссылыгыннан калкып чыккан колонналар б-н көчәйтелгән. Үзенчәлекле ялган балюстрада — фасадның мөһим элементы. Чиркәү интерьерында баскычлы тромплар һәм 8 кырлы гөмбәз сакланып калган. Алтарь гөмбәзе күп кырлы итеп эшләнгән. Чиркәүнең үзәк залы өч ярусла иконостас, аш бүлмәсе исә изгеләрдән — Дионисий, Симеон Столпник, Ходай бәндәсе Алексий, Тихвин Мәрьям Ана (иконостасы юкка чыккан) сурәтләре б-н бизәлгән. Чиркәү тартмаларында Рус Православие чиркәве тарафыннан хөрмәт ителгән 50 дән артык христиан изгесенең һәм могҗиза тудыручысының сөякләре саклана. К.и.м.ның икенче бер сакланып калган корылмасы (1895) Декабристлар урамына почмагы б-н чыгып торган өч катлы таш йорттан гыйбарәт. Әҗнәбиләрдән чиркәү укытучылары әзерләүче семинария урнашкан Г-рәвешле бина көнбатыш яктан Владимир чиркәвенә кушып салынган; ул — соңгы классицизм стилендә, фасадлар һәм интерьерларны бизәгәндә декор аз кулланылган.

Бинада чиркәү-приход мәктәбе урнашкан. 2002 дә сакланып калган биналарның күпчелеге чиркәүгә тапшырыла, 2003 тән монастырь яңадан эшли башлый (2006 ның сен-

тябренә кадәр К.и.м. биналарының бер өлешендә Казанның Мәскәү р-ны хәрби комис-ты урнаша). К.и.м.ның зиратында күп кенә мәшһүр казанлылар: Г.П.*Каменев*, И.М.*Симонов*, И.А.Толстой һ.б. җирләнгән.

*Әд.:* Никанор (Каменский). Кизический Казанский монастырь: Исторический очерк его двухсотлетнего существования. К., 1891; Загоскин Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; Дульский П.М. Зилант и Кизицы. К., 1917.

*Л.М.Мортазина, Г.И.Середа.*

**КИЗЛӘВИ́** (псевд., чын исеме-фамилиясе Сөләйманов Ягъкуб) (якынча 1885, Казан губ., Чистай өязе Кизләү а. — 1940), шагыйрь, тәрҗемәче. «Күз яшьләре» (1913) исемле шигъри җыентык, үзенең шигырьләре һәм М.Ю.Лермонтов, А.В.Кольцов, С.Д. Дрожжин, Л.Н.Толстой әсәрлеренең тәрҗемәләре кергән «Бер баланың җир хакында уйлавы. Күңел ачкычы. Толстой әкиятләре» китабы (1913) авторы. Г.Тукай вафатына кайгырып, «Сөекле шагыйремез мәрхүм Габдулла Тукаев рухына» (1913) шигырен яза. Иҗатында татар халкын мәгърифәтле булырга өнди, аның киләчәк язмышын кайгырта. Шигырьләренә күңел төшенкелеге (пессимистик рух), тормышның гаделсез булуына офтану хас («Дөньяда тордым...», 1913).

*Әд.:* Татар шигърияте: XX гасыр башы / Төз. З.Рәмиев. К., 2004.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**КИЗЛӘ́Ү** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 753 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәдрәсә һәм 4 нче җамигъ мәчет — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, кирпеч сугу, мич чыгару, урманчылык, балта эше, тәгәрмәч ясау һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 4 мәчет, мәдрәсә (18 йөздән билгеле, аны тәмамлаучылар арасында Г.*Утыз Имәни* дә бар), 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3156 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 1183, 1897 дә — 1714, 1908 дә — 2110, 1920 дә — 2548, 1926 да — 1885, 1938 дә — 1650, 1949 да — 1107, 1958 дә — 1104, 1970 тә — 1386, 1979 да — 1143, 1989 да — 792, 2002 дә — 897 кеше.

**КИЗЛӘҮЛӘ́Р**, к. *Җир асты су чыганаклары.*

**КИЗНЕ́Р РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1939 елда оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Кизнер посёлогы (Ижевскидан 166 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 20549 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 2199, 1979 да — 1886, 1989 да — 1775, 2007 дә — 2756 кеше.

**КИКБО́КСИНГ** (ингл. kick — аяк б-н тибү һәм boxing — *бокс*), контактлы кара-каршы көрәш төре. Татарстанда 1985 елдан Эчке эшләр министрлыгының җинаятьләрне эзләү бүлеге хезмәткәрләре арасында, ә спорт төре буларак 1993 тән тарала башлый. Оештыручылары — А.Н.Афонин, А.А.Кашшафетдинов, И.В.Куркульский, Р.А.Йосыпов (1993–97 дә К. буенча Казан федерациясе президенты). Казан, Әлмәт, Чаллы, Алабуга, Чистай, Нурлат, Менделеев шәһәрләрендә үсеш ала. 1993 тән ТР чемпионатлары, Идел буе зоналары, халыкара турнирлар (халыкара проф. К. берлеге карамагында) уздырыла. К. буенча ТР командасы РФ чемпионатларында бронза медаль ала (1993–97), «Евразия» чемпионатында җиңә (1997). РФ, БДБ, Европа, дөнья (ш.и. яшьләр) ярышларында, ш.у. РФ, Европа, дөнья кубокларында медальләр алучылар һәм җиңүчеләр, иң яхшы спортчылар — А.Л.Алёшина, Е.Ахаев, А.Газизов, И.А.Илькаев, В.И.Куркульский, П.Макаров, А.Г.Осипов, В.Панфилов, В.Петренко, М.Р.Сафин, А.Чичеров, Р.Дәүләтшина, И.Сәйфуллин, К.Кривоногова, С.Сагорин, А.Сагорин, М.Скугорев, А.С.Сухова. Иң яхшы тренерлар — А.Н.Афонин, Г.Кобшильский, И.В.Куркульский, С.Л.Шумихин, Р.А.Йосыпов, А.В.Макейчев, С.П.Платонов, Р.У.Дәүләтшин, Л.Игнатова, А.П.Комаров, С.Г.Осипов, Ф.Ф.Шәрипов. Халыкара категорияле судьялар — М.З.Вәлиуллин, Е.Ф.Королёв. ТР К. федерациясе президентлары: Ф.Ф.Шәрипов (2002–2006), И.С.Шәфиков (2006 дан).

**КИ́КИН** Дмитрий Андреевич (16 йөз), тасвирлама төзүче. 1564–68 елларда Н.В.*Борисов-Бороздин* б-н берлектә посадлары, бистәләре б-н бергә Казан, Зөя, Чабаксарның, 1567–68 дә — посадлары һәм чиркәү җирләре б-н бергә — Лаеш шәһәренең, 1564–68 дә Борисов-Бороздин, подьячийлар Б.Павлов һәм А.Сумороков б-н бергә — Казан өязенең, 1564–67 дә Борисов-Бороздин һәм дьяк А.Новиков б-н бергә Зөя өязенең тасвирламасын төзи.

*Әд.:* Симбирский сборник. М., 1845. Т. 1; Писцовые книги города Казани 1565–1568 гг. и 1646 г. // Тр. Ист.-археогр. ин-та. Л., 1932. Т. 3; Ермолаев И.П. Казанский край во второй половине XVI–XVII вв.: Хронол. перечень док-ов. К., 1980.

*Д.Г.Мостафина.*

**КИЛӘХМӘ́Д**, к. *Колмөхәммәд бәк.*

**КИЛӘЧИ́** Бәдретдин (19 йөз ахыры — 20 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь. Шигырьләре «Аң» ж-лында, «Идел» г-тасында басыла; 4 шигыре Г.Тукайга багышланган. 1930 елларда нахакка репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.


**КИЛДЕБӘ́К** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 8 *км* көнчыгыштарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 594 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда «Казныш елгасы буендагы авыл» дип тә теркәлә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урман кәсәбәчелеге, балта эше, тегү, көмештән әйберләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, су тегермәне, тимерчелек, почта станциясе, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2299,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 86 ир-ат; 1859 да — 741, 1897 дә — 834, 1908 дә — 1025, 1926 да — 1098, 1938 дә — 1002, 1949 да — 780, 1970 тә — 783, 1979 да — 750, 1989 да — 588, 2002 дә — 578 кеше.

**КИЛДЕБӘ́К ХАН** (?-1362), Алтын Урда ханы (1361 дән). Чыганакларга караганда, Җанибәк хан улы дигән ялган исем б-н йөри. Сарай аксөякләре, Күк Урда ханнарына каршы килеп, К.х.ның тәхеткә булган шикле дәгъвасын яклыйлар. Фетнә ярдәмендә һәм Урда Мәлик ханны үтереп, тәхеткә утыра. Сарай әл-Җәдид, Азак, Мухша шәһәрләрендә (1361) акча суктыра. Кырымда һәм Алтын Урданың көнбатыш өлешендә ныгып алган әмир Мамай б-н сугыша. Үз олысында террор режимы урнаштыра, көндәшләрен юк итә, шуның б-н сарай аксөякләренең ризасызлыгын тудыра. *Мөрид хан* тарафыннан тәхеттән төшерелә, Азакка кача. 1362 елның җәендә Мөрид К.х.га каршы яуга китә. Сугышта К.х. үтерелә, аның гаскәрләре тар-мар ителә.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**КИЛДЕБӘ́КОВ** Мөхәммәтһади Нурмөхәммәт улы (29.3.1881, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Ишле а. — 18.8.1949, Свердловск ш.), журналист, язучы. Туган авылы мәдрәсәсендә белем ала. 1907–11 елларда Оренбург һәм Уфа шәһәрләрендә басмаханәдә эшли, «Госмания» мәдрәсәсендә укыта. Шул елларда «Фәлсәфә ноктаи нәзарыннан дин», «Ислам һәм музыка», «Егерменче гасырда безнекеләр» дигән китапларын чыгара, К.Гамсунның «Ачлык» («Голод», Оренбург, 1907) романын татарчага тәрҗемә итә. 1911–12 дә Уфа, соңрак Минзәлә земстволарында татар мәктәпләре бүлеге инструкторы булып эшли. 1908 дә журналистлык эшчәнлеген башлап җибәрә, «Вакыт» г-тасында (псевд. Нукайский), «Мәктәп» (псевд. Кемтерин), «Ялт-йолт» ж-лларында язмалары басыла. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 1916 да большевиклар партиясенә керә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң — Төньяк фронтның мөселман солдатлары ком-ты җитәкчелеге составында, «*Сугыш сафы*» г-тасы мөхәррире. 1918–19 да Эчке Россия мөселманнары эшләре комис-тының матбугат бүлеге җитәкчесе, «*Чулпан*» г-тасы мөхәррире. 1920–26 да Уфада мәгариф, игенчелек, юстиция халык комис-тларында эшли, язмалары «Урал», «Башкортстан хәбәрләре», «Яңа авыл» г-таларында басыла. 1927–29 елларда Казан ун-ты рабфагы җитәкчесе булып эшли, «Кызыл Татарстан» г-тасы б-н хезмәттәш-



Р.Ә. К и л д е б ә к о в. 1. «Алтынчәч». Кәгазь, көмеш, гуашь. 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Биюче дәрвиш». 2003; 3. «Портрет». Картон, майлы буяу. 2004.

лек итә. 1930–33 елларда — Н.К.Крупская исем. Коммунистик тәрбия академиясе тыңлаучысы. Аны тәмамлаганнан соң, Свердловскида татар пед. техникумының директоры булып эшли, анда «Социализм юлы», «Урал эшчесе» г-таларында хезмәттәшлек итә. «Ислам һәм хатын-кызлар» (Уфа, 1929), «Дания» (1929), «Төркия» (1929), «Коллектив хуҗалык һәм диннәр» (1930) китаплары авторы.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

*Р.М.Нуруллина.*


**КИЛДЕБӘ́КОВ** Рөстәм Әхмәт улы (30.3.1934, Казан), нәкышьче, график, сынчы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык рәссамы (2006), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан сәнгать уч-щесен (1954), Львов гамәли-сәнгать ин-тын (1960) тәмамлый. 1960 елдан Казанда яши һәм иҗат итә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1987). К. — сәнгатьнең күп төрләрен һәм жанрларын: монументаль-бизәлеш, станлы нәкышь, графика, *гобелен* сәнгатен гамәлгә ашырган күпкырлы талант иясе. Казанда С.М.Бубеннов һәм В.М.Маликов б-н автордашлыкта «Волга» кунакханәсе фасадын — «Казан — биш диңгез порты» сграффитосы (1961); С.М.Бубеннов һәм В.К.Фёдоров б-н автордашлыкта тимер юл вокзалы бинасын — «Казан — Татарстан башкаласы» сграффитосы (1967); «Татарстан» кунакханәсенең банкетлар залын — каюлы күн панносы (1970); В.В.Карамышев б-н автордашлыкта Төзүчеләр мәдәният сараеның тамаша залын смальта мозаикасы (1972) б-н бизи. К.ның Чаллы «Энергетик» мәдәният сараендагы «Энергия» мозаикасы (1973), Минзәлә Мәдәният йортындагы «Минзәлә җире» смальта мозаикасы Татарстанның монументаль-бизәлеш сәнгатендә җитди этап булып тора. К. Казандагы элекке Яшьләр үзәгенең йөзү бассейны бинасында (1978) һәм элекке «Казан» санаторие биналары фасадларында смальтадан ясалган мозаика паннолары («Яз», «Җәй», 1980) иҗат итә. К.ның станлы нәкыше һәм графикасы символик образларны гомумиләштерүдә декоратив-пластика байлыгы, төсләр һәм тоннар көчешенең төрлелеге б-н аерылып тора. Рәссамның программ хезмәтләре: «Әңгәмә» («Карт белән балык», 1964), «Челтәр бәйләүче хатын-кызлар» (1962–64), «Зәңгәр фондагы автопортрет», «Рәссам хатыны портреты» (икесе дә 1964 тә), «Кызыл атка атланган малай» (1965) — К. картиналарында сәнгати алым үсешен билгеләүче үзенчәлекле сыйфатларны гәүдәләндерә. 1970 елларда К. татар халык нәфис кәсепчелек темасына багышланган әсәрләр сериясен : «Арча осталары», «Арча натюрморты», «Кукмара итекләре» һ.б. картиналар иҗат итә. 1980 елларда Г.Тукай образы һәм аның шигъриятендә гәүдәләндерелгән рухи традицияләр темасына («Г.Тукайның лирик дәфтәрләреннән», «Өч шагыйрә» (икесе дә — 1986)); татар халкы тарихындагы фаҗигале вакыйгаларга («Мөһаҗирләр», «Чукындыру», «Мөртәт» һ.б.) мөрәҗәгать итә; 1990 елларда урта гасырлар татар тарихы, мөселман Шәрекъ дөньясы темасын Коръәнне сәнгатьле-образлы шәрехләү аша жанрлы әсәрләр сериясен («Чыбык-чабык күтәргән карчык», 1990; «Кунакка бару», 1991; «Хаҗилар», 1992; «Кайту», 1992; «Җирсү», 1999; «Биюче дәрвиш», «Лачын белән ауга йөрү», икесе дә — 2003 тә; «Касыйм-калада кыш. Сөембикә улы белән», 2005) тудыра. К.ның графика иҗаты киң диапазонлы: каләм һәм тушь б-н эшләнгән рәсем, акварель, гуашь, офорт, плакат сәнгате. Аның тарафыннан «Татар халык әкиятләре» (1964), «Цирк» (1970), «Урта Азия буйлап» (1983) һ.б. график серияләр әзерләнә. К.ның хезмәтләре арасында — сәнгать әсәрләренә тематик һәм стилистик яктан якын торган гобелен эскизлары; автордашы һәм башкаручысы — хатыны *М.С.Килдебәкова*. Республика (1960 тан), төбәк — «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Волгоград ш., 1969; Горький ш., 1974; Казан, 1980, 1991), бөтенроссия (Мәскәү, 1967); ТАССРның Әдәбият һәм сәнгать көннәрендә — Татарстан рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1980), Татарстан рәссамнары (Уфа, 1988; Каракалпак АССР, Нукус, 1989), Казанның 1000 еллыгына — «Татарстан рәссамнары» (Мәскәү, 2005); Җиңү көненә багышланган бөтенроссия һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәсе 1994 тә (Казан) үткәрелә.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, Нукус Сынлы сәнгать музеенда, Халык иҗаты һәм этнография музеенда (Яшел Үзән ш.), Саратов сәнгать музеенда саклана.

*Д.Д.Хисамова.*

**КИЛДЕБӘ́КОВА** Мария Семёновна (20.7.1932, Украина ССР, Одесса ш.), гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Львов гамәли сәнгать уч-щесен «тукыма сәнгате» белгечлеге буенча тәмамлый (1956). 1960 елдан Казанда яши һәм иҗат итә. 1974 тән Татар сәнгать фондындагы *гобелен* иҗат остаханәсен һәм гамәли бизәлеш секциясен җитәкли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1978). К. — 1960 елларда Татарстандагы проф. гамәли-бизәлеш сәнгатенең яңа төре — гобелен остасы. К.ның гобеленнары композиция һәм төсләр гармониясенең камиллеге б-н үзенә җәлеп итә; аларда материалның декоратив сыйфатын ачып бирүдә җанлы фантазия б-н камил зәвык үзара яраша. К.ның беренче гобеленнарыннан — «Музыка» (1964) халыкчан типаж, өс киемнәре, стильләштерелгән милли бизәкләр декоратив символиканың зарури өлешләре булып кабул ителә; «Сабантуй» (1969) татар туку һөнәрчелегенә хас үзенчәлек һәм асалап туку алымы б-н башкарылган һ.б. 1970 еллар башында К. гобелен остаханәсе рәссамнары б-н бергә (Г.Маликова, Г.Шәрипова, Р.Килдебәков, А.Егоров) Көнкүреш йортының төп залы өчен 64 $м^2$ зурлыктагы «Татарстан» дивар келәме иҗат итә (Казан, 1976). Келәмдә орнаментлы символика б-н беррәттән төсләр экспрессиясе хисләр доминантына әверелә. Төп әсәрләре: «Алтынчәч» (1970), «Очыгыз, күгәрченнәр» (1971), «Гөлчәчәк» (1974), «1918 ел» (1979), «Икар» (1970 еллар, Чит ил белгечләре йорты, автордаш — Р.Ә.Килдебәков), «Г.Тукай» (1986, автордаш — Р.Ә.Килдебәков), «Нигез салу» (1986, Татар дәүләт академия т-ры, автордаш — Р.Ә.Килдебәков) гобеленнары, «Балачак дөньясы» (Казан курчак т-ры, 1980 еллар), «Йортлар» (1997), «Татар сөлгесе» (2000), «Хаҗи» (2000, автордаш — Р.Ә.Килдебәков), «Чишмә буенда» (2002, автордаш — Р.Ә.Килдебәков) гобеленнар сериясе һ.б.

Республика (1966 дан), ш.и. гамәли-бизәлеш сәнгате (1983 тән); төбәк — «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Волгоград ш., 1969; Горький ш., 1974; Казан, 1980, 1991); «Советская Татария» (Ленинград, 1972), ТАССРның Әдәбият һәм сәнгать көннә-



М.С. К и л д е б ә к о в а. «Юлчы». Йон, кулдан туку. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.





М.С.Килдебәкова. 1. «Мисырга качу». Йон, туку. 1990; 2. «Икәү». Йон, туку. 1995. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

рендә — Татарстан рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1980); РСФСРның автономияле республикалары һәм өлкәләре рәссамнары (Мәскәү, 1989) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, Халык иҗаты һәм этнография музеенда (Яшел Үзән ш.) саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Гулова Ф.Ф. Путь утверждения гобелена в искусстве Советского Татарстана // Искусство Татарстана: пути становления. К., 1985; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Д.Д.Хисамова.*

**КИЛДЕ́Ш** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тәтеш–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 457 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә чиркәү, мәктәп була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2198 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 1202, 1880 дә — 1498, 1913 тә — 2404, 1926 да — 1963, 1938 дә — 1583, 1949 да — 1216, 1958 дә — 1158, 1970 тә — 1004, 1979 да — 761, 1989 да — 580, 2002 дә — 504 кеше.

**КИЛДИ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 38 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чангар елгасы буенда. 2010 елда 217 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1565–67 еллардан мәгълүм. Халкы башта Троица-Сергий монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек, урманчылык, тегү һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә Троица чиркәве (1792 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1864 елдан эшләүче приход мәктәбе җирлегендә 1885 тә ачыла), 8 җил тегермәне, тимерчелек, 2 сырыханә, 1 казна шәраб, 4 вак-төякләр кибете була; җомга саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3110 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 281, 1782 дә — 359 ир-ат; 1859 да — 855, 1897 дә — 1014, 1908 дә — 1131, 1920 дә — 1097, 1926 да — 1010, 1938 дә — 673, 1949 да — 388, 1958 дә — 359, 1970 тә — 346, 1979 да — 330, 1989 да — 288, 2002 дә — 262 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый ... К., 2001.

**КИЛДУРА́З** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 21 *км* төньяктарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 348 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да волость идарәсе урнаша; мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 841,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 346, 1897 дә — 516, 1908 дә — 655, 1920 дә — 748, 1926 да — 863, 1938 дә — 821, 1949 да — 758, 1958 дә — 582, 1970 тә — 540, 1979 да — 656, 1989 да — 380, 2002 дә — 367 кеше.

**КИЛДУРА́З** тимер юл станциясе посёлогы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов — Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 299 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 73%) яши. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 1942 дә нигез салына. Оештырылган көннән Апас р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1989 да — 349, 2002 дә — 361 кеше.

**КИЛЕ́Ш**, исемнәргә хас грамматик категория. Исемнең җөмләдәге башка сүзләргә карата төрле мөнәсәбәтен белдерә. Хәзерге татар телендә килеш мөнәсәбәтләре төрле чаралар ярдәмендә хәл ителә. Бер очракта бары суффикслар гына кулланыла (һәрвакыт сүз ахырында) — синтетик чаралар; икенче бер очракта бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр генә кулланыла — аналитик чаралар. Моннан чыгып, синтетик һәм аналитик К.ләрне аерып күрсәтәләр. Татар грамматикасында традицион 6 синтетик К. билгеле: баш килеш, иялек килеше, юнәлеш килеше, төшем килеше, чыгыш килеше, урын-вакыт килеше.

Татар телендә К. кушымчаларының берничә варианты бар. Сүзнең нигезенә карап, кушымчада я алгы рәт сузыклар, я арткы рәт сузыклар кулланыла (к. *Сингармонизм*): -ның/-нең (ташның, мәктәпнең), -ны/-не (ташны, мәктәпне) һ.б. Юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт К.ләре кушымчаларының яңгырау һәм саңгырау тартыклардан башланган төрләре дә бар: -га/-гә (балага), -ка/-кә (мәктәпкә), -дан/-дән (баладан), -тан/-тән (мәктәптән), -да/-дә (балада), -та/-тә (мәктәптә). Ң, н яки м тартыкларына беткән сүзләргә чыгыш килешендә -нан/-нән кушымчалары ялгана (таңнан, урамнан, көннән). 1960 еллар ахырында М.З.Зәкиев төрки телләргә күпкилешлелек хас дигән фикер әйтә. Ул -лы, -сыз, -ча, -дай, -дагы кебек кушымчаларны да, исемнәрнең башка сүз төркемнәре б-н үзара бәйләнешен барлыкка китерүчеләр буларак, килеш кушымчалары рәтенә кертеп карый. Ф.Ә.Ганиев тә әлеге фикерне куәтли, шулай да М.З.Зәкиев тарафыннан килеш кушымчасы буларак каралган -ча ны ул бу төргә кертми; галим дуслар белән, Ватан өчен, шәм кебек, дуслар хакында, юл буенча, болыт астыннан, вагон өстенә, игътибарсызлыгы аркасында кебек бәйлекләр, бәйлек сүзләр һәм бәйлек ролендәге ярдәмче исемнәр б-н килгән тезелмәләрне дә килешләр системасына кертеп карарга тәкъдим итә. Ул ш.у. синтетик-аналитик К.ләрне (килеш кушымчасы б-н бәйлекнең ярашуы — урманга хәтле) һәм аналитик-синтетик К.ләрне дә (килеш кушымчасы б-н бәйлек сүзнең ярашуы — урман янына) аерып күрсәтә.

*Әд.:* Сәмирханова Г.Р. Хәзерге татар әдәби телендә килеш мөнәсәбәтләренең белдерелүе. К., 2005; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Зәкиев М.З. К вопросу о категории падежа в тюркских языках // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. К., 1964; Ганиев Ф.А. О синтетических и аналитических падежах в татарском языке // Вопросы тюркологии. К., 1970; Татарская грамматика. К., 1993. Т. 2.

**КИЛИ́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы буенда. 2010 елда 357 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч

мәктәп, мәдәният йорты. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда «Олы Норма кыры чиге» исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 810,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 535, 1897 дә — 679, 1908 дә — 731, 1920 дә — 676, 1926 да — 520, 1938 дә — 631, 1949 да — 510, 1958 дә — 400, 1970 тә — 384, 1979 да — 359, 1989 да — 304, 2002 дә — 325 кеше.

**КИЛМӨХӘММӘ́Т** бине Ишман (17 йөзнең 2 нче яртысы), ташка уеп язу остасы, хаттат. К.нең сәнгатьчә бизәп язган кабер ташлары Татарстан терр-ясендәге Кама елгасының уңъяк ярына урнашкан һәр районда очрый. Кайчакта аларны 17–18 йөзләрдәге мөселман зиратлары урыннарында табалар. Кабер ташларының бизәлеше Казан ханлыгы һәм Касыйм ханлыгы чорыннан сакланып калган үрнәкләргә якын, ләкин аларның күләме кечкенә, буе беркадәр тәбәнәк, хәрефләрнең биеклеге ике тапкырга ким. Эпитафия текстларында да аермалыклар бар: элегрәк кабул ителгән «фани дөньялыктан бакыйлыкка күчте» дигән башлангыч формула урынына К. мәрхүмнең исемен һәм аның өчен үтенүле дога юлларын уеп яза. Башка урыннарны ул урта гасырлар традицияләренә таянып бизи. Ак таш плитәләрнең очын оста ярымтүгәрәк яки өчпочмак рәвешендә ясый; өске өлешен тирәнәйтелгән уемлау ысулында традицион матур чәчәкле үсемлек сурәте б-н бизи. Бизәк һәм язулардан торган композиция рельефлы кайма б-н әйләндерелә. Текст юллары арасында 3–4 *см* ара калдырыла. Гадәттә, текстлар 5–7 юлга урнаша һәм гарәп каллиграфиясе б-н сөлес имлясында уеп языла. Үзенең хезмәтләрен автор «Килмөхәммәт Ишман углы» дип имзалый. Ташка уеп язу остасы — хаттатның исемен беренче тапкыр 1960 елларда Һ.В.Йосыпов хезмәтендә искә ала. Соңрак К. эшләгән кабер ташлары туган якны өйрәнүче М.Тарханов һәм М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан табыла.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Татар кулъязма китабы. К., 2000; Ю с у п о в Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; А х м е т з я н о в М.И. О лексике татарских эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. К., 1983.



Килмөхәммәт бине Ишман. Кабер ташы. Уеп бизәкләү. Имәнкискә авылы. 17 йөз.

**«КИМ»** с о в х о з ы п о с ё л о г ы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 38 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 547 кеше (руслар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Халкының төп шөгыле — кырчылык, нәселле терлек үрчетү. Май з-ды. 1917 дә Михайловский һәм Александровский авылларының кушылуы нәтиҗәсендә төзелә. Башта Казан губернасының Спас өязе Спас волостенда. 1920 дән — ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 326, 1949 да — 284, 1970 тә — 826, 1979 да — 717, 1989 да — 608, 2002 дә — 575 кеше.


**«КИМ»** с о в х о з ы н ы ң и к е н ч е ф е р м а с ы п о с ё л о г ы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 36 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 175 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, нәселле терлек үрчетү. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1949 да — 59, 1989 да — 186, 2002 дә — 186 кеше.

**КИМӘ́К КАГАНЛЫГЫ́**, 10–11 йөзләрдә Көнбатыш Себер, Көньяк Урал һәм Төньяк Арал җирләрендәге урта гасырлар төрки дәүләте. Уйгыр каганлыгыннан аерылып чыккан *кимәкләр* кабиләләренең берләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. К.к.нда татарлар кабиләсе ыругы идарә итә. 8–9 йөзләрдә кимәкләр идарәчесе — шад, К.к. оешкач (10–11 йөзләр), ул каган титулы йөртә. К.к.нда берничә шәһәр — Кимакия, Сангир һ.б. була. 10 йөздә — 11 йөз башында караханилар дәүләте һөҗүменә каршы тора, көчсезләнә һәм көнчыгыш төрки кабиләләр һөҗүме аркасында таркала.

Әд. к. *Кимәкләр*.


*И.Л.Измайлов.*

**КИМӘКЛӘ́Р** (йәмәк, имәк), 7–13 йөзләрдә Үзәк Азиядә, Көньяк Себердә һәм Урал буйларында яшәгән төрки кабиләләр берлеге. Чыгышлары буенча Иртеш буе һәм Алтай төрки кабиләләре б-н бәйле. Фаразланганча, Сросткино археол. культурасына керәләр. Көнбатыш Төрки һәм Уйгыр каганлыклары составында булалар. Кабиләләр берлеге нигезен ими, йәмәк, татар, баяндур, кыпчак, ләникәз, аҗлад кабиләләре тәшкил итә. Төп шөгыльләре — ярымкүчмә терлекчелек, ш.у. игенчелек һәм һөнәрчелек (тимердән, бронзадан әйберләр эшләү һ.б.). Диннәре — мәҗүсилек (ш.и. тәңречелек); 9 йөздән — ислам. Күмү йоласы, археол. мәгълүматларга кара-



Кимәкләрнең таш балбаллары (А.А.Чариков буенча). 11–12 йөзләр.

ганда, курган астына таш өеп башкарыла; мәет б-н бергә ат, әйберләр (корал, сугыш кирәк-яраклары, бизәнү әйберләре һ.б.) урнаштырыла. 10 йөз ахырында кимәк кабиләләре берлегеннән Көнчыгыш Европа далаларына басып кергән *кыпчаклар* аерылып чыга. 10–11 йөзләрдә К. *Кимәк каганлыгы* оештыралар. Ул таркалганнан соң 12 йөздә — 13 йөз башында К.нең иң көчле этносәяси берләшмәсе Илбари була. 13 йөздә К.не монгол ханнары буйсындыра, аларның аксөякләре һәм кабилә системасы юк ителә. К. монголларның олыс структурасына кушыла, Алтын Урданың сул канаты (Күк Урда) сос-



Кимәкләр каберлекләреннән табылган әйберләр комплексы (Д.Г.Савинов буенча).

тавына керәләр һәм «татар» үзатамасы алган төрки халыклар арасында йотылалар. К. Үзәк Азия һәм Идел буе дәүләтләре тарихында зур роль уйныйлар (хәрби, сәүдә һәм дипломатия элемтәләре, хәрби хезмәткә күчү һ.б.).

*Әд.:* Кумеков Б.Е. Государство кимаков IX–XI вв. по арабским источникам. А.-А., 1972; Савинов Д.Г. Народы Южной Сибири в древнетюркскую эпоху. Л., 1984; Кляшторный С.Г., Султанов Т.И. Государства и народы Евразийских степей: Древность и средневековье. СПб., 2000; Кляшторный С.Г., Савинов Д.Г. Степные империи древней Евразии. СПб., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**КИМЕЛЬБЛА́Т** Владимир Израилевич (15.8.1951, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2002), проф. (2008). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1981 дән «Пластик» ФҖБдә (сектор башлыгы). 1992 дән Эластомерлар эшләү үзәгенең лаб. мөдире, 2004 тән Казан технол. ун-тында (бүленеп, 2001–04 тә Казан энергетика ун-ты профессоры). Хезмәтләре полимерлар химиясенә һәм технологиясенә карый. К. полимерлар һәм композицияләрне тикшерүнең реалогик алымнарын эшли, каучуклар, термопластлар, катышмалар үзлекләренең макромолекуляр структурага бәйлелеген билгели. Полимер материаллар һәм алардан эшләнмәләр алу алымнарын (компаудирлау, экструзия, пресслау, кою, эретеп ябыштыру) эшли. Фәнни хезмәтләре «Казаноргсинтез», «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкама шин з-ды», «Кварт», «Киров шин заводы» һ.б. АҖләрдә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КИМЕРҮЧЕЛӘ́Р** (Podentia), имезүчеләрнең иң күпсанлы отряды, кискеч тешләренең көчле үсеше (алар гомер буе үсә), ш.у. казык тешләре һәм азау теш өслеге булмау б-н морфологик характерлана. 40 тан артык семьялыгы һәм якынча 1700 ләп төре билгеле. Татарстан терр-ясендә очкалак тиен, тиенсыманнар, кондызлар, йонлачлар, кушаяклылар, тычкансыманнар һәм әрләнсыманнар семьялыгыннан булган 32 төре яши. Күп кенә К. үлән ашаучылар, алар — 5 *см* дан 1 *м* га кадәр зурлыктагы хайваннар, имезүчеләр арасында иң күп үрчүчеләр; ел буе үрчиләр. Кайбер К. (*тиеннәр*, *нутрия*, *очкалак тиен*, *бурындыклар*, *ондатра*, *кондызлар*) — мех җәнлекләре. Күпчелек К. (күселәр, кыр тычканнары, әрләннәр, йомраннар һ.б.) а.х. культураларына (бигрәк тә бөртеклеләргә) зыян китерәләр. ТРда, башлыча, 2 төркем К. зыян китерә: а) кыр тычканнары һәм тычкансыманнар семьялыгыннан чын тычканнар; б) тиенсыманнар семьялыгыннан йомраннар. Тычкансыман К.нең 5 төре киң таралган: гади, яисә соры кыр тычканы, җирән кыр тычканы, су тычканы, йорт тычканы. Тычкансыманнар күпләп үрчү сәләтенә ия. Гади кыр тычканы 1 елга 6–8 тапкыр (һәрберсендә 8 гә кадәр бала) китерергә мөмкин. Тычкансыманнар яз һәм җәй көннәрендә яшел терлек азыгы б-н тукланалар, иген өлгергәндә сабакларны кимерәләр һәм башактагы бөртекләрне ашыйлар, ә кыш көне кар астындагы уҗым, яшь агачларның кайрысы б-н тукланалар, печән һәм салам кибәннәрен чүп-чарга әйләндерәләр. Моннан тыш, К. терлекчелек объектларында, катнаш терлек азыгы з-дларында, элеваторлар һәм складларда зыян китерәләр, анда аларның саны уннарча меңнәргә җитәргә мөмкин.

К.нең күп төрләре — төрле куркыныч йогышлы авыруларны (кеше чумасы, лептоспироз, туляремия, котыру авыруы, дуңгыз рожасы, геморрагик бизгәк һ.б.) таратучылар.

Көрәш чаралары: биол. алым (экол. яктан чистарагы), К.нең табигый дошманнарын булдыруга нигезләнгән алым (мәчеләр, этләр, көзәннәр, ерткыч кошлар), агротехник алым — тирән туңга сөрү (кыр тычканнарының ояларын тузгыта), химик алым — азыкка кушып родентицидлар куллану. Печән һәм салам кибәненә кертелгән (сиптерелгән) сусыз аммиак (яисә аммиаклы су) К.не куркыта. ТРда К. б-н көрәшү өчен ш.у. «бактероденцид» һәм «шторм» препаратлары кулланыла.

*Әд.:* Кузнецов Н.Н. Животный мир: Географические описания Татарской Республики. К., 1921; Виноградов Б.С., Оболенский С.И. Вредные и полезные млекопитающие. М.–Л., 1932; Огнев С.И. Звери СССР и близлежащих стран. М.–Л., 1940–48. Т. 4–6; Наумов Н.П. Очерки сравнительной экологии мышевидных грызунов. М.–Л., 1948; Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1971; Попов В.А. Редкие и исчезающие виды животных Татарии. К., 1978.

*О.Л.Горшевникова, Ф.С.Зыятдинов.*

**КИНДЕ́Р** (Gannabis), киндерчәләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Ике өйле үсемлек. Ата җенесе — баса киндер, ана җенесе ана киндер була. Сабагы 0,5–4 *м* биеклектә. Яфраклары калаксыман. Баса киндернең чәчәк оешмасы — себеркәчле, ана киндернең башлы була.

Җимеше — бер орлыклы чикләвек. Яктылык, җылылык һәм дым яратучан культура. Ашламага, бигрәк тә органик ашламаларга таләпчән. К. өчен иң яхшы туфраклар — кара туфрак һәм киптерелгән торфлык. К.нең ватаны — Үзәк Азия, анда ул б.э.к. 1 нче меңьеллыктан үстерелә, ш.у. чыгышы б-н Һималайдан булуы мөмкин. ТРда 2 төре очрый: чүп үлән К. (G. ruderalis) — чәчүлекләрдәге чүп үлән, һәм чәчүле К. (G. sativa) — май һәм җеп алу өчен үстерелә. 1970 еллардан К. чәчүле туктатыла. Чәчүле К.нең матур ачык яшел төсле бакча формасын декоратив үсемлек буларак үстерәләр.



Чәчүле киндер.

**КИ́НДЕР** Иван Фёдорович (30.9.1928, Украина ССРның Каменец-Подольск өлкәсе, Шепетовка р-ны Судилково а. — 1.12.1995, Казан), язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Казан ун-тын тәмамлый (1959). 1961–89 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли. Бөек Ватан сугышы елларында эш урынында имгәнә һәм гомерлек гарип булып кала. Повесть һәм хикәяләр кергән «Текә юл» («Крутая дорога», 1971), «Юллар чатында» («Развилок», 1978), «Озын җәй» («Долгое лето», 1983), «Тәгәрмәч» («Колесо», 1987), «Дөньяда могҗиза күпме?» («Сколько чудес на свете?», 1990) һ.б. җыентыклар авторы. Аның геройлары — замандашлары, катлаулы язмышлы кешеләр, алар тыйнак, максатчан, гражданлык бурычына тугрылар. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Винокуров И. Свет души // Советская Татария. 1987. 9 авг.

**КИНДЕ́Р КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама алдында. Элеккеге су юлында сакланып калган. Алабуга р-ны Айталан авылыннан 2,3 *км* көнбатыштарак. Вятка елгасының сулъяк яры тугаенда. Су өслегенең мәйданы 3,08 *га*. Озынлыгы 970 *м*, иң зур киңлеге 45 *м*.

**КИНДЕ́Р КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама аръягында. Элеккеге су юлында сакланып калган. Азнакай р-ны Сөендек авылыннан көнчыгыштарак. Ык елгасының сулъяк яры тугаенда. Су өслегенең мәйданы 0,56 *га*. Озынлыгы 270 *м*, иң зур киңлеге 32 *м*.

**КИНДЕРКҮ́Л** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оштырма елгасы буенда. 2010 елда 398 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кадрәкүл исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, тегермән, ярма яргыч, 2 вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 734,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән — ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 273, 1897 дә — 375, 1908 дә — 429, 1920 дә — 417, 1926 да — 388, 1938 дә — 341, 1949 да — 232, 1958 дә — 224, 1970 тә — 253, 1979 да — 235, 1989 да — 205, 2002 дә — 329 кеше.

**КИНДЕРЛЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 26 *км*, бассейнының мәйданы 105 *км*². Елга, нигездә, Биектау р-ны терр-ясеннән ага, түбән агымының зур булмаган өлеше



Киндерле елгасы.

Казан чигендә урнашкан. Елга башы урман массивында, Пановка авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Колсәет авылында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 12%. К.нең 0,4 тән алып 3,7 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 113 *мм*, ташу агымы катламы 108 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*³*/с*. Суы язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 0,7 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. К. үзәнлегендә «*Остачы сөзәклеге*» табигать истәлеге урнашкан.

**КИНДЕРЛЕ́** авылы, Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында, Биектау тимер юл станциясеннән 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1595 тән Елантау Успение монастырена карый. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек, күн эшкәртү, арба тәгәрмәчләре ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә земство мәктәбе (1887 дә ачыла), тимерчелек, 2 сырахanә, 1 казна шәраб, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1348,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. 1998 нең 25 ноябреннән Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1646 да — 227, 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 657, 1897 дә — 664, 1908 дә — 746, 1920 дә — 772, 1926 да — 884, 1938 дә — 1274, 1949 да — 1317, 1958 дә — 1085, 1970 тә — 1361, 1989 да — 1883 кеше.



Киндерле авылы. Земство мәктәбе бинасы.
21 йөз башы фоторәсеме.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КИНДЕРЛЕ́** тимер юл разъезды поселогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Екатеринбург тимер юлы буенда. 2010 елда 365 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50%, татарлар — 46%) яши. 1930 елларның 2 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән Юдино р-нында. 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 32, 1958 дә — 48, 1970 тә — 102, 1989 да — 375, 2002 дә — 375 кеше.

**КИНЕМАТО́ГРАФ**. Техник аттракцион сыйфатында, «җанлы сурәтләр», «хәрәкәтләнүче фоторәсем» исемнәре б-н Казанда 19 йөз ахырында барлыкка килә. Төшерелгән сюжетлар беренче тапкыр 1897 елның 2 маенда шәһәр театрында күрсәтелә. Программада 68 картина, ш.и. Россиядә төшерелгән эпизодлар да була: «Тәхеткә утыру тантаналары» («Коронационные торжества»), «Кызыл болдыр. Император Галиҗанәпләренең тантаналы рәвештә тәхеткә атлавы» («Красное крыльцо. Торжественное шествие Их Императорских Величеств на коронацию») һ.б. 1908 дән Казанда һәм Казан губернасында хосусый стационар кинотеатрлар төзелә башлый, аларда Россия һәм чит илләрдә җитештерелгән фильмнар күрсәтелә. Беренче булып Ю.Гренингның «Аполло» кинотеатры ачыла (1916 елдан хуҗасы — О.Э.Петцольд, ул эшләгән елларда «Электра» кинотеатры дип атала башлый, соңыннан — «Татарстан»). Шулай ук «Олимп», «Ампир», «Буфф», «Пассаж», «Палас», «Художественный», «Большой театр» (1914 тә төзелә, хуҗасы — Г.А.Розенберг, хәзер Казан Зур драма театры бинасы) һ.б. кинотеатрлар ачыла. Мамадыш өязе Кукмара авылы (хәзер Кукмара штп; хуҗасы Н.И.Юзиев), Чистай («Мир чудес», 1913 тә сәүдәгәр И.Т.Токарев тарафыннан ачыла) кинотеатрлары мәгълүм. 1917 нең мартында Казанда Кинематографларда хезмәт күрсәтүчеләр берлеге оеша; аның әгъзасы О.Э.Петцольд Кинематография театрлары хуҗаларының бөтенроссия берлеге хакыйкый әгъзасы булып сайлана. 1918 дә Мәскәү киноком-ты әмере б-н Казанда шәһәрнең барлык кинотеатрларын исәпкә алучы киноком-т бүлеге оеша. 1919 да алар губерна мәгариф бүлегенең кино секциясе карамагына күчә, 1921–23 тә кинопрокат, кино һәм фотога төшерү эшләрен оештыру мәсьәләләре б-н Главполитпросветның кинофото бүлеге шөгыльләнә. 1924 тә Татарстан кинематография берләшмәсе (*Таткино*) оеша, ул кино төшерү, кино хезмәткәрләрен әзерләү б-н шөгыльләнә. 1927 дә аның функцияләре Тамаша пр-тиеләренең Татарстан идарәсенә (ТУЗП) тапшырыла. 1928 дән Казан һәм ТАССРда кино эшен оештыру һәм аның б-н җитәкчелек итү «*Востоккино*» АҖ карамагына күчә. 1930 да ТАССР ХКС каршында киноком-т оештырыла (1932 дә «Роскино» карамагына күчерелә), 1938 дән 1988 гә кадәр төрле исемнәр астында Кинофикация идарәсе эшли (к. *Татарстан АССР Кинофикация дәүләт комитеты*). 1991 дә ТССР МС каршында Кинематографияне үстерү буенча дәүләт фонды оеша (к. *Татарстан Республикасының Кинематография дәүләт комитеты*). Казанда кинофильмнар прокаты б-н беррәттән үз фильмнарыбыз да җитештерелә башлый. 1898 дә шәһәр театрында Театр мәйда-







«Казанны алу» фильмыннан кадрлар.

нында төшерелгән кадрлар да өстәп күрсәтелә: «Казан–Саратов драма артистлары ширкәтенең «Трильби» спектакле репетициясеннән соң шәһәр театрыннан чыгып барышлары». Аларда В.И.Качалов та төшереп алына. 1909 да «Пассаж» кинотеатрында — «Казан гарнизоны гаскәрләренең тантаналы парады» («Торжественный парад войскам казанского гарнизона») тасмасы, 1910 да «Аполло» кинотеатрында «Кыш озату бәйрәмендә Казан» («Казань во время Масленицы»), «Васильево. Балалар бәйрәме» («Васильево. Детский праздник»), «Ослан. Каекларда узышу» («Услон. Гонки на яликах»), «Казан авиация атналыгы» («Казанская авиационная неделя») фильмнары күрсәтелә. 1914 тә Казан земство идарәсе заказы буенча земство оештырган автомобиль ярышлары, «Казанда аеклар бәйрәме» («Праздник трезвости в Казани»), «Казанда ак чәчкә көне» («День белого цветка в Казани») фильмнары төшерелә. 1920 дә Мәскәү операторлары тарафыннан ТАССР Советларының 1 нче съездын, Казан гарнизоны гаскәрләре парадын төшерү эшләре башкарыла, 1921 дә, Казанны ак чехлардан азат итүгә 3 ел тулу уңаеннан кинотеатрларда «Казанны алу» («Взятие Казани») фильмы (Мәскәү операторы П.В.Ермолов эше) күрсәтелә. Таткино һәм «Востоккино» берләшмәләре берничә хроникаль-документаль, ш.и. «Казанда Октябрь еллыгы» («Октябрьская годовщина в Казани»), «Иптәш Луначарскийның Казанга килүе» («Приезд тов. Луначарского в Казань») һ.б. фильмнар төшерә. Аларны эшләүдә Казан кинематографистлары активлык күрсәтә; 1926 да оператор К.Ф.Мотков беренче тапкыр Сабан туе бәйрәмен төшерә. 1932 дән, *Казан кинохроника студиясе* оешканнан соң, ТАССРда даими рәвештә кино җитештерү эше булдырыла, проф. кинематография хезмәте кадрлары барлыкка килә, нәфис фильмнарның татар һәм башка Идел буе халыклары телләренә дубляжын ясау башлана. 1981 елда Кинематографистлар берлеге төзелә. Ш.у. к. *Татарстан Республикасы кинематографистлар берлеге*.

*Әд.:* Алексеев И. Рубежи кинодокументалистов Татарии. К., 1974; Алексеева Е. Живые картины: История зарождения кинематографа в Казани // Казань. 2001. № 9/10; шул ук. Первый казанский автомобильный пробег // PRO-автомобили. 2002. № 5; шул ук. Первая казанская авиационная неделя // PRO-автомобили. 2003. № 6.

*Е.П.Алексеева.*

**КИНЗИКИ́ЕВ** Әхтәм Рәхмәтулла улы (1.1.1922, БАССРның Бүздәк р-ны Бүздәк а.), нефтьче-геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1966), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1982). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли. 1955 елдан Уфа нефть ин-тында, 1956 дан Башкорт нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-тында. 1957 дән ТатНИПИнефтьтә нефть чыганакларын эзләү лаб-ясе мөдире. 1965–71 дә Гомель ун-тында нефть кафедрасын җитәкли, проф. (1969); 1972–88 дә Башкорт ун-тында геол. һәм геоморфология каф. мөдире. Палеозой утырмаларындагы карбонат коллекторлар перспективасы һәм стратиграфик төзелеше, табигый ресурсларны рациональ файдалану нигезендә нефть запасларын исәпләү (ш.и. Ромашкино, Яңа Елховой һ.б. чыганакларда), утырма катламнарның комплекслы анализы (геол.-геофизик, геохимик һәм гидродинамик) ысулларын эшләүдә катнаша. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1997.

**КИНОСЬЯ́Н** Владимир Андреевич (16.5.1936, Краснодар крае Анапа ш.), философ, филос. фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан авиация ин-тының авиация приборлары төзү ф-тын тәмамлый (1961). 1959–68 елларда авиация сәнәгатенең Тәҗрибә-конструкторлык бюросында (Казан). 1968–70 тә Казан энергетика техникумында укыта. 1971 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, философия каф. мөдире (1991 дән). Хезмәтләре табигыять белеме, фән һәм техниканың фәлсәфи мәсьәләләре, рус дини философиясенә карый.

Хезм.: Философские проблемы физики гравитации. К., 1982; Прерывное и непрерывное. Киев, 1984; Пространство и время в космологии. Киев, 1984; Концепции современного естествознания: Курс лекций. К., 1998.

**«КИҢ ИДЕЛДӘ́» («НА ВОЛГЕ ШИРОКОЙ»)**, документаль-хроникаль киножурнал. 1961 елда Казан кинохроника студиясендә чыгарыла башлый. Аның төп бурычы — Урта Идел автономияле республикаларының сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышының әһәмиятле вакыйгаларын яктырту. Материаллар әзерләү өчен Саранск (Мордва Респ-касы) һәм Йошкар-Ола (Мари Респ-касы) шәһәрләрендә кинохәбәрче пунктлары булдырыла, журналны татар, чуаш, мари, мордва, удмурт телләрендә дубляж ясау өчен иҗат төркемнәре оеша. Беренче редакторы — В.Г.Гузанов, кинохәбәрче пунктлары б-н Г.Г.Әмиров, К.Ф.Мотков, Л.В.Барышев, В.В.Райский, А.А.Дымич җитәкчелек итә. КамАЗ төзелеше башлангач, Чаллы шәһәрендә кинооператор һәм режиссёр Е.Н.Афанасьев җитәкләгән хәбәрче пункты булдырыла. Төрле елларда киноелъязманы төзүдә Х.Ф.Фәхретдинов, В.Е.Игнатюк, Й.Г.Карамышева, Э.Х.Үтәгәнов, Б.А.Максимов, В.Е.Кузьмина, Н.К.Вәлитов кебек режиссёрлар катнаша, Э.В.Гущин, Р.И.Копосов киносценарийлар иҗат итә. Башта журналның периодик рәвештә айга 3 саны чыга, һәм ул берничә сюжеттан тора; аерым махсус саннары әһәмиятле вакыйгаларга багышлана: «Миллиард тонна» («Миллиардная тонна») — Татарстанда нефть чыгару хакында; «Автогигант төзелә» («Автогигант строится») — КамАЗ төзелеше турында; Татар акад. театрының 60 еллыгына багышланган махсус чыгарылыш; «Хатирә. Май 1987» («Память. Май 1987») — Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмаучылар хакында; «Көтү» («Ожидание») — Мордва АССР Темников Мәдәният йортының халык уен кораллары оркестры турында һ.б. Бөтенсоюз төзелешләренең («Оргсинтез», Түбән Кама химия з-ды, Чабаксар ГЭСы һ.б. пр-тиеләр) барышын яктыртуга зур игътибар бирелә. Алга таба журналның елга 10–12 саны чыга башлый, «Россия» колхозының дүрт ел фасылы» («Четыре времени года колхоза «Россия» — Мари Респ-касының Куженер р-ны хуҗалыгы турында), «Союз күләмендәге көрәш» («Поединок союзного значения» — Казанда бокс буенча СССР чемпионаты үтү турында, 1991 дән), «Башлангычларның башы» («Начало начал» — Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты турында, 1993 тән), «Ерагая баручы Казан» («Казань уходящая», Казан коллекционерлары — борынгы әйберләрне җыючылар турында, 2003 тән) темаларын яктырткан саннар чыгуын дәвам итә. 2004 тән периодик рәвештә «Көн артыннан көн — Идел буе округы» — «Поволжский округ день за днём» тематик альманахы чыга башлый.

*Е.П.Алексеева.*

**«КИҢӘ́Ш»**, атналык газета. 1917 елның июленнән Ташкентта татар һәм үзбәк телләрендә нәшер ителә. «*Шураи ислам*» г-тасының дәвамчысы. Нәшир ителүнең туктаган вакыты билгесез.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**«КИҢӘ́Ш»**, сул эсерларның иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газетасы. Үзәк мөселман комис-тының Самара бүлеге органы. 1918 елның 15 маеннан башлап Самара шәһәрендә татар телендә 3 саны нәшер ителә. Самара губернасы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының матбугат органы булып торган «Солдат, эшче һәм крәстиян» г-тасы бәяләвенчә, «К.» г-тасы Совет хакимияте сагында тора һәм капитализм б-н көрәш алып бара». Аны нәшер итүдә Г.Ашмасов, К.Мотыйгый, Г.Садри актив катнашалар. 1918 нең июнь башында Самарада КОМУЧ хакимияте урнашканнан соң, газета чыгудан туктатыла.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Октябрь в Поволжье. Саратов, 1967.

**«КИҢӘ́Ш»**, иҗтимагый-сәяси газета. Башта ул татар керәшен секциясе органы була, соңрак ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты агитация-пропаганда бүлеге органына әверелә. «*Кызыл әләм*» г-тасының дәвамчысы. 1922 елның 30 сентябреннән 1929 нең 30 декабренә кадәр Казанда татар телендә кириллицада барысы 250 саны нәшер ителә. 1924 нең 16 гыйнварыннан 1925 нең 31 гыйнварына кадәр газета чыгудан туктатылып тора, 1924 нең февраль-апрелендә аның урынына шул ук исем б-н 3 санда журнал чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — Г.Мельников, А.Порфирьев, А.Григорьев, Г.Белаев.

*Әд.:* Григорьев А.Н. Кряшенский вопрос в Татарии и его разрешение Советской властью: Дис. ... М., 1945; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1825 гг.). К., 1978; Глухов М.С. Tatarica: Энциклопедия. К., 1997.

*Т.М.Насыйров.*

**КИПКӘ́Р**, үпкә үләне (Filaginella), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, Җир шарының, тропиклардан тыш, барлык өлкәләрендә таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: рус К. (F. rossica)

һәм саз К. (F. uliginosa). Барлык районнарда да очрый. Куаклар арасында, урман буйларында, болыннарда, сулык ярлары буенда, чүп үләне буларак чәчүлекләрдә үсә. 10–25 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырлары нәзек, үзәк. Сабагы җәенке, тармаклы, ак киез б-н капланган. Яфраклары чиратлашкан, ланцетсыман яки кыяк-ланцетсыман. Чәчәкләре вак, саргылт-ак, кәрзингә җыйналган. Җимешләре — яшькелт соры бүрекчәле озынча орлыкчалар. Июнь ахырыннан сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре август–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. К.нең җир өсте өлешләрендә алкалоидлар, флавоноидлар, дуплау матдәләре, сумала, эфир мае бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсен гомуми хәлсезлек, бавыр авырулары вакытында кулланалар, пешкән урыннарга, яраларга куялар.

**КИРАТМАНИ́** Таҗетдин бине Ибраһим бине Мөхәммәд (14 йөз), болгар галиме, дин эшлеклесе, Әбү Мөхәммәд Садр бине Галәэддин әл-Болгариның шәкерте. «Имам Фәхреислам ысулы» дигән хезмәт (1363) авторы.

**КИРӘМӘ́Т** (Яңа Чәке урман даласы), ландшафтлы табигать истәлеге. Чүпрәле р-ны Түбән Чәке авылыннан көньяк-көнчыгыштарак (Ульянов өлкәсе б-н чиктәш) урнашкан. 1991 елда билгеләнә. Мәйданы 121,5 *га*. Маклауш (Олы Яклы елгасының сул кушылдыгы) елгасы үзәненең көнбатышындагы текә сөзәклектә үсүче гади нарат һәм сабакчалы имән урманнарыннан тора. Куаклы һәм төрле үләнле-солычалы дала участоклары сакланган. Сөзәклекләрнең карбонат токымнарында һәм урман буйларында үскән төрләре ТРның Кызыл китабына кертелгән: яфраклы тубылгы, Герман буяу куагы, язгы адонис, ромашкасыман кашкарый; киң яфраклы йод үләне. Фаунасы өйрәнелмәгән.

**КИ́РДИН** Владимир Филиппович (20.1.1949, Оренбург өлкәсенең Северный р-ны Староборискино а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (1992), проф. (2003), РФ нең атказ. уйлап табучысы (2003). 1968–74 елларда Бөгелмә а.х. район идарәсендә агроном. 1974 тә Бөтенсоюз а.х. читтән торып уку ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты Бөгелмә тәҗрибә кырының өлкән фәнни хезмәткәре. 1988 дән РФнең Кара туфраклы булмаган зоналары Үзәк р-ннарының а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. мөдире, ин-т директоры урынбасары (1996 дан). Хезмәтләре а.х. культураларын үстерүгә, туфрак эшкәртү теориясе һәм практикасына карый. Бөртекле культураларның интенсив сортлар потенциалын файдалану өчен туфракның уңдырышлылыгын кабаттан торгызуны тикшерә. Туфракта югары углеродлы органик кушылмалар таркалганда черемә барлыкка килүнең активлашуы күренешен ача. Уйлап табуга 7 патенты бар.

Х е з м.: Теория и практика обработки почвы в Центральных районах РФ. М., 1992; Регистр технологий возделывания сельскохозяйственных культур. М., 2002; Земледелие на рубеже XXI века. М., 2003.

**КИРЕ́ЕВЛАР**, татар морзалары нәселе. Беренче тапкыр 1650 елда морзалар Ишәй һәм Булай Досаевларга Уфа өязенең Усы даругасында җир бирелгәч искә алыналар. 17 йөз ахыры – 18 йөз башында Булай Досаевның гаиләсе Алатырь өязенә күчеп утыра, шуннан аның варислары Башкортстанга әйләнеп кайта (Күчәрбай а., БРның хәзерге Благовар р-ны). 1778 дән — ясаклы татарлар катлавында. Ишәй варислары мишәрләр катлавында булалар һәм Каракучык, Ихсан (хәзерге Чакмагыш р-ны Үрнәк а.), Рәсмәкәй, Әхмәт (хәзерге Кушнаренко р-ны), Биреказган (хәзерге Аургазы р-ны) авылларында яшиләр. Варисларының бер өлешенә, Россия армиясендә хезмәт иткән өчен, дворян дәрәҗәсе бирелә. Досайның улы Бигәй морза варислары Чиләбе өязендәге башкортлар ташлап киткән җирләргә барып урнаша (18 йөздә, татар-башкорт күтәрелешен бастыруда катнашканнары өчен, бу җирләр аларга гомерлек биләмәгә бирелә). Кайберләре Оренбург дворян депутатлары җыенының 1800 ел, 23 декабрь карары нигезендә дворяннар шәҗәрәсе китабының 4 нче бүлегенә языла. 19 йөздә К.ның күпсанлы нәселе вәкилләре Оренбург губернасының Ихсан, Каракучык, Әхмәт, Рәсмәкәй, Күчәрбай, Урьяды (хәзерге Мишкә р-ны), Биреказган һәм Күзәк (хәзерге Аургазы р-ны), Яңавыл (хәзерге Чишмә р-ны), Суба, Мансур, Корман, Касыйм, Карач, Коншак һәм Ахун (хәзерге Чиләбе өлкәсе), Казан губернасы Чистай өязенең Кәләй һәм Мөслим авылларында (хәзерге Чистай р-ны) яшиләр.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**КИРЕ́ЛЬСКИЙ** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы буенда. 2010 елда 512 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 54%, татарлар — 32%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1915 еллар тирәсендә балыкчылар посёлогы буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Воскресенский исеме б-н билгеле. Халкы башта Казан Архиерей йортына карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, бакчачылык, яшелчәчелек, чүлмәк ясау, балта эше, тегүчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Воскресение чиркәве (1754 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 3 җил тегермәне, тимерчелек, 2 ашлык киптергеч, йон тетү һәм чүлмәк ясау остаханәләре, 2 сырыханә, 1 казна шәраб һәм 10 вак-төякләр кибете була; пәнҗешәмбе саен базар, елга 2 тапкыр (9 май, 1 октябрьдә) ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3992,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Сөйке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1745 тә — 740, 1782 дә — 656 ир-ат; 1834 тә — 1129, 1859 да — 1052, 1897 дә — 1538, 1908 дә — 1568, 1920 дә — 1616, 1926 да — 1401, 1938 дә — 1075, 1949 да — 943, 1979 да — 649, 1989 да — 511, 2002 дә — 607 кеше.

**КИРИ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 32 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1651–54 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пучегино исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), 5 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 676 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 404, 1897 дә — 567, 1908 дә — 734, 1920 дә — 676, 1926 да — 666, 1938 дә — 615, 1949 да — 382, 1958 дә — 278, 1970 тә — 129, 1979 да — 84, 1989 да — 52, 2002 дә — 35 кеше.

**КИРИ́ЛЛ** (Смирнов Константин Илларионович) (26.4.1863, Петербург губ. Кронштадт ш. — 20.11.1937, Казакъстан ССР, Чимкент ш.), дин эшлеклесе. 1887 елда Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, С.-Петербург һәм Кронштадт чиркәүләрендә рухани. 1902 дән — монахлыкта, архимандрит, Урмия шәһәрендә (Иран) рухани миссия башлыгы. 1904 тән Гдов епископы, Петербург епархиясе викарие, 1908 дән Тамбов һәм Шацк епископы (1913 тән — архиепископ). 1917–18 дә Рус Православие чиркәве Җирле соборында катнаша (патриархлыкка кандидат). 1918 дә Тифлис һәм Баку митрополиты итеп билгеләнә, әмма, Грузия Православие чиркәвенең мөстәкыйльлек игълан итүе сәбәпле, вазифаларын башкарырга өлгерми. 1918–19 да Мәскәүдә патриарх Тихон администрациясе хезмәткәре. 1919–20 дә сов. хакимиятенә каршы эшчәнлектә гаепләнә, төрмәгә ябыла. 1920–29 да Казан һәм Зөя митрополиты, берничә тапкыр кулга алына (1920–22, 1922–24). 1924 тә Мәскәүгә кайта, патриарх Тихонның Урын саклаучысы итеп билгеләнә. 1925 нең башында кулга алына, Вятка губернасының Котельнич шәһәренә сөрелә. 1927 дә Красноярск краена җибәрелә. Православие чиркәвенең сов. хакимиятенә карата күндәмлек саклавына каршы чыгучы чиркәү оппозициясе лидерларының берсе (К. чиркәүнең подпольега китүен таләп итә). 1933 тә азат ителгәннән соң, Гжатск шәһәрендә (хәзер Смоленск өлкәсендәге Гагарин шәһәре) яши, 1934 тә Көньяк Казакъстанга сөргенгә озатыла, 1937 дә кулга алына, НКВД «өчлеге»нең хөкем карары буенча атыла. 2000 дә изгеләштерелә, 20 ноябрьдә — һәлак булган көнендә искә алына.

*Әд.:* Ж у р а в с к и й А.В. Во имя правды и достоинства церкви: Жизнеописание и труды священ-

номученика Кирилла Казанского в контексте исторических событий и церковных разделений XX века. М., 2004. *Е.В.Липаков.*

**КИРИ́ЛЛИЦА**, ике борынгы славян алфавитының берсе (глаголица б-н беррәттән). Аның барлыкка килүе славян мәгърифәтчеләре бертуган Кирилл (827–869 тирәсе) (алфавит аның исеме б-н аталып йөртелә) һәм Мефодий (815–855 тирәсе) исемнәре б-н бәйле. Башка караш та яшәп килә: К. Кирилл һәм Мефодий шәкертләре, алар эшен дәвам итүчеләр тарафыннан болгар патшасы Симеон (893–927) заманында, грекларның тантаналы язу графикасына нигезләнеп, борынгы болгар авазларын бирү өчен, алфавитка берничә хәреф өстәп төзелә. 11–12 йөзләргә кадәр глаголица б-н бергә кулланыла, соңрак аны тулысынча алыштыра.

Русьта 10–11 йөзләрдә христианлашу вакытында кулланылышка керә. 1708–10 елларда Пётр I Фәрманы б-н, К.га нигезләнеп, хәзерге хәрефләргә якын торган «гражданлык» шрифты булдырыла. Окт. рев-циясеннән соң рус-кириллица язуының алфавитны шактый җиңелләштергән икенче реформасы уздырыла.

Татар язуын бирү өчен К. беренче тапкыр Н.И.*Ильминский* тарафыннан Казан үзәк керәшен татар мәктәбендә кулланыла.

Татарларның рус (кириллица) алфавитына күчүе 1938 дә СССР ХКСы һәм ВКП(б) ҮКның «Милли республикалар һәм өлкәләрдәге мәктәпләрдә рус телен мәҗбүри укыту турында»гы карары чыккач тормышка ашырыла. Шул ук елда, К.га нигезләнеп, М.А.*Фазлуллин* эшкәртүендә үз эченә рус алфавитының барлык хәрефләрен дә алган татар алфавиты проекты да басылып чыга. 1939 да М.Х.*Корбангалиев* һәм Ш.А.*Рамазанов* чыгарган тагын 2 руслаштырылган татар алфавиты барлыкка килә. Соңгысы нигезендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты тарафыннан татар әдәби теленең орфографик кагыйдәләре эшләп чыгарыла. 1939 ның апрелендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросы «Латин графикасындагы татар алфавитының рус графикасына нигезләнгән яңа алфавитка күчүе турында» карар һәм 1939 ның маенда ТАССР ЮС шундый ук указ кабул итәләр. Әрмәнстан һәм Грузиядән кала, СССРның башка милли респ-каларында да алфавитны руслаштыру процессы башкарыла. 1937–40 елларда рус графикасына нигезләнгән 66 милли алфавит кулланылышка керә. Ш.у. к. *Алфавит.*

*Әд.:* Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998; Байрамова Л.К. Татарстан: языковая симметрия и асимметрия. К., 2001.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**КИРИ́ЛЛОВ** Валерий Константинович (1945, Тула өлкәсенең Тепло-Агаревск р-ны Теплое а.), сәламәтлек саклау эшлеклесе. 1969 елда Казан. мед. ин-тын тәмамлагач, Байконурдагы Космонавтлар үзәгендә табиб хезмәтен үти. 1974–81 дә Мамадыш р-ны үзәк хастаханәсе табиб-хирургы, баш табибе. 1981–84 тә Мамадыш р-ны башкарма ком-ты рәисе. 1984–86 да ТАССР Сәламәтлек саклау министры. 1986 дан Республика психиатрия клиник хастаханәсе баш табибе урынбасары, табиб-хирургы. 1989 дан Казан Татавтотрансының сан.-мед. часте табибе.

**КИРИ́ЛЛОВ** Григорий Петрович (1850–1922), вет. хирургы. 1876 елда Петербург мед.-хирургия академиясенең вет. бүлеген тәмамлагач, шунда ук эшли. 1879–81 дә Пенза губернасында вет. табибе. 1888 дән Казан вет. ин-тында, доцент, экстраординар проф., хирургия каф. мөдире, 1908–11 дә директор. Теоретик хирургия һәм катлаулы операцияләр ясау, акушерлык буенча лекцияләр укый, гамәли дәресләр үткәрә, клиника мөдире була; аның лекцияләре студентлар өчен дәреслек буларак нәшер ителә. Хезмәтләре гомуми һәм оператив хирургиягә карый. К. гамәли хирургиягә авыртуны басуның яңа ысулларын һәм операциядән соң дәвалау методикаларын кертә. Хирургик патология өлкәсендә теоретик тикшеренүләр үткәрә, 1891 дә беренче булып туберкулёз төерен тасвирлый, туберкулёз патологиясенең йогышлы булуын фаразлый. 39 ел буена «Учёные записки Казанского ветеринарного института» ж-лы мөхәррире була. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Хирургическая патология: Литографированный курс лекций. К., 1894.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КИРИЛЛО́ВИЧ** Александр Александрович (30.6.1912, хәзерге Украина Респ-касының Житомир өлкәсе Крошня а. — 23.7.1983, Казан), сәнәгый җитештерүне оештыручы, ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). Мәскәү тәҗрибә-күргәзмә сәнәгать техникумын тәмамлаганнан соң (1936), «Каучук» з-дында (Мәскәү) цех механигы, остаханә башлыгы булып эшли. 1937–38 елларда 52 нче заводның (Ленинград) җиһазлар бюросы башлыгы, 1938–42 дә 392 нче комб-тның (Кемерово ш.) җиһазлар бүлеге башлыгы, 1944–45 тә 9 нчы з-дта (Украина ССР, Шостка ш.) директор урынбасары, 1945–55 тә 101 нче комб-т (Ростов өлкәсе Каменск-Шахтинский ш.) башлыгы, 1955–56 да СССР Оборона сәнәгате министрлыгының 5 нче төзү-монтаж тресты (Куйбышев ш.) управляющие, 1956–57 дә 580 нче з-д (Красноярск ш.) директоры. 1942–44 тә СССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы органнарында хезмәт итә (Кемерово ш.). 1957 дән Казанда: Татарстан икътисади адм. р-ны ХХСнда производство бүлеге, машина төзелеше идарәсе, производство-техника идарәсе башлыгы, ТАССР Коммуналь хуҗалык министры (1963 тән), Казан «Полимерфото» з-ды директоры (1965–82). К. Шостка, Каменск-Шахтинский шәһәрләрендәге сугыш тарафыннан җимерелгән пр-тиеләрне торгызуда, Татарстан икътисади адм. р-ны сәнәгатен булдыруда һәм үстерүдә актив катнаша. Аның җитәкчелегендә «Полимерфото» з-дын реконструкцияләү һәм техник җиһазлау үткәрелә, бу исә җитештерү күләмен 1,5, хезмәт җитештерүчәнлеген 1,2, халык куллануы товарларын эшләп чыгаруны 3 тапкырга арттырырга мөмкинлек бирә. Пр-тиедә төп производствоны механикалаштыру дәрәҗәсе 87% ка, ярдәмчесен механикалаштыру 76% ка җиткерелә; азык желатины, азык преципитаты, сөяк оны, кассеталар һ.б. җитештерү үзләштерелә; кино һәм фото сәнәгатендә һәм халык хуҗалыгының башка тармакларында зур әһәмияткә ия яңа төр продукция җитештерү технологияләре кулланылышка кертелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Ике Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш, бронза медальләре, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

**КИРИ́ЛЛОВКА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кырлай елгасы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сайра, Олы Сайра исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе (1897 дә ачыла), 2 су тегермәне, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 247,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир-ат; 1859 да — 227, 1897 дә — 216, 1908 дә — 243, 1920 дә — 250, 1926 да — 278, 1938 дә — 305, 1949 да — 270, 1958 дә — 143, 1970 тә — 98, 1989 да — 33, 2002 дә — 37 кеше.

**КИРИ́ЛЛОВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оренбург өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 13 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Михайловка волостенда. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1926 да — 187, 1938 дә — 254, 1949 да — 180, 1958 дә — 141, 1970 тә — 127, 1979 да — 76, 1989 да — 32, 2002 дә — 5 кеше.

**КИРИ́ЛОВ** Иван Кириллович (1695, башка мәгълүматлар буенча, 1689, Мәскәү — 14.4.1737, Оренбург крае), дәүләт эшлеклесе, географ, картограф, статский советник (1734). Рухани улы. 1711–34 елларда Сенатта хезмәттә, секретарь (1721 дән), обер-секретарь (1727 тән). Астрономия, топография һәм картография эшләренә җитәкчелек итә. 1731–33 тә Камчаткага, Төньяк-Көнчыгыш Азиягә экспедицияләр оештыруда катнаша. 1734 тән Оренбург экспедициясе башлыгы. Оренбургка нигез сала (1737), аның җитәкчелегендә Оренбург төбәгендә 20 ләп кальга-ныгытма төзелә. Ул Башкортстанда тау эшләрен башлап җибәрә. 1735 тән башкортлар кузгалышын бастыруда катнаша. Геогра-

фия, икътисад, тарих өлкәләрендә фәнни тикшеренүләр алып бара. «Бөтенроссия империясе атласы»ның («Атлас Всероссийской империи», СПб., 1734) 1 нче чыгарылышын төзи һәм нәшер итә, анда «Генераль карта» һәм аерым 14 өлкәнең, ш.и. Казан губернасының картасы урын ала. 1720 елларда Казан губернасындагы шәһәрләр топографиясе, шәһәр ныгытмаларының озынлыгы турында материаллар, халык, почта элемтәсе, сәнәгать, сәүдә, финанс, армия һәм җирле идарә органнарының торышы турында мәгълүматлар кертелгән. «Бөтенроссия дәүләтенең чәчәк ату дәвере» («Цветущее состояние Всероссийского государства», кн. 1–2, 1831) фундаменталь хезмәте — Россиянең беренче стат.-геогр. тасвирламасы авторы (1727).

*Әд.:* Новлянская М.Г. И.К.Кирилов и его Атлас Всероссийской империи. М.–Л., 1958; шулук Иван Кирилович Кирилов, географ XVIII века. М.–Л., 1964.

*Е.Б.Долгов.*

**КИРИ́ЛОВ** Сергей Иванович (7.11.1941, Бөгелмә р-ны Сула а.), эчке эшләр хезмәте генерал-майоры (1987). Свердловск юридик ин-тының Уфа ф-лын (1966), Горький югары партия мәктәбен (1970) тәмамлый. 1963–74 елларда Бөгелмә шәһәрендә: ВЛКСМ шәһәр ком-ты (1965 кә кадәр), 1965–68 дә һәм 1970 тән КПССның шәһәр ком-ты инструкторы, 2 нче секретаре. 1974–79 да ТАССР Эчке эшләр министрлыгы коллегиясе әгъзасы, 1983–93 тә ТР эчке эшләр министры. 1993–95 тә ТР Премьер-министры урынбасары. 1995–2000 дә ТРның Дәүләт Советы Парламент контроле ком-ты рәисе. 2000 елдан ТР эчке эшләр министры киңәшчесе. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1995–2000 дә ТР халык депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КИРИЛЮ́К** Дмитрий Афанасьевич (29.12.1931, хәзерге Украина Респ-касы, Винница өлкәсенең Литин р-ны Микулинцы а. — 15.1.2007. Казан), вет. микробиологы, вет. фән. д-ры (1989). 1960 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, Куйбышев (хәзер Самара) өлкәсе Шонталы р-нында вет. участогы мөдире булып эшли. 1962–83 тә Казан вет. ин-тында. 1983–95 тә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре патоген микроорганизмнарның тышкы мохиттә яшәүгә сәләтен өйрәнүгә, азыкларны зарарсызландыру чаралары һәм ысулларын, терлекләрне асрау өчен җиһазлар, махсус кием, аяк киеме, төзелеш материалларын эшләүгә карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: О выживаемости микробактерий туберкулёза птичьего типа в зернофураже // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1965. Т. 97; Выживаемость микробактерий птичьего туберкулёза на грубых кормах // Ветеринария. 1973. № 1.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КИРКАЗО́Н**, к. *Алма үләне.*

**КИРЛЕГӘ́Ч** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 59 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 518 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1746 дан мәгълүм. Беренче исеме — Сәет-Карлыгач. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 4 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3564 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 1170, 1889 да — 1986, 1908 дә — 2392, 1920 дә — 2415, 1926 да — 1672, 1949 да — 1133, 1958 дә — 970, 1970 тә — 994, 1979 да — 732, 1989 да — 533, 2002 дә — 589 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**КИРМӘ́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Омар елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 36,3 *км*, бассейнының мәйданы 181,1 *км*². Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Норма урманчылыгы посёлогы янында, тамагы Омар авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. К. елгасының 0,8 дән алып 7,5 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 5,1–10 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 150 *мм*, ташу агымы катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче унконлегендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа, аерым урыннары кыш буена боз б-н капланмый. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,325 *м*³*/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,2 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КИРМӘНЧЕ́К**, урта гасырларда (якынча 11–14 йөзләр) Кирмән елгасы буендагы болгар шәһәре. 15–16 йөзләрдәге рус елъязмаларыннан һәм 17–18 йөзләрдәге татар тарихи-фольклор әдәбиятыннан мәгълүм. 14 йөздә Чулман алды төбәгендә эре икътисади һәм сәяси үзәкләрнең берсе була. 1399 елда Болгар, Җүкәтау, Казан б-н бергә Мәскәү кенәзе Юрий Дмитриевич гаскәрләре тарафыннан яулап алына. Россия тарих фәнендә Мамадыш р-нындагы Урта Кирмән авылы янәшәсендәге, Кирмән елгасы буендагы шәһәрлекне К. б-н тиңлиләр. Шәһәрлек көнбатыштан — тирән ерым, көньяктан һәм көньяк-көнбатыштан Кирмән елгасы б-н чикләнгән биек борында урнашкан. Мәйданы 8,6 *га* чамасы. Көньяктан шәһәрлеккә Казан–Чаллы автомагистрален төзегәндә юкка чыгарылган ачык типтагы торулык (шәһәр яны бистәсе) һәм 14 йөзгә нисбәтле 20 дән артык кабер ташы һәм ватыклары сакланган «Ханнар зираты» дип аталган мөселман каберлеге табылган. К. 1957 дә А.П.Шокуров тарафыннан ачыла. К. шәһәрлегендә төрле елларда Е.Т.Соловьёв, Н.И.Воробьёв, Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков һ.б. тикшеренүләр алып бара. Ерымнан гыйбарәт саклану ныгытмалары, җир өстендә корылган тораклар һәм хуҗалык корылмалары калдыклары тикшерелә. Керамика, эш кораллары һ.б. табыла.

*Әд.:* Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; Нигамаев А.З. Булгарские города Предкамья: Алабуга, Кирмень, Чаллы. К., 2005.

*А.З.Нигамаев.*

**КИ́РОВ** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 32 *км* көньяк-көнбатыштарак, Терпеле елгасы буенда. 2010 елда 977 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык; киптерелгән сөт з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1930 да 201 нче Актаныш совхоз-посёлогы буларак нигез салына; хәзерге исемен 1935 тән йөртә. Оештырылган көннән Актаныш р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 627, 1949 да — 504, 1958 дә — 1068, 1970 тә — 1295, 1979 да — 1302, 1989 да — 1112, 2002 дә — 1003 кеше.

**КИ́РОВ** исемендәге посёлок, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 289 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 53%, руслар — 24%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 1937 елда нигез салына. Оештырылган көннән Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 39, 1949 да — 193, 1958 дә — 340, 1970 тә — 311, 1979 да — 260, 1989 да — 321, 2002 дә — 304 кеше.

**«КИ́РОВ НЕ́ФТЬЧЕСЕ»**, иҗтимагый-сәяси газета. Әзәрбайҗан КП(б) Киров райкомы Эшче, кызылармияче һәм крәстиян депутатлары советы һәм район промысел ком-ты органы. 1932 елның 23 июленнән 1935 нең 23 апреленә кадәр Бакуда татар телендә 96 саны нәшер ителә. Әзәрбайҗан нефть промыселында хезмәт итүче татар эшчеләре өчен чыгарыла. Газета бер үк вакытта шул исем б-н әзәрбайҗан һәм рус телләрендә дә басыла.

*Т.М.Насыйров.*

**КИ́РОВ ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. 1936 елда оештырыла. Мәйданы — 120,8 мең *км*². Үзәге — Киров шәһәре. Халкы — 1391059 кеше (2010), 43415 татар (2002). Татарлар, башлыча, Вятка Аланы, Көлмез һәм Малмыж р-ннарында, ш.у. Вятка Аланы (8,7 мең кеше), Киров (4,5 мең), Малмыж (3,6 мең), Сосновка (3 меңләп) шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Красная Поляна (5,5 меңләп) һәм Көлмез (2 меңләп) посёлокларында яшиләр. Татарларның К.ө.нә килеп төпләнүе бернichә

этапта бара. Әлеге төбәкне үзләштерү 10 йөздә башлана, бу — болгар сәүдәгәрләренең Нократ елгасы буенда сәүдә нокталары барлыкка килү б-н бәйле. 14 йөзнең 2 нче яртысында элеккеге *Идел буе Болгар дәүләте* халкының бер өлеше, Алтын Урда отрядлары һәм рус елга юлбасарлары һөҗүмнәреннән сакланып, К.ө. территориясенә күчеп килә, бер өлеше карин этник төркемен (к. *Нократ татарлары*) барлыкка китерә. К.ө.нә татарларның күпләп күченүләренең икенче агымы Казан ханлыгы җимерелү һәм халкын көчләп христианлаштыру б-н, ә совет чорында татарларның бу өлкәгә күченүе, башлыча, а.х. күмәкләштерү б-н бәйле. К.ө.ндә күпчелеге татарлардан торган (90% тан артыгы) 27 торак пункт исәпләнә. 32 мөселман җәмгыяте — мәхәлләсе бар. 5 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 4 сендә фән буларак укытыла. Малмыж шәһәрендә 1990 нан «Дуслык» г-тасы нәшер ителә, 1991 дән Татар милли мәдәни үзәге эшли. Малмыж, Вятка Аланы, Көлмез р-ннарында һәм Киров шәһәрендә татарларның җирле милли-мәдәни автономиясе оештырылган. «Идел» (Сосновка ш.) һәм «Сәфәр» (Вятка Аланы ш.) татар ансамбльләре бар. Малмыж шәһәрендәге Төбәкне өйрәнү музеенда М.Г.*Худяковның* кульъязмалары саклана. 1999 да К.ө. җитәкчелеге һәм ТР хөкүмәте арасында сәүдә-икътисад, фән-техника һәм мәдәният өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итү турында килешү төзелә.

*К.Ә.Әхәтов.*

**КИ́РОВ** (чын фамилиясе Костриков) Сергей Миронович (15.3.1886, Вятка губ. Уржум ш. — 1.12.1934, Ленинград), дәүләт, партия эшлеклесе. Уржум шәһәр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1901), Казан сәнәгать уч-щесенә (механика-техника бүлегенә) билгеләнә. 1903 тә К. студентлар һәм эшчеләрнең яшерен түгәрәкләре б-н элемтә урнаштыра, тыелган китаплар укый. 1904 тә Томскига күчеп китә. 1905 тән — РСДРПның Томск ком-ты әгъзасы; яшерен басмаханәне җитәкли. 1905–06 да полиция тарафыннан берничә тапкыр кулга алына, 1907 дә 1 ел да 4 айга төрмәгә ябыла. 1908 дә иреккә чыккач, Иркутск шәһәренә, 1909 ның маенда, полициядән качып, Владикавказ шәһәренә китә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Владикавказ Эшче һәм солдат депутатлары советын, РСДРПның берләштерелгән Терек өлкә ком-тын оештыруда катнаша (ком-т секретаре була). 1921 дән Әзәрбайҗан Коммунистлар партиясе ҮК секретаре. 1926 дан ВКП(б)ның Ленинград губерна ком-ты (өлкә ком-ты) һәм ВКП(б) ҮКның Төньяк-Көнбатыш бюросы 1 нче секретаре; бер үк вакытта, 1934 тә ҮК секретаре. Смольныйда ачыкланмаган шартларда револьвердан атып үтерелә. Казанда элеккеге сәнәгать уч-щесе (хәзерге Казан технол. ун-ты) бинасында мемориаль такта куела. К. исеме бер урамга (2005 тән — Мәскәү урамы), технол. ун-тына, ясалма каучук з-дына бирелә; Казанның бер районы аның исеме б-н атала. К.ка Казанда Карл Маркс урамында (1949, скульпт. Н.В.Томский, арх. А.А.Любимов) һәм К.Цеткин урамында (1930 еллар) һәйкәлләр урнаштырыла.

*Әд.:* Костриковы А.М. и Е.М. Детские и юношеские годы Сергея Мироновича Кирова: Воспоминания. Киров, 1940; Татьянинов Д.Н. С.М.Киров в Казани. К., 1941; Амиров К.Ф. Казань: где эта улица, где этот дом?: Справочник улиц города Казани. К., 1995.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КИРПЕ́Ч ҖИТЕШТЕРҮ́**, төзелеш материаллары җитештерү сәнәгате тармагы; минераль материаллардан, яндыру (керамик кирпеч) яки пар б-н эшкәртү (силикат кирпеч) нәтиҗәсендә, нык һәм су тәэсиренә чыдам булган ясалма эшләнмәләр алу процессы. ТРда К.җ.дә эшләүчеләр саны — 5 мең кеше чамасы (2009).

Казан губернасында беренче эре кирпеч з-длары Поповка, Воскресенский (1860, хуҗасы П.А.Смолин), Зур Клыки (1860, 1862, хуҗасы И.Д.Иванов), Әмәт (1899, хуҗасы Л.В.Кекин) авылларында һ.б. җирләрдә барлыкка килә.

19 йөзгә кадәр Россиядә кирпеч гади һәм күп хезмәт таләп иткән ысул б-н җитештерелә. Махсус сайлап алынган яки ком кушылган балчыкны сугаралар, болгаталар һәм озак вакытка әзерләнүдә калдыралар. Агач формаларга салып, тукмак б-н тыгызлыйлар, җәйге чорда күләгәдә киптерәләр. Яндыру өчен



Төзелеш керамикасы эшләнмәләре.

чи кирпечләрдән корылган, тыштан балчык сыланган кыр мичләре файдаланыла. Мич эчендә махсус каналлар эшләнгән, каналларга ягулык тутырылган, ягулык янгандагы ялкын мичнең чи кирпечләрдән өелгән диварларын тулысынча урап алырга тиеш булган. Яндыру берничә көн дәвам иткән. Кирпеч, башлыча, дини, адм., җәмәгать һәм торак биналарны төзү өчен файдаланылган. 1830 елларда Казан ун-ты китапханәсен төзегәндә куыш кирпеч эшләнә һәм уңышлы кулланыла. 19 йөз ахырында К.җ. технологиясе зур үзгәрешләр кичерә. Балчык эшкәртү машиналары, формага салу өчен тасмалы пресслар, яндыру процессында ягулык кертүне һәм һава бирүне көйләү мөмкинлегенә ия Гофман мичләре һ.б. барлыкка килә. Сов. хакимияте елларында кирпеч з-длары национализациялә нә. Казанда беренче силикат кирпеч з-ды 1930 елда төзелә. Алдагы чорда, халык хуҗалыгы үсешенә, сәнәгый һәм гражданнар төзелешләренең күләме шактый артуга бәйле рәвештә, К.җ. күп тапкырлар арта. 2011 дә ТРда 25 кирпеч з-ды исәпләнә, шуларның 21 е, елга 50 млн. данәдән артык кирпеч җитештерүче эре заводларны кертеп («Казан силикат дивар материаллары заводы», «Казан төзелеш материаллары комбинаты», «Камаиндустрия» ҖЧҖ), ел дәвамында эшли. Тулы эчле (тоташ), куыш, ярыклы кирпечләрне «Арча уртак кирпеч производствосы» («Арское совместное производство кирпича») АҖ эшләп чыгара. 1990 елларда төрле төстәге тышлык кирпече, яхшыртылган җылылык саклау сыйфатларына ия эре бушлыклы-сызыклы кирпечләр җитештерү үзләштерелә («Алексеев керамикасы» ҖЧҖ). Шулай ук торбалар сузганда кулланыла торган лекалолы кирпеч һәм юл япмасы кирпече — урамнарга түшәлә торган клинкер эшләнә («ЖБИ-3» ҖЧҖ). 2009 да 409,3 млн. данә шартлы кирпеч җитештерелә. 1990 да иң зур күрсәткечкә ирешелә (к. табл.).

Татарстанда кирпеч җитештерү 1940–2009 еллар (шартлы кирпеч млн. данәдә)

| 1940 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 2000 | 2007 | 2009 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Төзелеш кирпече | | | | | | | |
| 73,3 | 423 | 504 | 688 | 762 | 532 | 600 | 409,3 |
| ш.и. силикат кирпеч | | | | | | | |
| 26,4 | 90 | 124 | 259 | 322 | 94 | 315 | 142,1 |

Хәзер К.җ. механикалаштырылган, күбесенчә автоматлаштырылган, ул керамик массаны гомогенлаштыру һәм аны куәтле вакуум-пресслар ярдәмендә формалау б-н шөгыльләнүче балчык әзерләү бүлегенә дә үз эченә ала. Чи кирпеч тоннельле мичләрдә яки 950–1020 °С темп-рада периодик рәвештә эшләүче мичләрдә яндырыла. Чимал буларак бернәрсә дә кушылмаган яки ком, пычкы чүбе, карабодай кибәге һ.б. катнаштырылган балчык һәм балчыклы туфрак файдаланыла. Эшләнмәләрнең технол. һәм файдалану үзенчәлекләрен яхшыртучы өстәмә кушылмалар сыйфатында төрле техноген калдыклар кулланыла. Керамик кирпечтән аермалы буларак, силикат (известьле-комлы) кирпеч автоклавларда катырыла. Ш.у. к. *Кирпеч сугучылар бистәсе, Саман.*

*Әд.:* Производство строительной керамики. К., 2003. *А.М.Сәлахов.*

**КИРПЕ́Ч СУГУ́ БАЛЧЫКЛАРЫ́** (кирпеч-чирәп балчыклары, җиңел эри торган, полиминераль балчыклар), балчыксыл токымнар, утка чыдамлыгы 1350 °С тан артмый. Балчыкка, балчыклы туфракка, аргиллит һәм балчыксыл сланецларга бүленә. Төп минераллар — монтмориллонит, гидрослюдалар, каолинит, хлоритлар, кварц. Дөньяда К.с.б. чыганаклары чыгышы һәм яше төрле булган утырмаларда киң таралган. Татарстан терр-ясендә алар, нигездә, субүләр массивларның сөзәклек өлешләрен тәшкил иткән дүртенчел система токымнары б-н бәйле. К.с.б. неоген, акбур, юра һәм Пермь яшендәге токымнарда була. К.с.б. авыллар барлыкка килгәннән бирле файдаланыла. 1930 еллардан системалы рәвештә К.с.б.на геол. разведка эшләре үткәрелә. 290 га якын чыганак табылган, аларның республика терр-ясе буенча таралышы тигез түгел: Әтнә һәм Балтач р-ннарында — 1 әр, Зәй, Бөгелмә, Тукай, Әлмәт һәм Лениногорск р-ннарында 14–21 чыганак. Гомуми запасы якынча 460 млн. $м^3$, аеруча зурлары A+B+C категорияләре буенча Бөгелмә, Әлмәт һәм Тукай р-ннарында.



П.А. Кирпичников.



М.П. Кирпонос.

Әтнә, Чүпрәле һәм Лаеш р-ннарыннан кала (биредә чыгарылмыйлар) барлык районнарда 1–2 чыганак эшкәртелә, аларда чыгару күләме 2–130 мең $м^3$. Чимал 75–200 маркалы кирпеч, керамик блоклар, тышлау плитәсе, чирәп ясау өчен яраклы.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*А.А.Сабитов.*

**КИРПЕЧЧЕЛӘ́Р БИСТӘСЕ́**, Казанның көньяк-көнчыгыш читендә 17 йөздә барлыкка килгән бистә. Хәзерге Бутлеров һәм Петербург урамнары кергән җирләрне били. К.с.б.ндә шәһәр корылмалары (ш.и. Казан Кремле диварларын төзекләндерү) өчен кызыл кирпеч җитештерелә. 18 йөз башында Әрмән бистәсе б-н кушыла. 1774 елдан шәһәр чикләре эченә керә.

**КИРПИ́ЧНИКОВ** Пётр Анатольевич (5.1.1913, Вятка губ. Царёвосанчурск ш. — 26.3.1997, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1972), РФАнең мөхбир әгъзасы (1991; 1976 елдан СССР ФАнең мөхбир әгъзасы), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1969, 1975), БР һәм ТР ФАләренең шәрәфле әгъзасы (1991, 1992), СССРның атказ. химигы (1973). Пермь (1931–32) һәм Мәскәү (1933–35) химия-технол. ин-тларында укый, 1936 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, 1940 ка кадәр С.М.Киров исем. Казан ясалма каучук з-дында эшли. 1940–46 да Совет Армиясе сафларында, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 дан Казан химия-технол. ин-тында (бүленеп, 1947–54 тә Шкопау ш. (Германия), «Буна» химия комб-тында баш инженер, киңәшче), 1957 дән технол. ф-ты деканы, 1960–87 дә ясалма каучук технологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта проректор (1961 дән), ректор (1964 тән), проф. (1965); 1988 дән ректор киңәшчесе һәм Эластомерлар эшләү үзәгенең фәнни җитәкчесе. 1982–87 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Президиумы рәисе.

Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм технологиясенә карый. Полимерларны искерүдән саклау өчен фосфорорганик кушылмалар куллану ысулларын өйрәнә. Мономерларны һәм полимерларны фосфорорганик кушылмалар б-н тотрыклыландыруның фәнни нигезләрен булдыра, фосфорлы антиоксидантлар, аруга каршы матдәләр, ингибиторлар, стабилизаторлар эшли. Бутадиенның стирол б-н сополимерлашуын, винилиденхлоридның бутадиен б-н радикаль сополимерлашуын өйрәнә. Полисульфид һәм уретан эластомерларын өйрәнүгә зур өлеш кертә, реакциягә керү мөмкинлеге булган функциональ төркемнәр, ш.и. озонолиз юлы б-н (герметиклар, полимер композицияләр модификаторлары, майларга өстәмәләр һ.б.) олигомерлар синтезлау ысулларын эшли. Синтез стадиясендә һәм кабаттан эшкәрткәндә полисульфид олигомерларны туендырылмаган төрле кушылмалар б-н модификацияли. К. җитәкчелегендә кристаллашу көйләнелә торган туендырылмаган вальцовкаланучы каучуклар, коелган уретан каучуклар, нефть эмульсияләре деэмульгаторлары сыйфатында кулланылучы этилен оксиды б-н изобутилен блоксополимерлары синтезлана; коррозия һәм кокс ясау термополимерлаштыру процесслары ингибиторлары, химик җиһазлар һәм корылмалар өчен коррозиягә каршы капламнар, аппаратларда һәм торбалы үткәргечләрдә тозлар һәм полимерлар утырмаларын булдырмый калу ысуллары эшләнә; төзелеш техникасында, нефть һәм нефть чыгару сәнәгатендә файдаланылучы тиоколлар, полиуретаннарның яңа типлары алына. К. «Оргсинтез» ҖБдә, «Түбәнкаманефтехим» АҖ пр-тиеләрендә, С.М.Киров исем. ясалма каучук з-дында, Татарстанның һәм Россиянең башка сәнәгать үзәкләрендә органик синтез продуктларын, каучукларны, полимерларны җитештерүне үзләштерүдә катнаша. Аның инициативасы б-н Казан химия-технол. ин-тында (хәзер Казан технол. ун-ты) яңа факультетлар, кафедралар оештырыла, яңа белгечлекләр: эластомерларны кабаттан эшкәртү технологиясе, химик кибернетика, сәнәгый биотехнология, электрохимия җитештерү, лаклы-буяулы капламнар технологияләре, икенчел материалларны рекуперацияләү, тирән вакуум, сыту техникасы, биоорганик синтез; химия һәм нефть химиясе сәнәгате өчен инженер-икътисадчылар әзерләнә башлый. К. химия буенча өлкә һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләр — югары сыйныф укучылары өчен «Орбиталь» җәйге химия мәктәбенә нигез салучы (1997 елдан аның исемен йөртә). Югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы. Уйлап табуга 330 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Тынычлык фонды Советының Татарстан респ-касы бүлеге (1966 дан), Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе (1975–85), ТАССР ЮСның фәнни-техник прогресс комиссиясе (1983–88) рәисе. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). Казанда К. исемендәге урам бар. 1966–71, 1983–88 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин, Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, РСФСР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия и технология мономеров для синтетических каучуков. Л., 1981 (автордаш); Полисульфидные олигомеры и герметики на их основе. Л., 1983 (автордаш); Химия и технология синтетического каучука. Л., 1987 (автордаш).

*Әд.:* Член-корреспондент АН СССР, доктор технических наук, профессор, ректор Казанского химико-технологического института П.А.Кирпичников: Биобиблиогр. К., 1982; Пётр Анатольевич Кирпичников: Избранные труды, воспоминания, материалы. К., 2003.

*В.Г.Абзалова.*

**КИРПИ́ЧНЫЙ** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы бассейнында. 2010 елда 4 кеше (руслар, чуашлар) яши. 1920 еллар башында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Иске Әлмәт волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 226, 1949 да — 238, 1958 дә — 159, 1970 тә — 121, 1979 да — 82, 1989 да — 16, 2002 дә — 10 кеше.

**КИРПОНО́С** Михаил Петрович (21.1.1892, хәзерге Украина Респ-касы, Чернигов өлкәсенең Нежинск р-ны Вертиевка штп. — 20.9.1941, Украина ССР, Полтава өлкәсенең Лохвицкий р-ны Дрюковщина а.), генерал-полковник (1941), Сов. Союзы Герое (21.3.1940). Киев кызыл старшиналар мәктәбен (1922), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1927) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Гражданнар сугышы елларында Н.А.Щорс җитәкчелегендәге дивизиядә полк командиры. 1922 елдан Киев кызыл старшиналар мәктәбендә башлык ярдәмчесе һәм комиссар, 1927 дән укчы дивизия штабы башлыгы. 1934–39 да ТАССР ҮБК исем. Казан пехота хәрби уч-ще-се башлыгы. Совет-фин сугышында укчы дивизия командиры; сугыш хәрәкәтләре б-н җитәкчелек иткәне өчен Герой исеме бирелә. 1940–41 дә корпус командиры, Ленинград хәрби округы, аннан аерым Киев хәрби округы гаскәрләре командующие. 1941 нең июнь–сентябрь айларында Үңъяк яр Украина терр-ясендә авыр сугышлар алып барган Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре командующие. Сугышта һәлак була. Сугыштан соң Киевның Дан паркына күчереп җирләнә. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены (үлгәннән соң) һәм медаль б-н бүләкләнә. Чернигов шәһәрендә К.ка бюст урнаштырыла, Казанда, Казан Кремле терр-ясендә, элеккеге хәрби уч-ще бинасына мемориаль такта куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ц е р к о в н ы й М.Ф., Ш и г а н о в А.Д., Ю р ь е в Б.Ф. Героев подвиги бессмертны. Киев, 1982; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КИРСА́НОВ** Александр Васильевич (23.12.1898, Казан — 16.11.1994, Минск), генерал-майор (1942), Сов. Союзы Герое (15.1.1944). Казан реаль уч-щесен, укытучылар семинариясен, Берләштерелгән Киев мәктәбенең артиллерия бүлеген (1926), командирлар составы белемен камилләштерү курсларын (Мәскәү, 1939), К.Е.Ворошилов исем. Югары хәрби академияне (Мәскәү, 1949) тәмамлый. Гражданнар сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы алдыннан артиллерия полкы, фронтта Курск дугасы сугышында (1943), Днепр елгасын кичкәндә (1943), Белоруссияне (1944), Польшаны (1945) азат иткәндә батырлык күрсәткән 76 нчы гв. Кы-

зыл байраклы Чернигов дивизиясе б-н җитәкчелек итә. Днепр елгасын кичкәндә сугыш хәрәкәтләре б-н җитәкчелек иткәне өчен Герой исеме бирелә. Дивизия, Пренцлау шәһәрен алганда, тоткыннар лагереннан Бельгиянең барлык генералитетын — 33 генералны азат итә. 1945 тә К. Мәскәүдә Җиңү парадында катнаша. 1949–60 та Совет Армиясендә командир вазифаларын башкара. 1960–74 тә Белоруссия ун-ты проректоры. Ике Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Польшаның «Крест» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чернигов шәһәре, шәһәр тибындагы Брагин посёлогы һәм Калинковичи (Белоруссия Респ-касы) шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КИРСА́НОВ** Анатолий Александрович (9.11.1923, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1983), РМА академигы (2001; 1985 тән СССР ПФАнең мөхбир әгъзасы), ТАССРның атказ. укытучысы (1980), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). 1953 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1941–49 да Совет Армиясендә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 дән КПССның Казан шәһәр ком-ты инструкторы. 1956 дан урта мәктәп директоры (Казан). 1964–67 дә ТАССР мәгариф министры урынбасары. 1967 дән Казан пед. ин-тында проректор, бер үк вакытта психол. каф. мөдире. 1981 дән СССР ПФАнең Проф.-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары. 1994–2008 дә Казан технол. ун-тында Идел буе һәм Урал югары уку йортлары укытучыларын әзерләү һәм квалификациясен күтәрү үзәге директоры. Хезмәтләре укытуны индивидуальләштерү һәм дифференциацияләү, проф. белем бирүнең эчтәлеген проектлау, югары техник мәктәп укытучыларын проф. пед. әзерләүдә методологик һәм методик нигез, югары уку йортын тәмамлаганнан соң, проф. белем бирү стандартының фәнни нигезләре проблемаларына карый. СССР ПФА Президиумы бүләге лауреаты (1983). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Культура умственного труда. К., 1968; Индивидуализация педагогической деятельности как учебная проблема. К., 1982; Совершенствование организационных форм обучения. М., 1987; Интегративные основы широкопрофильной подготовки специалистов в техническом вузе. Н.Новгород, 1999 (автордаш).

**КИРСА́НОВ** Николай Васильевич (16.6.1914, Казан — 18.8.1988, шунда ук), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1974), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1936), Мәскәү геол. тресты Татарстан бюросында геол. партия башлыгы. 1936–38 елларда ВЛКСМның Бауман райкомы (Казан) секретаре. 1946–88 дә ЦНИИгеолнерудта, тау-химия чималы геологиясе лаб-ясе мөдире (1947–80). СССР терр-ясендәге утырма формацияләрдә бентонит балчыкларның таралу закончалыклары турындагы тәгълиматка нигез салучы. Әлеге чыганакларның генетик классификациясе авторы; бентонит чыганакларының яңа утырма геол.-сәнәгый тибын аера. К. җитәкчелегендә СССР терр-ясендә фаразлау-минерагеник тикшерү үткәрелә һәм илдә бентонитлар чималы базасы булдырыла, Россиянең Европа өлешендә Көнчыгыш акчагыл утырмалары стратиграфиясенең бердәм схемасы эшләнә. ТАССР Госпланы әгъзасы (1965–72). Бөек Ватан сугышында катнаша. 3 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Богатство недр Татарии. К., 1956 (автордаш); Пентониты // Неметаллические полезные ископаемые СССР. М., 1984.

*Әд.:* Заслуженный геолог республики // Вечерняя Казань. 1987. 1 апр.


**КИРСА́НОВ** Эдуард Юрьевич (29.3.1944, Казан), хисаплау техникасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (1999). 1970 елда Львов политехник ин-тын тәмамлый. 1969–73 тә Ивано-Франковск приборлар төзү з-дының Махсус КБда хисаплау техникасы чаралары лаб-ясе башлыгы булып эшли. 1977 дән Казанда: СССР Үзәк статистика идарәсенең Бөтенсоюз проект-технол. ин-тының Идел-Вятка ф-лында, хисаплау техникасы чаралары бүлеге мөдире (1981–86); «Нефтепромавтоматика» фәнни ҖБдә проектлау баш конструкторы (1986–90); Хисаплау системалары фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек башлыгы (1990–94). 1994 тән Казан техник ун-тының компьютер системалары һәм мәгълүмати куркынычсызлык кафедрасында, бер үк вакытта 1998 дән «Интеграл» радиоэлектроника һәм хисаплау техникасы фәнни-тикшеренү уку-укыту үзәге директоры (Казан техник ун-ты каршында), 1997 дән ТР ФАнең «Нейросистемалар» нейрокомпьютер системалары һәм челтәрле технологияләр фәнни-тикшеренү үзәге директоры. Хезмәтләре нейрокомпьютерларга, нейроматематикага һәм нейрон челтәрләргә карый. Бердәм ЭВМ системасының күп кенә эшләнмәләрен төзүдә һәм сериягә кертүдә катнаша, безнең илдә эшләнелүче «Геркулес» цифрлы нейрокомпьютерлар сериясенең баш конструкторы. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Нейронные системы памяти. М., 1991 (автордаш); Цифровые нейрокомпьютеры: архитектура и схемотехника. К., 1995; Организация ЭВМ и систем. К., 2003; Нейрокомпьютеры с параллельной архитектурой. М., 2004.

**КИРСА́НОВ** Юрий Анатольевич (12.6.1940, Яшел Үзән ш.), җылылык физикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005). 1969 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1974–86 да Киров политехник ин-тында укыта. 1986 дан Казанда: «Турбокомпрессор» фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек башлыгы, 1990–2005 тә Казан энергетика ун-тында, 2003 тән РФА КГҮнең Энергетика проблемаларын тикшерү үзәгендә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре каналларда һәм күзәнәкле тирәлекләрдә җылылык алмашуга һәм агымнарның гидродинамикасына, каты һәм агучан тирәлекләрдә җылы үткәрүчәнлеккә карый. Кайнар һәм салкын тирәлекләр б-н циклик җылылык алмашуы барышында каты җисемнең гиперболик җылы үткәрүчәнлеге кырый мәсьәләсен хәл итә. Күзәнәкле җисемнең җылылык-гидродинамик характеристикаларын тикшерү методикасын эшли, җылылык бирүнең һәм гидродинамик каршылыкның критерийлы тигезләмәләрен ала. Медальләр б-н бүләкләнә.



А.В.Кирсанов.




А.А.Кирсанов.

Х е з м.: Циклические тепловые процессы и теория теплопроводности в регенеративных воздухоподогревателях. М., 2007; Тепловой резонанс как условие для самопроизвольной передачи теплоты от холодной среды к горячей // Изв. РАН. Энергетика. 2009. № 3; Оценка коэффициентов критериальных уравнений теплопередачи отдельных трактов в теплообменнике // Промышленная энергетика. 2009. № 5 (автордаш).

**КИРТӘЛЕ́** елгасы, Идел алдында, Кылна елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,8 *км*, бассейнының мәйданы 50,2 *км²*. Идел буе калкулыгыннан ага, Тәтеш р-нында. Елга башы урман массивында, Красный Восток авылыннан 2,4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Жуково авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. К.нең 1,1 дән алып 1,5 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,009 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**КИРТӘЛЕ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тәтеш–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 435 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек,



В.А. Киршин.

терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә чиркәү була, 1913 тә мәктәп төзелә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1813,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән — ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 917, 1880 дә — 1215, 1913 тә — 1585, 1926 да — 1722, 1938 дә — 1234, 1949 да — 852, 1958 дә — 881, 1970 тә — 915, 1979 да — 735, 1989 да — 570, 2002 дә — 483 кеше.

**КИ́РШИН** Василий Алексеевич (13.1.1928, хәзерге Удмурт Респ-касы, Можга р-ны Югары Кватчи а. — 20.12.2007. Мәскәү), радиобиолог, вет. фән. д-ры (1968), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). 1950 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1950–53 елларда Удмурт Респ-касы Большеучинск р-нының баш вет. табибе. 1953 тән Казан вет. ин-тының патологик физиол. кафедрасында. 1960 тан радиобиол. бүлеге мөдире, проф. (1970); 1984–93 тә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында радиобиол. бүлеге мөдире. 1993–99 да Мәскәү ун-тының гамәли биотехнол. каф. профессоры. 1999 дан Мәскәү вет. медицинасы һәм биотехнол. академиясендә радиобиол. каф. профессоры. Хезмәтләре а.х. терлекләре һәм кошларының радиация б-н зарарлану патогенезына, радиоэкология мәсьәләләренә карый. К. тикшеренүләре Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә һәм радиация б-н зарарланган җирләрдә терлекчелекне рациональ алып бару өчен файдаланыла. Аз микъдарда нурланышның биол. тәэсирен һәм аны терлекләрнең продукциялелеген арттыру өчен файдалану үзенчәлеген ача. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ветеринарная радиобиология. М., 1987 (автордаш); Краткий экологический словарь. Саранск, 2000 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КИРЬЯ́НОВ** Борис Фёдорович (16.1.1935, Ленинград), радиоэлектроника һәм информатика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1975), проф. (1977), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). 1959 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп, 1963–66 да оборонага караган фәнни-тикшеренү ин-тында), радиотехника (1968–70), хисаплау һәм идарә итү системалары ф-тлары (1974–76) деканы, ЭВМ каф. мөдире (1976–78). 1978 дән Новгород ун-тында, проректор (1980–85), радиосистемалар (1985–89), югары (1989–93) һәм гамәли (1993–2005) матем. кафедралары мөдире. Хезмәтләре хисаплау җайланмаларын ихтималлылык принциплары буенча төзү һәм эшләтүнең теоретик нигезләренә карый. К. мәгълүмат тапшыру системаларында циклик эзлеклелекләрне өйрәнә; псевдоочраклы эзлеклелекләр генераторларының (ГПСП) синхронлашуга керүе алгоритмнарын билгели һәм аларның ихтималый характеристикаларын анализлый, нәтиҗәдә ГПСП параметрларын алдан бирелгән шартлар буенча сайлау мөмкинлеге туа; гомуми кулланылыштагы элемтә каналлары буйлап мәгълүмат тапшыру алгоритмнарын тәкъдим итә. Стохастик хисаплау җайланмаларын эшли (Казан ЭВМ з-дында гамәлгә кертелә). Стохастик модельләштерү һәм аның кулланылышы мөмкинлекләрен тикшерә. Машина юлы б-н псевдоочраклы саннар табуның оперативлыгын күтәрә торган алгоритмнар тәкъдим итә (бергәләп), ирекле бүленгән координаталы очраклы векторлар модельләштерү алымнарын эшли. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Многоканальный генератор псевдослучайных символов // Изв. АН СССР. Сер. Техн. кибернетика. 1970. № 4; Эквивалентность систем, реализующих стохастический принцип вычислений // Изв. АН СССР. Сер. Техн. кибернетика. 1972. № 5; Имитация случайностей в задачах математического моделирования // Вестн. Новгор. ун-та. Сер. Естеств. и техн. науки. 1995. № 1.

**КИСА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Сөлчә елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,2 *км*, бассейнының мәйданы 40,8 *км*$^2$. Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Түбән Баланда авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Покровка авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 50%. К.ның 0,4 һәм 4 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры вакытта елганың югары агымнары еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 89 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,021 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында су күләме 0,8 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КИСА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Сөлчә елгасының (Олы Сөлчә, Олы Чирмешән елгалары бассейннары) сул кушылдыгы. Озынлыгы 10 *км*, бассейнының мәйданы 48,9 *км*$^2$. Аксубай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Кече Аксубай авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак, тамагы — Киса авылында. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 99 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 55%. К.ның 0,6 дан алып 4,5 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,24 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, зур күпчелекне кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры вакытта елга урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 92 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,004 *м*$^3$*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Елгада суның гомуми күләме 1,2 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КИСА́** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 4 *км* көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 466 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1710 нан мәгълүм. 20 йөз башыннан 1963 елга кадәрге рәсми чыганакларда 2 торак пункт: Рус Кисасы һәм Чуаш Кисасы буларак теркәлгән. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да чиркәү, укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1897 дә ачыла), ярма яргыч, дегет кайнату бинасы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1812 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 982, 1897 дә — 984, 1908 дә — 1049, 1920 дә — 1021, 1926 да — 1055, 1938 дә — 1159, 1949 да — 783, 1958 дә — 767, 1970 тә — 728, 1979 да — 771, 1989 да — 446, 2002 дә — 473 кеше.

**КИСӘКЧӘЛӘ́Р**, аерым сүзләргә яки җөмләләргә төрле мәгънәви һәм модаль төсмерләр өсти торган ярдәмлек сүзләр. Форма ясагыч, логик-мәгънәви һәм модаль К.не аерып карыйлар. Форма ясагыч К.гә, сыйфат алдыннан килеп (иң-иң татлы) яки аның нигезен өлешчә кыскартып һәм п, м тартыклары ялганып (ап-ак, кап-кара), артыклык дәрәҗәсе ясаучы К. керә. Логик-мәгънәви К.гә чикләү, аерып кую (гына/генә, кына/кенә; бары, тик, бары тик; фәкать, исә), көчәйтү (ук/үк, да/дә, та/тә, ә, тагы, тагы да, хәтта), аныклау (нәкъ), инкяр итүне (түгел) белдерүче К. керә. Модаль К.гә саф модаль (билгесезлек, икеләнү төсмерләрен бирүче -дыр/-дер, -тыр/-тер кисәкчәләре: баргандыр, килгәндер), мо-

даль-ихтыяри (үтенү, ялваруны белдерүче -чы/-че, -сана/-сәнә кисәкчәләре: китче, барсана), сорау (-мы/-ме, -мыни/-мени, ә: килдеме, танымыйсыңмыни), эмоциональ-экспрессив (раслау-ныгытуны белдерүче лабаса/ләбаса, ла/лә, бит, ич, соң, әле, инде кисәкчәләре: бирде ләбаса, бәйрәм бит, мактыйм әле) К. керә.

К., үзләренең мәгънә үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, бер үк вакытта теркәгечләр вазифасын да үти ала, шуңа күрә К. төркеме эчендә теркәгечле К. төркемен дә аерып күрсәтәләр. Җөмләдә К.нең язылышы төрле. Кайбер К. үзләре бәйләнгән сүздән һәрвакыт алда килә. Аларның берише (өр-, чем-, ямь-, кып-, ап- һ.б.) сызыкча аша, икенчеләре (иң, җете, үтә һ.б.) аерым языла. К.нең икенче төре үзләре бәйләнгән сүздән соң килә һәм ике төрле: а) гына/генә, кына/кенә, бит, ич, лабаса/ләбаса һ.б. К. аерым; б) -мы/-ме, -мыни/-мени, -дыр/-дер, -че һ.б. К. кушылып языла. К.нең өченче төре — әле, инде, соң һ.б. — үзләре бәйләнгән сүздән алда да, аннан соң да килә ала. Алар һәрвакыт аерым языла. К.не өйрәнүгә К.Насыйри, Җ.Вәлиди, Г.Алпаров һәм В.Хангилдин кебек күренекле галимнәр зур өлеш кертә.

*Әд.:* Насыйри К. Әнмүзәҗ. К., 1895; Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы. К., 1919; Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр (татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). К., 1945; Хангилдин В. Татар теле грамматикасы. К., 1959; Татар грамматикасы. Т. 2. Морфология. К., 2002.; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

*М.Сәгыйтов.*

**КИСӘ́Р ҮЛӘ́Н** (Libanotis), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр семьялыгы. 20 гә якын төре билгеле, күбесенчә Евразиянең уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төр — арадаш К.ү. (L. intermedia), барлык районнарда очрый. Коры үзәнле болыннарда, далаланган тау битләрендә үсә. 60–120 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы соры-яшел, кырлы, җиңелчә тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, җиңсәле, асты күксел-яшел, аскы яфраклары икеле каурыйсыман, өскеләре — каурыйсыман, үзенчәлекле хуш исле. Чәчәкләре вак, аксыл, күп яфраклы чәчәк төргече б-н катлаулы чатырга җыйналган. Җимеше — ике орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре сентябрь ахырында өлгерә. Орлыктан үрчи. Эфир майлы үсемлек. Халык медицинасында орлык төнәтмәсе геморрой, бүсер вакытында, бәвел кудыру, кан туктату чарасы буларак кулланыла. Вакланган үләнне яраларга һәм эренле шешләргә куялар. Баллы үсемлек.

**КИСӘ́Ү ГӨМБӘСЕ́**, үсемлекләр авыруы, К.г. гөмбәләре (Ustilaginales) китереп чыгара. ТРның барлык районнарында киң таралган, аеруча бөртекле культураларга (йончалар һәм лаләчәләр семьялыгыннан) зур зыян китерә. Үсемлекләрнең вегетатив һәм генератив органнарының (башлыча, җимшән, башак, себеркәч, чәкән, ш.у. сабак, яфрак, тамыр муентыгы) кара споралар массасына әйләнүе К.г. б-н зарарлануның төп билгесе булып тора. Симптомнарына карап, тузан, каты, сабак һәм куыклы К.г.нә аералар. Иң зарарлы һәм еш очрый торганнары — бодай, арпа, солы, тарының каты К.г.; арыш һәм бодайның сабак К.г.; суганның куыклы К.г. һ.б. Тузан К.г. үсемлекләрнең генератив органнарын зарарлый (башак, себеркәч), куыклы К.г. булганда, үсемлекләрнең җир өстендәге органнарында кабырчыклар барлыкка килә, соңрак алар кара споралар массасына әверелә.

Зарарлану орлыклар тишелеп чыккан вакытта (үсентеләр зарарлану тибы), башаклану һәм чәчәк ату вакытында (чәчәкләр зарарлану тибы), кайбер очракта бөтен вегетация чоры дәвамында (катнаш тип) була. Үсентеләр зарарлану тибына бодайның каты К.г., арышның сабак К.г. керә. Чәчәкләр зарарлану тибына үсемлекләрнең чәчәк ату чорында зарарлануы хас, мицелий төрендәге инфекция орлыклык материалның яралгысында саклана (бодай һәм арпаның тузан К.г.). Катнаш типта инфекция әлпәләрдә, әлпәләр астында һәм бөртекчәләр өслегендә саклана (солының тузан К.г., солының каты К.г., тары К.г.). Саклагыч чараларның төре зарарлану тибына карап билгеләнә. Үсентеләр зарарлану тибында орлыклар тишелешен көчәйтү кирәк (соңрак чәчү, үсешне көчәйтүче препаратлар һәм контактлы орлык агулагыч — ТМТД, паноктин, максим куллану). Чәчәкләр зарарлану һәм катнаш типта сорт үзенчәлекләре һәм системалы орлык агулагычлар (фундазол, витавакс, фенорам, раксил һ.б.) куллану мөһим роль уйный.

Барлык типлар өчен көрәш чаралары: чыдамлы сортлар игү, югары агротехника куллану, орлыкларны чистарту һәм аларны химик препаратлар яисә термик ысул б-н йогышсызландыру, орлыкларны һавада — җылыда яисә кояш астында җылыту һ.б. Профилактика чарасы булып каты һәм тузан К.г. б-н зарарланган орлыкларны 0,5% тан артык чәчмәү тора.

*Р.И.Сафин, Ф.С.Зыятдинов.*

**КИСЕКБА́Ш**, татар фольклоры һәм язма әдәби әсәрләр персонажы. Күп кенә әкиятләрдә («Алтын чүлмәк», «Унике егет» һ.б.), легендаларда («Кисекбаш», «Кисек башлы әүлия»), «Идегәй» дастанында очрый. К.ның барча эш-гамәлләре, үзенең бар булуы кебек үк, гайре табигый характерга ия: гәүдәдән аерылган баш сорауларга җавап бирә, өйрәтә, киләчәкне юрый, үзенең дошманнарын юк итә һ.б. К. образы фольклор әсәрләрдән язма әдәбиятка да күчә («Печән базары, яхуд Яңа Кисебаш», Г.Тукай). Ш.у.к. «*Кисекбаш китабы*».

*Әд.:* Әхмәтгалиева Я.С. «Кисекбаш китабы» // Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1; Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Идегәй: Татар халык эпосы. К., 1988.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«КИСЕКБА́Ш КИТАБЫ́»**, 14–15 йөзләр төрки-татар дини-дидактик әдәбияты ядкәре. Авторы билгесез. 270 шигъри юлдан тора. Поэманың сюжеты әкияти-маҗаралы: Мөхәммәд пәйгамбәргә киселгән кеше башы, ярдәм сорап, үтенеч б-н мөрәҗәгать итә. Ул аңа *диюнең* шәһәрне җимерүе, улын йотуы, чибәр хатынын урлавы, ә үзен *Кисекбашка* әверелдерүе турында сөйли. Мөхәммәд пәйгамбәр кушуы буенча аның тугрылыклы сәхабәсе Гали дию биләмәсенә бара һәм әсирләрне коткара. Явызлык җиңелә, гаделлек җиңә. 1846 елдан поэма, күп тапкырлар нәшер ителеп, Идел-Урал төрки халыклары арасында киң тарала, мәдрәсәләрдә өйрәнелә. «К.к.»ның Казан, С.-Петербург, Мәскәү, Баку, Әнкара китапханәләрендә күпсанлы кульязма нөсхәләре саклана. Татар әдәбиятында, «К.к.» сюжетына нигезләнеп, Г.Тукай, Н.Исәнбәт, Н.Баян, Ш.Мөдәррис, Ә.Исхак, Ә.Камал сатирик әсәрләр иҗат итәләр.

*Әд.:* Әхмәтгалиева Я.С. «Кисекбаш китабы» // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1984. Т. 1; Кисекбаш. К., 2000; Наджип Э.Н. О средневековых литературных традициях и смешанных письменных тюркских языках // Советская тюркология. 1970. № 1.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**КИСЕЛЁВ** Владимир Дмитриевич (23.11.1942, Краснодар өлкәсенең Динск р-ны «Агроном» с-зы), химик-органик, химия фән. д-ры (1987), проф. (1992), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1998). 1965 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли; 1991 дән А.М.Бутлеров исем. химия ин-тында, 1992 дән югары басым химиясе бүлеге мөдире, 1992–2003 тә директор, 2004–2009 да директор урынбасары. Хезмәтләре цикллар кушуның гадәти һәм каталитик реакцияләре кинетикасы һәм термохимиясенә карый. К. цикллар кушу процессларының тизлеген һәм тигезләнешен үзгәртү алымнарын тәкъдим итә, реагентларның химик халәтен алдан белергә мөмкинлек бирүче микъдари нисбәтләрне ачыклый. Яңа бис-реагентлар синтезлый һәм алар нигезендә югары молекуляр кушылмалар ала. Югары гидростатик басым шартларында реакцияләрне спектраль күзәтү өчен оптик блок эшли, фторкаучуклар өчен вулканизаторлар әзерләү алымын җитештерүгә кертә. Дильс-Альдер реакциясе өлкәсендәге тикшеренүләре өчен Д.И.Менделеев исем. Бөтенроссия химия җәмгыяте бүләгенә (1976), диен-диенофил системаларының реакциягә керү сәләтен тикшерүләре өчен РФАнең Н.Д.Зелинский исем. бүләгенә (2008) лаек була.

Хезм.: Факторы, определяющие реакционную способность в обычной и катализируемой реакциях Дильса-Альдера // Успехи химии. 1989. Т. 58, вып. 3 (автордаш); Реакционная способность диен-диенофильных систем. Влияние внутренних и внешних факторов // Изв. АН СССР. Сер. хим. 2003. № 2 (автордаш); Experimental proof that the Diels-Alder reaction tetracyanoethylene with 9–10 dimethylanthracene passes through formation of a molecular complexes between the reactants // J. Am. Chem. Soc. V. 97, № 14 (автордаш).

**КИСЕЛЁВ** Владимир Николаевич (6.12.1930, Самара ш.), философ, филос. фән. д-ры (1973), проф. (1973), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). Казан хәрби Суворов уч-щесен (1949), Казан ун-тын (1954), Мәскәү ун-ты каршындагы Җәмгыять фәннәре укытучылары квалификациясен күтәрү ин-тын тәмамлый (1972). 1957–62 елларда Казан авиация ин-тының диалектик һәм тарихи материализм кафедрасында. 1962 дән

Казан мед. ин-тының филос. каф. мөдире. 1974 тән — Хезмәт һәм социаль мөнәсәбәтләр академиясе (Мәскәү) фәнни-тикшеренү бүлегенең сектор мөдире, 1992 дән — социаль партнерлык ф-ты деканы, шул исемдәге каф. мөдире. Хезмәтләре социаль партнёрлык, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Формирование научного мировоззрения трудящихся советского общества в период строительства коммунизма. К., 1968; Социальное партнёрство в России. М., 2002 (автордаш); Социальное партнёрство: Словарь-справ. М., 2002 (автордаш).

*Әд.:* А л е к с е е в П.В. Философы России XIX–XX столетий. М., 2002.

**КИСЕЛЁВ** Михаил Андреевич (6.11.1897, Екатеринбург губ., Шадрин өязе Катайское а. — 20.11.1937, Казан), физиолог, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1935). Пермь ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1924), Казан ун-тында эшли. Кыллы гальванометрда эшләү алымын үзләштерә, проф. А.Ф.*Самойлов* б-н берлектә нерв системасы физиологиясе буенча күп кенә тикшеренүләр үткәрә. 1930–31 елларда Казан ун-тында хезмәт физиологиясе буенча яңа уку курсы оештыра, су астына кессон җайланмаларда төшкәндә кеше организмының функциональ халәтен тикшерә. 1931 дә проф. И.Л.Кан чакыруы буенча Мәскәүгә күчә һәм Мәскәү ун-тында физиология лаб-ясен җитәкли. 1935 тән яңадан Казан ун-тында, физиол. каф. мөдире. Казан ГИДУВында Россиядә беренче клиник электрофизиология лаб-ясен оештыра һәм аны җитәкли. Хезмәтләре электрофизиологиягә, үзәк нерв системасы һәм кан әйләнеше физиологиясенә карый. К. ярсынучан системалар физиологиясе өлкәсендә Введенский тетанизацияле ялгыз кыскару феноменын локальләштерү буенча тикшеренүләр үткәрә. Бу күренешнең нигезендә югары ярсынучанлык ятканлыгын күрсәтә, ул исә тәэсир агымының тискәре эзле фазасында ярсынудан соң бара. К.ның йөрәк физиологиясе, электрофизиол. һәм ашказаны-эчәк тракты өлкәсендә, талакта кан әйләнеше үзенчәлекләре турында хезмәтләре билгеле.

Х е з м.: Влияние поляризации небольших участков нерва на его проводимость в обе стороны на основании изучения отрицательного колебания нервного тока // Изв. Перм. биол. НИИ. 1923. Т. 2, вып. 3; Кессонные заболевания и санитарные условия жизни рабочих при постройке железнодорожного моста через р. Казанка // Гигиена труда. 1927. № 2 (автордаш).

*Әд.:* Л е б е д е в К.В., В о л к о в а И.Н., З е ф и р о в Л.Н. Из истории Казанской физиологической школы. К., 1978; Казанская физиологическая школа на рубеже веков // Материалы 18 съезда физиологов России. К., 2001.

*Н.В.Звёздочкина.*

**КИСЕЛЁВ** Олег Михайлович (7.10.1933, Кисловодск ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1973), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1956 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: 1959 дан хисаплау үзәгендә, 1966–99 да Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, газлар динамикасы бүлеге мөдире (1975–90). Хезмәтләре теоретик гидроаэромеханикага карый. К. бирелгән хордалы диаграмма буенча канатлы профильләр һәм әйләнү җисемен төзү алымнарын, кысылмаучан сыеклыкның яссы һәм күчәр симметрияле тавыш тизлегенә кадәрге агынтылы агымнарны тикшерүнең санлы-аналитик ысулын тәкъдим итә. Ул кысылмаучан сыеклыкның яссы агымнары үзлекләрен, кысылучан сыеклыкның кавитацион агымнарын һәм максималь критик Мах санлы газларның агынтылы агымнарын (бергәләп) тикшерә; технол. газ лазерларын матем. модельләү буенча эшләр башкара (бергәләп). 1999 дан АКШта яши.

Х е з м.: Нелинейные задачи теории струйных течений тяжёлой жидкости. К., 1978 (автордаш); О расчёте кавитационного обтекания кругового конуса дозвуковым потоком сжимаемой жидкости // Прикладная математика и механика. 1994. Т. 58, вып. 4 (автордаш); Об обтекании струи газа из конического сопла // Прикладная математика и механика. 2000. Т. 64, вып. 1 (автордаш).

**КИСЕЛЁВ** Сергей Васильевич (11.6.1957, Казан), химик-органик, мед. фән. д-ры (2006). 1980 елда Казан. мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук физик һәм коллоид химия кафедрасында эшли, 1987 дән биоорганика һәм биофизика химиясе, 1999 дан гомуми һәм органик химия кафедраларында. Хезмәтләре тукыма тромбопластинының, эритроцитларның һәм альвеоляр макрофагларның кеше протромбины б-н үзара тәэсире, протромбин б-н күзәнәк өслегенең үзара бәйләнешенә гепаринның тәэсирен өйрәнүгә карый.


Х е з м.: Взаимодействие витамина К-зависимых факторов свёртывания крови с фрагментами клеточных мембран // 3 съезд биохимического общества. СПб., 2002 (автордаш); Взаимодействие фактора «Х» человека с тканевым тромбопластином // Биомедицинская химия. 2003. № 5 (автордаш).

**КИСЕЛЁВ** Сергей Владимирович (10.2.1955, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1997), проф. (1997). 1976 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук фәнни-тикшеренү лаб-ясендә эшли. 1977–78 һәм 1981–82 дә Казан мед. ин-тында. 1982–87 дә Казан язу җайланмалары з-дында бүлек башлыгы, ген. директор урынбасары. 1987–89 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында социаль-икътисад секторы мөдире. 1990 нан Казан мед. академиясенең сәламәтлекне иминиятләштерүле саклау каф. мөдире. Хезмәтләре мед. иминияте мәсьәләләренә карый. ТР МК каршындагы Иминиятләштерү мәсьәләләре буенча эксперт советы әгъзасы.

Х е з м.: Теоретические и методологические основы страхового дела. К., 1992; Медицинское страхование. К., 1995 (автордаш); Социально-экономические основы медицинского страхования в условиях становления рыночных отношений в России. К., 1996 (автордаш).

**КИСЕЛЁВА** Елизавета Васильевна (30.10.1925, Красноярск краеның Курагинск р-ны Берёзовка а. — 15.2.1996, Казан), график, нәкышьче, сынчы, медальер, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976). Кострома өлкәсенең Красносельск металларны нәфис эшкәртү техникумын (1948), Мәскәү полиграфия ин-тын (1964) тәмамлый. 1949 елдан Казанда яши һәм эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971).

1960–70 елларда Татарстандагы әйдәп баручы графикларның берсе, линогравюра өлкәсендәге «кырыс стильдә» иҗат итүчеләрнең талантлы вәкиле. Эстампларда зур форматка, героик-рев-цион тематикага («Революция», «Күтәрел, ләгънәт ителгән! (1905 ел)» триптихлары, икесе дә — линогравюралар, 1967), космосны яулау темасына («Башка планеталарга — тормыш!», «Йолдызларга», икесе дә — линогравюралар, 1967) мөрәҗәгать итә. Акварель, гуашь, темпера техникасы б-н жанрлы композицияләр, натюрмортлар, пейзажлар тудыра, аларда рәссам дөньяны лирик планда кабул итүче үзенчәлекле талант иясе буларак ачыла — «Виноград тәлгәше» (гуашь, 1968), «Балерина» (акварель, 1970), «Кыш» (гуашь, 1972) һ.б. 1960 еллар уртасыннан К. — Казандагы «Агитплакат» остаханәсендә иң актив рәссамнарның берсе, тарихи-революцион һәм сәяси плакат жанрларында эшли, күргәзмәләр өчен һәм театр, концерт афишалары иҗат итә. 1960 еллар ахырында «Г.Тукай исем. премия лауреаты», «ТАССРга 50 ел» һ.б. истәлек һәм бүләк ме-



Е.В.К и с е л ё в а. 1. «Флокслар». Кәгазь, акварель, гуашь. 1975; 2. «Балерина». Кәгазь, акварель, гуашь. 1970 еллар; 3. «ТАССРга 60 ел». Плакат, эскиз. Кәгазь, гуашь. 1980. Барысы да — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

дальләре ясый. 1960–70 елларда республикада монументаль-декоратив сәнгатьнең күп кенә яңа төрләренең үсеш алуында башлап йөрүче була. К. интерьерларны бизәүдә металлга чүкеп бизәк төшерүне кулланылышка кертә — Казандагы Химиклар мәдәният сарае (1969), Яшел Үзәндәге мәдәният сарае (1971–72) интерьерларындагы декоратив композицияләр. Ригада өйрәнгән техниканы кулланып, Казанда, беренчеләрдән булып, витражлар эшли башлый. 1970 еллар башында К. гипска уеп бизәк төшерүгә мөрәҗәгать итә (Казан мәдәният ин-ты фойесындагы (1971) һ.б. декоратив композицияләр). 1970–80 елларда ул гамәли һәм сәнәгый графика өлкәсендә, товар төрү дизайны, реклама афишалары, сувенир значоклар, чакырулар, Яңа ел һ.б. бәйрәм билетларын ясау юнәлешендә күп эш башкара.

Республика, төбәк, бөтенроссия һәм бөтенсоюз күргәзмәләрендә (1957 дән) катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, А.М.Горькийның Әдәби-мемор. музеенда (Казан), Әлмәт картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись. Скульптура. Графика. М., 1978; Шулук. Художники Советской Татарии. К., 1984. *О.Л.Улемнова.*

**КИСЕЛЁВА** Любовь Андреевна (1.9.1924, Пермь өлкәсенең Чердынь ш. — 18.1.1997, Казан), агроном-селекция белгече, ТАССРның атказ. агрономы (1974). Ленинград а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Казан селекция станциясендә эшли. 1962 елдан Татарстан а.х. тәҗрибә станциясендә, 1969 дан Татарстан А.х фәнни-тикшеренү ин-тында. Болын арышбашының «Казан», болын солычасының «Казан», люцернаның «Айсылу» сортларын чыгаруда катнаша. «Почёт билгесе» ордены, СССР ВДНХсының бронза медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Виды многолетних трав для создания долголетних культурных пастбищ и их семеноводство: Материалы Респ. науч.-произв. аграр. конф. К., 1971; Организация семеноводства лугопастбищных трав // Резервы прочной кормовой базы. К., 1982.

**КИСЕЛЁВКА** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2010 елда 27 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Александровский, Крутогорский исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да су тегермәне, май з-ды була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1524 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 274, 1870 тә — 338, 1884 тә — 451, 1897 дә — 584, 1913 тә — 694, 1920 дә — 605, 1926 да — 403, 1938 дә — 349, 1949 да — 232, 1958 дә — 188, 1970 тә — 175, 1979 да — 141, 1989 да — 93, 2002 дә — 41 кеше.

**КИСЕЛЁВКА** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 1923 тә Иске Тәкмәк авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Әхмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 167, 1949 да — 150, 1958 дә — 113, 1970 тә — 68, 1979 да — 36, 1989 да — 7, 2002 дә — 4 кеше.

**КИСКЕ́Ч ҮЛӘ́Н** (Falcaria), чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 4 төре билгеле, Евразия, Төньяк Африканың уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади К.ү. (F. vulgaris) барлык районнарда да очрый. Далалы болыннарда, урман буйларында, чәчүлекләрдә, чүплекләр тирәсендә үсә. 30–60 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабагы цилиндрсыман, күгелҗем яшел, ботаклы. Яфраклары тыгыз, тиресыман, тамыр янындагылары — бөтен яки өчәрле, кыяк-пычкы читле өлешләрдән тора. Чәчәкләре вак, ак төстә, күп тармаклы чатырда. Җимеше — аз гына җыерчыклы саргылт-көрән орлыкча. Июль–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Җир өсте өлешләрендә алкалоид, эфир майлары бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе ашказаны согының әчелеге түбән булганда, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Вакланган яфракларын яраларга куялар. Баллы үсемлек.

**КИСЛИ́НКА** (Вязовка) елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Урман Чишмәсе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 15,9 *км*, бассейнының мәйданы 109,6 *км*$^2$. Бөгелмә–Бәләбәй калкулыгыннан ага, Лениногорск р-нында. Елга башы — Алёшкино авылының көнбатыш читендә, тамагы — Сугышлы авылында. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 130 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 60%. К.ның 4,4 тән алып 10,5 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, иң зурысы (уң) — Кузай елгасы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, яртысын диярлек кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–10 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,235 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20 *мг-экв/л*дан күбрәк). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КИСМӘННӘ́Р** (Tenthredinidae), утырма корсаклы элпәканатлылар семьялыгы. 4 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 200 дән артык, Урта Идел буенда 50 гә якын төре яши. Гәүдәсе 30 *мм* га кадәр озынлыкта. К.нең личинкалары (ялган гусеницалар) ачык яшиләр һәм тышкы ягы б-н күбәләк гусеницаларын хәтерләтәләр, алардан күпсанлы ялган корсак аяклары (6–8 пар) б-н аерылалар. Курчаклану алдыннан ялган гусеница ефәк җебе бизләре сыекчасыннан пәрәвез кузы ясый. Олы бөҗәкләр әкреннәр, көчсез, чаккычлары юк. Кушылудан соң, ата зат үлә. Күкәй салгычлары пычкы кебек булган ана бөҗәкләр үсемлек тукымасын кисеп (исеме шуннан) күкәй салалар. Күпчелек олы К.нең личинкалары үсемлек б-н туклана. Татарстан терр-ясендә а.х. һәм җимеш культураларына (чия, крыжовник, карлыган, рапс, кәбестә һ.б.) зарар китерүче төрләре күп. 2000–01 дә республиканың бөтен терр-ясе буенча җирән нарат кисмәне (Neodiprion sertifer), зур каен кисмәне (Cimbex femorata), гади нарат кисмәне (Diprion pini) һ.б. тарала. Еш кына саклагыч утыртмаларда, урман-паркларда, питомникларда очрый, нигездә, үсентеләрне һәм яшь агачларны зарарлый.

*Н.В.Шулаев.*

**КИСТӘ́Н**, борынгы сугыш һәм ау коралы. Өч өлештән тора: тотка, каеш бау яки тимер чылбыр, сөяк яки металл шар яисә кечкенә гер; соңгысы каеш бау яисә тимер чылбыр б-н тоткага тоташтырыла. Атлы бәрелештә сугыш киемнәре б-н сакланган дошманга бәрү өчен кулланылган. Үзәк Азия күчмә халыклары коралы буларак мәгълүм. Европада К. 7–8 йөзләрдә кулланышка керә. 8–13 йөзләрдә ул болгарларда таралыш ала һәм төрле формаларда була. 13–14 йөзләрдә элек кулланышта йөргән К.нәрдән авыррак булуы, эш-



Кистән. Бронза. 13 йөз. Идел буе Болгар дәүләте.



Кистәннәр. 12–13 йөзләр. Идел буе Болгар дәүләте.

ләнгән материалы (тимер, бронза) б-н аерыла. 16 йөз башында сугышчылар К. кулланмый башлыйлар, ул юлбасарлар һәм казаклар коралына әверелә. Төркиләр эпосында сугыш камчысы — батырның өстәмә коралы рәвешендә тасвирлана.

*Әд.:* Измайлов И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII вв. Магадан, 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**КИТ-О́ЗЕРО** (Кит Күле) авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак,Ваешур елгасы буенда. 2010 елда 87 кеше (удмуртлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Поповка волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 86, 1938 дә — 115, 1949 да — 91, 1958 дә — 84, 1970 тә — 95, 1979 да — 75, 1989 да — 83, 2002 дә — 75 кеше.

**«КИТАБЕ́ ГӨЛЕСТА́Н БИТ-ТӨРКИ́»** («Төркичә Гөлестан китабы»), урта гасырлар төрки-татар әдәби ядкәре. Алтын Урда дәвере шагыйрьләреннән Сәйф Сараи, Әхмәд Хуҗа, Габделмәҗид, Мәүлә Казый Мөхсин, Мәүләнә Гыймад Мәүләви, Мәүләнә Исхак, Тугълы Хуҗа, Сараи Гөлестани һ.б. шагыйрьләрнең тезмә һәм чәчмә формада язылган әсәрләре җыентыгы. 14 йөз ахырында мәмлүкләр Мисырында аноним автор (кайбер фаразлар буенча, Сәйф Сараи) тарафыннан төзелгән һәм Мәмлүкләр әмире Бәтхас бәккә багышланган. Җыентыкның төп өлешен *Сәгъдинең* (1258) «Гөлестан» китабын тәрҗемә иткән Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәре тәшкил итә, ш.у. китапка аның югарыда исемнәре аталган шагыйрьләр газәлләренә җавап-нәзыйрәләре дә кергән. Китап патшалар тормышы, дәрвишләр әхлагы, эндәшмичә торуның файдасы һәм аздан канәгать булуның хәере һ.б. турында сөйләгән 8 бүлектән тора. Бу җыентык әсәрләренә афористик стиль, фикер тирәнлеге һәм ачыклыгы хас. Китапның бары бер генә кулъязмасы (373 бит) билгеле, ул Голландиянең Лейден ун-ты китапханәсендә саклана. Беренче тапкыр Әнкарада (1954), аннан Будапештта (1969) һәм Казанда (1980, 1999) нәшер ителә.

Чыг.: Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи : Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; шул ук. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Надҗип Э.Н. Тюркоязычный памятник XIV в. «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык: В 2 ч. А.-А., 1975.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«КИТАБЕ́ ДӘДА́М КОРКЫ́Т»**, 10–11 йөзләр төрки-татар әдәби ядкәре. Китап угыз баһадирларының үзләре басып алган Кавказ җирләрендә кяферләргә каршы сугышканда кылган батырлыклары турында героик *дастаннар* циклын тәшкил итә. Төп геройлар — угызлар ханы Баюндур, аның кияве Казан баһадир, улы Гаруз һ.б. Хикәяләү акыл иясе Коркыт исеменнән бара. Аның турында мәгълүмат китапның кереш өлешендә бирелгән. Ике күчермәсе билгеле: Дрездендагы (12 дастаннан тора) һәм Ватикандагы (6 дастаннан тора) кулъязмалар. «К.д.К.»ның бердәм сюжеты юк. Дастаннарның күбесендә Кавказда яшәгән угызларның патриархаль-феодаль күчмә тормышлары тасвирлана. Хәзерге Әзәрбайҗан җирләрендә һәм аның тирәсендә урнашкан шәһәрләр, кальгалар, елгалар, күлләрнең исемнәре аталып үтелә. Аерым эпизодлар әкияти, мифик характерда бирелә. «К.д.К.» болгар-татар шагыйре *Кол Гали* иҗатына, «*Кисекбаш китабы*» авторына зур йогынты ясый. Ядкәрнең 1922 дә В.В.Бартольд тарафыннан эшләнгән русча тәрҗемәсе 1950 елда аның вафатыннан соң басылып чыга. Китап берничә тапкыр Германия, Италия, Төркиядә нәшер ителә. Иң борынгы күчермәсе 16 йөзгә карый.

*Әд.:* Деде Коркут. Баку, 1950; Книга моего деда Коркута. М.–Л., 1962.

*А.М.Ахунов.*

**КИТА́ЕВ** Әхмәт Гыйбадулла улы (15.2.1925, Мордва АССРның Татар Юнки а. — 13.7.1996, Мәскәү), нәкышьче. 1939 елдан Мәскәүдә яши. В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын, Е.Е.Ряжский остаханәсен тәмамлый (1950). Мәскәү урта сәнгать мәктәбендә укыта (1951–53). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1951). К.ның әсәрләре совет сынлы сәнгате тарихында танылу ала һәм дәреслекләргә кертелә. Аның танылган һәм социарт дип аталган юнәлеш рухында башкарылган әсәрләре 1950–80 елларның 2 нче яртысы совет нәкышь мәктәбен ачык гәүдәләндерәләр, лирик-реалистик стилистикасы, фәзаи композицияләренең масштаблылыгы, төсләр палитрасының байлыгы б-н аерылып торалар. К. — Окт. рев-циясе һәм Бөек Ватан сугышы, ш.и. татар мохитенә багышланган темаларны яктырткан сюжетлы-тематик күләмле әсәрләр, көнкүреш жанрындагы картиналар һәм портретлар авторы: «Тәүге мәртәбә беренче класска» (1950 еллар), «Дошман тылында» (1955), «Азат итүче» (1956), «Бюрократның кабул итү бүлмәсендә» (1957), «Сугышчы истәлегенә» (1959), «Татар авылында» (1968), «Тынычлык сагында» (1973), «Кызыл мәйдан» (1978, герой шәһәр исеме бирелү уңаеннан Минск шәһәренә Л.И.Брежнев бүләге), «Генерал-лейтенант Я.Җ.Чанышев» (картина 1957 елны Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уздырылган көннәрдә күргәзмәгә куела), «Җырлар иҗат итүче популяр татар композиторы Сара Садыйкова», «Татар скульптурасына нигез салучы С.С.Ахун» (икесе дә — 1969 да), «Татар шагыйре Әхмәт Саттаров» (1968), «Анджела Дэвис» (1973), Казакъстан чирәм җирен күтәрүчеләр, Түмән нефтен тәүге ачучылар, Карпов исем. Мәскәү физ.-химия ин-ты галимнәре (1975–79) портретлары сериясе һ.б. К.ның иң уңышлы әсәрләре — «Пушкин һәм Бенкендорф» (1950), «Совет властеның солых һәм җир турында беренче декретлары» (1955), «Алтын туй» (1960), «Муса Җәлил Моабит төрмәсендә» (1966) һ.б. — эстамп һәм открыткалар рәвешендә күп тираж б-н чыгарыла (40 млн. данә тирәсе), ил («Огонёк») һәм чит илләр (Кытай, АКШ) журналларында басыла.

К. республика, бөтенсоюз һәм чит ил күргәзмәләрендә катнаша. 1991 елда шәхси күргәзмәсе (Мәскәү) уздырыла. Әсәрләре А.С.Пушкин исем. Сынлы сәнгать музеенда, Кораллы көчләр Үзәк музеенда, К.Маркс һәм Ф.Энгельс Үзәк музеенда (Мәскәү), Дәүләт сәнгать музеенда (Ташкент), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Минск, Одесса, Симферополь, Калинин, Псков, Краматорск, Владивосток һ.б. шәһәрләрнең музейларында һәм картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Альменов Б. Зур талант иясе // Азат хатын. 1969. № 11; Әйди Т. Заман сулышын тоеп // Социалистик Татарстан. 1979. 22 июль; Мустафин Я. Впервые в столице // Литературная Россия. 1991. № 23.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КИТА́ЕВ** Йосыф Бикбау улы (? — 22.12.1813, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр. Иске Татар бистәсендә 2 сабын кайнату з-ды (1818 елда з-дларның берсендә 5 мең пот продукция җитештерелә), 3 йорты (Захарий урамында 1 катлы йорт, Кабан күле буенда һәм Печән базары мәйданында 2 агач йорт, соңгысында сәүдә кибете урнаша), Гостиный дворда 4 сәүдә кибете була. Товар б-н Кытайга йөри. Ярлыларга хәйрия ярдәме күрсәтә.

*Л.М.Свердлова.*

**КИТА́ЕВ** Фёдор Яковлевич (13.4.1875, Новгород губ. Устюжна ш. — 26.12.1935, Саратов ш.), йогышлы авырулар белгече, мед. д-ры (1908). 1899 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, госпиталь клиникасының терапия бүлегендә эшли. 1904 тән Бактериология ин-тында, проф. Н.А.Миславскийның физиол. лаб-ясендә лаборант ярдәмчесе. 1909 дан Пермьдә Бактериология ин-ты ас-





Ә.Г. Китаев. 1. «Муса Җәлил Моабит төрмәсендә». 1966; 2. «Җырлар иҗат итүче популяр татар композиторы Сара Садыйкова». 1969. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

системты. 1916 дан Казан Бактериология ин-тында, бер үк вакытта факультет терапиясе клиникасында (җитәкчесе проф. М.Л.Фофанов). Н.К.Горяев җитәкчелегендә гематология мәсьәләләрен ачыклый (Казан). 1917 дән Саратов мед. ин-тында: госпиталь терапиясе клиникасы кафедрасында, 1921 дә йогышлы авырулар клиникасы кафедрасын оештыра; 1924 тән шул каф. профессоры һәм мөдире; 1928 дән госпиталь терапиясе кафедрасында, 1931 дән йогышлы авырулар каф. профессоры. Хезмәтләре бизгәк авыруы мәсьәләләренә, аны дәвалау һәм диагноз куюга, кардиология һәм гематологиягә карый.

Х е з м.: К иннервации глотательных движений: Эксперим. исслед.: Дис. ... К., 1908.

*Әд.:* Профессор Ф.Я.Китаев // Казан. мед. журн. 1936. № 3.

**КИТА́ЕВ** Юрий Петрович (1.2.1923, хәзерге Киров өлкәсенең Яранск ш. — 16.8.2006, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1968), проф. (1970), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1950 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 8 нче номерлы Казан киноплёнка ф-касында эшли, 1956–91 дә РФА КФҮнең Органик һәм физик химия ин-тында: директор урынбасары (1965–81), бер үк вакытта азотлы органик кушылмалар лаб-ясе мөдире (1965–91). 1973–78 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Президиумы рәисе урынбасары. Хезмәтләре азотлы органик кушылмалар химиясенә карый. К. гидразоннар таутомериясен һәм цикллашуын тикшерә. Арилгидразоннар индолизлашу реакцияләрен, Фишер-Арбузов реакциясе механизмын һәм бу реакция барышындагы аномаль күренешләрне өйрәнә. Фталазин, фталазоннар һәм 1,2,4-триазинның амин- һәм гидразинлы кушылмаларының фәзаи һәм электрон төзелешен билгели. Гидразин кушылмалары төзелешен, аларның физик, физик-химик һәм химик үзлекләре б-н үзара бәйленеше законнарын ачыклый. К. җитәкчелегендә азотлы һәм элементорганик кушылмаларның квант химиясе һәм фотоэлектрон спектроскопиясе өлкәсендә тикшеренүләр үткәрелә, биологик актив гидразоннарның каталаулы системаларында конформацион һәм эчке молекуляр тәэсир итешүләре өйрәнелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Применение полярографии в органической химии // Успехи химии. 1959. № 28 (автордаш); Гидразоны. М., 1978 (автордаш); Промежуточные продукты в электрохимических реакциях. М., 1982 (автордаш).

**КИТА́П БЕЛЕМЕ́**, китап һәм китап эше турындагы барлык мәгълүматларны үз эченә алган фән. Китаплар нәшер итүне, бастыруны, китап сәүдәсен, китапханәләр эшен, библиографияне өйрәнә. Әлеге фәннәрнең һәрберсе, мөстәкыйль фән булу өстенә, китап белеменең янәшә тармаклары б-н тыгыз бәйләнештә тора.

16 йөзнең 2 нче яртысыннан алып, Казан Мәскәү басмаханәләрендә басылган китаплар б-н тәэмин ителә башлый. 17 йөз башында Казандагы басмаханә патриарх *Гермогенның* өндәмәләрен бастыра. Казанда китап сәүдәсе 18 йөздә башлана. Бу вакытта руханилар семинариясендә китап кибете һәм акча түләү шарты б-н өйгә китап бирә торган китапханә ачыла. 1770 елларда Рюминның Казандагы китап кибете мәгърифәтче Н.И.Новиков басмаларын сату буенча специальләшә. 18 йөз ахырында — 19 йөзнең беренче яртысында китаплар, башка товарлар б-н беррәттән, яшелчә, кәгазь һ.б. б-н сәүдә итүче кибетләрдә сатыла. Мәгърифәтче, тәрҗемәче һәм нашир Р.*Әмирханов*, якынча 1840 еллардан башлап, татар китапларын шәм кибетләрендә сата.

«Казанские известия» г-тасында басылган белдерүдән күренгәнчә, 1810 елларда китап сәүдәсе б-н П.И.Пугин, Е.Андреев, Базунов һәм Инихов кебек сәүдәгәрләр шөгыльләнә.

19 йөз башында Казанда Г.И.Мясников та китап кибете тота. Аның улы А.Г.*Мясников* әтисенең эшен дәвам итә, башта китап лавкасы, 1834 тә китап кибете һәм аның каршында китапханә ача (1863 кә кадәр эшләп килә-ләр).

19 йөздә Казанда басылган китапларның йөзен Шәрекъ телләрендә, бигрәк тә татар телендә басылган китаплар һәм фәнни әдәбият басмалары билгели.

Беренче китаплар — «Әт-тәхият» һәм «Һәфтияк» — 1801 дә басыла. 1800–29 елларда эшләгән *Азия басмаханәсендә* гомуми тиражы 280 мең данәдән артып киткән 90 га якын исемдәге китап дөнья күрә. 19 йөз башында Россиянең күп кенә шәһәрләрендә губерна идарәләре каршында басмаханәләр ачыла. Казанда губерна басмаханәсе 1805 тә оеша (к. *Казан губерна идарәсе басмаханәсе*).

Казан ун-ты басмаханәсе (к. *Казан университеты басмаханәсе, Казан университеты нәшрияты*) Университет уставы нигезендә 1809 да ачыла. Анда университет басмалары, профессорлар хезмәтләре, дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре басыла. 1915 кә кадәр якынча 2,5 мең басма дөнья күрә. Университет китапханәсе фондларына Г.А.Потёмкин һәм В.И.Полянский китапханәләре нигез сала, соңрак Н.Н.Булич, И.Ф.Готвальд, К.Ф.Фукс һ.б.ның китапханәләре өстәлә.

Казанда гимназияләр, университет һәм китап базары булу башкаланың китап сәүдәгәрләре А.В.Глазуновны (1830 еллар) һәм Д.Е.Кожанчиковны (1860 еллар) җәлеп итә, һәм алар Казанда үзләренең китап кибетләре бүлекләрен тоталар.

1811 дә беренче рус провинция газеталарының берсе «Казанские известия» г-тасы чыга башлый. 1838 дә император Николай I губерна идарәләре каршында газеталар бастыруга рөхсәт бирә. Шушы чордан башлап, «*Казанские губернские ведомости*» г-тасы басыла башлый.

Казанда беренче шәхси басмаханә 1841 дә оеша (к. *Шевиц Л. басмаханәсе*). Тиздән Р.Сәгыйтов басмаханәсе һәм Ш.Яхин ташбасмасы татар телендә китаплар баса башлый.

Библиография тармагы Казанда 1805 тә Казан ун-ты ачылу б-н барлыкка килә. Татар тарихи чыганакларының беренче библиографлары — проф. К.Ф.Фукс, адъюнкт М.С.Рыбушкин, татар мәгърифәтчеләре К.Насыйри, Ш.Мәрҗани һ.б.

Төбәкне өйрәнү материаллары туплана, соңрак алар библиографик өйрәнү объектына әверелә. 1844–52 елларда «Прибавление к «Казанскому губернскому вестнику» г-тасының мөхәррире булып А.И.Артемьев эшләгән дәвердә төбәкнең тарихы, этнографиясе һәм географиясе буенча мәкаләләр басыла. Аның «Казан буйлап сәяхәтләр»ендә («Прогулки по Казани», газетада 1849–52 елларда дөнья күрә) шәһәрнең күренекле урыннары рәтендә Казан ун-ты китапханәсе дә искә алына. 1851 дә «Прибавление...» г-тасында Н.К.Чупин төзегән аннотацияле исемлек «Казан губернасы турында географик һәм статистик мәгълүматлар урнаштырылган китапларга һәм журнал мәкаләләренә күзәтү» («Обозрение книг и журнальных статей, заключающих в себе географические и статистические сведения о Казанской губернии») басыла.

1855 ел *Казан руханилар академиясе китапханәсе* өчен (1842 дә ачыла) аеруча уңышлы була. С.-Петербург җәмәгать китапханәсеннән — 1,5 меңнән артык исемдәге китап, Соловки монастыреннан 1356 кульъязма һәм иске басма китаплар алына. Соловки китапханәсен фәнни тасвирлауның башлангычы Казанда салына.

1865 елда Казанда шәһәр җәмәгать китапханәсе ачыла. Аның фондларының нигезен И.А.Второв китаплары тупланмасы тәшкил итә. Китапларны И.А.Второвның улы Н.И.*Второв* шәһәргә бүләк итеп бирә (бүләк 903 исемдәге 1908 том китаптан тора, алар арасында 18 йөз — 19 йөз башының сирәк һәм әһәмиятле басмалары да сакланган).

1867 дә Казанда проф. С.М.Шпилевский «Казан шәһәре белешмәләр листогы» («Справочный листок города Казани») беренче шәхси г-тасын нәшер итә башлый. Шул ук елда Казанда барысы 6 басмаханә (аларның 3 се шәхси), 4 хәреф кою ширкәте һәм 5 ташбасма эшли.

Китап эше киңәйтелү б-н, библиография дә үсеш ала. Нәкъ менә шул вакытта Н.Я.*Агафонов* һәм П.П.*Васильев* төзегән җыентык — «Казан китапчылык эше» («Казанское книжное дело», 1867) басыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында китап сәүдәсендә специальләшү сизелә башлый. 1870 елларда Э.С.Перимова чит ил китаплары кибете ача, кибет каршында китапханә һәм уку бүлмәсе дә була.

1874 тән «Шәрекъ лирасы» кибете эшләп килә, анда музыка уен кораллары, музыка буенча китаплар сатыла, ноталар абонементы да була. 1880 елларда Л.П.Рейнгардтның балалар китапханәсе эшли. 1886 да Казанда 5 китап кибете һәм берничә лавка исәпләнә. «1884 ел өчен Казан календаре» («Казанский календарь на 1884 год») мәгълүматларына караганда, шәһәрдә 4 шәхси китапханә, 11 шәхси китап басу оешмасы (5 басмаханә, 3 типолитография, 1 хромолитография, 1 ташбасма һәм 1 гектографлы ташбасма) эшли.

Басмаханәләрнең хуҗалары еш үзгәреп тора. 1881 дә, мәс., В.М.Ключников тарафыннан ачылган басмаханә 1908 дә кызы И.В.Ермолаевага күчә. Әммә икенче елга ук, социал-демократик эчтәлекле әдәбият нәшер

ителү аркасында цензура эзәрлекләүләре башлангач, ул аны Н.М.Чижовага сатарга мәҗбүр була. Аңардан соң басмаханә 1910 да В.З.Еремеевка тапшырыла. Шулай итеп, басмаханә 1916 га кадәр В.Еремеев һәм А.Шашабринның сәүдә йорты басмаханәсе буларак эшли.

1890 елгы Казан фәнни-сәнәгый күргәзмәсе җирле полиграфия һәм наширлек эшчәнлегенең яхшы сыйфатлы булуын күрсәтә. Университет басмаханәсе күргәзмәнең югары бүләгенә — Мактаулы бәяләмәгә лаек була. Типохромолитография хуҗасы В.М.Ключниковка «Литография эшләренең матурлыгы һәм нәфислеге өчен» алтын медаль бирелә. Г.М.Вечеслав «гальванопластика һәм басмаханә эшләре өчен» Зур көмеш медаль б-н бүләкләнә. Наширлек эшчәнлеге өчен китап кибете хуҗасы А.А.Дубровинга кече көмеш медаль тапшырыла.

Казан шахмат сөючеләр җәмгыяте каршында бай гомуми белем китапханәсе эшләп килә. «Мәгариф» («Образование») китапханәсе матур әдәбиятка специальләшә. 1911 дә аның фондын К.Бальмонт, И.Анненский, А.Блок, В.Брюсов, М.Метерлинк һ.б.ның әсәрләре тәшкил итә. 1897 дән мәдәни агарту максатларында хәйрия җәмгыятьләре һәм төрле оешмалар каршында гади халык өчен ачылган китапханәләр-уку бүлмәләре киң таралыш ала. Алафузов ф-касы һәм Дары з-ды хезмәткәрләре — эшчеләр өчен бушлай китапханә-уку бүлмәсе, хезмәт биржасының халык китапханәсе, Россиядәге яһүдләр арасында аң-белем тарату җәмгыятенең китапханә-уку бүлмәсе һәм Аеклар җәмгыятенең 4 уку бүлмәсе эшләп килә.

1913 тә проф.-тюрколог Н.Ф.*Катанов* тырышлыгы б-н Г.Барудиның бушлай җәмәгать китапханәсе ачыла (Үзәк шәрекъ китапханәсе), ул 1930 га кадәр төрле исемдә эшли. Н.Ф.Катановның шәхси китапханәсе 1910 да Истанбулга күчерелә.

1899 елгы «Бөтен Казан» («Вся Казань») адреслар китабы мәгълүматларына караганда, Гостиный дворда К.П.Алексеевның, Пассажда А.С.Дубровин һәм бертуган Башмаковларның, Проломный урамында бертуган Ярыгиннарның, Балык рәтләре урамында В.Ф.Бороздинның китап кибетләре эшләп килә. *Изге Гурий борадәрлеге* Спас-Преображение һәм Богородица монастырьларында Тәрҗемәчелек комиссиясе басмаларын сата. Татар китаплары б-н Печән базары мәйданында Кәримов һәм Хөсәенов сәүдә итә. Казан 19 йөздә татар китапларын нәшер итү үзәгенә әйләнә. 19 йөзнең 1 яртысында татар китапларының күпчелеге Казан ун-тында басылса, 19 йөзнең 2 яртысына аларның яртысыннан артыгы (3242 нең 1827 се) шәхси басмаханәләрдә дөнья күрә, 80 е генә Казаннан читтә урнашкан була. 1897 нең 1 гыйнварына полиграфия пр-тиеләренең күбесе Мәскәү (212) һәм Петербургта (255) туплана, Одессада — 55, Киевта — 22, Казанда 15 басмаханә исәпләнә.

20 йөз башында китап басуның сыйфаты үзгәрә. Текстны әзерләү күпкә гадиләшә. Фотосурәтләр, полиграфия техникасы камилләшү төсле репродукциянең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә. Полиграфчы М.*Идриси* 1905–11 елларда Мәскәү, Германия, Төркия, Мисырның иң яхшы басмаханәләрендә китап басу техникасының яңа казанышларын өйрәнә, соңыннан Казанның «Милләт» басмаханәсендә күп төсләр б-н басуны гамәлгә кертә.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында китап басуда китап эше тармакларының бер үзәккә берләшү омтылышы күренә. 1896 да И.Н.*Харитонов* Казанда үзенең шәхси басмаханәсен ача, соңрак хәреф кою ширкәте оештыра. Ул ш.у. нашир һәм китап сәүдәгәре буларак таныла.

1910 елгы «Бөтен Казан» адреслар китабы мәгълүматларына караганда, ул чорда хәрби округ штабы басмаханәсе, университет һәм губерна басмаханәләре, Л.П.*Антонов*, Д.М.*Гран*, И.Н.Харитоновның шәхси басмаханәләре һәм «Милләт» эшләп килә. Басмаханәләрнең бер фирмага берләшү омтылышы сизелә. 1911 дә «Сабах» ширкәте каршында ташбасма, хәреф кою ширкәте һәм китап тышлау остаханәсе б-н берләштерелгән «Өмид» басмаханәсе ачыла. Кул хезмәтенә нигезләнгән вак кустарь производство китап басуны, мәс., төсле, рәсемле басмаларны югары сыйфатлы итә алмый. Шунлыктан алар бөлгенлеккә төшәргә мәҗбүр була. 1921 елга Казанда полиграфия сәнәгатен национализацияләү тәмамлангач, 11 ташбасма машинасыннан эшкә яраклы 5 е генә кала.

«Бөтен Казан» адреслар китабы хәбәр иткәнчә, 1910 да Казанда бертуган Башмаковларның, М.А.Голубев, В.Ф.Маркелов һәм В.А.Шаронов, П.А.Дубровин (элек А.А.Дубровинның), В.И.Бреевның эре китап кибетләре, Мәскәү «Культура» китап сәүдәсе ширкәтенең ф-лы эшләп килә. Букинистика сәүдәсе б-н 3 кеше шөгыльләнә.

Казанда Петербургның «Брокгауз һәм Ефрон» китап нәшрияты вәкиллеге дә була (Р.Ф.Гергард). 1910 елларда сәнгать буенча китаплар нәшер итүче «На рассвете» нәшрияты да эшли («Зилант» җыентыгы, 1913; А.Ф.*Мантель*, Н.К.Рерих әсәрләре).

1909–22 дә «Молодые силы» нәшрияты «Тарихи әдәбият. Рус әдәбияты ядкәрләре» («Историческая библиотека. Памятники русской литературы») сериясен нәшер итә «А.Н.Афанасьев тарафыннан җыелган легендалар» («Легенды, собранные А.Н.Афанасьевым», 1914) һәм «Күренекле кешеләр тормышы» («Жизнь замечательных людей») сериясеннән Е.А.Соловьёвның «Ф.Достоевский, тормышы һәм әдәби эшчәнлеге» («Ф.Достоевский, его жизнь и литературная деятельность», 1922) китабын кабат бастырып чыгара.

1908 дә автор-нашир И.С.Михеев 61 мең данә тираж б-н бәясе 16 мең сумлык 6 дәреслек чыгара (наширлек эшчәнлеге 1917 елга кадәр дәвам итә).

20 йөз башында нәшрият һәм китап сату фирмаларын берләштерү башлана. А.А.Дубровин, В.Ф.Маркелов һәм В.А.Шароновның китап кибетләре каршында эре нәшриятлар, *Башмаковларның китап басу һәм китап сәүдәсе*, «Гасыр» китап басу һәм сату итү ширкәте эшли.

Китап кибете хуҗасы М.А.Голубев 1912–17 елларда Казан ун-ты профессорлары Е.Ф.Будде, А.М.Миронов, Д.И.Нагуевский, Н.А.Васильев, М.П.Петровский һ.б.ның хезмәтләрен, «Яңа Россия гражданы китапханәсе» («Библиотека гражданина новой России») китап сериясен нәшер итә. 1900 да бертуган Кәримовларның китап сату фирмасы каршында 1919 елгы национализацияләүгә кадәр эшләп килгән басмаханә ачыла. 1901–17 еллар арасында Кәримовлар тарафыннан гомуми тиражы 20 млн. данәдән артык булган 1763 басма нәшер ителә.

20 йөз башыннан татар телендә, дини һәм уку китапларыннан тыш, әдәби әсәрләр, мәс., Г.Тукай шигырьләре, А.С.Пушкин, Н.А.Некрасов һ.б.ның тәрҗемә әсәрләре, фәнни-популяр әдәбият күпләп басыла. Рус, бигрәк тә татар наширләре һәм китап кибетләре хуҗалары эшчәнлеге цензура күзәтүе астына алына. Шуңа да демократик җәмәгатьчелекнең 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң беренче таләбе Баш матбугат идарәсен тарату була (1917 ел, 27 апрель). Демократик матбугат ирегенең төп шарты итеп цензура ярдәмендә басмага рөхсәт бирелү түгел, ә аны теркәү принцибы куела. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казан библиографиясе өлкәсендә Н.Ф.Катанов һәм Н.П.*Лихачёв* исемнәре киң таныла. Профессор Н.Ф.Катанов 1894 тән «Археология, тарих, этнография җәмгыяте хәбәрләре» («Известия Общества археологии, истории, этнографии») битләрендә Шәрекъне өйрәнү буенча хезмәтләрен, библиографик күзәтүләрен һәм белешмәлекләрен даими рәвештә бастыра. «Деятель» ж-лында «Шәрекъ библиографиясе» («Восточная библиография») бүлеген алып бара, Казан ун-ты басмаханәсендә басылган көнчыгыш китаплары исемлеген, проф. И.Ф.Готвальдның шәхси китапханәсе каталогын төзи.

Н.П.Лихачёв — Петербург җәмәгать китапханәсенең булачак директоры — бүгенге көндә дә фәнни әһәмиятен югалтмаган китапларын: «Казанда басмаханәләр эшләгән беренче илле елда китап басу» («Книгопечатание в Казани за первое пятидесятилетие существования в этом городе типографий...» (СПб, 1895), «Казан матбугатының уйдырма башлангычы» («Мнимый первенец казанской печати» (СПб., 1897), «Бер алпавыт китапханәсе шәҗәрәсе» («Генеалогическая история одной помещичьей библиотеки» (СПб., 1913) хезмәтләрен бастыра.

1917 елның 22 ноябреннән «Матбугат турында декрет» («Декрет о печати») китап эшенең бар тармаклары эшчәнлеге өстеннән дәүләт күзәтчелеген игълан итә.

1921 нең урталарына Казанда 18 шәхси һәм ведомство полиграфия пр-тиесе (ш.и. 9 басмаханә, 1 хәреф кою ширкәте) национализацияләнә һәм эреләндерелә.

1919 да Казанда дәүләт нәшриятының бүлеге оештырыла (1920 дән — Татгосиздат). 1920 елда «Казанский библиофил» ж-лын (1921–23) чыгарып килгән «Китап дуслары» библиографик түгәрәге оеша. 1921 дә биб-

лиография бүлеген сов. библиографиясенә нигез салучы Е.И.Шамурин җитәкли. 1911 дә ул «Камско-Волжская речь» г-тасында Казандагы даими басмалар турында мәкалә бастыра. ТАССР *Китап палатасы* оешканнан соң (1926), китап продукциясе исәпкә алып барыла, библиография материалларының даими чыганагы барлыкка килә. Үзәкләштерү һәм хуҗалыкларның бөлгенлек шартларында шәхси нәшриятлар 1926 елга эшчәнлекләрен туктатырга мәҗбүр булалар. Китап эшенең башка тармаклары кебек үк, шәхси һәм ябык оешмаларның китапханәләре национализацияләнә һәм дәүләт китапханәсенә (китап саклау урынына) кушыла.

А.Ф.*Лихачёв* китапханәсе Казан ун-ты китапханәсенә тапшырыла. 1958 дә Татполиграф һәм Татарстан китап сәүдәсе (Таткниготорг) оешканнан бирле китапларны бастыру һәм сату б-н *Татарстан китап нәшрияты* шөгыльләнә башлый. 1963 тә КПСС ҮК пленумының «Партиянең идеологик эшенең чираттагы бурычлары» дигән карарыннан соң китап эшенең барлык тармаклары, ведомствога буйсынган булуларына карамастан, СССРның нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре буенча Дәүләт ком-ты канаты астына кертелә. Әлеге ком-тның бурычы «әдәбиятның барлык төрләрен бастыруны, оештыру һәм аңа юнәлеш бирүне» контрольдә тоту була. Беренчел цензураны Матбугатта дәүләт серләрен саклау ком-ты тормышка ашыра.

Китап белеме проблемалары, ш.и. җирле проблемалар «Китап. Тикшеренүләр һәм материаллар» («Книга. Исследования и материалы» (М., 1959–2011) җыентыгында чагылыш таба. 1976 дан Ленинградта китап тарихы буенча конференцияләр — «Фёдоров укулары» үткәрелә. «Казан университеты китапханәсе: Фондлар, раритетлар, тарих...» («Библиотека Казанского университета: Фонды, раритеты, история...», 1989), «Кульъязма һәм борынгы басма китап, туплау, саклау һәм өйрәнү проблемалары» («Рукописная и старопечатная книга, проблемы сбора, сохранения и изучения», 1995) җыентыклары Казан китап белеме мәсьәләләренә багышлана. Татар китабы тарихы буенча атаклы белгеч булып Ә.Г.*Кәримуллин* санала. 19 йөзнең 1нче яртысында университет китапханәсе тарихы В.В.Аристов һәм Н.В.Ермолаева тарафыннан «Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә тарихы» («История Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского», 1985) һ.б. хезмәтләрдә тикшерелә.

Китап басуның яңа принциплары СССРның «Матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Законында (1990) актыртыла. Аның нигезендә матбугат иреге игълан ителә, цензура алына, дәүләт органнары һәм җәмәгать оешмаларына гына түгел, 18 яшенә җиткән барлык гражданнарга массакүләм мәгълүмат чаралары оештыру мөмкинлеге бирелә, ул рөхсәт бирү түгел, ә теркәү характерында карала. Шундый ук принциплар РФнең 1991 елгы «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Законында чагылыш таба. Яңа нәшрият системасы, нигездә, дәүләти булмаган оешмаларга йөз тота. Россия — дөньяның китап басу буенча иң алдынгы ун иле арасында.

1990 елларда, базар икътисады шартларында, дәүләт нәшриятларын хосусыйлаштыру башлана, шәхси фирмалар оеша. Басмаларның тематикасы төрләнә, коммерциячел һәм дини әдәбият барлыкка килә. «Мәгариф» («Образование») нәшрият йорты «Кризис-менеджер китапханәсе» («Библиотека кризис-менеджера») сериясен чыгара, ТРның Милли китапханәсе каршында «Милли китап» нәшрияты эшли башлый, «Китапханә хәбәрчесе» («Библиотечный вестник») даими басыла. ТР Милли музее каршында нәшрият бүлеге оеша. «Раннур», «Заман», «Хәтер» һ.б. нәшриятлар уңышлы гына эшләп килә. 1991–2010 елларда «Мәгариф» нәшрияты мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр, сүзлекләр, балалар әдәбияты бастыра. «Җыен» һәм «Рухият» фондлары татар телендәге китаплар бастыруда акчалата һәм оештыру ягыннан ярдәм итәләр.

*И.А.Новицкая.*

**КИТА́П ГРА́ФИКАСЫ**, китап төзү сәнгатенең бер өлеше; *графика* сәнгате бүлеге. Үз эченә басма яки кульъязма текстны, графика элементларын: иллюстрацияләр, виньеткалар, китапның башы-ахырына бизәкләр урнаштыру; бизәүле баш хәреф һәм орнаментлы кысалар кую һ.б.; тышлыклар, супертышлыклар, титул битен һәм титул бите алдын әзерләү, китап төпләүне үз эченә ала. К.г. эчтәлеккә буйсына, басманың, әсәрнең әдәби эчтәлегенә тәңгәл килгән образлар һәм сюжетларга бәйле. К.г.ндагы өлкәләрнең берсе — китап басу барлыкка килгәнче гамәлдә булган борынгы кульъязма китаплардагы миниатюра. Ул кулдан башкарылган һәм күптөрле график рәсемнәр (акварель, тушь, җилемле буяулар, табаклы алтын һ.б.) һәм декоратив бизәлеш элементлары (инициаллар, китап бите башындагы бизәк) б-н тулыландырылган. Китап басу эше алга киткән саен, К.г. китапны яңача бизәү ысуллары: ксилография (15 йөздән), офорт һәм уеп ясалган гравюра (17 йөздән), литография (19 йөздән) б-н тыгыз бәйләнешкә керә барган. Бизәлеш чараларының даими нигезгә салынуына ак б-н кара төсләрнең үзара бәйләнеше сәбәп була. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан К.г.нда күпләп бастыруның фотомеханик ысуллары кулланыла башлый. Ул темасы б-н басылучы текстларга бәйләнгән һәм полиграфия үзенчәлекләренә буйсынган газета-журнал графикасына якын тора.

Татар К.г.ның безгә билгеле иң әүвәлге үрнәкләре — кульъязма китаплар, ярлыклар, борынгы кульъязмалар — Казан ханлыгы чорына нисбәтле (15–16 йөзләр). Ләкин соңгырак чор күчермәләрендә аларның 10–12 йөзләргә караган борынгырак прототиплары булуы турында мәгълүмат бар. Алтын Урда чорыннан безнең көннәргә килеп җиткән ярлыклардагы, кульъязмалардагы мөһерләр, нишаннар — басма графиканың беренче үрнәкләре. Нишан үзе култамгадан (хакимият формуласы) һәм идеограммадан (нәсел тамгасы) торган бизәкле-каллиграфик миниатюраны тәшкил итә. Асылда, ул — агачтан уеп ясалган (агачының төре билгеле түгел) кабарынкы гравюраны хәтерләткән төсле мөһер (төс документның әһәмиятенә бәйле). Татар мәдәниятендә кульъязма китап сәнгате традициясе киң таралу ала, борынгыдан килә һәм ныклы нигезгә корылган була (к. *Хаттатчылык*). Анда каллиграфиягә өстенлек бирелә, катлаулы композицияле һәм ритмик структуралы текстның өлешләрен аерып күрсәтү өчен колористик (төрле төстәге буяулар куллану), график (төрле стильдәге һәм зурлыктагы язу рәвешен куллану) ысуллардан файдалану күздә тотыла. Кульъязмаларны үсемлек элементлары төшерелгән кысалар, китап бите башындагы һәр бит саен кабатлана торган сурәт — унваннар бизи. Кульъязма сәнгатенең әһәмияте 19 йөз башында татарларда китап басу эше киң таралганнан соң да саклана, аны, мәс., татар һәм шәрекъ авторларының кульъязма китапларын бизәгән күренекле татар каллиграф-хаттаты М.*Мәхмудов* иҗатында күрергә була.

Татар басма китабы туу 1800 елда Казанда *Азия басмаханәсе* барлыкка килүгә (1829 га кадәр эшли) бәйле. Басма китап бизәлешендә аңлы рәвештә борынгы кульъязмаларга йөз тотыла. Нәфис һәм бормалы гарәп язуына акцидент (сирәк кенә — литографик) ысул б-н башкарылган орнаментлы кысалар, китап бите башына куелган үсемлек сурәтләре һәм геом. бизәкләр өстәлә. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөзнең 1 нче чирегендә Казанда кириллица шрифты б-н «Аноним басмаханә» эшли. Кайбер тикшеренүчеләр «Казан изге Мәрьям Ана иконасына гыйбадәт кылу» («Служба Казанской иконе Божией Матери», 1570 еллар) китабын беренче Казан басма китабы дип саныйлар. Сәнгатьчә бизәлгән беренче китаплар — университет (1809), соңрак Казандагы шәхси рус һәм татар басмаханәләрендә басыла. Аларда, башлыча, Казан төбәге тарихына багышланган фәнни-популяр һәм матур әдәбият басмаларын бизәү өчен башкала басмаханәләреннән алынган җыелма бизәкләр, ш.у. җирле рәссамнар башкаруындагы (Н.Н.Кафтанников, А.В.Котельников, Л.И.Шевиц, Ткачук, П.Ф.Табуре) иллюстрацияләр кулланыла. Рәсемнәрне басма формага күчергәндә офорт файдаланыла. Бизәлешле беренче татар басмаларыннан Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен (1839), төзүчесе, мөхәррире һәм еш кына мәкаләләрне бизәүчесе *К.Насыйри* булган, аның башлангычында нәшер ителгән өстәл календарьларын (1871–97) күрсәтергә мөмкин. 19–20 йөзләр арасында сәнгатьчә бизәлгән татар китаплары Казан, Петербург, Оренбург, Әстерхан, Уфа һәм Россиянең башка шәһәрләрендәге басмаханәләрдә шактый күп басыла.

Китапларның сәнгатьчә бизәлеше үсешендә *Харитонов И.Н. басмаханәсенең* әһәмияте зур була. Анда эшләү өчен татар хәрефләренең нәфис рәсемнәрен әзерләгән Г.*Камал* чакырыла. Типографиядә ш.у. хәрефләренең җентекләп эшкәртелүе һәм нәфислеге б-н аерылып торган хәреф кисүче-гравёр И.И.*Юзиев* эшли. Бу исә китапларның титул битләрен




**Китап графикасы.** 1. Ш. Т а һ и р о в. З. Таһированың «Тасбият» кулъязма китабыннан унван. Кәгазь, тушь, каләм, акварель, алтын йөгертү. 1890 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Нео-футуризм. Җәмәгать зәвыгына каршы чыгу». Төсле литография. 1913; 3. Ш.Н. М ө х ә м м ә т җ а н о в. Б. Доминовның «Рәсем ясарга өйрән» китабының тышлык эскизы. Кәгазь, гуашь, тушь. 1929. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. В.В. К а р а м ы ш е в. Т. Янның «Ай кызы» китабына титул бите эскизы. Кәгазь, тушь, кәлам. 1959. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. И.Л. Я з ы н и н. М. Җәлилнең «Моабит дәфтәре» китабына фронтиспис эскизы. Линогравюра. 1962. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. А.Р. Т у м а н о в. Х. Туфанның «Лирика» китабына иллюстрация. Офорт. 1980. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Б.И. У р м а н ч е. Г. Тукайның «Шүрәле» әкият-поэмасына иллюстрация. Кәгазь, акварель, кытай туше. 1966. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. Р.М. Я к у п о в а, Н.В. Р о д и о н о в а. «Гөлчәчәк» татар халык әкиятенә иллюстрация. Кәгазь, гуашь. 1969; 9. Г.Л. Э й д и н о в. В.Н. Гаршинның «Сәяхәтче бака» китабы тышлыгы эскизы. Кәгазь, гуашь. 1990 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Р.Г. Ш ә м с е т д и н о в. «Ибне Фазлан сәяхәте» – «Путешествие Ибн Фадлана» китабы тышлыгы эскизы. Кәгазь, тушь, каләм, гуашь. 1995–96. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Т.Г. Х а җ и ә х м ә т о в. Г. Тукайның «Сабыйга» җыентыгына иллюстрация. 1990 еллар. Кәгазь, акварель тушь; 12. И.И. Н ә ф и е в. Х. Җәләловның «Турай батыр» китабы тышлыгы. Компьютер графикасы.

һәм текстларын тагын да төрлерәк итеп бизәргә мөмкинлек бирә.

Әгәр татар басма К.г. баштарак шрифтлар һәм орнаментларның үзара ярышуына нигезләнсә, 19 йөз ахырыннан исә, башлыча, үзешчән рәссамнар башкаруында, сюжетлы иллюстрацияләр барлыкка килә; еш кына рус һәм чит ил басмаларындагы әзер клишеләр файдаланыла. Татарлар арасында сынлы сәнгатьне пропагандалауда Г.*Тукай* зур роль уйный. Аның тырышлыгы б-н «Юаныч» дигән гомуми исемдә балалар өчен беренче рәсемле китапчыклар чыга башлый. Аларга рәсемнәрне Тукайның шәхси катнашында литография осталары әзерли. Татар китап сәнгатенең эре үзәге — «Милләт» басмаханәсендә М.*Идриси* рәсемнәре буенча китаплар өчен китап бите башы (заставка), ахыры (концовка) һәм виньеткалар файдаланыла. Татар китапларын бизәүдә рус рәссамнары да катнаша.

Китап эстетикасын сәнгать ансамбле буларак пропагандалауда нашир һәм рәссам А.Ф.*Мантель* мөһим роль уйный. В.В.Вараксин типохромолитографиясендә аның тарафыннан «Сәнгать дөньясы» берләшмәсе рәссамнары А.Н.Бенуа, И.Я.Билибин, Д.Н.Кардовский, Е.Е. Лансере, К.А.Сомов һ.б.ның репродукцияләре б-н бизәлгән күп кенә китаплар әзерләнә. Казандагы «Җайдак» («Всадник») графика берләшмәсе рәссамнары иҗаты йогынтысында китапка авторның оригиналь гравюрасын урнаштыру башланып китә (И.Н.*Плещинский*, К.К.*Чеботарёв*, А.Г.*Платунова* һ.б.). 1920 еллар башында Казан нәшриятлары (Госиздат, «Шагыйрьләр витринасы») *линогравюра* һәм *литография* техникасында бизәлгән тышлыклар б-н әдәби һәм башка әсәрләр бастырып чыгаралар. Алар К.г. сәнгатендәге авангард агымнарны чагылдыралар, мәс., П.М.Дульскийның «Казан төзелеш сәнгатендә классицизм» («Классицизм в казанском зодчестве», 1920); П.А.Радимовның «Авыл» («Деревня», 1922); З.Гыйффәтнең «Зөһрә Йолдыз» (1922) һ.б.

Республиканың К.г. үсешендәге яңа күтәрелеш 1920 еллар уртасы — 1930 еллар башында Казан сәнгать-техника ин-тында (соңрак — техникум), *А.В.Луначарский исем. полиграфия мәктәбендә* милли профессиональ сәнгать кадрларын әзерләү б-н бәйле була. Китап бизәү принципларында ике: конструктивизм һәм жанрга карап иллюстрацияләү юнәлешләре барлыкка килә. Икесе дә беренче чиратта китап тышлыкларын бизәүгә кагыла. Иң отышлы сюжет-образ чишелешләрен А.Н.*Коробкова* («Азат хатын» ж-лы; гуашь, 1926), Ш.Н.*Мөхәммәтҗанов* (Б.Доминовның «Рәсем ясарга өйрән» китабы; гуашь, 1929) һ.б. тәкъдим итә. Алар ачык чагылышлы рәсемнәрнең гарәп шрифты борылмалары б-н оста кушылуына ирешәләр. Конструктивизм концепциясенең күренекле вәкиле Ф.Ш.*Таһиров* гарәп графикасындагы китап бизәү традицияләрен заманча сәнгать чаралары б-н табигый берләштерә, аерым алганда, Ә.Мәҗитовның «Авыл клублары өчен җыентык», Г.Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» (икесе дә — 1925) китаплары тышлыкларын бизәгәндә фотомонтаждан оста файдалана.

Полиграфия өлкәсендә акциденция, җирлекне төсле яки кара итү (выворот), битләрне бизәгәндә билгеле бер ритм саклау кебек җыю ысулларын киң куллану Татарстанда чыгучы китаплар һәм журналларга заманча динамик төс-кыяфәт бирә.

1930 еллар уртасында К.г.нда, сәнгатьнең башка төрләрендәге кебек, соц. реализм алымы урын ала. Китап бизәүдә сөйләп бирү башлангычы, образларны сурәтләүдә сынлы сәнгать чаралары өстенлек итә. Бу — әйдәп баручы китап графигы Б.М.*Әлминов* иҗатында, аның Г.Тукай шигырьләренә ясаган иллюстрацияләр сериясендә аеруча ачык чагыла (тушь, каләм, 1937–39; кара акварель, 1944–46) һ.б. 1950 елларда реалистик иллюстрацияләр традицияләрен Х.Г.*Якупов* («Хәзинә», Г.Ахунов) һәм Л.Г.Фәттахов («Кара йөзләр», М.Гафури, «Татар халык әкиятләре») үстерә. 1950 еллар ахыры — 1960 еллар башы К.г.нда яшь рәссамнар плеядасы — илнең әйдәп баручы сәнгать ин-тларын тәмамлаган В.В.*Карамышев*, И.К.*Колмогорцева*, Ю.Б.*Лысогорский*, Р.Г.*Төхвәтуллин*, Т.Г.*Хаҗиәхмәтов*, И.Л.*Язынин* һ.б. эшли. Аларның иҗаты 20 йөзнең 2 нче яртысында респ-када китап сәнгате үсешен билгели. Китап ансамбленең бербөтенлеккә кайтуын, К.г. сәнгате теленең яссы сурәт һәм сурәтнең хәрәкәтчән ритмикасы аша тоемланучы яңаруын алар тәэмин итә, аларда ш.у. линогравюра б-н кызыксыну туа: И.К.Колмогорцева «Гөлчәчәк» татар халык әкиятен (төсле линогравюра), И.Л.Язынин М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре» китабын (линогравюра, 1962) бизи һ.б.

1970–80 елларда Татарстанның К.г.нда яңа буын рәссамнар: Н.У.*Әлмиев*, Ю.М.Каспина-Вургафт, Г.Е.Трифонов, А.Р.Туманов, А.М.Үтәгәнов һ.б. эшли башлый. Бу чорда әдәби әсәрләрне бизәүдә рәссам интерпретациясе, аның китапка карата булган шәхси мөнәсәбәте һәм хисси кичерешләре өстенлек ала. Офорт һәм ксилография киң тарала: Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына (офорт, 1981) һәм С.Власованың «Бәллүр шәһәр» китабына (ксилография, 1977) Н.У.Әлмиев иллюстрацияләре; Г.Г.Маркеснең «Йөз еллык ялгызлык» китабына (офорт, 1987) Г.Л.Эйдинов иллюстрациясе һ.б.

Полиграфиянең гаять зур мөмкинлекләренә, сәнгатьтә шартлы гадиләштерү тенденциясенең киңәюенә һәм тәэсир итү көчен гадәттән тыш арттыру мөмкинлеге бирүче компьютер технологияләре кулланылуга карамастан, 20 йөз ахыры — 21 йөз башында К.г.нда оригиналь рәсем саклана, һәм автор техникасы диапозоны киңәя. К.г.нда өлкән һәм урта буын рәссамнар б-н бергә (Л.С.Золондинова, Д.Н.Җәләлетдинова, З.В.Мөхәммәтҗанова, А.А.Тимергалина, Ф.Ш.*Хәсьянова*, Т.Г.Хаҗиәхмәтов, Р.Г.Шәмсетдинов, Г.Л.Эйдинов) яшь осталар да актив эшли (Б.А.Гыйльванов, Е.А.Дербилова, А.М.Кузнецов, Р.З.Мөхәммәтдинов, И.И.Нәфиев, М.А.Покалёв, Н.Т.Хаҗиәхмәтов, И.Нурмыев һ.б.).

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Книга и её художественная внешность (в связи с Казанским книгопечатанием). К., 1921; ш у л  у к. Оформление татарской книги за революционный период. К., 1930; К о р н и л о в П.Е. Художественные издания Казани за 10 лет: 1917–1927 гг. К., 1930; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги: От начала возникновения до 60-х годов XIX века. К., 1971; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись. Скульптура. Графика. М., 1978; К л ю ч е в с к а я Е.П. У истоков казанской графики // Художник. 1986. № 6.

*О.Л.Улемнова.*

**«КИТА́П ДУСЛАРЫ́» ТҮГӘРӘГЕ́**, Дәүләт нәшриятының Казан бүлеге каршындагы библиография түгәрәге, нәшриятның библиография бүлеге б-н тыгыз бәйләнештә эшли. 1920 елның октябрь аенда кабул ителгән устав нигезендә түгәрәк б-н җитәкчелекне рәис һәм аның иптәше (урынбасары), сәркәтип һәм казначейдан торган совет тормышка ашыра. Түгәрәкнең иң танылган 12 оештыручы әгъзасы арасында: Дәүләт нәшрияты Казан бүлеге мөдире И.П.Кочергин, сәнгать белгече П.М.Дульский, театр тәнкыйтьчесе М.Д.Прыгунов, Көнбатыш Европа китабы белгече А.А.Фирсов, библиофиллар Б.И.Смирницкий һәм А.М.Вилькен, нашир Н.Н.Андреев бар. «К.д.»т.нең төп максаты — әдәбиятны библиографик тикшерү була, бигрәк тә җирле басмаларны, ш.и. татар, чуаш, мари телләрендәге китапларны эзләп табуга һәм җентекләп өйрәнүгә күп көч сарыф ителә.

Түгәрәк эшчәнлегенең төп юнәлешен җәмәгать утырышлары, докладлар, лекция, китапларга бәяләмә бирү һ.б. формаларда «киң халык массалары арасында яхшы китапны пропагандалау» тәшкил итә. Дәүләт нәшрияты кысаларында яңа басмалар өчен уку заллары, китап музее булдыру, китап күргәзмәләре һәм конференцияләр уздыру карала. Түгәрәкнең үз журналы — «*Казанский библиофил»да* аның күпьяклы эшчәнлеге яктыртыла.

*Әд.:* Устав библиографического кружка «Друзей книги». К., 1921; А р и с т о в В.В. Мечта библиофила // Здравствуй, книга! К., 1989.

**КИТА́П ЕЛЪЯЗМАСЫ́**, к. «*Татарстан Республикасы матбугат елъязмасы*».

**КИТА́П СӨЮЧЕЛӘ́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, массакүләм иҗтимагый оешма. 1974 елда төзелә. Союздаш респ-каларда, өлкә, край, автономияле респ-каларда һәм 4 меңнән артык шәһәрдә бүлекләре булган 15 җәмгыятьне берләштерә. 1979 да җәмгыятьтә 9 млн.га якын кеше исәпләнә. Казанда К.с.җ.нең Татар бүлеген оештыру конференциясе 1974 нең ноябрендә була. 1997 дә респ-када 1200 башлангыч оешма, 110 мең индивидуаль, 407 коллектив әгъза, 185 совет һәм секция, 175 китап сөючеләр клубы, 46 халык китап кибете һ.б. исәпләнә. Җәмгыятьнең бурычлары: китап пропагандалау, фәнни, сәяси һәм техник белемнәрне тарату, нәшрият эшен үстерүгә булышу. Иҗат берлекләре «Белем» җәмгыяте, Мәгариф министрлыгы һ.б. оешмалар б-н берлектә китап күргәзмәләре, смотр-конкурслар, әдәби юбилей кичәләре, укучылар конференцияләре үткәрә. 2000 дә республикада К.с.җ.нең эшчәнлеге туктатыла. К.с.җ.нең Татарстан бүлеге идарәсе рәисләре булып

М.Т.*Низамиев* (1974–97), Е.И.Осипова (1997–99) эшли.

*И.А.Новицкая.*

**КИТА́П ЯДКӘРӘ́**, кулъязма, ш.у. иске басма китап яки соңгырак еллардагы тарихи-мәдәни яктан мөһим саналучы басмалар. «К.я.» дигән термин («сирәк китап» терминының синонимы) 1980 еллар уртасында киң колач ала. К.я.нең әһәмиятен аның рухи, фәнни, сәнгати абруе һәм башкарылу сыйфаты билгели. Теләсә кайсы китап, әгәр дә аңарда тарихи шәхесләр һ.б. атаклы кешеләр аерым билгеләр, өстәмә язулар яки автографларын калдырган булсалар, К.я. була ала. Тарихи-мәдәни кыйммәте ягыннан К.я.н берничә категориягә бүләләр: дөньяви, дәүләти (федераль), төбәк һәм җирле. К.я.нә үз чорын, аның рухи-әхлакый, эстетик, иҗтимагый-сәяси атмосферасын, икътисади, технологик һәм техник (беренче чиратта, полиграфик)



«Кырым ханнары тарихы» китабының титул бите. Казан. 1832.

культурасын тулысынча һәм үзенчәлекле яктырткан китаплар; мөһим эчтәлекле тыелган яки конфискацияләнгән әсәрләр басмалары; атаклы фән, әдәбият, сәнгать эшлеклеләренең беренче һәм үзләре исән чагында басылган китаплары, текстологик яктан иң уңышлы кабат нәшер ителгән басмалары; атаклы рәссамнар бизәгән басмалар; төрлечә басу техникасының беренче һәм үзенчәлекле үрнәкләре; басмаларның библиофиль берәмлекләре; гадәти булмаган материалда яки гадәти булмаган формадагы, мәс., чокып басылган, ефәктә тукылган һәм тиражга салынган китаплар, кулдан бизәлгән пергамент, төрле өстәмә битләр б-н бөкедә басылган басмалар; атаклы эшлеклеләр яки фонд тотучылар тарихы б-н бәйле коллекцияләрдәге китаплар һ.б. керә.

Татарстанда төрле культураларның берничә мең дистә саклау берәмлеге К.я. бар (мәс., Шәрекъ кулъязмалары, кириллицадагы китаплар). К.я.нең күпчелеге Казанда, Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, башка югары уку йортлары китапханәләрендә, ТР Милли музеенда һ.б.да саклана. К.я. шәхси тупланмаларда да очрый. ТР китап саклау урыннарында 13–20 йөзләрдә гарәп шрифтында һәм яңалифтә, кириллицада язылган татар һәм рус телендәге кулъязма китаплар; атаклы татар, рус, немец, чуаш, мари, башкорт галимнәре, язучылары, шагыйрьләре, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләренең кулъязмалары, беренче китаплары; аларның автографлары һәм истәлек язулары булган һ.б. китаплар саклана. ТР китапханәләре, музей һәм архивларында *Варсоно*фий, К.К.*Клаус*, Н.Н.*Зинин*, А.М.*Бутлеров*, Г.*Тукай*, Л.Н.*Толстой*, И.А.*Бодуэн де Куртенэ*, В.И.*Ленин*, К.*Насыйри*, Г.*Исхакый*, М.*Фәйзи* һ.б. атаклы фән, әдәбият, сәнгать, сәясәт эшлеклеләре исемнәре б-н бәйле К.я.ләре бар.

Казанда сакланучы иң борынгы басма К.я. — 14–16 йөзләрдә иң абруйлы Библия аңлатмаларының авторы Николай Лира китабы («Postilla super Epistolas Pauli additionibus Pauli Burgensis et replicationibus Matthinae Doering» — «АпостолПавел юлламасына карата аңгәмәләр»). Казан китап саклау урыннарында Казанда басылган К.я.ләре: «Казан изге Мәрьям Ана иконасына гыйбадәт кылу» («Служба Казанской иконе Божией Матери» (1590 еллар уртасында «*Аноним басмаханә*»дә кириллицада басылган иң беренче китапларның берсе), «Әт-тәхият» (1801; *Азия басмаханәсендә* нәшер ителгән беренче басма татар китабы), «Һәфтияк» (1801; Азия басмаханәсендә дөнья күргән икенче басма татар китабы), Д.Н.Зиновьевның «Французлар белән сугыш форсатыннан чаң сугу» («Набат по случаю войны с французами», 1807; Казан губерна басмаханәсендә гражданлык шрифтында басылган икенче рус китабы) һ.б. саклана.

*Әд.:* Книговедческое аннотирование и систематизация книжных памятников: Метод. рекомендации. М., 1997; Рукописный фонд Русского сектора отдела рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского: Путеводитель. К., 1999; Горохова Л.В., Султанбеков Б.Ф., Шарафутдинов Д.Р. Концепция создания Научной лаборатории Национального архива РТ (НЛ НА РТ) по выявлению и изучению документальных источников по истории народов Татарстана // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1/2; Григорьев Е.И. «Научная лаборатория, конечно же, должна быть!» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2; Книга: Энцикл. М., 1999.

*Е.И.Григорьев.*

**КИТАПХАНӘ́ ГЫЙЛЕМӘ́**, китапханә эшен, китапханә системасының оешу, үсү, эшләү принциплары һәм закончалыкларын өйрәнә торган фән. Үз эченә китапханә эшенең гомумтеоретик нигезләрен ала: документаль тупланма булдыру, мәгълүмат-эзләү системаларын оештыру, укучыларга китапханә хезмәте күрсәтү, китапханә эше тарихын, китапханә эше б-н идарә итү һ.б. Казан губернасында китапханә белеме өлкәсендәге беренче хезмәтләр 19 йөзнең 1 нче яртысында барлыкка килә. Казан ун-ты китапханәсендә эшләгән К.К.Фойгт һәм Н.И.Лобачевский идеяләре хәзерге китапханәгә нигез салалар. К.К.Фойгтның фондлар оештыру өчен 1834 елда төзелгән «Китапханәнең урнашу планы...» («План расположения библиотеки...») иң уңышлысы дип табыла, һәм аның авторы хөкүмәт тарафыннан бүләкләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында китапханә белеме түбәндәге юнәлешләрдә үсеш ала: эре китапханә һәм китап тупланмалары тарихы; китапханә оештыру һәм эшләтү мәсьәләләре; кулъязмалар һәм сирәк китапларны җыю, язып алу. Казан руханилар академиясе һәм Казан руханилар семинариясе китапханәләренең тарихы К.В.Харлампович, С.А.Терновский, П.В.Знаменский һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла. Аерым китап коллекцияләре, кулъязмалар һәм иске басма китаплар А.П.Щапов, П.В.Знаменский, И.Я.Порфирьев, Н.Ф.Катанов, А.И.Артемьев, И.Ф.Готвальд һ.б. тарафыннан тасвирлана. Китапханәне туплау, укучыларга әдәбиятны тәкъдим итү мәсьәләләре П.П.Васильев, Н.Я.Агафонов, И.А.Шидловский һ.б. хезмәтләрендә карала. Аларның идеяләре И.Ф.Готвальд җитәкчелегендәге Казан ун-ты китапханәсе, җәмәгать китапханәсе (хәзерге *Татарстан Республикасының Милли китапханәсе)*, иң яхшы җәмәгать китапханәләре эшчәнлегендә тормышка ашырыла. Беренче җәмәгать китапханәсе эшендә фондларны туплау, укучыларга хезмәт күрсәтү принципларын өйрәнгән Казан ун-ты галимнәре Н.Н.Булич, Н.П.Загоскин, Д.А.Корсаковлар якыннан катнашалар. Җәмәгать китапханәләре хуҗалары фондларның эчтәлегенә, аларның каталогларда җентекле һәм үз вакытында чагылуына, укучыларга яңа әдәбият турында мәгълүмат бирүгә игътибар итәләр. Фәнни һәм мәгариф җәмгыятьләре китапханәләре эшчәнлегенең төп юнәлешләре аларның устав һәм программаларында чагыла. Татар халкының әдәбият һәм тарих истәлекләрен җыю һәм язу б-н зур шәхси китапханәләре булган галим һәм мәгърифәтчеләр Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Баруди, Х.Фәезханов шөгыльләнә. Татар китапханәләре тарихы, аларны оештыру мәсьәләләре, эш юнәлешләре 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Р.Фәхретдин, Ә.Максуди, Ш.Күлтәси, Ф.Кәрими хезмәтләрендә чагыла. 1917 дән соң китапханә белеме тикшеренүләре үзәкләре булып эре дәүләт китапханәләре санала. 1920–30 елларда аерым китаплар һәм китап коллекцияләрен өйрәнү б-н — П.М.Дульский, Е.И.Шамурин, М.А.Васильев һ.б., татар халкының кулъязма мирасы б-н С.Вахиди, С.Алимов һ.б. шөгыльләнә. Совет чорында, Окт. рев-циясенә кадәрге кебек үк, китапханә белеме тикшеренүләрендә төп урын китапханә тарихына (В.В.Аристов, Е.В.Ермолаева, В.И.Шишкин, Ж.В.Щелыванова, А.В.Гайнуллина һ.б.), кулъязмалар һәм сирәк китапларны өйрәнүгә (М.Г.Госманов, Ә.Г.Кәримуллин, М.И.Әхмәтҗанов һ.б.) бирелә. 1970 еллар башыннан Татарстанда китапханәләр үсеше икетеллелек шартларында укучыларга хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен, төбәкне өйрәнүдә мәгълүмат-эзләү системасын барлыкка китерүне, китапханәнең башка оешмалар б-н эшчәнлеген үзара яраклаштырып торуны өйрәнүче Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты б-н бәйле. Китапханәнең мөстәкыйль фәнни проектлары татар китаплары истәлекләреннән торган фондларны оештыру һәм

өйрәнү, иске татар китаплары репертуарын төзү, мәгълүматларның электрон базасын булдыру, китапханә-библиографик оешмаларның эшен автоматлаштыру шартларында эбунәчеләргә хезмәт күрсәтү һ.б. б-н бәйле. Китапханәнең фәнни-тикшеренү эшләре, ш.у. китапханә белеменең төбәкләрдәге торышы Татарстанда китапханә эше үсешенең гомуми концепциясе б-н билгеләнә.

*Әд.:* Максуди Ә. Көтебханәи исламия // Казан мөхбире. 1905. № 4; Кәрими Ф. Көтебханәләр // Заман календаре. 1906; Васильев П.П. Частные библиотеки в Казани // Журн. М-ва нар. просвещения. 1862. Ч. 119; Библиотека при Казанской духовной семинарии. К., 1889; Краткий исторический очерк Казанской публичной библиотеки за 50 лет её существования... К., 1915; Аристов В.В., Ермолаева Н.В. Всё началось с путеводителя: Поиски литературные и исторические. К., 1975; Библиотека Казанского университета: фонды, раритеты, история... К., 1989; Библиотеки Татарстана: история и современные реалии. К., 1999; Ш.у. к. Китапханәләр.

*Г.Г.Габделганиева.*

**КИТАПХАНӘ́-БИБЛИОГРА́ФИЯ БЕЛЕМЕ́**, китапханә-библиография оешмалары өчен урта һәм югары белемле белгечләр, китапханә-библиография һәм мәгълүмат фәннәре укытучыларын әзерләү системасы. Россиядә — 20 йөз башыннан, Татарстанда 1930 еллар уртасыннан үсеш ала. Махсус урта белемле белгечләрне — Алабуга мәдәният уч-щесе, югары белемлеләрне Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты әзерли. Университет кадрларны түбәндәге белгечлекләр буенча укытып чыгара: китапханә белеме, библиография белеме, гамәли информатика (социаль-мәдәни өлкәдә), документлар белеме һәм идарәне документлар б-н тәэмин итү (китапханә эшендә менеджмент, китапханә-мәгълүмати системаны автоматлаштыру, документларны аналитик-синтетик эшкәртү, адм.-идарә эшчәнлеген документлар б-н тәэмин итү һ.б. буенча специальләшү). 4 махсус кафедра: китапханә белеме, библиография, информатика, документларны фәнни эшкәртү кафедралары эшли. 1996 да — аспирантура, 1999 да «Китапханә белеме, библиография, китап белеме» белгечлеге буенча диссертация советы ачыла.

*З.А.Сафиуллина.*

**КИТАПХАНӘ́-МӘГЪЛҮМА́Т ҮЗӘГЕ́**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына караган күпфункцияле мәгълүмат органы. 1920 елда комис-т хезмәткәрләре өчен ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты каршында китапханә буларак оештырыла. Аның башлангыч фондын Ортопедия ин-ты һәм проф. Р.А.Лурия тарафыннан бүләк ителгән 450 китап тәшкил итә; 1945 тә китапханә Республика фәнни мед. китапханәсе итеп үзгәртелә.

1960 елларның беренче яртысында Республика фәнни мед. китапханәсе фонды — 23 мең, ә 80 нче елларда 40 меңнән артык саклау берәмлеген тәшкил итә. 1992 дә мед. учреждениеләрендә һәм мед. уку йортларында китапханәнең ф-ллары ачыла. 1994 тә Республика фәнни мед. китапханәсе һәм аның ф-ллары җирлегендә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика мед. китапханә-мәгълүмат үзәге — фәнни мед. китапханәсен һәм ТР мед. учреждениеләре каршындагы 47 ф-лны үз эченә алган үзәкләштерелгән китапханә системасы оештырыла. Структурасы һәм башкару функцияләре буенча К.-м.ү.нең Россиядә тиңе юк. К.-м.ү.нең функцияләренә түбәндәгеләр керә: биол.-мед. тематикасына караган басмаларны һәм нәшер ителмәгән документларны туплаган республика фондын, мед. өлкәсендә ТРның фәнни потенциалы турындагы мәгълүматлар базасын булдыру; ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының барлык белгечләренә китапханә-библиография хезмәте күрсәтү.

К.-м.ү.нең алга киткән белешмә-эзләнү аппараты — 6 каталогы һәм 75 картотекасы, «Татарстанда сәламәтлекне саклау» уникаль библиографик картотекасы; фәнни-мед. һәм методик бүлекләре (Үзәк китапханә системасының барлык буыннары б-н идарә итүне, К.-м.ү. б-н Россия китапханәләр ассоциациясенең бер-берсе б-н элемтәдә эшләвен тормышка ашыра) бар; мед. буенча 19 йөз – 20 йөз башындагы сирәк һәм әһәмиятле басмаларның хуҗасы булып тора. К.-м.ү.нең халыкара элемтәләр бүлеге Springer-Verlag (Германия) нәшрияты б-н элемтәдә тора. К.-м.ү. составында оператив полиграфия базасы булган «Медицина» нәшрияты эшләп килә, «Медицинские вести» г-тасы чыга, мед. әдәбияты (монографияләр, методик һәм белешмә әсбаплар һ.б.) бастырыла. Медицина тематикасы буенча библиографик, мәгълүмати, фәнни, белешмә, методик, уку һ.б. басмаларны бастыра.

К.-м.ү. Халыкара китапханәләр ассоциацияләре федерациясе (IFLA), Россия китапханә ассоциациясенең (РБА) актив әгъзасы булып тора. Һәр елда 40 меңгә якын укучыга хезмәт күрсәтә, 2011 елга аның фондын 660 мең саклау берәмлеге тәшкил итә.

*Ю.Н.Дрешер, Р.Г.Исхакова.*

**КИТАПХАНӘЛӘ́Р** (гарәп. كتاب — китап, фарсы خانه — йорт), тиражлы документларны җыю, саклау һәм куллануны тормышка ашыручы мәгълүмат һәм мәдәният учреждениеләре. Татарстан терр-ясендә беренче китапханәләр Идел буе Болгарында барлыкка килә. Казан ханлыгында шәхси (өй), сарай, уку йортлары (мәдрәсә һәм мәктәпләр каршында) китапханәләре, мәчетләр каршында китап тупланмалары була. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, китапханәләрнең күбесе юкка чыгарыла. 16–17 йөзләрдә монастырь һәм чиркәү китапханәләре, скрипторийлар оеша башлый. К.нең алга таба үсеше 18 йөздә цифирь мәктәбе (1718), Казан руханилар семинариясе (1733), «Буби» мәдрәсәсе (1781) ачылу б-н бәйле. Татар һәм рус руханиларында, крәстияннәрдә, сәүдәгәрләрдә шәхси китаплар, китап җыелмалары була. Шәхси китапханәләрнең иң зурлары һәм атаклыларының хуҗалары — шул чорның дворян һәм иҗат интеллигенциясе вәкилләре, мәс., М.И.Веревкин, Ю.И. фон Каниц, И.И.Панаев, В.И.Полянский, Л.И.Лихачёв, С.А.Москотильников, Г.П.Каменев, С.Х. һәм И.И.Хәлфиннәр, Н.М. һәм Л.Н.Ибраһимовлар, М.М.Мәхмүдов һ.б. 19 йөздә эре уку йортлары: Казан ун-ты (1804), Казан руханилар академиясе (1842), «Мәрҗания» (1870), «Мөхәммәдия» (1882) мәдрәсәләре китапханәләре оеша. 1834 елда Казанда А.Г.Мясниковның беренче җәмәгать китапханәсе, 1850 елларда — И.А.Сахаровның һәм чит ил китаплары тупланган Кастнер китапханәләре ачыла. Кайбер уку йортлары китапханәләре төрле елларда җәмәгать китапханәсе ролен дә башкара. 1861 дә Казан губернасында 42 китапханә була, аларда 148 мең том китап саклана. 1860 тан башлап Казанда җәмәгать файдалануындагы шәхси китапханәләр киң таралыш ала: И.Н.Кунавин, А.И.Шидловский, А.Н.Соловьёв, Михайлов, Рязановныкы. 1870 елларда — Э.С.Перимова, Степанова, А.А.Штукенберг, А.А.Михайлова, А.А.Хомякова, В.И.Картиковский китапханәләре; 1880 елларда — Н.С.Пальчинская, Н.В.Рейнгардт, Л.П.Рейнгардт (балалар китапханәсе), А.Н.Сергеева, А.В.Брюно китапханәләре; 1890 елларда — А.И.Картиковская, Л.Г.Юшкованың «Шәрекъ лирасы» («Восточная лира») китапханәләре; 1900 елларда В.И.Терентьев, Г.П.Ачинская, В.Н.Янова, С.И.Сыздыкова, Е.С.Ружевскаяның «Мәгариф» («Образование»), Л.В.Кротова, Е.И.Ярыгин китапханәләре ачыла. 1892 дә китапханәләрдә 28453 исемдә китап (48457 том) һәм 1472 китап укучы исәпләнә. Иң күп басмалар А.В.Брюно (8951 исемдә, 14287 том) һәм «Шәрекъ лирасы» (6478 исемдә, 14724 том) китапханәләрендә саклана. Бәясе ягыннан иң кыйммәтле китапханә дә А.В.Брюноныкы була. 1860–70 елларда Казан ун-тының гыйльми җәмгыятьләре китапханәләре оеша (табибләрнеке; физика-матем.; табигать фәннәре белгечләре, археология, тарих һәм этнография һ.б. фәнни җәмгыятьләрнеке). 1865 тә — Казанда беренче җәмәгать китапханәсе (хәзерге Татарстан Республикасының Милли китапханәсе), 1875 тә Чистай шәһәрендә беренче земство китапханәсе барлыкка килә. 1880–90 елларда аларны оештыру шәһәр һәм земство үзидарә органнарына тапшырыла. 1883 тә китапханәләр — Зөя, Спас, 1887 дә — Лаеш һәм Тәтеш, 1895 тә — Минзәлә, 1896 да Алабуга шәһәрләрендә дә ачыла. 1892 дә Казан губернасында 12 җәмәгать китапханәсе эшли, аларда 11402 исемдә китап (32280 том) һәм 20349 китап укучы исәпләнә. Китапханәләрнең 11е өязләрдә (16048 томда 4322 исемдәге басма, 837 китап укучы) эшли. 1900 елда губернада 13 җәмәгать китапханәсе була.

Легаль булмаган китапханәләр дә эшләп килә (А.С.Деренковның, Ревель пехота полклары офицерларыныкы һ.б.). 1890 еллардан Казан губернасында халык китапханәләре ачыла башлый. 1909 да Спас өязендә 32 шундый китапханә оеша, Тәтеш өязендә — 23, Чистай өязендә — 13, Зөя өязендә — 12, Мамадыш өязендә — 6 һ.б. Аларның 70е Казан аеклар җәмгыятенә, халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләү буенча попечительлек ком-тына һәм Казан өяз земствосына карый. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казанда төрле төрдәге аң-белем тарату, үзлегектән укып бе-

лем алу җәмгыятьләренең үз китапханәләре оешa: китап басучыларныкы (1887), аеклар җәмгыятенең беренче китапханәсе (1892), бакчачылык һәм коммерция җәмгыятьләренеке (1909), немец хатын-кызлар җәмгыятенеке (1910) һ.б. Бушлай кереп уку бүлмәләре дә эшли: Казан дары з-ды каршында (1896 дан), Алафузов ф-касы каршында (1900 дән),Гоголь исем. (1902 дән) һәм Некрасов исем. (1903 тән) китапханәләрдә, аеклар җәмгыятендә һ.б. 20 йөз башыннан татар җәмәгать китапханәләре ачыла: «Көтебханәи исламия» (1906), Алафузов ф-касында татар эшчеләренеке (1906), «Шәрекъ» клубыныкы (1908), Г.Шәрәф китапханәсе һәм уку бүлмәсе (1916) һ.б. К.Ф.Фукс, Х.Д.Френ, Ф.И.Эрдман, А.К.Казимбәк, К.Насыйри, Ш.Мәрҗани, Ф.Әмирхан, С.Вахиди, Г.Баруди һ.б. шәрекъ кульъязмалары һәм китапларының бай тупланмаларына ия булалар. 1910 елларда Казан хәрби гарнизоны частьләрендә мөселман уку бүлмәләре оештырыла.

1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң күп кенә китапханәләр ябыла, аларның фондлары таратыла яки юк ителә. Республиканың күпмилләтле халкына хезмәт күрсәтү өчен, яңа массакүләм китапханәләр челтәре киңәйтелә (совет хакимиятенең беренче елларында 218 китапханә һәм уку заллары оештырыла, ш.и. 138е татарлар өчен). 1919 да — балалар китапханәсе, 1920 дә — ТАССРның Сәламәтлек саклау халык комис-ты китапханәсе (хәзер Республика мед. китапханә-мәгълүмат үзәге), 1930 еллар башыннан — профсоюзлар китапханәсе, 1935 тә махсус Сукырлар өчен китапханә ачыла. 1920–30 елларда китапханәләрдә, беренче чиратта, эре китапханәләрдә укучылар өчен ябык булган «махсус фондлар» оеша, аерым кульъязма һәм басмалар юк ителә. Бөек Ватан сугышы алдыннан респ-када 2251 массакүләм китапханә эшли. Сугыш елларында аларның саны кыскара. 1946 да СССР ФАнең Казан ф-лы китапханәсе (к. *Казан физика-техника институты китапханәсе*) ачыла. 1950–60 елларда партия китапханәләре челтәре оештырыла, массакүләм китапханәләр челтәре тәртипкә китерелә (1289 китапханә, филиал һәм китап бирү пунктлары ачыла). 1960 елда Мәдәният министрлыгы карамагында 2379 китапханә исәпләнә. 1975–80 елларда массакүләм китапханәләр үзәкләштерелгән китапханә системасына берләштерелә. 1977 дә Республика яшүсмерләр китапханәсе ачыла. 1980 дә Татарстанда — 1745 массакүләм китапханә, 1990 да — 1799, 2009 да Мәдәният министрлыгы карамагында 1580, ш.и. 1576 муниципаль китапханә, *Татарстан Республикасының Милли китапханәсе*, Республика балалар китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Сукырлар өчен махсус республика китапханәсе эшли. Аларның берләштерелгән фондларында 24 млн.нан артык саклау берәмлеге исәпләнә. Республикада массакүләм китапханәләрдән тыш югары уку йортлары (12541947 саклау берәмлеге), башка уку йортлары, җәмәгать оешмалары китапханәләре һ.б. да эшләп килә. Республика китапханәләрендә басылган яки басылмаган төрле документлар; Россия халыклары, Европа һәм шәрекъ телләрендә язылган басмалар; ноталы, картографик һ.б. материаллар; мәгълүмат-эзләү системаларында чагылдырылган электрон, аудио һәм визуаль документлар саклана. Татарстанның иң эре китапханәләре: Татарстан Республикасының Милли китапханәсе, Казан ун-тының фәнни китапханәсе.

Китапханәләр «Татарстан Республикасында китапханәләр һәм китапханә эше турында»гы Законга (1998), «2001–2005 елларда Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерүнең дәүләт программасы»на (2000) таянып эш итәләр.


*Әд.:* Г а й н у л л и н а А.В. Публичные библиотеки и их роль в развитии культуры народов Татарстана (конец XIX — начало XX вв.) // Слово о книге. К., 1994; М и н у л л и н З.С. Татарские общественные библиотеки конца XIX — начала XX вв. // шунда ук; История библиотечного дела Татарстана (XVI век — 2-я половина XX века). К., 1997. Вып. 1. Закон Республики Татарстан о библиотеках и библиотечном деле. К., 1998; Д е л е ш о в а М.Х. На языке души. К., 1999; Библиотеки Татарстана в 1999 году. К., 2000; Государственная программа развития библиотечного дела в Республике Татарстан в 2001–2005 гг. К., 2000. Ш.у.к. *Китапханә белеме.*

**КИТЕЛГА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 43 *км* төньяк-көнбатыштарак, Каты Елга елгасы буенда. 2010 елда 131 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1870 еллар тирәсендә Новотроицк авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе (1907 дә ачыла), ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, 3 май з-ды, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1726 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостена керә, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1900 дә — 994, 1920 дә — 926, 1926 да — 799, 1938 дә — 639, 1949 да — 515, 1958 дә — 362, 1970 тә — 292, 1979 да — 181, 1989 да — 133, 2002 дә — 166 кеше.

**КИ́ТЕР** Александр-Людвиг Александрович (1813, Лифляндия губ. Венден ш. — 22.3.1879, С.-Петербург), хирург, медицина д-ры (1836). 1835 елда Дерпт ун-тының мед. ф-тын тәмамлый, 1836–38 дә Н.И.Пирогов җитәкчелегендә шул ук университетның хирургия ф-тында эшли. 1838–40 та Германия клиникаларында тәҗрибә үтә. 1840 тан Казан ун-тының теоретик хирургия кафедрасында, 1846 дан проф., 1848–70 тә С.-Петербург медицина-хирургия академиясендә, 1848–58 дә госпиталь хирургиясе каф. мөдире. Гинекологиядә хирургия юнәлешенә нигез сала. К. акушерлык-гинекология гамәлендә хатын-кыз авыруларын дәвалауның хирургик ысулларын куллана. 1846 да, Россиядә беренче буларак, яман шешле аналыкны җиңсә аша алуны уңышлы башкара (Ф.О.*Елачич* б-н берлектә). 1847 дән наркоз куллана башлый. Акушерлык-гинекология эшләрен киң җәелдерә, Идел-Урал төбәгендә таныла.

Х е з м.: Лечение геморроя // Зап. по части врачебных наук. 1844. № 2; Вырезывание всей матки, поражённой раком, без выпадения, произведённое по новому способу ... // Зап. по части врачебных наук. 1847. № 4; Руководство к изучению акушерской науки: В 2 ч. СПб., 1857–58.

**КИТТА́РЫ** Модест Яковлевич (1825, Пермь губ. — 23.3.1880, С.-Петербург), химик-технолог, химия д-ры (1848), проф. (1852). 1844 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: химик технол., аналитик химия һәм минерал. укыта, технол. кабинетына нигез сала, 1848 елдан технол. каф. мөдире; бер үк вакытта, 1847–53 тә Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында бушлай табигый тарих фәнен укыта. 1857–69 да Мәскәү ун-ты проф., Мәскәү практик академиясе инспекторы була. 1860 еллар урталарыннан Хәрби министрлыкта хезмәт итә, 1867 дән Баш интендант идарәсе каршындагы Техника ком-ты рәисе. Ясалма минераль сулар җитештерүне нигезли. Натрий карбонаты алу, шәм, стеарин, туң май җитештерү, сабын кайнату һәм тире эшкәртү технологияләрен эшли. Җитештерүгә фәнни методикаларны кертү өчен, яшь технологлар мәктәбе булдыра.


1848.

М. К и т т а р ы. Гадәти һәм чәнечкеле сольпуганы анатомик тикшерү. Титул бите. Казан. 1848.

1850 еллар башында технология буенча ачык лекцияләр циклы укый. Казан икътисадчылар җәмгыяте эшчәнлегендә катнаша, «Записки Императорского Казанского экономического общества» ж-лын (1854–61), «Промышленный листок» г-тасын (1858–59) редакцияли һәм нәшер итә. Казанда беренче а.х. күргәзмәсен үткәрүне (1852) башлап җибәрүче, Вятка күргәзмәсен (1854), Мәскәүдә Политехник күргәзмәне (1872) оештыручыларның берсе. Ирекле икътисадчылар җәмгыятенең Зур алтын медале б-н бүләкләнә (1857). К.ның васыяте буенча Казан ун-тында ул калдырган капитал процентыннан аның исемендәге 2 стипендия булдырыла.

Х е з м.: Очерк современного положения нужд русской мануфактурной промышленности. М., 1857; Публичный курс товароведения: В 4 вып. М., 1860.

*Әд.:* М у с а б е к о в Ю.С. Модест Яковлевич Киттары // Журн. прикладной химии. 1952. Т. 25, № 11; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*В.Г.Абзалова.*

**КИЧКЕ́ ЯРКАНАТЛА́Р** (Nyctalus), ярканатлар ыругы. 7 төре билгеле, Европа, Көнчыгыш һәм Көньяк-көнчыгыш Азиядә очрыйлар. ТР терр-ясендә 2 төре яши. Гади кичке ярканат (N. noctula) барлык районнарда бар. Гигант кичке ярканат (N. lasiopterus) — бик сирәк төр. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарда яши. Карт агач куышларында, сирәк кенә каралтыларда оялый. Гигант кичке ярканат кышлау өчен көньякка очып китә. Гәүдәсенең озынлыгы 70 тән (гади кичке ярканат) 104 *мм* га (гигант кичке ярканат) кадәр. Гәүдәсе бәрхетсыман кыска мех б-н капланган. Канатлары тар, озын. Күзләре гадәттән тыш кечкенә. Күрү сәләте начар, ишетү һәм сизү органнары яхшы үскән. Эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. К.я. оча торган бөҗәкләр б-н тукланалар, аларны еш кына зур биеклектә аулыйлар. 1–2 бала чыгаралар. 12 яшькә кадәр яшиләр. Гигант кичке ярканат ТРның Кызыл китабына кертелгән.


**КИЧКЕ́ЕВО** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 72 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Алексеев Пүчинкәсе исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Изге Параскева чиркәве, земство мәктәбе (1888 дә ачыла), җил һәм су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1080,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 126 ир-ат; 1859 да — 373, 1897 дә — 574, 1908 дә — 685, 1920 дә — 734, 1926 да — 673, 1938 дә — 460, 1949 да — 299, 1958 дә — 200, 1970 тә — 154, 1979 да — 118, 1989 да — 89, 2002 дә — 92 кеше.

**КИЧКЕТА́Ң** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 70 *км* көньяктарак, Барҗы елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 673 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1722–23 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, чыпта сугу һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1809 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 27 ир-ат; 1859 да — 404, 1877 дә — 684, 1905 тә — 835, 1920 дә — 1162, 1926 да — 979, 1938 дә — 1067, 1949 да — 643, 1958 дә — 574, 1970 тә — 458, 1989 да — 759, 2002 дә — 642 кеше.



«Кичкетаң». Тугай күлләре.

**«КИЧКЕТА́Ң»**, комплекслы табигать тыюлыгы, Әгерҗе р-нының көньяк-көнбатышында. Иж елгасы үзәненең түбәнге агымындагы участокны били, Кичкетаң авылыннан көнчыгыштарак, Салагыш авылыннан көнбатыштарак, Кырынды авылыннан көньяктарак. 1997 елда оештырыла. Мәйданы 9800 *га*, ш.и. урман б-н капланган өлеше 1676 *га*. Елга тугае һәм тамак өлешендәге беренче тугай өсте террасасы Түбән Кама сусаклагычы сулары астында калган. Күп кенә, ш.и. әлеккеге су юлындагы күлләр бар. Сөзәклек итәкләрендә суы зур дебитлы булган чишмәләр ага. Нигездә, ылыслы һәм киң яфраклы урманнар үсә. Сирәк куаклы һәм ярлы үлән капламлы чыршылыклар һәм яшел мүкле урманлыклар гадәти булып тора. Аеруча зур мәйданнарны чыршы, имән, каен, өрәңге, юкә катнаш катлаулы чыршылыклар били. Комсу катламлы утыртмаларда киң яфраклы һәм йомшак яфраклы токымнар күп. Елга террасаларының сазлыкланган түбән урыннарында кара зирек, бөдрә каен, тал агачлары үсә. 1970 елларда киселгән урманнар урынында — тигезлекләрдә йонча катнаш төрле үләнле һәм дымлы иңкү урыннарда болынчыл катнаш төрле үләнле болыннар барлыкка килгән. Болын киңлекләрендә ялгыз агачлар һәм аларның зур булмаган утраучыклары матур булып күренә. Тыюлык терр-ясендә ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләр: канлы бармактамыр, сарана лалә, сары төнбоек очрый. Хайваннар дөньясы күптөрле. Биредә елга (Европа) кондызы, Америка чәшкесе, ондатра, поши, кабан дуңгызы яши. Иж елгасы тугаена язгы һәм көзге очып китү вакытларында үрдәкләр, казлар, аккошлар төшә. Кошларның 100 гә якын төре билгеле, ш.и. зур күлбога, ысылдавык аккош, кыр карчыгасы, елга каракошы, чеглок, бытбылдык, соры торна, кечкенә яңгыр чыпчыгы, саескан-шөлди, зур улит, кызылаяк шөлди, шаркылдык акчарлак, саз ябалагы, чыпчык ябалагы, сары корташар, эрбетче ТРның Кызыл китабына кертелгән. Тыюлык терр-ясендә нарат, чыршы һәм ак чыршыдан торган «Катлаулы наратлык» (табигать истәлеге) урнашкан.



«Кичкетаң». Иж елгасы үзәне күренеше.

*И.Ф.Томаева, М.А.Горшков.*

**КИЧУ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 110 *км*, бассейнының мәйданы 1314 *км*$^2$. Елга башы Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының төньяк-көнбатыш сөзәклегендә, Әлмәт р-ның Миңлебай авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак; Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага; тамагы — Яңа Чишмә р-ның Ленино авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 275 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданы елга үзәннәре, ерымнар һәм сызалар б-н ергаланган җиңелчә калкулыклы яссы таулыкны (плато) хәтерләтә. Ерымнар челтәренең аеруча куе урыны — бассейнның уңъяк ярында. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. К. тирән үзән буенча ага. Югары агымнардан алып Әлмәт р-ның Нагорный авылына кадәр аз тугайлы яки бөтенләй тугайларсыз; түбәндәрәк тугае ике яклы, киңлеге 0,2–1 *км* га кадәр; болын үсемлекләре б-н капланган. Елга юлы уртача бормалы, киңлеге 6–20 *м* га кадәр. К. елгасының 46 кушылдыгы бар. Иң зурлары: Бота (10 *км*), Чупай (12 *км*), Батрас (15,3 *км*), Ямаш (14 *км*), Тетвел (17 *км*), Өргәнче (18,7 *км*) — уң; Чупай (13,7 *км*) — сул. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*$^2$. Ту-



Кичү елгасы. Яңа Чишмә районының Зирекле авылы янында.

енуы катнаш, яртысыннан күбрәген кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–5 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы Яңа Чишмә р-нының Әдәмсә авылы янындагы суүлчәгеч постта өйрәнелә (1935 тән). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 121 *мм*, ташу агымы катламы 65 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. К. елгасының югары агымы ноябрь башында, түбәнге агымы ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 2,6 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*); химик составы буенча югары агымында гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы, түбәнге агымында гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы. Гомуми минеральләшүе язын 200–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,8 млн. *м³* булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

*О.Н.Урбанова.*

**КИЧҮ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 550 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1734–36 елларда *Кама аръягы чик буенда* Кичү фельдшанецы (дошманнан саклану өчен төзелгән кыр ныгытмасы) буларак нигез салына. Башта монда отставкадагы солдатлар яши, 19 йөздә алар дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 1750 еллар ахырында Богословский бакыр эретү з-дында эшләүче сәүдәгәр Г.И.Глазовның крепостной крәстияннәре К.гә килеп урнаша. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек, ш.у. чана һәм тәгәрмәч дугасы өчен тугым ясау б-н шөгыльләнәләр. 1880 елларда К.дә а.х. чималы эшкәртүгә көйләнгән кечкенә заводлар: 1 тире эшкәртү, 1 аракы һәм 2 селитра з-ды эшли. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе, почта-телеграф бүлекчәсе, земство станциясе урнаша; Покров чиркәве (1784 тән яшәгән элеккеге авыл урынында 1882–92 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство (1863 тә ачыла) һәм чиркәү-приход мәктәпләре, авыруларны кабул итү бүлмәсе, 3 су тегермәне, 3 май язу з-ды була; дүшәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3002 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Самара губернасының Бөгелмә өязе Варвара (1918 дән — Кичү) волосте үзәге. 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 тән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1859 да — 841, 1897 дә — 1446, 1910 да — 1713, 1926 да — 1524, 1949 да — 763, 1958 дә — 713, 1970 тә — 720, 1979 да — 547, 1989 да — 346, 2002 дә — 486 кеше.

**КИЧҮБА́ЕВ** Мөхит Әхрар улы (16.8.1910, Пермь губ., Красноуфимск өязе Сызгы а. — 24.6.1979, Минзәлә ш.), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1957). Сәхнә эшчәнлеген 1935 елда Башкортстанда һәвәскәрләр коллективында башлап җибәрә, 1936 дан Минзәлә колхоз-совхоз театрында. Театр өлкәсендә махсус белеме булмаса да, талантлы һәм хезмәт сөючән булуы б-н тиз арада әйдәп баручы актёрлар рәтенә баса. Госман («Козгыннар оясында», Ш.Камал), Ярулла, Гаяз («Мактаулы заман», «Чаткылар», Т.Гыйззәт) кебек олы яшьтәге кешеләр рольләрен башкарып, үзен бик үзенчәлекле, характерлы актёр итеп таныта; колхоз-совхоз театрларының Мәскәүдә узган Беренче Бөтенсоюз фестивалендә катнаша һәм зур уңыш казана (1939). Тышкы тасвирлауның колоритлы булуы, буяулар куелыгы б-н аерылып торган, тормышчан дөреслеккә туры килгән образлар иҗат итә: Рәшит, Зариф, Мансур («Гөлзада», «Ил өчен!», «Якын дус», Р.Ишморат), Морат («Рәйхан», Н.Исәнбәт), Шәйхенур («Язылмаган законнар», Ю.Әминев), Шаһнияз («Куендагы елан», Ә.Мирзаһитов), Гобәй («Һәйкәл», Ә.Баян), Ямали («Әниләрем — бәгырь кисәкләрем», А.Каххар), Арчи («Намус», Г.Д.Мдивани). Татар һәм рус классикасы әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә К. тудырган образлар социаль характеристиканың кискенлеге б-н үзенчәлекле: Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Юныс («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Прохор («Васса Железнова», М.Горький), Паратов, Дороднов («Бирнәсез кыз», «Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский). Сәүдәгәр Сөләйман («Аршин мал алан», Г.Хаҗибәков), Вәли («Башмагым», Х.Ибраһимов), Фәтхи («Акчарлаклар», Ә.Фәйзи), Закир («Идел буенда», Г.Насрый) рольләрендә К.ның җырлау осталыгы да ачыла. Муз. сәләткә ия буларак, ул җырлар да яза, спектакльләргә көйләр чыгара («Гөлзада», «Якын дус», Р.Ишморат; «Кадерле минутлар», Г.Насрый һ.б.), концерт программалары б-н чыгышлар ясый.

*Әд.:* Гыйманова Д.Ә. Сабир Өметбаев исем. Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007; Народные артисты. К., 1980.

**КИЧҮЧА́Т** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 900 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та 2 мәчет, мәктәп, тимерчелек, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2792 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варвара волостена керә, 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 тән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 36 ир-ат; 1762 дә — 78, 1795 тә — 270, 1834 тә — 478, 1859 да — 846, 1889 да — 1373, 1897 дә — 1454, 1908 дә — 1650, 1920 дә — 1734, 1926 да — 1132, 1938 дә — 1035, 1949 да — 952, 1958 дә — 868, 1970 тә — 839, 1979 да — 697, 1989 да — 349, 2002 дә — 859 кеше. К.та галим, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Р.Фәхретдин туган (музей).



Кичүчат авылы. Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл.

**«КИШӘНГЕ́Р»**, ерым-сызалар системасы, ТРның табигать истәлеге. Яшел Үзән р-нының Олы Җәке авылыннан төньяктарак урнашкан.1981 елда билгеләнә. Мәйданы 69 *га*. Питиал елгасы үзәненең уңъяк сөзәклегендә кеше тарафыннан барлыкка китерелгән урман-болын биоценозы. 1970–76 да Яшел Үзән күргәзмә-тәҗрибә урман хуҗалыгы б-н бергә Татарстан урман-тәҗрибә станциясе тарафыннан су эрозиясе б-н көрәштә мелиорация эшләре үткәрелә: сөзәклекләрне террасалау ысулы б-н 30 *га* мәйданда урман утыртыла, болыннар яхшыртыла, су агымнарын читкә юнәлдерү өчен гидротехник корылмалар төзелә. Төрле технологияләр буенча каен, карагай, нарат, имән, тополь һ.б. токымнардан торган саклагыч утыртмалар булдырыла. Фәнни җитәкчелек а.х. фән. канд. Ч.С.Хәсәнкаев тарафыннан алып барыла. Хәзерге вакытта туфрак эрозиясе процессы туктатылган, болын үсемлекләре яңадан үсеп чыга. Сирәк очрый торган үсемлек төрләре үсә: тау бөҗәк чәчәге, хуш исле кыр кишере, гади арчан һ.б.



«Кишәнгер» ерым-сызалар системасы.

**КИШЕ́Р** (Daucus), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан ике-, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Борынгы заманнардан билгеле. Килеп чыгышы — Европа һәм Урта Азия. К. барлык континентларда үстерелә. Көпшәк, уңдырышлы комлы туфракны, нейтраль һәм аз ачылыклы балчыксыл туфракны ярата. Корылыкка чагыштырмача чыдам, яхшы үсеше өчен дым кирәк. Беренче елны каурыйсыман телгәләнгән яфраклары һәм

яхшы аерылып торган, ике катламлы тамыразык барлыкка килә: тышкы катламы (кабыгы) куерак төстә, баллы, тәмле һәм эчке катламы (үзагачы) ачыграк төстә, төзелеше буенча тупас. Икенче елда яңадан яфраклары, ботакланган сабаклары, чәчәкләре һәм орлыклары барлыкка килә. Каротинга, кыйммәтле минераль тозларга, шикәргә бай. Әһәмиятле яшелчә һәм азык культурасы. Орлыклары грунтка чәчеп үстерелә. К.не иртә язда чәчәләр яисә кышка чәчеп калдыралар.



Игүле кишер.

Чәчү нормасы 1 гектарга 1–1,5 *млн.* данә. ТРда чәчүлек мәйданы 700 *га*, уңышы 1 гектардан 170–275 *ц* чыга. Үстерелә торган сортлары: «Нантская 4» (1942), «Шантанэ 2461» (1943), «Витаминная 6» (1973), «Консервная» (1981), «Лосиноостровская 12» (1989), «Гибрид Каллисто» (1993), «Ахтубинская» (1998), «Нантес 2 Тито» (2001). Корткычлары — кишер чебене, чатыр көясе, аксыл болын күбәләге; авырулары — фомоз, кара һәм ак черек. К. яңа өлгергән килеш, консервланган һәм пешерелгән хәлдә кулланыла. К. согы витаминнар чыганагы һәм дәвалау чарасы буларак файдаланыла.

**КИШЕ́Р ҮЛӘНЕ́** (Peucedanum), чатырчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 120 гә якын төре билгеле, бөтен Евразиядә диярлек таралган. ТР терр-ясендә 3 төре билгеле. Саз кишере (саз акбашы, сазлык чыршы уты) (P. palustre) барлык районнарда очрый, сазлыклы болыннарда, торфлыкларда үсә. Тау кишере (P.oreoselinum) — Идел алдында, Любименко саз кишере (P. lubimencoanum) — күбесенчә Кама аръягында; нарат һәм имән урманнарында, коньяк ялангач сөзәклекләрдә үсә.

30–125 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы кырлы-буразналы. Яфраклары икешәр, өчәр каурыйсыман. Чәчәкләре ак, сары яки яшькелт-сары, чатырда урнашкан. Җимеше — ике орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Тау кишеренең җир өсте өлешендә флавоноидлар, эфир майлары бар, халык медицинасында үт кудыру, тонусны күтәрү чарасы буларак кулланыла; ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КИШЕ́РТ РАЙОНЫ́**, *Пермь краеның* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 елның 27 февралендә оештырыла. Мәйданы — 1400 *км²*. Үзәге — Усть-Кишерт авылы (Пермьнән 121 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 14455 кеше (2010), 477 татар (2002). Татарлар 1800 елдан билгеле булган Югары Солянка авылында (365 кеше) тупланып яши. 19 йөзнең 2 нче яртысында бу авылда мәчет була. Хәзерге вакытта монда татар мәктәбе эшли.

**КИЯ́СОВ** Андрей Павлович (24.2.1961, Бөгелмә ш.), гистолог, анатом, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2001). 1985 елда Казан мед. ин-тын (хәзер Казан мед. ун-ты) тәмамлагач, шунда ук эшли, 1995 тән үзәк фәнни-тикшеренү лаб.-ясе мөдире. 1993–95 тә Бельгиядә фәнни командировкада була. 2000 нән нормаль анатомия кафедрасында, 2001 дән мөдире. Хезмәтләре скелет мускуллары регенерациясен, бавырның кире синусоидаль йолдызча күзәнәкләрен (Ито күзәнәкләре, алар бавырдагы фиброз һәм цирроз чыганагы булып санала) өйрәнүгә карый. К. бавыр онтогенезы барышында һәм репаратив яңадан торгызылу чорында күзәнәкара тәэсирләрне өйрәнә.

Х е з м.: Иммунологистохимическое изучение фенотипов клеток в органотипической культуре печени эмбрионов крыс // Цитология. 2001. Т. 43, № 1; Патогистологическая диагностика хронических вирусных гепатитов. К., 2001 (автордаш); Клетки Ито в онтогенезе и регенерации печени // Цитология. 2002. Т. 44, № 4 (автордаш).

**КИЯ́СОВО РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньягында урнашкан. 1926 елның 4 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 821 *км*. Үзәге — Киясово авылы. Халкы — 11583 кеше (2010). Татарлар саны: 1989 да — 671, 2003 тә — 607, 2005 тә — 629 кеше. Алар күпләп Тауҗамал (313 кеше), Байсар (84) һәм Мөшәк (78) авылларында яши. Иң күптәнге татар авылы — Тауҗамал (1834). 1991 дән татар мәдәни оешмасы эшли. Мөшәк авылы мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә, «Чишмә» балалар иҗат коллективы (2004 тән), Байсар авылында «Каз канаты» үзешчән фольклор коллективы, 2001 елдан Тауҗамалда мәчет бар.

**КИЯҮ́ КАМЧЫСЫ́** (Phlomis), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы, сирәк кенә ярымкуакчыклар. ТР терр-ясендә, башлыча, Европа һәм Азиядә үсүче бер төре — бүлбеле К.к. (Ph. tuberosa) бар. Бөтен республикада, күбесенчә Кама аръягында, Идел һәм Камадан көньяктарак очрый. Куаклар арасында, даланган сөзәклекләрдә үсә. Бүлбе хасил итүче 70–120 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, 4 кырлы, кызгылт төстә. Аскы яфраклары яфрак таралгысында, озын саплылар — өчпочмаклы йөрәксыман пластинкалы, сабаклылар — йомырка-ланцетсыман, кырыйлары каяу-тешәүле. Чәчәкләре шәмәхә яки алсу төстә, сабак очындагы куе боҗракта урнашкан. Җимеше — очында төкчәләр булган чикләвекчек. Май–июльдә чәчәк ата. Бүлбеләрендә крахмал, яфракларында аскорбин к-тасы, алкалоид, сапонин, дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында эч киткәндә, үт кудыру, ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Терлек азыгы. Декоратив, баллы үсемлек.

**КЛАДО́НИЯ** (Cladonia), кладониячәләр семьялыгыннан лишайниклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап таралган. ТР терр-ясендә Альп К. (C. alpestris), формасыз К. (C. deformis), урман К. (C. arbuscula), нәфис К. (C. amaurocraea), безсыман К. (C. subulata) h.б. очрый. Күбесенчә комлы туфракта, нарат урманнарында, черегән агачларда, агач төпләрендә, сирәк кенә сазлык түмгәкләрендә үсә. К. ыругы катламны 2 гә: беренчел һәм икенчел өлешләргә бүлүе б-н сыйфатлана. Беренчел катлам субстратны каплаучы (туфрак, кабык, агач h.б.) төрле формадагы һәм зурлыктагы (1 дән 30 *мм* га кадәр) кабырчыклардан тора. Лишайниклар кайвакыт тыгыз каплам хасил итәләр, картаю б-н сирәкләнә яисә юкка чыгалар. Беренчел горизонталь катламнан икенчел вертикаль катлам (подецияләр) үсеп чыга. Формалары буенча күп төрле подецияләр хасил итә: бармаксыман гади, сирәк яки куе тармаклы h.б. Түбәнге өлештә алар акрын гына үлә, ә өске өлешендә үсүне дәвам итә һәм аерым очракларда 20 *см* биеклеккә (гадәттә, 5–10 *см*) җитә. Подецияләр очында кызгылт яисә коңгырт җимешләре — апотецияләр бар. К. һаваның чисталыгына гадәттән тыш сизгер һәм атмосфераның пычрануына биоиндикатор буларак кулланыла. Кәҗәболан, поши өчен азык булып тора. Формасыз К.дә шактый күләмдә уснин к-тасы (8% ка кадәр) бар, шунлыктан антибиотиклар ясау өчен чимал буларак хезмәт итә. Төз К. (C. amaurocraea) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.: Жизнь растений. М., 1977. Т. 3.*

**КЛА́ССЕН** Виктор Иванович (21.1.1950, Оренбург өлкәсенең Переволоцкий р-ны Степановка а.), физик, техник фән. д-ры (1986). 1973 елда Мәскәү физика-техника ин-тын тәмамлый. 1976–87 дә «Вымпел» фәнни-җитештерү берләшмәсенең А.А.Расплетин исем. Радиофизика фәнни-тикшеренү ин-тында: сектор (1978 дән), бүлек (1986 дан) җитәкчесе. 1987 дән «Вектор» радиокомпаниясе АҖдә (Чистай ш.), директор (1990 нан), ген. директор (1992 дән), бер үк вакытта Казан техник ун-тының гамәли электродинамика каф. мөдире (1987 дән). Хезмәтләре антенналы-фидер җайланмаларга карый. «Антенналар теориясе һәм техникасы» («Теория и техника антенн», М., 1985) монографиясе авторы. Икенче буын космик антенналар (ш.и. көзгеле гибрид) төзүнең төп электродинамик проблемаларын хәл итә. Ленин комсомолы бүләге лауреаты (1982).

Х е з м.: Оценка некоторых типичных тригонометрических сумм, встречающихся в радиофизике // Изв. вузов. Радиофизика. 1976. № 4 (автордаш); Метод анализа статистических характеристик КНД ФАР при случайных амплитудах, фазах и расположении излучателей // Радиотехника и электроника. 1981. № 3 (автордаш); О направленных свойствах раскрывающихся зеркальных антенн // Радиотехника и электроника. 1982. № 8 (автордаш).

**КЛАССИЦИ́ЗМ** (лат. classicus — үрнәк), сәнгатьтә һәм архит-рада антик чорның классик сәнгате һәм архит-расындагы иң камил кагыйдәләр һәм традицияләр культына нигезләнгән сәнгать стиле юнәлеше, Россиядә 18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөзнең 1 нче яртысында үсеш ала.

Рус К.ы әүвәлге чор (1760–70 еллар), катгый (1770–90 еллар), «Александр дәвере» (ампир, 19 йөзнең 1 нче чиреге), соңгы яки «Николай дәвере» (19 йөзнең 2 нче чиреге, эклектика кысаларында) төрләренә бүленә. Провинцияләрдә башкаладагы стиль кагыйдәләре еш кына бозыла. Россия архит-расында К.ның төп принциплары һәм алымнары канун чыгару документларында беркетелгән һәм



Классицизм. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе. Архитекторлар В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников. 1811. 20 йөз башы фоторәсеме.

шәһәрләр төзелешендә куллану өчен мәҗбүри беренче сәнгать стиле юнәлеше булган.

К. архит-расы фәзаи композицияләрнең ачыклыгы, планлаштыруның төгәллеге, симметрик композицияләрнең кырыслыгы, зур күләмле формаларның геом. камиллеге, ордер куллану, бизәкләрнең гадилеге б-н аерылып тора.

К. мохите бербөтен була. Биналарны бизәгәндә социаль дәрәҗәләр игътибарга алынмый. Сенат, бояр йорты, азык-төлек склады, беседка һ.б. бер үк формаларга нигезләнеп, бер үк кагыйдәләр буенча төзелә, эчке фәзалар тышкы формаларга охшатып бизәлә. Интерьерларда, тәрәзә-ишекләрне каймалау өчен фасад алымнары файдаланыла, колонналар, карнизләр һ.б. элементларда күләмнәр һәм формалар тигезлеге саклана. Ордер элементлары һәм детальләре ак төс б-н аерылып тора, әмма, бароккодан аермалы буларак, яссылыклар соры, тонык сары, кызыл һ.б. гади төсләр б-н бизәлә. Сарайларны, аерым йортларны, кайбер җәмәгать биналарының залларын сюжетлы һәм бизәккә бай плафоннар бизи. К.да бина интерьерларындагы нәкышь урыны төгәл билгеләнә. Бизәкләр плафон, гөмбәз кырыйларын урап ала. Скульптура рельефларын һәм архит-ра детальләрен имитацияләү өчен, монохром «гризайль» алымы кулланыла. Бинаның композициясендә скульптурага катгый урын бирелә: рельефлар — фронтоннар тимпаннарында, аттикларда, фасад куышларында; статуар скульптура бина түбәсенең очында, төп ишек баскычларында урнаштырыла. Шәһәрләрдә атаклы кешеләргә һәйкәлләр куела башлый. Илдәге урбанизация процессында губерна, өяз шәһәрләре һәм штатка кермәгән шәһәрләрнең планы, регуляр нигезгә ярашлы рәвештә, өр-яңадан төзелә. Яңа шәһәрләр регуляр план буенча корыла. Шәһәрләрнең планын үзгәрткәндә яки яңа төзелешләр башланган вакытта, торак һәм җәмәгать биналары «үрнәк» типтагы проектлар буенча төзелергә тиеш була. 19 йөз башында Петербургта, әүвәлге К.ның беренче «үрнәк» проектлары нигезендә, К. стилендәге төрле типтагы бина һәм корылма проектларының альбомнары («дәфтәрләре») әзерләнә. Алар, шәһәрләр һәм торак пунктларны регуляр план буенча төзү өчен, губерна һәм шәһәр идарәләренә җибәрелә. К. чорында барлыкка килгән шәһәр үзидарәсе яңа типтагы җәмәгать корылмаларын: кабулханәләр, мәхкәмә, казначейство, дворяннар һәм сәүдәгәрләр җыены биналарын төзүне шарт итеп куя. Алар катгый К. стиленә хас симметрияле композицияләр, планлаштырудагы чишелешләрнең гадилеге, пилястра рәвешендәге ордер структурасы кулланылу һәм бизәкләрнең бөтенләй диярлек булмавы б-н аерылып торган «үрнәк» проектлар буенча торгызылалар. К. стиле театрлар, музейлар, китапханәләр, университетлар, храмнар, гыйбадәтханәләр тибындагы биналарны корганда иң көчле үсеш чорын кичерә. К.ның Россия башкалалары архит-расында барган барлык үзгәрешләре Казанда һәм губерналарда да чагылыш таба. Казан өчен регуляр ген. план төзелә (1768, арх. В.И.Кафтырев), шәһәр 50 елдан артык шуның буенча корыла (к. *Шәһәр төзелеше*). Бу чорда Казанда шәһәрнең расланмаган беренче регуляр планын эшләгән арх. А.В.Квасовның торак йортларга нисбәтле К. стилендәге «үрнәк» проектлары барлыкка килә. Әлеге «үрнәк» проектлар буенча беренче йортлар Болак ярлары буенда төзелә. Казандагы әүвәлге К. стиле биналары барокконың кайбер сыйфатларыннан арынып бетми. Аларны К. сыйфатлары булган соңгы барокко стиле яки соңгы бароккога якын К. дип тә карарга мөмкин: *Мәрҗани мәчете*, Дүрт Евангелист чиркәве, *Адмиралтейство конторасы комплексы* һ.б.

Барокко элементларыннан арынгач, К. ордер кагыйдәләрен саклаган катгый, ачык аңлаешлы стильгә әйләнә. И.Е.Старов проекты буенча катгый К. стилендә *Казан Богородица хатын-кызлар монастыре* соборы, *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе* төзелә. *Гостиный двор* К. стилендәге күренекле ансамбльләрдән санала. «Александр дәвере» К.ы *университет шәһәрчеге* ансамблендә чагылыш таба.

Казан губернасында К. стилендә күп кенә дворян утарлары төзелә, иң билгелеләре: Спас өязендәге Антоновка авылында Мусин-Пушкиннар (18 йөз ахыры — 19 йөз башы) һәм Кураловодагы Молостповлар (19 йөзнең 1 нче яртысы) утарлары.

Казанда К. стилендәге беренче һәйкәл 1847 елда университет шәһәрчеге ишегалдында Г.Р.Державинга куела. Триумфаль а́ркалар Иван мәйданында, Мәскәү трактыннан шәһәргә кергән җирдә күтәрелә. К. чорында шәһәргә керү урыннарында ордер формаларын файдаланып капкалар һәм заставалар төзиләр (к. *Себер заставасы*).

Архит-ра өлкәсендә регламент билгеләү гамәле дини корылмаларга да кагыла. 19 йөз



Классицизм. Казан Богородица хатын-кызлар монастыре. Никола Тульский чиркәве. Арх. Я.М.Шелковников. 1810–16. 20 йөз башы фоторәсеме.



Классицизм. Университетның төп корпусы. Казан. Арх. П.Г.Пятницкий. 1822–25. 20 йөз башы фоторәсеме.

башыннан гыйбадәтханәләрнең рәсми расланган «үрнәк» проектлары үз көченә керә. Алар катгый күләмнәре, ордерлы портиклары һәм ярымшар рәвешендәге гөмбәзләре б-н аерылып торалар, еш кына нечкә шпильгә беркетелгән хач б-н тәмамланалар. Чистайдагы Никола соборы, Алабугадагы Покров-Богородица чиркәве һәм Никола чиркәве К.ның дини архит-ра истәлекләреннән санала. К. чорындагы гыйбадәтханәләрнең яңа төре түгәрәк формада була, портиклар һәм люкарналар б-н кушылган пирамида формасындагы корылмалар гыйбадәтханәләр төзелешендә яңалык булып тора (к. *Рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсе*). 18 йөз ахырыннан К. стилендә мәчетләр һ.б. биналар төзелә башлый. *Пороховой бистәсе беренче мәчете*, *Галиев мәчете*, *Зәңгәр мәчет, костёл*, *Казан шәһәр хастаханәсе* мәгълүм. Борынгы Казанның бөтен үзәк өлеше К. чорындагы шәһәр төзелеше истәлекләренә карый. 19 йөзнең уртасыннан эклектика кысаларында соңгы К. стилендәге биналар салу дәвам итә (күбесенчә торак йортлар). Архитекторлар П.Г.Пятницкий, М.П.Коринфский, А.К.Шмидт, Ф.И.Петонди Казанда һәм губернада күренекле осталардан саналалар.

*Әд.:* Е г е р е в В.В. Классицизм в казанском зодчестве. К., 1958; История русской архитектуры. СПб., 1994.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КЛА́УС** Карл Карлович (11.1.1796, Дерпт ш., хәзерге Эстониянең Тарту ш., — 24.3.1864, шунда ук), химик-нәорганик, ботаник, рәссам, фәлсәфә д-ры (1839), Мед.-хирургия академиясе (С.-Петербург, 1850), Петербург (1861) һәм Берлин (1863) ФАләре мөхбир әгъзасы. 1817–21 елларда Саратов шәһәрендә даруханәче, 1821–29 да Казанда даруханә тота. Казан ун-ты профессорлары б-н бергәләп экспедицияләрдә катнаша: 1828 дә А.Я.Купфер б-н — Урал буеның, 1829 да Э.А.Эверсман б-н Идел аръягы далаларындагы үсемлекләр дөньясын өйрәнә. 1831 елдан Дерпт ун-тында укый һәм эшли (1835 тә тәмамлый), Идел аръягы тозлы туфраклы далаларын өйрәнү буенча проф. Ф.Гёбель экспедициясендә катнаша (1834). 1837 дән Казан ун-тының химия лаб-ясе мөдире, проф. (1843 тән). 1851 дән Дерпт ун-ты фармация каф. мөдире. Платиналы металлар химиясенә нигез салучыларның берсе. К. Урал платина рудасын «патша аракысы»нда эреткәннән соң калган матдәнең составын билгели. Пла-

тина төркеме металларын аеруның яңа алымнарын, аналитик реакцияләрне, анализлар методикасын эшли, беренче тапкыр родий һәм иридий тозларының аммиак б-н кушылмаларын ала һәм характерлый. 1844 тә платина рудасы калдыкларында *рутений* элементын ача, аның



К.К. Клаус.

атом массасын билгели, үзлекләрен тасвирлый. Рутений-родий-палладий һәм осмий-иридий-платина өчлекләре арасындагы охшашлыкны күрсәтә, соңыннан ул Д.И.Менделеев периодик законы нигезендә аңлатыла. Платиналы металларны өйрәнгәндә бергә утырымга төшү күренешен күзәтә, аларны чистартуның яңа алымнарын тәкъдим итә. Платиналы металларны өйрәнү буенча фәнгә өлеш керткәне өчен Петербург ФАнең Демидов бүләгенә лаек була (1846). К. — фитохимиягә нигез салучыларның берсе. Аның «Идел буе илләренең җирле флоралары» («Флоры местные Приволжских стран», СПб., 1852) хезмәте 1950 төрдәге үсемлекне тасвирлый; К. исеме, беренче уйлап табучы буларак, үсемлекләр дөньясындагы 8 төр һәм төрчә атамасына керә. Беренчеләрдән булып чагыштырма флористикада микъдари ысуллар куллана (1851). Э.А.Эверсман турындагы истәлекләр, фармация һәм аның тарихы буенча мәкаләләр авторы. Үз гаиләсе әгъзаларының портретларын ясый (майлы буяу), Парижда рәсемнәр сериясен (Казан, Урал заводлары күренешләре һ.б.) бастыра (1833), тәңкә акчалар һәм медальләр коллекциясен туплый, соңыннан Казан ун-ты музеена тапшыра. Рутений ачылуга 125 ел тулу уңаеннан Казан ун-тының иске химия лаб-ясе (хәзер А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты) диварына мемориаль такта куела.

Х е з м.: Избранные труды по химии платиновых металлов. М., 1954.

*Әд.:* К л ю ч е в и ч А.С. Карл Карлович Клаус. К., 1972. *В.Г.Абзалова.*

**КЛЕ́ВЕР** (Trifolium), кузаклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләннәр ыругы. Сабаклары күтәрелә баручы яисә туры, сирәгрәк җәенке, яфраклары өчәрләнгән (кайбер очракта 5–9 яфраклы). Чәчәк оешмасы башлы, таҗы алсу, кызыл, сирәгрәк ак һәм сары төстә. Майдан сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Үзәк тамыр системалы, кайбер очракта бик нык ботакланган. Вак тамырчыкларында бүлбеләр үсә, аларда атм. азотын тотарга сәләтле бүлбе бактерияләре була. Кузагы калын кабыклы, 1–2, сирәгрәк 3–9 орлыклы, гадәттә, җимешендә калган таҗ б-н әйләндереп алынган. Якынча 300 төре, Татарстанда 10 нан артык төре билгеле: песи табан К. (T. arvense), тау К. (T. montanum), шуышма К. (T. repens), гибрид К. (T. hibridum), кызыл К. (T. medium), альп К. (T. alpestre) һ.б. К.ны язгы бөртеклеләр алдыннан чиста килеш яисә люцерна һәм кыяклы үләннәр катнашмасында чәчәләр.



Болын клеверы (кызыл клевер).

1997–2003 елларда чиста чәчүлекләр 25 мең *га* дан 35 мең *га* га кадәр мәйданны били. К. үстерү өчен аз ачылыклы, яхшы яисә уртача культуралаштырылган балчыксыл туфрак кирәк. К. артык дымлы һәм ачы туфракны яратмый. Терлек азыгы өчен чәчүлек нормасы 1 *га* га 12–14 *кг*, орлык өчен 1 *га* га 4–6 *кг*, рәтләр арасын 30 *см* итеп чәчәләр. Уңышы 1 *га* дан яшел масса — 170–180 *ц*, печән — 25–35 *ц*, орлык — 1–1,5 *ц* дан (соң өлгерешле) 2,5 *ц* га кадәр (иртә өлгерешле). ТРда болын К.ының «Казан 1» (1939, бер тапкыр чабыла торган), «ВИК-7» (1988), «Орлик» (2001), «Трио» (2001), «Ранний 2» (2002, ике тапкыр чабыла торган иртә өлгерешле) сортлары чәчелә. Халык медицинасында болын К.ының чәчәкләре, үләне ютәлдән (какырык куптару), тир һәм бәвел кудыру чаралары буларак файдаланыла, ш.у. пешкәндә, эренле шеш булганда, буыннар авыртканда кулланыла. Баллы үсемлек.

**КЛЕМЕНТЕ́ЙКИНО** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 60 *км* көнбатыштарак, Баграж елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 436 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730 еллар тирәсендә Үби авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да миссионерлык мәктәбе (1890 да ачыла), бакалея һәм шәраб кибете, 2 су тегермәне, 2 ашлык саклау-сату кибете, тимерчелек, 3 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1412,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80, 1795 тә — 87 ир-ат; 1870 тә — 406, 1897 дә — 585, 1900 дә — 688, 1913 тә — 805, 1920 дә — 822, 1926 да — 714, 1938 дә — 681, 1949 да — 630, 1958 дә — 711, 1970 тә — 723, 1979 да — 643, 1989 да — 462, 2002 дә — 487 кеше.

**КЛЕТНЁВ** Геннадий Сергеевич (8.2.1944, Казан), махсус машиналар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1986), проф. (1904). 1967 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз Физик-техник һәм радиотехник үлчәүләр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1969–75 тә Казан химия-технол. ин-тында, 1975 тән Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, бүлек башлыгы (1976–86). 1987–89 да Казан химия-фотография сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында лаб. башлыгы. 1989 дан Ульянов шәһәрендә: «Машиналар төзелешендә микроэлектроника һәм автоматлаштыру куллану үзәге» җитештерү комплексында КБ директоры, бер үк вакытта 1990–94 тә Ульянов политехник ин-тында укыту эшендә. 1994 тән Казанда: Казан энергетика ин-тында кичке һәм читтән торып уку ф-ты деканы (1997 гә кадәр), инженерлык графикасы каф. мөдире (1996–99); 2000 елдан «ТИСБИ» Идарә ун-тының информацион технологияләр кафедрасында. Хезмәтләре метрологиягә, махсус технол. җиһазларны матем. модельләштерүгә, ш.у. кеше эшчәнлегенең әйләнә-тирә мохиткә тәэсирен өйрәнүгә карый. Космос шартларында эшләүче электрон җиһазлар өчен монокристаллар үстерүче технол. җайланма булдыра. Уйлап табуга 50 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Разработка новой технологии и аппаратуры с использованием кавитационно-пульсационных акустических эффектов. М., 2000 (автордаш); Физико-химические основы и аппаратурное оформление технологии производства пироксилиновых порохов // Нитроцеллюлозные (пироксилиновые) пороха. К., 2000. Т. 2 (автордаш).

**КЛИБА́НОВ** Григорий Михайлович (31.5.1928, Түбән Новгород ш.), радиофизик, конструктор, Ленин бүләге лауреаты (1978). Горький ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), Казанның оборона пр-тиесендә эшли, тәҗрибә КБ лаб-ясе башлыгы (1955–60), баш инженеры (1960–63). 1963–84 елларда Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында баш инженер урынбасары, бер үк вакытта ген. конструктор урынбасары — баш конструктор. 1984–98 дә Кишинёв «Альфа» телевизорлар з-дында: баш инженер урынбасары, техник директор урынбасары — баш конструкторы (1992 дән). 1998–99 да «Радиофар» коммерция фәнни-тикшеренү фирмасында (Кишинёв). 2000–10 да Казан электротехника з-дында эшли. Төрле билгеләнештәге гидроакустик приборлар төзүдә катнаша. К. җитәкчелегендә икенчел радиолокациягә караган махсус системалы корабль аппаратурасы булдырыла (РФ Хәрби көчләрендә файдаланыла). Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Ленин бүләге радиотехника өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**КЛИКО́ВКА СӨЗӘКЛЕГЕ́**, табигать истәлеге (1987). Югары Ослан р-ны терр-ясендә, Яр буе Моркваш авылыннан көньяктарак урнашкан. Мәйданы 10 *га*. Кликовка инеше



Кликовка сөзәклеге.

үзәне сөзәклегендә бай флоралы далага әйләнгән урын: чәчәкле үсемлекләрнең 185 төре бар, шуларның 15% ы сирәк очрый һәм бетә бара (биек испәрәк, рус төймәбашы, чын башмакчәчәк, йөнтәс каеккузак, ураксыман мәче борчагы, ефәксыман әрем, өч аерчалы күгелҗем ут, каурыйсыман кылган һ.б.). К.с.нең С.И.Коржинский, П.Н.Крылов исемнәренә бәйле 100 еллык тарихы бар.

**КЛИ́МАТ** [грек. klíma — авышлык (кояш нурларының — җир өслегенә)], билгеле бер терр-ягә хас һәм аның геогр. халәте б-н бәйле уртача күпьеллык һава торышы режимы; җирлекнең төп физик-геогр. характеристикаларыннан берсе. Җир шарының әлеге өлкәсендә К.ны барлыкка китерүче өч мөһим процесс — җылылык һәм дымлылык әйләнешләре, атмосфераның гомуми циркуляциясе үзенчәлекләре б-н билгеләнә. К.ның санча характеристикаларын метеорологик зурлыкларның уртача күпьеллык һәм чик күрсәткечләре, ел дәвамында аларның үзгәрү үзенчәлеге билгели. Кайбер елларда һава торышы режимы шактый югары чикләрдә үзгәрергә мөмкин, әмма озак еллар дәвамындагы уртача атм. шартлары бер-берсеннән күпкә аерылмый (гадәттә, бу үзгәрешләр тирбәнешләр характерында бара), ягъни К. билгеле бер тотрыклылыкка ия. К.ны *климатология* өйрәнә.

ТРның К.ы уртача континенталь, җәе җылы, кышы уртача салкын. *Кояш радиациясе*, *атмосфера циркуляциясе* тәэсирендә формалаша. К.ка һәм аеруча *микроклиматка* ш.у. урынның рельефы, үсемлекләр капламы, гидрографик челтәр, ә 20 йөз урталарыннан башлап кешеләр эшчәнлеге дә йогынты ясый. Еллык гомуми кояш радиациясе 3900 *МДж/м²* чамасы һәм терр-я буенча чагыштырмача аз үзгәрә. Еллык радиация балансы 1350 *МДж/м²*, ноябрьдән мартка кадәр аның кыйммәте тискәре. Кояш балкышы бер елга 2000 *сәг.* кә якын һәм Татарстанның төньяк-көнбатышында 1800–1910 *сәг.* тән төньяк-көнчыгышында 2050 *сәг.* кә кадәр үзгәрә. Елның салкын вакытында республика терр-ясе Атлантик океан (Исландия минимумы) һәм Себер (Азия максимумы) һава массалары тәэсиренә дучар ителә, шуңа күрә һава темп-расы көнбатыштан көнчыгышка таба төшә бара. Җылы вакытта (апрель-октябрь) циркуляция процесслары кими, темп-ра режимының формалашуында кояш радиациясе һәм җирле шартларның роле арта. Һаваның уртача темп-расы гыйнварда –14°С чамасы, июльдә 19°С. Абс. мин. –52°С, абс. макс. 40°С. Көзен-кышын, гомумән, ел дәвамында җилләр көньяк һәм көньяк-көнбатыштан исә, җәен төньяк һәм төньяк-көнбатыш җилләре кабатлана. Көчле җилләр ешрак кышкы сезонда күзәтелә. Терр-я буенча җылы көннәр (темп-ра 0°С тан югары) 198–209, салкыннар 156–167 көн дәвам итә. Еллык явым-төшем күләме 460–540 *мм*. Идел алды, Кама алды төбәкләре һәм Кама аръягының көньяк-көнчыгышы дымлырак. Явым-төшемнең 60–70%ы җылы вакытка туры килә. Тотрыклы кар капламы ноябрь ахырында хасил була, кар яту 140–150 көнгә сузыла. Туфракта туң тирәнлеге 74–114 *см*. Зур шәһәрләрнең климатик шартлары тирә-як К.ыннан шактый аерыла. Шәһәр өстендәге һавада антропоген пычрак матдәләрнең (төтен, корым, аэрозоль) артуы атм.ның үтә күренүчәнлеген һәм шуның б-н бергә кояш радиациясе агымын киметә (бу вакытта югалту 20% ка җитәргә мөмкин). Һава бассейнының пычрануы эффектив нурланышны һәм төнге суынуларны киметә, ягулык яндыру хисабына өстәмә җылылык туа, ул, түшәлмә материалларның (асфальт, бетон һ.б.) парга аз әйләндерүчәнлеге сәбәпле, күп тотылмый, шунлыктан шәһәр эчендәге темп-раның күтәрелүенә китерә, ягъни «җылылык утраулары» барлыкка килә. Шәһәр К.ына хас үзенчәлек: төтенле томан (гадәттә, елның салкын вакытында). Йөзмә кисәкчекләрдән һәм су тамчыларыннан торучы гөмбәзсыман тонык томан пәрдәсе үзәк өстендә тотылып тора.

*Әд.:* Смоляков П.Т. Климат Татарии. К., 1947; Климат Татарской АССР. К., 1983; Климат и загрязнение атмосферы в Татарстане. К., 1995.

*Э.П.Наумов, Ю.П.Переведенцев.*

**КЛИМАТОЛО́ГИЯ** (*климат* һәм ...*логия*), Җир шарының климатын, аның формалашу законлылыкларын һәм типларын, геогр. бүленешен һәм вакыт буенча үзгәрешләрен өйрәнүче фән. Атмосфера турындагы геофизика фәне — *метеорология* б-н тыгыз бәйләнештә булуы б-н бергә, К. — шул ук вакытта геогр. фәне дә (физик геогр. бүлеге), чөнки климат — геогр. мохит компонентларының берсе. К. бүлекләре — гомуми К., климатография, палеоклиматология, климат теориясе, аэроклиматология (ирекле атм. климаты). К.нең гамәли тармаклары — биоклиматология, агроклиматология, мед. К.се һ.б.

Климат һәм аның законлылыклары турында башлангыч белем Борынгы Грециядә (Гиппарх) барлыкка килә. 17–18 йөзләрдә инструменталь метеорологик күзәтүләр базасында климатны беренче тасвирлаулар башлана. Россиядә планлы рәвештә климатологик тикшеренүләр император Николай I фәрманы буенча 1849 да ачылган Баш физика обсерваториясендә (оештыру инициаторы һәм беренче директоры А.Я.Купфер) үткәрелә башлый.

Климат мәсьәләләренә *Казан метеорология фәнни мәктәбе* зур игътибар бирә. Казан ун-тының *Метеорология обсерваториясе* директоры Ф.К.Броннерның «Казанские известия» (1815, № 35–36) г-тасында басылган «1814 елда Казанда метеорологик күзәтүләр нәтиҗәләре» («Следствия из метеорологических наблюдений в Казани 1814 года») мәкаләсе — К. буенча беренче фәнни хезмәт. Анда төрле метеорологик зурлыкларның уртача һәм экстремаль күрсәткечләре китерелә һәм анализлана, кайбер Европа шәһәрләренең климат шартлары б-н чагыштыру бирелә. 1825 тә Антарктида экспедициясендә (1819–21) катнашучы И.М.Симоновның «Көньяк һәм Төньяк ярымшарларда темп-ралар аермасы турында» («О разности температуры в Южном и Северном полушариях») мәкаләсе басыла, ул исә, ихтимал, Россиядә әлеге теманы яктырткан беренче мәкалә була. 1829 да «Казанский вестник» ж-лында Н.И.Лобачевский искәрмәләре б-н А.Я.Купферның «Көнчыгыш Россиянең кайбер урыннарында һава һәм туфракның уртача температурасы турында» («О средней температуре воздуха и почвы в некоторых местах Восточной России») мәкаләсе дөнья күрә. Метеорологик күзәтүләр үсешендә һәм аларны берләштерүдә Э.А.Кнорр зур роль уйный. Аерым алганда, ул Мәскәү климатының Казан климаты кадәр кырыс түгеллеген билгели, һава торышын һәм климатны өйрәнүнең кешелеккә зур файда китерүен күрсәтә. 19–20 йөзләрнең беренче яртысында климат тикшеренүләре үсешенә А.С.Савельев, И.Н.Смирнов, И.А.Картиковский, П.Д.Кушников, О.А.Дроздов, П.Т.Смоляков һ.б. өлеш кертә. 20 йөзнең 2 нче яртысында Урта Идел буе (Н.В.Колобов, Е.Д.Федотова), Татарстан (Р.И.Гомәрова, Р.Ш.Иманаева, В.М.Степанова, А.И.Мишкарёв һ.б.), Казан климатын өйрәнүгә бөтен яклап алып барыла. Төньяк ярымшарның тропиктан тыш киңлекләрендә энергетика һәм циркуляция процессларының климат үзенчәлекләре өйрәнелә (Н.В.Колобов, Ю.П.Переведенцев, Р.Р.Хәйруллин, Э.П.Наумов, В.Д.Тудрий, В.В.Гурьянов). 1990 елларда авторлар коллективы (Ю.П.Переведенцев, М.А.Верещагин, Э.П.Наумов, К.М.Шанталинский) тарафыннан соңгы 150 елда төрле гелиогеофизик факторлар йогынтысында климатның глобаль һәм региональ үзгәрешләрен өйрәнү буенча яңа нәтиҗәләр алына. Төньяк ярымшар тропосферасында һәм, гомумән, Җирдә климатның төп параметрлары режимында фәза-вакыт законлылыклары ачыклана.

*Әд.:* Климатология. Л., 1989; Современные глобальные и региональные изменения окружающей среды и климата. К., 1999; Переведенцев Ю.П. Метеорология в Казанском университете: становление, развитие, основные достижения. К., 2001.

*Э.П.Наумов, Ю.П.Переведенцев.*

**КЛИМЕНКО́В** Александр Иванович (19.10.1923, Калинин өлкәсенең хәзерге Весьегонск р-ны Савёлово а. — 29.7.1992, Казан), журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). Ленинград партия мәктәбен (1948), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1957) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944–46 елларда район радиотапшырулар мөхәррире (Калинин өлкәсе), 1948–50 дә «Калининская правда» г-тасы әдәби хезмәткәре һәм үз хәбәрчесе, 1951–54 тә Калинин өлкәсенең «Смена» комсомол г-тасы мөхәррире. 1957–67 дә ТАССР һәм Мари АССР буенча «Известия» (Мәскәү ш.) г-тасының үз хәбәрчесе. 1967–77 дә «Советская Татария» г-тасының баш мөхәррире. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Ш.Н.Мулаянов.*

**КЛИМЕНКО́В** Владимир Александрович (12.11.1945, Калинин өлкәсенең Кесьма а.), инженер-программист, СССРның Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Казан авиация ин-тын (1973), Казан ун-тын (1982) тәмамлый. 1963–66 елларда «Электроприбор» з-дында эшли. 1973–76 да Хисаплау техникасын халык хуҗалыгында гамәлгә кертү ин-тында.

1976–89 да Казан язу җайланмалары з-ды бүлегендә инженер, КБ, бүлек башлыгы. Дәүләт бүләге автоматлаштырылган идарә итү системасын булдырганы өчен бирелә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

**КЛИ́МОВ** Евгений Александрович (11.6.1930, Киров өлкәсенең Вятка Аланы ш.), психолог, пед. фән. д-ры (1968), СССР ПФА академигы (1985; 1974 тән мөхбир әгъза). В.С.*Мерлин* шәкерте. 1953 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1959 дан Һөнәри-техник уч-щеләрнең үзәк укыту-методика кабинеты каршындагы проф. пед. лаб-ясенең Казан ф-лында фәнни җитәкче. 1968 дән Бөтенсоюз проф. техник белем бирү фәнни-тикшеренү ин-тында хезмәт психологиясе бүлеге мөдире (Ленинград), проф. (1970). 1976 дан Ленинград пед. ин-тында психол. каф. мөдире. 1983–2003 тә Мәскәү ун-тының хезмәт психологиясе һәм инженерлык психологиясе каф. мөдире, психол. ф-ты деканы (1986–2000). Хезмәтләре нерв авырулы кешеләрне хезмәт б-н дәвалау, кешенең проф. эшчәнлеге һәм индивидуаль үзенчәлекләренең үзара бәйләнеше, һөнәри ориентациянең психол. нигезләре, дөньяны күзаллау рәвеше һәм үзаңның проф. эшчәнлеккә бәйле булу проблемаларына карый. Россия психол. җәмгыяте президенты (1994 тән). Почёт ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Путь в профессию. Л., 1974; Психолого-педагогические проблемы профессиональной консультации. М., 1983; Как выбирать профессию: Книга для учащихся. М., 1984; Образ мира в разнотипных профессиях. М., 1995; Введение в психологию труда. М., 1998.

*Әд.:* Евгению Александровичу Климову — 70 // Психол. журн. 2000. Т. 21, № 4.

**КЛИ́МОВ** Иван Митрофанович (19.12.1907, Могилёв губ., Климовичи өязе Иловня а. — 28.3.1999, Воронеж ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1962), проф. (1963). Мәскәү тарих, философия һәм әдәбият ин-тын тәмамлый (1939). Смоленск совет-партия мәктәбен тәмамлаганнан соң (1928), Смоленск өлкәсенең Вязьма өязе Липец авылында, ВКП(б)ның Новодугинск райкомында партия эшендә. 1930–31 елларда профсоюзларның Смоленск өлкә советы президиумында сектор мөдире, секретарь. 1933 тән Красноярск краенда: Тойнинск ит җитештерү с-зында сәяси бүлек башлыгы урынбасары, 1935 тән Хиточинск ит җитештерү с-зы башлыгы. 1935–41 дә Смоленск а.х. ин-тында һәм элемтә электротехникумында укыта. 1941 нең июнендә элемтә эл. техникумы директоры итеп билгеләнә, июльдә аны Казанга эвакуацияләүне җитәкли; 1941–43 тә директор урынбасары; 1949–63 тә Казан ун-тында (бүленеп, 1944–48 дә Винница пед. ин-тында, 1954–55 тә Чехословакиянең Карлово ун-тында укыта). 1963–91 дә Воронеж ун-тында проф., 1966–88 дә совет җәмгыяте тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Татарстан АССР, Татарстан партия оешмасы, Бөек Ватан сугышы, Үзәк Кара туфраклы зонада эшчеләр сыйныфы формалашу тарихына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Образование и развитие Татарской АССР (1920–1926 гг.). К., 1960; Татарская партийная организация в восстановительный период (1921–1925 гг.). К., 1961 (автордаш); Фальсификация истории Великой Отечественной войны Советского Союза 1941–1945 гг. буржуазной историографией. Воронеж, 1975; Из истории формирования рабочего класса Центрального Черноземья. Воронеж, 1977.

*Әд.:* Л а п п о Д. Солдат идеологического фронта // Воронеж. ун-т. 1978. 15 марта; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Памяти профессора И.М.Климова // Ист. зап. 2000. Вып. 5.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КЛИМОВИ́ЦКИЙ** Евгений Наумович (10.1.1947, Казан — 25.8.2010, шунда ук), химик-органик, химия фән. д-ры (1989), проф. (2002), ТРның атказ. химигы (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1970), А.М.Бутлеров исем. Химия ин-тында эшли, стереохимия һәм катализ бүлеге мөдире. Хезмәтләре органик кушылмалар стереохимиясенә карый. К. планар фрагментлы («кәнәфи», «ванна», «твист» формалары) җиде һәм сигез буынлы гетероциклләр синтезлый һәм фәзаи төзелешен өйрәнә. Кәнәфисыман булмаган партнёрлар катнашындагы тигезләнешле системаларның конформацион анализы принципларын формалаштыра, конформерларның реакциягә керү мөмкинлеген өйрәнүдә яңа алым эшли. Сулы-нефтьле эмульсияләрне сусызландыру һәм тозсызландыру өчен синтетик деэмульгаторлар тәкъдим итә. Уйлап табуга 8 патенты бар.

Х е з м.: Кинетика реакций конформеров. 1. Новый подход // Журн. общей химии. 1996. Т. 566, № 3 (автордаш); Влияние среды на равновесие стереоизомерных шести- и семичленных циклических кресловидных ацеталей. Роль неспецифических и специфических взаимодействий // Журн. органической химии. 2002. Т. 38, вып. 12 (автордаш); Molecular structure of 2-tert-butyl-2-oxo-1,3, 2,-dioxaphosphepine and its benzo derivative // J. of Molecular Structure. 2004. V. 693 (автордаш).

**КЛИ́НОВ** Александр Вячеславович (22.7.1969, Куйбышев ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2005). 1991 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2006 дан химия технологиясе процесслары һәм аппаратлары каф. профессоры. Хезмәтләре газлы һәм сыек катнашмаларның үзлекләрен молекуляр-статистик тасвирлау алымнарына; химия технологиясе процессларын матем. модельләштерүгә карый. К. күп компонентлы газлы һәм сыек фазалы системаларда термодинамик характеристикаларны, фазалар тигезләнеше шартларын һәм массаны молекуляр күчерү коэффициентын исәпләү алымнарын, молекулаара тәэсирләрне сурәтләүнең төрле модельләре нигезендә эшли. Уйлап табуга патенты бар.

Х е з м.: Расчёт коэффициентов самодиффузии углеводородов в жидкофазном состоянии на основе атом-атомных потенциалов взаимодействия // Теплофизика высоких температур. 2003. Т 41, № 2 (автордаш); Описание фазовых переходов на основе интегральных уравнений для частичных функций распределения (Однокомпонентные системы) // Журн. физ. химии. 2004. Т. 78, № 3 (автордаш); Новый центральный межмолекулярный потенциал для описания термодинамических свойств жидкостей и газов // Вестн. Казан. технол. ун-та 2005. № 1.

**КЛИ́НОВКА** т и м е р  ю л  р а з ъ е з д ы  п о с ё л о г ы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Ульянов–Уфа тимер юлы буенда. 2010 елда 6 кеше (чуашлар, татарлар) яши. 1959 ның 18 ноябрендә торак пункт буларак теркәлә. Оештырылган көннән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1958 дә — 89, 1970 тә — 141, 1979 да — 55, 1989 да — 21, 2002 дә — 17 кеше.

**«КЛИЧ СВОБО́ДЫ»** («Азатлык авазы»), иҗтимагый-сәяси газета. Казан студентлар кооперативы органы. 1917 елның 20 мартыннан 10 апреленә кадәр Казанда рус телендә 3 саны нәшер ителә. Нашире — Казан ун-ты укучы-студентлар җәмгыяте. Газетаның башлангычы кооператив тарафыннан «Бетсен, сугыш!», «Бетсен, хөкүмәт!», «Яшәсен революция!» лозунглары б-н 1917 елның гыйнварында чыгарылган «Клич» гектографик ж-лы була. «К.с.»ның мөхәррирләре — Я.Венецианов, А.Орлик, Н.Пономарёв, А.Попов, И.Цитронблат. Мөхәррирләрдән тыш, газетада Л.Венецианов, П.Драверт, И.Левган, Б.Фридман һ.б. үз язмаларын бастыра. Даими рубрикалар: «Көн кадагы мәсьәләләре», «Безнең дошманнарның тактикасы», «Матбугат (Казан басмалары)», «Профессиональ хәрәкәт», «Чит илләрдә». Газета 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казанда чыккан беренче революцион демократик басма.


г. Казань. Цѣна 7 коп.

КЛИЧ СВОБОДЫ

№ 3 Понедѣльникъ 10-го апрѣля 1917 г.

(ИЗДАНІЕ СТУДЕНЧЕСКАГО КООПЕРАТИВА).

Во вторникъ 11-го апрѣля въ 11 ч. дня въ аудитор. № 1

Состоится Общее Собраніе Членовъ

Казанскаго студенческаго кооператива.

«Клич свободы» газетасы.

«К.с.»ның барлык саннары да Февр. рев-циясе җиңүенә бәйле шатлык хисләре б-н сугарыла. Редакция фикеренчә, Учредительләр җыенын чакыру һәм урыннарда демократик сайлаулар нигезендә яңа шәһәр һәм җирле үзидарә органнары төзү Россиянең республика юнәлешендәге үсешендә беренче адымнар була. Газета Россиянең федератив-демократик төзелеше өчен көрәшә; 27 март санында «Россия составындагы эре һәм вак милләтләргә үз эчке тормышларын үзләре төзергә мөмкинлек бирү» тәкъдим ителә, нәтиҗәдә, аерым «Россия өлкәләре федерациясе (Малороссия, Кавказ, Себер, Төркестан, Идел буе һ.б.) мәнфәгатьләр уртаклыгы б-н кушылган дәүләтләр берлеге булачак», диелә. Басма соц. партияләрнең тактик хезмәттәшлеге һәм социал-демократлар б-н элемтәдә торуның кирәклеге турындагы Мәскәү эсерлар конференциясе резолюциясен хуплый. Сугышны туктатырга чакыра, Петроград Эшче һәм солдат депутатлары Советының «Бөтендөнья

халыкларына» дигән мөрәҗәгатен бастырып чыгара, шуның өчен «*Камско-Волжская речь*» исемле кадетлар г-тасының кискен тәнкыйтенә дучар була. Сугыш мәсьәләсендә оппозициядә торганга, газета чыгудан туктатыла.

*Т.М.Насыйров.*

**«КЛИЧ Ю́НОГО КОММУНА́РА»**, газета; к. «*Молодёжь Татарстана*».

**КЛО́КОВ** Владимир Васильевич (18.5.1937, Мәскәү — 28.1.2010, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1985), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003), Казан ун-тының атказ. профессоры (2007). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1961 дән шунда ук эшли: аэрогидромеханика каф. мөдире (1994–2002), бер үк вакытта механика-матем. ф-ты деканы (1993–96). Хезмәтләре транставыш тизлекле газлар динамикасына, электрохимик форма үзгәртүләрне исәпләүнең гидродинамик алымнарына карый. К. авиация һәм приборлар төзелешендә кулланыла торган үлчәнешле стационар электрохимик форма үзгәртү мәсьәләләрен тикшерү өчен тизлек годографы алымын эшли. Аның металларны үлчәнешле электрохимик эшкәртүне матем. сурәтләү өлкәсендәге тикшеренүләре кире катнаш кырый мәсьәләләр теориясенең аналитик функцияләр өчен кулланылышын киңәйтә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Применение метода прямых для построения профиля по известному годографу скорости дозвукового потока // Тр. семинара по краевым задачам. 1968. Вып. 5; Электрохимическое формообразование. К., 1984; Методы расчёта электрохимического формообразования. К., 1990 (автордаш).

**КЛОЧКО́В** Владимир Васильевич (15.8.1953, Зәй р-ны Бохарай а.), физик-химик, химия фән. д-ры (1992), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1975), шунда ук эшли. Хезмәтләре органик кушылмаларны ТМР-спектроскопия ысулы б-н тикшерүгә карый. К. эремәләрдә 6–12 буынлы карбоһәм гетероцикллар төзелешен билгели. Нитроцеллюлозаның мономер фрагментларының углеродлы спектрларын аерып күрсәтә. Ике үлчәнешле ТМР-спектроскопиясе б-н органик кушылмалар төзелешен билгеләү өчен методик алымнар тәкъдим итә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009).

Х е з м.: Новые аспекты приложения ЯМР к исследованию процессов химического обмена // Успехи химии. 1985. № 10 (автордаш); Влияние среды на термодинамические параметры конформационных превращений в циклах // Журн. общей химии. 1993. Т. 63, вып. 4 (автордаш); The separation of cross-relaxation and exchange in two-site spin systems without resolved couplings // Applied magnetic resonanse. 2002. V. 22, № 4 (автордаш).

**КЛЫЧО́ВА** Гүзәлия Салих кызы (25.10.1961, Буа р-ны Яңа Чәчкаб а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2002), проф. (2004). 1986 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1980–82 дә Буа р-ның «Үзәк» к-зы бухгалтеры. 1986–93 тә Казан а.х. ин-тының бухгалтерлык исәбе кафедрасында эшли. 1994–99 да Төрекмәнстан а.х. ин-тында. 1999 дан Казан аграр ун-тында, аудит каф. мөдире (2003 тән). Хезмәтләре а.х. финанс нәтиҗәләренең бухгалтерлык исәбен реформалауга карый.

Х е з м.: Стандартизация бухгалтерского учёта в сельском хозяйстве. К., 2001; Управленческий учёт в сельском хозяйстве. К., 2001; Основы бухгалтерского учёта. М., 2003.


**КЛЮЧ ТРУДА́** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 9 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 23 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Ширәмәт р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1938 дә — 160, 1949 да — 160, 1958 дә — 127, 1970 тә — 154, 1979 да — 97, 1989 да — 42, 2002 дә — 44 кеше.

**КЛЮЧАРЁВ** Александр Сергеевич (19.2.1906, Казан — 30.3.1972, шунда ук), композитор, музыка-җәмәгать эшлеклесе, фольклорчы, ТАССРның халык артисты (1964), ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939, 1969). 1926 елда Казан музыка уч-щесен фортепиано буенча (О.Родзевич классы), 1932 дә Мәскәү консерваториясен композиция буенча (Р.Глиэр классы) тәмамлый. 1924–26 да Татар театр техникумында музыка бүлеге мөдире; 1926–28 дә Мари драма театры (Йошкар-Ола), 1928–34 тә Мәскәү эшче театрында музыка җитәкчесе; 1934–37 дә Башкорт Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында музыка секторы мөдире, 1937–38 дә Татар радио ком-тында муз. тапшырулар бүлеге баш мөхәррире, 1938–51 дә ТАССР МС каршындагы Сәнгать эшләре идарәсендә музыка фольклоры кабинеты мөдире; бер үк вакытта 1939–40, 1968–70 тә ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле һәм 1940–42, 1951–53 тә Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе.

К.ның иҗаты халык җырларын эшкәртүдән башлап балет һәм симфонияләргә кадәр булган киң жанр формаларын колачлый. Аның театр өчен язган музыкасы муз. фикерләүнең образлылыгы, аңлаешлылыгы, милли төсмерләрнең ачык чагылышы б-н үзенә җәлеп итә (М.Фәйзи пьесасы буенча куелган «Галиябану» спектаклендә, К.Тинчурин пьесасы буенча куелган «Зәңгәр шәл» һәм «Ил» мелодрамаларына музыка һ.б.). Күп кенә җырлары һәм спектакльләр өчен язылган инструменталь әсәрләре мөстәкыйль



А.Ключарёв (уңда) һәм М.Садри. Фольклор материалны эшкәртү. Пластинкага яздыру. 1930.



А.С.Ключарёв.

яши башлый, алар арасында моңлы, тәэсирле лиризмы б-н аерылып торган «Галиябану» симф. сюитасы да (1933) бар. К. халык көйләрен («Әллүки», «Пар ат», «Кара урман», «Агыйдел» һ.б.) эшкәрткәндә, аларга карата сак мөнәсәбәт саклап, үзенә генә хас үзенчәлекле стиль барлыкка китерә. К.ның камил дәрәҗәдә иҗат ителгән фортепиано әсәрләре («Шүрәле», «Этюд», «Токката», «Туган як күренешләре» циклы һ.б.) уку программаларында һәм концерт репертуарларында төп урынны били. Композитор симф. музыкада үзен аеруча жанр-характер планында таныта. «Башкорт биюләре», «Салават» симф. поэмасы, «Урал» һәм җыр материалына нигезләнгән «Татар сюитасы» муз. картиналары матур яңгырашы һәм бай тембры, ачык милли төсмерләргә ия булуы б-н үзенчәлекле. К.ның иҗатында Идел темасы, аның ярларында яшәүче халыклар дуслыгы символы буларак, аерым урын алып тора. Татар симфонизмының бер этабын тәшкил иткән «Идел» лиро-эпик симфониясендә (1955) катлаулы яшәү мохитен фәлсәфи сурәтләү симф. үсеш фабуласы б-н кушылган кайгы, лирик кичереш-уйланулар, дәрт, драматизм, пафос образларында чагыла. К.ның «Тау экияте» балеты социаль мотивлар (халыкның патша самодержавиесенә каршы көрәше) катнашкан башкорт әкиятләренә һәм риваятьләренә нигезләнеп иҗат ителгән (К. б-н Р.Хисамов либреттосы). Тормыш чынбарлыгы фантастик-әкияти образлар б-н үрелеп бара. Башкорт җырларына, биюләренә, инструменталь көйләренә таянып, композитор үзенчәлекле күмәк күренешләр, халыкчан муз. образлар һәм фантастик күренешләр тудыра. Үзенең иҗатында К. классик балет традицияләрен уңышлы дәвам итә, С.Прокофьевның балет иҗаты принципларына да таяна. «Тау әкияте»нең төп үзенчәлеге — үзәк теманың өзлексез үсүе, симфонизациягә тартым булуында. К. — җыр жанры остасы. Аның милли интонацияләргә нигезләнгән җырлары моңлылык, тәэсирлелек, яңа гармоник алымнар, якты лиризм, табигать образларын нечкә чагылдыру б-н аерылып тора: М.Хөсәен шигырьләренә «Идел дулкыннары», «Безнең дусларыбыз», М.Садри шигыренә «Яз җыры» һ.б. Композиторның иҗат стилен көйнең якты милли колориты, гүзәл гәүдәләнеше, яңа гармоник мөмкинлекләрен куллану, тембрлар байлыгы, сәнгати техниканың аңлаешлы булуы, тавыш хәрәкәтләренең төзеклеге билгели. Композитор, башкаручы, музыка өлкәсендә җәмәгать эшлеклесе буларак, К. Татарстан һәм Башкортстанның музыка сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Аның композицияләре ТАССР Җыр һәм бию ансамбле коллективының иҗади үсешенә ярдәм итә. К.ның иҗади мирасының мөһим өлеше халык муз. фольклорын җыю, туплап бастырудан гыйбарәт.

Ул (В.Виноградов һәм М.Садри б-н берлектә) — татар халык җырларының беренче җыентыгы авторы (1941). ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1970).

Төп әсәрләре: С.Сәйдәшев музыкасына нигезләнгән «Наёмщик» операсы (1961), Т.Гыйззәтнең шул ук исемдәге пьесасына Х.Вахит либреттосы; «Тау әкияте» балеты



А.С.К л ю ч а р ё в. «Тау әкияте» балеты. Башкаручылар — Г. Бәширова һәм Р.Садыйков. 1959.

(1951; 2нче редакциясе — 1959), А.Ключарёв һәм Р.Хисамов либреттосы; «Идел» симфониясе (1955); «Галиябану» симф. сюитасы (1933), «Татар сюитасы» (1945); «Башкорт сюитасы» (1955); инструменталь әсәрләр; җырлар; татар һәм башкорт халык җырларына эшкәртмәләр; драма спектакльләренә музыка; инструменталь пьесалар һ.б.

*Әд.:* Д ж а л и л ь М. Татарская советская музыка и композитор Ключарёв // Коммунист. 1933. 30 нояб.; Ш у м с к а я Н. Александр Ключарёв. М., 1962; Народные артисты. К., 1980.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КЛЮЧЕ́ВИЧ** Александр Соломонович (23.1.1903, хәзерге Украина Респ-касы Запорожье өлкәсенең Мелитополь ш. — 1.6.1990, Казан), химик, химия фән. канд. (1941). Казан ун-тын тәмамлый (1928), М.Вахитов исем. Казан май комб-тында эшли (1928–34, 1941–48). 1934–41 һәм 1960–77 елларда Казан ун-тында, 1947–60 та Казан вет. ин-тында (1956 га кадәр нәорганик һәм аналитик химия каф. мөдире). Хезмәтләре нәорганик химиягә, фән тарихына карый. К. металларны электрохимик оксидлаштыру юлы б-н катализаторлар әзерләү ысулын тәкъдим итә. Юу матдәләре һәм майларны эшкәртү сәнәгате үсеше өлкәсендәге тикшеренү нәтиҗәләре «Россиянең матди мәдәнияте һәм халык хуҗалыгы тарихыннан. Борынгы заманнардан 1917 елга кадәр юу чаралары һәм майларны кабат эшкәртү» («Из истории материальной культуры и народного хозяйства России. Моющие средства и переработка жиров с древнейших времён по 1917 г.», 1971) монографиясендә бәян ителә. Казан ун-тының күренекле химиклары турындагы хезмәтләр циклы өчен акад. А.Е.Арбузов исем. истәлек медаленә лаек була.

Х е з м.: История Казанского жирового комбината имени Мулла-Нур Вахитова (1855–1945). К., 1950; Карл Карлович Клаус. К., 1972; Флавиан Михайлович Флавицкий. К., 1978.

*В.Г.Абзалова.*

**КЛЮЧЕ́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Томбарлы елгасы буенда. 2010 елда 23 кеше (руслар, чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1808 дән Рыково буларак билгеле; 1937 дән хәзерге исемен йөртә. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство станциясе, чиркәү, земство мәктәбе эшли; якшәмбе саен — базар, ел саен ярминкә (8–14 ноябрьдә) үткәрелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1731 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 25, 1889 да — 572, 1908 дә — 930, 1920 дә — 956, 1926 да — 1008, 1938 дә — 596, 1949 да — 567, 1958 дә — 309, 1970 тә — 165, 1979 да — 85, 1989 да — 61, 2002 дә — 31 кеше.

**КЛЮЧЕ́ВСКАЯ** Екатерина Петровна (4.11.1947, Казан), сәнгать белгече, сәнгать фән. канд. (1986). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1968), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын тәмамлый (1978). 1968 елдан Якутск шәһәре Рус драма театрында бизәүче-рәссам, 1970–2010 да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда (1983–86 һәм 1991–2006 да бүленеп), 2006 дан — фәнни эшләр буенча директор урынбасары, 1991–97 дә ТР ФАнең «Прометей» фәнни-тикшеренү ин-тында, 1997–2006 да ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында мәдәният бүлеге мөдире булып эшли. Урта Идел буеның музей тупланмалары тарихы һәм сәнгать тормышы, 16 йөзнең икенче яртысы – 20 йөз православие сәнгате һәм Казан рәссамнары иҗаты буенча тикшеренүләр авторы. Музей проектларын фәнни эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Изящные искусства в Казанском университете. К., 2008; Казанская художественная школа. 1895–1917. СПб., 2009; Словарь казанских художников: вторая половина XVI – начало XX века. СПб., 2009; Фрески и иконы Свияжского Успенского собора. СПб., 2009.

**КЛЮЧЕ́ВСКИЙ** Василий Осипович (16.1.1841, Пенза губ., Пенза өязе Воскресенское а. — 12.5.1911, Мәскәү), тарихчы, чыганакларны өйрәнүче галим, историограф, рус тарихы д-ры (1882), Петербург ФАнең хакыйкый, шәрәфле әгъзасы (1900, 1908), яшерен советник (1903). Чыгышы б-н руханилардан. Мәскәү ун-тын тәмамлагач (1865), шунда ук укыта: профессор стипендиаты (1867 елга кадәр), 1879–82 дә доцент, 1882–85 тә экстраординар проф., 1885–97 дә ординар проф., 1897 дән рус тарихы каф. атказ. профессоры. 1866 ның сентябре-декабрендә Казанда булып китә, анда руханилар академиясе китапханәсендә рус агиографиясе буенча иң тулы кулланма булган «Тарихи чыганак сыйфатында изгеләрнең борынгы рус чорындагы тәрҗемәи хәлләре» («Древнерусские жития святых, как исторический источник», М., 1871) фундаменталь монографиясе өчен материаллар җыя. К.ның методологиясе һәм концепциясе нигезендә позитивистик карашлар ята. Ул тарихи процессның, гомуми алгарышның тышкы һәм эчке шартлары үрелеше буларак, закончалыклы күренеш булуы турындагы идеяне эшли, Россия тарихына яңача карау системасын формалаштыра. Күләмле «Рус тарихы курсы»нда («Курс русской истории», 1880 еллар; М. басмасы, т. 1–5, 1904–21) ул Россиянең борынгы заманнардан 19 йөзгә кадәрге тарихи үсеш процессын социологик яссылыкта карый, ш.и. Алтын Урданың Россия үзәкләшкән дәүләте оешуга булган йогынтысын күрсәтә; Мәскәү кенәзләре һәм патшаларының Алтын Урдага, Идел буендагы һәм Себердәге татар ханлыкларына карата сәясәтен өйрәнә; рус халкының Көнчыгыш Европаны колонияләштерү этапларын тикшерә. К. Батыйның Русьны яулап алуы ил өчен милли һәлакәт булган, рус халкы әхлагының һәм үз-үзен тотышының тупаслануына китергән, дип исәпли. Ләкин ул Урда ханнары хакимиятенең уңай якларын да күрә: алар Мәскәү бөек кенәзе хакимиятенең ныгуы һәм рус бердәмлеге үзәге барлыкка килү өчен алшартлар тудырган, дип саный. К. фикеренчә, татарлардан башка феодаль кенәзләр «Россияне кисәкләргә таркатырлар иде». Үткәнне җанлы күренешләрдә сәнгати сурәтләүгә омтылып, галим үзен искиткеч стилист итеп күрсәтә. Аның игътибарны җәлеп итәрлек формадагы, аңлаешлы һәм бай эчтәлекле хезмәтләре бөтен дөньяда Россия тарихы буенча чыгарылган дәреслекләрнең нигезе һәм төп чыганагы булып хезмәт итә.



В.О. Ключевский.

Х е з м.: Краткое пособие по русской истории. М., 1897; Опыты и исследования: Первый сб. статей. М., 1912; Очерки и речи: Второй сб. статей. М., 1913; Отзывы и ответы: Третий сб. статей. М., 1914; Соч.: В 8 т. М., 1956–59.

*Әд.:* В.О.Ключевский: Характеристики и воспоминания. М., 1912; К и р е е в а Р.А. В.О.Ключевский как историк русской исторической науки. М., 1966; Н е ч к и н а М.В. В.О.Ключевский: История жизни и творчества. М., 1974; К а р а г о д и н А.И. Философия истории В.О.Ключевского. Саратов, 1976; Ч е р е п н и н Л.В. Отечественные историки XVIII–XX вв. М., 1984.

*Е.Б.Долгов.*

**КЛЮЧЕ́НКО** Тамара Ивановна (3.3.1938, Украина ССРның Кировоград ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1997), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Харьков китапханә ин-тын тәмамлый (1960). 1955 елдан Харьков шәһәре китапханәләрендә эшли, 1968 дән Ленинград мәдәният һәм сәнгать ин-тында. 1972 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында: китапханә белеме һәм библиография, библиография һәм мәгълүмат та-

рату (1974 тән), информатика (1980 нән) кафедралары мөдире. Хезмәтләре китапхanә-мәгълүмат белемен укыту проблемаларына карый.

Х е з м.: Сборник задач по математическому моделированию библиотечно-информационных процессов. К., 1993 (автордаш); Математизация библиотечного образования. К., 2001.

**КЛЮЧИ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 21 *км* көнчыгыштарак, Кырымсарай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 473 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 60%, татарлар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче чирегендә нигез салына. Тарихи чыганакларда Елховка исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе, сабын кайнату з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 925 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 307, 1889 да — 444, 1920 дә — 503, 1926 да — 547, 1938 дә — 387, 1949 да — 323, 1958 дә — 303, 1970 тә — 272, 1979 да — 448, 1989 да — 450, 2002 дә — 475 кеше.

**КЛЮЧИ́-САП** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 31 *км* төньяктарак, Шура елгасы бассейнында. 2010 елда 305 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Беренче исеме — По Ключу Сап. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-С.та мәчет, 3 җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1366,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Шиньша волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 283, 1897 дә — 551, 1908 дә — 695, 1926 да — 818, 1938 дә — 724, 1949 да — 486, 1958 дә — 524, 1970 тә — 548, 1979 да — 467, 1989 да — 373, 2002 дә — 331 кеше.

**КЛЮЧИ́ЩЕ** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 3 *км* көньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 1710–11 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, күн итек, башмак һәм киез итек өчен агач калып ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе, кибет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1678,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 158 ир-ат; 1859 да — 540, 1897 дә — 640, 1908 дә — 742, 1920 дә — 810, 1926 да — 798, 1938 дә — 452, 1949 да — 376, 1958 дә — 202, 1970 тә — 100, 1979 да — 50, 1989 да — 23, 2002 дә — 10 кеше.

**КЛЮЧИ́ЩЕ** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 15 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы яр буенда. 2010 елда 134 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 81%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Һөнәри-техник уч-ще, китапханә. Чиркәү. Маркиз Паулуччилар утары (19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге). 16 йөз ахырында нигез салына. Халкы башта сарай идарәчелегенеке булып санала, 1690 еллардан алар б-н дворян Нарышкиннар нәселе идарә итә. Игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, йон-тукыма мануһәм бизәк төшерү б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында К.да Иоанн-Предтеча чиркәве (1797–1804 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1879 да ачыла), китапханә-уку залы, механика һәм кирпеч з-длары, җил тегермәне, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1052 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташкабак волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 285, 1782 дә — 303 ир-ат; 1859 да — 581, 1897 дә — 551, 1908 дә — 612, 1920 дә — 779, 1926 да — 343, 1938 дә — 939, 1949 да — 784, 1958 дә — 592, 1970 тә — 706, 1979 да — 572, 1989 да — 377, 2002 дә — 196 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**КЛЮ́ЧНИКОВ В.М. БАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Хуҗасы — нашир, мөхәррир, беллетрист, 1891–1895 елларда Казан шәһәр думасы гласные, типолитохромография тоткан Казан сәүдәгәре Вениамин Михайлович Ключников. 1880 дә ул, Самара губернасы Бөгелмә өязендәге аракы з-дын сатып, Казанда йорт ала, анда типолитохромография, кәгазь кибете һәм китап төпләү остаханәсе урнаштыра. 1881 нең 11 августында ачылган әлеге басмаханә Казандагы иң яхшы басмаханәләрнең берсе була. Анда китаплар, брошюралар, земство һәм шәһәр идарәләре хисапнамәләре, «Казанский биржевой листок», «Казанские новости» һәм «Камско-Волжский край» г-талары басыла. Адреслар һәм визит карточкалары, бланклар, этикеткалар, реклама белдерүләре һ.б. әлеге басмаханәдә эшләнә. Хромолитографиядә олеографик һәм хромолитографик картиналар, иллюстрацияле фәнни басмалар өчен рәсемнәр дөнья күрә. 1900 дә анда тиз басучы 2 басмаханә машинасы, 2 басмаханә станогы, 1 ташбасма машинасы, 3 ташбасма станогы, 1 бостон прессы һәм 328 пот шрифт исәпләнә. 1900 дә — 32 мастер, 1902 дә — 48; 1900 дә — 8 эшче, 1902 дә — 13; 1900 дә — 10, 1902 дә 11 өйрәнчек эшли. Типолитография Казан а.х. күргәзмәсендә көмеш (1886) һәм алтын (1890) медальләр ала. 1906 ның 9 мартында кызына — И.В.Ермолаевага күчә (к. *Ермолаева И.В. һәм аның варислары басмаханәсе*).

Кәгазь кибетендә, галантерея товарлары һәм канцелярия кирәк-яракларыннан тыш, басмаханәләр, ташбасмалар һәм китап төпләүчеләр, рәсемгә төшерүчеләр өчен буяулар, кәгазь һ.б. сатыла.

Ключников ш.у. прозаик («Өч хикәя» — «Три рассказа», 1887; «Чикерткәләр» — «Парочка сверчков», 1892) һәм драматург («Авылда ыгы-зыгы» — «Деревенские переполохи», 1889; «Караңгыны кисә нур» — «Свет сильнее тьмы», 1889) буларак та таныла. 33 нче Казан өяз земствосы җыелышының уч-ще советы эшчәнлеге кысаларында ул Казан губернасында халык мәгарифенең ул чактагы хәле һәм тарихы буенча 3 брошюра төзи. «Казанский биржевой листок» г-тасында Нестор Бугульминский псевдонимы б-н басыла. Ключниковның махсус белеме булмаса да, ул талантлы шәхес була. 1890 еллар башында яшь журналист П.П.Перцовка зур йогынты ясый. 1885–86 елларда «Казанские новости» г-тасының нашир-мөхәррире, 1883 тә «Городской листок» һәм 1883–84, 1890–92 елларда «Казанский биржевой листок» г-таларында нашир вазифаларын башкаручы һәм мөхәррире, 1891 һәм 1904 елларда «Волжский вестник» наширдәше, «1884 ел өчен Казан календаре»ның («Казанский календарь на 1884 год») нашире.

*Әд.:* Памятная книжка Казанской губернии за 1891–92 годы. К., 1892; Вся Казань: Адресная и справочная книга. К., 1899; П е р ц о в П.П. Литературные воспоминания. 1830–1902 гг. М.–Л., 1933; К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

*И.А.Новицкая.*

**КЛЮ́ЧНИКОВ** Олег Романович (7.9.1961, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2005). 1984 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бийск лицеенда (Алтай крае) эшли, химия һәм экология каф. мөдире (1991–96). 1996 дан Казан энергетика ун-тында. Хезмәтләре полимерлар химиясенә карый. К. чиксез каучукларның С-нитроз системалар б-н вулканлашу реакцияләре кинетикасын һәм механизмнарын тикшерә. Чиксез каучуклар һәм 1,3,5-тринитробензол нигезендәге композитларның өч функцияле вулканлашу системасын ача. Гамәли декоратив иҗат өчен композицион материал уйлап таба (Ключников пластилины дип атала). Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Вулканизация непредельных каучуков мононитрозоаренами // Докл. РАН. 2004. Т. 398, № 1 (автордаш); Способ получения и вулканизирующие свойства 1,3,5-тринитробензола // Журн. прикладной химии. 2004. Т. 77, ч. 8 (автордаш); Features of Unsaturated Rubbers Vulcanization by P-Dinitrosobenzene. N.-Y., 2006 (автордаш).

**КЛЮ́ЧНИКОВ** Пётр Иванович (22.2.1922, хәзер Липецк өлкәсенең Тербунск р-ны Сол-

датское а. — 27.6.1983, Казан), генерал-майор (1968). Елец пед. уч-щесен (1939), Ульянов элемтә уч-щесен (1941), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия (Мәскәү, 1952) тәмамлый. 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, взвод командирыннан укчы полк штабы башлыгы ярдәмчесенә кадәрге хәрби хезмәт юлы үтә. 1946–49 да Карпат буе хәрби округы полкында укчы батальон штабы башлыгы урынбасары. 1952 дән Горький, 1953 тән Идел буе хәрби округы штабы оператив бүлегендә хезмәт итә. Пенза өлкәсе (1961 дән), ТАССРның (1966–78) хәрби комиссары. 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

**КЛЮ́ШКИН** Иван Владимирович (29.8.1948, Чистай р-ны Изгар а.), нурлар б-н диагноз куючы, хирург, мед. фән. д-ры (1997), проф. (1997). 1975 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Чистай мед. учреждениеләрендә эшли. 1980–82 дә Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1982 дән Чистай р-н үзәк хастаханәсендә, табиб-травматолог, 1984 тән баш табиб. 1986 дан — Казандагы 2 нче Республика хастаханәсе, 1990 нан Республика мед. диагноз кую үзәге баш табибе. 1994 тән Казан мед. ун-тының кичке укыту бүлегендә хирургик авырулар каф. мөдире, бер үк вакытта Казан мед. академиясенең нурлар б-н диагноз кую лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре баш сөяге һәм терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын, озын куыш сөякләрнең ачык сынуын дәвалау үзенчәлекләренә карый. К. баш сөягенең һәм баш миенең механик зарарлануына компьютер, ультратавышлы томография һәм җылылык чыганагының сурәтен бирүче җайланмалардан файдаланып, нурлар б-н диагноз кую ысулларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Особенности лечения больных с сочетанной травмой черепа и опорно-двигательного аппарата // Лечение сочетанных и множественных повреждений. Л., 1982; Дистрофические поражения позвоночника: лучевая диагностика и лечебная тактика. К., 1998; Лучевые методы исследования в диагностике врождённых аномалий развития позвоночника и спинного мозга // Актуальные вопросы диагностики и лечения больных в клинике. К., 2000 (автордаш).

**КЛЯ́ЧКИН** Григорий (Гирш-Давид) Абрамович (3.11.1866, Минск губ. Несвиж ш. — 1946, Казан), физиотерапевт, невропатолог, мед. д-ры (1897). 1891 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Казан мед. учреждениеләрендә эшли. 1890 да хосусый дәвалау пункты ача (халык телендә «Клячкин хастаханәсе»), 1899 дан директоры, бер үк вакытта Александров хастаханәсе консультанты, 1912 дә хосусый хатын-кызлар фельдшер-акушерлар мәктәбендә эшли. 1917–20 дә Казан хәрби госпитальләрендә табиб-киңәшче. 1920 елларда Казан клиник ин-тын оештыруда катнаша, 1920 дә физиатрия клиникасын җитәкли. 1925–37 дә Казан ГИДУВында физиатрия каф. мөдире, профессоры, бер үк вакытта, 1931–32 дә Казан мед. ин-тында физиатрия курслары мөдире. Казанда физиатриягә нигез салучы. Хезмәтләре су-электр б-н дәвалау ысулларына, кояш нурлары б-н дәвалауның физиол. нигезләренә карый. К. фосфор б-н агуланганда нерв системасында патологик үзгәрешләрне өйрәнә; баш сөягендәге V, VI, VII, IX, X, XI, XII пар нервлары килеп чыгышы һәм үзәк йөреш юллары турында материаллар (тәҗрибә-аналитик тикшеренүләр уздыра) туплый. Казан ун-тының Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте әгъзасы, фәнни мед. ассоциациясенең физиотерапия секциясе рәисе.

Х е з м.: Врачебное применение электрического света. К., 1902; Лечение экстрапульмонального tbc ультрафиолетовыми лучами // Казан. мед. журн. 1927. Т. 23, № 6/7 (автордаш); О бальнеологической реакции // Современная медицина и гигиена. 1928. № 11.

**КЛЯ́ЧКИН** Лев Наумович (15.7.1892, Минск губ. Несвиж ш. — 12.5.1953, Казан), лекарь, физиотерапевт, мед. фән. канд. (1935), ТАССРның атказ. табибе (1945). 1916 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шәһәр земство хастаханәсендә, күз клиникасында эшли, 1918 дән Кызыл Армиядә, 1921 дән Казан ГИДУВының терапия клиникасында, бер үк вакытта (1926–36 да) Уралда Ново-Сергеевск курортында киңәшче, 1931 дән Кызыл Хачның Россия җәмгыяте поликлиникасы һәм Казанда НКВД санчасте табибе. 1935 тән Казан ГИДУВында, 1937 дән физиотерапия каф. мөдире, 1941 дән дәвалау буенча директор урынбасары, 1945–46 да факультет деканы. Хезмәтләре эксперименталь һәм клиник физиотерапиягә карый. К. кыска дулкынлы һәм ультрашәмәхә нурларны, зарарланган үзәктән читтәге нерв системасын дәвалау өчен аларны куллануны өйрәнә; хәрби имгәнүләр, җәрәхәтләрне дәвалауда физиотерапия ысулларын тәкъдим итә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение экстрапульмонального tbc ультрафиолетовыми лучами // Казан. мед. журн. 1927. Т. 23, № 6/7 (автордаш); Физиотерапия в условиях участка // Медицина. 1929. № 12.

*Әд.:* Клячкин Л.Н.: Некролог // Красная Татария. 1953. 14 мая.

**КЛЯШТО́РНЫЙ** Сергей Григорьевич (4.2.1928, Гомель ш., Белоруссия ССР), тарихчы, тюрколог, тарих фән. канд. (1963), проф. (1992). Ленинград ун-тын тәмамлый. 1950–57 елларда Бөтенсоюз геол. ин-тының мәгълүмат-библиография бүлеге мөдире, 1957 дән РФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Петербург ф-лында, 1964 тән төркиләрне һәм монголларны өйрәнү секторы мөдире. Хезмәтләре төрки халыкларның тарихына, мәдәниятенә һәм тел белеменә, Үзәк Азия рун язуларын (Монголия, Тува, Көньяк Себер), китап ядкәрләренең борынгы төрки телен өйрәнүгә карый. «Татарлар тарихы» («История татар», т.1, 2002) китабы мөхәррирләренең һәм авторларының берсе.

Х е з м.: Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964; Государства и народы евразийских степей. СПб., 2000 (автордаш); История Центральной Азии и памятники рунического письма. СПб., 2003.

**КМИЗ**, к. *Казан медицина инструментлары заводы*.

**КМПО**, к. *Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе*.

**КНИА́Т**, к. *Казан авиация технологиясе фәнни-тикшеренү институты*.

**КНИТИ́ ВТ**, к. *Казан хисаплау техникасы институты*.

**КНО́БЛОК** Андрей Борисович (25.6.1938, Мәскәү), театр рәссамы, нәкышьче, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын тәмамлый (1963). Рәссамнар берлеге (1966), Театр эшлеклеләре берлеге (1976) әгъзасы. 1970–89 елларда Казан театрларында эшли. Татар опера һәм балет театрында этисе, театр һәм кино рәссамы Б.Г.*Кноблок* б-н берлектә Ә.Бакировның «Су анасы» (реж. И.Смирнов, 1970), Н.Җиһановның «Ике риваять» (реж. Д.Арипова, 1971) балетларын бизи. Соңрак К. 30 га якын спектакль бизи, алар арасында — М.П.Мусоргскийның «Борис Годунов» (реж. В.Дмитров, 1979), Җ.Фәйзинең «Башмагым» (реж. Н.Даутов, 1986),


1


2


3

А.Б.К н о б л о к. 1. Р. Паулс музыкасына «Кэрри туташ» балеты декорациясе эскизы. Картон, темпера. 1982. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Фреска». 2000; 3. «Барселона. Порт». 2001.

Ф.Яруллинның «Шүрәле» (реж. К.Рассадин, 1985), Р.Щедринның «Канатлы ат» («Конёк-Горбунок») (реж. Л.Исхакова, 1975) әсәрләре һ.б. К.ның сәхнә бизәлешенә 20 йөз башы рус романтик нәкышьле театр сәнгате принципларын куллану хас. Аппликацияле-нәкышьле җиңел челтәрле пәрдә, декоратив панно-коллажлар, уемтыклы транспарант декорацияләр куллану сәхнә фәзасын һәрчак яңача төзергә мөмкинлек бирә. Бер үк вакытта рәссам сурәтләнүче чор стиленең характерлы билгеләренә таяна, өс киеменең һәр детален җентекләп сайлый һәм гомумиләштерә, спектакльнең сүлпән фонын тәшкил иткән декорацияне көчле сәнгати образга әверелдерә. Татар акад. театрында К. 7 спектакльне, ш.и. Н.Исәнбәтнең «Качаклар» (реж. М.Сәлимҗанов, 1981), Т.Миңнуллинның «Моңлы бер жыр» (реж. М.Сәлимҗанов, 1981), Г.Камалның «Бәхетсез егет» (реж. П.Исәнбәт, 1984), Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» (реж. М.Сәлимҗанов,1990) һ.б.ны бизи. Бер үк вакытта К. станлы нәкышь сәнгатенең пейзаж, натюрморт, сынлы композицияләр жанрларында да эшли: «Тәрәзә төбендә розалар», «Көнбагышлар», «Мәскәүдәге кечкенә ишек алды» (барысы да — 1999) һ.б.

«Россия рәссамнары — Мәскәүгә» (Мәскәү,1998), «Акванәкышь» (Мәскәү, 2003) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша.

*Р.Р.Солтанова.*

**КНО́БЛОК** Борис Георгиевич (6.4.1903, Мәскәү — 4.2.1984, шунда ук), театр рәссамы, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1955). ВХУТЕИНда (Югары дәүләт сәнгать-техника ин-ты) К.А.Коровин һәм П.М.Шухминда (1919), рәссам В.Н.Яковлев студиясендә (1926) укый. 1927–33 елларда, хәрби хезмәттә булган хәлдә, газета һәм журнал графикасы, плакат иҗат итү б-н шөгыльләнә, «Центрсоюз», «Изогиз» нәшриятларында эшли. 1934 тә театр рәссамы буларак эшли башлый, соңрак реж. Н.П.Охлопков тарафыннан Реалистик театрга (Мәскәү) чакырыла; 1941–44 тә Кече театрда баш рәссам, ш.у. Е.Вахтангов исем., Ленсовет исем. театрларда эшли. 1945–48 елларда Новосибирск опера һәм балет театрында, 1948 дән Үзәк балалар театрында баш рәссам, бер үк вакытта цирк, кинематограф рәссамы; VI Бөтенсоюз яшьләр һәм студентлар фестивалендә (Мәскәү) баш рәссам була. Татар опера һәм балет театрында (улы А.Б.*Кноблок* б-н берлектә) «Алтын тарак» («Су анасы», 1970, Ә.Бакиров музыкасы; Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1973) һәм «Ике риваять» (1971, Н.Җиһанов музыкасы) балетларын бизи. Спектакльләрне сәнгатьчә бизәүдә татар халык сәнгатенең бизәлеш ысулларын киң файдалана. «Су анасы» һәм «Ике риваять» балетларына ясалган декорацияләр буяуларның җетелеге һәм ачыклыгы, татар риваятьләре һәм ышануларының әкияти атмосферасын көчле һәм төгәл итеп бирә белүе б-н игътибарга лаек. Бөтенсоюз театр, кино, телевидение рәссамнары күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе Мәскәүдә (1963) уздырыла. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1948).



Б.Г.Кноблок, А.Б.Кноблок. М.П.Мусоргскийның «Борис Годунов» операсына декорация эскизы. Картон, темпера. 1979.

Әсәрләре М.И.Глинка исем. Дәүләт музыка культурасы музеенда, А.А.Бахрушин исем. Дәүләт театр музеенда саклана.

*Әд.:* Луцкая Е. Кноблок сегодня // Сцена. 2003. № 2 (24); Театральная энциклопедия. М., 1966. Т. 3. *Р.Р.Солтанова.*

**КНОРР** Эрнест Августович (23.11.1805, Герцберг ш., Германия — 1879, Дрезден ш.), физик, физик географ, философия д-ры (1830). Берлиндагы Иоахимсталь гимназиясендә укыта. 1832–46 елларда Казан ун-ты профессоры; 1846 да Изге Владимир ун-тына (Киев ш.) күчерелә, бер үк вакытта, 1855–58 дә Затлы нәсел кызлар ин-тында физика укыта. Хезмәтләре магнит һәм метеорология күренешләрен өйрәнүгә карый. К. Казанда һәм Казан уку-укыту округында метеорологик күзәтүләрне үстерүгә мөһим өлеш кертә. Ул эшләгән елларда физик һәм химик тикшеренүләр өчен аерым бина төзелә, бина түбәсенә корылган метеорологик обсерваториядә К. уйлап тапкан үзьязгыч термометр да була. 1858 дә ялга чыгып, Дрезденда яши.

Хезм.: Выводы из барометрических и термометрических наблюдений в 1828–1833 гг. на метеорологической обсерватории Казанского университета. К., 1833; Речь о пользе непрерывных метеорологических наблюдений. К., 1840.

*Р.Г.Усманов.*

**КНО́РРЕ** Евгений Павлович (18.1.1902, Пенза губ. Неклюдовка а. — 21.3.1986, Саратов өлкәсе Энгельс ш.), урман белгече, зоолог, биол. фән. канд. (1949). Казан а.х. һәм урманчылык ин-тын тәмамлаганнан соң (1929), Боровая урман тәҗрибә станциясендә (Оренбург өлкәсе), бирредә Бозаулык наратлыгы үзенчәлекләрен өйрәнә, «Бозаулык наратлыгы» урман саклаулыгын оештыру инициаторы һәм проекты авторы, фәнни бүлек мөдире. 1948 елда дөньяда беренче булып поши фермасы оештыра (Печора-Илыч саклаулыгы), аны 1962 гә кадәр җитәкли. 1962–67 дә Идел-Кама саклаулыгында эшли, саклаулык күрсәткечен төзүчеләрнең берсе. Васильево урманчылыгы терр-ясендә (Яшел Үзән р-ны) Европаның урта полосасындагы иң зур (300–400 оя) колонияләрнең берсе булган соры челән колониясен (1983 тә табигать истәлеге булып билгеләнә) тасвирлый (1977). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Бузулукский бор. Чкалов, 1940 (автордаш); Опытная лосеферма. Сыктывкар, 1956; Экология лося // Тр. Печоро-Илычского гос. заповедника. 1959. Вып. 7.

*Әд.:* Гаранин В.И. Казанская школа экологов (А.А.Першаков и его окружение) // Татарстан. 1996. № 5; шул ук. Евгений Павлович Кнорре (к 100-летию со дня рождения) // Тр. Волжско-Камского гос. природного заповедника. 2002. Вып. 5. *В.И.Гаранин.*

**КНПО ВТИ**, к. *Казан хисаплау техникасы һәм информатика фәнни-җитештерү берләшмәсе.*

**КНУБОВЕ́Ц** Самуил Яковлевич (2.10.1929, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1977). 1953 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук, соңрак Казан мед. учреждениеләрендә эшли. 1962–64, 1967–80 дә Казан мед. ин-тында. 1964–67 дә һәм 1980–2000 дә Республика клиник хастаханәсендә. Хезмәтләре үт юллары хирургиясендә рентгеноманометрия һәм эндоскопия куллануга карый. К. папиллосфинктеротомия өчен зонд тәкъдим итә, холециститның катлаулы формаларында оператив катнашуны клиник-эксперименталь рәвештә нигезли.

Хезм.: Хирургическая тактика при операциях на жёлчных протоках по поводу холецистита и его осложнений // Актуальные вопросы гастроэнтерологии. К., 1969; Клинико-экспериментальное обоснование оперативных вмешательств на терминальном отделе желчного протока при осложнённом холецистите: Дис. .... К., 1976; Билиодигестивное шунтирование // Хирургия. 1982. № 1.

**КНУБОВЕ́Ц** Яков Самуилович (15.2.1902, Минск губ. Лемешевичи а. — 1981, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1967). 1943 елда Казан мед. стоматология ин-тын тәмамлагач, шунда ук, бер үк вакытта Казан ГИДУВының стоматология кафедрасында (1950–58) һәм Казан мед. ин-тында (1957–70) эшли. Хезмәтләре яңак протезлары әзерләү технологиясенә, теш-яңак системасы иннервациясенә карый.

Хезм.: Влияние раздражения периферических нервов на развитие дистрофических процессов в зубочелюстной системе: Дис. ... К., 1966; Вопросы стоматологии. К., 1971.

**КНЯГИ́НИНО РАЙОНЫ́**, *Түбән Новгород өлкәсенең* үзәк өлешендә урнашкан. 1944 елда оештырыла. Мәйданы — 769 *км*². Үзәге — Княгинино шәһәре (Түбән Новгород шәһәреннән 120 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 11,9 мең кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, 341 татар (1779 да — 102, 1859 да — 1281, 1970 тә — 914, 1998 дә — 425 кеше). Татарлар К.р. терр-ясендә 15–16 йөзләрдә төпләнә башлыйлар, алар Ыргу авылында тупланып яшиләр (беренче тапкыр 1617 дә телгә алына; рус чыганакларында Ырга, Бакаево-Ивакаево исемнәре б-н дә билгеле). 1930 елларга кадәр К.р. терр-ясендә 3 мәчет һәм 1 мәдрәсә эшли. 1933 дә җидееллык татар милли мәктәбе ачыла. 1990–95 тә Казаннан радиотапшырулар трансляцияләнә. Хәзерге вакытта авылда мәчет бар (1992 дән), тулы булмаган урта мәктәп эшли, анда татар теле фән буларак укытыла.

*Әд.:* Булатов И.Ф. Урга: Прошлое и настоящее. Сергач, 2000.

**КНЯГО́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 14 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 134 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе (1870 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 834,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 276, 1897 дә — 450, 1908 дә — 441, 1920 дә — 408, 1926 да — 413, 1938 дә — 397, 1949 да — 317, 1958 дә — 326, 1970 тә — 346, 1979 да — 343, 1989 да — 186, 2002 дә — 161 кеше.

**КНЯЖА́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 11 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 157 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 71%, татарлар — 29%) яши. А.х. химиясе сәнәгате пр-тиесе. Клуб. 1565–67 еллардан Мемер исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1903 тә ачыла), су тегермәне, тимерчелек, 3 зур һәм 2 кечкенә вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 570 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 320, 1897 дә — 432, 1908 дә — 400, 1920 дә — 387, 1926 да — 413, 1949 да — 267, 1958 дә — 266, 1970 тә — 301, 1979 да — 289, 1989 да — 272, 2002 дә — 196 кеше.

**КНЯ́ЗЕВ** Сергей Львович (12.9.1908, Дон гаскәре өлкәсенең 2 нче Дон округы Түбән Курмояр станицасы — 31.12.2002, Казан), партия эшлеклесе. Грозный нефть ин-тын тәмамлый (1940). 1940–42 елларда ВКП(б)ның Чечен-Ингуш өлкә ком-ты инструкторы, 1942–43 тә секретаре; 1943–48 дә — Грозный өлкә ком-ты секретаре урынбасары, 1948–49 да бүлек мөдире. 1949–74 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында: 1949–56 да нефть сәнәгате бүлеге мөдире, 1956–60 та, 1963–74 тә секретаре. 1960–63 тә Татарстан икътисади адм. р-ны ХХС рәисе. Татарстанда нефть сәнәгате барлыкка килүгә һәм аны үстерүгә күп көч куя. Нефтьне эзләү, табу һәм эшкәртү тарихына караган китаплар авторы. 1951–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе ордены, дүрт Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефть Татарии: Страницы истории. К., 1981; Нефть Татарии: Путь к большому будущему. К., 1984.

**КНЯ́ЗЕВА** Ольга Николаевна (9.8.1954, Казан), спортчы (фехтование — рапира), СССРның атказ. спорт остасы (1976), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). «Динамо» физкультура һәм спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренеры — В.В.*Житлов*. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1979). СССР (1976, команда беренчелеге), дөнья (1974–75, 1977–78, команда беренчелеге), (1974–78, шәхси беренчелек), Олимпия уеннары (1976, команда беренчелеге) чемпионы. Дөнья чемпионатларында (1973, яшүсмерләр арасында, шәхси беренчелек; 1973, команда беренчелеге) көмеш медаль ала. Европа кубогы (1973–78, команда беренчелеге), дөнья кубогы (1975, шәхси беренчелек) иясе. 1971–73 тә, 1983–84 тә «Динамо» (Казан) физкультура спорт җәмгыятендә, 1973–83 тә ТАССР Физкультура, спорт һәм туризм буенча дәүләт ком-тында инструктор. 1984–91 дә 3 нче Олимпия резервындагы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Казан) тренер-укытучы, 1991 дән Казан финанс-икътисад ин-тында укытучылык эшендә.

**КНЯ́ЗЕВО** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Буклы елгасы буенда. 2010 елда 200 кеше (руслар, татарлар) яши. Крахмал-патока з-ды. Мәдәният йорты. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Марьина Пустошь исеме б-н дә билгеле. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урман кисү, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Никола чиркәве (1905–10 да төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1882 дә ачыла), җил тегермәне, поташ з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 633 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 982, 1897 дә — 615, 1913 тә — 732, 1920 дә — 742, 1926 да — 463, 1938 дә — 458, 1958 дә — 360, 1970 тә — 313, 1979 да — 453, 1989 да — 356, 2002 дә — 140 кеше.

**КНЯЗЬКО́В** Иван Иванович (19.7.1873, Рязань губ. Солотча а. — август, 1942, Казан), нәкышьче. Крәстияннәр катлавыннан. Сынлы сәнгатьтәге беренче күнекмәләрен икона язучыдан ала. 1916 дан — Казанда, Алафузовлар ф-касында эшли. 1920–23 елларда Казан ирекле сәнгать остаханәләрендә П.П.*Беньковта* укый, бер үк вакытта кантон декоратив нәкышь остаханәсендә В.С.Щербаковка ярдәм итә, рев-ция хәрәкәте эшлеклеләренең портретларын ясый. Казан мәктәпләрендә (1931–35), авыл хуҗалыгы техникумында һәм финанс-икътисад ин-тында (1937–38), сәнгать уч-щесендә (1939–40), төзүче-инженерлар ин-ты рабфагында (1940–41) рәсем дәресләре бирә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936). 1920 елларда К., нигездә, көнкүреш жанрында эшли: «Клирошанка», «Татреспубликада ачлык» (1922), «Авыл митингы» (1923), «Казанда татар базары» (1926), «Кызыл Армиягә алу (мед. тикшерүе)» (1936). 1930 елларда Татарстанда тарихи нәкышь сәнгате формалашуга һәм үсешенә лаеклы өлеш кертә. Үзенең картиналарында илнең 16–20 йөзләр тарихыннан киң темалар панорамасына мөрәҗәгать итә: «Казан Кремле. 1552 ел» (1925), «Пугачёв Казанда» (1926), «Степан Разин Иделдә» (1931), «Казан постаучыларының патша Николай I гә үтенеч тапшыруы» (1936 еллар тирәсе), «1905 елда Казандагы православие һәм мөселман руханиларының бергәләшеп котырту чыгышлары» (1940). Казан рәссамнарыннан беренчеләрдән булып, В.И.Ленинның Казанда революцион хәрәкәттә катнашуы темасына мөрәҗәгать итә («В.И.Ленин Казан университетындагы сходкада», 1940). К. нәкышь чаралары б-н кульминацион мизгелләрне һәм үзәк персонажларның образларын калку итеп күрсәтүе нәтиҗәсендә, сюжет драматургиясен, күп фигуралы күренешләрнең динамикасын оста бирә белә. Аның әсәрләренә еш кына картиналарның гомуми эскизлылыгын тулыландыручы хисләр байлыгы, төсмерләр һәм төсләрнең контрастлылыгы хас.

2 нче Дәүләт нәкышь, скульптура һәм графика (Казан, 1921), ТатАХРРның 4 нче картиналар, скульптура, архит-ра һәм графика (Казан, 1925), АХРРның 8 нче «СССР халыкларының тормышы һәм көнкүреше» (Ленинград, 1926), АХРның 11 нче «Сәнгать массаларга» (Мәскәү-Ленинград, 1929) күргәзмәләрендә һ.б. катнаша. Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.





И.И. К н я з ь к о в. 1. «Казанны яулап алу». 1930 еллар; 2. «Иван Грозныйның Казанга керүе». 1930 еллар. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.



М.В.Кобчикова.



И.Г.Кобяков.

**КО́БЕЛЕВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. Йомышлы татарлар нәселеннән. Икмәк сәүдәсе б-н кәсеп итәләр, Казан губернасы Мамадыш өязендә, Нократ губернасы Малмыж өязендә бакыр кою заводлары була. Бертуган **Афанасий Иванович** (1724–1796 соң) һәм **Иван Иванович** (1737–1811 соң) — Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре. Афанасий Иванович шәм һәм тире эшкәртү заводлары, ш.у. Болакның сулъяк ярындагы агач өй һәм ташпулат хуҗасы. 1768 гә кадәр Сенат әмере б-н Казан губернасы канцеляриясенең яшерен эшләр бүлегендә татарчадан тәрҗемә итүче вазифасын башкара. Иван Иванович Пыжма бакыр кою һәм башка з-дларның хуҗаларыннан берсе. Икмәк б-н сәүдә итә. Воскресенская урамында таш өе була. Казаннан депутат буларак, Яңа кануннар эшләү комиссиясе эшендә катнаша (1767–69), Казан татарларының шәһәрдә сәүдә итүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итүләрен кире кагучылар ягында була. 1782–84 елларда Казан шәһәре башлыгы. **Иван Афанасьевич** (1752–1809 дан соң) Казанның 3 нче гильдия сәүдәгәре, хезмәте б-н танылган шәхес (1791), Пыжма бакыр кою, Мамадыш һәм Малмыж өязләрендәге заводларның хуҗаларыннан берсе. 1779–81 дә Казан шәһәр магистраты бургомистры. 1781 һәм 1784 тә вөҗдан мәхкәмәсенә судья һәм Казан шәһәр магистратына утырышчы итеп сайлана. 19 йөздә К. нәселенең абруе төшә.

Чыг.: Достойны памяти потомков. Городские головы Казани 1767–1917 гг.: Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* Агафонов Н. Казань и казанцы. К., 1906. Кн. 1. *Л.М.Свердлова.*

**КОБЛО́В** Яков Дмитриевич (1876, Оренбург губ. — ?), дин галиме, миссионер, педагог, илаһият магистры (1905). 1901 елда Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, мөселманнарга һәм мәҗүсиләргә каршы эш алып баручы миссионер. Е.А.*Малов* һәм М.А.*Машанов* шәкерте. 1908 дән — Казан губернасының Казан өязе халык уч-щесе, 1914 тән — Киев уку-укыту округы инспекторы. Соңгы язмышы билгесез. Хезмәтләре татар дини мәгариф тарихы, татарларда ислам, мариларда мәҗүсилек үсеше, ислам белеменә карый. «Казан татарларында конфессиональ мәктәпләр» (1916) китабында К. татар җәдиди мәктәпләренең торышын җентекләп сурәтли, халык мәгарифендә ислам һәм мөселман руханиларының ролен анализлый.

Хезм.: Антропология Корана в сравнении с христианским учением о человеке // Миссионерский противомусульманский сборник. К., 1905. Вып. 23; Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе. К., 1908. *Е.В.Липаков.*

**КО́БЧИКОВА** Марина Всеволодовна (21.8.1941, Казан), драма актрисасы, педагог, ТРның халык артисты (1995). 1962 елда Мәскәү Дәүләт театр сәнгате ин-тын (А.А.Гончаров һәм Б.И.Равенскихлар курслары) тәмамлаганнан соң, Казан Зур драма театрына кабул ителә. Катерина («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Ника («Сау булыгыз, егетләр», Б.Балтер, В.Н.Токарев), Варя («Күтәрелгән чирәм», М.А.Шолохов романы буенча), Наташа («Мәхәббәт турында 104 бит», Э.С.Радзинский), Лика («Минем бичара Маратым», А.Н.Арбузов) кебек беренче рольләреннән үк актрисага хас әчке динамизм, сәхнәдәге вакыйгалар киеренкелеген саклый белүе, көчле, ярсу темпераменты күзгә ташлана. Павла («Зыковлар», М.Горький) ролендә К.ның катлаулы, каршылыклы характер тирәнлегенә үтеп керә белү осталыгы, күп мәгънәгә ия булган чишелеш игътибарны җәлеп итә. К. башкаруында Геля («Варшава мелодиясе», Л.Г.Зорин) һәм Анисья («Төшемле төпкелдә», Д.Н.Мамин-Сибиряк) образларының нечкә психологизм б-н сугарылганлыгы, лирик дулкынлану б-н драматик кискенлекнең бергә үрелеп баруы, Дилбәр («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин) һәм Анка («Министр ханым», Б.Нушич) образларында жанрны нечкә тоемлавы, социаль характеристиканың катгыйлыгы күзгә ташлана. 1971–80 елларда Львов Сов. Армиясе драма театрында эшли. Казан Зур драма театры сәхнәсенә кайткач, шактый тәҗрибә туплаган булуын, катлаулы характерларны тирән аңлап башкара белү осталыгына ирешкәнлеген раслый. К.ның Елизавета («Патша авы», Л.Г.Зорин), Абби («Карамалар төбендәге мәхәббәт», Ю.О'Нил), Кыз («Барысы да бетте», Э.Олби), Анна Андреевна («Ревизор», Н.В.Гоголь), Валентина («Конкурс», А.М.Галин) кебек рольләре актриса иҗатының колачлылыгын, ул кулланган төсләрнең гаҗәеп төрлелеген, ул тудырган образларның масштаблылыгын, аларның социаль асылын тиешле дәрәҗәдә яктырта алуын, автор әйтергә теләгән төп фикерне җиткерә белүен дәлиллиләр. 1986 дан Казан театр уч-щесендә укыта.



М.В.Кобчикова Катерина («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский; сулда — Е.А.Кузин) ролендә.

*Әд.:* Золотарёв Е. Наша она, казанская // Театральная жизнь. 1967. № 13; Данилова Г. Пути, которые мы выбираем // Театральная жизнь. 1968. № 5. *Ю.А.Благов.*

**КОБЯКО́В** Иван Григорьевич (21.1.1917, хәзерге Брянск өлкәсенең Суземка р-ны Красная Слобода а. — 2.12.1993, Казан), генерал-майор (1966), Сов. Союзы Герое (22.8.1944). Медицина техникумын (Орджоникидзе ш., 1936), Ленинград укчы-пулемётчылар уч-щесен (1941), Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең И.В.Сталин исем. Бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләр хәрби академиясен (Мәскәү, 1948) тәмамлый. Совет-фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында мотоукчы батальоны командиры, Бобруйск тимер юл станциясе һәм шәһәр тибындагы Марьина Горка посёлогы (хәзер Белоруссия Респ-касы) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1948 елдан Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара. 1963–76 да Казан югары танк командирлары уч-щесе һәм бер ук вакытта Казан гарнизоны башлыгы. 1971–75 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Марьина Горка шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КОВАЛЕ́ВСКАЯ-ШӘКУ́РОВА** Сара Вакыйф кызы (16.3.1933, Казан), гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, зәргәр. Зәргәрчеләр нәселенә (В.О.Ковалевский, Е.В.Ковалевская, О.В.Ковалевская) нигез салучы. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1954). 1950–70 елларда рәсем һәм сызым дәресләре укытучысы, бизәүче-рәссам, 1968–70 тә ТАССР Жирле сәнәгать министрлыгының Проектлау-конструкторлык бюросында рәссам-конструктор, 1971–88 дә Казан оптика-механика з-дындагы мәдәният сараеның сәнгать студиясендә эшли. 1968 дә Түбән Новгород өлкәсенең Вачский р-ны Казаково авылындагы сәнгать эшләнмәләре з-дында һәм Красносельский ювелир кәсепчелек пр-тиесендә (Кострома өлкәсе Красное а.) курсларда укый, җепкырлы ювелир технологиясен үзләштерә.

К.-Ш. татар күпертмә җепкырының тиңдәшсез техникасын яңартуга сизелерлек өлеш кертә, татар зәргәрчелек сәнгатенә хас бизәкләр иҗат итә. Аның эскизлары һәм үрнәкләре буенча 1960 еллар ахыры — 1970 еллар башында милли стильдәге ювелир эшләнмәләр, хатын-кыз бизәнү әйберләре (йөзек, муенса, кадама-бизәк) сериялап чыгарыла башлый. «Малахит» (алкалар һәм муенсалар; көмеш, малахит, 1979), «Алтынчәч»





С.В. Ковалевская-Шәкүрова. 1. «Малахит» гарнитуры. Көмеш, малахит, җепкыр. 1979. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Күбәләк» гарнитуры. Көмеш, фирәзә. Күпертмә җепкыр. 1980; 3. «Чәчәк ату» . Көмеш, фирәзә, гранат. Җепкыр, глиптика. 1989.

(муенса һәм алка; яссы һәм күпертмә җепкыр, фирәзә, ахак, көмеш, 1983), «Чәчәк ату» (алка һәм муенса; җепкыр, глиптика, көмеш, гранат, фирәзә, 1989) гарнитуралары; «Кышкы тәрәзә» алкасы (җепкыр, көмеш, кара ахак, 1980), «Кара бөрлегән» беләзеге (җепкыр, көмеш, гранат, 1983) авторы. К.ның әсәрләре югары профессиональлек һәм башкару нәфислеге б-н аерылып тора, аларда металлның шома өслеге (көмеш, мельхиор) һәм асылташларның (ахак, фирәзә, лазурит, яшма) үзара ярашуына нигезләнгән милли зәргәрчелек сәнгатенә хас бизәк төшерү традицияләре чагылыш тапкан. Ювелир эшләнмәләр сериясе өчен ТАССР МС бүләге бирелә (1969). Төбәк («Зур Идел», Казан, 1980; Чабаксар ш., 1985) һәм бөтенроссия («15 автономияле республика», Мәскәү,1987) күргәзмәләрендә катнаша. Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәге музеенда, шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**КОВАЛЕ́ВСКИЙ** Андрей Петрович (1.2.1895, Харьков ш. – 29.11.1969, шунда ук), шәркыятьче галим, тарих фән. д-ры (1948). Лазарев көнчыгыш телләре ин-тында (Мәскәү, 1916–18) укый. 1922 елда Харьков ун-тын тәмамлый. 1920–30 елларда Матди мәдәният ин-ты (Харьков ш.), 1935 тән СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының (Ленинград) этнография музеенда Гарәп кабинеты хезмәткәре. 1938 дә репрессияләнә һәм 5 елга сөрелә. 1943–45 тә Саранск пед. ин-тында чит телләр каф. укытучысы. 1949 дан Харьковта фәнни һәм пед. эштә. К. урта гасырлар гарәп авторларының Көнчыгыш Европа халыклары тарихына караган әсәрләрен, ш.и. Ибне Фазланның Идел Болгарына сәяхәте турында язмаларын тикшерә һәм тәрҗемә итә. Ибне Фазлан китабының рус теленә беренче фәнни тәрҗемәсе К. исеме тәрҗемәче буларак күрсәтелмичә нәшер ителә (Л., 1939). «Әхмәд Ибне Фазланның Иделгә сәяхәте» («Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу», Харьков, 1956) Идел Болгарына Багдад хәлифәсе әл-Мөктадирның илчелеге маршруты автор аңлатмалары б-н тасвирлана. К.ның Ибне Фазлан китабына бирелгән фәнни аңлатмалары Идел Болгарында ислам динен рәсми кабул итүне өйрәнүгә мөһим өлеш кертә; анда угызлар, бәҗәнәкләр, болгарлар, руслар һ.б. Европа халыкларының тормышы һәм гадәтләре турында мәгълүматларга анализ ясала.

Хезм.: Чуваши и булгары по данным Ахмеда Ибн-Фадлана. Чебоксары, 1954.

*Әд.:* Авербух С.И. А.П.Ковалевский — исследователь путешествия Ибн Фадлана на Волгу // Страны и народы Востока. 1994. Вып. 27; Митряев А.И. Андрій Петрович Ковалівський // На честь заслуженного діяча науки України Андрія Петровича Ковалівського: Тези міжнародної наукової конференції, присвяченої 100-річчю від дня народження. Харків, 1995.

**КОВАЛЕ́ВСКИЙ** Виталий Ольгердович (23.4.1933, Ленинград), нәкышьче, график, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, зәргәр, фотограф. 1957 елда Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый, 1957–2003 тә С.Сәетгалиев исем. мәдәният сараенда эшли ( «Казан» халык фотостудиясе җитәкчесе). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977).

К. үзен сынлы сәнгатьнең төрле өлкәләрендә таныта. Күбрәк рәссам-зәргәр буларак билгеле. С.В.*Ковалевская-Шәкүрова* б-н бергә Татарстанның хәзерге зәргәрчелек сәнгатендәге милли традицияләрне яңартуга өлеш кертә. К.ның әсәрләре оста эшләнеше, нәфис формасы, татар бизәкләренең традицион элементлары, зәркән эшләнмәләрнең заманча стильгә үзенчәлекле кушылып китүе б-н аерылып тора. К. эшләнмәләренең күбесен көмештән, челтәрле һәм *купертмә җепкыр* техникасында һәм ярымасылташлар (ахак, фирәзә, яшма, лазурит һ.б.) б-н корлап эшли: «Варяг диңгезе» муенсасы (1971), «Амозонит», «Любава» чигә асылмалары (1971, 1972), «Язгы», «Купшы кием», «Шәркый» беләзекләре (1974, 1975, 1980), «Алтынчәч», «Минем чәчәкләрем» гарнитуралары (1977, 1980).

Нәфис фотография өлкәсендә К. төрле сюжетларга мөрәҗәгать итә һәм үзен фотопейзажлар («Зөя» циклы, 1980 еллар) һәм жанрлы күренешләр («Дөнья шатлыклары», «Ике кешегә бер өстәл», «Дулкын», «Теплоходта», 1990 еллар) остасы итеп таныта. Акварель серияләре авторы буларак та билгеле: «Идел аръягы», «Идел ярлары», «Идел» (1996–98), «Урман буендагы кибәннәр» (1994), «Кичкә



В.О. Ковалевский. «Көзге иртә». Кәгазь, акварель. 1996.

таба. Октябрь». (1994), «Кышкы салкын көн» (1995), «Буа буенда» (1996). 1990 еллардан башлап, К. Казандагы православие чиркәүләре һәм соборлары өчен иконалар яза: «Котелмәгән шатлык» (Никола соборы, 1981), «Тиздән монашка буласы хатын» (1988), Деисус (Петр һәм Павел соборы алтаре, 1991), «Казан изгеләре соборы» (1995), «Христос туган көн» (2000).

Республика (Татарстан декоратив-гамәли сәнгать рәссамнарының беренче күргәзмәсе,





В.О. Ковалевский. 1. «Язгы» беләзек. Көмеш, халцедон, алсу ахак. Җепкыр. 1974. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Алтынчәч» гарнитуры. Көмеш, ярымасылташлар. Яссы һәм күпертмә җепкыр. 1977. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Минем чәчәкләрем» муенсасы. Мельхиор, ярымасылташлар, җепкыр. 1980. ТР Дәүләт сынлы сәнгаь музее.

1983), төбәк («Зур Идел», Казан, 1980), бөтенроссия (РСФСРның 16 автономияле республика рәссамнары әсәрләре, Мәскәү, 1971; «Советская Россия»нең 5 нче, 6 нчы күргәзмәләре, Мәскәү, 1975, 1980), бөтенсоюз, халыкара фотокүргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәни үзәгенең Милли мәдәният музеенда саклана.


*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Будыленко Н. Сорок лет вместе // Казань. 2003. № 2.
*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**КОВАЛЕ́ВСКИЙ** Николай Осипович (8.5.1840, Казан — 5.9.1891, шунда ук), физиолог, мед. д-ры (1865), Ф.В.Овсянников шәкерте. 1862 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1865–91 елларда физиол. каф. профессоры, мөдире, бер үк вакытта, 1878 дән мед. ф-ты деканы, 1880–82 дә ректор. 1862–64 тә Германия һәм Австриядә фәнни эштә. Россия физиологиясендә тәҗрибәләр юнәлешен башлап җибәрүчеләрнең берсе, Казан мед. фәнни мәктәбендә физиол. юнәлешенә нигез сала. Хезмәтләре вегетатив нерв системасы физиологиясенә, кан әйләнеше, сулыш алу һәм организмның башка органнар системасын рефлектор көйләүгә карый. Газ алмашын өйрәнү ысулын эшли. Германиянең Анатомия җәмгыяте әгъзасы, С.-Петербургтагы Рус табибләре җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы.

Хезм.: Анатомико-физиологические исследования селезёнки. К., 1861; Современное состояние вопроса о происхождении мозговых извилин. К., 1886.

*Әд.:* Григорян Н.А. Николай Осипович Ковалевский (1840–1891). М., 1978.

**КОВАЛЕ́ВСКИЙ** (Kowalewski) Осип (Юзеф, Иосиф) Михайлович (28.12.1800, Гродно губ., Гродно өязе Великая Бржестовица а. — 20.10.1878, Варшава), шәркыятьче галим, Россиядә монголларны өйрәнү фәненә нигез салучыларның берсе, Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1847). Дворяннар нәселеннән. Вильно ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1820), шунда ук эшли. 1823 елда «Фән дуслары» яшерен оешмасында катнашканы өчен (җитәкчесе А.Мицкевич) кулга алына, 1824 тә «махсус күзәтү астына» Казанга җибәрелә, ун-тка гарәп, фарсы һәм татар телләрен өйрәнү өчен урнаштырыла. «Казан ханлыгы тарихы»н яза (басылып чыкмый). 1827 дә Байкал арьягына бурят телен һәм бурятларның көнкүрешен өйрәнү өчен җибәрелә. 1829–32 дә Монголиядә, Кытайда яши, җирле халыкларның телен, әдәбиятын, тарихын һәм этнографиясен өйрәнә. 1833–55 тә Россиядәге беренче монгол теле каф. мөдире, Казан ун-ты профессоры (1833). Рус телендә беренче «Монгол китап теленең кыскача грамматика»сын («Краткая грамматика монгольского книжного языка», 1835), ике томлы «Монгол хрестоматиясе»н («Монгольская хрестоматия», 1836–37) әзерләп бастыра; аның тарафыннан төзелгән өч томлы «Монголча-русча-французча сүзлек» («Монгольско-русский-французский словарь», 1844–49) Петербург ФАнең югары бүләге — Демидов бүләгенә лаек була (1846). 1845 тән Казандагы Икенче ир балалар гимназиясе һәм Казан губернасы уч-щеләре директоры. 1855–60 та Казан ун-ты ректоры. 1862 дә Варшавага Баш мәктәпнең (1869 дан Варшава ун-ты) ординар профессоры итеп күчерелә. Монгол телен һәм буддизмны өйрәнүгә караган хезмәтләренең бер өлеше («Монголлар тарихы», т. 1–2; «Монголлар тарихына кереш») басылмыйча кала, алар Россия ФА Азия халыклары ин-тының Петербург бүлеге Шәрекъ кульязмалары фондында һәм ТР Милли архивы кульязмалар фондында саклана. К.ның бик күп кульязмалары, ш.и. Монголия, Кытай, Бурятиягә багышланган алты томлык тасвирламасы, Варшавадагы янгын вакытында югала (1863). К. тарафыннан Кытайда җыелган бай этнография коллекциясе Казан ун-тының этнография музеенда саклана.



О.М.Ковалевский.

Хезм.: Поездка из Иркутска в Ургу // Казан. вестн. 1829. Ч. 1, кн. 5; О забайкальских бурятах // Казан. вестн. 1829. Ч. 27, кн. 9–10; Каталог санскритским, монгольским, тибетским, манджурским и китайским книгам и рукописям в библиотеке Казанского университета хранящимся // Уч. зап. Казан. ун-та. 1834. Т. 2; Буддийская космология. К., 1837.

*Әд.:* Шамов Г.Ф. О.М.Ковалевский — основоположник научного монголоведения в России // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116, кн. 1; шул ук. Научная деятельность О.М.Ковалевского в Казанском университете // Очерки по истории русского востоковедения. М., 1956. Сб. 2; Мезенин Н.А. Лауреаты Демидовских премий Петербургской Академии наук. Л., 1987.

**КОВАЛЕ́ВСКИЙ** Павел Иванович (1849, Екатеринослав губ., Павлоград өязе Петропавловка а. — 1923), психиатр, мед. д-ры (1877). 1874 елда Харьков мед. ун-тын тәмамлый, шунда ук акылга зәгыйфьләр һәм нерв авырулары кафедрасында эшли. 1894–97 дә Варшава ун-ты ректоры. 1899 дан Петербург ун-тында. 1903 тән Казан ун-тының нерв авырулары һәм акылга зәгыйфьлек турында системалы һәм клиник укыту кафедрасында. 1906 да Петербургка кайта. Хезмәтләре мәхкәмә психиатриясенә, эпилепсия һәм неврастенияне дәвалауга карый. «Архив психиатрии, нейрологии и судебной психопатологии» фәнни-гамәли ж-лының беренче санын нәшер итүне оештыра (1883).

Хезм.: Исследования кожных чувств. М., 1876; Об изменении чувствительности кожи у меланхоликов. СПб., 1877.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**КОВАЛЕ́НКО** Борис Иванович (7.1.1925, Украина ССРның Николаев өлкәсе, Октябрь р-ны Свято-Троицк а. — 6.9.2007, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1972). 1951 елда Николаев корабльләр төзү ин-тын тәмамлаганнан соң, Калининградта ЦКБ-820 дә эшли, 1953 тән бүлек башлыгы. 1954 тән Зеленодольск проектлау-конструкторлык бюросында, бүлек башлыгы (1958–63), баш инженер (1963–71), махсус КБның машиналар төзелеше буенча башлыгы (1971–86), әйдәп баручы инженер (1986–2000). Машиналар төзелешенең кечкенә үлчәмле эшләнмәләрен булдыруда һәм гамәлгә кертүдә катнаша. Дәүләт бүләге суднолар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга 51 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КОВАЛЕ́НКО** Валерий Игнатьевич (11.3.1942, Красноярск крае Канск ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1995), проф. (1998). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1977–88 дә Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында физик-химик тикшерүләр лаб-ясе башлыгы. 1988 дән Казан технол. ун-тында молекуляр спектроскопия лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта 1996 дан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында оптик спектроскопия лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре органик кристаллар, сыек кристаллар һәм полимерларның полиморф модификацияләренең конформацион анализына карый. К. элементорганик кушылмалар һәм полимерлар реакциясенең механизмнарын һәм кинетикасын өйрәнә. Яңа продуктлар һәм материаллар алу максатыннан целлюлозаны этерификацияләү процесслары б-н идарә итәргә мөмкинлек бирә торган концепция — целлюлоза эфирларының молекуляр-структур бертөрле булмау концепциясен эшли. К. җитәкчелегендә молекулалары катлаулы өч үлчәмле архитектуралы (фуллереннар, дендримерлар, каликсареннар) матдәләрнең төзелеше тикшерелә. Фуллерен молекулаларының электрон төзелеше үзенчәлекләре б-н әлеге матдәләрнең реакциягә керү мөмкинлеге һәм тотрыклылыгының үзара бәйләнеше күрсәтелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Нитрат целлюлозы: молекулярно-структурная неоднородность. К., 2002 (автордаш); Кооперативная внутримолекулярная водородная связь и конформации молекул тиокаликс [4] аренов // Изв. РАН. Сер. хим. 2002. № 5 (автордаш); Open-shell fullerene C74: phenalenyl-radical substructures // Chem. Phys. Lett. 2003. V.377 (автордаш).

**КО́ВАЛЬ** Александр Моисеевич (2.7.1913, хәзер Воронеж өлкәсе, Талов р-ны Абрамовка пос. — 26.2.2005, Казан), Сов. Союзы Герое (28.4.1945), подполковник. Фабрика-завод уч-щесен (Гороховец ш., 1932), М.В.Фрунзе исем. Сумы артиллерия уч-щесен (1938), Югары офицерлар артиллерия мәктәбен (Ленинград, 1946) тәмамлый. 1933 елда Кызыл Армия сафларына чакырылганчы, заводта эшли (Мәскәү). Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 23 нче гв. артиллерия полкында дивизион командиры (4 нче гв. армиянең 4 нче гв. укчы дивизиясе). Ленин-


А.М.Коваль.

град, Волхов, Сталинград, Дон һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Смоленск (1941) сугышында, Белгород-Харьков һөҗүм операциясендә (1943), Днепр елгасы өчен барган сугышта (1943), Кировоград, Корсунь-Шевченко, Умань-Ботошаны һәм Яссы-Кишинёв (барысы да — 1944) сугышларында, Будапешт, Балатон һәм Вена (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең апрелендә Вена шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: 5 апрельдә батареядан ут ачып, укчылар полкы һөҗүменә булыша, дошманның 9 пулемётын һәм танкка каршы атучы 6 тубын юк итә; 12 апрельдә К. җитәкчелегендәге дивизион, Дунай каналын кичеп, Дунай аша салынган күперне басып ала һәм аны дивизиянең төп көчләре килгәнче саклап тота; авыр яралана, әмма сугыш кырын ташламый. Сугыштан соң Венгрия һәм Көнчыгыш Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә командирлык вазифаларын башкара. 1948–52 дә 26 нчы бригаданың артиллерия полкында дивизион командиры урынбасары (Казан). 1952 елдан запаста. ТАССР Сәүдә министрлыгында суыткыч җайланмалар буенча инженер булып эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Дмитровск (Запорожье өлкәсе Орехов р-ны) урта мәктәбе К. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Гринько А.И., Улаев Г.Ф. Богатыри земли Воронежской. Воронеж, 1965; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1; Коваль Александр Моисеевич: Некролог // Респ. Татарстан. 2005. 1 марта.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КОВАЛЬНО́ГОВ** Николай Николаевич (5.5.1950, Киров өлкәсенең Куменск р-ны Бельтюги а.), термофизик, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1973 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1993 тән Ульянов техник ун-тында, җылылыкны газ б-н тәэмин итү, вентиляция һәм гидравлика (1997–99), җылылык энергетикасы (1999 дан) кафедралары мөдире. Хезмәтләре агымнардагы җылылык-масса алмашуга һәм ышкылуларга карый. К. җитәкчелегендә нәстационар агымнардагы турбулентлыкны үлчәү алымы һәм автомат чаралары булдырыла. Интенсив тәэсирләргә дучар агымнарда турбелент күчерү моделен, чик катламда турбулент күчерү б-н идарә итү алымын, катлаулы җылылык-газ хәрәкәте шартларында алмашу процессларын исәпләү юлын тәкдим итә. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Хезм.: Научно-исследовательские лаборатории теплофизического профиля. К., 1988 (автордаш); Теория и техника теплофизического эксперимента. М., 1993 (автордаш); Пограничный слой в потоках с интенсивными воздействиями. Ульяновск, 1996; Drag reduction and heat transfer of a turbulent flow in a tude due to perforations with damping cavities // Journal of Engineering Thermophysics. 2002. V.11, № 4 (автордаш).

**КОВА́ЛЬСКИЙ** Мариан Альбертович (Войтехович) (15.8.1821, Добжинь ш., хәзерге Польша Респ-касы — 9.6.1884, Казан), астроном, матем. һәм астрономия д-ры (1852), Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1863). 1845 елда Петербург ун-тын тәмамлый. 1847–49 да Төньяк Уралдагы пунктларның геогр. координатларын билгеләү экспедициясендә эшли. 1850 дән Казан ун-тында, проф. (1852 дән), декан (1862–68 дә һәм 1881–82 дә), бер үк вакытта Казан шәһәр астрономия обсерваториясе директоры (1854 тән). 1851 дә Нептун хәрәкәте теориясен эшли, 1855 дә аны камилләштерә. 1856 да күк җисемнәренең тотылулары теориясен үстерә, бер үк вакытта йолдызларның Ай тарафыннан каплануларын алдан исәпләү өчен уңайлы алым тәкъдим итә. Куш йолдызлар орбиталарын билгеләүнең К. эшләгән алымы (1872) әле дә иң яхшылардан санала. К. йолдызларның торышын күпләп күзәтүләр б-н (4200 дән артык) шөгыльләнә, оригиналь рефракция теориясен тәкъдим итә. Кояш системасының фәзадагы хәрәкәтен билгеләү алымын эшли һәм куллана, беренче тапкыр Галактиканың әйләнү үзәген табу мәсьәләсенә математик чишелеш бирә; йолдызлар хәрәкәтендәге закончалыкларны өйрәнү өчен поляр диаграммалар алымын тәкъдим итә («Брадлей каталогы йолдызларының үз хәрәкәте законнары турында», 1859). Бу хезмәт фр. телендә язылган. К. — Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыятенең физика-матем. фәннәре секциясен, ш.у. Рус астрономия җәмгыятен оештыручыларның берсе, Россия һәм чит ил фәнни җәмгыятьләре әгъзасы. Айдагы бер кратерга К. исеме бирелгән.

Хезм.: Избранные работы по астрономии. М.–Л., 1951.

*Әд.:* Перель Ю.Г. Выдающиеся русские астрономы. М.–Л., 1951.


*Р.Г.Усманов.*

**КО́ВАНОВА** Галина Константиновна (21.4.1957, Әлмәт ш.), инженер-программист, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). 1979 елда Куйбышев ун-тын тәмамлаганнан соң, Куйбышев үзәк махсуслаштырылган КБда инженер, инженер-конструктор булып эшли. 1989 дан «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» НГДУында: мәгълүматлар эшкәртү хезмәтендә инженер-программист, инженерлык-технол. хезмәтләренең автоматлаштырылган эш урыны төркемендә әйдәп баручы инженер-программист, 1 нче нефть һәм газ чыгару цехында башлык урынбасары. Дәүләт бүләге «Нефть чыгару системасында оператив күзәтү һәм идарә итүдә корпоратив мәгълүмат системасын эшләү һәм сәнәгатьтә гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

Хезм.: «АРМИТС» осваивает нефтепромыслы // Нефт. хоз. 2001. № 10 (автордаш).

**КОВА́РСКАЯ** Маргарита Яковлевна (12.3.1941, Казан), пианистка, педагог, ТРның халык артисты (1999). 1964 елда Казан консерваториясен (Э.Монасзон классы) тәмамлый. 1964–70 елларда Татар опера һәм балет театрында концертмейстер булып эшли. 1970 тән Казан пед. ин-тында укыта, проф. (2003). К.ның башкару эшчәнлеге дөнья классикасын һәм татар музыкасын пропагандалау б-н бәйле. Татарстанның әйдәп баручы башкаручылары (М.Әхмәтов, М.Булатова, М.Галиев, Г.Ластовка, З.Сөнгатуллина һ.б.) б-н концертмейстер һәм солист буларак чыгышлар ясый. Аның соло программалары арасында — «С.Рахманинов», «Э.Григ», «Татар сонатасы тарихы», «Салон музыкасы» һ.б. бар. Режиссёр һәм башкаручы буларак, А.Ключарёв, С.Сәйдәшев, З.Хәбибуллин, Р.Яхин һ.б. композиторларга багышланган тематик концерт кичәләре оештыра. Россия шәһәрләрендә, чит илләрдә (Төркия, Израиль һ.б.) чыгышлар ясый. Фортепиано өчен вокаль музыка эшкәртмәләре җыентыкларын һәм пед. музыка уку йортлары өчен уку-укыту методик әсбапларын төзүче.

*Ф.Ш.Салитова.*


М.А.Ковальский.


М.Я.Коварская.

**КОВЕЛЛИ́Н**, сульфидлар классы минералы,CuS. Итальян минералогы Н.Ковелли (1790–1829) исеме белән аталган. Fe, сирәгрәк Ag кушылмалары бар. Гексогональ сингониядә кристаллаша. Юка элпәләр, майлар, корымлы порошоклар ясый. Зәңгәр-индигодан кара төскә кадәр. Алмашучан төсләр хас. Тонык ялтыравыклы. Ныклыгы 2–2,5. Сульфид ятмалары цементлашкан җирдә, гидротермаль юлларда барлыкка килә. Вулкан лавасында һәм газларында булуы билгеле. ТРда конкрецион типтагы *бакыр казылмалары* б-н бәйле, конкрецияләрнең үзәк өлешен төзи.

*Әд.:* Проблемы геологии твёрдых полезных ископаемых Поволжского региона. К., 1997.

**КОВЕЛЬКО́ВА** Екатерина Георгиевна (27.1.1876, Казан — 7.2.1964, шунда ук), җырчы (контральто), педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1956). 1898–99 елларда вокалдан Петербург консерваториясендә (Ферни-Джиральдони классы) һәм Казанда (Л.Люценко классы) укый. 1899 дан Казан, Пермь, Саратов, Киев, Екатеринбург, Тифлис, Харьков һ.б. шәһәрләрнең опера сәхнәләрендә чыгышлар ясый. Җырчының башкару манерасы югары вокал техникасы, тәэсирлелеге, сүз һәм музыканың гармоник бердәмлегенә омтылуы б-н аерылып тора. Замандашлары җырчы тавышының матур, йомшак бәрхет тембрлы булуын, аның барлык регистрларда тигез яңгыравын билгеләп үтәләр. Опера партияләре арасында Ваня, Ратмир («Патша өчен яшәү», «Руслан һәм Люд-

мила», М.Глинка), Ольга, Полина, Миловзор («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский), Кончаковна («Князь Игорь», А.Бородин), Фёдор, Шинкарка, Марина Мнишек («Борис Годунов», М.Мусоргский), Лель («Кар кызы», Н.Римский-Корсаков), Маддалена («Риголетто», Дж.Верди), Кармен (шул исем. опера, Ж.Бизе), Миньон (шул исем. опера, А.Тома). К. Татарстанда вокал белеме үсешенә сизелерлек өлеш кертә. 1922–52 дә Казан музыка уч-щесендә, 1945–60 елларда Казан консерваториясендә укыта. Шәкертләре арасында — М.Рахманкулова, З.Байрашева, Г.Кайбицкая, У.Әлмиев. Җырчының пед. принциплары рус вокал мәктәбе традицияләренә таянып эшләвендә чагыла.

**КОВКО́В** Виктор Антонович (7.6.1933, Кострома өлкәсенең Макарьево р-ны Варша а.), оптик-конструктор, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). 1963 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «КОМЗ» ЖБнең «Фотон» ҮЗӘК КБда эшли, 4 нче бүлекчәнең әйдәп баручы конструкторы (1976–78), конструкторлар бүлеге башлыгы урынбасары (1978–86), әйдәп баручы конструктор (1986–90), 2 нче бүлекчәдә сектор башлыгы (1990–94). Дәүләт бүләге космик тикшеренүләр өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**КО́ВТУН** Георгий Анатольевич (19.2.1950, Одесса ш.) балет артисты, балетмейстер, муз. театр режиссёры, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1988), ТРның халык артисты (2010). 1973 елда Воронеж хореография уч-щесен, 1985 тә Ленинград консерваториясен режиссура классы буенча тәмамлый.

Сәнгатьнең күп кенә жанрларында (балет, цирк, кино, боз өстендә балет, драма, мюзикл, телевидение, опера, оперетта) эшли. Күпләгән сәхнә мәйданнарында 300 дән артык спектакль, миниатюра, композицияләр куя. Одесса, Чабаксар, Баку, Краснодар, Новосибирск, Магнитогорск, Сургут, Воронеж, Элиста шәһәрләрендә һәм чит илләрдә эшли.

Казанда, режиссёр буларак, Р.Кәлимуллинның «Ерактагы кәккүк авазы» (1989), Дж. Вердиның «Аида» (2002), Ж.Бизеның «Кармен» (2011) операларын; балетмейстер буларак Л.Любовскийның «Кыйссаи Йосыф» (2002), Э.Григның «Пер Гюнт» (2003), А.Хачатурянның «Спартак» (2008) балетларын куя.

К. халыкара балетмейстерлар (Мәскәү, 1980), «Сочи-82» эстрада артистлары, Бөтенсоюз җыр һәм бию ансамбльләре (Мәскәү, 1986) конкурслары һәм Ленин комсомолы (1985) бүләге лауреаты.

Ә с ә р.: По белу свету. СПб., 2003.

*В.Н.Горшков.*

**КОВЯ́ЗИН** Владимир Григорьевич (13.2.1943, Киров өлкәсенең Лебяжье р-ны Окунев с-зы), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1953), проф. (1993). 1966 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1970 тән СССР Химия сәнәгате министрлыгының Казан фәнни-тикшеренү ин-тында. 1992 дән Казан мед. ун-тының хезмәт гигиенасы кафедрасында. Хезмәтләре химия сәнәгатендә эшләүчеләрнең агулануларга каршы санитариясенә, хезмәт гигиенасына һәм сәламәтлеген саклауга карый.

Х е з м.: Основные вопросы гигиены труда в производстве жидкого тиокола: Автореф. дис. ... К., 1970.

*Әд.:* Казанские профессора-гигиенисты: Биогр. словарь. К., 1995.

**КОДА́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,9 *км*, бассейнының мәйданы 45,5 *км²*. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап ага, Бөгелмә р-нында. Елга башы урман массивында, Кодаш авылыннан 5,4 *км* төньяктарак; тамагы Карабаш посёлогыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 119 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 50%. К. елгасының 1,4 тән алып 3,3 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 54 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,052 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. К. бассейнында су күләме 0,09 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КОДА́Ш** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Юри елгасы буенда. 2010 елда 250 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә, капчык-чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1820 дән), земство мәктәбе (1914 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1670,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсенә керә. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1762 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 400, 1877 дә — 562, 1905 тә — 719, 1920 дә — 994, 1926 да — 848, 1938 дә — 864, 1958 дә — 316, 1970 тә — 295, 1989 да — 309, 2002 дә — 279 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КОДА́Ш** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 47 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы бассейнында. 2010 елда 87 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту, тегү, мунчаладан аркан ишү, читек өчен галош ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет (1857 дә төзелә), мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 768,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 313, 1897 дә — 416, 1908 дә — 431, 1920 дә — 426, 1926 да — 480, 1938 дә — 571, 1949 да — 478, 1958 дә — 366, 1970 тә — 351, 1989 да — 131, 2002 дә — 110 кеше.

**КОДА́Ш** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кодаш елгасы буенда. 2010 елда 744 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1747 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстиянннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та 2 мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2117 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулино волостенда, 1920 дән — ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 26 мартыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 770, 1889 да — 823, 1897 дә — 1317, 1908 дә — 1378, 1920 дә — 1666, 1926 да — 1544, 1938 дә — 1161, 1949 да — 1043, 1958 дә — 1028, 1970 тә — 920, 1979 да — 672, 1989 да — 538, 2002 дә — 842 кеше.

**КОДА́Ш КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Биектау р-ны Кодаш авылының төньяк-көнчыгыш чигендә, Ашыт, Питиал һәм Сола елгалары субүләрендә. Су өслегенең мәйданы 3,4 *га*. Күләме 20 мең *м³* тирәсе. Озынлыгы 350 *м*, иң зур киңлеге 170 *м*, уртача тирәнлеге 0,75 *м*, иң зур тирәнлеге 1,3 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст күренеше б-н бәйле. Формасы катлаулы. Суы бик йомшак, гидрокарбонат-сульфат магнийлы типта. Үтә күренмә-



Кодаш күле.

лелеге 35 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла.

**КОДАЯ́РОВ** (Ходаяров) Габдулла Хәбир улы (1899–1984), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1962), проф. (1962), БАССР, РСФСР-ның атказ. фән эшлеклесе (1967, 1973). 1943–75 елларда Уфа трахоматоз ин-ты директоры, бүлек мөдире, бер үк вакытта 1955–75 тә Башкорт мед. ин-тының күз авырулары каф. мөдире, проф. (1975–82). 1933 тән БАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы күз табибе. Хезмәтләре трахома, вируслы күз авырулары, герпес эпидемиологиясен, клиникасын, патоморфологиясен һәм аны булдырмауны өйрәнүгә, катаракта (кара су) һәм глаукоманы хирургик дәвалауга карый.

**«КО́ДЕКС КУМА́НИКУС»** («Codex Cumanicus» — «Коман мәҗмугасы»), 13 йөз ахыры — 14 йөз башы *кыпчак телендәге* язма ядкәрләренең берсе. Христиан миссионерлары тарафыннан төрки телләрнең көнбатыш һун тармаклары сөйләм теленә нигезләнеп төзелә. Латин-фарсы-коман һәм коман-немец сүзлекләрен, кыпчак грамматикасыннан мәгълүматларны, кыпчак теленә тәрҗемә ителгән Тәүрат хикәятләрен үз эченә алган ике дәфтәрдән гыйбарәт. «К.к.» аңлатмалары латин хәрефләре б-н язылган. Анда иске татар теленә хас булган архаик грамматик формалар күпләп очрый: «оглан» (угыл, ул), «кар йагды» (кар яуды), «йыгламас» (еламас). Хәзерге татар әдәби телендәгечә кулланылган сүзләр дә бар: «һәр елда», «килдем», «бәхет бирсен» һ.б. Текcттагы «алгышлатур алар, ким йазыксыз» (гөнаһсыз кеше бәхеткә лаек) кебек аналитик формалар латин-итальян синтаксик конструкцияләрен турыдан-туры калькалаштыру нәтиҗәсе булып тора. «К.к.» фразеологизмнарга (соңгы заманда кеше булдың; ант эчәрмен), мәкаль һәм әйтемнәргә (кем миңа бирсә, мин дә аңар бирәйем; кем миңа бирмәсә, мин дә аңар бирмәм), табышмакларга бай. «К.к.» ны төзүчеләр беренче булып төрки телләргә лингвистик анализ ясарга омтылалар (фигыльләрнең төрләнеше, исем, сыйфат, алмашлыкларның төрләнүе һәм үзгәрүе турында мәгълүматлар китерелгән). «К.к.» ны өйрәнүгә А.Н.Самойлович, С.Е.Малов, В.В.Радлов, А.Курышжанов, Л.Т.Мәхмүтова, Х.Мәхмүтов, Г.Клапрот, Г.Кун, К.Грёнбек, Россия һәм чит илләрнең һ.б. тюркологлары зур өлеш кертәләр. Кульязма Венеция шәһәренең Изге Марк китапханәсендә (Италия) саклана.

*Әд.:* Р а д л о в В.В. О языке куманов: По поводу издания куманского словаря // Зап. Имп. АН. СПб., 1884. Т. 48, № 4; История татарского литературного языка (XIII — первая четверть XX в.). К., 2003. *В.Х.Хаков.*

**КОДЫБИРДЕ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 14 *км* төньяктарак, Ышналы елгасы буенда. 2010 елда 61 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, сарык тиресен эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 350 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир-ат; 1859 да — 210, 1897 дә — 446, 1908 дә — 555, 1920 дә — 143, 1926 да — 470, 1938 дә — 366, 1949 да — 252, 1958 дә — 154, 1970 тә — 135, 1979 да — 110, 1989 да — 73, 2002 дә — 67 кеше.

**КОЕРЧЫ́К (Коурчак) ХАН** (? — 1398 дән соң), Алтын Урда ханы (1396–97). Ырыс хан улы. Әтисе үлгәннән соң Туктамыш хан сараенда яши. Туктамыш яныннан Урта Азия идарәчесе Аксак Тимер тарафына качып китә. Туктамыш б-н Аксак Тимер ягында торып сугыша, аның 1395 елда Алтын Урдага яу б-н килүендә катнаша. Аксак Тимер ярдәмендә Алтын Урдада тәхеткә утыра. Аның идарәсе озакка сузылмый. Исеме сугылган акчалар очрамый. Әмир Идегәй тарафыннан бәреп төшерелә.

*Әд.:* Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941. Ч. 2; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; М у х а м м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983. *И.Л.Измайлов.*

**КОЖА́ЕВКА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 60 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 172 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт һәм удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), 3 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1471,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Никола-Пичкас волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 190 ир-ат; 1859 да — 457, 1897 дә — 847, 1908 дә — 900, 1920 дә — 873, 1926 да — 503, 1938 дә — 484, 1949 да — 362, 1958 дә — 423, 1970 тә — 293, 1979 да — 250, 1989 да — 237, 2002 дә — 188 кеше.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**КОЖА́ЕВКА КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Актай елгасының (Иделнең сул кушылдыгы) уң ярында Спас р-нының Кожаевка һәм Бураково авыллары янында урнашкан. Ядкәрләр 20 йөз башыннан алып В.Ф.Смолин (1914), С.И.Покровский, М.Г.Худяков, Е.П.Казаков (1961), М.М.Кавиев (1987–96) һ.б. тарафыннан тикшерелә. Комплекс борынгы авыллыкны, 11–14 йөзләр каберлеген һәм Болгар археол. культурасының башка ядкәрләрен үз эченә ала.

Кожаевка IV авыллыгы 1961 елда Е.П.Казаков тарафыннан ачыла. Авыллыкта (мәйданы 9,6 мең $м^2$) 70 ләп объект, ш.и. ашлык, балык, җиләк-җимеш, инвентарь саклау, балчык изү, көл түгү һ.б. өчен файдаланылган хуҗалык чокырлары, ярымземлянка тибындагы 5 торак корылма калдыклары тикшерелә. Торакларның берсе квадрат формасында (3,5×3,5 *м*), аның почмаклары дөньяның дүрт тарафына юнәлтелгән. Диварлары горизонталь рәвештә кыртыш б-н эчләнгән, идәне балчык б-н сыланган. 0,7 *м* киңлектәге ишек һәм тәбәнәк басмалы баскыч корылманың көнчыгыш ягында үзәктә урнашкан. Ишекнең сул ягында, турыпочмаклы формадагы биегрәк җирдә, учак урыны булган. Фаразлаганча, чатыр түбә салам б-н ябылган, ишек өстенә лапас корылган.

Каберлектә (1987 дә М.М.Кавиев тарафыннан табыла) 170 тән артык кабер тикшерелә. Аларда мәетләр мөселман йоласы буенча җирләнгән, әмма мәҗүсилек элементлары да күзәтелә (корбан китерү чокырлары, каберләр өстендә мәрхүмнәрне искә алу учаклары эзләре һ.б.). Бу үзенчәлеге б-н каберлек әлеге терр-ядәге башка каберлекләрдән аерыла. Антропологик материаллар шул җирдә яшәгән халыкның европеоид типка караганлыгын күрсәтә.

К.к. терр-ясендә сланец кайрак, балчык орчык башы, 2 урак һәм 3 урак кисәге, сабан төрәннәре, сукалар, китмән, кыргычлар, тегермән ташлары, балыкчы җәтмәсе батыргычлары, зур кармаклар, сөяктән эшләнгән сөңге очлыклары, бизәнү әйберләре (к. *Кожаевка хәзинәсе*) һ.б. табыла. Остеологик материалга караганда (А.Г.Петренко, О.Г.Богаткина), халык, башлыча, мөгезле вак һәм эре терлек, атлар үрчетү (хуҗалыкларда ш.у. ишәкләр, этләр, мәчеләр дә асралган), сунарчылык (гадәттә, кошлар, куяннар, кондызлар, төлкеләр ауланган) б-н шөгыльләнгән.

*Әд.:* Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986; К а в е е в М.М. О некоторых итогах работ археологической экспедиции Болгарского заповедника // Ежегодник-9, Государственный объединённый музей Республики Татарстан. 1998. *М.М.Кавеев.*

**КОЖА́ЕВКА ХӘЗИНӘСЕ́**, 11 йөз ахыры — 12 йөз башына нисбәтле болгар зәркән эшләнмәләре хәзинәсе. 1987 елда *Кожаевка комплексы* терр-ясендәге Кожаевка IV авыллыгындагы торак урынрының берсендә сай чокырда табыла. Көмеш чыбыклардан үрелгән зур муенсадан, 6 көмеш йөзектән һәм муенса бөҗрасы уртасындагы 2 алтын чигә асылмасыннан тора. Муенса 6 чыбыкны бергә үрү ысулы б-н эшләнгән, чыбыкларның очларына каптырма ыргаклар куелган, тарая баручы түгәрәк стерженьгә ябыштырылган. Йөзекләр чүкү ысулы б-н ясалган. Кашларының өслеге каралту фонында кырлап бизәкләнгән. Йөзекләрнең берсе зур, алты почмаклы, калын кырлы. Аның өслегендәге рәсем җуела язса да, почмакларга таба кырлап



А.В. Козин.

йөрәк рәвешендә ясалган бизәк шәйләнә. Бу — тупланмадагы озак вакыт дәвамында кулланылышта булган бердәнбер йөзек. Икенче йөзектә — туры сызыклар б-н тулыландырылган шундый ук рәсем. Сызыклар кушылган урыннарда каралту ысулы б-н уксыман фигуралар төшерелгән. Дүртпочмаклык рәвешендәге кашлы өченче йөзек авыш сызыклар б-н бизәлгән. Уемланган алтыпочмаклык каралтылып каймаланган. Яссылык үзәгендә — вертикаль буенча бүленгән овал, өске һәм аскы өлешләрдә — симметрик сызыклар. Овалның уртасында уң һәм сул яклардан сигезлек рәвешендәге фигура хасил итүче 2 дуга сызылган. Дүртенче йөзектә алты почмаклы кашының периметры буенча S-рәвешле тамгалар төшерелгән, кашның уртасындагы дүртпочмаклы өслек уемланган һәм каралтылган, аңа дугасыман бизәк ясалган, бизәк каймаланган. Бишенче йөзектәге алты почмаклы каш каралтылган, аның үзәгенә уемлап күбәләк рәвешле бизәк төшерелгән, күбәләк «канатларының» уртасын овал сызыклар (һәр яктан 2 шәр) кисеп үтә. Йөзекнең дугасы һәм кашы тоташкан урыннарда 3 әр уксыман фигура ясалган. Алтынчы йөзек кашының өске һәм аскы якларына авыш тамгалар төшерелгән. Каралтылган кашка схематик рәвештә тормыш символы булган кош рәсеме уемланган. Аның сынлану рәвеше, койрык каурыйлары һәм аяклары останың үрдәк рәвешендәге — легендар кошны сурәтләвен күрсәтә.

*Чигә асылмалары* ачылган имән чикләвеге рәвешендәге өч «куык» киертелгән (алар арасында — үрелгән алтын чыбык чорналган стерженьнәр) зур божралардан гыйбарәт. «Куык»лар бөртекле тасмалар б-н бизәлгән. Үзәктәге «куык»ларга, шундый ук «имән-чикләвекләр»ен асу өчен, эленмә чылбырлар б-н тоташучы 3 әр кечкенә божра ябыштырылган. Мондый чигә асылмалары Идел буе Болгар дәүләте терр-ясендә табылган монголларга кадәрге чорга хас бизәнү әйберләре үрнәге булып исәпләнә.

*М.М.Кавиев.*

**КОЖЕ́ВНИКОВ** Лев Афанасьевич (5.3.1947, Киров өлкәсенең Омутнинск ш.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Киров пед. ин-тын (1971), Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1976), Театр сәнгате ин-ты каршындагы Югары режиссёрлар курсларын (1983–85) тәмамлый. 1977 дән Казанда. 1977–80 елларда «Советская Татария», «Вечерняя Казань» г-таларында үзхәбәрче булып эшли. К. иҗатына жанр төрлелеге хас. Ул — Мәскәү, Кустанай, Рязань, Магадан һ.б. шәһәрләр сәхнәләрендә куелган «Вакансия» (1982), «Анонимка» (1985), «Алдау» («Подлог», 1987) пьесалары, курчак театры өчен язылган «Пётр I һәм солдат» («Пётр I и солдат», 1983), «Барабашка» (1996), «Ут-кош» («Жар-птица», 2003) пьесалары, «Афродита елмаюы» («Улыбка Афродиты», 1993), «Прокурор үлеме» («Смерть прокурора», 1993) повестьлары, «Олимпия» (1993) романы, фәнни-популяр «Славян мәҗүси аллалары, ияләр һәм җеннәр» («Славянские языческие боги, духи и нечистая сила», 1994) китабы авторы. Г.Р.Державин исем. әдәби бүләк лауреаты (2004).

Ә с ә р.: Театральный детектив: Пьесы. К., 1983.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КОЖЕ́ВНИКОВ** Юрий Васильевич (4.2.1932, Удмурт АССРның Дебесск р-ны Заречная Медла а. — 22.3.2001, Казан), очышлар динамикасы һәм оптималь идарә итү өлкәсе галиме, техник фән д-ры (1967), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР, РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1982, 1993), Казан техник ун-тының атказ. проф. (1997). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1955) шунда ук эшли, проф. (1968), югары матем. (1967–72), гамәли матем. һәм информатика (1972–2001) кафедралары мөдире, бер үк вакытта хисаплау һәм идарә итү системалары ф-ты деканы (1972–73), ректор (1977–87). Очраклы үзлеккә ия булган процессларны һәм системаларны оптимальләштерү буенча фәнни юнәлешкә нигез салучы. К. очкыч аппаратлар һәм очраклы үзлекле системалар б-н оптималь идарә итү теориясе нигезләрен булдыра (тикшеренү нәтиҗәләре баллистик ракеталар һәм Җирнең ясалма иярченнәренең ракета йөрткечләрен исәпләгәндә кулланыла). Өзекле стохастик системаларны оптимальләштерүнең санлы алымнарын эшли. Катлаулы техник системаларда проектлаштыруның һәм карарлар кабул итүне автоматлаштыруның теориясе нигезләрен үстерә (нәтиҗәләре СССР Авиация министрлыгы пр-тиеләрендә авиация двигательләрен сынауның автоматлаштырылган системаларын булдыруда һәм эксплуатацияләүдә кулланыла). Очкыч аппаратлар һәм двигательләрне статистик оптимальләштерү (ш.и. векторлы критерийлар кулланып) буенча тикшеренүләр үткәрә. Компьютерлар дидактикасы принципларын нигезли, бу нигезләр Россиядә беренче компьютер дәреслекләреннән булган «Математик статистикага кереш» («Введение в математическую статистику», 1996) хезмәтенең асылын тәшкил итә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр, ш.и. СССР Космонавтика федерациясенең ике медале (акад. С.П.Королев исем., акад. М.В.Келдыш исем.), СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1978).

Х е з м.: Статистическая оптимизация летательных аппаратов. М., 1978; Автоматизированные испытания в авиастроении. М., 1989 (автордаш); О принципе оптимальности в среднем для разрывных стохастических систем // Автоматика и телемеханика. 1996. № 4; Адаптивная аппроксимация функций // Изв. вузов. Математика. 1999. № 1.

**КОЖЕ́ВНИКОВА** Роза Хәби кызы (19.12.1950, Әстерхан өлкәсенең Красноярск р-ны Дельта станциясе — 27.12.2007, Казан), шагыйрә, тәрҗемәче, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Рус телендә яза. Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1977) тәмамлаганнан соң, 1983 елга кадәр Казан резина-техник әйберләр з-дының күп тиражлы «Прогресс», Татшвейбытның «Рабочая честь» г-талары редакцияләрендә, КПСС-ның Татарстан өлкә ком-ты нәшриятында, «Комсомолец Татарии» г-тасы редакциясендә эшли. 1983–89 да ТАССРның Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире. 1989-2006 да «Идел» ж-лында: бүлек мөхәррире, 1991 дән баш мөхәррир урынбасары. «Миләш тәлгәше» («Гроздь рябины», 1985), «Ике тавыш» («Два голоса», 1990), «Таң сызыгы» («Меж светом и тьмой», 2000) шигъри җыентыклары, балалар өчен «Кышкы яңгыр» («Зимний дождик», 1988) шигырьләр китабы авторы. К.ның иҗаты ихлас һәм шул ук вакытта парадоксаль дә. Ул Г.Сәмитова, Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арсланов, Ш.Галиев, Ә.Баян, Г.Сабитов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Зөлфәт, Р.Миңнуллин, Г.Зәйнашева, Х.Халиков шигырьләрен, татар халык әкиятләрен, курчак театры өчен пьесаларны русчага тәрҗемә итә.

*Әд.:* М а л ы ш е в С. Три жизни Розы Кожевниковой // Татарстан. 2002. № 3.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КОЗГЫ́Н** (Corvus corax), *карга кошлар* семьялыгындагы кош. Көньяк-көнчыгыш Азиядән кала, бөтен Төньяк ярымшар буенча таралган. ТР терр-ясендә гадәти кош, әмма саны күп түгел, һәр җирдә очрый. Утрак кош. Гәүдәсенең озынлыгы 60–65 *см*, ана кошлар ата кошлардан кечкенәрәк. Авырлыгы 1,1–1,4 *кг*. Металлсыман ялтыравыклы кара төстә. Очлы, зур, кара томшыгының төбе каурыйсыман төкләр б-н капланган. Канатлары озын (канат җәеме 1,2 *м* га кадәр), койрыгы чөйсыман. Елга бер тапкыр үрчи, көрән тимгелле 2–3 зәңгәрсу-яшел йомырка сала. Оясын биек агачларда, яр кыяларында, биек корылмаларда ясый. Бер үк урындагы ояга берничә ел рәттән урнаша. Кышын шәһәр һәм зур авыллар тирәсендә яши. Кайвакыт бер урында 20 дән 100 гә кадәр кошны очратырга мөмкин. Төрле азык б-н туклана.

**КО́ЗИН** Алексей Владимирович (28.5.1976, Казан — 5.9.1999, Чечен Респ-касы Дучи а., Казанда җирләнә), РФ Герое (12.11.1999), лейтенант (1999). 1994 елда Россия армиясе сафларына алына. Кул сугышы буенча спорт мастерлыгына кандидат. Казан авиация техникумын (1994), Чиләбе танк ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1999). 1999 ның июлендә Төньяк Кавказ округы (Дагстан Респ-касы) Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләренең оператив бурыч үтәүче 100 нче дивизиясенең танк взводы командиры итеп билгеләнә. Тиз хәрәкәт итүче отряд составында Чечен Респ-касы адм. чикләрен саклау операцияләрендә катнаша. 1999 ның 5 сентябрен-

дә Новолак р-ны үзәгендә засадага эләккән оператив бригаданы коткарганда батырлык күрсәтә: К. танкы Дучи авылында каршы якның берничә ныгытма позициясен юк итә, үз танкы сафтан чыга. К. яралы солдатларга чигенергә әмер бирә, дошманга танкны кулга төшерергә юл куймый, үзе автоматтан, аннан соң зенит пулемётыннан ут ача. К. сәгать ярым вакыт дәвамында каршы якның 2 ут ноктасын, 3 миномётын юкка чыгара; авыр яралана, әсир төшә һәм дошман тарафыннан җәзалап үтерелә. Герой исеме үлгәннән соң бирелә. Казанда ул яшәгән йортка мемориаль такта элenә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КО́ЗИН** Виктор Георгиевич (27.9.1941, Тәтеш ш. — 17.12.2003, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1969 дан Казан химия-технол. ин-тында, нефть һәм нефтехимия ф-ты деканы (1991–99), нефть һәм газ эшкәртүнең химик технологиясе каф. мөдире (2000 елдан). Хезмәтләре нефть эшкәртү һәм нефть химиясенең аерып алу процесслары теориясенә һәм практикасына карый. К. дизель фракцияләреннән күкерторганик кушылмалар аерып алу технологиясенең физик-химик нигезләрен эшли. Күкертле һәм кислородлы кушылма эремәләре һәм поляр эреткечләрдәге углеводородлар термодинамикасы буенча мәгълүматлар банкы булдыра. Нефть сульфоксидлары һәм сульфоннары алу технологияләрен, ш.у. түбән темп-ралы фракцияләү ысулы б-н табигый битумнарны һәм югары үзлекле нефтьләрне аеру өчен альтернатив технология тәкъдим итә. Нефть чыгару һәм әзерләү процессларын интенсивлаштыру өчен химик реагентлар эшли.

Х е з м.: Оценка экстракционных свойств растворителей для разделения среднедистиллятных фракций // Проблемы химии нефти. Новосиб., 1992 (автордаш); Способы проектирования нефтеперерабатывающих заводов. К., 1998 (автордаш); Сопоставление различных способов фракционирования тяжёлого органического сырья // Журн. прикладной химии. 1998. Т. 71, вып. 6 (автордаш).

**КОЗЛО́В** Александр Илларионович (1817, Оренбург ш. — 20.3.1893, Казан), акушер-гинеколог, медицина д-ры (1848). Казан (1836), Дерпт ун-тларын тәмамлый. 1837 елдан Россия мед. ун-тларында эшли. 1850 дән Бердичев шәһәре (Киев губ.) табибе. 1854–66 елларда Казан җәмәгать тәрбиясе приказы өлкән табибе, бер үк вакытта, 1856 дан Казан ун-тының акушерлык, хатын-кызлар һәм балалар авырулары каф. мөдире, профессоры, 1863 тән мед. ф-ты деканы. К. җитәкчелегендә 1856 да акушерлык мәктәбе, үзе 13 ел бердәнбер укытучысы булып эшләгән Акушерлык ин-ты ачыла. 1876 да отставкага чыга. Казан табибләре җәмгыятен (1868) оештыручыларның берсе. Акушерлык клиникасы эшенә асептика ысулларын кертә.

Х е з м.: Новое лекарство против водобоязни // Воен.-мед. журн. 1855. Ч. 66; Случай проявления сахара в околоплодной жидкости из последнего времени беременности // Воен.-мед. журн. 1861. Ч. 80.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904.


**КОЗЛО́В** Александр Павлович (13.12.1958, Горький өлкәсенең Красно-Баковск р-ны Ветлужский пос.), гидродинамика һәм җылылык алмашы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995). 1982 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1996–2000 дә РФА КГҮнең Энергетика проблемаларын тикшерү үзәгендә лаб. мөдире. 2000 нән АКШта эшли. Хезмәтләре энергетика җайланмаларында гидродинамик һәм җылылык процессларына, җылылык алмашын көчәйтүгә, турбулентлыкны үлчәү алымнарына карый. К. өзек-өзек агымнарда җылылык алмашын көчәйтү механизмын, турбулентлык микроструктурасын тикшерә. Турбулент агым һәм җылылык алмашы параметрларын үлчәү алымнарын һәм чараларын эшли. Турбулент агымның уртача тизлеге нульгә тигез булган өлкәләрдә кисәкчекләрнең даими хәрәкәт итүе күренешен ача.

Х е з м.: Турбулентные струйные течения в каналах. К., 1988 (автордаш); Термоанемометрические методы исследования отрывных течений. К., 1990 (автордаш); Термоанемометрические измерения поверхностного трения в отрывных течениях. К., 1998 (автордаш).

**КОЗЛО́В** Владимир Константинович (10.3.1954, Иваново өлкәсенең Ильинский р-ны Назорное а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1997), проф. (2001). 1975 елда Горький ун-тын тәмамлаганнан соң ГИПО ФҖБдә эшли, бүлек җитәкчесе (1991 дән). 1995–96 да Казан югары артиллерия командирлары уч-щесендә. 1996 дан Казан энергетика ун-ты профессоры, мед.-биол. электроника (2001–02), электроэнергетик системалар һәм челтәрләр (2002 дән) кафедралары мөдире. Хезмәтләре катлаулы молекулалар спектроскопиясенә, медицинада һәм энергосистемалардагы спектраль диагностикага карый. К. газ фазасындагы катлаулы ароматик кушылмаларның квазисызыкча спектрлары табигатен ачыклый. Кешенең эчке органнары сәламәтлеген билгеләү алымын эшли.

Х е з м.: Влияние излучения $CO_2$-лазера на квазилинейчатый спектр флуоресценции паров антрацена // Журн. прикладной спектроскопии. 1990. Т. 53, № 5; Природа изменения положения контура квазилиний спектра флуоресценции паров антрацена при изменении частоты возбуждения // Оптика и спектроскопия. 1990. Т. 68; Спектроанализатор и основы методики флуоресцентной диагностики состояния биоткани и её составляющих // Журн. прикладной спектроскопии. 1993. Т. 58, № 1–2 (автордаш); Прибор для спектральных исследований изоляционных масел в диапазоне 600–1100 нм // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2001. № 9–10 (автордаш).

**КОЗЛО́В** Григорий Андреевич (1884 — 1963, Мәскәү), сынчы. Казан укытучылар семинариясен (1904), Казан сәнгать мәктәбенең скульптура бүлеген (1915) тәмамлый, В.С.*Богатырёв* шәкерте. Революцион эшчәнлеге өчен кулга алынуларга дучар була. 1917 елдан соң Казан губернасында крәстиян депутатлар Советы оештыруга җитәкчелек итә. 1919–23 елларда Казан архит-ра-техника ин-тының башлангыч һәм махсус скульптура остаханәсендә укыта (Б.И.*Урманче* — аның укучыларыннан), АХРР әгъзасы (1923). Соңрак Мәскәүдә яши һәм эшли, Ленин р-ының Пионерлар йорты сәнгать студиясе б-н җитәкчелек итә. Скульптура композицияләре:«Башкорт кызы — комсомолка» (1925), «Ленин эш вакытында» (1924), «Ленин табуты янында», «Көтүче башкорт», «Татар крәстияне» (барысы да 1925 тә), «Рабфакта укучы кыз» (1926); «Себер партизаннары» барельефы (1927) авторы. Рев-ция музее заказы



Г.А. К о з л о в. «А. Барбюс портреты». Гипс. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

буенча Коминтернның 2 нче һәм 3 нче конгрессларында халыкара революцион хәрәкәт эшлеклеләре К.Цеткин, М.Кашен, Э.Тельман, А.Барбюсның портретларын натурадан ясый. К.ның Казан чорындагы иҗади һәм мөгаллимлек эшчәнлеге 20 йөз башы пластикасы (төп гәүдәләндерүче вәкиле — В.С.Богатырёв) һәм хәзерге заман скульптура сәнгате (иң күренекле вәкиле — Б.И.Урманче) традицияләрен үзара бәйләп тора.

1 нче Дәүләт фән һәм сәнгать (Казан, 1920), 2 нче Дәүләт нәкышь, скульптура һәм архит-ра (Казан, 1921), АХРРның 8 нче «СССР халыкларының тормышы һәм көнкүреше» (Мәскәү, 1926) күргәзмәләрендә катнаша.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Камни говорят // Причал. 1925. № 10; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Каталог выставки произведении художников Татарии 20–30-х годов. К., 1990.

*Е.П.Ключевская.*

**КОЗЛО́В** Иван Фёдорович (19.4.1885, Самара губ., Яңа Узен өязе Борисоглебовка а. — 14.5.1948, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1921), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940), РСФСРның атказ. табибе (1945). В.С.*Груздев* шәкерте. 1910 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Цивиль өязендә табиб хезмәтендә. 1912 дән акушерлык-гинекология клиникасында дәвалаучы, бер үк вакытта 1919–24 тә Казан ун-тының мед. ф-тында укыта. 1925 тән Омск мед. ин-ты профессоры. 1930–48 дә Казан ГИДУВында, 1 нче акушерлык һәм гинекология каф. мөдире, 1942–44 тә ректор, бер үк вакытта акушерлык клиникасы директоры. Хезмәтләре гинеколо-



Н.А. Козлов.



С.И. Козлов.

гик операцияләр һәм бала тудыру вакытында анестезия техникасын камилләштерүгә карый. К. аналыктан читтә балага узу, акушерлыкта кан китүне, агулануны, җенес органнары шешләрен өйрәнә.

Х е з м.: О токсикозах при внематочной беременности // Тр. Казан. ГИДУВа им. В.И.Ленина. 1935. Т. 4; Внематочная беременность // Неотложная хирургия живота. К., 1947 (автордаш).

*Әд.:* С и д о р о в Н.Е. И.Ф.Козлов: Некролог // Акушерство и гинекология. 1948. № 5.

**КОЗЛО́В** Илларион Александрович (6.2.1878, Казан — 4.12.1933, шунда ук), скрипкачы, педагог. 1896 елда Казанның Р.Гуммерт музыка мәктәбен (аңарда композиция классында, К.Русста скрипка классы буенча укый) тәмамлый. К.ның укучылар концертларындагы уңышлы чыгышлары турында төбәк һәм шәһәр матбугатында искә алына. 1900 дә Мәскәү консерваториясен скрипка (В.Гржимали классы), шунда ук пед. бүлеген музыка теориясе буенча (танылган композитор С.Танеев классы) тәмамлый. 1900 еллар башында концертлар б-н Петербург, Вена шәһәрләрендә чыгышлар ясый. 1905 тә Казанга күчеп кайта. 1907 дән татар тамашачылары алдында татар җырчылары һәм музыкантлары б-н әдәби-муз. кичәләрдә, концертларда солист (скрипкачы, пианист), пианист-аккомпаниатор буларак актив чыгышлар ясый. Татар, башкорт халык көйләрен һәм үзенең әсәрләрен башкара. Концерт эшчәнлеген 20 нче еллар ахырына кадәр дәвам иттерә. Татар халкының музыка сәнгате үсешен өйрәнү б-н шөгыльләнә. 1921–22 дә Шәрекъ консерваториясе каршындагы Фәнни муз.-этнография ассоциациясе әгъзасы буларак, «Россиянең төньяк мөселманнары музыкасы» («Народная музыка северных мусульман России»), «Татар җыры, тексты һәм мелодиясе, шулай ук гармонизациясе турында» («О татарской песне, тексте и мелодии, равно как и гармонизации»), «Казан татарларында театр һәм музыка сәнгате үсеше турында» («О ходе развития театра и музыки у казанских татар») һ.б. темаларга багышланган докладлар б-н чыгышлар ясый. Хәзерге татар музыка сәнгате үсешенә сизелерлек өлеш кертә.

Төп әсәрләре: Скрипка һәм фортепиано өчен татар көе (1896); скрипка һәм фортепиано өчен «Ашказар», «Тәфтиләү», «Сәлим бабай», «Мөхәммәдия» татар, башкорт җырлары гармонизациясе (1907); җырлар; скрипка һәм фортепиано өчен пьесалар һ.б.

Х е з м.: Пятизвучные бесполутоновые гаммы в татарской и башкирской народной музыке и их музыкально-теоретический анализ // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1928. Т. 34, вып. 1–2.

*Әд.:* С м и р н о в Л.М. Жизнь в музыке. К., 1972.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КОЗЛО́В** Лев Александрович (22.1.1930, Ульянов өлкәсе Астрадамовка а.), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1973), проф. (1974), ТАССРның атказ. табибе (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). 1954 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач Шөгер р-ны хастаханәсендә, Казан оптика-механика з-ды мед.-сан. частендә эшли. 1957 дән Казан мед. ун-тының 1 нче акушерлык-гинекология кафедрасында. 1972–75 елларда каф. мөдире, 1995 тән профессор-консультант. Хезмәтләре оператив гинекологиягә карый. К. неовагина тараю сәбәпләрен ачыклый, патологияне булдырмау, аны дәвалау ысулларын эшли һәм мед. клиникасы гамәлгә кертә. Тәҗрибә юлы б-н тире кольпопоэзы ысулын (тире күчереп урнаштыруны) нигезли, ул тире кисәге хатын-кызның җенси органнарында анатомик яктан җайлашып, аларның эшчәнлеген яңадан торгыза, ш.и. бала тудыруга да мөмкинлек бирә. Баланы ана карынныннан ярып алу тәҗрибәсен өйрәнә, аның зарурлыгын дәлилли, операциягә таләпләр эшли, бу исә аналар үлемен киметүгә китерә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия акушер-гинекологлар фәнни җәмгыятьләренең идарә әгъзасы.

Х е з м.: Опыт родовспоможения при позднем токсикозе беременных // Казан. мед. журн. 1976. № 3 (автордаш); Ошибки в диагностике беременности // Казан. мед. журн. 1997. № 2 (автордаш).

*Әд.:* С а д ы к о в Б.Г. Профессор Лев Александрович Козлов // Казан. мед. журн. 1990. № 1.

**КОЗЛО́В** Леонид Михайлович (18.7.1911, Түбән Новгород өлкәсенең Кстово а. — 1979, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1968), проф. (1968), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1975). 1937 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, директор урынбасары (1942 дән), директор (1944–59), нефть һәм газ эшкәртү химиясе һәм технол. кафедрасына нигез салучы һәм аның мөдире (1955 тән). К. җитәкчелегендә нефть ф-ты, нитропарафиннарның проблемалы лаб-ясе оештырыла (1958). Хезмәтләре нитроспиртлар, нитропарафиннар һәм аларның кушылмалары химиясенә карый. 200 дән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар. 1951–59 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*В.Г.Абзалова.*

**КОЗЛО́В** Николай Андреевич (12.10.1916, Уфа губ., Минзәлә өязе Рус Акташы пос. — 10.10.1943, Ленинград ш.), Сов. Союзы Герое (6.2.1942), лейтенант. Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1939). Армия сафларына кадәр туган посёлогында урман сәнәгате хуҗалыгында хисапчы булып эшли. 1937 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 749 нчы укчы полкның штаб башлыгы ярдәмчесе (55 нче армиянең 125 нче укчы дивизиясе). Ленинград фронты гаскәрләре составында Ленинградның көньягында оборона сугышында катнаша. 1941 нең октябрь–декабрендә Ленинград өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: Хаболово авылы (Ленинград өлкәсе Кингисепп р-ны) һәм Колпино шәһәре (Ленинград янында) тирәсендә К. җитәкчелегендәге рота дошманның җанлы көчләренә һәм сугышчан техникасына зур зыян китерә; яралануына карамастан, сугыш кырын ташламый һәм батальон б-н җитәкчелек итүен дәвам итә. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Нурлат шәһәрендәге бер урам Герой исемен йөртә, Самара шәһәрендә һәйкәл куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Б у р о в А.В. Твои герои, Ленинград. Л., 1970; Герои огнённых лет. Ярославль, 1985; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КОЗЛО́В** Николай Хәлим улы (7.5.1924, Чиләбе ш. — 3.6.1985, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан елга техникумын (1942), Бөтенсоюз юридик читтән торып уку ин-тын (Мәскәү, 1956) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1951–53 елларда Казанда ВЛКСМның Бауман район ком-ты 1 нче секретаре. 1956–62 дә Беренче Май р-нында: район башкарма ком-ты рәисе (1957гә кадәр), КПСС район ком-тының 1 нче секретаре (1957 дән). 1962 дә Октябрь р-ны терр-ль-производство колхоз-совхоз идарәсе башлыгы. 1962–65 тә Казан елга порты партия ком-ты секретаре. 1965–66 да ТАССР МС Җирле һәм ягулык сәнәгате идарәсе башлыгы, 1966 дан ТАССР җирле сәнәгать министры. 1959–63 тә, 1971 дән ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**КОЗЛО́В** Степан Игнатьевич (1921, Лаеш кантоны Тангачы а. — 12.8.1945), Сов. Союзы Герое (23.10.1943), рядовой. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 178 нче танк бригадасының мотоукчылар батальоны автоматчысы (40 нчы армиянең 10 нчы танк корпусы). Брянск, Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Харьков һөҗүм һәм оборона операциясендә (1943), Днепр елгасы өчен барган сугышта (1943), Умань-Ботошаны һөҗүм операциясендә (1944) катнаша. 1943 нең 24 сентябрь төнендә Днепр елгасын кичеп, Ржищев посёлогы (Киев өлкәсе) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып елганы йөзеп чыга; сугышның кискен мизгелендә солдатларны контрһөҗүмгә күтәрә. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; За нашу Советскую Родину. Орджоникидзе, 1957; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КОЗЛО́ВКА** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 91 кеше (руслар, чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр-

чылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә, 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 324,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 135, 1880 дә — 340, 1887 дә — 355, 1913 тә — 342, 1920 дә — 588, 1926 да — 645, 1938 дә — 532, 1949 да — 415, 1958 дә — 283, 1970 тә — 239, 1979 да — 169, 1989 да — 105, 2002 дә — 107 кеше.

**КОЗЛО́ВКА РАЙОНЫ́**, *Чуаш Республикасының* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 516,8 *км*². 1927 елның 5 сентябрендә оештырыла. Үзәге — Козловка шәһәре (Чабаксардан 95 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 23,3 мең кеше (2010), 1543 татар (2002). Башлыча, алар Кармыш (367 кеше) һәм Әлмән (198) авылларында яши. 1917 гә кадәр Кармыш авылында мәчет һәм мәдрәсә (1860 тан, 1890 да земство уч-щесе итеп үзгәртелә) була. Хәзерге вакытта Кармыш (1994 тән) һәм Әлмән (2001 дән) авылларында мәчетләр бар. 2002 дән Кармышта китапханә каршында татар китаплары үзәге, «Ләйсән» фольклор ансамбле эшли; 2004 тә «Әдәби караван» проекты чикләрендә «Кулга-кул тотышыйк, дуслар!» дигән татар китабы фестивале уздырыла. К.р.нда Сов. Союзы Герое М.А.*Салихов*, Дан орденының тулы кавалеры Я.Г.*Бикчәнтәев* туган.

*Әд.:* Ксенофонтов Г.Н., Марков Ю.К. Козловский район: Люди, факты, цифры. Чебоксары, 1998; Ксенофонтов Г.Н. Знатные люди — выходцы из Козловского района. Козловка, 2004.

**КОЗЛО́ВСКИЙ** Михаил Борисович (24.3.1954, Казан), фотожурналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2002). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1978). 1979 елда Казан шәһәре Киров р-ны саклык кассалары идарәчесе урынбасары. 1980–91 дә «Советская Татария», «Вечерняя Казань», «Известия Татарстана» г-талары фотохәбәрчесе. 1992 дән ТРның Президент аппараты матбугат үзәгенең әйдәп баручы референты. Төп хезмәте Татарстанның иҗтимагый-сәяси тормышын һәм президент М.Ш.Шәймиевнең эшчәнлеген яктырту б-н бәйле. Иҗатының төп темасы — мәдәният, сәнгать, спорт; яраткан жанрлары — портрет һәм пейзаж. К.ның хезмәтләре 30 дан артык китап һәм альбомның бизәлешендә кулланылган. Халыкара — «Ассофото» (ГДР, 1982), Истанбул (Төркия, 1992), Куала-Лумпур (Малайзия, 2005) күргәзмәләрендә; шәхси (Казан: 1993, 1997, 2004) фотокүргәзмәләрдә катнаша.



М.Б.Козловский. «Ветеран». 1991.




М.Б.Козловский. «Төштә һәм өндә очу». 2002.

**КОЗЛЯ́НИНОВ** Пётр Фёдорович (1807, Новгород губ. — 1869 дан соң), хәрби, дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант (1862). Дворяннар нәселеннән. Баш инженерлар уч-щесен (С.-Петербург, 1824) тәмамлый. 1824 елдан хәрби хезмәттә. 1830–31 дә Польшадагы күтәрелешне һәм 1848–49 дагы Венгрия рев-циясен бастыруда, 1853–56 да Кырым сугышында катнаша. 1858–63 тә Казанның гражданнар эшләре хәрби губернаторы. Аның заманында Казанда телеграф станциясе (1859) эшли башлый, хәрби уч-ще (1861), Сәүдәгәрләр йорты (1861), Алафузов з-ды ачыла (1860); губернада шәһәр һәм өяз полиция идарәләре барлыкка килә (1863); 1860 та Казан а.х. күргәзмәсен үткәрү өчен тырышлык күрсәтә. 1861–63 тә Казан губернасының крәстияннәр эшләре кабулханәсе рәисе. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы* крәстияннәрен бастыру өчен генерал-майор А.С.Апраксин җитәкчелегендәге отрядның хәрби көч куллануын хуплый. Казан губернасының Спас өязе Рус Бизнәсе авылы вакыйгалары һәм *Куртина чиркәвендәге панихида* Россиядә киң җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә һәм К.ның губерна административ башлыгы буларак абруена зыян китерә. *Казан фетнәсе* ачылгач, К. вазифасыннан азат ителә һәм С.-Петербургка кайтарыла.

*Әд.:* Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «врученной на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**КО́ЗЫРЕВ** Борис Михайлович (4.5.1905, Ашхабад ш. — 21.10.1979, Казан), физик-химик, физика-матем. фән. д-ры (1957), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1968), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1965). 1930 елда Казан ун-тының химия бүлеген тәмамлаганнан соң А.М.Бутлеров исем. Химия ин-тында, 1931 дән Казан ун-тының нәорганик химия кафедрасында эшли. 1934–46 да Казан пед. ин-тында. 1946 дан СССР ФА Казан ф-лы Физика-техника ин-тында, физика секторы, радиоспектроскопия лаб-ясе (1947 дән), радиоспектроскопия бүлеге һәм ЭПР лаб-ясе (1965 тән) җитәкчесе, проф. (1972). Хезмәтләре эремәләрдә ЭПРга һәм релаксациягә карый. К. ирекле радикалларда ЭПР күренешен ача (1947, бергәләп), ЭПР спектрларында үтә нәзек тәэсирләшүләр чагылышын таба (1948, бергәләп). Тимернең $^{57}Fe$ изотобы төше спинын билгели (1957, Н.С.Гарифьянов һәм М.М.Зарипов б-н бергәләп). «Электрон парамагнитик резонанс» («Электронный парамагнитный резонанс»), М., 1961) монографиясе авторларының берсе, соңыннан бу хезмәт тулыландырылып АКШта, ГДРда, Польшада яңадан басыла. Шигырьләр яза, инглиз һәм француз теленнән Китс, Бодлер һ.б. авторларның шигырьләрен тәрҗемә итә. К.ның шигырьләре 1994 тә «Казан» ж-лында басылып чыга. Ф.И.Тютчев иҗатына багышланган тикшеренүләр авторы. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.



Б.М.Козырев.

*Хезм.:* К теории парамагнитной релаксации в перпендикулярных полях // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1947. Т. 17, вып. 12 (автордаш); Влияние ядерного спина на резонансное парамагнитное поглощение в растворах солей марганца и меди // Докл. АН СССР. 1950. Т. 71, № 5 (автордаш); Электронный парамагнитный резонанс // Успехи физ. наук. 1957. Т. 63, вып. 3 (автордаш); Письма о Тютчеве // Литературное наследство. М., 1988. Т. 97.

*Әд.:* Борис Михайлович Козырев // Успехи физ. наук. 1975. Т. 116, вып. 3; Борис Михайлович Козырев. К., 2004.

*Р.Г.Усманов.*

**КО́ЗЫРЕВ** Борис Михайлович (13.10.1046, Удмурт АССРның Кизнер р-ны Кибек-Пельга а.), авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2003), ТРның атказ. а.х. механизаторы (2001). 1971 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп, 1973–75 тә «Татсельхозпроект» проектлар конторасында сектор башлыгы, 1984–87 дә «Сельхозаммиак» махсус КБсының Идел буе ф-лы конструкторлар бүлегендә сектор башлыгы, 1987–92 дә Казан ун-тының ботаника бакчасында әйдәп баручы конструктор). Хезмәтләре а.х. техникасы конструкцияләренең файдалы кулланылышын күтәрүгә һәм аны камилләштерүгә карый. Яңача төзелешле ротацион механизмнар, перспективалы туфрак эшкәртү механизмнарын эшли (ТР һәм РФнең машиналар төзү һәм а.х. пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). К. камыллы басуларны әйләндереп салусыз төп эшкәртү, туфракны культивацияләү өчен катнаш агрегат, а.х. культуралары чәчүлекләрен карап тоту коралларын уйлап таба («КМПО» һәм «Пензагрореммаш» АҖләрендә серияләп чыгарыла). Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә. «СССРның уйлап табучысы» билгесенә ия.

Х е з м.: Ротационные рабочие органы нетрадиционной формы // Тракторы и с.-х. машины. 1989. № 12; Перспективы механизации почвообработки и посева сельскохозяйственных культур // Проблемы механизации сельского хозяйства. К., 2000; Почвообрабатывающие машины с коноидальными ротационными рабочими органами. К., 2001.

**КОЗЬМОДЕМЬЯ́НСК ӨЯЗЕ́**, 1781–1920 елларда Казан губернасындагы адм. берәмлек. 16 йөз ахырында Казан өязеннән аерылып чыга, үзәге Козьмодемьянск шәһәре, 1583 елда Идел елгасының уң ярында төзелгән Чикмекола торак пункты урнашкан аралыкта (Идел-Сура елгалары кушылган җирдә) оеша. 1708 дә Козьмодемьянск үз тирәсендәге җирләре б-н Казан карамагына теркәлә, 1719 да Казан губернасының Зөя провинциясенә кертелә. 1781 дә К.ө. Казан губернасына керә (Козьмодемьянск өяз шәһәре статусын ала), 1796, 1802–03 тәге адм.-терр. бүленешләрдән соң Казан губернасында кала һәм губернаның төньяк-көнбатыш өлешен били. Төньякта һәм төньяк-көнбатышта Нократ губернасының Яран өязе, Көнчыгышта Царёвококшайск һәм Чабаксар өязләре, Көньякта Казан губернасының Ядрин өязе, Көнбатышта Түбән Новгород губернасының Васильсурск һәм Макарьев өязләре б-н чикләшә. Территориясе ике өлешкә бүленә (3/4 — уңъяк таулар һәм 1/4 — сулъяк үзән өлеше); Идел һәм аның кушылдыклары; Рутка, Арда, Парать, Олы һәм Кече Юнга, Ветлуга, ш.у. Олы Кокшага елгасы кушылдыгы Олы Кундыш, Цивиль елгасы кушылдыгы Унга елгасы сулары б-н бүлгәләнә. К.ө. 4,4–4.6 мең кв. чакрымны били. 2–3 полиция участогы булган 2 станга бүленә. Волостьлар саны һәм составы күп тапкыр үзгәрә: 19 йөз уртасында К.ө. 12 волостьтан һәм аерым Тойдаков җәмгыятеннән гыйбарәт. 1860 еллар башында Руткин волосте Чабаксар өязенә күчә, Иванькова волосте бетерелә. 1870 еллар башында Кулаков, 1909–12 дә Ахмылов волостьлары төзелә. 1913 тә К.ө. 12 волостька бүленә. 1 нче станга (үзәге Покров, соңрак Юркин бистәсе) — Ардин, Ахмылов, Кулаков, Козьмодемьянск, Янгилде волостьлары, 2 нче станга (үзәкләре — Кожваши, Ильинская Пустынь авыллары, Козьмодемьянск ш.) Әкрам, Большеюнгинск, Виловатовражск, Малокарачкинск, Татаркасинск, Сюндыр, Тойдаков волостьлары керә. 1715–18 дә Еласов (Большеюнгинск һәм Малокарачкинск кушылуы нәтиҗәсендә), Пайгусов (Большеюнгинск өлеше), Ново-Троицк (элек Виловатовражск), Отар (элек Ардин), Идел буе (элек Кулаков) волостьлары оеша. 1920 ел башына волостьлар саны, ш.и. Троицк, 20 гә җитә. К.ө.ндәге халык саны 105,6 мең кеше, шуларның 47,3% чуашлар, 36,3% марилар, 16,3% руслар (1897); халкы игенчелек (асылда, арыш, солы игү), бакчачылык, умартачылык, балыкчылык, мич чыгару, урман һөнәрчелеге (урман кисү, сумала кайнату, деготь җитештерү, агач савыт-саба, арбалар, тәгәрмәчләр һ.б. ясау), ш.у. кап, чыпта сугу, чабата үрү, таш, известь чыгару, мүк, мүк җиләге җыю б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында К.ө.дә май, он, салат җитештерү, икмәк пешерү, йон эшкәртү вак пр-тиеләре эшли. Козьмодемьянск шәһәрендә өч класслы ирләр һәм хатын-кызлар уч-щеләре, 3 земство уч-щесе, чирмеш хатын-кызлар мәктәбе, 2 ирләр чиркәү-приход мәктәбе, өяздә 2 уч-ще һәм 36 чиркәү-приход мәктәбе эшли. К.ө. 1920 дә бетерелә, волостьлары Чуаш (к. *Чуаш Респ-касы*) һәм мари (к. *Мари Республикасы*) автономияле өлкәләренә керә.

КОЗЬМОДЕМЬЯНСК ӨЯЗЕ
(19 йөз ахыры)




1 Сембер губернасы
2 Цивильск (Чуел) өязе
3 Чабаксар өязе
4 Царёвококшайск өязе
1 : 2 000 000

Чыг.: Губернии Нижне-Волжской области // Волости и важнейшие селения Европейской России. СПб., 1884. Вып. 4; Памятная книжка Казанской губернии за 1891–1892 год: В 2 ч. К., 1892; Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892; Памятная книжка Казанской губернии за 1893–1894 год: В 2 ч. К., 1894; Адрес-календарь Казанской губернии на 1905 г. К., 1905; Список сёл Казанской губернии. СПб., 1908; Справочник по городу Казани и Казанской губернии на 1920 г. Ч. 1. Центральные, губернские и уездные установления. К., 1920.

*Д.Г.Мостафина.*

**КОЙНЕ́** (грек. koiné, koinós сүзеннән — гомуми), берничә кардәш диалектларны кушу нигезендә барлыкка килгән гомумхалык сөйләм теле. Диалектара һәм диалекттан тыш аралашу чарасы буларак хезмәт итә; әдәби телнең барлыкка килүенә нигез булып тора. Төрле диалект вәкилләре арасында үзара аралашу булмаган вакытта К. фольклор әсәрләре, сукбай чәчәннәр (риваятьчеләр) телен хасил итә. Казан ханлыгы яуланганнан соң, татар халкы Идел һәм Урал буйларындагы төрле төбәкләргә күчеп китә, *Казан татарлары* б-н Идел буе *кыпчаклары* бергә кушыла; Казан татарлары, кыпчаклар һәм җирле төрки телле халыклар (башкортлар, хәзерге Себер татарларының борынгы бабалары) арасында тыгыз элемтә урнаша, алар якыннан аралаша башлый. Әлеге күренешләр нәтиҗәсендә төп диалектларның иң гомуми үзлекләрен үз эченә алган авыл К. се барлыкка килә. 19 йөз башында күп кенә шәһәрләрдә, ш.и. Казан, Уфа, Оренбург, Уральск, Троицк һәм Екатеринбургта сәнәгать үсеш ала. Шул сәбәпле, төрле татар диалектларында сөйләшүче авыл кешеләре әлеге шәһәрләргә эшкә агыла. Бу исә үз чиратында шәһәр К.сен барлыкка китерә. Авыл һәм шәһәр К.ләре нигезендә 19 йөзнең 2 нче яртысында һәм 20 йөз башында хәзерге татар әдәби теленең төп стильләре формалаша.

*Әд.:* З ә к и е в М.З. Төрки-татар этногенезы. М., 1998; ш у л ук. Койне, традиционные нормы, старотатарский и современный татарский литературные языки // Истоки татарского литературного языка. К., 1988.

*М.З.Зәкиев.*

**КОЙРЫГАЯКЛЫЛА́Р** (Collembola), яшерен казналыклы бөҗәкләрнең беренчел канатсызлар отряды. 35 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 300 ләп төр. Татарстан терр-ясендә төр составы җитәрлек өйрәнелмәгән. Су К. (Podura aquatica) һәм яшел К. (Sminthurus viridis) киң таралган. К. күбесенчә дымлы урыннарда — туфракта, чери баручы агач төпләрендә, сулык ярлары буенда, агымсыз су өслекләрендә; сирәк кенә — үсемлекләрдә яши. Кайбер төрләре һава темп-расы түбән булганда активлар һәм кар өстендә дә күренергә (кайвакыт күпләп) мөмкин. Гадәттә, вак (1–2 *мм*) гади бөҗәкләр, сирәк кенә 5–10 *мм* га җитәләр. Гәүдәсе озынча яки шарсыман. Сулыш системасы юк яки кыскарган. Авыз аппараты кимерүгә яки чәнчеп суыруга җайлашкан. Отрядның төп аерымлык билгесе — корсагының арткы өлешендә сәнәккә охшаш өстәмә сикерү үсентеләре, алар ярдәмендә исә К. субстрат яки су өслегеннән этәрелә ала һәм шактый зур сикерешләр ясый. Үсемлек, гөмбә, суүсемнәр, лишайниклар б-н туклана. Нигездә, файдалы бөҗәкләр — минераль һәм үсемлек калдыкларының таркалуына булышлык итәләр. Кайбер төрләре культуралы үсемлекләргә, ш.и. теплицаларга зыян китерә.

*Н.В.Шулаев.*

**КОКЛЮ́Ш** (Pertussis) (франц. cogueluche), б у м а ю т ә л, кискен антропороз бактериаль йогышлы авыру. Беренче тапкыр К. эпидемиясен Парижда Г.де Байю (1578 дә) тасвирлый; 1900 елда франц. галимнәре Ж.Борде һәм О.Жангу авыру кузгатучыны аерып чыгаралар. К. ны өйрәнүгә совет галимнәре М.Г.Данилевич, А.И.Доброхотова, В.И.Иоффе, С.Д.Носов һ.б. зур өлеш кертәләр. 1957 дә СССРда Захаров К. вакцинасы эшләнә. 1965 тән ассоциатив вакцина (АКДС) ысулы гамәлгә керә. Авыру чыганагы — авыру кеше, һава-тамчылар б-н тарала. Авыру таралу вакыты, асылда, көз-кыш фасылы. Сулыш юллары ялкынсыну, токсинемия һәм өзгәләнеп йөткерү нәтиҗәсендә үпкәләрдәге һава йөреше бозыла (гипоксия һәм гипоксемия). Авырудан соң организм тотрыклы иммунитетка ирешә. Авыруның катлаулану очрагында энцефалопатия, пневмония, пневмоторакс, тирегә һәм күзгә кан төшү, борыннан кан китү күзәтелә. К.ның җиңел формасына охшаш клиник үзенчәлекле кискен антропороз йогышлы авыру — паракоклюш.

ТРда К. б-н авырулар ешаюының югары проценты күзәтелгән еллар: 1968 елда 100 мең кешегә — 856, 3 — 26935 авыру очрагы, 1978 — 100 мең кешегә — 369, 5 — 12562 авыру очрагы, 1988 — 100 мең кешегә — 122, 3 — 4402

авыру очрагы, 1993 — 100 мең кешегә — 36,7 — 1372 авыру очрагы. Казан галимнәре тарафыннан К., дифтерия һәм йогышлы тартышу авыруларына каршы интерназаль ревакцинация ысулы эксперименталь рәвештә нигезләнә һәм тәкъдим ителә (Е.И.*Алатырцева* һ.б., 1969); К.ка диагноз куюның универсаль лаборатор ысуллары эшләнә (Н.Ф.*Амфитеатрова*, Д.К.*Бәширова*, Р.К.Галиева, 1991); организмның бу йогышлы авыруга каршы тору вакытында иммунологик һәм аллергик реакцияләре тикшерелә; К. һәм дифтериягә каршы интерназаль ревакцинация нәтиҗәләре һәм диагноз кую ысуллары берләштерелә, ш.у. авыру селәгәендә антитәнчекләрне ачыклау өчен турыдан-туры булмаган иммунофлюоресценция, латекс-микроаглютинация һәм аглютинациянең буяулы пластина реакциясен тикшерү эшләре башкарыла (Н.Ф.Амфитеатрова, 1974–92); К. эпидемиологиясе һәм аны булдырмау мәсьәләләре карала (М.Ш.Шәфиев, Л.М.Зорина, И.К.Хәсәнова, 2002).

*Әд.:* Качурец В.И. Эпидемиологические особенности современного коклюша // Казан. мед. журн. 1975. № 4; Амфитеатрова Н.Ф. Динамика противококлюшных антител в слюне и сыворотке крови вакцинированных доноров // Казан. мед. журн. 1987. № 4; Гурьянов М.Х., Царегородцев А.А., Лобзин Ю.В. Инфекционные болезни. М., 1998.

*В.А.Анохин.*

**КОКО́ВИН Н.П. БАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Басмаханәне 1849 елда Л.И.Щевицтан (соңыннан басмаханә мөдире булып эшли) Алабуганың 3 нче гильдия сәүдәгәре Н.П.Коковин сатып ала. Коковин татар, рус, француз, немец һ.б. (яһүд теленнән кала) телләрдә цензура рөхсәт иткән һәм хуплаган китаплар, брошюралар, аерым битләр, игъланнар һ.б. бастыру хокукын ала. Тиздән басмаханә С.И.Чирковка арендага бирелә. 1891–1905 тә ул, «М.А.Чиркова варислары басмаханәсе» булып таныла. Татар наширләренең заказларын үти. 1901–1907 дә татар телендә тиражы якынча 2,5 млн. данә булган 171 исемдәге китап нәшер ителә. 1907 дә басмаханә ябыла: заказларга югары бәяләр, шрифтларның искерүе аны бөлгенлеккә төшерә.

**КО́КОРЕВ** Александр Михайлович (1869, Казан — 16.12.1944, шунда ук), нәкышьче, педагог, *Кокорев А.М. һәм К° ташбасмаханәсе* (типохромолитография) ширкәте хуҗасы. Мәскәү нәкышь, скульптура һәм архит-ра уч-щесен тәмамлый (1896). 1907 елда этнографик рәсемнәр туплау өчен Печорага барып кайта. САнең Югары сәнгать уч-щесендә Д.Н.Кардовский остаханәсендә белем ала (1903–05). 1907 дән Казанда, 2 нче реаль уч-щедә, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында, уч-щеләр һәм мәктәпләрдә рәсем дәресләре укыта. 1900 да Парижда Бөтендөнья күргәзмәсендә була. 1916 да Алтайга иҗади сәяхәткә бара. 1917 дән соң рабфакларда һәм төрле курсларда, 1930 еллар ахыры — 1940 еллар башында Казан сәнгать уч-щесендә укыта. ТатАХРР (1925), Рәссамнар берлеге (1940) әгъзасы. Күбрәк лирик пейзаж һәм портрет жанрларында эшли: «Кәшәнә», «Кич (Алтай)», «Дача йорты», «Юрта (Алтай)», «Иделдә» (барысы да — 1920 дә), «Чинарова портреты» (пастель, 1925), «Көз» (1937) һ.б.



А.М.Кокорев. «Су коену». ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Җирле һәм чит шәһәрләрдә яшәүче рәссамнарның беренче картиналар һәм этюдлар күргәзмәсендә (Казан, 1896), «Хәзерге заман рус сәнгате» (Казан,1909), Казанда үткәрелгән периодик күргәзмәләрдә (1915, 1916), Казандагы Беренче дәүләт фән һәм сәнгать күргәзмәсендә (1920) һ.б. катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; шул ук. Художники Советской Татарии. К., 1984.



А.М.Кокорев. 1. «Е.В.Климина портреты»; 2. «М.Я.Казимбәк портреты». 1990 еллар. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

**КО́КОРЕВ А.М. һәм К° ТАШБАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. Басмаханә хуҗасы — А.М.*Кокорев*, идарә итүчесе — К.П.Воскобойников ташбасмаханәсе хуҗасының улы — Казан мещаны В.К.Воскобойников. 1898 елда ачыла. 1899 да тиз баса торган ташбасма машинасы, 2 ташбасма станогы, гравирлау машинасы, зурайту һәм кечерәйтү аппарасы, буяу өчен 7 плитә һ.б. була. 1898 дә анда — 7 кеше, 1902 дә 28 эшче эшли. Татар китаплары һәм шәмаилләре басыла, басмаханәдә басу өчен металлга, агачка яки ташка төшерелгән рәсемнәр, сызым ясау өчен заказлар эшләнә, заказ буенча клишелар җитештерелә. Басмалары сәнгатьчә югары бизәлеш б-н аерылып торалар. Татар наширләреннән алынган заказлар да табыш китерә. 1904 тә аны В.В.Вараксин сатып ала. (К. *Вараксин* В.В. *ташбасмаханәсе*).

**КО́КОРЕВ** Василий Александрович (23.4.1817, Вологда ш. — 22.4.1889, С.-Петербург), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, иганәче. Чыгышы б-н мещаннардан. Шәраб сату б-н баеп китә. Казанның Проломный урамында, ш.у. Успенский, Лядов урамнарында шәраб кибетләре була. Фарсылар б-н сәүдә итә. Бакуда беренче нефть эшкәртү з-дына нигез сала. 1870 тә Казанда Идел-Кама коммерция банкы бүлеген ача, идарә әгъзасы була. Тимер юл һәм пароходлар җәмгыятенең акция пакетларының зур өлеше хуҗасы. Император Александр II нең үзгәртеп корулары либераль тарафдары: сәүдәгәрләр акчасына алпавыт крәстияннәре җирләрен сатып алырга тәкъдим итә, түләү системасын салымга алмаштыру ягында була.

*Л.М.Свердлова.*

**КО́КСИН** Владимир Петрович (20.9.1949, Казан), биохимик, микробиолог, биол. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1971), Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшерену ин-тында эшли. 1993 елдан Республика СПИДка каршы профилактика үзәгендә биохимия лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре микроорганизмнар һәм вирусларның антиген төзелешенә карый. К. тарафыннан диагноз куюда аеруча куркыныч инфекция (бруцеллёз, туләмә, туберкулёз, мөгезле эре терлектәге инфекцияле ринотрахеит, дуңгызларда классик чума) тудыручыларны аеру өчен иммунохимик тест-системалар эшләнә һәм вет. өлкәсендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы һәм 1 патенты бар.

Х е з м.: Диагностическое значение субъединичного сибиреязвенного антигена // Ветеринария 1996. № 1 (автордаш); Мониторинг некоторых иммунохимических показателей на различных стадиях ВИЧ-инфекции // Аллергология и иммунология. 2000. Т. 1, № 2 (автордаш).

**КО́КСИН** Яков Петрович (9.10.1880, Саратов ш. — 11.9.1969, Казан), таксидермист. Ф.Ф.Шиллленгер остаханәсендә (Түбән Новгород ш.) препаратлау сәнгатен өйрәнә (1902–06). Енисей губернасы Минусинск шәһәрендә Мартьянов музееның (1906–09), ТАССР Дәүләт музее һәм Казан ун-ты Зоология музееның фауна фонды экспонатларын эшли. Материал җыю һәм өйрәнү максатыннан, Идел буе республикалары һәм өлкәләренә СССР ФА КГУ, Казан ун-ты, Татарстан Дәүләт музее оештырган экспедицияләрдә катнаша. Таксидермиядә экологик юнәлешкә нигез салучы. «Нарат урманында суер», «Ак куяннар», «Яр чыпчыгы» биологик төркемнәрен һ.б. экспонатлар һәм таксидермик скульптуралар ясый, алар исә ТР Милли музеендагы табигать экспозицияләренең нигезен тәшкил итә. Анда ш.у. К. тарафыннан эшләнгән 100 дән артык хезмәт саклана; кайберләре медаль һәм дипломнарга лаек була. К.ның эшләрен күп кенә музейлар сатып ала.

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Птицы парка КГПИ // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1939. Вып. 81.

*Әд.:* Кудряшова Э.В. О Коксине Я.П. К., 1953.

**КОКША́Н СУЫ́** елгасы, Көнчыгыш Идел алдында, Ерыкса елгасының (Туйма елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 18,4 *км*, ТР чикләрендә — 6 *км*. Бассейнының мәйданы 55,7 *км*². Елга башы — Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы — Менделеев р-ны Татар Кокшаны авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагынныкы — 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. К.ның 0,4 тән алып 4,6 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,52 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 153 *мм*, ташу агымы катламы 116 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. К. елгасы ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м*³*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КОЛ ГАЛИ́** (якынча 1183 — 1233 һәм 1240 арасы), шагыйрь. «*Кыйссаи Йосыф*» лиро-эпик поэмасы авторы. Татар тюркологы Ә.Н.Нәҗип, әсәрнең тел үзенчәлекләреннән чыгып, аның Түбән Иделдә язылган булуын фаразлый, чөнки ул чорда угызлар һәм кыпчаклар арасында актив рәвештә үзара этномәдәни аралашу барган. Әсәр ахырында автор аның язылу вакытын күрсәтә:

Ул мәүләдән ярдәм, җиңү килгән көндә,
Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында,
Һәм тарихның нәкъ алты йөз утызында,
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде инде.
(Яңача 1233 елның 12 маенда).

Поэманың эчтәлеге (мәс., төп персонажларның берсе — акыл иясе Ягкуб картның фикерләре), стиле һәм яңгырашы К.Г. нең үз заманы өчен тирән белемле кеше булганлыгын, гарәп-фарсы әдәбиятын яхшы белгәнлеген күрсәтә. Поэма ахырында ул болай яза:

Йосыф сәүче кыйссасын без тәмам иттек,
Гъәрәб-фарсы телләречә бәян иттек...

Аерым юлларның тәмамланмаган булуы хәвефле монгол явы чоры, яки авторның үлүе (ихтимал, монголлар һөҗүме вакытында) текстка тулысынча редакция ясарга мөмкинлек бирмәгән дигән фикер уята. К.Г. иҗаты татар язма әдәбияты, бигрәк тә поэзиясе формалашуга аеруча көчле йогынты ясый.

К.Г. образы татар әдәбияты әсәрләрендә һәм сынлы сәнгатьтә киң чагылыш таба: 1965 тә Б.Урманче мәрмәрдән «Кол Гали» сынын ясый, 1973 тә Татар акад. театры сәхнәсендә Н.Фәттахның «Кол Гали» исемле трагедиясе күрсәтелә, 2005 тә Казанның меңьеллыгы паркында *Кол Гали һәйкәле* куела һ.б.

Әсәр.: Гали (XII йөзнең азагы — XIII йөзнең башы) // Татар поэзиясе антологиясе. К., 1956; Йосыф вә Зөләйха // Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; Кыссаи Йосыф. К., 1983; Йосыф кыйссасы. К., 2000; Юсуф и Зулейха (отрывки из поэмы) // Антология татарской поэзии. К., 1957; Сказание о Йусуфе. К., 1985.

*Әд.:* Таһирҗанов Г. Фирдәүси һәм Колгали // Казан утлары. 1968. № 12; Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т. 1. К., 1984. 1 том; Хисамов Н.Ш. Бөек язмышлы әсәр. К., 1984; Фәсиев Ф. «Кыйссаи Йосыф» һәм аның авторы турында // Казан утлары. 1988. № 3; Поэт-гуманист Кул Гали. К., 1987; Ахунов А.М. Арабский источник средневековой тюрко-татарской литературы: на материале трудов ат-Табари. К., 2001; Хисамов Н.Ш. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XII–XV вв.: Проблема версий. К., 2001.

*Н.Ш.Хисамов.*

**КОЛ ГАЛИ́ ҺӘЙКӘЛЕ́**. Кабан күле яры буенда, Казанның меңьеллыгы паркы үзәгендә урнаштырылган. Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итәргә килгән шәрәфле кунаклар, ш.и. РФнең Дәүләт Советы әгъзалары катнашында 2005 елның 26 августында һәйкәлне ачу тантанасы була. Авторлары: скульпторлар А.В.Балашов, А.М.Миңнуллина һәм арх. Р.М.Нургалиева. Шагыйрьнең 4 метрлы бронза гәүдәсе балтыйк-грин ташлардан дөрес булмаган формасы б-н валунны



Кол Гали һәйкәле. Бронза. Скульп. А.В.Балашов, А.М.Миңнуллина. Арх. Р.М.Нургалиева. 2005.

хәтерләткән баскычлы мәйданчыкның үзәгендә, постаментта калкып тора. Авторлар шагыйрьнең йөз төзелешенең ихтимали үзенчәлекләрен генә түгел, аның образын, хәтта ул иҗат иткәндәге чорның характерын да монументлаштыралар. Кол Гали тыныч кыяфәттә басып тора; уң кулы б-н күкрәген кыскан, сулына китап тоткан. Йөзе эчке дөньясы б-н уй-фикерләренә бирелеп торуын чагылдыра. Сын формасының эрелеге, вак детальләрнең булмавы, киемендәге җыерылган урыннарның билгеле бер тәртиптә салмак кына ритм б-н аска төшүе шагыйрь сынының тантаналылыгын һәм бөеклеген чагылдыра.

*А.И.Новицкий.*

**КОЛА́Й** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1037 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, чиркәү. Спас чиркәве (1757–63 тә төзелә; архит-ра истәлеге; 1990 елларда яңадан эшли башлый). Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Спасский исеме б-н билгеле. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, агач кисү һәм яру, йөн-тукымаману, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; земство мәктәбе (1877 дә ачыла), су тегермәне, тимерчелек, трактир, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете, 1 сырыханә була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1062,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан үзәге губернасының Казан өязе Колай волосте, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 302 ир-ат; 1859 да — 594, 1897 дә — 546, 1908 дә — 637, 1920 дә — 876, 1926 да — 757, 1949 да — 798, 1958 дә — 729, 1970 тә — 1064, 1979 да — 1090, 1989 да — 968, 2002 дә — 1040 кеше.

**КОЛАҢГЫ́** елгасы, Идел алдында, Бәрле елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 8,4 *км*, бассейнының мәйданы 23,4 *км*². Кайбыч р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Урта Колаңгы посёлогыннан 2 *км* көньяктарак, тамагы — Бәли авылының көньяк-көнбатыш чигендә. Елганың абс. биеклеге 100 *м*, тамагынныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.ның 2,3 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 86 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең 2 нче яртысында туңа. Җәйге челләдә елга еш кына кибә. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**КОЛАҢГЫ́** тимер юл станциясе посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ульянов — Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 339 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 66%, руслар — 28%) яши. Катнаш терлек азыгы әзерләү з-ды, чөгендер саклау базасы бар. Башлангыч мәктәп, клуб. 1943 тә нигез салына. Оештырылган көннән Кайбыч р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1989 да — 201, 2002 дә — 305 кеше.

**КОЛАЧЫ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 15 *км* көнбатыштарак, Кызылсу елгасы бассейнында. 2010 елда 88 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәк-

тәп, клуб. 16 йөз урталарына кадәр нигез салына; 1930 еллар уртасына кадәр рәсми чыганакларда Ключи Пүчинкәсе буларак телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1122,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 126 ир-ат; 1859 да — 584, 1897 дә — 811, 1908 дә — 924, 1920 дә — 828, 1926 да — 805, 1938 дә — 697, 1949 да — 468, 1958 дә — 482, 1970 тә — 414, 1979 да — 232, 1989 да — 116, 2002 дә — 90 кеше.

**КОЛӘХМӘ́ТОВ** Гафур (Габделгафур) Юныс улы (5.5.1881, Пенза ш. — 1.4.1918, Пенза губ. Краснослободск ш.), язучы, публицист. 1902 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1902–11 дә рус-татар уч-щесендә укыта, 1911–16 елларда «Касыймия» мәдрәсәсендә. Уку елларында марксистик әдәбиятны өйрәнә, с.-д. түгәрәкләренә йөри башлый, эшчеләр арасында «Искра» г-тасын тарата, РСДРП ның Казан ком-ты листовкаларын, революцион характердагы брошюраларны татарчага тәрҗемә итә. 1905 нең 21 октябрендә шәһәр короллы күтәрелешендә катнаша һәм кулга алына. Халык уч-щеләре инспекторы үтенече б-н 19 ноябрьдә азат ителә. 1913 кә кадәр полициянең даими күзәтүе астында яши. «Азат», «Азат халык», «Казан мөхбире», «Волжско-Камская речь» г-таларында Казан губернасы эшчеләре һәм крәстияннәренең яшәү шартлары, Казанның мәдәни тормышы, Европа дәүләтләре конституцияләре һ.б. хакында мәкаләләр бастыра. Дүрт пьеса авторы. Икесенең кульязмалары («Кем гаепле?», «Әбүҗәһел») югалган. «Ике фикер» (1906; «Кара һәм кызыл» исеме б-н 1919 да куела) һәм «Яшь гомер» (1907, 1917 дә куела, 2 нче басма, 1981) пьесаларында татар әдәбиятында тәүге күренеш буларак сыйнфый көрәш идеологиясе гәүдәләндерелә, эшчеләр һәм революцион зыялылар образлары тудырыла, яңа (аллегорик һәм метафорик образлар) сәнгати ысуллар файдаланыла. Әдип Г.Камал б-н берләттән татар сәхнәсе телен формалаштыруда зур роль уйный. «Уалган мол» (1906; 2 нче басма 1981) хикәясендә К. аллегория аша (көчле су стихиясе юлындагы киртәләрне җимерә) кешеләрнең бөтен киртәләрне дә ерып чыга алырлык бердәмлек көчен күрсәтә; «Ник уйгандым?» (1910) сатирик хикәясендә дини фанатизм фаш ителә.

*Әд.:* Гафур Кулахметов: Сб. статей, посвящённых 100-летию со дня рождения писателя-революционера. К., 1983.

*А.Г.Әхмәдуллин.*


**КОЛӘХМӘ́ТОВ** Марат Мөнир улы (1959, Пенза ш.), генерал-майор (2001). М.Х.*Коләхмәтов* улы. Ленинград югары гомумхәрби командирлар уч-щесен (1980), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1991), РФ Кораллы Көчләре Генштабы академиясен (2001) тәмамлый. Хәрби хезмәтен Ленинград хәрби округында башлый, мотоукчы взводы командирыннан бригада командирына кадәрге барлык командирлык баскычларын үтә. 2001 елдан Төньяк Кавказ хәрби округында 19 нчы мотоукчы дивизия командиры. 2004 тән грузин-осетин конфликты зонасында тынычлык саклаучы катнаш көчләр б-н җитәкчелек итә. «Почёт ордены» һәм медальләр б-н бүләкләнә.



Г.Ю. Коләхмәтов.



М.Х. Коләхмәтов.



Ф.Ә. Колбарисов.

**КОЛӘХМӘ́ТОВ** Мөнир Хәлил улы (22.12.1927, хәзер Пенза өлкәсе, Неверкин р-ны Кунчерово а.), генерал-лейтенант (1986). Ленинград артиллерия уч-щесен (1947), Пенза пед. ин-тын (1958), Пенза югары артиллерия инженерлар уч-щесен (1963), К.Е.Ворошилов исем. СССР Кораллы Көчләре Генштабы Хәрби академиясен (Мәскәү, 1980) тәмамлый. 1947 елдан Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә, 1950 дән Белоруссия, 1953 тән Идел буе хәрби округларында хезмәт итә. 1963 тән Ерак Көнчыгыш хәрби округында, ракеталар берләшмәсе баш инженеры (1966 дан), округның ракета-артиллерия көчләре идарәсендә ракеталар бүлеге башлыгы (1969 дан). 1972 дән Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә ракета-артиллерия көчләре идарәсе башлыгы урынбасары. 1975–79 да Кораллар идарәсе башлыгы, 1980–89 елларда Ленинград хәрби округы гаскәрләре командующие урынбасары. Кызыл Йолдыз, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КОЛӘХМӘ́ТОВ** Нариман Хәсән улы (15.10.1929, Саратов өлкәсенең Яңа Өзен р-ны Александров Гай а.), геолог-нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), геол.-минерал. фән. канд. (1969), РФнең атказ. геологы (2000). Саратов ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), «Минусинскнефтегазразведка» трестында (Абакан ш.) эшли, экспедициянең баш геологы (1957 елдан). 1959 елдан Красноярск геол. идарәсендә экспедиция, 1962 дән Себер минераль чимал геологиясе һәм геофизикасы фәнни-тикшеренү ин-тының Төмән ф-лында тематик партия башлыгы. 1971 дән Көнбатыш Себер нефть геологиясе һәм разведкасы фәнни-тикшеренү ин-тында: директор урынбасары (1971–87, 1990–92), тышкы икътисади мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире (1992–98), нефть һәм газ ресурслары лаб-ясе мөдире (1998 дән). К. Заполярьеның Тазов, Рус һ.б. чыганакларындагы уникаль нефть-газ ятмаларының күп стадияле формалашуын нигезли; платформа тышында утырма тупланудa ярылган бозылулар һәм өзеклекләрнең киң таралуын исбатлый. Мезозой утырмаларының стратиграфик схемасын, углеводород ятмаларының бүленеп урнашуы закончалыкларын, Көнбатыш Себердәге эре нефть һәм газ чыганакларында эзләнү эшләрендәге төп юнәлешләрне, Ямал-Ненец автономияле округы терр-ясе газ чыгару комплексында чимал базасын үстерү программасын эшләүдә катнаша. Дәүләт бүләге Ямбург нефть газ конденсат чыганагын ачканы һәм эшләтүне тизләтелгән әзерлек б-н алып барганы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нефтяные и газовые месторождения СССР. М., 1987 (автордаш).

**КОЛБАРИ́СОВ** Фатих Әкрәм улы (10.7.1921, БАССРның Мишкә кантоны Субай а. — 7.10.1981, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1968). Сәхнә эшчәнлеген 1937 елда Татар акад. театрында ярдәмче состав актёры сыйфатында башлап җибәрә, бер үк вакытта әлеге театр студиясендә белем ала. Нарский («Серләр», А.Әхмәт), Бикбулат, Вәзир («Рәйхан», «Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), доктор Ломбарди («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) кебек шактый үзенчәлекле образлар тудыра. Батырхан образы («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин) К. иҗатына зур үзгәреш алып килә: әлеге геройны гәүдәләндергәндә актёр эчтәлек һәм форма берлегенә ирешә; тарих тәгәрмәчен кирегә борырга тырышучы образы аның тарафыннан гротеск дәрәҗәсенә җиткерелә (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1958). Хөрмәтулла («Җиз кыңгырау», А.Гыйләҗев), Яков Бардин («Дошманнар», М.Горький), Мартин («Сукыр», Э.Альт), Максим («Ата хакы — Тәңре хакы», В.Лаврентьев),



Ф.Ә. К о л б а р и с о в Арсланов («Бәхтияр Канкаев», Т.Миңнуллин) ролендә.

Паскуалино («Бәйрәм кичендә», Эд. де Филиппо), Лавр Мироныч («Соңгы корбан», А.Островский), Дятлов («Баһадирлар», Н.Ф.Погодин), Розенберг, Әҗәл («Моңлы бер җыр», «Әлдермештән Әлмәндәр», Т.Миңнуллин) образларын да К. югары дәрәҗәдә, төгәл итеп яктырта. Тормыш дөреслеге б-н башкарудагы психол. төгәллекнең бергә үреләп баруы актёрга геройларының катлаулы, каршылыклы характерларын ышандырырлык итеп, кайвакыт, хәтта гражданлык пафосы б-н публицистик югарылыкта ачарга ярдәм итә. Нәфис сүз остасы буларак, К. еш кына радиотапшыруларда һәм концертларда катнаша: татар шагыйрьләренең шигъри әсәрләрен укый; 1944–48 елларда Татарстан радиосы дикторы булып эшли. «Юлдан язган» («Блудный сын», Э.Раннет), «Кол» («Эзоп», Г.Фигейредо), «Ешрак елмаегыз!» («Сослуживцы», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов) һ.б. шактый гына пьесаларны татарчага тәрҗемә итә.

*Әд.:* Иллалова И.И. Г.Камал артистлары: Биографик белешмәлек. К., 2005.

*Д.Ә.Гыйимранова.*

**КОЛБАРИ́СОВ** Шамил Зөфәр улы (23.5.1923, БАССР, Уфа кантоны Нөрле а. — 30.9.2009, Уфа), композитор, җырчы (баритон), режиссёр, БАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968, 1990). 1952 елда Мәскәү консерваториясен вокал (С.Стрельцов һәм В.Карин классы) һәм композиция (Е.Месснер классы) буенча тәмамлый. 1952–68 дә Башкорт опера һәм балет театры солисты. Төп партияләре: Сәүбан («Акбүзат», А.Спадавеккиа һәм Х.Заимов), Ваһап («Карлыгач», Н.Чемберджи), Әхмәт («Айсылу», Н.Пейко һәм М.Вәлиев), Пугачёв, Чураман («Салават Юлаев», З.Исмәгыйлев) һ.б. 1968–74 тә Башкорт филармониясендә солист һәм режиссёр, 1974–78 дә сәнгать җитәкчесе, 1978–88 дә Башкорт акад. драма театры музыка бүлеге мөдире һәм дирижёры. Күпкырлы музыка эшлеклесе буларак, башкорт музыка сәнгате үсешенә сизелерлек өлеш кертә. Төп әсәрләре: опереттала — «Мәхәббәт килгән чакта» (Ш.Биккол һәм Ш.Колбарисов либр., 1965), «Сөйгән яр — Гөлчибәр» (Н.Әсәнбаев либр., 1983); «Уфа кызлары» (И.Абдуллин либр., 1969), «Җизнәкәй» (Х.Ибраһимов либр., 1983) муз. комедияләре; симф. оркестр өчен «Бәйрәм увертюрасы» (1981); тавыш һәм симф. оркестр өчен М.Акмулла шигыренә «Васыятьләр» кантатасы (1981); á capella хор өчен Ш.Биккол шигыренә «Урал» поэмасы (1953); 100 гә якын җырлар һәм романслар; драма спектакльләренә музыка һ.б.

*Әд.:* Ахметова Г.С. Шамиль Кульбарисов // Композиторы и музыковеды Башкортостана: очерки жизни и творчества. Уфа, 2002; Башкортстан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

**КОЛГЫНА́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 184 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 785,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы Тәтеш өязе Черки-Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 46 ир-ат; 1859 да — 333, 1897 дә — 624, 1908 дә — 727, 1920 дә — 705, 1926 да — 577, 1938 дә — 472, 1958 дә — 356, 1970 тә — 349, 1979 да — 311, 1989 да — 203, 2002 дә — 191 кеше.

**КОЛЕГА́ЕВ** Андрей Лукич (22.3.1887, Тобол губ. Сургут ш. — 23.3.1937), сәясәт, дәүләт эшлеклесе; сул эсерлар фиркасенең күренекле вәкиле. Харьков ун-тында укый. 1907 елда революцион эшчәнлеге өчен куыла. 1906 дан социалист-революционерлар фиркасе әгъзасы. 1909 да 4 елга Архангельск губернасына сөргенгә озатыла (Россиядән 4 елга читкә чыгарылу б-н алмаштырыла). Эмиграциядә 7 ел була. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Мәскәү — Казан тимер юл җәмгыятенең ышанычлы вәкиле (Казан). 1917 нең май аеннан губерна земство идарәсе әгъзасы, Казан шәһәр думасына сайлана. 1917 нең мартында эсерлар партиясе таркалгач, Казан эсерлар партиясе оешмасын җитәкли, 1917 нең октябреннән ҮК әгъзасы; сул эсерларның «За землю и волю» г-тасы редакциясе әгъзасы. 1917 нең маенда губернаның 1 нче крәстияннәр корылтаен җитәкли. Крәстиян депутатларының Казан губерна советы рәисе итеп сайлана. Крәстиян депутатлары Казан губерна советының 1917 нең 13 маенда чыгарылган шәхси биләмәләрдәге җирләр һәм утарларны волость ком-тлары карамагына тапшыру турындагы карары авторларының берсе. К. РСДРП(б) сәясәтенә якын позицияне били. 1917 нең августында Казан хәрби округының солдат секцияләре советлары депутатларының 1 нче корылтаендагы чыгышында солдатларны пролетариат көрәшенә кушылырга чакыра. 1917 нең сентябрендә Казан губернасы крәстияннәренең 2 корылтаенда губернадагы крәстияннәр чыгышлары җитәкчеләрен тоткынлыктан азат итүгә ирешә. Петроградта Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша. 2 нче Бөтенроссия эшче һәм солдат депутатлары советы корылтае депутаты (1917 ел, 25–27 октябрь), БҮБК әгъзасы итеп сайлана. Казан губернасыннан Учредительләр җыенына депутат. 1918 нең гыйнварында Учредительләр җыенын тарату турындагы мөрәҗәгатькә имза куя. 1917 нең ноябре — 1918 нең мартында ХКС әгъзасы, РСФСР җир эшләре халык комиссары. Совет хөкүмәте кабул иткән «Җирне социализацияләү турында» законы проекты авторларыннан берсе. 1918 нең мартында Брест килешүен ратификацияләүгә каршы чыга. 1918 нең май–июль айларында Казан губернасы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары башкарма ком-ты президиумы рәисе. «Нишләргә?» мәкаләсендә сул эсерларның ХКСтан чыгуларын хата дип бәяли, рев-циянең социаль нигезен киңәйтүдә авылларда сыйнфый катлаулар булдыруны һәм кулаклар б-н көрәш алып баруны яклый. Бу позициясен сул эсерларның 1 нче Казан губернасы конференциясендә дәлилли (1918, май). 1918 нең июлендә сул эсерлар фетнәсенә катнашмый, фетнә бастырылгач, сул эсерлар партиясе б-н арасын өзә. 1918 нең ноябрендә РКП(б)га керә. Гражданнар сугышында катнаша, 1918 нең ноябрендә — 1919 ның гыйнварында 13 нче укчы дивизия хәрби комиссары, 1919–20 дә Көньяк фронтның Махсус азык-төлек комиссиясе һәм Революцион Хәрби Совет әгъзасы. 1920–21 дә СССР Юллар халык комис-ты коллегиясе әгъзасы. 1921 дә адм.-хуҗалык эшендә. Репрессияләр чоры корбаны, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Революционная борьба крестьян Казанской губернии. К., 1958; Первое Советское правительство. К., 1991; Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993.

*С.И.Ионенко.*

**КОЛЕ́РИЯ**, изолома, тидея (Kohleria) геснериячәләр семьялыгыннан үләнчел үсемлекләр ыругы. 500 гә якын төре билгеле. Чыгышы — Американың дымлы тропиклары. ТРда бүлмә гөле буларак үстерелә; аеруча таралганнары: уймаксыман К. (K. digitaliflora), матур К. (K. amabilis), йөнтәс чәчәкле К. (K. eriantha), богот К. (K. bogotensis). Матур чәчәк атучы, туры сабаклы үсемлек, соңыннан ботаклары ятып үсә (озынлыгы 80 *см* га кадәр җитә). Бүлбесыман кабырчыклы тамырчасы 2 *см* юанлыкка җитә. Яфраклары каршыдаш, йомшак, төкчәле, йомыркасыман озынча. Чәчәкләре кыңгыраусыман, иенке, кайтарылып киң итеп ачылган таҗ яфракчыклары сары яисә кара-кызыл тимгелле; сабак очында һәм өске яфраклар куентыгында урнашкан. Кышка кайбер төрләренең сабак һәм яфраклары үлә, чүлмәкләрдә кышлый. Өске сабаклардан һәм кабырчыклы тамырчадан үрчетелә. Җылылык, яктылык, дым яратучы үсемлек; су бөркү киңәш ителми.

**КОЛЕ́СНИКОВ** Михаил Семёнович (5.11.1938, БАССРның Белорет р-ны Үзән а.), кою производствосы технологияләре өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1964 елда Магнитогорск тау эшләре металлургиясе ин-тын тәмамлаганнан соң, Куйбышев шәһәре (хәзер Самара ш.) подшипниклар з-дында, Куйбышев политехник ин-тында (1970–76), Казан төзүче-инженерлар ин-тында (1976–80) эшли. 1980 елдан Кама политехник ин-тында (Чаллы ш.; 2012 дән Казан (Идел буе) федераль ун-ты составында), кою производствосы машиналары һәм технологияләре каф. мөдире (1982 дән). Хезмәтләре кою производствосында материаллар һәм ресурс саклаулы технологияләр булдыруга карый. К. төсле металлар кою өчен корычларның яңа составларын, пресс-формалар һәм штамплар өчен инструменталь корычлар, биметалл штамплар кою алымнарын тәкъдим итә. Коелма формаларны автомат проектлаштыру системасын эшли (КамАЗда гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Проектирование производства литой прессоснастки. К., 1989; Разработка и применение высокопрочных чугунов в машиностроении. Наб. Челны, 1998 (автордаш); Модификаторы для получения высокопрочных чугунов. Наб.Челны, 2002.

*Б.А.Канеев.*

**КОЛЕ́СНИКОВ** Николай Алексеевич (15.3.1952, Бөгелмә р-ны Наратлы а.), спортчы (авыр атлетика), СССРның атказ. спорт остасы (1976), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). 1977 дә Үзәк физкультура ин-тын (Мәскәү) тәмамлый, 1983 тән — СССР Эчке эшләр министрлыгы Мәскәү академиясенең Казан ф-лында. «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә (Бөгелмә) тәрбияләнә; тренерлары — Е.Ә.*Тимерҗанов*, Р.В.Плюкфельдер. СССР (1975, 1977–79), Европа (1976–79), дөнья (1976–78), Олимпмия уеннары (1976) чемпионы. СССРның 17 тапкыр, дөньяның 8 тапкыр рекордчысы. 1983 тән РФнең ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**КОЛЕ́СНИКОВА** Анастасия Николаевна (6.3.1984, Казан), спортчы (гимнастика), РФнең атказ. спорт остасы (2000). Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тын тәмамлый (2005). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан); тренерлары — Т.А.Агалина, И.Г.Сапрыкин. РФ чемпионатларында (бронза, 2000–01), Олимпия уеннарында (көмеш, 2000) команда беренчелегендә приз иясе. Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә. 2005 тән РФнең ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы органнарында.

**КО́ЛЕСОВ** Николай Александрович (17.12.1956, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2001), ТРның атказ. машина төзүчесе (1999). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1987). 1975–77 елларда Казандагы ЭВМ з-дында радиомонтажчы булып эшли. 1977–95 тә «Казан оптика-механика з-ды» ҖБдә радиоаппаратура көйләүче, цех башлыгы урынбасары, производство башлыгы, бүлек башлыгы. 1995–97 дә «Санди», «Доламит» ҖЧҖләрдә ген. директор (Казан). 1997–2007 дә «Элекон заводы» АҖ ген. директоры. Хезмәтләре радиоэлектроника һәм сәнәгать икътисады өлкәләренә карый. Завод үсешенә сизелерлек өлеш кертә. «ТРның медицина учреждениеләрендә яңа, көндәшлеккә сәләтле, күп функцияле лазерлы медицина техникасын булдыру, аны җитештерү һәм кулланылышка кертү» дигән хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (2002). 2007–08 дә Амур өлкәсе губернаторы, 2008 дән «Радиоэлектрон технологияләр концерны» АҖ ген. директоры (Мәскәү). 1999–2004 тә ТР Дәүләт Советы депутаты. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Конкурентоспособность российских боевых самолетов тактического назначения. М., 1999; Организация производства на диверсифицируемом оборонном предприятии. К., 1999; Формирование отношений собственности в оборонном комплексе Республики Татарстан. К., 1999.

**КО́ЛЕУС**, к ы ч ы т к а н г ө л е, ә д р ә с г ө л е (Coleus), иренчәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 гә якын төре билгеле. Чыгышы — Азия һәм Африканың дымлы тропиклары. ТРда бүлмә гөле буларак үстерелә; аеруча таралганнары: гибрид К. (C. hybridus) һәм Блюм К. (C. blumei). Сабагы дүрт кырлы, туры, ботаклы, сусыл, вак төкчәле. Яфраклары каршыдаш урнашкан, сабакчыл, киң озынча түгәрәк, читләре каяулы, өслеге бәрхетсыман, төрле төстә (сары-яшел, көрән-кызыл, алтынсыман яки яшел каймалы карасу-көрән, кайвакыт саргылт-яшел кызыл). Чәчәкләре вак, шәмәхә-зәңгәр; сирәк катламлы очлы чукка яки катлаулы башакка җыелган. Сабактан (үсемлекнең бөтен нәфислеге саклана) һәм орлыктан үрчетелә. Дым, җылылык һәм яктылык яратучы үсемлек. Яктылык җитәрлек булмаган бүлмәләрдә яфраклар төс ачыклыгын югалта.

**КОЛИБАКТЕРИОЗГА́ КАРШЫ́ ВАКЦИ́НА**, бозауларда һәм дуңгыз балаларында диареяларны булдырмау өчен махсус препаратлар. Колибактериоз (эшерихиоз) авыруларыннан яшь терлекләрнең 20 дән 90% ка кадәре үләргә мөмкин. 1970 елларда Казан вет. ин-тында В.М *Ибраһимов*, Х.М.*Хәкимова*, Х.Х.*Абдуллин* тарафыннан уйлап табылган К.к.в. ТАССРда һәм СССРда 1976–77 елларга кадәр кулланыла. Яңа туган терлекләрдә йогышлы диареяны, нигездә, рото-, короно- һәм герпес-вируслар, ш.у. коли эшерихиясының адгезив антигеннар синтезлаучы энтеропатоген серотиплары (К99, А20) китереп чыгару сәбәпле, Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тының Х.З.*Гаффаров* җитәкчелегендәге эпизоотология лаб-ясе хезмәткәрләре яңа ассоциатив вакцина уйлап табалар. Бозаулауга кадәр 30 һәм 15 көн алдан бу вакцинаны ике тапкыр 10 *мл* дозада сыерга тире астына кертү бозауларның 95–97% ын саклап кала ала. Бер үк вакытта шул ук авторлар яңа туган дуңгыз балаларында була торган рото- һәм короновируслы һәм эшерихиозлы (К88, 987 Р, К99) диареяга каршы да ассоциатив вакцина тәкъдим итәләр. Ана дуңгызга балалауга 12–15 көн кала 5 һәм 10 *мл* доза б-н бу вакцинаны ике тапкыр кертү 91,0–96,6% яшь терлекне сакларга мөмкинлек бирә.

1994 тән ассоциатив вакциналар Татарстанда, Башкортстанда, Мари, Чуаш Респ-каларында, Ленинград һәм Түбән Новгород өлкәләрендә кулланыла.

*Х.З.Гаффаров.*

**КОЛКАМӘ́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 26 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1621 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә чиркәү — приход мәктәбе, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 691 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 88 ир-ат; 1859 да — 304, 1897 дә — 467, 1908 дә — 533, 1920 дә — 564, 1926 да — 440, 1949 да — 361, 1958 дә — 370, 1970 тә — 314, 1979 да — 235, 1989 да — 154, 2002 дә — 118 кеше.

**«КОЛЛЕКТИ́ВНЫЙ 6 ТВ»**, кукуруз гибриды. 1963 елда Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясендә Г.С.*Галиев* һәм Ш.В.*Вәлиев* тарафыннан чыгарыла. Сынау елларында яшел массасының уңышы 1 *га* дан уртача 399 *ц* тәшкил итә (стандарт «Буковинский 3 ТВ» сортыннан 83 *ц* га югары). Иртә өлгерешле, салкынга чыдам. Татарстанда 1968 дә районлаштырыла. Сөрлегүгә бирешми. Уңышын техника б-н җыярга мөмкин. Куыклы кисәү гөмбәсе авыруына чагыштырмача чыдам. Силос сыйфаты яхшы. Хәзерге вакытта үстерелми.

**«КОЛЛЕКТИ́ВНЫЙ 10 ТВ»**, кукуруз гибриды. 1966 елда Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясендә Г.С.*Галиев* һәм Ш.В.*Вәлиев* тарафыннан чыгарыла. Сынау елларында яшел массасының уңышы 1 *га* дан уртача 493,2 *ц* тәшкил итә (районлаштырылган «Буковинский 3» гибридыннан 74,2 *ц* га яки 18% ка югары). Башлыча, төньяк районнарда силос әзерләү өчен үстерелә.

**КОЛЛЕ́КТОРЛАР** (лат. collector — җыючы), г е о л о г и я д ә, күзәнәкле, каверноз яисә ярыкланган тау токымнары, куышлыкларында нефть, газ, битум яисә су була. К.га караган токымнарның билгеләре булып — күзәнәкләр, каверноз, ярылулар, үсеш б-н бәйле үтешлелек һәм сыешлык зурлыклары санала. Нефть, газ һәм су өчен файдалы сыешлык зурлыгы су-нефть күләменә бәйле. Үтешлелек һәм файдалы сыешлыкның түбәнге чиге пластларны сәнәгый яктан бәяли. Фильтрлаштыруда һәм сыешлыкта күзәнәкләр, каверн һәм ярыкларның нисбәте К.ның типларын билгели: күзәнәкле, ярыкланган һәм катнаш. Матди составына һәм килеп чыгышына карап терриген, карбонатлы, вулканоген утырма һ.б. К.ны аералар. Углеводородларның күп өлеше комлы һәм карбонатлы (рифоген) өлешләрдә туплана. К. скважиналарны геофизик тикшергәндә һәм лаборатор анализлар ясаганда ачыклана. К. үзлекләре — ятмаларның күләмен бәяләүдә һәм файдалы казылмалар чыгару режимын билгеләүдә мөһим күрсәткеч.

ТРда терриген һәм карбонат К. (утырмаларда) азрак дәрәҗәдә — вулканген-утырма (кристалл нигездә) К. күбрәк таралган. Девон һәм карбонның терриген катламнарында нефть К.на комлыклар һәм комлы алевролитларны кертәләр, алар үткәрмәүчән аргиллитлар арасында ята. Палеозойның карбонат катламнарында нефть К.ын күзәнәкле һәм ярыклы известьташлар һәм доломитлар тәшкил итә. К.ның сәнәгый әһәмиятлеләре 1,5–2 *км* тирәнлектә ятучы девонның терриген катламнарында, ТРның төп нефть запаслары шунда тупланган. Нефтьле катламнарның шартлы индекслары билгеләнгән (өстән аска): девонда $Д_0$, $Д_I$-$Д_{IV}$ ($Д_v$ катламы сулы), карбонда $А_1$-$А_8$, $В_1$- $В_v$, $А_1$ катламыннан

өстә азот газы ятмалары. ТР терр-ясендәге Пермь ятмалары К.да аз гына нефть, газ ятмалары, битумнарның төп тупланышы билгеләнгән.

*Әд.:* Юсупов Б.М., Веселов Г.С. Размещение нефтяных месторождений Татарии. М., 1973.

**КОЛЛЕКЦИ́ЯЛӘҮ** (лат. collectio — туплау), әйләнә-тирәлекнең теге яки бу предметлары б-н кызыксынуны чагылдыручы, билгеле бер максатка юнәлтелгән тупланма. Казанда К., гомумән алганда, Россиядәге К. үсеше б-н үзара бәйләнештә була. 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башында синкретизм б-н аерылып торган, иң элек китаплардан, сынлы сәнгать әсәрләреннән тупланган беренче шәхси һәм гаилә коллекцияләре барлыкка килә.

19 йөзнең 1 нче яртысында К. Казан ун-тының көчле йогынтысын кичерә. Аның үзенчәлеге фәнни юнәлеш, музей эшчәнлеге б-н элемтәдән, Шәрекъ мәдәнияте б-н кызыксынудан гыйбарәт була. Университет профессорлары һәм укытучылары, үз тупланмаларын булдыру б-н бергә, параллель рәвештә ун-т коллекцияләрен оештыралар һәм тулыландыралар (к. *Казан университеты музейлары*). Коллекцияләргә дөнья буйлап экспедицияләр һәм сәяхәтләрдән алып кайткан төрле экзотик һәм сирәк очрый торган табигый, фәнни әйберләрне кертәләр. К.нең Көнчыгышны өйрәнү тематикасы төбәкнең мәдәни-тарихи үсеш үзенчәлекләре һәм ун-тның *Шәрекъ бүлеге* эшчәнлеге б-н бәйле. Проф. К.Ф.Фуксның зур тупланмасы булдырыла, тупланма аның кызыксыну өлкәләренең энциклопедик киңлеген чагылдыра: ботаник, зоологик, минералогик, нумизматик (Алтын Урда, фарсы һ.б.ның тәңкәләре) һәм археол. коллекцияләреннән тора, аның бай китапханәсе (к. *Фукс К.Ф. китапханәсе*) һәм картиналар галереясы да була. К.Ф.Фукс беренчеләрдән булып җирле этнографик материалларны җыю б-н шөгыльләнә башлый.

Шәрекъ тәңкәләре өстенлек иткән нумизматик коллекцияләр аеруча киң таралыш ала. Аларның хуҗалары — П.И.Пото, Ф.И.Эрдман, К.К.Клаус, М.П.Молоствов, Д.И.Неелов, А.И.Артемьев.

19 йөзнең 1 нче яртысында Казанда К. б-н барон Е.Врангель, кенәз Дадиани, шәркыятьче галим И.Н.Березин, тарихчы С.В.Ешевский, табиб Н.А.Толмачёв, университет казначее В.К.Савельев шөгыльләнәләр. 19 йөзнең 1 нче яртысына караган коллекцияләрнең берсе дә тулаем сакланмаган. Төрле тупланмаларның аерым өлешләре һәм кайбер әйберләр башка хуҗаларга һәм өлешчә университетка күчәләр. Казанда 4 нче археологлар съезды (1877) үткәрелеп, *Археология, тарих* һәм *этнография җәмгыяте* оештырылганнан соң Казанның барлык күренекле коллекционерлары диярлек аның әгъзалары була. К. тарих, археол. һәм этнография юнәлешләренең киң җәелүенә көчле этәргеч бирә. Җәмгыятьнең фәнни һәм коллекцияләр туплау эшчәнлеге эш тематикасына һәм методикасына, коллекцияләрнең төрләрен сайлауга, күп тупланмаларның охшаш типларын булдыруга йогынты ясый. Җирле К.нең төп үзенчәлеге — аның археол., нумизматик һәм этнографик коллекцияләрдән, ш.у. язма ядкәрләрдән, китаплар, борынгы көнкүреш әйберләре, картографик материаллардан, сынлы һәм гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләреннән торган, башлыча, «тарихи» җыелмалар тәшкил итүендә. Идел буе Болгар дәүләте ядкәрләренә һәм Идел буе халыкларының (беренче чиратта, Казан татарларының) традицион мәдәниятенә нисбәтле әйберләргә аеруча игътибар ителә. Җирле мирас б-н кызыксынуга өстенлек бирү б-н беррәттән, башка мәдәни-географик мәдәният, мәс., Шәрекъ, Көнбатыш Европа, борынгы рус, антик, борынгы Мисыр әйберләре коллекцияләрен туплау да киң колач ала. Шәрекънең борынгы һәм хәзерге мәдәнияте Казанда К.дә зур урын били; коллекцияләрнең төрле геогр. терр-ялардан (Кытай, Япония, Себер, Урта Азия, Персия һ.б.) туплануы һәм аларның составы (декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре, дини гыйбадәт кылу әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары) шуны чагылдыра.

А.Ф.Лихачёв, Н.Ф.Высоцкий, В.И.Заусайлов шактый зур тупланмалар (берничә дистә мең данә әйбер) җыйныйлар. Замандашлары бу коллекцияләрне хосусый музейлар дип атыйлар. Л.О.Сиклер һәм Н.Ф.Катанов танылган коллекционерлар булалар.

А.Ф.Лихачёв тупланмасында 15 мең археол., этнография һәм тарихи-көнкүреш әйберләре; 24 меңнән артык Болгар, Алтын Урда, Греция, Рим һәм Персия тәңкә акчалары, 315 медаль; 1500 китаптан, кульязмалар, брошюралар, тарих, археол. һәм сәнгать буенча атлас карталарыннан тупланган китапханә; Көнбатыш Европа һәм рус рәссамнарының киндер тукымага ясалган 400 дән артык әсәре һәм сынлы сәнгать коллекциясе; пыяладан һәм фарфордан ясалган эшләнмәләр исәпләнә. Тупланмада ш.у. дворян Лихачёвлар нәселеннән килгән мирасның бер өлеше урын ала.

Н.Ф.Высоцкийның зур археол. (Идел-Кама төбәге, Россиянең башка өлкәләре һәм Көнбатыш Европа, борынгы Болгар, таш һәм бронза гасырлар табылдыклары), антик керамика әсәрләре, русларның 17–19 йөзләргә караган көнкүреш кирәк-яраклары коллекциясе була. Шәрекъ мәдәнияте бүлеге (шаман һәм буддистларның табыну әйберләре, Кытай һәм Япония фарфоры, тәңкә акчалар) үзенең байлыгы б-н аерылып тора.

В.И.Заусайлов тупланмасы тулысынча диярлек, башлыча таш, бронза һәм тимер гасырларга хас, Казан коллекцияләре өчен гадәти булмаган охшаш бертөрле составлы археол. әйберләрдән (11 меңләп) гыйбарәт була.

Л.О.Сиклер гамәли-бизәлеш сәнгатенә караган 5 меңгә якын предметтан: рус халкының борынгы әйберләреннән; марилар һәм чуашларның өс киемнәре үрнәкләреннән; Казан татарларының өс киемнәре һәм көнкүреш, зәркән бизәнү әйберләреннән (коллекцияләрнең аеруча кыйммәтле өлеше), чигү эшләреннән бай коллекция туплый. Л.О.Сиклер ш.у. Болгар һәм Биләрнең борынгы әйберләре, Шәрекъ акчалары коллекцияләренә, Көнчыгыш тәңкәләре, рус, татар һәм Шәрекъ кульязма китаплары булган китапханәгә; Рус һәм Көнбатыш Европа осталарының зур булмаган сәнгать әсәрләре тупланмасына ия була.

Н.Ф.Катанов Шәрекъне өйрәнү юнәлеше буенча Көнчыгыш нумизматикасы, китапханә, шәмаилләрдән, шаманнар һәм буддистларның табыну әйберләреннән, Себер, Кытай, Монголия халыкларының этнографик материалларыннан зур тупланма булдыра. Н.Ф.Катанов коллекцияләре Казан руханилар академиясе музееның тарихи-этнографик материаллары нигезен тәшкил итә. Н.Ф.Катанов ш.у. Казан К.нең тарихын өйрәнүче беренче белгеч тә була.

19 йөз ахырыннан К. эшендә китаплар туплауга зур игътибар юнәлтелә. Казанның күп кенә китап сөючеләренең коллекцияләрендә язма ядкәрләр, сирәк документлар һәм шәхси архивлар туплануы (к. *Шәхси китапханәләр*) К.нең үзенчәлеген тәшкил итә.

Китапчылыкка һәм язма мәдәниятккә зур ихтирам — татар халкының укымышлы даирәсендә гадәти күренеш, сәүдәгәрләр, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре М.И.Юнысов, Г.М.Галиев (Баруди), С.М.Аитовларның берничә тупланмасы барлыкка килә. К.нең башка юнәлешләренә бу төбәктәге татарлар әллә ни игътибар итмиләр.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында О.С.Гейнс (Александрова), А.А.Лебедев, А.Г.Ге, А.М.Миронов, А.Ф.Мантель, Н.М.Сапожникованың сәнгати коллекцияләре туплана, алар, нигездә, сынлы сәнгать, графика, гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләреннән җыйнала.

Казан шәһәре фәнни-сәнәгый музеен һәм аның фондларын оештыруда һәм үстерүдә коллекционерлар зур роль уйный (к. *Татарстан Республикасы Милли музее*). 1895–1917 дә музей советы рәисләре, аның бүлекләре директорлары, Лихачёв бүлегенең попечительләр советы әгъзалары, саклаучылары арасында коллекционерлар — А.А.Штукенберг, В.И.Заусайлов, Н.Ф.Катанов, Ф.А.Лихачёв (А.Ф.Лихачёв улы), Р.В.Ризположенский һ.б., иганәче коллекционерлар — Д.И.Образцов, Ф.Т.Васильев, В.И.Заусайлов, Н.Ф.Катанов, Ф.А.Лихачёв һ.б. булалар.

Гомумән, Казан коллекционерлары өчен гыйльми фикерләү, җыючылык өлкәсе б-н генә чикләнмичә, тупланманы оештыруга, эзләнү методикасына һәм предметны өйрәнүгә фәнни яктан якын килү, төп нөсхәне охшаш әйбердән аера белү, коллекцияләрне системалаштыру һәм аларны нәшер итү үзенчәлеге хас. 20 йөз башында Казанда 100 гә якын коллекционер исәпләнә, алар арасында мәшһүр галимнәр, педагоглар, дин һәм сәясәт эшлеклеләре, иганәчеләр була.

19 йөзнең 60 нчы елларында — 20 йөз башында шәхси тупланмалардан берничә күргәзмә оештырыла: 1873–74 һәм 1891–92 еллардагы күргәзмәләр (төрле шәхесләр туплаган сынлы сәнгать әсәрләре күрсәтелә), 1890 елгы Казан фәнни-сәнәгый күргәзмәсе (В.И.Заусайлов, А.Ф.Лихачёв, Н.Ф.Высоцкийларның археол. коллекцияләре), 1912 ел-

гы Сәнгати археол.-этнографик күргәзмә (Л.О.Сиклер коллекцияләреннән оеша), рус һәм чит ил рәссамнарының шәхси эшләреннән (О.С.Гейнс тупланмасы) уеплау сәнгате әсәрләре һәм картиналар күргәзмәсе, 1916 елгы «Казанның сәнгати хәзинәләре» күргәзмәсе шәхси сәнгати коллекцияләрне күрсәтүдә күренекле чара була.

Совет хакимиятенең беренче елларында күп кенә шәхси тупланмалар конфискацияләнә һәм национализацияләнә.

1919 да музей эшләре һәм элеккеге сәнгать ядкәрләрен саклау эшләре буенча Бөтенроссия коллегиясе экспедициясе Казанда И.Э.Грабарь җитәкчелегендә Н.Ф.Катанов һәм Л.О.Сиклер коллекцияләрен сатып ала. Шәрекъ халыклары музеен төзү проекты күпләгән кыйммәтле коллекцияләрнең язмышында әһәмиятле роль уйный, аның беренче этабын гамәлгә ашырган «*Шәрекъ халыклары мәдәнияте күргәзмәсе*» оештырыла. Шәхси коллекцияләрдәге күп кенә ядкәрләр мәгълүм була, Н.Ф.Высоцкий тупланмасыннан кытай фарфоры һәм Шәрекъ тәңкә акчалары, Н.Ф.Катановның Алтын Урда һәм Болгар тәңкә акчалары коллекциясе, В.Ф.Смолинның Болгар чоры археол. әйберләр коллекциясе, Е.Е.Маловның кытай әйберләре коллекциясе сатып алына. Шулай ук күргәзмә экспонатлары арасына коллекционерлар М.Е.Евсевьев (Идел буе халыкларының этнографик коллекциясе), С.М.Галиев, Г.М.Галиев (Баруди), А.М.Миронов, Г.М.Залкинд һ.б.ның тупланмалары да керә. Күргәзмәдә беренче тапкыр татар халкы вәкилләре коллекцияләренең аерым өлешләре киң рәвештә тәкъдим ителә.

1938 дә галим-табиб, мәгариф эшлеклесе В.М.Флоринскийның китапханәсе, шәхси архивы, кытай фарфоры һ.б. коллекциясе булган зур тупланмасы табыла. Тупланма Казан ун-ты музеена һәм китапханәсенә, ТАССР Дәүләт архивына һәм Дәүләт фондына тапшырыла.

1930–40 еллар К. үсеше өчен уңайсыз шартлар б-н үзенчәлекле.

Алдагы 1950–80 елларда К. эшенең популярлыгы үсә, ул киң колач ала, әмма бу өлкәдә гадилеккә һәм һәвәскәрлеккә якынаю күзәтелә (филокартия, филателия, нумизматика).

1950 елларда ТАССР Дәүләт музеенда 60 тан артык әгъзасы булган Коллекционерлар клубы эшли.

20 йөзнең 2 нче яртысында Казанда аеруча күренекле коллекционерлар арх. В.В.Чумаков һәм Г.Н.*Вульфсон* эшчәнлеге игътибарга лаек.

Хәзерге вакытта Казанда калган коллекцияләр мирасы ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә, ТР Милли китапханәсендә һ.б. учреждениеләрдә саклана. Тупланмаларның аерым өлешләре ш.у. Мәскәү һәм Петербургның төрле китапханәләрендә, архивларында, музейларында урын ала. Борынгы шәхси коллекцияләр мирасының бер өлеше аерым хуҗаларда саклана.

Озакка сузылган өзеклектән соң, 20 йөз ахырында шәхси коллекцияләр яңадан күргәзмәгә куела башлый. 1999 да ТР Дәүләт музее ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее б-н бергәләп Александрова-Гейнска багышланган «Александров пассажы хуҗабикәсе» күргәзмәсен оештыра.

2000 дә ТР Дәүләт музееның 105 еллыгына багышлап, «Евразия мәдәният хәзинәләре системасында музей» дип аталган Бөтенроссия фәнни-практик конференциясе үткәрелә, анда «Социомәдәни феномен буларак казанлыларның шәхси коллекцияләре» секциясе һәм «Иске Казан коллекционерлары» дигән темага күргәзмә эшли, соңгысында Казан музейлары һәм китапханәләре фондларыннан 19 йөз ахыры — 20 йөз башына караган 20 дән артык шәхси тупланманың аерым өлешләре күрсәтелә.

*Әд.:* Краткий указатель Художественной этнографическо-археологической выставки: собрание Л.О.Сиклера. К., 1912; Выставка картин «Художественные сокровища Казани»: Каталог. П., 1916; Каталог выставки частной коллекции картин и гравюр русских и иностранных художников. К., 1916; Выставка культуры народов Востока: Путеводитель по выставке. К., 1920; Катанов Н.Ф. Несколько слов о казанских коллекционерах // Казан. музейный вестн. 1920. № 7–8; Музей в системе ценностей евразийской культуры: Материалы Всерос. науч.-практ. конф. 25–28 сент. 2000 г. К., 2000; Хозяйка Александровского пассажа: Материалы о жизни и художественной коллекции О.С.Гейнс (Александровой). К., 2001.

*Е.И.Карташёва.*


**КО́ЛЛИ** Роберт Андреевич (25.6.1845, Мәскәү губ. Петровско-Разумовское а. — 2.8.1891, Мәскәү), физик, физика д-ры (1878). 1869 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли (1873 тән). 1876–87 дә Казан ун-тында, проф. (1878). 1887 дән Мәскәү ун-ты профессоры. Тикшеренүләре электр тәгълиматы өлкәсенә, электролитларда поляризациягә, электромагнитик тирбәнешләрне өйрәнүгә карый. К. — Казанда физика лаб-ясенә нигез салучы, студентлар б-н практик дәресләрне оештыручы һәм экспериментлар куючы.

Хезм.: Опыты над электрокинетическим действием поляризационного тока // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1875. Т .7 (автордаш); О существовании пондеро-электрокинетической части энергии электромагнитного поля // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1881. Т. 13, вып. 5.

**КОЛМА́К** (Humulus), киндерчәләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык ике өйле үрмәле үсемлекләр ыругы. 2 төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралган. Дымлы куаклыкларда очрый. Культурада гади К. (H.lupulus) очрый — шнурсыман тамырлы күпьеллык үләнчел лиана. Сабагы үрмәле, озынлыгы 3–5 *м*. Яфраклары каршыдаш, 8–15 *см* озынлыкта һәм шундый ук киңлектә, 3–5 аерчалы, яфрак төбе йөрәксыман формада. Югарыдагы яфраклары виграк һәм тоташ. Серкәч чәчәкләре себеркәчсыман чәчәк оешмасында (диаметры 8–9 *мм*), җимешлек чәчәкләре — башаксыман чәчәк төркемендә урнашкан, алар яфрак эченнән чыгалар. Июнь–августта чәчәк ата, җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Чәчәк яны яфраклары җимешләр өлгергәндә 14–18 *мм* га кадәр үсеп җәелә, элпәләнә һәм башаксыман чәчәк төркеме 2,5–3,5 *см* озынлыктагы күркәгә әверелә. Җимеше — спиральсыман бөтерелгән бөбәкле чикләвек. К. күркәләре сыра кайнату сәнәгатендә чимал буларак, медицинада, икмәк пешерүдә, косметикада кулланыла. Составында 8–10% әче, дуплау һәм хуш исле матдәләр бар. Күркәләрнең уңышы 1 *га* дан 12–13 *ц* (20–22 *ц* га кадәр) чыга. К. кара туфраклы һәм җиңелчә әче кәсле-көлсу туфракларда, бик эссе булмаган һәм уртача дымлы җәйге шартларда, вертикаль терәкләр буйлап яхшы үсә, салынкы килеш үсеше начарлана. Корткычлары: пәрәвез талпаны, колмак гөбләсе, каты корт һ.б.; авырулары — ялган ончыл чык. К. куаклары 20–30 ел яши. ТРда декоратив үсемлек буларак үстерелә.

*Әд.:* Либацкий В.П. Хмелеводство. М., 1984; Атлас сосудистых растений Татарстана. К., 2008.

**КОЛМА́К ҮЛӘ́Н**, (Calystegia), уралма сабаклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр. 25 кә якын төре билгеле, нигездә, ике ярымшарның да уртача поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — койма буе К.ү. (C. sepium) бар. Сирәк кенә барлык районнарда да очрый. Елга, күл ярлары буенда, кырларда, куаклар арасында үсә. Сабагы үрмәле, 150–300 *см* озынлыкта. Тамыр системасы вертикаль һәм горизонталь шнурсыман тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, өчпочмаклы-уксыман, озын саплы. Чәчәкләре берле, ак яки аксыл-алсу, бүрәнкәсыман, яфрак куентыгында урнашкан. Җимеше — шарсыман, өч орлыклы тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Июль–сентябрьдә җимеш бирә. Үсемлек составында сапониннар, алкалоидлар, С витамины бар. Халык медицинасында яфраклары авыртуны басу өчен һәм яра төзәтү чарасы буларак кулланыла. Ачы тәме бар. Бөтен өлешләре дә агулы. Декоратив, баллы үсемлек.



Колмак үлән.

*Ф.З.Вәлиев.*

**КОЛМАКО́В** Иван Никитич (1861, Курск ш. — 1907, Казан), архитектор, инженер, 1886 елда Гражданлык инженерлары



И.Н.Колмаков. Шәһәр музее. Казан. 1895. 1900 елгы фоторәсем.



Х.М. Колмәмәт.





И.К. К о л м о г о р ц е в а. 1. «Әҗем мәчете». Төсле офорт, акватинта. 1979. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Төньяк-көнчыгыш яктан Казан Кремле күренеше». Офорт. 1996.

ин-тын тәмамлый. 1887–91 дә — Ровно шәһәренең Төзелеш комиссиясендә, 1891–94 тә — Казан шәһәре архитекторы, 1895–99 да Казан губерна идарәсенең Төзелеш бүлегендә эшли. 1899–1906 елларда Казан шәһәре архитекторы, бер үк вакытта, 1899–1903 тә — Казан ун-ты архитекторы. Иван мәйданында арх. О.Шервуд проекты буенча император Александр II гә һәйкәл кую б-н җитәкчелек итә. Гостиный дворның төньяк өлешен музейга яраклаштырып торгыза (1895). 1896–1901 дә Мәскәү архитекторы К.М.Быковский проекты буенча, проектка үзгәрешләр кертеп, ун-тның яңа клиникаларын төзи. Казан чукрак-телсезләр уч-щесе (1905) һ.б. биналарның проектлары авторы. 1906 дан соң хезмәттән китә, архит.-техник бюро оештыра, Казанда бертуган Цейтерлар б-н бергә силикат кирпеч з-дына хуҗа була. Эклектика һәм модерн юнәлешендә эшли.

*Әд.:* М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999. *Л.М.Мортазина.*

**КОЛМАКЧЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 75 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 336 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 60%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да җамигъ мәчет, 2 тегермән, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 831 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1956 ның 22 сентябреннән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 1004, 1897 дә — 1059, 1908 дә — 1106, 1920 дә — 1156, 1926 да — 449, 1949 да — 717, 1958 дә — 664, 1979 да — 625, 1989 да — 405, 2002 дә — 433 кеше.

**КОЛМӘМӘ́Т** (чын фамилиясе Азимов) Хәмит Мөхәммәт улы (15.6.1895, Казан — 10.1.1942, шунда ук), драма актёры. Сәхнә эшчәнлеген 1915 елда «Сәйяр» труппасында башлап җибәрә. Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында эшли, 1922 дән Татар акад. театрында, 1939 дан Татарстан Респ-ка күчмә театрында. Характерлы рольләр уйнаучы актёр. К. шактый гына зур рольләр башкара, алар арасында Исмәгыйль («Галиябану», М.Фәйзи), Хан («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Кара фикер («Ике фикер», Г.Коләхмәтов), Пристав («Сакла, шартламасын!», К.Тинчурин), Земляника («Ревизор», Н.В.Гоголь), Татар кешесе («Тормыш төбендә», М.Горький), Яго, Клавдий («Отелло», «Гамлет», У.Шекспир) һ.б. образлар бар.

**КОЛМӘ́Т** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 8 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 123 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1719–22 еллардан мәгълүм. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 729,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәт — Муллино волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 352, 1913 тә — 536, 1920 дә — 546, 1926 да — 481, 1938 дә — 521, 1949 да — 423, 1958 дә — 278, 1970 тә — 230, 1979 да — 192, 1989 да — 152, 2002 дә — 148 кеше.

**КОЛМОГО́РЦЕВА** Ирина Константиновна (5.7.1930, Свердловск ш.), график, китап рәссамы, плакатчы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1981), ТРның халык рәссамы (2005). И.Фёдоров исем. Украина полиграфия ин-тын тәмамлый (Львов ш., 1953). 1957 елдан Казанда. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1960). Татарстанда әйдәп баручы график-рәссамнарның берсе. Күптөрле техника кулланып эшләүче гравюра остасы: линогравюра, литография, офорт, монотипия; респ-када күп төсләр б-н эшләүче аз санлы гравёрларның берсе. Станлы рәсем өлкәсендә карандаш, тушь, акварель, пастель техникасын куллана. Рәссам үзенчәлекле эш алымы, форма-бизәкләрне гадиләштерә белүе, кәгазь яссылыгында бизәкле чишелешләр табуы, хисләр байлыгы, халык сәнгатен, лубокны, бала күңелен тирән аңлап иҗат итүе һәм үзенчә ачып бирүе б-н аерылып тора. К. шәһәр пейзажы жанрына мөрәҗәгать итә — «Казан» сериясе (төсле офорт, 1970 еллар; офорт, 1990), «Алабуга» (офорт, 1980 еллар), рус шәһәрләре архит-расы пейзажы (фломастер, 1970); тарихи портретлар — «Пушкин Казанда» (төсле офорт), «Надежда Дурова» триптихы (төсле офорт, 1991). К. ш.у. М.Цветаевага, Г.Тукайга (төсле офорт, төсле автолитография, 1990 еллар) һ.б.га багышланган серияләр тудыра. Ул Рәссамнар берлеге каршындагы Казан агитплакат остаханәсе б-н хезмәттәшлек итә (1960–93), күпчелеге сатирик темаларга багышланган 100 гә якын плакат ясый. Китап графикасы К.ның иҗат эшчәнлегендә әһәмиятле урын алып тора. Аның тарафыннан Казан, Мәскәү, Свердловск, Львов, Киев нәшриятлары өчен 100 дән артык исемдәге китаплар бизәлә. К. — Казанда китап бизәүдә гравюра техникасын кулланучы (линогравюра, офорт) сирәк рәссамнарның берсе. «Кызыл Хач» халыкара плакатлар конкурсы дипломанты (Мәскәү, 1983).




И.К. К о л м о г о р ц е в а. «Гөлчәчәк» әкияте китабы тышлыгы эскизы. Төсле линогравюра. 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Республика, төбәк, бөтенроссия, бөтенсоюз, халыкара күргәзмәләрдә катнаша (1957 дән). Аерым күргәзмәләре Казанда (1980, 2000, 2002), Әлмәттә (1980) уздырыла.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, А.М.Горькийның әдәби-мемориал музеенда, Габдулла Тукай музеенда, Әлмәт картиналар галереясында, Марина һәм Анастасия Цветаевалар музеенда (Владимир өлкәсе Александров ш.), «Бородино сугышы» музей-панорамасында (Мәскәү), Н.А.Дурова музей-утарында (Алабуга ш.), М.Цветаева әдәби музеенда (Алабуга ш.), Сиэтлдагы Шәһәр музеенда (АКШ) саклана. ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исем. бүләге лауреаты (2007).

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись. Скульптура. Графика. М., 1978; ш у л у к. Художники Советской Татарии. К.,

1984; Улемнова О.Л. Палитра зрелого мастера // Казань. 2001. № 7.

*О.Л.Улемнова.*

**КОЛМӨХӘММӘ́Д** (Киләхмәд, Колмәмәт) (?-1503), карачы бәк, күренекле сәясәт эшлеклесе, Казан ханлыгының Мәскәү яклы аксөякләре лидерларының берсе. Тарихчы М.Г.Худяков аны «...тирән акылга, хәйләкәрлеккә, көчле ихтыярга ия һәм ... бик намуслы кеше» буларак билгеләп үтә. *Мөхәммәдәмин ханга* каршы булган «көнчыгыш» партиянең башында тора, аны бәреп төшерүгә булышлык итә. Казан тәхетенә Себер патшасы улы *Мамыкны* чакыра. Алар арасында килеп чыккан каршылыклар аркасында кулга алына. Төрмәдән азат ителгәннән соң К. Мамык ханның Арчага оештырылган явында катнаша, яу вакытында башка Казан бәкләре б-н бергә ханны калдырып китә, Казанга кайта һәм аксөякләр өнәмәгән ханны бәреп төшерүне оештыра. Мәскәү яклылар тарафына күчеп һәм Мәскәү б-н мөнәсәбәтләрен җайга салып, ул Казанга Мөхәммәдәминне кайтаруга каршы чыга. Габделлатыйф хан идарә иткән чорда (1495–1502) К. илнең сәяси тормышында әһәмиятле роль уйнавын дәвам итә. Хан б-н үзара каршылыклар килеп чыгу аркасында 1501 ел ахырында К. Мәскәүгә китә, шуның нәтиҗәсендә Габделлатыйф хан бәреп төшерелә. Мөхәммәдәмин хан тәхеткә кайтканнан соң К. җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVII вв. К., 1995.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КОЛМӨХӘММӘ́Д** бине Солтанбәк әл-Ушмави әл-Болгари (1775, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе Түбән Карамалы а. — 1845, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе Кормантау а.), шагыйрь. Татар һәм фарсы телләрендә яза. Казан губернасы Казан өязе Иске Ашыт авылы мәдрәсәсендә укый. Казан губернасы Мамадыш өязе Югары Ошма (1803–30), Ак чишмә (1810), Олыяз (1815) авылларында имам булып тора. 1830 да Оренбург губернасына күчә, Кормантау авылы мәдрәсәсендә илаһият фәннәре укыта. «Нәсыйхәте Шәһре Казан» (фарсы телендә), «Мөһиммәт ас-сыйбъян» («Сабыйларның бурычлары», 1810), «Тәгъриф әл-вилдан» («Балаларга аңлатма», 1815) исемле үгет-нәсыйхәт б-н сугарылган шигырь һәм поэмалар авторы. Әсәрләрендә әхлакый-фәлсәфи проблемаларны, тәрбия, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен күтәрә. Лирик шигырьләр циклын яза (бүгенгә табылмаган). К.нең иҗатын М.И.Әхмәтҗанов, Г.Н.Зәйниева өйрәнә.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Әхмәтҗанов М.И. Татар кулъязма китабы. К., 2000; Зәйниева Г.Н. Шагыйрь Кол Мөхәммәд тормышына караган яңа мәгълүматлар (XVIII йөз ахыры — XIX йөз башы) // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре. К., 2002.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**КО́ЛОБОВ** Николай Васильевич (3.11.1911, Сембер губ. Зур Ключище а. — 26.3.1993, Казан), метеоролог, климатолог, геогр. фән. д-ры (1966), проф. (1968), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1936), Казан аэропорты метеобюросы башлыгы. 1937 елдан Казан ун-тында, метеорология һәм климатология каф. мөдире (1952–78), геогр. ф-ты деканы (1972–78). Хезмәтләре метеорология һәм климатологиягә карый. Җил режимы, табигый күренешләрнең экстремаль чагылышлары (атм. һәм туфрак корылыклары) мәсьәләләре б-н шөгыльләнә, аларның Татарстан терр-ясендәге физик табигатен аңлата. Идел буе сусаклагычларының яр буе районнарының климатына һәм гидрометеорология режимына тәэсирен өйрәнү буенча берничә экспедиция оештыра (1950–60 еллар). К. — глобаль һәм зур масштаблы циркуляция күренешләре, башлыча, циклон эшчәнлеге буенча хезмәтләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Метеобюро башлыгы буларак, 4 нче һава армиясен катлаулы һава шартларында метеофаразлар б-н тәэмин итүдә катнаша. Октябрь Рев-циясе, өч 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ветровой режим Татарии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116, кн. 3; Вопросы климата Среднего Поволжья: Автореф. дис. ... Пермь, 1966. Климат Среднего Поволжья. К., 1968; Засухи на территории Татарской АССР. К., 1980 (автордаш); Флуктуации циклонических процессов в Северном полушарии Земли. К., 1984 (автордаш).

*Әд.:* Верещагин М.А. Николай Васильевич Колобов. 1911–1993. К., 2001; Переведенцев Ю.П. Метеорология в Казанском университете: становление, развитие, основные достижения. К., 2001. *М.А.Верещагин.*

**КОЛО́ДИН** Михаил Андреевич (15.11.1917, Самара губ., Бозаулык өязе Алексеевка а. — 28.3.1978, Ульянов ш.), журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1944). 1944–53 елларда Куйбышев өлкәсе Таволжск МТСы политбүлеге газетасы хезмәткәре, район газетасының җаваплы сәркәтибе, ВЛКСМның Оренбург өлкә ком-ты инструкторы һәм секретаре, ш.у. КПСС ҮК пропаганда бүлеге инструкторы булып эшли. 1953–63 тә — «Советская Татария», 1963–71 дә — «Новгородская правда», 1971–78 дә — «Ульяновская правда» г-таларының баш мөхәррире. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, РСФСР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Ш.Н.Мулаянов.*

**КОЛОКО́ЛЬНИКОВ ЙОРТЫ́**, Казанда классицизм архит-расы истәлеге. Казан сәүдәгәре Н.Н.Колокольниковның торак утары; 1836 елда Постаучылар бистәсендә арх. Ф.И.Петонди проекты буенча төзелә. Ике катлы, антресольле, төп фасады Георгиевский урамына (хәзерге Петербург ур.) караган торак йорт янәшәсендә хуҗалык корылмалары, түрдә бакча була.

П-рәвешле йортның аскы катындагы складлар сәүдә залларыннан коридор б-н бүлеп алына, югарыда бер рәткә тезелгән торак бүлмәләре урнаша. Кибеткә керү ишеге фасадның үзәк өлешендә эшләнгән, 2 нче катка ишегалды ягыннан күтәрелгәннәр.



Н.Н. Колокольников йорты. Казан. Арх. Ф.И. Петонди. 1836. 20 йөз башы фоторәсеме.

Урамга карап торган төп фасад биналар салу сәнгатендәге төрле алымнар кулланылуы б-н игътибарны җәлеп итә. Композициянең эстетик тәэсирлелеге әүвәлге классицизм стилендә башкарылган.

1879 дан йорт штабс-ротмистр хатыны К.П.Лихачёва карамагына күчә. Шул ук елда ишегалды түренә Лихачёвлар аракы заводының безнең көннәргә кадәр сакланмаган ике катлы бинасы төзелә. 1912 дә техник Ф.Захаров проекты буенча төп торак бинага Чабакса осталары эшләгән чуен баганаларга терәлеп торган бер кыеклы түбә астында, ачык балкон-террасалы көнбатыш фасадның бөтен буена беркатлы кирпеч йорт кушып салына (1990 елларда юкка чыга). Соңрак ишегалдына керү капкасының сул ягында бер катлы таш кибет, төп йортның уң ягына бер катлы кирпеч корылма кушып салына (1912–13 тә күрше җир кишәрлеген сатып алган йорт биләүче М.Б.Терёшинга сатыла).

Йортның төрле елларда һәм 20 йөз ахырында юкка чыккан флигельләрендә И.Д.Цульцның буяуханәсе, Е.Гендельның махсус серкә з-ды, итек тегү остаханәсе, Бабушкинаның кием тегү мәктәбе, 24 нче хосусый мәктәп, «Т.Селиванов һәм уллары»ның йомырка порошогы җитештерү з-ды һ.б. эшли. К.й. 2005 тә юкка чыга.

*Әд.:* Адресная книга Казани. К., 1895; Вся Казань. К., 1910; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. К., 1993.

*Л.М.Мортазина, Г.И.Середа.*

**КОЛО́НИЯЛӘШТЕРҮ**, яуланган яки буш яткан җирләргә яшәү өчен килеп утыру һәм ул җирләрне хуҗалыкчыл максатта үзләштерү. Урта гасырларның элгәреге чорында кабиләләрнең зур күләмле күченүләре (к. *Халыкларның бөек күчеше*) Евразияне, ш.и. Казан төбәген К.гә башлангыч бирә. 7–9 йөзләрдә болгарлар һ.б. төрки телле кабиләләр акрынлап фин-угор һәм төрки телле кабиләләр яшәгән Идел-Чулман буйлары һәм Вятка җире терр-яләрен үзләштерә. 13–14 йөзләрдә монголларның яулап алулары (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*) нәтиҗәсендә Идел буе Болгар дәүләтенең төньяк-көнчыгыш читләрен К. көчәя, анда соңрак *Казан бәклеге* оеша. 14 йөздән Урта Идел буенда стихияле рәвештә руслар таралып урнаша башлый. *Казан ханлыгы* һәм *Әстерхан ханлыгы* яулангannan соң бу терр-яләрне русларның К.е массачыл һәм оешкан төс ала. К. процессы еш кына җирле халыкны кыру яки аны уңайсыз җирләргә кысрыклап чыга-




Н.Г. Колосов.

ру б-н бергә бара (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56)*). Казан төбәген К. процессында рус хөкүмәте хәлиткеч роль уйный. Ул, 16 йөзнең 2 нче яртысында төзелгән шәһәр-кальгаларга (Чабаксар, Козьмодемьянск, Царёвококшайск, Уржум, Малмыж, Цивильск һ.б.) таянып, татар феодалларының һәм ясаклы кешеләрнең күпчелек җирләрен тартып ала һәм ул җирләрдә патша сарае милкендәге рус торак пунктлары оештыра. Бер үк вакытта татарлар элеккеге эре икътисади һәм мәдәни үзәкләрдән кысрыклап чыгарыла, төп су (Идел һәм Чулман) һәм коры җир юлларыннан читкә куыла. Шундый сәясәт нәтиҗәсендә Казан тирәли 30 чакрым чамасы киңлектә читләштерү зонасы булдырыла. Элеккеге үзәк — Казан янында күчеп килгән йомышлы татарларның торак пунктлары оештырыла (к. *Иске Татар бистәсе*). Шул ук вакытта рус хөкүмәте яулап алынган җирләргә качак рус крепостной крәстияннәре килеп утыруны хуплый. 1570 еллар ахырына Казан төбәгендә руслар К.е 206 авылны һәм 60 бушап калган җирне колачлый (к. *Крәстияннәр*). Төбәк терр-ясендә оештырылган монастырьларга (Зилант, Спас-Преображение, Богородица, Раифа, Семиозёрный монастырьлары һ.б. — к. *Казан епархиясе*) зур җир биләмәләре бирелә. Казан төбәгендәге җирле халыкны ирексезләп *христианлаштыру* сәясәте татарларның бер өлешен үз җирләреннән китеп Кама аръягындагы һәм Урал алдындагы далалы (башлыча, буш яткан) җирләрне үзләштерергә мәҗбүр итә. Бер үк вакытта чик буе киртәләрен төзү барышында Кама аръягын руслар (өлешчә татарлар) тарафыннан К. башлана, бу чорда анда, рус торак пунктлары б-н беррәттән, татар, мари, чуаш һ.б. халыкларның авыллары барлыкка килә. 18 йөз уртасына таба төбәкне К. төгәлләнә, нәтиҗәдә барлык халыкның яртысын диярлек руслар тәшкил итә башлый.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н Г.С. Татар тарихы. К., 1992; Е ш е в с к и й С.В. Русская колонизация Северо-восточного края // Вестн. Европы. 1866. Т. 1, март; Ф и р с о в Н.А. Инородческое население прежнего Казанского царства в новый России до 1762 года и колонизация закамских земель в это время. К., 1869; П е р е т я т к о в и ч Г.И. Поволжье в XV и XVI веках: Очерки из истории колонизации края. Од., 1882; Ф и р с о в Н.Н. Колонизация Волжско-Камского края и связанная с ней политика. К., 1930; Е р м о л а е в И.П. Проблема колонизации Среднего Поволжья и Приуралья в русской историографии (Вторая половина XIX — начало XX в.): Дис. ... Куйбышев, 1965.

**КОЛОРА́ДО КОҢГЫЗЫ́** (Leptinotesa decemlineata), яфрагашарлар семьялыгыннан бөҗәк, бәрәңге һәм башка паслёнчаларны зарарлый. Озынлыгы 9–12 *мм* лы кызгылт-сары коңгыз, аркасының алгы өлешендә — кара таплар, канат өслегендә — озынча кара буйлар бар. Личинкасы 15 *мм* озынлыкта, кызгылт, башы һәм аяклары кара. Карантин объекты. Төньяк һәм Үзәк Америкада, Көнбатыш Африкада, Европада (Бөекбритания һәм Скандинавия илләреннән башка), Төркиядә, Россиядә (көнбатыш, үзәк һәм Европа өлешенең көньяк өлкәләрендә) таралган. Татарстанда беренче тапкыр 1975 елда теркәлә. Барлык районнарга тарала һәм бәрәңге өчен аеруча куркыныч корткыч булып санала. Республика шартларында бер ел эчендә 1–2 буыны үсеп өлгерә, яхшырак климатлы илләрдә 3–4 буынга кадәр үсә. Коңгызлар



Колорадо коңгызы. 1. Коңгыз; 2. Личинка.

туфракта кышлый. Язгы чорда бәрәңге, баклажан, помидор һ.б. паслёнчаларны зарарлыйлар, яфракларын ашыйлар. Көнгә 500 *м* арага оча алалар. Йомыркаларын (15–20 шәр данә, барлыгы 2,5 меңгә кадәр), гадәттә, бәрәңге яфрагына салалар. Личинкалары бәрәңге яфрагын тулысынча, кайбер очракта сабакларын да ашап бетерәләр.

Көрәш чаралары: энтомофаглар куллану; чәчүлекләрне битоксибациллин, бацикол (кышлаган коңгызларның күпләп чыгуы вакытында һәм 1 нче, 2 нче буын личинкалары барлыкка килгәндә), хлорофос, децис, моспилан, регент, цимбуш, амбуш, сумицидин (3 нче буын личинкалары барлыкка килгәндә) һ.б. препаратлар б-н эшкәртү.

Ш.у. к. *Бәрәңге, Бәрәңге үстерүчелек.*

*И.Н.Афанасьев.*

**КО́ЛОС** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 31 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Баравыш елгасы буенда. 2002 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, даими яшәүчеләр юк. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1946 га кадәр Рус Келәнчесе исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 49,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 151, 1897 дә — 166, 1908 дә — 195, 1920 дә — 168, 1926 да — 221, 1949 да — 219, 1958 дә — 183, 1970 тә — 65, 1989 да — 7 кеше.

**КОЛОСКО́ВА** Анна Васильевна (12.5.1914, Казан губ. Цивильск ш. — 18.4.1992, Казан), туфрак белгече, биол. фән. д-ры (1966), проф. (1968), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1974). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1936) Удмурт АССРның Игенчелек халык комис-ты Туфрак бюросында эшли. 1938 елдан Казан ун-тында, туфрак белеме һәм агрохимия каф. мөдире (1964–85). Хезмәтләре Татарстан туфракларына характеристика бирүгә һәм нәтиҗәле файдалануга, фән тарихын өйрәнүгә карый. А.х. җитештерүе процессында туфракның физик-химик һәм агрохимик үзенчәлекләре үзгәреше закончалыкларын өйрәнү буенча М.А.*Винокуровның* фәнни традицияләрен дәвам итә. Туфрак белемендә тикшеренүләрнең агрофизик юнәлешләрен торгызуга шактый өлеш кертә. Идел-Кама урман-дала туфракларында гумус халәтен, азот формаларын тасвирлый. Әлеге хезмәтләренең нәтиҗәсе туфракны культуралаштыру һәм уңдырышлылыгын күтәрү буенча күрсәтмә-тәкъдимнәргә нигез итеп алына. Татарстан, Башкортстан, Бурят АССРлар, Актүбә һәм Ульянов өлкәләре терр-ясендә туфракны тикшерү һәм картография эшләре буенча Казан ун-ты оештырган экспедицияләрнең фәнни җитәкчесе була. Бөтенсоюз туфрак белгечләре җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе (1970–89), әлеге җәмгыятьнең шәрәфле әгъзасы (1985 тән). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Агрофизическая характеристика почв Татарии. К., 1968; Чернозёмы Татарии. К., 1976 (автордаш); Влияние окультуривания на свойства почв Волжско-Камской лесостепи. К., 1981.

*Әд.:* Анна Васильевна Колоскова (к 70-летию со дня рождения) // Почвоведение. 1984. № 11.

*Ф.Г.Борһанов.*

**КО́ЛОСОВ** Николай Григорьевич (7(30) 1897, Сембер губ., Карсун өязе Красная Сосна а. — 1.3.1979, Ленинград), нейрогистолог, мед. фән. д-ры (1935), СССР МФА (1945), ФА (1953) мөхбир әгъзасы. Н.И.*Миславский* шәкерте. 1924 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1939 дан Сталинград, 1950 дән Саратов мед. ин-тларының гистология һәм эмбриология кафедралары мөдире. 1950-74 тә СССР ФАнең И.П.Павлов исем. Физиология ин-тының морфология лаб-ясендә ми морфологиясе бүлеге җитәкчесе (Ленинград), бер үк вакытта Ленинград ун-тының анатомия һәм гистология каф. мөдире. К. вегетатив нерв системасының һәм сизүчән нерв очларының нечкә төзелешен; эчке әгъзалар иннервациясе закончалыкларын, үзәк һәм үзәктән читтәге нерв системаларында синаптик бәйләнешләр төзелешен өйрәнә, вегетатив ганглияләрдәге нейрогеннарда рецепторлар барлыгын исбатлый. Лаборатория шартларында беренче тапкыр рефлектор дуга субстраты барлыгын ачыклый, вегетатив ганглияләрдә афферент нерв очларының нечкә төзелешен җентекләп өйрәнә. ЮНЕСКО каршындагы Баш миен тикшерү халыкара оешмасы әгъзасы. СССР МФАнең В.П.Воробьёв исем. бүләге лауреаты (1966), Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые главы по морфологии автономной нервной системы. Саратов, 1948; Иннервация внутренних органов и сердечно-сосудистой системы. М.–Л., 1954; Нервная система пищеварительного тракта позвоночных и человека. Л., 1968.

*Әд.:* А л а е в А.Н. С п е р а н с к а я В.С. Зарубежные и отечественные анатомы. Саратов, 1977.

**КО́ЛОСОВКА** (Уразбакты) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 8 *км* көнбатыштарак, Танай елгасы буенда. 2010 елда 209 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә; көнлекче булып эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.да тегермән була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1850,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 573, 1887 дә — 675, 1905 тә — 950, 1920 дә — 974, 1926 да — 1095, 1938 дә — 1103, 1949 да — 626, 1958 дә — 547, 1970 тә — 358, 1979 да — 230, 1989 да — 151, 2002 дә — 173 кеше.

**КОЛОТИ́НСКИЙ** Николай Диомидович (21.4.1867, Вятка губ. Усад ш. — 17.4.1927, Казан), хокук белгече. Дворяннар нәселеннән. 1889 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң шунда ук эшли: 1890–93 тә профессорлык стипендиаты, 1893–1918 дә приват-доцент, 1918–22 дә Рим хокукы каф. профессоры, 1925–26 да — эшчеләр ф-тында. Бер үк вакытта, 1905–18 дә Казан югары хатын-кызлар курсларында лекцияләр укый. ТАССР Статистика идарәсе каршындагы стат. курсларын оештыручыларның берсе һәм директоры (1922–24). 1925 тән Казан юридик курсларында укыта. Рим хокукы буенча дәреслекләр һәм программалар авторы.

Х е з м.: История римского права: Курс лекций: В 2 ч. К., 1894–95; Каталог библиотеки Общества любителей шахматной игры в г.Казани. К., 1908.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1. *Е.Б.Долгов.*

**КО́ЛОТОВ** Виктор Михайлович (3.7.1949, Юдино штп — 3.1.2000, Киев), спортчы, тренер (футбол), СССРның атказ. спорт остасы (1975), Украина ССРның атказ. тренеры (1986). Киев физкультура ин-тын тәмамлый (1974). «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә; тренерлары — Г.К.Востоков (1958 дән), А.М.*Дятлов* (1967 дән). «Чайка» (Яшел Үзән, 1967), «Трудовые резервы» (Казан, 1968), «Рубин» (Казан, 1968–70), «Динамо» (Киев, 1971–81) клублары командаларында уйный. СССР (1971, 1974–75, 1977) чемпионы, СССР Кубогы (1974, 1978), Европа кубоклары кубкы һәм суперкубок иясе (1975). СССР чемпионатларында көмеш (1972–73, 1976, 1978), бронза (1979), Европа чемпионатында (1972) көмеш, Олимпия уеннарында (1972, 1976) бронза медальләр ала. СССР җыелма командасы составында 55 матч уздыра, 22 туп кертә. Илнең иң яхшы 33 футболчысы исемлегенә керә (1971–72 дә, 1974–76 да — № 1; 1977 дә — № 2; 1973 тә — № 3). «Динамо» (Киев, 1972–76, 1978–79), СССР җыелма командалары (1975–76) капитаны. 1984–92 дә «Динамо» (Киев) командасы тренеры, 1993 тә «Борисфен» (Киев), 1996–97 дә «Прикарпатье» командаларында (Ивано-Франковск ш.), 1995–96, 1998–99 да Украинаның Олимпия җыелма командасында баш тренер. 1971 дән Киевта яши. Яшел Үзән шәһәрендәге «Комсомолец» стадионына К. исеме бирелә (2005), стадион алдында аңа һәйкәл куела (2004).

*Әд.:* М а к а р о в Д.А. «Рубин» (Казань): История и статистика. 1958–2000. К., 2001.

**КО́ЛПИКОВ** Михаил Васильевич (9.5.1897, Саратов губ., Кузнецк өязе Иске Мачим а. — 10.12.1964, Ленинград), урман белгече, а.х. фән. д-ры (1937), проф. (1938), Мари АССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1944, 1946). 1924 елда Казан а.х. һәм урманчылык ин-тын (шул ук елда — Казан ун-тының физика-матем. ф-тын) тәмамлый, шунда ук эшли. 1932–49 да Идел буе урман-техник ин-тында (Йошкар-Ола ш.), урманчылык каф. мөдире (1938 дән). Бер үк вакытта, 1937 дән Татарстан урман-тәҗрибә станциясендә өлкән фәнни хезмәткәр. 1949 дан Урал урман-техник ин-тында, 1953 тән — Ленинград урман-техник академиясендә. Хезмәтләре урман экологиясенә карый. Урман һәм урман хуҗалыгы чаралары тәэсирендә үзгәрүчән әйләнә-тирә мохиттәге бәйләнешләрне ачыклау буенча тикшерүләр үткәрә. Урман техникумнары өчен урманчылык буенча дәреслекләр авторы, «Урманчылык фәне» («Лесоводство», М., 1936; Вып. 4. 1962) дөньяның 5 теленә тәрҗемә ителгән. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Живой почвенный покров в лесу. Вып. 1. Споровые растения. К., 1933 (автордаш); Общее лесоводство с описанием лесных пород. М., 1944; Лесоводство с дендрологией. М.–Л., 1954; К вопросу повышения производительности таёжных лесов. Л., 1956.

**КОЛСӘ́ЕТ** авылы, Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында, Казан тимер юл станциясеннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә постау ф-касы, 2 бакалея кибете эшли. Монда тирә-юньдә билгеле зур он тарту тегермәне була, анда 70 тән артык эшче эшли һәм елга 700 мең сумлык он тартыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 438,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. 1984 нең 15 октябреннән Казанның Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 412, 1897 дә — 488, 1908 дә — 419, 1920 дә — 500, 1926 да — 798, 1938 дә — 667, 1949 да — 510, 1958 дә — 495, 1970 тә — 417, 1989 да — 211 кеше.

**КОЛУНЕ́Ц** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 8 *км* көнбатыштарак, Үләмә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 105 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1617–18 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский, Чудовка исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та Михаил-Архангел чиркәве, земство мәктәбе (1880 дә ачыла), 10 җил тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек, 2 йон тетү, май язу һәм йон-тукыма ману йортлары, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4019 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 225 ир-ат; 1859 да — 1381, 1897 дә — 2059, 1908 дә — 2190, 1920 дә — 2114, 1926 да — 1362, 1938 дә — 875, 1949 да — 522, 1958 дә — 451, 1970 тә — 403, 1979 да — 289, 1989 да — 186, 2002 дә — 163 кеше.

**КОЛХО́З**, күмәк хуҗалык, а.х. хезмәтен оештыру формасы, СССРда җәмәгать а.х. җитештерүен күмәкләп алып бару максатында крәстияннәрне берләштерү юлы б-н *крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* барышында төзелә. К.лар хәрәкәтенең төрле чорларында күмәк хуҗалыкларның 3 формасы оеша: *авыл хуҗалыгы коммунасы, җирне бергәләп эшкәртү ширкәте*, а.х. артеле. Алар арасындагы аерма җитештерү чараларын берләштерү дәрәҗәсе һәм табышларны бүлү тәртибе б-н билгеләнә.

1918 елда Казан губернасында беренчеләрдән булып Спас шәһәрендә хезмәт артеле, соңрак Яңа Чишмә а.х. артеле оештырыла. Совет хакимиятенең беренче елларында артельләр б-н берррәттән коммуналар һәм *совхозлар* барлыкка килә. 1918 нең августына кадәр төзелгән а.х. артельләре һәм коммуналар ак чехлар тарафыннан таратыла. Чехлар киткәннән соң К.лар яңадан оештырыла башлый. Аларның күпчелеге гади крәстиян инвентарен һәм эш терлекләрен берләштерү нигезендә барлыкка килә. Әмма 1920–23 тә а.х. тирән кризис хәлендә була. 1921 дә бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 0,4 *ц* гына тәшкил итә. 1913 ел б-н чагыштырганда бөртекле ашлык җыйнап алу 94% ка кими (112 млн. поттан 6,4 млн. потка кадәр). Республикада азык-төлек кризисы хөкем сөрә, азык-төлекнең даими рәвештә җитешмәве 1921–22 еллардагы ачлыкка сәбәп була (1923 нең 1 февраленә 1 млн. тирәсе кеше ачлык кичерә). Мондый шартларда К.лар санын арттыру тенденциясе билгеләнә, чөнки күп кенә крәстияннәр атларын, сыерларын, вак тер-

*1 нче таблица*

Татарстанда 1938–97 елларда авыл хуҗалыгының хезмәт ресурслары динамикасы, мең кеше

| Күрсәткечләр | Еллар | | | | | | | 1997, 1938 гә % ларда |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1938 | 1950 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 1997 | |
| Барлык а.х. пр-тиеләрендә эшләүче кеше | 832,0 | 544,7 | 417,9 | 372,6 | 340,0 | 257,6 | 222,0 | 26,6 |
| ш.и. колхозларда (күмәк хуҗалыкларда) | 815,4 | 528,4 | 363,0 | 295,3 | 259,0 | 166,8 | 27,5 | 3,4 |
| совхозларда, ярдәмче а.х. пр-тиеләрендә һ.б. | 16,6 | 16,3 | 54,0 | 77,3 | 81,0 | 91,8 | 40,2 | 242,2 |

*2 нче таблица*

Колхозларны эреләндерү динамикасы

| Күрсәткечләр | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1932 | 1940 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 |
| Колхозлар саны | 3707 | 3873 | 742 | 588 | 557 | 691 |
| | Бер колхозга уртача туры килә | | | | | |
| Сөрүлек җирләр, мең *га* | 0,6 | 0,8 | 3,5 | 4,2 | 4,2 | 3,1 |
| Мөгезле эре терлек, баш | 24 | 37 | 664 | 1162 | 1550 | 1182 |
| Дуңгызлар, баш | 9 | 26 | 705 | 1106 | 1190 | 766 |
| Сарыклар, баш | 38 | 103 | 1042 | 1136 | 1227 | 746 |
| Тракторлар, данә | 0,2 | 2,4 | 10 | 27 | 36 | 30 |
| Ашлык җыю комбайннары, данә | – | – | 8 | 13 | 15 | 14 |
| Йөк машиналары, данә | – | – | 7,6 | 12 | 14 | – |

лекләрен югалта, чәчүлек орлыксыз һәм инвентарьсыз кала, мохтаҗлык аларны артельләр төзүгә мәҗбүр итә. Ләкин мондый шартларда төзелгән К.лар озак яши алмый, күпчелеге таркала.

1928 нең 1 октябренә Татарстанда К.лар саны 333 кә җитә, һәр кантонда диярлек уңышларга ирешкән хуҗалыклар була: Чистай р-нында — «Агрокультура», Чаллыда — «Луч», Минзәләдә — «Дружба», Бөгелмәдә — Ленин исем., Актанышта — «Искра», Тәтештә — «Ярдәм». К.ларны башлап оештыручылар еш кына авыл активистлары (күбесенчә коммунистлар, комсомоллар) — чыгышлары буенча ярлы крәстияннәр һәм элекке кызыларміячеләр була.

1929 да ВКП(б) ҮК урыннардагы партия оешмаларын һәм совет органнарын бишьеллык ахырына күмәкләштерүне нигездә тәмамлауга юнәлтә. 1929 ның 1 маена К.лар барлык крәстиян хуҗалыкларының 1,52% ын берләштерсә, 1 декабрьгә бу күрсәткеч 17,8% ка җитә. 1930 ның гыйнварында гына да Татарстанда 500 дән артык яңа К. төзелә. Әмма 1930 ның беренче яртысында республикада К.лар хәрәкәте алар төзелешендәге ялгышлар һәм «арттырып җибәрүләр» б-н бәйле зур кыенлыклар кичерә. Күмәкләштерүнең югары темплары артыннан куып, К.га кергәндә еш кына крәстияннәрнең иреклелек принцибын бозу күзәтелә, урта хәллеләрне кулаклар исәбенә кертү очраклары да була. Болар барысы да крәстияннәрдә канәгатьсезлек тудыра. Урыннарда терлекләрне күпләп чала башлыйлар. Бу хәлдән файдаланып, *кулаклар* күмәкләштерү хәрәкәтенә каршы көрәштә күп төрле ысуллар кулланa. 1930 ның февралендә ВКП(б) ҮК тарафыннан а.х.н күмәкләштерүдә мәҗбүрләү һәм ашыгуны тыю, тоташ күмәкләштерү башланмаган урыннарда кулакларны эзәрлекләүне туктату, милли республикаларда җирле шартларны исәпкә алу турында күрсәтмәләр эшләнә; шул ук елның мартында ҮК «Колхозлар хәрәкәтендә партия юнәлеше бозылулар б-н көрәш турында» дип аталган карар кабул итә. Кимчелекләрне һәм ялгышларны төзәтү К.лар төзелешен тәртипкә салуга ярдәм итә. Бирелә «егерме биш меңчеләр», ягъни — шәһәрләрдән колхозларга даими эшкә җибәрелгән 25 мең алдынгы эшче мөһим роль уйный. Татарстанда алар К. производствосының иң җаваплы урыннарын җитәкли, 402 «егерме биш менче»нең 200 дән артыгы К. рәисләре булып сайлана.

1931 нең ахырына республикада крәстиян хуҗалыкларының төп өлешен күмәкләштерү бурычы хәл ителә. 3933 К. ярлылар һәм урта хәллеләрнең 322320 хуҗалыгын берләштерә. Авыл хуҗалыгы артеле кооперацияләрнең төп формасы булып кала, крәстиян берләшмәләренең башка формалары арасында аның өлеше 98,9% (1931) була. К.ларга 1361,9 мең *га*, ягъни республиканың барлык сөрү мәйданнарының 45% ы, барлык терлекнең 50,6% ы туры килә. 1930 да К.лар 16 млн. сумлык тулай продукция бирсә, 1931 дә бу күрсәткеч 87 млн. сумнан арта, ягъни Татарстандагы тулай а.х. продукциясе бәясенең 52,6% ын тәшкил итә. 1932 дә республика ВКП(б) ҮКна һәм совет хөкүмәтенә барлык а.х. эшләренең срогыннан алда үтәлүе турында хәбәр итә. Татарстанның алдынгы районнары исемлегенә Балтач, Чистай, Октябрь, Сарман, Саба, Арча р-ннары кертелә. 11 а.х. алдынгысы Татарстанның Соц. төзелеш Герое исеменә лаек була. 1932 нең ахырына республиканың соц. секторына барлык сөрүлекләрнең 77,5% ы туры килә, чәчү җирләре 3154,5 мең *га* га җитә. 1929 дан башлап дәүләт *машина-трактор станцияләре* (МТС) төзелә башлый, алар а.х.н үзгәртеп коруның терәк пунктларына әверелә. Авыл хуҗалыгында ВКП(б) карарларын гамәлгә ашыру өчен 53 МТСның барысында да сәяси бүлекләр оештырыла.

1933 нең 15 маенда Казанда Колхозчы-ударникларның беренче бөтентатар съезды үзенең эшен башлый, анда 3 меңләп делегат катнаша; «бөтенсоюз старостасы» М.И.Калинин съезда чыгыш ясап, Татарстан колхозчыларының а.х. продукциясе җитештерүне ике тапкыр арттыру теләгеен хуплый; ул Казан авыл р-нының «Заветы Ильича» һәм Арча р-нының «Авангард» к-зларында була, авыл советларының, артель идарәләренең эше б-н таныша, 1933 тә СССРның край, өлкә һәм республикалары соц. ярышында Татарстан колхозлары 1 нче урынны яулый, СССР ҮБК Президиумының 1934 ел 3 гыйнвар Указы нигезендә ТАССР Ленин ордены б-н бүләкләнә.

К.ларның оештыру-хуҗалык эшләрен ныгытуда һәм колхозчы крәстияннәрне тәрбияләүдә а.х. артеленең Үрнәк уставы зур әһәмияткә ия була, аны 1935 тә 2 нче Бөтенсоюз алдынгы колхозчылар съезды кабул итә. Аның нигезендә Татарстанның барлык К.ларында да, җирле шартларны исәпкә алып, үз уставлары эшләнә һәм гамәлгә кертелә.

К. үзенең эшчәнлеген колхозчыларның гомуми җыелышы кабул иткән колхоз уставы буенча алып бара. Уставта К. әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары күрсәтелә. Колхозчының күмәк хуҗалыктан чыгу турындагы гаризасы идарә һәм К. әгъзаларының гомуми җыелышы тарафыннан карала. К.дан вакытлыча китеп торган затлар, ш.у. картлык яки гариплек сәбәпле эштән чыгып, әмма К. терр-ясендә яшәүче колхозчылар К. әгъзасы булып калалар. 1937 дә Татарстанда 3847 К. булып, алар 416,7 мең (91,5%) крәстиян хуҗалыгын берләштерә, аларга сөрү җирләренең 94,4%ы туры килә.

2 нче бишьеллыкның соңгы елында (1937) Татарстан респ-ка өчен рекордлы уңыш ала: төрле культуралардан 200 млн. поттан артык, ягъни 1 *га* дан уртача 13,9 *ц* бөртекле ашлык җыйнала. Гомумән, 2 нче бишьеллыкта бөртеклеләрдән уңыш алу һәм уртача 1 *га* дан 9,7 *ц* (алдагы биш елда 6,4 *ц*) тәшкил итә. 1932–37 дә мөгезле эре терлекнең баш саны 2 тапкыр арта. Колхозчылар тормышы матди яктан яхшыра.

К.ларның бер өлешен үзгәрткәннән соң 1940 та республикада 3873 К. исәпләнә; алар а.х. биләмәләренең 95% ын били. Бөек Ватан сугышы елларында а.х. гаять зур зыян күрә. Шулай да гадәттән тыш кыен шартларда К.лар үзләренең яшәү сәләтен күрсәтәләр, сәнәгатьнең чималга, армия һәм халыкның азык-төлеккә булган ихтыяҗын канәгатьләндерәләр.

1958 дә МТСлар ремонт-техник станцияләр итеп үзгәртелә, ә аларның техникасы колхозларга сатып бирелә. Тик техникадан һәм хезмәт ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге кими, чөнки хуҗалыкларның күпчелеге зур булмый; нәтиҗәдә хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеше тоткарлана. 1960 еллардан К.ларны эреләндерү зарурлыгы туа.

1940 та СССРда 235,5 мең, 1960 та — 44 мең, 1971 дә — 32,3 мең К. була. Татарстанда К.лар саны: 1940 та — 3873, 1960 та — 742, 1990 да — 691, 1995 тә — 254. К.лар санының кимүе аларның бер өлешен совхозлар итеп үзгәртү б-н дә бәйле.

1971 дә ТАССРда К.лар а.х.ның 49% товарлыклы продукциясен җитештерә, (ш.и. 57% үсемлекчелек һәм 44% терлекчелек буенча). 1971–90 елларда тулай һәм товарлыклы продукциянең кайбер төрләрендә К.ларның өлеше 3 нче таблицада бирелә. Мөгезле эре терлекнең баш саны (мең баш) 145,2 дән (1941 дә) 898,4 кә (1986), (ш.и. сыерлар тиңдәшле рәвештә 48 дән 270,8 гә), дуңгызларның баш саны — 160,7 дән 608 гә, сарыкларның баш саны 398,8 дән 601 гә үсә.

*3 нче таблица*

1971–1990 елларда республиканың барлык категория хуҗалыклары җитештергән тулай һәм товарлыклы продукциядә колхозларның өлеше, %

| Культуралар | Колхозларның өлеше | |
|---|---|---|
| | гомуми продукциядә | товарлыклы продукциядә |
| Бөртекле ашлык | 53 | 50 |
| Шикәр чөгендере | 16 | 76 |
| Бәрәңге | 23 | 33 |
| Яшелчә | 26 | 35 |
| Ит | 33 | 41 |
| Сөт | 36 | 53 |
| Йомырка | 14 | 24 |
| Йон | 38 | 40 |

1990 да бөртекле ашлыкның товарлыклыгы — 70%, яшелчәнеке — 88%, итнеке — 97%, сөтнеке — 86%, йонныкы — 99%, техник культураларныкы 100% тәшкил итә. К. производствосының үсеше һәм югары дәрәҗәдә товарлыклы булуы К.ларның керемнәре күтәрелүгә сәбәп була. 100 *га* а.х. җирләренә исәпләгәндә, 1970–90 елларда тулай керем 2,6 тапкыр диярлек арта (313,8 млн. нан 822 млн. *га* кадәр).

К.лар кеременең үсеше җитештерүгә һәм мәдәни-көнкүреш төзелешенә капитал салуларны арттыру өчен шартлар тудыра. К. строе колхозчыларның матди һәм мәдәни хәлен өзлексез күтәрүне тәэмин итәргә омтыла. Рев-циягә кадәрге Россия крәстияннәренең кереме б-н чагыштырганда колхозчыларның реаль керемнәре (түләүсез уку һәм дәвалану, пенсияләр, социаль тәэминат, башка түләүләр һәм өстенлекләрне исәпкә алып) 1940 та 2,3 тапкыр, 1971 дә — 12, 1990 да 35 тапкыр арта. К.ларның үз интеллигенциясе формалаша. Аларда эшләүче югары һәм урта белемле белгечләрнең саны тулаем ил күләмендә 29 меңнән (1940) 390 меңгә (1970) кадәр җитә, ш.и. агрономнар, зоотехниклар, ветеринария табибләренең саны 19 меңнән 234 меңгә кадәр арта. Авыл хезмәтчәннәренең һөнәри-техник дәрәҗәсе күпкә үзгәрә. К.ларда төп хезмәткәрләрне механизаторлар тәшкил итә, 1972 нең 1 апреленә аларның саны 2052 мең кеше исәпләнә. Татарстан К.ларында 1990 еллардагы үзгәртеп коруларга кадәр эшләүчеләр саны 1938 ел б-н чагыштырганда 5 тапкыр диярлек кими, ә совхозларда һәм башка а.х. пр-тиеләрендә 5,5 тапкыр арта.

К.лар берничә тапкыр эреләндерелә һәм вагайтыла, аларның бер өлеше совхозлар итеп үзгәртелә, 1990 елларда хуҗалык итүнең башка формалары барлыкка килә. 1990 еллар башында ТРда 691, 1995 тә — 254, 2002 дә — 32, 2009 да 2 К. исәпләнә. 1990 да бер К.га уртача 4100 *га* а.х. җирләре, 1180 баш мөгезле эре терлек, 30 трактор, 14 ашлык җыю комбайны һәм 1190 мең сум тулай керем туры килә, 1993 тә тиңдәшле рәвештә 3350, 1075, 29, 12 һәм 1965.

Нәтиҗәдә а.х.ның тулай һәм товарлыклы продукциясендә К.лар өлеше кискен кими, төп продукция җитештерүчеләр булып яңа хокукый формалы пр-тиеләр (кооперативлар, күмәк предприятиеләр, АЖ һ.б.) санала.

*Әд.:* Куркин М.И., Зиятдинов Ф.С. Интенсификация и трудовые ресурсы колхозов. К., 1974; Зиятдинов Ф.С. Ресурсный потенциал агропромышленного комплекса: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001; Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). К., 2004.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**«КОЛХО́З БРИГА́ДАСЫ»**, журнал; к. «*Татарстан авыл хуҗалыгы*».

**«КОЛХО́З БРИГАДИРЫ́»**, журнал; к. «*Татарстан авыл хуҗалыгы*».

**«КОЛХО́З ГАЗЕ́ТАСЫ»**, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР Җир эшләре халык комис-ты органы. 1924 елның 25 апреленнән 1935 нең 30 августына кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 733 саны чыга. 1930 нең 25 февраленә кадәр «Крәстиян газеты» исеме б-н басыла. 1932 нең 18 октябрендә «*Авыл хуҗалыгы эшчесе*» г-тасы б-н берләштерелә. Төрле елларда мөхәррирләре — С.Фәйзуллин, Г.*Толымбай*, И.Агишев, Г.*Кушаев*, Т.Имаметдинов, Н.Мансуров, Г.Нәбиев. Актив авторлар арасында — И.Бибиков, Ш.Вәлиев, Г.Галиев, М.Гали, М.Парсин, К.Рәхим, Г.Төхфәт, А.Хәлим, М.Якуб. «К.г.»ның күчмә редакциясе 1931 нең 1 мартыннан 10 маена кадәр Сарман р-нында «Колхоз газетасы» чәчүдә» (28 сан, мөхәррире — Ш.Рәмзи), 1932 нең язында Актаныш р-нында «Колхоз газетасы» Актанышта» г-таларын чыгара. «К.г.»ның төп бүлекләре: «Советлар Союзында», «Чит илдә», «Татарстан хәбәрләре», «Казан яңалыклары», «Татарстан авыллары буйлап», «Республика басуларында», «Авыл хезмәткәрләренә киңәшләр». 1930 да тоташ күмәкләштерүләр башлангач, газета исемен алыштыра, «Колхозлар үсә», «Алдынгы колхозлар», «Колхоз ударниклары» һ.б. яңа рубрикалар ачыла. Төп игътибар авыл хуҗалыгында производство үсеше мәсьәләләренә бирелә. Агроном һәм ветеринар белгечләрнең язмалары даими басылып бара. Республиканың а.х. тормышы мәсьәләләре киң яктыртыла. Шулай ук илдә баручы индустрияләштерү турында материаллар басыла. Татарстан вәкилләренең Донбасс шахталарында эшләве турында мәкаләләр урын ала, редакция «*Донбасс эшчесе*» г-тасы б-н үзара сәхифәләр дә алмаша. «К.г.»нда авыл җирендә мәдәният, халык мәгарифе үсеше, наданлыкка каршы көрәш, авыл китапханәләре, клублары эшчәнлеге турында язмалар басыла. «К.г.» җанлы һәм аңлаешлы телдә төрле тематика, бай иллюстрацияләр б-н чыга. Яшь талантларга (К.Әлми, Х.Миңнеханов, М.Ногман, Г.Сәгъди һ.б.), шулай ук танылган әдипләрнең әсәрләренә дә (Ф.Кәрим, С.Рәфыйков, Г.Теләш) урын бирелә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОЛХО́З ПРА́ВДАСЫ»**, иҗтимагый-сәяси газета. КПССның Горький өлкә ком-ты һәм өлкә башкарма ком-тының Сергач р-ны терр.-производство колхоз-совхоз идарәсе органы. 1962 елның 22 апреленнән 1963 нең 31 мартына кадәр Сергач шәһәрендә (Түбән Новгород өлкәсе) татар телендә нәшер ителә, барысы 182 саны чыга. Төп рубрикалары: «Еллар һәм кешеләр», «Советлар Союзы буйлап», «Бер атнада дөнья», «Социалистик илләрдә», «Әхлак темасына», «Безнең заман кешесе», «Кеше хезмәте б-н күркәм», «Партия тормышы», «Әдәби сәхифә». Төп игътибар өлкәнең татар авыллары тормышына бирелә. Производство алдынгыларының уңышлары һәм тәҗрибәләре, мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлеге җентекләп яктыртыла. Танылган әдипләрнең һәм җирле әдәбиятчыларның әсәрләреннән өзекләр басыла. Шагыйрь А.Сәләхетдинов газета б-н актив хезмәттәшлек итә.

*Әд.:* Фәтхуллин К. Каурый каләм эзеннән (Нижгар татар журналистика тарихы. 1919–1963 еллар). Түбән Новгород, 2004.

*К.Р.Фәтхуллин.*

**«КОЛХО́З УДАРЧЫСЫ́»**, газета. БАССР Җир эшләре халык комис-ты органы. 1931 елның 19 апреленнән 1933 нең 13 мартына кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 56 саны чыга. Нашире — ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты «Коммуна» г-тасы. Төрле елларда мөхәррирләре — Р.Камал, И.Насыйров, М.Бикбулат, Г.Гозәй. Газета наданлыкка каршы көрәшкә бик зур игътибар бирә, 1932 ел хезмәт халкы арасында наданлыкны бетерү буенча соңгы ел булачак дип яза. Бу эштә комсомолларның роле ассызыклана. «Яңалиф дәресләрен өйрәнү» рубрикасында укырга-язарга өйрәнүчеләргә ярдәм итүче материаллар басыла. «К.у.» сәхифәләрендә колхоз һәм авыл хуҗалыгы артельләре тормышы, алдынгыларның хезмәте киң яктыртыла, хезмәттәге җитешсезлекләр, а.х. артельләре Уставын бозу тәнкыйтьләнә; агрономнар һәм ветеринарлар тәкъдимнәре басыла. Илдәге индустрияләштерү барышы турында материаллар, яңа төзелешләр турында фоторепортажлар урын ала. Әдәби бүлектә әдәби әсәрләрдән өзекләр бирелә. Язучы Г.Әмири әсәрләре еш басыла.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОЛХО́З ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Тобол шәһәр ком-ты һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның район советы органы. Тобол шәһәрендә (Омск өлкәсе) 1930 елның 23 апреленнән

1936 нең 11 февраленә кадәр татар телендә нәшер ителә, барысы 371 саны чыга. Беренче 42 саны (1931 нең 25 мартына кадәр) «Советский Север» (ВКП(б)ның Тобол округ ком-ты органы) г-тасына кушымта булып чыга. Наширләре — 1932 нең 1 февраленә кадәр — «Советский Север» г-тасы редакциясе, 1932 нең 7 апрелена кадәр — «Тобольская правда» г-тасы редакциясе. Газета суднолар төзү верфе һәм Тобол биофабрикасы татар эшчеләре, ш.у. районның авыл халкы өчен чыгарыла. Җирле иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышны чагылдыра. Төп игътибар колхоз һәм совхозлар эшчәнлегенә, алдынгы хуҗалыклар тәҗрибәсен пропагандалауга бирелә.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОЛХО́З ЯШЬЛӘРЕ́»**, айлык журнал. ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты органы. 1922–33 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәрә: 1922–24 тә — «Кызыл Шәрекъ яшьләре», 1924–25 тә — «Октябрь яшьләре», 1925–30 да — «Авыл яшьләре», 1930 дан — «К.я.». 1933 елда «Атака» ж-лы б-н берләштерелә. Ш.у.к. «*Бөек чор*».

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Нуруллина Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**КОЛХО́З-СОВХО́З ТЕА́ТРЛАРЫ**, авыл тамашачысына хезмәт күрсәтү өчен ачылган проф. күчмә театрлар. 1930 еллар башында барлыкка киләләр, проф. актёрлардан һәм һәвәскәрләр коллективларының аеруча талантлы катнашучыларыннан оешалар. РСФСР Мәгариф халык комис-тының «Колхоз-совхоз театрлары челтәрен киңәйтү турында»гы 1934 елгы 15 март карарыннан соң киң таралыш алалар. 1933 тән ТАССРда Татар акад. театрының беренче колхоз ф-лы эшли башлый. Труппаның нигезен Мәскәү Үзәк татар эшчеләр театры актёрлары тәшкил итә. 1933 тә — Әлмәт К.-с.т. (җитәкчесе Ф.Г.Ковалинский), 1934 тә Чистайда татар (җитәкчесе С.Г.Өметбаев) һәм рус (җитәкчесе С.И.Кальбин) күчмә районара К.-с.т. ачыла. 1935 тә Минзәлә (җитәкчесе Ф.Хәбибуллин), Мамадыш (җитәкчесе З.Сабитов), Бөгелмә (җитәкчесе Е.М.Волков), Алексеев, Баулы, Чаллы һәм Буа К.-с.т. эшли башлый. Аларның репертуарында Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Ш.Камалның «Томан арты», Ф.Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь»), В.П.Катаевның «Чәчәкләр юлы» («Дорога цветов»), А.Е.Корнейчукның «Платон Кречет», А.Н.Арбузовның «Яраткан алты кеше» («Шестеро любимых») һ.б.ның пьесалары була. Финанс ягы хәл ителмәү сәбәпле, театрлар даими эшләми, аларның урнашкан урыннары, актёрлар составы үзгәреп тора. Бөек Ватан сугышы елларында К.-с.т.ның саны кими. Сугыштан соңгы елларда сакланып калган театрлар стационарлаша, алар җирлегендә шәһәр театрлары оеша: Әлмәт татар, Минзәлә татар, Чистай рус драма театрлары (авыл тамашачысына хезмәт күрсәтү шарты б-н). Татар акад. театрының колхоз ф-лы 1944 елда Татарстан респ-касының Күчмә театры итеп үзгәртелә һәм Буа шәһәреннән (1940 елларда шунда урнашкан була) Казанга күчерелә (к. *Татар драма һәм комедия театры*).

**«КОЛХО́ЗНИК ТАТА́РИИ»** («Татарстан колхозчысы»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР Җир эшләре халык комис-ты органы. Казанда рус телендә 1924 елның 25 апреленнән 1933 нең 10 мартына кадәр нәшер ителә, барысы 628 сан. 1930 ның 28 февраленә кадәр «Новая деревня» исеме б-н чыга. Баштарак атнага бер, ә 1928 дән атнага ике тапкыр басыла башлый. Төрле елларда мөхәррирләре — П.Иванов, Е.Самсонов, Г.*Кушаев*, А.Хәлимов. Актив авторлары — Е.Гришин, П.Евгеньев, М.Еселев, С.Ильин, М.Назаров, А.Фёдоров, А.Френкель, М.Черноземный. Даими бүлекләре: «Дөнья буйлап», «Совет Республикалары Союзы буйлап», «Кызыл Татария буйлап», «Авыллар буйлап», «Күрше өлкәләр буйлап», «Безнең кооперация», «Крәстиян үзара ярдәмләшү комитетлары», «Мәгариф фронтында» һ.б. Тулаем күмәкләштерү башлангач, яңа рубрикалар барлыкка килә: «Колхоз басуларында», «Колхозлардан хатлар», «Колхозчы почтасы», «Авыл хуҗалыгы фәне һәм техникасы яңалыклары». А.х.ның төрле мәсьәләләре буенча язмалар басыла, аларны әзерләү өчен әйдәп баручы агрономнар һәм ветеринарлар җәлеп ителә. Кайвакыт мәкаләләргә өстәмә рәвештә хуҗалыкны алып бару буенча иллюстрацияле киңәшләр б-н кушымта-плакатлар чыгарыла. Газета авылдагы социаль үзгәртеп корулар идеясен, аерым хуҗалыкларны күмәкләштерүләрне пропагандалый, нык тормышлы хуҗалыклы крәстияннәрне репрессияләүне хуплап чыга. «Красная Татария» г-тасы б-н берлектә авыл хәбәрчеләре слётлары һәм семинарлары үткәрә. Басмада танылган җирле шагыйрь һәм язучыларның әсәрләре басыла: «Эшче һәм крәстияннәр иҗаты» бүлегендә яшь әдипләрнең язмалары бирелә. Авыл эшчәннәре тормышына багышланган «Колхозчы сәхифәсе» чыгарыла. Наданлыкка каршы көрәш, яшьләр арасына мәҗбүри башлангыч белем үтеп керү төп игътибар үзәгендә була.

*Әд.:* Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОЛХОЗЧЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Куйбышев өлкә ком-ты һәм Эшче депутатлар советының өлкә башкарма ком-ты органы. 1928 елның 6 октябреннән 1938 нең 28 мартына кадәр Куйбышев шәһәрендә (1935 кә кадәр Самара ш.) татар телендә 1170 саны нәшер ителә. 1930 ның 21 гыйнварына кадәр «Урта Идел» дип атала һәм ВКП(б)ның Урта Идел крае ком-ты һәм Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатлар советының край башкарма ком-ты органы. Төрле елларда мөхәррирләре — И.Исхаков, Ф.Мөбәр. Актив авторлар — Д.Акчурин, Г.Габдҗәлилов, Н.Кадыйров, Г.Камалетдинов, М.Сәгыйдуллин, Г.Сәйфи, А.Сәлимов, Н.Хәмидуллин. Төп игътибар колхоз тормышына, алдынгы а.х. артельләре һәм колхозчы-ударникларның уңышларына бирелә; хезмәттәге кимчелекләр өчен а.х. пр-тиеләренең җитәкчеләре тәнкыйтьләнә. Газетада һәрдаим агрономнар һәм ветеринарлар тәкъдимнәре, илдә, Урта Идел буенда баручы индустрияләштерү һәм мәдәни яңарыш турындагы язмалар басылып килә. 1928 нең декабреннән 1929 ның августына кадәр «К.»га кушымта булып «Урта Идел» айлык әдәби, иҗтимагый-сәяси, иллюстрацияле а.х. ж-лы чыга (8 сан, мөхәррире — З.Шәркый). 1931 нең 7 ноябреннән «К.» редакциясе кушымта — яңалифне кабул итүгә багышланган «Культура фронты» г-тасын чыгара (44 сан).

*Т.М.Насыйров.*

**КОЛХОЗЧЫ́-УДА́РНИКЛАРНЫҢ ИКЕНЧЕ́ БӨТЕНТАТА́Р СЪЕЗДЫ́**, 1933 елның 27 сентябре — 4 октябрендә Казанда уза. 3 меңләп делегат катнаша. Докладчы — М.О.Разумов. Съездда а.х.ндагы еллык эш нәтиҗәләре, авылда социаль үзгәртеп кору мәсьәләләре тикшерелә. Съезд, а.х. җитештерүендә югары күрсәткечләргә ирешүгә өндәп, Татарстан АССР, Башкортстан АССР, Урта Идел буе, Днепропетровск һәм Одесса өлкәләре колхозчыларына мөрәҗәгать кабул итә.

*Әд.:* Залялов А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии. 1883–1985. К., 1985. Кн. 1.

**КОЛЧА́К** Александр Васильевич (4.11.1874, Петербург губ., Петербург өязе Александровский а. — 7.2.1920, Иркутск ш.), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, гидролог, котыпны тикшерүче, адмирал (1918). Дворяннар нәселеннән. Диңгез кадетлары корпусын тәмамлый (С.-Петербург, 1894). 1894 елдан хәрби хезмәттә. 1900–02 дә котып экспедициясендә була. Рус-япон һәм Беренче бөтендөнья сугышларында катнаша. 1916–17 дә Кара диңгез флоты командующие. 1918 нең ноябрендә Себердә, Идел буенда, Уралда һәм Ерак Көнчыгышта Аклар хәрәкәте җитәкчесе; үзен Россиянең иң югары идарәчесе дип игълан итә. 1919 ның язында Мәскәүгә яу б-н баруны җитәкли, аның армияләре Бөгелмә, Алабуга, Минзәлә, Чистай шәһәрләрен, ш.у. Казан губернасының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш өязләрендәге терр-яләрне басып ала. 1919 ның маенда-сентябрендә Кызыл Армиянең контрһөҗүме нәтиҗәсендә, Богырыслан, Бөгелмә һәм Бәләбәй һөҗүм операцияләре барышында, К.ның гаскәрләре тар-мар ителә. Урал артына чигенгәннән соң ул союзниклары чех-словаклар тарафыннан тотып бирелә һәм Иркутск хәрби революцион ком-ты карары б-н атып үтерелә. Хезмәтләре гидрографиягә, хәрби диңгез эшенә карый. Карс диңгезендәге утрауларның берсе К. исеме б-н аталган.

Хезм.: Лёд Карского и Сибирского морей. СПб., 1909; Какой нужен России флот // Сб. докл. Санкт-Петербург. военно-морского кружка. СПб., 1909. Т. 2.

*Әд.:* Мухарямов М.К. Гражданская война в Татарии (1918–1919). К., 1969; Гражданская война в Поволжье 1918–1920 гг. К., 1974.

*Е.Б.Долгов.*

**КОЛЧА́НОВ** Михаил Егорович (16.12.1923, Арча кантоны Осоко-Ковали а. — 19.5.1972, Казакъстан ССР, Алма-Ата), Сов. Союзы Герое (21.2.1945), гв. өлкән сержанты. Казанда заводта слесарь булып эшли. 1939–40 елларда һәм 1941 нең ноябреннән Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 279 нчы җиңел артиллерия полкында разведка отделениесе командиры (69 нчы армиянең 4 нче һөҗүм артиллериясе корпусы, 5 нче артиллерия дивизиясенең 23 нче гв. җиңел артиллерия бригадасы). Воронеж, Дала һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Харьков һөҗүм һәм оборона операцияләрендә (1943), Курск шәһәре өчен сугышта (1943), Люблин-Брест (1944), Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең июль–август айларында Польшаны азат иткәндә батырлык күрсәтә: Люблин шәһәрендә барган урам сугышларында дошманның ут нокталарын юк итә һәм укчы подразделениегә һөҗүмне дәвам итәргә мөмкинлек тудыра; 1944 нең 1 августында беренчеләрдән булып Висла елгасы аша Застув-Карчмиски (Пулавы шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Польша) торак пункты янына йөзеп чыга; дошманның ут ноктаҗлары координатларын хәбәр итә; дивизион туплары утына төгәллек кертә, шул рәвешле плацдармны киңәйтүгә булыша. 1946 да демобилизацияләнә. Белгород өлкәсе Губкин шәһәрендә (1964 кә кадәр), Алма-Атада яши һәм эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә Дан орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.



М.Е.Колчанов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КО́ЛЧИН** Николай Тимофеевич (13.1.1927, хәзерге Киров өлкәсенең Малмыж р-ны Калинино а. — 1.12.1998, Казан), спортчы (җиңел атлетика, волейбол), Татарстанда физик культура һәм спортны оештыручыларның берсе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1968), РСФСРның атказ. физик культура хезмәткәре (1988). Казан пед. ин-тының тарих ф-тын (1949), ш.у. физик тәрбия һәм спорт ф-тын (1953) тәмамлый. РСФСР (1946, яшүсмерләр арасында, ядрә ыргыту), (1946–50, ун төр ярыш) чемпионы; СССР (1946, көмеш, яшүсмерләр арасында, ядрә, граната ыргыту), (1952, көмеш, ун төр ярыш), РСФСР (1947, бронза, волейбол), (1963, көмеш, кышкы күп төр ярыш) чемпионатларында, РСФСР халыклары спартакиадаларында (1956, 1959, бронза, ун төр ярыш) медальләр ала. РСФСР җыелма командасы (1947–50, волейбол) әгъзасы. Җиңел атлетика төрләре буенча (биш-, ун төр ярыш; диск, сөңге, граната ыргыту; озынлыкка сикерү, колга б-н сикерү, өчләтә сикереш; эстафеталар — 4×100 *м*, 4×400 *м*) берничә тапкыр Казан, ТАССР, РСФСР рекордчысы. 1953–80 елларда Казан пед. ин-тының спорт уеннары каф. мөдире, 1981–91 дә физик тәрбия һәм спорт каф. мөдире, 1991–93 тә Казан финанс-икътисад ин-тының сәламәтләндерү үзәге мөдире; 1993–95 тә ТР Волейбол федерациясе инструкторы. ТАССРның спорт журналистлары конкурсы лауреаты (1976). ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә.

**КОЛЧЫ́К** посёлогы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 24 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1647–51 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кулгукова исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, тимерчелек, галантерея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 240 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 22 ир-ат; 1859 да — 122, 1897 дә — 183, 1908 дә — 197, 1920 дә — 254, 1926 да — 173, 1938 дә — 135, 1949 да — 69, 1958 дә — 100, 1970 тә — 94, 1979 да — 77, 1989 да — 39, 2002 дә — 32 кеше.

**КОЛШӘРИ́П** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1545 кеше (татарлар) яши. Кошчылык ф-касы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1740 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләргә бүленә, игенчелек, терлекчелек, күн итек тегү, такта яру, тегү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә 2 мәчет, 2 мәдрәсә, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2747 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 44, 1762 дә — 72 ир-ат; 1795 тә — 325, 1859 да — 681, 1889 да — 1088, 1897 дә — 1094, 1908 дә — 1408, 1920 дә — 1418, 1926 да — 673, 1938 дә — 838, 1949 да — 973, 1958 дә — 800, 1970 тә — 897, 1979 да — 914, 1989 да — 835, 2002 дә — 1309 кеше.

**КОЛШӘРИ́П** т и м е р ю л с т а н ц и я с е посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әгерҗе — Акбаш тимер юлы буенда. 2010 елда 18 кеше (татарлар) яши. 1954 тә нигез салына. Оештырылган көннән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1958 дә — 93, 1970 тә — 96, 1979 да — 80, 1989 да — 47, 2002 дә — 30 кеше.

**КОЛШӘРИ́Ф** (Шәриф Хаҗитархани, Мөхәммәд-Шәриф) (? — 1552 нең октябре, Казан), дәүләт һәм дин эшлеклесе, шагыйрь. 1546 елдан (бүтән мәгълүматларга караганда — 1551 дән) Казан ханлыгының дин башлыгы (сәет). Чыгышы б-н Әстерханнан (татар вариантында Хаҗитархан, соңыннан шагыйрь псевдонимнарының берсе) сәет Мансур улы. 1551 дә Мәскәүнең Казанга каршы яңа хәрби һөҗүмнәрен булдырмый калу максатын күздә тотып, *Шаһгали хан* б-н җитди сөйләшүләр алып бара. Чапкын Отучев б-н бергә Казан тәхетенә чакырылган *Ядегәр Мөхәммәд хан* хөкүмәте әгъзасы. 1552 дә Казанны соңгы көннәрендә саклап калырга тырышучыларның берсе. Шәкертләрдән төркем төзи, хан нугытмасы өчен барган сугышта һәлак була.

К.нең шигъри мирасыннан соңрак «*Бакыргани китабы*»на кергән 5 газәле мәгълүм. «Кыйссаи Хөбби хуҗа» дастанын да аңа нисбәтлиләр (1889 да нәшер ителә). Әсәр урта гасырлар төрки-татар әдәбиятында киң таралган сюжетка нигезләнә. Тасвирланган вакыйгалар 12 йөздә Урта Азиядә бара. Әсәрнең төп геройлары — Бакыргани һәм аның кече улы Хөбби. Төрле могҗизалар (суелган сыерларны терелтү, дингездә суга баткан кешеләрне коткару һ.б.) башкара торган Хөббинең изгелегенә Бакыргани ышанмый. Бөтен игътибарын ул олы уллары Әзһәр һәм Мәхмүдкә бирә. Атасының «Икебез дә акыл иясе булып, бер илгә сыймабыз без» дигән сүзләреннән соң Хөбби, аккошка әйләнеп, читкә очып китә. Атасының улына карата миһербансызлыгы Бакырганинең рухи остазы Ә.Ясәвигә мәгълүм була. Ул үзенең мөридәнә бер ел буе авыр физик эш б-н шөгыльләнү җәзасын бирә һәм аңа Аллаһның әмерен җиткерә. Шушы әмер аркасында Бакыргани улы б-н фәкать үлгәннән соң гына очраша ала.

«Зафәрнамәи вилаяте Казан» (1550) исемле тарихи әсәрнең авторы да — К. Бу чәчмә әсәр текстына 8 шигырь кергән. Аларда Иван IV нең Казанга 1549–50 еллардагы һөҗүмнәре тасвирлана, Казан ханлыгы чоры дәүләт эшлеклеләренең исемнәре аталып үтелә, камалыштагы Казанны дошманнан коткарып калган сакчыларның батырлыгы турында бәян ителә. Тюрколог Ә.Вәлиди, әсәрнең кулъязмасын Төркиянең Көтәһия шәһәрендәге китапханәдән табып, 1963 тә беренче тапкыр бастырып чыгара. 1995 елда әсәр Казанда беренче тапкыр татар һәм рус телләрендә басыла. Ш.у. к. *Колшәриф мәчете*.

Ә с ә р.: Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр: Газәлләр, кыйсса. К., 1997; Ш е р и ф и Х. Зафер наме-и вилайет-и Казан // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1995. Май.

*Әд.:* Ш ә р и п о в Ә. Ничек килеп җиттең син, борынгы кыйсса? // Аргамак. 1993. № 11; Подлинная о Казанском походе запись Царственной книги 1552 г. и сказание князя Курбского о покорении Казани. М., 1902; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; И с х а к о в Д.М. Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. К., 1997; Кул Шариф и его время. К., 2005; T o g a n Z.V. Kazan Hanliğında Islâm Türk Kültürü // İslâm Tetkikleri Enstitüsü Dergisi. Istambul, 1965. Cilt III. Sayı 3–4; Kaya Ö. Kul Şerif'in İr Hubbi Destanı // KÖK Araştırmalar. 2000. Cilt II. Sayı 1.

*А.М.Ахунов.*

**«КОЛШӘРИ́Ф»**, Казанда хәзерге заман мөселман дини, фәнни һәм мәдәни-агарту комплексы. 1996–2005 елларда Казан Кремле терр-ясендә төзелә. Исеме 1552 дә Иван IV гаскәрләре Казан ханлыгын яулаганда җимерелгән легендар *Колшәриф мәчете* истәлегенә нисбәтле. Проект авторлары — архитекторлар А.Г.Саттаров, И.Ф.Сәйфуллин, М.В.Сафронов, Ш.Г.Латыйпов. Проектның баш архитекторы — А.В.Головин, баш инженеры — А.И.Исхаков («Татинвестгражданпроект» ДУП).

Комплекс Кремль дивары һәм элекке юнкерлар уч-щесе бинасы арасында, мәйданның урта өлешендә урнашкан. Дини биналарның үзәк гөмбәзле, күпманаралы төренә карый. Коплекска мәчет, 2 павильон һәм күләгәләүле өскормалар керә. «К.» мәчете бинасы планда 45° почмак ясап кисешкән ике квадраттан тора. Сигез кырлы фәзаи үзәккә урнашкан ирләр залы 32 *м* биеклектәге уксыман гөмбәз б-н төгәлләнә. Төп бинаның почмакларындагы стилобатларга 58 *м* биеклектәге 4 манара урнашкан. Тагын өстәмә 2 кече манара һәм төп ишек порталы почмакларында ш.у. 2 манара бар. Мәчетнең күпманаралылыгы тарихи *Колшәриф мәчетенең* сигез манаралы булуы турындагы легендага бәйле. Төп гөмбәз «*Казан таҗы*» — Казан яулаганнан соң Мәскәүгә озатылган Казан ханнары таҗы образына охшаш форманы алган. Бинаның эчке күләме 5 каттан (цоколь һәм техник катларны кертеп) һәм ярдәмче вазифалар үтәүче берничә арадаш мәйданчыктан тора. Беренче, җир өстендәге катта төп ишек вестибюле һәм имам бүлмәләре урнашкан. Калган ике катны 720 ир-атка исәпләнгән гыйбадәт залы һәм 300 хатын-кыз сыйдырулы балкон-галерея били. Бинаның стилобатын (итәген) хасил итүче цоколь катында хатын-кызлар өчен вестибюль, тәһарәт алу бүлмәләре, гардероблар һәм Татарстанда ислам мәдәнияте музее залы урнашкан. Мәчеткә төп гыйбадәт мәйданына — бинаның төньягыннан, музейга — аскы көньяк платформадан керелә. Ритуаллар үткәрү һәм музей бүлмәләре аерым зоналарга бүленгән. Керүчеләр икегә — ир-атлар һәм хатын-кызлар агымына аерыла. Алар өчен ишекләр аерым эшләнгән.

Уксыман аркаларның үзара үрелгән конструкцияләре Идел буе Болгар дәүләтендә һәм Казан ханлыгында яшәгән күчмә төркиләрнең борынгы тораклары — тирмәләрнең каркаслы конструкцияләре б-н охшашлыкны ассызыклап тора. Бинаның архит-расында, декоратив-сәнгать бизәлеше элементы буларак, борынгы болгарларда яңарыш һәм чәчәк ату билгесе булган лалә чәчәге чагылыш таба. Яктылык барабанының 12 тәрәзәсе аның формасын хәтерләтә. Фасадларны һәм интерьерларны бизәүдә ак мәрмәр, гранит, мәрмәр ониксы, серпантин минералы файдаланылган. Мәчет гөмбәзе һәм чатырсыман манара очлары фирүзә төсендәге металл чирәп б-н капланган. Манара очларындагы айлар тринитротитан эретмәсеннән эшләнгәннәр.

Мәчетнең интерьерлары арх. А.Г.Саттаров эскизлары буенча бизәлгән. Төп залның диварлары якты мәрмәр б-н тышланган. Уксыман биек тәрәзәләр (биеклеге — 12 *м*) төсле витражлар б-н бизәлгән. 16 *м* диаметрлы гөмбәзнең терәк бонжасына Коръән аятьләре язылган (зәңгәр фонда алтын хәрефләр). Гөмбәзнең эчке ягына татар халык орнаменты үрнәкләре төшерелгән. Гөмбәз розеткасын алтын б-н язылган Коръән текстлары бизи; үзәккә бәллүр люстра эленгән (А.Г.Саттаров проекты). Зал идәненә кулдан тукылган келәмнәр Иранда җитештерелгән (алар бүләк итеп бирелгән). Комплексның башка бүлмәләре дә агачка уеп ясалган бизәкләр, орнаментлы керамик плитәләр, фаянс кирпечләрдән төзелгән паннолар һ.б. милли бизәкләр б-н баетылган. Музейда 300 дән артык борынгы кульязма һәм басма Коръәннәр күргәзмәгә куелган һәм саклана. 2012 дә «К.» проекты ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була.

*Әд.:* Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Хайретдинов, Р.Р.Салихов. К., 2002; Саттаров А., Сафронов М. Интерьеры мечети «Кул Шариф» // Дизайн и новая архитектура. 2002. № 9; Иванова Л. Архитектура казанского возрождения // Дизайн и новая архитектура. 2005. № 20–21. *Х.Г.Надыйрова.*

**КОЛШӘРИ́Ф МӘЧЕТЕ́**, Казанда 16 йөзнең 1 нче яртысында хан кирмәнендә урнашкан мөселман гыйбадәтханәләренең берсе. *Колшәриф* хөрмәтенә шулай аталган. Кирмәннең көньяк дивары буенда, Таҗик чокыры янында урнашкан дип фаразлана. 2 төрдәге 8 манаралы, үзәге чатыр-гөмбәз б-н төгәлләнгән мәчет. Әүвәлге Ренессанс һәм госманлы төрекләр архит-расы стиле элементларын кулланып, болгар-татар традицияләрендә корылган. Мәчет янында мәдрәсә биналары урнашкан. 16 йөз ахыры – 17 йөз башында сүтелә. Архитектура тарихчылары С.С.Айдаров һәм Н.Х.Халитов башкаруында фәнни-гипотетик реконструкция үткәрелә.

*Әд.:* Айдаров С.С. Монументальные каменные сооружения и комплексы Волжской Булгарии и Казанского ханства: Автореф. дис. ... М., 1990; Халит Н. Очерки по архитектуре ханской Казани: Гипотезы. Факты. Размышления. К., 1999.

**КОЛЫ́Н** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 54 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 137 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1701 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә; *Крәстияннәр кузгалышында* (1773–75) Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.да мәчет (1837 дән телгә алына), мәктәп, кредитлау ширкәте була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1945,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 97, 1859 да — 386, 1870 тә — 413, 1884 тә — 475, 1897 дә — 694, 1906 да — 642, 1913 тә — 919, 1920 дә — 854, 1926 да — 790, 1938 дә — 630, 1949 да — 377, 1958 дә — 340, 1970 тә — 379, 1979 да — 286, 1989 да — 176, 2002 дә — 156 кеше.

**КОЛЫ́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 33 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында. 2010 елда 131 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1717 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балык тоту, капчык сугу, чабата һәм кәрзин үрү б-н шөгыльләнә; *Крәстияннәр кузгалышында* (1773–75) Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.та мәчет, рус-татар башлангыч мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1095 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 78, 1859 да — 254, 1870 тә — 259, 1884 тә — 397, 1906 да — 529, 1913 тә — 584, 1920 дә — 550, 1938 дә — 493, 1949 да — 430, 1958 дә — 395, 1970 тә — 399, 1979 да — 313, 1989 да — 157, 2002 дә — 140 кеше.

**КОЛЫШЧЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 50 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 188 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1619 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровский, Кече Сон исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе (1869 да ачыла), фельдшерлык пункты, 2 су тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1487,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 95 ир-ат; 1859 да — 739, 1897 дә — 1078, 1908 дә — 1210, 1920 дә — 1318, 1926 да — 967, 1938 дә — 1057, 1949 да — 719, 1958 дә — 606, 1970 тә — 583, 1979 да — 355, 1989 да — 220, 2002 дә — 216 кеше.

**КОЛЬЦО́ВА** Любовь Александровна (9.10.1922, Мамадыш р-ны Келәүш а. — 1.7.2000, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1971). 1943 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Новосибирск эвакуация госпиталендә оториноларингология бүлегендә эшли. 1964 тән Новосибирск травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, бер үк вакытта 1953–57 дә Новосибирск мед. ин-тында. 1958–85 тә Казан. мед. ин-тында, 1968 дән хирургик стоматология каф. мөдире. Хезмәтләре катлаулы булмаган яңак сынуларын дәвалауга, колак ярылары формалашу мәсьәләләренә, яңак-бит өлкәсендәге




**«Колшәриф».** 1. Төньяк-көнбатыштан гомуми күренеше. Проект авторлары — архитекторлар А.Г.Саттаров, И.Ф.Сәйфуллин, М.В.Сафронов, Ш.Г.Латыйпов. Проектның баш архитекторы — А.В.Головин, баш инженер — А.И.Исхаков («Татинвестгражданпроект» ДУП); 2–5. Фасадларның бизәлеш фрагментлары; 6–7. Төп гыйбадәт залы гөмбәзенең декоратив бизәлеше; 8. Татарстанда ислам үсеше музее залы интерьеры; 9. Мәчетнең мөнбәрле төп гыйбадәт залы интерьеры; 10. Хатын-кызлар гыйбадәт залының балкон-галерея ишеге.

яман шешләрне хирургик дәвалауга карый. Уйлап табуга авторлык таныклыклары бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хирургическая санация полости рта у детей дошкольного возраста // Вопр. стоматологии. К., 1962. Т. 1; Димедрол в лечении одонтогенных воспалительных процессов. Уфа, 1967; О возможности использования пигментов в восстановительной хирургии лица // Стоматология. 1968. № 4.

*Әд.:* Андреев И.М., Красильников С.Н. Стоматологический факультет: Истории в биографиях. К., 1996.

**КОМ-ВАК ЧУЕРТА́Ш КУШЫЛМАСЫ́**, төрле дәрәҗәдә шомарган тау токымнарының, үзгәрүчән үлчәмле һәм бәйләнешле минералларның табигый һәм техноген көпшәк тупланмалары. К.-в.ч.к. *вак чуерташ* һәм комның күләме, бөртеклелек, эрелек модуле, ныклык, йомшак токымнарның бөртекләре булу, суыкка чыдамлык, тузансыман, ләмле һәм балчыксыл кисәкчекләр һәм органик кушылмаларның күләме минерал-петрографик составы б-н сыйфатлана. К.-в.ч.к. тау токымнарының табигать күренешләре б-н (җилләнү, елга сулары яки бозлыклар тәэсирендәге көчешләр, диңгез һәм зур күлләрнең дулкын йогынтысы) җимерелүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. Эре фракцияләрнең составында (4% ка кадәр) йомшаграк токымнарның ватыклары: сланецлар, известьташлар, доломитлар, комташлар һ.б. бар. Минерал-петрографик, химик составы, эрелеге буенча төрле фракцияләрнең бәйләнеше, балчык һәм ләм кисәкчекләрнең күләме, физик-механик һ.б. үзлекләре К.-в.ч.к.н сәнәгатьнең теге яки бу тармагында табигый яки баетылган халәттә кулланырга мөмкинлек бирә. Татарстан терр-ясендә К.-в.ч.к. ятмаларының аеруча зуры (запаслары — млн., уннарча млн. $м^3$) һәм сыйфатлысы Кама елгасы үзәненә, аның юлына һәм тугай асты террасаларына (Кама Тамагы, Котловка, Алабуга, Чаллы һ.б.) туры килә һәм ул барлык билгеле чыганакларның 80% ын тәшкил итә. Сәнәгать категорияләре буенча К.-в.ч.к.ның 42 чыганагы (20 се үзләштерелгән) 200 млн. $м^3$ (2007) запаска ия. 1970 елларда навигация чорында республикада К.-в.ч.к.н һәм вак чуерташ чыгару күләме 20–25 млн. *т* га, 21 йөз башында 5–6 млн. *т* га җитә. Вак чуерташ һәм К.-в.ч.к. елга транспорты б-н Идел буеның (Мәскәүдән Әстерханга кадәр) 14 өлкәсенә һәм 6 республикасына җибәрелә. К.-в.ч.к. һәм аннан иләнгән вак чуерташ барлык төзелеш эшләрендә кулланыла.

*Әд.:* Минеральное сырьё. Сырьё песчано-гравийное: Справ. М., 1998; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Г.Н.Бирюлёв, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**КОМАЗА́Н** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 31,3 *км*, бассейнының мәйданы 115,6 $км^2$. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Комазан Башы авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, Яңа Комазан авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан элеккеге Арпач елгасына коя. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 50%. К.ның 10,2 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,098 $м^3/с$. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 0,9 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КОМАЗА́Н БАШЫ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак Комазан елгасы буенда. 2010 елда 160 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.нда чиркәү-приход мәктәбе (1869 да Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе буларак ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1192,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 121 ир-ат; 1859 да — 500, 1897 дә — 674, 1908 дә — 845, 1920 дә — 819, 1926 да — 845, 1938 дә — 687, 1949 да — 480, 1958 дә — 446, 1970 тә — 525, 1979 да — 466, 1989 да — 321, 2002 дә — 189 кеше.

**КОМАЗА́Н УРМАНЧЫЛЫГЫ́** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ушма елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 138 кеше (татарлар) яши. Такта яру з-ды. Клуб. 1940 елларда нигез салына. Халык саны: 1958 дә — 261, 1970 тә — 207, 1979 да — 198, 1989 да — 141, 2002 дә — 130 кеше.

**КОМА́Й** (Glyceria), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында, ш.у. Көньяк Америка һәм Австралиядә очрый. ТР терр-ясендә 5 төре бар. Йөзгәләк К. (G. fluitans), озын К. (G. maxima), тамгалы К. (G. notata) бөтен районнарда таралган; камыш К. (G.arundinacea) һәм Литва К. (G. lithuanica) Кама алдында очрый. Сулык ярлары буенда, уйсулыклы сазлыкларда, дымлы болыннарда, сазлыклы урманнарда үсә. 20–180 *см* биеклектә, җир асты ботаклары озын һәм үрмәле, яфрак җиңсәләре бөтен озынлыгында диярлек йомык (кырыйлары б-н кушылып үскән). Яфрак пластинкалары кыяк. Башакчыклары күп чәчәкле, зур себеркәчле чәчәк төркемендә. Җимеше — бөртекчә. Июнь–августта чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Орлыклары кошлар һәм балыклар өчен азык булып тора. К.ны артык дымлы урыннарны кәсләндерү өчен чәчәргә мөмкин. Камыш К. һәм Литва К.ы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КОМАННА́Р**, к.*Кыпчаклар*.

**КОМАРО́В** Виктор Николаевич (18.12.1931, Смоленск өлкәсенең Понизовье р-ны Сопцы а.), философ, филос. фән. д-ры (1982), проф. (1984), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1991), РФнең атказанган югары мәктәп хезмәткәре (2003). 1955 елда Казан ун-тының геология ф-тетын тәмамлаганнан соң геофизика партиясе башлыгы булып эшли. 1959–61 дә Казанда урта мәктәптә укыта. 1961 дән Казан ун-тының филос. кафедрасында (бүленеп, 1983–88 дә Казан авиация ин-тында филос. каф. мөдире) эшли. Хезмәтләре табигыять фәннәренең филос.-методологик проблемаларына карый.

Х е з м.: Характеристика некоторых сторон движения в неорганической природе. К., 1970; Философские проблемы науки о земле. К., 1972.

**КОМАРО́В** Николай Иванович (9.5.1905, Сембер губ., Карсун өязе Вешкайма а. — 15.7.1968, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1952), проф. (1953), ТАССРның атказ. табибе (1945). 1929 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Казан ГИДУВында эшли, 1953–67 дә оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре баш сөяге һәм баш миенең йогышлы авырулы яраларын хирургик дәвалау ысулларын эшләүгә, баш сөяге, баш мие тамырлары (веналар) хирургиясенә карый. К. көндәлек тормышта хәрби госпиталь хирургиясе тәҗрибәсен куллана. Ул Казан халкына нейрохирургия ярдәме оештыра. Пункция алу өчен К. инәле оригиналь скальпель уйлап таба. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вторичная обработка огнестрельных черепно-мозговых ранений по материалам госпитальной практики в период Великой Отечественной войны (1941–45): Автореф. дис. ... К., 1951; Хирургическое лечение инфицированных ран черепа и мозга. К., 1957; Об использовании полимеров для пластики нижней полой вены выше почечных вен в эксперименте // Казан. мед. журн. 1965. № 2 (автордаш).

**КОМАРО́В-ЗАВО́Д** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 31 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кубыр суы буенда. 2010 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.-З.та мәчет була. Авыл җәмәгатенең имана җире 822,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Түбән Чутай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938

нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 458, 1884 тә — 659, 1905 тә — 890, 1920 дә — 951, 1926 да — 891, 1938 дә — 567, 1949 да — 335, 1958 дә — 190, 1970 тә — 190, 1979 да — 145, 1989 да — 117, 2002 дә — 100 кеше.

**КОМАРО́ВКА** (Кумырык) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 30 *км* төньяктарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 84 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1762 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Никола чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), тимерчелек, 2 май язу йорты, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 685,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 341, 1897 дә — 707, 1908 дә — 845, 1920 дә — 605, 1926 да — 484, 1938 дә — 208, 1949 да — 279, 1958 дә — 388, 1970 тә — 402, 1979 да — 315, 1989 да — 177, 2002 дә — 131 кеше.

**КОМАРО́ВКА** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 253 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1649 дан Рус Ачысы исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе, тимерчелек, май язу йорты, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 607,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 204, 1897 дә — 316, 1908 дә — 391, 1920 дә — 391, 1926 да — 390, 1938 дә — 382, 1949 да — 319, 1958 дә — 193, 1970 тә — 81, 1979 да — 51, 1989 да — 55, 2002 дә — 146 кеше.

**КОМА́ЦУ** (Komatsu) Хисао (28.2.1951, Токио), тарихчы, тюрколог, проф. (1996). 1980 елдан Токио ун-тында (Япония). Хезмәтләре мөселман төрки халыкларның сәяси тарихына, татарларның Үзәк Азиядәге сәүдә һәм мәдәни эшчәнлегә мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Revolutionary Central Asia. Tokyo, 1996; Orta Asyada Türkçülük ve Devimçilik. Ankara, 1999.

**КОМА́Ч МАНУФАКТУ́РАЛАРЫ**, текстиль сәнәгате пр-тиеләре. Казан губернасында 18 йөздән билгеле: 1718 елда сәүдәгәр Ходайголов Арча тирәсендә мануфактура ача. К.м., башлыча, читтән китерелгән чимал кулланып эшлиләр. Комач Казанда, Әстерхан, Оренбург шәһәрләрендә, Мәкәрҗә һәм Эрбет ярминкәләрендә һ.б. сатыла. Башлыча, татар сәүдәгәрләре С. һәм М. Хуҗасәетовларга (4 пр-тие), И.Йосыповка (3), Н.Баязитовка (1), А.Бикбовка (1), И.Пчелинга (1) нисбәтле була. Иң зур пр-тие — Яңа Кишет авылында, Н.Баязитовныкы (46 станок, җитештерүчәнлеге елына 48 мең аршын чамасы тукыма). Эшләүчеләре ш.у. татарлар була.

*Әд.:* К о з л о в а К.И. Очерки этнический истории марийского народа. М., 1978; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**КОМБЕДЛА́Р**, к. *Ярлылар комитеты.*

**«КОМВУ́З СТУДЕНТЫ́»** («Студент КОМВУЗа»), журнал. Татар коммунистлар ун-тында (ТКУ) ВКП(б)ның ячейкасы һәм студентларның башкарма бюросы органы. 1925 елның июненнән 1928 нең декабренә кадәр Казанда татар һәм рус телләрендә нәшер ителә, барысы 3 сан. 1925–27 дә «ТКУ студенты», «Студент ТКУ» исемендә чыга. Мәкалә авторлары — ТКУ студентлары. Иң активлары — Я.Әбраров, М.Агишев, А.Баһау, Б.Ильясова, Т.Имаметдинов, К.Кәримов, Г.Кильдин, Г.Надыйров, И.Рәхмәтуллин, Х. Садри, М.Сәлахов, И.Төхфәт, М.Хуҗиәхмәтов, Я.Ярмәки. Максаты — коммунистлар ун-ты студентлары тормышы б-н укучыларны таныштыру, чыгарылыш курсларны РКП(б)ның принципларын тормышка ашырырга әзерләү. РКП(б) ячейкасының ТКУда эшчәнлеге, комсомол активистлары тәҗрибәсе турында язмалар, ун-т студентларының шигырь һәм хикәяләре басыла.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**КОМГА́Н**, тар муенлы кувшин формасындагы борынлы, тоткалы һәм капкачлы металл су савыты, гадәттә, аңа нәфис бизәк төшерелгән була; татар халкының көнкүрешендә кулланыла. Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә, Кавказда, башка төрки халыклар арасында мәгълүм; мөселманнар К.ны тәһарәт алу өчен файдаланалар. Татар К.ы 20 йөз башына кадәр Идел буенда яшәүче башка халыклар арасында да популяр була. К. бакырдан, җиздән (сирәк кенә бронзадан) ясалган, чүкү, уеплау, басма ысулы б-н бизәлгән. Татар К.ының аеруча нәфис үрнәкләре 18–19 йөзләргә карый, Касыйм шәһәрендәге тарихи-архит-ра музей-саклаулыгы тупланмасында 15–16 йөзләр татар аксөякләренең купшы итеп бизәлгән берничә К.ы саклана. 16–17 йөзләрдә татар К.нары, башлыча, яндырылган балчыктан эшләнгәннәре русларда, аеруча аның аксөяк катламында киң тарала. К. формаларында Идел болгарларында һәм 15–16 йөзләр Казан татарларында очрый торган балчык савытлар б-н охшашлык бар. Борыннары кош яки хайван башларына охшатып эшләнә (к. *Керәч сәнгате*). 18 йөздә – 20 йөз башында Казан һәм Казан арты авылларындагы (Олы Әтнә, Тимерче-Чемер-



**Комган.** 1. Җиз. Чүкү, уеплау. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы; 2. Җиз. Чүкү. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. Бакыр. Чүкү. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы. ТР Милли музее; 4. Җиз. Кою, чүкү. 20 йөз уртасы; 5. Җиз. Кою, чүкү. 19 йөз ахыры. Лениногорск р-ны Ормышлы авылы мәктәбе музее; 6. Калай. Кою. 1980 еллар. Әлмәт р-ны Габдрахман авылы.

че һ.б.) татар бакырчылары сәнгатьчә камил, гадәттә чүкеп бизәлгән, үзенчәлекле (тәбәнәк, «бүксәле») җиз К.нар җитештерәләр. К.ның тагын да гадирәк формалары рус шәһәрләрендәге татар бистәләрендә, һәр татар авылында диярлек эшләнә. Хәзерге вакытта чуен, алюминий (сирәк кенә — бакыр) К.нар Татарстанның аерым авылларында халык осталары тарафыннан ясала, сәнәгый җитештерү Казанның кайбер пр-тиеләрендә, Каслинск з-дында (Урал) җайга салынган.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920 е-начало 1990 гг.). К., 1995.

*Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.*

**КОМЕ́ДИЯ** (грек. kōmōdía — күңел ачып йөрү һәм ōidē — җыр), хәрәкәт, конфликт, характерлар юмористик һәм сатирик формада сурәтләнгән, азагы мәҗбүри рәвештә бәхетле тәмамланырга тиеш булган драма жанры. К., шыксызлыктан көлеп, чынбарлыкны көлке категориясеннән чыгып гәүдәләндерә. К.нең персонажы, көлкеле ситуациягә эләгеп, үзен үзе фаш итә. Кайбер К.ләрдә тискәре геройга уңай герой каршы тора, кайберләрендә көлке автор идеяләрен үткәрү өчен хезмәт итә.

К. жанры татар әдәбиятында халык уеннарына, йолаларга, бәйрәмнәргә, фольклор әсәрләренә барып тоташа. Шулай ук аның үсешенә «театрлаштырылган уеннар» сюжетлары («Мәҗмугыль-хикайәт», «Мең дә бер кичә»), диалогларга корылган дастаннар («Бүз егет», «Таһир белән Зөһрә»), төрек, әрмән, әзәрбайҗан әдәбияты әсәрләре дә сизелерлек йогынты ясый. Мөстәкыйль жанр буларак, К. татар әдәбиятында 19 йөз ахырында — 20 йөз башында формалаша; бу процесска рус һәм Көнбатыш Европа әдәбияты һәм театры нык тәэсир итә. Төрек һәм рус телләреннән тәрҗемә ителгән К.ләрдә («Хөсет бабай», «Комедия Чистайда») артта калганлык көлү объекты була, белемгә омтылу, әхлаклылык хуплана, барлык кешеләрнең тигезлеге идеясе алга сөрелә. Г.Камал («Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре»), Г.Исхакый («Җәмгыять», «Кыямәт»), И.Богданов («Помада мәсьәләсе»), С.Рәмиев («Низамлы мәдрәсә»), Ш.Камал («Хаҗи әфәнде өйләнә»), К.Тинчурин («Көйсез кияү») һ.б. иҗатында К. аеруча зур гәүдәләнеш таба. Г.Камал, Г.Исхакый К.ләрендә халыкның көлү традициясе торгызыла, замананың милли сатирик типлары барлыкка килә («Банкрот»та Сираҗетдин, «Беренче театр»да Хәмзә бай, «Җәмгыять»тә Муса мирза, «Кыямәт»тә Шаһияздан бай), әхлак, социаль, милли мәсьәләләр, тормышның югары һәм түбән яклары бер-берсе б-н тыгыз бәйләнештә тора. 1920–30 еллар К.се 3 төргә бүлеп карала: беренчеләрендә — ирония ярдәмендә үткән заманнар һәм вакыйгалар, буржуазия вәкилләре (Н.Исәнбәтнең «Һиҗрәт»е, К.Әмиринең «Печән базары»), икенчеләрендә — яңа тормышта үз урыннарын таба алмыйча, үткән заманның кире кайтуы турында хыялланып, гомерләрен «җәмгыять өчен» мәгънәсез кайнашуда уздыручылар (К.Тинчуринның «Американ»ы), өченчеләрендә иҗтимагый тормыш бюрократизмыннан, эш урынын шәхси мәнфәгатьләрдә файдалануише тискәре яклар (Г.Тинчуринның «Хикмәтле доклад», Н.Исәнбәтнең «Портфель» комедияләре) көлке объектына әверелә. Ләкин, тулаем алганда, бу К.ләргә замананың актуаль мәсьәләләреннән читләшү, вульгар социологизм принципларын гәүдәләндерү хас. Г.Исхакыйның «Жан Баевич» пьесасында фарс элементлары да бар. 1930 еллар репрессияләре жанр үсешенә тискәре йогынты ясый. Бөек Ватан сугышы елларында фольклор сюжетына нигезләнеп язылган пьеса (Н.Исәнбәтнең «Җирән Чичән белән Карачәч сылу»ы) аеруча көчле иҗтимагый-мәдәни яңгыраш ала. Сугыштан соңгы елларда К. әхлакый эзләнүләр юлында үсә, ләкин совет әдәбият белемендә тамыр җәйгән «конфликтсызлык теориясе» ул елларда язылган пьесаларда үз йогынтысын нык сиздерә һәм К. үсешен тоткарлый. Язучыларның хөкем сөргән идеология таләпләренә буйсынуы К.не мораль уку б-н мавыгуга, конфликтларның җиңел чишелеш алуына китерә. Шул ук вакытта карьеризмга, эгоизмга, бюрократизмга, артта калганлыкка каршы чыгучы яңа фронтовик-геройның тууы жанрны бераз җанландыра, көнкүрешне чагылдырган водевильләр язылуга сәбәп була (Ш.Хөсәеновның «Профессор кияве», Р.Ишморатның «Директор хатыны», Н.Исәнбәтнең «Зифа»сы, Г.Насрыйның «Яшел эшләпә»се). 1960 еллардагы «Хрущёв җепшеклеге» К.дә халыкчанлык традициясен торгыза. Замана героена игътибар арта, пьесаларда конфликт тормышчан характер ала. Жанрны сизелерлек баеткан яңа төр водевиль (Х.Вахитның «Күк капусы ачылса»), көнкүреш К.се (Ю.Әминовның «Әй эшнәләр, эшнәләр!»), трагикомедия (Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы») языла. Т.Миңнуллинның «Нигез ташлары» һәм Ю.Әминевнең «Сатучылар» пьесалары көнкүреш К.се һәм драма синтезы үрнәге булып тора. Көн кадагына куелган әхлакый проблемаларны күтәрү, замандашның рухи дөньясына үтеп керергә тырышу комедиячел характерларның драматизмын арттыра, психол. тәэсирне көчәйтә. 1970 елларда идея-эстетик эзләнүләр жанрлар синтезына, психологик аспектның тирәнәюенә, чынбарлыкны фәлсәфи тирәнлектә аңлауга китерә. А.Гыйләҗевнең «Әңгер-меңгер», Ю.Әминовның «Кан кардәшләр», Ф.Садриевның «Кондырлы кодачасы» пьесаларында көлү объекты булып көнкүрештәге ыгы-зыгылар, әхлаксызлык, гаделсезлек, артта калганлык тора. «Җитди» (И.Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә»), «моңсу» (Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр») К.ләр туа; музыкаль К. (Х.Вахитның «Кияүләр»), водевиль (Т.Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү») үсеш ала. Идеологик басым арткан саен, «тыелган» темалар барлыкка килә, җәмгыятьтәге социаль һәм сәяси мәсьәләләр әдәбият даирәсеннән читтә кала. 1990 елларда җәмгыятьтә барган үзгәрешләр нәтиҗәсендә К. активлаша төшә. Җәмгыятьтә туган сәяси һәм идеологик каршылыклар, әхлаксызлык, рухи ярлылык, карашлар тарлыгы, түрәләр алдында баш ию кебек күренешләр К. объектына әверелә (З.Хәкимнең «Кишер басуы», «Мин төш күрдем»; Т.Миңнуллинның «Баҗа мал түгел, кәҗә туган түгел»; М.Гыйләҗевнең «Баскетболист»; Ф.Яруллинның «Бер күрешү — үзе бер гомер»; Д.Салиховның «Булса кодаң генерал» пьесалары). Чынбарлыкны сатирик югарылыкта тасвирлауның яңа формалары, ысуллары һәм чаралары К.дә тема һәм жанр ягыннан төрлечә чагылыш таба (лирик К. — Т.Миңнуллинның «Йөрәк маем»; сатирик К. — Д.Салиховның «Пуля»; музыкаль К. — Г.Каюмовның «Һинд кызы»; иҗтимагый К. — И.Юзеевның «Безнең эти мировой», З.Хәкимнең «Чапты атым Казанга»; көнкүреш К.се — Ф.Яруллинның «Бер күрешү — үзе бер гомер»; водевиль — Р.Батуллаң «Сөйгән ярым ятка кала»).

*Әд.:* Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия (истоки и развитие). К., 1996.

*Ә.М.Закирҗанов.*

**КОМЕ́ТАЛАР** (грек. komḗtēs, сүзгә-сүз тәрҗемәдә — озын чәчле), Кояш системасының аеруча сузынкы орбиталар буенча хәрәкәт итүче җисемнәре; Кояштан еракта булганда — овал формасындагы зәгыйфь яктылык таплары, Кояшка якынайган саен, аларның «баш» һәм «койрык» дип йөртелүче өлешләре аерылып күренә. Астероидлар һәм метеор кисәкчекләре б-н бергә кече җисемнәр төркеменә керә. К.ның төп өлешләре — төш, кома һәм койрык. К.ның төше (диаметры 0,5–20 *км*) туңган газлар б-н әйләндереп алынган начар эрүчән һәм ташлы кисәкчекләр катнашмасыннан гыйбарәт. Кояшка якыная барганда газлар парга әйләнә һәм үзләре б-н К.ның тузанлы кисәкчекләрен дә алып китә. Шул чакта төш газ-тузан сүрүе (кома) б-н әйләндереп алына. К.ның койрыгы тузаннан, газлардан һәм ионлашкан кисәкчекләрдән тора; күбесенчә Кояштан капма-каршы якка юнәлгән була.



Галлей кометасы.

Кыска периодлы К. хәрәкәтен өйрәнүдә Казан К.ны өйрәнү төркеме зур роль уйный. Төркемне оештырган А.Д.Дубяго хезмәтләрендә К.ның орбиталарын билгеләүнең теоретик нигезләре салына, бу җисемнәрнең һәм аларның таркалу продуктларының (метеор кисәкчекләре) үткәнен дә, киләчәген дә өйрәнү юллары билгеләнә. Казан астрономнары кыска периодлы К. күренүнең уннарча очрагын тикшерәләр, аларның күп кенә метеор күчләре б-н бәйләнешен исбатлыйлар,

К. орбиталары эволюциясендә зур планеталарның, бигрәк тә Юпитерның ролен ачыклыйлар.

*Әд.:* Бредихин Ф.А., Этюды о метеорах. М., 1954; Ананьева Л.Я., Корытников С.Н. Александр Дмитриевич Дубяго (1903–1959) // Ист.-астрон. исслед. 1961. Вып. 7; Чеботарёв Г.А. Аналитические и численные методы небесной механики. М., 1965; Добровольский О.В. Кометы. М., 1966.

*Е.Д.Кондратьева.*

**КОМЗ**, к. *Казан оптика-механика заводы.*

**КО́МИ РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, РФнең кырый Төньяк-Көнчыгыш Европа өлешендә, Печора, Вычегда һәм Мезень елгалары бассейнында урнашкан. 1921 елның 22 августында Коми автономияле өлкәсе буларак оештырыла, 1936 ның 5 декабрендә Коми АССР итеп үзгәртелә; 1992 нең 26 маеннан хәзерге исемен йөртә. Мәйданы — 415,9 мең *км*². Башкаласы — Сыктывкар шәһәре (Мәскәүдән 1515 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 951155 кеше (2010). Татарлар саны: 1939 да — 970, 1959 да — 8459, 1970 тә — 11906, 1979 да — 17836, 1989 да — 25980, 2002 дә — 15680 кеше. К.Р.нда Татар җәмгыяте 1930 елларда Печора күмер бассейны чыганагын эшкәртү б-н бәйле рәвештә оеша башлый. Бөек Ватан сугышыннан соң Коми АССРда татарлар шактый күбәя. Урта Идел буе һәм Урал буе респ-калары һәм өлкәләреннән күчеп килүчеләр нефть, газ тармакларын үстерүдә актив катнаша. 1990 лардан К.Р.ннан татарлар китә башлый, бу — күмер чыгару тармагындагы кризис һәм Төньякның халык өчен социаль җәлеп итү дәрәҗәсе киму б-н бәйле. Хәзерге вакытта татарлар Воркута (4795 кеше), Усинск (3860), Ухта (1644), Сыктывкар (1544), Инта (1096), Печора (681), Сосногорск (477), Вуктыл (359 кеше) шәһәрләрендә тупланып яшиләр; Княжпогост (212), Усть-Вымь (187), Удор (153), Сысола (130), Троицк-Печора (112), Сыктывдин (99), Корткерос (92), Прилуз (45), Усть-Цильма (21), Ижма (15 кеше) р-ннарында да татарлар бар. К.Р. татар һәм башкортларының республика милли-мәдәни автономиясе (Усинск ш., 1991; рәисе — Г.Ә.Бәдретдинова), татарларның «Татарстан» милли-мәдәни автономиясе (Сыктывкар, 1997), «Бердәмлек» (Ухта ш., 1997), «Идел» (Инта ш., 1997), «Чулпан» (Воркута ш., 2003), «Якташ» (Вуктыл ш., 2003) татар һәм башкорт милли-мәдәни автономияләре, «Болгар» татар-башкорт иҗтимагый-мәдәни үзәге (Усинск ш., 1992; рәисе — Г.Ә.Бәдретдинова), татар һәм башкорт яшьләре оешмасы (Усинск ш., 2002) эшли. К.Р.нда яшәүче татарларның һәм башкортларның 3 съезды була. К.Р.нда Мөселман диния нәзарәте, Ислам мәдәнияте үзәге (Воркута), «Нур мәхәлләсе» мөселман дини җәмгыяте (Сыктывкар; арендага алган бинаны мәчет итеп тоталар), «Риза» мөселман җәмгыяте (Княжпогост р-нының Емва пос.) бар. К.Р. татарларының иҗтимагый-мәдәни тормышы үзәге — Усинск шәһәре. Шәһәрнең бер мәктәбендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла (1998 дән; 1992–96 да — өч, 1996–98 дә ике мәктәптә укытыла. 1995–97 дә монда «Туган як авазлары» (айга 1 тапкыр) телевидение һәм «Җомга»(атнага 1 тапкыр) радио тапшырулары эфирга чыга. «Болгар» шәһәр иҗтимагый-мәдәни үзәге каршында шул ук исемдәге татар һәм башкорт җыр ансамбле (2005 тә Казанның 1000 еллыгына багышланган бәйрәмдә чыгыш ясый), «Таң йолдызлары» татар яшьләре эстрада һәм халык җырлары ансамбле, балалар «Агыйдел» халык биюләре хореография ансамбле, балалар «Ләйсән» татар җыры ансамбле оештырыла. Усинск татарлары турында документаль фильмнар төшерелә: «Халкым минем» («Татарстан–Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе) һәм «Болгар» иҗтимагый-мәдәни үзәге эшчәнлеге турында (1997,Үзәкнең 5 еллыгына багышлана). Воркутада 2003 тән М. Сәлимҗанов исем. татар театры, Ухта «Дуслык» татар-башкорт җыр ансамбле, Вуктылда милли көрәш секциясе эшли. 1992 дән Сабан туе бәйрәме — республика дәрәҗәсендә, 2002 дән татар-башкорт җыры фестивале шәһәр һәм республика күләмендә уздырыла. К.Р. һәм ТР арасында мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү төзелә. 1994 елдан Казан һәм Татарстан артистлары, иҗат коллективлары гастрольләре булып тора. Шәһәр һәм район милли-мәдәни автономияләре вәкилләре татар җырын башкаручыларның республика төбәкара һәм халыкара фестивальләре һәм конкурсларында катнаша. Татар акад. театрында коми язучысы А. Попов пьесасы буенча «Мөгезләр» спектакле куела. Җырчы, РФнең атказанган артисты Ә.Коротаеваның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге К.Р. б-н бәйле.

*Г.Ә.Бәдретдинова.*

**КОМИНТЕ́РН** посёлогы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 66 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 80 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Спас кантоны Спас волостенда. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. К. тирәсендә *Коминтерн комплексы* урнашкан. Халык саны: 1938 дә — 183, 1949 да — 315, 1958 дә — 753, 1970 тә — 411, 1979 да — 297, 1989 да — 184, 2002 дә — 102 кеше.

**КОМИНТЕ́РН II КАБЕРЛЕГЕ́**, Имәнкискә һәм Турбаслы археол. культуралары истәлеге. Актай елгасының (Иделнең сул кушылдыгы) сул ярында, Спас р-ны Коминтерн посёлогы каршында урнашкан. *Коминтерн комплексына* керә. 1984 елда Е.П.Казаков тарафыннан ачыла. 80 кабер тикшерелә (2003). Имәнкискә культурасына караган каберләр артык тирән дә, зур да түгел. Аларда яндырылган мәет сөякләре һәм балчык савытлар табыла. Турбаслы культурасына караган каберләр ингумация йоласы буенча күмелгән. Мәетләр озын һәм киң, кайчак ләхет уелган кабер чокырларына башлары б-н төньякка каратып куелган. Аларда ш.у. балчык савытлар, кием-салым, бронза һәм көмештән эшләнгән табыну әйберләре табыла. Бай хатын-кыз каберләрендә атларның баш һәм аяк сөякләре ияр һәм йөгән б-н бергә куелган була. Мондый каберләр соңгы чор сарматлар өчен хас. Аларның каберләрендә табылган әйберләр ш.у. Арал буендагы Җетеасар культурасы истәлекләренә охшаш һәм б.э.ның 6–7 йөзләренең 2 нче яртысы, ягъни төрки каганлыклар чорына карый. Каберлек Куйбышев сусаклагычы сулары б-н юыла (су күтәрелгән чакта каберлек утрауда кала).

*Әд.:* Казаков Е.П. Коминтерновский II могильник в системе древностей эпохи тюркских каганатов // Культуры евразийских степей второй половины I тысячелетия н. э. (вопросы хронологии). Самара, 1996.

*Е.П.Казаков.*

**КОМИНТЕ́РН КО́МПЛЕКСЫ** (археол.). Актай елгасының (Иделнең сул кушылдыгы) түбәнге өлешендә Спас р-ны Коминтерн посёлогы янында урнашкан. К.к. истәлекләре 1960–2000 елларда Е.П.Казаков, П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә. Таш гасыр тукталышы (палеолит); бронза гасыр курган каберлекләре һәм тукталышлары; Имәнкискә һәм Турбаслы культураларына караган шәһәрлек, авыллыклар һәм каберлекләр (к. *Коминтерн II каберлеге*); Болгар культурасы шәһәрлеге, авыллыклары һәм каберлекләре керә. Болгар торулыкларында торак-хуҗалык һәм җитештерү корылмалары калдыклары табыла; күпсанлы артефактлар: Алтын Урда чорына нисбәтле хезмәт һәм сугыш кораллары, әйләнмәле ысул б-н һәм әвәләп ясалган керамика калдыклары, ат дирбияләре, кием детальләре, төсле металлдан эшләнгән бизәнү әйберләре, көмеш һәм бронза таңкәләр җыеп алына. Күп кенә истәлекләр тулысынча юкка чыккан, Куй-





1. Бронза һәм көмеш эшләнмәләр. Төрки каганлык; 2. Бил каешы җыелмасындагы көмеш аеллар һәм бизәкләр. ТР ФА Тарих институтының Археологик тикшеренүләр милли үзәге фондлары.

бышев сусаклагычы сулары тәэсирендә җимереләләр.

*Әд.:* Старостин П.Н. Памятники именьковской культуры // Свод археол. источников. М., 1967. Вып. 1–32; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

*Е.П.Казаков.*

**КОМИССАРЕ́НКО** Юлий Семёнович (17.7.1910, хәзерге Украина Респ-касының Одесса өлкәсе Балта ш. — 29.12.1984, Казан), хуҗалык эшлеклесе, химик-технолог. Киев сәнәгать техникумын (1932), Текстиль һәм җиңел сәнәгать читтән торып уку ин-тының 5 курсын (Мәскәү, 1934), Коммунистик ун-т (Горький ш., 1934) тәмамлый. 1922–29 елларда күн з-дында, Тегү-текстиль кәсепчелеге кооперациясенең җитештерү берлеге инструкторы булып эшли (Балта ш.). 1932–39 да «Белка» мех ф-касында (Киров өлкәсе Слободской ш.) баш инженер (1933 тән). 1939–40 та СССР Җиңел сәнәгать министрлыгында Главмехның баш инженеры. 1940–41 дә Мәскәү мех комб-ты директоры. Татарстан мех җитештерү берләшмәсе директоры (1943–61, 1963–71). 1961–63 тә Татарстан ХХСның Җиңел сәнәгать идарәсе башлыгы. К. җитәкчелегендә Татарстан мех җитештерү берләшмәсендә реконструкция һәм яңа техник җиһазлау үткәрелә. Аның турыдан-туры катнашы б-н, иләнгән сарык тиресеннән әзерләнгән мехны затлыландыру технологиясе эшләнә һәм кулланылышка керә (соңрак ул СССР мех сәнәгате пр-тиеләренә дә кертелә). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). К. — «Казан мехчылары турында хикәят» («Сказ о казанских меховщиках», 1974), «Кәсеп итми табыш булмый» («Овчинка стоит выделки», 1978) китапларын төзүчеләрнең берсе. 1955–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин, Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**КОМИССАРЖЕ́ВСКАЯ** Вера Фёдоровна (27.10.1864, С.-Петербург — 10.2.1910, Ташкент), драма актрисасы, антрепренёр. Күренекле рус актрисаларының берсе. Иҗаты 19–20 йөзләрдә рус театры үсешен билгели. Актёрлык осталыгы дәресләрен В.Н.Давыдовтан һәм үз этисеннән — танылган опера җырчысы Ф.П.Комиссаржевскийдан ала. 1890 елда беренче тапкыр һәвәскәр сәхнәдә чыгыш ясый, 1893 тә профессиональ сәхнәдә (Новочеркасск ш.) эшли башлый. 1896–1902 елларда — С.-Петербургтагы Александра театрында; 1904 тә С.-Петербургта үз театрын булдыра. Теге яки бу образны иҗат иткәндә К., көнкүреш гадәтилегеннән баш тартып, аның поэтик башлангычын, рухи дөньясын тамашачыга җиткерергә омтыла. Ул башкарган Лариса («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский), Нина Заречная, Саша, Соня («Акчарлак», «Иванов», «Ваня абзый», А.П.Чехов), Луиза («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Рози, Клерхен («Күбәләкләр сугышы», «Содомның һәлак булуы», Г.Зудерман), Нора («Курчак йорты», Г.Ибсен) рольләре театр тормышында гына түгел, ә иҗтимагый тормышта да зур вакыйга була: әлеге героиняларда ирekкә, гаделлеккә көчле омтылыш сизелә, рухи золымга каршы ялкынлы протест чагыла. 1903, 1904, 1905, 1909 елларда Казанда гастрольләрдә була, биредә ул иң уңышлы рольләрен башкара, һәм алар җәмәгатьчелектә гаять зур резонанс тудыра.



В.Ф. Комиссаржевская.

*Әд.:* Комиссаржевская В.Ф.: Письма, воспоминания, материалы. Л.–М., 1964.

**КОМИССА́РОВ** Владимир Сергеевич (19.5.1938, Апас р-ны Биеш а. — 2.2.2005, Казан), инженер-механик, ТАССРның атказ. механизаторы (1973), РСФСРның атказ. рационализаторы (1985), РСФСР Дәүләт бүләге лауреаты (1990). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1965). 1958–61 елларда Апас р-нының Горбунов исем. к-зында шофёр. 1965–75 тә Казан вет. ин-тының укыту-тәҗрибә хуҗалыгында баш инженер. 1975–99 да «Татсельхозтехника» ЖБдә: Биектау р-н бүлегендә баш инженер, идарә, бүлек башлыгы, ЖБ рәисе урынбасары (1991–98). Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен модуль-блоклы культиваторлар эшләү, аларны технологик нигезләү һәм җитештерүне үзләштерү» дигән хезмәт өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КОМИССА́РОВ** Иван Михайлович (26.1.1948, Чистай р-ны Троицкий пос.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1998). Саратов югары партия мәктәбен тәмамлый (1979). 1964–80 дә Чистай р-нында: «Рассвет» к-зында (1970 кадәр), «Урожай» к-зы партоешма секретаре (1970–73), «Советский труд» к-зы рәисе (1973 тән) булып эшли. 1980 нән Түбән Кама р-нында: район агросәнәгать берләшмәсе башлыгы, 1990 нан «Советский труд» к-зы рәисе (1998 дән «Ялантау» а.х. җитештерү кооперативы). К. җитәкчелегендә мөгезле эре терлек өчен товарлыклы-сөтчелек комплекслары, ат абзарлары, терлек азыгы цехлары, механика мастерское, тегермән, пекарня, ашлык складлары, терлек азыгы саклау биналары, өчәр бүлмәле 50 фатир, балалар бакчасы, һ.б. социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары төзелә, Ялантау авылына газ һәм телефон кертелә, юл, урам һәм җитештерү объектлары терр-яләрендә асфальт җәелә. 2001–05 тә хуҗалыкта бөртекле ашлык җитештерү, 1991–95 б-н чагыштырганда, 54,5% ка, ит — 43,5 ка арта.

*И.Н.Афанасьев.*

**КО́МЛЕВ** Абрам Павлович (30.10.1879, Харьков губ., Валково өязе Петропавловка а. — 7.8.1918, Казан), Казанда профсоюз хәрәкәтен оештыручыларның берсе. 1905–07 еллардагы рев-циядә катнаша (Казан, Донбасс). 1906–09 да Вологда губернасында сөргендә була. 1907 дә К. катнашында Казанда Профсоюзларның үзәк бюросы оештырыла. Ул татар революция эшлеклеләре, ш.и. Х.Ямашев б-н тыгыз элемтәдә тора. 1911 дән РСДРПның Казан ком-ты әгъзасы, шәһәр пр-тиеләрендә стачкалар оештыручыларның берсе. 1914–16 да эшчеләр һәм Казан хәрби гарнизоны солдатлары арасында сугышка каршы актив агитация алып бара. 1917 дән Казанда профсоюз эшендә, Казан губерна азык-төлек җитештерүчеләр берлеге җитәкчеләренең берсе. Казан алынганнан соң ак чехлар тарафыннан атып үтерелә.

*С.И.Ионенко.*

**КО́МЛЕВА** Татьяна Ивановна (28.12.1956, Яшел Үзән ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1980 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, «ВНИИУС» АҖдә эшли, өлкән фәнни хезмәткәр (2008 дән). Хезмәтләре углеводород чималын күкерттән чистартуга карый. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КОМЛЫ́ КАВА́Л** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 23 *км* көньяктарак, Кавал күле буенда. 2010 елда 1833 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 75 %, татарлар — 23 %) яши. Халкының төп шөгыле — ит терлеге асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ильинский, Кавал исемнәре б-н дә билгеле. Башта авыл Казан архиерей йорты карамагында була. 1764 тә халкы — экономик крәстияннәр, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту һәм тимерчелек эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Илья чиркәве (1820 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1871 дә ачыла), 2 тимерче алачыгы, 4 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3391,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 158 ир-ат; 1859 да — 857, 1897 дә — 1219, 1908 дә — 1339, 1920 дә — 1377, 1926 да — 1486, 1949 да — 901, 1958 дә — 1083, 1970 тә — 739, 1979 да — 1221, 1989 да — 1553, 2002 дә — 1682 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**КОМЛЫ́-ЧОКЫРЛЫ́ ҖИРЛӘРНЕ́ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ́ КАЗА́Н О́КРУГЫ**, 1913 елда Казан һәм Вятка губерналарында комлы җирләрне һәм чокырларны ныгыту өчен Казан һәм Вятка губерналарында оештырыла. 1913 кә кадәр Казан губернасы терр-ясе

Саратов комлы-чокырлы округы составына керә. 1918 дә бетерелә.

**«КОММУ́НА»**, газета; к. «*Кызыл таң*».

**КОММУНА́ЛЬ ХУҖАЛЫ́К**, шәһәр, авыл һәм посёлоклар халкына хезмәт күрсәтү пр-тиеләре һәм оешмалары җыелмасы. Сан.-техника (сүүткәргечләр, канализация һ.б.), энергетика (эл., газ һәм җылылык бүлү челтәрләре, котельныйлар, ТЭЦлар, эл. станцияләре) пр-тиеләрен, тышкы төзекләндерү корылмаларын (юллар, тротуарлар, транспорт күперләре, җәяүлеләр өчен җир асты һәм җир өсте кичүләре һәм эстакадалар, гидротехник корылмалар, яшел утыртылмалар, урамнарны яктырту һ.б.), кунакханәләрне һ.б.ны үз эченә ала. К.х. эшчәнлегенә ш.у. торак фондыннан файдалану хезмәте дә керә, ул, үз чиратында, халык яшәгән терр-янең коммуналь пр-тиеләре һәм тышкы төзекләндерү хезмәте б-н бәйләнгән. К.х.ның үсеш темплары сәнәгать җитештерүенең үсүе һәм шәһәр халкының саны арту б-н билгеләнә.

Шәһәрләрне төзекләндерүнең беренче элементлары кар суларын агызу өчен канаулар казудан, җәмәгать коеларын һәм чишмәләрен төзеклектә тотудан гыйбарәт була. Казанда беренче төзекләндерү омтылышлары (урамнарга һәм мәйданнарга таш җәю, сүүткәргеч төзү) 19 йөздә башлана. 19 йөз ахырында шәһәр эчендә 500 дән артык кое исәпләнә; шәһәрдән көнкүреш калдыкларының 10 нан бер өлеше чыгарыла. Черек күл тирәсендә урамнардан һәм ишегалларыннан яңгыр һәм кар суларын агызу өчен торба үткәрелә, аңа кушып канаулар ерыла.

Казанда үзәкләштерелгән су тәэминаты 1874 елда сафка баса. Баштарак сүүткәргеч юлларының озынлыгы 25 *км* була. Сүүткәргечнең төрле урыннарында су алу будкалары, янгын сүндерү хезмәте өчен краннар урнаштырыла.

1850 елларда Казан урамнары киндер мае яга торган фонарьлар б-н яктыртыла, 1874 тә газ фонарьлары барлыкка килә. 1895 тә шәһәрдә «*Газ һәм электр*» АҖгә караган беренче эл. станциясе файдалануга тапшырыла. 1897 дә үзәк урамнар эл. б-н яктыртыла башлый.

Шәһәрләрне төзекләндерү җирле үзидарә органнары, җәмәгатьчелек тырышлыгы б-н алып барыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында ш.у. хосусый төзекләндерү эшчәнлеге дә күзәтелә.

Сов. хакимияте елларында Татарстанның К.х.ы үзгәртеп корыла: гамәлдәге сүүткәргеч станцияләрнең куәтләре арттырыла; чистарту корылмалары төзелә, газлаштыру һәм җылылык б-н тәэмин итү буенча зур эшләр башкарыла. 1938 дә сәнәгый сүүткәргечнең 1 нче чираты эшли башлый, эчәргә яраклы су күбрәк күләмдә бирелә. 1940 та сүүткәргечләрнең озынлыгы 76,4 *км* тәшкил итә. Шәһәрләрдә чисталыкны саклау өчен автоцистерналар, чүп чыгару торбалары, су сиптерү машиналары кулланыла башлый. 1939 да пычрак суларны канализациягә чыгаручы 1 нче агызу станциясе файдалануга тапшырыла. Канализациянең гомуми озынлыгы 1932 дә 5,2 *км* булса, 1940 та 48,2 *км* га җитә.

Массакүләм торак төзелеше башлану б-н (1950 еллар), К.х. системасы ныграк үсеш ала. Мунчалар, механик кер юу йортлары һ.б. коммуналь пр-тиеләр төзелә һәм капиталь төзекләндерелә. Урамнарны яктырту буенча эшләр башкарыла. 1970 елларда торак йортларны төзекләндерү максатында фатирларны үзәкләштерелгән су, канализация, җылылык, кайнар су б-н тәэмин итү һәм газлаштыру буенча чаралар күрелә.

1990 елларга шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы посёлокларның торак фонды сүүткәргеч б-н 96% ка, канализация б-н 94% ка, кайнар су б-н 69% ка, үзәкләштерелгән җылыту системасы б-н 95% ка тәэмин ителә. 1990 елларның 2 нче яртысында торак-коммуналь хуҗалыкта реформалар башлана.

1992–2003 елларда коммуналь хуҗалык объектлары аз күләмдә төзелә.

2009 да торак фондының 84,4% ы сүүткәргечләр б-н (шәһәрләрдә 93,7%, авылларда 59,2%), 77,8% ы канализация б-н (91,7% һәм 40,9%), 96,2% җылыту системасы б-н (98,2%, 90,8%)(ш.и. үзәкләштергәне 63,6%), 70,7% кайнар су б-н (ш.и. үзәкләштерелгәне 52,1%) тәэмин ителә. Республикада комплекслы төзекләндерелгән торакның уртача өлеше 70,7% тәшкил итә. Су тәэминаты системасы барлык шәһәрләр һәм шәһәр тибындагы посёлокларны, ш.у. 1884 авыл җирлеген (гомуми исәптән 62,2%) колачлый. Республикада 2012 су җыю җайланмасы (Казанда 14, ш.и. «Идел» җир өсте су җыю җайланмасы) эшли. Барлык шәһәрләрдә, 18 шәһәр тибындагы посёлокта, 77 авыл җирлегендә канализация системасы бар. Иң яхшы җиһазландырылган су б-н тәэмин итү системалары — Балтач, Түбән Кама, Питрәч, Бөгелмә р-ннарында (тиңдәшле рәвештә барлык торак фондның 97,2%, 96,4%, 94,5%, 93,9%).

Сүүткәргеч-канализация хуҗалыгында төп фондларның тузу дәрәҗәсе — 49%.

1990 елларда — 2000 еллар башында ведомстволар карамагындагы объектларны (котельныйлар һ.б.) муниципаль милеккә әверелдерү хисабына коммуналь энергетиканың җитештерү-техник базасы 20% тан артык күләмгә үсә. Халыкның җылылык энергиясенә ихтыяҗын 6 ТЭЦ, 2 ГРЭС, 1 ГЭС, 3 район һәм 1897 сәнәгый котельныйлар тәэмин итә.

2003 нең башыннан күп фатирлы торак йортлар б-н идарә итү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшләре бүленә; торак йортларга капиталь ремонт эшләре конкурс нигезендә башкарыла. Торак-коммуналь хезмәт өчен түләүләрне исәпләү өчен хисап-касса үзәкләре; коммуналь исәп-хисап приборларын урнаштыру һәм карап тоту оешмалары булдырыла. Барлык юнәлешләрдә эшчәнлекне муниципаль һәм хосусый оешмалар алып бара. Хәзерге шартларда дәүләт органнары торак-коммуналь хуҗалык б-н идарә итүне гаиләләрнең төрле тормыш дәрәҗәсен һәм тулаем керемен исәпкә алып, халыкка тиешле сыйфатлы хезмәт күрсәтү принцибыннан чыгып оештырырга тырыша.

2008 дә 137 *км* сүүткәргеч, 145 *км* канализация, 4,4 җылылык һәм 41,3 газ челтәре гамәлгә кертелә.

2000 нең 1 гыйнварына К.х. тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган шәһәр җирләренең гомуми мәйданы 146,8 мең *га* (ш.и. яшел утыртылмалар 24,5 мең *га*), урам-юллар челтәренең (урамнар, юллар, яр буйлары) гомуми озынлыгы 8495 *км* (ш.и. яктыртылулы — 7117,5 *км*) тәшкил итә. Шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы посёлокларда 411 күпергә һәм юл киселешләренә хезмәт күрсәтелә. Механикалаштыру ысулы б-н 49686,8 мең $м^2$ мәйдандагы шәһәр терр-ясе җыештырыла, җыештыруда һәм көнкүреш калдыкларын чыгаруда 1723 автомашина эшли.

Түләүле хезмәт күрсәтүләрнең гомуми күләмендә торак-коммуналь хезмәткә түләүләр 24% туры килә, шуның 80,8%ы халыктан җыеп алына. Шәһәрләрдәге торак-коммуналь хезмәт өчен түләү системасында гражданнарны адреслы социаль яклау каралган. Аз керемле гаиләләргә торак компенсацияләре бирү (субсидияләр) программасы эшли. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә халыкны социаль яклауның бер формасы — өстенлекле категория — дәүләт (шәһәр) алдындагы аерым хезмәтләр өчен, профессиональ билге, социаль билге (инвалидлар, хезмәт ветераннары һ.б.) буенча ташламаларның гамәлдә булуы. 2007 дә ТРда 138096 гаилә (барлык гаиләләрнең 10,6%ы) ай саен уртача 526 сум ташламадан файдаланган.

*Әд.:* История Казани: В 2 кн. К., 1988–91.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**«КОММУНИ́ЗМ БАЙРАГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Төмән губерна комитеты органы. 1919 елда Төмән шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**«КОММУНИ́ЗМ БАЙРАГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Горький өлкәсе Петрякс райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы башкарма ком-ты органы. 1945 елның маеннан 1957 нең 17 ноябренә кадәр Петрякс авылында (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе) татар телендә нәшер ителә, барысы 928 сан. 1956 ның 5 августына кадәр «Сталин байрагы» исеме б-н чыга. Төрле еллардагы мөхәррирләре — А.Шевкаев, А.Чарлаганов, А.Якупов, И.Нәүретдинов. Газета төп игътибарны мәдәният һәм мәгариф учаклары эшчәнлегенә бирә, район тормышын һәрьяклап яктырта. Татар мәдәниятенең танылган хезмәткәрләре турында язмалар басыла. «Әдәби сәхифәләр» рубрикасында җирле әдипләргә, «Безнең «Чаян», «Шомбай камчысы» һ.б. рубрикаларда тәнкыйть материаллары (мәкалә, фельетон, шигырь, карикатура) урын ала. Газетада өлкәдә туган җырчы Р.Ваһапов һәм язучы К.Нәҗми язмалары басыла.

*Әд.:* Фәтхуллин К. Каурый каләм эзеннән (Нижгар татар журналистика тарихы. 1919–1963 еллар). Н.Новгород, 2004.

*К.Р.Фәтхуллин.*

**«КОММУНИ́ЗМГА»**, к. «*Бәйрәкә*».

**«КОММУНИ́ЗМГА»**, к. «*Богады*».

**«КОММУНИ́ЗМГА»**, к. «*Игенче*».

**«КОММУНИ́ЗМГА»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Төмән шәһәр ком-ты һәм

Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатларның шәһәр советы органы. 1931 елның 7 ноябреннән 1936 нең 17 апреленә кадәр Төмән шәһәрендә (Омск өлкәсе) машина төзү пр-тиеләрендә, Төмән агач эшкәртү һәм химия сәнәгатендә эшләүче татар эшчеләре өчен татар телендә нәшер ителә, барысы 427 сан. 1932 дә «Ударник» г-тасын кушымта итеп чыгара.

*Әд.:* Ф а с а х о в К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОММУНИ́СТ»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Коммунистлар һәм чит ил эшчеләре, крәстияннәренең революцион комиссиясе төркеме органы. 1918 елның 26 ноябреннән 1919 ның мартына кадәр Казанда венгр, немец, рус телендә нәшер ителә, барысы 6 сан. Мөхәррире — Шандор Апати.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОММУНИ́СТ»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Чиләбе өлкә ком-ты һәм хезмәт ияләре депутатларының өлкә советы органы. 1931 елның 20 декабреннән 1938 нең 1 апреленә кадәр Чиләбе шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 709 сан. 1935 нең 6 апреленә кадәр «Төзү ударнигы» исеме б-н чыга. Чиләбе трактор, металлургия, торба үткәргеч з-длары һәм Магнитогорск, Златоуст, Копейск шәһәрләре пр-тиеләренең татар эшчеләре, Чиләбе өлкәсе авыл хезмәтчәннәре өчен чыгарыла. 1933–34 елларда «Курылыс ekningici» («Төзелеш ударнигы») исемендә казакъ телендә кушымта да нәшер ителә.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОММУНИ́СТ»**, иҗтимагый-сәяси газета. СССР ҮБКның Милләтләр советы палатасы органы. 1932 елның 9 гыйнварыннан 1934 нең 30 декабренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 845 сан. «*Эшче*» һәм «*Игенчеләр*» г-талары җирлегендә оештырыла. Мөхәррире — И.Агишев; әдәбият һәм сәнгать бүлеге җитәкчесе, күчмә редакцияләр җаваплы мөхәррире — М.*Җәлил*. Актив авторлары — А.Айдар, З.Бәширова, Г.Баязитова, З.Насыйров, В.Садри, Н.Сафаров, Ф.Уразаев. Даими рубрикалар: «Советлар Союзында», «Бишьеллыкны — вакытыннан алда», «Колхозларны ныгыту өчен көрәшкәндә», «Ленинчыл милли сәясәт өчен», «Дингә каршы көрәштә», «Мәскәүдә», «Чит илләрдә», «Бездә һәм аларда», «Театр һәм музыка» һ.б. Икътисад мәсьәләләрен яктыртуга, илне индустрияләштерүгә зур игътибар бирелә. Газета 1 нче һәм 2 нче бишьеллыкның яңа төзелешләренә — Беломор-Балтыйк каналы, Магнитогорск металллургия комб-ты, «Уралмаш» з-ды, Днепрогэс, Мәскәү метро төзүчеләр хезмәте, Донбасс шахтёрлары, Әзәрбайҗан нефтьчеләре һәм шуларда татар эшчеләренең керткән өлешенә аеруча зур игътибар һәм урын бирә. Татарстандагы үзгәртеп корулар һәм сәнәгать төзелеше: «Спартак» ф-касы, Казан мех комб-ты, ясалма каучук з-ды, киноплёнка ф-касы, Казандагы авиатөзелеш з-ды, Зеленодольск (Яшел Үзән) шәһәре суднолар төзү з-ды һ.б. турында язмалар чыга. Социалистик ярыш барышы, авыл тормышы, колхоз төзелеше киң яктыртыла, агротехник киңәшләр басыла. Басма халык мәгарифе торышы, әдәбият һәм сәнгать үсеше турында яза. Н.Баян, Ә.Гәрәй, М.Җәлил, Ә.Ерикәй, М.Зәйни, Г.Ибраһимов, Г.Иделле, Ш.Камал, М.Крымов, Г.Кутуй, М.Максуд, Ш.Маннур, К.Нәҗми, М.Садри, Д.Фәтхи һ.б.ның әдәби әсәрләре басыла. «К.» та 1 нче Бөтенсоюз язучылар съезды материаллары җентекләп яктыртыла (Мәскәү, 1934), М.Горький, К.Нәҗми, В.Кирпотин, В.Киршон, А.Таһиров, К.Тинчурин, А.Толстой, В.Ставский, П.Юдин докладлары, Әрмәнстан, Әзәрбайҗан, Башкортстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Каракалпакстан, Таҗикстанда әдәбият торышы турында чыгышлар урнаштырыла. «К.» даими рәвештә татар вакытлы матбугатына, ш.и. «Кызыл Татарстан», «Урал кочегаркасы», «Пролетар», «Баку эшчесе»нә күзәтүләр бастыра. «Ленинчыл милли сәясәт өчен» бүлегендә Татарстан һәм Башкортстанның иҗтимагый-сәяси тормышы яктыртыла, милли мәсьәләдә «партиягә каршы юнәлеш»кә, «вак буржуаз милләтчелек һәм солтангалиевчелек»кә каршы көрәш турында язмалар урын ала. Газета СССРда татарларның тупланып яшәү урыннарында киң тарала.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОММУНИ́СТ»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Оренбург өлкә ком-ты һәм хезмәт ияләре депутатларының өлкә советы органы. 1935 елның 28 июленнән 1939 ның 27 февраленә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 474 сан чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — Х.Йосыпов, С.Алиев. Оренбург өлкәсендәге сәнәгать, а.х., мәдәният һәм мәгариф учреждениеләрендә эшләүче татарлар өчен чыгарыла. Редакциянең төп өлеше нахак рәвештә буржуаз милләтчелектә гаепләнеп кулга алынганнан соң, партия өлкә ком-ты карары б-н газетаны бастыру туктатыла.

*Әд.:* П а н и н а Т.С. Оренбургская областная татарская газета «Коммунист». Оренбург, 1997.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОММУНИ́СТ»**, газета, к. «*Социализм юлы*».

**«КОММУНИ́СТ ТАТА́РИИ»** («Татарстан коммунисты»), айлык теоретик һәм иҗтимагый-сәяси журнал. КПССның Татарстан өлкә ком-ты органы. Казанда 1920 елның декабреннән (өзеклекләр б-н) нәшер ителә. 1920 нең февраль-ноябрендә (14 сан) «Известия губкома РКП(б)» исеме б-н атнага 2 тапкыр чыккан (ТАССР төзелгәннән соң — «Бюллетень Татарского обласкома РКП(б)») газетаның дәвамчысы. 1920 нең 1 декабреннән «Вестник Татарского областного комитета РКП(б)» ж-лына үзгәртелә (мөхәррирләре — А.*Таняев*, С.Якимов; 5 сан, соңгысы — 1921 нең 20 апреле). Журнал югары партия органнары карарларын, җирле партия органнарының хисапларын, партия съездлары һәм конференцияләре турында хәбәрләр, үзәктәге һәм урыннардагы партия тормышы хакында күзәтүләр, партия, профсоюз төзелеше турында аналитик мәкаләләр бастыру өчен чыгарыла. 1921 нең сентябрь–ноябрендә «Спутник агитатора» исеме б-н 4 саны дөнья күрә. Алга таба 1925 нең гыйнварына кадәр «Коммунистический путь» исеме б-н чыга (1923 нең октябреннән 1924 нең сентябренә кадәр журнал басылудан туктатылып тора; ВКП(б) өлкә ком-тының һәм ТАССР Главполитпросветының берләштерелгән органы; мөхәррирләре — Г.*Мансуров*, М.*Корбут*, В.Сергеев; 26 сан). 1925 нең гыйнварыннан апреленә кадәр айга ике мәртәбә




**«Коммунист Татарии».** 1. «Вестник Татарского областного комитета РКП(б)»; 2. «Коммунистический путь»; 3. «Путь Ильича»; 4. «Спутник партийного активиста»; 5–6. «Җитәкче»; 7. «Татарстан большевигы»; 8. «Коммунист Татарии».

«Путь Ильича» ж-лы чыга (4 сан). 1925 нең маеннан сентябренә кадәр «Причал» ж-лы чыгарыла (мөхәррирләре — Г.Цыпин, Я.Виленский; 8 сан); ул — «*Красная Татария*» («Кызыл Татарстан») г-тасына кушымта булган иллюстрацияле әдәби-иҗтимагый басма. 1926 ның 11 гыйнварында ВКП(б) ҮКның матбугат бүлеге ТАССР матбугаты турында карар кабул итә, моның б-н ул Татарстан өлкә ком-тына татар һәм рус телләрендә партия журналы чыгарырга боерык бирә. 1926 ның маенда өлкә ком-ты 1927 нең февраленә кадәр чыгып килгән «Спутник партийного активиста» («Партия активисты юлдашы») исеме б-н рәсми органын яңадан бастыра башлый (мөхәррире — М.*Хатаевич*; 10 сан). 1935 нең маеннан 1938 нең апреленә кадәр өлкә ком-ты «Большевик Татарии» ж-лы чыгара (мөхәррирләре — Б.Абдуллин, Л.Пинхасик, И.Кондратьев, С.Мөхәммәтов; 36 сан). 1926 ның июненнән өлкә ком-ты рус телендәге басма б-н параллель рәвештә татар телендә мөстәкыйль «Җитәкче» ж-лы чыгара башлый (мөхәррире — З.Гыймранов, А.Әхмәтов, Б.Абдуллин; 78 сан). Ул партия оешмалары җитәкчеләре һәм активистлары өчен чыгарыла һәм шуңа күрә теоретик мәсьәләләргә зур урын бирә. 1932 елның мартында журналның исеме «Татарстан большевигы» дип үзгәртелә, ул 1941 елның июненә кадәр чыга (мөхәррире — Б.Абдуллин, А.Әхмәтов, Ф.Рәхмәтуллин, Х.Галиев, С.Мөхәммәтов; 139 сан). «Җитәкче»дән аермалы буларак, бу басма урыннардагы партия хезмәткәрләренең сорауларына җавап бирә.

Озак вакытка тукталып торганнан соң, 1958 нең гыйнварында журнал бер үк вакытта рус («Коммунист Татарии») һәм татар («Татарстан коммунисты») телләрендә яңадан чыга башлый (мөхәррирләре — Ш.*Хамматов*, М.*Мусин*, Җ.*Гыйльманов*, Ш.*Вәлиев*, А.*Афанасьев*). 1990 ның декабрендә аның соңгы 698 нче саны чыга. 1991 нең гыйнварында «К.Т.» базасында яңа — «*Татарстан*» ж-лы нәшер ителә башлый. Бөтен совет чоры дәвамында журнал ТАССРда әйдәп баручы идеологик басма булып тора, анда партия һәм хөкүмәт документлары, җирле хакимият органнарының карарлары, партия төзелеше һәм идея-тәрбия эше өлкәсендә теоретик һәм методик күрсәтмәләр, төбәктәге алдынгы коммунистик һәм революцион хәрәкәт активистлары турында очерклар, матбугатка күзәтүләр басыла. Журнал Халыклар дуслыгы ордены (1977), РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1970) б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979; Валеев Ш.М. Страницы истории татарской прессы // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4; шул ук. Старейший в республике журнал // Тонус. 2000. № 6.


*Т.М.Насыйров.*

**«КОММУНИСТИ́ЧЕСКИЙ ПУТЬ»**, журнал; к. «*Коммунист Татарии*».

**КО́МПЛЕКСЛЫ АШЛАМАЛА́Р**, үсемлекләр өчен катнаш яки эретелгән тозлар (катлаулы, катнаш ашламалар) яки 2 яисә 3 төп элементтан торган (азот, фосфор, калий) химик кушылмалар. К.а.га микроэлементларны да кертәләр. К.а.ны икеле (азотлы-калийлы, азотлы-фосфорлы, фосфорлы-калийлы) һәм өчле (азотлы-фосфорлы-калийлы), катлаулы (аммофос, нитроаммофос, нитрофос, нитрофоска, нитроаммофоска, аммоний полифосфаты), катлаулы-катнаш һәм катнаш ашламаларга аералар. К.а.да азот, фосфор һәм калийның бәйләнеше төрлечә; ул җитештерү ысулына, алынган компонентларга, үсемлекләргә кирәклеге дәрәҗәсенә бәйле. К.а., нигездә, югары концентрацияле була, 45–60% NPK дан тора. Алар яхшырак саклана, транспорт б-н күчергәндә зарарланмый, яхшы физик үзлекләргә ия: озак ятудан укмашмый, туфракка механик ысул б-н керткәндә, яхшы сибелә. К.а. ТРның бөтен типтагы туфракларында барлык а.х. культуралары өчен кулланыла. Аларның күләме туфрак картограммаларыннан һәм уңыш программаларыннан, үсемлекләрнең таләпләреннән, уңышның планлаштырылган (программалаштырылган) булуыннан чыгып исәпләнә. К.а. үсемлекләргә шундый ук күләмдә туклыклы матдәләр булган гади ашламалар катнашмасы кебек тәэсир итә. Ләкин ярлы көлсу туфракларда. К.а., магний, күкерт, молибден, бакыр, цинк һ.б. микроэлементлары булмаганлыктан, гади катнашмалардан калыша.

*И.Н.Афанасьев.*

**КОМПОЗИЦИО́Н ЭЛЕКТРОХИ́МИК КАПЛАМНА́Р** (КЭК), электр үткәрүчән өслекле әйберләргә юка катлам рәвешендә капланган, бик вак металл-калыплы каты композицион материалларның (КМ) микро- һәм ультрамикро төрләре. КМ — күп компонентлы материаллар, калып нигездән (полимерлар, металлар, углеродлар, керамика һ.б.) һәм дисперс фазадан — ДФ (сүс, җепсыман кристаллар, нечкә дисперс кисәкчекләр) гыйбарәт. Тоташ һәм дискрет сүсләрдән һәм полидисперс кисәкчекләрдән (а, в) торучы кайбер КМ һәм ДФ төрләренең сурәте схемада күрсәтелгән:



ДФ материалга йөкләнешнең өстәмә өлешен үзләштерә, аның механик, термофизик, фрикцион, магнит, электр һәм радиотехник үзлекләрен модификацияли. ДФ матдәләре (КМ техникасында аларны кайвакыт тутыргычлар буларак билгелиләр) табигатьләре буенча органик (полимер) һәм нәорганик (углерод, металлар, пыялалар, карбидлар, нитридлар һ.б.) була алалар. Калып материал ныклыгын, фазалар арасындагы көчәнеш күчерү һәм бүлүне тәэмин итә, КМның герметиклыгын, җылылыкка, дымга, утка һәм химик чыдамлыгын билгели. Мономатериаллардан өстенлекләре — зуррак механик ныклык, югары коррозион чыдамлык, түбәнрәк тыгызлык, яңа химик һәм/яки физик үзлекләр комплексы, каталитик активлык, пластикларның электр үткәрүчәнлеге, декоратив сыйфатлар. Макрокомпозицион материаллар күптән билгеле: техникада — гетерофазалы металл эретмәләре (чуен, корыч, вольфрамның кобальт-карбидлы бик каты эретмәсе һ.б.), цементлар һәм бетоннар, порошоксыман матдәләр, сүсләр яки тукыма б-н ныгытылган пластмассалар, алюминийның бакыр-оксидлы эретмәсе, ситаллар (өлешчә кристалланган пыялалар); табигатьтә — гранит, опаллар, үзагач һ.б. күзәнәкле материаллар. КЭК макрокомпозицион материаллардан югары дисперслы халәттә эреми торган һәм авыр эри торган матдәләре булган (микро- һәм субмикроүлчәмле өлешләр, сүсләр һәм монокристаллик «мыеклар») электролит эремәләре яки эретелмәләреннән электрохимик юл б-н әйберләр өслегенә юка металл — калыплы катлам рәвешендә каплануы б-н (өлештән алып берничә дистә микрометрга кадәр) принципиаль аерылалар. Электр ярдәмендә утыртылган металлар (никель, бакыр, көмеш, алтын һ.б.) калып булып тора. Электролит-суспензияләрдә 1 дән алып 500 *г/л* га кадәр концентрацияле һәм кисәкчек үлчәмнәре 5–10 нанометрдан алып 0,5–5 микрометрга кадәрге ДФ (углерод, бор, кремний, алюминий, цирконий оксидлары, кремний, хром оксидлары һәм карбидлары) бар. Катламның микрокалынлыгы һәм чит җисемнәрнең югары дисперслылыгы машина төзелеше, прибор төзелеше, электрон, электротехник сәнәгатьнең һ.б. тармакларында әйберләр өслеген модификацияләүдә яңа мөмкинлекләр ачалар.

СССРда беренче тапкыр буларак КЭК булдыру буенча фәнни һәм гамәли юнәлеш 1960 елларда Казан технол. ун-тында (Р.С.*Сәйфуллин* һәм аның хезмәттәшләре) үсеш ала (чит илдәге эшләр б-н бер үк вакытта); аннан соң тикшеренүләр Казан авиация, мед., һәм а.-х. ин-тларында, илнең төрле фәнни үзәкләрендә (Вильнюс, Донецк, Киев, Кишинёв, Красноярск, Мәскәү, Новочеркасск, Төмән һ.б. шәһәрләрдә) дәвам иттерелә. Казан галимнәре тарафыннан тикшерелгән һәм эшләнгән капламнарда, аерым шартларда никель, бакыр, көмеш яки башка металларга катнашып, графит һәм молибден дисульфиды кисәкчекләре аларга үзлегеннән майлану үзлеге, канифольнең утырымга бергә төшкән өлешләре — уңайлы эретеп ябыштыру, оксид өлешләре ышкылуга һәм коррозиягә югары чыдамлык үзлекләрен бирә. Электр ярдәмендә утыртылган уннан артык металл калыплары б-н КЭК; кайбер оксидлар һәм карбидлардан, бор, кремний, углеродның авыр эретелүчән порошокларыннан торган, классик гальваник капламнарга караганда коррозиягә каршы торучанрак, җылытуга һәм ышкылуга чыдамрак ДФ тәкъдим ителә. Көмеш яки алтын б-н эл. контактларында билгеле төрдәге кисәкчекләрнең утырымга бергә төшүе бик нәзек катламнарның эшләнмәләрдән файдалану вакытын монометаллика караганда күп тапкырга арттыруы, электрон сәнәгать пр-тиеләрендә кыйммәтле металларны экономияләргә ярдәм итүе ачыклана. Кайбер гидратлашкан металл оксидлары коллоид кисәкләрен көмеш б-н утырымга бергә төшереп, тоныклануга чыдам катламнар алына. КЭКны өйрәнү һәм форма-







**Компрессорлар төзү.** 1. 10ТХМВ–2000–2 суыту җайланмасының компрессор агрегаты; 2. Кислород өчен 3ЦКК-100/3,5 М компрессор җайланмасы корпусы; 3. Гомуми куллану өчен МЦК 43ВЦ-160/9.

лаштыру өчен стационар булмаган электрик режимнар, анализның заманча физик ысуллары кулланыла (И.А.*Абдуллин*, И.М.Вәлиев). Югары температуралы коррозиягә чыдам капламнар булдырыла (И.Г.*Хәбибуллин*). Нанометр үлчәмнәрендәге ДФ кисәкчекләрен куллануга нигезләнеп, капламнар сыйфатын яхшыртуга һәм аларны куллану өлкәсен киңәйтүгә мөмкинлек бирүче яңа буын КЭК эшләнә (Р.С.Сәйфуллин һ.б.). Фәнни эшләнмәләр «Элекон» ФҖБ (баш металлург П.С.Мельников), «Органик синтез» АҖдә, «Теплоконтроль» ҖБдә, С.М.Киров исем. ясалма каучук з-дында, Тольятти, Харьков, Кишинёв шәһәрләрендәге машина төзү пр-тиеләрендә һ.б. гамәлгә кертелә. КЭКны камилләштерү, аны алу процессларын интенсивлаштыру һәм үзлекләрен модификацияләү эшләре Казан технол. һәм мед. ун-тларында, Казан аграр ун-тында алып барыла.

*Әд.:* С а й ф у л л и н Р.С. Неорганические композиционные материалы. М., 1983; ш у л у к. Комбинированные электрохимические покрытия и материалы. М., 1990; С а й ф у л л и н Р.С., А б д у л л и н И.А. Композиционные электрохимические покрытия: Современные исследования казанских учёных // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3–4. *Р.С.Сәйфуллин.*

**КОМПРЕ́ССОРЛАР ТӨЗӮ́**, махсуслаштырылган энергетика машиналары төзү тармагы, газүткәргечләр буенча газны ерак араларга күчерү һәм газ яки парларны 4 бар (400 *кг/см*²) һәм аннан да зуррак басымга кадәр кысу өчен компрессорлар техникасын җитештерә. Россиядә беренче компрессор («һава кыскыч») 1860 елда уйлап табучы С.И.Барановский тарафыннан С.-Петербургның Александр з-дында (хәзер «Компрессор» АҖ) эшләнә. СССРда сәнәгать компрессорларын серияләп чыгару 1930–32 дә М.В.Фрунзе исем. Сумы машина төзү з-дында (Украина) башланып китә, 1934 тә азот-водород катнашмасын кысу өчен беренче пешкәкле компрессор чыгарыла, ул пар машинасы күчергече б-н эшли, ахыргы басым 300 *кг/см*² һәм җитештерүчәнлеге 10 мең *м*³/*сәг*, 1938–39 да 850 *кг/см*² басымлы компрессор җитештерә башлый. Бөек Ватан сугышыннан соң компрессорлар җитештерү илнең һәм чит илләр ихтыяҗларын канәгатьләндерә. РФдә компрессор җиһазлары җитештерү б-н 22 завод шөгыльләнә. ТР — компрессор машиналары төзелешенең зур үзәкләреннән берсе; тармак *Казан компрессор машиналары төзү заводы* (К.к.м.т.з.) һәм 1957 дә компрессорлар техникасының төп төрләрен булдыру буенча үз базасын үстерү өчен төзелгән Компрессорлар төзү буенча махсус конструкторлык бюросы (хәзер «Турбокомпрессор» АҖ, к. *Үзәктән кугыч һәм роторлы компрессорлар институты*) продукцияләре б-н билгеләнә. ТРда компрессор җиһазлары *Казан төгәл машиналар төзү заводы*нда, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе»ндә, ш.у. гомуми куллану компрессорларын җыю буенча кече һәм урта пр-тиеләрдә җитештерелә. Беренче продукция — 2 РК-1,5/220 пешкәкле кислород компрессоры 1951 дә К.к.м.т.з.нда эшләнә; 1955 тә ЦК-100 тибындагы үзәктән кугыч һава компрессорлары чыгарыла башлый. 1957 дә кислород алу җайланмаларында һаваны 220 атм.га кадәр кысу өчен пешкәкле КД-8/5–220 компрессорларының беренче эшче проекты эшләнә (1972 гә кадәр заводта чыгарыла). 1959–65 тә эшләнеп гамәлгә кертеләләр: фреонлы (1АЦ4 1–2–7), пропанлы (АТП-5,3) һәм аммиаклы (АТКА-545–4000) машиналар, ш.у. турбосуыту машиналары (ВХМ 1–29 һәм МТХМ 1–25), аларда салкын агент сыйфатында һава кулланыла (Казанда гына чыгарылалар); теләсә нинди сәнәгать газлары өчен пешкәкле махсус компрессорлар, куәтле үзәктән кугыч кислород компрессорлары (КТК-7/35, КТК-12,5/35, 4 ЦКК-250/15), циркуляцияле герметик азот-водородлы компрессор (2ЦКК-10/300 һәм 2ЦКК-10/350). Күләмле кысу компрессорлары җитештерүендә төп урынны винтлы машиналар алып тора. Дөнья практикасында беренче тапкыр «Турбокомпрессор» АҖ хезмәткәрләре тарафыннан иярчен нефть газын май тутырылган компрессорлар б-н компримирлау идеясе чынга ашырыла: 1972 дән К.к.м.т.з. һәм Чита машиналар төзү з-дында төрле типтагы һәм максаттагы винтлы компрессорлар серияләп чыгарыла башлый (криоген техникасында, газны җыю, эшкәртү һәм аеруда, нефтьне газ б-н күтәртүдә һ.б. максатларда), 1987 дә «Такат» тибындагы блоклы компрессор җайланмалары төзелә, 1988 дә Уфа нефть эшкәртү з-дына факел газын кысу өчен компрессор куела. 1972–77 дә корпуслары вертикаль аерулы үзәктән кугыч югары басым компрессорларын проектлаштыру һәм җитештерү башлана. 1970 еллар ахырында фәнни-тикшеренү ин-тында гомуми кулланылыштагы күп кенә типта һәм үлчәмнәрдә компрессорлар проектлаштырыла, 1980 дә күп валлы мультипликаторлы компрессор (32 ВЦ-100/9) эшләнә, 1992–96 да күп валлы суыткыч компрессорлар проекты әзерләнә. Бу схема буенча газ лифты өчен уртача җитештерүчән компрессор җайланмасы (КЦКУ-4000) (Самотлор газ чыганагында, Көнбатыш Себер), ш.у. азотны һәм газлар катнашмасын кысу өчен үзәктән кугыч компрессорлар (ТЦ-86/3–7,1) («Каустик» АҖдә кулланыла, Эстәрлетамак ш.) эшләп чыгарыла. 1996–97 дә К.к.м.т.з.нда Халыкара «Диңгез старты» («Морской старт») проектының космик ракеталар комплексы составындагы ракеталар бүлекләрен термостатиклаштыру системалары өчен «АЭРОКОМ» маркалы күп валлы 4 компрессор җайланмасы проектлаштырыла һәм эшләп чыгарыла. 1970 еллар башында, Төньякның ерак төбәкләреннән салына торган магистраль газүткәргечләр һәм компрессор станцияләрен тизләтеп төзегән чорда, фәнни-тикшеренү ин-тында 6,3 *МВт* егәрлекле ГПА-Ц-6,3 тибындагы блоклы газ кудыру агрегаты әзерләнә (хәрәкәт үзенең очу ресурсын эшләгән авиация двигателеннән күчерелә); 1996 дан яңа принциптагы ГПА-16 «Волга» газ кудыру агрегатын эшләү башлана (К.к.м.т.з. һәм Казан моторлар төзү ҖБ б-н берлектә), аның кудыргычына майлау таләп ителми, электромагнитик подшипниклар һәм газодинамик тыгызлагычлар куела. Газ һәм нефть чыгару сәнәгате өчен блоклы детандер-компрессорлы БДКА2–4 УХЛ4 агрегатлары (Ноябрьск газ эшкәртү з-дында кулланыла, Ямал-Ненец авт. округы) һәм ТКО-75/42 детандер-компрессорлы турбоагрегатлар (Оренбург гелий з-дында) эшләп тапшырыла. Аз суытулы суыткыч машиналарга ихтыяҗ туу сәбәпле, фәнни-тикшеренү ин-тында стандарт режимда эшләүче 1 МКТ-130–7–3 тибындагы винтлы компрессорларның яңа буыны булдырыла (К.к.м.т.з., Ижевскиның «Агрохолодмаш» з-ды чыгара), ияртүче роторының диаметры 83 *мм*, тешләр нисбәте 5/7 булган винтлы суыткыч компрессор проектлаштырыла (Мәскәүнең «Компрессор» з-ды үзләштерә), салкынлык җитештерүе 1,5–10 *кВт* булган спираль компрессорлар тудырыла (Казан төгәл машиналар төзү з-дында чыгарыла башлый). Энергия саклаулы технологияләрне тормышка ашыру һәм экология мәсьәләләрен хәл итү өчен махсус кулланылыштагы компрессор техникасы булдырыла: парга әйлән-


дерү җайланмаларында механик җылылык насослары сыйфатында куллану өчен үзәктән кугыч вакуумкомпрессорлар, аэрация һәм озонлау җайланмалары өчен һава кудыргычлар, нефть саклагычларда углеводородларның очучан фракцияләрен тотып алу һәм җыйнау, ш.у. газларны түбән температуралы куеруы хисабына эшкәртү өчен компрессорлар һәм суыту машиналары эшләнә.

Компрессор машиналары төзү буенча инженер һәм фәнни кадрларны Казан технол. ун-тының илдә бердәнбер энергомашиналар һәм технол. җиһазлар ф-ты (1970 тә компрессорлар төзү ф-ты буларак оештырыла, кафедралары — компрессор машиналары һәм җайланмалары, суыту техникасы һәм технологияләре) әзерли. Фәнни-тикшеренү эшләре компрессорлар техникасының барлык юнәлешләре буенча алып барыла («Турбокомпрессор фәнни-тикшеренү ин-ты» АҖ б-н берлектә); «Компрессорлар төзү» дигән фәнни юнәлеш булдырыла, аның кысаларында докторлык диссертацияләре яклаучылар: Г.А.Поспелов, В.А.Максимов, В.Б.Шнепп, А.А.Мифтахов, И.Г.Хисамиев, Ә.М.Галиев, С.С.Евгеньев, Г.С.Баткис, М.Б.Һадиев; «Проектирование и исследование компрессорных машин» дигән фәнни хезмәтләр җыентыгы басыла (1982 елдан). Компрессорлар төзү үзәге буларак, Казан халыкара танылу ала. Төрле елларда «Турбокомпрессор фәнни-тикшеренү ин-ты» АҖ, «Казанкомпрессормаш» АҖ һәм Казан технол. ун-ты б-н берлектә компрессорлар техникасы буенча 5 халыкара фәнни-техник конференция үткәрелә.

*Әд.:* Барановский С.И. Воздухосжиматель // Промышленность. 1862. Кн. 4; История ПО «Компрессор». Л., 1988; 50 лет ОАО «Казаньcompressормаш». К., 2001.

*В.А.Максимов.*

**КОМСОМО́Л КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Казан эчендә, Дербышки микрорнының көньяк чигендәге урман массивында. Су өслегенең мәйданы 2 *га*. Озынлыгы 350 *м*, иң зур киңлеге 60 *м*, иң зур тирәнлеге 3 *м*. Ясалма күл. Озынча түгәрәк формада. Күл карст казанлыкларыннан тора, аның төбе 1970 елларда техника ярдәмендә тирәнәйтелә, тигезләндерелә, аннан соң казанлыклар К.к. ярында урнашкан артезиан сулары б-н тутырыла. Сулык ярлары чагыштырмача биек; көньяк яры текә; нарат, имән, юкә агачларыннан торучы катнаш урман б-н капланган; төньяк ярында нарат утыртмалары бар. Туенуы катнаш, явым-төшем һәм артезиан сулары исәбенә. Кайвакыт язын К.к. казанлыклары су б-н тула, һәм ике юнәлештә агым барлыкка килә: көнчыгышта Киндер елгасы үзәнлегенә һәм көнбатышта күрше карст казанлыкларына. Ял итү урыны.



Комсомол күле.

**КОМСОМО́Л РАЙОНЫ́**, *Чуаш Республикасының* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1939 елның 22 маенда оештырыла. Мәйданы — 630,3 *км*². Үзәге — Комсомол авылы (Чабаксардан 115 *км* көньяктарак). Халкы — 27251 кеше (2010), ш.и. 7135 татар (2002). Татарлар, башлыча, 9 торак пунктта: Урмай (2681 кеше), Чичкан (874), Татар Шарауты (296), Алибаш (484), Каенлык, Татар Ивашкиносы, Әхмәт, Тукай (1819), Комсомольск (591) авылларында яши. 1917 гә кадәр районда 3 мәчет эшли. Соңгы елларда Тукай (1992), Урмай (1990, 2005, 2012), Чичкан (1991), Алибаш, Каенлык (икесе дә 1994 тә), Татар Шарауты (1995), Әхмәт (2004) авылларында мәчетләр ачыла. Районның 5 мәктәбендә башлангыч сыйныфларда укыту татар телендә алып барыла, ә өлкән сыйныфларда татар теле фән буларак өйрәнелә. Урмай һәм Алибаш авылларындагы мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә дәресләр татар телендә бара.1984 тән Урмай авылында «Мишәр» эстрада-фольклор коллективы (1996 да аңа халык коллективы исеме бирелә) эшли. Районда ТР телевидениесе тапшырулары трансляцияләнә. 2005 тә К.р.ның ун китапханәсендә 7583 исемдәге татар китаплары фондлары була.

*Ф.А.Гыйбатдинов.*

**КОМСОМО́Л СПО́РТ ФЛОТЫ́**, республика ярымхәрби оешмасы. 1923 елда ТАССР Коммунистик Яшьләр Союзы инициативасы б-н яшүсмерләрне Хәрби-диңгез флотында хезмәткә әзерләү өчен оештырыла. Оештыру структурасы «хәрби суднолар»дан (дредноутлар) торган спорт түгәрәкләреннән гыйбарәт, аларның һәрберсенә хәрби-диңгез корабльләренең исемнәре бирелә («Марат», «Аврора», «Парижская коммуна», «Комсомолец» һ.б). Дредноутлар район яки кантон «эскадралары» составына керәләр. К.с.ф.ның башкомандующие итеп иң беренче оештыручыларның берсе И.Маргалин билгеләнә, аның урынбасары — С.Н.*Гладков*. Дәресләрнең программасы булачак хәрби морякларның сәяси, физик (гимнастик күнегүләр, уеннар) һәм махсус әзерлекләрен күздә тота. Дредноутлар әгъзаларының («спортвоенморлар») үз хәрби формалары (бескозыркалар, җиңдәге билгеләр) була. К.с.ф. 1925 тә физик культураның шәһәр һәм кантон советлары булдырылу һәм Физкультура югары советының ХКС структурасыннан ТАССР ҮБК карамагына күчүе сәбәпле үзгәртеп корыла.

*Әд.:* Колчин Н.Т. Физическая культура и спорт в Татарии. К., 1969.

**КОМСОМО́ЛЕЦ** посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы елгасы (Каманың сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 879 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 51%, руслар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз, куян асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1930 да нигез салына. Оештырылган көннән Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 394, 1958 дә — 285, 1970 тә — 267, 1979 да — 144, 1989 да — 611, 2002 дә — 709 кеше.

**«КОМСОМО́ЛЕЦ ТАТА́РИИ»**, газета; к. «*Молодёжь Татарстана*».

**КОМСОМО́ЛКА** посёлогы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 75 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кырыкмас елгасы буенда. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1941 дә нигез салына. Оештырылган көннән Красный Бор р-нында. 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1958 дә — 22, 1970 тә — 134, 1989 да — 26, 2002 дә — 2 кеше.

**КОМСЫ́Л БАЛЧЫ́К**, ком-балчыклы көпшәк утырма тау токымы, составында балчыклы кисәкчекләр һәм вакланган материаллар 10–30 % (массасы буенча) була. Ком бөртекләре һәм тузан кисәкчекләренең составы буенча — эре, вак комлы һәм тузансыман К.б.ка аералар. Килеп чыгышы, гадәттә, континенталь. Татарстан терр-ясендә К.б.ның уннарча чагылмасы һәм чыганаклары ачыкланган, шулардан Алабуга-2, Афанасьев (Алабуга р-ны), Буа-6 (Буа р-ны) һ.б. файдаланыла. Табигый чыганаклардан тыш, К.б.ның эре карьерлардан (Ворошилов, Биклән һәм Элеватор) ачык ысул б-н чыгарылучы техноген чыганаклары билгеле. К.б. кирпеч һәм чүлмәк савытлар җитештерүдә кулланыла.

**КОМТА́Ш**, утырма тау токымы, цементлашкан ком бөртекләреннән (0,1 дән алып 2 *мм* га кадәр үлчәмдә) һәм минераллардан тора. К.та цемент балчыксыл, известьле, тимерле, ак ахаклы һ.б. булырга мөмкин. К.ның төсе вакланган компонентларның төсенә бәйле; соры, саргылт соры яки ак төсләр өстенлек итә, сирәк кенә кызгылт булырга мөмкин. Кайнар сулар һәм газлар йогынтысы астында К. кварцитка (кварцитлы комташ) күчә. Минераль составы буенча К.ны түбәндәгеләргә аералар: бакырлы, кварцлы, кыр шпатлы, гипслы һ.б. ТРда битуминозлы К. чыганаклары билгеле — күбрәк көньяк-көнчыгыш районнарда (к. *Битумнар*), бакырлы — төньяк-көнчыгыш районнарда (к. *Бакыр рудалары*), төзелеш К.ы — республиканың күпчелек районнарында. Күбесенчә Пермь яшендәге утырмаларда К. линзалар һәм катламнар хасил итә, файдалы катламның калынлыгы 2–3 тән 20 *м* га кадәр, запасы уннарча, йөзләрчә мең *м*³ тан берничә млн. *м*³ ка кадәр. К.ның көпшәк төрләре — ком сыйфатында; катылары вакташ, бут ташы, тышлау, абразив (шомарту), утка чыдам материаллар, флюслар җитештерүдә; чиста кварцлылар ($SiO_2$>95%, $Fe_2O_3$<2%) — пыяла җитештерү сәнәгатендә һ.б.да кулланыла.

*Әд.:* Закономерности размещения и пути использования строительного минерального сырья на востоке Татарии // Тр. КФАН СССР. Сер. геол. 1957. Вып. 4; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*Г.Н.Бирюлёв.*

**КОМУ́Ч**, к. *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты*.

**КОМЫРГУЖА́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* көньяктарак, Шәмәк елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 291 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 4 җил тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1703,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 771, 1897 дә — 1082, 1908 дә — 1217, 1920 дә — 1263, 1926 да — 1274, 1938 дә — 1330, 1949 да — 684, 1958 дә — 519, 1970 тә — 411, 1979 да — 297, 1989 да — 301, 2002 дә — 340 кеше.

**КОНАНБА́ЕВ** Абай (Ибраһим) (29.7.1845, хәзерге Казакъстан Респ-касының Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе, Абай р-ны Каскакболак а. — 23.6.1904, Балачакпак җәйләве, хәзерге Казакъстан Респ-касының Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе Җидебай авылында җирләнә), мәгърифәтче шагыйрь, казакъ язма әдәбиятына нигез салучы. Каркалы округы приказы өлкән солтаны Конанбай Үскенбаев улы. 10 яшеннән Семипалатинск мәдрәсәсендә укый (мөдире Әхмәт Риза), бер үк вакытта рус мәктәбенә дә йөри. Куныркукшин волосте бие итеп сайлап куела; 1885 елда волость биләре җыелышында биш өяздән «Семипалатинск казакъларының төбәк белән идарә итүне яхшырту буенча теләкләре» комиссиясе рәисе итеп тәгаенләнә.

Мәдрәсәдә укыган елларда яза башлый. К. гаять тирән белем иясе була. Шәрекъ дин галимнәре тәфсиреннән файдаланып, мантыйк һәм мөселман фикъһе нигезләрен, әт-Табари, Рабгузи, Рәшидеддин, татар тарихчысы Ш.Мәрҗани һ.б.ларның тарихи хезмәтләрен өйрәнә. Әсәрләренең ахырына Кокпай Җантасов дигән иптәшенең исемен куя. Иҗади активлыгының иң югары ноктасы 40 яшенә туры килә. Шуннан соң гына Абай псевдонимын куллана башлый.

К. — лирик һәм сатирик шигырьләр, «Мәсгуд» (1887), «Әзим кыйссасы» («Әзім», 1901), «Искәндәр» («Ескендір», 1901) поэмалары авторы. «Нәсыйхәт сүзләре» («Гакълия») исемле фәлсәфи-әхлакый әсәрендә шул замандагы казакъ җәмгыятенең төрле катлаулары тормышы, төрле характердагы актуаль мәсьәләләр сәнгати чагылыш таба. Анда татарлар турында К.: «... алар яхшы солдатлар; алар яхшы укучылар, эшли беләләр», — дип яза. Әсәрләрендә әдип казакъларны, традицион күчмә терлекчелек б-н көн күрүдән тыш, игенчелек б-н дә шөгыльләнергә, төрле һөнәрләр өйрәнергә, дөньяви белем алырга чакыра. Икътисади үсешкә, мәдәниятка һәм прогресска илтәчәк юлны ул гомуми бәхеткә китерүче гадел хезмәттә күрә.

К. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, И.Гёте, А.Мицкевич һ.б. әсәрләрен казакъ теленә тәрҗемә итә. А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» шигъри романындагы «Татьяна хаты»н көйгә сала, һәм ул популяр булып китә. К. үз шигырьләренә дә көйләр яза. Аның думбра һәм кубыз өчен язылган көйләре һәм җырлары бүген дә билгеле. К.ның шигырьләре телдән телгә күчеп тә, язма рәвештә дә тарала, 1886 дан атна саен чыга торган «Акмолинские ведомости» г-тасының казакъ телендәге кушымтасында басыла. Беренче китабы 1909 да нәшер ителә.

К. әсәрләре 60 телгә (ш.и. татарчага да) тәрҗемә ителгән. Аның иҗади мирасы 20 йөз башы татар әдипләренә дә йогынты ясый. К.ның шигъри җыентыклары Казанда 1947 һәм 1981 дә татар телендә басылып чыга. 1961 дән Караганда өлкәсендәге шәһәр, Алма-Атадагы ун-т, Казакъ опера һәм балет театры һ.б. Абай исемен йөртә. Казакъстан Респ-касының берничә шәһәрендә Абай музейлары эшли.

Ә с ә р.: Казакъ акыны Ибраһим Күнанбай угълының өлеңі. СПб., 1909; Абай тирмәсе. Оренбург, 1916; Абай Конанбай өлеңнері. К., 1922; Тандамалы өлеңнер. Таш., 1922; Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1947; Өлеңдер мен поэмалар. Аудармалар мен кара сөз: 2 т. Алматы, 1977; Шигырьләр, поэмалар һәм Хикмәтле сүз. К., 1981; Лирика и поэмы. М., 1940.

*Әд.:* И б р а һ и м о в Г. Телләре башка булса да, күңелләре бер // Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре. К., 1924; С и л ь ч е н к о М.С. Творческая биография Абая. А.-А., 1957; А у э з о в М.О. Мысли разных лет: Исслед. и статьи. А.-А., 1961; ш у л у к. Абай Кунанбаев: Статьи и исслед. А.-А., 1967; Абай энциклопедиясі. Алматы, 1990.

*Л.Х.Хәмидуллин, А.М.Ахунов.*

**КОНА́ХИНА** Ирина Александровна (2.8.1966, Казан), җылылык энергетикасы галиме, техник фән. д-ры (2005). 1989 елда Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлый, Казан энергетика ун-тында эшли, сәнәгать җылылык энергетикасы каф. мөдире (2007 дән). Хезмәтләре җылылык алмашу гидродинамикасына һәм процессларына, сәнәгатьтә энергия технологияләре комбинациясенә карый. Күпшәле җылылык элементларындагы нәсызыкча-үзле тирәлекләр агышының җылылык алмашу процессларын интенсивлау закончалыкларын тикшерә. Нефть химиясе сәнәгатендә энергия технологиясе комплексларын анализлау, синтезлау һәм оптимальләштерүнең методологик нигезләрен эшли (ясалма изопрен каучук синтезлау производствосында кулланыла). К. җитәкчелегендә изоамиленны изопренга дегидрирлауның югары темп-ралы участоклары системаларын эффектив термодинамик синтезлау үткәрелә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2010). Уйлап табуга патенты бар.

Х е з м.: Организация энерготехнологических комплексов в нефтехимической промышленности. М., 2001 (автордаш); Организация эффективных систем энерготехнологического комбинирования в нефтехимической промышленности. К., 2008.

**КОНВЕ́РСИЯ**, тел белемендә махсус сүз ясагыч аффикслар кулланмыйча гына яңа сүз ясау. Бу очракта сүз яки аның формасы бер сүз төркеменнән икенчесенә үзгәрешсез күчә. К. — герман, роман, төрки һ.б. телләргә хас күренеш. Татар телендә К. юлы б-н исемнәр, сыйфатлар, рәвешләр, теркәгечләр, кисәкчәләр, ымлыклар, бәйлекләр ясала. Башка сүз төркеменә күчкән сүзләр тулысынча шул сүз төркеменең лексик-грамматик үзенчәлекләрен алалар. Мәсәлән, башка сүз төркемнәреннән исемгә күчкән сүзләр исем сүз төркеме парадигмасын кабул итәләр, ягъни килеш, сан, тартым һәм хәбәрлек б-н төрләнә башлыйлар; семантик яктан алар грамматик мәгънәдәге предметны (затны) белдерәләр: кара (төс) — кара (язу карасы); карт (яшь үзенчәлеге) — карт (олы яшьтәге кеше); буяу (эш-хәрәкәт) — буяу (эш-хәрәкәтне башкару өчен кирәк булган әйбер).

*Әд.:* Г а н и е в Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. К., 2006; ш у л у к. Конверсия в татарском языке. К., 1985.

*Ф.Ә.Ганиев.*

**КОНГЛОМЕРА́Т** (лат. conglomeratus — тупланган), ватыклары цементлашып каткан тау токымы, 50% тан артыгы 1 *см* дан зуррак (2 *см* да була) үлчәмдәге механик нык ташлардан тора. Алеврит, ком, гравий катышмалары булган галька. Гадәттә, Fe оксидлары, карбонат һәм балчык материаллар, сирәгрәк кремнезём б-н цементлашып каткан. Составы буенча К.: полимикт (төрле токымнардан) һәм мономикт (бер токымнан); материал



Шомартылган конгломерат. Татарстан.

туплану ысулы буенча: диңгез, күл, аллювиаль, пролювиаль. К.ның токымнар эчендә булуы борынгы катламнарның көчле юылуын, коры җирнең яисә рельефның күтәренке урыннары якын булуын күрсәтә. Республиканың көнчыгышындагы Пермьнең татар ярусында К. галькасы үлчәмнәренең артуы һәм аның составы җимерелмә материалларның Урал сулары б-н килүен чагылдыра. Та-



Малахит сызыклы конгломерат. Вятка елгасы бассейны югары Пермь утырмаларыннан. Татарстан.

тарстан терр-ясендә К. мезозой һәм полеозой яшендәге катламнарда очрый. Юра һәм акбур К.ларында *фосфоритлар* ятмалары бар (к. *Сөендек фосфоритлар чыганагы*).

**КОНДАКО́В** Вадим Александрович (15.3.1886, Пермь губ. Усы ш. — 25.5.1959, Казан), педагог, географ, ПФАнең мөхбир әгъзасы (1945). 1911 елда Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң, Уфа шәһәре урта уку йортларында табигать белеме һәм география укыта. 1916 да Уфа татар-башкорт укытучылар семинариясендә директор. 1918 дән Екатеринбург укытучылар ин-тында. Ак армия частьләре б-н Екатеринбург шәһәреннән китә, Томск, Бийск шәһәрләре уку йортларында укыта. 1922 дән Пермь губернасының халык мәгарифе бүлегендә. 1923 тән Пермь ун-тының геогр. кафедрасында, 1930 дан Екатеринбург корыч һәм эретмәләр ин-тында, 1932 дән Пермь пед. ин-тының физик геогр. каф. мөдире. 1947–59 да Казан пед. ин-тында, 1952 елга кадәр геогр. методикасы каф. мөдире. Хезмәтләре Урал төбәге тарихына һәм физик географиясенә, мәктәптә төбәкне өйрәнү һәм география укыту методикасы мәсьәләләренә карый. К. муляжлар һ.б. күрсәтмә әсбаплар булдыра. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экономическая география в школах и техникумах. Пермь, 1924; О краеведении в школе // Изв. АПН РСФСР. 1950. Вып. 21; Краеведческий принцип в преподавании географии // Изв. АПН РСФСР. 1951. Вып. 24.

*Әд.:* З у е в а О.В. Географ Вадим Александрович Кондаков. Пермь, 1977.

*Е.В.Липаков.*

**КОНДИ́ТЕР СӘНӘГАТЕ́**, азык-төлек җитештерү сәнәгатенең махсуслаштырылган ф-каларда, икмәк комб-тлары, консерв з-длары һәм азык-төлек комб-тлары цехларында кондитер эшләнмәләре җитештерүче тармагы. Шикәрле (конфетлар, карамель, ирис, драже, шоколад һәм какао-порошок, пастила-мармелад эшләнмәләре, хәлвә, Шәрекънең башка төр тәм-том ризыклары) һәм камыр (печенье, крекерлар, галетлар, пряниклар, вафли, пирожныйлар, тортлар, кекслар һ.б.) азык-төлек товарлары җитештерә. Тармакта 3,3 меңләп кеше эшли, җитештерү күләме 44 мең *т* тәшкил итә (2008).

Казан губернасында К.с. 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Беренче эре кондитер фабрикалары Казанда 1868 (хуҗасы — И.С.Одинцов), 1888 (В.Ибраһимов һәм Е.С.Смоленцев), 1892 (Н.П.Пирогов) елларда оештырыла; 1897 дә И.Д.Смирнов кондитер-шоколад з-дын нигезли. 1913 кә Казан губернасында 14 пр-тие була (шуларның 12 се — Казанда), пр-тиеләрдә эшләүчеләр саны 300 ләп кеше тәшкил итә, 1 млн. сумлык продукция эшләп чыгарыла. Җитештерү ярымкустарь характерда башкарыла. Утлы пешерү мичләре, кул пресслары, кул туглагычлары булган ачык пешерү казаннары кулланыла. Эшләнмәләр кулдан төрелә.

Совет хакимияте елларында тармак пр-тиеләре национализацияләнә. 1924 тә Казанда «Светоч» ф-касы (соңыннан 2008 гә кадәр — *«Заря» кондитер фабрикасы»* АҖ), 1943 тә шәһәр азык-төлек комб-ты җирлегендә Чистай кондитер ф-касы оештырыла. Кондитер эшләнмәләре ш.у. районнардагы 20 азык-төлек комб-тында җитештерелә. Бөек Ватан сугышы елларында пр-тиеләр фронт өчен эшлиләр. Шәһәр азык-төлек комб-тлары җирлегендә Әлмәт кондитер ф-касы (1964) һәм Зәй ф-касы (1978) төзелә. 1970 еллар башында К.с.ндә ресурс саклаучы яңа технологияләр, җитештерүне комплекслы механикалаштыру һәм автоматлаштыру, төяү-бушату һәм күчерү-саклау эшләрен механикалаштыру алымнары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. «Птичье молоко», «Чио-Чио-Сан», «Сказки Тукая», «Рудольф Нуриев», «Мой Татарстан» һ.б. исемдәге продукция чыгарыла. Соңгы елларда К.с. «Казан күмәч-кондитер комбинаты», «Казан икмәк заводы» (№ 2, 3, 4, 5, 7) АҖләрен, «Бәхетле», «Акульчев» ҖЧҖләрен, «Мета», «Регина» кече пр-тиеләрен, «Движение» ФҖБ (Казан), «Джойта», «Булай» ҖЧҖләрен (Чаллы ш.), Зәй, Чистай шәһәрләрендәге кондитер ф-каларын һ.б. колачлый. Кондитер эшләнмәләренең бер өлеше Казанның «Алекс» азык-төлек товарлары з-ды, «Чаллы икмәге» АҖ, азык-төлек комб-тлары, җәмәгать туклануы пр-тиеләре тарафыннан чыгарыла. Тармак пр-тиеләренең зур өлеше җирле әһәмияткә ия һәм продукцияне эчке базар өчен җитештерә, продукциянең 10% чамасы РФнең башка төбәкләренә, БДБ илләренә җибәрелә. Башлыча, җирле чимал (он, шикәр, бал, атланмай, терлек майлары һ.б.) кулланыла, чималның һәм ярымфабрикатларның бераз өлеше РФнең көньяк төбәкләреннән һәм БДБ илләреннән китерелә. Хәзерге вакытта Татарстанда кондитер эшләнмәләрен төп җитештерүчеләр: «Чаллы икмәге» ЯАҖ, «Күмәч-кондитер комбинаты» ААҖ, «Чистай кондитер фабрикасы» ААҖ, икмәк заводлары җирлегендә оештырылган пр-тиеләр, ш.у. «Акульчев» ҖЧҖ.

Т Р д а  к о н д и т е р  э ш л ә н м ә л ә р е  җ и т е ш т е р ү,  1940–2010  е л л а р,  м е ң  *т*

| 1940 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 2000 | 2010 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6,5 | 23,4 | 39,7 | 42,6 | 66,6 | 33,6 | 42,2 |

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; Н а з и п о в а К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976; Ф а с х у т д и н о в К.Ф. Индустриальное развитие Республики Татарстан (1920–1990). К., 2002.

*Р.З.Мансуров, К.Ф.Фәсхетдинов.*

**КОНДРА́ТЬЕВ** Владимир Владимирович (5.8.1950, Алтай краеның Барнаул ш.), педагог, механика өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1979), пед. фән. д-ры (2000), проф. (2000). 1973 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук махсус двигательләр кафедрасында эшли. 1983 тә Казан технол. ун-тының югары матем. кафедрасында, бер үк вакытта, 1999 дан шул ук ун-тның Идел буе һәм Урал уку йортлары укытучыларын әзерләү һәм квалификациясен күтәрү үзәгендә директор урынбасары, 2008 дән — директор. Хезмәтләре югары инженерлык белеме методологиясе һәм фундаментализациясе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Фундаментализация профессионального образования в технологическом университете. К., 2000; Методология науки и высшего профессионального образования. К., 2001; Методология науки и высшего профессионального образования в условиях информатизации. К., 2004.

**КОНДРА́ТЬЕВ** Гавриил Григорьевич (22.3.1902, Казан губ., Чабаксар өязе Миснер а. — 11.9.1991, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1941), проф. (1947). 1927 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, шунда ук тире-венерология клиникасында эшли. 1941–45 елларда хәрби медицина хезмәтендә, эвакуация госпитале башлыгы, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 дан Кырым (Симферополь ш.), 1954 тән Омск, 1960 тан Казан мед. ин-тларында тире-венерология каф. мөдире, 1971 дән проф.-консультант. Хезмәтләре тире һәм венерик авырулар патогенезын, дерматологиядә аллергия һәм аутоаллергияне, олы күзәнәкләрнең функциональ активлыгын, нуклеин кислоталар динамикасын һәм тире микроэлементлары составын өйрәнүгә карый. Омск, Симферополь, Казан шәһәрләренең дерматологлар фәнни җәмгыятьләре идарәсе рәисе. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реактивность организма и стафилококковая инфекция: Дис. ... К., 1940.

*Әд.:* Памяти профессора Гавриила Григорьевича Кондратьева // Казан. мед. журн. 1992. № 2.

**КОНДРА́ТЬЕВА** Екатерина Сергеевна (8.4.1982, Пенза өлкәсенең Колышлей р-ны Колышлей штп), спортчы (җиңел атлетика), Россиянең халыкара класслы спорт остасы (2004). Спорт б-н 1994 елда Павлово шәһәренең 1 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый, тренерлары — М.Н.Комлев (1998 гә кадәр), Е.Н.Борисенко (1999 дан), О.И.Павлова (2003 тән). РФ (1999 дан), ТР (2003 тән) җыелма командалары әгъзасы. Олимпия уеннарында (2004), Европа (2005), дөнья (2005) чемпионатларында катнаша. Клуб командалары арасында Европа чемпионнары кубоклары (2000–05), 4×400 *м* эстафета узышларында Россия (2004) һәм Европа СПАР (2005) кубоклары иясе. 4×400 *м* эстафета узышында Бөтендөнья универсиадасы чемпионы (2003). «Россия-Бөекбритания-США» матчларында, «Россия-АКШ» 4×100 *м* эстафета узышында (2005), 60 һәм 100 *м* га йөгерүдә Ислам хатын-кызларының 4 уенында (Иран, 2005) җиңүче. Халыкара Гран-при җиңел атлетика серияләре ярышларында (көмеш 100 һәм 200 *м* га, бронза — 200 *м* га йөгерүдә, 2005), РФ чемпионатында, Бертуган Знаменскийлар мемориалында, «Русская зима» (бронза, 200 *м* га йөгерүдә, 2004–05), «Россия-АКШ» матчында (бронза, 200 *м* га йөгерүдә, 2005) медальләр ала. Дөнья (4×200 *м* эстафета узышында), Азия (60 һәм 200 *м* га йөгерүдә, 2005) рекордчысы.

**КОНДРА́ЦКИЙ** Борис Леонтьевич (февр. 1887, хәзерге Краснодар краеның Усть-Лаба станицасы — 1947, Казан), химик-технолог,

химия фән. д-ры (1944), Артиллерия ФАнең мөхбир әгъзасы (1947), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1944). Кадетлар корпусын (1904) һәм артиллерия уч-щесен (Воронеж ш., 1906) тәмамлаганнан соң хәрби хезмәттә, Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1916 елдан Сестрорецк корал з-дында. 1919 да Артиллерия академиясен (Петроград) тәмамлый, Охта химия з-дында эшли. 1926 дан Самара химия з-дында: сынау һәм тикшеренүләр бүлеге мөдире, фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире. 1933 тә Шостка химия-технол. ин-тында хәрби дисциплиналар каф. мөдире. 1934 тән Казан химия-технол. ин-тында, азот кушылмалары технологиясе һәм химиясе каф. мөдире, проф. (1938). К. шартлаткыч матдәләр характеристикаларын (шартлау җылылыгы, детонация тизлеге, тыгызлык, бәрүгә карата сизгерлек), аларның химик составы һәм төзелеше б-н үзара бәйләнешен өйрәнә. 29 фәнни хезмәт авторы.

*В.Г.Абзалова.*

**КОНДЫ́З** (Castor fiber), кимерүчеләр отрядындагы кондызлар семьялыгыннан имезүче хайван. Евразия һәм Төньяк Америкада аерым яшәү урыннары сакланган. Археол. казу эшләре күрсәткәнчә, 1–4 нче йөзләрдә К.лар төбәкнең бөтен терр-ясендә яшәгән, 19 йөз башында кырып бетерелгән. 1949 елда Воронеж саклаулыгыннан китерелгән 20 К. Кама елгасының түбәнге агымына җибәрелә. Татарстан терр-ясендә Кече Чирмешән, Шора, Казансу, Зөя, Илләт, Шомбыт, Бәтке һ.б. елгаларда колонияләр булып яши. Гәүдәсенең озынлыгы 100 *см* га,



авырлыгы 30 *кг* га кадәр. Койрыгы яссы, көрәксыман, 30 *см* га кадәр озынлыкта, мөгезсыман кабырчык б-н капланган. Суда койрыгы руль урынына хезмәт итә, коры җирдә терәк буларак файдаланыла. Арткы аякларындагы йөзү ярылары суда хәрәкәт итәргә булыша. Колак яфраклары һәм хәрәкәтчел калын борын тишекләре чумган вакытта томалана. К.ның йон капламы ялтыравыклы кылчыксыман тупас кылдан һәм бик куе ефәксыман йомшак мехтан тора. Төсе аксыл коңгырттан кара көрәнгә кадәр. Койрык төбендә биз сыекчалары бүлеп чыгаручы мускус бизләре бар. К., чыгу юлын су астына калдырып, оясын текә ярларда казып ясый. Тәбәнәк ярларда агач ботаклары, кәүсә түмәрләре һәм ләмнән «өй», кечкенә елга һәм инешләрдә буалар кора. Үсемлек азыклары: җәен — үләнчел үсемлекләр, кышын — яфраклы агач һәм куакларның кайрысы, ботаклары б-н туклана. К. яшәгән сулык ярлары буенда тополь һәм агачсыман талларның саны кими бара. К. — моногамик хайван, даими пар булып берничә ел буена яши. Елга бер тапкыр 6 га кадәр бала китерә. 20–30 ел яшиләр. К.ның биз сыекчасы мед. максатларында һәм парфюмерия сәнәгатендә кулланыла. К.ның мехы югары бәяләнә.

**КОНДЫ́З ҮЛӘНЕ́**, т р и ф о л ь (Menyanthes), кондыз үләнчәләр семьялыгыннан күпьеллык саз үләннәре ыругы. Ыругта бер төр — өч яфраклы К.ү. (M. trifoliata). Бөтен Европада, Азия һәм Төньяк Американың уртача поясында үсә. ТР терр-ясенең барлык районнарында очрый. Кечкенә инеш, буа ярларында, уйсулыклы сазлыкларда үсә. 15–30 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы юан, яшел, шуышма, очында кутәрелеп тора. Яфраклары өчәрле, озын сапта урнашкан. Чәчәкләре алсу яки ак төстә, йолдызчыклар формасында, куе туры чукка җыелган. Җимеше — тартмачык. Июньдә чәчәк ата, җимешләре июль–августта өлгерә. Яфракларында гликозидлар, алкалоидлар, дуплау матдәләре, С витамины, йод бар. Медицинада үлән төнәтмәсе түбән әчелекле гастрит, ш.у. үт кудыру, тән кызышу вакытында кулланыла.



Өч яфраклы кондыз үләне.

**КОНДЫЗЛЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 90 *км* көньяктарак, Әзи елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 32 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз ахырында Сарапул өязенең Козловка волосте Бобровка авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, дегет-сумала кайнату б-н шөгыльләнә; Пермь һәм Вятка губерналарына китеп эшли. 1895 тә К.да земство мәктәбе ачыла. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 660,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның Алабуга кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 298, 1887 дә — 448, 1905 тә — 478, 1920 дә — 551, 1926 да — 676, 1938 дә — 671, 1949 да — 498, 1958 дә — 393, 1970 тә — 219, 1989 да — 73, 2002 дә — 47 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КО́НДЫРЕВ** Пётр Сергеевич (11.10.1786, башка мәгълүматлар буенча, 1789, Курск губ. — 24.3.1823, Казан), тарихчы, географ, статистик, шагыйрь, тәрҗемәче, магистр (1809), надворный советник (1821). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1809), шунда ук эшли: 1807 елдан студентлар инспекторы ярдәмчесе, 1811–14 тә адъюнкт, 1814–20 дә политэкономия һәм статистика каф. экстраординар профессоры, ординар профессоры. Бер үк вакытта, 1807–13 тә, университет китапханәчесе ярдәмчесе, 1813–21 дә китапханәчесе, 1813–16 да «Казанские известия» г-тасы баш мөхәррире, 1818 дән *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе* инспекторы. Казан уку-укыту округы попечителе М.Л.Магницкий сәясәтенә каршы чыга. Зөя, Чабаксар, Чистайда һ.б. шәһәрләрдә өяз уч-щеләре ачылуга булышлык итә. Политэкономия мәсьәләләрендә А.Смит карашларын яклый. Хезмәтләре Россия һәм Көнбатыш Европа илләренең географиясе һәм статистикасына карый («Россия дәүләте статистикасыннан кыскача кулланма» («Краткое начертание статистики Российского государства»), «Россия дәүләте статистикасы» («Статистика Российского государства»), «Европа дәүләтләренең географиясе һәм статистикасы» («География и статистика европейских государств»); басылмаганнар. «Филипп Ефремовның кыргыз даласы, Бохарстан, Хива, Персия, Тибет, Һиндстан буйлап илләр гизүе һәм аның Англия аша Россиягә кайтуы» («Странствия Филиппа Ефремова по киргизской степи, Бухарии, Хиве, Персии, Тибету и Индии и возвращение его оттуда чрез Англию в Россию», 1811) әсәренең 3 нче басмасын әзерли, андагы Бохара-рус сүзлеген татар теленә тәрҗемә итә, китап авторы б-н уздырылган әңгәмә язмалары һ.б. материаллар б-н тулыландырып, аны дөньяга чыгара. Г.Сарториусның студентлар өчен уку ярдәмлегенә әверелгән «Халык байлыгының башлангыч нигезе һәм дәүләт хуҗалыгы» («Начальное основание народного богатства и государственное хозяйство», 1812) дип аталган монографиясен немец теленнән рус теленә тәрҗемә итә. «Дәүләт хуҗалыгы тарихына һәм әдәбиятына карашлар» («Воззрения на историю и словесность государственного хозяйства») басмасына кереш сүз яза һәм әдәбият күрсәткече төзи. Немец теленнән Ф.-В.Д.Снелльнең «Философиянең башлангыч курсы» («Начальный курс философии», ч. 1–5, 1913–14) дигән хезмәтен тәрҗемә итә. 1807 — 14 тә Казан ун-тында тантаналы җыелышларда башкарылган «Кант» хөрмәтенә язылган сүзләр авторы (А.В.Новиков көе). Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыятен гамәлгә куючы-әгъза һәм аның секретаре (1806 дан).

Ә с ә р.: Стихи на случай торжества основания Казанского университета. К., 1809; Описание татарских каргалинских училищ // Периодическое сочинение об успехах народного просвещения. СПб., 1819.

*Әд.:* Б у л и ч Н.Н. Из первых лет Казанского университета (1805–1819): Рассказы по архивным документам: В 2 ч. СПб., 1904; Б и з я е в а Т.В. Петр Сергеевич Кондырев. К., 2004.

*Т.В.Бизяева.*

**КОНДЫРЛЫ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 28 *км* төньяк көнбатыштарак, Сая елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 79 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә; көнлекчелектә ялланып эшли. 20 йөз башында К.да мәчет (1871 дә төзелә), мәктәп, вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җи-

ре 611 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52 ир-ат; 1859 да — 70, 1897 дә — 158, 1908 дә — 217, 1920 дә — 386, 1938 дә — 383, 1949 да — 271, 1958 дә — 169, 1970 тә — 112, 1989 да — 86, 2002 дә — 76 кеше.

**КОНДЫРЧА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Сок елгасының (Идел елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 294 *км*, ТР чикләрендә — 25 *км*. Бассейнының мәйданы 4360 *км*². Сок ярлары калкулыгыннан башлана. Елга башы, тамагы һәм төп агымы — Самара өлкәсе терр-ясендә. ТРда Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 29 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 14%, сөрүле җирләре 60%. К.ның 54 кушылдыгы бар, Татарстан терр-ясендә К. елгасына Шлама елгасы (37,8 *км*) коя. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары



Кондырча елгасы. Нурлат шәһәре янында.

б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга режимын күзәтүләр Самара өлкәсенең Кошки (1937 дән) һәм Украинка (1993 тән) авылларындагы суүлчәгеч постларда алып барыла. Уртача еллык тирбәнешләр дәрәҗәсе Кошки авылы янында 4,26 *м* (макс. 5,15 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы Нурлат шәһәре тирәсендә 0,52 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 150–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–800 *мг/л*. ТР терр-ясендә К. бассейнында су күләме 0,5 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КОНДЫРЧА́ ЕЛГАСЫ́ БУЕНДАГЫ́ СУГЫ́Ш** (18 июнь, 1391 ел), Аксак Тимернең Туктамышка каршы оештырган беренче зур сугышы. Туктамыш бәрелешне Җаек елгасы буенда уздырырга планлаштыра, ләкин Аксак Тимер гаскәренең яшерен генә Җаек елгасын кичеп чыгуы аны көтелмәгән хәлгә куя. Ул гаскәрен Урта Идел буена алып китәргә мәҗбүр була. Сугыш Кондырча елгасы буенда (Сок елгасы кушылдыгы) уза. Каршы яклар тигез көчкә ия булалар (200 меңәр сугышчы), төрле стратегия кулланалар. Туктамыш дошманны фланглардан әйләндереп алырга омтыла. Аксак Тимер, флангларын өстәмә көчләр б-н ныгытып, сугышка акрынлап резервтагы көчләрен кертү исәбенә Туктамышның атлы гаскәре һөҗүмен кире кайтара. Аксак Тимер гаскәре алга омтыла һәм башта дошманын чигенергә, ә аннары сугыш кырыннан качарга мәҗбүр итә. Туктамыш зур югалтуга дучар була (100 меңгә якын кеше һәлак була). Югалтулардан көчсезләнгән Аксак Тимер гаскәре дә алга таба һөҗүмен туктата һәм, Идел буен талаганнан соң, үз дәүләте чикләренә әйләнеп кайта.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.
*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**КО́НЕВ** Иван Никитич (23.12.1898, Самара губ., Бөгелмә өязе Чишмә Кирмәне а. — 19.11.1983, Куйбышев ш.), генерал-майор (1950), Сов. Союзы Герое (13.9.1944). Подпрапорщиклар мәктәбе каршындагы унтер-офицерлар бүлеген (Казан, 1916), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1936) һәм Генштаб Хәрби академиясен (Мәскәү, 1939) тәмамлый. Гражданнар сугышында, Халхин-Гол елгасы буендагы бәрелештә катнаша (1939). Бөек Ватан сугышы елларында Умань дивизиясендә 3 нче гв. һава десанты командиры, Яссы-Кишинёв операциясендә батырлык күрсәтә; сугыш хәрәкәтләре б-н оста идарә иткәне өчен Герой исеме бирелә. 1945–55 елларда Совет Армиясендә җитәкче вазифалар башкара. Өч Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 2 нче дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Малоархангельск (Орёл өлкәсе), Тульчин, Радомышль, Умань (Украина Респ-касы) шәһәрләренең Мактаулы гражданы.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Подвиг во имя Родины. Куйбышев, 1965. Кн. 1; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КО́НИ** Анатолий Федорович (29.1.1844, С.-Петербург — 17.9.1927, Ленинград), хокук белгече, дәүләт эшлеклесе, язучы, җинаять эшләре хокукы д-ры (1890), Петербург ФАнең шәрәфле әгъзасы (1896), хакыйкый яшерен советник (1910). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1865). 1866–67 елларда Мәскәү мәхкәмә палатасы прокуроры секретаре. 1867–70 тә Сумы, Харьков һәм Петербург округ мәхкәмәләре прокуроры иптәше (урынбасары). 1870–71 дә Казан округ мәхкәмәсе прокуроры. Казан губернасы терр-ясендә 1864 елгы Мәхкәмә реформасын үткәрү барышында кертелгән яңа мәхкәмә учреждениеләрен оештыруда катнаша. 1871 дән С.-Петербургта хезмәт итә: прокурор (1875 кә кадәр), 1877–81 дә округ мәхкәмәсе, 1881–85 тә мәхкәмә палатасының гражданнар департаменты рәисе, 1885–96 да (бүленеп) Сенатның җинаять эшләре кассацион департаменты обер-прокуроры, 1891–1917 дә сенатор. Бер үк вакытта, 1907–17 дә, Россия Дәүләт Советы әгъзасы. 1918–22 дә 1 нче Петроград ун-ты профессоры. 1864 елгы мәхкәмә реформасын әзерләүдә иң актив катнашучыларның берсе. Юриспруденциягә караган хезмәтләре бар. К. — дәүләт эшлеклеләре, хокук белгечләре, рус мәдәнияте вәкилләре хакында очерклар авторы. 1907 дән «Русская Старина» ж-лында «Мәхкәмә тикшерүчесе язмаларыннан һәм истәлекләреннән» («Из заметок и воспоминаний судебного следователя») дигән очерклар сериясен бастырып чыгара, аларда Казан губерна идарәсе һәм суд органнарына характеристика бирә, губернаның чиновниклар даирәсен сурәтләгән үткен язмалар бастыра. К. мемуарлары Россиянең 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башындагы иҗтимагый һәм мәдәни тормышы буенча кыйммәтле чыганак булып тора.



И.Н. Конев.

Хезм.: Судебные речи. 1868–1888. СПб., 1897; Очерки и воспоминания. СПб., 1906; На жизненном пути: В 5 т. СПб. — Ревель — Берлин — Л., 1912–29; Отцы и дети судебной реформы. 1864–1914. М., 1914; Собр. соч.: В 8 т. М., 1966–69.

*Әд.:* Смолярчук В.И. Анатолий Фёдорович Кони. М., 1981; Высоцкий С.А. Кони. М., 1988.
*Е.Б.Долгов.*

**КО́ННОВ** Игорь Васильевич (8.2.1958, Украина ССРның Волынь өлкәсе Луцк ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1998), проф. (1999). 1980 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң шунда ук эшли: хезмәтләре шома бармаучы оптимальләштерү теориясенә һәм алымнарына, вариацияле тигезсезлекләргә, тигезләнеш мәсьәләләренә һәм аларны катлаулы системаларда куллануга карый. К. бер- һәм күпмәгънәле чагылдырулы вариацион тигезсезлекләр өчен комбинацияле релаксацион алымнар, шома бармаучы оптимальләштерүнең күп кенә алымнарын тәкъдим итә. Күп мәгънәле өстәмәлек мәсьәләләре өчен координаталы алымнар төзи. Вариацион катнаш тигезсезлек һәм нәсызыкча тигезләмәнең эквивалентлыгын, Парето кире тәртипләре системасы һәм лексикографик тәртипнең эквивалентлыгын күрсәтә. Аукционнарның, очраклы коммуникация челтәрләренең иң гади модельләрен (системаларын) эшли. РФнең мактаулы югары проф. белем бирү хезмәткәре (2008).

Хезм.: Методы недифференцируемой оптимизации. К., 1993; Combined Relaxation Methods For Variational Jnequalities. B., 2001; Equilibium Models And Varational Jnequalities. Amst., 2007.

**КОННОДО́Л МӘГАРӘСЕ́**, к. *Юрьев мәгарәләр системасы.*



А.И. Коновалов.



С.В. Коновалов.

**КО́НОВ** (Әлмиев) Минһаҗ Гайнетдин улы (1893–1934), журналист, педагог. Казанда мәдрәсәдә, ш.у. Ленинград көнчыгыш-пед. ин-тында белем ала (1927–29). 1915 елда Россия армиясенә чакырыла, Төньяк фронтның 5 нче армиясе составында сугыша. 1918 нең гыйнварында Төньяк фронтның мөселман ком-ты һәм «Сугыш сафы» фронт г-тасының редколлегия әгъзасы итеп сайлана. Эчке Россия мөселманнары эшләре комис-ты эшендә катнаша, Мәскәүдә 1 нче татар-башкорт пехота батальонын оештыручыларның берсе. Коммунист мөселманнарның 1 нче Бөтенроссия корылтаенда (1918 нең 4–12 ноябре, Мәскәү), Шәрекъ халыклары коммунистлар оешмаларының 2 нче Бөтенроссия съездында (1919 ның 22 ноябре – 3 декабре, Мәскәү) катнаша. 1919 да РКП(б)ның мөселман оешмалары Үзәк бюросының нәшрият бүлеге мөдире, «Эшче» г-тасын чыгаруны оештыра (1920 нең гыйнвары-маенда дежур мөхәррир). 1920–27 дә Эшче-крәстияннәр инспекциясендә, Халык мәгарифе халык комис-тларында, ТАССР ҮБКнда эшли. 1931 дән Казанда пед. эштә: Казан пед. техникумында, Хезмәтне фәнни оештыру ин-тында укыта.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**КОНОВА́ЛОВ** Александр Иванович (30.1.1934, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1974), РФА (1992; 1990 елдан мөхбир әгъза), ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1991). 1956 да Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз кинофото фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1957–99 елларда Казан ун-тында, химия ф-ты деканы (1968–72), органик химия каф. мөдире (1974–99), проф. (1975), ректор (1979–90). 1990 нан РФА КФҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, 2001 гә кадәр директор, 1991 дән яңартылулы табигый чимал химиясе лаб-ясе мөдире, 2000 нән супрамолекуляр химия бүлеге мөдире һәм супрамолекуляр системалар физик химиясе лаб-ясе мөдире. А.М.Бутлеров исем. Химия фәнни-тикшеренү ин-ты (1988–2003) һәм Казан ун-тының органик кушылмалар структурасын тикшерү лаб-ясе (1991 дән) фәнни җитәкчесе. 1996–2008 дә РФА КФҮ Президиумы рәисе, 1997–2006 да ТР ФАнең, 1991 дән Д.И.Менделеев исем. Россия химия җәмгыятенең вице-президенты; РФА Президиумы әгъзасы (2001), 1999 дан РФАнең Химия һәм материаллар турындагы фәннәр бүлегенең органик һәм элементорганик химия буенча фәнни советы, 1996 дан А.М.Бутлеров исем. бүләкне билгеләү буенча РФА комиссиясе рәисе. Хезмәтләре органик, физик органик, супрамолекуляр химиягә карый. Дильс-Альдер реакциясе механизмын өйрәнә, циклкушылу реакцияләрендә аддентларның реакциягә керү мөмкинлеген билгеләүче факторларны һәм аның үзгәрешен (аддентларның донор-акцептор, термохимик, стереохимик характеристикаларын файдалану нигезендә) микъдар ягыннан күрсәтә. Диен синтезы реакциясенең «нейтраль» тибын ача (РФАнең Н.Д.Зелинский исем. бүләге, 2008), бу донор-акцептор билгеләр буенча әлеге реакцияләр классификациясен төгәлли. Сусыз эреткечләрдә сольватлашу термодинамикасын өйрәнгәнe, ш.у. сольватлашу процессларының микъдар ягыннан закончалыкларын билгеләгәне өчен СССРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1987). Сусыз эреткечләрдә органик кушылмаларның ачылыгын өйрәнүгә өлеш кертә. К. җитәкчелегендә сольватлашу сәләте төрле булган тирәлекләрендә сольватлы бүленгән ионлы парларның универсаль (гомуми) моделе һәм органик кушылмалар ачылыгын билгеләүнең криптат ысулы эшләнә, төрле полярлыктагы эреткечләрдә ачылыкның универсаль ионлы-парлы шкаласы булдырыла. Азык компонентларын (пектиннар, аксымнар һ.б.) аерып алу максаты б-н яңартыла торган үсемлек чималын (амарант, люпин) технол. эшкәртүнең фәнни нигезләре эшләнә. Супрамолекуляр химия өлкәсендә макроциклик рецепторлар (каликсареннар нигезендә) булдыру һәм аларны, биол. яктан әһәмиятле кушылмалар һәм радионуклидларны да кертеп, органик, нәорганик субстратлар буларак селектив тоташтыру, экстракцияләү һәм транспортлау өчен куллану буенча тикшерүләр үткәрелә. Супрамолекуляр системалар катнашында молекуляр тану, мембраналы күчерү, ионлы каналлар булдыру, экстракция процесслары буенча нәтиҗәләр алына. Азотлы гетероциклларның фосфорорганик кушылмалары нигезендә үсемлекләр үсешенә тәэсир итүче эффектив «Мелафен» (Бөтенроссия күргәзмә үзәгенең көмеш медале) булдырыла. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Физик органик һәм супрамолекуляр химия өлкәсендәге тикшеренүләре өчен К. РФАнең Д.И.Менделеев исем. алтын медаленә лаек була. Супрамолекуляр химия буенча Россиядә беренче халыкара конференцияне оештыручы (Казан, 2000, 2002), Казан ун-ты каршындагы «XXI гасыр материаллары һәм технологияләре» («Материалы и технологии XXI века») фәнни-мәгариф үзәген оештыручы һәм җитәкчесе. 1980–90 елларда ТАССР ЮС, 1989–92 дә СССР халык депутаты. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реакционная способность аддентов в реакции диенового синтеза // Успехи химии. 1983. Т. 52, № 11; Термохимия сольватации органических неэлектролитов // Успехи химии. 1991. Т. 60, № 1 (автордаш); Фосфорсодержащие каликсарены // Успехи химии. 1998. Т. 67, № 1 (автордаш).

*Әд.:* Александр Иванович Коновалов: Жизнь, отданная науке. К., 2004; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**КОНОВА́ЛОВ** Валерий Николаевич (21.1.1938, Чита ш. — 21.5.1998, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1996), проф. (1997). Ярославль пед. ин-тын тәмамлый (1960). 1967–98 елларда Казан ун-тында эшли (1982–87 дә чит ил студентлары б-н эшләүче декан, 1988 дән рус һәм чит илләр әдәбияты каф. мөдире). Хезмәтләре 1860–80 еллар рус әдәбияты һәм әдәби тәнкыйтенә карый (Н.Г.Чернышевский иҗаты, метод мәсьәләләре һәм әдәби тәнкыйть тарихын чорларга бүлү, язучы иҗатында тәнкыйтьнең үзенчәлеге). Халыклар Дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Литературная критика народничества. К., 1978; Русская литература последней трети XIX в. К., 1980.

*Әд.:* Памяти В.Н.Коновалова // Уч. Зап. Казан. ун-та. 1998. Т. 136.

**КОНОВА́ЛОВ** Семён Васильевич (15.2.1920, Зөя кантоны Ямбулат а. — 4.4.1989, Казан), Сов. Союзы Герое (31.3.1943), подполковник. Куйбышев хәрби пехота уч-щесен (1941), Ленинград югары офицерлар бронетанк мәктәбен тәмамлый (1952). Хәрби хезмәткә алынганчы туган авылында хат ташучы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 9 нчы армиянең 15 нче танк бригадасы танк командиры. Көньяк, Көньяк-Көнбатыш, Төньяк Кавказ һәм Кавказ арты фронтлары гаскәрләре составында Донбасс операциясендә (1941), Ростов оборона (1941) һәм һөҗүм операцияләрендә (1942), Кавказ өчен сугышта (1942–43) катнаша. 1942 нең 13 июлендә Түбән Митякин хуторы (Ростов өлкәсе Тарасов р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: аның җитәкчелегендә экипаж 16 танкны, 2 броняль автомобильне һәм 8 автомашинаны юк итә. 1946–50 дә һәм 1956 дан запаста. Казанда яши һәм эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Казанда бер урам К. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Т р о к а е в А.А. Подвиг на шахтёрской земле. Донецк, 1983; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КОНОВА́ЛОВА** Ирина Вадимовна (18.4.1933, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1973), проф. (1975), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984). 1956 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз кинофото фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1958 дән Казан ун-тында, химия ф-ты деканы (1972–87). К. 3, 4, 5 координацияле фосфорның органик кушылмаларын синтезлый, реакциягә керү мөмкинлеген өйрәнә. Күбесе төрле яклап биол. активлыкка ия булган азотлы гетероциклик кушылмалар синтезлау алымнарын эшли. Фосфор химиясендә яңадан төркемләүне тикшерүгә, электрофиль һәм нуклеофиль реагентлар б-н өч координацияле фосфор кушылмалары реакцияләренең механизмнарын өйрә-

нүгә, фосфит к-тасының салицил эфирлары химиясен, фосфорлы фторорганик кушылмалар химиясен эшләүгә өлеш кертә. Уйлап табуга 40 тан артык авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реакции присоединения фосфорсодержащих соединений с подвижным атомом водорода // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1968. Кн. 19 (автордаш); Реакции производных кислот трёхвалентного фосфора с электрофильными реагентами // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1973. Кн. 23 (автордаш); Реакция Пудовика. К., 1991 (автордаш).

**КОНОВА́ЛОВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 653 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; сәүдәгәр Стахеевларда ялланып эшли. 20 йөз башында К.да су тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1751,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1870 тә — 263, 1913 тә — 579, 1920 дә — 659, 1926 да — 683, 1938 дә — 588, 1949 да — 415, 1958 дә — 348, 1970 тә — 295, 1979 да — 366, 1989 да — 701, 2002 дә — 787 кеше.

**КОНОГО́РОВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 14 *км* көнбатыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 49 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 19 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Николаевка исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 910 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1889 да — 198, 1908 дә — 288, 1920 дә — 281, 1926 да — 306, 1938 дә — 291, 1958 дә — 220, 1970 тә — 186, 1979 да — 134, 1989 да — 50, 2002 дә — 31 кеше.

**КО́НОНОВ** Андрей Николаевич (27.10.1906, С.-Петербург — 30.10.1986, Ленинград), тел галиме, төрки телләр белгече, филол. фән. д-ры (1948), СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1974). Ленинград Шәрекъ ин-тын тәмамлый (1930). 1937–81 елларда Ленинград ун-тында, төрки филол. каф. мөдире (1949–72), проф. (1950). Бер үк вакытта, 1938 елдан СССР ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Ленинград бүлегендә, 1961–63 тә аның директоры. «Хәзерге төрек әдәби теле грамматикасы» («Грамматика современного турецкого литературного языка», М.–Л., 1956), «Хәзерге үзбәк әдәби теле грамматикасы» («Грамматика современного узбекского литературного языка», М.–Л., 1960), «Ватандаш тюркологларның биобиблиографик сүзлеге: Октябрьгә кадәрге чор» («Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов: Дооктябрьский период», М., 1974) хезмәтләре авторы. Төрки телләрнең хәзерге һәм тарихи грамматикасына, текстология һәм лексикологиясенә, Шәрекъне һәм төрки халыклар телләрен, мәдәниятләрен өйрәнүче фәннәр тарихына караган хезмәтләрендә К. төрки телләрнең агглютинатив төзелешле табигатенә, хәзерге төрки телләр грамматик төзелешенең күп кенә үзенчәлекләрен аңлауга ачкыч булып торучы төрки-рун язма истәлекләре теленең грамматик төзелешенә, әлеге тел тарихы буенча гына түгел, ә гомумтөрки мәдәният тарихы буенча да мәгълүматлар чыганагы булган борынгы язмаларга карата үз карашларын бәян итә; синтаксик бәйләнештә кайбер мөстәкыйль һәм ярым мөстәкыйль элементларның үзгәрүләре һәм теркәгечсез иярткүле бәйләнешләре ролен нигезли.

СССР һәм Россиядә төрки телләрне өйрәнү тарихына караган хезмәтләре бар. К. Советлар Союзының төрки телле республикалары өчен фәнни кадрлар әзерләү һәм тәрбияләү эшендә аларга зур ярдәм күрсәтә, аерым алганда, СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты һәм Казан ун-ты галим-тюркологлары (төрки телләр галимнәре) б-н тыгыз элемтәдә тора.


Төрек лингвистикасы җәмгыяте (1957 елдан), Венгрия ориенталистлары фәнни җәмгыяте (1970 тән), Венгрия ФА (1973 тән), Польша шәркыятьче галимнәр җәмгыяте (1974 тән) һ.б. әгъзасы була. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Тюркская филология в СССР. 1917–1967. М., 1968; История изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период. Л., 1972; Из истории татарского языка: татарская грамматика Иосифа Гиганова // Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри. К., 1976; Очерк истории изучения турецкого языка. Л., 1976.

*Әд.:* В е к и л о в А.П., И в а н о в С.Н. К 60-летию А.Н.Кононова // Изв. АН СССР. Сер. лит-ры и языка. 1966. Т. 25; Андрей Николаевич Кононов. Материалы к биобиблиографии учёных СССР. М., 1980. Вып. 13; Т е н и ш е в Э.Р. Академик Андрей Николаевич Кононов (к 75-летию со дня рождения) // Изв. АН СССР. Серия лит-ры и языка. 1981. Т. 6; Turcologica. 1986: К 80-летию академика А.Н.Кононова. Л., 1986.

*В.Х.Хаков.*

**КОНОПЛЁВ** Юрий Геннадьевич (6.12.1939, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән д-ры (1983), ТР ФА академигы (1992), ТР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998, 2000), Казан ун-тының атказ. проф. (2009). 1962 дә Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли: Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1986 га кадәр), проректор (1986–90), ректор (1990–2001), бер үк вакытта теоретик механика каф. мөдире (1988 дән), проф. (1988). К. тырышлыгы б-н Казан ун-тында яңа ф-тлар, кафедралар, бүлекләр, секторлар оештырыла, яңа белгечлекләр ачыла; Яшел Үзән (1996), Чаллы (1997) ф-лллары төзелә, Тел белеме (1994), Көнчыгышны өйрәнү (2000) ин-тлары булдырыла. Хезмәтләре деформацияләнә торган каты җисем механикасына карый. К. деформацияләнә торган каты җисем механикасы мәсьәләләрен чишүнең теоретик-тәҗрибә алымын эшли, аны сүрүләр һәм пластиналарның ныклыгы, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләре мәсьәләләрен гамәли чишүдә куллана. Очкыч аппаратлар, химия һәм нефть җиһазлары, оптик-механик конструкцияләр, төзелеш корылмалары проектларын төзүдә, ш.у. зур йөк автомобильләренең рамнары төзелешен оптимальләштерүдә, порт краннарының металл өлешләрендә тәэсир итүче көчәнешне динамик йөкләнешләрне исәпкә алып билгеләүдә, краннардагы металл конструкцияләрнең аерым өлешләрен ныгытуга карата тәкъдимнәр эшләүдә катнаша. Югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы. Халыкара югары мәктәпләр ФА президиумы (1996 дан), РФ Мәгариф министрлыгының теоретик механика буенча фәнни-методик советы (1991–2001), фән һәм техника өлкәсендә РФ (1992–2000), 1993 тән ТР Дәүләт бүләкләрен билгеләү комиссияләре әгъзасы. «СССРның югары белем бирү өлкәсендә аеруча зур уңышлары өчен», «РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре», Франциянең «Академик пальмалар» ордены офицеры билгеләре, медальләр, ш.и. Россия Космонавтика федерациясенең Ю.А.Гагарин исем. алтын медале, Гессен ун-тының (Германия) иң югары бүләге — Юстус Либих исем. медаль б-н бүләкләнә.



Ю.Г. Коноплёв.

Х е з м.: Голографическая интерферометрия и фототехника. К., 1994 (автордаш); Устойчивость упругих пластин и оболочек при динамических воздействиях. К., 1996 (автордаш); Лекции по динамике сооружений с движущимися нагрузками. К., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Р.Г.Усманов.*

**КОНСА́Р** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 9,2 *км*, бассейнының мәйданы 42,9 *км*². Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Чарлы авылы тирәсендә, тамагы — Татар Толлысы авылыннан 1,6 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. К.ның 0,1 дән алып 2,7 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахы-

ры — апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен уртача катылыкта (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында су күләме 0,4 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КОНСОНАНТИ́ЗМ**, к. *Тартык авазлар*.

**КОНСТАНТИ́НОВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 15 кеше (руслар) яши. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 167, 1938 дә — 157, 1949 да — 134, 1958 дә — 67, 1970 тә — 52, 1979 да — 37, 1989 да — 10, 2002 дә — 8 кеше.

**КОНСТАНТИ́НОВКА** авылы, Казан шәһәренең Совет р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 12 *км* көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2008 елда 3063 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51%, татарлар — 45%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. Чиркәү. 17 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстиянннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе (1885 тә ачыла), вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1495,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Воскресенский волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында; 2007 дән Казан составында. Халык саны: 1646 да — 61, 1782 дә — 175 ир-ат; 1859 да — 768, 1897 дә — 809, 1908 дә — 1000, 1920 дә — 962, 1949 да — 732, 1958 дә — 765, 1970 тә — 846, 1989 да — 2198, 2002 дә — 2806 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**КОНСТИТУЦИО́Н ДЕМОКРАТЛА́Р ПА́РТИЯСЕ** («Халык азатлыгы партиясе», кадетлар), гомумроссия либераллар партиясе. Традицион земство либерализмы һәм либераль-демократик интеллигенция вәкилләрен берләштерә («Азатлык берлеге» һәм «Земствочылар-конституциячеләр берлеге» иҗтимагый-сәяси оешмалары). Оештыру съезды 1905 елның 12–18 октябрендә Мәскәүдә уза; анда Устав һәм Программа кабул ителә, составына 30 кеше кергән ҮК сайлана. Партиянең программасы сәяси һәм социаль мәсьәләләрнең киң даирәсен үз эченә ала: конституцион һәм парламент монархиясен урнаштыру; демократик ирекләрне гамәлгә ашыру; Россиянең барлык халыклары өчен мәдәни үзбилгеләнү, Польшага һәм Финляндиягә адм. мохтарият бирү; дәүләт, кабинет һәм монастырь биләмәләре хисабыннан җирсез һәм аз җирле крәстияннәргә җир бүлеп бирү, ш.у. алпавыт җирләрен өлешчә ирексезләп сатып алу; социаль өлкәгә чыгымнарны арттыру максатында бюджетны яңадан карау; сыгылмалы салым системасын, вәкаләтләрен һәм хокукларын зурайтып, илнең барлык төбәкләрендә земство үзидарәсен гамәлгә кертү; «эшчеләр мәсьәләсе»н закон нигезендә хәл итү, ш.и. мөмкин булган җирләрдә кичекмәстән 8 сәгатьлек эш көнен кертү һ.б. Партия лидерлары — П.Н.*Милюков*, И.В.Гессен, В.Д.Набоков, И.И.Петрункевич, П.Д.Долгоруков һ.б. Төп тактика — программадагы бурычларны бары тик көрәшнең парламент чаралары б-н генә хәл итүгә ирешү. Нәтиҗәдә, партия әгъзаларының эшчәнлеге иң элек Дәүләт Думасына сайлау кампанияләре тирәсендә һәм аның эчендә туплана. 1 нче Думада кадетлар җитәкче урынны биләүләр, Дума таратылганнан соң, кадетлар фракциясе башлангычында депутатлар төркеме хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән *Выборг өндәмәсенә* кул куя. 2 нче Думада кадетлар, 98 урынга ия булып, элеккечә үк лидерлык итәләр. 1 нче һәм 2 нче Думаларда алар аграр мәсьәләне хәл итү буенча үз закон проектларын алга сөрәләр. 3 нче һәм 4 нче Думаларда, азчылыкта булып, тырышлыкларын хөкүмәт проектларын тәнкыйтьләүгә юнәлтәләр.

Кадетлар партиясенең Казан бүлекчәсе 1905 нең октябрендә оеша. Беренче гомуми җыелыш 1905 нең 31 декабрендә уза; партиянең Казан губерна ком-тын төзү турында карар кабул ителә, аның составына Й.*Акчура*, С.Ш.*Алкин*, И.И.Бабушкин, А.Г.Бать, А.В.*Васильев*, М.С.Венецианов, И.С.Кривоносов, Е.Г.Рогозин, А.А.*Симолин*, М.М.*Хвостов*, Г.Г.Тельберг, А.Д.Черноярoв сайлана. 1906 да Лаеш, Чистай, Цивильск, Ядрин шәһәрләрендә өяз ком-тлары эшли. Әгъзаларының гомуми саны — 700 ләп кеше. Партиянең тарафдарлары тагын да күбрәк була, ләкин күпләр үзләренең оппозицион партия яклы икәнлекләрен ачыктан-ачык әйтергә базмыйлар (партияне легальләштерү турындагы мәсьәлә хәл ителми). Казаннан партиянең ҮК составына Й.Акчура һәм Г.Ф.*Шершеневич* кертелә. Сәүдәгәрләр катлавының кайбер вәкилләре (бертуган И.И. һәм П.И.Александровлар, А.Д. һәм Д.Д.Черноярoвлар, И.Казаков, М.Галиев, С.Аитов, Б.Апанаев һ.б.) губерна оешмасына финанс ярдәме күрсәтәләр.

Дәүләт Думасына сайлау алды кампанияләре чорында партиянең губерна бүлекчәсе әгъзалары сәяси яктан активлаша. Сайлауларда «*Иттифак әл-мөслимин*» партиясе әгъзалары К.д.п.нең төп союзниклары булалар, шул рәвешле губернаның татар халкы катнашкан сайлаулар вакытында (бигрәк тә 1 нче һәм 2 нче Думаларга сайлаганда) кадетлар партиясен яклау тәэмин ителә. 1 нче Дәүләт Думасы таратылганнан соң, К.д.п.нең Казан губерна ком-ты әгъзалары хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән Выборг өндәмәсен хуплап чыгалар, бу губернада оешманың хәле катлаулануга китерә. Партиянең күп кенә әгъзалары һәм аңа теләктәшлек белдерүчеләр репрессияләргә дучар ителә (мәс., Й.Акчура). Оешма яшерен хәлдә диярлек эшли. 1906 ның ноябрендә партиянең губерна ком-ты каршында (Казан ун-тында) студентлар фракциясе оеша, аны студентлар К.В.Белилин, Н.В.Утехин һ.б. җитәкли. Партия тактикасыннан риза булмаган кайбер әгъзалар 1907 дә «Тыныч яңарыш партиясе»н оештыралар, ләкин аз санлы булуы сәбәпле, Казан губернасының иҗтимагый-сәяси тормышында ул сизелерлек роль уйнамый. 1905–07 еллар рев-циясеннән соң кадетлар оешмасы сан ягыннан азая, өяз бүлекчәләренең эшчәнлеге туктала. 3 нче Дәүләт Думасына сайлауларда Казан кадетларына октябристлар (к.«*Унҗиденче октябрь берлеге*») б-н бер блокка керергә туры килә. 1908 дә Казанда 400 ләп партия әгъзасы исәпләнә. Бу чорда Г.Ф.Шершеневич, А.В.Васильев, М.М.Хвостов, И.В.Мандельштам, А.В.Завадский, А.Г.Бать, С.Ш.Алкин, И.И.Бабушкин, Н.П.Гусев аеруча актив эшлиләр.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында төбәктә кадетларның эшчәнлеге активлаша. Алар сугыш алып бару өчен матди һәм кеше ресурсларын мобилизацияләүдә мөһим роль уйнаган оешмалар эшендә катнашалар. Кадетлар П.П.Набоков, Н.И.Порфирьев, И.Н.Овчинников Казанда Хәрби сәнәгать ком-тын җитәклиләр. С.Ш.Алкин, Н.П.Загоскин, И.И.Бабушкин, Н.П.Гусев «Земство берлеге» һәм «Шәһәр берлеге» структураларында эшлиләр. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң К.д.п.нең Казан губерна ком-ты беренчеләрдән булып оеша.

1917 нең мартында аның әгъзаларының гомуми җыелышы булып уза, анда губерна ком-тының яңа составы сайлана (рәисе — А.А.Симолин). 1917 нең җәендә Арча, Козьмодемьянск, Лаеш, Спас, Тәтеш, Царёвококшайск, Чистай шәһәрләрендә, Мариинский Посадта аның бүлекчәләре барлыкка килә. Казан шәһәр оешмасы Идел буенда иң зурлардан була (800 ләп кеше). Моннан тыш, Казанда 2 студентлар фракциясе (Казан руханилар академиясе һәм Казан ун-ты каршында) эшли. Партия клублары, китапханәләр оештырыла. Партия әгъзалары хәйрия эшчәнлеге б-н шөгыльләнәләр. 1917 дә Казанда К.д.п.нең өч губерна съезды уздырыла. 1 нчесе 17–18 июльдә уза, анда җиде өяз ком-тыннан һәм Казаннан делегатлар катнаша. Төп максат Казан губерна оешмасының илдә һәм губернада хөкем сөргән сәяси вазгыятькә карата мөнәсәбәтен ачыклаудан гыйбарәт була. Съезд резолюция кабул итә, резолюциядә: «Россияне коткару өчен исемдә генә түгел, асылда да коалицион булган хөкүмәт рәвешендәге бердәм ныклы хакимият кирәк, һәм бу коалицион хөкүмәттә Халык азатлыгы партиясе әгъзалары катнашырга тиеш», — диелә. 29–30 августта узган 2 нче съезд Россия кораллы көчләре башкомандующие генерал Л.Г.Корнилов фетнәсенә нис-

бәтле рәвештә чакырыла. Төп максат губерна оешмасы тактикасын эшләү була. Делегатлар партиянең 9 нчы гомумроссия съездында (1917 нең 23–28 июле) ҮК тәкъдим иткән программаны һәм тактиканы нигездә хуплыйлар; ләкин П.Н.Милюков җитәкчелегендә ҮК, чынлыкта переворотка риза булып, илдә «көчле һәм бәйсез» хакимият урнаштыруны хуплап чыкса да, 2 нче съезд делегатлары Вакытлы хөкүмәтне яклаучы һәм, кайсы тарафтан янаса да, аңа каршы юнәлдерелгән теләсә нинди күтәрелешне гаепләүче резолюция кабул итәләр. 3 нче съезд 1917 нең октябре ахырында чакырыла. Бу съездда кадетларның Казан губерна оешмасы әгъзалары большевиклар переворотын гаепләп чыгалар һәм большевиклар хакимиятен законсыз дип таныйлар. Казанның кайбер кадетлары большевикларга каршы көрәштә актив катнаша. ХКС 1917 елның 28 ноябрь Декреты б-н К.д.п.н «халык дошманнары партиясе» дип игълан итә һәм аның эшчәнлеге тыела. 1917 нең 30 ноябрендә Казан большевиклары шәһәр думасының кадетлар партиясендә торган барлык әгъзаларында, ш.у. «*Камско-Волжская речь*» г-тасы редакциясендә тентүләр уздыралар.

Басма органнары: «*Казанский вечер*», «*Волжско-Камская речь*», «Камско-Волжская речь» г-талары.

*Әд.:* Ш е л о х а е в В.В. Кадеты — главная партия либеральной буржуазии в борьбе с революцией 1905–1907 гг. М., 1983; ш у л  у к. Идеология и политическая организация российской либеральной буржуазии. 1907–1914 гг. М., 1991; Д у м о в а Н.Г. Кадетская партия в период 1-й мировой войны и Февральской революции. М., 1988; А й н у т д и н о в а Л.М. Либеральное движение в Казанской губернии (1900–1911 гг.). К., 2003.

*Л.М.Айнетдинова.*





**Конструктивизм.** 1. Мергасов йорты. Казан. Арх. Д.М. Фёдоров. 1928. 1970 еллар фоторәсеме; 2. Матбугат йорты. Казан. Арх. С.С. Пэн. 1933-35.

**КОНСТРУКТИВИ́ЗМ**, 1920–30 елларда СССР архит-расы һәм сәнгатендәге төп юнәлешләрнең берсе; рационализмның бер төре. Аның үзенчәлеге — бинаның функциональ яктан файдаланылуын югары дәрәҗәдә ачып бирү. 1923–27 дә Казанда К. юнәлешендә эшләүче Яшь архитекторлар берләшмәсе (ЯАБ) оештырыла. Совет К.ы концепцияләре Мәскәүдә генә түгел, илнең күп кенә башка шәһәрләре архит-расында да барлыкка килә.


К. 1920 — 1930 елларның 1 нче яртысы архит-расында Казанда да өстенлек итә. Монда яңа социаль ихтыяҗларга җавап бирүче күп вазифалы яңа төр җәмәгать биналарын төзү буенча эзләнүләр алып барган Мәскәү конструктивистлары М.Я.Гинзбург, Н.Я.Голосов, Г.С.Гурьев-Гуревич, С.С.Пэн эшли. Җәмәгать биналары аерым максатлар өчен күләмле-планлаштыру чишелешләрендә функциональ һәм конструктив шартларга бәйләп төзелә. Казан архитектор-конструктивистлары казанышларыннан 1928 дә Мәскәүдә узган заман архитекторлары берләшмәсенең 1 нче конференциясендә тәкъдим ителгән Казан төзелеше схемасын һәм торак комплекслары проектын, ЯАБ декларациясе кебек теоретик һәм гамәли эшләнмәләр игътибарга лаек. ЯАБ декларациясе «Современная архитектура» үзәк ж-лында 1928 нең 1 нче санында дөнья күрә. ЯАБ халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча учреждениеләр комплексын күздә тоткан коммуна-йортлар идеясен эшләп чыгара; биналарны проектлау схемаларын архит-ра формасының функциональ шартлылыгы нигезендә эшләү аның казанышы булып тора.

1920 еллар ахыры — 1930 еллар башыннан архит-ра һәм монументаль сәнгать синтезының төп элементлары агитация чарасына әверелә: биналарның архит-ра образларын формалаштыруда язулар, эмблемалар, символлар, флагштоклар мөһим роль уйный. Казанда К. стилендәге аеруча билгеле корылмаларга *Татарстан АССРның 10 еллыгы исемендәге мәдәният сарае*, *Матбугат йорты* һ.б. керә.

К. сынлы сәнгатьтә 1920 нең 1 нче яртысында *ТатЛЕФ* һәм *Сулф* составына кергән рәссамнарның иҗатында үсеш ала. Казан архит-ра-сәнгать остаханәләренең (к. *Казан сынлы сәнгать училищесе*) сәнгать педагогикасына «производство сәнгате» һәм Пролеткульт идеологиясенә (Ф.П.*Гаврилов*, К.К.*Чеботарёв*, И.А.*Никитинның* укыту программасы) нигезләнгән әзерлек курслары кертелә. Кешене чолгап алган матди мохитнең яңа формаларын төзү җәмгыятьне социаль үзгәртеп коруның мөһим чарасы буларак карала. Сәнгатьнең гамәви-агитация һәм бизәү төрләренә, яңа материаллар һәм техникалар б-н тәҗрибәләр үткәрүгә (төсле гипс, фанерда гравюра ясау һ.б.) аеруча әһәмият бирелә. Станлы нәкышькә — монументаль панно алымы (К.К.Чеботарёв, Е.А.Михайлов, Е.К.Частихина һ.б. әсәрләре), китап һәм журнал графикасына — плакат, лозунг, фотомонтаж элементлары (Ф.Ш.*Таһиров*, Д.Н.*Красильников*, Ш.Н.*Мөхәммәтҗанов* һ.б. графикасы), театр декорациясе сәнгатенә — спектакльләрдә сәхнә күренешләре образлары иҗат итүче конструкцияләр һәм «стан»нар (К.К.Чеботарёв, М.В.Барашов, *Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе* спектакльләре сценографияләре) кертелә. К. идеологиясе күпчелек очракта утопик, вульгар-социол. характерда була. Ләкин, шуңа да карамастан, гамәлдә К. сәнгать төрләре чараларын тагын да киңәйтүгә һәм баетуга ярдәм итә.

*Әд.:* З а к и р о в а Т.Р. Архитектура Советской Татарии. Проблемы становления и развития общественных зданий (на примере Казани): Дис. ... М., 1988; К л ю ч е в с к а я Е.П. Казанская архитектурная школа 1920-х гг. // Дизайн и новая архитектура. 2001. № 8.

*Т.Р.Закирова, Е.П.Ключевская.*





**Конструктивизм.** Ф.Ш. Таһиров. 1. Трибуна проекты. 1920 еллар; 2. «Уң аяктан!» плакаты. 1920 еллар. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

**КОНТАРИ́НИ** (Contarini) Амброджио (15 йөз), Венеция дипломаты, Персиягә барган Венеция илчелеге җитәкчесе (1474–77). 1474 елның февралендә, Венеция б-н берлектә Төркиягә каршы сугышта катнашуга күндерү өчен, илчелек б-н Ак Коюнлу дәүләте шаһы Озын Хәсән тарафына җибәрелә. Алтын Урдада (Азак, Хаҗитархан шәһәрләрендә), Кавказда, Мәскәү дәүләтендә һ.б. җирләрдә була. Үзенең сәфәрен «Персиягә сәяхәт» дигән хезмәтендә (1487) тасвирлый. Аның бу китабында нугайларның һәм татарларның тормышы һәм көнкүреше, Идел, Мәскәү дәүләте, 15 йөз ахырында Русь-Венеция-Алтын Урда сәясәте, Әстерханда чума авыруы һәм ачлык турында мәгълүматлар бирелә.

Х е з м.: Путешествие А.Контарини, посла светлейшей Венецианской республики к знаменитому персидскому государю Узун-Гассану // Библиотека иностранных писателей о России. СПб., 1836.

*И.Л.Измайлов.*

**КОНТРАСТИ́В ЛИНГВИ́СТИКА**, чагыштырма *тел белемендәге* юнәлеш. 20 йөзнең

2 нче яртысыннан көчле үсеш ала. Максаты — тел төзелешенең барлык катламнарындагы охшаш һәм аермалы якларын ачыклау өчен ике яки берничә телне чагыштырып өйрәнү. Телләр арасындагы капма-каршылык (контрастивлык) бер үк лингвистик категорияләрне төрле телләрдә үзенчәлекле яктыртканда, ш.у. билгеле бер лингвистик тасвирламалар булмаган, яки чагыштырыла торган телләрдә үзара ярашканлык билгеләре күзәтелмәгән очракларда ачык күренә. Мондый вакытта контрастив тикшерү объекты булып чагыштырыла торган телнең лакуналары б-н үзара бәйләнештәге лакунар берәмлекләр тора. К.л.да барлык төр лакунар берәмлекләр дә өйрәнелә: фонетик (мәс., татар [ң], инглиз [ŋ] авазлары борын авазлары бөтенләй булмаган рус теленә карата лакунар булып тора); лексик (рус сүзе «субботник» инглиз, испан h.б. телләрдә лакуна б-н үзара бәйләнгән); фразеологик (инглиз телендәге yellow dog (сары эт) — эшкә урнашкан вакытта стачкаларда катнашмау, профсоюзга кермәү, эш көнен арттыру б-н килешү турында үзеңә йөкләмә алу); морфологик (рус телендәге род категориясе — татар теленә карата, татар телендәге тартым категориясе — рус теленә карата) h.б. К.л. күп кенә телләр материалын анализлаган вакытта билгеләнә торган лингвистик уникалияләрне (телдә сирәк очрый торган күренешләр) дә тикшерә. Лингвистик уникалияләргә чикләнгәнлек, бердәнберлек, үзенчәлеклелек, үзгәлек хас. Японнарның ике график формадагы (катакана һәм хирагана) иҗекле фонетик алфавитын һәм кытай иероглификасын берләштергән япон алфавит системасы уникаль күренеш булып тора.

Телләрне капма-каршы куеп (контрастив) тикшерү аларга хас системаның үсеш үзенчәлеген, объектив дөнья күренешләренең төрле халыклар тарафыннан кабул ителү үзгәлеген ача; матди культураларның, йола, гореф-гадәтләрнең үзенчәлеген, җәмгыятьнең иҗтимагый торышын, халыкларның дөньяга карашларындагы һәм менталитетларындагы аермалыкларны чагылдыра.

*Әд.:* Я р ц е в а В.Н. Контрастивная грамматика. М., 1981; А х у н з я н о в Э.М. Контрастивная лингвистика: морфология русского и тюркских языков. К., 1987; Б а й р а м о в а Л.К. Введение в контрастивную лингвистику. К., 2004.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**«КОНТРРЕВОЛЮЦИО́Н ФЕТНӘЧЕЛӘ́Р ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́** («Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясе»), аерым затларны Сов. хакимиятен корал кулланып бәреп төшерү һәм гомуми сайлау хокукы нигезендә чикләүсез яшерен тавыш бирү юлы б-н буржуаз-демократик республика төзү максатында җинаятьчел төркем булдыруда гаепләү буенча 1933 елда ОГПУ органнары тарафыннан оештырыла. Мәсәлән, М.*Бигиев* оешманың һәм советларга каршы юнәлдерелгән ячейкаларның контрреволюцион эшчәнлеге б-н җитәкчелек итүдә, Сов. хакимияте б-н көрәш алымнары (соңгы чиктә кораллы күтәрелешне дә кертеп) билгеләнгән һәм оешмага крәстияннәрне тарту өчен файдаланылган яшерен фатир тотуда, чит илләрдәге контрреволюцион оешмалар б-н агентура аша һәм, СССР чиген яшерен булмаган рәвештә үтеп чыгу юлы б-н, шәхсән элемтәдә торуда гаепләнә. Оешманың җитәкче составы — Р.В.Алкин, М.Бигиев, Ә.Н.*Максуди*, С.Г.Мусин, М.А.Мостафин, И.Г.Үтәмешев. Эш буенча 109 кеше (җитәкчеләрне кертеп), ш.и. И.М.Әҗемов, А.И. һәм Г.И.Апанаевлар, Ш.З.Апанаев, М.Х.Арсаев, З.А.Вәлиев, С.М.Вахитов, А.С.Галиев, Г.С.*Гобәйдуллин* (читтә яшәгән хәлдә), Г.Г.Гомәров, С.Ш.Зәетов, Ш.Г.Иманаев, С.Б.Мәһдиев, Г.Мөслимов, Г.Н.Насыйров, М.Ф.Тарасов, Г.М.Урманов, А.А.Үтәгәнов, И.Г.Үтәмешев, К.Г.Хәсәнов, М.М.Шигаев тикшерүгә тартыла. Шулардан 47 кеше ОГПУның Хәрби коллегиясе мәхкәмәсенә тапшырыла (мәхкәмә процессы 1933 нең 13 декабрендә Казанда уза). Гаепләнүчеләрнең күбесе төрле срокларга ябылуга (уртача алганда, өч елга кадәр сөргендә һәм тәрбияләү-хезмәт лагерьларында яшәүгә; кайберәүләр, алдан ябылып тотылулары исәпкә алынып, сак астыннан чыгарыла) хөкем ителә. 1956 да СССР Югары мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе тарафыннан хөкем карары юкка чыгарыла, гаепләнгән затларның гамәлләрендә җинаять составы булмау сәбәпле, эш туктатыла.

**КОНТЮКО́В** Гомәр Туктар улы (1907, Иркутск ш. — 22.10.1965, Казан), халык мәгарифе эшлеклесе. Иркутск совет партия мәктәбен тәмамлаганнан соң (1927), ВЛКСМның Иркутск губерна ком-тында инструктор булып эшли. 1929 елдан Мәскәүдә урта мәктәп укытучысы, 1931 дән директор. 1934 тән РСФСР Мәгариф халык комис-тының рус булмаган мәктәпләр бүлегендә инспектор. 1939 дан ТАССР мәгариф халык комиссары, 1946–48 дә министры. Бөек Ватан сугышы елларында күп уку йортларының биналары хәрби учреждениеләргә бирелгән һәм финанслау кыскартылган вакытта, К. республикада халык мәгарифе системасы эшен тәэмин итүдә зур роль уйный. 1948–63 тә Казанда урта мәктәп директоры. 1947–51 дә ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**КОНФОРМАЦИО́Н АНА́ЛИЗ**, стереохимия өлкәсе; молекулалар конформациясен (төрле фәзаи формаларын) һәм матдәләрнең физик һәм химик үзлекләре б-н бәйләнешен өйрәнә. Шул ук вакытта электрон тәэсир итешү турындагы күзаллаулар б-н бергә, молекулаларның фәзаи структураларын, реакциягә керү мөмкинлеген һәм физик параметрларын бергә бәйләргә мөмкинлек биргән теоретик органик химияне тәшкил итә. К.а.га голланд химигы Я.Вант-Гофф нигез сала (1874), ул углеродның туендырылган атомының тетраэдрик моделен тәкъдим итә һәм гади бәйләнешләр әйләнәсендә аларны өзмичә генә башка алмаштыргычларның иреклe әйләнүе законын формалаштыра. Соңрак исә барлыкка килгән конформацияләрнең энергетик тигезсезлеге беленә. Тегe яки бу конформациянең өстенлеге молекулада барлык тәэсир итешүләрнең (электростатик, электрон, стерик h.б.) нәзек балансы б-н билгеләнә. Кагыйдә буларак, болар — миним. энергиягә ия булган капланмаган (шахматлы) конформацияләр, әмма молекулада бу энергияне түбәнәйтергә сәләтле (водородлы бәйләнеш, иярү, аттрактив h.б. эффектлар) тәэсир итешүләр булса да, традицион булмаган, ш.и. капланган конформацияләр булырга мөмкин. К.а.да немец галиме Г.Заксе һәм инглиз химигы Д.Бартонның циклогексан кушылмалары рәтендәге конформацияләр турындагы өйрәнүләре, ш.у. немец химигы Э.Мор, швед химигы В.Прелог, Норвегия физик-химигы О.Хассел, акад. Н.С.Зефиров h.б. хезмәтләре зур әһәмияткә ия. Заманча К.а.га нигез салучы булып Бартон исәпләнә, «Конформацион анализ» терминын да ул кертә (Нобель бүләге, 1969). 1970 елларда дөньяда органик (ОК) һәм элементорганик (ЭОК) кушылмаларның эксперименталь К.а. интенсив үсә. СССРда фосфорорганик кушылмалар (ФОК) структурасын өйрәнү эшләре 1940 елларда Б.А.Арбузов тарафыннан башлана һәм аның шәкертләре тарафыннан дәвам иттерелә. Берничә күчәрле эчке әйләнүле ОК һәм ЭОК катлаулы молекулаларының К.а. нигезләрен А.Н.Верещагин сала, ул физик ысуллар комплексы — диполь моментлар, Керр эффекты, яки даими электр кырында икеләтә нур сыну (аның тарафыннан Керр константасын билгеләү өчен прибор эшләнә), Коттон–Мутон эффекты, яки магнитик кырда икеләтә нур сыну, Релеевча яктылык таралу, магнитик икеләтә нур сыну парамагнит эффекты (1984 елда С.Г.Вульфсон б-н бергәләп ачыла), ш.у. тирбәнешләр, ультрашәмәхә, ТМР һәм фотоэлектрон спектроскопия, газ электронографиясе ысуллары нигезендә тикшеренүләргә теоретик һәм эксперименталь якын килүне, аларның методологиясен эшли. ОК һәм ЭОК молекуляр структурасын билгеләү өчен кристаллик фазада структур рентген анализы ысулы кулланыла. Төрле класстагы ОК, ФОК һәм ЭОК К.а. буенча тирәнтен өйрәнүләр РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында (Б.А.Арбузов, А.Н.Верещагин, С.Г.Вульфсон, В.А.Наумов, В.Е.Катаев, А.А.Бредихин, Э.Х.Казакова, өлкән фәнни хезмәткәр В.В.Зверев h.б.), Казан ун-тында, А.М.Бутлеров исем. Химия ин-тында (Э.А.Ишмаева, И.И.Пацановский, Г.А.Чмутова, Л.К.Юлдашева, Р.П.Аршинова, Е.Н.Климовицкий, Л.М.Катаева h.б.) үткәрелә. ОК һәм ЭОК К.а.да тирбәнешле спектроскопия куллану мөмкинлекләре өйрәнелә (Р.Р.Шаһидуллин, А.Б.Ремизов, В.И.Коваленко, С.А.Кацюба h.б.). Циклик ОК һәм ЭОК К.а.га Й.Ю.Сәмитов зур өлеш кертә, илдә беренчеләрдән булып ТМР-спектрометрларны конструкцияли (1960). Сәмитов һәм аның шәкертләре (А.В.Ильясов, А.В.Аганов, Р.М.Әминова, В.В.Клочков, Ф.Х.Каратаева, Т.А.Зябликова h.б.) тарафыннан ТМР-спектроскопия, ОК һәм ЭОК К.а.да аны куллану буенча нигезләнгән фәнни нәтиҗәләр алына. Квант химиясе һәм исәпләү техникасы ысуллары үсеше К.а. мөмкинлекләрен дә киңәйтә.

*Әд.:* Конформационный анализ. М., 1969; Конформационный анализ элементоорганических со-

единений. М., 1983; Конформационный анализ углеводородов и их производных. М., 1990.

*Э.А.Ишмаева.*

**КО́НЮХОВ** Владимир Михайлович (20.7.1956, Грузия ССРның Батуми ш.), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (2004). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп, 1978–81 дә Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында), гамәли матем. каф. профессоры (2005 тән), бер үк вакытта Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1984 тән). Хезмәтләре күп фазалы агымнарны матем. һәм санлы модельләштерүгә, җир асты җылылык гидромеханикасына карый, К. забой янын төрле алымнар б-н эшкәрткәндә скважина һәм катламдагы гидродинамик һәм җылылык процессларын тикшерә, органик һәм нәорганик пычранулар күчкән вакытта су йөртүчән анизотроп катламнарда фильтрлану-диффузия процессларын өйрәнә. Уйлап табуга 3 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Дисперсные потоки в нефтяных скважинах. К., 1990; Математическое моделирование имплозионного воздействия на пласт. К., 2004 (автордаш); Двухфазная многокомпонентная фильтрация в нефтяных пластах сложной структуры. К., 2009 (автордаш).

**КО́НЮХОВА** Татьяна Петровна (22.7.1944, Иваново өлкәсе Комсомольск ш.), химик-технолог, техник фән. канд. (1985), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1976). Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (1974 елдан); 1977 елдан ЦНИИгеолнерудта лаб. мөдире, 2006 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре минераль чимал сыйфатын технол. бәяләүгә һәм аны файдалануга карый. Уйлап табуга 30 лап авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге руда булмаган чималны кабат эшкәртүнең яңа технологияләрен эшләгәне өчен бирелә.

**КО́НЮШЕВА** Әдилә Ибраһим кызы (23.9.1953, Мордва АССРның Рузаевка ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре. Мордва ун-тын (1976), СССР МС каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (1991) тәмамлый. 1976–79 елларда ТАССР Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгының техник-икътисади бюросы икътисадчысы. 1979–85 тә ритуаль хезмәт күрсәтү комбинатының бүлек башлыгы. 1985–96 да ТРның Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министры урынбасары. Бер үк вакытта 1990–96 да «Илдан» ширкәтенең коммерция директоры. 1996–97 дә ТРның сәүдә һәм кулланучыларга хезмәт күрсәтү министры. 1997–2001 дә ТР Премьер-министры урынбасары. 2001–09 да «Холод» АҖ ген. директоры.

**КОҢГЫЗЛА́Р**, к а т ы к а н а т л ы л а р (Coleoptera), иң зур бөҗәк отрядларының берсе. 4 асотрядтан тора: Archostemata — 3 семьялык, Myxophaga — 3 семьялык, Adephaga (ерткычлар) — 10 семьялык, Polyphaga (төрле азык б-н тукланучылар) — 120 семьялык (дөнья фаунасында иң зур асотряд). 300 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 20 меңнән артык, Татарстанда 2 меңнән артыграк төре бар. К.ның күпчелеге нык һәм каты хитин япма б-н капланган. Аларның алгы канатлары каты, склеритлашкан өске канатларга яки элитрларга (катыканатлылар исеме шуннан) үзгәргән. Арткы зәгыйфь җепселле элпә канатлары очу өчен хезмәт итә, тыныч халәттә өске канатлар астына җыела. Кайбер төрләренең канатлары үсеш алмаган. Авыз аппараты кимерә торган. Формасы һәм озынлыгы төрле булган мыекчыклары, гадәттә, 11 буынлы. К.ның күкрәге 3 сегменттан тора, аеруча алгы күкрәк үскән. Ул урта күкрәк б-н хәрәкәтчел тоташа, урта күкрәк исә арткы күкрәк б-н хәрәкәтсез тоташа. Аяклары гадәти йөгерә һәм йөри торган, әмма яшәү рәвешенә карап сикерүгә, казуга, йөзүгә, эләктереп алуга, ябышуга җайлашкан. Тәпиләре 5, 3, кайвакыт 2 буынлы. Корсагы хәрәкәтсез, тышкы үсентеләрдән башка гына арткы күкрәк б-н тоташкан. Корсак сегментлары 10 нан артмый. К.ның төсе төрлечә. Гәүдә япмасында буяучы матдәләр — пигментларның (металлик булмаган төсмерләр) булуына, яки япманың үзенчәлекле микроскопик төзелешенә, яисә аларның комбинациясенә бәйле. К.ның үсеше тулы әверелеш б-н бара. Гадәттә, йомыркалары озынча түгәрәк, ярым үтәкүренмәле, пигментлашмаган юка тышчалы. Личинкаларның төзелеше төрле, башлары яхшы склеритлашкан һәм авыз өлешләре кимерә торган. Күкрәк аяклары үскән яки җитәрлек үсеш алмаган, хәтта бөтенләй булмаска да мөмкин (*филчекләрнең* личинкалары). Күп кенә личинкалар яшерен яшәү рәвеше алып баралар. Яфрагашарларның личинкалары һәм кайбер башка семьялык вәкилләре үсемлекләрдә ачык яшиләр. Курчаклары иркен, йомшак, юка кабыклы капламда, күп кенә төрләрнеке туфрак яисә агачта яшерен үсә. К. бөтен җир өсте биотопларында, төче суларда һәм аз гына тозлы суларда яши. Аларның күбесе туфракның өске катламнарында һәм үсемлек калдыкларында, кайберләре тирестә һәм хайван үләксәләрендә яши. Үсемлекләрнең төрле өлешләрендә (яфрак, чәчәк, җимеш, ботак, кайры, үзагач, тамырларда) яшәүчеләр аеруча күп. Күп кенә умырткалы хайваннарның туклану чылбырында К. төп компонент булып тора. Туклану тибы буенча К. ерткычларга (барысын ашаучылар һәм махсуслашкан) һәм үсемлек б-н тукланучыларга (фитофаглар) бүленәләр. Соңгылары арасында яфрак (фитофаглар үзләре), тамыр (ризофаглар), агач һәм кайры (ксилофаглар), чәчәк (антофаглар), җимеш һәм орлык (карпофаглар) ашаучылар бар. Гөмбә б-н туенучыларны мицетофаглар төркеме, черүче үсемлек һәм хайван матдәләрен ашаучы сапрофаглар һәм некрофаглар төркеме тәшкил итә. Катыканатлыларның кайберләре (хәйләкәр коңгызлар, *тире-йон коңгызлары*, кайбер кара коңгызлар, *бөртек коңгызлары*, филчекләр, башлыклылар) урман һәм а.х.на, ш.у. азык-төлек запасларына зыян китерә. Илл. к. 448–449.

*Әд.:* Я к о б с о н Г.П. Жуки России и Западной Европы. СПб., 1905; Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2; М а м а е в Б.М. Определитель насекомых по личинкам. М., 1972; Насекомые и клещи-вредители сельскохозяйственных культур. Л., 1972. Т. 1; Вредители сельскохозяйственных культур и лесных насаждений. Киев, 1974. Т. 2; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3; Ж е р е б ц о в А.К. Определитель жужелиц Республики Татарстан. К., 2000.


*А.К.Жеребцов.*

**КООПЕРАТИ́В** (лат. cooperutio — хезмәттәшлек), затларның финанс эшләрендә һәм хезмәттә катнашуга корылган, бергәләп продукция җитештерү һәм сату, товарлар яки хезмәт күрсәтүләрне сатып алу һәм куллану, торак йортлар төзү һәм файдалану һ.б. эшчәнлекне алып бару максатында ирекле рәвештә тигез пайлар, тигез хокуклылык нигезендә оештырылган берләшмәсе. К.лар Казан губернасында 19 йөз ахырында эшли башлыйлар. 1930 еллардан 1980 еллар ахырына кадәр ТАССРда, башлыча, кулланучылар, а.х., бакчачылар, торак-төзелеш К.лары таралыш ала. К.ларның яңадан үсеше 1990 еллар башыннан күзәтелә, алар җитештерү, сәүдә, халыкка хезмәт күрсәтү, хокукый ярдәм һ.б. өлкәләрне колачлый.


К.лар, башлыча, җитештерү (җитештерү һәм хезмәт күрсәтүләр; халык куллану товарлары эшләп чыгару һәм сату яисә халыкка төрле түләүле хезмәт күрсәтүләр, ш.у. производство-техник продукция эшләп җитештерү һәм сату, халык һәм пр-тиеләр өчен төрле эшләр башкару) һәм куллану (товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр әйләнеше һәм шулар б-н бәйле җитештерү; күбесенчә а.х. продукциясе һәм чимал әзерләү һәм эшкәртү, сәүдә, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү, дачалар һәм гаражлар төзү) буенча специальләшәләр. К. әгъзасы булу өчен аның эшчәнлегендә шәхси хезмәт б-н катнашу мәҗбүри. Кулланучылар К.лары берлекләргә (берләшмәләргә) берләшергә мөмкин, алар күбрәк кулланучылар кооперациясе системасын (*Татарстан Республикасы Кулланучылар җәмгыятьләре берлеге*) тәшкил итә. Җитештерүче К.лар Татарстанда а.х.нда таралган. 1999 ның башына республикада — 341, 2004 тә 430 а.х. К.ы исәпләнә. Яңа формалы оешмалар арасында К.ларның өлеше Балтач, Зәй, Менделеев, Балык Бистәсе, Спас, Яшел Үзән, Әлмәт, Актаныш, Азнакай, Тәтеш, Чирмешән һ.б. р-нннарда зуррак. 2006–10 елларда а.х. К.ларының саны кими.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КООПЕРА́ЦИЯ**, хезмәтне, милекне яки капиталларны ирекле берләштерүгә, ш.у. уртак идарәгә нигезләнгән вак товар җитештерүне, сатуны, вак кредитлар бирүне оештыру формасы. Эре сәнәгать һәм сәүдә көндәшлеге шартларында вак товар җитештерү һәм вак сәүдә үсешен тәэмин итә; ш.у. алыпсатарлардан саклану өчен оештырыла. Җитештерү ассоциациясенең һәм капиталларның башка формалары (башлыча, эре җитештерү; сәүдә йортлары, акц. җәмгыятьләре, капиталистик монополияләр) б-н бергә үсә. К. кулланучылар, кредитлашу (ссуда-саклау ширкәтләре, оешмалары, кассалары), җитештерү (артельләр, ширкәтләр, җәмгыятьләр) төрләренә бүленә.




**Коңгызлар мәкаләсенә.** 1. Герман чапкыны (Cicindela germanica L.); 2. Исле матур коңгыз (Calosoma sycophanda L.); 3. Алтын чокырлы бызылдавык (Carabus clathratus L.); 4. Ашлык бызылдавыгы (Zabrus tenebrioides Goeze); 5. Сары аяклы әйләнчек коңгыз (Gyrinus hatator L.); 6. Зур сусөяр (Hydrous piceus L.); 7. Киң йөзгәләк (Dytiscus latissimus L.), ата зат, 7а. ана зат; 8. Болан коңгыз (Lucanus cervus L.), ата зат, 8а. ана зат; 9. Герман кабер коңгызы (Necrophorus germanicus L.); 10. Гүзәл ерткыч коңгыз (Staphylinus caesareus L.); 11. Кызыл түшле үләксәашар (Oeceoptoma Thoracica L.); 12. Эзтабар кабер коңгызы (Necrophorus vestigator Hersch); 13. Бертөсле шомырткоңгыз (Hister unicolor L.); 14. Hister uncinatus Ill; 15. Гади тирес коңгызы (Geotrupes stercorarius L.); 16. Төнге копр (Copris lunaris L.); 17. Мөгезборын коңгыз (Oryctes nasicornis L.).




18. Алтынсыман бронзак (Cetonia aurata L.); 19. Көнчыгыш май коңгызы (Melolontha hippocastani L.), 19 a. аның личинкасы; 20. Икмәк башак коңгызы (Anisoplia austriaca Hbst.), 20 a. аның личинкасы; 21. Тире-йон коңгызы (Dermestes lardarius L.); 22. Көрән йомшактән (Cantharia fusca L.); 23. Гади утлы коңгыз (Lampyris noctiluca L.), ата зат, 23 a. ана зат; 24. Җиде ноктaлы камка (Coccinella septempunctata L.); 25. Ашлык коңгызы (Tenebrio molitor L.); 26. Җиһаз тисмәне (Anobium domesticum Gffr.); 27. Буй-буй шыртлавык коңгыз (Agriotes lineatus L.), 27 a. аның личинкасы; 28. Зур нарат алтын коңгызы (Burestis mariana L.); 29. Кабыгашар-типограф (Ips tupographus L.); 30. Тополь яфрагашары (Melasoma populi L.); 31. Зур имән кисмәне (Cerambyx credo L.); 32. Аксыл аяклы кәбестә борчасы (Phyllotrefa nemorum), 32 a. аның личинкасы; 33. Шәмәхә майка (Meloë uiclaceus Mrsh.); 34. Борчак коңгызы (Bruchus pisorum L.), 34 a. аның личинкасы; 35. Коңгыз-умарта корты (Trichodes apiarius L.); 36. Корычагач чебенчәсе (Litta vesicatoria L.).

Россиядә кооперативларның иң элгәресе декабристларның Чита төрмәсендәге «Зур артель» дип аталган оешмасыннан башлангыч ала (уставы 1831 дә раслана). Илдә тотрыклы кооперативлар хәрәкәте 1860 елларда *крепостнойлык хокукы* бетерелгәннән соң үсә башлый. Баштарак ул илнең читтәге өлкәләрен (Новороссия, Кавказ, Балтыйк буе, Себер) колачлый, авылларда — кредитлашу, шәһәрләрдә кулланучылар җәмгыятьләре өстенлек итә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында К. халыкның киң катлаулары арасында җәелә, үзәк губерналарда, Идел буенда, Украинада тарала; җитештерү К.се (май язу, сөтчелек, бакчачылык артельләре һ.б.) үсеш кичерә; кулланучылар кооперативлары тарафыннан чәчкечләр, ургычлар, сортларга аеру машиналары, ашлык сугу җайланмалары, сепараторлар һ.б. сатып алына, заводлар төзелә. Кооперативлар таралуда земстволар билгеле роль уйный. Алар артельләргә складлар һәм җиһазлар сатып алу өчен акча бирәләр, артельләрне вак товар җитештерүче аерым хуҗалыклар тәҗрибәсе б-н таныштыралар, эшләнмәләрнең иң яхшы үрнәкләрен, аларны җитештерү технологияләрен һ.б.ны күрсәтү өчен күчмә күргәзмәләр һәм музейлар (мәс., Казан шәһәр фәнни-җитештерү музее), агропунктлар оештыралар.

Татарстан терр-ясендә кулланучылар, кредитлашу, кәсепчелек, а.х. һ.б. кооперативлар эшләве мәгълүм. Алар арасында «Казан шәһәре кулланучылар җәмгыяте» (уставы 1868 нең 18 февралендә раслана) һәм Спас-Затон кулланучылар җәмгыяте (1868 нең 30 октябре, Казан губ. Спас өязе) беренчеләрдән булалар. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казан губернасында кулланучылар җәмгыятьләре, беренче чиратта эшчеләр тарафыннан оештырылганнары үсә башлый. 1896 ның 31 октябрендә — Алафузовлар пр-тиеләре кулланучылар җәмгыятенең, 1915 нең 10 ноябрендә Казан дары заводы мастерлары, эшчеләре һәм хезмәткәрләре кулланучылар җәмгыятенең уставлары һ.б. раслана. К. хәрәкәте Беренче бөтендөнья сугышы елларында активлаша: 1916 да җәмгыять оештыруга рөхсәт сорап — 252, 1917 нең 9 аенда 208 гариза теркәлә. Губерна шәһәрләрендә җәмгыятьләр терр. принцип буенча оештырыла (мәс., «Казанның Зур Игумный бистәсе предприятиеләре кулланучылар җәмгыяте», уставы 1915 нең 26 ноябрендә раслана; Плэтән кооперативы, 1917 нең 9 июлендә төзелә).

Казан губернасында беренче кредитлашу ширкәтләре 20 йөз башында барлыкка килә (Лаеш өязендә — «Емельяново» һәм Тәтеш өязендә — «Бакырчы»). Кредитлашу К.сенең интенсив таралышы аның үзәкләшү тенденциясен билгели, бу кооперативлар берлекләре, съездлары, матбугаты оешуга китерә. К. хәрәкәте б-н җитәкчелек итүдә һәм кредитлашу кооперативларының тиз генә үсеп китүендә 1915 тә Казан кредитлашу һәм ссуда-саклау ширкәтләренең губерна берлеге төзелү зур роль уйный (к. *Казан төбәге кредит кооперативлары берлеге*).

К.нең демократик характеры барлык органнарның да сайланып куелуында, аларның кооператив әгъзалары каршында хисап тотуында, барлык пайчыларның тигез хокуклы булуында, керү взносларының кечкенә күләмендә, табышның бер өлеше мәдәни-агарту максатларында сарыф ителүдә чагыла. Авыллардагы кооперативлар җитәкчелегендә — таза тормышлы крәстияннәр, шәһәрләрдәге кооперативлар җитәкчелегендә — хезмәткәрләр һәм квалификацияле эшчеләр өстенлек итә. Кооператив органнарында барлык сәяси партияләрнең дә диярлек вәкилләре эшли, ләкин эсерлар партиясе әгъзалары күпчелек була. 1917 елгы Февр. рев-циясе чорында күп кенә җирләрдә кооперативлар иске хакимиятне бәреп төшерүдә һәм яңа хакимият урнаштыруда билгеле роль уйныйлар. К. 1 нче Бөтенроссия крәстияннәр Советлары съездын чакыруны (1917 нең мае) финанслый, 1917 нең сентябрендә К. җитәкчеләре Демократик киңәшмәдә катнашалар.


«Татселькредитсоюз»ның Чаллы бүлекчәсе. 1921.

Патша хөкүмәтенең К.гә карата мөнәсәбәте бертөрле генә булмый. Бер яктан, ул башта ук К.нең һәр җирдә һәм иркле үсешенә комачаулык тудыручы законнар чыгара, икенче яктан, аерым алганда, 1890 еллар ахырыннан Дәүләт банкы һәм аның вак кредит инспекциясе аша ярдәм күрсәтеп, кредитлашу К.се үсешенә булышлык итә. 1917 нең мартында Вакытлы хөкүмәт, кооперативлар турындагы закон кабул итеп, К.гә караган барлык чикләүләрне бетерә. Февр. рев-циясеннән соң эшчеләр К.сенең вәкиллекле органы булдырыла: 1 нче съездда (1917 нең 1–5 августы; 511 мең әгъза исәпләнгән 124 оешмадан 207 делегат) эшчеләр К.сенең Бөтенроссия советы сайлана. 1917 нең 1 апрелендә Казан губернасы кулланучылар учреждениеләренең Оештыру съезды карары нигезендә кулланучылар К.се эшчәнлеген җайга салу өчен Казан губерна кулланучылар җәмгыятьләре берлеге оештырыла.

Окт. рев-циясеннән соң, «хәрби коммунизм» чорында К.нең күп кенә төрләре, бигрәк тә кредитлашу кооперативлары, бетүгә йөз тота. Казан губернасында бу чорда, башлыча, хуҗалык функцияләре шактый күләмдә чикләнгән кулланучылар К.се пр-тиеләре (әзерләү, эшкәртү һ.б.) саклана. Алар күбесенчә җитештерелгән киң куллану сәнәгать товарларын һәм продразвёрстка барышында крәстияннәрдән тартып алынган а.х. продукциясен халыкның аерым катлаулары арасында бүлү б-н шөгыльләнә. 1918 дә Казан губернасы шәһәрләрендә хакимият структуралары шәһәр халкын иң кирәкле товарлар һәм туклану продуктлары б-н тәэмин итү максатында эшчеләр кооперативлары оештыра башлыйлар (к. *Казан эшчеләренең үзәк кооперативы*). 1918 нең ахырында — 1919 ның башында РСФСР ХКСның 1918 нең 25 октябрендә чыгарылган бердәм кулланучылар җәмгыятьләрен оештыру турындагы Декреты нигезендә кулланучылар К.се пр-тиеләрен һәм учреждениеләрен үзәкләштерү башлана, алар, асылда, дәүләт хакимияте органнарына буйсындырыла һәм Казан губерна ХХСның кооперативлар бүлеге карамагына күчерелә. 1919 ның 20 мартында кайбер кооператив учреждениеләре һ.б. оешмалар *Казан кулланучылар җәмгыятенә* берләштерелә, бу җәмгыять «яңадан бүлү» вазифасы б-н бергә, ш.у. җәмәгать туклануын оештыру, хастаханәләр һәм шифаханәләр төзү, мәдәни-агарту эше һ.б. б-н шөгыльләнә. Шул ук вакытта шәһәр һәм авыл арасындагы икътисади мөнәсәбәтләрнең натуральләшүе кредитлашу К.се эшчәнлегендә үзгәрешләргә китерә (к. *Казан төбәге кредит кооперативлары һәм хезмәт артельләре берлеге*), К.нең бу төре, башлыча, шәһәрдәге һәм авылдагы җитештерүчеләр арасында продуктлар алмашуда арадашчылык итү б-н шөгыльләнә. 1919 ның мартында, аучылар һәм балыкчылар эшчәнлеген үзара яраклаштыру өчен Казан губерна хезмәт аучылары берлеге оештырыла (к. *Татарстан аучылар һәм балыкчылар кооперативлары өлкә берлеге*). РСФСР ХКСның 1920 нең 27 гыйнварында кабул ителгән «Кооперативлар съездлары Советларын бетерү турында»гы Декреты б-н элеккеге кооперативлар учреждениеләре таратыла, аларның мөлкәтләре һәм капиталлары Центросоюзга күчерелә. *Комбедлар* һәм сәясиләштерелгән авыл активы ярдәмендә хакимият структуралары национализацияләнгән алпавыт, өлешчә крәстиян хуҗалыклары җирлегендә җитештерү кооперативлары оештыра башлыйлар (к. *Колхоз, Җирне бергәләп эшкәртү ширкәте, Авыл хуҗалыгы коммунасы*).

*Яңа икътисади сәясәткә* (НЭП) күчү б-н К. үсешендә чираттагы этап башлана. Җитештерү (бигрәк тә вак кәсепчелек һәм а.х. кооперативлары) һәм кулланучылар К.се киң таралыш ала. 1926 ның октябрендә К.нең төрләре эшчәнлеген үзара яраклаштыру өчен Татарстанда *ТАССР кооперация советы* оештырыла, аның составына кооперативлар берлекләре б-н беррәттән ш.у. финанс-кредит учреждениеләре дә (ш.и. Бөтенсоюз кооперативлар банкының Татарстан бүлеге һәм Татарстан а.х. банкы) керә.

НЭП елларында кредитлашу К.се челтәре яңадан эшли башлый, ул, башлыча, халыкны кредит хисабына машиналар, хезмәт кораллары, чимал б-н тәэмин итү һ.б. б-н шөгыльләнә. 1923 нең февралендә кредитлашу кооперативлары эшчәнлеге б-н җитәкчелек итү максатында *Идел-Кама төбәге авыл хуҗалыгы, кредит һәм вак кәсепчелек кооперациясе берлеге* оештырыла. 1927 нең уртасына барлык әгъзаларның 85% ын берләштергән а.х. К.се челтәренең төп оешу формасы а.х. кредитлашу К.сеннән гыйбарәт була.

1920 елларда хакимиятләр крәстиян хуҗалыкларын коммуналарга һәм колхозларга К.ләү буенча максатчыл сәясәт уздыралар, ул ирексезләп *крәстиян хуҗалыкларын кумәкләштерү* б-н төгәлләнә. Бер үк вакытта НЭП чорында вак кәсепчеләрне һәм һөнәрчеләрне массачыл К.ләү башлана, алар куллану предметлары җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өчен берләштерелә. 1920–30 елларда металл эшкәртү, киез басу һәм урман кәсепчелеге, төзелеш материаллары җитештерү, күн һәм сарык тиресе эшкәртү һ.б. б-н шөгыльләнгән вак кәсепчеләрнең һәм һөнәрчеләрнең күпчелек өлеше хакимиятләр тарафыннан мәҗбүри рәвештә төрле кооперативларга берләштерелә (к. *Вак һөнәрче һәм кәсепчеләрнең Казан җәмгыяте, ТАССР инвалидлар кооператив артельләре берлеге, Татарстан көнкүреш кәсепчелеге берлеге, Татарстан төрле кәсепләр берлеге, Татарстан металл эшкәртү кәсепчелеге кооперативлары берлеге, Татарстан сөт кооперациясе берлеге, Татарстан чимал калдыкларын җыю һәм эшкәртү кәсепчелеге кооперациясе берлеге, ТАССР туку-тегү кәсепчелеге кооперациясе берлеге*). 1930 еллар башына артельләр, вак кәсепчеләр һәм кәсепчелек кооперативлары кәсепчелек К.се системасын төзиләр (к. *Татарстан кәсепчелек кооперативлары советы*). 1939 елга кәсепчелек һәм инвалидлар К.се буенча тулай продукция күләме 248,6 млн. сум тәшкил итә. 1937 дә кәсепчелек К.се тарафыннан 778,6 мең пар күн аяк киеме, 421,9 мең пар оек, 31500 данә металл кровать, 20700 данә йозак, 18 млн. данә төзелеш кирпече, 223,8 мең данә чирәп, 15900 *т* известь, 5600 *т* алебастр, 41200 $м^2$ ак таш, 91200 $м^2$ чуерташ, 487,2 *т* чамасы кондитер эшләнмәләре һ.б. җитештерелә. Бөек Ватан сугышы чорында һәм сугыштан соңгы елларда халыкны иң кирәкле товарлар б-н тәэмин итү (сәнәгатьнең фронт ихтыяҗларына юнәлдерелүе сәбәпле) һәм сугыш инвалидларын эшкә урнаштыру өчен төрле кәсепчелек-көнкүреш кооперативлары оештырыла башлый (к. *Казан шәһәре көнкүреш эйберләре кәсепчелеге берлеге, Казан шәһәре тегү, күн эшкәртү, киез басу һөнәрчелеге берлеге, ТАССР инвалидлар кооперациясенең Казан шәһәре берлеге, Татарстан азык-төлек җитештерү кәсепчелеге берлеге*). 1950 еллар башында кәсепчелек кооперативлары берлекләрен эреләндерү һәм вакландыру процессы башлана, бу аларның җитештерү эшчәнлегендә тискәре яктан чагыла. 1950 елларның 2 нче яртысында Сов.хөкүмәте карары б-н кәсепчелек К.сенең барлык берлекләре һәм артельләре диярлек бетерелә.

1920 еллар ахырында — 1930 елларда хосусый вак товар җитештерүнең, сатуның һәм кредитлашуның бетерелүе нәтиҗәсендә җитештерү һәм куллану өлкәсендә массачыл күренеш буларак кооперативлар яшәүдән туктый. 1930–50 елларда К., асылда, дәүләтләштерелә, күп кенә кооператив оешмалары (берлекләре) бетерелә, соңрак, башлыча, кулланучылар (к. *Татарстан Республикасы Кулланучылар җәмгыятьләре берлеге*) һәм а.х. К.се үсә башлый. «Кооперация турында закон» кабул ителгәннән соң, кооператив эшмәкәрлекнең яңа формалары барлыкка килә, элеккеге (дәүләтләштерелгән) кооперативлар үзгәртелә башлый. Ш.у.к. *Кооператив.*

*Әд.:* А р б а т о в С. Сельхозяйственная кооперация Татреспублики (1920–1930 гг.). К., 1930; Потребительская кооперация Татреспублики за 10 лет. К., 1930; 20 лет Татарской АССР (1920–1940). К., 1940; К л и м о в И.М. Образование и развитие Татарской АССР (1920–1926). К., 1960; З а л я е в А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974.

*Р.В.Шәйдуллин.*


**КООРДИНАЦИО́Н ХИ́МИЯ**, химия фәне бүлеге, комплекс хасил итүче (үзәк атом, ион) һәм үзәк атомнан баскычлап һәм кайтма бүленергә сәләтле лигандалардан (молекулалар, ионнар) торган координацион (комплекслы) кушылмаларны (КК) өйрәнә. КК кристаллик халәттәге кебек үк, эремәләрдә дә булалар; молекуляр хәлдә мөстәкыйль яшәргә сәләтле гади молекулалардан торучылар кебек тикшерелә алалар. КК турында нигезләнгән төп фәнни тәгълиматны Швейцария галиме А.Вернер кертә, ул КК эремәләренең электр үткәрүчәнлеген өйрәнүләре нигезендә нейтраль молекулаларның металл ионнарына координациясен исбатлый һәм төзелешнең координацион теориясен формалаштыра (1893). А.Вернер тарафыннан тәкъдим ителгән теорияне киңәйтеп, проф. Л.А.Чугаев үзенчәлекле буялган КК хасил булу б-н бара торган, никель һәм осмийга сизгер аналитик реакцияләрне ача (1905), органик реагентларның сыйфат һәм микъдар анализларында кулланылу мөмкинлеген күрсәтә, ККны ул химия фәненең мөстәкыйль өлкәсенә аера. А.А.*Гринберг* — агалтынсыман металларның физик химиясенә нигез салучы — (акад. И.И.Черняев б-н берлектә) ККда яраштырылган төркемнәрнең бер-берсенә тәэсирен өйрәнә, лигандаларның транс-йогынты эффектына теоретик аңлатма бирә һәм яңа цис-йогынты эффектын таба, ул алга таба проф. Ю.Н.Кукушкин һәм аның шәкертләре тарафыннан җентекләп өйрәнелә.

Казанда К.х. өлкәсендәге беренче эшләр К.К.Клаус тарафыннан агалтынсыман металларны өйрәнгәндә 1840 елларда үткәрелә. Фундаменталь тикшеренүләр 1942 елда, каф. мөдире А.А.Гринберг җитәкчелегендә Ленинград технол. ин-тының нәорганик химия каф. Казанга эвакуацияләнгәннән соң башлана. Аның фосфорорганик кушылмалар синтезы б-н шөгыльләнүче А.Е.Арбузов б-н очрашуы элементорганик лигандалы ККны тикшерү буенча яңа фәнни юнәлешкә нигез була. Бу юнәлешне А.Д.*Троицкая* җитәкли. Аның тарафыннан (шәкертләре б-н берлектә) катализаторлар һәм биол. актив кушылмалар сыйфатында кулланылыш тапкан агалтынсыман металлар комплексы синтезлана. Киләчәктә органик синтезда эффектив катализаторлар сыйфатында кулланылучы элементорганик лигандалар б-н гадәти булмаган дәрәҗәдә оксидлашу нәтиҗәсендә палладий, агалтын һәм родий кушылмалары алына (Н.С.Әхмәтов, В.К.Половняк); кластер тибындагы кушылмалар һәм лигандаларның төрле характерда тоташкан комплекслары структурасын модельләштерү буенча эшләр башкарыла. Эремәләрдә электрохимик ысуллар кулланып комплекслар хасил итү процессларын өйрәнү аналитик һәм нәорганик химиядә электрохимик ысуллар куллануның яңа фәнни юнәлеше үсешенә нигез була (В.Ф.Торопова). Органик, ш.и. биол. актив лигандалар б-н агалтын һәм арадаш металларның электрохимик реакцияләре өйрәнелә; гадәти булмаган оксидлашу халәтендәге металларның арадаш кушылмалары барлыкка килүне дә исәпкә алып, сусыз тирәлектә комплекслар хасил булуның төп закончалыклары билгеләнә (Г.К.Будников, Н.А.Улахович). 1950 елларда эремәләрдә нәорганик һәм координацион кушылмаларны тикшерү өчен ТМР ысулы тәкъдим ителә, ул комплекслы кушылмаларда лигандалар координациясе составын һәм характерын билгеләргә ярдәм итә (А.А.Попель). Сольватлы, лигандалы, протонлы алмашуны исәпкә алып, эремәләрдә комплекс хасил булу шартлары һәм закончалыклары өйрәнелә, бу процессларның механизмнары (Ю.И.Сальников, З.А.Сапрыкова, А.Н.Глебов), ш.у. бинар тирәлекләрдә комплекслар хасил булу һәм сольватлашуны тикшерүнең яңа структур-динамик алымнары тәкъдим ителә (Ф.В.Девятов). К.х. закончалыклары һәм кагыйдәләре химия фәненең органик, нәорганик, аналитик, физик тармакларында кулланыла. КК углерод, кислород, водород оксиды, алкен һәм алкин молекулаларын активлаштырырга сәләтле, гомоген һәм каплагыч катализаторлар сыйфатында кулланыла. Арадаш металларның КК нигезендәге катализаторлары югары активлыгы һәм селективлыгы б-н аерылалар, классик гетероген катализаторлардан аермалы буларак, йомшаграк шартларда эшләргә ирек бирәләр. Казан ун-тында, Казан технол. ун-тында һәм тармак фәнни-тикшеренү ин-тларында К.х. проблемлары тирәнтен өйрәнелә.

*Әд.:* В е р н е р А. Новые воззрения в области неорганической химии. Л., 1936; Г р и н б е р г А.А. Введение в химию комплексных соединений. М., 1966; И н с ц е д и Я. Применение комплексов в аналитической химии. М., 1979; К у к у ш к и н Ю.Н. Реакционная способность координационных соединений. Л., 1987.

*В.К.Половняк.*

**КОПВИ́ЛЛЕМ** Уно Херманович (4.10.1923, Эстония, Таллин ш. — 23.10.1991, Владивосток ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1967), проф. (1970). 1951 елда Киров пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Киров, Уржум, Слободской шәһәрләрендә физика фәнен укыта. 1958 дән Казан ун-тында. 1961 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында, теоретик физика секторы, квант акустикасы бүлеге (1968–73) мөдире. 1973 тән Калининград ун-тында теоретик физика каф. мөдире. 1975 тән СССР ФАнең Тын океан океанология ин-тында (Владивосток ш.) квант океанологиясе бүлеге мөдире. Хезмәтләре радиоспектроскопиягә, магнитик квант акустикасына, когерент һәм нәсызыкча оптикага, гравитация, океанология, геофизикага карый. К. фонон мазеры (бергә-



В.Е. Копылов.

ләп, 1962), яктылык кайтавазы (бергәләп, 1962) күренешләрен фаразлый. Магнитик квант акустикасының физик принципларын, квант океанологиясе нигезләрен эшли. Сегнетоэлектрикта озакка сузылган полярлашкан кайтавазны, төш спин-системаларында тавышның үтә нурланышын, пыялаларда һәм аморф җисемнәрдә кайтавазны таба; океаник тереклек параметрларын (су молекулаларының протон релаксациясе вакытларын, акустик нәсызыкчалык параметрларын, диңгез суында парамагнитик ионнар коэф.), атмосфераның электр кырын һәм аның диэлектрик үтешлелеген, Җирнең мәҗбүри үзнурланышын һәм үзтирбәнүләр фонын билгели. «Параэлектрик резонанс» («Параэлектрический резонанс», М., 1982), «Полярлашкан кайтаваз» («Поляризационное эхо», М., 1985) монографияләре авторларының берсе.

Х е з м.: Световое эхо и перспективы его применения в науке и технике // Изв. АН СССР. 1973. Т. 37, № 10; Когерентность в физике, сейсмике и биологии // Изв. АН СССР. 1989. Т. 53, № 12; Оптическое эхо-ускорение частиц, эхо-разделение изотопов и стимулирование когерентных химических эхо-реакций // Световое эхо и проблемы когерентной оптики. Куйбышев, 1990; Acoustic Superradiance // Adv. Mol. Relax. Processes. 1976. V.8, № 4 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**КОПЕ́ЙКИН** Валерий Александрович (12.3.1939, Мәскәү), геолог-геохимик, геол.-минерал. фән. д-ры (1985), проф. (1985). Кривой Рог тау-руда ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), СССР Дәүләт геол. ком-тының 105 нче геол. экспедициясендә эшли. 1966–72 һәм 1988–96 елларда ЦНИИгеолнерудта, радиогеоэкология секторы мөдире (1988–96). 1973–87 дә һәм 1996 дан Ухта индустриаль ин-тының гомуми геол. кафедрасында. СССР терр-ясендә кремнийсыман сорбентлар, борлар, фосфатлар, кабыклар ашалу буенча тикшерүләрнең фәнни җитәкчесе. К. фосфатлар, боратлар һәм аларның чыганакларының физик-химик модельләрен эшли. Радиоактив зарарлану зоналарында эрегән радионуклидларны тотып алу өчен геохимик барьерлар тәкъдим итә. Чернобыль АЭСындагы фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнаша (1987–96). Әлеге АЭС районында плутоний һ.б. авыр элементлар миграциясен ачыклый. Казанда һәм Менделеев шәһәрендә радиологик тикшерүләр үткәрә. Батырлык ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные минеральные парагенезисы бокситоносных кор выветривания // Докл. АН СССР. 1975. Т. 225, № 2; Поведение железа в процессе выветривания // Докл. АН СССР. 1982. Т. 267, № 1.

**КОПЕ́ЙСК** шәһәре, *Чиләбе өлкәсендә.* Халкы — 138,7 мең кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, 8414 татар (1959 елда — 10080, 1970 тә — 9700, 1979 да — 9016, 1989 да — 8700 кеше). К.дан тыш, татарлар тагын шәһәр карамагындагы Бажово, Вахрушево һәм Старокамышинск эшчеләр посёлокларында яши. 1993–2002 дә С.М.Киров исем. Мәдәният сарае каршында татар телендә гарәп графикасын өйрәнү курслары, 1999 дан Татар мәдәни үзәге эшли. 1999 да К.да татар-башкорт фестивале үткәрелә, 2002 дә Татар мәдәниятен торгызу бөтенроссия фестивале кысаларында «Түгәрәк өстәл» һәм «Заман» Казан эстрада ансамбле концерты оештырыла. 2000 нән шәһәр телевидение һәм радиосында айга 2 тапкыр татар телендә тапшырулар һәм концерт программалары трансляцияләнә. Мәчет төзелә.

**КО́ПОСОВ** Геннадий Фёдорович (5.1.1938, Кострома өлкәсенең Кадуй р-ны Тренино а.), туфрак белгече, биол. фән. д-ры (1984), проф. (1989). Ленинград урман-техника академиясен тәмамлаганнан соң (1965), шунда ук эшли. 1970–88 дә СССР ФАнең Себер бүлеге Туфрак белеме һәм агрохимия ин-тында (Новосибирск ш.). 1988 дән Казан ун-тында, туфрак белеме каф. мөдире (1991 дән). Хезмәтләре тау туфрагы барлыкка килү өлкәсенә карый. Байкал буеның биеклек поясларында һәм аккумулятив тигезлекләрендә туфракларның зональ типлары генезисын, вакланган материал барлыкка килү үзенчәлекләрен күрсәтә. ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004).

Х е з м.: Генезис почв гор Прибайкалья. Новосиб., 1984; Почвы Баргузинской котловины. Новосиб., 1984; Почвенные ресурсы сельскохозяйственного назначения. Новосиб., 1989.

**КО́ПОСОВ** Роберт Иванович (26.2.1938, Архангельск өлкәсе Пинега а.), журналист, кино сәнгате тәнкыйтьчесе, сценарийлар авторы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1961). 1961–64 елларда «Теплоконтроль» з-ды г-тасының әдәби хезмәткәре, 1964–68 дә «Комсомолец Татарии» г-тасының җаваплы сәркәтибе, 1968–72 дә «Казанская неделя» г-тасы мөхәррире, 1972–86 да Казан кинохроника студиясенең баш мөхәррире. Бер үк вакытта Казан телевидение студиясендә «Киноэкраннарда яңалыклар» («Новое на киноэкранах») тапшыруының авторы һәм алып баручысы, Казан кино сөючеләр клубын оештыручыларның берсе. 1986–91 дә «Крис» г-тасының җаваплы сәркәтибе. 1991–93 тә Татар кино үзәге директоры һәм бер үк вакытта «Эфир» телекомпаниясе мөхәррире, 1993–96 да ТР Кинематографистлар берлеге идарәсе рәисе. 1996–99 да вакытлы матбугат басмаларында эшли. 1999–2008 дә ТР МК Аппаратының баш референты. «Бу — КамАЗ» («Это — КамАЗ», 1982) фильмының сценарий авторы, «Киң Иделдә» («На Волге широкой») киножурналларының диктор тексты һәм сценарий планнары авторы; «Образның тууы» («Рождение образа», 1980), «Башка төрле инде булa алмыйм» («Иным уже не буду», 1995) фильмнарының сценарий авторы һәм режиссёры. Театр һәм кино сәнгате тәнкыйтьчесе буларак, матбугатта Казан театрлары спектакльләренә рецензияләр, кино сәнгате һәм аның эшлеклеләре турында мәкаләләр б-н чыгышлар ясый.

**КОПЫЛО́В** Александр Юрьевич (7.7.1975, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), техник фән. канд. (2000). 1998 елда Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 2001 дән «ВНИИУС» АҖдә, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2006 дан). Хезмәтләре нефть химиясенә һәм нефть эшкәртүгә карый. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**КОПЫЛО́В** Виталий Егорович (12.6.1926, Самара өлкәсенең хәзерге Кошки р-ны Югары Берёзовка а. — 9.2.1995, Казан), инженер-механик, сәнәгый җитештерүне оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1971), РФнең атказ. машина төзүчесе (1994). 1949 елда Куйбышев авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Ерак Көнчыгыш машина төзү з-дында (Комсомольск-на-Амуре ш.) эшли: технолог, цех башлыгы, баш технолог, баш инженер урынбасары, директор (1965–73). 1973–94 тә Казан авиация ҖБдә директор, ген. директор. СССР авиация сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертә. К. җитәкчелегендә заводта ерак араларга оча торган Ил-62 самолетын, ТУ-160 стратегик бомбардировщигын күпләп эшләп чыгару үзләштерелә; Лениногорск шәһәрендә заводның ф-лы ачыла һәм «Казанка-5», «Казанка-2М» көймәләрен конвейерлы җитештерү оештырыла. Аның тәкъдиме б-н завод каршында йортлар төзү комб-ты төзелә һәм һәр елны заводта эшләүчеләр өчен уңайлыклары булган 30 мең *м*² га кадәр торак файдалануга тапшырыла. 1975–90 да ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. К. исемен Казанның Авиатөзелеш р-нындагы урам һәм Комсомольск-Амур шәһәрендәге проспект йөртә (1995).

*Әд.:* Завод стратегического назначения. К., 2002; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена «Трудовой славы» — наши земляки. К., 2003.

*Д.С.Фәхретдинов.*

**КОРАБЛЁВ** Михаил Григорьевич (10.11.1954, Новгород өлкәсенең Бурга станциясе), инженер-оптик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). 1977 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан моторлар төзү буенча проектлау бюросында инженер булып эшли. 1981–88 дә Татарстан «Радиоприбор» ҖБдә өлкән, әйдәп баручы инженер. 1988 дән «Элекон заводы» АҖдә: инженер-конструктор, лаб. башлыгы, әйдәп баручы белгеч. Уйлап табуга 4 патенты бар. Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасы медицина учреждениеләрендә көндәшлеккә сәләтле күпфункцияле яңа лазер медицина техникасын булдыру, җитештерүне оештыру һәм гамәлгә кертү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**КОРА́БЛЬЛӘР ТӨЗҮГӘ́ ЯРАКЛЫ́ УРМАННА́Р БУЕНЧА́ ТҮБӘ́Н О́КРУГ ИДАРӘСЕ́**, 1817 елда Казанда оештырыла. Аның карамагына Казан, Түбән Новгород, Вятка, Оренбург, Сембер, Пенза, Тамбов һәм Саратов губерналарындагы корабльләр төзүгә яраклы урманнар (имән һәм мачталык нарат урманнары) керә. Балтыйк флотын, Каспий флотилиясен, *Казан адмиралтействосын*, имән агачлары б-н Архангельск адмиралтействосын, флот өчен яраксыз агачлар б-н артиллерияне тәэмин итү бурычы йөкләнә. Идарә, *лашманнар* хезмәтен файдаланып, корабльләр төзүгә яраклы урманны «кисүне, эшкәртүне һәм чыгаруны», ягъни пристаньга кадәр илтүне тәэмин итәргә, округтагы «иң яхшы кыргый урманнар» арасыннан 300 имән урманы аерып алырга, флот ихтыяҗлары өчен даими запас сыйфатында аларны тәртиптә тотарга тиеш була (кайбер мәгълүматлар буенча, 1817–21 дә идарә чиновниклары Казан губернасында корабльләр төзүгә яраклы 100 дән артык, Сембер губернасында 5 урманны аерып алалар). Финанс министрлыгының Дәүләт милке департаментына, 1828 дән Диңгезчелек министрлыгының Кораблар төзүгә яраклы урманнар департаментына буйсына. 1859 да бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 34. № 27023.

*Әд.:* Корабельные дубравы Чувашии. Чебоксары, 1997. *И.Р.Вәлшуллин.*

**КОРАЙВА́Н** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет (20 йөз башы архит-ра истәлеге). 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Сухие Валы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киез-киез итек басу һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 678,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 79 ир-ат; 1859 да — 283, 1897 дә — 396, 1908 дә — 437, 1920 дә — 490, 1926 да — 421, 1938 дә — 371, 1949 да — 330, 1958 дә — 237, 1970 тә — 168, 1979 да — 152, 1989 да — 92, 2002 дә — 96 кеше.

**КОРАЛША́Т** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мөшек елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,7 *км*, бассейнының мәйданы 39,7 *км*². Елга башы — Мөслим р-нының Кызылъяр авылы янында, тамагы — Минзәлә р-нының Татар Мөшеге авылыннан 0,8 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 95 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. К.ның 1,7 дән алып 3,6 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,48 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 99 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*³*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада су күләме 1,3 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КОРБА́Н БАЛЫКЛА́Р** (Abramis), карплар семьялыгыннан балыклар ыругы. 3 төре билгеле: корбан балык (A. brama), аккүз (A. sapa), синец (A. ballerus). Евразия сулыкларында таралган. Татарстанның елга, сусаклагычларында, күлләрендә барлык төрләре дә яши; аеруча уылдык чәчү чорында зур төркемнәрдә очрыйлар. Корбан балыгының озынлыгы 25–40 (кайвакыт 55 кә кадәр) *см*, авырлыгы 1 *кг* (кайвакыт 5 *кг* га кадәр) тирәсе. Вак корбан балык көмешсыман, эресе алтынсу кара төстә. Гәүдәсе киң, ян-яктан кысылган, анальйөзгече гадәттән тыш озын. Авызы бераз өскә күтәрелеп тора. Аккүз кечкенәрәк, гәүдәсе озынча, көмешсыман төсле, эре тәңкәле, авызы бераз аска төшеп тора. Синец озынча гәүдәле, тәңкәсе вак, авыз чите кыек ярым рәвешендә өскә күтәрелеп тора. К.б. 3–6 яшендә җенси яктан җитлегә. Уылдыкны апрель–майда, сай сулыкта, суның темп-расы 10–14 °С булганда берьюлы чәчә. Үрчемлелеге — 68–390 мең уылдык бөртеге. Корбан балык һәм аккүз бентос б-н туклана, синец — карплар семьялыгында зоопланктон б-н тукланучы бердәнбер төр. Корбан балык һәм синец — кәсәбәчелек балыклары, аккүз — балык тоту спорты объекты.

**КОРБА́Н БӘЙРӘМЕ́**, исламда төп бәйрәмнәрнең берсе. Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә, *Мәккәгә* хаҗ кылу тәмамлангач башлана һәм 3–4 көн дәвам итә. Аллаһ җибәргән сынауларга түземлек күрсәтеп, аның ихтыярына тулысынча буйсынган *Ибраһим* пәйгамбәр б-н бәйле вакыйга истәлегенә үткәрелә. Пәйгамбәр улы *Исмәгыйльне* корбан итеп китерүен төшендә күрә: «Мин төшемдә сине корбан итеп чалганымны күрдем. Моның төбендә нинди мәгънә ята икән, уйлап кара әле», ди ул. «Әтием, — дигән угыл, — нинди әмер бирелсә, шуны үтә. Аллаһка шулай кирәк икән, мине түземлеләр арасыннан табарсың» (Коръән, 37:102). Ибраһим инде корбан чалырга әзер була, әмма Аллаһ, аның инануы хак икәнлегенә ышангач, «көн кебек ачык сынауның» тәмам булуын белдерә. Корбанга бәрән китерелә. Гарәбстан терр-ясендә, Мәккәдә һәм аның тирә-юнендә К.б.н бәйрәм иткән көннәрдә хаҗ кылучылар иртәнге намаз һәм вәгазьдән соң Мина үзәнлегенә юнәләләр. Анда һәркем *Иблисне* гәүдәләндергән баганаларга 7 шәр таш ата. Корбан чалу йоласын корбан малын алырга мөмкинлеге булган һәр мөселман башкарырга тиеш: 1 кеше сарык корбан итә, 10 кешегә кадәр төркем — бер баш мөгезле эре терлек чала (корбанга ш.у. кәҗә, сыер, үгез, дөя чалырга рөхсәт ителә). К.б. иртә таңнан башлана. Тулы тәһарәт алган мөселманнар (еш кына алар алдан мунчада юынган була), бәйрәмчә киемнәр киеп, мәчеттә гает намазы һәм *Коръәннән* сүрәләр укыйлар, вәгазь — имам-хатибның *хөтбәсен* тыңлыйлар. Вәгазьдә бәйрәмнең килеп чыгу тарихы һәм аның мөселманнар өчен әһәмияте бәян ителә. Бәйрәм намазыннан соң, корбан чалу йоласы башкарыла; терлек ите, гадәттә, бергәләп ашау, күршеләргә, дус-ишләргә бүлеп бирү һәм фәкыйрьләргә тарату өчен 3 өлешкә бүленә. Мөселман-татарлар К.б. көннәрендә туганнарының, якыннарының хәлен белешәләр, аш мәҗлесләре («Корбан гаете» дип атала) үткәрәләр. ТРда К.б.нең беренче көне 1992 елдан ял көне дип игълан ителде.

*Әд.:* Уразманова Р.К. Ислам в семейно-бытовой обрядности татар // Татары. М., 2001; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**КОРБАНГАЛИ́ЕВ** Мөхетдин Хафизетдин улы (26.10.1873, Вятка губ., Алабуга өязе Биктау а. — 3.4.1941, Казан), педагог, тел белгече, җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Батыры (1928), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). 1891, 1893–95 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә укый (1892 дә хакимияткә каршы протестта катнашканы өчен мәктәптән чыгарылган була). 1895 тән Казан губернасының Мамадыш өязе Чәбия-Чүрчи, Вятка губернасының Алабуга өязе Биктау авылларында, 1901 дән Вятка губернасының Малмыж шәһәрендә рус-татар башлангыч уч-щеләрендә укыта. 1903–17 дә Мөселман балалар приютында (Казан) укытучы-күзәтче. 1907–17 дә Шәрекъ клубы идарәсе әгъзасы һәм старшинасы, 1911–17 дә Казан шәһәрендәге Ярлы мөселманнарга ярдәм җәмгыяте сәркәтибе. 1917 дә Казан шәһәр думасында, Казан өяз земство управасында эшли, татар мәктәпләрен үзгәртеп кору мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 1918 дән Казан губернасының халык мәгарифе органнарында, 1920–28 дә ТАССР Мәгариф халык комис-тында хезмәт мәктәбе бүлеге мөдире, бер үк вакытта Шәрекъ пед. ин-тында, татар пед. техникумында һ.б. уку йортларында укыта, 1924–27 дә Академик Үзәк рәисе урынбасары. 1928–40 та Казан ун-тында, 1930 дан татар теле каф. мөдире һәм профессоры, бер үк вакытта Казан пед. ин-ты профессоры. 1940 тан Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-тында. 1920 елларда ТАССР Советларының күп кенә съездлары делегаты була, Татарстан ҮБКның берничә чакырылышы әгъзасы. 1906 дан «Азат», «Азат халык» г-таларында хезмәттәшлек итә. 1912 дә яңа җәдит мәдрәсәләре өчен уку ярдәмлекләре комплектын бастыра (татар һәм рус әлифбалары, уку өчен китаплар, «Дөнья» исемле табигать белеме, матем. дәреслекләре). 1913–14 тә «*Мәктәб*» ж-лы хезмәткәре. 1920 еллар башыннан программалар һәм уку ярдәмлекләре комплексын булдыру җитәкчесе, үзе тарафыннан эшләнгән аналитик-синтетик аваз методы нигезендә татар теленә өйрәтү методикасы авторы; башлангыч, урта

сыйныфлар һәм наданлыкны бетерү курслары өчен, Х.Бәдигый, Г.Шәрәф, Р.С.Газизов б-н бергәләп, дәреслекләр, сүзлекләр һәм методик ярдәмлекләр төзи. 1930 елларда татар телен укыту методикасын яңалиф һәм кириллица нигезендә яңадан эшли. К. шул чордагы татар мәктәпләрендә рус телен укыту һәм татар телен татар булмаганнарга өйрәтү методикасын булдыруда әһәмиятле роль уйный; Татарстан төбәген өйрәнү буенча уку ярдәмлекләре, матем., геогр. буенча рус дәреслекләренең татарчага авторлаштырылган тәрҗемәләрен бастыра. Программалар төзүдә, милли пед. кадрлар әзерләүдә, уку процессын оештыру һәм системалар булдыруда әйдәп баручы эшлекләләрнең берсе була. Татар теле грамматикасы проблемаларын өйрәнә, 1930–31 дә татар фәнни терминологиясен булдыруда Татарстан ҮБК каршындагы комиссияне җитәкли. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ханбиков Я.И. История педагогической мысли татарского народа. К., 1975; шул ук. Мөхетдин Корбангалиевнең төп фәнни хезмәтләре исемлеге // Фән һәм тел. 2000. № 2; Вәлиева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевнең татар телен укыту буенча методик системасы. К., 2004; Асадуллин А.Ш. Заглядывая в прошлое методической науки: Из методического наследия по преподаванию русского языка в национальной школе. К., 2001.

**КОРБАНГАЛИ́ЕВ** Салих Мөхетдин улы (18.11.1901, Вятка губ., Алабуга өязе Биктау а. — 6.5.2001, Казан), сәламәтлек саклау эшлеклесе, хирург, мед. фән. д-ры (1955), проф. (1956), мактаулы уйлап табучы. 1924 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, шунда ук 1935 кә кадәр хирургия клиникасында эшли, бер үк вакытта, 1924–26 да ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының сан. профилактика бүлеге мөдире. Казан мед. ин-тын оештыручыларның берсе һәм 1930–31 дә беренче директоры, 1931–34 тә ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары. 1935–54 тә 2 нче Ленинград мед. ин-тының хирургия клиникасында эшли. Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армия госпитальләрендә әйдәп баручы хирург. 1955 тән Ленинград мед. ин-тында госпиталь хирургиясе кафедрасында, 1961–77 дә гомуми хирургия каф. мөдире, 1977–79 да проф.-консультант. Институт клиникасында кан тамырлары хирургиясенең беренче махсус бүлеген оештыручы. К. кан тамырлары протезларын эшли һәм камилләштерә, илдә беренче терплен (лавсан) протезларны сәнәгый җитештерүне оештыра. Хезмәтләре кан тамырлары авыруларына һәм трофик шешләргә диагноз кую, хирургик дәвалауга; үлекле авырулар хирургиясе мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. ВДНХның бронза медале (1968) б-н бүләкләнә.

Хезм.: Радикальное хирургическое лечение невралгии тройничного нерва. Л., 1961; Актуальные вопросы гнойной хирургии. Л., 1977 (автордаш); Гнойная инфекция в хирургии. М., 1985.

**КОРБАНГАЛИ́ЕВА** Хәлимә Мөхетдин кызы (4.5.1910, Казан — 26.3.2004, шунда ук), гидробиолог, биол. фән. д-ры (1960), проф. (1964). Казан ун-тын тәмамлый (1931), шунда ук эшли (1981 елга кадәр), умырткалылар зоологиясе каф. мөдире (1950–74). Хезмәтләре Урта Идел буеның төче сулыклар гидробиологиясенә карый. К. Урта Идел сулыклары һәм Куйбышев сусаклагычы планктонын һәм бентосын өйрәнә. ТАССР күлләрен балык хуҗалыкларында файдалану максатыннан, аларга продукция бирүчәнлеге буенча классификация ясый. Куйбышев сусаклагычын хуҗалыкта куллану чараларын булдыру өчен аның зоопланктоны һәм бентосы формалашу үзенчәлекләрен билгели. «Югары мәктәпләр өчен зоология дәреслеге» (Җ.Сәгъди б-н берлектә, 1932) һәм «Гидробиология буенча лекцияләр конспекты» (1974) уку ярдәмлеге авторы. Бөтенсоюз гидробиология җәмгыятенең Казан бүлеген оештыручы (1968) һәм рәисе (1975 кә кадәр). Ленин ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Планктон и бентос водоёмов поймы Волги, заиливаемых Куйбышевским водохранилищем в пределах ТАССР // Уч. зап. Казан. ун-та. 1957. Т. 117, кн. 6; Данные по бентосу Куйбышевского водохранилища // Уч. зап. Казан. ун-та. 1966. Т. 123, кн. 7; Гидробиологическая характеристика озёр // Озёра Среднего Поволжья. Л., 1976; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977 (автордаш).

*Әд.:* Кузнецов В.А., Яковлев В.А. Халима Мухутдиновна Курбангалиева. К., 2002.

*В.А.Кузнецов.*

**КОРБАНЛЫ́К**, аграр культ б-н бәйле халык йоласы; татарлар яшәгән кайбер төбәкләрдә бүгенге көннәргә кадәр саклана. Җәйге көннәрнең берендә авыл халкы кырда яки зират янында гомуми муллык, бай уңыш теләп бергәләп дога кылу һәм корбан (сарык, сыер һ.б.) итеннән әзерләнгән йола ашы б-н сыйлану өчен җыела. Йола ш.у. башка исемнәр б-н: «сабан боткасы», «тәкәле келәү», «изгеләр ашы», «тавык теләге» буларак та мәгълүм. 20 йөз башына кадәр К., гадәттә, язгы чәчү эшләре башланыр алдыннан үткәрелгән.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; Уразманова Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл (XIX — нач. XX вв.). К., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КОРБА́НОВ** Алексей Габдрахман улы (23.2.1925, хәзер Үзбәкстан Респ-касының Ташкент өлкәсе, Яңа Юл р-ны Ниязбаш пос.), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), гв. рядовое. Ташкент юридик ин-тын тәмамлый (1947). 1943 елның мартыннан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 282 нче гв. укчы полкында снайпер (37 нче армиянең 92 нче гв. укчы дивизиясе). Дала фронты гаскәрләре составында 1943 нең 30 сентябреннән 17 октябренә кадәр Днепр елгасын кичкәндә һәм Дериевка авылы (Украина ССР, Кировоград өлкәсе Онуфриев р-ны) янындагы плацдармда барган сугышта батырлык күрсәтә: снайпер винтовкасыннан дошманның 150 солдатын һәм офицерын юк итә; үзе яралана. 1944 тә демобилизацияләнә. Ташкентның Фрунзе р-нында прокурор ярдәмчесе, туган авылында укытучы булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Джураев Т.Д. Верные сыны Родины. Таш., 1964; Подвиг. Таш., 1980; Березняк Н.Г. Герои Советского Союза — узбекистанцы. Таш., 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КОРБА́НОВ** Барый (Гаделбарый) Шаһивәли улы (1904, Казан губ., Казан өязе Яңа Авыл а. — 1979, Казан), журналист. Журналистика ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1933). 1922 елдан Арча кантоны Кавал, Минзәлә кантоны Минзәлә волисполкомнарында эшли. 1923–28 дә комсомол эшендә. 1928–29 елларда «Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы» г-талары, «Авыл яшьләре» ж-лы мөхәррире. 1930–45 тә — район, завод, фронт газеталары хезмәткәре. 1946–48 дә ТАССР МС каршындагы Татарстан респ-ка радиофикация һәм радиотапшырулар ком-тының баш мөхәррире. 1949–64 елларда «Социалистик Татарстан» г-тасының бүлек мөдире. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

*Р.М.Нуруллина.*

**КОРБА́НОВ** Рафис Харис улы (1.1.1957, Биектау р-ны Кече Битаман а.), язучы. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1982–89 елларда ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында мөхәррир булып эшли. 1989 да «Салават күпере» ж-лында, 1990 да «Идел» ж-лында җаваплы сәркәтип. 1991–93 тә «Әдәби жомга», 1993 тә «Заман-Татарстан» г-таларының баш мөхәррире. Бер үк вакытта Татарстан Язучылар берлеге Әдәби фондында директор (1992–94). 1993–95 тә «Әкият» татар курчак театрында әдәби-драматик бүлек мөдире. 1996 дан Татарстан китап нәшриятында, 1999 дан матур әдәбият һәм балалар әдәбияты редакцияләре мөдире, 2007–2008 елларда баш мөхәррир. 2008 дән — шәхси эшмәкәр, «Илһам» нәшриятын гамәлгә куя, китаплар чыгара, балалар өчен «Күчтәнәч» ж-лы нәшер итә. 2012 дән ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Балалар өчен язылган «Буран кайда йоклый?» (1987), «Сөзгәк болыт» (1991), «Капкорсак» (1992), «Болыт суны болгаткан» (2000), «Алмалы төн» (2002), «Тапкырларга табышмак» (2003) шигъри җыентыкларында туган як табигате, аны саклау, хезмәт сөючән, гадел, мәрхәмәтле булу турында яза. К.ның «Куркуын җиңгән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1995), «Керпе малае дуслар эзли» (1995), «Ак күлмәктә кара елан» (1996), «Кәҗә белән бүре» (2008) пьесалары буенча куелган спектакльләр «Әкият», Татар яшьләр театры, Чаллы курчак театры, «Нур» татар театры, Әстерхан курчак театры сәхнәләрендә уңыш б-н бара. «Бардым күлгә, салдым кармак» пьесасы буенча куелган спектакль Измир (Төркия, 1999), Канн (Франция, 2000) шәһәрләрендә узган халыкара курчак театрлары фестивальләрендә дә күрсәтелә. Аның балалар өчен язылган сәхнә әсәрләре «Куркуын җиңгән Куян» (2000) җыентыгына тупланган. К. ш.у. «Уян, татар!» (1999), «Яра» (2004) исемле лирик-публицистик шигъри

җыентыклар һәм «Тамырларны өзмәгез» (2008), «Мәмдәл егете» (2011) әдәби-публицистик китаплары авторы. ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге лауреаты (2003).

Ә с ә р.: Яра. К., 2004; Куда уходит ночь? К., 2007.

*Әд.:* Г а л и е в Ш. Сайланма әсәрләр. К., 2002. 4 т.; М и ң н у л л и н Р. Дөрес яшисең, Рафис Корбан // Әсәрләр. К., 2007. 5 т.

**КОРБА́НОВ** Рифат Җамал улы (1.10.1951, Арча р-ны Мирҗәм а.), вет. хирургы, вет. фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1974 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, Югары Ослан р-ның «Свияга» с-зында баш вет. табибе булып эшли. 1975 тән Казан вет. медицинасы академиясендә (бүленеп, 1991–92 дә Саратов зоовет. ин-тында хирургия каф. мөдире), 1993–2004 тә клиник диагноз кую каф. мөдире, 1993–2003 тә ректор. 2004 тән «Вамин-Татарстан» ААҖ ген. директоры киңәшчесе. Интраплевраль новокаин-антибиотик блокадасын, сынулардан соң сөякләрне төзәтү өчен җайланмалар, терлекләрне карау өчен өстәл эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). «Күңел сүрәләре» (1906), «Ташта үскән чәчәкләр» (2010) шигырь җыентыклары авторы. ТР Язучылар берлеге әгъзасы.

Х е з м.: Үрчем сәламәт булсын. К., 1989 (автордаш); Терлекләргә беренче ярдәм. К., 1995 (автордаш); Физиология крови. К., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КОРБА́Ш** посёлогы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 19 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 76 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Буа волостенда. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 69, 1938 дә — 55, 1949 да — 60, 1958 дә — 68, 1970 тә — 90, 1979 да — 107, 1989 да — 72, 2002 дә — 63 кеше.

**КО́РБУТ** Ксаверий Александрович (6.10.1869, Литва, Ковно ш. — 1938, Казан), пианист, органчы, педагог. 1894 елда Петербург консерваториясен фортепиано, орган, музыка теориясе белгечлекләре буенча тәмамлый. 1894–95 тә Казанда П.Юргенс музыка мәктәбендә, 1895–1904 тә Р.Гуммерт музыка мәктәбендә фортепиано һәм музыка теориясе фәннәрен укыта; 1904 тән Казан музыка уч-щесендә әйдәп баручы педагогларның берсе. К. Татарстанда проф. музыка белеме үсешенә зур өлеш кертә. Пианист һәм органчы буларак актив концерт эшчәнлеге алып бара. Казанның лютераннар чиркәвендә тематик концертлар һәм орган концертлары б-н чыгышлар ясый. Тыңлаучыларны фортепиано һәм орган классик музыкасының иң яхшы үрнәкләре б-н даими таныштырып тора. Фортепиано педагогикасы мәсьәләләренә караган методик әсбаплар авторы. 1937 дә репрессияләнә; 1938 дә атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КО́РБУТ** Михаил Ксаверьевич (16.8.1899, Казан — 1.8.1937, шунда ук), тарихчы. Казан ун-тын тәмамлый (1922); укыган вакытта эшчеләр ф-тына нигез салучыларның берсе, аның оештыру бюросы әгъзасы, эшчеләр ф-тында президиум секретаре (1922 елга кадәр), мөдир (1926 га кадәр) булып эшли. Бер үк вакытта Шәрекъ пед. ин-тының марксизм һәм политэкономия кафедрасында (1922–23), Казан политехник ин-тында (1923–25), Татар коммунистик ун-тында (1924–25), Казан а.х. һәм урманчылык ин-тында (1925 тән; 1926–28 дә ректор, 1926 дан проф.) эшли. 1926 дан Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте рәисе урынбасары, Шәрекъ пед. ин-ты каршындагы мари халкын өйрәнү җәмгыяте советы әгъзасы, Татарстан архив идарәсе комиссары, Казанда чыгып килүче көндәлек матбугат һ.б. төрле басмаларның мөхәррире һәм редколлегия әгъзасы («Голос пролетарского студенчества», «Казанский библиофил»). 1921–26 да ИСТПАРТ уполномоченные (Казан подкомиссиясе рәисе). 1927 нең декабрендә «троцкийчы-зиновьевчы оппозицион агым»да катнашуда гаепләнеп, партиядән чыгарыла (1928 дә яңадан партиядә торгызыла). 1930 дан Татарстан фәнни-тикшеренү икътисад ин-тының директоры урынбасары.

Казан ун-ты һәм эшчеләр хәрәкәте тарихы буенча хезмәтләре бар; 1933 тә репрессияләнә, 3 елга хөкем ителә (Казакъстан лагерьларында була), 1936 ның февралендә «Ухтпегаз» лагерена 5 елга ябыла (Алма-Ата), 1936 ның декабрендә Казан төрмәсенә күчерелә (к. *«Троцкийчыларның контрреволюцион-террористик оешмасы»* эше); атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Рабочее законодательство Третьей Государственной Думы. К., 1925; Казанские рабочие перед Октябрьской революцией. К., 1928; Василий Константинович Магницкий и его труды 1839–1901 гг. Чебоксары, 1929; Национальное движение в Волжско-Камском крае: Национальные съезды в период Временного правительства. К., 1929; Казанский государственный университет им. В.И.Ульянова-Ленина за 125 лет. 1804/05–1929/30: В 2 т. К., 1930; Казанское студенчество в народнический период. К., 1930.

*Әд.:* Л и т в и н А.А. Корбут Михаил Ксаверьевич (1899–1937) // Возвращённые имена. К., 1990; К л ю ч е в с к а я Е.П. Забытая графическая сюита // Татарстан. 1996. № 9.

*Е.С.Маслова.*


**КОРЕПА́НОВ** Кронид Иванович (18.10.1947, Удмуртия АССРның Шаркан р-ны Иске Быги а.), тарихчы, археолог, тарих фән. д-ры (2000), проф. (2004). Удмурт ун-тын тәмамлый (1974). Липецк (1978–82), Камчатка (1982–86), Алабуга (1986–94) пед. ин-тларында эшли. ТР Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-ты директоры урынбасары. 1998–2000 дә Әлмәт муниципаль ун-ты проректоры. 2000 нән Әлмәт нефть ин-ты гуманитар белем каф. профессоры. Хезмәтләре Идел буе һәм Кама буе халыкларының милли-мәдәни мирасы мәсьәләләренә карый. Идел-Урал төбәге халыклары сынлы сәнгатенең борынгы тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Х е з м.: Сквозь века. Ижевск, 1997; История изобразительного искусства Урало-Поволжского региона с древнейших времен до конца 13 в. Уфа, 2002; Образ человека в древнем искусстве. К., 2003.

**КОРЖЕНЕ́ВСКИЙ** Арнольд Геннадьевич (30.1.1939, БАССРның Иглин р-ны Таутөмән а.), геолог-геофизик, геол.-минерал. фән.



А.Г. Корбанов.




М.К. Корбут.

д-ры (1989), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1989). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1968). «Татнефтегеофизика» АҖдә эшли: 1959 елдан Лениногорск промысел-геофизик конторасында өлкән инженер, 1968 дән Бөгелмә промысел-геофизик конторасында баш инженер, 1976 дан промысел геофизикасы бүлеге башлыгы, 1985–2007 елларда АҖдә баш инженер. Скважиналарда түбән инерцияле электротермометрларны, гидродинамик тикшерүләр аппаратурасын һәм технологиясен, катламнарга импульслы тәэсир итү технологияләрен эшләүдә, горизонталь скважиналарны тикшерүнең яңа ысулын булдыруда һәм куллануда катнаша; яңа кабель конструкцияләрен фәнни нигезли. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Информационно-геофизическое обеспечение горизонтальных скважин // Разработка нефтяных месторождений горизонтальными скважинами. К., 1998.

*Әд.:* Геофизики России: Информ.-биогр. сб. М., 2001.

**КОРЖИ́НСКИЙ** Сергей Иванович (26.8.1861, Әстерхан ш. — 18.11.1900, С.-Петербург), ботаник-флорист, систематик, ботаник-географ, Петербург ФА академигы (1893); Казан геоботаника фәнни мәктәбен оештыручыларның берсе. 1885 елда Казан ун-тының физика-матем. ф-тының табигыятьчеләр бүлеген тәмамлый, шунда ук ботаника кафедрасында эшли. Систематика һәм ботаник геогр. буенча курслар укый. 1888 дә Казан ун-тында ботаника д-ры дәрәҗәсе алу өчен диссертация яклый. 1888–92 дә Томск ун-тының ботаника каф. профессоры. 1893 тә С.-Петербургка күчә: Император ботаника бакчасының баш ботанигы (1893–99), бер үк вакытта (1898 дән) Император ФАнең Ботаника музее директоры һәм Петербург хатын-кызлар (Бестужевлар) югары курслары профессоры. П.Н.*Крылов* һәм А.Я.*Гордягинның* дусты һәм хезмәттәше. Хезмәтләре ботаник географиягә, систематикага, флористикага карый. К. беренчеләрдән булып Урта Азиянең үсемлекләр дөньясына ботаник-геогр. тасвирлама бирә. Россия терр-ясен гомумботаник-географик районлаштыруны тәкъдим итә. Урманның далага күчү теориясе авторы. Казан губернасы туфракларын тасвирлый, бирәдә кара, карасыман, соры, аксыл соры, аксыл туфракларны билгели. Бу туфракларның урманның агач үсемлекләре йогынтысында кара туфраклар деградациясенең эзлекле стадияләре булуын әйтә.





М.П. К о р и н ф с к и й. 1. Университет шәһәрчегенең генераль планы. Казан. 1830 еллар; 2. Астрономия обсерваториясе. Университет шәһәрчеге. 1833–38; 3. Грузия Мәрьям Ана чиркәве. Раифа Богородица монастыре. 1835.

Үсемлекләр систематикасында геоморфологик алымга нигез салучыларның берсе. Үсемлекләр систематикасына «раса» төшенчәсен кертә (1892), төрләр систематикасын төзергә тырыша. Генетик методлар барлыкка килгәнче үк бик күп алдан төрле геогр. чыгышлардагы расалар арасында ыруглык дәрәҗәсен билгеләү өчен гибридлаштыру алымын тәкъдим итә. Нидерланд галиме Хуго Де Фриздан бәйсез рәвештә, эволюциядә дарвинизмга капма-каршы булган яңа мутация теориясен («гетерогенезис теориясе») тудыра (1899). Беренчеләрдән булып үсемлекләрдән ясалма рәвештә полиплоидияләр алу мөмкинлеген күрсәтә. К. исеме б-н үсемлекләрнең бер ыругы һәм 45 төре, ландшафтлы табигать тыюлыгы (к. *Коржинский сөзәклекләре*) аталган.

Х е з м.: Северная граница чернозёмно-степной области восточной полосы Европейской России в ботанико-географическом и почвенном отношении // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1888. Т. 18, вып. 5; 1889. Т. 19, вып. 6; 1891. Т. 22, вып. 6; Флора Востока Европейской России в её систематическом и географическом соотношениях // Изв. Томского ун-та. 1893. Кн. 5.

*Әд.:* К р ы л о в Т.Н. Памяти С.И.Коржинского. Томск, 1901; Выдающиеся отечественные ботаники. М., 1957; Г е х т м а н Г.Н. Выдающиеся географы и путешественники. Тб., 1962; М а р к о в М.В. Ботаника в Казанском университете. К., 1980.

*А.П.Ситников.*

**КОРЖИ́НСКИЙ СӨЗӘКЛЕКЛӘРЕ́**, табигать тыюлыгы. Яңа Чишмә р-ны терр-ясендә, Гәр авылыннан көнчыгыштарак. 1991 елда оештырыла (1972 дән — 2 *га* мәйданда табигать истәлеге). Мәйданы 150 *га*. Устье елгасының известьле токымнарыннан торучы уңъяк текә сөзәклекне били. Көнбатыш Кама аръягында ташлы даланың классик участогы. Үсемлекләрнең ТРның Кызыл китабына кертелгән сирәк төрләре үсә: яктылык яратучан клаусия, башаклы каеккузак, Гмелин тәңкәяфрагы, Исет ялмачасы, Альп кашкарые, әрмән әреме һ.б. 19 йөз ахырында К.с.ен беренче тапкыр тикшерүче С.И.*Коржинский* генофондны саклауда бу объектның фәнни әһәмиятен күрсәтә.

*Әд.:* Памятники природы Татарии. К., 1977.




Коржинский сөзәклекләре.

**КОРИА́НДР** игүле (Coriandrum sativum), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Чыгышы — Урта диңгез буе; Көньяк Украинада, Төньяк Кавказда, Урта Азиядә игелә. К. чагыштырмача җылы, дым (аеруча ботакланудан чәчәк атуга кадәр) һәм яктылык яратучы культура. Сабагы биек (70 *см* га кадәр), тармакланган. Чәчәк оешмасы — вак кына ак һәм алсу чәчәкләрдән торган катлаулы чатыр. Җимеше шарсыман (аркылыга 2–5 *мм*), коңгырт яисә сары төстә. Июль–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Чәчү алдыннан орлыкларны 2–3 көн 25–30 °С темп-рада җылыталар. Орлыклар 1–1,5 *см* тирәнлектә күмелә. Яңа өлгергән һәм киптерелгән яшел үләнен (кинза) һәм орлыкларын (кориандр) тәмләткеч итеп файдаланалар. Орлыклары азык сәнәгатендә икмәк пешергәндә, кондитер әйберләрне, маринад, соус, казылык, ликёр, шәраб, сыраны хуш исләндерү өчен, кулинариядә — ит һәм балыктан томалап пешерелгән ризыклар әзерләгәндә, парфюмерия һәм сабын кайнату сәнәгатендә К. орлыгыннан алынган эфир мае кулланыла. Баллы үсемлек. Яфракларында В группасы, С витаминнары, каротин, рутин бар. Җимеше медицинада үт кудыру, авыртуны басу, тынычландыру өчен, йөткерүгә, көзән җыеруга каршы чара, ш.у. антисептик булларак файдаланыла. Корткычлары — К. орлыгын ашаучы; авырулары — бактериоз һәм рамуляриоз. ТРда К. бакчаларда үстерелә; торак йорт яннарында, юл буйларында һ.б. урыннарда чүп үлән буларак очрый.

**КОРИ́НФСКИЙ** (чын фамилиясе Варенцов) Михаил Петрович (1788, Арзамас ш. — 1851, Казан), архитектор, рус классицизмы вәкиле. 1809 елда — Арзамастагы А.В.Ступин мәктәбен, 1811 дә СА тәмамлый. А.Н.Воронихин шәкерте. 1812 елдан — Арзамаста, 1823 тән Сембердә эшли. 1823 тә Сембердә 1812 елгы Ватан сугышы истәлегенә төзелгән собор проекты өчен Архит-ра академиясенә әгъза итеп сайлана. 1832 елдан Казанда, архитектор, 1837 дән — Казан ун-ты архитекторы. К. иҗатына классицизм архит-расының ландшафт б-н органик бәйләнеше, күләмле композицияләрнең тәңгәллеге һәм төгәллеге, силуэтны нечкә тоемлау хас. Аның Казандагы төп эшчәнлеге *университет шәһәрчеген* проектлаштыру һәм төзү б-н бәйле (1832–38). Комплексның П.Г.Пятницкий төзегән ген. планын нигез итеп алып, архитектор аңа кайбер үзгәрешләр кертә. Үзәккә ул анатомия театрын урнаштыра, обсерваторияне буш урынга (кишәрлекнең көнбатыш өлешенә) күчерә, элек ун-тның төп корпусына тәңгәл рәвештә проектлаштырылган ике торак йорт урынына китапханә һәм химик лаб. корпусы кора. К. бернечә бинадан, ике ярымтүгәрәк хезмәткәрләр корпусы, җәмәгать бакчаларыннан торган киң, симметрик композицияле ансамбль төзи. Барлык төзелешләр классицизм стилендә башкарыла. К. проектлары



«М.П. Коринфский портреты».
Рәссам З.И. Иванов. 1846. ТР Милли музее.

буенча Казанның үзәк өлешендә байтак торак йортлар төзелә. Аларның берсе — Е.С.Галкинның провинциаль классицизм стилендәге ике катлы торак йорты (1837). Урам фасады композициясенең симметриялелеге аның аеруча портиклар һәм парлы пилястралар б-н аерылып торган урта өлешендә күренә. Акчурин утары да соңгы классицизм стилендә төзелә (1840). Йортның үзенчәлекле фасадын сандриклар һәм күпертмә декоратив фигуралар, ш.у. күпертмә бизәкле фризлар ачып тора (волюталар, грифон сурәтләре һ.б.). 1835–42 елларда *Раифа Богородица пустыненда* К. тарафыннан ампирның соңгы стилендә әвернә гөмбәзле, бер апсидалы Грузия Мәрьям Ана чиркәве корыла. 1841 дә Отарка авылында (хәзерге Мамадыш р-ны) К. Покров чиркәвен яңадан торгыза. 1845 тә Казан Кремленең Губернатор сарае интерьерын бизи. 1843 тә аңа *Дворяннар җыены* бинасын проектлау эше тапшырыла. К. төзегән проект И.П.Ефимов тарафыннан үзгәртелүгә карамастан, бинаның үзеген тәшкил иткән ике як тәрәзәле тантаналар залы саклanып кала (корылманың фасадлары гына үзгәреш кичерә). Ул ш.у. Арзамас, Түбән Новгород, Кострома һ.б. шәһәрләрдәге биналарны проектлау б-н дә шөгыльләнә.

*Әд.:* Е г е р е в В.В. Архитектор М.П.Коринфский. К., 1961; Ф е х н е р М. Великие Болгары, Казань, Свияжск. К., 1978.

*Л.М.Мортазина.*

**КОРКАЧЫ́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 770 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, бау ишү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет (1831 дә төзелә), мәктәп, су тегермәне, 3 вак-тәяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 655,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 125 ир-ат; 1859 да — 559, 1897 дә — 675, 1908 дә — 813, 1920 дә — 808, 1926 да — 860, 1938 дә — 970, 1949 да — 796, 1958 дә — 617, 1970 тә — 628, 1989 да — 682, 2002 дә — 709 кеше.

**КОРКАЧЫ́К** т и м е р ю л с т а н ц и я с е посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан — Екатеринбург тимер юлы буенда. 2010 елда 1850 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 83%) яши. Төзү пр-тиеләре, он тарту з-ды, казылык ясау цехы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан




**Корлау.** 1. Ат дирбиясе бизәкләре. Алтын, төсле пыяла. Кою, корлау (Кубрат хан хәзинәсе). 7 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 2. Муенса һәм пута бизәкләре. Алтын, гранат, аметист. Чүкү, корлау (Кубрат хан хәзинәсе). 7 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 3. Зәркән эшләнмәләр үрнәкләре: пута каптырмалары һәм аел (үзәктә). Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. Яссы һәм күпертмә җепкыр, корлау. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее.

Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 48, 1949 да — 56, 1958 дә — 513, 1970 тә — 700, 1989 да — 1810, 2002 дә — 1919 кеше.

**КОРЛА́У**, пластина яки алтын, көмеш, фил сөяге, перламутр һ.б. каты (еш кына зиннәтле) материалларны бизәлүче предмет өслегенә уеп урнаштырып, декоратив композицияләр ясау ысулы; гамәли-бизәлеш сәнгатенең бер төре. Көмеш һәм алтын чыбыкларны нәфис геом., үсемлек орнаменты һәм гарәп алфавитындагы үрмәле язулар рәвешендә К.ны болгар осталары 10–12 йөзләрдә асылмалы бронза йозаклар, 13–14 йөзләрдә айбалталар (Түбән Идел буе шәһәрләрендә үткәрелгән археол. казу эшләре вакытында табыла) бизәгәндә кулланганнар; Алтын Урда чоры эшләнмәләрендә К. бронза шкатулкалар бизәгәндә кулланылган (үсемлек орнаменты рәвешендәге зиннәтле бизәк). 18–20 йөзләрдә элек киң кулланылышта булган кыйммәтле металлар б-н К. кыйммәтле, ярымкыйммәтле һәм ясалма ташлар, кырлы пыяла куеп К.га кайтып кала. Асылташлар алтын һәм көмеш бизәнү әйберләренең бер өлешен алып торганнар һәм талисман ролен үтәгәннәр. К.ның әлеге төре — «төсле таш корлау» — Евразиянең бронза һәм әүвәлге урта гасырлар чоры (сарматлар, һуннар, протоболгарлар) дала күчмә кабиләләре полихром стилендә карый. Асылташлар б-н корланган иң әүвәлге үрнәкләр Татарстан терр-ясендә үткәрелгән археол. казу эшләре вакытында табылган Пьянобор культурасына нисбәтле металл бизәмәләрдә (б.э.к. 2 йөз — б.э. 5 йөзе) очрый. 7 йөз ахырыннан башлап, асылташлар б-н К. элгәреге болгарлар (Олы Тархан, Танкеевка һ.б. каберлекләрдән табылган, калканчыгына ахак һәм төсле пыяла беркетелгән Салтау культурасына хас көмеш йөзек) һәм Алтын Урда чорына кадәрге Идел буе Болгарындагы зәркәнчелек эшендә киң кулланыла (асылташлар, кайвакыт уеплау алымында, төсле паста һәм пыяла б-н корланган алкалар, йөзекләр, мөһерле балдаклар). Алтын Урда чоры Болгарында һәм Җучи Олысының башка өлкәләрендә бизәнү әйберләренең кыйммәтле һәм ярымкыйммәтле ташлар (зәңгәр якут, кызыл якут, фирәзә, хризопраз, зөбәрҗәт, ахак, аметист, яшма, энҗе) б-н бай итеп корланган яңа төрләре барлыкка килә (өс-баш киемен бизәүче кадама, тегелмә бизәкләр, күп буынлы беләзекләр, бөти тартмачыклары, бил каптырмалары). Мономах бүрегендәге, Симферополь хәзинәсеннән хатын-кыз баш киемнәре очларындагы бизәкләр шундыйлардан. Гадәттә, үтә күренмәле ташлар түгәрәк, озынча, дүрткел формадагы махсус ояларга урнаштырыла, кайвакыт тар пластиналар — эләктергечләр б-н беркетелә, *бөртекләү*, җепкыр чыбыклар б-н каймалана. Асылташлар ялтыратыла һәм кырлары эшкәртелә. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы тупланмасындагы «*Казан таҗы*» һәм Коръән тартмасы капкачы Казан ханлыгының зәркәнчелек сәнгатендә асылташлар б-н К. алымының гүзәл үрнәге булып тора. Алар зәңгәр (фирәзә), миләүшә (альмандин), яшел (яшма, зөбәрҗәт), кызыл (гранат, топаз) һәм ак (энҗе) асылташлар б-н чиратлаштырып бизәлгәннәр. 18 йөз — 20 йөз башы татар бизәкләрендә асылташлар б-н К. орнаментлы декорга яраштырып кулланылган (җепкыр, бөртекләү, уеплау, чүкеп бизәк төшерү), ул төрле төстә булуы б-н аерылып тора. К. үрнәкләрендәге үтә күренмәле алтынсу топаз, шәмәхә аметист, күк төстәге фирәзә, тонык яшел яшма, ак катламлы зәңгәр аквамарин, кызыл сердолик, катламнарында ак, кызыл, кара төсләр булган буйлы ахак, ак якут, үтә күренмәле зәңгәр сапфир, терракота сыман яшел һәм ак тамырлы халцедон, ак энҗе, алтынсу-сары гәрәбә кебек ташлар төсләре буенча композиция ясап урнаштырылганнар. Бизәкләрдәге эре ташлар, гадәттә, ваграк, нигездә, төрле төсмерләрдәге: күк төстәге фирәзә, яшькелт-сары хризолитлар, кызыл гранат һәм якут, тау бәллүре һ.б. б-н каймаланганнар. Зөбәрҗәт, коралл, перламутр сирәк кулланылган. Күпләп җитештерелгән арзанлы бизәкләрдә төсле һәм кырлары эшкәртелгән пыялалар файдаланылган. Ташлар, гадәттә,

тирән ояларга урнаштырылганнар һәм еш кына юка кысалар б-н беркетелгәннәр. Асылташларны Түбән Новгород, Эрбет һәм Минзәлә ярминкәләрендә сатып алганнар. Татар зәргәрчеләре арасында ташлар һәм асылташларның кырын кырлаучы осталар да булган. Алар Казанда (Яңа татар бистәсе), Казан арты авылларында (Тенәкәй, Килдебәк, Байлар Сабасы, Мөндеш һ.б.) эшләгәннәр һәм татар бизәкләрендәге таш кырлау техникасының киң танылган «кабошон», «каре» (баскычлап кырлау), «роза», сирәк кенә «груша» һәм «маркиз» (өч яссылыкта кырланган бриллиант) төрләрен үзләштергәннәр. 18 йөз уртасыннан төсле фольга таралу сәбәпле, еш кына гади пыяланы да кырлый башлыйлар, фольганы пыяла куеласы шатон ояларга салып калдыралар. Асылташлар һәм пыяла кайвакыт төсле мастика, башлыча, силикат һ.б. катнашмаларны эретү юлы б-н алынган терракота төсендәге куе масса б-н алмаштырыла (к. *Глиптика*). Асылташлар, нигездә, җепкырлы бизәкләрдә кулланылган, чөнки алтын яки көмеш чыбыклар фонында күзгә бәрелеп торган. 19 йөз — 20 йөз башы бизәкләре композициясендә асылташлар үзәк яки форманың контуры буенча урнаштырыла, вак ташлар бизәк үзәгендәге төп асылташны каймалый. Фирәзә һәм ясалма ахак б-н К. Балык Бистәсе рус зәркән кәсепчелеге осталарының, гадәттә, Шәрекъ бизәге үрнәгендә стильләшкән (татар, Урта Азия һәм Кавказ типлары) бизәкләрендә киң таралган була (к. *Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе*). 20 йөзнең 2 нче яртысына кадәр асылташлар б-н К., татар *зәргәрчелек сәнгате* кебек үк, төшенкелек чоры кичерә. 1960 елларның 2 нче яртысыннан асылташлар б-н К. традицияләре проф. зәргәрчеләр иҗатында (С.Шәкүрова, В.Ковалевский, И.Фазылҗанов, И.Васильева һ.б.), башлыча, татар яки хәзерге заман модасы стилендәге бизәкләрдә үсешкә ирешә. Аларда шома металл пластиканы зиннәтле һәм ярымзиннәтле ташлар б-н К. уңышлы ярашып килә. Алтын һәм көмеш бизәнү әйберләре, гадәттә, гарнитурларга туплана (муенса, беләзек, алка, йөзек һ.б.), аларның декорына, асылташларның традицион җыелмасыннан башка, фианит, нефрит, лазурит һ.б. кертелә.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — 1990-е гг.). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КОРМАЧЁВ** Михаил Васильевич (10.1.1954, Лаеш р-ны Ташкирмән а.), гигиена белгече, сәламәтлек саклау эшен оештыручы, ТРның атказ. табибе (1998). 1977 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, ГИДУВның 1 нче терапия кафедрасында эшли. 1979 дан 2 нче Республика хастаханәсендә табиб-терапевт, 1982 дән Лаеш р-ны Столбище хастаханәсенең баш табибе. 1987 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсендә мед. экспертизасы буенча баш табиб урынбасары. 1996 дан 3 нче Республика клиник хастаханәсендә баш табиб. 2002 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсе баш табибе. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007).

**КОРМА́Ш** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 11 *км* төньяктарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 209 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, 2 су һәм 1 җил тегермәне, тимерчелек, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1015,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1927 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 46 ир-ат; 1859 да — 380, 1897 дә — 474, 1908 дә — 973, 1920 дә — 1007, 1926 да — 965, 1938 дә — 701, 1949 да — 610, 1958 дә — 473, 1970 тә — 379, 1979 да — 290, 1989 да — 255, 2002 дә — 255 кеше.

**КОРМА́Ш** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 57 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 557,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 295, 1913 тә — 212, 1920 дә — 223, 1926 да — 192, 1938 дә — 243, 1949 да — 215, 1958 дә — 185, 1970 тә — 181, 1979 да — 135, 1989 да — 95, 2002 дә — 72 кеше.

**КОРМА́ШЕВ** Гайнан Нури улы (Гайнан Кормаш) (27.2.1919, Тургай өлкәсе Актүбә ш., хәзерге Казакъстан Респ-касы — 25.8.1944, Берлин, Германия), Бөек Ватан сугышы чорында 1942–43 елларда сов. хәрби әсирләренең Польша терр-ясендәге яшерен антифашистлар төркеме җитәкчесе. Бәрәңге пед. техникумын (1936), Кызыл Армия кече командирлары мәктәбен (1940) тәмамлый. 1936–37 дә Бәрәңге р-ны Куян авылы мәктәбе укытучысы, 1937–39 да Актүбәдәге мәктәптә укытучы, директор. 1939 дан Кызыл Армиядә. Сов. фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, разведчиклар төркеме командиры. 1942 дә, «иң ышанычлы офицер» буларак, аерым төркем составында махсус бурыч



Г.Н. Кормашев.

б-н дошман тылына төшерелә. Немецларга әсирлеккә эләгә, Демблин кальгасында һәм Едлино шәһәрендә (Польша) хәрби әсирләр лагерьларында тотыла, анда немец командованиесе Сов. Союзына каршы сугыш хәрәкәтләрендә файдалану өчен Идел буе халыкларының әсирлеккә эләккән вәкилләреннән (татарлар, башкортлар, марилар, удмуртлар, мордвалар, чуашлар) иреклеләрнең *«Идел-Урал»* легионын төзи. Едлинодагы лагерьда легионерлар арасында агитация җәелдерү өчен немецлар тарафыннан 13 кешелек муз. капелла (мәдәни взвод) оештырыла. К. труппаның сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә. Төркем әгъзалары хәрби әсирләр лагерьларындагы чыгышларын антифашистик пропаганда алып бару, «Идел-Урал» г-тасының Берлиндагы редакциясендә әзерләнгән листовкаларны тарату өчен файдаланалар.

Яшерен төркем эшчәнлеге нәтиҗәсендә «Идел-Урал» легионының Витебск өлкәсенә (Белоруссия ССР) партизаннар хәрәкәтен бастырырга җибәрелгән беренче (825 нче) батальоны ук 1943 нең 23 февралендә тулысынча диярлек партизаннар ягына чыга. Шушы вакытта антифашистик төркем эшенә М.*Җәлил* дә кушыла. «Идел-Урал» легионының Франциягә җибәрелгән икенче (826 нчы) батальонына да Кормаш-Җәлил төркеме әгъзалары җәлеп ителә.

1943 нең июлендә төркем Едлинодагы лагерьда кораллы баш күтәрү һәм легионерларның массачыл рәвештә партизаннар ягына күчүен әзерли башлый. Партизаннар һәм сов. командованиесе б-н элемтә урнаштыру өчен фронт сызыгына элемтәчеләр җибәрелә. Баш күтәрү 14 августка билгеләнә, ләкин махсус әзерләнгән провокаторлар ярдәмендә немецлар татар яшерен оешмасы әзенә төшәләр һәм аның барлык әгъзалары (40 лап кеше) 1943 елның 10–11 августында кулга алына.

Германиянең икенче империя суды «Кормашев һәм тагын 10 кеше» эше буенча көрәшчеләрне аеруча куркыныч дәүләт җинаятьчеләре сыйфатында гильотина аша җәзалап үтерүгә хөкем итә. Антифашистик төркемнең 11 әгъзасы «Германия рейхының хәрби куәтен какшату»да гаепләнә. Төркем җитәкчесе буларак, К. 1944 нең 25 августында Плетцензее (Берлин) төрмәсендә беренче булып җәзалап үтерелә. 1990 ның 5 маенда СССР Президенты М.С.Горбачёв Указы б-н антифашистик төркем әгъзалары үлгәннән соң 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнәләр. Куян авылы мәктәбе диварына К.ка мемориаль такта куела, Актүбә шәһәрендә бер урамга К. исеме бирелә.

*Әд.:* Мостафин Р.Ә. Өзелгән җыр эзеннән. К., 2011; Ахтамзян А.А. О «Курмашеве и десяти других», казненных в Берлине за «подрыв военной мощи» Германского рейха // Татарские новости. 2002. № 1.

*М.В.Черепанов, М.З.Хәбибуллин.*

**КОРМАШИ́** (псевд., чын исеме-фамилиясе Әхмәд Мөхәммәдзариф улы Уразаев) (якынча 1855, хәзерге Курган өлкәсе Звериноголовск р-ны Звериноголовский а. — 1883), шагыйрь. Мулла гаиләсендә туа. Татар һәм казакъ телләрендә иҗат итә. Псевдоним итеп Минзәлә өязендәге бабасы туган һәм гомер иткән Кормаш авылы исемен ала. Петропавловск шәһәрендәге (хәзерге Казакъстан Респ-касы) «Кышкар» мәдрәсәсендә укый. 1880 еллар башында шунда ук мөгаллимлек итә. Шигырьләрен мәдрәсәдә укыган елларда яза башлый. Мәхәббәт турында ике романтик поэма-дастан авторы. «Кыйссаи бүз егет» (1874) поэмасы татар шагыйре Баһавинең шул исемдәге поэмасына нигезләнеп языла. Әсәрдә шигъри юллар прозаик юллар б-н аралашып бара. Поэмада әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә, гаделлеккә, әйткән сүзеңә тугры калу, тапкырлыкка дан җырлана. «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1876, нәшер ителә 1882) — киң таралган шәрекъ сюжетына язылган (к. «*Таһир белән Зөһрә*») төрек вариантының ирекле тәрҗемәсе. Ике поэмасы да зур популярлык казана һәм 1917 гә кадәр берничә тапкыр басыла. Кайбер мәгълүматларга караганда, К.ның бүтән әсәрләре дә булган, ләкин алар сакланмаган.

*Әд.:* Вәлиди Ж. «Бүз егет» хакында бер мөляхәзә // Безнең юл. 1923. № 6–7; Рәхим Г. «Бүз егет» белән «Таһир-Зөһрә»нең язучысы кем булган? // Безнең юл. 1928. № 5; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том.; Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX века. К., 1975.

*А.М.Ахунов.*

**КОРМЫ́Ш** авылы, Нурлат шәһәре карамагында, аннан 2 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2002 елда 505 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1921 дә нигез салына. Беренче исеме — Кормаш. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. 2001 нең 27 июленнән Нурлат шәһәре составында. Халык саны: 1926 да — 83, 1938 дә — 152, 1958 дә — 117, 1970 тә — 279, 1979 да — 367, 1989 да — 449 кеше.

**КОРНЕ́ЕВ** Емельян Михайлович (7.11.1780, Полтава губ. Хородский өязе — 1839, Мәскәү, башка мәгълүматлар буенча, Варшава), график-сурәтче, гравёр, театр рәссамы. Россия САдә укый (1788–1800). 1802 елдан, «күренешләрне, төрле халыкларның кием-салымнарын тасвирлау» өчен, император Александр I тарафыннан Россиянең Азия һәм Европа өлешен хәрби-стратегик яктан тикшерү максатында оештырылган экспедиция составындагы Г.М.Спренгпортен җитәкләгән төркемнең рәссамы булып тора. 1805–06 елларда Италиядә яши. 1807 дә арх. А.Н.Воронихин юлламасы буенча Петербургта «Казан Мәрьям Ана чиркәвен төзү» комиссиясенә хезмәткә кабул ителә, әлеге собор өчен иконалар яза. Бер үк вакытта рәссамнар төркеме б-н хезмәттәшлек итеп, А.С.Строганов коллекциясендәге әсәрләрдән алынган гравюралар альбомы чыгаруда катнаша. 1810–12 елларда Мюнхенда яшәли, монда Рус сарае каршындагы Бавария илчесе К.Рехберг чакыруы буенча 1812 дә Парижда басылган 2 томлы «Les peuples de la Russia» («Россия халыклары») альбомын нәшер итүдә катнаша. 1816–18 дә Тау һәм тоз эшләре департаментында медальләр сурәтен ясаучы булып эшли. 1818–22 дә М.Н.Васильев җитәкчелегендәге экспедиция составында дөнья тирәли сәяхәт кыла, шул чакта теркәлгән геогр. тикшеренүләр чагылдырылган 170 кә якын күренешне ясый. 1826 да Император театрлары конторасына баш бутафор (баш рәссамга тиң) итеп билгеләнә. 1828 дән Мәскәүдә Дәүләт күзәтчелеге ведомствосына хезмәткә керә (мөһим эшләр башкаручы чиновник). Гомеренең соңгы еллары турында мәгълүматлар юк.

К. — 19 йөзнең 1 нче яртысында сурәтле графика өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Аның сәнгать мирасы фондының күпчелек өлешен Россия, Урта диңгез буйлап һәм дөнья тирәли сәяхәт итү вакытында эшләгән рәсемнәре алып тора. 1803 тә К. Казан һәм Саратов губерналарында була, «Көнбатыш тарафтан Казан күренеше» (акварель, ак буяу, карандаш, тушь, каләм, 1803), «Петербургтан 1500 чакрымдагы Казансуның Иделгә койган урыны күренеше» (акварель, ак буяу, тушь, каләм, 1810–12) һ.б.ны иҗат итә. К.Рехберг коллекциясе исемлеге буенча мәгълүм эшләре: «Казан губернасындагы Зөя каласының Идел буендагы күренеше», «Казанда мәчет күренеше», «Болгар хәрабәләре». К. рәсемнәре буенча эшләнгән гравюралар «Казан татарларында ат чабышы» (офорт, акватинта, төсле басма; К.-Х.Гесс уеплавында, 1812), «Татар мулласы» һәм «Казан татар хатын-кызы» (очерк өчен гравюра, акварель; Е.Скотников уеплавында, 1808–09, «Корнеевның костюмнар тупланмасы» альбомыннан). К.ның сәнгать мирасы рус пейзаж жанры мәктәбе үсешендә бер баскыч булып тора. Фәнни максатларда иҗат ителгән әсәрләрдәге мотивларның, өс киемнәренең, аксессуарларның топографик төгәллеге табигый шартларда туган хисләр, табигать һәм мохитнең дөрес итеп тасвирлануы б-н кушылып бара. Алардагы классик мәгърифәтчелек стиле романтизмга хас сыйфатлар б-н бергә үрелә. Казан төбәге иконография сәнгатендә К.ның әсәрләре сюжет һәм темаларының төрлелеге, көнкүреш вакыйгаларының күплеге, төсләренең ачыклыгы б-н аерым урын алып тора. Иҗатының күләме буенча алар рәссамның 19 йөз башында Казан төбәгенә багышланган иң күләмле рәсемнәр сериясен тәшкил итә. К.ның әсәрләре Россия Милли китапханәсендә, А.С.Пушкин исем. Дәүләт музеенда, Дәүләт Тарих музеенда, Рус музеенда саклана.

*Әд.:* Гончарова Н.Н. Е.М.Корнеев: Из истории русской графики начала XIX века. М., 1987.

*Е.П.Ключевская.*

**КОРНЕ́ЕВ** Михаил Никифорович (1.10.1906, хәзерге Тула өлкәсенең Бобрики ш. — 12.8.1976), инженер-механик, авиация полковнигы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949). Мәскәү политехник ин-тын тәмамлый (1930). 1931–37 елларда Мәскәү авиация з-дында цех, техник контроль бүлеге башлыгы. 1937–40 та 18 нче Воронеж авиация з-дында, 1940–49 да Казан авиация з-дында баш инженер. 1950 дән Мәскәүдә. Дәүләт бүләге яңа авиация техникасын — Ту-4 самолётын җитештерүне үзләштергәне һәм аны камилләштергәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Д.С.Фәхретдинов.*

Е.М.Корнеев. 1. «Көнбатыш тарафтан Казан күренеше». Акварель, ак буяу, карандаш, тушь, каләм. 1803. Дәүләт тарих музее; 2. «Себер татары». Офорт, акватинта. 1812; 3. «Казан татар хатын-кызы». Офорт, акватинта. 1812.








**КОРНИ́ЛОВ** Анатолий Васильевич (29.4.1955, Питрәч р-ны Арышхазда а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1978), шунда ук эшли. 1989 елдан ЦНИИгеолнерудта сынау үзәге җитәкчесе урынбасары. ТРдагы минерал төзелеш чималының технол. үзенчәлекләрен өйрәнә һәм аның нигезендә продукциянең төрле төрләрен эшли. Уйлап табуга 20 ләп авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге руда булмаган чималны эшкәртүдә яңа технологияләр уйлап тапканы өчен бирелә.

**КОРНИ́ЛОВ** Владимир Юрьевич (20.11.1952, Сахалин өлкәсенең Южно-Сахалинск ш.), автоматлаштырылган контроль һәм идарә системалары галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1975 елда Казан югары хәрби инженерлар уч-щесен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, старт батареясының старт отделениесе башлыгы (1978–81), сынау-эшләтеп җибәрү эл. җиһазлары кафедрасының лаб. башлыгы (1981–83), ракеталар б-н идарә итү һәм аларның әзерлеген тикшерү системалары кафедралары башлыгы (1996 да), реактив системалар һәм танкка каршы ракета комплексларын конструкцияләү, проектлаштыру һәм эксплуатацияләү кафедралары (1996–2001) башлыгы, уч-ще башлыгының укыту һәм фәнни эшләр буенча урынбасары (2001–2006). 2006 дан Казан энергетика ун-тының беренче проректоры. Хезмәтләре ракета һәм артиллерия гаскәрләрен кораллландыру һәм аларның хәрби техникасы өлкәсенә карый. К. ракеталарның идарә системаларына автоматлаштырылган контрольнең дөреслеге күрсәткечләрен фаразлау алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теоретико-экспериментальные основы анализа автоматизированных систем контроля и управления по ограниченной исходной информации. К., 2000.

**КОРНИ́ЛОВ** Пётр Евгеньевич (3.7.1896, Сембер ш. — 10.10.1981, Ленинград), сәнгать белгече, музей эшлеклесе, коллекционер, библиофил, сәнгать фән. канд. (1939), проф. (1964). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1943). Казандагы 1 нче реаль уч-щене тәмамлый (1915). Мәскәү җир төзү ин-тында укый (1915–17), шуннан Кызыл Армия сафларына чакырыла. Демобилизациядән соң 1921–30 елларда (бүленеп, 1922–25 тә Ленинград ун-ты иҗтимагый фәннәр ф-тының археол. һәм сәнгать тарихы бүлегендә укый) ТАССР Үзәк музеенда сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре, китапханәче, гыйльми секретарь һәм бер үк вакытта ТАССР Халык мәгариф комис-тының музей бүлегендә гыйльми секретарь. 1927, 1928, 1930 да Шәрекъ архит-расы һәм сәнгате ядкәрләрен өйрәнү өчен Урта Азиягә сәфәр кыла. 1930–32 елларда Бохарада музей төзелеше б-н шөгыльләнә, бер үк вакытта Бохара пед. ин-тында укыта. 1932 дән Ленинградта яши. Рус музеенда графика бүлеге мөдире, бер үк вакытта 1936 дан СССР ХКС каршындагы Сәнгать эшләре ком-тының Дәүләт сатып алу экспертлык комиссиясе әгъзасы була (1948 дә бетерелгәнчегә кадәр). Ленинград блокадасы вакытында (1941–44) рәссамнар остаханәләрендәге һәм шәхси тупланмалардагы сәнгать әсәрләрен Рус музеена тапшырып,



П.Е. Корнилов.

аларны саклап калуга булышлык итә. 1942–48 дә «Искусство» нәшриятының Ленинград бүлегендә өлкән мөхәррир. 1950–60 да СССР САнең фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары. И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тында, В.И.Мухина исем. Ленинград югары нәфис сәнәгать уч-щесендә укыта.

К.ның күптөрле һәм гаять нәтиҗәле эшчәнлеге 1920 елларда Татарстандагы сәнгать белеменә һәм музей эшенә ныклы нигез сала. ТАССР Үзәк музееның фәнни хезмәткәре буларак, ул музей тарихында беренче тапкыр борынгы рус сәнгате бүлеген оештыра. Моның өчен хакимият тарафыннан Казан чиркәүләре һәм соборлары ябылган вакытта музейга тапшырылган күпсанлы сәнгать әсәрләрен (иконалар, чигелгән әйберләр, вак пластика) барлап-ачыклап чыга. Казанда күренекле Мәскәү һәм Петербург рәссамнарының (П.А.Шиллинговский, К.А.Богаевский, Д.И.Митрохин, В.Д.Замирайло, Е.С.Кругликова, В.А.Фаворский, К.Ф.Юон, И.Ф.Рерберг, И.Н.Павлов, А.П.Остроумова-Лебедева, Г.К.Лукомский, Г.С.Верейский, С.И.Лобанов) әсәрләреннән күргәзмәләр оештыра; әлеге күргәзмәләргә каталоглар төзи, аларда катнашырга Мәскәү һәм Ленинградтагы әйдәп баручы сәнгать белгечләрен чакыра.

1920 елларда К. Петроград библиофиллары җәмгыятенең гамәлгә куючысы-әгъзасы һәм Ленинград экслибристлар җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы булып тора, аның утырышларында Казан китап ядкәрләренә багышланган докладлар б-н даими чыгышлар ясый. Окт. рев-циясеннән соңгы беренче унъеллыкта Казанда басылган сәнгать әсәрләрен тикшерә, «10 ел эчендә Казанның сәнгать басмалары — 1917–27» (Казан, 1927), графика остаханәсе әгъзалары арасында экслибриска карата кызыксыну уята, экслибрис күргәзмәләрен оештыра һәм аларның җыентыкларын бастыра. К. Казан график-рәссамнарның *«Всадник»* берләшмәсенең беренче историографы була, әйдәп баручы осталарның — Н.С.*Шикалов*, М.А.Андриевская, И.Н.Плещинский, К.К.*Чеботарёвның* күргәзмәләрен оештыра. Провинцияләрнең сәнгать культурасын, халык арасында аз билгеле һәм онытылган осталарның иҗатын өйрәнүгә лаеклы өлеш кертә, бу Идел буе рәссамнарының сүзлеген төзү максатында киң планда уйланылган, гомере буе алып барылган күпьеллык хезмәтенең бер өлеше була. Аның рәссамнар А.Н.*Ракович*, В.Г.Худяков, Р.А.*Ступин*, М.П.*Коринфский*, Д.И.Архангельский, А.И.Трапицынның Казан чоры иҗатына багышланган очерклары хәзергә көнгә кадәр әһәмиятләрен югалтмый. К. борынгы истәлекләрне саклау һәм өйрәнү б-н шөгыльләнә, Казанда узган 1 нче Урта Идел буе музей конференциясендә катнаша, музей төзелешенә өлеш кертә. Казандагы һәм Тәтештәге иконография сәнгатен, болгар ядкәрләре торышын өйрәнә, беренче булып Казандагы зиратларның архит-ра-сәнгати халәтен, 18 йөз ядкәре — «Тверь» галерасын һ.б.ны тикшерә. Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре, Тәтеш музейларындагы коллекцияләрнең торышын тасвирлый. 1927 дә И.И.Шишкинның 100 еллык юбилеен үткәрү буенча Казанда рәссамның мирасын өйрәнү максатында планлы эшләр башкару үзәген һәм Алабугада аның мемореаль музеен төзүне оештыру ком-тын җитәкли. К. республикада редакцияләү-нәширлек эшен үстерүгә зур өлеш кертә: күргәзмәләрнең музей каталогларын бастыра, *«Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете»* ж-лының библиография бүлеген алып бара. К. — танылган сов. коллекционерларының берсе, 18–19 йөзләр рус рәссамнарының графика һәм нәкышь әсәрләре коллекциясен туплый, берничә тапкыр үз тупланмасындагы әсәрләрне Казан музейларына һәм китапханәләренә бүләк итә.

1920 елларда К.ның гомумроссия кысаларында өлкәнең сәнгати мирасы б-н фәнни кызыксынуы аеруча көчәя, хәзерге заман сәнгатен һәм нәширлек эшен үстерүгә ярдәм итә.

Х е з м.: Охрана памятников ТССР (1917–1927). К., 1928; Казанский плакат. К., 1929; Изучение искусства деревни Татарстана. К., 1930 (автордаш); И.И.Шишкин — мастер офорта. К., 1945; Арзамасская школа живописи. Л., 1949.

*Әд.:* Краткий список печатных работ П.Е.Корнилова / Сост. Н.Е.Яковлева. К., 1946; К л ю ч е в с к а я Е.П. «Знать прошлое, дабы строить настоящее...» // Татарстан. 1996. № 12; ш у л у к. Пётр Евгеньевич Корнилов — знаток и коллекционер экслибриса // Краеведческие среды: Материалы заседаний 2003 г. К., 2004. Вып. 4; К а р г а л о в а Т.А. П.Е.Корнилов как заведующий библиотекой Центрального музея Татреспублики // Дьяконовские чтения: Материалы 2001 г. К., 2001.

*Е.П.Ключевская.*

**КОРНИ́ШИН** Михаил Степанович (21.11.1920, Чуаш АССРның Порецк р-ны Турдаково а. — 28.4.1991, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1963), проф. (1970), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1981, 1991). 1942 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 543 нче оборона з-дында (Казан) эшли. 1951 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында; сүрүләрнең нәсызыкча механикасы лаб-ясе мөдире (1965–76), сүрүләр теориясе бүлеге мөдире (1976–87), баш фәнни хезмәткәр (1988 дән). Хезмәтләре сүрүләрнең нәсызыкча теориясе мәсьәләләрен санлы чишү алымнарына карый. К. мәсьәләләрне күчешләрдә вариатив алымнар б-н чишкәндә җыелучанлыкны тизләтү ысулын, бериш булмаган кисәкле сүрүләрне һәм планда катлаулы формадагы сүрүләрне исәпләү өчен эзлә-

нелә торган функцияләрнең апроксимацияләрен төзү юлларын тәкъдим итә; сүрүләр һәм пластиналарны исәпләү өчен югары төгәллекле соңгы аермалар алымын куллана. К. җитәкчелегендә сүрүләр механикасы мәсьәләләрендәге нәсызыкча тигезләмәләрнең зур системаларын итерацион чишү юллары үстерелә; тоташ коррозия шартларында йөкләнеш астындагы пластиналар һәм сүрүләрнең ныклыгы һәм тотрыклылыгына караган нәсызыкча мәсьәләләр куела һәм чишелә; пластиналар һәм сүрүләрне авырлыгы һәм катылыгы буенча оптимальләштерүгә карата геом. һәм физик куелыштагы ике үлчәнешле мәсьәләләрнең санлы чишелешләре табыла; хәрәкәт итүче йөкләнешләр тәэсирендәге пластиналар һәм куыш сүрүләрнең соңгы бөгелешләре тикшерелә; пластиналар һәм куыш сүрүләрнең кабаттан йөкләнешләр вакытындагы бөгелешләре һәм тотрыклылыгы мәсьәләләре геометрик һәм физик нәсызыкчалылыкны исәпкә алып чишелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нелинейные задачи теории пластин и пологих оболочек и методы их решения. М., 1964; Вычислительная геометрия в задачах механики оболочек. М., 1989 (автордаш); Введение в метод конечных элементов статики тонких оболочек. К., 1990 (автордаш).

**КОРНОУ́ХОВО** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ырга елгасы буенда. 2010 елда 599 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 41%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1565–67 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Никольский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, сандык ясау, терлек кылы һәм йон эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Никола чиркәве (1891 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1875 тә ачыла), су тегермәне, аракы з-ды, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 651 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән Солтан р-нында. 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово р-ны үзәге. 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 118 ир-ат; 1859 да — 370, 1897 дә — 530, 1908 дә — 561, 1920 дә — 845, 1926 да — 660, 1949 да — 1379, 1958 дә — 1190, 1970 тә — 1263, 1989 да — 727, 2002 дә — 631 кеше.

**КОРНОУ́ХОВО** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 12 *км* көнбатыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 145 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1594 елга кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү һәм мунчала ясау, чыпта сугу, тугым, чана табаны ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Казан Богородица чиркәве, земство мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1489 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 138 ир-ат; 1859 да — 533, 1897 дә — 1025, 1908 дә — 1306, 1920 дә — 1204, 1926 да — 1184, 1938 дә — 725, 1949 да — 385, 1958 дә — 297, 1970 тә — 233, 1979 да — 167, 1989 да — 91, 2002 дә — 147 кеше.

**КОРНОУ́ХОВО РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә Лаеш һәм Балык Бистәсе р-ннарының бер өлешеннән төзелгән *Солтан районы* буларак оештырыла. 1946 ның 5 апрелендә район үзәге Олы Солтан авылыннан Корноухово авылына күчерелә һәм район К.р. дип үзгәртелә. 1948 тә К.р.нда 15 авыл советы, 49 торак пункт исәпләнә. 1954 нең 19 ноябрендә район бетерелә, терр-ясе Лаеш һәм Балык Бистәсе р-ннарына бирелә.

**КО́РНУХ-ТРО́ЦКИЙ** Пётр Яковлевич (1803 — 2.7.1877, Казан), морфолог, үсемлекләр физиологы, систематик-флорист. Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1827, башка мәгълүматлар буенча 1828). Дворяннар нәселеннән. 1828 елда Дерпт (хәзерге Тарту) ун-тының профессорлар ин-тына кабул ителә, анда филос. д-ры дәрәҗәсе ала (1832). 1833–35 тә Көнбатыш Европада эшли, Урта Европа флорасын өйрәнә, Вена табигать тарихы музее гербариенда эшли. 1835 тә Россия ФАдә «Гомумән үсемлек турында» («О растении вообще») сынау лекциясе укый һәм Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан Киев ун-тына ботаника укытучысы итеп билгеләнә; үсемлекләр органологиясе һәм физиологиясе буенча курслар укый. 1836 да Казан ун-ты профессоры, ботаника каф. мөдире. К.-Т. ботаника кабинетының матди базасын ныгыту буенча чаралар күрә, өч зур гербарий сатып ала; алар буенча аерым каталоглар булдырыла. Казан ун-тының Кабан күле буендагы яңа ботаника бакчасына нигез сала. Казан губернасының флорасын өйрәнә һәм гербарий төзүне башлап җибәрә. 1858 елда хезмәттән китә (сәламәтлеге начараю сәбәпле). Әвернә чәчәкләләр семьялыгы антемис ыругыннан үсемлек төре (Anthemis Trozkiana) К.-Т. хөрмәтенә аталган.

Х е з м.: О семействе маковых растений. М., 1826; Рассуждение о семействе крестовидных растений. М., 1826; О растении вообще. СПб., 1835; Лекции по ботанике. К., 1840.

*Әд.:* Л и п ш и ц С.Ю. Русские ботаники. М., 1852. Т. 4. Марков М.В. Ботаника в Казанском университете за 175 лет. К., 1980.


**КОРОБКО́В** Александр Михайлович (18.7.1942, Горький өлкәсе Выкса ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1994), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). 1964 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1999 дан гетероген системалар химиясе һәм технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре гетероген процесслар химиясе һәм технологиясенә, физик химиягә һәм дисперслы системалар механикасына карый. К. порошоксыман материалларның янып китү һәм яну процессларында физик-химик һәм өслек күренешләренең ролен билгели. Яхшыртылган физик-химик һәм механик үзлекле материаллар алу өчен порошоксыман металлар, тозлар һәм оксидларны модификацияләү ысулларын тәкъдим итә. Нефть табуны интенсивлаштыру максаты б-н, нефть скважиналарын термогазохимик эшкәртү өчен пиротехник составлар нигезендә яңа буын термогазогенератор эшли. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**КОРОБКО́В** Фёдор Александрович (5.2.1969, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), техник фән. канд. (2004). 1994 елда Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң, «ВНИИУС» АҖдә эшли. Хезмәтләре нефть химиясенә һәм нефть эшкәртүгә карый. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләгәне һәм гамәлгә кертүе өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**КОРОБКО́ВА** Александра Николаевна (11.2.1905, Вятка губ. Уржум ш. — 20.10.1998, Мәскәү), график, полиграфчы, нәкышьче. Ф.Ш.*Таһировның* хатыны. 1927 елда Казан сәнгать-пед. техникумын (П.П.*Беньков*, В.К.*Тимофеев*, К.К.*Чеботарёв* шәкерте), 1931 дә — Мәскәү югары сәнгать-техник ин-тын (ВХУТЕИН; Д.С.Моор, Л.А.Бруни шәкерте) тәмамлый. Мәскәүдә, 1941–43 тә (эвакуациядә) Казан янындагы Васильево посёлогында яши. ТатЛЕФ (1923–27), «Молодой Октябрь» берләшмәсе әгъзасы (1927–31). 1920 елларда Казанда чыккан «Авыл яшьләре» («Сельская молодёжь»), «Азат хатын», «Безнең юл», «Крестьянская газета», «Чаян», «Кызыл армеец» г-та һәм ж-ллары, Мәскәүдәге «Эшче», «Игенчеләр», «Нәшрият» г-талары редакцияләре, СССР халыкларының Үзәк нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә. 1932 дән СССР Авыр сәнәгать халык комис-тының Мәскәү күрсәтмә әсбапларны техник пропагандалау нәшриятында, 1938–41 һәм 1943–45 тә «Трансжелдориздат»та — мөхәррир, 1946–60 та Полиграфия машиналары төзү фәнни-тикшеренү ин-тында титул һәм акцидент хәрефләр җыю лаб-ясе мөдире.

Рәссамның күпкырлы иҗади мирасы нәкышь эшләрен, бер-берсенә охшамаган графика төрләрен (плакат, станлы рәсем, газета һәм журнал иллюстрацияләре), полиграфия бизәлешен, хәреф-шрифт белеме буенча теоретик хезмәтләрне колачлый. Казанда уку елларында К. тарихи-сәнгати әһәмияткә ия натура рәсемнәре сериясен (техникум сту-





А.Н.Коробкова. 1. «Караучысыз үсмерләр». Төсле кәгазь, аппликация. 1926; 2. «Азат хатын» журналының тышлык эскизы. Кәгазь, гуашь. 1927. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

дентлары һәм укытучылары К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, Ф.П.Гаврилов, П.Т.Сперанский, Н.М.Сокольский, В.К.Сотонина һ.б.), график композицияләр — сатирик һәм шаржчы таланты б-н аерылып торган үзенчәлекле студентлар тормышы елъязмасын («АХРР ЛЕФтан женнәрне куа», «Имтиханнар бара», «Нәкышь дәресендә» һ.б.) иҗат итә.

1920 елларда К. татар совет полиграфия сәнгатен үстерүгә күп көч куя. Хезмәтләре арасында — «Азат хатын» (1927, №3,5,10), «Авыл яшьләре» (1925, №16), «Кечкенә иптәшләр» (1917, №10,11) ж-ллары тышлыгын бизәгән тарихи һәм заман темасына каләм б-н ясалган рәсемнәр һәм иллюстрацияләр. К.ның журнал графикасы композиция динамикасы, рәсемнең ачыклыгы һәм төгәллеге, детальләрнең оста тотып алынуы, өс киемнәре һәм аксессуарларның ышандыру көче, бу сәнгать төрендәге мөмкинлекләрнең киң файдаланылуы б-н аерылып тора. Ире Ф.Ш.Таһиров б-н автордаш буларак, А.Неверовның «Марья — большевик кыз» («Марья — большевичка», М., 1927), А.Кравченконың «Хәсән ничек кызылармияче булды» («Как Хасан стал красноармейцем», М., 1927), «Октябрь һәм яшь буын» («Октябрь и молодое поколение», М., 1927), «Көрәш еллары» («Годы борьбы», М., 1927), К.Залеевның «Урамнан коммунага» («С улицы в коммуну», М., 1928), Х.Фәйзуллинның «Октябрь балалары» («Дети Октября», М., 1928), М.Крыймовның «Комсомол җырлары» («Комсомольский песенник», М., 1928), М.Җәлилнең «Иптәшкә» («Товарищу», М., 1929) һ.б. язучылар китапларының тышлыкларын бизи. К., таланты рәссам буларак, аларга затлылык, сәнгати осталык, китап басуда типографик чаралар мөмкинлек биргән күптөрле график алымнар куллана. 1920–30 еллар ахырында плакат сәнгате б-н шөгыльләнә: «Алмаш» (1928), «Тимерне кыздырып ябыштыру» (1928), «СССР — бөек тимер юл дәүләте» (1939), «Тимер юл транспорты — Кызыл Армиянең бертуганы» (1940) һ.б. К.ның станлы нәкышь әсәрләре: «Татарстан авылы кызы кырда» (1926), «Кызларның интернациональ әйлән-бәйлән уены» (акварель, гуашь, 1936), «Төрле халык балалары» (акварель, гуашь, 1944) һ.б. 1950 елларда ташбасма шрифтларның яңа гарнитурасын әзерләү б-н шөгыльләнә: «Коробкованың кулъязма шрифты» (рус алфавиты хәрефләре), ракурслы фотопроектлаштыру алымы кулланып, күп кенә алфавитлар өчен дүрт төрле язылыштагы «Газета өчен брусковый шрифт» һ.б. К.ның шрифтлары китап басуда кулланыла. 1960–80 елларда «Мәскәү урамнары», «Мәскәү яны табигате», «Чәчәкләр» монотипия серияләрен иҗат итә. Гомеренең соңгы елларында ул Ф.Ш.Таһиров б-н автордашлыкта бизәгән китап тышлыкларының эскизларын автор буларак кабатлавын дәвам иттерә, аларны башка хезмәтләре б-н бергә ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музеена бүләк итеп тапшыра.

«СССР халыклары сәнгате» (Мәскәү, 1927), «Яшь Октябрь» берләшмәсе (Мәскәү, 1930), халыкара «Китап сәнгате» (Париж, Нью-Йорк, 1931), техник плакат (Мәскәү, 1933), халыкара «Инполиграфмаш-69» (Мәскәү, 1969), Мәскәү китап рәссамнарының 4 нче шрифт һәм орнамент (Мәскәү, 1978), Респ-ка юбилеена багышланган сәнгать (Казан, 1980), 1920–30 еллар Татарстан рәссамнары әсәрләре (Казан, 1990) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси — Ф.Ш.Таһиров һәм А.Н.Коробкованың график эшләре күргәзмәсе Казанда 1976 елда уздырыла.

Хезм.: Композиционные принципы шрифтов эпохи Возрождения // Сб. трудов НИИ Полиграфмаш. 1957. № 2; Автобиография и некоторые воспоминания о художественных школах 20-х годов Казани и Москвы // Советское искусство 20–30-х годов: Сб. статей. К., 1992.

*Әд.:* Дульский П.М. Искусство в Татреспублике за годы революции. К., 1929; Гречихо М.В., Шицгал А.Г. Книжный шрифт. М., 1964; Червонная С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Ключевская Е.П. Феномен художественной полиграфии // Татарстан. 1995. № 11–12.

*Е.П.Ключевская.*

**КОРОБКО́ВО** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 26 *км* көньяктарак, Сулы елгасы (Димнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 20 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1880 дә нигез салына. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1100 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1889 да — 243, 1908 дә — 282, 1920 дә — 306, 1926 да — 307, 1938 дә — 285, 1949 да — 244, 1958 дә — 160, 1970 тә — 137, 1979 да — 90, 1989 да — 49, 2002 дә — 29 кеше.

**КО́РОБОВ** Сергей Яковлевич (12.8.1955, Белоруссия ССРның Полоцк ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). 1974–76 елларда Мәскәү авиация ин-тында эшли. Мәскәү авиация ин-тын тәмамлый (1979). 1981 дән «Казан вертолёт заводы» АҖдә: инженер-конструктор, әйдәп баручы инженер, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, баш технолог урынбасары (2001 дән), баш технолог (2006 дан). Дәүләт бүләге «Ми-8 МТВ-1, Ми-8 МТВ-2, Ми-8 МТВ-3, Ми-8 МТВ-5, Ми-172 камилләштерелгән вертолётларын һәм аларның модификацияләрен серияләп җитештерүгә кую» дигән хезмәте өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**КОРОВА́ЕВ** Евгений Николаевич (14.12.1898, Вятка ш. — 20.4.1962, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1950), проф. (1952). 1926 елда Казан мед. ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, шунда ук балалар клиникасында эшли. 1945 тән Казан мед. ин-тында: балалар авырулары, 1946 дан балаларда йогышлы авырулар, 1953 тән госпиталь педиатриясе кафедралары мөдире. Хезмәтләре балаларда йогышлы авыруларны булдырмау һәм дәвалауга, балаларда иммунитет һәм аллергияне өйрәнүгә карый. К. сыркынды авыруының патогенетик классификациясен тәкъдим итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ревматизм и скарлатина // Тр. Казан. мед. ин-та. 1935. Т. 1–2; Лечение ревматизма у детей // Педиатрия. 1941. № 1 (автордаш); Переливание крови у детей при различных заболеваниях детского возраста по материалам детской клиники // Тр. Казан. мед. ин-та. 1946. Вып. 1.

*Әд.:* Профессор Евгений Николаевич Короваев: Некролог // Казан. мед. журн. 1962. № 4.

**КОРО́ВИННАР**, Казан сәүдәгәрләре. Чыгышлары б-н крәстияннәрдән. **Иван Иванович** (1763 тирәсе — 12.10.1841, Казан), Казанның 3 нче гильдия сәүдәгәре. Воскресенский урамындагы таш йорт хуҗасы. Аның улы **Аким Иванович** (1792, Казан — 1852, шунда ук), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Икмәк б-н сату итә. Беркадәр вакыт Казан губернасы Мамадыш өязе Нырты авылындагы бакыр кою з-ды хуҗасы булып тора. Хәйрия эшчәнлеге өчен алтын медаль б-н бүләкләнә. 1820 еллардан Казанда иске дин тарафдарлары — попчылар җәмгыяте башлыгы. Болак буендагы иске дин тарафдарлары кәшәнәсе аның хисабына эшли (1854 тә Эчке эшләр министрлыгының махсус вазифалар башкаручы чиновнигы П.И.Мельников — ул ш.у. Андрей Печерский псевдонимы б-н дә билгеле — тарафыннан бөлдерелә). Бертуган **Антон** һәм **Андрей Акимовичлар** (яшәгән еллары билгеле түгел), Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре. Уртак сәүдә эше б-н шөгыльләнәләр, бүленмәс капиталга ия булалар, аталарының эшен дәвам итәләр. 1854–57 дә Андрей Акимович — Казан шәһәр җәмәгать банкында директор иптәше (урынбасары).

*Әд.:* А г а ф о н о в Н. Казань и казанцы. К., 1906. Кн. 1; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**КОРОЛЕ́НКО** Владимир Галактионович (15.7.1853, Житомир ш. — 25.12.1921, Полтава ш.), язучы, җәмәгать эшлеклесе. «Макар төше» («Сон Макара», 1883), «Сукыр музыкант» («Слепой музыкант», 1886), «Павлов очерклары» («Павловские очерки», 1890), «Тел белмәү» («Без языка», 1895) исемле хикәя һәм повестьлар, автобиографик «Замандашым турында» («История моего современника», 1922) әсәре һ.б. авторы. 1879 елда революционерлар б-н элемтәдә тора дигән шик тудыруы сәбәпле, аны кулга алалар һәм сөргенгә озаталар. Казанда Якутия ягына сөргенгә барганда (1880) һәм аннан әйләнеп кайтканда (1884) була. 1885 тә «Волжский вестник» г-тасында язышa. Анда ул «Изге бәйрәм алдыннагы төн» («В ночь под светлый праздник»), «Чиркәүдә чаң кагучы карт» («Старый звонарь»), «Диңгез» («Море»), «Караңгы почмак» («Глушь»), «Станокта» («На станке») исемле очерк һәм хикәяләрен бастыра. 1888 нең маенда Красновидово авылында бергә сөргендә яшәгән М.А.Ромась исемле дустында була. Соңыннан ул «Рәссам Алымов» (1896) хикәясендәге төп геройның прототибына әверелә. 1888 елның августында язучылар һәм журналистлар берлеге төзү нияте б-н Казанга килә (полиция рөхсәт бирми). 1895 тә Чистай, Алабуга, Мамадышта булып китә.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 10 т. М., 1953–56; Собр. соч.: В 6 т. М., 1971.

*Әд.:* В.Г.Короленко в воспоминаниях современников. М., 1962.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**КОРОЛЁВ** Евгений Никифорович (7.11.1913, Кострома губ., Кологрив өязе Югары Межа а. — 16.2.2001, Әлмәт ш.), техник-төзүче, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, Соц. Хезмәт Герое (1971), ТАССРның атказ. төзүчесе (1970). Новосибирск төзелеш техникумын тәмамлый (1933). 1935 елда армиягә алына һәм төзелеш батальоны составында Комсомольск-Амур шәһәре төзелешенә җибәрелә. Бөек Ватан сугышы башланган елларда аккумуляторлар з-ды төзелеше җитәкчесе итеп билгеләнә, завод 1943 нең июнендә эшли башлый. 1950–54 тә Новосибирск шәһәренең 43 нче төзелеш трестында управляющий; К. катнашында һәм аның җитәкчелегендә «Тяжстангидропресс», буйга струклау станоклары, турбогенераторлар, югары вольтлы аппаратура, металлургия, «Сибсельмаш», аккургаш з-длары төзелә. 1954–63 тә Калинин, Красноярск шәһәрләренең төзелеш трестларында управляющий булып эшли; Бежецк, Вышний Волочёк, Торжок шәһәрләрендә сәнәгать пр-тиеләре төзелешләре б-н җитәкчелек итә. 1963–77 дә «Татэнергострой» төзелеш-монтаж трестында управляющий, идарә башлыгы. К. җитәкчелегендә ТРның Төньяк-Көнчыгыш Кама буе икътисади р-нында төзелеш индустриясенең зур базасы булдырыла: нефтехимия комб-ты, шин з-ды, энергетика һәм шәһәр хуҗалыгы объектлары төзелә (Түбән Кама ш.). Герой исеме илнең энергетика үсешендә 8 нче бишьеллык (1966–70) план йөкләмәләрен үтәгәндә ирешелгән уңышлары өчен бирелә. 1967–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Түбән Кама, Мамадыш шәһәрләренең мактаулы гражданы. Түбән Камада һәйкәл куела, К. музее ачыла (2002). Түбән Кама политехник көллияте аның исемен йөртә.


*Әд.:* Д р я г и л е в Л. Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**КОРОЛЁВ** Сергей Павлович (30.12.1906, Житомир ш. — 14.1.1966, Мәскәү), ракеталар төзелеше һәм космонавтика өлкәсе галиме һәм конструкторы, гамәли космонавтиканы оештыручы һәм аңа нигез салучы, СССР ФА академигы (1958; 1953 тән мөхбир әгъза), Соц. Хезмәт Герое (1956, 1961), Ленин бүләге лауреаты (1957). Одесса һөнәри-төзелеш мәктәбен тәмамлый (1924), Киев политехник ин-тында укый (1924–1926), 1929 елда Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесен, бер үк вакытта очучы-планёрчылар мәктәбен тәмамлый. 1930 дан Үзәк аэрогидродинамика ин-ты (Мәскәү) инженеры, биредә ул «Коктебель», «Кызыл йолдыз» һ.б. планёрларның конструкцияләрен эшли. 1932–33 тә Реактив хәрәкәтне өйрәнү төркеме (ГИРД, Мәскәү) башлыгы. 1933 тән Реактив фәнни-тикшеренү ин-ты (ГИРД һәм Ленинград газодинамика лаб-ясе нигезендә оештырыла) башлыгы урынбасары, 1934–37 дә ракета очкыч аппаратлары бүлеге башлыгы. К. җитәкчелегендә сыек ягулыклы беренче сов. ракетасы җибәрелә (1933), идарә ителүле канатлы ракета 212 (1939 да очыртыла), беренче тапкыр очучы В.П.Фёдоров тарафыннан идарә ителеп очыш ясалган, РП-318–1 ракетопланёры (1940) проектлары эшләнә. 1938 дә К. репрессияләнә, сәяси тоткынлыкта (ГУЛАГ лагерьларында) була; 1940–42 дә — Ту-2 бомбардировщигын серияләп җитештерүне үзләштергән 156 нчы з-д каршындагы Үзәк КБ-29 да (Мәскәү), 1942–46 елларда 16 нчы моторлар төзү з-ды каршындагы Махсус тәҗрибә КБ-456 да (Казан) эшли, биредә серияле хәрби самолётларга сыек ягулыклы ракета тизләткечләрен кую мәсьәләләре хәл ителә, 1944 тә баш конструктор урынбасары итеп билгеләнә, бер үк вакытта, 1945–46 да, Казан авиация ин-тының ракета двигательләре кафедрасында (В.П.*Глушко* тырышлыгы б-н төзелә) укыту эшендә. 1946–66 да 88 нче фәнни-тикшеренү ин-тының тәҗрибә КБ-1 дә (Мәскәү өлкәсе Калининград ш., хәзер Королёв ш.) бүлек башлыгы — баллистик ракеталарның баш конструкторы, ген. конструктор-директоры (1956 дан). 1957 дә реабилитацияләнә. Татарстанда кабат 1961 нең мартында Зәй р-нында «Восток» космик корабленең һәлакәтле төшүе китергән зыянны бетерү чараларын оештыру максатында була.

К. исеме космосны үзләштерү өлкәсендәге беренче казанышлар б-н бәйле. Аның фәнни һәм техник идеяләре бу тармакта киң кулланy таба. К. җитәкчелегендә баллистик һәм геофизик ракеталар, йөрткеч ракеталар һәм пилот идарәсендәге космик корабльләр («Восток», «Восход» һ.б.) төзелә, алар ярдәмендә тарихта беренче тапкыр космик очышлар гамәлгә ашырыла; Җир һәм Кояшның ясалма иярченнәре, «Зонд» сериясе планетаара разведчиклар җибәрелә, Айга, Венерага, Марска планетаара автомат станцияләр очырыла, Ай өслегенә космик аппарат утыртыла. Өч Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең К.Э.Циолковский исем. алтын медале б-н бүләкләнә. 1971 дә СССР ФА Президиумы С.П.Королёв исем. «Ракета-космик техника өлкәсендәге зур казанышлар өчен» алтын медален булдыра. Илнең шәһәрләрендә галимгә һәйкәлләр куела, урамнарга (ш.и. Казанда) аның исеме бирелә, Житомир, Мәскәү һ.б. шәһәрләрдә, Байконур космодромында мемориаль музей-йортлар ачыла. Самара аэрокосмик ун-ты, 2 фәнни-тикшеренү судносы, Памирда тау түбәсе, Тянь-Шаньда тау үткеле, астероид, Айдагы талласоид К. исемен йөртә. Кызыл мәйданда Кремль стенасы буенда җирләнә.



Е.Н.Королёв.



С.П.Королёв.

Х е з м.: Планёр «Красная звезда» // Самолёт. 1931. № 1; Данные для подсчёта весов // Самолёт. 1932. № 4; Ракетный полёт в стратосфере. М., 1934; Крылатые ракеты и применение их для полёта человека // Пионеры ракетной техники. М., 1972.

*Әд.:* А п е н ч е н к о О. Сергей Королёв. М., 1969; А с т а ш е н к о в П.Т. Академик С.П.Королёв. М., 1969; Р о м а н о в А.П. Конструктор космических кораблей. М., 1971.

**КОРОЛЁВ** Юрий Петрович (26.3.1948, БАССРның Эстәрлетамак р-ны Петровский пос.), генерал-майор (1995). Саратов политехник ин-тын (1971), Чиләбе югары хәрби автомобильләр команда уч-щесен (1974) тәмамлый. 1971 елдан Әлмәт газ сәнәгате техникумы укытучысы. 1972 дән ТАССРның Хәрби комис-тында, 1983–85 тә Балык Бистәсе р-ны хәрби комиссары. 1985 тән СССР ДОСААФының Казан техник мәктәбе башлыгы, Татарстан ДОСААФ өлкә ком-ты рәисе урынбасары, 1990–2003 тә ТР оборона спорт-техник оешмасының Республика советы рәисе. «Хәрби хезмәтләре өчен» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КОРОТА́ЕВ** Константин Георгиевич (25.12.1919, Владивосток ш. — 5.1.1999, Севастополь ш.), инженер-тикшеренүче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1950 елда Ленинград политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Яшел

Үзән проект-конструкторлык бюросында эшли, бүлек башлыгы. Корабльләрнең гидродинамик сыйфатларын камилләштерүнең эксперименталь-хисаплау алымнарын эшләүдә катнаша (1975–85). Дәүләт бүләге яңа техниканы файдалануны үзләштерүгә керткән хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КОРОТА́ЕВА** Әлфия Сәетнур кызы (27.6.1959, Чиләбе ш.), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано), Коми Респ-касының халык (2001), РФнең атказ. артисты (2005). 1985 елда Урал (Свердловск ш.) консерваториясен тәмамлый. 1985 тән Коми Респ-касы опера һәм балет театры солисты. Башкарган партияләре арасында: Төн патшабикәсе («Тылсымлы флейта», В.А.Моцарт), Розина («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Норина («Дон Паскуале», Г.Доницетти), Марфа («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Виолетта, Джильда, Дездемона («Травиата», «Риголетто», «Отелло», Дж.Верди), Микаэла («Кармен», Ж.Бизе), Адель («Ярканат», И.Штраус) һ.б. Петербург һәм Мәскәү театрларының опера спектакльләрендә катнаша, Россия һәм чит илләрдә концертлар бирә, радио һәм телевидениедән чыгышлар ясый, аудиодисклар яздыра. Җырчының концерт репертуарына Көнбатыш Европа, рус, Россиянең хәзерге заман композиторлары әсәрләре, РФ халыклары җырлары керә. «Славян базары» (Витебск ш., Беларусь Респ-касы), «Төньяк Пальмирада музыкаль раштуа очрашулары» (С.-Петербург), «Җырчы Россия, мәхәббәтем минем», «Рус кышы», «Мәскәүдә Рамазан» (Мәскәү), «Кантеле» (Петрозаводск) халыкара һәм бөтенроссия музыка фестивальләрендә, татар җыры конкурсларында һәм фестивальләрендә (Казан) һ.б.да катнаша. Халыкара, бөтенроссия һәм региональ, ш.и. И.Юрьева истәлегенә багышланган 2 нче халыкара (Таллин, Эстония, 2001, 1 нче премия), рус романсларын башкаручыларының 3 нче бөтенроссия (Владимир, 2001, 1 нче премия), «Яңа исемнәр» (Одесса, Украина, 2003, Гран-при) конкурслары лауреаты һәм дипломанты.

Х е з м.: Как в сказке о Золушке. Сыктывкар, 2004; Театр: проблемы и надежды. Сыктывкар, 2005.

**КОРОТКО́В** Александр Григорьевич (5.5.1921, хәзерге Удмурт Респ-касының Сарапул р-ны Шелья а. — 21.5.2006, Казан), нейроморфолог, мед. фән. д-ры (1958), проф. (1959), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). 1945 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук нормаль анатомия кафедрасында эшли, 1963 тән каф. мөдире, бер үк вакытта 1964–74 елларда дәвалау ф-ты деканы, 1985 тән проф.-консультант. 1958–63 тә Ставрополь мед. ин-тының нормаль анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре нерв системасы морфологиясенә карый. К. беренче булып эчәклек парасимпатик иннервациясенең иң тулы схемасын төзеп бирә, Кен-Куренең «өченче арка мие парасимпатикусы» теориясенең дөрес булмавын дәлилли. Ул тәкъдим иткән ашказаны-эчәклектәге парасимпатик нервлар бүленеше схемасы классик система булып китә. Казан мед. ун-тының Анатомия музеенда ватаныбыз һәм чит илләрдәге күренекле галим-морфологлар портретлары галереясын (400 гә якын портрет) оештыручы. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Бөтенроссия анатомнар, гистологлар, эмбриологлар фәнни җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы.

Х е з м.: Материалы к парасимпатической иннервации кишечника: Дис. ... К., 1957; Морфология сосудистой системы в норме и патологии // Сб. статей кафедры нормальной анатомии и кафедры патологической анатомии. К., 1977.

*Әд.:* Профессор Александр Григорьевич Коротков // Казан. мед. журн. 1981. № 3.

**КОРОТКО́В** Виталий Петрович (22.12.1936, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). 1961 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Пермь полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1967–2002 дә Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1973 тән сектор башлыгы. Хезмәтләре эчке баллистикага, ыргытылма зарядларның янып китүе һәм януына карый. К. төрле билгеләнештәге системаларга 20 ыргытылма зарядның серияле җитештерүен булдыруда һәм үзләштерүдә катнаша. Дәүләт бүләге махсус аппаратлар төзелеше өлкәсендәге хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**КО́РОЧКИН** Михаил Васильевич (24.11.1947, Яшел Үзән ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999), ТРның атказ. машина төзүчесе (2003). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1990). 1962–96 елларда Чистай «Восток» сәгать з-дында эшли: көйләүче, мастер, цех, производство-диспетчерлык бүлеге башлыгы, директор урынбасары. 1996 дан Чистай «Автоспецоборудование» з-дында директор. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге «Туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен модуль-блоклы культиваторлар эшләү, аларны технологик нигезләү һәм җитештерүне үзләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КОРСАГАЯКЛЫЛА́Р**, ә к ә м - т ө к ә м - н ә р (Gastropoda), моллюсклар тибындагы умырткасыз хайваннар классы. К.ның үзенчәлекле билгесе — өч өлештән: баш, гәүдә, зур аяклар (табаннар) һәм калпаксыман яки еш кына спиральсыман бормалы (4–5 әйләнешле) кабырчыктан (лайлачларда юк) торучы асимметрияле гәүдә. Зурлыгы 1 дән 35–45 *мм* га кадәр. 90 меңгә якын төре билгеле, Татарстанда 40 тирәсе. Алар арасында К.ның 3 отрядыннан (асклasстан) 2 вәкиле бар: алсаңаклы һәм үпкә моллюсклары. Алсаңаклы моллюсклар суда яшиләр һәм саңаклары б-н сулыйлар. Аларга керүче тереләй тудыручы моллюсклар (Viviparus) — 2 төр, ябылмалы (Valvata) — 3 төр, битинияләр (Bithynia) — 2 төр зур һәм кече сулыкларда яши. Идел елгасының тамак өлешендәге учасaskлардан килгән мигрант-литоглиф (Litogliphus naticoides C. Pfeiffer) күп санда таралган төр. Атмосфера һавасын сулаучы үпкә моллюсклары арасында сулыкларда һәм җир өстендә яшәүче төрләр бар. Күл, елга, сазлык һәм күлләвекләрдә даими яшәүчеләр — гади буа әкәм-төкәме (Lymnaea stagnalis Linne), озынча түгәрәк буа әкәм-төкәме (Lymnaea ovata), кәтүкләр (Plamorbis) һ.б. Җир өсте үпкә моллюскларына гәрәбә һәм бакча әкәм-төкәмнәре, ш.у. Agriolimax, Limax ыругыннан лайлачлар һ.б. керә. Алсаңаклы лайлачлар аерым җенеслеләр булса, үпкә моллюсклары исә гермафродитлар. К.ның күпчелеге үсемлекләр б-н туклана, йоткылыкта урнашкан махсус органнары «кыргычлары» ярдәмендә азыкны кыра һәм ваклый. Су моллюсклары күлләрне үсемлекләр б-н капланудан саклый. Җир өсте әкәм-төкәмнәре урманнарга һәм урман хуҗалыгына зыян китерә. Буа әкәм-төкәмнәре, тереләй тудыручы моллюсклар, саз-буа әкәм-төкәмнәре һ.б. хайван һәм кеше паразитларының арадаш хуҗалары (тасма суалчан, бавыр имгеч суалчан; описторхис суалчаны һ.б.).

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2.

*В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.*

**КОРСА́К ТИФЫ́**, көчле йогышлы авыру; бизгәк тоту, агулану, тәнгә тимгелләр чыгу, эчәкнең лимфа аппараты зарарлану хас. К.т.ын беренче тапкыр француз табибләре Ф.Бретанно (1813) һәм Ш.Луи (1829 да) тасвирлыйлар. Тышкы мохиттә тотрыклы булган К.т. бактериясе — Salvaonella typhi — авыруны кузгатучы булып санала. Җәй, көз фасылларында авыру ныграк тарала. К.т. б-н фәкать кешеләр авырый. Авыру чыганагы — авырулар, бактерия йөртүчеләр; авыру пычрак куллар, зарарланган су һәм ашамлыклар аша тарала. Авыруларның 3–5%ы бактерия йөртүчегә әверелә. Авыру килеп чыгу су тәэминатында, җәмәгать туклану урыннарында, сәүдә пр-тиеләрендә һәм көнкүрештә сан. режимын бозуга бәйле. Авыру ешрак шәһәрләрдә очрый. Д.К.Бәширова К.т. вакытындагы патогенезны, диагноз кую, иммуногенезның күзәнәк аспектлары нигезен, лимфацитларның эшчәнлеген, авыруны дәвалауда һәм үзгәрешендә иммунитетның күзәнәк механизмнарын өйрәнә (1980 еллар). К.т. Казан губернасында 20 йөз башында ел саен кабатлана (2000 нән артык очрак, 1910). Татарстанда, массакүләм авыру буларак, 1950 еллардан соң күзәтелми; очраклы килеп чыгуы гына билгеле.

*Әд.:* Б а ш и р о в а Д.К. Иммунные реакции в патогенезе брюшного тифа. Л., 1989; Справочник-путеводитель практикующего врача. 2000 болезней от А до Я. М., 1999.

*В.Х.Фазылов.*

**КО́РСАКОВ** Александр Григорьевич (15.6.1941, Яшел Үзән ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1993). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң Брянск химия з-дында эшли. 1969 елдан Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, 1976 дан лаб. башлыгы, 1983 тән бүлек башлыгы, 1992 дән баш инженер, 1997 дән баш фәнни хезмәткәр, 2004 тән баш технолог һәм бүлек башлыгы. Хезмәтләре махсус технологиягә карый. Артиллерия өчен югары энергияле дарылар проектлау һәм бул-

дыруга нигез сала. Аның җитәкчелегендә коралландыруга кабул ителгән югары энергияле эффектив 6 продукт эшләнә. К. — пилотларның һәлакәт катапульты өчен ыргытылма зарядларны уйлап табучыларның берсе. 105 фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 121 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1996). Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Лучшие люди России: Энцикл. М., 2004. Ч. 2.

**КО́РСАКОВ** Дмитрий Александрович (10.7.1843, Мәскәү — 26.5.1919, Казан), тарихчы, рус тарихы д-ры (1880), Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1905), хакыйкый статский советник (1883). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1864). 1864–66 елларда Казан губернасы дворяннар җыены канцеляриясендә эшли. 1868 дән земство һәм җәмәгать учреждениеләрендә, 1874–1900 дә Казан губернасы Казан өязенең мактаулы җәмәгать судьясы. 1871 дән Казан ун-тында: нәфис сәнгать кабинеты саклаучысы (1872 гә кадәр), 1872–81 дә доцент, 1881–84 тә экстраординар проф., 1884–97 дә ординар проф., 1897 дән рус тарихы кафедрасының атказ. профессоры, 1900–1905 тә тарих-филол. ф-ты деканы. Бер үк вакытта, 1884–90 да «Учёные записки Императорского Казанского университета» ж-лы мөхәррирләренең берсе. Россияне үзгәртеп кору һәм аның дәүләт ин-тларын яңа тормыш шартларына җайлаштыруны эзлекле рәвештә алып бару тарафдары. «Меря һәм Ростов кенәзлеге: Ростов-Суздаль җире тарихыннан очерк» («Меря и Ростовское княжество: Очерк из истории Ростово-Суздальской земли», 1872) хезмәтендә Россия дәүләтчелегенең барлыкка килүен иң борынгы заманнардан алып, 13 йөзгә кадәр рус халкы этногенезы процесслары һәм яңа җирләрне колонияләштерү б-н бәйләп карый. «Императрица Анна Иоанновнаның тәхеткә утыруы: Тарихи этюд» («Воцарение императрицы Анны Иоанновны: Исторический этюд», 1880) монографиясе Россиядә 1730 да самодержавиене конституция б-н чикләргә омтылуны өйрәнүгә багышлана. А.П.Волынский шәхесе б-н кызыксыну аның турында махсус хезмәт язуга этәрә. Әлеге әсәргә Россия сәяси элитасының күренекле вәкилләре турында биографик очерклар да керә, К. аларны «XVIII йөз рус эшлеклеләре тарихыннан» («Из истории русских деятелей XVIII в.», 1891) җыентыгына туплап бирә. Идел буе Казан җирлеге тарихын һәм төбәкне өйрәнү б-н шөгыльләнә. «XIX йөзнең беренче яртысында Идел буе тормышындагы үзенчәлекләр» («Черты из жизни Поволжья первой половины XIX века», 1890), «Күргән-белгәннәр. 1856–1860 еллар Казан тормышыннан: Үткәннәр турында хатирәләр» («Былое. Из казанской жизни 1856–1860 годов: Воспоминания о прошлом», 1898), «Казанда күп еллар яшәүче хатирәләреннән. 1861 елның 19 февралендә крәстияннәрне азат итү турында» («Из воспоминаний казанского старожила. Об освобождении крестьян 19 февраля 1861 г.», 1911) китаплары һәм мәкаләләре; Н.Н.Булич, Н.П.Загоскин, П.В.Знаменский, К.Ф.Фукс, А.П.Щапов һ.б. турында язмалар; мемуарлар авторы. «Дворян Люткиннар нәселенә нисбәтле актлар җыентыгы» («Сборник актов, относящихся до рода дворян Люткиных», СПб., 1899) һәм «XVIII йөздә Казан төбәге тарихы буенча материаллар җыентыгы» («Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в.», 1908) мөхәррире. Казан шәһәр музеен оештыручыларның берсе (1895). Казан өяз (1868–85) һәм губерна (1874–77) земство җыеннары гласные. Казан ун-ты каршындагы Табигыять фәннәре җәмгыятенең хакыйкый (1871), Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең оештыручы (1878) һәм шәрәфле (1903), Казан икътисадчылар җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1888).

Х е з м.: Артемий Петрович Волынский: Биогр. очерк // Древняя и Новая Россия. 1876. Т. 1; 1877. Т. 1–2; Сергий Радонежский и основанный им Троицкий монастырь (Троицкая лавра): Ист. очерк. К., 1894; Кавелин К.Д.: Критико-биогр. очерк. СПб., 1896; Введение в науку русской истории [У.к.], [Е.к.].

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета. 1905–1917. К., 1986; М у х а м а д е е в А.И. Дмитрий Александрович Корсаков: 1843–1919. К., 2002; Казанский университет (1804–2004): Библиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**КОРТ**, әчетелгән сөт продукты, эремчекнең бер төре; татар халкының милли ризыгы. *Катык* салып әчетелгән сөттән ясала һәм суы беткәнче кайнатыла. Кызгылт-көрән төсе өчен К.ны «кызыл эремчек» дип тә атыйлар. К. чәй янына бирелә, камыр ризыклары, *гөбәдия* пешергәндә әчлек итеп файдаланыла. Кортлы май — бал (шикәр) б-н кайнатылган һәм май салынган К. электән бәйрәм өстәленә куела торган сыйлардан санала. Озак саклау өчен К.ны, гадәттә, киптерәләр; элек аны юл ризыгы буларак кулланганнар.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1999.

**КОРТЛЫ́К**, к. *Пчеловод*, Кукмара р-ны.

**КОРТЧАЛА́Р**, тигезканатлылар отряды кокцидияләр асотрядыннан бөҗәкләр семьялыклары төркеме. 2 меңгә якын төре билгеле, БДБда якынча 250 төре бар. Күпчелеге — хәрәкәтсез бөҗәкләр, суда яшәмәүчеләр арасында утырма яшәү рәвеше алып баручы бердәнбер бөҗәк, шунлыктан аларда сизү һәм хәрәкәт органнары юкка чыккан. Балавызсыман бүлендекләрдән торучы төкчәләр б-н капланган. Хортумчыгы ярдәмендә ана затлар үсемлеккә берегәләр. Ата затлар канатлы, парлашудан соң үләләр. Личинкалар ярдәмендә таралалар, алар исә үсемлекләр буйлап хәрәкәт итә, җил б-н күчәргә мөмкин. Татарстанда бүлмә һәм оранжерея үсемлекләрендә онычыл кортча теркәлгән. Бөреләрдә, яфракларда, чәчәк бөреләрендә, чәчәкләрдә яши. Үсемлекләргә зыян китереп, аларның согы б-н туклана.

**КОРЧА́ГИН** Владимир Владимирович (14.10.1924, Казан), геолог, язучы, геол.-минерал. фән. канд. (1954), ТРның. атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм шунда ук 1987 гә кадәр укыта. Минералогия буенча «Татарстан АССРның көньяк-көнбатыш өлешендә һәм янәшә районнарындагы югары юра утырмаларының литологиясе» («Литология верхнеюрских отложений юго-западной части Татарской АССР и смежных с ней районов», 1962), «Татарстан АССРның көньяк-көнбатыш өлешендәге һәм Идел буеның аның белән чиктәш Ульянов төбәге түбән акбур утырмалары литологиясе» («Литология нижнемеловых отложений юго-западной части Татарской АССР и смежных с ней районов Ульяновского Поволжья», 1964) монографияләре авторы. 1988 дән ТР Язучылар берлегендә: рус әдәбияты секциясе җитәкчесе, 2003 тән әдәби консультант. Иҗаты фәнни-фантастик һәм мәҗаралы әсәрләрдән гыйбарәт: «Явыз рухлар елгасы сере» («Тайна реки злых духов», 1962), «Үткәннәр өрәге» («Призрак минувшего», 1993), «Ташландык бала» («Подкидыш», 1998) повестьлары, «Тау сырты аша юл» («Путь к перевалу», 1968), «Астий эдельвейсы» («Астийский эдельвейс», М., 1982), «Курку әсирләре» («Узники страха», 1991), «Карадан киенгән хатын» («Женщина в чёрном», 2002) романнары. Аларда төрле юнәлештәге күпкырлы темалар яктыртыла: кешелек дөньясында аң барлыкка килгән вакыттан алып термотөш сугышын булдырмау юлларын уйлап табу, ш.у. башка планета цивилизацияләре вәкилләре б-н элемтә урнаштыру ихтималы һ.б.

Г.Р.Державин исем. әдәби бүләк лауреаты (2000).

*Әд.:* Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; Ш е м е л о в а Е. Благословлённый самим Державиным // Детская библиотека. 2002. № 2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**КОРЧА́ГИН** Геннадий Никифорович (12.7.1926, Казан — 16.11.1989, шунда ук), материалларны электрохимик эшкәртү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1986). 1945 елда Казан авиация техникумын тәмамлаганнан соң, Казанның авиация з-дларында эшли (1945–53). 1952 дә Казан авиация ин-тын тәмамлый һәм шунда ук эшли, комплекслы технол. тармак фәнни-тикшеренү лаб-ясе (1971–75), хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау каф. мөдире (1983–88). Хезмәтләре детальләрне зурлыклары буенча электрохимик эшкәртүгә карый. К. электрофизик һәм электрохимик технол. процессларны тикшерә. Материалларны үлчәмнәре буенча электрохимик эшкәртеп формалар ясауның технол. күрсәткечләрен күтәрү өчен исәпләү алымнары һәм күрсәтмәләр тәкъдим итә. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү юллары, ш. у. җитештерү процессларын проектлаштыру һәм гамәлгә кертү вакытында хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Аның эшкәртмәләре ТР пр-тиеләрендә кулланыла. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Моделирование стационарного и нестационарного процессов электрохимической размерной обработки деталей с длинномерными межэлек-

тродными каналами // Электрохимическая размерная обработка металлов. Киш., 1974; Аналитический метод расчёта поверхности катода-инструмента для электрохимической обработки лопаток ГТД // Электрофизические и электрохимические методы обработки материалов. М., 1975; Основы повышения точности электрохимического формообразования. Киш., 1977.

**КОРЧА́ГИН** Евгений Александрович (19.4.1951, Чуаш АССРның Алатырь р-ны Мирёнки а.), педагог, техник фән. канд. (1991), пед. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1977 елдан Югары Ослан р-ның Келәнче урта мәктәбендә директор. 1978 дән Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында. 1992 дән РМАнең Пед. һәм психол. проф. белем бирү ин-тында (Казан), 1993 тән махсус һәм гамәли әзерлек лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре проф. белем бирүне стандартлаштыру мәсьәләләренә карый.


Х е з м.: Научное обеспечение стандартизации профессиональной подготовки. К., 2000; Нормативная область профессиональной педагогики. К., 2001.

**КОРЧАҢГЫ́ ТАЛПАННАРЫ́**, к ы ч ы т - т ы р г ы ч т а л п а н н а р (Sarcoptoidea), акариформлылар отрядыннан талпаннар өссемьялыгы. Гәүдәсе шарсыман, озынлыгы 0,15–0,3 *мм*. Ана затлар аталарына караганда эрерәк. 20 гә якын төре билгеле. Имезүчеләрнең тән тиресендә яшәүче паразитлар. Тире тукымалары б-н тукланалар, аның мөгезчел катламында, кимереп, бормалы юллар (15 *мм* га кадәр озынлыкта) ясыйлар, аларда исә ана затлар йомырка сала һәм личинкалар үсә. Парлашу тире өстендә төнлә бара, соңыннан ата затлар үлә, ә аналары яңадан тире эченә керә. Кайвакыт терлекчелеккә шактый зыян китерә. К.т. (ascaris siro) кешедә инвазион тире авыруын — корчаңгы китереп чыгаралар.

**КОРШАНГА́-ШИГАЛИ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 21 *км* төньяктарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 148 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 615,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1880 дә — 250, 1897 дә — 314, 1913 тә — 431, 1920 дә — 448, 1926 да — 507, 1938 дә — 577, 1949 да — 540, 1958 дә — 523, 1970 тә — 497, 1979 да — 342, 1989 да — 215, 2002 дә — 197 кеше.

**КОРШО́К** Юрий Александрович (1.8.1927, Украина ССРның Кировоград ш. — 6.10.2010, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1987). Кировоград драма театры каршындагы студияне тәмамлый (1945). 1945–59 елларда Кировоград өлкә драма театры, 1959–66 да Жданов шәһәрендә Сталин исем. өлкә драма театры, 1966–2006 да Казан Зур драма театры актёры. К. — үзенчәлекле, характерлы актёр, аның талантына лирикадан алып үткен сатирага кадәр булган төрледән-төрле төсләр хас. Казан театры сәхнәсендә Оптимистенко («Мунча», В.В.Маяковский), Создатель («Илаһи комедия», И.В.Шток), Нинкович («Министр ханым», Б.Нушич), Тиссаферн, Лейзер Вольф («Геростратны онытыргамы?!», «Мәрхүмне искә алу догасы», Г.И.Горин), Клешнин («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой), Дулебов («Талантлар һәм аларга баш иючеләр», А.Н.Островский), Лещ («Соңгылар», М.Горький) һ.б. образлар иҗат итә. Нигездә, көнкүреш һәм комедия рольләрен башкарып, К. беркайчан да теге яки бу күренешнең, геройның көлкеле якларына махсус басым ясамый, кеше шәхесенең асылын, характер үзенчәлекләрен бөтен каршылыклары б-н ачарга омтыла. Шул рәвешчә дөреслеккә туры килә торган, ышандырырлык характерлар иҗат итә. «Сабый һәм түбәдә яшәүче Карлсон» спектаклендәге (А.Линдгреннең шул исем. повесте буенча) Карлсон образы актёр иҗатында аерым урын алып тора. К. башкарган «дөньядагы иң яхшы Карлсон» образында зирәклек, шаян беркатлылык, балаларча эчкерсезлек, хисләр сафлыгы, үз-үзеңне күрсәтергә омтылу һәм шәхесне ирексезләүгә каршы көчле нәфрәт ярылып ята. Бу очракта актёр һәм роль арасында гармонияле бәйләнеш камиллек дәрәҗәсенә җитә. Актив рәвештә җәмәгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә.

*Ю.А.Благов.*



Ю.А. Коршок.



Ю.А. К о р ш о к Нинкович («Министр ханым», Б. Нушич) ролендә.

**КО́РШУН** Александра Ивановна (21.5.1926, Ульянов ш. — 24.3.2009, Казан), патофизиолог, радиобиолог, биол. фән. д-ры (1967), проф. (1969). 1949 елда Ульянов а.х. ин-тын тәмамлагач, Харьков зоотехния ин-тында эшли, 1954–71 дә Троицк вет. ин-тында, 1967 дән патанатомия каф. профессоры (Чиләбе өлкәсе). 1971–84 тә Казан вет. ин-тының патофизиол. лаб-ясе мөдире. 1985 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире. Хезмәтләре терлекләр радиобиологиясенә, физиологиясенә, патофизиологиясенә карый. К. ашкайнатуны көйләү механизмын, организмга ионнар нурланышы тәэсирен тикшерә, терлекләрне радиацион зарарланудан саклау ысулларын эшли. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние хлористого кобальта на секреторную функцию кишечных желёз у свиней // Тр. Троицкого вет. ин-та. 1962. Т. 8, вып. 1; Влияние центральной нервной системы на секреторную функцию тощей кишки у свиней. М.–Л., 1964. Т. 11, вып. 1.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КО́РШУН** Вадим Петрович (3.8.1928, Украина ССР Житомир ш. — 21.10.1996, Казан), терлекләрне тукландыру белгече, а.х. фән. д-ры (1974), проф. (1976), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1987). 1950 елда Харьков зоотехния ин-тын тәмамлый. 1954–71 дә Троицк вет. ин-тында терлекләрне тукландыру кафедрасында (Чиләбе өлкәсе), бер үк вакытта 1961–69 да зоотехния ф-ты деканы. 1971 дән Казан вет. ин-тында. 1971–95 тә терлекләрне тукландыру каф. мөдире, бер үк вакытта 1972–79 да зооинженерия ф-ты деканы. Хезмәтләре саламны электрохимик эшкәртүгә, фермент препаратлар, традицион булмаган азыкларны терлекчелектә куллану, мөгезле эре терлек, дуңгызлар, тавыклар, куяннарны ритмлы тукландыруга карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние ферментных препаратов, применяемых в пищевой промышленности на энзиматическую активность пищеварительного химуса крыс // Вопр. питания. 1976. № 2 (автордаш); Ферментные препараты в кормлении животных. М., 1985 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КО́РШУНОВА** Ольга Николаевна (8.2.1955, Удмурт АССРның Игра р-ны Игра пос.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1977). 1980 елдан Казан технол. ун-тында, 2004 тә н гуманитар фән. каф. мөдире. Хезмәтләре 18–19 йөзләрдә Идел буе һәм Урал алды халыклары мәдәниятләренең үзара йогынтысы тарихына карый. Культурология буенча уку ярдәмлеге авторы.

Х е з м.: Традиции взаимовлияния культур народов Поволжья. К., 1997 (автордаш); Взаимодействие культур народов Поволжья и Приуралья в новое время: исторический аспект. Чебоксары, 2000; Поволжье и Приуралье: Культура многонациональной провинции. К., 2001 (автордаш).

**КОРЪӘ́Н** (гарәп. ألقرآن — уку, кычкырып уку), мөселманнарның төп изге китабы; 610 һәм 632 еллар арасында *Мөхәммәд* пәйгамбәр сөйләгән һәм язмача теркәп калдырылган вәхиләр. Мөхәммәд пәйгамбәр исән вакытта телдән-телгә тапшырылган. Вафатыннан соң (632) сәхабәләре арасында К.нең беренче язмача вариантлары пәйда була. Аның кануни тексты хәзрәти Госман хәлифәлек иткән чорда (644–56) төзелә. К. төрле күләмдәге аятьләрдән торган (3 тән 287 гә кадәр) 114 сүрәдән гыйбарәт. Сүрәләр Мөхәммәд пәйгамбәр Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләрендә сөйләгән-




Кулъязма Коръән. 1809 елгы күчермә.

гә бәйле рәвештә, Мәккә (610–22; 90 сүрә) һәм Мәдинә (622–32; 24 сүрә) дәверләренә бүленәләр. К. мөселманнарның үз-үзләрен тоту һәм яшәү рәвешләрен, ислам йолаларының башкарылу кагыйдәләрен билгеләүче дини-хокукый күрсәтмәләрдән тора. 1530 елда Венециядә басылып чыккан К. (гарәп телендә) беренче басма К. булып санала (1537 дә кабат басыла). К.нең гарәп телендәге басмалары 1694 тә Гамбургта (А.Хинкельман шәрехләвендә) һәм 1698 дә Падуяда (Л.Мараччи шәрехләвендә) дөнья күрә; китаплар, башлыча, фәнни максатларны күздә тотып бастырыла. К.нең славян (белорус) телендәге беренче тәрҗемәсе якынча 15–17 йөзләрдә Бөек Литва кенәзлегендә хезмәт иткән *Польша-Литва татарлары* тарафыннан әзерләнә. Россиядә К.нең рус телендәге беренче тәрҗемәсе Пётр I заманында француз Андре де Риеның гарәп теленнән французчага тәрҗемәсе аша нәшер ителә: «Мөхәммәд турында әл-Коръән яки төрек Законы...» («Алькоран о Магомете, или Закон турецкий, переведённый с французского на русский...», СПб., 1716). Соңрак Казанның Беренче ир балалар гимназиясе директоры М.И.*Верёвкин* (СПб., 1790, ш.у. де Рие тәрҗемәсеннән), А.В.Колмаков (СПб., 1792, Дж.Сэйльнең инглизчәгә тәрҗемәсеннән), К.Николаев (М., 1864, А.Б.Казимировскийның французчага тәрҗемәсеннән) әзерләгән К. тәрҗемәләре басыла. Россиядә К.нең гарәп телендәге төп тексты (мәтене) 1787 елда император Екатерина II Фәрманы б-н Шнор басмаханәсендә басылып чыга. Мулла Госман Исмәгыйль махсус шрифтлар әзерли, текстны җентекләп шәрехли. Беренче тиражы 20 данә була (хәзерге вакытта аның 2 нөсхәсе билгеле: Мәскәүдә Россия милли китапха-



1803 елда типографик ысул белән басылган «Казан Коръәне»нең факсимиль басмасы (2005).

нәсендә һәм Истанбулдагы «Сөләймания» китапханәсендә). 1800 дә мөселман дини әдәбиятын нәшер итүне чикләү бетерелә; шул ук елда Казанда Г.Т.Бурашёвның 1 нче мөселман басмаханәсе (*Азия басмаханәсе*) ачыла, анда 1859 га кадәр 150 мең данә К. нәшер ителә. 1803 елның августында Казанда мөселман халыкларының изге китабы К. беренче мәртәбә типографик ысулда басылып чыга. 1859 да Казан ун-ты проф. Г.К.*Казимбәк* Россиядә *исламият* фәне туода төп этапларның берсе булган «Коръәннең тулы Конкордансы яки Китаптагы дини, хокукый, тарихи һәм әдәби нигезләрне өйрәнүгә кулланма буларак тексттагы барлык сүзләргә һәм гыйбарәләргә ачкыч» («Полный Конкорданс Корана, или Ключ ко всем словам и выражениям его текстов для руководства к исследованию религиозных, юридических, исторических и



Коръән. 2012 дән Болгар шәһәрендә саклана.

литературных начал сей книги») исемле хезмәтен бастыра. 1870 елларда Д.Н.Богуславский (СПб., 1871) һәм Г.С.*Саблуков* (1879) тарафыннан рус теленә төп нөсхә буенча тәрҗемә ителгән 2 К. дөнья күрә. Г.С.Саблуков тәрҗемәсе Казан исламият мәктәбенең зур уңышы дип бәяләнә. 1963 елда Мәскәүдә И.Ю.Крачковский тәрҗемә иткән К. басылып чыга. 1990 елларда В.М.Порохова (1993), М.-Н.О.Османов (1995), Т.А.Шумовскийның (1995) яңа тәрҗемәләре дөнья күрә; 2003 тә К.нең Б.Я.Шидфар, 2004 тә Э.Кулиев тәрҗемәләре нәшер ителә. Күп кенә илаһият галимнәре субъектив берьяклылыкка юл куймау өчен К.нең коллектив тәрҗемәсен эшләргә тәкъдим итәләр.

Мөселманнарга К.не үз ана телләренә тәрҗемә итү тыелганлыктан, 20 йөз башына кадәр К.нең татар телендәге тәрҗемәсе булмый, шунлыктан К.гә шәрехләүләр сыйфатындагы *тәфсирләр* киң тарала. Гарәп телен белгән татар зыялылары дини текстларны иркен укыган, шуңа күрә К.нең тәрҗемәсенә җәмгыятьтә ихтыяҗ булмаган. 1912 елда М.Бигиев тәрҗемә иткән К. Оренбург Мөселман Дини Мәҗлесе катнашуы нәтиҗәсендә басылмый кала. Бу хәл кызу бәхәсләр тудыра: зыялыларның бер өлеше һәм кадими руханиларның (к. *Кадимчелек*) күпчелеге К.не тәрҗемә итүгә каршы чыгалар. Татар зыялыларының алдынгы өлеше (к. *Җәдитчелек*) К.нең фәнни һәм танып-белү өчен әһәмияте барлыгына күрсәтеп, тәрҗемәнең зарурлыгын яклый. 20–21 йөзләр чигендә К.нең татарча тәфсирен Ф.Х.Сәлман (1999), Р.М.Батулла (2000), Ә.Халидов (басылмаган) һ.б. әзерли. 2011 дә Италиядән Казанга Республика «Возрождение–Яңарыш» тарих һәм мәдәният ядкәрләрен торгызу фонды (рәисе — ТРның беренче Президенты, ТР дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев) заказы буенча «Ревера ЛТД» компаниясе (Трест ш.; директоры — Н.Братасевич) тарафыннан эшләнгән дөньядагы иң зур басма К. (2×1,5 *м*, 632 бит) китерелә; ул «*Колшәриф*» комплексы мәчетендә урнаштырыла, 2012 дә даими саклау урынына — Болгар шәһәренә (Спас р-ны) күчерелә. Аны бизәүдә сусаль алтын, көмеш, ярымасылташлар кулланыла.

*Әд.:* Бигиев М. Тарих аль-Куран ва аль-Масахив. СПб., 1905; Готвальд И.Ф. Опыт арабско-русского словаря на Коран. К., 1863; Саблуков Г.С. Приложение к переводу Корана. К., 1879; Баязитов А. Ислам и прогресс. СПб., 1899; Ислам: религия, общество, государство. М., 1984; Пиотровский М.Б. Коранические сказания. М., 1991; Резван Е.А. Коран и коранистика // Ислам. Историогр. очерки. М., 1994; Ибрагим Т.К., Ефремова Н.В. Мусульманская священная история от Адама до Иисуса. М., 1996; Амерханова Э. Коран: от Петербурга до Казани // Ислам. 2005. № 2; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1998. Вып. 1; Торваль И. Мусульманская цивилизация: Энцикл. словарь. М., 2001.

**КОРЪӘ́Н ТАРТМАЧЫГЫ́**, кечкенә күләмле Коръән, аннан алынган *сүрәләр* һәм *аятьләрдән* торган догалар, бөтиләр саклау өчен нәфис итеп эшләнгән металл савыт. К.т. ритуал әһәмияткә ия булган саклангыч итеп кулланылган; аны чылбыр яки тасма б-н муенга, җилкә аша янга асканнар, култык астына бәйләп йөрткәннәр, махсус кесәгә салганнар яки тукымадан әзерләнгән күкрәк бәйләвече — *хәситә* эченә тегеп куйганнар. К.т. ш.у. татар хатын-кызларының толымнарын бизәүче укалы чәч тасмасына (толым төбенә беркетелгән) — тезмәгә дә асылган. Дога савытларының иң әүвәлге үрнәкләре Салтау культурасы истәлекләренә карый. 10–12 йөзләрдә дога савытлары К.т.на охшый башлаган һәм еш кына К.т.ның капкачы яки турыпочмаклы җиз тәңкәләр б-н алмаштырылган. Моңа охшаш традиция Казан татарларына да хас. Алар бизәк өчен К.т. урынына Коръәннән алынган, кыска аятьләр уеп язылган зур җиз тәңкәләр куллана башлыйлар. Монголларга кадәрге һәм Алтын Урда чоры Идел буе болгарларының К.т. капкачларында тупса б-н ачыла торган, вак бөртекләү, ябыштырылган җепкыр һәм ярымасылташлар б-н чәмчәләп бизәлгән яссы бронза тартмачыкларның югары сәнгать дәрәҗәсендә башкарылган үрнәкләре сакланган. Капкачлары җепкыр, бөртекләү һәм ярымасылташлар б-н бизәлгән болгар К.т. формалары үзгәрешсез диярлек Казан татарларында да кулланылган. Цилиндр рәвешендәге һәм контурлар ярдәмендә катлаулы фигуралар төшерелгән алтын









**Коръән тартмачыклары.** 1. Алтын, энҗе. Чүкү, басма, бөртекләү, җепкыр. 14 йөзнең 1 нче яртысы. Дәүләт Тарих музее. Мәскәү; 2. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. Җепкыр, бөртекләү, ялган бөртекләү. 16 йөзнең 1 нче яртысы. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы; 3. Көмеш, алтын йөгертү. Уеплау. 19 йөз. «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее; 4. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. Игү, уеплау, җепкыр, корлау. Автор —Р.А.Мөхәммәтшин. 2005.

К.т. Идел буе һәм Кырымдагы Алтын Урда чоры шәһәрләрендә археол. казу эшләре алып барганда һәм хәзинәләрдә очрыйлар. Алар ябыштырылган бөтеркә, челтәрле бизәк, басма ысулы б-н төшерелгән үсемлек һәм эпиграфик орнаментлар (к. *Басма*), корлау ысулы б-н беркетелгән фирәзә, ахак, энҗе, яшма б-н бизәлгәннәр. Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы фондында Казан ханлыгы чорына караган көмеш К.т. үрнәге саклана. Аның капкачы чәчәк рәсемен гәүдәләндерүче борчактай эре бөртекләр һәм ромб формасындагы кечкенә металл борысчыклар, ябыштырылган җепкыр, ш.у. шатоннарның тирән ояларына беркетелгән 10 асылташ (фирәзә, гранат, зөбәрҗәт, зәңгәр якут ташлары сакланган) б-н бизәлгән.

18 йөздә — 20 йөз башында табаклы көмеш, алтын һәм бронзадан эшләнгән, җепкыр, *бөртекләү, уеплау*, кайвакыт *каралту*, басма һәм штамплау ысуллары б-н бизәлгән, ярымасылташлар б-н (фирәзә, топаз, тау бәллүре һ.б.) корланган (к. *Корлау*) К.т.ның турыпочмак, дүрткел, ромб, бишпочмак, түгәрәк, озынча түгәрәк, ш.у. цилиндрсыман формалары очрый. Гадәттә, эре яки вак бөртекләү ысулы б-н тартманың тышкы ягы каймаланган һәм ярымасылташлар тирәли җепкырлы, дулкынсыман яшь ботак мотивлары сурәтләнгән, чәчәккә охшаган бизәкләр (кайвакыт ромб рәвешендә) төшерелгән.

К.т., дингә хөрмәт күрсәтү, табыну элементы буларак, халыкның көнкүрешеннән 20 йөз башында юкка чыга. Хәзер формасы б-н К.т.на охшаган һәм чылбыр б-н асып йөри торган, мөселман илләрендә киң таралган кечкенә тартма рәвешендәге К.т. үрнәкләре яңадан җитештерелә башлады.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953. Мальм В.А. Симферопольский клад: Каталог Государственного Исторического музея. М., 1980; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984. Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М., 1990.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КОРЫ́ АККО́Ш КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Казан шәһәренең Киров р-нында, «Аккош күле» урман паркы терр-ясендә, Идел елгасының биек террасасы буенда. *Аккош күлләре* (көнбатыш өлешендә) системасы составына керә; ермак б-н *Олы Аккош күленә* кушылган. Ермак б-н тоташкан ике плёстан тора. Язын К.А.к. нык кына ташып чыга һәм, зур сулык ясап, иңкү ярларны баса. Күлнең төньяк яры сөзәк, болын һәм сазлык үләннәре б-н капланган көньяк яры — нарат урманы үскән комлы калкулыклар. Җәйге саегу вакытында су өслегенең мәйданы 10 *га*



Коры Аккош күле.

тирәсе, су күләме 36,3 мең $м^3$, озынлыгы (ермакларны кертеп) 960 *м*. Плёсларның иң зур киңлеге 350 һәм 120 *м*, тиңдәшле рәвештә иң зур тирәнлеге 1,7 һәм 1,75 *м*. Коры елларда К.А.к. тулысынча диярлек кибә, көчле яңгырлар нәтиҗәсендә яңадан барлыкка килә. Кыш көне күлнең күп өлеше төбенә кадәр ката. Ял итү урыны.

**КОРЫ́ ЕЛГА́**, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 18,1 *км*, бассейнының мәйданы 90,5 $км^2$. Елга башы — урман массивында, Биектау р-нының Күлле посёлогыннан төньяктарак, урта һәм түбәнге агымы — Казан чигендә; тамагы — Борисоглебский авылыннан көнчыгыштарак. Югары агымында елга *Урман Күле* аша ага. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 55%, урманнары күбесенчә катнаш. Үзәне асимметрияле: сул ягы текәрәк һәм калкурак. К.Е.ның 0,6 һәм 1,8 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 $км/км^2$. Туенуы катнаш, якынча өчтән ике өлешен кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 165 *мм*, ташу агымы катламы 108 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана һәм айга якын дәвам итә. Җәен суының күләме әкренләп кими бара, һәм, яңгыр озак яумый торса, елганың шактый гына өлеше кибеп бетә (исеме шуннан килә). Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,11 $м^3/с$. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**КОРЫ́ КӨРНӘЛЕ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Көрнәле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 349 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Верхняя исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, мәдрәсә, 4 җил тегермәне, ярма яргыч, тимерче алачыгы, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2312 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Левашёво волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 219 ир-ат; 1859 да — 1218, 1897 дә — 1591, 1908 дә — 1959, 1920 дә — 2023, 1926 да — 1281, 1938 дә — 1068, 1949 да — 1084, 1958 дә — 1063, 1970 тә — 1013, 1979 да — 622, 1989 да — 417, 2002 дә — 399 кеше.

**КОРЫ́ САЗ**, күл. Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-нының Столбище һәм Комлы Кавал авыллары арасында. Су өслегенең мәйданы 1,5 *га*. Күләме 7500 $м^3$. Озынлыгы 690 *м*, иң зур киңлеге 50 *м*. Уртача тирәнлеге 0,5 *м*, иң зур тирәнлеге 2 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст-суффозия күренеше б-н бәйле. Фор-

масы озынча. Ярлары сөзәк, таллар б-н капланган. Күлнең уртасында йөзмә «үлән-утрау» бар. Күбесенчә явым-төшем сулары б-н туена. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийле типта. Җиңелчә минеральләшкән, бик йомшак. Сызалар буйлап зур күләмдә ком-балчык, яңгыр һәм кар сулары агып кергәнгә, күл акрынлап үлән б-н каплана һәм ләмләнә. *Күл акчарлаклары колониясе* табигать истәлеге составына керә.

**КОРЫ́ ҮЛӘМӘ́** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 46 *км*, бассейнының мәйданы 629 *км*². Идел буе калкулыгы буйлап ага. Елга башы — урман массивында, Кама Тамагы р-нының Кече Кариле авылыннан 7 *км* ераклыкта, Сөйке тавының төньяк сөзәклегендә, тамагы — Апас р-нының Кече Күккүз авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 55 *м*. Су җыелу мәйданы калкулыклы тигезлектән гыйбарәт; аның уңъяк яр өлеше күбрәк бүлгәләнгән һәм калкурак рельеф хасил итә. Үзәне асимметрияле: уң ягы текәрәк. К.Ү.нең 1,2 дән алып 16,5 *км* га кадәр озынлыктагы 14 кушылдыгы бар, иң зурлары: Симгә (11 *км*), Саравыл (14 *км*), Кыярмәт (16,5 *км*), Мәми (13,1 *км*) — уң; Олы Шаһиян (15 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, зур күпчелеге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 121 *мм*, ташу агымы катламы 107 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,32 *м*³/*с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К.Ү. бассейнында суның гомуми күләме 2,5 млн. *м*³ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КОРЫЛТА́Й**, урта гасырлар төрки-монгол дәүләтләрендә югары феодаль катлау вәкилләре җыены. Борынгыдан килгән халык җыеннары традициясенең дәвамы. К.ларның барлыкка килүе Чыңгыз хан (монгол нойоннарының Темучинны хан итеп сайлаган һәм аңа Чыңгыз хан титулы биргән 1206 елгы бөек К.нан билгеле) исеме б-н бәйле. К. тәхет варисын билгеләгәндә яки ханны тәхеттән төшергәндә, яу йөрү, дошман явына каршылык күрсәтү, илдә тынычлык булдыру мәсьәләләрен хәл иткәндә, чит дәүләтләр б-н килешүләр төзегәндә, хан варислары өйләнгән яисә кияүгә чыккан вакытта чакырыла. Монголларның феодаль хокук кануннары мәҗмугасында (Яса) К.га зур әһәмият бирелә. Ике патша идарәләре арасында К. дәүләт хакимиятен тулысынча үз кулында тота. Тарихта билгеле 1246 елгы К.да монгол нойоннарыннан тыш чит ил вәкилләре дә була (Владимир бөек кенәзе Ярослав Всеволодович, сәяхәтче Плано Карпини). Монгол империясе таркалгач, яңа барлыкка килгән һәр биләмә Яса нигезендә үз К.ен җыя. Казан ханлыгында К.да 3 катлау вәкилләре — руханилар, җирбиләүчеләр (бәкләр һәм морзалар), угъланнар катнаша. Татар ханлыкларында К.лар әлеге дәүләтләр яшәгән дәвердә даими рәвештә җыела.

*Әд.:* Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1896. Т. 17.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**«КОРЫЛТА́Й»**, иҗтимагый-сәяси газета. *Мөселманнар комитеты*, соңрак *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы* (Милли Шура) башлангыч органы. 1917 елның 2 июленнән 1918 нең 4 апреленә кадәр һәм 1918 нең август уртасыннан 5 сентябренә кадәр — «К.», 1918 нең 8 апреленнән 23 маена кадәр «*Алтай*» исемендә нәшер ителә. «Милләт» басмаханәсендә барлыгы 90 саны чыга. Наширләре — «Корылтай» ширкәте һәм Г.Әлмәтов. Мөхәррирләре — Ф.*Туктаров*, Г.Сәйфелмөлеков, Г.*Баттал*, Н.Мөхтәров. Газетада Х.Әбелхан, С. һәм Ш.Алкиннар, Ф.Әхмәтов, Җ.Вәлиди, Г.Газиз (Гобәйдуллин), Н.Хәлфин, Г.Шнаси һ.б. хезмәттәшлек итә. Февр. рев-циясеннән соң әйдәп баручы татар басмаларының берсе. Редакция милли бергәлек лозунгларын яклап чыга, үзенең сыйнфый булмаган, гомуммилли позицияләрен белдерә. Федератив-демократик республика һәм милли-мәдәни автономия идеяләрен пропагандалый; пролетариат диктатурасы һәм Россиянең социализм юлыннан үсү мөмкинлеге турындагы тәгълиматны кире кага. Басма Вакытлы хөкүмәт эшчәнлеген яклый, мөселманнарны аны хупларга чакыра, большевикларны 1917 елгы канлы Петроград вакыйгаларын оештыруда гаепли. Редакция Окт. рев-циясе һәм большевикларның аннан соңгы эшчәнлекләренә тискәре карашта була. Большевикларның милли мәсьәләне чишү моделе һәм мөселман комис-ты оештыру эшчәнлеге кискен тәнкыйтьләнә. Газета Милли Шура һәм *Милли Идарәне* чыннан да милли оешмалар дип саный; большевикларны демократик милли оешмаларны тар-мар итүдә гаепли. Милли Идарәнең юкка чыгарылуын тарихта татар милли хәрәкәтенә иң авыр һөҗүм итү дип исәпли. 1918 дә шундый карар чыгарган М.Вахитов «милли хәрәкәтне изүче» дип атала. 1918 нең 22 мартындагы Татар-Башкорт Респ-касы турындагы нигезләмә «К.» тарафыннан Идел-Урал штатын төзү юлындагы киртә дип бәяләнә. Басма хакимиятләр тарафыннан ябыла, Ф.Туктаров, Г.Сәйфелмөлеков, Г.Әлмәтов һәм Җ.Вәлиди кулга алына. Апрельдә Г.Баттал мөхәррирлегендә «Алтай» г-тасы чыга башлый, ул да Казан Советының мөселман комис-ты тарафыннан яптырыла. Чех-словак корпусы һәм КОМУЧ халык армиясе Казанны алганнан соң, газета «К.» исеме б-н яңадан чыга башлый (мөхәррире — Г.Баттал, 10 сан). КОМУЧның махсус вәкиле, Казан губернасы буенча аның урынбасары И.Алкин эшчәнлеге турында язмалар басыла. Большевикларга каршы лозунглар пропагандалаган һәм хакимиятне Учредительләр җыенына бирүне таләп иткән, татарлар арасында агитация алып барган, ш.у. күпсанлы җыелыш һәм митинглар үткәргән Мөселман коллегиясенең эшчәнлеге яктыртыла. Яңадан торгызылган җирле хакимият органнары һәм идарәләре эше турында язмалар басыла, ш.и. Казан шәһәр думасы, аеруча аның гласныйларыннан мөселманнар: С.Алкин, Г.Әлмәтов, Р.Дәминов, В.Ибраһимов, Г.Исхакый, С.Максуди, А.Мостафин, Ф.Туктаров, Н.Хәлфин, Ш.Шәкүров һ.б. эшчәнлегенә урын бирелә. «К.» г-тасында Казан вәкилләре катнашында Чиләбе шәһәрендә узган Дәүләт киңәшмәсе һәм Уфада үткәрелгән Бөтенроссия төрки-татар конференциясе материаллары шәрехләнә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Исхакый Г. Солых хәйәте әгъзасы Фуад бәк Туктар вафат // Татарстан. 1993. № 3; Насыйров Т.М. Гражданнар сугышы чорындагы большевистик булмаган татар матбугаты // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4; Мухарямов М.К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии. К., 1958; Хайрутдинов Р.Г. На путях к советской автономии. К., 1972; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975.

*Т.М.Насыйров.*

**«КОРЫЛТА́Й»**, Казандагы хосусый-ширкәти нәшрият. 1918 елда оеша. Нигездә, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре нәшер итә. 1920 елның май аеннан мәктәп дәреслекләрен чыгаруны Губерна мәгариф бүлегенең матбугат комиссиясе тәртипкә сала. 1918 дә 13 татар китабы дөнья күрә. 1918–23 елларда 43 басма нәшер ителә, аларның 30 ы — мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм пед. әдәбият, 8 е — матур әдәбият, 1 се — дарвинизм һәм марксизм турында китап. Нәшрият 1924 кә кадәр эшли. 1921 гә кадәр заказлар «*Милләт*» басмаханәсенә, соңрак төрле дәүләт басмаханәләренә бирелә.

Шулай ук педагог һәм галим М.Корбангалиев, татар мәдәнияте эшлеклеләре Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Җ.Вәлиди, Ф.Бурнаш әсәрләре басыла. «Шәрекъ шагыйрьләре» (1920) тупланмасына Г.Хәйям, Сәгъди, Р.Тагор әсәрләре кертелә.

*Әд.:* Каримуллин А. Становление и развитие татарской советской книги: 1917–1932. К., 1989.

**КОРЫЛЫ́К**, озак вакытлар явым-төшемнәрнең җитәрлек булмавы. Еш кына һава темп-расының югары күтәрелүе, дымлылыкның кимүе күзәтелә. Тотрыклы антициклоннарның өстенлек итүе б-н бәйле, аяз көндә һава нык кына җылына һәм аның чагыштырмача дымлылыгы кискен кими. Бу атм. К.ына, ә соңыннан, *парга әйләнү* көчәю нәтиҗәсендә туфракта дымлылык запасы беткәннән соң, туфрак К.ына китерә.

ТР терр-ясе уртача 3 елга 1 тапкыр кабатлана торган озак вакытларга сузылучы атм. һәм туфрак К.ның даими йогынтысына дучар, бу исә уңышның шактый кимүенә китерә. Н.В.Колобов мәгълүматлары буенча, 1884 елдан 1963 кә кадәрге вакыт аралыгындагы 26 коры җәй эчендә 8 язгы, 16 язгы-җәйге һәм 11 җәйге К. була. 1891 һәм 1921 дә Урта Идел буен тулысынча, ш.и. Татарстан терр-ясен дә яулап алган хәтәр К.лар массакүләм ачлыкка һәм халыкның күпләп үлүенә китерә. Бик көчле К.лар 1957, 1972 һәм

2010 елларда була. К. б-н көрәшү өчен агротехн. комплексы (туфракны махсус эшкәртү, кар тоту, кар суларын тоткарлау, чиста пар басулары, мулчәләү һ.б.) һәм мелиоратив чаралар үткәрелә, кыр ышыклау урман утыртмалары булдырыла һ.б. К. аркасында килеп чыккан зыянны киметү өчен, а.х. культураларының корылыкка чыдам сортларын үстерәләр.

*Әд.:* Колобов Н.В., Муракаева С.А. Засухи на территории Татарской АССР. К., 1980; Климат Татарской АССР. К., 1983.

**«КОРЫ́Ч КУЛ»**, Сарман р-нындагы а.х. җитештерү кооперативы. 1928 елда төзелгән бер үк исемдәге колхоз җирлегендә 1994 тә оештырыла. 1945 тә «К.к.»ны 3 хуҗалыкка аералар — «Корыч кул», «Чапаев», «Яңа юл»; 1950 дә алар яңадан «К.к.» к-зына берләштерелә; 1990 да колхозның 3 нче бригадасы (Яңа Минзәләбаш һәм Кызыл Бакча) «Җәлилче» ҖЧҖгә күчерелә. 1994 тән хуҗалык коллектив пр-тие итеп үзгәртелә, 2002 дән — а.х. җитештерү кооперативы. Аңа Иске Минзәләбаш (үзәк утар) һәм Кужак авыллары керә. 2005 тән терр-ясе «Җәлил агрофирмасы» ЯАҖ составында.

2005 тә хуҗалыкта эшләүчеләр саны — 119 кеше. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 5566 га, ш.и. сөрү җирләре — 4501 *га*. Мөгезле эре терлек — 820, ш.и. сыерлар — 330 баш. Төп тармаклары — бөртекле ашлык, шикәр чөгендере, сөт җитештерү.

«К.к.» җитештерүдә тотрыклы югары күрсәткечләргә ия. «К.к.» эшчеләре уңайлыклары булган тораклар б-н тәэмин ителгән; торак пунктлар һәм җитештерү объектлары асфальт юллар б-н тоташтырылган, 5 кибет, ашханә, 2 мәктәп, 2 мәдәният йорты, мед. пунктлары бар. Терлекчелектә гаилә подряды, хуҗалык исәп-хисабы, тикшерүнең чек формасы, прогрессив бәяләү, продукциянең сыйфаты һәм җитештерүдә югары күрсәткечләр өчен бүләкләү гамәлгә кертелә.

Хуҗалык эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. ТРның мактаулы исемнәре — 6 кешегә, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 1; 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены — 3, СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре 3 кешегә бирелә. Хуҗалыкның беренче рәисе. Г.Вәзетдинов (1928–31) була. Төрле еллардагы җитәкчеләре: М.Габдрахманов (1945–50), Я.Р.*Ганиев* (1953–58), С.Г.Халитов (1960–67), В.Г.Галиев (1967–79), М.М.Вәлиев (1979–87), И.Р.Әшрәфуллин (1987 дән).

*И.Н.Афанасьев.*

**КОРЫЧАГА́Ч** (Fraxinus), зәйтүнчәләр семьялыгыннан яфрак коючан агачлар, сирәк кенә куаклар ыругы. 70 кә якын төре билгеле. Төньяк ярымшарның уртача поясында, сирәк кенә субтропик һәм тропикларда таралган. Татарстан терр-ясендә гади К. (F. excelsior), нигездә, Идел алдында очрый, киң яфраклы урманнарда үсә. Күп өйле үсемлек 30 *м* га кадәр биеклектәге агач, кайрысы аксыл-соры төстә, аскы өлеше вак кына ярыгаланган. Яфраклары каршыдаш, парсыз каурыйсыман, өсте кара яшел, аскы ягы чыгып торучан аксыл сеңерчәле. Бөреләре кара. Чәчәкләре күрексез, вак, чәчәк тирәлеге юк, яфрак ярганчы, апрель–майда чәчәк ата. Җимешләре — тар, бер орлыклы канатчалар, салынкы себеркәчкә җыйналган. Сентябрь–октябрьдә өлгерә, еш кына бөтен кыш дәвамында агачта саклана. Орлыктан үрчи. Дымлы, уңдырышлы, нейтраль туфракларны үз итә. К. аерым урманнар хасил итми. К. физиол. актив матдәләр бүлеп чыгара, алар исә яфрак коелдыгы, тамыр кисәкләре, орлыклар б-н туфракка үтеп керә һәм башка үсемлекләрнең коруына китерә. Туфракта фитоксинлы матдәләрнең тупланyы К. утыртмаларының үз-үзләреннән сирәкләнүенә һәм түбән продуктивлыгына китерә. Туфракның көчле тыгызлануын, һаваның тузан һәм төтен б-н пычрануын уңай кичерә. Торак пунктларда үстерелә. К. — кыйммәтле агач токымы. Үзагачыннан гимнастика борыслары өчен колгалар,



Корычагач.

чаңгылар, бильярд таяклары ясыйлар. К. фанеры җиһазларны һәм музыка коралларын бизәү өчен кулланыла. Декоратив. Кәүсә һәм ботакларына корычагач кабыгашары, яфракларына *корычагач чебенчәләре*, орлыкларына орлык филчекләре зыян китерә. Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогында Америка К.ы (F. americana) үстерелә.

**КОРЫЧАГА́Ч ЧЕБЕНЧӘЛӘРЕ́** (Lytta), шештергеч коңгызлар семьялыгыннан коңгызлар ыругы. Гәүдәсе озынча, озынлыгы 10–25 *мм.* РФдә якынча 10 төре бар. Татарстан терр-ясендә аеруча корычагач чебенчәсе (L.vesicatoria) таралган. Металлик ялтыравыклы ачык яшел төстә. Коңгызлар яфраклар, ш.у. күпләп үрчегәндә корычагач, сирень, җимеш агачларының сабакчалары һәм яшь ботаклары б-н туклана. Личинкалары кыргый бал кортлары ояларында үрчи. Кискен үзенчәлекле исе буенча коңгызлар төркеме җиңел табыла, бу исә аларның гәүдәсендә кантаридин (агулы матдә, К.ч. куркыныч янаганда бүлеп чыгара) булу б-н бәйле. Халык медицинасында кипкән һәм порошокка уылган коңгызлар пластырьлар (үлекле шешләргә каршы) әзерләгәндә кулланыла.


**КОРЯКО́ВА** Алла Сергеевна (27.7.1937, Ставрополь крае Георгиевск ш.), архитектор, ТАССРның атказ. архитекторы (1988). СССР Архитекторлар берлеге әгъзасы (1971). 1955–58 елларда Ленинград архит-ра техникумында укый. 1958–61 дә Комсомольск-Амур шәһәрендә «Горпроект»ның техник-архитекторы була. 1967 елда Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татгражданпроект» ин-тында (Казан) архитектор булып эшли. 1968 дән Казан төзүче-инженерлар ин-тының архитектур проектлаштыру кафедрасында укыта. 1979 дан «Казгражданпроект» ин-тында проектларның баш архитекторы (1985), генпланнар бүлеге башлыгы (1990 нан), архит-ра-төзелеш бүлегендә проектларның баш архитекторы (2002). 2004 тән — Казан муниципаль учреждениеләрнең Архит-ра идарәсендә генпланнар тикшерү бүлеге белгече. К. хезмәтләре арасында Казанның үзәк өлешләрен торгызу (В.И.Борисов б-н бергә, 1968), Киров р-нының 46 нчы, 53«Б» микрорайоннарындагы (1967–69) һәм Совет р-нының Дербышки бистәсенең «В» микрорайонындагы төзелешләр (1970), «Азино-2» торак р-нын детальле планлаштыру һәм төзү (Н.А.Бакулина, Н.Ә.Мөхәммәтшина б-н бергә, 1980–81), Казан ун-тының төп бинасын төзекләндерү (Н.Н.Козлова, И.Ю.Елкина б-н бергә, 1983), «Кремльнең көнбатышы» һәм «Бирге Кабан» р-ннарын детальле планлаштыру (Н.А.Бакулина, Н.Н.Козлова, И.Ю.Елкина б-н бергә, 1991), Эсперанто урамындагы 6 катлы торак йорт (Ш.Х.Латыйпов, конструктор В.М.Талыбова б-н бергә, 1996), Павлюхин урамындагы 9 катлы торак йорт (Т.Н.Брикнер, Н.Н.Козлова, Т.Ә.Вәлиева, В.С.Кобзев б-н бергә, 1997), Островский урамындагы административ комплекслар (О.Н.Анисимова, конструктор В.М.Талыбова б-н бергә, 2001), Петербург урамы (О.Н.Анисимова, С.Ляхова б-н бергә, 2005), Некрасов урамы (О.Н.Анисимова б-н бергә, 2006) проектлары бар.

**КО́САРЕВ** Анатолий Петрович (1.1.1934, Югары Ослан р-ны Сәет а.), социолог, филос. фән. д-ры (1987), проф. (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1965 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң шунда ук эшли; бер үк вакытта 1968–71 дә СССР ФАнең Философия ин-тында аспирантурада укый. 1985 тән Казан технол. ин-тында социализм теориясе каф. мөдире, 1991 дән дәүләт, муниципаль идарә һәм социология каф. профессоры. Хезмәтләре социология, политология, Россиядә һәм соц. илләрдә барган иҗтимагый процесслар өлкәсенә карый.

Х е з м.: Демократические партии в политической системе социализма. К., 1986; Введение в социологию. К., 1996 (автордаш); Основы политологии. К., 1998 (автордаш).

**КО́САРЕВ** Иван Петрович (7.10.1929, Бөгелмә кантоны Соколка а. — 21.3.2001, Оренбург ш.), бораулау җайланмаларын төзекләндерү буенча слесарь, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1974, 1978, 1983). Хезмәт эшчәнлеген 1941 елда туган авылында башлый, тракторчы (1945 тән). 1952–70 тә «Татнефтегазразведка» трестының 4 нче нефть эзләү-тикшерү-бораулау конторасында эшли (Лениногорск ш.). 1970 тә Оренбург өлкәсенә җибәрелә, шунда 1993 кә кадәр

нефть-газ чыгару пр-тиеләрендә хезмәт итә. 1986–88 елларда җайланмаларны яңарту, материаллар һәм запас частьләрне сакчыл куллану буенча К.ның 20 рационализаторлык тәкъдиме гамәлгә кертелә. Орден һәм медальләр б-н бүләкләнә. «Оренбурггаз» берләшмәсенең Хезмәт Даны музеенда К.ка багышланган экспозиция ачыла. Лениногорск шәһәрендә Ватан Геройлары аллеясында К. барельефы б-н обелиск куела.


И.П. Косарев.

*Әд.:* Золотые страницы Газпрома. М., 2009; Ветераны: из истории нефтяной и газовой промышленности. М., 2010. Вып. 23.

*М.Ж.Гаитов.*

**КОСМЕ́ТИКА** (грек. kosmetikḗ — бизәү сәнгате), 1) кешенең кыяфәтен яхшырту чаралары һәм алымнары турындагы тәгълимат. Табиблек К.сына (кыяфәттәге кимчелекләрне бетерү өчен косметик чараларны гына түгел, төрле дәвалау процедураларын, ш.у. хирургия алымнарын, ш.и. пластик операцияләрне файдалана) һәм декоратив К.га (аның ярдәмендә йөзнең кайбер кимчелекләре яшерелә яки аерым чалымнары ныграк күрсәтелә) бүленә. 2) Тирене, чәчләрне, тешләрне һәм тырнакларны карау-тәрбияләү чаралары. Татарларда физик матурлык һәм камиллек идеалы Шәрекъ халыкларының эстетик һәм гигиена традицияләренең көчле йогынтысы б-н формалаша, шуңа күрә аларның гармоник кыяфәт турындагы карашларында уртаклыклар күп: охшаш макияж, тәнне карау-тәрбияләү процедуралары һәм чаралары. Татар халкының көнкүрешен өйрәнүче барлык тикшеренүчеләр тарафыннан диярлек татарларның пөхтәлегеә билгеләп үтелә. Татар халкының этник аңында тәнне һәм өс-башны гына түгел, торакны да чисталыкта-пөхтәлектә тоту гадәте яши. Атна саен мунчада юыну, гадәти көндәлек гигиена процедураларыннан тыш, мөселманнар көн саен башкара торган биш вакыт *намаз* алдыннан тәһарәт кылалар. Кагыйдә буларак, кыяфәтнең матурлыгына хатын-кызлар аеруча зур әһәмият бирә, алар — декоратив К.ны төп кулланучылар. Декоратив фабрика К.сы (хушбуй, иннек, кершән һ.б.) татарлар арасында 19 йөз ахырыннан тарала башлый. Аңа кадәр алар күбесенчә Урта Азия һәм Кытайдан кертелгән косметик чаралардан файдалана. Татар археологлары тарафыннан табылган махсус савытлар, мәс., исле майлар салынган кечкенә шешәләр һәм бронза көзгеләр Идел буе Болгар дәүләтендә Шәрекъ К.сы киң кулланылуын чагылдыра. К.ны төрле яшьтәге хатын-кызлар кулланган. Татар хатын-кызлары битләренә һәм муеннарына, гадәттә суда эретеп, кургаштан эшләнгән яки Кытайдан китерелгән кершәннәр («упа» дип йөрткәннәр) сөрткәннәр. Битне кызарту өчен төрле чаралар — сатып алынган иннекләр, кызыл чөгендер согы һ.б. кулланганнар, кашларны — басма, күз кабакларын һәм керфекләрне сөрмә б-н каралтканнар. Шулай ук тешләрне дә каралтканнар (бигрәк тә өлкән яшьтәге хатын-кызлар), моның өчен читтән кайтарылган «таш көле» (тимер касмагы һәм төелгән пестә агачы орысы катнашмасы) яки имән чикләвеге төнәтмәсе кулланылган. Кына б-н тырнакларны саргылт-кызыл төскә буяганнар. Хушбуй сыйфатында экзотик ислемайлар — мускус, хуш исле рәйхан согы, роза мае файдаланылган. Традицион причёсканы (уртадан ачып үрелгән ике толым) ныгыту өчен махсус сыекча сөрткәннәр яки чәчне шикәр сиробына чылатканнар. Чәчләр куе һәм озын булып үссен өчен башны әчегән сөт яки *катык* б-н юганнар. Традицион бизәнү-ясану җыелмасына кечкенә көзге, еш тешле агач яки сөяк тарак, кайчы, кашларны нечкә, кыйгач рәвешкә кертү өчен кулланылган эскәк, бакырдан яки көмештән эшләнгән сөрмә савыты (сөрмәлек), хуш исле чәчәк сабыны һ.б. кергән. Ш.у. к. *Халык медицинасы.*

*Әд.:* Шәрипова С.Ш. ...дәваларның олысы вә асылы (Әбугалисина һәм халык медицинасы). К., 1992; Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; шул ук. О татарских женщинах // Казан. губ. ведомости. 1844. № 1; Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КОСМОДЕМЬЯ́НСКАЯ** Мира Анатольевна (3.5.1927, Ульянов ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлый (1950). 1952–77 елларда Яшел Үзән шәһәрендә: укытучы (1953 кә кадәр), 1953–62 дә урта мәктәп директоры, 1962–64 тә шәһәр халык мәгарифе бүлеге мөдире, 1964–73 тә халык депутатларының шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1973 тән КПССның шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1977–85 тә ТАССР социаль тәэминат министры. 1975–85 тә ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**КОСМЫ́ЛИНА** Луиза Гариф кызы (5.9.1937, Казан), хуҗалык-хакимият хезмәткәре, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1959–62 елларда Казандагы 59 нчы мәктәп укытучысы. 1962–67 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире, секретарь. 1967–73 тә КПССның Казан шәһәре Совет райкомы, 1973–77 дә Вахитов райкомы 2 нче секретаре. 1977–91 дә халык депутатларының Казан шәһәр советы башкарма ком-тында секретарь, эшләр идарәсе җитәкчесе. 1991–2004 тә Казан шәһәр хакимияте аппараты җитәкчесе. 2004 тә Казан шәһәре хакимияте башлыгы киңәшчесе, шәһәр сайлау комиссиясе рәисе. 2004 тән «Казан» милли мәдәният үзәгендә: директор урынбасары, Казанның 1000 еллыгы музее директоры. 2004–2008 дә ТР Дәүләт Советы депутаты, дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә буенча ком-т әгъзасы. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КОСТЕНЕ́ЕВО** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 541 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Рождество Иоанн-Предтеча чиркәве (1722 дә төзелә; архит-ра истәлеге). 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекчеләр булып эшли, бурлаклыкта йөри. 20 йөз башында К.да чиркәү, мәктәп, китапханә (1896 да ачыла) була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3500,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда. 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантоннарында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. 1944 нең 19 февраленнән Костенеево р-ны үзәге. 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1230, 1887 дә — 1516, 1905 тә — 1415, 1920 дә — 1170, 1926 да — 1160, 1938 дә — 844, 1949 да — 534, 1958 дә — 411, 1970 тә — 352, 1979 да — 454, 1989 да — 483, 2002 дә — 533 кеше.

**КОСТЕНЕ́ЕВО РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 нең 19 февралендә Алабуга р-нының бер өлешеннән оештырыла. Үзәге — Костенеево авылы. 1944 нең 8 июнендә район үзәге Морт авылына күчү сәбәпле, *Морт районы* дип үзгәртелә.

**КОСТЕ́РИН** Александр Васильевич (6.7.1944, Кама Тамагы р-ны Куйбышев Затоны штп), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1988), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли: аэрогидромеханика кафедрасында (1970–76), Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1976–96), ин-тның директоры (1990–94), экологик системаларны модельләштерү каф. профессоры (1996–2001), аэрогидромеханика каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре күзәнәкле туенган тирәлекләр механикасы өлкәсенә карый. К. күзәнәкле туенган тирәлекләрдә үзара бәйләнгән деформация һәм фильтрлаштыру процессларын тикшерү юлларын эшли; күзәнәкле матрица бушанган өлкәләрдә динамик тулы булмаган туену зоналары булган фильтрлаштыру консолидациясе мәсьәләләре классын билгели һәм матем. сурәтли; материалларны киптергәндә көчәнешләр һәм деформацияләр үсүнең матем. модельләрен эшли.

Хезм.: Консолидация и акустические волны в насыщенных пористых средах. К., 1990 (автордаш); Фильтрация жидкости в деформируемых нефтяных пластах. К., 1999 (автордаш); Автомодельные решения задач об уплотнении и водоотдаче глин при отборе жидкости из пластов // Докл. РАН. 2002. Т. 383, № 2 (автордаш).

**КОСТЕ́РИН** Валентин Александрович (13.4.1926, Киров өлкәсенең хәзерге Санчурск р-ны Починок Александровский а.), авиация двигательләрен төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1973), проф. (1974), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлекле-

се (1989), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1999), Казан техник ун-тының атказ. профессоры (2001). 1948 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый һәм шунда ук эшли, очкыч аппаратлар двигательләре ф-ты деканы (1971–74). Хезмәтләре двигательләр һәм энергетик җайланмалардагы яну процессларына, авиация двигательләренең эчке һәм тышкы газ динамикасына карый. К. газ турбиналы һәм катнаш двигательләрнең яну камерасындагы яну процессларының камера алды һәм газ-динамик төрләрен исәпләү һәм алар б-н идарә итү алымнарын эшли (бергәләп). Ул тикшергән яну алымнары нигезендә төзелгән форсаж камералар тулы үлчәмле газ турбиналы двигательләрдә стенд сынауларын уңышлы үтә (РД-9Б). К. термоэнергетик җайланмалар өчен (АИ-20 газ турбиналы авиация двигательләре нигезендә), нефть чыгаруны арттыру максатында катламнарга су җылытып тутырту өчен газ сыман ягулык б-н эшли торган һәм газ хәрәкәте тотрыклы хәлгә китерелгән яну камераларын проектлаштыруда һәм төзүдә катнаша. Чуеннан корыч эретеп табу процессының экологик сыйфатларын яхшырту өчен сыек металл ваннасына кислородлы порошоклар җылытып өрдерү фурмаларын эшли. Уйлап табуга 124 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале, РФ Космонавтика федерациясенең акад. М.В.Келдыш исем. медале б-н бүләкләнә. «СССРның уйлап табучысы» билгесенә лаек була.

Х е з м.: Стабилизация пламени на струях и некоторые вопросы интенсификации горения смесей в потоке // Физика горения и взрыва. 1969. № 3 (автордаш.); Аэродинамическая стабилизация пламени в форсажных камерах ТРДФ // Тр. Центр. ин-та авиац. моторостроения. 1977. № 781; О связи аэродинамики камеры сгорания с динамикой тепловыведения // Изв. вузов. Авиац. техника. 1982. № 3.

**КО́СТИН** Алексей Михайлович (23.3.1922, хәзерге Мордва Респ-касының Зубово-Полянский р-ны Авдалово а. — 8.5.2010, Казан), су транспортын эксплуатацияләү буенча инженер, РФнең мактаулы транспорт хезмәткәре (2002). 1951 елда Горький су транспорты инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, Горький елга портында участок башлыгы, баш диспетчер булып эшли. 1958–64 тә Берләштерелгән Идел буе пароходчылыгы идарәсендә пассажирларны күчерү хезмәте башлыгы урынбасары, портлар хезмәте башлыгы (Горький ш.), 1964–87 дә Казан елга порты башлыгы. Елга флотын үстерү һәм ныгытуга сизелерлек өлеш кертә. Ул җитәкләгән чорда Казан елга портының йөк әйләнеше — 3,5 тапкыр (10 нан 35 млн. *т* га кадәр), пассажирлар әйләнеше 3 мәртәбә (1 дән 3 млн. кешегә кадәр) арта; РСФСР Елга флоты министрлыгына караган портлар арасында беренче булып Казан елга портында порт эшчеләренең эреләндерелгән комплексны бригадалары оештырыла. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, өч «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ф у р е р Л.Н., Л у к ь я н о в Г.М., С и н и ц и н а К.Р. Речники Татарии. К., 1977.

**КО́СТИН** Владимир Алексеевич (17.5.1947, Горький ш.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2003), проф. (2005), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1971 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, авиация конструкцияләренең ныклыгы лаб-ясе мөдире (1973–76), проректор (1995 тән), очкыч аппаратларны төзү механикасы каф. профессоры (1998 дән), югары мәктәп педагогикасы (2005–2007), очкыч аппаратларны төзү механикасы (2007 дән) кафедралары мөдире. Хезмәтләре деформацияләнә торган каты җисем механикасына һәм очкыч аппаратларның ныклылыгына карый. К. очкыч аппаратлар конструкцияләренең сыгылмалылык үзлекләрен һәм аларга тәэсир итүче йөкләнешләрне тикшерә. Оптималь идарә итү теориясенә нигезләнеп, хисаплау алымнарын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теория оболочек с учётом поперечного сдвига. К., 1976 (автордаш); Методы оптимизации при решении коэффициентной обратной задачи вынужденных колебаний тонкостенной конструкции // Изв. вузов. Авиац. техника. 1998. № 1 (автордаш); Обратные задачи прочности летательных аппаратов. К., 2002 (автордаш.).

**КО́СТИН** Иван Михайлович (7.10.1946, хәзерге Түбән Кама р-ны Борок а.), тау эшләре инженер-механигы, РФнең атказ. машина төзүчесе (1994), РФ Икътисад министрлыгының мактаулы машина төзүчесе (1999), РФнең Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Пермь политехник ин-тын тәмамлый (1969). 1962–64 елларда «Татнефтепроводстрой» трестының 2 нче төзелеш идарәсендә электрик булып эшли (Әлмәт ш.). 1969–74 тә Пермь тау шахтасы машиналары төзү з-дында мастер, механик, механизмнар җыю цехы башлыгы урынбасары. 1974–2002 дә «КАМАЗ» АҖдә: технологик җиһазларны ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү идарәсенең металл конструкцияләр цехы башлыгы (1979 га кадәр), агрегатлар з-дының ремонтлау, автомат-токарьлык хезмәте башлыгы (1979–82), Төзәтү-монтаж эшләре идарәсенең әзерләүләр буенча башлыгы урынбасары (1982–84), «КАМАЗавтоцентр» әзерләүләр фирмасының Запас частьләр идарәсе башлыгы урынбасары (1984–86), «КАМАЗ» АҖнең җитештерү буенча директор урынбасары (1986–87), двигательләрне ремонтлау з-ды директоры (1987–95), ген. директор урынбасары (1995–96), 1 нче вице-президент — башкаручы директор (1996–97), «КАМАЗ» АҖ ген. директоры (1997–2002). К. автомобиль сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. 1994–2004 елларда ТР халык депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Грузовые автомобили. Прогнозирование ёмкости российского рынка // Автомобильная пром-сть. 2001. № 9 (автордаш); Грузовые автомобили на «Автосалоне-2001» // Грузовик. 2001. № 11 (автордаш); Обеспечение конкурентоспособности грузовых автомобилей на этапе разработки. Наб. Челны, 2001 (автордаш).



Я.Д. Костин.

**КО́СТИН** Яков Дмитриевич (20.10.1917, хәзерге БРның Бакалы р-ны Бакалы а. — 20.9.1993, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (5.8.1944, 27.3.1945, 31.5.1945), кече сержант. Көергәзе (БАССР, Ермолаево пос.) а.х. техникумын тәмамлый. Туган авылында вет. табибе булып эшли. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1234 нче укчы полкның укчы ротасы отделение командиры (69 нчы армиянең 370 нче укчы дивизиясе). Воронеж, Дала һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Харьков һөҗүм һәм оборона операцияләрендә (1943), Курск һәм Днепр елгасы өчен сугышларда (икесе дә — 1944), Люблин-Брест (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 18 июлендә Тивалы авылы (Украина ССР Владимир-Волын өлкәсе) янындагы сугышта (расчёты б-н ут ачып, подразделениегә һөҗүм итәргә булыша), 1945 нең 5–6 февралендә Одер елгасын кичеп, Фюрстенберг шәһәре янындагы сугышта (беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга, плацдармны яулап алуда катнаша; шоссе юлын кулга төшерү өчен отделение сугышчыларын атакага күтәрә), 1945 нең 16 апрелендә Маттель-Мюлень (Германия) торак пункты янындагы сугышта (беренчеләрдән булып дошман траншеясына бәреп керә) батырлык күрсәтә. 1945 тән демобилизацияләнә. Туган авылында столярлык остаханәсендә эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Е р о ш и н А.Е. Слава солдатская. Уфа, 1967; Г и м а д а е в М.Г. Солдатская слава. К., 1971; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КО́СТИНА** Татьяна Емельяновна (10.3.1925, хәзерге Ульянов өлкәсенең Мәләкәс р-ны Суходол а. — 17.06.2008, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1974), проф. (1977). 1949 елда Ульянов а.х. ин-тын тәмамлый. 1950 дән Казан вет. ин-тында, 1964–68 дә терлекләр физиологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре онтогенезның постнаталь чорында терлекләрнең ашкайнату системасының нерв-гуморалъ механизмын көйләүгә, организмда матдәләр алмашы һәм җайлашу процессларының яшь үзенчәлекләренә бәйле булуы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: О роли симпатической иннервации в гуморальной фазе секреции поджелудочной железы // Физиол. журн. СССР. 1958. Т. 44; Физиологические особенности функциональных систем у овец. К., 1980; Этология сельскохозяйственных животных. К., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**КОСТОМА́РОВ** Николай Иванович (4.5.1817, Воронеж губ., Острогожск өязе

Юрасовка бистәсе — 7.4.1885, С.-Петербург), тарихчы, археограф, публицист, рус тарихы д-ры (1864), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1876), хакыйкый статский советник (1870). Харьков ун-тын тәмамлый (1836). 1846–47 елларда Киев ун-тының адъюнкт-профессоры. 1846 да яшерен сәяси оешма — Кирилл-Мефодий җәмгыятен оештыручыларның берсе. 1847 дә кулга алына, 1848–59 да Саратов шәһәрендә сөргендә яши. 1858 дә Казан ун-тының экстраординар профессоры итеп сайлана, ләкин Халык мәгарифе министрлыгы аны расламый. 1859–62 дә Петербург ун-тының экстраординар профессоры, 1862 дә ординар профессоры. 1860 тан Рус геогр. җәмгыятенең Археография комиссиясе әгъзасы. Хезмәтләре Россия һәм Украина тарихына, фольклорга карый. Үзенең тикшеренүләрендә К. «халык тормышы»н беренче урынга куя. Ул төп бурыч итеп «тарих фәненә халык элементын кертүне» исәпли, демократик һәм самодержавиеле башлангычлар көрәшендә ил тарихы үзәген билгели. К. фикеренчә, Рус дәүләте баштан ук кабиләләр федерациясе буларак төзелә, ләкин монгол яулары Борынгы Русь тормышын кискен борылышка китерә. Бердәм дәүләт идеясен Русь Алтын Урдадан үзләштерә, бер үк вакытта халыкта югары хакимияткә буйсыну тамыр җәя башлый. Ил тормышында башланган тамырдан үзгәрешне К. 1861 елгы Крәстиян реформасы б-н бәйли, бу реформа «яңа рус тарихына башлангыч бирә», чөнки «дәүләтчелек халыкчанлык б-н татулаша» дип исәпли. К.ның фәнни мирасында «Рус тарихы аның иң төп эшлеклеләренең тәрҗемәи хәлләрендә» («Русская история в жизнеописаниях её главнейших деятелей», т. 1–3, СПб., 1873–88) хезмәте — Чукындыручы Владимирдан Елизавета Петровнага кадәрге чорның биографияләре җыелмасы аерым урын алып тора; анда ул Россиянең урта гасырларда Шәрекъ халыклары б-н бәйләнышларын тасвирлый, Мәскәү кенәзләренең һәм патшаларының Алтын Урдага, 13–16 йөзләр татар ханлыкларына карата сәясәтен тикшерә. Иван IV заманы турында «Кудеяр» романы (СПб., 1875), драма, повестьлар, хикәяләр авторы.

Х е з м.: Литературное наследие. СПб., 1890; Собр. соч. Исторические монографии и исследования: В 8 кн. СПб., 1903–06; Автобиография. М., 1922.

*Әд.:* К о р с а к о в Д.А. Памяти Н.И.Костомарова. К., 1885; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; П и н ч у к Ю.А. Исторические взгляды Н.И.Костомарова: Критический очерк. Киев, 1984; Историки России: XVIII – начало XX в. М., 1996.

*Е.Б.Долгов.*

**КОСТОМУ́КША**, *Карелия Республикасындагы* шәһәр (Петрозаводск шәһәреннән 500 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 29,7 мең кеше (2010), 1000 гә якын татар (2002). К.да татарларның күренә башлавы 1970 еллар ахыры — 1980 еллар башында анда тау казылмаларын баету комб-ты (хәзер «Карелия окатышы» АҖ) төзелү б-н бәйле. Татарлар, башлыча, Чиләбе, Свердловск, Пермь өлкәләреннән, Казакъстан һәм Башкортстаннан күчеп киләләр. 1990 нан «Ханым» татар-башкорт җәмгыяте, 1996 дан К. мөселманнар җәмгыяте эшли.

**КО́СТОЧКО** Анатолий Владимирович (3.3.1939, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1979), проф. (1982), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1961 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1981 дән дарылар һәм каты ракета ягулыгы технологиясе каф. мөдире, 1982–85 тә инженерлык химия-технол. ф-ты деканы. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмаларның техник химиясенә һәм химик технологиясенә карый. К. югары энергияле компонентлар файдаланып махсус эшләнмә составлары алуның фәнни принципларын, нефть табу сәнәгатендә һәм оборона техникасында куллану өчен термик чыдам дары булдыру һәм аны эшләү технологиясенең теоретик нигезләрен эшли (Россиянең төрле пр-тиеләрендә кертелгән). Рецептур модификация ярдәмендә яңа махсус эшләнмәләрнең төп эксплуатация характеристикаларын көйләү алымнарын, искергән дарыларны яңа дарыга, ягулыкка һ.б. халык хуҗалыгы продукциясе төрләренә кабаттан эшләү ысулларын тәкъдим итә. Энергетик баетылган полимерлар модификациясенең теоретик нигезләрен эшли, аларны пластификацияләү закончалыкларын һәм механизмнарын өйрәнә; югары энергияле полимерларның башка полимерлар һәм пластификаторлар б-н яраша алуын бәяләү юлларын тәкъдим итә. К. тарафыннан полимер материалларның эксплуатация характеристикаларын билгеләү ысуллары (полимерларда пластификаторлар бүленешенең бериш булмавын сыйфат һәм сан ягыннан бәяләү, дарыларның термик чыдамлылыгын бәяләү һ.б.) сәнәгатькә кертелә. Уйлап табуга 165 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. «Специальная химия и технология» ж-лы мөхәррире (1979–2004). Сиань заманча химия ин-тының шәрәфле профессоры (1999, Кытай). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Энергетические и баллистические свойства порохов и твёрдых ракетных топлив. Пенза, 1995 (автордаш); Полимерные компоненты порохов и твёрдых ракетных топлив. Пенза, 1996 (автордаш); Специальные полимеры и композиции. К., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**КОСТРО́ВА** Елена Юрьевна (19.9.1965, Ижевск ш.), балет артисты, ТРның халык артисты (2004). 1984 елда Пермь хореография уч-щесен (педагог — Р.Шлямова) тәмамлаганнан соң, Татар опера һәм балет театры артисты (1984–2009). 2009 дан шунда ук педагог-репетитор. Хореографик партияләре арасында: Лиза («Файдасыз саклык», Л.Герольд), Жизель (шул исем. опера, А.Адан), Гөлнара, Медора («Корсар», А.Адан), Маша («Щелкунчик», П.Чайковский), Анюта (шул исем. опера, В.Гаврилин), Белоснежка («Белоснежка һәм җиде гном», К.Хачатурян), Довр кызы, Диңгез кызы, Күк кызы («Пер Гюнт», Э.Григ музыкасы), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин), Зөләйха («Йосыф кыйссасы», Л.Любовский). К. романтик пландагы рольләргә тартылган киң иҗади диапазонлы балерина. Аның биюе җиңел, хәрәкәтләре нәфис, бию техникасы югары тәэсирле актёрлык осталыгы б-н аерылып тора.

*Әд.:* Г о р ш к о в В.Н. Солисты татарского балета. К., 2000.

*В.Н.Горшков.*

**КОСТРОМА́ ӨЛКӘСЕ́**, РФнең Европа өлеше үзәгендә урнашкан. Үзәге — Кострома шәһәре. 1944 елның 13 августында оештырыла. Мәйданы — 60,1 *км²*. Халкы — 688,3 мең кеше (2010), 2700 татар (2002). Татарлар, башлыча, Кострома, Галич, Нерехта, Шарья шәһәрләрендә яшиләр. К.ө.нә 18 йөзнең 2 нче яртысында Романов шәһәреннән (хәзер Ярославль өлкәсенең Тутаев шәһәре) йомышлы татарлар күчеп киләләр. Аларның төп шөгыльләре — иген игү, йөк ташып сәүдә итү. 1780 нән Кострома шәһәрендә мәчет эшли (1930 га кадәр). 1936 да «Промартельләр» татар хоры оештырыла. Хәзерге вакытта К.ө.ндә татар өлкә милли-мәдәни автономиясе (2002 дән) һәм мөселман дини оешмасы (1992 дән) эшли, 1999 дан «Ислам» г-тасы нәшер ителә, Костромада мәчет төзелә. ТР һәм К.ө. арасында мәдәни бәйләнешләр урнашкан. 2003 тә Костромада ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее «Татарстан сәнгате» күргәзмәсен уздыра, шәһәргә Татарстанның иҗат коллективлары килеп тора.

**КОСТРОМА́ ТАТАРЛАРЫ́** (үзатама нугай; ш.у. Романов татарлары буларак та билгеле), Идел буе-Урал яны татарлары төркеме. Якынча 200 кеше исәпләнә (2002). Кострома шәһәренең Чернореченск р-нында һәм Татар бистәсе авылында тупланып яшиләр. Күбесенчә рус телендә сөйләшәләр. Ислам динен тоталар. Тарихи чыганаклар буенча аларның борынгы бабалары нугай татарлары буларак билгеле, алар рус патшаларында хезмәттә торалар һәм элегрәк Ярославль губернасының Роман-Борисоглебский өязендә һәм Романов (хәзер Ярославль өлкәсенең Тутаев ш.) шәһәрендә яшиләр. Патша Иван Грозныйның рухи васыятендә түбәндәге юллар бар: «... Иделдәге Романов шәһәрчеге (ә син аны, улым, нугай морзалары кулында тот)». К.т. күбесе: Булатовлар, Бильгилдиевләр, Мөхәммәтовлар, Мәмәтовлар, Йосыповлар дворянлык дәрәҗәсенә ия була һәм хәрби хезмәтләре өчен бүләк итеп бирелгән бик зур поместьелар һәм вотчиналарны кулларында тоталар. 18 йөз башында патша хакимияте рус булмаган йомышлыларның җир биләвен бетерүгә юнәлтелгән берничә фәрман чыгара. Йомышлы мөселманнарның бер өлеше православиегә күчәргә мәҗбүр була; соңрак алар рус дворяннары составына кертелә. Чукынудан баш тартканнарны 1761 елда Костромадан читкә — Татар бистәсенә күчерәләр, анда инде Казаннан күчеп килгән татарлар яшәгән була; 1762 дә аларның гомуми саны 128 кеше тәшкил итә. Соңрак император Екатерина II, татар феодалларын үзенә социаль таяныч итүгә ниятләп, аларга кайбер өстенлекләр бирә. К.т. дәүләт крәстияннәре катлавына кертелә, һәм алар Кострома өязенең Гридинск волостена беркетелгән аерым авыл

җәмгыяте төзиләр. 1874 тә аларның саны 365 кә, 1902 дә 525 кешегә җитә. 19 йөздә — 20 йөз башында К.т.ның төп шөгыле игенчелек була, өстәмә рәвештә балык тоту, кеше, йөк ташу, кымыз җитештерү һәм аны сату б-н дә шөгыльләнәләр; ирләр ш.у. пароходларда эшчеләр, лоцманнар, капитаннар булып ялланалар, юлаучылар йөртлары тоталар, атлар б-н сату итәләр; хатын-кызлар, гадәттә, җепләр, баулар кебек вак товарлар сата. 20 йөзгә кадәр К.т.нда мәктәп, мәдрәсәләр



Кострома шәһәре татарлары. 20 йөз башы.

эшли, 1880 елларда ук инде аларның сөйләм теле рус теле булуга да карамастан, укыту татар телендә алып барыла. Туган телнең саклануына Касыйм һәм Казаннан татарлар килү булышлык итә: алардан дин әһелләре, укытучылар чакырыла, кәләшләр алына. Замандашлар әйтүе буенча, 19 йөз ахырына Татар бистәсе гаҗәеп күренешкә ия була: урам уртасында агач рәшәткәле мәчет тора, Идел елгасының сул яры буйлап ике рәт булып 70 тән артык төрле төстәге такта түбәле, бизәкле ишекле һәм зур булмаган балконлы, күбесенчә ике катлы, кирпеч йөртлар тезелеп китә. Ике яклы өйалды б-н тоташкан ак һәм кара өйләр өстенлек итә. Ак өй гомумшәһәр көнкүрешенә хас җиһазлар һәм предметлардан (буфет, шкаф, диван, кәнәфи, урындык, көзге, пәрдәләр, чынаяк кирпеч б-н тышланган мич яисә голландка) тора. Кара өй кухня буларак хезмәт итә һәм традицион рәвештә корыла: анда икмәк пешерә торган рус миче салына, тик аның казаны да була (әлегрәк мич биек булмый һәм йөртның уртасына урнаштырыла). Ишек өстенә сәндерә корыла, ишек каршына киң *сәке*, стена буйлап ян сәкеләр (эскәмияләр), сандыклар куела. Өйнең почмакларына, стеналарына тукылган сөлгеләр эленә, идәнгә кулдан сугылган паласлар җәелә. Утарларда, тораклардан тыш, хуҗалык корылмалары — амбар, ат абзары, лапас, кар базы була; яшелчә бакчасы артында ак мунча урнаштырыла. К.т. киеме озак вакытлар милли колоритны саклап килә: ир-атлар утыртма якалы күлмәк, жилет, билле бишмәт һәм киң балаклы чалбар, башларына түбәтәй, аның өстеннән урамга чыкканда кыйисыз күк киез эшләпә кияләр; сезонга карап, кара күн итекләрдән, галошлы ботинкалардан яки киез итектән йөриләр. Хатын-кызлар киеме киң җиңле күлмәктән һәм билләп тегелгән җиңсез озын кафтан — «корсет»тан гыйбарәт була. Кайтарма якалы билле бишмәтләр өске кием буларак кулланыла. Диагональ буйлап өчпочмак кебек бөкләнгән һәм үзенчәлекле рәвештә бәйләнә торган яулыклар көндәлек баш киеме санала. Бәйрәмнәрдә кызлар — такыя, яшь хатыннар калфак кияләр. Өлкән яшьтәге хатын-кызлар башларына тастар урыйлар. Кәләшнең туйда кия торган баш киеме ак яулык — кихчә, маңгай бәйләвече — битлек һәм япмадан (бильгинец) тора. Хатын-кызлар костюмын тәңкәләрдән һәм сәйләннән төрле бизәмәләр, бәйләнгән ак оеклар һәм йомшак күн башмаклар, ботинкалар яисә бәйрәмчә аяк киеме — чигүле сәхтиян читекләр тулыландыра. К.т. традицион азык-төлеккә: ит һәм сөт продуктларына, камыр ризыкларына өстенлек бирәләр. Рус кухнясыннан үзенчәлекле ризык — «горшок бәлеш» үтеп керә. Мөселманнарның барлык дини бәйрәмнәре дә билгеләп үтелә. Язын «кызыл җомырка» («кызыл йомырка») көнен уздыралар, бу көнне йомыркалар буяп, балаларга өләшәләр. Яз һәм җәй көннәрендә болынга чыгып, бистәнең барлык халкы һәм рус кунаклары катнашында күмәк күңел ачулар оештырыла, русларның «Семик» бәйрәме вакытында исә кызлар өчен күңел ачулар уздырыла. Өйләнешү димләп оештырыла. Башта вәгъдәләшү, аннары кыз ярәшү үткәрелә; шуннан соң дус кызлар б-н кыз озату кичәсе һәм егетнең дуслары б-н җыелышу кичәсе уздырыла; никахлашу кәләш ягында, туй кияү йортында үтә. Туй йолалары арасында рус милли традицияләреннән алынганнары да аз түгел. Хәзерге көнгә кадәр К.т. үзләрен татарлар дип санайлар һәм җирле этник үзаңны саклыйлар, милли мәдәниятккә, телгә, ислам диненә карата зур ихтирам күрсәтәләр. Костромада укучыларны татар халкының тарихы, традицион рухи һәм матди мәдәнияте, хәзерге тормышның төрле өлкәләрендә ирешкән казанышлары б-н таныштырып баручы «Ислам» г-тасы чыгып килә.

*Әд.:* Козловский А. Взгляд на историю Костромы. Кострома, 1840; Пирогов В. Материалы для статистики Костромской губернии. Кострома, 1881. Вып. 4; Карамзин Н.М. История государства Российского. СПб., 1897. Т. 5; Скворцов Л. Материалы для истории г.Костромы. Кострома, 1913. Ч. 1.

*Ф.Л.Шәрифуллина.*

**КОСТРОМИТИ́НОВ** Николай Михайлович (29.7.1925, Вятка губ. Яранск ш. — 2.8.2010, Казан), вет. клиницисты, вет. фән. д-ры (1981), проф. (1983). 1952 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1952–55 тә Тобол шәһәренең вет. дәвалау бүлеге табибе. 1955–60 та Омск вет. ин-тында, 1960–64 тә Дагстан, 1964–69 да Дон а.х. ин-тларында эшли. 1969–72 дә Төньяк Кавказ вет. фәнни-тикшерену ин-тының (Новочеркасск ш.) лейкозларны өйрәнү лаб-ясе мөдире. 1972 дән Казан вет. медицинасы академиясендә, 1985–92 дә клиник диагноз кую каф. мөдире. Хезмәтләре бозауларда кан, сөяк мие, мөгезле эре терлекләрдә лейкоз авыруларын өйрәнүгә карый.

Хезм.: Возрастные изменения кровообразования у телят // Ветеринария. 1961. № 2; К патогенезу лимфолейкоза крупного рогатого скота // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1975. Т. 118; Диагностика лейкозов крупного рогатого скота. К., 1980.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КОСТЫЛЁВ** Константин Владимирович (25.11.1916, Иркутск ш. — 25.5.1990, Казан), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1971), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1977). 1941 елда Казан ун-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Казан ун-тында эшли, Астрономия обсерваториясенең астрофизика бүлеге җитәкчесе (1952–56), радиоастрономия каф. мөдире (1962–87), проф. (1987–90). Хезмәтләре метеор күренешләрен матем. модельләштерүгә карый. К. электрофотометр, метеор радиолокаторлары өчен автомат рәвештә теркәүче аппаратлар, метеор. радиоэлемтәсен эшли. Метеор радиотрассаларын модельләү һәм исәпләүләр үткәрә. СССР ФА Астрономия советының кометалар һәм метеорлар буенча комиссиясе рәисе урынбасары (1962–73). Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Общая теория коэффициентов заполнения // Метеорное распространение радиоволн. К., 1963; Астрономические основы метеорной радиосвязи. К., 1970; Возможность использования методов оптимизации для определения параметров метеоров // Астрон. вестн. 1980. Т. 14, № 2 (автордаш).

*Әд.:* Тептин Г.М. Константин Владимирович Костылёв. К., 2003.

*Р.Г.Усманов.*

**КОСТЫ́ЛЬ**, күл. Көнчыгыш Кама алдында. Мамадыш р-ның Малмыш авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Вятка елгасының уңъяк яры тугаенда элеккеге су юлында сакланып калган. Су өслегенең мәйданы 10,12 *га*. Озынлыгы 1200 *м*, иң зур киңлеге 165 *м*.

**КОСТЮ́НИН** Демьян Евстигнеевич (21.10.1928, Чаллы кантоны, хәзерге Әлмәт р-ны Никольский а. — 7.1.2004, шунда ук), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Лениногорск нефть техникумын тәмамлый (1966). 1941–52 елларда Әлмәт р-ның «На штурм» к-зында, 1952–89 да «Татнефть» ҖБнең «Әлмәтнефть» НГДУында (өлкән оператор, нефть һәм газ чыгару буенча мастер). Дәүләт бүләге СССР нефть сәнәгатен үстерүдәге казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

**КОСЯКА́У** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә һәм Буа елгалары арасында урнашкан. 2010 елда 194 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1565–67 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ишеево буларак та билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да волость идарәсе урнаша, Троица чиркәве (1751 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), фельдшерлык пункты, 6 җил тегермәне, 2 май з-ды, тимерчелек, 2 ашханә, 1 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр

кибете була; дүшәмбе саен базар, ярминкә (1октябрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 438 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 297 ир-ат; 1859 да — 244, 1897 дә — 405, 1908 дә — 477, 1920 дә — 646, 1926 да — 668, 1938 дә — 1062, 1949 да — 622, 1958 дә — 430, 1970 тә — 238, 1979 да — 301, 1989 да — 223, 2002 дә — 185 кеше.

**КОСЯКА́У КҮЛЕ́**, Идел алдында. Яшел Үзән р-нының Косякау авылы үзәгендә, Әрә һәм Буа елгалары субүләрендә. Су өслегенең мәйданы 4 *га*. Су күләме 56 мең *м*³. Озынлыгы 250 *м*, иң зур киңлеге 210 *м*. Уртача тирәнлеге 1,4 *м*, иң зур тирәнлеге 2,2 *м*. Күлнең барлыкка килүе карст-суффозия күренеше б-н бәйле. Формасы түгәрәк. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.



Косякау күле.

**КОТБ** (Котби) (якынча 1297 — 14 йөз уртасы), төрки-татар шагыйре. Аерым мәгълүматларга караганда Котоба шәһәрендә (Урта Иделдә) туган. Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрендә яшәгән. Алтын Урда ханы Тәнибәк һәм аның хатынына багышлап язылган «Хөсрәү вә Ширин» (1342) поэмасы авторы. Поэма 1383 елда шагыйрь *Бәркә Фәкыйһ* кулы б-н күчерелгән бердәнбер нөсхәдән билгеле (Парижның Милли китапханәсендә саклана). Кульязманың фотокүчермәсе А.Зайончковскийның шәрех-аңлатмалары һәм сүзлеге б-н бергә 1958–61 елларда Варшавада нәшер ителә, соңрак Казанда («Хөсрәү-Ширин хикәяте», 1969) һәм Ташкентта (1973) басыла. Поэма 4659 бәйттән тора, ул — Низаминың шул исемдәге поэмасының фарсы теленнән ирекле тәрҗемәсе. Текстка төрки-татар шагыйренең оригиналь шигырьләре дә кергән. К. Аллаһка, Мөхәммәд пәйгамбәргә, Тәнибәк ханга дан җырлый, язарга алынуының серен-максатын ача. Аннары әсәрнең төп герое Хөсрәүнең тормыш юлын, Ширин h.б. геройлар б-н мөнәсәбәтен тасвирлый.

«Хөсрәү вә Ширин» — бөек мәхәббәт, тормыш мәгънәсе, хөкемдар б-н халык арасындагы мөнәсәбәтләр, әхлакый кыйммәтләр турындагы романтик әсәр. К. фикеренчә, мәхәббәт — галәмнең этәргеч көче. Ул кеше тормышын мәгънәле итә, бер-берең карата хөрмәт һәм татулык хисе тәрбияли. Поэма геройлары Фәрһад һәм Ширин тышкы матурлыклары б-н генә түгел, рухи камиллекләре б-н дә аерылып торалар: аларга әхлакый пакьлек, тугрылык, кыюлык, гаделлек хас. Хөсрәү образы каршылыклы. Ул чибәр, акыллы, кыю, бер үк вакытта бик үк гадел булмаган, яман гамәлләр дә кыла. Көнчелегеннән ул Фәрһадне үлемгә дучар итә. Көчле рухлы бу зат үз мәхәббәте өчен көрәштә һәлак була.

Әсәрнең иң мөһим темасы — гадел хөкемдарлык. К. фикеренчә, халык бәхете, беренче чиратта, хөкемдарның әхлакый сыйфатларына бәйле: ул гадел һәм акыллы булырга тиеш, якыннарының (яраннарының) эшләрен күзәтеп торырга, гадел хөкем итү яклы булырга, үз халкының ихтыяҗын, теләк-омтышларын белеп торырга бурычлы. К. фикеренчә, тәхеткә бары тик вөҗданлы һәм көчле рухлы, олы мәхәббәткә ия булган кешеләр генә дәгъва итә ала. Шагыйрь сугышны һәм кан коюны гаепли, кеше үлемен зур югалту дип саный. К. иҗатына шәхеснең рухи дөньясына, геройларның кичерешләренә игътибар итү хас. Аның поэтик сөйләме матур аһәңле, стилистик фигуралар (градация, анафора, риторик сорау, мөрәҗәгать), образлы тәгъбирләр б-н сугарылган.

Ә с ә р.: Хөсрәү вә Ширин. К., 2003.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Котб иҗаты. К.. 1976; М и н н е г у л о в Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Z a j a c z k o w s k i A. Najstarsza wersja turecka «Husrävu Širin» Qutba: 3 cz. Warsz., 1958–61.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**КОТДУ́СОВ** Җәвид Габдерәим улы (28.12.1928, Симферополь ш.), хор дирижёры, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968, 1977). 1962 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1961–67 дә ТАССРның Җыр һәм бию ансамблендә хормейстер, 1967–70 тә баш хормейстер. 1970 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта (1998 гә кадәр хор дирижёрлыгы каф. мөдире, 1987 дән проф.). К. җитәкчелегендә эшләгән хор коллективлары төрле классик, рус һәм чит ил хор репертуарларын (Ф.Гайдн, Ф.Шуберт, Р.Вагнер, Дж. Верди, М.Равель, Дж.Гершвин, Д.Шостакович, А.Шнитке h.б.) югары дәрәҗәдә проф. һәм сәнгатьчә башкару б-н аерылып тора. К. татар хор музыкасын («Зиләйлүк», «Гөлҗамал», «Сакмар» татар халык җырлары эшкәртмәләре; Б.Мөлековның «Казан» ораториясе, И.Якуповның «Анчар» кантатасы h.б.) пропагандалауга зур өлеш кертә. Россия шәһәрләре коллективларында хор дирижёры буларак чыгышлар ясый. 1998 дән Кырым дәүләт индустриаль-пед. ун-тының муз. тәрбия каф. мөдире. Кырым татарларының музыка сәнгатен пропагандалау буенча актив эш алып бара. Хор әсәрләре җыентыкларын төзүче, хор өчен язылган әсәрләр авторы.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КОТДУ́СОВА** Шәфика Йосыф кызы (18.3.1910, Севастополь ш. — 20.4.1956, Мәскәү, Казанда җирләнә), җырчы (колоратуралы сопрано), пианист, ТАССРның атказ. артисты (1950). 1950 елда Казан консерваториясен (К.Цветов классы) тәмамлый.



Ш.Й. Котдусова .

1931–41 дә Керчь һәм Симферополь шәһәрләрендә радио концертмейстеры, Кырым татарлары җыр һәм бию ансамбле солисты, 1941–51 дә Татар опера һәм балет театры, 1951–54 тә Татар филармониясе, 1954–56 да СССР Гастрольләр бюросы солисты. Төп



Ш.Й. К о т д у с о в а «Алтынчәч» ролендә. 1949.

партияләре: Джильда («Риголетто», Дж.Верди), Розина («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Алтынчәч (шул исем. опера, Н.Җиһанов), Фраскита, Микаэла («Кармен», Дж.Бизе), Сәрвәр («Башмагым», Җ.Фәйзи). Классик оперетталарда да төп партияләрне башкара. Җырчының концерт репертуарын



Ш.Й. К о т д у с о в а Гөлчәһрә («Аршин мал алан», У.Гаҗибәков музыкасы) ролендә.

татар композиторларының вокаль әсәрләре, татар һәм башкорт җырлары h.б. тәшкил итә. Җырчының тавышы матур тембрлы, хисле булуы, мул яңгырашы б-н аерылып тора.

*Р.И.Такташ.*

**КОТЕЛО́В** Иван Петрович (1823, Чабаксар ш. — ?), архитектор, архит-ра академигы (1856). 1852 елда СА тәмамлый. А.К.Тон шәкерте. 1853 тән — Казан шәһәре архитекторы ярдәмчесе; 1856 тән — Казан губернасының казна палатасы, 1866–93 тә — Казан дары з-ды архитекторы. К. үзен гражданлык архит-расы өлкәсендә тәҗрибәле белгеч һәм сәнәгать архит-расы өлкәсендә оста архитектор итеп таныта. Аның проектлары буенча түбән чиндагы хәрбиләр өчен казармалар, дары з-ды хезмәткәрләре өчен ике катлы таш йортлар, эшмәкәрлек йорты б-н янәшә мәчет салына. К. завод биналарының күпсанлы проектларын әзерли: 1866–93 елларда дары з-ды терр-ясендә агач амбарлар, каланча, заводның инженерлык идарәсе бинасы, металл кою өчен таш алачык һ.б. төзелә. 1870–73 тә Постаучылар бистәсендәге казарма биналарын яңарту б-н шөгыльләнә. К. проектлаштырган аеруча билгеле төзелешләрнең берсе — заводның 100 еллыгы хөрмәтенә корылган *Юбилей а́ркасы* (1888). Шул хезмәтендә автор, классицизм элементларын һәм формаларын чын осталарча кулланып һәм камилләштереп, аларны эклектика классицизмы рухында яңарта, үз стилистикасы омтылышларын тулысынча чагылдыруга ирешә.

*Әд.:* Республика Татарстан: памятники истории и культуры: Каталог — справ. К., 1993.

*Л.М.Мортазина.*

**КОТЕЛО́В ЙОРТЫ́**, Казанда архит-ра истәлеге; 19 йөз башы рус классицизмы үрнәге. Казанның Киров р-нындагы җитен комб-ты терр-ясендә урнашкан. 1833 елда арх. П.Г.Пятницкий проекты буенча завод хуҗасы Н.И.Котелов өчен төзелә. Турыпочмаклы, ярты өлеше таштан салынган мезонинлы ике катлы йортның түбәнге катында башта завод конторасы урнаша. Өске катта хуҗаның торак-ял бүлмәләре була. Төп фасад буенча урнашкан заллар анфилада рәвешендә планлаштырылган, аларны торак бүлмәләреннән коридор аерып тора. Мезонинда хезмәтчеләр бүлмәләре урнашкан. Беренче катның кирпеч стеналары штукатурланган, икенче кат такта б-н тышланган. Симметрик композицияле төп фасадның үзәк өлешендә портиклы ишек бар. Портик фронтон б-н тәгәлләнүче Коринфский стиле ордерындагы 6 колоннага терәлеп тора. Аскы катның тәрәзә уемнары рустовкаланган а́рка хасил итә, өске каттагылары турыпочмаклык рәвешендә эшләнгән. Өске кат тәрәзәләренең зуррак булуы аларга өстенлек биреп тора. Икенче катның колонналар арасын челтәрле металл рәшәткәләр бизи.



Н.И.Котелов йорты. Казан. Арх. П.Г.Пятницкий. 1833.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Л.М.Мортазина.*

**КОТЕЛО́В** Киприан Иванович (1773, Казан — 7.4.1826, шунда ук), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе. Бабасы Алексей (17 йөз ахыры — 18 йөзнең 1 нче яртысы) шәһәр янындагы Ягодный авылы (Казан) экономик крәстияне була, 1722 елда Казан делегациясе составында император Пётр I б-н очрашуда катнаша. К.лар гаиләсе 18–19 йөзләрдә күпсанлы күн з-длары тота. К.ның үзенең дә Ягодный авылында күн з-ды була (1812 дә анда 4 чан, 54 эшче эшли, елга 36500 күн эшкәртелә, Казанда бу — ул чорда иң югары күрсәткеч). Күн һәм мех товарлар б-н сәүдә итә. 1806–08 дә Казан шәһәр магистраты ратманы, 1809–11 дә бургомистры. 1819–21 дә Казан вөҗдан мәхкәмәсе әгъзасы. 1824–26 да Казан шәһәре башлыгы. Казан ярлыларны яклау ком-тына зур күләмдә акча иганә кыла, ш.у. Адмиралтейство бистәсендәге ике катлы таш йорты б-н сабын кайнату з-дын һәм утар җирен (35289 сумлык бәяләнә) Җәмгыять тәрбиясе приказына бирә. Хәйрия эшчәнлеге өчен 1833 тә (үлгәннән соң) алтын медаль б-н бүләкләнә.

Чыг.: Достойны памяти потомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н. Казань и казанцы. К., 1907. Кн. 2.


*Л.М.Свердлова.*

**КОТЕ́ЛЬНИКОВ** Александр Петрович (20.10.1865, Казан — 6.3.1944, Мәскәү), математик һәм механик, техник фән. д-ры (1934), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1934), П.И.*Котельников*ның улы. 1888 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Ксения кыз балалар гимназиясендә, Киев политехник ин-тында (1900–03), Казан (1904–14) һәм Киев (1914–24) ун-тларында укыта. 1924 тән Н.Э.Бауман исем. Югары техник уч-ще, Транспорт инженерлары ин-ты һәм Мәскәүнең башка югары уку йортлары, бер үк вакытта Н.Е.Жуковский исем. Үзәк аэрогидродинамика ин-ты (1930 дан) профессоры. Хезмәтләре гидродинамикага, график динамикага, винтлар теориясенә, кватернионнар һәм комплекслы саннар теориясенең геометриядә һәм механикада кулланылышына карый. К. нәевклид фәзаларда механика һәм векторлы исәпләүләрнең нигезен сала; *Н.И.Лобачевский геометриясенең* (к. *Лобачевский геометриясе*), Эйнштейн һәм Галилей–Ньютон механикаларының оригиналь интерпретацияләрен тәкъдим итә. Механикада векторлы исәпләүләр кулланулы дәреслекләр авторы. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1943). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Винтовое счисление и некоторые приложения его к геометрии и механике. К., 1895; Винты и комплексные числа. К., 1896; Введение в теоретическую механику. М.–Л., 1925; Некоторые применения идей Лобачевского в механике и физике. М.–Л., 1950 (автордаш).

*Әд.:* Александр Петрович Котельников (1865–1944). М., 1968.

**КОТЕ́ЛЬНИКОВ** Алексей Васильевич (1800- ?), каләм б-н рәсем ясаучы, гравёр. САдә укый (1809–18). Казанга килеп чыгуының сәбәпләре билгесез. М.С.Рыбушкинның «Заволжский муравей» ж-лында аерым бүлекләр рәвешендә басылган «Казан каласының кыскача тарихы» китабына (1834) иллюстрацияләр («Казан гимназиясе күренеше», «Һәйкәл күренеше» — 1833, №8, 13) һәм Казанның 3 планын («Казан каласы планы. Бу кала биредә 1552 елның 2 октябрендә патша Иоанн Васильевич Грозный буйсындырган вакыттагыча төгәл күрсәтелгән»,



А.В. К о т е л ь н и к о в. «Казан гимназиясе күренеше». Офорт. «Заволжский муравей» журналындагы иллюстрация. 1883.

«1552 елда Казанны камап алу планы», «Губерна каласы Казанның 1831 елдагы урыны һәм әйләнә-тирәсе планы») ясый. Уемлап эшләнгән рәсемнәр, беренче чиратта, Казан вакытлы матбугатында басылган беренче иллюстрацияләрнең берсе буларак тарихи-мәдәни әһәмияткә ия (Н.Н.Кафтанников хезмәтләре б-н бергә).

*Е.П.Ключевская.*

**КОТЕ́ЛЬНИКОВ** Владимир Александрович (6.9.1908, Казан — 11.2.2005, Мәскәү), радиотехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1947), РФА академигы (1991, 1953 тән СССР ФА акад.), Соц. Хезмәт Герое (1969, 1978). А.П.*Котельниковның* улы. 1931 елда Мәскәү энергетика ин-тын (МЭИ) тәмамлаганнан соң, шунда ук укыта (1980 гә кадәр), проф. (1947), радиотехника ф-ты деканы, каф. мөдире. Бер үк вакытта СССР Элемтә халык комис-тының Элемтә фәнни-тикшеренү ин-тында (1933–44) эшли, МЭИ Махсус КБның директоры һәм баш конструкторы (1947–53) була, СССР ФА Радиотехника һәм электроника ин-тында эшли (1953–87): директор урынбасары, директоры (1954 тән). 1970–75 тә СССР ФАнең вице-президенты, 1975–88 дә — 1 нче вице-президенты, 1988 дән РФА президенты киңәшчесе. Хезмәтләре радиосигналлар кабул итү алымнарын камилләштерүгә, радио кабул итүдә комачаулыкларны өйрәнүгә һәм аларга каршы көрәш алымнарын эшләүгә карый. К. комачаулыкларга потенциаль тотрыклылык теориясен фәнни нигезли. Электр элемтәсе линияләренең үткәрүчәнлек сәләте өлкәсендә беренче тапкыр «исәп башлангычлары теоремасы»н матем. яктан формалаштыра һәм исбатлый, соңыннан ул К. теоремасы дип аталала башлый (1933), элемтә һәм информатика теориясенең төп принципларыннан берсенә әверелә. Математик яктан ачыла алмаслык

шифрлау системасына таләпләр билгели һәм аның шифрын ачуның мөмкин түгеллеген дәлилли (бу хәл илебез криптографиясе үсешенең нигезенә салына). К. җитәкчелегендә төзелгән ачыла алмаслык шифрлы элемтә системалары 1942–45 тә хәрәкәттәге армиядә фронтлар б-н элемтәдә, ш.у. Германиянең капитуляциясен кабул иткән сов. делегациясенең Мәскәү б-н бәйләнешләрендә киң кулланыла. Космосны тикшерүләрдә яңа юнәлеш — планета радиолокациясенең барлыкка килүе һәм үсүе К. исеме б-н бәйле; аның идеяләре идарә итү системалары төзелешендә һәм космик аппаратларны контрольдә тотуда киң кулланыла. РСФСР ЮС депутаты һәм 1973–79 да рәисе, 1979–89 да СССР ЮС депутаты. СССРның Дәүләт (1943, 1946), Ленин (1964), Халыкара Дж. Неру (1985) бүләкләре лауреаты. Алты Ленин ордены, Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ФАнең алтын медальләре (А.С.Попов, М.В.Ломоносов, М.В.Келдыш исем.) б-н бүләкләнә. Казанның Н.Ершов урамындагы скверда галимнең бюсты куелган. К. исеме кече планетага (№ 2726) бирелгән.



В.А.Котельников.

Х е з м.: Основы радиотехники: В 2 ч. М., 1950–54 (автордаш); Теория потенциальной помехоустойчивости. М.–Л., 1956; Сигналы с максимальной и минимальной вероятностями обнаружения // Радиотехника и электроника. 1959. Т. 4, вып. 3; Радиолокационная установка, использованная при радиолокации Венеры в 1961 г. // Радиотехника и электроника. 1962. Т. 7, № 11 (автордаш); Результаты радиолокации Венеры в 1961 г. // шунда ук. Связь с внеземными цивилизациями в радиодиапазоне // Внеземные цивилизации. Ереван, 1965.

*Әд.:* Т е п т и н Г.М. Учёный божьей милостью (В.А.Котельникову — 95 лет) // Науч. Татарстан. 2003. № 3/4.

*Р.Г.Усманов.*

**КОТЕ́ЛЬНИКОВ** Пётр Иванович (1809, Курск губ., Суджа ш. — 28.5.1879, Казан), математик һәм механик. 1828 елда Харьков ун-тын тәмамлаганнан соң, Дерпт профессорлар ин-тына математиклар М.Ф.*Бартельс* һәм В.Я.Струве җитәкчелегендә эшләү өчен җибәрелә, 1833–35 тә Берлинда Я.Штейнер һәм Л.Дирихле лекцияләрен тыңлау өчен командировкада була. 1835 тән Казан ун-тында: гамәли матем. кафедрасында укытучы, экстраординар (1837 дән), ординар (1838 дән) проф., физика-матем. ф-ты деканы (1839–62), атказ. проф. (1863). Хезмәтләре механикага карый. К.ның саф һәм гамәли матем. буенча лекцияләре күпсанлы тыңлаучыларны үзенә җәлеп итә. Университет архивында аның аудиториядә һәм халык алдында ясаган чыгышлары, ш.и. Н.И.Лобачевскийның нәевклид геометриясенә бәя бирелгән «Математикага каршы бару турында» («О предубеждении против математики», 1842) чыгышы текстлары сакланган. К. фәнни җәмгыятьләрнең, ш.у. Казанны төзекләндерү буенча комиссияләрнең эшендә актив катнаша.

Х е з м.: О численном значении некоторых сумм // Уч. зап. Казан. ун-та. 1848. Т. 4.

*Әд.:* К о т е л ь н и к о в а Е.П., С у в о р о в Ф.М. П.И.Котельников (1809–1879). К., 1887; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

**КО́ТЛИН** Зәки Йосыф улы (17.11.1900, Казан губ., Спас өязе Коры Көрнәле а. — 1942), генерал-майор (1942). Мөселман кызыл командирлар курсын (Казан, 1920), «Выстрел» курсларын (Мәскәү, 1926), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1931) тәмамлый. 1914–16 елларда Казан тимер юл станциясендә ремонтлаучы булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918 дән Кызыл Армиядә, Көнчыгыш фронтта сугыша, рота, батальон б-н җитәкчелек итә. 1931 дән 1 нче Казан укчы дивизия полкының штаб башлыгы ярдәмчесе, башлыгы. 1933–39 да штаб башлыгы, полк командиры, 57 нче Урал укчы дивизия командиры ярдәмчесе. 1939–41 дә М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия укытучысы. 1941 нең июленнән 270 нче укчы дивизия командиры. 1942 нең маенда Көньяк-Көнбатыш фронтта сугышта һәлак була. Ленин, «Бохара Йолдызы» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КОТЛО́ВКА** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасындагы пристань. 2010 елда 248 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 75%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык б-н шөгыльләнә, елга судноларына матрос булып яллана. 20 йөз башында Ильинский чиркәве (1838 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе, китапханә була; базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7271,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда. 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 2221, 1887 дә — 2320, 1905 тә — 2597, 1920 дә — 2111, 1926 да — 2126, 1938 дә — 1649, 1949 да — 757, 1958 дә — 467, 1970 тә — 328, 1979 да — 257, 1989 да — 160, 2002 дә — 274 кеше.

К. янында *Котловка комплексы* бар.

**КОТЛО́ВКА** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 58 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 120, 1938 дә — 173, 1949 да — 134, 1958 дә — 171, 1970 тә — 208, 1979 да — 148, 1989 да — 90, 2002 дә — 71 кеше.

**КОТЛО́ВКА КО́МПЛЕКСЫ** (археол.). Кама елгасының уң ярында Алабуга р-ны Котловка авылы янында урнашкан. К.к. ядкәрләре 1888 елда А.А.Спицын, 1892–94 тә Ф.Д.Нефёдов, 1895 тә И.Н.Смирнов, 1930 да А.В.Збруева, 1959 да А.Х.Халиков һ.б. тарафыннан тикшерелә. Бронза гасыр Котловка туктаулыгы; б.э.ның 1 нче меңьеллыгы уртасы Котловка I авыллыгы, элгәреге тимер гасыр Котловка авыллыгы, 2 шәһәрлек (б.э.ның 1 нче меңьеллыгы Котловка I «Шишка» һәм монголларгача дәвер болгар чоры шәһәрлеге; б.э.ның 1 нче меңьеллыгы уртасы һәм элгәреге тимер гасыр Котловка II шәһәрлеге) һәм элгәреге тимер гасыр Котловка (Дмитриевка) каберлеге керә.

К.к. терр-ясендә төелгән кабырчык кушылган керамика кисәкләре табыла, бизәкләре юк. Әлеге савыт-саба Пьянобор археол. культурасы б-н бәйле дип фаразлана.

*Әд.:* Н е ф ё д о в Ф.Д. Отчёт об археологических исследованиях в Прикамье, проведённых летом 1893 и 1894 // Материалы по археологии восточных губерний России. М., 1899. Вып. 3; З б р у е в а А.В. История населения Прикамья в ананьинскую эпоху. М., 1952; Х а л и к о в А.Х. Волго-Камье в начале эпохи раннего железного века. М., 1977; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

*П.Н. Старостин.*

**КОТЛЫ́ БӨКӘ́Ш** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 1309 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Кирпеч, май з-длары. Урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә. Авыл тарихы музее. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Б.тә мәчет (1816 да салынган иске мәчет урынында 1907 ел тирәсендә төзелә; архит-ра истәлеге; хәзерге көндә эшли), кирпеч з-ды, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1234,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында, 1927 нең 14 февраленнән Балык Бистәсе р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз р-ны үзәге. 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 121 ир-ат; 1859 да — 576, 1897 дә — 828, 1908 дә — 1045, 1920 дә — 1053, 1926 да — 1000, 1938 дә — 1212, 1949 да — 1389, 1958 дә — 2044, 1970 тә — 1764, 1989 да — 1299, 2002 дә — 1264 кеше.

**КОТЛЫ́КЪ СОЛТА́Н** (Кулук, Котлыгъ) (?–?), Себер ханлыгы идарәчесе, Ибакъ хан-

ның улы. Атасы вафатыннан соң (1485) күрше олыс хөкемдарлары б-н көрәшә. 1505 елда Пермь җирләренә яу чаба.

*Әд.:* Устюжский летописный свод. М.–Л., 1954.

**КОТЛЯ́Р** Леонид Михайлович (19.6.1937, Киев), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1975), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1964–82 дә Казан ун-тының Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1982 дән Кама политехник ин-тында (Чаллы ш.; 2012 дән Казан (Идел буе) федераль ун-ты составында) югары һәм гамәли матем. каф. мөдире, бер үк вакытта, 2000 нән проректоры. Хезмәтләре гидромеханикага карый. Сыеклыкның ирекле өслекле агымнарын, сызыкча бүленгән корылмалар шартлау теориясен, градиенты үзгәрешле фильтрлаштыру, тигезләнешсез газ динамикасы һәм металларны электрохимик формалаштыру теориясен тикшерә.

Х е з м.: Об одном случае струйного течения идеальной жидкости // Изв. вузов. Математика. 1976. № 2; Нелинейные задачи теории струйных течений тяжёлой жидкости. К., 1978 (автордаш); Плоские стационарные задачи фильтрации жидкости с начальным градиентом. К., 1978 (автордаш).

**КО́ТОВ** Александр Михайлович (24.1.1925, Тула өлкәсенең Серебрянопрудский р-ны Крутовец а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1956). 1956–60 елларда СССР авиация сәнәгате министрлыгының Казан проект-конструкторлык бюросы инженеры, конструкторлык бригадасы башлыгы, 1960–61 дә профком рәисе. 1961–62 дә КПССның Казан Ленин райкомы секретаре, 1962–65 тә 1 нче секретаре. 1965–71 дә КПССның Казан шәһәр ком-ты секретаре. 1971–85 тә ТАССР МС рәисе урынбасары (1973–80 дә 1 нче урынбасары). Сәнәгать, төзелеш, юл хуҗалыгы, транспорт, элемтә һ.б. тармаклар б-н җитәкчелек итә. 1963–75, 1980–85 тә ТАССР (1967–71 дә Президиум әгъзасы), һәм 1975–80 дә РСФСР ЮСлары депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**КО́ТОВ** Леонид Николаевич (21.2.1912, Тамбов ш. — 17.4.1995, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1936). 1936–41 елларда Казан авиация з-дында инженер, бүлек башлыгы, 1941–42 дә партком секретаре урынбасары. 1942–47 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында авиация сәнәгате бүлеге мөдире, 1947–49 да машина төзелеше бүлеге мөдире урынбасары. 1949–52 дә ВКП(б) ҮКның Казандагы 22 нче заводы парторгы, 1952–53 тә КПССның Казан өлкә ком-тында сәнәгать-транспорт бүлеге мөдире. 1953–63 тә ТАССР коммуналь хуҗалык министры. 1963–73 тә Мәскәү технол. һәм җитештерүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы инженеры. Авиация сәнәгатен үстерү мәсьәләләренә караган мәкаләләр авторы. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**КО́ТОВ** Сергей Архипович (9.1.1950, Казан), спортчы, тренер (алкалы хоккей), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1975), Россиянең атказ. тренеры (1992). Мәскәү өлкә физик культура ин-тын тәмамлый (1982). СССР чемпионы (1974), СССР чемпионатларында медальләр (көмеш, 1975; бронза, 1973, 1978) ала, СССР кубогы (1974) һәм Европа чемпионнары кубогы иясе (1975). 1967–70 тә Урицкий исем. спорт клубы (Казан), 1970–71 дә Куйбышев армия спорт клубы, 1971–72 дә — ЦСКА, 1972–83 тә «Крылья Советов» (Мәскәү), 1985–86 да «Инсбрук» (Австрия) хоккей клублары составында уйный. 1983–85 тә «Крылья Советов» спорт клубының балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы, 1986–2003 тә «Крылья Советов» (Мәскәү), 2003–2005 тә «Ак Барс» (Казан), 2005–06 да ХК МВД (Тверь ш.), 2006–08 дә «Сибирь» (Новосибирск ш.), 2008–10 да «Динамо» (Мәскәү), 2010 нан «Югра» (Ханты-Мансийск ш.) клублары тренеры.

**КОТО́ВСКИЙ** Михаил Петрович (7.4.1946, Белоруссия ССРның Могилёв өлкәсе, Кричев р-ны Сычик а.), генерал-майор (1984). Ташкент танк уч-щесен (1966), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (1974) тәмамлый. Чирчик, Слуцк, Мәскәү, Овруч-Хмельницкий, Мукачево, Бердичев шәһәрләрендә хезмәт итә; 1966–69 елларда танк взводы, ротасы командиры, 1974–79 да штаб башлыгы, танк полкы командиры, 1979–87 дә штаб башлыгы, танк берләшмәсе командиры. 1987 дән Сүрия Гарәп Респ-касында (Дәмәшкъ) хәрби белгеч. 1990–2001 елларда Казан суворовчылар хәрби уч-щесе башлыгы. Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 1996. Вып. 2.

**КОТО́ВЩИКОВ** Николай Иванович (30.8.1846, Казан губ., Зөя өязе Горные Моркваши а. — 25.12.1905, Казан), терапевт, мед. д-ры (1875). Н.А.Виноградов шәкерте. 1869 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, 1870–72 дә Чабаксар шәһәрендә земство хезмәтендә, табиб. 1872 дән Казан ун-тында: госпиталь терапиясе клиникасында (1875 кә кадәр), 1876–94 тә диагноз кую каф. профессоры, 1894 тән госпиталь терапиясе клиникасы, 1903 тән факультет терапиясе кафедраларында; атказ. проф. (1900). Хезмәтләре диагноз кую мәсьәләләренә, чәчәк авыруын булдырмау, аускультация ысулларына карый. К. гамәли табиб буларак киң танылa. Эчке авыруларны клиник тикшерү ысуллары буенча кулланма авторы. Казан табибләре җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы.

Х е з м.: Способы определения азотной и азотистой кислот (в разведённых растворах) индиго-серною кислотою. К., 1875; Исследование органов груди и живота. К., 1881; О вакцинации в период нагноения натуральной оспы. К., 1899.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; К а з е м - Б е к А.Н. Николай Иванович Котовщиков, профессор: Некролог // Казан. мед. журн. 1905. № 5.

**КО́ТЫЛЕВ** Олег Александрович (31.1.1929, Уфа ш.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (1976), проф. (1979). ТАССРның атказ. вет. табибе (1979). 1952 елда Иванов а.х. ин-тын тәмамлый. 1952–53 тә Карел-Фин АССРның Пудож шәһәрендә Үзәк зоовет. участогы мөдире, 1953–54 тә Ярославль өлкәсе Данилов р-ны Захаровск МТСының өлкән вет. табибе, 1954–55 тә Иваново а.х. ин-тының кичектергесез хирургия ярдәме каф. ассистенты, 1955–56 да Ярославль өлкәсенең Тутаев зоотехния һәм вет. техникумы директоры урынбасары, 1956–60 та Ленинград вет. табибләре белемен камилләштерү ин-тында. 1961 дән Казан вет. ин-тында, 1977 дән аэрозольләр бүлеге мөдире. 1984 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тының аэрозольләр б-н иммунлаштыру лаб-ясе мөдире. 1994–96 да Республика вет. лаб-ясендә вет. табибе, 1996 дан А.х. терлекләре авыруларын дәвалау һәм кисәтү чараларын камилләштерү буенча фәнни-җитештерү лаб-ясендә (Биектау пос.) бүлек мөдире. Хезмәтләре аэрозоль формада биол. һәм дәвалау препаратларын куллануга, дәвалау чараларын терлекләрдә йогышлы авыруларга каршы вакциналар, бактериологик диагноз кую ысулларын эшләүгә, терлекчелек хуҗалыкларын лептоспироз, листериоздан арындыруга карый.

Х е з м.: О заболевании свиней листериозом в Татарской АССР // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1969. Т. 102; Групповая иммунизация свиней против листериоза // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1978. Т. 129.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины. К., 2006.

**КОЦЮБЕ́НКО** Николай Макарович (21.5.1949, Украина ССРның Николаев өлкәсе, Первомайский р-ны Станиславчик а.), таможня хезмәте генерал-лейтенанты (1998). Одесса ун-тын тәмамлый (1980). 1971–78 дә Ильичёв, 1978–81 дә Григорьев (Украина ССР, Одесса өлкәсе), 1981–87 дә Железнодорожный (Калининград өлкәсе) таможняларында инспектор, өлкән инспектор, башлык. 1987–93 тә Казан таможнясы башлыгы, 1993–2000 дә Татарстан таможня идарәсе, 2001 дән Татарстан таможнясы башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КОЧЕЛА́ЕВ** Борис Иванович (19.4.1934, Мәскәү өлкәсенең Долгопрудный ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1968), проф. (1970). ТАССРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1984, 2000), Казан ун-тының атказ. профессоры (2004). 1957 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1960 тан шунда ук эшли, теоретик физика каф. профессоры (1968 дән), каф. мөдире (1973–2000). Хезмәтләре гадәти һәм югары температуралы үтә үткәргечләрнең (ВТСП) магнит, электр һәм кинетик үзлекләренә, түбән үлчәмле системаларның һәм парамагнитик каты җисемнәрнең үзлекләренә карый. К. үтә югары ешлыклы кыр, яктылык, гипертавыш тәэсирендә парамагнитик кристаллардагы спиннар һәм фононнарның көчле корреляцияләнгән системасында нәсызыкча күренешләр теориясен төзи. Шушы теория нигезендә ЭПР сызыгы канатын импульслы туендырганда резонанслы фононнар ташкыны барлыкка килү һәм яктылыкның спинлы үтә чәчелүе күренешләрен

аңлата. Парамагнитик катышмалары булган үтә үткәргечләрдә спин кинетикасы һәм ЭПР теориясен эшли. ВТСП магнитлануының гадәттән тыш тиз релаксациясе үлчәү алымын тәкъдим итә һәм ВТСПда электрон-фонон тәэсирләшүләренең ролен билгели. Ике үлчәнешле магнетикларның магнитик һәм кинетик үзлекләре теориясен спин дулкыннары турындагы күзаллаулар нигезендә үстерә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Studies of spin-systems by means of light scattering in paramagnetic crystals // Spectroscopy of solids containing rare-earth ions. Amst., 1987 (автордаш); Spin dynamics in $La_{2-x}Sr_xCuO_4$ doped with Mn as revealed by an ESR study // Phys. Rev. B., 1994. V. 49 (автордаш); The Beginning of Paramagnetic Resonance. Singapore–New Jersey–L.–Hong Kong, 1995 (автордаш); Three-Spin Polarons and their Elastic Interactions in Cuprates // Mod. Phys. Lett. B., 2003. V. 17 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**КОЧЕРГИ́Н** Анатолий Васильевич (18.11.1951, Ульянов өлкәсенең Мәләкәс ш.), гамәли акустика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), проф. (1997), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1999). 1975 елда Казан хәрби инженерлар уч-щесен тәмамлаганнан соң, Совет Армиясендә хезмәт итә (Белая Церковь ш.), 1981–85 тә Үзәк гаскәрләр төркемендә (Чехословакия). 1985 тән Казан югары артиллерия командирлары уч-щесендә, полковник (1994), артиллерия коралларын конструкцияләү, куллану һәм проектлаштыру нигезләре каф. башлыгы (1998 дән). Хезмәтләре реактив двигательле очкыч аппаратлар кузгалып киткәндә туган акустик кырларны өйрәнүгә карый. К. авиация двигательләре элементларына (компрессор калаклары, турбиналар, яну камералары корпусларының эретмәле җөйләре һ.б.) диагностика үткәрә, эчке янулы двигательләргә виброакустик диагностика ясый. Реактив двигательләрдә яну продуктлары агымнарының тавыш тизлегенә кадәрге һәм аннан югары тавышын киметү буенча күп кенә чаралар эшли. К. җитәкчелегендә сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын экологик чиста яндыру һәм зарарсызландыру, бер үк вакытта, чыккан газларның җылысын утильләштерү өчен термик җайланмалар уйлап табыла һәм эшләнә. Энергетика машиналары тавышының кешегә эшчәнлегенә тәэсирен өйрәнү буенча тикшеренүләр җитәкчесе. Ишетү һәм сөйләү сәләте бозылган кешеләрне укыту өчен ишетү аппаратының (протез) универсаль технологиясен, ш.у. «ишетергә һәм сөйләргә» дип аталган методика булдыра. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Газодинамика сопел и струй ракетных двигателей. К., 1991 (автордаш); Система обучения глухих и слабослышащих на основе информационно-энергетических кодов русского алфавита. К., 2003 (автордаш); Обеспечение жизнедеятельности. К., 2004 (автордаш).

**КОЧЕРГИ́Н** Сергей Михайлович (4.11.1912, Казан — 3.5.1965, шунда ук), электрохимик, химия фән. д-ры (1956), проф. (1957), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1961). 1935 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Ногинск «Грампластинка» з-дында (Мәскәү өлкәсе), 1938–41 дә Мәскәү химия-технол. ин-тында эшли. 1945 тән Казан химия-технол. ин-тында: технол. ф-ты деканы (1946–53), физик химия каф. мөдире (1953–65), проректор (1957–61). Хезмәтләре электрохимик юл б-н алынган металларның һәм эретмәләрнең структурасын һәм текстурасын өйрәнүгә карый. К. структураларны өйрәнү методологиясен эшли, беренчеләрдән булып төрле типтагы текстураларның классификациясен бирә. Текстураны камилләштерү процессында электролиз шартларының һәм орлык үлчәменең тәэсирен ачыклый, электролиз вакытында текстураланган өслекнең табигатен бәяли, аллотроп күчешләрнең ролен билгели. Электрод процессларына ультратавыш тәэсире, икеләтелгән электр катламы төзелеше теориясен эшләү, полимер электролитларның сулы булмаган эремәләре электрохимиясе, эретмәләр составын анализлау өчен радиоактив индикаторлар файдалану буенча фәнни юнәлешләр башлангычына нигез сала. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Текстура электроосаждённых металлов. М., 1960; Краткий курс физической химии. М., 1968 (автордаш); Electrodeposition of metals in ultrasonic fields. N.Y., 1966 (автордаш).

*В.Г.Абзалова.*

**КОЧЕРГИНА́** Ольга Сергеевна (6.1.1957, Казан), невропатолог, мед. фән канд. (1988). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1980 елда, Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан ГИДУВында эшли. 1993–94 тә Республика мед. клиника берләшмәсенең нерв авырулары клиникасында. 1994–96 да дәвалау-диагноз кую, фәнни-методик вертеброневрология үзәге директоры урынбасары, 1996–2000 дә оештыру-методик эшләр буенча директор урынбасары. 2000 нән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика сәламәтлекне ныгыту клиник хастаханәсе баш табибенең оештыру-методик эшләр буенча урынбасары. Хезмәтләре вертеброневрология өлкәсенә: клиника, диагноз кую, ярдәм оештыруга карый. Дәүләт бүләге «Вертеброневрологик нерв системасы авыруларының невраль һәм мускулләрдагы билгеләре, фундаменталь һәм гамәли аспектлар» хезмәте өчен бирелә. Күп кенә укыту-методик кулланмалар авторы. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Особенности мышечно-тонического и нейродистрофического синдрома в детском и подростковом возрасте в зависимости от уровня поражения позвоночника // Вертеброневрология. 2002. № 1–2 (автордаш); Оценка эффективности специализированной помощи пациентам с вертеброгенными заболеваниями на основе критериев качества жизни // Вертеброневрология. 2006. № 1–2 (автордаш); Дифференциально-диагностические критерии сколиозов у детей и подростков (этиология, патогенез, клиника, классификация): Уч. пособие. К., 2005 (автордаш); Реабилитационно-профилактические мероприятия в постинсультном периоде: В 3 ч. К., 2009 (автордаш).

**КО́ЧЕТОВ** Александр Леонидович (29.4.1957, Иваново ш.), драма актёры, ТРның халык артисты (2005). Иваново химия-технол. ин-тын (1979) һәм Түбән Новгород өлкә драма театры каршындагы театр студиясен (1983) тәмамлый. 1984–87 елларда — Күкчәтау, 1987–89 да Актүбә шәһәрләрендә өлкә драма театры актёры, 1989 дан Бөгелмә рус драма театрында эшли. Күп кенә зур рольләрдә уйный: Алан Стренг («Эквус», П.Шеффер), Ричард («Барысы да бакчада», Э.Олби), Арман («Камелияле ханым», А.Дюма — улы), Умберто («Филумена Мартурано», Э.де Филиппо), Эйлиф («Кураж ана һәм аның балалары», Б.Брехт), Онек («Бөкре», С.Мрожек), Талейран («Наполеон I», Ф.Брукнер), Фредерик («Кара кәләш», Ж.Ануй), Оргон («Суган суфые», Ж.Б.Мольер), Марк («Туфраксыз бакча», Л.Н.Разумовская) һ.б. Аның геройларына ачык экспрессив форма, темперамент, гамәлләрендә эзлеклелек хас.

*Ю.А.Благов.*

**КОЧКЕ́ШЕВ** Адриан Иванович (1831, Казан — 22.2.1916, шунда ук), дин эшлеклесе. 1861 дән Казан иске дин тарафдарлары җәмгыятенең рухани җитәкчесе, Россиядә иске дин тарафдарлары мәзһәбендәге поморлар б-н борадәрлектәге иң абруйлы дини китап белгечләренең берсе. К. җитәкчелегендә Казандагы *Казан Богородица чиркәве* төзелә. Ул Крюков мәкамендә җырлау (борынгы рус чиркәү җырын башкару ысулы, киң таралган җырлау төре) белгече буларак билгеле. Аның җитәкчелегендәге Казан иске дин тарафдарлары җәмгыяте хоры иске дин тарафдарларының барлык мәзһәбләре арасында абруй казана.

*Әд.:* Адриан Иванович Кочкешев // Щит веры. 1916. № 4.

*Е.В.Липаков.*

**КО́ЧКИН** Михаил Андреевич (4.6.1908, Вятка губ. Кленовая а. — 6.1.1980, Кырым өлкәсенең Ялта ш.), туфрак белгече, а.х. фән. д-ры (1957), проф. (1961), Украина ССРның атказ. фән эшлеклесе (1962). Горький а.х. ин-тын тәмамлый (1934). Казан (1937–41) һәм Кырым (1951–52) а.х. ин-тларында укыта. 1945 елдан Кырым саклаулыгының фәнни эшләр мөдире (Алушта ш.). 1948 дән СССР ФАнең Кырым ф-лында гыйльми секретарь (Симферополь ш.). 1956 дан Украина туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тында лаб. мөдире (Харьков ш.). 1958 дән Никита ботаника бакчасында (Ялта ш.): директор, консультант (1977–80); җимеш культураларын, декоратив һәм яңа техник үсемлекләрне рациональ урнаштыру максатында туфрак үзлекләрен һәм климат үзенчәлекләрен өйрәнү буенча эш җәелдерә. Хезмәтләре таулы Кырым табигатен өйрәнүгә, табигать комплексларыннан рациональ файдалануга, далалы Кырымда урман үрчетү буенча чаралар эшләүгә карый. Үзенең тикшеренүләрендә табигать характеристикасын бергәндә, аны үсемлек-туфрак-климат системасы буларак карап, үзара бәйләнешле комплекслы алымнар куллана. Украинаның туфрак һәм агротуфрак карталары автордашы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бер алтын һәм ике көмеш медале, Украина ССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.



И.Е. Кочнев.



Н.М. Кошаев.

Х е з м.: Почвы, леса и климат горного Крыма и пути их рационального использования. М., 1967; Основы рационального использования почвенно-климатических условий в земледелии. М., 1972.

*Әд.:* Памяти Михаила Андреевича Кочкина // Почвоведение. 1982. № 3.

**КО́ЧНЕВ** Александр Михайлович (3.6.1955, Алабуга ш.), педагог, технолог, техник фән. канд. (1982), пед. фән. д-ры (1998), РФнең атказ. югары мәктәп укытучысы (2003). 1977 елда Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң, пластмассалар технологиясе кафедрасында эшли: 1998 дән югары проф. белем бирү педагогикасы каф. профессоры, 1999 дан ун-тның Полимерлар ин-тында: директор, бер үк вакытта пластмассалар технологиясе, 2004 тән ясалма каучук кафедралары мөдире. Хезмәтләре полимерларны үзгәртү, инженерларны киң профильле рәвештә техник әзерләү проблемаларына карый. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Физико-химия полимеров: В 4 ч. К., 1996–97; Современная высшая школа: состояние и тенденции развития. К., 1997; Модификация полимеров. К., 2002 (автордаш).

**КО́ЧНЕВ** Иван Егорович (15.9.1921, Чистай кантоны, хәзер Алексеев р-ны Николаевский Баран а. — 8.2.1958, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. өлкән сержанты. Туган авылында колхозда тракторчы булып эшли. 1941 елның апреленнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 995 нче укчы полкта орудие командиры (2 нче гв. армиясенең 263 нче укчы дивизиясе). Дон, Сталинград, Көньяк, 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Донбасс, Мелитополь (икесе дә — 1943), Шяуляй, Мемель (икесе дә — 1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 16 — 19 августында Балтыйк буен азат итү сугышларында батырлык күрсәтә: Литва ССР терр-ясендә барган аяусыз сугыш барышында К. расчёт составында туп уты б-н дошманның 4 танкын, штурмлау тубын, 5 бронетранспортёрын һ.б. хәрби техникасын сафтан чыгара. Демобилизацияләнгәннән соң, 1958 дә туган авылында авыл советы рәисе булып эшли. Ленин ордены, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Дан ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КО́ЧНЕВ** Олег Сергеевич (17.8.1932, Казан — 8.2.1993, шунда ук), хирург, мед. фән. д-ры (1972), проф. (1974), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1987). 1956 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Баулы р-н хастаханәсендә эшли. 1960 тан Казан ГИДУВының хирургия, 1980 нән кичектергесез ярдәм хирургиясе кафедраларында. Хезмәтләре үт юллары һәм корсак куышлыгы органнары авыруларына диагноз кую, эндоскопия, лимфология, яраларны дәвалауга карый. К. кичектергесез хирургиядә корсак куышлыгы әгъзаларына диагноз кую ысулларын эшли һәм тәкъдим итә, ш.у. тукымаларны тоташтыруның, папиллоспазмга һәм папиллостенозга диагноз куюның яңа ысулларын тәкъдим итә; хирургиядә яраларны тизрәк төзәтү, эренләүне булдырмау өчен ксимедон препаратын кулланылышка кертә; эренле яраларны эшкәртү һәм аларны булдырмау өчен аппарат уйлап таба. К. — эндоскопик хирургиядә, лимфологиядә һәм яралар турында тәгълиматта оригиналь юнәлеш авторы. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Хирургия неотложных заболеваний. К., 1981; Экстренная хирургия желудочно-кишечного тракта. К., 1984; Способы ушивания ран. К., 1992 (автордаш).

**КО́ЧНЕВА** Надежда Михайловна (25.10.1951, Казан), актриса, ТРның халык артисты (2009). 1975 елда Казан театр уч-щесен тәмамлый. 1974–89, 1991–96 һәм 1997 дән Казан Яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актрисасы, 1989–91 дә Киров, 1996 да Чиләбе яшь тамашачылар театрларында эшли. Ялкынлы, энкерсез яшүсмер кызлар рольләрен уйный. «Могҗиза тудыручы» (У.Гибсон пьесасы буенча) спектаклендә актриса ишетми-күрми торган, бары капшап тою органнары гына эшләгән Элен образының катлаулы эчке дөньясын ачып сала; ул яши торган караңгылыктан бөтен барлыгы б-н котылырга теләгән кыз бала образын яңача гәүдәләндереп, К. үзенең тәҗрибәле башкаручы булып өлгерүен раслый. Тышкы күренешнең төгәл уйланылган булуы б-н беррәттән актриса чынбарлык б-н әкренләп элемтә урнаштырырга тырышучы кешенең эзлекле рәвештә үзгәреш кичерә баруын тәэсирле һәм ышандырырлык итеп күрсәтә. Бу аңа тирән мәгънә салынган образ тудырырга ярдәм итә. К. башкаруында Катя («Сөйгәннәрегез белән аерылышмагыз», А.М.Володин), Елена («Җәйге төндә күргән төш», У.Шекспир), Бетти («Хәтәр борылыш», Дж.Б.Пристли), Инфанта («Сид», П.Корнель), Елена Тальберг («Турбиннар көннәре», М.А.Булгаков), Эльвира («Санта Крус», М.Фриш), Инга («Ашыгучы юлаучылар», А.Н.Казанцев) рольләре психол. яктан төгәл уйланылган, тирән эчтәлекле булулары б-н аерылып торалар. Аларда актриса нечкә күңелле, рухи яктан камил, матур, үз-үзләрен аямаучы фидакарь хатын-кыз образларын гәүдәләндерә. К. иҗат иткән Репникова («Июньдә хушлашу», А.В.Вампилов), Пахомов хатыны («Профиль һәм анфас», В.М.Шукшин повестьлары буенча), Романның әнисе («Романнар гаиләсе», В.Сигарёв), байбикә Капулетти («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир) — тормыш дөреслегенә туры килә торган, тирән психологизм б-н сугарылган характерлы образлар.

*Ю.А.Благов.*

**КОШ АУЛАУЧЫ́ КРӘСТИЯННӘ́Р**, сарай егермейстеры карамагындагы удел крәстияннәре категориясе. Аучы кошларны (карчыга, лачын, шоңкарларны) тоту һәм өйрәтеп патша сараена җибәрү б-н шөгыльләнгәннәр. 1731 елгы Фәрман буенча алар ел саен Мәскәүгә 20 шоңкар һәм 30 лачын җибәреп торырга тиеш булганнар. Чыгымнар һәм хезмәт хакын К.а.к. таможнядан һәм кабаклардан кергән табышлардан алганнар. Лачын аулаучылар — Переяславль-Залесский, Ростов шәһәрләрендә, Суздаль, Белозёрск һәм Вологда өязләрендә, шоңкар аулаучылар Казан һәм Пермь губерналарында, Себердә кәсепчелек иткәннәр. 1746 да халык саны алу мәгълүматлары буенча К.а.к. 868 кеше исәпләнгән. Казан губернасында алар Казан, Козьмодемьянск, Зөя һәм Чабаксар өязләрендә яшәгән. 1800 дә Россиядә бу категория (Казан губернасындагы 102 ир-аттан тыш) дәүләт крәстияннәре төркеменә күчерелә. 1827 нең августында хөкүмәт аларның барысын да салым түләүче катлауларга — шәһәр кешеләре (сәүдәгәрләр, мещаннар) һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына күчерү турында карар кабул итә.

*Әд.:* Б р о к г а у з Ф.А., Е ф р о н И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1898. Т. 48; Х а й р у т д и н о в Р.Р. Управление государственной деревней в Казанской губернии в конце XVIII — первой трети XIX вв. К., 2002.

**КОШ ТЕЛЕ́**, татар халкының милли ризыгы. Сөткә, майга, йомыркага изелгән камырдан җәймә җәеп, кош теле кебек озынча итеп киселә һәм чәлпәк, урама, гөлбәнәк, роза рәвешенә китерелеп, кайнап торган майда пешерелә. Суынгач, өстенә шикәр оны сибеп, табынга куела.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1999.

**КОШ ЯСМЫГЫ́** (Thesium), санталчалар семьялыгыннан ярымпаразит күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 дән артык төре билгеле, Антарктидадан тыш бөтен Җир шары буйлап таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Чыпчык чикләвеге (T. ebracteatum) — ара-тирә барлык, күбрәк көньяк районнарда; кыр К.я. (T. arvense) Идел алдында һәм Кама аръягында очрый. Далаланган болыннарда, куаклар арасында үсә. Башка үсемлек тамырларында паразитлык итә. 15–30 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырлары нәзек, озын. Сабагы туры яки аз гына ботаклы. Яфраклары чиратлашкан, кыяк-ланцетсыман, бөтен читле. Чәчәкләре вак, тонык төстә, һәрберсе бер-рәр чәчәк яны яфраклы, ш.у. кыр К.я. икешәр чәчәк яны яфракчыклы. Җимеше — чикләвекчек. Июньдә чәчәк ата. Җимешләре июльдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Чыпчык чикләвеге ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КОША́ЕВ** Николай Михайлович (22.5.1911, Уфа губ., Минзәлә өязе Чаллы а. — 25.9.1976, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (11.3.1944), гв. полковнигы. Урал индустрия ин-тын (1934), В.В.Куйбышев исем. Хәрби инженерлар академиясе каршындагы командирлар составы

белемен күтәрү курсын тәмамлый (1937, Мәскәү). Түбән Тагил шәһәрендә металлургия з-дында төзүче-инженер булып эшли. 1935 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет гаскәрләренең Көнбатыш Украина походында катнаша (1939). 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 2 нче танк армиясендә 11 нче гв. танк бригадасы командиры. Брянск, Үзәк, 1 нче, 2 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Чернигов-Припять (1943), Корсунь-Шевченко, Умань-Ботошаны, Люблин-Брест (барысы да — 1944), Варшава-Познань, Көнчыгыш Померания һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1945) катнаша. 1944 нең март башында Умань шәһәре янында батырлык күрсәтә: дошман тылына танклар төркеме рейдын җитәкли; аның җитәкчелегендәге танкистлар дошман штабын басып ала, элемтәне һәм коммуникацияләрне боза, берничә танкны сафтан чыгара. 1944 тән Мәскәүдә Корыч һәм эретмәләр ин-тының хәрби кафедрасы башлыгы булып эшли. 1962 дән отставкада. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои-освободители Черкасщины. Днепропетровск, 1980; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КО́ШКИ** авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2010 елда 164 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1700 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий-Кошкино исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балык тоту ятьмәсе бәйләү, он тарту, кирпеч сугу, балта эше һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Троица чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 13 җил тегермәне, ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете була; ярминкә (6 декабрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3780,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 1086, 1897 дә — 1640, 1908 дә — 1959, 1920 дә — 1798, 1926 да — 1128, 1938 дә — 735, 1949 да — 665, 1958 дә — 595, 1970 тә — 593, 1979 да — 399, 1989 да — 310, 2002 дә — 282 кеше.

**КО́ШКИ РАЙОНЫ́**, *Самара өлкәсенең* төньягында урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 164,6 *км*². Үзәге — Кошки авылы (Самара шәһәреннән 130 *км* төньяктарак). Халкы — 25,8 мең кеше (2010), 2,5 мең татар (2002). Татарлар, башлыча, Иске Фәйзулла (300 кеше), Яңа Фәйзулла (300), Берёзки (130), Моисеевка (30) авылларында яшиләр. К.р.нда татарлар 19 йөзнең 1 нче яртысында күренә башлый: Сембер һәм Казан губерналарыннан күчеп килүчеләр Иске Фәйзулла авылына нигез салалар. 1910 елда барлык татар торак пунктларында мәчетләр була, Иске Фәйзуллада 2 мәктәп эшли. Хәзерге вакытта Иске Фәйзулла һәм Яңа Фәйзулла авылларындагы ике мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. Район мәдәният йорты каршында «Идел» татар ансамбле эшли. К.р.нда генерал-лейтенант Х.И.Мирзаҗанов, тарихчы Г.С.*Сабирҗанов*, шагыйрь Г.Ш.*Сәгыйров* туган.

**КО́ШКИ-ЯҢА́ ТИМБА́Й** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 227 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1728 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-Я.Т.да чиркәү, Халык мәгарифе министрлыгының 2 сыйныфлы мәктәбе, хатын-кызлар мәктәбе, агач эшләре остаханәсе була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1718,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 679, 1880 тә — 812, 1897 дә — 1016, 1913 тә — 1244, 1920 дә — 1258, 1926 да — 1042, 1938 дә — 865, 1949 да — 492, 1958 дә — 272, 1970 тә — 577, 1979 да — 416, 1989 да — 232, 2002 дә — 249 кеше. К.-Я.Т. — чуаш халкының мәгърифәтче педагогы И.Я.*Яковлевның* туган авылы (аның музее эшли).

**КО́ШКИ-ЯҢА́ ТИМБА́Й ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, к. *Хулаш шәһәрлеге.*

**КО́ШКИН** Андрей Евдокимович (18.12.1922, Зөя кантоны Зур Подберезье а. — 30.1.1958, Мари АССРның Волжск ш.), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), гв. кече сержанты. Волжскида кәгазь комб-тында эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 106 нчы гв. аерым разведка ротасы разведчигы (37 нче армиянең 110 нчы гв. укчы дивизиясе). Көньяк, Төньяк Кавказ, Кавказ арты, Дала, 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Донбасс операциясендә (1942), Кавказ (1942–43) һәм Днепр елгасы өчен барган сугышларда (1943), уңъяк яр Украинаны (1944) азат иткәндә, Яссы-Кишинёв һөҗүм операциясендә (1944) катнаша. 1943 нең сентябрь–октябрь айларында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 29 сентябрьдә бер төркем сугышчылар б-н дошманның көчле уты астында, беренчеләрдән булып, елганы кичеп чыга; Кременчуг шәһәре (Полтава өлкәсе) янында дошманның оборона системасы ут нокта给ларын ачыклый һәм мөһим документларны кулга төшерә; 5 октябрьдә К. җитәкчелегендәге разведчиклар төркеме Куцеволока авылы (Украина ССРның Кировоград өлкәсе Онуфриев р-ны) янында дошманның сугыш кораллары һәм ягулык складларын шартлата, солдатларын әсирләкә ала. Сугыштан соң демобилизацияләнә. Туган төбәгендә кәгазь комб-тында эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә. Волжск шәһәренең Геройлар аллеясында аңа бюст, кәгазь комб-ты алдында барельеф куела, бер урамга исеме бирелә.



А.Е. Кошкин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Наши герои. Йошкар-Ола, 1985; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КОШКУНМА́С АГА́Ч** (Rhamnus), эт шомыртычалар семьялыгыннан куаклар яки зур булмаган агачлар ыругы. 140 ка якын төре билгеле, Европа, Азия, Африка һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — К. а. (эт шомырты) (R. cathartica) бар. Республиканың барлык районнарында очрый. Далаланган коры тау битләрендә, урман буйларында, елга тугайларында үсә. 3 *м* га кадәр биеклектәге нык, күп ботаклы куак, ботаклары чәнечкеле. Яшь ботакларының кабыгы кызгылт көрән, ялтыравыклы, карт ботаклары һәм кәүсәсе кара төстә диярлек, кытыршы, катлау-катлау булып яргаланган. Яфраклары каршыдаш, эллипссыман. Чәчәкләре вак, саргылт яшел, яфрак куентыгында бәйләмгә җыелган. Җимеше — сусыл, шарсыман кара төшчә. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Кабыгында — органик к-талар, эфир мае, дуплау матдәләре, җимешендә флавоноидлар, шикәр, пектин матдәләре, антрагликозидлар бар. Яфраклары С витаминына бай. Халык медицинасында җимешләренең суы эч йомшарту чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек. Үзагачыннан вак эшләнмәләр ясыйлар.

**КОШЛА́Р** (Aves), умырткалы хайваннар классы. 27 отрядка, 270 семьялык һәм 2400 ыругка берләшкән 9 меңгә якын төрне үз эченә ала. Арктикадан Антарктидага кадәр таралган, 80% ка якын төр — тропикларда. Татарстан терр-ясендә 321 төр (19 отряд), ш.и. оя коручы 198 төр, 52 — күчмә, 71 очып килгән төр. Чыпчыксыманнар (130), шөлдисыманнар (59), казсыманнар (32), лачынсыманнар (31) отрядындагы төрләр аеруча күп. Чыпчыксыманнар отрядында 21 семьялык, *әрәмә чыпчыклары* (26 төр), *тау чыпчыклары* (19), *чебенче кошлар* (19) аеруча күп санда. Оя коручы К.дан чыпчыксыманнар (94 төр), шөлдисыманнар (27), лачынсыманнар (18), казсыманнар (11) отряды вәкилләре очрый. К.ның күпчелеге урманнарда (тавык карчыгасы, бүдәнә карчыгасы, гади елак карчыга, сары чыпчык һ.б.), сулыкларда (соры яңаклы

чомга, кыр үрдәге, соры үрдәк һ.б.), аз өлеше — кырларда, болын, торак пунктларда (йорт чыпчыгы, кара карга, гади сыерчык, кара керәшә һ.б.) яши. Татарстан терр-ясендә яшәүче К. арасында 5–8 *г* лы кечкенә кошлар (сары башлы кәрлә тургай) һәм 10 *кг* га кадәрле, ш.у. аннан да авыррак зур кошлар (ысылдык аккош) да бар. Аеруча үзенчәлекле билгеләренең берсе — темп-ра үзгәрешләреннән саклаучы һәм очу вакытында мөһим роль уйнаучы йон-каурый капламы. Күпчелек кошларның тән төзелеше очуга җайлашкан: алгы очлыклары канатларга әверелгән, скелеты җиңеләйгән, күкрәк мускуллары бик көчле, тире астында һава куышлыклары урнашкан. Күрү һәм сизү органнары яхшы үскән. Оялау ысуллары һәм урыннары күп төрле. Йомырка салып үрчиләр. Үсемлек һәм хайван азыклары б-н тукланалар. Бөҗәк ашаучы К. (песнәкләр, *чыелдык кош, урмәләч*, әрәмә чыпчыклары, *камыш чыпчыклары,* чебенче кошлар һ.б.) урман һәм а.х. корткычларын, ерткыч К. (лачынсыманнар һәм ябалаксыманнар) тычкансыман кимерүчеләрне юк итәләр; кайберләре бакча культураларына, чәчүлекләргә зарар китерә. Көртлек кош, *суер, боҗыр, урман үрдәге, бытбылдык* һ.б. — ау спорты объекты. Күбесе — йорт тавыгы, үрдәк, күркә, каз токымнарының нәсел башы. 84 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КОШМА́Н** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 5 *км* көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 714 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 2 мәчет. К. Казан ханлыгы чорында төзелгән һәм 1948 дә кушылган Олы һәм Кече Кошман авылларын берләштерә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында ике авыл халкы да дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Олы Кошманда волость идарәсе урнаша, ике авылга 3 мәчет, 2 мәдрәсә, 1 су һәм 6 җил тегермәне, 11 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда ике авыл җәмәгатенең имана җире 2652,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Олы Кошман авылы — Казан губернасының Зөя өязе Кошман волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны (2 авыл халкы бергә): 1782 дә — 235 ир-ат; 1859 да — 1407, 1897 дә — 2404, 1908 дә — 2916, 1920 дә — 2289, 1926 да — 2160, 1938 дә — 1297, 1949 да — 1323, 1958 дә — 1141, 1970 тә — 1182, 1979 да — 979, 1989 да — 746, 2002 дә — 843 кеше.

**КОШТАУЛЫ́** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов — Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 280 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1647–51 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, ат дирбиясе ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1299,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 111 ир-ат; 1859 да — 428, 1897 дә — 837, 1908 дә — 994, 1920 дә — 1227, 1926 да — 1140, 1938 дә — 888, 1949 да — 913, 1958 дә — 680, 1970 тә — 618, 1979 да — 475, 1989 да — 336, 2002 дә — 324 кеше.

**КОШЧА́К БӘК** (? — 1551, Мәскәү), углан, Казан ханлыгының хәрби һәм дәүләт эшлеклесе. 1546–51 елларда Сафагәрәй хан, Сөембикә ханбикә чорында хөкүмәтне җитәкли. Мәскәү тарафдарларына каршы көрәшә. Шаһгали хан вакытында Казан ханлыгыннан кача, русларга әсирлеккә эләгә. Христианлык кабул итүдән баш тарткач, җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1. *М.Г.Госманов.*

**КОШЧЫЛЫ́К**, терлекчелекнең йомырка, ит, мамык һәм йон җитештерү өчен кош үрчетү б-н шөгыльләнүче тармагы. ТР да тавык, каз, үрдәк, күркә асрыйлар. Продукциянең төп күләме 8 кошчылык фабрикасы һәм 2 кошчылык совхозында, «Птицевод» кошчылык з-дында (Бөгелмә р-ны), «Юдино» кош репродукторында (Яшел Үзән р-ны), 15 кошчылык инкубатор станциясендә, фермер хуҗалыкларында һәм шәхси хуҗалыкларда җитештерелә. 1960 еллар урталарына кадәр Татарстанда К., башлыча, экстенсив юл б-н алып барыла. Гадәттә колхоз һәм совхозларда кечкенә кошчылык фермалары өстенлек итә, аларда башлыча кул хезмәте файдаланыла, җитештерүчәнлек түбән була. Уртача бер колхозга — 860, бер совхозга 2000 йомырка тавыгы туры килә, бер тавыктан елга 66–102 йомырка алына. Республикада интенсив хуҗалык формаларына корылган берничә эре кошчылык совхозы эшли: Чаллы (хәзер Тукай) р-нында «Красный Ключ», Бөгелмә р-нында «Бөгелмә» (нәсел с-зы), Питрәч р-нында «Колай», Лаеш р-нында «Комсомольский». 1965 елда Татарстан «Птицепром» тресты (1987 дән — «Татарское» ЖБ, 1999 дан — «Татптицепром» а.х. ЖБ, 2003 тән — «Колай» с-зыннан тыш югарыда саналган барлык хуҗалыкларны берләштергән АҖ) һәм 34 кошчылык инкубатор станциясе төзелә. К. сәнәгать нигезендә алып барыла башлый. 65–90 елларда К. тармагында җитештерү интенсив рәвештә үсә, эре пр-тиеләр барлыкка килә: йомырка җитештерү юнәлешендәге «Юбилейная», «Чаллы» ф-калары; «Казан», «Питрәч», «Тукай», «Түбән Кама» бройлер ф-калары; ит өчен үрдәк, күркә җитештерүче совхозлар. Эшләп килүче хуҗалыкларда яңартулар кертелә. «Птицепром» системасындагы пр-тиеләрдә йомырканың тулай җыемы 25,6 млн.нан 814,9 млн. данәгә, кош ите сату 0,56 меңнән 43,4 мең *т* га җитә, 1 мең йомырка җитештерү өчен тотылган хезмәт 22,9 дан 1,52 кеше/сәгатькә кала, азык чыгымнары 450 дән 187 азык берәмлегенәчә кими, тармакның рентабельлеге 58,9% тәшкил итә. Тотылган чыгымнар 1,5–2 ел эчендә каплана.

Базар икътисадына күчүнең башлангыч чорында (1991–98) азык һәм энергия ресурслары кыйммәтләнгән шартларда, продукция җитештерү күләме кискен кими. 1998 дә йомырка җитештерү 1990 ел б-н чагыштырганда 36,2%ка, ит җитештерү — 51,3%ка кими. Пр-тиеләрнең күпчелеге зыянга яки аз файда б-н эшли, шул сәбәпле кошларны яңартып тору мөмкинлеге калмый. «Апас», «Буа» һәм «Түбән Кама» кошчылык ф-калары, «Атабай», «Комсомольский» с-злары яшәүдән туктый. Республика шәһәрләренә чит ил продукциясе кертелә. 1999 дан Татарстанның К. тармагы үсешендә яңа чор башлана. Кошчылык ф-каларының байтагы эре инвесторларга («Ак Барс» холдинг компаниясе, «Татэнерго», «Татфондбанк», «Таттрансгаз» һ.б. АҖләре) бирелә, кошчылык пр-тиеләрендә милек реформасы уздырыла. Кошчылык ф-каларында җиһазлар яңартыла, җитештерүчәнлеге зуррак булган тавык кроссслары сатып алына, яңа технологияләр кертелә, азыктагы компонентлар балансы көйләнә, ит продукциясен эшкәртү тамырдан үзгәрә. Күп кенә кошчылык ф-каларында реконструкция уздырыла: «Лаеш» (2004–07), «Чаллы» (2003–07), «Чистай кошчылык фабрикасы» АҖ (2006–07). «Тукай кошчылык фабрикасы» АҖ 2003 тә «Чаллы-бройлер» ҖЧҖ дип үзгәртелә, аның составына «Чаллы» (2004), «Түбән Кама» (2005) ф-калары кертелә. 2006 да дөнья стандартларына ярашлы кош ите эшкәртү комплексы (куәте сәгатькә 9 мең кош) сафка баса. Катнаш азык б-н «Кама-зернопродукт» АҖ (Чаллы), «Казань-зернопродукт», «Магнитогорск-комбикорм», «Ситко» икмәк продуктлары АҖ, «Биофакторы» ҖЧҖ (Екатеринбург), «Кормозаготовка» ҖЧҖ (Мәскәү), «Провими» ҖЧҖ (Мәскәү, Түбән Новгород), «Содружество» компаниясе (Балтыйк буе) тәэмин итә. Кошчылык ф-каларының кайберендә катнаш азык цехы бар. Татарстанда тавыкларның йомырка һәм ит юнәлешләрендәге кросслары асрала. Йомырка юнәлешендәге кроссларның барысы да йомырка тавыкларыннан иң яхшы токым саналучы ак леггорннан китереп чыгарылган. 1980–90 елларда республикада ике линияле П-46 кроссы үрчетелә, йомырка юнәлешендәге барлык кошчылык хуҗалыкларында шул кросс таралыш ала. 1999 дан әлеге кросс Голландиянең «Хендрикс» фирмасыннан кайтартылган дүрт линияле кросс — ак бованс б-н яхшыртыла (тавыкның йомырка салышлыгы — 350 данә, йомырканың уртача массасы — 61–62 *г*).

1990 еллар ахырында Свердловск өлкәсеннән кертелгән родонит кроссы киң тарала, йомырка юнәлешендәге тавыкларның 42% чамасы шул кросска карый. Әлеге кросс югары генетик потенциалга ия: тавыкның йо-

мырка салышлыгы 296 данә. Аерымлылык билгесе — төс буенча аутосекслы (бер тәүлеклек чебиләрнең ачык сарылары — тавык, сорылары — әтәч).

21 йөз башында «Птицевод» дәүләт нәсел з-ды белгечләре Бөтенроссия К. фәнни-тикшеренү һәм технол. ин-тлары галимнәре б-н берлектә җитештерүчәнлеге югары булган өч линияле бөгелмә кроссы (БТ-125) булдыра. Бу кроссның 50 процентлы җитештерүчәнлеккә ирешү чоры — 145 көн, йомырка салышлыгы — 300–320 данә, чеби чыгару — 86%, чебиләрнең сакланышы — 98%. 1 мең йомырка алу өчен 1,47 *ц* азык берәмлеге тотыла. Кайбер кошчылык хуҗалыкларында 1990–2000 елларда Германиядән кайтартылган ак ломанн, соры ломанн кроссына караган тавыклар үрчетелә. Йомырка өчен тавык асрау б-н шөгыльләнүче иң эре хуҗалыклар (2011): «Птицевод» нәсел з-ды — 273 мең, Бөгелмә р-нындагы «Репродукт» — 107 мең, Лаеш р-нындагы «Юбилейное» — 2 млн. 505 мең, «Лаеш» кошчылык комплексы — 588 мең, «Лениногорск кошчылык фабрикасы» — 230 мең баш.

Корниш, плимутрок, лангшан, брама һ.б. токым төркемнәре ит юнәлешенә карый. Бройлер алу өчен кулланыла торган хәзерге кроссларның барысы да корниш (ата форма) һәм ак плимутрок (ана форма) нигезендә китереп чыгарылган. Ит өчен тавык асрау б-н Тукай р-нының «Чаллы-бройлер» ҖЧҖ (2011 дә — 4 млн. 23 мең баш), «Казан» кошчылык фабрикасы» АҖ (1 млн. 300 мең), «Ак Барс–Питрәч» агрофирмасы (923 мең), Яшел Үзән р-нының «Марс» крәстиян фермер хуҗалыгы (57 мең баш; Франциядән кайтартылган «гибро» ит тавыклары кроссларын, азрак күләмдә Россиянең «конкурент», «смена» кроссларын үрчетә) шөгыльләнә. К. тармагы пр-тиеләре тарафыннан ел саен 3 млн.нан артык чеби һәм бәбкәләр сатыла (1980 елларда бу сан 10–14 млн. *га* җитә).

2011 ел башына республикада 30 мең каз исәпләнә, шуларның 15,7 меңе — йомырка сала торган ана казлар. Токымнары: 60% — линд, 30% — рейн (Венгриядән кайтартылган), 10% — Кубань казлары. Каз асрау б-н Питрәч р-нының «Карповка» ярдәмче хуҗалыгы (10 мең), «Чистай» агрофирмасы (5 мең), «Гайфуллин һәм К°» ҖЧҖ (2 мең) шөгыльләнә. 2010 да үрдәкләр саны 10 мең, шул исәптән ана үрдәкләр 7,5 мең баш. Башлыча, Пекин үрдәкләре үрчетелә. 2011 елда республиканың К. тармагында тулаем 13 млн. баш кош (шуннан 3,6 млн. — йомырка тавыгы) исәпләнә, 2011 елгы күрсәткечләр (тиңдәшле рәвештә): 7217,8 млн. һәм 2588,9 млн. Шәхси хуҗалыкларда кош-кортның төрлесен, шул исәптән тәвә кошлары да асрала. 2011 дә 13 мең *т* кош ите җитештерелә.

ТРның азык-төлек базарында «Татптицепром» АҖ өлеше: кош ите буенча — 50% чамасы, йомырка буенча — 95,6%. Кош итеннән 200 ләп исемдәге продукция җитештерелеп сатыла. Татарстанның К. тармагы җитештергән продукциянең 25% ы күрше өлкә һәм республикаларга чыгарыла, ш.у. Мәскәү, С.-Петербург һ.б. шәһәрләргә озатыла.

2000–11 елларда халыкара һәм Россия күләмендәге конкурсларда респ-каның К. тармагы җитештергән продукция 13 алтын, 8 көмеш медаль яулый, лауреат дипломнарына лаек була, Россиянең иң яхшы 100 товары исемлегенә кертелә. К. өлкәсендә эшләүчеләрдән дәүләт бүләкләренә лаек булучылардан: Соц. Хезмәт Герое — 1, РФнең атказ. терлекчелек хезмәткәре — 3, ТАССРның атказ. терлекчелек хезмәткәре — 59, орден һәм медаль б-н бүләкләнүчеләр — 100 кеше. К. тармагы өчен белгечләрне Казан вет. мед. академиясе, Буа вет. техникумы, Әтнә һәм Минзәлә а.х. техникумнары әзерли.

«Татптицепром» АҖнең җитәкчеләре: Я.М.Никудимов (1965–79), И.И.Журавлёв (1979–84), Г.М.Мавлин (1984–95), Ф.Ф.Фәхруллин (1995–98), М.Ш.Алиев (1998 дән).

*Әд.:* Ихсанов Н. Восхождение: Ист. очерк о восьмидесятилетнем пути птицефабрики «Красный Ключ». Нижнекамск, 1999; Кочиш И.И., Петраш М.Г., Смирнов Г.Б. Птицеводство. М., 2004; Алиев М.Ш. Птицеводство — прибыльная и социально значимая отрасль республики // Татарстан. 2007. № 7.

*Ә.Х.Фазылҗанов, А.Р.Вәлиев, М.Ж.Гаитов.*

**КОЩА́КОВО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Нокса елгасы буенда. 2010 елда 1901 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, җәнлекчелек. Тире иләү цехы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авыл тарихы музее. Чиркәү. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да волость идарәсе урнаша; Троица чиркәве, земство мәктәбе (1881 дә ачыла), 2 җил тегермәне, тимерчелек, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 599 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Казан өязе Кощаково волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1957 нең 30 октябреннән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. 1950 елларның 2 нче яртысында «Кощаково» җәнлек с-зы б-н берләшә. 1988 нең 30 маенда совхозга Барановка авылы кушыла. 2000 нең 20 декабрендә К.ның бер өлеше мөстәкыйль Иске Кощаково авылы буларак бүленеп чыга. Халык саны: 1782 дә — 106 ир-ат; 1859 да — 270, 1897 дә — 345, 1920 дә — 387, 1926 да — 439, 1949 да — 839, 1958 дә — 775, 1970 тә — 1351, 1979 да — 1442, 1989 да — 1731, 2002 дә — 1776 кеше.

**«КОЩА́КОВО»**, Питрәч р-ндагы җәнлек с-зы. 1958 елда «Бөреле» җәнлек с-зы бүлегe җирлегендә оеша (к. *«Бөреле»*). 2002 дән а.х. пр-тиесе һәм АҖ. Үзәк утары — Кощаково а. 2011 елда эшләүчеләр саны — 115 кеше. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 2500 *га*, ш.и. сөрү җирләре 2333 *га*. Төп хезмәт тармагы — кыйммәтле мех җитештерү. 1997 дә чәшке — 23000 баш, ак төлке —



Чәшке фермасы. 2005.

2160, төлке — 260, куян 2000 баш була; җитештерүгә яраклы яшь җәнлекләр саны: чәшке — 93015, ак төлке — 18810, төлке — 931, куян — 46550 баш. 2003 тә чәшке — 9392, ак төлке — 10099, куян — 9099 баш исәпләнә (сатылган җәнлек тиресенең күләме таблицада). 2009 да чәшке 7200 баш.

1980–2009 да сатылган җәнлек тиресе (данә).

| Еллар | Сатылган җәнлек тиресе | | |
|---|---|---|---|
| | чәшке | ак төлке | куян |
| 1980 | 80386 | 9805 | 34103 |
| 1990 | 123319 | 12453 | 29285 |
| 1991–95 (уртача 1 елга) | 88820 | 10371 | 26869 |
| 1996–2000 (уртача 1 елга) | 79228 | 11595 | 40674 |
| 2000 | 21105 | 5718 | 15826 |
| 2001 | 8738 | 1508 | 10002 |
| 2002 | 88155 | 2309 | 4197 |
| 2003 | 10042 | 14347 | 14579 |
| 2009 | 53000 | ... | ... |

2009 да сатылган гомуми продукциядә җәнлекчелек продукциясе — 75%, үсемлекчелек 25% тәшкил итә. Хуҗалыкта заманча матди-техник база булдырыла: 23 мең $м^2$ мәйданлык торак төзелә. Мәдәният сарае, мәктәп, балалар комб-ты, китапханә, сәүдә үзәге, 2 профилакторий, аптека, көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты, мунча, 2 аш-





1. Чәшкеләр;
2. Ак төлкеләр.

ханә, хастаханә, АТС, биочистарту станциясе. Хуҗалыкта газ, телефон кертелгән, урамнарга һәм терлекчелек объектлары терр-ясенә асфальт түшәлгән. «К.» Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, РСФСР МС һәм ВЦСПС, РСФСР А.х. министрлыгы һәм А.х. эшчеләре профсоюзлары ҮКның күчмә Кызыл байраклары б-н бүләкләнә. 1968 дән «Игенчелектә югары культуралы хуҗалык» исемен йөртә. 1976–80 дә РСФСР а.х. пр-тиеләре арасында нәселле терлек үрчетү буенча соц. ярышта 1 урынны ала. Хуҗалык эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. РФ һәм ТРның мактаулы исемнәре — 12 кешегә; Ленин ордены — 2, Октябрь Революциясе — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы — 11, Халыклар дуслыгы — 1, «Почёт билгесе» — 5, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары — 3; медальләр — 199 кешегә, шулардан СССР ВДНХсы медальләре — 139 кешегә бирелә. Совхоз җитәкчеләре: К.Ф.Фәтхетдинов (1958–62), Н.Н.Заһидуллин (1962–64), Н.Ф.Сафонов (1964–68), Р.М.Сыпченко (1968–70), И.Б.Вәлиев (1998–2000), К.Ш.Вәлиуллин (2000–01), Р.Р.Әхмәтов (2001–03), Ф.М.Гайнетдинов (2003–2006), Б.Г.Идиянов (2006 дан).

*И.Н.Афанасьев.*

**КОЩА́КОВО КИРПЕ́Ч БАЛЧЫГЫ́ ЧЫГАНАГЫ́**, Питрәч р-ны Кощаково авылы тирәсендә урнашкан. ТРда иң эре файдаланулы казылма урыны. Запасы 6 млн. $м^3$ дан артык. 1967 елда ачыла, 1983 тән эшкәртелә. Продуктив өлеше дүртенчел чорның континенталь катламнарында урнашкан. Пласт һәм линза рәвешендә ятмалар балчыклардан, балчык алевритлар һәм алевритлы балчыклы туфрактан тора. Файдалы катлам 3–21 *м*, өске өлеше 0,05–1,3 *м*. Балчык сыйфаты: формалашу дымлылыгы 20,8–21%, су сеңдерү 11–11,5%, кысылуга чыдамлыгы 242– 328,5 $кг/см^2$. Балчык ОСТ21–78–88 таләбенә туры килә. Чыгару күләме 120 мең $м^3$. Чималдан 200 маркалы кирпеч алалар. Казан кирпеч з-длары К.к.б.ч. чималы б-н эшли.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

**КОЮ́ СӘНГАТЕ́**, эретелгән металлны махсус калыпларга кою юлы б-н төрле эшләнмәләр әзерләү ысулы. К.с. алымы б-н *гамәли-бизәлеш сәнгате* эшләнмәләре (металл, үзле балчык, пыяла һ.б.), биналарның архит-ра элементлары (коймалар, капкалар, капительләр, колонналар) иҗат ителә, *скульптура* әсәрләре металлга күчерелә. Металл җиһазлар һәм бизәнү әйберләрен күпләп әзерләү өчен кулланылган иң борынгы һәм гади ысул. Татар осталары — *бакырчылар* һәм *зәргәрләр* — үзле балчык, таш һәм металл формаларда җитештергәннәр, эшләнмәләрне балавыз модельләр буенча койганнар. Әлеге ысул б-н балавыздан булачак эшләнмәнең моделе яки аның детальләре әзерләнгән һәм аларга сыек балчык салынган. Балчык кипкәннән соң балавыз эретелгән һәм аның урынына металл коелган. Шундый алым б-н 20–25 ләп төр әйбер, гадәттә, бизәнү әйберләре (җиз тәңкәләр, балдак, йөзек, *беләзекләр*, чулпы, алка, каптырма, чигә асылмалары детальләре һ.б.) эшләнгән. Анары процесс тагын кабатланган, ләкин бу юлы балавыз урынына металл модель файдаланылган. К.с. предметларның катлаулы конфигурацияләрен, рельефлы орнаментлар иҗат итәргә, *бөртекләү*, сырлау, кайвакыт ялган *җепкыр* бизәкләр ясарга мөмкинлек биргән. Соңыннан коелган эшләнмәнең шомартылган өслегенә *чүкеп бизәк төшерү* һәм *уеплау* техникасында геометрик һәм үсемлек бизәкләре ясалган.

Татарстан терр-ясендәге археол. табылдыклар арасында бронза һәм тимер гасырларның К.с. эшләнмәләре, ш.и. Казан яны, Ананьино, Пьянобор, Имәнкискә һ.б. культураларга караган борынгы кабиләләргә нисбәтле көнкүреш кирәк-яраклары, корал һәм бизәнү әйберләре, үзле балчыктан ясалган калып калдыклары табыла.

К.с. *болгар бизәлеш сәнгатендә,* җиз, бронза, көмеш, алтын, кургаш һәм тимердән көнкүреш (көзгеләр, зиннәтле балталар, асылмалы йозаклар һ.б.) һәм бизәнү әйберләре (тегелмә бизәкләр, җиз тәңкәләр, беләзекләр, алкалар, йөзекләр һ.б.) җитештерүдә югары үсешкә ирешә. Геометрик (кояш мотивлары), үсемлек (чәчәк үрнәкләре) һәм зооморф (ат, эт, сарык, арыслан, үрдәк һ.б.) сурәтле коелма эшләнмәләрне үзле балчык һәм аерылма таш формаларда җитештергәннәр. Өслек өстәмә рәвештә уеп яки чүкеп ясалган орнаментлар б-н бизәлгән. Алтын Урда шәһәрләре урыннарында (Сарай әл-Җәдид, Сарай әл-Мәхрүсә, Болгар, Үкәк, Сарайчык һ.б.) алып барылган казу эшләре вакытында бизәнү (чигә асылмалары, алкалар, йөзекләр), еш кына бизәкләре җепкыр һәм бөртекләү алымы б-н әзерләнгән көнкүреш әйберләрен (шәмдәлләр, йозаклар, көзгеләр) һәм савыт-сабаларны (уеп бизәлгән савытлар) күпләп җитештерү өчен таштан (ак известьташ һәм кара сланец), ш.у. үзле балчыктан ясалган коелма (ш.и. аерылма) һәм балавыз моделендәге калыплар табыла.

Казан ханлыгы чорының ТР Милли музее, Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы фондларында саклануучы К.с. үрнәкләре татар аксөякләре киемнәрендәге көмеш һәм алтын йөгертелгән декоратив төймәләр сыйфатында тәкъдим ителә. Рус булмаган милләт вәкилләренә, ш.и. татарларга, металлны кыздырып эшкәртүне тыю турындагы патша боерыгы 16 йөзнең 2 нче яртысыннан төбәктә К.с. үсешен туктата. Әмма ул бакыр һәм көмештән ясалган, уеп һәм чүкеп ясау, җепкырлау, кырланган асылташлар һәм шомартылган сөякләр б-н бизәлгән чиркәү һәм көнкүреш кирәк-яраклары (чүмечләр, касәләр, кубоклар, чәркәләр һ.б.) эшләгән рус кою осталары иҗатында дәвам итә (к. *Казан көмешчеләре*). Православие дине биналары һәм аксөякләр йортлары төзелү барышында, К.с. *архитектура бизәгендә* үз урынын ала. 18 йөздә — 20 йөз башында ул татар *зәргәрчелек сәнгатендә* киң кулланыла, *Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе* осталарының бизәкләр әзерләүдәге төп ысулларының берсе була. Соңгылары К.с. эшләнмәләрен еш кына арзан металлардан (кургаш, бакыр, түбән сыйфатлы көмеш) һәм аларның эретмәләреннән әзерлиләр, авылларда яшәүче *та-*



**Кою сәнгате.** 1. Җәнлек рәвешендәге йозаклар. Бронза. Кою, чүкү. Идел буе Болгар дәүләте. 11–14 йөзләр. ТР Милли музее; 2. Көзге. Арткы ягы. Бронза. Кою. Идел буе Болгар дәүләте. 12 йөз. ТР Милли музее; 3. Сарык фигуралы касә. Фрагмент. Көмеш, эмаль. Кою. Алтын Урда. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 4. Чакма ташы тоткасы. Бронза. Кою, чүкү, уеплау. Алтын Урда. 14 йөз. Дәүләт Эрмитажы; 5.Татар аксөякләренең милли киемнәрендәге декоратив төймәләр. Көмеш, алтын йөгертү. Кою, ялган җепкыр, бөртекләү. 16 йөз. ТР Милли музее; 6. Алкалар. Көмеш. Кою. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы.Россия этнография музее. С.-Петербург; 7. «Казан» медале. Г.В.Богородская. Бронза. Кою.1977.

*тар халкының милли киемен* һәм фин-угор халыкларының милли киемнәрен бизәүдә Екатерина II заманында популяр булган тәңкә акчалардан файдаланалар.

20 йөзнең 1 нче яртысында респ-каның вак һөнәрчелек системасында кою ысулы б-н көнкүреш һәм хуҗалык кулланылышындагы предметлар әзерләүче пр-тиеләр эшли. Чуеннар, комганнар, казаннар һ.б. савытларны Әлмәт авылындагы «Металлпром» пр-тиесе (1939 да төзелә) күпләп чыгара. Ләкин болар Советлар Союзының күпчелек шәһәрләрендә сугыштан соңгы унъеллыкта киң таралган стандарт эшләнмәләр була.

Металл эшкәртү, зәргәрчелек һәм медаль ясау сәнгате өлкәсендә иҗат итүче хәзерге заман рәссамнары (И.*Башмаков*, Г.Богородская, А.Петров, З.Хөсәенов һ.б.) К.с. алымнарын куллана. Ш.у. к. *Металлны нәфис эшкәртү сәнгате*.

*Әд.:* Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; шул ук. Татарский народный орнамент. К., 2002; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КОЯ́Р**, атның башына, күкрәгенә һәм ян-якларына капланган күп катлы җәймә яки киез япмадан торган дирбия. Идел буенда б.э.к. 1 нче меңьеллыкта барлыкка килә. Төрки һәм Хәзәр каганлыкларында киң тарала. Алтын Урдада күннән, күп катлы киездән һәм тимер кисәкчекләреннән эшләнгән К.лар файдаланылган. 14–16 йөзләрдә атның башын саклаучы тимер япма һәм атның гәүдәсенә капланган, күннән (яки постаудан) эшләнгән, тимер кисәкләре беркетелгән тукыма (чалдар) кулланылышта булган. Гадәттә, К.дан бай һәм аксөяк сугышчылар, ш.у. башлап һөҗүм итүче гаскәриләр файдаланган.

*Әд.:* Горелик М.В. Ранний монгольский доспех (IX — первая половина XIV вв.) // Археология, этнография и антропология Монголии. Новосиб., 1987.

**КОЯ́Ш**, Кояш системасының үз тирәсендә башка объектлар (планеталар, астероидлар, метеоритлар, кометалар, космик тузан) әйләнеп йөргән үзәк җисеме; нигездә, водород һәм гелийдан торучы кызган плазма шар; безнең планетага иң якын урнашкан (149,6 млн. *км*) һәм Кояш системасы планеталары аннан яктылык һәм җылылык ала торган йолдыз. К. нурланышы Җирдә яшәүне тәэмин итә (фотосинтез процессының башлангыч стадиясендә фотоннар кирәк). К. массасы Кояш системасының суммар массасының 99,8% ын тәшкил итә. К. уртача үлчәмнәрдәге йолдыз булып исәпләнә (радиусы 696 мең *км*, тыгызлыгы 1,4 $т/м^3$, яктыртучанлыгы $3{,}86\cdot10^{26}$ *Вт*, спектраль классы G2, йолдызларга карата әйләнү периоды 25,28 җир тәүлеге), яше ш.у. уртача (5 млрд. ел); аның массасы ($2\cdot10^{30}$ *кг*) Җир массасыннан — 330 мең тапкыр, диаметры 109 тапкыр зуррак. Өслегенең темп-расы 5,5 мең °С. Эчке өлешендә темп-ра якынча 14 млн. °С, шуңа күрә анда водородның гелийга әверелүе һәм бик зур энергия бүленеп чыгу хас термотөш реакцияләре була.

К. көчле магнит кырына ия. Магнит кырының көчәнешлелеге һәм юнәлеше вакыт узу б-н үзгәреп тора (юнәлеше һәр 11 ел саен үзгәрә — кояш активлыгы циклы). Кояш магнит кырының үзгәрүчәнлеге төрле рәвештәге эффектлар (К. активлыгы дип бер төшенчәгә берләштерелгәннәр) китереп чыгара һәм үз эченә К. таплары, К. шартлаулары, К. җиле кебек күренешләрне ала, ә Җирдә поляр балкышлар һәм геомагнитик давыллар күзәтелә, соңгысы элемтә чаралары эшенә, электр энергиясен тапшыруларга, тере организмнар эшчәнлегенә тискәре йогынты ясый. К.та атмосфера 3 катламнан тора: фотосфера, хромосфера, Кояш таҗы. Яктылык нурландыручы фотосфера катламы дип К.ның күренмә өслеген атыйлар, аның радиусы К. радиусы булып санала. Өслеге үзгәрүчән, гранулаланган — кызган газлар югары күтәрелә һәм түбән төшә. К. экваторының ике ягында да караңгы таплар төркемнәре — К. эченнән өске катламнар аша куәтле магнит көчләре бәреп чыккан өлкәләр күзәтелә. Тапларның иң зурлары үлчәмнәре б-н Җирне узып китә һәм 2 айга кадәр саклана ала. Вакыт үтү б-н, К. тапларының саны үзгәрә; макс. саннар кояш активлыгы циклының ахырында күзәтелә.

Хромосфера — фотосфера өстендә урнашкан кайнар (темп-расы 6 мең °С тан 15 мең °С ка кадәр) газлар катламы. Тагын да өстә, берничә К. радиусы ераклыгына җәелеп, сирәкләнгән кояш таҗы тора (аның темп-расы 1 млн. °С тан да югары). Тулы К. тотылулар вакытында ул гади күзгә дә күренә. Темп-расы югары булса да, матдәсенең тыгызлыгы аз булу сәбәпле, яктылыгы зур түгел. Таҗ — көчле рентген нурланышы чыганагы. Хромосферадан таҗга берничә йөз *км/с* тизлек б-н куәтле газ агынтылары — протуберанецларыргытыла. Кабынышлар тудырган элементар кисәкчекләрнең (нигездә, водород һәм гелий) ташкыннарыннан тыш, аларның өзлексез агышы да дәвам итә, бу күренеш К. таҗындагы сирәкләнгән кисәкчекләрнең фәзада «агып таралуы» б-н бәйләнгән, аны К. җиле дип тә атыйлар. К. җиле Җир орбитасын күпкә узып тарала. Фотосферадан аермалы буларак, хромосфера һәм таҗны бары тик биек тауларга урнаштырылган махсус телескоплар ярдәмендә яки К. тотылулар вакытында — Ай дискы, Җир-Кояш хәрәкәтләре сызыгына туры килеп, К.ның якты фотосферасын каплаганда гына күзәтергә мөмкин (к. *Кояш һәм Ай тотылулар*). К. тотылулар еш булып торса да (ел дәвамында 5 тапкыр), аларны Җирнең тар полосасы буйлап кына күзәтеп була. Беренче тапкыр 1851 елда Казан астрономнары М.А.*Ковальский* җитәкчелегендә Бердянск шәһәренә (Кырым) бу күренешне күзәтү өчен баралар. 1941 нең 21 октябрендә Д.Я.*Мартынов* җитәкчелегендә Алма-Атада К. тотылуны уңышлы күзәтү оештырыла. Казан ун-тының астрономия каф. һәм Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе хезмәткәрләре К. тотылуларны күзәтү эшен дәвам иттерәләр.

*Әд.:* Миттон С., Миттон Ж. Астрономия. М., 1995; Физика космоса: Маленькая энцикл. М., 1986.

*Е.Е.Беляева.*

**КОЯ́Ш** (фольк.), күп кенә халыкларда, ш.и. татарларның борынгы бабаларында табыну объекты; барлыкка китерүче, яңадан тудыручы көч символы. К. һәм Ай культлары үзара тыгыз бәйләнгән. Борынгы көнчыгыш мифологиясендә К. б-н Ай, гадәттә, бергә йөри (абый б-н сеңел, ир б-н хатын, егет б-н кыз һ.б.). Әлеге күзаллауларның кайтавазы төрки-татар фольклорында да сакланган. Бараба татарларыннан язып алынган «Кузы Күрпәч белән Баянсылу» исемле гомумтөрки лироэпик дастанда К. б-н Ай хан һәм аның хатыны сыйфатында йөриләр. Татар риваятьләренә караганда, К., Ай һәм йолдызлар эпик герой тарафыннан тудырылган булырга мөмкин дип фаразлана. Татар йола поэзиясендә К.ка мөрәҗәгать итү еш очрый. Им-том җырларында җырчылар К.ка мөрәҗәгать итәләр, аны чакыралар, үзләрен ташламавын үтенәләр: «Асыл кояш, кил бире...». К., Ай һәм йолдызлар турында табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, тапкыр сүзләр һәм такмазалар күп: «Лампа түгел — яктырта, мич түгел — җылыта», «Кая барсаң да, бер кояш». Кайбер татар ялгызлык исемнәрдә дә К.ка табыну күзәтелә (Кояш, Кояшбикә, Кояшҗиһан).

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Урманче Ф. Дастаннарга лаек замана. К., 1990; Тресиддер Д. Словарь символов. М., 2001.

*Ф.Н.Урманчеев.*

**«КОЯ́Ш»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби, либераль-демократик юнәлешле көндәлек газета. Басма, үзе билгеләп үткәнчә, «бернинди партия программасына да буйсынмый». 1912 елның 10 декабреннән 1918 нең 11 июненә кадәр атнага 3 мәртәбә Казанда татар телендә барлыгы 1245 саны нәшер ителә. Мөхәррире һәм нашире — З.Садретдинов. Актив авторлары арасында Я.Айманов, М.Әхмәров, И.Биккулова, С.Вәлидов, Г.Газиз, Г.Гыйсмәти, Г.Лотфи, М.Мастукаев, Г.Мөхәммәтҗанов, С.Нигъмәтулла, Д.Парчинский, А.Стогов, Г.Шәрәф, С.Йосыпов, Ф.Яушев һ.б. була. Төп рубрикалары: «Дәүләт Думасы», «Ислам дөньясыннан», «Сәүдә һәм сәнәгать», «Әдәбият», «Музыка һәм театр», «Библиография». «К.» илдәге һәм дөньядагы сәяси вазгыятькә, Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясе эшчәнлегенә, татар хәйрия, мәдәни-агарту оешмалары эшенә, Беренче бөтендөнья сугышы чорында яраланучыларга, гаскәриләргә һәм качакларга ярдәм күрсәтү мәсьәләләренә, ш.у. мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләргә караган язмалар басыла. Окт. рев-циясеннән соң күбрәк татарларның милли азатлык хәрәкәтенә, мөселман съездлары, Мөселман ком-ты, Милли Мәҗлес, Милли Идарәгә кагылышлы мәсьәләләрне күтәрә. Татар әдипләре әсәрләренә (Ш.Бабич, Н.Ду-

мави, Х.Мәхмүдов, Г.Тукай), татар халкы тарихына бәйле язмаларга зур урын бирә.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**КОЯ́Ш КАЛЕНДАРЕ́**, Кояшның күренүче периодик хәрәкәтенә нигезләнеп, елдагы көннәрне исәпкә алу ысулы; нигез итеп кояш (тропик) елы алына. Тәүге К.к.ларының берсе Борынгы Мисырда б.э.к. берничә мең ел элек барлыкка килә; ул 30 ар көнлек 12 айдан тора, һәм ел ахырында 5 көн өстәлә. Хәзерге К.к. б.э.к. 45 елның 1 гыйнварыннан башланып киткән (Рим дәүләте башлыгы Юлий Цезарь тарафыннан кертелә һәм шул сәбәпле Юлиан календаре дип йөртелә) Юлиан календарена барып тоташа. Бу календарь түбәндәге эзлеклелектә чиратлаша: 365 әр тәүлекле өч (гади) ел һәм һәр дүртенчесе 366 тәүлекле кәбисә ел. Тәртип саны номерлары 4 кә калдыксыз бүленгән еллар кәбисә еллар була. Кәбисә елда февраль — 29 көннән, гади елда 28 дән тора. Юлиан календарендa елның озынлыгы 4 елда уртача 365,25 кояш тәүлегенә тигез, ягъни календарь ел тропик елдан бары тик 0,0078 тәүлеккә генә озынрак. Бу аерма 128 ел эчендә — 1 тәүлеккә, 400 елда 30 тәүлек озынлыгына җыела һәм шулай дәвам итә. Шуның аркасында чиркәү бәйрәмнәрен исәпләү катлаулана, һәм Рим папасы Григорий XIII, язгы көн-төн тигезлеге һәрвакыт 21 мартка туры килерлек итеп календарьны үзгәртү өчен, махсус комиссия төзи. 1582 дә 4 октябрьдән соң, 10 тәүлекне төшереп калдырып, икенче көнне 15 октябрь дип исәпләргә һәм моннан соң «кәбисәләр кагыйдәсен» үтәргә дигән карар кабул ителә. Бу кагыйдә буенча ике нульгә тәмамланучы «гасыр» еллары әгәр 400 гә бүленсәләр — кәбисә, бүленмәсәләр гади ел булып исәпләнә. Календарьдагы яңа исәп системасы Григориан календаре яки яңа стиль дип атала башлый. 16–17 йөзләрдә бу календарь Европа илләренең күпчелегендә кертелеп бетә. Безнең илдә яңа стильгә 1918 дә күчәләр; Совет хөкүмәте декреты б-н 1 февральне 14 февраль итеп күчерәләр, чөнки бу вакытка аерма инде 13 тәүлекне тәшкил итә. Григориан календаре К.к.ннан бары 20 секундка гына озынрак, һәм б.э.ның 50 нче йөзендә генә артык тәүлекләр барлыкка киләчәк. Идел буе Болгар дәүләтендә һәм татарларда К.к. гарәп язуы һәм ислам дине б-н бер үк вакытта киң таралыш ала. Мөселманнарга туклану һәм намаз вакытларын К.к. буенча алып барырга кушыла. Ул а.х. бәйрәмнәрен һәм аларга бәйле бәйрәмнәр чиратын да билгели. К.к. буенча ел исәбе мөселманнарда язгы көн-төн тигезлегеннән — 622 нең 21 нче мартыннан (б.э.) башлана. 19 йөз ахырында татарларның көнкүрешенә Пётр I тарафыннан Россиядә 18 йөзнең башында кертелгән христиан К.к. кулланыла. Ш.у. к. *Календарь, Ай календаре.*

*Әд.:* К л и м и ш и н И.А. Календарь и хронология. М., 1981; Х р е н о в Л.С., Г о л у б И.Я. Время и календарь. М., 1989.

*Е.Е.Беляева.*

**КОЯ́Ш РАДИА́ЦИЯСЕ**, Кояшның яктылык тизлеге б-н таралучы электромагнит нурланышы. К.р. — атм. күренешләре энергиясенең төп чыганагы һәм климат хасил итә торган төп факторларның берсе. Туры, сибелгән һәм гомуми К.р.нә бүленә, ТР терр-ясендә (Карамалы метеостанциясе мәгълүматлары буенча) иң зур К.р. суммасы (*МДж/м*²) июньдә (374 — туры, 283 — сибелгән һәм 657 — гомуми), иң азы декабрьдә (тиңдәшле рәвештә 10, 32 һәм 42). Гомуми К.р.нең еллык күләме 3900 *МДж/м*² га җитә. Еллык радиация балансы 1350 *МДж/м*² тәшкил итә, ноябрьдән февраль–мартка кадәр тискәре (ягъни К.р.нең йотылуы җир өслегенең эффектив (файдалы) нурланышыннан азрак). Кояшлы вакыт ел барышында 1880 сәгатьтән (төньяк-көнбатышта) 2050 сәгатькә кадәр (төньяк-көнчыгышта) дәвам итә. Апрельдән августка кадәрге чор аеруча кояшлы. Кояшлы вакыт озынлыгы еллык мөмкин булганның якынча 45–50% ын тәшкил итә, ә кояшсыз көннәрнең саны — 90–100. К.р.нең күрсәтелгән сыйфатлары үзгәрүчәнлеген һава шартларының еллык үзгәрешләре билгели.

*Әд.:* Климат и загрязнение атмосферы в Татарстане. К., 1995.

*Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.*

**КОЯ́Ш ҺӘМ АЙ ТОТЫЛУ́** (фольк.), күпчелек халыклар мифологиясендә, фольклор һәм әдәбиятында киң чагылыш тапкан табигать күренешләре. Бу күренештә серле һәм куркыныч мәгънә яшеренгән дип санала. Ул чирләр һәм бәхетсезлекләр билгесе булып тора. Төрки мифологиядә Ай һәм Кояш тотылу сюжеты Алтай халыклары риваятьләрендә очрый торган *Җилбегән* аждаһа б-н бәйле. Хакас халкында ул аеруча төгәл бәян ителгән: Җир шарының нәкъ уртасында Субур (Сюбюр) тавы бар, аның тирәсендә Кояш һәм Ай әйләнә. Күп башлы Җилбегән аларны йотса, бөтен җирне караңгылык каплап ала. Татарларда һәм башкортларда күктәге йолдызларның тотылуы турындагы борынгы күзаллаулар бары «Ай тотыла» һәм «Кояш тотыла» кебек сүзтезмәләрдә генә сакланып калган. Н.Исәнбәтнең «Татар халык табышмаклары» (К., 1970) китабында кара болыт, яңгыр һәм җир турында табышмаклар китерелә. Анда *Албасты* күктәге йолдызларны йотучы ролен үти. Татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләрендә К.һ.А.т. сюжеты үзенең борынгы мәгънәсендә дә (шом, хәвеф символы, бәхетсезлек билгесе), геройның рухи халәтен чагылдыру өчен дә кулланыла.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Табышмаклар. К., 1977; К а т а н о в Н.Ф. Шаманские песнопения сибирских тюрков. М., 1996; Т р е с и д д е р Д. Словарь символов. М., 2001.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КОЯ́Ш ҺӘМ АЙ ТОТЫЛУЛА́Р**, Җир Айның күләгәсенә (Кояш тотылу) яки Ай Җирнең күләгәсенә (Ай тотылу) кергән вакытта күзәтелә.

**Кояш тотылулар**. Ай фәзага күләгә конусын тарата, бу конусның түбәсе Ай үзәгеннән 368–380 мең *км* да урнаша; һәм конус Айдан 363–406 мең *км* ераклыктагы Җиргә кадәр җитәргә мөмкин (рәс.1).





Рәс. 1. Кояш тотылу схемасы.

Җирдә Ай күләгәсенең диаметры 270 *км* дан артмый, бу — Җирдә тулы Кояш тотылу күзәтелә торган иң зур өлкә, ягъни шушы өлкәдә Ай Кояшны тулысынча каплый. Әгәр дә бу көнне Ай, үзенең сузынкы орбитасы буенча күчеп, Җирдән ераграк урнашса, аның күренмә дискы зур булмый һәм Кояшны тулысынча каплый алмый, шунлыктан Ай күләгәсе тирәли Кояш божрасы күренеп кала (божрасыман тотылу). Айның — үз орбитасы буйлап, ә Җирнең үз күчәре тирәли хәрәкәтләре аркасында, Ай күләгәсе Җир өслеге буенча 1 *км/сәг.* тирәсе тизлек б-н күчә бара һәм тулы тотылуның тар, әмма озын (15 мең *км* га кадәр) полосасын сыза. Өлешчә Кояш тотылу күзәтелә торган ярымкүләгә конусның радиусы 3501 *км* тирәсе. Күләгә үзәгеннән ярымкүләгә кырыена таба ераграк киткән саен, тотылу фазасы (Кояш диаметрының ай каплаган өлеше) кечерәк була бара. Өлешчә Кояш тотылу вакытында Кояш дискы тулысынча капланмый. Зуррак фазалы өлешчә Кояш тотылу 2 сәгатькә кадәр дәвам итә, бу вакыт аралыгының уртасында, әгәр күзәтү урыны ай күләгәсенең юлына туры килсә, 7,5 *мин.* тан (божрасыманда 12 *мин.* тан) кимрәк вакыт эчендә тулы (яки божрасыман) Кояш тотылу күзәтелә.

Тулы Кояш тотылулар, бу вакытта Айның якты Кояшны гына түгел, Җир атмосферасының да беркадәр өлешен каплавы аркасында, зур фәнни кызыксыну тудыралар, чөнки Кояш тирәсен, ш.и. хромосфераны һәм Кояш таҗын күзәтү өчен комачаулыклар юкка чыга. Караңгылыкта калган Кояш тирәсендәге йолдызлар «Эйнштейн эффекты» дип аталучы күренешне — ихтималлык теориясенең астрономик чагылышын күзәтергә мөмкинлек бирә (күк гөмбәзендә Кояшка якын урнашкан йолдызлардан килгән яктылык нурларының Кояшның гравитация кыры тәэсирендә кәкрәю күренеше).

**Ай тотылулар**. Өлешчә Ай тотылу аның Җир күләгәсенә керүеннән башлана (рәс. 2),





Рәс. 2. Ай тотылу схемасы.

3,75 *сәг.* дәвам итәргә мөмкин; бу вакытның урталыгында 1,75 *сәг.* дәвамындагы тулы ай тотылулар була ала. Тулы тотылу вакытында Ай тонык коңгырт-кызыл төскә керә, чөнки аңа Кояшның Җир атмосферасында сынган нурлары төшә. Атмосфераның бу өлкәләрендә болытлар булу-булмауга карап, әлеге нурларның көче һәм төсе төрлечә була, шунлыктан Айның караңгылану дәрәҗәсе дә төрлечә күзәтелә; сирәк кенә Ай бөтенләй күренмәскә дә мөмкин.

**Кояш һәм ай тотылуның периодлары**. Кояш тотылулар бары тик яңа ай туган вакытларда гына, ә Ай тотылу алар Ай орбитасында Кояш б-н Айның күк йөзендәге күренмә нурлары кисешә торган төеннәргә якын урнашкан очракларда, тулы ай вакытында кү-

зәтелә. К.һ.а.т.ның дәвамлылыгы һәм фазасы Ай һәм Кояшның бу төеннәргә никадәр якын булуына бәйле. Ел саен 2 дән 5 кә кадәр Кояш тотылу һәм өчтән дә күп булмаган Ай тотылу күзәтелә. Җирдә, тулаем алганда, Кояш тотылулар ешрак була. Ай тотылулар Җирнең аңа караган тулы ярымшарында, Кояш тотылулар шактый ук кечерәк өлкәдә — Айның ярымкүләгәсе яки кечкенә генә күләгәсе төшкән урыннарда күренә. Билгеле бер урында тулы Кояш тотылулар уртача 300–400 елга 1 тапкыр була. Әйтик, Казанда Кояшның тулы тотылуы 1762 елның 17 октябрендә күзәтелгән, ә шуннан соңгысы 2061 дә булачак.

Ай һәм Кояш тотылулар эзлеклелегендә период саклана (6858,3 тәүлек), шуның эчендә К.һ.а.т. бер үк эзлеклелектә кабатлана. Бу период әле б.э.к. 6 йөздә үк «сарос» исеме б-н билгеле булган. Бер сарос дәвамында 43 тапкыр Кояш (15 өлешчә, 14 боҗрасыман, 2 боҗрасыман-тулы һәм 12 тулы) һәм 28 тапкыр Ай тотыла. Сарос киләсе тотылуның көнен билгеләргә мөмкинлек бирә; урынын, төгәл вакытын һәм күренмә фазасын өстәмә исәпләүләр б-н табалар. Тотылу вакыты моментларын исәпләүләрдә ялгышлык 2–3 *с* тан артмый, ә Җир өстендә тулы тотылу полосасы 1 *км* га кадәр төгәллек б-н исәпләнә.



Кояшның тулы тотылуы. Фоторәсем төньяк Байкалда 1981 елның 31 июлендә төшерелгән.

Төрле халыкларның елъязмаларында К.һ.а.т. га сылтамалар кайбер әһәмиятле тарихи вакыйгаларның даталарын билгеләргә, төрле календарь системалары арасындагы нисбәтләрне ачыкларга, берничә мең ел эчендә Кояш һәм Айның хәрәкәт траекторияләрен төгәл ачыкларга мөмкинлек бирә.

**Татарстан һәм Россия терр-ясендә кояш тотылулар**. Кояшның соңгы тулы тотылуы респ-каның көньягында 1961 нең 15 февралендә күзәтелә, шуннан соңгысы 2061 нең 20 апрелендә булачак. Шулай ук Россия терр-ясендә 2006 ның 29 мартында һәм 2008 нең 1 августында Кояшның тулы тотылуы күзәтелде.

Казан ун-тының астрономия кафедрасы һәм астрономия обсерваториясе галимнәре 20 йөздә Россия терр-ясендә күзәтелгән барлык тулы Кояш тотылуларны да өйрәнүдә катнашалар.

*Әд.:* Струве О., Линдс Б., Пилланс Э. Элементарная астрономия. М., 1964; Михайлов А.А. Солнечное затмение 31 июля 1981 года и его наблюдение. М., 1980.

*Р.В.Заһретдинов.*

**КӨБӘ́ КҮЛМӘ́К**, сугышчының өс киеме; тимер боҗралардан үреп эшләнгән күлмәк. Б.э.к. 1 нче меңъеллыкта Урта диңгез буйларында барлыкка килә. Авырлыгы 6–8 *кг* чамасы булган. Идел-Чулман буйларында б.э. башыннан мәгълүм. 7–14 йөзләрдә болгарларда киң тарала. 12 йөз ахырыннан үзгәреш кичерә: ул тезгә кадәр озыная, аны эшләү өчен яссы боҗралар файдаланыла башлый.



Көбә күлмәк. 14–17 йөзләр. ТР Милли музее.

13–16 йөзләрдә К.к.не эшләгәндә катнаш рәвештә төрле зурлыктагы эретеп ябыштырылган һәм чүкелгән боҗралар кулланыла, К.к.тә каеш б-н эләктермәле утыртма биек яка, аска таба киңәеп киткән итәк барлыкка килә, авырлыгы арта (17 *кг* га җитә). 14–17 йөзләрдә ш.у. зур диаметрлы яссы алка-боҗралардан торган күлмәк тә файдаланыла. Яулар вакытында К.к. махсус капчыкка салып йөртелә.

*Әд.:* Кирпичников А.Н. Древнерусское оружие. Л., 1971. Вып. 3; Горелик М.В. Ранний монгольский доспех (IX — первая половина XIV вв.) // Археология, этнография и антропология Монголии. Новосиб., 1987; Измайлов И.Л. Вооружение и военное дело населения Волжской Булгарии X — начала XIII вв. К.–Магадан, 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**КӨДРӘ́Ч** (Atraphaxis) карабодайчалар семьялыгыннан куаклар һәм куакчыклар ыругы. 25 кә якын төре билгеле, Евразиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — К. куак (A.frutescens) Кама аръягында очрый. Известьле һәм акбурлы тау битләрендә үсә. 20–70 *см* биеклектәге ярымкуакчык. Кабыгы коңгырт соры, кубаклы. Ботаклары нәзек, чәнечкесез. Яфраклары кыска саплы, озынча эллипссыман-нан тар ланцетсыманга кадәр, соры яшел яки зәңгәрсу күк, бөтен, яссы иисә аскы ягына аз гына кайтарылган читле, өске ягы — яссы, шома, аскы ягы чыгып торучан үзәк сеңерле. Чәчәк төркеме — сабак очында урнашкан 30–40 чәчәкле куе чук. Җимеше — очлы кабыргалы өчкырлы чикләвекчек. Июньдә чәчәк ата. Августта җимеш бирә. Декоратив үсемлек. Халык медицинасында бизгәкне дәвалауда кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Көдрәч куак.

**КӨЕ́К** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Юраш елгасының (Үмәкнең сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 12 кеше (татарлар) яши. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 276,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Черкасово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 65, 1887 дә — 171, 1905 тә — 124, 1920 дә — 215, 1926 да — 235, 1938 дә — 243, 1958 дә — 159, 1970 тә — 123, 1979 да — 70, 1989 да — 21, 2002 дә — 14 кеше.

**КӨЕ́К** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 4 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 127 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1710–11 еллардан мәгълүм. 1930 елларга кадәрге рәсми чыганакларда Туктамыш Көек исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1888 дә төзелә), мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 605,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 252, 1897 дә — 291, 1908 дә — 321, 1920 дә — 345, 1926 да — 270, 1938 дә — 304, 1949 да — 272, 1958 дә — 169, 1970 тә — 174, 1979 да — 161, 1989 да — 114, 2002 дә — 130 кеше.

**КӨЕ́К** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 4 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, мич чыгару, түбә ябу, балта эше, агач савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә Покров чиркәве (1880 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек оешмасы, 2 җил тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 818,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең

12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 600, 1897 дә — 875, 1908 дә — 979, 1920 дә — 1060, 1926 да — 1186, 1938 дә — 1002, 1949 да — 788, 1958 дә — 469, 1970 тә — 244, 1979 да — 90, 1989 да — 15, 2002 дә — 5 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. К., 1997.

**КӨЕ́К** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Нокса елгасы бассейнында. 2010 елда 368 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту, тимерчелек, май язу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә Никола чиркәве, земство (1880 елларда ачыла) һәм чиркәү-приход (1902 дә ачыла) мәктәпләре, 4 җил тегермәне, 4 май язу з-ды, 4 йон тетү бинасы, 2 тимерчелек, 2 сырыханә, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3430,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 184 ир-ат; 1859 да — 936, 1897 дә — 1273, 1908 дә — 1402, 1920 дә — 1318, 1926 да — 1600, 1949 да — 612, 1958 дә — 561, 1970 тә — 335, 1979 да — 160, 1989 да — 120, 2002 дә — 168 кеше.

**КӨЕ́К** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 134 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Икшермә, Өчнарат исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, киез итек басу һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, тегермән, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 632,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 138 ир-ат; 1859 да — 315, 1897 дә — 537, 1908 дә — 635, 1920 дә — 511, 1926 да — 507, 1938 дә — 446, 1949 да — 288, 1970 тә — 244, 1979 да — 222, 1989 да — 141, 2002 дә — 143 кеше.

**КӨЕ́К** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 65 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Актай елгасы буенда. 2010 елда 312 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, киез-киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә 2 мәчет (1862 һәм 1865 тә төзелә), 2 мәктәп, 5 тегермән, тимерчелек, 3 ярма яргыч, 2 йон тетү остаханәсе, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4457,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 166 ир-ат; 1859 да — 892, 1897 дә — 1828, 1908 дә — 1855, 1920 дә — 2087, 1926 да — 1480, 1938 дә — 1364, 1949 да — 999, 1958 дә — 751, 1976 тә — 708, 1979 да — 506, 1989 да — 384, 2002 дә — 332 кеше. К.тә язучы А.*Алиш* туган (музей).


**КӨЕ́К-ЕРЫКСА́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Комазан елгасы буенда. 2010 елда 592 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-Е.да мәчет, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 975,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 94 ир-ат; 1859 да — 563, 1897 дә — 957, 1908 дә — 1170, 1920 дә — 1079, 1926 да — 992, 1938 дә — 1038, 1949 да — 598, 1958 дә — 790, 1970 тә — 925, 1979 да — 842, 1989 да — 651, 2002 дә — 630 кеше.

**КӨЕКБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 6 *км* көньяктарак, Норма елгасы бассейнында. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 18 йөздә Норма авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Норма, Кармала, Биктимер исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чана ясау, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1912 дә мәчет ачыла. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 546,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1834 дә — 88, 1859 да — 92, 1897 дә — 146, 1908 дә — 179, 1920 дә — 183, 1926 да — 190, 1938 дә — 181, 1949 да — 139, 1958 дә — 178, 1970 тә — 128, 1979 да — 86, 1989 да — 14, 2002 дә — 1 кеше.

**КӨЕРГӘЗЕ́ РАЙОНЫ́**, БРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 2238 *км*². Үзәге — Ермолаев эшчеләр посёлогы (Уфадан 245 *км* көньяктарак). Халкы — 26259 кеше (2010), 3501 татар (2002). Районда 84 торак пункт, ш.и. 4 татар һәм 8 татар-башкорт авылы. Иң зур татар авыллары (2009): Зәк-Ишмәт (748 кеше), Шабагыш (571). 2004/05 уку елында районның 5 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла.

**КӨЗ**, ел фасылы, аерым бер билгеләр (астрономик, календарь, климатик, фенологик һ.б.) буенча билгеләнә. Астрономиядә төньяк ярымшарда К.гә көзге көн тигезлегеннән (22–23 сентябрь) кышкы кояш торгынлыгына (21–22 декабрь) кадәр булган вакыт аралыгын кертәләр. 1 сентябрьдән 30 ноябрьгә кадәрге чор календарь К. дип санала. Климатик сезон буларак, җәйдән кышка күчү вакытын тәшкил итә һәм темп-раның түбән төшүе б-н характерлана. К. башы дип салкын булмаган чорның тәмамлануы (Татарстан терр-ясендә сентябрьнең 2–3 нчеункөнлегендә) яки һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 10 °С аша узу (15–20 сентябрьгә туры килә) датасы алына. Климатик К.нең тәмамлануы һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 0 °С аша (24 октябрь–2 ноябрь) узу датасы яки кар капламы барлыкка килү (20–31 октябрь) б-н билгеләнә. Шул рәвешчә, ТР терр-ясендә көзге чор уртача 1,5 ай дәвам итә. Һаваның уртача айлык темп-расы сентябрьдә 10–12 °С (абс. макс. 33 °С, абс. мин. — 10 °С), октябрьдә 2–4 °С (абс. макс. 25 °С,







Көзге күренешләр.
1. Иж елгасы үзәненең сулъяк сөзәклеге;
2. Васильево посёлогы янындагы күл; 3. Кыр.

абс. мин. –27 °С). Көзен яңгырлы һәм болытлы көннәрнең саны арта, һаваның дымлылыгы күтәрелә. Атмосфера явым-төшемнәре тоташ характерлы. Явым-төшемнәр сентябрьдә якынча 13, октябрьдә 13–16 көн күзәтелә. Явым-төшемнәр суммасы 43–55 *мм* (Казанда 1919 елда 147 *мм* һәм 1938, 1974 тә 5 *мм*), октябрьдә 40–52 *мм* (1905 тә 121 *мм* һәм 1878, 1940, 1961 дә 4 *мм*). Көзен көньяк-көнбатыш һәм көньяк юнәлештәге җилләрнең кабатлануы арта, төньяк һәм төньяк-көнбатыш җилләрнең кабатлануы кими. Җилнең уртача тизлеге 4–5 *м/с*. *Томаннар* еш һәм озаграк дәвам итә, сентябрьдә уртача — 1–3 (макс. 4–9), октябрьдә 2–4 (макс. 7–12) көн. Көзен, ел саен диярлек, берникадәр вакыт җылы һәм коры һава («әбиләр чуагы») күзәтелә, бу тотрыклы антициклон һәм һава массаларының көньяктан керүе б-н бәйле. Күпчелек а.х. культураларының үсү чоры көзен тәмамлана, күчмә кошлар җылы якларга очып китә.

*Әд.:* Климат Татарской АССР. К., 1983.

*Э.П.Наумов.*

**КӨЗӘННӘ́Р** (Mustela), сусарсыманнар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 3 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Сасы көзән (M. putorius) барлык районнарда очрый. Урманнарда, елга тугайларында һәм кырларда яшиләр. 20 йөз ахырына аларның саны кискен кими. Дала көзәне (M. eversmanni) ачык ландшафтларда, еш кына Кама аръягында очрый, республика терр-ясендә 20 йөз башында күренә. Сасы көзәннең гәүдәсе 29–48 *см*, койрыгы 10–15 *см* озынлыкта, авырлыгы 1,3 *кг* га кадәр, ана затлар аталарына караганда кечерәк. Кара көрән төстә, мехы аксыл, койрыгы кара. Утрак яшәү рәвеше алып бара. Дала көзәненең гәүдәсе 40–52 *см*, койрыгы 10–18 *см* озынлыкта, авырлыгы 2 *кг* га кадәр. Сасы көзәннән аермалы буларак, ул аксылрак, аркасы саргылт-көрән. К.нең гәүдәсе озынча, сыгылмалы. аяклары кыска. Танавы сузынкы, түгәрәкләнгән киң колаклы. Җәен йоны сирәк, кышкыга караганда кыскарак. Күбрәк эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Ояларын куышларда, агач төпләре, чыбык-чабык, авылларда каралты-куралар астында ясыйлар. Куркыныч янаганда, аналь бизләрдән исле сыекча бүленеп чыга. Елга 2–3 тапкыр үрчи. Кушылу вакыты март-апрельдә, 1,5 айдан соң 4–6 (сирәк кенә 12 гә кадәр) бала китерәләр. 1 елдан җенси яктан җитлегәләр. Вак кимерүчеләр (йомраннар, байбаклар, әрләннәр, чыелдыклар, күселәр), ш.у. кошлар (үрдәкләр, көртлекләр) б-н тукланалар. Тычкансыман кимерүчеләрне, а.х. корткычларын юк итеп, зур файда китерәләр. 12 ел яшиләр. К. — кыйммәтле мехлы җәнлекләр.

**КӨЗГЕ́ УСА́Л ЧЕБЕ́Н** (Stomoxys calcitrans), чын чебеннәр семьялыгындагы бөҗәк. Һәр җирдә таралган, синотроп төр. Уртача зурлыкта, тышкы кыяфәте буенча бүлмә чебененә охшаш, әмма хортумчыгы чәнчеп суыруга җайлашкан. Личинкалары черүче органик калдыкларда үрчи, черемә һәм черүче үлән өеме аларның үрчүе өчен аеруча уңай. К.у.ч. кешене һәм йорт хайваннарын авырттырып тешли. Түләмә һ.б. авыруларны таратучылар.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. Л., 1970. Т. 5; Р о с с Г., Р о с с Ч., Р о с с Д. Энтомология. М., 1985.

*С.М.Шәфигуллина.*

**КӨЛӘГЕ́Ш САЗЛЫГЫ́**, Татарстандагы иң зур сазлык. Актаныш р-ны терр-ясендә урнашкан. Ык елгасының түбәнге агымыннан көнчыгыштарак, Кама-Агыйдел тугаендагы сазлыклы түбәнлекләрнең киң системасын били. Озынлыгы көнбатыштан көнчыгышка таба 17,5 *км*, төньяктан көньякка 10 *км*. Өстенлек итүче биеклекләр 62–65 *м*.

К.с.ның терр-ясе катлаулы комплекслы. Аеруча зур мәйданнарны кураклы сазлыклар били, биредә курак б-н бергә тар яфраклы җикәнбаш, камыш, су буе күрәне үсә. Иңкүлек сыртлары арасында ланцетсыман һәм Лансдорф чәчбайларыннан торучы чәчбайлы сазлыклар тоташ массив хасил итә. Чәчбайлы-куаклы сазлыклар көлсу, розмарин яфраклы, өч серкәчле таллар һәм кәрлә каен үскән сыртлара зур һәм кечкенә түбәнлекләрне били. Көнбатыш өлешендә сазлык *Игим наратлыгы* биләгән дюналы рельефлы биек комсу терраса б-н чикләнә. Субүләр битләре итәгенең көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләрендә чишмәле туену режимы булган сазлыклар таралган.

Сазлык комплексы чикләрендә ТРдагы иң зур Көләгеш торф чыганагы урнашкан. Торф ятмалары нуленче чиктәге 4 (мәйданы 4,6 мең *га*) һәм сәнәгать тирәнлеге чикләрендәге 11 участоктан (мәйданы 2,1 мең *га*) тора. Торфның гомуми запасы 5 млн. *т*, ш.и. баланста — 4,6 млн. *т*, бу исә республика торф запаслары балансының якынча 20%ын тәшкил итә. Торфның таркалу дәрәҗәсе 25%, көллелеге 11%, дымлылыгы 90,8%. Биредә торф ятмаларының барлык типлары бар: катнаш (0,9 млн. *т*), өске (0,9 млн. *т*), арадаш (0,3 млн. *т*). Ятмаларның төп төрләре: магелланикум, катнаш сазлыклы, уйсу-күрәнле. Торф ягулык, органик ашлама, ш.у. гидролизлы чимал һәм җылылык саклаучы плитәләр эшләүдә файдаланыла. Сазлык уртасында Көләгеш күле (исеме шуннан) урнашкан. Мәйданы 47 *га*, көньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба 3 *км* га сузылган. Төньягында күл 1,5 *км* озынлыктагы 2 култыкка аерыла. Төньяк-көнбатыштарак Әтер, Әҗби күлләре, көнчыгыштарак тар муен б-н 2 су өслегенә бүленгән Киндеркүл урнашкан. Яр буйларында куе булып су-сазлык үсемлекләре (камыш, курак, җикәнбаш, укъяфрак, котүче кубызы) үсә. Су үсемлекләреннән ак һәм сары төнбоек (ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр) бар. Кама һәм Агыйдел тугайларының элекке су юлларында сузынкы формадагы һәм тирән булмаган күп кенә күлләр (Куаклы, Сазак күл, Өшәр, Аяз күл һ.б.) урнашкан. 40 мең *га* дан артык булган мәйданда Көләгеш комплексly табигать тыюлыгын оештыру күздә тотыла.

*Әд.:* Б а р а н о в В.И. Кулигаш // Тр. КФАН СССР. Сер. биол. и с.-х. наук. 1948. Вып. 1.

*Ф.Г.Борһанов, Л.И.Корчагина.*

**КӨЛКӘ́Ш** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 31 *км* көнбатыштарак, Бола елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 51 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К. тә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 576 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782–53 ир-ат; 1859 да — 247, 1897 дә — 365, 1908 дә — 437, 1920 дә — 425, 1926 да — 390, 1938 дә — 361, 1949 да — 281, 1958 дә — 187, 1970 тә — 180, 1979 да — 143, 1989 да — 88, 2002 дә — 62 кеше.

**КӨЛМЕ́З РАЙОНЫ́**, Киров өлкәсенең көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 3106,4 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Көлмез посёлогы (Киров шәһәреннән 250 *км* көньяк-көнчыгышта-



Көләгеш сазлыгы.

рак). Халкы — 14792 кеше (2010), 2914 татар (2002), шуларның 500 дән артыгы үзләрен керәшеннәр дип саный. Район терр-ясендә татарлар 1920–30 елларда күренә башлый. Бу чорда алар Татар Көлмезе (259 кеше), Четай (254), Татар Бояры (158), Яңа тормыш (86), Тархан (65) һәм Волга (60) авылларына нигез сала. Татарларның күпчелеге район үзәгендә (2000 ләп кеше) һәм Рыбная Ватага (146) авылында яши. К.р.да татар мәдәни автономиясе, татар китапханәсе эшли, 2005 тән Сабан туе бәйрәме үткәрелә, 1990 елларда 7 мәчет төзелә. Районда а.х. фән. д-ры И. Фатыйхов туган.

**КӨЛСУ́ ТУФРАКЛА́Р**, туфрак тибы, уртача салкын климатлы, үтә юылу режимлы шартларда, ылыслы һәм ылыслы-яфраклы урманнарның карбонатсыз токымнарында хасил була. Туфрак барлыкка килү шартларының үзенчәлекләре: үсемлек калдыкларының күләме түбән, аз көлле, органик калдыклар нигезләренә ярлы булу. К.т.да көлсулану процессы үсеше: туфрак профиленең югары өлешендә органик матдәләрнең таркалу барышында барлыкка килгән түбән молекуляр кислоталарның беренчел һәм икенчел минералларны җимерүләре һәм җимерелү продуктларының түбәндәрәк ятучы горизонтларга һәм грунт суларына агып чыгуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. К.т.ның 120–130 *см* га кадәр калынлыктагы профиле ачык соры яки аксыл төстәге (көл төсендә, исеме шуннан) элювиаль (көлсу) горизонттан ($A_2$) тора, ул исә кремнезёмның ончыл бөртекләре һәм чикләвексыман структур аерымлыкларда гумусның ялтыравыклы утырмаларыннан торган коңгырт төстәге иллювиаль горизонт (B) б-н алышына. К.т. глейлы-көлсу (аэрациянең җитәрлек булмавы һәм өслектән глейлану б-н аерыла), көлсу һәм кәсле-көлсу (гумуслы горизонт шактый үсеш алган) астипларга бүленә. ТРда глейлы-көлсу һәм көлсу туфраклар Кама алдының төньяк районнардагы караңгы ылыслы урманнарда, зур булмаган мәйданнарда очрый. Кәсле-көлсу туфраклар К.т. мәйданының 90% ыннан артык өлешен, ТР мәйданының 9,9% ын (669,5 мең *га*) били. Кама алды районнарына хас туфрак, аеруча аның төньяк-көнбатыш өлешендә, урыны б-н Идел алды һәм Кама аръягында таралган. Субүләр тигезлекләрен, сөзәклекләрнең югарыгы һәм урта өлешләрен били. Кәсле-көлсу балчыксыл туфраклар өстенлек итә (мәйданның 73%ы). Зур елгаларның тугай асты югары террасаларына борыңгы аллювиаль утырмалардагы комсу һәм комсыл туфраклар туры килә, аларда исә нарат урманнары таралган. Кәсле-көлсу туфраклар а.х.да киң кулланыла, туфракның 40% тан артыгы сөрү җирләре. Бөртекле, азык культуралары, бәрәңге үстерелә, бакчалар утыртыла, печәнлек һәм көтүлек җирләре; 284 мең *га* дан артык мәйданны урманнар биләп тора. Гумуслы горизонтның калынлыгы зур түгел, гумус аз (1–4%, сирәк кенә 6% ка кадәр), ачы реакцияле, йоту комплексы түбән һәм нигезләр җитәрлек түгел, һава-су һәм җылылык режимы тискәре. Кәсле-көлсу туфракларның уңдырышлылыгын күтәрү өчен известь, органик һәм минераль ашламалар кертәләр, күпьеллык үләннәр чәчәләр, көлсуланган һәм түбән ятучы иллювиаль горизонтлар исәбенә сөрү катламын акрынлап арттыралар (чәчү әйләнешендә 25–28 *см* га кадәр).

*Әд.:* Почвы Татарии. К., 1962; Почвоведение. Ч. 2. Типы почв, их география и использование. М., 1988. *Ф.Г.Борһанов.*

**КӨМЕ́Ш**, Ag, табигатьтә саф килеш табыла торган элементлар классындагы минерал, составында Au, Sb, Bi һ.б. катышмалар бар. Ак агачсыман агрегатлар, бөртек һ.б. формалар рәвешендә. Катылыгы 2–3. Тыгызлыгы 10,1–11,1 *г/см*$^3$. Табигатьтә саф килеш (20 *т* га кадәр авырлыкта) һәм төрле минералларда катышма рәвешендә очрый. К. Татарстан терр-ясендә Вятка-Кама бакыр зонасында табылган югары Пермь утырмаларының сульфидлы минераллары һәм органик матдәләр составына керә. Бу зонада 218 табигый һәм 100 техноген руда чагылмаларыннан торган 80 бакыр участогы ачыкланган. Табигый зоналарда К. — Кама аръягында (30 *г/т* га кадәр) бакыр рудасы кырларында (Сарман һәм Чатыр Тау), Кама алдының Синтәк авылы янында (34 *г/т*) күмерле-балчыклы катламда аеруча күп; техноген руда җыелмаларында — бакыры алынган тау токымнары өемнәрендә: төерләрдә (конкрецияләрдә 386 *г/т* га кадәр), руда токымнары ватыкларында (1000 *г/т* га кадәр) билгеләнә. К. акча сукканда, зәргәр һәм көнкүреш әйберләре, лаборатория савытлары ясаганда, электро- һәм радиотехникада, медицинада һ.б. кулланыла.

*Әд.:* Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999. Ч. 1; Геологическое изучение земных недр Республики Татарстан. К., 2002; Минеральное сырье. Серебро. М., 1998.

*Р.Р.Хәсәнов.*

**«КӨМЕ́Ш КЫҢГЫРА́У»**, атналык балалар-яшүсмерләр газетасы. Оештыручылары — халык депутатларының Чаллы шәһәр советы һәм шәһәр хакимияте. 1993 елның ноябреннән Чаллы шәһәрендә «Шәһри Чаллы» г-тасының кушымтасы, 1995 нең октябреннән, мөстәкыйль басма буларак, рус һәм татар телләрендә нәшер ителә. Мөхәррире — Н.И.Садыйкова.

**КӨМЕ́Ш КЫТЛЫГЫ́ ЧОРЫ́**, Көнчыгыш Европа илләрендә 11 йөзнең 1 нче яртысыннан — 12 йөзнең 1 нче яртысында көмеш акчалар сугуның кимүе, аларның сыйфаты түбәнәю һәм әйләнештәге микъдары азаю. Якын Көнчыгыш һәм Алгы Азиянең көмеш рудниклары ярлылану, ш.у. һөнәрчелек һәм сәүдәнең көчле үсеше нәтиҗәсендә акча алмашына ихтыяҗ арту аркасында килеп чыга. Идел-Балтыйк сәүдә юлы буйлап көмеш кертүнең кимүе һәм халыкара сәүдәнең үсеше Көнчыгыш Европада акча сугуның тукталуына китерә. К.к.ч.нда Көнчыгыш Европа илләрендә алыштыру акчасы урынына көмеш коелмалары, тире һәм мех «акчалар» (идарәчеләрнең тамгасы яки мөһере басылган затлы тиреләр) кулланыла башлый. Нумизматлар фикере буенча, Русьта һәм Идел буе Болгар дәүләтендә акча сугу 12 йөз ахырында — 13 йөз башында яңадан торгызыла.

*Әд.:* М ө х ә м м ә д и е в Ә. Борынгы хәзәр һәм болгар-татар акчалары. К., 1986; ш у л у к. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Я х и н В.Л. Денежно-весовые системы русского средневековья: Домонгольский период. М., 1956. *И.Л.Измайлов.*

**КӨМЕ́Ш ҮРМӘКҮ́Ч**, с у ү р м ә к ү ч е (Argyroneta aquatica Clerck), Argyronetidae семьялыгының бердәнбер вәкиле. Европаның төче сулыкларында таралган. Татарстан терр-ясендә сирәк очрый. Үсемлекләр күпләп үскән акрын агымлы һәм агымсыз сулыкларда яши. Ата затлар 15–20 *мм*, ана затлар — 10–12 *мм* озынлыкта. Су астында сулыш алу өчен һава катламы җыеп кала торган, юешләнмәүче йомшак төкләр б-н капланган корсагы терекөмеш тамчысы кебек ялтырый (фәнни исеме шуннан). Үпкә б-н сулауга караганда, тән сулавы өстенрәк. Ана зат, пәрәвезне тыгыз үрү сәбәпле, һаваны тотып торучы кыңгыраусыман оясын су астында ясый, анда исә йомыркалы кузыны урнаштыра һәм маймычлар чыкканчы аны саклый. Су бөҗәкләре, еш кына личинкалар б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Н.В.Шулаев.*

**КӨМЕШКҮ́Л** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Өске елгасы буенда. 2010 елда 305 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1680 нән Түбән Биләтли буларак билгеле; хәзерге исемен 1954 тән йөртә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, тегермән, 2 ярма яргыч, постау остаханәсе, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1164,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир-ат; 1859 да — 525, 1897 дә — 998, 1908 дә — 1111, 1926 да — 1073, 1938 дә — 908, 1949 да — 702, 1958 дә — 509, 1976 да — 619, 1979 да — 532, 1989 да — 436, 2002 дә — 401 кеше.

**«КӨН»**, газета, к. «*Таң*».

**КӨНБАГЫ́Ш** (Helianthus), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 50 төре билгеле. Чыгышы — Төньяк Америка. Россиядә культурага 1829 елда кертелә. Казан төбәгендә 19 йөз уртасында үстерелә башлый. ТРда 2 төре бар: майлы К. (H. annus) һәм *топинамбур*, яисә җир грушасы (H. tuberosus). Майлы К.ның тамыр системасы бик көчле (төп тамыр 140 *см* га кадәр), ян-як тамырлары яхшы үскән. Сабагы биек, агачсыман, каты төкләр б-н капланган. Яфраклары эре, йөрәксыман озынча формада. Чәчәк оешмасы — кәрзин, диаметры 20 *см* дан 50 *см* га кадәр. Читтән серкәләнә. Җимеше — орлык.



ТРда К. май алу өчен һәм терлек азыгы (силос) буларак игелә. ТРда чәчелә торган сортлар: «Донской 60» (1997), «ВНИИМК 8883» камилләштерелгән (1997), «Скороспелый 87» (2001); гибридлар: «Харьковский 49» (1993), «Р.453» (1997), «Донской 22» (1997), «Санмарин 361» (2001). 2006 да К. чәчүлеге мәйданы 2,4 *га* (1941 дә — 29,3 мең *га*). Баллы үсемлек. Корткычлары — каты корт, ялган каты корт, көнбагыш утчыллары, кимерүче ябалакчалар һ.б.; авырулары — склеротиниоз, соры черек һ.б.

**КӨ́НБАТЫШ ДИАЛЕ́КТ**, к. *Мишәр диалекты*.

**КӨ́НБАТЫШ КА́МА АЛДЫ́**, ТРның физик-географик төбәге. Кама елгасының түбәнге агымыннан төньяктарак, көньяк-көнбатышта Идел һәм көнчыгышта Вятка елгалары арасында. Мәйданы 17,9 мең *км*². Рус платформасының Идел-Урал антеклизасы чикләрендә. Платформаның фундаменты архей һәм протерозойның кристаллик токымнарыннан тора, көнчыгышта 1550 *м* дан, көнбатышта 1800 *м* дан тирәндәрәк ята һәм девон, ташкүмер, Пермь, неоген һәм дүртенчел системаның диңгез һәм континенталь утырмалары б-н капланган. Өске катламы югары Пермь утырмаларыннан хасил булган: елга үзәннәренең сөзәклекләре — Казан ярусы токымнарыннан (известьташлар, доломитлар, ш.у. көнчыгышта Бәләбәй свитасының комташлары һәм балчыклары), субүләрләр татар ярусының континенталь утырмаларыннан (комташ һәм известьташ катламнары б-н мергель һәм төрле төстәге балчыклар) гыйбарәт. Идел, Казансу, Мишә елгаларының борынгы үзәннәре плиоценның ком-балчыклы катламнарыннан ясалган, елга террасалары дүртенчел системаның аллювиаль токымнарыннан (ком, чуерташ, балчык) тора, сөзәк битләре делювиаль-солифлюкцион балчыклы-вакташлы утырмалар б-н капланган. Идел, Казансу һәм Илләт елгаларының югары террасаларының комнары урыны б-н дюналар хасил итә.

К.К.а. рельефы елга үзәннәре, сыза һәм ерымнар б-н бүлгәләнгән тигезлектән гыйбарәт. Рельефның абс. биеклеге 53–228 *м*, уртача 150 *м* тирәсе тәшкил итә. Тигезлекнең калкулыклы урыннары (200–220 *м*) тектоник структуралар б-н бәйле — көнбатышта Вятка өелмәсенең түбәнәеп баручы көньяк өлеше һәм көнчыгышта Татар гөмбәзенең төньяк күтәрелмәсе. Бу калкулыклар арасында 180–200 *м* биеклектәге тигезлекләр ята. Көньяк-көнбатышта Иделнең уңъяк террасалары 60–130 *м* абс. биеклектә киң полоса булып (20–25 *м* га кадәр) сузылган. К.К.а. өчен тыгыз (0,36 *км/км*²) ерымнар челтәре хас, бу ТРдагы уртача күрсәткечтән 1,5 тапкырга артык. Территориянең 50 % ында туфрак эрозиясе таралган. Идел һәм Казансу үзәннәрендә, ш.у. Вятка өелмәсе зонасында карст, ә Кама һәм Вятка үзәннәренең сулъяк текә сөзәклекләрендә шуышма процесслары көчле үсеш алган.

К.К.а. климаты чагыштырмача дымлы һәм салкынча җәй, уртача салкын һәм карлы кыш б-н аерыла. Гыйнварның уртача темп-расы көньяк-көнбатышта –13,5 °С тан төньяк-көнчыгышта –14,3 °С ка кадәр, июльдә — төньякта 18,6 °С тан көньякта 19,6 °С ка кадәр үзгәрә. Абс. мин. темп-ра –48 °С (1978, Арча), абс. макс. — 38 °С (1971, Казан). Салкын булмаган чор 120 дән (төньяк-көнбатышта) 150 көнгә (көньякта, Куйбышев сусаклагычы тирәсендә) кадәр сузыла. Еллык атм. явым-төшемнәренең күләме 490–540 *мм*, ш.и. җылы чорда 330–360 *мм*. Кар капламының калынлыгы 36–47 *см*.

Төбәк терр-ясе Иделнең сул кушылдыклары б-н дренажлана: төньяк-көнбатыш чиктә — Илләт һәм аның кушылдыгы Ашыт, көнчыгышка таба — Казансу елгасы. Үзәк һәм көньяк өлештә Каманың уң кушылдыклары — Мишә, Бырыс, Әшнәк, Бәтке, Суша, Шомбыт, Бөрсет ага. Төбәкнең төньяк-көнчыгыш өлеше Вятка елгасы бассейнына (кушылдыклар — Шыя, Бөре, Шушма) карый. Елга челтәренең уртача тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Биредә, аеруча төбәкнең көнбатыш өлешендә, тирән күлләр күп — Раифа, Осиново, Тирән күл, *Зәңгәр күлләр*, Кабан, Архиерей күлләре һ.б.

К.К.а.нда төбәкнең иң уңдырышлы аксыл соры һәм соры урман туфраклары өстенлек итә (а.х. җирләренең якынча 70 % ын алып тора). Кәсле-көлсу (17 %) һәм кәсле-карбонатлы (5 %) туфраклар яссы субүләрләрдә таралганнар. Территориянең сөрүле җире 61–86 % тәшкил итә. Уртача урманлылык 16,6 %, иң азы — Әтнә (4%), иң күбе Мамадыш (28 %) р-ннарында. Файдалы казылмалардан төзелеш чималы запаслары зур. Известьташ, доломит, балчык, комташларның эре чыганаклары эшкәртелә. Мишә үзәнендә торф, сапропель запаслары билгеле.

ТРдагы аеруча сакланулы табигать терр-яләренең күбесе К.К.а. төбәгендә билгеләнә: *Идел-Кама саклаулыгы*; табигать тыюлыклары: *Ашыт*, Зәңгәр күлләр, «*Иске тегермән*», табигать истәлекләре: урманнар — «Соколка урманы», «Казансу башы», «Утыртылма урман», Семиозёрка урманы, Порфирьев акчыршылыгы һ.б.; ботаник — Яңасала сөзәклеге, Остачы сөзәклеге һ.б.; зоологик — Курса һәм Сумка соры челән колонияләре, Күл акчарлаклары колониясе; ландшафтлы — Кукмара тавы, «Терлек таулары», ерым-сызалар системасы: «Фәхри яры», «Кишәнгер», «Никольский» һ.б.; 10 елга (Казансу, Мишә, Бөрсет, Лубян, Шушма һ.б.), 18 күл (Аккүл, Кавал күле, Архиерей, Куян күле, Чиста күл, Саламык күле һ.б.).

Кыргый хайваннарның кәсәбәчелек төрләре санын арттыру һәм аларны саклау максаты б-н, аучылык тыюлыклары (Сорнар, Шомбыт, Столбище, Мишә, Саба) оештырылган.

*Әд.:* Рельеф Татарии. К., 1951; Очерки по географии Татарии. К., 1957; Географическая характеристика административных районов Татарской АССР. К., 1972.

*А.П.Дедков, Г.П.Бутаков.*

**КӨ́НБАТЫШ КА́МА А́РЪЯГЫ**, ТРның физик-географик төбәге. Идел һәм Каманың сулъяк ярлары буенда, Чишмә елгасыннан көнбатыштарак урнашкан. Мәйданы 13,8 мең *км*². Мәләкәс тектоник батынкылыгының төньяк өлешенә туры килә. Архей һәм түбән протерозой токымнарыннан торган кристаллик нигезе төньякта 1650–1700 *м* дан түбәндәрәк, көньякта 2000 *м* га кадәр тирәнлектә ята. Палеозойның девон, ташкүмер һәм Пермь системасы, кайнозойның неоген һәм дүртенчел системасы утырма токымнары катламы б-н капланган. Девон һәм ташкүмер утырмалары составында — известьташлар, терриген комташ горизонтлы доломитлар, алевролит һәм аргиллитлар. Түбән Пермь токымнары известьташлардан, гипс һәм ангидрит катламлы һәм линзалы доломитлардан гыйбарәт. Түбән Пермь токымнарының юылган һәм карстланган өске катламында Пермь системасының югары бүлегендәге

Көнбатыш Кама алды күренеше (Лаеш районы).



Уфа, Казан һәм Татар яруслары утырмалары ята. Уфа ярусы утырмалары — кызыл төстәге комташлар һәм балчыклар — төбәкнең көнчыгыш өлешендә, түбән Казан известьташлары, доломитлар һәм балчыклар бөтен җирдә таралганнар. Көнбатышта югары Казан утырмалары известьташ, доломит һәм гипслардан тора, көнчыгышта исә алар Бәләбәй свитасының комташлары, конгломерат һәм балчыклары б-н алышына. Өстәрәк Татар ярусының төрле төстәге балчыклары, мергельләр, комташлар һәм конгломератлар ята, алар К.К.а.ның үзәк һәм көнчыгыш өлешләрендә күп кенә субүләрләр төзиләр. Югары Пермь утырмаларының гомуми калынлыгы 300–400 *м* га кадәр. Аларның эрозияле тигезсез өске катламында неоген һәм дүртенчел системаларның балчык, комсыл балчык, ком һәм чуерташлары ята. 200–300 *м* га кадәр калынлыктагы неоген утырмалары Идел, Кама һәм аларның кушылдыкларының борынгы үзәннәрен түши, барлыкка килүләре буенча алар күл һәм елгаларга бәйле, Каспийның акчагыл трансгрессиясе утырмаларының 10–20 *м* калынлыктагы горизонтына ия. Дүртенчел система утырмалары, нигездә, барлык үзәннәрдә елга террасаларын сөзәк тау битләренең делювиаль-солифлюкцион шлейфларын, субүләрләрдә эол капламнары комплексын төзи.

К.К.а. рельефы тирән булмаган үзәннәр, сызалар һәм ерымнар б-н бүлгәләнгән уйсу тигезлектән гыйбарәт. Рельефның абс. биеклеге 53–243 *м*, уртача 120 *м*. Биеклеге, килеп чыгышы һәм яше буенча рельефның өч баскычы билгеләнә. Көнбатыш — иң түбән (биеклеге 120 *м* га кадәр), дүртенчел системаның Идел террасалары комплексы б-н барлыкка килгән; үзәк (160–200 *м*) — денудацион-аккумулятив, нигездә, Татар ярусы һәм плиоцен токымнарыннан тора; көнчыгыш (200–243 *м*) — денудацион, югары Пермь токымнарында хасил була. К.К.а. өчен ТРдагы ерымнар челтәре тыгызлыгының иң түбәне (0,09 *км/км*²) хас, сызалар челтәре тыгызлыгы 0,63 *км/км*² га җитә. Үзәк һәм көнбатыш өлешләрдә еш кына сазлыклы, суффозион-карстлы иңкүлекләр һәм упкыннар күп. Куйбышев сусаклагычының ярлары урыны б-н (Спас р-ны Балымер һәм Полянка авыллары участогында, Актай елгасы тамагыннан төньяктарак һ.б.) абразияле.

К.К.а.ның климаты җылы һәм аз дымлы җәй, уртача салкын һәм чагыштырмача карлы кыш б-н аерыла. Гыйнварның уртача темп-расы көнбатышта –13,5 °С тан көньяк-көнчыгышта –14,3 °С ка кадәр, июльдә — көньяк-көнчыгышта 19 °С тан көнбатышта 19,6 °С ка кадәр үзгәрә, абс. мин. –50 °С (1942, Чулпан), абс. макс. 39 °С (1971, Аксубай). Бик салкын көннәр (–35 °С һәм түбәнрәк) Нурлат р-нында күзәтелә — кышкы чорда уртача 3 көн. Салкын булмаган чорның озынлыгы 120–140 көн. Еллык явым-төшемнәрнең күләме 460–500 *мм*, шуның 310–340 *мм* елның җылы чорына туры килә. Кар капламының калынлыгы 35–45 *см*.

Гидрографик челтәр елга, күл һәм сазлыклардан гыйбарәт. Төбәк көнбатыштан Идел, ә төньяктан Кама, көнчыгыштан Чишмә елгалары б-н юыла. Аеруча зур агымлы сулар: Олы Чирмешән, Актай, Олы Сөлчә. Елга челтәренең уртача тыгызлыгы 0,27 *км/км*², бу Татарстанда иң түбән күрсәткеч. Элекке елга юлында сакланып калган һәм суффозион-карстлы күлләр күп. Елга үзәннәрендә һәм үзәктәге түбәнлекләрдә — сазлыклар, ш.и. Кече Чирмешән елгасы үзәнендә *Татар Әхмәте торфлы сазлыгы* урнашкан. Кубесенчә уртача катламлы һәм уртача гумуслы селтесезләнгән кара туфраклар өстенлек итә; зур мәйданнарда, аеруча субүләрләрдә соры һәм куе соры урман туфраклары таралган. Сөрүле а.х. җирләре 76–85 % мәйданны били. Урманнар күбрәк көньяк-көнчыгышта сакланган. Урманлылык Нурлат (38,8 %), Чирмешән (24,2 %) р-ннарында югары, Спас (8,6 %) һәм Чистай (6,6 %) р-ннарында түбән.

Нурлат, Аксубай һәм Чирмешән р-нна-рында нефть чыгару эшләре бара. Бентонит балчыгының зур (Россия күләмендә) чыганаклары (Югары Нурлат, Тарн-Вар, Берёзовка) эшкәртелә. Төбәк кирпеч балчыклары б-н яхшы тәэмин ителгән, зур чыганаклар Аксубай, Яңа Чишмә, Чистай торак пунктлары янында. Россиядә бердәнбер булган мәрмәр ониксы — Пичкас чыганагы табылган. Ком чыгару перспективалы (Болгар ш., Әлки р-ны Каракүл а. янында). Торф чыганаклары (Аппак, Кады, Калинка) бар.

К.К.а.ның күп кенә табигать объектлары аеруча саклануы терр-яләр буларак билгеләнгән, алар исәбендә табигать тыюлыклары — *Ивановский наратлыгы, Коржинский сөзәклекләре*, табигать истәлекләре — Татар Әхмәте торфлы сазлыгы, «*Спас*» тыюлыгы, ш.у. елгалар — Олы һәм Кече Чирмешән, Олы һәм Кече Сөлчә, Талкишка, күлләр — Атаман күле, Исемсез күл, Чистакүл, Чуртан күле (Спас р-ны), Упкын күле (Алексеев р-ны), Каракүл (Нурлат р-ны). К.К.а.ның үзәк өлешендә Биләр аучылык тыюлыгы урнашкан.

*Әд.:* Рельеф Татарии. К., 1951; Очерки по географии Татарии. К., 1957; Географическая характеристика административных районов Татарской АССР. К., 1972; География Татарстана. К., 1994.

*А.П.Дедков, Г.П.Бутаков.*



Көнбатыш Кама аръягы. Типик ландшафт.

**КӨНГЕ́Р РАЙОНЫ́**, *Пермь краеның* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 елның 27 февралендә оештырыла. Мәйданы — 4,4 мең *км*². Үзәге — Көнгер шәһәре (Пермь шәһәреннән 101 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 46653 кеше (2010), 3866 татар (2002). Татарлар, башлыча, Усть-Турка (915 кеше), Бырма (813), Бажуки (947), Красный Берег (206), Липовка (87), Татар Шишмарасы (58), Ключ (97), Казаево (454), Баташи (289) авылларында яшиләр. К.р. терр-ясендә татарлар Казан ханлыгы яулангannan соң килеп төпләнә. 1678–79 елларда-гы халык санын теркәү кенәгәсендә Көнгердә — 785 татар, 1795 елгы ревизия вакытында 4399 татар теркәлгән. Бырма (1902 елда), Казаево (1908), Усть-Турка (1916), Бажуки (1924) кебек татар авылларында 20 йөзнең 1 нче чирегендә дөньяви мәктәпләр ачыла. 1940–50 елларда башлангыч мәктәпләр — җидееллык, 1959 дан сигезьеллык итеп үзгәртелә. 2005/06 уку елында Усть-Турка һәм Бажуки авыллары мәктәпләрендә укыту татар телендә алып барыла, Бырма мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. 1993 тән Усть-Турка авылында Татар милли мәдәнияте һәм халык иҗаты үзәге эшли. Хәзерге вакытта К.р.ның Көнгер шәһәрендә һәм Бырма, Усть-Турка авылларында 3 мәчет бар.

*Әд.:* Харитонов В.И. Очерки по истории села Бырма Кунгурского района. Бырма, 1992; Валиуллин Р.Ш. Очерки по истории родного края. Барда, 1998; Минсадырова Г.Ш. Из истории села Усть-Турка Кунгурского района. Усть-Турка, 2000; Чагин Г.Н., Черных А.В. Народы Прикамья: Очерки этнокультурного развития в XIX–XX вв. Пермь, 2002.

**КӨНГЕ́Р ТАТАРЛАРЫ**, к. *Пермь татарлары*.

**КӨНГЕ́Р Я́РУСЫ**, (Пермь губернасындагы Көнгер өязе атамасыннан), *Пермь системасы (чоры)* Урал буе бүлегенең өске өлешендәге тау токымнары катламы. Казан ун-ты профессоры А.А.*Штукенберг* тарафыннан ачыла (1888). Татарстан терр-ясендә К.я. катламнары көнчыгыш районнарда бораулау скважиналары ярдәмендә ачыклана, Иж елгасы тамагы, Чишмә бассейны һ.б. урыннарда

аерым өскә чыгу очраклары бар. Асылда доломитлар, ангидритлар, мергельләр, гипс һәм балчыктан торалар. К.я.ның калынлыгы 120 *м*. Бу токымнар 280 млн. ел элек тереклек билгеләре булмаган, акрынлап тозлана барган сулыкларда ясалган.

*Әд.:* Геология Татарстана. К., 2003.

**КӨ́НКҮРЕШ ГИГИЕ́НАСЫ**, гигиена бүлеге, кеше сәламәтлегенә яшәү мохите, сан.-эпидемиологик тирәлек, социаль һәм техноген факторлар тәэсирен өйрәнә; халык сәламәтлеген ныгыту өчен уңайлы сан.-эпидемиологик шартлар булдыручы гигиена кагыйдәләрен, сан. чараларын эшли. К.г.ның өйрәнү объектлары булып халыкның яшәү шартлары, экология системасы (һава, су, туфрак) санала.

Казан гигиена белгечләренең беренче тикшеренүләре 19 йөз башына карый: Ф.Д.Калайдович, И.К.Ерохов, И.С.Дмитриевский, Г.И.Блюсфельд Казандагы су чыганаклары сыйфатын өйрәнәләр (Сасы күлләр, Черек күл, Мунча күле), соңрак аларның сулары эчәргә яраксыз табылып, күмеләләр. 1939 елда К.И.Клаус Казансу елгасының һәм аның кушылдыкларының сулары б-н җир асты сулары арасында элемтә булуын фаразлый. Казансу елгасының һәм җир асты суларының шәһәргә су алу урынындагы үрнәкләре сыйфатын тикшерү җир асты су катламнарының охшаш сыйфатлы булуын ачыклый (К.В.Бренинг лаб-ясе). 1874 тә Казанда шәһәрне Пановка чишмәләре сулары (Киндерле елгасы башы) б-н тәэмин итүче беренче суүткәргеч төзелә. 1870–80 елларда су чыганакларын өйрәнүдә химик А.И.Бутлеров, математиклар А.П.Котельников, Б.Больцано, гигиена белгечләре А.И.Якобий, И.П.Скворцов катнашалар. 1900–20 елларда су чыганакларын һәм туфракны сан. саклау буенча фәнни тикшеренүләрне К.Е.Добровольский, А.И.Раммуль дәвам итә. А.А.Штукенберг һәм А.Я.Щербаков Казанның Мокрая урамындагы (Адмиралтейство бистәсе тирәсендәге Игумный бистәсе), Постаучылар бистәсендәге, шәһәр читендәге Архиерей дачасындагы, Алафузов з-ды терр-ясендәге һ.б. артезиан коеларындагы су сыйфатын тикшерәләр. Казанда су б-н тәэмин итү мәсьәләләрен ш. у. гигиена белгечләре В.Д.Орлов, В.А.Арнольдов, Н.И.Орлов тирәнтен өйрәнәләр. Алар тарафыннан, Казанны су б-н тәэмин итү чыганагы буларак, Идел һәм аның кушылдыклары сулары составы тикшерелә. В.В.Милославский һәм аның шәкертләре су тәэминаты буенча тикшеренүләрне дәвам итәләр, Казанда һәм республикада суүткәргечләрне проектлауны фәнни яктан нигезлиләр. Казан гигиена белгечләре тарафыннан су чыганакларын тикшерүнең бердәйләштерелгән ысуллары гамәлгә кертелә (А.Я.Щербаков, А.И.Якобий), торак пунктларда, яшәү урыннарында атмосферадагы һаваның аэроион составына бәйле рәвештә халык сәламәтлеге торышы өйрәнелә (И.А.Скворцов); 1930 еллар башында А.Н.Сысин Казан шәһәр төзелешенә нисбәтле гигиена тәкъдимнәрен эшли. 1943 тә Казан мед. ин-тында оештырылган К.г. каф. (мөдире С.С.Шулпинов) республика халкын эчәргә яраклы су б-н тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү юлларын эшли. 1960–70 тә Идел, Казансу, Зөя елгалары суларының химик составы, аларның нитратлашу процессына авыр металлар тәэсире, су-нитратлашу метгемоглобинемиясе мәсьәләләре (Н.И.Петухов) өйрәнелә; республикадагы җир асты суларына гигиеник характеристика бирелә. Эчү өчен яраклы суда нитратларның иминлек күрсәткече (45 *мг/л*) Н.И.Петухов һәм А.В.Иванов тарафыннан тәкъдим ителә, халыкара һәм РФ дәүләт стандартларына кертелә (эчәргә яраклы суның сан. нормалары). Алар тарафыннан «Танкодром» су җыю урынын сан. саклау чикләре нигезләнә. Казан терр-ясендә тышкы мохиттәге объектларда канцероген кушылмалар барлыгы ачыклана, ш.у. онкологик авырулар китереп чыгару куркынычы булган факторларга анализ бирелә. Казан гигиена белгечләре тарафыннан ТРның көньяк-көнчыгышындагы экологик системаның төп компонентларына (су, һава, туфрак) характеристика бирелә, «Татарстан Республикасының районнарын планлаштыру схемасы» (1975), «Казан шәһәре тирәсе зонасы үсеше проекты» (1978) эшләнә. 1980 еллар башында сулыкларда дипроксамин ПДК, ВВ-2 реагенты, 1,2-пентадиол, 1,5-пентадиол, 1,4,5-пентадиол, атмосфера һавасында, нефть продукциясендә, туфракта С1-С10 рәтендәге углеводородлар күрсәткечләре эшләнә һәм фәнни нигезләнә. 1990 еллар башында нефть химиясе пр-тиеләрендә сулар сан.-гигиеник яктан бәяләнә (1991), авыр нефть һәм табигый сумала табу районнарында әйләнә-тирә мохиткә гигиеник характеристика һәм халык сәламәтлегенә бәя бирелә. 2000 елларда Казан, Чаллы, Түбән Кама һ.б. шәһәрләрдә әйләнә-тирә мохит чисталыгына, халык сәламәтлеге торышына бәя бирү буенча тикшеренүләр үткәрелә.

*Р.Г.Исхакова.*

**КӨ́НКҮРЕШНЕ СУРӘТЛӘ́Ү ЖА́НРЫ**, сынлы сәнгатьтә әчтәлеге халыкның көндәлек шәхси һәм җәмгать тормышы темалары һәм сюжетларына бәйле традицион жанрларның берсе. К.с.ж. үзенчәлекләре нәкышь (К.с.ж. атамасы «жанрлы нәкышь» төшенчәсенә якын) һәм графика, азрак дәрәҗәдә камера характерындагы скульптура чаралары б-н аеруча тулырак ачылалар. К.с.ж.ның үсү процессында аңа хас мөмкинлекләр һәм характерлы үзенчәлекләр, көнкүреш вакыйгаларын һәм кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен дөрес теркәүдән башлап, көндәлек күренешләрнең эчке мәгънәсе һәм иҗтимагый-тарихи әчтәлеге ачылуга кадәрге сыйфатлар билгеләнә. К.с.ж. Европа сәнгатендә, мөстәкыйль юнәлеш буларак, 17 йөздә формалаша. Россиядә К.с.ж.ның үсеше 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башына туры килә. Бу анда яшәгән халыкларның көнкүрешендәге этнографик үзенчәлекләргә, крәстиян тормышына игътибар б-н бәйле була. К.с.ж. үсешенә ш.у. дәүләт провинцияләре буенча РФА оештырган фәнни-экспедициядә катнашкан рәссамнарның костюм-типаж һәм этнографик-көнкүреш характерындагы натурадан ясаган рәсемнәре йогынты ясый (Е.М.*Корнеев*, И.И.*Георги*). Казан татарларының көнкүреш картиналарын үзләренең әсәрләрендә В.Г.*Худяков*, К.Ф.*Гун*, рәссамнардан — Казанда эшләгән нәкышьче Н.И.*Зеблов*, график Н.Н.*Кафтанников* гәүдәләндерәләр. 19 йөзнең 2 нче яртысында сәнгатьтә барыннан да элек җәмгыятьтә хакимлек иткән социаль мөнәсәбәтләрне һәм әхлакый нормаларны бәяләүгә һәм фаш итүгә юнәлтелгән «тәнкыйди реализм» методы урнашу б-н, К.с.ж. иҗтимагый әһәмияткә ия сыйфатлар туплый. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында мизгел эчендәге гадәти, очраклы хәлләрнең, үзгәрүчән кәеф һәм халәтнең сәнгать б-н өретелгән матурлыгын чагылдыручы жанрлы картиналар төре беренче планга чыга. Х.Н.*Скорняков*, Г.А.*Медведев*, П.А.Радимов, А.М.Конарев, П.П.Беноковның ике юнәлештә чагылдырылган иҗатлары күбрәк К.с.ж.нда үсә. Н.И.*Фешин* иҗаты Идел буе халыклары тормышы турындагы күзаллауларны шактый киңәйтә. Беренче проф. татар рәссамнары Г.*Гомәров*, Л.*Мостафин*, Г.Камал, Х.Акчурина һ.б.ның журнал графикасы көнкүреш үрнәкләре б-н байый. Окт. рев-циясеннән соң К.с.ж. халыкның тормышы һәм көнкүрешендәге барлык өлкәләрендә коллектив, җәмәгать башлангычы өстенлек ала баруы б-н бәйле яңа сыйфатлар туплый. Сәнгатьне революционлаштыру һәм «көнкүрештән» арындыру лозунгы б-н урбанистик үрнәкләрне өстен иткән, «җитештерү сәнгате»нә һәм конструктивлык идеяләренә йөз тоткан *Сулф* рәссамнары иҗаты үсеш ала. Киресенчә, Идел буе халыклары көнкүрешенең традицион формаларын чагылдыру *ТатАХРР* иҗат программасының бер өлеше була («Татарларның көнкүреше һәм хезмәте», «Татреспубликада ачлык», «Фабрика-завод хезмәте», «Татарларда халык кәсепчелеге һәм һөнәрчелеге», «Кызыл Армиянең тормышы һәм көнкүреше» һ.б. исемле тематик конкурслар, күргәзмәләр үткәрү һ.б.).

К.с.ж. әсәрләренә еш кына агитация юнәлешендә һәм газетада көнүзәк мәсьәләне яктыртуда ачык чагылган сыйфатлар да хас. Ул 1930–50 еллар нәкышь сәнгатендәге иң зур бүлекләрнең берсен тәшкил итә һәм, соц. реализм сәнгате принципларына туры китереп, иҗтимагый тормышның уңай якларын яктыртуга һәм раслауга йөз тота. Рәссамнар Д.П.*Архипов*, В.Л.*Лаптев*, П.М.*Байбарышев*, С.С.Фёдоров, А.М.Родионов, И.И.*Князьков*, А.К.Лукоянов, Җ.Г.*Булат*, Н.К.*Вәлиуллин*, Н.М.*Сокольский*, Ш.Н.*Мөхәмматҗанов*, В.К.*Тимофеев* һ.б. үзләренең иҗатында индустриаль һәм колхоз хезмәте темаларына зур игътибар бирәләр. К.Е.*Максимов*, А.М.*Родионов*, Н.М.*Сокольскийның* 1940 еллардагы жанрлы нәкыше авыр сугыш елларының фронт һәм тыл тормышын чагылдыра. Ул чорның К.с.ж. әсәрләренә репортаж, эскиз, натурадан алган тәэсирләргә үзгәртүләрсез иярү сыйфатлары хас була. 1950 елларның 2 нче яртысыннан башлап, К.с.ж., нәкышь б-н бергә графика, скульптура тармагында үсешкә ирешеп, сынлы сәнгатьтә зур уңыш казана. Жанр осталары агымдагы чорга хас берьяклы вак темалардан арыналар, аларда



**Көнкүрешне сурәтләү жанры.** 1. К.Х. Г е с с. «Казан татарларында ат чабышы». Е.М. Корнеев рәсеме буенча . Офорт, акватинта. 1812. А.С. Пушкин исем. Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Н.И. Фешин. «Су сибешү». 1911–15. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. Л.Н. Александров. «Наданлыкны бетерү». 1927. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. В.К. Тимофеев «Мари туе». 1927—29. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. Ш.Н. Мөхәммәтҗанов. «Колхоз оештыру» 1930 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Л.Г. Фәттахов. «Сабантуй». 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Р.Г. Заһидуллин. «Авылда яз». 1960; 8. И.В. Рәфыйков «Кунакка ». 1964. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. В.Н. Скобеев. «Кама өстендә акчарлаклар». 1973–74. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Х.Г. Якупов. «Чаллы гүзәлләре (КамАЗ)». 1975. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Ш.М. Шәйдуллин. «Карт алмагач төбендә». 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. И.К. Зарипов «Алтын көлтә». 1997.

заманча тормыш б-н кызыксыну өлкәсе киңәя, республика нефтьчеләренең хезмәтләрен, яңа шәһәрләр төзелешен күрсәтәләр, хәзерге заман авыл тормышының шигърияттен, халык гореф-гадәтләрен, бәйрәм тантаналарын чагылдыралар (нәкышьтә — Х.Г.*Якупов*, Л.Г.*Фәттахов*, В.Н.*Скобеев*, И.М.*Хәлиуллов*, М.Х.*Хәертдинов*, Х.Х.*Хәйдәров*, И.В.*Рәфыйков*, графикада — Э.Я.*Зарипов*, В.В.*Карамышев*, В.А.*Попов*, Э.Г.*Ситдыйков*). Эре форматлы картиналар, күп фигуралы «күмәк» композицияләр өстенлек итә башлый. Болар б-н бергә ТАССР Рәссамнар берлеге эшчәнлегендә бригада иҗаты формалары («Нефть», «КамАЗ», «Авыл иҗат төркемнәре» һ.б.), «җитештерү», «социаль» темаларга картиналар язу өчен заказлар алу һәм килешүләр төзү системасы барлыкка килә, һәм соңрак шул системаның юкка чыгуы б-н бергә үзенең әһәмиятен югалткан бик күп картиналар иҗат ителүгә китерә. 1980 елларның 2 нче яртысыннан жанрлы нәкышьтә социаль тематикадан читләшү өстенлек ала, бу көндәлек сюжетлы тәэсирне лирик кичерешләр б-н алмаштыруда чагыла. Әлеге юнәлешне нәкышьчеләр И.К.Зарипов, З.Ф.Гыймаев, Ш.М.Шәйдуллин, А.А.Абзгильдин, Б.И.Урманче, В.Н.Скобеев, Р.Ә.Килдебәков, сынчы Р.Х.Нигъмәтуллина һ.б. чагылдыра. Алар иҗатындагы үзәк темаларның берсе — көнкүрештәге, авыл тормышындагы милли үзенчәлекләр поэтикасы. К.с.ж. үсеше юнәлешләрен бер яктан, нәфис образларның кинаялелеге, фольклор-мифологик темаларга әйләнеп кайту, икенче яктан, «соцарт»ның фаш итү үрнәкләре билгелиләр.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983.

*Е.П.Ключевская.*

**КӨНЛЕКЧЕЛӘ́Р** (Ephemeroptera), бөҗәкләр отряды. 1,6 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 250 тирәсе, Татарстан терр-ясендә 20 гә якын төре яши. Аеруча гадәти төр гади К. (Ephemera vulgata). К. — бик борынгы һәм гади бөҗәкләр. Күпчелек төрләрнең ареалы тундра зонасына кадәр таралган. Зур булмаган озынча гәүдәле, юка канатлы, койрыгы озын өч (кайвакыт ике) җепселле. Авыз органнары үсеш алмаган. Олы К. (имаго) һавада яшәү рәвеше алып баралар, бу стадия берничә сәгать яки тәүлек дәвам итә. Кушылудан соң, ана бөҗәкләр йомыркаларын суга сала. Личинкаларга тулы булмаган әверелешле үсеш хас. Олы бөҗәкләргә охшаш личинкалар (нимфа) 1–3,5 ел дәвамында 20–25 тапкыр кабыгын салалар. Личинкаларның корсак сегментларында 5 тән 7 парга кадәр трахея саңаклары, корсак соңында 3 (сирәк кенә 2) койрык җепселе урнашкан. Cloën, Caenis, Baëtis, Siphlonurus һ.б. К.нең личинкалары су үсемлекләре арасында елга һәм күлләрдә яши. Leptophlebia, Paraleptophlebia һ.б. ләмле грунтларда очрый. Гади К., Palligenuia longicauda һ.б. яшерен яшәү рәвеше алып бара, алар исә елгаларның балчыклы ярларында юллар казый, моның өчен аларның казуга җайлашкан аяклары һәм казналыклары үсеш алган. К. таркала барган органик матдәләр, үсемлек детритлары, вак умырткасызлар б-н туклана. Үзләре балыклар өчен азык булып тора. Күп кенә төрләре су чисталыгының индикаторы. Сулыклар пычрану сәбәпле, К. ареалының һәр җирдә кимүе күзәтелә. Су көнлекчесе (Polymitarcys virgo) һәм буйлы көнлекче (Ephemera lineata) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 3; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Райков Б.Е., Римский-Корсаков М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

*В.А.Яковлев.*

**КӨ́НЧЫГЫШ ДИАЛЕ́КТ**, *Себер татарлары* шивәләре җыелмасы. Беренче тапкыр К.д. терминын 1938 елда Л.Җәләй куллана. Ул диалектка билгеләмә, аның төп (том, бараба, түбән, тобол, тара, тәвриз) сөйләшләренә гомуми характеристика бирә. Сугыш алды елларында Көнбатыш Себергә К.д.ны өйрәнү максаты б-н комплекслы экспедицияләр оештырыла. Аларның нәтиҗәләре С.Әмировның «Көнбатыш Себердәге татарларның сөйләм үзенчәлекләре» дигән мәкаләсендә яктыртыла (басылмаган; ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивында саклана). 1950 елларда Көнбатыш Себер татар диалектларын һәм сөйләшләрен өйрәнүне Д.Г.Тумашева дәвам итә. Түбән, Омск, Новосибирск, Томск, Кемерово өлкәләрендә тикшеренүләр үткәрелә. Нәтиҗәдә өч диалект — тобол-иртеш (түбән, тобол, тәвриз, тара, саз ягы сөйләшләре керә), бараба (сөйләшләргә бүленми), том (юеште-чат һәм калмак сөйләшләре керә) диалектлары ачыклана һәм тасвирлана. Г.Х.Әхәтов, Тобол пед. ин-тында эшләү дәверендә, Түбән һәм Омск өлкәләренең торак пунктларында җыелган материал нигезендә «Көнбатыш Себер татарлары диалекты» («Диалект западносибирских татар», Уфа, 1963) китабын бастырып чыгара. Әлеге китапта ул К.д.ның (сөйләшләргә бүлмичә) фонетик, лексик-фразеологик һәм грамматик үзенчәлекләрен яктырта.

К.д. сөйләшләренең фонемалар системасына түбәндәге үзенчәлекләр хас: б, д, з тартыкларының саңгыраулашуы — палых (балык), пелмәте (белмәде); ц-лаштыру: циләк (чиләк); цац (чәч), пецән (печән); сонор авазларның саңгырау тартыклар б-н ярашуы — нт, рт, лт: анта (анда), парты (барды), килте (килде). Тобол-иртеш диалектында п,к тартыклары яңгыраулаша: аба (апа), кургып (куркып), пер гөн (бер көн); бараба диалектында һәм том диалектының калмак сөйләшендә с,ш,т тартыклары яңгыраулаша: утын кизеп (утын кисеп), ике теже бар (ике теше бар). Бараба диалекты борынгы төрки а/ә сузыкларын — сәксән (сиксән), әртә (иртә) һәм гомумтөрки о,ө сузыкларын — отыс (утыз), конак (кунак), көп (күп) — өлешчә саклый. Тобол-иртеш диалектының тәвриз сөйләшендә, хакас теленә хас булганча, сузыкларның киңәюе һәм тараюы күзәтелә: йырлыйр (ул җырлар), сөйлир (ул сөйләр). К.д. сөйләшләренең морфология тармагында түбәндәге үзенчәлекләре бар: 1. Инфинитивның -галы формасы гомумдиалект күренеше булып тора: паргалы кәрәк (барырга кирәк). Бараба диалектында әлеге формадан көтелә торган, әмма әле башкарылмаган эш-хәлне белдерүче -галак формасы ясалган: Күгел ашатыңысмы? — Йук әле, пешкәләк (Кук җиләк ашадыгызмы? Юк, әле пешмәгән). Бу форма тува, хакас һәм чулым-төрки телләренә хас. 2. Чулым-төрки телендә тиңдәше булган, ниятне белдерүче — галты формасы: йырлагалтык, оркестр килмәй йаты. (Без җырларга җыенган идек, әмма оркестр соңга кала).

Тобол-иртеш диалектында кыпчак үзенчәлекләре өстенлек итә; бараба диалектында кыпчак төркеме һәм көнчыгыш-төрки телләр үзенчәлекләре бергә катнаша; том диалекты Идел буе татар һәм көнчыгыш-төрки элементларын берләштерә.

*Әд.:* Җәләй Л.Җ. Татар телендәге диалектлар // Совет мәктәбе. 1938. № 5–6; шул ук. Татар диалектологиясе. К., 1947; Әхмәтов В. Тобол татарларының диалектлары // Совет мәктәбе. 1940. № 2–3; Тумашева Д.Г. Көнбатыш Себер татарлары теле: Грамматик очерк һәм сүзлек. К., 1961; шул ук. Диалекты сибирских татар: Опыт сравнительного исследования. К., 1977; шул ук. Словарь диалектов сибирских татар. К., 1992.

*Д.Г.Тумашева.*


**КӨ́НЧЫГЫШ КА́МА АЛДЫ́**, ТРның физик-географик төбәге. Кама елгасыннан төньяктарак һәм Вятка елгасыннан көнчыгыштарак урнашкан. Алабуга, Менделеев һәм Әгерҗе р-ннарын үз эченә ала. Мәйданы 3,9 мең *км*$^2$.

Татар гөмбәзенең Төньяк (Кукмара) күтәрелмәсенең көнчыгыш сөзәклегендә Рус платформасының көнчыгыш өлешендә. Нигезе архей һәм протерозойның кристаллик токымнарыннан гыйбарәт, көнбатышта 1600 *м*, көнчыгыш өлештә 1900 *м* һәм аннан да күбрәк тирәнлектә ята. Утырма катлам югары протерозойдан дүртенчел системага кадәрге диңгез һәм континенталь утырмалардан хасил булган. Җир өстенә Пермь, неоген һәм дүртенчел система токымнары чыга. Алабуга шәһәре янында Кама елгасының уңъяк яры буенда Уфа ярусының комсу-балчыксыл токымнары ачыла. Өстәрәк Татар һәм Казан ярусларының известьташ катламлы комсу-балчыксыл токымнары (Вятка, Кама, Туйма, Иж елгалары үзәннәре буенда ачыла) ята. Иж, Туйма һәм Вятка елгалары сул кушылдыкларының борынгы үзәннәрен неогенның комсу-чуерташлы һәм балчыксыл утырмалары тәшкил итә. Дүртенчел система утырмалары (ком, комсыл балчыклар, балчыклар), Каманың уңъяк текә ярыннан кала, неоген һәм югары Пермь токымнарын бөтен җирдә диярлек каплыйлар.

К.К.а. рельефы — җиңелчә калкулыклы тигезлек, Иж елгасы үзәне б-н ике өлешкә бүленгән. Көнбатышта — Можга калкулыгының көньяк чиге (иң зур биеклеге 225 *м* — Таңай елгасының югары агымында, 226 *м* — Иж тамагы елгасының югары агымында), көнчыгышта — *Сарапул калкулыгының* көньяк-көнбатыш чиге (иң зур биеклеге 224 *м* — Красный Бор авылы янында Каманың уңъяк

ярында). Иң түбән биеклекләр: 53 *м* — Чаллы шәһәреннән түбәнрәк Куйбышев сусаклагычының су өсте һәм 62 *м* — Түбән Кама сусаклагычының су өсте. Уртача биеклеге якынча 120 *м*. Төбәк ерым челтәре тыгызлыгының югары (0,39 *км/км*²) һәм сыза челтәре тыгызлыгының уртача (0,5 *км/км*²) булуы б-н аерыла.

К.К.а.ның климатик күрсәткечләренә чагыштырмача кискен территориаль үзгәрешләр хас. Гыйнварда уртача темп-ра −14° тан −14,5 °С ка кадәр, июльдә 19 °С тан 19,5 °С ка кадәр үзгәрә; абс. мин. −52 °С (1979, Әгерже), абс. макс. 40 °С (1981, Алабуга). Бик салкын көннәр (−35 °С һәм түбәнрәк тә) Әгерже р-нында теркәлде — кышкы чорда уртача 3,5 көн. Салкын булмаган чорның озынлыгы 106 көннән (Әгерже) 142 көнгә кадәр (Алабуга). Еллык явым-төшем 480–530 *мм* тәшкил итә. Кар капламының биеклеге 40–45 *см*. К.К.а. Иж елгасының түбәнге агымы (кушылдыклар — Бимә, Чаж, Барҗы), Туйма (кушылдыклар — Бужай, Юраш, Каринка), Таңай, Вятка (Үмәк, Әнҗерә) елгалары б-н дренажлана. Елга челтәренең уртача тыгызлыгы 0,48 *км/км*² — ТРда иң югары. Елга тугайларында элекке елга юлында сакланып калган күл һәм сазлыклар бар. Вятка һәм Туйма елгалары арасында соры урман туфраклары, Иж елгасының сулъяк ярында кәсле-көлсу туфраклар таралган. Вятка, Кама, Туйма елгалары үзәннәре буенда туендырылган аллювиаль кәсле туфрак үсеш алган, Иж, Чаж елгалары үзәннәрендә кара болын туфраклары очрый. Төбәк көньяк тайга асзонасына, урман зонасына карый. Урманлы җирләр 14,9 %. Каен һәм усак катыш юкәләрдән, чыршы, ак чыршыдан торучы караңгы ылыслы-киң яфраклы аеруча зур урманнар Иж елгасының сулъяк ярында сакланган. Зур булмаган участокларда чыршы һәм ак чыршыдан торучы караңгы ылыслы урманнар очрый. Кама елгасы үзәнендә нарат урманнары сакланган.



Көнчыгыш Кама алды. Иж елгасы үзәне күренеше.

К.К.а.ның көньяк өлешендә нефть чыгарыла. Кирпеч житештерү өчен балчыксыл чимал (Әгерже, Исәнбай), вакланган таш һәм бут (ак таш) (Бондюг, Максимов, Камай) җитештерү өчен төзелеш ташларының кечкенә чыганаклары бар. Кама елгасы юлында һәм Иж елгасы тамагында ком-чуерташ кушылмалары чыганаклары тикшерелә һәм өлешчә эшкәртелә.

К.К.а. *Түбән Кама милли паркының* шактый өлеше — Зур наратлык, Кече наратлык, Танай дачасы, Танай һәм Алабуга болыннары, *«Кичкетаң»* комплекслы табигать тыюлыгы, «Катнаш наратлык» табигать истәлеге, Әгерже һәм Алабуга аучылык тыюлыгы урнашкан. Иж һәм Туйма елгалары ТРның табигать истәлеге дип игълан ителгән.

Әд.к.: *Көнчыгыш Кама аръягы.*

*Г.П.Бутаков.*

**КӨ́НЧЫГЫШ КА́МА А́РЪЯГЫ**, ТРның физик-географик төбәге. Кама елгасыннан көньякта һәм Чишмә елгасыннан көнчыгыштарак урнашкан. Мәйданы 22,5 мең *км*².

Геологик бәйләнештә Татар гөмбәзенең Көньяк күтәрелмәсенә туры килә. Нигезе архей һәм протерозойның кристаллик токымнарыннан гыйбарәт; Әлмәт шәһәре янында 1600 *м*, төбәкнең көньяк-көнчыгышында һәм төньяк-көнчыгышында 2000 *м* тирәнлектә урнашкан. Нигезенең юылган өслегендә югары протерозой, өстәрәк девон һәм карбон токымнары ята. Өслеккә Пермь, неоген һәм дүртенчел система утырмалары чыга. К.К.а. терр-ясенең төп өлеше югары Пермь токымнарыннан тора. Уфа ярусының юка мергель катламлы, известьташ һәм доломитлы комсу-балчыклы токымнары Кама, Ык, Чишмә һәм аларның кушылдыклары үзәннәрендә (сөзәклекләрнең түбәнге өлешләрендә) ачыла. Зур гына мәйданнарда Казан ярусы утырмалары үсеш алган: астарак — балчык һәм известьташлар, өстә — юка катламлы кызыл төстәге карбонаттан торган комсу-балчыклы токымнар. Аеруча биек субүләрләр татар ярусы токымнарыннан гыйбарәт — кызыл төстәге аргиллит, алевролит, комташлар. Неоген утырмалары Кама, Агыйдел, Ык, Зәй, Чишмә елгалары һәм аларның кушылдыкларының тирән уелган борынгы үзәннәрен ясый. Киселешнең нигезендә — елга һәм күл-елга, комсу-чуерташлы, комсу балчыклы токымнар, урта өлешендә — балчыксыл диңгез, өстә континенталь комсу-балчыксыл утырмалар ята. Төбәкнең төньяк-көньягында — Кама-Агыйдел түбәнлегендә зур мәйданнарны били. Дүртенчел система утырмалары бөтен җирдә диярлек очрый, әмма аеруча калыннары елга үзәннәренә туры килә, биредә алар 5–6 га кадәр тугай асты террасалары сериясен ясый яки авыш сөзәклекләрдә шлейфлар хасил итә.

К.К.а. рельефы күбрәк калкулы, кискен асимметрияле елга үзәннәренең тирән уемнары (150–250 *м*) булу, сөзәклекләрдә структуралы террасаларның, ә елга үзәннәре буйлап карст формаларының киң таралуы б-н аерыла. Төп өлешен *Бөгелмә яссы калкулыгы* били. Төньяк-көнчыгышта Кама-Агыйдел түбәнлеге урнашкан. Аеруча зур биеклекләр (280–360 *м*) көньякта Сола, Томбарлы һәм Дим елгаларының югары агымында. ТР терр-ясендә иң зур биеклеге — 381 *м* (Оренбург өлкәсе б-н чиктәш).

Төньяктарак һәм төньяк-көнчыгыштарак субүләр 240–200 *м* га кадәр түбәнәя. Территория елга үзәннәренең (0,5 *км/км*²) һәм сызаларның (0,61 *км/км*²) тыгыз челтәре б-н бүлгәләнгән. Ерымнар челтәре үсеш алмаган (0,13 *км/км*²).

К.К.а.ның төньяк өлешендә климат салкынча, җәен — явым-төшемнәрнең бүленеше тигезсез, кышын чагыштырмача суык һәм аз карлы. Көньяк калкулык өлеше салкынча һәм дымлы җәй, уртача салкын һәм карлы кыш б-н характерлана. Гыйнварның уртача темп-расы −13,8 °С тан −14,7 °С ка кадәр, июль 18,3 °С тан 19,5 °С ка кадәр үзгәрә, абс. мин. −49 °С (1942, Мөслим), абс. макс. — 39 °С (1952, Мөслим). Салкын булмаган чорның озынлыгы уртача 120–130 көн тәшкил итә. Явым-төшемнәрнең еллык күләме 480–530 *мм*. Кар капламының калынлыгы 31–46 *см*.



Көнчыгыш Кама аръягы. Типик ландшафт.

К.К.а. югары үсеш алган елга челтәре б-н характерлана. Ык (кушылдыклары — Минзәлә, Мәллә, Эстәрле, Дим), Дала Зәе (кушылдыклары — Зәй, Урман Зәе, Зичә), Чишмә (кушылдыклары — Кичү, Урман Чишмәсе) елгалары белән терр-я дренажлана. Кама-Агыйдел түбәнлегеннән Агыйдел һәм аның кушылдыгы — Сөн елгасы ага. Елга тугайлары буенда — элеккеге елга юлында сакланып калган һәм карст күлләре, Кама-Агыйдел түбәнлегендә ТРда иң зур *Көләгеш сазлыгы* урнашкан.

Төбәкнең төньяк өлешендә — соры урман туфраклары, көньякта — селтесезләнгән кара туфраклар, типик һәм карбонатлы, елга тугайлары буйлап туендырылган кәсле аллювиаль, Кама-Агыйдел түбәнлегендә сазлыклы аллювиаль һәм кәсле аллювиаль туфраклар таралган. К.К.а. терр-ясе урман-дала зонасына керә; юкә, карама, имән өстенлек иткән киң яфраклы урманнар; каенлык һәм усаклыклар күп. Аеруча зур урман массивлары Лениногорск, Әлмәт һәм Зәй р-ннарының көнбатыш өлешендә, Түбән Каманың көньягында урнашкан. Территориянең уртача урманлылыгы 17%. Дала участоклары текә, еш кына ташлы сөзәклекләрдә сакланган.

Янучан һәм руда булмаган файдалы казылмалар — төбәкнең төп байлыгы. Янучан казылмалар — нефть һәм табигый газ, битум, таш һәм көрән күмер. Нефть һәм газ девон һәм ташкүмер катламнарына туры килә. Күп кенә чыганаклар (Ромашкино һ.б.) 50 елдан артык эшли. Төп чыганаклар Лениногорск, Әлмәт, Азнакай р-ннарында тупланган. Битум чыганаклары Чишмә, Урман Чишмәсе елгаларының югары агымына, Кичү елгасының урта агымына туры килә; Сарман р-нында — ташкүмер, Тукай һәм Минзәлә р-ннарында көрән күмер запаслары билгеле. Ык (Әпсәләм, Димтамак, Новониколаш-

кино, Муллино һ.б.), Кама (Соколка, Кама Аланы, Соболевский), Чишмә (Нагайский) һ.б. елгаларның үзәннәрендә руда булмаган файдалы казылмалардан ком-чуерташ чыганаклары эшкәртелә. Төзелеш комнары Кама үзәнендә (Ворошилов) чыгарыла. К.К.а. бентонит балчыкларга (Бикләр, Олы Аты) бай. Кирпеч балчыклары, төзелеш һәм кисү ташларының кечкенә чыганаклары (Яңа Кәшер, Сарман, Кама-Исмәгыйль, Сугышлы, Кармалы) күп.

К.К.а.нда, Каманың уңъяк ярында, «Түбән Кама» милли паркы өлеше — «Кызыл Тау» урман массивы урнашкан. 13 ландшафтлы терр-я аеруча саклаулы булырак (*Урдалы Тау, Игим наратлыгы, Борок урман дачасы, Татар Димескәе аланы, Петровка нарат-лары, Чыршылы сөркә (байбак) колониясе* һ.б.) һәм 7 сулык табигать истәлеге (Дим, Ык, Сөн, Чишмә һ.б.); 8 табигать (*Сөлек урманы, Адонис урманы, Нарастасты урманы, Чатыр Тау* һ.б.) һәм 5 аучылык (Бөгелмә, Баграж, Азнакай, Шөгер һ.б.) тыюлыгы билгеләнгән.

*Әд.:* Очерки по географии Татарии. К., 1957; Географическая характеристика административных районов Татарской АССР. К., 1972; География Татарстана. К., 1994.

*Г.П.Бутаков.*

**КӨ́НЧЫГЫШ ТӨРБӘ́**, аксөяк болгар нәселенең гаилә каберлеге. Болгар шәһәренең Алтын Урта дәвере Болгар архит-расы истәлеге; *Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы* терр-ясендә урнашкан. 1330 елларда Болгар җамигъ мәчетенең көнчыгыш фасады каршында төзелгән. Шәрекъ илләренә хас үзәкләшкән композицияле, чатырсыман К.т. Башта тәбәнәк дүрткырлыктан (10,5× 10,5 *м*) очлаеп сигезкырлыкка әверелгән, ярымшарсыман гөмбәзе сигез кырлы чатыр б-н очланган корылмадан гыйбарәт була. Зур порталлы уксыман ишек уемы көньяк фасадта урнашкан. Дүрткырлыкның башка якларында уксыман тәрәзәләр уелган. Сигезкырлыкның ян-якларында декоратив куышлар бар. Төрбә ак известьташтан төзелгән һәм туф блоклар б-н тышланган. Интерьерның дивар өлешләре башта штукатурланган һәм декоратив сталактитлар б-н бизәлгән, тәрәзәләре каймаланган. 18 йөз башында К.т. бинасы Успение монастыреның Никола чиркәве итеп яраклаштырыла (1770 кә кадәр), төрле үзгәртүләргә дучар ителә: ишек көньяктан төньяк фасадка күчерелә, чатыр сигезкыеклы, гөмбәзле агач түбә б-н алыштырыла, дүрткырлыкның көнчыгыш дивары ике контрфорс б-н ныгытыла, төньяк һәм көнчыгыш тәрәзә уемнары киңәйтелә. 20 йөз уртасына К. т. түбәсен, порталын, фасад тышлыгының күпчелек өлешен һәм интерьерларының штукатурасын югалта. 1967–68 елларда С.С.Айдаров проекты буенча портал хәрабәләре консервацияләнә, фасадларның бер өлеше реставрацияләнә, агач чатыр б-н очлана. 1982 елларда уксыман тәрәзә уемнары реставрацияләнә, сигезкырлыкның көньяк-көнчыгыш өлешендәге куыш формасы цемент измәсе б-н торгызыла.

*Әд.:* Гарипова Ф. Борынгы Болгар шәһәрләре. К., 1990; Хлебникова Т.А. Археологические исследования мавзолеев города Великие Булгары // Поволжье в средние века. М., 1970; Айдаров С. С., Аксёнова Н.Д. Великие Булгары. К., 1971; Мухаметшин Д. Г. Великие Булгары: Путеводитель. М., 1982.

**КӨ́НЧЫГЫШ ФРО́НТ**, 1918 елның июнендә Кызыл Армиянең Чиләбе — Омск — Екатеринбург шәһәрләре, Сембер — Сызрань — Самара — Пенза — Казан шәһәрләре, Оренбург — Уфа һәм Саратов — Урал юнәлешләрендә хәрәкәт итүче частьләре һәм отрядларыннан оештырыла. 1918 нең июне — августында К.ф.ның *Беренче армия, Икенче армия, Өченче армия, Дүртенче армия, Бишенче армияләре* төзелә. 1919 ның марты — июнендә К.ф. составына Төркестан армиясе керә. Командующийлары: М.А.Муравьёв, И.И.Вацетис, С.С.Каменев, А.А.Самойло, П.П.Лебедев, М.В.Фрунзе, В.А.Ольдерогге. К.ф. штабы Казанда урнаша, аннары Зөя, Алатырь, Арзамас, Сембер, Уфа шәһәрләрендә була. 1918 нең июне — июлендә К.ф. гаскәрләре Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык Армиясе частьләренә каршы оборона сугышларында катнаша. 1918 нең август башында К.ф. гаскәрләре һөҗүм башлый, әмма һөҗүм ай ахырында Казан, Сембер, Екатеринбург һәм Хвалын юнәлешләрендә туктатыла. 1918 нең сентябре — 1919 ның февралендә К.ф. гаскәрләре *Казанны азат итү операциясен* (5–10 сент., 1918), Сембер (9–28 сент., 1918), Сызрань–Самара (14 сент. – 8 окт., 1918), Ижевск–Воткинск (15 сент. – 16 нояб., 1918) һ.б. операцияләр үткәрәләр, Урта Идел буе терр-ясен, Көньяк һәм Көнбатыш Уралның бер өлешен (Казан, Сембер, Буа, Тәтеш, Сызрань, Самара, Бөгелмә, Ижевск, Уфа, Оренбург һ.б. шәһәрләр) азат итәләр. 1919 ның мартында, адмирал А.В.Колчак гаскәрләре тарафыннан Уфа юнәлешендә фронтның өзелүе сәбәпле, К.ф. гаскәрләре Идел елгасына чигенергә мәҗбүр булалар, апрель ахырында контрһөҗүмгә күчәләр. К.ф.ның Көньяк гаскәрләре төркеме (1 нче, 4 нче, 5 нче, Төркестан армияләре), Богыруслан (28 апр.–13 май, 1919), Бәләбәй (15–19 май, 1919) һәм Уфа (25 май–19 июнь, 1919) операцияләрен гамәлгә ашырып, Богыруслан, Бөгелмә, Бәләбәй, Уфа шәһәрләрен ала. 2 нче һәм 3 нче армияләр, Сарапул–Воткинск (25 май–12 июнь, 1919), Пермь (21 июнь–1 июль, 1919) һәм Екатеринбург (5–20 июль, 1919) операцияләрен уздырып, Әгерҗе авылын, Алабуга, Сарапул, Ижевск, Пермь, Көнгер, Красноуфимск, Екатеринбург шәһәрләрен яулый. 1919 ның июне — 1920 нең гыйнварында К.ф. гаскәрләре, һөҗүмнәрен җәелдереп, Колчак армиясенең төп көчләрен җиңүгә ирешә, Урал һәм Себер терр-яләрен азат итә. 1920 нең 15 гыйнварында К.ф. таратыла.

*Әд.:* Ненароков А.П. Восточный фронт. 1918. М., 1969.

**КӨ́НЧЫГЫШ ФРОНТТАГЫ́ КОММУНИ́СТ МӨСЕЛМАННА́Р КОНФЕРЕ́НЦИЯСЕ**, 1919 елның 27–30 апрелендә Сызрань шәһәрендә (Самара губ.) уза. Җитәкчеләре: Г.Баембәтов, С.Атнагулов. Конференция Көнчыгыш фронтта мөселман секцияләренең мәдәни-агарту һәм агитация-пропаганда эше алып баруы, Татар-Башкорт ССР төзү, татар-башкорт корпусын оештыру һ.б. турында резолюцияләр кабул итә. Конференциядә *РКП(б)ның Көнчыгыш фронттагы татар-башкорт үзәк бюросы* сайлана.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*


**КӨРӘЕ́Ш БИСТӘСЕ́**, Казанда урта гасырлардагы татар бистәсе. 15 йөз ахырында — 16 йөзнең 1 нче яртысында шәһәрнең көньяк-көнбатышында, Болак суының уң ярында барлыкка килә. Татар морзасы Көрәеш исеменә нисбәтле. Бистә уртасында *Отыч мәчете* була. К.б. 1552 елда, Казанны яулап алу вакытында, өлешчә җимерелә.

*Әд.:* Айдаров С.С. Архитектурное наследие Казани. К., 1978; Бикбулатов Р. Казань и её слободы. К., 2001.

**КӨРӘЛЕ́** (Әҗем) авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кыярмәт елгасы буенда. 2010 елда 206 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөздә Иске Казиле авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет (1894 тә төзелә), 2 су тегермәне, 5 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1247 дис. тәшкил итә. 1930 еллар башында К.дә «Кызыл маяк» к-зы оештырыла, 1960 та аңа «Торский» к-зы (Варварино а.) кушыла. Соңрак бу ике торак пункт та К.Маркс исем. хуҗалыкка берләшә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1938 нең 9 ноябреннән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә-125 ир-ат; 1790 елларда — 417, 1859 да — 662, 1884 тә — 997, 1897 дә — 1130, 1908 дә — 1305, 1926 да — 880, 1938 дә — 703, 1949 да — 538, 1958 дә — 522, 1970 тә — 488, 1979 да — 390, 1989 да — 275, 2002 дә — 254 кеше.

**КӨРӘ́Н АЮ́** (Ursus arctos), аюлар семьялыгыннан имезүче ерткыч хайван. ТР терр-ясендә Арча, Саба һәм Кызыл Йолдыз урманчылыгы урманнарында очрый. Ерткычлар отрядында иң зур хайван. Ата К.а.ның озынлыгы 2 *м* га якын, биеклеге җилкә калкымында 1 *м* тирәсе, авырлыгы 200–300 *кг*. Ана аю гәүдәгә кечкенәрәк. Башы зур, кыска танаулы, кечкенә күзле. Колаклары зур түгел, йонтәс. Койрыгы бик кыска, мех астында бөтенләй күренми. Аяклары биек түгел, бөтен табанына басып йөри, бармакларында — нык бөгелгән зур тырнаклар. Мехы озын, куе, тупас, җәен кышкысына караганда кыскарак һәм сирәк. Көрән яки коңгырт төстә; яшь затларның җилкәсендә һәм күкрәгендә ак «муенчагы» бар, гадәттә, олыгаю б-н ул бетә. Кышны К.а. өндә үткәрә. Җенси активлык вакыты җәен була, буазлык чоры 7 айга якын, гыйнвар–февральдә шәрә һәм күчсез,

500–600 *г* авырлыктагы 1–2 бала китерә. Үзенең май катламы хисабына ана аю 3 ай дәвамында аларны имезә, үзе бу вакытта тукланмый. Балалар ана аю карамагында бер елга якын була һәм аның б-н бер үк өндә кышларга мөмкин. Җенси җитлегү — яшәешенең



Көрән аю.

3 нче елында. К.а. 30–40 ел яши. Башлыча, үсемлек азыклары (имән чикләвеге, чикләвек, җиләк, бүлбе, үсемлекнең яшел сусыл өлешләре), ш.у. бөҗәкләр (кырмыскалар, бал кортлары, аларның личинкалары һәм курчаклары), вак җәнлекләр б-н туклана; бал ярата. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КӨРӘ́Н ТИМЕРТА́Ш**, к. *Лимонит*.

**КӨРӘ́Ш** (татар-башкорт спорт көрәше), халык күңел ачуының бер төре, спортча кара-каршы көрәш. Татарларда борынгы заманнардан билгеле. Атаклы татар зыялылары Ш.Мәрҗани һәм Һ.М.Атласов берничә тапкыр Сабан туе батыры булалар. 18–19 йөзләрдә Казанда К. буенча ярышлар Урта Кабан күленең көньяк-көнбатыш ярында (1895–1920 еллар ахырында — «*Аркадия» бакчасында*) уздырыла. Казан һәм башка губерналарның иң яхшы көрәшчеләре — А.Оренбурлы, Х.Бәрәзә, Курса Корысы, М.Хәбибуллин. Татарстанда К., спорт төре буларак, 1920 еллардан үсеш ала. Милли көрәш буенча зур Сабан туе бәйрәмендә (1923), РАРО (автономияле респ-калар һәм өлкәләр районнары) спартакиадасында беренче баш батыр, 1 нче Бөтенсоюз спартакиадасында (1928) чемпион — Ш.Хәйруллин. ТАССРда К. буенча чемпионат беренче тапкыр 1940 та уздырыла (җиңүчеләр — Ш.Исламов, К.Бәдретдинов, Х.Сәхибуллин), 1959 дан даими рәвештә үткәрелә башлый. 1960 тан татар-башкорт көрәше буенча РСФСР чемпионатлары уздырыла, 1961 дә «Спортның милли төрләре остасы» дигән исем билгеләнә. 1965 тән Татарстанда К. буенча ярышлар герой-шагыйрь М.Җәлил призына үткәрелә. 1968 дә Татарстанда Көрәш федерациясе оештырыла, рәисләре — Д.Р.*Шәрәфетдинов* (1968–71), М.М.*Сәхәбетдинов* (1971–89), И.Г.Илдарханов (1989–91), Ф.С.Сибагатуллин (1991–96), Р.Р.Галимов (1996–2001), М.Г.Әхмәтов (2001 дән). К. буенча ярышлар 1929–58 дә — Н.А.Семёнов, 1958–71 дә — Р.А.*Азизов*, 1971–85 тә — Д.Р.Шәрәфетдинов, 1985–97 дә — М.М.Сәхәбетдинов, 1997 дән — М.Г.Әхмәдиев, М.К.Кадыйров эшләгән кагыйдәләр буенча үткәрелә. 2005 тә Бөтендөнья татар конгрессы башлангычында, РФнең 57 субъектыннан килгән делегатлар катнашындагы оештыру конференциясе карары б-н, Россиянең «Татарча көрәш» милли спорт көрәше федерациясе төзелә, аның президенты булып Җ.М.Миңнәхмәтов сайлана; шул вакыттан Россия һәм дөнья күләмендәге ярышлар әлеге федерация тарафыннан үткәрелә. 2009 да Сабан туйлары Россиянең 70 тән артык төбәгендә һәм 20 чит илдә булып уза.

2009 да Халыкара татарча көрәш ассоциациясе оештырыла, ул дөнья һәм Европа чемпионатлары уздыра башлый. Халыкара билбау көрәше ком-ты составындагы Халыкара «Көрәш» ассоциациясе Көрәшнең берләштерелгән стильләре халыкара федерациясенә (ФИЛА) керә, соңгысы Халыкара Олимпия ком-ты әгъзасы булып тора. Билбау көрәше 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада (Казан) программасына кертелә.

К. буенча иң яхшы спортчылар — берничә тапкыр республика һәм бөтенроссия ярышларында җиңүче һәм медаль алучылар, ш.и. ТРның атказ. спорт осталары (бу исем 1995 тә билгеләнә) — Г.Г.Әхмәдиев, Ф.Г.Әхмәдиев, Ф.Г.Әхмәтҗанов, Р.Р.Әхмәтханов, И.А.Бәширов, Һ.Х.*Бикташев*, Г.А.Борһанов, М.П.Васильев, Ә.Г.Гайфуллин, Д.Ю.Галиев, Җ.Б.*Гафиятуллин*, А.Т.Гыйлаев, Р.Я.Гыйниятов, Ә.С.Гобәйдуллин, Н.Г.*Жеребцов*, Р.Җ.*Камалов*, В.И.Канашев, В.Я.*Кузнецов*, Ф.Ә.*Мадьяров*, Н.И.*Моряшичев*, Р.Сәйфуллин, Л.С.*Сәлимуллин*, Р.Ә.Сәмигуллин, Ш.С.*Сафин*, Р.И.Сафиуллин, Р.В.Синякаев, М.Ш.Таһиров, С.Ф.Тимофеев, Ф.Ф.Фатыйхов, Ә.Г.Фәхретдинов, А.Ф.Хәйретдинов, Н.Г.Хәмидуллин, Р.Х.*Хәмитов*, З.С.Ханов, Х.Х.Шәйхетдинов, Ф.Н.Шакиров, Р.Г.Шәрипов, С.И.Йосыпов һ.б. Иң яхшы тренерлар — Р.Р.Галимов, В.Г.Гарифуллин, В.Т.Дәүләтшин, И.С.Димиев, Н.С.Зыятдинов, Г.Г.Мөхәммәдиев, И.М.*Мөхәрләмов*, А.Ә.Хәйруллин, Д.Х.Хәлилов һ.б.

*Әд.:* Илдарханов И.Г. Без көрәшле халык. К., 2003; Без көрәшче халык. — Родом из борьбы. К., 2009; Шарафутдинов Д.Р. Сабантуй — образ жизни народа (научно-исторический очерк). К., 1997;

**«КӨРӘ́Ш»**, иҗтимагый-сәяси газета. Уфа губернасы ХКС каршындагы Эчке Россия мөселман эшләре комис-ты органы. Элеккеге исеме — «Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советларының Уфа вилаять инкыйлабы ком-ты депутатлары һәм Мөселман хәрби шурасы мөхбире». Уфа шәһәрендә 1918 елның 24 гыйнварыннан 3 июленә кадәр татар телендә 68 саны нәшер ителә. Мөхәррире — Г.С.*Баембәтов*. Оештыручылары А.Хәбиби һәм Б.Нәриманов Оренбургка китү сәбәпле, «*Алга*» г-тасы Уфада чыгудан туктагач басыла башлый. «К.»тә сул эсерлар актив хезмәттәшлек итә. Төп бүлекләре: «Үзәк хөкүмәт эшчәнлеге», «Җирле идарә эшчәнлеге», «Россия буйлап», «Губерна буйлап», «Уфа тормышы», «Хәрби күзәтү». Актив авторлары — Ф.Әхмәтов, Г.Дәүләтшин, С.Шәрәфетдинов. Газета 1918 нең 12 гыйнварында Советларның 3 нче Бөтенроссия съездында кабул ителгән Хезмәт ияләре һәм изелүче халык хокуклары декларациясен пропагандалый. Ул Идел-Урал һәм Себер төрки-татар крәстияннәрен, эшче һәм солдатларны «Бөтен власть Советларга!» лозунгы астына берләштерүне үзенең максаты итеп куя. Ярлы һәм аз җирле крәстияннәрне, җирне социальләштерү нигезендә игенчелек ширкәтләре һәм берлекләре оештырырга чакыра. Аерым язмаларны Мәскәүдә чыгучы «*Чулпан*» г-тасыннан күчереп бастыра. Совет хөкүмәте, Милләтләр эше буенча халык комис-ты һәм милли сәясәтне тормышка ашыру буенча Үзәк мөселман комис-ты эшчәнлекләрен яктырта. Газетада 1918 нең 22 мартындагы Татар-Башкорт Республикасы турындагы Милләтләр эше буенча халык комис-ты нигезләмәсе һәм аңа карата уңай бәяләмәләр басыла. 1918 нең маенда Мәскәүдә узган Татар-Башкорт Республикасы Советларының Учредительләр съездын чакыру буенча киңәшмә карарлары җентекләп яктыртыла.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Образование Башкирской АССР. Уфа, 1959; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978.

*Т.М.Насыйров.*

**КӨРӘ́Ш-БҮЛӘ́К** авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, БР б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 154 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1919 да нигез салына. Оештырылган көннән Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 325, 1949 да — 215, 1958 дә — 175, 1970 тә — 305, 1979 да — 247, 1989 да — 132, 2002 дә — 184 кеше.

**КӨРЕ́Н** (Каринка) елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Туймә елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 25,6 *км*, бассейнының мәйданы 101,9 *км*$^2$. Елга башы Алабуга р-нының Разживино авылы (кеше яшәми торган) янында, тамагы Менделеев р-нының Тихоново авылыннан 2,5 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 4%. К.нең 0,1 дән алып 2,5 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 148 *мм*, ташу агымы катламы 117 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,11 *м*$^3$*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын

100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 3,2 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КӨРНӘЛЕ́** (Архиповка, Архаровка, Курлянка) елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 27,4 *км*, бассейнының мәйданы 218,1 $км^2$. Идел аръягы түбәнлегеннән ага, Алексеев р-нында. Елга башы — Коры Көрнәле авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Юеш Көрнәле авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елганың түбәнге агымнары Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган. Елга башының абс. биеклеге 130 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.нең 0,6 дан алып 11,6 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,17 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 40 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Корылык вакытында елганың аерым урыннары кибә. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында гомуми күләме 1,8 млн. $м^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КӨРНӘЛЕ́ ӘМЗӘ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 64 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гәрәй елгасы буенда. 2010 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ә.дә тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 799 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 480, 1897 дә — 746, 1908 дә — 940, 1920 дә — 924, 1926 да — 2087, 1938 дә — 257, 1949 да — 174, 1958 дә — 151, 1970 тә — 202, 1979 да — 167, 1989 да — 106, 2002 дә — 79 кеше.

**КӨРНӘЛЕ́ ИНЕШЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Гәрәй елгасының (Мораса, Кече Чирмешән елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,6 *км*, бассейнының мәйданы 44,2 $км^2$. Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — урман массивында, Көрнәле Әмзә авылыннан 3,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Иске Әмзә авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 113 *м*. К.и.нең 3,3 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Җәйге саегу вакытында елганың аерым урыннары кибә. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КӨРПӘ́ ҮЛӘНЕ́** (Draba), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә ике- яки берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 270 кә якын төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарда таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — имәнсәр К.ү. (D. nemorosa), барлык районнарда очрый. Болыннарда, ерым битләрендә, урман буйларында, чәчүлекләрдә үсә. 5–10 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Туфракта тирәнгә китүче тамырлары үзәк. Сабагы туры яки тармаклы. Яфраклары бөтен читле, йолдызсыман төкчәле. Чәчәкләре вак, ак яки аксыл сары, чуксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — озынча элипсыман кузакчык. Апрель–июньдә чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Чүп үлән.

**КӨРТЛЕ́К** (Lyrurus tetrix), көртлек кошлар семьялыгындагы кош. Евразиянең урман-дала һәм урман зоналарында таралган. Татарстан терр-ясендә оя коручы гадәти утрак төр. Каен өстенлек иткән катнаш урманнарда яши. Ата кошның гәүдә озынлыгы 53–57 *см*, авырлыгы 1,2–1,8 *кг*, ана кошлар ата кошлардан кечерәк. Ата затлар яшел яки шәмәхә төсмерле кара, койрык асты һәм канатларындагы «көзге» ак, күзе өстендә шәрә кызыл тап бар, томшыгы кара. Ана зат кара чуар коңгырт төстә. К.к.ның койрыгы кисемтәле. Полигамнар (пар хасил итмиләр), кечкенә урманнарда, кисенделәрдә һәм яныкларда яши. Күбрәк җир өстендә яшәү рәвеше алып бара, җиңел йөри, яхшы йөгерә; агачларда иркен утыра, биредә исә ул иң нечкә ботаклар буенча да җитез хәрәкәтләнә. Җирдән шаулап очып китә. Башында берничә карт ата кош торган зур көтү (аеруча көз ахырына) барлыкка китерәләр. Кар төшкәннән язга кадәр бер урман буеннан икенчесенә даими рәвештә күчеп йөриләр, куну урыннарын да еш алыштыралар. Карга күмелеп, җирдә төн куналар, кайвакыт кар астында озын юллар ясыйлар. Көтү яз җитү б-н тарала: ана кошлар берәрләп, аталар зур булмаган төркемнәр булып яши. Март башында үзенчәлекле туй җырын ишетергә мөмкин. Кушылу мәйданында ата кош койрыгын җәеп җибәрә, муенын һәм канатларын суза, әйләнүләр б-н сикерешләр ясый, шаулап очып китә һәм гел җырлый. Оялары — чыбык-чабык яки куе куаклар астында тирән булмаган чокырчыклар. Май башында ана кош кызыл көрән таплы 6–8 җете кызыл йомырка сала. 21 көннән балалары чыга, беренче айда бөҗәкләр, нигездә, турыканатлылар б-н туклананалар; җәен азык буларак — җиләкләр, көзен — бөртеклеләрнең орлыклары; кышын каен һәм зирек алкалары, гөлҗимеш, артыш җимешләре өстенлек итә. Кәсәбәчелек һәм аучылык спорты объекты. К.к.ның урмандагы дошманнары: төлке, сусар, тавык карчыгасы.

**«КӨТЕБХАНӘИ́ ИСЛАМИЯ́»**, 1906 елның гыйнварында Казанда ачыла. Оештыручысы — «Йолдыз» г-тасының мөхәррире һәм нашире Ә.Максуди. Китапханә ачуга рөхсәтне ул 1905 нең февралендә шәһәр думасыннан ала. Соңгысы, үз чиратында, моның өчен аңа 590 сум акча һәм «Болгар» кунакханәсеннән ике бүлмә бүлеп бирә. Китапханә үз эшчәнлеген «Сабах» һәм «Мәгариф» нәшриятлары, бертуган Кәримовлар, Ә.Сәйдәшев, Ә.Максуди һ.б. татар эшлеклеләре бүләк рәвешендә тапшырган китаплардан башлый. Китапханә фондының нигезен Г.Тукай, С.Рәмиев, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Ф.Кәрими, Р.Фәхретдин, Г.Ибраһимов, А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, М.Ю.Лермонтов, И.С.Тургенев, А.Н.Островский, Л.Н.Толстой, У.Шекспир һ.б. әсәрләре тәшкил итә. Китаплар бары тик уку залында гына укырга бирелә. Китапханәдән көнгә 150 гә якын кеше файдалана.

1913 тән мөселман хатын-кызлары да китапханәгә йөрү хокукы ала. 1915 тә китапханәгә җәмгысе 22373 кеше килә. 1922 нең маенда, Ә.Максуди мөхәррирлектән киткәч, китапханәнең исеме М.Вахитов исем. Шәрекъ китапханәсе дип үзгәртелә. 1929 да ТАССР Мәгариф халык комис-ты карары б-н шәһәр китапханәсенә кушыла. Әлеге китапханәдә татар бүлеге ачыла. Гарәп хәрефләре б-н басылган әдәбият Казан ун-тының фәнни китапханәсенә тапшырыла.

*Әд.:* «Китапханәи Исламия»нең ун елы // Йолдыз. 1916. 5 гыйн.; Ибраһимова Ф. Мәгърифәт йорты // Казан утлары. 1986. № 8.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**КӨТЕ́К** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 170 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 597,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 192, 1897 дә — 242, 1908 дә — 219, 1920 дә — 353, 1926 да — 406, 1938 дә — 296, 1949 да — 317, 1958 дә — 232, 1970 тә — 306, 1979 да — 248, 1989 да — 201, 2002 дә — 193 кеше.

**КӨТҮЛЕКЛӘ́Р**, терлекләр көтү өчен файдаланыла торган үләнчел үсемлекле җирләр. А.х. терлекләре өчен арзан һәм аеруча мөһим төп яшел азык чыганакларының берсе. Яшел азыкка булган ихтыяҗ К. хисабына ка-

нәгатьләндерелә. Табигый яисә чәчелгән — ясалма (культуралы) К.гә аералар. Иң продукциялеләре — чәчелгән К. Татарстанда табигый үлән үсә торган К. күп мәйданнарны били (терлекләр көтү өчен файдаланыла). Нигездә, болар — рельеф һәм сөзәклекләрнең күтәренке өлешләрендә урнашкан абсолют, нормаль һәм вакытлыча дымлы үзәнлекләр һәм кечкенә елгаларның уйсу урыннарындагы К. Абсолют үзәнлекләрдә, башлыча, — йонча, сарык солычасы, кырчыл, күрән, болын күкбашы, меңьяфрак, кылган (Көньяк-Көнчыгышта) һ.б. (коры массаның уртача уңышы 1 *га* дан 4–7 *ц*); нормаль үзәнлекләрдә ш.у. болын тимофеевкасы, кылчыксыз кындырак, айравык, клевер, тәпичә (коры массаның уртача уңышы 1 *га* дан 6–15 *ц*) үсә, вакытлыча дымлы булган үзәнлекләрдә, әлеге үләннәрдән тыш, тубылгы, каз тәпичәсе, ак клевер, болын солысы үсә (коры массаның уртача уңышы 1 *га* дан 10–15 *ц*). Уйсулыктагы К.не төрле үләннәр һәм күрән били (коры массаның уртача уңышы 1 *га* дан 9–20 *ц*). ТРның Идел алды һәм Кама арты К.енең үлән капламы төрлелеге б-н аерылып тора һәм көньякка таба алышына бара; монда туры кындырак, мөгезле лядвенец, шуышма сарут, болын тимофеевкасы, солыча, болын чинасы, сары люцерна, эспарцет, арышбаш, кылган үсә (коры массаның уртача уңышы 1 *га* дан 15 *ц*). Татарстанның культуралы сугарулы К.ендә, нигездә, кылчыксыз кындырак, болын солычасы, тимофеевка, люцерна, кызыл һәм ак клевер (күп өлеше катнаш төрдә) үстерелә. Аларны дөрес файдаланганда, терлекләр көткәндә һәм көтүлекләр әйләнешен дөрес саклаганда яшел массаның уңышы 1 *га* дан 300–500 *ц* һәм күбрәк тә була.

К.дән нәтиҗәле файдалану өчен кирәкле шарт булып көтүлек әйләнеше санала: терлекләрне көтү, үләннәрне чабып алу, үлән капламын карау чаралары ел саен алышына. Терлекләрне ялан киртәдә (абзар) көтү, үләннәрне ашламалар б-н тукландыру, чүп үләннәр һәм агулы үләннәр б-н көрәш, табигый орлык чәчелеше өчен кыйммәтле терлек азыгы үләннәрен орлыкларын койганчы калдыру, кузаклы һәм кыяклы үләннәрнең орлыкларын чәчү, кар суларын тоту күздә тотыла.

1990 еллардан башлап, Татарстанда сөзәклекләрдәге эрозияләнгән сөрүле җирләрне К.гә әйләндерү хисабына, аларның мәйданы шактый арта һәм терлек азыгы җирләренең күп өлешен алып тора (2009 да 872,7 мең *га*). К. ш.у. *Болынчылык*.

*Әд.:* Смелов С.П. Теоретические основы луговодства. М., 1966; Сенокосы и пастбища. М.–Л., 1968; Мовсисянц А.П. Использование пастбищ. М., 1969; Маликов М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

*И.Н.Афанасьев.*

**КӨТҮЧЕ́ КОШЛА́Р** (Rallidae), торнасыманнар отрядындагы кошлар семьялыгы. 138 төре билгеле. Поляр өлкәләрдән тыш, бөтен җирдә таралган. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Саз көтүчесе (Rallus aqyaticus) Кама алдында һәм Кама аръягында; гади кугыч (Porzana porzana), *кашкалак* — барлык төбәкләрдә, кечкенә кугыч (Porzana parva) — сирәк төр, Көләгеш сазлыгында (Актаныш р-ны) һәм Зөя елгасы тугаенда (Буа р-ны); *тартар*, камыш тавыгы (Gallinula chloropus) — аз санлы төрләр, Кама аръягында очрыйлар. Күчмә кошлар. Әрәмәлекләр һәм үсемлекләр күпләп үскән сулык ярлары буенда яшиләр. К.к.га хас үзенчәлек — ян-яктан кысылган гәүдә, кыска канат һәм койрык. Аяклары чагыштырмача кыска. Кашкалак һәм камыш тавыгы — кара, тартар, саз көтүчесе, кугычлар көрән һәм соры төстә. Маңгаенда зур ак тап һәм тәпиендә телле-телле элпәләр — кашкалак өчен хас билгеләр; камыш тавыгының маңгаенда кызыл тап бар; саз көтүчесенең томшыгы озын, җиңелчә бөгелгән. Эңгер-меңгердә яшерен яшәү рәвеше алып баралар, яхшы йөзәләр һәм чумалар, начар очалар. Ояларын җир өстендә, түмгәкләрдә, куак ботакларында ясый. Вак тимгелле 6–12 соры-кызыл йомырка сала. Бөҗәкләр, моллюсклар, суалчаннар, үсемлек орлыклары б-н туклана. Гади кугыч һәм кашкалак — ау спорты объекты. Камыш тавыгы һәм саз көтүчесе ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КӨТҮЧЕ́ КУБЫЗЫ́** (Alisma), көтүче кубызчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 га якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә 4 төре бар. Бака яфрагысыман К.к. (A. plantagoa-quatica) барлык районнарда очрый; кыяклы К.к. (A. gramineum), Юзепчук К.к. (A. juzepczukii) һәм ланцет яфраклы К.к. (A. lanceolatum) — республика өчен сирәк төрләр. Сулык ярлары буенда, сай сулыкларда, уйсулыклы сазлыкларда, сазлыклы болыннарда үсәләр. 10–70 *см* биеклектәге үсемлекләр. Сабагы туры, өч кырлы. Яфраклары күксел яшел, озынча түгәрәк-ланцетсыман, озын саплы, тамыр яны таралгысында. Чәчәкләре ак яки аксыл алсу, себеркәч чәчәк төркемендә. Җимеше — бер орлыклы коры җимешчектән торучы күп чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Бака яфрагысыман К.к.ның тамырчасында крахмал, шикәр матдәләре, эфир мае, үләнендә агулы алкалоидлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе бөер авырулары вакытында, геморрой, сары судан дәвалау өчен кулланыла. К.к. ондатра һәм үрдәкләр өчен азык булып тора. Мөгезле терлек өчен агулы. Ланцет яфраклы К.к. һәм кыяклы К.к. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КӨТҮЧЕ́ СОРНАЕ́**, куыш көпшәдән ясалган бер телле традицион милли музыка уен коралы. К.с. ясау өчен кипкән җитен сабагы, балтырган яисә шома көпшә үләне (курай үләне) файдаланыла. К.с. ясау өчен тышкы диаметры төп ягында 10–12 *мм*, очында 8–10 *мм*, озынлыгы 250–400 *мм* булган юка кабыклы сабак сайлап алына. Сабак көпшәнең нәзек ягыннан буынтыктан югарырак өлештә кәүсәдә табигый каплагыч хасил итеп кисеп алына. Икенче очы кыйгачлап яисә корпуска перпендикуляр рәвештә киселә. Буынтыкның ябык ягыннан бераз түбәндәрәк үткен пычак б-н 30–35 *мм* озынлыкта, 8–10 *мм* киңлектә тел уеп алына. Тел уеп ясау процессында тавыш сыйфаты юка сабак тиресен куеп һәм берничә тапкыр һава өреп тикшерелә. Нык, тотрыклы тавыш чыга башлагач, тел кисү туктатыла. Киселгән урынны яндырып яисә аз гына киртек тамга куеп билгелиләр. Уен коралын көйләү 3 яисә 4 бармаклы тишекләр ясаганда тикшерелә. Кагыйдә буларак, К.с. ангемитон, сирәк кенә диатоник тавыш рәтләрендә эшләнә. Еш кына уен коралы көйләрне мажор һәм минор пентатоникада башкару өчен алдан билгеләнә. Артык өргәндә уен коралы билгеләнгән тавыш яңгырашын югалта. К.с.ның диапазоны квартадан секстага кадәр була. К.с.дагы түбән авазлар кискен, тыңкыш-яңгыравык тембрлы контрфаготның урта регистры тавышына охшаш булып чыга. Уен коралының динамик мөмкинлеге — mf-ff. К.с. тормышта көтүчеләр өчен сигнал бирүче уен коралы буларак кулланыла. Көтүче-башкаручыларның репертуары иң элек төрле көйләрдән, муз. сигналлар системасыннан тора: малларны чыгарыр алдыннан ерак арага хәбәр бирү, аларны көтүлеккә чыгару, көтүне су эчәргә алып бару һәм аны яңадан авылга алып кайту һ.б. Уен коралы билгеле бер сезонда гына кулланыла. Шуңа да карамастан, оста музыкантлар аңарда бизәкләргә бай, төрле ритмик комбинацияләр б-н баетылган җырлар, инструменталь көй импровизацияләре башкаралар, бию көйләренең матур яңгырашына ирешәләр. Бу уен коралы бүгенге көндә сирәк кулланыла.

*Р.Ф.Халитов.*

**КӨТҮЧЕ́ СУ́МКАСЫ** (Capsella), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер- яисә икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы; чүп үлән. 5–7 төре билгеле, Җир шарының уртача һәм субтропик төбәкләрендә үсә. ТРда бер төре — гади К.с. (C. bursa-pastoris) таралган, республиканың барлык җирендә очрый, яшелчә чәчүлекләрен, кыр культураларын чүпли. Тамыр яны яфраклары яфрак таралгысына җыелган, алар — тоташ, каурыйсыман телмә, ланцетсыман, сабаклы һәм сабакны тоташ каплаган яфраклар. Чәчәкләре вак, ак, алсу яисә саргылт, калкансыман (чәчәк ата башлаганда), аннан соң озынчаланган чуксыман чәчәк оешмасында урнашкан. Җимеше — ян-якларыннан кысылган өчпочмаклы кузак формасы б-н сумкага охшаган (исеме шуннан алынган). Майдан сентябрьгә кадәр, вегетация чоры беткәнче чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Бер үсемлек 50 меңгә якын орлык бирә, алар туфракта 6 елга кадәр яшәргә сәләтле (җәй дәвамында 2–3 буын өлгерә); язгы һәм көзге формалары бар. Көрәш чаралары — агротехник һәм химик. Яшь яфраклары ашарга яраклы. К.с.ның төнәтмәсе һәм сыек сыгынтысы медицинада һәм ветеринариядә кулланыла.



*Әд.:* Артамонов В. Пастушья сумка — цветок ноября // Наука и жизнь. 1995. № 11.

**«КӨЧ»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Әстерхан губерна ком-ты каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары үзәк бюросы һәм губерна башкарма ком-ты каршындагы милләтләр эше бүлеге органы. «*Тартыш*» г-тасының дәвамчысы. Әстерхан шәһәрендә 1919 елның 24 гыйнварыннан 1921 нең 6 сентябренә кадәр атнага 3 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барлыгы 274 саны чыга. Нашире — Коммунистларның Әстерхан мөселман оешмасы ком-ты. Төрле елларда мөхәррирләре — Х.Сәйфи, К.Гобәйдуллин, Ә.Гомәров. Газетада Х.Әбүбәкеров, Д.Биньядзадә, К.Габидуллин, И.Исмәгыйлев, З.Кәримов, Х.Мөслимова, Х.Мөхәммәтов, Т.Нияз, Н.Пещеряков, Г.Терегулов, Х.Ханбикова, М.Йосыфый һ.б. язмалары басыла. «Бөтендөнья эшче һәм крәстияннәре, берләшегез!» лозунгы астында чыга. Социализм һәм коммунизм идеяләрен пропагандалый. Әстерхан коммунистик яшьләр оешмалары, Казакъстан, Әзәрбайҗан, Украина, Төркестан, Венгриядәге большевистик хәрәкәтләр турында мәкаләләр басыла. «Кызыл фронт» сәхифәсендә адмирал А.В.Колчак армиясе һәм ак казакларга каршы көрәш барышы яктыртыла. В.И.Ленин, Л.Д.Троцкий, И.В.Сталин докладлары һәм мөрәҗәгатьләре; эшче һәм крәстияннәрнең икътисади хәле, а.х. һәм сәнәгать, мәктәптә укыту, эчке һәм тышкы сәясәт турында күзәтүләр басыла. 1919 ның октябреннән газетаның күләме икеләтә кыскартыла. *А.Ә.Хәсәвнех.*

**КӨШКӘ́Т** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 26 *км*, бассейнының мәйданы 186,6 $км^2$. Балтач р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Каенсар авылы янында, тамагы — Борнак авылының көньяк чигендә. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. К.нең 1,4 тән алып 9,4 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 130 *мм*, ташу агымы катламы 105 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,15 $м^3/с$. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында су күләме 0,6 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.



Көшкәт елгасы.

**КӨШКӘТБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 20 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы буенда. 2010 елда 450 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.та мәчет (1897–98 дә төзелә; архит-ра истәлеге) була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 2808,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 127, 1884 тә — 335, 1905 тә — 383, 1920 дә — 639, 1926 да — 1242, 1938 дә — 1179, 1949 да — 686, 1958 дә — 579, 1970 тә — 547, 1979 да — 454, 1989 да — 401, 2002 дә — 469 кеше.

**КӨШКӘТБА́Ш** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 31 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 3 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1711 елдан мәгълүм. 1860 ларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 630,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир-ат; 1859 да — 219, 1897 дә — 339, 1908 дә — 364, 1920 дә — 420, 1926 да — 427, 1938 дә — 304, 1949 да — 258, 1958 дә — 169, 1970 тә — 159, 1979 да — 87, 1989 да — 57, 2002 дә — 24 кеше.

**КӨЯ́ ҮЛӘНЕ́**, п и р е т р у м (Pyrethrum), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Калканлы К.ү. (P. corymbosum) сирәк кенә барлык районнарда очрый, аланнарда, коры урман буйларында, куаклар арасында үсә. Кызлар К.ү. (P. parthenium) өй яны бакчаларында үстерелә, кайвакыт кыргыйлаша. 20–120 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырчасы калынайган. Сабаклары туры. Яфраклары азрак теленмә. Чәчәк төркемнәре берле яки калкансыман кәрзингә җыелган. Кәрзиндәге кырый чәчәкләре көпшәле, җимшәнле, ак, диск чәчәкләре көпшәле, ике җенесле, сары. Җимеше — озынча, ачык көрән төстәге орлыкча. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–июльдә өлгерә. Декоратив үсемлек.

**КПСС**, к. *Советлар Союзы Коммунистлар партиясе.*

**КПССНЫ́Ң ТАТАРСТА́Н ӨЛКӘ́ КОМИТЕТЫ́**, 1920–91 елларда ТАССРда иң югары партия башкарма учреждениесе. РКП(б) ҮК Политбюросының ТАССР төзелү турындагы Декретны гамәлгә ашыру хакында 1920 нең 8 июнендә чыгарылган махсус карары нигезендә оештырыла. Карарда Татарстан респ-касында барлык җаваплы хезмәткәрләрне билгеләү һәм аларны төрле урыннарга күчерү, ш.у. органнардагы вазифаларга кандидатлар күрсәтү РКП(б) өлкә ком-тының гадәттән тыш хокукы дип билгеләп үтелә. Өлкә ком-ты үзенең эшчәнлегендә КПСС Программасына һәм Уставына, партия съездлары һәм конференцияләре карарларына таяна, партия ҮК каршында хисап тота, аның карарларын башкара. К.Т.ө.к. конференцияләр арасында партия оешмасының алгымдагы барлык эшләре б-н җитәкчелек итә, партия сәясәтен гамәлгә ашыра, аның югары органнары күрсәтмәләрен үтәүне оештыра һәм башкара; аңа партия һәм сов. органнары эшчәнлеге, сәнәгать пр-тиеләре һәм а.х. оешмалары, мәдәният, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, коммуналь һәм торак хуҗалыгы, сәүдә, төзелеш учреждениеләре эше б-н җитәкчелек итү; өлкә партия һәм сов. органнарында җитәкче вазифаларда эшләү өчен хезмәткәрләр сайлап алу, бүлү һәм билгеләү йөкләнә. Партия конференциясендә яшерен тавыш бирү юлы б-н сайлана, өлкә ком-тының бюросына һәм пленумына аерым сайлаулар уздырыла (соңгысының составына бюроның барлык әгъзалары да керә). Барлык партия ком-тлары әгъзаларын сайлагандагы кебек үк, өлкә ком-ты әгъзаларын сайлаулар вакытында аның составын системалы рәвештә яңарту һәм җитәкчелекнең дәвамчанлыгы принцибы сакланырга тиеш була. Партия эшчәнлегенең төрле өлкәләре б-н идарә итү өчен өлкә ком-тында секретариат, махсус бүлекләр һәм секторлар оештырыла. Аларда штаттагы хезмәткәрләр даими эш алып баралар. Өлкә ком-ты пленумнары 4 айга 1 тапкырдан да сирәк булмаган тәртиптә чакырыла. Беренче елларда өлкә ком-ты бюросында секретариат һәм өлкә ком-тының бюро утырышларында хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия булган 1 нче секретаре сайлана. Өлкә ком-ты бюросының 1 нче составына А.И.Бочков, Б.И.Гольдберг, А.И.Догадов, И.М.Казаков, С.С.Сәетгалиев, А.С.Самохвалов, А.П.Таняев (1 нче секретарь), И.И.Ходоровский керә.

СССР Конституцияләре буенча Коммунистлар партиясе «хезмәт ияләренең коммунистик җәмгыять төзү өчен көрәшендә аларның алдынгы отряды» һәм хезмәт ияләренең барлык иҗтимагый һәм дәүләт оешмаларының җитәкчелек итүче үзәге (СССРның 1936 елгы Конституциясе), Совет дәүләтенең «җитәкчелек итүче һәм юнәлеш бирүче

көче» (СССРның 1977 елгы Конституциясе) дип игълан ителә. ТАССРның 1937 елгы Конституциясе буенча республиканың иң югары закон чыгаручы органы — ЮС, иң югары башкарма органы — ХКС булса да, республикадагы барлык принципиаль мәсьәләләрне хәл итү хокукына партия өлкә ком-ты гына ия була. Дәүләт органнары җаваплы хезмәткәрләренең төп составы, сәнәгать пр-тиеләре, кадрларны сәяси һәм һөнәри әзерләү оешмалары җитәкчелеге өлкә ком-ты, шәһәр һәм район ком-тлары номенклатурасына кертелә. Өлкә ком-тының аппараты зур булмый, шуңа күрә ул агымдагы эшне, башлыча, башкарма хакимиятнең тиешле органнары аша алып бара. Өлкә ком-тының 1 нче секретаре партия өлкә ком-ты һәм республика тормышында гаять мөһим роль уйный, ул партия ҮК органнары б-н турыдан-туры элемтәдә тора. Бу вазифа сайланулы санала (1 нче секретарьны республика партия конференцияләрендә сайлыйлар), чынлыкта 1 нче секретарьны ҮК билгели. Эшчәнлегенең беренче елларында Татарстан өлкә ком-ты 9 кешедән тора, ул чорда аның бюросында нибары 2–3 татар була, 1944 кә кадәр партиянең Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре вазифасына татар милләте вәкилләре тәгаенләнми. 1920 елларда өлкә ком-ты структурасына 5 бүлек — оештыру-инструкторлык (инструкторлык, мәгълүмат, хисап-башкару, транспорт бүлекчәләре һәм хәрби бюро), агитация һәм пропаганда (матбугат һәм составында керәшен, чуаш, мари, яһүд, латыш, поляк, немец, венгр һәм югослав секцияләре булган милли азчылыклар бүлекчәләре, өмәләр бюросы), хатын-кызлар арасында эш алып бару, авылда эш башкару бүлекләре, ш.у. гомуми бүлек керә. 1923 тә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тына 12 кантком, Казандагы 4 райком, 282 башлангыч партия оешмасы буйсына. Республика терр-ясенең районнарга бүленешенә бәйле рәвештә, өлкә ком-тына буйсынулы шәһәр һәм район оешмаларының исәбе даими үзгәреш кичерә: 1977 дә 9 шәһәр ком-ты, 36 райком, 3775 башлангыч партия оешмасы була.

1934 нең 27 мартында, ВКП(б)ның 17 нче съездының (1934 нең 26 гыйнвары — 10 феврале) партия органнарын җитештерү-тармак принцибы буенча төзү турындагы карарыннан чыгып, өлкә ком-ты бюросы өлкә ком-ты аппаратында сәнәгать-транспорт, а.х., сов. сәүдәсе, мәдәният һәм марксизм-ленинизмны пропагандалау, җитәкче партия органнары бүлекләре һәм махсус сектор оештыру турында карар кабул итә. ВКП(б)ның 18 нче съезды (1939 ның марты) күрсәтмәләре, ҮК Политбюросының союздаш республикаларның ҮКлары, крайкомнар, өлкә ком-тлары һәм шәһәр ком-тлары составында сәнәгать тармаклары буенча бүлекләр оештыру турындагы карары (1939 ның 29 ноябре) нигезендә, Татарстан өлкә ком-ты составында оборона сәнәгате, транспорт (1939), алга таба — җиңел сәнәгать һәм азык-төлек җитештерү сәнәгате (1940 ның 21 мае), авиация сәнәгате (1941), сәүдә һәм җәмәгать туклануы (1942), электр станцияләре, җирле ягулык сәнәгате, совхозлар, терлекчелек (1943), мәктәпләр, азык-төлек сәнәгате (1944) бүлекләре булдырыла. Бөек Ватан сугышы елларында, барлык көчләрне дошманга каршы көрәшкә юнәлтеп, партия өлкә ком-ты үз эшен тулысынча үзгәртеп кора. Өлкә ком-ты үзгәртеп корыла, яңа бүлекләр оештырыла, пропаганда, оборона, авиация сәнәгатьләре, җиңел һәм җирле сәнәгатьләр, транспорт һәм элемтә, сәүдә һәм җәмәгать туклануы буенча ВКП(б) өлкә ком-ты секретарьлары вазифалары кертелә. 1943 нең августында ВКП(б) ҮКның «Шәһәр комитетлары, өлкә комитетлары, крайкомнар һәм союздаш республикалар ҮКлары эшен оештыруны тәртипкә китерү турында» карары б-н тармак секретарьлары ин-ты бетерелә, бары тик 1 нче, 2 нче һәм 3 нче секретарьлар, ш.у. пропаганда һәм кадрлар буенча секретарьлар вазифалары гына гамәлдә калдырыла; секретарьларның урынбасарлары вазифалары булдырыла, алар бер үк вакытта тармак бүлекләре б-н җитәкчелек итәләр. ВКП(б)ның шәһәр һәм район ком-тларында да тармак бүлекләре оештырыла. ВКП(б)ның 1948 нең 25 октябрендә кабул ителгән «Өлкә комитетлары, крайкомнар һәм республикалар компартияләре ҮКлары аппаратларын үзгәртеп кору турында» карарыннан чыгып, 1948 нең 29 октябрендә өлкә ком-ты алга таба үзгәртелә. Пропаганда һәм агитация, партия, профсоюз, комсомол органнары, авыр сәнәгать, җиңел сәнәгать, а.х., адм., план-финанс-сәүдә, партколлегия бүлекләре, махсус сектор, финанс-хуҗалык секторы, нефть сәнәгате секторы (1949 дан) оештырыла. 1952 нең апрелендә Татарстан крайкомы төзелә, аның составына оештырылган Казан һәм Чистай өлкәләренең партия оешмалары керә. 1953 нең апрелендә өлкәләр бетерелгәннән соң, крайком КПССның Татарстан өлкә ком-ты итеп үзгәртелә. 1962 дә КПСС ҮК карары б-н илдә җитештерү принцибы нигезендә партия оешмаларын чиратдагы үзгәртеп кору уздырыла. Өлкә ком-ты бюросының 1962 ел 6 декабрь карарыннан чыгып Татарстан өлкә ком-ты сәнәгать җитештерүе б-н җитәкчелек итү (3 партком буйсынуында) һәм а.х. җитештерүе б-н җитәкчелек итү (17 партком) буенча 2 өлешкә бүленә. КПСС ҮКның 1965 ел 4 гыйнвар карары нигезендә колхоз-совхоз җитештерү идарәләре үзгәртеп корылганнан соң, Татарстан өлкә ком-ты составына оештыру-партия эше, пропаганда һәм агитация, фән һәм уку йортлары, сәнәгать-транспорт, оборона сәнәгате, нефть һәм химия сәнәгате, җиңел сәнәгать, азык-төлек җитештерү сәнәгате һәм сәүдә, төзелеш. а.х., адм. органнар бүлекләре, махсус сектор, финанс-хуҗалык секторы һәм партия комиссиясе кергән яңа структурасы раслана. Алга таба өлкә ком-ты структурасы аз үзгәрешләр кичерә: 1966 да махсус сектор гомуми бүлек итеп үзгәртелә, 1969 да мәдәният бүлеге, 1983 тә икътисад бүлеге оештырыла, сәнәгать-транспорт бүлеге 2 бүлеккә — сәнәгать, транспорт һәм элемтә бүлекләренә аерыла; 1981 дә җиңел сәнәгать, азык-төлек җитештерү сәнәгате һәм сәүдә бүлегеннән сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү бүлеге аерылып чыга.

1990 ның 30 августында ТАССР ЮС тарафыннан ТССРның дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәннән соң, 1990 ның 12 сентябрендә 42 нче өлкә партия конференциясендә партия өлкә ком-ты КПССның Татарстан респ-ка ком-ты (рескомы) итеп үзгәртелә. КПСС рескомының 1990 ел 1 декабрь карары нигезендә өлкә ком-тының структурасы үзгәрә — бүлекләр урынына оештыру-партия эше һәм башлангыч партия оешмаларын яңарту, идеология, иҗтимагый-сәяси берләшмәләр һәм хәрәкәтләр б-н эшләү, социаль-икътисади сәясәт, аграр сәясәт мәсьәләләре буенча комиссияләр, эшләр идарәсе оештырыла. РФ Президенты Б.Н.Ельцинның РСФСР Коммунистлар партиясенең тыелуы турындагы 1991 ел 6 ноябрь Указы чыкканнан соң, КПССның Татарстан рескомы үз эшчәнлеген туктата. Татарстан өлкә ком-ты эшчәнлеге дәверендә 42 өлкә партия конференциясе уздырыла.

Татарстан өлкә ком-тының 1 нче секретарьлары: А.П.Таняев (1920), Д.А.Орлов (1920–21), К.Я.Фиге (1921), Н.И.Барышев (1921), А.И.Карпов (1921), А.П.Галактионов (1922), Д.Е.Живов (1922–23), Б.Д.Пинсон (1923–24), И.М.Бажанов (1924), И.Т.Морозов (1924–25), М.М.Хатаевич (1925–28), М.О.Разумов (1928–33), А.К.Лепа (1933–37), А.М.Алемасов (1937–42), А.Г.Колыбанов (1942–43), В.Д.Никитин (1943–44), З.И.Моратов (1944–57), С.Д.Игнатьев (1957–60), Ф.Ә.Табиев (1960–79), Р.М.Мусин (1979–82), Г.И.Усманов (1982–89), М.Ш.Шәймиев (1989–90), Р.Р.Идиятуллин (1990–91). Ш.у. к. *Советлар Союзы Коммунистлар партиясе.*

Чыг.: Партийная организация Татарии в цифрах и документах (1917–1977 гг.): Сб. стат. материалов и документов. К., 1978.

*Әд.:* Климов И.М., Саркин В.Г. Татарская партийная организация в восстановительный период. 1921–1923. К., 1962; Очерки истории партийной организации Татарии. К., 1973; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии. 1883–1985: В 2 кн. К., 1985.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КРА́ВЧЕНКО** Николай Николаевич (30.10.1880, Могилёв ш. — 1955, Мәскәү), хокук белгече, халыкара хокук магистры (1913), статский советник (1913). Дворяннар нәселеннән. 1903 елда Новороссийск ун-тын (Одесса ш.) тәмамлагач, шунда ук эшли: 1904–07 дә профессорлык стипендиаты, 1907–08 һәм 1911 дә энциклопедия һәм хокук философиясе каф. приват-доценты. 1912–13 тә приват-доцент, 1913–17 дә Томск ун-тының халыкара хокук каф. ординар профессоры. 1917–22 дә Казан ун-тында: халыкара хокук (1919 га кадәр), халыкара мөнәсәбәтләр һәм халыкара хокук (1919 дан) кафедралары профессоры; бер үк вакытта, 1919 ның апреленнән 1921 гә кадәр иҗтимагый фәннәр ф-ты деканы. 1923–29 да Саратов ун-тында: иҗтимагый фәннәр ф-тларының халыкара хокук (1924 кә кадәр), хокук һәм хуҗалык (1924 тән) каф. профессоры. 1929 дан 1 нче Мәскәү ун-ты, Бөтенсоюз юридик читтән то-

рып уку ин-ты (Мәскәү) профессоры. Хезмәтләре халыкара хокук мәсьәләләренә карый. «1890 елгы Берлин конференциясенә кадәрге тарихи үсеше чорында фабрика хезмәтен халыкара-хокук ягыннан регламентацияләү идеясе» («Идея международно-правовой регламентации фабричного труда в её историческом развитии до Берлинской конференции 1890 *г.*», Томск, 1915) монографиясендә халыкара эшчеләргә кагылышлы законнарга гомуми бәяләмә бирә, Көнбатыш илләрендә пролетариатның хезмәт шартларын регламентацияләүгә дәүләт тыкшынуы тенденциясе көчәюне билгеләп үтә. Хәрби, консуллык хокукына, халыкара бәхәсләрне тыныч юл б-н чишү чараларына караган хезмәтләре бар.

Х е з м.: Институт военнопленных в понимании Германского генерального штаба. Томск, 1915; Об основных началах консульского права применительно к Советской России // Уч. зап. Саратов. ун-та. 1925. Т. 3, вып. 4; По поводу советского консульского права // Уч. зап. Саратов. ун-та. 1927. Т. 6, вып. 4.

*Әд.:* Ф е л ь д м а н Д.И. К истории науки международного права в Казанском университете // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Ч. 116, кн. 13; Профессора Томского университета. Томск, 1996.

*Е.Б.Долгов.*

**КРА́ВЧЕНКО** Пётр Васильевич (23.6.1907, Воронеж губ. Бирюч ш. — 30.1.1967, Мәскәү), хирург, мед. фән. д-ры (1955), проф. (1956). 1930 елда Воронеж ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Воронеж, Горький шәһәрләренең мед. учреждениеләрендә (1937–55) эшли, бер үк вакытта, 1943–51 дә Горький мед. ин-ты директоры. 1955–67 дә Казан ГИДУВында кичектергесез хирургия каф. мөдире. Хезмәтләре ашказаны асты бизен, ашказанын, үт юлларын хирургик дәвалауга карый. К. операциядән соң ашказаны асты бизенең калган өлешен эшкәртү ысулын тәкъдим итә (К. ысулы). Казанда беренче булып, тумыштан килгән йөрәк зәгыйфьлегенә (1956); аневризм булганда киңәйгән бот артериясен дакрон протез б-н алмаштыру (1961), уңәчне һәм ашказанын бер вакытта кисеп алу (1966) операцияләрен үткәрә.

Х е з м.: Материалы к хирургии поджелудочной железы. Г., 1947; Применение антикоагулянтов при острой тромбоэмболии // Казан. мед. журн. 1963. № 4 (автордаш).

*Әд.:* Жизнь и деятельность проф. П.В.Кравченко // Тр. Казан. ГИДУВа им. В.И.Ленина. 1969. Т. 26.

**КРА́ЕВ** Анатолий Николаевич (14.9.1911, Казан губ. Лаеш ш. — 26.2.1981, Казан), мәдәният эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). 1926 елда «Электра» кинотеатрында киномеханик өйрәнчеге. 1929–30 да киномеханиклар курсларында, 1949 да — Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-ты каршындагы камилләштерү курсларында, 1951–53 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы совет партия мәктәбендә укый. 1931–32 дә «Первый Звуковой» (элекке «Электра») кинотеатры администраторы, 1932–33 тә «КИМ» кинотеатры, Эшче яшьләр театры, 1933–38 дә «Электро» кинотеатры директоры. ТАССР ХКС каршындагы Татар кино тресты (Татар кинопрокаты) җитәкчесе, 1940–51 дә ТАССР ХКС (1946 дан — МС) каршындагы Кинофикация идарәсе башлыгы, 1953–55 тә мәдәният хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан өлкә ком-ты рәисе, 1955–61 дә ТАССР мәдәният министры урынбасары, 1961–74 тә — Казан кинохроника студиясе, 1974 тән СССР Кинематографистлар берлеге каршындагы кино сәнгатен пропагандалау буенча Татар өлкәара бюросы директоры. Талантлы оештыручы, республика һәм Идел буе регионы кинематографиясе үсешендә мөһим роль уйный, кинематография объектларының материаль-техник җирлеген ныгытуга, кадрлар булдыруга зур өлеш кертә. Ул эшләгән вакытта Казан кинохроника студиясендә илдә иң яхшылардан саналган кинооператорлар мәктәбе оештырыла, Казан студиясендә эшләнгән фильмнар бөтенсоюз, бөтенроссия һәм халыкара фестивальләрдә танылу таба. Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.П.Алексеева.*

**КРАЙНО́В** Степан Матвеевич (14.11.1920, Спас кантоны Базарлы Матак а. — 20.7.2005, Түбән Новгород ш.), Сов. Союзы Герое (23.9.1944), гв. майоры. Горький су транспорты инженерлары ин-тының 3 курсын (1942), Ленинград бронетанк команда составын камилләштерү курсларын (1942), Вологда сөтчелек ин-тын (1949) тәмамлый. 1941 елның октябреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 52 нче гв. танк бригадасының танк командиры (3 нче гв. танк армиясенең 6 нчы гв. танк корпусы). Брянск, Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Украинаның сулъяк ярын азат итүдә (1943), Киев һөҗүм һәм оборона операцияләрендә (1943), Житомир-Бердичев (1943–44), Львов-Сандомир (1944), Берлин һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 13 августында Сандомир плацдармында Мокре (Сташув шәһәреннән көнбатыштарак, Польша) торак пункты янында дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда батырлык күрсәтә: К. командалыгындагы танк экипажы дошманның 2 танкын юк итә. 1946 елдан запаста. Горький шәһәре сөт з-дында баш инженер ( 1974–76), Горький өлкәсе Сөт сәнәгате идарәсендә җиһазларны комплектацияләү буенча инженер булып эшли (1976–83), Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Түбән Новгород шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Я г о д и н с к и й Е.А. Золотые Звёзды речников. М., 1971. Вып. 1; Т ю л ь н и к о в Л.К., Б а с о в и ч Я.И. Герои Советского Союза — горьковчане. Г., 1981; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КРА́МБЕ**, к. *Катран.*

**КРАМП** Христиан Вильгельм (1814, Дания — 1849, Казан), архитектор, архит-ра академигы (1842). Даниядә белем ала. 1840 елда Копенгагеннан Россиягә килә. 1842 елгы янгыннан соң шәһәрне торгызу буенча Төзелеш комиссиясендә эшләү өчен 1843 тә Казанга җибәрелә. Шәһәр думасын (1846), Казан арестантлар ротасы мунчасын (1846), соңгы классицизм стилендә башкарылган күпсанлы торак утарларны яңартып төзү проектларының авторы. Антресоль катлы зур агач йорттан, төп йортның ян-ягына урнашкан берәр катлы ике флигельдән (уң ягындагысы 20 йөз башында сүтелә) һәм ишегалды түрендәге хуҗалык корылмаларыннан торган комплекс (С.Ф.Гоппе өчен төзелгән торак утары, 1844); Ю.А.Крюкованың торак йорты (1844); П.Р.Регистратов өчен киң йөзлекле кәрнизләр б-н төзелгән ике катлы торак йорт (1849; хәзер сүтелгән); ярдәмче каралтылары да булган, агачтан салынган кечкенә, бер катлы Каховский йорты (19 йөз уртасы); Н.М.Вениаминовның торак утары (1849) аеруча әһәмиятле хезмәтләреннән санала.

*Л.М.Мортазина.*



С.М.Крайнов.




М.В.Красавин.



Х.В.К р а м п. Шәһәр хакимияте бинасы. Казан. Хәзерге күренеше.

**«КРАСА́ ТАТА́РИИ»**, чия сорты. Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясендә 1966 елда Н.М.Росточков, Л.А.*Севастьянова* тарафыннан чыгарыла. Уртача кычка чыдам, иртә өлгерешле. Коккомикозга бирешми. 2,5–3 *м* биеклектәге куак. Ябалдашы киң пирамидасыман яисә түгәрәк, куе, яхшы яфраклaнган. Яфраклары эре, калын тиреле, киң, яссы йомыркасыман, тонык яки ялтыравыксыз. Җимешләре 4,8 *г*, яссы-түгәрәк, куе кызыл, уртача тыгызлыкта, тәме әчкелтем-баллы; яңа өлгергән һәм эшкәртелгән килеш файдаланыла. 3–4 елда җимеш бирә башлый. Бер куактан 16–18 *кг* уңыш алына. Бу сорт ТРда 1984 тән районлаштырыла.

**КРАСА́ВИН** Михаил Васильевич (22.10.1919, Казан губ. Зөя өязе, хәзерге Югары Ослан р-ны Урман буе Морквашы а. — 28.12.1992, шунда ук), Сов. Союзы Герое (30.10.1943), гв.











Д.Н.Красильников. 1. «Автопортрет». Кәгазь, тушь, акварель, карандаш. 1946; 2. «Мәгариф» журналы тышлыгы эскизы. Кәгазь, тушь, гуашь, каләм. 1927; 3. Яковенконың «Өч элемент» китабы тышлыгы эскизы. Кәгазь, тушь, гуашь. 1931; 4. «Октябрь баласы» журналы тышлыгы эскизы. Кәгазь, тушь, акварель. 1932, №4. Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

полковнигы. Казан танк уч-щесен тәмамлый (1945). Туган авылында МТСта комбайнчы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 61 нче гв. аерым моторлаштырылган понтон күпер салу батальонының отделение командиры (65 нче армиянең 14 нче гв. инженер сапёрлар бригадасы). Көнбатыш, Брянск һәм Үзәк фронтлар гаскәрләре составында Курск (1943) сугышында, Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 15 октябрендә Днепр елгасын кичеп, Радуль торак пункты (Украина ССР, Чернигов өлкәсе Репкин р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: отделениесе б-н понтоннардан паром ясап, 400 кешедән артык пехотачыны, миномёт ротасын һәм полкның артиллерия батареясын елга аркылы чыгара. Сугыштан соң Казанда Эчке эшләр министрлыгында эшли. 1964 елдан запаста. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КРАСИ́ЛЬНИКОВ** Дмитрий Михайлович (30.7.1948, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТР, РФнең атказ. табибе (1996, 1998). 1972 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Казанның 12 нче шәһәр хастаханәсендә хирург булып эшли. 1975 тән Казан мед. ин-тының 1 нче госпиталь хирургиясе кафедрасында. 1977 дән Казан 1 нче шәһәр клиник хастаханәсе хирургы. 1979 дан Казан мед. ун-тында, 1992 дән 1 нче хирургия авырулары каф. мөдире. Хезмәтләре ашказаны җәрәхәтен хирургик дәвалауга, ашкайнату тракты авыруларына диагноз куюя һәм дәвалауда нурлар куллануга карый. К. абдоминаль, торакаль һәм эндоскопик хирургиядә операциядән соң ук авыртулар көчәю чорында профилактик диагноз кую һәм комплекслы дәвалау чараларын фәнни эшкәртә. Уйлап табуга 9 патенты бар. Операцияләр ясау өчен 4 атлас төзи. Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Атлас операций на жёлчных путях. К., 2000; Руководство по практической хирургии. К., 2001 (автордаш).

**КРАСИ́ЛЬНИКОВ** Дмитрий Николаевич (7.11.1903, Уфа губ., Минзәлә өязе Урта Пиняги а. — 1952, Минск), график. 1922 елда — Пермь сәнгать остаханәләрендә, 1923–26 да — Казан архит-ра-сәнгать остаханәләрендә, 1927–30 елларда ВХУТЕИНның полиграфия ф-тында укый. К., беренче милли китаплар бизәүче рәссам, журнал һәм газеталар өчен рәсемнәр ясаучы, реалистик илл. остасы буларак, Татарстанның сәнгатендә тирән эз калдыра. 1923–28 елларда татар вакытлы басмалары б-н хезмәттәшлек итә (карандаш б-н эшләнгән портретлар, пейзажлы рәсемнәр, сатирик графика — «Кызыл яшьләр», «Чаян», «Безнең юл» ж-ллары, «Кызыл Татарстан», «Эшче» һ.б. г-талар). Таткнигоиздат китапларын бизи һәм иллюстрацияләр ясый. Хезмәтләрен «ДНК» монограммасы б-н бастыра. 1928 дә Дж.Лондон, М.Горький, Х.Туфанның карандаш б-н ясалган портретларын иҗат итә («Авыл яшьләре» ж-лында басылып чыга). 1920 еллар ахырыннан — Мәскәүдә, СССР халыкларының Үзәк нәшриятындагы татар секциясендә эшли, редакторы М.Җәлил булган «Октябрь баласы» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. Бөек Ватан сугышы елларында белорус телендә чыккан «Раздавим фашистскую гадину!» г-тасы редакциясендә. «Вожык» белорус сатирик ж-лына нигез салучыларның берсе, 1945–52 елларда сәнгать бүлеге мөдире, консультант, рәссам. К.ның график мирасы 100 дән артык әсәрне үз эченә ала: карандаш б-н башкарылган миниатюралар, репортаж рәсемнәр, акварель портретлар, тушь, каләм б-н ясалган рәсемнәр, сатирик рәсемнәр; арада «Крокодил» ж-лында басылган шаржлар да бар. К. совет сатирик графикасына сәяси карикатура остасы буларак лаеклы өлеш кертә.

«Китап сәнгате» (Париж, 1931), «СССРның хәзерге заман сәнгате» (АКШ,1933), «Бишьеллык хезмәтендә — плакат» (Мәскәү, 1932) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе Казанда 1978 елда оештырыла.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983; Зарипов Э.Я. Художники // Здравствуй, книга! К., 1989.

*О.Л.Улемнова, Р.Г.Шаһиева.*

**КРАСИ́ЛЬНИКОВ** Юрий Михайлович (7.2.1933, Казан — 3.11.1998, шунда ук), тренер (җиңел атлетика), РСФСРның атказ. тренеры (1980), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1997). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1955). 1958–93 елларда 2 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә өлкән тренер, бер үк вакытта, 1982–88 дә ТАССР Җиңел атлетика федерациясе рәисе, 1973–82 дә СССР Җиңел атлетика федерациясе әгъзасы. 1971–82 дә СССР җыелма командаларының өлкән тренеры. 1973–98 дә РСФСР судьялар коллегиясе әгъзасы, 1994 тән Олимпия резервы 3 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Казан) тренер. Шәкертләре арасында — РСФСР, СССР чемпионатларында, Олимпия уеннарында җиңүче, медаль алучы һәм рекордчылар В.Данилов, Р.Р.Кадыйрова, О.М.*Рукавишникова*, Җ.Л.Хайкина, В.И.Юдинцев.

**КРАСИ́ЛЬНИКОВА** Евгения Анатольевна (11.7.1927, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1974), проф. (1977), Казан технол. ун-тының атказ. проф. (2003), ТАССРның атказ. мәдәният һәм РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1988, 1998). 1950 елда Казан ун-тын тәмамлый, Казан технол. ун-тында эшли, нефть ф-ты деканы (1962–65). Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Фосфор-күкерт бәйләнешле кушылмаларның ике яклы реакциягә керү мөмкинлеген өйрәнә, өч координацияле фосфор тиокислоталары кушылмаларының реакция сәләтенең гомуми теориясен эшли. Күкертле фосфорорганик кушылмалар өлкәсендәге хезмәтләре өчен

Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыяте бүләгенә лаек була (1974). Арбузов реакциясендә металл комплекслы катализны өйрәнә, өч координацияле фосфор к-талары кушылмалары б-н арилгалогенидларының нуклеофиль алмаштыру реакциясенең күп стадияле механизмын тәкъдим итә. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Вопросы строения и реакционной способности эфиров тиокислот трёхкоординированного фосфора // Успехи химии. 1977. Т. 46, вып. 9; О механизме катализа реакции Арбузова комплексными соединениями переходных металлов // Журнал органической химии. 1991. Т. 61, вып. 2 (автордаш).

**КРА́СИН** Михаил Яковлевич (1832, Орёл губ. Брянск өязе — 6.7.1880, Казан), илаһият белгече, филолог, илаһият д-ры (1873). Мәскәү руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1858), Ярославль руханилар семинариясендә укыта. 1859 елдан Казан руханилар академиясендә: физика, математика, француз һәм латин телләре, рим әдәбияты укыта, проф. (1868); бер үк вакытта Казан ун-тының рим әдәбияты профессоры. Хезмәтләре догматика, Рус Православие чиркәвенең урта гасырлар соборлары эшчәнлегенә карый.

Хезм.: Обзоры правил древних русских митрополитов // Православный собеседник. 1864–66; Творение Блаженного Августина De crivate Dei как апология христианства в его борьбе с римским язычеством. К., 1873.

*Әд.:* Добротворский И.М. Михаил Яковлевич Красин // Православный собеседник. 1880. Ч. 2; Знаменский П.В. История Казанской Духовной Академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870 годы): В 3 вып. К., 1891–92.

*Е.В.Липаков.*

**КРА́СИН** Павел Михайлович (8.3.1875, Казан — 1935, шунда ук), хирург, медицина д-ры (1907). 1899 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук, госпиталь хирургиясе клиникасында эшли. 1904–05 тә, табиб буларак, рус-япон сугышында катнаша. 1908 дә колак, тамак һәм борын авыруларын өйрәнү өчен чит илгә җибәрелә. 1909 дан Казан ун-тында: 1911 дән госпиталь хирургиясе кафедрасында приват-доцент. 1912 дән прозектор, 1917 дән топографик анатомия б-н оператив хирургия кафедрасының ординар профессоры. Гражданнар сугышы елларында Кызыл Хач лазаретларында һәм Казанның Шамов хастаханәсенең хирургия бүлегендә хирург. 1927 елда оператив хирургия һәм топографик анатомия укыту ысулларын өйрәнү өчен Германиягә җибәрелә. 1928–30 да Казан ун-тының гомуми хирургия каф. мөдире. 1931 дән Казан мед. ин-тының пропедевтик хирургия клиникасы профессоры. Хезмәтләре үзәктән читтәге нервлар регенерациясенә, аяк табанына һәм балтыр буынына операцияләр ясауга карый.

Хезм.: К учению о регенерации периферических нервов после повреждения их. К., 1907; К лечению открытых переломов длинных трубчатых костей // Хирургия. 1911. Т. 29; Новый способ временной частичной остеопластической резекции нижней челюсти для удаления рака языка // Казан. мед. журн. 1922. № 3.

**КРАСНА́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кызылсу елгасы буенда. 2010 елда 62 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлек асрау. 1565–67 еллардан мәгълүм. Революциягә кадәрге чыганакларда Красная исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет (1907 дә төзелә), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 346,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 154, 1897 дә — 292, 1908 дә — 346, 1920 дә — 346, 1926 да — 329, 1938 дә — 254, 1949 да — 194, 1958 дә — 155, 1970 тә — 114, 1989 да — 66, 2002 дә — 62 кеше.

**«КРА́СНАЯ А́РМИЯ»**, газета, к. «*Красный Восток*».

**«КРА́СНАЯ ГЛИ́НКА»**, археол. ядкәре; Тәтеш р-ны Бессоново авылы янындагы (хәзер Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган) таш гасыр (якынча, б.э.к. 100–35 мең еллар) торулыгы. 1951 елда М.З.Паничкина, 1954 тә З.А.Абрамова тарафыннан тикшерелә. Таштан ясалган зур әйберләр: эре чакматаш ярчыклардан ясалган кыргычлар, баш-башлары очланган чуерташлар, шомартылган һәм эшкәртелмәгән ярчыклар, неандерталецлар торулыкларына хас аморф ядрәләр һәм «тупас» эшләнгән башка кораллар, ш.у. палеолит чоры фаунасы (мөгезборын, зубр, ат һ.б.) калдыклары табыла. Л.В.Кузнецова фаразлавынча, ядкәр Мустье культурасына карый.

*Әд.:* Паничкина М.З. Разведки палеолита на Средней Волге // Советская археология. 1953. № 1, 8; Абрамова З.А. Разведки палеолита на Средней Волге в 1954 году // Краеведческие зап. Ульяновск, 1958. Вып. 2.

**КРА́СНАЯ ГО́РКА** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 19 кеше (руслар) яши. 17 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Г.да ашлык саклау-сату һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 683,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 25 гыйнварыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 23 ир-ат; 1859 да — 293, 1897 дә — 456, 1908 дә — 468, 1920 дә — 390, 1926 да — 235, 1938 дә — 192, 1949 да — 158, 1958 дә — 138, 1970 тә — 96, 1979 да — 56, 1989 да — 40, 2002 дә — 31 кеше.

**КРА́СНАЯ ГО́РКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 67 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 27 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Яңа Чишмә р-нында. 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1938 дә — 103, 1949 да — 95, 1958 дә — 106, 1970 тә — 89, 1979 да — 69, 1989 да — 34, 2002 дә — 35 кеше.

**КРА́СНАЯ ГО́РКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 3 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасы буенда. 2010 елда 1333 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 55%, руслар — 43%) яши. Төзү пр-тиеләре. Мәдәният йорты, китапханә. 1652 дән мәгълүм. Революциягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Г.да волость идарәсе урнаша; Архангел Михаил чиркәве (1787–1802 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство, чиркәү-приход мәктәпләре (1887 дә ачыла), 2 тегермән, тимерчелек, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5468,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красногорск волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 810 ир-ат; 1859 да — 1993, 1897 дә — 2052, 1908 дә — 2237, 1920 дә — 2046, 1926 да — 1752, 1938 дә — 1479, 1949 да — 830, 1958 дә — 794, 1970 тә — 1206, 1979 да — 1386, 1989 да — 1224, 2002 дә — 1391 кеше.

**КРА́СНАЯ ПОЛЯ́НА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 8 *км* төньяктарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 1650–51 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Успенский исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.П.да волость идарәсе урнаша; Успение чиркәве (1757 дә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 чиркәү-приход мәктәбе (ирләрнеке — 1888 дә, хатын-кызларныкы 1896 да ачыла), кредит ширкәте, 7 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2215 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Тәтеш өязе Красная Поляна волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 372 ир-ат; 1859 да — 993, 1897 дә — 1391, 1908 дә — 1514, 1920 дә — 1513, 1926 да — 1426, 1938 дә — 1472, 1949 да — 820, 1958 дә — 503, 1970 тә — 226, 1979 да — 131, 1989 да — 32, 2002 дә — 11 кеше.

**КРА́СНАЯ ПОЛЯ́НА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 28 *км* көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 29 кеше (руслар,

мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Котыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1938 дә — 130, 1949 да — 281, 1958 дә — 253, 1970 тә — 285, 1979 да — 167, 1989 да — 72, 2002 дә — 42 кеше.

**«КРА́СНАЯ ТАТА́РИЯ»**, газета, к. «*Республика Татарстан*».

**«КРА́СНАЯ ТАТА́РИЯ»** («Кызыл Татарстан»), танк колоннасы. ТАССРда җыелган акчага 1944 елда төзелә. 1944 нең февралендә Кайбыч р-ны колхозчылары Кызыл Армиянең Җиңү фондына акча җыю тәкъдиме б-н чыгалар. Алар аңа 1 млн. 300 мең сум акча кертәләр. 1944 нең декабре уртасына Җиңү фондында 62 млн. сум акча, 26880 пот икмәк һәм 131580 пот бәрәңге җыела. Акчаның зур өлеше «К.Т.» танк колоннасын төзүгә тотыла. 1944 нең язында ян-якларына «К.Т.» сүзләре язылган танклар генерал-лейтенант А.О.*Ахманов* җитәкчелегендәге 23 нче танк корпусы сугышчыларына тапшырыла.

*Әд.:* Гильманов З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

*В.Ф.Телишев.*

**КРАСНИ́ЦКИЙ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистраленнән 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 39 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — ТАССРның Арча кантоны Ильин волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенск, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1926 да — 79, 1938 дә — 90, 1949 да — 60, 1958 дә — 80, 1970 тә — 125, 1979 да — 88, 1989 да — 75, 2002 дә — 47 кеше.

**КРАСНО́В** Александр Васильевич (1866–1907, Варшава ш.), астроном. Казан ун-тын тәмамлый (1893), шунда ук эшли, проф. (1898). 1898 елдан Варшава астрономия обсерваториясе директоры. Хезмәтләре күк механикасына, гамәли астрономиягә һәм гравиметриягә карый. Россиядә беренче булып Айга гелиометрик күзәтүләр үткәрә (Казан, 1895–98). Ай кратерларының берсенә К. исеме бирелгән.

Хезм.: Апсидная кривая и особенное решение дифференциальных уравнений геоцентрической орбиты Луны. Варшава, 1900; Получение периодической лунной орбиты непосредственно из уравнения Якоби. Варшава, 1905.

*Әд.:* Воронцов-Вельяминов Б.А. Очерки по истории астрономии в России. М., 1956.

**КРАСНО́В** Анатолий Васильевич (23.5.1952, Минзәлә ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2008), проф. (2009), ТР ФА мөхбир әгъзасы ( 2010), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2001). 1976 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлый. 1976–79 да Алабуга р-нында: «Волна Революции» с-зының механизаторы, агрономы, район а.х. идарәсе икътисадчысы. 1989 га кадәр партия эшендә: КПССның Алабуга шәһәр ком-тында (1985 кә кадәр), Татарстан өлкә ком-тында (1988 гә кадәр), Биектау райкомының 1 нче секретаре. 1990–91 дә «Татрапс» ФҖБнең, 1991–97 дә «Санво» ААҖнең ген. директоры. 1997–98 дә Бөтенсоюз химияләштерү фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-ты (Казан) директоры. 1998 дән ТР Премьер-министры киңәшчесе, ТР МКның җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары агросәнәгать комплексы идарәсе башлыгы, 2010 нан ТР Президенты ярдәмчесе. Хезмәтләре агросәнәгать комплексына, аграр икътисад фәнендә социаль-хезмәт һәм социаль-икътисади мөнәсәбәтләрне үстерүгә, кадрлар һәм азык-төлек куркынычсызлыгына карый. 2015 елга кадәр ТР авыл хуҗалыгының социаль-ориентлашкан региональ икътисады һәм агросәнәгать комплексында мәгълүмат-консультация системалары концепцияләрен эшли. 6 монография һәм 11 китап авторы. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Минзәлә шәһәренең мактаулы гражданы.

Хезм.: Проблемы регулирования социально-трудовых отношений в экономике сельского хозяйства. М., 2007; Концепция развития информационно-консультационных систем АПК до 2015 года. М., 2007 (автордаш); Эффективность использования земельных ресурсов региона. К., 2009 (автордаш); Экономическая безопасность: роль человеческого капитала в инновационном развитии экономики Республики Татарстан // Вестн. экономической интеграции. 2011. № 10.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КРАСНО́В** Виктор Васильевич (2.2.1928, Казан авыл р-нының Дербышки а. — 14.3.2004, Казан), спортчы, тренер (бокс), СССРның атказ. тренеры (1959), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1988). 1955 тән ТАССР профсоюзларының физкультура-спорт җәмгыятендә өлкән тренер, бер үк вакытта, 1960 тан «Ракета» спорт клубында тренер (Казан). Шәкертләре арасында — РСФСР халыклары спартакиадаларында, РСФСР, СССР (Россия), Европа, дөнья чемпионатларында җиңүчеләр һәм медаль алучылар Б.В.Гребнев, В.Д.Индюков, А.К.*Хаматов*, В.П.Шабанов һ.б.

**КРАСНО́В** Николай Кузьмич (17.5.1928, Буа кантоны Төрләмә а. — 25.6.2000, Кайбыч р-ны Хуҗахәсән а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1987). Ключище а.х. техникумын (1949), Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1962). 1949 дан Подберезье р-нының Мәлки МТСында участок агрономы, 1955–56 да — ВЛКСМның Подберезье, 1956–57 дә — Кайбыч райкомы секретаре. 1958–61 дә Мәлки МТСында баш агроном. 1961–63 тә Кайбыч, 1963–68 дә Буа р-ннары а.х. идарәләре башлыгы. 1968–89 да Апас р-нының Киров исем. к-зы рәисе. К. җитәкчелегендә колхоз югары табышлы хуҗалыкка әверелә. Бөртекле ашлык җитештерү — 2,4, шикәр чөгендере — 1,9, ит — 1,3, сөт — 1,4 тапкырга арта. Савым 1 сыердан 3400 *кг* га җитә. К. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**КРАСНОВИ́ДОВО** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 елда 469 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. М.Горький музее. Чиркәү. Казан Архиерей йорты җирләрендә 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1763 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, бакчачылык, яшелчә үстерү, кирпеч сугу, мичкә ясау, тимерчелек, тегүчелек, балта эше, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Богоявление чиркәве, земство мәктәбе (1856 дан яшәп килгән авыл приход мәктәбе җирлегендә 1869 да ачыла), 7 җил тегермәне, 2 тимерчелек, пароход һәм урман материаллары җибәрү пристаньнары, 3 сыраханә, 1 казна шәраб, 1 мануфактура һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2459 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Тәмте волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1745 тә — 304, 1782 дә — 318 ир-ат; 1834 тә — 1045, 1859 да — 1480, 1897 дә — 1954, 1908 дә — 2991, 1920 дә — 1994, 1926 да — 1147, 1938 дә — 1632, 1949 да — 827, 1958 дә — 1135, 1970 тә — 903, 1979 да — 773, 1989 да — 642, 2002 дә — 570 кеше.

**КРАСНО́ВСКИЙ** Архип Алексеевич (19.2.1885, Чернигов губ., Новозыбково өязе Тимоновичи а. — 9.4.1953, Мәскәү), педагог, педагогика тарихчысы. 1910 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1912 дән Казан югары хатын-кызлар курсларында, 1919 дан Казан ун-тының пед. каф. профессоры (1921). Бер үк вакытта, 1918–22 дә Казан рус пед. техникумы мөдире, 1922–24 тә татар икееллык пед. курслар җитәкчесе. 1925 тән Мәскәү индустриаль-пед. ин-тында, 1943 тән Мәскәү чит телләр ин-тында. 1930 га кадәр укытучыларның Европа пед. тарихы проблемалары б-н шөгыльләнә. Я.А.Коменскийның пед. хезмәтләрен рус теленә тәрҗемә итә һәм басмага әзерли.

Хезм.: К вопросу об объёме и содержании педагогического образования преподавания школы фабрично-заводского ученичества. М., 1928; Ян Амос Коменский. М., 1953.

*Әд.:* Кречетова Е.А. Архип Алексеевич Красновский // Советская педагогика. 1985. № 7; Хабриева О.А. Архип Алексеевич Красновский. 1885–1953. К., 2004.

**КРАСНОГВАРДЕ́ЙСК РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1966 елда оештырыла. Үзәге — Плешаново авылы (Оренбург шәһәреннән 227 *км* төньяк-көнбатыштарак). Мәйданы — 2,8 мең *км²*. Халкы — 23185 кеше (2010). Татарлар саны: 1979 да — 1347, 1989 — 1176, 2002 дә 1693 кеше. Районда 2 татар торак пункты — Үтә (2003 тә — 372 кеше) һәм Иб-

рай (253) бар. 1740 елларда К.р.на татарларның килеп урнашуы Яңа Мәскәү тракты төзелеше б-н бәйле. Ямщик булып хезмәт итүдән башка, алар сәүдә, төрле һөнәрләр (аяк киеме тегү, күн эшкәртү, ат дирбиясе ясау) б-н шөгыльләнә.

**«КРА́СНОЕ ЗНА́МЯ»** («Кызыл байрак»), иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге органы. 1918 елның 5 июленнән 2 августына кадәр Казанда рус телендә 5 саны нәшер ителә. Мөхәррире күпсанлы мәкаләләр авторы һәм татар теленнән русчага тәрҗемәче М.*Солтангалиев* була (псевд. Тамерлан, Кан-Темир, Кульку-Баш, Сухой). «Безнең юл» («Наш путь») мәкаләсендә (№ 1) ул газетаны чыгаруны рус эшче һәм крәстияннәренә Татар-Башкорт Респ-касын оештыруның әһәмиятен аңлату, мөселман пролетариаты тормышын яктырту омтылышы б-н нигезли. Мөхәррир «Знамя революции» г-тасында Татар-Башкорт Респ-касына каршы чыгыш ясаган К.*Грасисны* тәнкыйтьли. Солтангалиев үзенең «Мөселман социалистлары контрреволюцион заговор көннәрендә», «Эшчеләр һәм мөселман кызылармиячеләрнең митингы» һ.б. мәкаләләрендә Казан хәрби гарнизонының сугышка әзерлек чорында мөселман социалистик оешмалары һәм хәрби частьләренең позициясен аңлата. Ул ш.у. меньшевик, анархист, кадет, уң һәм аларга бигрәк тә нык якынайган сул эсерларның контрреволюцион чыгышларына каршы көрәшергә чакыра. «Юлына ак җәймә» мәкаләсендә Солтангалиев, сул эсерлардан аерылу большевикларның позициясен бары ныгытачак кына, дип раслый. Газета мөселманнарны кулларына корал алып революция казанышларын акгвардиячеләр һөҗүменнән сакларга чакыра. Солтангалиев басмада үзенең «Мин метеор идем ...», «Тормыш миражы», «Тормыш һәм кешеләр», «Җырланып бетмәгән җыр» (Г.Тукай истәлегенә) һ.б. революцион һәм лирик шигырьләрен бастыра. Казан Чех-словак корпусы һәм КОМУЧ халык армиясе тарафыннан басып алынганнан соң, газета чыгудан туктый.

*Әд.:* Н а с ы й р о в Т. Совет властенең беренче елларда татар вакытлы матбугаты (1917–1920) // Совет әдәбияты. 1956. № 9; Новый собрат // Правда. 1918. 25 июля; С у л т а н - Г а л и е в М. Статьи. Выступления. Документы. К., 1992; ш у л у к. Избранные труды. К., 1998.

*Р.А.Айнетдинов.*

**КРА́СНОЕ НЕЧА́СОВО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. 18 йөздә нигез салына. 1940 ка кадәр Барское Нечасово исемен йөртә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1896 да ачыла), 4 җил тегермәне, йон тетү йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 620 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 341, 1897 дә — 516, 1908 дә — 591, 1920 дә — 511, 1938 дә — 224, 1949 да — 226, 1958 дә — 187, 1970 тә — 76, 1979 да — 48, 1989 да — 20, 2002 дә — 4 кеше.

**КРА́СНОЕ О́ЗЕРО** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасының югары агымы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Олы Тархан волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 125, 1949 да — 112, 1958 дә — 120, 1970 тә — 129, 1979 да — 86, 1989 да — 24, 2002 дә — 13 кеше.

**КРА́СНОЕ ПО́ЛЕ** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кыят елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (мордва) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кыят исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), 3 җил тегермәне, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 922 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1957 нең 30 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 38 ир-ат; 1859 да — 425, 1897 дә — 696, 1908 дә — 863, 1920 дә — 831, 1926 да — 681, 1938 дә — 107, 1958 дә — 70, 1970 тә — 166, 1979 да — 107, 1989 да — 47, 2002 дә — 20 кеше.

**КРАСНОЖЁН** Владимир Николаевич (22.1.1958, Саратов өлкәсенең Энгельс р-ны Квасынковка а.), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (2001). 1981 елда Саратов мед. ин-тын тәмамлагач, Йошкар-Ола шәһәренең 1 нче балалар клиникасында эшли. 1987 дән Казан ашыгыч ярдәм күрсәтү хастаханәсенең оториноларингология бүлегендә. 1991 дән Казан ГИДУВының (хәзер Казан мед. академиясе) шул исемдәге кафедрасында, 2002 дән каф. мөдире, бер үк вакытта, 1997 дән Казанның 16 нчы шәһәр хастаханәсендә оториноларингология бүлеге мөдире. Хезмәтләре өске сулыш юлларын өйрәнүгә, эндоскопик ринохирургиягә карый. К. борын һәм борын яны куышлыклары авыруларын дәвалауның яңа ысулларын: борын яны куышлыкларында оксигенация һәм димефосфон б-н дәвалауны, ринохирургиядә эндоскопия ысулларын, аргеноплазмалы һәм радиохирургия ысулларын гамәлгә кертә. Дөньяда беренче булып «борынның акустик феномены»н тасвирлый. Гайморитны дәвалауда яңа ысул тәкъдим итә.

Х е з м.: Эндоскопическая ринохирургия. СПб., 2004.

**КРАСНОКА́МА РАЙОНЫ́**, БРның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1554 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Николо-Берёзовка посёлогы (Уфадан 210 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 27601 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 7721, 1979 да — 7306, 1989 да — 16660, 2002 дә — 6176 кеше. Районда 69 торак пункт, ш.и. 11 татар, 16 татар-башкорт, 3 татар-мари, 2 татар-рус авылы бар. Иң зур татар авыллары (2009): Яңа Кабан (879 кеше), Кызгау (299), Яңа Хаҗы (315). 2004/05 уку елында районның 24 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 7 сендә татар теле һәм әдәбияты фән буларак укытыла. К.р.да республика буйсынуындагы Агыйдел шәһәре урнашкан, анда 9 меңгә якын татар яши.

**КРАСНОКА́МСК** шәһәре, *Пермь краеның* көньяк-көнбатыш өлешендә (Пермь шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнбатыштарак) урнашкан. Халкы — 52,6 мең кеше (2010). Татарлар саны: 1989 да — 3031, 2002 дә — 2351 кеше. Татарлар К.та 1920 еллар ахырында Кама целлюлоза-кәгазь комб-ты төзелеше вакытында күренә башлыйлар. 1999 да мөселман дини җәмгыяте оештырыла.

**КРАСНОМА́ЙСКИЙ** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 53 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы бассейнында. 2010 елда 134 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Иске Әлмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1949 да — 162, 1958 дә — 165, 1970 тә — 239, 1979 да — 225, 1989 да — 134, 2002 дә — 143 кеше.

**КРАСНОПЕ́РОВ** Фёдор Тимофеевич (18.9.1922, Әгерҗе кантоны Иске Чыкалда а. — 31.1.2008, Свердловск өлкәсенең Сысерть р-ны Двуреченск пос.), терапевт, фтизиатр, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). 1953 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1972 дән фтизиатрия каф. мөдире, 1989 дан фтизиопульмонология каф. профессоры. Хезмәтләре ревмокардия вакытында йөрәк ритмы бозылуы мәсьәләләренә, аллергиягә, пульмонологиядә дифференциаль (бүленешле) диагноз куюга карый. К. тромбозлар һәм эмболияләр вакытында гемокоагулянт һәм антикоагулянт терапия, туберкулёзлы авыруларны дәвалауда гепарин куллануны тәкъдим итә. Татарстанда фтизиатрия һәм туберкулёз б-н көрәшү тарихы мәсьәләләрен өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Антикоагулянтная терапия сердечно-сосудистых заболеваний. К., 1962; Гемодинамика большого круга кровообращения и лёгочная вентиляция при туберкулёзе // Советская медицина. 1986. № 1.

*Әд.:* В и з е л ь А.А., А р с л а н о в Ш.Ш., Г а л и у л л и н Б.В. Профессор Фёдор Тимофеевич Красноперов // Казан. мед. журн. 1992. № 5; Всегда в кипении. К., 1996.

**КРАСНОСЕ́ЛЬЦЕВ** Николай Фомич (1845, Уфа губ. Емашовка а. — 11.9.1898, Истанбул ш.), чиркәү тарихчысы, археолог, чиркәү тарихы д-ры, (1892). Уфа руханилар семинариясен, Казан руханилар академиясен тәмамлый (1870). 1870 елда Самара руханилар семинариясендә укыта. 1871 дән Казан руханилар академиясенең литургика һәм чиркәү археологиясе кафедрасында эшли (бүленеп, 1881–82 дә Италиядә фәнни командировкада була), проф. (1884). 1889 да Новороссийск ун-тында (Одесса ш.) чиркәү тарихы профессоры. Хезмәтләре 18–19 йөзләрдә татарлар һәм Кавказдагы төрки халыклар арасындагы миссионерлык эше тарихына карый. Соловки китапханәсенең Казан руханилар академиясендә саклanучы литургик һәм кануни эчтәлектәге кульязмаларын өйрәнә.

*Әд.:* Западные миссии против татар-язычников и, особенно, против татар-магометан. К., 1872; О древней христианской архитектуре // Православный собеседник. 1874. Ч. 2–3; Древнехристианские усыпальницы в Риме и значение сделанных в них открытий для богословской науки. К., 1883; К истории православного богослужения: По поводу некоторых церковных служб и обрядов, ныне употребляющихся... К., 1889.

*Әд.:* Бердников И.С. Памяти профессора Николая Фомича Красносельцева // Православный собеседник. 1898. Ч. 2.

*Е.В.Липаков.*

**«КРАСНОСТРЕЛЕ́ЦКАЯ»**, беренче эре бөртекле диплоидлы карабодай сорты. 1965 елда Бөтенсоюз бөртекле-кузаклы һәм ярма культураларны фәнни-тикшеренү ин-тында (Орёл ш.) һәм Татарстан респ-ка тәҗрибә станциясендә Н.Н.*Петелина* тарафыннан карабодайның тетраплоидлы «Большевик» сорты серкәсенең ментораль катнашында «Казан» сорты нигезендә гибридлаштыру юлы б-н чыгарыла. Беренчел формасыннан һава һәм туфракның түбән темп-расына чыдамлылыгы, кыска срокта чәчәк атуы һәм өлгерүе б-н аерылып тора. Уңышын теләсә нинди һава шартларында җыярга мөмкин, чөнки сөрлегүгә бирешми, бөртекләренең тулысынча бер вакытта өлгерүе һәм суктырып алу мөмкинлеге б-н характерлана. Уңышы буенча стандарт («Богатырь») сорттан 1 *га* га 2,4–4,8 *ц* га югары. Күп яңа эре бөртекле сортларны булдыру өчен материал була.

Уңышы һәм бөртегенең технол. сыйфатлары югары. 1971 дән Татарстанда (Кама аръягы), Рязань һәм Тула өлкәләрендә, Чечен-Ингуш АССРда районлаштырыла. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә (1974).

**КРАСНОУФИ́МСК РАЙОНЫ́**, *Свердловск өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 2,4 мең *км*². Үзәге — Красноуфимск шәһәре (Екатеринбург шәһәреннән 224 *км* көнбатыштарак). Халкы — 71,8 мең кеше, (2010), 20 мең татар (2002). Беренче татар авыллары район терр-ясендә 16 йөздә төзелә. Хәзерге вакытта 14 татар авылы: Бишково, Олы Турыш, Югары Баяк, Куян, Кече Турыш, Яңа Бугалыш, Озёрки, Рахмангулово, Урта Баяк, Урта Бугалыш, Сызгы, Усть-Баяк, Усть-Бугалыш, Яман Елга бар. Татарларның күпчелеге район үзәгендә яши. 1917 елга кадәр һәр татар авылында мәчет, ә зуррак авылларда мәдрәсә (шуларның берсе Красноуфимск шәһәрендә) эшли. Красноуфимск өязендә 4 татар газетасы нәшер ителә. Совет чорында кайбер татар авылларында татар мәктәпләре була. К.р.ның өч мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла; ике мәктәптә факультатив дәрес буларак керә. 1989 да Красноуфимскида татар халык театры, 1990 елдан «Кызыл яр» Татар мәдәни үзәге, 1997 дән татар милли-мәдәни автономиясе эшли. К.р.н Татарстан б-н, башлыча, мәдәният өлкәсендәге төрле проектлар бәйләп тора.

*Әд.:* Мулланур ов М.М. История деревни Средний Бугалыш Красноуфимского района. Красноуфимск, 1996; Уездные столицы: Ирбит, Алапаевск, Камышлов, Красноуфимск. Екатеринбург, 2002; Чагин Г.Н. Народы и культура Урала в XIX–XX вв. Екатеринбург, 2002.

**КРАСНОЩЁКОВА** Екатерина Емельяновна (1.12.1928, Арча кантоны Петровка а.), микробиолог, мед. фән. д-ры (1986). 1952 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, БАССРның Туймазы р-нында табиб-эпидемиолог, 1953 тән сан.-бактериология лаб-ясе мөдире. 1956 дан Казан ГИДУВының микробиология кафедрасында. 1957–87 дә Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-ты лаб-ясе бактериологы, 1969 дан микробиологлар төркеме җитәкчесе. Хезмәтләре ярада йогышлы авыруларны микробиология күзлегеннән өйрәнүгә карый. «Травматология һәм ортопедиядә нурлар куллану» дигән хезмәте өчен СССР ВДНХсының дипломы һәм бронза медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Новая среда для выделения стафилокока при смешанной инфекции // Вопросы травматологии и ортопедии. К., 1960 (автордаш); Организация помощи и лечение ортопедо-травматологических больных // Тр. Казан. НИИТО. 1965. Т. 11.

**КРАСНОЯ́РСК КРАЕ́**, РФдә. Көнчыгыш Себердә, башлыча, Енисей елгасы бассейнында урнашкан. 1934 елда оештырыла. Мәйданы — 2339,7 мең *км*². Үзәге — Красноярск шәһәре. Халкы — 2894 мең кеше (2010), 2002 дә 44,4 мең татар (1959 да — 40 мең, 1970 тә — 46,5 мең, 1979 да — 50 меңләп, 1989 да — 49,5 мең кеше). Татарлар Красноярск (1989 да — 11,6 мең кеше), Лесосибирск (4,3 мең), Норильск (3,8 мең), Назарово (1,1 мең), Канск (1,2 меңләп), Минусинск (900 кеше), Шарыпово (900), Енисейск (700), Игарка (600) шәһәрләрендә, ш.у. Пировский (3,4 мең кеше), Казачин (1,3 мең), Зур Морты (1,2 мең), Ужур (1,2 мең), Бирилюссы (900), Олы Улуй (200 дән артык кеше) р-нnarында яши. Йомышлы татарлар Красноярск шәһәрендә 17 йөзнең 1 нче яртысында күренә башлый, 18 йөз ахырында алар крайны үзләштерүгә керешәләр. Транссебер магистрале төзелеше (1891–1916), Столыпин аграр реформасын үткәрү (1906) һәм Идел буендагы 1921–22 еллардагы ачлык чорында анда татарлар саны күпкә арта. 1917 гә кадәр Красноярскида мәчет һәм мөселман дини мәктәбе (икесе дә 1908 дә ачыла) эшли. 1917 елгы рев-ция вакыйгалары татарлар тормышын тамырдан үзгәртә: партия органнары структурасында һәм халык мәгарифе системасында татар секцияләре оештырыла. 1924 елгы мәгълүматларга караганда, К.к. терр-ясендә 39 башлангыч, 3 тулы булмаган татар урта мәктәбе эшли. 1941 дә Енисейск шәһәрендә татар пед. уч-щесе ачыла. 1930 елларга кадәр Красноярскида *Сабан туе* бәйрәме үткәрелә, 1960–80 елларда шәһәргә Татарстаннан иҗат коллективлары килеп тора. Хәзерге вакытта крайда 5 татар иҗтимагый оешмасы: «Яңарыш» татар милли-мәдәни автономиясе (1998), Красноярскида «Чишмә» татар-башкорт мәдәни үзәге, «Дуслар» татар милли-мәдәни оешмасы (2002), Лесосибирскида «Ватан» татар мәдәни агарту үзәге (1991), Железногорск шәһәрендә «Ислам мәдәни үзәге» (1998) эшли. Крайның берничә торак пунктында: «Чишмә» (Красноярск) һәм «Дуслар» (Лесосибирск), Железногорскида фольклор иҗат коллективлары бар. 2004 тә крайда 9 мөселман берләшмәсе исәпләнә, ш.и. К.к. мөселманнарының бердәм дини идарәсе (2002 дән); 11 мәчет, ш.и. Енисейскидагы таш мәчет (19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге) эшли. 2003 тән К.к.ның 14 шәһәрендә һәм авылларында Сабан туе бәйрәме яңадан үткәрелә башлый. 2003 тән Красноярскида «Нур» г-тасы рус һәм татар телендә нәшер ителә. Казачин р-нының Отношка авылы мәктәбендә татар теле фән буларак, Бирилюссы р-нының Арефьево, Зур Морты р-нының Югары Казанка, Пировский р-нының Пировский, Олы Улуй р-нының Елга, Казачин р-нының Гамурино авыллары һәм Лесосибирск мәктәпләрендә татар теле факультатив дәресләрдә өйрәнелә. 2001 дә Красноярск һәм Казан шәһәрләре арасында хезмәттәшлек турында килешү төзелә. К.к.да техник фән. д-ры Л.Г.Шәймәрданов, СССРның атказ. спорт остасы И.Г.*Фәйзуллин*, Дан орденының тулы кавалеры М.Н.*Мөхәммәтҗанов* туган. Язучы Р.Х.*Солнцев*, техник фән. д-рлары Н.Х.*Заһиров* һәм Р.Х.*Йосыпов*, математик Ш.Г.*Даутовның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге К.к. б-н бәйле.

**КРА́СНЫЙ БАРА́Н** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 36 *км* көньяктарак, Бәрән елгасы буенда. 2010 елда 366 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1685 тән мәгълүм; беренче исеме — Балчыклы, 1920 еллар уртасына кадәр Крещёный Баран буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында кәшәнә, Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1873 тә ачыла, 1908 дән — чиркәү-приход мәктәбе), 3 җил тегермәне, 2 тимерчелек, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 976 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 395, 1897 дә — 706, 1908 дә — 830, 1920 дә — 1012,

1926 да — 963, 1938 дә — 818, 1949 да — 610, 1958 дә — 876, 1970 тә — 805, 1979 да — 697, 1989 да — 501, 2002 дә — 413 кеше.

**КРА́СНЫЙ БИСТӘСЕ́**, Казанның көнчыгыш чигендә, Казансу ярында 17 йөздә барлыкка килгән бистә. Вахитов р-ндагы хәзерге Зур һәм Кече Кызыл, Карл Маркс, Горький, Пушкин, Гоголь урамнары урынында калкулыкта урнашкан. Атамасы «матур» мәгънәсен аңлаткан «красный» сүзеннән алынган. Бистә терр-ясендә эре дворян утарлары төзелгән. 18 йөздән шәһәр чикләренә керә.

*Әд.:* Бикбулатов Р., Мустафин Р. Казань и её слободы. К., 2001.

**«КРА́СНЫЙ БОЕ́Ц»** («Кызыл сугышчы»), газета; к. «*Татарская беднота*».

**КРА́СНЫЙ БОР** авылы, Әгерже р-нында, Әгерже шәһәреннән 91 *км* көньяктарак, Түбән Кама сусаклагычындагы пристань. 2010 елда 1443 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча руслар — 63%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә. Пароходлар конторасы бинасы — 19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 1680 нән мәгълүм; 1920 еллар башына кадәр Пьяный Бор исемен йөртә. Рев-циягә кадәр Тихоновский буларак та билгеле. 1860 ларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, аучылык, балык тоту, урман эшкәртү, тимерчелек, йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә, көнлекче булып яллана. 1887 елгы мәгълүматларга караганда, К.Б.да волость идарәсе урнаша; чиркәү, малайлар өчен чиркәү-приход мәктәбе, кыз балалар земство мәктәбе, ашлык пристане, пароходчылык конторасы; базар, ярминкә (елга өч тапкыр) эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 3464 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Вятка губернасының Алабуга өязе Пьяный Бор волосте үзәге, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсенә керә, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор р-ны үзәге, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерже р-нында. Халык саны: 1859 да — 2039, 1877 дә — 1917, 1887 дә — 1917, 1905 тә — 2180, 1920 дә — 2582, 1926 да — 2057, 1938 дә — 2208, 1949 да — 1926, 1958 дә — 2254, 1970 тә — 1702, 1989 да — 1588, 2002 дә — 1601 кеше. Авылның элеккеге исеме б-н археол. культура (к. *Пьянобор культурасы*) атала.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КРА́СНЫЙ БОР** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак; Кама елгасыннан 4 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 43 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Афонас волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 178, 1938 дә — 270, 1949 да — 218, 1958 дә — 127, 1970 тә — 143, 1979 да — 107, 1989 да — 48, 2002 дә — 30 кеше.

**КРА́СНЫЙ БОР РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1930 ның 10 августында оештырыла. Үзәге — Красный Бор авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе — Вятка губернасының Алабуга өязенә, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. Оештырылган көннән К.Б.р.на 29 авыл советы, 92 торак пункт керә, 34651 кеше (татарлар — 20409, руслар — 9978, башка халыклар — 4264) яши. 1940 та районның мәйданы — 1201 *км*$^2$, халкы — 36,9 мең кеше, 26 авыл советы, 72 торак пункт була. Тора-бара адм. берәмлекләр саны кими: 1956 да районда — 19, 1960 та 11 авыл советы кала. 1960 ның 28 октябрендә К.Б.р. бетерелә, терр-ясе Әгерже р-нына бирелә.

**КРА́СНЫЙ ВАЛ** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Болгар – Базарлы Матак автомобиль юлы буенда. 2010 елда 209 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 19 йөз башында нигез салына. 1930 еллар уртасына кадәр Молоствовка исемен йөртә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 3 тегермән, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 153,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Трёхозёрский волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр Куйбышев р-нында. Халык саны: 1815 тә — 139 ир-ат; 1859 да — 384, 1897 дә — 583, 1908 дә — 717, 1920 дә — 682, 1926 да — 590, 1938 дә — 423, 1949 да — 267, 1970 тә — 290, 1979 да — 188, 1989 да — 241, 2002 дә — 226 кеше.

**«КРА́СНЫЙ ВО́ИН»** («Кызыл сугышчы»), кызылармиячеләр газетасы. Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе Революцион Хәрби Советы сәяси бүлеге органы. 1918 елның 24 сентябреннән 1919 ның 9 июленә кадәр Вятка Аланы, Сарапул, Казан, Арча, Ижевск, Екатеринбургта нәшер ителә, барлыгы 230 саны чыга. 1918 нең 27 декабренә кадәр «Известия II армии» дип атала. Мөхәррирләре — Л.Авенир, А.И.Парамонов. Төп бүлекләре: «Советлар Россиясендә», «Чит илләрдән хәбәрләр», «Кызыл фронтларда», «Дошманнар станында». Актив авторлары — Н.Алексеев, Н.Антипов, Н.Бутенин, М.Зубков, А.Иванов, П.Ионов, И.Йосфи, С.Коричев, А.Кучкин, Л.Лукин, С.Оков, М.Солтангалиев, Ф.Таипов, В.Шәфигуллин, А.Эшкинин. 1919 ның апрель–май айларында газета төп игътибарны адмирал А.В.Колчак армиясе частьләре б-н көрәшкә юнәлтә. «Колчак нәрсә китерә?», «Колчак станында», «Колчак скипетоды астында» рубрикаларында аның хәрби-сәяси планнары, яуланган җирләрдәге терроры турында сөйләнә. Хәрби хәрәкәтләрдән тыш газета тыл тормышын да киң яктырта. 1919 ның апрель–июнендә рус телендәге басма б-н беррәттән «К.в.» татар, чуаш, мари, удмурт телләрендә дә чыга башлый, аларны бастыру сәяси бүлекнең милли секцияләре өстенә йөкләнә. Бу чорда «*Ярлы*», «*Эш*», «*Йошкар кәче*» исемле Казан г-талары чыгудан туктап тора, ә аларның редакцияләре «К.в.»ны чыгаруга мобилизацияләнә. Рус телендәге сәяси мәкаләләр, армия боерыклары һәм рәсми хәбәрләрнең тәрҗемәләреннән тыш «К.в.»ның милли чыгарылышлары үз журналистларының язмаларын, кызылармиячеләр хатларын һ.б. бастыра. Ш.у. к. «*Кызыл көрәшче*».

*Әд.:* Негробов А. На фронтах гражданской войны // Большевистская печать. 1935. № 8–9; Литвин А.Л. Из истории борьбы местной печати за победу на Восточном фронте в 1918–1919 гг. // Из истории возникновения и развития партийно-советской печати Удмуртии. Ижевск, 1964; Насыров Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970; Сергеев М.Т. Возникновение и развитие печати Марийской АССР. Йошкар-Ола, 1971.

*Т.М.Насыйров.*

**КРА́СНЫЙ ВОСТО́К** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы бассейнында. 2010 елда 11 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Олы Тархан волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 118, 1958 дә — 112, 1970 тә — 117, 1979 да — 99, 1989 да — 54, 2002 дә — 24 кеше.

**«КРА́СНЫЙ ВОСТО́К»**, иҗтимагый-сәяси газета. Башта (1920 елның 25 февраленнән 10 сентябренә кадәр) Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы («Красная Армия» исемен йөртә), соңрак (1920 нең 13 сентябреннән 29 декабренә кадәр) — Республика Революцион Хәрби Советы сәяси идарәсе каршындагы Көнчыгыш бүлек органы. Казанда рус телендә 31 саны нәшер ителә. Мөхәррире — И.Терегулов. Газетада Г.Арсланов, С.Атнагулов, М.Борындыков, М.Зубков, А.Краснов, С.Сәетгалиев, М.Терегулов, Ш.Усманов, И.Фирдәвес, С.Чавайн, Г.Чудаков хезмәттәшлек итәләр. «К.в.»ның соңгы санында Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең оешу тарихы, структурасы һәм эшчәнлеге турында мәкалә басыла.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Насыров Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970; Сбитнева А.А. Литература для красноармейцев нерусской национальности: Из истории деятельности политотделов Красной Армии на Восточном фронте в годы гражданской войны // Военно-ист. журн. 1973. № 4; Гиззатуллин И.Г. Защищая завоевания Октября. Центральная мусульманская военная коллегия. 1918–1920. М., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**«КРА́СНЫЙ ВОСТО́К» БАСМАХАНӘСЕ́**, к. «*Шәрекъ матбагасы*».

**КРА́СНЫЙ КЛЮЧ** (Чургат) посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 7 *км* төньяктарак, Кама елгасы буенда. 2010 елда 2815 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча руслар — 51%, татарлар — 41%) яши.



В.А.Крат.

Кошчылык ф-касы (2004кә кадәр). Урта мәктәп, музыка мәктәбе, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. Мәчет. Алабуга сәүдәгәре И.И.Стахеев утары — 19 йөзнең 1 нче яртысы архит-ра ядкәре. К.К. элек генерал Крыжановскийның Святой Ключ утары буларак билгеле, соңрак бу җирләргә Стахеев хуҗа була. 1919 да утар җирлегендә «Святой Ключ» (1925 тән — «Красный Ключ») с-зы оештырыла, аның каршында посёлок төзелә. 1920 гә кадәр К.К. Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонас волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 20, 1938 дә — 496, 1958 дә — 724, 1970 тә — 1566, 1979 да — 2804, 1989 да — 3144, 2002 дә — 2782 кеше. Посёлок янында ял итү базасы, балалар өчен ял итү лагерьлары, Түбән Кама пр-тиеләре һәм учреждениеләренең санаторийлары урнашкан.

**«КРА́СНЫЙ КЛЮЧ»**, Түбән Кама р-нындагы кошчылык ф-касы. 1930 елда «Красный ключ» с-зы җирлегендә (1925 кә кадәр «Святой ключ», 1919 да төзелә) кошчылык хуҗалыгы буларак оештырыла. 1957 елда 7 колхоз: «На штурм», «12 лет Октября», «Вторая пятилетка», «Восходящая Заря», «Победа», «8-е Марта», «Колос» берләштерелә. 1965 тә бу колхозларны яңадан аералар, хуҗалык кошчылык з-ды итеп үзгәртелә, 1974 тә — кошчылык ф-касы, 2002 дә — «Красный Ключ» кошчылык ф-касы» АҖ. Үзәк утары — Красный Ключ посёлогы. 2003 елда АҖдә эшләүчеләр саны — 674 кеше. А.х. файдалану җирләренең мәйданы — 529 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 228 *га*. 1960–80 елларда кошчылык ф-касы берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЛКСМ ҮК, ВЦСПС, РСФСР ЮС Президиумы, РСФСР МС, СССР, РСФСР А.х. министрлыкларының күчмә Кызыл байраклары, Мактау грамоталары, Мактау дипломнары, Россия, республика, халыкара күргәзмә һәм конкурслар дипломнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

Хуҗалык эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Соц. Хезмәт Герое исеме — 1 кешегә; ТРның мактаулы исемнәре 10 кешегә бирелә; Ленин ордены — 1, Хезмәт Кызыл Байрагы — 1, Халыклар дуслыгы — 1, 3 нче дәрәҗә Дан ордены б-н — 1; медальләр б-н — 13 кеше, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н — 3; ТР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н 2 кеше бүләкләнә. Пр-тиенең беренче җитәкчесе Д.И.Недотёпин (1919 дан). Хуҗалыкның төрле еллардагы җитәкчеләре: Г.А.Абросимов (1921–29), М.М.Шабашвили-Зусманович (1931–48), И.И.Шишонин (1948–58), В.М.Мартынов (1960–63), Г.Н.Чигвинцев (1963–76), А.А.Ишелин (1977–88). 2004 тә фабрика банкротлыкка чыга. Аның җирлегендә Түбән Кама шәһәренең ат спорты мәктәбе урнаша.

*И.Н.Афанасьев.*

**КРА́СНЫЙ ЯР РАЙОНЫ́**, *Самара өлкәсендә*. Мәйданы — 2479 *км²*. 1965 елның 12 гыйнварында оештырыла. Үзәге — Красный Яр авылы (Самара шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 52 мең кеше (2010), 1703 татар (2002). К.Я.р-нында татарлар, башлыча, Яңа Урайкино авылында (18 йөз башында нигез салына; 204 кеше) һәм Угловой посёлогында (1910–12 елларда нигез салына; 415 кеше) яши. Ике торак пунктта да мәчет (Яңа Урайкинода 1999 дан, Угловойда 1997 дән) эшли. 2000 дә Угловой посёлогында беренче тапкыр Сабан туе бәйрәме үткәрелә. 2003 тә К.Я.р. тарих музеенда «Аксак Тимер, Туктамыш һәм Алтын Урда» дигән күргәзмә оештырыла.

*Ю.В.Брыков.*

**КРАТ** Владимир Алексеевич (21.7.1911, Сембер ш. — 2.6.1983, Ленинград), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1936), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1972). 1932 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә эшли. 1938 дән СССР ФА Баш астрономик обсерваториясенең (Ленинград өлкәсенең Пулково ш.) Кояш физикасы бүлеге мөдире, 1964–79 да директоры. Совет баллон астрономиясенә нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре тыгыз урнашкан икеле йолдызларны, Кояш физикасын һәм космогонияне өйрәнүгә карый. 1944 тә К. тотылучан йолдызларның җентекле төгәл классификациясен төзи. Кальцийның H һәм K сызыкларында күзәтелә торган хромосфера факелларының түбәнге хромосферада (0 дән 1 мең *км* га кадәр биеклектә) урнашуын һәм аларда тагын да кайнаррак газның чикле биеклекләрдәге оешмалары булуын билгели (1960, 1963). 1945 елдан Кояш тотылу мәгълүматлары буенча Кояш таҗының өзлексез спектрында энергия бүленеше б-н Кояш дискы үзәгенең спектрындагы энергия бүленеше бер үк икәнлеген ачыклый. Кояшны күзәтү өчен беренче стратосфера обсерваториясе төзү б-н җитәкчелек итә. К. исеме кече планеталарның берсенә бирелә. Өч орден, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фигуры равновесия небесных тел. М.–Л., 1950; Баллонная астрономия. Л., 1972 (автордаш); Стратосферная астрономия. Л., 1976 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**КРАТ**, 3036 номерлы кече планета. 1937 елда Кырымдагы Симеиз обсерваториясендә ачыла һәм В.А.*Крат* исеме б-н атала. К.ның Кояштан ераклыгы 2,9 дан 3,5 а.б. аралыгында үзгәрә. Кояш тирәли әйләнү периоды 5,8 ел.

**КРАХМА́Л-ПА́ТОКА ҖИТЕШТЕРҮ́**, азык-төлек җитештерү сәнәгате тармагы. Крахмал, мальтоза һәм крахмал патокасы, квас ачыткычы концентраты, арыш салаты, саго эшләп чыгара. Эшләүчеләр саны — 196 кеше (2010).

Элек төбәктә халык кәсебе буларак яшәп килә. Крахмал-патока з-длары 1843 елда Казанда, 1881 дә Столбище һәм 1885 тә Дәүләки авылларында нигезләнә. 1888 дә заводларда 57 кеше эшли, җитештерү күләме 50 мең сумнан арта, 1906 да 200 мең сум тирәсе тәшкил итә. 1918–20 дә А.В.Соломин, Е.С.Смоленцев, Ю.П.Шмелёв заводлары национализацияләнә һәм Татпищетрест (1931 гә кадәр саклана) составына кертелә.

1966 да «Таткрахмалпатока» ҖБ оештырыла, аның составына Казан мальтоза з-ды (баш пр-тие), Арча крахмал з-ды (1964 тә нигезләнә), Князево крахмал-патока з-ды (хәзерге Тукай р-ны Князево а., 1971), Лаеш крахмал з-ды (1974), Куралово мальтоза з-ды (Югары Ослан р-ны Куралово а., 1987) керә. 1996 дан АҖ, кукуруз (елга 3 мең *т*), арпа (1000 *т*), арыш (12 мең *т*) эшкәртү, мальтоза патокасы (3 мең *т*), квас ачыткычы концентраты (10 мең *т*), саго (600 *т*) җитештерү, арыш, арпа, бодай үстерү (мәйданы 1800 *га*, сөрүлек җирләр 1500 *га*) цехлары итеп үзгәртелгән Казан һәм Куралово мальтоза, Лаеш крахмал з-длары җирлегендә төзелә.

1996 дан пр-тие төп продукцияне эшләп чыгару өчен ферментланган коры арыш салаты һәм чимал арпа салаты җитештерә; Халыкара «Сыра һәм эчемлекләр. 21 нче гасыр» тикшеренү үзәге б-н хезмәттәшлек итә. 2008 дә квас ачыткычы концентраты җитештерүнең яңа технологиясе гамәлгә кертелә. Нәтиҗәдә, продукция чыгару арта, аның сыйфаты яхшыра.

«Таткрахмалпатока» АҖ продукциясен Россия һәм якын чит илләр азык-төлек җитештерү сәнәгатенең икмәк пешерү, кондитер, сыра, алкогольсез эчемлекләр җитештерү тармаклары пр-тиеләренә (барлыгы 400 дән артык, ш.и. 350 даими кулланучы) сата.

Пр-тие җитәкчеләре: Х.Г.Сафиуллин (1966–76), А.Н.Никифоров (1976–84), А.М.Айбатов (1984–87), Ю.К.Кулемин (1987–89), А.И.Прокопьев (1989 дан).

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. П., 1914; Н а з и п о в а К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976.

*М.Ж.Гаитов, Р.З.Мансуров.*

**КРА́ЧКАЛАР** (Sterninae), акчарлак кошлар семьялыгыннан кошлар ассемьялыгы. 43 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка, Төньяк-көнбатыш Африкада таралган. Диңгез, елга һәм күл ярлары буенда яши. ТР терр-ясендә 5 төре очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 20–50 *см*, авырлыгы 600–700 *г*. Канатлары озын, очланган. Койрыгы уемлы. Томшыгы нәзек, озын. Аяклары кыска, көчсез. Алгы бармаклары арасында зур булмаган йөзгеч ярылары бар. Елга крачкасы зур һәм уртача елгаларның комлы сайлыкларында һәм утрауларында колонияләр булып оялый; кече крачка — оя коручы күчмә төр. Сусакалгычлар төзелгәннән соң сирәк күренә; ике төре дә аксыл төстәге каурый капламы һәм башындагы «бүрекчеге» б-н үзенчәлекле. Кара крачка, колонияләр булып, үсемлекләр күп-

ләп үскән күл һәм сазлыкларда, еш кына акчарлаклар б-н бергә яши. Ак канатлы крачка — ак койрыклы, аксыл-соры канатының алгы чите ак, үсемлекләр күпләп үскән күлләрдә, түмгәкле сазлыкларда оялый, Ык елгасы түбәнлекләрендә колонияләр хасил итә. Ак яңаклы крачка аксылрак төсе, ак яңагы һәм ияге б-н аерыла. Республика терр-ясеннән әлеге төр ареалының төньяк чиге уза. К. күбесенчә үсемлекләр күпләп үскән зур күлләрдә һәм сусаклагыч ярлары буенда яши. Бу кошлар берничә дистә пар булып оялый, еш кына башка К.лар б-н бергәләп колонияләр хасил итә. Майдан августка кадәр очрый. Кара тимгелле 2–4 көрән кызыл яки коңгырт-көрән йомырка сала. Кош балалары июнь–июль башында чыга. Вак балыклар, кысласыманнар, бөҗәкләр б-н туклана. Кече крачка һәм ак яңаклы крачка ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КРАЧКО́ВСКИЙ** Игнатий Юлианович (4.3.1883, Вильнюс ш. — 24.1.1951, Ленинград), шәркыятьче галим, Россия ФА академигы (1921), Россиянең Гарәп мәдәниятен өйрәнү мәктәбенә нигез салучыларның берсе. 1905 елда Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп, 1908–10 да Сүрия һәм Мисырда фәнни командировкада була), 1918 дән проф. 1918 дә СССРда Гарәп теле һәм әдәбияты белгечләре ассоциациясен оештыруны башлап йөрүче һәм ассоциациянең җитәкчесе. Хезмәтләре Россия һәм чит илләрдә шәркыять белеме тарихы, шәрекъ мөселман илләре тарихы һәм географик әдәбияты, классик һәм хәзерге заман гарәп теле, әдәбияты, тарихы һәм мәдәнияте өлкәсенә карый. *Коръәнне* рус теленә тәрҗемә итә (М., 1963). Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Абу-л-Фарадж ал-Вава Дамасский. Материалы для характеристики поэтического творчества. П., 1914; Над арабскими рукописями. М.–Л., 1949; Очерки по истории русской арабистики. М.–Л., 1950; Введение в эфиопскую филологию. М.–Л., 1955; Избр. соч.: В 6 т. М.–Л., 1955–60.

*Әд.:* Игнатий Юлианович Крачковский. М.–Л., 1949; Б е л я е в В.И., В и н н и к о в И.Н. Память академика И.Ю.Крачковского // Палестинский сборник. Л., 1954. Вып. 1; Д о л и н и н а А.А. Невольник долга. СПб., 1994.

**КРАШЕНИ́ННИКОВ** Михаил Алексеевич (17.2.1939, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1993), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004), 1964 елда Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия-технол. ин-тының филос. кафедрасында. 1969 елдан КПССның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда бүлеге лекторы. 1979–89 да Казан ун-тының фәнни коммунизм кафедрасында (бүленеп, 1980–82 дә Әфганстан Демократик Респ-касының мәгариф министры киңәшчесе). 1989–91 дә Кама пед. ин-тының (Чаллы ш.) иҗтимагый фәннәр кафедрасында. 1991–93 тә Казан технол. ун-тының Түбән Кама ф-лында шул ук исемдәге каф. мөдире. 1993–95 тә Казан технол. ун-тының социол. һәм тарих каф. профессоры. 1995 тән Казан энергетика ун-тының филос. каф. мөдире. Хезмәтләре рев-ция теориясе, хакимият проблемалары, фәлсәфи тикшеренүләр методологиясенә карый.

Х е з м.: Субъективный фактор революции. К., 1974 (автордаш); Политическая власть рабочего класса. К., 1990; Социология: Курс лекции. К., 1990 (автордаш).

**«КРӘСТИЯ́Н ГАЗЕТЫ́»**, газета; к. «*Колхоз газеты*».

**«КРӘСТИЯ́Н ЖУРНАЛЫ́»**, журнал; к. «*Сабанчы*».

**«КРӘСТИЯ́Н ИТТИФАГЫ́»**, к. «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы*» эше.

**КРӘСТИЯ́Н РЕФО́РМАСЫ** (1861), Россиядә *крепостнойлык хокукын* юкка чыгарган һәм *капитализм* үсешен тизләткән законнар системасы. Реформаның төп сәбәбе — феодаль-крепостнойлык системасының кризисы. Беренче хөкүмәт программасы император Александр II нең 1857 елның 20 ноябрендә Вильно генерал-губернаторы В.И.Назимов исеменә җибәрелгән рескриптында бәян ителә. Анда, барлык җирләр алпавыт милке булып сакланган очракта да, крәстияннәрнең шәхси бәйлелеген юкка чыгару мәсьәләсе куела; крәстияннәргә билгеле бер күләмдә җир бүлеп бирелергә тиеш була, аның өчен оброк түләү яисә барщинаны үтәү карала, ә вакытлар узу б-н каралтыларны сатып алу хокукы бирү дә күздә тотыла. Рескриптта ш.у. һәрбер губернада алпавытлардан торган «Алпавыт крәстияннәренең көнкүрешен җайлау һәм яхшырту турында» кайгыртучы ком-тлар төзергә тәкъдим ителә. 1858 ел дәвамында андый ком-тлар Россиянең барлык губерналарында, ш.и. Казан губернасында да оештырыла. Аларның эшчәнлегендәге төп нәтиҗә «Алпавыт крәстияннәренең көнкүрешен яхшырту турында положениеләр» проектлары булырга тиеш дип санала. Казан губернасында андый ком-т булдыруга рескрипт 1858 нең 1 апрелендә бирелә, формаль яктан ком-т 11 сентябрьдә төзелә, 1 ноябрьдә эшкә керешә, 1859 ның 11 апрелендә бетерелә. Рәисе — губерна дворяннары башлыгы И.Х.Нейков. Ком-т составына хөкүмәттән 2 әгъза (гвардия поручигы В.М.Молоствов һәм коллегия советнигы В.В.Трубников) һәм өязләрдән 2 шәр вәкил: Казан өязеннән — генерал-майор А.Л.Корсаков, камер-юнкер А.Г.Осокин, канд. — коллегия советнигы А.Н.Бекетов; Козьмодемьянск һәм Чабаксар өязләреннән — дворяннар башлыгы М.Н.Арцыбашев, коллегия советнигы П.И.Логинов; Лаеш өязеннән — статский советник М.И.Мельников, коллегия асессоры П.А.Костливцев, канд. — полковник В.А.Соловцов; Мамадыш һәм Чистай өязләреннән — коллегия советнигы В.А.Жуков, подпоручик Н.Б.Рыбушкин; Зөя өязеннән — статский советник И.А.Сокольский, гвардия капитаны Н.И.Мергасов, канд. — надворный советник Н.В.Тиле; Спас өязеннән — полковник И.П.Умов, ротмистр Е.М.Наумов, канд. — титуляр советник Г.М.Толстой; Тәтеш өязеннән — статский советник И.Г.Горемыкин, коллегия советнигы К.И.Крамер, канд. — Н.А.Плотников; Цивильск һәм Ядрин өязләреннән — дворяннар башлыгы Ф.В.Матюнин, генерал-майор П.Н.Арцыбашев, канд. — коллегия советнигы А.А.Акчурин керә. Комитетка үз биләмәләрендә хуҗалык эшчәнлеге һәм гражданлык хезмәте, ш.и. сайлаулар буенча да тәҗрибәсе булган кешеләр керә. Алар Казан дворяннар җәмгыятендә абруй казанган һәм өяз администрациясе арасында йогынтыга ия булган чиновниклардан исәпләнә. Казан дворяннары губерна ком-ты тарафыннан әзерләнгән нигезләмә проекты 9 бүлектән тора. Проект буенча нигезләмә өч ел эчендә гамәлгә ашырылырга тиеш була, аннан соң крәстияннәрнең 12 еллык мәҗбүри бурычлылыкта булуы күздә тотыла. Яшәп килүче утарлар составына кергән барлык җирләр (ш.и. андагы җир асты байлыклары, сулар) алпавытларның кагылгысыз милке булып кала. Крәстиян каралтысының зурлыгы 600 кв. сажин җир дип билгеләнә һәм 200 сумга бәяләнә. Крәстияннәр каралты-кураларны алпавытка тиешле хакны берьюлы түләү бәрабәренә сатып ала алганнар. Сатып алганга кадәр алар алпавытка акчалата яки крәстиян каралтысы бәясенең 3 әр %ы күләмендә эшләп түләргә тиеш булалар. Мәҗбүри бурычлы крәстияннәргә алпавытлар сөрүлек һәм болын җирләрен биреп торалар. Аз җирле биләмәләрдә крәстияннәргә биләмәдәге барлык сөрүлек җирләрнең яртысы, уртача һәм күп җирле биләмәләрдә исәпкә кергән һәр җан башына 1,5 дис. бирелә. Болыннарны бүлеп бирү, биләмәнең төрен аермыйча, җан башына 1,25 дисәтинәдән карала. Крәстияннәрнең бурычлары өч төрле була: акчалата (оброк), натуралата (барщина) һәм катнаш (оброк һәм барщина). Һәр дисәтинә җир өчен крәстияннәр алпавытка ел саен 4,5 сум акча түләргә, яисә ирләр җәй көне 11 көн һәм хатын-кызлар ел буена 10 көн бушка эшләргә тиеш дип билгеләнә. Алпавыт хезмәтчеләре крепостной бәйлелектән 12 елдан соң йолым түләп (ирләр өчен 120 дән 200 сумга кадәр, хатын-кызлар өчен 60 тан 100 сумга кадәр) котыла. Алпавыт үз биләмәсенең тулы хуҗасы һәм авыл җәмгыятенең башлыгы булып кала. Казан дворяннары губерна ком-тында 5 кешенең: Арцыбашев, Осокин, Молоствов, Трубников һәм Казан губернаторы П.Ф.Козляниновның фикере өстенлек итә. Казан дворяннары проекты иң реакционнардан санала. Редакция комиссияләренә Казан губернасыннан И.А.Сокольский һәм И.П.Умов сайлана.

1861 нең 19 февралендә Александр II Крепостнойлык хокукын юкка чыгару турында манифестка һәм 17 документтан торган «Крепостнойлык бәйлелегеннән чыккан крәстияннәр турындагы 19 февраль нигезләмәсе»нә кул куя. Крәстияннәр шәхси ирек һәм үз мөлкәтләреннән теләгәнчә файдалану хокукы ала. Алпавыт җирләре аларның үз милке булып кала, әмма алар крәстияннәргә йолым бәрабәренә даими файдалану өчен басу җирләрен бүлеп бирергә тиеш булалар. Басу җирләренең һәм бурычларның күләмен устав грамоталарында тәгаенләү күздә тотыла, аны эшләү алпавытларга тапшырыла.

Казан губернасында *алпавыт крәстияннәренең* саны артык күп булмый (1857 дә кре-

постнойлар барлык категориядәге крәстияннәрнең 14 % ка якынын, ягъни 212851 кеше тәшкил итә). Кабул ителгән «Крәстияннәр турында гомуми нигезләмә» буенча Казан губернасында җир кара туфраклы булмаган һәм кара туфраклы полосаларга аерып карала. Һәр полоса иң зур һәм иң кечкенә имана җирләренә бүленә: Ядрин, Козьмодемьянск, Зөя, Тәтеш, Цивильск өязләре, Лаеш, Мамадыш һәм Чабаксар өязләренең бер өлешендәге (Идел елгасының уң ягы) кара туфраклы полоса өчен иң зур имана җире — 3 дис. 1200 кв. сажин, иң кечкенәсе — 1 дис. 400 кв. сажин, Спас һәм Чистай өязләрендә иң зур имана җире — 4 дис., иң кечкенәсе — 1 дис. 700 кв. сажин; Казан, Царёвококшайск өязләре, Лаеш, Мамадыш, Чабаксар өязләренең бер өлешендәге (Иделнең сул ягы) кара туфраклы булмаган полоса өчен иң зур имана җире — 4 дис., иң кечкенәсе 1 дис. 400 кв. сажин дип билгеләнә. Крәстияннәргә зур имана җире, аеруча уңдырышлы туфраклы урыннардан, бик сирәк бирелә. Реформаны гамәлгә ашыру барышында Казан губернасында алпавыт җирләре мәйданы 11,6 % ка арта (668 меңнән 745,8 мең дис.гә кадәр), җан башына уртача крәстиян имана җире 3 тән 2,7 дис.гә кими: Цивильск өязендә ул 1,4 дис., Чабаксар өязендә — 1,8 дис., Мамадыш өязендә — 1,9 дис., Зөя өязендә — 3,4 дис., Казан өязендә 3,5 дис. тәшкил итә. Тулаем алганда, губернада алпавыт крәстияннәренең имана җирләре өлеше 23,6 % исәпләнә. Казан губернасы алпавыт крәстияннәренең үзләренә бирелгән җирләр өчен түләве 1854–58 елгы бәяләр буенча 3,4 млн. сумнан артмаска тиеш булса да, алар 6,8 млн. сум түлиләр. Россиянең Үзәк Европа губерналары арасында Казан губернасы имана җирләрен бүләккә алган крәстияннәр саны буенча алдагы урыннарның берсендә тора (бирелә һәр төбәк өчен билгеләнгән иң зур имана җиренең 1/4 енә тигез өлеш күздә тотыла, ул алпавытлар тарафыннан крәстияннәргә бүләк ителә). Крәстияннәрне азат итү шартлары шулкадәр гаделсезлеккә корыла, хәтта күп кенә урыннарда крәстиян чуалышлары кабынып китә; аларның кайберләрен бастыру өчен регуляр гаскәр кертелә (к. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы*).

Чыг.: Положение об улучшении быта помещичьих крестьян Казанской губернии. К., 1859.

*Әд.:* Ч е р н ы ш ё в Е.И. Крестьянская реформа в Казанской губернии // Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1; В у л ь ф с о н Г.Н. Борьба вокруг реформы 1861 г. в Казанской губернии: Дис. ... М., 1950; С м ы к о в Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма. М., 1984; Т е п л о в а Е.И. Деятели крестьянской реформы в 1861 г. в Казанской губернии // Литературные чтения в усадьбе Баратынских. К., 2001; Ф р о л о в а С.А. Губернатор и дворянское общество Казанской губернии в период подготовки реформы 1861 г. // Уроки Вульфсона. К., 2003.

*С.А.Фролова.*

**КРӘСТИЯ́Н (ФЕ́РМЕР) ХУҖАЛЫГЫ́**, а.х. җитештерү формасы; милектән (яисә гомерлек варислык биләмәсеннән) яки арендага алынган җирдән файдалануга нигезләнгән шәхси а.х. пр-тиесе. К.(ф.)х. — юридик зат хокукларына ия мөстәкыйль хуҗалык итүче субъект, ул ирекле җитештерү эшмәкәрлегенә һәм үз милкендәге җирдән файдалануга нигезләнеп, а.х. продукциясе җитештерә, эшкәртә һәм сата. К.(ф.)х. милкендә торак йортлар, хуҗалык корылмалары, а.х. техникасы һәм инвентаре, транспорт чаралары һ.б. булырга мөмкин. Җитештерелгән продукция һәм алынган керем К.(ф.)х.ның милке булып санала. 2010 елның 1 гыйнварына ТРда 2524 К.(ф.)х. исәпләнә, аларга 300,0 мең *га* а.х. җирләре (бер хуҗалыкка уртача 118,9 *га*) туры килә. Алар милкендә 2 меңнән артык трактор, 180 автомобиль, 200 ләп ашлык җыю комбайны һ.б. төрле техника исәпләнә. ТР К.(ф.)х.ларының төп күрсәткечләре таблицада бирелә.

К р ә с т и я н (ф е р м е р) х у җ а л ы к л а р ы н д а
а в ы л х у җ а л ы г ы п р о д у к ц и я с е җ и т е ш т е р ү (1 9 9 9 – 2 0 1 0).

| Күрсәткечләр | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1999 | 2000 | 2005 | 2008 | 2009 | 2010 |
| Теркәлгән крәстиян (фермер) хуҗалыклары саны (1 гыйнварга) | 1370 | 1631 | 2254 | 2885 | 2547 | 2524 |
| Аларга бирелгән җир кишәрлекләре (мең *га*) | 89,2 | 123,9 | 256,0 | 324,2 | 316,0 | 300,0 |
| Җир кишәрлегенең уртача зурлыгы (*га*) | 65,0 | 76,0 | 113,6 | 112,4 | 124,1 | 118,9 |
| Җитештерелгән а.х. продукциясе (мең *т*): | | | | | | |
| бөртекле ашлык (эшкәртелгәннән соңгы авырлыкта) | 56,8 | 73,0 | 559,4 | 809,3 | 564,7 | 82,3 |
| шикәр чөгендере | 4,2 | 1,8 | 86,0 | 198,7 | 109,9 | 90,8 |
| бәрәңге | 3,7 | 6,5 | 39,2 | 70,9 | 44,9 | 10,8 |
| терлек һәм кош-корт (сугым авырлыгы) | 0,9 | 1,0 | 5,3 | 8,9 | 10,9 | 13,4 |
| сөт | 12,1 | 10,0 | 78,3 | 101,0 | 117,0 | 127,8 |
| бал (*т*) | 42,0 | 61,0 | 286,0 | 380,0 | 583,0 | 498,0 |


*Әд.:* З и я т д и н о в Ф.С. Ресурсный потенциал АПК: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2010.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КРӘСТИЯ́Н ХУҖАЛЫКЛАРЫ́Н КҮМӘКЛӘШТЕРҮ́**, СССРның авыл хуҗалыгында 1920 еллар ахырында — 1930 елларда аерым крәстиян хуҗалыкларын бетерү һәм төп а.х. җитештерү чараларын берләштерү б-н бергә алып барылган массакүләм күмәк хуҗалыклар (колхозлар) оештыру. Баштарак, «*хәрби коммунизм*» елларында (1918–21) К.х.к. крәстиян хуҗалыкларының ирекле кооперацияләнүе рәвешендә бара. БҮБКның «Җирне социальләштерү турында» дип аталган Декретында (1918 нең гыйнвары) игенчелектә күмәк хуҗалыкларны үстерү бурычы куела; аерым крәстиян хуҗалыклары б-н чагыштырганда аларга билгеле бер өстенлекләр бирелә. 1918 дән җирле сов. һәм партия хакимият стуктуралары башлангычында авылларда алпавыт биләмәләре һәм крәстиян хуҗалыклары нигезендә ярлылар һәм җәмгыятьнең сыйнфыйлыктан арындырылган элементлары (җитештерү чараларын тулысынча яки өлешчә берләштерү юлы б-н) тарафыннан күмәк хуҗалыклар төзелә башлый. Алар төрле формада оештырылып, а.х. коммуналары (к. *Авыл хуҗалыгы коммунасы*), *бергәләп җир эшкәртү ширкәтләре*, а.х. артельләре (колхозлар) рәвешендә булалар. *Яңа икътисади сәясәт* елларында (1921 — 1920 еллар ахыры) К.х.к. оешканрак төс ала һәм вак крәстиян җитештерүчеләрен эре хуҗалыклар итеп кооперацияләү (к. *Кооперация*) формасында уздырыла. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары, *Ачлык* (1921–22) чорында бөлгән крәстияннәрнең күпчелеге күмәк хуҗалыклар әгъзаларына дәүләт кредитлары, акчалата һәм орлыклата ссудалар, яңа җирләр бирелү һ.б. ташламалар ясалу нәтиҗәсендә үз хуҗалыкларын торгызуга ирешәләр.

Крәстияннәр (бигрәк тә 1920 еллар башындагы ачлык вакытында), ш.у. хакимият структуралары теләге б-н «авылда күмәк тәзелеш» башлана. Авылларда коллектив хуҗалыкларның иң гади (җитештерү чаралары гаять түбән дәрәҗәдә берләштерелгән) төрләре — терлекчелек, җир, машина, посёлок, умартачылык, бакчачылык, орлыкчылык ширкәтләре һ.б. киңрәк таралыш ала. Алар озак яшәмиләр, гадәттә, ике-өч ел дәвамында бергә эшләгәч таркалалар. Дәүләт хисабына үзләренең икътисади хәлләрен ныгыткаңнан соң, кагыйдә буларак, крәстияннәр аерым хуҗалык алып баруга әйләнеп кайталар. К.х.к. бик әкрен темплар б-н башкарыла. 1929 да Татарстанда 724 вак колхоз исәпләнә, алар тулай а.х. продукциясенең 2,8% ын җитештерәләр. К.х.к., башлыча, горизонталь рәвештә — җирләрне һәм җитештерү чараларын берләштерү формасында бара. Вертикаль буенча К.х.к. (фермерлык тибындагы крәстиян хуҗалыкларын а.х. продукциясен эшкәртүче пр-тиеләр тирәсенә туплау) а.х. җитештерүенең нык артта калуы һәм ялгыш сәясәт (хуҗалыкларны иң элек коммуналар рәвешендә оештыру), илдә кискен бюджет кытлыгы (авылны калдык принцибы буенча финанслау, рациональ булмаган салымнар һ.б.) аркасында киң таралмый.

Совет тарих фәнендә хөкем сөргән ялгыш фикер буенча, тоташ (массачыл) К.х.к. 1927 нең декабрендә — ВКП(б)ның 15 нче съезды уздырылган вакытта башланган дип исәпләнә. Съездда яңа икътисади сәясәт принциплары нигезендә кооперациянең барлык формаларын үстерү турында карар кабул ителә, ш.и. эзлекле рәвештә җирне күмәкләшеп эшкәртү хакында сүз була. Гамәлдә тоташ К.х.к. 1929 да башлана. Икмәк әзерләүдәге



Заявление

Колхозга кабул итү турындагы гариза.

кискен кризис (1927–29) һәм крәстияннәрнең а.х.да бөлдергеч сәясәткә актив икътисади һәм сәяси каршылык күрсәтүе сталинчыл җитәкчелекне ВКП(б) ҮКның 1929 ның ноябрендә уздырылган пленумында аерым өлкәләрдә тоташ К.х.к.гә күчү бурычы куйган «Колхоз төзелешенең нәтиҗәләре һәм алдагы бурычлары» карарын кабул итүгә этәрә. «Күмәкләштерүнең темплары һәм дәүләтнең колхоз төзелешенә ярдәм чаралары турында» карарында (1930 ның гыйнвары) ВКП(б) ҮК җирле сов. һәм партия җитәкчеләрен К.х.к.не 1932 нең ахырына төгәлләүгә юнәлтеп, аның катгый срокларын билгели. Бу карарларны гамәлгә ашыру максатында даими эшләү өчен авылларга 25 мең эшче, ягъни «егермебишменчеләр» җибәрелә, сәнәгать пр-тиеләре күмәк хуҗалыкларны шефлыкка алалар. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты февр. пленумы (1930) җирле хакимият структураларына алдагы язгы кампаниягә кадәр крәстиян хуҗалыкларының 75–80% ын колхозларга берләштерү һәм республикада К.х.к.не 1930 ның көзенә төгәлләү турында күрсәтмә бирә. Татарстан районнарына «егермебишменче» 402 эшче, ш.и. Мәскәүдән һәм Мәскәү өлкәсеннән — 243, Бакудан — 50, Казаннан 100 дән артык кеше җибәрелә. Татарстанда ирексезләп К.х.к.нең яңа дулкыны башлана. Һәр җирдә крәстияннәрнең колхозларга ирекле рәвештә керү принципларын бозу, крәстияннәр милкен тулысынча берләштерү («коммунизацияләү»), тоташ кулаклардан арыну һәм аерым хуҗалык ияләрен гражданлык хокукларыннан мәхрүм итү, крәстияннәрнең орлыкларын, терлекләрен, торак, хуҗалык корылмаларын һ.б. мөлкәтен тартып



Мәскәү «егермебишменчеләр»е отряды Бөгелмә кантонында. 1930.

алу киң тарала. 1930 ел башына республика К.х.к. буенча СССРда 3 нче урынга чыга, 3422 колхоз оештырыла. 1930 ның 20 февраленә крәстияннәрнең 73,9%ы, 20 мартка 84%ы колхозларга берләштерелгән булып исәпләнә. Кайбер районнарда (Кайбыч, Минзәлә р-ннарында) барлык крәстиян хуҗалыклары да күмәкләштерелә. Мондый сәясәт крәстияннәрдә ризасызлык уята, массачыл рәвештә терлекләрне суюга, милекне сатуга, авыл халкының шәһәрләргә күченүенә китерә; авылларда яшәүчеләрнең хөкүмәткә каршы күтәрелеш очраклары һ.б. була.

Авылларда социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең кискенләшүе хакимиятләрне тоташ К.х.к. сәясәтен вакытлыча туктатуга, ш.у. авылны «коммунизацияләү»дән баш тартуга мәҗбүр итә. 1930 ның 2 мартында И.В.Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе басылып чыга. Анда К.х.к.не башкарганда ашыгу һәм иреклелек принциплары б-н санлашмауның ярамаганлыгы, милли респ-каларда җирле шартларны исәпкә алу зарурлыгы турында әйтелә; Сталин «чиктән тыш бөгүләр» өчен җирле җитәкчеләрне гаепли, аларга Колхозларның үрнәк уставы тәкъдим ителә. ВКП(б) ҮКның «Колхозлашу хәрәкәтендә партия линиясен бозуларга каршы көрәш турында»гы 1930 ел 14 март карарыннан соң, крәстияннәр күмәк хуҗалыклардан күпләп чыга башлыйлар. Ашыгып оештырылган колхозлар тиз арада таркала. Соңрак ВКП(б) ҮКның дек. (1930) һәм июнь (1931) пленумнары карарлары нигезендә барлык милли респ-каларда һәм өлкәләрдә К.х.к.не уздыруның яңа сроклары билгеләнә. Татарстан массачыл К.х.к.не 1932 нең ахырына төгәлләү күздә тотылган төбәкләр төркеменә кертелә. 1930 ның көз-кышында ирексезләп К.х.к. кампаниясе янә көчәя. Ул, башлыча, 1930 еллар ахырына төгәлләнә. 1937 нең июленә Татарстанда 417,8 мең крәстиян хуҗалыгын (91,4%) берләштергән 3847 колхоз исәпләнә; алар карамагында 5 млн. *га* (94,4%) чамасы чәчүлек җирләр була.

К.х.к. барышында җирләр, барлык төп җитештерү чаралары, хезмәт берләштерелә; колхоз крәстияннәре милкендә торак корылмалар, вак инвентарь, а.х. артеле Уставында каралган күләмдә продукт алу өчен үрчетелә торган терлек, алар файдалануында *шәхси ярдәмче хуҗалык* алып бару өчен кечерәк мәйданлы утар кишәрлеге (0,5 *га* га кадәр) калдырыла. Колхозчы ударникларның 2 нче Бөтенсоюз съездында (1935 нең 17 феврале) кабул ителгән а.х. артеленең Үрнәк уставы авылдагы яңа мөнәсәбәтләрне гомумиләштерә һәм закон рәвешендә раслый, колхоз строеның хокукый нигезләрен, колхозларда җитештерүне һәм иҗтимагый тормышны оештыруның төп принципларын билгели. 1939 ның ахырына республикада 60 меңләп аерым хуҗалык исәпләнә. Уртача алганда, бер аерым хуҗалыкка 1,7 *га* сөрүлек җир туры килә. Республикада соңгы аерым хуҗалыклар 1950 елларда юкка чыга.

К.х.к. крәстияннәр хезмәтенең, көнкүрешенең традицион шартларын һәм бөтен тормыш рәвешен тамырдан үзгәртә. Колхоз строе Сов. дәүләтенең аграр сектордагы сәяси позицияләрен ныгыта, крәстияннәргә икътисади басым ясау өчен мөһим мөмкинлекләр тудыра. К.х.к. нәтиҗәсендә авылда *кулаклар* «изүче сыйныф» буларак бетерелә, акрынлап яңа социаль катлау (сыйныф) — колхоз крәстияннәре оеша. Авыл хуҗалыгында К.х.к. төп а.х. продуктларының зур күләмдә кимүенә, 1930 елларда республика халкын массачыл ачлыкка, авылларда күп кенә матди һәм кеше югалтуларга һ.б.га китерә. Терлекчелек җитди зыян кичерә: 1928 ел б-н чагыштырганда атларның баш саны — 39% ка, мөгезле эре терлекнеке — 39% ка, сарыклар һәм кәҗәләр — 65% ка, дуңгызлар 64% ка кими. 1929 — 40 та колхозларда бөртекле культураларның уртача уңышы 1 *га* дан 5–6,5 *ц* тәшкил итә (1914 кә кадәр — 1 га дан 7–7,5 *ц*). 1930–50 елларда, уртача алганда, һәр колхозга 4 мең сумлап акчалата табыш туры килә. 1930 елларда кыр эшләре нибары 15–30% ка механизацияләнә (к. *Машина-трактор станциясе*).



«Красная звезда» колхозы икмәк тапшыра. 1930.

К.х.к. елларында барган процесслар җәмгыять тормышының күп кенә яклары б-н авыр яраклаша, каршылыкка керә. К.х.к. дәвамында авыл җәмәгатенең социаль структурасында, крәстияннәрнең тормыш һәм көнкүреш шартларында, аларның аңында кискен үзгәрешләр барлыкка килә. 1932 дә катгый паспорт системасы гамәлгә кертелү нәтиҗәсендә, колхозчылар, асылда, үз хуҗалыкларына беркетеләләр. Үрнәк уставта (1935) колхоздан ирекле чыгу мөмкинлеге каралмый. 1970 елларның 2 нче яртысына кадәр гомуми җыелыш карарыннан башка колхоз әгъзаларының кулларына паспорт бирелми, шуңа күрә алар шәһәрләргә китеп эшли яки башка төрле хуҗалык эшчәнлеге б-н шөгыльләнә алмыйлар. Нәтиҗәдә, колхоз крәстияннәренең чын асылы югалуга, хуҗалыкчыл һәм эшмәкәрлек инициативасы сүнүгә йөз тота: крәстиян яшьләре шәһәрләрдә, «бөек төзелешләр»дә берегеп калырга омтылалар һ.б. Катлаулы тормыш шартлары, авыр хезмәт, демографик һәм миграцион процесслар аркасында респ-каның крәстиян халкы саны бертуктаусыз кими бара. Шул ук вакытта колхоз крәстияннәренең зур өлеше күмәк хуҗалыкларда хезмәт көннәрен (норма елга 200 хезмәт көне тәшкил итә) эшләп тутырырга тиеш булалар, нормалар үтәлмәгән очракта хакимиятләр утар яны кишәрлекләрен тартып

алу кебек һәм башка төрле адм., мәхкәмә-репрессия рәвешендәге чаралар кулланалар. Шулай ук авылларда агротехник һәм контора-идарә хезмәткәрләренең саны арту күзәтелә, асылда, аларның составы республика халкының барлык социаль катлаулары вәкилләре хисабына тулылана.

К.х.к. динамикасы, авылның халык хуҗалыгы һәм социаль структурасы эволюциясе, колхоз крәстияннәренең көндәлек көнкүреше җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Татарстанда К.х.к. тарихы, башлыча, республикада кооперация төзелеше үсеше һәм авылның социаль-икътисади тормышының аерым яклары яктыртылган хезмәтләрдә чагылыш таба. Тарихи-икътисади әдәбиятта К.х.к.нең формалары һәм алымнары, эчке объектив ихтыяҗлар һәм тышкы факторлар йогынтысы нисбәте турында төрле фикерләр хөкем сөрә. Хәзерге чор илебез тарихчылары һәм икътисадчылары фикеренчә, К.х.к. аграр секторның зур үсешенә китерми (колхозларның 70–80% ы табышлы булмый, крәстияннәр, башлыча, шәхси ярдәмче хуҗалыклар хисабына көн күрәләр), асылда, ул озак еллар дәвамында авылда крепостнойлык-җәмәгать калдыкларын саклый һәм авылдагы эшлекле хуҗалар (фермерлар) катлавын (төркемен) юкка чыгара. Төрле икътисади укладлар үсеше вакытында колхозлар, аерым *крәстиян (фермер) хуҗалыклары* б-н беррәттән, а.х. продукциясе җитештерүдә билгеле бер роль уйныйлар. 1990 елларда, крәстиян (фермер) хуҗалыклары оешу чорында, Татарстан а.х.да күмәкләштерүне бетерү башлана. Ш.у. к. *Совхоз*.

Чыг.: Коллективизация сельского хозяйства Татарской АССР (1927–1937): Док. и материалы. К., 1968.

*Әд.:* Б а й р а м о в К.Л. Тракторные колонны и первая МТС в Татарии // Сб. науч. трудов Казан. мед. ин-та. 1957. Вып. 3; Х а р и т о н о в П.М. Колхозный строй в Татарии и новый этап его развития. К., 1958; У с т ю ж а н и н Е.И. Колхозное строительство в Татарии в начальный период индустриализации страны (1926–1928 гг.). К., 1959; Сельское хозяйство Татарии за 50 лет Советской власти. К., 1967; Ленинский кооперативный план и его осуществление в Татарии. К., 1970; З а л я л о в А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Ф р о л о в Н. Коллективизация: помнить, чтобы не повторилось // Татарстан. 1993. № 9; Ф о м и н ы х Г. «Безумная жестокость при раскулачивании ...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1995. № 5; Ш а й д у л л и н Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КРӘСТИЯ́Н ЭШЛӘРЕ́ ИДАРӘХАНӘЛӘРЕ́** (крәстиян эшләре буенча өяз идарәханәләре), адм. органнар. Казан губернасы өязләрендә 1874 елның 27 июнендә кабул ителгән «Крәстиян эшләре буенча җирле учреждениеләр төзелешендәге үзгәрешләр турында нигезләмә» буенча җәмәгать арадашчыларына һәм өяз җәмәгать җыеннарына алмашка оештырыла. Алпавытлар һәм крәстияннәр арасында җиргә нисбәтле мөнәсәбәтләргә, крәстиян үзидарәсе торышына күзәтчелек итәләр, ш.и. волость старшиналарының вазифаларга керешүен раслыйлар, волость һәм авыл писарьларын вазифадан азат итәләр, волость идарәләрендәге вазифаи затларга җәза бирәләр, авыл җәмәгате һәм волость идарәләрен тикшерәләр һ.б. Идарәханә составына өяз дворяннары башлыгы (рәис), өяз исправнигы, өяз земствосы идарәсе рәисе, шәрәфле җәмәгать судьясы һәм даими әгъза (һәр 3 ел саен өяздәге дворян-җирбиләүчеләр арасыннан губерна земствосы җыелышында сайланган ике кандидаттан эчке эшләр министры тарафыннан билгеләнә) керә. К.э.и. өчен *Казан губернасының крәстиян эшләре кабулханәсе* апелляция инстанциясе була. Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсына. 1889 ның 12 июлендә кабул ителгән «Земство участок башлыклары турында нигезләмә» һәм Россия Дәүләт Советының император Александр III тарафыннан расланган 1891 ел 16 июнь карары нигезендә бетерелә, вазифалары *земство башлыкларына* тапшырыла.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 4.

*Е.Б.Долгов.*

**КРӘСТИЯННӘ́Р**, социаль катлау. «Крәстиян» («крестьянин») төшенчәсе (чыгышы б-н «христианин» сүзеннән) 14 йөздә барлыкка килә. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында «крәстиян» атамасы Казан төбәгенең төп халкына, ш.и. татар игенчеләренә дә тарала.

Б.э.к. 1 нче меңьеллык уртасында — б.э. 1 нче меңьеллыгы башында Азелино, Ананьино, Городец, Имәнкискә, Пьянобор һ.б. археол. культуралар халкының төп шөгыльләре игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, сунарчылык, авыл һөнәрчелегеннән гыйбарәт була (к. *Тимер гасыр*). Идел буе Болгар дәүләте оешып җиткәндә ышна ачу һәм яткын җирләр калдыру пар системасы (ике һәм өч басулы чәчү әйләнеше б-н) тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Болгарларда сөрүле игенчелек хөкем сөрә, җигүле сөрү кораллары — авыр *сабан* һәм сука кулланыла. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Даста (10 йөз) хәбәр иткәнчә, болгарлар борай, арпа, бодай, тары һ.б.ны игәләр. Палеоботаник тикшеренүләргә караганда, болгарларның агрикультурасында 15 тән артык төрдә культуралы үсемлекләр үстерелә, алар арасында йомшак бодай, арыш, тары, борай һәм арпа төп урынны билиләр. Шулай ук көзге арыш, каты бодай, солы, карабодай; кузаклылардан борчак һәм ясмык; майлы-җепселлеләрдән житен, киндер; яшелчә культураларыннан кишер, чөгендер, суган, сарымсак һ.б. игелә. Рус елъязмаларында болгарларның 1024, 1229 һ.б. елларда рус җирләренә икмәк китерүе турындагы хәбәрләр Идел буе Болгар дәүләтендә игенчелекнең киң үсеш алуын күрсәтә. Болгарлар хуҗалыгының тагын бер гаять мөһим тармагы — мөгезле эре һәм вак терлек (сыерлар, сарыклар, кәҗәләр), атлар, кош-корт (тавыклар, үрдәкләр, казлар) үрчетү. Болгар археол. ядкәрләрендә терлекчелек кирәк-яраклары — авызлыклар, тышаулар, ат кыргычлары, сыерларга һәм атларга тагыла торган кыңгыраулар еш очрый. Кыңгыраулар һәм тышаулар мисалында көтүнең иректә (көтүчесез) йөрүе исә бу очракта җирле фин-угор халыкларының терлекчелек традицияләре йогынтысы дип карала. Шулай ук далалардагы күчмә терлекчелек традицияләре (көтүдә сан ягыннан мөгезле вак терлек өстенлек итү) яшәп килә, бу Идел буе Болгар дәүләтенең көньяк җирләре өчен аеруча хас була. Авылларда өйдә җеп эрләү һәм туку, агач һәм сөяк эшкәртү, чүлмәкчелек, тимерчелек, күн иләү таралыш ала. Тимерчеләр, мәгъдәннән тимер эретеп алучылар, зәркәнчеләр, чүлмәкчеләр, кагыйдә буларак, аерым затлар кушуы буенча эшлиләр һәм шул ук вакытта игенчелек б-н дә шөгыльләнәләр (к. *Әҗмәр авыллыгы*).

Монгол яулары нәтиҗәсендә (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*) 13 йөзнең 2 нче яртысында акрынлап авыл халкының социаль-икътисади хәле үзгәрә. Ирекле авыл җәмәгате әгъзалары Алтын Урдага ясак түләү бәйлелегенә эләгәләр (к. *Урда салымы*), өлешчә әмирләр, даруга бәкләре һәм олыс бәкләре хакимияте астына күчәләр. Идел буе Болгар дәүләте Алтын Урданың аерым бер автономияле өлешенә (Болгар олысы) әверелә. Анда төрки, фин һәм угор телле К. язмышында чагылыш тапкан катлаулы демографик процесслар бара. Урманлы далаларда яшәгән авыл халкының зур күпчелеге Казан алды төбәгенә, башлыча, элеккеге Болгар дәүләтенең төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш терр-ясенә күчеп китә (к. *Колонияләштерү*). Урман массивлары һәм субүләрләр булган җирләрне үзләштерү күләмле башлангыч хезмәт чыгымнарын таләп итә. К.нең Болгар олысының чиктәш көньяк һәм көньяк-көнчыгыш терр-ясенә күченүе Алтын Урда, 16 йөз башыннан Кырым ханнары һәм нугайларның еш кабатланган һөҗүмнәре аркасында катлаулана. Алтын Урда идарәчеләре һәм аксөякләр тарафыннан ирекле авыл җәмәгате әгъзаларының даими рәвештә ясак түләргә дучар ителүе җирнең дәүләт (феодаллар) милкенә әверелүенә китерә (к. *Җир биләү, Җирдән файдалану*). Күп кенә галимнәр фикеренчә, дәүләтнең һәм җәмәгатьнең җир милке бер-берсеннән аерым була. 13 йөз ахырында — 14 йөз башында авыл җирләрендә хан биләмәләре барлыкка килә һәм киңәя. Аларда бәйле халыкның төрле категория вәкилләре, ш.и. а.х. хезмәте б-н шөгыльләнүчеләр дә эшли. 14 йөзгә хан биләмәләре б-н беррәттән, феодал җирләре дә (*тарханлык, сөюргаллар*) барлыкка килә.

13–16 йөзләрдә авыл халкының төп массасы ирекле була, алар чыганакларда «*ясаклылар*» атамасы б-н күрсәтелә. Бер үк вакытта бәйле һәм ярымбәйле игенчеләр (*кара халык*) категорияләре дә формалаша. 16 йөздән «кеше»ләр искә алына, аларның бер өлешен феодаль аксөякләрнең утарларында, ш.и. басуларда эшләгән халык тәшкил итә. «Кеше»ләрдән тыш, феодаль аксөякләр хуҗалыкларында сугышларда әсирлеккә төшерелгән, «җиргә утыртылган» коллар да җир эшкәртү б-н шөгыльләнә. Колларның күбесе игенчеләргә әверелү б-н «кеше», «әсир» атамалары ясак бурычын барщина рәвешендә



**Крәстияннәр мәкаләсенә.** 1. Бөртеклеләрне кулдан чәчү. 1920 еллар фоторәсеме. Әлдермеш авылы (хәзерге Биектау р-ны); 2. Крәстиян йорты; 3. Крәстияннәрнең көнкүреш һәм хуҗалык инвентаре; 4. Крәстиян йортының эчке күренеше; 5. Татар миче; 6. Савыт-саба киштәсе; 7. Ураклар, чалгы; 8. Агач кул тегермәне; 9. Он иләү кирәк-яраклары; 10. Бәрәңге кыргыч; 11. Агач киле; 12–13. Кисмәкләр; 14. Үрелгән юл сандыгы; 2–14. Г.Тукай музее (Сәгъди йорты). Арча р-ны Яңа Кырлай авылы.

үтәүче хезмәтчеләргә карата кулланыла башлый. Авыл халкының бу категорияләре хокук субъектына әверелми, теләсә-нинди мәхкәмә низагында тулысынча алар өчен җавап тоткан хуҗаның шәхси милкендә була. Документларда ш.у. феодал утарларында яшәгән тоткыннарга карата кулланылган «кол» атамасы очрый. Ихтимал, Казан төбәгендәге кайбер топонимнар «кол» исеме б-н бәйледер (Коллар, Колсәет һ.б.).

Чыганакларда авыл халкының бурычлары турында мәгълүматлар бик аз. Төп бурычлар дәүләт файдасына натуралата һәм өлешчә акчалата түләүләрдән гыйбарәт була. Сәхибгәрәй хан ярлыгында Казан ханлыгы халкы түләргә тиешле 13 төрле салымнар, түләүләр һәм бурычлар санала (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*).

13 йөздә — 16 йөз уртасында игелгүче культураларның төрләре арта. Игенчелек эсулларын һәм хезмәт коралларын — тырмаларны, чалгыларны (бөкре һәм озын чалгыларны) эшләүне камилләштерү дәвам итә, туфракның сыйфатына һәм сөрү рәвешенә карап, берничә төрле сабан кулланыла. Өч басу әйләнешле пар системасы өстенлек иткән шартларда, төп бөртекле культуралар буларак, көзге арыш, солы, арпа, тары, карабодай игелә, алар барлык бөртеклеләрнең 75–95% ын тәшкил итәләр. 16 йөз башыннан атларның баш саны Нугай Урдасыннан һ.б. җирләрдән китерелгән көтүләр б-н тулылана. Авылдагы теләсә кайсы гаиләдә буйга җиткән һәр кешегә, уртача алганда, берәр ат, 2–3 баш мөгезле эре терлек туры килә. Авыл халкы бөртеклеләрдән чагыштырмача югары уңыш җыеп ала. Бу кенәз А.М.Курбский мәгълүматларында да күренә. Ул, Казан ханлыгының төньяктагы төбәге — Арча ягын тасвирлап: «Ул җирдә кырлар бик зур һәм төрле җиләк-җимешләргә гаҗәеп бай; ... авыллар еш очрый; күктәге йолдызлар кебек үк, анда төрле ашлык искиткеч күп; шулай ук төрле терлек көтүләре дә исәпсез-хисапсыз», — дип яза. Казан алды авылларында төрле күннәр (юфть, сафьян һ.б.) һәм күн әйберләр җитештерелә. Һәр җирдә авыл халкы агач эшкәртә, кальгалар һәм йортлар өчен буралар бурау, авыл тормыш-көнкүреше өчен кирәк-ярак, савыт-саба ясау б-н махсус шөгыльләнә. Һәр йортта хатын-кызлар җеп эрлиләр, тукыйлар, 16 йөздән тупас постау җитештерелүе мәгълүм. Тимерчеләр, чүлмәкчеләр һ.б. авылдашларының ихтыяҗларын канәгатьләндерә һәм сату өчен дә әйберләр җитештерә.

Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулапганнан соң (1552), авыл халкы тормышында зур үзгәрешләр башлана. 16 йөз уртасында — 17 йөздә (130 ел чамасы) Урта Идел буйларында Казан төбәге җирләрен бөлдергән сугышлар, кузгалышлар (к. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56), Казан ханлыгы яулангапннан соңгы фетнә-чуалышлар, «Болгавыр заман», Җангали хәрәкәте* һ.б.), эпидемияләр һ.б. булып уза. Климат шартларының озак вакыт дәвамында уңайсыз торуы массачыл күләмдә игеннәр уңмауга һәм 1601–1603 еллардагы ачлыкка китерә; 1610–20 еллар, 1650 еллар ахыры — 1660 еллар башы, 1680 еллар ахырында ш.у. уңыш булмый. Шул ук вакытта Рус дәүләте даими рәвештә казна сәясәтен катгыйландыра бара. Төбәк үтә авыр хуҗалык кризислары кичерә. Бөлгән авыл җирләрендә ташландык авыллар һәм буш җирләр барлыкка килә, аларның күпчелек өлешендә соңрак тормыш тергезелми.

16 йөзнең 2 нче яртысында җирле җирбиләүчеләрнең җир милке яңадан бүленә. Төбәкне руслар басып алуга актив каршылык күрсәтүчеләрнең күбесе һәлак була яки үзләренең нәселдән килгән җир биләмәләреннән мәхрүм ителә. Казан тирәли 30 чакрымлы читләштерү каймасы оештырыла, андагы авылларның төп халкы тулысынча диярлек куыла, ул җирләрне читтән килгән рус К.е һәм өлешчә *йомышлы татарлар* били. Казан ханнары, җирле татар аксөякләре һәм ирекле җәмәгать әгъзалары (ясаклы кешеләр) җирләрендә күбесенчә рус кешеләре килеп төпләнгән патша сарае, алпавыт һәм чиркәү-монастырь биләмәләре барлыкка килә. 16 йөз ахырына — 17 йөз башына Казан өязендә буш җирләр фонды таратылып бетерелә, сөюргал һәм тарханлык җирбиләүчелеге кискен кими, дөньяви җирбиләүчелекнең нигезен тәшкил иткән поместье системасының роле арта (к. *Алпавыт крәстияннәре*). 16 йөз уртасы — 17 йөз рәсми документларында К. хуҗа (алпавыт К.е, йомышлылар, руслар хезмәтендәге татарлар һәм чуашлар; монастырьлар, чиркәүләр, патша сарае К.е), дәүләт К.енә (ясаклы кешеләр, *кош аулаучы крәстияннәр*) бүленә. 16 йөз ахырыннан документларда *бобыльләр* искә алына, аларның крәстияннәрдән төп аермасы хуҗалыкларының аз җегәрлелегеннән гыйбарәт була. 17–18 йөзләрдә чиркәү-монастырь җирбиләүчелеге киңәя, Казан төбәгендә православие монастырьларына гаять зур җир кишәрлекләре тапшырыла. А.х. эшләрен башкару өчен аларга рус К.е, өлешчә христианлаштырылган төп халык вәкилләре беркетелә.

17 йөз ахырында — 18 йөздә яулап алынган җирләрдәге халыкларны көчләп христианлаштыру һәм алга таба колонияләштерү төп крәстиян халкының, бигрәк тә татарларның, моңарчы күрелмәгән күләмдә күченүләренә китерә. 18 йөзнең 1 нче яртысында Казан арты һәм, өлешчә, Тау ягы К.е Кама арьягына юнәлә. К.нең дулкынсыман барган колонияләштерү хәрәкәте Кама арьягы, Агыйдел елгасының югары агымы буе җирләрен, Башкортстан–Пермь төбәген, 18 йөзнең 2 нче яртысында көньяктагы чик буйларын (Сембер, Самара җирләрен һ.б. төбәкләрне) колачлый. *Чик буе киртәләре* корып, дәүләт илнең көньягына күчеп утыручыларның иминлеген тәэмин итә. Шул ук вакытта, 17 йөздә Кама арьягына Россиянең үзәк төбәкләреннән рус К.е, отставкадагы солдатлар, ш.у. Мордовиядән, Пенза, Түбән Новгород җирләреннән һ.б. төбәкләрдән татарлар күчереп утыртыла.

К.нең икътисади һәм социаль-хокукый хәле начараю аларның дөньяга карашларында К.гә генә хас булган үзгәрешләргә китерә. 16–17 йөзләр чигендә гадел «коткаручы патша» һәм «законсыз» идарәче турындагы соц.-утопик идея туа. К.нең бер өлеше «законсыз» идарәчегә каршы көрәшне изге гамәл дип исәпли. К. яңа, «чын» патшага турыдан-туры, боярлар һәм приказлар түрәләре арадашчылыгыннан башка гына мөрәҗәгать итү мөмкинлеге турында хыялланалар. 17–18 йөзләрдә җирле авыл халкы *крәстияннәр кузгалышларында* (1670–71; 1773–75) катнаша. 18 йөзнең 1 нче чирегендәге социаль тетрәнүләр татарлар арасында «тәкъва җир» — «илаһи Болгар шәһәре» турындагы идея туугa җирлек бирә. Бу илне эзләү татар К.енең *Морад* мулла җитәкчелегендәге хәрәкәте башлануга сәбәпче була.

18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында нисбәти өлешләре 95% тан 90% ка кадәр кимесә дә, К. төбәктә сан ягыннан халыкның иң зур катлавы булып калалар. Аларны крепостной бәйлелеккә беркетү дәвам итә, 17 йөз ахырында — 18 йөз башында дәүләтнең салым изүе көчәя (1724 тә крепостнойлардан җан башыннан алынган салым 74 тиен тәшкил итә); 18 йөзнең 2 нче яртысында барщинаның күләме кискен (4–5 көнгә кадәр) арта. Император Петр I реформалары барышында, К.нең төрле төркемнәре — ясаклы (дәүләт), хуҗа (алпавыт), монастырь, сарай (патша гаиләсе — удел — крәстияннәре) К. составында һәм исәбендә җитди үзгәрешләр була. Дәүләт крәстияннәре разряды юридик яктан 1719–24 елларда чыгарылган фәрманнар б-н рәсмиләштерелә, аның составына крепостной бәйлелектә булмаган К.нең төрле төркемнәре — «ясаклылар», «йомышлы татарлар», «экономик крәстияннәр» (1764 тә монастырьлар карамагыннан алынып, Экономик коллегиягә тапшырылган, шуңа күрә шулай аталган К.) һ.б. керә. Рәсми рәвештә дәүләт К.е «ирекле авыл кешеләре» дип атала, алар ш.у. К.нең бәйле категориясенә керә. Дәүләт К.енең хәле тотрыклы булмый, чөнки аларны төрле рәвештә крепостной бәйлелеккә дучар итә алганнар. Петр I заманында ук дәүләт К.ен казна заказларын башкарган заводларга беркетү гамәлгә кертелә (к. *Казна эшенә беркетелгән крәстияннәр*). Мәсәлән, 1798 дә Ижевск тимер з-дында һәм Вознесенск бакыр эретү з-дында 2635 казна эшенә беркетелгән крәстиян (ир-атлар) исәпләнә. 18 йөздә дәүләт К.ен «бүләк итү» рәвешендә мануфактураларда эшләү өчен хосусый затларга арендага (посессияләргә) бирү киң тарала (к. *Посессион крәстияннәр*). 1797 дә *Казан постау мануфактурасында* элеккеге 1247 крәстиян эшли. Петр I фәрманы нигезендә кайбер дәүләт К.е (башлыча, татарлар) *Казан адмиралтейсвосына* беркетеләләр, алар анда кораблар төзүгә яраклы урманнарны кисү һәм ташу б-н шөгыльләнәләр (к. *Лашманнар*).

*Патша гаиләсе (удел) крәстияннәре* разряды «Император гаиләсе турындагы учреждение» (1797) нигезендә оештырыла, патша сарае К.е Уделлар департаменты (1826 дан — Император сарае һәм уделлар министрлыгы) карамагына тапшырыла. Патша гаиләсе (удел) К.енең саны табигый ишәю, К.не алпавытлардан сатып алу, ш.у. казна К.ен уделга

күчерү хисабына арта. Үзләренең хокукый статуслары буенча патша гаиләсе (удел) К.е алпавыт һәм дәүләт К.е арасындагы урынны билиләр һәм, «алпавыт крәстияннәре алпавытларга карата нинди мөнәсәбәттә булсалар, алар император гаиләсенә карата да шундый ук мөнәсәбәттә булалар». Патша гаиләсе (удел) К.е составына «государь» К.е (император милкендәге) һәм «конюшенный»лар (император сараеның атлар тоту ведомствосына беркетелгәннәр) керә. 1857 дә губернада 15,7 меңнән артык патша гаиләсе (удел) К.е исәпләнә.

18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан губернасында крепостной К.нең саны салымнар түләүче халыкның төрле төркемнәрен крепостной бәйлелеккә беркетү һәм авыл халкының табигый ишәюе хисабына ир-атлар 45,8 мең кешедән (1760 еллар) 103 мең кешегә кадәр (1857) арта. Ләкин К.нең барлык катлаулары арасында Казан губернасында дәүләт К.е күпчелекне тәшкил итә (1857 елгы мәгълүматлар буенча 541781 ир-ат, ягъни барлык крәстиян халкының 80% чамасы). Александр I заманында К.не хосусый затларга өләшү туктатыла, ләкин крепостной бәйлелеккә беркетүнең башка формалары саклана: 19 йөзнең 1 нче яртысында дәүләт милкендәге җирләрне күпләп сату, аларны уделлар ведомствосына тапшыру һ.б. таралыш ала. 19 йөзнең 1 нче яртысында отставкадагы һәм *игенче солдатларга*, кош аулаучы крәстияннәргә, ямчыларга, 1860 тан лашманнарга дәүләт К.е статусы бирелә.

Игенчелек элеккечә К. өчен хуҗалык итүнең төп формасы булып кала. К. җирдән авыл җәмгате кысаларында файдаланалар, вакыт-вакыт җир кабат тигезләп бүленә. 1800 дә дәүләт К.е карамагында 3,4 млн. дис. чамасы җир, ягъни Казан губернасының барлык терр-ясенең яртысыннан артык өлеше исәпләнә. Имана җиренең мәйданы бертуктаусыз кими: 18 йөз ахырында ул, уртача алганда, җан башына (ир-атлар) 15 дис. чамасы, 19 йөзнең 1 нче яртысында 8 дис. тәшкил итә. Дәүләт К.енең төп өлеше казнага акчалата рента түли; бу түләү Петр I заманында ревизиядәге һәр җан башына елга 40 тиен туры килә, 19 йөзнең 1 нче яртысында оброк күләме 7 сум 50 тиеннән 10 сумга кадәр тирбәлә. Моннан тыш, К. җан башыннан салым түлиләр һәм төрле бурычлар (рекрутлык, лашманлык, юл төзү, олаучылык, фатирга кертү һ.б.) үтиләр, земство ихтыяҗлары һәм җәмгать чыгымнары өчен акча кертәләр. Имана җирләренең мәйданы кимү һәм бурычларның артуы нәтиҗәсендә, 19 йөз башында дәүләт К.енең салымнарны түләп бетермәвенең үсә баруы ачыклана: 1797 дә Казан губернасы буенча түләнеп бетмәгән салымнар — 924470 сум, 1832 дә 3476640 сум тәшкил итә.

Крәстияннәр реформасын (1861) гамәлгә ашыру барышында К.нең иҗтимагый-икътисади хәле үзгәрә. Реформа процессында алпавыт К.енең җир мәйданы 23,6% ка (327 мең дис.дән 249,1 мең дис.гә кадәр), патша гаиләсе (удел) К.енеке 10,9% ка (69687 дис.дән 62048 дис. гә кадәр), дәүләт К.енеке 36% ка (4376,6 мең дис.дән 2801,2 дис.гә кадәр) кими; К.нең бу категорияләре буенча һәр җан башына (ир-атлар) уртача 2,7 дис., 3,9 дис. һәм 5,2 дис. имана җире туры килә. 1866 елгы реформа нәтиҗәсендә рус К.енә, рус булмаган авыл халкына караганда, җан башына зуррак имана җирләре бүлеп бирелә: рус игенчеләренә ревизиядәге һәр җан башына уртача 6,4 дис., мордва һәм удмурт К.енә — 6 дис., татарларга 4,7 дис. имана җире бирелә. К., бигрәк тә татарлар, үз имана җирләрен арттыруның төрле юлларын эзләргә мәҗбүр булалар. 1880 еллардагы мәгълүматлар буенча татар К.е арасында аз җирләр: авыл җәмгатьләре (ир-атларга җан башына 3 дис.гә кадәр) — 43,1%, хуҗалыклар — 43,5%, игенчеләр — 43,5%, рус К.е арасында аз җирле авыл җәмгатьләре — 16,2%, чуашларда — 18,9%, мариларда 4,2% тәшкил итә.

Тимер юллар челтәре барлыкка килү, шәһәр халкының саны арту, Көнбатыш Европа базарларында а.х. продуктларына ихтыяҗ үсү крәстиян хуҗалыгының товарлыклылыгы күтәрелүгә китерә. Реформа чорында К.нең хуҗалык эшчәнлеге шактый катлаулана, аларның а.х. продукциясе җитештерүдә роле үсә. Төбәктә икмәкнең зур өлеше крәстиян хуҗалыклары тарафыннан җитештерелә. 20 йөз башында игенчелек һәм терлекчелек тулай продуктын җитештерүдә крәстиян хуҗалыкларының өлеше 90% тәшкил итә (бәяләр буенча). 20 йөз башына арыш, солы һәм бодайның чәчүлек җирләре зурая. 1880–1910 елларда Казан губернасында арышның чәчүлек мәйданнары якынча 30% ка арта. К.нең имана җирләре мәйданының кечерәюе, әйләнешкә кермәгән соңгы яткын һәм кысыр җирләрнең юкка чыгуы, уҗым арышы чәчелгән кишәрлекле өч басу системасының тагын да киңрәк таралуы бу процессның төп сәбәбе була. Сабан ашлыклары арасында солы чәчүлекләре зур урын били (мәс., 1900 дә — барлык чәчүлек мәйданнарының 28,8% ы). 1870 елларда солы б-н бергә карабодай да сабан ашлыгы буларак игелә, ләкин 20 йөз башында, бодай, солы һәм тары чәчүлекләре б-н чагыштырганда, аның чәчүлек мәйданнары кими. 20 йөздә борай чәчүлекләре барлык чәчүлек мәйданнарның 5,6% ын гына тәшкил итә. Крәстиян хуҗалыклары башлыча арыш, борай һәм карабодайга ихтыяҗ кичерә. Бәрәңге киң таралыш алмый. 1891–1900 дә бәрәңге игү һәр җан башына 0,27 чирек, ә ашлык 2,77 чирек туры килә. 1861–1900 дә К.дә ашлык уңышы һәр дис.дән уртача 32 пот, алпавытларда 37 пот тәшкил итә. Бу елларда крәстиян ашлыгының уңышы 29% ка кадәр күтәрелә. 1913 тә чәчүлек мәйданнар структурасында бөртеклеләр — 96,5%, техник культуралар — 1,6%, терлек азыгы культуралары — 0,3%, бәрәңге — 1,5%, яшелчә культуралары 0,04% тәшкил итә. Беренче бөтендөнья сугышы һәм Гражданнар сугышы елларында бәрәңге кырлары мәйданы 29,3 мең дис.дән 53,8 мең дис.гә кадәр арта.

Терлекчелек элеккечә үк крәстиян хуҗалыгында икенче урынны били. 1883 тә Казан губернасында авылларда яшәгән 1 мең кешегә 218,7 баш ат, 187,7 баш мөгезле эре терлек туры килә. 1903–08 дә умарталыкларның һәм умарта ояларының саны 4,2 меңнән һәм 93,7 меңнән 6,8 меңгә һәм 131,8 меңгә кадәр арта.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан К.нең а.х. инвентаренда сизелерлек үзгәрешләр күзәтелә. 20 йөз башында Казан губернасы авылларында 53 меңнән артык тимер сабан, 10 мең җилгәргеч һәм сортларга аеру җайланмасы, 1 меңнән артык суктыргыч һәм ургыч исәпләнә. Яңа игенчелек техникасының төп өлеше (60% тан артыгы) авыл буржуазиясе кулында туплана, урта хәлле хуҗалыкларда ул 32% чамасы була, ярлы хуҗалыкларда 7% тан артмый. Ярлылар һәм урта хәллеләрнең зур өлеше примитив техника куллана: 100 сөрү коралына 17 авыр сабан, 75 сука, 6 косуля (суканың бер төре), 2 сабан туры килә (басуларның 17% ы — авыр сабан, 75% ы — сука, 8% ы косуля б-н эшкәртелә).

Капиталистик мөнәсәбәтләрнең тиз үсеше крәстиян халкында җитештерүнең игенчелек б-н бәйле булмаган тармакларына тартылу процессын көчәйтә. 1857–97 дә Казан губернасының К. секторында а.х. җитештерүчеләре исәбе 94% тан 84,7% ка кадәр кими. 1880 еллар уртасында Казан губернасында игенчелек б-н бәйле булмаган 23 кәсеп б-н 20 мең кеше шөгыльләнә, шулардан 16,3 мең кеше өйләрендә эшли. Шул ук вакытта авылдагы вак эшмәкәрләрнең 60% ы имана җире б-н бәйле була. Моннан тыш, реформа барган чорда читкә китеп эшләүче К. шактый күбәя (сатылган паспортларның уртача еллык исәбе буенча): аларның саны 15,2 мең кешедән (1861–70) 147,8 мең кешегә кадәр (1891–1900) арта. 1913 тә читкә китеп кәсеп итү б-н 228317 кеше шөгыльләнә. Читкә китеп эшләгән а.х. эшчеләренең сезонлык уртача хезмәт хакы 10 сумнан 25 сумга кадәр тирбәлә, ләкин аларның өйләренә алып кайткан акчалары 10–15 сумнан артмый.

К.нең җир күләме буенча катлауларга аерылуы аларның барлык күрсәткечләр буенча бүленүенә китерә. Бай тормышлы К. (к. *Кулаклар*) милкендә чәчүлек җирләр, атлар, терлекләр, инвентарь, камилләштерелгән машиналар һ.б. күбрәк була. 1880 елларда Казан губернасында руслар арасында ярлы К. һәм батраклар төркеменә авыл халкының 39,7% ы, урта хәллеләргә — 48,7% ы, авыл буржуазиясе төркеменә 12% ы керә; татар авылларында бу нисбәт — 56,8%, 37,9% һәм 5,3%. Катлауларга бүленү К.нең төрле төркемнәрендә сан ягыннан үзгәрешләргә генә түгел, авылның тормыш рәвешендә дә чагыла. Ярлылар хезмәт итү өлкәләрен киңәйтергә мәҗбүр булалар: төрле кәсеп б-н шөгыльләнәләр, акча эшләргә ялланалар, шәһәрләргә китәләр. Бай хуҗалыкларда җир, машиналар, ашламалар сатып алына, игенчелек системалары үзгәртелә, яллы хезмәт куллану киңәйтелә. Авылда батраклар саны бертуктаусыз арта, эшче көчләр чамасыз күбәя (бу хәл барлык эшчеләргә карата 36,6% тәшкил итә). Урта хәлләләр һәм ярлылар, башлыча, хуҗалыкларның күп булуы хисабына, товарлыклы икмәкнең якынча өчтән бер өлешен җитештерәләр, җыелган икмәкнең нибары

10–15% ын гына саталар, 85–90% ын үзләре кулланалар. К.нең катлауларга аерылуына салым системасы да җирлек тудыра, чөнки салымнар керемнәр буенча түгел, ир-атларның җан башыннан чыгып билгеләнә. Ярлы К. салымнарны тулысынча түләрлек хәлдә булмыйлар, бу түләүләр буенча бурычларның бертуктаусыз артуында күренә. 1875 елга К.нең салымнар буенча түләп бетермәгән бурычлары 451,8 мең сум, 1882 елга — 2801,1 мең сум, 1891 елга 8405,8 мең сум күләмдә исәпләнә. Азык-төлек әҗәтләрен дә кертеп, авыл халкының барлык салым бурычлары 10977,4 мең сумга җыела. Шул ук вакытта К.нең ярлылануы дәвам итә. Казан губернасында крәстиян хуҗалыкларының 30% тан артык өлешендә атлар булмый, аларның 30–50% ы, а.х. б-н шөгыльләнүгә кармастан, үз ихтыяҗларын тәэмин итә алмый. К.нең аянычлы хәле крәстиян фетнәләренең төп сәбәбенә әверелә. 1861–1900 дә Казан губернасында 263 крәстиян кузгалышы, ш.и. 117 — рус, 75 — татар, 19 чуаш К.е чуалышлары була. Элеккеге алпавыт (64,5%) һәм патша гаиләсе (удел) (34,9%) К.е аларда аеруча актив катнаша. 1861 елгы крәстиян реформасыннан соң кузгалышларның иң зур ташкыны булып уза (к. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы*). Ашлык уңмау, салым бурычларының артуы, икмәккә бәяләр төшкәннән соң, тормыш шартларының катлаулануы, салым изүенең көчәюе 1870 еллар ахырында — 90 елларда К. активлыгы үсүенә китерә. Бигрәк тә татар К.е активлык күрсәтә (к. 1878–79 дагы *татар крәстияннәре кузгалышы*, 1892–94, 1896–97 дәге *татарларның баш күтәрүләре*), алар үзләрен милли һәм дини яктан кыерсыткан күрсәтмәләрне гамәлдән чыгаруны таләп итәләр. Рус булмаган халыкларны системалы рәвештә руслаштыру, туган телнең ролен түбәнсетү, милли гореф-гадәтләргә кимсетүле мөнәсәбәт татар К.енең күченүләренә (өлешчә чит илгә китүгә дә) сәбәп була (к. *Мөһаҗирләр хәрәкәте*). Шулай да төп таләпләр сыйфатында К. салымнарны һәм йөкләмәләрне киметүне (46,2%) һәм имана җирләрен арттыруны (11%) алга куялар; алар ш.у. патша чиновникларының башбаштыкларына каршы чыгалар (30%). Крәстиян чуалышларының 37% ы диярлек хәрби командалар җәлеп итеп бастырыла.

*Беренче бөтендөнья сугышы* елларында Казан хәрби округыннан армиягә 290 меңнән артык кеше, башлыча, К. чакырыла. Сугыш чорында крәстиян хуҗалыкларында продуктив һәм эш терлекләренең баш саны, а.х. культураларының (бигрәк тә бодайның һәм техник үсемлекләрнең) чәчүлек мәйданнары кими, аларның уңдырышлылыгы түбәнәя, крәстиян инвентаренең бер өлеше яраксыз хәлгә килә. Сумның инфляциясе, икмәк бәяләренең тиз үсүе, иң кирәкле сәнәгать товарларына бәяләрнең тагын да тизрәк күтәрелүе нәтиҗәсендә К.нең хәле авырая. Бай тормышлы крәстияннәрдә һәм алпавытларда икмәк сатуга кызыксыну булмый, алар икмәкнең зур запасларын үз кулларында тоталар һәм натуралата алмашуга өстенлек бирәләр. 1916 да патша хөкүмәте Казан губернасында икмәккә тотрыклы бәяләр урнаштырырга, армияне икмәк б-н тәэмин итү өчен 1917 нең 1 гыйнварыннан *продразвёрстканы* гамәлгә кертергә омтыла. 1916 ел ахырында — 1917 ел башында шәһәрләргә икмәк китерү кими. Аның зур өлешен спекулянтлар сатып ала, алар, бәяләр үсүеннән файдаланып, зур байлык туплыйлар. Барлык өязләрдәге ярлы хуҗалыкларга да икмәк җитми. Терлекчелек продуктлары, шикәр, үсемлек мае җитештерү мәсьәләсе тагын да кискенрәк тора. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Вакытлы хөкүмәт барлык җирләрдә дә диярлек продразвёрстка кертергә һәм азык-төлеккә ныклы бәяләр билгеләргә тырыша, тик аның бу омтылышы нәтиҗәсез тәгәлләнә.

Окт. рев-циясе җиңгәннән соң, большевиклар һәм эсерларның «җир» һәм «җирне социальләштерү» турындагы декретларын гамәлгә ашыру барышында, хосусый җирбиләүчелек бетерелә, барлык җир биләмәләре яңа социаль нигездә яңадан бүленә. К.гә өстәмә рәвештә 714 мең дис. чамасы алпавыт, кабинетлар, удел җирләре һ.б. биләмәләр бирелә. Жан башына исәпләнгән имана җире 10,4% ка (1,47 дис.дән 1,64 дис.гә кадәр) арта. Ул русларда — 1,89 дис., татарларда — 1,52 дис., милли азчылык вәкилләрендә (мариларда, удмуртларда, чуашларда һ.б.да) 1,51 дис. тәшкил итә. 1918 дә азык-төлек диктатурасы урнаштырыла (к. «*Хәрби коммунизм*»). «Артык икмәкләрен» яшергән һәм икмәкне «яшерен» базарда саткан («капчыкчылык») К.гә карата репрессия чаралары кулланыла. 1918 нең август-сентябрендә шәһәр б-н авыл арасында мәҗбүри товар алмашу кертелә, ләкин ул, сәнәгать товарлары җитмәү аркасында, сизелерлек нәтиҗәләр бирми. 1919 ның гыйнварында продразвёрстка гамәлгә керә. Авылда «җирне социальләштерү» декретын тормышка ашыру барышында хуҗалык итүнең яңа формалары — күмәк хуҗалыклар оештырыла (*к. Колхоз, Авыл хуҗалыгы коммунасы, Совхоз, Җирне бергәләп эшкәртү ширкәте*). 1920 елга чәчүлек мәйданнар — 22% ка (2,2 млн. дис.дән 1,71 дис.гә кадәр); арыш уңышы — 2,5, солыныкы — 2,1, карабодай уңышы — 2,7, ашлыкның гомуми җыемы 4,3 тапкыр, атларның баш саны (1917–21 дәге мәгълүматлар буенча) — 41% ка (586 меңнән 346 мең башка кадәр), мөгезле эре терлекнеке 48,7% ка (742 меңнән 389 мең башка кадәр) кими.

1920 еллар башында, К.нең имана җирләре мәйданының кискен кимүе сәбәпле, дәүләт тарафыннан һәр крәстиян хуҗалыгы өчен чәчеләчәк культуралар күрсәтелгән мәҗбүри чәчү планы билгеләү юлы б-н мәсьәләне җайга салу омтылышы була. Моның өчен чәчүлек ком-тлары (посевкомнар) һәм К.нең орлык материалын туплау җәмәгать пунктлары оештырыла. Ләкин дәүләтнең а.х җитештерүенә тыкшынуы К. һәм сов. хөкүмәте арасында каршылыкларның кискенләшүенә генә китерә. Казан губернасында 30 лап эре крәстиян чуалышлары булып уза (к. *Арча ягы крәстияннәре кузгалышы, «Сәнәкчеләр» фетнәсе*). 1921 нең мартында ил хөкүмәте «хәрби коммунизм» сәясәтенең нигезсез булуын таный һәм *яңа икътисади сәясәтне (нэп)* гамәлгә кертә. 1920 еллар башындагы начар табигать-климат шартлары крәстиян хуҗалыкларында хөкем сөргән икътисади вазгыятьне һәм азык-төлек мәсьәләсен тагын да катлауландыра (к. *Ачлык (1921–22)*). 1924 тән игенчелек продукциясен җитештерү темплары акрынлап үсә башлый (1923 тә икмәкнең гомуми җыемын 100% дип исәпләгәндә, 1925 тә ул — 306% ка, 1926 да 426% ка кадәр арта).

Крәстиян хуҗалыгында элеккечә үк арыш, солы, бодай, арпа, карабодай, борай һ.б. традицион культуралар булып кала. Арыш һәм солы бөртекле культуралар чәчүлекләренең яртысыннан күбрәк өлешен били. 1927–28 дә сабан ашлыгы чәчүлекләрендә бөртекләләр — 76%, бүлбелеләр һәм тамыразыклар — 10%, үләннәр — 9,5%, техник культуралар 4,5% тәшкил итә. Татар К.енең чәчүлекләр структурасында, русларныкы б-н чагыштырганда, беркадәр үзенчәлек күзәтелә. 1925 тә Татарстанда татар К.енең сабан ашлык чәчүлекләрендә солы (% ларда) — 41,9, рус К.енекендә — 25,8, бодай, әлеге нисбәттә — 7,3 һәм 10,1, арпа — 1,38 һәм 10,1, карабодай — 12,9 һәм 17,7, борай — 6,2 һәм 5,1, борчак — 6,3 һәм 6, ясмык — 5,3 һәм 3,9, җитен — 1,5 һәм 3,8, киндер 0,9 һәм 1,2 били. 1920 елларның 2 нче яртысында Татарстанда, уртача алганда, һәр дисәтинәдән 30–40 пот икмәк җыела.

1920 елларда дәүләт органнары тарафыннан крәстиян хуҗалыкларында терлекләрнең токымнарын яхшырту буенча эш башкарыла. 1927 гә Татарстанда 274 дәүләт каплату пункты исәпләнә, 1922–27 дә аларда К.нең 60 меңләп сыеры каплатыла. К. терлекләре токымнарын яхшырту өчен Бестужев, Холмогор һәм Ярославль токымлы үгезләр файдаланыла. Ләкин атсыз һәм сыерсыз хуҗалыклар күп була (мәс., 1924 тә 43,9% — атсыз, 49,0% — бер атлы, 6,2% — ике атлы, 31,1% — сыерсыз, 58,7% — бер сыерлы, 9,5% — ике сыерлы, 0,5% күп сыерлы хуҗалыклар исәпләнә). Хәтта крәстиян хуҗалыкларын массачыл рәвештә күмәкләштерү башланыр алдыннан да К.не терлекләр б-н тәэмин итүдә мөһим үзгәрешләр күзәтелми. 1927 дә крәстиян хуҗалыкларының 35% тан артыгының салымнар түләргә хәлләреннән килми, шуңа күрә алар салымнардан азат ителә. Авыл хуҗалыгының түбән керемле булуы һәм үсешенең артта калуы, чагыштырмача һәм абс. аз җирлелек К. арасында *эшсезлек* артуга китерә. ТАССР мәгълүматлары буенча, 1926–27 дә авылларда 213 меңләп шартлы эшсез исәпләнә, ягъни К.нең 34% ының даими эше булмый.

К.нең күпчелеге туфрак эшкәртүдә, уңышны урып-җыюда элеккечә сука, сабан, чалгы, урак һәм чабагач куллана; ләкин крәстиян хуҗалыгы бу хезмәт коралларына да еш кына кытлык кичерә. 1926 да 100 *га* чәчүлек мәйданга уртача 9,07 сабан туры килә. Мәсәлән, 1925 нең язында К. арасында уздырылган сорашу мәгълүматлары буенча, крәстиян хуҗалыкларының 51,5% ы — үз милекләрендәге, 42,9% ы — арендаланган, 5,6% ы катнаш милектәге а.х. инвентареннан файдаланганнар. Бер үк вакытта, 1920 елларда, совхозларда һәм колхозларда гына түгел, өлеш-

чә крәстиян хуҗалыкларында да суктыргычлар, җилгәргечләр, ургычлар, сортларга аеру машиналары, талкылар, печән кыскычлар, салам турагычлар һ.б. катлаулы а.х. машиналары кулланыла, аларның күбесе алпавытлардан һәм кулаклардан тартып алына. Катлаулы машиналар арасында ургычлар, җилгәргечләр һәм сортларга аеру машиналары өстенлек итә (мәс., 1920 дә крәстиян хуҗалыкларында 2738 ургыч, 18675 җилгәргеч һәм сортларга аеру машинасы була). Татарстан а.х.нда тракторлар кулланыла башлый (1928 дә паркта 135 трактор исәпләнә). Бу техниканың зур өлеше совхозларда һәм колхозларда игенчелек эшләрендә файдаланыла. Крәстиян хуҗалыкларының техник базасы шактый примитив була, эшләрнең 90% ы чамасы кул көче б-н башкарыла. К.нең шактый өлеше гади а.х. инвентаре куллана. Мәсәлән, Буа кантонында крәстиян хуҗалыкларында 34673 сука, 1907 косуля һәм сабан, 15173 авыр сабан исәпләнә.

1920 елларда авылларда хуҗалык итүнең яңа формалары — колхозлар һәм совхозлар үсеш ала. Бу хуҗалык берләшмәләре, башлыча, ярлы, өлешчә урта хәлле хуҗалыклар җирлегендә оештырыла. 1927 дә Татарстанда 397 күмәк хуҗалык, ш.и. 15 коммуна, 145 артель, 199 а.х. һәм 38 посёлок ширкәте исәпләнә. 1928–29 да кооперативлар секторында 49,4 мең *га* җир һәм 6,2 мең баш ат була. 1928 дә колхозлар секторы барлык крәстиян хуҗалыкларының 0,5% ын колачлый (ш.у.к. *Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү*). 1920 еллар ахырында Татарстанда 123 совхоз булып, алар биләгән җирләр республикадагы барлык чәчүлек мәйданнарның 0,25% ын тәшкил итә. 1928–29 да дәүләт секторында 10,3 мең *га* җир һәм 1,6 мең баш ат исәпләнә. Үзләренең икътисади күрсәткечләре буенча колхозлар һәм совхозлар крәстиян хуҗалыкларыннан әллә ни аерылмыйлар.

1920–30 елларда авылларда күпләп дөньяви мәктәпләр, наданлыкны бетерү пунктлары, клублар, уку өйләре һ.б. мәдәни-массачыл һәм мәгариф учреждениеләре ачыла башлый. 1928/29 уку елында Татарстанда 2504 мәктәп эшли, аларда 181300 бала, ш.и. 91882 татар, 75862 рус һәм 13556 башка милләт балалары укый. Мәктәпләрнең 80% чамасы авыл җирләрендә эшли. Ләкин К.нең белемлелек дәрәҗәсен күтәрү процессы акрын бара. 1926 да үткәрелгән халык санын алу мәгълүматлары буенча, наданнар исәбендәге 565 мең кешедән (15 яшьтән 50 яшькә кадәр) 1926/27 уку елында — 18,7 мең, 1927/28 дә — 22 мең, 1928/29 да 50 мең кеше укырга-язарга өйрәнә. 1927/28 уку елында 658 пункт эшли, аларда житлеккән яшьтәге 22002 кеше укый. 1928 дә Татарстанда 501 уку өе хезмәт күрсәтә. 1920 еллар уртасына авыл җирендә татар К.е акчасына 800 дән артык мөселман дини мәктәпләре ачыла, аларга 30 меңнән артык шәкерт йөри. 1930 елларда наданлыкны бетерү хәрәкәте барышында 800 меңнән артык крәстиян укып чыга. 1940 еллар башына К. арасында грамоталылык 80% чамасы тәшкил итә (ш.у. к. *Культура революциясе*). 1926 ел ахырына крәстиян хуҗалыклары төп күрсәткечләр буенча 1917 дәге дәрәҗәгә якынлаша. 1917 дәге а.х. күрсәткечләрен 100% дип исәпләгәндә, торгызу чоры нәтиҗәләре түбәндәге мәгълүматлар б-н билгеләнә: чәчүлек мәйданнар — 93,4%, атларның баш саны — 68,6%, мөгезле эре терлекләр — 97,5%, сарыклар — 76,7%, дуңгызлар 91,8% тәшкил итә. 1928–29 да гомуми чәчүлек мәйданы 2546,05 мең *га* (ш.и. крәстияннәр секторында — 2486,3 мең *га*), атлар 535 мең баш (ш.и. крәстияннәрдә — 527 мең чамасы) исәпләнә.

1927–28 дәге һәм 1928–29 дагы икмәк әзерләү кампанияләре вакытында гадәттән тыш чаралар гамәлгә кертелү һәм нэп принципларыннан баш тарту нәтиҗәсендә аграр секторда гаять үзенчәлекле вазгыять урнаша. Хуҗалыкны камилләштерүгә, а.х. инвентарен һәм терлекләрнең продуктлылыгын арттыруга юнәлтелгән һәртөрле омтылыш кулаклар исәбенә кертелүдән курку аркасында туктала. Салым түләүләрен җыю һәм а.х. продукциясен тартып алу буенча үткәрелгән гадәттән тыш гамәлләр К.не сыйныф буларак бетерү чарасына әверелә башлый. Икмәк әзерләү буенча катгый йөкләмәләр кертелгәннән соң, хәлле хуҗалыкларны бетерү тагын да киңрәк колач ала (к. *Кулакларны йорт-җирләреннән куу*). Бу сәясәтнең драматик дәвамы К. язмышындагы кискен борылышка — аларның хуҗалыкларын ирексезләп күмәкләштерүгә кайтып кала. 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында барлык крәстиян хуҗалыклары да диярлек (аларның гомуми исәбе 520 меңнән арта) күмәк хуҗалыкларга берләштерелә, аларның төп эш башкару кораллары (ш.и. җир) җәмәгатьләштерелә һәм колхозларның бүленмәс фондына әверелә. Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү барышында крәстиян терлекләренең баш саны — 207,3 мең башка (23,5%), ш.и. сыерларныкы — 137,9 меңгә (29,6%), дуңгызларныкы — 186,9 меңгә (56,1%), сарыклар һәм кәҗәләрнеке — 2001,3 меңгә (3 тапкырга), атларныкы (1934 ел мәгълүматлары буенча) — 340,3 меңгә (37,5%), ш.и. эш атларының баш саны 275,9 меңгә (23,2%) кими. 1930 елларның 2 нче яртысында Татарстанда 70857 аерым крәстиян хуҗалыгы булып, алар файдалануында 107428 *га* сөрүлек җирләр исәпләнә. Бу чорда җирдән файдалануның аерым хуҗалыкка туры килгән уртача район нормасы 1,7 *га* чамасы тәшкил итә. 1950 еллар башында барлык аерым крәстиян хуҗалыклары бетерелә. 1932 дә илдә паспорт системасы гамәлгә кертелү б-н, колхоз К.енең зур өлеше 1970 елларның 2 нче яртысына кадәр колхозларга беркетелә. Колхозның гомуми җыелышы рөхсәтеннән башка К.гә паспортлар бирелми, шуңа күрә алар шәһәрдә эшкә урнаша алмыйлар. Ләкин сталинчыл җитәкчелек, икътисади зарурияттән чыгып, колхоз К.енә һәм совхоз эшчеләренә шәхси ярдәмче хуҗалыклар тотарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була, бу хуҗалыклар озак еллар дәвамында крәстиян көнкүрешенең күпгасырлык традицияләрен саклаучы ролен башкаралар.

1990 елларда, базар мөнәсәбәтләре урнашуы нәтиҗәсендә ТРда, колхозларны һәм совхозларны үзгәртеп кору б-н бергә, аерым *крәстиян (фермер) хуҗалыклары* үсеше өчен сәяси-хокукый һәм социаль-икътисади шартлар тудырыла башлый. Ш.у. к. *Авыл хуҗалыгы.*

Чыг.: Труды статической экспедиции, снаряжённой в 1883 году Казанским земством. К., 1884; Казанская губерния в сельскохозяйственном отношении по сведениям, полученным от корреспондентов за 1885 год. К., 1885. Вып. 5; Материалы для исследования промыслов населения Казанской губернии. К., 1887; Общий свод данных хозяйственно-статистического исследования Казанской губернии. Часть экономическая. К., 1896; Казанская губерния в сельскохозяйственном отношении за 1907 год. К., 1909.

*Әд.:* Попов И.П. О движении крестьянского скотоводства Казанской губернии. К., 1858; шулук. Породы домашних животных и птиц. СПб., 1909; Вечеслав Н. Экономический быт крестьян Казанской губернии // Тр. Казан. губернского стат. комитета. 1870. Вып. 1; Энгельгардт А.П. Очерк крестьянского хозяйства в Казанской и других средневолжских губерниях. К., 1892; Обзор кустарных занятий в Казанской губернии. К., 1896; Воробьёв Н.И. Казанские татары (этнографическое исследование материальной культуры дооктябрьского периода). К., 1953; Ермолаев В.М., Шараф Р.Ш., Хасанов М.А. Очерки по экономической географии Татреспублики. К., 1931; Климов И.М. Образование и развитие Татарской АССР (1920–1926). К., 1960; Бусыгин Е.П. Русское сельское население Среднего Поволжья. К., 1966; Халиков А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Литвин А.Л. Крестьянство Среднего Поволжья в годы гражданской войны. К., 1972; Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании. К., 1973; Залялов А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Петренко А.Г. Древнее и средневековое животноводство Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1984; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма (социально-экономическое исследование). М., 1984; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1995; Хайрутдинов Р.Р. Управление государственной деревней в Казанской губернии в конце XVIII — первой трети XIX вв. К., 2002; Шайдуллин Р.В. Крестьянство Татарстана: экономический и общественно-политический аспекты (1920–1929). К., 2004.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КРӘСТИЯННӘ́Р ҖИР БА́НКЫНЫҢ КАЗА́Н БҮЛЕГЕ́**, 1886 елда җирне залогка салу хисабына крәстияннәрне озак вакытка ссудалар б-н кредитлау өчен оештырыла. Төп максаты 1861 елгы реформаны алга таба җәелдерү, крәстияннәрнең җирсезлеген һәм аз җирлелеген бетерү була. Эре җирбиләүчеләр һәм крәстияннәр арасында җир сату-сатып алу вакытында арадашчы ролен башкара. Казан һәм Вятка губерналары терр-яләрендә эшчәнлек алып бара. 1895 нең 27 ноябрендә кабул ителгән Устав банкка һәм аның бүлекләренә киләчәктә крәстияннәргә сату өчен үз капиталлары хисабына җир сатып алу хокукы бирә. 1906 ел 3 ноябрь Фәрманы б-н җирне чикләүсез күләмдә сатып алу һәм әйләнешкә заклад кәгазьләре чыгару рөхсәт ителә. Казан бүлеге карамагында 684 мең дис. җир була (1906). 1906–15 тә бүлек тарафыннан 49138 дис. җир сатыла, аның арадашчылыгы аша крәстияннәр 110127 дис. җир сатып алалар. 1917 нең декабрендә национализацияләнә.

**КРӘСТИЯННӘ́Р КУЗГАЛЫШЫ́** (1670–71), Россиядә казаклар, крепостной крәстияннәр, посад кешеләренең хөкүмәткә каршы Идел буе халыклары (татарлар, чуашлар, марилар, мордвалар һ.б.) да катнашкан хәрәкәте. Донны һәм Идел буен колачлый. 17 йөзнең 2 нче яртысында крепостной изүнең көчәюе, социаль каршылыкларның кискенләшүе нәтиҗәсе булып тора. С.Т.*Разин*, В.Р.Ус, Ф.Шелудяк җитәкчелегендә оештырыла. 1667–69 да Разин ярлы казаклар һәм качак крәстияннәр отряды б-н Каспий яр буендагы шәһәрләргә талау походлары («за зипунами») оештыра. 1670 нең язында Разин гаскәре Иделгә юнәлә. Май–июньдә баш күтәрүчеләр Царицын, Әстерхан шәһәрләрен алалар. Августта Саратов, Самара шәһәрләре Разин ягына күчә. Сентябрьдә Разин гаскәре Семберне камап ала. Татарлар хәрәкәте Идел буендагы башка халыклар хәрәкәте б-н бер үк вакытта башлана. Алар баш күтәрүчеләргә килеп кушылалар һәм разинчыларның күп кенә сугышларында катнашалар. 1670 нең сентябрендә Сембер һәм Зөя өязләренең баш күтәргән татарлары башкалар б-н бергә Алатырь шәһәренә һәм өязенә аларны «бөлдерү өчен» барырга җыеналар. Чыганакларда Сембер һәм Корсун тирәләрендә хәрәкәт итүче казаклар, татарлар, чуашлар һәм мордвалардан торган 6 мең кеше турында мәгълүматлар бар. 1670 нең 19 сентябрендә татарлар Саранск шәһәрен алуда катнашалар. Соңрак Саранскидан Арзамас шәһәрен штурмлауга руслар, татарлар һәм мордвалардан торган отряд юнәлә; Арзамас янында сугышкан 15 мең баш күтәрүченең берничә меңе татарлар була. 1670 нең 20–27 сентябрендә баш күтәргән татарлар кенәз Ю.Н.Барятинскийның Сембергә ярдәм өчен җибәрелеп, камалуда калган гаскәрләрен Колангы авылы, Карлы елгасы, Корысадак дигән татар һәм Поклоуш исемле мордва авыллары янында тоткарлыйлар. Семберне штурмлауда Зөя морзалары һәм татарлары катнаша. Цивильск шәһәре янында төрле өязләрдән җыелган татарлар катнашындагы баш күтәрүчеләр отряды хәрәкәт итә (җитәкчеләре арасында — Зөя татары Алмакай, морза Күлдәбәков). Керенск һәм Козьмодемьянск шәһәрләрен яулаган баш күтәрүчеләр арасында да татарлар була. Хөкүмәт отрядларына каршы Темников һәм Кадом татарлары сугыша. Разин тарафдарлары кузгалыш файдасына актив агитация алып бара. Баш күтәрүчеләр, өндәмәләр җибәреп, халыкны үзләренә кушылырга чакыралар. Х.*Карачурин* язган шундый өндәмәләрнең берсе Казан һәм Казан өязе татарларына җибәрелә. Баш күтәрүчеләрне мөселман руханиларының бер өлеше яклый. Болын ягында грамоталарны аркадашлары б-н *Иштирәк абыз* тарата. Ул морзаларны, татарларны һәм чуашларны Разинны якларга чакыра. 1670 нең октябрендә Разин гаскәре Сембер тирәсендә җиңелүгә дучар була. Разин казаклар төркеме б-н Донга әйләнеп кайта. 1671 нең апрелендә ул кулга алына, июньдә Мәскәүдә җәзалап үтерелә. Казан губернасының Цивильск, Чабаксар һәм Ядрин өязләре баш күтәрүчеләре 1671 нең башына кадәр көрәшне дәвам итәләр. 1670 нең ноябре-декабрендә хөкүмәт гаскәрләре разинчылар тарафыннан яуланган Идел буе шәһәрләрен яңадан үз кулларына алалар. 1671 нең ноябрендә хөкүмәт гаскәрләре Әстерханны яулый. Кузгалыш бастырыла.

Чыг.: Крестьянская война под предводительством Степана Разина: Сб. док-ов: В 4 т. М., 1957–76.

*Әд.:* П о р ф и р ь е в С.И. Разинщина в Казанском крае. К., 1916; Ф и р с о в Н.Н. Разиновщина как социологическое явление народной жизни. М., 1920; ш у л у к. Разин и разиновщина. Пугачёв и пугачёвщина. К., 1930; Г у б а й д у л л и н Г.С. Несколько слов об участии татар в народных движениях XVII века // Вестн. Науч. об-ва Татароведения. 1930. № 9–10; С т е п а н о в И.В. Крестьянская война под предводительством Степана Разина в Среднем Поволжье // Уч. зап. Ленингр. ун-та. 1956. Вып. 24; А л и ш е в С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI–XIX вв.). К., 1999.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**КРӘСТИЯННӘ́Р КУЗГАЛЫШЫ́** (1773–75), Урал буен, Урал аръягын, Урта һәм Түбән Идел буен колачлый. Феодаль-крепостной, милли һәм дини изүнең көчәюе аркасында килеп чыга. Җаек казаклары, Урал заводларында эшләүчеләр, Идел буе һәм Урал буе халыклары (татарлар, башкортлар, марилар, мордвалар һ.б.) катнаша. 1773 елның 17 сентябрендә Оренбург губернасында император Петр III исеменнән эш итүче Дон казагы Е.И.*Пугачёв* җитәкчелегендә Җаек казаклары чыгышы б-н башлана. 1773 нең 18 сентябрендә баш күтәрүчеләр отряды Җаек шәһәрчегенә якыная, ләкин Пугачёв, артиллериясе булмау сәбәпле, аны штурмлауга бармый. Ул Оренбург шәһәренә юнәлә, анда бару юлында берничә кальганы яулап ала. 1 октябрьдә Пугачёв *Каргалы бистәсенә* керә, анда татар полкы оештырыла; аның командиры М.*Алиев* була. 5 октябрьдә баш күтәрүчеләрнең 2500 кешелек отряды (аларның 600 дән артыгы татарлар) Оренбургны ала. Ноябрьдә кузгалышта катнашучылар генерал В.А.Кар һәм полковник П.М.Чернышёв җитәкчелегендәге хөкүмәт гаскәрләрен тар-мар итәләр. Пугачёвның халыкка ирек бирү, салымнардан азат итү, дин ирегә, җир бирү һ.б. манифест һәм фәрманнары, ш.у. беренче җиңүләре баш күтәрү хәрәкәтенең географиясе киңәюгә китерә. Уфа (И.Н.Зарубин), Екатеринбург (И.Н.Белобородов), Чиләбе (И.Н.Грязнов), Самара (И.Ф.Арапов), Көнгер, Красноуфимск (И.Кузнецов, Салават Юлаев) шәһәрләре, ш.у. Җаек шәһәрчеге (М.П.Толкачёв) тирәсендә кузгалыш учаклары кабынып китә. Кайбер мәгълүматлар буенча, К.к.да Уфа провинциясендә яшәүче 34 мең һәм Казан губернасыннан 50 меңнән артык татар катнаша. К.к. барышында татарлар арасыннан Пугачёвның көрәштәшләре һәм отряд җитәкчеләре аерылып чыга — С.*Сәетов* (Пугачёвның Хәрби коллегиясе әгъзасы), Б.*Канкаев*, К.*Усаев*, Г.*Аитов*, И.*Әхмәтов* һ.б. Казан губернасында Оренбург тирәсеннән килгән аерым баш күтәрүчеләр отрядларыннан тыш (мәс., 1773 нең ноябрендә — Казан өязенең Богородское һәм Языково авылларында) җирле отрядлар оештырыла. Аларның иң күпсанлысы (3 меңгә якын кеше) — Казан–Арча–Мамадыш төбәгендә хәрәкәт иткән М.*Гомәров* отряды. Ижевск һәм Воткинск з-дларына беркетелүчеләрдән торган икенче зур отрядны (1700 ләп кеше) А.Носков җитәкли. А.Сомов, И.Богданов (Казан өязе), Й.*Енгалычев* (Казан губернасының көньяк төбәкләре), М.Мостафин һәм А.*Уразмәтов* (Бөгелмә төбәге) отрядлары хәрәкәт итә. Крәстияннәр хакимияте урнашкан Тирсә волостенда баш күтәрүчеләр җитәкчеләренең берсе Ә.*Сөләйманов* була. Крәстияннәрнең бер өлеше кузгалышта катнашучылар сафына ирекле рәвештә кушыла, башкалары исә Пугачёв боерыгы, баш күтәрүчеләр хакимиятләре һәм учреждениеләре күрсәтмәләре нигезендә («...башкортмы, мишәрме, татармы, русмы, һәркайсына... һәр ике йорттан берәр кешегә хезмәт итәргә...» һ.б.) мәҗбүри хезмәткә чакырыла. 1773 нең декабре—1774 нең гыйнварында баш күтәрүдә катнашучылар «полковник» К.*Моратов* һәм Сяңфин җитәкчелегендә Минзәләне, Н.Әсәнов һәм А.*Асеев* кул астында Зәйне, К.Ишмәтов, Ш.Якупов, Н.Алексеев, Ш.Тәүфиков һ.б. җитәкчелегендә Алабуганы камап алалар. 1774 нең 15 гыйнварында Н.Әсәнов һәм А.Асеев отрядлары сөйләшүләр нәтиҗәсендә шәһәргә сугышсыз гына килеп керә. Әмма алдагы көннәрдә полковник Ю.Бибиков җитәкчелегендәге гаскәрләр тарафыннан баш күтәрүчеләр тар-мар ителә, 22 татар авылы буйсындырыла, Зирекле һәм Тоба авыллары яндырыла. 1774 нең гыйнвар ахырында полковник Ю.Бибиков гаскәрләре Минзәлә тирәсенә килеп җитә. Хәлиткеч сугыш Пьяный Бор авылы янында була, анда 400 гә якын пугачёвчы үтерелә. Хөкүмәт гаскәрләре киткәннән соң, баш күтәрүчеләр Минзәләне кабат камыйлар, камалыш 1774 нең мартына кадәр дәвам итә. Баш күтәрүдә катнашучылар Алабуга тирәсендә ш.у. җиңелүгә дучар булалар, 200 ләп кешене югалталар. Баш күтәрүчеләр хәрәкәтенең алга таба көчәюе Пугачёвның Казанга явы б-н бәйле. 1774 нең июнендә ул Усыны яулый, Кама аша чыгып, Әгерҗегә килеп җитә. Алабуга, Мамадыш һәм Арчаны үтеп, 11 июльдә Пугачёв Казанга якынлаша. 12 июльдә баш күтәрүчеләр Казанны штурмлыйлар. Сугыш барышында алар шәһәрне кулга төшерәләр, әмма Кремльне ала алмыйлар. 12 июль кичендә Арча кырында Пугачёв һәм подполковник И.И.Михельсон корпусы гаскәрләре арасында сугыш булып уза. 15 июльдәге бәрелештә баш күтәрүчеләр җиңелүгә дучар була (к. *Казан өчен сугыш*): 2 меңнән артык кеше үтерелә һәм 5 меңләп кеше әсирлеккә эләгә; Пугачёв гаскәре калдыклары б-н Иделнең уң ярына чыга. Пугачёвның төп көчләре чигенгәннән соң, Б.Канкаев (1774 нең июль ахырына кадәр), У.Тимеров һ.б. баш күтәрүчеләр башлыкларының отрядлары хәрәкәтне дәвам иттерә. 1774 нең 25 августында Пугачёв подполковник И.И.Михельсон корпусы тарафыннан Чёрный Яр тирәсендә тәмам тар-мар ителә. Җи-

целүдән соң меңләгән баш күтәрүчеләр каты җәзага тартыла.

*Әд.:* Губайдуллин Г.С. Участие татар в пугачёвщине // Новый Восток. 1925. Кн. 1; шул ук. Пугачёвщина и татары // Изв. об-ща обследования и изучения Азербайджана. 1927. № 4; Крестьянская война в России в 1773–1775 гг.: Восстание Пугачёва: В 3 т. Л., 1961–70; Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973; шул ук. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI–XIX вв.). К., 1999.

*И.Р.Вәлиуллин.*


**КРЕДИТАРТЕЛЬСОЮ́З**, к. *Казан төбәге кредит кооперативлары берлеге.*

**КРЕ́ЙЗЕР** Яков Григорьевич (4.11.1905, Воронеж ш. — 29.11.1969, Мәскәү), армия генералы (1962), Сов. Союзы Герое (22.7.1941). Воронеж пехота мәктәбен (1923), «Выстрел» югары офицерлар курсларын (Мәскәү, 1931), Югары хәрби академиянең тизләтелгән курсын (Мәскәү, 1942), К.Е.Ворошилов исем. Югары хәрби академия каршындагы Югары академик курсларны (Мәскәү, 1949) тәмамлый. 1921 елдан Кызыл Армиядә. 1923–41 дә укчы подразделениеләр һәм частьләр, дивизия б-н җитәкчелек итә, Казан пехота уч-щесендә эшли. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында; 1 нче мотоукчы дивизия командиры (20 нче армиянең Көнбатыш фронты). 1941 нең июлендә Белоруссиянең Борисов, Орша шәһәрләрендәге оборона сугышларында батырлык күрсәтә; Сов. Союзы Герое исеменә лаек булган беренче совет хәрби башлыкларыннан. 1943 нең августыннан 51 нче армия, сугыштан соң 45 нче армия, Көньяк-Урал, Байкал аръягы, Урал,



Я.Г. Крейзер.

Ерак Көнчыгыш хәрби округлары гаскәрләре б-н җитәкчелек итә. 1963 тән «Выстрел» курслары башлыгы, 1969 дан СССР Оборона министрлыгының ген. инспекторлар төркемендә. 1962–66 да СССР ЮС депутаты. Биш Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрә-




С.Х. Алишевның "Урта Идел татарлары Пугачёв кузгалышында" ("Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании". К., 1973) китабы буенча төзелде.

җә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Гринько А.И., Улаев Г.Ф. Богатыри земли Воронежской. Воронеж, 1965; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Навечно в сердце народном. Минск, 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КРЕЛЛЕНБЕ́РГ** Генрих Иванович (1829, Лифляндия губ. Перново ш. — 1898, Казан), педагог. Перново шәһәрендә пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1851), Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә латин теле укыта, 1856 елдан инспектор, 1861–96 да директор. Бер үк вакытта, 1884–96 да Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында инспектор. 1861–62 дә Мәгариф министрлыгы карары б-н Көнбатыш Европа илләрендә командировкада була, аның хисаплары гимназиянең яңа уставын төзегәндә мөһим роль уйный.

*Әд.:* Владимиров В.В. Историческая записка о Первой Казанской гимназии: В 3 ч. К., 1867–68; Горталов Н.К. Памятная книжка Императорской Первой гимназии на 1897/1898 уч.г. К., 1897. *Е.В.Липаков.*

**КРЕМЛЁВ** Анатолий Николаевич (1859, Казан — 1919, Петроград), хокук белгече, язучы. 1880 елда Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлый. 1880 елларда Казанда мировой судья булып эшли, 1890 елларда — Петербургта антлы ышанычлы. 1917 дән соң Петроградта Эшче һәм солдат депутатларының район советы әгъзасы. У.Шекспир, А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь иҗатлары буенча брошюралар; тәрҗемә мәсьәләләренә, рус-инглиз әдәби бәйләнешләренә караган мәкаләләр; «Сайланма шигырьләр» («Избранные стихотворения», 1887), «Иске һәм Яңа Дөнья җырлары» («Песни Старого и Нового Света», СПб., 1910) исемле шигъри җыентыклар, тәрҗемәләр, пьесалар авторы.

*З.А.Старицына.*

**КРЕМЛЁВ** Николай Александрович (11.7.1833, Тобол губ. Төмән округы — 12.4.1910, Казан), хокук белгече, гражданлык хокукы д-ры (1868), яшерен советник (1906). Сәүдәгәрләр нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1855). 1856–57 елларда Казан уку-укыту округы попечителе канцеляриясендә өстәл башлыгы ярдәмчесе. 1857–62 дә Казандагы Беренче һәм Икенче ир балалар гимназияләрендә укытучы. Бер үк вакытта, 1858–90 да (бүленеп), Казан ун-тында: 1861–67 дә адъюнкт, 1867–68 дә доцент, 1868–83 тә ординар проф., 1885 тән Рим хокукы кафедрасының атказ. профессоры; 1876–83 тә юридик ф-т деканы, 1872–76, 1885–89 да ректор. 1879–81 дә Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында сыйныфлар инспекторы (Казан). 1883–85 тә Демидов юридик лицее директоры (Ярославль ш.). 1890 нан Юстиция министрлыгы каршында консультация бүлеге әгъзасы һәм 1909 га кадәр Петербург ун-тының Рим хокукы каф. приват-доценты, 1875–76 да Халык мәгарифе министрлыгы каршында 1863 елгы университет уставын яңадан карау комиссиясе әгъзасы. Хезмәтләре Рим хосусый хокукына, милеккә хуҗа булу һәм аны сату-алу мәсьәләләренә карый. Казан игенчелек колонияләре һәм һөнәрчелек приютлары җәмгыятенең оештыручы-әгъзасы (1872) һәм рәисе (1872–81). Казан ун-ты каршындагы Юридик җәмгыятьнең оештыручы әгъзасы (1879) һәм рәисе (1879–81). Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый (1886), Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1891).



Н.А. Кремлёв.

Хезм.: К учению о праве добросовестного владельца на плоды. К., 1866; Сепарация как способ приобретения собственности добросовестным владельцем по классическому римскому праву. К., 1868.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Дормидонтов Г.Ф. Речь, сказанная на похоронах ... Н.А.Кремлёва. К., 1910; Нольде А.Э. Н.А.Кремлёв: Некролог // Журн. М-ва нар. просвещения. Новая сер. 1911. Ч. 31; Казанский университет (1804–1904): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1. *Е.Б.Долгов.*


**КРЕ́МНИЙЛЫ СУ́ҮСЕМНӘР** (Bacillariophyta), түбән төзелешле үсемлекләр бүлеге, 300 ырукка караган 20 меңгә якын хәзерге һәм казылма төрләре билгеле. ТР терр-ясендә К.с. ырукларының түбәндәге вәкилләре киң таралган: гомфонема (Gomphonema), табеллярия (Tabellaria), диатома (Diatoma), мелозира (Melosira), синедра (Synedra), ропалодия (Rhopalodia) һ.б. Төче сулыклар планктоны һәм бентосы составына кергән өлешләре су үсемлекләрендә, сазлык өсләкләрендә һәм мүк түмгәкләрендә, ташларда, туфракта һәм аның өслегендә яшиләр. Бер күзәнәкле микроскопик (4–1000 *мкм*) организмнар ялгыз яки төрле типтагы колонияләргә тупланып яши: чылбыр, җеп, тасма, йолдызчык, куакчык яки лайлалы әлпәләр. Күзәнәк протопласттан тора, ул исә панцирь-кремнезёмлы тышча б-н әйләндереп алынган, панцирь берсе өстенә икенчесе салына торган 2 капкачтан тора. Целлюлоза тышчасы юк. Хлоропластлар төсләренең интенсивлыгына, аларның зурлыгы төрлечә булуга һәм суүсемнәрнең яшәү рәвешенә бәйле: планктон төрләрдә алар — алтынсыман-сары, вак, диск формасында; төптәге һәм субстратка беркетелгәннәрдә — эре, пластинкасыман, кара көрән төстә. Тышкы тирәлек б-н матдәләр алмашы панцирь стеналарындагы тишемнәр аша бара. К.с.дә фотосинтез процессы вакытында запас матдәләр: май, волютин туплана. Туенуы күбесенчә автотроф. Еш кына күзәнәкләрнең ике өлешкә вегетатив бүленүе б-н үрчи. Органик матдәләр чыганагы буларак, алар даими азык базасы һәм күп кенә организмнар өчен азык чылбырында беренчел звено булып тора. Корыган вакытта, бактерияләр һәм иң түбән төзелешлеләрнең туенуы өчен кирәк булган детрит һәм эрүчән органик матдәләрне зур күләмдә бирә. К.с. умырткасыз хайваннар һәм күп кенә балык маймычлары өчен азык булып тора. К.с. панцирьларыннан кремний токымнары утырмалары: диатомитлар һәм трепеллар барлыкка килгән.

*Әд.:* Жизнь растений. М., 1977. Т. 3.

**КРЕПОСТНОЙЛЫ́К ХОКУКЫ́** (крепостнойлык), крәстияннәрнең феодаль бәйлелек формасы, аларны җиргә беркетү, феодалның адм. һәм мәхкәмә хакимиятенә буйсындыру. 13–15 йөзләрдә феодаль бәйлелек мөнәсәбәтләре крәстияннәрнең күп өлешенә тарала, ләкин К.х. ул вакытта әле зур үсеш алмый. 15 йөз уртасыннан крәстияннәрнең кайбер категорияләре өчен феодаль бәйлелектән чыгу чикләнә; ул Юрий көненә (27 ноябрь) кадәрге һәм аннан соңгы икешәр атна арасындагы вакыт б-н билгеләнә. Гомумдәүләт нормасы буларак, яшәгән өчен салым (пожилое, ягъни крәстиян утарыннан файдаланган өчен хуҗа файдасына җыем) күләмен тәгаенләгән 1497 елгы Судебник (Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III заманында кабул ителә) б-н беркетелә. Патша Иван IV нең 1550 елгы Судебнигы б-н бу салымның күләме арттырыла һәм, бәйлелектән чыгуның вакыты кыскартылып, ул Юрий көне б-н генә чикләнә. 16 йөзнең 2 нче яртысында тыюлы еллар (крәстияннәрнең бәйлелектән чыгуын вакытлыча тыю) һәм билгеләнгән еллар (качак крәстияннәрне эзләү вакыты) турындагы фәрманнар чыга. К.х. 1649 елгы Кануннар мәҗмугасы б-н (патша Алексей Михайлович заманында) тәмам ныгытыла. 17–18 йөзләр дәвамында феодалның крәстиян шәхесенә карата хокуклары арта, тора-бара крепостнойлар гражданлык хокукларының һәм шәхси ирекләренең барысын да диярлек югалталар. 17 йөзнең 1 нче яртысында җирбиләүчеләр ихтыярына буйсынмаган крәстияннәргә тән җәзасы бирү кертелә. 1741 дән алпавыт крәстияннәре патшага ант бирүдән читләштерелә, бу дворяннарның крепостнойларны милеккә әверелдерүен монополияләштерүгә китерә. 18 йөзнең 2 нче яртысында алпавытларга ошамаган утар кешеләрен һәм крәстияннәрне Себергә (1760), каторга эшләренә сөрү (1765), төрмәләргә ябу (1775), балаларны ата-аналарыннан аеру (1760) хокукы турындагы фәрманнар чыгарыла. Крепостнойны үтергән очракта алпавыт җавап тотмый яки кечерәк кенә җәзага тартыла (мәс., 1831 дә Тәтеш алпавыты А.В.Страхов биләмәсендә газаплаулардан 4 кеше үлә, ләкин ул җәзага тартылмый). Крәстияннәр К.х.на каршы көрәшәләр, баш күтәрәләр, крәстиян сугышлары башлыйлар (к. *Крәстияннәр кузгалышы* (1670–71), *Батырша хәрәкәте, Крәстияннәр кузгалышы* (1773–75)). 18 йөздә К.х. илнең җитештерүче көчләре үсешендә төп тоткарлык факторына әверелә, мәдәни һәм социаль алгарышка комачаулый. К.х.н чикләү һәм бетерү турындагы проектлар эшләнә башлый. 1803 тә кабул ителгән «Ирекле игенчеләр турында»гы закон нигезендә крәстияннәрнең азсанлы өлешенә беркадәр ирек бирелә. Крепостной крәстияннәр төп өч төркемгә бүленә: 1) алпавытныкылар (к. *Алпавыт крәстияннәре*), 2) төрле ведомстволар карамагындагылар (*посессион крәс-*

*тияннәр*), 3) хосусый заводларга һәм фабрикаларга беркетелгәннәр (*Казна эшенә беркетелгән крәстияннәр*). Алпавыт крепостнойлары алпавыт җирендә урнаштырылган крәстияннәргә һәм җирләре булмаган утар кешеләренә аерыла.

Казан төбәгендә К.х. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан, Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан соң (1552), тыюлы еллар һәм билгеләнгән еллар турындагы фәрманнар нигезендә формалаша башлый. Казан губернасында крепостной крәстияннәр 1765 тә — 45800 кеше (губернадагы авыл халкының



Кияүгә бирү өчен 40 сумга сатылган крәстиян кызы Анисия Борисовна исеменә язылган таныкнамә. ТР Милли музее.

17,4%ы), 1835 тә — 96219 ир-ат (14% чамасы), 1857 дә — 212851 кеше (103088 ир-ат, шулардан 7846 сы утар кешесе; 109763 хатын-кыз, шулардан 8097 се утар кешесе) исәпләнә. Алпавыт җирбиләүчелеге, башлыча, кара туфраклы өязләрдә таралыш ала; 1857 дә: Лаеш өязендә — 58990 крепостной (шулардан 4789 ы — утар кешесе), Спас өязендә — 28331 (1768), Зөя өязендә — 25126 (1221), Казан өязендә — 19782 (1830), Тәтеш өязендә — 14694 (910), Цивильск өязендә — 4588 (729), Мамадыш өязендә — 2144 (201), Ядрин өязендә — 2038 (65), Царёвококшайск өязендә 760 кеше (42 крепостной) алпавытларга бәйле була. Утар кешеләре саны буенча 1857 дә Казан губернасы Россиядә 27 нче урынны били. Казан губернасындагы барлык җирләрнең 3353169 дисәтинәсеннән 831784 дис. (24,8%) алпавытлар милкендә була, шуның 310900 дисәтинәсеннән крәстияннәр файдалана, алпавытлар карамагында 454850 дис. (шуның 59,4%ын — 211405 дис. урманнар һәм 194754 дис. сөрүлек җирләр тәшкил итә) исәпләнә. Гадәттә, крепостной крәстияннәрнең имана җирләре башка крәстиян төркемнәренекенә караганда кечерәк була: уртача алганда, губерна буенча алар ревизияләрдә теркәлгән җан башына 3 дис. чамасы туры килә (Зөя өязендә — 3,73 дис.гә кадәр, Спас өязендә — 3,09 дис., Казан өязендә — 2,91 дис., Тәтеш өязендә — 2,8 дис., Лаеш, Чистай һәм Мамадыш өязләрендә — 2,2 дән 2,4 дис.гә кадәр). 1800–61 еллар арасында имана җирләренең мәйданы 2 тапкырдан да күбрәккә кими. Казан губернасы алпавытларының күпчелеген вак биләмәләләр тәшкил итә. 19 йөзнең 1 нче яртысында эре биләмәләләр (500 һәм аннан да күбрәк крепостнойларга хуҗа булучылар) 907 алпавыттан 9 гына кеше була, алар арасында алпавытлар Болховскийлар, *Молоствовлар,* Сахаровлар, Толстойлар аерылып тора (1000 нән 4000 гә кадәр крепостной). Казан алпавытларының зур өлеше 100 гә кадәр санда крепостной били (588 алпавыт). Губернадагы крепостнойларның күпчелеге барщина йөкләмәсен үти (86% чамасы); барщина үсә бара һәм 19 йөздә ул атнаның 4–5 көненә җитә. 18 йөзнең 1 нче яртысында алпавыт крәстияннәреннән җан башыннан 74 тиен, 18 йөз ахырында 6 сум чамасы, 19 йөз уртасында 15 сум салым алына. Оброк түләүчеләр: Казан өязендә — 77%, Зөя өязендә — 71%, Тәтеш өязендә — 17,3%, Чистай өязендә — 16,4%, Лаеш өязендә — 7,63%, Спас өязендә — 2,7%, Мамадыш өязендә — 0,47%. Капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсендә Казан губернасында мануфактуралар барлыкка килә, 18 йөздә аларда, башлыча, крепостной крәстияннәр эшли. 18 йөздә Казанда крепостнойлар хезмәтеннән файдаланган иң эре пр-тиеләр — Адмиралтейство һәм Постау мануфактурасы. Кайбер алпавытлар үз утарларында ук производство оештыралар, мәс., поташ з-дларының барысы да диярлек алпавытлар милкендә була, гадәттә, аларның һәрберсендә 5–7 кеше эшли. 1812 дә Казанның 137 пр-тиесендәге 4732 эшченең 1457 се крепостнойлардан була (30,84%), 1857 дә губернада заводларга 1597 крепостной беркетелә. К.х. *Крәстиян реформасы* (1861) б-н бетерелә, ләкин аның алпавыт җирбиләүчелеге, алпавытка эшләү кебек калдыклары Россиядә 1917 гә кадәр, аралашкан басу, община (авыл җәмәгате) h.б. 1930 елларга кадәр саклана.

*Әд.:* Тройницкий А. Крепостное население России по 10-й народной переписи. СПб., 1861; Селовский В.И. Крестьянский вопрос в России в XVIII и первой половине XIX в.: В 2 т. СПб., 1888; Чернышёв Е.И. Татария в период разложения крепостного строя // Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1; Греков Б.Д. Крестьяне на Руси с древнейших времен до XVII в.: В 2 кн. М., 1952–54; История Татарской АССР (с древнейших времён до наших дней). К., 1968; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма (социально-экономическое исследование). М., 1984.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КРЕ́СТНИКОВО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 37 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 210 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, бакчачылык. Тулы булмаган урта мәктәп. 1565–67 еллардан Кече Пустошь Кайлеп исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рус Кайлепы буларак телгә алына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1912 дә ачыла), җил һәм су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 451 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 140 ир-ат; 1859 да — 275, 1897 дә — 294, 1908 дә — 361, 1920 дә — 385, 1926 да — 285, 1938 дә — 357, 1949 да — 430, 1958 дә — 248, 1970 тә — 286, 1979 да — 250, 1989 да — 228, 2002 дә — 204 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый. К., 2001.

**КРЕСТО́ВНИКОВЛАР**, Мәскәү һәм Казан сәүдәгәрләре, эшмәкәрләр. Чыгышлары б-н крәстияннәрдән. 18 йөз уртасыннан Переяславль сәүдәгәрләре. Сәүдәгәрләр династиясен нигезләүче булып 1 нче гильдия Переяславль сәүдәгәре **Козьма Васильевич** (1755–1814) исәпләнә. 1772 елда Мәскәүгә күчеп килә, рафинад-шикәр һәм буяу-агарту з-длары (Мәскәү), туку фабрикасы (Мәскәү губ., Мәскәү өязе Поляны а.) ача. 1812 елгы Ватан сугышы чорында Россия армиясе файдасына 50 мең сум акча күчерә.

Аның балалары: **Александр** (1794–1850), **Ксенофонт** (1796–1832) һәм **Константин** (1796–1841), Мәскәү сәүдәгәрләре. 1831 дә «Бертуган А., К. һәм К. Крестовниковлар» сәүдә йорты (1849 дан «А.Крестовников кардәшләре б-н», 1851 дән «Бертуган Крестовниковлар һәм К°») оештыралар. 1855 тә Казанда *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү һәм химия заводы*, 1859 да нигез капиталы 600 мең сум булган «Казан күн заводы пай ширкәте» эшли башлый. К. «*Сәүдәгәрләрнең сәүдә биржасы*»н (1866) һәм «Казанский биржевой листок» г-тасын (1869) ачуны башлап йөриләр. 1871 дә К.ның фирмасы 2 млн. сум нигез капиталы булган «Крестовниковларның фабрика-сәүдә пай ширкәте» булып акционерлаша.

Аның оныгы **Григорий Александрович** (10.1.1855, Мәскәү — 1918, шунда ук), сәнәгатьче, җәмәгать эшлеклесе, нәселдән килгән дворян (1910 нан). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1878). 1878–79 да Казан химия з-дында эшли, 1879–91 дә Мәскәү-Курск тимер юллары җәмгыятендә идарә әгъзасы. 1887 дән «Фабрика-сәүдә...» идарәсе директоры, 1890 еллар башыннан Мәскәү сәүдәгәрләр банкы башлыгы, советы рәисе (1903–17). 1892–94 тә Мәскәү биржа ком-ты старшинасы, 1905–15 тә рәисе. 1906–15 тә Дәүләт Советы әгъзасы. 1905 тә «Сәүдә-сәнәгать партия»сен оештыручыларның берсе була,

1906 дан «Унҗиденче октябрь берлеге» партиясенең ҮК әгъзасы.

*Әд.:* Семейная хроника Крестовниковых: В 3 кн. М., 1903–04; Отечественная история: Энцикл. М., 2000. Т. 3.

**КРЕСТО́ВНИКОВЛАР ЗАВОДЫ́ БИНАЛАРЫ́ КО́МПЛЕКСЫ**, Казанда, 19 йөз — 20 йөз башы сәнәгать архит-расы ядкәре. Иске Татар бистәсе һәм Пләтән авылы янындагы Югары Кабан күленең көнбатыш ярына урнашкан. 1855 елда нигез салына. *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү һәм химия заводы* башта зур турыпочмаклы ишегалдыннан, периметр буенча төзелгән бер һәм ике катлы кызыл кирпеч корпуслардан һәм ике биек җылыту системасы торбаларыннан тора. Аның терр-ясендә Крестовниковларның агачтан салынган ике катлы торак йорты була. Завод үсә, берничә тапкыр үзгәртеп корыла һәм 20 йөз башында технологик процесслар б-н бәйләнгән зур биналар комплексы барлыкка килә. Урамның кызыл сызыгы буенча бер-берсенә якын урнашкан ике һәм дүрт катлы корпуслар үсеп чыга, комплексның төп фасадын тәшкил итүче капка һәм кирпеч койма корып куела. Сузынкы ике катлы корпус ишегалды ягыннан уксыман һәм а́ркалы тәрәзәләр б-н бизәлә, кыек түбә б-н ябыла. Тагын ике корпус, баскычсыман композиция ясап, 1–2 катка калкыбрак тора; ике кат арасындагы тар кәрнизләрдә декоратив бизәлеш алымнары кулланылган. Әлеге биналар шундый ук архит-ралы башка җитештерү корпуслары урнашкан ишегалдын урамнан аерып тора. Сигез кырлы торба башка корпуслар өстеннән биек булып күтәрелә. Рев-циядән соң завод дәүләт карамагына тапшырыла, совет чорында М.Вахитов исем. химия комб-ты дип атала. Иске биналарга реконструкция ясала, яңа җитештерү һәм адм. корпуслар төзелә. Хәзер «*Нәфис Косметикс*» АҖ.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

**«КРЕСТЬЯ́НСКАЯ ГАЗЕ́ТА»** («Крәстиян газетасы»), иҗтимагый-сәяси басма. 1906 елның 29 гыйнварыннан 2 ноябренә кадәр Казанда рус телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә, 73 саны чыга. Наширләре — А.Ф.Гросс, Н.А.Башмаков; мөхәррирләре — С.А.Маслов, А.А.Себякина.

**«КРЕСТЬЯ́НСКАЯ ЖИЗНЬ»** («Крәстиян тормышы»), иҗтимагый-сәяси басма. Казан губерна земствосы органы. 1918 елның 24 гыйнварыннан 1 февраленә кадәр Казанда рус һәм татар телләрендә 8 саны нәшер ителә. Мөхәррире — Казан губерна земство җыены вәкаләтле вәкиле В.Вегер. Газета «илнең барлык демократик көчләренең, Россия халыкларының федератив демократик республика, рус социализмы агымнары нигезендә берләшүен, Учредительләр җыенына хезмәт халкы мәнфәгатьләрен яклау мөмкинлекләре бирүне, барлык социалистик партияләрне берләштерүче хакимият төзүне» яклый. «*Земская неделя*» ж-лы редакциясе б-н тыгыз хезмәттәшлек итә. «К.ж.» битләрендә 100 нче Гадәттән тыш Казан губерна җыелышы (1918 нең 10 гыйнварында ачыла) карарлары яктыртыла, газета аның карары нигезендә чыгарыла. Җыелыш, Учредительләр җыенының эшчәнлеген торгызуны таләп итүе өчен, большевиклар тарафыннан куып таратыла. Редакция Казан Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының 1918 нең 30 гыйнварында игълан ителгән Казан шәһәр думасын бетерү турындагы декретын кискен тәнкыйтьли. Газетаның соңгы санында: «Бөтен халык сайлаулары нәтиҗәсендә төзелгән учреждениене таркатырга аларга кем хокук биргән? Бу — башбаштаклык. Без большевиклар б-н килешмибез», — диелә. Совет хакимияте органнары Игъланнар монополиясе турындагы декретны бозу сылтавы б-н басманы яптыра. Шуннан соң земство яңа «*Трудовой путь*» г-тасы чыгара башлый.

*Т.М.Насыйров.*

**«КРЕСТЬЯ́НСКАЯ КАЗА́НСКОГО ГУБЕ́РНСКОГО ЗЕ́МСТВА ГАЗЕ́ТА»** («Казан губерна земствосының крәстияннәр газетасы»), иҗтимагый-сәяси басма. 1917 елның 18 июленнән 20 декабренә кадәр Казанда рус телендә 121 саны нәшер ителә. Мөхәррирләре — С.П.*Покровский*, А.А.Колегаев. Газета б-н М.Вахитов, М.Гурьянов, П.Дульский, Г.Залкинд, С.Знаменский, А.Иванов, Д.Карягин, П.Леонтьев, М.Ляхов, М.Маркелов, Г.Мирянин, Н.Никольский, Г.Скитский, И.Шадрин, П.Ящерицын хезмәттәшлек итәләр. Газетада Н.Колесников шигырьләре еш басыла. Даими рубрикалары: «Сугыш», «Газеталардан», «Көн вакыйгалары», «Петроград телеграф агентлыгы телеграммалары», «Кооперация», «Аграр мәсьәлә», «Икътисади аңгәмәләр», «Хроника (Казан яңалыклары)», «Өлкә бүлеге (Губерна өязләреннән хәбәрләр)», «Театр һәм музыка». Газета, губернаның вакытлы матбугат басмаларыннан берсе буларак, төбәк тормышын киң яктырта: губерна һәм өяз земстволары, земство идарәләре, губерна һәм земство җыеннары эшчәнлеге турында хәбәрләр бирә; земство мәктәпләре, шифаханәләре, фельдшерлык пунктлары, аптека челтәрләре булдыру, почта, телеграф һәм телефон учреждениеләре эшчәнлеге, азык-төлек б-н тәэмин итү, иҗтимагый тәрбия торышы, аграр хезмәт һәм прокат пунктларын оештыру юлы б-н крәстиян хуҗалыкларын үстерүгә булышу, юллар төзү һәм төзекләндерү турында җентекләп бәян итә. Язмаларда Россиянең республикачыл үсеш юлы һәм Учредительләр җыенын чакыру идеясе пропагандалана. Редакция Вакытлы хөкүмәт сәясәтен яклый, аның тарафыннан чыгарылган «Ирек заёмы»на язылырга чакыра. Газетада Казандагы 1917 елгы Окт. вакыйгалары, хәрби гарнизон эшчәнлеге киң яктыртыла; һәлак булганнар һәм яралылар исемлекләре басыла. Редакция Окт. рев-циясе һәм большевикларның элеккеге хакимият органнарын бетерү турындагы декретына, большевикларныкы булмаган басмаларны ябуга тискәре мөнәсәбәттә була. 1917 нең 31 октябрендә анда А.Ф.Керенскийның большевикларга барлык чаралар б-н каршылык күрсәтү турындагы күрсәтмәсе басылып чыга. Октябрь ахыры — ноябрь башында, кайбер материалларны цензура үткәрмәгәнлектән, газета буш битләр б-н чыга (1917 ел 23 ноябрь саны яртылаш буш беренче бит һәм «Яшәсен сүз ирегә һәм матбугат ирегә!» шигаре б-н чыгарыла). Басма Учредительләр җыенына сайлауларда актив катнаша, 3 нче (кооператорлар һәм бәйсез социалистлар) һәм 9 нчы (Казан эсерлар партиясе ком-ты) исемлекләргә кертелгән кандидатлар өчен тавыш бирергә чакыра. 1917 елның ноябрь–декабрендә газетада большевикларның гамәлләре — күпсанлы кулга алулар, Учредительләр җыены эшенә каршылыклар тудыру, Германия б-н сепарат солых төзергә омтылыш һ.б. тәнкыйтьләнә. Крәстиян депутатларының Казанда уздырылган 3 нче губерна съезды 1917 нең 17 декабрендә уң эсерлар газетасын ябарга карар чыгара. 1918 елның 24 гыйнварында Казан губерна земствосы аның урынына «*Крестьянская жизнь*» г-тасын чыгара башлый.

*Әд.:* Мухарямов М.К. Октябрь и национальный вопрос в Татарии (октябрь 1917 — июль 1918 гг.). К., 1958; Окороков А.З. Октябрь и крах русской буржуазной прессы. М., 1970; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975. *Т.М.Насыйров.*

**КРЕ́ТОВ** Анатолий Степанович (1.6.1952, Тула өлкәсенең Новомосковск ш.), очкыч аппаратларның ныклыгы һәм аларны проектлаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2002). 1975 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре очкыч аппаратларның җылылык-көч конструкцияләрен проектлаштыруга карый. К. үтә көчле җылыту һәм йөкләнеш шартларында эшли торган конструкцияләр проектлаштыру алымнарын булдыра. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: Проектирование нагретых конструкций максимальной жёсткости // Изв. вузов. Авиац. техника. 1996. № 4 (автордаш); Проектирование термосиловых конструкций по условиям прочности // Изв. вузов. Авиац. техника. 1999. № 1; Прочность высокотемпературных конструкций летательных аппаратов. К., 2004 (автордаш).

**КРЕ́ЧЕТОВ** Александр Михайлович (26.8.1885, Таганрог ш. — 26.12.1948, Баку), драма актёры, режиссёр, педагог. Сәхнә эшчәнлеген 1903 елда Екатеринодар шәһәрендә М.М.Петипа труппасында башлый, Рязань, Иваново, Калуга, Әстерхан, Ростов-Дон, Одесса, Харьков (Н.Н.Синельникова труппасында) шәһәрләре театрларында уйный. 1932–36 да Мәскәүдә Кызыл Армия Үзәк театрында, 1941–46 да Баку рус драма, 1922–24, 1926–27 дә Казан Зур драма театрларында эшли. Күп кенә зур рольләр башкара: Репетилов («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Борис Годунов («Фёдор патша», «Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой), Марк Волохов («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча), Лаврецкий («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев романы буенча), Свидригайлов («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча), Каренин, Нехлюдов, Сергий атакай («Анна Каренина», «Катюша Маслова», «Сергий атакай», Л.Н.Толстой әсәрләре буенча), Пётр патша («Патша улы Алексей», Д.С.Мережковский), Отелло (У.Шекспир-

ның шул исем. әсәре буенча) һ.б. К. — социаль-психол. портрет остасы, рольләрне искиткеч яхшы башкара, үзенең һәр роленә масштаблылык һәм тирәнлек өсти белә. Бер үк вакытта режиссёр булып та эшли. Казан Зур драма театрында «Мәкер вә мәхәббәт», «Юлбасарлар» («Коварство и любовь», «Разбойники», Ф.Шиллер), «Бөркеткәй» («Орлёнок», Э.Ростан), «Кеше тормышы» («Жизнь человека», Л.Н.Андреев), «Павел I» (Д.С.Мережковский); Татар дәүләт театрында «Мәкер вә мәхәббәт» (Ф.Шиллер), «Трильби» (Г.Г.Ге) әсәрләрен сәхнәләштерә. Шул театр студиясендә һәм Татар театр техникумында укыта. *Ю.А.Благов.*

**КРЕ́ШЕТОВ** Евгений Васильевич (3.8.1938, Владимир өлкәсе Муром ш. — 30.12.1996, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1994). 1961 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1985 тән хирургик стоматология каф. мөдире. Хезмәтләре балаларның яңак-бит авыруларын дәвалауга, кискен одонтоген инфекция вакытында гумораль һәм күзәнәкләр иммунитетларын, кискен одонтоген остеомиелит очрагында бөер өсте бизләре эшчәнлеген өйрәнүгә карый. К. яңак һәм бит ялкынсынуларын дәвалау ысулларын; сөяк өчен дәвамлы кулланылышлы инфузион җайланма, маңгай ретракторын тәкъдим итә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Некоторые показатели функции надпочечников у больных острым одонтогенным остеомиелитом челюстей в зависимости от методов лечения: Дис. ... К., 1970; Обследование больных с хирургическими стоматологическими заболеваниями. К., 1996.

*Әд.:* А н д р е е в И.М., К р а с и л ь н и к о в С.Н. Крешетов Евгений Васильевич // Стоматологический факультет. История в биографиях. К., 1996.

**КРИВОНО́СОВ** Иван Семёнович (1810, Казан — 1892, шунда ук), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан, җәмәгать эшлеклесе. Итчеләр мәйданында май эретү з-ды (җитештерүчәнлеге елга 1500 пот сарык мае), таш кибетләр, Новогоршечная урамында терлек чалу бинасы, таш йорт, Өченче тауда агач йорт, Казан губернасы Лаеш өязендә 250 дис. болынлык җирләре хуҗасы. Ит һәм терлек мае (туңмай) б-н сәүдә итә (ел саен кышкы саклауга 20 мең пот әзерләп куела). 1849–52, 1871–75 елларда Казан шәһәр думасы гласные. 1857–60 та Казан шәһәре җәмәгать банкы директоры иптәше (урынбасары). 1852–63 тә Богоявление чиркәве старостасы. 1876 дан Александр хастаханәсе һәм аның каршындагы чиркәү попечителе. Казан губернасының Мамадыш өязе Әрнәш (Албай) авылында чиркәү һәм аның руханилары өчен ике йорт, Александр хастаханәсе каршында Александр Невский чиркәве, квадрат рәвешендәге Апостол Андрей Первозванный чиркәве б-н Богоявление чиркәве чаң манарасы (25 мең сум), Васильево авылында земство мәктәбе, балалар ятимханәләре һ.б. төзелешләргә акчалата ярдәм итә. 1888 дә үз өендә 20 кешелек гариплар йорты ача (вафатыннан соң йорты тулысынча шул максатларга тапшырыла һәм аның исеме б-н атала). Хәйрия эшчәнлеге алып барган өчен Балалар ятимханәләре баш попечительлегенең Казан бүлеге шәрәфле әгъзасы итеп сайлана. 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, Станислав тасмалы алтын һәм көмеш медальләр, Кызыл Хач билгесе б-н бүләкләнә.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н. Казань и казанцы. К., 1906. Кн. 1. *Л.М.Свердлова.*

**КРИВОШЕ́ИН РАЙОНЫ́**, *Томск өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 елның 12 июлендә оештырыла. Мәйданы — 4400 *км²*. Үзәге — Кривошеино авылы (Томск шәһәреннән 170 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 15,1 мең кеше (2010), 2002 дә 421 татар (1989 да — 483 кеше). Татарлар, башлыча, Кривошеино һәм Яңа Исланбул авылларында яши, 1980 елларга кадәр тагын бер татар авылы — Нөркәй булган. Хәзерге вакытта Яңа Исламбул мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. Кривошеино авылында «Нур» мөселман дини оешмасы эшли (1998 дән). К.р.нда Сов. Союзы Герое Ф.Г.*Камалетдинов* туган.

**КРИНА́РИ** Александр Иванович (25.5.1917, Вятка губ., Уржум өязе Щипок а. — 1.8.1997, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. канд. (1950). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1941), Көньяк Урал геол.-разведка партиясендә эшли, эзләнү эшләре башлыгы (1945–48). 1948 елдан ЦНИИгеолнерудта, СССРда һәм дөньяда бердәнбер нәметаллар геологиясе ин-тын оештыручы һәм аның директоры (1964–84). Коллекторлар классификациясен эшли. СССРда руда булмаган файдалы казылмаларның минераль чимал базасын фәнни тикшерүләрне җитәкли. СССР Геология министрлыгының Фәнни-техник советы әгъзасы (1964–84). Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Коллектора нефти в терригенных отложениях девона востока Татарии. М., 1969; Перспективы поисков промышленных месторождений цеолитов в СССР // Советская геология. 1970. № 4.

**КРИСТА́ЛЛ КЫРЫ́**, кристалл эчендәге ирекле ноктада бу кристаллик рәшәткәне тәзүче атомнарның (ионнарның) барлык электроннары һәм төшләре тудырган электр кыры. Каты җисем физикасында К.к. төшенчәсе кристалларда электрон сүрүләре тулы булмаган парамагнитик ионнарның энергетик спектрын тикшергәндә кулланыла. К.к. ирекле ионның өстәлеп үскән мультиплетларын (термнарын) ваклый һәм спектрның һәр ион һәм кристаллик рәшәткә өчен үзенчәлекле структурасын формалаштыра. Беренче тапкыр мондый ваклауларның симметрияле анализын немец физигы Х.Г.Бете таба (1929). Үз эченә ирекле ион энергиясе б-н бәррәттән ионда локальләшкән электроннарның К.к. б-н тәэсирләшү энергиясен дә алган Гамильтон операторына кристаллдагы парамагнитик ион энергиясе каршы куела.

Ионның спектрын төзү һәм дулкын функцияләрен билгеләү мәсьәләсе ярсынулар теориясе алымнары б-н чишелә. К.к. теориясендә К.к. параметрларын исәпләүнең күпчелек алымнары нигезендә парамагнитик ионны



А.М.Кречетов.



А.И.Кринари.

һәм аның якын тирәлеген үз эченә алган кластерлардагы бер электронлы энергияләрне квант-механик исәпләүләр ята. 20 йөзнең 2 яртысында Казан ун-тында парамагнитик кристалларны оптик һәм магнитик резонанслы спектроскопия алымнары ярдәмендә систематы тикшерүләр, алынган нәтиҗәләрне интерпретацияләү һәм квант электроникасының эшче җисемнәре сыйфатламасын фаразлау өчен, К.к. теориясен тагын да үстерү таләп ителә. Кристаллик рәшәткәнең составы һәм структурасы б-н парамагнитик ионнарның энергетик спектры арасындагы үзара бәйләнешләрне ачык билгеләү максатында, Б.З.Малкин К.к. теориясенә ярымфеноменаль — алмашулы корылмалар моделен (МОЗ) кертә: бу ачыш Женева ун-ты (Швейцария) проф. К.Йоргенсенның почмакча капланыш моделен гомумиләштерә. МОЗда җөп К.к.ның параметрлары валентлык электроннарының дулкынча функцияләрен һәм лигандларның дулкынча функцияләрен каплаучы интеграллар квадратларының сызыкча функцияләре рәвешендә бирелә. МОЗ куллану К.к.ның так компоненты параметрларын да төгәл исәпләргә мөмкинлек бирә, бу компонент төп конфигурация халәтләре арасындагы электрик диполь күчешләргә җавап бирүче парамагнитик кристалларның оптик спектрлары көчен билгели. М.В.Ерёмин үзенең шәкертләре б-н бергә МОЗның микроскопик нигезләмәсен тәкъдим итә, электрон конфигурацияләр аралашу б-н бәйләнгән эффектларга җентекле анализ ясый, кристаллдагы валентлык электроннары арасында электростатик тәэсирләшү үзгәрешләре тудырган коррелир К.к.ны анализлый.

К.к.ны кристаллик рәшәткә тирбәнешләре б-н модуляцияләү электрон-фонон тәэсирләшүенең иң нәтиҗәле механизмы булып тора. Казан ун-тында төзелгән МОЗны куллангарда электрон-фонон тәэсирләшүенә бәйләнгән төрле эффектларның микъдари анализына, К.к.дагы парамагнитик ион спектры төзелешеннән чыгып билгеләнүче параметрлардан тыш, өстәмә феноменаль параметрлар таләп ителми.

*Әд.:* Б а л ь х а у з е н К. Введение в теорию поля лигандов. М., 1964; А б р а г а м А., Б л и н и Б. Электронный парамагнитный резонанс переходных ионов: В 2 т. М., 1972–73; Е р ё м и н М.В. Теория кристаллического поля в диэлектриках // Спектроскопия кристаллов. Л., 1989; M a l k i n B.Z. Crystal field and electron-phonon interaction in rare-earth ionic paramagnets // Spectroscopy of solids containing rare-earth ions. Amst., 1987. Ch.2. *Б.З.Малкин.*



**Кристаллик нигез.** 1. Гранатлы гнейс. 2 мең *м* дан артык тирәнлектәге кристаллик нигездән. Татарстан; 2. Кристаллик сланец. 5 мең *м* дан артык тирәнлектәге кристаллик нигездән. Татарстан; 3. Пирротинлы биотит — гранатлы гнейс. 3 мең *м* дан артык тирәнлектәге кристаллик нигездән. Татарстан.

**КРИСТА́ЛЛИК НИГЕ́З**, җир кабыгының өске гранит өлеше; утыртма тышлыкны каплаучы геол. киселешнең аскы структур ярусы. Татарстан терр-ясендә К.н. архей һәм түбән протерозой чорлары токымнарыннан тора (к. *Архей, Протерозой*). Тулысынча өйрәнүләр Миңлебай, Яңа Елховойның үтә тирән скважиналарында үткәрелә. К.н. тирәндәге җимерелүләр б-н төрле зурлыктагы, рәвештәге һәм матди составтагы кисәкләрдән тора, төньякта 1,52 мең *м*. дан — төньяк-көнчыгышта 3 мең *м* га кадәр тирәнлектә ята.

К.н.нең эре тектоник элементлары: *Татар гөмбәзе, Токмов гөмбәзе, Казан–Киров бөгелеше*, Кама–Агыйдел (к. *Югары Кама иңкүлеге*) һәм Серноводск-Абдулино авлакогены. К.н. өслеге җилләнү нәтиҗәсендә барлыкка килгән токымнардан тора. К.н. токымнарында руда минераллары таралган (магнетит, ильменит, алтын һ.б. минераллар), җимерелүләр зонасында углеводородлар күчеше эзе бар. Тирәнрәк урыннарда нефть һәм газ булуы мөмкин. Р.Х.*Мөслимов* фикеренчә, К.н.нең тирән өлешеннән даими рәвештә утырма тышчасындагы нефть ятмаларына углеводородлар күчә.

*Әд.:* Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996; М у с л и м о в Р.Х. Потенциал фундамента нефтегазоносных бассейнов — резерв пополнения ресурсов углеводородного сырья в XXI веке // Георесурсы. 2003. № 4; К а в е е в И.Х., Г а т и я т у л л и н Н.С., М у с л и м о в Р.Х. Основные этапы изучения кристаллического фундамента в Татарстане // шунда ук.

**КРИСТАЛЛОГРА́ФИЯ** (грек. krýstallos — боз, тау хрустале һәм *графия*), матдәнең кристаллик халәте һәм кристаллар турындагы фән. Табигый (ш.и. тере организмнарда) һәм синтетик кристалларның симметриясен, төзелешен, ясалышын һәм үзенчәлекләрен өйрәнә. К. бурычларыннан берсе — катлаулы органик кушылмаларның төзелешен ачыклау. Мөстәкыйль фән буларак, 18 йөз уртасында барлыкка килә һәм *минералогия* б-н тыгыз бәйләнештә үсә. Кристалларны кырлап эшкәртү законнары ачыклана (фр. галимнәре Ж.Ромэ-Делиль, 1783; Р.Аюи, 1784); кристалларның тышкы формалары симметриясе теориясе (рус галиме А.В.Гадолин, 1867) һәм аларның эчке фәзаи төзелеше теорияләре үсеш ала (фр. галиме О.Браве, 1848; рус кристаллографы Е.С.Фёдоров, 1890; немец галиме А.Шёнфлис, 1891 һ.б.), кристаллар төзелеше ачыклана (ингл. физиклары У.Г. һәм У.Л.Брэг, 1913). К. үсеше ш.у. рус галимнәре Г.В.*Вульф*, Е.Е.Флинт, Н.В.Белов, А.В.Шубников, А.И.Китайгородский һ.б., Америка галиме Л.Полинг, немец физигы В.Фохт һ.б. эшчәнлекләре б-н бәйле. К. геометрик (тышкы форма һәм эчке төзелеш өйрәнелә), физик (кристаллофизика, кристалларның физик үзенчәлекләрен тикшерә) һәм физик-химик (кристаллохимия) өлешләргә бүленә. Кристаллар синтезлау өчен теоретик нигез булып тора (алмаз, германий, зөбәрҗәт, кварц һ.б.).

Татарстанда кристалларны тикшерү 19 йөздән башлана. 1893 елда Г.В.Вульф дөньяда кристаллографлар киң куллана торган «Вульф челтәре»н эшли. Кристаллар почмакларын төгәл үлчәү буенча теоретик эшләр башкарыла.

Күкерт, авгит, крокоит, целестин һ.б. минералларның кристаллик формалары катышмаларның изоморф һәм изоморф булмаган характерда кристалларга үтүе, аларның кристалларда урнашуы; альбитларның оптик үзенчәлекләренең химик составы б-н бәйләнеше; корунд кристаллары буенча слюда псевдоморфозлары (Ф.Ф.*Розен*, П.И.*Кротов*, Л.М.*Миропольский*, Б.А.Успенский һ.б.) өйрәнелә; кристалларның магнит үзенчәлекләре радиоспектроскопик ысуллар б-н тикшерелә. 20 йөзнең 2 нче яртысында яңа фәнни юнәлеш — *минераллар физикасы* (В.М.*Винокуров*) төзелә. Кристаллофизика һәм кристаллохимия (А.И.*Бахтин*, Г.Р.Булка, Н.М.Низаметдинов һ.б.), кристаллогенез (В.А.Тимесков, В.П.Морозов һ.б.) буенча тикшеренүләр үткәрелә. ЦНИИгеолнерудта Т.З.*Лыгина* җитәкчелегендә руда булмаган минераль чималның төп төрләрен рентгентөзелеш фазалы (В.В.Власов, С.А.*Волкова*), спектроскопик (В.А.Гревцев, В.Ф.*Крутиков*) дифференциаль термик (Е.Н.Шляпкина, А.М.Гобәйдуллина) һәм фотолюминесцент (В.А.Гревцев) анализ ысулы б-н структур-кристаллохимик характеристикаларын билгеләү буенча федераль стандартлар эшләнә.

*Әд.:* У и т т е к е р Э. Кристаллография. М., 1983; В и н о к у р о в В.М. История кафедры минералогии и петрографии Казанского государственного университета. К., 1990.

*В.А.Тимесков.*

**КРИЧИ́НСКИЙ** Степан Самойлович (20.1.1874, Вильно губ., Ошмян өязе Каскевичи а. — 9.8.1923, Петроград), архитектор. Польша-Литва татарларыннан. 1897 елда Петербургта Гражданлык инженерлары ин-тын тәмамлый. 1899–1917 дә Чик буе сакчылары корпусының баш архитекторы. 1918–20 дә Кубань политехник ин-ты профессоры, 1921 дән Гражданлык инженерлары ин-тында укыта. Башлыча, Петербургтагы һәм шәһәр янындагы йөздән артык торак һәм җәмәгать биналарының проектлары авторы. Аеруча билгеләләре арасында Парголовода Воронцова-Дашкова сарае (1908), Гатчинада Щербов йорты (1913), Петербургта Бохара әмире йорты (1913) бар. *Санкт-Петербург җамигъ мәчете* проектының автордашы һәм төзелеш җитәкчесе. Төрле стильләрдә: неоклассицизм, модерн, ясалма рус һәм эклектиканың көнчыгыш юнәлешендә эшли.

*Әд.:* Степан Самойлович Кричинский: Некролог // Зодчий. 1924. № 1; С а б л и н И.Д. Степан Кричинский // Зодчие Санкт-Петербурга. XIX — начало XX вв. СПб., 1998; Н о в и к о в П. Архитектор Кричинский // Нева. 2002. № 12.

**КРОПО́ТКИН** Пётр Алексеевич (27.11.1842, Мәскәү — 8.2.1921, Мәскәү губ. Дмитров ш.), кенәз, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе, анархизм теоретигы һәм практигы, галим, сәяхәтче. Пажлар корпусын тәмамлаганнан соң (1861), император Александр II нең камер-пажы итеп билгеләнә; бер елдан Амур казаклар гаскәренә йөзбашы итеп күчерелә. Көнчыгыш Себердә төрмәләрне һәм сөрген урыннарын үзгәртеп кору, Чита шәһәре өчен шәһәр үзидарәсе проектын эшләү ком-тлары эшчәнлегендә катнаша. Рус геогр. җәмгыяте кушуы буенча Төньяк Маньчжурия (1864), Көнчыгыш һәм Көнбатыш Саян таулары (1865–66) буйлап экспедиция оештыра һәм аны җитәкли: Себер орографиясе схемасын эшли (бу Себер орографиясе һәм геол. төзелешенә карата хөкем сөргән карашларның үзгәрүенә китерә). Экспедиция нәтиҗәләре «Русский вестник» ж-лында басыла (1862–63, 1865, 1867). 1867–70 елларда Петербург ун-тының физика-матем. ф-тында укый. 1868 дән Рус геогр. җәмгыятенең физик геогр. бүлеге секретаре. Шпицберген һәм Төньяк Җир арасында коры җир булуын теоретик яктан нигезли (соңрак анда Франц Иосиф җире дип аталган архипелаг ачыла). 1871 дә Швециягә һәм Финляндиягә оештырылган экспедицияләрдә катнаша, аның нәтиҗәләре буенча материкның бозлануы турындагы үз теориясен эшли. 1872 дә Швейцариягә бара. 1 нче Интернационал әгъзасы, М.А.Бакунинның дәвамчысы. 1872 дә Россиягә кайткач, народникларның «чайковскийчылар» түгәрәгенә кушыла. 1874 тә кулга алына, 1876 да чит илгә кача. М.А.Бакунин вафатыннан соң, анархизмның иң абруйлы теоретигы булып таныла. Анархо-коммунизм теориясен эшли («Фетнәче нотыклары», Париж, 1885, фр. телендә; СПб., 1906, рус телендә). 1877 дә Женевада «Le Revolté» ж-лын нәшер итә. 1881 дә

Россия хөкүмәте таләбе буенча Швейцариядән чыгарып җибәрелә. Франциядә һәм Англиядә яши. Революцион эшчәнлеген дәвам итә. Бер үк вакытта фәнни тикшеренүләр б-н шөгыльләнә; Британия фәнни ассоциациясе әгъзасы. Аңа дөньякүләм танылу китергән «1789–1793 еллардагы бөек француз революциясе» («Великая французская революция 1789–1793», Лондон, 1914) хезмәте авторы. 1917 дә Россиягә кайта. 1862 нең җәендә С.-Петербургтан Себергә барганда Казан губернасында була. Казанда, Козьмодемьянскида, Алабугада булып китүе турында көндәлегендә истәлекләр язып калдыра (1923 тә алар басылып чыга). К. Казандагы пароходлар пристанен, Адмиралтейство һәм Татар бистәләрен, Кремльне, шәһәрнең үзәк урамнарын, Идел (Югары Ослан а.), Кама ярларын тасвирлый. 1918 дә Казанда К.ның «Башлангычсыз коммунизм һәм экспроприация» («Безначальный коммунизм и экспроприация») дигән хезмәте басыла. Казандагы анархистлар оешмаларында К.ның анархо-коммунизм теориясенең дәвамчылары күп була. 1980 еллар ахырында — 1990 елларда Россиядә анархизм идеяләре киң тарала, М.А.Бакунинның һәм К.ның хезмәтләре яңадан басыла, 1989 да Казанда «Казан анархистлары альянсы» оешмасы төзелә (к. *Анархизм*).

К.ның туганнары (кенәз Кропоткиннар нәселенең бер тармагы) Казан губернасы дворяннары шәҗәрәсе китабының 5 нче кисәгенә кертелә (1896). Алексей Алексеевич (1856-?) — отставкадагы поручик, 1914–17 дә Цивильск һәм Ядрин дворяннары башлыгы. Е.П.Галаховага өйләнгәннән соң, Лаеш өяздендә җир һәм аракы з-ды аның милкенә күчә. Губернаның иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша, монархист була. 4 нче Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан «Крәстияннәргә», «Җирбиләүчеләргә» өндәмәләрен яза.

*Әд.:* Знаменитые люди о Казани и Казанском крае. К., 1999; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеал. словарь. К., 2001.

*А.В.Гарзавина, Л.М.Айнетдинова.*

**КРО́ТОВ** Абдулла (1920, Мордва Респ-касының Инсар р-ны Иса а. — 2002, шунда ук), татар халык җырларын туплаучы һәм башкаручы. Аңардан язып алынган 50 дән артык җырның күбесе «Татар халык җырлары» (1965) җыентыгына кертелгән.

*Әд.:* Нигметзянов М. Татарские народные песни. М., 1970; Сайдашева З., Ярми Х. Татарско-мишарские песни. Из коллекции фольклориста. М., 1976.

**КРО́ТОВ** Борис Петрович (9.6.1882, Казан — 21.9.1974, Мәскәү), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1938), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1957). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1904), шунда ук минерал. һәм геол. кафедрасында эшли, бер үк вакытта Казан вет. ин-тында укыта. 1908, 1910, 1911 елларда Мюнхен шәһәрендә стажировка үтә. 1930 елдан Ленинград тау ин-тында файдалы казылмалар каф. профессоры. 1933 тән Руда чыганаклары геологиясе, петрография һәм геохимия ин-тында, тимер рудасы чыганаклары төркеме җитәкчесе (Мәскәү). Хезмәтләре руда чыганаклары геологиясенә карый. К. тарафыннан өйрәнелгән Урал тимер рудасы чыганаклары, аерым алганда, Хәлилов хром-никель-тимер рудасы чыганагы яңа тармак — сыйфатлы табигый-эретеп катыштырылган чуен-корыч металлургиясе барлыкка килүгә сәбәп була. Дәүләт бүләге Хәлилов тимер-руда чыганагын ачканы өчен бирелә. СССР ФА каршындагы Урал табигый ресурсларын мобилизацияләү комиссиясе әгъзасы (1942–45), бер үк вакытта СССР Баш геол. ком-ты һәм Авыр сәнәгать халык комис-тының Никель һәм кобальт сәнәгате баш идарәсе әгъзасы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Доломиты, их образование, условия устойчивости в земной коре. К., 1925; Дифференциация элементов при выветривании на примере Урала. М., 1959.


*Әд.:* К 100-летию со дня рождения Б.П.Кротова // Литология и полезные ископаемые. 1982. № 5.

**КРО́ТОВ** Пётр Иванович (21.9.1852, Вятка губ., Глазов өязе Елово а. — 24.11.1914, Казан), геолог, минерал. һәм геол. д-ры (1888). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1878), шунда ук эшли, геогр. һәм этнография (1895 елдан), геол. һәм палеонтология (1905 тән) кафедраларын җитәкли, физика-матем. ф-ты деканы (1908–13), проф. (1885). Хезмәтләре геология, палеонтология, археология, этнография һ.б. мәсьәләләргә карый. Казан, Уфа, Вятка һәм Пермь губерналары терр-яләрендә, Россиянең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш р-ннарында геол., геогр. һәм археол. тикшерүләр үткәрә; Пермь утырмаларына тәфсилле характеристика бирә, фосфорит ятмаларын, палеолит дәвере торулыкларын, Иж минераль су чыганагын, Пермь губернасында метеорит төшү урынын өйрәнә. *Вятка өелмәсен* аерып ала һәм өйрәнә (1894), Уралда тау хрустале чыганагын ача. Казан ун-тында геогр. кабинеты оештыра.

Х е з м.: Казанское Закамье в геологическом отношении // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1890. Т. 22, вып. 5 (автордаш); О новых поселениях каменного века в Казанской губернии // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1905. Т. 21, вып. 3.

*Әд.:* Дедков А.П. Пётр Иванович Кротов. К., 2002.

**КРУГЛО́В** Александр Никифорович (1887, Сембер губ., Сембер өязе Арча а. — 1968, Казан), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1946), проф. (1934). Акад. В.В. Чирковский шәкерте. 1912 елда Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Сембер губернасының Алатырь өяземдә земство табибе. Беренче бөтендөнья сугышы елларында кыр госпитальләрендә табиб; 1918–22 дә Казан ун-ты клиникасында хәрби табиб. 1922 дән Казан трахоматоз ин-тында. 1930–34 тә Казан, 1934–45 тә Хабаровск, 1946–48 дә Саратов мед. ин-тларында күз авырулары кафедрасында эшли. 1951–64 тә Казан ГИДУВында, бер үк вакытта, 1950–56 да Казан трахоматоз ин-ты директоры урынбасары. Хезмәтләре трахоманы өйрәнүгә (патогенезы, кичектергесез ярдәм һәм авыруны дәвалау) карый. Россия медицинасында К. операциясе — «авыр формалы трахоманың регрессия чорында иренең лайлалы тышчасын күчереп утырту» ысулы киң таныла.



П.И. Кротов.

Х е з м.: Тканевая терапия тяжёлых форм трахомы // Казан. мед. журн. 1962. № 11 (автордаш); Инъекционный метод подсадки тканей под конъюнктиву глазного яблока в глазной практике // Материалы науч. конф., посвящённой 100-летию кафедры глазных болезней Казан. мед. ин-та. К., 1967.

**КРУ́ГЛОЕ ПО́ЛЕ** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Биклән елгасы буенда. 2010 елда 26 кеше (руслар) яши. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богоявленский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.П.да Богоявление чиркәве (1842 дә төзелә; архит-ра ядкәре), чиркәү-приход мәктәбе (1882 дә ачыла), җил тегермәне, ярма яргыч, ашлык киптергеч була; ярминкәләр (6 гыйнвар, 8 июль һәм 22 октябрьдә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2911,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 883, 1897 дә — 874, 1913 тә — 1083, 1920 дә — 994, 1926 да — 688, 1938 дә — 404, 1949 да — 396, 1958 дә — 255, 1970 тә — 169, 1979 да — 113, 1989 да — 20, 2002 дә — 5 кеше.

**КРУГЛЯКО́В** Тимофей Петрович (1890, Дон өлкәсе Ермаковский станциясе — 1954, Казан), генерал-майор (1940). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Гражданнар сугышы вакытында кызыл партизаннар отряды һәм бригада командиры; Сальск округында, Польша фронтында акгвардиячеләр б-н көрәшә; Баку шәһәрен интервентлардан азат итүдә, Н.И.Махно отрядын юк итүдә катнаша. 1921 елдан Ростов өлкәсенә партия эшенә җибәрелә. 1929 дан хәрби хезмәттә. Бөек Ватан сугышы елларында дивизия, корпус командиры, армия командующие урынбасары, Сталинград сугышында катнаша (1942–43). 1946 дан ТАССРның хәрби комиссары. 1941–45 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ике Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КРУПЕ́НИКОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. 17 йөздән билгеле. 18 йөздә чәй, кәҗә тиресе,

күн, постау һ.б. б-н сәүдә итеп баеп китәләр. 19 йөздә Казанда йортлар, сәүдә кибетләре, күн, кирпеч з-длары хуҗалары. Губернада «Леонтий Крупеников уллары» (1839–63), «Крупеников һәм К°» (1864–1917) сәүдә йортлары эшләп килә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында аларның пр-тиеләре бөлгенлеккә төшә. Династияне башлап җибәрүче — **Артемий** (17 йөз), һөнәрче.

**Леонтий Филиппович** (1755, Казан — 7.5.1839, шунда ук), 1 нче гильдия сәүдәгәре (1812), нәселдән күчмә мактаулы граждан (1833), күн з-длары һәм 3 таш йорт хуҗасы. 1774 елның июлендә Казанны Е.И.Пугачёв гаскәрләреннән саклауда катнаша. 1787–88 дә Казан алты тавышлы шәһәр думасы гласные, 1789–94 тә Казан губерна магистраты, 1802–05 тә Казан вөҗдан мәхкәмәсе утырышчысы, 1809–11 дә Казан шәһәре башлыгы. Воскресение чиркәве чаң манарасы төзелешенә акча иганә кыла. 1833 нең 7 сентябрендә үз йортында А.С.Пушкинны кабул итә һәм аның б-н истәлекләрен уртаклаша, алар киләчәктә шагыйрь тарафыннан «Пугачёв фетнәсе тарихы»н («История Пугачёвского бунта», СПб., 1834) язганда файдаланыла. **Александр Леонтиевич** (1788 яки 1791, Казан — 25.10.1855, шунда ук), Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре (1812), нәселдән күчмә мактаулы граждан (1833), коммерция советнигы (1855), «Леонтий Крупеников уллары» сәүдә йорты хуҗаларының берсе. 1839–41 дә Казан шәһәре башлыгы. Хәрби госпиталь каршында йорт чиркәве төзелешенә, *Николай исемендәге балалар приюты* (1844) һәм аның янында кунып чыгу бүлеге (1846) ачуга акча бирә. 1839 да Җәмәгать тәрбиясе приказына 3 мең сум акча кертә. 1852 дә шәһәргә Воскресенский урамындагы 96 лавкасын бүләк итә (алардан кергән табышның өчтән бер өлеше ярлы һәм картайган мещаннар өчен салым түләүгә, өчтән бере — мещаннар җәмгыяте ятимнәренә пособие таратуга, өчтән бере — балалар ятимханәсен тотуга җибәрелүен оештыра). Николай балалар приютының беренче мактаулы старшинасы итеп сайлана, 1849–53 тә аның директоры. Шагыйрь Г.П.*Каменев*, әдәбиятчы Д.Н.Зиновьев, масон С.А.Москательников кергән хөр фикерле кешеләр түгәрәгенә йөри. Владимир һәм Анна тасмалы «Тырышлык өчен» алтын медальләре б-н бүләкләнә.

**Константин Леонтиевич** (1801, Казан — 19.4.1885, шунда ук), Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан (1833), «Леонтий Крупеников уллары» сәүдә йорты хуҗаларының берсе. 45 яшендә сәүдәдән китә һәм үзен чиркәүгә багышлый. К. йорты каршында Спас Нерукотворный хакына йорт чиркәве төзелә һәм изгеләндерелә (1867). Аның башлангычында һәм акчасына Казанда ятимәләр һәм аз керемле гаиләдән чыккан кыз балалар өчен *Александра исемендәге кыз балалар ятимханәсе* ачыла (аның беренче мактаулы старшинасы булып сайлана). Вафатыннан соң шәһәргә васыять итеп калдырылган 78 мең сум акчасы хисабына Крупениковлар исем. шәһәр картлар йорты ачыла (1891).

Чыг.: Достойны имени потомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* А г а ф о н о в Н.Я. Из казанской истории. К., 1906.

*Е.Б.Долгов, Л.М.Свердлова.*

**КРУПИ́Н** Владимир Павлович (21.7.1925, Тәтеш ш. — 6.10.2006, Казан), хирург, СССРның халык табибе (1980). 1952 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Чуаш АССРда хирург булып эшли. 1953 тән ТАССР мед. учреждениеләрендә, 1958 дән Казанның 5 нче хастаханәсе табиб-хирургы, 1966 дан хирургия бүлеге мөдире, 1991 дән «Татавтотранс» пр-тиесе медсанчасте хирургы, соңрак Казанның 21 нче поликлиникасында хирургия кабинеты мөдире. 2000 нән «Татфлот» компаниясе медсанчасте хирургы. К. 9 меңнән артык операция башкара. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**КРУПИ́Н** Станислав Васильевич (24.8.1938, Казан), физик-химик, техник фән. д-ры (1991), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1961 дән Казан химия-технол. ин-тында (хәзер Казан технол. ун-ты). Хезмәтләре электрохимиягә, коллоидлы һәм нефть сәнәгате химиясенә карый. К. нефть скважиналарына су агуны чикләүнең коллоид-химик нигезләрен эшли. Аның җитәкчелегендә катламны гидроизоляцияләү ысулы эшләнә, бу ысул өчен составлар төзелә (полимерлар, сыек пыяла нигезендә интерполимер комплекслар; бентонитлы балчык порошоклары нигезендә күп компонентлы составлар һ.б.), нефть скважинасында гидроизоляция материалы формалашу процессының матем. моделе тәкъдим ителә. Чыгарылган нефтьнең составын һәм физик-химик үзлекләрен анализлап, К. катламның нефть бирүчәнлеген арттыруның утырым гель ясаучы технологияләре эффектын бәяләү алымын эшли. Югары модульле эрүчән пыялалар нигезендә катламның нефть бирүчәнлеген арттыруның фәнни эшләнмәләре һәм технологиясе сәнәгатькә кертелә («Татнефть» АҖ). Уйлап табуга 27 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Гидролизующие экраны на основе полиэлектролитных комплексов // Нефтяное хоз-во. 1982. № 9 (автордаш); Водорастворимые полимеры и их применение. К., 1984 (автордаш); Моделирование процессов образования водоизоляционного экрана вокруг нефтяной скважины // Изв. вузов. Сер. Нефть и газ. 1987. № 12 (автордаш); Применение смеси L-олефинов в качестве растворителя-экстрагента // Хим. пром-сть. 1998. № 9 (автордаш).

*Әд.:* Институт полимеров (полимерный факультет). 1971–2001: Краткий биогр. справ. К., 2001.

**КРУ́ТИКОВ** Виктор Филиппович (10.6.1940, Омск өлкәсенең Тюкалинск ш. — 20.11.2005, Казан), радиоспектроскопия белгече, геол.-минерал. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1965), шунда ук магнит радиоспектроскопиясе проблемалы лаб-ясендә эшли. 1979–2003 елларда ЦНИИгеолнерудта, физик тикшерү ысуллары лаб-ясе мөдире (1993 тән). Беренчеләрдән булып руда булмаган файдалы казылмаларны технол. тикшерүләрдә һәм геол.-эзләнү эшләре барышында минералларны өйрәнүнең тизләтелгән яңа физик-минерал. ысулларын куллана.

Х е з м.: Спектроскопическое изучение природы растворимости фосфата кальция фосфоритов в слабых кислотах // Горный вестник: Спец. вып. 1996.

**«КРУТУ́ШКА»**, санаторий (Казаннан 22 *км* ераклыкта). Казансу елгасының сулъяк ярында, катнаш урманда, карст токымнары булган, кышын туңмый торган Зәңгәр күл тирәсендә урнашкан. 1935 елда нигез салына, 1969 га кадәр ял йорты. Табигый-дәвалау факторлары: хлорид-натрийлы эремәләр, Зәңгәр күлнең сульфид балчыклы ләме. Эчү һәм процедуралар өчен скважинадан алынган (550 *м* тирәнлектән) су файдаланыла. Санаторий кан әйләнеше системасын (ревматик эндомиокардит, йөрәк зәгыйфьлеге, йөрәктә канның акрын йөрүе, гипертония, очлыклар тамырларының үткәрмәүчәнлеге) һәм үзәк һәм вегетатив нерв системасын (нерв имгәнүләре, баш миенең ябык имгәнүләре һәм эшчәнлеге бозылу) дәвалау юнәлешендә эшли. Дәвалау эше амбулатор-курслап дәвалау эше оештырылган. Санаторий комплексы күпкатлы ял һәм дәвалау корпусларыннан тора; диагноз кую лаб-яләре, функциональ диагноз кую, дәвалау кабинетлары эшли. Дәвалауда ясалма родон ванналары, парафинлы озокерит б-н дәвалау, су б-н дәвалау, массаж (ш.и. су асты массажы), ингаляция, дәвалау физкультурасы, мануаль терапия, психологик һәм диеталар б-н дәвалау кулланыла. Концертлар залы, китапханә, бильярд залы, спорт мәйданы һәм залы, сауна, автомобильләр өчен урын бар. Санаторий ел әйләнәсе эшли. Баш табибе —Ю.К.Чумаков (2011 дән).

*Әд.:* Татарстан — курорт. К., 1993.

*В.Маркелов.*

**«КРУТУ́ШКА»** с а н а т о р и е  п о с ё л о г ы, Казанның Авиатөзелеш р-ны составында, Казан тимер юл станциясеннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2000 елда 549 кеше (1989 елгы халык исәбе буенча, руслар — 52%, татарлар — 40%) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Казан авыл р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан Биектау р-нында. 1984 нең 15 октябреннән Казанның Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1938 дә — 132, 1949 да — 150, 1958 дә — 143, 1970 тә — 293, 1989 да — 580 кеше.

**КРУШЕ́ВСКИЙ** (Kruszewski) Николай Вячеславович (6.12.1851, Луцк ш., Украина — 31.10.1887, Казан), тел галиме, гомуми һәм Һинд-Европа телләре белгече, чагыштырма тел белеме д-ры (1883). *Казан лингвистика фәнни мәктәбе* вәкиле, И.А.*Бодуэн де Куртенэ* шәкерте. Варшава ун-тын тәмамлый (1875). 1875–78 елларда Троицк гимназиясендә (Оренбург губ.) классик телләр укыта. 1878 дән Казан ун-тында, проф. (1883 тән). Тел үсешенең төп закончалыгы, К. фикеренчә, «сүзләр дөньясының төшенчәләр дөньясы б-н ярашуы»ннан гыйбарәт («Тел турында фәнни очерк» — «Очерк науки о языке», 1883). К. телнең системалы һәм билгеләр б-н

аңлатылуын дәлилли һәм аның фонетик, семантик, морфологик тармакларын аерып күрсәтә (хәзерге тел белемендә — телнең 3 баскычы); телгә карата логика һәм психологиядә файдаланыла торган ассоциацияләр (бәйләнешләр) теориясен куллана. К.ның охшашлык һәм янәшәлек буенча ассоциацияләр хакындагы идеясе хәзерге Россия һәм чит илләрнең тел белемендә — тел парадигмасы һәм синтагматикасы турындагы теориядә — үсеш ала. К.ның фонетик чиратлашулар (альтернацияләр) теориясе В.В.Радлов тарафыннан төрки телләргә карата да кулланыла һәм үстерелә (1881).

Х е з м.: Избранные работы по языкознанию. М., 1998.

*Әд.:* Бодуэн де Куртенэ И.А.Николай Крушевский, его жизнь и научные труды // Избранные труды по общему языкознанию. М., 1963. Т. 1; Б а й р а м о в а Л.К. Варшавский период научной деятельности казанского профессора Н.В.Крушевского // Польские профессора и студенты в университетах России (XIX — начало XX в.). Варшава, 1995; Николай Крушевский: Научное наследие и современность: Материалы междунар. науч. конф. «Бодуэновские чтения». К., 2002.

*Л.К.Бәйрәмова.*

**КРУШЕЛЬНИ́ЦКИЙ** Герман Николаевич (13.7.1940, Казан — 30.10.2007, Казан), скрипкачы, ТАССРның халык артисты (1987). 1964 елда Казан консерваториясен (Н.Брауде классы) тәмамлый. 1966–95 тә ТР Дәүләт симф. оркестры (1970 тән концертмейстер) артисты, 1995–2004 тә Татар опера һәм балет театры оркестры концертмейстеры.

**КРЫЖО́ВНИК** (Grossularia), крыжовникчалар семьялыгыннан куаклыклар ыругы, җиләк культурасы. 50 дән артык төре билгеле, РФдә — 3 төре бар. ТР терр-ясендә бер төре — гади К. (G. reclirata) төре билгеле; йорт яны бакчаларында җимеш бирүче үсемлек буларак үстерелә, кыргыйлану очраклары сирәк. Биеклеге 1,5 *м*, озын чәнечкеләр б-н капланган. Яфраклары кыска сабаклы, бөреләре түгәрәк. Чәчәкләре ике җенесле, вак, яшькелт яисә кызгылт төстә. Май ахырында чәчәк ата, июль–августта өлгерә. Җимешләре эшкәртелмәгән яисә кайнатма, джем килеш, медицинада матдәләр алмашы бозылганда кулланыла. Баллы үсемлек. ТРда районлаштырылган сортлары: «Уральский виноград», «Малахит», «Смена», «Русский». Бер рәттә 1,5 *м* ара, рәт араларында 2,5 *м* ара калдырып утыртыла. К.ны агачланган һәм катнаш чыбыкчалардан үрчетәләр. Үрчетүнең меристема ысулы эшләнгән һәм житештерүгә кертелгән, бу ысул сәламәт утырту материалы алырга мөмкинлек бирә. К. корылыкны начар кичерә, яктылык һәм бай балчыксыл туфракны ярата. Корткычлары — крыжовник утчыллары, авыруы — ончыл чык.



**КРЫ́ЙМОВ** Мансур Кәрим улы (1898, Казан губ., Тәтеш өязе Чүри-Бураш а. — 1.8.1938, Уфа ш.), шагыйрь. Гражданнар сугышында катнаша. Грозный шәһәрендәге нефть һәм Әстерхан балык промыселларында, Мәскәүдә «Кызыл Шәрекъ» басмаханәсендә эшли. 1921 елдан «Эшче», «Яшь эшче» г-таларында, «Ударниклар», «Кечкенә иптәшләр» ж-лларында хезмәттәшлек итә. Мәскәүдә 1925 тә аның «Чүкеч җырлары», «Комсомол җырлары», 1927 дә «Шигырьләр», 1929 да «Кызыл лачыннар», 1933 тә «Үсү рапортлары» исемле, Окт. рев-циясенә мәдхия җырлаган шигъри җыентыклары дөнья күрә. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында К. поэзиясендә эшчеләр сыйныфы төп темага әйләнә, лирик геройның рухи дөньясына игътибар арта («Эш иртәсе», 1929; «Җырларымны бирдем көмергә», 1931). 1930 еллар поэмаларында («Онытылган җырлар», «Провокатор», «Фатыйма», «Партизаннар») социаль юнәлеш өстенлек ала.

Ә с ә р.: М.Крыймов әсәрләре: 4 томда. К., 1930–32; Шигырьләр, поэмалар. К., 1961.

*Әд.:* Мансур Крыймов // Казан утлары. 1968. № 12. *Р.Р.Мусабәкова.*

**КРЫ́ЙМОВ** Миргазиян Галиулла улы (7.4.1891, Самара губ., Бөгелмә өязе Мөэмин Каратай а. — 15.4.1945), хәрби эшлекле, полковник (1935). Казан татар укытучылар мәктәбен (1911), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1926) тәмамлый. 1911–15 елларда Минзәлә өязендә земство мәктәбе укытучысы булып эшли. 1915 тә Россия армиясенә чакырыла. 1916 да Тифлисның 2 нче прапорщиклар мәктәбен тәмамлый, Чиләбе шәһәрендә 109 нчы запас пехота полкында хезмәт итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Чиләбе Эшче һәм солдат депутатлары советы башкарма ком-ты әгъзасы, хәрби гарнизон башлыгы. Окт. рев-циясе вакытында совет хакимияте ягында Чиләбе оборонасы б-н җитәкчелек итә. 1917–18 дә сул эсерлар партиясе әгъзасы, 1918 нең ахырында РКП(б) сафларына керә. Гражданнар сугышында катнаша. 1918–19 да Хәрби эшләр буенча Халык комис-ты каршындагы Мөселман хәрби коллегиясенең хәрби бүлек мөдире (Мәскәү); Казанда Мөселман пехота командирлары курсларын оештыруда катнаша, Казан, Сарапул, Чиләбе, Акмулла ныгытылган р-ннары штабында командирлык вазифаларын башкара. 1926–31 дә Кызыл Армия штабының Тикшерү идарәсе карамагында, Төркиягә махсус боерык үтәргә җибәрелә. 1931–32 дә Кавказ Кызыл байраклы армия штабының бүлек башлыгы. 1933–35 тә штаб башлыгы, 1 нче Казан укчы дивизиясе командиры. 1935–42 дә педагог: М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиядә гомуми тактика каф. җитәкчесе, И.В.Сталин исем. Мәскәү корыч ин-тында хәрби каф. укытучысы, Кызыл Армиянең Югары хәрби гидрометеорология ин-тында тактика каф. өлкән укытучысы. Бөек Ватан сугышында катнаша, дивизия командиры урынбасары. Сугышта һәлак була, Самбор шәһәрендә (Чехословакия) җирләнә. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

**КРЫЛО́В** Борис Леонидович (5.3.1905, Сембер ш. — 23.6.1966, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1953), проф. (1954). 1928 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, ТАССР Мәгариф халык комис-тында эшли. 1931–44 тә Казан ун-тында. 1944 тән Казан авиация ин-тында, югары матем. каф. мөдире (1963 тән). Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләр теориясенә карый. К. Гаусс системасын тикшерү буенча күп эшли: каноник матрицаларның төркемен билгеләү һәм аларны төзү, Риман проблемасын каноник рәвештә чишү h.б. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Определение группы системы Гаусса // Изв. физ.-матем. об-ва и НИИ математики и механики при КГУ. 1937. Т. 9; Построение канонических интегральных матриц системы Гаусса // Изв. физ.-матем. об-ва и НИИ математики и механики при КГУ. 1940. Т. 12; К вопросу о единственности решения проблемы Римана // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1959. Вып. 45.

**КРЫЛО́В** Порфирий Никитич (1.8.1850, Енисей губ., Минусинск өязе Сагайский а. — 27.12.1931, Томск ш.), ботаник-флорист, систематик, ботаник-географ, Украина ССР, СССР ФАләренең мөхбир әгъзасы (1925, 1929). 1873–75 елларда Казан ун-ты мед. ф-ты каршындагы фармацевтика курсларында укый; бер үк вакытта ботаника, зоология, химия, геология буенча лекцияләр тыңлый. 1879–85 тә Казан ун-ты Ботаника бакчасында бакчачы-галим. 1874–76 һәм 1878 дә — Пермь, 1880 дә — Казан, 1882 дә — Вятка, 1883 тә Түбән Новгород губерналарында ботаник-геогр. тикшеренүләр б-н шөгыльләнә. 1885 тә Томскига — оешып килүче университеткa бакчачы-галим хезмәтенә күчерелә, биредә исә үзе тарафыннан оештырылган ботаника бакчасын (коллекциянең нигезен Казан ун-ты Ботаника бакчасы үсемлекләре тәшкил итә) җитәкли (1928 гә кадәр). Бер үк вакытта, 1888 дән университет музеенда һәм ботаника кабинетында җаваплы саклаучы. 1908 дән ассистент, 1910 нан ботаника кафедрасының штаттан тыш профессоры. «Алтай һәм Томск губернасы флорасы» («Флора Алтая и Томской губернии») хезмәтенең беренче 4 томы (1901–07) өчен, 1909 да диссертация якламыйча гына Казан ун-тының шәрәфле ботаника д-ры дәрәҗәсенә лаек була. 1913 тән Петербург ФА Ботаника музееның Себер гербарие мөдире һәм кече ботанигы. 1917 дә Томскига кайта. Томск ун-тының ботаника кафедрасын һәм гербариен (1924 тән) җитәкли, бер үк вакытта (1919 дан) Себерне тикшерү ин-тының ботаника бүлегендә эшли. Хезмәтләре флористикага, систематикага һәм ботаник географиягә карый. К., Үзәк Россияне, Себер, Алтай, Ерак Көнчыгышны өйрәнү максаты б-н, 36 экспедиция оештыра. «Алтай һәм Томск губернасы флорасы» («Флора Алтая и Томской губернии», т. 1–7, Томск, 1901–14) хезмәтендә, «Көнбатыш Себер флорасы» («Флора Западной Сибири», чыг. 1–12, Томск, 1927–64, автордаш) исеме б-н чыккан 2 нче басмада тикшеренү нәтиҗәләрен гомумиләштерә, 3 меңнән артык үсемлек төренә тасвирлама бирелә һәм мәгълүмат киңәйтелә. Көнбатыш Себер далалары үсемлекләр дөньясының классификациясен

төзи. Үсемлек бергәлекләре турында тәгълимат төзүчеләрнең берсе. Фитогеографик тикшерену алымнары һәм мәсьәләләре буенча хезмәтләр авторы. Илнең көнчыгышында иң зурлардан һәм Себердә беренче булган ботаника мәктәбенә нигез салучы. Үсемлекләрнең 50 гә якын төренә һәм Томск ун-тының үзе нигез салган (1933) Ботаника бакчасына К. исеме бирелгән.

Х е з м.: Материалы к флоре Пермской губернии // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1876. Т. 4, вып. 6; 1881. Т. 9, вып. 6; 1882. Т. 11, вып. 5; 1885. Т. 14, вып 2; Тайга с естественно-исторической точки зрения. Томск, 1898; К вопросу о колебании границ между лесной и степной областями // Тр. бот. музея Петербург. АН. 1915. Т. 14.

*Әд.:* Памяти П.Н.Крылова (в связи с 100-летием со дня рождения) // Тр. Томского ун-та. Сер. биол. 1951. Т. 116; С е р г и е в с к а я Л.П. Порфирий Никитич Крылов. Новосиб., 1952; Выдающиеся отечественные ботаники. М., 1957; М а р к о в М.В. Ботаника в Казанском университете за 175 лет. К., 1980.

*А.П.Ситников.*

**КРЫЛО́ВА** Нина Александровна (16.1.1910, Вятка губ. Кукарка бистәсе — 24.12.1998, Казан), вет. патофизиологы, вет. фән. д-ры (1953), проф. (1955), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1973). 1932 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1931–44 тә Казан кетгут з-дында эшли, 1936 дан ампулалар ясау һәм кетгут җитештерү цехы башлыгы, техник директор. 1944–47 дә ТАССР ит, сөт сәнәгате министры урынбасары. 1948 дән Казан вет. ин-тында, 1952–85 тә патофизиология каф. мөдире. Хезмәтләре кетгут җитештерү, радиобиол. мәсьәләләренә, терлекләрнең патологик һәм иммунологик реакциясенә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины, (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

*М.С.Ежкова.*

**КРЫЧЫ́НЬСКИЙ** Леон (25.9.1887 — 11.11.1939), җәмәгать эшлеклесе, хокук белгече. Польша-Литва татарларыннан. Петербург ун-тын тәмамлый (1911). Варшава ярлы мөселманнарга ярдәм итү җәмгыяте секретаре. *Польша-Литва татар студентлары түгәрәге* җитәкчеләренең берсе. 1917 елда Польша, Белоруссия һәм Украина татарлары берлеге ҮК секретаре. 1918–19 да Кырым төбәк хөкүмәте премьер-министры канцеляриясе мөдире, 1919–20 дә Әзәрбайҗан хөкүмәте әгъзасы. 1920–32 дә Вильно шәһәрендә: Вильно повяты тикшерүчесе, аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче, Вильно округ мәхкәмәсе судьясы. 1932–34 тә Замостье шәһәре, 1935–39 да Гдыня шәһәре округ мәхкәмәсе рәисе урынбасары. Бер үк вакытта, 1925–29 да «Польшадагы татар нәселләре гербовнигы»н («Гербовник родов татарских в Польше») чыгару буенча ком-т рәисе. 1929 дан Речь Посполита татарлары мәдәни-агарту берлегенең үзәк советы секретаре, 1938–39 да рәисе. Варшавада татар музеен оештыручы. «Рочник Татарски» басмасының өч томы мөхәррире, «Мөселман календаре»н чыгаруны башлап җибәрүче. Польшада яшәүче татарлар тарихына багышланган популяр мәкаләләр авторы. 1939 ның сентябрендә гестапо тарафыннан кулга алына, соңыннан атып үтерелә.

*Я.Я.Гришин.*

**КРЫЧЫ́НЬСКИЙ** Ольгерд (1884, Вильно ш. — 1942), җәмәгать эшлеклесе, хокук белгече. Польша-Литва татарларыннан. Петербург ун-тын тәмамлый (1908). *Польша-Литва татар студентлары түгәрәге* җитәкчеләренең берсе. 1918–19 елларда Кырым төбәк хөкүмәте әгъзасы. 1919–20 дә Әзәрбайҗан хөкүмәте вице-министры. 1920–32 дә Вильно шәһәре округ мәхкәмәсе вице-прокуроры. 1933–38 дә Варшавада Югары мәхкәмә прокуроры, 1938–39 да Апелляция мәхкәмәсе вице-рәисе. Бер үк вакытта, Речь Посполита татарлары мәдәни-агарту берлеге үзәк советы (1929–38) һәм Варшава дини гминасы рәисе (1933 тән).

*Я.Я.Гришин.*

**КРЫЧЫ́НЬСКИЙ** Самуил Борисович (1803, Вильно губ. — 1876), генерал-майор (1852). Польша-Литва татарларыннан. 1819 елдан Россия армиясендә, Улан полкы лейб-гвардиясе юнкеры. 1844 тән полковник, 4 нче җиңел кавалерия дивизиясенең 2 нче бригадасы командиры. Польшадагы 1830 елгы кузгалышны бастыруда, 1854–55 елларда Кырым сугышында катнаша. 4 нче дәрәҗә Изге Георгий, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 4 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче, 2 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я., Ш а р а ф у т д и н о в Д.Р. Отчизны верные сыны. К., 2001; ш у л а р у к. На службе Родине. К., 2005.

*Я.Я.Гришин.*

**КРЫЧЫ́НЬСКИЙ** Станислав (3.5.1911, Новы Сонч ш., Польша — 1.11.1941, Лович ш.), тарихчы. Польша-Литва татарларыннан. Львов ун-тының хокук белеме ф-тында, Ягелло (Краков ш.) ун-тының тарих бүлегендә укый. 1936–38 елларда Варшава ун-тының тюркология кафедрасында стажировка уза. 1938–39 дан Варшава Борынгы актлар үзәк архивы хезмәткәре. Польша оккупацияләнгәннән соң немец хакимияте тарафыннан эштән чыгарыла. Литва татарлары турында монография авторы.

Х е з м.: Tatarzy Litewscy. Proba monografii historyczno-etnograficznej // Rocznik tatarski. Warsz., 1938. T. 3.

*Я.Я.Гришин.*

**КРЮ́КОВ** Виктор Георгиевич (24.11.1945, Казан), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1986), проф. (1990). 1968 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1993–2003 тә Бразилиянең Ижуи ун-тында). Хезмәтләре энергия җайланмаларындагы югары темп-ралы процессларга карый. К. очкыч аппаратларның двигатель агрегатларында бара торган югары темп-ралы һәм химик тигезләнешсез процессларны исәпләү алымнарын тәкъдим итә (ракета-космос һәм авиация комплексларында гамәлгә кертелә). Двигательләрне автомат проектлаштыру системаларын төзү б-н җитәкчелек итә. Үсемлек майлары җитештерүче сәнәгый экстракторларда барган процессларның матем. модельләрен эшли. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Математическое моделирование высокотемпературных процессов в энергосиловых установках. М., 1989 (автордаш); Горение и течение в агрегатах энергоустановок. М., 1997 (автордаш); Modelagem Matematica dos Processos de Combustro un Motores Aerospaciais (Motores de foguetes) // Instituto Tecnologico de Aeronautica. 2000. V. 1 (автордаш).

**КРЮ́КОВ** Лев Дмитриевич (1783 — 13.5.1843, Казан), нәкышьче, педагог. 1806 елдан Казанда яши. 1807 дә «студентларны оригиналлардан, натурадан һәм миниатюра рәвешендә коры, сулы һәм майлы буяулар б-н рәсем ясарга, нәкышькә өйрәтү өчен»







Л.Д. К р ю к о в.
1. «И.И. Протопопов портреты». 1816;
2. «Молоствов портреты». Акварель. 1820;
3. «А.А. Фукс портреты». 1820 еллар.
Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

К.Ф.Фукс булышлыгында университетка хезмәткә алына. К. студентларны «карандаш һәм кыл-каләм б-н кеше башлары, тулы фигуралар һәм ландшафтлар ясарга» өйрәтә. Университетта ш.у. декоратор, иллюминатор һәм фейерверклар оештыручы вазифаларын да башкара (1814 тә ун-тны югары дәрәҗәдә ачу хөрмәтенә «Император Галиҗәнаблары алдында музалар тантанасы» транспарантын ясый). Университетның рәсем ясау классын сәнгать, нәкышь һәм графика сәнгате җыентыклары туплап, китапханә итеп тулыландыра (соңыннан алар Казан ун-тының Сәнгать һәм борынгы истәлекләр музееның нигезен тәшкил итәләр). Сәнгать әсәрләре һәм сыннарның күчермәләрен алу өчен 1829 да Петербургка бара. 1813 тә Ф.Х.Эрдман һәм Х.М.Френның Болгарга оештырган экспедициясендә рәсем ясаучы сыйфатында катнаша, натурадан барлык ядкәрләрне, ш.и. хәзергәчә сакланмаганнарын рәсемгә төшерә һәм берничә гарәп язулы һәм әрмән кабер ташының күчермәсен ала. 1811–36 елларда Казан уку-укыту округының уку йортларында рәсем укытучысы дәрәҗәсен алуга дәгъва итүчеләрнең әсәрләрен бәяләү өчен сәнгать эксперты сыйфатында ун-т каршындагы Училищеләр ком-ты комиссиясе составына керә. Казанда шәһәр җәмәгатьчелегенең күренекле вәкилләрен гәүдәләндереп, портретчы һәм миниатюрачы буларак танылды. К.Ф.Фукс һәм А.А.Фукс (1820 еллар), И.И.Протопопов, М.С.Коринфская портретларын, миниатюра жанрында — И.Ф.Яковкин, Г.И.Солнцев, М.Ф.Вейер, А.Г. һәм К.К.Людевич һ.б. портретларын иҗат итә. Портретларның композицияләре, гадәттәгечә, бертөрле, нейтраль фонда билдән ясалган сурәт, ачык йөз картинаның өслегенә терәлеп, портрет иясенең күз карашы тамашачыга төбәлгән. Колорит йөзнең алсу-кызыллык йөгертелгән ап-ак төсе һәм өс киеменең төгәл башкарылган аксессуарлары ярашуында башкарылган. К. тарихи-дини нәкышь жанрында да эшли (ун-тның Крестовоздвижение чиркәве өчен «Касә сорап ялвару»; Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты йорт чиркәве өчен «Яхшы хәбәр», «Газап чигүче изге Александра» әсәрләре). 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә. Рәссамның әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Д е н и к е Б.П. Л.Д.Крюков — первый казанский университетский живописец. К., 1916; Э т т и н г е р П.Д. Материалы к истории казанского портрета. Лев Дмитриевич Крюков // Казан. музейный вест. 1921. № 3–6; Д у л ь с к и й П. Лев Крюков: Материалы к истории миниатюры в России. К., 1923.

*Е.П.Ключевская.*

**КСЕМБА́ЕВ** Сәгыйд Сәлман улы (12.11.1950, Казакъстан ССРның Павлодар өлкәсенең Галкин р-ны Баймбәт пос.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2006). 1978 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шәһәр мед. учреждениеләрендә эшли. 1987 дән Казан мед. ун-тының стоматология хирургиясе кафедрасында, бер үк вакытта, 1988 дән Казан мед. академиясендә. Хезмәтләре имгәнү һәм көчле эренләү-ялкынсыну авырулары вакытында бит-яңак өлешендә кан әйләнеше торышын, бит-яңак ангиологиясен өйрәнүгә карый. К. беренче булып баш мие тамырларында кан басымын турыдан-туры булмаган ысул б-н билгеләүне тәкъдим итә; бит-яңак имгәнүләре һәм ялкынсынулары вакытында регионар гипертензияне ачыклый; көчле одонтоген ялкынсыну чыганагындагы тукымаларның каршылык сәләте бозылу дәрәҗәсен бәяләргә мөмкинлек бирүче биол. үрнәкләрнең физик-химик күрсәткечләрен ачыклый. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Применение методов лучевой диагностики для оценки состояния очага острого одонтогенного воспаления // Сб. трудов 3 Междунар. конф. по челюстно-лицевой хирургии. СПб., 1998; Комплексная лучевая диагностика и патологическое лечение острых одонтогенных воспалительных заболеваний челюстей. К., 1999; Предраковые заболевания в клинической стоматологической практике. К., 2004.

**КСЕНОФО́НТОВ** Александр Кузьмич (1910, Казан губ., Мамадыш өязе Әбде а. — 13.3.1940, Ленинград өлкәсе Приморск ш.), Сов. Союзы Герое (21.3.1940, үлгәннән соң), рядовой. Колхозда эшли. 1933–35 елларда һәм 1940 тан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 169 нчы укчы полк пулемётчысы (7 нче армиянең 86 нчы мото-укчы дивизиясе). 1940 та батырлык күрсәтә: 4 нче мартка каршы төндә К. подразделениегә чолганыштан чыгарга булыша; 12 нче марттагы сугышта дошманның берничә ут ноктасын юк итә һәм авыр яралана. РФ Елга флоты министрлыгының бер пароходы Герой исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*



А.К. Ксенофонтов.

**КСЕНОФО́НТОВ** Юрий Александрович (30.10.1946, Калинин өлкәсенең Вышний Волочёк ш.), су асты тикшеренүләре өчен махсус техника җитештерү конструкторы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1987). 1970 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук очкыч аппаратлар конструкциясе һәм аларны проектлаштыру кафедрасында эшли, лаб. мөдире (1989–91). 1991 дән «Южморгеология» ҖБнең (Геленджик ш.) Су асты геофизика приборлары эшләү буенча тәҗрибә КБ директоры. Океанны өйрәнү һәм үзләштерү өчен су асты техникасы эшләү б-н шөгыльләнә. СССР ФА П.П.Ширшов исем. Океанология ин-тының «Дмитрий Менделеев» исемле фәнни-тикшеренү судносының 19 нчы рейсы экспедициясе составында идарә ителүле су асты аппаратларын (Казан авиация ин-тында эшләнә) сынауда катнаша (1977). Дәүләт бүләге үтә тирән су асты техникасы комплексларын эшләгәне һәм гамәлгә кerткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 43 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Технология поисков и разведки минеральных ресурсов с использованием подводных аппаратов // Советская геология. 1990. № 12.

**КСИМЕДО́Н** (1-(2-гидроксиэтил)-4,6-диметил-1,2-дигидропиримидин-2-он), дару, пешүгә каршы иммун тәэсирле препарат. Ак төстән көрән төсмергә кадәр, суда һәм органик эремәләрдә эри, стерильләштерүгә тотрыклы, агулы түгел. РФА Казан фәнни үзәгенең А.Е.Арбузов исем. Органик һәм физик химия ин-тында синтезлана (В.С.Резник, Н.Г.Пашкуров). Препаратның фармакологик активлыгы беренче тапкыр Казан мед. ун-тының фармакология кафедрасында өйрәнелә (И.В.Заиконникова, Н.Г.Абдрахманова, С.М.Горбунов).

К. сәнәгый җитештерү өчен рөхсәт ителгән, тирән һәм зур пешүләрне дәвалау өчен мед. гамәлендә, ш.у. пешкән авыруларны аутодермопластикага — тире күчереп утыртуга әзерләүдә кулланыла. Препаратның үзенчәлеге: келоид җөйләр очрагын киметә. Пиримидин препаратлар рәтендәге башка матдәләрдән аермалы буларак, К. югары дәрәҗәдә отышлы дәва чарасы, аллергик реакцияләр һ.б. төр кире тәэсирләр китереп чыгармый.

Препаратны тәҗрибә юлы һәм клиникада тикшерү вакытында аның ашказаны, уникеилле эчәк, трофик җәрәхәтләр, операциядән соңгы яралар, остеомиелитны дәвалауда файдалы булуы ачыклана (Г.А. һәм С.Г.Измайловлар һ.б.). К. иммун системасын көчәйтү үзлегенә ия (А.П.Цибулькин, Д.Ю.Слабнов һ.б.) һәм шул сәбәпле иммун системасы бозылуларына бәйле авыруларны дәвалауда кулланылырга мөмкин. Гамма-радиация нурлары, мутагеннар, кластогеннар, яман шешләрне дәвалау чаралары, герпес вируслары һ.б. тәэсире вакытында К.ның цитопротектор җавап тәэсире исбатланган (В.Г.Черпнёв). Препарат «Татхимфармпрепаратлар» химия-фарм. сәнәгате берләшмәсендә 0,25 *г* актив матдәсе булган таблеткалар формасында җитештерелә.

*Әд.:* Г а р а е в Р.С. Моделирование экспрессии ключевых молекул мембран иммунокомпетентных клеток пиримидиновыми производными // Иммунология. 1998. № 4 (автордаш); И з м а й л о в С.Г. Ксимедон в клинической практике. Н.Новгород, 2001 (автордаш).

*Р.С.Гәрәев.*

**КТЫРЬЛА́Р** (Asilidae), ю л ч е б е н н ә р е, парканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. 5,5 меңнән артык төре билгеле, Россиядә — берничә йөз, Татарстан терр-ясендә 10 га якын төре бар. Гәүдә озынлыгы 4 тән 50 *мм* га кадәр (еш кына 15–25 *мм*), кыска төкләр б-н капланган. Күбесенчә урман-дала һәм дала зоналарында яшиләр. Ачык урыннарда — юл, урман кырыйларында, авыл юлларында очрыйлар. Көндез актив: җитез очалар, кояш яктысы төшкән агач кәүсәләренә һәм түмгәкләргә куналар. Олы К. — ерткычлар; төрле бөҗәкләр, үрмәкүчләр, талпаннар б-н тукланалар, кайвакыт умарталарга һө-

җүм итәләр. Үзләренең ау урыннары бар. Озын һәм көчле хортумчыгы б-н табышын һавада эләктереп ала. К.ның үсеше 1 дән 3 елга кадәр сузыла. Ана затлар яфракларга, сабакка, кайры астына, туфракка яки җир өслегенә ак төстәге орчыксыман вак йомыркалар салалар. Йомыркалардан личинкалар чыга, алар исә үсемлек калдыклары, шыртлавыклар, кара коңгызлар, хрущлар, саранчалар б-н тукланып, күбрәк комлы туфракларда яки черек үзагачта яшиләр (кайбер төрләре филчекләр һәм мыеклач коңгызларның личинкалары һәм курчаклары б-н тукланып, аларның юлында яши); җәй башында олы чебеннәргә әверелә. Күп кенә күзәнәк корткычларын юк итүче бөкре К. (Laphria gibbosa) һәм җирән К. (L. flava) Татарстан терр-ясе өчен гадәти бөҗәкләр. Шөпшәсыман К. (Asilus crabroniformis) һәм нечкәкорсак юл чебене (Leptogaster cylindrica Degeer) — сирәк төрләр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КУ БИЗГӘГЕ́**, төрле клиник күренешле көчле йогышлы авыру. Кешеләр, хайваннар һәм кошлар арасында Бёрнет коксиеллалары китереп чыгара, ринит, пневмония, конъюктивит һәм йөклелек өзелү б-н характерлана. Дәвамлы һәм кискен булмаган формалары сирәк. Чыганактан таралу юлы күп төрле, табигый чыганаклы авыру. Иммунитеты аз өйрәнелгән. 1937 елда беренче тапкыр тасвирлана, барлык континентларда, 51 илдә теркәлгән.

Табигый шартларда К.б. б-н зарарлануга 70 төр имезүчеләр, 50 төр кош, 40 тан артык буынтыгаяклы кан суыручылар (талпан, бет, борча) бирешә. А.х. терлекләреннән авыруга мөгезле эре һәм вак терлек тиз бирешүчән, Бёрнет коксиелласы аларда көчле һәм дәвамлы авыру китереп чыгарырга мөмкин. Үлем очрагы сирәк. К.б. патогенезы тәҗрибә терлекләрендә өйрәнелгән. Авыру китереп чыгаручылар организмга аэроген, алиментар яисә контакт юлы б-н яисә, кан суыручы бөҗәкләр тешләгәндә эләгеп, ретикулоэндотелиаль система тукымаларында һәм күзәнәкләрендә үрчиләр һәм йогышлы каты авыруга китерәләр, аннан гениталь система әгъзаларында урнашалар. Бу әгъзаларда урнашу абортка китерә һәм авыру чыганагы яралгы капчыгы сыеклыгы, плацента, сөт б-н чыга. Лаборатория тикшеренүләре өчен кан, хайван өстеннән җыелган талпаннар, аналык һәм җенсә бүлендекләре, йөклелеге өзелгән терлек плацентасы, ш.у. үлгән һәм суелган (диагноз кую өчен) терлекләрнең зарарланган үпкә, баш мие, үт, лимфа өлешләре алына. Тикшеренүләр РФ Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Вет. департаменты раслаган методик күрсәтмәләр нигезендә К.б.нә диагноз кую лаб-ясендә үткәрелә. К.б.н булдырмау һәм аның б-н көрәш РФ Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Дәүләт сан.-эпидемиология күзәтчелеге ком-ты раслаган сан. һәм вет. кагыйдәләре нигезендә үткәрелә. 1980 еллар башында Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү вет. ин-ты галимнәре авыруга диагноз кую, аны булдырмау һәм дәвалау ысулларын эшлиләр (Р.Г.Госманов, Р.Х.Йосыпов, Н.Ә.Хисмәтуллина, И.А.Корбанов һ.б.). Терлекләрдәге К.б.нә диагноз кую һәм антиген алу ысулына авторлык таныклыклары бар. 1985 елда Биектау р-нында институт галимнәре серологик тикшеренүләр юлы б-н мөгезле эре терлекләргә диагноз куялар (5–7% авыру), 1985–86 елларда Украина ССР, Вологда һәм Одесса өлкәләрендә мөгезле эре һәм вак терлекләргә диагноз куела (тикшерелгән хайваннарның 10% ы авыру).

*Әд.:* Усманов Р.Г., Юсупов Р.Х., Коршун А.И. Оценка эпизоотического состояния лихорадки КУ // Вопр. риккетенологии. М., 1985; шулар ук. Методические указания по лабораторной диагностике лихорадки КУ. М., 1986.

*Р.Г.Госманов.*

**КУАДЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәләкәс елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,5 *км*, бассейнының мәйданы 68 *км²*. Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Куады авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы — Чаллы шәһәренең көньяк-көнбатыш чигендә. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. К.ның 1,4 тән алып 5,3 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км²*. Туенуы катнаш, абс. күпчелек кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 105 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. К. бассейнында суның гомуми күләме 2 млн. *м³* булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КУАДЫ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 15 *км* көньяктарак, Мәләкәс елгасы бассейнында. 2010 елда 292 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 2 мәктәп, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, әвен эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1131,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 513, 1897 дә — 671, 1913 тә — 971, 1920 дә — 926, 1926 да — 533, 1938 дә — 617, 1949 да — 439, 1958 дә — 384, 1970 тә — 427, 1979 да — 341, 1989 да — 246, 2002 дә — 260 кеше.

**КУА́К** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 30,7 *км*, бассейнының мәйданы 319 *км²*. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап ага. Елга башы — Әлмәт р-ны Яңа Сүркә авылыннан төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Лениногорск р-нының Иске Куак авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 293 *м*, тамагынныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. К. елгасының 20 кушылдыгы бар, иң зурысы (уң) — Баллы елгасы (8,1 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км²*. Туенуы катнаш, яртысын диярлек кар сулары алып тора. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 150 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,88 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1,3 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Елга үзәненең уңъяк сөзәклегендә *Чыршылы сөркә (байбак) колониясе* табигать истәлеге урнашкан.

**КУА́К КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-ны Травкино авылыннан 0,6 *км* көнчыгыштарак, Мишә һәм Идел елгалары субүләрендә. Су өслегенең мәйданы 1,2 *га*. Су күләме 7 мең *м³* тирәсе. Озынлыгы 230 *м*, иң зур киңлеге 85 *м*. Уртача тирәнлеге 0,5 *м*, иң зур тирәнлеге 1,2 *м*. Күлнең барлыкка килүе



Куак күле.

карст-суффозия күренеше б-н бәйле. Формасы озынча. Суы йомшак, җиңелчә минеральләшкән, коңгырт төстә, Үтә күренмәлелеге 15 *см*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**КУАКБА́Ш** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Куак елгасы буенда. 2010 елда 817 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, көл җыеп сату б-н шөгыльләнә. 1864 елгы мәгълүматларга караганда, К.та мәчет, мәдрәсә (1822–23 тә Г.Утыз Имәни ача) була. 20 йөз башында К.та волость идарәсе, земство станциясе урнаша; 3 мәчет, 3 су тегермәне була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда

авыл җәмәгатенең имана җире 3460 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузайкино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 1159, 1889 да — 1662, 1900 дә — 1926, 1910 да — 2178, 1926 да — 1764, 1938 дә — 1444, 1949 да — 1168, 1958 дә — 1068, 1970 тә — 1237, 1979 да — 1032, 1989 да — 879, 2002 дә — 883 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**КУАКЛЫ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаллы–Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 17 кеше (татарлар) яши. 1947 дә Бикләп урман эшкәртү хуҗалыгы посёлогы буларак нигез салына. 1989 ның 19 маенда торак пункт булып теркәлә. Оештырылган көннән — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1958 дә — 139, 1970 тә — 116, 1979 да — 89, 2002 дә — 23 кеше.

**КУАКЛЫ́ КҮЛ**, Көнчыгыш Кама алдында. Элеккеге су юлында сакланып калган. Алабуга р-ны Танайка авылыннан 4 *км* көньяктарак, Кама елгасының уңъяк яры тугаенда. Су өслегенең мәйданы 17,08 *га*. Озынлыгы 1960 *м*, иң зур киңлеге 180 *м*. Формасы озынча.

**КУӘТЛЕ́ ЕЛГА́** (Кәкре Елга), Көнчыгыш Кама аръягында, Кәкре Елганың (Мәллә, Ык елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,1 *км*, бассейнының мәйданы 20,4 $км^2$. Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — урман массивында, Куәтле Елга авылыннан 2 *км* көньяктарак, тамагы — Кәкре Елга авылында. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 160 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. К.е.ның 0,4 тән алып 3,4 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,73 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 74 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең 2 нче яртысында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**КУБАКА́ЕВ** Тимерәй (1919, хәзерге БРның Калтасы р-ны Түлди а. — 15.1.1943, Ростов өлкәсенең Тарасов р-ны Красновка станциясендә туганнар каберлегендә җирләнә), Сов. Союзы Герое (31.3.1943, үлгәннән соң), гв. кече сержанты. Туган авылында тракторчы, урманда сал агызучы булып эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 130 нчы гв. укчы полкның автоматчылар взводы командиры (1 нче гв. армиянең 44 нче гв. укчы дивизиясе). Сталинград, Дон һәм Көньяк-Көнбатыш фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43) катнаша. 1943 нең 15 гыйнварында Донской (хәзер Красновка станциясе) посёлогы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: 13 сугышчыдан торган төркем б-н 3 йортны саклап тота; дошман йортларны яндыргач та К. сугышны дәвам итә һәм һәлак була. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Красновкадагы музей экспозициясе 13 каһарман сугышчыга багышлана. СССР Кораллы Көчләре Үзәк музеенда (Мәскәү) «Красновканың унөч Герое» дигән стенд бар. Калтасы авылында К.ка бюст куелган. Туган авылы мәктәбе Герой исемен йөртә.



Т. Кубакаев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Высоты мужества. Уфа, 1982; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУ́БАРЕВ** Юрий Григорьевич (2.4.1947, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1994), проф. (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), СССР ФА Себер бүлегенең Физика ин-тында эшли (Красноярск ш.); 1986 дан Красноярск технол. академиясендә, физика каф. мөдире (1991 дән). 1997 дән Казан энергетика ун-тында, агросәнәгать пр-тиеләренең энергия б-н тәэмин ителеше каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре фаза күчешле кушылмаларда релаксация күренешләренә, куерган халәттә зур масштаблы структуралар барлыкка килүгә, дефектлы матдәләр һәм җиһазлар диагностикасына карый. К. кристаллик кушылмаларда аномаль релаксация эффекты теориясен эшли; ваклanмалы үлчәнешләр турындагы геометрик күзаллаулардан чыгып, бериш булмаган фазаларның динамик үзлекләре нигезләрен үстерә; дефектлы матдәләрдә релаксациянең яңа механизмнарын таба; экстремаль шартлардагы кушылмаларда дефектлар барлыкка килүнең теориясен эшли һәм механизмнарын ачыклый.


Х е з м.: Аномальная квадрупольная спин-решёточная релаксация в примесных сегнетоэлектриках типа порядок-беспорядок // Журн. физ. химии. 1979. Т. 53, № 1 (автордаш); Магнитный резонанс и электронно-ядерные взаимодействия в кристаллах. Новосиб., 1983 (автордаш); Фрактальные свойства сегнетоэлекрических кристаллов // Изв. РАН. Сер. физ. 1993. Т. 57, № 3; Пространственно неоднородные структуры вблизи фазового перехода // Изв. РАН. Сер. физ. 1998. Т. 62, № 8.

**КУБА́С** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 19 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклыгычы ярында. 2010 елда 561 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сергеевский исеме б-н дә билгеле. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, Вознесенский тимер эшкәртү з-дына беркетелә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та Никола чиркәве, земство мәктәбе (1866 да ачыла), 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4020 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 219 ир-ат; 1859 да — 860, 1897 дә — 1308, 1908 дә — 1764, 1920 дә — 1777, 1926 да — 1854, 1938 дә — 1270, 1949 да — 977, 1958 дә — 838, 1970 тә — 548, 1979 да — 543, 1989 да — 509, 2002 дә — 603 кеше.

**КУБРА́Т ХАН** (? — 640 нчы еллар), *Бөек Болгар дәүләтенә* нигез салучы һәм идарәче (632 дән). Чыгышы б-н идарә итүче огур (төрки-огур) *Дуло* ыруыннан. Кайбер мәгълүматлар буенча, беркадәр Константинопольдә император сараенда яши, император Ираклий б-н дустанә мөнәсәбәттә була. 605–30 елларда Төрки каганлык составындагы бәклек идарәчесе, каганлык көчсезләнә башлагач, үз сәясәтен үткәрә, аварлар б-н сугышлар алып бара. Аварларга каршы император Ираклий б-н союз төзи. Константинопольдә чукындырылган булуы да ихтимал (619). 629–30 да аварларны җиңүгә ирешә. Византия каршындагы казанышлары өчен аңа дәүләт хезмәтендәге аксөякләр титулы — патрикий исеме бирелә. 632 еллар тирәсендә Төрки каганлыктан бәйсезлеккә ирешә һәм мөстәкыйль Бөек Болгар дәүләтенә нигез сала.

*И.Л.Измайлов.*

**КУБЫ́З** (варган), традицион татар музыка уен коралы, телле-чиртеп уйный торган идиофон. 8 *см* га якын озынлыкта, тараеп килгән очлы, уртасында башы ыргаксыман бөгелгән 7–10 *см* озынлыктагы нәзек корыч тел беркетелгән металл дагасы бар. Музыкант К.ны, иреннәре б-н кысып, авызында сул кулы б-н тота, уң кулының бармаклары б-н корыч тел очын чеметкәләп ала. К. тавышы безелдәвекле, аның биеклеге корыч телнең зурлыгына бәйле. Татар көнкүреш музыкасында агач К. һәм сөяк К. кулланылган. Агач К. 150–170 *мм* озынлыктагы турыпочмаклы өрәңге яки чыршы тактадан эшләнә, 30–35 *мм* киңлектә, 3 *мм* калынлыкта, урта өлешеннән тел кисеп ясала. Уйнаган вакытта К.ның шушы тел очыннан иреннәр арасында тоталар. Башкарыла торган көй бу телгә кидерелгән



Тимер кубыз.

җепне тарткач чыга. Сөяк К.ны ясау өчен мөгезле эре терлекнең кабырга сөякләре кулланыла. Аның озынлыгы 18–20 *см*, ш.у. уртасында тел кисеп ясала. Сөяк К.да көй башкару алымнары агач К.да уйнау алымнарына охшаш. Татар халкының көнкүрешендә К.ның элек һәм хәзерге вакыттагы популярлыгы (бигрәк тә хатын-кызлар һәм балалар арасында) аның кечкенә һәм уйнау алымы гади булуы б-н аңлатыла. К. киләчәктә дә тотрыклы яшәячәк, чөнки хәзер дә бу архаик уен коралын ясаучы халык осталары бар. Бигрәк тә И.Хисамов тарафыннан ясалган дагасыман һәм пластинкалы К.лар югары бәяләнә; бу оста эшләгән 600 дән артык уен коралы (дагасыман һәм пластинкалы К.лар) Татарстанның барлык районнарында диярлек кулланыла.

*Әд.:* А б д у л л и н А.Х. Некоторые вопросы татарского музыкального исполнительства // Вопросы народного творчества и музыкального исполнительства. К., 1960; Н и г м е д з я н о в М.Н. Народная музыка // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; ш у л у к. Татарские музыкальные инструменты // Музыкальная фольклористика. М., 1978. Вып. 2; Х а л и т о в Р.Ф. К изучению татарского народного инструментария // Актуальные вопросы татарской музыки. К., 1980; Я к о в л е в В.И. Традиционные музыкальные инструменты народов Среднего Поволжья. К., 1991.

*Р.Ф.Халитов.*

**КУГА́** (Juncus), кугачалар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 дән артык төре билгеле, ике ярымшарның да уртача һәм салкын поясларында, тропик һәм субтропикларның биек тауларында таралган. Татарстан терр-ясендә 13 төре бар. Билгесез К. (J. ambiguus), гөберле бака К.сы (J.bufonius), җепсыман К. (J. filiformis) һ.б. барлык районнарда очрыйлар, оешма К. (J. conglomeratus), салынкы К. (J. effusus), вак К. (J. minutulus) һ.б. — сирәк төрләр. Дымлы болыннарда, сулык ярлары буенда, куаклар арасында үсәләр. 5–50 *см* биеклектәге үсемлекләр. Сабагы цилиндрсыман. Яфраклары ачык җиңсәле һәм кыяк пластинкалы, кайвакыт бөтен яфраклары җиңсәгә кадәр кыскарган. Чәчәкләре вак, күрексез, дөрес формада, ике җенесле, башча, учма яки чатырсыман чәчәк төркемендә. Җимеше — 3 оялы, күп орлыклы тартмачык. Май–августта чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Декоратив, терлек азыгы үсемлекләре.

**КУГАЛЫ́П ҮЛӘ́Н** (Triglochin), кугалыпсыманнар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап, башлыча, Австралиядә һәм Көньяк Американың уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Саз К.ү. (T. palustres) — барлык районнарда, диңгез К. ү.(T.maritima) — Кама аръягында очрый. Дымлы һәм тозлы туфраклы болыннарда, торфлы сазлыкларда үсә. 15–90 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырчасы юан, кыска. Сабагы туры, цилиндрсыман, калын. Тамыр яны яфраклары тар кыяк. Чәчәкләре ике җенесле, вак, яшькелт, сабак очындагы чуксыман чәчәк төркемендә. Саз К.ү. җимеше озынча кыяклы, безсыман 3 очлы өлешкә аерыла, диңгез К.ү. — озынча йомыркасыман, 6 озынча эллипсыман җимешчектән тора. Май–августта чәчәк ата. Җимешләре июнь–сентябрьдә өлгерә. Күбрәк орлыктан үрчи. Җимешләре каз һәм үрдәкләр өчен азык булып тора. Диңгез К. ү. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КУГУБО́Р** (Кубыр, Чутай) елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 44,9 *км*, ТР чикләрендә — 32,2 *км*. Бассейнының мәйданы 329,3 $км^2$. Елга башы һәм югары агымы Киров өлкәсе терр-ясендә, тамагы Балтач р-ны Чутай авылыннан көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 65 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. К. елгасының 2,2 дән алып 8,8 *км* га кадәр озынлыктагы 23 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,44 $км/км^2$. Туенуы катнаш, зур күпчелекне кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–5 $л/с·км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 128 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,21 $м^3/с$. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). К. бассейнында суның гомуми күләме 1,1 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КУ́ГУШЕВ** Наил Ислам улы (28.5.1958, Ленинград), нәкышьче, график. 1986 елда И.Е.Репин исем. Нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (СССРның халык рәссамы Е.Е.Моисеенко остаханәсе), 1990 да САнең Казандагы нәкышь иҗади остаханәсен тәмамлый (СССРның халык рәссамы Х.Г.Якупов җитәкчелегендә). 1985 тән Петербург сәнгать мәктәбендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (2000). К. посткубистик юнәлештә иҗат итә. Аның сәнгати алымы хистән бигрәк акылга нигезләнүе б-н күзгә ташлана, картиналарындагы геом. төзелмәләре планиметриягә, күләмнәргә яссылыкка тартылалар.



Н.И. К у г у ш е в. «Автопортрет». 1996.



Н.И. К у г у ш е в. «Кызыл өчпочмак». 2003.

Композицияләре аңлаешлы, бруталь, тотрыклы сызыкларга, ачык формаларга, контраст төсләргә, кырыс ритмнарга корылган. Төп әсәрләре: нәкышь — «Автопортрет» (1996), «Кызыл өчпочмак», «Өч чирек», «Сиксән сигез» (барысы да — 2003); графика — «Савыт» (катнаш алым, 1998), «Йорт» (коллаж, 1999), «Җиләк-җимеш» (коллаж, 2001). Петербургта уздырылган «Яңа традицияләр» (1997), «17 апрель» сәнгать берләшмәсе (1998–2000), «Стерлигов фәзасы» (2001), «Традицияләр һәм хәзерге заман» (2003) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Әсәрләре «Царское Село коллекциясе» Хәзерге заман сәнгате музеенда (Пушкин ш.), Россиядәге һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* К о р о л ь ч у к А. Прикосновение к истокам русского авангарда // Нева. 1998. № 6; Пространство Стерлигова: Альбом. СПб., 2001; Традиции и современность: Каталог выставки. СПб., 2003.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**КУГУ́ШЕВЛАР**, татар бәкләре нәселе. Бихан токымыннан булган Кугуш бәктән башлана. 1627 елда К. Касыйм өязендәге Биркеево авылы хуҗалары була. 1639 да К. нәселеннән Акай морза Айтугановка Темников өязендә биләмә (вотчина) бирелә һәм ул патша грамоталарында кенәз буларак күрсәтелә. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында К. нәселе вәкилләре Ләмбрә йомышлы татарлары арасында күрсәтелә. К. нәселе дворяннар катлавында 18 йөз ахырында раслана. К. Краснослободск өязенең Тархан, Темников өязенең Каменка һәм Митрәле авылларында яшиләр, бер өлеше Сембер губернасында гомер кичерә.

*Әд.:* Сборник исторических и статистических материалов о Симбирской губернии. Симбирск, 1868; Е н и к е е в С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**КУДА́Ш ИЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. Даими яшәүчеләр юк. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шө-

гыльләнә. 20 йөз башында К.и.дә ашлык саклау-сату һәм вак-төякләр кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 203,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 117, 1897 дә — 187, 1908 дә — 198, 1920 дә — 192, 1926 да — 254, 1949 да — 173, 1958 дә — 133, 1970 тә — 47, 197 да — 24, 1989 да — 6, 2002 дә — 2 кеше.


С. Кудаш.

**КУДА́Ш** (Кудашев) Сәйфи (Сәйфетдин) Фәттах улы (3.10.1894, Уфа өязе Келәш а. — 26.6.1993, Уфа ш.), шагыйрь, БАССРның халык шагыйре (1964), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач (1918), Уфа өязе Красная Горка авылында (1918–19), Омск шәһәренең 2 нче ир балалар урта мәктәбендә (1919–20) татар теле һәм әдәбияты укыта, бер үк вакытта «Азат Себер» г-тасында хезмәттәшлек итә. 1925 елдан Уфа шәһәрендә яши. «Башкортстан» г-тасы (1925–33), «Октябрь» ж-лы (1931–33) редакцияләрендә эшли. 1935 тән БАССР Язучылар берлегендә (1943–48 дә идарә рәисе). К.ның 1914 елда «Тормыш» г-тасында (Уфа) һәм «Кармак» ж-лында (Оренбург ш.) басылып чыккан беренче шигырьләре идея-тематик юнәлеше һәм сатирик алымнары б-н Г.Тукай әсәрләренә охшаш. Аның башлангыч чор иҗатына җәмгыять төзелешеннән риза булмау, самодержавие изүенә каршы протест, җәберләнгән халык, хатын-кызның хокуксызлыгы өчен әрнү кебек мотивлар б-н беррәттән өметле киләчәккә ышану чалымнары да хас. 1917 елда аның татар телендә басылган ике шигъри җыентыгы дөнья күрә: «Ак билетлар бәете» һәм «Азатлык җырлары» дип аталган бу җыентыкларда шагыйрь ул чор өчен мөһим булган тынычлык, җир һәм ирек хокукы, татар халкының мөстәкыйльлеге кебек мәсьәләләрне күтәреп чыга, тарихи үткәнгә мөрәҗәгать итеп, татарларның кайчандыр үз дәүләтләре булганлыгына басым ясый («Татар теләге» җыентыгы, 1918). Гражданнар сугышы чоры шигырьләрендә шагыйрь яңа эпоханың бөеклегенә, иректә иҗади хезмәткә, эшче һәм крәстияннәр дуслыгына дан җырлый: «Сабан җырлары» (Уфа, 1926), «Утауда» (1927), «Көрәш батыры» (Уфа, 1928) җыентыклары. 1930 еллар башыннан К. башкорт телендә иҗат итә. «Бәхет законы» (Уфа, 1937), «Республика йырлай» (Уфа, 1940) шигъри җыентыклары, «Икенсе йәшлек» (Уфа, 1934), «Хәмиҙәнең шатлығы» (Уфа, 1936) хикәяләр җыентыклары, «Атаҡлы кешеләр» (Уфа, 1935) очерклар сериясе, «Кушкаен» (Уфа, 1936) шигъри романы һ.б.ларның төп темалары — туган республикасының соц. төзелештәге уңышлары, замандашларының уңай образлары. Шулай ук К. тормыш чынбарлыгын матурлап күрсәтергә дә омтыла: «Алтын асҡыс» (Уфа, 1939), «Кауышыу» (Уфа, 1939) поэмалары. Бөек Ватан сугышы еллары иҗатының геройлары — фашист илбасарларына каршы көрәшүче фидакарь сугышчылар («Саҡырыу» (Уфа, 1942), «Бөтә йөрәктән» (Уфа, 1943) шигъри җыентыклар; «Башҡорт атлылары» (Уфа, 1943) очерклар җыентыгы). Сугыштан соңгы шигырь һәм поэмалары тормыш мәгънәсе, замандашлары язмышы турында фәлсәфи уйланулар б-н сугарылган («Минең мөхәббәтем» (Уфа, 1956), «Япраҡтар койолғанда» (Уфа, 1960), «Минең баҡсамда» (Уфа, 1964), «Тау юлында», (Уфа, 1972), «Һөйөү һүҙҙәре» (Уфа, 1981) җыентыклары). К. ш.у. сатирик шигырьләр һәм мәсәлләр, проза әсәрләре дә иҗат итә. «Яҙҙы ҡаршылағанда» (Уфа, 1954) исемле тарихи-биографик повестенда Г.Тукайның, 1912 елның язында Уфага килеп, М.Гафури б-н очрашуына бәйле вакыйгалар яктыртыла. «Хәтерҙә ҡалган минуттар» (Уфа, 1958), «Йәшлек эҙҙәре буйлап» (Уфа, 1964), «Бабич менән осрашҡанда» (Уфа, 1964) исемле истәлекләр китапларында К.ның 1910–30 елларда Башкортстанның, Татарстанның һәм Казакъстанның күренекле әдәбият әһелләре б-н шәхсән очрашып сөйләшүләреннән алган тәэсирләре яктыртыла. К.ның балалар өчен язган китаплары да бар: «Боярҙар бар сакта» (Уфа, 1928); «Әҙер бул!» (Уфа, 1935); «Урман әкияте» (Уфа, 1937); «Бәхетле балалыҡ» (Уфа, 1940). Ул хәзерге әдәбиятка, әдәби иҗатның теоретик һәм гамәли мәсьәләләренә багышланган публицистик мәкаләләр б-н дә чыгыш ясый. Аның күп кенә әсәрләре рус, татар, үзбәк, украин, таҗик, казакъ һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. Башкортстан АССРның Салават Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма шигырьләр. Уфа, 1940; Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1941; Хәтердә калган минутлар. К., 1959; Яшьлек эзләре буйлап. К., 1964; Избранные произведения: В 2 т. Уфа, 1970; Стихи и поэмы. Уфа, 1984; Әҫәрҙәр: 4 томда. Өфө, 1946–53; Һайланма әҫәрҙәр: 3 томда. Өфө, 1965–67; Шиғырҙар. Өфө, 1974.

*Әд.:* Кудашев А. Жизненный путь поэта. Уфа, 1943; Кудашева С., Кузеев Р. Жизнь длиною в один век: Воспоминания. Уфа, 1998; Хөсәйенов Г. Сәйфи Ҡудаш ижады. Өфө, 1959; Сәйфи Ҡудаш ижады: Мәҡәләләр йыйынтығы. Өфө, 1986.

*С.Г.Сафуанов.*


И.М. Кудашев.

**КУДА́ШЕВ** Идрис Моисеевич (23.9.1914, хәзер Саратов өлкәсенең Базар-Караболак р-ны Яковлевка а. — 9.5.1970, Саратов ш.), Сов. Союзы Герое (21.3.1940), кече командир. Туган авылында колхозда эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 68 нче укчы полкның взвод командиры (7 нче армиянең 70 нче укчы дивизиясе). 1940 ның 29 февралендә Выборг култыгында Пуккионсари күле (хәзер Козлиный күле) янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: үзе б-н взвод сугышчыларын ияртеп, ротада беренче булып атакага күтәрелә; рота б-н җитәкчелек итүне үз кулына ала һәм куелган бурычны үти. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945 тән запаста. Саратов шәһәрендә яши һәм эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Румянцев Н.М. Люди легендарного подвига. Саратов, 1968; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*


И.Б. Кудашев-Ашказарский.

**КУДА́ШЕВ-АШКАЗА́РСКИЙ** Ильяс Батыргәрәй улы (3.3.1884, Оренбург ш. — 1942), актёр, режиссёр, Хезмәт Батыры (1926); беренче проф. татар театры труппасын оештыручы. 1904 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый, Оренбург шәһәрендә укытучы булып эшли, 1905 тә, даими проф. театр оештыру максатыннан, театр сәнгатен сөючеләр төркемен җыя. Беренче спектакль — «Наданнар белән галимнәр» (А.Н.Островскийның «В чужом пиру похмелье» пьесасының үзгәртелгән варианты) — реакцион рухлы татар руханилары һәм сәүдәгәрләренең катгый таләпләре нигезендә губернатор тарафыннан тыела. 1907 дә Оренбург шәһәрендәге Халык йорты бинасында К.-А. татар телендә күп кенә спектакльләр куя — «Өйләнү» («Женитьба», Н.В.Гоголь) комедиясеннән күренешләр, «Морат Сәлимов» (Ф.Халиди), «Кыз сорау» («Предложение», А.П.Чехов), «Наданлык илә галимлек» («Свет и тьма», А.Н.Островский пьесасы буенча), «Денщик Гали» (С.Турбин), «Оят, яки күз яше» (Я.Вәли) пьесалары сәхнәләштерелә. Спектакльләрдә В.Мортазин, Ә.Кулалаев, Г.Гайнуллин һ.б. актёрлар катнаша. Шул ук елда К.-А. тарафыннан оештырылган «*Россиядә беренче күчмә мөселман драма артистлары труппасы*» Россия буенча сәфәргә чыга (спектакльләр Самара, Сембер, Казан, Түбән Новгород, Мәскәү, Рязань, Касыйм шәһәрләрендә күрсәтелә). Гастрольләр вакытында труппа составына Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Ф.Шаһимәрдановалар керә. Г.Кариев җитәкләгән актёрларның бер өлеше труппадан киткәч, нигездә, муз.-драма спектакльләре куела башлый. Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында, соңыннан Оренбург, Казан театрларында, 1928–29 да Татар акад. театры труппасында эшли. Алдагы елларда адм. органнар (Главлито, шәһәр советы) эшендә актив катнаша, 1931 дә «Востоккино» Татар бүлекчәсенең сәхнә курсларында белем ала, әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә, халык җырларын җыя



Ф.Я.Кудашева.

һәм эшкәртә. Актёр буларак сәхнәдә шактый гына мөһим образлар иҗат итә: Ильяс бәй («Оят, яки күз яше», Я.Вәли), Салих («Мөгаллим», Г.Исхакый), Әхмәтҗан («Уйнаш», Г.Камал), Кәрим бай («Җиңел хезмәттә», Ф.Ярыгин).

*Әд.:* Мортазин В., Чәнәкәй Т. Татар театры тарихыннан. М., 1926; Татар совет театры. К., 1975; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Иляĺлова И.И. Г.Камал артистлары: Биографик белешмәлек. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**КУДА́ШЕВА** Фәридә Яһүдә кызы (15.12.1920, Уфа губ. Уфа кантоны хәзер БРның Чишмә р-ны Келәш а. — 9.10.2010, Уфа), артист, җырчы, БАССР, ТССРның халык артисты (1968, 1990), РСФСРның атказ. артисты (1972). 1939 елда Уфа театр-сәнгать уч-щесенең театр бүлеген тәмамлый. 1939–41 дә Дүртөйле колхоз-совхоз театрында, 1944–47 дә Башкорт акад. драма театрында артист. 1941–44, 1956–78 дә Башкорт филармониясендә, 1948–56 да Башкорт радиосында солист. К. иҗаты — татар һәм башкорт эстрада сәнгатенең иң күренекле казанышларыннан берсе. Җырчы сирәк очрый торган гаҗәеп нәзакатьле, йомшак тембрлы тавышка ия була. Җырларын ихлас күңелдән, тирән хис б-н башкара. К.ның киң концерт репертуарына Татарстан һәм Башкортстан композиторларының вокаль әсәрләре, татар һәм башкорт халык җырлары керә. Башкорт һәм татар халык җырларын тыңлаучыга иң камил җиткерүчеләрнең берсе («Сибай кантон», «Урал», «Уел», «Сакмар», «Сарман», «Ашказар», «Азамат», «Сандугач», «Илче Гайсә», «Зөлхиҗә», «Хәмдия», «Колай кантон», «Салкын чишмә», «Бибкәй», «Казан кантоны» һ.б.). Киң масса тыңлаучылар алдында зур популярлык казана. Халыклар Дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Башкортстан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.


**КУДА́ШЕВЛАР**, татар бәкләре нәселе. 16 йөзнең 1 нче яртысында яшәгән Темников бәге Ефай улы Кудаштан башлана. 1629 елда крепостной крәстияннәре булган Темников бәкләре Булай, Ишәй, Чепай һәм Билгилдей К. хакында искә алына. Чепай бәк (аның дәвамчылары православие динен кабул итәләр) Польша б-н сугыш вакытында (1618) Мәскәү камалышында катнаша, шуның өчен биләмә б-н бүләкләнә. Бәкләр К.ның нәсел шәҗәрәсе тармагы Темников морзасы Булайдан башлана, аңа патша Василий Шуйский грамотасы буенча 1608 нең 14 октябрендә 36 еллык хезмәте өчен Киршә мордваларының варислыкта булмаган җирләре бүләк ителә. 17 йөзнең 1 нче яртысында К. нәселеннән Байбулат һәм Досай Булаевлар, Кодрәк Досаев телгә алына. 1713 тә К. нәселеннән Ислан һәм Янгуҗа Тохтаровларның Пенза өязе Колчурак авылында крепостной крәстияннәре була. Чукынудан баш тарткан өчен Булай нәселе дәвамчылары җирләре патша карамагына алына, ә алар үзләре Темников һәм Краснослободск өязләренең дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. 18 йөз башында К. Саранск өязенең Мелцапино, Кадом өязенең Булай һәм Чёрная авылларында яшиләр. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында алар Ахун (хәзер БРның Благовар р-ны), Бүздәк, Ышланлыкүл (хәзер БРның Бүздәк р-ны) һәм Айбулат (хәзер БРның Чакмагыш р-ны) авылларына килеп урнашалар. Сенатның 1796 ел 1 декабрь фәрманы б-н К. нәселенә дворянлык дәрәҗәсе кайтарыла.

*Әд.:* Лобанов-Ростовский А.Б. Русская родословная книга. СПб., 1895. Т. 1; Еникеев С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**КУДЕ́ЛЬКИН** Виктор Иванович (9.1.1911, Алатырь ш. — 14.6.1995, Казан), нәкышьче, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1960), ТАССРның халык рәссамы (1971), РСФСРның атказ. рәссамы (1978). Чабаксар сәнгать уч-щесен тәмамлый (1938), 1938–40 елларда Мәскәүдә рәссамнарның квалификациясен күтәрү курсларында В.А.Бакшеевта укый. 1940 тан Казанда яши һәм эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1940). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–75 елларда Казан сәнгать уч-щесендә укыта. Нәкышьче буларак, күбрәк портрет жанрында эшли. Аның тарафыннан башкарылган замандашлар портретларының зур галереясы барлыкка килә — авыл хезмәтчәннәре, эшчеләр сыйныфы һәм интеллигенция вәкилләре. Үзләренә якын мохиттә сурәтләп, рәссам аларның эчке дөньясын тулысынча ачуга ирешә. Иҗат исулының ихласлык һәм тормыш чынбарлыгын сурәтләү кебек төп сыйфатлары 1950 елларда формалаша. К. — психол. портретлар остасы: «Корея кызы Ким Ден Ок» (1951), «Яшь рәссам кыз» (1955), «Бораулау остасы Г.З.Гайфуллин портреты» (1956), «Ахирәт кызлар Л.Әхмәтҗанова һәм Т.Бирюкова» (1968). Казан «Органик синтез» пр-тиесе эшчеләре образларын иҗат итүе рәссам иҗатында мөһим этап булып тора. Әлеге сериянең үзәгендә («Тәнәфес» картинасы, 1964) К. булачак завод биналарын коручы төзүчеләр бригадасының коллектив портретын сурәтли. 1970 еллар башында Рәссамнар берлеге каршында «КамАЗ» һәм «Авыл» иҗат төркемнәре оештырылуы рәссамнарга яңа батырлар тудыручы тынгысыз хезмәт стихиясенә кереп чуму мөмкинлеге ача: «КамАЗның хатын-кызлар бригадасы» (1972), «КамАЗны төзүче-бригадирлар Сәлахов һәм Новолодский портретлары» (1975), «ТАССРның Куйбышев районы Никольский авылындагы М.Кузьмин бригадасының алдынгы сыер савучылары портреты» (1978–79), «Игенче С.Гыйматдинов» (1983). К. мәдәният һәм фән эшлеклеләре образларын гәүдәләндерүдә дә актив эшли. Портретларның һәркайсында — Х.Туфан (1974), Н.Исәнбәт (1974), Н.Арсланов (1977), Д.Вәлиев (1983), М.Сәлимҗанов (1985) — оста иҗади шәхес илһамлы хезмәт халәтендә күрсәтелә. Ул бернич тапкыр тарихи темага («М.И.Калинин Татарстан крәстияннәрендә кунакта», 1968–69), элеккеге фронтовик буларак, хәрби-патриотик темага да («Исемсез биеклектә», 1969; «Шәфкать туташы Р.Даггелете портреты», 1976; «Советлар Союзы Герое Н.Якупов портреты», 1977; «Питрәч районы Бөек Ватан сугышы хатын-кыз ветераннарының төркемле портреты», «Политрук (М.Җәлил)», 1985–86) мөрәҗәгать итә.

Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге Татарстанның хезмәт алдынгылары, авыл хезмәтчәннәре һәм мәдәният эшлеклеләренә багышланган картиналар сериясе өчен бирелә (1986). Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.







В.И.Куделькин. 1. «Ахирәт кызлар...». 1968; 2. «Советлар Союзы Герое Н.Якупов портреты». 1977; 3. «...М.Кузьмин бригадасының алдынгы сыер савучылары портреты». 1978–79. Барысы да — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

Республика (1942 дән); төбәк — «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Волгоград ш., 1967; Ульянов ш., 1969; Горький ш., 1974; Казан, 1980); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1960), «РСФСР рәссамнарының Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган күргәзмәсе» (Волгоград ш., 1975) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1959, 1961, 1971, 1976, 1981) һәм Әлмәттә (1982) уздырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Казандагы А.М.Горький әдәби-мемориаль музеенда, Чаллы шәһәренең Тарих музеенда, Әлмәт һәм Лениногорск шәһәрләре картиналар галереяларында саклана.

*Әд.:* Художники Российской Федерации: В.Куделькин: Буклет. Л., 1960; Выставка произведений Виктора Ивановича Куделькина: Каталог. К., 1961; Червонная С.М. Художники Советской Татарии: К., 1984.

*Т.В.Голубцова.*

**КУДРЯ́ВЦЕВ** Мефодий (Нефёд) Никитич (1676 тирәсе — 12.7.1774, Казан), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-майор (1740). Н.А.*Кудрявцевның* улы. Дворяннар нәселеннән. 1700–21 еллардагы Төньяк сугышында катнаша. 1711 дә Казан губернаторы П.М.Апраксин отряды составында Кубаньда яуда була. 1712–18 дә һәм 1726 дан Идел буенда флот өчен корабльләр төзүгә яраклы агач материалларын барлау һәм әзерләү б-н шөгыльләнә. 1722–23 тә Персиягә яу вакытында армия өчен атлар сатып ала һәм Кавказ сугышында калмыклар б-н җитәкчелек итә. 1723 тә үз хисабына Казан губернасы Казан өязе Каймар авылында гыйбадәтханә салдыра. 1727–33 тә Казанның вице-губернаторы. 1728–30 да губернатор А.П.Волынскийның җирле халыктан законсыз рәвештә бик зур салымнар җыюы турындагы эш буенча тикшерүләр алып бара һәм аны вазифасыннан читләштерүгә ирешә. 1733–40 та Казан адмиралтействосы обер-комиссары. 1740 тан Каймар авылында яши, анда ат заводы ача. Казан губернасында 20 мең дис.дән артык җир били. Е.И.Пугачёв кузгалышы вакытында, 1774 тә, җирле дворяннардан баш күтәрүчеләр б-н көрәшү өчен аерым корпус оештыручыларның берсе. Казанны пугачёвчылар штурмлаган вакытта һәлак була.



М.Н. Кудрявцев.

*Әд.:* Веселаго Ф.Ф. Общий морской список. СПб., 1885. Ч. 1; Корсаков Д.А. Из жизни русских деятелей XVIII века. К., 1891.

*Е.Б.Долгов.*

**КУДРЯ́ВЦЕВ** Никита Алфёрович (1650 тирәсе — 1729, Казан), дәүләт эшлеклесе. М.Н.*Кудрявцевның* атисе. Дворяннар нәселеннән. 1670 еллардан дәүләт эшендә һәм хәрби хезмәттә. 1695 һәм 1696 дагы Азов яуларында катнаша. 1697 дән Казанда: 2 нче воевода (1699 га кадәр), 1699–1706 да 1 нче воевода, 1706–10 да комендант, 1710–14 тә обер-комендант. 1705–11 дә башкорт-татар кузгалышлары вакытында Казан һәм Биләр тирәсендә баш күтәрүчеләрне бернича тапкыр җиңә һәм төбәк халкын буйсындыра. 1708 елгы губерна реформасын әзерләүдә һәм Казан губернасын оештыруда катнаша. 1712–27 дә Идел буенда корабльләр төзүгә яраклы агач материаллары әзерләү (аларны С.-Петербургка озату эшләре б-н җитәкчелек итә) буенча баш мөдир. Бер үк вакытта, 1714–27 дә Казанның вице-губернаторы. 1718 дә лашманлык бурычын кертүдә катнаша. Казан адмиралтействосы оештырылганнан соң (1718), К. күзәтчелеге астында Россия флоты өчен 50 дән артык судно төзелә, шәһәрнең төньяк-көнбатыш читендә Адмиралтейство бистәсенә нигез салына. 1719–24 тә Казан постау мануфактурасы б-н идарә итә.

*Әд.:* Веселаго Ф.Ф. Общий морской список. СПб., 1885. Ч. 1; Корсаков Д.А. Из жизни русских деятелей XVIII века. К., 1891.

*Е.Б.Долгов.*

**КУДРЯ́ВЦЕВА** Нина Петровна (14.1.1918, Казан — 7.2.1984, шунда ук), йогышлы авырулар буенча балалар табибе, мед. фән. д-ры (1955), проф. (1958), ТАССРның атказ. табибе (1964). 1942 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук балалар йогышлы авырулары кафедрасында (бер үк вакытта, 1942–45 тә эвакуация госпиталендә) эшли, 1955–80 дә балалар йогышлы авырулары каф. мөдире, профессоры. Хезмәтләре балаларда йогышлы авыруларның актуаль мәсьәләләренә карый (ш.и. прививка ясалган балаларда дифтерия). К. тикшеренүләре чистартылган ассоциаләнгән вакциналарның дәвамлы иммунитет булдыруын, дифтериягә каршы тотрыклылыкны арттыруын ачыклый, бу исә аларны СССРда дифтерия иммунопрофилактикасы гамәленә күпләп кертергә ярдәм итә. К. респиратор вируслы йогышлы авыруларны дәвалау өчен яңа фосфорорганик кушылмаларга клиник тикшеренүләр үткәрә. Казанда дифтериягә диагноз кую стационарын — ТАССРда һәм Урта Идел буе төбәгенең башка республикаларында дифтериягә каршы көрәш оештыру-методик үзәген (1958) оештыра.

Хезм.: Клинико-этиологическая характеристика вирусно-бактериальных пневмоний у детей и принципы их неотложной терапии // Казан. мед. журн. 1979. № 6; Детские болезни. М., 1980 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Нина Петровна Кудрявцева: Некролог // Казан. мед. журн. 1985. № 3.

**КУДРЯ́ШЕВ** Герасим Павлович (14.3.1910, хәзер Оренбург өлкәсенең Северный р-ны Кирсановка а. — 15.7.1979, Бөгелмә ш.), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. өлкән сержанты. Бөгелмә пед. уч-щесен тәмамлый (1932). Туган авылында укытучы булып эшли. 1941 елның октябреннән Кызыл Армиядә. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 23 нче гв. мотоукчы бригаданың артиллерия дивизионында (3 нче гв. танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы) туп командиры. Брянск, Үзәк һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Киев һөҗүм һәм оборона операциясендә (1943), Житомир-Бердичев, Львов-Сандомир (икесе дә — 1944) һәм Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 23 гыйнвар төненә каршы Одер елгасын кичеп, Грошовице торак пункты (Ополе шәһәреннән 5 *км* көньяктарак, Польша) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: укчы подразделениеләргә елга аша кичеп чыгарга булыша, һөҗүм төркеме б-н дошманның ут нокталарын юк итә. 1945 тә демобилизацияләнә. Бөгелмә шәһәрендә яши һәм эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.



Г.П. Кудряшев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУДРЯШО́В** Владимир Викторович (2.7.1950, Кама Тамагы пос.), тренер (акробатика), РСФСРның атказ. тренеры (1988). Волгоград физик культура ин-тын тәмамлый (1978). 1967–69 елларда 1 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Чистай ш.) тренер-укытучы, 1973–83 тә «Әлмәтнефть» НГДУының 1 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Әлмәт ш.) өлкән тренер-укытучы, 1983–90 да «КамАЗ» спорт клубында, 1990–92 дә физкультура һәм спорт буенча шәһәр ком-ты рәисе, 1992–94 тә «Булинь» альпинистлар һәм кыя тауга менүчеләр клубында коммерция директоры, 1994–96 да «Дельфин» спорт-сәламәтләндерү комплексында директор урынбасары (Чаллы ш.), 1996–2004 тә коммерция эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, 2004 тән олимпия резервындагы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Чистай ш.) тренер. Шәкертләре арасында — СССР (1987, 1990), дөнья (1990) чемпионнары А.Ш.Абдуллов, И.И.Чернов, Европа чемпионатында һәм Дөнья кубогына ярышларда көмеш медаль алучылар бар.


**КУДРЯШО́В** Владимир Владимирович (25.7.1902, Тәтеш өязе Кече Яльчик а. — 9.11.1944, Мәскәү), сынчы, график. Казан архит-ра-техник (1923) һәм Мәскәү югары сәнгать-техника (ВХУТЕИН, 1923–29) ин-тларын тәмамлый. Мәскәүдә яши. Казанда укыганда монументаль пропаганда планын тормышка ашыруда катнаша, М.Вахитов һәйкәле проекты авторы (1923). Сәяси плакатлар иҗат итә: «Көчле, тырыш хезмәт белән җиме-

реклекләр богауларын юк итик» (1921), «Профсоюзлар, җитештерүне оештырып, җимереклекләрне җиңәр» (1921) һ.б.; театр декорацияләре эскизлары: «Тропик урман», «Тау күренеше», «Урман күренеше», «Маргарита бакчасы», «Җәйге бакча», «Кышкы урман» һ.б. (1920 еллар). «Яшерен манара», «Сөембикә манарасы», «Кафедраль собор гөмбәзләре», «Почмактагы манара», «Спас манарасы» (офорт, акватинта, коры энә) рәсемнәре кертелгән «Казан Кремле» офортлар



В.В.К у д р я ш о в. «Кафедраль собор гөмбәзләре». «Казан Кремле» офортлар альбомыннан. 1922. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

альбомы авторы (1922). Рәссам яктылык һәм күләгә контрастларын, архитектур детальләр һәм ракурсларның масштаблы бәйләнешләрен файдаланып, архит-ра материалының зурлыгын күрсәтә. Казан Кремленең күләмле нәфис иконографиясендә К.ның офортлары композицияләренең кискенлеге һәм аларга салынган монументальлек б-н аерылып тора. Кредитартельсоюз музее өчен К. вак пластик сәнгать әсәрләре иҗат итә: «Көлтә бәйләүче крәстиян хатын», «Ялангач кыз», «Хәер эстәүче карчык», «Ярымъялангач кыз», «Крәстиян» (барысын да — агач, уеп бизәкләү, 1920 еллар башы) һ.б. Алар композиция алымнарының төрлелеге, материалны эшкәртүдә яңа техник ысуллар куллану б-н үзенчәлекле. К.ның 1920 еллар Казан сәнгатендә көнкүреш жанрында эшләнгән камера скульптурасына мөрәҗәгать итүе аерым игътибарга лаек. 1920 еллар ахырында К. гаммәви революцион бәйрәмнәрне бизәү өчен декоратив скульпту-



В.В.К у д р я ш о в. «Сакаллы ир башы». Агач. Уеп кисү. 1921–22. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

раның А.В.Луначарский тарафыннан хупланган һәм шул сәбәпле киң таралган махсус конструкцияләү ысулы проектын төзи. 1930 елларда К. арх. А.В.Щусев б-н хезмәттәшлек итә, В.Э.Мейерхольд театры бинасы фасады өчен маскалар эшли, Ново-Москворецк күпере өчен скульптур төркем проектын һ.б. төзи. ИзоГиз (Дәүләт сынлы сәнгать нәшрияты) өчен плакатлар иҗат итә. Станлы сыннар авторы: «Кытай Кызыл армиясе», «Париж коммунасы», «Ана дөньясы» (барысы да — гипс, 1930 еллар). Пастель, сангина, карандаш техникасында график әсәрләр сериясе иҗат итә: «Гаилә», «Балалар», «Су коенучы хатын-кызлар» һ.б. А.С.Пушкинга багышланган Бөтенсоюз юбилей күргәзмәсенә әзерләнү уңаеннан 1937 дә киң күләмле картиналар сериясе тудыра: «Пушкин портреты» (пастель), «Эшләпә кигән Пушкин портреты» (сангина), «Пушкин диңгез буенда» (сангина, карандаш), «Пушкин эш өстәле янында» (сангина, карандаш) һ.б., ш.у. А.С.Пушкин, А.С.Грибоедов һәйкәлләренең проектларын әзерли. Бөек Ватан сугышында катнаша, антифашистик плакатлар һәм листовкалар авторы.

Казанда узган 1 нче Дәүләт сәнгать һәм фән (1920), 2 нче Дәүләт нәкышь, скульптура һәм архит-ра (1921), «Казан сәяси плакаты» (1929), «РСФСР рәссамнары 15 елда» (Мәскәү, 1933), «РККАга 15 ел» (Мәскәү, 1933) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Революция музеенда (Мәскәү) саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Каталог выставки произведении художников Татарии 20-х годов. К., 1990.

*Е.П.Ключевская.*

**КУЕДА́ РАЙОНЫ́**, *Пермь өлкәсенең* көньягында урнашкан. 1926 елда оештырыла. Мәйданы — 2616 *км²*. Үзәге — Куеда посёлогы (Пермь шәһәреннән 267 *км* көньяктарак). Халкы — 30360 кеше (2010), ш.и. 2339 татар (2002). Татарлар, башлыча, Куеда посёлогында, Бадашка, Маныш, Татар Чикәше һәм Рус Чикәше авылларында яши. Районда татарлар 17–18 йөзләрдә күренә башлыйлар, алар удмуртлар нигез салган Татар Чикәше авылына килеп урнаша. 19 йөзнең 2 нче яртысында күп кенә татарлар Пермь өлкәсенең хәзерге Барда р-ны һәм БР терр-яләреннән күчеп килә. Хәзерге вакытта Маныш авылы мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла. Куеда посёлогында татар һәм башкорт милли-мәдәни үзәкләре (1999 дан), «Сандугач» вокаль ансамбле (2000 нән), «Миләш» бию ансамбле (2000 нән), мөселман дини оешмасы бар; 2005 тән мәчет эшли.

*Әд.:* Ч е р н ы х А.В. Краеведение. Куединский район: Учеб. пособие. Куеда, 1998; Ч а г и н Г.Н., Ч е р н ы х А.В. Народы Прикамья: Очерки этнокультурного развития в XIX–XX вв. Пермь, 2002.

**КУЖА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 19 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 184 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәктәп була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 845,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 385, 1897 дә — 636, 1912 дә — 739, 1920 дә — 737, 1926 да — 620, 1938 дә — 607, 1949 да — 410, 1958 дә — 401, 1970 тә — 475, 1979 да — 377, 1989 да — 231, 2002 дә — 239 кеше.

**КУЗА́ЕВА** Дамира Нәҗмиҗан кызы (16.5.1948, Пермь өлкәсенең Барда р-ны Тунгук а. — 20.12.1993, Әлмәт ш.), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1984). Сәхнә эшчәнлеген 1966 елда Әлмәт татар драма театрында башлап җибәрә, бер үк вакытта шул театр студиясендә укый. Беренче рольләре — София («Кияүләр», Г.Хугаев), Зөбәрҗәт («Ай тотылган төндә», М.Кәрим). Казан театр уч-щесен (М.Х.Сәлимҗанов курсы)



Д.Н.К у з а е в а Лебёдкина («Соңарган мәхәббәт», А.Н.Островский) ролендә. 1972.

тәмамлаганнан соң (1970), Әлмәт театрына кайта һәм әйдәп баручы актрисага әверелә. К. иҗат иткән Майя («Эх, Уфа кызлары», И.Абдуллин) һәм Нила Снижко («Барабанчы кыз», А.Д.Салынский) образларына табигыйлек, тирән психологизм, эмоциональлек, ритмик һәм поэтик тональлекне тоемлау хас; соңгы ролен иҗат иткәндә, актриса каһарманлыкның психол. алшартларын ачарга ом-



Д.Н.К у з а е в а Тулганай («Анам кыры», Ч.Айтматов) ролендә. 1977.

тыла (Бөтенроссия театр фестивалендә Татарстанның 1 нче һәм Россиянең 2 нче бүләкләре, 1977). Алиман (1971) ролендә К. героиняның катлаулы рухи дөньясын, әчке драматизмын, кеше хәсрәтенең тирәнлеген поэтик, романтик рухта гәүдәләндерә; Тулганай образын (1977) иҗат



Д.Н. Кузаева.

иткәндә эпик масштабка ирешә («Анам кыры», Ч.Айтматов повесте буенча). Мирандолина («Тылсымлы кыз», К.Гольдони) образында үзенчәлекле хатын-кыз характеры иҗат итә; актрисаның уены ачык, төсләрнең күптөрле булуы, сәхнәдә үзен иркен тотуы б-н аерылып тора. Зур әхлакый көч б-н башкарылган Антигона (Ж.Ануйның шул исем. әсәре буенча) образында К. кешенең хис-кичерешләрен ирексезләүгә каршы чыга. Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәре буенча куелган спектакльдәге Мәдинә образы б-н К. халык тарафыннан киң танылa (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1979). Образны фәлсәфи гомумиләштерү дәрәҗәсенә күтәреп, ул рухи байлыгы, әчке бөтенлеге, тормыш кыенлыклары алдында нык торуы, сыгылмас булуы б-н хәйран калдырган героинясының дөньяга карашы, характеры формалашуын эзлекле һәм дәлилле күрсәтә. А.Гыйләҗевнең махсус К. өчен язылган «Әгәр бик сагынсаң» һәм «Әткәй җырлый да, җылый да» дилогиясендә укытучы Фәүзия образын иҗат иткәндә актриса талантының күпкырлылыгы, үзенчәлеге калку чагылыш таба. Режиссёр буларак, Әлмәт театры сәхнәсендә «Кияү белән кәләш» (М.Байҗиев), «Олы юлның тузаны» (Р.Хәмид), «Өченче бүлмәдә эт яши» (Р.Мингалим) һ.б. әсәрләрне куя.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**КУЗА́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кислинка елгасының (Урман Чишмәсе елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,5 *км*, бассейнының мәйданы 41,6 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага, Лениногорск р-нында. Елга башы Кузайкино авылыннан 1,8 *км* төньяктарак, тамагы Сугышлы авылының төньягындарак. Елга башының абс. биеклеге 245 *м*, тамагыныкы — 130 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. К.ның 2,6 дан алып 3,3 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, ртысын диярлек кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 124 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КУЗА́ЙКИНО** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 720 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 70%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Авыл тарихы музее. 1722 елга кадәр нигез салына. 1860 елларда халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да почта станциясе, этап пункты урнаша; Троица чиркәве (1891 дә ачыла), чиркәү-приход мәктәбе (1889 да), Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе (1915 тә) ачыла, ашлык саклау-сату, 8 бакалея, 1 тукыма һәм 1 шәраб кибетләре, фельдшерлык пункты, 2 су тегермәне, 1 сыраханә була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1518,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостенда, 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 тән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 269 ир-ат; 1859 да — 732, 1897 дә — 982, 1905 тә — 1265, 1913 тә — 1528, 1920 дә — 1458, 1926 да — 1193, 1938 дә — 931, 1958 дә — 789, 1970 тә — 559, 1979 да — 623, 1989 да — 592, 2002 дә — 609 кеше.

**КУЗА́ЙКИНО** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 17 *км* көнбатыштарак, Кузай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 47 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Клуб. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вновь Заселённая Сугушла, Мордовская Сугушла исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да чиркәү, укырга-язарга өйрәнү мәктәбе, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2624 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузайкино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 732, 1889 да — 983, 1910 да — 1152, 1920 дә — 1105, 1926 да — 1122, 1938 дә — 1100, 1949 да — 944, 1958 дә — 695, 1970 тә — 533, 1979 да — 623, 1989 да — 122, 2002 дә — 90 кеше.

**КУЗАКЛЫ́ КУЛЬТУ́РАЛАР** (Fabaceae), ике өлешле чәчәкле үсемлекләр семьялыгыннан. РФ терр-ясендә 1800 гә кадәр төре исәпләнә. Кузаклылар семьялыгын берничә ассемьялыкка бүлеп йөртәләр. ТР терр-ясендә күбәләк чәчәклеләр (Papilionate) ассемьялыгы төре үстерелә. Чәчәкләре ике җенесле, 5 таҗ яфракчыгыннан тора — иң эресе югарырак урнашкан (җилкән), икесе ян-якта кечерәк үлчәмле (ишкәк яисә канатлар) һәм калган икесе тагын да ваграк, өске яклары бер-берсенә кушылган (көймә). Көймәдә җепләр б-н берегеп үскән 10 серкәч бар. Үзәк тамыр системалы. Туры һәм сөрлегүче сабаклы. Яфраклары катлаулы. Җимеше — кузак. Уңай шартларда (туфракның реакциясе нейтраль күрсәткечкә якын, фосфор, молибден, дым, һава җитәрлек булганда) К.к.ның төп һәм ян тамырларында һәм ботакларында бүлбеләр барлыкка килә. Аларда бактерияләр үрчи, алар үсемлекләр һәм туфракны баету өчен кирәкле азотны һавадан үзләштерүгә сәләтле. Борчак, 1 *га* дан 20 *ц* уңыш чыкканда, туфрактагы азотны 1 *га* да 30 *кг* га, 1 *га* дан 50 *ц* уңыш алганда 1 *га* да 70 *кг* га арттыра. Люцерна 1 *га* да 300–400 *кг* га кадәр азот туплый ала. Шуңа күрә К.к. азот туплаучы буларак, башка үсемлекләр өчен кыйммәтле элгәрләр булып торалар.

Күпчелек К.к. азык үсемлеге буларак та кыйммәтле, алар аксымга бай; орлыклары (борчак, фасоль, кырлы борчак, ясмык, соя), яшь җимешләре — кузаклар (фасоль, борчак) кулланыла. К.к.ның орлыкларында күп күләмдә аксым бар (%): фасоль — 24, нут (бәрән ногыты) — 25, борчак — 28, кырлы борчак — 29, терлек азыгы кузаклары һәм ясмык — 30, вика — 35, люпин — 38, соя — 39. ТРда бөртекле кузаклы культуралардан борчакка, викага, күпьеллык кузаклы үләннәрдән — люцернага, клевер, донник, эспарцетка өстенлек бирелә. Бөртекле кузаклы культураларның чәчүлекләрдә тоткан урыны Татарстан тарихының төрле этапларында а.х. һәм игенчелек культурасында җитештерүче көчләрнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле була. Рев-циягә кадәрге чорда зур булмаган мәйданнарда азык өчен борчак һәм ясмык игелә. 1930 елларда крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүгә бәйле рәвештә һәм үсемлекчелек һәм терлекчелектә фәнни алымнарны үзләштерә башлау сәбәпле, ул вакытта киң таралган бишкырлы чәчү әйләнешендәге басуларның яртысына борчак чәчелә, алар сөрүлек җирләрнең 10 % ын били. Бу елларда борчак чәчелгән мәйданнар Татарстанда 220 мең *га* тәшкил итә. 1960 елларда терлекләр рационында кукуруз силосының өлеше арту б-н, аларны аксым буенча тигезләү өчен борчак чәчүлекләре 550 мең *га* га кадәр җиткерелә. Шуннан соң пар басуларын биләү өчен викалы-солылы катнашмага өстенлек бирелә башлый, чәчүлек мәйданнары 150–200 мең *га* дәрәҗәсендә тотрыклана, ә борчакныкы — 200–300 мең, 1990 елларда 60–80 мең *га* га кадәр кими. Ясмык чәчүлекләре, борчак б-н чагыштырганда аз уңышлы булу сәбәпле, 1940 еллар уртасында бөтенләй бетерелә. Бөек Ватан сугышы елларында самолёт төзелешендә фанера ябыштыру өчен кулланыла торган казеин җилеме чималы алу өчен, кырлы борчак чәчелә. 1997 дә ТРда бөртекле-кузаклыларның чәчүлек мәйданнары — 82,4 мең *га*, уңышы 1 *га* дан 26,1 *ц*. Кузаклылар (клевер, люцерна, сераделла, вика, люпин һ.б.) терлек азыгы үсемлеге буларак зур урын алып тора. А.х.н күмәкләштерүгә кадәр ТР терр-ясендә күпьеллык кузаклы




**Кузаклы культуралар.** 1. Ногыт борчагы; 2. Игүле вика; 3. Игүле борчак; 4. Сары донник; 5. Кызыл клевер (болын клеверы); 6. Зәңгәр люпин; 7. Ураксыман люцерна (сары клевер); 8. Гади фасоль.

үләннәрдән зур булмаган мәйданны клевер били. Люцерна һәм бу төркемнән башка үләннәр (лядвенец, донник, эспарцет) бөтенләй диярлек чәчелми. Аларны чәчү 1950 елларда үлән басулы чәчү әйләнешен үзләштерү кампанияләре б-н бәйле рәвештә башлана. Казан селекция станциясендә З.Х.Шәрәф тарафыннан клеверның «*Казан 1*», люцернаның «*Казан 64/95*» һәм «*Казан 36*» яңа сортлары, соңрак М.Ш.Лапина тарафыннан люцернаның «Айсылу», «Татарская пастбищная», «Мөслимә» сортлары чыгарыла. К.к. буенча ТРда фәнни тикшеренүләрне Р.Р.Хөсәенов (кырлы борчак һәм нутның биологиясен тикшерү, төрләрен өйрәнү), А.А.Җиһаншин (программалаштырылган уңыш алуга борчак чәчүлекләре агротехникасы һәм моделе), Э.М.Шалыгина, Г.А.Емельянов (борчак б-н солының катнаш чәчүлекләре), И.С.Возовик (борчак уңышын җыюны механикалаштыру), Альварес А.Җиһаншин (бөртекле-кузаклыларның төрен һәм сортын өйрәнү, кырлы борчак агротехникасы), П.А.Чекмарёв (викалы-солылы катнашма) алып бара.

*Әд.:* Мосолов В.П. Агротехника люцерны. К., 1940; Лисицын П.И. Вопросы биологии красного клевера. М., 1947; Зиганшин А.А., Шакуров В.З. Возделывание зернобобовых культур. К., 1953. Митрофанов А.С., Рожков М.М. Вика (яровая и озимая). М., 1961; Артюков Н.В. Донник. М., 1973; Макашова Р.Х. Горох. Л., 1973; Бондарь Г.В., Лавриненко Г.Т. Зернобобовые культуры. М., 1977; Зиганшин А.А., Исмагилов Х.Х. Зернофуражное поле. К., 1985.

*А.А.Җиһаншин.*

**КУЗАХМЕ́ДОВ** Рафаил Хәйретдин улы (27.6.1935, Дагстан АССРның Буйнак ш.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1988), РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1993). Бөтенсоюз нефть техникумын тәмамлый (1966). 1958–66 еллардан Фирганә бораулау-разведка конторасы сынау цехында, «Северный Риштан» бораулау участогында, «Фирганәнефтегаз» ҖБнең «Северный Сох» нефть промыселында моторист булып эшли. 1966–67 дә «Елховнефть» нефть промыселы идарәсендә махсус агрегатлар буенча механик, 1967–93 тә «Татнефть» АҖнең «Җәлилнефть» НГДУында нефть чыгару буенча өлкән инженер, 2 нче район инженерлык-диспетчерлык хезмәтендә смена башлыгы, нефть һәм газ чыгару буенча өлкән механик, мастер. Дәүләт бүләге хезмәттәге казанышлары өчен бирелә. СССР Нефть сәнәгате министрлыгы бүләге лауреаты (1987). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.


**КУЗГАЛА́К** (Rumex), карабодайчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 150 төре билгеле, башлыча Төньяк ярымшарның уртача поясларында таралган; ТРда 5 төре — дымлы болыннарда, урман аланнарында, түбәнлекләргә сазлыкларда үсә. Гади К., яисә әче К. (R. acetosa) — яшелчә культурасы. Тармаклы, үзәк тамырлы. Сабаклары туры, буразналы, 1 *м* га кадәр биеклектә. Тамыр яны яфраклары сабаклы, йомыркасыман-озынча, төбендә сөңгесыман-очлы; сабаклы яфраклары — ваграк, утырма. Чәчәкләре вак, кызгылт-сары, себеркәчле чәчәк оешмасына җыелган. Җимеше — ялтыравыклы, өчкырлы, көрән төстәге чикләвексыман. К. аерым җенесле, бер өйле яисә ике өйле үсемлек. Башлыча җил б-н серкәләнәләр. Салкынга бик чыдам, дым яратучан, күләгәдә яхшы үсә. Азык сыйфатында составында кузгалак, алма һәм лимон кислоталары, дуплау матдәләре, С витамины һәм каротин булган яфрак таралгылары кулланыла; алардан яшелчә ашлары пешерелә, пирог эчлекләре ясала, консервлана. ТРда йорт яны бакчаларында үстерелә.

**КУЗИ́ЕВ** Раил Гомәр улы (10.1.1929, БАССРның Уфа кантоны Әмин а. — 2.8.2005, Уфа), этнолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (1971), Россия ФА мөхбир әгъзасы (1991), БР ФА академигы (1991), БАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1969, 1979). Башкорт пед. ин-тын тәмамлый (1950). 1954 елдан СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында, 1955–61 дә тарих, археол. һәм этнография секторы мөдире. 1960–87 дә СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Президиумы рәисе урынбасары, проф. (1972). 1983–2000 дә Россия ФА Урал гыйльми үзәге Археология һәм этнография музееның Урал халыклары бүлеге мөдире. 1995–96 да БР ФА вице-президенты вазифаларын башкара. Россия Этнографлары һәм антропологлары ассоциациясе президенты (1994–2000). Хезмәтләре Идел-Урал төбәгендәге төрки һәм фин-угор халыклары тарихын һәм этнографиясен өйрәнүгә, башкорт халык сәнгатенә, этнос теориясенә, чыганакларны өйрәнүгә, археографиягә, ономастикага карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Хезм.: Очерки по исторической этнографии башкир. Уфа, 1957. Ч. 1; Башкирские шежере. Уфа, 1960; Происхождение башкирского народа: Этнический состав, история расселения. М., 1974; Историческая этнография башкирского народа. Уфа, 1978; Народы Среднего Поволжья и Южного Урала: Этногенетический взгляд на историю. М., 1992.

*Әд.:* Кузеев Раиль Гумерович: Библиогр. указ. Уфа, 1988.

**КУЗИ́ЕВ** Рөстәм Гомәр улы (5.1.1923, БАССРның Уфа кантоны Әмин а. — 23.3.1998, Уфа ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1972), проф. (1973), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1973). Ульяновск танк уч-щесен (1942), Башкорт пед. ин-тын (1949), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1962) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1949–51 елларда «Кызыл таң» г-тасында (Уфа) әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире булып эшли. 1951–55 тә СССР ФАнең Башкортстан ф-лы Тарих, тел һәм әдәбият ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре. 1962–71 дә Башкорт ун-тының СССР тарихы каф. мөдире. 1971–83 тә Башкорт пед. ин-ты ректоры, бер үк вакытта, 1994 кә кадәр, Россия тарихы каф. профессоры. Хезмәтләре Башкортстанның эшчеләр сыйныфы тарихына карый. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Раил Г. Кузиев.



Е.А. Кузин.

Хезм.: Рабочий класс Башкирской АССР на современном этапе. Уфа, 1983; Испытание временем. Уфа, 1993; Новые шаги Башкортстана. Уфа, 1994.

**КУ́ЗИН** Владимир Андреевич (18.7.1924, Казан — 1992, шунда ук), философ, филос. фән. д-ры (1968), проф. (1969), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1980). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1946), шунда ук филос. кафедрасында эшли (бүленеп, 1953–55 тә Германия Демократик Респ-касында). 1959–90 да Казан химия-технол. ин-тының филос. каф. мөдире. Хезмәтләре рев-ция теориясенең иҗтимагый-фәлсәфи проблемаларына карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Марксизм-ленинизм о роли народных масс в социальных революциях. М., 1963; Народные массы и революция. К., 1966; Ленинская теория социалистической революции и современность: Учеб. пособие. К., 1986 (автордаш).

**КУ́ЗИН** Евгений Андриянович (2.4.1933, Ульянов өлкәсенең Иске Майна р-ны Зур Кандала а. — 16.6.2004, Казан), драма актёры, педагог, ТАССРның халык артисты (1975), РСФСРның атказ. артисты (1981). Казан ун-тының геол. факультетын тәмамлый (1956). Анда укыганда студентлар театры түгәрәгендә актив катнаша: Тетерев («Мещаннар», М.Горький), Боровцов («Упкын», А.Н.Островский), Павел Струнин («Кара урман», И.О.Щеглов) рольләрен уңышлы башкара. 1955 елда К.ны Казан Зур драма театрына «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» (М.Н.Елизарова пьесасы буенча) спектаклендәге Алексей Пешков роленә чакыралар (аның катнашындагы спектакль 1957 дә Мәскәүдә Татар



Е.А. Кузин Алексей Пешков («Давыл хәбәрчесенең яшьлеге», М.Н. Елизарова; уңда – А.М. Бабахан) ролендә.



Е.А. Кузин Михай Груя («Изгеләрдән изге», И.П. Друцэ; уңда — Ю.С. Федотов) ролендә.

сәнгате һәм әдәбияты декадасы көннәрендә күрсәтелә). 1956–58 дә Свердловск өлкәсе Асбест посёлогында Асбест-Нейвинск геол. партиясенең инженер-геологы булып эшли. 1958 дә Казан Зур драма театрында, 1959–98 дә актёр, бер үк вакытта, 1985–87 дә театр директоры, 1965 тән Казан театр уч-ще-се педагогы. Андрей Ершов («Бертуган Ершовлар», В.А.Кочетов), Алексей («Барабанчы кыз», А.Д.Салынский), Лёвка («Хуҗа», И.М.Соболев), Кубасов («Сезгә 22, картлачлар!», Э.С.Радзинский), Майданников («Күтәрелгән чирәм», М.А.Шолохов романы буенча), Митя, Борис («Ярлылык гаеп түгел», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский) кебек яшь герой рольләрен иҗат иткәндә К. образны индивидуальләштерүгә, тышкы күренеш б-н характерның эчке асылы ярашуына омтыла. В.С.Розов пьесаларындагы рольләре (Михаил — «Туй көнендә», 1964; Сергей Сорокин — «Уен оештыручы», 1966; Сергей Усов — «Гадәт буенча җыелу», 1967) актёр иҗатының төп темаларын билгели: гражданлык бурычы, кешенең үзе һәм җәмгыять алдындагы җаваплылыгы. К. геройлары әхлакый башлангычның социаль башлангычтан күпкә өстен булуын раслыйлар, әдәплелек һәм намуслылык сыйфатларын кешенең хезмәт урынында тоткан дәрәҗәсенә караганда



Е.А. Кузин Коновалов («Астория» кунакханәсе», А.П. Штейн) ролендә.

югарырак куялар. Казан Зур драма театры сәхнәсендә К. иҗат иткән коммунист образлары әһәмияткә ия: Канунин («Мәхәббәт турында эш», Д.Г.Павлова, В.Н.Токарев), Позднышев, Коновалов («Көчле яңгырлар арасында», «Астория» кунакханәсе», А.П.Штейн), Садовников («Бердәнбер шаһит», А.С. һәм П.Л.Тур), Старосельский («Озату», И.М.Дворецкий), Михай Груя («Изгеләрдән изге», И.П.Друцэ), Лоншаков («Эш башында торучылар», А.И.Гельман). К. башкаруында алар барысы да — югары әхлакый бурыч хисен тоеп яшәүчеләр. Алар да кимчелекләрдән, каршылыклардан азат түгел, үзләре хезмәт иткән эшкә чын күңелдән тугры; куйган максатларына ирешү өчен төрле компромиссларга барганда, алар да вөҗдан газабы кичерәләр; чын күңелдән идеалларга ышанып яшиләр һәм шулар хакына үз тормышларын да аямыйлар. К.га тормышка артык дәгъвачыл булмаган халык уллары, хезмәтчәннәр образлары аеруча якын: Чмутин («Сагыш», А.М.Галин), Кузякин («Мәхәббәт һәм күгәрченнәр», В.П.Гуркин), Фёдор («Иван һәм мадонна», А.И.Кудрявцев), Степан («Мәрхүмне искә алу догасы», Г.И.Горин). Юмор хисен нечкә тоемлау, тапкырлык, теге яки бу персонажны ачканда көтелмәгән һәм төгәл детальләр куллана белү актёрга комик һәм сатирик характерлар тудырырга ярдәм итә: Гусятников («Күңелгә якын иске йортта», А.Н.Арбузов), Себейкин («Иске Яңа ел», М.М.Рощин), Ата («Туй», М.М.Зощенко) һ.б. Рус һәм чит ил авторларының әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә дә К. тирән эчтәлекле образлар иҗат итә: Черкун («Варварлар», М.Горький), Шуйский («Фёдор патша», А.К.Толстой), Серебряков («Ваня абзый», А.П.Чехов); Язон («Медея», Ж.Ануй), сэр Томас («Булыргамы, булмаскамы», У.Гибсон), Табиб («Барысы да бетте», Э.Олби).

К. татар әдәбиятын пропагандалау эшенә дә зур өлеш кертә. Шактый еллар Г.Тукай, Һ.Такташ, С.Хәким, Х.Туфан, М.Җәлил, И.Юзеев, Р.Харис шигырьләре б-н телевизион һәм радио тапшыруларда чыгышлар ясый. 1971–75 елларда ТАССР ЮС депутаты. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1981). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991; Благов Ю. Гражданское призвание художника // Казань. 2003. № 3.

*Ю.А.Благов.*

**КУЗНЕ́ЦК РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 2,1 мең *км²*. Үзәге — Кузнецк шәһәре (Пенза шәһәреннән 121 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 40,8 мең кеше (2010), 2002 дә 11317 татар. Татарлар, башлыча, район үзәгендә (6760 кеше), Зур Труев (элеккеге исеме Ялгаш Безводное; 1789 кеше), Кече Труев (элеккеге Дехтерни; 1311 кеше), Татар Кынадысы (2336), Татар Пәндәлгәсе (388), Берестянка (1353) авылларында яшиләр. К.р. терр-ясендә татарлар 17 йөздә даими яши башлыйлар. Бу чорда Тамбов өязенең Түмән авылыннан күчеп килүчеләр нигез салган Зур Труев, Татар Пәндәлгәсе авыллары барлыкка килә. 1720 еллардан Кече Труев авылы мәгълүм. Татарларның төп шөгыле күн эшкәртү һәм сарык тиресен дуплау була. 1917 гә кадәр Кече Труев һәм Татар Пәндәлгәсе авылларында — 2 мәчет, мәктәп; 1934 кә кадәр Каменка авылында мәчет эшли. Хәзерге вакытта К.р. терр-ясендә 8 мәчет бар. Районның ике мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. К.р.нда генерал-майор А.Х.*Бичурин*, язучы Г.Н.*Кутуй* туган.

**КУЗНЕЦО́В** Александр Семёнович (2.8.1955, Яңа Чишмә р-ны Черёмуха Бистәсе а.), педагог, спортчы, тренер (грек-рим көрәше, милли көрәш), пед. фән. д-ры (2002), ТР, РФнең атказ. тренеры (1996, 2000). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1984). Россиянең авыл спортчылары (1978), РСФСРның «Уңыш» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советы (1977) спартакиадаларында көмеш медальләр ала. 1981 дән Тукай район советының «Уңыш» ирекле спорт җәмгыятендә, 1989 дан — 2 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә, 1994 тән Кама физкультура ин-тында (Чаллы ш.), 1996 дан көрәш каф. мөдире, проф. (1999), 1995 тән ректор вазифасын башкара, 2005–10 да ректор. ТРның Грек-рим көрәше федерациясе президенты (1999 дан), халыкара категорияле судья (1998). Шәкертләре — Россия чемпионы А.А.Саенко (1990–91, 1995), Европа чемпионы (яшүсмерләр арасында) С.Ю.Воронцов.

**КУЗНЕЦО́В** Анатолий Иванович (1914, Казан губ., Чистай өязе Каравыл Тавы а. — 19.1.1943, Ленинград өлкәсенең Ломоносов р-ны Лебяжье торак пункты), Сов. Союзы Герое (22.2.1943, үлгәннән соң), гв. капитаны. Ейск хәрби-диңгез авиация уч-щесен тәмамлый. 1936 елдан Хәрби диңгез флотында, совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 4 нче гв. истребительләр авиациясе полкы штурманы (Балтыйк флоты Хәрби һава көчләренең 61 нче истребительләр авиациясе бригадасы). К. 270 сугышчан очыш ясый, 60 һава сугышында һәм 57 һава һөҗүмендә катнаша; дошманның 9 самолётын бәреп төшерә. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак ордены һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои войны. Таллин, 1984; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУЗНЕЦО́В** Андрей Михайлович (21.3.1955, Магадан өлкәсенең Анадырь ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1977 елда Казан ун-тын тәмамлый, Казан технол. ун-тында эшли, 1996 дан нәорганик химия каф. мөдире. Хезмәтләре электрохимик фазаара чикләрнең квант химиясенә карый. К. структур, термодинамик һәм кинетик факторларны эзлекле рәвештә исәпкә алып квант-механик теория һәм квант-химик модельләштерү кысаларында поляр тирәлекләрдә фазаара чикләрдә корылма күчерү процессларын өйрәнә. Киң катлау электрохи-

мик процессларны өйрәнү өчен беренчеләрдән булып электрод өслегенең кластер моделен куллана. Электролитларның ионлы компонентлары һәм эреткечләренең электрохимик адсорбциясе механизмын өйрәнә, металлар гидрофильлегенең микроскопик рәтен билгели. Яктылыкның адсорбция б-н көчәйтелгән комбинацион сибелүенең молекуляр механизмын, комплексы ионнар катнашында электрохимик реакцияләр механизмын водород аерып алу реакцияләре механизмын тәкъдим итә.

Х е з м.: Каталитическое влияние проводящей поверхности на реакции гомогенного внешнесферного электронного переноса // Электрохимия. 1991. Т. 27, № 11; Квантово-химическое исследование механизма электровосстановления циано-комплексов Cu(1) // Электрохимия. 2002. Т. 38, № 2 (автордаш); Electronic charge density transfer along a constrained reaction path from a hydronium ion configuration into a hydrogen chemisorption state // Chem. Phys. (Netherlands). 1997. V. 214 (автордаш).

**КУЗНЕЦО́В** Аркадий Васильевич (20.11.1928, Тамбов өлкәсенең хәзерге Бондарь р-ны Иске Челищево а.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1970), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1984, 1989). Казан ун-тының атказ. профессоры (2008). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: гомуми матем. һәм аэрогидромеханика кафедраларында, 1961 дән Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында бүлек мөдире, проф. (1974), баш фәнни хезмәткәр (1991 дән).

Хезмәтләре гидроаэромеханикага карый. Каршылыкны кавитацион ягалап агу схемасын (К. схемасы) тәкъдим итә, чикләре иркле булган аныкланмаган агымнарны тикшерү алымын (Гуревич–Хаскинд алымы) камилләштерә, җисемнәрнең сыеклыкка тизлек б-н керүен һәм алгы чигендә һава тизлеге тавыш тизлегенә кадәр булган канатны тавыш тизлегеннән артык тизлек б-н ягалап агуны исәпләүнең гомуми алымын эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нестационарные возмущения течений жидкости со свободными границами. К., 1975; Сверхзвуковое обтекание тонкого крыла с дозвуковыми передними кромками // Изв. АН СССР. Механика жидкости и газа. 1981. № 5; Обтекание вихря двухслойным потоком тяжёлых жидкостей, разделённых полубесконечной пластиной // Изв. РАН. Механика жидкости и газа. 2002. № 3 (автордаш).

**КУЗНЕЦО́В** Борис Кириллович (26.12.1925, Казан), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), полковник (2005), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1971). Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1944). Хәрби хезмәткә кадәр токарь булып эшли. 1942 елның ноябреннән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 791 нче артиллерия полкының элемтә отделениесе командиры (52 нче армиянең 254 нче укчы дивизиясе). Воронеж, Дала, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен барган сугышта (1943), Корсунь-Шевченко, Умань-Ботошаны (икесе дә — 1944), Сандомир-Силезия, Берлин һәм Прага (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең октябрендә Днепр елгасын кичеп, Крещатик (Украина ССР, Черкассы өлкәсе Черкассы р-ны) авылы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: 2 октябрьдә сал ясап отделениесе б-н дошман уты астында елганы кичеп чыга, кабель линиясе сузып, алдынгы отряд б-н артиллерия батареясы арасында элемтә урнаштыра; плацдармда көн дәвамында барган сугышта бозылган элемтә линиясен күп тапкырлар ялгый; ике тапкыр яраланса да, К. сафта кала; 20 октябрьдә, командирлар булмаганда, сугышчыларны һөҗүмгә күтәрә. 9 тапкыр дошман тылында булып, кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта; дошман утыннан частьнең сугышчан байрагын алып чыга. 1946 дан запаста. 1946–53 тә МТСта (Көнбатыш Украина) сәяси бүлек башлыгы, 1953–60 та Казанда Кирпеч-чирәп з-ды директоры урынбасары, 1960–65 елларда монтаж комб-ты директоры, «Главметаллсбыт» пр-тиесе җитәкчесе урынбасары, җитәкчесе. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Мәскәүдә Җиңү Парадында катнаша (1945–47, 1995).

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; П л е с ц о в К.М. Люди высокого подвига. М., 1962; Герои-освободители Черкасщины. Днепропетровск, 1980; Связисты — Герои Советского Союза. Л., 1982. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУЗНЕЦО́В** Борис Леонидович (13.7.1939, Свердловск өлкәсенең Шаля р-ны Шаля пос.), инженер-металлург, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1961 елда Урал политехник ин-тын (Свердловск ш.) тәмамлаганнан соң, металл кою з-дында (Свердловск өлкәсенең Каменск-Уральск ш.) эшли, баш металлург урынбасары (1970–74). 1974 тән КамАЗда (Чаллы ш.): баш металлург урынбасары (1974–76), проект-технология бүлеге башлыгы (1976–79), баш инженер урынбасары (1979–80). 1980–84 тән СССР Автомобильләр төзү сәнәгате министрлыгының Җитәкче хезмәткәрләрнең белемен күтәрү ин-тында (Чаллы ш.) автомобильләр төзү технологиясе каф. мөдире. 1984 тән Кама политехник ин-тында (2012 дән Казан (Идел буе) федераль ун-ты составында), производство икътисады, аны оештыру һәм идарә итү каф. мөдире (1992 дән). Хезмәтләре металларны коеп эшкәртү белеменә, технологиядә, икътисади һәм социаль-сәяси системаларда синергетизм процессларына, машиналар төзелеше менеджментына һәм проектлар б-н идарә итүгә карый. К. югары ныклыктагы шарсыман графитлы чуен алу, чуен һәм корычларны мич эчендә һәм тышында эшкәртү юлларын (КамАЗда гамәлгә кертелә) булдыра. Синергетик базар, менеджмент, маркетинг теориясен тәкъдим итә. Технологияләрне программ-максатчан проектлаштыру концепциясе авторы. «Бизнес-класс» г-тасының баш мөхәррире урынбасары (Чаллы ш.). Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.



А.И.Кузнецов.



Б.К.Кузнецов.

Х е з м.: Введение в литейное металловедение чугуна. М., 1995; Введение в экономическую синергетику. Наб. Челны, 1999; Общая теория систем. Наб. Челны, 1999; Управление проектами в машиностроении. Наб. Челны, 2000; Синергетический менеджмент в машиностроении. Наб. Челны, 2002.

*Б.А.Канеев.*

**КУЗНЕЦО́В** Вадим Алексеевич (3.6.1930, Мордва АССРның Надошкин р-ны Ногай а.), хирург, мед. фән д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. табибе (1990). И.В.Домрачев, А.Н.Миславский шәкерте. 1954 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук хирургия кафедрасында эшли (бүленеп, 1962 дә Алжир Үзәк госпитале хирургия бүлеге мөдире), 1971 дән факультет хирургиясе каф. мөдире, профессоры. 1983 тән Казан мед. академиясенең хирургия каф. мөдире, профессоры, 1997 дән проф.-консультант. Тикшеренүләре хирургия өлкәсенә — гастроэнтерология, эндохирургия, гепатологиягә карый. К. ашказанына, бавырга, үт юлларына, ашказаны асты бизенә оригиналь операцияләр эшли. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Профилактика нарушении эвакуаторной функции желудка при наложении малого поперечного желудочно-кишечного анастомоза // Клиническая хирургия. 1989. № 10 (автордаш); Моторика желудка и постгастрорезекционный деленпинг-синдром // Хирургия. 1990. № 3 (автордаш); Этапы развития хирургии язвенной болезни в Казани // Казан. мед. журн. 1990. № 3.

*Әд.:* Профессор В.А.Кузнецов (к 60-летию со дня рождения) // Хирургия. 1990. № 12.

**КУЗНЕЦО́В** Виталий Яковлевич (1941, Минзәлә р-ны Яңа Мажын а. – 12.10.2011, Мәскәү), спортчы (дзюдо, самбо, милли көрәш), СССРның атказ. спорт остасы (1972). Милли көрәш буенча ТАССР (1960–61), самбо буенча СССР (1968, 1971, 1975, 1978–79), Европа (1972), дөнья (1975, 1982) чемпионы, СССРның абсолют беренчелегендә (1974, 1977), СССР халыклары спартакиадасында (1975, 1979), «Красная звезда» г-тасы призына бөтенсоюз ярышларында (1989) җиңүче, Дөнья кубогы иясе (1982). Дзюдо буенча Европаның абсолют чемпионы (1971), дөнья чемпионатында (1971), Олимпия уеннарында (1972, ачык беренчелектә) көмеш медаль, Европа чемпионатында (1971) бронза медаль ала. 1970 еллардан Мәскәүдә яши.

**КУЗНЕЦО́В** Вячеслав Алексеевич (7.12.1939, Архангельск өлкәсенең Моржовец утравы), ихтиолог, биол. фән. д-ры (1981), проф. (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993).

Казан ун-тын тәмамлый (1962), шунда ук умырткалылар зоологиясе каф. мөдире (1974–2009). Хезмәтләре эчке сулыкларда балык үрчетү буенча тикшеренүләргә карый. К. елга агымнарын ясалма көйләү шартларында балыклар популяциясенең үрчү чорындагы микроэволюциясенең төп юнәлешләрен һәм ясалма сулыкларда балыкларның антропоген тәэсирләргә яраклашу юлларын билгеләде. Балык ресурсларын нәтиҗәле файдалану һәм сусаклагычларның продукт бирүчәнлеген күтәрү буенча чаралар комплексы тәкъдим итә. Тигезлек сусаклагычларында экосистема формалашу концепциясен эшли, аларның эволюциясендә яңа — дестабилизация фазасын аерып күрсәтә. Зөя елгасының түбән агымында уникаль фауна һәм флора генофондын саклау максаты б-н «Зөя» комплексы тыюлыгын оештыру зарурлыгын нигезли (ТР МКның 1998 ел 4 февраль карары б-н раслана). Казан ун-тының атказ. профессоры (2009).

Х е з м.: Динамика численности и выживаемости молоди пресноводных рек. К., 1975; Особенности воспроизводства рыб в условиях зарегулированного стока реки. К., 1978; Рыбы Среднего Поволжья и метод их изучения. К., 1981 (автордаш); Основы экологии рыб. К., 2001.

**КУЗНЕЦО́В** Герман Ефимович (31.7.1936, Удмурт АССРның Сарапул ш. — 13.12.2002, Казан), геолог-геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), «Татнефтегеофизика» трестында эшли. 1961–70, 1980–2002 елларда ЦНИИгеолнерудта, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1992 дән). 1970–80 елларда Индустриаль ин-тта (Ухта ш.), геофизика каф. мөдире (1978 дән). Хезмәтләре руда булмаган файдалы казылмалар һәм җир асты байлыкларын эзләүдәге геофизик алымнарга карый. К. җир кабыгы, лито- һәм тектоносфераның геотектоник халәте суммар күрсәткечләре нигезендә төбәкләрнең җир асты төзелеше үзенчәлекләрен бәяләү системасын тәкъдим итә. Идел-Урал төбәге, ш.и. ТР терр-ясенең тирәнлек төзелеше картасын төзи.

Х е з м.: Карта рельефа поверхности дорифейского фундамента Восточно-Европейской платформы. М., 1985 (автордаш); Применение послойного сейсмоскоростного профилирования при поисках самородной серы // Разведка и охрана недр. 1987. № 10 (автордаш); Глубинное строение Республики Татарстан в связи с прогнозно-поисковой оценкой на алмазы. К., 2002.

*Е.В.Кузьмина.*

**КУЗНЕЦО́В** Евгений Васильевич (17.11.1912, Казан — 3.12.1991, шунда ук), химик-технолог, химия фән. д-ры (1972), проф. (1970), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1970, 1977). 1938 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, 1958–87 елларда пластик массалар технологиясе кафедрасының оештыручысы һәм мөдире. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясе һәм технологиясенә, аларны югары молекуляр кушылмалар синтезында куллануга карый. К. җитәкчелегендә төп макромолекула чылбырында фосфор атомы б-н янмый торган полимерлар; алкилдиоксиметилфосфин нигезендә химик чыдам һәм янмый торган полиуретаннар; бис-(оксиметил) фосфинат к-тасы нигезендә полиэтилен, полистирол һ.б. полимерлар өчен антипиреннар; фосфорлы полисульфоннар; титанорганик кушылмалар нигезендә мономерлар һәм полимерлар һ.б. синтезлана. Нигез характерлы кушылмалар (амидлар, аминнар һ.б.) катнашында тулыланмаган бәйләнешле к-таларны полимерлаштыру юлы б-н сополимерлар алына, алар кинофотоматериаллар җитештерүдә антистатиклар, кабель сәнәгате өчен полиэтилен композициясе модификаторлары, нефть скважиналарын бораулаганда промысел сыеклыгы стабилизаторлары сыйфатында кулланыла. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Взаимодействие аминоалкокси- и алкоксиаминоалкоксититанов с хлористым водородом. Сообщение 1. Взаимодействие аминоалкокси и алкоксиаминоалкоксититанов, содержащих третичную аминогруппу, с хлористым водородом // Журн. орган. химии. 1969. Т. 39, № 8 (автордаш); Прогресс полимерной химии боратов // Успехи химии. 1987. Т. 56, № 3 (автордаш).

*Әд.:* Кузнецов Евгений Васильевич: Библиогр. справка. 1912–1991. К., 2002.

*В.Г.Абзалова.*

**КУЗНЕЦО́В** Иван Александрович (15.1.1920, Тула ш. — 26.2.1992, Бөгелмә ш.), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1979). Тула өлкә драма театры каршындагы студияне тәмамлый (1939). 1939 елда Кызыл Армия сафларына алына, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1944 тә авыр яралангannan соң, демобилизацияләнә. 1944–45 тә Тула яшь тамашачылар театры, Тула өлкә драма театры, Иваново яшь тамашачылар театры, Уржум һәм Пугачёв (Саратов өлкәсе) шәһәр театрлары; 1955 тән Бөгелмә шәһәр драма театры актёры. Бөгелмә театры сәхнәсендә Кнуров, Залешин, Прибытков, Епишкин, Градобоев («Бирнәсез кыз», «Җимерелгән бәхет», «Соңгы корбан», «Күктән төшкән бәхет», «Ялкынлы йөрәк», А.Н.Островский), Карт (М.Горькийның шул исем. әсәре буенча), Пётр («Хәсрәт дәрьясы», В.Я.Шишков романы буенча), Забродин («Ленинград проспекты», И.В.Шток), Трофим («Ата хакы — Тәңре хакы», В.Лаврентьев), Степан Казанец («Пешекче хатын», А.В.Софронов), Литвинов («Кыргый ярда», Б.Н.Полевой романы буенча) кебек үзенчәлекле образлар иҗат итә. Актёр үткән кырыс тормыш мәктәбе, образның эчке асылына төшенергә омтылу аңа персонажларны тормышчан дөрес һәм



И.А. К у з н е ц о в Ахов («Гел май да бал түгел», А.Н. Островский; унда — Е.Ф. Павлова) ролендә.

ышандырырлык итеп гәүдәләндерергә ярдәм итә. Детальләштерүне, үтә купшы тышкы күренеш алымнарыннан артык файдаланмыйча, сурәтләү чараларын мул кулланмыйча гына, К. персонажы кылган гамәлләренең мәгънәлелеге, аның рухи яшәеше дөреслеге б-н тамашачыны ышандыра. Актёр рольне башкарганда һәрвакыт гадилеккә һәм табигыйлеккә, образның чын асылын дөрес җиткерергә омтыла. Медальләр б-н бүләкләнә.



И.А. Кузнецов.

*Ю.А.Благов.*

**КУЗНЕЦО́В** Иван Леонидович (28.4.1951, Аксубай р-ны Югары Баланда а.), металл конструкцияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), проф. (1999). 1973 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит.-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, металл конструкцияләр һәм корылмаларны сынау каф. мөдире (1997 дән). Хезмәтләре оптималь проектлаштыру теориясенә, җиңел металл конструкцияләрнең конструктив формаларын булдыруга карый. К. биналар өчен оптималь формалар һәм а́ркаларның конструктив чишелешләрен тәкъдим итә (Смоленск, Краснотуринск, Витебск шәһәрләре заводларында гамәлгә кертелә). К. җитәкчелегендә җиңел биналарның төп конструкцияләре эшләнә («Агропроектпромстрой» берләшмәсе з-дларында кулланыла). Уйлап табуга 102 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт и оптимизация несущих конструкций облегчённых арочных зданий. К., 1985; Выбор оптимального конструктивного решения в системе ЛМК. К., 1990; Расчёт и конструирование лёгких арок. К., 1998.

**КУЗНЕЦО́В** Николай Дмитриевич (23.5.1923, Яшел Үзән р-ны, Васильево пос. — 15.12.1974, Казан), нәкышьче, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). 1945 тә Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (бүленеп, Бөек Ватан сугышы елларында Казанда заводта эшли). 1946 дан «Татхудожник» берләшмәсендә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1950). РСФСР крайлары, өлкәләре һәм автономияле респ-калар рәссамнары әсәрләренең Респ-ка күргәзмәсендә (Мәскәү, 1951) «Паровозлар җиһазлары», «Яшел урам» картиналары куелганнан соң таныла. «Мәскәү. Өченче километр» (1952), «Транспортта яз» (1957) һ.б. әсәрләре К.ның зур осталыкка ирешүен күрсәтәләр. 1960–70 еллардагы гаять зур этюд материаллары нигезендә «Язга таба. Казан органик синтез заводы» (1964), «Киләчәк шәүләләре» (1964), «Салкын кыш. Миңлебай газ эшкәртү заводы» (1974) картиналары языла. Рәссам үзенең әсәрләрендә туган як образын — табигать матурлыгын, портлары һәм причаллары б-н Идел киңлекләрен, шәһәрдәге яңа төзелешләрне, нефть химиясе төзелешләрен тасвирлый.




Н.Д. К у з н е ц о в. 1. «Татарстанның индустриаль пейзажы». 1966–69; 2. «Казанның үткәне һәм хәзергесе». Картон, майлы буяу. 1972. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

К.ның әсәрләренә эпик һәм героик-романтик рух хас. Рәссам Иделгә һәм елга портының кайнар хезмәт көннәренә багышланган пейзажлар сериясен: «Казан — биш диңгез порты» (1959), «Навигация алдыннан» (1960), «Бүгенге Идел ярлары» (1967) әсәрләрен иҗат итә.

К. Казан, Мәскәү, ш.у. Россия һәм чит илләрдәге башка шәһәрләрнең үзенчәлекләрен һәм аермалыкларын чагылдырган күренешләр яза: «Яңа Мәскәү. Комсомол мәйданы» (1953), «Казан Кремле» (1955), «Изге Марк мәйданы. Венеция» (1960).

К. елның һәр фасылыннан, табигатьнең һәр халәтеннән кабатланмас гүзәллек табып, пленэрда күп эшли; табигатьнең якты хыял кебек садә халәтеннән, яктылык һәм күләгәнең уйнаклавыннан таң калуын тапшыруга ирешә («Судагы каеннар», «Март кояшы» (икесе дә — 1958) һ.б. К. үзенең осталыгы, һәр үзенчәлекне күрә белүе нәтиҗәсендә, мөстәкыйль мәгънәгә ия булган сирәк сәнгать әсәрләренә тиң күп этюдлар иҗат итә — «Мста елгасы» (1968), «Алтынсу агачлар» (1971). Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1971) хәзерге заман индустриаль пейзажлар циклы өчен бирелә. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Респ-ка (1947–98); төбәк — «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Волгоград ш., 1967; Ульянов ш., 1969; Горький ш., 1974; Казан, 1980); бөтенроссия — Окт. рев-циясенең 40-еллыгына багышланган «РСФСР рәссамнары әсәрләре» (Мәскәү, 1957), «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1960, 1970, 1975); бөтенсоюз (Мәскәү, 1951, 1955, 1957, 1958); халыкара — сынлы сәнгать һәм гамәли сәнгать әсәрләре күргәзмәсендә (Мәскәүдәге VI Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале уңаеннан) һәм Монголия, Германия, Чехословакия, Польшада совет сәнгате күргәзмәләрендә (1971–72) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1963–64, 1971, 1973), Әлмәттә (1974) уздырыла.



Н.Д. К у з н е ц о в. «Казан Кремле». 1955. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Түбән Тагил һәм Оренбург сынлы сәнгать музейларында, Самара, Түбән Новгород, Ульянов, Краснодар сәнгать музейларында, Чаллы тарих музеенда, Әлмәт картиналар галереясында һ.б.да саклана.

*Әд.:* Е л ь к о в и ч Л. Николай Дмитриевич Кузнецов. М., 1962; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Т.В.Голубцова.*

**КУЗНЕЦО́В-ФЕТИ́СОВ** Лев Иванович (26.9.1907, хәзерге Тула өлкәсенең Тёпло-Огарёвск р-ны Лидинка а. — 6.4.1983, Казан), химик-технолог, химия фән. канд. (1936). 1931 елда Мәскәү химия-технол. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1937 дән Казан химия-технол. ин-тында: төп химия каф. мөдире, 1947–73 тә нәорганик матдәләр технологиясе каф. мөдире (бүленеп, 1944–47 дә Дәүләт азот сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проект ин-тының кислота-тозлар лаб-ясе җитәкчесе, Мәскәү). Хезмәтләре нәорганик кушылмалар химиясе һәм технологиясенә карый. К. кремний хлориды һәм аның эфирларын синтезлый, бөртекләндерелгән аммоний нитраты алу ысулын эшли, химик технологиядә ультратавыш куллануны тәкъдим итә, төрле адсорбентларда азот оксидлары адсорбциясен, күкерт триоксидын стабильләштерүне өйрәнә. Полимер фосфатлар эшли һәм өйрәнә, аларны пыяла җитештерү өчен материал, бәйләгеч матдәләр, акрын тәэсир итүче ашлама сыйфатында куллануны нигезли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу о полимерном строении фосфатных стёкол // Изв. АН СССР. Неорганические материалы. 1965. Т. 5, № 6 (автордаш); Кинетика адсорбции двуокиси азота на гранулах селикогеля КСМ-6 // Основные проблемы теории физической адсорбции. М., 1970 (автордаш).

*Әд.:* Л.И.Кузнецов-Фетисов: Биобиблиогр. К., 1987. *В.Г.Абзалова.*

**КУЗНЕЦО́ВА** Алевтина Васильевна (14.8.1940, Свердловск өлкәсе Түбән Тагил ш.), педиатр, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1991). 1964 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, 1964–66 да Киров өлкәсенең Даровск эшчеләр посёлогында эшли. 1966–69 да Казан ГИДУВында (1995 тән Казан мед. академиясе), 1989 дан педиатрия һәм неонатология каф. мөдире. 1969–85 тә Казан мед. ин-тының госпиталь педиатриясе кафедрасында. Хезмәтләре аллергология, неонатология, иммунология, пульмонология, ана һәм бала сәламәтлегенә мед.-экология тәэсире мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Сывороточные липопротеиды у детей при острых желудочно-кишечных заболеваниях // Казан. мед. журн. 1966. № 5; Лямблиоз и кишечная колиинфекция у детей // Казан. мед. журн. 1973. № 2 (автордаш); Особенности реактивности новорождённых при ОРВИ и пневмонии // Педиатрия. 1982. № 2.

**КУЗНЕЦО́ВА** Зинаида Михайловна (6.8.1951, Чаллы р-ны Сарсаз-Баграж а.), педагог, пед. фән. д-ры (2000), велосипед спорты буенча спорт остасы (1974). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1974). 1980 елдан Кама политехник ин-тының (Чаллы ш.; 2012 дән Казан (Идел буе) федераль ун-ты составында) физик тәрбия һәм спорт кафедрасында, проф. (2000). Хезмәтләре физик тәрбия һәм спорт тарихы, спортчылар әзерләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: История физической культуры и спорта в Республике Татарстан. Наб. Челны, 1999; Физическая культура и спорт среди женщин в Республике Татарстан. Наб. Челны, 2001 (автордаш).

**КУЗНЕЦО́ВА** *Ләлә Миңлебай кызы* (4.8.1946, Казакъстан ССР, Уральск ш.), фоторәссам. Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Казан «Вакууммаш» фәнни-тикшеренү ин-тында инженер-механик булып эшли (1972–77). Казандагы «Волга» (1966–74), «Тасма» (1974–89) фотоклублары әгъзасы. 1978–79 елларда ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музее фотографы, Литва фотоҗәмгыяте әгъзасы (1979–80), «Вечерняя Казань» г-тасы, «Ялкын» ж-лы фотохәбәрчесе (1980–84), Казандагы Респ-ка модельләр йорты фотографы (1984–90). Фоторәссамнар (1988), Журналистлар берлеге (1994) әгъзасы. Фоторәссам буларак халыкара танылу ала. Сюжетлары һәм образлары эре форматлы циклар һәм серияләргә берләштерелгән аклы-каралы һәм төсле сәнгати фоторәсемнәр авторы. К. ның хезмәтләре арасында эчтәлеге буенча аеруча масштаблысы — чегән халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, көнкүрешен һәм дингә карашын ачып биргән «Чегәннәр» сериясе (1979–98). Сериядәге фоторәсемнәрнең һәркайсы — романтика һәм драматизм б-н сугарылган новелла. Аның бу һәм башка хезмәтләре «Дөнья фоторәсемнәре энциклопедиясе»нә (Лондон, 1982) кертелә, авторга иң дәрәҗәле бүләкләрнең берсе — «Leica» (АКШ, 1997) фирмасы тарафыннан гамәлгә куелган медаль тапшырыла. К. әсәрләренең психол. образлылыгы композицияләрне фәзаи күрә белүдә, форманың аңарга хас стилистикасы (масштабларның контрастлы ярашуы, эре, төсле тапларның ритмнары, көтелмәгән ракурслар һ. б.) б-н аерылып тора; әсәрләренең каһарманнары ышаныч, шатлык һәм кай-



Л.М.К у з н е ц о в а. 1. «Чегәннәр» сериясеннән. Уральск. 1979. Коркоран галереясе. Вашингтон; 2–3. «Риштан керәче» циклыннан. 1998.

гы, бәйрәм һәм көндәлек тормыш мизгелләрендә гәүдәләнгән «Хатын-кыз турында» (1978), «Рус зиратлары» (1980 еллар) циклларында чагыла, «Күчмә цирк» (1982), «Дин» (1983), «Үзбәкстан» (1991) һ. б. серияләре киң абруй казана. Аның «Рус чегәннәре» һәм «Гасырлар тузанын какканда» альбомнары Германия, АКШ, Бөекбритания, Франциядә басыла. 1990 еллардан К. «Риштан керәче» темасын яктырта.

Европа һәм Америка илләрендә узган «Хәзерге заман совет фоторәсеме» исемле 17 чит ил күргәзмәләрендә (1979–89), Арль (Франция, 1989), Хьюстон (АКШ, 1989), Наардан (Нидерланд, 1995) шәһәрләрендәге халыкара фоторәсемнәр фестивалендә, Хайдельбергтагы «Идел белән Эльба арасында» (Германия, 1989), Нью-Йорктагы «Mother Jones» (АКШ, 1997) халыкара күргәзмәләрендә һ.б.да катнаша. Чит илләрдә: Вильнюс, Берлин, Мюнхен (барысы да — 1989), Париж (1990), Сант-Етьен (Франция, 1991), Франкфурт-Майн (Германия, 1993), Берлин (1994), Коимбрада (Португалия, 1998) һ.б.да узган 10 аерым күргәзмә авторы К. турында «Минем карашым» исемле фильм төшерелә (Үзәк документаль кино студиясе, реж. Э. Киселёв, Мәскәү, 1987). Әсәрләре Вашингтондагы Коркоран сәнгать галереясында, Берлиндагы Сәнгать китапханәсендә, Париж мәриясенең «Виль де Париж» фотомузеенда, Коимбрадагы фоторәсемнәр музеенда, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

«Гуманизм өчен» алтын медале (Франция),«Leica» фирмасының (АКШ) «Мәшһүрлек медале» б-н бүләкләнә; халыкара «Mother Jones» (АКШ), «Austauschdienst» акад. стипендиясенә (Германия, 1996) лаек була.

*Әд.:* Das Buch der Sinti. Elefanten Press. Germany, 1981; Another Russia. Themes & Hudson, 1987; Different thinking. Finland, 1988; Un Regard Surla. France, 1988; Changing reality. Starwood Publishing. USA, 1991.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КУЗНЕЦО́ВА** Марина Вадимовна (8.5.1957, Казан — 8.3.2012, шунда ук), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1998). 1980 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Республика офтальмология хастаханәсендә эшли. 1986 дан Казан мед. академиясендә, 1996 дан офтальмология каф. мөдире. Хезмәтләре күз авырулары (миопия, макулодистрофия, катаракта, кылый күзлелек), наталь күрә карау килеп чыгуда умырткалык патологиясе роле; күз авыруларын рефлекс-мануаль ысуллар б-н дәвалауга, күрүне контактлы көйләүгә карый.

Х е з м.: Клиника и диагностика натально обусловленной миопии. К., 1988; Современные методы диагностики и лечения заболеваний. К., 1998; Лечение натально обусловленной миопии. К., 1999.

**КУЗНЕЧИ́ХА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 62 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үтәк елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 467 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Петропавловский, Покровский исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә, тәгәрмәч ясау, балта эше, тегүчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да волость идарәсе урнаша; Покров, Обновление храма Господня чиркәүләре (1874–78, 1902–04 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дән эшләп килүче авыл приход мәктәбе җирлегендә 1896 да ачыла), чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), фельдшерлык пункты, кредитлау ширкәте, 15 җил тегермәне, йон тетү йорты, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете, 1 сырыханә була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3461,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлки р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха р-ны үзәге. 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 372 ир-ат; 1859 да — 1894, 1897 дә — 2508, 1908 дә — 2839, 1920 дә — 3069, 1926 да — 2451, 1938 дә — 2325, 1949 да — 1799, 1958 дә — 1859, 1970 тә — 1053, 1979 да — 1010, 1989 да — 612, 2002 дә — 547 кеше. К. янында *Суар шәһәрлеге* урыны саклана.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**КУЗНЕЧИ́ХА РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә оештырыла. Үзәге — Кузнечиха авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе — Казан губернасының Спас өязенә, 1920 дән — ТАССРның Спас кантонына, 1930 дан Әлки һәм Спас р-ннарына керә. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та мәйданы — 1178 $км^2$, халкы — 27,5 мең кеше, 23 авыл советы, 65 торак пункт була. 1944нең 19 февраленнән К.р. терр-ясенең бер өлеше яңа оештырылган Юхмачы районына бирелә (1956 ның 7 декабрендә яңадан кире кайтарыла). 1960 та районның мәйданы — 1114,6 $км^2$, аңа 9 авыл советы, 58 торак пункты керә. 1960 ның 28 октябрендә К.р. бетерелә, терр-ясе Әлки һәм Куйбышев р-ннарына бирелә.

**«КУЗЫ́ КҮРПӘ́Ч БЕЛӘ́Н БАЯНСЫЛУ́»**, гомумтөрки лиро-эпик *дастан.* Алтай, башкорт, казакъ, татар һәм башка төрки халыкларда таралган. Дастанның барлыкка килү вакыты хакында бердәм фикер юк. Казакъ фольклорчысы И.Дүйсенбаев казакъча версиясенең барлыкка килүен 11–12 йөзләр б-н билгели. В.М.Жирмунский исә мондый әсәрләрнең иҗат ителүен 15–17 йөзләргә нисбәт итә. Дастанның туу һәм таралу вакытын Алтын Урда чоры (13–15 йөзләр) б-н бәйләү дөресрәк дип табыла.

Үзәктә — яшьләрнең мәхәббәт тарихы. Бервакыт, ауга чыккач, Ак хан б-н Кара хан әле тумаган балаларын бер-берсенә өйләндерергә сүз куешалар. Кайтыр юлга чыккач, Ак хан үлә. Кара хан биргән вәгъдәсен кире алырга уйлый: кызы Баянсылуны мәрхүм Ак ханның улы Кузы Күрпәчкә кияүгә бирергә теләми һәм ерак далаларга күченеп китә. Үзенә ярәшелгән кәләше барлыгын белеп алган Кузы Күрпәч, әнисенең каршы килүенә карамастан, аны эзләргә юлга чыга. Баянсылуның әтисе кызын Кара Калмыкка кияүгә биргән була. Кызның абыйлары Кузы Күрпәчне үтерәләр һәм яр буена күмеп куялар. Аның кабере өстендә Баянсылу үз-үзенә кул сала. Кызны елганың каршы ягындагы ярга күмәләр. Гашыйкларның каберләре өстендә, елга аша ботаклары б-н бер-берсенә үрелеп, ике алмагач үсеп чыга (кайбер вариантларда геройлар кабат тереләләр һәм 33 ел бергә бәхетле гомер кичерәләр).

Дастанның татарча версиясе беренче тапкыр 19 йөз уртасында В.В.Радлов тарафыннан бараба татарларыннан, икенче варианты 1940 елда Х.Х.Ярми тарафыннан Новосибирск өлкәсе Тернә авылында яшәүчеләрдән язып алына; аның 20 дән артык себер-татар варианты 1967–68 елларда теркәлә (ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кульязмалар бүлегендә саклана).

*Әд.:* У р м а н ч е е в Ф. Мәхәббәт дастаны // Татар әдәбияты мәсьәләләре. К., 1974; Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Р а д л о в В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи.

СПб., 1872. Ч. 4; В а л и х а н о в Ч.Ч. Собр. соч. А.-А., 1964. Т. 3; Народный эпос «Кузы-Курпес и Маян-Хылу». Уфа, 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КУЗЬМИ́Н** Анатолий Андреевич (18.3.1956, Оренбург өлкәсенең Бозаулык ш.), спортчы (автомобиль спорты), Россиянең халыкара классы спорт остасы (1996). Тольятти политехник ин-тын тәмамлый (1978). «Париж-Гранада-Дакар» (1996) ралли марафонында җиңүче, «Париж–Мәскәү–Пекин» (1992), «Мәскәү–Улан-Батор–Пекин» (1995) раллиларында бронза медаль ала. 1978 дән «КамАЗ» АҖдә (Чаллы ш.), Фәнни-техник үзәкнең йөк һәм җиңел автомобильләр бүлеге башлыгы (1995 тән). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Я к у б о в а О. Мой финиш — горизонт. К., 1998.

**КУЗЬМИ́Н** Василий Иванович (1851, Түбән Новгород губ. — ?, Мәскәү), хирург, медицина д-ры (1879), хакыйкый статский советник (1896). 1875 елда С.-Петербургта Мед.-хирургия академиясен тәмамлый. 1875–76 да Клиник хәрби госпитальдә дәвалаучы. 1877 дән Мед.-хирургия академиясендә (проф. Н.Ф.Склифосовский җитәкчелегендә). 1878 дән баронет Виллиснең Михайловскоедагы клиник хастаханәсендә ассистент. 1877–78 елларда рус-төрек сугышында катнаша. 1880 дә Александр яралылар ком-тында, бер үк вакытта Мәскәү уку-укыту округы попечителе һәм Мәскәү ун-тының хирургия ф-ты клиникасында. 1861 дән Мәскәү Император тәрбия йортында, бер үк вакытта приват доцент, балалар хастаханәсенең штаб-консультанты; 1883 тән округ хастаханәсе мөдире, өлкән табиб. 1885 тән Мәскәү ун-тының госпиталь хирургиясе кафедрасында. 1894 тән Казан ун-тында ординар проф., факультет хирургиясе каф. мөдире. 1893–96 да Мәскәүдә хосусый хирургия хастаханәсенең ирекле табибе һәм хуҗасы. Хезмәтләре бүсер чыгуның төрләрен (кендек, касык, корсак һ.б. бүсерләр) тикшерүнең объектив ысулларына һәм хирургик дәвалауга карый. 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Центральные саркомы костей в клиническом и патолого-анатомическом отношениях. СПб., 1879; Ущемлённые грыжи: Методика хирургического лечения их // Хирург. летопись. 1893. № 2; Курс хирургической патологии и терапии для врачей и студентов: В 4 вып. М., 1886–90.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**КУЗЬМИ́Н** Георгий Анатольевич (27.11.1904, Пенза ш. — 2.12.1979, Казан), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1945), проф. (1966). 1929 елда Мәскәү югары техник уч-щесен тәмамлаганнан соң, СССР Авиация сәнәгате министрлыгы КБда эшли (1930–46), бер үк вакытта Рыбинск авиация ин-тында укыта (1932–41). 1946 дан Казан авиация ин-тында, авиация двигательләрен конструкцияләү каф. мөдире (1946–63), бер үк вакытта моторлар төзү ф-ты деканы (1947–51). Хезмәтләре авиация двигательләрен проектлауга һәм конструкцияләүгә карый. К. ныклык, чыдамлык, ресурс, тавышны киметү мәсьәләләрен тикшерә, төп элементларның ныклыгын исәпләү алымнарын тәкъдим итә, авиация двигательләре модификацияләрен эшләүдә катнаша. «Авиация двигательләрен конструкцияләү» («Конструкция авиационных двигателей», М., 1962) уку ярдәмлеге авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование работы высокоскоростных роликовых подшипников ГТД при подаче больших количеств масла // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1958. Вып. 33 (автордаш); К вопросу о влиянии массы вала ротора на его критические обороты // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1958. Вып. 34; Расчёт на прочность дисков турбомашин, находящихся в упругом состоянии // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1960. Вып. 55.

**КУЗЬМИ́Н** Михаил Кузьмич (1915, Казан губ., Цивильск өязе Иске Тәрбит а. — 29.11.1941, Ленинград өлкәсенең Тихвин ш.), Сов. Союзы Герое (17.12.1941, үлгәннән соң). Горький хәрби-сәяси уч-щесен тәмамлый (1941). Хәрби хезмәткә чакырылганчы, бораулар вышкасы урнаштыру буенча техник булып эшли. 1935 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 46 нчы танк полкында рота политругы (4 нче аерым армиянең 46 нчы танк бригадасы). Көнбатыш, Үзәк һәм Волхов фронтлары гаскәрләре составында Брест юнәлешендәге оборона сугышларында (1941), Тихвин оборона һәм һөҗүм операциясендә (1941) катнаша. 1941 нең 29 ноябрендә Ленинград өлкәсе Тихвин р-ны Кордон Спасский торак пункты янындагы сугышта батырлык күрсәтә: К. танкы сафтан чыга; соңгы патронына кадәр атып бетерә һәм танкта янып һәлак була. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. К. каберендә обелиск урнаштырыла. Тихвин шәһәрендәге бер урам К. исемен йөртә, йортларның берсенә мемориаль такта эленә. Түбән Новгород шәһәрендә Мәңгелек ут янындагы стелага Герой исеме чокып язылган; К. укыган мәктәпкә (Иске Тәрбит а.) аның исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Твои герои, Ленинград. Л., 1970; Т ю л ь н и к о в Л.К., Б а с о в и ч Я.И. Герои Советского Союза — горьковчане. Г., 1981.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУЗЬМИ́Н** Павел Алексеевич (16.11.1908, Оренбург ш. — 31.7.1992, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1948), проф. (1949), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1957). 1932 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли, теоретик механика каф. мөдире (1938–75). Хезмәтләре аналитик механикага, стационар хәрәкәтләрнең тотрыклылыгы мәсьәләләренә, тирбәнүләр теориясенә карый. К. тоташ тирәлекләр һәм стационар хәрәкәтләр тотрыклылыгы, параметрик ярсынулар вакытындагы тотрыклылык, Ляпунов функцияләрен куллану буенча нәтиҗәләр ала. Казанда традицион «Четаев укулары» конференцияләрен үткәрүнең инициаторы һәм оештыручысы. Хезмәт Кызыл Байрагы,



М.К.Кузьмин.



С.Е.Кузьмин.

«Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К теории устойчивости движения // Прикладная математика и механика. 1954. Т. 18, вып. 1; Устойчивость при параметрических возмущениях // Прикладная математика и механика. 1957. Т. 21, вып. 1; Малые колебания и устойчивость движения. М., 1973.

**КУЗЬМИ́Н** Сергей Евдокимович (14.7.1910, Казан губ., Чистай өязе Кубас а. — 1989, Мәскәү), генерал-майор (1962), Сов. Союзы Герое (6.4.1945). Сумы артиллерия уч-щесен (1936), Ф.Э.Дзержинский исем. Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең артиллерия академиясен (Мәскәү, 1941), К.Е.Ворошилов исем. Югары хәрби академияне (Мәскәү, 1948), Ф.Э.Дзержинский исем. Артиллерия-инженерлар академиясе каршындагы Югары академик курсларны (Мәскәү, 1962) тәмамлый. 1930 елдан Сталинград трактор з-дында фрезерчы булып эшли. 1932 дә Кызыл Армия сафларына чакырыла. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 5 нче гв. армиянең артиллерия штабы разведкасы башлыгы (1 нче Украина фронты). 1945 нең гыйнвар-февраль айларында Висла-Одер операциясе барышында батырлык күрсәтә. 1945 нең мартында армиянең тупчы артиллерия бригадасына командир итеп билгеләнә. 1945–69 елларда, җаваплы хәрби урыннарда эшли, СССР Оборона министрлыгы үзәк аппаратында җаваплы вазифалар башкара. Ике Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Новоукраинка һәм Кралупи (Чехословакия) шәһәрләренең Мактаулы гражданы. Кралупидагы бер урамга К. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КУЗЬМИНА́** Екатерина Антоновна (17.11.1927, Арча кантоны Пановка а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1941–51 елларда Биектау р-ның «Победа» к-зында, 1951–82 дә «Бөреле» с-зында эшли. Һәр сыердан савылган сөт 1963 тә — уртача 4000 *кг*, 1965 тә 4635 *кг* тәшкил итә. К. «ТАССРның иң яхшы сыер савучысы» исеменә лаек була. Герой исеме терлекчелекне үстерүдә, сөт һәм ит җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешелгән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә.


Е.А. Кузьмина.


С.Д. Кузьминых.

*Әд.:* М а т в е е в а Е. Кузьмина Екатерина Антоновна // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.


**КУЗЬМИ́НОВКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 58 *км* көнбатыштарак, Куак елгасы буенда. 2010 елда 125 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча чуашлар — 64%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1830 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да чиркәү-приход мәктәбе, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 759 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 280, 1889 да — 461, 1910 да — 529, 1920 дә — 601, 1926 да — 414, 1938 дә — 654, 1949 да — 574, 1958 дә — 585, 1970 тә — 480, 1979 да — 309, 1989 да — 204, 2002 дә — 163 кеше.

**КУЗЬМИНЫ́Х** Софья Даниловна (19.12.1927, Казан), гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, ТАССР ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980), ТРның халык рәссамы (1998). Рязань өлкәсенең шәһәр тибындагы Кадом посёлогында «сәнгатьле чигү» белгечлеге буенча тегү сәнгате техникумын (1949), Мәскәү технол. ин-тының келәм-тукыма бүлеген (1963) тәмамлый. Ярославль өлкәсенең Курба район үзәгендә «Восход» артеле рәисе һәм технологы (1949–51), Казандагы «Культпром» күпләп тегү артелендә цех башлыгы (1951–52), «Художпром» артелендә рәссам булып эшли (1955–63). Казан сәнгать уч-щесе укытучысы (1963–64), бер үк вакытта Арча милли аяк киемнәре ф-касы рәссамы. 1967–92 елларда Казан күн-галантерея ф-касында баш рәссам-модельер. 1980–81 дә Казан мәдәният ин-тында, 1993–97 дә 40 нчы һөнәри-техник уч-щедә укыта. Рәссамнар берлеге (1975), СССР Җиңел сәнәгать министрлыгының сәнгать-эксперт советы (1972–92), ТАССР МС каршындагы республика сәнгать советы (1957–92) әгъзасы.

К. — татар каюлы күн, басма һәм аппликация сәнгате традицияләрен беренче булып яңарткан проф. осталарның берсе, гамәли-бизәлеш сәнгатенең башка төрләрен: элмәләп чигү, батик (ефәккә бизәк төшерү), кулдан йон-мамык келәмнәр туку, тире каю, өс киемнәре моделен әзерләүне үзләштерә. Нәфис сәнәгать һәм халык нәфис кәсепчелеге пр-тиеләре чыгарган күргәзмәләр өчен житештерелгән уникаль һәм сериялəп тиражга куелган эшләнмәләр авторы. 1960–70 елларда К. үрнәкләре: Казан тегү ф-касында — машинада элмәләп чигелгән эшләнмәләр (сөлгеләр, эскәтерләр, күлмәкләр, блузалар һ. б. ); Арча милли аяк киемнәре ф-касында — модалы силуэт һәм стильләшкән бизәк б-н тегелгән аяк киемнәренең яңа модельләре, өс киеменә ятышлы итеп каелган аяк киеме һәм аксессуар ансамбльләре (сумкалар, перчаткалар, путалар); Казан күн-галантерея ф-касында басма, яндырып бизәк, рәсем төшерү техникасында бизәлгән күн эшләнмәләр үрнәкләре һәм модельләре (сумкалар, акча янчыклары, адрес папкалары, футлярлар һ. б.) күпләп житештерүгә кертеләләр. К.ның, башлыча, чын күннән әзерләнгән күпчелек эшләнмәләре, кагыйдә буларак, үзе үк иҗат иткән хатын-кыз киемнәре ансамбльләре комплексына өстәмә буларак керә (мәс., 1983 тә татар милли өс киемнәре үрнәгендә әзерләнгән «Яшьләр» костюмы кыска камзул-җилеттән, күлмәк, туфли, сумка, перчатка, билбау һәм муенсадан тора). К. еш кына күнне мех, велюр, замша бизәкләр б-н баета, укалап чигү, металл сәйләп, төрле ялтыравык бизәкләр б-н тулыландыра. Эшләнмәләр еш кына ачык, кызыл-көрән, яшел, кызыл, сары һәм зәңгәр төсләр чагылышларында бирелсә дә, К. төрле төсләр палитрасыннан файдаланырга ярата. К. — татар милли орнаментларын стильләштерү остасы, аның структурасына табигый рәвештә кергән яңа бизәкләр иҗат итүче. Формаларны гомумиләштереп һәм бизәкләрне эреләндереп, ирекле фон яссылыгын киңәйтеп, әйберләрнең формаларына ярашлы яңа композиция чишелешләре табып, бизәкләргә сюжетлы рәсемнәр кертеп, ул традицион бизәкләргә заманча яңгыраш өстәүгә ирешә. Күнгә басма бизәк төшерү техникасы б-н К. яңа жанр — татар фольклоры үрнәкләре буенча сюжетлы-тематик характердагы дивар панносы барлыкка китерә — «Болгар калканы», «Җик Мәргән» триптихы, «Ябалак — хикмәтле кош» һ.б. (барысы да — 1978 дә).

Төп әсәрләре: чигү (тамбур) — «Алан» эскәтере (1960); «Татар бизәкләре» (1960), «Сөембикә» (2001) сөлгеләре; чуклы-чачаклы яулык (1971), «Бәйрәм яулыгы» (1979); «Кәләш өчен ак калфак» (1979); «Сабантуй» (2001), «Картлач» (2002) түбәтәйләре; каюлы күн — «Йөрәккәем» (1957), «Әңгер-меңгер» (1985), «Татар читеге» (1986) читекләре; «Зур мендәр» (1984), «Декоратив» (1987), «Алсу» (1988) мендәрләре; «Намазлык» келәме (2001); күн, басма — «Сандык» (1969), «Зилант» (1975), «Букча» (1977), «Асылмалы сумка» (1979) сумкалары; «Хатын-кыз путасы» (1979), «Декоратив пута» (2001); күн чигү — «Көмеш гасыр» хатын-кыз читекләре (2001), «Алтын гасыр» комплекты (итек, сумка) (2001); батик — «Гөлчәчәк» яулыгы (1958), Казан Кремлендәге Президент сараеның «Идел-Волга» пәрдәсе (1997), «Зәңгәр» палантины (2002); катнаш техника — Татар акад. театры өчен җиһаз бизәү (күн, каю, басма; 1982), «Кичке әкият» панносы (күн, каю, аппликация, чигү; 1998); келәмнәр — «Татар үрнәкләре» (мех, күн, велюр, коллаж; 1974), «Казан» (мех, күн, мозаика, аппликация; 1986).

Республика (1957–2002), төбәк («Зур Идел», 1969–98), бөтенсоюз (1 нче халык нәфис кәсепчелеге күргәзмә-смотры, Мәскәү, 1960; «16 автономияле республика», Мәскәү, 1980; Олимпиада-80 гә багышланган сувенирлар күргәзмәсе, Мәскәү, 1980; СССР ВДНХсында халык нәфис кәсепчелеге, Мәскәү, 1969–89; «СССРда гамәли-бизәлеш сәнгате», Мәскәү, 1990 һ. б. ), халыкара («Аяк ки-

С.Д. К у з ь м и н ы х.
1. «Болгар мотивлары» (триптих фрагменты). Күн, басма. 1980 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее;
2. «Зәңгәр шәл» (автордаш — С.Ю. Гарбузова). Крепдешин. Батик. 1988. Г.Камал исем. Татар акад. театры;
3. Декоратив панно (автордаш – С.Ю. Гарбузова). «Өйлә вакыты». Ефәк. Батик. 1998.

еме-69», Мәскәү, 1969; Димәшкъта (1975–76), Будапешттә (1976), Дәһлидә (1985) һ.б. шәһәрләрдә нәфис һәм җиңел сәнгать күргәзмәләре; Лейпцигтагы күргәзмә-ярминкә, (1980) һ. б. ) күргәзмәләрдә катнаша. Аерым күргәзмәләре Казанда (1978, 1984, 1989 — С.Гарбузова һәм И.Гайнетдинов б-н берлектә, 1995, 1999, 2002), Ленинградта (1990, С.Гарбузова һәм И.Гайнетдинов б-н берлектә) уздырыла.

Әсәрләре Россия халыкларының этнография музеенда (С.-Петербург), Бөтенроссия гамәли сәнгать һәм халык сәнгате музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Мари Респ-касының Сынлы сәнгать музеенда (Йошкар-Ола ш.), М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда (Уфа ш.) һ.б.да саклана. ТР Мәдәният министрлыгының сынлы сәнгать өлкәсендәге Б.Урманче исем. бүләге лауреаты (2001).

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Творческий портрет художницы Софьи Кузьминых // Панорама: Ежегодник. М., 1985; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Софья Даниловна Кузьминых: Каталог выставки. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КУЗЯ́ЕВ** Андрей Равил улы (6.10.1965, Пермь ш.), икътисадчы, пр-тие җитәкчесе. Пермь ун-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук эшли. 1990 елдан «Пермь финанс-сәнәгать төркеме» АҖ президенты, 1996 дан «ЛУКОЙЛ-Пермь» АҖ ген. директоры, 2000 нән «ЛУКОЙЛ Оверсиз Холдинг ЛТД» президенты. Аның җитәкчелегендәге компания күп кенә халыкара нефть-газ проектларын гамәлгә ашыруда катнаша. Пермь өлкәсенең Законнар чыгару җыены депутаты (1994 тән). Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

**КУЗЯ́ЕВ** Рафаэль Зыяфетдин улы (22.5.1941, Пермь ш.), микробиолог, мед. фән. д-ры (1998), проф. (1999). 1965 елда Пермь мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1998 дән Пермь мед. академиясенең микробиология кафедрасында. Хезмәтләре Көнбатыш Уралда талпан энцефолиты иммуногенезы диагностикасына, профилактикасына карый. Умарта кортларын тикшерү өчен экологик мониторинг лаб-ясен оештыра.

Хезм.: Совершенствование иммунологических методов исследования и их применение в клинико-лабораторной и эпидемиологической диагностике клещевого энцефалита: Дис. ... Пермь, 1997.

**КУЙ ЕЛГАСЫ́**, Көнчыгыш Кама аръягында, Кандыз елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,4 *км*, бассейнының мәйданы 57,6 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага, Баулы р-нында. Елга башы Оренбург өлкәсе б-н арадаш чиктә, Югары Фоминовка авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан; тамагы — Татар Кандызы авылында. Елга башының абс. биеклеге 278 *м*, тамагыныкы — 147 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 125 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,09 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**КУ́ЙБЫШЕВ**, Болгар шәһәренең 1935–91 еллардагы исеме.

**КУ́ЙБЫШЕВ ЗАТОНЫ́**, шәһәр тибындагы посёлок, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярындагы пристань. 2010 елда 2677 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 74,4%, татарлар — 22,1%) яши. Урта мәктәп, һөнәр уч-щесе, музыка мәктәбе, китапханә. Чиркәү. Нефть флотының судноларны ремонтлау-файдалану базасы. Аның тарихы 1842 дә «Русалка» пароходчылык җәмгыятенең ремонтлау базасы буларак төзелгән Спас Затоны посёлогыннан башлана. Башта Идел елгасының сул ярында (хәзер су астында калган) урнаша. 1850 елларда база «Кавказ вә Меркурий» җәмгыяте милкенә күчә, монда пароходлар төзи башлыйлар. 1876 дан 1913 кә кадәр 18 судно төзелә. 20 йөз башында Спас Затонында Никола чиркәве (1861 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1867 дә ачыла; 1878–83 тә земство, 1883 тән хосусый мәктәп), хастаханә, фельдшерлык пункты, «Кавказ вә Меркурий» җәмгыятенең суднолар төзү-механика з-ды, 1 казна шәраб һәм 12 вак-төякләр кибете, 2 сыраханә, пароходлар пристане була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 180 дис. тәшкил итә. 1935 тә Спас Затоны К.З. итеп үзгәртелә. 1955–56 да хәзерге урынына күчерелә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ширбәт волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Спас кантонында. 1929 ның 30 декабреннән — шәһәр тибындагы посёлок. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 1 апреленнән — Куйбышев, 1956 ның 22 сентябреннән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1858 дә — 81, 1892 дә — 1357, 1908 дә — 1192, 1926 да — 2480, 1979 да — 3,1 мең, 1989 да — 2,9 мең, 2002 дә — 2914 кеше.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**КУ́ЙБЫШЕВ РАЙОНЫ́**, *Новосибирск өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1936 елның 20 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 8847 *км*². Үзәге — Куйбышев шәһәре (Новосибирск шәһәреннән 316 *км* көнбатыштарак). Халкы — 18 мең кеше (2010), 2412 татар (2002) (1970 тә — 719, 1979 да — 904, 1989 да — 968 кеше). Татарлар Куйбышевта (1029 кеше) һәм Аул-Омь (360), Аул-Шагиры (345), Аул-Бергуль (619), Кульча (59) авылларында яши. 1917 гә кадәр районда 3 мәчет була. Хәзерге вакытта 2 татар мәктәбе эшли, аларда татар теле фән буларак укытыла. 2001 дә К.р. идарә органының мәдәният бүлеге каршында Татар үзәге оештырыла.

**КУ́ЙБЫШЕВ РАЙОНЫ́**, *Спас районының* 1935–91 еллардагы аталышы.

**КУ́ЙБЫШЕВ СУСАКЛАГЫЧЫ́**, Идел елгасындагы сусаклагычлар каскадының алтынчы баскычы, дөньяда мәйданы буенча елга үзәннәрендәге иң зур сусаклагычларның берсе. Ульянов һәм Самара өлкәләре, Татарстан, Мари һәм Чуаш Респ-калары терр-яләрендә. 1953 елда Иделдә В.И.Ленин исемендәге Идел ГЭСын төзегәндә Ставрополь (хәзерге Тольятти) шәһәре янында Жигули таулары р-нында Иделдә плотина кору нәтиҗәсендә барлыкка килә. 1955–57 дә су б-н тутырыла. Нормаль терәк биеклеге 53 *м* тәшкил итә. Мәйданы 5900 *км*², күләме 56 *км*³, Идел буенча 510 *км*, Кама елгасы буенча 280 *км* озынлыкта, иң зур киңлеге 27 *км* (Кама елгасы тамагы). Уртача тирәнлеге 9,4 *м*, плотина янында иң зур тирәнлеге 41 *м*, Казан янында 16–18 *м*, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы янында 19 *м*, Чистай шәһәре янында 12–14 *м*. Яр буе линиясенең озынлыгы 2604 *км*, шуның 1392 *км*ы (су өслегенең яртысыннан артыгы) ТР терр-ясендә.



Куйбышев сусаклагычы. Саескан Тавы янында.

К.с.ның уңъяк яры Идел буе калкулыгына тоташа. Рельефта «таулар» исемен йөртүче аерым калкулыклар билгеләнә. ТР чикләрендәге таулар: Ослан (Казанга каршы), Сөйке (Кама Тамагы пристаненнан көньяктарак), Тәтеш (Тәтеш шәһәре тирәсендә) һәм Чуртан (Олы Тархан авылыннан көнчыгыштарак).

К.с.ның су өслеге катлаулы конфигурацияле. Киң участоклар (12–20 *км*), киңлеге 3–5 *км* дан артмаган тар бугазлар б-н чират-

лаша. 8 киң тирән участок бүлеп йөртелә, шуның 4 се Татарстан терр-ясендә: Идел, Идел-Кама, Кама, Тәтеш. К.с.на 100 дән артык елга, ш.и. Иделдән кала иң зур һәм Идел бассейнында иң күп сулы елга — Кама коя. Шулай ук ТР терр-ясендә К.с.на Вятка, Мишә, Зөя, Казансу, Зәй, Чишмә, Бөрсет, Актай, Бизнә елгалары коя. Елгаларның түбән агымы су астында калган, кайберләрендә зур култыклар (Мишә, Зөя, Чишмә һ.б.) барлыкка килгән.

К.с.нда тотрыклы боз катламы ноябрь ахыры — декабрь башында хасил була, боздан ачылу — апрель уртасында (иртә булганда апрельнең беренче көннәрендә, соңга калганда — апрель азагында). Боз катуның уртача дәвамлылыгы — 143 тәүлек (Иделдә К.с. төзелгәнгә кадәр — 138 тәүлек). Суның иң югары темп-расы (22–25 °С) июльнең 2 нче яртысында күзәтелә. Апрельдән октябрьгә кадәрге чорда К.с.нда 3–5 *м/с* (көзен — 4–6 *м/с* ка кадәр) тизлектәге төньяк, көнбатыш һәм төньяк-көнчыгыш җилләре өстенлек итә. Дулкыннарның биеклеге, гадәттә, 0,5–0,75 *м* дан азрак, акваториянең аерым киң участокларында ел саен 2,5–3 *м* (шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы р-нында 3,7 *м* макс.) биеклектәге дулкыннар күзәтелә.

К.с.нда агымны сезонлы көйләү үткәрелә. Ул режимның үзенчәлеге — ел саен язын нормаль терәк биеклеккә кадәр су тутыру. Язгы тутыру вакытында, кыш азагындагы б-н чагыштырганда, су биеклеге 4–9 *м* га (уртача 5 *м*) күтәрелә. Суны күтәртү, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана һәм ай дәвамында аеруча көчле була. Октябрь башына кадәр су биеклегенең үзгәреше сизелерлек түгел (1 *м* дан артмый), көз ахырында һәм кышын су биеклеге акрынлап кими.

К.с. — комплекслы файдаланыла торган сулык (энергетика, суднолар йөртү, су басулар б-н көрәш, су б-н тәэмин итү, сугару, балык хуҗалыгы, ирригация һ.б.). Идел ГЭСының уртача еллык электр җитештерүчәнлеге 10,26 млрд. *кВт/сәг*. ТРда тотыла торган балыкның (корбан балык, судак, чуртан, чөгә балык, җәен, синец, густера, чабак, бёрш, налим, кәлчәк) 90% ка кадәрен К.с. тәэмин итә. Сусаклагычның төзелүе ш.у. тискәре күренешләр дә китереп чыгара: болын, урман, торак пунктлар су астында кала, сай сулыклар барлыкка килә, суның санитар торышы начарлана, яр буйлары ашала һәм җимерелә һ.б.

Татарстан чигендә К.с.ның уңъяк ярында Казан, Түбән Кама, Яшел Үзән, Алабуга, Чистай, Тәтеш, Болгар, Лаеш шәһәрләре, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы урнашкан. К.с. р-нында ял йортлары, санаторийлар, балалар сәламәтләндерү лагерьлары, туризм, аучылык, балык тоту базалары эшли.

*Әд.:* Волга и её жизнь. Л., 1978; Куйбышевское и Саратовское водохранилища. Л., 1978; Куйбышевское водохранилище. Л., 1983; Средняя Волга: Геоморфол. путеводитель. К., 1991.

*Ф.Г.Борһанов, О.В.Ерёгин.*

**КУ́ЙБЫШЕВ ТОКЫМЛЫ́ САРЫКЛА́Р**, ярым нечкә йонлы, ит-йон юнәлешендәге токым. 1938–48 елларда Куйбышев (хәзер Самара) өлкәсенең Кошки һәм Кутузов р-ннары колхозларында тупас йонлы черкас сарыкларын ромни-марш токымлы тәкәләр б-н кушып чыгарыла. К.т.с. нечкәлеге 46–56 сыйфатлы ярым нечкә йон бирә, йонның озынлыгы — 12–17 *см*, рекордчыларыныкы 25 *см* га кадәр җитә, штапель кебек аерым терлекләрдә толым характерында була. Йонның нечкәлеге бертөрле, эре бөдрәле. Йон куелыгы яхшы, үсеп җиткән тәкәләрдән — 6,5, ике яшьлекләрдән — 6, бер яшьлекләрдән — 5,3, сарыклардан — 3,8, ике яшьлекләрдән — 3,6, бер яшьлекләрдән 3,3 *кг* йон алына. Чиста йон 56–60% тәшкил итә. 100 сарыкка үрчем — 130 бәрән. Тәкәләрнең уртача авырлыгы — 102 (зурлары 164), сарыкларның 73 (130) *кг*. Ите йомшак, мускул катламнары арасында май («мәрмәр») үсә. Ит чыгышы 52–60%. Татарстанга К.т.с. 1960 елда (Норлат р-нына) кертелә. К.т.с. җәмәгать секторында — 14,1 мең баш, гомуми санга карата 5,35% урын алып тора (1995). 2004 елдан үрчетелми.

*Әд.:* Н и к о л а е в А.И. Овцеводство. М., 1960; Е с а у л о в П.А., Л и т о в ч е н к о Г.Р. Овцеводство. М., 1963; М о р о з В.А. Овцеводство и козоводство. Ставрополь, 2002.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*


**КУ́КЛИН** Виктор Тимофеевич (2.4.1935, Мари автономияле өлкәсенең Совет р-ны Шанер а. — 3.5.2003, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1988), проф. (1991). 1964 елда Иркутск мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1974–89 елларда РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгының Свердловск тире-венерология фәнни-тикшеренү ин-тында. 1989 дан Казан ГИДУВының дерматология кафедрасында. Хезмәтләре нәселдән килгән тире авырулары клиникасына һәм патогенезына карый. К. беренче булып ихтиозга клиник-генеалогик, морфологик, дерматоглифик, функциональ тикшеренүләр үткәрә; авыруларны дәвалау һәм реабилитацияләү ысулларын тәкъдим итә. 1992 дә ТР Республика тире-венерология диспансеры каршында генодерматоз буенча үзәк оештыручыларның берсе. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Клинико-генетическая классификация ихтиоза // Вестн. дерматологии и венерологии. 1974. № 6; Морфология «отторжения» части эпидермиса при hystrix форме ихтиоза // Вестн. дерматологии и венерологии. 1977. № 9; Детская дерматовенерология. К., 1996 (автордаш).

**КУКЛЯ́ШЕВ** Салихҗан Бикташ улы (1811, Оренбург губ. Бөгелмә өязе — 1864, Оренбург ш.), педагог, тел белгече. Морзалар нәселеннән. 1831 елда Оренбургта Неплюев хәрби уч-щесен (к. *Неплюев кадетлар корпусы*) тәмамлаганнан соң, Оренбург чик буе комиссиясендә тәрҗемәче булып эшли. 1832 дән Казан ун-тының мед. ф-тында, 1834 тән Шәрекъ бүлегендә укый. 1836–50, 1856–59 да Неплюев хәрби уч-щесендә гарәп һәм фарсы телләре укыта. 1850–56 да Оренбург чик буе комиссиясе каршында кыргыз (казакъ) ир балалар мәктәбендә тәрбияче. 1834 тә «Заволжский муравей» ж-лында аның «Бакчачы һәм Сандугач» («Садовник и Соловей») дигән фарсы мәсьәләнең тәрҗемәсе басыла. К. тарафыннан әзерләнгән «Татар хрестоматиясе» («Татарская хрестоматия», 1859) 1870 һәм 1895 тә кабат бастырыла һәм 19 йөз ахырына кадәр русларга татар телен өйрәнү өчен уку ярдәмлеге булып хезмәт итә, ә хрестоматиядә бирелгән сүзлеге татар тел белеменә зур өлеш кертә.

*Әд.:* З а к и е в М.З. Влияние Казанского университета на развитие тюркологии в первой половине XIX в. (до 1855 г.) // Вопр. татар. языковедения. К., 1965. Кн. 2; М и х а й л о в а С.М. Формирование и развитие просветительства у татар Поволжья (1800–1861). К., 1972.

**КУКМАРА́**, шәһәр тибындагы посёлок, Кукмара р-ны үзәге. ТРның төньягында, Киров өлкәсе б-н чиктәш, Норма елгасы буенда урнашкан. Казан — Екатеринбург тимер юлындагы станция. Казаннан 120 *км* читтә. 2010 елда 16918 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 81,2%; руслар — 8,7%, удмуртлар — 8,2%) яши. Җиңел сәнәгать (киез итек-киез комб-ты, мех, тегү ф-калары) һәм азык-төлек сәнәгате (сөт-май, азык комб-тлары) пр-тиеләре. Кирпеч, металл савыт-саба җитештерү з-длары. Элеватор. 4 урта һәм 1 музыка мәктәбе, гимназия, һөнәр уч-щесе. Мәдәният йорты, 3 китапханә. Төбәк тарихы музее. 3 мәчет. Чиркәү. Таишевның бакыр кою з-ды посёлогы буларак, 18 йөзнең 2 нче чирегендә оештырыла. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, балта эше, күн эшкәртү, тегү, туку, бау ишү, киез итек басу, бакыр һәм никельле савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Петропавел чиркәве, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе (1873–98 ләрдә земство мәктәбе буларак эшли), земство хастаханәсе, почта станциясе, телеграф, 4 киез итек басу ф-касы һәм 2 остаханә, 2 чуен кою пр-тиесе, 4 тимерчелек,



Шәһәр тибындагы Кукмара посёлогы. Гомуми күренеше.







Шәһәр тибындагы Кукмара посёлогы.
1. Сәнәгатьче С.В. Комаров йорты. 1870 еллар; 2. Тимер юл вокзалы бинасы; 3. Гомуми күренеше.

6 кибет, 1 казна шәрабханәсе, 1 чәйханә, 3 сырахана һәм 10 вак-тәякләр кибете була; дүшәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 104,8 дис. тәшкил итә, 1930 елларда К.га Икенче Кукмара авылы (1678 дән мәгълүм) кушыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1928 дән шәһәр тибындагы посёлок. 1930 ның 10 августыннан Кукмара р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Саба р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — кабат район үзәге. Халык саны: 1782 дә — 131 ир-ат; 1859 да — 398, 1897 дә — 1047, 1908 дә — 1332, 1920 дә — 1366, 1926 да — 1345, 1979 да — 13,2 мең, 1989 да — 14,7 мең, 2002 дә — 16,8 мең кеше.

**КУКМАРА́ КИЕ́З ИТЕ́К-КИЕ́З КОМБИНАТЫ́**, җиңел сәнәгатьнең киез аяк киеме (ш.и. аскы өлешенә резина сеңдерелгәннәре дә), тезелештә, аяк киемнәре җитештерүдә һ.б.да кулланыла торган киез һәм аңардан төрле әйберләр эшләп чыгаручы пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 800 гә якын кеше (2012). 1867 елда Мамадыш өязенең Кукмара авылында «Бертуган Комаровларның фабрикада эшләнгән киез һәм бурки аяк киемнәре сәүдә йорты» ф-касы буларак нигезләнә. 9 тарау һәм 1 йон тетү машинасы, дизель һәм пар двигательләре урнаштырылган ф-када йоннан мамык ясаганнар, шуннан соң аны, киез итекләр басу һәм буркилар — күн табанлы киез итекләр тегү өчен, өйдә эшләүче крәстияннәргә таратканнар. Бу эшкә җәлеп ителүчеләрнең саны — 1,5 мең кешегә, киез итек басу көнгә — 500–600, буркилар тегү — 200 парга, ф-каның еллык җитештерү күләме 1,5 млн. сумга җиткән. Эшләнмәләр Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә киң танылa, Парижда һәм Лейпцигта узган халыкара күргәзмәләрдә бүләкләр б-н бәяләнә. Национализацияләнгәннән соң (1918) һәм элеккеге «Бертуган И.Д. һәм Н.Д.Родыгиннар ширкәте» ф-касы (1886 да нигезләнә, Кукмара а.) б-н берләштерелгәч, Кукмара «Кызыл текстильче» киез аяк киемнәре ф-касы оештырыла. Җитештерү бер корпуста туплана, эшчеләр даими эш режимына күчерелә, цехлар булдырыла. 1936 да яңа корпус төзелә, анда тарау, әвәләү һәм басу цехлары урнаша; авыр хезмәт таләп иткән күп кенә процесслар механикалаштырыла. Эшләүчеләр саны — 1,6 мең кешегә, киез аяк киеме җитештерүнең тәүлеклек күләме 3 мең парга җитә. Бөек Ватан сугышы елларында ф-ка армия өчен 1,5 млн. пардан артык киез итек эшләп чыгара һәм 6 млн. пардан артыгын яңарта. 1956 да җитештерүне оештыруның конвейерлы алымнарына күчеш башлана. Киптерү һәм әвәләү цехлары конвейерлаштырыла, итек булып басылачак өлгеләрне өзлексез эшкәртүче басу-юу җайланмасы, киез аяк киемен эшкәртүче конвейерлы линия, үтәли ману һәм кислота б-н эшкәртү алымы эшләнә һәм гамәлгә кертелә. 1956 да киез итек җитештерү 1 млн. 16 мең пар тәшкил итә, 1965 тә аның күләме, эшләүчеләр саны артмаган хәлдә, 1 млн. 329 мең парга җитә. 1979 да аяк киеме киезе чыгарыла башлый. 1965–85 тә ф-ка коллективы күп тапкырлар РСФСР МСның, тармак профсоюзы ҮКның һәм СССР Җиңел сәнәгать министрлыгының күчмә Кызыл байраклары б-н бүләкләнә. 1985 тә пр-тиегә КПССның Татарстан өлкә ком-ты, ТАССРның ЮС, МС һәм тармак профсоюзы өлкә ком-тының байрагы мәңгелек саклауга тапшырыла. 1993 тә ф-ка «К.к.и.-к.к.» АҖ итеп үзгәртелә. 1990–2000 елларда продукция ассортименты техник киез, одеал, йоклау капчыклары, автомобиль сүрүләре, бияләйләр, мунча комплектлары һ.б. хисабына киңәйтелә; барлык җитештерү цехлары модернизацияләнә. Пр-тие елга 1 млн. пардан артык киез аяк киеме эшләп чыгара. Җитәкчеләре арасында — Ю.И.Неометов (1928–30), М.М.*Голубев* (1951–73), К.Б.Бариев (1973–88), Ш.М.Әхмәтшин (1988 дән).

*С.Г.Белов.*

**КУКМАРА́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньягында, Киров өлкәсе һәм Удмурт Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. Кама алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1492,1 *км*². 1 шәһәр һәм 29 авыл җирлеген, 123 торак пунктны берләштерә. Үзәге — шәһәр тибындагы Кукмара посёлогы. Халкы — 52 мең кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 78,2 %, удмуртлар — 14,2 %, руслар — 5,5%. Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 35 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязендә, 1920 дән ТАССРның Арча һәм Мамадыш кантоннарында. Оештырылган чорда К.р.на 1 посёлок һәм 54 авыл советы, 88 торак пункт керә, аларда 56095 (татарлар — 43187, руслар — 3289, башка халыклар — 9619) кеше яши. 1940 та мәйданы — 994 *км*², халкы — 52,1 мең кеше, 36 авыл советы, 88 торак пункт исәпләнә. Районның адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1956 да — 26, 1960 та 18 авыл советы кала. 1963 нең 1 февралендә, ТАССРда адм. берәмлекләрне берләштерү сәбәпле, К.р. таркатыла, биләмәсе Саба р-нына бирелә. Яңадан торгызылганнан соң (1965 нең 12 гыйнв.), районның мәйданы — 1523 *км*², халкы — 64 мең кеше, 2 посёлок һәм 22 авыл советы, 130 торак пункт була. К.р.ның рельефы — елга үзәннәре б-н бүгәләнгән калку тигезлек (биеклеге 175–220 *м*). Вятка һәм аның кушылдыклары Бөре, Оштырма елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры һәм соры урман, көрән соры һәм кәсле-карбонатлы туфраклы. Урманлылыгы — 20 %. Известьташ, балчык, балчыксыман туфрак, ком ятмалары бар. Саклаулы табигать терр-яләре: Мишә, Норма, Лубян елгалары; табигать истәлекләре — *Кукмара тавы*; *Саба аучылык тыюлыгы*. А.х. 90,6 мең *га* җир били, ш.и. сөрүлек җирләр — 76,2 мең *га* (2009). Сабан бодае, арыш, арпа, борчак, солы игелә; бәрәңге үстерелә. Мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау зур үсеш алган. 2010 да К.р.нда 13 а.х. пр-тиесе эшли. Сәнәгать пр-тиеләре район







Кукмара төбәк тарихы музее.
1. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар өе интерьеры; 2. Экспозиция фрагменты.

үзәгендә һәм Лубян авылында урнашкан. К.р. җиреннән Казан–Екатеринбург тимер юлы уза. Вятка елгасы буенда Лубян пристане эшли. Районда 73 гомуми белем бирү мәктәбе, (2010 — 11 уку елында 6535 укучы укый), ш.и. 42 башлангыч, 2 тулы булмаган урта, 28 урта, физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен коррекция мәктәбе; урман эшләре техникумы (Лубян а.), 2 лицей, һөнәр уч-щесе, 49 китапханә, 57 мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениесе һәм 82 клуб, 314 урынлы хастаханә (2010) бар. Төбәк тарихын өйрәнү музее (Кукмара). Татар һәм рус телләрендә «Хезмәт даны» — «Трудовая слава» район г-талары нәшер ителә.

**КУКМАРА́ ТАВЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан төньяктарак урнашкан. 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 186 *га*. Норма елгасы үзәненә таба көньяк-көнбатыш текә сөзәкле зур булмаган калкулыкны (абс. биеклеге 205 *м*) били. Төрле яшьтәге наратлыклар, каенлыклар һәм усаклыклардан тора, ачык урыннарда болын үсемлекләре өстенлек итә. Үсемлекләрнең сирәк төрләре үсә: Цингер ракитнигы, киң яфраклы йод үләне, соры кырлы борчак һ.б. Кошларның — 40, күбесенчә очып кергән төрләре билгеләнгән; колаклы ябалак, сапсан ТРның Кызыл китабына кертелгән. К.т.нда тауда чаңгы шуу трассасы салынган, спортның кышкы төрләре буенча ярышлар үткәрелә.

**КУКМАРА́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогында, 1995 елның 8 маенда ТРның Берләштерелгән дәүләт музее (2001 дән ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2007 дән муниципаль музей. Бертуган Родыгиннарның элеккеге йортының (1870 еллар; архит-ра ядкәре) беренче катын били. Экспозиция мәйданы — 85 $м^2$, төп фонд 4 мең саклау берәмлеген тәшкил итә. Экспозиция төбәкнең борынгы чорыннан алып 20 йөз ахырына кадәр булган тарихы б-н таныштыра. Археология бүлегендә шәһәр тибындагы Кукмара посёлогы, Кукмара р-нының Мәчкәрә авылы һәм Зур Кукмара каберлеге янындагы археол. казылмаларыннан Алтын Урда чоры керамикасы һәм керамик торба кисәкләре, сәйлән б-н чигелгән чигү бизәү әйберләре һ.б. күрсәтелә. Кукмара тарихына багышланган бүлектә документлар, фоторәсемнәр, 19–20 йөзләрдәге этнография һәм көнкүреш әйберләре урын алган; 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар өйләренең интерьер өлешләре торгызылган. Бөек Ватан сугышына багышланган бүлектә «Үлем үзәне»ннән (Новгород өлкәсендә 2 нче удар армия сугышлар алып барган урын) һәм «Нева мәйданчыгы»ннан (Ленинград өлкәсе) кайтарылган совет һәм немец солдатларының сугыш кирәк-яраклары, коралларының аерым өлешләре куелган. Шулай ук Кукмара р-нында туган Сов. Союзы Геройлары — С.А.*Әхтәмов*, П.Е.*Воробьёв*, И.Г.*Газизуллин*, Н.С.Савин фоторәсемнәре, бүләкләренең күчермәләре бар. Музей фондында Соц. Хезмәт Геройлары Р.И.*Зарипов*, Ә.Ж.*Җиһаншин*, Г.Г.Идрисов, Л.Н.Козлов, В.С.*Мәүликов*, К.Ф.*Шакиров*; язучылар Л.Ф.*Ихсанова*, М.Н.*Насыйбуллин*; шагыйрьләр Р.Г.*Бәшәр*, Г.В.*Морат*; әдәбият белгече Ф.Г.*Галимуллин* һ.б.ның документлары, фоторәсемнәре тупланган. Аеруча кыйммәтле экспонатлар: археол. (100 саклау берәмлеге) һәм палеонтология (20 саклау берәмлеге) коллекцияләре, 19 йөздә бертуган Комаровлар ф-касында эшләнгән чигүле итекләр (3 пар), 19 йөзнең 2 нче яртысында Володиннар остаханәсендә ясалган комганнар һәм самоварлар коллекцияләре (20 саклау берәмлеге), татар, рус, удмурт, марийларның өс киемнәре (20 саклау берәмлеге) һ.б. Ел саен Халыкара музейлар (18 май), Балаларны яклау (1 июнь) көннәре үткәрелә.



Кукмара тавы.

**КУКУРУ́З**, маис (Zea mays), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Җирдәге иң борынгы культуралы үсемлекләрнең берсе, үзеннән-үзе чәчелеп үсүгә һәм кыргыйлануга сәләтсез. Җылылык, яктылык яратучы язгы үсемлек, корылыкка чыдам культура. Чыгышы — Үзәк һәм Көньяк Америка. Европага 15 йөз ахырында китерелә. Бер өйле үсемлек, чәчәк оешмасы аерым җенесле, сабаклары туры, 50–80 *см* дан 5–6 *м* га кадәр биеклектә, кайбер очракта тармаклана, тамыры 100–150 *см* тирәнлеккә китә. Яфраклары чиратлашкан, киң кыяклы, дулкынлы, өске өлеше төкле. Ата чәчәк оешмасы (сабак очында) — себеркәч; ана чәчәк оешмасы (яфрак куентыгында) — катлаулы башак (чәкән) 4–50 *см* озынлыкта, диаметры — 7–10 *см*, авырлыгы 30–50 *г*. 1–2, сирәгрәк 3 чәкәне тулысынча үсеп өлгерә. Җимеше — бөртекчә.



К. — төрле кулланыштагы үсемлек. Азык (он, ярма, кукуруз таякчыклары, Е витаминына бай кукуруз мае һ.б.), крахмал-патока, сыра ясау, спирт сәнәгатендә кулланыла. Бөртеге катнаш азык сәнәгате өчен чимал һәм концентрацияләнгән терлек азыгы буларак файдаланыла. Җимешлегенең чәчләре медицинада кулланыла. Татарстанда К. — төп силос культурасы, 1954 елдан игелә. Органик һәм минераль ашламалар керткәндә, кара, соры урман, аксыл-коңгырт һәм кәсле-көлсу туфракларда югары уңыш бирә. К.ны кырда һәм терлек азыгы чәчүлекләрендә үстерәләр. Элгәрләре — көзге бөртекләләр, бөртекле-кузаклылар, сызма культуралар һәм язгы бодай. 6–12 *см* тирәнлектә чәчелә. К.ны — бөртеге тулысынча өлгергәч, ә силос өчен балавыз сыман өлгерү чорында җыялар. Республикада силос һәм яшел терлек азыгы өчен чәчүлекләр мәйданы 126 мең *га* тәшкил итә. Яшел массаның уңышы 1 *га* дан 212 *ц* (2004). 1993 тән «Пионер» Америка фирмасының бөртекләләр технологиясе буенча үстерелә. ТРда районлаштырылган кукуруз гибридлары: «Молдавский 215 АМВ» (1990), «Росс 144 СВ», «Коллективный 181 СВ», «ТОСС

205 МВ» (барысы да — 1993), «Росс 197 АМВ», «Бемо 182 СВ», «Молдавский 238 АСВ» (барысы да — 1995), «Кубанский 247 МВ», «Коллективный 172 МВ», «Каскад 282 МВ» (барысы да — 2001). Корткычлары — чыбык личинкалар һәм ялган чыбык личинкалар, ябалакчыклар, сабак күбәләге һ.б.; авырулары — куыклы һәм тузанлы кисәү гөмбәсе, фузариоз, нигроспороз, чәкәннең агаруы һ.б.

**КУЛА́ГИН** Владимир Константинович (1.4.1937, Сталинград өлкәсенең Енотаевка р-ны Енотаевка а. — 18.6.2004, Казан), сәнәгый җитештерүне оештыручы, ТРның, РФнең атказ. машина төзүчесе (1991, 1993), ТРның атказ. төзүчесе (1995). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1982). Хезмәт эшчәнлеген 1956 елда Казан резина-техник эшләнмәләр з-дында металл үрүче буларак башлый. 1957–59 да, 1966–2004 тә (бүленеп) «Теплоконтроль» АҖдә эшли, цех башлыгы урынбасары, цех, производство башлыгы, ген. директор (1981–2004). 1959–66 да комсомол эшендә: ВЛКСМның Идел буе райкомы инструкторы. Татарстан өлкә ком-тында оештыру бүлеге мөдире урынбасары, мөдире. К. җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция һәм яңа техник җиһазлау уздырыла, прогрессив технологияләр гамәлгә кертелә, яңа төр продукция җитештерелә башлый, элек эшләп чыгарыла торган продукция камилләштерелә. Хезмәткәрләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга зур игътибар бирә (күп фатирлы торак йортлар, 200 дән артык коттедж, йөзү бассейны, ашханә һ.б. төзелә). 1989–91 дә СССР халык депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КУЛАКЛА́Р**, 19 йөздә — 20 йөзнең 30 нчы елларында крәстияннәрнең социаль катлауларга бүленүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән авыл буржуазиясе. Баштарак Россиядә кулаклар дип кабат сату максаты б-н авылларда халыктан киндер, эрләнгән җеп, җитен, киндер сүсе, сарык тиресе, дуңгыз кылы, май, терлек мае һ.б. сатып алу б-н шөгыльләнгән вак авыл сәүдәгәрләрен, базарларда һәм пристаньнарда икмәк, ит һәм балык сәүдәсендә арадашчылык иткән сатучыларны («маклаклар», «прасоллар») атыйлар. В.И.Дальнең «Аңлатмалы сүзлеге»ндә «кулак» сүзенә рус телендә «скупец», «скряга», «жидомор», «кремень», «крепыш», «торгаш» һ.б. мәгънәләр китерелә; «үзенең акчасы юк; ялган тормыш белән, санаганда һәм үлчәгәндә алдау хисабына яши», дип аңлатма бирелә. Урта хәлле һәм ярлы крәстияннәр б-н чагыштырганда, К. эре җир һәм җитештерү чаралары милекчеләре, ростовщиклар, арендачылар булалар, үз хуҗалыкларында батраклар һәм авылның ярлы, урта хәлле халкы хезмәтеннән файдаланалар. Культура дәрәҗәсе һәм көнкүреш җәһәтендә алар крәстияннәрдән аз аерылалар, ш.у. крәстиян физик хезмәтендә катнашалар. Крәстияннәрнең аз өлешен тәшкил итәләр. Шул ук вакытта К. игенчелек өлкәсендә иң күпсанлы капиталистик эшмәкәрләр катлавы булалар.

Товарлыклы җитештерү үсешенә бәйле рәвештә, К. авыл җирендә капиталистик мөнәсәбәтләргә кадәрге дәвердә үк барлыкка килә башлыйлар, сыйныф буларак реформа чорында оешалар. Крәстияннәр, алпавытлар һәм казна җирләрен «эләктерү» нәтиҗәсендә, К. үз хуҗалыкларында зур җир биләмәләре туплыйлар. 1880 еллар башында Казан губернасында К. өлешенә крәстиян хуҗалыкларының 12% ы (ш.и. 5,3% ы — татарлар) туры килә. К. товарлыклы ашлыкның 40–50% ын җитештерәләр, а.х. машиналарының һәм хезмәт коралларының күпчелек өлеше, атлар баш санының яртысы аларның хуҗалыкларында була; алар сәүдә оешмалары һәм сәүдә-сәнәгать пр-тиеләрен билиләр, шәрабханәләр һәм вак-төякләр сату кибетләре тоталар, ростовщиклык б-н шөгыльләнәләр. Ләкин К.ның мөмкин кадәр күбрәк җир мәйданнарына, җитештерү чараларына хуҗа булуга омтылулары крепостнойлык калдыклары — алпавыт һәм авыл җәмгате җирбиләүчелеге — каршылыгына юлыга, бу К.да дворян-алпавытларга һәм авыл ярлыларына карата дошманлык мөнәсәбәтләре тудыра. 1905–07 еллардагы рев-циядән соң, алпавыт җирбиләүчелеген кагылышсыз калдырып, К.да үзе өчен яңа социаль терәк булдырырга омтылып, хөкүмәт аларны ныгыту һәм тиз арада крәстиян җәмгатен таркату юлына баса (к. *Столыпинның аграр реформасы*). Реформа барышында алпавыт һәм крәстияннәрнең җирләрен сатып алу юлы б-н К. актив рәвештә үз җир биләмәләрен киңәйтә, авыл җәмгатеннән отрублар һәм хуторлар булып аерылып чыга, җитештерү кораллары булдыра, авыл җирендә эшкәртү пр-тиеләре ача башлый.

Окт. рев-циясеннән соң К. барлык крәстияннәр б-н бергә алпавыт җирбиләүчелеген бетерүне (1918 нең җәенә кадәр), хутор-отруб системасын таркатуны яклап чыгалар. Яхшы оешканлык һәм йөк транспорты б-н тәэмин ителү нәтиҗәсендә К. иң уңдырышлы җирләрне, алпавытлардагы хезмәт коралларын һәм терлекләрне тартып алалар. Алар ш.у. авыл, волость советларына һ.б. вәкиллекле органнарга үтеп керәләр, аларның эшен үз мәнфәгатьләренә буйсындыралар. Зур икмәк запасларына хуҗа булган хәлдә, К. актив рәвештә большевикларның икмәк монополиясенә каршылык күрсәтәләр, ирекле сәүдәне торгызырга, яңа хакимиятне «җирне социализацияләү»дән баш тартырга мәҗбүр итәргә омтылалар. 1918 нең җәй–көзендә алар крәстияннәрнең Сов. хакимиятенә каршы чыгышларын җитәклиләр. Казан губернасы буйлап крәстиян чуалышлары дулкыны уза. Гражданнар сугышы чорында К. советларга каршы көчләрнең төп таянычына әвереләләр. Аларга каршы көрәштә *ярлылар комитетлары* (комбедлар) һәм азык-төлек отрядлары зур роль уйный. 1919 да гамәлгә кертелгән *продразвёрстка* авылда, беренче чиратта К.дан, ирексезләп артык икмәкне җыюга юнәлдерелә. К.га көчле һөҗүм ясала, хуҗалыкларының бер өлеше тартып алына. Комбедлар, азык-төлек отрядлары, сов. салым органнары эшчәнлеге (контрибуцияләр, гадәттән тыш революцион салымнар һ.б.) нәтиҗәсендә К. җир биләмәләренең, җитештерү чараларының, мөлкәтләренең күпчелек өлешеннән мәхрүм ителәләр. Шул ук вакытта ярлыларга һәм урта хәллеләргә алпавытларның һәм К.ның җирләрен бушлай өләшү, күп чәчүлекле хуҗалыкларның тагын да вагая баруы, икмәк һәм а.х. чимал базарларының кискен азаюы, гомумән, крәстияннәрнең, аерым алганда К.ның, җирдән файдалану структурасында зур үзгәрешкә китерә: күп чәчүлек җирле хуҗалыклар төркеме — 11,4% тан (1917) 0,7% ка (1922), чәчүлексез хуҗалыклар 13,8% тан 5,3% ка кадәр кими. Комбедлар эшчәнлеге чорында кулак хуҗалыкларының нисбәти өлеше 13% тан 4,5% ка кадәр кими. Сов. дәүләтенең К.га карата булган сәясәте нәтиҗәсендә кулак хуҗалыкларының күбесе урта хәллеләр төркеменә күчә, ләкин аларда капиталистик типтагы хуҗалыкларга хас төп сыйфатлар саклана.

*Яңа икътисади сәясәткә* күчү б-н, авыл халкының социаль катлауларга таркалуы җирлегендә яңадан кулак хуҗалыклары үсә башлый. 1922–25 тә Татарстанда аларның саны 0,7% тан 4,8% ка кадәр арта (ихтимал, алар исәбенә таза тормышлы крәстияннәрнең дә бер өлеше кергәндер). 1927 дә Татарстанда кулак хуҗалыклары 2,4% исәпләнә. К.га чәчүлек җирләрнең 14% ы, атлар санының 25% ы туры килә. Татар крәстияннәре арасында К.ның өлеше зур булмый, татар К.ының күпчелеге сәүдә эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. Ләкин К. үзләренең рев-циягә кадәрге позицияләрен торгыза алмыйлар. Җирне национализацияләү нәтиҗәсендә авыл җирендә капитал туплауның төп чыганагы юк ителә. Сов. хакимияте К.ны чикләү һәм кысрыклап чыгару сәясәте уздыра, аларга зур салымнар сала, җирне арендалау һәм эшче көчләр яллау күләмен чикли, аларны сәяси хокуклардан мәхрүм итә һ.б. Икенче яктан, К.ның башкаларны изү мөмкинлекләре дәүләтнең ярлыларга һәм урта хәллеләргә икътисади ярдәме б-н чикләтелә, нәтиҗәдә хезмәт крәстияннәренең хуҗалыклары ныгый. Дәүләтнең адреслы ярдәме б-н авыл халкының бу категориясенең җитештерү чаралары б-н тәэмин ителеше көчәя: 1920 елларның 1 нче яртысында сөрүлек җирләрнең мәйданы 22% ка, сабаннар саны 77% ка, атлар саны 23% ка, мөгезле эре терлекнең баш саны 8% ка, сарыклар саны 57% ка арта. Хәзер капитал туплауда төп рольне, рев-циягә кадәр булганча, җирләрнең бер милеккә җыелуы түгел, эш терлекләренең, а.х. машиналарының һәм хезмәт коралларының бергә тупланы уйный. Ярлылар һәм урта хәллеләр К.дан һәм таза тормышлы крәстияннәрдән бөлдергеч шартларда арендага эш терлекләре һәм инвентарь алырга мәҗбүр булалар. Җитештерү чараларын арендалауга нигезләнгән мөнәсәбәтләр крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүгә кадәрге дәвердә авыл җирендә аеруча киң тарала. 1925 нең язында крәстиян хуҗалыкларын тикшерү мәгълүматлары буенча, хуҗалыкларның 51,5% ы — үзенең а.х.

инвентареннан, 42,9% ы — арендага алынганнан, 5,6% ы — катнаш инвентарьдан; 54,5% ы — үзенең эш терлекләреннән, 44,9% ы — арендага алынганнан, 1,6% ы катнаш эш терлекләреннән файдалана. Гадәттә, авыл җирендә җитештерү чараларын арендага бирү «хезмәт күрсәтү» рәвешендә була, ул хәлсез хуҗалыкларда чәчүлек мәйданнарның кимүенә, көчле хуҗалыкларда аларның артуына китерә. 1927 дә К. авыл ярлыларының һәм хәлсез урта тормышлыларның 800 мең дис. чамасы сөрүлек җирләрен арендалыйлар. Югары керем китерүче катлаулы а.х. машиналарын җитәрлек күләмдә сатып алу мөмкинлекләре булмаганга күрә, К. үз хуҗалыкларын ярлылардан өстәмә җир кишәрлекләре тартып алу юлы б-н киңәйтергә омтылалар. Бу ярлы крәстияннәрне яшерен изүгә җирлек тудыра. К.да барлыгы 10 меңләп батрак даими эшли. Ләкин шул ук вакытта К. физик хезмәттән тулысынча читләшмиләр: алар, ярлы хуҗалыклар вәкилләренә караганда, төрле хуҗалык эшләренә үзләренең эш вакытын 2,1 тапкырга күбрәк сарыф итәләр, шул сәбәпле ярлылардан 3,5 тапкыр артыграк тулай керем алалар. Зур күләмдә җитештерү чараларына хуҗа булу, җир арендалау, батраклар һәм ярлылар хезмәтеннән файдалану, ростовщиклык кредиты ярдәмендә аларны бәйлелеккә төшерү нәтиҗәсендә 1920 еллар уртасында кулак хуҗалыклары шактый ныгый, Сов. хакимиятенең авыл җирендәге сәясәтенә каршылык күрсәтүләре көчәя. Сов. хөкүмәтенең крәстияннәрне җәберләүче сәясәтенә каршы тору, үзләренең икътисади һәм сәяси мәнфәгатьләрен яклау өчен К. һәм урта хәллеләрнең аеруча актив өлеше «крәстияннәр берлеге»н оештыру таләбе б-н чыгалар. К. вәкиллекле органнарга үтеп керәләр, авыллардагы кооперация оешмаларына контроль урнаштырырга омтылалар, колхозларга каршы актив агитация алып баралар, үзләрен чикләү һәм кысрыклап чыгару сәясәтен өзү максатында төрле иҗтимагый-сәяси һәм икътисади чаралар уздыралар. 1927 ел ахырында, дәүләткә ныклы (базарча булмаган, үзләре өчен зыянлы) бәяләр буенча икмәк сатудан баш тартып, К. урта хәлләләр б-н бергә «икмәк стачкасы» оештыралар. Крәстияннәрнең икътисади каршылыгына каршы көрәшү өчен 1927 нең 20 декабрендә Сов. хөкүмәте илдә гадәттән тыш хәл кертә. К. законнан тыш дип игълан ителә. 1928–29 да, икмәк әзерләү кризисы чорында, К.ның хуҗалыкларын, ягъни икмәкне, фураж, терлекләр, җитештерү чаралары, кредитлар һәм акчалар, йорт милке һәм хуҗалык корылмаларын тартып алу буенча киң колачлы чаралар уздырыла, җирне һәм җитештерү чараларын арендалауга, эшче көчләр яллауда чикләүләр катгыйландырыла, салымнар һ.б. теркәлгән җыемнарның күләмнәре арттырыла, шәхси салым гамәлгә кертелә. Тоташ рәвештә *крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* К.ны чикләү һәм кысрыклап чыгару сәясәтен аларны сыйныф буларак бетерү сәясәтенә күчү өчен нигез була. 1920 еллар ахырында — 1930 елларда, колхоз-совхоз системасын ирексезләп кертү барышында, колхозлашу хәрәкәтенә каршы аяусыз көрәшүләренә (колхозга каршы агитациядән башлап, активистларны үтерү, колхоз милкенә ут төртү, фетнәләр оештыру һ.б.) карамастан, К. бетерелә, тартып алынган матди байлыклар (икмәк, терлекләр, җитештерү чаралары, милек һ.б.) ярлы крәстияннәр һәм батраклар взносы сыйфатында *колхозларның* бүленмәс фондына тапшырыла (к. *Кулакларны йорт-җирләреннән куу*).

*Әд.:* А л е к с е е в с к и й А.П. К вопросу о расслоении крестьянства в Татреспублике // Труд и хозяйство. 1926. № 1; К о л о с о в А.М. К вопросу расслоения крестьянства Татреспублики // Труд и хозяйство. 1926. № 5; Социальный слой крестьянства в Татреспублике // Труд и хозяйство. 1926. № 6/8; Е р м о л а е в В.М. Баланс рабочего времени крестьянской семьи ТР // Труд и хозяйство. 1926. № 9; Л е в и т и н А. Крестьяне арендаторы государственных земель в Татреспублике // Труд и хозяйство. 1927. № 7; Н о в и ц к и й Л. Батраки в Татреспублике: Численность и состав // Труд и хозяйство. 1928. № 7; Ф ё д о р о в а Н.А. Сельское население Среднего Поволжья накануне коллективизации (опыт социально-демографического изучения). К., 1990.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КУЛАКЛАРНЫ́ ЙОРТ-ҖИРЛӘРЕННӘ́Н КУУ́**, авыл халкыннан җитештерү чараларын (ш.и. җирне) көчләп тартып алуның бер төре; 1918–53 елларда СССР да *кулакларны* сыйныф буларак бетерү максатында уздырыла. Баштарак, «*хәрби коммунизм*» елларында, К.й.-җ. к. «капиталга кызыл гвардия һөҗүме» рәвешендә бара, таза тормышлы крәстияннәрнең һәм сәүдә-сәнәгать оешмалары хуҗаларының милке өлешчә тартып алына. Россия кулаклары Окт. рев-циясенә кадәр биләгән 50 млн. *га* җирдән (барлыгы 80 млн. *га*), җитештерү чараларының зур өлешеннән мәхрүм ителә. Казан губернасында сов.-партия структуралары күрсәтмәсе буенча таза тормышлы крәстияннәрнең, хосусый сәүдәгәрләрнең һәм эшмәкәрләрнең җир биләмәләренең һәм җитештерү чараларының, сәнәгать һәм сәүдә оешмаларының бер өлеше *ярлылар комитетлары* тарафыннан конфискацияләнә (к. *Национализацияләү*). Бер үк вакытта, «хәрби коммунизм» елларында, аларга, «ят» (капиталистик) элементлар буларак, төрле гадәттән тыш (революцион) салымнар (контрибуцияләр) салына. *Яңа икътисади сәясәткә* — нэпка күчү б-н (1921 нең марты), кулакларга карата көч кулланулы сәяси-адм. һәм икътисади чаралар туктатылып тора, һәм 1920 еллар ахырында, хакимиятләр нэп принципларыннан баш тартып, крәстияннәр тоташтан крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерүгә керешкәч, бу чаралар яңадан башлана. 1930 да, К.й.-җ.к. сәясәтен көчәйтү максатында, махсус закон актлары эшләнә, алар ВКП(б) ҮК Политбюросы (1930 ел 30 гыйнвар), СССР ҮБК һәм ХКС (1930 ел 1 һәм 4 февраль) карарларында һәм күрсәтмәләрендә чагылыш таба. Крәстиян хуҗалыкларын тоташ күмәкләштерү барган төбәкләрдә (ш.и. Татарстанда) җирне арендага алу һәм яллы хезмәт куллану тыелгач, җирле органнарга кулакларның милкен тартып алу турындагы мәсьәләне хәл итү хокукы бирелә, кулак хуҗалыкларын 3 категориягә бүлү күздә тотыла, беренче категориягә («советларга каршы һәм контрреволюцион көрәштә актив катнашучылар» дип тамгаланганнарга) карата рәхимсез репрессия чаралары (ату, төрмәләргә һәм концлагерьларга ябу, махсус торулыкларга күчерү, җитештерү чараларын һәм милекне тулысынча тартып алу һ.б.) кулланырга тәкъдим ителә. Икенче категориягә (ярымкапиталистик яки ярымалпавытчыл типтагы, икътисади яктан куәтле кулак хуҗалыкларына) карата җитештерү чараларыннан тулысынча мәхрүм итү һәм СССР ның ерак төбәкләренә (Себергә, Соловкига, Казакъстанга һ.б. җирләргә) сөрү карала. Кулакларның төп массасын (75–80 %) — яллы хезмәттән файдаланган, куәтләре азрак хуҗалыклар, вак пр-тиеләр һәм сәүдә оешмалары тоткан, актив рәвештә сов. хакимиятенә каршы чыкмаган затларны — шул ук адм. район чикләре эчендә, районның җир б-н тәэмин ителү дәрәҗәсеннән чыгып (һәр хуҗалыкка 1,5–2 *га* чамасы), кагыйдә буларак, уңдырышсыз һәм уңайсыз җирләргә күчерү күздә тотыла. 1930 ның 16 февралендә ТАССР ҮБКның һәм ХКСның «Татарстанда кулакларны сыйныф буларак бетерү турында» дип аталган карары чыга. Кулакларны үз хуҗалыкларын яллы хезмәттән файдаланып алып бару мөмкинлегеннән мәхрүм итү, колхозларны аларның корткычлык эшчәнлегеннән саклау, авыл хуҗалыгын күмәкләштерүне уңышлы уздыру максатында аеруча «явыз» кулакларны республикадан читкә сөрергә күрсәтмә бирелә. Карарда ш.у. «кулакларның милкен конфискацияләү авыл советлары, колхозлар һәм батрак-ярлылар төркемнәре вәкилләренең мәҗбүри катнашында район башкарма ком-тларының вәкаләтле вәкилләре тарафыннан уздырылырга тиеш» дип билгеләп үтелә. Милекне барлап-язып алу, бәяләү һәм саклау авыл советларына йөкләнә. Тартып алынган җитештерү чаралары һәм милек (аларның кулак хуҗалыкларының дәүләт һәм кооперация оешмаларына бурычларын каплауга киткән өлешеннән тыш) — батракларның һәм ярлыларның пай взнослары сыйфатында колхозларның бүленмәс фондларына, торак һәм җитештерү корылмалары авыл советларының һәм колхозларның җәмәгать һәм хуҗалык ихтыяҗларына файдалануга тапшырыла. Партия-сов. структураларының карарлары һәм күрсәтмәләре гамәлгә кертелгәннән соң, Татарстанда К.й.-җ.к.га 13668 хуҗалык (40 меңнән артык кеше) дучар ителә. «Правда» г-тасының 1930 елгы 1 март санында И.В.Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе басылып чыккач, йорт-җирләреннән куылган крәстияннәрнең бер өлешенә (20–30 % чамасы) хокуклары һәм өлешчә милекләре кире кайтарыла. 1931 дә өстәмә рәвештә 5 меңләп хуҗалыкта К.й.-җ.к. уздырыла. Якынча исәпләүләр буенча, 1930 еллар уртасына Татарстанда 20 меңнән артык хуҗалык К.й.-җ.к.га дучар ителә; тулы булмаган мәгълүматлар буенча, колхозларның бүленмәс фондларына кулакларның 9 млн. сумнан артык суммага бәяләнгән милке, 14 мең баштан артык ат, 6 меңләп сы-

ер, 5 мең баштан артык мөгезле вак терлек һ.б. тапшырыла.

К.й.-җ.к. сов. һәм партия хакимият структуралары, ярлылар төркемнәре һәм колхоз активы вәкилләре катнашында иҗтимагый кампания буларак уздырыла. Ләкин теге яки бу затка карата К.й.-җ.к. чаралары куллану турындагы мәсьәлә, кагыйдә буларак, партия яки колхоз активында («авыл өчлеге»ндә) карала; К.й.-җ.к. буенча контроль саннар урыннарга югарыдан төшерелә. Мәсәлән, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросының 1930 ның 10 февралендә кабул ителгән карарында: «ТРда категория буенча якынча 4% кулакларны, ягъни 22000ләп хуҗалыкны теркәргә, шулардан 9000 ләп хуҗалыкны беренче ике категория буенча билгеләргә» дип күрсәтмә бирелә (чынлыкта 1927 дә Татарстанда кулаклар исемлегендә 2,4% крәстиян хуҗалыгы исәпләнә). Өлкә ком-ты карары «үтә яшерен» язу б-н барлык кантоннарга, райкомнарга җибәрелә, анда волость башкарма ком-тларына һәм авыл советларына җан башлары күрсәтелгән кулак хуҗалыклары исемлекләрен төзүне — 10 мартка, 3 нче категорияле кулакларга җирләр билгеләүне 15 мартка төгәлләргә кушыла. 1930–31 дә республикадан 9424 кулак гаиләсе төрле төзелешләргә, рудникларга, шахталарга, урман эшләренә, промыселларга, ш.у. махсус билгеләнгән — кеше яшәмәгән һәм аз халыклы буш җирләргә (концлагерьларга, махсус торулыкларга һ.б. урыннарга) сөрелә. Кулак гаиләләрен сөрү тәртибе ВКП(б)ның директивасында тәгаенләнә. Директивада сөрелүче һәр хуҗалыкның өч айлык азык-төлек (гаиләнең һәр әгъзасына 2 потлап он, 2–3 пот бәрәңге, 15 кадак ярма), эш кораллары минимумы (балта, сәнәк, көрәк һ.б.) б-н тәэмин ителергә, һәр 5 хуҗалыкка дирбияләре һәм ике атналык фураж запасы б-н 1 ат бирелергә тиешлеге күрсәтелә.

Татарстанда К.й.-җ.к. процессы крәстияннәрнең киң массаларына карата репрессия чаралары куллану б-н бергә алып барыла (к. «*Әлмәт эше*»). Кулакларга каршы көрәш чаралары еш кына урта хәллеләргә, кайбер очракларда колхозларга керүдән, «артык» ашлыкны тапшырудан, индивидуаль үзара салымнарны түләүдән баш тарткан ярлыларга, ш.у. сов. һәм партия хакимиятләренең социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси гамәлләре б-н риза булмаган затларга каршы юнәлдерелә. Чынлыкта кулак хуҗалыкларының нисбәте 2–3% тан артмаса да, нәтиҗәдә Татарстанның кайбер районнарында йорт-җирләреннән куылган крәстиян хуҗалыкларының исәбе 10% ка җитә һәм аннан да арта (бу күрсәткечнең үсүе «түбәндәгеләр инициативасы» б-н аңлатыла, К.й.-җ.к.ның югарыдан төшерелгән контроль саннарына арттырылып үтәлгән процентлар б-н җавап бирәләр). К.й.-җ.к. процессында ш.у. крәстияннәргә карата мәхкәмә санкцияләре дә кулланыла. 1931 дә ТАССР Баш мәхкәмәсендә 7510 кешенең эше карала, шулардан 4793 кеше, ш.и. 1276 кулак, 527 таза тормышлы крәстиян, «хезмәт төркеме затлары»ннан (урта хәллеләр, ярлылар, колхозчылар һ.б.) 400 кеше хөкемгә тартыла. Үз адм. районнарында калган кулак хуҗалыкларына аерым колхозга керергә рөхсәт бирелми, аларга икътисади яктан көч җитмәслек индивидуаль үзара салым салына. ТАССРның 44 районыннан алынган мәгълүматлар буенча, 1931 дә индивидуаль салым түләргә 5761 крәстиян хуҗалыгы дучар ителә, 1932 нең февраленә алардан казнага 1388 мең сум иминият түләүләре, 1042 мең сум үзара салым акчалары керә. 1931 дә 1 колхозчы хуҗалыгына — уртача алганда, 3 сум чамасы, 1 аерым хуҗалыкка — 30 сумнан артык, 1 кулак хуҗалыгына 314 сум чамасы а.х. салымы туры килә. Республикада К.й.-җ.к. процессы, башлыча, 1930 елларның 1 нче яртысында тәгәлләнә; ул авыл җирендәге җитештерүче көчләргә зур зыян китерә: асылда авыл җәмәгатендә урта сыйныфның эшкә зур сәләтле вәкилләре юкка чыгарыла. 1953 кә кадәр Татарстанда төрле репрессияләргә (ш.и. К.й.-җ.к.га) 350 меңләп кеше дучар ителә. 1930 еллар ахырында Татарстан терр-ясендә яшәп калган, әмма йорт-җирләреннән куылганнарның зур өлешенә колхозларга керү мөмкинлеге бирелә, ТАССРның 1937 елгы Конституциясе нигезендә аларга гражданлык хокуклары кайтарыла. Ш.у.к. *Репрессияләр*.

Чыг.: Коллективизация сельского хозяйства Татарской АССР (1927–1937): Док. и материалы. К., 1968; Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2007–09. Т. 19–23.

*Әд.:* Залялов А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Фролов Н. Коллективизация: помнить, чтобы не повторилось // Татарстан. 1993. № 9; Фоминых Г. «Безумная жестокость при раскулачивании...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1995. Май.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**КУЛАЛА́ЕВ** (чын фамилиясе Ишморатов) Әхмәт (1887–1924), драма актёры, педагог; проф. татар театрын башлап җибәрүчеләрнең берсе. Сәхнә эшчәнлеген И.Б.Кудашев-Ашкадарский труппасында башлый. Характерлы комедия актёры, К.Камали («Бәхетсез егет», Г.Камал), Рәхим («Оят, яки күз яше», Я.Вәли), Госман («Яшь хатын», Д.Таҗдаров), Галиәкбәр хәзрәт («Помада мәсьәләсе», И.Богданов) рольләре б-н таныла. Шулай ук Сираҗетдин («Банкрот», Г.Камал), Миллер («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) кебек зур әһәмияткә ия рольләр дә башкара. 1913 елдан соң мәктәпләрдә пед. эшчәнлек алып бара, һәвәскәр театр коллективлары б-н җитәкчелек итә. Татар проф. театрының тәүге адымнары сурәтләнгән «Артистлар» пьесасының авторы.

**КУЛЕ́ША** Андрей Степанович (12.10.1874, Смоленск губ. Белый ш. — 14.6.1910, Тобол губ. Ялуторовск ш.), иҗтимагый-сәяси хәрәкәттә катнашучы. Дворяннар нәселеннән. 1894–97 елларда Мәскәү, 1899–1905 тә Казан ун-тлары студенты. 1899–1901 дә Казан с.-д. төркеме әгъзасы, шәһәрдәге укучы яшьләр арасында пропаганда алып бара. 1901–03 тә берничә мәртәбә кулга алына, ун-ттан куыла. 1904 тә РСДРПның Казан ком-тын яңадан торгызуда катнаша. 1905 тә студентлар с.-д. фракциясе әгъзасы, Алафузовлар пр-тиеләрендә митинглар, ун-тта җыеннар үткәрә, «Волжский листок» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1906 да Казаннан озатыла, Екатеринбург, Мәскәү шәһәрләрендә, Тобол губернасында иҗтимагый-сәяси эшчәнлек б-н шөгыльләнә. Карагруһчылар тарафыннан үтерелә.

*Әд.:* Борцы за счастье народное. К., 1967; Долгов Е.Б. Из истории Казанской социаль-демократической организации в 1900–1903 гг. // Социалистический строй: Вопросы теории и исторического опыта. К., 1990.

*Е.Б.Долгов.*

**КУЛИ́** (Кулиев) Ибраһим Габделвахит улы (12.12.1885, Сембер губ. Буа ш. — 1936), тәрҗемәче, журналист. 1901–04 елларда «Мәрҗания» мәдрәсәсендә укый. 1917 гә кадәр Кәримовлар типографиясендә, «Казан мөхбире» г-тасында корректор, «Йолдыз» г-тасында җаваплы сәркәтип, «Кояш» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли; татар теле мәсьәләләренә караган мәкаләләре вакытлы матбугат битләрендә даими басылып тора. 1917 дә *Мөселман социалистлар комитеты* сәркәтибе. 1921–36 да Татарстан дәүләт нәшриятында фәнни сәркәтип. «Кызыл байрак», «Эш», «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» г-талары б-н хезмәттәшлек итә; аларда И.Терегулов, Х.Ямашев, М.Вахитов, Г.Кариевлар турында мәкаләләр бастыра. «Татарча-русча сүзлек»не (1927; М.Корбангалиев һәм Р.Газизов б-н берлектә), «Татар теленең орфография сүзлеге»н (1930; И.Рәми б-н берлектә) төзүдә катнаша. 1914 тә М.А. Кирьяковның «Шәфкать туташы» («Сестра милосердия»), 1916 да билгесез авторның «Тормыш юлында» («На пути жизни»), 1917 дә С.Шиманскийның «Кан» («Кровь») пьесаларын («Сәйяр» труппасы тарафыннан уйнала), ш.у. А.Д.Лавров, Г.Дригилли, А.Афиногенов пьесаларын татарчага тәрҗемә итә. Репрессияләнә, Караганда шәһәре төрмәсендә үлә. Соңыннан аклана.

*Әд.:* Шамов А. «Гомеремне газета эшенә багышладым...» // Социалистик Татарстан. 1983. 19 авг.; Ибраһимова Ф. Ул калдырган эз (журналист И.Кули) // Социалистик Татарстан. 1986. 3 февр.

*Ф.Ибраһимова.*

**КУЛИКО́ВА** Лидия Ивановна (14.4.1956, Югары Ослан р-ны Ключище а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2002), проф. (2003), ТРның атказ. икътисадчысы (2005). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли, бухгалтерлык исәбе каф. профессоры (2001 елдан), финанс хисапчылыгы каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре озак вакытка нисбәтле матди активларга бухгалтерлык исәбе алып бару, халыкара финанс хисапчылыгы стандартлары кысаларында Россиядә бухгалтерлык хисапчылыгын камилләштерү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Учёт основных средств: современная концепция и тенденции развития. К., 2000; Налоговый учёт. М., 2003; Бухгалтерское дело: Уч. пособие. М., 2005 (автордаш); Учётная политика организации: Новое решение. М., 2010; Финансовый учёт: Уч.пособие. М., 2011.

**КУЛИКО́ВО КЫРЫ́ СУГЫШЫ́** («Дондагы кырылыш», «Мамай явы»), 1380 елның

8 сентябрендә Алтын Урданың *бәкләр бәге Мамай* һәм Мәскәүнең бөек кенәзе Дмитрий Иванович гаскәрләре арасында булган зур сугыш. К.к.с. турындагы мәгълүматлар кыскача (Рогожск елъязмачысы, Симеон һәм Мәскәү — Акад. елъязмалары составына керә) һәм тәфсилле (беренче София һәм дүртенче Новгород елъязмаларында) елъязма хикәятләрендә, «Задонщина» шигъри повестенда, «Мамай явы турында хикәят» эпик повестенда, ш.у. Дмитрий Ивановичның (к. *Дмитрий Донской*) һәм Сергий Радонежскийның тәрҗемәи хәлләрендә сакланган. 14 йөз ахырында — 15 йөз башында язылган хикәят арада иң борынгысы һәм иң ышанычлысы санала; тәфсилле хикәят 15 йөз уртасында барлыкка килә. «Задонщина»ның язылу вакыты төгәл ачыкланмаган (14 йөз ахыры), хикәят, елъязмалар материалларын файдаланып, «Игорь полкы турында җыр» нигезендә язылган. «Мамай явы турында хикәят» 15 йөз ахырында — 1520–30 елларда барлыкка килә; ул — елъязмалар текстлары нигезендә төзелгән яугирләр хикәяте; анда урта гасырлар рыцарьлар романнарыннан өзекләр кертелгән (батырларның сугыш алдыннан бергә-бер бәрелеше, гаскәр башлыгының гади яугир сугыш киемнәрен киюе, яшерелгән полк — постырма).

Сугыш алдыннан Алтын Урдада 1360–80 елларда хан тәхете өчен *Җүчиләр* нәселенең *Ак Урдадагы* һәм *Күк Урдадагы* тармаклары арасындагы үзара бәрелешләр б-н бәйле вакыйгалар (к. *Алтын Урдада тәхет чуалышлары*) булып уза. 1360 тан чынлыкта Ак Урда б-н рәсми рәвештә тәхеттә утырган ханнар исеменнән Мамай идарә итә. Сарай шәһәрендә көчле хан хакимияте булмаган шартларда һәм Мамай шәхсән үзе генә бөек кенәзлек итү ярлыгын бирү мәсьәләләрен хәл итәргә омтылганда, Мәскәүнең бөек кенәзе Дмитрий Иванович, кайбер рус (Тверь, Смоленск һ.б.) кенәзләренең ярдәменә таянып, 1375 тә *урда салымын* түләүне туктата. Шул ук елда ул Тверьгә яу б-н бара, Мамай тәхеткә утырткан кенәз Михаилны Мөхәммәд Бүләк хан биргән бөек кенәзлек итү ярлыгыннан баш тартырга мәҗбүр итә һәм чынлыкта Русьның бәйсез идарәчесенә әверелә. Бу Мамайны хәрби чаралар башлап җибәрергә этәрә, аның гаскәре әледән-әле чиктәш рус кенәзлекләрен бөлдерә, ә Дмитрий Ивановичның гаскәрләре 1376 да Болгар шәһәрен басып алалар (аның идарәчеләре үзләренең Мәскәүгә бәйле булуларын таныйлар һәм ясак түли башлыйлар), 1378 дә Вожа елгасы буендагы (Рязань җире) сугышта әмир Бигеч гаскәрен тар-мар итәләр. Шуннан соң Мамай Литваның бөек кенәзе Ягайло б-н союз төзи, Рязань кенәзе Олегны үз ягына чыгарга ризалаштыра һәм, рус кенәзлекләрен бөлдерү, аларны буйсындыру нияте б-н гаскәр туплый башлый. Елъязмалардагы мәгълүматлар буенча, Мамай үз гаскәренә «Кыпчак һәм Татар җирләреннән яугирләр, фрязларны, чиркәсләрне һәм ясларны чакыра». Тарихчылар аның гаскәрендәге яугирләр санын төрлечә атыйлар (А.Н.Кирпичников — 40–60 мең кеше, Б.А.Рыбаков — 300 мең кешегә кадәр), ләкин бу гаскәрнең саны 30 мең кешедән дә артмагандыр. 1380 нең августында Мамай гаскәре Дон елгасы буйлап Мәскәү кенәзлегенең көньяк чикләренә юнәлә. Моңа җавап йөзеннән Дмитрий Иванович полклар туплый башлый. Руслар гаскәре Мәскәү кенәзенә буйсынудагы шәһәрләр һәм җирләр (Белоозеро, Ростов, Звенигород, Новосиль һ.б.) ополчениеләреннән, ш.у. Смоленск, Дорогобуж һәм Брянск кенәзләренең аерым отрядларыннан җыела (Тверь һәм Түбән Новгород кенәзләре катнашмыйлар). 30 меңләп яугир исәпләнә (әдәбиятта рус гаскәрләренең саны да төрлечә күрсәтелә: С.М.Соловьёв фикеренчә, 150 мең, А.Н.Кирпичников фикеренчә, 40–60 мең кешегә кадәр). Полклар 29 июльдә җыелалар һәм, Мамай көчләрен Ягайло гаскәре б-н кушылдырмас өчен, Донның югары агымы буена юнәләләр. 8 сентябрьдә Дмитрий Иванович гаскәре Непрядва елгасының (Донның уң кушылдыгы) уң ярына чыга һәм сугышка кирәргә тезелә. Рус һәм татар полкларының ничек тезелүе турында ышанычлы мәгълүматлар юк. Рус гаскәрләренең 5 зур полктан (алгы, уң һәм сул, үзәк һәм резерв) торуы ихтимал. Сугыш барышында Мамай гаскәре каршы якны кысрыклый, ләкин рус полкларының фланглардан ясалган һөҗүмнәре нәтиҗәсендә ул тар-мар ителә. Мамай үз гаскәренең калдыклары б-н качып китә һәм яңа гаскәр тупларга тырыша, ләкин шул вакыт Күк Урда ханы *Туктамыш* аңа каршы чыга. Бу каршылыкта Ак Урда әмирләре яңа хан ягында булалар. Мамай Кафа шәһәренә (Кырым) кача, анда ул генуялылар (итальян сәүдәгәрләре) тарафыннан тотыла һәм үтерелә. К.к.с.ндагы җиңү Мәскәү кенәзлегенең башка рус кенәзлекләре арасында абруе ныгуга китерә һәм ул кенәзлекләрдә Алтын Урдага карата тискәре карашлар көчәюгә булышлык итә. Ләкин бу җиңү Русьны Алтын Урда хакимиятеннән котылуга китерми; 1380 дә Туктамыш хан Алтын Урданы үз хакимияте астына берләштерүгә ирешә. 1382 дә ул Руська яу б-н бара, Мәскәүне басып ала, яндыра, кенәз Дмитрий Ивановичны кабат үз хакимиятен танырга һәм узган еллар өчен дә ясак түләргә мәҗбүр итә. 16 йөзнең 1 нче яртысыннан, Мәскәү дәүләте Казан ханлыгын яулау өчен көрәш башлагач, К.к.с.ның әһәмияте ясалма рәвештә күпертелә башлый, аның нәтиҗәләре максатчыл рәвештә сәясиләштерелә. К.к.с.ның әһәмиятен бәяләүдәге бу юнәлеш Россия историографиясенең алдагы барлык чорларында да өстенлек итә.

Чыг.: Полное собрание русских летописей. СПб., 1913. Т. 18; М., 1965. Т. 15; 1997. Т. 1; 2000. Т. 3, 6; «Слово о полку Игореве» и памятники Куликовского цикла. М.–Л., 1966; Сказания и повести о Куликовской битве. Л., 1982.

*Әд.:* Насонов А.Н. Монголы и Русь. М.–Л., 1940; Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Греков И.Б. Восточная Европа и упадок Золотой Орды. М., 1975; Прохоров Г.М. Повесть о Митяе. Л., 1978; Кирпичников А.Н. Куликовская битва. Л., 1980; Куликовская битва. М., 1980; Скрынников Р.Г. Куликовская битва: Проблема изучения // Куликовская битва в истории и культуре нашей родины: Материалы науч. конф. М., 1983; Горский А.А. Москва и Орда. М., 2000; Данилевский И.Н. Русские земли глазами современников и потомков (XII–XIV вв.). М., 2001.

**КУЛИ́НИЧ** Вадим Владимирович (13.7.1936, Пермь өлкәсе Кизел ш. — 25.6.2010, Алма-Ата), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1993). Свердловск тау ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), геол. партияләрнең Кызыл Ком төркемендә (Казакъстан ССР) эшли. 1962 елдан Казакъстан ССР ФАнең Геология фәннәре ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998–2000, 2005–10). 2000–05 елларда ЦНИИгеолнерудта. Көньяк Казакъстан терр-ясендә металл булмаган файдалы казылмаларны билгеләүнең фаразлау-минерагеник карталар комплектын, «Казакъстандагы тау рудалары, тау-химия чималлары, тышлау ташы чыганаклары» («Месторождения горнорудного, горнохимического сырья и облицовочного камня Казахстана») (т. 1–7, Алматы, 1997–2001; автордаш) бeлешмәсен төзи. ТРда компьютерлардагы геол. мәгълүмат банкы авторларының берсе.

Хезм.: Генетические типы и геохимия баритов Атасуйского рудного района // Барит. М., 1986 (автордаш).

**КУЛКАНАТЛЫЛА́Р** (Chiroptera), имезүчеләр отряды. 950 гә якын төре билгеле, нигездә, тропик һәм субтропикларда таралган. Татарстан терр-ясендә *озын колаклы яркант, төн ярканатлары*, зур ярканатлар, *кичке ярканатлар*, тиреканатлылар ыругларына карачы 12 төр бар. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарда, сулык ярлары буенда, каралтыларда һ.б.да очрыйлар. Озак очуга сәләтле имезүчеләрнең бердәнбер төре. Алгы очлыклары канатка әйләнгән: очу ярысы өчен каркас булып нык озынайган бармаклары (1 нче бармак кына азат), уч сөякләре һәм беләкләре хезмәт итә. Арткы очлыклар тез буыннары б-н як-якка җәелгән. Йон капламы кара төстә, йомшак, кыска; исле тире бизләре бар. Эңгер-меңгердә яки төнге яшәү рәвеше алып баралар. Яхшы сизәләр һәм күрәләр, колак яфраклары зур (мәс., озын колаклы ярканат). Елга бер тапкыр үрчиләр, 1–2 бала китерәләр. Даими парлар булмыйлар, ата затлар нәсел турында кайгыртуда катнашмый. Умырткасызлар б-н тукланалар. Күп кенә утрак төрләре кышлау өчен җир астындагы яшеренү урыннарын (мәгарәләр, штольня, баз, подваллар) файдалана. 11 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КУЛТЫ́К КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама алдында. Кама елгасының уңъяк яры тугаенда, елганың элеккеге юлында сакланып калган күл. Алабуга шәһәреннән 2,2 *км* көньяктарак. Су өслегенең мәйданы 13,92 *га*. Озынлыгы 1360 *м*, иң зур киңлеге 160 *м*.

**КУЛУ́Ш ПУ́СТОШЬ** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Пакшин елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. 1619 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сәкинәс исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер-

лекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.П.та земство мәктәбе (1906 да ачыла), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 306 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Троица-Сәкинәс волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 11 ир-ат; 1859 да — 207, 1897 дә — 269, 1908 дә — 396, 1920 дә — 282, 1926 да — 285, 1938 дә — 203, 1949 да — 176, 1958 дә — 88, 1970 тә — 96, 1979 да — 82, 1989 да — 19, 2002 дә — 10 кеше.

**КУЛЫ́ГИНСКИЙ** Пётр Никитич (1802, Вятка губ. Алабуга ш. — 22.5.1855, шунда ук), тарихчы, төбәкне өйрәнүче, дин эшлеклесе. Вятка руханилар семинариясен тәмамлый (1822). 1822–24 елларда Сарапул өяз руханилар, 1840 тан Алабуга приход уч-щеләре укытучысы. 1824 тән Алабуга өязендә рухани, 1837–40 та миссионер. Дини мәсьәләләр, Алабуга шәһәре һәм Алабуга өязе тарихы буенча, ш.и. «Пугачёвчылар һәм Пугачёв 1773–1774 елларда Трёхсвятск — Алабугада» («Пугачёвцы и Пугачёв в Трёхсвятском — Елабуге в 1773–1774 гг.», 1845; басыла — 1882) дигән хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. К биографии первых историков-вятчан // История и культура Волго-Вятского края. Киров, 1994.

*Е.Б.Долгов.*

**КУЛЬБА́КА** Степан Митрофанович (14.8.1924, Украина ССР, Полтава өлкәсе Опошнянский р-ны Поповка а. — 5.1.2000, Казан), график. Казан сәнгать уч-щесен (1951), Киев сәнгать ин-тын (1958) тәмамлый, И.Н.*Плещинский* остаханәсендә китап һәм станлы графика өлкәсендә специальләшә. 1947 елдан Казанда яши һәм эшли. 1957 дән Татарстан нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1976).

К. Татарстанда китап бизәү сәнгате үзенчәлекләренә дәвамлы юл салган сугыштан соңгы беренче проф. графиклар буынына карый. Ул 300 дән артык китап бизи (алар арасында Л.Толстой, М.Җәлил, А.Фадеев, С.Маршак һ.б.ның китаплары). К. иҗатында балалар китабы зур урын алып тора. Рәссамның стиле шартлылыкның һәм кызыксындыручанлыкның мәгълүм чараларын таләп итүче жанрны аңлап эш итү кысаларында формалаша. М.Рәфыйковның «Төлке баласы Хәйләпүш» (1973), Р.Газизованың «Безнең Туган илебез» (1977), А.Мельниковның «Кадерле сукмаклар» (1979), К.Булатованың «Марс китабы» (1982), М.Рәфыйковның «Оста куллы Гаффар» (1984) китапларына ясаган иллюстрацияләре шуңа ачык дәлил.



С.М.К у л ь б а к а. «Алъяпкычлы Наташа». Кәгазь, тушь. 1970 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.


Станлы графика остасы буларак, К. 1960 еллардагы «кырыс стиль» урнашкан вакытта формалаша. Моның чагылышы булып, аның иҗатында М.Җәлил шигырьләре буенча эшләнгән линогравюралар циклы («Очыгыз күгәрченнәр!», «Концлагерь», «Гаиләдә», «Дусларга», «Авыру янында», барысы да — 1961 дә); ш. у. «Язучы Софья Радзиевская портреты» (1963), «Матрёшка» (1967), «Фатиха бирәбез» (1971), «Уйлану» (1972) һ.б. линогравюралары барлыкка килә. Алар композициянең монументаль-яссылыкта чишелүе, ачыклыгы, образларның җанлылыгы б-н аерылып тора. Рәссам иҗатындагы темалар кешелекнең ватан, хәтер, тынычлык, гаилә, мәхәббәт кебек мәңгелек кыйммәтләрен раслый.

1970–80 елларда К. төгәллеге һәм сәнгати тәэсирләр уятуы б-н станлы графикага якын торган натурада ясалган рәсемнәр өлкәсендә актив эшли: «Балалар бакчасы», «Житен комбинатында эшләүче кызлар», «Компрессорлар заводы» (1970 еллар) серияләре; Ильинка авылы пейзажлары (Казан янында), рәссамның туган ягында эшләнгән авылдашлары портретлары (1980) һ.б.


К.ның әсәрләренә шартлылык, гомумиләштерү, стильләштерү, дөньяны декоратив рәвештә күрә белү, рәссам иҗаты чыганакларының берсе булган халык сәнгатенә якын тору хас. Алар, аеруча ирекле һәм көчле булып, аның соңгы чор станлы графикасында, 1990 еллар пастельләрендә һәм гуашьларында чагыла: «Идел яры», «Кич», «Ак пароходлы пейзаж», «Бер үзе», «Очар кошлар белән пейзаж». Аларда Украин халкы йорт бизәү традициясе, чигү, кәгазьгә бизәк төшерү алымнары ярылып ята. Республика, бөтенроссия, бөтенсоюз күргәзмәләрендә катнаша. Мөстәкыйль күргәзмәсе 1999 да оештырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана. Б.Солтанбәковның К. бизәвендәге «Туган як турында хикәяләр»е 1968 дә узган Бөтенсоюз китап сәнгате конкурсында дипломга лаек була.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии К., 1984; Е л ь к о в и ч Л.Я. Степан Кульбака. Станковая и книжная графика: Буклет. К., 1988; В е р б и н а О.Г. Темы на всю жизнь // Казань. 2000. № 9.

*О.Л.Улемнова.*








С.М.К у л ь б а к а. 1. «Матрёшка». Линогравюра. 1967; 2. «Ильинка авылы пейзажы». Кәгазь, төсле карандаш. 1980 еллар; 3. «Очар кошлар белән пейзаж». Картон, гуашь. 1990 еллар. Барысы да — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

**КУЛЬПИ́Н** Олег Александрович (6.3.1946, Иваново өлкәсенең Родники ш.), нәкышьче, педагог, ТР ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Холуй шәһәрендәге (Иваново өлкәсе) сәнгать мәктәбен «лаклы миниатюралар рәссамы» белгечлеге буенча тәмамлый (1966). 1969–74 елларда Кострома пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тында укый. Аны тәмамлаганнан соң, Лениногорск сәнгать-пед. уч-щесендә нәкышь, рәсем һәм композиция укыта, иҗат б-н шөгыльләнә. 1978–99 елларда Лениногорск шәһәренең баш рәссамы, 1980 дә — РСФСР Сәнгать фонды Татарстан җитештерү комб-тының Лениногорск иҗат-җитештерү участогы башлыгы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1985).

К. нәкышь һәм графика өлкәсендәге буяулы миниатюралар сәнгате традицияләрен үстерә, бер үк вакытта 1980 елдан башлап аның иҗатында рус реалистик сәнгате йогынтысы өстенлек ала («Лениногорск тирәсе», 1980). К. пейзаж һәм натюрморт жанрларында күп һәм нәтиҗәле эшли. Нәкышь чаралары ярдәмендә ул еш кына авылдагы көндәлек куллану әйберләренең, җиләк-җимеш, яшелчәләрнең матурлыгын һәм камиллеген сурәтли («Дәү әни мәшәкатьләре» натюрмортлар сериясе, 1990 еллар); композицияләре үзләренең ачыклыгы, сафлыгы, буяуларының күп төслелеге б-н аерыла. К. пейзажларына табигатьне чагылдыруда шигъри аһәң, нәфислек, тирән кичерешләр хас.



О.А.К у л ь п и н. 1. «Кичке Казан». 1979. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееe.





О.А.К у л ь п и н.
1. «Шимбә. Мунчалар». 1995. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Көз бүләкләре». 1999.

Үзенең беренче мөстәкыйль күргәзмәсендә (Кострома ш., 1973) ул «Иван Сусанин җирендә» исемле пейзажлар циклын күрсәтә, соңрак «Валдайда Ивер монастыре», «Вышний Волочёк», «Мета елгасы» (барысы да — 1990 еллар) кебек лирик серияләр иҗат итә. 1973–96 елларда К.ның Казан (1980, 1990, 1993,1996), Лениногорск (1988, 1995, 1996), Сарман (1986), Җәлил (1989), Баулы (1991), Зөя (1992), һ.б. шәһәрләрдә 15 мөстәкыйль күргәзмәсе уза. 1974 тән К. барлык респ-ка һәм бөтенроссия күргәзмәләрендә («Бөтенроссия рәссам-педагоглар күргәзмәсе», Мәскәү, 1979; «Россия Х», Мәскәү, 2004), төбәк күргәзмәләрендә («Зур Идел», Казан, 1980; Чабаксар, 1985; Казан, 1991); Казанның 1000 еллыгына багышланган — «Татарстан рәссамнары» (Мәскәү, 2005) күргәзмәсендә катнаша. Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт шәһәре Картиналар галереясында, Чуаш Дәүләт сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись. Скульптура. Графика. М., 1978; Ф а й н б е р г А.Б. Художники Татарии. Л., 1983.

*М.И.Ильина.*

**КУЛЬПИ́Н-ГОБӘЙДУ́ЛЛИН** Эдуард Сәлмән улы (28.9.1939, Баку ш.), тарихчы, философ, икътисад фән. канд.(1975), филос. фән. д-ры (1992), проф.(1992). *Г.С.Гобәйдуллинның* оныгы. 1963 елда Мәскәү полиграфия ин-тын тәмамлаганнан соң, Дәүләт электрокерамика тикшеренү ин-тында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1965–70 тә Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате министрлыгында. 1970 тән СССР ФАнең Халыкара эшчеләр хәрәкәте ин-тында. 1991 дән РФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тында, баш фәнни хезмәткәр (1998 дән). Бер үк вакытта Халыкара экология-политология ун-ты, Мәскәү мәдәният һәм сәнгать ун-ты, Мәскәү физика-техника ун-ты профессоры. 1993 тән «Социотабигый тикшеренүләр үзәге» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (Мәскәү), «История и современность» ж-лы баш мөхәррире (2005 тән). Хезмәтләре Алтын Урда, Кытай, Россиянең социотабигыять тарихын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Технико-экономическая политика руководства КНР и рабочий класс Китая. М., 1975; Человек и природа в Китае. М., 1990; Путь России. М., 1995; Золотая Орда: Проблемы генезиса Российского государства. М., 1998; Восток. Человек и природа на Дальнем Востоке. М., 1999; Китай: истоки перемен. М., 2002 (автордаш).

*Әд.:* М о с и о н ж н и к Л.А. Синергетика для гуманитариев. СПб.–Киш., 2003.

**«КУЛЬТАРМЕ́ЕЦ ГАЗЕТЫ́»**, РСФСРның «Бетсен наданлык» җәмгыяте үзәк советы һәм ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы. 1930–33 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. 1930–32 дә «Башлап уку газеты» исеме б-н чыга. Җаваплы мөхәррире — Н.Шаһиев.


*Әд.:* Н а с ы й р о в Т. Утызынчы елларда татар матбугатын буу // Идел. 2002. № 7; Ф а с а х о в К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979.

**КУЛЬТИВА́ТОРЛАР**, туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен билгеләнгән блоклы-модульле, комплекслы а.х. коралллары. Агрегат бер тапкыр узганда берничә операция башкара: тырмалау, икеләтә көпшәкләндерү (йомшарту), чәчү алдыннан тигезләү. К. б-н эшкәртү басу өслегенең тигез булуына, чүп үләннәр үрентеләрен бетерүгә, орлыклар өчен тыгызланган оялар һәм орлыклар күмелү тирәнлегендә йомшак һәм мульча капланган катлам булдыруга мөмкинлек бирә, ш.у. орлыклар тишелеп чыгу өчен туфракның җылылык, дымлылык һәм һава режимы булдырыла.

К.ны эшләү һәм җитештерүгә кертү буенча тикшеренүләр 1979–2000 елларда Н.К.*Мәҗитов* җитәкчелегендә *Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты* хезмәткәрләре һәм «Сибсельмаш» ҖБ б-н берлектә уздырыла. Кырдагы сынаулар К. куллануның югары нәтиҗәлелеген күрсәтә (орлыкларның тишелеп чыгышы 18% ка арта, 50% чүп үлән юкка чыгарыла, а.х. культураларының уңышы 1 *га* дан 12 *ц* га кадәр арта, чыгымнар тизрәк каплана). Бу хезмәт РФ һәм ТРның Дәүләт бүләкләренә лаек була (1990, 1999). К. Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсендә (КМПО), Буа (КМПОның ф-лы) һәм Нурлат машиналар төзү з-дларында, Чистай «Автоспецоборудование» з-дында җитештерелә. Тагылмалы һәм асылмалы модульле К. (КБМ-10,5П, КБМ-15П; КБМ-2,1Н, КБМ-8,4Н) эшләп чыгарыла.

*Әд.:* Комплекс влаго-, энерго-, ресурсосберегающих блочно-модульных культиваторов, адаптированных к условиям многоукладного хозяйствования. К., 2001.

*Н.К.Мәҗитов, Р.Л.Сәхапов.*



Ф.С.Культин.

**КУ́ЛЬТИН** Фёдор Сергеевич (20.5.1920, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Сеченов р-ны Липовка а. — 8.2.1983, Казан), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), старшина. Туган авылында колхозда эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 21 нче аерым понтон-күпер батальонында сапёрлар отделениесе командиры (60 нчы армия). Воронеж, Үзәк, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Идел елгасының сулъяк яры буенда Унжа-Козьмодемьянск (1941) оборона чигендә, Дон елгасының (Воронеж шәһәреннән төньяктарак) сулъяк ярындагы оборона сугышында (1942), Воронеж-Касторнен, Харьков (икесе дә — 1943), Житомир-Бердичев (1943–44), Ровно-Луцк, Львов-Сандомир (икесе дә — 1944), Югары Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең октябрендә Днепр елгасын (Киевтан 40 *км* төньяктарак) кичкәндә батырлык күрсәтә: 7 октябрьдә расчёт б-н бергә паромда дошман бомбалары шартлавыннан башланган янгынны сүндерә һәм аннан соң 12 көн дәвамында гаскәрләрне һәм сугыш кирәк-яракларын елга аркылы чыгара. 1945 тә демобилизацияләнә. Казанда яши, «Гидроспецстрой» оешмасында товар белгече булып эшли. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; За Отчизну, свободу и честь! Г., 1967. Кн. 3; Т ю л ь н и к о в Л.К., Б а с о в и ч Я.И. Герои Советского Союза — горьковчане. Г., 1981.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУЛЬТУ́РА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 28 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 81 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Башта Сулбаевка дип атала. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Кривозёрки волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 182, 1938 дә — 213, 1949 да — 189, 1958 дә — 181, 1970 тә — 171, 1979 да — 109, 1989 да — 102, 2002 дә — 101 кеше.

**КУЛЬТУ́РА КАТЛАМЫ́** (археол.), җирдәге кеше эшчәнлеге калдыклары: борынгы корылмалар, төзелеш, көнкүреш әйберләре һәм хуҗалык чүп-чары, көл һ.б. табыла торган катлам. Кайбер эре торак пунктларның, мәс., Казан, Болгар шәһәрләренең, К.к. 10 *м* дан артык. К.к. калынлыгына карап халыкның яшәү вакыты, аның хуҗалык һәм мәдәни тормышы дәрәҗәсе һ.б. билгеләнә.

**«КУЛЬТУ́РА ӨЧЕН»**, газета; к. «*Социализм юлы*».

**КУЛЬТУ́РА РЕВОЛЮ́ЦИЯСЕ**, дәүләт хакимиятен марксизм-ленинизм идеологиясенә таянган партияләр биләгән илләрдә мәдәният өлкәсендә партия һәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру процессы. К.р.нең асылы илдә рухи эшчәнлекнең эчтәлеген һәм максатларын, кешеләрнең дөньяга карашын, халык йөз тоткан кыйммәтләрне һәм тормыш рәвешен тамырдан үзгәртүдән гыйбарәт. К.р.нең төп сәяси максаты — мәдәниятне Коммунистлар партиясенең җитәкчелек ролен алга сөргән «пролетариат диктатурасы»н ныгыту чарасына әверелдерү. «К.р.» термины беренче тапкыр 1923 елда В.И.Ленинның «Кооперация турында» дип аталган әсәрендә кулланыла. Соңрак, 1950–60 елларда, К.р. сов. иҗтимагый фәннәр белгечләре тарафыннан, а.х. җитештерүендә *крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* һәм илне *индустрияләштерү* б-н беррәттән, социализм төзүнең төп закончалыклары исәбенә кертелә. Ләкин сов. мәдәният белемендә эчтәлеге һәм гамәлгә ашырылу рәвеше буенча СССРдагы К.р. б-н 1960 елларның 2 нче яртысында Кытайда «бөек пролетар культура революциясе» буларак уздырылган сәяси кампания арасында бернинди дә уртаклык юклыгы ассызыклана.

СССРда К.р. большевиклар партиясенең Окт. рев-циясе барышында хакимияттә ныгып урнашуыннан башлана һәм Бөек Ватан сугышына кадәр дәвам итә.

Бу чорда мәдәният яшәешенең идея-сәяси принциплары һәрьяклап үзгәртеп корыла: массакүләм мәгълүмат чаралары, мәгариф һәм мәдәни агарту системасы, фән һәм сәнгать учреждениеләре тулысынча Коммунистлар партиясе күрсәтмәләренә буйсындырыла һәм «яңа» сов. кешесен тәрбияләү эшенә җәлеп ителә.

К.р. тарихын өч төп этапка бүләләр: 1917–20 еллар — Гражданнар сугышы, Сов. хакимиятен урнаштыру, аны ныгыту өчен көрәш шартларында мәдәният яшәеше һәм үсешенең идея-сәяси нигезләрен тамырдан үзгәртеп коруның башлангыч этабы; 1921–27 еллар — К.р.н халык хуҗалыгын торгызу (к. *Яңа икътисади сәясәт*) һәм аны социализм принциплары нигезендә үзгәртү чорында җәелдерү; 1928–41 еллар — яңа мәдәният төзү өлкәсендә төп чараларны гамәлгә ашыру, рәсми бәяләнгәнчә, К.р.нең хәлиткеч уңышлары этабы.

Аңа хас мөһим сыйфатлар Сов. хакимиятенең беренче елларында ук илнең барлык өлкәләрендә ачык чагыла башлый. Илнең башка төбәкләрендәге кебек үк, Казан губернасында ул массакүләм мәгълүмат чаралары, мәдәни агарту системасы эшчәнлеген оештыру һәм аның эчтәлеге, мәгариф системасы өстеннән партия контроле урнаштырылудан, дини оешмаларны дәүләттән һәм мәктәпне дини оешмалардан аерудан башлана. 1917 нең 27 октябрендә В.И.Ленинның «Матбугат турында» Декреты, 9 ноябрьдә БҮБК һәм ХКСның «Мәгариф буенча Дәүләт комиссиясен оештыру турында» Декреты, 1918 нең 20 гыйнварында «Вөҗдан, чиркәү һәм дини оешмалар иреге турында» Декреты имзалана. Казанда 1917 нең 14 декабрендә беренчеләрдән булып Казан кадетларының «*Камско-Волжская речь*» г-тасы, 22 декабрьдә уң эсерлар органы булган «*Крестьянская Казанского губернского земства газета*», 1918 нең феврале уртасында «*Крестьянская жизнь*» г-тасы, 1918 нең мартында Казан уң эсерларының «*Трудовой путь*» г-тасы, 1918 нең 16 маенда меньшевикларның «*Рабочее дело*» г-тасы, 1918 нең 30 маенда «*Йолдыз*» г-тасы, Мөселман ком-ты органы булган «*Корылтай*» һ.б. ябыла. Шул ук вакытта 1917 нең 29 октябреннән Казанда ВКП(б) ның җирле органнарының «*Знамя революции*» г-тасы, 1918 нең сентябреннән татар телендә «*Эшче*» г-тасы чыга башлый. Нәкъ шул чорда өязләрдә беренче сов. газеталары — Чистай шәһәрендә «Власть Советов», Алабуга шәһәрендә «Народная воля», «Известия Тетюшинского Совета» һ.б. барлыкка килә; татар телендәге газеталар да басыла башлый: 1918 нең гыйнварыннан Эчке Россия мөселманнары эшләре комис-ты органы булган «*Чулпан*» г-тасы, 1918 нең мартыннан Казан мөселман комис-ты органы — «*Эш*» г-тасы нәшер ителә. Казанда губернаның башка халыклары телләрендә — мари телендә «*Ужара*», чуаш телендә «*Канаш*» г-талары чыга. Бу басмалар халык массаларын большевиклар һәм Сов. хакимияте ягына җәлеп итүдә зур роль уйныйлар.

Казан губернасында халык мәгарифе системасын үзгәртеп кору да төбәктә Сов. хакимияте урнаштырылганнан соңгы беренче айларда ук башлана. Шәһәр думасын тарату һәм 1918 нең гыйнварында Казан шәһәр хуҗалыгы советын оештыру барышында әлеге совет составында мәктәп комиссиясе булдырыла, ул мәктәпләр һ.б. уку-укыту оешмалары эшчәнлегенең эчтәлеген үзгәртү б-н шөгыльләнә. 1918 нең февралендә Казан шәһәр хуҗалыгы советы башкарма бюросы карары б-н *Казан уку-укыту округы* бетерелә һәм Казан губернасы Халык мәгарифе комис-ты төзелә (халык комиссары — А.А.*Максимов*). 1918 нең апрелендә Казан шәһәр хуҗалыгы советының Мөселман комис-ты составында Мөселманнарның халык мәгарифе бүлеге оештырыла (мөдире — Ш.Г.*Әхмәдиев*). Халык мәгарифе системасын тамырдан үзгәртеп кору максатында 1918 нең 30 маенда ХКСның «Барлык ведомстволарның уку-укыту, мәгариф учреждениеләрен һәм оешмаларын Мәгариф халык комиссариаты карамагына берләштерү турында» дип аталган Декреты кабул ителә. 1918 нең 18 июнендә «Россия Республикасында халык мәгарифе эшен оештыру турындагы нигезләмә» гамәлгә кертелә. 1918 нең маенда Казан губернасы өязләрендә халык уч-щеләре дирекцияләре һәм инспекцияләре бетерелә, аларның эшләре халык мәгарифе советларына тапшырыла.

1918 нең октябрендә Халык мәгарифе комис-ты Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлар Советы каршындагы Губерна халык мәгарифе бүлеге итеп үзгәртелә; соңрак милли мәктәпләр мәсьәләләрен хәл итү өчен аның структурасында халык мәгарифе буенча 5 милли бүлек — рус, мөселман (татар), чуаш, чирмеш (мари) һәм «башка вак халыклар» бүлекләре оештырыла. Алга таба мәгариф системасын үзгәртеп кору планлы һәм оешкан төс ала. РСФСР Мәгариф халык комис-тының 1918 ел 26 февраль күрсәтмәсе б-н барлык дөньяви уку-укыту оешмаларында Илаһи Канунны (Закон Божий) дәресләрдә һәм дәрестән тыш укыту туктатыла. 1918 нең февраль-мартында ук шәһәрләрдә һәм өязләрдә укытучылар съездлары уздырыла башлый, ләкин пед. интеллигенциянең яңа хакимиятне һичшиксез хуплавына багланган өметләрнең акланмавы ачыклана: рус һәм татар укытучыларының шактый өлеше Сов. хакимиятен кабул итми, югары уку йортларындагы укытучы-профессорлар составының зур өлеше дә аңа каршы була. Шул сәбәпле, укытучыларны һәм фәнни-пед. кадрларны яңа строй ягына җәлеп итү, ш.у. эшче-крәстиян



«За культурную революцию» журналы тышлыгы.

яшьләреннән Сов. хакимиятенә тугры белгечләр әзерләү мәдәният өлкәсендә иң мөһим бурычларның берсенә әверелә. 1918 нең мае башында «укытучыларны һәм татар тәрбиячеләрен кабаттан әзерләү өчен» өч айлык курслар ачылу турында белдерү басылып чыга; Казан губернасында 1917/18 уку елында эшләгән барлык укытучылар бу курсларны узарга тиеш булалар. 1918 нең 2 августында В.И.Ленин ХКСның «РСФСРның югары уку йортларына кабул итү турында» дип аталган Декретын һәм ХКСның «Югары уку йортларына пролетариат һәм ярлы крәстияннәр вәкилләрен өстенлекле кабул итү турында» карарын имзалый. Югары мәктәпне «пролетариатлаштыру»га башлангыч биргән бу документлар РСФСР Мәгариф халык комис-тының югары уку йортларында әзерлек курслары — *эшчеләр факультетлары* (рабфаклар) ачу турындагы карары б-н тулыландырыла, бу ф-тлар тиз арада эшчеләрне һәм крәстияннәрне югары мәктәптә укуга әзерләүне максат итеп куя. 1919 ның ноябрендә, Казанда беренче булып, Казан ун-тында рабфак ачыла (504 студент). 1920 нең июнендә *Казан политехник институтында* рабфак оештырыла (Казанда рабфакларда укучылар саны 730 кешегә җитә).

Мәктәп яшеннән чыккан халыкта наданлыкны бетерү һәм хезмәт ияләре арасында мәдәни-агарту эшен оештыру, ягъни мәктәптән тыш аң-белем тарату К.р.нең аеруча мөһим юнәлешләре була. 1919 ның 26 декабрендә Ленин ХКСның «РСФСР халкы арасында наданлыкны бетерү турында» дип аталган Декретын имзалый, бу документны А.В.Луначарский «Совет хакимиятенең иң бөек декретларының берсе» дип бәяли. Декретта күрсәтелгәнчә, илнең 8 яшьтән 50 яшькәчә укый-яза белмәгән барлык халкы туган телендә яки рус телендә грамотага өйрәнергә тиеш була. 1920 нең 21 гыйнварында Казан губерна башкарма ком-ты президиумы «Казан губернасында наданлыкны бетерү проекты» карарын кабул итә. Бөтен илдәге кебек үк, губернада аны үтәү буенча эш моңарчы күрелмәгән колач б-н башкарыла. Наданнарны укытуга белемле кешеләр җәлеп ителә. Мәктәпләрдә, төрле учреждение биналарында, яңа ачылган клубларда һәм китапханәләрдә, армия частьларында — бөтен җирдә наданлыкны бетерү пунктлары (к. *Наданлыкны бетерү*), «ликвидаторлар курслары» (эшчеләрне һәм крәстияннәрне укырга-язарга өйрәтүгә җәлеп ителгән кешеләрнең дәресләре) уздырыла, төрле уку ярдәмлекләре бастырыла һ.б. 1920 дә Татарстанда наданлыкны бетерү пунктларында 127155 кеше укып чыга, шулардан 47650 кешенең укый-яза белүе раслана. Бу РСФСРда иң яхшы күрсәткечләрдән санала.

1920 нең июлендә РСФСР Мәгариф халык комис-ты каршында Бөтенроссия наданлыкны бетерү гадәттән тыш комиссиясе төзелә (1930 га кадәр эшли), шуннан соң халыкны укыту тагын да киңрәк колач җәя. 1926 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, төбәктә яшәгән 2589645 кешенең 1399889ы укый-яза белсә (54%), 1935 тә халыкның укый-яза белүе 72,6%, 1939 да 90,4% тәшкил итә.

1930/31 уку елыннан илнең мәгариф системасы 8–10 яшьлек балаларны мәҗбүри башлангыч укытуга күчә (1933/34 уку елында гамәлгә кереп бетә), 1934–35 уку елыннан шәһәрләрдә гомуми 7 еллык укытуга юнәлеш тотыла. Шулай итеп, кыска вакыт эчендә халыкның белем дәрәҗәсен шактый күтәрүгә ирешелә, хезмәт ияләре өчен югары белем алуга реаль мөмкинлекләр булдырыла.

1914/15 уку елында хәзерге Татарстан терр-ясендә 117,2 мең укучысы булган 1835 гомуми белем бирү мәктәбе исәпләнсә, 1940/41 уку елы башында инде 541,8 мең укучысы булган 3537 мәктәп эшли; шул ук вакытта авылларда мәктәпләрнең саны 1640 тан 3327 гә, укучылар саны 91,1 меңнән 435 меңгә кадәр (ягъни 4,8 мәртәбә) арта.

Яңа хакимият тарафыннан «мәдәни-агарту фронтында» да күпсанлы чаралар уздыра. Кагыйдә буларак, «китап ташучылар» — сов. хакимияте чорында басылган китапларны һәм брошюраларны таратучылар ролен башкарган агитаторларның халык алдындагы чыгышларына зур әһәмият бирелә. Ләкин урыннарда яңа — «революцион» әдәбият җитми.

Урыннардагы агитация-пропаганда эшенә ярдәм күрсәтү йөзеннән, 1918 нең көзендә Мәскәүдә «В.И.Ленин исемендәге хәрби-күчмә фронт әдәби поезды» оештырыла. Ул Казанга 1918 нең 21 сентябрендә килә. Аның агитация-инструкторлык составы атна дәвамында партия һәм сов. активистлары, клублар, китапханә мөдирләре б-н укыту-методик эш алып бара; җирле «культармиячеләр»гә яңа басма продукция җыелмалары тапшырыла.

1919 ның октябрендә Казанда китапханә хезмәткәрләренең губерна съезды булып уза, ул китапханә эшенең актив үсешенә башлангыч бирә. 1920 дә үк Казанда 71 китапханә эшли, 1914 тә нибары 19 китапханә була. Җәмәгать китапханәләре булмаган авыл җирендә китапханәләр эшен үстерүгә зур игътибар юнәлтелә; 1928 дә үк китап фонды 743,5 мең данә булган 608 китапханә эшли, 1939 ахырына 2029,3 мең китап исәпләнгән 2030 китапханә була. Рев-циягә кадәрге 6 клуб учреждениесе (Затлылар һәм Хәрбиләр җыеннары, Шахмат, Сәүдәгәрләр, Яңа һәм Шәрекъ клублары) урынына шәһәрдә 38 эшчеләр клубы эшли; алар ш.у. Казанның татар микрорайоннарында, губернаның өязләрендә һәм волостьларында оештырыла. Авыл җирендә клуб учреждениеләренең саны 1913 тә 11 дән 1939 да 3114 кә җитә.

К.р. елларында мәдәни-агарту учреждениеләренең уку өе (гадәттә, крәстиян йортының кичләрен яңа газеталар, журналлар һәм китаплар укырга теләүчеләрне кабул итәргә җайлаштырылган бер бүлмәсе), кызыл почмаклар (пр-тиеләрдә, соңрак колхозлар, совхозлар фермаларында, машина-трактор станцияләрендә һ.б. да оештырыла) кебек яңа төрләре барлыкка килә. 1935 кә ТАССР да 750 уку өе эшли, 1936 елда республиканың хуҗалыгын һәм мәдәниятен үстерү планында аларның санын 1712 гә җиткерү күздә тотыла.

Җитәкче партия һәм сов. органнары массачыл-сәяси эштә киноның роленә зур әһәмият бирәләр. Бу максатларда кинотеатрларны файдалану буенча чаралар күрелә. 1918 нең ноябрь-декабрендә үк Губерна халык мәгарифе бүлеге составында киноком-т төзелә, ул Казан кинотеатрларын муниципальләштерә; тиздән шәһәрнең 11 кинотеатры да аның җитәкчелегендә эшли башлый. 1913 тә авыл халкына — 9, 1928 дә — 27, 1939 да 162 кинотеатр һәм стационар кино җайланмасы хезмәт күрсәтә (ш.у.к. *Кинематограф*).

Татарстанда К.р.нең иң мөһим үзенчәлекләренең берсе татар язуы *алфавитының* ике тапкыр алышынуыннан гыйбарәт: ТАССР ХКСның 1927 ел 3 июль карары б-н татар халкын Европа халыклары мәдәниятенә тартуны җиңеләйтү максатында гарәп графикасыннан латин язуына күчү гамәлгә ашырыла (к. *Яңалиф*), шуннан соң, ТАССР ЮС Президиумының 1939 ның 5 маенда чыгарылган «Татар язуының латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчүе турында» дип аталган Указы б-н латин язуы *кириллица* б-н алыштырыла. Бу чаралар оештыру ягыннан гаять күп көч һәм зур матди чыгымнар таләп итә. Әлеге реформа нәтиҗәсендә халык китап мирасыннан һ.б. байлыклардан читләштерелә, шул рәвешле халыкның интеллектуаль алгарышы, рухи мәдәнияте үсеше тоткарлана.

Яңа хакимият органнары нәфис сәнгать өлкәсенә — әдәбиятка, музыка, сынлы сәнгать, театр сәнгатенә, яңа, совет сәнгате интеллигенциясен әзерләүгә, матур әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең эчтәлеген контрольдә тотуга зур игътибар бирәләр.

1919 ның гыйнварында Губерна халык мәгарифе бүлеге турындагы нигезләмәне раслаганда аның составында ике секциядән: сынлы сәнгать һәм театр, музыка, матур әдәбият секцияләреннән торган бүлекчә булдыру күздә тотыла. Бүлекчәнең төп бурычлары «... киң халык массаларын сәнгатькә тарту һәм, аерым алганда, яңа сәнгатьне пропагандалау»дан гыйбарәт була. Шул ук вакытта партия органнары сәнгатькә массалар аңына көчле тәэсир итү чарасы буларак карыйлар. Шуңа күрә драма театрларының репертуары, китап нәшриятларының эш планнары, җырчылар, композиторларның, рәссамнарның иҗаты аларның даими контроле астында тотыла, бу контроль еллар узган саен тагын да катгыйрак рәвешкә керә, чынлыкта партиячел-идеологик диктатка әверелә. 1930 елларда иҗат берлекләре (к. *Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге, Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге*) төзелү б-н иҗат интеллигенциясенә ясалган мондый басым аеруча ачык сизелә башлый.

Шулай да К.р. елларында партия һәм дәүләтнең максатчыл мәдәни төзелеш сәясәте гамәлгә ашырылу зур казанышларга китерә: халыкның гомуми белем дәрәҗәсе сизелерлек үсә, халык хуҗалыгының төрле тармаклары өчен югары квалификацияле белгечләр (ш.и. милли кадрлар) әзерләнә. Бу елларда авыл җирендә мәдәни-агарту учреждениеләре челтәрен үстерү, торак пунктларны радиолаштыру һәм кинофикацияләү юнәлешләрендә зур эшләр башкарыла. Ил һәм һәр халык моңарчы күзәтелмәгән мәдәният-мәгариф күтәрелеше кичерә. Якынча 1930 еллар уртасына кадәр (массачыл репрессияләр башланганчы), һичшиксез, К.р. халык массаларында электән яшәп килгән, царизм шартларында кирәк дип табылмаган көчле иҗат энергиясен дөньяга чыгаручы фактор була.

1920 елларда татар матур әдәбиятының күп кенә үрнәкләре иҗат ителә: 1924 тә СССР халыклары Үзәк нәшриятында (Центриздат, Мәскәү) Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» повесте басыла, 1928 дә аның «Тирән тамырлар» романы дөнья күрә. Шул елларда К.Тинчурин киләчәктә киң танылачак «Казан сөлгесе», «Американ», «Сүнгән йолдызлар» (барысы да — 1924), 2 елдан соң «Җилкәнсезләр» пьесаларын бастырып чыгара. 1927 дә Ш.Камалның «Таң атканда» романы нәшер ителә. Драматурглар М.Фәйзи, Г.Камал, Ф.Бурнаш, прозаиклар К.Нәҗми, А.Шамов, шагыйрьләр М.Гафури, Һ.Такташ һ.б.ның яңа әсәрләре басыла.

К.р. елларында татар драма театры зур казанышларга ирешә. 1926 да Татар акад. театрының Мәскәү-Оренбург-Кызыл Урда-Ташкент-Сәмәрканд-Әстерхан-Сталинград-Ростов-Донбасс-Саратов маршруты буенча гастрольләре уңышлы уза (к. *Татар академия театры*).

1920 еллар башында татар композиторы С.Сәйдәшев үзенең музыкаль җәүһәрләрен иҗат итә. 1925 нең җәендә Казан тамашачысына беренче татар операсы — Г.С.Әлмөхәммәдов, В.И.Виноградов, С.Х.Габәшинең «Сания» операсы күрсәтелә, 5 елдан соң шул ук композиторларның яңа — «Эшче» милли операсының премьерасы була.

Казан рәссамнары Н.И.*Фешин*, П.А.*Радимов*, П.П.*Беньков*, Г.А.*Медведев*, В.К.*Тимофеев* һ.б.ның әсәрләре киң таныла, сынлы сәнгатьтә беренче татар рәссамнары — Ф.Ш.*Таһиров*, Б.И.*Урманче*, С.С.*Ахун* үсеп чыга.


Шул ук вакытта илнең, һәр халыкның һәм аерым шәхеснең рухи күтәрелеше өчен К.р. ачкан киң мөмкинлекләр халыкның рухи тормышын оештыру өлкәсендә Коммунистлар партиясе диктаты хакимлек итү нәтиҗәсендә үз бәясен югалта. Бу диктат шәхеснең иҗади инициативасын, ирекле эзләнүен һәм үсешен тоткарлый. 1920–30 елларда танылган талантлы мәдәният эшлеклеләренең күбесе 1930–40 еллардагы массачыл репрессияләр чорында юк ителә.

Чыг.: Основные материалы к плану хозяйства и культуры Татарской АССР на 1936 год. К., 1936; Культурное строительство в Татарии. 1917–1941: Сб. док. и материалов. К., 1971; Культурное строительство в Татарии. 1941–1970: Док. и материалы. К., 1978; Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

*Әд.:* Сабиржанов Г. Татарстанда культура революциясе һәм аның казанышлары // Совет мәктәбе. 1980. № 6, 11; Культурная революция в СССР. 1917–1965 гг. М., 1967; Гарипова З.Г. Культурно-просветительная работа в Татарии в годы 1-й пятилетки. К., 1985; Культурная революция в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1985; Семенихина И.Н. Советская историография культурной революции в Среднем Поволжье: Дис. ... К., 1987.

*Г.С.Сабиржанов.*

**«КУЛЬТУ́РА РЕВОЛЮ́ЦИЯСЕ»**, бизәлешле айлык журнал. РСФСР Мәгариф халык комис-ты һәм «Яңалиф» ҮК органы. «*Мәгариф эшчесе*» ж-лы дәвамчысы. 1931 елның июнь аеннан 1932 нең декабрь аена кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 19 саны чыга. 1931 нең октябрь аена кадәр — СССР халыкларының үзәк нәшриятында, соңрак «Учгиз»да басыла. Мөхәррире — И.Юмангулов. Журналның иң актив авторлары — М.Арифуллин, М.Арсланов, Г.Вәлид, З.Газиз, Х.Мансуров, Ф.Мостафин, А.Талиб, М.Тәрҗеман, Ә.Фәйзи. Басманың төп максаты — *культура революциясе* бурычларын тормышка ашыруда ярдәм итү, наданлыкны бетерү. Журналда ВКП(б) ҮКның мәдәният мәсьәләләренә кагылышлы карарлары басыла, илдәге мәдәният төзелешен, сәяси мәгърифәт, Ленинның милли сәясәтен тормышка ашыру, профсоюзлар хәрәкәте үсеше, дингә каршы көрәш мәсьәләләре яктыртыла. Мәктәптәге тәрбия эшләре, пед. кадрлар әзерләү, яңа уку программалары турындагы мәкаләләргә дә журналда зур урын бирелә. Анда әдәбиятка, татар сәнгатенә, музыкага, библиографиягә багышланган бүлекләр дә була. Татар язуын латин әлифбасына күчерү мәсьәләләренә дә игътибар ителә.


„KUL'TURA RIVOLYTSIƏSE"
ƵURNALь
HƏR BER UQьTUCьNьN
HƏR BER KUL'TƏRMIESNEN
HƏR BER KUL'TURA FRONTь
EŞCESENEN
EŞ ӨSTƏLNDƏ
BULRQA TIEŞ.

«Культура революциясе» журналының беренче саны.

*Т.М.Насыйров.*

**«КУЛЬТУ́РА ФРОНТЫ́»**, газета; к. «*Колхозчы*».

**КУЛЯ́БКО** Алексей Александрович (15.3.1866, Омск ш. — 6.8.1930), физиолог, мед. д-ры (1897). 1893 елда Томск мед. ун-тын тәмамлагач, Германиядә, Франциядә, Швейцариядә стажировка уза, физиол. лаб-яләре эше б-н таныша. 1895 тән Петербург ФАндә. 1898 дән Петербург ун-тының физиол. каф. приват-доценты, бер үк вакытта Лейпцигта, Неапольдә эшли. Диңгез хайваннарының мускул-нерв эшчәнлеген тикшерә. 1902–03 тә С.-Петербургта проф. П.Ф.Лесгафт биол. лаб-ясенең физиол. курсларында һәм Хатын-кызлар сәламәтләген саклау җәмгыятендә гигиена курсларында укыта. 1903 тән Казан ун-тында физиол. каф. профессоры, шул ук елда Томск ун-тының физиол. каф. профессоры итеп сайлана. Реаниматологиягә нигез салучыларның берсе. К. йөрәк-тамырлар системасына препаратлар тәэсирен тикшерә; үлемне эзлекле процесс итеп карый, кеше үлгәч, кайбер әгъзаларның бернигә көннән үз эшчәнлекләрен кайтара алуын тәҗрибә юлы б-н исбатлый; организмга елан агуы тәэсирен өйрәнә.

Х е з м.: О строении Бартолиновых желез // Тр. Имп. Санкт-Петерб. об-ва естествоиспытателей. 1889. Т. 20, вып. 1; Дальнейшие опыты оживления сердца. Оживление человеческого сердца // Изв. Имп. АН. 1902. Т.17, № 5.

*Әд.:* А.А.Кулябко: Некролог // Медико-биол. журн. 1930. № 6.

**КУЛЯ́СОВ** Александр Петрович (10.3.1919, Казан губ., Чистай өязе Кече Талкыш а. — 25.6.1944, Украина ССР, Гомель өлкәсенең Рогачёв р-ны Озераны а.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), капитан. Пед. уч-ще, пед. ин-тының бер курсын, Гомель пехота уч-щесен (1941), «Выстрел» югары офицерлар курсларын (1943) тәмамлый. Хәрби хезмәткә чакырылганчы, туган авылында укытучы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1086 нчы укчы полкның батальон командиры (3 нче армиянең 323 нче укчы дивизиясе). Брянск һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү өчен барган сугышта (1941–42), Орёл, Брянск, Гомель-Речица (барысы да — 1943) һәм Рогачёв–Жлобин (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 25–26 июнендә Озераны һәм Олы Крушиновка авыллары янындагы сугышта батырлык күрсәтә: дошманның каршылык күрсәтүен бастыра, полкка һөҗүмне җәелдерүгә булышлык итә, үзе һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Туган ягында К.ка бюст куела. Чистай шәһәренең бер урамы Герой исемен йөртә, шәһәрдә аның исеме язылган истәлек ташы — стела урнаштырылган.



А.П. Кулясов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Совесткого Союза — наши земляки. К., 1984; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУМСКО́ВА** Наилә Хәсән кызы (19.1.1934, Кыргызстан Респ-касы Ош ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1983), проф. (1984), Кыргызстан Респ-касының атказ. мәгариф хезмәткәре. 1957 елда Мәскәү икътисад ин-тын тәмамлый. 1967–73 тә Физкультура ин-тында, 1973–93 тә Кыргызстан мед. ин-тында укыта ( хәзерге Бишкәк ш.). 1993 тән Кыргызстан-Россия славян ун-тында каф. мөдире. Хезмәтләре халыкның таралып урнашуы һәм демография мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Экономическая теория. Бишкек, 2007.


*Ф.С.Зыятдинов.*

**КУМЫРСА́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Бимә елгасының (Кырыкмас, Иж елгалары бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,2 *км* (ТР чикләрендә 10 *км* га якын), бассейнының мәйданы 71,4 *км*². Сарапул калкулыгыннан ага. Югары һәм түбән агымнары — Әгерҗе р-ны терр-ясендә, урта агымы — Удмурт Респ-касы терр-ясендә. Елга башы — Яңа Чыкалды авылыннан 1 *км* көнбатыштарак, тамагы — Исәнбай авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 105 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.ның 0,3 *км*дан алып 7,1 *км* га кадәр озынлыктагы 12 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,7 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 105 *мм*, ташу агымы катламы 91 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакы-

тындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 1 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КУМЫРЫ́К**, к. *Комаровка*, Мамадыш р-ны.

**КУМЫ́С КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Кама елгасының уңъяк ярында Алабуга р-ны Поспелово авылы янында (элеккеге Кумыс посёлогы үзәгендә) урнашкан. К.к. ядкәрләре 1959 елда В.Ф.Генинг, 1968 дә П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан тикшерелә. Таш гасыр торулыгы һәм бронза гасыр каберлекләре керә. Торулыкның культура катламы бик зур җимерелүләргә дучар булган, анда неолит дәвере һәм бронза гасыр артефактлары табыла.



Кумыс комплексыннан бронза гасыр керамикасы. Кумыс торулыгы.

1959 да бронза гасырның соңгы чорына караган курган өемнәре эзләре калган 12 кабер калдыкларын тикшерү уздырыла. Каберләр янында йомры төпле корбан бирү савытлары чыга. 1968 дә бронза гасырның икенчел кабер эзләре өйрәнелә; посёлок уртасында ачылган 12 йөзгә караган болгар каберендә коеп ясалган аел табыла.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; ш у л у к. Приказанская культура // Свод археол. источников. 1980. Вып. 13–14; Г е н и н г В.Ф., С т а р о с т и н П.Н. Кумысская стоянка и могильники // Отчёты Нижнекамской археол. экспедиции. М., 1972. Вып. 1.


*П.Н.Старостин.*

**КУМЫ́СНИКОВ** Абдрахман Лотфулла улы (28.11.1913, Түбән Новгород губ. Мәдәнә а. — 7.9.1985, Ленинград), балет артисты, педагог-хореограф, БАССРның атказ. артисты (1957), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1964). 1938 елда Мәскәү хореография уч-щесен (педагог — П.Гусев), 1939 да Ленинград хореография уч-щесенең белемне камилләштерү классын (педагог — В.Пономарёв), 1949 да Ленинград консерваториясенең педагог-хореографлар бүлеген (педагог — В.Ваганова) тәмамлый. 1939–59 да Ленинград опера һәм балет театры солисты. 1940–41 дә беренче татар балеты — Ф.Яруллинның «Шүрәле»сен сәхнәгә куюда катнашу (Былтыр роленд) өчен Казанга Татар опера һәм балет театрына эшкә җибәрелә (Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, спектакль куелмый кала). Хореографик партияләре арасында Кияү («Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Центурион, этрусклар биюе («Спартак», А.Хачатурян), фламенко («Лауренсия», А.Крейн), испан биюе, мазурка («Аккош күле», П.Чайковский), чегән биюе («Дон Кихот», Л.Минкус) бар. 1946–70 тә Ленинград хореография уч-щесе педагогы, 1970–73 тә Ленинград Кече опера һәм балет театрында солистлар классын алып бара, 1978 дән Ленинград опера һәм балет театрының педагог-репетиторы. Бер үк вакытта төрле илләрдә Нидерланд балетының солистлар классын алып бара, Варшава балет мәктәбендә, Белград, София, Будапешт, Берлин хореография уч-щеләрендә белем бирә.

**КУМЫ́СНИКОВ** Халит Лотфулла улы (27.2.1926, Түбән Новгород губ. Мәдәнә а. — 12.5.2008, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, театр белгече, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986), сәнгать фән. канд. (1963). Мәскәү Дәүләт театр сәнгате ин-тының Татар театр студиясен (1949) һәм театр белеме ф-тын (1955) тәмамлый. 1949 елда студияне тәмамлаучылар б-н бергә Казан Яшь тамашачылар театрының татар төркеме составында, төркем таркалганнан соң, 1951 гә кадәр рус төркеме актёры, күп кенә рольләр башкара, шулар арасында Вәли («Кызлар», В.Ф.Панова), Шенадье («Хокуксызлар», В.Гюго романы буенча) образлары да бар. 1955–58 дә Татар акад. театрының әдәби бүлек мөдире, 1958–60 та Казан телевидение студиясе режиссёры. 1961–69 да Казан пед. ин-тында укыта, 1969 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында, проф. (1992). «Г.Камал исем. Татар дәүләт академия театрына 50 ел», «Г.Камал исем. Татар дәүләт академия театрына 60 ел» дип аталган альбомнарны бастыруга әзерли; фәнни җыентыкларга һәм «Театр энциклопедиясе»нә («Театральная энциклопедия») кертелгән мәшһүр татар театры эшлеклеләре турындагы фәнни-популяр хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Татар совет театры. К., 1975 (автордаш); Народные артисты. К., 1980 (автордаш); Истоки сценического реализма. К., 1982; Халил Абжалилов. К., 1984; Шафика Кутдусова. Наб. Челны, 1995; К столетию татарского театра (1906–2006) // Идель. 2003. № 11–12; 2004. № 1, 3–5, 7–12; 2005. № 1–11.

**КУМЫ́СНИКОВА** Наилә Халит кызы (4.4.1958, Казан), театр һәм гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2009). Казан сәнгать уч-щесен (1977), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын, М.М.Курилко-Рюмин остаханәсен (1983) тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1987). Казан сәнгать уч-щесендә укыта (1983–97). К. Татар акад. театрында Р.Батулланың «Елантау», Әлмәт татар драма театрында К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1984), Бөгелмә рус театрында М.Горькийның «Соңгылар», Татар яшь тамашачылар театрында К.Тинчуринның «Ил», Татар яшьләр театрында Д.Вәлиевнең «Намус хөкеме» (1983) пьесалары һ.б. буенча куелган спектакльләргә декорация һәм костюмнар авторы. Аның тарафыннан С.Прокофьевның «Өч әфлисунга мәхәббәт» операсына (1983), М.Горькийның «Соңгылар» пьесасына (2001) һ.б. декорация эскизлары, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле (2001), «Салават» театр студиясе (2001–05) өчен сәхнә бизәлеше әзерләнә. К. — «Болгари» беренче халык нәфис кәсепчелек иҗат остаханәсен оештыручы (1995); 18–19 йөзләр татар бизәкле аяк киемнәре-







Н.Х.К у м ы с н и к о в а. 1. С.Прокофьевның «Өч әфлисунга мәхәббәт» операсына декорация эскизы. Оргалит, темпера. 1983; 2. «Тормыш агачы». Панно фрагменты. Каюлы күн, көмеш җеп, укалап чигү. 2003. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Яз» панносы. Каюлы күн. 2005.

нә, Казан Кремлен казу вакытында (1990 еллар ахыры — 2000 еллар) табылган болгар костюмына һәм 16 йөз татар гаскәриенең сугыш кирәк-яракларына (садак, җәя савыты) реконструкция ясый. 1995 елдан ул татар каюлы күн технологиясен үзләштерә; бу өлкәдә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Аның күргәзмәгә куелган әсәрләре башкаларныкына охшамаган, формаларының нәфислеге, милли бизәкләрнең иҗади интерпретациясе, югары сәнгать дәрәҗәсендә эшләнүе б-н аерылып торалар. К. татарларның бизәкле, җөйсез итекләрендә, «төз» кунычлы ир-ат читекләрендә, күптөсле җөйләр кулланылган эшләнмәләрендә мөстәкыйль бизәк элементлары ролен уйнаган борынгы технологияләрне яңарта. Каюлы күн сәнгатендәге милли традицияләр К. тарафыннан модалы нәфис хатын-кыз итекләрендә даими файдаланыла, еш кына сумкалы комплектлар да («Зөбәрҗәт», «Алсу», икесе дә — 1996; «Ал», 1997; «Фирүзә», 2002; «Зәңгәр якут», 2003 һ.б.) укалап чигелгән бизәкләр б-н баетыла. К. каюлы күн сәнгате өчен яңа, ассоциатив-символик эчтәлекле һәм бай колоритлы, бизәкле дивар панносы жанрын тематик циклларда берләштерә. Каюлы бизәкләр композицияләренә ул бизәк стилендәге кошлар сурәтләрен урнаштыра («Ел фасыллары» панносы, 1995, 1997; панно һәм 2 «Ак кошлар» мендәре, 1999; укалап чигү һәм каюлы күн техникасында эшләнгән 4 «Ел фасыллары» панносы, 2002; Мәскәүдәге ТР вәкиллегендә «Сак белән Сок» панносы, 2003; «Яз», 2005 һ. б.).

Төбәк («Зур Идел», 1985 тән), бөтенроссия («Совет Россиясе», 1985, 2004; «Театр, кино һәм телевидение рәссамнары», Казан, 1985; «Россия X», Мәскәү, 2004; «Җиңүнең 60 еллыгына», Мәскәү, 2005), бөтенсоюз («Ил яшьлеге», 1982; «Театр һәм кино рәссамнары», 1989), халыкара («Төрки дөнья», Әнкара, 2000) күргәзмәләрдә катнаша. Аерым күргәзмәләре Казанда (1993, 1996, А.Федотов б-н бергә; 1998, Ф.*Хәсьянова* һәм А.Тимергалина б-н бергә) уздырыла. К. ның әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең милли мәдәният музеенда саклана. ТР Мәдәният министрлыгының Сынлы сәнгать өлкәсендәге Б.Урманче исем. бүләге лауреаты (2001).

*Әд.:* И Айседора ичиги носила // Идель. 1996. № 1/2; Изделия народных художественных промыслов и декоративно-прикладного искусства Республики Татарстан: Каталог. К., 2002; Саттарова Л. Казанская узорная кожа. М., 2004.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КУНА́ВИН Н.И. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. Казандагы шәхси, җәмәгать файдалануындагы китапханә. 1860 еллар башында Казан хәрби уч-щесе казначее Н.И.Кунавин тарафыннан ачыла. Анда, нигездә, әдәби әсәрләр, журналлар саклана. 1864 елда И.А.Шидловскийга сатыла (к. *Шидловский И.А. китапханәсе*).

*Әд.:* Агафонов Н.Я. Заволжская вивлиофика. К., 1887. Вып. 1; Шишкин В.И., Щелыванова Ж.В. Казанские частные библиотеки для чтения 30–60-х годов XIX века // Библиотека Казан. ун-та: фонды, раритеты, история...: Сб. статей. К., 1989.

**КУНАКБА́ЕВ** Сабир Абдулла улы (29.12.1901, хәзерге БРның Кырмыскалы р-ны Олыкүл а. — 3.7.1996, Уфа ш.), агроном-селекция белгече, а.х. фән. канд. (1950), РСФСРның атказ. агрономы (1957), БАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1963), Соц. Хезмәт Герое (1987). К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый (1927). 1932 елдан Башкортстан селекция станциясендә бүлек мөдире урынбасары, директор урынбасары. 1955 тән Башкортстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында агротехника бүлеге мөдире, директор урынбасары. 1958 дән Башкортстан игенчелек һәм селекция фәнни-тикшеренү ин-тында көзге культуралар селекциясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре а.х. культуралары селекциясенә карый. К. арышның югары уңышлы интенсив сорты селекциясенең теоретик нигезен эшли, дөньяда беренче булып кыска сабаклы «Чулпан» сортын чыгара. Ул ш.у. арышның «Саратовка чишминская» (1949), «Чишминская 2», «Чишминская 3» (икесе дә 1963 тә), «Чулпан 3» (1979), карабодайның «Чишминская» (1972), «Дёмская» (1981); терлек азыгы өчен тритикаленең — «Башкирская 1» (1984) сортлары авторы. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре; БАССР ЮС Президиумының 4 Мактау грамотасы, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Озимая рожь и пути повышения её урожайности в Башкирии. Уфа, 1961; Селекция озимой пшеницы в Башкирии. М., 1968; О некоторых фактах формообразования у озимой ржи // Сельскохозяйственная биология. 1970. Т. 4, № 6.

**КУНАХО́ВИЧ** Александр Викторович (2.9.1911, Казан — 21.2.1968, Яшел Үзән ш.), корабльләр төзүче инженер, ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960), СССР Дәүләт бүләге (1949), Ленин бүләге (1965) лауреаты. Горький индустриаль ин-тын тәмамлый (1940). 1929–31 елларда Сталинград трактор з-дында фрезерчы. 1931–34 тә Саратов шәһәр советында физкультура инструкторы, 1934–38 дә «Динамо» җәмгыятенең Горький шәһәр советы су комб-тында физкультура инструкторы, директор. 1938–49 да Үзәк 51 нче КБда конструктор, баш конструктор урынбасары (Горький ш.). 1949–68 дә Зеленодольск проектлау-конструкторлык бюросында җитәкче, бер үк вакытта баш конструктор. К. җитәкчелегендә эшләнгән проектлар буенча якынча 800 корабль төзелә. Ул Хәрби диңгез флотында газ турбиналары, су асты канатлары, алюминий коелмаларыннан эшләнгән конструкцияләр, су асты көймәләрен сикерешле тактика кулланып эзләүне башлап тәкъдим итә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар. К. исеме су асты канатлы кече корабльгә бирелә (1977). Яшел Үзән шәһәрендә проектлау-конструкторлык бюросы бинасына һәм К. яшәгән йортка мемориаль такталар куела. Дәүләт бүләге — суднолар төзегәндә позицион агым алымын гамәлгә кертүгә катнашканы өчен, Ленин бүләге махсус машиналар төзү өлкәсендәге хезмәте өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.



С.А. Кунакбаев.

*Әд.:* Полвека в кораблестроении (к производственной деятельности Зеленодольского проектно-конструкторского бюро). К., 1999.

*Г.Я.Мәүлетова, Л.Р.Хәлилова.*

**КУ́НОШ** (Kunos) Игнац (1860–1945), венгр тюркологы, фольклорчы. 1915–16 елларда Эгер, Эстергом (Венгрия) шәһәрләре тирәсендә урнашкан лагерьлардагы татар хәрби әсирләреннән фольклор материаллары язып ала. «Татар әсирләре лагерьда. Мөселман хәрби әсирләре лагерьларында башкарылган эш турында доклад» («Tatar foglyok táborában: Jelentés a Mohamedán fogolytáborokban Vegzett tanulmanyokrál») «Будапешт күзәтчесе» («Budapesti szemle», Bdpst., 1916) дип исемләнгән еллык басмада дөнья күрә. К. җыйган татар фольклоры материаллары тупланмасы Ж.*Какук* тарафыннан түбәндәге хезмәтләрдә басыла: «Казан татарларының халык җырлары» («Kasantatarische Volkslieder», Bdpst., 1980), «Казан татарларының халык әкиятләре» («Kasantatarische Volksmärchen», Bdpst., 1989), «Лөгатьлек белән мишәр-татар текстлары» («Mischärtatarische Texte mit Wörterverzeichnis», Szeged, 1996). Аларда татар текстлары б-н бергәттән транскрипциядә немец теленә тәрҗемәләре дә бирелә.

*Әд.:* Әсирлектән кайткан әкиятләр. К., 2002.

*Л.Ш.Җамалетдинов.*

**КУНЫ́Р** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 36 *км* төньяктарак, Кубыр елгасы буенда. 2010 елда 869 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1619 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.да 2 мәчет була. Авыл җәмәгатенең имана җире 1914,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 777, 1884 тә — 1104, 1905 тә — 1236, 1920 дә — 1868, 1926 да — 1724, 1938 дә — 305, 1958 дә — 811, 1970 тә — 832, 1979 да — 819, 1989 да — 770, 2002 дә — 854 кеше.

**КУПА́ЛА** Янка (псевд., чын фамилиясе һәм исеме Луцевич Иван Доминикович) (25.6.1882, хәзерге Белоруссия Респ-касының Минск өлкәсе, Молодечно р-ны Вязынка а. — 28.6.1942, Мәскәү), Белоруссия ССР-

ның халык шагыйре (1925), Белоруссия ССР ФА (1928) һәм Украина ССР ФА (1929) академигы. «Жалейка» (1908), «Тормыш юлыннан» («Дорогой жизни», 1913), «Мирас» («Наследство», 1922), «Чын йөрәктән» («От сердца», 1940) шигырь җыентыклары, «Курган» (1910), «Оресса елгасында» («Над рекой Орессой», 1933) һ.б. поэмалар, «Таланган оя» («Разорённое гнездо», 1913), «Мондагылар» («Здешние», 1924) пьесалар авторы. 1941 елның октябреннән 1942 нең июненә кадәр Печище авылында эвакуациядә була. Биредә ул «Малай һәм лётчик сугышта» («Мальчик и лётчик на войне»), «Тормыш янә иректә һәм бәхетле булыр» («Жизнь снова станет вольной и счастливой») шигырьләрен, «Тугыз усак казык» («Девять осиновых кольев») поэмасын (төгәлләнмәгән) яза. Радиодан, 1942 нең мартында Белоруссия ССР ФАнең Казанда узган сессиясендә чыгышлар ясый. 1975 елда Печищеда *Купала Янка музей-фатиры* ачыла.

Ә с ә р.: Сочинения: В 3 т. М., 1982.

*Әд.:* Н у р и З. Янка Купала һәм аның иҗади варислары // Казан утлары. 1972. № 7; Б е р ю з к и н Г.С. Мир Купалы. М., 1973.

**КУПА́ЛА Я́НКА МУЗЕ́Й-ФАТИРЫ́**, Югары Ослан р-ны Печище авылында, 1975 елда Минск шәһәрендәге Я.*Купала* әдәби музее ф-лы буларак ачыла. 1981 дән ТР Милли музее ф-лы. Печище икмәк комб-ты комплексында И.П.Оконишниковның элеккеге тегермән конторасы бинасында (1895) урнашкан. Бөек Ватан сугышы елларында эвакуация вакытында (1941–42) Я.Купалага бирелдә фатир бирелә. Музей мәйданы — 80 *м*², коллекциясе 700 саклау берәмлеген тәшкил итә. Шагыйрьнең Печищедагы тормышына һәм иҗатына багышланган бүлектә аның фатир комплексы интерьерының кайбер өлешләре яңартып торгызыла, күргәзмәгә шәхси әйберләре, китаплары, документлары куела. Музей экспозициясе ш.у. Печище авылы (1600 да нигез салына) тарихы һәм андагы тау эшләре (17 йөздән башлап) үсеше б-н таныштыра. Экспозициядә мөһим урынны «И.П.Оконишников һәм уларының сәүдә йорты» тарихы, пар тегермәне төзелеше, аның хуҗаларының биографиясе һәм язмышы турындагы материаллар алып тора. Шулай ук тегермәннең совет чорындагы эшчәнлеге чагылдырыла. Музейның кыйммәтле экспонатлары арасында Я.Купаланың «Белоруссия партизаннарына» («Белорусским партиза-



Янка Купала музее (тегермәнче И.П.Оконишниковның элеккеге контора бинасы).



Янка Купала музее. Экспозиция фрагменты.

нам») исемле шигырь язылган листовка (1942 дә Казанда басылып чыга), Печище тегермәне милектәше М.И.Оконишниковның һәм тегермәннең икенче директоры А.Алиевның мемориаль коллекцияләре бар.

Музей ел саен Халыкара музейлар көнен (18 май), Я.Купала туган көнне (8 июль), Белем (1 сент.), Игенчеләр бәйрәмен (10 окт.) уздыра.

Директоры — Р.Ю.Абызова (2003 тән).

*Әд.:* Д м и т р и е в а Л.П. Музей Янки Купалы в с. Печищи: Буклет. К., 1987; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1; «Песней только на свете живу я...»: Буклет. К., 2001; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1.

**КУПКА́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы бассейнында. 2010 елда 526 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 507 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 118, 1887 дә — 209, 1905 тә — 1085, 1920 дә — 1226, 1926 да — 1137, 1938 дә — 959, 1949 да — 680, 1958 дә — 608, 1970 тә — 583, 1979 да — 548, 1989 да — 487, 2002 дә — 483 кеше.

**КУПРИЯ́НОВ** Валерий Николаевич (29.6.1940, Мари АССРның Косолаповск р-ны Косолапово а.), төзелеш материаллары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), Россия архит-ра һәм төзелеш ФАнең мөхбир әгъзасы (1998), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2000). 1963 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, архит-ра-төзелеш ф-ты деканы (1975–81), ректор (1988–2008), архитектура (1994–2007), биналарны проектлау (2007 дән) кафедралары мөдире, проф. (1990). Хезмәтләре материаллар һәм конструкцияләрне климатик һәм дәвамлы чыдамлылыкка тиз рәвештә сынауларга карый. К. тиз рәвештә сынаулар үткәрү өчен күп кенә җайланмалар төзи. Алдан билгеләнгән эксплуатация шартларында материалларның файдаланылу вакытын бәяләү алымнарын эшли. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дуслык ордены б-н бүләкләнә, РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Плёночные сельскохозяйственные сооружения (опыт применения и долговечность). К., 1978; Плёночно-тканевые материалы для строительных конструкций. К., 1989; Строительные материалы. М., 2002 (автордаш).

**КУПРИЯ́НОВА-А́ШИНА** Флёра Гариф кызы (22.7.1935, Мамадыш р-ны Көек-Ерыкса а.), микробиолог, биол. фән. д-ры (1992), проф. (1996). 1958 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Мари витамин з-дының (Йошкар-Ола ш.) витамин $B_{12}$ цехында баш микробиолог. 1965–71 дә Свердловск вируслы инфекцияләр фәнни-тикшеренү ин-тында. 1972 дән Казан ун-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1985 тән). Хезмәтләре молекуляр биология һәм микробиологиягә карый. К.-А. микроорганизмнарның тереклек эшчәнлегендә һәм үсешне тизләтүдә экзоген нуклеодеполимеразаларның ролен (микроконцентрацияләрдә) билгели, бу исә биотехнологиядә кулланылучы (бакыр һәм тау рудасы чыгару сәнәгатендә, а.х.нда һ.б.) микроб массасы чыгышының артуына китерә. Аның тарафыннан микроорганизм культураларының үсешен шушы ферментлар б-н көйләүнең молекуляр-биол. механизмнары ачыклана. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм 3 патенты бар.

Х е з м.: Основы молекулярной биологии. К., 1986; Влияние дезоксирибонуклеаз на синтез ДНК, рост и деление клеток микроорганизмов. К., 1992; Стабилизация ферментов аутоиндукторами анабиоза как один из механизмов устойчивости покоящихся форм микроорганизмов // Микробиология. 2000. Т. 69, № 2 (автордаш).

**КУ́ПФЕР** Адольф Яковлевич (17.1.1799, Курляндия губ. Митава ш., хәзер Латвиянең Елгава ш. — 23.5.1865, С.-Петербург), физик, минералог, кристаллограф, метеоролог, РФА академигы (1828, 1826 елдан мөхбир әгъза), Петербург ФА академигы (1841), хакыйкый статский советник. 1815 елда — Дерпт, 1816 дан — Берлин, соңрак Гёттинген (бирелдә филос. д-ры дәрәҗәсе ала) ун-тларында укый. 1823–28 дә Казан ун-ты профессоры, 1823 тә проф. И.М.Симонов б-н бергәләп ун-тка физик һәм астрономик приборлар алу өчен Парижга командировкага җибәрелә; 1827 дә Казан магнит обсерваториясен төзү өчен рөхсәт ала һәм 1828 дә төзелеш эшләре б-н җитәкчелек итә. 1829 дан С.-Петербургта: минерал. музее директоры, Баш физик обсерваториягә нигез салучы һәм аның беренче директоры (1849 дан). Хезмәтләре физикага, минералогия, кристаллографиягә карый. К. беренче булып төрле минераллар-

ның (1821), кристаллик күкертнең (1824) төгәл кристаллографик үлчәмнәрен ала. Менгит минералын (К. хөрмәтенә купферит дип исемләнә) өйрәнә; металл эретмәләрен термик анализлауны кертә (1829); ике металлы эретмәләрнең (кургаш-аккургаш, кургаш-терекөмеш, аккургаш-терекөмеш амальгамалары һ.б.) чагыштырма авырлыгын һәм эрү темп-раларын үлчәүгә ирешә. Эвтектика хасил булган вакытта кургаш-аккургаш эретмәләрендә киңәю күренешен ачыклый. К.ның «Металлның сыгылучанлыгын сынап тикшерүләр» («Опытные исследования упругости металлов», СПб., 1860) дигән хезмәте металл эретмәләренең физик-механик үзлекләрен өйрәнүгә багышлана. Рус үлчәү системаларын тәртипкә салу буенча комиссия эшендә эшлекле катнаша (1835); магнитик һәм метеорологик күзәтүләрне оештыра; Россиядә беренче булып һава составына анализ ясый (1829). К.ның тырышлыгы б-н Россиянең төрле пунктларында метеорологик станцияләр төзелә. Лондон король җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы. 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Руководство к деланию магнетических и метеорологических наблюдений. СПб., 1841; Handbuch der rechnenden Krystallonomie. St. Peterburg, 1831.

*Әд.:* Р ы к а ч ё в М.А. Исторический очерк Главной физической обсерватории за 50 лет её деятельности, 1849–1899. СПб., 1899. Ч. 1; П а с е ц к и й В.М. Адольф Яковлевич Купфер, 1799–1865. М., 1984.

*Р.Г.Усманов.*

**КУПЦО́В** Александр Иванович (25.2.1955, Казан), драма актёры, ТРның халык артисты (2002). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1975, В.Г.Остропольский, В.В.Кешнер, В.М.Портнов класслы), Казан яшь тамашачылар театрына кабул ителә. Актёрның беренче рольләре үк башкарудагы табигыйлеге, гадилеге б-н аерылып тора: Шумилов («Сөйгәннәрегез белән аерылышмагыз», А.М.Володин), Фёдор Фёдорович («Укытучылар бүлмәсендә сөйләшүләр», Р.Э.Кац),



А.И.К у п ц о в Макар Девушкин («Мескеннәр», Ф.М.Достоевский романы буенча; сулда – Р.В.Хәйруллина) ролендә.

Шелонов («Казан университеты», Д.Н.Вәлиев), Юрий Леонидович («Гуманоид күктә җилдерә», А.Г.Хмелик). Макар Девушкин («Мескеннәр», Ф.М.Достоевский романы буенча) образында нечкә психологизм, персонажның рухи тормышын сурәтләүдә җентекле логик эзлеклелек сизелә; тышкы күренеше б-н төгәл һәм бер үк вакытта юаш образ күз алдына килеп баса; шул рәвешчә, актёр социаль яктан гомумиләштерелгән тирән мәгънәле характер тудыра. Образны иҗат иткәндә, яңача гәүдәләндерү принцибына таянып, билгеле тарихи чор үзенчәлекләре нигезендә шул заман кешесенең төс-кыяфәтенә хас детальләр куллана һәм беренче чиратта үз героеның рухи дөньясын ачып салуга зур игътибар бирә, һәр персонажында якты башлангыч эзли. Аның башкаруында Бессольцев («Бойкот», В.Железников), Шишок («Ямансулама, Шишок, мин кайтырмын»,




А.И.К у п ц о в Эзоп («Төлке һәм йөзем җимеше», Г.Фигейредо) ролендә.

А.Л.Александров), Древоед («Рядовойлар», А.А.Дударев), Байрулла («Погром», Б.Л.Васильев повесте буенча), дон Диего («Сид», П.Корнель) — шундыйлардан. Тальберг («Турбиннар көне», М.А.Булгаков), Шарлемань («Аждаһа», Е.Л.Шварц), Сганарель («Дон Жуан», Ж.Б.Мольер) образларында актёр, төрле сәнгатьчә сурәтләү чаралары кулланып, характерның күпкырлылыгын ача. Тирән фәлсәфи идеяләр б-н сугарылган Эзоп («Төлке һәм йөзем җимеше», Г.Фигейредо) образы актёр иҗатында зур сәнгати казаныш булып тора. РФнең «Алтын битлек» милли бүләгенә лаек булган «Давыл» (У.Шекспир) спектаклендә Алонзо ролен башкара (1993).


*Әд.:* Б л а г о в Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**КУПШЫЛЛА́Р** (Carduelis), тау чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 2 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк-көнбатыш Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре бар — кара башлы купшыл (C.carduelis). Бөтен районнарда очрый. Болын һәм сөргүле җирләр б-н чиратлашучы яфраклы һәм катнаш урманнарда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 12 *см* тирәсе, авырлыгы 20 *г* га кадәр. Аксыл төстә. Башының өсте,



А.Я.Купфер.



А.И.Купцов.

канатлары һәм койрыгы кара. Канатларында ачык сары зур таплар. Түше ак төстә, ачык-көрән 2 таплы. Томшыгы озын, очланган, ачык кызыл кечкенә каурыйлар б-н әйләндереп алынган. Утрак яшәү рәвеше алып баралар яки күчеп йөриләр, оя коруны тәмамлагач, төркемгә җыелалар. Оясын агачта ярымшар формасында ясый. Көрән таплы 4–5 зәңгәрсу йомырка сала. Чүп үләннәренең орлыклары, ш.у. бөҗәкләр б-н туклана.

**КУРА́ ҖИЛӘГЕ́**, роза чәчәклеләр семьялыгыннан Rubus ыругы яфрак коючы ярымкуакчыл үсемлек. 120 төре билгеле. ТРда 4 төре бар: күксел К.җ., яисә кара бөрлегән, сирәгрәк су баса торган урманнарда, сулыкларның яр буйларында очрый; ташчыл К.җ., яисә кызыл бөрлегән, урманнарда, башлыча, нарат урманнарында үсә; несская К.җ., яисә куманика — сазлыклы урманнарда, сазлык тирәләрендә үсә; гади, яисә кызыл К.җ., урман кисенделәрендә, янган урманнарда, сирәкләтелгән урманнарда таралган, йорт яны һәм бакча кишәрлекләрендә күпләп үстерелә. Кызыл, аксыл-саргылт һәм кара җиләкле (җимешле) сортлары очрый. Үсентеләре чәнечкеле, яфраклары парсыз каурыйсыман, өске өлеше яшел, аскы өлеше аксыл төстә. Чәчәкләре зур булмаган чуклы, ак; җимешләре — җыелма төшчекләрдән тора, өлгергәч, кәшәнкәдән җиңел аерыла. К.җ. тамыр үрентеләреннән, тамыр һәм яшел чыбыкчалардан куакны аеру ысулы б-н үрчетелә. Житештерүгә сәламәт утырту материалын меристема ысулы б-н алу (өске бөреләрне тамырландыру) кертелгән. К.җ. чагыштырмача кышка чыдам, уңдырышлы, кәсле туфракта яхшы уңыш бирә. Дым ярата. Май ахыры – июньдә чәчәк ата, июль–августта өлгерә. Икенче елда җимеш бирә башлый, 7–10 елга кадәр яхшы уңыш бирә. Уңышын җыеп алганнан соң, җимеш биргән, начарланган, зарарланган һәм артык үсентеләрен кисәләр, 1 *м* лы рәттә 15–20 үсенте калдыралар, рәт араларына органик һәм минераль ашламалар кертәләр.



Гади кура җиләге.

Кышка ботакларын җиргә таба бөгәләр, кайбер очракларда җир б-н каплыйлар. ТРда үстерелә торган сортлар: иртә өлгерешлеләр — «Новость Кузьмина» «Теньковская ранняя»; уртача өлгерешле — «Барнаульская» (2001). 1 *га* дан 80–120 *ц* уңыш алына. К.җ. — баллы, азык үсемлеге. Медицинада җиләкләре һәм яфраклары тир кудыру һәм темп-ра төшерү чарасы буларак кулланыла. Төп корткычлары — К.җ. коңгызы, К.җ. һәм каен җиләге озын борыны, гөбләләр, К.җ. чебене; авырулары — антракноз, тутык авыруы, күк черек, рак. К.җ.нә чормавык үләне зур зыян китерә.

**КУРА́ ҖИЛӘГЕ́ КОҢГЫЗЫ́** (Byturus tomentosus), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан кура җиләге коңгызлары семьялыгындагы коңгыз. Бөтен җирдә (Ерак Төньяк р-ннардан кала), ш.и. Татарстан терр-ясендә дә таралган. Культуралы һәм кыргый кура җиләген зарарлый. Сирәк кенә саз җиләге, кызыл бөрлегән, кара бөрлегән, алмагач, чия, груша, слива, миләш һ.б. роза чәчәклеләр семьялыгындагы үсемлекләрдә очрый. Гәүдәсе 3,8–4,3 *мм* озынлыкта, озынча түгәрәк, соргылт кара, җирән-сары яки соры төстәге куе төкләр б-н капланган. Мыекчалары 11 буынлы, чукмарсыман. Коңгыз һәм личинкалары туфракта, гадәттә, кура җиләге куаклары астында, 20 *см* тирәнлектә кышлый. Апрель ахыры — майның 1 нче яртысында, туфракның өске катламы 12–13 °С булганда, коңгызлар җир өстенә чыгалар. Башта алар культуралы (карлыган, крыжовник, алмагач, чия, груша, слива һ.б.), чүп үләннәрнең чәчәк нектары һәм серкәлеге б-н тукланалар, аннары кура җиләгенә (аерым елларда чәчәк бөресе чыкканчы) күчәләр, сеңерләр арасында тар озынча тишекләр тишеп, яшь яфраклар, аннан соң чәчәк бөреләре һәм чәчәкләре б-н тукланалар. Коңгызлар зыяны аркасында зәгыйфьләнгән чәчәкләрдән җимешләнгән җиләкләр гарип булып җитешә. Өстәмә туклану чоры якынча 2 атна дәвам итә, аннан соң ана затлар йомырка сала, аларны чәчәкләргә һәм чәчәк бөреләренә берәрләп урнаштыра. Личинкалары (6–6,5 *мм* озынлыкта, суалчансыман, аксыл көрән төстә) берникадәр вакыт яшел җимеш өслегендә яши, ә аннары аларны тишә, итчел чәчәк төбе һәм төшчекнең аңа тиеп торучы өлеше б-н тукланалар. Кура җиләге җимешендә личинкаларның үсеше якынча 1,5 ай дәвам итә. Личинкалар б-н зарарланган җиләкләр вак, тонык төстә, шиңә яки чериләр. Үсешен тәмамлаучы личинкалар җимештән төшәләр һәм туфракка күмеләләр, анда 5–20 *см* тирәнлектә курчакланалар. Августның 2 нче яртысы — сентябрьнең 1 нче яртысында яшь коңгызлар чыгалар һәм туфракта кышларга калалар.

**КУРА́Й**, озынча флейта тибындагы традицион татар милли тынлы музыка уен коралы. Исеме чатыр чәчәкле үсемлекләрнең куыш сабагы «кура көпшә»дән барлыкка килгән. К.лар бик күп төрле була (агач К., камыл К., җиз К., бакыр К.). Алар төрле материаллардан (чатыр чәчәкле үсемлекләр сабагыннан, сөяктән, мөгездән, металлдан) эшләнә һәм конструктив үзенчәлекләре б-н аерыла. Академик П.С.*Паллас*: «Татарлар үзләренең сыбызгысын ... «кура» дип атыйлар», — дип яза. К.ның мензурасы һәм тавышлар рәте халык музыкантларының гадәти берәмлекләр («тотым» — дүрт бармак киңлеге һәм «бармак киңлеге») үлчәме б-н билгеләнә. Алар традицион җирлектә барлыкка килгән һәм халык музыкасында ладлар төзелеше үзенчәлеген чагылдыра. К.ның үлчәме, аның төрләренә карап, 120–180 *мм* дан (камыл К.) 580–800 *мм* га кадәр (Казан К.е) үзгәреп тора. Кайбер уен коралларының (көпшә К., нугай К.е) озынлыгы, гадәттә, 8–9 кул тотымына кадәр җитә.

Көпшә К. (куыш сабактан ясалган ачык флейта) элек киң кулланылышта булган, хәзер Татарстан терр-ясендә сирәк очрый. Ике очыннан перпендикуляр рәвештә кисеп алынган куыш сабактан гыйбарәт. Сабакның аскы өлешендә ике бармак өчен тишек ясала, аларның аралары бармакларны җайлы куе б-н билгеләнә: беренчесе — сабакның аскы кырыеннан алты бармак киңлегендәге арада, икенчесе — беренче бармак тишегеннән биш бармак киңлегендә югарырак була. Уен коралының диаметры сайлап алынган сабакның калынлыгыннан гыйбарәт. Көпшә К.да уйнау өчен музыканттан махсус осталык таләп ителә. Паллас: «Уйнар өчен зур осталык кирәк. Әгәр дә анда оста уенчы уйнаса, шул чагында


Курай.

көпшә авазы кече флейта авазына охшый», — дип искә ала. Аваз чыгару принцибы буенча көпшә К. тавышы күп кенә төрки халыкларның тынлы уен коралы тавышына охшаш. Анда уен коралы мензурасына бәйләнгән билгеле бер тональлектә күптөрле тембрларның һәм диатоник аваз рәтләрнең барлык тавышларын чыгарырга мөмкин. Диапазоны өч октавага кадәр җитә. Мелизмнарны киң кулланып, К.ның матур яңгырашына ирешеп була. Көпшә К.да төрле штрихларны (legato, non legato, staccato) уйнап була.

Нугай К.е — сызгыра торган тәрәзәчеге һәм аваз чыгара торган ике тишеге булган озынча флейта. Хатын-кызларның музыка уен коралы. К.ны ясау процессына берничә операция керә, аларны башкару өчен белем, тәҗрибә, эстетик зәвык таләп ителә. Материалны сайлап алуга аеруча әһәмият бирелә. Далалы районнарның калкулыклы, таулы урыннарында үскән куыш сабак сыйфатлы санала. Уен коралының озынлыгы якынча 690–775 *мм*, уйный торган тишекләрнең арасы бармаклар киңлегендә (беренчесе — сабакның төбе кырыеннан биш бармак киңлегендә, икенчесе — беренче тишекнең өске кырыеннан дүрт бармак киңлегендә). Нугай К.енда бишкә кадәр табигый аваз чыгарып була. Диапазоны — 2,5 октава, тембры чиста, тавышы кискенрәк, динамик мөмкинлеге — p дан алып — f га кадәр. Бу уен коралының физик үзенчәлеге күптөрле характердагы татар халык җырларын һәм бию көйләрен башкарырга мөмкинлек бирә, аның моң һәм лад үзенчәлекләре нугай К.е үзенчәлеге б-н бәйләнгән.

Агач К. — чикләвек куагы, өрәңге, балан агачы ботакларыннан эшләнгән агач көпшә. Аның югары өлешендә сызгыра торган җайланмасы бар, икенче ягында дүрттән алып алтыга кадәр тавыш чыгара торган тишекләр бораулап тишелә. Мондый К.ны ясау өчен 250–300 *мм* озынлыктагы, диаметры 20–25 *мм* булган агач сайлап алына; борау б-н уелган соң, тишекләрнең диаметры 12–15 *мм* тәшкил итә. Сызгыру җайланмасы югары очыннан 10–15 *мм* ара калдырып ясала. Тавыш чыгара торган тишекләр сыбызгылы тәрәзәнең капма-каршы ягында бораулана. Аларның саны оста музыкант тарафыннан башкарылачак репертуарга карап билгеләнә. Тавыш чыгара торган дүрт тишекле агач К. пентатоникага корыла, ә инде алты тишеклесе, кагыйдә буларак, диатоник тавыш рәтле була. Уен коралының тавышы көчле, сызгыра торган, ачык тембрлы. Түбән регистрның динамик мөмкинлеге — mp-mf, югарыныкы — ft. Диапазоны — 2,5 октава. Хәзер бу төр К. сирәк кулланыла.

Җиз К. (сызгыра торган ярыклы флейта) — цилиндрсыман җиз көпшәдән эшләнә. 260–265 *мм* озынлыкта, диаметры 20–23 *мм*. Сызгыру җайланмасы бар. Гадәттә, бу уен коралы җиде тавыш чыгара торган тишекләрдән тора: алтысы — уң ягында, берсе — аста урнашкан. Һаваны аз гына өрү дә чиста һәм тотрыклы тавыш чыгара. Тембры ачык, диапазоны 2,5 октава, тавыш рәте диатоник.

Казан К.е — сызгыра торган озынча флейта. Конуссыман металл көпшәдән ясалган, биш, алты һәм җиде тавыш чыгара торган тишекләре булган уен коралы. Аның акустик тавышы көпшәнең озынлыгына, формасы һәм калынлыгына бәйле. Казан К.еның якынча озынлыгы — 580–800 *мм*, көпшә очының диаметры — 20–30 *мм*, аскы өлеше — 10–15 *мм*. Мондый мензурада уен коралының үзенчәлеге көпшә К.ның табигый тавыш параметрларына якыная. Казан К.еның тавыш рәтләре бүленеше нигезендә обертон тавышларның тембрлы сыйфатлары ята. Төп обертон регистрының тавышы шомлы драматик төсмергә ия. Төп регистр киң яңгырашлы көйләрне дә, виртуоз мелодияләрне башкарырга да мөмкинлек бирә. Уен коралының югары регистрында тембр төсмерләре яктыра. Казан К.еның тавыш рәтләре диатоник. Ул өч октавага кадәр җитә. Динамик мөмкинлеге — pp — f. Хәзер Казан К.е югары акустик сыйфатлы заманча материаллардан ясала һәм осталарга яхшы сыйфатлы музыка уен коралларын эшләргә мөмкинлек бирә. Дюралюминий, текстолит, карболиттан цилиндр формасында эшләнгән, 7 тишеге һәм диатоник тавыш рәте булган уен кораллары бигрәк тә киң кулланыла.

Камыл К. — саламнан ясалган бер телле аэрофон. Бер башы табигый буынтык б-н ябылган 120–180 *мм* озынлыктагы, диаметры 3–3,5 *мм* булган арыш, бодай яисә арпа сабакларыннан эшләнә. Көпшәнең ябык өлешеннән 8–10 *мм* арада озынлыгы 20–25 *мм*, киңлеге 2,5–3 *мм* булган сыбызгы — тел кисеп алына. Уен коралы мензурасы гадәттәгечә билгеләнә. Беренче тишекнең югары чиге сабакның ачык өлешеннән зур бармак киңлегендәге арада калдырыла. Бүтән тишекләр арасы алдагы тишекләрдән башка бармаклар киңлеге кадәр билгеләнә. Тавышның динамик мөмкинлеге һәм интонацион тотрыклылыгы турыдан-туры һава өрү көченә бәйләнгән. Тавышның көче p дан f га кадәр үзгәрә. Тембры йомшак, ягымлы; диапазоны — секста-октава; лады — пентатоник. Осталар уен коралын диатоник тавыш рәте б-н ясыйлар. Камыл К.ның техник мөмкинлеге анда салмак һәм күтәренке рухлы көйләрне зур булмаган диапазонда уйнарга мөмкинлек бирә. Салмак көйләр бай бизәлеш ала. Мондый К.да башкарыла торган көйләрдә сикерешле алымнар юк диярлек. Уен коралы кыр эшләре вакытында яшьләр, көтүчеләр арасында популяр булган. Камыл К. соңрак кулланылыштан төшеп калды.

*Әд.:* Габәши С. Татарстанда курайчылар һәм гармунчылар // Атака. 1932. № 1; Паллас П.С. Путешествие по разным провинциям Российской империи. СПб., 1809. Ч. 1; Махмудов М. Практическое руководство к изучению татарского языка. К., 1858; Нигмедзянов М.Н. Народная музыка // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Шулук. Татарские музыкальные инструменты // Музыкальная фольклористика. М., 1978. Вып. 2; Халитов Р.Ф. К изучению татарского народного инструментария: Татарские народные духовые инструменты // Актуальные вопросы татарской музыки. К., 1980; Шулук. Татарские народные музыкальные духовые инструменты: Описание и методика изготовления. К., 1992; Яковлев В.И. Традиционные музыкальные инструменты народов Среднего Поволжья. К., 1991. *Р.Ф.Халитов.*

**КУРА́Й ҮЛӘНЕ́** (Angelica), чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан ике- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — урман К.ү. (A. sylvestris) бар. Республиканың барлык терр-ясендә: урман аланнарында, кисенделәрдә үсә. 90–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабагы көпшәсыман, күк төстәге кунык б-н капланган. Яфраклары икешәр, өчәр каурыйсыман, өскеләре — нык кабарынкы җиңсәле. Чәчәкләре вак, ярымшарсыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — сaлынкы җимешлек. Июнь–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Тамырларында — эфир мае, аскорбин к-тасы, яшел өлешләрендә протеин, бор, тимер, бакыр һ.б. матдәләр бар. Халык медицинасында тамыр төнәтмәсе үпкә ялкынсынуы вакытында кулланыла. Үсемлекнең яшь сусыл өлешләре ашарга яраклы. Баллы үсемлек.

**КУРА́Й-ЕЛГА́**, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 12,7 *км*, бассейнының мәйданы 92,8 *км*². Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Әгер авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Тымытык авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. К.-е.ның 8,2 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, ятрысыннан күбрәге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу агымы катламы 65 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артык. Елгада су күләме 0,7 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КУРА́ЙЛЫ ЕЛГА́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 22 *км* төньяктарак, Ык елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 25 кеше (татарлар) яши. 1928 дә Зур Сукаеш авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 212, 1949 да — 165, 1958 дә — 138, 1970 тә — 147, 1979 да — 81, 1989 да — 29, 2002 дә — 25 кеше.

**КУРА́К** (Phragmites), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 5 төре билгеле, күбрәк тропикларда таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади К. (башаклы камыш) (P. australis, яки communis) барлык районнарда очрый. Сулык ярлары буенда, сазлыкларда һәм сазлыклы болыннарда, урманнарда куе булып үсә. 50–200 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы озын, бик тармаклы. Сабагы туры, куыш, калын, яфраклы, күпсанлы буыннардан тора. Яфраклары — кыяк, зәңгәрсу-яшел, ясы, каты, кытыршы читле. Яфрак төбендә каты туры төкчәләр бәйләме бар. Чәчәк ату вакытында себеркәче җәелеп китә, төсен орлыкларның өлгерү дәрәҗәсе буенча үзгәртә (алтынсу көрәннән көмешсыман акка кадәр). Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре көзен өлгерә. Тамырчалардан үрчи. Яшь үсемлекләр — терлек азыгы. Ондатра һәм нутрия өчен азык булып тора. Ярларны ныгыту, чыпта үрү өчен, чәчәкләрен кипкән букетлар ясаганда кулланалар. Кайвакыт К.ны *камыш* б-н бутыйлар.



Гади курак.

**КУРА́КИН** Григорий Семёнович (? — 1679 дан соң), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1651). 1629 елдан — дәүләт, 1654 тән хәрби хезмәттә. Вязьма (1638), Венёв (1641), Тобол (1643–44), Ливны (1647–49), Новгород (1657–61), Севск (1668–69) шәһәрләрендә воевода. 1662–68 елларда Казанда 1 нче воевода. 1663 тә баш күтәргән башкортларга каршы юнәлдерелгән яуларда, *Кама аръягы иске чик сызыгын* саклауда катнаша; илчелек хезмәтләренә билгеләнгән судноларны кирәк-яраклары сатып алу б-н шөгыльләнә. 1667–68 елларда К. С.Т.Разин җитәкләгән казак отрядлары б-н көрәшә. Максаты «аларны Иделдән куу һәм диңгезгә уздырмау» була. 1669 дан Мәскәүдә.

*Әд.:* Корсакова В.Д. Список начальствующих лиц в городах теперешней Казанской губернии. К., 1908; Ермолаев И.П. Казанский край во второй половине XVI–XVII вв.: Хронол. перечень док-ов. К., 1980. *Е.Б.Долгов.*

**КУРА́КОВО** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 41 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1755 елдан мәгълүм. Халкы башта Казан *Седмиозёрный пустыне* карамагында, 1764 тә — экономик крәстияннәр, 1841 дә дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, 1781 дә Воткинск тимер эшкәртү з-дына беркетелә. Игенчелек, терлекчелек, олаучылык, Самара губернасында йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, К.да волость идарәсе урнаша; Козьмодемьянск чиркәве (1812–19 елларда төзелә; архит-ра ядкәре), земство мәктәбе (1845–1871 дә Дәүләт милке министрлыгы карамагында), ашлык саклау-сату кибете, кабак, 2 тегермән, 2 кечкенә базар эшли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Куралово волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсенә керә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1781 дә — 116 ир-ат; 1836 да — 349, 1859 да — 429, 1887 дә — 617, 1905 тә — 697, 1920 дә — 638, 1926 да — 631, 1938 дә — 588, 1949 да — 374, 1958 дә — 310, 1970 тә — 209, 1979 да — 236, 1989 да — 86, 2002 дә — 53 кеше.

**КУРА́ЛОВО** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 52 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 403 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 83%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Алпавыт Молоствовларның утар йорты (19 йөзнең 1 нче яртысы архит-ра ядкәре). 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Городище исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Преображение чиркәве, земство (1864 тә ачыла) һәм чиркәү-приход мәктәбе (1893 тә ачы-




Р.С. Курамшин. П.С. Курасанов.

ла), 3 җил тегермәне, тимерчелек, 1 зур һәм 3 кечкенә кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1452,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ширбәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 1 апреленнән — Куйбышев, 1991 нең 5 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 314 ир-ат; 1859 да — 789, 1897 дә — 1018, 1908 дә — 1108, 1920 дә — 1362, 1926 да — 1258, 1938 дә — 894, 1949 да — 623, 1958 дә — 848, 1970 тә — 634, 1979 да — 620, 1989 да — 541, 2002 дә — 450 кеше.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**КУРА́ЛОВО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 1210 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау, яшелчәчелек. Крахмал җитештерү комб-ты. Урта мәктәп. «Сулица» ял итү үзәге, сәнгать мәктәбе, китапханә. Чиркәү. 1646 елдан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, балта эше, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да земство мәктәбе (1884 тә ачыла), 5 җил һәм 1 пар тегермәне, спирт-аракы һәм сыр з-длары, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1445 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 221 ир-ат; 1859 да — 867, 1908 дә — 863, 1926 да — 893, 1938 дә — 1292, 1958 дә — 1284, 1970 тә — 1252, 1979 да — 1373, 1989 да — 1249, 2002 дә — 1181 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый ... . К., 2001.

**«КУРА́ЛОВО»**, Югары Ослан р-ныңдагы совхоз. 1918 елда В.В.Обуховның алпавыт утары терр-ясендә оештырыла. Үзәк утары — Куралово авылы. 1957 дә «Куралово»га «Победитель», «Смычка», «Пробуждение», «Красная Горка», 1976 да «Свияга» с-зы, «Волга» к-зы берләштерелә. 1970 елларда «К.» ТАССРда иң эре хуҗалыкларның берсе була, а.х. файдалану җирләренең мәйданы — 12794 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 9721 *га* тәшкил итә. Төп җитештерү тармаклары — терлекчелек, ш.и. дуңгыз асрау. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 15–20 *ц*. Савым 1 сыердан якынча 3 мең *кг*. «К.» югары җитештерү һәм икътисади күрсәткечләре б-н билгеле. Республикада беренче булып фермалардагы авыр хезмәт процесслары механикалаштырыла, хезмәтне оештыруда Щёкин алымы кертелә. 1980 елларда күп социаль-хезмәт объектлары төзелә. 1979 да җирләрнең бер өлешендә «Новая жизнь» с-зы, 1988 дә «Зелёный Бор» с-зы оештырыла, соңгысы 2001 дә бетерелә, аның җирләре «К.» с-зына кушыла.

2001 дә «К.»да 8,5 мең *т* бөртекле ашлык җитештерелә, 1 *га* дан 25,8 *ц* уңыш алына. Табышлылык 9% тәшкил итә.

Совхоз эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. ТРның мактаулы исемнәре — 5 кешегә; Ленин ордены — 3, Октябрь Революциясе — 1, Хезмәт Кызыл Байрагы — 7, «Почёт билгесе» — 5, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» орденнары — 2; СССР ВДНХсының бронза медале — 2 кешегә бирелә. Совхозның беренче директоры — М.И.Верещагин (1918–32). Төрле еллардагы җитәкчеләре: Ф.О.Дефлер (1941–45), Т.Х.Никифоров (1947–51), Е.А.Житков (1951–55), Е.И.Борисов (1955–66), В.А.*Ахтонов* (1966–79), А.Я.Иванов (1979–97), И.Г.Әхмәтҗанов (1997 дән). 2002 дән совхоз «Ышанычлылык ширкәте һәм К° Әхмәтҗанов» — «Куралово» агрофирмасы» итеп үзгәртелә, 2003 тә «Кызыл Шәрекъ» агросәнәгать комплексы составына кертелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**«КУРА́ЛШӘ»** («Сукачы»), а.х. журналы. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан шәһәр советы каршындагы мари бүлекчәсе органы. 1918–19 елларда Казанда мари телендә нәшер ителә.

*Әд.:* П а ш у к о в В.Ф. Марийский край в годы гражданской войны. Йошкар-Ола, 1965; С е р г е е в М.Т. Возникновение и развитие печати Марийской АССР. Йошкар-Ола, 1971.

**КУРА́МШИН** Искәндәр Якуп улы (6.3.1947, Казан — 6.5.2006, шунда ук), педагог, химик, химия фән. канд. (1973), пед. фән. д-ры (1993), проф. (1993), ТАССР, РФнең атказ. мәктәп укытучысы (1990, 2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли (1973 тән). 1976 елдан СССР ПФАнең Проф.-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында (соңрак РМА урта проф. белем бирү ин-тында), лаб. мөдире (1981 дән). 1995 тән Казан технол. ун-тында, өстәмә белем бирү ф-ты деканы (1998 дән), бер үк вакытта ТР Мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү ин-тында табигыять фәннәрен укыту методикасы каф. мөдире (1992 дән). Хезмәтләре элементорганик химия, химияне укыту методикасы, югары мәктәп укытучыларын проф. әзерләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Концепция химического образования в средних специальных учебных заведениях. М., 1992; Методологические и методические основы профессионально-педагогической подготовки преподавателя высшей технической школы. К., 1997 (автордаш); Учебно-программное обеспечение профессионально-педагогической подготовки преподавателя высшей школы. К., 1997.

**КУРА́МШИН** Наил Сафатдин улы (3.2.1942, Буа ш.), фотожурналист, ТАССР, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1981, 1998). 1961–63 елларда Казан авиация ин-тында укый, бер үк вакытта Казан авиация з-дында радист-оператор булып эшли. 1975 тә Казан ун-тын тәмамлый. 1963–65 тә ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында тавыш операторы. 1965–68 дә «Ялкын» ж-лының штаттан тыш хәбәрчесе, 1969 дан «Советская Татария» («Республика Татарстан») г-тасы фотохәбәрчесе. К.ның фоторепортажлары Татарстанның әйдәп баручы басмаларында, «Правда», «Известия», «Труд» г-таларында, «Огонёк», «Коневодство» һ.б. ж-ларда урын ала. К. иҗатының төп темасы — кешенең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормыштагы роле, бүгенге чорның тиз үзгәрүчән шартларында шәхес асылының чагылышы.

*Әд.:* К о ж е в н и к о в а Н.В. В объективе — личность // Республика Татарстан. 2002. 31 янв.; Фотогалерея «А и Ф» // Аргументы и факты. Регион. 2002. № 5.

**КУРА́МШИН** Рамил Сөләйман улы (16.7.1947, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Кучкай Пожар а.), баянчы, педагог. ТРның халык артисты (2001). 1968–94 елларда Татар филармониясе солисты һәм аккомпаниаторы, 1995 тән «Казан» милли мәдәният үзәге солисты. Баян өчен татар халык көйләренә эшкәртмәләр, концерт пьесалары (Баян һәм оркестр өчен концерт, Баян һәм оркестр өчен концертино һ.б.) авторы. Баянда виртуоз башкаруы, татар халкының муз. иҗатын тирән белүе К.га Татарстан инструменталист-башкаручылары арасында әйдәп баручыларның берсе булырга һәм киң популярлык яуларга мөмкинлек бирә.

**КУРАМЬЯ́Л** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 29 *км* төньяктарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөз ахырында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет (1835 тә төзелә) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 427 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1795 тә — 67, 1834 тә — 101, 1850 дә — 178, 1859 да — 176, 1884 тә — 283, 1905 тә — 245, 1920 дә — 407, 1926 да — 344, 1949 да — 187, 1958 дә — 235, 1970 тә — 144, 1979 да — 119, 1989 да — 59, 2002 дә — 66 кеше.

**КУРАСА́НОВ** Пётр Семёнович (25.1.1917, Самара губ., Бөгелмә өязе Чирмешән а. — 14.2.2008, Омск ш.), генерал-майор (1961), Сов. Союзы Герое (31.5.1945). Смоленск артиллерия уч-щесен (1941), Югары офицерлар артиллерия мәктәбен (Мәскәү, 1951) тәмам-

лый. Кызыл Армия сафларына чакырылганчы (1937), Казан укытучылар ин-тында укый, район халык мәгарифе бүлегендә инспектор булып эшли. 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, танкларга каршы көрәшүче артиллерия полкы командиры урынбасары. К. 1945 нең апрель–май айларында Берлин терр-ясендә барган сугышларда һәм дошман оборонасын өзгәндә батырлык күрсәтә. 1951–65 елларда Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара. Омск шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Шлевко Г.М. Ради жизни на земле. Омск, 1972; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

**КУРА́Т** Әкъдәс Нигъмәт (Нигъматов Әкъдәс Таһир улы) (22.4.1903, Уфа губ., Минзәлә өязе Бәркәтә а. — 8.9.1971, Төркия, Истанбулда җирләнә), тарихчы, филос. д-ры (1933). Бөгелмә гимназиясен (1920), Истанбул ун-тын (1929) тәмамлый. 1921 елда «*АРА*» иҗтимагый хәйрия-ярдәм оешмасы эшендә катнаша. 1924 тән Төркиядә. 1929–33 тә Германиядә фәнни командировкада. 1933–37 дә Истанбул ун-тында укыта. 1939 дан Гази пед. ин-тында (Әнкара), проф. (1944), тел, тарих һәм геогр. ф-ты деканы (1953–55). 1946 дан Англия, АКШ, Австралия, Бразилия, Мексика һ.б. илләрдә фәнни-тикшеренү эшләре б-н еш кына командировкаларда була. Алтын Урда һәм Кырым ханлыгы хөкемдарларының (Олуг Мөхәммәд, Хаҗигәрәй һ.б.) хат-ярлыкларын бастырып чыгара. Хезмәтләре Көнчыгыш Европада яшәгән төрки халыклар тарихына карый.

Хезм.: Topkapı Sarayi Müzesi Arşivindeki Altın Ordu, Kırım ve Türkistan Hanlarına ait yarlık ve bitikler. Ist., 1940; Rusya, Türkiye ve Idil Boyn. Ankara, 1966.

*Әд.:* Октай А. Ататөркнең университет реформасында казанлы остазларыбыз // Мәгариф. 2001. № 12; Шәрәфетдинов Ф. Һиҗрәттәге бөек милләттәшебез // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 3/4; Prof. Dr. Kazim Yaşar Kopraman. «Hokam Profesör Doktor Akdes Nimet Kurat» // Turk Dunyası aydınları Sempozyumu Bildirileri (23–26 Mayis, 1996). Kayseri, 1996.

*Ф.Х.Шәрәфетдинов.*

**КУРАШО́В** Владимир Игнатьевич (1.12.1951, Казан), философ, химия фән. канд. (1980), филос. фән. д-ры (1993), проф. (1994). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казан технол. ун-тында (бүленеп, 1982–88 дә «Вакууммаш» фәнни-җитештерү берләшмәсенең фәнни-тикшеренү лаб-ясендә) филос. каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре фән һәм техника философиясе, танып белү теориясе һәм онтология, фәнни логика һәм методология, милли үзаң, химия, физика өлкәләренә карый.

Хезм.: Химия на перекрёстке наук. М., 1989 (автордаш); Познание природы в интеллектуальных коллизиях научных знаний. М., 1995; Философия: Познание мира и феномены технологии. К., 2001; Философия: Человек и смысл его жизни. К., 2001; Теоретическая и практическая философия в кратчайшем изложении. К., 2003.

*Әд.:* Алексеев П.В. Философы России XIX–XX столетий. М., 2002.

**КУРАШО́В** Сергей Владимирович (1.10.1910, Тамбов губ. Ключики а. — 27.8.1965, Мәскәү), социаль гигиена белгече, сәламәтлек саклау эшлеклесе, мед. фән. д-ры (1963), СССР МФА мөхбир әгъзасы (1965), ТАССРның атказ. табибе (1940). 1931 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук психиатрия кафедрасында эшли, 1935–36 да клиниканың баш табибе; бер үк вакытта 1931–35 тә наркология диспансеры мөдире, 1931–32 дә ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының дәвалау буенча инспекторы; 1936–41 дә Казан психиатрия хастаханәсе баш табибе, өлкән психиатры. 1942 дән РСФСР сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары; 1946 дан СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Баш курортлар идарәсе башлыгы, 1951 дән Баш уку йортлары идарәсе башлыгы. 1953 тән СССР сәламәтлек саклау министры урынбасары, 1955 тән РСФСР сәламәтлек саклау министры һәм 1 нче Мәскәү мед. ин-тының көнкүреш гигиенасы һәм сәламәтлек саклауны оештыру каф. мөдире, 1959–64 тә СССР сәламәтлек саклау министры. Хезмәтләре мед. белеме бирүне үзгәртеп коруга, халыкка дәвалау-профилактика ярдәме күрсәтүне яхшыртуга, йогышлы авыруларны булдырмауга, курортологиягә карый. «СССР һәм союздаш республикаларның сәламәтлек саклау турындагы законнары нигезләре» («Основы законодательства Союза ССР и союзных республик о здравоохранении», 1969) авторларының берсе. СССР мед. уку йортларында социаль гигиена (1966 дан социаль гигиена һәм сәламәтлек саклау) укыту дисциплинасын, соңрак мед. статистикасы дисциплинасын кертүдә башлап йөрүчеләрнең берсе. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының 5 нче ассамблеясы президенты (1962). «Здоровье» ж-лының беренче мөхәррире. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 1965–94 тә Казан мед. ин-ты К. исемен йөртә. Казан урамнарының берсенә аның исеме бирелгән.

Хезм.: Состояние психоневрологической помощи в СССР и пути ее дальнейшего развития // Журн. невропатологии и психиатрии. 1963. Т. 63, вып. 9.

*Әд.:* Трофимов В.В. С.В.Курашов — выдающийся теоретик и организатор социалистического здравоохранения // Здравоохранение РФ. 1986. № 1.

**КУРБА́ТОВ** Владимир Анатольевич (2.6.1948, Калуга өлкәсенең Перемышль а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1985), проф. (1989), ТАССРның атказ. химигы (1984). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, «Түбәнкаманефтехим» ҖБдә эшли, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә эшләре идарәсе башлыгы. 1988–91 елларда СССРның Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе министрлыгында баш фәнни-техник идарә башлыгы, 1991 дән күп кенә фәнни-тикшеренү фирмалары җитәкчесе (Мәскәү). Хезмәтләре полимерлар химиясенә карый. К. фосфорорганик стабилизаторларны синтезлый, аларның реакцияләренең кинетикасын һәм механизмын өйрәнә. Термик полимерлаштыру механизмының теоретик нигезләрен тәкъбирли, мономерларның үзлегеннән тирбәнеп полимерлашу күренешен ача. Мономерларны сәнәгый аерып алу процесслары өчен полимерлашу ингибиторлары булдыруның алгоритмын эшли. Ректификация ысуллары б-н ясалма каучук мономерларын аерып алганда химик реакцияләрнең тизлеген киметүче яңа системаларны эшләгәне һәм сәнәгатькә керткәне өчен Ленин комсомолы бүләгенә лаек була. СССР Дәүләт бүләге нефтехимик синтез, сәнәгый катализ, ясалма каучук мономерлары җитештерүдәге яңа интенсив алымнар эшләгәне һәм сәнәгатькә керткәне өчен бирелә (1989). Фәнни эшләнмәләре «Түбәнкаманефтехим» АҖдә, Эстәрлетамак ясалма каучук з-дында һ.б. нефть химиясе пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 85 авторлык таныклыгы бар.



С.В. Курашов.

Хезм.: Термическая полимеризация стирола и её ингибирование // Высокомолекулярные соединения. 1982. Т. 24А, № 7; Термическая полимеризация и олигомеризация мономеров // Успехи химии. 1987. Т. 46, № 5; Перспективные нефтехимические процессы и новые продукты // Журн. Всесоюз. хим. об-ва им. Д.И.Менделеева. 1989. Т. 34, № 6.

**КУРБА́ТОВ** Хәлиф Рәхим улы (28.2.1927, ТАССРның Минзәлә кантоны Иске Богады а. — 16.7.2005, Казан), тел галиме, филол. фән д-ры (1993). Пермь ун-тын тәмамлый (1950). 1953 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (хәзер ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты). Хезмәтләре алфавит тарихы, татар әдәби теленең стилистикасы, поэтикасы, орфография мәсьәләләренә карый. «Татар теленең алфавит һәм орфографиясе тарихы» (1999) китабында татар язуының борынгы руннан башлап хәзергәчә тарихы тасвирлана. «Сүз сәнгате: татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы» (2002) китабында К. татар теленең фәнни һәм сөйләм стильләренең фонетик һәм лексик үзенчәлекләрен, стилистик фигураларның (анафора, антитеза, градация һ.б.) функцияләрен фәнни яктан тикшерә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Татар теленең стилистик системасы. К., 1971; Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Шигырь энҗеләре ничек барлыкка килә. К., 2002; Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М., 1978; Ритмика татарского стиха. К., 2005.

*Әд.:* Нигматуллин А.З. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика // Вопр. языкознания. 1990. № 3.

**КУ́РБСКИЙ** Андрей Михайлович (1528–83, Ковель ш.), кенәз, сәяси һәм хәрби эшлекле, язучы-публицист, Казанны яулап алу вакытында һәм Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, илдә җирле халыкның баскыннарга каршы көрәшен бастырган рус гаскәрләре башлыкларының берсе. 1540–50 елларда Иван IV нең аеруча якын кешеләре арасында була, адм. һәм хәрби вазифалар башкара, Рус дәүләтенең рәсми булмаган «Избранная Рада» хөкүмәте әгъзасы. Анда хөкүмәт сәясәтенең төп юнәлеше — Казан ханлыгын юкка чыгару һәм Идел буен кушу була. *Казанга рус дәүләтенең яуларында* (1545–52) катнаша. Казанны камаган вакытта (к. *Казанның яулап алынуы*) ул рус гаскәрләренең «уң кул»ы б-н җитәкчелек итә, шәһәргә хәлиткеч һөҗүм вакытында, 2 октябрьдә, аның полкы мөһим урыннарның берсендә — Казансу ярыннан Кремльнең Алабуга (соңрак Воскресение) капкасына ташлана. *Казан җирләрендә азатлык сугышлары* (1552–56) башлангач, К. җәза отрядлары б-н җитәкчелек итә. Бу отрядлар Урта Идел буенда яшәгән төп халыкларның русларга каршы көрәшен бастыру өчен җибәрелә. Шундый яуларның берсе турында К. соңрак: «... алар артыннан 1 ай куып йөрим, ә безнең алгы полклар алар артыннан Уржум һәм Мет елгасына хәтле, калын урманнар артына кадәр, ә аннан хәтта Кама елгасыннан югарыга — Себергә хәтле сузылган башкорт җирләренә кадәр барды... Шуннан соң басурманнарның 10 меңнән артык кешелек гаскәрен аларның башлыклары б-н бергә юк иттек», — дип яза.

1556 да К. бояр чины б-н бүләкләнә һәм Балтыйк буендагы рус гаскәрләренең башлыгы итеп билгеләнә. Ливон сугышы (1558–83) вакытында 1562 дә Витебскига каршы барган яу б-н җитәкчелек итә. Әмма Иван IV нең җәзалар һәм үч алу б-н янаулары көчәю сәбәпле, К. 1564 тә Польша короле һәм Литваның бөек кенәзе Сигизмунд II Август янына качарга мәҗбүр була, Сигизмунд үз чиратында аңа Литва һәм Волыньдагы, ш.и. Ковель шәһәрендәге бернечә утарны бүләк итә. 1564 нең сентябрендә К. Россиягә каршы сугышта катнаша. Соңрак сәяси эшчәнлектән читләшә. Иван IV кә юллама (1564) һәм дүрт хат авторы. Аларда ул патшаны аклап булмаслык явызлыкта гаепли.

1573 тә К. «Мәскәүнең бөек кенәзе турында тарих» («История о великом князе Московском») китабын яза. Анда ул Казанга каршы яулар, шәһәрне дошманнардан саклауны оештыру эшләре, шәһәр сакчыларының батырлыклары һәм дәүләтнең байлыгы турында тәэсирләнеп яза: «... Ул җирләрдә кырлар киң һәм иркен, бакчалар мул һәм җиләк-җимешкә бай, — ди ул. — Кенәз кызлары һәм зур түрәләрнең сарайлары искиткеч матур һәм, чыннан да, сокланугa лаек, авыллар да бихисап; ашлыкның нинди генә төре юк, әйтеп бетергесез...; мал-туар һәм байлыкның иге-чиге юк...».

К.ның 1833, 1842, 1868 елларда тарихчы Н.Г.Устрялов редакциясендә басылып чыккан «Кенәз Курбский риваятьләре» («Сказания князя Курбского», Ч.1–2, СПб., 1833) дип исемләнгән хезмәте Казан, чуаш, мари һәм Урта Идел буе татарлары турында язылган әһәмиятле чыганак булып тора.

Хезм.: Переписка Ивана Грозного с Андреем Курбским. Л., 1979.

*Әд.:* Горский С. Жизнь и историческое значение князя А.М.Курбского. К., 1858; Устрялов Н. О жизни и сочинениях князя Курбского. СПб., 1868; Петровский М. «Князь А.М.Курбский. Историко-библиографические заметки по поводу его Сказаний» // Уч. зап. Казан. ун-та. 1873. № 6; Скрынников Р.Г. Переписка Грозного с Курбским: Парадоксы Эдварда Кинана. Л., 1973; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995. *Г.С.Сабирҗанов.*

**КУ́РБСКИЙ** Глеб Петрович (24.7.1918, Түбән Новгород — 25.7.1996, Казан), нефтехимик, химия фән. канд. (1966). Горький ун-тын тәмамлый (1941). 1941–49 елларда тоткынлыкта була, ГУЛАГның гидролиз-чүпрә з-дында (Горький өлкәсе) химия производствосы цехы башлыгы, техник җитәкче булып эшли. 1947 дән Ухта нефть эшкәртү з-ды лаб-ясенең фәнни-тикшеренү төркемендә, 1956 дан Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе (хәзер РФ Табигый ресурслар министрлыгының Ухта геол. экспедициясе) мөдире. 1958 дә аклана. 1966 дан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, нефть химиясе лаб-ясе мөдире (1979 га кадәр). К. Татарстан һ.б. төбәкләрдәге 150 дән артык чыганактагы нефть һәм битумнарның геохимик һәм химик составын һәм үзлекләрен өйрәнә. Россия нефтен классификацияләү принципларын тәкъдим итә. Нефтьнең геохимик типларын идентификацияләү ысулларын эшли. Аның җитәкчелегендә җилләнеп ашалган, биодеградирланган, икенчел күкертләндерелгән нефтьләрне идентификацияләү методикасы; битумогенез линиясе продуктларын экспресс классификацияләү методикасы, калдык нефтьне өйрәнү программасы эшләнә. К. җитәкчелегендә башкарылган эшләр ТРның нефть чыгаруны арттыру буенча максатчан комплекслы программасына кертелә һәм «Татнефть» АҖдә яңа нефть чыганакларын разведкалау проектын төзегәндә файдаланыла.

Хезм.: О некоторых закономерностях состава и свойств углеводородной части нефтей // Происхождение нефти и газа и формирование их месторождений. М., 1972; Геохимия нефтей Татарии. М., 1987; Состав и свойства пермских битумов Татарии в зависимости от характеристик вмещающих их отложений // Геохимия. 1993. № 12 (автордаш).

*Әд.:* Каюкова Г.П., Романов Г.В., Нигмедзянова Л.З. Глеб Петрович Курбский (к 85-летию со дня рождения) // Институт органической и физической химии им. А.Е.Арбузова: Ежегодник–2003. К., 2004.

*В.Г.Абзалова.*

**КУРГА́Н ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Себернең көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1943 елның 6 февралендә оештырыла. Үзәге — Курган шәһәре. Мәйданы — 71,5 мең *км²*. Халкы — 9476 мең кеше (2010), 23 мең татар (2002). Татарлар, башлыча, Курганда (2081 кеше), Сафакүл (5661 кеше; Сафакүл, Атҗитәр, Бахарево, Карасево, Мансур, Сөлекле, Боровичи, Максимовка авылларында), Әлмән (3528 кеше; Әлмән, Иванково, Өчкүл, Алакүл, Тузово, Вишняково а.), Шадринск (3222 кеше; Йолдыз а.), Шатров (1127 кеше; Кызылбай а.), Целинный (1349 кеше; Трёхозёрки, Белозёрки а.) р-ннарында яши. К.ө.нә татарлар Казан ханлыгы яуланганнан соң (1560 еллардан) килеп урнашалар. 17 йөз уртасыннан күчеп килүчеләр саны күбәя (бигрәк тә өлкәнең көньяк-көнбатыш өлешендә). 18 йөздә монда казак хезмәтендәге татарлар күчеп утыра. 1932–33 елларда Шадринск шәһәрендә «Ленин юлы» г-тасы нәшер ителә. 1950–60 елларда Сафакүл р-нында «Коммунист» г-тасына татарча кушымта чыга. Хәзерге вакытта К.ө.нең сигез мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. К.ө.ндә 15 мәчет һәм Курган шәһәрендә ислам мәдәни үзәге (1998 дән) эшли. Сафакүл, Әлмән авылларында төбәк тарихы музейлары, Әлмән (1981 дән), Зур Дубровный (1992 дән) авылларында фольклор коллективлары, Сөлекле авылында татар халык театры (1984 тән) бар. 1995–98 дә Трёхозёрки авылында «Җомга» һәвәскәрләр клубы, 1996 дан Курганда — «Туган тел» татар җәмгыяте, 2001 дән Сафакүл авылында татар-башкорт мәдәният үзәге эшли. 2000 нән Сафакүлдә «Замандаш» татар-башкорт өлкә г-тасы нәшер ителә. Сафакүл һәм Әлмән р-ннарында «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең татар телендәге тапшыруларын карыйлар (2004 тән). 1997 дә Сафакүл авылында — татарларның өлкә съезды, 2004 тә Курганда Урал аръягы татарларының 2 нче съезды үткәрелә. 2000–02 дә К.ө.ндә ТР Мәгариф министрлыгы ярдәме б-н махсус курсларда 22 татар теле һәм әдәбияты укытучысы әзерләнә. 1998 елда К.ө. б-н ТР арасында икътисад, фән-техника һәм мәдәният, сәүдә, иҗтимагый фәннәр өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүләр төзелә. 1987 дән Казанда «Травматология һәм ортопедия» Курган Бөтенсоюз фәнни үзәге ф-лы эшли. К.ө.дә Татарстанда чыгарылган сортлар: карабодай — «Казанская крупнозёрная», люцерналар — «Казан 64/95», тары — «Казан 61» районлаштырылган. К.ө.ндә Сов. Союзы Герое Х.Г.*Гыйззәтуллин*, шагыйрьләр М.*Гатау*, Җ.Х.*Юмаев*, журналист, тәрҗемәче Җ.Г.*Байбулатов* туган.

**КУРГА́НОВ** Ростислав Александрович (10.12.1929, Казан — 26.2.1996, шунда ук), физик, физика-матем. фән д-ры (1989), проф. (1990). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Николаев судноләр төзү техникумында укыта. 1957–96 да Казан ун-тында, проблемалы радиоастрономия лаб-ясе мөдире (1966 дан), радиодулкыннар таралуның физик нигезләре лаб-ясенең фәнни җитәкчесе (1973 тән), радиоастрономия каф. профессоры (1989 дан). Хезмәтләре радиодулкыннарның Җир ионосферасында метеорча, авыш һәм кайтма-авыш таралуын өйрәнүгә карый. К. ионосферадагы чәчелмә сигналның метеорча төзүчесен формалаштыруның

теоретик моделен эшли, аның ешлыклар спектрын үлчи. Ионосфераның E катлавында критик ешлык балкышларының стат. моделен төзи, E катлавы чәчкән радиосигнал балкышының көчен кыска вакытлы фаразлау алымын тәкъдим итә. Югары киңлек өлкәләрендә радиоэлемтә вакытында радиоаврора балкышларының әйләнеп үтүче формасын билгели. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прогнозирование наклонного рассеяния радиоволн метеорными ионизациями. К., 1973; Исследование частотных искажений метеорной составляющей ионосферно-рассеянного сигнала // Геомагнетизм и аэрономия. 1982. Т. 22, № 5 (авторлаш); Ионосферное рассеяние УКВ-КВ диапазона. К., 1992; Статистическая модель и краткосрочное прогнозирование всплесков критической частоты слоя E и рассеянного КВ-радиосигнала // Геомагнетизм и аэрономия. 1996. Т. 36, № 3.

*Р.Г.Усманов.*

**КУРГА́НОВ** Фёдор Афанасьевич (18.4.1844, Пенза ш. — 1.8.1920, Казан), тарихчы, илаһият д-ры (1881), хакыйкый статский советник (1896). 1870 елда Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: 1881–95 тә ординар проф., 1895 тән чиркәү тарихы каф. атказ. профессоры. Бер үк вакытта ординар проф., 1910–19 да чиркәү тарихы каф. атказ. профессоры. 1919 дан Казан ун-тының чиркәү тарихы каф. профессоры. К. протестантизм һәм Көнбатыш-Европа мәдәниятенең православие илләрендәге чиркәү тормышына рациональ йогынты ясавына каршы чыга. Аның «Грек Корольлеге чиркәвендә идарә итү тәртипләре» («Устройство управления в церкви Королевства Греческого», 1871) дип исемләнгән монографиясе автокефаль чиркәү тарихына багышлана. К. — Россиядә чиркәү византологиясенә нигез салучыларның берсе. «Византия империясендә чиркәү һәм гражданлык хакимияте арасындагы мөнәсәбәтләр» («Отношения между церковной и гражданской властью в Византийской империи», 1880), «Константинополь патриархлары тарихына карата» («К истории константинопольских патриархов», Сергиев Посад, 1895), «Император Константин Великий Святой Равноапостольный» (чыг. 1, 1918) дип аталган хезмәтләрендә К. дәүләт б-н чиркәү арасындагы үзара мөнәсәбәтләр системасын ача, императорлар һәм патриархлар хакимлеге һәм вәкаләтләренең хасиятен күрсәтә, Византиядәге Синод эшчәнлеген тасвирлый. Хезмәтләре ш.у. Румыниянең чиркәү тарихына, историографиягә карый.

Х е з м.: Заметки по вопросу о византийской противомусульманской литературе. К., 1878 (автордаш); Наброски и очерки из новейшей истории румынской церкви. К., 1899; Что такое либерализм? СПб., 1906.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Сорокалетие службы профессора Ф.А.Курганова. К., 1911; С о к о л о в И.Ф. Ф.А. Курганов // Византийский временник. 1926. Т. 24; Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета, 1905–1917. К., 1986.

*Е.Б.Долгов.*

**КУРГЕ́М** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 30 *км* төньяктарак, Кубыр елгасы буенда. 2010 елда 57 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Куремшур исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 483,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 142, 1884 тә — 207, 1905 тә — 252, 1920 дә — 272, 1926 да — 271, 1949 да — 204, 1958 дә — 154, 1970 тә — 103, 1979 да — 79, 1989 да — 74, 2002 дә — 70 кеше.

**КУРДЮКО́В** Геннадий Иринархович (23.7.1940, Чиләбе өлкәсенең Еманжелинск ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1984), проф. (1986), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1963). 1963–65 елларда Казанның Киров һәм Идел буе р-ннары прокуратуралары тикшерүчесе. 1966 дан Казан ун-тында: 1991 дән дәүләт һәм халыкара хокук каф. мөдире. Хезмәтләре халыкара хокукка, халыкара хокук субъектлыгы, халыкара мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Основные тенденции развития международной правосубъектности. К., 1974 (автордаш); Международное право: Библиография 1917–1977 гг. М., 1976; Государства в системе международно-правового регулирования. К., 1979.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**КУРЕНКО́В** Валерий Фёдорович (21.5.1941, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1983), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә, радикал полимерлашу кинетикасына һәм механизмнарына карый. К. җитәкчелегендә экологик мәсьәләләрне хәл итү өчен суда эрүчән полимерлар алу һәм кулланУның перспективалы технологияләре эшләнә («Казаноргсинтез», «Водоканал» пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә).

Х е з м.: Полимеры и сополимеры стиролсульфокислоты. А.-А., 1989 (автордаш); Полиакриламид. М., 1992 (автордаш); Щелочной гидролиз полиакриламида // Журн. прикладной химии. 2001. Т. 74, вып. 4 (автордаш); Acrylamide polimers // Handbook of Engineering Polymeric Materials. New Jersey, 1997. Ch.3.

**КУРИ́ЕВ** Мәүлет Шакир улы (15.10.1922, Чуаш автономияле өлкәсенең Батыр өязе Татар Согыты а. — 29.12.1995, Казан), слесарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). 1939–83 елларда Казан авиация ҖБдә эшли. Дәүләт бүләге универсаль җайланмалар һәм стапельләр конструкцияләрен җыюда принципиаль яңа технол. процесслар куллану хисабына самолёт җитештерүдә яңа алымнар эшләүгә һәм гамәлгә кертүгә катнашканы өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**КУРИНЕ́НКО** Борис Михайлович (29.2.1940, Украина ССРның Ровно өлкәсе Острог ш.), микробиолог, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1990). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1963), Казан ун-тында эшли. Хезмәтләре энзимотерапиягә (ферментларны медицинада дару препаратлары буларак файдалануга) карый. Рибонуклеазаларның (РНКаза) вирусларга һәм шешкә каршы активлык механизмын тикшерә. Аларның организмның саклагыч факторларын һәм кан ясалуны стимуллаштыручы тәэсирен күрсәтә. РНКазаларны химик модификацияләү ысулларын эшли, алар исә ферментларның үзгәртелгән биологик активлыкка ия булган молекуляр формаларын алырга мөмкинлек бирә. Ксенобиотикларның деструктур микроорганизмнар б-н үзгәрүе стратегиясенең аларның деструкторга карата токсинлык дәрәҗәсенә бәйлелеген ачыклый. СССР МС бүләге генетик инженерия, биотехнология һәм мед. өчен микроб нуклеазалары препаратлары һәм тугандаш ферментлар эшләгәне өчен бирелә (1987). ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2008).

Х е з м.: Противоопухолевая активность РНКаз // Эксперим. онкология. 1985. Т. 7, № 2; Энзимотерапия опухолей // Антибиотики и биотехнологии. 1987. Вып. 8; Нуклеазы бактерий. К., 1991 (автордаш); Микробная биотехнология. К., 2000 (автордаш).

**КУ́РКИН** Михаил Иванович (20.11.1918, хәзерге Орёл өлкәсенең Покровск р-ны Верхососна а. — 9.12.1995, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1971), проф (1972), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1968,1978). 1937 елда Орёл финанс-икътисад техникумын тәмамлаганнан соң, саклык кассасы бухгалтеры (ТАССРның Ширәмәт р-ны) булып эшли. 1939 да, Казан финанс-икътисад ин-тында укыган җиреннән үзе теләп совет-фин сугышына китә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947 дә Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлап, Казан а.х. ин-тында эшли. Институтта сәяси икътисад кафедрасын оештыруда башлап йөри һәм аның б-н 30 ел дәвамында җитәкчелек итә (1954–84), 1984 тән шул кафедраның консультанты, бер үк вакытта, 1993 тән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе бүлеге (1994 тән ин-т) өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре аграр мөнәсәбәтләрне камилләштерү, а.х.да матди кызыксындыру һәм хезмәтнең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә карый. Фәнни-тикшеренү эшләрен координацияләүнең Идел буе советы икътисадчы-аграрийлар секциясе җитәкчесе. 20 елдан артык телевидениедән аграр икътисад мәсьәләләренә караган тапшырулар циклын алып бара. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пути снижения издержек колхозного производства. К., 1958; Денежная оплата труда в колхозах Татарии. К., 1960; Интенсификация и

трудовые ресурсы колхозов. К., 1974 (автордаш); Село: дела и проблемы. К., 1986; АПК Татарии: проблемы и пути решения. К., 1990.

*Әд.:* Зиятдинов Ф.С. Увековечим память учёного // Актуальные проблемы экономического развития регионов России: Материалы науч.-практ. конф. К., 2004.

**КУ́РКИНО** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 90 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1678 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 582,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 259, 1897 дә — 366, 1908 дә — 446, 1920 дә — 440, 1926 да — 400, 1938 дә — 472, 1949 да — 362, 1958 дә — 227, 1970 тә — 176, 1979 да — 131, 1989 да — 112, 2002 дә — 111 кеше.

**КУРЛЯ́НКА** елгасы; к. *Көрнәле*.

**КУРМА́ЕВ** Осман Җамалетдин улы (27.12.1903, Пенза губ., Саранск өязе Суркино а. — 8.4.1981, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1951), проф. (1951), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1968). 1931 елда Шәрекъ пед. ин-тын (1934 тән — Казан пед. ин-ты) тәмамлый. 1930–81 дә Казан пед. ин-тында зоол. һәм физиол. каф. мөдире (1940–46), анатомия, кеше һәм хайваннар физиологиясе (1950–74) кафедрасын оештыручы һәм мөдире, бер үк вакытта табигыять белеме ф-ты деканы (1945–61), проректор (1961–65). К. җитәкчелегендә: гизүче һәм симпатик нерв үзәкләре тонусы, сулыш аритмиясе, физик йөкләнешләргә яраклашуда яшь үзенчәлекләре, күнеккәнлек брадикардиясе механизмнары; канда һәм йөрәк мускулларында катехоламин, ацетилхолин һәм холинэстераз күләме анализы өйрәнелә. Дөньяда беренчеләрдән булып, К. гизүче һәм симпатик нервларның үзара бәйләнеше бер-берсен компенсацияләү характерында икәнлеген күрсәтә. СССР ЮС депутаты (1958–62). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О взаимоотношении между хромаффинной тканью и симпатической иннервацией сердца теплокровных // Бюл. эксперим. биологии и медицины. 1949. Т. 27, № 3; Механизмы нервной и гуморальной регуляции деятельности сердца. К., 1966.

*Әд.:* Казанская физиологическая школа на рубеже веков. К., 2001.

**КУРМАЛА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 149 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Норма исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тарак ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәктәп, мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 546,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 58 ир-ат; 1834 тә — 219, 1850 дә — 253, 1859 да — 257, 1897 дә — 370, 1908 дә — 400, 1920 дә — 333, 1926 да — 355, 1938 дә — 312, 1949 да — 247, 1958 дә — 179, 1970 тә — 167, 1979 да — 141, 1989 да — 96, 2002 дә — 118 кеше.

**КУРМА́НОВ** Мидхәт Мәзгут улы (2.8.1959, Ульянов өлкәсенең Яңа Малыклы р-ны Урта Исәнтимер а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры. (2010), ТРның атказ. юристы (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1982). 1982–92 елларда ТРның эчке эшләр органнарында. 1992–95 тә ТР ЮСының Законлылык, хокук тәртибе, кеше хокуклары һәм өстенлекләр буенча даими комиссиясе рәисе урынбасары. 1995–99 да ТР Дәүләт Советының Парламент күзәтчелеге рәисе урынбасары. 2000–04 тә ТР Дәүләт Советының Законнар чыгару, законлылык, регламент, депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе. 2004 тән ТРның юстиция министры. 1990–95 тә ТР ЮСы депутаты. 1995–2004 тә ТР халык депутаты. Конституцион хокук мәсьәләләренә караган мәкаләләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КУРМА́ШЕВ** Йолдыз Вагыйз улы (5.11.1930, Зәй р-ны Югары Ложы а.), партия һәм хуҗалык хезмәткәре. Алабуга китапханә техникумын (1949) һәм пед. ин-тын (1963), Минзәлә а.х. техникумын (1969) тәмамлый. 1956–58 елларда ВЛКСМның Ширәмәт райкомы 2 нче секретаре. 1958–59 да КПССның Зәй райкомы инструкторы, 1959–60 та Зәй р-ны башкарма ком-тының мәдәният бүлеге җитәкчесе. 1960–70 тә Зәй р-нының «Якты йолдыз» к-зы рәисе, 1973–76 да Чаллы р-ны халык депутатлары советы башкарма ком-ты рәисе, КПССның Тукай (1976–83) һәм Алабуга (1983–88) райкомнары 1 нче секретаре. 1988 дән «Кама» агросәнәгать комплексы ген. директоры, бер үк вакытта ТРның Агросәнәгать комплексы рәисе урынбасары. ТАССР (1975–80) һәм РСФСР (1985–90) ЮСлары депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. *С.С.Елизарова.*

**КУРМУКО́В** Әнвәр Гафур улы (18.3.1932, Әстерхан ш.), фармаколог, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1980). 1957 елда Ташкент мед. ин-тын тәмамлагач, Ташкентта 2 нче Респ-ка психиатрия хастаханәсендә бүлек мөдире булып эшли. 1959 дан Үзбәкстан ССР ФАнең Үсемлек матдәләре химиясе ин-тында. 1978 дән Үзбәкстан Респ-касы Сәламәтлек саклау министрлыгының Кардиология фәнни-тикшеренү ин-тында экспериментал кардиология бүлеге һәм патофизиология лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре йөрәк-кан тамырлары патологиясенә, патофизиология, фармакотерапия, үсемлекләр алкалоидлары фармакологиясенә карый. Респ-ка кардиологлары һәм фармакологлары, Халыкара кардиологлар җәмгыятьләре әгъзасы. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар.

Хезм.: Фармакология растительных алкалоидов и их применение в медицине. Таш., 1981 (автордаш); Препарат исферул (карван) и применение его в медицине и народном хозяйстве. Таш., 1992.

**КУРНАКО́В** Евгений Васильевич (12.9.1941, Яшел Үзән ш. — 7.1.1997, шунда ук), инженер-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1978). 1961–73, 1975–89 елларда Казан хисаплау системалары ҖБдә эшли: мастер, инженер-технолог, цех җитәкчесе урынбасары, җитәкчесе, баш технолог (1977 дән), директор урынбасары (1986 дан). 1973–75 тә Казан хисаплау техникасы фәнни-тикшеренү һәм технол. ин-тында производство җитәкчесе. 1989–93 тә «Казан газ аппаратуралары заводы» АҖдә баш инженер урынбасары. Дәүләт бүләге ЭВМның ярдәм системасын эшләгәне, аны җитештерүгә гамәлгә куйганы һәм халык хуҗалыгында куллануга керткәне өчен бирелә. ВДНХның бер алтын, ике көмеш, бер бронза медале б-н бүләкләнә.

**КУРОПА́ТЕНКО** Дмитрий Семёнович (23.2.1902, хәзерге Украина Респ-касының Харьков өлкәсе, Волчанск р-ны Ивановка а. — 8.5.1977, Казан), генерал-майор (1943). Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең командирлар составы 1 нче пехота курсын (Мәскәү, 1921), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия (Мәскәү, 1934) тәмамлый. 1918 елдан Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышы вакытында А.И.Деникин, П.Н.Врангель армияләренә каршы сугыша. 1921 дә Грузиядә Совет хакимияте урнаштыруда катнаша. 1938–41 дә М.В.Фрунзе исем. Хәрби акад. укытучысы, проф. Бөек Ватан сугышы елларында штаб башлыгы, укчы дивизия командиры. 1945–49 да Германиядә Совет гаскәрләре төркемендә корпус командиры урынбасары. 1949–57 дә Казан ун-тының хәрби каф. башлыгы. Ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**КУ́РОЧКИН** Леонид Михайлович (9.8.1950, Түбән Кама р-ны Соболеково а. — 1.7.2000, Түбән Кама ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001, үлгәннән соң), техник фән. канд. (1998), ТРның атказ. химигы (1995). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1973). 1968–2000 елларда «Түбәнкаманефтехим» АҖдә эшли: аппаратчы, смена башлыгы, ясалма каучук эшләү һәм киптерү цехы җитәкчесе урынбасары, экстрактив ректификацияле газ бүлү цехы җитәкчесе, баш инженер, СКИ-3 № 1 з-ды директоры, ясалма каучук җитештерү з-ды директоры (1994 тән). К.ның турыдан-туры катнашында, тармакта беренче булып, изоамиленнарны 2 нче стадиядә дегидрирлауга К-24 маркалы тимер окисьлы (ИМ-2204 урынына)

яңа катализатор гамәлгә кертелә, бу атмосферага 4 мең *т* күләмендә регенерация газлары чыгаруны туктатуга һәм 1 *т* изопрен исәбенә изопентан куллану нормасын 2,063 *т* дан 1,96 *т* га кадәр кыскартырга ярдәм итә. Ясалма каучукның яңа — олигопиперилен, этиленпропилен төрләрен сәнәгый җитештерү гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге «Россиядә беренчеләрдән булып этиленпропилен каучукларны эре тоннажлы унификацияләнгән җитештерүне оештыру һәм үзләштерү» дигән хезмәте өчен бирелә.

**КУРСА́** тимер юл разъезды посёлогы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Казан–Екатеринбург тимер юлы буенда. 2010 елда 279 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — урманчылык. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. Мәчет. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Саба р-нында. 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 114, 1949 да — 244, 1958 дә — 342, 1970 тә — 246, 1979 да — 175, 1989 да — 228, 2002 дә — 244 кеше.

**КУРСА́ ПОЧМА́К** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 16 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы бассейнында. 2010 елда 407 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Курса Темяк исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.П.та мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1026,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 84 ир-ат; 1859 да — 593, 1908 дә — 724, 1920 дә — 757, 1926 да — 752, 1938 дә — 791, 1949 да — 793, 1958 дә — 653, 1970 тә — 661, 1979 да — 592, 1989 да — 459, 2002 дә — 423 кеше.

**КУРСА́ СОРЫ́ ЧЕЛӘ́Н КОЛО́НИЯСЕ**, табигать истәлеге. Арча р-ны Урта Курса



Курса соры челән колониясе.

авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. 1991 елда билгеләнә. Мәйданы 0,5 *га*. Җирле зират терр-ясендәге карт агачларда (нарат, чыршы, каен) соры челәннәрнең 60 лап оясы бар (1991). Бирсдә үк кара каргалар колониясе (120 дән артык оя) яши. Гади торымтай һәм колаклы ябалак очрый. Объект беренче тапкыр танылган зоолог М.Д.Рузский тарафыннан тасвирлана (1893).

**КУРСАБА́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы бассейнында. 2010 елда 398 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, киез-киез итек басу, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1402,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 510, 1897 дә — 705, 1908 дә — 789, 1920 дә — 822, 1926 да — 667, 1938 дә — 818, 1949 да — 737, 1970 тә — 520, 1979 да — 482, 1989 да — 413, 2002 дә — 402 кеше.

**КУРСАВИ́** Габделхаликъ (? – 1843 яки 1844), дин эшлеклесе. Г.*Курсавиның* энесе. Бохара шәһәрендәге мәдрәсәдә суфилар борадәрлеге *Нәкышбәндийәнең* күренекле вәкиле Ниязколый әт-Төрекмәнидә (1820 елда яки 1821 дә вафат) белем ала. Казан губернасы Казан өязе Югары Курса авылы мәчетендә имам һәм мәдрәсәдә мөдәррис була.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар: 2 томда. К., 1897–1900; Kemper M. Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: Der islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. B., 1998.

*Г.Г.Идиятуллина.*

**КУРСАВИ́** Габденнасыйр Ибраһим улы (1771–76 арасы, Казан губ., Казан өязе Югары Курса а. — сентябрь, 1812, Истанбул ш.), дин эшлеклесе, илаһият галиме. Г.*Курсавиның* абыйсы. Вятка губернасының Малмыж өязе Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә, аннары Бохарада укый. Суфилар борадәрлеге *Нәкышбәндийәнең* мәшһүр шәехе Ниязколый әт-Төрекмәнинең (1820 елда яки 1821 дә вафат) шәкерте була. Үзлегеннән белем ала, мөселман илаһияты-хокукы яктыртылган әдәбиятка карата тәнкыйди карашны нигезли, исламият гыйлеменә кагылышлы бәхәсләрдә актив катнаша. Аның урта гасырлар исламият галиме әт-Тәфтазанинең «Шәрех әл-гәкаид ән-Нәсафи» («Нәсафи инануын аңлату») хезмәтенә язган аңлатмасы шул вакытка карый дип исәплиләр. Югары Курсага әйләнеп кайткач, анда имам-хатиб һәм мәдрәсәнең мөдәррисе була. 1807 ел тирәсендә К. яңадан Бохарага китә, Аллаһ сыйфатларына (гыйлем, ихтыяр һ.б.) кагылышлы илаһият мәсьәләләре буенча шау-шулы бәхәсләрдә катнаша. Бохарадагы дин галимнәре Аллаһ сыйфатларының санын билгеләгәндә борынгы галимнәр фикеренә таянуны яклап чыгалар. Ләкин К. иң дөресе Аллаһ тарафыннан *Коръәндә* бирелгән билгеләмәләрдән файдаланырга кирәк дигән карашта тора. 1868 нең апрелендә К. исламият мәсьәләләренә карашын ачыклау максаты б-н Бохара әмире катнашачак мәҗлескә чакырыла. Мәҗлестә Аллаһ сыйфатларының билгеләнгән санын танымаган теләсә-кайсы мөселманны диннән язган дип санарга һәм үлем җәзасына хөкем итәргә дигән *фәтва* (дини-хокукый карар) чыгарыла. Фәтвага илаһият галимнәре, мөфтиләр һәм әмир тарафыннан имзалар куела. Ниязколый әт-Төрекмәни үзенең шәкертен яклап чыгыш ясый. Шулай да К. үзенең сүзләреннән баш тартырга мәҗбүр була, аның әсәрләре халык алдында яндырыла; шәехе киңәше б-н ул шәһәрдән качып китә. Ватанына кайту б-н К. укытуын дәвам иттерә, ләкин аның дин өлкәсенә керткән яңалыклары, ш.у. Оренбург Дини Мөселман кануннары Җыенында мәҗбүри имтихан бирү тәртибе б-н санлашмавы җирле мөселман руханилары арасында кискен ризасызлык уята. Даими бәйләнүләрдән һәм нахакка гаепләүләрдән тәмам арыган К. 1812 дә туганнары б-н бергә хаҗ кылырга китә. Август ахырында Истанбулга барып җиткәч, К. ваба чиреннән вафат була. К. үзеннән соң гарәп телендә язылган уннан артык хезмәт калдыра, татар телендә «Һәфтияк тәфсире»н («Коръәннең 1/7 өлешен шәрехләү») әзерли. Болардан башка язган хатларының өзекләре сакланып кала; аларда галим ислам тәгълиматы мәсьәләләре буенча үзенең карашларын бәян итә. К.ның аеруча билгеле булган «әл-Иршад ли-л-гибад» («Аллаһ коллары өчен нәсыйхәт») хезмәтендә *фикъһның* (хокук белеме) чыганакларына һәм нигезләренә кагылышлы мәсьәләләр тикшерелә. Хезмәт бәхәс тудыра торган характерда һәм мөселман традицияләренә, *тәкълид* эзеннән баручы исламият галимнәренә каршы юнәлтелгән була. *Иҗтиһад* нигезләрен яклап (Коръән һәм Сөннә нигезендә дини һәм иҗтимагый тормыш мәсьәләләре буенча шәхси фикер чыгару хокукы), К. *хәдиснең* фәкыйһләр (хокук белгече) фәтвасыннан өстен торуын раслый: хәдис нигезендә Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре ята, ә фәкыйһ сүзләре баштан ук хата булырга да мөмкин. К. Коръәнне һәм Сөннәне өйрәнүдә ваемсызлык һәм сүлпәнлек күрсәтү нәтиҗәсендә галимнәр арасында килеп туган томаналык яңалыклар кертүгә — *бидгатькә* юл ача, дип саный. Җәмгыятьнең төзәлү юлын К. кимчелекләрнең тамырын корытудан, кабат Коръән һәм Сөннәгә кайтудан, ш.у., галим фикеренчә, һәр укымышлы мөселманның бурычы саналган иҗтиһадны яңадан торгызуда күрә. К. Коръән һәм Сөннәнең дин өлкәсенә караган кагыйдәләре камил һәм үзгәрми торган сыйфатка ия булуына басым ясый, иҗтиһадны бары тик хокукый нормаларга карата гына кулланырга мөмкин дип саный. Иҗтиһадны куллану өлкәсен шулай чикләү Аллаһның асылы, сыйфатлары,

тегe дөньяда биреләчәк җәза, фәрештәләр һ.б. турындагы бәхәсләр б-н мәшгуль булган рәсми дин әһелләренә кискен каршы чыгуны аңлаткан.

К. үзенең оппонентларын Коръәндә Аллаһ тарафыннан нигезләнгән идеяләрне дөрес шәрехләмәүдә, Аллаһны кеше сыйфатларына ия дигән тупас мәгълүмат бирүдә гаепли. Иҗтиһадның кулланылышын социаль-хокукый характердагы мәсьәләләр б-н чикләп, К. дин гыйлеме мәсьәләләрен җәмгыятьтәге проблемаларга якынайтуга аеруча зур әһәмият бирә, мөселманнарны тормышта актив катнашырга өнди. К. ш.у. исламдагы шәригать б-н килештерелмәгән мистик-аскетик агымның — суфичылыкның вульгар күренешләрен: ясалма диндарлыкны, читтән тыш аскетизмга бирелүне гаепли. Илаһият галиме *әл-Газәли Әбу Хәмиднең* фикерләрен яклаучы буларак, аның өчен суфичылыкның әхлакый нигезләрен традицион ислам гыйлеме б-н бергә кушу иң кыйммәтле хәзинәләрдән санала. К. фикеренчә, үз карашларының хаклыгына ышанган галим, хәтта аның фикерләре күпчелекнең тәнкыйтенә дучар ителүгә карамастан, үз белүенчә эш итәргә хокуклы. Аерым шәхеснең үзбәясенә әһәмият биреп, К. хакыйкатьне яклаучы кеше җәмгать б-н бер тигез була ала, дип раслый. Аның идеяләре йогынтысында Ш.*Мәрҗанинең* карашлары формалаша, ул үз хезмәтләрендә К. тәгълиматының кайбер якларын үстерә. 20 йөз башында К.ның идеяләре Г.Буби, М.Бигиев, З.Камали һ.б. татар исламият галимнәренең хезмәтләрендә чагылыш таба.

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Абдуллин Я.Г. Татарская просветительская мысль (социальная природа и основные проблемы). К., 1976; Юзиев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX вв.: В 2 кн. К., 1998; Кемпер Н. Между Бухарой и Средней Волгой: Столкновение Абу ан-Насра ал-Курсави с улемами-традиционалистами // Мир Ислама. 1999. 1/2; Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. К., 2000; Kemper M. Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: Der islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. B., 1998.

*Г.Г.Идиятуллина.*

**КУРТИ́НА ЧИРКӘВЕНДӘГЕ́ ПАНИХИ́ДА**, Рус Бизнәсе крәстияннәре кузгалышы корбаннарына багышланган искә алу мәрәсиме (к. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы*), Казанда хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән беренче сәяси демонстрация. 1861 елның 16 апрелендә Казанның Арча зиратындагы Куртина чиркәвендә уздырыла. Башлап йөрүчеләр — яшерен студентлар түгәрәге әгъзалары. Панихиданы әзерләүдә Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе студентлары Н.В.Копиченко, И.К.Олигер, А.М.Темников, И.Н.Умнов, А.Х.Христофоров, В.С.Боголюбов, Ф.И.Новицкий һ.б. катнаша. 12 апрельдә коралсыз крәстияннәр төркемен аттырганнан соң, Рус Бизнәсе авылына, анда булган хәлләр турында мәгълүматлар җыю өчен, университетның элекке студенты С.А.Клаус һәм ирекле тыңлаучы М.К.*Элпидин* җибәрелә. Панихида алдыннан үтерелгән һәм яраланган Бизнә крәстияннәре гаиләләре файдасына иганә җыела. Иң элек панихиданы Богоявление чиркәвендә уздырырга уйлыйлар, әмма чиркәүнең өлкән побы каршы килгәч, Куртина (Арча) зиратындагы чиркәүдә (панихиданың исеме шуннан килә; башка исеме — Бизнә панихидасы) уздыралар. К.ч.п.да 450 ләп кеше катнаша. Казан ун-ты профессоры А.П.*Щапов* кыска гына чыгышында бер гаепсез крәстияннәр каны түгелгән җир халыкны баш күтәрергә һәм ирек яуларга чакыра дип белдерә. Үзенең чыгышын ул: «Яшәсен демократик конституция!» — дигән сүзләр б-н тәмамлый. К.ч.п.да катнашканнары өчен ун-ттан — 9, руханилар академиясеннән 3 студент куыла; руханилар академиясенең 2 дин әһеле монастырьга озатыла, А.П.Щапов кулга алына.


*Әд.:* Вульфсон Г.Н., Бушканец Е.Г. Общественно-политическая борьба в Казанском университете в 1859–1861 гг. К., 1955; Вульфсон Г.Н. Разночинно-демократическое движение в Поволжье и на Урале в годы первой революционной ситуации. К., 1974; шул ук. Глашатай свободы: Страницы из жизни А.П.Щапова. К., 1984.

**КУРЧАКО́В** Азат Гайнулла улы (6.3.1931, хәзерге Ульянов өлкәсенең Чынлы р-ны Елховое Озеро а.), зоотехник, а.х. фән. канд. (1972), РСФСРның атказ. зоотехнигы (1971). Ульянов а.х. ин-тын тәмамлый (1955). Ульянов өлкәсендә Баш зоотехник (1955–60), КПССның Богдашкино райкомы 2 нче секретаре (1960–62), Ульянов а.х. идарәсендә җитәкче урынбасары, җитәкче (1962–75, 1979–85), Ульянов өлкәсенең сөт сәнәгате җитештерү берләшмәсе ген. директоры (1975–79). 1985–92 дә Ульянов а.х. ин-тында проректор. 1992 дән Ульянов кадрларны яңадан әзерләү һәм агробизнес ин-тында ректор (2002 гә кадәр), проф. (1994).

Хезмәтләре игенчелек һәм терлекчелекнең фәнни нигезләнгән системаларын булдыруга карый. Ульянов өлкәсе татарларының милли-мәдәни мохтарияте рәисе (1997 дән). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Ульянов өлкәсенең (1997) һәм Чынлы р-нының (2001) мактаулы гражданы.

Хезм.: Научно обоснованная система земледелия — основа повышения плодородия почв и урожайности сельскохозяйственных культур. Ульяновск, 1981 (автордаш); Система ведения животноводства Ульяновской области. Ульяновск, 1983 (автордаш); Из поколения в поколение (о жизни татар Ульяновской области). Ульяновск, 2002.

**КУРЧА́ТОВ** Игорь Васильевич (30.12.1902, хәзерге Чиләбе өлкәсенең Аша р-ны Сим а. — 7.2.1960, Мәскәү), физик, физика-матем. фән. д-ры (1934), СССР ФА академигы (1943), Соц. Хезмәт Герое (1949, 1951, 1954), СССРда атом фәне һәм техникасы буенча эшләрне оештыручы һәм җитәкләүче. 1923 елда Кырым ун-тын тәмамлый. 1924–25 тә Әзәрбайҗан политехник ин-тында (Баку ш.), 1925 тән Ленинград физика-техника ин-тында фәнни-пед. эштә. 1933 тән атом төше физикасы мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 1934 тә нейтроннар б-н бомбага тоту нәтиҗәсендә туган төш реакцияләренең тармаклану күренешен ача, күп кенә элементларның ясалма радиоактивлыгын тикшерә.



И.В.Курчатов.

К. җитәкчелегендә ясалма радиоактив изотопларның төш изометриясе (1935), уран төшләренең үзеннән-үзе бүленүе (1940) күренешләре ачыла. Бөек Ватан сугышы елларында К. зур хәрби әһәмияткә ия булган күп кенә эшләр башкара. 1942 дә Казанда эшли. 1942 нең сентябрендә СССР Дәүләт оборона ком-ты К.ка атом бомбасын уйлап табу б-н җитәкчелек итү эшен тапшыра; атом төше лаб-ясе һәм 10 фәнни хезмәткәргә яшәү өчен Казанда 500 $м^2$ мәйданлы торак бүленеп бирелә. 1943 тә К. Мәскәүгә күчә, биредә ул СССР ФАнең Атом энергиясе ин-тына нигез сала һәм аның беренче директоры (1943 тән) була (1960 тан К. исемендә). Аның җитәкчелегендә СССРда Европадагы беренче атом реакторы төзелә (1946), беренче сов. атом бомбасы (1949) һәм дөньяда беренче термотөш бомбасы (1953) эшләнә, дөньяда беренче атом электр станциясе (1954) һәм идарә ителүле термотөш реакцияләрен тормышка ашыру буенча тикшеренүләр өчен иң зур җайланма (1958) сафка кертелә; Ташкент, Тбилиси, Киев, Алма-Ата, Минск, Рига, Новосибирск һ.б. шәһәрләрдә атом-тикшеренү үзәкләре төзелә. СССР ЮС депутаты (1950–60). СССР Дәүләт бүләкләре (1942, 1949, 1951, 1954), Ленин бүләге (1957) лауреаты. Биш Ленин ордены, башка орденнар; медальләр, ш.и. СССР ФАнең М.В.Ломоносов исем. һәм Л.Эйлер исем. алтын медальләре, Бөтендөнья Тынычлык Советының Ф.Жолио-Кюри исем. көмеш медале б-н бүләкләнә. Белоярск атом эл. станциясенә (Свердловск өлкәсенең Заречный пос.), Айдагы бер кратерга, фәнни-тикшеренү судносына, илдәге шәһәрләрнең урам һәм мәйданнарына, Курск өлкәсендәге посёлокка К. исеме бирелә. СССР ФА И.В.Курчатов исем. бүләк һәм алтын медаль булдыра, ул төш физикасы өлкәсендәге зур казанышлар өчен бирелә (1960). «Курчатов институты» Россия Фәнни үзәге терр-ясендә К.ның мемориаль музее эшли. Кызыл мәйданда Кремль дивары буенда җирләнә.

Хезм.: Сегнетоэлектрики. Л.–М., 1933; Расщепление атомного ядра. М.–Л., 1935; Некоторые вопросы развития атомной энергетики в СССР // Атомная энергия. 1956. № 3.

*Әд.:* Кикоин И.К. Игорь Васильевич Курчатов // Атомная энергия. 1963. Т. 14, № 1; Головин И.Н. И.В.Курчатов. М., 1967; Асташенков П.Т. Академик И.В.Курчатов. М., 1971; Академик Игорь Васильевич Курчатов // Атомная энергия. 2003. Т. 94, вып. 1.

*Р.Г.Усманов.*

**КУ́РШЕВ** Виктор Николаевич (30.11.1943, Казан), идарә итү теориясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1999), проф. (2002). 1967 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2004 тән идарә итү, маркетинг һәм эшмәкәрлек кафедрасында. Хезмәтләре бүленгән

параметрлы стохастик системалар б-н оптималь идарә итүгә, катлаулы идарә системаларын аналитик проектлаштыруга карый. К. космик объектларның бүленү системаларына оптималь параметрлар сайлап алу методикасын эшли һәм гамәлгә кертә. Парашют системаларын аналитик һәм машина ярдәмендә проектлаштыруның матем. модельләрен тәкъдим итә. Берле һәм икеле кәкрелеккә ия детальләрне формага китерүнең технол. процессларын проектлаштыру алымнарын гамәлгә кертә. Нефть катламына термодинамик тәэсир ясау алымын һәм җайланмасын эшли (бергәләп). Күп кенә катлаулы икътисади системаларның матем. модельләре һәм аларны проектлау алымнары авторы. Уйлап табуга патентлары бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Об оптимальном управлении одномерными стохастическими процессами с распределёнными параметрами // Автоматика и телемеханика. 1972. № 1 (автордаш); К аналитическому проектированию сложных технических систем // Изв. вузов. Авиац. техника. 1981. № 2; Синтез оптимального закона наддува баков ЖРД // Изв. вузов. Авиац. техника. 1994. № 1; Динамическое моделирование сложного экономического объекта // Изв. вузов. Авиац. техника. 2003. № 1.

**КУ́РШЕВ** Николай Васильевич (21.2.1910, Пенза ш. — 23.6.1968, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1952), проф. (1955), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). 1934 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1934–39 да Үзәк аэрогидродинамика ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Жуковский ш.). 1939–53 тә оборона з-дларында (Казан). 1953–68 дә Казан авиация ин-тының аэрогидродинамика каф. мөдире, бер үк вакытта проректоры (1955–68). Хезмәтләре аэромеханиканың вариатив мәсьәләләренә карый. Бөек Ватан сугышы елларында хәрби самолётлар төзүдә катнаша. Самолётларның аэродинамик характеристикаларына җир өстенә якын булуның тәэсирен тикшерә. Самолётның очу режимнарын оптимальләштерү турындагы фәнни юнәлешкә нигез салучы. Беренчеләрдән булып двигательләре төрле типта булган самолётларның очыш режимнарын һәм динамикаларын оптимальләштерү мәсьәләсен куя һәм хәл итә. Ягулыкның оптималь чыгымын самолётның хәрәкәт режимына бәйле рәвештә исәпләү приборы уйлап таба һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние близости поверхности земли на распределение подъёмной силы по размаху крыла самолёта // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1935. Вып. 3; Оптимальные задачи динамики полёта. К., 1967 (автордаш); Оптимальные режимы движения самолёта. К., 2000.

*Әд.:* П о с п е л о в К. Записки старого директора // Казань. 1999. № 3/4.

**КУРЫ́НОВ** Александр Павлович (8.7.1934, хәзерге Владимир өлкәсенең Уршель пос. — 30.11.1973, Казан), спортчы (авыр атлетика), СССРның атказ. спорт остасы (1960). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1963). «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренеры — В.А.*Павлов*. Дуслык кубогы ярышларында җиңүче (1959–60, 1962), СССР (1960), Европа (1960–63), Олимпия уеннары (1960), дөнья (1961–63) чемпионы. 1958–65 елларда ярым уртача авырлыкта (75 *кг* га кадәр) 14 дөнья рекорды куя. 1958–68 тә «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан советында өлкән тренер, 1968–71 дә Казан югары спорт осталыгы мәктәбендә тренер. 1971–73 тә Хисаплау техникасын гамәлгә кертү буенча фәнни-тикшеренү ин-тында инженер. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Казан



А.П. Курынов.

техник ун-тының бер бинасына (Ирек мәйданы) К.ка мемориаль такта куела. 1975 тән Казанда ел саен К. истәлегенә авыр атлетика буенча халыкара ярышлар уздырыла.

**«КУРЬЕ́Р»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1908 елның 22 декабреннән 1909 ның 12 гыйнварына кадәр Казанда рус телендә 3 саны нәшер ителә. «*Восточный курьер*» г-тасының дәвамчысы. Мөхәррире — М.Е.Некрасова-Вильман.

*Әд.:* Б е л я е в а Л.Н., З и н о в ь е в а М.К., Н и к и ф о р о в М.М. Библиография периодических изданий России, 1901–1916: В 2 т. Л., 1958–61.

**КУСА́ РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1940 елның 17 февралендә оештырыла. Мәйданы — 1513 *км*². Үзәге — Куса шәһәре (Чиләбедән 180 *км* көнбатыштарак). Халкы — 30,2 мең кеше (2010) 1572 татар (2002). Татарлар, башлыча, Куса шәһәрендә (807 кеше), Магнитка (408), Петрушкино, Каскиново, Туктарово, Петропавловка (барлыгы 357 кеше) посёлокларында яшиләр. Район терр-ясендә татарлар 18 йөздә башкорт җәмәгатьләре карамагындагы припущенниклар сыйфатында төпләнәләр. 1916 да Куса Заводы (хәзер Куса ш.) посёлогына берничә татар гаиләсе килеп урнаша, алар җирле чуен кою һәм тимер эшкәртү з-дларында эшли. 1920–23 елларда анда татар-башкорт мәктәбе була. Хәзерге вакытта ТР б-н икътисади хезмәттәшлек кысаларында Чистай шәһәренә К.р.ннан сәгать ташлары, Әлмәткә вак таш китерелә.

**КУ́СОВ** Владимир Васильевич (9.4.1930, Казакъстан ССРның Актүбә өлкәсе Чалкар ш.), икътисадчы, РСФСРның атказ. азык-төлек



Л.Г. Кустабаева.

индустриясе хезмәткәре (1989). Мәскәү ит һәм сөт эшкәртү сәнәгате технол. (1954), Казан финанс-икътисад ин-тларын (1981) тәмамлый. 1954–59 елларда Россошанск кошчылык комб-тында (Воронеж өлкәсе) һәм Чкалов ит комб-тында (Горький өлкәсе) җитештерү-вет. күзәтүе бүлекләре башлыгы. 1959–65 тә Оренбург өлкәсе, Урта Идел ХХС (Куйбышев ш.) ит-сөт сәнәгате идарәләрендә эшли, 1965–91 дә Казан ит комб-ты директоры. Ит-сөт сәнәгате үсешенә мөһим өлеш кертә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**КУСТАБА́ЕВА** Лима Гали кызы (3.8.1945, Чиләбе өлкәсе Магнитогорск ш.), хор дирижёры, режиссёр, сценарист, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980, 1987), РФнең халык артисты (1995), проф. (2003). 1969 елда Казан консерваториясен Хор дирижёры белгечлеге буенча тәмамлый. 1971–78 дә ТАССР Җыр һәм бию ансамбленең баш хормейстеры, 1978–2002 дә сәнгать җитәкчесе. 2000 нән «Сәйдәш» мәдәният үзәге директоры (Казан). Сәнгатьчә идея һәм сценарийлар авторы, режиссёр-куючы һәм сәнгать җитәкчесе буларак, ТРның Җыр һәм бию ансамбле б-н 25 тән артык программаны гамәлгә ашыра. Шулар арасында сәхнәләштерелгән вокаль-хореография күренешләре: «Сабан туе» (1980; 2 нче ред. 1985), «Ватаным минем» (комп. Р.Яхинның 60 еллыгына, 1981), «Истә һәм җырда» (Бөек Ватан сугышы җиңүенә 40 ел тулуга, 1984), «Күңелем яктысы» (элекке лирик җырлар һәм биюләр, 1985), «Якты көзге» (Г.Тукайның тууына 100 ел тулу уңаеннан, 1986), «Гастроль меридианнарында» (дөнья халыклары милли сәнгате, 1987), «Урал көйләре» (1988; икенче исеме «Башкорт сюитасы»), «Минем Сәйдәш» (С.Сәйдәшевнең тууына 90 ел, 1990), «Төрки дөнья» (төрки ха-



«Аулак өй» композициясе.
Сәхнәгә куючы — Л.Г. Кустабаева.



Р.И. Кутуев.

лыклар сәнгате, 1992), «Корбан бәйрәме» (1992), «Саумы, кояш!» (М.Мозаффаровның тууына 90 ел, 1992), «Шәрекъ клубы» (шәһәр татарлары фольклоры җирлегендәге күренеш, 1993), «Чишмә» (А.Ключарёвның тууына 90 ел, 1996), «Былбыл Сара» (С.Садыйкованың тууына 90 ел, 1997), «Рамазан» (фәлсәфи муз. мистерия, 1998); «Безнең мирас» исемле рубрика астында мәктәп укучылары өчен ел саен уздырыла торган махсус программалар циклы зур әһәмияткә ия. К. синкретик иҗатның аерым бер төре буларак, милли ансамбль тарафыннан сәхнәдә җыр һәм бию башкаруның яңа юнәлешен формалаштыруга, аны үстерүгә өстенлек бирә — бердәм сәнгатьчә идея б-н сугарылган, халык традицияләренә нигезләнеп һәм Татарстан композиторлары, шагыйрьләре мирасына таянып эшләнгән, тоташ сюжетка корылган, театральләштерелгән тамашалар куела башлый. К. җитәкчелегендә ТРның Җыр һәм бию ансамбле сәнгать һәм башкару осталыгы ягыннан югары дәрәҗәгә ирешә һәм татар халкы сәнгатен зур уңыш б-н СССР, БДБ илләрендә, РФ буйлап һәм чит илләрдә (Италия, Мальта, Нигерия, Сенегал, Бенин, ГДР, ГФР, Чехословакия, Япония, Йәмән, Финляндия, Югославия, Төркия, Венгрия, Франция, Бөекбритания һ.б.) таныта. Ансамбль бөтенроссия проф. коллективларының смотр-конкурслары (1978, 1986, Мәскәү); Карфаген (1977) һәм Вавилон (1995) халыкара фестивальләре лауреаты. К., үзенчәлекле, тирән эчтәлекле сценарийлар авторы һәм режиссёр буларак, театральләштерелгән концерт программалары төзеп, әйдәп баручы төп иҗади коллективлар һәм башкаручылар катнашында С.Сәйдәшевнең 90 еллыгына («Россия» Үзәк концерт залы һәм Союзлар йортының Колонналы залы, 1990), Ф.Әхмәтовның 60 еллыгына (Татар опера һәм балет театры, Казан, 1995), Татарстан Респ-касы көненә (Үзәк стадион, Казан, 1996), С.Садыйкованың 90 һәм 95 еллыгына (Татар опера һәм балет театры, Казан, 1996, 2001), Казанда Ф.Шаляпинга һәйкәл (1999) һәм Җиңү Паркы ачылу уңаеннан (2000), Мәүлид, Корбан бәйрәмнәрен билгеләп үтү («Россия» Үзәк концерт залы, Мәскәү, 2000), Җиңү бәйрәменең 60 еллыгына, Казанда С.Сәйдәшевкә һәйкәл ачылу хөрмәтенә һ.б. чаралар үткәрә; ш.у. «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестиваленә багышланган «Бөек Болгар» концерт программасы әзерли.



«Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносының беренче фестивале кысаларында «Бөек Болгар» концерт программасы. Сценарий авторы һәм сәхнәгә куючы — Л.Г.Кустабаева.

К. милли сәнгатьнең иң яхшы традицияләрен пропагандалауга һәм үстерүгә, саклауга үзеннән зур өлеш кертә. Аның иҗади стиле фикер камиллеге, тематик диапазонының киңлеге, күптөрлелеге, табигыйлек һәм тасвирлау чараларының үзара аерылгысыз бәйләнеше; ш.у. музыка, җыр, бию, сценография, режиссураның бердәм булуы б-н аерылып тора. К. күп кенә җырларның («Олы юлның тузаны», 1973; «Республикам минем», Ә.Рәшитов шигыре, 1996) һәм хор әсәрләренең эшкәртмәләре авторы. Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Милли учак яктысы // Казан утлары. 1998. № 12; Нафиса Василова // Народные артисты. К., 1980; Сценическое решение национального костюма в творчестве Б.И.Урманче // Сб. статей по материалам науч. конф., посвященной 90-летию Б.Урманче. К., 1989; Мой Сайдаш // Казань. 2000. № 12.

*Әд.:* З ә й н ә ш е в а Г. Чын безнеңчә матур, милли // Казан утлары. 1993. № 12; З а р и п о в Р. Пегас кашына микән? // Казан утлары. 2004. № 9; Ш а д р и н а Н., Г о г о б е р и д з е Г. Из народных истоков // Советская культура. 1986. 19 апр.; Г о н ч а р о в а Л.И. Мастерство, и вдохновенье, и жизнь, и слёзы, и любовь // Лидер Татарстана. 2003. № 6.

*Ф.Ш.Салитова.*

**КУТА́СОВА** Илфа Мәҗит кызы (13.2.1930, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1985), проф. (1988). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1952). 1952–56 елларда мәктәптә эшли (Мәскәү). 1956–64 тә СССР ФАнең Шәрекъне өйрәнү ин-тында. 1965 тән Мәскәү пед. ун-тының филос. кафедрасында. Хезмәтләре экзистенциализм философиясенә карый.

*Әд.:* Антифилософия «новой философии». М., 1984; Хрестоматия по истории философии. М., 1994 (автордаш).

**КУТУ́ЕВ** Рәүф Ибраһим улы (1925, Самара ш. — 5.12.1944, Эрчи шәһәре тирәсендә җирләнә, Венгрия), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), кече лейтенант. Кече лейтенантлар курсын тәмамлый (1944). Актүбә шәһәрендә «Актюбрентген» з-дында эшли. 1943 елның гыйнварыннан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1 нче укчы полкта взвод командиры (46 нчы армиянең 99 нчы укчы дивизиясе). Көньяк һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Донбасс һәм Мелитополь һөҗүм операцияләрендә катнаша (1943). 1944 елның 5 декабрендә Дунай елгасын кичеп, Эрчи шәһәре янындагы сугышта батырлык күрсәтә: елганың уңъяк ярында дошман ныгытмасын кулга төшерә һәм саклап тота, шунда һәлак була. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Актүбә шәһәренең бер урамы К. исемен йөртә, «Актюбрентген» з-ды терр-ясендә Герой хөрмәтенә таш стела урнаштырыла.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Актюбинцы — Герои Советского Союза. А.-А., 1966; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1987. Т. 1.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КУТУ́ЕВА** Зәйнүл (Зәйнәп) Мөхәммәт кызы (1903, Саратов губ., Кузнецк р-ны Татар Кынадысы а. — 1996, Казан), фтизиатр, ТАССР, РСФСРның атказ. табибе (1945, 1958). 1929 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Әтнә р-нында эшли: Күлле Киме хастаханәсендә 1930 дан табиблек амбулаториясе мөдире, бер үк вакытта район башкарма ком-тының сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 1932 дән Казан ГИДУВының туберкулёз авырулары кафедрасында. 1936 дан Казан туберкулёз ин-тының клиника бүлеге ассистенты. 1939 дан Казан мед. ин-тында туберкулёз курслары укыта, бер үк вакытта 1947 дән Казан туберкулёз диспансеры директоры. Тикшеренүләре туберкулёз китереп чыгаручы бактерия полиморфизмы өлкәсенә һәм туберкулёз аллергиясенә карый. К. — Татарстанда туберкулёз б-н авыручыларга диспансер хезмәтен оештыручы. Ул туберкулёз авыруларын «зәңгәр таякчыклар» вакцинасы б-н дәвалауның отышлылыгына клиник күзәтүләр үткәрә.

Х е з м.: Кожная аллергия и полиморфизм возбудителя туберкулёза // Казан. мед. журн. 1934. № 9 (автордаш).

**КУТУ́ЗОВ** (Голенищев-Кутузов-Смоленский) Михаил Илларионович (5.9.1745, С.-Петербург — 16.4.1813, Силезия, Бунцлау ш.), кенәз (1812), полководец, дипломат, генерал-фельдмаршал (1812). Дворяннар нәселеннән. 1761 елдан хәрби хезмәттә. 1768–74, 1787–91 елларда рус-төрек сугышларында катнаша. 1793–96 да Казан һәм Вятка генерал-губернаторы. Казанда 1791 дә оешкан рус халык театры үсеш кичерә, шәһәрне төзекләндерү эше дә дәвам итә. Бер үк вакытта, 1793–94 тә, К. Константинопольдә гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илче, 1794–97 дә Петербургтагы коры җир шляхта кадетлар корпусының баш директоры.



М.И. Кутузов.

1799–1801, 1809–11 дә Литва, 1801–02 дә Петербург генерал-губернаторы. 1805 тә, Наполеон б-н сугышкан вакытта, рус гаскәрләре б-н җитәкчелек итә; 1811–12 дә рус-төрек сугышында Молдова армиясенең башкомандующие була; Россиягә файдалы 1812 елгы Бухарест солыхы төзи. 1812 нең августыннан Наполеонга каршы сугышкан барлык гаскәрләрнең башкомандующие. 26 августта К. Бородино кырындагы сугышка җитәкчелек итә, шуннан соң рус гаскәрләре, Тарутино манёвры ясап, Мәскәүне калдырып китә һәм дошманнан аерылуга ирешә. Нәтиҗәдә, К. французларны Мәскәүдән китәргә һәм, сугыша-сугыша, Россиянең көнбатыш чикләренә таба чигенергә мәҗбүр итә. 1812 елның декабрендә дошманның төп көчләре тар-мар ителә һәм илдән куыла. К. Европага яу б-н барган вакытта һәлак була.

*Әд.:* Синельников Ф. Жизнь, военные и политические деяния Его Светлости, генерал-фельдмаршала князя М.И.Голенищева-Кутузова-Смоленского...: В 6 ч. СПб., 1813–14; Гуляев Ю.Н., Соглаев В.Т. Фельдмаршал Кутузов. М., 1995; Фельдмаршал Кутузов: Документы, дневники, воспоминания. М., 1995.

*Е.Б.Долгов.*

**КУТУ́Й** (Кутуев) Гадел (Гаделша) Нурмөхәммәт улы (28.11.1903, хәзерге Саратов губ., Кузнецк өязе Татар Кынадысы а. — 15.6.1945, Польша, Згеж ш.), язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Башта туган авылы мәдрәсәсендә, 1912 елдан — Саратов губернасы Алексеевский авылында рус мәктәбендә, соңыннан Самара шәһәрендә рус-татар мәктәбендә укый. Шул вакытта ук рус әдәбиятына тартыла башлый: А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, М.Горький, В.В.Маяковский һ.б.ларның әсәрләрен укый. 1920 дә Казанга килә. 1922 гә кадәр Казан политехник ин-тында укый, аннан Алтынчы берләштерелгән татар-башкорт (хәрби) командирлары мәктәбендә (хәзер Чиләбе танк ин-тының Казан ф-лы) укыта. Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1929), урта мәктәптә, Казан авиация техникумында (1932–41), Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында (хәзер Казан арх-ра-төзелеш ун-ты) рус теле һәм әдәбияты укыта. 1920 елларда хикәяләр, пьесалар яза, республика вакытлы матбугатында күпсанлы фельетоннар, очерклар, мәкаләләр, ш.у. Татар акад. театрының һәр спектакленә диярлек рецензияләр язып бастыра. 1922 дә «Безнең юл» ж-лында беренче шигырьләре дөнья күрә. К. шигъри форма өлкәсендә тәҗрибә туплый башлый, конструктивизм рухындагы композиция ысулларына, революцион-романтик образларга мөрәҗәгать итә. Аның беренче «Көннәр йөгергәндә» (1925) исемле шигъри җыентыгында чагылыш тапкан тәүге иҗади эзләнүләрендә футуризм йогынтысы сизелә. Бу җыентык ул еллар поэзиясе өчен үзенчәлекле бер күренеш була. К. шигырьләрендә халыклар дуслыгы, җәмгыятьтәге революцион үзгәрешләр, социаль гаделлек өчен көрәш темалары күтәрелә; алар иске тормышны инкарь итү рухы б-н сугарылган («Егерменче броневик», «Октябрьдә», «Тимер чәчәкләрдән», «Биш минутка дөнья туктады», «Эшче шагыйрь», «Атла, диңгез»). Шагыйрь метафора ярдәмендә кинаяле, фантастик, әмма психологик яктан чынбарлыкка туры килгән күренешләр тудыра. К.ның лирик герое бөтен дөнья, бар табигать өчен җаваплылыкны үз өстенә ала (Адәм баласын илаһилаштыру татар әдәбиятында идеологик схемачылыктан котылуның бер варианты була). К.ның коммунистик идея б-н сугарылган поэзиясенә көчле эмоциональлек хас. 1930 еллар — К. өчен иҗади яктан күтәрелеш чоры. Ул яңа кеше һәм яңа соц. әхлакның формалашуы гаять катлаулы процесс икәнен күрсәтергә тырыша. «Фәрзәнә» (1928), «Солтанның бер көне» (1938), «Вөҗдан газабы» (1939), «Нишләргә?» (1940) хикәяләренең, «Балдызкай» (1926), «Күк күгәрчен» (1929), «Җавап» (1929) пьесаларының, «Сә-



Г.Кутуй (сулда) журналистлар З.Габитов һәм М.Дибаева белән.

лимә» (1927) поэмасының геройлары — автор идеалы югарылыгына күтәрелгән, сәләтле, гайрәтле яшьләр. Аларның кылган гамәлләре һәм хыяллары К.га якты киләчәккә ышаныч б-н карарга өмет бирә. Язучы иҗатының иң югары ноктасы — «Тапшырылмаган хатлар» (1935; рус теленә тәрҗемә — 1954) һәм «Рөстәм маҗаралары» (1944) повестьлары. «Рөстәм маҗаралары»нда халыкның Бөек Ватан сугышы елларында кичергән фаҗигасе яшүсмер бала күңеле аша яктыртыла. «Тапшырылмаган хатлар» повестенең асылын татар хатын-кызы язмышы билгели. Авторны әхлак мәсьәләләре, кешенең рухи дөньясы борчый. Яшь ир б-н хатын арасында туган конфликт гаиләдә хатын-кызга карата булган искергән патриархаль һәм яңа караш-



Г. Кутуй (сулда) һәм Һ. Такташ. 1931.

лар бәрелешен чагылдыра. Повесть герое Галия — йомшак, мөлаем, бер үк вакытта көчле ихтыярлы хатын. Ире ташлаганнан соң да ул төшенкелеккә бирелми, врач булу максатына ныклы адымнар б-н бара, балаларын үстерә, кешеләрнең хөрмәтен яулый, чын мәхәббәтен таба. Повесть тиз арада зур популярлык казана, рус, башкорт, казакъ, каракалпак, кыргыз, мари, тува, үзбәк, хакас, чуаш, албан, корея, кытай, монгол, чех телләренә тәрҗемә ителә. Әсәргә Җ.Фәйзи тарафыннан музыка һәм либретто языла, һәм 1960 та Татар опера һәм балет театрында шул исемдә опера, 1961 дә Татар күчмә театрында спектакль (авторы Г.Минский) куела.



Г. Кутуй.

Бөек Ватан сугышы елларында К. «Кызыл сугышчы», «Ватанны саклауда», «Тревога», «Алга, дошман өстенә» фронт г-таларының хәбәрчесе була, аларда, сугышта күргәннәрен чагылдырып, үзенең очерклар сериясен, хикәяләрен, шигырьләрен бастыра. Аның сугыш еллары герое — батыр кеше, үз-үзен аямыйча көрәшүче сугышчы: «Без — сталинградчылар», «Хәнҗәр». «Сагыну» нәсерендә туган ягын сагынучы солдат образы гәүдәләнә. К.ның сугыш еллары әсәрләренә гражданлык пафосы, җиңүгә ышаныч хисе хас.

Хәрби госпитальдә вафат була. Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Публицистика. К., 1957; Сайланма әсәрләр. К., 1965.

*Әд.:* Нуруллина Р. Һәрвакыт сафта: (Гадел Кутуйның публицистик эшчәнлеге). К., 1966; Усманова З. Адель Кутуй: Жизнь и творчество. К., 1966.

*Н.М.Йосыпова.*

**КУТУ́Й** (Кутуев) Рөстәм Гаделша улы (11.11.1936, Казан — 7.1.2010, шунда ук), язучы, ТАССРның атказ мәдәният хезмәткәре (1987). Г.*Кутуй* улы. Рус телендә иҗат итә. 1960 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1960–61 елларда Татарстан китап нәшрияты, 1961- 63 тә Казан телестудиясенең әдәби тапшырулар мөхәррире. 1994 тән «Казан» ж-лы редколлегиясе әгъзасы. Беренче шигырь һәм хикәяләре «Ленинец», «Комсомолец Татарии» г-таларында, күмәк җыентыкларда басыла. Беренче әсәрләрендә үк: «Малайлар» («Мальчишки», 1961), «Яңгыр явачак» («Дождь будет», 1963) хикәя һәм повестьлар, «Мин җирдән атлыйм» («Я иду по земле», 1962) шигъри җыентыкларында язучының төп тематикасы һәм кызыксыну даирәсе күренә башлый: сугыш чоры балачагы, сугыштан соңгы яшьлек еллары, тол хатыннар һәм ятим балалар язмышы. К. түбәнлекне, хыянәтне инкарь итә («Мин кар бабай ясыйм» («Я леплю снежную бабу», М., 1966), «Учымдагы кояш» («Солнце на ладони», М., 1973), «Бер көз» («Одна осень», М., 1985), «Көләм, буылам һәм елыйм» («Смеюсь, задыхаюсь и плачу», 1996) җыентыклары). Аның геройлары — батыр, дуслыкка тугры

кешеләр. К.ның шигырьләрендә — «Өмет учаклары» («Костры надежды», 1965), «Яңа ай туганда» («Новолуние», 1971), «Җир яфрагы» («Лист земли», М., 1980), «Кичке җыр» («Песня вечерняя», 1993) — кояш, һава, музыка өстенлек итә; алар сәнгатьле, оптимизм б-н сугарылган. К. — балалар өчен язылган шигъри җыентыклар авторы: «Алтын болан» («Золотой олень», 1979), «Иләктәге могҗиза» («Чудеса в решете», 1989) һ.б. Аның әсәрләре татар, кыргыз, литва, поляк, испан һ.б. телләрдә дөнья күрә. Үзе Г.Тукай, Г.Кутуй, Ә.Еники, С.Хәким, Ә.Давыдов, Р.Фәйзуллин һ.б.ның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Г.Р.Державин исем. әдәби бүләк лауреаты (2009).

*Әд.:* Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970; П а у ш к и н Г. Зрелость таланта // Казанские ведомости. 1996. 11 ноябрь.

*В.С.Мостафин.*

**КУТУ́ШЕВ** Фәттах Хәлим улы (2.5.1923, Мордва АССРның Кызыл Октябрь р-ны Черный Студенец а.), хирург, мед. фән. д-ры (1959), проф. (1964). 1949 елда Ленинград педиатрлар мед. ин-тын тәмамлый. 1946 дан Ленинград хәрби мед. академиясендә. 1964–94 елларда Ленинград педиатрия мед. ин-тының гомуми хирургия каф. мөдире, бер үк вакытта 1964–87 дә Ленинградның баш хирургы. Хезмәтләре торакаль (күкрәк читлеге) һәм йөрәк-кан тамырларының гомуми һәм госпиталь хирургиясе мәсьәләләренә карый. Аутогемотрансфузия ысулын эшләгәне һәм хирургия гамәленә керткәне өчен СССР МС бүләге бирелә (1986). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Диагностика и лечение открытого артериального протока. Л., 1962; Искусственное кровообращение. Л., 1962.

**КУ́ТЫРЕВ** Геннадий Андреевич (1.3.1947, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1986), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли. 1987 елдан Казан фотоматериаллар ин-тында: директор урынбасары, директор (2001–05); бер үк вакытта Казан технол. ун-ты профессоры (1989 дан). Хезмәтләре органик һәм элементорганик күкертле кушылмалар химиясенә карый. К. фосфор-күкерт-органик кушылмаларның реакциягә керү мөмкинлеге һәм синтезы буенча фәнни юнәлешкә нигез сала. Фосфорның инсектоакарицид, фунгицид һәм үсешне көчәйтү активлыгына ия кремнийле һәм аккургашлы тиокушылмаларын алуның яңа ысулларын ача. К. җитәкчелегендә сенсибилизаторлар, стабилизаторлар, антивуалентлар, медицинада һәм махсус билгеләнгән яктыга сизгер материаллар өчен полимер өстәмәләрнең яңа тип технологияләре эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. К.ның фәнни эшләнмәләре аэрокосмик өйрәнүләр өчен яңа төр фотоматериаллар булдыруга ярдәм итә. Уйлап табуга 24 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Взаимодействие силилдитиофосфатов с карбонильными соединениями // Докл. АН СССР. 1979. Т. 247, № 3 (автордаш); Organophosphorus reagents in organic synthesis // Tetrahedron. 1985. V. 41 (автордаш); The reactivity of phosphorus-containing sulfenyl chlorides in addition reactions // Sulfur Reports. 1992. V. 11 (автордаш).

**КУ́ТЫШЕВ** Фирдәүс Хөсәен улы (22.8.1931, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1986), проф. (1990). 1954 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. 40 нчы махсус җитештерү техн. бюросында (1955–57), Казан технол. ун-тында (1960–2004) эшли. Хезмәтләре техник химиягә карый. Каты ягулыклы ракета двигательләрендә һәм заряд кабынып киткәндә артиллерия тубы көпшәсендә камера эче процессларын өйрәнә. Каты ягулыктан һәм дарылардан заряд кабынып китү процессына пиротехник кабызгыч һәм төтенле корал дарысының җылылык агымы элементлары тәэсир итүен билгели. Җылылык агымын кушылучыларга бүлү методикасын эшли, һәр кушылучының үзгәрешенә һәм тиңдәшле рәвештә корылмалар кабынуга тәэсир итүче факторларны өйрәнә. Каты ракета ягулыклары һәм дарылардан эшләнгән әйберләрнең гарантияле саклану вакытын һәм кабынып китүнең критик параметрларын билгели. Фәнни эшләнмәләре оборона сәнәгате пр-тиеләрендә файдаланыла. 60 басма, ш.и. өч монография авторы. Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**КУФТИ́Н** Борис Алексеевич (21.1.1892, Самара ш. — 2.8.1953, Ленинград), археолог, этнограф, тарих фән. д-ры (1940), Грузия ССР ФА академигы (1946; 1944 елдан — мөхбир әгъза). Мәскәү ун-тын ботаника (1917), антропология, археол. һәм этногр. (1919) курслары буенча тәмамлый. Россиядә антропологиягә һәм географлар фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе булган акад. Д.Н.Анучин шәкерте. 1919–33 тә Мәскәү ун-тының антропология кафедрасы доценты, бер үк вакытта Матди культура тарихы дәүләт академиясенең Мәскәү секциясе этнология комиссиясе рәисе урынбасары, Халыкларны өйрәнү үзәк музееның (Мәскәү) Урта Азия һәм Себер бүлеге мөдире. 1933 тән Грузия дәүләт музееның галим-консультанты. 1920 елларда К.(О.Н.*Бадер*, В.А.Городцов, Н.И.Лебедева, А.А.*Мансуров*, А.М.Россова-Куфтина б-н берлектә) Үзәк сәнәгать өлкәсенә, Кырым, Себер, Ерак Көнчыгышта күпсанлы экспедицияләрдә тикшеренүләр үткәрә. К.ның баштагы хезмәтләре СССР халыклары, ш.и. Кырым, Касыйм татарлары, мишәрләрнең этнографиясе, этногенезы һәм археологиясенә карый. Галимнең этногр. тикшеренүләренең асылы һәм төп эчтәлеге киң геогр. параллельләр үткәрүгә, тирән тарихи чагыштыруларга нигезләнә. Идел буе татарларының этник мәдәниятенә караган типларны ачыклаганда К. татарларның һ.б. күпсанлы чиктәш халыкларның торак, кием-салым, бизәкләү элементларына анализ ясый. Грузиянең археол. истәлекләрен өйрәнгәндә, ул б.э.к. 2 нче меңьеллыкның бронза дәверенә караган, моңа кадәр билгеле булмаган Кавказ арьягы культурасын ача; әлеге тикшеренүләрне гомуміләштергән «Триалетида археологик казу эшләре (1936–40 еллар)» («Археологические раскопки в Триалети (1936–40 гг.)», Тб., 1941, т. 1) дигән хезмәте СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1942). К. беренче булып Кура-Аракс энеолиты культурасын аерып күрсәтә; «Колхида археологиясенә материаллар» («Материалы к археологии Колхиды», т.1–2, Тб., 1949–50) исемле хезмәтендә Көнбатыш Грузия һәм Көньяк Осетиядәге истәлекләрне тасвирлый. Урта Азиянең иң борынгы тарихын яктырту өчен әһәмиятле мәгълүматларны К. үзенең Көньяк Төрекмәнстанга ясаган соңгы комплекслы археол. экспедициясе вакытында таба (1952).



Б.А. Куфтин.

Х е з м.: Жилище крымских татар в связи с историей заселения полуострова. М., 1925; Южнобережные татары Крыма // Крым. 1925. № 1; Материальная культура русской Мещеры. М., 1926; Краткий очерк северного буддизма и ламаизма в связи с историей учения. М., 1927; Татары касимовские и татары-мишари Центрально-промышленной области // Культура и быт населения Центрально-промышленной области. М., 1929.

*Әд.:* Д е б е ц Г. Памяти Б.А. Куфтина // Сов. этнография. 1954. № 1.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КУХНИНА́** Татьяна Михайловна (9.2.1952, Мордва АССРның Саранск ш.), вертеброневролог, мед. фән. д-ры (2001). 1975 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук нерв авырулары кафедрасында эшли. 1989 елдан Реабилитация үзәгендә (Мәскәү). 1994 тән Украина балалар курортлары һәм физиотерапия үзәгендә (Евпатория ш.). 1997 дән Казан мед. академиясенең неврология һәм вертеброневрология кафедрасында. К. балаларда неврологик авыруларны өйрәнә, курорт шартларында авыруларны реабилитацияләү ысулларын эшли.

**КУХТИ́Н** Виктор Александрович (5.7.1929, Украина ССРның Донецк өлкәсе «Червона Зирка» шахта пос. — 3.1.1980, Чабаксар ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1962), проф. (1964), Чуаш АССРның атказ. уйлап табучысы (1979). 1950 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1956 дан Кинофотоматериаллар фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында лаб. мөдире, 1962 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Химия ин-тында полимерлар лаб-ясе мөдире. 1964–69 да Физик проблемалар фәнни-тикшеренү ин-тының бионика бүлеге мөдире (Мәскәү), бер үк вакытта Мәскәү электрон техника ин-ты профессоры. 1969 дан Чуаш ун-тының органик химия каф. мөдире. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. К. өчвалентлы фосфор к-тасы эфирларының тулы булмаган бәйләнешле альдегидлар, кислоталар, дикетоннар б-н реакцияләрен эшкәртә, фосфорлы буягычлар (ш.и. полиметин) ала һәм җитештерүгә кертә. Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы бар.

*В.Г.Абзалова.*

**КУША́ЕВ** Гобәйдулла Габдулла улы (3.9.1902, Казан — 3.8.1937, Мәскәү), журналист. Мәскәү журналистика ин-тын тәмамлый (1928), ТАССР комсомол оешмасы җитәкчеләренең берсе, 1920–22 елларда «Кызыл яшьләр» г-тасының беренче мөхәррире, 1922–25 тә «Яшь юксыл» һәм «Башкортстан яшьләре» г-таларының оештыручысы һәм мөхәррире. 1928 дән «Кызыл Татарстан» г-тасының мөхәррир урынбасары, 1930–33 елларда «Колхозник Татарии», ә 1933 елдан күптиражлы «Крылья Советов» г-тасының җаваплы мөхәррире. Репрессияләр чоры корбаны (к. *«Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террорчылык оешмасы» эше*). Үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Журналистлык әлифбасы. К., 1927 (автордаш); Кызыл кичәләр. К., 1927 (автордаш); Никах һәм гаилә турында Совет законнары. М., 1928; Капитал илләрендә яшьләр. М., 1930; Колхоз яклымы, әллә каршымы. К., 1931.

*Әд.:* Сәяси репрессия корбаннарының хәтер китабы — Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2003. Т. 7.

**КУША́ЕВЛАР**, элекке сәүдәгәрләр династиясе. Аның башында торучы — **Мөхәммәт** К., йомышлы татар. Бакалея товарлары б-н сәүдә итә, фирмасы 1832 елдан билгеле. Эшен балалары дәвам итә: **Мортаза Мөхәммәт улы** (1790–1877), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре һәм **Ибәтулла Мөхәммәт улы** (1822–82); аларның вафатыннан соң — **Габдерахман Габдулла улы** К. (1862–1917 дән соң), 2 нче гильдия сәүдәгәр, шәхси мактаулы граждан. 1909–13 елларда Казан шәһәр думасы гласные. Казан шәһәр җәмәгать банкы идарәсе әгъзасы, Казанның 1 нче җамигъ мәчете һәм «Мәрҗания» мәдрәсәсенең җәмәгать идарәчесе. Беренче бөтендөнья сугышы елларында яралылар өчен госпиталь оештыруда катнаша. Актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге алып барган өчен Станислав һәм Владимир тасмалы ике көмеш «Тырышлык өчен» медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1994.

**КУША́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Зәй елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,8 *км*, бассейнының мәйданы 99,7 *км*². Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Кушай авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Байгол авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 55%. К.ның 4 кушылдыгы бар; иң зурысы (уң) — Алан елгасы (10,4 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,56 *км/км*². Туенуы катнаш, өчтән икегә якынын кар сулары алып тора. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 91 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,108 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада су күләме 0,4 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КУША́Й** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 15 *км* көньяктарак, Кушай елгасы буенда. 2010 елда 31 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, агачтан әйберләр ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 380,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афонас волостена керә. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 161, 1870 тә — 179, 1884 тә — 235, 1913 тә — 486, 1920 дә — 441, 1926 да — 308, 1949 да — 356, 1958 дә — 267, 1970 тә — 229, 1979 да — 130, 1989 да — 66, 2002 дә — 67 кеше.

**КУШКУА́К** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 5 *км* көнбатыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 521,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Чүпрәле волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1880 дә — 422, 1897 дә — 513, 1913 тә — 654, 1920 дә — 507, 1926 да — 360, 1938 дә — 392, 1949 да — 311, 1958 дә — 181, 1970 тә — 226, 1979 да — 156, 1989 да — 20, 2002 дә — 2 кеше.

**КУШКУ́Й** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Бисәр елгасы буенда. 2010 елда 129 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1929 да нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Олы Шәмәк волостенда. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 247, 1949 да — 281, 1958 дә — 290, 1970 тә — 310, 1979 да — 261, 1989 да — 190, 2002 дә — 139 кеше.

**КУШКУ́Л** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1937 дә нигез салына. Оештырылган көннән Кайбыч р-нында. 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1938 дә — 191, 1958 дә — 99, 1970 тә — 98, 1979 да — 88, 1989 да — 90, 2002 дә — 92 кеше.



Р.К. Кушловская.

**КУШЛАВЫ́Ч** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кызылсу елгасы буенда. 2010 елда 141 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Г.Тукай туган гаиләнең музей-йорты. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, тимерчелек, 2 юлаучылар йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1260,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 89 ир-ат; 1859 да — 730, 1897 дә — 802, 1908 дә — 798, 1920 дә — 693, 1926 да — 682, 1938 дә — 669, 1949 да — 347, 1958 дә — 268, 1970 тә — 208, 1979 да — 189, 1989 да — 137, 2002 дә — 164 кеше. К. — халык шагыйре Г.Тукайның туган авылы.

**КУШЛО́ВСКАЯ** Рокыя Камалетдин кызы (...12.1901, Казан – 31.5.1986, шунда ук), драма актрисасы. ТАССРның атказ. артисты



Р.К. К у ш л о в с к а я Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшев) ролендә.

(1957). Сәхнә эшчәнлеген фронт театр труппаларында башлый (1918–20). 1920 елдан Беренче Татар дәүләт труппасында (1921 дән Татар дәүләт театрында). 1925–42 елларда Уфа, Оренбург шәһәрләрендәге татар театрларында, 1942–57 дә (бүленеп) Татарстан Респ-ка күчмә театрында. Җырлау сәләтенә ия актриса; образның муз. һәм драматик тукымасын табигый берләштереп, К.Тинчуринның «Казан сөлгесе» (Мәршидә), «Сүнгән йолдызлар» (Сәрвәр); М.Фәйзинең «Галиябану» (Галиябану, алга таба Галимәбану); Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә» (Зөһрә) әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә онытылмас образлар иҗат итә. Дилбәр («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Ксения («Убылу», Б.А.Лавренёв) образлары да — аның иң яхшы иҗат уңышлары.

**КУШМИ́Н** Шамил Әхмәтҗан улы (17.9.1948, Лаеш р-ны Татар Янтыгы а.), галим-агроном, ТР, РФнең атказ. агрономы (2002, 2007). Казан а.-х. ин-тын тәмамлый (1971). 1971–78 елларда Үзәк а.х. эксперименталь фәнни-тикшеренү ин-тында агроном, 1978 дән «Хәерби» с-зында, 1995 тән «Хәерби» күмәк пр-тиесендә, 2003 тән «Хәерби» ҖЧҖдә баш агроном булып эшли. ТРда беренче тапкыр үсентесез кәбестә үстерү ысулының сәнәгый технологиясен куллана, бәрәңге игүнең универсаль технологиясен гамәлгә ашыра, бөртекле культураларның орлыкчылык тармагы үсешенә зур өлеш кертә. Бөртеклеләр, азык һәм яшелчә культураларыннан зур уңышлар алуга ирешүе өчен медаль, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының күпсанлы мактау грамоталары һәм дипломнары б-н бүләкләнә.

**КУШМӨХӘММӘ́ТОВ** Гариф Зариф улы (9.7.1901, хәзерге Оренбург өлкәсенең Переволоцкий р-ны Чесноковка а. — 11.8.1958, шунда ук), а.х. җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1957). 1920 елга кадәр әтисе хуҗалыгында эшли. Гражданнар сугышында катнаша. 1923–38 дә (бүленеп) Чесноковкада сельпо рәисе булып эшли. 1933–37 дә Переволоцкий р-нының «Интернационал» к-зында рәис, Чесноковка МТСнда директор урынбасары (1938 дән), ВКП(б)ның Краснохолмский райкомы инструкторы (1939 дан), Кызыл Мәйдан МТСның сәясәт бүлеге җитәкчесе (1942 дән), Томар-Уткүл (1943 тән), Акболак (1949 дан), Чесноковка (1957 дән) МТСларында директор. Герой исеме чирәм һәм яткан җирләрне үзләштергәндә күрсәткән хезмәтләре, 1956 да уңыш җыюны һәм икмәк әзерләүне уңышлы оештырганы өчен бирелә. 1934–58 дә Оренбург өлкә советы депутаты. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының кече алтын медале б-н бүләкләнә. Чесноковка авылында бер урамга К. исеме бирелә, мәктәп музеенда экспозиция булдырыла. Элеккеге Акболак МТСы бинасында мемориаль такта куела. Ел саен К. исем. призга район чаңгы ярышлары уздырыла.






1. Танкеевка һәм Такталачык каберлекләрендә табылган савытлар; 2. Такталачык каберлегеннән көмеш чылбыр. ТР ФА Тарих институтының Археологик тикшеренүләр милли үзәге фондлары.

**КУШНАРЕ́НКО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Көньяк Урал һәм Урал алды урман-дала р-ннарында ачыла (якынча, 6 йөзнең 2 нче — 10 йөзнең 1 нче яртылары). Атама БРның Кушнаренко авылы янындагы каберлек исеменнән алынган. Беренче тапкыр В.Ф.Генинг тарафыннан 1959 елда тасвирлана. 4 этапка бүленә: элгәреге (6 йөзнең 2 нче яртысы — 7 йөз башы), Мәнәк (7–8 йөзләр), Хөсәен (8 йөз ахыры — 9 йөз), Танкеевка (9 йөз ахыры — 10 йөзнең 1 нче яртысы). Мажар кабиләләренә якын булган Көнбатыш Себер күчмә угор халыклары калдырган дип фараз ителә. Башта Кушнаренко кабиләләре Урал алдына килеп утыралар. Мәнәк этабында алар терр-яләрен киңәйтәләр — Көнчыгыш Кама аръягының Турбаслы-Имәнкискә халкы җирләрен үзләштерәләр. 9 йөзнең урталарында мажар-кыпчак сугышлары чорында Кушнаренко җирләре бушап кала, халкы Көнбатыш Кама аръягына күчеп китә, анда болгар этносы һәм культурасын формалаштыруда катнаша.

К.к. кабиләләре терлекчелек, аучылык б-н шөгыльләнә. Татарстан терр-ясендә бик аз күләмдә культура катламы билгеләре сакланган 10 авыллык, 8 каберлек һәм 20 дән артык башка ядкәрләр ачыклана. Аларда әвәләп эшләнгән озын муенлы, йомры төпле, сырлы, тарак тешле һәм фигуралы-штамплы бизәкләр төшерелгән савытлар табыла.




Кушнаренко культурасы ядкәрләре: 1–4, 6, 7, 9–11 — геральдик типтагы билбау каптырмалары; 5, 8, 12 — чулпылар; 13 — элмәк; 14 — балчык савыт.

Мәетләрне тирән булмаган (кайчак зур булмаган курганнар астында) каберләрдә корал, ат җигү кирәк-яраклары, савытлар, бизәнү әйберләре б-н бергә җирләгәннәр. Каберләрдә һәм курган өемнәрендә корбанга китерелгән ат сөякләре очрый. Көнчыгыш Кама аръягында — Актаныш р-нының Такталачык, Чишмә, Мөслим р-нының Мәлләтамак, Рус Шуганы авыллары тирәсендә 7–8 йөзләргә караган каберлекләр булганлыгы билгеле. Идел буе Болгар дәүләте чорына нисбәтле К.к.на караган каберләрдә (Алексеев р-ны Зур Тигәнәле каберлеге) көмештән ясалган мәет битлекләре, сасаниларга хас мотивларны (канатлы атлар, этләр, аждаһалар һ.б.) чагылдырган төрле бизәкләр төшерелгән бронза һәм көмеш эшләнмәләр табып алына.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П. Кушнаренковские памятники Нижнего Прикамья // Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой. К., 1981; ш у л у к. Культура ранней Волжской Булгарии. М., 1992; C h a l i k o v a E.A., C h a l i k o v A.H. Altungarn an der Kama und im Ural (Das Graberfeld ron Bolshie Tigani). Bdpst., 1981.

*Е.П.Казаков.*

**КУШНАРЕ́НКО РАЙОНЫ́**, БРның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1748 *км²*. Үзәге — Кушнаренко авылы (Уфадан 60 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан). Халкы — 28607 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 18606, 1979 да — 14020, 1989 да — 22232, 2002 дә — 11641 кеше. Элгәрәк төзелгән авыллар — Илморза (1681–85), Көдешлебаш (1700), Мортаза (1713), Рәсмәкәй (1714), Калтай (1716), Гумәр (1750), Ислан посёлогы (1734). К.р.на урнашу барышында татарлар еш кына башкорт торак пунктларына туктала, шунлыктан алар еш кына татар торак пунктлары булып китә. Шулардан татарлар элегрәк урнашкан авыллар: Каратәкә (1719) һәм Солтанай (1714 яки 1719). 2004/05 уку елында районның 37 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 6 сында татар теле фән буларак өйрәнелә. Кушнаренко пед. уч-щесендә татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерләнә. Район балалар музыка мәктәбе каршында татар балалар хоры коллективы эшли.

**КУ́ШНИКОВ** Дмитрий Алексеевич (15.10.1856, Казан губ., Спас өязе Каравае-

во а. — 20.12.1911, Казан), табиб, җәмәгать эшлеклесе. Казан руханилар семинариясендә укый (куыла). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1875). 1875 елдан Себер приискаларында табиб. 1889–1906 да Казан губернасының Чабаксар өязендә земство табибе булып эшли, земство каршындагы казанышлары өчен аның портреты Исмелевский авылы хастаханәсенә куела. Халык өчен укулар, китапханә-уку бүлмәләре оештыра, метеорологик станция б-н җитәкчелек итә. Конституцион демократлар партиясенең Казан бүлеге әгъзасы. 1 нче Дәүләт Думасы сайлауларында катнашканнан соң (1906) хезмәтеннән читләштерелә һәм полициянең яшерен күзәтүе астында яши. Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), кадетлар партиясе фракциясе әгъзасы. Дума куып таратылганнан соң (1907) Казанга кайта: ун-т клиникасында ординатор, бертуган Крестовниковлар хастаханәсендә табиб; хосусый практика б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Члены второй Государственной Думы. СПб., 1907; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Л.М.Айнетдинова.*

**КУШТА́НОВА** Галия Гата кызы (21.4.1951, Свердловск өлкәсенең Дегтярск ш.), җир асты гидродинамикасы өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2007). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли (бүленеп, 1976–88 дә Урал-Идел промысел-геофиз. трестында). Хезмәтләре җир асты гидродинамикасына, нефть һәм газ скважиналарындагы термодинамик процессларга, җир кабыгының җылылык кырына карый. К. төрле төзелешле скважиналар өчен термодинамик эффектларны исәпкә алып, катлам-скважина системасында газның изотермик агымы модельләрен тәкъдим итә. Күзәнәкле-ярыклы тирәлекләрдә сыеклыкның нәстационар һәм периодик тигезләшмәгән фильтрлануын, ш.у. җирнең югары мантиясендә конвектив агымнарның тәэсирен тикшерә. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Выработка трещиновато-пористого коллектора нестанционарным дренированием. К., 2000 (автордаш); Температурный контроль разработки месторождений нефти и газа. К., 2003; Метод фильтрационных волн давления как средство исследования нефтяных месторождений. К., 2008 (автордаш).

**КУШЪЕЛГА́** (Ашыт) авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 34 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Зичә елгасы бассейнында. 2010 елда 211 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Кабер ташындагы язмалар — 19 йөз эпиграфик истәлеге. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кушнарат-Елга, Ашыт исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, мичкә, тәгәрмәч ясау, тимерчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1416 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 февраленнән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 408, 1870 тә — 471, 1897 дә — 806, 1913 тә — 1112, 1920 дә — 1203, 1926 да — 646, 1938 дә — 712, 1949 да — 700, 1958 дә — 725, 1970 тә — 754, 1979 да — 524, 1989 да — 280, 2002 дә — 244 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**КУЫГАЯКЛЫЛА́Р**, т р и п с л а р (Thysanoptera), бөҗәкләр отряды. Дөнья фаунасында — 2 меңгә якын, Россиядә 200 тирәсе төре билгеле. Татарстанда К. таралганнар, әмма төр составлары өйрәнелмәгән. Бик кечкенә (0,5–1,5 *мм* озынлыкта, тропикларда 1 *см* га кадәр) бөҗәкләр. Башы конуссыман, очы б-н аска һәм аз гына артка юнәлгән. Авыз аппараты чәнчеп суыручы типта. Тар, озын канатлары нечкә төкле чук булып урнашкан һәм каурыйларны хәтерләтә. Җилпенеп очалар. Кайбер төрләрендә канатлары үсеш алмаган, яисә бөтенләй юк. Аяклары кыска. Тәпиләре ике буынлы, очында тырнаклары һәм субстратка тиз генә ябышу өчен кирәкле махсус куыксыман имгече (исеме шуннан) бар. Корсак б-н этәрелеп, К. кискен сикерешләр ясый алалар. Үсемлекләрдә (күбрәк чәчәк һәм чәчәк төркемнәрендә), аларның соклары б-н тукланып яшиләр; кайбер төрләре — ерткычлар, вак буынтыгаяклыларга һөҗүм итәләр һәм эчке сыеклыгын суыралар. К.ның 2 асотрядын билгелиләр: күкәй салгычлы (Terebrantia) һәм көпшәкойрыклылар (Tubulifera). Күкәй салгычлы К.ның әчтә улагы (күкәйләр үтү өчен) булган, тешле 4 калак кебек пычкысыман күкәй салгычы бар, алар шул рәвешле ясалган ярыкка күкәй салалар. Көпшәкойрыклы К.ның күкәй салгычы юк һәм алар йомыркаларын күче б-н үсемлеккә беркетәләр. Үсеше 2–3 ай. Җәй дәвамында 3 буын бирә. К.ның күпчелеге үсемлекләрнең согын суырып, аларга зыян салып кына калмый, ә бәлки күп кенә вируслы авыруларны таратучылар булып та тора.

*Әд.:* Сельскохозяйственная энтомология. М.–Л., 1955; Общая и сельскохозяйственная энтомология. М., 1983; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3.

*Н.В.Шулаев.*

**КУЫ́К АБАГА́** (Cystopteris) , чын абагалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, Җир шарының таулы һәм урманлы зоналарында таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре: сынучан К.а. (C. fragilis) сирәк кенә барлык районнарда, Судет К.а (C. sudetica) Көнбатыш Кама алдында, күбесенчә карбонатлы туфракларда үсәләр. 10–30 *см* биеклектәге абагалар. Тамырчасы нәзек, шуышма, карасу төстәге иске сап калдыклары б-н капланган. Яфраклары озынча, юка, каурыйсыман, бәйләмгә җыелган. Яфрак саплары сары яки көрән төстә, бик нәзек. Соруслары түгәрәк, тыгыз энәле яки куыклы (ыругның исеме шуннан). Июнь–июльдә спораларлардан, ш.у. вегетатив юл (тамырчалардан) б-н үрчи. Кышка чыдам. Агулы (составында синиль к-тасы бар), декоратив үсемлек. Судет К.а. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КУЫ́К ГӨМБӘЛӘ́Р** (Lycoperdon), куык гөмбәчәләр семьялыгыннан гөмбәләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, барлык континентларның диярлек тропик һәм уртача поясларында очрый. ТР терр-ясендә грушасыман куык гөмбә (L. pyriforme) һәм чын яки төкчәле куык гөмбә (L. perlatum) киң таралган. Грушасыман куык гөмбә урман кисендеәрендә, черек төпләрдә, кәүсә төпләрендә төркем булып үсә. Йомырка яки грушасыман формада, аска таба ялган сапка тарайган. Тышкы тышчасы юка бөртекле, ак, соры яки коңгырт төстә. Чын куык гөмбә яфраклы һәм ылыслы урманнарда, чыбык-чабыкта тыгыз төркемнәр булып үсә. Шарсыман формада, кайвакыт җәлпәк, очлаеп килгән ялган саплы. Өске катламы энәләр сыман озын төкчәләр (2 дән 4 *мм* га кадәр) б-н капланган. Яшь гөмбә ак төстә, карты — соры көрән, өстендә коелган төкчәләр урынында челтәрсыман-уемтылы бизәкләр кала. Яшькелт көрән споралы порошоктан йомшагы хасил була. Споралары өске өлештәге тышчаның ертылуы аша «тузан туздыра». Халык медицинасында споралы порошогы кан туктату чарасы буларак кулланыла. К.г. май ахырыннан көз соңына кадәр үсә. Яшь гөмбәләр ашарга яраклы.

**КУЫ́К УТЫ́** (Utricularia), куыкутычалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел саз үсемлекләре ыругы. 250 гә якын төре билгеле, тропик, субтропик һәм уртача поясларда таралган. ТР терр-ясендә 3 төре бар. Гади К.у. (U. vulgaris) сирәк кенә барлык районнарда, уртача К.у. (U. intermedia) һәм вак К.у. (U. minor) — Кама алдында һәм Көнбатыш Кама арьягында очрый. Агымсыз һәм акрын агымлы сулыкларда үсә. 5–30 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырлары юк. Яфраклары җепсыман сегментларга телгәләнгән. Чәчәкләре дөрес формада түгел, таҗ орысы бар, кызыл-көрән буйлы кызыл-сары төстә, яфраксыз чәчәк сабы очындагы чукка җыелган. Җимеше — күп орлыклы тартмачык. Ыруг үзенең исемен яфракларында, сирәк кенә сабагында урнашкан ау куыклары булу хисабына алган. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Күбесенчә вегетатив юл б-н, бәбәк очларындагы кышлаучы бөреләр ярдәмендә үрчи. Уртача К.у. һәм вак К.у. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КУЫ́Ш ТАҖЪЯФРА́К** (Coeloglossum), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 2 төре билгеле, Евразиянең уртача зонасында, ш.у. Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — яшел К.т.(C.viride) бар. Кама алдында һәм Көнчыгыш Кама арьягында очрый. Якты урманнарда, алан, болыннарда, сирәк үләнле урыннарда үсә. Бүлбе хасил итүче 10–30 *см* биеклектәге үсемлек. Бүлбесе озынча, бармаксыман теленмә, ике өлешле, очлары безсыман сузылган. Яфраклары озынча түгәрәк яки озынча ланцетсыман, аскылары җәенке, өскеләре очлы. Чәчәкләре вак, саргылт яшел, утырма, чәчәк яфраклы, тыгыз



Куяк кигән сугышчылар. Урта гасырлар миниатюралары. 13–14 йөзләр (М.В.Горелик буенча).

булмаган башакка җыйналган, җиңелчә бал исле; чәчәк тирәлеге яфракчыклары (иреннәреннән башка) өскә күтәрелгән. Җимеше — тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июльдә өлгерә. Орлыктан үрчи. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КУЯ́К**, сугышчы киеме. Тышына яки эчке ягына турыпочмаклы яки озынчарак эре корыч пластиналар тегелгән постау яки күн кием. К., кагыйдә буларак, озын итәкле җиңсез күлмәк рәвешендә эшләнә. Аңа ш.у. пластиналардан эшләнгән иңсәлек б-н күкрәк һәм муенны каплау өчен яка-битлек өстәлә. Беренче тапкыр К. Ерак Көнчыгышта барлыкка килә. Монгол яуларыннан соң (13 йөз)



Куяк. Фарсы миниатюрасы. 14 йөз.

Көнчыгыш Европада киң тарала. 14–16 йөзләрдә татар ханлыкларында атлы аксөяк сугышчылар киеме.

*Әд.:* Г о р е л и к М.В. Ранний монгольский доспех (IX — первая половина XIV вв.) // Археология, этнография и антропология Монголии. Новосиб., 1987; И з м а й л о в И.Л. Из истории домонгольского и раннезолотоордынского защитного доспеха волжских булгар // Волжская Булгария и монгольское нашествие. К., 1988.


*И.Л.Измайлов.*

**КУЯ́Н** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 249 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1780 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар катлавына керә. *Крәстияннәр кузгалышы* (1773–75) чорында Е.И.Пугачёв ягында сугыша; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, арба ясау, кәрзин үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәктәп эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1420 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 елның 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 250, 1834 тә — 456, 1859 да — 529, 1870 тә — 576, 1884 тә — 601, 1897 дә — 636, 1906 да — 681, 1913 тә — 753, 1920 дә — 669, 1926 да — 712, 1938 дә — 749, 1949 да — 414, 1958 дә — 492, 1970 тә — 486, 1979 да — 392, 1989 да — 286, 2002 дә — 260 кеше.

**КУЯ́Н** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Брустан елгасы буенда. 2010 елда 54 кеше (татарлар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 елдан Маткауш елгасы буендагы Пустошь исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә, тирә-яктагы алпавыт утарларында көнлекле эштә эшли. 20 йөз башында К.да мәчет (1911 дән), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 292 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Мәлкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 67, 1859 да — 121, 1870 тә — 576, 1884 тә — 177, 1897 дә — 636, 1906 да — 261, 1913 тә — 312, 1920 дә — 341, 1926 да — 321, 1938 дә — 200, 1958 дә — 385, 1970 тә — 345, 1979 да — 252, 1989 да — 125, 2002 дә — 67 кеше.

**КУЯ́Н ЙОНЫ́** (Filago), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — басу К. й. (F. arvensis) республиканың барлык терр-ясендә очрый. Чәчүлек, яткын җирләрдә, юл буйларында, комсыл туфракларда үсә. 15–30 *см* биеклектәге үсемлек, киезсыман куе төкчәле. Яфраклары бөтен, ланцетсыман. Чәчәк кәрзиннәре ак, яфрак куентыгына йомгак булып җыйналган. Җимеше — орлыкча. Июнь–августта чәчәк ата. Җир өсте өлешләрендә дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе тире авырулары вакытында кулланыла.

**КУЯ́Н КӘБЕСТӘСЕ́** (Sempervivum), кантибәрчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 45 төре билгеле, Урта Азиядә, Көньяк Европада, Кавказ артында, Азиядә, Россиянең Европа өлешендә таралган. К.к.нең йомыркасыман озынча һәм итләч, бер-берсенә тыгыз ябышып үскән, шома яисә төрле дәрәҗәдә төкле яфракларыннан төп розетка барлыкка килә. Розетканың үлчәме 2–3 *см* дан 16–20 *см* га кадәр диаметрда була. Чәчәкләре йолдызсыман, кыска чәчәк сабагындагы (10–15 *см* озынлыкта) калкансыман чәчәк җыелмасына тупланган. Чәчәкләре ак, алсу, аксыл, кызыл, куе кызыл төстә. Җимеше — күпьяфрак. Июнь–июльдә чәчәк ата. Яктылык яратучы, салкынга чыдам үсемлек, черемәгә бай, ш.у. ярлы, ташлы туфракта да тишелеп үсә. Орлыктан яисә аерылып үскән розеткалардан үрчетәләр. Көз яисә яз көне чәчелә. ТРда К.к. декоратив үсемлек булып тора. Гибрид К.к.нең «Альфа», «Топаз», «Бета» һ.б. сортлары бүлмә гөле булараk та үстерелә.



Куян кәбестәсе.

**КУЯ́Н КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-ны Столбище авылының көньяк-көнбатыш чигендә, Идел елгасының биек террасасы буенда. Су өслегенең мәйданы 10,8 *га*, шуның 1,2 *га* йөзмә «үлән-утрау» алып тора. Су күләме якынча 189 мең $м^3$. Озынлыгы 1105 *м*, киңлеге 140 *м*, уртача тирәнлеге 2 *м* тирәсе, иң зур тирәнлеге 8,7 *м*. К.к.ннән автомобиль юлы б-н *Кече Куян күле* бүленгән. Якынча, 1950 еллар башында К.к. *Столбище күле* б-н зур сулык ясап кушыла. Соңрак, Зур Кабан авылы ягыннан ерым китерелмәләре килү сәбәпле, күлләр бүленә, ә 1970 тә алар арасында дамба салына. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Суы җиңелчә минеральләшкән (117 *мг/л*), йомшак (3 *мг-экв/л*), үтә күренмәле (200 *см* га кадәр), гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Даими рәвештә җир асты сулары б-н туена. Акрынлап ләмләнә һәм суүсемлекләр б-н каплана. ТРның табигать истәлеге (1978).



Куян күле.

**КУЯ́Н ТУКРАНБАШЫ́** (Coronilla), кузаклылыр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр һәм зур булмаган куаклар ыругы. 25 кә якын төре билгеле, Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — чуар К. т. (C. varia) урман буйларында, куаклар арасында, чәчүлекләрдә үсә. 30–125 *см* биеклектәге күтәрелмә сабаклы үләнчел үсемлек, ботаклы. Яфраклары каурыйсыман парсыз, саплы. Чәчәкләре аксыл


алсу яки ак, озын чәчәк сапларында урнашкан кыска башлы кәрзин хасил итәләр. Җимеше — кузак. Майдан сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Орлыклары июльдә өлгерә башлый. Медицинада җир өсте өлешләрен һәм орлыкларын кулланалар, аларда гликозидлар, углеводлар, дуплау матдәләре һ. б. бар. Халык медицинасында К. т. төнәтмәсе йөрәк авыруларын дәвалау һәм бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**КУЯННА́Р** (Lepus), куяннар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. Кыргый куянның РФдә 3, Татарстанда 2 төре: ак куян (L. timidus) һәм үр куяны (L. europaeus), ш.у. йорт куяны (кролик) яши.

Ак куян — урман һәм куаклыкларда яшәүче гадәти җәнлек. Гәүдәсе 50–60 *см*, койрыгы 5–11 *см* озынлыкта, авырлыгы 3–5,5 *кг*; гадәттә, ана куян атасыннан зуррак. Җәен коңгырт-көрән, кышын ак төстә; колак очлары ел әйләнәсе кара. Мехы кышын аеруча йомшак һәм куе. Арткы аяклары алгыларына караганда озынрак, шунлыктан К. сикереп хәрәкәтләнәләр. Тәпиләре киң, бу исә көпшәк кар өстеннән хәрәкәтләнергә ярдәм итә. Колаклары зур, алга кайтарылган. Койрыгы түгәрәк, кыска. К. бигрәк тә эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Башлыча имән һәм усак үскән, ш.у. катнаш урманнарны өстен күрә. Ана куян, гадәттә, 3 тапкыр (һәрберсендә 4–5, кайвакыт 8 гә кадәр) бала тудыра. 8–9 ел яшиләр. Ак куян үләнчел, агач һәм куакчыл үсемлекләр б-н туклана.


Үр куяны кыр, болын, далалы җирләрдә, урман буйларында, кыр ышыклау урман полосаларында һәм куаклыкларда яши. Ак куяннан берникадәр зуррак: гәүдәсенең озынлыгы 55–70 *см*, колаклары һәм койрыгы озынрак, авырлыгы 4–7 *кг*. Җәен карасу чуар җирән-соры, ян-яклары бер төстә, койрыгының өсте кара, колак читләре кара-көрән. Кышын аксыл, кайвакыт бөтенләй ак диярлек, әмма сыртында кара буй кала. Мехы куе, көмешсыман йонлы. Җәен кыяклылар, кузаклылар һ.б. үләнчел үсемлекләр б-н туклана. Кышкы чорда усаклык, таллык һәм имәнлекләрдә, еш кына җимеш бакчаларында, агач һәм куакларның ботак һәм кайрылары б-н тукланып яши. Сунарчылык кәсебе (ите, тиресе) объекты.

Йорт куяны, куяннар семьялыгы кимерүчеләр отрядыннан имезүче хайван, нәсел башы — кыргый куян. Гомер озынлыгы 7–10 ел. Ана куян елга 3–4 тапкыр 6–8 әр бала тудыра. Татарстанда йорт куяннарын 1930 елдан үрчетәләр; ит, мамык, тире өчен үстерелә. Токымнары: ак великан, соры великан, Вена



Йорт куяны. «Кощаково» АҖ.

зәңгәрсуы, кара-соры, көмешсыман, совет шиншилласы. Аларны үрчетү б-н «Бөреле» нәсел үрчетү з-ды, «Бөрсет» агрофирмасы, «Кощаково» һәм «Матюшино» АҖ шөгыльләнә. 2004 ел башына 31408 баш үрчем алынган. 2005 кә кадәр йорт куяннарын үрчетү б-н (соры великан, ак великан токымнары) Мамадыш р-ны «Бөрсет» агрофирмасы шөгыльләнә, анда 500 ана куяннан 7,5 мең баш үрчем (2005) алына. ТРда 2007 дән бары тик шәхси хуҗалыкларда гына үрчетелә.




1 2

Куяннар: 1. Ак куян; 2. Үр куяны.


**КҮӘ́М** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 774 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1920 елларга кадәрге рәсми рус чыганакларында 3 өлешкә бүленә: Күәм Пүчинкәсе, Иске Күәм һәм Күәм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 4 мәчет, 8 вак-төякләр кибете була; сишәмбе саен базар эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 3378 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1766, 1897 дә — 2236, 1908 дә — 2415, 1920 дә — 1236, 1926 да — 2250, 1938 дә — 2178, 1949 да — 1346, 1958 дә — 1205, 1970 тә — 1227, 1979 да — 1121, 1989 да — 865, 2002 дә — 853 кеше.

**КҮБӘ́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 27 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2010 елда 230 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб. 1747 елдан мәгълүм. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, мәдрәсә, мәктәп, 2 су тегермәне, ярма яргыч, иген киптергеч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5152,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 412, 1897 дә — 739, 1913 тә — 795, 1920 дә — 836, 1926 да — 482, 1938 дә — 579, 1949 да — 409, 1958 дә — 407, 1970 тә — 397, 1979 да — 344, 1989 да — 249, 2002 дә — 243 кеше.

**КҮБӘЛӘКЛӘ́Р**, тәңкәканатлылар (Lepidoptera), бөҗәкләр отряды. Мезозойның юра чорында барлыкка килгәннәр, дип исәпләнелә. Үзенчәлекле билгеләре: гәүдә һәм канатларын каплаучы тәңкәләр, хортумчык сыман суыра торган (тешле көяләрдә — кимерә торган) авыз аппараты тора. Үсеше тулы әверелешле — йомырка, личинка (гусеница), курчак, олы бөҗәк. Олы К.нең канат җәеме 3,2 дән 300 *мм* га кадәр. Аларның төсе һәм бизәге саклагыч роль уйный һәм үз төре вәкилен тануда әһәмиятле. Башының ян-ягында мозаик сурәт бирүче катлаулы зур күзләр (27 меңгә кадәр фасетлы) урнашкан. Сизү органнары мыекчыклар өслегендә, тәм органнары авыз өлешендә һәм тәпиләрендә урнашкан, ишетү органнары әлегә төнлә актив югары формалы отрядларныкы гына билгеле. Үрчемлелеге һәр төр өчен төрлечә, бер дистәдән берничә йөзгә кадәр (кайбер ефәк күбәләкләре), хәтта 2–3 мең (ябалакчыклар) күкәй салырга мөмкин. К. күкәйләрен, гадәттә, гусеницалар өчен азык булып торган үсемлеккә сала. Йомырка формалары еш кына үзенчәлекле, бу исә систематика өчен мөһим. Личинкаларында кимерә торган авыз аппараты һәм ялган корсак аяклары бар. К.нең күп кенә төрләренең гусеницалары а.х., җимеш һәм урман үсемлекләренә зыян китерә, ш.у. азык-төлек запасларын, мех һәм йон әйберләрне боза. Курчаклары, гадәттә, капланган (кузы) типта. К. отрядына 140 меңгә якын төр керә. *Ябалакчыклар* (2300 тирәсе), *карышлавыклар* (1500 тирәсе), яфрактөргечләр (1250), көяләр группасындагы (к. *Чын көяләр*) төрләр аеруча киң таралган һәм күп санлы. К.нең гомум кабул ителгән классификациясе юк. Традиция буенча отряд 2 асотрядка бүленә: тигезканатлылар (беренчел көяләр, нечкәканатлылар) һәм төрлеканатлылар. Тигезканатлылар фәкать төнге К.не генә үз эченә алса, төрлеканатлыларга исә көндезге һәм ш.у. төнге К. дә керә. Татарстан терр-ясендә К.нең 1000 гә якын төре очрый: 150 көндезге күбәләк, аларны ш.у. чукмар мыеклылар дип тә атыйлар, һәм 800 тирәсе төнге күбәләк яки төрле мыеклылар. Бөтен җирдә яшиләр. Кәбестә күбәләге, лимонница, *кычыткан күбәләге,* көндезге тавискүз, икар күбәләк, утлы күбәләк — Татарстанда гадәти яшәүче көндезге күбәләкләр. Төнге күбәләкләрдән алмагач җимешашары, гамма-ябалакчык, йогырт балкарак, каен карышлавыгы һ.б. еш очрый. Бөҗәкләрнең аеруча зур отрядларыннан берсе буларак, К. табигатьтә зур роль уйныйлар. Туклану чылбырында аларның әһәмияте зур, чөнки гусеницалар, үсемлек биомассасын кулланып, үзләре дә күп кенә умырткалы һәм умырткасыз хайваннар




**Күбәләкләр мәкаләсенә,** таблица I. 1. Адмирал (Vanessa atalanta L.); 2. Поликсена (Zerynthia polyxena D.); 3. Мнемозина (Parnassius mnemosene L.); 4. Кәбестә күбәләге (Pieris brassicael); 5. Дүләнә күбәләге (Aporia crataegi L.), 5 а. аның гусеницасы; 6. Галатея (Melanagria galathea L.); 7. Зур перламутр урман күбәләге (Agrinnis paphia L.); 8. Подалирий (Iphiclides podalirius L.); 9. Махаон (Papilio machaon L.), 9 а. аның гусеницасы; 10. Аполлон (Parnassius apollo L.); 11. Кайгылы күбәләк (Nymphalis antiopa L.); 12. Кычыткан күбәләге (Aglais urticae L.); 13. Шалкан күбәләге (Pieris rapae L.); 14. Сары күбәләк (Gonopteryx rhamni L.); 15. Таң күбәләге (Zegris eupheme Esp.); 16. Зәңгәр күбәләк (Polyommatus meleager Esp.); 17. Икар күбәләге (Polyommatus icarus Rott.), 17 а. ата зат, 17 б. гусеница; 18. Утлы алтын күбәләк (Chrysophanus virgaureae L.).




**Күбәләкләр мәкаләсенә,** таблица II. 1. Күлмәк көясе (Tineola bicelliella Hum.); 2. Зур тополь пыялач күбәләге (Sesia apiformis L.); 3. Кече төнге тавискүз (Eudia pavonia L.); 4. Исле агачтишәр (Cossus cossus L.); 5. Күзләч балкарак (Smerinthus ocellatus L.); 6. Так ефәк күбәләге(Lymantria dispar L.), ана зат, 6а. ата зат, 6б. гусеница; 7. Үле баш (Acherontia atropos L.); 7а. аның гусеницасы; 8. Алмагач җимешашары (Laspeyresia pomonella L.), 8а. аның гусеницасы; 9. Авыл аюкүбәләге (Arctia villica L.); 10. Бикә аюкүбәләк (Callimorpha dominila L.); 11. Аюкүбәләк Гера (Callimorpha hera L.); 12. Гамма-ябалакчык (Phytometra gamma L.); 13. Биш бармаклы телмәканат (Alucita pentadactila L.); 14. Зелпеле төклетурасыман күбәләк (Hemaris fuciformis L.); 15. Крыжовник карышлавыгы (Abraxas grossulariata L.); 16. Орденлы зәңгәр тасма күбәләк (Catocala fraxini L.); 17. Орденлы кура җиләге тасма күбәләге (Catocala sponsa L.); 18. Алтынкорсак (Euproctis chrysorrhoea), ата зат, 18а. ана зат; 19. Көмешсыман ай күбәләк (Phalera bucephala L.), 19а. аның гусеницасы.

өчен азык булып тора. К. ш.у. үсемлекләрне серкәләндерүдә мөһим (еш кына үзенчәлекле) бөҗәкләр. Алар арасында а.х. һәм урман хуҗалыгы корткычлары (мәс., кәбестә күбәләге, алмагач җимешашары, *парсыз ефәк күбәләге*) да очрый. Күп кенә төрләренең саны кими. Кайберләре — юкка чыгу алдында (мәс., таң күбәләге). ТРның Кызыл китабына К.нең 27 төре кертелгән.

*Әд.:* Горностаев Г.Н. Насекомые СССР. М., 1970; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3; Гордиенко С.Г. Бабочки Татарии. К., 1990; Плавильщиков Н.Н. Определитель насекомых. М., 1994.

*Н.В.Шулаев, Н.Г.Петров.*

**КҮГӘ́Й** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 412 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1647–51 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Айдар исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек, тимерчелек, борыс эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, 4 җил тегермәне, йон тетү йорты, тимерчелек, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1435 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 127 ир-ат; 1859 да — 600, 1897 дә — 1408, 1908 дә — 1610, 1920 дә — 1632, 1926 да — 1411, 1938 дә — 1580, 1949 да — 1038, 1958 дә — 873, 1970 тә — 819, 1979 да — 695, 1989 да — 519, 2002 дә — 543 кеше.

**КҮГӘЛНӘ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1780 елдан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 241,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 135, 1880 дә — 169, 1897 дә — 258, 1913 тә — 363, 1920 дә — 484, 1926 да — 375, 1938 дә — 390, 1949 да — 260, 1958 дә — 232, 1970 тә — 175, 1979 да — 97, 1989 да — 54, 2002 дә — 32 кеше.

**КҮГӘ́Н** (Prunus spinosa), роза чәчәклеләр семьялыгы *слива* ыругыннан үсемлек төре. Кыргый төре Кече Азия, Көнбатыш Европа, Урта диңгез буенда, Россиянең Европа өлешендә таралган. ТРда кыргый төре аланнар, урман читләре, чокыр буйларында куаклык булып үсә. Культурада аз таралган. Куак яисә күп кәүсәле 3–5 *м* лы зур булмаган агач, тармакланган ябалдашлы һәм тамырдан чыккан күп үсентеле. Ботаклары чәнечкеле. Яфраклары эллиптик формада яисә йомыркасыман. Чәчәкләре вак, ак төстә. Майда чәчәк ата, башлыча умарта кортлары ярдәмендә серкәләнә. Җимешләре вак (12 *мм* диаметрлы) авызны бөрештерә, кара-зәңгәр (шәмәхә) төстә, балавыз куныклы. Башлыча, тамырдан чыккан үсентеләрдән үрчи. Дүртенче елда җимеш бирә башлый. Җитлеккән куактан 3–4 *кг* уңыш алына. К.нең җимешләре һәм орлыклары азык һәм мед. сәнәгатендә кулланыла. К.нең орлыкларыннан сливаның культурадагы сортларын ялгау өчен ялганмалар үстерәләр. Культуралы слива б-н серкәләндереп, эре җимешле, кышка һәм корылыкка чыдам, туфрак шартларына аз таләпчән сорт чыгарыла. Коллектив бакчаларда һәм йорт янында үстерелә.

*Әд.:* Плодоводство. М., 1979.

**КҮГӘ́Н КУАГЫ́**, божыр орлыгы (Swida), кызылчалар семьялыгыннан куак яки куак булмаган агачлар ыругы. 40 ка якын төре билгеле, уртача пояста, башлыча, Көнчыгыш Азиядә, Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — ак К.к. (S. alba), Көнчыгыш Кама алдында очрый. Урман сазлыклары һәм сулык ярлары буенда үсә. 1–4 *м* биеклектәге куак, сузынкы яки иенке нәзек озын ботаклы. Яшь ботаклары яшел, соңыннан кызгылт яисә җете кызыл төскә керә. Яфраклары каршыдаш, киң йомыркасыман, кара яшел, сырышкан сирәк төкчәле. Чәчәкләре ак, калкансыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — шарсыман төшчә. Өлгермәгән җимеше зәңгәрсу, соңыннан ак куныкб-н каплана. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамыр үрентеләре, ботаклардан) б-н үрчи. Салкынга чыдам. Туфракка талымсыз, әмма дымлы урыннарны үз итә. Һаваның пычрануын җиңел кичерә. Декоратив куак буларак, ш.у. сулык ярларын ныгыту өчен һәм кыр ышыклау урман полосаларында файдаланыла.

**КҮГӘРЧЕ́Н** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Суша елгасы буенда. 2010 елда 1119 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1565–67 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, арба-чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 3 тегермән, 13 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2426 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 156 ир-ат; 1859 да — 1289, 1897 дә — 2189, 1908 дә — 2559, 1920 дә — 2456, 1926 да — 2347, 1938 дә — 2464, 1949 да — 1951, 1958 дә — 1855, 1970 тә — 2328, 1989 да — 1742, 2002 дә — 1251 кеше.

**КҮГӘРЧЕ́Н БҮРЕГЕ́** (Melampyrum), сыраҗчалар семьялыгыннан берьеллык ярымпаразит үләнчел үсемлекләр ыругы.30 га якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Болын К.б. (M.pratense), урман К.б. (M. sylvaticum), әтәч кикриге (M. cristatum) барлык районнарда очрый; ала миләүшә яки Иван-Марья (M. nemorosum) — Кама алдында һәм Идел алдының көньяк өлешендә очрый. Ылыслы һәм катнаш урманнарда, куаклар арасында, урман аланнарында үсә. 15–50 *см* биеклектәге үсемлек. Сабаклары туры, төкчәле. Яфраклары кыяклы-ланцетсыман, каршыдаш. Чәчәкләре вак, сары яки кызгылт-сары, эре чәчәк яфраклары куентыгында, башаксыман яки чуксыман чәчәк төркеменә җыелган. Ала миләүшә — ике төстәге чәчәк төркеменнән тора (икенче исеме шуннан). Җимеше — ике оялы җәлпәгрәк тартмачык. Орлыклары кара көрән, эре, озынча, орлык яны яфраклы. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Итләч үсентеле орлыклардан үрчи. Тамырлары гаустория хасил итә, башка үсемлек тамырларына берегеп, алардан туклыклы матдәләрне суыра. Күпчелек төрләрдә паразитлык тулы яшәү циклын тудыру өчен кирәк. Ала миләүшә — дару үсемлеге; ялкынсынуга каршы һәм яра төзәтү чарасы. Җимешләренең төнәтмәсе зарарлы бөҗәкләргә каршы кулланыла.

**КҮГӘРЧЕ́Н КҮЗЕ́** (Myosotis), кыярчалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, нигездә, Евразиянең уртача поясында, Көньяк Африка тауларында, Австралия һәм Яңа Зеландиядә очрый. ТР терр-ясендә 9 төре бар. Кыр К.к. (кыргый гөлкәй чәчәк) (M. arvensis), вак чәчәкле К.к. (M. micrantha), иминлек К.к. (M. nemorosa), сирәк чәчәкле К.к. (M. sparsiflora) киң таралган. Урманнарда, дымлы болыннарда, кырларда үсә. 5–60 *см* биеклектәге туры сабаклы, күп ботаклы үсемлек. Яфраклары бөтен, озынча — ланцетсыман, төкчәле. Чәчәкләре вак, зәңгәр, сирәк кенә алсу яки ак, гади яки катмарлы, озынча



1. Саз күгәрчен күзе; 2. Кыр күгәрчен күзе.

бөтеркәләргә җыйналган. Җимеше 4 чикләвекчектән тора. Апрель–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июньнән октябрьгә кадәр өлгерә. Орлыктан үрчи. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе хроник бронхит, тире ялкынсынулары һәм коры экзема вакытында кулланыла. Баллы үсемлек. Күп кенә төрләре декоратив үсемлек буларак үстерелә. Попов К.к. (M.popovii) ТРның Кызыл китабына кертелгән (2006 га кадәр).

**КҮГӘРЧЕ́Н РАЙОНЫ́**, БРның көньягында урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 3371 *км²*. Үзәге — Мраково авылы (Уфадан 271 *км* көньяктарак). Халкы — 32356 кеше (2010), 3519 татар. Районда 115 торак пункт, ш.и. 4 татар, 15 татар-башкорт, 1 татар-рус-башкорт авылы бар. Иң зур татар авыллары (2009) — Күгәрчен (866 кеше) һәм Увары (179). Бу төбәктә беренчеләрдән булып нигез салынган татар авылы — Увары (1775)). 2004/05 уку елында районда 3 мәктәптә укыту татар телендә алып барыла.

**КҮГӘ́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Буклы елгасы буенда. 2010 елда 95 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1735 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә мәчет, мәктәп, 2 ярма яргыч, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1254,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 532, 1897 дә — 728, 1913 тә — 1016, 1920 дә — 970, 1926 да — 674, 1949 да — 262, 1958 дә — 184, 1970 тә — 196, 1979 да — 145, 1989 да — 97, 2002 дә — 80 кеше.

**КҮГЕЛҖЕ́М УТ** (Laser), чатырчәчәкләләр семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 дан артык төре билгеле, Евразиядә таралган. ТР терр-ясендә бер төре — өч аерчалы К.у. (L. trilobum) Кама алдында һәм Идел алдында очрый. Нарат урманнарында һәм киң яфраклы урманнарда, куаклар арасында, юылган тау битләрендә үсә. 60–200 *см* биеклектәге, калын тамырлы күпьеллык үсемлек. Сабагы калын, төбендә корыган яфракларның җепсел калдыклары бар. Түбәнге яфраклары — озын сапларда, икеле, өчле каурыйсыман теленмә җәймәле, өске сабак яфраклары — вак, утырма, кабарынкы җиңсәле. Җимешләре — чыгып торучан буй кабыргалы, икегә бүленгән озынча орлыкчалар. Май–июньдә чәчәк ата. Июльдә җимеш бирә. Җимешләрендә гликозидлар, сумала, эфир майлары бар. Халык медицинасында тамырларыннан әзерләнгән төнәтмә тән кызышканда, ш.у. авыртуны басу чарасы буларак кулланыла.

**КҮГЕ́Ш** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 317 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә 2 җәмигъ мәчет, мәдрәсә, 4 җил тегермәне, тимерчелек, 1 зур һәм 6 кечкенә вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1649,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Яңа Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 266 ир-ат; 1859 да — 993, 1897 дә — 1706, 1908 дә — 2142, 1920 дә — 1613, 1926 да — 1116, 1938 дә — 1256, 1949 да — 880, 1958 дә — 665, 1970 тә — 663, 1979 да — 561, 1989 да — 437, 2002 дә — 409 кеше.

**КҮҖӘКӘ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 35 *км* көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 410 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1706 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, мәктәп һәм мәдрәсә, 2 җил тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 4524,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 156, 1850 дә — 906, 1859 да — 1020, 1870 тә — 1104, 1884 тә — 1069, 1897 дә — 1576, 1906 да — 1822, 1913 тә — 1707, 1920 дә — 1631, 1926 да — 1360, 1938 дә — 1121, 1949 да — 703, 1958 дә — 631, 1970 тә — 903, 1979 да — 847, 1989 да — 546, 2002 дә — 426 кеше.

**КҮЗ УТЫ́** (Euphrasia), сыраҗчалар семьялыгыннан бер-, сирәк кенә күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 200 гә якын төре билгеле, Евразиядә, Көньяк Америка, Африкада, Австралиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 8 төре бар. Сырлы К.у. (E. pectinata), вак төкле К.у. (E. brevipila), Фин К.у. (E. fennica) — барлык районнарда, туры К.у. (E. stricta), вак чәчәкле К.у. (E. parviflora) һ.б. Кама арьягында очрый. Болыннарда, куаклар арасында, коры сөзәклекләрдә үсә. 5–40 *см* биеклектәге ярымпаразит берьеллык үсемлекләр. Сабагы туры, кызыл-көрән, кыска төкчәләр б-н капланган. Яфраклары каршыдаш, утырма. Чәчәкләре вак, аксыл-шәмәхә, куентылы, ботак очларындагы башаксыман чәчәк төркеменә җыелган. Ике иренле таҗ; өске ирене шлемсыман, бөгелгән читле, аскысы — яссы, өч калаклы. Җимеше — күп орлыклы тартмачык. Май–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе күз авыруларын дәвалау өчен (исеме шуннан), ангиналар вакытында кулланыла.

**КҮЗӘНӘКЛЕ́ ЧАКМАТА́Ш** (опока), вак күзәнәкле тыгыз җиңел тау токымы, опал-кристобалиттан торган кремнеземның бик вак (0,005 *мм* дан аз) кисәкчәләреннән тора. Тыгызлыгы 1100–1600 *кг/м³*, күзәнәклелеге 55% ка кадәр, гадәтиләренең ныклыгы 5–20 *МПа*, төсе аксыл сорыдан кара сорыга кадәр. Суда юешләнми. Сәнәгати К.ч.ның составында опал-кристобалит 50–90%, балчыксыл минераллар 10–40%, вакланган (күбесенчә кварцлы) материаллар 10–20% ка кадәр була. Сәнәгать ресурслары Идел буе, Россиянең Үзәк һәм Көньяк-көнбатыш районнары, Урал, Сахалин, Үзәк һәм Көнбатыш Европаның (Англия, Франция, Германия), Кытай һ.б.ның палеоген һәм югары акбур утырмалары б-н бәйле. К.ч. Татарстан терр-ясенең көньяк-көнбатыш өлешендә (Бизнә, Чынлы елгаларының югары агымында) югары акбур утырмаларында табылган. Продуктив катламның калынлыгы 20–38 *м*. Татар-Шатрашан чыганагы ачыкланган, A+B+C категорияләре буенча баланс запаслары — 88,3 млн. *т*. Цеолит һәм карбонатлылардан цеолитлы мергельләргә кадәрге К.ч. хас. ТРда К.ч.ның ресурслары 0,5–0,6 млрд. *м³* тәшкил итә. Кулланылышы: цемент җитештерүдә актив гидравлик кушылмалар, ашламалар кулланганда мелиорантлар һәм пролонгаторлар, майларны һ.б.ны чистарту, сыек пыяла, волластитлы керамика, терлек азыгы җитештерү өчен адсорбентлар (бөртекле һәм порошоксыман).

*Әд.:* Кремнистые породы СССР.К., 1973; Д и с т а н о в У.Г. Минеральное сырьё. Породы опал-кристобалитовые: Справ. М., 1997; ш у л у к. Опал-кристобалитовый цеолитосодержащий промышленный тип // Геология твёрдых и полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*У.Г.Дистанов.*

**КҮЗБИ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Лашчы елгасы буенда. 2010 елда 14 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кузбеева исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 473,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Черкен-Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир-ат; 1859 да — 202, 1897 дә — 333, 1908 дә — 403, 1920 дә — 364, 1926 да — 248,

1938 дә — 286, 1949 да — 224, 1958 дә — 147, 1970 тә — 115, 1979 да — 88, 1989 да — 38, 2002 дә — 21 кеше.

**КҮЗИКМӘ́К**, к. *Кыстыбый.*


**КҮЗКӘ́Й** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 32 *км* көнчыгыштарак, Тиргәвеш елгасы бассейнында. 2010 елда 649 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1745 тән мәгълүм. 18 — 19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышында* (1773–75) Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 1809 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә мәчет була, 1821 дә аның каршында мәктәп ачыла. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе, почта станциясе урнаша; 3 мәчет, 4 мәктәп, 3 су һәм 2 җил тегермәне, 8 ярма яргыч, 6 ашлык киптергеч була; базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4951,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 207, 1859 да — 908, 1870 тә — 968, 1884 тә — 1483, 1897 дә — 1496, 1906 да — 1828, 1913 тә — 2128, 1920 дә — 2108, 1926 да — 1497, 1938 дә — 1561, 1949 да — 1280, 1958 дә — 1280, 1970 тә — 963, 1979 да — 1130, 1989 да — 836, 2002 дә — 622 кеше.

**КҮЗЛҮ́Б** (Scutellaria), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләннәр һәм ярымкуаклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, Көньяк Африкадан тыш бөтен Җир шары буенча таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Гади К. (S. galericulata) — бөтен районнарда да, шикле К. (S. dubia) — Кама алдында, сөңге яфраклы К. (S. hastifolia) Кама алдында һәм Кама аръягында очрый. Тугайлы болыннарда, куаклар арасында, сулык ярлары буенда үсә. 15–40 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы нәзек, шуышма. Яфраклары бөтен һәм каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре алсу, зәңгәрсу шәмәхә, зәңгәр төстә, өске яфраклар куентыгында урнашкан. Җимеше 4 чикләвекчеккә таркала. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Гади К.ның җир өсте өлешләрендә флавоноидлар, сапониннар, органик к-талар, микроэлементлар, дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе гипертония авырулары, кан туктату, бәвел кудыру һәм бөрештергеч чара буларак кулланыла. Баллы үсемлек.

**КҮЗЛҮ́Т** (Galeopsis), иренчәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы; чүп үлән. Якынча 10 төре билгеле. Татарстан терр-ясендә 4 төре үсә: ике киселешле (ике кисәкле) К. яисә жабрей (G. bifida), ладан К. (G. ladanum), матур К. яисә зябра (G. speciosa), гади К. (G. tetrahit). К.ның сабагы дүрт кырлы, төбе куе төкле, еш кына кызыл төстә була; ботаклана, кырыйлары тупас-тешле, йомыркасыман — ланцет рәвешле сабакчалы яфраклары бар. Чәчәкләре 3–15 ләп урта һәм югары яфраклар эчендә урнашкан, саргылт-ак төстә, ачык бизәкле. Июнь–августта чәчәк ата. Баллы үсемлек. Җимеше — чикләвек. Бер үсемлек 8 меңгә кадәр орлык бирә, алар туфракта 14 елга кадәр сакланырга сәләтле. Иген чәчүлекләрен, бакча культураларын чүпли. А.х. терлекләре өчен агулы.

*Әд.:* Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

**КҮК ҖИЛӘ́К** (Vaccinium uliginosum), арчанчалар семьялыгыннан куаклар төре. Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә Кама алдының төньяк-көнбатыш өлешендә очрый. Сазлыклы урманнарда, торфлыкларда үсә. 20–100 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы җир өслегендә. Яфраклары озынча йомыркасыман, өсте куе яшел, аскы ягы күгелҗем, күп санлы тармаклы сеңерчәләре бар. Чәчәкләре вак, ак яки алсу, ботакчыклар очында 1–3 әр булып урнашкан. Җимеше — озынча түгәрәк җиләк, күксел куныклы зәңгәр төстә, йомшагы яшел. Июнь–июльдә чәчәк ата. Беренче чәчәк атуы — 11–18 елдан соң. Август–сентябрьдә җимеш бирә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Яшәү вакыты 90 елдан артык. Суыкка чыдам. Җимешләре ашарга яраклы. Яңа өлгергән килеш тә, эшкәртелгән хәлдә дә кулланырга мөмкин. Составында шикәр, органик к-талар, тимер, марганец, калий, кальций, дуплау матдәләре һ.б. бар. Халык медицинасында җиләк согы һәм кипкән җиләкләренең суы гомуми ныгыту чарасы буларак, яфракларыннан ясалган төнәтмә матдәләр алмашы бозылганда кулланыла.



**КҮК КҮБӘЛӘКЛӘ́Р** (Lycaenidae), төрлеканатлылар асотрядыннан көндезге күбәләкләр семьялыгы. 2500 дән артык төре билгеле. Канат җәеме 4 *см* га кадәр. Алгы аяклары кыска. Башы кечкенә, алгы күкрәгенә батып кергән. Ата затлар — металлсыман ялтыравыклы күк, зәңгәр, яшел, кызгылт-сары, ана затлар көрән төстә. Урман буйларында, болыннарда, елга буйларында яши. Кортлары агач, куак, үләнчел үсемлек яфраклары б-н туклана, кайберләре ерткычлар — гөбләләрне (бетләр), кортчаларны ашыйлар. А.х. үсемлекләренә зур зыян китермиләр. Татарстан терр-ясендә Икар күбәләге (Polyommatus icarus), кузак күбәләге (P.semiargus), утлы күбәләк (Chrysophanus virgaurea) һ.б. — гадәти бөҗәкләр. Зәңгәр күбәләк (Мелеагр) (P. Daphnis) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* П л а в и л ь щ и к о в Н.Н. Определитель насекомых. М., 1994; Красная книга Республики Татарстан. К., 1995.

**КҮК КҮГӘРЧЕ́Н** (Columba livia), күгәрчен кошлар семьялыгындагы кош. Шәһәрләрдә һ.б. торак пунктларда, кеше яши торган урыннарда очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 30–36 *см*, авырлыгы 250–300 *г*. Каурый капламы соргылт күк төстә, муены һәм бүксәсе яшькелт алсу, аркасы һәм канатларының эчке өлеше ак. Гадәттә, йорт чарлакларында һ.б. корылмаларда оялый. Парлап яши һәм утрак яшәү рәвеше алып бара. Бөртек, икмәк, азык-төлек калдыклары б-н туклана. Февральдә оя ясарга керешә, бер сезонда 2–3 тапкыр бала чыгара. Йомыркалар өстендә утыруда һәм кош балаларын ашатуда ата һәм ана кошлар икесе дә катнаша. 17–18 көннән кош балалары чыга. Алар сукыр, көчсез, ата-аналары бүксәсеннән чыккан кикерек («күгәрчен сөте») б-н туена. Соңрак, ш.у. ата һәм ана кошлар бүксәсендә бүрткән орлыклар аларга азык булып тора. Иделнең уңъяк ярында, К.к.нең кыргый төрчәсен — кыя күгәрченен очратырга мөмкин, ул исә кыя ярыкларында оялый; күптөрле декоратив һәм почта күгәрченнәренең нәсел башы.

**КҮК МЕХА́НИКАСЫ**, астрономиянең бер бүлеге, Кояш системасы җисемнәренең гравитация көчләре тәэсирендә өйрәнә. «К.м.» терминын беренче булып француз астрономы П.Лаплас кертә (1798). Классик К.м. нигезләре инглиз математигы И.Ньютон тарафыннан «Натураль философиянең математик башлангычлары» («Математические начала натуральной философии», 1687) хезмәтендә салына. 19 йөз башында Д'Аламбер, А.Клеро, Ж.Лагранж һәм П.Лаплас К.м.ның Кояш системасының зур планеталары хәрәкәтен билгеләүче төп алымнарын эшләп бетерәләр. 1846 елда немец астрономы И.Галленың Нептун планетасын ачуы К.м.ның «алтын гасыры» таҗы буларак бәяләнә; бу планетаның урынын француз галиме У.Леверье исәпләүләр буенча алдан әйткән була.

К.м.ның төп бурычлары: 1) күк җисемнәренең гравитация кырындагы хәрәкәтенең гомуми тәгълиматын эшләү; 2) конкрет табигый һәм ясалма күк җисемнәре (зур планеталар, иярченнәр, комета, астероид һәм космик аппаратлар) хәрәкәтенең аналитик һәм санлы теорияләрен төзү; 3) күк җисемнәре хәрәкәтенең матем. теорияләрен астрономик күзәтүләр б-н чагыштыру һәм фундаменталь астрономик даими берәмлекләр билгеләү (күк җисемнәренең массасы, орбита элементлары, җир фигурасы параметрлары һ.б.) ачыклау; 4) геодезиядә, астрометриядә һәм фәннең башка өлкәләрендә куллану өчен астрономик календарьлар төзү.

Беренчел исәпләүләрдә зур планеталарның хәрәкәте, кагыйдә буларак, ике җисем мәсьәләсе кысаларында тикшерелә (Кояш — планета). Бу мәсьәләнең дифференциаль тигезләмәләре коник киселешләр (Кеплер орбиталары) тигезләмәләре рәвешендәге йомык чишелешкә ия. Башка җисемнәрнең ярсытулар дип аталучы тәэсире рәтләргә таркату яисә санлы алымнар юлы б-н исәпкә алына. Планеталар иярченнәре, ш.и. Айның хәрәкәте чикләнгән өч җисем (планета-иярчен-Кояш) мәсьәләсе кысаларында карала.

Комета һәм астероидларның орбиталарында еш кына зур авышулар һәм эксцентриситетлар булу һәм моның аналитик теориясен төзү мөмкинлегә булмаганлыктан, аларның хәрәкәте дифференциаль тигезләмәләрне санлы интеграллау юллары б-н тикшерелә. Астрономик координаталарны билгеләүдә К.м.ның Җир һәм Ай әйләнеше б-н бәйле бүлеге әһәмияткә ия. 20 йөз ахырына астрономик күзәтүләрнең төгәллеге арту күк җисемнәре хәрәкәтендә, А.Эйнштейнның ихтималлык теориясенә нигезләнеп, релятивистик эффектларны исәпкә алу зарурлыгына китерә. К.м.ның хәзерге актуаль проблемаларына Кояш системасының берничә йөз млн. еллык вакыт аралыгындагы эволюциясе мәсьәләләре; Җирнең гравитация кырында аның ясалма иярченнәре хәрәкәтен өйрәнү; космик аппаратларның траекторияләрен исәпләү керә.

Россиядә К.м. өлкәсендәге фәнни үзәкләр булып РФАнең С.-Петербургтагы Гамәли астрономия ин-ты һәм Мәскәүдәге П.К.Штернберг исем. Астрономия ин-ты санала. Казанда К.м. өлкәсендәге казанышлар А.Д.Дубяго һәм Ш.Т.Хәбибуллин исемнәре б-н бәйле. Казан ун-ты профессоры А.Д.Дубяго Кояш системасының кече җисемнәре хәрәкәтен тикшерү буенча фәнни юнәлешкә нигез сала (к. *Казан астрономия фәнни мәктәбе*). Аның «Орбиталарны билгеләү» («Определение орбит», М., 1949; соңрак чит илләрдә кабат басыла) монографиясе кометалар хәрәкәтен өйрәнү буенча классик кулланмага әверелә. Кометалар хәрәкәтендә нәгравитацион эффектны билгеләү өчен А.Д.Дубягоның шәкертләре Л.Я.Ананьева, Ю.В.Евдокимов, Е.Д.Кондратьева, В.В.Емельяненко аның эшен дәвам иттерәләр. Ай әйләнүнең нәсызыкча теориясе (Айның физик либрациясе теориясе дип тә атыйлар) төзелү Казан ун-ты профессоры Ш.Т.Хәбибуллин һәм аның шәкертләре (Н.Г.Ризванов, Р.А.Кащеев, Ю.Чиканов, Н.К.Петрова) исемнәре б-н бәйле. Бөек Ватан сугышы вакытында Казанга Мәскәү һәм Ленинградтан К.м. өлкәсендә әйдәп баручы галимнәр эвакуацияләнә. Бу елларда академик О.Ю.Шмидт Казанда Кояш системасының барлыкка килүе турындагы космогоник теориясен төгәлли.

*Әд.:* Б р а у э р Д., Клеменс Дж. Методы небесной механики. М., 1964; С у б б о т и н М.Ф. Введение в теоретическую астрономию. М., 1968; Х а б и б у л л и н Ш.Т. Нелинейная теория физической либрации Луны // Тр. Казан. гор. астрон. обсерватории. 1966. № 34.

*Р.В.Заһретдинов.*

**КҮ́К УРДА́**, Алтын Урданың сул канаты (өлеше), Җүчинең өлкән улы Урда Эҗен һәм аның нәселе вәкилләре, 1277 тән Тука Тимер нәселе (сул канат Җүчиләр) вәкилләре идарә итә. 13 йөз уртасыннан К.У.да Җүчиләрнең уң канат (*Ак Урда*) вәкилләре өстенлекле була. Әмма К.У. ханнары Алтын Урданың сәяси тормышында актив катнашалар. К.У.ның терр-ясенә Каспий буе, Урал итәге, Көньяк Себер, Төньяк һәм Көнчыгыш Арал буе җирләре керә. К.У. ике өлештән тора: көнбатышта (Урал итәге, Көнбатыш Арал буе һәм Себер) — Җүчи, Шәйбан, Тука Тимер уллары биләмәләре, көнчыгышта (Төньяк Казакъстан һәм Көнчыгыш Арал буе) — Урда Эҗен уллары биләмәләре. К.У.ның зур шәһәрләре — Сыгнак, Җәнд, Утрар.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

**КҮКДӘ́Й** (Күктай) (13 йөзнең 1 нче яртысы), монгол яубашы. 1229 елда гаскәр башлыгы Сөбедәй б-н бергә 30 меңле гаскәр башында Идел буе Болгарына яу б-н бара, Җаек елгасы буенда болгар чик сагы отрядларын тар-мар итә.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х., Х а л и у л л и н И.Х. Основные этапы монгольского нашествия на Волжскую Булгарию // Волжская Булгария и монгольское нашествие. К., 1988.

**КҮКЕ́ ЧӘЧӘГЕ́**, л и х н и с (Lychnis), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 25 тән артык төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре гади күке чәчәге яки татар сабыны (L.chalcedonica) бар. Идел алдында һәм Кама аръягында урманнарда, куаклар арасында үсә. Тулысы б-н каты төкчәле, 30–100 *см* биеклектәге үсемлек. Яфраклары йомыркасыман, төбендә йөрәксыман. Июнь–июльдә чәчәк ата. Чәчәкләре ачык кызыл төстә, калкансыман-башчалы куе чәчәк төркемендә. Җимеше — тартмачык. Орлыктан үрчи. Элек-электән халыкта «сабынлы тамыр» исеме б-н йөртелә, сабын сыйфатында файдаланыла. Йорт яны бакчаларында декоратив үсемлек буларак үстерелә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КҮКЕБА́Ш** (Pulmonaria), кыярчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 70 кә якын төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Тонык К. (P. obscura) республиканың бөтен терр-ясендә, йомшак К. (P. mollis) Кама алды һәм Кама аръягында, тар яфраклы К. (P. angustifolia) Кама алдында һәм Идел буеның көньяк өлешендә очрый. Киң яфраклы һәм катнаш урманнарда үсә. 15–60 *см* биеклектәге кыска тамырчалы үсемлек. Яфраклары чиратлашкан, өскеләре утырма, озынча-йомыркасыман, аскылары — сапка таба тарайган; йомшак К.ның яфрак пластинкасы зуррак һәм бәрхетсыман йомшак төкчәләр б-н капланган. Чәчәкләре салынкы, көпшәсыман-кыңгыраучыклы, серкәләнгәнгә кадәр ачык җете кызыл, соңыннан зәңгәр-шәмәхә яки зәңгәр, сабак очындагы чәчәк төркеменә җыйналган. Составында нектарин бар. Җимеше — чикләвекчек. Апрель–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Үсемлекнең җир өсте өлешләрендә дуплау һәм лайлалы матдәләр, флавоноидлар, сапониннар, органик к-талар, марганец, тимер, йод бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсен кан туктату чарасы буларак, ашказаны-эчәк авырулары вакытында кулланалар. Декоратив, баллы үсемлек.

**КҮКЕЛӘ́Р** (Cuculus), күке кошлар семьялыгындагы кошлар. 12 төре билгеле, Евразия һәм Африкада таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Гади күке (C. canorus) бөтен республика терр-ясе буенча, яфраклы һәм катнаш урманнарда, бакча, әрәмәлекләрдә, саңгырау күке (C. saturatus) төньяк урманнарда очрый. Татарстан терр-ясе буйлап әлеге төр ареалының көньяк һәм көнбатыш чикләре уза. К. алан һәм кисенделәр б-н чиратлашкан ылыслы һәм катнаш урманнарда яшиләр. Гәүдәләренең озынлыгы 25–40 *см*, авырлыгы 70–150 *г*. Каурый капламының өсте — кара яки аксыл соры, асты аксыл, дулкынсыман кара буйлы, ана кошлар охрасыман куныклы көрән яки җирәнрәк төстә. Озын, киртләч койрыклы. Томшыгы зур түгел, туры, очында җиңелчә аска бөгелгән. Күз кабагы ачык кызгылт-сары. Аяклары кыска, электергеч тырнаклы. Саңгырау күке гади күкедән кечкенәрәк, гәүдәсенең түбәнге өлешендә ачык һәм киңрәк аркылы сызыклар булуы б-н аерыла. Күчмә кошлар, апрель ахыры — май башында киләләр. Бу вакытта гади күкенең




Гади күке.

һәркемгә таныш тавышын (җырлавын) ишетергә мөмкин. К.гә оя паразитлыгы хас — ана кошлар йомыркаларын (20 гә кадәр) башка кошлар (камыш чыпчыклары, нарат чыпчыклары, чәперчек кошлар һ.б. чыпчыксыманнар отрядындагы сайрар кошлар) оясына сала. К. балалары июнь–июль башында чыгалар. Бөҗәкләр (коңгыз, аю чикерткәләр, филчекләр, аю күбәләк гусеницалары), ш.у. җиләкләр б-н туклана. К. июль ахырында, яшьләре сентябрьдә очып китәләр.

*Әд.:* А с ь к е е в И.В., А с ь к е е в О.В. Орнитофауна Республики Татарстан (конспект современного состояния). К., 1999.

**КҮКЕ́РТ**, табигатьтә саф килеш табыла торган элементлар классындагы минерал (S). Кайвакыт аның составында селен (5,2% ка кадәр), теллур, мышьяк катышмалары, балчыклы һәм органик матдәләр була. Кристаллик агрегатлар, тоташ, сирәк кенә җирсыман массалар, куныклар һ.б. хасил итә. Катылыгы 1–2. Уалучан. Яхшы изолятор. Вулканнар атылып чыгу, сульфидларның ашалуы һәм гипслы токымнарның яңадан торгызылуы вакытында барлыкка килә. Татарстан терр-ясендә 17 йөздән Идел елгасының уң ъяк ярында Сөйке авылы (Кама Тамагы р-ны) тирәсендә чыгарыла. 1890 еллар ахырында 134 *т* дан артык алына. 1917 һәм 1930 елларда Пермь чоры битуминоз доломитларында К.нең сибелмәләр һәм зур булмаган оялар рәвешендә вак ятмалары табыла. К. күкертле водород рәвешендә ирекле һәм иярчен газларда, битум, нефтьтә бар. Ел саен Түбән Кама нефть эшкәртү з-дында углеводородтан гранулалар рәвешендә 30 мең *т* дан артык күкерт алына. К. чыганагы булып техноген



Микрокатламлы доломитта гипслы һәм кальцитлы күкерт.

калдыклар хезмәт итә, ел саен атмосферага стационар чыганаклардан 30–40 мең *т* $SO_2$ чыгарыла. К. химия, кәгазь, резина, төзелеш сәнәгатендә, медицинада, а.х.нда һ.б. тармакларда кулланыла.

*Әд.:* В а л и т о в Н.Б. Минеральное сырьё. Сера. М., 1998.

*Н.Б.Вәлитов.*

**КҮКЕРТЛЕ́-ВОДОРОДЛЫ́ СУ ЧЫГАНАКЛАРЫ́ ҺӘМ ШИФАЛЫ́ ЛӘМНӘ́Р**, составында күкертле водород булган җир асты суларының һәм балчыклы органик матдәләрнең җир өстенә табигый чыгышы. Татарстан терр-ясендә $H_2S$ нең концентрациясе 30–50 *мг/л* дан артык булмаган (торфлы утырмаларда) һәм составында $H_2S$ берничә йөз *мг/л* га кадәр булган (Пермь системасының күбесенчә нефтьле һәм карбонатлы-битуминозлы токымнарында) сулар чыга. К.-в.с.ч.һ.ш.л. Сөйке (Кама Тамагы р-ны), Фиков-Колок (Чистай р-ны), Сарабиккол, Иске Куак, Шөгер, Петропавловка, Бәкер, Иске Иштирәк авыллары (Лениногорск р-ны) янында очрый. 1933 елдан «Бәкер» санаторие эшли, аның суы һәм ләме составында $H_2S$ 10 *мг/л* га кадәр. Ш.у.к. *Шифалы ләмнәр*.

*Әд.:* С о б о л е в В.Г., Б л ю м ш т е й н З.Н. Серные воды и грязи в Татреспублике // Казан. мед. жур. 1932. № 8–9; С о л о д у х о М.Г. Минеральные источники и грязи Татреспублики // Геология и полезные ископаемые ТАССР. К., 1940; Минерально-сырьевая база Республики Татарстан. К., 2006.

*Н.И.Афанасьева.*

**КҮКЕРТОРГА́НИК КУШЫЛМАЛА́Р**, молекулаларында углерод атомы б-н бәйле (C-S бәйләнеше) күкерт атомы булган кушылмалар. К.к.ның түбәндәге төрләре бар: меркаптаннар (тиоллар), тиоэфирлар (органик сульфидлар), органик ди- һәм полисульфидлар, күкертле гетероцикллар (тиофен һәм алкилтиофеннар), сульфокислоталар һәм аларның кушылмалары, тиоальдегидлар, тиокетоннар һәм тиокарбон к-талары, сульфоксидлар һәм сульфоннар. Нефть һәм газ конденсатлары күкертле кушылма чыганаклары булып тора ($H_2S$+RSH+COS+$CS_2$), аларны тикшеренү лаб-яләрендә синтезлыйлар.

Татарстанда яңа К.к. синтезлау, аларның төзелешен, үзлекләрен, алар катнашындагы реакция механизмнарын, гамәли кулланылышын эзләү буенча тикшеренүләр алып барыла. Казан химиклары күкертле гетероцикллар, конденсатлашкан тиазоллар, 1, 3, 4-тиадиазоллар һәм 1, 3, 4-тиадиазиннар химиясенә өлеш кертәләр; өч цикллы һәм тагын да катлаулырак конденсатлашкан тиазол структуралар төзүнең гомуми принцибы ачыла (В.М.Мамедов, Я.В.Левин, Е.А.Бердников). А.х. үсемлекләре корткычлары б-н көрәш чараларын эзләү максатыннан 4-алмаштырылган тиазоллар химиясе һәм технологиясе буенча тикшерүләр үткәрелә (Б.И.Бузыкин, Я.А.Левин, А.А.Муслинкин). Күкертле функциональ төркемле пиримидиннар химиясе өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләр нигезендә яңа биол. актив препаратлар һәм дару әйберләре булдырыла (В.С.Резник, Н.Г.Пашкуров). 20 йөзнең 2 нче яртысында К.к. химиясе үсеш ала: аларның регио- һәм стерео юнәлдерелгән синтезы, комплекс хасил итү мөмкинлекләре өйрәнелә, алар катнашында кушылу, алмаштыру, аерып алу, яңадан төркемләү реакцияләре механизмнарын тикшерелә (Е.Г.Катаев, Е.А.Бердников, Ф.Р.Танташева, Т.Г.Маннафов, Г.А.Чмутова һ.б.). Төрле тирәлектә кушылмаларның супрамолекуляр структураларга кадәр молекулаара тәэсир итешүе, ш.у. К.к.ның оксидлашу-кайтарылу электрохимик реакцияләре һ.б. процесслар (А.И.Мовчан, А.Р.Корбангалиева, Г.А.Чмутова, Е.А.Бердников); табигый (терпен) углеводородларга күкертле фрагментлар кертү реакцияләре өйрәнелә (В.В.Племенков, Л.Е.Никитина), аларны бишбуынлы N- һәм O- гетероцикларга селектив кертү алымнары эшләнә. Физиологик актив матдәләр булдыру максатыннан җидебуынлы тиоацетальләр һәм алар кушылмаларының фәзаи структурасын теоретик өйрәнүләр үткәрелә (Е.Н.Климовицкий, Ю.Г.Штырлин).

Татарстан галимнәре тарафыннан мотор ягулыклары һәм нефть эшкәртү продуктларының сыйфатын күтәрү, нефть продуктларын хәвеф-хәтәрсез саклау һәм йөртү максатыннан нефтьне күкерттән һәм аның кушылмаларыннан арындыру; күкертле кушылмаларны файдалану (эшкәртү) буенча һәм алар нигезендә физиологик актив матдәләр — дару препаратлары, пестицидлар, гербицидлар, технол. процесслар өчен компонентлар (антиоксидлаштыргычлар, пластификаторлар, эреткечләр, җылыйөрткечләр, затлы һәм сирәк металларны, ароматик углеводородларны аерып алганда комплекс хасил итүчеләр) алу мәсьәләләре хәл ителә. Ә.М.Мазһаров җитәкчелегендә нефтьне чистарту максатыннан түбән молекуляр меркаптаннар һәм күкертле водородны каталитик оксидлаштыру тормышка ашырыла. Идел буе углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты АҖ коллективы, Иваново технол. ин-ты, Мәскәү ун-ты, Органик ярымпродуктлар һәм буягычлар фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) б-н бергәләп, «ИВКАЗ» катализаторын, чималны демеркаптанлаштыру (ДМС) һәм дистиллятны демеркаптанлаштыру (ДМД) технологияләрен эшли, ул Россия һәм чит ил пр-тиеләрендә (Болгария, Литва, Казакъстан) нефть һәм газ конденсатларын чистарту өчен кертелә. ДМС-1 технологиясе буенча «Шеврон» Америка нефть компаниясе тарафыннан Тенгиз нефтен күкертле водород һәм меркаптаннардан чистарту буенча дөньяда беренче завод (Казакъстан) төзелә. Нефть һәм газ конденсатларын чистартканнан соң кала торган К.к.дан $C_2$-$C_4$ меркаптаннары кушылмалары алу өчен Оренбург газ эшкәртү з-дына ДМД-Odorant технологиясе (табигый газлар өчен одорант) кулланука кертелә. Иран милли нефть компаниясенә нефть чистарту технологиясенә һәм одорантлар җитештерүгә лицензияләр сатыла. ДМД процессларында өстәмә продукт — диалкилдисульфидлар катнашмасы — кокс ясауда ингибитор (күкертсез чимал пиролизлаганда), гидрочистарту катализаторларын күкертләүдә реагент, ш.у. тиофен һәм алкансульфокислоталар алуда чимал сыйфатында файдаланыла. Нефть продуктларыннан һәм үзагачны сульфат б-н эреткәндә аерылып чыккан тиоэфирлар сульфоксидлар һәм сульфоннар алу өчен кулланыла. Тиокол полимер кушылмасы дихлордиэтил эфирын натрий полисульфиды б-н поликонденсатлаштырып алына (Казан ясалма каучук з-ды). К.к.ны сульфоксидлар һәм сульфоннарга кадәр оксидлаштыру процесслары методикасы (Н.М.Лебедева, Х.Э.Харлампиди), тиокол җитештерү технологияләре камилләштерелә (Л.А.Аверко-Антонович, В.А.Минкин). Элементлы күкерттән сульфидлар һәм тиацикланнар, меркаптаннар алу ысулы эшләнә (В.К.Хәйруллин, Ф.Н.Мәҗитова). Нефть сульфоннарыннан ветеринария һәм а.х. өчен файдалы матдәләр булдырыла (Ф.Н.Мәҗитова, Н.А.Игламова).

*Ә.М.Мазһаров, Г.А.Чмутова, Е.А.Бердников.*

**КҮКИ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 39 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чошы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 630 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Агач әзерләү бүлеге. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Суши Кутеево исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба-чана ясау, күмер ясап сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, тегермән, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 606, 1897 дә — 1221, 1908 дә — 1496, 1920 дә — 1523, 1926 да — 1561, 1938 дә — 1588, 1949 да — 1291, 1958 дә — 1303, 1970 тә — 1460, 1989 да — 815, 2002 дә — 708 кеше.

**КҮКЛЕ́К** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Үмәк елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,9 *км*, бассей-

нының мәйданы 70,7 *км*². Алабуга р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Чиркәс авылыннан 2 *км* көньяктарак, тамагы Түбән Күклек авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. К.нең 1,2 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 108 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**КҮКРӘКЧӘ́**, татар хатын-кызлары киеменең бер өлеше, эчтән киелә торган күкрәк каплавычы. Өске почмаклары бөгелгән, аны күлмәкнең күкрәк уемы астыннан тотып торучы бәйләвечләре булган дүртпочмаклы тукыма кисәгеннән (зурлыгы 20×30 — 25×40 *см*) тегәләр.

К.нең күлмәк уемына туры килгән өлеше чигелгән яки аппликация б-н бизәлгән була. Гадәти бизәк — чәчәк бәйләме, чәчәкле ботак. Ул тигез яки (ешрак) тамбур чигүе б-н, кайбер очракларда келәм җөенә катнаштырып чигелә. Борынгы үрнәкләре бизәк-мөгезсыман фигуралардан һәм розеткасыман бизәкләрдән торган композицион вариацияләр; алар алтын җепләр б-н, кайбер очракларда төсле ефәк кушып, тигез чигү б-н чигелгән, мишәрләрдәге К.ләрдә озаграк сакланган. К.гә ике төрле мәгънә йөкләнгән: бизәү чарасы булудан тыш, сәнгати образга саклаучы мәгънә салынган, ул хатын-кызны явыз рухлардан сакларга тиеш булган. К.не осталар үзләре өчен, туй бүләкләре һәм үлемтек (өлкән яшьтәге хатын-кызны җирләгәндә аның төсе итеп яшьтәшләренә К.ләр өләшү гадәте булган) сыйфатында тарату өчен теккәннәр. К.ләр 20 йөз уртасында, Европа костюмы модага кергәннән соң, кулланылыштан чыга.

*Әд.:* Гулова Ф.Ф. Татарская народная вышивка. К., 1980; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

*Ф.Ф.Гулова.*





Күкрәкчә. 1. Ефәк. Алтын-көмеш җепләр. Тамбурлы чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее; 2. Тамбурлы чигү. 20 йөз башы.

**КҮКТА́У** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1910 елларда Юлтимер авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1920 дә — 117, 1926 да — 148, 1938 дә — 207, 1949 да — 159, 1958 дә — 138, 1970 тә — 89, 1979 да — 68, 1989 да — 39, 2002 дә — 101 кеше.

**КҮКТӘКӘ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 354 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17–18 йөзләр чигендә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1383 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык; 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1889 да — 540, 1908 дә — 735, 1920 дә — 751, 1926 да — 512, 1949 да — 573, 1958 дә — 542, 1970 тә — 591, 1979 да — 445, 1989 да — 289, 2002 дә — 359 кеше.

**КҮКТӘ́К-МИРСӘЕ́Т** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 49 *км* көньяктарак, Инеш елгасы (Игәнәнең сул кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 125 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1926 да — 282, 1938 дә — 357, 1949 да — 305, 1958 дә — 279, 1970 тә — 253, 1979 да — 181, 1989 да — 131, 2002 дә — 134 кеше.

**КҮКЧӘ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2010 елда 193 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет (1862 дә төзелә), мәдрәсә, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 966,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 86 ир-ат; 1859 да — 486, 1897 дә — 665, 1908 дә — 744, 1920 дә — 670, 1926 да — 510, 1938 дә — 485, 1949 да — 481, 1958 дә — 418, 1970 тә — 412, 1979 да — 343, 1989 да — 257, 2002 дә — 213 кеше.

**КҮКЧӘ́-БИРӘЗӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бирәзә елгасы буенда. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-Б.дә җамигъ мәчет, су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1195,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 117 ир-ат; 1859 да — 463, 1897 дә — 669, 1908 дә — 734, 1920 дә — 597, 1926 да — 700, 1938 дә — 735, 1949 да — 344, 1958 дә — 287, 1970 тә — 233, 1979 да — 180, 1989 да — 132, 2002 дә — 97 кеше.

**КҮКЧӘЧӘ́К** (Centaurea), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә ике- яки берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Чәчәк оешмасында (кәрзиндә) төкчәле чәчәк төбе һәм көпшәсыман (кайбер очракта көпшә — бүрәнкәсыман) чәчәкләр (зәңгәр, алсу, куе кызыл, сары һ.б.) урнашкан. 550 дән артык төре билгеле (Европада, Азия, Америка, тропик Африка, Австриядә), РФдә якынча 180 төре бар. Татарстан терр-ясендә зәңгәр К., яисә чәчүлек К.е (K. cyanus), бо-

лын К.е (K. jacea), кытыршы К. (K. scabiosa) киң таралган. Болыннарда, урман аланнарында, кырларда үсәләр. Зәңгәр К. — баллы һәм дару үсемлеге, бөртекле ашлык (аеруча арыш), сөрүле культуралар һәм терлек азыгы үләннәре чәчүлекләрен чүплиләр. Көрәш чаралары: алдан туфракның өске катлавын йомшартып, үз вакытында туңга сөрү, дөрес чәчү әйләнеше, орлыкларны чистарту, гербицидлар куллану.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КҮКЧЕ́Л** (Polemonium), күкчелчәләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, Евразиянең салкын һәм уртача поясларында, Төньяк һәм сирәк кенә Көньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — зәңгәр К. (P. caeruleum) барлык районнарда очрый. Дымлы урманнарда, куаклар арасында, тугайлы болыннарда үсә. 30–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамырчасы кыска. Сабагы туры. Яфраклары чиратлашкан, парсыз каурыйсыман, аскылары — озын саплы, өскеләре — утырма. Чәчәкләре зәңгәр, кыңгыраусыман, себеркәчле чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — шарсыман өч ояλы тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Үсемлекнең барлык өлешләрендә (башлыча, тамырларында) сапонин, сумала, органик к-талар бар. Тамыр һәм тамырчаларыннан ясалган төнәтмә тамак йомшарту һәм тынычландыру өчен кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

**КҮКЧИШМӘ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 56 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 15 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 373,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 18 ир-ат; 1859 да — 166, 1897 дә — 319, 1908 дә — 342, 1920 дә — 343, 1926 да — 339, 1938 дә — 319, 1949 да — 406, 1958 дә — 230, 1940 тә — 179, 1979 да — 144, 1989 да — 72, 2002 дә — 31 кеше.

**КҮКШЕ́Л** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 22 *км* төньяктарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 876 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; катнаш азык з-ды. Мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, слесарьлык һөнәре б-н шөгыльләнә; Мәчкәрә авылындагы комач ф-касында эшли. 1792 дә К.дә поташ з-дына нигез салына. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, монда мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1735,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1905 тә — 1202, 1920 дә — 1261, 1926 да — 1252, 1938 дә — 1112, 1949 да — 887, 1958 дә — 871, 1970 тә — 928, 1979 да — 954, 1989 да — 835, 2002 дә — 904 кеше.

**КҮКШЕ́М** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 37 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш. 2010 елда 94 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Хуҗахәсән исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 680 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1859 да — 232, 1897 дә — 439, 1908 дә — 532, 1920 дә — 535, 1926 да — 405, 1938 дә — 298, 1949 да — 312, 1958 дә — 237, 1970 тә — 140, 1979 да — 188, 1989 да — 125, 2002 дә — 123 кеше.

**КҮЛ**, Идел алдындагы күл. Югары Ослан р-нының Юмат авылыннан 1,4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сөлчә елгасы үзәненең уңъяк сөзәклегендә. Су өслегенең мәйданы 0,08 *га*. Су күләме 2 мең *м*³. Озынлыгы 40 *м*, киңлеге 35 *м*, уртача тирәнлеге 2 *м* га якын, иң зур тирәнлеге 5,2 *м*. К. карст күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы түгәрәк. Ярлары калкулы, киң яфраклы урман б-н капланган. Җир асты сулары б-н туена. Суы каты (6,7 *мг/л*), җиңелчә минеральләшкән (11,5 *мг/л*); җәй көне суы «чәчәк ата». К.дә сары төнбоек үсә (ТРның Кызыл китабына кертелгән). Сулык ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).



Күл акчарлаклары колониясе.

**КҮЛ АКЧАРЛАКЛАРЫ́ КОЛО́НИЯСЕ**, табигать истәлеге. Лаеш р-ның Столбище авылыннан көньяк-көнбатыштарак. 1983 елда теркәлә. Мәйданы 30 *га*. Су үсемлекләре б-н каплана барган Коры һәм Чета күлләрендә акчарлакларның ТРдагы иң зур колониясе, 1973 тән билгеле. 2 меңләп оя исәпләнә, 1990 еллар ахырында акчарлакларның саны кими. Фаунада: амфибияләр (5 төр), кошлар (18), имезүчеләр (4); ТРның Кызыл китабына кертелгән төрләр: зур энә карагы, кыр чапкыны, зур сусөяр, соры гөберле бака, кызыл муенлы чомга, сары корташар. 1983 тә Коры күлендә ак канатлы акчарлаклар (300 гә кадәр оя) колониясе билгеләнә. Үсемлекләрнең 50 дән артык төре үсә (гади курак, очлы күрән, камышсыман кушбашак, төлке күрәне, көтүче кубызы, вак бака тәңкәсе, соргылт яки ланцетсыман чәчбай һ.б.; сирәк төр — ак төнбоек).

*Әд.:* Вадолажская Т.И., Залетаев В.С. Отряд чайкообразные Lariformes // Птицы Волжско-Камского края. Неворобьиные. М., 1977.

**КҮЛ ҺӘМ ЕЛГА́ БАЛЫКЧЫЛЫ́К ХУҖАЛЫГЫ́ ИНСТИТУТЫНЫ́Ң ТАТАРСТА́Н БҮЛЕГЕ́**, дәүләт фәнни-тикшеренү бүлеге (ГосНИОРХ). 1931 елда Казанда ТАССР кулланучылар берлеге каршында оештырылган Идел-Кама балыкчылык хуҗалыгы станциясеннән башлангыч ала; 1932 дән Ленинград (шул ук елда — Бөтенсоюз) фәнни-тикшеренү ихтиология ин-ты бүлеге; 1958 дән хәзерге исемдә. Балыкчылык буенча Федераль агентлык карамагында. Бүлек составында — чимал ресурслары лаб-ясе, 2 сектор (җылы сулыкларда балык үрчетү һәм балык ресурс-

ларын ясалма рәвештә яңарту. Балык үрчетү һәм балыкчылык өлкәсендә эзләнү эшләре алып бара, Урта Идел терр-ясендә су биоресурсларының дәүләт мониторингын башкара. Төп юнәлешләре: эчке сулык биоресурсларын нәтиҗәле файдалану алымнарын һәм биологик нигезләрен эшләү, товарлыклы балыкны үстерү биотехникасын һәм селекция-токым эшләрен камилләштерү; Куйбышев, Түбән Кама һ.б. сусаклагычларда балык запасын ясалма рәвештә яңарту алымнарын эшләү һәм гамәлгә кертү, ш.и. үсемлек б-н туклануччы балыклар хисабына аларның продуктивлыгын күтәрү. «Куйбышев сусаклагычындагы кәсәбәчелек балыкларының саны, бүленеше һәм аларга бәйле факторлар» («Распределение и численность промысловых рыб Куйбышевского водохранилища и обусловливающие их факторы», 1972) дигән атлас чыгарыла. 1933–72 елларда «ГосНИОРХның Татарстан бүлеге хезмәтләре» (Труды Татарского отделения ГосНИОРХ, вып. 1–12) басыла. Бүлек җитәкчеләре: А.В.Лукин (1931–64), Ю.М.Махотин (1964–80), Р.А.Ризванов (1980–95), Р.Г.Таиров (1995 тән).

*Ф.М.Шакирова.*

**КҮЛ ЧЕРКЕНЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* төньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 592 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Черкен исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ч.ндә 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1397,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 568, 1897 дә — 1232, 1908 дә — 1457, 1920 дә — 1595, 1926 да — 1238, 1938 дә — 1360, 1949 да — 1184, 1958 дә — 1125, 1970 тә — 1365, 1979 да — 1261, 1989 да — 836, 2002 дә — 629 кеше. К.Ч.ндә сынчы Б.И.*Урманче* туган.

**КҮЛӘГӘ́Ш** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 94 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 317 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1722 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Киясово исеме б-н дә билгеле. 18 — 19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше һәм урман материаллары әзерләү б-н шөгыльләнә. Авыл җәмгатенең имана җире 215,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 75, 1887 дә — 79, 1905 тә — 320, 1920 дә — 323, 1926 да — 347, 1938 дә — 416, 1949 да — 336, 1958 дә — 373, 1970 тә — 389, 1989 да — 293, 2002 дә — 302 кеше.

**КҮЛБА́Й-МОРАСА́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 59 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мораса елгасы буенда. 2010 елда 704 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, мичкә ясау, күн аяк киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.-М.да земство мәктәбе (1900 дә ачыла), 30 тимерче алачыгы, 2 шырпы ф-касы, 2 кибет, 17 кечкенә вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4706 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 233 ир-ат; 1859 да — 1797, 1897 дә — 2911, 1908 дә — 3870, 1920 дә — 3721, 1926 да — 2020, 1938 дә — 1848, 1949 да — 1750, 1958 дә — 1281, 1970 тә — 1383, 1979 да — 1141, 1989 да — 727, 2002 дә — 891 кеше. К.-М. — актёр Г.Х.*Кариевның* туган авылы.

**КҮЛБА́КОВ** Шәрәфетдин Габделгалләм улы (1849–1910 нан соң), җәмәгать эшлеклесе. Оренбург кадетлар корпусын тәмамлый. Оренбург губернасының Златоуст өязе земство җыены волость судьясы, гласные. 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), мөселман фракциясе әгъзасы. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясе әгъзасы.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России (1906–1917): Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Д.М.Госманова.*

**КҮЛБУЕ́ МӘДРӘСӘСЕ́**, к. *«Касыймия» мәдрәсәсе.*

**КҮЛИ́ЕВ** Марат Тәүфыйк улы (3.5.1926, Казан), педагог, төзүче-инженер, техник фән. канд. (1962), ТАССРның атказ. төзүчесе (1977), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998), Рфнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1998), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1951 елда Казан гражданлык төзелеше инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, Смоленск шәһәрендә өлкә төзелеш трестында прораб булып эшли. 1954 тән КПССның Смоленск шәһәр ком-тында инструктор, сәнәгать-транспорт бүлеге мөдире. 1956–2006 да Казан архит-ра-төзелеш ун-тында: (бүленеп: 1966–68 дә Мисырда Асуан плотинасы төзелешендә катнаша), 1968–88 дә ректор. 1974–79 елларда фундамент салу һәм инженерлык геологиясе каф. мөдире, 1988–2006 да — шул ук каф. профессоры. К. башлангычы б-н яңа факультетлар һәм белгечлекләр ачыла, уку-укыту процессында электрон-хисаплау машиналары киң кулланыла башлый, төзелеш буенча Мәскәү, Ленинград, Киевтагы фәнни-тикшеренү ин-тлары б-н фәнни һәм иҗади элемтәләр урнаштырыла. «Почёт билгесе», Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Противофильтрационная завеса Асуанской плотины. М., 1970; Глубинное закрепление грунтов в строительстве. К., 1983; Дороги и окружающая среда. К., 1990.

**КҮЛЛӘ́Р**, җир өслегенең иңкү урыннарында (казанлыкларда) су алмашы акрынайган табигый сулыклар. Татарстан терр-ясендә 8 меңнән артык күл бар (су ресурслары 28 млн. $м^3$). К.нең 70% тан артыгы кече К. категориясенә керә: су күләме 5 мең $м^3$ тан, су өслегенең мәйданы 5 *га*дан артмый. Республиканың күпчелек К. (83%) зур һәм уртача елгаларның — Вятка, Ык, Зөя, Олы һәм Кече Чирмешән елгалары тугайларында, Сөн, Зәй, Чишмә, Мишә уйсулыкларында, ш.у. Кама-Агыйдел түбәнлегендә урнашкан. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәр күп кенә тугай күлләре Идел һәм Каманың сулъяк ярында, Казансу елгасының уң ягында (Казан эчендә) була. Әлеге тип К. тар, озынча, ураксыман яки дагасыман формада. Аларның мәйданы еш кына 1 *га* га, тирәнлеге 2 *м* га кадәр. Күпчелек елгаларның элекке юллары аллювиаль китермәләр б-н бүленү нәтиҗәсендә хасил була. ТРда элекке су юлларындагы аеруча зур К.: Кама Тугаенда *Бака күле* (45 *га*), *Подборное күле* (41 *га*), Тары-Бары (33,5 *га*); Вятка елгасы тугаенда Этбай (76 *га*), Тутак (48 *га*); Агыйдел елгасы тугаенда Бакилде (109 *га*). Республика терр-ясендә К. күбесенчә карст күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Сумка елгасы юлында агымсулы *Аккул, Раифа күле, Ильинка күле* урнашкан, Иделнең югары комсу террасаларына һәм Казан ярусының карбонат-сульфатлы токымнарының яту өслегенә якын булган башка елгаларга *Зәңгәр күл, Осиново күле, Кавал күле, Хәерби күле, Чиста күл, Архиерей күле* һ.б. туры килә. Карст К. шактый — Вятка увалының көньяк чигендә: *Кәрәкәле күле, Мунчала күле, Каракул, Кодаш күле, Хәбри күле, Сөләнгер күле.* Су өслеге мәйданнары зур булмаган карст К. шактый тирән (берничә *м* га кадәр), ярлары түгәрәк яки озынча түгәрәк. Аларда су чиста, аның минеральләшүе югары. Кайбер карст К.енең (*Аккош күлләре, Кабан күлләре* системасы, *Карабалык күле, Чуртан күле*) казанлыклары вак минераль кисәкчекләр һәм суда эрегән матдәләрнең юылуы, утырма иңкүлекләр, бөрәнкәләр барлыкка килү б-н бәйле суффозион процесслар нәтиҗәсендә катлауланган.

К.нең туену чыганагы булып аларга коючы елгалар, атм. явым-төшемнәре, җир асты сулары тора. К.дә су биеклеге сезонлы үзгәрешләр кичерә, аеруча зур күрсәткеч язгы кар эрү чорына, иң азы җәйнең 2 нче яртысына туры килә. Агымсыз йомык К. өстенлек итә. К.нең күбесендә су гидрокарбонатлы, аз һәм уртача минеральләшкән (0,2–0,5 *г/л*); карст К.ендә су тагын да югары минеральләшкән. *Олы Зәңгәр күл* һәм Кече Зәңгәр күл-

ләр уникаль, алар күкертле водород күләме югары булган җир асты су чыганакларыннан («чоңгыллардан») туеналар.

К. кәнкүреш һәм сәнәгать сулары чыганагы буларак, балык һәм су кошлары үрчетү өчен, ял итү максатларында файдаланыла. Республиканың күп кенә К. кечле антропоген йогынтыга дучар, сулыклар әкренләп үсемлекләр б-н каплана һәм ләмләнә.

Туфрак эрозиясе һәм агым суларның агып керүе К.нең гидрологик режимы җимерелүгә, суның пычрануына һәм, шул сәбәпле, аларда яшәүче организмнарның җитди үзгәрешләренә китерә. 33 күл ТРның табигать истәлеге булып тора.

*Әд.:* Озёра Среднего Поволжья. Л., 1976; Уникальные экосистемы солоноватоводных карстовых озёр Среднего Поволжья. К., 2001; Т а й с и н А.С. Озёра приказанского района, их современные природные и антропогенные изменения. К., 2006.

*Л.В.Мошкова, О.В.Ерёгин.*

**КҮЛЛЕ́** посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* көнбатыштарак, Коры Елга буенда. 2010 елда 494 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 77%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1980 дә С.П.Горбунов исем. Казан авиация ҖБ ярдәмче хуҗалыгы үзәге буларак нигез салына. Оештырылган көннән Биектау р-нында. Халык саны: 1989 да — 471, 2002 дә — 485 кеше.

**КҮЛЛЕ́ КИМЕ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үртәм елгасы бассейнында. 2010 елда 371 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.К.дә мәчет, мәдрәсә, земство хастаханәсе, вет. фельдшерлык пункты, тимерчелек, 1 казна шәраб кибете, 2 сыраханә, 1 тукымалар һәм 5 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1712 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 149 ир-ат; 1859 да — 902, 1897 дә — 1104, 1908 дә — 1168, 1920 дә — 1115, 1926 да — 1134, 1938 дә — 1259, 1949 да — 877, 1958 дә — 758, 1970 тә — 597, 1979 да — 550, 1989 да — 471, 2002 дә — 393 кеше. К.К. — шагыйрь С.*Хәким* туган авыл (музее бар).

**КҮЛНӘ́** (Күлпә) (Көлнә) (?–1359), Алтын Урда ханы (1359). Бирдебәк ханны бәреп төшереп, Алтын Урдада хакимиятне үз кулына ала. Дәүләтнең барлык терр-ясендә акча суктыра. Аның сәясәтеннән риза булмаучыларны юк итүгә юнәлтелгән гамәлләре фетнәләр килеп чыгуга китерә. Нәүрүз хан тарафыннан тәхеттән төшерелә һәм җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Куликовская битва. М., 1980.

*И.Л.Измайлов.*

**КҮЛТӘГИ́Н** (?-731), тәгин (каган улы), Төрки каганлыкта хәрби җитәкче. *Билге каганның* энесе. 711–15 елларда Капаган каган ягында карлук, чигил, уйгырларга каршы, 718 һәм 720–721 дә Билге каган җитәкчелегендә Тан империясенә (Кытай) каршы алып барылган сугышларда катнаша. К.гә багышлап төрки һәм кытай телләрендә язу язылган зур һәйкәл ташы сакланган. (к. *Күлтәгингә куелган һәйкәлташ*).


*Әд.:* Г у м и л ё в Л.Н. Древние тюрки. М., 1993.

**КҮЛТӘГИНГӘ́ КУЕЛГА́Н ҺӘЙКӘЛТА́Ш**, 8 йөз борынгы төрки эпиграфик ядкәре; төркиләр хакиме *Билге каган* һәм аның энесе *Күлтәгингә* куелган кабер ташы. Кошо-Цайдам үзәнлегендә Орхон елгасы ярында (Монголия) урнашкан. Борынгы гыйбадәтханәгә килү юлында, аерым төрбәдә, мәрмәр ташбака өстенә урнаштырылган дүртпочмаклы озынча зур таш. Аның янәшәсенә табигый зурлыкта берничә кеше сыны — хезмәткәрләр һәм яраннар сыннары бастырып куелган. Гыйбадәтханә эчендә (10,25×10,25 *м*) гыйбадәт кылу учагы һәм Күлтәгин б-н хатынының мәрмәр сыннары булган (сынның баш өлеше генә сакланган). Ядкәрне 1889 елда рус галиме Н.М.Ядринцев ача, таштагы ике телдәге язуларны 1893 тә Дания тел галиме В.Томсен ачыклый һәм күчереп ала. Әчтәлеген 1894 тә беренче булып Казан галиме



Күлтәгингә куелган һәйкәлташ (көньяктан күренеше).

В.В.Радлов укый. Һәйкәлташтагы текст *рун язуы* б-н язылган; зур һәм кечкенә 2 өлешкә бүленгән, алар, үз чиратында, ике вариантта — кытай телендә һәм төрки телдә эшләнгән (к. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*). Кечкенә ташъязмада төрки нәселләрне һәм кабиләләрне берләштерүче каганга дан җырлана; зур ташъязмада Төрки һәм Уйгыр каганлыклары, ш.и. отуз (утыз) татар, токуз (тугыз) татар кабиләләре һ.б. турында мәгълүматлар бар. Күлтәгингә куелган һәйкәлташтагы язмадан өзекләр:



«Тәңредәй күкләрдә яратылган зирәк төрки каган булып бу вакытта тәхеткә утырдым. Сүземне төгәл ишетегез: барыгыз — кече туганнарым, улларым, биредә оям халкы, көньякка — шад-апыт бәкләр, төньякка — таркат-боерык бәкләр, утыз тугыз бәкләр халкы! Бу сүземне яхшы ишет, ныклап тыңла. Алга — кояш чыгышына, уңга — көн уртасына, артка — көн батышына, сулга — төн уртасына кадәр сузылган җирдә яшәүче халыкны тупладым, күбәйттем...».

*Әд.:* Н у р и е в а Ф.Ш. Борынгы төрки тел. К., 2007; М е л и о р а н с к и й П. Памятник в честь Кюль-Тегина // Зап. Вост. отд-ния Рус. археол. об-ва. СПб., 1900. Т. 12; М а л о в С.Е. Памятники древнетюркской письменности: Тексты и исслед. М.–Л., 1951; Г у м и л ё в Л.Н. Древние тюрки. М., 1993; К л я ш т о р н ы й С. Кимаки, кипчаки и половцы // История татар с древнейших времён. К., 2002. Т. 1; T h o m s e n V. Alttürkishe Inschriften aus der Mongolei // Zeitschrift der Deutschen Morgenländischen Gesellschaft. 1924. Bd. 78, h. 2.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**КҮЛТӘ́С** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1617 елдан Пустошь Березняк буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пошалым исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә; 1840 еллар башына «*Бәрәңге фетнәләре*»ндә катнаша. 20 йөз башында К.тә мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 714,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 218, 1897 дә — 356, 1908 дә — 431, 1920 дә — 505, 1926 да — 622, 1938 дә — 744, 1949 да — 600, 1958 дә — 573, 1970 тә — 461, 1979 да — 350, 1989 да — 251, 2002 дә — 178 кеше. К.тә мәгърифәтче Ш.*Күлтәси* туган.

*Әд.:* Арча төбәге тарихы — История Арского края. К., 1996.

**КҮЛТӘСИ́** Шәмсетдин (1856 яки 1857, Казан губ. Казан өязе, хәзер Арча р-ны Күлтәс а. — 25.3.1933, шунда ук), дин эшлеклесе, мәгърифәтче, астроном. Әтисендә, Күлтәс авылы имамында, соңрак Казан губернасының Казан өязе Югары Курса авылы һәм Вятка губернасы Малмыж өязе Түнтәр авылы мәдрәсәләрендә укый. Россия армиясен-

дә хезмәт итә, анда писарь вазифаларын башкара. 1884 елдан мәчет имамы, Күлтәс мәктәбендә дини һәм дөньяви фәннәр укыта. Татар җәмгыятендә яшәп килүче тәртипләрне тәнкыйтьләве нәтиҗәсендә, хөкүмәт тарафыннан күп тапкырлар эзәрлекләүләргә дучар була. 1909 дан үзен, нигездә, мөгаллимлеккә һәм дини эшчәнлеккә багышлый. К. — илаһият, философия, астрономия, физика, химия буенча хезмәтләр авторы. «Һәйәте җәдидә» («Яңа астрономия», 1899) хезмәтендә ул Галәмдә баручы процессларны бәян итә; фәнни эзләнүләр иреген таләп итеп чыгыш ясый. «Һикмәте җәдидә» («Яңа философия», 1899) хезмәтендә К. дөнья яратылышының гелиоцентрик системасы идеясен яклаган фикерләр әйтә, геоцентрик системаның дөрес түгеллеген исбатлый. Динне, нигездә, кире какмаган хәлдә, ул фән б-н диннең бурычларын аерып куярга кирәк дип исәпли, спекулятив илаһият — *кәлямны* тәнкыйтьли, татар халкының заманадан артта калуын шуннан күрә. К. җәмгыятьтәге торгынлыкны җиңеп чыгу өчен техник прогресс казанышларын, белемнәрне вакытлы матбугат һәм мәгариф системасы аша пропагандалауга зур әһәмият бирә. Октябрь рев-циясеннән соң эшчәнлеген мәгариф өлкәсендә дәвам итә.

Х е з м.: Һәйәте җәдидә ысулыны нусус шәргыйя тәтбикъ. К., 1896; Мөфассаль һәйәте җәдидә. К., 1900; Халемездән шикайәт. К., 1903; Мәктәп баласы яхуд Сәхилә әби (кечкенә балалар өчен). К., 1909.

*Әд.:* А б д у л л и н Я.Г. Татар мәгърифәтчеләре философиясенең кайбер мәсьәләләре // Казан утлары. 1972. № 12; Арча төбәге тарихы — История Арского края. К., 1996; Духовная культура и татарская интеллигенция: Исторические портреты. К., 2000. *Н.М.Алиев.*

**КҮЛЧӘ́** (Lolium), кыяклылар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразиянең, Төньяк Африканың уртача поясында очрыйлар. Татарстан терр-ясендә 4 төре билгеле. Күпьеллык яки инглиз райграс (L. perenne) барлык районнарда очрый. Җитен күлчәсе (L. remotum), күп чәчәкле (L. multiflorum) — сирәк, тиле бодай (L. temulentum) — юкка чыга баручы төрләр. Чәчүлекләрдә, болыннарда, чүплек тирәләрендә үсәләр. 20–80 *см* биеклектәге бер- һәм күпьеллык үсемлекләр. Тамыр системасы чук. Сабагы туры, күп, нәзек. Яфраклары тар кыяк. Чәчәк төркеме — ике рәтле башак. Башчалары күп чәчәкле, ян-яктан кысылган, башак үзәгенең чыгынтысында берәрләп утыралар. Җимеше — бөртекчә. Май–августта чәчәк аталар. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Күпьеллык К., азык үсемлеге буларак, культурага кертелгән, газоннар ясау, туфракны ныгыту өчен кулланыла.

**«КҮМӘ́К ХУҖАЛЫ́К»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Ялутор райкомы һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының район Советы органы. 1931–35 елларда Төмән өлкәсе Ялутор шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. 1931–32 дә «Икмәк өчен» исеме б-н чыга.

**«КҮМӘ́К ХУҖАЛЫ́К»**, журнал; к. «*Татарстан авыл хуҗалыгы*».

**«КҮМЕ́Р ӨЧЕ́Н»**, эшчеләр өчен көндәлек газета. Украина КП(б)ның Чистяково шәһәр ком-ты, Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатларның шәһәр Советы башкарма ком-ты органы. 1932 елның 1 июненнән 1935 нең 15 июненә кадәр Донецк өлкәсе Чистяково шәһәрендә татар телендә 108 саны нәшер ителә. Украин һәм рус телләрендә чыгучы «Горняк» г-тасы редакциясе каршында басыла. Күмер сәнәгатендә эшләүче татарлар өчен чыгарыла. *Т.М.Насыйров.*

**«КҮМЕ́Р УДА́РНИГЫ»**, эшчеләр өчен атналык газета. Украина КП(б)ның Макеевка шәһәр ком-ты, Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатларның шәһәр Советы һәм профсоюзларның шәһәр Советы органы. 1932 елның 10 октябреннән 1934 нең 31 июленә кадәр Донецк өлкәсе Макеевка шәһәрендә татар телендә барлыгы 107 саны нәшер ителә. Мөхәррире — Ш.Әхмәтҗанов. Макеевка шахталарында, металлургия, торба кою, кокс-химия һәм цемент з-дларында, күмер сыйфатын яхшырту ф-касында эшләүче татарлар өчен чыгарыла. Газетада хезмәт ударниклары А.Галиев, С.Ибраһимов, Т.Фәйзрахманов, Н.Яруллин һ.б. турында язмалар басыла. Эшче-хәбәрчеләрнең язмалары даими урын ала. *Т.М.Насыйров.*

**«КҮМЕ́Р УДА́РНИКЛАРЫ»**, эшчеләр газетасы. Профсоюзларның Ерак Көнчыгыш крае Советы, Күмерчеләр берлегенең край ком-ты һәм ВКП(б)ның Артём шәһәр ком-ты органы. 1932 елның 27 гыйнварыннан 1933 нең 23 апреленә кадәр Приморье крае Артём эшчеләр посёлогында татар телендә 109 саны нәшер ителә. Крайның күмер сәнәгате пр-тиеләрендәге татар эшчеләре өчен чыгарыла. *Т.М.Насыйров.*

**КҮМЕРТА́У** шәһәре, БРда (Уфадан 257 *км* көньяктарак). 1947 елда нигез салына. Халкы — 66,8 мең кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 5729, 1979 да — 6232, 1989 да — 8158, 2002 дә — 8517 кеше. 2004/05 уку елында бер мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, тагын бер мәктәптә татар теле фән буларак укытыла.

**КҮН** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 800 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1648 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, 2 мәдрәсә, су тегермәне, тимерчелек, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2029 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 824, 1897 дә — 1315, 1908 дә — 1248, 1920 дә — 1555, 1926 да — 1379, 1949 да — 1317, 1958 дә — 1434, 1970 тә — 1392, 1979 да — 1223, 1989 да — 998, 2002 дә — 860 кеше.

**КҮН ГАЛАНТЕРЕ́Я ФИ́РМАСЫ**, җиңел сәнәгатьнең натураль һәм ясалма күннән эшләнмәләр җитештерүче пр-тиесе. Казанда урнашкан. Эшләүчеләр саны — 270 кеше (2010). 1937 елда В.И.Ленин исем. Казан күн комб-ты составыннан бүленеп чыккан Казан күн галантерея ф-касы буларак нигезләнә. 1993 тән хәзерге исемдәге АҖ. Фабрика, хәрби заказлар үтәп, Бөек Ватан сугышы елларында аеруча интенсив үсеш ала. 1960–70 елларда анда эшләүчеләр саны 1 мең кешедән арта. 1980 елларда елга 2 млн. га кадәр эшләнмәләр чыгара, совет күн галантерея продукциясе җитештерүчеләрнең әйдәп баручы өчлегенә керә. 1995–98 дә ил базарында читтән кертелгән товарларның өлеше шактый артуы нәтиҗәсендә җитештерү 5 тапкыр диярлек кими. 1998 дән аның тотрыклану һәм алга таба үсеш чоры башлана. 2000 нән фирма Россиянең күн галантерея продукциясе җитештерүче әйдәп баручы 5 пр-тиесе исәбенә керә. Киң ассортиментта хатын-кыз һәм ир-ат сумкалары, портфельләр, папкалар, перчаткалар, каешлар; гражданлык һәм көч структуралары өчен кирәк-яраклар; индивидуаль заказлар буенча натураль һәм ясалма күннән, техник тукымалардан төрле эшләнмәләр җитештерә. Елга 300 дән артык исемдәге модель тәкъдим ителә. 2002 дә автоматлаштырылган проектлау, яңа продукция үрнәкләрен эшләү системалары гамәлгә кертелә, нәтиҗәдә, модельер-конструкторлар хезмәтенең җитештерүчәнлеге һәм техник документациянең сыйфаты 2–3 тапкыр яхшыра. Натураль күннән ясалган эшләнмәләрнең товарлыклы йөзен һәм сыйфатын яхшыртуга мөмкинлек биргән заманча итальян җиһазлары комплексы урнаштырыла. Чимал Казан һәм Россиянең башка күн пр-тиеләреннән китерелә. 2002 нән К.г.ф. бу тармакта аеруча тотрыклы эшләүче пр-тиеләр исәбенә керә; даими рәвештә Россия һәм төбәк күргәзмә-ярминкәләрендә катнаша. Пр-тие җитәкчеләре: Г.Салканов (1937–41), С.С.Отачнец (1941–48), Г.Г.Кагадуллин (1948–65), М.Е.Тимирясов (1965–74), Н.А.Мясников (1974–89), В.А.Рубинштейн (1989 дан). *И.Н.Афанасьев.*

**КҮН ҖИТЕШТЕРҮ́**, җиңел сәнәгатьнең хайван тиреләреннән өс һәм аяк киемнәре, галантерея әйберләре һәм дирбия-иярләр, төрле машиналарның детальләрен һ.б.ны эшләү өчен кулланыла торган йомшак һәм каты күннәр, ш.у. ясалма күн җитештерү б-н шөгыльләнүче тармагы. Эшләүчеләр саны — 1 меңләп кеше (2008).

*Күн эшләү һөнәрчелеге* Идел буе Болгар дәүләте дәверендә үк киң танылা. 18 йөз башында, күбесенчә, ирекле яллы хезмәттән файдаланган дәүләт һәм хосусый *күн эшләнмәләр мануфактуралары* була. 19 йөзнең 2 нче яртысында фабрика-завод тибындагы пр-тиеләр барлыкка килә. Эре пр-тиеләрнең күбесе — Л.А., Н.И., Н.Н.Алафузовларның күн һәм дирбия-ияр (1860, к. *Алафузовларның завод-фабрикалар һәм җитештерү-сәүдә ширкәте*), бертуганнар А.М., Г.М., Р.М.Гольберг һәм К° күн-чи каеш (1872), С.В.Жулин, Даутов һәм Смолинның (1875), Луи Зальм-

ның (1885), И.Я.Голитцерның (1894), В.Г.Шабанов, Е.Л.Сафронов һәм К° (1906) күн з-длары — Казанда урнаша. Шулай ук Чистайда М.Я.Вачуговның күн з-ды (1858), Минзәлә өязенең Ширәмәт авылында пр-тиеләр һ.б. ачыла. Алар пар һәм нефть двигательләре, локомобильләр, махсус машиналар һәм механик җиһазлар б-н коралландырыла. Җитештерүдә элеккечә үк яртылаш кул хезмәте файдаланыла, тире иләү вак чаннарда традицион үсемлек материаллары (кайры, кыяклылардан ясалган махсус кесәл), көл кулланып башкарыла. Эшкәртү процессы 100–180 тәүлек дәвам итә, эшчеләрнең сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирәгә зыян китерә. 1890 еллар уртасына Казан күн з-дларының 40% тан артыграк өлеше сәнәгый борылыш кичерә. Алафузовларның пр-тиеләре техник яктан иң алдынгылардан санала, аларда ел саен 130 мең данәгә кадәр чи тире эшкәртелә; тире иләүнең ул заман өчен иң алдынгы механик ысулы кулланыла, чит илләрдән осталар һәм белгечләр чакыртыла, күп кенә җиһазлар кайтартыла. 1890 елларда пр-тиеләргә электр кертелә, электр двигательләре, күнне өлешләргә кисүче яңа конструкцияле машиналар урнаштырыла.

1888 елда Казан губернасында 69 күн ф-касы һәм з-ды була, аларда 440 кеше эшли. 1917 дә барлыгы 4 мең эшчене берләштергән 33 пр-тие исәпләнә; ел саен 2 млн. данә эре терлек һәм 4 млн. данә сарык тиресе эшкәртелә, 2 млн. сумнан артык бәяләнгән күләмдә продукция чыгарыла, бу Россиядә күн җитештерүнең якынча алтыдан бер өлешен тәшкил итә.

Окт. рев-циясеннән соң тармак пр-тиеләре национализацияләнә һәм алар җирлегендә Казанның 1 нче (к. «*Сафьян*»), 2 нче, 3 нче, 4 нче һәм 5 нче күн з-длары, «Кызыл күнче» ф-касы һ.б. оештырыла. 1920 дә, квалификацияле кадрларга ихтыяҗ арту сәбәпле, хромлы һәм үсемлек материаллары б-н иләү буенча техник-технологлар әзерләү өчен, Казан күн техникумы ачыла. Нэп чорында заводлар Таткожтрестка берләштерелә һәм алар, башлыча, Кызыл Армия ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә эшли. 16 пр-тие аерым затларга тапшырыла. Мәсәлән, Казан күн эшкәртү ширкәте тарафыннан арендаланган 5 нче дәүләт күн з-ды Казан күн АҖгә әверелә, Ширәмәт күн з-дларын «Братство» һөнәрчеләр кооперативы арендалый. 1922–26 да республикада эре тиреләрдән күн эшләү — елга 149 меңнән 177 мең данәгә, уртача зурлыктагы күн җитештерү 77 меңнән 111 мең данәгә кадәр арта. Җирле терлекчелекнең үсеш алуы, төбәкнең уңайлы сәүдә-геогр. урын биләве нәтиҗәсендә 1920 еллар ахырына кадәр К.җ. Татар сәнәгатенең иң эре тармакларыннан санала.

Индустрияләштерү башлану б-н хосусый заводлар дәүләт милкенә күчә, пр-тиеләр эреләндерелә һәм модернизацияләнә. 1 нче бишьеллыкта (1929–32) Казанда күнне беренчел эшкәртү, хромлау, олтан эшләү заводлары файдалануга тапшырыла; «*Спартак*» күн аяк киемнәре, В.И.Ленин исем. күн комб-тлары реконструкцияләнә; «Кызыл күнче» ф-касында күнне майдан арындыручы яңа җиһазлар урнаштырыла. 2 нче бишьеллыкта (1933–37) күн суррогаты (к. *Казан ясалма күн заводы*) һәм күн галантерея (к. *Күн галантерея фирмасы*) з-длары сафка баса. Җитештерү технологиясе камилләшә. Тире иләүдә һәм күн эшкәртүдә һәр җирдә дә хром һәм төрле минераль экстрактлар кулланыла башлый; технол. процесс кыскара һәм 20–30 көнгә кала. 1926–36 да республикада күн эшләп чыгару 4,4 тапкыр арта. Бөек Ватан сугышы елларында тармак фронт һәм оборона сәнәгате пр-тиеләре өчен продукция җитештерүгә күчерелә. 1950–80 елларда пр-тиеләр заманча техника б-н коралландырыла, технология камилләштерелә, җитештерүне оештыру яхшыртыла. 1980 еллар ахырына кадәр К.җ.дә бары тик җирле чимал гына кулланыла һәм әлеге тармак чималны беренчел эшкәртү, төрле сортлы күннәр эшләүдән башлап, ахыргы продукция (күн галантерея, дирбия-ияр әйберләре) чыгаруга кадәрге тулы технол. чылбырны үз эченә ала, ш.у. республиканың аяк киемнәре җитештерүче пр-тиеләрен чимал б-н тәэмин итә. Йомшак күннең якынча 50%ы һәм хромлы күннең 30%ы илнең башка төбәкләренә җибәрелә. Даими рәвештә продукция эшләп чыгару, аның сыйфатлы һәм күп хезмәт таләп итүче төрләренең чагыштырмача өлеше үсә. 1940–90 елларда каты күн товарлар җитештерү — 50 дән 56, йомшак күн — 28,3 тән 55,6, хром күн товарлар — 70,4 тән 133 млн. *дм²* га, күн галантерея эшләнмәләре җитештерү 8,5 тән 33,2 млн. сумга кадәр арта. 1990 елларда икътисади кризис, чит илләрдән арзан күн товарлар керү нәтиҗәсендә продукция эшләп чыгаруның күләме сизелерлек дәрәҗәдә, эшләүчеләрнең саны 3 тапкыр кими. Тармакта дәүләти булмаган милектәге пр-тиеләр барлыкка килә, Казанда, Чаллы, Чистай шәһәрләрендә яңа кечкенә фирмалар ачыла. 1990 еллар ахырында – 2000 елларда күп кенә пр-тиеләрдә технол. җиһазлар алыштырыла. Хәзерге вакытта күн эшләү, ясалма күн җитештерү һәм алардан товарлар эшләп чыгару б-н «Сафьян» АҖ, Казан ясалма күн з-ды, Күн галантерея фирмасы шөгыльләнә. Ел саен (2010) каты күн товарлар — 0,3 млн. *дм²*, хромлы күн товарлар — 29,7 млн. *дм²*; күн галантерея эшләнмәләр 100 млн.га якын сумлык күләмдә җитештерелә. Татарстанның К.җ. тармагы эшләп чыгарган әйберләр арасында камытлар, йөгәннәр, ыңгырчак баулары, иярләр, юл йөрү һәм спорт сумкалары, рюкзаклар, мылтык тышлыклары, патронташлар һ.б. бар. Күн технологиясе, күн эшләнмәләр технологиясе һәм аларны конструкцияләү буенча югары квалификацияле белгечләр Казан җиңел сәнәгать техникумында һәм Казан технол. ун-тында әзерләнә. Ш.у. к. *Аяк киеме җитештерү сәнәгате.*

*Әд.:* Труфус М.А. Кожевенная промышленность Казанского края. К., 1928; Бражников Н.Г. Промышленность Татарии, рождённая Октябрём. К., 1969; Рабочий класс Татарии. К., 1981; История Казани: В 2 кн. К., 1988–91; Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

*С.Г.Белов, К.Ф.Фәсхетдинов.*

**КҮН ЭШЛӘНМӘЛӘ́Р МАНУФАКТУ́РАЛАРЫ**, җиңел сәнәгать предприятиеләре. Казан губернасында 18 йөз башыннан мәгълүм. К.э.м.ның күбесе Казанда урнаша (барлыгы 16). 18 йөзнең 1 нче яртысында 40 тан артык шәхси пр-тие була (сәүдәгәрләр Г.Попков, И.А.Михляев, Аникиев, Чернов, Н.Ростовцев, С.Каменев, И.Кожевников, П.Шапшинский, А.Муравьёв, мещан И.Чечулин һ.б.); сәүдәгәр И.Галиевнең Казандагы күн мануфактурасы иң эреләрдән санала. Һәр пр-тие елга 50 мең тире эшкәртә, алар эчке һәм тышкы базарларда сатыла. 1777–78 елларда Казанда 39 күн эшкәртү пр-тиесе була, күбесенең хуҗалары — татарлар (1890 да — 20 пр-тие), анда ирекле ялланган татарлар эшли. 19 йөздә андый пр-тиеләрне фабрика-заводлар алмаштыра. Эре завод һәм фабрикалардан В.Ф.Булыгин, Алафузовлар, Апанаевлар пр-тиеләре киң таныла.

*Әд.:* Мещерский А.А., Модзалевский Н.Н. Свод материалов по кустарной промышленности в России. СПб., 1874; История Казани. К., 1988. Кн. 1.

**КҮН ЭШЛӘҮ́ ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ́**, тирене гади ысуллар б-н эшкәртү. Казан төбәгендә беренче тире эшкәртү һөнәрчелеге Идел буе Болгар дәүләтендә барлыкка килә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы дәверендә үсеш ала (к. *Сафьян, Юфть*). 1565–68 елларда Казанда 532 һөнәрченең 21 е күн остасы була, 1616 да күн эшкәртү осталары һөнәрчеләр арасында сан ягыннан 3 нче урында тора — 111 кеше. Казан губернасында К.э.һ. 18–19 йөзләрдә киң тарала. Казан, Лаеш, Зөя, Спас, Тәтеш, Царёвококшайск һәм Чистай өязләрендә 19 йөз ахырында 500 гә якын күн эшкәртү остасы исәпләнә, шуларның 481 е татарлар була. Кәсеп итү гаиләләрдә алып барыла, кайвакыт яллап эшләтү очраклары да күзәтелә. Төп җитештерелгән әйбер — йомшак (юфть, бозау тиресе күне, итек өчен материал) һәм каты (табан һәм чи каеш) күн. Күп кенә авылларда чи күн җитештерелә, һәм бу һөнәр ат дирбияләре эшләү б-н бәйләнгән була. Ат дирбияләре җитештерү — җиңелрәк (останың күн чылату һәм изү җиһазы гына була), К.э.һ. катлаулы һәм күп чыгымнар таләп итүче эш санала: остаханә аерым корылма, күбесенчә сарай салына, анда су җылыту мичкәсе, буяу (сандал) кайнату казаны, шунда ук күн йомшарту һәм изү чаннары, эрерәк пр-тиеләрдә кайры ваклау тегермәннәре урнаша. Чи күн әзерләгәндә тирене чылаталар, йонын кыркалар, киптерәләр, изеп йомшарталар, хайван мае сөртәләр һәм яңадан изәләр. Әзер күн каеш һәм ат дирбияләре ясау өчен тотыла. Тирене эшкәртү тагын да күбрәк вакыт таләп итә. Аны 3–5 көн чылаталар, ит һәм май калдыкларыннан чистарталар, берничә көнгә известь һәм мич көле катнашмасы тутырылган чанга салалар (100 тирегә 15 пот известь һәм 5–6 пот көл исәбеннән), 2–3 атна буе йомшарталар. Тиреләрнең йонын кыркалар, калыплар тиренең йомшак ярысын кисәләр, еш кына, яхшы йомшарсын өчен, икенче тапкыр көлгә күмәләр. Шуннан соң көлдән чистарту өчен яңадан чылата-

лар, 2–3 көнгә «икмәккә» — арыш яисә арпа онынннан әзерләнгән тозлы кесәлгә батыралар (бер тирегә 2 кадак он исәбеннән). Чималны чайкыйлар һәм кайрылыйлар: күнне таякларга элеп тал куагы кайрысы чылатылган эретмәгә салалар. Күпмедер вакыт үтү б-н кайры вагы сибәләр, яңа эретмә өстиләр, 1–1,5 ай тирәсе эретмәне алмаштырып торалар. Бу күннән аяк киеме табаны ясала. Юфть җитештерү өчен тирене суда юалар, квас б-н чылаталар (100 тирегә 5 кадак исәбеннән), киптерәләр һәм буйыйлар. Вак итеп изелгән кызыл сандалны казанда кайнатып буяу ясыйлар, шуны кайнап торган килеш күнгә сибәләр һәм киптерәләр. Әзер күннең читләрен тигез итеп кисәләр, йоннардан чистарталар, сумала б-н буйыйлар һ.б. Урал арты (Оренбург губ. Троицк өязенең Түбән Әмин һәм Яуш авыллары) татарларында кымыз йөртү өчен ат тиресеннән турсык ясау һөнәре таралган була. Тирене йоннан чистарталар һәм су үткәрмәсен өчен җир казып, агачтан-кирпечтән ясалган кое-мичләрдә тоталар. Шуннан 1–10 чиләк сыешлы турсыклар тегәләр. Һөнәрчеләр әзерләгән тиренең төп өлеше аяк киеме ясауга китә. Күн сәнәгате алга китү сәбәпле, К.э.һ. акрынлап сүрелә, әмма Чүпрәле, Буа р-ннарында 1960 елларга кадәр саклана. 1990 еллар башында ТРның аерым р-ннарында К.э.һ. үсеш ала. Ш.у. к. *Читек*.

*Әд.:* Стронский К.Р. Кожевенное производство в Вятской и Казанской губерниях // Отчёты и исследования по кустарной промышленности России. СПб., 1894. Т. 5; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1995; шул ук. Промыслы и ремёсла татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1998.

**КҮННӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Югары Кандыз елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,1 *км*, бассейнының мәйданы 40,5 *км*². Баулы р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Салих авылында, тамагы — Шалты авылыннан 1,5 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 245 *м*, тамагыныкы — 124 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. К.нең 0,3 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 94 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. К. елгасының сулъяк сөзәклегендә *Салих тавы* табигать истәлеге урнашкан.

**КҮНТӘ́Ч** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 36 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 93 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек, умартачылык, олаучылык, тимерчелек һәм киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.тә земство мәктәбе (1887 дә ачыла), 5 җил тегермәне, 2 йон тетү йорты, тимерчелек, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете, сырахәнә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2556,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 157 ир-ат; 1884 тә — 1172, 1859 да — 842, 1897 дә — 1355, 1908 дә — 1378, 1920 дә — 1403, 1926 да — 1405, 1949 да — 728, 1958 дә — 827, 1970 тә — 612, 1979 да — 392, 1989 да — 178, 2002 дә — 129 кеше.

**КҮНЧЕЛӘ́Р БИСТӘСЕ́**, Мәскәүдә 14 йөздә нигезләнгән татар торулыгы. Хәзерге Кожевнический урамы һәм Кожевнический тыкрыгы тирәсендә урнашкан. Кайбер мәгълүматларга караганда, бистәне оештыручылар күрше Татар бистәсе татарлары була. Бистә халкы күн эшкәртү б-н шөгыльләнә. Соңрак аларның урынын рус һөнәрчеләре ала.

*Әд.:* Сытин П.В. Из истории Московских улиц. М., 1958.

**КҮҢГӘ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* төньяктарак, Шашы елгасы буенда. 2010 елда 281 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2108 дис. (Шашы Пүчинкәсе авылының имана җире б-н бергә) тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 724, 1897 дә — 950, 1908 дә — 865, 1920 дә — 843, 1926 да — 859, 1938 дә — 928, 1949 да — 458, 1958 дә — 394, 1970 тә — 388, 1979 да — 346, 1989 да — 271, 2002 дә — 278 кеше.

**КҮПЕРБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 448 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан Күтәрнәс исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урман материаллары әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та мәчет, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1090 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 554, 1897 дә — 651, 1908 дә — 894, 1920 дә — 821, 1926 да — 1149, 1938 дә — 1024, 1949 да — 809, 1958 дә — 687, 1970 тә — 602, 1979 да — 527, 1989 да — 435, 2002 дә — 418 кеше.

**КҮПЕРЛӘ́Р**, нинди дә булса тоткарлык аша юл салынган корылмалар.

К.не борынгы заманнарда ук төзегәннәр. Русьта йөзмә яки су өстенә үк салынган К. — 10 йөздә, таш К. 16 йөздә төзелә башлыйлар. «Элгәреге заманнар хикәяте» («Повесть временных лет») елъязмасында Киевта Днепр аша салынган йөзмә күпер хакында искә алына (1115). К. (башлыча таш К.) төзү Әрмәнстанда һәм Грузиядә киң тарала. 16–17 йөзләрдә коры җир һәм су юллары үсеш кичерә; судновлар узу өчен зур торыклы К. булуы таләп ителә. Үзлегеннән өйрәнгән механик И.П.Кулибинның Нева елгасы аша 298 *м* лы торыклы а́ркалы агач күпер проекты чорның күренекле казанышы санала. 18 йөз ахырыннан К. төзүдә металл кулланыла башлый. Бөекбританиядә 1 нче металл (чуен) күпер Северн елгасы аша 1779 елда, Россиядә С.-Петербургта 1850 дә төзелә, Россиядә беренче асылма күпер С.-Петербургта (1824–27), зур чылбырлы күпер Киевта корыла.

Казанда зур а́рка рәвешендә беренче таш күпер (башта Бөкре күпер дип атала) 1907 елда Болак аша салына, ул озак вакытлар дәвамында бердәнбер таш күпер булып кала. 19 йөз уртасыннан шәһәрне бистәләр б-н тоташтыру өчен дамбалар корыла башлый. 1842–49 да Иске Мәскәү дамбасы төзелә, соңрак ул Адмиралтейство (хәзер — Киров) дамбасы дип атала. Бу дамба шәһәрне турыдан Адмиралтейство, җыелма күпер аша Дары бистәләре б-н тоташтыра. 1850–60 елларда Кизик (соңрак Кремль, хәзер Ленин) дамбасы корыла. Бер үк вакытта Казансу аша агач күпер салына. Соңрак Кәҗә бистәсе һәм Гривка аша Гривка дамбасы төзелә, ул Кизик дамбасы аша Дары бистәсен шәһәр б-н тоташтыра. 1903 тә Казан–Оренбург трактында (хәзерге Яңа Чишмә р-ны терр-ясендә) известьташтан өч а́рка торыклы күпер салына. 20 йөз башыннан К. төзелешендә төп материалларның берсе сыйфатында тимер-бетон куллана башлыйлар (а́ркалы, балкалы К.). 1913 тә Свияжск станциясе янында Идел аша тимер юл күпере ачыла, ул Романов исеме б-н атала (инженер-арх. Н.А.Белелюбский проекты буенча). 1940–50 елларда Болакның элеккеге агач күпере урынына Ү.Г.Алпаров, М.К.Игъламов, Е.Ю.Брудный һ.б. проекты буенча тимер-бетон күпер төзелә. Куйбышев ГЭСы төзелүгә бәйле рәвештә Ленин

һәм Киров транспорт дамбалары реконструкцияләнә, 1956–57 дә Ленин һәм Киров тимер-бетон К., 1976 да Казансу аша 3 нче транспорт дамбасы — Ямашев күпере, соңрак Академия күпере һ.б. файдалануга тапшырыла. 1989 һәм 1997 дә Югары Ослан р-нында Идел һәм Зөя аркылы автомобиль күпере гамәлгә кертелә. 2002 дә Кама елгасы аша салынган, ТРдагы иң озын күпер (1 нче чираты) файдалануга тапшырыла. Аның гомуми озынлыгы — 14 *км*, ш.и. К., эстакадалар һәм юл үткәргечләрнең озынлыгы 2,7 *км* тәшкил итә. Каманың төп үзәне аша тартмасыман киселешле, кисемтесез металл торыклардан җыелган, өске өлешендә юл җәелгән күпер сузыла. Машиналар юлының киңлеге 23 *м*, ш.и. 1 нче чиратның ике юллы хәрәкәткә исәпләнгән, үлчәме 11,5 *м*, тротуар киңлеге 0,75 *м*. 2005 елда — Казансу аша салынган тимер-бетон «Миллениум» күперенең 1 нче, 2007 дә 2 нче чираты файдалануга тапшырыла (озынлыгы 1524 *м*). Күпернең пилоны «М» хәрефе рәвешендә эшләнгән, күпер үзе вантлы корылмалар төренә карый (К. төзү тарихында беренче шундый ук күпер 1963 тә Киевта төзелә). 2006 да ТР да гомуми озынлыклары 48479,04 *м* тәшкил иткән 1060 күпер (ш.и. тимер-бетон К. — 17247,04 *м*, металл К. — 30339,4, агач К. — 892,6 *м*; башлыча, балкалы уртача зурлыктагы һәм кечкенә кисемтеле К.) файдалануда була. Казанда 100 гә якын күпер, ш.и. Болак (Татар бистәсе, Печән базары, Романов, Варлаам, Лебедев, Гостиный двор К.е), Казансу (Адмиралтейство күпере, йөзмә күпер) аша салынган; тимер юл (Авиатөзелеш, Архангел, Кабан, Компрессор, Яңа Татар, Оренбург, Вокзал яны, Романов, Савин, Урак-Чүкеч, Троица, Техник, Тукай, Юдино), җәяүле-транспорт (Алафузов, Арбузов, Хастаханә, Гвардия, Бөкре, Гривка, Достоевский, Желатин, Займище, Ибраһимов, Крестовниковлар, Морквашы, Себер тракты, Юдино), җәяүлеләр (Депо, Маяковский, Карбышев, Красная Горка, Туристлар) К.е файдаланыла. Хәзер К. тулысынча заводта җитештерелгән модульле конструкцияләрдән индустриаль төзү алымнары кулланып корылалар, статик һәм динамик көйләнешләргә сынаулар узалар. Татарстанда К. төзү б-н махсус оешмалар («Волгомост», «Татавтодор», «Гидромантаж» һ.б.) шөгыльләнә. Ш.у.к. *Болак ярлары.*

*Әд.:* Е в г р а ф о в Е.К., Б о г д а н о в Н.Н. Проектирование мостов. М., 1966; Индивидуальное строительство мостов. К., 1978; Ш а п о в а л И.П. Проектирование мостов и путепроводов на автомобильных дорогах. К., 1978; К а з а к о в В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998; Символ тысячелетия: Мост через Казанку // Казань. 2005. № 7/8.

*А.И.Брехман, Г.П.Иванов, Г.Я.Мәүлетова.*


**КҮПЕРЛЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Чаллы — Сарман автомобиль юлы буенда. 2010 елда 186 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1719–22 еллардан мәгълүм. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, мәктәп, су һәм җил тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 909 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 475, 1897 дә — 634, 1913 тә — 762, 1920 дә — 746, 1926 да — 486, 1938 дә — 470, 1949 да — 316, 1958 дә — 278, 1970 тә — 329, 1979 да — 264, 1989 да — 169, 2002 дә — 186 кеше.


**КҮПЕРТМӘ́ ҖЕПКЫ́Р**, зәргәрчелек сәнгате төре; татар зәргәрләренең иҗатында күләмле җепкыр алымы. Бизәк тыгыз бөтеркәләрдән күләмле конус рәвешендә чорналган нечкә югары сыйфатлы алтын яки көмеш җыпкыр чыбыклардан тора. Чыбык, гадәттә, чорналган яки бөтерелгән ике җептән тора, бөтеркә күпертмәләре кискечләр ярдәмендә эшләнә һәм нечкә сырлар б-н каплана. К.ж.ның тәбәнәклеге яки биеклеге конусларның зурлыгыннан тора, ә беркетелгән һәм челтәрле булуы металл астар кулланылуы б-н аерыла.

К.ж. башка халыкларның зәргәрчелек сәнгатендә киң таралу алмаган үзенчәлекле һәм кабатланмас эшләү алымы. Казанның Яңа һәм Иске Татар бистәләрендәге, Арча һәм Саба р-ннарының аерым авылларындагы оста зәргәрләр тарафыннан башкарыла. Эшләү серләре нык саклана һәм нәселдән нәселгә тапшырылып килә. Гаять нечкә хезмәт төре буларак, К.ж. сәнгате б-н хатын-кызлар шөгыльләнә. Сакланып калган эшләнмәләр 18 — 20 йөзләргә карый. Кораллар палатасы тупланмасында (Мәскәү) 15–16 йөзләрнең гүзәл үрнәге сыйфатындагы астарлы К.ж. б-н бизәлгән Коръән тартмачыгы саклана. К.ж. сәнгатенең зур үсеш алган вакыты 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөзнең 1 нче яртысына туры килә. Әлеге чор эшләнмәләре җепкыр бизәгенең тыгызлыгы, эре бөтеркәләр арасында тигез урнашуы, коелмаларның чисталыгы һәм челтәрләрнең матурлыгы б-н аерылып тора. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан җепкыр бизәкләр һәм чыгынты конуслар эреләнә. Өслекләре җепкыр б-н капланган эшләнмәләрнең челтәрләре зурая, бизәкләре татар осталары иҗатына йогынты ясаган модерн стилендәге әсәрләр кебек чуарлана бара. 20 йөздә К.ж. алымы б-н эшләгән аерым зәргәрләр: Арча р-нының Кызыл Яр авылыннан М.Җәмилев, Мөндештән К.Шәмсетдинов, Саба р-нының Йосыф-Алан авылыннан Җ.Ганиев һ.б. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан В.Ковалевский, С.Шәкүрова, И.Фазылҗанова, Е.Бакакин кебек проф. рәссам-зәргәрләр хәзерге за-

**Күперләр.** 1. Яшел Үзән шәһәре янындагы Идел елгасы аша салынган тимер юл (Романов) күпере; Автомобиль күперләре: 2. Минзәлә шәһәре тирәсендәге Минзәлә елгасы аша салынган күпер (1970 еллар ахырына кадәр файдаланыла); 3. Казанда Казансу елгасы аша салынган күпер (Ленин күпере); 4. Казанда Казансу елгасы аша салынган күпер («Миллениум»); 5. Саескан Тавы авылы тирәсендәге Кама елгасы аша салынган күпер.











**Күпертмә җепкыр.** 1–2. Ает. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. 19 йөзнең 2 нче яртысы; 3. Ает. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. 19 йөзнең 1 нче яртысы; 4. Пута. Фрагмент. Көмеш, алтын йөгертү, фирәзә. 19 йөзнең 1 нче яртысы; 5. Хәситә. Фрагмент. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. 19 йөзнең 1 нче яртысы. ТР Милли музее.

ман татар бизәкләренең стильләшкән формаларын яңартуга ирешәләр.


*Әд.:* Вәлиев Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; Шулук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1974; Вәлиева-Сөләйманова Г.Ф. Татарская филигрань: в контексте генезиса и развития ювелирного искусства // Из истории татарского народного искусства. К., 1995.

*Г.В.Вәлиева-Сөләйманова.*

**КҮПЛӘ́П АЛУ́-САТУ́ СӘҮДӘСЕ́**, к. *Сәүдә.*

**КҮ́ПМӘГЪНӘЛЕЛЕК**, к. *Полисемия.*

**КҮ́ПТАМЫР** (Spirodela), нәрәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 4 төре билгеле, ике ярымшарның да уртача һәм тропик поясларында таралган. РФ терр-ясендә бер төре — гади К. (S. polyrhiza) бар. Татарстан терр-ясенең барлык районнарында агымсыз яки тын агымлы сулыкларда очрый. Сулык өстендә йөзүче һәм күп кенә вак тамырлар бәйләменнән (исеме шуннан) торучы үзгәргән түгәрәк сабак-яфракчыклы үсемлек. Яфракчыкларының озынлыгы 3–10 *мм*, киңлеге 1,2–8 *мм*. Яфрак пластинкасының өске ягы куе яшел төстә, дугасыман сеңерчәләре яхшы беленеп тора, суга күмелеп торучы аскы ягы шәмәхә яки җете кызыл. Чәчәкләре бер җенесле, чәчәк тирәлеге юк, өч чәчәктән торучы гадиләшкән чәкәнгә җыйналган. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре сирәк өлгерә. Споралардан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Сулыкларны углекислоталардан чистарта һәм аларны кислород б-н туендыра. Халык медицинасында тамырлары, яфраклары һәм чәчәкләре тән кызышканда, тир чыгару һәм бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла.



Гади күптамыр.

**КҮ́ПТИРАЖЛЫ ГАЗЕ́ТАЛАР**, министрлыклар, иҗтимагый оешмалар, пр-тиеләр, уку йортлары тарафыннан нәшер ителүче һәм, башлыча, аларның эшчәнлеген яктыртучы вакытлы матбугат. 1920 елларда стена газеталарын тиражлы бастыру нигезендә (исеме дә шуннан килеп чыккан) барлыкка киләләр. ТАССРда иң беренче К.г. — «Красный железнодорожник» (Мәскәү–Казан тимер юлының Кәнчыгыш бүлеге, 1920), «Вахитовец» (Казан май комбинаты, 1923), «Дизель» (электротрест, 1923), «Кооперативный листок» (Татсоюзның Минзәлә конторасы, 1923), «Вопросы авиации» (ТАССР Хәрби һава флоты дуслары җәмгыяте, 1923), «Совработник» (ТАССР сов. органнары хезмәткәрләре профсоюзы, 1923), «Казанский печатник» (Полиграфия производствосы союзы һәм басмаханә завкомы, 1924) һ.б. 1920 елларда татар телендә дә К.г. басыла башлый: «Байтарлык сәхифәсе», (Татар Үзәк вет. идарәсе, 1923), «Кызыл печатник», (Полиграфия производствосы союзы һәм басмаханә завкомы, 1924), «Безнең һава флоты» (ТАССР Хәрби һава флоты дуслары җәмгыяте, 1924), «Ялчы» (Татарстан Авыл һәм урман хуҗалыгы хезмәткәрләре профсоюзы Советы, 1927) һ.б. 1920 дә газеталар, акча һәм кадрлар җитмәгәнлектән, озак вакыт һәм даими басылмыйлар, кайберләре бер генә тапкыр — юбилейларга һәм сәяси кампанияләргә багышлап кына чыгарылалар.

ТАССРда К.г.ның киң тармакланган челтәре индустрияләштерү чорында барлыкка килә, аның нигезен фабрика-завод газеталары тәшкил итә. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты үзенең 1929 ел 11 октябрь карарында К.г. редакцияләренә татар телендәге мәкаләләргә зур урын бирергә һәм газетаның татарча өлешен *яңалифкә* күчерүне тизләтергә тәкъдим итә. «Дубитель» (Кун тресты), «Текстильщик» (Казан җитен комб-ты), «Красный текстильщик» (Кукмара киез аяк киемнәре ф-сы), «Бондюжский рабочий» (Бондюг химия з-ды) кебек газеталарның яртысы диярлек татар телендә басыла. 1931 дә ВКП(б) өлкә ком-тының «Завод-фабрика күптиражлы газеталары турында» дип аталган карары үзләренең газеталарында татар телендә полосалар чыгарган пр-тиеләргә аерым татар газеталарын «чыгаруны җайга салырга» тәкъдим итә. 1931 дә — «Мехчы» (Казан мех комб-ты), «Полиграфчы» (Александров исем. Казан басмаханәсе), «Советлар канаты» (Казан машиналар төзү з-ды), «Спартакчы» («Спартак» аяк киемнәре ф-касы), «Тегүче» (ТАССР ҮБКның Тегүчеләр берлеге), «Финплан өчен» (Финанс хезмәткәрләре берлеге) һ.б.; 1932 дән «Вахитовчы» (Казан май комб-ты), «Идел ударнигы» (Казан пристане), «Яшь печатник» (Казан полиграфия сәнәгате з-ды), «Удар темп өчен» (Казан киез итек басу комб-ты) һ.б. газеталар басыла башлый. 1920–30 елларда ТАССР чикләреннән тышта татар эшчеләре эшләгән эре пр-тиеләрнең татар телендә 50 дән артык К.г.ы да нәшер ителә, ш.и. Мәскәүдә — «Метрострой коммунисты», «Можрез ударнигы», «Электросталь ударнигы», Ленинградта — «Ленинград Кызыл портовигы».

К.г.га зур әһәмият биреп, ВКП(б) ҮКның «Завод-фабрика газеталары турында»гы 1932 ел 19 август карарында партия органнарына К.г. б-н җитәкчелек итүне көчәйтергә һәм ярдәм итәргә, ВКП(б) район ком-тлары карары б-н завод-фабрика газеталары мөхәррирләрен раслап куярга тәкъдим ителә. Татарстан өлкә ком-ты К.г.ның редколлегия составын яңадан карап чыгарга куша. Редакцияләрнең кадрлар составын яхшырту максатыннан, «Тревога» (Казан ГРЭСы), «Швея» (Тегү тресты), «Ударник» (Казан җитен комб-ты) һ.б. газеталарга «Кызыл Татарстан» г-тасы хезмәткәрләре һәм Татар коммунистлар ун-ты аспирантлары җибәрелә.

*Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү* чорында МТСларның һәм совхозларның сәяси бүлек газеталары нәшер ителә башлый. Югары уку йортларының К.г. арасында, иң беренче булып, Казан ун-тының («Путь пролетарского студенчества», 1924), соңрак — Казан пед. ин-тының («Педвуз», 1929), Татар коммунистлар ун-тының («За ленинизм», 1929), Казан мед. ин-тының («За медицинские кадры», 1931), Казан химия-технол. ин-тының («За кадры», 1934) газеталары басыла башлый. 1934 тә 120 дән артык К.г. нә-

шер ителә, ш.и. завод-фабрика газеталары — 43, транспорт оешмаларыныкы — 6, МТС-ларныкы — 49, совхозларныкы — 43, югары уку йортларыныкы — 3. 1937 елга МТСларның газеталары чыгудан туктый, совхоз һ.б. газеталарның саны сизелерлек кими. Газеталарның гомуми саны 60 ка кадәр кими (аларның бер тиражы уртача 66,5 мең данә). 1930 еллар ахырына ТАССРдан читтә татар телендәге К.г. чыгудан туктый.

К.г.ның күпчелеге, кагыйдә буларак, зур булмаган күләмдә чыга, ике сәхифәле генә була; Казан моторлар төзү берләшмәсе, Казан авиация з-ды, Кама автомобиль з-ды һ.б. шундый эре сәнәгать пр-тиеләре дүрт сәхифәле басмалар чыгаралар. 1980 еллар уртасында К.г. СССРда матбугатның иң зур таралышлы матбугат басмасына әвереләләр: 4 меңнән артык күптиражлы газета нәшер ителә. 1989да Татарстанда 61 К.г. басыла, 1999 да — 54. Совет чорыннан соң ТРда, РФнең башка өлкәләреннән аермалы буларак, К.г. саны кискен кыскармый. Базар икътисадының яңа структуралары — банклар, акционерлык җәмгыятьләре, иминиятләштерү компанияләре — тарафыннан чыгарылган һәм үз хезмәткәрләренә яки клиентларга юнәлдерелгән «корпоратив» газеталар үсеш ала. Традицион К.г. да, сәяси-идеологик вазифаларыннан баш тартып, үз юнәлешләрен үзгәртәләр.

Чыг.: Печать, радиовещание и телевидение Татарии. 1917–1980: Сб. док. и материалов. К., 1981.

*Р.А.Айнетдинов.*

**КҮ́ПЬЕЛЛЫК ЧҮП ҮЛӘННӘ́Р**, бер урында бер елдан артык (кагыйдә буларак, берничә ел) үсә, үзләренең яшәү циклында даими җимеш бирә торган үсемлекләр. Вегетатив рәвештә (мыекчалар, ботаклар, бөреләр, суганчалардан һ.б.), ш.у. генератив рәвештә (орлыктан) үрчиләр. Чүп үләннәр биол. төркемнәргә аерыла — үренте тамырлы, тамырчалы, үзәк тамырлы, чук тамырлы, бүлбеле, суганчалы, шуышма үләннәр.

Үренте тамырлы К.ч.ү. (кыр билчәне, иисә сары билчән, кыр каклавычы яисә алсу билчән, кыр эт эчәгесе, сөтлегән, кече кузгалак, гади җитен, шуышма ачыкый, сөтле текәнәк һ.б.) вегетатив рәвештә үрчиләр. Тамыр системасы бик көчле. Төп тамырлары туфракта 6–7 *м* га кадәр тирәнлеккә китә, күпчелек ян-яктагы тамырлары 3 яруста урнаша: 1 нче — 14–16 *см*, 2 нче — 50–60 *см*, 3 нче — 80–100 *см*. Төп тамырларында һәм ян-яктагы тамырларда 1 $м^2$да 500 дән 1500 гә кадәр бөре була, шулардан уңай шартларда яңа үләннәр үсеп чыга. К.ч.ү.нең тамырларында туклыклы матдәләр күп туплана, шуңа күрә алар бик яшәүчән һәм хәтта кечкенә кисәкләрдән дә яңа үсемлек бирергә сәләтле. Тамырларның механик рәвештә зарарлануы бөреләрнең күпләп үсешенә этәргеч бирә. К.ч.ү.нең бу төркеме тышкы шартларга бик тиз җайлаша, шуңа күрә алар барлык чәчүлекләрне чүплиләр.

Тамырчалы К.ч.ү. (шуышма сарут, кыр наратбашы, тармаклы тарлау һ.б.) җир асты сабаклары (тамырчалар) ярдәмендә үрчиләр, алар аерым тамыр капламыннан һәм үрчү өчен хезмәт итүче яфраклардан торалар, үсү зонасындагы бөреләрне каплыйлар. Тамырчаларда яңа үсемлекләр үсү өчен кирәкле булган туклыклы матдәләр туплана, бу тамырчалар 10–12 *см* тирәнлектә ята. Табигый шартларда үрчүгә караганда, тамырча механик зарарланганда бөреләр яхшырак үсеп чыга. К.ч.ү.нең иң күп таралганнары — шуышма сарут һәм кыр наратбашы (барлык культураларны чүплиләр). Бу төркемгә караган К.ч.ү. б-н көрәш чаралары бигрәк тә вегетатив үрчү органнарын бетерүгә юнәлтелгән.

Үзәк тамырлы К.ч.ү. (дарулы тузганак, көмешсыман тәпичә, кыргый кашкарый, соры-яшел кыр-кырый, ачы әрем, гади һиндыба һ.б.) орлыктан үрчиләр. Җимешләре — орлыкчалар, үсеп чыгу чоры озак, туфракта яшәү сәләтләре 2 елдан 7 елга кадәр саклана. 5–7 *см* тирәнлектән үсеп чыгалар, чәчүлекләрне, яшелчәләрне һәм культураларны чүплиләр, бакча һәм болыннарда очрыйлар. Туфракны системалы рәвештә эшкәртеп торганда, камыллы җирне йомшартканда, ш.у. тунга сөргәндә юкка чыгалар һәм яңадан юл кырыйларыннан, болыннардан үрчеп, тагын чәчүлекләрне чүплиләр. Алар гербицидлар б-н эшкәрткәндә генә тулысынча юкка чыгарга мөмкин.

Чук тамырлы К.ч.ү.нең (зур бака яфрагы, зәһәр казаяк һ.б.) көчле үскән өстәмә тамырчыклы кыска төп тамыры була, вегетатив үрчүләре чикләнгән (нигездә, орлыктан үрчиләр). Бүлбеле һәм суганчалы К.ч.ү. (сазлык нәдербашы, бүлбеле чина, йомры камыш, сары каз суганы, кош сөтчәсе һ.б.), башлыча, сазлыклы җирләрне чүплиләр.

Шуышма К.ч.ү. (каз тәпичәсе, шуышма казаяк һ.б.) болыннарда, тиешенчә эшкәртелмәгән бакчаларда очрый. К.ч.ү. б-н көрәшү максатында һәрбер хуҗалык өчен, туфрак төрен (тибын) һәм чүпләнү дәрәҗәсен исәпкә алып, профилактик, оештыру, агротехник һәм химик чаралар системасы эшләнә. Ш.у. к. *Үсемлекләрне саклау, Чүп үләннәр.*

*Әд.:* Хабибрахманов Х.Х. Современные меры борьбы с сорными растениями. К., 1979; Фирсюков А.В. Справочник по борьбе с сорняками. М., 1984.

*И.Н.Афанасьев.*

**«КҮР УГЫЛЫ́»**, гомумтөрки героик *дастанның* Себер-татар версиясе. «К.у.»ның версияләре күп халыкларда бар (әзәрб. «Кёр-оглы», төркм. «Гур-углы», таҗик. «Гургули» һ.б.). Төп герой — «вөҗданлы юлбасар». Аны иҗтимагый бунтка этәрүче башлангыч мотив, гади халыкны яклап, изүчеләргә каршы көрәш башлау характерын ала (Истанбул ханы Бүлбәк аркасында сукыр калган этисе Күр батыр өчен үч алу). Дастанда күп кенә кискен драматик үзгәрешләргә (мәс., геройның зинданга эләгүе һәм патша кызы Никар тарафыннан азат ителүе) дучар ителгән баһадирны кодалау, баһадир аты — Караатны эзләү мотивлары да бар. Хикәяләү геройның җиңүе б-н тәмамлана. Сюжетның башлангыч нигезе төрекмән-әзәрб. мохитендә барлыкка килгән дип фаразлана, соңрак ул башка Урта Азия халыклары арасында киң таралыш таба, алардан Тобол татарларына барып җитә. Яңа җирлектә сюжет җитди үзгәрешләр кичерә: күп кенә әкияти-мифологик мотивлар, геройлар һәм вакыйгаларны тасвирлау өлешләре төшеп кала, иҗтимагый мотивлар шактый көчәя (деспотизм б-н көрәш). Әзәрбайҗан һәм Урта Азия версияләренең зур күпчелеге яхшылап өйрәнелә һәм басылып чыга. Себер-татар версиясе беренче тапкыр 1860 еллар ахырында язып алына һәм В.В.Радлов тарафыннан нәшер ителә.

*Әд.:* Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4; Каррыев Б.А. Эпические сказания о Кёр-оглы у тюркоязычных народов. М., 1968; Урманчеев Ф.И. Героический эпос татарского народа. К., 1984.

*Ф.И.Урманчеев.*

**КҮРӘ́З** (Әтәс) авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак, Чөмән елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1710–11 еллардан мәгълүм. 1860 ларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу б-н шөгыльләнә; Минзәлә өязендә Уфа губернасы сәүдә итә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, К.дә мәчет була. Авыл җәмәгатенең имана җире 1060,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Вятка губернасының Алабуга өязе Салауш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 356, 1870 тә — 349, 1887 дә — 490, 1920 дә — 467, 1926 да — 346, 1938 дә — 407, 1949 да — 295, 1958 дә — 222, 1970 тә — 201, 1979 да — 135, 1989 да — 83, 2002 дә — 75 кеше.

**КҮРӘ́Н** (Carex), күрәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 1,5 меңгә якын төре (башка мәгълүматлар буенча 2,5 меңгә кадәр) билгеле, күбрәк Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында очрый. Татарстан терр-ясендә 57 төре бар. Очлы К. (C. acuta), кәсле К. (C. caespitosa), төкле К. (C. pilosa) һ.б. киң таралган. Дымлы һәм сазлыклы болыннарда, сулык ярлары, зирек урманнары буенда үсә. 10–150 *см* биеклектәге үсемлекләр, шуышма яки кыскарган тамырчалары көпшәк яисә тыгыз кәс, кайвакыт түмгәкләр ясый. Сабаклары өч кырлы, гади. Гадәттә, җиңсә, кыяк яфраклы, кырыйлары кытыршы очлы һәм тар телсыман. Чәчәкләре бер җенесле, чәчәк төркеменә җыелган күп чәчәкле башакларда. Чәчәк тирәлеге юк. Җимшәне элпә яки калын тышча — капчык (серкә капчыгы) б-н капланган. Җимеше — бер орлыклы чикләвекчек. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамырчаларыннан) үрчи. Очлы К., озынча К. (C. elongata), кара К. (C. nigra) һ.б. — көтүлек җир үсемлекләре.



Колхида К. (C. colchica), иртә К. (C. praecox) һ.б. — комлык ныгытучылар. Богемия К. (C. bohemica), чәчсыман К. (C. capillaris) — декоратив үсемлекләр. 18 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КҮРӘНЧӘЛӘ́Р** (Cyperaceae), бер өлешле үсемлекләр семьялыгы. 120 гә якын ыругны һәм 5,6 меңнән артык төрне үз эченә ала. Башлыча, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә 10 ыругтан 83 төре бар. Аеруча *күрән, камыш, мамыкбаш, җир миндале* һ.б. киң таралган. Күпьеллыклар, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр, озын һәм кыскарак тамырчалы. Сабаклары өч кырлы яки цилиндрсыман (камыш ыругы), эче паренхима тукымасынан тора, җиңелчә буыннарга бүленгән. Яфраклары чиратлашкан, өч рәтле, кыяк яки кыяк-ланцетсыман, күпчелеге сабак төбендә бөтерелгән. Яфрак җиңсәсе, гадәттә, йомык. Чәчәкләре вак, ике җенесле (җир миндале, камыш) яки аерым җенесле (күрән), каплавыч тәңкәчекләр куентыгында берәрләп утыралар. Җимешләре — өч кырлы, шарсыман яки җәлпәгрәк чикләвекчек. Терлек өчен азык, дару үләне, декоратив, комлыкларны ныгытучы үсемлек. Мамыкбаш һәм күрәннең кайбер төрләре торфлы туфрак хасил итә. К. үскән сазлык һәм су буйлары күп кенә кош һәм хайваннарның яшәү, саклану һәм туклану урыны булып тора. К.нең 30 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КҮРГӘЗМӘ́ МӘГЪЛҮМА́Т-КОММЕ́РЦИЯ БЕРЛӘШМӘСЕ́**, к. *Казан ярминкәсе.*

**КҮРГӘЗМӘЛӘ́Р ЗАЛЫ́**, ТР Рәссамнар берлегенең Казандагы бинасы. 1979 елда авторлар төркеме: арх. Г.А.Бакулин (җитәкче), Р.Х.Галиев, В.И.Мулюкин, инженер Г.Н.Дружкова (Г.Тукай исем. ТАССР Дәүләт бүләге, 1981) проекты буенча төзелә. Өч катлы, турыпочмаклы, баскычсыман чыгынтылы (төньяк-көнбатыш почмак) бина. Күргәзмә залларының түбәсе турыпочмаклы колонналарга терәлеп тора. Заллар үзара үзәк һәм ярдәмче баскычлар б-н тоташкан, төньяк-көнчыгыш өлешендәге 2, 3 нче катлар бердәм фәза б-н берләштерелгән, тар, озынча тәрәзәләр б-н яктыртылган. 3 нче каттагы залга төньяктан өстәмә тәрәзәләр куелган. Фасадтагы кирпечләр вертикаль рустовка ысулы б-н салынган. Бина 1970 еллар совет архит-расының рационалистик формаларында төзелгән. Аның каршына «Идел» скульптура композициясе куелган (чүкелгән бакыр, 1979, скульп. — Р.П.Харитонов). Бина 2009 да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеена бирелә.

**КҮСКЕ́М** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 29 *км* төньяктарак, Кугубор елгасы буенда. 2010 елда 49 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 549,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 18, 1763 тә — 26, 1795 тә — 42, 1811 дә — 33 ир-ат; 1859 да — 179, 1884 тә — 197, 1905 тә — 235, 1920 дә — 257, 1926 да — 240, 1949 да — 170, 1958 дә — 110, 1970 тә — 57, 1979 да — 45, 1989 да — 53, 2002 дә — 51 кеше.

**КҮТӘМӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Сөлчә елгасының (Олы Кәминкә, Чишмә елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,5 *км*, бассейнының мәйданы 83,4 *км*². Чирмешән р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Күтәмә авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы — Кармыш авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 178 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. К.нең 0,3 тән алып 5,3 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысын диярлек кар сулары тәшкил итә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 135 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,186 *м*³*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада су күләме 1 млн. *м*³ тирәсе булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КҮТӘМӘ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 25 *км* төньяктарак, Күтәмә елгасы буенда. 2010 елда 496 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 81%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богоявленский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә волость идарәсе урнаша; Богоявление чиркәве, земство мәктәбе (1870 тә ачыла), фельдшерлык пункты, 3 тегермән, ярма яргыч, 5 вак-төякләр һәм 1 казна шәраб кибете, 3 сыраханә була; дүшәмбе саен — базар, 8 сентябрьдә ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 403 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 313 ир-ат; 1859 да — 1559, 1897 дә — 2659, 1908 дә — 2911, 1920 дә — 2866, 1926 да — 1725, 1949 да — 1157, 1958 дә — 848, 1970 тә — 990, 1979 да — 829, 1989 да — 679, 2002 дә — 574 кеше.

**КҮТӘМӘЛЕ́** (Камышлы) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 17 *км* көньяктарак, Камышлы елгасы буенда. 2010 елда 372 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710–11 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә 2 мәчет, 5 мәктәп эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1565,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 73 ир-ат; 1870 тә — 397, 1897 дә — 973, 1913 тә — 1351, 1920 дә — 1320, 1926 да — 945, 1938 дә — 936, 1949 да — 917, 1958 дә — 737, 1970 тә — 612, 1979 да — 492, 1989 да — 335, 2002 дә — 359 кеше.

**КҮЧЕМСЕ́З МИЛЕ́К**, гражданлык хокукында физик һәм юридик затларның хосусый милкендә булган җир һ.б. табигать биләмәләре, җиргә карата башка мөлкәт хокуклары, ш.у. җиргә теркәлгән һәм аның б-н нык бәйләнгән башка төрле милек (биналар, корылмалар һ.б.). К.м. б-н алыш-бирешләргә махсус теркәлү таләп ителә. «К.м.» категориясе, башка дәүләтләр закончылыгында булган кебек, рев-циягә кадәрге рус хокукында да мәгълүм була, аңа мөһим мәгънә салына. «Күчемсез милек» термины Пётр I нең «Күчемле һәм күчемсез милекне мираслыкка алу (бирү) тәртибе турында»гы Фәрманында (1714) әйләнешкә кертелә. Рев-циягә кадәрге гражданлык законнары җыелмасында К.м. закон буенча танылган «җирләр һәм һәртөрле биләмәләр, йортлар, заводлар, фабрикалар, кибетләр, һәртөрле корылмалар ..., ш. у. тимер юллар ... һәм аның (җирнең) эчендәге металлар һәм башка казылма байлыклар», дип каралган. Окт. рев-циясеннән соң, хосусый милек төшенчәсе бетерелгәч, милекне күчемле һәм күчемсезгә бүлү гамәлдән чыга, һәм сов. хокук законнарында милек күчемле б-н күчемсезгә бүленми, чөнки төп К.м. — җир — бары тик дәүләт милкенә әверелә, җир кишәрлекләре б-н алыш-бирешләр тыела. РФ субъектларында, ш.и. ТРда икътисадта базар үзгәртеп корулары барышында, 20 йөз ахырында хосусый милек законнар б-н кабат торгызыла. РФнең гражданнар кодексы (1994 ел, 21 октябрь) гражданнар хокукы объектларын күчемле һәм күчемсез төрләргә бүлә. 130 нчы маддәдә билгеләнгәнчә, җир кишәрлекләре, казылма байлыклар кишәрлекләре, аерымланган су объектлары, биналар, корылмалар, торак һәм торак булмаган йортлар, урманнар, күпьеллык утыртылмалар, пр-тиеләр һәм җир б-н бәйле башка объектлар (аларны күчереп урнаштыру гадәттән тыш зыян сала) күчемсез әйберләр булып исәпләнә. Дәүләт теркәлүендәге һава һәм диңгез кораблары, ил эчендәге суднолар, галәм объектлары да К.м. булып санала.

Күчемле милектән аермалы буларак, К.м., сатылган очракта, урынында кала, сатып алучыга объектка карата билгеле бер хокуклар һәм шуңа бәйләнгән бурычлар гына тапшырыла. К.м. — икътисади мөмкинлекләрнең иң мөһим өлеше һәм ул урнашу урыны, саны һәм сыйфаты, техник халәте, уңайлылык дәрәҗәсе, объектларның бәясе һәм бу күрсәткечләрнең үзгәреше турында мәгълүмат алу максатында, бердәм дәүләт теркәвен узарга тиеш. Биналар, корылмалар һәм йортларның техник инвентаризациясе һәм исәптә торуы — дәүләт кадастр һәм стат. исәпкә алу системасының мөһим өлеше; салым салу, К.м. б-н алыш-бирешләр һәм аңа хокук б-н идарә итү, аларны теркәү өчен мәгълүмати нигез булып тора. ТР терр-ясендә К.м. объектларын техник исәпкә алу ТРның Төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Техник инвентаризация бюросы тарафыннан гамәлгә ашырыла (ТРның эре пр-тиеләре, АҖ һ.б.ның К.м. объектларына инвентаризация һәм дәүләт теркәвенә кую эше үткәрелә).

2007 елда К.м. б-н бәйле эшләрне ТРның Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы, Федераль теркәү хезмәтенең ТР буенча Баш идарәсе, К.м. объектларының Федераль кадастр агентлыгы ТР идарәсе, ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, ш.у. аларның кайбер инспекцияләре һәм ф-ллары башкара.

Чыг.: Гражданский кодекс Российской Федерации. К., 1995. Ч. 1.

*Әд.:* Теория и методы оценки недвижимости: Учеб. пособие. СПб., 1998; З и я т д и н о в Ф.С. Ресурсный потенциал АПК: Анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**КҮЧМӘ́ ТЕА́ТРЛАР**, к. *Колхоз-совхоз театрлары.*

**КҮЧҮ́М ХАН** (1520–98 еллар тирәсе), Себер ханы (1563 тән). Чыңгызый, Бохара хакиме Мортаза хан улы. 1555 елдан, Себер ханлыгы (башкаласы — Кашлык ш.) тәхетен яулау өчен, *Ядегәр хан* б-н көрәшә башлый, 1563 тә аны кугач тәхеткә утыра. Буйсынырга теләмәгән бәкләр һәм кабилә башлыклары б-н көрәш алып бара, ислам динен таратуны яклап чыга. Ханлыкны ныгытып, Нугай Урдасы морзалары б-н дустанә мөнәсәбәтләрне торгыза. 1569 да рус патшасы Иван IV К.х.нан Себер ханлыгының Рус дәүләтенә бәйле булуын һәм ясак түләвен таләп итә. 1573 тә К.х. гаскәр б-н Пермь шәһәренә бара. Шуңа да карамастан, ул 1570 елларда Рус дәүләте б-н дустанә мөнәсәбәтләрне саклап кала. 1582–85 тә атаман Ермак баскыннарына каршы көрәшә; 1582 дә җиңелә һәм көньяк Урал далаларына кача. 1585 нең язында, гаскәр туплап, Кашлыкны камый, Бетишев шәһәрчеге янында җиңелә. Ермак һәлак булгач, Кашлык шәһәрен кайтарып ала (1585). Әмма ханлыкны ныгыту һәм берләштерү юлында җирле аксөякләр каршылыгына очрый. *Сәед хан* б-н *Карачы бәк* җитәкчелегендә К.х.га каршы фетнә оештырыла. К.х. үз урдасын Иртеш буе даласына күчерергә мәҗбүр була. Анда ул яңа ханлык нигезләргә омтыла. Моңа җавап итеп, рус воеводалары Иртеш буен актив рәвештә үзләштерә башлыйлар. 1596 да К.х. Тумус шәһәрчеге тирәсендә кенәз Ф.Елецкий гаскәре тарафыннан җиңелә. 1598 дә ул рус гаскәрләренә каршы Иртеш буенда яңа һөҗүмгә әзерләнә, әмма воевода А.Воейенков Бараба даласында К.х. урдасына көтелмәгән һөҗүм ясый һәм аның гаскәрен тар-мар итә. К.х.ның әсирлеккә төшкән берничә улы русларга хезмәт итә башлый, ул үзе руслар ягына күчү тәкъдимен кире кага һәм далага китә. Нугайлар б-н бәрелешләрнең берсендә һәлак булган дип фаразлана. Ермакка каршы алып барган сугыш-бәрелешләре хакында халык телендә күп риваять-хикәятләр сакланып калган.

*Әд.:* М и л л е р Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; Т и х о м и р о в М.Н. Россия в XVI столетии. М., 1962; П р е о б р а ж е н с к и й А.А. Урал и Западная Сибирь в конце XVI — начале XVIII веков. М., 1972; С к р ы н н и к о в Р.Г. Сибирская экспедиция Ермака. Новосиб., 1982.

*И.Л.Измайлов.*

**КҮШӘ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ашыт елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 635 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, колмак үстерү, балта эше һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2902 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 203 ир-ат; 1859 да — 786, 1897 дә — 955, 1908 дә — 878, 1920 дә — 1095, 1926 да — 1298, 1938 дә — 465, 1949 да — 822, 1958 дә — 815, 1970 тә — 769, 1979 да — 716, 1989 да — 636, 2002 дә — 647 кеше.

**КҮШКЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 16 *км* көньяктарак, Чилчә елгасы буенда. 2010 елда 306 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1545,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 296, 1897 дә — 789, 1913 тә — 995, 1920 дә — 862, 1926 да — 699, 1938 дә — 762, 1949 да — 659, 1958 дә — 699, 1970 тә — 731, 1979 да — 760, 1989 да — 361, 2002 дә — 324 кеше.

**КЦРК**, к. *Казан эшчеләренең үзәк кооперативы.*

**КЫДЫРЛЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сарсак елгасы буенда. 2010 елда 6 кеше (татарлар) яши. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сарсак, Сарсак-Кибә исемнәре б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, чыпта-капчык сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, мәдрәсә, мәктәп (1817 дән), рус-татар земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1333,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда. 1920 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 10 апреленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1762 дә — 56 ир-ат; 1859 да — 226, 1887 дә — 452, 1920 дә — 662, 1926 да — 667, 1938 дә — 522, 1958 дә — 170, 1970 тә — 121, 1989 да — 14, 2002 дә — 7 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КЫЕКЧА́**, к. *Өрпәк.*

**КЫЗ БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯЛӘРЕ**, 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Россиядәге урта уку йортлары. 1 һәм 2 разрядлы кыз балалар уч-щеләре 1858 елгы карарга туры китереп, иганә хисабына тотылучы һәм императрица Мария ведомствосы карамагында булган уку йортлары буларак ачылалар. 1869–70 тә алар Халык мәгарифе министрлыгы карамагындагы К.б.г. итеп үзгәртеләләр. Кагыйдә буларак, министрлыкның хосусый милкенә күчә торган биналар һәм җиһазлар төзүче һәм сатып алучы шәһәр үзидарәсе һәм җәмгатьчелек органнары инициативасы б-н оештырылалар. Кечкенә өяз шәһәрләрендә К.б.г.нең 1–4 сыйныфлар программасы буенча укытыла торган прогимназияләре ачыла; соңрак аларның күбесе мөстәкыйль К.б.г. итеп үзгәртеләләр. Шәхси гимназияләр дә эшли, шул ук программа б-н укыталар; аларның саны 1905 тә бюрократик киртәләрне бетергәннән соң арта. К.б.г.дә үзенчәлекле укыту системасы барлыкка килә. Ир балалар гимназияләреннән аермалы буларак, аларда чит телләр укытылмый, математика һәм яңа телләргә сәгатьләр аз бирелә, күбрәк гуманитар һәм эстетика фәннәренә игътибар ителә, фортепьянода уйнау мәҗбүри өйрәтелә. Уку срогы башлангыч мәктәптән соң — 7 ел, әзерлек сыйныфларыннан соң 8 ел. 1872 дән 8 нче (пед.) сыйныфлар ачыла башлый, аны тәмамлаучылар халык укытучылары исемен алалар. К.б.г. урта мәктәпнең иң төп төрләреннән берсе була, хатын-кызларны азат итү процессында әһәмиятле роль уйный, аны тәмамлаучыларның күбесе укытучылар булып китә, югары белем ала, иҗтимагый тормышта актив катнаша.

Казанда дәүләт К.б.г.: Мария (беренче) (1859), Ксения (икенче) (1876), Өченче (1905 тән; башта, 1876 дан — Вагнер-Котованың шәхси гимназиясе), Дүртенче (1910; башта, 1905 тән — Ряхинаның шәхси гимназиясе), шәхси: Бобровникова, Пономарёва (1906), Шумкова (1908, асылда 1895 тән), Кавано (1913) гимназияләре эшли. Татарстан терр-ясендә К.б.г. һәм прогимназияләр Алабуга (1860), Минзәлә, Чистай (1862), Бөгелмә (1903), Тәтеш (1906), Мамадыш (1910), Буа, Лаеш, Зөя (1911), Спас (1913) кебек өяз шәһәрләрендә дә ачыла.

*Әд.:* Лихачёва Е.О. Материалы для истории женского образования в России. 1856–1880. СПб., 1901; Женские гимназии и прогимназии Министерства народного просвещения. СПб., 1905.

*Е.В.Липаков.*

**КЫЗАМЫ́К** (Morbilli), вируслы көчле антропоз авыру. Авыру кузгатучы — рибонуклеин кислоталы вирус (Morbilivirus ыругы, Paramyxoviridae семьялыгы). Авыруның вируслы табигатен Европа галимнәре Андерсон һәм Гольдбергер исбатлыйлар (1911); К. вирусын Дж.Эндерс һәм Т.К.Пибле аерып тасвирлыйлар (1954); тере К. вакцинасын А.А.Смородинцев җитәкчелегендәге совет галимнәре төркеме (1967 дән файдаланыла) уйлап таба. Авыру чыганагы — авыру кеше; тапшырылу юлы — һава-су тамчылары аша (йөткергәндә, төчкергәндә, сөйләшкәндә һ.б.). К. йоктыруга күпләр бирешүчән. Авыруга агулану, катараль һәм респиратор билгеләр, үзенчәлекле тамга-тимгелләр (Бельский–Филатов–Коплик тамгалары), таплы-тимгелле сыткылар хас. Вирус акрын узучан йогышлы авыруга китерергә сәләтле (склерозлы панэнцефалит һәм таркау склероз). Авырудан соң гомерлек иммунитет формалаша. Авыруны булдырмау өчен тере кызамык вакцинасы уңышлы кулланыла.

ТРда К. б-н авыру аеруча зур процентлы күрсәткеч б-н 1968 дә — 951 авыру очрагы (100 мең кешегә — 30,2) һәм 1993 тә — 1142 авыру очрагы (100 мең кешегә — 30,5) теркәлә. Казан мед. ун-ты галимнәре тарафыннан К.ның биологиясе өйрәнелә (В.К.*Меньшиков*, 1904), массакүләм профилактик нәтиҗәләр гомумиләштерелә (К.Г.Александров, 1946), профилактик прививкалар календаре, эпидемиологик күзәтү ысуллары эшләнә (М.Ш.Шәфиев, Ф.Ф.Садыйков, Л.М.Зорина, 1997); ТРда К. б-н авыру һәм 6–7 яшьлек балаларга ревакцинация үткәрү нәтиҗәсе күзәтүгә алына (Г.А.Савицкая, 1998).

*Әд.:* Мухутдинов И.З. Характеристика эпидемиологического процесса кори в Татарской АССР // Казан. мед. журн. 1974. № 1 (автордаш).

*В.А.Анохин.*

**«КЫЗЫ́Л АРМЕ́ЕЦ»**, газета. 1924 елның 7 июненнән 15 ноябренә кадәр Самара шәһәрендә, Идел буе хәрби округы сәяси идарәсенең атналык органы буларак, татар телендә барлыгы 18 саны нәшер ителә. Редколлегия составына Х.Күрми, Ф.Таипов, А.Шнитков керә. 1925 нең 23 февраленнән 1938 нең 8 маена кадәр Казанда: 1937 нең маена кадәр — Идел буе хәрби округының сәяси идарәсе һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты органы, соңрак ТатҮБК исем. Казан укчылар дивизиясенең сәяси бүлеге органы буларак чыга. 1938 елның 8 маенда соңгы саны рус телендә басыла. Төрле елларда мөхәррирләре — М.Давыдов, Я.*Чанышев*, М.*Парсин*, С.*Гыйльфан*, З.*Гали*, Г.Усманов, Г.Гыйльманов. 1928 нең маеннан 1933 нең гыйнварына кадәр «К.а.» редакциясе кушымталар рәвешендә «ОСОАВИАХИМ» (124 сан), «Кызыл командир», «Военкор» һ.б. г-талар чыгара.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать в восстановительный период). К., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**«КЫЗЫ́Л А́РМИЯ»**, хәрби-сәяси газета. 1918 елның 20 апреленнән 6 июленә һәм 15 ноябреннән 1919 ның 6 февраленә кадәр Мәскәүдә, 1918 нең 3–22 октябрендә, 1919 ның 5 мартыннан 1921 нең 15 мартына кадәр Казанда татар телендә, барысы 430 саны нәшер ителә. 1920 нең 25 февраленнән 29 декабренә кадәр башта — «Красная Армия», соңрак — «*Красный Восток*» исеме б-н рус телендә дә чыга. Элек ул татар-башкорт революцион гаскәрләре үзәк органы була, нашире — Үзәк мөселман комис-тының хәрби бүлеге (1918 нең маенда ул Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе дип үзгәртелә). Соңрак газета Республика Революцион Хәрби Советы сәяси идарәсе каршындагы Көнчыгыш бүлек органы буларак чыга. Беренче саннарны әзерләүдә Г.Ибраһимов инициативасы б-н чакырылган Төньяк фронтның мөселман солдатлары ком-ты әгъзалары Һ.*Килдебәк* (газетаның 1 нче мөхәррире), М.Алиев (*Дулат Али*), Ю.Ибраһимов, М.*Конов* зур роль уйный. Төрле еллардагы мөхәррирләре — Ш.*Әхмәдиев*, Г.Мансуров, С.*Атнагулов*, А.Алмаев, Б.Мансуров, Ф.Бурнаш. Газетада К.Әмири, Ф.Әмирхан, Б.Белоусов, М.Вахитов, Н.Вахитов, М.Гали, М.Гафури, З.Голзарский, Г.Ибраһимов, И.Йосфи, Г.Камал, Г.Мангушев, Г.Матросов, А.Мөхетдинов, К.Нәҗми, Б.Нуриманов, Б.Рәхмәт, И.Рәхмәтуллин, С.Сәетгалиев, К.Тинчурин, Ш.Усманов, Ш.Ходайбирдин, К.Якубов һ.б. танылган татар һәм башкорт революционерлары, язучылар, журналистлар хезмәттәшлек итә. Газета Гражданнар сугышы елларында татарча чыккан иң популяр кызылармиячел басма була (тиражы 40 мең данәгә җитә): «Советлар сәясәте» рубрикасында Советлар съездлары материаллары, җитәкчеләрнең докладлары һәм чыгышлары, БҮБК карарлары, Эшчеләр һәм крәстияннәр оборонасы Советы, ХКС, РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты карарлары басыла. «Партия тормышыннан» рубрикасында РКП(б)ның 8 нче һәм 9 нчы съездлары материаллары, РКП(б) ҮК документлары урын ала. Газетада В.И.Ленинның РКП(б) ҮКның «Көнчыгыш фронттагы хәлләр б-н бәйле тезислары» дигән хезмәте, РКП(б) ҮКның «Барыбыз да Деникин белән көрәшкә», «Шәрекъ халкы арасында эш алып бару турында» һ.б. хатлары басыла. Хәрби мәсьәләләргә зур игътибар бирелә: Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе карарлары игълан ителә; Кызыл Армиядә милли частьләр оештыру буенча үткәрелгән чаралар, Гражданнар сугышы фронтларындагы хәлләр һәм анда татар-башкорт частьләренең катнашуы яктыртыла. 1918–19 да Көнчыгыш фронттагы сугышлар тәфсилле тасвирлана. Газета эшче һәм крәстияннәрне акгвардиячеләргә ныклап каршы торырга чакыра, аларның басып алган җирләрдә террор урнаштыруы турында яза. Мәсәлән, газета 1919 ның 15 июль санында Пермь шәһәрендә меңнән артык кызылармиячеНең тереләй яндырылуы һәм Екатеринославта 4 мең эшченең атып үтерелүе турында хәбәр итә. Аклар армиясе солдатларын агитацияләү максатыннан махсус язмалар басыла. Тылның фронтка ярдәм итүе, халык мәгарифе (бигрәк тә кызылармиячеләр арасында), ТАССРда мәгарифнең үсешенә зур урын бирелә. «Әдәби сәхифә» даими чыгып килә; «Казан хәбәрләре» рубрикасында шәһәрнең икътисади һәм мәдәни тормышы яктыртыла. Газета Республика Революцион Хәрби Советы сәяси идарәсе каршындагы Көнчыгыш бүлек таратылгач чыгудан туктый.

*Әд.:* Мухарямов М.К. Гражданская война в Татарии (1918–1919). К., 1969; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; Гиззатуллин И.Г. Защищая завоевания Октября: Центральная мусульманская военная комиссия. М., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**«КЫЗЫ́Л А́РМИЯ АГИТА́ТОРЫ БЛОКНОТЫ́»**, айлык хәрби-сәяси журнал. Кызыл Армиянең Баш сәяси идарәсе органы. 1943 елның августыннан 1945 нең сентябренә кадәр Мәскәүдә татар телендә блокнот рәвешендә Хәрби нәшрият тарафыннан нәшер ителә. Мөхәррире — Н.Брычев, А.Габдрахманов. Командирлар, политруклар, агитаторларга сугышчылар арасында сәяси эш алып бару өчен ярдәмлек итеп чыгарыла. Башкомандующий, Оборона халык комис-ты боерыклары, бүләкләүләр турында указлар, Совет информбюросы хәбәрләре басыла. Сугышчан уставны, сугыш кырында солдатның үз-үзен ничек тотарга тиешлеген, комсомол-солдатлар арасында алып барыла торган эшчәнлекнең үзенчәлекләрен аңлатучы методик материаллар урын ала. 1920–30 еллардагы сугыш идеологиясеннән аермалы буларак, журналдагы пропаганда ш.у. рев-циягә кадәрге Россия армиясенең җиңүле традицияләре мисалына да таяна. 1945 тә берничә сан аерым темага багышлана: № 2 — И.В.Сталинга, № 3 — Ялта конференциясенә, № 5 — Германиянең капитуляциясе турындагы актка, № 8/9 — Потсдам конференциясенә. Татар сугышчыларының батырлыкларын тасвирлаучы язмалар урнаштырыла, Советлар Союзы Геройлары Г.*Салихов*, М.*Сыртланова*, З.*Шәймәрдәнов* һ.б. турында очерклар басыла. ТАССР тормышы һәм аның фронтка ярдәме турында язмаларга күп урын бирелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**КЫЗЫ́Л А́РМИЯ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә оештырыла. Үзәге — Каргалы авылы. 1920 гә кадәр К.А.р. терр-ясе — Казан губернасының Чистай өя-

зенә, 1920–30 елларда — ТАССРның Чистай кантонына, 1930–35 ләрдә Чистай р-нына керә. 1940 та районның мәйданы — 667 *км*², халкы — 20,7 мең кеше, 19 авыл советы, 38 торак пункт була. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1958 нең 23 маенда К.А.р. бетерелә, терр-ясе Яңа Чишмә һәм Чистай р-ннарына бирелә.

**КЫЗЫ́Л А́РМИЯ ҺӘМ ФЛОТ ӘДӘБИ́ ОЕШМАСЫНЫ́Ң ТАТА́Р СЕ́КЦИЯСЕ** (ТатЛОКАФ), Казандагы татар язучыларының иҗтимагый берләшмәсе (1930–32). Максаты — хәрби темага язучыларны берләштерү, Кызыл Армия һәм флотта хезмәт итүче каләме өметле яшьләрдән язучылар тәрбияләү. Оештыручылары: К.Нәҗми, Г.Иделле, М.Әмир. Татар телендә 4 җыентык чыга: «Штурм» (1931), «Манёвр» (1932), «Кызыл Армия ударниклары», «Сакта» (1933).

*Н.Г.Гыйззәтуллин.*

**«КЫЗЫ́Л ӘЛӘ́М»**, иҗтимагый-сәяси газета. Башта Казан губерна башкарма ком-ты каршындагы керәшен татарлар бүлекчәсе, соңрак РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршындагы Үзәк керәшен татар бүлеге һәм РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы милли азчылык бүлеге, аннан РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы Керәшен татарлар эше буенча югары коллегия органы буларак нәшер ителә. 1919 елның 3 октябреннән 1922 нең 9 гыйнварына кадәр Казанда татар телендә кириллицада 159 саны чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — Н.Тимофеев, П.Губин, Г.Мельников, В.Филиппов. Актив авторлары — И.Егоров, С.Золотов, Д.Касыймов, Ф.Купцов. «К.ә.» г-тасының дәвамчысы — «*Киңәш*» г-тасы.


КЫЗЫЛ ӘЛӘМ


«Кызыл әләм» газетасы.

*Әд.:* Григорьев А.Н. Кряшенский вопрос в Татарии и его разрешение Советской властью: Дис.... М., 1945; Насыров Т.М. Октябрь и печать Татарии. К., 1975; Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать в восстановительный период). К., 1979.

*Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л БАЙРА́К** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 31 *км* көньяктарак, Инеш елгасы (Игәнәнең сул кушылдыгы) бассейнында. 2010 елда 123 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1924 тә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Әхмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 285, 1949 да — 229, 1958 дә — 192, 1970 тә — 198, 1979 да — 136, 1989 да — 89, 2002 дә — 103 кеше.

**КЫЗЫ́Л БАЙРА́К** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 35 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 120, 1949 да — 203, 1958 дә — 330, 1970 тә — 276, 1979 да — 220, 1989 да — 170, 2002 дә — 120 кеше.



Кызыл Байрак посёлогы. Мәчет.

**«КЫЗЫ́Л БАЙРА́К»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Мөселман социалистлар ком-ты органы. 1917 елның 15 июненнән Казанда, 1918 нең 10 маеннан 28 июленә кадәр Мәскәүдә атнага 2 тапкыр татар телендә, барысы 42 саны нәшер ителә. Мөхәррире — М.*Вахитов*, аерым саннарына Г.*Нугайбәк*, С.Борһан имза куйган. Авторлар арасында Җ.Вәлиди, М.Вахитов, Х.Гайнуллин, Б.Мансуров, Х.Урманов, С.Сәетгалиев, М.Солтангалиев, В.Шәфигуллин була. Күпчелек язмалар псевдоним б-н яки имзасыз бирелә. 1 нче санда «Иптәшләр, алга!» дип исемләнгән программ мәкалә басылып чыга. Ул түбәндәге сәяси таләпләрне куя: бөтен хакимиятне Советларга бирергә; Дәүләт Думасын һәм Дәүләт Советын таратырга, хөкүмәтнең чит илләр б-н яшерен килешүләр төзүенә чик куеп, барысын да ачыктан-ачык эшли башларга; Беренче бөтендөнья сугышын туктатырга; җирне — крәстияннәргә, заводларны — эшчеләргә бирергә. Газета социализм һәм интернационализм идеяләрен пропагандалый, аннексия һәм контрибуцияләрсез тынычлык урнаштыруны яклый, крәстияннәрне, Учредительләр җыенын көтеп тормыйча, алпавыт һәм монастырь җирләрен басып алырга чакыра, сигез сәгатьлек эш көне һәм пр-тиеләрдә эшне контрольдә тотуны таләп итә, хатын-кыз хокукларын яклый, милли буржуазия һәм дин әһелләре омтылышларына каршы чыга. Сәяси партияләрнең эшчәнлеген һәм программаларын анализлаган һәм соц. идеяләрне пропагандалаган мәкаләләрнең күпчелеге «Рабочий» («Эшче»), «Социал-демократ» г-таларыннан һәм брошюралардан, РСДРП(б) ҮК басмаларыннан күчереп басыла. Зур урынны сугышка каршы язылган публицистика, фронттан язылган солдат хатлары алып тора. Башта редакция татарлар өчен Эчке Россиядә һәм Себердә милли-мәдәни автономия төзү идеясе яклы була; 1917 нең көзендәге үзгәрешләрдән соң ул терр. автономия мәсьәләсен күтәрә. Газета Окт. рев-циясен хуплап каршы ала. Совет чорында Үзәк мөселман комис-ты ярдәме б-н чыгарыла. Анда Совет властеның декретлары, карарлары басыла, аларның асылы аңлатыла. Редакция Учредительләр җыенын тарату турындагы карарны, чиркәүне дәүләттән аеру турындагы Декретны, РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршында Татар-Башкорт комис-ты оештыруны хуплый. Газетаның басылудан туктавына М.Вахитовның Казаннан китүе һәм чыгарырга акча җитмәү сәбәп булырга мөмкин.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Насыров Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970.

*Р.М.Нуруллина.*

**«КЫЗЫ́Л БАЙРА́К»**, газета; к. «*Ленин байрагы*».

**КЫЗЫ́Л БАКЧА́** посёлогы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 26 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 71 кеше яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Кармалы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында, 1991 нең 14 мартыннан шәһәр тибындагы Җәлил посёлогы составында. Халык саны: 1926 да — 36, 1938 дә — 17, 1949 да — 78, 1958 дә — 71, 1970 тә — 131, 1979 да — 113, 1989 да — 46 кеше.

**КЫЗЫ́Л БИСТӘ́** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 6 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 410 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек дворян Молоствовларның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау, балта эше, тимерчелек һәм тегү б-н шөгыльләнә; күн аяк киеме тегә. 20 йөз башында К.Б.дә Казан Богородица чиркәве (1855–59 да төзелә; архит-ра ядкәре), земство (1878 дә ачыла) һәм һөнәрчелек мәктәпләре, 6 җил һәм 1 пар тегермәне, 2 тимерчелек, зур һәм 6 кечкенә кибет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1912 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өя-

зе Ширбәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир-ат; 1859 да — 1024, 1897 дә — 1253, 1908 дә — 1416, 1920 дә — 1286, 1926 да — 989, 1938 дә — 1279, 1949 да — 861, 1958 дә — 1133, 1970 тә — 1066, 1979 да — 772, 1989 да — 571, 2002 дә — 459 кеше.

**КЫЗЫ́Л БОЛГА́Р** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 16 *км* көньяктарак, Чистай-Нурлат автомобиль юлы буенда. 2010 елда 160 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Халык саны: 1938 дә — 500, 1949 да — 449, 1958 дә — 339, 1970 тә — 331, 1979 да — 260, 1989 да — 199, 2002 дә — 165 кеше.

**КЫЗЫ́Л БОЛГА́Р** посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 32 *км* көнчыгыштарак, Казансу елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 10 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Арча р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 107, 1949 да — 112, 1958 дә — 77, 1970 тә — 74, 1989 да — 27, 2002 дә — 17 кеше.

**КЫЗЫ́Л БӨРЛЕГӘ́Н** (Rubus saxatilis), роза чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлек. Евразиядә, Төньяк Америкада очрый. Татарстанның бөтен терр-ясендә киң таралган. Нарат урманнарында, урман аланнарында, куаклыклар арасында үсә. Тамырчасы вертикаль, калын. Сабагы туры, 15–30 *см* биеклектә, үткен энәле һәм тырпайган төкле. Яфрагы өчәрле, озын сапларда, сабагы кебек үк энәсыман төкләр б-н капланган. Чәчәкләре ак, сабак очында 3–6 шар булып калкансыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимешләре сусыл, ачык-кызыл, әчкелтем, берничә төштән тора. Май ахырыннан июньгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Башлыча өстәмә тамырлар ярдәмендә буыннарда тамырланучы горизонталь җир асты бәбәкләреннән (мыеклардан) үрчи. Яфрак һәм җимешләрендә флавоноидлар, органик к-талар, минераль һәм пектин матдәләр, майлар бар. Җимешләре азык буларак файдаланыла, халык медицинасында бөердә таш булганда, ашказаны-эчәк авырулары, салкын тигәндә кулланыла. Баллы үсемлек.

**КЫЗЫ́Л ГӨМБӘ́** (Lactarius torminosus), ал гөмбәләр семьялыгыннан җәймәле гөмбәләр ыругы. Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: алсу йөнтәс гөмбә (L. torminosus), ак йөнтәс гөмбә (L. pubescens). Катнаш (каенлы) урманнарда, яшь каенлыкларда, берәрләп яки төркем булып очрый. Каен б-н бергә микориза хасил итә. Алсу йөнтәс гөмбәнең эшләпә диаметры 4–15 *см*, яшь гөмбәнең эшләпәсе кабарынкы, картайганнары киң бүрәнкәсыман, кайтарылган йөнтәс читле, итчел, коры яки җиңелчә лайлалы, алсу кызыл, үзәктәш зоналар ачык беленә. Ак йөнтәс гөмбә диаметры 7 *см* дан артмаган эшләпәсе, зональлекнең булмавы, ак яки аксыл сары төсе б-н аерыла. К.г.нең йомшагы сынучан, ак, аксыл соры, зәһәр, җиңелчә сумала исле. Сөтле сыекчасы ак, ачы, һавада төсе үзгәрми. Споралы порошогы ак. Сабы цилиндрсыман яки төпкә таба аз гына тарайган, аксыл алсу. Гөмбәләр бөҗәк личинкалары б-н зарарлануга чыдам. Ашарга яраклы. Тозлау һәм маринадлау өчен кулланыла.

*Әд.:* Д о д и к С.Д. Грибы российских лесов. М., 1999.

**«КЫЗЫ́Л ДӨНЬЯ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Самара губкомы каршындагы татар-башкорт бюросы һәм Идел аръягы хәрби округы органы. 1918 елның 18 октябреннән 1920 нең 14 декабренә кадәр Самара шәһәрендә татар телендә 98 саны нәшер ителә. 1920 нең 11 июленә кадәр «Яңа көч» исемендә чыга.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Н а с ы р о в Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970.

**КЫЗЫ́Л ИГЕНЧЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 43 *км* төньяктарак, Шубан елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урман питомнигы. Клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1989 да — 69, 2002 дә — 72 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ИГЕНЧЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Эчке Россия мөселман эшләре комис-тының Орск бүлеге органы. 1919–20 елларда Орск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**«КЫЗЫ́Л ИДЕ́Л»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның төрки халыкларның Әстерхан губкомы каршындагы коммунистик оешмалары бюросы һәм губерна башкарма ком-ты карамагындагы милләтләр эше бүлеге органы. «*Көч*» г-тасының дәвамчысы. 1921 елның 13 июленнән 11 декабренә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 29 сан. Мөхәррирләре — Ә.Умәров, К.Гобәйдуллин. Газетада С.Габделгалиев, Г.Ибраһимов, И.Мифтах һ.б. хезмәттәшлек итә. Төп бүлекләре: «Совет Россиясендә», «Чит илләрдә», «Әстерхан тормышыннан», «Театр яңалыклары», «Сатирик сәхифә». Әстерхан губернасының икътисади үсешенә һәм балыкчылык кәсәбәчелегенә зур игътибар бирелә. Басмада РКП(б)ның 10 нчы съездында кабул ителгән яңа икътисади сәясәт турындагы карарлар җентекләп яктыртыла, съездның милли мәсьәләләр буенча карарлары (элек изелеп яшәгән халыкларның артта калганлыгын бетерү, партиягә каршы юнәлешләр — бөекдержавачыл шовинизм һәм җирле милләтчелеккә каршы көрәшү) аңлатыла. Культура төзелеше һәм төрки-татар халыклары мәгърифәте темасы көн тәртибенә куела. Газета Идел буендагы ачлыкка каршы көрәшкә үзеннән өлеш кертергә омтыла. Аерым язмалар хатын-кызлар эшчәнлегенә багышлана; басма Әстерхан губернасы төрки-татар хатын-кызларының конференциясе турында тәфсилле язма бастырып чыгара. «К.И.»дә әдәби әсәрләр, фельетоннар да урнаштырыла. М.Ю.Лермонтовның «Демон» поэмасыннан өзекләр тәрҗемә итеп басыла, җирле шагыйрь Я.Ярмәки шигырьләре урын ала. «К.И.»нең дәвамчысы «*Кызыл ил*» г-тасы.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; К а р и м у л л и н А. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

*Т.М.Насыйров.*

**«КЫЗЫ́Л ИДЕ́Л»**, кызылармиячеләр газетасы. Көнчыгыш фронтның Көньяк төркеме Революцион Хәрби Советының сәяси бүлеге органы. 1919 нең июнь–июль айларында Самара шәһәрендә татар телендә барысы 5 саны нәшер ителә. Мөхәррирләре — М.Давыдов, С.*Атнагулов*. Актив авторлары арасында — Г.Садри, Х.Сәлимов, Х.Исхаков, Г.Хәлим була. 1919 елның июль башында Көнчыгыш фронтның Төркестан армиясе «*Кызыл маяк*» г-тасы б-н берләшә.

*Әд.:* М у х а р я м о в М. Гражданская война в Татарии (1918–1920). К., 1969; Н а с ы р о в Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970. *Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л ИЛ** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Лаеш р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 116, 1958 дә — 136, 1970 тә — 63, 1979 да — 24, 1989 да — 15, 2002 дә — 7 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ИЛ»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Әстерхан губкомы азчылык милләтләр бүлекчәсе органы. «*Кызыл Идел*» г-тасының дәвамчысы. 1922 елның 10 июленнән 1926 га кадәр Әстерханда атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Төрле еллардагы мөхәррирләре — К.Гобәйдуллин, И.Акъегет була. Актив авторлары — Ф.Арабский, А.Әхәтов, Г.Әхмәтский, К.Бисангалиев, Х.Ибраһимов, Ф.Моратов, Р.Насыйров, В.Сәлимҗанов, М.Фәтхуллин, А.Фәхриев, Т.Шәһәри һ.б. Иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм фәнни-популяр эчтәлекле язмалар басыла. Төп рубрикалары: «Чит илләрдә», «Әстерхан татарлары», «Дин һәм тормыш», «Театр сәхнәсе тирәли», «Совет мәктәпләре торышы». Газета дингә каршы пропаганда алып бара. Әдәби сәхифәдә Г.Тукай шигырьләре, аның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган язмалар басыла. 1923–26 елларда редакция «Яшьләр сәхифәсе» чыгара.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; К а р и м у л л и н А. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–132). К., 1999.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**КЫЗЫ́Л ЙОЛДЫ́З** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 16 *км* көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 5 кеше (татарлар) яши. 1927 дә Үчәлле авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән

ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 128, 1949 да — 102, 1958 дә — 63, 1970 тә — 47, 1979 да — 7, 1989 да — 4, 2002 дә — 4 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЙОЛДЫ́З** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 2 кеше яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Борындык волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 42, 1938 дә — 114, 1949 да — 120, 1958 дә — 256, 1970 тә — 151, 1979 да — 136, 1989 да — 22, 2002 дә — 5 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ЙОЛДЫ́З»**, кызылармиячеләр газетасы. Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясе сәяси бүлеге һәм РКП(б)ның Каспий аръягы өлкә ком-ты органы. 1920 елның 19 апреленнән 9 сентябренә кадәр Сызрань шәһәрендә, Сорочинск станицасында (Оренбург өлкәсе), Бозаулык, Оренбург һәм Полторацк (хәзерге Ашхабад) шәһәрләрендә татар телендә нәшер ителә. 1920 дә төрек һәм үзбәк телләрендә бастырыла. Барысы 129 саны чыга, 84 е — татар телендә. Актив авторлары арасында — Г.Әлми, Б.Гәрәй, Н.Еники, Ш.Камал, И.Рәмиев, Ә.Хәбиби, Д.Юлтый була. «К.й.»да М.Җәлил үзенең беренче шигырьләрен бастыра.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Аниакурдов М.Д. К истории коммунистической печати в Туркменистане. Аш., 1958; Насыров Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970; Сбитнева А.А. Литература для красноармейцев нерусской национальности (Из истории деятельности политотделов Красной Армии на Восточном фронте в годы гражданской войны) // Военно-ист. журн. 1973. № 4.

*Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л ЙОЛДЫ́З РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә оештырыла. Үзәге — Котлы Бөкәш авылы. 1920 гә кадәр К.Й.р. терр-ясе Казан губернасының Мамадыш һәм Лаеш өязләренә, 1920–27 елларда — ТАССРның Лаеш һәм Мамадыш кантоннарына, 1927–30 ларда — ТАССРның Мамадыш кантонына һәм Балык Бистәсе р-нына, 1930–35 тә Мамадыш һәм Балык Бистәсе р-ннарына керә. 1940 та районның мәйданы — 1418 *км*², халкы — 45,9 мең кеше, 34 авыл советы, 79 торак пункт була. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1959 ның 26 мартында К.Й.р. бетерелә, терр-ясе Мамадыш һәм Балык Бистәсе р-ннарына бирелә.

**КЫЗЫ́Л ЙОЛДЫ́З УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Саба, Теләче, Мамадыш һәм Балык Бистәсе р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1940 елда оештырыла. Урман хуҗалыгының гомуми мәйданы 46713 *га*, ш.и. урман мәйданы — 45000 *га*. Әбде (13337 *га*), Арыш (7035 *га*), Теләче (10895 *га*), Котлы Бөкәш (9571 *га*), Балык Бистәсе (5875 *га*) урманчылыкларын үз эченә ала.

1 нче төркем урманнар 9725 *га* мәйдан били, ш.и. эрозиягә каршы утыртылган урманнар — 2492 *га*, кыйммәтле промысел балыкларының уылдык чәчү урыннарын саклаучы урман полосалары — 1073 *га*, автомобиль юллары буйлап саклагыч полосалар — 741 *га*, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен әһәмиятле урманнар — 5051 *га*, су саклагыч урманнар — 368 *га*. 2 нче төркем, ягъни җирле файдалануда әһәмиятле урманнар — 36988 *га*; урман культуралары мәйданы — 13211 *га*. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 52%, урта яшьтәгеләре — 39%; өлгереп килүчеләре — 5%, өлгергәннәре һәм картайганнары 4 % тәшкил итә. Ылыслы урманнар 10119 *га* (ш.и. нарат урманнары — 4819 *га*, чыршы — 4984 *га*, карагай — 316 *га*) мәйдан били, яшь һәм урта яшьтәге кулдан утыртылган урманнардан гыйбарәт. Урман хуҗалыгының төньяк өлешендә — Әбде һәм



Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы.
Усак урманнары көзен.

Теләче урманчылыгында чыршы — ак чыршы урманнары сакланган. Каты яфраклы урманнарның мәйданы — 14385 *га*, ш.и. имәнлекләр — 10165 *га* (шуның 80% тан артыгы орлыктан үскән яшь һәм урта яшьтәге утыртмалар). Йомшак яфраклы урманнарның мәйданы — 18679 *га*, ш.и. каенлыклар — 10189 га, усаклыклар — 4364 *га*, юкәлекләр — 3786 *га*.

Каен һәм усак урманнары төп токым булган имән һәм чыршыны кисkәннән соң яңадан үсеп чыккан. 1–1а класс бонитеты буенча усак һәм каен өстенлек иткән утыртмаларның җитештерүчәнлеге 250–270 *м*³/*га*. Төп кулланылыш буенча еллык урман кисү күләме якынча 24 мең *м*³ тәшкил итә. Урманны карау максатыннан 1540 *га* мәйданда кисү эшләре башкарыла, шуның б-н бергә 29,5 мең *м*³ эшкә яраклы агач әзерләнә. Ел саен 250 *га* мәйданда урман утырту эшләре башкарыла, ш.и. имән — 55 *га* мәйданда; а.х. җирләре өчен уңайсыз булган урыннарда урман утырту эшләре башкарыла (ел саен 50 *га* мәйданда), автомобиль юллары буенда саклагыч полосалар (50 *км* дан артык) булдырыла. Урман хуҗалыгының даими эшләүче питомникларында 12 төрле агач-куак токымнарының 5 млн.нан артык үсентесе һәм чәчкене үстерелә. Ел саен 1,3 млн. суммага халык хуҗалыгы товарлары (агач-такта материаллары, коймa такталары, буралар һ.б.) җитештерелә. 2007 елда К.Й.у.х. шул исемдәге урманчылык итеп үзгәртелә. 1954–88 дә урман хуҗалыгы б-н ТРның атказ. урманчысы Т.Г.Габделхаков җитәкчелек итә.

**КЫЗЫ́Л КАНАТСЫ́З КАНДАЛА́**, солдатчалар (Pyrrhocoris apterus), кызыл кандалалар семьялыгындагы бөҗәк. Таралу ареалы бик киң, төньяктан кала һәр җирдә таралган. Татарстан терр-ясендә һәркайда очрый. Гәүдәсе 7–12 *мм* озынлыкта, канатлары кыска. Кара таплы кызыл төстә. Кояш җылыткан урыннарда: җирдә, агач төпләрендә, рәшәткәләрдә, йорт стеналарында һ.б. еш кына төркемләп җыела. Нигездә, коелган агач орлыклары, җимеш соклары, бөҗәк йомыркалары, органик калдыклар б-н туена. Лаборатор тикшеренүләр объекты.

**КЫЗЫ́Л КАПКА́**, к. *Юбилей аркасы.*

**КЫЗЫ́Л КАРМЫ́Ш** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сумка елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 25 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан авыл р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1938 дә — 141, 1949 да — 250, 1958 дә — 150, 1970 тә — 156, 1979 да — 131, 1989 да — 53, 2002 дә — 47 кеше.

**КЫЗЫ́Л КИТА́П**, сирәк очрый һәм югалу куркынычы янаган үсемлек һәм хайван төрләре исемлеге, аларның элеккеге һәм хәзерге таралышы, төрләрнең саны азаю яки бетү сәбәпләре, яңадан торгызу, саклауда кабул ителгән һәм зарури чаралар теркәлгән басма.

Халыкара табигатьне һәм табигать ресурсларын саклау берлеге (МСОП) тарафыннан, сакланылучы төр статусының торышына бәйле рәвештә К.к.ка кертелү өчен 5 категория эшләнә һәм 1949 елдан мәгълүмат җыю башлана. 1 нче категориягә югалу куркынычы янаган төрләр керә, саннары кискен кимү сәбәпле, аларны саклап калу саклаулык, тыюлыклар оештырудан башка мөмкин түгел, 2 нче категориядә — саны кими баручы төрләр. 3 нче категориягә турыдан-туры бетү куркынычы алдында булмаган, әмма аз санда яки кечкенә терр-яләрдә очраучы төрләр керә, теләсә нинди куркыныч аларның бик тиз бетүенә китерергә мөмкин, 4 нче категориядә аз билгеле, җитәрлек өйрәнелмәгән, бетү куркынычы астында булган төрләр, 5 нче категориядә — яңадан кайтарылган төрләр, аларның саны кабул ителгән чаралар ярдәмендә арта бара.

К.к.ның халыкара, милли һәм төбәк вариантларын аерып йөртәләр, ш.у. үсемлекләр, хайваннар һ.б. систематик төркемнәргә караганнары бар. 1966 да МСОП «Фактлар Кызыл китабы»ның («Red Data Book») беренче томнарын чыгара, биредә имезүчеләр һәм кошларның саны, таралышы турында мәгълүматлар һәм аларны саклау нисбәтеннән зарури чаралар теркәлә. 1979 елга аларда имезүчеләрнең 321 төре һәм астөре, кошларның — 485, җир-су хайваннарының — 41, сөйрәлүчеләрнең 141 төре кертелә. 1976 да Европаның сирәк, югала баручы һәм эндемик

үсемлекләренең беренче җыелма исемлеге чыгарыла. 1977 дә балыклар исемлеген (194 төр һәм астөр) туплаган том төзү эше башлана.

К.к.ка нинди дә булса төрне кертү, бу төр яшәгән илнең аның алдагы халәте өчен билгеле бер җаваплылык алуын күрсәтә. Хайваннар һәм үсемлекләрнең аерым төрләрен саклауда норматив актлар кабул ителгән илләрдә сакланылучы организмнарның исемлеге басыла, алар турындагы кыскача документация җыентыкларын ш.у. милли К.к., Кызыл исемлекләр, сирәк үсемлекләр исемлеге дип йөртәләр.

СССРда К.к. 1974 тә булдырыла. Беренче басма — 1978 дә, икенчесе 1983 тә чыгарыла. 1982 дә РСФСР МСның «РСФСРда Кызыл китап булдыру турында» карары кабул ителә. 1997 дә РФ К.к.ына үсемлекләрнең 487 төре (ябыкорлыклылар яки чәчәклеләр — 440, ачыкорлыклылар — 11, абагасыманнар — 10, мүкләр — 22, плаунчалар — 4), лишайникларның — 29, гөмбәләрнең 17 төре; 415 төр хайван (ш.и. бөҗәкләрнең — 34, бөжраавызлылар — 4, балыклар — 39, амфибияләр — 8, рептилияләр — 21, кошлар — 123, имезүчеләрнең 65 төре) керә. Шуның б-н бергә РФ К.к.ыннан хайваннарның 38 төре чыгарыла, аларның халәте һәм саны инде куркыныч тудырмый. Хайван һәм үсемлекләрнең төр һәм астөрләренең санын һәм таралышын җентекләп тасвирлау республика һәм төбәккә караган К.к.ның үзенчәлеге һәм өстенлеге булып тора. Бу нисбәттә аларны РФнең К.к.ын тулыландыручы булып тора дип исәпләргә мөмкин, бергә алар бердәм информацион система тудыралар.

ТР МКның 1993 ел 25 октябрь карары б-н булдырылган ТР К.к.ы беренче тапкыр 1995 тә чыгарыла. Аңа имезүчеләрнең 32 төре, кошлар — 82, сөйрәлүчеләр — 4, җир-су хайваннары — 2, балыклар — 9, умырткасызлар — 107 (ш.и. бөҗәкләр — 100); ябыкорлыклы үсемлекләр — 398, ачыкорлыклылар — 1, абагасыманнар — 11, плаунчалар — 6, наратбашсыманнар — 2, мүкләр — 15, суүсемнәр — 22, лишайниклар — 24, гөмбәләрнең 34 төре керә.

Хайван һәм үсемлек төрләре халәтендәге үзгәрешләр аларның статус категорияләрендә чагылыш таба, бу турыда җәмәгатьчелеккә белдерелә. К.к. — документ, аның өстендә даими эш алып барыла. 2006 да ТР К.к.ының 2 нче басмасы чыга, аңа умырткалы һәм умырткасыз хайваннарның 258 төре (имезүчеләр — 34, кошлар — 84, сөйрәлүчеләр — 5, җир-су хайваннары — 3, балыклар — 10; умырткасызлар — 122 төр); үсемлекләрнең 377 төре (ябыкорлыклылар — 290, ачыкорлыклылар — 1, абагасыманнар — 11, плаунчалар — 6, наратбашсыманнар — 1, мүкләр — 24, суүсемнәр — 20, лишайниклар — 24) һәм гөмбәләрнең 40 төре керә. ТР терр-ясендә аерым игътибарга лаек (71 төр), ш.у. юкка чыккан хайваннарның (27 төр) аннотацияле исемлеге китерелә. К.к.ка кертелмәгән, әмма республика терр-ясендә даими күзәтүгә мохтаҗ (хайваннар — 72, үсемлекләр — 142, гөмбәләр 30 төр), сирәк һәм зарарланучан таксоннар исемлеге бирелгән. К.к.ка кертелгән хайваннарны аулау һәм үсемлекләрне җыю дәүләт органнарының махсус рөхсәте б-н генә башкарыла.

*Әд.:* Красная книга РСФСР: Животные. М., 1983; Красная книга СССР. Редкие и находящиеся под угрозой исчезновения виды животных и растений: В 2 т. М., 1984; Красная книга РСФСР: Растения. М., 1988; Редкие животные нашей страны. Л., 1989; Красная книга Республики Татарстан: Животные, растения, грибы. К., 2006; Снакин В.В. Экология и охрана природы: Словарь — справ. М., 2000.

*С.И.Кадошников.*

**КЫЗЫ́Л КИЧҮ́** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Кама елгасы (Дала Зәенең бассейны) буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1930 елларда нигез салына. Халык саны: 1938 дә — 120, 1949 да — 103, 1958 дә — 74, 1970 тә — 30, 1979 да — 12, 1989 да — 3 кеше.

**«КЫЗЫ́Л КӨРӘШЧЕ́»**, кызыларміячеләр газетасы. Көнчыгыш фронтның 2 нче армиясе Революцион Хәрби Советы сәяси бүлеге органы һәм 2 нче ариянең 1918 елда Вятка Аланы авылында октябрь–декабрь айларында чыгып килгән «Алга» г-тасы дәвамчысы. 1919 ның 8 февраленнән Сарапул шәһәрендә, 1919 ның 1 маеннан 1 июнена кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Ф.А.Таипов. 1919 ның 17–29 апрелендә вакытлыча *«Эш»* г-тасы б-н берләштерелә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Мухарямов М. Гражданская война в Татарии (1918–1920). К., 1969; Насыров Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970.

*Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л КӨЧ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 58 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1938 дә — 91, 1949 да — 186, 1958 дә — 162, 1970 тә — 183, 1979 да — 178, 1989 да — 61, 2002 дә — 64 кеше.

**«КЫЗЫ́Л КӨЧ»**, Актаныш р-ныңдагы колхоз. 1930 елда оештырыла. 1955 тә «Тимеркүл» һәм «Октябрь» к-злары б-н берләштерелә, 1994 тә а.х. кооперативлары берләшмәсе итеп үзгәртелә, 2003 тән «Әлем» а.х. җитештерү кооперативы. Аңа Яңа Әлем (үзәк утар) һәм Иске Әлем авыллары керә. 2003 тә 506 хуҗалык, эшләүчеләр саны — 315 кеше була. А.х. файдалану җирләренең мәйданы — 6483 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 5717 *га*. Мөгезле эре терлек — 1508 баш (ш.и. 570 баш сыер), дуңгызлар — 1043 баш. Хуҗалыкның төп тармаклары — бөртекле ашлык, ит, сөт җитештерү. 1980 дә хуҗалыкта хезмәтне оештыруда цех системасы, 1987 дә аренда подряды кертелә. Производство һәм социаль-көнкүреш объектлары (терлекчелек биналары, мәктәп, клуб, балалар бакчасы, универмаг һ.б.) төзелә.

Күп кенә эшләүчеләр дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. ТРның мактаулы исеме 6 кешегә; Ленин ордены — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 5, «Почёт билгесе» ордены — 2; 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены — 3; медальләр — 6, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре 2 кешегә бирелә. Җитәкчеләре: Я.Газнанов (1930–32), К.Әхмәтҗанов (1936–41), К.Шәкүров (1943–49), Т.Төхвәтуллин (1949–63), Г.К.*Сәләхетдинов* (1963–91), А.Л.Сәрвәров (1998–2001), Х.Х.Хуҗин (2001 дән).

*И.Н.Афанасьев.*

**«КЫЗЫ́Л МАЯ́К»**, кызыларміячеләр газетасы. 1919 елның 29 маеннан 29 августына кадәр Богырыслан һәм Самара шәһәрләрендә татар телендә, барысы 20 саны нәшер ителә. Башта Төркестан армиясе сәяси бүлекләре, 1–12 августта — Көнчыгыш фронтның Көньяк төркемнәре, соңрак — Төркестан фронты органы була. Мөхәррире — З.Мозаффарый. Актив авторлары арасында Ю.Шәркый-Дәүликамов, шагыйрь Ярлы Кәрим бар. 1919 ның июлендә «К.м.» Көнчыгыш фронтның Көньяк төркеменең Революцион Хәрби Советы газетасы *«Кызыл Идел»* г-тасы б-н берләшә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Насыров Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970.

*Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л МӘЧЕ́Т**, к. *Солтан мәчете.*

**КЫЗЫ́Л МИШӘ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 313 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты. 1619 дан мәгълүм; 1946 га кадәр Бөкмеш исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.М.дә мәчет, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1743,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 694, 1897 дә — 1006, 1908 дә — 1071, 1920 дә — 1161, 1926 да — 1119, 1949 да — 708, 1970 тә — 657, 1979 да — 591, 1989 да — 370, 2002 дә — 353 кеше.

**КЫЗЫ́Л ОКТЯ́БРЬ** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 16 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Кукмара р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 179, 1949 да — 218, 1958 дә — 178, 1970 тә — 101, 1979 да — 87, 1989 да — 45, 2002 дә — 43 кеше.

**КЫЗЫ́Л ОКТЯ́БРЬ** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 11 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 66 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1928 дә нигез салына. Оештырылган

көннән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1938 дә — 163, 1949 да — 174, 1958 дә — 139, 1970 тә — 184, 1979 да — 1938, 1989 да — 87, 2002 дә — 73 кеше.

**КЫЗЫ́Л ОКТЯ́БРЬ** совхозы посёлогы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 8 *км* көньяктарак, Чөкәнеш елгасы буенда. 2010 елда 621 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1929 да нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Яңа Чишмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 213, 1949 да — 422, 1958 дә — 217, 1970 тә — 514, 1979 да — 510, 198 да — 795, 2002 дә — 706 кеше.

**КЫЗЫ́Л ОКТЯ́БРЬ РАЙОНЫ́**, *Түбән Новгород өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 886,2 *км²*. 1929 елда оештырыла. Үзәге — Уразовка авылы (Түбән Новгород шәһәреннән 168 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 11,7 мең кеше, (2010), 9033 татар (2002). Районда 17 татар торак пункты бар, аларның иң зурлары — Уразовка (1349 кеше), Мәдәнә, Яндавишча, Семёновка, Чүмбәли, Зур Рбишча, Кече Рбишча (1962 гә кадәр К.О.р.на 28 татар торак пункты керә) авыллары. К.О.р. терр-ясенә татарлар (күбесенчә йомышлылар) 14–15 йөзләрдә килеп урнаша. Беренче булып Сафаҗай, Петрякс, Мәдәнә, Карга, Яндавишча авылларына нигез салына. 1917 гә кадәр районда (Куйсу авылында) мөселман дини академиясе була, соңрак аның җирлегендә Татар пед. техникумы (1920–57) ачыла. 1931 дән Уразовка авылында «Колхозчы» (төрле елларда төрле исемдә — «Октябрь коммунасы», «Колхоз правдасы», «Ленин байрагы», «Знамя коммунизма») г-тасы нәшер ителә, 1998 дән татар һәм рус телләрендә «Авылым хәбәрләре» — «Сельские вести» г-таларына кушымта чыга. Хәзерге вакытта районда 20 мәчет, 6 музей (ш.и. 1988 дән Актук авылы мәдәният йорты каршында Р.В.*Вәһапов* музее) исәпләнә, Куйсу авылында 1979 дан «Ләйсән» татар фольклор ансамбле эшли. 1990 нан Уразовка авылында пед. көллияте эшләп килә. К.О.р.да техник фән. д-рлары А.А.Әхмәтҗанов, Ә.У.Галиев, А.А.Садретдинов, физика-матем. фән. д-ры Ә.Җ.*Җаффаров*, мед. фән. д-рлары Н.Х.Җәмлиханов, Р.А.Сөләйманов, тарих фән. д-ры У.Б.*Билалов*, филол. фән. д-ры И.А.Таһиров, юридик фән. д-ры М.С.Хәкимов; җырчылар Р.В.*Вәһапов*, Х.А.*Бигичев*, Н.Фатихова; журналист Р.Ә.*Фәттахов*; СССРның атказ. спорт остасы Ш.С.*Сафин*, СССРның атказ. тренеры, халыкара спорт остасы Р.Г.*Нәҗметдинов*, бокс буенча Россия чемпионы Н.Н.*Алимов*, билбау көрәше буенча дөнья чемпионы Х.Г.Мусин; Сов. Союзы Геройлары С.Ф.*Әбелханов*, Г.Г.*Аббасов*, Дан орденының тулы кавалеры А.Х.Айсин туган.

*Әд.:* Феткуллин К.Р. Краснооктябрьский район. Страницы истории: История административно-территориального устройства. Уразовка, 2002; шул ук. Татарская жемчужина Нижегородчины. Н.Новгород, 2004.

**«КЫЗЫ́Л ӨМЕ́Т»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы. 1918 елда Мәскәүдә, аннан соң Казанда татар телендә нәшер ителә. Мөхәррирләре — Ш.Әхмәдиев, Ф.Бурнаш, С.Атнагулов, сәркәтибе — Г.Баембәтов. Газетада Ф.Әмирхан, Ф.Сәйфи-Казанлы һ.б. язмалары басыла.

*Әд.:* Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925 гг.). К., 1978.

**КЫЗЫ́Л СУАЛЧА́Н**, нигездә, Chironomus ыругыннан булган яңгыравык озынборыннар төренең личинкалар рәте. Күбесенчә агымсыз сулыкларның ләмендә яши. Палеарктика фаунасында 80 нән артык төрнең личинкалары билгеле, Россиядә — 25 кә якын, Татарстан терр-ясендә — 10 тирәсе (төрләрне билгеләү кыен булганлыктан, төгәл саны юк). Аеруча Cl. plumosus озынборыны личинкасы таралган. К.с.ның гәүдәсе 30 *мм* га кадәр озынлыкта, суалчансыман, склеритлашкан башында бер пар мыекча, 3 күкрәк һәм 10 корсак сегменты, алгы һәм арткы сегментларында 2 пар ялган аяк бар. Судагы тозларны йоту өчен гәүдәсенең арткы өлешендә юка капламлы үсентеләр һәм 2 төк бәйләме урнашкан. Куе кызыл төстә, бу гемоглобин — пигмент булу б-н аңлатыла, ул кислородны бәйләү һәм запаска хәзерләү өчен хезмәт итә һәм личинкаларга анаэроб мохиттә яшәргә мөмкинлек бирә. Сулау гәүдәнең бөтен өслегендә бара. К.с. сулыкларда органик матдәләрне эшкәртә. Балыклар өчен азык булып тора. Аквариум балыкларын ашату өчен, ш.у. балык тотуда җим буларак кулланыла. Сулыкларның көчле пычрануы индикаторы.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1966. Т. 3; Определитель пресноводных безпозвоночных России. СПб., 1999; Экологические проблемы малых рек республики Татарстан. К., 2003; Catalogue of Palaearctic Diptera. Bdpst., 1990.

*В.А.Яковлев.*

**«КЫЗЫ́Л СУГЫШЧЫ́»**, фронт газетасы. Мәскәү хәрби округы органы. 1943 елның гыйнварыннан 1945 нең 23 декабренә кадәр татар телендә 108 саны нәшер ителә. 1944 нең октябрь ахырларында 1 нче Белорусия фронтының сәяси идарәсенә тапшырыла. Мөхәррире — Я.Ярмәкиев. Хәрби хәбәрчеләре булып И.Гази (псевд. — лейтенант И.Зарипов), Г.Галиев, Г.Кутуй (псевд. К.Гаделшин), М.Максуд, М.Садри эшли.

*Әд.:* Айнутдинов А.К. Летопись подвига: Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет. К., 1984.

**КЫЗЫ́Л СУКАЧЫ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* көнбатыштарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 31 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 1924 тә нигез салына. Беренче исеме — Красный Пахарь. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлки волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 463, 1938 дә — 544, 1949 да — 423, 1958 дә — 300, 1970 тә — 205, 1979 да — 128, 1989 да — 51, 2002 дә — 50 кеше.

**КЫЗЫ́Л ТАҢ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 6 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1938 дә — 97, 1949 да — 124, 1958 дә — 42, 1970 тә — 58, 1979 да — 39, 1989 да — 25, 2002 дә — 8 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ТАҢ»**, Башкортстан Республикасының көндәлек иҗтимагый-сәяси газетасы. Оештыручылары: БРның Дәүләт җыены — Корылтае һәм хөкүмәте. Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

1918 елның 1 нче мартыннан Башкортстан Вакытлы революцион советы «Башкортстан» г-тасын чыгара башлый. 1924 нең 2 августыннан Башкортстан ВКП(б) өлкә ком-ты карары б-н 2 мөстәкыйль басма рәвешендә чыга: башк. телендә — «Башкортстан» һәм татар телендә — «Яңа авыл». 1930 ның 1 гыйнварыннан 1941 нең 8 июленә кадәр «Коммуна» исеме б-н басыла. 1944 нең 12 мартында «Кызыл таң» исеме б-н яңадан чыга башлый. Төрле еллардагы мөхәррирләре — М.Йосыпов, Г.Габбасов, И.Насыйри, М.Бикбулатов, Ш.Шәймәрданов, Г.Ризванов, Г.Гозәиров, Ф.Шаяпов, Г.Алмаев, Т.Ахунҗанов, Р.Дашкин, М.Мөлеков, Р.Ханнанов, М.Муллакаев, Ф.Фәтхетдинов (2001 дән). Газетада күренекле әдипләр, публицистлар, галимнәр: Н.Әсәнбаев, Ә.Атнабаев, Ә.Бикчәнтәев, М.Гафури, Ү.Гыймадиев, Г.Гомәр, Д.Исламов, М.Бакиров, С.Кудаш, Р.Кузиев, А.Мирзаһитов, И.Низамов, С.Поварисов һ.б. хезмәттәшлек итә. Республиканың иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади, мәдәни тормышын яктырта. Редакция кушымталар да чыгара: балалар өчен «Очкын» исем. атналык газета һәм айлык «Әллүки» ж-лы. Газета Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**«КЫЗЫ́Л ТАҢ»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. РКП(б)ның Пермь губкомы агитация һәм пропаганда бүлеге каршындагы татар секциясе һәм Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатлары Советының губерна башкарма ком-ты каршындагы милләтләр эше бүлеге органы. 1920 елның апреленнән 1922 нең 15 февраленә кадәр Пермь шәһәрендә татар телендә 55 саны нәшер ителә. Баштагы атамасы — «Шәрекъ ачкычы». Нашире — Пермь дәүләт нәшрияты. Төрле елларда мөхәррирләре — Р.Халиков, С.Хәсәнкаев, Ә.Юнысов.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.


*Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л ТАРХА́Н** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле —

кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1923 тә Олы Тархан һәм Түбән Тархан авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Олы Тархан волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 299, 1938 дә — 387, 1949 да — 200, 1958 дә — 225, 1970 тә — 241, 1979 да — 163, 1989 да — 125, 2002 дә — 124 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ТАТАРСТА́Н»**, газета; к. «*Ватаным Татарстан*».

**КЫЗЫ́Л ТА́У**, «Түбән Кама» милли паркының бер өлеше (1991 елдан). Урман-дала зонасына тоташучы көньяк тайга тибындагы уникаль урман массивы; Себер ак чыршысы ареалының Кама аръягына күчкән урыны. Боровецкий корабль урманнары исеме б-н мәгълүм. Мәйданы 9539 *га*. Урман массивының шактый өлеше Кама елгасы үзәненең



Кызыл Тау.
Ак чыршылы-яфраклы урман участогы.

сулъяк ярындагы комсу һәм комсыл утырмалардан ясалган беренчел һәм урта дүртенчел террассалары тигезлекләрен били. Нарат урманнары күпчелекне тәшкил итә: караңгы ылыслы (ак чыршы, чыршы) һәм киң яфраклы (имән, юкә) токымнар катнаш куаклы-мүкле наратлыклар; 2 нче яруста имән катнаш наратлыклар, биредә чикләвек куагы, кара җиләк, кызыл бөрлегән, кыяклылар һәм яшел мүкле үлән капламы яхшы үскән. Ак чыршы һәм имән булуга терр-янең геологик төзелеше — бай минераль составлы һәм шактый югары дәрәҗәдә дым тоткарлау үзлегенә ия Пермь системасының карбонат комташлары, комсыл балчык һәм балчыкларның җир өслегенә якын ятуы сәбәпче. Иңкүлекләрдә, аеруча урман массивының үзәк өлешендә, балчыксыл туфракларда катлаулы акчыршылыклар формалашкан. Алар Идел-Кама буе ак чыршы урманнарының төп тибын тәшкил итә, күп төрле көньяк тайга һәм урман-дала үсемлекләренең аеруча тулы флористик составын берләштерә. Бу ак чыршылыкларның аерым участоклары 1972 дә ТРның табигать истәлеге булып билгеләнә. Ак чыршылы урман типларының 3 төркемен аерып йөртәләр: куаклы-кымызлыклы-яшел мүкләләр, аларда исә ак чыршы 2 нче яруста (1 нче яруста нарат) үсә; катнаш — юкәле һәм чикләвек куаклылар, бирердә исә ак чыршы, имән һәм юкә катнаш урманнар хасил итә. Бу урманнарның үлән капламында үсемлекләрнең тайга (кымызлык, сөңгесыман какалия, тамырчалы күрән, май чәчәге, каеш яфрак, күләгә миләүшәсе), киң яфраклы урман (болын наратбашы, Европа тайтоягы, гаҗәеп миләүшә) һәм якты урманнарда урман-дала (зару кәстерәсе, төньяк йогырты, каурыйсыман кыска сабак) төрләре үсә. Мүкле урман төрләре б-н яхшы үскән мүк капламы хас.

Фаунасы тайга һәм дала төрләре б-н катнаш. Кыр тычканы, борындык, дала чуар тычканы, саңгырау күке, күк карга, һөдһөдләр; 1949 да Алтайдан тиен — телеутка кертелә. Кама елгасы тугаена тоташучы участокларда имәнлек чыпчыгы, сары аркалы һәм сары башлы чәперчекләр, кара миләш чыпчыгы, чуар сандугач, урман күгәрчене; гади кара елан; җир-су хайваннарыннан — үлән бакасы, сасы бака, сулыкларда күл һәм буа бакасы яши.

*Ф.Г.Бөрһанов, Г.Г.Миңнекәева.*

**КЫЗЫ́Л ТӘНЛЕ́ ТАЛПАННА́Р** (Trombiculidae), акариформалылар отрядыннан талпаннар семьялыгы. Личинка фазасында, башлыча, имезүчеләрнең вакытлыча эктопаразитлары; олы талпаннар һәм нимфалар паразит түгелләр, башлыча, ерткычлар (вак буынтыгаяклылар һәм аларның йомыркалары б-н туклана). Туфракның өске катламында, кәстә, коелган яфраклар астында яши. Олы талпаннарның гәүдәсенең озынлыгы 2–4 *мм*, гадәттә, кызгылт сары төстә, каты төк (хет) б-н капланган. Личинкалары вак, 0,5 *мм* га кадәр. Авыз аппараты чәнчеп суыручы типта. Үсемлекләрдән яки туфрак өслегеннән личинкалары хайваннарга һөҗүм итә, гәүдәнең йомшак тиреле өлешенә (еш кына колак яфрагының урта куышлыгына) берегә. Хайваннарда һәр сезонда һәм шактый күп санда (50 гә кадәр һәм күбрәк тә) очрый. Личинкалары 3–12 тәүлек дәвамында тукыма сыеклыгы (паразитлар селәгәенең литик компонентлары йогынтысында тукымаларның мезис продукты) б-н туклана, соңыннан алар җиргә кубып төшә һәм прото-, аннан соң дейтонимфага һәм олы затка әверелә. К.т.т. һәр җирдә таралган, аеруча субтропик һәм тропикларда күп төрле һәм күп санлы.

Татарстан терр-ясендә К.т.т.ның 6 төре билгеле, алар арасында аеруча Hirsutiella zachvatkini һәм Neotrombicula autumnalis төрләре күп санда (нигездә, имезүчеләрдә күрелә, кошларда табылмаган) очрый. N. autumnalis һәм N. vulgaris личинкалары кеше тәненә ябышып, кычыту, өлешчә ялкынсыну, бизгәк (тромбидиоз) тудыра.

*В.А.Бойко.*

**КЫЗЫ́Л ТӨБӘ́К** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 31 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшек елгасы бассейнында. 2010 елда 126 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. 1939 га кадәр Чүплек исеме б-н билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышында* (1773–75) Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.Т.тә мәчет (беренче тапкыр 1828 дә телгә алына), су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1588 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостена керә. 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 97, 1859 да — 408, 1870 тә — 453, 1884 тә — 402, 1897 дә — 688, 1906 да — 799, 1913 тә — 822, 1920 дә — 851, 1926 да — 797, 1949 да — 507, 1958 дә — 355, 1970 тә — 365, 1979 да — 287, 1989 да — 168, 2002 дә — 173 кеше.

**КЫЗЫ́Л УРАКЧЫ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 50 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 117 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Башлангыч мәктәп. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Биләр волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1926 да — 36, 1938 дә — 293, 1949 да — 189, 1958 дә — 147, 1970 тә — 153, 1979 да — 133, 1989 да — 129, 2002 дә — 126 кеше.

**«КЫЗЫ́Л УРА́Л»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Чиләбе губкомы каршындагы төрки халыклар коммунистлары бюросы һәм милләт эшләре буенча губерна бүлеге каршындагы татар-башкорт бүлекчәсе органы. 1920–22 елларда Чиләбе шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. 1920 дә кушымта итеп «Яшьләр» г-тасын чыгара.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Каримуллин А. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**КЫЗЫ́Л УТА́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Оры елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 89 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан Семёнов Утары буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.У.да мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 970,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Шиньша волостенда, 1920 дән — ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 54 ир-ат; 1859 да — 461, 1897 дә — 587, 1908 дә — 509, 1938 дә — 399, 1949 да — 317, 1958 дә — 256, 1970 тә — 208, 1979 да — 188, 1989 да — 121, 2002 дә — 98 кеше.

**КЫЗЫ́Л ХАЧ ҖӘМГЫЯТЕ́**, аз keремле һәм социаль яктан яклaнмаган халык төркеменә мед.-көнкүреш ярдәме күрсәтүче иректә хәйрия җәмгыяте. Төп эш юнәлешләре: йогышлы авыруларны кисәтү һәм бетерү буенча чаралар үткәрү; гадәттән тыш хәлләргә дучар булганнарга, сугышта яраланучыларга һәм хәрби әсирләргә ярдәм итү. Күнбатыш Европа илләрендә К.Х.җ. 1863 елда оештырыла башлый. Россия 1863 елгы Женева конвенциясен хуплый һәм 1867 дә аңа кушыла, Александр II җәмгыять Уставын раслый. Россия К.Х.җ. гадәттән тыш хәлләр вакытында, 1878 дә чума, 1879 да дифтерия эпидемияләре б-н көрәштә, 1911 дә ачлыктан җәфа чигүче халыкка ярдәм итүдә катнаша. 1917 дә К.Х.җ.дә 45 мең табиб, 20 мең шәфкать туташы, 50 меңнән артык санитар эшли.

1886 да Казанда Россия К.Х.җ. бүлеге (1890 нан Кызыл Хач общинасы) оештырыла. 1925–89 да — РСФСР Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай җәмгыятенең республика бүлеге; 2002 дән — Россия К.Х.җ.нең Татарстан бүлеге. 1989 дан ул БМОның Балалар фондында (ЮНИСЕФ) Татарстан вәкиле булып тора һәм халыкара К.Х.җ., Кызыл Хач һәм Кызыл Ярымай җәмгыяте лигасы составына керә. Россия К.Х.җ. дәүләт органнары, җәмәгать оешмалары һәм төрле оешмалар б-н хезмәттәшлек итә. Иң югары җитәкче орган — конференция (5 елга 1 үткәрелә), анда комитет, президиум һәм бюро сайлана, түбәнге оешмалар районнарда һәм шәһәрләрдә терр. принцип нигезендә төзелә.

Казанда К.Х.җ. бүлеге 1886 ның 22 октябрендә Казан Мәрьям Ана могҗизалы иконасы бәйрәме көнендә төзелә; Кызыл Хачның губерна попечительлеге 1881 нең 26 сентябрендә раслана. Бүлек рәисе итеп җәмәгать эшлеклесе В.Д.Мещерина сайлана, рәис урынбасары генерал-лейтенант П.П.Казанский, штаб әгъзалары — Казан губернаторы П.А.Полторацкий, губерна земствосы идарәсе рәисе И.М.Останков, Казан һәм Зөя архиепискобы Павел, губерна дворяннары башлыгы С.Н.Теренин, генерал-лейтенант К.В.Граве, шәһәр башлыгы С.В.Дьяченко, шәһәрнең мактаулы гражданы В.И.Заусайлов, Казан ун-ты профессорлары Л.Л.Лёвшин, Н.Н.Феноменов, Е.И.Радзишевская һ.б. Түбәндәге иганәчелек юнәлешләре раслана: уңдырышсыз елларда зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү (азык-төлек, мед. әйберләре, кием-салым); түләүсез тукландыру ашханәләре, ашханәләргә һәм икмәк пешерүгә акчалата ярдәм оештыру; губерна өязләрендә шәфкатьлелек учреждениеләре төзү һ.б. К.Х.җ. шәфкать туташларын әзерләү б-н шөгыльләнә. Ике еллык курс теоретик (лекцияләрне Л.Л.Лёвшин, В.С.Бронников, П.П.Плюшков, Б.А.Блохин, рухани Преображенский укый) һәм гамәли дәресләрне үз эченә ала. Укуны тәмамлаган шәфкать туташлары кимендә ике ел хезмәт итәргә һәм, сугыш башланган очракта, К.Х.җ. бүлегенә килергә тиеш булалар. 1895 тә җәмгыятьтә 25 әгъза исәпләнә. 1890 да Казан Кызыл Хач шәфкать туташлары бүлеге К.Х.җ.нең Казан шәфкать туташлары общинасы итеп үзгәртелә.

1889–92 дә тиф һәм ваба эпидемияләре вакытында Казан общинасының 15 шәфкать туташы көмеш медальләр б-н бүләкләнә (В.Адамович, А.Богоспасаева, А.Иванова, М.Иванова, С.Климентова, А.Кононникова, Е.Лепихина, Е.Малинина, Е.Маркова, А.Морозова, Е.Никулина, С.Сабинина, О.Санникова, С.Соболева, В.Степанова). Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышлары елларында ашыгыч мед. ярдәме күрсәтүче сан. отрядлары, дезинфекция үткәрү һәм эпидемия б-н көрәшү отрядлары, тимгелле тиф һәм ваба б-н авыручылар өчен махсус госпиталь һәм лазаретлар төзелә. Казан Кызыл Хач эгидасы астында Ф.И.Шаляпин солдатлар өчен 2 лазарет ача һәм аларны үз акчасына тота. К.Х.җ. аналар һәм балаларны саклау проблемаларын даими күзәтчелеккә ала. 1920–30 да Казан җәмгыяте үз эшчәнлеген туберкулёз, трахома, бизгәк һәм ачлык б-н көрәшүгә юнәлтә. Амбулаторияләр, дәвалау-профилактика учреждениеләре, бала тудыру йортлары ачыла; сан. дружиналары, «кызыл шәфкать туташлары» курслары. «Яшь пионерлар сәламәтлеге хезмәте» оештырыла, Шеланга, Ключищи, Моркваш авылларында санаторий юнәлешендәге пионер лагерьлары ачыла. 1930 да Казан К.Х.җ. «Эпидемия б-н көрәшүдән хезмәт һәм көнкүрешне сәламәтләндерүгә» лозунгы б-н чыга. Татарстанда К.Х.җ. катнашында керләр юу, мунча һәм сан. тикшерү пунктлары оештырыла, җәмәгать ашханәләрендә, тулай торакларда һ.б. сан. контроле булдырыла, мед. техникларын, санитарлар, дезинфекторлар, фармацевтлар, парикмахерлар, мунча һәм кер юуу урыннары башлыкларын, ш.у. сан. дружиналары әзерләү алып барыла. Мед.-сан. идарәсе карамагына парикмахер пунктлары, дезбюролар, сан.-гигиена кибетләре һәм лавкалары тапшырыла. 1934 тә Россия К.Х.җ. «СССРны санитар саклауга әзер бул!» күкрәк билгесен раслый. 1938 дә СССР ХКС карары б-н К.Х.җ. хуҗалык һәм сан.-дәвалау эшчәнлегенә алына. 1939 да пр-тиеләрдә колхозларда, совхозларда сан. постлары һәм дружиналары төзелә, сан. саклану белгечләре әзерләү алып барыла.

Бөек Ватан сугышы елларында Җәмгыять яралы һәм авыру сугышчыларга мед.-көнкүреш ярдәме күрсәтү, фронт өчен мед. шәфкать туташлары әзерләү эшчәнлеге алып бара (Казан К.Х.җ. 3,4 мең шәфкать туташы әзерли). Госпиталь палаталары һәм балалар йортлары шефлыкка алына, донорлык хәрәкәтләре барлыкка килә (1944 тә «СССРның мактаулы доноры» билгесе раслана, сугыштан соңгы елларда бушлай кан бирү оештырыла), авыруларга, сугыш һәм хезмәт ветераннарына мед.-социаль ярдәм күрсәтү өчен патронаж хезмәте (соңрак шәфкатьлелек хезмәте) төзелә.

1960 елларда Җәмгыять ялгыз һәм өлкән яшьтәге кешеләр өчен шәфкать йортлары төзүдә һәм җиһазландыруда ярдәм итә. 1967 дә тынычлык өчен көрәштә актив катнашканы өчен совет К.Х.җ. Ленин ордены б-н бүләкләнә. 1980–90 да республика К.Х.җ. акчасына Аксубай (Аксубай а.), Алексеев (Биләр а.), Апас (Апас а.), Тәтеш (Шемякино а.), Питрәч (Күн а.), Чирмешән (Чирмешән а.) р-нnарында, Буа шәһәрендә өлкәннәр өчен интернат йортлар төзелә; Казанда К.Х.җ. акчасына вакытлыча яшәп тору өчен пансионат йортлар ачыла, 22 ашханәдә бушлай тукландыру оештырыла. Төрле елларда хөкүмәтара килешүләр кысаларында Әрмәнстан, Башкортстан, Таҗикстан, Төньяк Осетия-Алания, Абхазия, Ингушетия, Бурятия, Грузия, Саха-Якутия, Чечен, Таулы Карабах респ-калары, Иркутск өлкәсе, Краснодар, Ставрополь төбәкләрендә көтелмәгән һәлакәтләргә дучар булучыларга ярдәм күрсәтелә. 1998 дән К.Х.җ.нең туберкулёз һәм СПИДны булдырмауга һәм дәвалауга юнәтелгән программалары эшли.

Хәзерге вакытта К.Х.җ. эшчәнлегендә һәлакәткә, гадәттән тыш хәлләргә дучар булганнарга ашыгыч гуманитар ярдәм күрсәтүгә, интегүчеләргә мед. ярдәме һәм матди ярдәм күрсәтү, качакларга, ирексездән күчеп килүчеләргә, репрессия корбаннарына һәм элекке тоткыннарга квалификацияле юридик ярдәм күрсәтү; өлкәннәр һәм гарипләр өчен хәйрия йортлары һәм вакытлыча яшәү урыннары төзүгә, шәфкать туташлары хезмәтенә, бушлай кан тапшыруга; сугыш һәм кораллы бәрелешләр, көтелмәгән хәлләрдән соң хәбәрсез югалганнарны эзләүгә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга зур игътибар бирелә. Ел саен 8 майда Татарстанда халыкара К.Х.җ. көне билгеләп үтелә, хәйрия концертлары һәм спектакльләре күрсәтелә.

Җәмгыять эшен В.Д.Мещеринова (1881 дән, Кызыл Хачның Казан губерна попечительлеге), Л.П.Базанова (1915 тән, Россия К.Х.җ.нең Казан җирле ком-ты), Р.Г.Рәхимов (1948 дән, Россия К.Х.җ. бүлеге), 1974 тән Россия Кызыл Хач бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан респ-касы төбәк бүлеген Л.М.Әхмәдуллина җитәкли.

2010 елда К.Х.җ.ндә 23,3 мең кеше, төбәк бүлеге штатында 6 хезмәткәр, ирекле лекторлар төркемендә 35 кеше исәпләнә. Җәмгыятьнең матди средстволары әгъзаларның взнослары, җитештерү-хуҗалык эшчәнлеге, хәйрия чаралары, аерым шәхесләрнең кертемнәре, Халыкара К.Х.җ. матди ярдәменнән гыйбарәт.

*Әд.:* Устав Общества «Красного Креста и Красного Полумесяца РТ». К., 1991; БСЭ. М., 1974. Т. 18.

*Л.М.Әхмәдуллина, Д.Р.Нуретдинова, Т.Ф.Степанова.*

**КЫЗЫ́Л ЧАПЧА́К** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 33 *км* көньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2010 елда 470 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Ч.та мәчет, 2 мәктәп эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1788,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр — Уфа губернасының Минзәлә өязе Су-

харево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 736, 1897 дә — 1060, 1912 дә — 1413, 1920 дә — 1421, 1926 да — 1021, 1938 дә — 1082, 1949 да — 767, 1958 дә — 836, 1970 тә — 1093, 1979 да — 749, 1989 да — 530, 2002 дә — 498 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЧАТЫ́Р** (Centaurium), гентианачалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади яки кече (C.erythraea яки C.minus) үсә. Идел алдында очрый. Республика терр-ясе аша ареалының төньяк чиге уза. Болыннарда, куаклар арасында, урман аланнарында үсә. 15–30 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабагы туры, дүрт кырлы. Тамыр яны яфраклары озынча — кире йомыркасыман, яфрак таралгысында, 5 сеңерчәле, сабактагылары — ланцетсыман. Чәчәкләре алсу, калкансыман чәчәк төркемендә. Җимеше күпсанлы көрән орлыклы тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрь өлгерә. Җир өсте өлешләрендә алкалоидлар, гликозидлар, эфир мае, органик к-талар бар. Үлән төнәтмәсе ашкайнату органнарының эшчәнлеген яхшырта һәм халык медицинасында ашказаны-эчәк, бавыр һәм үт куыгы авыруларын дәвалаганда файдаланыла. К.ч. үләне — аппетитны күтәрүче үлән җыелмалары компоненты. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫЗЫ́Л ЧӘЧӘ́К** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 30 *км* көнбатыштарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 67 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Кукмара р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 181, 1949 да — 211, 1958 дә — 112, 1970 тә — 146, 1979 да — 99, 1989 да — 60, 2002 дә — 62 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЧИШМӘ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 28 *км* көньяктарак, Бәрән елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Биләр р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1938 дә — 225, 1949 да — 284, 1958 дә — 120, 1970 тә — 113, 1979 да — 63, 1989 да — 15 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЧИШМӘ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 38 *км* төньяк-көнбатыштарак, Карабаш сусаклагычыннан 5 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 34 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1933 тә нигез салына. Оештырылган көннән Әлмәт р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан — Лениногорск, 1959 ның 26 мартыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 444, 1949 да — 490, 1958 дә — 418, 1970 тә — 263, 1979 да — 141, 1989 да — 62, 2002 дә — 77 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЧИШМӘ́** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 31 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының (Олы Сөлчәнең уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 34 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Беренче Май р-нында, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1938 дә — 444, 1949 да — 490, 1958 дә — 418, 1970 тә — 263, 1979 да — 141, 1989 да — 48, 2002 дә — 56 кеше.

**КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 17 *км* көнчыгыштарак, Казансу елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 61 кеше (татарлар) яши. Клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан авыл р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 192, 1949 да — 199, 1958 дә — 165, 1970 тә — 166, 1989 да — 94, 2002 дә — 92 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ»**, газета; к. *«Себер юксыллары»*.

**«КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Уральск губкомы каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары бюросы органы. 1919 елның 15 июленнән 1920 нең 30 ноябренә кадәр Уральск шәһәрендә (Казакъстан) татарча атнага 2 тапкыр, барысы 33 саны нәшер ителә. «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг б-н чыга. Татар, башкорт, кыргыз халыкларының революцион хәрәкәте тарихын яктырта.

*Әд.:* Гайнанов Р.Ф., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать (1905–1924). К., 1999.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби-нәфис һәм фәнни-популяр журнал. Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы һәм РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты органы. Мәскәүдә 1918–20, 1922–23 елларда, Казанда 1920–21 елларда татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Б.Мансуров. «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» лозунгы астында чыга. С.Атнагулов, М.Борындыков, С.Вафин, А.Енукидзе, Г.Ибраһимов, И.Казаков, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ә.Мөхетдинова, Ә.Сәгыйди, Г.Шәрәф, В.Шәфигуллин һ.б. язмаларын бастыралар. Газета Шәрекъ халыклары коммунистлар оешмасының 2 нче Бөтенроссия съезды эшчәнлеген, Коммунистик интернационалның 2 нче Конгрессы, ТАССРның 1 нче съезды эшен киң яктырта. Журналда К.Әмири, В.Җәләл, Б.Рәхмәтуллин, Х.Сәгыйди, Сүнчәләй шигырьләре; язучы һәм философ Р.Тагор иҗатына багышланган махсус мәкаләләр сериясе, Ә.Сәгыйди тәрҗемәсендә аның шигырьләре басыла.



«Кызыл Шәрекъ» журналы.

*Әд.:* Фасахов К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать в восстановительный период). К., 1979.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ ЯШЬЛӘРЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКСМның Себер өлкә ком-тының кыргыз-татар секциясе органы. 1920 елның 15 маеннан 20 сентябренә кадәр Омск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**«КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ ЯШЬЛӘРЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. РКСМның Уральск шәһәр ком-тының татар секциясе органы. 1920 елның июлендә Уральск шәһәрендә (Казакъстан) татар телендә нәшер ителә. Башлангыч 3 саны «Яшь көрәшче» исеме б-н чыга. Мөхәррире — Г.Төхфәтуллин.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978.

**«КЫЗЫ́Л ШӘРЕ́КЪ ЯШЬЛӘРЕ́»**, журнал; к. *«Колхоз яшьләре»*.

**«КЫЗЫ́Л ШИМА́ЛЬ»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Петроград ком-ты карамагындагы губерна төрки халыкларының пропаганда һәм агитация бюросы, РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-тының Петроград ком-ты татар бүлеге органы. 1918 елның 25 июленнән 1921 нең 7 ноябренә кадәр Петроградта татар телендә нәшер ителә. 1918 нең 4 октябренә кадәр «Хөррият» исемендә чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — Х.Гайнуллин, Б.Мансуров. Актив авторлар арасында Ч.Илдарым-Солтан, Х.Мәүлетов, Я.Мәмишев, М.Мирсадыйков, И.Рәхмәтуллин, Ч.Солтанов, Б.Талыбов, Н.Яруллин була. «Бөтендөнья хезмәт ияләре, берләшегез!» лозунгы б-н чыга. Газета чит ил интервентларыннан Ватанны сакларга чакыра; халыкның ярлы катлавы арасында коммунистик идеяләр тарату һәм буржуазиягә каршы сыйнфый көрәшне активлаштыру яклы була. «Авыллардан яңалык-

лар» исемле даими рубрикада а.х.ндагы хәлләрнең торышы, наданлыкны бетерү эшчәнлеге турында информация бирә, авылларда коммунистик агитацияне көчәйтергә чакыра. Германия, Польша, Чехия, Румыния, Норвегиядә революцион хәлләрне яктырта. Үзенең төп идея дошманнары — Мөселман ком-ты һәм Милли Шураның эшчәнлеген тәнкыйтьли. Россия мөселман коммунистларның 1 нче съезды эшчәнлеген яктырта. Клублар, уку заллары, китапханәләр һ.б. ачылу турында белдерүләр бастыра.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«КЫЗЫ́Л ЭШЧЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Эчке Россия мөселман эшләре комис-тының Харьков бүлеге органы. 1920 елда Харьков шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**КЫЗЫ́Л ЮЛ** посёлогы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зичә елгасы бассейнында. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 1926 да Югары Лоҗы һәм Кызыл Кадка авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Токмак волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1938 дә — 107, 1949 да — 69, 1958 дә — 81, 1970 тә — 108, 1979 да — 54, 1989 да — 23, 2002 дә — 7 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЮЛ** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 62 *км* төньяктарак, Шәрбән елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 103 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 67%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1938 дә — 419, 1949 да — 268, 1970 тә — 499, 1979 да — 344, 1989 да — 244, 2002 дә — 180 кеше.

**КЫЗЫ́Л ЮЛ** посёлогы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаллы — Түбән Кама автомобиль юлы буенда. 2010 елда 41 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Чаллы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 136, 1949 да — 101, 1858 дә — 71, 1970 тә — 95, 1979 да — 52, 1989 да — 9, 2002 дә — 30 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ЮЛ»**, атналык сәяси һәм әдәби журнал. 1921 елда Ташкентта үзбәк һәм татар телләрендә нәшер ителә. Журнал эшендә Ш.Әхмәдиев катнаша.

**«КЫЗЫ́Л ЮЛ»**, газета; к. «*Урал*».

**КЫЗЫ́Л ЮЛ РАЙОНЫ́**, к. *Тукай районы.*

**КЫЗЫ́Л ЯЛА́Н** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Талкыш елгасы буенда. 2010 елда 321 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет (1848 дә төзелә; архит-ра ядкәре; Татар Талкышы авылыннан күчерелә). Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Мөслим волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 550, 1949 да — 516, 1958 дә — 402, 1970 тә — 488, 1979 да — 406, 1989 да — 314, 2002 дә — 337 кеше.

**«КЫЗЫ́Л Я́У»**, кызылармиячеләр газетасы. Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясе Революцион Хәрби Советының сәяси бүлеге органы. 1918 елның 6 декабреннән 1919 нең 7 ноябренә кадәр Бөгелмә, Уфа, Чиләбе, Омск шәһәрләрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 101 саны чыга. Башта атнага 2, 1919 нең апрелендә Уфа Кызыл Армия тарафыннан алынганнан соң, атнага 1 тапкыр чыга. 1919 ның май–июнь айларында «К.я.» редакциясе акгвардиячеләр арасында тарату өчен «Өндәү» г-тасын чыгара. Төрле елларда мөхәррирләре — Г.*Баембәтов*, С.*Атнагулов*, Ф.*Әхмәтов*. Актив авторлар арасында Х.Искәндәров, Г.Нигъмәти, И.Рәмиев, Х.Сәлимов, М.Тимербаев, Ш.Фидаи, Ш.Ходайбердин, С.Шәрәфетдинов, М.Йосыпов, К.Якупов була. Омск шәһәрендә 1919 ның 23 декабреннән «К.я.» нигезендә «*Азат Себер*» г-тасы чыга башлый.

*Әд.:* Башкортстан милли матбугат альбомы // Ватандаш. 2003. № 3; А д а м о в З.А. Роль большевистской печати Башкирии в установлении и упрочении Советской власти (1917–1918): Дис. ... К., 1966; Н а с ы р о в Т.М. Из истории красноармейской печати на татарском языке (1918–1920) // Татария в период Октября. К., 1970; К а р и м у л л и н А. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

*Т.М.Насыйров.*

**КЫЗЫ́Л ЯШЬЛӘ́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 105 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, урман хуҗалыгы; агач эшкәртү цехы. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Халык саны: 1949 да — 109, 1958 дә — 114, 1970 тә — 113, 1979 да — 110, 1989 да — 120, 2002 дә — 101 кеше.

**«КЫЗЫ́Л ЯШЬЛӘ́Р»**, к. «*Татарстан яшьләре*».

**КЫЗЫЛБА́Ш** (Sanguisorba), роза чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үлән, сирәк кенә ярымкуаклар һәм куаклар ыругы. 30 га якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — дарулы К (S. officinalis) таралган. Кече елгаларның тугайларында, куаклар арасында, урман буйларында һәм аланнарда үсә. Кыска тамырчалы күпьеллык үләнчел үсемлек. Сабагы туры, өске өлешендә тармаклы, биеклеге 30–90 *см*. Яфраклары сыңар каурыйсыман, чите тешле, йомыркасыман-озынча, өске ягы ялтыравыклы, кара яшел, аскы ягы күк, тонык; тамыр яны яфраклары эре, озын саплы, очы түгәрәкләнгән, чите тешле. Чәчәкләре вак, кара кызыл, башаксыман тыгыз чәчәк төркемендә. Җимеше — саргылт көрән 4 кырлы чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Тамыр һәм тамырчаларында дуплау матдәләре, крахмал, эфир мае, сапониннар, органик к-талар, микроэлементлар бар. Халык медицинасында тамыр һәм тамырчаларыннан әзерләнгән төнәтмә кан туктату, ялкынсынуга каршы һәм бөрештергеч чара буларак кулланыла.



Дару кызылбашы.

**КЫЗЫЛКАНА́Т** (Scardinius erythrophtalmus), карплар семьялыгындагы төче су балыгы. Европа сулыкларында (Төньяк Боз океанына коючы елгалардан башка), сирәк кенә Азиядә очрый. Татарстан терр-ясендә су үсемлекләре мул үскән күл, буа һәм елгаларда яши. Озынлыгы 25 *см* га кадәр, ян-яктан берникадәр кысынкы, тәңкәсе чагыштырмача эре. Авырлыгы 300–400 *г*. Сырты коңгырт яшел, ян-яклары металлга хас ялтыравыклы сары төстә, корсак өлеше көмешсыман ак. Пар аналь һәм койрык йөзгечләре ачык кызыл (исеме шуннан) төстә. Йөткылык тешләре ике рәтле. Уылдыгын яз ахыры — җәй башында, өлешләп, су үсемлекләренә чәчә. Үрчемлелеге — 36–138 мең уылдык бөртеге. Яшәвенең 2–3 елында җенси яктан өлгерә. Су үсемлекләре, моллюск уылдыклары, вак умырткасызлар б-н туклана.

**КЫЗЫЛКУ́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 30 *км* көнчыгыштарак, Казансу елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 24 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1938 дә — 212, 1949 да — 190, 1958 дә — 177, 1970 тә — 88, 1989 да — 37, 2002 дә — 30 кеше.

**КЫЗЫЛЛА́Р ҺӘМ АКЛА́Р ТЕРРОРЫ́**, билгеле бер тәртипне көчләп тагу максатында сәяси дошманнарны индивидуаль һәм массачыл җәзалау актлары. Сәяси карашлары хакимият органнарының теге яки бу терр-ядә урнаштырган төп кагыйдәләре б-н тәңгәл килмәгән кешеләр террор корбаннарына әверелә. 1918 елда җәза чараларын нигезләү һәм аклау максатында вакытлы матбугатта даими рәвештә сәяси дошманнарның сыйнфый характеристикалары басыла башлый. Большевиклар һәм аларның дошманнары махсус көч куллану органнары оештыралар. ХКСның В.И.Ленин тарафыннан имзаланган 1917 ел 7 (20) декабрь карары б-н киң вәкаләтләр бирелгән, башлыча, репрессив характердагы Бөтенроссия гадәттән тыш контррев-ция, спекуляция һәм саботаж белән көрәш комиссиясе (ВЧК) төзелә. Ул заложниклар алырга, эзләү һәм тентү-тикшерү уздырырга, хө-

кем карарлары чыгарырга һәм аларны гамәлгә ашырырга хокуклы була. Хәрби трибуналлар да шундыйрак вазифалар башкара. Массачыл террор уздырганда аларга Совет дәүләтенең күпсанлы көч структуралары буйсына. Сәяси дошманнар б-н көрәш формасы буларак террор большевиклар тарафыннан РСФСР ХКС ның «Кызыл террор хакында» дип аталган 1918 ел 5 сентябрь карары б-н законлаштырыла. Бу карарда дошманнарны концлагерьларда тоту зарур, «заговорларга, фетнәләргә һәм акгвардиячеләр оешмаларына мөнәсәбәтле затлар атылырга тиеш», диелә. Әлеге чорда күп кенә газеталарда һәм журналларда «Кызыл террор» дип аталган махсус җәза рубрикасы булдырыла, анда Сов. хакимиятенең атып үтерелгән дошманнарының исемлекләре басыла. Террор Гражданнар сугышы дәвамында дәүләтнең рәсми сәясәте була. Большевиклар җитәкчеләренә ясалган һөҗүмнәр массачыл кызыл террорның киң колач алуына китерә. Сәяси дошманнардан тыш илнең төп халкы — крәстияннәр дә террорга дучар ителә. Бу заложниклар итеп алынган таза тормышлы крәстияннәрне һәм баш күтәрүчеләрне атып үтерүләрдә, азык-төлекне тартып алуларда һ.б.да чагылыш таба. Беренче тапкыр массачыл террор киң күләмдә 1918 нең җәй-көз айларында уздырыла.

Казан губернасында Окт. рев-циясеннән соң контррев-циягә каршы көрәшү өчен губерна революцион трибуналының Тикшерү комиссиясе каршында махсус бүлек булдырыла, аның җирлегендә 1918 нең гыйнварында Гадәттән тыш комиссия (к. *Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитеты)* оештырыла, ул төбәктә кызыл террор уздыручы төп органга әверелә. 1918 нең көзендә КОМУЧ (к. *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты*) гаскәрләре тар-мар ителгәннән соң, Казан гадәттән тыш комиссиясе рәисе М.И.Лацис әмере буенча шәһәрдә масса күләм атулар уздырыла (А.Н.*Боратынский,* эсер Б.Фликкель, күп кенә элеккеге офицерлар, ш.у. комучлылар б-н хезмәттәшлек иткән шәһәр кешеләре атып үтерелә). Сәяси репрессияләргә күпме кеше дучар ителүе (ш.и.атылуы) турында төгәл мәгълүматлар юк. Казан губчекасы мәгълүматлары буенча, 1919 ның 7 аенда 117 кеше атыла.

Аклар терроры да шулай ук рәхимсез була. 1918 нең августында Казанны алган комучлылар ш.у. дәүләт сагы хезмәте (контрразведка) оештыралар, ул дошманнарны ачыклау б-н шөгыльләнә. 1918 нең 11 августында Казанда шәһәр коменданты генерал-лейтенант В.В.Рычков рәислегендә хәрби-кыр суды була. Беренче атналарда ук партия һәм сов. хезмәткәрләре М.М.*Вахитов*, С.Н.*Гассар*, А.П.*Комлев*, М.И.*Межлаук*, Я.С.*Шейнкман* һ.б. атыла. Комучлылар сәяси дошманнарны төрмәләргә утырталар, авылларга җәза отрядлары җибәрәләр, крәстияннәрне кыйныйлар, эшчеләрне үтерәләр. Казанда комучлылар рәхимсез рәвештә эшчеләр күтәрелешен бастыралар: В.В.Рычков әмере б-н эшчеләрне туплардан һәм пулемётлардан аттыралар. Комучлылар терроры Казан губернасы өязләрендә дә котырына: Чистай өязенең Егоркино авылында кулга алынганнар төркемен үзләре өчен кабер казырга мәҗбүр итәләр, шуннан соң аларны аталар; Спас өязендә укытучы М.А.Вертинская-Аросева атып үтерелә һ.б.

Ш.у. к. *Гражданнар сугышы, Арча ягы крәстияннәре кузгалышы, «Сәнәкчеләр» фетнәсе.*

Чыг.: Казанская губернская Чрезвычайная Комиссия (1917–1922): Сб. док. и материалов. К., 1989.

*Әд.:* Л и т в и н А.Л. «Дело сдать в архив...»: ВЧК в Татарии в 1917–1920 гг. К., 1986; ш у л у к. Красный и белый террор в России. 1918–1922 гг. К., 1995.

**КЫЗЫЛСУ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 25,7 *км*, бассейнының мәйданы 144 *км*². Елга башы Әтнә р-нының Яңа Җөлби авылыннан 3 *км* төньяктарак, Арча р-ны терр-ясеннән ага, тамагы Биектау р-нының Сасмак авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 2%. К.ның 0,7 дән алып 9,8 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар; иң зурысы (сул) — Орнаш Чишмә елгасы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Явым-төшем күзәтелмәгән елларда җәен елга еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 136 *мм*, ташу агымы катламы 105 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 0,4 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЫЗЫЛТАМЫ́Р**, к. *Эфедра.*

**КЫЗЫЛТА́У** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 278 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1929 да Иске Кыязлы авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Көтеш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1940 ның 26 апреленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1949 да — 376, 1958 дә — 416, 1970 тә — 600, 1979 да — 513, 1989 да — 344, 2002 дә — 325 кеше.

**КЫЗЫЛТА́У** посёлогы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үмәк елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (татар, рус) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонының Чиркәс волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1938 дә — 89, 1858 дә — 88, 1970 тә — 44, 1977 дә — 6, 2002 дә — 7 кеше.

**КЫЗЫЛТА́У** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 32 *км* көнбатыштарак, Бола елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 352 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 1946 га кадәр Коллар исемен йөртә. 1861 елгы реформага кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 мәчет, мәдрәсә, 3 җил һәм 1 су тегермәне, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1811,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 232 ир-ат; 1859 да — 1150, 1897 дә — 1296, 1908 дә — 1630, 1920 дә — 1542, 1926 да — 1334, 1949 да — 895, 1958 дә — 755, 1970 тә — 796, 1979 да — 645, 1989 да — 414, 2002 дә — 409 кеше. К.да әдәбият галиме М.Х.*Гайнуллин* туган.

**КЫЗЫЛТА́У** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 30 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Өске елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 104 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм; 1954 кә кадәр Югары Биләтли исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 473 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 27 ир-ат; 1859 да — 163, 1897 дә — 299, 1908 дә — 350, 1920 дә — 398, 1926 да — 387, 1958 дә — 257, 1970 тә — 271, 1979 да — 238, 1989 да — 173, 2002 дә — 131 кеше.

**КЫЗЫЛТҮ́Ш** (Fringilla coelebs), тау чыпчыклары семьялыгыннан сайрар кош. Европа, Көнбатыш Азия һәм Төньяк-көнбатыш Африка урманнарында яши. Татарстанда оя коручы күчмә кошларның аеруча гадәти һәм күпсанлы төрләренең берсе. Зур түгел, гәүдәсенең озынлыгы 15 *см* тирәсе. Ата кошлар кауры́й капламының аксыл төстә булуы б-н аерыла: түш һәм яңаклары коңгырт-кызыл, башы — зәңгәр-соры, аркасы — кара, канаты — ак буйлы; ана кошлар тоныграк яшькелт соры, түше соры коңгырт төстә. К. Якын Көнчыгышта һәм Кавказ аръягында кышлый.

Апрельнең икенче ункөнлегендә (ата кошлар аналарга караганда берничә көнгә иртәрәк килә) очып киләләр. Урманнарда (биек кәүсәле агачлар үсмәгән куаклыклардан һәм иң караңгы урман участокларыннан тыш), бакча, парк, скверларда оялый. Ана кош оясын 1,5–10 *м* биеклектә, ылыслы һәм яфраклы агачларда ясый, гадәттә, куш кәүсәдә яки калын ботакта урнаштыра. Кагыйдә буларак, 5–6 йомырка сала. 13–14 көн утыра. Якынча 2 атнадан кош балалары ояны ташлап китә. Алар күбрәк вак умырткасызлар, башлыча, коңгызлар б-н туеналар. К. бер сезонда еш кына 2 тапкыр бала чыгара һәм икенчесендә утырган вакытта беренче оя балаларын да ашата.

**КЫЗЫЛЧА́** (Cotoneaster), роза чәчәклеләр семьялыгыннан яфрак коючан яки мәңге яшел куаклар, сирәк кенә зур булмаган агачлар ыругы. 100 дән артык төре билгеле. Евразиянең уртача поясларында һәм Төньяк Африкада таралган. Татарстанда бер төре: кара җимешле К. (C. melanocarpus) үсә. Республиканың бөтен терр-ясендә, ешрак көньяк районнарда очрый. Ташлы сөзәклекләрдә, известьташларда, якты урманнарда, урман буйларында үсә. 50–100 *см* биеклектәге ябалдашлы куакчык. Яшь ботаклары киезсыман төкчәле, карт ботаклары шома, ялтыравыклы, кызыл-көрән кабыклы. Яфраклары чиратлашкан, йомыркасыман, очы җәенке, еш кына уемтыклы, өсте кара яшел, аскы ягы киезсыман аксыл. Чәчәкләре алсу, вак, берле, яфрак куентыгында. Җимешләре — ончыл йомшаклы һәм 2–5 төшле кара алмалар. Апрель ахыры — май башында чәчәк ата. Җимешләре сентябрь–октябрьдә өлгерә. Яктылык яратучы, корылыкка чыдам үсемлек. Туфракка талымсыз; бакча һәм паркларда үстерелә. Декоратив, аеруча, язын, чәчәк ату вакытында, ш.у. көзен, кызгылт яфрак һәм кара ялтыравыклы җимешләр б-н капланганда матур. Баллы үсемлек. Үзагачы саргылт-алсу, каты, сыгылмалы, вак эшләнмәләр ясауда кулланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 29 *км* көньяктарак, Зирекле елгасы буенда. 2010 елда 11 кеше (татарлар, чуашлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 36, 1938 дә — 69, 1949 да — 44, 1958 дә — 53, 1970 тә — 126, 1979 да — 61, 1989 да — 31, 2002 дә — 13 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 42 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оры елгасы буенда. 2010 елда 169 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 16 йөздә нигез салына; 1917 гә кадәр — Селенгур, 1920–30 еллардагы рәсми чыганакларда Иске Коллар исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 мәчет, җил һәм су тегермәне, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1701,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Шиньша волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 948, 1897 дә — 1300, 1908 дә — 1209, 1949 да — 490, 1958 дә — 405, 1970 тә — 378, 1979 да — 270, 1989 да — 209, 2002 дә — 203 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 52 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1950 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Кызыл Йолдыз р-нында. 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1970 тә — 80, 1989 да — 26, 2002 дә — 12 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 1330 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек; катнаш азык з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1815 тән мәгълүм. 19 йөздә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 3 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4202 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1889 да — 1556, 1908 дә — 2701, 1920 дә — 2386, 1926 да — 1984, 1938 дә — 1550, 1949 да — 1311, 1958 дә — 1407, 1970 тә — 1401, 1979 да — 1360, 1989 да — 1146, 2002 дә — 1285 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** посёлогы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 13 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2002 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, даими яшәүчеләр юк. 1906–11 елларда нигез салына. Беренче исеме — Красноярский. Оештырылган көннән Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда. 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1920 дә — 108 (Иринский, Забродный посёлоклары халкын да кертеп), 1926 да — 37, 1938 дә — 94, 1949 да — 96, 1958 дә — 47, 1970 тә — 42, 1979 да — 17, 1989 да — 5 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Коралшат елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 111 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Мөслим р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 343, 1949 да — 282, 1958 дә — 249, 1970 тә — 240, 1979 да — 370, 1989 да — 136, 2002 дә — 111 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** посёлогы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 6 кеше (татарлар) яши. 1907–12 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирек волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 68, 1938 дә — 63, 1949 да — 70, 1958 дә — 93, 1970 тә — 54, 1979 да — 27, 1989 да — 9, 2002 дә — 6 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** (Яуш) авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Инеш елгасының (Зәйнең сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 107 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1924 тә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Шәңгәлче волостена керә. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 158, 1938 дә — 230, 1949 да — 288, 1958 дә — 280, 1970 тә — 373, 1979 да — 212, 1989 да — 99, 2002 дә — 81 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 16 *км* төньяктарак, Олы Кәминкә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Күтәмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1926 да — 165, 1949 да — 192, 1958 дә — 162, 1970 тә — 208, 1979 да — 176, 1989 да — 101, 2002 дә — 59 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 39 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасы тамагында урнашкан. 2010 елда 251 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1550

дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 1035, 1897 дә — 1089, 1908 дә — 1141, 1920 дә — 1276, 1926 да — 1126, 1938 дә — 1282, 1949 да — 838, 1958 дә — 726, 1970 тә — 545, 1979 да — 387, 1989 да — 315, 2002 дә — 289 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 8 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. Башта ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 112, 1938 дә — 117, 1949 да — 83, 1958 дә — 102, 1970 тә — 122, 1979 да — 94, 1989 да — 49, 2002 дә — 24 кеше.

**КЫЗЫЛЪЯ́Р** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 10 *км* көнчыгыштарак, Сумка елгасы Иделгә койган урында урнашкан. 2010 елда 558 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 53%, татарлар — 45%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантоны Ильинский волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенкий, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1926 да — 14, 1938 дә — 45, 1958 дә — 188, 1970 тә — 1048, 1979 да — 968, 1989 да — 663, 2002 дә — 617 кеше.

**КЫЙБЛА́** (гарәп. قبلة — каршыда), *Кәгъбәгә* караган як: биш вакыт *намаз* укыганда, төрле дини йолалар үткәргәндә, мөселманнар йөз б-н К.га карап торалар. К. юнәлеше үзгәреп торган: күп кенә тикшеренүчеләр фикеренчә, элек Мөхәммәд пәйгамбәр намаз укыганда Иерусалим ягына караган, кайберәүләр пәйгамбәр намаз укыганда йөзе б-н Шәрекъкә карап баскан, дип саныйлар. Мөхәммәд пәйгамбәр Мәдинәгә күчкәч, К. үзгәртелә һәм Мәккә юнәлешендә кала. Мәчетләрдә К. махсус куыш — *михраб* б-н билгеләнә. Мөселманнарны җирләгәндә мәрхүмне кабергә башын К. ягына каратып куялар. Хайван чалганда терлекнең башын К. ягына боралар.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**КЫЙГЫ́ РАЙОНЫ́**, БРның төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1688 *км²*. Үзәге — Үрге Кыйгы авылы (Уфадан 256 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 19064 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 12591, 1979 да — 11096, 1989 да — 10841, 2002 дә — 10306 кеше. Районда 69, ш.и. 14 татар һәм 4 татар-башкорт торак пункты бар. Иң зур татар авыллары (2009): Үрге Кыйгы (7438 кеше), Түбәнге Кыйгы (1431), Еланлы (845), Юкәлекүл (682), Тугызлы (587). 2004/05 уку елында районның 7 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 4 сендә татар теле фән буларак өйрәнелә.

**КЫЙССА́** (гарәп. قصة — хикәя, тарихи вакыйга, риваять), Шәрекъ мөселман халыклары фольклоры һәм әдәбиятындагы (ш.и. татар әдәбиятында) *дастанга* якын булган эпик, кайвакыт лиро-эпик жанр. Гарәп, фарсы һәм төрки телләрдә «К.» атамасы б-н *хикәят*, повесть, әкият, риваять һ.б. жанрларны атыйлар. К. героик, мәхәббәт-романтик, дини-суфи, әкияти, тарихи сюжетларны үз эченә ала, анда гыйбрәтле, маҗаралы, кызыклы вакыйгалар тасвирлана. Шул ук вакытта Шәрекъ әдәбиятына хас чынбарлык б-н фантастиканы берләштергән образлар һәм ысуллар кулланыла; романтик сәнгати фикерләү тибы өстенлек итә. К. тезмә, чәчмә һәм катнаш формаларда була. Кайберләрендә (бигрәк тә шигъри әсәрдә) лирик чигенешләр, автор, әсәр геройларының фәлсәфи уйланулары урын ала. «Кысалы кыйссалар» аерым бер төр тәшкил итәләр. Аларда берничә мөстәкыйль сюжет бер сюжетка берләшә. Татар әдәбиятында К. жанрындагы әсәрләр 13 йөздән үк билгеле (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, Рабгузинең «Кыйссас әл-әнбия»се һ.б.). К.лар бигрәк тә 19 йөздә киң тарала (Ә.Кормаши, Г.Мәхмүдов, К.Минзәләви, Ш.Рәхмәтуллин һ.б.ның поэтик әсәрләрендә).

*Әд.:* Миңнегулов Х. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. К., 1998.


*Х.Й.Миңнегулов.*

**«КЫЙССАИ́ АВЫ́К»** («Тау кәҗәсе турында кыйсса»), 14–15 йөзләр төрки-татар әдәби ядкәре. Авторы билгесез. 38 строфадан тора. Әсәрнең нигезен кәферләр кулына эләккән кыргый тау кәҗәсенең Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан коткарылуы турында маҗаралы сюжет тәшкил итә; кыйссада пәйгамбәрнең мәрхәмәтлелеге һәм гадәттән тыш мөмкинлекләре турында бәян ителә, ныклык һәм әйткән сүзгә тугрылык сыйфатлары хуплана. «К.А.» Идел буе һәм Урал төбәге татарлары арасында зур популярлык казана, һәм аның кульязма нөсхәләре күп таралган була.

*Әд.:* Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.; Хан кызы: Мөнәҗәтләр. К., 1994; Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«КЫЙССАИ́ ЙОСЫ́Ф»** («Йосыф турында кыйсса», 1233), урта гасырлар төрки-татар әдәби ядкәре. Авторы — шагыйрь *Кол Гали.* Поэманың сюжеты Йосыф пәйгамбәр турында Библиядә һәм Коръәндә бәян ителгән кыйссага нигезләнә. Бу темага дөнья, аеруча Шәрекъ (100 гә якын) әдәбияты әсәрләре күпләп багышланган. Әлеге сюжетка беренче булып мөрәҗәгать иткән төрки телле язучы — Кол Гали. Аның әсәре урта гасырлар башы төрки телле әдәбиятлар тарихында яңа сәхифә ача. Урта гасырларның төрки шагыйрьләре Шәйяд Хәмзә, Сүли Фәкыйһ, Дурбәк һ.б. иҗатында да Кол Гали поэмасының йогынтысы сизелә. Әсәрнең фабуласын эшкәрткәндә, автор төрки эпос традицияләренә таяна. Мәсәлән, әсәрнең төп геройлары — чыгышлары б-н төрле илләрдән: Йосыф — Кәнганнан (Палестина, Финикия һәм Сүрия җирләренең борынгы исеме), Зөләйха — Мәгъриб (Төньяк-Көнбатыш Африка) патшасы кызы. Йосыфның тышкы кыяфәтен шагыйрь төркиләрчә итеп тасвирлый: чәчләре толымлап үрелгән. Бу күренеш төркиләр этнографиясе буенча аның аксөякләр нәселеннән булуы турында сөйли. Әсәрдә күп кенә гомумкешелек мәсьәләләре чагылыш тапкан: яхшы б-н яман арасындагы көрәш, кешеләрнең бәхеткә, гаделлеккә, әхлакый камиллеккә омтылуы. Хикәяләүдә шагыйрь гипербола, күпкатлы метафорага мөрәҗәгать итеп, характерларны, вакыйгаларны, конфликтларны эреләтә, геройларның әхлакый асылын ачып бирә. Әсәр үзәгендә — хөкемдар



«Кыссаи Йосыф»ның Дрезден күчермәсе кульязмасының башлангыч бите. 18 йөз ахыры.

һәм аның халык тормышы өчен уңай шартлар тудыруда тоткан роле . Алар Йосыф образы аша хәл ителә. Әсәрнең калган проблематикасы да шушы тема б-н бәйле. Төп герой язмышында ул заман өчен өр-яңа идея — түбән катлам кешесенең хөкемдар дәрәҗәсенә ирешүе гәүдәләндерелә. Ләкин бу әле әсәрнең масштаблы мәгънәсен ачып бетерми. Йосыф күп газаплар кичерә һәм бәхетсезлекләргә юлыга: көнче агалары хыянәте (алар аны агулы еланнар б-н тулган коега ташлыйлар), чит илгә эләгүе, коллыкка сатылуы, зинданга ябылуы. Ләкин ул күңел төшенкелегенә бирелми, намусына хыянәт итми, һәрвакытта да иманлы, дөрес, тотнаклы, нык, сатылмас, гадел, шәфкатьле, гади һәм кеше сөючән булып кала. Төп геройның иң мөһим сыйфаты — тугрылык; бу аның антына, кабиләсенә һәм гореф-гадәтләргә тугрылыгында гәүдәләнә. Шул рәвешчә тугрылык, бәхеткә ирешүнең төп шарты сыйфатында, поэманың лейтмотивы булып китә. Әлеге мотив Йосыфның төшендә чагылып, поэманың ахырына кадәр (Йосыфның атасы б-н очрашуына кадәр) дәвам итә.

Икенче бер әһәмиятле тема — ата б-н бала арасындагы мөнәсәбәтләр. Ягкуб акыл иясе, сабыр, улы б-н кайчан да булса очрашуына ышанып яшәүче зат буларак тасвирлана.

Зөләйха образы да зур әһәмияткә ия. Бу ике персонаж да төп геройга мөнәсәбәтләре аркылы ачыла. Зөләйха, Йосыфны төшендә күреп, аңа гашыйк була. Шул рәвешчә, әсәргә Шәрекъ әдәбиятына хас читтән торып гашыйк булу мотивы килеп керә. Зөләйха укучы күз алдына тугрылык һәм сабырлык үрнәге булып килеп баса. Геройның агалары әсәрдә гомуми планда гына бирелә. Алар индивидуальләштерелмәгән, 11 дән бары 4 сенең генә исеме аталган: Бинъямин, Равил, Йәһүд, Шәмгун. Бинъяминнән башкалары үзара бик охшаш: кече энеләренә карата көнче, алдакчы, рәхимсез. Йосыф исә, Мисыр хакиме булгач, абыйларын кичерә, алар аннан гафу үтенәләр.

Беренче булып поэманы татар шагыйре һәм фикер иясе Г.*Утыз Имәни* өйрәнә. Ул 1824 тә 10 га якын күчермәне чагыштырып, «К.Й.»ның җыелма текстын басмага әзерли. Поэма 1839 да татар мәгърифәтчесе Р.*Әмирханов* тарафыннан нәшер ителә. 1831 дә немец шәркыятьчесе Г.Л.Флейшер Дрезден китапханәсендә саклаган поэманың күчермәсен шәрекъ кулъязмалары каталогына кертә. 1889 да Голландия галиме М.Хоутсма текстның берничә кулъязмасы нигезендә әсәргә сюжет һәм тел ягыннан анализ ясый. 1885 тә поэмага Ш.*Мәрҗани* мөрәҗәгать итә. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтенең 1 нче томында ул поэма теленең Идел буе Болгар дәүләте чоры эпитафияләре б-н охшашлыгы турында яза. 1917 дә язылган хезмәтендә немец шәркыятьчесе К.Брокельман поэманың кайсы милләтнеке икәнен ачыкларга омтылып карый. 1918 дә төрек галиме Ф. Күпрелезадә әсәрнең поэтик үзенчәлекләренә игътибар итә һәм поэманың формасын борынгы төрки халык поэзиясендә традицион булган формалар б-н бәйли. 20 йөзнең 1 нче яртысында поэманы рус һәм татар галимнәре А.Н.Самойлович, Е.Э.Бертельс, Г.Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Б.Ә.Яфаровлар өйрәнә. 20 йөзнең 2 нче яртысында татар галиме Җ.Алмаз поэма текстын фәнни басмага әзерли, ләкин әсәр басылмый кала. 1960–70 елларда әсәрне өйрәнүне татар галимнәре М.Х.Гайнуллин, Х.Г.Госманов, Р.К.Ганиева, Х.Й.Миңнегулов һ.б. дәвам итә. 1983 тә поэманың билгеле булган барлык күчермәләре нигезендә беренче тапкыр җыелма тәнкыйди-фәнни академик басма нәшер ителә. Кулъязмаларны тасвирлау, төп текстларны әзерләү, кереш мәкалә һәм комментарийлар язу эшен Ф.С.*Фасиев* башкара. 1979 да һәм 1984 тә Н.Ш.Хисамовның «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы: Сюжет чыганаклырына һәм автор иҗатына анализ» («Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али: Анализ источников сюжета и авторского творчества», М., 1979) һәм «Бөек язмышлы әсәр» (1984) монографияләре басылып чыга. Бу хезмәтләрдә барлык чыганаклар өйрәнелә. Алар арасында автор төп чыганак итеп Һират (хәзер Әфганстан) галиме Ә.Әнсариның «Әнисәл-мөридин вә шәмсәл-мәҗалис» («Мөридләр дусты һәм мәҗлесләр кояшы») әсәрен (11 йөз) күрсәтә, иң мөһим сюжет мотивларының фольклор-эпик һәм этнографик тамырларын ача, әсәргә төрле яклап филол. анализ ясый. Н.Ш.Хисамов поэманың хәзерге татар телендә шигъри тәрҗемәсен дә бирә (2000). «К.Й.» поэмасы татар халык поэзиясенә хас булган манерада язылган: строфа дүрт юлдан тора, **аааб** схемасында рифмалаша, текстның буеннан буена «имди» рәдифе кабатлана.

Гәүһәр — таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас,
Бу назымның кадерен һич ахмак белмәс,–
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер **имди**.

Строфика моделе Урта Азия шагыйре Әхмәд Ясәвидән алынган. Поэма әдәби төрки телдә язылган, бер үк вакытта угыз һәм кыпчак элементлары да очрый (мондый күренеш башка урта гасыр төрки-татар әдәби ядкәрләренә, ш.и. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәрләренә дә хас). Әсәр татар халкының эстетик күзаллавын тәрбияләүдә, аның әдәби телен үстерүдә зур роль уйный, халык авыз иҗатына әһәмиятле йогынты ясый. ТРда һәм татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә (Пермь өлкәсе, Башкортстан Респ-касы, Түбән Новгород һәм Оренбург өлкәләре, Әстерхан шәһәре һ.б.) поэманың 300 гә якын күчермәсе табыла. 1983 ел мәгълүматларына караганда, «К.Й.» ның ул вакытта билгеле булган гомуми (161) күчермәләренең күбесе (115) Татарстан җирендә табыла. Казанда гына да 1839 дан башлап поэма 80 тапкыр чамасы нәшер ителә.

Поэма мотивлары буенча Н.Ш.Хисамов тарафыннан «Йосыф–Зөләйха» (1992) исемле тарихи драма языла, Л.З.Любовский «К.Й.» балетын иҗат итә һәм аның премьерасы 2001 дә була (РФнең Дәүләт бүләге, 2005).

Чыг.: Гали (XII йөзнең азагы, XIII йөзнең башы) // Татар поэзиясе антологиясе. К., 1956; «Йосыф вә Зөләйха» // Борынгы татар әдәбияты. К., 1963; Кыссаи Йосыф. К., 1983; Йосыф кыйссасы. К., 2000; Юсуф и Зулейха (отрывки) // Антология татарской поэзии. К., 1957; Сказание о Йусуфе. К., 1985.

*Әд.:* Т а һ и р җ а н о в Г. Фирдәүси һәм Колгали // Казан утлары. 1968. № 12; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1; Х и с а м о в Н.Ш. Бөек язмышлы әсәр. К., 1984; А л м а з Дж. «Кысса-и Юсуф» Али — булгаро-татарский памятник // Тр. 25 Междунар. конгр. востоковедов. М., 1960; Н а д ж и п Э.Н. О языке памятника начала XIII в. «Кысса-и Юсуф» Али // Советская тюркология. 1976. № 2; Т е н и ш е в Э.Р. О языке поэмы Кул Гали «Кысса-и Юсуф» // Turcologika 1986. Л., 1986; Поэт-гуманист Кул Гали. К., 1987; А х у н о в А.М. Арабский источник средневековой тюрко-татарской литературы: на материале трудов ат-Табари. К., 2001; К у з ь м и н а Х.Х. Лексика поэмы Кул Гали «Кыссаи Йусуф». К., 2001; Х и с а м о в Н.Ш. Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XII–XV вв.: Проблема версий. К., 2001.

*Н.Ш.Хисамов.*

**«КЫЙССАЙ СӘЕТБАТТА́Л ГАЗЫ́Й»** («Сәетбаттал каһарман турында кыйсса»), урта гасырлар госманлы төрек әдәбияты ядкәре; героик *дастан*. Төп герой — Абдәллаһ Баттал (ш.у. фарсы тарихчысы әт-Табари (839–923) әсәренең төрек версиясендә искә алына) гарәпләр ягында византиялеләргә каршы сугыша. 740 та Акроинос (Кече Азия) янында сугышканда һәлак була. Дастан сәлҗүкләр эпосына нигезләнә. Анда төрки сугышчыларның каһарманлыгы, башлыклары Сәетбатталның легендар батырлыклары сурәтләнә.

Башта телдән-телгә йөри, 14–15 йөзләрдә языла. Татарлар арасында 17 йөзгә кадәр киң таралган була. Дастанның иң борынгы татарча нөсхәсе 1709 елга карый. 19 йөздән алып берничә тапкыр нәшер ителә. Сәетбаттал каһарманлыгы темасы татар әдәбиятында да эшкәртелә. Әсәрнең «Сәетбаттал китабы», «Мәнакыйбе Сәетбаттал газый», «Сирәте Сәетбаттал газый» кебек охшаш исемле күптөрле татар вариантлары да бар. Әлеге ядкәрне Европа, рус һәм татар галимнәре өйрәнә: Г.Флейшер, Гаммер-Пургшталь, В.Д.Смирнов, Г.Гобәйдуллин, Гали Рәхим. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты каршындагы кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсендә «К.С.г.»ның 7 нөсхәсе саклана.

*Әд.:* Г а з и з Г., Р ә х и м Г. Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. К., 1923. 2 бүлек.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«КЫЙССАЙ СӘКЯ́М»**, («Сәкям турында кыйсса»), төрки-татар әдәбиятының тезмә (шигъри) ядкәре; героик дастан. Авторы билгесез. 17 йөзнең 1 нче яртысында Касыйм ханлыгында языла. 377 строфадан тора. Эчтәлеге һәм теле ягыннан татар әдәбияты ядкәре «*Дәфтәре Чыңгызнамә*» (17 йөз) б-н аваздаш. Әсәрнең исеме төп герой-баһадир Сәкям исеменнән алынган. Аны мәҗүси Хуранның Җиһаншаһ исемле идарәчесе Мәккәгә Али хәлифә б-н сугышырга җибәрә. Җиңгән очракта аңа үзенең кызын кияүгә бирергә вәгъдә итә. Ләкин баһадир җиңелә һәм ислам динен кабул итә. Җиңеп чыгучы Сәкямга данлыклы Зөлфикар кылычын, могҗизалы Дөлдөл атын, Мәлик баһадирның чукмарын бүләк итә һәм кире Хуранга ислам динен таратырга кайтарып җибәрә. Җиһаншаһ янына кайтып, Сәкям аны дошманны җиңдем дип алдый һәм кызына өйләнә. Туй уздырып яткан вакытта, кунак кыяфәтендә үзенең сугышчылары б-н Али килеп керә һәм, Дөлдөлгә атланып, кулына Зөлфикар кылычын һәм Мәликнең чукмарын алып, Җиһаншаһны җиңә. Хуран халкы, мөселманлыкка чыгып, гомерен саклап кала.

«К.С.» киная формасында Касыйм ханлыгында Шаһгали хакимлек иткән вакыттагы сәяси вазгыятьне тасвирлый, Мәскәү яклы хакимнәрдән котылу юлларын күрсәтә, мөселман җитәкчеләр тирәсендә берләшергә чакыра. Әсәр 19 йөздә күчерелгән 5 нөсхәдә сакланган (Казан, С.-Петербург, Уфа архивлары һәм китапханәләрендә табыла).

*Әд.:* Г о с м а н о в М. Каурый каләм эзеннән. К., 1994; Д м и т р и е в а Л.В. Описание тюркских рукописей Института востоковедения. М., 1980. Т. 3; Р о д и н Н.А. Касимов — Городец Мещерский. Рязань, 2004.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«КЫЙССА́С ӘЛ-ӘНБИЯ́»** («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар»), төрки язма әдәбияты (чагатай) ядкәре (1310–11). Авторы — Насретдин Рабгузи «К. әл-Ә.»не ислам динен

кабул иткән беренче чагатай хәкимнәреннән Тармаширин хан (1326–34) өчен язган. Әсәр шул чордагы «пәйгамбәрләр турында риваятьләр» жанрында иҗат ителгән. Аны язганда Рабгузи Коръән шәрехләүләрен — *тәфсирләрне*, пәйгамбәрләр турындагы гарәп һәм фарсы риваятьләрен файдалана. 33 пәйгамбәр тарихыннан тыш (*Мөхәммәдне* кертеп), «К. әл-Ә.» борынгы төрки легендаларны, риваятьләрне һ.б. үз эченә ала. Пәйгамбәрләрнең, аерым алганда, *Ибраһимның* тормышы тасвирланган риваять Библиядәге аңлатмаларга якынрак тора. Шул ук вакытта Иуда (Шамун) тарихы гомум кабул ителгән христиан һәм мөселман аңлатмаларыннан аерыла: Иуда Гайсәгә хыянәт итми, хәтта исламга өндәү өчен аны Кече Азиягә җибәрә, шуннан соң Гайсә пәйгамбәр була. *Сөләйман* (Соломон), Әюб (Иов), Даниял (Даниил) пәйгамбәрләр турындагы кыйссалар авторның үз фаразлавында тәкъдим ителә. «К. әл-Ә.», төрки-мөселманнар арасында иң популяр дини әсәрләрнең берсе була (литография ысулы б-н 20 гә якын, ш.у. Казан (1859 дан) һәм Әнкарада хәреф җыю юлы б-н берничә китап нәшер ителә). Әсәр өлешчә В.В.*Радлов* төзегән «Төрки телләр сүзлеге төзү тәҗрибәсе» («Опыт словаря тюркских наречий», т. 1–4, 1888–1911) исемле борынгы төрки сүзлекнең нигезен тәшкил итә.

*Әд.:* Катанов Н.Ф. Мусульманские легенды: Тексты и переводы. СПб., 1894; Малов С.Е. Мусульманские сказания о пророках по Рабузи // Зап. Коллегии востоковедов при Азиатском музее АН СССР. 1930. Т. 5; шул ук. Памятники древнетюркской письменности: Тексты и исслед. М.–Л., 1951; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 2001, Вып. 3; Emiloglu Ed. Kissas-i Enbiya. Ankara, 1994.

**КЫЙТГА́** (гарәп. قطعة — кисәк, өлеш, бүлек). 1. Классик шәрекъ поэзиясендә жанр формасы; фәлсәфи яки дидактик характердагы зур булмаган шигырь. Гадәттә, *бәйт* яки *гаруз* б-н языла. *Газәл* яки *касыйдә* үрнәгендә рифмалаша (ба, ва, га), ләкин беренче бәйтендә рифмасы парсыз. К.га фикер һәм хис тирәнлеге, чарланган тел һәм стиль, афористик яңгыраш хас. К. үрнәкләрен Сәйф Сараи, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Ш.Бабич һ.б. шагыйрьләр иҗатында очратырга мөмкин. 2. Проф. хаттат кулы б-н сәнгатьчә бизәлгән кыска шигырь яки чәчмә әсәр; хаттатчылык сәнгате төре. К.ны панно рәвешендә диварга элгәннәр, алардан каллиграфия үрнәкләре альбомнары төзегәннәр (моракка). Татар сәнгатендә К. *шәмаилнең* бер төре буларак очрый, кәгазьдә каләм һәм тушь б-н башкарыла, кайбер чакта тиражлана. Фарсы телендә язылган шигъри әсәрләрдән (авторы — М.*Мәхмүдов*), гарәп телендәге ике юллы шигырьләрдән (авторы — Йосыф хәзрәт Йасари), Мөхәммәд әл-Басыйриның касыйдәләреннән өзекләр рәвешендәге К. үрнәкләре Казан ун-ты фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә һәм ТР Милли музее фондларында саклана. Ш.у. к. *Хаттатчылык.*



Гарәп телендә ике юллы шигырь язылган кыйтга: «Аһ, җилкәй, әгәр син тыелган җирдә пәйда булсаң, минем сәламемне хөрмәтле Пәйгамбәр (с.г.в.) йөргән бакчага җиткер». Авторы — Йосыф Йасари. Литография. ТР Милли музее.

*Әд.:* Миңнегулов Х. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003.

*Х.Й.Миңнегулов, Р.И.Шәмсутов.*

**КЫЛГА́Н** (Stipa), кыяклылар семьялыгыннан, башлыча, күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 300 гә якын төре билгеле, уртача киңлекләрдә, тропикларда һәм субтропикларда таралган. Татарстан терр-ясендә 9 төре бар. Төкле яфраклы К. (S.dasyphylla), матур К. (S.pulcherrima), тар яфраклы (тырса) К. (S.tirsa), Залесский К. (S.zalesskii) — республика флорасы өчен сирәк төрләр. Далаланган көньяк сөзәклекләр буенда үсә. 30–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Яфраклары тар кыяклар, күбесенчә төрелгән, сирәк кенә яссы. Чәчәк төркеме — бер яллы себеркәч. Башаклары бер чәчәкле. Башак кабыгы ике; түбәнге чәчәкле кабык калын, каты, югарыгы чәчәкле кабыкны нык итеп әйләндереп алган һәм очында буынлы бөгелгән кылчык бар, ул исә түбәнге өлешендә ялангач, бөтерелгән, өсте — төкчәле яки шома. Җимеше — бөртекчә. Май–июльдә чәчәк ата. Корылыкка чыдам үсемлек, дымның туфракта җитәрлек булмавын җиңел кичерә. Чәчсыман К. (S. capillata), сарепта К. (S. sareptana), каурый К. (S. pennata) башак чыгарганчы терлек азыгы буларак кулланыла, картайгач катылана һәм ашарга яраксыз хәлгә килә. Каурый К. кипкән чәчәк бәйләмнәре ясау өчен кулланыла. К.ның 8 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Төкле яфраклы кылган.

**КЫЛНА́** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 32,7 *км*, бассейнының мәйданы 576,5 *км*². Идел буе калкулыгыннан ага, Тәтеш р-нында. Елга башы урман массивында, Красное Озеро авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Кошки-Яңа Тимбай авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 68 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.ның 15 кушылдыгы бар, иң зурлары — сул: Киртәле (13,8 *км*) һәм Бидәңге (29,9 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 89 *мм*, ташу агымы катламы 74 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,29 *м*³*/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 7,3 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЫЛЧЫКСЫ́З КЫНДЫРА́К** (Bromopsis inermis), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлек. Биеклеге 150 *см* га кадәр, яхшы яфракланган күп кенә вегетатив үрентеләр җибәрә. Яфраклары киң, бераз кытыршы. Чәчәк оешмасы — эре таралып торган себеркәч, җимеше — бөртек. Чәчәкләрендә кызгылт-сары серкәлекләр бар. Июнь–июльдә чәчәк ата. Орлыгының озынлыгы 8–12 *мм*. Татарстанда терлек азыгы үсемлеге буларак үстерелә, культуралы печәнлекләр һәм көтүлекләр булдырганда чәчелә. Шулай ук су баса торган һәм үзәнлекле болыннарда, аланнарда, йорт яннарында, юл буйларында очрый. Көтү ашап киткәч, ш.у. чабып алынганнан соң яхшы үсеп китә. Язгы чорда иртә үсә башлый. Уҗым урынына иртә яшел тукландыру өчен, шулай ук киптерелгән сазлык һәм җил эрозиясе б-н зарарланган җирләргә чәчү өчен кулланыла. Салкынга чыдам, корылыкка бирешми, язгы дәвамлы су басуларны яхшы кичерә. Тулысынча 2–3 нче елда өлгерә, үлән буларак 10 елдан артык үсә. Көпшәк туфракларда яхшы җайлаша. Яшел массасының уңышы 1 *га* дан 200–500 *ц*, печән уңышы 30–60 *ц*. Чәчү нормасы: чиста килеш 1 *га* га 24–30 *кг*, үлән катнашмасында 10–12 *кг*; чәчү тирәнлеге 2,5–3,5 *см*. ТРда районлаштырылган сортлар: «Моршанский 760» (1955), «Факельный» (1990). К.к.ның терлек азыгы буларак туклыклылыгы люцерна, клевер, эспарцет катнашмасында чәчкәндә арта.



**КЫЛЫ́Ч ГӨЛ**, к. *Гладиолус.*

**КЫМЫ́З**, этногенетик яктан күчмә терлекчеләр б-н бәйле халыкларның әчетелгән сөттән ясалган традицион эчемлеге. Сусауны һәм ачыгуны баса, дәвалау максатларында

(бигрәк тә үпкә туберкулёзын дәвалаганда файдасы зур) кулланыла; эчемлек «кәефләндерә», чөнки сөт әчетү нәтиҗәсендә спирт барлыкка килә. Иң таралганы — бия сөтеннән әзерләнгән К. (элек аерым төбәкләрдә аны ш.у. дөя, кәҗә сөтеннән ясаганнар). К.ны традицион әзерләү ысулы гади: яңа савылган, сөзелгән бия сөтен турсыкка салалар, ачыткы (су кушылган *катык* (*әйрән*) яки 1 стакан К.) өстиләр, шуннан соң күбекле сыеклык барлыкка килгәнче болгаталар. Акрынлап утрак тормышка күчү барышында терлекчелек б-н гомер кичергән дала халыкларының көнкүрешендә эчемлекне әзерләүдә кулланыла торган махсус кирәк-яраклар — чокып ясалган (ешрак юкәдән) кисмәкләр, гөмбәсыман очлы туглагыч таяклар, К. б-н сыйлау өчен ясалган нечкә сырлар б-н бизәлгән агач касәләр, чүмечләр барлыкка килә. К. әзерләүнең иң зур осталары булып башкортлар, казакълар һәм кыргызлар санала; 18 йөз ахырында алар яшәгән җирләрдә стихияле рәвештә дөньядагы беренче кымыз б-н дәвалау шифаханәләре барлыкка килә, аларда халык медицинасы традицияләре дәвам иттерелә. Идел буенда 1 нче кымыз шифаханәсе Самара янында 1858 елда ачыла, соңрак ул Казан хәрби округы хәрбиләрен дәвалау өчен яраклаштырыла. 1888 дә Кама ярында Алабуга янында К. б-н дәвалаучы сезонлы курорт тибындагы (май–сентябрь айларында эшли), килүчеләр өчен номер-фатирлары һәм дачалары булган Танеев шифаханәсе ачыла. 19 йөз ахырында, башлыча, кечерәк җәйге рестораннар рәвешендәге К. йортлары Казанда да (1899 да Аргы Кабан күле буенда, Кизик һәм Болынасты бистәләрендә) барлыкка килә. К.ның шифалы үзенчәлекләре һәркем тарафыннан танылган. К. б-н дәвалау алымы Татарстанның туберкулёздан савыктыру санаторийларында («Каменка», «Обсерватория», «Тарловка») киң кулланыла. Татарларның милли эчемлекләре арасында иң танылганы булмаса да, Идел буеның далалы р-ннарында казакълар б-н күршеләр булып, ш.у. Урал алдында — Башкортстан Респ-касы терр-ясендә һәм аңа чиктәш җирләрдә яшәүче татарлар өчен К. традицион эчемлек санала.

*Әд.:* Г у б а й д у л и н ы М.С. и К.С. Пища казанских татар // Вест. Науч. об-ва татароведения. 1927. № 6; Б у ш к о в Р.А., М а з и т о в а Ф.Г. Букет напитков Татарстана. К., 1993; Х а й р у т д и н о в а Т.Х. Названия пищи в татарском языке. К., 1993; З а л я л и е в А.Н. Река времени. К., 2001; М у х а м е д о в а Р.Г. Пища и домашняя утварь // Татары. К., 2001.

**КЫМЫЗЛЫ́К** (Oxalis), кымызлыкчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуаклар һәм куаклар ыругы. 800 гә якын төре билгеле, башлыча, Көньяк Африка, Көньяк Америка һәм Мексикада, берничә төре Евразиядә очрый. Татарстан терр-ясендә бер төре гади К. (O. acetosella) Кама алдында очрый. Ылыслы һәм катнаш урманнарда үсә. 5–10 *см* биеклектәге сабаксыз күпьеллык үләнчел үсемлек, җир өслегеннән үрмәләүче тамырчасы итчел алсу кабырчык б-н капланган. Яфраклары тамыр яны яралгысында, өчәрле, ачык яшел; болытлы көннәрдә ш.у. төнгә җыелалар һәм иеләләр. Чәчәкләре эре, ак, берле, озын чәчәк сапларында. Җимеше — алты оялы тартмачык. Орлыклары вак, яссы, җирән, ак итчел үсентеле, өлгерү вакытында тышка атыла. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Күбрәк тамырчадан үрчи. Үсемлекнең барлык өлешләрендә әчкелтем кузгалак калие, С витамины, каротин, рутин бар. Үсемлек әчкелтем хуш исле. Аш һәм салатлар әзерләгәндә кулланыла. Халык медицинасында яңа җыелган яфракларыннан әзерләнгән төнәтмә бавыр авырулары, бөер ялкынсынуы, ашказанату эшчәнлеге бозылганда кулланыла. Вакланган яфракларын үлекле яраларга, җәрәхәт, шешләргә куялар. Яфрак һәм җимешләре кыргый җәнлекләр өчен азык. Декоратив, баллы үсемлек.

**КЫНА́** (Impatiens), кыначалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 45 кә якын төре билгеле, Евразия, Африка, Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Гади К.г. (I. noli-tangere) — күләгәле урманнарда, куаклар арасында, вак чәчәкле К.г. (I.parviflora) торак пунктларда, бакча участокларында, юл буйларында үсә. Кама һәм Идел алдында очрый. Бизле К.г. (I. glandulifera) йорт яны участокларында үстерелә, сирәк кенә кыргыйлана. 30–120 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Сабагы калын, сусыл, буынлы. Яфраклары чиратлашкан, йомырка-ланцетсыман, төпчек яфраклары юк. Бизле К.г.нең яфраклары төбендә 2 бизчек бар. Чәчәкләре гади, кызыл, ак, сары төстә, берле яки куентылы чукка җыйналган. Җимеше — тартмачык, өлгергәч, кагылу б-н ачылып китә, бу вакытта капкачлары астан өскә таба спиральсыман бөтерелә һәм орлыклар тышка атыла. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Гади һәм вак чәчәкле К. г. халык медицинасында кулланыла. Үлән төнәтмәсе аз күләмдә сары су авыруы, бөердә таш булганда, ш. у. костыру чарасы буларак кулланыла; К.г.нең вакланган яфракларын яраларга куялар. Декоратив үсемлек.




Вак чәчәкле (1), гади (2) кына гөле.

**КЫҢГЫРА́У ЧӘЧӘ́К** (Campanula), кыңгырау чәчәкләр семьялыгыннан бер яки күпьеллык үләннәр һәм ярымкуаклар ыругы. 400 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә 12 төре үсә. Каты төкле К.ч. (C. cervicaria), оеш К.ч. (C. glomerata), Себер К.ч. (C. sibirica) һ.б. бөтен районнарда очрый. Урманнарда, болыннарда, сөзәклекләрдә, юл буйларында үсә. Күләгәгә һәм салкынга чыдам. 120 *см* биеклеккә җитүче күпьеллык үсемлек. Сабагы туры, еш кына төкле. Яфраклары чиратлашкан, бөтен. Чәчәкләре ябышып үскән таҗ яфракчыклы, кыңгырау рәвешендә, зәңгәр, күк, сирәк кенә шәмәхә төстә, себеркәч яки чуксыман чәчәк төркемендә. Җимешләре — күп орлыклы тартмачык. Май–августта чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Суган тамырлы К.ч. (C. rapunculoides), шафталу яфраклы К.ч. (C. persicifolia) бакчаларда декоратив үсемлек буларак үстерелә. Ончыл К.ч., оеш К.ч., чуклы К.ч. һ.б. — баллы. Киң яфраклы К.ч. (C. latifolia), түгәрәк яфраклы К.ч. (C. rotundifolia), Идел буе К.ч. (C. wolgensis) ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Кычыткан яфраклы кыңгырау чәчәк.

**КЫПЧА́К**, 15–17 йөзләрдә Казан, Кырым һәм Касыйм ханлыкларында идарәче ыругларның берсе. К. ыругы башлыгы *карачыбәкләрнең* берсе була. Ыругның куәте һәм байлыгы, татар ханлыкларында сәясәткә йогынты ясау дәрәҗәсе буенча *Ширин* ыругыннан гына калыша.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследования о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

**КЫПЧА́К ТЕЛЕ́** (коман теле), кулланылыштан төшеп калган *төрки телләрнең* берсе. Төрки телләрнең көнбатыш–һун тармагына карый, берничә диалекты бар; хәзерге татар, башкорт, казакъ, караим, каракалпак, карачай-балкар, кырымтатар, комык, нугай телләренә якын. 11–14 йөзләрдә *Дәште кыпчак* (Кыпчак даласы) җирләрендә таралыш алган. Бу телдә сөйләшүче халыклар — *кыпчаклар* — мөселман чыганакларында — «кыпчаклар», «кыфчаклар», Көнбатыш Европада — «команнар», «куаннар», рус чыганакларында — «половецлар» дип теркәлгән. Кыпчакларның теле турында беренче мәгълүматларны *Мәхмүд Кашгариның* «Диване лөгать әт-төрк» («Төрки телләр җыентыгы», 11 йөз) хезмәтендә күрергә мөмкин. К.т.нең сакланып калган язма истәлекләреннән иң борынгысы — «Тәрҗемәни төрки вә араби» («Төрки-гарәп сүзлеге») — 1894 елда М.Хоутсман тарафыннан немец телендә нәшер ителә. К.т. үрнәкләре «*Кодекс Куманикус*» язма истәлегендә дә (13 йөз), 14–15 йөзләр глоссарийларында да, мәхкәмә актларында һәм Каменец-Подольск шәһәренең (Украина) әрмән җәмгыяте хроникаларында (18 йөз) һ.б.да сакланып калган.

К.т.нә хас күренешләр: тар сузык авазлар булу һәм аларның аффиксларда иренләшмәве (лабиальләшмәве), сузыкларда көчле булмаган ирен гармониясе күзәтелү, озын сузыклар булмау, интервокаль позициядә саңгырау авазларның яңгыраулашуы. Ш.у. к. *Телләрнең кыпчак төркеме*.

*Әд.:* Радлов В.В. О языке куманов: По поводу издания куманского словаря // Зап. Имп. АН. 1884. Т. 48, № 4; Баскаков Н.А.Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Хаков В.Х. Кыпчакские письменные памятники как источник изучения истории татарского языка // Археография и лингвистическая текстология. Уфа, 1977; Наджип Э. Исследования по истории тюркских языков XI–XIV вв. М., 1989.

*В.Х.Хаков.*

**КЫПЧАКЛА́Р** (команнар; рус елъязмаларында — половецлар), төрки телле халык. Урнашу ягыннан көнчыгыш К.га — Идел аръягы һәм көнбатыш К.га — Иртеш буйларына кадәр (Көнчыгыш чыганакларында бу терр-я Дәште Кыпчак — Кыпчак даласы дип атала) бүленәләр. 11 йөз — 13 йөз башында К.да ханнар (хаканнар) идарәсендә кабилә берләшмәләре (берлекләре) барлыкка килә. К. күчмә тормыш алып баралар. Халыкның төп шөгыле терлекчелек була. 12 йөздә Дон, Түбән Идел һәм Арал буйларындагы саксиннар, болгарлар һ.б. б-н бергә К. яшәгән шәһәрләрдә һөнәрчелек үсеш ала. К. еш кына рус кенәзлекләренә, Идел буе Болгар дәүләтенә һөҗүмнәр ясыйлар. Аларның гаскәрләре җиңел һәм авыр коралланган атлылардан гыйбарәт булып, аеруча җитезлеге б-н аерылып тора. 12 йөз башында Киев кенәзләре Святополк Изяславич һәм Владимир Мономах гаскәрләреннән берничә тапкыр җиңелгәннән соң, К.ның бер өлеше грузин патшасы Давид Төзүчегә хезмәткә күчә. 12 йөзнең 2 нче яртысында кабилә берлекләре сизелерлек ныгый һәм К. рус җирләренә һөҗүмнәр ясый башлыйлар. 1223 тә алар монголлар тарафыннан Төньяк Кавказда, аннан соң *Калка елгасы буендагы сугышта* җиңеләләр. Көнчыгыш К. Алтын Урда халкының төп өлешен тәшкил итәләр, алар читтән яу б-н килгән монголларны ассимиляциялиләр; *кыпчак теле* аралашуда, әдәбият үсешендә һәм эш кәгазьләренең гамәлдә кулланылуында төп чарага әверелә. Көнбатыш К. Венгриягә күченеп китәләр. Алар күп кенә төрки халыкларның, ш.и. татарларның, башкортларның, нугайларның, казакъларның, каракалпакларның, үзбәкләрнең, Кырым татарларының этномәдәни йөзе формалашуга көчле йогынты ясыйлар. «Игорь полкы турында җыр» («Слово о полку Игореве», 12 йөз ахыры) дип аталган борынгы рус әдәбияты ядкәрендә рус-кыпчак сугышлары вакыйгасы — Игорь Святославичның 1185 елгы уңышсыз явы чагылыш тапкан.



Кыпчак сыны (таш балбал). 12 йөз.



Кыпчак ханы. 12 йөз. М.В.Горелик реконструкциясе.



Кыпчак ханының сугыш кирәк-яраклары. 12 йөз –13 йөз башы (С.А.Плетнёва буенча).

*Әд.:* Бартольд В.В. Сочинения. М., 1968. Т. 5; Фёдоров-Давыдов Г.А. Курганы, идолы, монеты. М., 1968; Рыбаков Б.А. «Слово о полку Игореве» и его современники. М., 1971; Ахинжанов С.М. Кипчаки в истории средневекового Казахстана. А.-А., 1989; Плетнева С.А. Половцы. М., 1990; Гумилев Л.Н. Древние тюрки. М., 1993; Кляшторный С. Кимаки, кипчаки и половцы // История татар с древнейших времён. К., 2002. Т. 1.



Кенәз Игорь Святославичның 1185 елда кыпчаклар станына һөҗүме. Радзивил елъязмасы миниатюрасы.

*Ф.Г.Кәлимуллина.*

**КЫР ӘНӘЛЕСЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 100 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пүчинкә исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 397 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 19 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 132, 1897 дә — 228, 1908 дә — 264, 1920 дә — 342, 1926 да — 205, 1938 дә — 359, 1949 да — 289, 1958 дә — 264, 1970 тә — 271, 1979 да — 189, 1989 да — 128, 2002 дә — 113 кеше.

**КЫР БУАСЫ́**, к. *Яңа Буа*, Кайбыч р-ны.

**КЫР КИШЕРЕ́**, йонлы көпшә (Chaerophyllum), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле, Европа, Азия һәм Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Прескотт йонлы көпшәсе (Ch. prescottii), бүлбеле елан көпшә (Ch. bulbosum) урман буйларында, чүп үлән буларак кырларда үсә. Тамырлары юан — бүлбесыман, бүлбенең йомшагы ак; 28% ка кадәр крахмал бар. Ашарга яраклы. Сабагы туры, 30–180 *см* биеклектә, бүлбеле елан көпшәсенең тимгелләре юк, Прескотт йонлы көпшәсе — шәмәхә тимгелле. Яфраклары каурыйсыман, теленмә. Чәчәкләре вак, ак төстә, катлаулы кәрзингә җыйналган. Җимешләре цилиндрсыман, ярымҗимешчекләрдән тора. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Исле К. к. (Ch. aromaticum) — сирәк төр, Яшел Үзән р-нында очрый. Берникадәр кыскарак, яфракларының ике яклы каурыйсыман булуы б-н аерыла. Барлык төрләре дә баллы.

**КЫР ТӘҮГЕЛДЕСЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 180 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 1920 елларга кадәр Яңа Көлкәш исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 831,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш,

1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 115 ир-ат; 1859 да — 442, 1897 дә — 577, 1908 дә — 712, 1920 дә — 630, 1926 да — 409, 1938 дә — 786, 1949 да — 384, 1958 дә — 351, 1970 тә — 339, 1979 да — 283, 1989 да — 227, 2002 дә — 188 кеше.

**КЫР ТЫЧКАННАРЫ́** (Microtinae), вак кимерүчеләр, әрләнсыманнар ассемьялыгыннан берничә ыруг вәкиле. 65 тән артык төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарда таралган. Татарстан терр-ясендә 2 ыругтан 5 төре очрый: урман К.т. һәм соры К.т. Урман К.т. (җирән һәм кызыл тычканнар) төрле типтагы, аеруча имән-юкә һәм чыршы катнаш урманнарда яши. Гәүдә озынлыгы 9–13 *см*, авырлыгы 15–45 *г*. Җирән кыр тычканының (Clethrionomys glareolus) аркасы җирәнсу-көрән, корсагы соры, койрыгы ике төрле төстә: өсте кара, асты аксыл, алар арасындагы чик җирән. Кызыл кыр тычканы (C. rutilus) аркасының җирәнсу-кызыл төсе һәм чагыштырмача кыска (4 *см* дан артык түгел) чук б-н тәмамланучы куе төкле бер генә төстәге койрыгы б-н аерыла. Соры К.т. (гади, карасу, күсе башлы) кыр, болын, көтүлекләрдә, урман буйларында, елга үзәннәрендә, сазлык, ерымнарда яши. Гади кыр тычканының (Microtus arvalis) гәүдәсе 8,5–12 *см*, койрыгы 2,5–4 *см* озынлыкта. Аркасы төрле төсмерләрдәге көрән-соры төстә. Карасу кыр тычканы (M. agrestis) гади кыр тычканыннан зурлыгы (гәүдә озынлыгы 11,5–14 *см*, койрыгы — 3–5 *см* га кадәр), җирән-соры аркасы, саргылт соры корсагы һәм ике төстәге (өсте карасу, асты аксыл) койрыгы б-н аерыла. Соры К.т.ның иң зурысы — күсе башлы тычкан (M. oeconomus). Гәүдә озынлыгы 12–14,5 *см*, койрыгы 5,5–6,5 *см* га кадәр; аркасында кара буй үтә.

К.т. тәүлекнең теләсә кайсы вакытында актив, әмма җир өстенә, нигездә, эңгер-меңгердә һәм төнлә чыгалар. Күбесенчә җылы вакытта, һава шартлары уңай һәм азык күп булганда кышын да үрчиләр. Елга берничә тапкыр бала китерә, һәркайсында 5–8 бала була, алар исә 1,2–2 айдан соң үзләре дә үрчем бирә. К.т. үсемлек кабыгы, сабагы, бөреләр б-н тукланып, урман һәм а.х.на зыян китерә. Ерткыч җәнлекләр һәм кошлар тормышында мөһим роль уйный. Бүре, төлке, селәүсен, бурсык, ләтчә, ас, сусар, көзән, һ.б. өчен азык булып торалар. Геморрагик бизгәк, лептоспироза, туляремия һ.б. йогышлы авырулар таратучылар. Гадәттә, табигатьтә берничә ай яшиләр. Кызыл кыр тычканы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫР ҮРДӘГЕ́** (Anas platyrhynchos), үрдәк кошлар семьялыгындагы кош. Евразия, Америка, Төньяк Африкада таралган. Гәүдәсенең озынлыгы 50–60 *см*, авырлыгы 0,7–1,4 *кг*. Ана үрдәкләр ата үрдәкләрдән берникадәр кечерәк. Ата үрдәкнең башы яшькелт-кара, бүксәсе аксыл-коңгырт, койрык өсте кара, томшыгы сары, аяклары кызгылт сары төстә. Ана үрдәк кара чуар көрән, канатында зәңгәр «көзгесе» бар; алсу төстәге томшыгының уртасы кара. Татарстан терр-ясендә язгы кайту һәм көзге китү чорында бик күп очрый, кайберләре оялау һәм балалар чыгару өчен (су үсемлекләре мул үскән сулык ярлары буенда, сазлык, елга тугайларында) кала. Оясын җирдә ясый. Ак яки яшькелт 9–14 йомырка сала; үрдәк балалары июнь башында чыга. Вак умырткасызлар (бөҗәкләр һәм аларның личинкалары, кыслачыклар, моллюсклар), су үсемлекләре һәм аларның орлыклары б-н туклана. Козгыннардан зыян күрә, алар ояларны, кош балаларын юкка чыгара, олы кошларга һөҗүм итә. Ау спорты объекты. К.ү.нән йорт үрдәкләренең күп кенә токымнары килеп чыккан. Йортка ияләштерү күп йөз еллар элек Кытайда башлана. Бу үрдәкләр Европага б.э. башында кертелә.

**КЫР ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Acanthis), тау чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 4 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Гади кыр чыпчыгы (A. flammea) барлык районнарда очрый, тау чыпчыгы (A. flavirotris) һәм аксыл тау чыпчыгы (A.hornemanni) сирәк очып килүче төрләр. Каен, зирек һәм тал утыртмаларында яшиләр. Гәүдә озынлыгы 12–14 *см*, авырлыгы 10–15 *г*. Каурый капламы куе, тыгыз. Гади тау чыпчыгының өсте буй-буй кара-чуар, соры-көрән, асты ак төстә. Башы куе кызыл «бүрекчек»ле. Муены кыска. Томшык астында муенында зур булмаган кара тап бар. Ата кошларның түше ачык кызыл төстә. Тау чыпчыгы гади кыр чыпчыгыннан куе кызыл «бүрекчеге» булмау б-н аерыла. Аксыл кыр чыпчыгының өсте аксыл, койрык өсте — ак, ата кошның түше алсу төстә. Очкан вакытта кошның төсе ак булып күренә. Томшыгы нык, төбенә таба калынайган. Канатлары уртача озынлыкта. Оясын агач һәм куакларның аскы ботакларында ясый. Төркем булып яшиләр. Кызыл-көрән тимгелле 4–6 зәңгәрсу-яшел йомырка сала. Йомыркалар өстендә, чиратлашып, ата б-н ана кош икесе дә утыра. Орлыклар, җиләкләр һәм вак бөҗәкләр б-н туклана.

**КЫР ШОНТАЛЫСЫ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Шонталы елгасы буенда. 2010 елда 598 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1312 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кызыл Яр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 78 ир-ат; 1859 да — 558, 1897 дә — 915, 1908 дә — 1103, 1920 дә — 1146, 1926 да — 1123, 1938 дә — 1184, 1949 да — 743, 1958 дә — 912, 1970 тә — 1011, 1979 да — 880, 1989 да — 676, 2002 дә — 701 кеше.

**КЫР-КАЕНТҮБӘ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәбез инеше буенда. 2010 елда 118 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп. 1707 дән Каентүбә авылы буларак билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, киез, киез итек басу б-н шөгыльләнә. К.-К. халкы *Крәстияннәр кузгалышы* (1773–75) чорында Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында К.-К.дә мәчет (1853 тә беренче тапкыр телгә алына), мәктәп (1862 дә ачыла) эшли. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1109 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 86, 1859 да — 342, 1870 тә — 362, 1884 тә — 394, 1897 дә — 658, 1906 да — 550, 1913 тә — 541, 1920 дә — 506, 1926 да — 273, 1938 дә — 354, 1949 да — 210, 1958 дә — 199, 1970 тә — 263, 1979 да — 214, 1989 — 121, 2002 дә — 115 кеше.

**КЫРАВЫ́Л** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 233 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Мәчет. 1680 нән билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шарбашская Пустошь, Коры Авыл буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 2 тимерче алачыгы, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 271,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССР ның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 166, 1897 дә — 301, 1908 дә — 328, 1920 дә — 317, 1926 да — 325, 1949 да — 266, 1958 дә — 244, 1970 тә — 283, 1979 да — 252, 1989 да — 211, 2002 дә — 226 кеше.

**КЫРА́У**, һаваның тәүлеклек уртача темп-расы уңай булганда туфрак (туфракта К.) яки җир өстендәге (һавада К.) һава темп-расының кыска вакытка 0 °С тан түбән төшүе. Татарстан терр-ясендә К. язын һәм көзен салкын һава массалары кергәндә яки антициклон вакытында күзәтелә, алар төнлә аяз һәм тыныч һавада көчле нурланыш барлыкка китерә, шул сәбәпле туфрак һәм үсемлек капламы суына. Һавада К. уртача 7–25 майда тәмамлана, 7–29 сентябрьдә беренче К.лар башлана; туфракта К. уртача 19 май — 6 июньдә тәмамлана, 3–18 сентябрьдә башлана. Язын К. төшү ихтималы 21–35, көзен 13–29 көн дәвам итә. Рельефның күтәренке урыннарында (сөзәклекләрнең югары өлешендә һәм калкулык түбәләрендә) К. көчле түгел һәм тигез-

лекләргә караганда 2–4 көнгә иртәрәк тәмамлана. Рельефның батынкы формаларында (елга үзәннәре, ерымнар), урман аланнарында К. көчлерәк һәм тигез яки ачык урыннарга караганда 5–10 көнгә соңрак бетә. Түбән темп-ра, көчсез җил, аяз көн һәм төн — К. өчен уңай шартлар. Җылылык яратучан а.х. культураларына зыян китерә (кайвакыт һәлак итә). К.дан саклау ысуллары — төтенләү, үсемлекләрне томалау һәм җылыту, кичке сугару.

*Әд.:* Смоляков П.Т. Весенние и осенние заморозки в Татарии. К., 1935.

*М.А.Верещагин.*

**КЫРБА́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 21 *км* төньяктарак, Кече Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 85 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантоны Яңа Чүриле волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1926 да — 265, 1938 дә — 252, 1949 да — 270, 1970 тә — 397, 1979 да — 182, 1989 да — 125, 2002 дә — 98 кеше.

**КЫРБА́Ш** елгасы; к. *Юкәче.*

**КЫРГАЯКЛА́Р** (Oniscoidea), *тигезаяклы кысласыманнар* асотряды. Гәүдәсе 1–50 *мм* озынлыкта, сырт-корсак юнәлешендә яссыланган. Башында 2 пар мыекча һәм 3 пар казналык; гәүдәнең калган сегментларында төрле рәвештә махсуслашкан очлыклар (кыскычлар, йөрү аяклары, сизү функцияләре, сулау, үрчү б-н бәйле очлыклар һ.б.) бар. 1 меңгә якын төре билгеле, һәр җирдә таралган. Дымлы урыннарны өстен күрә, күпчелек төрләр коры җирдә яшәргә җайлашкан. Татарстан терр-ясендә стена К.ы (Oniscus murarius) — агач кабыгы, түмгәкләр астында, мүктә һәм М.Porcellio Scaber дымлы базларда, корылмаларда, парникларда очрый. К. урманнарда туфрак барлыкка китерүче буларак файдалы. Югары дымлылык шартларында, ачык һәм ябык грунтта шытып килүче орлыкларны, шытымнарны, яшь яфракларны, тамырларны кимереп, үсемлекләргә зыян китерә; еш кына теплицадагы шампиньоннарны зарарлый.

**КЫРГЫЗСТА́Н**, к. *Кыргызстан Республикасы.*

**КЫРГЫЗСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, Урта Азиянең төньяк-көнчыгышында урнашкан. Мәйданы — 198,5 мең *км*$^2$. Үзәге — Бишкәк шәһәре. Халкы — 5276 мең кеше (2008). Татарлар саны: 1926 елда — 4902, 1959 да — 56274, 1979 елда — 71744, 1989 да — 70068, 1999 да — 45460, 2001 дә — 43179 кеше. Алар, башлыча, Бишкәк (1926 га кадәр — Пишпәк, 1926–91 дә Фрунзе), Ош, Җәлалабад, Каракүл (элеккеге Пржевальск), Карабалта, Карасу, Кызылкыя, Сөлүктә, Ташкүмер, Талас, Токмак шәһәрләрендә; Ноокат, Араван, Атбашы, Сокылык һ.б. авылларда яши.

К. Р. терр-ясенә татарлар 19 йөзнең 1 нче яртысында сәүдәгәрләр, тылмач, муллалар буларак урнаша башлый. Төбәк Россия империясе составына кергәннән соң (1860–70), татарлар аның төрле өлкәләрендә (Сөлүктәдә күмер руднигында, Ош шәһәрендә эре сәүдә йортларында, Пишпәктә сәнәгать пр-тиеләрендә һ.б. җирләрдә) тарала. Татарлар төрле тарихи чорда кыргыз һәм башка Урта Азия халыклары арасында мәдәният таратуда мөһим роль уйный. 20 йөз башында Кыргызстан терр-ясендә Ташкентта Ш.Б.*Бикколов* бастырган китаплар һ.б. басмалар тарала. Монда *«Урал»*, *«Шура»*, *«Аң»*, *«Ак юл»*, *«Вакыт»*, *«Йолдыз»*, *«Идел»*, *«әл-Ислах»* г-та һәм ж-ллары килә. Татар балалары шушы төбәктәге яңа ысул мәдрәсәсендә укый, Пржевальскиның бер мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла.

Совет чорында республикада татарлар саны Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары, 1950–80 елларда илне индустрияләштерү барышында күчеп килүчеләр исәбенә арта. 1920–30 елларда татар укытучылары кыргыз милли интеллигенциясен әзерләүгә зур өлеш кертә. Кыргызстан вузлары һәм мәктәпләрендә Курмаевлар, Мусиннар, Шәмгуновлар, Яушевлар һ.б. укытучы династияләре белем бирә. Күп кенә татарлар дәүләт идарәсе органнарында (Ш.Г. *Әхмәдиев,* З.Х. *Булушев*, *Гыйффәт туташ*, Ә.К. *Умәров*), фән, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләрендә, массакүләм мәгълүмат чараларында эшли. Кыргыз әдәбиятын өйрәнүдә — М. И. *Богданова* һәм К. А. Рәхмәтуллин, балет сәнгатен үстерүдә Р. Х.Уразгилдиев зур активлык күрсәтә. Филос. фән. д-ры М.С.*Жунусов*, а. х. фән. д-рлары С.Г.*Еникиев* һәм К.Җ.*Мөхәммәтшин*, мед. фән. д-ры Н. Җ. *Мохтарова*, икътисад фән. д-ры Р. З. *Сәйфуллин*, скульптор З. А. *Хәбибуллин*, Соц. Хезмәт Герое А.А.Сөнчәлиеваның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге К. Р. б-н бәйле. СССР таркалу б-н Кыргызстандагы татарлар саны, тарихи ватаннарына һәм башка төбәкләргә күченүләре сәбәпле, кими башлый. Хәзерге вакытта Бишкәктә «Туган тел» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге, Ош шәһәрендә (1991 дән) «Илкәем» татар-башкорт милли үзәге, Токмакта «Идел» татар мәдәният үзәге; «Чәчәкләр», «Шатлык» бию ансамбльләре эшли. *Сабан туе* бәйрәме үткәрелә. Татарстан артистлары һәм иҗат коллективлары гастрольләре булып тора. 1997 елдан «Ирек» г-тасы чыга. Кыргыз әдәбияты классигы Ч.Айтматовның әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән. (Бу әсәрләр буенча спектакльләр Татар акад. һәм Әлмәт татар драма театрлары сәхнәләрендә куела).

*Н. М. Морадымов.*

**КЫРКҮ́Л** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 12 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 483 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Троица чиркәве (1868–73 тә төзелә, архит-ра истәлеге; 2004 тән яңадан эшли башлый). 1710 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, казна Вознесенский з-дына беркетелә. Игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, тегү һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.дә чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 10 җил тегермәне, 3 ярма яргыч, 5 йон тетү йорты, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2518,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 210 ир-ат; 1859 да — 1111, 1897 дә — 1729, 1908 дә — 2226, 1920 дә — 2205, 1926 да — 1972, 1938 дә — 993, 1949 да — 733, 1958 дә — 822, 1970 тә — 756, 1979 да — 592, 1989 да — 448, 2002 дә — 492 кеше.

**КЫРЛА́Й** (Шуман) елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шәмәк елгасының (Казансу елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 22,1 *км*, бассейнының мәйданы 106,9 *км*$^2$. Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Топкино авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Керасиново авылының көньягындарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. К. елгасының 0,2 дән алып 6,9 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 121 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,17 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 0,8 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЫРЛА́К** (Eragrostis), кыяклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 500 гә якын төре билгеле, Җир шарының субтропик, тропик һәм уртача поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар: вак К. (E. minor), төкле К. (E. pilosa) һәм хуш исле К. (E. suaveolens); барысы да сирәк очрый. Күбрәк елга тугайларында, комсу китерелмәләрдә үсә. 10–50 *см* биеклектәге берьеллык үсемлекләр. Сабагы туры. Яфраклары — тар кыяк, яссы. Чәчәк төркеме — җәенке себеркәч. Башакчыклары күп чәчәкле. Җимеше — бөртекчә. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Терлек азыгы. Кайбер төрләре — комнарны ныгытучы үләннәр.

**КЫРЛА́Ч**, (Polygonum), карабодайчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, сирәк кенә ярымкуакчыклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, бөтен

Җир шары буенча, күбесенчә уртача пояста таралган. Татарстан терр-ясендә 14 төре бар. Үрмәле К. (P. convolvulus), кабызлык (елан тамыры) (P. bistorta), яткын К. (P. procumbens), чыпчык аягы (P. aviculare) һ.б. барлык районнарда очрый. Болыннарда, сазлык, сулык буйларында, чәчүлекләрдә, чүплекләр тирәсендә үсә. 10–150 *см* биеклектәге бер- һәм күпьеллык үсемлекләр. Сабагы туры, җәенке яки үрмәле. Яфраклары күбесенчә ланцетсыман. Чәчәкләре алсу яки ак, куентылы учмаларда, берле яки башаксыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — кара-көрән өч кырлы чикләвекчек. Майдан көзгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Су борычы (P. hydropiper), кабызлык, чыпчык аягы — дару үсемлекләре. Җир өсте өлешләрендә дуплау матдәләре, эфир мае, органик к-талар һ.б. бар. Үлән суы һәм төнәтмәсе бәвел кудыру, эч йомшарту һәм кан туктату үзлегенә ия. Куак К. (P.dumetorum), үрмәле К., кытыршы К. (P. scabrum) — чүп үләннәр; кабызлык, бүсер үләне (P.persicaria), куян кузгалагы (P. lapathifolium) — баллы үсемлекләр; кабызлык К. — декоратив, җир-су К. (P. amphibium), чыпчык аягы — терлек азыгы. Кабызлык К. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫРЛЫ́ БОРЧА́К** (Lathyrus), кузаклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 дән артык төре билгеле; Европада, Азиядә, Африканың төньяк-көнбатышында, Көньяк Америкада таралган. ТРда 6 төре билгеле; болыннарда, урман аланнарында очрый. Күпчелеге — терлек азыгы үсемлеге. Үзәк тамырлы, күп санлы бүлбе бактерияләре б-н туфракка тирән китә. Күпчелек төрләренең төп сабагы дүрткырлы, ботаклана, эләктереп һәм үрмәләп тармаклана торган, 25 *см* дан 150 *см* га кадәр озынлыкта. Ян ботаклары үзәк сабактан озынрак булып үсеп китәләр. Яфраклары катлаулы, бер парлы (сирәгрәк 2–4 парлы), өчкә тармакланган мыекчалар, чәнечкеле энәләр б-н яисә очланып тәмамланалар. Яфракчыклары ланцетсыман формада, төкчек яфраклары зур түгел, ярым уксыман. Чәчәге — зур, вак күбәләк формасында; чәчәк түшәгендә ак, зәңгәр, шәмәхә, сары яисә чуар төстәге бер яки ике себеркәч урнашкан, кагыйдә буларак, үзеннән-үзе серкәләнә. Җимеше — сызыкча ланцетсыман формадагы, төрле төстә һәм эрелектәге 2–6 орлыклы кузак. 1 *г* га 8–15 орлык исәпләнә. Культурада игүле К.б. киң таралган, ашлык, яшел терлек азыгы һәм печән өчен үстерелә. Үсемлек туфракка аз таләпчән, корылыкка чыдам, –8 °С ка кадәргә түбән темп-рага түзә. 100 *кг* бөртектә 108,2 азык берәмлеге, 20,5 *кг* үзләштерелә торган протеин бар: яшел массада тиндәшле рәвештә — 15,8–3,6, печәндә — 27,3 һәм 6,2. Яшел азык өчен — чәчәк аткач, печән өчен — кузаклана башлагач, ашлык өчен кузаклары 75% саргайгач җыела. Чиста чәчүлекләрдә яшел масса уңышы 1 *га* дан — 220–260, печән — 30–45, ашлык 15–20 *ц* чыга. ТРда чәчүгә «Степная 12» (1939) сорты тәкъдим ителә, кечерәк мәйданнарда үстерелә.

*Әд.:* Справочник по кормопроизводству. М., 1973.

**КЫРЛЫГА́Н** (Epilobium), кырлыганчалар семьялыгыннан күпьеллык үлән яки ярымкуаклар ыругы. 200 гә якын төре билгеле, тропиклардан кала, бөтен Җир шары буйлап таралган. Татарстан терр-ясендә 9 төре бар. Төкле К. (E. hirsutum), саз К. (E. palustre), вак чәчәкле К. (E. parviflorum) барлык районнарда да очрый; тимер сабаклы К. (E. adenocaulon), ал чәчәкле К. (E. roseum) һ.б. — республикада сирәк очраучы төрләр. Су буйларында, сазлыклы болыннарда, чишмәле сазлыкларда үсә. 15–150 *см* биеклектәге төкчәле үләнчел үсемлек, озын җир асты һәм җир өсте үсентеле. Яфраклары тасма, ланцетсыман, бөтен, утырма яки кыска сабаклы. Чәчәкләре алсу яки куе кызыл, чук яки башаксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — күп орлыклы ачылучан тартмачык. Орлыклары — озын төкчәле бүрекчә. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Төкле К. халык медицинасында бөрештергеч һәм ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. К.ның барлык төрләре дә баллы.



Тар яфраклы кырлыган.

**КЫРЛЫ́К** (Spergula), канәферчәләр семьялыгыннан чәчүлекләрне чүпли торган берһәм икееллык үсемлек. Уртача климатлы төбәкләрдә очрый, барлык җирдә таралган, яткын җирләрдә, юл буйларында, чүпле урыннарда үсә. Татарстанда 4 төре билгеле. Иң таралганнары — басу кырлыгы (S. sativa). Үзәк тамырлы, вак ян тамырларга тармаклана. Сабаклары нечкә, нәфис, үләнчел, өске өлештә ботакланган, биеклеге 15–40 *см,* каты төкле. Яфраклары җепсыман, 2–3 *см* озынлыкта, сабакларда боҗраланып урнашкан. Чәчәкләре элпәле ян чәчәкләр б-н озын чәчәк сабагында. Таҗ яфраклары озынча, тонык ак төстә. Июньнән августка кадәр чәчәк ата. Җимешләре — күп орлыклы, шарсыман яисә киң — йомыркасыман тартмачыклар. Орлыклары кара, вак сөялләр б-н капланган һәм тар, коңгырт төстә, беленер-беленмәс кенә каймаланган. Кыш чыкканнан соң гына тишелеп чыга, бер үсемлек 3000 меңнән 28000 меңгә кадәр орлык бирә. Иген чәчүлекләрен чүпли, туфракны ярлыландыра, культуралы үсемлекләрнең яшь тишемнәрен каплап китә. Чәчү К.н мөгезле эре терлек һәм сарыклар яратып ашый.

*Әд.:* Новицкий С.М. Сорные растения и меры борьбы с ними. Минск, 1966.

**КЫРЛЫКЧА́** (Spergularia), канәферчәләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, бөтен Җир шары буйлап диярлек, нигездә, тозлы туфракларда таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Кызыл К. (S. rubra) ара-тирә барлык районнарда үсә, көтүлек җирләрдә, юл буйларында, чәчүлекләрдә, еш кына көзге культуралар арасында чүп үлән буларак очрый. Тозлак К. (S. salina) Көнчыгыш Кама аръягында тозлы туфраклы болыннарда үсә. 8–20 *см* биеклектәге берһәм күпьеллык үсемлек. Сабаклары җәенке яки туры. Яфраклары тар кыяк, парлашып үскән элпәле вак төпчек яфраклы. Чәчәкләре алсу-җете кызыл төстә, чук чәчәк төркемендә. Җимеше — өч капкачлы тартмачык. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә, ботакларда кышка кадәр саклана. Орлыктан һәм вегетатив (тамырчалардан) юл б-н үрчи. Кызыл К. — терлек азыгы.

**КЫРМЫСКАЛА́Р** (Formicoidea), элпәканатлылар отрядыннан бөҗәкләр өссемьялыгы. Гәүдәсе 1 дән 30 *мм* га кадәр озынлыкта. Күкрәге б-н корсагы нечкә һәм хәрәкәтчел буын б-н тоташкан. Күбесендә агу бизе көчле үскән, ул исә мускуллы капчык б-н әйләндереп алынган. Мускуллар кыскарганда, нигездә, кырмыска к-тасыннан торган агу 50 *см* га кадәр сиптерелә. 10 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 300 тирәсе, Татарстанда — 40. Җирән урман кырмыскасы (Formica rufa) һәм кара бакча кырмыскасы (Lasius niger) киң таралган. Барлык К. — җәмгыять булып яшиләр, катлаулы ояларда гаилә коралар; алар, функцияләренә карап, ана, ата һәм эшче затларга — касталарга бүленә. Үрчемсез ана бөҗәкләр эшче затлар була, төрләрнең иң зур күпчелегендә тумыштан канатсызлар, башкаларында аталанганнан соң канатлары өзелеп төшә. Ата затлар һәрвакыт канатлы. Кайбер төрләре социаль паразитлар — башка кырмыска төрләренең эшче затларын куллана («колбиләүчеләр»). К. ояларын туфракта, ташлар астында, черек үзагачта ясый, кайвакыт коры ботаклардан, ылыстан һ.б. шуңа охшаш материаллардан җир өсте конуслары (кырмыска оялары) төзи. Күпчелек К. ерткычлар, бөҗәкләр һәм умырткасызлар б-н туклана. Аерым төрләре — үсемлек б-н тукланучылар. Күп кенә умырткасызларның санын көйләүче булып торалар. Урманнарда яшәүче җирән урман К.ы зарарлы бөҗәкләрне (нарат ябалакчыгы, нарат карышлавыгы, кисмәннәр һ.б.) юк итеп, зур файда китерәләр һәм шуның б-н агачларның зәгыйфьләнүенә юл куймыйлар. Алар, үлгән бөҗәкләрне юкка чыгарып, санитар ролен башкара. Күпләре урман түшәлмәсен көпшәкләндерә һәм туфрак ясалу процессына булышлык итә, черек үзагачның таркалуын тизләтә, үсемлек орлыкларын тарата. Билгеле бер шартларда аерым төрләре бакчаларга зарар китерә, гөбләләрнең сыекчасы б-н тукланып, җимеш агачларында аларның таралуына булышлык итә. Кайвакыт бал корты ояларына урнаша, кайбер төрләре тере бал кортларын ашый. Күп кенә төрләре файдалы булганлыктан, аларны саклау һәм ясалма үрчетү буенча чаралар күрелә. Уракчы кырмыска (messor clivorum) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Н.В.Шулаев.*

**КЫРМЫСКАЛЫ́ РАЙОНЫ́**, БРның үзәк өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырылы. Мәйданы — 1751 *км*$^2$. Үзәге — Кырмыскалы авылы (Уфадан 50 *км* көньяктарак). Халкы — 51979 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 25863, 1979 да —

23229, 1989 да — 21756, 2002 дә — 15811 кеше. Районда — 124, ш.и. 28 татар, 12 татар-рус, 5 татар-башкорт, 1 татар-башкорт-рус торак пункты бар. Иң зур татар авыллары (2009): Бозаяз (1541 кеше), Сахай (1569), Яңа Кыешкы (1283), Шәйморатов (826), Атҗитәр (492), Сарт-Чишмә (956), Иске Шәрәй (498). Иң борынгылары: Сахай (18 йөз башы), Атҗитәр (1735), Шәрәй (1739), Олыкүл (1752), Бозаяз (1757), Кырмыскалы (1758), Кабак (1760). 2004/05 уку елында районның 7 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 17 сендә татар теле фән буларак укытыла. *Каз өмәсе, Нәүруз, Сабан туе* бәйрәмнәре үткәрелә. Районда ел саен татар теле грамматикасы һәм әдәбияты буенча олимпиада үткәрелә. Күп кенә торак пунктларда татар фольклор коллективлары бар. Кырмыскалы авылында һәм Прибельский посёлогында татар халык театрлары эшли. «Хезмәт даны» г-тасы нәшер ителә. 1998 дә Башкортстан татарлары корылтае башкарма ком-ты бүлеге оештырыла. Районда ш.у. Татар иҗтимагый үзәге эшли. К.р.нда генерал-майор М.М.*Шәйморатов*, агроном-селекционер С.Г.*Кунакбаев*, язучылар Ф.Әсәнов, Р.*Ханнанов*, Д.Булгакова, Р.Чурагулов, Соц. Хезмәт Герое Р.Камалов туган.

**КЫРНЫ́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1678 елдан Кырнаш исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дәүләт-Бахтина буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балык тоту, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 19 йөз башында Воткинск тимер эшкәртү з-дына беркетелә. 20 йөз башында К.та земство һәм чиркәү-приход мәктәпләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 962,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарий волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән — Чаллы, 1924 тән Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1858 дә — 311, 1870 тә — 385, 1884 тә — 398, 1906 да — 471, 1913 тә — 505, 1920 дә — 486, 1926 да — 476, 1949 да — 343, 1958 дә — 288, 1970 тә — 76, 1979 да — 40, 1989 — 15, 2002 дә — 34 кеше.

**КЫРТАПА́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 43 *км* төньяк-көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 158 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кыртапа исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, сарык тиресе эшкәртү, балта эше, йон тетү, тегүчелек, урман кәсепчелеге б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, тимерчелек, җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 950,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Иске Барыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 11 ир-ат; 1859 да — 413, 1897 дә — 732, 1908 дә — 845, 1920 дә — 865, 1926 да — 600, 1949 да — 411, 1958 дә — 468, 1976 тә — 391, 1979 да — 327, 1989 да — 252, 2002 дә — 249 кеше.

**КЫРТЫ́Ш**, шыртлака (Gymnocephalus cernua), алабугалар семьялыгындагы балык. Европа һәм Азиянең төче сулыкларында очрый, Төньяк Америкага үтеп кергән. Татарстан терр-ясендә киң таралган. Төркемнәр булып, әкрен агучы сулыкларда, гадәттә, ботаклы агачлар астында, чокырчыкларда яши. Вак балык, озынлыгы 20 *см*, авырлыгы 20–50 *г*. Күзләре зур, тонык алсу, кайвакыт зәңгәрсу төстә. Сырты карасу тимгелле соры-яшел төстә. Гәүдә капламы күпләп лайла бүлеп чыгара. Тәңкәсе бик вак. Сырт йөзгечендә 11–16 чәнечкеле нурлар бар. Җенси җитлегү 2–3 яшендә. Язда уылдык чәчә, вак сары уылдыкны өлешләп, хәрәкәтчел үсемлекләргә беркетә. Үрчемлелеге — 4–17,5 мең уылдык бөртеге. Моллюсклар, кыслачыклар, бөҗәк личинкалары, ш.у. уылдык һәм маймычлар б-н туклана. К. судак, чуртан, җомба (налим) өчен азык булып тора. Кәсәбәчелек әһәмияте зур түгел.

**КЫРЧЫ́Л** (Agrostis), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 гә якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында һәм тропикларның тауларында таралган. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Гигант К. (A. gigantea), нәзек К. (A. tenuis), үрентеле К. (A. stolonifera), йөземле К. (A. vinealis) ара-тирә барлык районнарда очрый. Эт К.ы (A. canina) һәм Корчагин К.ы (A. korczaginii) Идел алдында үсә. Нигездә, сирәкләнгән урманнарда, болын тугайларында, сулык ярлары буенда үсә. 15–20 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабагы туры, көпшәле, буынлы. Яфрак пластинкалары кыяктан гыйбарәт, яссы. Чәчәк төркеме — бер чәчәкле вак башакчыклы җәенке себеркәч. Җимеше — бөртекчә. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамырчалардан) үрчи. Терлек азыгы. Күп кенә төрләре газон ясау өчен кулланыла.

**КЫРЧЫЛЫ́К**, кыр культуралары продукциясен (бөртеклеләр, техник культуралар, терлек азыгы, бәрәңге) җитештерү; үсемлекчелек тармагы. Җирле төбәк халкының электән килгән хуҗалык эшчәнлегенең төп төрләреннән берсе. Казан губернасында, өч басулы чәчү әйләнешен кулланганда, кыр культураларының гомуми чәчүлек мәйданы 1913 елда — 2491,2, 1920 дә 2115,7 мең *га* тәшкил итә. Татарстан терр-ясендә, күп басулы һәм аеруча үлән басулы чәчү әйләнешен, ш.у. биләүле пар җирләрен файдаланганда, ул 1928 дә — 2781,4 мең, 1940 та — 3190,2, 1960 та — 3533,3, 1970 тә — 3655, 1980 дә 3595,3 мең *га* га җитә; терлек азыгы культураларының, бәрәңге чәчүлекләренең мәйданнары киңәйтелә, шикәр чөгендере үстерелә башлый (1944 тән). Чиста пар җирләренең мәйданнарын арттыру һәм эрозияләнгән җирләрнең бер өлешен болынлыкка (табигый терлек азыгы җирләре) күчерү нәтиҗәсендә, чәчүлек мәйданнары 2008 гә 2998 мең *га* га кадәр кими. Төп кыр культураларының уңышы: бөртеклеләр һәм бәрәңгенең 1928 дә — 1 *га* дан 6,8 һәм 80 *ц*, 1940 та — 7 һәм 46, 1970 тә — 14,8 һәм 155, 2008 дә — 37,2 һәм 196 *ц*; шикәр чөгендеренең 1960 та — 101, 1971 дә — 171, 2008 дә 300 *ц* тәшкил итә.

К. өлкәсендә фәнни тикшеренүләр Төньяк-көнчыгыш фермада (хәзер Ферма-2), Казан а.х. тәҗрибә станциясендә, Югары Идел селекция үзәгендә, Казан селекция, Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станцияләрендә үткәрелә; хәзерге вакытта алар Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, Казан аграр ун-тында, Россия а.х. академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында башкарыла.

*Әд.:* Мосолов В.П. Сочинения. М., 1955. Т. 5; Карнаухов И.П., Леонтьев В.М. Полеводство и луговодство. М.–Л., 1956; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992; Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**КЫРЫ́Й ЙОРТКҮ́Л** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 41 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.Й. дә мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, йон тетү йорты, 1 тукыма һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1349,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Йорткүл волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1859 да — 510, 1897 дә — 641, 1908 дә — 772, 1926 да — 355, 1938 дә — 288, 1949 да — 275, 1958 дә — 319, 1970 тә — 311, 1979 да — 263, 1989 да — 163, 2002 дә — 147 кеше.

**КЫРЫ́К САДА́К** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 32 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 528 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә.

Мәчет. 1652 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; лашманлыкта эшли, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.С. та 3 мәчет, 3 мәдрәсә, тегермән, 11 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1763,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 596, 1897 дә — 927, 1910 да — 1297, 1920 дә — 1331, 1926 да — 1370, 1938 дә — 1401, 1949 да — 1330, 1958 дә — 1001, 1970 тә — 937, 1979 да — 819, 1989 да — 610, 2002 дә — 533 кеше.

**КЫРЫ́К ТАТА́Р** (Кырык Ир, хәзер Литваның Вильнюс р-ны Кятурясдяшимт Тоторю а.), урта гасырлардан мәгълүм Литва татарлары авылы, Вильнюс (Вильно) б-н Тракай (Троки) шәһәрләре арасында, Вока елгасы буенда урнашкан. 15 йөздә, якынча *Грюнвальд сугышыннан* (1410) соң нигез салына. Риваятьләрдән күренгәнчә, К.Т. авылына әлеге сугышта Литва бөек кенәзе Витовтның гомерен саклап калган татар сугышчысы тарафыннан нигез салына; ул җирләр б-н бүләкләнә. Шундый риваятьләрнең берсендә аның нәсел дәвамчылары булган кырык улы турында әйтелә. Авылның исеме дә шуның б-н бәйле булса кирәк (Кырык татар). К.Т. авылында иң элек, чыгышлары б-н Алтын Урдадан булып, Бөек Литва кенәзлегенә хезмәткә чакырылган кешеләр һәм Витовтның Кырымга 1397 елгы явы вакытында әсир ителгән татарлар яши. Кайбер мәгълүматларга караганда, 1414 тә Троки шәһәре һәм аның тирәсендәге берничә авылда «бик күп татар» яши диелә. Башка татар авыллары кебек үк, К.Т. көнбатыш һәм көньяк-көнбатыштан Троки һәм Вильно шәһәрләрен саклап тора. Бу авылда яшәүчеләр хәрби хезмәткә кавалерия отрядлары җибәреп торырга тиеш була. Моннан тыш алар курьер, каравыл, полиция һ.б. хезмәтләргә дә тартыла. Төрле чорда К.Т. авылы б-н 38 татар нәселе вәкилләре, ш.и. Дзешинскийлар, Сулькевичлар, Шешковлар, Шабловлар идарә итә. 1558 дә К.Т.да мәчет төзелә. 1997 дә К.Т. терр-ясе мемориаль зона статусы ала.

*Әд.:* Мухлинский А. Исследование о происхождении и состоянии литовских татар. СПб., 1857; Гришин Я.Я. Польско-литовские татары. К., 1995; Dziadulewicz S. Herbarz rodzin tatarskich w Polsce. Wilno, 1929.

*Ф.К.Фәизов.*

**КЫРЫКБУЫ́Н** (Galatella), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 45 кә якын төре билгеле, Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә 5 төре бар. Тар яфраклы К. (G. angustissima), йөнтәс К. (G. villosa), ике чәчәкле К. (G. biflora), татар К. (G. tatarica) — Кама аръягында, рус К. — Кама алдында һәм Кама аръягында очрый. Мергельле сөзәклекләрдә, тозлы туфраклы болыннарда, урман буйларында, куаклар арасында үсә. 10–120 *см* биеклектәге үзәк тамырлы үсемлекләр. Сабагы туры, яфраклы. Яфраклары бөтен, кыякчыл. Таҗ яфрагы сыман җимешсез чәчәкле яки аларсыз гына булган кәрзиннәр сабак очындагы калкансыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимешләре — озынча орлыкчалар. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре август–октябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм тамырчалардан үрчи. Декоратив үсемлек. Ике чәчәкле К., рус К., татар К. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫРЫКМА́С** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Иж елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 108 *км*, ТР чикләрендә — 26 *км*. Бассейнының мәйданы 2100 $км^2$. Сарапул калкулыгыннан ага. Елга башы һәм төп агымы — Удмурт Респ-касы терр-ясендә; елганың Бимә һәм Шихостанка кушылдыкларының тамаклары арасындагы өлеше һәм иң түбәнге агымнары — Әгерҗе р-ны терр-ясендә, тамагы — Салкын Чишмә авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. К.ның 38 кушылдыгы бар. Иң зурлары: уң — Салкын Чишмә (13,2 *км*), Шихостанка (39,4 *км*); сул — Бимә (58,3 *км*), Кады (21,2 *км*), Чыкалда (17,8 *км*). Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–1 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы



Кырыкмас елгасы.

ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 121 *мм*, ташу агымы катламы 99 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,56 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. К. бассейнында суның гомуми күләме 5,2 млн. $м^3$ булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**КЫРЫКТАРТМАЧЫЛА́Р** (офенялар), 18 йөз уртасында — 20 йөз башында китаплар, ксилография, литография басмалары, галантерея һ.б. вак товарлар (башлыча, Владимир, Мәскәү һәм Тула губерналарыннан китерелгән) б-н ваклап сату итүчеләр. Җәй ахыры — көз башыннан (кыр эшләре тәмамланганнан соң) Масленица яки Пасхага кадәр авыллар буйлап товар таратып йөриләр. Сәүдәләренең серен башкаларга сиздермәс өчен, кырыктартмачылар үз сөйләмнәрен (жаргоннарын; офеня теле) булдырганнар. Крәстияннәр арасында бердәнбер диярлек басма продукция таратучылар булганнар. Агачка чокып эшләнгән форма ярдәмендә басылган картиналар (аларны лубок басмалар дип атап йөрткәннәр), башлыча, дини, үгет-нәсыйхәткә корылган, кайвакыт публицистик эчтәлекле булган (мәс., Петр I реформаларына каршы юнәлтелгән һәм Казанның иске дин тарафдарлары арасында киң таралган «Казан мәчесе» һәм «Тычканнар ничек мәчене җирләгәннәр» лубоклары). Ксилография ысулы б-н басылган һәм кулдан тупас итеп буялган гади картиналар зур тиражлар б-н чыгарылган. Аларда көнкүреш сурәтләре, шәһәр күренешләре, геройларның портретлары төрле текстлар (җырлар, мәкальләр, такмазалар) б-н бирелгән. Лубоклар крәстияннәр, мещаннар, вак чиновникларның йорт эчен бизәү өчен файдаланылган. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан лубок басмалар рәвешендә әкиятләр, былиналар, төшлекләр, рыцарь романнарына ияреп язылган китаплар чыгарыла. Владимир губернасы Вязники өязе кырыктартмачылары Казанда һәм тирә-як авылларда фәкать китаплар һәм лубоклар б-н генә сәүдә итәләр. С.Т.Аксаков 19 йөз башында бер Казан гимназистының лубок картиналарыннан торган зур тупланмасын («Бова Королевич турында әкият», «Еруслан Лазаревич» һ.б.) тасвирлый һәм үзен лубокны ихлас яратучы дип атый. Казанда иске китаплар һәм гравюраларны Толчук базарында (Гостиный двор янында) сатканнар, читтән килгән сәүдәгәрләр һәм кырыктартмачылар аларны күмәртәләп алганнар. 19 йөздә кайбер кырыктартмачылар китап сатучы бай алыпсатарларда хезмәттә торган. 19 йөз ахырында, капитализм үсеше б-н бәйле рәвештә, Россиядә китап базарын кулга төшерү өчен көрәш бара. Мәскәүнең китап нашире И.Д.Сытин фирмасы илнең барлык кырыктартмачыларын да диярлек үзенә хезмәткә җәлеп итә. Татар авылларында китап сәүдәсе б-н муллалар, шәкертләр, крәстияннәр шөгыльләнә (алар «Милләт», «Мәгариф», «Гасыр» нәшриятлары б-н бәйләнештә тора). Күп кенә наширләр (Ш.Хөсәенов, бертуган Кәримовлар, М.Кадыйров һ.б.) үзләре дә китап агентлары булып эшли башлыйлар. Китап б-н сәүдә итү, аңа таныклама бирелгәннән соң, ярминкәләрдә, халык бәйрәмнәрендә (Сабан туе, Җыен) гамәлгә ашырыла. Китап таратучылар Идел буендагы һәм Уралдагы барлык губерналарның татар авылларында сәүдә итәләр.

*Әд.:* Бахтин В., Модзалевский Д. Русский лубок XVII–XIX вв. М.–Л., 1962; Кариму ллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

*И.А.Новицкая.*

**КЫРЫ́М ТАТАРЛАРЫ́** (үзатама, 20 йөздә барлыкка килә; 16–17 йөзләр рус чыганакларында — кырымлылар, Кырым татарлары, 18–19 йөзләрдә — татарлар), төрки халык; кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, 20 йөз башы алдыннан оешкан аерым татар этносы. 1989 елгы Бөтенсоюз халык санын алу буенча, 270 меңнән артык кеше. Башлыча,



«Кырым татарлары». Кәгазь. Акварель. Рәссам Е.М.Корнеев. 1802.

Кырым Автономияле Республикасында (Украина) яшиләр; 2001 елгы Бөтенукраина халык санын алу мәгълүматлары буенча, алар 243433 кеше исәпләнә, бәяләмә мәгълүматлар буенча, 2002 ел башына Кырымда яшәгән К.т.ның саны 260000 нән дә ким түгел. РФ дә, 2002 дә халык санын алу буенча, К.т. 4131 кеше исәпләнә; башлыча, Краснодар һәм Ставрополь крайларында, күбесенчә шәһәрләрдә яшиләр. К.т.ның тупланып яшәгән торулыклары Үзбәкстанда һәм Таҗикстанда бар; алар ш.у. Болгариядә, Румыниядә, Төркиядә колонияләр булып урнашкан. Дөньяда барлыгы 5 млн. лап кеше исәпләнә (2005). Субэтносларга — дала (нугай), тау алды (татлар), көньяк яр буйлары (ялыбойлу) татарларына бүленәләр; кайбер очракта дала татарлары б-н катнаш нугайлар варислары төркеме (нугайлар, ногайлар) аерып күрсәтелә. Әдәби телләре — төрек, кумык, карачай-балкар, ш.у. Азов буендагы грек-румнар телләренә якын, кардәш. Башта К.т.ның бабалары рун язуыннан файдаланганнар, 13 йөз ахыры — 14 йөз башыннан Кырым йорты терр-ясендә татарлар арасында гарәп язуы тарала. 1929 дан К.т. — латин, 1938 дән кириллица язуына күчәләр. 1992 дә Кырым татар халкының Милли Мәҗлесе латин әлифбасына кайту турында карар кабул итә. Динле К.т. — мөселман-сөнниләр. К.т.ның этномәдәни йөзе формалашуда 7–13 йөзләрдә Кара диңгез буендагы далалардан Кырымның төньяк өлешенә күченгән төрки телле халыклар (хәзәрләр, кыпчаклар, нугайлар һ. б.), 11–12 йөзләрдә сәлҗукларның яулап алулары вакытында көньяк яр буйларын биләгән төркиләр, ш.у. Кырым ярымутравының таулы һәм яр буе төбәкләрендә яшәгән җирле утрак халыклар (таврлар, киммерилар, аланнар һ. б.) хәлиткеч роль уйныйлар. Төрки телле төркемнәр составына бирегә төркиләр килгәнче яшәгән яки соңрак таралып урнашкан византияле греклар, әрмәннәр, итальяннар (13–15 йөзләрдә Кырымның көньяк яры чынлыкта итальян сәүдә республикалары — Венеция, аннан соң Генуя идарәсендә була), готлар (Кырымга 4 йөздә киләләр, 17 йөзгә кадәр аерымланып яшиләр), Грузиядән, Молдавиядән, славян җирләреннән чыгучылар кушыла. Төп берләшү процесслары Алтын Урда чорында һәм ул таркалганнан соң оешкан, 1475–1783 елларда Госманлылар империясенә вассал бәйлелектә яшәгән, шул сәбәпле К.т.ның этномәдәни үсеше госманлы төрекләрнең көчле йогынтысына дучар булган Кырым ханлыгы чикләре эчендә бара. 18 йөз ахырында К.т. Кырымда сан ягыннан өстен булалар, ләкин 20 йөз башына аларның зур өлеше тарихи ватаннарыннан читтә яши. Бу бигрәк тә Россия колониаль сәясәтенең нәтиҗәсе һәм Төркиягә күченүнең ике дулкыны (1783 тә Кырымны Россия империясенә кушкач, 1790 елларда; Кырым сугышы вакытындагы (1853–56 да һәм аннан соң) вакыйгалар б-н бәйле. 20 йөзгә кергәндә К.т. Керчь һәм Тархункут ярымутрауларында, Евпатория шәһәре тирәсендә һәм Сиваш култыгы ярында, көнбатышта — Балаклавадан, көнчыгышта — Судак шәһәренә һәм Карасубазардан (хәзер Белогорск) Ялта шәһәренә кадәрге җирләрдә яшиләр. 1802–1921 дә бу терр-я Таврия губернасы составына керә. 20 йөз башында губерна Бердянск, Днепр, Евпатория, Мелитополь, Перекоп, Симферополь, Феодосия һәм Ялта өязләрен колачлый. К.т.ның традицион шөгыльләре — игенчелек, бакчачылык, виноград һәм яшелчә, тәмәке үстерү, терлекчелек, яр буйларында — балыкчылык; ш.у. сәүдә, тоз чыгару б-н шөгыльләнәләр, төрле һөнәрләр — агачны, металлны (кораллар, зәргәр бизәмәләре ясау), күнне нәфис эшкәртү, бизәкле тукымалар, киез җитештерү, алтынлап чигү һ. б. б-н шөһрәт казаналар. 19 йөздә — 20 йөз башында Россиядәге татарларның иң шәһәрләшкән төркемнәреннән берсе булалар; Евпатория, Керчь, Симферополь, Феодосия шәһәрләрендә яшиләр. Бакчасарай һәм Карасубазар шәһәрләре К.т.ның иң танылган үзәкләре була; анда эре милли кием-салым тегү, бизәмәләр, савыт-саба һ. б. ны җитештерү остаханәләре урнаша; мәчетләр, мәдрәсәләр, мәктәпләр ислам дине һәм мәдәнияте, милли үзаң үсешендә зур роль уйныйлар. 19–20 йөзләр чигендә Кырымда яңа милли интеллигенция формалашуга башлангыч биргән, мөселман халкын укыту һәм агартуга юнәлтелгән киң колачлы программа гамәлгә керә. Бу эшкә һәм барлык төрки телле дөньяның рухи күтәрелешенә кырымтатар мәгърифәтчесе, педагогы, нашире И.*Гаспринский* гаять зур өлеш кертә. 1883–1914 тә ул Бакчасарайда, яңа мәгариф алымнарын һәм яңа мөселман тормышы идеяләрен пропагандалап, *җәдитчелек* хәрәкәтенең төп принциплары барлыкка килүдә һәм формалашуда аеруча актив катнашкан «Тәрҗеман» г-тасын нәшер итә. 1906 дан газета хатын-кызлар өчен дөньяда беренче әдәби агарту басмасы булган кушымта — «Галәме нисван» («Хатын-кыз дөньясы») ж-лы б-н бергә чыга башлый. 1917 ел ахырында Бакчасарайда кырымтатар халкының 1 нче корылтаена сайлаулар уза, ул 1918 ел башында ук аның тарафыннан оештырылган, татар буржуаз-милләтче «Милли Фирка» ҮК әгъзаларыннан торган Кырым татар милли хөкүмәте б-н бергә таратыла. 1918 нең мартында Таврида Кырым Совет Социалистик Республикасы төзелә; ул озак яшәми: 1918 нең 25 июнендә Кырым терр-ясен басып алган Германия оккупантлары канаты астында генерал М.А.Сулькевич җитәкчелегендә курчак буржуаз-милләтчел Кырым крае хөкүмәте оештырыла. 1918 нең 15 ноябрендә, Кырымнан Германия оккупацион гаскәрләре киткәннән соң, Сулькевич хөкүмәте хакимиятне кадет-эсер-меньшевиклар хөкүмәтенә тапшырырга мәҗбүр була, аның башлыгы булып кадет С.С.Крыйм сайлана. Яңа Кырым крае хөкүмәте үзенең эшчәнлегендә Кырымга басып кергән француз, инглиз гаскәрләренә, акгвардиячеләр отрядларына таяна. 1919 ның апрелендә, Севастополь Кызыл Армия частьләре тарафыннан азат ителгәннән соң, үзәге Симферопольдә урнашкан Кырым Совет Социалистик Республикасы (РСФСР составында) төзелә, май аенда Д.И.Ульянов рәислегендә Вакытлы эшче-крәстияннәр хөкүмәте оештырыла. 1919 ның июнендә Кырым ярымутравын А.И.Деникин гаскәрләре басып ала, 1920 нең ахырында анда сов. хакимияте торгызыла. 1921 нең октябрендә төзелгән Кырым АССР (РСФСР составында, 1921–24 тә ХКС рәисе — С.С.*Сәетгалиев*) 1945 тә Кырым өлкәсе итеп үзгәртелә, ул 1954 тә Украина ССР составына кертелә.

Бөек Ватан сугышы Кырымның күптелле халкы өчен аеруча фаҗигале төс ала: ул ярымутрауның героик оборонасының, немец оккупациясе шартларындагы тормышның барлык авырлыкларын кичерә; совет хөкүмәтенең «ышанычсызлык» сәбәпле ирексезләп сөреп чыгару турындагы карары аның өчен иң аяныч вакыйга була. 1941–44 тә рус булмаган халыклар тулаем диярлек (300 меңнән артык кеше) Кырымнан сөрелә. К.т.н яшәгән җирләреннән чыгаруның иң зурысы (187859) 1944 нең 18–20 маенда гамәлгә ашырыла (1993 тән 18 май рәсми рәвештә Ма-



Кырым татарлары. Ситниковның төп нөсхәсеннән К.Ф. Гун тарафыннан күчерелгән рәсемнең төсле литографиясе. Кәгазь. 1862.

тәм көне буларак билгеләп үтелә). Махсус фәрман б-н армиядән җибәрелгән хәрбиләрне дә кертеп, яшәгән җирләреннән күчерелгән К.т.ның гомуми саны 200 мең кешедән арта. Сөрелгән башка халыклар кебек үк, К.т., аерымлап, Идел буе һәм Уралдан алып, Урта Азия һәм Себергәчә зур терр-ядә таратылып урнаштырыла; аларның яртысы диярлек юлда һәм күчерелүчеләргә каралган махсус режим шартларында яңа урыннарда яшәүнең беренче айларында һәлак була. 1967 дә К.т.ның конституцион хокуклары торгызыла, ләкин 1980 еллар ахырына кадәр аларның ватаннарына кайтуы ясалма рәвештә тоткарлана. 1990 еллар башында К.т. күпләп, асылда, стихияле рәвештә кайта башлыйлар, ләкин аларның яңадан Кырымда төпләнүе этабында күп кенә проблемалар — сәяси, икътисади, социомәдәни кыенлыклар туа. 1991 нең февралендә Украина ЮС сессиясендә «Кырым АССРн торгызу турында» Закон кабул ителә (хәзер — Кырым Автономияле Республикасы). Хәзерге кырымтатар хәрәкәтенең идеологик нигезе 1991 нең июнендә Симферопольдә «кырымтатар халкының иң югары вәкаләтле вәкиллеге органы» буларак Милли Мәҗлес оешуны игълан иткән Корылтай уздырылганда салына. Мәҗлеснең, милли сәяси партияләрнең Украина һәм Кырым дәүләт структуралары б-н мөнәсәбәтләре 1999 да Бөтенкырым акциясе — К.т. ның үз хокукларын яклау өчен каршылык маршы — нәтиҗәсендә Украина Президенты указы б-н Президент каршында Кырымтатар халкы вәкилләре советы оештырыла. Хәзерге көндә милли хәрәкәттә 3 юнәлеш күзәтелә: уртача — К.т. милли хәрәкәте сәяси оешмасы эшчәнлеге б-н билгеләнә, әлеге позицияне «Арекет» г-тасы яклый; милли-либераль — Мәҗлес һәм Кырымтатар милли хәрәкәте оешмасы юнәлеше, «Авдет», «Кырым тавышы» г-талары, радио һәм телевидениенең милли редакцияләре аның идеяләрен алга сөрә; радикаль — «Адалет» партиясе тарафыннан алып барыла. К.т., гасырлар буе дәвам иткән мәдәни кыйммәтләрнең күпчелеге юкка чыгуга да карамастан, үзләренә генә хас үзенчәлекләрне (тел, дин, гаилә-көнкүреш традицияләре, халык йолалары, җырлар, биюләр, милли кухня) саклап калалар. Социаль ярашу һәм милли-мәдәни яңарыш алар өчен хуҗалык төзелеше һәм көнкүрешне җайлау кебек үк мөһим бурыч булып тора. Гуманитар юнәлештәге мәсьәләләр «Маарифчи» Кырымтатар мәгариф хезмәткәрләре ассоциациясе, Кырымтатар хатын-кызлары лигасы, Кырым язучылары советы каршындагы кырымтатар язучылары секциясе, Кырымтатар рәссамнар ассоциациясе, Кырым мөселманнары диния нәзарәте тарафыннан бергәләп хәл ителә. 1991–92 дә Симферопольгә Үзбәкстанда оештырылган «Хайтарма» кырымтатар хореография ансамбле, милли әдәбият, «Янъы дөнья» («Новый мир») г-тасы һәм «Йолдыз» («Звезда») ж-лы редакцияләре күчеп килә. Соңрак Симферопольдә Кырымтатар акад. музыкаль-драма театры, Республика кырымтатар сәнгать музее, Кырым индустриаль-педагогия ун-тында кырымтатар теле һәм әдәбияты укытучыларын әзерләү ф-ты ачыла, И.Гаспринский исем. Республика кырымтатар милли китапханәсе оештырыла.

*Әд.:* Гаспринский И. Русское мусульманство: Мысли, заметки и наблюдения мусульманина. Симферополь, 1881; Куфтин Б.А. Южнобережные татары Крыма // Крым. 1925. № 1; Бочагов А.К. Милли Фирка: Национальная контрреволюция в Крыму (1917–1920). Симферополь, 1932; Баскаков Н. А. Тюркские языки. М., 1960; Воробьёв Н.И. Поволжские татары // Народы Европейской части СССР. Сер. Народы мира. М., 1964. Т. 2; Забвению не подлежит... (Из истории крымско-татарской государственности и Крыма). К., 1992; Исхаков Д.М. Татары. Наб. Челны, 1993; Червонная С.М. Проблемы возвращения и интеграции крымских татар в Крыму: 1990-е гг. М., 1997; Габриелян О.А. Политические процессы в Крыму: Последнее десятилетие XX века. Симферополь, 2000; Крымские татары — гордость тысячилетий... Симферополь, 2001; Татары. М., 2001; Гражданская война и военная интервенция в СССР: Энцикл. М., 1983; Крымскотатарская энциклопедия: В 2т. Симферополь, 1993–95; Народы России: Энцикл. М., 1994; Отечественная история: История России с древнейших времён до 1917 года: Энцикл. М., 2000. Т. 3; Венера Якубова. Крымские татары, или Привет от Сталина. К., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**КЫРЫ́М ХАНЛЫГЫ́** (1441/43 — 1783), Кырымны, Кавказ алдының көнбатышын һәм Кара диңгез буйларының Днестр елгасыннан Дон елгасына кадәрге төньяк өлешен биләгән урта гасырлар дәүләте. *Алтын Урданың* таркалу чорында аның Кырым олысы терр-ясендә барлыкка килә. К.х.н нигезләүче — Кырымда җирле татар аксөякләре һәм Польша-Литва дәүләте ярдәме б-н хакимияткә килгән *Хаҗигәрәй хан* (1441/43 — 66). К.х. иң куәтле заманда (15 йөз уртасы) аның чикләре Кара диңгез буйларының төньяк өлешендә, көнбатышта — Днестр тамагыннан, көнчыгышта — Донның уңъяк ярына, төньякта — Бурсыклы (Ворскла) елгасына кадәрге терр-яне колачлый.

К.х.дагы адм. бүленеш урта гасырлардагы төрки-татар дәүләтләре өчен традицион була һәм дүрт нәселнең — *Аргын, Барын, Кыпчак* һәм *Ширин* ыругларының эре биләмәләреннән тора, соңрак төрек адм. системасы йогынтысында үзгәрешләр кичерә. К.х.на күчмә Едисан, Буҗак, Кече Нугай Урдасы биләмәләре бәйле була. Чәчәк ату чорында ханлык бәклекләргә бүленә, аларның һәрберсе берничә торулык җирләрен берләштерә һәм төрле татар нәселләре вәкилләре тарафыннан идарә ителә. Башкаласы Бакчасарай — эре дини, сәяси һәм сәүдә үзәге. Башка эре шәһәрләре — Солхат (Иске Кырым), Кафа, Аккирмән, Азак (Азов), Кырык Йорт (Чуфут Кала), Гёзләү, Судак. Алар барысы да бәйлекләрнең адм. хакимият, һөнәрчелек, сәүдә, дини тормыш үзәкләре булалар. К.х. җирләрендә татарлар, греклар, әрмәннәр, караимнар, кырымчаклар, порт шәһәрләрендә ш.у. итальян сәүдәгәрләре яши.

Аксөякләр үзләрен — татарлар (кайбер очракларда «кырымлы» өстәмәсе б-н), төп халык күбрәк үзен дини төсмер б-н мөселманнар дип атый. К.х.да төп тел төрки тел була, шул телдә ш.у. эш кәгазьләре тутырыла, дипломатик язышулар алып барыла һәм әдәби әсәрләр иҗат ителә, 16 йөздән аңа госманлы төрекләр теленнән күпсанлы сүзләр үтеп керә башлый.

К.х. халкының хуҗалык итү рәвеше төбәкләрнең үзенчәлекләренә бәйле була: югары үсеш алган игенчелек, ш.у. бакчачылык һәм йөзем үстерү — таулар итәгендәге көньякта, ярымкүчмә терлекчелек Кырымның далалы өлешендә һәм Кара диңгезнең төньягында таралыш ала. Шулай ук бодай (аның бер өлеше сатуга чыгарыла), арпа, тары, дөге, ясмык, бакчаларда шәфталу, груша, слива, чия, чикләвек агачлары, алмагачлар үстерелә. Халык умартачылык, балыкчылык һәм сунарчылык б-н шөгыльләнә. Шәһәрләр, бигрәк тә портлары булганнары, югары үсеш алган һөнәрчелек (тимер эшкәртү, сугыш кораллары ясау, туку, күн җитештерү, агач эшкәртү, чүлмәкчелек, зәркәнчелек, төзелеш һ.б.) үзәкләре була. Төркия, Россия, Польша, Кавказ арты илләре б-н сәүдә бәйләнешләре үсә. К.х.нан читкә чыгарылган төп товарлар — бодай, бал, ш.у. коллар; башка илләрдән корал, тукымалар, тәмләткечләр, затлы әйберләр һ.б. кертелә. Иң зур ярминкәләрнең Кафа, Гёзләү, Судак һәм Ор-Капуда (Перекопта) уздырылуы мәгълүм. К.х.нда иң югары хакимият Җүчи хан варислары — *Гәрәйләр* нәселе ханнары кулында була. К.х.ның тамгасы (гербы) — өч тешле тарак, туграсы Кырым ханнарының дипломатик документларында төрле формаларда сакланган каллиграфик язмалы тамга рәвешендә була. 1475 елда К.х. Госманлылар империясенең вассалына әверелгәннән соң, анда башка төрле хакимият системасы урнаша. К.х. б-н чынлыкта төрек солтаны идарә итә; ул, ханнарны тәхеттән төшерүгә һәм аларны билгеләүгә хокуклы булган хәлдә, ханлыкның барлык халыкара бәйләнешләрен контрольдә тота, ш.у. Кырым гаскәрләрен яуга җибәрергә әмер бирә ала. Формаль рәвештә К.х. ханнары бүленмәс хакимияткә ия монарх булып калалар, ләкин чынлыкта аларның хакимияте төрек солтаннары һәм идарәче кланнар тарафыннан чикләнә. Ханнар үз мөһерләре б-н илнең барлык кануннарын раслыйлар, башка төрле вәкиллек вазифалары башкаралар. Ханның Альма, Кача һәм Салгир елгалары үзәннәрендәге олысы аның байлыгының нигезен тәшкил итә. 15 йөз ахырыннан ханнарның резиденциясе Бакчасарайда урнаша. Ханнан кала әһәмияте буенча Гәрәйләр нәселенең икенче дәрәҗәдәге иң өлкән вәкиле — калга, ягъни тәхет варисы санала. Аның резиденциясе һәм администрациясе Ак Мәчеттә урнаша. Калга биләмәсе калгалык-варислык буенча тапшырылмый, ә дәүләт милке булып исәпләнә. 1578 дән К.х.нда тагын бер тәхет варисы (әһәмияте буенча нәселдә өченче дәрәҗәдәге *нурадын* титулы) барлыкка килә; аның биләмәләре Альма үзәнендәге Качи-Сарайда урнаша. Чынлыкта К.х.нда хакимият татар аксөякләре кулында була; алар арасында 4 идарәче ыруг: Ширин (бу ыругның күренекле вәкилләре — дәүләт эшлеклеләре Әмәнәк (15 йөз ахыры) һәм Җантимер морза (18 йөзнең 1 нче яртысы), Аргын, Барын һәм Кып-




чак (Яшлау) ыруглары йогынтылы урын били. Соңрак аларга нугайларның Мангыт (Мансур) һәм Сиҗәүт ыруглары кушыла. 16–18 йөзләрдә кланнарның абруйлык дәрәҗәләре үзгәрә: мангытлар Аргын, Кыпчак һәм Барын ыругларын хакимият структураларыннан кысрыклап чыгаралар. Аксөякләр хан каршында оештырылган *диван* аша дәүләт эшләренә йогынты ясыйлар. Аның составына калга, нурадын, ширин-бәй, *мөфти, карачыбәкләр* җитәкчелегендә дүрт идарәче ыруг вәкилләре, өч күчмә урда (Буҗак, Едисан, Нугай) идарәчеләре — серакәсирләр керә. Диван барлык дәүләт эшләре б-н җитәкчелек итә, ш.у. сословиеле һәм җирле мәхкәмәләр карамагына кермәгән җитди мәхкәмә эшләрен карый, дәүләт чыгымнарын (ш.и. хан һәм сарай даирәсен тоту) билгеләү б-н шөгыльләнә.

Иң югары адм. һәм хәрби хакимият Ширин ыругыннан булган карачыбәк (каймакан, ширин-бәй) кулында туплана (аның резиденциясе Солхатта урнаша). Дәүләтнең тышкы иминлеген тәэмин итү б-н ор-бәк шөгыльләнә (резиденциясе Перекопта була). Финанс эшләре һәм салымнар җыю б-н хан агасы (вәзир), ш.у. төрле чиновниклар — казандар башы, актачы башы, дәфтәрдар башы, килләрҗе башы һ.б. җитәкчелек итә; гадәттә, аларның вазифалары идарәче ыруглар арасында бүленә. Төркия империясенә бәйлелеккә кергәннән соң, Кырым тормышында солтан вәкиле мөһим роль уйный башлый.

К.х.нда аксөякләрнең социаль статусы җир биләү (яки бер төрле салым җыю) хокукларына нигезләнгән иерархия системасына таяна. Җир биләү өчен аның хуҗалары үзләре буйсынган затка хезмәт итәргә тиеш булалар. Биләмә шартлы (икта, *сөйургал*) һәм шартлар б-н чикләнмәгән төрдә була (*тархан*, ягъни салымнардан һәм төрле җыемнардан тулысынча яки аларның бер өлешеннән азат ителү). Аксөякләрнең югары катлавын Гәрәйләр вәкилләре — калга, нурадын һ.б. солтаннар, ш.у. *морзалар, бәкләр* һәм йомышлы вак аксөякләр — әмәлдәшләр һәм сердәшләр тәшкил итә. К.х.ның гаскәре, хан гвардиясеннән (капы-кулу) һәм татар ыруглары халкыннан, ш.у. хәрби чара максатларыннан чыгып, 4 меңнән 200 мең яугиргә кадәр исәпләнгән күчмә кабиләләр гаскәрләреннән туплана. Армиянең үзәге хәрби җитәкчеләрдән һәм, башлыча, авыр коралланган җайдаклардан (аларның гомуми саны 8–10 мең кешегә җиткән), йомышлы аксөякләрдән тора. 16 йөз башында төрек армиясе тибындагы даими проф. армия төзелә башлый, аның составына мушкетлар б-н коралланган (җанисcәрләр һәм түфәнекче) җәяүле яугирләр отрядлары, ш.у. кыр артиллериясе (зарбузан) керә. Тора-бара бу отрядлар сугыш хәрәкәтләрендә мөһим роль уйный башлыйлар. Ачык кырдагы сугышларда һәм ныгытмаларны саклаганда артиллерия кулланыла. Елгаларны кичүдә һәм елга сугышларында хәрби һәм транспорт максатындагы флот файдаланыла. 16–18 йөзләрдә Кырым ханы отрядлары күбесенчә Төркия гаскәрләре составында хәрәкәт итәләр. Кырдагы бәрелешләрдә оператив манёврлар, флангләрдан кысып алу, алдаулы чигенүләр кулланыла. Сугыш вакытында татарлар, дошманга уклар яудырып, дистанция сакларга омтылалар.

Халыкның төп массасын дәүләткә яки феодалга салымнар түләгән катлаулар тәшкил итә. Төп салым татар дәүләтләре өчен традицион ясактан гыйбарәт була. Гамәлдә булган башка төрле салымнар, җыемнар һәм бурычлар: гаскәрләргә һәм хакимиятләргә азык-төлек, кирәк-яраклар тапшыру (анбар малы, өлүфә сүсүн һ.б.), ям бурычы (илче кунак), руханилар өчен җыелучы салым (гошер һәм зәкят) һ.б. Кырым татарларының хәрби отрядлары төрек солтаннарының яуларында катнашкан өчен түләүләр, Польша һәм Россия тарафыннан үз терр-яләренә һөҗүмнәр булмасын өчен түләнгән акчалата контрибуцияләр, ш.у. ганимәт малы К.х. казнасына зур керемнәр китерә. 17 йөз уртасында Россиянең К.х.на акчалата түләүләре (русча «поминки» дип аталган) 12 мең сумга җитә.

К.х.да исламның хәнәфиләр мәзһәбенә караган сөнниләр юнәлеше дәүләт дине була. Руханилар вакыфлар билиләр. Аларны *сәедләр* нәселеннән булган мөфти җитәкли. Мөфтиләр һәм сәедләр илнең сәяси тормышында актив катнашалар һәм казыйлык эшчәнлегенә алып баралар. Руханилар катлавына гыйбадәт кылу һәм гражданнар эшләре буенча мәхкәмә эшләрен карау б-н шөгыльләнгән шәехләр, казыйлар, муллалар, имамнар, хафизлар керә. Руханилар ш.у. дини уку йортлары — *мәктәпләр* һәм *мәдрәсәләр* б-н җитәкчелек итәләр. Әлеге уку йортларында ил халкының бер өлеше укырга-язарга өйрәнә һәм диннең төп кануннарын үзләштерә. Мәдрәсәләр һәм хан сарае каршында кульязмалар китапханәләре булуы, ш.у. китапларны күчереп язучылар эшләве турында мәгълүматлар сакланган. Безнең көннәргәчә килеп җиткән язулы әйберләр, эпиграфик язулы кабер ташлары, эш кәгазьләре халыкның белемлелеген һәм мәдәнилеген күрсәтә. Әдәбият көчле үсеш ала. Газигәрәй ханның (псевд. «Бора» — «Давыл») «Гөл вә былбыл» (16 йөз) дигән поэмалар һәм шигырьләр җыентыгы сакланган. Шулай ук Баһадиргәрәй һәм Сәлимгәрәй ханнар да шагыйрьләр булалар. Башка шагыйрьләр хакында да мәгълүматлар бар (мәс., Хифзи, Хәмди). К.х.нда рәсми историография була. 16–17 йөзләрдә Рәммал хуҗаның «Тарих-и Сәхиб-Гәрәй хан», билгесез автор тарафыннан язылган «Тәварих-и Дәшт-и Кыпчак» (1638 тирәсе), Хаҗи Мәхмәд Сенаинең «Тарих-и Сәед-Гәрәй хан» әсәрләре барлыкка килә. Сәйед Мөхәммәд Ризаның 18 йөздә язылган «Әс-сәбгъ әс-сәййар» («Җиде планета») дип аталган фундаменталь хезмәте мәгълүм. Бу әсәрләрнең төп мотивы — татарлар тарихының үзбәясен дәлилләү, Төркия тарихында Кырым ханнарының ролен һәм тоткан урынын күрсәтү.

Төзелеш эшләре һәм архит-ра югары дәрәҗәдә үсеш кичерә. Мәсәлән, Бакчасарай ак таштан төзелгән Тахталы Җами (1704), Яшел Җами (1764), Хиҗи Җами (1762–69) мәчетләре б-н шөһрәт казана. Евпаториядә Җөми Җами (16 йөз) мәчете төзелә. Шулай ук Кырым ханнарының һәм ханбикәләренең — Турабәк ханым, Миңлегәрәй, Мөхәммәдгәрәй һ.б. ханнарның дөрбәләре барлыкка килә. Ташны уеп бизәкләү сәнгате югары үсешкә ирешә, ш.у. үсемлек орнаменты б-н уеп бизәлгән кабер ташлары эшләнә. Музыка да үсеш кичерә (Гәрәйләр нәселенең Төркиядә белем алган кайбер вәкилләре, мәс., Сәхибгәрәй, Газигәрәй һ.б. танылган музыкантлар булалар).

К.х. халкы, төп сәяси, мәдәни һәм тел традициясенә нигез салып, хәзерге Кырым-татар милләте оешуга җирлек тудыра (к. *Кырым татарлары*). 17–18 йөзләрдә Кырымда татар аксөякләре мәдәниятенә Европа йогынтысы көчәя, нәтиҗәдә, сәяси корылышны һәм мәдәниятне европалаштыруга һәм модернизацияләүгә омтылыш үсә. К.х. актив тышкы сәясәт уздыра. Дәүләт эчендә үзләренең хәлләрен ныгытканнан соң, Хаҗигәрәй һәм аның оныклары *Олы Урда* ханнары б-н сугышлар алып баралар, еш кына Рус дәүләте б-н союз төзиләр. Ләкин бу чорда үзенең хакимиятен тулысынча Кара диңгез буйларына җәелдергән Госманлылар империясенең (ул Константинопольне яулап ала һәм Балкан ярымутравын били) йогынтысы кискен көчәя. 1475 нең 1 июнендә төрек флоты Кафаны һ.б. итальян колонияләрен һәм готлар кальгаларын басып ала. Шул вакыттан Кырым ханы Төркия солтанының вассалына әверелә. 16 йөзнең 30 елларында, Төркиянең көчәюе һәм Россиянең Идел буенда экспансиясе башлануы нәтиҗәсендә, Россия-Кырым мөнәсәбәтләре катлаулана. Алар, Казанда руслар тарафыннан хакимияткә куелган *Шаһгали хан* бәреп төшерелеп, тәхеткә Сәхибгәрәй хан утыртылганнан соң, аеруча кискенләшә. Казан тәхетенә Сәхибгәрәйне, шуннан соң аның энесе Сафагәрәйне утырту Мәскәү һәм К.х. арасында низаглар һәм сугышлар башланып китүгә китерә. 1546 да Сафагәрәй вафат булганнан соң, русларның яулары ешая (к. *Казанга Рус дәүләте яулары*), һәм бу процесс Казанны яулап алу (1552) б-н тәмамлана. К.х.ның Россиягә каршы сугышлары башлана, бу сугышларда Кырым ханы Казанга Гәрәйләр нәселеннән булган ханнарны кайтаруны төп таләп итеп куя. Төркия К.х.на булыша, ул, үз йогынтысын Төньяк Кавказга җәелдерергә омтылып, Әстерханга һөҗүм итә, ләкин яу уңыш китерми (1569). 1571 дә Дәүләтгәрәй хан Мәскәү янына килеп җитә,

шәһәрне яндыра, әмма 1572 дә Молоди янындагы сугышта җиңелә, ул Мәскәү б-н солых төзергә мәҗбүр була. Казанны рус хакимлегеннән азат итү омтылышлары барысы да уңышсыз тәмамлана. 17–18 йөзләрдә К.х. Төркия империясенең барлык хәрби чараларында да (Венгриягә, Речь Посполита, Россия, Австрия һәм Иранга каршы сугышларда) катнаша. К.х. гаскәрләре берничә тапкыр Россия, Украина, Польша һәм Валахия терр-яләренә һөҗүмнәр ясыйлар.

17 йөз ахырында Төркиягә каршы сугыш вакытында Россия Кырымга яулар б-н килә (1687, 1689), алар нәтиҗәсез тәгәлләнә. 1711 дә К.х. гаскәрләре Россиягә каршы сугышта катнаша; сугыш Прут солыхы төзү б-н тәмамлана, нәтиҗәдә, К.х. сакланып кала. 18 йөз ахырында Россия империясенең яулап алу сәясәте рус-төрек сугышлары башлануга китерә. 1774 елгы Кечек-Кайнарҗи солых шартнамәсе буенча К.х. Төркия вассалы булудан туктый һәм Россия йогынтысы сферасына күчә. Шаһибгәрәй хан (1777–83) сәясәте халыкта һәм аксөякләрдә ризасызлык уята һәм баш күтәрүгә китерә. Яңа ханның Россия тарафыннан расланмавын сәбәп итеп, Кырымга рус гаскәрләре керә. 1783 тә К.х. Россия империясенә кушыла. 1783 нең 8 апрелендә императрица Екатерина II Манифест чыгара, аның буенча Кырым, Тамань һәм Кубан рус өлкәләренә әверелә. Формаль рәвештә халыкның элеккеге хокуклары, аның тыныч тормыш итү һәм мәхкәмә тәртибе саклана. Кырым өчен яңа дәвер — русларның аны колонияләштерүе һәм татарларны акрынлап кысрыклап чыгару чоры башлана.

Ханнар: Хаҗигәрәй (1443–66), Нурдәүләт (1466–69, 1474–77), Миңлегәрәй I (1469–1515, 1474–78 дә бүленеп), Җанибәкгәрәй I (1477–78), Мөхәммәдгәрәй I (1515–23), Газигәрәй I (1523–24), Сәгадәтгәрәй I (1524–32), Исламгәрәй I (1532), Сәхибгәрәй I (1532–51), Дәүләтгәрәй I (1551–77), Мөхәммәдгәрәй II (1577–84), Исламгәрәй II (1584–88), Газигәрәй II (1588–97, 1597–1608), Фатихгәрәй I (1597), Сәламәтгәрәй I (1608–10), Җанибәкгәрәй II (1610–22, 1627–35), Мөхәммәдгәрәй III (1622–27), Инаетгәрәй (1635–38), Баһадиргәрәй (1638–42), Мөхәммәдгәрәй IV (1642–44, 1654–65), Исламгәрәй III (1644–54), Гаделгәрәй (1665–70), Сәлимгәрәй I (1670–77, 1684–91, 1692–98, 1702–04), Морадгәрәй (1677–83), Хаҗигәрәй II (1683–84), Сәгадәтгәрәй II (1691), Сафагәрәй (1691–92), Дәүләтгәрәй II (1698–1702, 1707–13), Газизгәрәй III (1704–07), Каплангәрәй I (1707, 1713–16, 1730–36), Карадәүләтгәрәй (1716–17), Сәгадәтгәрәй III (1717–24), Миңлегәрәй II (1724–30, 1737–39), Фатихгәрәй II (1736–37), Сәлимгәрәй II (1743–48), Арслангәрәй (1748–56, 1767), Максудгәрәй (1767–68), Хәлимгәрәй (1756–58), Кырымгәрәй (1758–64, 1767–69), Сәлимгәрәй III (1764–67, 1770–71), Дәүләтгәрәй III (1769–70, 1775–77), Каплангәрәй II (1770), Максудгәрәй II (1771–72), Сәхибгәрәй II (1772–75), Шаһибгәрәй (1777–83).

Чыг.: Я р ц е в Я.О. Ярлыки Крымских ханов // Зап. Одес. об-ва истории и древностей. 1848. Т. 2, отд. 1; М а л и н о в с к и й А. Историческое и дипломатическое собрание дел, происходивших между Российскими великими князьями и бывшими в Крыму татарскими царями с 1462 по 1533 г. // Зап. Одес. об-ва истории и древностей. 1863. Т. 5; Б е р е ж к о в М.Н. Древнейшая книга крымских посольских дел (1474–1505 гг.) // Изв. Таврической уч. арх. комиссии. 1894. Вып. 21; У с м а н о в М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Ч е л е б и Э. Книга путешествия. Походы с татарами и путешествия по Крыму (1641–1667). Симферополь, 1996; K u r a t A.N. Topkapı Sarayı Mizei Arşivindeki Altın Ordu, Kırım ve Türkistan hanlarına ait yarlık ve bitikler. Ist., 1940.

*Әд.:* Х а р т а х а й Ф. Исторические судьбы крымских татар // Вестн. Европы. 1866. Кн. 2, 6; С м и р н о в В.Д. Крымское ханство под верховенством Оттоманской Порты до начала XVIII в. СПб., 1887; ш у л у к. Крымское ханство под верховенством Оттоманской Порты в XVIII столетии. Од., 1889; Т у н м а н н И.Э. Крымское ханство. Симферополь, 1936; С м и р н о в Н.А. Россия и Турция в XVI — XVII вв.: В 2 т. М., 1946; Х о р о ш к е в и ч А.Л. Русь и Крым: От союза к противостоянию: Конец XV — начало XVI вв. М., 2001; Ф а и з о в С.Ф. Письма ханов Ислам-Гирея III и Мухаммад-Гирея IV к царю Алексею Михайловичу и королю Яну Казимиру 1654–1658. М., 2003; З а й ц е в И.В. Между Москвой и Стамбулом. Джучидские государства, Москва и Османская империя (начало XV — первая половина XVI вв.). М., 2004; O r t e k i n H. Kırım Hanlarinin Şeceresi. Ist., 1938; U l k ü s a l M. Dobrucâdaki Kırım türklerinde Atasözleri ve Deyimler. Ankara, 1970; F i s h e r A. The Crimean tatars. Stanford, 1987.

*И.Л.Измайлов.*

**«КЫРЫ́М ХАННАРЫ́ ТАРИХЫ́»**, китап ядкәре. 1832 елда Казан ун-тында Сәед Мөхәммәд Ризаның «Әс-сәб әс-Сәйәр, яки Миңлегәрәй I ханнан алып Миңлегәрәй II ханга кадәрге (ягъни 871 елдан (1466) 1150 (1737) елга кадәр Кырым ханнары тарихы турындагы Җиде планета» исемле 18 йөз кульязмасы нигезендә басылган.

Кулъязманы Казан ун-ты адъюнкты И.И.Хәлфин бер Казан мулласыннан ала. Ә ул муллага аны 1824 тә Мәккәгә хаҗ кылырга баручы бохаралы бирә. Гомеренең ахырында Хәлфин ун-т җитәкчеләренә әлеге һәм тагын ике Шәрекъ кулъязмасын сатып алырга тәкъдим итә.

Шәрекъ әсәрләре цензоры проф. Ф.И.Эрдман сүзләренә караганда, элек Шәрекъне өйрәнүче чит ил галимнәре бу кулъязманы Бакчасарайда «бик югары бәягә дә» сатып ала алмаганнар. Казан уку-укыту округы башлыгы М.Н.Мусин-Пушкин үтенече б-н Россия мәгариф министры аны бастырырга 1,5 мең сум акча бүлеп бирә. Университет ректоры Н.И.Лобачевский җитәкчелегендә «Кырым ханнары тарихын бастыру» ком-ты оеша.

Профессор А.К.Казимбәк, кулъязмадагы мәгълүматларны Казандагы шәхси китапханәләрдә булган башка чыганаклар б-н чагыштырып-тикшереп, зур фәнни эш башкара. Аерым мәсьәләләрдә мөфти һәм ахуннар б-н дә киңәшә. Китапның керешендә ул: «Кырым ханнары тарихы» Россия, Төркия, Польша һәм Германиягә катнашы булган маҗаралы вакыйгаларга ия, ул гыйлем дөньясына зур файда китерәчәк», — ди. Университет басмаханәсе җитәкчесе Мәскәү һәм С.-Петербургка махсус басмаханә кирәк-яраклары алырга командировкага җибәрелә. Наширләр китапның беренче битен бизәүгә зур тырышлык куялар. Китапны кәгазь табакның 1/4 өлешенә, европача (алга чыгып торган капкачлы) алтын б-н басып төшерелгән төрле геометрик һәм үсемлекләр орнаменты б-н бизәлгән рамкалы ачык коңгырт төстәге күн тышлыкта нәшер итәләр. Төрки кулъязманың тексты башланган беренче титул бите Шәрекъ стиле үрнәгендә ясалган. Китапның тиражы 430 данә.


АССЕБЪ О-ССЕЙЯРЪ
или
СЕМЬ ПЛАНЕТЪ
ИСТОРІЮ КРЫМСКИХЪ ХАНОВЪ
Сочиненіе
СЕЙИДА МУХАММЕДА РИЗЫ,
КАЗАНЬ

«Кырым ханнары тарихы» китабының титул бите. Казан. 1832.

Кулъязма 1466 дан алып 1737 гә кадәрге чорны үз эченә ала. Стиленә караганда, аның авторы — Риза — төрек кешесе булырга охшаган яки Төркиядә тәрбияләнгән дигән фикер дә бар. Ул үзенең әсәрен «Җиде планета» дип исемләгән. «Җиде планета» — Кырым тәхетенең иң куәтле җиде ханы. Алар — Миңлегәрәй I, Сәхибгәрәй, Дәүләтгәрәй, Баһадиргәрәй, Хаҗи Сәлимгәрәй, Миңлегәрәй II һәм, һичшиксез, кулъязмада исеме кызыл кара б-н билгеләнмәсә дә, 20 ел идарә иткән Газигәрәй. Сәед Риза кулъязмасының Казанда нәшер ителүе нәтиҗәсендә, Казан шәркыятьчелек гыйлеме дөнья фәне үсешендә күренекле урын били. 1829 да Лондонда Казимбәк Бөекбритания һәм Ирландия корольлеге Азия җәмгыятенә әгъза итеп сайлана. Китап басылганнан соң да, Казимбәк андагы мәгълүматларны өйрәнә. Аның нәтиҗәсе булып, 1835 тә «Төрле язучылардан «Җиде планета» тарихына кагылышлы чагыштырма өземтәләр» дигән мәкалә басылып чыга. Казимбәк мәкаләләре фән өлкәсендә үз урынын ала, шул ук елның ахырында ул Петербург ФА мөхбир әгъзасы итеп сайлана.

«Кырым ханнары тарихы» бары тик Казан ун-ты һәм Британия (Лондон) музей китапханәләрендә, акад. Х.М.Френдагы нөсхәсе Азия музее китапханәсе коллекциясендә (хәзерге РФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-тының С.-Петербург ф-лы) саклана. Сәед Риза кулъязмалары күчермәләренең Истанбулдагы Баязид Паша, солтан Әбделхәмид һәм С.-Петербургтагы Италинский китапханәләрендә булуы мәгълүм.

*Әд.:* К а з е м - Б е к А.К. Предисловие к Ризовой истории крымских ханов, написанное г. Ка-

зем-Беком // Казан. вестн. 1831. Кн. 1; Парамонова Н.Б. О публикации рукописи Сейида Ризы «История крымских ханов» // Книга в России XI–XX вв.: Сб. науч. трудов. СПб., 2004. Вып. 21. С. 140–147.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**КЫРЫМСАРА́Й** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Дим елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 18,1 *км*, бассейнының мәйданы 128 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы — урман массивында, Чирково авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы — Баулы р-нының Зирекле Каран авылыннан 1 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 116 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. К.ның 0,5 тән алып 4 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 99 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренчеункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,13 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елга үзәгенең сулъяк сөзәклегендә *Урдалы Тау* (Марков сөзәклеге) табигать истәлеге урнашкан.

**КЫРЫМСАРА́Й** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кырымсарай елгасы буенда. 2010 елда 503 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Зур Ефановка исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 чиркәү, земство һәм чиркәү-приход мәктәпләре, 8 су тегермәне була; дүшәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6629 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 1877, 1889 да — 1714, 1908 дә — 3657, 1920 дә — 3256 (Югары Кырымсарай а. халкын да кертеп), 1926 да — 841, 1938 дә — 2420, 1949 да — 1977, 1958 дә — 1039, 1970 тә — 808, 1979 да — 682, 1989 да — 612, 2002 дә — 541 кеше.

**КЫРЫ́Н ТАУ** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 7 кеше (татарлар) яши. 1920 еллар ахырында нигез салына. 1970–80 елларда авыл бетерелә, 1999 ның 20 маенда яңадан торгызыла. Оештырылган көннән ТАССРның Минзәлә кантоны Пучы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 2002 дә — 10 кеше.

**КЫРЫНДЫ́** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 50 *км* көньяктарак, Иж елгасы бассейнында. 2010 елда 637 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә көчләп чукындырылган татар халкының бер өлеше 20 йөз башында яңадан исламга кайта. 1840 елларда К.га руслар килеп урнаша. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, тимерчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да Петропавел чиркәве (1882–92 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәчет (1907 дә ачыла), мәктәп, миссионерлык мәктәбе (1871 дә ачыла), күн з-ды, 2 су тегермәне эшли. Авыл җәмәгатенең имана җире 1747,7 дис. тәшкил итә. 1920 елгы рәсми чыганакларда К. 2 торак пункт: Татар һәм Рус Кырындысы буларак билгеле. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Мөшек волостенда, 1921 дән ТАССРның Әгерҗе кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1744 тә — 18 ир-ат; 1859 да — 249, 1887 дә — 800, 1905 тә — 963, 1920 дә — 1046, 1926 да — 907, 1938 дә — 885, 1958 дә — 1156, 1970 тә — 990, 1989 да — 723, 2002 дә — 643 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**КЫСАЛЫ́ КЫЙССА́**, төрле характердагы эпик берәмлекләрне (новелла, әкият, мәсәл һ.б.) бергә туплап, бер кысага алган әдәби жанр; хикәяләү берәмлеге, гадәттә, катнашучыларның әңгәмәсе, бәхәс коруы, авторның теге яки бу вакыйгага сылтамасы б-н дәлилләнә.

К.к.ның башы борынгы Шәрекъ (Һиндстан, Иран, Гарәбстан) фольклоры һәм язма әдәбиятларына барып тоташа. Жанр буларак, 1 нче меңъеллыкның 1 нче яртысында Һиндстанда барлыкка килгән булса кирәк; тәрҗемә, назыйрәләр аркылы Европа әдәбиятларына үтеп керә. Хикәяләүдә теге яки бу дәрәҗәдәге дидактика б-н сугарылган «кысалы композиция»нең Шәрекъ традициясе антик чордан килгән автор сүзенә, әңгәмәсенә, бәхәсенә иллюстратив хикәяләү өстәү б-н берләшә. Андый композиция әсәргә кергән новеллаларның санын теләсә ничек үзгәртергә (мәс., киметергә, яңаларын кертергә, искеләрен үзгәртергә) мөмкинлек бирә. Мондый күренеш бер үк ядкәрнең төрле-төрле версияләре тууга китерә, күп халыкларның фольклорында һәм язма әдәбиятларында К.к. жанрының барлыкка килүенә сәбәп була. Һинд телләреннән тәрҗемәләр, җирле һәм чит халыклар фольклор чыганакларыннан компиляцияләр ясау аркасында, К.к. фарсы, гарәп, роман, славян һ.б. телләрдә киң тарала («Кәлилә вә Димнә», «Синдбад Дәрьяви», «Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә»; Дж.Боккаччоның «Декамерон»ы, В.Ф.Одоевскийның «Рус төннәре» һ.б.).

Татар әдәбиятында К.к. урта гасырлардан билгеле («Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә», «Мең дә бер кичә» тәрҗемәләре). Хәзерге татар әдәбиятында К.к жанрында З.Мәхмүди («Белмим»), М.Галиев («Нигез») иҗат итә.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Шкловский В. Развёртывание сюжета. Л., 1921; Гринцер П.А. Древнеиндийская проза (Обрамлённая повесть). М., 1963.

**КЫСКА́ ҖЫРЛА́Р**, татар халкының музыкаль-поэтик иҗатының популяр жанры; дүртьюллык җырлар. Аларның тематикасы — иҗтимагый тормыш, гаилә мөнәсәбәтләрен һ.б.ны төрле яклап чагылдыру. 18–19 йөзләрдә барлыкка килгән К.җ.да халыкның катлаулы тормышы, рекрут һәм солдат хезмәте, чит җирләрдә бәхет эзләү, шахта эшенә киткән крәстияннәр турында бәян ителә. 20 йөзнең 1 яртысында татар авылларындагы иҗтимагый һәм мәдәни үзгәрешләрне чагылдыручы К.җ. барлыкка килә. Аерым бер бүлекне туган як, хатын-кыз язмышы турында җырлар; мәхәббәт, табын җырлары, шаян җырлар тәшкил итә. Алар өчен махсус язылган көйләр юк. Бер үк куплетның берничә варианты була, шуңа күрә аларның гомуми саны билгеле түгел. К.җ. традицион татар поэтикасының сәнгатьчә чараларына, ш.и. психологик һәм логик параллелизмга (хисләр, кичерешләр, кеше тормышы табигать күренешләре, чәчәкләр, кошлар дөньясы һ.б. б-н тиңләштерелә яки чагыштырыла) нигезләнә. Җырларның зур күпчелеге монолог рәвешендә башкарыла, диалогка корылган җырлар да бар, аларны аеруча кунаклар өчен язылган цикллар арасында очратырга мөмкин. К.җ.ның шактые сәнгатьчә импровизация рәвешендә барлыкка килә; аларга аерым бер кешегә мөрәҗәгать итү хас. «Бердәй башлау» алымы кулланыла, ягъни беренче юлның беренче сүзләре кабатланып килә («Җырлыйк әле, җырлыйк әле», «Сөям сине, сөям сине», «Аерылабыз, аерылабыз»). Беренче тапкыр К.җ. 1842 елда нәшер ителә («Мартемьян Иванов тарафыннан төзелгән татар хрестоматиясе» — «Татарская хрестоматия, составленная Мартемьяном Ивановым»); беренче китапны Г.Ваһапов әзерли («Җырулар» — «Песни», 1869). К.җ.ның наширләре арасында рус (С.Г.Рыбаков, С.Е.Малов), венгр (Г.Балинт), немец (Р.Лах), фин (Х.Паасонен) галимнәре һ.б. бар. 6 меңгә якын К.җ.ны үз эченә алган «Татар халык иҗаты: Кыска җырлар (дүртьюллыклар)» (1976) җыентыгы — аеруча әһәмиятле басма. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кулъязмалар саклау бүлегендә К.җ.ның 50 меңнән артык тексты (төрле вариантлары б-н) тупланган. К.җ. татар әдәбияты әһелләрендә һәрвакыт җанлы кызыксыну уята. Заманында Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Ш.Камал, Г.Бәширов, Ә.Еники кебек татар язучылары үз әсәрләрендә әлеге жанр үрнәкләреннән уңышлы файдаланалар.

М.Фәйзи, Н.Исәнбәт, М.Җәлил һ.б. үзләре үк К.җ. иҗат итәләр, аларның кайберләре халык җыры буларак танылa. К.җ. проф. һәм үзешчән башкаручылар иҗатында бүгенге көннәргә кадәр популяр жанр булып кала.

*Әд.:* Насыйри К. Кырык бакча. К., 1880; Тукай Г. Халык моңнары. К., 1910; Надыйров И. Халык һәм җыр. К., 1961; Сборник башкирских и татарских песен, составленный Ив. Покровским // Зап. Оренбург. имп. рус. геогр. об-ва. К., 1870. Вып. 1; Рыбаков С.Г. Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897; Мошков В.А. Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волжско-Камского края // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1898. Т. 14, вып. 1–6; Paasonen H. Tatarische Lieder.: Gesammelt und Übersetzt // Journal de la Société Finno-Ougrienne XIX. Hels., 1901; Gotthold W. Tatarische Texte. Nach den in der Lautabteilung der Staatsbibliothek befindlichen Originalplatten. B., 1930.

*И.Н.Надыйров.*

**КЫСКА́ САБА́К** (Brachypodium), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразия, Үзәк һәм Көньяк Америкада, Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә ике төре очрый: каурыйсыман К.с. (B. pinnatum) һәм урман К.с. (B. sylvaticum). Республиканың катнаш һәм яфраклы урманнарында, куаклыклар арасында үсә. 50–100 *см* биеклектәге үсемлек, шуышма тамырчалы. Сабагы туры, юка, йонлач, аз гына йонтәс буынлы. Яфраклары яссы, каурыйсыман К.с.та — ачык яшел, урман К.с.та — кара яшел, каты очлы. Чәчәк төркеме — катлаулы туры куе башак. Җимеше — бөртекчә. Июньнән сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Яктылык яратучы үсемлек. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи, үз-үзеннән чәчелү көчле. Туфракны кәсләндерүче үсемлекләр буларак файдаланыла. Урман К.с. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫСЛАЛА́Р**, к. *Кысласыманнар.*


**КЫСЛАСЫМАННА́Р**, кыслалар (Crustacea), сегментлашкан гәүдәле беренчел буынтыгаяклы хайваннар классы, хитинлы кутикула б-н капланган. Казылма К. палеозойның кембрий чорыннан билгеле. Боҗралы суалчаннардан, икенче гипотеза буенча трилобитлардан килеп чыккан дип фаразлана. Гәүдәсе *мм* кадәр өлешләрдән алып 80 *см* га кадәр; баш, күкрәк һәм корсак өлешләреннән тора, алар исә бер-берсе б-н кушылырга мөмкин. Башы баш калагыннан һәм 4 сегменттан тора, 2 пар мыекчыгы һәм 3 пар авыз үсентеләре (үзгәргән очлыклар) бар: югары казналык һәм 2 пар түбәнге казналык. Күкрәк һәм корсак өлешләре төрле сандагы сегментлардан (төрле төркемнәрдә) һәм ш.у. очлыклардан тора. Күпчелек К.да корсак аякларының соңгы пары пластинкалы, корсак соңында ул аналь калак б-н бергә койрык йөзгечен барлыкка китерә. Күрү органнары — гади күзчек яки еш кына бер пар фасетлы күзләр; кайбер К.ның күзе юк. Саңаклар б-н, алар булмаганда, бөтен гәүдә өслеге б-н сулыйлар. Күпчелек төрләр аерым җенесле, кайберләренә партеногенез (аталанмаган күкәй күзәнәкләрнең үсүе) хас. Ана зат йомыркасын, гадәттә, үзендә йөртә: корсак очлыкларында яки аерым оя камераларында, кайвакыт суга сала. Үсеше, нигездә, метаморфоз, йомыркалардан личинкалар үсә (науплиус).

Дөнья фаунасында К.ның 40 меңгә якын төре билгеле; киң таралган, башлыча, диңгезләрдә һәм төче сулыкларда, кайберләре җирдә яшәргә җайлашкан; паразит формалары бар. Россиядә — 2 меңгә якын төр (ш.и. Байкал күлендә — 500 гә якын эндемик төр, башка континенталь сулыкларда — 650 дән артык); Татарстан терр-ясендә — 80 тирәсе (кабырчыклы кыслалардан башка, аларның фаунасы исә өйрәнелмәгән). Кабул ителгән систематика буенча К. классы 5 асклассны үз эченә ала, алар арасыннан 4 асклас Россиянең төче сулыкларында һәм ТРда яши: *саңагаяклылар* (саңагаялылар отряды — Anostraca һәм *яфрагаяклы кысласыманнар*), максилоподалар — Maxillopoda (*ишкәгаяклы кысласыманнар* һәм карп ашаучылар — Branchiura), кабырчыклылар — Ostracoda (подокопидалар отряды — Podocopida), югары төзелешле кыслалар — Malacostraca (мизидалар отряды — Mysidacea, кумлылар — Cumacea, *тигезаяклы кысласыманнар, төрле аяклы кысласыманнар, унаяклы кысласыманнар*). Идел һәм Камада яшәүче К.ның кайбер төрләре Понт-Каспий фауна комплексына керә һәм биоинвазияләр (читтән килгәннәр) яисә махсус климатлаштырылганнар санала (Paramysis intermedia һәм P.ullskyi, Pseudocuma cercaroides кум кыслачыгы, Dikerogammarus haemobophes, Pontogammarus obessus янъйөзәрләр һ.б.). Иделдә йонтәс куллы кытай крабы (Eriocheir sinensis) табыла. Биоинвазиянең төп сәбәбе — климатның җылынуы, зур масштабларда гидротөзелешләр бару, судноларлар йөрешенең активлашуы. Зәй сусаклагычында озынаяклы креветка (Macrobrachium asper) климатлаштырылган. К.ның 3 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән: гади саңагаяк (Branchipus stagnalis), язгы калкан кыслачык (Lepidurus apus) һәм *тараяклы кысла*. Планктон К.ы (дафнияләр, циклоплар) зоопланктонның еш кына төп өлешен тәшкил итәләр һәм балыклар өчен азык булып торалар. Тармакмыеклы планктон К. (Daphnia magna һ.б.) су сыйфатын тикшерү өчен тест буларак кулланыла. Күп кенә диңгез К.ының (креветкалар, омарлар, лангустлар, краблар, Антарктида крильләре) ите югары бәяләнә. Күп кенә төрләре үрчетү объекты булып тора. К.ны эшкәртү калдыкларыннан терлек азыгы оны әзерлиләр.

*Әд.:* Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977; Биологические инвазии в водных и наземных экосистемах. М., 2004; Рахимов И.И., Ибрагимова К.К. Растительный и животный мир Татарстана. К., 2006.

*Р.М.Сабиров.*

**КЫСНА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 31 *км* төньяктарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 152 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Березняк авылы буларак та билгеле; 1930 дан хәзерге исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиannәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1325 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 397, 1897 дә —




**Кысласыманнар**. 1. Гади саңагаяк (Branchipus stagnalis), озынлыгы 12 *мм* га кадәр; 2. Күл янъйөзәре (Gammarus lacustris), озынлыгы 20 *мм* га кадәр; 3. Ишкәгаяклы кыслачык (Calanus finmarchicus), озынлыгы 0,5–3 *мм*; 4. Тараяклы кысла (Astacus leptodactylus), озынлыгы 250 *мм* га кадәр; 5. Язгы калканкыслачык (Lepidurus apus), озынлыгы 40–60 *мм* га кадәр; 6. Тармыеклы кыслачык (Daphnia magna), озынлыгы 3 *мм* га кадәр.

443, 1908 дә — 558, 1920 дә — 574, 1938 дә — 517, 1949 да — 332, 1958 дә — 369, 1970 тә — 284, 1979 да — 223, 1989 да — 164, 2002 дә — 164 кеше.

**КЫСТЫБЫ́Й** (күзикмәк), татар халкының милли ризыгы. Төче камырдан әзерләнә юка җәймә читләре бөтерелмәгән килеш кызган табада майсыз гына пешерелә, кайнар килеш урталай бөкләнә, эченә бәрәңге боламыгы яки тары боткасы, төелгән мәк яисә киндер ягып, тышын майлап табынга бирелә.

*Әд.:* Әхмәтҗанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1999.

**КЫСЫ́Р ТИГӘНӘ́К**, гравилат (Geum), роза чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле, күпчелеге Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар — Аллеп К.т. (G. aleppicum), елга К.т. (G. rivale) һәм шәһәр К.т. (G. urbanum) барлык районнарда да очрый. Урманнарда, болыннарда, кырларда үсә. 15–100 *см* биеклектәге үсемлекләр, үрмәле юан тамырчалы. Тамыр яны яфраклары лирасыман-каурыйлы, сабактагылары — өчәрле яки өчәрле бүленмә. Чәчәкләре сары, кызгылт-сары яки алсу, берле яисә калкансыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — күп чикләвекчек. Май–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Яфракларында С витамины, тамырчасында шикәр, крахмал, гликозид, дуплау матдәләре, эфир мае бар. Халык медицинасында елга К.т. тамырчалары эч киткәндә һәм кан туктату чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы, терлек азыгы үсемлекләре.

**КЫТА́Й** (Кытай Халык Республикасы), Евразия материгының көнчыгыш өлешендә урнашкан ил. Мәйданы — 9,6 млн. *км*² тирәсе. Башкаласы — Пекин. Илнең төньяк-көнчыгышына, Маньчжуриягә Идел-Урал татарлары 19 йөз ахырында Кытай-Көнчыгыш тимер юлы төзелешенә эшкә киләләр, төзелеш беткәннән соң, күбесе шунда эшкә кала. Беренче күчеп килүчеләр арасында Пенза һәм Тамбов губерналарыннан татар сәүдәгәрләре дә була, алар мех, йон, тукыма һәм кием-салым б-н сәүдә итүне җайга сала. Татарлар, башлыча, Маньчжуриянең шәһәр үзәкләрендә (Маньчжурия, Харбин, Хайлар, Цицикар, Гирин, Чанчунь, Мукден, Аньшань, Дайрен (Далянь) һ.б.), порт шәһәрләре Шанхайда һәм Тиентсинда тупланә. Һәр шәһәрдә диярлек төрки-татар милли-дини җәмгыяте эшли; татарларның кибетләре, буфет һәм рестораннары ачыла, зур шәһәрләрдә һәм тимер юл станцияләрендә (Харбин, Хайлар, Мукден һ.б.) татар бистәләре барлыкка килә. 1920 елларга татарлар саны 10–15 меңгә (1945 тә — 5 меңләп) җитә. 1920–30 елларда Харбин шәһәрендә «Ерак Көнчыгыш», «Чаткы», «Меңьеллык мәчете», «Бәйрәм нуры» г-талары, «Татар әлифбасы», «Хисап» дәреслекләре, Г.Тукайның сайланма әсәрләре нәшер ителә. 1935 тән Мукден шәһәрендә «Милли байрак» г-тасы чыга башлый. 1935 нең февралендә Ерак Көнчыгыш Идел — Урал татар-мөселманнарының беренче, 1941 дә икенче корылтае уздырыла. К.ның күп кенә төньяк-көнчыгыш шәһәрләрендә (Харбин, Маньчжурия, Хайлар, Мукден, Дайрен, Гирин һ.б.) мәчетләр эшли. 1920 елларда Маньчжурия татар милли хәрәкәтендә катнашучыларның күбесе (Г.*Исхакый*, Ф.*Туктаров*, Г.*Терегулов* һ.б.) өчен эмиграция урыны булып китә. Татарларның башка, тагын да зуррак төркеме 19–20 йөзләр арасында Кытайның төньяк-көнбатыш өлешендә һәм Көнчыгыш Төркестанда оеша, ул, башлыча, Шәрекъ илләре б-н сату итүче сәүдәгәрләрдән тора. Садретдиновлар, Мөслимовлар, Салиховлар, Габитовлар, Усмановлар, Алдагаровлар, Миршановлар, Юлдабаевлар кебек атаклы сәүдәгәрләр һәм эшкуарлар була. Татарлар күбесенчә Өремче, Голҗа, Чүгүчәк шәһәрләрендә яши. Монда алар тегү ф-калары, тире эшкәртү һәм май з-длары, төрле остаханәләр, типография, китапханәләр, мәктәпләр, 2 мәчет ачалар. 1949 га кадәр Өремче шәһәрендә татар театры эшли. К.*Халиди*, Г.*Буби*, Б.*Шаһиди*, Ф.Г.*Мөслимовларның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Көнчыгыш Төркестан б-н бәйле. 1950–60 елларда, К.да соц. «экспериментлар» («зур сикереш», «культура революциясе» һ.б.) үткәрелү сәбәпле, күп кенә татарлар Австралия, Төркия, Япония, АКШ һәм СССРга күчеп китәргә мәҗбүр булалар. 1990 еллар ахырыннан ТР һәм К. арасында икътисади һәм мәдәни багланышлар үсеш кичерә. 2007 нең мартында Кытай Халык Респ-касы Рәисе Ху Цзиньтао Казанда булып китә. Казан югары уку йортларында К.дан килгән 200 ләп студент һәм аспирант, ш.и. Шөнҗан-Уйгыр автономияле р-ныннан 40 ка якын татар укый. 2011 дә Чүгүчәк, Өремче, Голҗа шәһәрләрендә Сабан туйлары уза.

*Әд.:* Йөртә безне язмышлар: Фәнни-популяр очерклар. К., 1992; Дәүләт Н. Ерак көнчыгыштагы татар-башкортларга ни булды. К., 2005.

*А.И.Хәбибуллина.*

**КЫЧЫТКА́Н** (Urtica), кычытканчалар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, Күбрәк төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә 4 төре: ике өйле К. (U. dioica) һәм зәһәр К. (U. urens) бөтен районнарда; киндер К. (U. cannabina) һәм күзлеут яфраклы К. (U. galeopsifolia) Кама алдында очрый. Күләгәле урманнарда, куаклар арасында, торак йортлар тирәсендә, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларында үсә. 30–150 *см* биеклектәге үсемлек. Яфраклары каршыдаш, йомыркасыман-озынча, читләре тешле. Сабак һәм яфраклары тирене ялкынсындыручы матдәләре булган бизле каты төкчәләр б-н капланган, шунлыктан аларга орынуга яндырып ала. Чәчәкләре вак, күзгә ташланмый, яшькелт, башаксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — саргылт-соры чикләвекчек. Майдан көзгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июльдән башлап өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Яфракларында витаминнар, минераль тозлар, каротин бар. Халык медицинасында ике өйле һәм зәһәр К. үләннәренең төнәтмәсе поливитамин һәм токсикозга каршы чара буларак кулланыла, анемия, кан китү вакытында, чәчне ныгыту һәм үстерү өчен файдаланыла. Яфраклары төрле дару үләннәре җыелмаларына, үт кудыру өчен «Аллохол» даруы составына керә. Яшь яфраклары аш, салатлар әзерләүдә, терлек азыгы буларак кулланыла. К. яфракларында кычыткан күбәләге һәм тавискүз гусеницалары яши һәм туклана. Баллы үсемлек.



Ике өйле кычыткан.

**КЫЧЫТКА́Н ГӨЛЕ́**, к. *Колеус*.

**КЫЧЫТКА́Н КҮБӘЛӘГЕ́** (Aglais urticae), нимфалидлар семьялыгыннан көндезге күбәләкләр. Гәүдәсе 16–20 *мм* озынлыкта. Канат җәеме 40–50 *мм*, читләре тешле. Канат өсте куе кызыл төстә, кара һәм сары таплы, кырыйлары ураксыман зәңгәр таплар төшкән кара каймалы. Канатының аскы ягы кара көрән. Европа һәм Азиянең уртача киңлекләрендә таралган. Парк, кыр, урман буйларында яши. Татарстан терр-ясендә көндезге күбәләкләр арасында иң иртә күренүчеләр, кар эреп ачылган урыннар күренү б-н — урман буйларында, ә шәһәр һәм посёлокларда тагын да иртәрәк оча башлыйлар. К.к.н, гадәттә, язгы кояш нурлары төшкән һәм җылыткан урыннарда күрергә мөмкин. Елга 2 буын бирә. Кычытканның яшь ботакларына ана затлар, тыгыз өем итеп, 50–100 әр йомырка салалар, аннан соң үләләр. Яшь гусеницалар кара төстә. Башта кычыткан яфракларында һәм ботакларында, зур төркем булып, пәрәвезсыман ояларда яшиләр; үсә төшү б-н, күрше үсемлекләргә үрмәли башлыйлар, төсе кара таплы аксыл яшел төскә кадәр үзгәрә. Курчаклары кызыл-көрәннән кара төскә кадәр, ян-яклары перламутр ялтыравыклы. 1 нче буын күбәләкләре май ахырыннан июль башына кадәр оча, 2 нче буын күбәләкләре август уртасында күренә, салкыннарга кадәр көз буе очалар, йорт подвалларында, түшәмнәрдә кышлыйлар.

**КЫЧЫТКА́Н ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Troglodytes), кычыткан чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 60 ка якын төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка, Төньяк-көнбатыш Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә гади К.ч. (T.troglodytes) очрый, Евразиядә таралган семьялыкта бердәнбер төр. Катнаш һәм чыршы урманнарында, куе булып үскән куаклыкларда яшиләр. Гәүдәсенең озынлыгы 10–12 *см*, авырлыгы 10 *г* га кадәр. Гәүдәсенең өске өлеше, канат һәм койрыгы аркылы кара рәсемле аксыл-коңгырт,



Гади кычыткан чыпчыгы.

аскы ягы шундый ук рәсемле соры коңгырт төстә. Түгәрәкләнеп килгән кыска канатлы. Койрыгы бик кыска, вертикаль рәвештә диярлек өскә күтәрелгән. Томшыгы нечкә, туры. Кашлары аксыл. Күчмә кош. Апрельдән октябрьгә кадәр очрый. Оясы шарсыман, аны, керү юлын яннан калдырып, мүк б-н капланган агач кәүсәләрендә, чыбык-чабык өемнәрендә ясый. Кызыл тимгелле 5–7 ак йомырка сала; балалары июнь уртасында чыга. Вак умырткасызлар б-н туклана. Урман корткычларын юк итә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫЧЫТКАНЛЫ́** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 47 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мораса елгасы буенда. 2010 елда 623 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Мораса исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманлыкта эшли, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, балта эше, мичкә һәм тәгәрмәч ясау, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 мәчет, 2 мәдрәсә, тимерчелек, 10 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1975 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 14 ир-ат; 1859 да — 635, 1897 дә — 1431, 1908 дә — 1470, 1920 дә — 1610, 1926 да — 1122, 1938 дә — 1093, 1949 да — 1028, 1958 дә — 1150, 1970 тә — 1159, 1979 да — 943, 1989 да — 668, 2002 дә — 699 кеше.

**КЫЧЫТТЫРГЫ́Ч ТАЛПАННА́Р**, к. *Корчаңгы талпаннары*.

**КЫШ**, ел фасылы, аерым бер билгеләр (астрономик, календарь, климатик, фенологик һ.б.) буенча билгеләнә. Төньяк ярымшарда астрономиядә К.ка кышкы кояш торгынлыгы (21 яки 22 декабрь) б-н язгы көн тигезлеге (20 яки 21 март) арасындагы вакытны кертәләр. Декабрь, гыйнвар, февраль айлары календарь К. дип санала. Климатик сезон буларак, һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 0 °С тан түбән төшеп, кар капламы (20–31 октябрь) барлыкка килү вакытыннан башлана. Фенологик К. сулыкларның боз б-н каплануыннан һәм тотрыклы кар капламы урнашу б-н башлана, кар эреп ачылган урыннар күренә башлау һәм кара каргалар килү б-н тәмамлана. Уртача 3 атна (кайвакыт 6 атна) тирәсе сузылучы фасыл башы (кыш алды) тотрыксыз һава режимы, темп-ра һәм һава басымының кискен үзгәрешләре, кар һәм яңгыр яву б-н характерлана. Тотрыклы К.ның башлану вакыты дип һаваның уртача тәүлеклек темп-расы –5 °С (10–18 ноябрь) аша узу һәм кар капламы урнашу (15–22 ноябрь) вакыты алына. К.ның тәмамлануы һаваның уртача тәүлеклек темп-расы 0 °С аша уңай күрсәткечләр ягына (5–10 апрель) үзгәрүе яки кар капламының эрүе (6–16 апрель) б-н билгеләнә. Шулай итеп, ТР терр-ясендә К. уртача 5 ай тирәсе яки 150–160 көн дәвам итә. Һаваның уртача айлык темп-расы ноябрьдә –4, –7 °С тан гыйнварда –13, –15 °С ка (абс. иң түбән –52 °С, Әгерҗе ш., 1979) кадәр төшә. Явым-төшемнәр күбрәк ноябрьдә (27–42 *мм*), К. буена уртача 130–180 *мм* була. Кар капламының калынлыгы уртача 35–45 *см* тәшкил итә, аерым елларда 115 *см* га җитә.

Һава торышының еш алышынуы ТРда К.ның үзенчәлеге булып тора һәм, П.Т.Смоляков фикеренчә, 3 типка бүленә. Һава торышының кышкы континенталь тибы төньяктан һәм төньяк-көнчыгыштан салкын арктик һава массаларының үтеп керүе, ш.у. Себер (Азия) антициклоны б-н бәйле. Аңа өчен көндез аз болытлылык һәм төнлә тулысынча аяз булу, көчсез җил һәм хәтта штиль вакытында тотрыклы суыклар хас. Көндез темп-ра –20, –25 °С тан югары түгел (мартта –15, –20 °С), төнлә –30, –35 °С ка (мартта –15, –20 °С) кадәр. Һавада салкын томан (томан төтене) рәвешендә күзәтелүче вак боз кристаллары барлыкка килә. Һава торышының әлеге тибы, кайвакыт 10–12 шәр көнгә сузылып, К. дәвамында 3–4 тапкыр билгеләнә (гомумән алганда, кышкы чорның якынча 25%). Уртача җылы һава торышына шактый болытлылык, еш, әмма күп булмаган явым-төшемнәр (күбесенчә кар) хас, җәяүле һәм гомуми бураннар б-н җилнең көчәюе (10–15 *м/с* ка кадәр) көнбатыштан атлантик, ш.у. көньяктан һәм көньяк-көнбатыштан тропик һава массалары керү вакытында билгеләнә. Температураның тәүлек дәвамындагы үзгәреше зур түгел: көндез –5, –10 °С тан (мартта 0, –5 °С) төнлә –10, –15 °С ка кадәр (мартта –5, –10 °С); мондый тип К.ның беренче яртысында аеруча еш күзәтелә (кышкы чорның уртача 55 % ын тәшкил итә) һәм 2–3 көннән берничә атнага кадәр сузыла. Җылы һава торышы көньяк-көнбатыштан Урта диңгез һәм көнбатыштан Атлантика дымлы җылы һава массаларының тиз керүе вакытында күзәтелә. Башта көчле җил (кайвакыт шторм) исә, кар ява, буран була, аннары кинәт кенә җылытып җибәрә (темп-ра 5 °С ка кадәр һәм тагын да югары). Җепшек кар һәм яңгыр ява, 3–4 көнгә кадәр сузыла; декабрь һәм гыйнвар өчен гадәти күренеш (кышкы чорның 10%). Шулай итеп, кышкы һава торышында көнбатыштан һәм көньяктан керүче, кышкы чорның 65 % ын тәшкил иткән җылы һәм дымлы һава йогынтысы өстенлек итә. Һава торышының аз дымлы континенталь тибына кышкы вакытның 25% гына туры килә; калган 10% күбесенчә күчү тибындагы билгеле бер һава торышына хас. ТР терр-ясендә К. буенча бозлавык көннәр — уртача 3–12 көн, бәсле — 7–24, буранлы — 24–58, томанлы көннәр 7–15 көн дәвам итә. Аеруча салкын К.лы еллар: 1870–71, 1941–42, 1978–79, 2009–2010.

*Әд.:* Смоляков П.Т. Климат Татарии. К., 1947; Иманаева Р.Ш. Климатическая характеристика тёплых и холодных зим в Татарии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116, кн. 3; Климат Татарской АССР. К., 1983.

**КЫШКА́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симет елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 250 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. А.И.Үтәмишев йорты, мәдрәсә бинасы — 19 йөз ахыры архит-ра ядкәре. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Революциягә кадәрге чыганакларда Каескар исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык,

Кышкы күренешләр.









киндер сугу һәм аяк киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да мәчет (1777 дә төзелә; архит-ра истәлеге; хәзерге вакытта эшли), җил тегермәне, 4 вак-төяклəр кибете була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 958,5 дис. тәшкил итә. 18 йөз — 20 йөз башында авылда атаклы мәдрәсә була, анда Россиянең күп кенә төрки халык вәкилләре укый (к. *«Кышкар»*). 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 521, 1897 дә — 480, 1908 дә — 434, 1920 дә — 444, 1926 да — 411, 1938 дә — 465, 1949 да — 262, 1958 дә — 481, 1970 тә — 492, 1979 да — 392, 1989 да — 317, 2002 дә — 319 кеше.

**«КЫШКА́Р»**, Казан губернасының Казан өязендәге шул ук исемдәге авылда мәдрәсә (хәзерге Арча р-ны). Кышкар авылында туган Казан сәүдәгәре Баязит бине Госман әл-Кышкарый тарафыннан 1770 елларда ачыла. 18 йөз ахырында — 19 йөзнең беренче яртысында Россиядә иң зур һәм атаклы мөселман уку йортларының берсе була. Аның б-н күренекле дин белгечләре һәм педагоглар җитәкчелек итә: Сәгыйть бине Ибраһим әл-Барыши (1813 кә кадәр), Фаяз бине әд-Дөбъязи (1844), Исмәгыйль бине Муса әл-Мәчкәри (Үтәмишев) (1887 гә кадәр, к. *Үтәмишевләр*), Ш.Үтәгәнов (1917 гә кадәр). Мәдрәсә тоту өчен аны нигезләүче Баязит һәм Казан сәүдәгәрләре Госмановлар (аның нәселе) күп акча бирәләр. Мәдрәсәдә Казан, Оренбург, Пенза һәм Рязань губерналарыннан татарлар, ш.у. башкорт һәм казакълар укый. «К.»да укучылар мөселман хокукы, логикадан тирән белемнәре, ораторлык осталыгы, диспутларда чыгыш ясый белүләре б-н аерылып тора. 1870 еллар ахырыннан, төп химаячесе М.М.Госманов бөлгенлеккә төшкәннән соң, мәдрәсәнең матди ягы начарлана, шәкертләр саны кискен кими, ләкин ул Казан арты өчен дин эшлеклеләре әзерләүдә әһәмиятле роль уйнавын дәвам итә. 1917 елга кадәр, нигездә, иске ысул мәдрәсәсе булып кала, ләкин Ш.Үтәгәнов җитәкчелек иткәндә авазлар алымы буенча укырга өйрәтү һәм рус телен укыту кертелә. «К.»да Г.Г.*Кандалый*, Г.*Баязитов*, Т.Г.Яхин, Р.*Ибраһимов*, Ф.Х.*Халиди*, К.*Мотыйгый*, М.Тукаев (Г.*Тукайның* этисе) укый. Мәдрәсә 1918 дә ябыла.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1890. Т. 2; Л о т ф и Г. Кышкар мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. К., 1992; Х ә й р е т д и н о в Р.Р., С а л и х о в Р.Р. Татарстан Җөмһүрияте: Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре (18 г. ахыры – 20 г. башы). К., 1995.

**КЫШКА́Р МӘЧЕТЕ́**, татар дини архит-расы ядкәре. Арча р-ны Кышкар авылында урнашкан. 1776–77 елда сәүдәгәр Баязит бине Госман әл-Кышкарый иганәсенә төзелә. 1865 тә аның оныгының улы Мортаза Госманов бинаны киңәйтә һәм кирпеч манара төзетә (1930 елларда манара җимертелә). Ике катлы, өч заллы, манарасы түбәгә урнашкан мәчет. Беренче кат хуҗалык бүлмәләре — складлардан торган. Икенче катта анфилада рәвешендә вестибюль һәм аркалар б-н тоташтырылган төрле зурлыктагы 3 гыйбадәт залы урнашкан. 2, 3 нче гыйбадәт заллары биек гөмбәз б-н төгәлләнгән. Турыпочмаклы михраб интерьерга тирән аркалы куыш рәвешендә чыгып тора. Мәчет фасады Петербург бароккосы стилендә бизәлгән. Гөмбәздәге бизәкләр Казандагы Мәрҗани мәчетендәге кебек итеп эшләнгән, алар, татар декоратив сәнгате һәм барокко элементлары кулланып, күпертеп ясалган. 1930 елларда мәчет ябыла. Бина хуҗалык ихтыяҗлары өчен кулланыла. Интерьерлары сакланмаган. Архитектор Р.В.Билаловның реконструкцияләү проекты буенча 1990 еллар ахырында өч ярусллы манара торгызыла, бина яңартыла һәм дин тотучыларга кайтарыла.



Кышкар мәчете. 1777.

*Әд.:* Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надыйрова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**КЫШЛА́У** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* төньяктарак, Шашы елгасы буенда. 2010 елда 369 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 16 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.да 2 мәчет, фельдшерлык пункты, 2 тегермән, мосафирханә, 1 зур һәм 2 кечкенә вак-төяклəр кибете була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1677 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1184, 1897 дә — 1340, 1908 дә — 1415, 1920 дә — 1315, 1926 да — 1224, 1938 дә — 947, 1958 дә — 565, 1970 тә — 557, 1979 да — 468, 1989 да — 371, 2002 дә — 358 кеше.

**КЫШСӨЯ́Р**, ч а т ы р  ч ә ч ә к (Chimaphila), каеш яфракчалар семьялыгыннан мәңге яшел ярымкуакчыклар ыругы. 8 төре билгеле, Төньяк ярымшарның урман зонасында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре бар — чатырлы К. (Ch. umbellata), Кама аръягында очрый. Ылыслы коры урманнарда үсә. 8–15 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы шуышма. Сабагы туры. Яфраклары калын, кире ланцетсыман, өсте карасу-яшел, асты аксыл. Чәчәкләре алсу төстә, чатырсыман чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Үләнендә флавоноидлар, сумала, дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында төнәтмәсе йөрәк һәм бөер авырулары вакытында кулланыла. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫШТЫ́М РАЙОНЫ́**, *Новосибирск өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1931 елда оештырыла. Мәйданы — 11200 *км²*. Үзәге — Кыштовка авылы (Новосибирск шәһәреннән 610 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 13,5 мең кеше (2010), 1044 татар (2002). Татарлар, башлыча, Усманка (341 кеше), Чеки-Аул (86), Яңа Майзасс, Кыштовка, Әлмән (170) авылларында яшиләр. Авылларның иң борынгысы — Әлмән (17 йөздә Идел буеннан качкан крәстияннәр нигез сала). 1930 га кадәр монда мәчет һәм мәдрәсә була. Хәзерге вакытта Кыштовкада 2 мәчет эшли, алар каршында башлангыч мәктәпләр оештырылган. Усманка авылы мәктәбендә татар теле факультатив дәрес буларак өйрәнелә, Усманка һәм Әлмән авыллары мәдәният йортлары каршында татар үзешчән сәнгать коллективлары бар.

**КЫЯКЛЫЛА́Р**, й о н ч а л ы л а р (Poaceae, Gramineae), бер өлешле үсемлекләр семьялыгы. Бер-, ике- һәм күпьеллык үләннәр, сирәк кенә куаклар яки агачсыман үсемлекләр. 100 меңгә якын төрне үз эченә алган 900 гә якын ыруг билгеле. Бөтен Җир шары буенча таралган. Татарстан терр-ясендә 49 ыруг һәм 122 төре бар. Тамыр системасы — чук. Сабагы цилиндрсыман, эче куыш, буын араларына бүленгән. Кайберләрендә (кукуруз) буын аралары йомшак матдәләр б-н тулган. К.ның күпчелегендә салам иң түбәнге өлешендә — куаклану төенендә генә тармаклана. Яфраклары чиратлашкан һәм ике рәтле, 2 төп өлештән: яфрак пластинкасы һәм җиңсәдән тора. Чәчәкләре саргылт яшел, вак, гади чәчәк төркемендә — башакчыкларда, алар исә катлаулы чәчәк төркеме — себеркәч, чук, башаклар хасил итә. К. читтән һәм үз-үзеннән дә серкәләнә. Җимеше — бер орлыклы бөртекчә. Икмәк (*бодай, арыш, арпа, солы, тары* һ.б.) һәм терлек азыгы (*йонча, тимофеевка, болын солычасы,* кындырак) К.ы аеруча әһәмиятле. К.ның башка төрләре газоннарны яшелләндерү, аэродром һәм спорт мәйданчыкларын кәсләндерү, комнарны, өемнәрне ныгыту өчен кулланыла. Бөртекле һәм техник культуралар чәчүлекләрендә кайберләре чүп үләннәр (*сарут, солычык, тавык тарысы*) буларак үсәләр. К.ның 31 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫЯМӘ́Т** (гарәп. قيامة — үлгәннән соң кабат терелү). Мөселманнар инануынча, Ахырзаман — үлгәннән соң терелеп хисап бирү көне. Үлгәннән соң адәм *Мөнкир вә Нәнкир*



Д.К.Кыямов.

исемле фәрештәләр б-н очраша, алар, адәм җир йөзендә *ислам* күрсәткән юлдан йөргәнме, әллә Аллаһ боерыкларын үтәмичә гөнаһ кылганмы — сорау алып, шуны билгелиләр. Һәркемнең язмышы К. көнендә хәл ителә. Ул вакытта аларның барысы да Аллаһ каршына килеп басачак. Бары тик тәкъва адәмнәр генә тәмуг өстенә салынган «кылдан нечкә, кылычтан үткен» Сират күпере аша *җәннәткә* үткәрелә. Гөнаһлылар исә *җәһәннәмгә* җибәрелә. К. турындагы күзаллаулар татар дини әдәбиятына да зур йогынты ясый (к. «*Ахырзаман китабы*»).

**КЫЯМКАРИ́** Зөлфәкарь (1870, хәзерге Әлки р-ны Төгәлбай а. — 1921, Казан), каллиграф-хаттат, фотограф. «Мөхәммәдия» (Казан) мәдрәсәсендә белем ала. К. күпкырлы талант иясе: ул татар бәге Чура-батырның борынгы нәсел шәҗәрәсен төзүче буларак та («Үтәк шәҗәрәсе», 1911), Г.Тукай исеме б-н бәйле 20 йөз башы биналарының фоторәсемнәрен тарихта калдырган беренче татар фотографы буларак та билгеле. 20 йөз башында литография ысулы б-н В.В.Вараксин типолитографиясендә басылган төсле «Шифа-



З. Кыямкари. «Дәва аятьләре» шәмаиле. В.В. Вараксин типолитографиясе. 20 йөз башы. ТР Милли музее.

лы аятьләр язылган шәмаил» һ.б. шәмаилләр авторы (ТР Милли музеенда саклана). К. ның, хаттат буларак, алтын кара б-н гарәп имлясының «сөлес» ысулында күчереп язган «Мәүлед китабы», «Әмәли гакыйдәсе», «Хөсне хат», «Хуш хат» кебек китаплары булганлыгы билгеле.

*Әд.:* Ш ә м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003. Әхмәтҗанов М. Татарлардан беренче фотограф // Татарстан хәбәрләре. 1992. 21 апр.

**КЫЯ́МОВ** Габдулла Хәйретдин улы (25.11.1931, Октябрь р-ны Иске Әлмәт а.), инженер-икътисадчы, хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре (1989). Бөтенсоюз текстиль һәм җиңел сәнәгать читтән торып уку ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1965). 1951–96 елларда «Спартак» аяк киемнәре җитештерү берләшмәсендә эшли: мастер, цех башлыгы, комб-тның аяк киемнәре җитештерү бүлеге мөдире, баш инженер, ген. директор (1980–96). К. җитәкчелегендә пр-тиене техник реконструкцияләү үткәрелә. Аяк киеме җитештерүдә яңа технологияләр — роботлаштырылган агрегатлар ярдәмендә беркетүнең кою методы, олтанны термоэластопластлар һәм поливинилхлоридтан кою һ.б. кулланылышка кертелә; берләшмәдә (Россиядә беренче тапкыр) мех унтлар җитештерү гамәлгә куела. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**КЫЯ́МОВ** Дәүли Кыям улы (10.5.1923, Ульянов өлкәсенең Чардаклы р-ны Поповка а. — 29.6.2004, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (28.3.1944, 10.9.1944, 10.4.1945), сержант. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елның февраленнән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1257 нче укчы полкның элемтә ротасы өлкән телефонисты (3 нче удар армиянең 379 нчы укчы дивизиясе); 901 нче укчы полкның элемтә ротасы отделение командиры (59 нчы армиянең 245 нче укчы дивизиясе). Калинин, 2 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Великие Луки (1942), Невельск (1943), Мадона (1944) һәм Түбән Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 10–11 мартында Норкино авылы (Псков өлкәсе Пустошкинский р-ны) янындагы сугышта (13 өзелгән линияне тоташтыра, полк штабы б-н ныклы элемтәне тәэмин итә; каты яралана, әмма сугыш кырын ташламый); 1944 нең августында Айвиекste елгасын кичеп, Ляудона торак пунктыннан 10 *км* төньяк-көнчыгыштарак (Латвия ССР, Мадона р-ны) булган сугышта (10 өзелгән линияне тоташтыра, яралы хәлендә укчы подразделение б-н бергә полк командиры өчен элемтә урнаштыруны оештыра); 1945 нең 14 февралендә Краков шәһәре (Польша) янында дошман оборонасын өзгәндә (дошман уты астында 20 дән артык өзелгән элемтә линиясен төзәтә) батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Туган авылында яши, комбайнчы, трактор бригадасы бригадиры булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. Паповка авылында К.ка һәйкәл куела.

*Әд.:* Р о щ и н И.И. Солдатская слава. М., 1988. Кн. 7; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**КЫЯ́Р** (Cucumis), кабакчалар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Килеп чыгышы — дымлы, тропик илләр. Татарстанда игүле К. (C. Sativus) үстерелә. Бер өйле үсемлек; җылылык, дым, уңдырышлы туфрак ярата. Тамыр системасы төп тамырдан (1 *м* га кадәр озынлыкта) һәм ян-як тамырлардан тора, алар, башлыча, туфракның югары катламында (10–30 *см*) урнаша. Сабагы шуышма, ботакланган, төссез төкләр б-н капланган, озынлыгы 1,5–2 *м* га җитә, эре яфраклы һәм бер үсемлектә аерым җенесле чәчәкле. Җимеше — яшел төстәге кабакча (ялган озынча җиләк). Химик составы (%): су — 95–97, шикәр — 1,1–2,5, аксым — 0,5–1,1. К.ны тотрыклы җылы вакытта чәчәләр (1 *га* га 5–7 *кг* орлык). Бу культура теплицалы һәм парниклы хуҗалыкларда киң таралган. Өлгереп җитмәгән кыярларны (ярымсулылары һәм ваклары — 4 *см* га кадәр — корнишоннар) яңа өлгергән, тозлаган һәм маринадлаган килеш кулланалар.



Татарстанда үстерелә торган сортлар: ачык грунт өчен — «Надёжный» (1987), «Изящный» (1992); гибридлар — «Мовир» (1987), «Великолепный» (1978), «Моравский корнишон» (1999), «Дездемона» (1999); ябык грунт өчен — «Грибовчанка» (1989), «ТСХА 4048» (1988); гибридлар — «Сентябрьский» (1985), «Эстафета» (1985), «Зозуля» (1986). Уңышы ачык грунтта 1 *га* дан 110 *ц*, парник һәм теплицаларда 1 *м*² дан 35–45 *кг* алына. Корткычлары — пәрәвез талпаны, гөбләләр; авырулары — очлары таплану, ончыл чык, ак черек, тамыр череге, антракноз, аскохитоз һ.б.

*Әд.:* Овощеводство. М., 1993.

**КЫЯРМӘ́Т** елгасы, Идел алдында, Коры Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,5 *км*, бассейнының мәйданы 59,2 *км*². Идел буе калкулыгы буйлап ага, Кама Тамагы р-нында. Елга башы — урман массивында, Варварино авылыннан 2,5 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы — Каратал авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 76 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. К.нең 1 дән алып 4,8 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 135 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, мартның өченче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КЫЯРЧАЛА́Р** (Boraginaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Бөтен Җир шарын-

да таралган. 115 ыруг һәм 2500 гә якын төрне берләштерә. Алар арасында агачлар һәм куаклар, ш.у. күпьеллык һәм берьеллык үләннәр бар. Татарстан терр-ясендә 17 ыруг, 23 төр, нигездә, цилиндрсыман сабаклы бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Яфраклары бөтен, чиратлашкан, сирәк кенә каршыдаш урнашкан, төпчек яфракларсыз. Сабак һәм яфраклары кылсыман каты төкчәле, чәнечкеле. Аерым төрләрендә, кыллылардан тыш, йомшак төкчәләр дә бар. Чәчәкләре бөтеркә — чәчәк төркеме, алар исә әкәм-төкәм сыман бөтерелгән һәм чәчәк ачылу б-н бергә турая, чукка охшап кала. Бөтеркәләр ялгыз яки парлап сабак очында урнашалар, яки себеркәч, калкансыман, башак яки башча чәчәк төркеме хасил итәләр. Бал кортлары, төклетуралар, күбәләкләр ярдәмендә читтән серкәләнәләр. Җимеше — коры, өлгергәч чикләвексыман 4 яки 2 өлешкә таркала, ә кайбер төрләрендә — сусыл төшчә. Бу семьялыкның күп төрләре (дарулы кыяр үләне, үпкә үләне, дарулы ишәкколак һ.б.) халык медицинасында кулланыла, аларның кайберләре баллы (йомшак күкебаш, дарулы ишәкколак, гади елан үләне һ.б.), чүп үләннәр (күгәрчен күзе), декоратив (гади кыяр үләне, садә оносма, күгәрчен күзенең кайбер төрләре) үсемлекләр. Җәлпәк җимешле гакелия, шуышма омфалодес ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**КЫЯ́Т** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,3 *км*, бассейнының мәйданы 64,7 *км*$^2$. Идел буе калкулыгы буйлап ага, Буа р-нында. Елга башы Яшевка авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Кыят авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 68 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. К.ның 0,8 дән алып 4,4 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, зур күпчелеге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 109 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*$^3$*/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**КЫЯ́Т** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кыят елгасы буенда. 2010 елда 749 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; спирт з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1614 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богоявленский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында К.та Богоявление чиркәве (1801 тә төзелә; архит-ра ядкәре, 1990 елларда яңадан эшли башлый), земство мәктәбе һәм хастаханәсе (1870 тә ачыла), спирт з-ды була; ярминкә эшли (14–16 июньдә). Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 662,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 409, 1859 да — 692, 1897 дә — 693, 1913 тә — 674, 1920 дә — 925, 1926 да — 857, 1938 дә — 888, 1949 да — 780, 1958 дә — 664, 1970 тә — 1121, 1979 да — 966, 1989 да — 834, 2002 дә — 878 кеше.



Кыят авылы. Богоявление чиркәве. 1801.

**КЭМСТ**, к. *Хәзерге заман театрының конструктив-тәҗрибә остаханәсе.*

**КЯФИ́Р** (гарәп. كافر — танымаучы), Аллаһка ышанмаучы. Исламда «К.» төшенчәсе нейтраль мәгънәгә ия: мөселман булмаган бөтен халык К. санала, чөнки алар *Коръәнне* һәм *Мөхәммәдне* соңгы пәйгамбәр буларак танымыйлар. Илаһият галимнәренең бер өлеше яһүдләрне һәм христианнарны, ш.у. көферлеккә төшкән мөселманнарны (вакытлыча һәм мәҗбүри рәвештә булганда) К. дип санамый. Күп аллаларга табыну, намаздан баш тарту, сихер, зина кылу, мордар китү, эчкечелек, комарлы уеннар уйнау һ.б. көферлеккә керә.

# Л

**ЛАББО́К** Абрам Иосифович (12.7.1904, Тамбов — ?), хирург, мед. фән. д-ры (1938), проф. (1939). 1925 елда Воронеж ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Донецк округы Миллерово шәһәре хастаханәсендә табиб-хирург. 1927 дән Саратов ун-тының хирургия клиникасында. 1930 дан Воронеж мед. ун-тында. 1934 тән Архангельск мед. ин-тының оператив хирургия каф. мөдире, 1939 дан Казан мед. ин-тының һәм бер үк вакытта ГИДУВының оператив хирургия каф. мөдире. 1945 тән Казан травматология һәм ортопедия фәнни тикшеренү ин-тында, ректор урынбасары, 1950 дән Караганда мед. ин-тының оператив хирургия каф. мөдире, директор урынбасары. 1955 тән Благовещенск (Амур өлкәсе) мед. ин-тының оператив хирургия каф. мөдире. Бөек Ватан сугышы чорында Казан эвакогоспитальләрендә киңәшче. Хезмәтләре оператив хирургиягә карый.

*Әд.:* Абрам Иосифович Лаббок // Сб. трудов по морфологии и хирургии. Благовещенск, 1960.

**ЛАБЫ́Ш** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 48 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 61 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.та земство мәктәбе, икмәк һәм агач материаллары ташу пристане, 2 тимерче алачыгы, 1 су һәм 7 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 440 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Тәмте волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1859 да — 412, 1897 дә — 542, 1908 дә — 498, 1920 дә — 623, 1926 да — 565, 1938 дә — 529, 1949 да — 480, 1958 дә — 421, 1970 тә — 365, 1979 да — 230, 1989 да — 151, 2002 дә — 82 кеше.

**ЛАБЫ́Ш ТАУЛАРЫ́**, табигать тыюлыгы, Кама Тамагы р-нының Лабыш авылыннан төньяктарак урнашкан. 1991 елда билгеләнә. Идел елгасының уңъяк ярындагы һәм Морковка елгасы (Идел кушылдыгы) тамагының сулъяк ярындагы калкулыклы участокларны алып тора. Мәйданы 198 *га*. Иделнең текә ярларын имән-юкә урманнары били, агачлар төбендә сәхләбчәләрнең сирәк төрләре очрый: чын башмакчәчәк, куе кызыл һәм киң яфраклы йод үләне, черки шәрә бизлеге. Матур табигатьле көньяк-көнбатыш сөзәклекләр б-н урмансыз киңлекләр өчен дала төрләреннән торган кылган ассоциацияләре (каурый кылган, чуклы шалфей һәм дала шалфее, бүлбеле кияү камчысы, ачамай һ.б.) хас. Элеккеге крәстиян бакчаларыннан калган җимеш агачлары үсә.

*Н.И.Усанова.*

**ЛАВРЕ́НТИЙ** (? – 11.11.1672, Казан), дин эшлеклесе. Новгород өязенең Вяжицкий монастыренда монахлыкка кабул ителә, шунда ук игумен була. 1657 дән Казан һәм Зөя митрополиты. Л. Смоленск Седмиозёр Мәрьям Ана иконасының танылуына ярдәм итә, ел саен, тәре һәм иконалар күтәреп, тантаналы рәвештә Казанга баруны оештыра. *Раифа Богородица пустынена* иганә кыла, аның иганәсенә пустыньда 3 чиркәү төзелә. Л. күрсәтмәсе буенча, аларның берсенә Новгород өязендәге Красногорск монастыренда сакланган Грузия Мәрьям Ана иконасының күчермәсе урнаштырыла.

*Е.В.Липаков.*

**ЛАВРЕ́НТЬЕВ** Александр Петрович (9.10.1946, Казан), инженер-механик, сәнәгый җитештерүне оештыручы, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2002), мактаулы авиатөзүче (1996). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1973). 1967–70 елларда Казан электрофизика ин-тында эшли. 1970 тән (бүленеп) «Казан вертолёт заводы» АҖдә: инженер-конструктор, бюро башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары, башлыгы, ген. директор (1984–89 да һәм 1990–2007). 1989–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. Л. җитәкчелегендә производствоны техник яңарту буенча комплекслы программа эшләнә һәм гамәлгә ашырыла. Ми-8, Ми-17 вертолётлары һәм аларның модификацияләре, җиңел «Ансат», урта класс Ми-38, аеруча җиңел «Актай» вертолётлары һ.б. эшләнә һәм җитештерүгә куела. Уйлап табуга 6 патенты бар. 1989–91 дә СССР халык депутаты. «Почёт билгесе», Почёт, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Казанның мактаулы гражданы (2005).

*Әд.:* Казанские вертолёты: полёт продолжается. К., 2000.

**ЛАВРЕ́НТЬЕВ** Борис Иннокентьевич (31.7.1892, Казан – 9.2.1944, Мәскәү), гистолог, мед. фән. д-ры (1926), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1939), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940); нейрогистологиядә гистофизиологик һәм эксперименталь юнәлешкә нигез салучы. К.А.Арнштейн шәкерте. 1914 елда Казан ун-тын тәмамлагач, полк табибе булып хезмәт итә. 1917–27 елларда Казан ун-тының гистология кафедрасында. 1922–24 тә ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының оештыру бүлеге мөдире урынбасары, 1924–26 да Казан мед. техникумында укыту бүлеге мөдире. 1927 дә Нидерландның Утрехт ун-тында фәнни командировкада. 1927 дән Мәскәү Югары зоотехния ин-тының гистология һәм эмбриология каф. профессоры һәм мөдире, бер үк вакытта В.А.Обух исем. Һөнәри авырулар ин-ты физиология лаб-ясенең морфология бүлеге мөдире. 1930 дан 1 нче Мәскәү мед. ин-тының гистология һәм эмбриология кафедрасында, бер үк вакытта 1 нче Мәскәү мед. ин-ты каршындагы Микроморфология ин-ты директоры. 1934–44 тә 2 нче Мәскәү мед. ин-тының гистология һәм эмбриология каф. мөдире, бер үк вакытта, 1937–43 тә Бөтенсоюз тәҗрибә мед. ин-тында морфология бүлеге мөдире, директор урынбасары. Хезмәтләре нерв системасы морфологиясе, нейрон теориясенә карый. РСФСР һәм СССР Сәламәтлек саклау халык комис-тларында гыйльми шура әгъзасы. Бөтенсоюз анатомнар, гистологлар һәм эмбриологлар җәмгыяте идарәсе әгъзасы һәм рәисе. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1941). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Морфология автономной нервной системы. М.–Л., 1939 (автордаш); Морфология чувствительной иннервации внутренних органов. М., 1947 (автордаш); Теория строения вегетативной нервной системы. М., 1983.

Лабыш таулары.



*Әд.:* Люди русской науки: Очерки о выдающихся деятелях естествознания и техники. М., 1963; Ф е л ь д м а н Н.Г. Борис Иннокентьевич Лаврентьев. М., 1983.

**ЛАВРЕ́НТЬЕВ** Иван Егорович (Георгиевич) (1879, Казан губ., Тәтеш өязе Зур Фролово а. — 17.12.1937, Куйбышев, хәзер Болгар ш.), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист. 1901–02 елларда Казан укытучылар семинариясендә экстерн тәртибендә имтиханнар тапшыргач, авыл приход мәктәбендә укыта. 1906 да кандидатурасы авыл һәм волость җыеннары крәстияннәре сайлаучылары һәм өяз съезды тарафыннан 1 нче Дәүләт Думасына күрсәтелә. Казан губернасы крәстияннәре куриясе буенча кадетлар блогыннан депутат булып сайлана; трудовиклар фракциясе һәм трудовикларның «Крестьянский депутат» г-тасы редколлегиясе әгъзасы. Хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән *Выборг өндәмәсенә* кул куя, шуның өчен 3 айга ябылуга хөкем карары чыгарыла, дәүләт хезмәтенә урнашу һәм иҗтимагый эш башкару хокукыннан мәхрүм ителә. Полициянең яшерен күзәтүе астында була. Туган авылында яши, крәстиян хезмәте (бакчачылык), әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә; әсәрләре «Крестьянинъ», «Влас Подгорный», «Иван Власов» һ.б. псевдонимнар б-н «Жизнь для всех» һәм «Северные записки» (С.-Петербург) ж-лларында басыла. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң трудовиклар төркеменнән чыга һәм сул эсерларга кушыла. 1917 дә Крәстиян депутатларының Казан губерна советы делегаты, Тәтеш өяз земство идарәсе һәм өяз башкарма ком-ты әгъзасы. Окт. рев-циясе җиңгәннән соң сов. хакимияте тарафдары, партиясез социалист була. Авыл, волость һәм өяз (кантон) башкарма ком-тлары әгъзалары булып сайлана. 1920 еллар башында Зур Фролово авылында 1 нче бергәләп җир эшкәртү ширкәте, соңрак — кулланучылар җәмгыяте һәм кредит ширкәте оештыра. Бер үк вакытта, 1918–23 тә, Буа кантонының Петровское һәм Зур Фролово авылларында укытучы булып эшли. 1921 нең октябрь–декабрендә Тәтеш кантоны халык мәгарифе бүлегендә һөнәри белем бирү бүлекчәсе мөдире. Хезмәт Герое буларак көмеш сәгать б-н бүләкләнә. 1923–29, 1935–37 дә Зур Фроловода китапханәче. Төбәк тарихын өйрәнә, табигать күренешләре буенча күзәтүләр алып бара (эшенең нәтиҗәләре җирле басмаларда дөнья күрә), язучылар А.М.Горький, А.Неверов, И.Вольнов; В.Н.Фигнер б-н языша. Л. булышлыгы б-н 1920 елларда Зур Фроловода В.Н.Фигнер акчасына җидееллык мәктәп төзелә. Берничә тапкыр сәяси репрессияләргә дучар ителә. 1937 дә «Тәтеш районында эсерларның 15 кешелек баш күтәрүчеләр төркемен оештыру»да гаепләнеп атып үтерелә. 1956 да аклана.

Х е з м.: Выборы от крестьян в Казанской губернии // К 10-летию 1-ой Государственной Думы 27 апреля 1916: Сб. статей перводумцев. П., 1916; Из воспоминаний о 1905 годе // Зап. Тетюшского музея. 1929. № 5; Письма 1912–1915/17 гг. Лаврентьева — А.М.Горькому // Горький М.: Материалы и исследования. М., 1935. Т. 1.

*А.Ф.Степанов.*

**ЛАВРЕ́НТЬЕВ** Михаил Алексеевич (6.11.1900, Казан — 15.10.1980, Мәскәү, Новосибирск шәһәрендә җирләнә), математик һәм механик, техник (1934) һәм физика-матем. (1935) фән. д-ры, Украина ССР, СССР ФА академигы (1939, 1946), Соц. Хезмәт Герое (1967). 1918–21 елларда Казан ун-ты студенты, укытучы вазифаларын башкаручы (1920–21). 1921 дән Мәскәүдә. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1922), Мәскәү хәрби-техник уч-щесендә укый (1921–29). 1927 дә Франциягә фәнни эшләр өчен командировкага җибәрелә. 1929–31 дә Д.И.Менделеев исем. Мәскәү химия-технол. ин-ты профессоры, бер үк вакытта Н.Е.Жуковский исем. Үзәк аэрогидродинамика ин-тында эшли (1929–35). Мәскәү (1931–41, 1951–53), Киев (1939–41, 1945–48) һәм Новосибирск (1959–66) ун-тлары профессоры; СССР Уртача зурлыктагы машиналар төзү министрлыгында баш конструктор урынбасары (1953–55); Мәскәү физика-техника ин-тының тиз узучан процесслар физикасы каф. мөдире (1955–58).

1933 тән Л.ның фәнни эшчәнлеге СССР ФАдәге хезмәте б-н бәйле: В.А.Стеклов исем. Матем. ин-тының функцияләр теориясе бүлеге мөдире (1934–41), Төгәл механика һәм хисаплау техникасы ин-ты директоры (1950–53), Физика-матем. фәннәре бүлекчәсенең акад. секретаре (1951–53, 1955–57), Президиумы әгъзасы (1955–80), вице-президенты (1957–75). Л. — СССР ФА Себер бүлеген төзүне башлап йөрүче, аның беренче рәисе (1957–75) һәм мактаулы рәисе (1975–1980), бер үк вакытта Гидродинамика ин-ты директоры (1975–76); Теоретик һәм гамәли механика буенча СССР Милли ком-ты рәисе (1976–80). 1939 дан Украина ССР ФАдә: Матем. ин-ты директоры (1939–49, Киев-Уфа-Киев), бер үк вакытта Матем. бүлекчәсе мөдире (1941–45), ФАнең вице-президенты (1945–48).

Л. — математикада яңа юнәлешләргә (күплекләр теориясе һәм функцияләрнең гомуми теориясе, комплекс үзгәрешле функцияләрне якынча исәпләүләр теориясе, конформ һәм квазиконформ чагылдырулар теориясе, дифференциаль тигезләмәләр теориясе, квазиконформ чагылдыруларның нәсызыкча класслары теориясе) нигез салучы; фәзаи квазиконформ чагылдырулар теориясендә ул куйган күп кенә проблемалар математика һәм матем. физиканың күпсанлы мәсьәләләрен чишүнең геометрик алымнары нигезен тәшкил итә.

Тоташ тирәлек механикасы һәм гамәли физика өлкәләрендә Л. канат теориясен, озын дулкыннар һәм агынтылар теорияләрен эшләүдә уңышлы нәтиҗәләргә килә; кумуляция күренешенең гидродинамик трактовкасын эшли (чит ил галимнәре б-н бер үк вакытта).

Л. җитәкчелегендә юнәлтүле шартлау теориясе, шартлату ярдәмендә эретеп ябыштыру, югары тизлекле бәрүләр кебек гамәли тикшеренүләр үсеш ала, шартлаучы зарядның яңа төре — шнурлы заряд эшләнә.

Чехословакия ФАнең хакыйкый әгъзасы (1957), Америка матем. җәмгыяте әгъзасы



Б.И.Лаврентьев.



М.А.Лаврентьев.

(1964), Болгария ФАнең шәрәфле чит ил әгъзасы (1966), ГДР ФАнең чит ил әгъзасы (1969), Халыкара астронавтика академиясенең хакыйкый әгъзасы (1970), Польша Халык Респ-касы ФАнең (1971), Табигыять фәннәре академиясенең (Париж, 1971), Германия «Леопольдина» табигыятьчеләр академиясенең (1971), Финляндия ФАнең (1975) чит ил әгъзасы, Халыкара математиклар берлегенең вице-президенты (1966–70). «Физика горения и взрыва» ж-лының баш мөхәррире. 1947–51 дә Украина ССР ЮС, 1958–79 да СССР ЮС депутаты. Ленин бүләге (1958), СССР Дәүләт бүләге (1946, 1949), Украина ССР ФАнең С.А.Лебедев исем. бүләге лауреаты (1974). Биш Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, дүрт Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 нче дәрәҗә Кирилл һәм Мефодий (Болгария), «Командор» дәрәҗәсендәге Шәрәфле легион (Франция) орденнары, СССР ФАнең М.В.Ломоносов исем. алтын медале б-н бүләкләнә. 1980 дә СССР ФАдә М.А.Лаврентьев исем. алтын медаль һәм шул исем. бүләк булдырыла, ул ике елга бер тапкыр математика, механика һәм физика өлкәсендәге тикшеренүләрне үстерүгә, шулай ук Себерне һәм Ерак Көнчыгышны үстерүгә керткән күренекле казанышлар өчен бирелә. Биш ел саен (1980 тән) математика, механика һәм физика буенча халыкара Лаврентьев укулары үткәрелә (1995 елда Казанда уза).

Л. — Новосибирск шәһәренең мактаулы гражданы. РФА Себер бүлегенең Гидродинамика ин-ты, Новосибирск ун-ты каршындагы физика-матем. мәктәбе, Мәскәүдә һәм Казанда урамнар, Новосибирск Академшәһәрчегендә проспект, фәнни-тикшеренү судносы, Памир һәм Алтайда тау түбәләре, 1979 елда ачылган кече планета аның исемен йөртә.

Х е з м.: Курс вариационного исчисления. М.–Л., 1938 (автордаш); Конформные отображения с приложениями к некоторым вопросам механики. М.–Л., 1946; Вариационный метод в краевых задачах для систем уравнений эллиптического типа. М., 1962; Методы теории функций комплексного переменного. М., 1965 (автордаш); Проблемы гидромеханики и их математические модели. М., 1977 (автордаш).

*Әд.:* Михаил Алексеевич Лаврентьев. 1900–1980. Новосиб., 1983; П р и т в и ц Н.А. Естествоиспытатель, преобразователь, просветитель // Лаврентьевские чтения по математике, механике и физике. Новосиб., 2000.

**ЛАВРО́В** Михаил Иванович (1.11.1927, Норлат р-ны Паново а. — 19.9.2002, Яшел Үзән

р-ны Октябрь пос.), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1979), проф. (1982). 1950 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, астрономия каф. профессоры (1981); бер үк вакытта В.П.Энгельгардт исем. астрономия обсерваториясендә эшли; астрофизика бүлеге мөдире (1958 дән), директор урынбасары (1960–70), СССР ФА Астрономия советының Җирнең ясалма иярченнәрен күзәтү буенча шәһәр станциясен оештыручы һәм аның җитәкчесе. Хезмәтләре якын урнашкан куш йолдызлар астрофизикасына карый. Л. тотылучан куш йолдызларның ялтырау кәкреләрен һәм спектраль куш йолдызларның нур тизлекләре кәкреләрен исәплəү машинасы б-н анализлау алымын эшли. Халыкара астрономия берлеге әгъзасы (1964 тән). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые статистические закономерности у затменных переменных звёзд и их физическое истолкование // Бюл. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1955. № 31; Библиография спектрально-двойных звёзд: В 4 вып. М., 1951–63 (автордаш); Курс сферической астрономии. К., 1991. *Р.Г.Усманов.*

**ЛАВРО́В** Сергей Дмитриевич (19.7.1884, Омск ш. — 1932, Ставрополь ш.), зоолог. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1909), шунда ук эшли (1912 гә кадәр). Саратов губернасы күлләрен өйрәнә, Турухан краенда күп кенә экспедицияләрдә була, Казан ун-ты музее коллекциясен 16 исемдәге балык, 148 исемдәге кош, 5 исемдәге имезүче, ш.у. күп кенә суалчан һәм кысласыманнар б-н тулыландыра. Казан ун-ты музеендагы умырткалы хайваннарның беренче систематик каталогын (т. 1–2, 1907–09) төзүдә катнаша. 1912–31 елларда Тамбов, Алма-Ата, Омск (Себер а.х. һәм урманчылык ин-ты профессоры) һ.б. шәһәрләрдә укыта. 1931–32 дә Казан ун-тының умырткалылар зоологиясе каф. мөдире. 1932 дә Ставропольгә күчеп китә. Хезмәтләре кошлар һәм имезүчеләр зоологиясе һәм зоогеографиясенә карый. Казан ун-ты каршындагы табигыятьчеләр җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1910 нан).

Х е з м.: По озеру Зайсану и окрестным степям // Сиб. природа. 1922. № 2; Зоологические экскурсии по березнякам сибирской лесостепи. // Тр. Сиб. пед. биостанции. 1928. Вып. 1; Материалы к изучению орнитофауны озера Чаны и его окрестностей // Тр. Сиб. ин-та с.-х. и лесоводства. 1930. Т. 13, вып. 1. *В.И.Гаранин.*

**ЛА́ВРСКИЙ** Константин Викторович (19.12.1844, Түбән Новгород губ. Горбатов ш. — 27.11.1917, Казан губ., Чабаксар өязе Козловка а.), хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе, публицист. Рухани гаиләсендә туа. Түбән Новгород гимназиясен тәмамлаганнан соң (1860), Казан ун-тының тарих-филол. ф-тына керә. Яшерен студентлар түгәрәге әгъзасы. *Куртина чиркәвендәге панихидада* катнаша. 1863 елда *Казан фетнәсе* турындагы эш буенча кулга алына, каторгага җибәрүгә хөкем ителә, Казан төрмәсендә тотыла. Амнистиядән соң (1867), апалы-сеңелле Дубровиналарның хосусый кызлар пансионында укыта. 1872 дә Н.Я.Агафонов б-н бергә «*Камско-Волжская газета*»ны оештыра. 1872 нең ахырында Л.га карата, төбәкне руслаштыруга каршы чыгуда гаепләп, әләк оештырыла. Ул кулга алынып, Вологда губернасының Никольск шәһәренә сөрелә, бераздан Самара шәһәренә күчерелә. Сөргеннән соң Казанга кайта. 1881 дә экстерн тәртибендә ун-тының юридик ф-тын тәмамлый, 1882 дә магистрлык имтиханын тапшыра. Адвокат буларак, башлыча крәстияннәр эшләре б-н шөгыльләнә. Казан мәхкәмә округы каршында антлы ышанычлы булып хезмәт итә. Казан губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906), трудовиклар фракциясе, аграр комиссия, «Крестьянский депутат» г-тасы редколлегиясе әгъзасы. Әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә, башкалада һәм Казанда чыгучы күп кенә басмалар б-н хезмәттәшлек итә. Казан ун-ты турындагы хатирәләр, күпсанлы мәкаләләр һәм очерклар авторы. «Татар ярлылары» («Татарская беднота», 1884) хезмәтендә Казан губернасындагы татар крәстияннәренең авыр тормышы сәбәпләрен анализлый.

Ә с ә р.: Из воспоминаний казанского студента // Первый шаг. К., 1876; К.Ф.Фукс и его время // Казанский литературный сборник. К., 1878; Воспоминания о профессорах и студентах в начале 1860-х годов // Литературный сборник к 100-летию Имп. Казан. ун-та. К., 1904.

*Әд.:* В у л ь ф с о н Г.Н., Н у р е е в а Ф.Ф. Братья по духу: Питомцы Казанского университета в освободительном движении 1840–1870 гг. К., 1989; В у л ь ф с о н Г.Н. Константин Лаврский и его историко-социологическое исследование «Татарская беднота» // Татарстан. 1992. № 9/10; Русские писатели, 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1994. Т. 3; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ЛАВУ́ЩЕНКО** Владимир Павлович (4.4.1949, Белоруссия ССРның Могилёв өлкәсе Климовичи ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2004), проф. (2003), ТРның атказ. икътисадчысы (1992). 1972 елда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1966 да Әлмәт юл төзелеше конторасында маляр булып башлый. 1967–72 дә Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тының кичке ф-тында эшли. 1972–84 тә «Әлмәтнефть» НГДУында инженер-программист, мастер, өлкән инженер, 1986–95 тә бухгалтер, 1984–86 да «Ямашнефть» НГДУында бүлек башлыгы, 1995–97 дә «Татнефть» АҖнең баш бухгалтеры, 1997 дән ген. директорының икътисад буенча урынбасары. «Луч» телекомпаниясен оештыручыларның берсе, «Нефтяник» хоккей клубы президенты. Хезмәтләре нефть-газ комплексы б-н идарә итүне камилләштерүгә карый. Л. җитештерү чыгымнарын стимуллаштыру һәм контрольдә тоту алымнарын гамәлгә кертә, түбән рентабельле, зыянга эшләүче, суланган һ.б. скважиналардан алына торган нефтькә дифференциаллаштырылган салым системасын нигезли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, медальләр, ТРның Мактау грамотасы, ТР Президентының Рәхмәт хаты б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Корпоративное управление нефтегазовым комплексом. М., 2003.

**ЛА́ГЕРКА** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,7 *км*, бассейнының мәйданы 45,2 *км*². Чирмешән р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Лагерка авылыннан 2 *км* көньяктарак, тамагы — Нагай посёлогыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 172 *м*, тамагыныкы — 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Л.ның 5 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысын диярлек кар сулары алып тора. Җир асты сулары б-н туену модуле 3,1–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 131 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Л. бассейнында су күләме 0,54 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ЛА́ГЕРКА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 16 *км* көнчыгыштарак, Лагерка елгасы буенда. 2010 елда 302 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1730 елларда отставкадагы солдатлар авылы буларак нигез салына. 1831 дә халкы дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1975 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонкәсе волостенда. 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1935 нең 10 февраленнән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 484, 1897 дә — 722, 1910 да — 822, 1920 дә — 846, 1926 да — 667, 1949 да — 829, 1958 дә — 722, 1970 тә — 813, 1979 да — 604, 1989 да — 423, 2002 дә — 343 кеше.

**ЛАЁ́Ш**, район карамагындагы шәһәр, Лаеш р-ны үзәге. ТРның үзәк өлешендә урнашкан, Казан тимер юл станциясеннән 62 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кама елгасының уң ярында урнашкан. 2010 елда 7735 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 72,1%, татарлар — 24,6%) яши. Балык з-ды, тегү ф-касы, 4 гомуми белем бирү мәктәбе, һөнәр уч-щесе, а.х. техникумы. Төбәк тарихын өйрәнү музее, сәнгать мәктәбе. Мәдәният йорты, 3 китапханә. Чиркәү, мәчет. Л.ка болгарлар 10 йөз ахыры — 11 йөз башында нигез сала. Л.ның рус авылы буларак тарихы 1557 дә Казан воеводасы кенәз П.И.Шуйскийның Кама аша чыгучыларны нугайлар һөҗүменнән саклау өчен кальга төзетүеннән башлана. 1565 тә Лаеш кальгасы диварының озынлыгы 284 сажин (500 *м* чамасы) исәпләнә һәм анда 6 манара була. Л. халкы, башлыча, стре-

лец, тупчылар, затинщиклар һ.б. хәрби кешеләрдән тора. Кальга эчендә 2 чиркәү — Успение һәм Никола, бистә өлешендә Воскресение Христово чиркәүләре була. Л. (Лаишев) 16 йөзнең 2 нче яртысыннан сәяси һәм хуҗалык мөнәсәбәтләрендә Казан хакимиятенә буйсынучы шәһәр бистәсе буларак телгә алына. 1646 елгы мәгълүматларга караганда, анда ул чорда 1736 ир-ат яши (ш.и. 752 йомышлы казак, 138 стрелец, 24 йомышлы әҗнәби (украиннар), 573 бистә кешесе, ялгызаклар һәм ярлылар, 242 балыкчы, 12 дин әһеле һ.б.), 405 хуҗалык исәпләнә. 1650 елларда Л. хәрби әһәмиятен югалта, йомышлы кешеләрнең күпчелеге *Кама аръягы иске чик сызыгы* (Минзәлә, Яңа Чишмә, Зәй һ.б.) кальгасына хезмәткә күчерелә. 1708 дә Казан губернасы бистәләре исемлегенә кертелә. 1780 елгы мәгълүматларга караганда, анда 1 сәүдәгәр, 86 ир-ат мещан, 261 сарай крәстияне, 203 җир сөрүче солдат яши. Халыкның барысы да диярлек а.х. б-н шөгыльләнә. 1780 елның 28 сентябрендә, Екатерина II Фәрманы нигезендә, Л. Казан наместниклыгының (1796 дан — губернасының) өяз шәһәре статусын ала, бу — халык саны артуга һәм икътисадның үсүенә китерә. 20 йөз



Лаеш шәһәре. 1. Гомуми күренеше. 2. Державин мәйданы. 3.Мәдәният йорты. 4. Сәнгать мәктәбе.



Лаеш шәһәре. Г.Р.Державин һәйкәле. Бронза. Скульп. М.Гасимов. 2003.

башында Л.та волость идарәсе урнаша, төрмә, Троица хатын-кызлар монастыре, София чиркәве (1767 дә төзелгән иске чиркәү урынында 1853–70 тә яңадан салына; архит-ра истәлеге), Троица, Сергий һәм Никола чиркәүләре, хатын-кызлар гимназиясе (1864 тә ачыла, 1914 тән — прогимназия), өяз уч-щесе (1817 дә ачыла), китапханә (1887 дә ачыла), вак кредит ширкәте, почта-телеграф станциясе (1908 дән), телефон, 40 урынлы өяз хастаханәсе, аптека, вет. амбулаториясе, 2 гариплләр йорты, 4 кечкенә завод (поташ, май, салат, шәраб з-длары), 4 зур кибет, 4 тегермән, 5 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 30 вак-төякләр кибете, 2 чәйханә, трактир, ярма яргыч була; пәнҗешәмбе саен базар эшли. 20 майдан 20 июньгә кадәр «кәрван ярминкәсе» үткәрелә, анда Урал з-дларыннан 6 млн. сумлык тимер, чуен, агач материаллары китерелә, 1 млн. сумга якын бәядә товар сатыла. Л. пристане аша ел саен 400 мең потлап иөк, башлыча, икмәк, агач материаллары озатыла. 1910 да Л.та башлангыч һөнәр уч-щесе ачыла. 1920 гә кадәр шәһәр — ТАССРның Лаеш кантоны үзәге. 1926 ның 18 октябрендә шәһәр булудан туктый һәм авыллар исемлегенә кертелә. 1927 нең 14 февраленнән Л. — Лаеш р-ны үзәге, 1950 дә шәһәр тибындагы посёлок статусы ала. 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан яңадан Лаеш р-ны үзәге, 2004 нең 9 сентябреннән район карамагындагы шәһәр. Халык саны: 1782 дә — 550 ир-ат; 1859 да — 3473, 1897 дә — 3742, 1908 дә — 4586, 1926 да — 3781, 1938 дә — 4658, 1949 да — 4473, 1979 да — 6,5 мең, 1989 да — 7,2 мең, 2002 дә — 7,7 мең кеше. Л.та А.Н.Радищев, А.С.Пушкин, А.И.Герцен, М.Е.Салтыков-Щедрин, Л.Н.Толстой булган.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**ЛАЕ́Ш АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1960 елда ачыла, башта агрономия, яшелчәчелек, бакчачылык буенча белгечләр әзерли. 1990 еллар ахырыннан хезмәт базарында хәлләр үзгәрү сәбәпле, аның эшчәнлек профиле үзгәрә: укыту авыл хуҗалыгы икътисады һәм бухгалтерлык исәбе, хокук белеме, а.х. менеджменты белгечлекләре буенча алып барыла. 2010 елга көндезге бүлектә 330, читтән торып уку бүлегендә якынча 100 студент укый, аларның 170 түләүле нигездә белем ала; пед. коллективта 26 кеше, ш.и. ТРның атказ. укытучысы — 1, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре — 1, ТРның атказ. икътисадчысы — 1 кеше. 10 меңнән артык белгеч әзерләнә.

1982 дә авыл төзүчеләре әзерләү өчен Казанда ф-лы ачыла. 1600 дән артык белгеч әзерләнә. Укыту читтән торып уку формасында: биналар һәм корылмалар төзелеше һәм алардан файдалану, хокук белеме, җир-милек мөнәсәбәтләре белгечлекләре буенча алып барыла. 2010 елга 225 студент укый, аларның 70 түләүле нигездә белем ала; пед. коллективта 12 кеше, ш.и. ТРның атказ. мәктәп укытучысы — 1, ТРның атказ. агрономы — 1 кеше.

**ЛАЕ́Ш КАНТОНЫ́**, ТАССРда 1920–27 елларда адм.-терр. берәмлек. Лаеш өязенең 18 волосте җирлегендә оештырыла. Үзәге — Лаеш ш. Мәйданы 4585 *км*². Халкы 166065 кеше, ш.и. руслар 54%, татарлар 46% (1926). Шәһәрдә яшәүчеләр саны — 3783 кеше. Халыкның гомуми тыгызлыгы 1 *км*² га 36,2 кеше, авыл җирендә 35,4 кеше. 317 торак пункт. 9 волость: Олы Солтан, Күгәрчен, Нармонка, Яңа Арыш, Пановка, Балык Бистәсе, Саралан, Теләче, Чырпы волостьлары. Металл эшкәртү һәм азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиеләре. Л.к.нда вак һөнәрчелектә 2,7 мең чама-



сы кеше эшли (1926). 35257 крәстиян хуҗалыгы, 21 а.х. кооперативы исәпләнә (1925). 1925 кә сөрүлек җирләре мәйданы 237404 дис. тәшкил итә. Чәчүлекләр (дис.): арыш — 66124, солы — 18851, карабодай — 12976, тары — 9025, бодай — 3351, борай — 1228, бәрәңге — 7196. 250412 баш терлек, ш.и. мөгезле эре терлек — 51605, атлар — 30292, сарыклар — 117493, дуңгызлар 35854 баш була. 1927 дә бетерелгән Л.к. урынына *Лаеш районы* һәм *Балык Бистәсе районы* оештырыла.

*Әд.:* Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928–29. Т. 3, 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К., 1928.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ЛАЕ́Ш КО́МПЛЕКСЫ** (археол.) Лаеш шәһәреннән көнчыгышта Брыска (Түбә) күле янында урнашкан (Л.к. терр-ясе хәзерге вакытта Куйбышев сусаклагычы сулары астында кала). Л.к. истәлекләрен өйрәнү-тикшерү эшләре 19 йөз ахырыннан алып барыла, 1960 елларда — Е.П.Казаков, П.Н.Старостин; 1970–80 дә Р.М.Фәттахов, К.А.Руденко һ.б. тарафыннан башкарыла. Комплекс авыллыклар, мөселман каберлекләре, туктаулыклар һ.б.ны үз эченә ала. Олы һәм Кече Чакма чокырлары янында урнашкан Лаеш авыллыгында торак урыннары, базлар, хуҗалык корылмаларыннан калган чокырлар ачыклана. Л.к. терр-ясендә керамик савыт-саба кисәкләре, эш һәм сугыш кораллары, кием-салым детальләре, бизәнү әйберләре һәм тимердән, төсле металлдан, сөяк, пыяладан эшләнгән башка әйберләр табыла. Әйберләр комплексының төп өлеше Болгар һәм Алтын Урда археол. культуралары чорына карый.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П. Работы в Татарии // Археологические открытия 1974 года. М., 1975; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; К а з а к о в Е.П., Р у д е н к о К.А., Г а з и м з я н о в И.Р. Лаишевский могильник // Историко-археологическое изучение Поволжья. Йошкар-Ола, 1994; Р у д е н к о К.А. Материальная культура булгарских селищ низовий Камы XI–XIV вв. К., 2001.

*Е.П.Казаков.*



**Лаеш комплексы.** 1. Бронза асма бизәк. 11-12 йөзләр; 2. Балчык савыт. 12 йөз; 3. Металл көзге. 14 йөз.





**ЛАЕ́Ш ӨЯЗЕ́**, 1781–1920 елларда Казан губернасында. 16 йөз ахыры — 18 йөздә Казан өязендә «эчке» өяз буларак яши. Үзәге — *Лаеш* шәһәре, Кама елгасының уңъяк ярында; 1555–57 дә элеккеге татар авылы Лаеш урынында барлыкка килә; Казан яны бистәсе булып исәпләнә. 1708 дә Лаеш үзе тирәсендәге терр-яләре б-н Казанга беркетелә, 1719 да Казан наместниклыгы составына керә, 1781 дә өяз шәһәре статусы ала. Л.ө. Казан губернасының үзәк өлешендә Казан өязеннән көньяк-көнчыгыштарак урнашкан була. Көнбатышта Тәтеш һәм Зөя, төньяк-көнбатышта һәм төньякта Казан, көнчыгышта Мамадыш, көньяк-көнчыгышта Чистай, көньякта Чистай һәм Спас өязләре б-н чикләшә. Л.ө. терр-ясе буйлап, аны тигез булмаган 2 өлешкә (зурргагы — уңъяк яр, кечерәге — сулъяк яр) бүлеп, Кама елгасы ага; ш.у. аның кушылдыклары: уң — Шомбыт, Суша, Бәтке, Әшнәк, Шуран, Бырыс, Мишә (кушылдыклары Кече Мишә, Тәмтебаш, Нурминкә б-н), сул — Шонталы, Көрнәле елгалары уза. Л.ө. 4,8–5,03 мең кв. чакрым мәйданны били. Станнар һәм волостьлар саны үзгәреп тора. 1903 кә кадәр 2, аннары 3, 1914 кә 4 станга бүленә. 1860 елларга Лаеш, Күгәрчен һәм Зур Мәтәскә волостьлары, 1892 гә Тимерче (Черемецкая) волосте бетерелә; 1893–1915 тә Л.ө. 18 волостьтан тора. 1902–04 тә Карабаян волосте бетерелә, 1917–20 дә Шомбыт волостеннан Кадрәк волосте аерып чыгарыла. 19 йөз ахыры — 20 йөз башына 1 нче станга (үзәкләре — Шуран а., Лаеш ш.) — Алексеев, Анатыш, Астраханка, Державино, Зюзино, Масловка, Саралан, Тимерче, Чырпы, 2 нче станга (үзәкләре — Карабаян, Казиле, Сәрдә авыллары) — Аркатау, Бәтке, Олы Кибәхуҗа, Казиле, Карабаян, Пановка, Уракчы, Черемыш, Шомбыт волостьлары карый. Һәр стан 5 полиция участогына бүленә. Л.ө.ндә 172,5 мең кеше яши, ш.и. 57,4% руслар, 42,4% татарлар (1897). Халкы иген игү, терлек асрау, бакчачылык, умартачылык, балык тоту, суднолар төзү, киндер туку, зәркән эшләнмәләр ясау (бигрәк тә Балык Бистәсе, Богородский авылларында), ш.у. читкә китеп эшләү — тегүчелек, сарык тиресеннән кием-салым тегү кәсебе, мич чыгару, кирпеч сугу, балта эше, түбә ябу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башына шәһәрдә һәм өяздә 16 зур булмаган фабрика һәм завод, 260 тан артык вак сәнәгать пр-тиесе (буяу, йон тетү, постау басу, салат оны ясау, капчык тегү ф-калары, поташ, канат, алебастр-известь-таш з-длары һ.б.) эшләп килә. Шәһәрдә ике сыйныфлы башлангыч ирләр, башлангыч хатын-кызлар уч-щеләре, 9 миссионерлар мәктәбе, 59 башлангыч халык мәктәбе, 86 мәдрәсә һәм мәктәп эшли. 1920 дә ТАССР төзелгәннән соң *Лаеш кантоны* дип үзгәртелә.

Чыг.: Опись городских поселений Казанской губернии. К., 1885. Вып. 1; Памятная книга Казанской губернии на 1863 год. К., 1862; Список населённых мест Российской империи по сведениям 1859 года. Т. 14. Казанская губерния. СПб., 1866; Волости и важнейшие селения Европейской России. Губернии Нижне-Волжской области. СПб., 1883; Адресная книжка Казанской губернии на 1900 г. К., 1900; Адрес-календарь Казанской губернии на 1905 г. К., 1905; Адрес-календарь и справочная книжка Казанской губернии на 1915 год. К., 1914; Справочник по городу Казани и Казанской губернии на 1920 г. Ч. 1. Центральные, губернские и уездные установления. К., 1920.

*Д.Г.Мостафина.*

**ЛАЕ́Ш РАЙОНЫ́**, ТРның үзәк өлешендә урнашкан. Казан икътисади р-нына керә. Мәйданы — 2169,5 *км*. 25 җирле үзидарә советын, 68 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — Лаеш шәһәре. 2010 елда 36,5 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 56,4%, татарлар — 40,9%) яши. Шәһәр халкы — 7,7 мең, авылларда 28,7 мең кеше яши. Халыкның уртача гомуми тыгызлыгы — 1 *км*² га 17 кеше. Район 1927 нең 14 февралендә оештырыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Лаеш өязендә, 1920–27 дә ТАССРның Лаеш кантонында. Оештырылган көннән Л.р.на 40 авыл советы, 85 торак пункт керә, анда 52997 кеше (руслар — 38252, татарлар — 14712, башка халыклар — 33 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1938 нең 4 августыннан терр-ясенең бер өлеше — Столбище, 1944 нең 19 февраленнән Солтан (1946 ның 5 апреленнән — Корноухово) р-нына кучә. 1948 дә Л.р.ның мәйданы 1331 *км*² була, аңа 28 авыл советы, 87 торак пункт керә. 1950 елларда район чикләре бетерелгән Корноухово (1954 нең 19 ноябрендә) һәм Столбище (1959 ның 26 мартында) р-ннары исәбенә арта. 1960 елгы мәгълүматларга караганда, районның мәйданы — 2168 *км*², 1 посёлок һәм 21 авыл советы, 107 торак пункт була. ТАССРның адм. берәмлекләрен эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Л.р. бетерелә, терр-ясе Питрәч р-нына кушыла. Район яңадан торгызылгач (1965 нең 12 гыйнвары), мәйданы —





**Лаеш төбәк тарихы музее.** 1. Бинаның гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты: балчыктан ясалган әйберләр; 3. «Дәверләр елгасы. Державинннның тормышы» экспозиция күргәзмәсе.

2212 *км*², халкы — 44 мең кеше, адм. берәмлекләр — 22 (1 посёлок һәм 21 авыл советы), 97 торак пункт исәпләнә. 1970–90 елларда Л.р.ның кайбер авыллары Казанга кушылу сәбәпле, район терр-ясе кими.

Л.р. терр-ясе төньяктан көньякка авыш (биеклеге 75–190 *м*) тигезлектән тора. Көнбатыш һәм көньяк чикләре Куйбышев сусаклагычы ярлары буйлап үтә. Мишә һәм Бырыс елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры, соры һәм карасу соры урман, көсле-көлсу туфраклы. Терр-ясенең 16,6% урманнар б-н капланган. Известьташ, доломит, мергель, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары — Мишә елгасы; Архиерей, Кавал, Куян, Мүкле, Урман, Саламык, Сабакүл, Саф, Столбище, Чиста күлләре, 2 Кара күл; *Күл акчарлаклары колониясе*, Идел-Кама саклаулыгының Саралан участогы (к. *Саралан урманы*), *Столбище аучылык тыюлыгы*.

Л.р. терр-ясендә бронза гасырдан алып Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларына кадәрге 170 тән артык археол. ядкәрләр (к. *Атабай торулыгы*, *Имәнкискә культурасы*) табыла. А.х. җирләре 94,3 мең *га*, ш.и. 71,8 мең *га* сөрүлек җир (2002). Сабан бодае һәм көзге бодай, арыш, солы, тары игелә, бәрәңге, яшелчә үстерелә. Бакчачылык нык үскән. Терлекчелекнең алга киткән өлкәләре — мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Районда 25 а.х. пр-тиесе, ш.и. 1 дәүләт унитар пр-тиесе, 1 ябык һәм 2 ачык АҖ,, 13 ҖЧҖ һ.б.




(2012) бар. Сәнәгать пр-тиеләре, нигездә, Лаеш шәһәрендә тупланган; район үзәгеннән читтә — консерв з-ды (Нурминкә а.), «Юбилейный» кошчылык ф-касы (Габишево пос.), «Лаишевский» кошчылык комплексы (Октябрьнең 25 еллыгы исем. совхоз пос.), «Казан май комбинаты» ААҖ (Усад а. янында) эшли. Урман хуҗалыгы. Район терр-ясендә «Казан халыкара аэропорты», «Татарстан авиакомпаниясе» ААҖ, «Санта» санаторие урнашкан, Казан–Оренбург автомобиль юлы уза. 35 гомуми белем бирү мәктәбе (4213 укучы), а.х. техникумы, һөнәр уч-щесе, 34 китапханә, 43 клуб, музыка мәктәбе (Лаеш ш.) һәм аның авылларындагы 10 филиалы, 22 балалар бакчасы, 157 урынлы 2 хастаханә, 2 амбулатория бар. Татар һәм рус телләрендә «Камская новь», «Кама ягы» район г-талары нәшер ителә. Л.р.ның тарихы шагыйрь Г.Р.*Державин*, декабрист Д.И.Завалишин, дәүләт һәм профсоюз эшлеклесе А.И.*Догадов* исемнәре б-н бәйле.

**ЛАЕ́Ш ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Лаеш шәһәрендә, 1969 елда оештырыла, 1997 нең 16 августында ТР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2006 дан муниципаль музей. Экспозиция мәйданы — 500 *м*², коллекциядә 7 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Музей Халык иҗаты йорты бинасында урнашкан. Экспозициядә өч төп бүлек бар: «Борынгы заманнан алып 20 йөз башына кадәр Лаеш төбәге», «1917 дән алып 1960 елларга кадәр Лаеш районы», «16 йөз уртасыннан алып 20 йөз ахырына кадәр Лаеш шәһәре». Экспозиция авторлары — ТР Дәүләт музее фәнни хезмәткәре С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташёва, Л.М.Хуторова, рәссам Ф.Ә.Зыязов. Күргәзмәгә археол. табылдыклар, этнография коллекцияләре, 18–20 йөзләрдәге иконалар, дворяннарның көнкүреш кирәк-яраклары куелган. Экспонатлар арасында өяз земство управасы мөһере, «Бәянелхак» мөселман г-тасын оештыручы Ә.Я.Сәйдәшевнең шәхси мөһере бар. 2001 нең 14 июлендә «Дәверләр елгасы. Державинның тормышы» стационар күргәзмәсе ачыла. Аеруча кыйммәтле коллекцияләр исәбенә: татар-мөселман, керәшен татарлар һәм рус милли костюмнары (40 саклау берәмлеге), 19 йөзгә караган сирәк китаплар (40 саклау берәмлеге), Ананьино һәм Азелино культуралары, Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларына караган археол. табылдыклар (300 саклау берәмлеге), 19 йөзгә караган фоторәсемнәр, Лаеш земство уч-щесе архив документлары (40 саклау берәмлеге), иганәче П.В.*Щетинкинның* мемориаль әйберләре, Г.Р.Державинның үзе исән чакта басылган шигырьләре (1808); китаплар һәм Троицк хатын-кызлар монастыре монахиняларының чигү үрнәкләре бар. Музей ел саен музейның ачылу көнен, Халыкара музейлар көнен (18 май), «*Каравон*» бәйрәмен (24 май), Г.Р.Державинның туган көнен (14 июль), Шәһәр көнен (9 сент.) билгеләп үтә.

Музейның басмалары: «Река времён. Жизнь Державина»: Буклет. К., 2001; «Я жил, сколь мог; для общего добра»: Буклет. К., 2004; «И дым отечества нам сладок и приятен»: Набор открыток. К., 2005.

**ЛАЕ́Ш УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Лаеш, Питрәч һәм Балык Бистәсе р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1931 елда оештырыла. Гомуми мәйданы 33692 *га*, ш.и. урман мәйданы — 32415 *га*, урман б-н капланганы — 31790 *га*. Урман хуҗалыгы составына Лаеш (12517 *га*), Питрәч (12935 *га*) һәм Янтык (8240 *га*) урманчылыклары керә. Л.у.х. карамагында 1960 та Идел-Кама саклаулыгына бирелгән Саралан урманчылыгы, ш.у. 1961 дә Куйбышев, соңыннан Биләр урман хуҗалыгы составына кергән Алексеев урманчылыклары да була. Урман хуҗалыгы дирекциясе Лаеш шәһәрендә. Эшләүчеләр саны 127 кеше.

1 нче төркем урманнар 28868 *га* мәйданны били, ш.и. эрозиягә каршы урманнар — 403 *га*, аеруча саклаулы терр-ялар — 287 *га*, уылдык чәчү урыннарын саклаучы урман полосалары — 1760 *га*, юл буйларында ышыклау полосалары — 21458 *га*, кыр ышыклаучы һәм туфрак саклаучы урманнар — 4486 *га*, 2 нче төркем, ягъни җирле әһәмияткә ия урманнар 4824 *га*. Урман культураларының мәйданы 10086 *га*. Яшь урманнар 25%, урта яшьтәгеләре — 48%, өлгереп килүчеләре — 14%, өлгергәннәре һәм картайганнары 13% ны тәшкил итә. Ылыслы урманнар 7960 *га* мәйданда: нарат — 7086 *га*, чыршы — 652 *га*, карагай — 212 *га*, эрбет утыртмалары 10 *га*. Ылыслы токымнарның гомуми агач запасы 1,6 млн. *м*³. Каты яфраклы токымнар 6687 *га* мәйдан били, шуның 90% ка якыны имән урманнары алып тора. Гомуми агач запасы 0,7 млн. *м*³. Йомшак яфраклы урманнар (юкәлекләр, каенлыклар, усаклыклар, зireклек-

ләр һ.б.) 16961 *га*, агач запасы 3,4 млн. *м³*. Питрәч урманчылыгында Мишә елгасының уңъяк ярында «*Иске тегермән*» табигать тыюлыгы урнашкан. Биредә үсемлек һәм хайваннарның сирәк төрләре очрый. Кеше тарафыннан утыртылган ылыслы урманнар Ленино-Кокушкино табигый-тарихи тыюлыгы составына кертелгән. Төп кулланылыш өчен еллык урман кисү күләме 18,5 мең *м³*. Урманны карау максатыннан 713 *га* мәйданда чистарту эшләре алып барыла, ш.и. 235 *га* мәйданда яшь урманнар карала, нәтиҗәдә 10,8 мең *м³* агач әзерләнә. 100–115 *га* мәйданда урман торгызу эшләре башкарыла. Ел саен юл буйларында саклагыч урман полосалары, ш.у. бозылган җирләрдә урман культуралары утыртыла. Урман питомнигында 1–1,5 млн. данә утырту материалы (агач-куак үсентесе һәм чәчкене) үстерелә. Урман хуҗалыгы ярдәмче сәнәгый эшчәнлек б-н шөгыльләнә. Ел саен 865 мең сумлык товар җитештерелә.

Л.у.х. үсешенә аның 1976–2001 еллардагы директоры, ТРның атказ. урманчысы (1993) С.Е.Ячменёв зур өлеш кертә. 2007 елда Л.у.х. Лаеш урманчылыгы итеп үзгәртелә.

*В.И.Гуськов.*

**ЛАЖЕ́ЧНИКОВ** Иван Иванович (14.9.1792, Коломна ш. — 26.6.1869, Мәскәү), язучы, рус тарихи романы жанрына нигез салучыларның берсе. «Соңгы Новик» («Последний Новик», Ч. 1–4, 1831–33), «Боз йорт» («Ледяной дом», 1835), «Басурман» (1838) һ.б. романнар, «Опричник» (1843), «Көндәш әниләр» («Матери-соперницы», 1867) драмалары, повестьлар авторы. 1824 тән Казанда яши. 1825 нең сентябрь–декабрендә Казан ун-ты студентлары инспекторы, 1827 гә кадәр — Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе һәм Казан губернасы халык уч-щеләре директоры; соңыннан Мәскәүгә күчә. Язучы тормышының Казан чоры «М.Л.Магницкийны мин ничек белә идем» («Как я знал М.Л.Магницкого», 1866) очеркында чагылыш таба. Анда Л. университеттагы иҗтимагый атмосфера турында яза, Казан аксөякләренең, шәһәрнең мәдәни тормышын тасвирлый.

Ә с ә р.: Полн. собр. соч.: В 12 т. СПб.–М., 1899–1900.

*Ж.Ф.Хәкимова.*

**ЛА́ЗАРЕВ** Александр Емельянович (1815, Пенза губ. — 15.12.1877, Казан), хокук белгече, яшерен советник (1871). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1834). 1935–39 елларда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә укытучы. 1939–40 та өстәл башлыгы ярдәмчесе, 1840–43 тә Казан дәүләт мөлкәте палатасында округ башлыгы. 1843–44 тә Кавказ дәүләт мөлкәте палатасы (Ставрополь ш.) советнигы, 1844–56 да управляющие, 1856–61 дә — Минск, 1961–63 тә — Олонецк, 1963–64 тә — Владимир, 1964–66 да Курск дәүләт мөлкәте палаталары управляющие. 1866–70 тә Курск дәүләт мөлкәте губерна идарәсе башлыгы. 1870–75 тә Казан округ мәхкәмәсе, 1875 тән Казан мәхкәмә палатасының гражданнар департаменты рәисе. Казан губернасында мәхкәмә реформасы уздыруда катнаша. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе турындагы 1827–40 елларга нисбәтле истәлекләр авторы. Рус геогр. җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1851).

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Вып. 1; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛА́ЗАРЕВ** Валерий Васильевич (25.10.1940, Горький өлкәсенең Сергач р-ны Коровинка пос.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1978), проф. (1981), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1963), шунда ук (бүленеп) эшли. 1982–98 дә РФ Эчке эшләр министрлыгы академиясенең дәүләт-хокук фән. каф. башлыгы (Мәскәү). Бер үк вакытта, 1991–92 дә, РФнең юстиция министры киңәшчесе. 1998–2003 тә РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасының РФ Конституция судындагы даими вәкиле — Дәүләт Думасы хокукый идарәсе башлыгының урынбасары. 2003 тән Мәскәү юридик академиясе профессоры. Хезмәтләре дәүләт һәм хокук теориясенә, сәяси һәм хокукый тәгълиматлар тарихына, конституцион хокукка карый. Ленин комсомолы бүләге лауреаты (1972). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пробелы в праве: Вопросы понятия пробелов и критика теории беспробельности права. К., 1969; Пробелы в праве и их устранение. М., 1974; Эффективность правоприменительных актов: Вопросы теории. К., 1975; Социально-психологические аспекты применения права. К., 1982.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛА́ЗЕР НУРЫНДА́ ЧЫНЫКТЫРУ́**, импульслы көчле лазер нурланышы тәэсирендә каты җисемнәрне тиз арада бирелгән юнәлештә кристаллаштыру күренеше. 1973 елда СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-тында ачыла (И.Б.Хәйбуллин, Е.И.Штырков, М.М.Зарипов, М.Ф.Галәветдинов, Р.М.Баязитов).

Баштарак «Л.н.ч.» термины ярымүткәргечнең легирлаучы катышманы ионлы имплантацияләү барышында тәртибе үзгәргән юка (калынлыгы 1 *мкм* дан ким) өслек яны катламының кристаллик структурасын яңадан торгызуны аңлаткан. Технол. алым буларак, Л.н.ч. микроэлектроникада киң кулланыла торган термик чыныктыруга альтернатива буларак эшләнә. Соңгысы ярымүткәргеч кристалларга ионлы катышмалар кертелгәннән соң дефектларны төзәтү һәм имплантант катышманы электрик яктан активлаштыру өчен кулланыла.

Киңрәк мәгънәдә Л.н.ч. — каты җисемнәрнең (ярымүткәргечләр, металлар, диэлектриклар) өслек яны катламнарында импульслы яки өзлексез лазер нурланышы тәэсирендә төрле структур һәм фаза әверелешләре ясауны аңлата. Л.н.ч. материалларны электромагнитик дулкыннар, электроннар, ионнарның көчле бәйләмнәре ярдәмендә импульслы модификацияләүнең фәнни юнәлеше һәм технологиясе нигезенә салына.

Лазер нурланышы импульсы озынлыкларының киң диапазоны өчен ярымүткәргечләрне һ.б. материалларны Л.н.ч.ның төп механизмы җылылык б-н бәйләнгән. Җылыту дәрәҗәсенә бәйле рәвештә (бу дәрәҗә нурланыш егәрлегенең тыгызлыгы, нурланыш вакыты, материалның оптик һәм җылылык үзлекләре б-н билгеләнә), Л.н.ч. 2 режимда үткәрелә: сыеклык фазасында һәм каты фазада кристаллаштыру. Термик чыныктыру б-н чагыштырганда, Л.н.ч.ның өстенлекләре һәм уникаль мөмкинлекләре сыеклык фазасында тиз арада кристаллаштыру режимында, куәтле лазер нурланышын импульсларның наносекундлар диапазонында кулланган очракта тулырак чагыла. Ярымүткәргечләрне наносекундларда, Л.н.ч. өслек яны катламын үтә тыгыз электрон-тишемле плазма ($10^{21}$ *см⁻³* кадәр) генерацияләү шартларында көчле ($10^{12}$ *град/с* ка кадәр) кыздыру б-н бара, һәм бу хәл бериш тотрыклы яки метастабиль эретелмәләрнең тиз эрүенә һәм аннан соң кристаллашуына китерә.

Эретелмәнең каты хәлгә килү фронтының хәрәкәт тизлеге кристаллашу, дефектлар хасил булу, кристаллик рәшәткәгә катышма атомнарының урнашуы процессында хәлиткеч роль уйный.

Физика-техника ин-тында И.Б.Хәйбуллин җитәкчелегендә 1973 тә башланып киткән тикшеренүләр нәтиҗәсендә Л.н.ч. вакытындагы төп физик процесслар өйрәнелә һәм аларның үзенчәлекләре ачыклана. Л.н.ч. алымы нигезендә, микроэлектрон приборлар төзү өчен күп кенә технол. яңалыклар тәкъдим ителә. 1975 тән Л.н.ч.ны күпьяклы тикшерүләр СССР ФАнең Себер бүлеге Ярымүткәргечләр физикасы ин-тында (Новосибирск ш.) Л.С.Смирнов җитәкчелегендә, 1982 дән СССР ФАнең А.Ф.Иоффе исем. Физика-техника ин-тында (Ленинград) акад. Ж.И.Алфёров җитәкчелегендә башланып китә.

Ионлы имплантация буенча СССР-АКШ 1 нче уртак семинарында (АКШның Олбани ш., 1977) совет галимнәре бәян иткән нәтиҗәләр дөньяда Л.н.ч. өлкәсендә күпкырлы тикшерүләр башлауга һәм төрле фәнни үзәкләрнең тырышлыгын берләштерүгә сәбәп була.

1980 еллар ахырына ярымүткәргеч катламнарын импульслы яктылык б-н эшкәртү проблемалары буенча 1 меңнән артык хезмәт басылып чыга һәм берничә зур халыкара конференция һәм симпозиум үткәрелә. Ярымүткәргеч материалларга диффузияле һәм вакуум-утырымлы катламнар модификацияләре (1978), шулай ук пикосекундлы лазерлар куллана торган нурланыш чыганаклары паркы (1979) кергән хәлиткеч мәсьәләләр саны да арта. Л.н.ч.ның берничә физик моделе, ш.и. плазмалы (термик булмаган) моделе тәкъдим ителә.

Казан физика-техника ин-ты һәм Ярымүткәргечләр физикасы ин-тының уртак тикшеренүләре нәтиҗәсендә нурланыш тәэсирендә ярымүткәргечләрнең структур трансформациясе өйрәнелә һәм дефектларсыз үсешле эпитаксиаль катламнар алу шартлары табыла.

Л.н.ч. вакытында җылылык һәм масса күчеше мәсьәләләрен чишү нигезендә, катышма концентрациясенең фәзада бүленеп ур-

нашуы теоретик яктан фаразлана һәм аномалияләр катышмаларның кристаллда эрү дәрәҗәсенә бәйләп аңлатыла. Мәскәү ун-ты һәм Белоруссия ССР ФАнең Электроника ин-ты б-н бергә алып барылган эшләр — фаза күчешләре динамикасын оптик зондлау кулланып тикшерүләр нәтиҗәсендә теория тәҗрибәләрдә раслана, шул ук вакытта кристалл эрүнең тигезләнеш нокталарына карата 10–15% ка түбән булган темп-раларда кыска вакытлы ($10^{-8}$ *с* аралыгында) метастабиль эретмә барлыкка килүе ачыклана.

Наносекундлы Л.н.ч. б-н беррәттән, тәртибе югалган ярымүткәргечләрнең миллисекунд-секунд аралыгында дәвам итә торган яктылык импульслары тәэсирендә каты фазалы кристаллашуы да өйрәнелә. СССРның әйдәп баручы микроэлектроника үзәкләре б-н бергә алып барылган тикшерү нәтиҗәләре импульслы лампалар нурланышы б-н чыныктыру җайланмаларын сәнәгый җитештерүне башларга мөмкинлек бирә. Әлеге алым микроэлектроника пр-тиеләрендә интеграль микросхемаларда имплантант керткәннән соң чыныктырылган, яхшы легирланган катламнар булдыру, юка элпәле капламнарны тыгызлау, контактларны яндырып эчкә кертү, өслекнең микрорельефын тигезләү һ.б. өчен кулланыла.

Тәэсир итү урынының төгәллеге, процессның кыска вакытлы булуы, яңа кушылмалар синтезлау, катышмалар диффузиясен минимальләштерү һ.б. технол. мөмкинлекләр аркасында импульслы тәэсир итүләр микро- һәм наноэлектроника приборларын уйлап табуда һәм җитештерүдә киң файдаланыла.

СССР ФАнең Казан ф-лы Физика-техника ин-ты (И.Б.Хәйбуллин, Е.И.Штырков, М.М.Зарипов, М.Ф.Галәветдинов, Р.М.Баязитов), СССР ФАнең Себер бүлеге Ярымүткәргечләр физикасы ин-ты (Л.С.Смирнов, Л.Н.Александров, Г.А.Качурин, А.В.Двуреченский), СССР ФАнең А.Ф.Иоффе исем. Физика-техника ин-ты (Ю.В.Ковальчук, О.В.Погорельский) һәм П.Н.Лебедев исем. Физика ин-ты (Ю.В.Копаев) галимнәренә Л.н.ч.ны ачкан һәм бу өлкәдәге тикшеренүләре өчен СССР Дәүләт бүләге бирелә (1988).

*Әд.:* Локальный лазерный отжиг ионно-легированных полупроводников // Физика и техника полупроводников. 1975. Т. 9, № 10; Импульсный отжиг полупроводниковых материалов. М., 1982; Модифицирование и легирование поверхности лазерными, ионными и электронными пучками. М., 1987.

*Р.М.Баязитов.*

**ЛАЗЬКО́** Валентина Андреевна (23.2.1918, Рязань ш.), вокал буенча педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970). 1952 елда Казан консерваториясен (К.Цветов классы) тәмамлый; 1958–83 тә шунда ук укыта (1971–73, 1981–82 дә ялгыз җырлау каф. мөдире). Л.ны педагог буларак югары профессионализм, репертуарны тирән белүе, классик вокаль мәктәбенең яхшы традицияләренә таяну сәләте аерып тора. Шәкертләре арасында — С.Аскаров, Р.Башаров, Л.Башкирова, В.Ганиева, В.Гыйззәтуллина, Х.Гыйниятова, С.Җиһанова, В.Пахомова, Т.Перепелица, Ю.Прокопьева, С.Рәинбәков, З.Сөнгатуллина, Э.Трескин, Р.Үзбәкова, А.Фадеичева, К.Хәйретдинова, Л.Хохлова.

*Әд.:* Вокальный факультет // Казанская государственная консерватория. К., 1998.

**ЛАЙ́СОВ** Наип Хәбибназар улы (10.8.1935, Актаныш р-ны, Түбән Яхшый а.), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1970), проф. (1996), ТРның атказ. укытучысы (1993). 1962 дә Алабуга пед. ин-тын (2003 тән Алабуга пед. ун-ты) тәмамлагач, шунда ук укыта. 1971–80 елларда декан урынбасары, филол. ф-ты деканы, 1980–89 да проректор, 1989–2000 дә ректор, бер үк вакытта 1994 тән татар филологиясе каф. мөдире, 2000 нән әдәбият каф. мөдире. Хезмәтләре Г.Тукай иҗатына, 20 йөз башы татар поэзиясе, рус-татар әдәби багланышлары, Г.Тукай әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Әдәбият теориясе. К., 1979 (автордаш); Лирика Тукая (вопросы метода и жанра). К., 1976.

**ЛАЙ́ШЕВ** Әнвәр Хафиз улы (2.6.1927, Мордва Респ-касы Краснослободский р-ны Байки а.), эпизоотолог; төньяк боланнар авырулары белгече, вет. фән д-ры (1977). 1952 елда Ленинград вет. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1956 дан Ерак Төньяк а.х. фәнни тикшеренү ин-тында (Норильск ш.), 1957–66 да вет. бүлеге мөдире, 1966–71 дә Мурманск боланнар станциясендә фәнни эшләр буенча директор урынбасары, директоры. 1979–80 дә мөгезле эре терлек авыруларын өйрәнү лаб-ясе мөдире, 1980 нән вет. бүлеге мөдире, бер үк вакытта төньяк боланнары бруцеллёзын өйрәнү лаб-ясе мөдире. Дөнья ветеринариясе өлкәсендә беренче булып төньяк боланнарында спонтан һәм экспериментал некробактериоз вакытында очлыкларның дисталь бүлегендәге сөяк-буын патологиясенә рентген тикшерүләре үткәрә, буыннар некробактериозын дәвалауның комплекслы ысулын эшли.

Х е з м.: Некробактериоз северных оленей. Якутск, 1971 (автордаш); Болезни северных оленей. М., 1980 (автордаш).

**ЛАЙЛА́Ч ГӨМБӘЛӘ́Р**, м и к с о м и ц е т л а р (Myxomyceta) (грек. mýxa — лайла һәм mýkēs — гөмбә), гөмбәсыман организмнар тибы яки бүлеге. 500 гә якын төре билгеле. Хлорофиллның булмавы, күпчелек Л.г.нең үрчү органнары барлыкка килү, сапрофит (кайберләре — паразит) яшәү рәвеше буенча гөмбәләргә охшаш; амёбасыман актив хәрәкәт аларны хайваннар б-н якынайта. Күп төшле цитоплазма масса рәвешендәге вегетатив гәүдәсе — плазмодия ачык (лимондай сары, алсу, кызыл, шәмәхә) төстә. ТР терр-ясендә һәр җирдә таралган. Таркала баручы коелган яфракларда яки чери торган агач кәүсәләрендә, туфракта, тирестә яшиләр. Сапрофит Л.г.нең гамәли әһәмияте юк. Кайбер паразит Л.г. а.х.на зыян китерәләр, мәс., кәбестә плазмодиофорасы (Plasmodiophora drassicae) әвернә чәчәкләләр авыруын китереп чыгара; бәрәңгедә порошоксыман кутыр авыруы сәбәпчесе спонгоспора (Spongospora solani) бүлбеләрне, тамырны һәм паслёнчалар семьялыгындагы башка төрләрне дә зарарлый.

**ЛАЙЛАЧЛА́Р**, кабырчыклары өлешчә яки бөтенләй беткән, нигездә, сабакчалы күзлеләр отрядыннан җирдә яшәүче үпкә корсагаяклы моллюскларның җыелма төркеме. Кабырчыклары сизелеп торса да, гәүдәне тулысы б-н сыйдырып бетермәгәнлектән, еш кына бу әкәм-төкәмнәрне ярымлайлачлар дип йөртәләр. Л.ның гәүдәсе суалчан-яки цилиндрсыман. Шуышып барганда озынлыгы 15–20 *см* га кадәр җитә, Татарстанда очраучы төрләр, гадәттә, 5–6 *см* дан озын түгел. Л.ның аркасы ягында аерым бер урынны мантия алып тора. 250 дән артык төре билгеле, Россиядә — 100 төр тирәсе, Татарстанда 10 нан артык. Күләгәле яфраклы урманнарда, дымлы болыннарда һәм кеше тарафыннан булдырылган яхшы дымланучы урыннарда яшиләр. Төнлә активлар, көндез ышыкка посалар. Аеруча киң таралган үсемлек б-н тукланучы формалар агриолимацид (Agriolimacidae) һәм лимацидлар (Limacidae) семьялыкларына керә. Яшь утыртмаларга һәм а.х. культураларына кыр Л.ы (Deroceras agreste), челтәрсыман Л. (D. Reticulatum), (Arion bourguignati) һ.б. зыян китерергә мөмкин. Үсемлек б-н тукланучы урман Л.ы агачлардагы лишайниклар (Limax arborum), гөмбәләр (Arion subfuscus), дымлы биотопларлардагы суүсемлекләр, ерткыч Л. — нигездә туфрак суалчаннары, ш.у. моллюскларның башка төрләре б-н тукланалар.

*Әд.:* Л и х а р е в И.М., Р а м м е л ь м е й е р Е.С. Наземные моллюски фауны СССР. М.–Л., 1952; Л и х а р е в И.М., В и к т о р А.И. Слизни фауны СССР и сопредельных стран (Gastropoda terrestria nuda). Л., 1980; Жизнь животных. М., 1988. Т. 2.

*Р.М.Сабиров.*

**ЛАЛӘ́** (Lilium), лаләчәләр семьялыгыннан суганчалы күпьеллык үсемлекләр ыругы. 90 нан артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 2 төре: кырпулы Л. (L. pilosiusculum) һәм сарана Л. (L.martagon) бөтен районнарда да очрый. Киң яфраклы һәм наратлы-киң яфраклы урманнарда үсә. 50–150 *см* биеклектәге үсемлек.



Сарана лалә.

Сабагы туры, яфраклар б-н капланган. Яфраклары чиратлашкан, кыяк яки кыяк-ланцетсыман. Чәчәкләре эре, төрле төстә, күпчелеге тимгелле, хуш исле, чалма-чуксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — капкачларда ачылучы өч оялы озынча тартмачык, көрән төстәге яссы эре орлыклы. Июнь–июльдә чәчәк ата. Вегетатив юл (суганча кабырчыкларыннан, суганча бәбиләрдән), сирәк кенә орлыктан үрчи. Суганчасы алтынсу-сары, ялангач, итчел сусыл кабырчыклы. Культурада 3,5 меңгә якын бакча формалары чыгарылган. Баллы үсемлек. Сарана Л. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЛАЛӘЧӘЛӘ́Р** (Liliaceae), бер өлешле үсемлекләр семьялыгы. Суганчалы күпьеллык үләнчел үсемлекләр. 10 га якын ыруг һәм 470 кә якын төре билгеле, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында таралган. ТР терр-ясендә 4 ырукга караучы 8 төре билгеле: *лалә, каз юасы, шадра үлән, тюльпан*. Яфраклары чиратлашкан, озынча, ланцетсыман яки кыяклы, бөтен читле. Чәчәкләре төрле зурлыкта, чук, башак яисә чатырсыман чәчәк төркемендә, сирәк кенә ялгыз (тюльпан). Чәчәк тирәлеге гади, таҗсыман; 6, сирәк кенә 4–8 аерым яки кушылган таҗ яфракчыклары ике әйләнәгә урнашкан. Җимеше — тартмачык яисә ачык төстәге җиләк. Орлыклары яссы яки шарсыман. Л. арасында азык (каз юасы), декоратив (лалә, тюльпан, шадра үлән) һәм баллы (каз юасы, лалә) үсемлекләр аерымлана. Шахматсыман шадра үлән, рус шадра үләне, бөртекле кыр суганы (каз юасы), сарана лалә, урман тюльпаны ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЛАМБЕ́РОВ** Александр Адольфович (1.1.1958, Свердловск өлкәсенең Березовский ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2002), проф. (2009). 1982 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 2001 дән Казан химия фәнни-тикшеренү ин-ты лаб-ясе башлыгы. 2002 дән Казан ун-тында, физик химия каф. профессоры. Хезмәтләре нәорганик химия, гетероген катализ, нефтехимия мәсьәләләренә карый. Элементорганик лигандалы комплекслы палладий кушылмалары төзелешен һәм үзлекләрен өйрәнә, синтезлый. Алюминийның актив оксиды синтезын һәм аның нигезендә катализаторлар технологиясен эшли. Нефть химиясе сәнәгате өчен гидрочистарту, селектив гидрирлау һәм дегидрирлау (водородны аеру) катализаторларын тәкъдим итә («Түбәнкаманефтехим» АҖдә, «ЮКОС» компаниясенең нефть эшкәртү з-дларында кулланугa кертелә). Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Нетрадиционный подход к синтезу оксидов ряда переходных металлов // Журн. прикладной химии. 1997. Т. 70, вып. 5; Investigation of acid-dase sites on the surfase of eletrochmicaly sensitized aliminium oxides // Journal of Molecular Catalysis. A: Chemical. 2000. V. 158, № 1.

**ЛА́ММЕРТ** Виль (5.1.1893, Хаген ш., Германия — 30.10.1957, Берлин), сынчы. Гамбург һәм Париж студияләрендә укый (1911–13). Эссен (1922 дән), Париж (1933), Мәскәү (1934 тән), Казанда (1941 дән) эшли. Портрет һәм мемориаль скульптура остасы. Казанда яшәгән вакытта гипстан иҗат иткән тематик скульптуралар композицияләре: «Фашизм» (1943), «Горький Казандагы икмәк кибете хуҗасы Семёновта» (1946), «Революция» (1947), «Татар крәстиян хатыны» һәм «Татар эшчесе» (икесе дә — 1947), ш.у. Казан Зур драма т-ры фойесы өчен К.С.Станиславский, В.И.Немирович-Данченко, В.И.Качалов, Л.П.Милова һ.б.ның портрет бюстларын (барысы да — гипс, 1950) ясый. Казандагы Татар опера һәм балет т-ры бинасында күпертеп ясау техникасы б-н рельефлы



В.Л а м м е р т. «Горький Казандагы икмәк кибете хуҗасы Семёнов янында». Гипс. 1946. А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музее. Казан.

бизәк төшерә (1951). Равенсбрюкта фашизм корбаннарына багышланган һәйкәл авторы (бронза, 1956–59). Германия сәнгать академиясе әгъзасы (1952), ГДР Милли бүләге лауреаты (1959).

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; Will Lammert. Dresden, 1963.

**ЛА́НГЕ** Иван Николаевич (1845, Варшава — 1912, шунда ук), вет. микробиологы, вет. фән. магистры (1873). Казан вет. фәнни мәктәбенә нигез салучыларның берсе. 1870 елда Петербург мед.-хирургия академиясенең вет. бүлеген тәмамлый. 1874 тән Казан вет. ин-ты профессоры, 1881–1906 да директоры. 1908–12 дә Варшава вет. ин-ты директоры. Хезмәтләре күшәүче хайваннарның йогышлы авыруларын, мөгезле эре терлекләрдә чума, котыру, сап, туберкулёз, Себер түләмәсен өйрәнүгә карый. Л. илнең төрле төбәкләрендә эпизоотияләрне бетерүдә катнаша. Себер түләмәсенә каршы вакцина (*Ланге вакцинасы*) эшли, аны куллану Россиядә хайваннарны вакцинацияләүнең беренче тәҗрибәсе була һәм Казан галимнәренең бу өлкәдәге өстенлеген билгели. Л.ның Казан вет. ин-ты б-н җитәкчелек итү дәверендә яңа бина, бактериологик станция төзелә, китапханә ачыла, «Учёные записки Казанского ветеринарного института» басмасы булдырыла, ярлы студентларга ярдәм фонды оештырыла. Уңыш булмаган 1890 елларда аның тырышлыгы б-н Казан губернасы өязләрендә крәстияннәрнең эш терлекләрен тукландыру пунктлары ачыла. 3 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 һәм 2 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бактериологические данные для диагностики заразных болезней животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1893. Т. 10.

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993.

**ЛА́НГЕ ВАКЦИ́НАСЫ**, Себер түләмәсен кисәтә торган препарат. 1890 елда Казан вет. ин-тында И.Н.*Ланге* тарафыннан эшләнә. Anyhracis вакцинасының Пастер алымы б-н көчсезләндерелгән тере капсула тәшкил итүче варианты. Ланге 1 һәм Ланге 2 дәрәҗәләрендә көчсезләндерелә. Вакцина Ланге 1 штаммын кертүдән гыйбарәт, ул Ланге 2 не кертү б-н иммунитет нигезен булдыра. 1920 елларга кадәр ел саен ревакцинация үткәреләп килә. Л.в. а.х. терлекләренең барлык төрләренә, бигрәк тә атларга (елга берничә мең баш терлеккә), аеруча Россиянең Үзәк, Идел буе, Себер һәм Ерак Көнчыгыш губерналарында, ш.у. рус-япон һәм Беренче бөтендөнья сугышлары чорларында хәрәкәттәге армия атларына ясау өчен киң кулланыла.

*Р.Г.Госманов.*

**ЛА́НДЫШ**, э н җ е ч ә ч ә к (Convallaria), ландышчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бер төре — май Л.ы (C. majalis) билгеле. Евразия һәм Төньяк Американың уртача поясында таралган. ТРның барлык районнарында очрый. Нарат урманнарында, киң яфраклы урманнарда, куаклар арасында, урман аланнарында үсә. Тамырчасы нәзек, шуышма, күп тамырлы. 15–25 *см* биеклегендә, берьеллык үсентеләре озын сабаклы 2–3 тамыр яны яфраклы. Чәчәкләре ак, хуш исле, шарсыман-кыңгыраулы, берьяклы нәфис чукка җыелган. Җимешләре — кызгылт-сары яки кызыл, өч оялы 2–8 орлыклы сусыл җиләк. Майның икенче яртысында – июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Вегетатив ысул б-н (җәелеп үскән тамырчадан), ш.у. орлыктан да үрчи. Дару үсемлеге. Л.ның барлык өлешләрендә йөрәк гликозиды, сапонин, эфир мае, органик к-талар бар. Бу үсемлектән ясалган дарулар йөрәк эшчәнлегенең кискен һәм хроник бозылуы, невроз вакытында кулланыла.



Май ландышы.

Чәчәкләре парфюмериядә файдаланыла. Декоратив, агулы үсемлек. Л.ның ак һәм алсу катмарлы бакча формалары чыгарылган. Саклауга мохтаҗ.

**ЛАНЦО́В** Владимир Михайлович (2.11.1940, Казан), физик, химия фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1963 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1970 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында: физика каф. мөдире (1972–83), проректор (1989–95), менеджмент каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре полимерлар физикасына, химик физикага, менеджмент мәсьәләләренә карый. Л. ТМР импульс ысулы б-н челтәрсыман полимерларның топологик төзелешен өйрәнә, челтәрсыман полимерлар хасил итү процессында бериш булмаган структура формалашуга төрле химик реакцияләрнең (поликонденсатлаштыру, полимерлашу һ.б.) тәэсир үзенчәлекләрен ачыклый. Реаль менеджмент турында фәнни нигезләнгән төшенчәләр, автоматлаштырылган идарә итү

өлкәсендә техник фәннәрнең объектив законнарына һәм казанышларына нигезләнеп, җәмгыятьтә идарә итү һәм үзидарә нигезләрен эшли. Макроикътисади системалар төзелешен һәм үзенчәлекләрен модельләү, исәпләү, фаразлауның төп алымнарын тәкъдим итә. Республикада торак төзелеше үсеше программасын эшләүдә, ТРда һәм илнең башка төбәкләрендә торак төзелеше буенча күп кенә инвестицион проектларны тормышка ашыруда катнаша. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Жилищно-коммунальное хозяйство: основа теории и критический анализ российского опыта. К., 2008 (автордаш); Ростовщичество и лихва в кредитных договорах и финансовой политике. К., 2009 (автордаш); Гражданская инициатива: Почему и как надо изменить закон об ипотеке. К., 2010 (автордаш).

**ЛА́ПИН** Александр Васильевич (6.2.1950, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли, матем. анализ проблемалары лаб-ясе мөдире (1980–85), матем. статистика каф. профессоры (1992 елдан), бер үк вакытта Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (2001 дән), исәпләү математикасы бүлеге мөдире.

Хезмәтләре тоташ тирәлек механикасында нәсызыкча процессларны матем. модельләштерүгә, чикләре ирекле булган мәсьәләләрнең санлы анализына, оптимальләштерү алымнарына карый. Л. нәсызыкча операторлы-аермал схемаларының корректлылыгы теориясен эшли һәм аны нәсызыкча параболик мәсьәләләрне чишүдә куллана; нәсызыкча ярымкоэрцитив операторлы вариатив тигезсезлекләрнең чишелешләре булу һәм аппроксимациясе мәсьәләләрен тикшерә; берничә күп мәгънәле операторлары һәм М-матрицалары булган соңгы үлчәнешле кертелмәләр өчен итерацион алымнар төзи һәм нигезли.

Х е з м.: Сеточные аппроксимации вариационных неравенств. К., 1984; Методы типа релаксации для суммы квадратичного и выпуклого функционалов // Изв. вузов. Математика. 1993. № 8; Численные методы в задачах и упражнениях. М., 2000 (автордаш).

**ЛА́ПИН** Трофим Якимович, к. 708 б.

**ЛА́ПИНА** Мөслимә Шәйхи кызы (12.12.1941, хәзерге Яшел Үзән р-ны Норлат а.), агроном-селекционер. 1974 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, өлкән фәнни хезмәткәр. «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт учреждениесенең ТР ф-лында күпьеллык үләннәр буенча әйдәп баручы белгеч. Хезмәтләре терлек азыгы культуралары селекциясе мәсьәләләренә карый. Люцерна селекциясе б-н шөгыльләнә; җитештерүдә куллануга тәкъдим ителгән 3 сорт авторы: «Айсылу» (1990), «Татарская пастбищная» (2000), «Мөслимә» (2002). Люцерна орлыкчылыгы буенча уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.


Х е з м.: Выявление селекционного потенциала исходных родительских форм при создании синтетического сорта люцерны // Селекция и семеноводство сельскохозяйственных культур в Татарской АССР. К., 1984; Результаты селекции люцерны // Кормопроизводство. 2001. № 2; Практические рекомендации по возделыванию и использованию многолетних трав в Республике Татарстан. К., 2001.

**ЛА́ПТЕВ** Анатолий Григорьевич (30.3.1953, Казан), химия аппаратлары төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), проф. (1997). 1978 елда Казан. химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, хисаплау үзәгендә ЭВМнар башлыгы (1980–84), инженерлык графикасы каф. мөдире (1997–2001). 2001 дән Казан энергетика ун-тында су һәм ягулык технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре химия технологиясе аппаратларын матем. модельләштерүгә һәм проектлаштыруга карый. Л. ике фазалы күп компонентлы тирәлекләрдә масса һәм җылылык алмашуны сурәтләүнең теоретик алымнарын, яңа контактлы элементлар, югары нәтиҗәле аппаратлар, химия, нефть һәм газ эшкәртү тармаклары өчен технол. схемалар (ректификация, абсорбция, экстракция, газлар һәм сыеклыкларны чистарту процесслары) эшли. Технологик җайланмаларны төзү һәм яңартып кору өчен проектлар тәкъдим итә (ТР һәм РФнең нефть һәм газ чыгару сәнәгатендә кулланыла). Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Теоретические основы и моделирование процессов разделения веществ. К., 1993 (автордаш); Проектирование и модернизация аппаратов разделения в нефте- и газопереработке. К., 2002 (автордаш); Устройство и расчёт промышленных градирен. К., 2004 (автордаш).

**ЛА́ПТЕВ** Борис Лукич (23.4.1905, Казан — 15.1.1989, шунда ук), математик, геометр, физика-матем. фән. д-ры (1959), проф. (1962), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1965, 1975). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), шунда ук эшли, геометрия каф. мөдире (1944–45), физика-матем. ф-ты деканы (1951–58), Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (1961–80), геометрия каф. проф.-консультанты (1980 нән).

Хезмәтләре гомумиләштерелгән фәзаларның дифференциаль геометриясенә һәм математика тарихына карый. Л. таяну элементлары фәзасы теориясен эшли һәм анда Ли дифференциясе аппаратын үстереп, аның төрле мәсьәләләр чишүдә кулланылышын күрсәтә; күрсәтелгән фәзаларда дифференциаль инвариантлар, бәйлелекләр, кәкрелек теорияләрен эшли, ковариант дифференциаллауны күрсәтеп бирә. Л. — Казан ун-ты математик галимнәренең эшчәнлеген популярлаштыручы, Н.И.Лобачевскийның 150 еллыгына басылып чыккан фәнни биография авторы, аның хезмәтләренең тулы җыентыгын нәшер итүне оештыручы, Казан ун-тында ел саен «Лобачевский укулары» конференцияләрен үткәрүне башлап йөрүче һәм аларның җитәкчесе. Яңа — Лобачевский геометриясе ачылуга багышланган «Бишенче постулат серләре» («Загадки пятого постулата») кинофильмын эшләгәндә фәнни консультант буларак катнаша. «Белем» җәмгыяте лекторы буларак, халык арасында зур популярлык казана. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, СССР ФАнең П.Л.Чебышев исем. медале б-н бүләкләнә.




Б.Л. Лаптев.

Х е з м.: Пространство опорных элементов // Тр. 4 Всесоюз. мат. съезда. 1964. Т. 2; Дифференцирование Ли / ВИНИТИ // Итоги науки. Алгебра. Топология. Геометрия. 1965. М., 1967; Альтернированная производная Ли в пространстве опорных элементов с геометрическим опорным объектом // Изв. вузов. Математика. 1972. № 12; Николай Иванович Лобачевский. К., 1976.

*Әд.:* Научное наследие Бориса Лукича Лаптева // Итоги науки и техники. Проблемы геометрии. 1989. Т. 21; Профессор Борис Лукич Лаптев (глазами учеников и друзей). К., 1992.

**ЛА́ПТЕВ** Владимир Лукич (5.4.1902, Казан — 9.12.1963, шунда ук), нәкышьче, график, бизәүче-рәссам. Казан архит-ра-сәнгать остаханәләрен тәмамлый (1925). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1944). Л. 1930–40 елларда монументаль һәм станлы нәкышь, гамәли һәм станлы графика, газета-журнал графикасы, бизәү сәнгате һәм дизайн өлкәсендә Татарстанның сынлы сәнгатен үстерүгә күп көч куя. Рәссамның монументаль хезмәтләре арасында — «Совет авылы. Уңыш җыю» дивар нәкыше (1924–25), «Кузбасс күмер сәнәгатенә эшчеләр яллау» панносы (1939) (икесе дә сакланмаган). Көнкүреш темаларына станлы нәкышь композицияләре («Татарлар көнкүрешеннән», 1924; «Җиләк-җимеш сатучы татар», 1925; «Мех фабрикасы. Тире эшкәртү», 1930 һ.б.), пейзажлар («Гөмбәгә бару», 1954; «Сүрән көн», 1957 һ.б.), натюрмортлар («Алмалар. Натюрморт», 1927) иҗат итә. График-рәссам буларак, 1923 елдан «Красная Татария», «Новая деревня» г-талары, «Причал», «Пролетарий Татарстана» ж-лары б-н хезмәттәшлек итә. Татарстан китап нәшрияты өчен плакатлар, календарьлар һ.б. төр полиграфия продукциясенә эскизлар әзерли. Офорт техникасында Казанның архит-ра пейзажлары (1920 еллар), «Абый портреты» (1924), «Шәһәр» (1925) һ.б. линогравюралар авторы. 1930 елларда өс, аяк киемнәре, савыт-саба, татар халык орнаменты элементлары кергән бизәкләр модельләрен проектлый (1937 дә Парижда узган Халыкара күргәзмә өчен эскизлар), Татпромсовет өчен уенчыклар модельләрен проектлаштыру б-н шөгыльләнә (1939), урамнарны бәйрәмчә бизәү эскизларын иҗат итә (1940 еллар). ТАССР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) өчен тарихи темаларга картиналар циклы яза: «Безнең як җирләрендә б.э.к.


Н.Н.Лаптев.


Г.Ф.Ларионов.


7–2 йөзләрдә кабиләләр көрәше» (1941), «Борынгы Болгар. 14 йөздә шәһри Болгарның үзәк мәйданы» (1941), «Ибне Фазлан Иделдә» (1945–48), «Татар ханы янында» (1949) һ.б.

Республика — ТАССР рәссамнары (Казан, 1925–57); халыкара — «Хәзерге заман тормышында сәнгать һәм техника» (Париж, 1937); Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы көннәрендә ТАССР рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1957) күргәзмәләрендә катнаша. Хезмәтләре ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.







В.Л.Лаптев. 1. «Татар орнаменты». Эскиз. Кәгазь, гуашь. 1940 еллар; 2. «Казандагы Елга аръягы эшчеләренең баш күтәрүе. 3.09.1918 ел». 1949; 3. «Багдад илчесенең Болгарга килүе». 1949.

**ЛА́ПТЕВ** Николай Николаевич (17.5.1958, Кемерово ш.), альтчы, педагог, ТРның халык артисты (2010). 1981 елда Казан консерваториясен (С.Басовский классы) тәмамлый. 1991 дән шунда ук укыта, бер үк вакытта 1995 тән шул ук уку йорты каршындагы махсус урта музыка мәктәп-көллиятендә. Солист, ансамблист һәм оркестр музыканты буларак, концерт эшчәнлеге алып бара. 1979–95 тә Татар филармониясенең симф. оркестры артисты, 1995–96 да Татар опера һәм балет театры, 1996 дан «La Primavera» камера оркестры артисты. Россиядә һәм чит илләрдә (Швеция, Франция, Швейцария һ.б.) чыгышлар ясый. Репертуарында, башлыча, классик һәм хәзерге заман альт репертуары әсәрләре (В.Телеманның оркестр б-н альт өчен Концерты, В.А.Моцартның Es-dur һәм A-dur оркестры б-н скрипка һәм альт өчен Симфоник концерты, П.Хиндемитның оркестр б-н альт өчен «Матәм музыкасы» һ.б.); Й.Гайдн, В.А.Моцарт, Л.Бетховен, Р.Шуман, П.Чайковский, Дм.Шостакович, С.Прокофьев, С.Гобәйдуллинаның квартет әсәрләрендәге альт партияләре һ.б. Альт, кыллы квартет, кыллы һәм камера оркестрлары өчен күчермәләр авторы һ.б.

**ЛА́ПТЕВА** Людмила Ивановна (19.2.1954, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (2001), проф. (2004). 1976 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1994 тән Казан төзелеш-архит-ра ун-тында. Хезмәтләре фосфор, мышьяк, Д.И.Менделеевның периодик системасындагы 5 нче төркемдә аларга охшаш матдәләрнең органик кушылмалары термохимиясенә карый. Эксперименталь термохимик күрсәткечләргә таянып, бу кушылмаларның төзелеше һәм реакциягә керү сәләтенең теоретик нигезләрен эшли. Тикшеренү нәтиҗәләре билгесез (яки тәҗрибә шартларында табып булмый торган) биохимик объектларның (аксымнар, аминокислоталар һ.б.) термохимик һәм термодинамик сыйфатларын фаразлауда кулланыла.

Л. коммуналь энергетика системаларында су әзерләү өчен агулы булмаган фосфорорганик комплексонат тәкъдим итә.

Хезм.: Термохимия гетероатомных соединений. Реакция Арбузова в растворе и в газовой фазе // Докл. РАН. 1995. Т. 341, ч. 2 (автордаш); Некоторые аспекты термохимии органических соединений фосфора // Рос. хим. журн. 1999. № 3–4 (автордаш); Экологический аспект комплексной модернизации котельных агрегатов коммунальной энергетики // Экология и промышленность России. 2007. № 8 (автордаш).

**ЛА́ПТЕВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 24 *км* төньяктарак, Мордвасу елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 97 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Никифоровка авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Сөйке, Төбәк исемнәре б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, он тарттыру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Александр Невский чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1889 да ачыла), 3 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 749 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 646, 1897 дә — 634, 1938 дә — 492, 1949 да — 457, 1958 дә — 424, 1970 тә — 367, 1979 да — 202, 1989 да — 181, 2002 дә — 141 кеше яши.

**ЛАПШИ́Н** Анатолий Александрович (30.1.1930, Минзәлә кантоны Ольгино а.), слесарь-инструментальщик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). 1947–2007 елларда Яшел Үзән шәһәренең А.М.Горький исем. з-дында эшли. Дәүләт бүләге суднолар төзелешендә яңа продукция җитештерүне гамәлгә керткәне өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛАРИО́НОВ** Виктор Михайлович (22.1.1949, Казан), термофизик, техник фән. д-ры (2005), проф. (2006). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре тирбәлүчән тирәлекләрдә яну һәм җылылык-масса алмашу процессларына, ресурс һәм энергия саклаулы технологияләргә карый. Җылылык чыганаклы системаларда газларның автотирбәнешләрен энергетик яктан исәпләүне һәм аның методикасын тәкъдим итә. Авиация двигательләрендә яну процессының акустик тотрыксызлыгын булдырмау; кече җылылык энергетикасы ихтыяҗлары, сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларын утилләштерү өчен пульсацияле яну җайланмаларын төзү буенча күрсәтмәләр эшли һәм гамәлгә кертә.

Хезм.: Автоколебания газа в установках с горением. К., 2003 (автордаш); Теоретические модели пульсационного горения твёрдого топлива в типовых установках // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2009. № 11–12 (автордаш); Оценка эффективности нагнетателя газа, выполненного на базе акустического резонатора // Хим. и нефтегазовое машиностроение. 2010. № 11–12 (автордаш).

**ЛАРИО́НОВ** Григорий Фёдорович (27.1.1905, Уфа губ. Минзәлә өязе, хәзерге Зәй р-ны Гулькин а. — 29.2.1968, шунда ук), Сов. Союзы Герое (5.11.1944), гв. подполковнигы. Ленинград артиллерия мәктәбен (1933), Харьков очучы-күзәтчеләр хәрби авиация уч-щесен (1934), Хәрби-һава инженерлар академиясен (Мәскәү өлкәсе Монино пос., 1940) тәмамлый. 1928 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 7 нче гв. штурм авиациясе полкы штурманы (9 нчы штурм авиациясе дивизиясе). Балтыйк флоты Хәрби-һава көчләре составында Выборг һәм Фин култыкларында дошманның хәрби-диңгез базаларын, корабльләрен, гаскәр тупланган урыннарын 193 сугышчан очыш вакытында утка тота. Сугыштан соң СССР Хәрби-һава көчләрендә хезмәт итә (1955 кә кадәр). Кишинёвта һәм туган авылында яши. Ике Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза Военно-Морского Флота.

1937–1945. М., 1977; Белокопытов В.И., Дюрягин Г.М. Шаг в бессмертие. К., 1980; Герои огненных лет. М., 1983. Кн. 6.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЛАРИО́НОВ** Иван Фёдорович (25.5.1931, Питрәч р-ны Кавал а. — 6.8..2002, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1971). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1964). 1946–50 елларда В.И.Ленин исем. шахтада эшли (Пермь өлкәсенең Кизел ш.). 1951 дән Питрәч р-нында: Ильич исем. к-зда; 1958 дән «Россия» к-зы агрономы, 1959 дан рәисе; 1991 дән район җир ком-ты рәисе. Л. җитәкчелегендә колхозда бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 30 *ц* га җитә, 1 сыердан 4 мең *кг* сөт савып алына; колхоз СССР МС һәм КПСС ҮК ның күчмә Кызыл байрагы б-н бүләкләнә. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын, көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛАРИО́НОВ** Семён Архипович (1.4.1915, Самара губ., Бөгелмә өязе Чирмешән а. — 29.12.1984, Казакъстан ССР, Жамбул өлкәсенең Мерке р-ны Мерке а.), Сов. Союзы Герое (30.10.1943), өлкән лейтенант. Рече лейтенантлар курсын (1944), Казакъстан КП ҮК каршындагы партия мәктәбен (1949) тәмамлый. Ново-Ивановский МТСында эшли (Жамбул өлкәсе Свердлов р-ны). 1937–39 елларда һәм 1941 нең декабреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 237 нче укчы полкның танкларга каршы батареясының ут ачу взводы командиры (65 нче армиянең 69 нчы укчы дивизиясе). Дон, Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш-Пруссия һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 16 октябрендә Радуль посёлогы (Чернигов өлкәсе Репкинский р-ны) янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: штурм төркеме составында елганы кичеп, сугыш мәйданын басып алуда һәм киңәйтүдә катнаша. 1946 дан запаста. 1974 елга кадәр Мерке авылында партия эшендә. Ленин ордены, Александр Невский, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Джураев Т.Д. Верные сыны Родины. Таш., 1964; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 1; Салахутдинов Ф., Хасанов М., Иосько М. Звёзды Самарканда. Таш., 1968.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЛА́РИЧЕВА** Эльвира Львовна (26.5.1930, Кострома ш. — 25.12.2001, Казан), журналист, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), урта мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыта (Ленинград). 1954–56 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасы хәбәрчесе, 1957–87 дә «Советская Татария» г-тасы хәбәрчесе, сәнәгать һәм транспорт бүлеге мөдире. Л.ның мәкалә һәм очерклары ТАССРның нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате үсешенә бәйле. Х.Ямашев исем. бүләк лауреаты (1979). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Если любишь... К., 1962; Наедине с совестью. К., 1987.

*Ш.Н.Мулаянов.*


**ЛА́РОЧКИНА** Ирина Андреевна (14.1.1950, Әлмәт ш.), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (1995), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2010), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996). Казан ун-тын (1972), Менеджмент академиясен (Целле ш., ГФР, 1994) тәмамлый. 1972–2000 елларда ТатНИПИнефтьтә, 1986–94 тә лаб., 1995–97 дә геол. разведка бүлеге, 1998–2000 дә разведка һәм промысел геологиясе бүлеге мөдире, 2000–02 дә ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, 2002–05 тә РФнең Федерация Советы әгъзасы. 2005 тән ТР экология һәм табигый ресурслар министры, 2007 дән ТР Президенты каршында җир асты байлыкларыннан файдалану, нефть, газ һәм экология мәсьәләләре буенча дәүләт киңәшчесе, бер үк вакытта, 2008 дән ТР ФА каршындагы Җир асты байлыкларыннан файдалану һәм экология проблемалары ин-ты директоры. 2010–12 дә ТР энергетика министры урынбасары. Л. — эзләү һәм разведкалау скважиналарын бораулау һәм нефть запасларын исәпләү алымнары буенча тәкъдимнәр авторларының берсе. ТР терр-сендә нефть һәм күмер катламнары таралуның төп закончалыкларын ача. Идел-Кама антеклизасы тектоник төзелешенең яңа моделен эшли. 1999–2004 тә ТР Дәүләт Советы депутаты. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Особенности размещения и перспективы поисков скоплений нефти и газа нетрадиционного типа Волго-Урала. М., 1994 (автордаш); К проблеме возможной нефтегазоносности кристаллического фундамента // Прогноз нефтегазоносности молодых и древних платформ. К., 2001 (автордаш).

**ЛАРЮ́ШИН** Александр Иванович (22.11.1938, Рязань өлкәсенең Сасово ш.), оптик һәм электрон техника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), проф. (1998), РСФСР, ТРның атказ. машина төзүчесе (1990, 1994). 1962 елда Рязань радиотехника ин-тын тәмамлаганнан соң, Ульяновск радиолампалар з-дында эшли, директор урынбасары (1979 дан). 1986–97 дә «Элекон» ФҖБнең ген. директоры, бер үк вакытта Мәскәү энергетика ин-ты Казан ф-лында мед.-биол. электроникасы каф. мөдире (1996–97). 1997 дән лазер техникасы җитештерү буенча фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары («Полюс», Мәскәү), бер үк вакытта Мәскәү энергетика ин-ты профессоры. Хезмәтләре лазер техникасы нигезләренә һәм лазерларны мед.-биол. практикасында куллануга карый. Л. лазерлар, авиация өчен электр агрегатлары, космик аппаратлар, галоген һәм люминесцент яктырткычлар булдыру өлкәсендә тикшеренүләр алып бару б-н шөгыльләнә. Ул тәкъдим иткән лазерлы мед. җайланмалары физио- һәм рефлексотерапиядә, урологиядә кулланылыш таба. Тикшеренү нәтиҗәләре медицинада төрле авыруларны хирургия ярдәменнән башка дәвалау мөмкинлеге бирә. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1981). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең С.П.Королёв, Э.К.Циолковский исем. алтын медальләре, СССР Космонавтика федерациясенең Ю.А.Гагарин исем. алтын, СССР ВДНХсының көмеш медальләре б-н бүләкләнә.



С.А.Ларионов.



Н.Г.Ларягин.

Х е з м.: Лазерная техника. К., 1995; Оптоэлектроника в промышленности и медицине. К., 1997; Оптико-электронные устройства для медицины. К., 2000.

**ЛАРЯ́ГИН** Николай Григорьевич (1923, Зөя кантоны Красновидово а. — 14.3.1945, Германия, Щецин ш.), Дан орденының тулы кавалеры (23.1.1944, 29.12.1944, 31.5.1945), гв. өлкән сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елның мартыннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 31 нче гв. артиллерия полкының 2 нче дивизион разведка идарәсендә отделение командиры (61 нче армиянең 12 нче гв. укчы дивизиясе). Брянск, Көнбатыш, 1 нче Белоруссия һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Белёв шәһәреннән көньяктарак һәм көньяк-көнбатыштарак оборона һәм һөҗүм сугышларында (1943), Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944), Варшава-Познань һәм Көнчыгыш-Померания (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 5–8 гыйнварында һөҗүм алдыннан дошманның 3 дзотын һәм 2 миномёты урынын билгели; дошман уты астында батарея атышын дошман утын бастыруга юнәлтә, подразделениегә һөҗүм исауны тәэмин итә. Александровка авылы (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсе Калинковичи шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак) янындагы сугышта; 1944 нең 4 ноябрендә (дошманның 3 пулемёты һәм 1 миномёты урынын билгели) Маздзелда тирәсендә (Латвия ССР, Рудбаржи шәһәреннән 11 *км* көньяктарак) дошманның Курляндия төркемен камап алу сугышында; 1945 нең 10–13 мартында (дивизион разведкасы башлыгы вазифаларын үтәгән хәлдә, дошманның 5 пулемёт ноктасын, 2 орудиесен билгели; сугышта яралана, әмма сафта кала; икенче авыр яраланудан соң госпитальгә озатыла һәм шунда вафат була) Розенгартен торак пункты (хәзер Домбе, Щецин ш.) янындагы сугышта батырлык күрсәтә. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



Г.Т.Ластовка.


**ЛАССИ́** де (Ласси, Ласи, Лассий) Борис (Мориц) Петрович (1737 — 18.1.1820, Гродно губ., Гродно өязе Августовский Ключ а.), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, инфантерия генералы (1798). Чыгышы — ирландияле дворяннар нәселеннән. 1762 елдан Россиядә хәрби хезмәттә. 1768–74, 1787–91 еллардагы рус-төрек сугышларында, 1783 тә Кырымны Россиягә кушу вакыйгаларында, 1794–95 тә Польшадагы кузгалышны бастыруда катнаша. 1797–98 дә Казан хәрби губернаторы. Агач әзерләү эшләрендә башбаштаклыкны бетерү, губерна терр-ясендәге урманнарны саклау һәм яңарту буенча чаралар күрә. Казанда император Павел I не кабул итү вакытында губерна шәһәренә яңа җирләр «кисеп» кушуга, Гостиный двор, больница бинасы төзелешенә акча алуга, Воскресенский урамындагы губернатор йортын кабат торгызылган Беренче ир балалар гимназиясенә (аның уставын Л. эшли һәм ул император тарафыннан раслана) тапшыруга ирешә. 1798–99 да Вильно, Ковно һәм Гродно генерал-губернаторы. 1805 тә Италиядә рус, инглиз һәм неаполитан гаскәрләре башкомандующие.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «врученной на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛА́СТИН** Лев Леонидович (16.6.1925, хәзерге Киров өлкәсе Малмыж ш. — 5.3.1998, Казан), инженер-технолог, сәнәгый җитештерүне оештыручы. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1950). 1948–52 елларда 230 нчы авиация з-дында (Казан): мастер, өлкән мастер, цех башлыгы (1951 дән). 1952–56 да КПССның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире урынбасары. 1956–85 тә Казан ясалма күн з-ды директоры. Л. җитәкчелегендә гамәлдәге цехларны үзгәртеп кору һәм яңа цехлар (40 мең $м^2$) төзү нәтиҗәсендә Казан ясалма күн з-дының җитештерү куәте 4 тапкыр арта; автотрактор сәнәгате өчен техник картон һәм аннан эшләнмәләр; поливинилхлорид плёнкалы материаллар; типография плёнкасы, канцелярия һәм көнкүреш товарлары җитештерү оештырыла. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛА́СТОВКА** Галина Трофимовна (1.1.1947, Мари Респ-касы, Сернур р-ны Семён-Сола а.), җырчы (меццо-сопрано), педагог. ТАССР һәм Мари Респ-касының халык артисты (1987, 1994), РФнең атказ. артисты (1998). 1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1973–80 дә Татар филармониясе солисты. 1980–2008 дә Татар опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты, бер үк вакытта 1984–86 да һәм 1995 тән Казан консерваториясендә ялгыз җырлау кафедрасында укыта, проф. (2003). Л.ның репертуары 40 тан артык партияне: Марина Мнишек («Борис Годунов», М.Мусоргский), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Амнерис («Аида», Дж.Верди), Графиня, Полина («Пики дамасы», П.Чайковский), Кармен (шул исем. опера, Ж.Бизе), Тугзак, Хәят («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов) һ.б.ны үз эченә ала. Җырчының киң концерт репертуарына — күп илләр һәм халыклар композиторларының төрле жанрдагы һәм стильдәге әсәрләре керә. Л. Казан консерваториясендә укыту эшчәнлеге алып бара. Россиядә һәм чит илләрдә (Көнбатыш Европа, АКШ һ.б. илләр) гастрольләрдә чыгышлар ясый.



Г.Т.Л а с т о в к а (сулда) Фенена (Дж.Верди, «Набукко»; Захария — М.Казаков) ролендә. М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры. 2005.



Г.Т.Л а с т о в к а Марина Мнишек (М.Мусоргский, «Борис Годунов») ролендә.

**ЛА́СТОЧКИНА** Елизавета Гурьевна (5.6.1869, Елизаветполь губ., Шуша ш., хәзерге Таулы Карабах — 1.1.1967, Мәскәү, Казанда җирләнә), сурдопедагог, Хезмәт Батыры (1929), РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1944). 1888 елда Казандагы Мария (беренче) кыз балалар гимназиясен тәмамлаганнан соң, Казанда башлангыч мәктәпләрдә эшли. 1889–1965 тә Казан чукрак-телсезләр уч-щесендә (1922 дән — институт, 1943 тән — мәктәп), 1893–1930 да директор, 1930 дан уку-укыту бүлеге мөдире, 1954–65 тә методист-консультант. Л.ның методик эшләнмәләре басылып чыкмаса да, ул сурдопедагогика үсешенә зур өлеш кертә. Л. җитәкләгән пед. курсларда авторлык методикасы һәм дидактик эшләнмәләр таратыла. Аның тарафыннан акылга зәгыйфь, ишетмәүче балаларны укыту системасы аеруча зур әһәмияткә ия. Рев-циягә кадәрге чорда Казан чукрак-телсезләр уч-щесе укытуның куелышы буенча Россиядә иң яхшылардан санала, совет чорында дефектолог пед. кадрларның квалификациясен күтәрү буенча эре үзәккә әверелә. 1920 елларда Л. җитәкчелегендә ишетмәүче татар балаларын ана телендә укыту оештырыла. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1926 дан Казан чукрак-телсезләр ин-ты (хәзер — мәктәп), 1972 дән Казан чукрак-телсезләр мәдәният сарае Л. исемен йөртә.

Х е з м.: О мимике. СПб., 1904; Малоспособные глухонемые и их обучение // Тр. Всерос. съезда деятелей по воспитанию, обучению и призрению глухонемых. М., 1911.

*Әд.:* Герои Труда Татарии. 1929–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974.

**ЛА́ТВИЯ РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, Европаның төньяк-көнбатышында урнашкан дәүләт. Мәйданы — 64589 *км²*. Үзәге — Рига. Халкы — 2067 мең кеше (2011), 3040 татар (2002). Л.Р. терр-ясенә татарлар 19 йөздә килә. 1897 елгы мәгълүматларга караганда, анда 1525 татар (нигездә, Елгава шәһәрендә урнашкан хәрби частьлар солдатлары) яши. 1890 да Ригада мөселман зираты ачыла, 1902 дә мөселман җәмгыяте теркәлә. Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Латвиядән татарлар күпләп китә. Шуңа да карамастан, 1920–44 елларда Ригада мөселман мәхәлләсе эшли. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Даугавпилс шәһәренең Двина крепостендә немец концлагере оештырыла, тоткыннар арасында татарлар һәм Татарстаннан чыккан кешеләр (ш.и. шагыйрь М.*Җәлил*) була. Сугыштан соң Л.Р.нда татар халкының саны, нигездә, элеккеге хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре һәм техник интеллигенция вәкилләре исәбенә арта (1959 да — 1811, 1970 тә — 2671, 1979 да — 3764, 1989 да — 4828, 1996 да — 3535 кеше). 1988 дә Ригада Латвия татарларының «Идел» (беренче рәисе З.Л.*Зәйнуллин*, соңрак И.С.Сабитов) җәмгыяте, 2000 дә «Чишмә» татар-башкорт мәдәни җәмгыяте (ф-лары Вентспилс һәм Даугавпилс шәһәрләрендә; рәисе З.З.Зәйнуллин), 1994 тән «Ак калфак» татар халыкара хатын-кызлар берләшмәсе ф-лы (җитәкчесе Г.Сабитова) эшли. 1991 дә Ригада татар телен укыту буенча якшәмбе татар мәктәбе ачыла, Латвия радиосында даими (айга 1 тапкыр) татарча радиотапшырулар чыга башлый, шул вакыттан башлап ел саен татар халкының милли бәйрәме — Сабан туе үткәрелә. 2000 нән «Чишмә» җәмгыяте каршында шул исем. вокаль ансамбль (сәнгать җитәкчесе Ф.Булушева), татар якшәмбе мәктәбе һәм китапханә эшли, кварталга бер тапкыр татарча «Чишмә» исемле хәбәрче г-та чыга. 1990 ның декабрендә Ригада Татар ислам үзәге оештырыла, 1994 тә шәһәр мөселман җәмгыяте (рәисе И.К.Сабитов) теркәлә. 1991 дән ел саен Корбан һәм Ураза бәйрәмнәре үткәрелә, шул ук вакытта башкала бистәсе — Яунциемста икенче мөселман зираты ачыла. Хәзерге вакытта Латвияда 10 мөселман җәмгыяте эшли. Та-

тарстан б-н Латвия арасында мәдәни һәм икътисади бәйләнешләр урнаша. 1990 да Л.Р.нда Татар акад. театры гастрольләре уза. Рига һәм башка шәһәрләрдә татар артистлары (И.Шакиров, В.Ганиева, В.Гыйззәтуллина, Л.Әхмәтова, А.Галимов, А.Әсәдуллин) чыгыш ясый. 2003 тә Ригага «Бөек Идел юлы» халыкара фәнни конференциясе делегатлары килә. «Татарстан-Балтия» сәүдә йорты (президенты З.З.Зәйнуллин) ТР б-н икътисади элемтә урнаштыра.

*И.К.Сабитов.*

**ЛАТИ́Н ЯЗУЫ́** (латиница), латин алфавитына нигезләнгән татар язуы системасы. Саф латин алфавиты б.э.к. 4–3 йөзләрдә барлыкка килә. Исеме Италиянең урта өлешендәге Лаций өлкәсендә яшәүче латин кабиләләреннән алына. Грек язуына барып тоташа. Сулдан уңга таба языла. Латин алфавиты Европа, Төньяк һәм Көньяк Американың күпчелек халыклары язуына нигез итеп алына. Россия империясенең төрки-мөселман халыкларында, аларның рухи мәдәниятен яңарту күренеше буларак, гарәп язуын Л.я.на алмаштыру турындагы фикер 19 йөз уртасында туа. Бу эшне әзәрб. язучысы һәм драматургы М.Ф.*Ахундов* башлап җибәрә. Ул 1850 еллар ахыры — 1860 еллар башында гарәп алфавитын үзгәртеп төзүнең 4 проектын тәкъдим итә. 3 нче проект буенча гарәп графикасын Л.я. нигезендә камилләштерү күздә тотылган була, әмма бу фикер яклау тапмый. 19 йөз ахырында гарәп алфавиты реформасына караган төрле проектлар б-н фарсы шагыйре Мирза Милкемхан, Иран шаһзадәсе Мирза Риза хан һ.б. чыгыш ясый. Татар язуын гарәп графикасыннан Л.я. нигезенә күчерү зарурлыгын беренчеләрдән булып татар шагыйре һәм язучысы С.*Рәмиев* әйтә. 1911–12 дә Әстерханда чыккан «Идел» г-тасындагы язмаларында ул татар язуын үзгәртү турындагы мәсьәләне катгый рәвештә күтәреп чыга, латин алфавитының үз вариантын тәкъдим итә, Л.я. үрнәкләрен китерә. Аның фикеренчә, Л.я. татар теленең авазлар төзелешен аеруча тулы итеп бирә ала. 1920 дә татар-башкорт журналистлары (Казан) конференциясендә дә латин алфавитына күчү турында сүз кузгатыла. 1924 тә 6 нчы Берләштерелгән Татар-башкорт командирлары мәктәбендә (хәзер *Казан югары хәрби командирлар училищесе*) беренче латинчылар ячейкасы барлыкка килә. Соңрак шуның җирлегендә Бөтентатар «Латин дусты» җәмгыяте оеша. Аның әгъзалары арасында Ш.*Усманов*, Ш.*Измайлов*, З.*Гали* була. Латинлаштыру хакында фикер алышу Татар-башкорт мәгариф хезмәткәрләре съездыннан соң (Мәскәү, 1924) тагын да көчәя. Монда килешүле карар тәкъдим ителә: «латинлаштыруга каршы чыкмаска», әмма «гарәп билгеләрен җиңеләйтү юлларын эзләп табу чараларын күрергә». Шуннан соң ук 1924 нең 18 гыйнварында Мәскәүдә Яңа алфавит ком-ты төзелә. 1924 нең ахыры — 1925 нең башында ТАССРда Л.я.н өйрәнү буенча ирекле түгәрәкләргә йөрүчеләр саны 1 меңгә якын була. Л.я.н хуплаучылар фикеренә килгәндә, гарәп графикасына нигезләнгән язу татар текстын аңлауны катлауландыра, чөнки ул татар теленең фонетик үзенчәлекләрен җитәрлек дәрәҗәдә чагылдырмый. Бөтен төрки халыклар өчен яңа алфавит кертү мәсьәләсе 1926 да Бакуда узган 1 нче Тюркология съездында карала. ТАССРдан анда делегатлар Г.*Ибраһимов*, Г.*Алпаров*, Н.*Хәким*, Г.*Сәгъди*, С.*Гафуров*, С.*Атнагулов* һ.б. катнаша. Татар иҗтимагый, сәяси эшлеклеләре һәм тел белгечләре Г.Ибраһимов, Г.*Шәрәф* үз чыгышларында, татар теленең үзенчәлекләрен исәпкә алып, гарәп шрифтын яхшыртуны тәкъдим итәләр. ТАССРдан башка делегатлар ш.у. латин алфавитын рәсми рәвештә кире какмасалар да, гарәп язуына реформа кертү ягында торалар. С.Атнагулов битарафлык күрсәтә. Көчле бәхәсләрдән соң, съезд «яңа латин алфавиты кертү» турында карар кабул итә. Шул ук елда ТАССР Советларының 6 нчы съездында «*Яңалиф*» җәмгыяте төзелә, соңрак шул исемдәге нәшрият һәм журнал булдырыла. 1927 нең башында язучы Ф.Сәйфи-Казанлы һәм тел белгече Г.*Нугайбәк* үзләренең Л.я.на нигезләнгән татар алфавиты проектларын халыкка игълан итәләр. Г.Нугайбәк проекты 1927 дә гарәп алфавиты урынына кабул ителгән *яңалифкә* нигез була (Әзәрбайҗанда Л.я. — 1923 тә, Төркиядә 1928 дә кабул ителә). Милли мәдәният үсешендә зур тоткарлыкларны булдырмый калу максаты б-н татар язуын Л.я.на алыштырганнан соң, республикада халыкны яңа әлифбага өйрәтү буенча зур эш башлана. Әмма 1939 да яңалиф рус алфавитына нигезләнгән графика б-н алыштырыла (к. *Кириллица*). Татар халкы тарихының яңа этабында латин графикасына нигезләнгән язуга кире кайту мәсьәләсе 1997 дә 2 нче Бөтендөнья татар конгрессында кузгатыла. Дискуссияләрдә ТРның күренекле галимнәре, мәдәният эшлеклеләре катнаша (Ә.Г.Кәримуллин, М.З.Зәкиев, Ф.Ә.Ганиев, Х.Р.Курбатов, В.Х.Хаков һ.б.). Конгресс чыгарган карарлар латин графикасын өйрәнү буенча курслар оештыру өчен җирлек тудыра, фәнни-методик әдәбият әзерләү һәм бастыру эшләре башлана, күп кенә татар мәктәпләрендә тәҗрибә сыйфатында Л.я. кулланугa нигезләнгән укыту кертелә. 1999 нын 15 сентябрендә ТР Дәүләт Советы «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Закон кабул итә. 2001 нең 1 сентябреннән ул ТРда дәүләт алфавиты булып саналырга, ә 2011 гә Л.я.на тулысынча күчеп бетү тәмамланырга тиеш була. Әмма РФнең 2002 нең 11 декабрендә «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» Законы кабул ителә. Аның 3 нче маддәсенә «Россия Федерациясендә Россия Федерациясе дәүләт теле һәм республикалар дәүләт телләре алфавитлары кириллица графикасы нигезендә төзелә. Россия Федерациясе дәүләт теленең һәм республикалар дәүләт телләре алфавитларының башка графика нигезләре федераль законнар тарафыннан гамәлгә ашырыла ала» дигән өстәмә кертелә. Шул нигездә, Л.я.н татар мәдәниятенә кире кайтару мәсьәләсен кузгату тыела. Шуңа карамастан Л.я. ТРның кайбер периодик басмаларында кулланылуын дәвам итә; басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларының кайберләрендә («Казан утлары» ж-лы, «Интертат» электрон г-тасы һ.б.) Л.я. үрнәкләре басыла. Ш.у.к. «*Алфавит*».

*Әд.:* Рәмиев С. Безгә тәкъдил вә ислах хөрүф кирәкме? Әллә бөтенләй тәбдил үк кирәкме? // Идел. 1911. 5 июнь; Сәйфи-Казанлы Ф. Татарлар арасында «Яңалиф» тарихы. К., 1928; Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар (80–90 нчы еллар). К., 1989; Xaqov V.X. Telen belgən il açar. Q., 1993; Курбатов Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Реформа мусульманской азбуки // Мир ислама. 1913. Т. 2, вып. 12; Шараф Г. К вопросу о принятии для тюркских народностей латинского шрифта // Вестн. Науч. об-ва Татароведения. 1926. № 5; Закиев М.З. Сохраним родной язык — сохраним и нацию // Науч. Татарстан. 1997. № 3–4; Мухаметшин Р.М. Переход на латинскую графику в Татарстане: между научной целесообразностью и политической конъюнктурой // Гражданское общество в многонациональных и поликонфессиональных регионах. М., 2005.

*В.Х.Хаков, Г.С.Сабирҗанов, А.М.Ахунов.*

**ЛАТИ́НИЦА**, к. *Латин язуы.*

**ЛАТЫ́ЙП** (Латыйпов) Галимҗан Шакир улы (20.1.1912, Уфа губ., Яңа Дөмәй а. — 4.11.1986, Казан), шагыйрь. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1939). Сов.-фин сугышында катнаша. 1941–51 елларда республиканың тикшерү-финанс оешмаларында инспектор булып эшли. 1951–60 та «Пионер» ж-лы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире. Беренче шигырь җыентыгы («Юл буйлап») 1939 да басылып чыга. Л.ның «Хезмәт иртәсе» (1950), «Кыр чәчәге» (1958), «Шигырьләр» (1962), «Чын күңелдән» (1964), «Адымнар» (1967), «Кояшлы яңгыр» (1971), «Кояшлы Идел» (1973), «Җир җыры» (1983) исемле җыентыклары на туган илгә багышланган, халыклар дуслыгын чагылдырган, авыл тормышы, гаилә бәхете турындагы лирик һәм шаян шигырьләре, җырлары, балладалары, поэмалары тупланган. Ул ш.у. Е.Исаев, Д.Бедный, С.Михалков, А.Твардовский, П.Неруда, Н.Вапцаров шигырьләрен татарчага тәрҗемә итә; популяр җырлар текстлары авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ЛАТЫ́ЙП** (Латыйпов) Кави Таһир улы (1.5.1927, Чуаш АССРның Батыр р-ны Кызыл Чишмә а. — 13.4.2008, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Бөек Ватан сугышында катнаша. А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1971). 1955–57 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1957–59 да ТАССР Мәгариф министрлыгы инспекторы, 1959–62 дә Казан телестудиясе мөхәррире, 1962–78 дә Казан дары з-дының күп тиражлы «Ленинчы» г-тасы мөхәррире, 1978–82 дә СССР ПФАнең Казан һөнәри-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тының өлкән фәнни хезмәткәре. Әдәбиятка фронт чынбарлыгын чагылдырган «Солдат эзләре» (1960) шигъри җыентыгы белән килеп керә. «Умырзая» (1966), «Тормыш төсмерләре» («Краски жизни», М., 1973) җыентыкларында Бөек Ватан



Габдрахман Х.Латыйпов.



Госман Х.Латыйпов.

сугышы темасын яктырткан, туган илне дошманнардан саклаган геройлар турында шигырьләр урын алган. Л. поэзиясенә кыскалык, тирән эмоциональлек хас. 1980 елларда Л. иректе шигырь — верлибрга мөрәҗәгать итә, аның «Вакыт канатында» (1983), «Хәтер йомгагы» (1986), «Иркен сулыш» (1991), «Иман кәрваны» (1997), «Шигырьләр» («Сывысем», Чабаксар, 2004, чуаш телендә), «Утлы күмер» (2005) җыентыкларына кергән шигырьләрендә көтелмәгән кыю рифма, ритмның кискен үзгәреше күзәтелә. Л. прозаик буларак та билгеле. Аның «Мизгел» (1972), «Ефәк әрем» (2002) җыентыкларындагы хикәя һәм повестьларында Бөек Ватан сугышы вакыйгалары кабат яңартыла, сов. кешеләренең кыюлыгы һәм тәвәккәллеге гәүдәләнә. «Йолдыз тапкан егет» (1964; чуашчага тәрҗемәсе «Шылтыр тупны качча», Чабаксар, 1972) документаль повесте космонавт А.Н.Николаевка багышлана. И.Я.Яковлев исем. Чуаш милли бүләге лауреаты (1994). 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, медальләр, Чуаш АССРның, ТРның Мактау грамоталары б-н бүләкләнә (1984, 2002).

*Әд.:* Ю з е е в И. Кави Латыйп // Казан утлары. 1983. № 1; Ә х м ә т җ а н о в М. Күңеле һаман унҗидедә // Килер бер көн. К., 1998; Г а т а у л л и н Р. Үҗәт яугир, самими шагыйрь // Казан утлары. 2002. № 5; Ю м а р т Г. Голос поэта // Ялав. 1983. № 5.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Әнвәр Латыйп улы (18.3.1923, БРның хәзерге Илеш р-ны Рсай а. – 27.6.2004, Казан), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1978). 1948 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Казан ГИДУВында эшли, 1972–93 елларда травматология һәм ортопедия каф. мөдире. Хезмәтләре балаларда тумыштан килгән буыннар чыгу, сколиоз, бот сөяге башы остеохондропатиясе, сөякләрнең гигант күзәнәкләр шеше этиологиясенә һәм дәвалау ысулларына карый. Сколиозны тиз дәвалау аппаратын уйлап таба (к. *Латыйпов аппараты*). Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. Бөтенроссия травматологлар һәм ортопедлар идарәсе әгъзасы (1990 нан). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О травматических вывихах бедра // Казан. мед. журн. 1967. № 2; Этиология и оперативное лечение сколиоза. К., 1988.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Габдрахман Хәким улы (1917, хәзерге БРның Чакмагыш р-ны Иске Бәшир а. — 25.1.1945, Польша, Вроцлав ш. җирләнә), Сов. Союзы Герое (10.4.1945, үлгәннән соң), сержант. Туган авылында финанс инспекторы булып эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 32 нче артиллерия полкында орудие командиры (52 нче армиянең 31 нче укчы дивизиясе). Воронеж, Дала, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Корсунь-Шевченко, Умань-Боташаны (икесе дә — 1944), Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 25 гыйнварында Бреслау (хәзер Вроцлав) шәһәреннән көньяк-көнчыгыштарак Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: елганы беренчеләрдән йөзеп чыгып, сугыш плацдармын басып алуда һәм дошманның 12 контрһөҗүмен кире кайтаруда катнаша; шушы сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Госман Хафиз улы (13.5.1925, Минзәлә кантоны Чишмәбаш а. — 8.9.2000, Минзәлә ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1970). Бөтенсоюз юридик читтән торып уку ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1952). 1942–52 елларда Мөслим р-ны Урәзмәт урта мәктәбендә укытучы, 1953–59 да Калинин р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире. 1959 дан Минзәлә р-нында: М.Вахитов исем. урта мәктәп директоры, КПССның район ком-тында бүлек мөдире (1960–61), «Гигант» к-зы рәисе (1961–77), район башкарма ком-ты рәисе (1977–80), Ленин исем. к-з рәисе (1980–86). Л. җитәкчелегендә «Гигант» к-зында бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 22 *ц* га, бәрәңгенеке — 164, шикәр чөгендеренеке — 237 *ц* га җитә; колхозга ике тапкыр РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл байрагы бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р у м я н ц е в Е. Латыпов Гусман Хафизович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена «Трудовой Славы» — наши земляки. К., 2003.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Линар Наил улы (6.2.1955, Казан), дипломатия хезмәткәре, филол. фән. канд. (1989), ТРның атказ. икътисадчысы (2010). Чит телләр ин-тын тәмамлый (Түбән Новгород ш., 1978). 1980–91 елларда Казан ун-тында укыта. 1987 дә «американистика» белгечлеге буенча Джорджтаун ун-тында стажировка уза (Вашингтон, АКШ). 1991–94 тә ТР Премьер-министрының тышкы бәйләнешләр буенча ярдәмчесе; 1994 тән ТРның АКШтагы даими вәкиле. 2005–07 дә ТР сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрының 1 нче урынбасары, 2007–11 дә ТР сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары. 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-ты проректоры, бер үк вакытта Шәркыять һәм халыкара мөнәсәбәтләр ин-ты директоры.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Мәсгут Гали улы (23.8.1913, Семиреченск өлкәсе Сергиополь ш., хәзер Казакъстан Респ-касының Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе Аягуз ш. — 9.4.1987, Казан), композитор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). 1920 еллар уртасында Казанда үзешчән муз. коллективларда катнашып чыгышлар ясый (тынлы уен коралларында башкаручы). 1930 да Мәскәү консерваториясе рабфагында тынлы уен кораллары һәм композиция бүлегендә, Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка уч-щесендә һәм Гнесиннар исем. музыка уч-щесендә, Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (композиция буенча педагоглары Е.Месснер һәм Г.Литинский) белем ала. Бер үк вакытта Эчке эшләр халык комис-тының (Мәскәү өлкәсе) эчке сагы тынлы уен кораллары оркестрында эшли. 1930 елларда төрле жанрларда әсәрләр (тынлы оркестр, хор өчен; җырлар, халык көйләре эшкәртмәләре һ.б.) иҗат итә. 1936 да Л. Мәскәүдә тынлы уен кораллары оркестры өчен язылган маршлар конкурсында бүләкләнә, 1937 дә аның «Кызыл Татарстан» маршы дөнья күрә. 1941–45 тә Кызыл Армия сафларында, сәнгать ансамбльләре җитәкчесе була. 1946–50 дә Казан, Идел буе (Куйбышев ш.) һәм 1950–53 тә Көнчыгыш Себер (Иркутск ш.) хәрби округларының Җыр һәм бию ансамбльләре б-н җитәкчелек итә; 1954–57 дә ТАССР Җыр һәм бию ансамблендә (Казан) дирижёр, шуннан соңгы елларда нефтьчеләрнең сәнгать коллективларын (1957 дә Мәскәүдә Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында чыгыш ясый), «Сарман розалары» ансамблен, Кукмара һәм Лениногорск яшьләр тынлы уен кораллары оркестрларын оештыручы һәм җитәкчесе була.

Төп әсәрләре: С.Баттал һәм Я.Меркурьев шигырьләренә «4 нче Удар армия геройлары турында» (1946), М.Хөсәен шигыренә (русчага Б.Зернит тәрҗемәсе) «Ватан турында кантата» (1954), Н.Исәнбәт шигыренә «Ватаныбыз башкаласы — Мәскәүгә» (1957) кантаталары; хор цикллары, тынлы уен кораллары оркестры өчен сюиталар һәм маршлар, романслар, җырлар, камера-инструменталь әсәрләр, татар һәм рус халык җырлары эшкәртмәләре.

*Әд.:* Композиторы Советского Татарстана. К., 1957; С а й д а ш е в а З.С. Масгут Латыпов // Композиторы Татарстана. М., 2009.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Рөстәм Мәсгут улы, к. 708 б.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Рөстәм Хафиз улы (28.5.1953, Үзбәкстан ССРның Наманган ш.), информатика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли, хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-ты деканы (1999 елдан). Хезмәтләре тотрыклы интеграль схемалар проектлаштыруга карый. Каршылыкларга тотрыклы кодлаштыру теориясе, цифрлы системаларга тестлар ярдәмендә диагностика үткәрү өлкәсендә тикшеренүләр алып бара.

Х е з м.: Приложение теории линейных последовательностных машин в системах диагностирования // Автоматика и телемеханика. 1988. № 9; Приближённые алгоритмы минимизации бинарных диаграмм решений на основе линейных преобразований переменных // Автоматика и телемеханика. 2004. № 6.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Урал Рәмдрәк улы (28.2.1951, БАССРның Бакалы р-ны Катай а.), хокук

белгече, дәүләт эшлеклесе, юридик фән. д-ры (1993), проф. (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1974–91 елларда СССР Дәүләт иминлеге ком-тының Йошкар-Ола, Мәскәү, Минскидагы органнарында эшли. Бер үк вакытта, 1989–94 тә, Белоруссия Респ-касы Милли иминлек ин-тында махсус фәннәр каф. башлыгы, ин-т җитәкчесе урынбасары. 1994 тән Белоруссия Респ-касы Президенты секретариаты җитәкчесе ярдәмчесе, 1995–96 да җитәкчесе. 1998–2000 дә Белоруссия Респ-касы Премьер-министры урынбасары — тышкы эшләр министры. 2000–01 дә Белоруссия Респ-касы Иминлек советының дәүләт секретаре. 2001 дән Белоруссия Респ-касы Президенты администрациясе башлыгы. 2006 дан «Лукойл-Беларусь» пр-тиесенең консультатив совет рәисе, 2009 дан «Директ Менеджмент» АЖ җитәкчесе (Мәскәү). Хезмәтләре халыкара терроризм мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словрь. К., 2004. Т. 2.

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Фәттах Мәннаф улы (дек. 1884, Ижевск ш. — 1.3.1966, Ташкент), актёр, беренче проф. татар җырчыларыннан (лирик тенор), муз. әсәрләр авторы. 1909 елдан татар театр труппаларында, ш.и. Ташкент, Уфа («Нур» труппасы) шәһәрләрендә эшли. 1911 дән концертлар бирә башлый. Урал, Себер, Урта Азия шәһәрләрендә гастрольләрдә йөри. 1912 дән Казанда системалы рәвештә чыгышлар ясый. Драма спектакльләренә музыка («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш; «Гашыйк Кәриб», К.Әмири, Уфа «Нур» труппасы куелышында), татар романс музыкасы тарихында популярлыкка ирешкән беренче «Мәхәббәтем» (1913) романсының авторы. Татар халык көйләренең ноталы язмаларын эшли.

*Әд.:* Ә м и р х а н Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1958. Т. 2. *Ф.Ш.Салитова.*

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Хәмит Нәҗип улы (5.3.1949, Пермь өлкәсе Губаха ш.), нәкышьче, график, керәч сәнгате остасы, агачка уеп бизәк төшерүче; шагыйрь. Рәссамнар берлеге (1998), Язучылар берлеге (2002) әгъзасы. Уфа сәнгать уч-щесен агачны нәфис эшкәртү белгечлеге буенча тәмамлый (1978). 1978–83 елларда Чаллы шәһәренең Сәнгать фондында эшли. 1983 тән — БАССРның Туймазы шәһәрендә, «Туймазы фарфоры» АЖ рәссамы (1990 га кадәр). Ефәк аша бизәк төшерү (шелкография) һәм тирән уемлы техника б-н күпләп җитештерелүче сувенир эшләнмәләрнең, декоратив вазаларның үрнәкләрен әзерли. 1992 дән нәкышь юнәлешендә эшли («Бабай һәм оныкъ», «Сабанчылар» һ.б.). 1995 тән — Уфада, пастель техникасында станлы картиналар иҗат итә. 1997 дә үзенең графика иллюстрацияләре б-н «Җир һәм күк» исемле шигырьләр җыентыгын бастыра. 2000–02 дә Казан сувенирлар ф-касында баш рәссам булып эшли, «ТуранАрт» ҖЧҖ б-н хезмәттәшлек итә, сувенир үрнәкләрен һәм уеп бизәк төшерелгән (агачтан) һәм диварга эленә торган тәлинкәләрнең сюжетлы-орнаментлы серияләрен иҗат итә. 2002–03 тә Шәмәрдән посёлогы сәнгать мәктәбендә укыта. 2004 тән — Башкортстанның Туймазы шәһәрендә, вак пластикада 200 сувенир эшләнмә эскизы әзерли, аларның бер өлешен агачтан уеп ясый («Карт белән кош», «Малай һәм Шүрәле» һ.б.). 2011 дән — Чаллыда яши.

Л. иҗат юлын күппланлы, яссы рельефлы техникада агачтан уеп бизәлгән әсәрләр иҗат итүдән башлый: «Шүрәле» (1976), «Җеп эрләүчеләр», «Җыр», «Сандугач» (барысы да — 1979). «Төрепкә тартучы карт» (1980) дивар паннолары, Чаллы шәһәренең балалар бакчасындагы музыка залына куелган «Г.Тукай әкиятләре буенча» мотивында эшләнгән ике якка ачылмалы ишекләр (1983) һ.б. 1980 еллар ахырыннан Л. керәч өлкәсендә дә актив эшли (шамот, фарфор, фаянстан декоратив вазалар, сервизлар, вак скульптур пластика), аның эскизлары буенча милли сувенир әйберләр күпләп җитештерелә башлый. Ул савыт-саба формалары өлкәсендә иҗади тәҗрибәләр ясый, аларда конструктив башлангыч күрә һәм үзара пропорциональ бәйләнешкә ирешә, орнаментлы ритмнарны һәм төсләр гаммасын файдаланып, эшләнмәләрдә бизәлеш тәэсирен көчәйтә: «Контрастлар» исемле вазалар сериясе (бисквит, төсле ялтыравык йөгертү, 1989), «Болгар» савыт-сабалары (фаянс, ялтыравык йөгертелгән бизәк, 1991), «Ритм» исемле вазалар сериясе (фаянс, кобальт б-н каплау; 1992), «Пластика» кувшиннар композициясе (фарфор, ялтыравык йөгертелгән бизәк, 1993), вак пластика — «Сак һәм Сок» (шамот, 1980), «Елан патша» (шамот, 1992), «Зилант» (үзле балчык, төсле ялтыравык, 1992) һ.б. Станлы графикада Л. күбрәк пастель б-н эшли («Суга бару», «Батыр», «Җайдак кыз» — барысы да 1995; «Курай», 1996; «Баламишкин», «Көтүче», «Чәй эчү», барысы да — 1997; 90 табаклы «Туган җирем» (2005) сериясе, ш.у. линогравюра, офорт техникасында нәтиҗәле иҗат итә; ул каләм һәм тушь б-н башкарылган китап иллюстрацияләре авторы. 1997 елда аның турында «Җирсү» документаль фильмы (Туймазы телевидение студиясе) төшерелә.

Республика (1975 тән — Уфа, Казан), төбәк («Социалистик Урал», Төмән ш., 1979), бөтентатар төбәкара («Татарт», С.-Петербург–Казан, 1991), чит ил («Татарстанның гамәли-бизәлеш сәнгате», Париж, 2001) һәм төркемле («Күптөслелек», Мәскәү, 1997) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Уфада (1996, 1997, 2000), Туймазы (1996), Казан (1998–99, 2000), Чаллы (2001) шәһәрләрендә, Байлар Сабасы посёлогында уза.

Әсәрләре ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, «ТуранАрт» ҖЧҖдә (Казан), М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, Туймазы шәһәрендәге төбәкне өйрәнү музеенда, Россия, Төркия, АКШ, Франция, Израилдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Ә с ә р.: Галәми гамь. Сынлы сәнгать һәм шигырьләр — Вселенский лад. Изобразительное искусство и стихи. К., 2006; Пастель. Керамика. Резьба. Живопись: Буклет. Уфа, 2000.

*Әд.:* М и ң н у л л и н Р. Җир белән күк кешесе. // Татарстан. 1999. № 1; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Шамил Камил улы (31.1.1962, Кемерово өлкәсенең Осинники ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (2000). 1984 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФАнең КГУ Органик һәм физик химия ин-тында эшли, радиоспектроскопия лаб-ясе мөдире (2000 нән). Хезмәтләре динамик ТМР-спектроскопиясе мәсьәләләренә карый. Циклик органик молекулаларның термодинамик па-







Х.Н. Л а т ы й п о в. 1. «Уйлар». Бисквит, фарфор буяулары. 1991; 2. «Хәбәр китерүче». Картон, пастель. 1995; 3. «Тату пар». Панно. Агач, уеплау. 2003.

раметрлары тигезләнешенең эреткеч үзенчәлегенә, матдәнең темп-расы һәм фаза халәтенә бәйлелеген билгели. Молекулалар конфигурациясен билгеләү моделен тәкъдим итә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009).

Х е з м.: Влияние среды на термодинамические параметры конформационных превращений некоторых частично закреплённых семичленных 1,3-гетероциклов по данным ЯМР // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1990. № 3 (автордаш); Conformational Analysis of 1-Alkoxymethyl-5(R)-methyl1–2-pyrrolidinone Derivatives. Determination of the Absolute Stereochemistry of Alcohols // Journal of Organic Chemistry. 1998. № 63 (автордаш).

**ЛАТЫ́ЙПОВ АППАРАТЫ́**, умырткалыкның янга бөгелүен оператив дәвалау җайланмасы. 1974 елда Ә.Л.*Латыйпов* тарафыннан уйлап табыла. Умырткалыкның бөгелгән аерым өлешләрен эзлекле рәвештә һәм өлешләп төзәтергә мөмкинлек бирә. Франция, ГФР, АКШ, Бөекбританиядә патент ала.

**ЛАТЫ́ЙПОВА** Венера Зиннәт кызы (30.11.1944, Казан), химик, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007), химия фән. д-ры (1986), проф. (1987), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1999, 2004). РФ нең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2006). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1973 тән Казан ун-тында, 1992 дә үзе оештырган факультетара экологик контроль лаб-ясе мөдире, 1994 тән гамәли экология каф. мөдире. Хезмәтләре органик кушылмалар электрохимиясенә, экол. химиягә һәм биогеохимиягә карый. Л. күп факторлы электроорганик процессларның аерым элементар стадияләрен өйрәнү һәм аларның параметрларын микъдари тасвирлауның фәнни нигезләмәләрен эшли. ТРда һәм РФдә экол. проблемаларны хәл итүгә, экол. нормалаштыруның биогеохимик нигезләрен, экол. мониторингның теоретик нигезләрен үстерүгә өлеш кертә. Токсикантның миграцион агымнарын һәм грунтларның сорбцион характеристикаларын исәпкә алып, төптәге утырмаларда агулы химик кушылмалар дәрәҗәсен билгеләү алымнарын тәкъдим итә. Л. җитәкчелегендә антропоген пычраткычлар туплану объектларында агулы матдәләр формалашу; үсемлекләрнең биоген миграциясе процессында микроэлементларны селектив йоту һәм микроэлементлар дифференциациясе закончалыклары эшләнә. Агымлы һәм агымсыз, чистартылган һәм чистартылмаган суларның, туфракның һәм төрле калдыкларның агулылык дәрәҗәсен билгеләү методикасы эшләнә. РФ Табигый ресурслар министрлыгы системасында электрон «Куйбышев сусаклагычының экологик су хуҗалыгы картасы» («Эколого-водохозяйственная карта Куйбышевского водохранилища») булдырыла һәм гамәлгә кертелә. ТР ФА Президенты каршындагы экология проблемалары буенча фәнни совет рәисе (2006 дан). ТР ФАнең В.А.Попов исем. бүләге лауреаты, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электрохимическая реакционная способность элементорганических соединений. Сообщ. 23. Механизм окисления гомо- и гетеродиэлементных соединений // Журн. общей химии. 1990. Т. 60, № 2 (автордаш); Региональное нормирование антропогенных нагрузок на природные среды. К., 2002 (автордаш); Создание тест-системы для оценки токсичности многокомпонентных образований // Экология. 2004. № 1 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в Российской аналитической химии: Справ. М., 2000; Юбилей профессора В. З. Латыповой // Экол. химия. 2004. Т. 13, вып. 3.

**ЛАТЫЙФИ́** (Латыйпов) Флүс Фатих улы (3.6.1943, Мөслим р-ны Мөслим а. — 16.2.2010, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, публицист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1969). 1967–68 елларда «Татарстан кооператоры» («Кооператор Татарстана») г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1968 дән ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында башта репортёр, мөхәррир, соңрак яшьләр тапшырулары редакциясе мөдире. 1985 тән «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, 1986 дан (бүленеп) «Казан утлары» ж-лында (1997 дән баш мөхәррир урынбасары). 1993–97 дә «Татарстан» ж-лы баш мөхәррире урынбасары. Беренче «Кырагай» исемле проза җыентыгы 1988 дә басыла. «Вөҗданыңнан сора» (1988) исемле очерклар һәм публицистик мәкаләләр җыентыгы Х.Ямашев исем. бүләккә лаек була. Катлаулы сюжетка корылган тарихи-мавыктыргыч «Хыянәт» романында (1993; русчага тәрҗемәсе «Измена», 2004) Казан ханлыгындагы вакыйгалар гәүдәләнә, ике яшь кешенең мәхәббәт тарихы тасвирлана. Л. татар язучылары арасында беренчеләрдән булып Румыния татарларының халык авыз иҗатына игътибар итә, «Чура-батыр» тарихи эпосын (1993) хәзерге татар теленә тәрҗемәдә бастырып чыгара. Аның ике телле «Тамга-След» (1993), «Соңгы кисәтү» (1995), «Игезәкләр» (1996) повестьлары фәнни-фантастик жанрда иҗат ителгән. «Әманәт» (2001) хикәяләр җыентыгы, «Ишелеп төшкән бәхет» (2001) һәм «Бәйсез этләрне атарга» (2002) романнары яшьләр тормышына багышлана.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 2001.

*Әд.:* Г а л и у л л и н Т. Тарихыңны онытсаң — киләчәгең юк // Замана балалары. К., 1993; С а ф и н Ф. Хыянәтсез иҗат // Казан утлары. 2001. № 6; З а һ и д у л л и н а Д. Милли реализм юлыннан // Казан утлары. 2003. № 6.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЛАТЫЙФУ́ЛЛИН** Таһир Мәгъсүм улы (2.12.1958, шәһәр тибындагы Баулы пос.) балет артисты, педагог, балетмейстер, ТРның халык артисты (2009). Казан мәдәният ин-тын «хореография» белгечлеге буенча (1981) тәмамлый, Куйбышев исем. ЖБ мәдәният сараеның «Чулпан» (Казан) үзешчән халык биюе ансамблендә эшли. 1984–2000 дә ТРның Җыр һәм бию ансамблендә балет солисты, 2000–2003 тә «Сәйдәш» мәдәният үзәгенең Бию театры сәнгать җитәкчесе. 2003 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында халык биюләре кафедрасында, 2005 тән каф. мөдире, бер үк вакытта «Сәйдәш» студентлар бию ансамбле җитәкчесе. Җыр һәм бию ансамблендә «Мәдрәсәдә булган хәл», «Кияү», «Егетләр», «Колхоз яшьләре», «Кырым татарлары биюе», «Җиңү белән өйгә» һ.б. хореографик композицияләрдә бии. Методик яктан камил, милли ритмнарны югары актёрлык осталыгы, җитезлек, хисле итеп башкаруы



Т.М.Латыйфуллин.

б-н аерылып тора. «Корбан бәйрәме» (1991), «Каз өмәсе» (1992) «Композитор Сара Садыйкова истәлегенә багышланган программа» (1996), «Рамазан» (1997) һ.б. вокаль-хореографик композицияләрнең хореографик өлешләрен куя.

«Сәйдәш» студентлар бию ансамблендә 30 дан артык бию куя. Алар арасында «Урта Идел халыклары биюләре сюитасы», «Сабан туе», «Кубань казаклары биюе», «Ярминкә» һ.б. бар.

«Сәйдәш» — халыкара һәм бөтенроссия конкурслары һәм халык биюләре фестивале лауреаты: 1 нче урын — Истанбул, Төркия (2004); 1 нче урын — Мәскәү (2008); 1 нче урын — Чиләбе (2008).

Төрле елларда рус һәм татар яшь тамашачылар театрларында балетмейстер булып эшли. Балетмейстер сыйфатында бай эчтәлекле композицияләр төзү, халык биюләренең күптөрле пластик материалын һәм төрле халыкларның фольклорын яхшы белүе б-н аерылып тора.

*Б.Н.Горшков.*

**ЛАТЫЙФУ́ЛЛИН** Фәрит Миңнеәхмәт улы (17.7.1955, Азнакай р-ны Уразай а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (2004). Мәскәү инженерлык-физика ин-тының Обнинск ф-лын тәмамлый (1978). 1982 елдан ТатНИПИнефтьтә, информацион технологияләрне үстерү һәм катлам системаларын модельләштерү лаб-ясе мөдире (1999 дан). Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлаштыру технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртүне башкару алымнарын булдырганы һәм сәнәгатькә кертkәне өчен бирелә.

**ЛА́ТЫШЕВ** Александр Николаевич (14.9.1953, Киров өлкәсенең Көлмез р-ны Плотбище пос.), журналист, филос. фән. канд. (1991), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998). Казан ун-тын (1980), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фән. академиясен (1991) тәмамлый. 1973–84 елларда «Ленинская правда» (Түбән Кама ш.) г-тасында фотохәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир урынбасары. 1984–87 дә КПССның Түбән Кама шәһәр ком-тында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире. 1987–88 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1991 дән «Республика Татарстан» г-тасының баш мөхәррир урынбасары, 2004 тән баш мөхәррир.

Х е з м.: Диалектика национального и религиозного в историческом сознании. М., 1991; Дворник и Клотильда // Когда падёт последний бастион. К., 2001.

**ЛА́ЦИС** Мартын Иванович (чын исем-фамилиясе Судрабс Ян Фридрихович) (13/14.12.1888, Лифляндия губ., Веденский өязе, Розенбек волосте Паутины усадьбасы — 11.2.1938), дәүләт, партия эшлеклесе. Приход уч-щесендә белем ала. 1905 елдан

Латыш крае социал-демократиясе (СДЛК) әгъзасы. 1905–07 елгы рев-циядә (Латвия) катнаша, Рига ком-ты һәм СДЛК ҮК пропагандисты. 1908 дә халык укытучысы исеменә имтихан тапшыра, приход уч-щесендә эшли. 1912 дән Мәскәүдә: А.Л.Шанявский ун-тында тыңлаучы, латыш социал-демократлары төркемен оештыручы. 1915 тә революцион эшчәнлеге өчен Иркутск губернасына сөрелә. 1916 да кача, Петроградка кайта, РСДРП(б)ның Петроград ком-ты составына кертелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Выборг ягы большевиклары төркемен җитәкли, Выборг р-нында Кызыл гвардия оештыручыларның берсе; Петроградта Окт. коралллы күтәрелешендә катнаша, Вакытлы революцион ком-т әгъзасы. Окт. рев-циясеннән соң НКВДның коллегия әгъзасы. 1918–21 дә Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясенең коллегия әгъзасы. 1918 нең май–июлендә Бөтенроссия контрреволюция б-н көрәш гадәттән тыш комиссиясенең бүлек башлыгы. 1918 нең июль–ноябрендә Гадәттән тыш комиссия һәм Хәрби трибунал рәисе, Көнчыгыш фронтның Реввоенсовет әгъзасы. Казанда Л. шәһәрне саклау өчен Көнчыгыш фронтның Гадәттән тыш комиссиясен һәм чекистлар отрядын берләштерә. Зөя шәһәрендә армия һәм өяз гадәттән тыш комиссияләрен оештыра. 1918 нең ноябре — 1920 нең сентябрендә Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясенең яшерен-оператив бүлеге башлыгы (бүленеп: 1919 ның апрель–сентябрендә Бөтенукраина гадәттән тыш комиссиясе рәисе). 1921–32 дә адм.-хуҗалык, партия һәм дәүләт эшендә: Главсоль рәисе, Тау сәнәгате баш идарәсе башлыгы урынбасары, РСФСР Җир эшләре халык комис-тының коллегия әгъзасы, ВКП(б) ҮКның авыл бүлеге мөдире урынбасары һ.б. 1932 дән Г.В.Плеханов исем. Халык хуҗалыгы ин-ты директоры (Мәскәү). СССР БҮБК, ҮБК әгъзасы. Кызыл Байрак, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. 1937 дә контрреволюцион милли оешмада торуда гаепләнеп кулга алына, репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Два года борьбы на внутреннем фронте. М., 1920; Чрезвычайная комиссия по борьбе с контрреволюцией. М., 1921.

*Әд.:* К о р о л ё в В.Г. Я.Лацис. М., 1980; Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993.

**ЛАЧЫ́Н КОШЛА́Р** (Falconidae), лачынсыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 60 ка якын төре билгеле, Антарктикадан кала бөтен Җир шары буенча таралганнар. Татарстан терр-ясендә 8 төре бар: *балобан, сапсан*, шоңкар, чеглок, дербник, төн лачыны, гади торымтай, дала торымтае. Очлы озын канатлы, эре һәм уртача зурлыктагы кошлар. Койрыгы тар, чагыштырмача озын. Тәпиләрендә каурый капламы юк. Томшыгында үзенчәлекле тешчеге бар. Яхшы ишетә һәм күрә. Сапсаннан кала барлык төрләре дә күчмә. Күбесенчә ачык ландшафтта, урман буйларында оялыйлар. Сапсанның гәүдә озынлыгы 50 *см*, каурый капламы тыгыз. Аксыл төстәге бугазының як-ягында кара таплар («мыеклар») бар. Канат җәеме 90–110 *см*. Тавышы өзек-өзек. Балобанның — гәүдә озынлыгы 47–56 *см*. Томшык өсте, тәпиләре һәм күз тирәсендәге кайма сары төстә. Тавышы яңгыравыклы. Шоңкар (F. gyrfalco) — эре лачыннарның берсе, гәүдә озынлыгы 60 *см* га якын. Гәүдәсенең өске ягы аркылыга күгелҗем буй төшкән күк төстә, башы караракк, түше кара төрткеле ак төстә. «Мыеклары» күренми. Карлыккан һәм көчле тавышлы. Оя ясамый, ерткыч кошларның яки козгыннарның ояларыннан файдалана. Чеглок (F. subbuteo) — гәүдә озынлыгы 34 *см* га җитә, озын канатлы һәм чагыштырмача кыска койрыклы лачын. Төсе: гәүдәнең өске ягы аркылы буйлы сары-күк, башы караракк, корсак өлеше буй-буй чуар аксыл төстә, койрык өсте җирәнрәк. «Мыеклары» күренеп тора. Томшыгы күксел, томшык өсте һәм аяклары сары төстә. Тавышы көчле, яңгыравыклы. Дербник (F. columbarius) — гәүдә озынлыгы 21–30 *см*, авырлыгы 210 *г* га кадәр. Гәүдәсенең өске өлеше күк, аскы ягы тар буйлы чуар аксыл-җирән төстә. Койрыгы күк, койрык очында кара сызыгы бар. Түбәннән оча, очканда канатлары урáксыман бөгелә; канатларын какмый. Төн лачыны (F. vespertinus) — 30 *см* га кадәр озынлыкта, авырлыгы 160 *г* га кадәр. Канатлары очлы. Ата кошларның каурый капламы соры-кара, койрык өсте җирәнрәк, аяклары кызыл. Ана кошларның өске өлеше аркылы буйлы күк төстә, башы һәм түбәнге өлеше җирән, аяклары кызгылт сары. Ата кошлар кара булганлыктан, аларны «эңгер-меңгер лачыннары» яки «төнге лачыннар» дип йөртәләр. Тавышы яңгыравыклы. Гади торымтай (F. tinnunculus) — гәүдәсе 35 *см* га кадәр озынлыкта, авырлыгы 200 *г* га кадәр. Чуар төстә, ана кошларның өске өлеше аркылы буйлы, күгәрекле-җирән, ата затларда — вак чуарлы кызгылт-көрән. «Мыеклары» күренми диярлек. Канатлары киң, койрыгы озын. Очкан вакытта еш кына койрыгын төшергән килеш канатларын җилпеп бер урында тора. Дала торымтае (F. naumfnni) — Татарстан өчен сирәк кош, республика терр-ясендә ареалының төньяк чиге уза. Гәүдәсенең озынлыгы 32 *см* га җитә. Аркасы күгәрек төсендә, гәүдәсенең аскы өлеше вак чуарлы кызыл төстә; тәпиләре, тырнаклары һәм томшык өсте — сары. «Мыеклары» күренми диярлек. Тавышы яңгыравыклы. Гади торымтайдан ак тырнаклары һәм өске өлешенең ачык төстә (ата зат) булуы б-н аерыла. Л.к. ояларын агачларда, кыяларда, җирдә, сирәк кенә йорт түбәләрендә кора. Моногамнар. 2–6 кызыл яки кызгылт-көрән йомырка салалар. Эре бөҗәкләр, тычкансыман кимерүчеләр, вак кошлар б-н тукланалар, аларны, башлыча, очкан вакытта аулыйлар. Күп кенә халыкларда, ш.и. төркиләрдә шоңкар, сапсан, балобан ау кошлары буларак кулланыла. Чеглоктан кала, барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЛАШКО́В** Вячеслав Александрович (6.4.1959, Биектау р-ны Салмачы а), химия машиналары төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2003), проф. (2004), ТРның атказ. уйлап табучысы (1994). 1982 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, машиналар гыйлеме каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре химия технол. процессларында җылылык-масса алмашуга, ресурс һәм энергия саклаулы технологияләр һәм җиһазлар эшләүгә карый. Уйлап табуга 79 авторлык таныклыгы һәм патенты бар (ТР, РФ һәм якын чит илләрдә гамәлгә кертелгән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Использование приближённых решений А.В.Лыкова для математического описания процесса самозамораживания материалов понижением давления // Инженерно-физ. журн. 2002. Т. 75, № 5 (автордаш); Системы с жидкой фазой в условиях непрерывно понижающегося давления парогазовой среды. К., 2009; Разработка рациональной конструкции сушилки на основе анализа современных технологий сушки // Вест. Казан. технол. ун-та. 2011. Вып. 4 (автордаш).

**ЛАШМА́Н** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 11 *км* төньяктарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 1346 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да мәчет, 3 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2800 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Югары Карамалы волостенда. 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 628, 1890 да — 1342, 1910 да — 1832, 1926 да — 1478, 1949 да — 1722, 1958 дә — 1849, 1970 тә — 2268, 1979 да — 2031, 1989 да — 1376, 2002 дә — 1383 кеше.

**«ЛАШМА́Н БӘЕТЕ́»**, *лашманнар* турындагы циклдан аеруча билгеле *бәет*. Башка бәетләрдән аермалы буларак, «Л.б.» циклында шәхси вакыйгалар турында бәян ителми: анда корабль төзүгә яраклы агач материалларын әзерләү, эшкәртү һәм төяп чыгаручы крәстияннәр тормышы сурәтләнә. Бәет, мөселманнарга хас гадәти күренеш буларак, Аллаһка мөрәҗәгать итү сүзләре б-н башлана. Татар фольклорының традицион образларында күзәтелгәнчә, лашманнарның авыр хезмәте һәм түзеп булмаслык кыен тормыш шартлары турында хикәяләү табигать күренешләренең поэтик тасвирланышы б-н бергә үрелеп бара. Бәет көч җитмәслек эш башкарып вафат булучылар өчен сызлану хисе б-н тәмамлана. Беренче тапкыр «Л.б.» 1929 елда язучы Г.Рәхим тарафыннан нәшер ителә.

*Әд.:* Р ә х и м Г. Халык зарларында // Безнең юл. 1929. № 3–4; Бәетләр. К., 1960; Я р м и Х. Татар халкының поэтик иҗаты. К., 1967; История Татарии в материалах и документах. М., 1937.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЛАШМАННА́Р** (нем. Laschmann, Laschen — кисү, юну, җайлау һәм Mann — кеше), 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халыкның дәүләт файдасына (Россия хәрби-диңгез суднолары төзелеше ихтыяҗлары өчен) агач ма-

териаллары әзерләү, эшкәртү һәм чыгару буенча феодаль йөкләмә үтәүче категориясе. «Л.» атамасы рәсми документларда 19 йөз башында гамәлгә керә, аңа кадәр «корабльләр төзүгә яраклы урманнар әзерләүгә беркетелгән» («Адмиралтейство эшләренә беркетелгән», «Адмиралтействога беркетелгән») төшенчәсе гомум кулланылышта йөри. Л. тарихы Петр I патшаның 1718 ел 31 гыйнвар Фәрманыннан башлангыч ала, анда: «Корабльләр төзүгә яраклы урманнар кисү, эшкәртү, чыгару һәм шуңа охшаш эшләр өчен Казан, Түбән Новгород, Воронеж губерналарыннан, ш.у. Сембер өязеннән йомышлы морзаларны, татарлар, мордвалар һәм чуашларны эшкә алырга» боерык бирелә. Документ гамәлгә кергән вакыттан корабльләр төзүгә яраклы агач әзерләү йөкләмәсе бетерелгәнчегә кадәр (1860) эшләүчеләр контингенты Россия империясенең Идел-Урал төбәгендәге рус булмаган халык вәкилләреннән тора. Сан ягыннан караганда Л. арасында элек-электән *йомышлы татарлар* өстенлек итә.

Чукындырылган әҗнәбиләрне «корабльләр эше»ннән азат итү турында Сенатның 1748 ел 7 декабрь фәрманы чыккач, мордвалар һәм чуашларны массачыл рәвештә православиегә күндерү нәтиҗәсендә, татарларның өлеше тагын да арта. 1 нче ревизия буенча (1719) Л. 56113 ир-ат, 2 нчесе буенча (1742) — 63920, 3 нчесе буенча (1762) — 75621, 4 нчесе буенча (1782) — 99337, 5 нчесе буенча (1796) — 112357 ир-ат исәпләнә. Л.ның иң күбесе Казан губернасына туры килә (3 нче ревизия мәгълүматлары буенча — 60800 кеше). 1799 елда лашманлык йөкләмәсе *ясаклыларга — татарларга,* чуашларга, арларга, мордваларга һәм чирмешләргә дә салына. 6 нчы ревизия (1811) материаллары буенча 7 губернаның 66 өязендә яшәүче Л.ның гомуми саны 943139 ир-ат тәшкил итә. Күпсанлы халык б-н идарә итүнең катлаулылыгы, ш.у. соңыннан беркетелгән күп кенә волостьларның агач әзерләү урыннарыннан еракта булуы (300 дән 1500 чакрымга кадәр) император Александр I не 1817 дә Л. санын 120 мең ир-атка калдыруга этәрә. Аларның күпчелеге әлеге йөкләмәне электән үк үтәгән йомышлы татарларның варислары була. 8–10 нчы ревизия материалларына караганда, алга таба Л.ның саны күп булмый һәм 1835 тә — 160440, 1851 дә — 146798, 1858 дә 120214 ир-ат тәшкил итә.

1718 дә Л. б-н җитәкчелек итү *Казан адмиралтействосына* йөкләнә. 1731 дән Л. икеләтә бәйлелектә була: аларның агач әзерләү эшенә — Казан адмиралтействосы конторасы, эштән буш вакытта губерна һәм провинция канцелярияләре күзәтчелек итә. Император Екатерина II заманында Л. б-н идарә итү 1782 дән Казан һ.б. казна палаталары хөкемендә була, император Павел I заманында Адмиралтейство коллегиясе бүлекчәләренә йөкләнә. 1817 нең 25 августында «Корабльләр төзүгә яраклы урманнар әзерләү идарәсе төзелү» уңаеннан йөкләмәне үтәүгә бәйле мәсьәләләр килеп чыгу сәбәпле Л., яңадан оештырылып, Казанда урнашкан һәм Финанс министрлыгына буйсынудагы Корабльләр төзүгә яраклы урманнар буенча түбәнге округ идарәсе карамагына бирелә; башка яктан алар урыннардагы хакимият органнарына буйсыналар. Җирле идарәнең түбәнге инстанциясе булып лашманнар волосте исәпләнә. Авыл старостасы һәм волость старшинасы һәр эшләүченең «вакытында килеп җитүе һәм төзек хәлдә» булуы өчен җавап бирәләр. Җәяүлеләрдән өс һәм аяк киеме, балталар һәм «азык-төлек юнәтүгә җитәрлек чаралар» булу таләп ителә; атлылардан «атлар һәм ат дирбияләре» булуы сорала. Лашманлык йөкләмәсе яшәгән чорда аны үтәгән Л.ның хәленә берничә тапкыр үзгәрешләр кертелә. Баштарак эшләүчеләрнең яше 15–60 яшь дип билгеләнә, 1797 дән агач әзерләүгә 18–55 яшьтәге кешеләр җәлеп ителә башлый. 1729 да Л. өчен законлы рәвештә 2 эш сезоны билгеләнә: җәйге — 1 апрельдән 1 октябрьгәчә, кышкы — 1 октябрьдән 1 апрельгә кадәр. 1799 дан җәяүле урман кисүчеләр 1 октябрьдән 18 декабрьгә кадәрге чорда нарядлар үтәргә тиеш булалар, атлылар урман чыгаруга агач киселү һәм чана юлы әзерлегенә карап җибәрелә (1817 дә әлеге сроклар 10 декабрьдән 20 мартка кадәр дип тәгаенләнә). Адмиралтействога беркетелгәннәр эшкә ел саен түгел, ә билгеләнгән чират буенча җәлеп ителә. 1718–19 да ук инде һәр сезонга билгеләп куелганнар нисбәте җәйга салына: «көздән һәм кышын алты айга 9 ар кешедән, атлы һәм җәяүле; ел әйләнә 25 әр кешедән, атлы һәм 2 җәяүле». Агач әзерләүгә җибәрелгән Л. саны дәүләтнең корабльләр төзүгә яраклы агач материалларына ихтыяҗы б-н (ул Россиянең хәрби кампаниясе вакытында кискен арта) тыгыз бәйләнештә була. 18 йөздә эшкә чакыру уртача 4–8 елга бер туры килә, ә агач әзерләү һәм чыгару б-н шөгыльләнүчеләр саны гасыр ахырына ел саен 2 дән 4 меңгә кадәр кеше исәпләнә. 1817 дә эшкә тартылучылар саны 8 мең күләмендә билгеләнә, тик чынлыкта бу сан азрак була. Йөкләмә гамәлгә кергән баштагы елларда Л. агач әзерләүне түләүсез башкаралар. Эшкә килмәүчеләр яисә аннан качып китүчеләр җәй көне Казандагы верфьтә транспорт суднолары төзелешендә эшләргә тиеш булалар. 1727 дән Л. га хезмәтләре өчен түләнә башлый: җәйге чорда атлы эшчегә көненә 10 тиен, җәяүлегә 5 тиен; кышкы чорда — тиңдәшле рәвештә, 6 шар һәм 4 әр тиеннән түләү карала. Эшләп табылган акчалар җан башына салынган салым буларак исәпләнәләр һәм Адмиралтейство карамагына күчәләр. Йөкләмәләрен үтәү мөмкинлеге булмаган очракта (авыру сәбәпле, яшькә карап һ.б.) Л. үзләре урынына ирекле рәвештә эшләүчеләр яллап, аларга рәсми бәядән 2–2,5 тапкыр артыграк түләргә тиеш булалар. Алга таба, инфляция һәм җан башына салым күләмнәре арту нәтиҗәсендә, хезмәт көненә түләү берничә мәртәбә үзгәреш кичерә. 1817 дә ул җәяүлегә 40 тиен, атлыга 80 тиен күләмендә билгеләнә. 18 йөзнең соңгы чирегендә Л.га өйдән агач әзерләү урынына килү һәм кире кайту вакыты өчен, ш.у. турыдан-туры эш вакытындагы күчеп йөрүләре өчен дә түли башлыйлар. Л.ның хезмәт һәм көнкүреш шартлары чиктән тыш авыр була, корабль төзү эшләренең «заводныкыннан чагыштыргысыз дәрәҗәдә газаплырак» икәнлеген хәтта хакимият вәкилләре дә таный. Күп кенә Л. гарипләнә, төрле авырулар һәм бәхетсезлек очраклары аркасында һәлак була. Авыр хезмәт шартлары, эшченең үз йортында озак вакыт булмавы сәбәпле шәхси хуҗалыгының таркалу хәленә килүе, Адмиралтейство һәм гражданлык чиновникларының башбаштаклыгы, корабль эшләре йөкләмәсеннән тыш башка йөкләмәләр үтәргә мәҗбүр ителү эшкә беркетелгәннәрдә ризасызлык тудыра һәм аларны үз хәлләрен җиңеләйтү һәм йөкләмәне бетерү өчен көрәшкә этәрә.

Л.ның күпсанлы үтенечләренә җавап йөзеннән, хөкүмәт күп мәртәбәләр (1729, 1763, 1774, 1824) аларны ирекле ялланып эшләүчеләргә алыштыруга омтылыш ясый. Әмма ирексез хезмәтнең арзанлыгы һәм казна өчен файдасы агач әзерләүнең элеккеге тәртибен саклап калуга сәбәп булып тора. Хакимиятләр тарафыннан Л.га карата ясалган иң зур ташлама аларны аерым чорларда (1722–37, 1757–66, 1817–60) рекрутлыктан азат итү була. 19 йөз уртасына, агачтан төзелгән җилкәнле флотның әкренләп юкка чыга баруы һәм Россиянең тимер корабльләр төзүгә йөз тотуы б-н бәйле рәвештә, лашманлык йөкләмәсенең әһәмияте кими. 1859 да корабльләр төзүгә яраклы урманнар Диңгез министрлыгыннан Дәүләт милке министрлыгы карамагына бирелә. Император Александр II нең 1860 елның 28 март Фәрманы б-н Л. дәүләт крәстияннәре гомуми разрядына күчерелә. Л. һәм лашманлык йөкләмәсе турындагы истәлекләр Идел-Урал төбәге халыкларында тарихи риваятьләр һәм бәетләр (*«Лашман бәете»*), торак пунктлар (мәс., Чирмешән р-ны Лашман а.) һәм топографик объектлар атамаларында (Лашман тракты, Чуаш лашманлыгы, Мачта юлы һ.б.ш.) сакланып калган.

*Әд.:* Фирсов Н.В. Инородческое население прежнего Казанского царства в новой России до 1762 г. и колонизация закамских земель в это время. К., 1869; Семевский В.И. Крестьяне в царствование Екатерины II. СПб., 1901. Т. 2; Даишев С.И. Лашманы Среднего Поволжья в первой половине XIX в. // Вопросы аграрной истории Среднего Поволжья: Дооктябрьский период. Йошкар-Ола, 1978; Кленянкин А.В. Лашманы // Вопр. истории. 1978. № 6; Ногманов А.И. Законодательство XVIII в. об участии нерусского населения Среднего Поволжья на адмиралтейских работах // История и исторический процесс. Н.Новгород, 2005.

*А.И.Ногманов.*

**ЛАШЧЫ́** елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 21 *км*, бассейнының мәйданы 100,5 *км²*. Елга Чуаш Респ-касы Яльчик р-нының Лащ-Таяба авылыннан һәм Буа р-нының Югары Лашчы авылыннан башланып киткән ике су агымының бергә кушылуыннан барлыкка килә. Тамагы — Күзби авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Л. елгасының су җыелу терр-ясе урмансыз диярлек. Л.ның 0,8 дән алып 2,7 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы

0,33 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 74 *мм*, ташу агымы катламы 65 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Югары агымында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,012 $м^3/с$, түбәнге агымнарында елга кибә. Суы язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Л. бассейнында су күләме 1,3 млн. $м^3$ булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ЛАШЧЫ́** тимер юл разъезды посёлогы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 10 *км* төньяктарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 350 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 74%) яши. Электр-механика з-ды. Китапханә. 1940 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Халык саны: 1989 да — 292, 2002 дә — 324 кеше.

**ЛАШЧЫ́ БАШЫ́**, к. *Югары Лашчы* (Буа р-ны).

**«ЛӘЙЛӘ́ ИЛӘ́ МӘҖНҮ́Н»**, мәхәббәт турындагы гомумтөрки романтик *дастан*. Шәрекътә киң таралыш тапкан. Урта Азиядә барлыкка килә. «Мәҗнүн», ягъни «Акылын югалткан» (Ләйләгә булган мәхәббәтеннән) дип йөртелүче гарәп шагыйре Кайс ибне Мүәд (7 йөз) турындагы риваятьләргә нигезләнгән. Шактый гына фольклор һәм китап вариантлары бар. Урта гасырлар Шәрекъ әдәбиятында бу гашыйкларның гомумбилгеле исемнәрен илаһи мәхәббәт символы буларак еш искә алу сюжетның киң танылганлыгы турында сөйли. Низами Ганҗәвинең шул исемдәге әсәрендә (1188) шактый охшашлыклар табарга мөмкин. Археографик экспедицияләр вакытында тупланган чыганаклар «Л.и.М.»нең фольклор һәм әдәби вариантлары татар мохитендә һәм шигъри, һәм чәчмә формада киң таралган булуын дәлилли. Дастанның аеруча танылган татарча чәчмә варианты «Татар халык иҗаты: Дастаннар» (1984) китабында урын алган. Анда Низами әсәреннән бераз читкә тайпылулар күзәтелә: мәс., Мәҗнүннең Нәүфәл кызына өйләнү эпизоды юк; Ләйләнең этисе хуҗа дәрәҗәсендә булмый. Мәҗнүн исә чит-ят җирләрдә түгел, ә Ләйләнең кабере өстендә җан бирә. Ләйлә һәм Мәҗнүн сюжеты күп кенә татар әдипләренең игътибарын җәлеп итә. Г.Динмөхәммәд мулланың шул исемдәге әсәре (19 йөз), Ф.Халидинең «Мәшһүр гашыйк-мәгъшука Ләйлә вә Мәҗнүн хикәясе» (1902), Г.Рәшидинең «Ләйлә вә Мәҗнүн хикайәте» (1917) мәгълүм.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов М. Ләйлә белән Мәҗнүн кыйссасының татарча вариантлары // Казан утлары. 1979. № 6; Бертельс Е.Э. Низами: Творческий путь поэта. М., 1956.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЛӘКЕ́** (Дербенка) елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кичү елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 8,4 *км*, бассейнының мәйданы 39,5 $км^2$. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Дербедень авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Кичү авылының төньягындарак. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагыныкы — 113 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. Л.нең 1,8 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 $км/км^2$. Туенуы катнаш. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 138 *мм*, ташу агымы катламы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,09 $м^3/с$. Суы язын уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЛӘКЕ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 13 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 383 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1691 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Петропавловск исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.дә Петропавел чиркәве (иске чиркәү (1782 дә салына) урынында 1893 тә төзелә), земство мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2210,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 700, 1897 дә — 1111, 1913 тә — 1503, 1920 дә — 1456, 1926 да — 1173, 1938 дә — 1008, 1949 да — 956, 1958 дә — 901, 1970 тә — 1019, 1979 да — 798, 1989 да — 478, 2002 дә — 445 кеше.

**ЛӘКЛӘКСЫМАННА́Р** (Ciconiidae), ләкләксыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. Зур кош, гәүдәсенең озынлыгы 70 *см* дан 1 *м* га кадәр, авырлыгы — 3–4 *кг*. Канатлары озын һәм киң. Томшыгы озын, нык. Тавыш ярылары үсмәгән, тавышны томшыгы б-н чыгара. 17 төрне берләштерүче 11 ыруг, башлыча, тропик, субтропик һәм уртача зоналарда таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Кара ләкләк (Ciconia nigra) — республикада оялаучы төр. Баш, муен, аркасындагы каурый капламы кара, түше һәм корсагы ак төстә. Урманның сазлыклы тыныч урыннарын өстен күрә. Яшерен яшәү рәвеше алып бара. Май–сентябрьдә очрый. Оясын агачларда кора һәм аннан кабат файдалана. Җир-су хайваннары, балык, суда яшәүче умырткасызлар, сирәк кенә вак имезүчеләр б-н туклана. 2–5 соргылт-ак йомырка сала, балаларны ана һәм ата кош 30 көн тирәсе утырып чыгара. Даими пар булып яшиләр. Кара ләкләк ТРның Кызыл китабына кертелгән. Ак ләкләк — республика фаунасы өчен сирәк очып килүче төр. Лаеш, Яшел Үзән, Буа р-ннарында күренгәли.



Кара ләкләк.

*Әд.:* Аськеев И.В., Аськеев О.В. Орнитофауна Республики Татарстан. К., 1999.

**ЛӘМБРӘ́ РАЙОНЫ́**, *Мордва Республикасының* үзәгендә урнашкан. 1933 нең 20 июлендә оештырыла. Мәйданы — 880 $км^2$. Үзәге — Ләмбрә авылы (Саранскидан 12 *км* төньяктарак). Халкы — 33,9 мең кеше, ш.и. 10,8 мең татар (2002). Татарлар, нигездә, Аксун (1564 кеше), Пунәт (271), Свәрби (359), Мельцан (67), Кырви (940), Ләмбрә (4380), Чирмеш (431), Пензятка (1209), Щербаково (90), Тарасполь (5), Таулы (810), Сырка (408) һәм Хаҗи (144) авылларында яшиләр. Бу якларга алар 1640 еллар тирәсендә Темников йомышлы татарларына биләмә җирләре бирелү сәбәпле килеп урнаша. 1920–30 елларда татар мәктәпләре Смольково, Свәрби, Таула, Пензятка авылларында була. 1954 кә кадәр Ләмбрә авылында татар пед. уч-щесе эшли. Хәзерге вакытта районда 8 милли мәктәп бар, аларда татар теле укытыла. 11 мәчет бар. Ләмбрәдә Татар милли мәдәни үзәге (1991 дә оештырыла, рәисе Р.А.Ипкаева), «Умырзая» җыр һәм бию ансамбле (1969, 1972 дә «халык коллективы» исемен ала), «Чулпан» (1987) һәм «Дуслык» (2004) эстрада ансамбльләре; Свәрби авылында «Зөләйха» фольклор ансамбле (1995) эшли. 1992 дән атнага бер тапкыр татар телендә «Туган тел» радио тапшырулары чыга. 2004 тә «Мордва Республикасы халыклары телләре — Россиянең мәдәни казанышы» республика фестивале кысаларында «Мәдәниятләрнең аралашуында татар теленең роле» татар мәдәнияте бәйрәме үткәрелә. 2002 дән Ләмбрәдә гарәп телен өйрәнү курслары оештырыла. 2002 дә Аксюн авылында яңа мәчет ачыла. Татарстан б-н Л.р. арасында тыгыз мәдәни элемтәләр урнаша: татар мәдәнияте эшлеклеләре б-н очрашулар уза, һәр ел Л.р.нда уздырыла торган Сабан туе бәйрәменә ТРның Буа һәм башка районнарыннан иҗат коллективлары килә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында тәҗрибә уртаклашу чаралары үткәрелә, Казанда «Умырзая» ансамбле чыгыш ясый. Л.р.нда Сов. Союзы Геройлары А.А.*Баляев* һәм Ф.Х.*Чураков* туган.

**ЛӘРГЕ́ БАЛЫКЛАРЫ́**, зәңгелә балыклары (Phoxinus), карплар семьялыгыннан балыклар ыругы. 10 га якын төре билгеле, Европа, Азия һәм Төньяк Америка елгаларында яши. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Гади зәңгелә (Ph. phoxinus) Урман Зәе, Бөрсет, Кече Шомбыт, Өлә һ.б. үтә күренмәле чиста сулы, ташлы һәм комлы төпле елга бассейннарының инеш һәм кече елгаларында

яши; калын кыска гәүдәле, 5–7 *см* озынлыктагы зур булмаган балык, бер-берсенә ятмаган бик вак тәңкәле; сырты коңгырт-яшел; үрчү чорында аеруча ачык төскә керә. Күл зәңгеләсе (Ph.percnurus) йомык сулыкларда яши; гәүдәсе 12,5 *см* озынлыкта; бер-берсенә яткан тәңкәләре эре яки уртача зурлыкта; сырты кара, күпсанлы кара таплар б-н капланган. 1–2 елдан җенси яктан өлгерә. Гади зәңгелә уылдыкны өлешләп язын, күл зәңгеләсе җәен чәчә. Үрчемлелеге 18,7 мең уылдык бөртеге. Судагы умырткасызлар, балык маймычлары, сирәк кенә суүсемнәр б-н туклана. Кәсәбәчелек әһәмияте юк. Гади зәңгелә ТР-ның Кызыл китабына кертелгән.

**ЛӘТЧӘ́** (Mustela nivalis), сусарсыманнар классыннан имезүче ерткыч хайван. Евразия, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада таралган. ТР терр-ясендә барлык районнарда да очрый. Болын, сазлык, урман буйларында, печән кибәннәрендә, хуҗалык каралтыларында яши. Гәүдәсе сузынкы, сыгылмалы, нәзек, озынлыгы 15–26 *см*, койрыгы



2–7 *см*; авырлыгы 40–100 *г*. Башы кечкенә, колаклары кыска һәм киң. Мыеклары озын һәм күзләре өстендә кыллар бар. Тәпиләрендәге тырнаклары конуссыман, нәзек һәм үткен. Мехы куе, кыска, кышын ак, җәен гәүдәнең өсте соргылт-кызыл, асты ак төстә. Оясын тычкан өннәрендә, агач тамырлары, чыбык-чабык өемнәре астында ясый. Парлашу вакыты — март–апрельдә. Балалары (3 тән 10 га кадәр) май–июнь аенда туа. Л. — кимерүчеләрнең барлык яшеренү урыннарына керә алучы бердәнбер ерткыч. Башлыча вак кимерүчеләр, ш.у. кошлар һәм бакалар б-н туклана. Төп дошманы — ас. Еш кына Л. башка ерткыч хайваннар һәм кошлар корбаны була. Кәсәбәчелек әһәмияте юк, әмма тычкансыман кимерүчеләрне юк итеп зур файда китерә.

**ЛӘТЫЙФӘ́**, Шәрекъ халыклары фольклоры һәм әдәбиятында, ш.и. татар сүз сәнгатендә кече эпик жанр. Гарәп, фарсы һәм төрки-татар телләрендә *мәзәк* һәм ***хикайәт*** жанрлары б-н беррәттән кулланыла. Л.гә кыскалык, юмористик яки сатирик яңгыраш, көтелмәгән чишелеш хас; омонимия, ирония, алогизм, күпмәгънәлелек, гипербола һ.б. сәнгатьчә чаралар, телнең стилистик алымнары киң файдаланыла. Л. жанрында язылган әсәрләр еш кына тематикаларына һәм персонажларына (Хуҗа Насретдин, Бирбал) карап төркемләнәләр; төрки-татар шагыйре *Сәйф Сараи* һ.б. иҗатында очрый. 19 йөздә берничә Л. җыентыклары басыла («Ләтаифе Хуҗа Насретдин» һ.б.).

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ЛӘҮХӘ́** (гарәп. لوحة) (язулы такта, рәсем-картина, игълан), изге язулы такта; татарларда Коръәннән төрле аятьләр һ.б. текстлар б-н бизәп язылган панно; тукымага чигелә, еш кына кысага алына һәм диварга эленә; *шамаилнең* бер төре. Л. композицияләрендә гарәп графикасындагы язулар, гадәттә, ефәк, киҗе-мамык һ.б. тукымаларның уртасына нагыш яки элмәләп чигү (к. *Чигү*), ***укалап чигү*** техникаларында чигелә, еш кына төрле сары төстәге бизәкләр б-н каймалана. Польша-Литва татарларында Л. «мухир» (гарәп. мөһер, штамп) дигән гомуми исем б-н йөри. Билгесез авторларның 1930–60 елларда иҗат иткән («Z. L» һәм «М. А.» тәхәллүсе б-н), З.Мицкевич (Белосток ш.) һәм З.Смайкевич (Гданьск ш.) тарафыннан чигелгән Л. үрнәкләре Бохоники һәм Кружнианы авыллары мәчетләрендә саклана (Польша). Алар автор стилистикасының индивидуальлеге б-н аерылып тора, кайбер Л. композицияләрендә мәчет рәсемнәре дә очрый. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында чигүле багышлау тексты түшәмә һәм нагыш чигү техникасында каймаланган Л.нең сәнгати үрнәге (авторы — Касыйм татары Г.Карамышева) ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее экспозициясенә куела. 1990 еллардан башлап, күп кенә Казан рәссамнары Л.не укалап чигү б-н иҗат итәләр (А.Кудряшова, А.Липина, О.Марсова, Л.Фәсхетдинова һ.б. ); Л.ләр «Туран» милли мәдәният үзәге фонды» остаханәләрендә әзерләнә. Л. үрнәкләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, ТР Милли музее, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли музее, Касыйм шәһәренең төбәк тарихын өйрәнү музее фондларында һәм шәхси тупланмаларда сакланалар.

*Әд.:* Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003; D r o z d A., D z i e k a n M., M a i d a T. Pismiennictwo i muhiry Tatarow polsko-litewskich. Katalog Zabytkow Tatarskich. Warsz, 2000. V.3.

*Г.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЛӘШӘ́Ү-ТАМА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 245 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Л.-Т.та су тегермәне була, 20 йөз башында мәчет, 3 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1363,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 498, 1897 дә — 813, 1913 тә — 948, 1920 дә — 950, 1926 да — 646, 1938 дә — 564, 1949 да — 444, 1958 дә — 415, 1970 тә — 408, 1979 да — 369, 1989 да — 226, 2002 дә — 215 кеше.

**ЛЕ́БЕДЕВ** Александр Александрович (1.4.1843, Казан — 29.4.1910, шунда ук), җәмәгать эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1888). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1863). 1877–78 елгы рус-төрек сугышында катнаша. 1866–68 елларда Казан губернасы Мамадыш өязенең мировой арадашчысы. 1868–74 тә Казанның участок мировой судьясы. Бер үк вакытта,







**Ләүхә.** 1. Ефәк, киҗе-мамык һәм ефәк җепләр. Нагыш, тырнак алмалау. 19 йөз; 2. Бәрхет, алтын һәм көмеш ука. Укалап чигү. Рәссам А.Кудряшова. 2002. 3. Бәрхет, алтын һәм ефәк җепләр, ялтыравыклар. Укалап чигү, чәмчә, нагыш. Рәссам А.Липина. 2005.

1871–79 да Казан–Царёвококшайск округы мировой судьялары съезды рәисе; 1874–1910 да Казан өязендә, 1875–78 дә Казан губернасы Мамадыш өязендә, 1878–83 тә Вятка губернасы Малмыж өязендә шәрәфле мировой судья. 1883–88, 1899–1903 тә Казан шәһәре башлыгы. Л.ның эшчәнлеге янгын командаларының финанс ягын ныгыту, шәһәрне төзекләндерү, халык мәгарифен үстерү һәм Казан уку йортлары укытучылары һәм укучыларының матди хәлен яхшыртуга юнәлдерелә. Болак елгасы аша тимер күпер салуга зур суммада акча бирә. Казан шәһәр думасы гласные (1880 нән). Казан губернасы Дворяннар җыены депутаты (1890 нан). Казан реаль уч-щесенең шәрәфле попечителе (1875–78). Казан ярлыларга ярдәм итү попечительләр ком-ты рәисе (1885–89). Болак аша салынган күпер һәм Казандагы бер урам Л. исемен йөртә; Казан реаль уч-щесендә һәм Мария кызлар гимназиясендә исемле стипендияләре булдырыла.

*Әд.:* Достойны памяти потомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛЕ́БЕДЕВ** Алексей Борисович (9.9.1960, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1995), проф. (2002). 1982 елда Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук филос. кафедрасында эшли. 1984–89 елларда Казан химия-технол. ин-тының шул исемдәге кафедрасында. 1989–2003 тә Казан консерваториясенең филос. һәм гуманитар фәннәр кафедрасында. 2003 тән Казан ун-тының филос. каф. профессоры. Хезмәтләре рухани тормыш теориясе, социол.-филос. методологиясе, рус философиясе тарихына карый.

Х е з м.: Духовное производство: сущность и функционирование. К., 1991; Русская православная соборность и протестанский индивидуализм как паттерны европейского менталитета. К., 2004.

**ЛЕ́БЕДЕВ** Евгений Павлович (15.3.1938, Украина ССРның Черкассы өлкәсе Каменка ш. — 4.6.2004, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1983), проф. (1985), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1982). 1961 елда Днепропетровск химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Нефть химиясе производстволары фәнни-тикшеренү ин-тында (Уфа) эшли. 1969 елдан Бөтенсоюз ясалма каучук фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында: үзе оештырган термочыдам эластомерлар лаб-ясе мөдире, директор урынбасары (1987 дән), бер үк вакытта, 1987–90 да, «Ясалма каучук заводы» ФҖБдә ген. директор урынбасары, 1990 нан «Силикон» кече фәнни-җитештерү пр-тиясе директоры. 1992 дән Махсус билгеләнешле каучуклар фәнни-тикшеренү ин-ты лаб-ясе мөдире, 1997 дән фәнни технология үзәге директоры, 2002 дән заводның үзәк лаб-ясе башлыгы, 2003 тән «Ясалма каучук заводы» АҖнең силикон эластомерлар лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре кремнийорганик кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә карый. Л. структурасында силоксан (Si-O-Si), силазан (Si-NH-Si), силтианлы (Si-S-Si) буыннары булган кушылмаларны синтезлый һәм аларның үзлекләрен, реакциягә керү мөмкинлеген, куллану өлкәләрен өйрәнә. Силоксан җитештерү продуктлары һәм ярымпродуктлары технологиясен, органик, нәорганик һәм элементорганик кушылмаларны силирлауның эффектлы алымнарын эшли. Л. җитәкчелегендә җитештерүгә махсус үзлекләре булган силоксан каучуклар, резина катнашмалары, герметиклар, компаундлар, силоксан каучук тотрыкландыргычлары, силикон резиналар өчен термототрыкландыргычлар һәм үзлекләрен көйләү модификаторлары, органоциклосилоксаннарны анионлы полимерлаштыру катализаторы кертелә («Ясалма каучук заводы» ФҖБ). Силоксан каучуклар һәм резиналар җитештерүдән калган калдыкларны эшкәртү һәм утильләштерү технологиясен эшли һәм гамәлгә кертә. Л.ның фәнни эшләре электротехникада, электрон, кабельләр сәнәгатендә, машиналар төзелешендә һ.б. тармакларда, махсус техникада кулланыла. Уйлап табуга 140 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыятенең А.М.Бутлеров исем. бүләге лауреаты (1979). Халыклар Дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Силиконовые герметики (производство, области применения) // Производство и потребление герметиков и других строительных композиций. К., 1997 (автордаш).

**ЛЕ́БЕДЕВ** Николай Алексеевич (18.4.1957, Казан), нефтьче, техник фән. канд. (1983), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1980). «НИИнефтепромхим» АҖдә эшли (1980–92), институт директоры (1992–97), АҖнең ген. директоры (1997 елдан). Л. — пластларның нефть бирүчәнлеген арттыру һәм нефть табу процессларын химияләштерү өчен 30 дан артык төрдәге химия продуктларын җитештерүне оештыра. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге ТРда авыр чыгарыла торган нефть ятмаларының нефть бирүчәнлеген күтәрүнең нәтиҗәле технологияләр комплексын эшләгәне һәм сәнәгатьтә киң кулланышка керткәне өчен бирелә.

**ЛЕ́БЕДЕВ** Николай Павлович (21.10.1933, Казан — 4.1.1998, шунда ук), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. канд. (1969), РФнең атказ. геологы (1994). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), шунда ук эшли. Хезмәтләре нефть һәм газ чыганакларын эзләүгә карый. Л. Урал-Идел буе үзәк районнарындагы палеозойга кадәрге утырмаларда углеводородлар таралуның төп геол. үзенчәлекләрен ачыклый (автордаш).

Х е з м.: Критерии оценки перспектив нефтегазоносности рифей-вендских отложений Татарии // Критерии оценки перспектив нефтебитуминосности. К., 1989 (автордаш).

**ЛЕ́БЕДЕВ** Сергей Фёдорович (12.9.1885, Тобол губ. Ишем ш. — 27.3.1956, Мәскәү), гамәли механика һәм машиналар белеме өлкәсе галиме, проф. (1949), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1953). Томск технол. ин-тын тәмамлый (1912). 1913–20 елларда Суджа шахтасында (Томск ш.) техника бүлеге башлыгы. 1920–23 тә Томск технол. ин-тында. 1923–27 дә Иваново-Вознесенск политехник ин-тында (1923–24 тә машина детальләре каф. мөдире, 1924 тән проф.). 1927–35 тә Мәскәү механика ин-тында. 1935–54 тә Казан авиация ин-тында машина детальләре каф. мөдире. Хезмәтләре механикага һәм машиналар белеменә карый. Материаллар каршылыгы өлкәсендә тикшеренүләр алып бара. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сопротивление материалов: В 2 ч. М., 1929–30; Детали машин. М., 1935; Цилиндрические зубчатые колёса Бакенгем. М., 1935.

**ЛЕ́БЕДЕВА** Нина Максимовна (2.4.1928, Омск ш. — 4.12.2001, Казан), химик-технолог., техник фән. д-ры (1973), проф. (1976), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан технол. ин-тында эшли, нефть ф-ты деканы (1965–70), гомуми химия технологиясе каф. мөдире (1976–90). Хезмәтләре органик кушылмалар оксидлаштыруның радикал-чылбырлы процессларына, гетероген процесслар технологиясенә карый. Л. актив өслекле матдәләр һәм синтетик юу матдәләре алу өчен күбекле-элпәле режимда парафинсыман углеводородлар оксидлаштыру процессы технологиясен эшли һәм аппаратур формалаштыра. Аның тарафыннан нефть продуктларын күкертле кушылмалардан сульфоксидлар һәм сульфоннар аерып алу рәвешендә чистарту алымнары тәкъдим ителә. Фәнни эшләре Новокуйбышевск һәм Новоуфимск химия комб-тларына кертелә. Уйлап табуга 28 авторлык таныклыгы бар. СССР МС бүләге лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ориентированная адсорбция катализаторов и кислородсодержащих соединений в поверхностном слое углеводородов // Журн. прикладной химии. 1974. Т. 47, № 11 (автордаш); Окисление жидких парафиновых углеводородов // Нефтехимия. 1982. Т. 20, № 5 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ – КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**ЛЕ́БЕДЕВА** Ольга Сергеевна, к. *Гөлнар ханым.*

**ЛЕБЕ́ДИНО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 елда 470 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 54%, татарлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. Хәзерге Л. 1930 елларда Иске Лебедино (17 йөз уртасында нигез салына; 18 йөздә Яңа Пановка, Русские Шигалки исемнәре б-н билгеле) һәм Яңа Лебедино (19 йөздә нигез салына) авыллары кушылу нәтиҗәсендә төзелә. 1861 елгы реформага кадәр ике авыл халкы да алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарттыру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Иске Лебединода Троица чиркәве, земство мәктәбе (1897 дә ачыла), кирпеч з-ды, тимерчелек, йон тетү, йон-тукыма ману остаханәсе, ярма яргыч, 6 җил тегермәне, 7 вак-төякләр кибе-

те эшли; Яңа Лебедино авылында 4 җил тегермәне, 1 казна шәраб һәм 1 вак-төякләр кибете була. 1920 гә кадәр 2 авыл да Казан губернасының Спас өязе Левашёво волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: (Иске Лебедино һәм Яңа Лебедино а.) 1782 дә — 169 ир-ат; 1859 да — 1032 (521), 1897 дә — 1882 (791), 1908 дә — 2041 (799), 1920 дә — 2324, 1926 да — 2168, 1938 дә — 1189, 1949 да — 788, 1958 дә — 1101, 1970 тә — 1026, 1979 да — 759, 1989 да — 614, 2002 дә — 585 кеше.

**ЛЕ́БЕДЬ** Семён Степанович (25.7.1934, Белоруссия ССРның Витебск өлкәсе Козяны а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994). Милләте буенча татар. 1953 елда Белоруссия урман техникасы ин-тын (хәзер Белоруссия технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, Осиповичи леспромхозында эшли (1958–61). 1961 дән Белоруссия технол. ин-тында, урман машиналары һәм урман материалы хәзерләү технологиясе каф. профессоры (1992). Агач материалларын төяү, алардан пакетлар формалаштыру һәм бүрәнә эшкәртү өчен мобиль машиналар төзегәндә кулланыла торган төяү-формалаштыру җайланмалары булдыру өстендә эшли (Чернобыль зонасында гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 48 авторлык таныклыгы бар. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Математическое моделирование процесса формирования пакетов цилиндрических изделий // Изв. вузов. Лесной журн. 1986. № 1 (автордаш); Неустановившееся движение заготовок в процессе загрузки // Технология и оборудование заготовки и переработки древесины. 1989. Вып. 4; Обоснование параметров загрузочных устройств // Технология и оборудование заготовки и переработки древесины. 1991. Вып. 6.

**ЛЕБЁДКА** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,3 *км*, бассейнының мәйданы 45,2 *км*$^2$. Яңа Чишмә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Новопоселённая Лебёдка авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы — Лебёдка посёлогыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 64 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Л.ның 0,4 тән алып 2,6 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, якынча дүрттән өч өлешен кар сулары алып тора. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 94 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпеллык чыгымы 0,037 *м*$^3$*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ЛЕБЁДКА** посёлогы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 17 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чишмә һәм Лебёдка елгалары кушылган урында урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1894 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 509 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 244, 1897 дә — 338, 1908 дә — 419, 1920 дә — 507, 1926 да — 450, 1938 дә — 552, 1949 да — 403, 1958 дә — 277, 1970 тә — 154, 1979 да — 77, 1989 да — 26, 2002 дә — 2 кеше.

**ЛЕБЯ́ЖЬЕ** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 717 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — игенчелек, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да Успение чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1778 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Алексеев волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1921–22 дә Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 398 ир-ат; 1859 да — 1269, 1897 дә — 1025, 1908 дә — 1378, 1920 дә — 1439, 1926 да — 1408, 1938 дә — 932, 1949 да — 605, 1958 дә — 814, 1970 тә — 684, 1979 да — 596, 1989 да — 483, 2002 дә — 563 кеше.

**ЛЕВА́ДНАЯ** (чын фамилиясе Измайлова) Ольга Георгиевна (2.6.1958, Украина ССРның Сумы ш.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2008). 1971 елдан Казанда яши. Казан индустриаль-пед. техникумын тәмамлый. 1978 дән Казанның Мәскәү районы ВЛКСМ ком-тында статист, 1981 дән кибет администраторы, 1988 дән Мәскәү р-ны ЗАГСында эшли. «Кар көтеп яшим» («В ожидании снега живу», 1992), «Сихри божра аша узу» («Пройти заколдованный круг», 1998), «Канат җилпешем» («В свободном падении вверх», 2003), «Уйлар баскычыннан менгәндә» («Поднимаясь по лестнице раздумий», 2005), «Кошлар тавышыннан хатирәләр туа» («Из крика птиц растут воспоминания», рус, татар, инглиз, төрек телләрендә, 2005), «Йолдызлар капкасы» («Звёздные врата», 2010) исемле шигъри җыентыклар авторы. Л. поэзиясенә лирик һәм фәлсәфи яңгыраш, ритмлылык һәм музыкальлек хас. Г.Р.Державин исем. әдәби бүләк лауреаты (2007).

**ЛЕВАКО́ВСКИЙ** Николай Фёдорович (28.4.1833 — 26.4.1898), ботаник, биол. фән. д-ры (1868). Харьков ун-тын тәмамлаганнан соң (1857), Екатеринослав (хәзерге Днепропетровск ш.) шәһәре гимназиясендә эшли. 1865–67 елларда Харьков, 1867–88 дә Казан (1869 дан проф., 1875–81 дә проректор) ун-тларында. Хезмәтләре экол. факторларның үсемлекләр морфологиясенә һәм үсешенә тәэсир итүен өйрәнүгә карый. Л. экспериментальфитоценологиягә нигез сала. Россиядә беренчеләрдән булып үсемлекләр арасында үзара бәйләнешне, тышкы факторларның аларга тәэсирен өйрәнә. Мимозаларның хәрәкәт реакцияләре механизмнарын экологик шартларга бәйләп аңлата.

Х е з м.: О влиянии некоторых внешних условий на форму корней // Уч. зап. Казан. ун-та. 1868. Вып. 3–4; К вопросу о вытеснении одних растений другими. К., 1872; К вопросу о влиянии среды на форму растений. К., 1873; Физиология растений. К., 1876.

*Әд.:* М а р к о в М.В. Из истории Казанской геоботанической школы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1952. Т. 112, кн. 7.


**ЛЕВА́НОВ** Валерий Николаевич (27.5.1952, Юдино пос.), гидрогеолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Казан ун-тының геол.(1974) һәм экол.(1995) ф-тларын тәмамлый. 1974–79, 1981–89 елларда «Татнефтегеофизика» ҖБдә (Әлмәт ш.), 1989 дан «Татнефть» АҖ системасында; 1992 дән Татарстан геологик разведка идарәсендә, баш гидрогеолог (2003 тән), «Гидрогеология» фәнни-житештерү үзәге башлыгы (2008 дән). 2001–03 тә ТР Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының гидрогеология һәм файдалы каты казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыгаручы районнарындагы шәһәрләрне су б-н тәэмин итү өчен җир асты су чыганакларын санлы модельләштерүгә нигезләп эзләүнең югары нәтиҗәле алымын эшләгәне өчен бирелә.

**ЛЕВА́НОВ** Валерий Петрович (9.5.1939, Мордва Респ-касы, Ичалковский р-ны Кергуды а.), хор дирижёры, педагог, проф. (2001), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1995), ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1975–1980). 1963 елда Казан консерваториясен (С.Казачков классы) тәмамлый. 1963–66 да Йошкар-Ола музыка уч-щесе укытучысы, 1966 дан Казан консерваториясенең хор дирижёрлыгы кафедрасында. Бер үк вакытта, 1966–2005 тә Казан ун-тының хор капелласында сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры. Капелла репертуарында бөтендөнья хор әдәбиятының иң яхшы әсәрләре башкарыла. Л. җитәкчелегендәге коллектив Россия һәм чит илләрдә уңышлы чыгышлар ясый, халыкара, бөтенроссия һәм республика фестивальләрендә һәм конкурсларында лауреат исемнәрен яулый.

*Әд.:* «Ave, капелла». К., 2005.

**ЛЕВА́НОВ** Владимир Алексеевич (7.1.1928, Бөгелмә кантоны Ивановка а. — 24.12.1981, Әлмәт ш.), нефтьче, бораулау мастеры, Соц. Хезмәт Герое (1971). Бораулау мастерлары мәктәбен тәмамлый (Әлмәт, 1964). 1952 дән «Баулынефть» трестында. 1953–81 дә (бүленеп) «Әлмәтбораулаунефть» трестында,

бораулау мастеры. 1968 дә «Главтюменьнефтегаз» АҖнең Мамонтов бораулау эшләре идарәсенә эшкә җибәрелә, бораулау мастеры булып эшли (1977 кадәр). Герой исеме нефть чыгару буенча бишьеллык (1966–70) планны үтәгәндәге казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәренең Геройлар аллеясында бюсты куелган.



В.А. Леванов.

*Әд.:* Три миллиарда: История. М., 2007.

*М.Ж.Гаитов.*

**ЛЕВАШЁВО** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Алексеев — Базарлы Матак автомобиль юлы буенда. 2010 елда 400 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Владимир Мәрьям Ана (1870 тә төзелә; архит-ра истәлеге) һәм Архангел Михаил чиркәве, земство мәктәбе (1886 да ачыла), кредит ширкәте, телефон станциясе, 4 тимерче алачыгы, 3 ярма яргыч, 7 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3021 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Левашёво волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 284 ир-ат; 1859 да — 1033, 1897 дә — 1520, 1908 дә — 2009, 1920 дә — 1502, 1926 да — 1258, 1938 дә — 946, 1949 да — 622, 1958 дә — 713, 1970 тә — 616, 1979 да — 531, 1989 да — 393, 2002 дә — 412 кеше.

**ЛЕВАШЁВО** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Л.да чиркәү, җил тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 186,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 398, 1913 тә — 266, 1920 дә — 283, 1926 да — 216, 1938 дә — 272, 1949 да — 288, 1958 дә — 212, 1970 тә — 108, 1979 да — 51, 1989 да — 18, 2002 дә — 12 кеше.

**ЛЕВАШО́В** Сергей Васильевич (5.7.1857, Тула губ., Белёв өязе Погорелое а. — 1919, Одесса ш.), терапевт, медицина д-ры (1879), җәмәгать эшлеклесе. 1876 елда С.-Петербург мед. хирургия академиясен тәмамлагач, шунда ук эшли: 1879 дан клиник госпитальдә, 1883 тән С.П.Боткин җитәкчелегендә эчке авырулар клиникасында. 1884 тән фәнни эш б-н чит илләрдә (Бреславль, Лейпциг ш.) фәнни командировкада. 1886 дан Казан ун-ты мед. ф-тының факультет терапиясе кафедрасында ординар проф. 1903–12, 1917–19 елларда Новороссийск ун-тында (Одесса ш.): 1907 дән мед. ф-ты деканы, 1912 елга кадәр ректор. Париж терапия җәмгыяте мөхбир әгъзасы (1899). 1912–17 дә 4 нче Дәүләт Думасы депутаты. Билгесез шартларда һәлак була. Хезмәтләре эчке органнар иннервациясе мәсьәләләренә, трофик һәм тамыр хәрәкәте нервларын тикшерүгә, плеврит, үт ташлары авыруын, тимгелле тиф һәм корсак тифын, ваба, йөрәк авыруларын дәвалауга; кымыз б-н дәвалауга карый.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Попелянский Я.Ю., Архангельский Т.В. Профессор Сергей Васильевич Левашов // Казан. мед.журн. 1991. № 2.

**ЛЕ́ВИН** Иосиф Фомич (26.11.1938, Воронеж ш.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Тельман исем. с-зда агроном булып эшли. 1962 елдан Казакъстан ССРның Кустанай өлкәсе Орджоникидзе р-ны «Кошаровский» с-зында агроном, 1963 тән а.х. җитештерү идарәсендә, 1968 дән Баулы р-ның а.х. терр.-җитештерү идарәсендә. 1974–81 дә ТАССР а.х. министрлыгында баш агроном-мелиоратор. 1981–88 дә «Татгипроводхоз» ин-тында баш белгеч. 1986–99 да «Татрапс» АҖдә баш агроном. «Татарстан кыры» ФҖБнең «Азык бодае» (1999), «Кызыл шәрекъ» АҖнең «Сыра кайнату арпасы» (1999 дан) төркемнәре җитәкчесе. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге «Туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен модуль-блоклы культиваторлар җитештерүне булдыру һәм технологик нигезләү» исемле хезмәте өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛЕ́ВИН** Яков Абрамович (24.4.1935, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1980), проф. (1988). 1957 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз кинофото фәнни-җитештерү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1963 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, нефтехимик (1983 тән), органик (1994 тән) синтез лаб-ияләре мөдире, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2002 дән), эксперт-аналитик бүлек башлыгы (2004 тән), бер үк вакытта, 2003 тән Казан технол. ун-тының Эластомерлар эшкәртү үзәгенең баш фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. Л. азотлы гетероцикллар химиясен өйрәнә. Фосфор төшләренең химик полярлашу күренешен ача, фосфорорганик кушылмаларның гомолитик әверелешләре кинетикасының төп закончалыкларын һәм механизмнарын билгели. Фосфорорганик мономерларның радикаль полимерлашуын һәм сополимерлашуын өйрәнә. Ясалма каучуклар производствосында эре тоннажлы мономерлар аерып алу һәм чистартуда термополимерлауны ингибирлау процессын кертә. Функциональләшкән оксираннар синтезлауның сәнәгый ысулын тәкъдим итә, аның нигезендә кинофотоматериаллар өчен дуплавыч, рак авыруына каршы *глицифон* препараты алу технологиясе эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Криптосинтез концепциясен булдыра, металл эшкәртү һәм югары сыйфатлы тимер-бетон әйберләр җитештерү өчен май һәм майлагыч-суыткыч сыеклыкларны калдыксыз алу ысулларын эшли. Квант химиясе алымнары б-н тетрафосфатетраэдран, тетраарсатетраэдран һәм икеләтә чиксез алты буынлы гетероцикллар стереоизомериясен билгели, газ фазасында һәм эремәләрдә нитроксил радикаллар төзелешен билгели, макроцикллар төзелү мөмкинлекләрен өйрәнүнең квант-химик методологиясен тәкъдим итә. Фәнни эшләре «Түбәнкаманефтехим», «Тасма» җитештерү берләшмәләрендә кертелә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994).

Х е з м.: Гомолитическая химия фосфора. М., 1978 (автордаш); Реакционная способность органических соединений в реакциях замещения терт-бутоксильным радикалом // Журн. органической химии. 1980. Т. 16, № 3 (автордаш); Аминоамидины. IV, 3 диарил-4-ариламиноимидазолийхлориды из № 1, № 2 — диарил-N-арилглицинамидинов // Журн. орган. химии. 1993. Т. 29, № 3 (автордаш).

**ЛЕВИРА́Т** (лат. levir — каенага, каене, ирнең агасы яки энесе), тол хатынның үлгән иренең абыйсы яки энесенә кияүгә чыгуының мәҗбүрилеге яисә кулайлыгы. Тарихи яктан Л. борынгы төркемле өйләнешү мөнәсәбәтләре традицияләренә барып тоташа (левиратлы полиандрия). Патриархат Л. шартларында әлеге йоланың таралуына өйләнешү түләве барлыкка килү сәбәп була. Үлгән кешенең балалары булмаса, Л. нәселне дәвам итүнең мәҗбүри булуын күздә тоткан дини карашлар б-н дә хуплана. Күп кенә халыкларда, ш.и. татарлар арасында да таралган була. Татарларда ш.у. башка йола — сорорат (лат. soror — сеңел), тол ирнең үлгән хатынының сеңлесенә (балдызга) өйләнү гадәте дә билгеле. Мондый өйләнешү беренче никахтан туган балаларны тәрбияләүне кайгырту булса да, еш кына кабат никахка кергәндә яңа түләүдән — *калымнан* котылуны да күздә тоткан.

*Әд.:* М у с и н а Р.Н. Семья и семейный быт // Татары. М., 2001; Народы России: Энцикл. М., 1994.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ЛЕВИ́ТСКИЙ** Пётр Иванович (1.10.1838, Пенза губ. Краснослободск ш. — 11.4.1880, Варшава), терапевт, медицина д-ры (1886). 1862 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук терапия клиникасында эшли, 1867 дән хосусый патология һәм терапия каф. профессоры.

1871 дә «Лесгафт эше»нә каршы чыккан һәм эшеннән җибәрелгән 7 профессорның берсе. 1873 тән Варшава ун-тының махсус патология һәм терапия каф. профессоры. 1875 тә Варшава клиникасы җитәкчесе һәм Александра-Мария исем. кызлар ин-тында кинәшче. Хезмәтләре кеше организмына химик матдәләр (бромлы патассий, хинин һ.б.) тәэсирен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О влиянии сернокислого хинина на температуру и кровообращение // Мед. вестн. 1869. № 19; 24–26; О некоторых способах изучения действия ядов на сосуды // Мед. вестн. 1870. № 6.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ЛЕГЕ́НДА** (лат. legenda, сүзгә-сүз тәрҗемәсе — укылырга тиешле нәрсә), әдәбият һәм фольклор жанры; дөреслеккә дәгъва итүче фантастик характердагы хикәя. Л. еш кына дини карашлар, татарларда — ислам һәм Коръәндә бәян ителгән вакыйгалар б-н бәйле. Татар фольклорында Л.ның берничә төркемен аерып күрсәтергә мөмкин:

1. Космогоник — дөнья һәм күк җисемнәренең яралуы турында: «Җир ничек ялралган?» — җирнең дөнья океаны төбеннән үрдәк тарафыннан чыгарылган кечкенә генә балчыктан барлыкка килүе; «Күкнең күтәрелүе» — күкнең җирдән аерылуы; «Ай өстендәге Зөһрә кыз», «Зөһрә кыз» — Айның ятимә кызны усал үги ана җәбер-золымнарыннан коткаруы турында һ.б.

2. Зоогоник — үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы турында: «Чыршы нигә мәңге яшел?» — Болгар ханы алып кайтырга кушкан тере суны батырның ялгыш чыршы төбенә түгеп бетерүе хакында; «Усак яфраклары» — Гали батыр хатыны Фатыйманың усак агачы төбендә иренең хыянәтләренә түзә алмыйча елавыннан яфракларның йөрәк рәвешен алуы, ә агачның баллы суы ачыга әйләнүе хакында; «Ни өчен мәче өйдә, эт тышта яши?» — эт б-н мәченең ярлы хуҗаларының мирасын — иске өй б-н каткан ипи кисәген бүлешүләре, шул вакыттан алып этләрнең ишек алдында, ә мәчеләрнең өйдә яши башлаулары турында.

3. Героик — каһарманнар, пәһлеваннар, *алыплар* турында: «Зур гәүдәле кеше» — пәһлеван хакында, бала-чага аны күрүгә үлә торган була; «Болгар пәһлеваны» — Болгар ханында хезмәттә булган, шлемы зур казаннан эшләнгән, коралын беркем дә урыныннан кузгата алмый торган пәһлеван турында. Кайбер Л.ларда баһадир хатын-кызлар да очрый (ихтимал, әлеге персонажларның барлыкка килүе матриархат чорына барып тоташадыр: «Дәфгый һәм аның сеңлесе» — пәһлеван Дәфгый (тамыры б-н йолкып алынган имән аның коралы була) һәм аның шундый ук көчкә ия сеңлесе турында.

4. Чын тарихи шәхесләр турында: Атилла, Кубрат хан, Идегәй, Колшәриф, Сөембикә һ.б. Гадәттә, аларның тормышларындагы аеруча әһәмияткә ия вакыйгалар бәян ителә.

5. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам диненең таралуы б-н бәйле Л.лар (иң зур күпчелекне тәшкил итүче төркем): «Айдархан һәм сәхабәләр» — Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләренең Айдархан падишаһның авыру кызы Туйбикәне терелтүләре, шуннан соң Болгар шәһәрендә яшәүче бар кешенең дә ислам динен кабул итүе турында; «Габдешшәмс» — чал сакаллы бер картның геройның төшенә кереп аның Габдешшәмс («шәмс» — кояшка табынучы) түгеллеген, ә Габдрахман («рахман» — Аллаһка табынучы) булуын әйтүе, шуннан соң Габдешшәмснең ислам динен кабул итүе турында; «Туйбикә мәдрәсәсе» — Болгар шәһәрендә иң зур кызлар мәдрәсәсе тотучы Туйбикә абыстай, аның әмере б-н 66 якка таралып кешеләрне ислам диненә өндәүче 66 шәкерте турында; «Сөләйман хуҗа» — Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан Мәккәдән Болгарга ислам динен тарату максаты б-н җибәрелгән изге Сөләйман турында. Бу төркемгә керүче кайбер Л.ларның нигезен чынбарлыкка туры килә торган нинди дә булса вакыйга яки тарихи эпизод тәшкил итә, ул үз чиратында уйдырма күренешләр, күп кенә фантастик элементлар б-н тулыландырыла. Кайвакыт Л. б-н риваятьне аерып булмый. Л.ның төп үзенчәлеге — анда уйдырманың шактый киң кулланылуы, фантастикага, могҗизаларга бай булуы.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; У р м а н ч е Ф. Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2002.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ЛЕ́КАРЕВО** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 17 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2010 елда 361 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1920 елларда Ленино исемен йөртә. 1960 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекчелектә эшли. 20 йөз башында Л.да волость идарәсе урнаша, Крестовоздвижение чиркәве (1812–30 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе, китапханә (1896 да ачыла) эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмгатенең имана җире 4001,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1255, 1887 дә — 1636, 1905 тә — 1978, 1920 дә — 1863, 1926 да — 1927, 1938 дә — 1274, 1949 да — 774, 1958 дә — 625, 1970 тә — 582, 1979 да — 438, 1989 да — 336, 2002 дә — 344 кеше.

**ЛЕ́КСИКА** (грек. lexikṓs — сүзгә кагылышлы), а) теге яки бу телнең һәм җирле сөйләшләрнең сүзлек составын тәшкил итүче сүзләр җыелмасы; б) сөйләмнең билгеле бер төренә караган сүзләр: көнкүреш Л.сы, фәнни Л., балалар Л.сы, рәсми Л. һ.б.; в) стилистик кулланылыш буенча уртак сүзләр җыелмасы: нейтраль Л., югары Л., поэтик (шигъри) Л., интернациональ Л.; г) теге яки бу кеше (автор) сөйләмендә кулланыла торган сүзләр җыелмасы, аның теленең сүзлек составы: Г.Тукай, Г.Ибраһимов һ.б.ның лексикасы.

Л. *лексикология*, семасиология, ономасиология, *диалектология*, *фразеология* тармакларының өйрәнү предметы булып тора.

«Л.» төшенчәсе, гадәттә, телнең 3 аспектындагы (авазлар составы, лексик һәм грамматик чаралар) аермаларга һәм капма-каршылыкларга нигезләнә. Сүзләр һәм сүзтезмәләрдән гыйбарәт булган лексик чаралар авазлар составы һәм грамматик чаралар б-н берләттән теләсә кайсы телнең нигезен тәшкил итә һәм аның универсаль билгеләре булып килә ала. Л. төрле юллар б-н барлыкка килгән сүзләрне үз эченә ала (к. *Этимология*). Күптәннән килә торган татар Л.сы, ягъни сүзләрнең төп лексик-семантик төркемнәре — кардәшлек терминнары, тән төзелешенә караган сүзләр, кыргый һәм йорт хайваннарының исемнәре, предмет атамалары (*исем*), предметның билгесен, сыйфатын белдерә торган сүзләр (*сыйфат*), эш-хәрәкәтне белдерүче сүзләр (*фигыль*) һ.б. гомумтөрки сүзлек фондын тәшкил итә һәм төрки телләрнең барлык төркемнәрендә дә күрсәтелә («Борынгы төрки сүзлек»тә (М.–Л., 1969) чагылыш таба). Татар Л.сында төрки тамырлы сүзләрдән башка төрле телләрдән кергән *алынмалар* да бар. Иң борынгы алынмаларга борынгы иран, кытай, санскрит телләреннән кергән сүзләр карый. Монгол, маньчжур (баһадир, бәрәңге), фин-угор (миләш, поши) сүзләрен берләштерган гомуми лексик катлау аерылып тора. 10–16 йөзләрдә ислам дине б-н бергә татар теленә гарәп (к. *Гарәп алынмалары*) һәм фарсы (к. *Фарсы алынмалары*) сүзләре, 17 йөздән *рус алынмалары* үтеп керә. 19 йөз ахырында грек һәм латин морфемаларына ия булган терминнарның саны зур тизлек б-н арта (к. *Терминология*).

Л. һәрвакыт үсеш-үзгәрештә: чынбарлык күренешләре б-н бәйле рәвештә, ул яңа предметларны, күренеш, хәлләрне, төшенчәләрне белдерүче яңа сүзләр б-н даими тулыланып тора. Бу сүзләр *неологизмнар* дип атала; телдә ныгып җитеп, алар яңа булудан туктый һәм төп сүзлек фондына керә.

Лексик составның артуы төрлечә гамәлгә ашырыла: 1) сүз ясагыч чаралар ярдәмендә (к. *Сүз ясалышы*); 2) сүзләрнең яңа мәгънәләре барлыкка килү хисабына (к. *Полисемия*); 3) *конверсия* юлы б-н яңа сүз ясау нигезендә; 4) башка телләрдән яңа сүзләр алу нәтиҗәсендә; 5) төрле кыскартулар барлыкка килү хисабына (к. *Аббревиатура*). Искергән лексик берәмлекләр һәрвакытта да юкка чыкмый, аларның кайберләре телнең пассив сүзлек фондына күчә (к. *Архаизмнар, Тарихи сүзләр*).

Л.да эчтәлекләре ягыннан — абстракт сүзләр, *синонимнар, антонимнар*; әйтелешләре ягыннан *омонимнар,* омографлар, омофоннар, паронимнар аерып күрсәтелә. Л.ны теркәп баруның төп чарасы булып сүзлекләр хезмәт итә, ә сүзлекләрне төзү теориясен һәм практикасын, үз чиратында, *лексикография* өйрәнә.

*Әд.:* Хәзерге татар әдәби теле. К., 1965; Ә х ә т о в Г.Х. Хәзерге татар теленең лексикологиясе. К., 1979; С а ф и у л л и н а Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. К., 1999.

*И.Б.Бәширова.*

**ЛЕКСИКОГРА́ФИЯ** (грек. lexikós — сүзлек һәм *графия*), *тел белеменең* сүзлекләр төзү теориясен һәм практикасын тормышка ашыручы тармагы. Практик Л. (сүзлек эше) иҗтимагый әһәмияткә ия функцияләр башкара; ул телләр өйрәнү (туган тел, чит телләр), туган телне тасвирлау һәм нормага салу өчен, телара аралашу чарасы буларак, теге яки бу телнең сүзлек составын (лексикасын) фәнни яктан өйрәнү өчен кирәк. Практик Л. үсешендә төрле халыкларда, ш.и. татарларда да 2 чорны аерып өйрәнәләр: 1. Иң әүвәлге сүзлекләр чорына (11–18 йөзләр) татар теленең безнең заманнарга килеп җиткән иң борынгы сүзлекләре карый: «Төрки, монгол, фарсы һәм башка телләр сүзләрен туплаган тәрҗемә сүзлек китабы» («Китабе мәҗмуге тәрҗемане төрки вә гаҗәми вә магули вә фарси», 1245), «Төрки телләргә аңлатмалар бирү китабы» («Китаб әл-идрак ли-лисан әл-әтрак», 1312), Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булатның «Гарәпчә-төркичә-татарча сүзлек» китабы (16 йөз), *«Кодекс Куманикус»* һ.б.; 2. Л. зур үсеш алган чорда (19 йөз башы) телнең сүзлек составын тасвирлау һәм нормага китерү, җәмгыятьнең тел культурасын күтәрү бара; төрле, ш.и. орфографик, грамматик, *аңлатмалы, фразеологик сүзлекләр* чыга башлый.

Татар Л.сендә терминологик сүзлекләр төзү аеруча өйрәнелгән юнәлеш булып тора. Аңа 19 йөз ахырында К.*Насыйри* тарафыннан нигез салына. Бу эш 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында, 1970 елларда һәм, аеруча, икътисад, җитештерү һәм мәдәниятнең барлык тармаклары буенча 70 тән артык терминнар сүзлекләре чыгарылган 1990 елларда актив алып барыла. Мондый сүзлекләр төзегәндә Л.гә караган мәсьәләләрне өйрәнү һәм хәл итү Л. теориясе үсешенә этәргеч бирә. Соңгысының формалашып һәм ныгып җитүе 20 йөзнең 2 нче яртысына туры килә.

Теоретик Л. яңа төр сүзлекләрне, сүзлек макроструктурасын (сүзләрне сайлап алу, сүзләрнең һәм сүзлек мәкаләләренең урнашу принцибы, турыдан-туры лексикографиягә кагылмаган материалны — грамматик мәкаләләр, иллюстрацияләр һ.б.ны кертү) һәм микроструктурасын (аерым бер сүзлек мәкаләсе) өйрәнү, эшкәртү б-н һәм аларның гомуми типологиясе б-н шөгыльләнә. Татар Л.се мәсьәләләре Ф.Ә.Ганиев, Ф.С.Сафиуллина, М.Ногман, Д.Б.Рамазанова, Ш.С.Ханбикова һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла.

Л. тел белеменең барлык тармаклары, аеруча *лексикология* һәм компьютер лингвистикасы б-н тыгыз бәйләнештә тора.

*Әд.:* Ногман М. XVII–XVIII йөзләрдәге русча-татарча кулъязма сүзлекләр. К., 1969; Миңнуллин К., Вәлиуллин Р. Татар теле — сүзлекләрдә. К., 1998; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Компьютерная лингвография. К., 1995.

*Д.Б.Рамазанова.*

**ЛЕКСИКОЛО́ГИЯ** (грек. lexikós — сүзгә кагылышлы һәм *...логия*), *тел белеменең* телдәге сүзлек составын — *лексикасын* өйрәнә торган тармагы. Л.нең өйрәнү предметы — *сүз*. Телнең төп берәмлеге буларак, сүзләр өч аспектта өйрәнелә: структур (төзелеше), семантик (сүзнең мәгънәсе), функциональ (сүзнең тел структурасындагы һәм сөйләмдәге роле). Структур аспектта сүз *сүзтезмә* б-н чагыштырып карала, сүзнең аналитик формасы тикшерелә, сүзформа категориясе билгеләнелә. Сүзгә семантик анализ ясау мәсьәләләре б-н *семантика* шөгыльләнә. Бу очракта сүзнең мәгънәләре өйрәнелә, лексикологик категорияләре (моносемия һәм *полисемия*), ш.у. сүзләрнең конкрет һәм абстракт, туры һәм күчерелмә мәгънәләре аерып күрсәтелә. Функциональ аспектта сүз телнең гомуми төзелеше һәм эшчәнлегендәге роле күзлегеннән чыгып карала.

Л. телнең лексикасын система буларак өйрәнә. Әлеге системаны барлыкка китерүче сүзләр төркеме күләмнәре, лексик берәмлекләрнең форма яки мәгънә охшашлыклары ягыннан аерылырга мөмкин. Формалары ягыннан охшаш аерым лексик берәмлекләр *омонимнар* барлыкка китерә; лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга мөнәсәбәтле рәвештә мәгънәләре ягыннан бер-берсенә якын, ягъни мәгънәдәш сүзләр (*синонимнар*), капма-каршы мәгънәдәге сүзләр (*антонимнар*) һ.б. аерып күрсәтелә.

Телнең лексик составы бертөрле генә түгел. Ул берничә категориягә бүленә: кулланылыш сферасына карап — гомумхалык теле сүзләре һәм билгеле бер шартларда, билгеле бер сөйләштә, аерым бер иҗтимагый катлау телендә кулланылучы сүзләр (*гади сөйләм, диалектизмнар*); тарихи күренеш буларак — *архаизмнар, неологизмнар*; сүзләрнең килеп чыгышы ягыннан — *алынмалар, варваризмнар, интернациональ сүзләр*; кулланылыш активлыгы ягыннан — актив һәм пассив сүзләр.

Л. телнең сүзлек составын тулыландыру һәм үстерү юлларын тикшерә; аның 4 ысулын аерып күрсәтә, шуларның 3 се телнең эчке ресурсларыннан файдалануга нигезләнә: яңа сүзләр ясалу (к. *Сүз ясалышы*), яңа мәгънәләр (полисемия, мәгънә күчеше), сүзтезмәләр барлыкка килү; дүртенче ысул башка телләрдән яңа сүзләр алуны күздә тота — алынмалар (лексик алынмалар һәм *калькалар*).

Гомуми, хосусый, тарихи, чагыштырма һәм гамәли Л. бар. Гомуми Л. сүз төзелеше, функциясе һәм үсешенең гомуми закончалыкларын билдирә; хосусый Л. аерым бер телнең сүзлек составын тикшерә; тарихи Л. теге яки бу әйбер-затның, төшенчәләрнең тарихы б-н бәйле рәвештә аларны белдерүче сүзләрнең тарихын өйрәнә; чагыштырма Л. сүзләрнең генетик якынлыгын билгеләүне күздә тота; гамәли Л. 4 тармакны үз эченә ала: *лексикография*, тәрҗемә, лингвопедагогика һәм сөйләм культурасы.

Л. казанышлары күп кенә фәннәрдә кулланылыш таба: психолингвистика (сүзләр ассоциациясен (бәйләнешен) өйрәнү), нейролингвистика (афазия төрләре), социолингвистика (телнең иҗтимагый асылын өйрәнү) һ.б.

Татар Л.се тел белеменең аерым тармагы буларак 1970 елларда аерылып чыга. Аңа Г.Х.Әхәтов, М.З.Зәкиев, Р.Х.Мөхиярова, К.С.Сабиров, Ф.С.Сафиуллина, В.Х.Хаков һ.б.ның хезмәтләре нигез була. Л.нең төрле тармакларына караган шактый гына хезмәтләр бар (синонимия — Ш.С.Ханбикова; интернациональ сүзләр — М.Б.Хәйруллин; фразеология — Г.Х.Ахунҗанов; этимология — Р.Г.Әхмәтьянов; ономастика — Ф.Г.Гарипова, Г.Ф.Саттаров, Р.Х.Субаева һ.б.).

*Әд.:* Сабиров К.С. Лексикология // Хәзерге татар әдәби теле. К., 1965; Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. К., 1999; Мөхиярова Р.Х. XX гасырның 80–90 нчы елларында татар әдәби теле лексикасы. Яр Чаллы, 2000.


*И.Б.Бәширова.*

**ЛЕЛЕ́ЙКИН** Михаил Никифорович (8.11.1905, хәзерге Тула өлкәсенең Горбачёво пос. — 16.6.1993, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1954). Хезмәт эшчәнлеген 1929 елда Мәскәү авиация з-дында токарь булып башлый. 1941–86 да Казан авиация ҖБдә: мастер, технолог, бүлек җитәкчесе, баш технолог урынбасары, баш технолог (1960–72). Дәүләт бүләге универсаль җайланмалар һәм стапельләр конструкциясен җыюда яңа технологияләр кулланып, самолётлар җитештерүдә яңа ысуллар эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Октябрь Революциясе, ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Д.С.Фәхретдинов.*

**ЛЕЛЬВИ́Ж** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы бассейнында урнашкан, 2010 елда 561 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1623,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдекбаш волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 358, 1884 тә — 387, 1905 тә — 424, 1920 дә — 628, 1926 да — 688, 1938 дә — 789, 1949 да — 614, 1958 дә — 594, 1970 тә — 725, 1979 да — 620, 1989 да — 477, 2002 дә — 595 кеше.

**ЛЕ́ЛЮХ** Валерий Алексеевич (23.2.1943, Кемерово өлкәсенең Прокопьевск ш.), тренер (су тубы спорты), РСФСРның атказ. тренеры (1984). 1970 елда Омск физик культура ин-тын тәмамлый. 1966–75 тә балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә йөзү һәм су тубы спорты буенча тренер (Прокопьевск), 1975–95 тә «Синтез» командасында өлкән тренер, бер үк вакытта Волгоград физкультура ин-тының Казан ф-лында укытучы (1975–85), 1995 тән 8 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер (Казан). Шәкертләре арасында: Н.И.Шәрәфиев — СССР халыклары спартакиадасы чемпионы (1983), А.Ю.Бойко — Европа чемпионнары Кубогы һәм Суперкубогы иясе (1983).



Н.В.Лемаев.



А.С.Леман.

**ЛЕМА́ЕВ** Николай Васильевич (1.11.1929, Урта Идел крае, хәзерге Самара өлкәсе Красный Яр а. — 24.12.2000, Мәскәү), дәүләт, хакимият-хуҗалык эшлеклесе, Соц. Хезмәт Герое (1980), техник фән. д-ры (1982), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1985), СССРның атказ. уйлап табучысы (1985). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1956). 1950–60 елларда Новоуфимск нефть эшкәртү з-дында (Уфа) эшли: оператор, җайланма, цех башлыгы, баш инженер урынбасары. 1960–63 тә ТАССР ХКСның Химия сәнәгате идарәсе башлыгы урынбасары. 1963–85 тә Түбән Кама нефть химиясе комб-ты («Түбәнкаманефтехим» ҖБ) директоры, ген. директоры. 1985 тән СССР нефть эшкәртү һәм нефть химиясе министрының беренче урынбасары, 1989 дан министры, 1989–90 да СССР химия һәм нефть эшкәртү сәнәгате министры. 1991 дән «Нефтек-Техно» АҖ (Мәскәү) президенты, бер үк вакытта, 1997 дән «Түбәнкаманефтехим» АҖнең директорлар советы рәисе. Л. җитәкчелегендә Татарстанда кыска вакыт эчендә илдәге һәм Европадагы иң эре нефть химиясе пр-тиесе — «Түбәнкаманефтехим» төзелә, анда нефть газыннан һәм нефть химиясе продукциясенең халык хуҗалыгының күп тармакларында киң кулланыла торган башка прогрессив төрләреннән этилен, дивинил, этилен окисе, изопрен-мономер, ясалма каучук җитештерү үзләштерелә; Түбән Кама шәһәре төзелә. Хезмәтләре нефть эшкәртү технологиясенә карый. Уйлап табуга 68 авторлык таныклыгы бар. СССР МС бүләге лауреаты (1973). Герой исеме нефть химиясе һәм нефть эшкәртү сәнәгатен үстерүдәге хезмәтләре, «Түбәнкаманефтехим» ҖБдә изопрен каучук җитештерү өчен комплекс төзүдә һәм аны сафка бастыруда ирешелгән зур уңышлары өчен бирелә. 1967–71 дә ТАССР, 1971–80, 1985–90 да РСФСР ЮСлары депутаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» (вафатыннан соң) орденнары б-н бүләкләнә. Түбән Камада Л.ка һәйкәл куелган, скверга аның исеме бирелгән.

Х е з м.: Автоматизированное управление газофракционными установками. М., 1980 (автордаш); Устремлённость. К., 1985.


*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЛЕ́МАН** Альберт Семёнович (7.7.1915, Саратов губ. Вольск ш. — 3.12.1998, Мәскәү), композитор, пианист, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның халык артисты (1968), РСФСР һәм Чуаш АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1965). 1940 елда Ленинград консерваториясен композиция (М.Гнесин классы), 1941 дә фортепиано буенча (В.Нильсен классы) тәмамлый. 1941–42 дә Ленинград шәһәре башкарма ком-тында Сәнгать эшләре идарәсенең музыка бүлеге мөдире. 1942 дә Казан шәһәренә эвакуацияләнә, репрессияләнә (1942–45). Казан консерваториясен оештыруда актив катнаша, 1945–69 да шунда ук укыта; махсус белгечлекләр буенча кафедралар оештыруда булыша. 1948–49, 1961–69 да музыка теориясе һәм композиция каф. мөдире (1961 дән проф.), 1964–67 дә консерваториянең проректоры була. 1969–71 дә Ленинград, Петрозаводск, 1971 дән Мәскәү консерваторияләрендә (1972–97 дә композиция каф. мөдире) укыта. Композиция, махсус фортепиано, камера ансамбле классларында пед. эшчәнлек алып бара. Татарстан һәм РСФСРның автономияле респ-калары өчен композиторлыкка кадрлар әзерләүдә Л.ның роле аеруча зур. Аның шәкертләре арасында композиторлар: Ф.Әхмәтов, Ә.Бакиров, Р.Белялов, А. һәм Х.Вәлиуллиннар, Р.Еникиев, А.Луппов, Л.Любовский, А.Монасыйпов, Б.Мөлеков, Б.Трубин, И.Шәмсетдинов, И.Якупов, М.Яруллин, М.Алексеев, Ф.Васильев, Э.Сапаев, Т.Фандеев, А.Чыргал-Оол; пианистлар: Э.Әхмәтова, И.Гобәйдуллина, Ф.Старателева бар. Мәскәү консерваториясендә эшләү дәверендә композиторлык белеме бирү концепциясен эшләүгә, студент-композиторларның фестиваль һәм конкурсларын оештыруга, консерваториянең композиторлар ф-ты өчен укыту программаларын төзүгә зур игътибар бирә. Аның классы төрле милләтләр яшь композиторларын үзенә җәлеп итү үзәге булып тора.

Л.ның иҗаты өчен даими яңарыш һәм өзлексез эзләнү хас. Ул, татар милли моңы үзенчәлекләрен уңышлы үзләштереп, шул нигездә «Татар көйләре» сюитасын, симф. оркестр өчен Татар рапсодиясен, Оркестр б-н скрипка өчен концерт (№ 1) һ.б. зур күләмле әсәрләрен иҗат итә. 1960–70 елларда язган зур әсәрләре арасында «Ленин», «Атлантлар» ораторияләре, Оркестр б-н скрипка өчен концерт (№ 2), Оркестр өчен концерт-каприччио һ.б. бар. Л. әсәрләренә югары интеллект, концептуаль мәгънә һәм техник камиллек хас.

Төп әсәрләре: 5 симфония, оркестр б-н фортепиано өчен 4 концерт, оркестр б-н скрипка өчен 3 концерт, оркестр б-н виолончель өчен 2 концерт, Бәйрәм увертюрасы (1951), Татар рапсодиясе (1955), «Татар көйләре» (1948) сюитасы, «Балет сюитасы» (1951); «Ленин» (1962), «Атлантлар» (1966), «Төньяк диңгезләр җыры» (1967, «Песни Поморья»), «Дюналар җырлый» (1976, «Дюны поют») ораторияләре; кантаталар, хор концертлары; фортепиано өчен, скрипка һәм фортепиано өчен, виолончель һәм фортепиано өчен сонаталар, фортепиано цикллары, вокаль цикллар, романслар һәм җырлар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952).

*Е.В.Порфирьева.*



В.И.Ленин.

**ЛЕ́НИН** (чын фамилиясе Ульянов) Владимир Ильич (10.4.1870, Сембер ш. — 21.1.1924, Мәскәү губ., Горки бистәсе), сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, революционер, Совет дәүләтен нигезләүче. Халык уч-щеләре инспекторы, нәселдән килгән дворян И.Н.*Ульянов* һәм М.А.Ульянова (кыз фамилиясе Бланк) улы. Хатыны — Н.К.Крупская. Сембер гимназиясен тәмамлаганнан соң (1887), Казан ун-тының юридик ф-тына укырга керә. Мотовилов-Богораз-Скворцов революцион түгәрәгенә йөри, студентларның Самара-Сембер якташлыгы әгъзасы. Яңа университет Уставының (1884) чиктән тыш тыюлы кагыйдәләренә каршы юнәлтелгән *студентлар җыенын (1887)* әзерләүдә һәм аны 4 декабрьдә ун-тның актлар залында уздыруда катнаша. Залдан чыкканда кафедра каршындагы өстәлгә үзенең студент билетын ыргыта. Университеттан куыла һәм полиция күзәтчелегендә яшәү өчен әнисе утарына — Казан губернасы Лаеш өязенең Кокушкино авылына (хәзер *«Ленино-Кокушкино» музей-саклаулыгы*) сөрелә. 1888 елның сентябрендә, университетка керү хокукыннан мәхрүм ителгән хәлдә, аңа Казанга кайтырга рөхсәт бирелә. Бу чорда Ульяновлар гаиләсе Орловларның Беренче Таудагы йортында (хәзер *Ленин В.И. музей-йорты*) яши башлый. Үзлегеннән белем ала: К.Маркс, Ф.Энгельс, Г.В.Плеханов әсәрләрен өйрәнә. *Федосеев түгәрәкләре* эшендә катнаша дигән мәгълүматлар бар. 1889 ның мае башында Л. гаиләсе б-н бергә Самара губернасына күчеп китә, бу аны яңадан кулга алынудан коткара, чөнки 1889 ның июлендә түгәрәкнең эше ачыла, Н.Е.*Федосеев* кулга алына. 1891 дә Петербург ун-тында экстерн рәвештә юридик ф-т курсы буенча имтихан тапшыра. 1892–93 тә Самара шәһәрендә антлы ышанычлы ярдәмчесе. 1893 нең августында С.-Петербургка күчеп килә, Технол. ин-ты каршындагы марксистик студентлар түгәрәге составына керә. 1895 тә С.-Петербургтагы «Эшчеләрне азат итү өчен көрәш берлеге»н оештыруда катнаша, шул ук елның декабрендә кулга алына, 1897 дә 3 елга Енисей губернасының Шушенское авылына сөрелә. 1900 дә чит илгә китә; Г.В.Плеханов һ.б. марксистлар б-н бергә «Искра» г-тасы чыгара. РСДРПның 2 нче съездында (1903 нең июле-августы, Брюссель, Лондон) большевиклар фракциясен җитәкли. Эмиграциядә партияне саклап калу һәм ныгыту өчен көрәшне дәвам итә. 1905–07 дәге Рев-ция елларында, большевикларның революцион эшчәнлеге б-н турыдан-туры җитәкчелек итү өчен, С.-Петербургка кайта (1905 нең ноябре — 1907 нең декабре). 1912 нең гыйнварында Прагада РСДРПның планлаштырылган 6 нчы Бөтенроссия конференциясе урынына большевикларның фракция конференциясен чакыра, ҮК әгъзасы булып сайлана.

Л. башлангычында большевикларның беренче легаль «Правда» г-тасы чыгарыла башлый. 1913 тә ҮКның җәйге киңәшмәсендә аның тарафыннан төзелгән резолюциядә с.-д. партиясе милләтләрнең үзбилгеләнү, ягъни аерылып чыгу һәм мөстәкыйль дәүләт төзү хокукы — шартлар б-н чикләнмәгән хокукы, диелә; шул ук вакытта бу мәсьәләне «теге яки бу милләтнең аерылып чыгуының максатка ярашлы булуы турындагы мәсьәлә б-н бутарга ярамый», дип ассызыклана. 1917 нең 3 апрелендә Петроградка кайта, шул ук көнне Кшесинская сараенда большевиклар җыелышында «Апрель тезислары» б-н чыгыш ясый, аларда буржуаз-демократик рев-циядән



В. Ульянов — Казан университеты студенты. 1887.

соц. рев-циягә күчү курсы игълан ителә. Кыска вакыт эчендә үз позициясенең партия оешмаларының күпчелеге тарафыннан танылуына һәм хуплануына ирешә. «Апрель тезислары» партия сәясәтенең Окт.рев-циясенә кадәрге чордагы төп юнәлешләрен билгели. Л.Петроградта Окт. кораллы баш күтәрелешен җитәкли. Советларның 2 нче Бөтенроссия съездында ХКС рәисе булып сайлана, бер үк вакытта (1918 дән) Эшчеләр һәм крәстияннәр оборонасы Советы (1919 дан Хезмәт һәм Оборона Советы) рәисе; СССР БҮБК һәм ҮБК әгъзасы. Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясен (ВЧК) төзү, Учредительләр җыенын тарату, оппозицион партияләрне һәм аларның матбугат органнарын бетерүдә; оппозицион карашлы интеллигенция һәм руханиларны кертеп, халыкның «пролетар булмаган» социаль катлауларына карата сәяси репрессияләрне, ш.и. «*хәрби коммунизм*» сәясәтен гамәлгә кертүдә, Брест солыхы төзүдә (1918 нең марты) башлап йөрүчеләрнең берсе. Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, кискен икътисади һәм социаль кризис шартларында, Л. «хәрби коммунизм» сәясәтенең хата икәнлеген танырга мәҗбүр була һәм сов. хакимияте шартларында икътисадның хосусый секторына юл куйган *яңа икътисади сәясәткә* күчү зарурлыгы турындагы нәтиҗәгә килә. Аның җитәкчелегендә Россияне электрлаштыру буенча Дәүләт программасы (*ГОЭЛРО*) эшләнә. Окт. рев-циясеннән соң милли мәсьәләгә зур игътибар бирә; Л. башлангычында 1917 нең 20 ноябрендә Россия ХКС утырышында «*Барлык Россия һәм Шәрекъ мөселман хезмәт ияләренә*» мөрәҗәгать кабул ителә, 1918 нең 17 гыйнварында Милләтләр эшләре халык комис-ты каршында М.*Вахитов* җитәкчелегендә *Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариаты* оештырыла. Л. күп тапкырлар татарларның үзбилгеләнү мәсьәләләре җентекләп каралган киңәшмәләр, төрле делегацияләр б-н әңгәмәләр уздыра, РКП(б) ҮК Политбюросы (11 тапкыр) һәм ХКС (9 тапкыр) утырышларында рәислек итә. Татарстан АССР төзелгәндә хәлиткеч роль уйный, 1920 дә «Автономияле Татарстан Социалистик Совет Республикасы турында»гы Декретны имзалый. 1922 нең декабреннән, агуланган пулядан яралану (1918) нәтиҗәсендә башланган авыруы аркасында, актив сәяси эшчәнлектән читләшә. Бу вакытта, тигез хокуклы республикаларның федератив берлеге планын дәлилләп һәм милли мәсьәлә буенча Сталинның гамәли сәясәтендә күренә башлаган яңа тенденцияләрне анализлап, ул: «Мөгаен, яманаты чыккан автономияләштерү турындагы мәсьәләгә җитәрлек дәрәҗәдә энергиямне салып һәм җитәрлек дәрәҗәдә кискен рәвештә чыгыш ясамавым б-н мин Россия эшчеләре алдында бик тә гаеплемен... Күрәсең, әлеге «автономияләштерү» нияте тамырдан ук дөрес һәм үз вакытында хәл ителмәгән... без аклана торган «берлектән чыгу иреге» Россия әҗнәбиләрен типик рус бюрократыннан гыйбарәт булган... залимнан яклауга сәләтсез буш кәгазь булып калачак», — дип яза (Әсәрләрнең тулы җыелмасы, т. 45, 356–357 б.). Л.ның үлеменнән соң Сталин интерпретациясендә аның тәгълиматы — ленинизм канунлаштырыла. Республикада ТАССР ҮБКның 1924 ел 26 гыйнвар карары б-н Л.ның истәлеген мәңгеләштерү буенча Үзәк комиссия төзелә, юлбашчыга иң яхшы һәйкәл булдыруга конкурс игълан ителә; Дәүләт банкы бүлекчәсендә һәйкәл төзелешенә акча җыю өчен махсус исәп ачыла. Аның тормышы һәм эшчәнлеге б-н бәйле төп 15 урын ачыклана. Казанда В.И.Ленин музей-йорты (1937), Кокушкино авылында В.И.Ленин музей-йорты (1939), Казан ун-тында Бүлмә-музей ачыла һ.б. Аның исеме б-н заводлар һәм фабрикалар, совхозлар һәм колхозлар, урамнар һәм районнар атала. Республикада Л. исемен Лениногорск шәһәре йөртә. Төп хезмәтләре: «Халык дуслары» кемнәр һәм алар социаль-демократларга каршы ничек көрәшәләр?» («Что такое «друзья народа» и как они воюют против социал-демократов?», 1894), «Россиядә капитализм үсеше» («Развитие капитализма в России», 1899), «Нәрсә эшләргә?» («Что делать?», 1902), «Материализм һәм эмпириокритицизм» («Материализм и эмпириокритицизм», 1909), «Капитализмның иң югары стадиясе буларак империализм» («Империализм как высшая стадия капитализма», 1916), «Дәүләт һәм революция» («Государство и революция», 1917), «Коммунизмда балаларча «суллык» авыруы» («Детская болезнь «левизны» в коммунизме», 1920). Ш.у. к. *Ульяновлар, Ленин В.И. һәйкәле, Ульянов Владимир-студент һәйкәле.*

Чыг.: В.И.Ленин и Татария: Сб. док., материалов и воспоминаний. К., 1964; Семья Ульяновых в Татарии: Док., материалы и воспоминания. К., 1985.

Х е з м.: Әсәрләр / 4 нче басмадан тәрҗемә / : 45 томда. К., 1955–72; Полное собрание сочинений: В 55 т. М., 1958–65.

*Әд.:* Х о д о р о в с к и й И. В.И.Ленин, великий вождь пролетарской революции. К., 1920; С а и д - Г а л и е в С. Татреспублика и Ленин // Пролетарская революция. 1925. № 9 (44); Ленин и библиотека. К., 1928; С а й д а ш е в а М.А. В.И.Ленин и некоторые вопросы социалистического строительства в Татарии. К., 1963; ш у л у к. День за днём (Биографическая хроника В.И.Ленина). К., 1987.

*Л.М.Айнетдинова, Г.С.Сабирҗанов.*

**«ЛЕ́НИН БАЙРАГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Нариманов райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы органы. 1931–59 елларда Әстерхан өлкәсе Нариманов р-ны Зарцево авылында татар телендә нәшер ителә. 1931 нең сентябреннән 1934 нең июленә кадәр — «Удар колхозчы», ә 1956 елның ноябренә кадәр «Сталинчы» исемендә чыга.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Голос времени: Газеты и журналы на татарском языке 1905–1990 годов. К., 1992.

**«ЛЕ́НИН БАЙРАГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Украина КП(б)ның Сороки райкомы, район башкарма ком-ты, профсоюзларның район советы органы. 1932–33 елларда Сороки шәһәрендә (Сталин өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**«ЛЕ́НИН БАЙРАГЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Первоуральск райкомы, район башкарма ком-ты, профсоюзларның район советы органы. 1932–33 елларда Первоуральск шәһәрендә (Свердловск өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**ЛЕ́НИН В.И. МУЗЕ́Й-ЙОРТЫ́**, Казанда, ТР Милли музее ф-лы. 1888 елның 4 сентябреннән 1889 ның 3 маена кадәр *Ульяновлар* гаиләсе вакытлыча яшәгән Орловлар йортының (1880 еллар корылмасы) флигелендә 1937 нең 7 ноябрендә Окт. рев-циясенең 20 еллыгына ачыла. 1991 гә кадәр КПССның Татарстан өлкә ком-ты карамагында була. Музейны оештыруда һәм өйне элеккечә җиһазландыруда М.И. һәм Д.И.Ульяновлар һәм аларның туганнан туган энесе Н.И.Веретенников катнашалар; өйнең интерьерлар планын А.И.Ульянова-Елизарова төзи. Музей мәйданы таш янкорма (1970 елгы реконструкция вакытында корыла) һәм янәшәдәге терр-я б-н 0,5 *га*, экспозиция мәйданы 169 *м*² били. 1960 тан табигать истәлеге статусы бирелә. Музей фондларында (үзәкләштерелгән) мемориаль әйберләр, Ульяновларның гаиләсе турында иллюстратив һәм документаль материаллар, фоторәсемнәр, китаплар, В.И.Ленин һәм аның туганнарының биографиясен ачкан, 19 йөз ахырындагы Казанны тасвирлаган материаллар бар. Хәзерге экспозиция авторлары: К.Г.Валидова, К.Н.Кузнецова, бизәүчеләр В.А.Нестеренко, А.О.Бойко





1. Казанда В.И.Ленин музей-йорты; 2. В.Ульянов бүлмәсе. Экспозиция фрагменты.

(А.Н.Тихонов җитәкчелегендә). Экспозиция В.И.Ульянов тормышының Казан чоры, аның Казан ун-тында укуы, Казан *студентлары җыенында (1887)* катнашуы, беренче тапкыр кулга алынуы һәм Кокушкино авылына сөргенгә җибәрелүе турында сөйләүче документаль бүлекне, ш.у. мемориаль бүлмәләрне үз эченә ала.

Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында — йорт кирәк-яраклары: фаянстан ясалган шикәр савыты һәм алты көмеш кашык, М.А.Ульянованың кул эшләре, шкатулкасы, өстәл көзгесе, аның әтисе А.Д.Бланкның пыяла кара савыты, ш.у. В.И.Ульяновның Сембер гимназиясе укытучылары һәм чыгарылыш сыйныф укучылары арасында истәлеккә төшкән уникаль фотосурәте бар. Музей директоры — Т.И.Басова (2009 дан).

*Әд.:* Государственный реестр особо охраняемых природных территорий Республики Татарстан. К., 1998; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004.

**ЛЕ́НИН В.И. ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. Татар опера һәм балет театрының төп фасады каршындагы Ирек мәйданы уртасында урнашкан, мәйданның композицион үзәге булып тора. 1954 елның 7 ноябрендә ачыла. Авторлары — скульптор П.П.Яцыно, арх. А.И.Гегелло. Һәйкәл совет монументаль скульптурасы традицияләрендә эшләнгән. Пластик эшләнү үзенчәлеге бөек образны тудыруга булышлык итә. Юлбашчының гәүдә торышы тыныч кыяфәттә бирелгән. Һәйкәлнең статик композициясе, басынкы пластик формасы, силуэтның ачыклыгы һәм төгәллеге скульптурага тантаналылык, тәэсирлелек, мәһабәтлелек бирә. Һәйкәлнең бөтенлекне тәшкил иткән күләмле-фәзаи композициясенә каракусу-кызыл шокшин кварцитыннан ясалган плитка б-н капланган турыпочмаклы постамент һәм баскычлы трибуна керә. Трибунаның алгы өлешендә юлбашчының беренче революцион чыгышын мәңгеләштергән, 1887 дә булып узган Казан *студентлары җыенына* багышланган бронза барельеф беркетелгән. Постаментта «Ленин» дигән язу бар. Совет хакимияте елларында һәйкәл Казанда идея-сәнгати яктан иң мөһим монументларның берсе була. Мәйданда һәйкәл янында 1 май һәм 7 ноябрьдә хезмәт ияләренең бәйрәм демонстрацияләре (1990 елларга кадәр), Җиңү бәйрәме үткәрелә. 20 йөз ахырында илдә иҗтимагый-сәяси шартлар үзгәрү сәбәпле, һәйкәл элеккеге әһәмиятен югалта.

*А.Н.Новицкий.*



Казанда В.И.Ленин һәйкәле. Бронза, кварцит. Скулып. П.П.Яцыно, арх. А.И.Гегелло. 1954.

**ЛЕ́НИН ИСЕМЕНДӘГЕ́ АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ КООПЕРАТИВЫ́**, Балтач р-нында. 1929 елда Ленин исем. к-з буларак оештырыла (Балтач а.). 1950 дә аңа Разин исем. к-з (Көекбаш а.), 1959 да «Победа» (Югары Ушма һәм Түбән Ушма, Зур Лызи, Кече Лызи авыллары, Урта Ушма пос.) һәм Сталин исем. (Курмала, Көек авыллары) к-злары берләштерелә. 1992 дә бер бригада (Курмала а.) «Сельхозтехника»ның Балтач бүлегенә кучерелә. 1996 да колхоз а.х. җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә (АХҖК), 2003 тә — ҖЧҖ, 2004 тә — АХҖК, 2006 да — «Сорнай» ҖЧҖ. Хуҗалык Көек, Югары Ушма, Урта Ушма, Түбән Ушма, Зур Лызи һәм Кече Лызи (үзәк утар) авылларын, Балтач шәһәр тибындагы посёлогын үз эченә ала. Халык саны 8808 кеше, ш.и. а.х. җитештерүендә эшләүчеләр 301 (2004), 270 (2007) кеше. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 4695 *га* (2007), ш.и. сөрү җирләре — 4188 *га*; мөгезле эре терлек 1846 баш (ш.и. 410 баш сыер), 883 баш дуңгыз, 38 баш ат. Төп тармаклары — бөртекле ашлык, бәрәңге, сөт, ит җитештерү. 2007 дә 5865 *т* бөртекле ашлык, 1728 *т* бәрәңге, 2738 *т* сөт, 243 *т* ит (тере үлчәмдә) җитештерелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 33,4 *ц*, бәрәңгенең 216 *ц* тәшкил итә; еллык савым уртача һәр сыердан 6679 *кг*. Хуҗалык 12,4 млн. сум керем ала. Табышлылык дәрәҗәсе 32,4% тәшкил итә. Хуҗалык а.х. продукциясен җитештерүдә зур күрсәткечләргә ирешкәне өчен, 4 тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байрагы б-н бүләкләнә. Эшчеләр дәүләт бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә лаек була, ш.и. РФ, ТАССРның атказ. хезмәткәре — 11 кеше; Ленин ордены — 1, Хезмәт Кызыл Байрагы — 4, «Почёт билгесе» — 3, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены 1 кешегә, медальләр 8 кешегә, ш.и. СССР ВДНХсының медальләре 4 кешегә бирелә. Хуҗалык үсешенә зур өлеш кертүчеләр: Н.А.Әхәтов (1957–85), Х.С.Сибгатуллин (1985 дән).

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛЕ́НИН ИСЕМЕНДӘГЕ́ АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ КҮМӘ́К ПРЕДПРИЯ́ТИЕСЕ**, 1994 елда шул ук исемдәге колхоз җирлегендә (1959 да Ленин исем. (Мамадыш-Әкил а.) һәм «Активист» (Татар Танае, Рус Танае, Панау авыллары) к-зларын берләштерү юлы б-н төзелә) оештырыла. Яшел Үзән р-нының Татар Танае (үзәк утары), Мамадыш-Әкил, Рус Танае, Панау авылларын үз эченә ала. Халык саны — 1295 кеше, ш.и. 390 эшләүче кеше (2002). А.х. файдалану җирләре 4488 *га*, ш.и. 3246 *га* сөрү җирләре; мөгезле эре терлек 3 мең баш. Хуҗалык нәселле бозаулар үрчетү б-н шөгыльләнә. Ел саен 1 мең *т* га кадәр суган, 1700 гә кадәр нәселле бозау саталар. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 340 *ц* га кадәр сөт һәм 92 *ц* га кадәр ит (тере үлчәмдә) җитештерелә. Бөртекле культураларның уртача уңышы 1 *га* дан 24–31,3 *ц* тәшкил итә; һәр сыердан елына 3000–3641 *кг* сөт савып алына (1980–97). Хуҗалык 10 тапкыр СССР ВДНХсының дипломнары, ике тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл байрагы б-н бүләкләнә. ТАССР һәм ТРның атказ. а.х. хезмәткәре исеменә 5 кеше лаек була. Хуҗалык үсешенә Т.Ә.*Гыйниятуллин* (1966–94), Х.Т.Һидиятуллин (1994–2002) зур өлеш керттәләр. 2003 тә банкротлыкка чыкканнан соң, хуҗалык бетерелә, терр-ясе «Кызыл Шәрекъ–Агро» АҖ составына кертелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛЕ́НИН ИСЕМЕНДӘГЕ́ ТӘҖРИБӘ́-ҖИТЕШТЕРҮ́ ХУҖАЛЫГЫ́**, Теләче р-нында. 1931 елда Сталин исем. с-з буларак оештырыла, шул ук исемдәге совхоз җирлегендә 1968 дә төзелә. 1937 дә хуҗалыкка «Алга», «Үрнәк» с-злары, 1957 дә Тельман исем., «Чулпан», «Кремль», «Новый Путь», Булганин исем., Маленков исем. к-злар берләштерелә. 1962 дә хуҗалык Ленин исем. с-з итеп үзгәртелә. Соңрак аңардан мөстәкыйль «Җәлил» (1965), «Баландыш» (1982) совхозлары аерылып чыга. 2005 тә хуҗалык «Агрофирма ВАМИН-Теләче» ҖЧҖнең Ленин исем. бүлеге итеп үзгәртелә. 2004 тә хуҗалык составына 6 торак пункт керә: Сауш, Шармыш, Карашырмә, Пановка авыллары, үзәк утар — Үзәк посёлогы, Петровский посёлогы (608 шәхси хуҗалык, гомуми халык саны — 1982 кеше; шулардан 801 е хезмәткә яраклы яшьтә). Хуҗалыкта а.х. файдалану җирләре 8104 *га* (ш.и. 6867 *га* сөрү җирләре), 3202 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 740 сы-

ер), 4760 баш дуңгыз, 146 баш ат исәпләнә. Бөртекле культуралар һәм бәрәңге орлыгы (элиталы һәм югары сортлы), ш.у. сөт, ит җитештерелә, нәселле терлек үрчетелә. 2004 тә 12348 *т* бөртекле ашлык, 2244 *т* бәрәңге, 4470 *т* сөт, 780 *т* ит (тере үлчәмдә) җитештерелә. Бөртекле ашлыкның уңышы 1 *га* дан 44,6 *ц*, бәрәңгенеке — 204 *ц* чыга; 1 сыердан 6124 *кг* сөт савыла; 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 552 *ц* сөт, 96,3 *ц* ит җитештерелә.

Хуҗалык җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен КПСС ҮКның, СССР ЮС Президиумы, СССР МС һәм ВЦСПСның Кызыл Байрагы (1967); КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮК ның Мактау грамотасы (1987) б-н бүләкләнә. Эшчеләр дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Соц.Хезмәт Герое исеме — 2 кеше, ТАССР, ТРның атказ. хезмәткәре — 20 кеше; Ленин ордены — 4, Октябрь Революциясе ордены — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 3, «Почёт билгесе» ордены — 8, СССР ВДНХсының медальләре — 9, СССР Дәүләт бүләге 1 кешегә бирелә. Хуҗалык үсешенә зур өлеш кертүче җитәкчеләр: Г.Г.*Галиев* (1960–77), П.Х.Хаҗиев (1977–88), И.Ю.Зәйнетдинов (1990–99).

*И.Н.Афанасьев.*

**«ЛЕ́НИН ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси журнал. ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты органы. 1928–37 елларда Уфада татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Башкорстанның милли матбугат альбомы // Ватандаш. 2000. № 3; Мәдәнийәт фырунтында Х йыл: Материалдар йыйынтыгы. Өфө, 1929.

**«ЛЕ́НИН ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Асбест райкомы, эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның шәһәр советы һәм район профсоюзлары советы органы. 1931–33 елларда Асбест шәһәрендә (Свердловск өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**«ЛЕ́НИН ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Шадринск райкомы, эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның район советы һәм район профсоюзлары советы органы. 1932–33 елларда Шадринск шәһәрендә (Курган өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**«ЛЕ́НИН ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Удмуртия өлкә ком-ты, Удмурт АССРның Югары Советы, хезмәт ияләре депутатларының Ижевск шәһәр советы органы. 1933 елның 10 февраленнән 1940 елның 6 октябренә кадәр Ижевск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барлыгы 917 сан. Мөхәррире — И.Р.Борнашев. Удмуртия татарлары өчен чыгарыла. Республиканың иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормышын, ш.у. металлургия, машина төзелеше сәнәгатендә эшләүче татар эшчеләре, авыл эшчәннәре, мәдәни-агарту учреждениеләре хезмәткәрләре тормышын яктырта.

*Әд.:* Удмуртская Республика: Энцикл. Ижевск, 2000. *Т.М.Насыйров.*

**«ЛЕ́НИН ЮЛЫ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Тобол колхоз-совхоз терр.-җитештерү идарәсе органы. 1957–63 елларда Тобол шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Р.Бекшенев.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989; Г а р и ф у л л и н И. Пресса в Сибири // Татарские края. 2003. № 5.

**«ЛЕ́НИН ЮЛЫННА́Н»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. ВКП(б)ның Пермь шәһәр ком-ты һәм хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы органы. 1932 елның 17 февраленнән 1938 нең 1 маена кадәр Пермь шәһәрендә татар телендә барлыгы 568 саны нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре — З.Әхмәтшин, Х.Закиров. Иң актив авторлары — Ю.Әгъли, Г.Әмири, Н.Җиһаншина-Шынгырлы, А.Мамаев, П.Мозаффаров, З.Тимчанов. Пермь шәһәре һәм Пермь өлкәсенең иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышын яктырта. Күпчелек язмалар өлкәдә яңа сәнәгать оешмалары төзелү, а.х. үсешенә багышлана. «Әдәби сәхифә» бүлегендә эшче-колхозчылар һәм производство алдынгылары эше турында хикәяләр, очерклар, шигырьләр басыла. 1933 һәм 1935 елларда газета каршында күчмә редакция эшли. *Т.М.Насыйров.*


**«ЛЕ́НИН ЯЛА́ВЕ»**, («Ленин байрагы»), газета. КПССның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР ЮСның чуаш секциясе органы. 1921 елның ноябреннән 1922 нең маена кадәр һәм 1936–63 елларда Казанда атнага 3 тапкыр чуаш телендә нәшер ителә. 1960 елга кадәр «Хĕрлĕ ялав» исеме б-н чыга.

*Әд.:* Из истории печати Чувашии 1917–1935 годов. Чебоксары, 2002; Краткая чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2001.

**ЛЕНИНГРА́Д ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Россиянең төньяк-көнбатышында урнашкан. 1927 елның 1 августында оештырыла. Мәйданы — 85,9 мең *км*$^2$. Үзәге — С.-Петербург шәһәре. Халкы — 1669 мең кеше, ш.и. 4060 татар (2002). Татарлар, нигездә, Всеволожск, *Гатчина*, Кронштадт, Луга, Тосно шәһәрләрендә яши. Л.ө.ндә татар милли-мәдәни оешмалары — «Гаилә» (1993, Луга ш., җитәкчесе Р.Ш.Яппаров), «Изге юл» (1997, Тосно ш., рәисе И.Г.Кутуев), «Юлдаш» (1999, Гатчина ш., җитәкчесе Ф.Б.Жалеев), «Дуслык» (2003, Всеволожский р-ны, җитәкчесе Х.Х.Мулеев) эшли. 2001 дән Гатчина шәһәрендә татар телен һәм ислам мәдәниятен өйрәнү буенча якшәмбе мәктәбе эшли. Яшел Үзән һәм Кронштадт шәһәрләре арасында тыгыз мәдәни һәм икътисади бәйләнешләр урнаша, Казан шәһәр хакимияте Балтыйк флотының кайбер корабльләренә шефлык итә. 2003 тән Л.ө.нең Тосно һәм ТРның Арча р-ннары — тугандаш р-ннар. Ш.у. к. *Санкт-Петербург.*

**ЛЕ́НИНО** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 18 *км* төньяктарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 552 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51%, татарлар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә Түбән Никиткино авылы буларак нигез салына, 1924 тән соң хәзерге исемен йөртә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да земство мәктәбе, су тегермәне, 2 вак-төякләр, бакалея кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1858 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152 ир-ат; 1859 да — 529, 1897 дә — 1149, 1908 дә — 1147, 1920 дә — 1319, 1926 да — 1204, 1938 дә — 1032, 1949 да — 795, 1958 дә — 762, 1970 тә — 828, 1979 да — 663, 1989 да — 683, 2002 дә — 657 кеше.


**ЛЕНИНОГО́РСК**, республика карамагындагы шәһәр, Лениногорск р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнчыгыш өлешендә, Дала Зәе елгасының югары агымы буенда урнашкан. Әгерҗе–Акбаш тимер юлындагы Писмән станциясе, автомобиль юллары төйнәлеше бар. Казаннан 322 *км* ераклыкта. Мәйданы — 16,4 *км*$^2$. 2010 елда 64127 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча руслар — 43,3%, татарлар — 42,8%, мордвалар — 5,8%, чуашлар — 5,3%) яши. Л. — ТР нефть сәнәгатенең иң эре үзәкләреннән берсе. Нефть һәм газ чыгару б-н бәйле оешмалар — «Лениногорскнефть» НГДУы, «Татнефть-Лениногорскбурнефть» ҖЧҖ, Лениногорск катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсе, Лениногорск тампонаж эшләре идарәсе, «Гео-





Лениногорск шәһәре. 1. Гомуми күренеше; 2. Г.Тукай урамы.

тех». «Автоспецоборудование», автоматлаштыру җиһазлары («Лозна»), ремонт-механика, тимер-бетон конструкцияләр җитештерү з-длары һ.б. Җиңел сәнгать (тегү ф-касы һ.б.) һәм азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиеләре («Торос сөте», «Лениногорск икмәге», май-сөт комб-ты). Казан техник ун-ты ф-лы, нефть техникумы, музыка-сәнгать пед. уч-щесе, һөнәри көллият, һөнәр уч-щесе. 12 гомуми белем бирү мәктәбе. Мәдәният сарае, Яшьләр йорты, «Максима» мәдәни-күңел ачу үзәге. 6 мед. учреждениесе. Төбәк һәм нефть тарихын өйрәнү музейлары, күргәзмәләр залы; балалар сәнгать һәм музыка мәктәпләре, 9 китапханә. Мәчет. Троица чиркәве. Боз сарае, спорт комплексы һәм «Юность» стадионы, чаңгы б-н трамплиннан сикерү комплексы, җиңел атлетика манежы, «Юбилейный» йөзү бассейны һ.б. спорт корылмалары һәм объектлары.



Лениногорск шәһәре. Татарстанда беренче нефть табучыларга багышланган монумент.

Л. тарихы Яңа Писмән авылыннан башлана, аңа 1790 елларда Иске Писмән авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тартыру б-н шөгыльләнә. 1883 тә Яңа Писмән авылы волость үзәге булып китә. 1885 тә чиркәү-приход мәктәбе ачыла, 20 йөз башында волость, стан идарәләре, вет., атлы хәрби хезмәткә алу пунктлары, земство станциясе; чиркәү, земство мәктәбе, 8 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5146 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. 1935 нең 10 февраленнән яңа оештырылган Яңа Писмән р-ны үзәге. Яңа Писмән авылының үсеп китүе 1948 дә Ромашкино нефть чыганагы ачылуга бәйле. Нефть эшкәртү өчен 1950 дә «Бөгелмәнефть» һәм «Татбурнефть» трестлары оештырыла. Яңа Писмән халкы монда күпләп килүче бораулаучылар, нефть чыгаручылар, Баку, Грозный, Краснодар шәһәрләреннән, Башкортстан һ.б. төбәкләрдән килүче төзүчеләр исәбенә кискен арта башлый. 1951 нең 1 августында авыл шәһәр тибындагы посёлок статусы ала, 1955 нең 18 августында Лениногорск шәһәре итеп үзгәртелә һәм Лениногорск районы үзәге булып китә. Халык саны: 1858 дә — 1416, 1889 да — 1946, 1897 дә — 1962, 1900 дә — 2058, 1910 да — 1959, 1920 дә — 2465, 1926 да — 2196, 1959 да — 38,6 мең, 1970 тә — 47 мең, 1979 да — 53,1 мең, 1989 да — 62,1 мең, 2002 дә — 65,592 мең кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997; Л а р и ч е в а Э.И. У истока (О возникновении, развитии г.Лениногорска). К., 1981.

**ЛЕНИНОГО́РСК «АВТОСПЕЦОБОРУ́ДОВАНИЕ» ЗАВОДЫ́**, машиналар төзү сәнәгате пр-тиесе. 1962 елда 12 нче автохуҗалык базасында «ЗИС-155» һәм «ПАЗ-65» автобусларының кузовларын ремонтлау буенча «Татавтотрест»ның цензланмаган авторемонт остаханәсе буларак оеша. 1965 тә ул «ГАРО» трестының Лениногорск авторемонт з-ды итеп үзгәртеп корыла. 1969 дан хәзерге исемдә. 2001 дән АҖ. Пр-тиенең терр-ясе 4,63 *га* (ш.и. производство мәйданнары 11 мең *м²*). Эшләүчеләр саны 94 кеше (2011). 1971–80 дә заводта икмәк-күмәч ризыкларын ташу өчен фургоннар, силикат кирпеч кучеру өчен аслыклар, җиһазлар ташу өчен контейнерлар, бензонасосларны тикшерү приборлары, трансмиссион май салу җайланмалары, изотермик фургоннар, аркылы гайка ачкычлары җыелмалары җитештерү оештырыла. 1980–90 елларда «ГАЗ-53», «ЗИЛ», «КАМАЗ» шассилы фургонлы автомобильләрен эшләп чыгару үзләштерелә, алар халык хуҗалыгына караган йөкләр, шиплар, йөк һәм җиңел машина шиналарына шиплар кую өчен стендлар ташый торган йөк күтәрү бортлары белән җиһазландырыла. 1996 дан нефть, газ һәм энергетика сәнәгатьләре өчен яңа төр продукция: төрле модификациядәге автомобиль фургоннары (каротаж станцияләр, газ чыгару сәнәгате өчен махсус фургоннар, аварияләр очрагына автофургоннар), вакытлыча яшәү өчен блок-бокслар, нефть скважиналары өчен изотермик ышыклану җайланмалары эшләп чыгара башлый. Завод газ һәм нефтьүткәргеч объектларга хезмәт күрсәтүче махсус техника җитештергәне өчен — 6 нчы «Нефть, газ-99», нефть чыгару һәм нефть эшкәртү сәнәгатен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен — 10 нчы «Нефть, газ, нефть химиясе — 2003» Халыкара махсуслаштырылган күргәзмәләре; «Казан ярминкәсе» Күргәзмәләр үзәгенең 4 нче «Нефть, газ, химия — 2003» 4 нче Бөтенроссия күргәзмәсе эшендә актив катнашканы өчен һәм «Әлмәт ярминкәсе» Күргәзмәләр үзәгенең дипломнары б-н бүләкләнә. Завод җитәкчеләре: М.П.Кирдянов (1962–68), Г.Д.Анисахаров (1968–69), И.А.Плеханов (1969–71), Г.Г.Әхмәтҗанов (1971–95), Ф.А.Гафаров (1995–2001), Р.Ф.Хәйретдинов (2001–05), Г.С.Гыймранов (2005–2007), Р.М.Абдулхәеров (2007 дән).

*Р.З.Мансуров.*

**ЛЕНИНОГО́РСК МУ́ЗЫКА-СӘНГА́ТЬ ПЕДАГО́ГИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Мәгариф министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1961 елда пед. уч-ще буларак ачыла, 2000 нән хәзерге исемдә. 3 меңнән артык белгеч әзерләнә. Укыту музыка белеме, дизайн, сынлы сәнгать һәм сызым, «мәктәпкәчә белем бирү» белгечлекләре буенча алып барыла. 2010 да көндезге бүлектә 320 (түләүле нигездә) студент укый; пед. коллективта 69 кеше, ш.и. ТРның атказ. укытучысы — 2, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре — 2, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе — 1 кеше.

**ЛЕНИНОГО́РСК НЕФТЬ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ Энергетика министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1966 елда ачыла. Эшләү елларында 7 меңнән артык белгеч әзерләнә. Укыту түбәндәге белгечлекләр буенча алып барыла: газ-нефть үткәргечләрен һәм газ-нефть саклау корылмаларын төзү һәм алардан файдалану, нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм файдалануга тапшыру, файдалы казылмалар чыганакларын тикшерүдә әзләүнең геофизик алымнары, сәнәгать җиһазларын монтажлау һәм техник файдалану, электр һәм электр-механика җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм файдалану, хисаплау техникасын һәм автоматлаштырылган системаларны программалар б-н тәэмин итү, нефть һәм газ сәнәгате икътисады һәм бухгалтерлык исәбе. 2010 да көндезге бүлектә — 900, читтән торып уку бүлегендә 450 студент укый, ш.и. якынча 900 студент түләүле нигездә белем ала; пед. коллективта 70 кеше, ш.и. РФнең атказ. мәктәп укытучысы — 2, ТРның атказ. нефтьчесе — 8 кеше.

**ЛЕНИНОГО́РСК РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк-көнчыгышында, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 1811,4 *км²*. 24 җирле үзидарә советын (ком-тын), 66 торак пунктны, ш.и. 57 авылны, 9 посёлокны берләштерә. Үзәге — Лениногорск шәһәре. 2010 елда 22,7 мең кеше (район үзәгеннән башка) яши. 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 74,8%, руслар — 12,9%, мордвалар — 5,4%, чуашлар — 5%. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км²* га 13 кеше. Л.р. 1935 нең 10 февралендә Яңа Писмән р-ны буларак оештырыла. 1920 гә кадәр район терр-ясе Самара губернасының Бөгелмә өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Бөгелмә кантонына, 1930–35 тә Бөгелмә һәм Шөгер р-ннарына керә. Район чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та аның мәйданы — 889 *км²*, халкы — 22,8 мең кеше, 16 авыл советы, 55 торак пункт була. 1955 нең 18 августында шәһәр тибындагы Яңа Писмән посёлогы Лениногорск шәһәре итеп үзгәртелә һәм район хәзерге исемен ала. 1959 ның 12 октябрендә аның составына бетерелгән *Шөгер районы* терр-ясе кушыла. 1960 та Л.р.ның мәйданы 1789 *км²*, аңа 2 посёлок һәм 16 авыл советы, 77 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә, ТАССРның адм. берәмлекләре эреләндерелү сәбәпле, Беренче Май р-ны терр-ясенең зур өлеше Л.р.на кушыла. Районның мәйданы — 2936 *км²*, халкы — 73,8 мең кеше, 26 авыл советы, 127 торак пункт исәпләнә. 1965 нең 12 гыйнварында,




ТАССРның адм.-терр. бүленеше үзгәрү сәбәпле, Л.р. терр-ясе — 1827 *км*², халкы — 41,8 мең кеше, 17 авыл советы, 79 торак пункт була. Район Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгында (биеклеге — 90–340 *м*) урнашкан. Җире елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән. Елгалар: Чишмә (Урман Чишмәсе кушылдыгы б-н), Дала Зәе. Җире күбесенчә селтесезләнгән, карбонатлы һәм типик кара туфраклы. Терр-ясенең 26% ын урманнар каплаган. Нефть (яңа Елховой һәм Ромашкино нефть чыганаклары), газ, битум, известьташ, доломит, ком-чуерташ катнашмасы, балчык, минераль сулар һәм дәвалау ләме ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары — Дала Зәе, Чишмә елгалары, *Чыршылы сөркә (байбак) колониясе, Шөгер аучылык тыюлыгы.* Л.р. терр-ясендә күбесе бронза гасырга караган 11 археол. истәлек табыла. А.х. җирләре 102,8 мең *га* били, ш.и. 73,8 мең *га* сөрүлек җир (2009). Арыш, бодай, арпа, солы, карабодай, борчак игелә. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау, кошчылык алга киткән. 2010 да районда 18 а.х. пр-тиесе, Шөгер җиләк-җимеш питомнигы эшли. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә, Шөгер авылында (нефть-битум, икмәк з-длары), Керкәле авылында (ком-таш карьеры) урнашкан. Урманчылык бар. Л.р. терр-ясеннән Әгерҗе-Акбаш тимер юлы уза, автомобиль юллары челтәре нык үскән. 24 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 1 башлангыч, 5 тулы булмаган урта, 18 урта мәктәп; 1 һөнәри уч-ще (Зелёная Роща а.), 32 китапханә, 38 клуб, 1 хастаханә (Шөгер а.), 31 фельдшер-акушерлык пункты, 1 табиблек амбулаториясе (Иске Куак а.) (2011) исәпләнә. «Бәкер» ләм б-н дәвалау курорты эшли. Татар һәм рус телләрендә «Заман сулышы», «Дыхание времени» г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**ЛЕНИНОГО́РСК ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е́**, Лениногорск шәһәрендә. 1992–2006 елларда ТР Милли музее ф-лы, 2007 дән муниципаль музей. Хәрби һәм хезмәт даны музее буларак, җәмәгатьчелек тәртибендә 1985 тә ачыла. 1993 тән музей составында — 1977 дә ачылган күргәзмә залы; коллекциянең төп өлешен нәкышь осталарының репродукцияләре (Н.Б.Гундыревныкы булган) алып тора. Башта музей торак йортның 1 нче катында (мәйданы 211 *м*²) урнаша. Экспозициядә «Безнең төбәктә Гражданнар сугышы. 1918–19 еллардагы Писмән операциясе» һәм «Бөек Ватан сугышы елларында Яңа Писмән районы» бүлекләре була. Окт. рев-циясе, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнашучылар турында бай мәгълүмат тупланган (язма чыганаклар, шәхси әйберләр). Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында Гражданнар сугышы вакытыннан калган парад кылычы, хәрби бүләкләр бар. 1993 тән башлап музей фонды район тарихы материаллары б-н тулыландырыла. Татар, мордва, чуаш, рус этнографиясенә караган бай коллекция (йорт кирәк-яраклары, зәркән эшләнмәләр, бизәнү әйберләре, сөлгеләр, чигүле баш киемнәре), гыйбадәт кылу әйберләре һ.б. тупланган. 2000 нән музей бинаны тулысынча били, экспозиция 5 залны үз эченә ала, коллекцияләр 2011 дә 9603 саклау берәмлеген тәшкил итә. Музей экспозициясе «Төбәкнең этнографиясе», «Хәтер залы», «19 йөз төбәк тарихы» бүлекләреннән тора. Ел саен Халыкара музейлар көне (18 май) үткәрелә.





Лениногорск төбәк тарихы музее.
1. Музей бинасы; 2. Экспозиция фрагменты.

Музей директорлары — К.К.Галләмов (1983–93), Н.Н.Галиева (2004 тән).

**ЛЕНИНОГО́РСК УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́**, Лениногорск һәм Бөгелмә р-ннары терр-ясендә урман хуҗалыгы эшләрен алып бара. 1991 елда Кәләй һәм Бөгелмә урман хуҗалыклары урманнары базасында оештырыла. Гомуми мәйданы 52837 *га*, ш.и. урман мәйданы — 48872 *га*, шуның урман б-н капланганы 48631 *га*. Урман хуҗалыгы составына Түбән Чыршылы (11588 *га*), Иске Куак (9106 *га*), Шөгер (10316 *га*), Лениногорск (12925 *га*), 2003 тән яңадан оешкан Зәй-Каратай (8902 *га*) урманчылыклары керә. Урман хуҗалыгы дирекциясе Лениногорск шәһәрендә урнаша. Эшләүчеләр саны ул чорда 131 кеше исәпләнә. .

1 нче төркем урманнар 22104 *га* мәйданны били, шулардан эрозиягә каршы урманнар — 1772 *га*, тимер юллары һәм автомобиль юлларын саклаучы — 1220 *га*, кыр ышыклаучы һәм туфрак саклаучы — 12689 *га*, шәһәрләрнең яшел зона урманнары — 2728 *га*, курортларны чистарту урманнары — 3695 *га*. Җирле әһәмияткә ия булган 2 нче төркем урманнар 30733 *га*. Урман культуралары мәйданы 7151 *га*. Яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 17,4%, урта яшьтәгеләр — 34,7%, өлгереп килүчеләр — 18,3%, өлгергәннәре һәм картайганнары — 29,6%. Юкә (10919 *га*, агач запасы 2146 мең *м*³) һәм усак (10710 *га*, агач запасы 1694 мең *м*³) урманнары өстенлек итә. Нигездә, кулдан утыртылган нарат урманнары 5117 *га* мәйданны били, алар 2 нче класс яшендәге яшь һәм урта яшьтәге утыртмалардан тора. Чыршылыклар мәйданы 1125 *га*. Каты яфраклы токымнардан орлыктан үстерелгән тәбәнәк каүсәле имән өстенлек итә (6896 *га*, агач запасы 914 мең *м*³). Өрәңгеле һәм өрәңгеле-юкәле имәнлекләр, катлаулы наратлыклар һәм чыршылыклар таралган. Төп кулланылыш өчен еллык урман кисү күләме 62 мең *м*³ тәшкил итә. 200 *га* мәйданда урман торгызу эшләре башкарыла. Террасалау методы б-н текә тау битләрендә урман утырту технологиясе башкарыла. Даими эшләп килүче питомникта 10 нан артык төрдәге агач-куак токымнарының 4–4,5 млн. үсентесе һәм чәчкене үстерелә. Урман хуҗалыгы елына якынча 1 млн. сумлык 700–800 *м*³ агач-такта материаллары җитештерә.

Л.у.х. терр-ясендә «Бәкер» курорты урнашкан. Урман хуҗалыгы тарафыннан терр-яне төзекләндерү, курорт зонасындагы текә тау битләрендә урман утырту эшләре башкарыла. 2007 ел ахырында шул ук исемдәге урманчылык дип үзгәртелә.

**«ЛЕНИНОГОРСКНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть чыганакларын тикшерү, нефть чыгару, әзерләү һәм сату, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлаштыру, төзү һәм файдалануга тапшыру буенча нефть һәм газ чыгару идарәсе (НГДУ). Лениногорск шәһәрендә урнашкан. 2 меңнән артык кеше эшли (2010). Республикадагы иң күптәнге нефть һәм газ чыгару пр-тиесе. Тарихы 1945 елда Татарстандагы беренче *Шөгер нефть чыганагында* (1943 тә ачыла) нефть чыгару өчен оештырылган Шөгер нефть промыселыннан башлана. Шушы ук промысел *Ромашкино чыганагында* (1948 дә ачыла) да беренче скважиналарны эшләтә. 1950 дә Шөгер, Ромашкино 1 нче (1949 да оештырыла) һәм Миңлебай (1950) нефть промыселлары нигезендә

Яңа Писмән авылы янында урнашкан «Бөгелмәнефть» дәүләт союзкүләм нефть чыгару тресты оештырыла. 1954 тән «Бөгелмәнефть» нефть промыселы идарәсе, 1961 дән — «Л.». Аның аерым промыселлары нигезендә мөстәкыйль идарәләр барлыкка килә: «Әлмәтнефть» (1952), «Азнакайнефть» (1956), «Елховнефть» (1962), «Иркеннефть» (1964), «Татнефтебитум» тәҗрибә-экспериментлар идарәсе (1985). 1970 тән «Л.» НГДУы. НГДУ составында нефть һәм газ чыгару буенча 8 цех, үзле нефть чыгару цехы, 2 катлам басымын тотып тору цехы, 2 скважиналарга капиталь һәм җир асты ремонты үткәрү цехы, автомобиль шиннарын пиролизлау участоклары ярдәмче производство бүлекчәләре бар. «Л.» үз эшчәнлеген Лениногорск, Бөгелмә һәм Әлмәт р-ннары терр-яләрендә (Ромашкино, Көнбатыш Лениногорск, Зәй-Каратай, Куакбаш мәйданнары, 8 ятма) алып бара, ш.и. Мордва Карамалысы, Коногоровка чыганакларын эшкәртә, Габдрахман мәйданында нефть чыгара. Төп тикшерү объекты булып югары девонның фран ярусындагы паша горизонты санала. Киселешендә ул аз сыланучан нефтьле төрле фациаль-бериш булмаган коллекторлар кебек кушылган 9 катламга кадәр җитә. Ятмалар, катлам басымын саклап, суны эчке һәм тышкы контур буенча сыртую юлы б-н эшкәртеләләр. Нефть бирүчәнлекне арттыру өчен, катламга тәэсир итүнең прогрессив (гидродинамик, физик-химик, геологик-физик) алымнары кулланыла, шуның хисабына ел саен нефтьнең 40% ка якын өлеше чыгарыла. Нефть чыгаруда иң югары күрсәткечкә (18 млн. 286 мең *т*) 1963 тә ирешелә. 2011 нең гыйнварына бораулаглан фонд 8222 скважина тәшкил итә. Скважиналарны файдалануның төп ысулы — насослар ярдәмендә. Нефтьне туплау системасы герметизацияләнгән. Нефть промыселларын комплекслы автоматлаштыру һәм телемеханикалаштыру тәэмин ителә.

НГДУ составына санаторий-профилакторий, йөзү бассейны, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 5 ял базасы, мәдәният сарае, поликлиника, нефть музее һ.б. керә. «Л.» НГДУы шәһәр төзелүгә нисбәтле пр-тие, Лениногорск шәһәрендә торак йортлар, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, социаль-мәдәни өлкәләргә караган объектлар, мәктәпкәчә учреждениеләр, спорт корылмалары һ.б. төзелешләргә заказ бирүче дә булып тора. 2006 да төп производствоны реконструкцияләү программасы буенча «Л.» НГДУына «Иркеннефть» НГДУы кушыла.

Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. ТРның атказ. нефтьчесе исеме — 34 кешегә бирелә, РФнең атказ. геологы — 6, РФнең, ТРның атказ. икътисадчысы — 6, РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре — 2, РФнең, ТРның атказ. төзүчесе — 8, РФнең, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре — 3, ТРның атказ. авыл хуҗалыгы хезмәткәре — 3, ТРның атказ. авыл хуҗалыгы механизаторы — 1, РФнең, ТРның атказ. торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре — 2, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре — 3 кеше; СССРның, ТРның Дәүләт бүләкләре лауреатлары — 4 кеше, Ленин комсомолы бүләге — 1 , СССР Нефть сәнәгате министрлыгы бүләге — 1; Ленин ордены — 15, Октябрь Революциясе ордены — 8, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 71, Халыклар дуслыгы ордены — 5, «Почёт билгесе» ордены — 70, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены — 34, медальләр 102 кешегә бирелә.

Пр-тие җитәкчеләре: А.И.Семёнов (1945–47), И.А.Мальков (1947–48), Я.Д.Ященко (1949–51), Р.Ш.Мингәрәев (1949–50, Ромашкино 1 нче нефть промыселы), П.Н.Сорокин (1949–50, Ромашкино 2 нче нефть промыселы), К.И.Пономарёв (1950), С.С.Мәһдиев (1950–52), П.С.Васильев (1952–60), Н.А.Мальцев (1960–61), Е.И.Швецов (1961–64), Н.Д.Сергеев (1964–71), Ә.К.Мөхәммәтҗанов (1971–73), Б.С.Лобанов (1973–83), Н.К.Җамалетдинов (1983–85), В.Ф.Лесничий (1985), Б.Ф.Абдуллин (1985–89), Р.С.Нурмөхәммәтов (1989 дан).

*Әд.:* Султанов С.А., Муслимов Р.Х. Нефть — чудо природы. К., 1987; Бесценное богатство. К., 1993; Князев С.Л., Гатиятуллин Н.С., Абражеев Г.П. Нефть и газ Республики Татарстан: Сб. док., цифр и материалов: В 3 т. М., 1993; Там, где растут ромашки. Альметьевск, 1993; Здравствуй, мой добрый город. Лениногорск, 1995; НГДУ «Лениногорскнефть» 50 лет. К., 1995; Гиниатуллин М.К. Развитие Татнефти. М., 2000.

*К.Ф.Фәсхетдинов, Г.Я.Мәүлетова.*

**ЛЕ́НИНО-КОКУ́ШКИНО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 10 *км* төньяктарак, Үшнә елгасы буенда. 2010 елда 2544 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 63%, руслар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, кошчылык; икмәк пешерү з-ды. 1 урта һәм 1 музыка мәктәбе, һөнәри лицей, китапханә. Мәчет. Чиркәү. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Беренче исеме — Яңасала, 18 йөздән — Кокушкино, 1924 тән — Ленино, 1964 нең 16 апрелендә Апакай авылы б-н кушылгач, авыл Л.-К. дип атала башлый. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.-К.да су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгыятенең имана җире 102 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Черемыш волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 41 ир-ат; 1859 да — 62, 1897 дә — 84, 1908 дә — 89, 1920 дә — 88, 1926 да — 95, 1970 тә — 839, 1979 да — 1716, 1989 да — 2270, 2002 дә — 2533 кеше. Л.-К. В.И.Ленинның бабасы А.Д.Бланкның нәсел утары һәм 1887–88 дә студент В.Ульяновның сөргендә яшәгән урыны буларак билгеле. В.И.Ленинның музей-йорты, «*Ленино-Кокушкино музей-саклаулыгы*» бар.



Ленино-Кокушкино авылы. Балалар-яшүсмерләр спорты һәм ял итү үзәге.

**«ЛЕ́НИНО-КОКУ́ШКИНО» МУЗЕ́Й-САКЛАУЛЫГЫ́**, Питрәч р-ны Ленино-Кокушкино авылында, 1934 елның 16 декабреннән БҮБК һәм 1936 ның 2 мартыннан ТАССР ҮБК Президиумы карары б-н В.И.Ленинның музей-йорты буларак оештырыла, 1939 ның 22 гыйнварында эшли башлый. ТР МК карары б-н 2003 нең 24 декабрендә музей-саклаулык дип үзгәртелә. Саклаулык мәйданы 8 *га*, коллекцияләрдә 650 саклау берәмлеге исәпләнә. Саклаулык үзәге — 1847 елда В.И.Ульянов-*Ленинның* бабасы





«Ленино-Кокушкино» музей-саклаулыгы.
1. Музей бинасы; 2. Экспозиция фрагменты: кунак бүлмәсе.

А.Д.Бланк сатып алган утар (ул чакта ук торак йорт төзелә, 1860 елларда — кечкенә флигель). 1870 тә А.Д.Бланкның вафатыннан соң, утар аның кызларына мирас булып кала, 1847–63 тә утарда яшәгән М.А.Бланк милектәшләрнең берсе була һәм бирeдә аның И.Н.*Ульянов* б-н туе уза. *Ульяновлар* гаиләсе, ш.и. император Александр III не үтерергә омтылган революционер-народник А.И.Ульянов, В.И.Ульянов, 1870–80 дә һәр җәй саен диярлек утарга кайтып йөриләр. В.И.Ульянов 1887 дә Казан *студентлары җыенында* катнашканы өчен кулга алынып, 1887 нең декабреннән 1888 нең сентябренә кадәр бирeдә сөргендә була. 1898 дә утар Кокушкино авылы крәстияне Н.Н.Фадеевка сатыла. 1902 дә торак йорт яна, 1917 дә утар талана. 1936–39 да утарның кечкенә янкормасы тор-

гызыла (Ульяновларның туганнары Н.И.Веретенников һәм Е.А.Жаков күрсәтүләре буенча), аны яңартып коруда М.И. һәм Д.И.Ульяновлар актив катнаша. 1980–82 дә арх. В.В.Чумаков һәм археолог Л.С.Шавохин җитәкчелегендә торак йорт торгызыла, 1986–87 дә каралтылар (ат абзары, амбар, мунча һ.б.), бакча, парк зонасы яңартыла. Хәзерге вакытта музей экспозициясе торак йортта һәм җәйге кечкенә флигельдә урнашкан. Йортта 19 йөздәге төрле типологик предметлар нигезендә А.Д.Бланк кабинеты, аның бер бүлмәсе торгызылган, «Ульяновлар гаиләсе — революционерлар гаиләсе» тарихи-документаль экспозициясе урнаштырылган. Флигельдә 19 йөзнең 2 нче яртысы көнкүреше торгызылган (аш, кунак, гаилә әгъзаларының торак бүлмәләре). Флигель каршында студент В.И.Ульяновка һәйкәл куелган (1958, скульп. И.А.Новосёлов). Директоры — Р.М.Габдерәхимов (2009 дан).

*Әд.:* Дом-музей В.И.Ленина в Кокушкино: Путеводитель. К., 1964; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1; Долгина Л. Село Кокушкино и его обитатели // Мир и музей. 2005. Вып. 11.

**ЛЕ́НИНО-КОКУ́ШКИНО ТАБИГЫ́Й-ТАРИХИ́ ТЫЮЛЫГЫ́**, Питрәч р-ны терр-ясендә, Ленино-Кокушкино авылы янында. 1991 елда оештырыла. Мәйданы 179 *га*. Үшнә елгасы үзәнендәге урман һәм кеше тарафыннан барлыкка китерелгән (В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңае б-н) биоценозларын берләштерә. Гади нарат, Себер карагае агачларыннан торучы паркта Ленин В.И. музей-йорты урнашкан.

**ЛЕНТО́ВСКИЙ** Александр Егорович (1798, Казан — 1867, Самара губ., Ставрополь өязе Иске Майна а.), акушер-гинеколог, атказ. проф. (1848). 1815 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Мәскәү мед.-хирургия академиясенә җибәрелә. 1818 дән Казан губернасы Лаеш шәһәрендә өяз табибе. 1821 дән Казан ун-тында: ун-т шифаханәсендә, акушерлык кафедрасында доктор ярдәмчесе, 1828 дән ординар проф., мөдир, 1820–34, 1841–45 елларда мед. ф-ты деканы. 1821–28 дә физиология, 1822–28 дә гомуми патология, 1825–28, 1833 тә клиника, 1823 тә мәхкәмә медицинасын укыта; акушерлыкны клиникада укытуны оештыра. 1830 еллар башында акушерлык клиникасын җитәкли. 1830 да проф. Л.Л.Фогель б-н Сергеев минераль су чыганакларын тикшерә. 1840 еллар башында балалар йортлары оештыру хезмәтендә, Николаев балалар йортында табиб, 1853 тән директоры була. Хезмәтләре яңа туган балалар гигиенасына карый.

Х е з м.: Медико-топографическое описание Казани // Казан. вестн. 1831. Ч. 31; Взгляд на гигиену новорождённых детей // Казан. вестн. 1832. Ч. 35.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ЛЕО́НОВ** Владимир Васильевич (21.10.1931, Орёл өлкәсенең хәзерге Хотынец р-ны Хотынец а.), инженер-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1986). Ленинград технол. ин-тын тәмамлый (1956). 1956–67 дә Балашиха машина төзү з-дында инженер, инженер-конструктор, баш конструктор бүлеге башлыгы урынбасары, 1967–81 дә «ВНИИКриогенмаш» бүлегендә бүлек башлыгы (Мәскәү өлкәсенең Балашиха ш.). 1981–85 дә «Вакуммаш» ФҖБнең ген. директоры. 1985–87 дә «Гелиймаш» ФҖБнең (Мәскәү) ген. директоры. Уйлап табуга 70 тән артык авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге ракета-космик комплексларның җир өстендәге криоген-вакуумлы системалары комплексын булдырганы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛЕО́НОВ** Леонид Максимович (19.5.1899, Мәскәү — 7.8.1994, шунда ук), язучы, СССР ФА академигы (1972), Соц. Хезмәт Герое (1967). «Бурсыклар» («Барсуки», 1924), «Карак» («Вор», 1927), «Соть» (1930), «Океанга юл» («Дорога на океан», 1935), «Рус урманы» («Русский лес», 1953; Ленин бүләге, 1957), «Пирамида» (1994) романнары, повестьлар, пьесалар, публицистик мәкаләләр һ.б. авторы. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның октябреннән 1942 нең мае ахырына кадәр Чистайда яши. Кабат анда 1942 нең октябрь–ноябрендә һәм 1943 нең июнендә була. Чистай чорында «Ябырылу» («Нашествие», 1942; СССР Дәүләт бүләге, 1943) пьесасы, «Безнең Мәскәү» («Наша Москва», 1941), «Язучылар фронтта» («Писатели на фронте», 1942) мәкаләләре языла, «Ленушка» (1943), «Алтын карета» («Золотая карета», 1946) пьесалары языла башлый. Л. шәһәрнең мәдәни тормышында актив катнаша, әдәби кичәләрдә аерым битләре Алабуга шәһәренә һәм Кама елгасына багышланган «Океанга юл» романыннан өзекләр укый. 1942 нең октябрендә Чистай театрында «Ябырылу» пьесасын сәхнәләштерүдә катнаша (премьерасы 1942 нең ноябрендә була). 1943 нең мартында пьеса Казан Зур драма театры, 1980 дә Татар акад. театры сәхнәләрендә куела. Л.ның күп кенә әсәрләрендә («Ябырылу», «Алтын карета», «Рус урманы», «Великошумскны алу») Чистай һәм Казанда алган тәэсирләре чагылыш таба. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1977). 1946–70 елларда СССР ЮС депутаты.



Л.М.Леонов.

*Әд.:* Д а в ы д о в И.В. С думой о фронте. К., 1984. *Г.С.Муханов.*

**ЛЕО́НТЬЕВ** Константин Михайлович (29.4.1849, Вологда губ. Тотьма ш. — 14.5.1904, Ялта ш.), мәхкәмә табибе, медицина д-ры (1885). 1875 елда Казан ун-тын тәмамлагач, мәхкәмә медицинасы кафедрасында хезмәт итә. 1878 дән хәрәкәттәге Кавказ армиясенең Боржоми госпиталендә хәрби-мед. хезмәтендә. 1887 дән Казан ун-тында, 1895 тән мед. ф-ты секретаре, 1899 дан мәхкәмә медицинасы кафедрасында ординар проф. Хезмәтләре асфиксия мәсьәләләренә, *«Мултан эше»* экспертизасына, мәхкәмә медицинасын укытуга карый.

Х е з м.: Очерк судебно-медицинских исследований // Дневник Казан. об-ва врачей. 1880. № 7; Судебно-медицинский случай огнестрельной раны сердца. К., 1885.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ЛЕ́ПА** Альфред Карлович (1896, Рига ш. — 9.5.1938, Казан), партия эшлеклесе. 1914 елдан РСДРП(б) әгъзасы, шул ук елда сугышка каршы пропаганда алып барганы өчен кулга алына һәм Нарым краена сөрелә. 1916 да кача, Екатеринбург шәһәрендә революцион эшчәнлек алып бара, 1917 дә яңадан кулга алына, 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң иреккә чыгарыла. 1917 дә РКП(б)ның Екатеринбург ком-ты секретаре булып сайлана. Гражданнар сугышында катнаша. Адмирал А.В.Колчакка каршы көрәш чорында азык-төлек комиссары, Көнчыгыш фронтның 3 нче армиясе сәяси органнары җитәкчесе. 1920 еллардан Курск һәм Вятка губерналарында, Үзбәкстанда партия эшендә. СССР ҮБК әгъзасы. 1933–37 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана (1955).

*Әд.:* С у л т а н б е к о в Б. Лепа Альфред Карлович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ЛЕПЁХИН** Иван Иванович (10.9.1740, С.-Петербург — 6.4.1802, шунда ук), натуралист, сәяхәтче, медицина д-ры (1767), Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1771). ФА оештырылганнан бирле аның алыштыргысыз секретаре (1783). Академия әгъзаларыннан беренче булып алтын медаль б-н бүләкләнә. 1751–62 елларда ФА каршындагы гимназиядә укый; акад. С.П.Крашенинников шәкерте. Белем алуын Страсбург ун-тында дәвам итә, анда 1767 дә медицина д-ры дәрәҗәсенә диссертация яклый. 1768–72 дә





Ленино-Кокушкино табигый-тарихи тыюлыгы. 1. Нарат урманнары; 2. Үшнә елгасындагы буа.


И.И.Лепёхин.


Е.М.Лепский.

ФАнең Урта һәм Түбән Идел буен, Уралны, Россиянең Европа өлешендәге төньяк районнарын тикшергән Оренбург экспедициясе отрядларының берсенә җитәкчелек итә. 1773 тә Балтыйк буенда һәм Белоруссиядә экспедициядә була. 1774 тән ФАнең Ботаника бакчасы директоры, 1777–94 тә акад. гимназия инспекторы. Ботаника һәм зоология, рус филологиясе фәннәре һ.б. буенча хезмәтләре бар. Ж.Л.Бюффонның 10 томлы «Табигый тарих»ының («Естественная история», СПб., 1802–27) 6 томын тәрҗемә итә; «Россия Академиясе сүзлеге»н («Словарь Академии Российской», т. 1–6, СПб., 1789–94) әзерләүдә катнаша. 1784 тә П.С.Паллас б-н берлектә Кырымны өйрәнү буенча инструкция төзи. Төп хезмәте — «Россия дәүләтенең төрле провинцияләре буйлап... сәяхәтләрнең көндәлек язмалары» («Дневные записки путешествия ... по разным провинциям Российского государства» (т. 1–4, СПб., 1771–1805; т. 4 — «Академик Иван Лепёхинның 1772 елдагы сәяхәтләре» («Путешествия академика Ивана Лепёхина в 1772») — вафатыннан соң Н.Я.Озерецковский тарафыннан нәшер ителә) — 18 йөздә Россия икътисады, географиясе һәм этнографиясе буенча киң фактик материалны үз эченә ала. «Көндәлек язмалар...»ның өченче томы Урта һәм Түбән Идел буен өйрәнүгә, җирле халыкларның, ш.и. татарларның мәдәнияте һәм көнкүрешенә багышлана (татарларда кырчылык һәм яшелчә үстерү техникасы, крәстиян кәсепчелеге һәм шәһәр һөнәрчелеге турында мәгълүматлар бирелә). Л. хезмәтләре — тарихи мәгълүматларның бәяләп бетергесез чыганагы булып тора.

Бөтенроссия этнография җәмгыяте (1770), Берлин табигатьне тикшерүчеләр җәмгыяте (1776), Гессен-Гамбург патриотик җәмгыяте (1778) әгъзасы.

*Әд.:* Озерецковский Н.Я. Жизнь И.И.Лепёхина // Журн. Департамента нар. просвещения. 1822. Ч. 2; Поленов В.Я. Краткое жизнеописание И.И.Лепёхина // Тр. Имп. Рос. академии., 1840. Ч. 2; Фрадкин Н.Г. Академик И.И. Лепёхин и его путешествия по России в 1768–1773 гг. М., 1953; Кулябко Е.С. Замечательные питомцы Академического университета. Л., 1977.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ЛЕПЁШКИН** Владимир Васильевич (12.8.1876, Мәскәү — 1947, АКШның Аризона штаты Тусон ш.), ботаник, ботаника д-ры (1909). Петербург технол. ин-тын тәмамлый (1898). Германия, Швейцария, Даниядә эшли. 1906–10 елларда Петербург ун-тында, 1910–21 дә Казан, 1921–22 дә Белоруссия, 1922–27 дә Карлово (Прага ш.) ун-тлары профессоры. Казан ун-тының ботаника кабинеты составыннан үсемлекләр физиологиясе лаб-ясен аерып ала (1910) һәм аның б-н 1921 гә кадәр җитәкчелек итә. 1927–33 тә АКШта, яңа оештырылган фәнни ин-тта (Тусон) биохимия лаб-ясе мөдире. 1933–44 тә Вена ун-тында (Австрия). Күп сәяхәт итә. 1947 елда АКШка кайта. Хезмәтләре үсемлекләр физиологиясенә һәм биохимиягә карый. Л. үсемлек күзәнәкләре протоплазмасының коллоид төзелеш концепциясен нигезли һәм үсемлекләр физиологиясен өйрәнүдә яңа физик-химик юнәлеш тудыра.

Хезм.: Исследования над осмотическими свойствами и тургором растительных клеток // Зап. Имп. АН. Сер. 8. 1907. Т. 22, № 2; О живом и мёртвом. К., 1910; Организм с точки зрения химии и физики. Прага, 1924.

*Әд.:* Гордягин А.Я. Отзыв о научных работах доктора ботаники В.В.Лепёшкина // Уч. зап. Казан. ун-та. 1911. Т. 78, кн. 2.

**ЛЕ́ПСКАЯ** Ревекка Израилевна (3.12.1885, Киев губ., Переяславль ш. — 17.3.1971, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1937) проф. (1935), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940), С.С.*Зимницкий* шәкерте. 1911 елда Париж ун-тын тәмамлагач, Казан ун-тында госпиталь терапиясе клиникасында эшли, бер үк вакытта 1918 дән 1 нче эшче хастаханәсенең терапия бүлеге мөдире. 1920–53 елларда Казан ГИДУВында, 1930 дан 1 нче терапия каф. мөдире. Хезмәтләре бавыр һәм бөерләр патологиясенә, матдәләр алмашы бозылуга, витаминологиягә карый. Бавырның кискен, субхроник һәм озакка сузылган дистрофик халәтен тикшерә. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Токсические дистрофии печени. К., 1929; Введение в клинику авитаминозов и гиповитаминозов. К., 1948 (автордаш); Болезнь Боткина и её исходы. К., 1951.

*Әд.:* Рахлин Л.М., Щербатенко А.А. Профессор Ревекка Израилевна Лепская (100-летию со дня рождения) // Казан. мед. журн. 1986. № 3.

**ЛЕ́ПСКИЙ** Ефим Моисеевич (13.5.1879, Украинаның Златополь ш. тирәсендәге Смела а. — 3.3.1955, Казан), педиатр, медицина д-ры (1915), проф. (1924), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1935). 1905 елда Берлин ун-тын тәмамлый. 1906 дан Казан ун-тының балалар авырулары кафедрасында, бер үк вакытта патологик анатомия кафедрасында, Ятимнәр йорты табибе, Сабыйлар йорты мөдире. 1919 дан Казан госпиталендә, бер үк вакытта губ. сәламәтлек саклау бүлегенең аналар һәм сабыйларны саклау бүлекчәсе мөдире. 1921–53 елларда Казан ГИДУВында; 1920 дә балалар клиникасын оештыра һәм аны җитәкли, 1924 тән балалар авырулары каф. мөдире. Бер үк вакытта 1932–35, 1940–45 тә Казан мед. ин-тының шул исем. каф. мөдире, 1932–35 тә педиатрия ф-тын оештыра, аның беренче деканы. Хезмәтләре рахит патогенезына, аны дәвалау һәм булдырмауга карый, бала яшендәгеләр патологиясендә витаминнарның ролен ачыклый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 1967 дән Казан мед. академиясенең балалар клиникасы Л. исемен йөртә.

Хезм.: Рахит и тетания рахитиков. М., 1945; Введение в клинику авитаминозов и гиповитаминозов. К., 1948 (автордаш); Гиповитаминозы в детском возрасте. М., 1953.

*Әд.:* Макаров Ю.В., Мамиш Р.М. Заслуженный деятель науки РСФСР профессор Е.М.Лепский: Некролог // Педиатрия. 1955. № 4.

**ЛЕПТОСПИРОЗЛА́Р** (Leptospirosis, Васильев-Вейль авыруы, су бизгәге), кискен йогышлы авырулар. Авыру китереп чыгаручылар лептоспирлар семьялыгына карый; Арадан бер төре (Leptospira interrogans) серотипларга һәм серологик төркемнәргә бүленә. ТРда күбрәк серологик төркемнәр (pomona, canicola, grippotyphosa) очрый. Авыру клиникасы күренешен беренче тапкыр рус галиме Н.П.Васильев (1883) һәм немец галиме А.Вейль (1886) тасвирлыйлар. Япон галиме А.Инадо (автордаш) L. авыру китереп чыгаручы тагын бер төрне (icterohaemorrhagiae) аерып күрсәтә (1915).

Авыру чыганагы булып күселәр, урман һәм кыр тычканнары, су күселәре, этләр, дуңгызлар санала. Зарарлану тире һәм лайлалы тышчаның йогышлы авыру булган материалга кагылуыннан (пычрак җир, су, ашамлыклар) башлана. Авыруга гомуми агулану, бизгәк тоту, йөрәк миокарды, бавыр, үт, бөерләр (уремия билгеләре), нерв һәм тамырлар системасы зарарлану, геморрагик билгеләр хас, сары авыруы күренеше күзәтелә. Үлем очрагы бөерләр зәгыйфьлеге б-н бәйләнгән. Авыру ел фасылларына бәйле.

Казан галимнәре З.Х.*Кәримова*, Г.З.Хәбирова, Н.И.Борознов Татарстанда һәм Идел буе төбәге республикаларында Л. мәсьәләләрен өйрәнәләр, бу йогышлы авыру чыганакларын ачыклыйлар, авыру китереп чыгаручыларның саф культураларын билгелиләр, лептоспирларның яңа штаммнарын ачыклыйлар («Кәримова», «Кабан», «Казан»), беренче тапкыр микроблар үстерү өчен уникаль туклану мохите (сыек һәм тыгыз) эшлиләр һәм тәкъдим итәләр, Л.ны булдырмауның махсус һәм махсус булмаган чараларын эшлиләр. Н.И.Борознов Л.га каршы вакцина тәкъдим итә (1989). 2000–05 тә ТРда авыруның спорадик очраклары күзәтелә.

*Әд.:* Каримова З.Х. К вопросу об источниках лептоспирозной инфекции // Вопр. теорет. и клинической медицины. 1960. № 1; Каримова З.Х., Хабирова Г.З. К вопросу выявления патогенных свойств лептоспир in yitro // Науч. тр. Казан. мед. ин-та. 1964. Т. 14.

*В.Х.Фазылов.*

**ЛЕ́РМАН** Игорь Михайлович (12.8.1952, Сахалин өлкәсенең Южно-Курильск ш.), скрипкачы, дирижёр, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994), ТР халык артисты (2008). 1978 елда Горький шәһәре консерваториясен тәмамлый. 1975 тән Горький филармониясе симф. оркестрында, 1948 дән Карачай-Чиркәс автономияле өлкәсенең Черкесск шәһәрендә музыка уч-щесе, 1980 нән Чаллы сәнгать уч-щесе укытучысы. «*Провинция*» (Чаллы ш.) камера оркестрын оештыра (1988), аның сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры, музыкантларның күбесе Л.ның шәкертләре. Бер үк вакытта, 2004 тән Казан консерваториясендә укыта.

**ЛЕРО́Н** Ләбиб (псевд., чын исем-фамилиясе Леронов Лемон Лерон улы) (11.11.1961, Мөслим р-ны Иске Карамалы а.), язучы, ТР-ның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый(1984). 1983–89 елларда (бүленеп) «Яшь ленинчы» г-тасы редакциясендә эшли (1988–89 да әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире), 1986–88 дә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры, 1989 дан «Салават күпере» ж-лында бүлек мөхәррире. 2011 дән РФ әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры, 2012 дән, бер үк вакытта, «Казан утлары» ж-лында бүлек мөхәррире. Балалар өчен язылган «Яңгырның ял көне» (1988), «Транзистор үч ала» (1989), «Тәгәрмәчле чана, яки Әкият боткасы» (1993), «Шайтан шаяруы» (1996), «Таһир маҗаралары» (1999), «Кояшны кочкан малай» (2004; Республиканың М.Җәлил исем. бүләге, 2007) китаплары юморга һәм фантазиягә бай. Ул ш.у. — «Сине генә сөям» (1997) исемле лирик-публицистик шигырьләр җыентыгы һәм татар язучыларына пародияләр һәм эпиграммалар тупланган «Күрше тавыгы» (1990) җыентыгы авторы. Л.ның «Чәпәләй белән Тәпәләй» (1995), «Аңгыра сарык җүләре» (1996) пьесалары буенча Әлмәт татар драма т-рында спектакльләр куела.

Ә с ә р.: Җил көймәсе. К., 2008; Бәхеткә биш минут кала. К., 2012.

**ЛЕ́СГАФТ** Пётр Францевич (21.9.1837, С.-Петербург — 28.11.1909, шунда ук), анатом, медицина д-ры (1865), хирургия д-ры (1868), җәмәгать эшлеклесе; Россиядә физик тәрбия һәм физик культурада табиб-педагог контролен фәнни нигезгә салучы. 1861 елда Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлагач, шунда ук фәнни-пед. эштә. 1868 дән Казан ун-тының физиол. анатомия каф. профессоры һәм мөдире. 1871 елда, Казан ун-ты һәм уку-укыту округы җитәкчелеге эшчәнлегенә каршы чыкканы өчен, эшеннән азат ителә («Лесгафт эше»). 1972–74 елларда Петербург мед.-хирургия академиясенең хатын-кыз табибләр курсларында укыта, 1878 дән Петербург ун-тында. 1874–86 да хәрби укыту йортларында курсантларны физик тәрбияләү эшен алып бара. 1877 дә офицерларны гимнастикага өйрәтү курсларын оештыра. 1886–97 дә Петербург ун-тында һәм Рождественский хатын-кызлар курсларындагы табигыять фәннәре ф-тында анатомия укыта. 1893 тә Петербург биол. лаб-ясен оештыра, 1896 да шунда Физик белем бирү буенча җитәкчеләр әзерләүнең югары фәнни курсларын булдыра. Россия хәрби уку йортларында физик тәрбияне гамәлгә кертә. Хезмәтләре теоретик анатомия, биология, педагогика, сөяк архитектурасы, буыннар һәм мускуллар төзелеше һәм эшчәнлегенә карый.

Х е з м.: Анатомия человека. СПб., 1892. Вып. 2.

*Әд.:* Ш а б у н и н А.В. Лесгафт Пётр Францевич. М., 1982.

**ЛЕСНО́Й** посёлогы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 15 *км* көнбатыштарак, Мәтәскә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 190 кеше (татарлар) яши. Урманчылык; агач эшкәртү цехы. Мәктәп, клуб. Торак пункт буларак 1963 тә теркәлә. Оештырылган көннән Саба р-нында. 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1989 да — 150, 2002 дә — 192 кеше.

**ЛЕСОСИБИ́РСК** шәһәре, *Красноярск краенда*. Халкы — 70 мең кеше, ш.и. 5138 татар (2002). Татарлар Л.ка Транссебер тимер юлын төзү елларында (1891–1916), Столыпин аграр реформасы (1906–11), 1921–22 еллардагы Идел буендагы ачлык вакытында килеп урнаша. Хәзерге вакытта шәһәрдә «Ватан» татар милли-мәгърифәт үзәге (1991 дән), «Дуслар» татар милли-мәдәни оешмасы (2002 дән) эшли.

**ЛЕСХО́З** посёлогы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 1058 кеше (татарлар) яши. Агач әзерләү һәм эшкәртү, халык киң куллану товарлары җитештерү пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Хастаханә. Мәчет. 1930 да нигез салына. Халык саны: 1938 дә — 478, 1949 да — 781, 1970 тә — 927, 1979 да — 904, 1989 да — 882, 2002 дә — 994 кеше. Л. — ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов үскән авыл.

**ЛЕ́УШЕВ** Владимир Николаевич (12.8.1946, Казан), генерал-майор (1989). ТАССРның ЮС Президиумы исем. Казан югары танк командирлары уч-щесен (1968), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1978), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясен (Мәскәү, 1986) тәмамлый. 1968–75 елларда Ерак Көнчыгыш хәрби округында хезмәт итә, 1972 дән танк батальоны командиры. 1975–89 да Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә, 1978 дән танк полкы командиры, 1983 тән дивизия командиры. 1989 дан штаб башлыгы — 38 нче армия командующиенең 1 нче урынбасары (Ивано-Франковск ш.). 1991 дән Никарагуа Респ-касында хәрби белгечләр төркеме башлыгы. 1994–97 елларда гадәттән тыш хәлләр районнары буенча округ гаскәрләре командующие урынбасары — Россия Эчке эшләр министрлыгы эчке гаскәрләренең Төньяк Кавказ хәрби округында оператив гаскәр төркеме башлыгы; Таҗикстан Респ-касындагы (1994–95), Чечен Респ-касындагы сугыш хәрәкәтләрендә (1995–97) катнаша. Батырлык, «Хәрби хезмәтләре өчен», 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткәне өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ЛЕЩИ́НСКАЯ** Инна Борисовна (21.2.1935, Мәскәү), микробиолог, биол. фән. д-ры (1973), ТР ФА академигы (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1958), шунда ук эшли, проф. (1982), микробиол. каф. мөдире (1991–2003). Казан ун-тының Биология фәнни-тикшеренү ин-тын оештыручыларның берсе һәм бер үк вакытта директоры (2001 дән). 2003 тән Израильдә. Хезмәтләре бактерия ферментларын тикшерүгә һәм аларны медицинада, ветеринариядә, биотехнологиядә кулануның теоретик нигезләрен эшләүгә карый. Л. — микроорганизм ферментлары биосинтезы буенча фәнни эшләр авторы, аның тарафыннан бактерия ферментларын көйләүнең яңа механизмнары ачыла, аларны сәнәгатьтә һәм медицинада куллану мөмкинлеге күрсәтелә. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы бар. ТР ФАнең В.А.Энгельгард исем. бүләге «Бактериаль ферментлар: биосинтезның молекуляр механизмнары, гамәли кулланууга характеристика һәм аны фәнни нигезләү» хезмәте өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



И.М.Лерман.



И.Б.Лещинская.

Х е з м.: Нуклеазы микроорганизмов. М., 1974 (автордаш); Нуклеазы сапрофитных бактерий. К., 1975; Биосинтез нуклеаз и протеаз микроорганизмами. М., 1979 (автордаш); Нуклеазы бактерий. К., 1991 (автордаш).

**ЛЁВШИН** Лев Львович (27.2.1842 — 23.9.1911, Мәскәү), хирург, медицина д-ры (1870), атказ. проф. (1899). 1866 елда Петербург мед.-хирургия акад. тәмамлагач, аның клиник госпиталендә, соңрак хирургия клиникасында һәм 1868 гә кадәр тасвирый анатомия кафедрасында эшли. 1869 да Император САдә пластик анатомия курсларын алып бара. 1870 тән хәрби-мед. хезмәтендә. 1874 тән Казан ун-ты профессоры, 1879 дан хирургик патология каф. мөдире, 1887–93 тә ф-т хирургиясе каф. директоры. 1877–78 дәге рус-төрек сугышы чорында Н.И.Пирогов кул астында хирург-киңәшче, 1879 дан Казан хәрби госпиталендә. 1893 тән Мәскәү ун-тының госпиталь хирургиясе каф. мөдире. 1903 тән Мәскәү яман шеш авырулары б-н интегүчеләрне дәвалау ин-тын оештыручы һәм директоры. Хезмәтләре антисептика, дезинфекция, кичектергесез хирургия, баш сөяге һәм баш мие травмаларын дәвалауга карый.

Х е з м.: Основы хирургии. К., 1880; Распространение каменной болезни в России // Летопись хирург. об-ва. 1890. № 6; Руководство по частной хирургии. М., 1896.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Н и к и т и н С.К. Профессор Лев Львович Лёвшин (к 50-летию со дня смерти) // Казан. мед. журн. 1961. № 5; К а п а ц и н с к и й Е.В. Памяти профессора Л.Л.Лёвшина // Вопр. онкологии. 1983. № 2.

**ЛИАКУМО́ВИЧ** Александр Григорьевич (5.3.1931, Белоруссия ССРның Могилёв өлкәсе Бобруйск ш.), химик-технолог. химия фән. д-ры (1966), проф. (1977), ТАССР, РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1981, 1997), РФнең мактаулы химигы (2003). Казан технол. ун-тының атказ. проф.(2004). 1954 елда Мәскәү нечкә химик технология-

ләр ин-тын тәмамлаганнан соң, «Гидрокаучук» фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1960 тан Эстәрлетамак ясалма каучук з-дында, баш инженер урынбасары, директор урынбасары (БАССР). 1975 тән Казан технол. ун-тында, Түбән Кама ф-лында гомуми теоретик дисциплиналар, ясалма каучук технологиясе кафедралары мөдире (1984 тән), Эластомерлар эшкәртү үзәге директоры (1989–2002). Хезмәтләре нефть химиясе синтезына, гамәлдәге нефть химиясе җитештерүен интенсификацияләүгә һәм камилләштерүгә карый. Л. бутадиен һәм изопрен җитештерүдә контактлы газларны чыныктыруның яңа процессларын гамәлгә ашыра, бутадиен аерып алу ысулларын камилләштерә, изопренны циклопентадиеннан, ацетилен кушылмаларыннан чистарту алымнарын эшли. Изопрен аерып алу процессларында термополимерлауның яңа төр ингибиторларын тәкъдим итә. Әлеге эшләре өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1989). Л. җитәкчелегендә феноллы антиоксидантлар синтезы буенча тикшеренүләр циклы үткәрелә, агулы булмаган антиоксидантлар җитештерү з-ды (Эстәрлетамак ш.) — Башкортстанның зур экспорт чыганагы һәм БДБ илләренә продукция җибәрүче пр-тие төзелә. Гәрәбә к-тасы, эндик ангидриды, полимер материаллар өчен химик өстәмәләр технологиясе һәм химиясе буенча эшләр җитәкчесе. Л.ның фәнни тикшеренү нәтиҗәләре «Казаноргсинтез», «Түбәнкаманефтехим», С.М.Киров исем. ясалма каучук з-дында, Эстәрлетамак ясалма каучук з-дына һ.б. пр-тиеләрдә кертелә. Уйлап табуга 600 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия и технология мономеров для синтетических каучуков. М., 1983 (автордаш); Получение и применение 3-метилбутена-1 // Темат. обзор. М., 1993. № 1 (автордаш); Современные нефтехимические синтезы на основе бутадиена // Темат. обзор. М., 1993. № 4 (автордаш).

*Әд.:* Институт полимеров (полимерный факультет, 1971–2001): Краткий биогр. справ. К., 2001.

**ЛИБЕРАЛИ́ЗМ** (лат. liberalis — ирекле), 17–18 йөзләрдә Европа илләрендә барлыкка килгән, гражданлык, сәяси һәм икътисади ирекләр игълан иткән идеячел иҗтимагый-сәяси хәрәкәт. Көнбатыш Европада Л. формалашуның нигезен антик чорның хокукый мәдәният мирасы, катлау-корпорацияләр ирекләре һәм вөҗдан иреге өчен көрәш традицияләре, ныгып җитлеккән хосусый милек хокукы һәм урта сыйныфның көчле йогынтысы тәшкил итә. 19 йөздә — 20 йөз башында Л. алга сөргән төп кыйммәтләр — гражданнар җәмгыяте, демократик сәяси ин-тлар, хосусый эшмәкәрлек һәм сәүдә ирегеннән гыйбарәт. Л.(неолиберализм) вәкилләре ирекле базар механизмы нәтиҗәле икътисади эшчәнлек, социаль һәм икътисади процессларны көйләү өчен аеруча уңай алшартлар тудыра дип исәплиләр; шул ук вакытта алар базар мөнәсәбәтенең, конкуренциянең нормаль шартларын саклау өчен дәүләт йогынтысы зарурлыгын да таныйлар.

Россиядә либераль традицияләрнең яңаруы Екатерина II идарә иткән чорга карый. Аның реформалары Россия мәгърифәтчелеге кысаларында либераль интеллектуаль тенденцияләр тууга гына түгел, дворяннар мохитендә европача укымышлы, либераль кыйммәтләрне кабул итүгә әзер кешеләр барлыкка килүгә дә этәргеч бирә. Екатерина II, Александр I һәм Александр II идарә иткән чорларда Л. хөкүмәт сәясәтенең бер өлешен тәшкил итә. Ул 1830–40 елларда иҗтимагый-сәяси фикернең мөстәкыйль агымы булып җитлегә. Бу крепостнойлык хокукына, адм. башбаштаклыкка каршы чыгып, сүз һәм вөҗдан иреген яклаган «көнбатышчылар» һәм «славянофиллар» идеологиясе таралу б-н бәйле. Либераллар һәрьяклап Александр II нең үзгәртеп коруларына булышлык итәләр, аларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда турыдан-туры катнашалар. Казанда интеллигенциянең аеруча мәгърифәтле һәм либераль фикерләүче өлеше актив рәвештә төрле җәмәгать оешмалары, ш.и. *Казан икътисадчылар җәмгыяте* эшчәнлегенә тартыла. Бу җәмгыятьнең күренекле әгъзаларының берсе — тарихчы һәм икътисадчы И.К.*Бабст* була. Аның 1856 да Казан ун-тындагы «Халык капиталын арттыруга ярдәм итүче кайбер шартлар хакында» («О некоторых условиях, способствующих умножению народного капитала») дип аталган нотыгы җәмәгатьчелектә зур яңгыраш ала. Анда Л.ның хосусый милекнең кагылгысызлыгын тәэмин итү, сәнәгать һәм сәүдә иреге кебек принциплары чагылыш таба. Россиядә реформалар уздырылган елларда Казанда либераль басма — «*Волжский вестник*» ж-лы чыгарыла. 1864 елгы Земство реформасы 1870 еллардан либераль хәрәкәтнең төп формаларының берсенә әверелгән земство хәрәкәте барлыкка килүгә китерә. Казан губернасы земствочылары арасында С.А.Бекетов, К.П.Берстель, Н.Е.*Боратынский,* А.Н.*Боратынский*, К.Н. һәм П.К.Буличлар, М.И.*Догель,* С.В.*Дьяченко*, В.В.*Морковников*, В.А.Юшков һ.б. Л. позицияләрендә торалар. Земство Л.ы идеяләрен Казанда чыгучы «Волжско-Камское слово» г-тасы яклый. Россия либераллары җирле үзидарәне гамәлгә кертүне конституциягә ирешү юлында беренче баскыч буларак карыйлар. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Л., сәяси агым буларак, яңа сыйфатларга ирешә (кайбер тикшеренүчеләр аны «яңа либерализм», яки неолиберализм дип атыйлар): сәяси үзгәртеп корулар гына түгел, социаль-икътисади реформалар уздыру таләбе дә алга куела. 20 йөз башында партия булып оешуга йөз тоткан либераль оешмалар 1905 елгы «17 октябрь Манифесты» басылып чыкканнан соң сәяси партияләргә әвереләләр. Россия Л.ы киң социаль базасы булган социаль-сәяси хәрәкәтнең бер формасына әверелә. Либераль партияләр 1 нче Дәүләт Думасына сайлауларда җиңү яулыйлар, башка думаларда фракцияләр оештыралар (к. *Дәүләт Думасы*). Казан губернасында либераль юнәлештәге иң эре оешмалар — *Конституцион демократлар партиясе, «Унҗиденче октябрь берлеге», «Иттифакъ әл-мөслимин»*. Либераллар тарафыннан алга сөрелгән таләпләр арасында халыкның киң катлаулары мәнфәгатьләренә кагылышлы аеруча кискен проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгәннәре дә шактый була («гадел бәягә» алпавыт җирләренең бер өлешен ирексезләп сатып алу, эшчеләр турындагы законнарны, 8 сәгатьлек эш көнен гамәлгә кертү һ.б.). 20 йөз башында төбәктәге либераль хәрәкәтнең актив эшлеклеләре — Й.Х.*Акчура*, С.Ш.*Алкин,* И.И.Бабушкин, А.Г.Бать, А.Н.Боратынский, Б.В.*Варнеке,* А.В.*Васильев*, М.С.Венецианов, И.В.*Годнев*, Н.П.Гусев, М.Я.*Капустин,* С.Н.*Максуди*, А.А.*Симолин*, Г.Г.Тельберг, М.М.*Хвостов*, Г.Ф.*Шершеневич* һ.б. Казан губернасының либераль оешмалары вәкилләре Дәүләт Думасы, Дәүләт Советы (А.В.Васильев), 1917 нең Февр. рев-циясеннән соң Вакытлы хөкүмәт (И.В.Годнев) эшендә актив катнашалар. Казан губернасы буенча барлык дүрт чакырылыш Дәүләт Думасына, ш.у. шәһәр думаларына һәм земство җыеннарына сайлаулар нәтиҗәләре либераль партияләр халыкның шактый зур өлеше (ш.и. татарлар) арасында популяр булуын раслый. Казан либераллары матбугат органнары — «*Волжско-Камская речь*», «*Вечернее эхо*», «*Казанский вечер*», «*Камско-Волжская речь*», «*Обновление*» г-таларын, «Наш край» ж-лын чыгаралар.

19–20 йөзләр чигендә илдә Россия Л.ы йогынтысында аерым бер агым буларак, мөселман Л.ы формалаша, аның тамырлары ислам ислахчылыгына барып тоташа (к. *Җәдитчелек, Мөселман ислахчылыгы*), бу аның үзенчәлеген билгели. Мөселман Л.ының социаль нигезен Россиядәге мөселман халкының европалашкан «югары катлавы» тәшкил итә. Мөселман Л.ы вәкилләре Россия хөкүмәтенең милли кыерсыту сәясәтенә каршы чыга, гражданлык тигезлеге һәм иреге идеясен яклыйлар, хокукый дәүләт төзү һәм Россия халыкларының милли-мәдәни үзбилгеләнү мөмкинлегенә ышанып карыйлар. Мөселман Л.ы идеяләрен, башлыча, «Иттифакъ әл-мөслимин» сәяси партиясе чагылдыра (Й.Х.Акчура, И.*Гаспринский*, С.Ш.Алкин, С.Н.Максуди, Ә.Н.*Максуди* һ.б.). Окт. рев-циясеннән соң либераль партияләр эшчәнлеге тыела, җитәкчеләре законнан тыш дип игълан ителә. Аларның күбесе чит илләргә китә. Казанда чыгарылган татар либераль басмалары — «Әхбар», «Казан мөхбире», «Йолдыз» г-талары.

1980 еллар ахырыннан кайбер либераль идеяләр һәм кыйммәтләр М.С.Горбачёвның һәм Б.Н.Ельцинның дәүләт сәясәтендә чагылыш таба. Хәзерге Россия Л.ының сәяси үзбилгеләнүе берничә этап уза, ул «Демократик Россия», «Выбор Росии», «Яблоко», «Уң көчләр берлеге» һ.б. берләшмәләр һәм партияләр эшчәнлеге б-н бәйле (к. *Татарстанда иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм хәрәкәтләр*).

*Әд.:* Л е о н т о в и ч В.В. История либерализма в России, 1762–1914. М., 1995; С е к и р и н с к и й С.С., Ш е л о х а е в В.В. Либерализм в России: Очерки истории (сер. XIX — нач. XX в.). М., 1995; Шелохаев В.В.Либеральная модель переустройства России. М., 1996; Ф а х р у т д и н о в Р.Р. Татарский либерализм в конце XIX — начале XX века (очерки политической истории). К., 1998; Я м а е в а Л.А. Мусульманский либерализм начала XX века как общественно-политическое движение. Уфа, 2002; А й н у т д и н о в а Л.М. Либераль-

ное движение в Казанской губернии (1900–1917 гг.). К., 2003. *Л.М.Айнетдинова.*

**ЛИБРЕ́ТТО** (итал. libretto — кечкенә китап, 1) опера, оперетта, балет, оратория өчен язылган әдәби текст (М.Җәлилнең «Алтынчәч», Ә.Фәйзинең «Илдар», «Шагыйрь», Ә.Исхакның Г.Бәширов романы буенча язылган «Намус», Х.Вахитның «Самат», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик», опералары Л.лары һ.б.; Р.Харисның «Шагыйрь мәхәббәте», «Кеше» поэмасы буенча язылган шул исем. ораториясе, Т.Гыйззәтнең Х.Ибраһимов пьесасы буенча язылган «Башмагым» муз. комедия Л.лары); 2) балет, пантомиманың әдәби сценарие (Г.Тукайның «Шүрәле» һәм «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмалары буенча Ә.Фәйзи язган «Кисекбаш», Р.Харисның «Кыйссаи Йосыф» балет Л.лары); 3) опера һәм балетның театр программасында яки аерым китапчыкта бәян ителгән эчтәлеге (М.Җәлилнең «Балыкчы кыз» («Дулкыннар») һәм «Хәмидә» опералары Л.лары); 4) кинофильм сценариеның сюжет планы яки схемасы (Гәрәй Рәхимнең «Борынгы Болгарны сагыну», М.Гыйләҗевнең «Бөркетләр» кинофильмнары өчен язган Л.лары). *Н.Г.Ханзафаров.*

**«ЛИВА́ДИЯ»**, санаторий. Казансу елгасының сул як ярында, Казанның урман-парк өлешендә, Совет р-нында урнашкан. 1942 елда нигез салына, 1962 гә кадәр Ял йорты булып исәпләнә. Табигый дәвалау факторлары: хлорид-натрий эретмәләре, бром (бальнеология максатында) б-н баетылган аз сульфидлы ләм балчыгы, сульфат-магний-кальцийлы минераль су, шифалы су (1995 тә бювет ачыла).

Санаторий кан әйләнеше органнарын (ш.и. миокард инфаркты һәм йөрәккә операциядән соң кискен йөрәк зәгыйфьлеге, сулыш органнарын, урология һәм гинекология, йөрү-хәрәкәтләнү аппараты, ашказаны-эчәк юллары, гепатобилиар система авыруларын дәвалауга корылган.

Дәвалау комплексында коры углекислоталы ванналар, гало- һәм спелеотерапия, ингаляция, барокамералар, шифалы душлар, массаж, гальваник ләм, парафинлы озокерит, мануаль терапия, физиотерапия (аппарат б-н), рефлексив, лазерлы, психологик һәм үләннәр б-н дәвалау кулланыла. Сәламәтләндерүнең бер өлешен дәвалау физкультурасы, маршрутлар буенча җәяү йөрү алып тора.

2 торак корпусы, дәвалау корпусы, функциональ диагноз кую кабинетлары (электрокардиография, пневмотахометрия, эхокардиография, велоэргометрия, ультратавыш б-н тикшеренүләр), мунча, сауна, су б-н дәвалау урыны, китапханә, клуб, кино залы, спорт мәйданы, пляж, бассейн бар. Санаторий ел әйләнәсе эшли.


*Әд.:* Татарстан — курорт. К., 1993. *Л.Г.Макарова.*

**ЛИВА́НОВ** Михаил Николаевич (7.10.1907, Казан — 25.5.1986, Мәскәү), физиолог, СССР ФА академигы (1970; 1962 дән мөхбир әгъза). Н.А.*Ливанов* улы. Россия электроэнцефалографиясенә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлый (1931). 1933 елдан Мәскәүдә: Баш мие ин-тында (1933–46), Патология һәм интоксикацияләр терапиясе ин-тында (1947–48), СССР МФАнең Биофизика ин-тында (1949–60) лаб-ялар мөдире; 1961 дән СССР ФАнең Югары нерв эшчәнлеге һәм нейрофизиология ин-тында. Төп хезмәтләре баш миенең зур ярымшарлары кабыгында гадәти һәм патологик халәттә барган биоэлектрик күренешләрне тикшерүгә карый. Л. төрле ялкынсынулар вакытында электроэнцефалограмманың аерым ешлыктагы компонентлары динамикасын һәм функциональ әһәмиятен күрсәтә. Электроэнцефалоскопия алымын эшли һәм тәкъдим итә (1960), ул исә баш миенең зур ярымшарлары кабыгының бөтен өслеге буенча бер үк вакытта узучы биоэлектрик процессларга җентекле анализ үткәрергә мөмкинлек бирә. Беренче булып баш мие кабыгының биоэлектрик тирбәнүләрен тикшерүдә — матем. анализ алымнары, экспериментлар үткәрүдә электрон хисаплау машиналары (ЭВМ) куллана. Нурлар патологиясе мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Л.ның теоретик эшкәртмәләре һәм методик ысуллары нейропсихиатрия клиникаларында, клиник (космик) һәм авиация медицинасында диагноз кую өчен кулланыла. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. И.П.Павлов исем. алтын медаль б-н бүләкләнә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (вафатыннан соң, 1987).

Х е з м.: Электроэнцефалоскопия. М., 1960 (автордаш); Некоторые проблемы действия ионизирующей радиации на нервную систему. М., 1962; Пространственная организация процессов головного мозга. М., 1972.

*Әд.:* Современные проблемы электрофизиологии центральной нервной системы. М., 1967.

**ЛИВА́НОВ** Николай Александрович (20.11.1876, Саратов ш. — 7.12.1974, Казан), зоолог, зоология д-ры (1914), биол. фән д-ры (1938), РСФСР-ның атказ. фән эшлеклесе (1942). Казан ун-тын тәмамлый (1901), шунда ук эшли, проф. (1919), умырткасызлар зоологиясе каф. мөдире (1918–48). Э.А.*Мейер* шәкерте. Казан ун-тының гомуми зоол. музеен оештыручы (1945), СССР ФАнең Казан ф-лы Биология ин-тының беренче директоры (1946–48), Идел-Кама саклаулыгын оештыруда башлап йөрүче (1960). Татарстан һәм Чуаш Респ-касының табигый байлыкларын, Байкал күле, Копет-Даг таулары, Кырым, Кавказ, Россиянең төньяк һәм ерак көнчыгыш диңгезләре фаунасын һ.б. өйрәнү эшләренә җитәкчелек итә. Хезмәтләре фаунистика, морфология, биоценология, гидробиологиягә, гомумбиология мәсьәләләренә карый. Хайваннар морфологиясендә экологик-функциональ юнәлешкә нигез сала; тиренең икенчел капламы — целоманың килеп чыгышы турында миоцель теориясе (1940), хайван типларының архитектоникасын анализлау алымы (1955), погонофора эчәксез суалчаннарының килеп чыгышы турында «аннелид теориясе» (1965), күпкүзәнәкле хайваннарның килеп чыгышының үзенчәлекле теориясе (1970) авторы. «Хайваннар дөньясының эволюция юллары» («Пути эволюции животного мира», М., 1945) китабы авторы. Казан ун-ты каршында Табигыятьчеләр җәмгыяте президенты һәм аның шәрәфле әгъзасы (1932 дән). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.А. Ливанов.

Х е з м.: Основные этапы эволюции нервной системы. К., 1941; О закономерностях живой природы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1960. Т. 120, кн. 6; Очерки планарий Байкала // Малощетинковые черви и планарии озера Байкал. М.–Л., 1962; Об «Аннелидной гипотезе» происхождения погонофор // Зоол. журн. 1965. Т. 44, вып. 2; О происхождении Metazoa // Зоол. журн. 1970. Т. 49, вып. 4.

*Әд.:* Выдающиеся отечественные зоологи. М., 1960; Арбузов Б,А, Мои воспоминания о профессоре Н.А.Ливанове // Казань. 2000. № 2/3; Г о л у б е в А.И., П о р ф и р ь е в а Н.А. Николай Александрович Ливанов. К., 2002. *Р.М.Сабиров.*

**ЛИВИСТО́НА** (Livistona), пальмачалар семьялыгыннан күпьеллык агачсыман үсем-











«Ливадия» санаторие. 1. Торак корпус; 2. Дәвалау корпусы; 3. «Акватория» бассейны.

лекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле. Иң матур пальмалар булып санала. Чыгышы — Азия, Австралия, Океаниянең тропиклары һәм субтропиклары. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә; аеруча таралганнары: көньяк Л. (L. australis) һәм кытай Л. (L. chinensis). Биеклеге 1,5–2 *м*. Сабагы яфрак сабакларының сүсчел калдыклары б-н капланган; яфрак сабаклары аска кайтарылган үткен чәнечкеләр б-н үсемлекнең түбәнге яртысында яки бөтен озынлыгында утыра, кайвакыт шома. Яфраклары зур, җилпәзәсыман, 60 һәм тагын да күбрәк бүлемнәргә телгәләнгән (кайвакыт яфрак сабына кадәр). Чәчәк төркеме куентылы, тармаклы, озынлыгы 1 *м* дан артык; озакка сузылган вегетатив үсү чорыннан соң чәчәк ата. Чәчәкләре вак. Җимеше шарсыман көрән җиләк. Җимеш биргәннән соң, үсемлек үлә. Орлыктан үрчетелә. Иркен, якты, чагыштырмача дымлы бүлмәләрдә яхшы үсә. Даими рәвештә яфракларын юу һәм су бөркү киңәш ителә.

**ЛИ́ВШИЦ** Борис Михайлович (17.10.1954, Саба р-ны Шәмәрдән штп), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), «Казан компрессор машиналары төзү заводы» АҖдә: баш технолог (1997 дән), техник хезмәт җитәкчесе (2001 дән). Дәүләт бүләге газ кудыру агрегатларының югары нәтиҗәле алмаш частьларын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**ЛИГНИ́Т** (лат. lignum — агач), янучан файдалы казылма; көрән күмер катламында җиңелчә күмерләшкән агач (башлыча ылыслы агачлар), үзенең үсемлек тукымасы төзелешен саклаган һәм тышкы рәвеше б-н үзгәрмәгән агачка охшаш. Аз черегән һәм күп агач калдыклары тупланган көрән күмерне дә Л. дип атыйлар (Л. күмере). Татарстанда Л. неоген чорындагы «Б» маркалы көрән күмердә бар. Буклы елгасы (Тукай р-ны Чыршылы а.), Талкыш елгасы бассейнында (Чистай р-ны Иске Ромашкино а.) очрый. Л.та (көлендә) сәнәгый чыгышы 500 *г/т* булган германий барлыгы ачыклана. Ш.у. к. *Казылма күмерләр*.

**ЛИ́ГОВО СТА́НЦИЯСЕНДӘ МӨСЕЛМАННА́Р ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́** (Петроград), 1914 елда оештырыла. Оештыручылары — М.Җиһаншин, С.Гатауллин, М.Х.Хәбибуллин. Төп максаты — мөселман балаларына белем бирүгә күзәтчелек итү, укытучыларны һәм мөселман руханиларын тоту өчен акча табу. Җәмгыять акчасына мәктәп салына. 1917 дән соң яшәүдән туктый.

**ЛИЗУНО́В** Борис Георгиевич (17.8.1912, Богородск ш., хәзерге Мәскәү өлкәсенең Ногинск ш. — 30.12.1996, Казан), техник-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Мәскәү авиация техникумын тәмамлый. 1933–86 да Казан авиация ҖБдә эшли: мастер, цех башлыгы, заводның производство җитәкчесе урынбасары, ҖБ директоры урынбасары (1974–75). Дәүләт бүләге самолётлар җитештерүдә стапель һәм универсаль җайланмаларны җыйганда принципиаль яңа технологияләр кулланып, яңа агымны эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Д.С.Фәхретдинов.*

**ЛИМА́Н РАЙОНЫ́**, *Әстерхан өлкәсенең* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1965 елда оештырыла. Мәйданы — 5234 *км²*. Үзәге — Лиман посёлогы (Әстерхан шәһәреннән 106 *км* читтә). Халкы — 35,2 мең кеше, ш.и. 1080 татар (2002). Татарлар, нигездә, Лиман посёлогында (140 кеше), Зинзәлә (836), Оля (42), Кряжевое (26) авылларында яшиләр. 1917 гә кадәр Зинзәлә авылында (1773 тә нигез салына) мәчет (1872 дә төзелә) була. 1990 еллардан монда Татар этник советы, авыл мәдәният йорты каршында «Дуслык» фольклор коллективы (1997 дән), «Татар кызы» татар вокаль хатын-кызлар төркеме (1997 дән), «Йолдызым» балалар фольклор ансамбле (1994 тән) эшли.

**ЛИМА́НОВ** Исмәгыйль (1870 тирәсе — ?), җәмәгать эшлеклесе, педагог. 1890 елларда «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә (Бакчасарай ш.) укыта, соңрак Петроград мөселманнары арасында мәгърифәт тарату җәмгыяте әгъзасы. Мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре съездында (1914) катнаша. 4 нче Дәүләт Думасының (1912–17) мөселманнар фракциясе секретаре. 1917 дә Милли Шураның башкарма ком-ты әгъзасы. Алдагы язмышы билгесез.

**ЛИМО́Н** (Citrus, limon), сәдәф утчалар семьялыгына караган цитрус ыругыннан агачсыман мәңге яшел үсемлек. Хәзер кыргый хәлдә очрамый. Чыгышы — Көньяк-Көнчыгыш Азия. ТРда декоратив үсемлек буларак үстерелә. Бүлмә шартларына яраклашкан төрләре киң таралган: Павлов, Курский, Мейер һ.б., 1,5 *м* га кадәр биеклеккә җитә, җимеше түгәрәк, юка кабыклы. Яфраклары гади, бөтен, чиратлашкан, йомыркасыман озынча түгәрәк, ланцетсыман, итчел, сабагы аз гына канатлы. Үзенчәлекле билгесе — яфракларда ноктасыман күренә торган күп санлы вак бизләр, аларда эфир майлары барлыкка килә. Яфрак куентыгында берәрле нык чәнечкеләр бар. Чәчәкләре вак, берәрле яки кечкенә чукларга җыелган, куентылы, хуш исле, ак таҗлы. Л. ярымүзагачланган чыбыкчадан, тамырланма ботактан (1–2 елдан җимеш бирә), орлыктан (нәфислеген югалта, 15 һәм тагын да күбрәк елдан соң гына җимеш бирә) һәм ялгау ысулы б-н үрчетелә. Дым һәм яктылык яратучан, югары темп-раны начар кичерә. Л.ны формалаштыру өчен язын ботакларын кыскарту мөһим.

**ЛИМОНИ́Т** (грек. leimṓn — болын, юеш урын), соры тимер, саз казылмасы, $FeO(OH{\cdot}nH_2O)$, табигый минераль агрегатлар — Fe гидроксидлары катнашмаларының (гётит, гидрогётит һ.б.) җыелма атамасы. Шулай ук Al, Mn, Si гидроксидлары һәм оксигидратлары, балчык минераллар һәм сорбир сулар керә. Саргылт һәм кызылсу-соры, порошоксыман йомшак җир, плёнкалар, майлар, агучан массалар һ.б. ясый. Л. җилләнү һәм явым-төшем нәтиҗәсендә тимерле минералларның үзгәрү продукциясе. Рудалар оксидлашу зоналарында: Франциядә, Люксембургта; РФдә — Уралда һәм Керчь ярымутравында үсеш алган. ТРда конкреция өслекләрендә бакыр рудасында, девонга кадәрге һәм мезозой дәверендәге токымнарда очрый, тимер оксидлы пигментлар составына керә (к. *Минераль буяулар*).



Лимонит конкрециясе. Татарстанның дүртенчел чор утырмаларыннан (плейстоцен).

**ЛИМО́НОВА** Инна Валерьевна (3.9.1955, Чиләбе ш.), шагыйрә. 1972 елда комсомол юлламасы б-н КамАЗ төзелешенә килә. 1973–75 елларда Казан ун-тында укый, 1982 дә Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый. 1990–95 тә Алабуга шәһәрендә М.Цветаева музее директоры. 1995 тән Мәскәүдә яши. «Российский обозреватель», «Инвестиции в России», «Дорожный патруль» ж-лларында эшли. 2001 дән «Лимпресс» нәшриятын җитәкли. «Шәһәр каеннары» («Городские берёзы», Чиләбе, 1980), «Иртәнге сәгатьтә» («В час предутренний», 1984), «Чаллы өстендә аккошлар» («Лебеди над Челнами», М., 1982) шигъри җыентыклары, проза һәм драма әсәрләре тупланган китаплар («Елга буена алып төш мине...» — «Отнеси меня к реке...», 1990 һ.б.) авторы. Л. шигъриятенә һәм прозасына гадилек, эчкерсезлек, дөньяны кабул итүдә самимилек һәм бөтенлек хас.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ЛИНГВИ́СТИК ГЕОГРА́ФИЯ**, тел белеме бүлеге, тел күренешләренең терр. таралышын геогр. картага төшерү юлы б-н өйрәнә. 19 йөз башында диалектологиядән аерылып чыгарыла, ареаль лингвистика б-н тыгыз бәйләнештә. Л.г. теориясенең нигезендә диалект (җирле сөйләш) аермасы турындагы төшенчә ята. Ул аерым диалект системаларында аларга гына хас рәвештә чагылыш таба һәм диалект теле төрләре катлаулы системасының бер өлеше булып тора; барлык тел өчен гомуми һәм ш.у. аерым сөйләшләргә һәм диалектларга гына хас булган аерым элементларны да үз эченә ала. Татар тел белемендә Л.г. тарихы 1940 еллар ахырында башлана. Бу елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты галимнәре татар телендәге диалект үзенчәлекләренең терр. таралышын өйрәнә башлый. Алар тарафыннан җыелган материалларга нигезләнеп, 1948–50 елларда Л.Җ.Җәләй җитәкчелегендә «Татарстанның диалектологик картасы» төзелә. 1950 еллар ахырында ин-тта Л.Т.Мәхмүтова җи-

тәкчелегендә диалектологлар төркеме оеша. Бердәм Программа нигезендә барлык татар сөйләшләренең төп үзенчәлекләре тикшерелә (1959), терр-яләрнең аерым квадратлары буенча микроатласлар булдырыла, изоглоссалар (аерым бер тел күренешенең терр. таралышын чикләп күрсәткән сызыклар) ачыклана. Күпьеллык масштаблы эш алып бару нәтиҗәсендә, 1989 да *Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы* бастырып чыгарыла. Л.г.нең алга таба үсеш алуы Д.Б.Рамазанова, Д.З.Мәхмүтшина, М.Р.Саттарова, Ф.Й.Йосыпов хезмәтләре б-н бәйле. Л.г. казанышлары татар сөйләшләрен классификацияләүдә, аларның барлыкка килү тарихын өйрәнүдә, ш.у. татарларга Идел буе — Урал яны төбәкләрендә яшәүче кардәш һәм кардәш булмаган телләрдә сөйләшүче кешеләр б-н элемтә урнаштыруда зур табыш булып тора.

*Әд.:* Б у р г а н о в а Н.Б., З а л я й Л.З. О принципах составления диалектологического атласа татарского языка // Вопросы диалектологии тюркских языков. К., 1960; Р а м а з а н о в а Д.Б. О достижениях и задачах татарской диалектологии // Науч. Татарстан. 2000. № 3.

*Д.Б.Рамазанова.*

**ЛИНГВИ́СТИКА**, к. *Тел белеме*.

**ЛИ́НДЕГРЕН** Иван Густавович (1798 — 8.9.1870, Германия, Дрезден ш.), терапевт, медицина д-ры (1824). Дерпт ун-тын тәмамлагач, Түбән Новгород губернасының Ардатово шәһәрендә өяз табибе булып эшли. 1825 елдан Түбән Новгород җәмәгать шифаханәсендә. 1830 да Дерпт ун-тында акушер дәрәҗәсе ала. 1837 дән Казан ун-тында: хосусый патология һәм терапия каф. профессоры (мед. тарихы һәм токсикология укыта), 1858–62 дә декан; 1830 да Түбән Новгородта ваба таралуны бетерүдә катнаша. «Вабаның үзлекләре» («О свойствах холеры». Н.Новгород, 1831) хезмәте, вабаны дәвалау, госпиталь клиникаларын оештыру буенча хезмәтләр авторы; 1850 дә госпиталь клиникасын оештыруны башлап йөри.

Х е з м.: О значении госпитальной клиники... // Уч. зап. Казан. ун-та. 1849. Кн. 4; Рассуждение о госпитальной клинике и об удобнейшем устройстве её при Императорском Казанском университете... // Уч. зап. Казан. ун-та. 1850. Кн. 3.

**ЛИНОГРАВЮ́РА** (лат. linum — тукыма, oleum — май һәм *гравюра*), ленолеумда яки шуңа охшаш материалларда эшләнгән кабарынкы гравюра. Өтерге рәвешендәге махсус кискечләр ярдәмендә басма форма өслегенең уентысы — ак төстә калырга тиешле өлешләре кисеп алына. Күчереләчәк кабарынкы рәсемнәр өслегенә валик ярдәмендә яки кул б-н буяу сөртелә. Л. техникасы зур күләмле, күп тиражлы гравюралар иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Л. аеруча төсле басма өчен кулай; аңа кыскалык, сызыклы һәм яссы элементларның бер-берсенә ярашуы, кара һәм ак тапларның контрастлылыгы, басма формаларны эшкәртү алымнарының күп төрлелеге хас. Л. үзенең техник һәм сәнгать чаралары буенча ксилографиягә якын тора (агачтагы гравюра), әмма арзан һәм эшләргә җиңел, 20 йөздә киң кулланылыш алуы шуның б-н бәйле.

Л. 19–20 йөзләр чигендә (П.Пикассо, А.Матисс, Ф.Мазерель һ.б.); Казанда беренче тапкыр 1919 елда барлыкка килә (Н.С.*Шикалов* әсәрләре). Аның үсеше «Всадник» графика коллективы иҗаты б-н бәйле. Махсус җиһазлар, озакка сузылган проф. әзерлек һәм кыйммәтле материаллар, техника таләп итмәгән Л. Гражданнар сугышы һәм сугыштан соңгы җимереклек шартларында аеруча актуаль була. Л. графиканың төрле төсләрендә һәм жанрларында: альбомнар, китап һәм журнал иллюстрацияләре, тышлыклары, экслибрислар, нәшрият маркалары, афишалар, сирәк кенә — плакатлар әзерләү өчен станлы табаклар һәм серияләр иҗат иткәндә кулланыла. Н.С.Шикалов гравюраның реалистик сурәтләүгә, сәнгати эзләнүләргә тартылган Мәскәү мәктәбе алымнарын кулланылышка кертә (М.Г.Андреевский, Н.М.*Сокольский* һ.б. иҗатларында шәһәр пейзажы жанрындагы төсле Л.). И.Н.*Плещинский* әсәрләрендә «Всадник»ның башка әгъзалары иҗатын формалаштыруга йогынты ясаган немец экспрессионизмы эстетикасы өстенлек итә. Экспрессионизмга хас гадилеккә йөз тоту Д.М.*Федоров*, А.Г.*Платунова* хезмәтләрендә чагыла. Шул ук вакытта соңгысының композицияләренә орнаментлы декоратив чишелешләр хас, аның иҗатында модерн стиле эстетикасы йогынтысы нык сизелә. «Всадник» әгъзалары абстракт сәнгать өлкәсендә дә тәҗрибә үткәрәләр (М.И.Меркушев, С.С.Федотов). Җәмгыятьнең революцион үзгәртеп кору рухы б-н сугарылган социаль әһәмиятле темаларына, ш.и. әһәмиятле социаль сюжетларга мөрәҗәгать итеп, К.К.*Чеботарёв* жанр һәм стиль төрлелеген киңәйтә. Аның әсәрләренә Совет Россиясенең гаммәви агитациясенә характерлы монументаль гомумиләштерү, образларны типиклаштыру хас. Л. типография хәрефләре җыюга якын торган техника буларак, *китап графикасында* аеруча нык кулланыла. Бу өлкәдә И.Н.Плещинский барысыннан да активрак эшли («Всадник» альманахы, 1920, № 1; П.Дульскийның «Казандагы халык архитектурасында классицизм» («Классицизм в казанском зодчестве», 1920); З.Славянованың «Эшче-крестьян театры» («Рабоче-крестьянский театр», 1921) китаплары тышлыклары). Г.Тукайның «Шүрәле» (1921) һәм «Кәҗә белән сарык» (1921) әкиятләренең рус телендәге басмалары аның бизәлешендә дөнья күрә. К.К.Чеботарёв П.Радимовның «Попиада» һәм «Авыл» поэмалары өчен (икесе дә — 1922) тышлыклар әзерли; С.С.Федотов «Карт һәм юкә» дигән удмурт халык әкиятен (1922) һ.б. бизи. К.К.Чеботарёв һәм А.Г.Платунова Л.да мәдәният эшлеклеләре өчен күп кенә экслибрислар әзерлиләр һәм аларны аерым басма — «Китап билгеләре. 1 нче чыгарылыш» («Книжные знаки. Вып. № 1», 1922) рәвешендә чыгаралар. В.Э.*Вильковиская* һәм Б.Н.*Столбовның* линолеумда эшләнгән берничә экслибрисы «Казан китап билгеләре»нең («Казанские книжные знаки» (1923)) икенче җыентыгында урын ала. 1920 елларда Л. плакатлар әзерләүдә аз кулланыла. Н.С.Шикаловның 3 (1921), билгесез авторларның берничә плакаты сакланып калган.




1960 елларда Казанда Л. үсешенең яңа этабы башлана. Ул 1950 еллар ахырында биргә илнең әйдәп баручы сәнгать уку йортларын тәмамлаган график-рәссамнарның кайтуы б-н бәйле. Алар Татарстанның графика сәнгатенә яңа сулыш өрәләр, гравюраның станлы формасын яңадан торгызалар, республикада һәм аның чикләрендә узган күпсанлы күргәзмәләрдә үзләренең әсәрләре б-н катнашалар. «Җепшеклек» чорының символына әверелгән һәм алдынгы карашлы рәссамнарның новаторлык эзләнүләрен чагылдырган «Кырыс стиль» рәсми юнәлеше Э.Г.*Ситдыйков*, С.М.*Кульбака*, Л.А.Потягунин, И.Л.*Язынин*, В.А.*Попов*, Е.В.*Киселёва*, Т.Г.*Хаҗиәхмәтов*, Л.П.Иванова иҗатында эзлекле гәүдәләнешен таба. Аларның әсәрләре социаль заказга туры киләләр һәм Гражданнар сугышының тарихи вакыйгаларыннан алып замандашларының тынгысыз хезмәте, батырлык кылуларыннан шәхси гаилә тормышы мәшәкатьләренә кадәрге киң спектрны яктырталар.


Казан Л.сында төрле образлы жанрлар — шәһәр пейзажы (Л.А.Потягунин, И.Л.Язынин, Л.П.Иванова), портрет һәм көнкүреш жанрлары (С.М.Кульбака, Э.Г.Ситдыйков) үсеш ала. Тематика мөһимлеген исәпкә алып, индустриаль пейзаж (В.А.Попов, Э.Г.Ситдыйков) һәм космосны үзләштерү темасы (Е.В.Киселёва) аеруча әһәмияткә ирешә. И.Л.Язынин тарихи темага мөрәҗәгать итә. Рәссамнар иҗатында аклы-каралы төстәге Л. өстенлек ала, төсле Л.да төсле буяу б-н каплау техникасында Л.А.Потягунин һәм И.Л.Язынин аеруча актив эшлиләр. Казан китап графикасында Л.ның янә мөһимлеге арта. Әлеге өлкәдәге аеруча уңышлы эшләрдән саналган төсле Л. техникасында башкарылган И.Л.Язынин (С.Злобин, «Степан Разин», 1957), В.А.Дайчман (А.С.Пушкин, «Бакыр җайдак», 1962), И.К.Колмогорцева («Гөлчәчәк», татар халык әкияте, 1967), В.Б.Зелинский (Б.Брехт, «Лукуллга хөкем», 1967) әсәрләрен күрсәтергә мөмкин.


1970–80 нче елларда Л.га ихтыяҗ кими, аңа Казан рәссамнарының бик азы гына тугры кала. И.К.*Әхмәдиев*, Э.Я.*Зарипов* КамАЗ төзелешен, Татарстан нефтьчеләре тормышын яктырта барып, индустриаль жанрны үстерә. Э.Я.Зарипов авыл темасына станлы серияләр иҗат итә. Н.*Исәнбәтнең* «Батыр песи» (1976) китабына Т.Г.Хаҗиәхмәтов эшләгән иллюстрация — әлеге чорда китап бизәү өлкәсендә Л. куллану тәҗрибәсенең бер үрнәге.

1990 елларда Л., графика төре буларак, Татарстан рәссамнары иҗатында күренми башлый. Л. б-н шөгыльләнүчеләр арасында Әлмәт рәссамы А.И.Максютин лубок традицияләренә якын тора. 2005 елда Л. техникасында Казан рәссамнары А.А.Артамонов һәм Г.Р.Фәйзрахманова форма һәм төсләр өлкәсендә тәҗрибәләр үткәрү мөмкинлекләреннән иркен файдалана. Ш.у. к. *Графика*.

*Әд.:* Д у л ь с к и й П.М. Казанские современные графики // Гравюра и книга. 1925. № 1/2; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; Ф а й н б е р г А.Б. Художники Татарии. Л., 1983; Р о з е н б е р г Н.А. Казанская











**Линогравюра.** 1. Д.М. Ф ё д о р о в. 1910-20 еллар; 2. Н.С. Ш и к а л о в. «Монастырь дивары». Төсле линогравюра. 1919. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. М.Г. А н д р е е в с к а я. «Җил». Төсле линогравюра. 1921. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. А.Г. П л а т у н о в а. «Композиция». 1922. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. Н.М. С о к о л ь с к и й. «Казан университеты». «Казан» альбомыннан. Төсле линогравюра. 1923. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. И.Л. Я з ы н и н. «Кызыл байрак белән рухланып». «Иделдәге гражданнар сугышы турында» сериясеннән. Төсле линогравюра. 1960. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Л.А. П о т я г у н и н. «Ленин бакчасы. Казан». 1962. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. И.К. К о л м о г о р ц е в а. «Сандугачым, оч әле». «Гөлчәчәк» татар халык әкиятенә иллюстрация. Төсле линогравюра. 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. Э.Г. С и т д ы й к о в. «Бәхетле ана. Беренче бала». Төсле линогравюра. 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. В.А. П о п о в. «Батырлык симфониясе». 1962. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Т.Г. Х а җ и ә х м ә т о в. «Татар кызлары биюе». 1970; 12. Э.Я. З а р и п о в. «Урак өсте». Төсле линогравюра. 1972. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. М.Ф. А х у н о в. «Рудник юлы». «Россиянең индустрия ритмнары» сериясеннән. 1976.

гравюра и книжная графика (1920-е — середина 1930-х годов) // Традиционная материальная культура и искусство народов Урала и Поволжья. Ижевск, 1995; Улемнова О.Л. Казань в графике 1920–1930-х годов // Казанский посад в прошлом и настоящем. К., 2002; АРХУМАС: Казанский авангард 20-х: Каталог выставки. М., 2005.

*О.Л.Улемнова.*

**ЛИНЬКО́ВА** Клавдия Александровна, (29.4.1927, Тәтеш кантоны Нармонка а.), агроном, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1941 елдан Тәтеш р-нының «Новый мир» к-зында эшли. Берьеллык а.х. мәктәбен тәмамлаганнан соң (1945), кырчылык звеносы җитәкчесе итеп билгеләнә. Л. җитәкчелегендә звено көзге бодай үстерүнең яңа агротехникасын үзләштерә, 1947 дә 1 *га* дан 30 *ц* дан артык арыш, 28,6 *ц* бодай уңышы алына. 1948–79 да «Память Ильича» к-зында эшли, 1975–76 да Тәтеш р-нының Фёдоровка авыл советы рәисе. Герой исеме көзге бодай һәм арыштан югары уңыш алганы өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЛИПА́ЕВ** Александр Анатольевич (7.12.1947, Свердловск өлкәсенең Эрбет ш.), физик, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000), ТРның атказ. нефтьчесе (2001). 1975 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1979 дан И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть һәм газ ин-тының Лениногорск гомумтехник ф-тында. 1987 дән Казан ун-тында. 1993 тән Әлмәт нефть ин-тында, югары матем. һәм исәпләү техникасы каф. мөдире (1996–97), нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм эксплуатацияләү каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре тау токымнарының җылылык физикасына, битумнар һәм аеруча үзле нефть ятмаларын эшкәртүгә карый. Л. тау токымнарының җылылык үзлекләрен тикшерү өчен методика һәм аппаратлар эшли, аларны ТРның битум чыганакларын эшкәрткәндә куллана. Тикшеренү нәтиҗәләре РФА Себер бүлегенең Күп фазалы тирәлекләр механикасы ин-тында (Төмән ш.), РФА Урал бүлегенең Геофизик ин-тында (Екатеринбург ш.) гамәлгә кертелә.

Хезм.: Теплофизические исследования в петрофизике. К., 1993; Тепломассоперенос в породах-коллекторах. К., 1997 (автордаш); Тепловые свойства горных пород нефтяных месторождений Татарстана: Справ. К., 2001 (автордаш).

**ЛИПА́ТОВ** Николай Дмитриевич (1916, Казан губ., Казан өязе Тимошкино а. — 13.8.1944, Польша, Грабщизна а. җирләнә), Сов. Союзы Герое (26.10.1944, үлгәннән соң), рядовой. Туган авылында колхозда эшли. 1936–38 елларда һәм 1942 нең апреленнән Кызыл Армия сафларында, Бөек Ватан сугышы фронтларында, 973 нче артиллерия полкында өлкән телефонист (70 нче армиянең 160 нчы укчы дивизиясе). Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Полесье һәм Люблин-Брест һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1944) катнаша. 1944 нең 13 августында Грабув торак пункты (Польша, Тлущ шәһәреннән 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак) янында батырлык күрсәтә: батальоннан берүзе исән калып, барлык снарядларын атып бетергәннән соң, дошман пулемётына ташлана һәм шунда һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казанда Л.ка һәйкәл куела һәм бер урам аның исеме б-н атала. Мәскәүдә 242 нче мәктәп Герой исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Плесцов К.М. Люди высокого подвига. М., 1962. *М.З.Хәбибуллин.*

**ЛИ́ПКИН** Семён Израилевич (6.9.1911, Одесса ш. — 1.4.2003, С.-Петербург), шагыйрь, тәрҗемәче. 1929 елдан Мәскәүдә яши. Мәскәү инженерлык-икътисад ин-тын (1937) тәмамлый. «Шаһит» («Очевидец», М., 1967), «Саз» («Лира», М., 1989) исемле шигъри җыентыклар, «Фатирчы язмалары» («Записки жильца», «Новый мир» ж-лы, 1992, № 9–10) автобиографик повесте, А.А.Ахматова, О.Э.Мандельштам, Э.Г.Багрицкий h.б. турында мемуарлар авторы. 1930 еллардан соң тәрҗемә б-н шөгыльләнә. Рус теленә «Җангар» (калмык), «Манас» (кыргыз) эпосларын, Нәвоиның «Ләйлә вә Мәҗнүн», Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмаларын; Г.Тукайның шигырьләрен, «Шүрәле», «Су анасы» поэмаларын, «Идегәй» дастанын (ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1992), Г.Чокрый, Акмулла, Дәрдемәнд, М.Җәлил, Г.Кутуй, Ә.Ерикәй, Ф.Кәрим, С.Хәким h.б. татар шагыйрьләренең шигырьләрен тәрҗемә итә. РФ Президентының әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге бүләгенә лаек була (2002).

*Әд.:* Рассадин Ст. «Кровь» рифмуется с «любовь» // Вопр. литературы. 1990. № 2.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ЛИ́ПОВКА** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Сулы елгасының (Дим, Ык елгалары бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 8,4 *км*, бассейнының мәйданы 18,4 *км*$^2$. Бөгелмә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — урман массивында, Яңа Чирково авылыннан (кеше яшәми торган) 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Коробково авылы һәм Сосновка посёлогы арасында. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 180 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. Туенуы катнаш, яртысыннан күбрәге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 131 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,035 *м*$^3$*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**ЛИПУ́ЖИНА** Валентина Николаевна (1.4.1943, Алексеев р-ны Балахчино а.), хакимият-партия хезмәткәре. Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1965). 1964–65 елларда ВЛКСМның Алабуга шәһәр ком-ты секретаре, 1965–66 да 1 нче секретаре. 1966–73 тә



К.А.Линькова.



Н.Д.Липатов.

ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире, секретарь. 1973–81 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире урынбасары. 1981–90 да КПССның Бауман райкомы 1 нче секретаре, 1990–92 дә халык депутатларының Бауман р-н советы рәисе, 1995–98 дә Казанның Бауман р-ны хакимияте башлыгы. 1995–98 дә ТР Дәүләт Советында социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссия рәисе урынбасары, 1998 дән ТР Дәүләт Советы секретаре. 1985–95 тә ТР ЮС депутаты. 1995 тән ТР халык депутаты. 2009 дан ТР Дәүләт Советының дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә ком-ты рәисе. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛИ́РИК ПРО́ЗА**, *эпосның* бер төре, анда мәгънәви һәм композицион үзәк булып герой аңының үсеш-үзгәреше тора, ул күңел кичерешләре һәм уй-фикерләр чылбырында гәүдәләндерелә. Л.п.ның төп үзенчәлеге аның поэтикасында лирика һәм эпоска хас хасиятләрнең үрелеп баруыннан гыйбарәт. Лирик компонент әсәрнең эчтәлегендә яки формасында өстенлек алырга мөмкин. Шул уңайдан, «Л.п.» төшенчәсе татар әдәбияты белемендә ике мәгънәдә кулланыла: 1) шигъри формада язылган проза әсәре (шигъри роман, шигъри повесть, шигъри хикәя). Л.п.ның жанр булып оешуы урта гасырлар төрки-татар әдәбиятына барып тоташа. Ул чорда зур күләмле сюжетлы әсәрләр (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмалары) шигъри яки элогиаль (катнаш) формада була. Эчтәлеге ягыннан алар — *кыйсса* яки *дастан* жанрына, формаль билгеләре б-н мәснәвигә (к. *Поэма*) тартым. 19 йөздән башлап татар эпосы традицион рәвештә чәчмә булып китә, эпик хикәяләү үзенчәлекләреннән тайпылу яңалык күренеше буларак кабул ителә. Ә.Давыдовның «Йокысыз төннән соң», С.Батталның «Чирмешән якларында» романнары, С.Батталның «Олы юл буйлап», Ә.Давыдовның «Күмер көйри», Ш.Маннурның «Җир-әнкәнең сылу кызы», Ш.Мөдәрриснең «Яшел тасма» повестьлары h.б. нәкъ шулай бәяләнә. Эпик һәм лирик башламнарның, автор һәм персонажлар дөньясының, сурәтләү һәм гәүдәләндерүнең табигый бергәлеген үзенә алган шигъри форма жанр төзүче шартка әверелә. 2) Хикәяләүнең шәхсиләшүе, тышкы дөньяның шәхес аңында үзенчәлекле чагылышы, чынбарлыкны шул аңның бер өлеше итеп күзаллау


Е.В.Лисецкая.


Н.В.Лисин.

хас булган лирик характердагы проза әсәре. Прозада лирик башлангычның көчәюенә китергән сәбәпләр арасында хикәяләүнең бергүзәкле булуын һәм монолог рәвешендә бирелүен, мәгънә һәм образлар тыгызлыгын, сурәтләү чараларының катлауландырылган һәм күпмәгънәле булуын аерып күрсәтү кирәк. Л.п.да сюжетлылык төп герой характерының күп — кырлылыгы, мотивлаштырулар, дөньяны танып белүгә юнәлтелгәнлек эпостан килә. Татар прозасында бу төрнең чишмә башы сәҗегъ (к. *Нәсер*) дигән гарәп әдәби жанрына барып тоташа. Татар әдәбиятында Л.п. күтәрелеш чорын ике тапкыр кичерә: 20 йөз башы (Ф.Әмирхан, М.Хәнәфи, Ә.Тангатаров һ.б.) һәм 1960–80 еллар (Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, Г.Сабитов, Ә.Баян, М.Галиев һ.б.). Татар Л.п. поэтикасына геройның эчке монологы, тәүбә итү, психологизм формалары, төрле хронологик күчешләр, үткәнгә мөрәҗәгать итү, импрессионистик сурәт кебек композиция һәм стиль алымнары кертелә.

*Әд.:* Х а т и п о в Ф.Х. Әдәбият теориясе. К., 2000; Ш а р и п о в А.М. Зарождение системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VIII–XV вв.). К., 2001.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ЛИСЕ́ЦКАЯ** Евгения Владимировна (12.3.1917, Орёл ш. — 10.4.1997, С.-Петербург), драма актрисасы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. артисты (1948, 1954). 1933–81 елларда Казан Зур драма т-ры артисты. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, труппаның ярдәмче составына кабул ителә, зур булмаган эпизодик рольләр башкара. Режиссёр А.Д.Дикий б-н А.Н.Островскийның «Кайнар йөрәк» (1943) спектаклендәге Параша образы өстендә эшләү нәтиҗәсендә Л. әйдәп баручы актрисалар рәтенә чыга. Аның тарафыннан тәэсирле һәм дәлилле башкарылып, «ялкынлы йөрәк» темасы төгәл гәүдәләнеш таба һәм спектакльнең үзәк урынын били. Лиза («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов, 1945), Ульяна Громова («Яшь гвардия», А.А.Фадеев романы буенча, 1947), Марфинька («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча, 1948), Луиза («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, 1948), Нина («Маскарад», М.Ю.Лермонтов, 1949) кебек яшь героиня образларын иҗат итеп, Л. һәр персонажның үзенә генә хас характер үзенчәлеген күрсәтә, сәхнәдә үз-үзләрен тотышлары аша аларның чын асылларын ачарга омтыла. Наташа, («Тормыш төбендә», М.Горький, 1949), Зәһрә («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт, 1950), Наталья Ивановна («Өч сеңел», А.П.Чехов, 1951) рольләре дә актрисаның олы казанышлары булып тора. Әлеге образлар өстендә эшләгәндә Л. ирешкән төгәл социаль-психол. анализ, тышкы сурәтне бирүдә тормышчан дөреслек драматургик уй-фикернең киңлеген һәм әһәмиятен ача. Актрисага хас нечкә тоемлау, күзәтүчәнлек сәләте, юмор хисе, теге яки бу характерны төгәл ачу өчен дөрес деталь, үз-үзеңне тоту манерасын сайлый белү аңа лирик кына түгел, ә комик, сатирик пландагы образлар да тудырырга ярдәм итә. Сатирик Поэма («Фамилияләрне атамый гына», В.П.Минко, 1953) һәм драматик Әминә («Үлмәс җыр», Р.Ишморат, 1956) рольләре төсмерләр, детальләр байлыгы б-н аерылып тора. Девица («Карт», М.Горький, 1956), Акулина («Караңгылык патшалыгы», Л.Н.Толстой, 1959) рольләрендә актриса үз героиняларының әхлакый кимчелекләрен, рухи караңгылыктан чыгарга омтылуларын оста гәүдәләндерә, кеше характерының аны формалаштыруда зур роль уйнаган иҗтимагый тормыш шартларына бәйле булуын ача. Варя («Чия бакчасы», А.П.Чехов, 1960), Валентина («Иркутск вакыйгасы», А.Н.Арбузов, 1960), Анечка («Диңгез», А.П.Штейн, 1961), Катерина Ивановна («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча, 1965), Поля («Мунча», В.В.Маяковский, 1967), Лидия Белова («Гадәт буенча җыелу», В.С.Розов, 1967), Богаевская («Варварлар», М.Горький, 1972) образлары — Л.ның зур әһәмияткә ия хезмәтләре. Казан Зур драма театры сәхнәсендә әйдәп баручы осталар рәтендә 150 гә якын роль башкара. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.


1


2

Е.В. Л и с е ц к а я: 1. Наталья Ивановна («Өч сеңел», А.П.Чехов); 2. Девица («Карт», М.Горький; Карт ролендә — Н.И.Якушенко) рольләрендә.

*Әд.:* И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991; Б л а г о в Ю. Тайны «заветного сундучка» // Татарстан. 1997. № 3.

*Ю.А.Благов.*

**ЛИ́СИН** Евгений Андреевич (25.9.1938, Амур өлкәсенең Тыгда р-ны Магдагачи пос. — 6.12.2004, Казан), журналист, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987, 1998). Казан авиация ин-тын (1962), Казан ун-тын (1968), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фән. академиясен (1980) тәмамлый. 1961–68 елларда Казан моторлар төзү з-дының проект-конструкторлык бюросында инженер-конструктор. 1968 дән «Советская Татария» г-тасында эшли (1971–73 тә — бүлек мөдире, 1973–74 тә баш мөхәррир урынбасары, 1974–78 дә — баш мөхәррир). 1980–85 тә ТАССРның Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт ком-ты рәисе. 1985–2003 тә «Советская Татария» («Республика Татарстан») г-тасының баш мөхәррире. Язмалары «Социалистическая индустрия», «Экономическая газета» г-таларында һәм «Журналист» ж-лында басыла. Икътисад мәсьәләләре буенча мәкаләләр, очерклар авторы. КамАЗ төзелешенә багышланган җыентыкның төзүчесе. 1975–80, 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1990–95 тә ТР халык депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Строка зовёт в будущее. М., 1983.

**ЛИ́СИН** Николай Викторович (11.12.1912, Казан губ., Зөя өязе Шеланга а. — 22.12.1981, Кама Тамагы р-ны Тәмте а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1966). Минзәлә терлекчеләр мәктәбен тәмамлый (1935). 1928–81 елларда Кама Тамагы (1963 кә кадәр Тәмте) р-нында: «Волгопромкооперация» артелендә эшче, Шеланга җиләк-җимеш з-дында кладовщик, «Луч Октября» к-зында колхозчы, ферма мөдире (1935–38), район җир бүлегендә зоотехник (1938–50), Мичурин исем. к-з рәисе (1950 дән). Л. җитәкчелек иткән елларда колхозда үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен җитештерүдә югары күрсәткечләргә ирешелә, хуҗалык СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм ВЦСПС (1973), РСФСР МС (1975), КПСС өлкә к-ты, ТАССР МС, ВЛКСМ өлкә ком-ты һәм Профсоюзлар өлкә ком-тының (1967) күчмә Кызыл байраклары б-н бүләкләнә. 1963–67 дә РСФСР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе ордены, медальләр, РСФСР, ТАССР ЮСлары Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена «Трудовой Славы» — наши земляки. К., 2003.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛИ́СОВ** Иван Игнатьевич (30.9.1923, Ульянов өлкәсенең хәзерге Новоспасск р-ны Рокотушка а. — 30.3.1975, Оренбург ш., Ленино-

горск шәһәрендә җирләнә), тау инженеры. Соц. Хезмәт Герое (1971). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1970). 1949 елдан «Куйбышевнефть» берләшмәсенең Черновский бораулау конторасында (Куйбышев өлкәсе), директор (1951 дән); 1952 дән «Татбурнефть» трестының 2 нче бораулау конторасы директоры; 1959 дан «Татнефтегазразведка» трестының 4 нче разведка-бораулау конторасы директоры (Лениногорск ш.); 1972 дән Оренбург бораулау эшләре идарәсендә директор (1975 кә кадәр). Л.җитәкчелегендә Татарстанда һәм Оренбург өлкәсендә нефть һәм газ чыганаклары тикшерелә һәм үзләштерелә башлый. 1973 тә скважиналар бораулаганда бер станок айга 1513 *м* уза, рекордлы тизлек куела, бер елга 81,4 мең *м* тау токымнары бораулана.



И.И.Лисов.

Герой исеме нефть чыгару буенча бишьеллык планны (1966–70) үтәгәндәге казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Лениногорск шәһәренең Ватан Геройлары аллеясында Л.ның барельефы б-н обелиск куелган.

*Әд.:* Р о с с о в с к и й В.П. Герои труда: Биогр. справ. Калуга, 1999; Оренбургская биографическая энциклопедия. Оренбург — М., 2000; Золотые страницы Газпрома. М., 2009; Ветераны: из истории развития нефтяной и газовой промышленности. М., 2010. Вып. 23.

*М.Я.Гаитов.*

**ЛИ́СОВ** Николай Иванович (5.5.1925, Казан — 25.10.2009, шунда ук), партия хезмәткәре, икътисад фән. канд. (1973). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли. 1953–60 та Югары Ослан р-нында: Макыл МТСы парткомы секретаре (1955 кә кадәр), 1955–58 дә КПСС райкомы секретаре, 1958 дән 1 нче секретаре. 1960–67 дә Татарстан Куллланучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. 1967–80 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында җиңел, азык-төлек сәнәгате һәм сәүдә бүлеге мөдире. 1995–2002 дә Идел-Вятка акц. банкы идарәсенең вице-рәисе, 2002 дән рәис киңәшчесе. Хезмәтләре социализмда икътисад, халык кулланавы товарлары әйләнешенең нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә карый. 1971–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛИСС** Арон Юдович (2.4.1925, Белоруссия ССРның Минск өлкәсе Коровщина а.), вертолётлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1976). 1948 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Үзәк аэрогидродинамика ин-тында эшли (Мәскәү өлкәсе Жуковский ш.). 1949–50 дә № 387 з-дның (хәзер Казан вертолёт з-ды) тәҗрибә КБсында. 1950–52 дә Себер Авиация фәнни-тикшеренү ин-тында (Новосибирск ш.). 1952 дән Казан «Ми вертолётлары» фәнни-җитештерү пр-тиесендә, әйдәп баручы конструктор (1957–69), бүлек башлыгы (1977 дән), бер үк вакытта, 1982 дән Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты) очкыч аппаратларны конструкцияләү һәм проектлаштыру каф. профессоры (1982–96). Хезмәтләре вертолётлар төзелешендә аэродинамикага һәм *аэросыгылмалылыкка* карый. Л. тарафыннан эшләнгән тавыш тизлегеннән тизрәк очучы самолётларның трамплиннан күтәрелү алымы (1957) авиайөрткеч крейсерларда кулланыла. Вертолётның төп винтын исәпләү алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 22 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт торсиона балочного типа // Изв. вузов. Авиац. техника. 2001. № 4; Совместное решение задачи о нагружении лопасти несущего винта и торсиона при полёте вертолёта // Изв. вузов. Авиац. техника. 2003. № 4.

**ЛИСТЕ́РА УТЫ́** (Listera), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Американың салкын һәм уртача поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — күкәйсыман Л.у. (L. ovata) Кама алдында һәм Идел алдында очрый. Дымлы болыннарда, аланнарда, куаклар арасында, уйсулыклы сазлык кырыйларында үсә. 25–50 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска, юанрак, күп тамырлы. Сабагының өске өлеше куе төкчәле, төбендә көрән 2–3 тәңкәсыман яфраклы. Чәчәкләре вак, яшькелт, күп чәчәкле чуксыман чәчәк төркемендә. Иреннәре чәчәк тирәлеге яфракчыкларыннан 2–3 тапкыр озынрак. Җимеше — тартмачык. Июнь ахыры – июльдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамыр үрентеләреннән) б-н үрчи. Декоратив. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЛИСТЕРИОЗГА́ КАРШЫ́ ВАКЦИ́НА**. 1974 елда Казан вет. ин-тында А.В.*Селиванов*, О.А.*Котылев*, А.М.*Алимов* тарафыннан эпизоотик штаммга ультрамиләүшә нурлар б-н тәэсир иткәннән соң, селекцион эшкәртү юлы б-н эшләнә. Л.к.в.сын әзерләү технологиясенә вакцина штаммын сыек туклыклы мохиттә үрчетү, сыек фазадан бактерияләр массасын аерып алу һәм препаратны лиофильләштерү керә. 1976 дан башлап РФнең барлык төбәкләрендә мөгезле эре терлек, сарыклар һәм дуңгызлар листериозы вакытында кулланыла. *А.М.Алимов.*

**«ЛИСТО́К ОБЪЯВЛЕ́НИЙ»** («Игъланнар сәхифәсе»), бушлай таратылган газета. 1875 елның 2 ноябреннән 1900 нең сентябренә кадәр Казанда атнасына 3 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Төрле елларда наширләре һәм мөхәррирләре — Л.Ленкевич, К.А.Тилли, П.К.Тилли. Игъланнар бастыручы коммерциячел реклама газетасы буларак чыга башлый, Идел-Кама буендагы эре шәһәрләрнең, Казан губернасы шәһәрләренең дәүләт оешмаларына, кибетләргә, трактир биналарына, навигация чорында пароход җәмгыятьләре конторларына таратыла. 1894 тән ай саен «сәүдә-сәнәгать һәм техника газетасы» буларак чыга башлый. Анда фән һәм техника өлкәсендәге (кирпеч җитештерү, электротехника, туку сәнәгате) яңа ачышлар турында кыска мәкаләләр, хәбәр-белдерүләр басыла. Газета укучыларны атаклы Россия фабрикантлары һәм сәнәгатьчеләре б-н таныштырып бара, сәнәгать фирмалары белешмәлекләрен бастыра, Россия эчендә шактый әйләнеше булган Мәскәү сәүдә-сәнәгать пр-тиеләре турында мәгълүмат биреп тора. Газета башкала газеталарында дөнья күргән мәкаләләрне дә кабаттан үзендә бастыра, сәүдә-сәнәгать статистикасын тәкъдим итә. «Сораулар һәм җаваплар» рубрикасында укучылар сорауларына атаклы юристлар, сәнәгатьчеләр һәм фабрика хуҗалары җавап бирә.

*Г.Р.Заманова.*

**«ЛИСТО́К ОБЪЯВЛЕ́НИЙ ПОКУ́ПКИ-ПРОДА́ЖИ ИМЕ́НИЙ, ЗЕМЕ́ЛЬ, ЗАВО́ДОВ ВСЕЙ РОССИ́И»** («Бөтен Россиядә утарлар, җирләр, заводлар сатып алу һәм сату игъланнары сәхифәсе»), газета; к. «*Камско-Волжский корреспондент для деловых людей*».

**ЛИТВА́ МӨСЕЛМАННАРЫНЫ́Ң ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**. 1909 елның мартында Вильно (Вильнюс) шәһәрендә төзелә. Оештыручылары — Е.А.Кричинская, Б.Д.Кричинский, О.Д.Базаревский, С.С.Шабанович. Идарә рәисе — А.М.Ильясович. Төп максаты — ярлыларга матди ярдәм күрсәтү, мөселман мәдәният оешмаларының үсешенә булышлык итү. 1917 дән соң яшәүдән туктый.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**ЛИТВА́ РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, Көнчыгыш Европадагы, Балтыйк диңгезе буендагы дәүләт. Мәйданы — 65,2 мең *км²*. Халкы — 3425 мең кеше (2005). Башкаласы — Вильнюс шәһәре. 2001 елгы халык исәбе буенча, Л.Р.нда 3,2 мең татар (1989 да — 5,2 мең) яши. Татарлар анда этник чыгышы, тарихы, традицияләре төрле булган 2 төркемгә бүленә. Беренче төркем, ягъни Литва татарлары (к. *Польша-Литва татарлары*), Алтын Урдадан, соңрак Олы һәм Кече Нугай Урдаларыннан, Кырым ханлыгыннан 14 йөз ахырында — 15 йөздә Бөек Литва кенәзлеге җирләренә күчеп килгән төрки мөселманнардан гыйбарәт. Хезмәтләре өчен (күбесенчә хәрбиләр) Литва кенәзлегеннән аларга җир бүлеп бирелә, һәм татарлар Польша-Литва шляхталарына (дворяннарына) тиңләштерелә. 16–17 йөзләрдә бу төркем вәкилләре туган телләрен онытып бетерәләр диярлек, ләкин ислам динен саклап калалар. Литва татарлары Вильнюс, Алитус, Каунас, Тракай һ.б. шәһәрләрдә — таралып, Вильнюс р-нының Немежис һәм Кятурясдяшимт Тоторю (*Кырык Татар*) авылларында, Алитус р-нының Райжяй авылында һәм Бутримонис бистәсендә тупланып яшиләр. Литва татарларының икенче төркеме — Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Литвадагы төзелеш һәм сәнәгать объектларына (Игналин АЭСы һ.б.) хезмәт күрсәтү өчен, нигездә, Совет Армиясе хәрби хезмәткәрләре, инженер-техник белгечләр һәм СССРның төрле р-ннарыннан (күбесенчә

Идел-Урал төбәгеннән) көчеп килүчеләр исәбенә формалаша. Алар бөтен ил буйлап, башлыча, зур шәһәрләргә тарала. Иң яхшы эшләүче җәмгыять Висагинас (элеккеге Снечкус) шәһәрендә урнашкан. Л.Р.нда Алитус (1989 дан), Каунас (1991 дән), Вильнюс (2004 тән; Швенчёнис шәһәрендә бүлекчәсе бар) округларында, Варна р-нында татар җәмгыятьләре эшли; Вильнюс крае татар җәмгыятенең (1990) бүлекчәләре Вильнюс (1990), Швенчёнис (1999), Немежис (1990) һәм Кятурясдяшимт Тоторю (1993) авылларында урнашкан, Висагинас шәһәрендә дә татар җәмгыяте бар (1997). Клайпеда (2004) һәм Паневежис (2004) шәһәрләрендә «Нур» татар җәмгыятьләре, «Муслимас» берләшмәсе эшли. Бу җәмгыятьләрнең күбесе оешкан төстә Литва татарлары ассоциациясенә (2002, Вильнюс; рәисе М.Якубовская) һәм Литва татар җәмгыятьләре берләшмәсенә (1995, Каунас; рәисе А.Якубаускас) керә. Литва мөселманнары дини үзәк — мөфтияткә берләшә, мәчетләр (Каунас ш., Немежис, Кятурясдяшимт Тоторю һәм Райжяй авылларында) бар, алар каршында ислам нигезләрен өйрәтүче якшәмбе мәктәпләре эшли. Литва татар җәмгыятьләре берләшмәсе 1995 тән литва телендә «Летувос тоторяй» г-тасын (г-таның рус телендә «Татары Литвы» электрон версиясе дә бар) нәшер итә. 1992 дән Вильнюста татар якшәмбе мәктәбе, 1996 дан шәһәр тибындагы Григишкес посёлогында «Алие» фольклор ансамбле, 1997 дән Висагинас шәһәрендә милли үзәк каршында татар якшәмбе классы һәм «Мирас» иҗат коллективы эшли. 1997 дә Литвада татарларның Бөек Литва кенәзлеге җирләренә килеп урнашуларының 600 еллыгы хөкүмәт дәрәҗәсендә бәйрәм ителә. Литва татарлары тарихына багышлап «Мин — Литва җирендә туган татар морзалары нәселеннән» документаль фильмы төшерелә (2005 тә Казанда «Алтын мөнбәр» халыкара кино фестивалендә иң яхшы сценарий призына лаек була). Л.Р. б-н Татарстан арасында элек-электән тарихи, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр яшәп килә. Литва татарлары иҗтимагый оешмалары Бөтендөнья татарлары конгрессының башкарма ком-ты б-н тыгыз элемтәдә тора, алар төрле чараларда катнаша, делегацияләр алмаша. 1992 нең ноябрендә ТР һәм Л.Р. хөкүмәтләре арасында сәүдә-икътисади, фән-техника һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куела. 1993 нең февралендә Каунаста ТРның Л.Р.ндагы сәүдә вәкиллеге ачыла. Висагинаста ел саен *Сабан туе* бәйрәме үткәрелә. 2004 тән җирле кабельле телевидение «ТНВ» спутник каналы тапшыруларын трансляцияли. 2005 тә Паневежиста Казанның 1000 еллыгына багышланган чаралар үткәрелә.

*Әд.:* Г р и ш и н Я.Я. Польско-литовские татары (наследники Золотой Орды). К., 1995.

**ЛИТВИ́Н** Александр Алтерович (14.2.1958, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982 елдан Казан энергетика ин-тының марксизм-ленинизм кафедрасында, 1992 дән Казан ун-тының хәзерге заман ватан тарихы кафедрасында, 2007 дән музей белеме каф. мөдире, 2010 нан Тарих ин-тының музей белеме, туризм һәм һәйкәлләрне саклау каф. мөдире. Хезмәтләре Идел буенда 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрне өйрәнү тарихына һәм А.М.Стопани, В.В.Адоратский, М.К.Корбут биографияләренә карый.

Х е з м.: Большевики Среднего Поволжья 1902–1907 гг.: Советская историография. К., 1985; Возвращение. К., 1989 (автордаш); Общественно-политическое движение в Поволжье. Конец XIX — начало XX вв: Российская историография. К., 2003.

**ЛИТВИ́Н** Алтер (Алексей) Львович (18.12.1931, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1976), проф. (1979), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 1999). Казан ун-тын тәмамлый (1955). 1951 елдан Казанның 75 нче мәктәбендә тарих укытучысы, 1957 дән ТАССР Дәүләт музее фәнни хезмәткәре, 1962 дән Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1963 тән Казан пед. ун-тының СССР тарихы кафедрасында, 1979 дан Казан технол. ун-тында (фәнни коммунизм каф. мөдире), 1985 тән Казан ун-тында СССРның совет чоры тарихы кафедрасында, 1989 дан историография һәм чыганакларны өйрәнү кафедрасында (1998 гә кадәр каф. мөдире). Күп еллар дәвамында СССР ФАнең «Бөек Октябрь социалистик революциясе тарихы», РСФСР Югары белем бирү министрлыгының «КПСС тарихы методологиясе һәм историографиясе» проблемалар советлары әгъзасы булып тора. «Сул эсерлар һәм ВЧК» («Левые эсеры и ВЧК», 1996), «Генрих Ягода: СССР эчке эшләр халык комиссары, дәүләт иминлеге Генераль комиссары» («Генрих Ягода: Нарком внутренних дел СССР, Генеральный комиссар государственной безопасности», 1997), «Меньшевиклар Советлар Россиясендә» («Меньшевики в Советской России», 1998) документлар җыентыкларын төзүчеләрнең берсе. Хезмәтләре сов. һәм чит илләр историографиясе, Гражданнар сугышы, крәстияннәр, НКВД органнары тарихына карый. 1993 тән ТР МК каршындагы сәяси репрессияләр корбаннарын аклау комиссиясе составында эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997).

Х е з м.: «Дело сдать в архив...»: ВЧК в Татарии в 1917–1920 гг. К., 1986; Советская историография гражданской войны в Поволжье. К., 1988; Запрет на жизнь: Сталинские репрессии в Татарстане. К., 1993; Без права на мысль: Историки в эпоху Большого террора: Очерки судеб. К., 1994; Красный и белый террор в России. 1918–1922 гг. К., 1995.

*Әд.:* Ч е р н о б а е в А.А. Историки России: Кто есть кто в изучении отечественной истории: Биобиблиогр. словарь. Саратов, 1998; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

**ЛИТВИ́Н** Генрих Соломонович (15.2.1915, Минск ш. — 1969), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1967). 1946 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1961 дән функциональ диагностика лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре периферик кан әйләнешен радиоэлектрон ысуллар б-н тикшерүгә карый.

**ЛИТВИ́НОВ** Александр Александрович (10.6.1861, Мәскәү — 25.5.1933, Казан), скрипкачы, дирижёр, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. артисты (1926, респ-када беренче). 1879 елда Мәскәү консерваториясен И.В.Гржимали скрипка классы буенча (музыка теориясе фәннәре буенча П.Чайковскийда шөгыльләнә), 1882 дә Петербург консерваториясен Л.Ауэрда скрипка классы буенча (Н.Римский-Корсаковның композиция классына йөри) тәмамлый, ш.у. дирижёрлык буенча А.Никиштан аерым дәресләр ала. Уку дәверендә данлыклы рус музыкантлары б-н бергә муз. кичәләрдә катнаша, 1879 да П.Чайковскийның «Евгений Онегин» операсының Мәскәү консерваториясе студентлары көче б-н сәхнәләштерелгән беренче куелышы оркестрында уйный. 1882–1902 дә Зур театр оркестры артисты (1 нче скрипка партиясе), Мәскәү филармониясе концертларында скрипкачы-солист буларак катнаша. Бер үк вакытта, 1886 дан Мәскәү ун-тының студентлар оркестры һәм һәвәскәр оркестрлар б-н симф. дирижёр буларак чыгышлар ясый. 1889 да «Иптәш» исемле һәвәскәр оркестр музыкантлары берлеген һәм 1895 тә «Оркестр, камера һәм вокаль музыка сөючеләр җәмгыяте»н оештыра. Дирижёр буларак, Көнбатыш Европа һәм рус симф. музыка әсәрләреннән төзелгән концерт программалары б-н Мәскәүдә, Петербургта, Киевта, Харьковта, Түбән Новгородта, Казанда һ.б. шәһәрләрдә чыгышлар ясый. 1917 дән музыка укытуны оештыруга актив керешә. Түбән Новгород муз. округы б-н җитәкчелек итә, Түбән Новгород консерваториясе директоры булып эшли. 1921 дә ТАССР Халык мәгарифе комис-тының сәнгать белеме секциясе мөдире һәм Ике баскычлы дәүләт муз. мәктәбе мөдире итеп билгеләнә (Казан). 1922–29 да Шәрекъ музыка техникумы директоры була. 1923 тә «Татреспублика музыка җәмгыяте»н («Татмузо») оештыра. Л. җитәкләгән техникум укучылары симф. оркестры актив башкару эшчәнлеге алып бара. Концерт башкаруында Ш.Гуноның «Фауст», Дж.Вердиның «Аида», П.Чайковскийның «Евгений Онегин» һ.б. опералары куела ; Көнбатыш Европа, рус композиторлары әсәрләреннән (П.Чайковский симфонияләре, Ф.Лист «Прелюдияләре», М.Глинканың «Арагон хота»сы, Н.Римский-Корсаковның «Шахерезада»сы һ.б.) симф. концертлар циклы уздырыла. Л. җитәкләгән Казан музыка техникумы оркестры һәм хоры С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдев һәм В.Виноградов иҗат иткән беренче татар опералары «Сания» һәм «Эшче»не (1925, 1930) куюда катнаша. Л. Татарстанда проф. музыка белемен үстерүгә зур өлеш кертә.

*Әд.:* Л и т в и н о в а Э.Б. Выдающийся деятель русской музыкальной культуры А.А.Литвинов // Вопр. истории, теории музыки и музыкального воспитания. К., 1975. Вып. 3.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЛИТВИ́НОВ** Игорь Анатольевич (12.4.1953, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1975), шунда ук эшли. 1979 елдан РФА КГҮнең Органик һәм

физик химия ин-тында, 1998 дән дифракцион тикшеренү ысуллары лаб-ясе мөдире, 2004 тән физик-химик тикшеренүләр бүлеге мөдире. Хезмәтләре структур химиягә карый. Л. циклик һәм ациклик фосфорорганик кушылмаларның фәзаи төзелеше закончалыкларын өйрәнә. Үтә ияреш теориясе кысаларында органик һәм элементорганик кушылмаларны рентген-структур тикшеренү нәтиҗәләрен интерпретацияләү моделен эшли. Кауран рәтенең табигый кушылмасы изостевиолның ароматик кушылма молекулалары б-н тотрыклы изоструктур кристаллар барлыкка китерүен, анда стехиометрик «хуҗа:кунак» нисбәте 2:1 булуын билгеләде; бу вакытта ароматик кушылма изомерларына карата супрамолекуляр комплекслар хасил булуның региоселективлыгы ачыклана.

Х е з м.: Рентгеноструктурное исследование фосфорорганических соединений // Проблемы кристаллохимии. М., 1984 (автордаш); Молекулярная структура восьмичленных сульфитов с двумя планарными фрагментами в цикле // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1988. № 9 (автордаш); Synthesis and Comparative Analysis of Molecular and Supramolecular Structures of 4,8-Disubstituted 1,5-Dichloro-2,6-dioxotricyclo [5.1.0.0$^{3,5}$] octants // Monatshefte fur Chemie. 2003. V. 134 (автордаш).

**ЛИТВИ́НОВ** Игорь Львович (18.2.1928, Минск — 5.12.2000, Казан), педагог, тел галиме, пед. фән. канд. (1967). Минск юридик (1950) һәм Казан пед. ин-тларын (1954) тәмамлый. 1959–97 елларда Казан вет. ин-тында чит телләр каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләренең төп темасы — мәктәптә һәм югары уку йортында чит телне өйрәнү мәсьәләләре. «Мин татарча сөйләшергә өйрәнәм» («Я начинаю говорить по-татарски», 1994) дәреслеге, «Мәктәп өчен татарча-русча сүзлек» («Школьный татарско-русский поурочный словарь», ч. 1–2, 1998), укыту программалары, урта мәктәптә татар теле укытучылары өчен методик ярдәмлекләр авторы.

**ЛИТВИ́НОВ** (чын фамилиясе Гуревич) Лев Маркович (28.3.1899, Минск — 21.3.1963, Казан), режиссёр, Белоруссия ССР һәм ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1946, 1953); белорус милли проф. театрын оештыручыларның берсе. Сәхнә эшчәнлеге 1919 елда һәвәскәрләр коллективында Г.Зудерманның «Иван төне утлары» («Огни Ивановой ночи») пьесасын сәхнәләштерүдән башлана. 1926 да Белорус театр сәнгате ин-тын тәмамлый. Л. тарафыннан Лопе де Вега пьесасы буенча куелган һәм 1930 да Мәскәүдә СССР милли театрлары Олимпиадасында күрсәтелгән «Сарыклар кизләве» («Овечий источник») спектакле совет театр сәнгате тарихына кереп кала. 1932–37, 1934–48 дә 1 нче Белорус театрында баш режиссёр, беренче тапкыр белорус сәхнәсендә К.Крапива, Д.Бядуля, К.Чорный пьесаларын сәхнәләштерә. 1950 дә Г.Д.Ригорин тарафыннан Казанга чакырыла. Казан Зур драма театрында 12 ел эшләү дәверендә 35 спектакль куя. Л.ның «Бирнәле туй» («Свадьба с приданым», Н.М.Дьяконов, 1950), «Өч сеңел» («Три сестры», А.П.Чехов), «Кияүләр» («Женихи», А.Токаев), «Ис әйдә, җил, ис!» («Вей, ветерок!», Я.Райнис) — барысы да 1951; «Дошманнар» («Враги», М.Горький, 1952), «Порт-Артур» (А.Н. Степанов, И.Ф.Попов, 1953) кебек беренче спектакльләрендә үк жанр табигатен төгәл тоемлау, форма ачыклыгы, сәнгатьчә чаралар төрлелеге, сәхнәдәге вакыйгалар хәрәкәте, автор фикеренең тирәнлеге гәүдәләнеш таба. Л. һәр актёрның үзенә генә хас булган иҗади үзенчәлеген ача белә, аларны иҗатташлыкка рухландыра ала. Аның «Фёдор патша» («Царь Фёдор Иоаннович», А.К.Толстой, 1955), «Филумена Мартурано» (Э.де Филиппо, 1957), «Урманда» («В лесах», П.И.Мельников (А.Печерский) романы буенча, 1958) спектакльләре тамашачыны вакыйгалар барган урындагы вазгыять, шул чорларны тою көче һәм бер үк вакытта вакыйгалар агышының тизлеге б-н җәлеп итә; заманалар арасында охшашлык, аваздашлык барлыгы хакында фикер уята. Чорның актуаль проблемаларын яктырткан «Барабанчы» («Барабанщица», А.Д.Салынский, 1960), «Хуҗа» («Хозяин», И.М.Соболев пьесасы буенча, 1961), «Хезмәттәшләр» («Коллеги», В.П.Аксёнов повесте буенча, 1962) спектакльләре, Л. тарафыннан куелып, көчле иҗтимагый яңгыраш ала. Тормышны төгәл аңлау, сәхнә кануннарын яхшы белү, югары гражданлык хисе әлеге режиссёрның һәр спектаклен театр сәнгатендә олы бер вакыйга итә.



Л.М.Литвинов.

*Ю.А.Благов.*

**ЛИТВИ́НОВ** Михаил Нилович (1860, Владимир губ. Иваново-Вознесенск ш., хәзер Иваново өлкәсе Иваново ш. — ?), архитектор. Гражданлык инженерлары ин-тын тәмамлый (С.-Петербург, 1886). 1886–88 елларда Казан ун-ты архитекторы, бер үк вакытта, 1886–90 да — Казан шәһәре архитекторы. 1880–90 елларда Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсе архитекторы. 1890 нан Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлеге техникы, 1891 дә Мәскәү губерна идарәсе төзелеш бүлеге кече архитекторы; 1897–1910 елларда Мәскәүдә Коткаручы Христос чиркәвенең төзеклеген күзәтеп торучы. 1910 да дәүләт хезмәтеннән китә һәм С.-Петербургка күчә. Төзелешкә бәйле материаллар бастыру б-н шөгыльләнүче «М.Н.Литвинов һәм К°» басма конторасын ача.

Казанда Л. сәүдәгәр йортын Ксения хатын-кызлар гимназиясенә яраклаштырып корганда (1888), Петропавел соборын һәм чиркәү манарасын реконструкцияләгәндә (1889–90), рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсен яңартканда (1890) үзен тәҗрибәле белгеч-реставратор буларак таныта. 1880–90 елларда аның тарафыннан Гостиный двор бүлмәләренең бер өлеше шәһәр ломбарды, торак йорт вакытлыча укыту өчен епархиаль хатын-кызлар уч-щесе бинасы итеп үзгәртелә, янгыннан соң газ з-дының җитештерү бипалары сафка бастырыла. Реставрацияләү эшчәнлеге б-н бергә, нигездә, эклектика стилендәге торак, җәмәгать һәм производство төзелешләрен проектлау б-н шөгыльләнә; аеруча әһәмиятле проектлары: шәһәр терлек чалу урыны (1888), В.И.Ложкин каберендәге кәшәнә (1889), Чернояров йорты (1890), Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсе павильоннары (1890), Алафузов складлары (1890), Унженинның шәһәр читендәге йорты (1890 еллар), Георгий чиркәвенең руханилар йорты (1890 еллар) һ.б. «Конструкцияләрнең гадилеге һәм ныклыгы, матурлыгы һәм төзелешләрнең арзанлыгы» өчен Император рус









Л.М.Литвинов сәхнәгә куйган спектакльләрдән күренешләр: 1. «Бирнәле туй», Н.М.Дьяконов; 2. «Порт-Артур», А.Н.Степанов, И.Ф.Попов; 3. «Өч сеңел», А.П.Чехов; 4. «Хезмәттәшләр», В.П.Аксёнов повесте буенча.

техник җәмгыяте медале б-н бүләкләнә (1888).

*Әд.:* М о р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

**ЛИТВИ́НОВ** Рөстәм Игорь улы (28.1.1954, Казан), биохимик, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1995). 1977 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук биохимия кафедрасында эшли. 2001 дән АКШта. Хезмәтләре кан оешу биохимиясенә, кан плазмасы аксымнары эшчәнлеге технологиясенә карый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: К вопросу о природе фибриногена B // Казан. мед. журн. 1975. № 3 (автордаш); Биохимическое обоснование пробы на фибриноген B // Лабораторное дело. 1980. № 9 (автордаш); Роль клеток Купфера и гепатоцитов в катаболизме фибриногена // Вопр. мед. химии. 1982. Вып. 4 (автордаш); Перспективы лечебного применения препаратов фибронектина // Казан. мед. журн. 1986. № 5.

**«ЛИТЕРАТУ́РНАЯ КАЗА́НЬ»** («Әдәби Казан»), ТАССР Язучылар берлеге альманахы. 1945–59 елларда Казанда рус телендә елга 1–2 тапкыр нәшер ителә. 1947–58 елларда «Литературный Татарстан» («Әдәби Татарстан») исемендә чыга. Төрле елларда мөхәррирләре — И.*Пехтелев*, Я.*Винецкий*, А.Кринкин, Г.*Паушкин*, Т.Журавлёв; редколлегия составына Г.Бәширов, А.Гомәров, Ә.Еники, И.Заботин, Б.Зернит, К.Лебедев, Г.Минский, Х.Хәйри, Т.Ян керә. Редакция Татарстанның рус телендә иҗат итүче язучылары, яшь авторлар, татар әдәбияты классиклары һәм хәзерге заман әдипләре әсәрләрен бастыруны максат итеп куя. «Л.К.»да басылган язмаларга жанр ягыннан төрлелек хас; хикәя, повесть, новелла, романнардан өзекләр, шигъри әсәрләр өстенлек итә. Актив авторлар арасында танылган Казан шагыйрьләре, язучы һәм драматурглардан Я.Винецкий, И.Заботин, Б.Зернит, К.Лебедев, Ю.Малевинский, А.Мелузников, Г.Паушкин, А.Салмин, Л.Топчий, Т.Ян була. Альманахта татар әдипләреннән Г.Әпсәләмов, М.Әмир, Н.Арсланов, С.Баттал, Ш.Галиев, М.Җәлил, Ә.Исхак, Г.Кутуй, Ш.Маннур, Ш.Мөдәррис, М.Ногман, З.Нури, Ә.Фәйзи, С.Хәким, М.Хөсәен һ.б. әсәрләренең тәрҗемәләре басыла. Әдәби әсәрләрдән тыш, «Безнең төбәкнең үткәненнән», «Тәнкыйть һәм библиография» рубрикаларында туган якны өйрәнү тематикасына материаллар, юлъязмалар, Татарстан нефтьчеләре турында очерклар, тәнкыйди-публицистик мәкаләләр, Мәскәү һәм Казанда чыккан яңа китапларга рецензияләр урын ала. Е.Бушканец, Р.Порман, Л.Юдкевичның туган якны өйрәнү турындагы язмалары басыла.

*Р.А.Айнетдинов.*







«Литературный Татарстан», «Литературная Казань» альманахы.

**«ЛИТЕРАТУ́РНЫЙ ТАТАРСТА́Н»**, альманах; к. «*Литературная Казань*».

**ЛИТИ́НСКИЙ** Генрих Ильич (17.3.1901, Винница өлкәсе Липовец ш. — 27.7.1985, Мәскәү), композитор, педагог, музыка белгече, ТАССРның, Якутия АССРның, РСФСРның, Чуаш АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939, 1947, 1957, 1963), Якутия АССРның һәм ТАССРның халык артисты (1964). 1928 елда Мәскәү консерваториясен композиция буенча (Р.Глиэр классы) тәмамлый. 1928–43 тә Мәскәү консерваториясенең композиция һәм полифония классларында (1932–37 һәм 1939 дан композиция каф. мөдире һәм композиторлык ф-ты деканы, 1933 тән проф.) укыта. Укытуның 1920 елларда югалган академик традицияләрен яңадан торгызуга булышлык итә. 1947–85 тә Гнесиннар исем. музыка-пед. ин-тында эшли, бер үк вакытта, 1949–64 тә Казан консерваториясенең теория-композиторлык ф-тында полифония курсларын алып бара. Талантлы педагог буларак, аңа «башка шәхесне тыдыру теләге» хас була (С.Гобәйдуллина). Милли яшь композиторларның муз. фольклорны үзләштерүен таләп итеп һәм, мәс., пентатоник интонациянең европача язу алымы б-н кушылуының катлаулылыгын тирән аңлап, аларны укытуда зур җаваплылык һәм сизгерлек күрсәтә. 1930–40 та Мәскәү консерваториясе каршындагы милли музыка студияләре б-н хезмәттәшлек итә. СССРда милли композиторлар мәктәбен формалаштыруга зур өлеш кертә. Укучылары арасында: Н.Җиһанов, Ф.Яруллин. СССР халыкларының милли музыка сәнгатен тирән аңлавы Л.ның композиторлык иҗатында сизелеп тора: ул, М.Жирков б-н берлектә, әрмән, төркмән, Дагстан фольклоры үрнәкләре нигезендә әсәрләр, беренче якут опера һәм балеты әсәрләрен тудыра. Л.ның композиторлык стиле югары проф. осталыгында, музыкаль идеяләрне үстерүдәге тапкырлыгында, полифоник фикерләү югарылыгында күренә. Фәнни һәм методик эшләр авторы.



Г.И.Литинский (утырган) укучылары (сулдан уңга — Н.Г.Җиһанов, Ф.З.Яруллин һәм Ә.Ә.Фәйзи) б-н.

Төп әсәрләре: 4 опера, ш.и. М.Жирков б-н автордаш «Ашкын Нюргун Боотур» («Нюргун Боотур стремительный», 1947; 2 нче редакциясе 1957) операсы һ.б.; 3 балет, ш.и. М.Жирков б-н автордаш «Кыр чәчәге» («Полевой цветок», 1947; 2 нче ред., 1960) балеты; симфония (1928), 2 сюита (1931, 1940), симф. оркестр өчен 2 рапсодия (1966, 1972) һ.б.

Х е з м.: О творчестве // Советская музыка. 1934. № 4; Задачи по полифонии для композиторов: В 3 ч. М., 1965–67; Образование имитаций строгого письма. М., 1971.

*Әд.:* Я м п о л ь с к и й И. Литинский Генрих Ильич // Музыкальная академия. М., 1976. Т. 3; Ч у г а е в А., Ж и г а н о в Н., А р у т ю н я н А. Отмечая 85-летие со дня рождения Г.И.Литинского // Советская музыка. 1986. № 6; Г р и г о р ь е в а А. Г.И.Литинский. Жизнь, творчество, педагогика: Сб. статей, воспоминаний, док-ов. М., 2001.

*Л.А.Федотова.*

**ЛИ́ТО**... (грек. líthos — таш), кушма сүзләрнең ташларга, тау токымнарына караган өлеше (мәс., *литография, литология*).

**ЛИТОЛО́ГИЯ** (*лито*... һәм ...*логия*), утырма токымнар һәм хәзерге заман утырмалары, аларның матдәләр составы, төзелеше, ясалу һәм үзгәрү шартлары һәм закончалыклары турындагы фән. Л. утырма токымнар петрографиясенә, седиментологиягә, фацияләр һәм формацияләр тәгълиматына бүленә. Л. тыгыз рәвештә геол. фәннәре: стратиграфия, тектоника, палеогеография, геохимия һ.б. б-н бәйләнгән. 20 нче йөз башында чит ил (Г.Сорби, Л.Кайе, Г.Потонье һ.б.), ш.у. рус геологлары (П.А.Земятчинский, Я.В.Самойлов, М.Э.*Ноинский* һ.б.) тикшеренүләре нәтиҗәсендә мөстәкыйль фән буларак формалаша. Академик Н.М.Страхов М.Э.Ноинскийның «Самара Дугасы» («Самарская Лука», 1913) монографиясен — «литологияне мөстәкыйль фән итүче зур казаныш» дип атый. Казан губернасында литологик тикшеренүләр 19 йөзнең 2 нче яртысында башлана, 1886 елда губернаның Л.П.Шлихтинг төзегән беренче литологик картасы нәшер ителә. Казан галимнәренең зур фәнни казанышлары булып саналган эшләре: фация һәм формацияләр тәгълиматы (Н.А.*Головкинский*, Л.М.*Миропольский*, Е.И.*Тихвинская* һ.б.); доломит, гипс, утырма тимер ятмалары, кремний, фосфорит һ.б. файдалы казылмаларның килеп чыгышы мәсьәләләрен тикшерү (Б.П.*Кротов*, М.Э.Ноинский, Л.М.Миропольский, У.Г.*Дистанов*, В.В.Корчагин һ.б.); минерал. методологиясе (Е.М.*Аксёнов*, Р.Н.*Вәлиев*, Л.М.Солонцов һ.б.), нефть һәм газ коллекторлары классификациясе (А.И.*Кринари*, В.И.*Троепольский*, С.С.*Эллерн* һ.б.); литологик тикшеренүләр өчен ысуллар һәм приборлар эшләү (Ю.В.*Сементовский*, В.М.*Винокуров*, И.М.*Пеньков* һ.б.). Литологик тикшеренүләр Казан ун-тында, ЦНИИгеолнерудта, «Татнефть» АҖ пр-тиеләрендә үткәрелә .

*Әд.:* С т р а х о в Н.П. Основы теории литогенеза: В 3 т. М., 1960–62; Ф р о л о в В.Т. Литология: В 3 т. М., 1992–95.

*У.Г.Дистанов, Г.А.Кринари, В.П.Морозов.*

**ЛИТТРО́В** (Littrow) Иосиф Антонович (Йозеф Иоганн) (13.3.1781, Бишофтайниц ш., Богемия — 30.11.1840, Вена ш.), астроном, Петербург ФА мөхбир әгъзасы. (1813). И.М.*Симоновның* һәм Н.И.*Лобачевскийның* остазы. 1803 елда Прага ун-тын тәмамлый. 1806–07 дә Вена обсерваториясендә астроном булып эшли. 1807–09 да Краков ун-тының астрономия кафедрасын һәм обсерваториясен җитәкли. 1809 да Россиягә күчеп килә. 1810 нан Казан ун-ты профессоры. Казан шәһәр астрономия обсерваториясенә нигез салучы (1814), биредә аның җитәкчелегендә системалы астрономик күзәтүләр башланып китә. 1816 да Австриягә кире кайта, Офен шәһәре обсерваториясендә эшли, 1819–40 та Вена обсерваториясе директоры. Төп хезмәтләре гамәли һәм теоретик астрономия мәсьәләләренә карый. Системалы төстә зур һәм кече планеталарны, комета һәм метеорларны күзәтә. «Теоретик һәм гамәли астрономия» («Theoretische und practische Actronomie», V. 1–3, W., 1821–27) курсын яза. Астрономияне популярлаштыручы буларак та танылa; аның «Күк серләре» («Die Wunder des Himmels», V. 1–3, Stuttg., 1834–36) хезмәте — үз вакыты өчен астрономиянең иң яхшы һәм иң тулы аңлатма китабы — күп тапкырлар басыла (рус телендә — «Тайны небес», СПб., 1904). Айдагы бер кратер Л. исеме б-н аталган.

*Р.Г.Усманов.*

**ЛИХАЧЁВ** Андрей Фёдорович (4.7.1832, Казан губ., Спас өязе Полянки а. — 11.8.1890, шунда ук), археолог, нумизмат, коллекционер. Борынгы дворяннар нәселеннән. И.Ф.*Лихачёвның* энесе. 1853 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан губернаторы канцеляриясендә эшли. 1858 дә отставкага чыкканнан соң (авыруы сәбәпле), үзен төбәк нумизматикасын, археологиясен һәм этнографиясен өйрәнүгә багышлый. Л. озак вакыт Болгар шәһәре хәрабәләреннән ерак булмаган туган авылында яши. Казан төбәгендә алып барылган казу эшләре вакытында табылган, палеолит дәвереннән 16 йөзгә кадәрге чорларга караган археол. табылдыкларны, ш.у. борынгы Мисыр ядкәрләрен җыя; аның тарафыннан 25 мең берәмлеккә якын акча һәм медаль, Идел буе халыкларының мәдәнияте һәм көнкүреше предметлары, төрле илләрдән һәм Шәрекъtән китерелгән Европа һәм рус осталарының күп кенә картиналары туплана. 1860–70 елларда тупланмаларын тулыландыру максаты б-н берничә тапкыр Германиядә, Франциядә, Италиядә була. Сынлы сәнгать б-н шөгыльләнә, В.Г.Перов, И.И.Шишкин һ.б. рәссамнар б-н аралаша. Язучылар В.И.Панаев, Д.В.Григорович, ш.у. Н.А.Некрасов б-н языша. 1, 2, 4 һәм 6 нчы Бөтенроссия археол. съездларында катнаша. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятен (1878) оештыручыларның берсе. Борынгы ядкәрләрне өйрәнү нәтиҗәсендә ул беренчеләрдән булып Казан төбәге терр-ясендәге таш һәм бронза гасырлар истәлекләрен аерым бүлеп чыгару мәсьәләсен куя, татар халкының килеп чыгышы мәсьәләсендә татар мәдәниятенең болгар мәдәниятенә карата варислык бәйләнешенә нигезләнгән теорияне алга сөрә. Идел буе Болгар дәүләте мәдәнияте буенча хезмәтләр («Идел Болгары тарихы» — «История Волжской Булгарии», басылмаган), акча хәзинәләре турындагы мәкаләләр авторы. Рус археол. җәмгыятенең хакыйкый (1886) һәм Мәскәү археол. җәмгыятенең мөхбир әгъзасы (1865). Вафатыннан соң И.Ф.Лихачёв аның тупланмасын (40 меңнән артык предмет) хатыныннан сатып ала һәм шәһәр карамагына тапшыра, ул Казан шәһәр фәнни-сәнәгать музееның нигезен тәшкил итә. Соңрак тупланма төрле саклау урыннарына (ТР Милли музее, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, Казан ун-тының археол. музее) тарала. Л.ның архивы Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана.



«А.Ф.Лихачёв портреты». Рәссам А.Е.Семёнов. П.А.Рёмерның төп нөсхәсеннән. 19 йөзнең 2 нче яртысы.

Х е з м.: Альбом археологических находок. К., 1868; Бытовые памятники Великой Булгарии // Тр. 2 археол. съезда. 1876. Т. 1; Новый клад джучидских монет. СПб., 1877; Скифский след на Билярской почве // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1884. Т. 2; Следы бронзового века в Казанской губернии // Тр. 7 археол. съезда. 1890. Т. 2; Археологический атлас. К., 1923.

*Әд.:* Т р у т о в с к и й В.К. А.Ф.Лихачёв: Биогр. очерк // Тр. Моск. нумизматического об-ва. 1898. Т. 1; Х у д я к о в М.Г. А.Ф.Лихачёв как археолог // Казан. музейный вестн. 1922. № 2; И з м а й л о в а С.Ю. А.Ф.Лихачёв как востоковед // Казанское востоковедение: Традиции, современность, перспективы. К., 1997; Н а з и п о в а Г.Р. Казанский городской музей: Очерки истории 1895–1917 годов. К., 2000.

*И.Л.Измайлов, С.Ю.Измайлова.*

**ЛИХАЧЁВ** Василий Николаевич (5.1.1952, Горький ш., хәзер Түбән Новгород ш.), хокук белгече, дәүләт эшлеклесе, юридик фән. д-ры (1990), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994). Казан ун-тын тәмамлагач (1975), 1978–88 елларда шунда ук дәүләт хокукы һәм сов. төзелеше кафедрасында эшли (бүленеп: 1982–83 тә Гвинея-Бисау Респ-касының Милли мәктәбендә, 1987–88 дә Мадагаскар Респ-касының Антананариву ун-тында укыта), проф. (1991). 1988–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1990–91 дә ТССРның Конституцион күзәтчелек ком-ты рәисе. 1991–95 тә ТР вице-президенты. 1995–98 дә ТР Дәүләт Советы рәисе. Бер үк вакытта, 1996–98 дә, РФ Федераль Җыенының Федерация Советы Рәисе урынбасары. ТССРның дәүләт суверенлыгы турындагы 1990 елгы Декларацияне, 1994 елгы РФ һәм ТР арасындагы Шартнамәне эшләүдә катнаша. 1998–2003 тә РФнең Европа бергәлекләре (Брюссель ш.) каршындагы даими вәкиле, гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илче. 2004–10 да Ингушетия Респ-касы Халык җыены — Парламентының РФ Федераль җыены Федерация Советындагы вәкиле. 2010-11 дә РФ юстиция министры урынбасары, 2011 дән РФ Дәүләт Думасы депутаты. Хезмәтләре халыкара хокук, дәүләт хокукы, федерализм, кеше хокуклары проблемаларына карый. 1995–98 дә ТР халык депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.



И.А.Литтров.



И.Ф.Лихачёв.

Х е з м.: Советская Конституция и международное право. К., 1981 (автордаш); Установление пробелов в современном международном праве. К., 1989; На стезе правды и справедливости. М., 1997.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛИХАЧЁВ** Иван Фёдорович (31.3.1826, Казан губ., Спас өязе Полянки а. — 15.11.1907, Париж. Казан губ., Зөя өязенең Зөя шәһәрендәге ирләр монастыренда җирләнә), Россия хәрби флоты вице-адмиралы (1874), коллекционер, Казан шәһәр музееn оештыручыларның берсе. Борынгы дворяннар нәселеннән. А.Ф.*Лихачёвның* абыйсы. Диңгез корпусын тәмамлый (1843). 1844–49 елларда Кара диңгез флотында (мичман, лейтенант). 1850 нең көзендә «Оливуца» корветында Кронштадттан Ерак Көнчыгышка сәяхәткә кузгала, 1851 нең көзеннән корвет командиры. 1853 тән С.-Петербургта, капитан-лейтенант чины ала. «Морской сборник» ж-лының мөхәррире иптәше (урынбасары) итеп билгеләнә. Кырым сугышында (1853–56) катнаша: вице-адмирал В.А.Корнилов янында флаг-офицер; 1855 тә Севастополь шәһәреннән кешеләрне һәм коралларны эвакуацияләүне оештыра. 1855 нең 26 августында авыр яралана. Сугыш тәмамланганнан соң, Кара диңгездә хезмәтен дәвам итә: Николаев шәһәрендә диңгезчелек бүлеге мөдире каршындагы штаб башлыгы. 1858 дән бөек кенәз генерал-адмирал Константин Николаевич каршында адъютант, диңгезчелек фәнни һәм корабльләр төзү техник кабинеты әгъзасы. Россия хәрби диңгез флотын реформалауда актив катнаша: Ерак Көнчыгышта Россия диңгез флотын тоту зарурлыгын исбатлый, Цусима утравында Россиянең күзәтчелек станциясен булдыру турында кайгырта (тәкъдиме игътибарсыз калдырыла). 1860 ның гыйн-



Н.П. Лихачёв.



П.Т. Лихачёв.

варында Л.ка эскадра тупларга һәм Кытай биләмәсенә кергән суларда җитәкчелек итәргә әмер бирелә. Шәхси җаваплылыгында Посьета култыгында пост урнаштыра (1860 ның 11 апреле), асылда Көньяк Приморьены Россиягә куша. Пекин килешүен (1860 ның 2 ноябре) әзерләүдә катнаша. 1861 дә Россиягә Цусима утрауларын кушу омтылышы ясый (уңышсыз тәгәлләнә). 1863 тән Диңгезчелек ком-тының артиллерия бүлекчәсе әгъзасы, 1 нче рус броненосецлар эскадрасы командиры. Броненосецлар тактикасына нигез сала. 1866 дан Артиллерия диңгезчелек техник ком-ты әгъзасы. 1883 тә отставкага чыга, Парижда яши. «Морской сборник», «Русское судоходство» ж-лларында флот проблемалары хакында күп яза. Диңгез ген. штабын булдыру зарурлыгын дәлилли. Археол. һәм этнография б-н мавыга, төрле илләрнең икътисади һәм сәяси хәле, төрле халыкларның телләре, йолалары һәм гореф-гадәтләре турында материаллар җыя. Энесе А.Ф.Лихачёвның вафатыннан соң, 30 мең сумга хатынынның аның тупланмасын сатып ала һәм музей оештыру өчен шәһәргә бүләк итә. Шәһәргә үзенең китапханәсен һәм тарихи ядкәрләр тупланмасын иганә кыла. Казанның мактаулы гражданы (1891). Изге Анна, Изге Станислав, Изге Александр Невский, Ак Бөркет орденнарының тулы кавалеры, ш.у. Төркиянең Мәҗидия, Швециянең Изге Олаф, Даниянең Данеброг орденнары б-н бүләкләнә. Бөек Петр култыгының көнбатыш өлешендәге Тунгус бухтасында борын, Анадырь култыгындагы Комсомольская бухтасында борын, Охота диңгезенең төньяк өлешендәге Тауна култыгында бугаз Л. исеме б-н атала.

*Әд.:* Клепацкий Г. Адмирал Лихачёв — забытая гордость нашего края // Персона exclusive. 2001. № 6.

**ЛИХАЧЁВ** Николай Петрович (12.4.1862, Чистай ш. — 14.4.1936, Ленинград), тарихчы, сәнгать белгече, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1925). Нумизматика, нәселләр тарихы, борынгы рус һәм итальян-грек иконалары, Рус дәүләтендәге документлар тарихы (16–17 йөзләр) буенча зур белгеч. Казан ун-тын тәмамлагач (1888), шунда ук эшли, соңрак Петербург ун-тына күчә. 1902 елдан Петербург халык китапханәсе директоры. 1920 елларда Матди мәдәният тарихы академиясендә (Ленинград). Үзенең тупланмалары нигезендә Палеография музее оештыра, 1925 тә аның директоры итеп билгеләнә. Хезмәтләре ярдәмче тарихи фәннәргә (сфрагистика, нумизматика һ.б.), китап тарихына, борынгы рус һәм Византия сәнгатенә карый. Академик С.Ф.Платонов «эше» буенча репрессияләнә, 1931 дә академик дәрәҗәсеннән мәхрүм ителә һәм Әстерхан шәһәренә сөрелә; 1936 да ирекккә чыгарыла.

Хезм.: Разрядные дьяки XVI в. СПб., 1888; Библиотека и архив московских государей в XVI в. СПб., 1894; Местнические дела 1563–1605. СПб., 1894; Книгопечатание в Казани в первое пятидесятилетие существования в этом городе типографий. СПб., 1895; Материалы для истории русского иконописания: В 2 ч. СПб., 1906; Материалы для истории византийской и русской сфрагистики // Тр. Музея палеографии. 1928. Вып. 1.

*Әд.:* Записка об учёных трудах Н.П.Лихачёва // Изв. АН СССР. Сер. 6. 1925. Т. 19, № 18; Янин В.Л. К столетию со дня рождения Н.П.Лихачёва // Советская археология. 1962. № 2.

*С.Ю.Измайлова.*

**ЛИХАЧЁВ** Пётр Тимофеевич (1.4.1906, Казан губ., Спас өязе Порфировка а. — 22.3.1942, Смоленск өлкәсе Гжатск ш., хәзер Гагарин ш.), Сов. Союзы Герое (21.7.1942, үлгәннән соң), өлкән сержант. Туган авылында кырчылык бригадасы бригадиры булып эшли. 1921–30 елларда һәм 1941 нең маеннан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 32 нче укчы полк взводы командиры ярдәмчесе (5 нче армиянең 19 нчы укчы дивизиясе). Көнбатыш фронт гаскәрләре составында 1942 нең 21 мартында Мәскәүдән ерак түгел Клячино авылы (Смоленск өлкәсенең хәзерге Гагарин р-ны) янында батырлык күрсәтә: 16 сугышчыдан торган төркемне җитәкләп, дошманның 2 дзотын кулга төшерә; төркем чолганышны өзгән вакытта һәлак була. Ленин ордены һәм медаль б-н бүләкләнә. Болгар шәһәренең бер урамы Л. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Навечно в строю. М., 1973. Кн. 6; Храпченков А.К. В боях на Сталинградской земле. М., 1975.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ЛИХАЧЁВЛАР ЙОРТЫ́**, Казанда 19 йөзнең 1 нче яртысында классицизм архит-расы истәлеге. Фукс (элекке Аркылы Покровский) һәм Зур Кызыл (элекке Кече Покровский) урамнары кисешкән җирдә урнашкан. Утар 1834 елда Казан архитекторы П.Г.Пятницкий проекты буенча дворян П.И.Депрейс өчен төзелә. Ике катлы таш торак йорт урам буйлап сузылган, ян-яклары почмакларда түгәрәкләнгән. Янкормаларсыз төзелгән беренче каты җиде өлешкә бүленгән. Аның көньягы алгы бүлмә, ашханә, кухня, хуҗалык бүлмәләреннән тора (пилястралар б-н бизәлгән классицизм стилендәге ишекләр, түшәмнәрнең нәфис борыслары, мич, паркет идәннәр сакланып калган). Икенче кат анфилада рәвешендә тоташкан төп ишектән һәм торак бүлмәләрдән тора. Фасадларның архитектур-композицион чишелеше бинаның классик схемасына тәңгәл килә. Урам як фасадлары ризолитлар б-н ныгытылган, ике ягында да ионик ордерлы пилястралар урнаштырылган һәм күпертмә бизәкле фриз б-н тәгәлләнгән. П.Г.Пятницкий куыш а́ркалы һәм портиклы урам фасадларын эшләгәндә үзенең яраткан бизәү алымнарын файдалана. Икенче каттагы иркен тәрәзәләрне архитектор ике колонна б-н аерып куйган, аларны күпертмә бизәкле розетка һәм рельефлы а́рка б-н берләштергән. А́рка рәвешендәге тәрәзәле аскы кат рустланган. Йортның түгәрәкләнгән почмак өлеше «венециан» стилендәге тәрәзәләре һәм чүкеп ясалган рәшәткәләре, 19 йөз ахырында куелган балконы б-н аерылып тора. 1908 дән йортта тимер юллар инженеры С.П.Лихачёв гаиләсе яши. 1917 дән соң Л.й. дәүләт милкенә күчә. Анда Казанның атаклы сәнгать белгече П.М.Дульский яши.



Лихачёвлар йорты.
Арх. П.Г.Пятницкий. 1834.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Республика Татарстан: памятники истории и культуры. К., 1993.

*Л.М.Мортазина.*

**ЛИХТЕНШТЕ́ЙН** Аврам Овсеевич (5.4.1923, Киев), хирург, мед. фән. д-ры (1966). 1946 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук топографик анатомия һәм оператив хирургия кафедрасында эшли. 1949 дан Морт р-нының Костенеев участогы хастаханәсендә баш табиб һәм хирург. 1953 тән Казанның 5 нче хастаханәсенең кичектергесез хирургия бүлегендә. 1954 тән Ютазы р-ны Урыссу посёлогы хастаханәсенең хирургия бүлеге мөдире. 1958 дән Казан тимер юлының табиблык-сан. хезмәте баш хирургы, 1961 дән Казан тимер юлы хастаханәсенең күкрәк хирургиясе бүлеге мөдире. Бер үк вакытта, 1958 дән Казан травматология һәм ортопедия фәнни тикшеренү ин-тының кичектергесез хирургия бүлегендә, 1966 дан реанимация һәм анестезиология бүлеге җитәкчесе. 1967–97 елларда Республика туберкулёзга каршы көрәш диспансерында торакаль хирург һәм киңәшче. Хезмәтләре үпкәләрдә гадәти булмаган дәвамлы авыруларны хирургик дәвалауга, күкрәк сыну травмалары патофизиологиясе һәм хирургиясенә карый. Л. беренче булып Татарстанда (1955) сигмасыман эчәктән җинсә ясау операциясе, 1961 дә панкреатодуоденаль резекция, 1965 тә йөрәккә операцияләр (панцерлы перикардит вакытында перикардэктомия, инструменталь комиссуротомия), 1970 тә бронхларга резекция һәм пластика, 1974 тә бронхиаль астма вакытында үпкә тамырларына денервация операцияләре үткәрә. РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының «Шок һәм коллапс» махсус комиссиясе әгъзасы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Хронические воспалительные заболевания лёгких. К., 1973.


**ЛИША́ЙНИКЛАР** (Lichenes), гөмбә (аскомицет яки базидиомицет) һәм суүсемнәр

(яшел, сирәк кенә саргылт-яшел һәм көрән) симбиозы нәтиҗәсендә барлыкка килгән түбән төзелешле үсемлекләр группасы. Л.ның вегетатив үрчү өлеше — катланма гөмбә гифларының үрелмәсеннән барлыкка килә. Л. катланмасы төсе (ак, ачык-сары, соры, көрән һ.б.), зурлыгы, төзелеше һәм формасы буенча төрле: кабык (юшкын Л.), җәймә (яфракчыл Л.), туры яки асылынма куакчыклар (куакчыл Л.) рәвешендә. Үрчү өлешендә барлыкка килүче споралардан яисә вегетатив ысул б-н (катланма кисәкләреннән) үрчи. 25 меңгә якын төре бар дип исәпләнелә, бөтен Җир шары буенча таралганнар. Туфракта, таш, койма, түбә, ешрак — агач кайрысында үсә. ТР терр-ясендә аеруча еш очраучылар: кабарынкы гипогимния (Hypogymnia physoides), җыерчыклы пармелия (Parmelia sulcata), дивар ксанториясе (Xanthoria parietina). Туфракта, күбесенчә коры нарат урманнарында зифа буйлы кладония (Cladonia gracilis), эт пельтигерасы (Peltigera canina) үсә. Күп кенә төрләре атмосфераның төрлечә пычрануына сизгер, шунлыктан һава чисталыгының үзенчәлекле индикаторы буларак кулланыла. Л. агач паразитлары булып саналмыйлар, ләкин күп кенә кечкенә умырткасызлар өчен вакытлыча яшеренү урыны, ш.у. азык булып торганлыктан аларга беркадәр зыян китерергә мөмкиннәр. Эпифит Л., бигрәк тә, усней, пармелия, кладония төрләре поши, кәҗәболан өчен азык булып торалар. Биологик актив матдәләргә ия Л. антибиотиклар ясау өчен кулланыла. 24 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ЛОБА́НОВ** Борис Степанович (27.12.1932, хәзерге Архангельск өлкәсенең Верхнетомск р-ны Варзеньга а.), тау инженеры, ТАССРның атказ. нефтьчесе (1980), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). Куйбышев индустриаль ин-тын тәмамлый (1956). 1956–86 елларда «Татнефть» ҖБдә эшли: фәнни-тикшерену лаб-ясендә скважиналарны тикшерү буенча инженер, «Бөгелмәнефть» промыселы идарәсендә нефть чыгару бригадасы мастеры, үзәк инженер-диспетчерлык хезмәтендә өлкән инженер, «Лениногорскнефть» НГДУы җитәкчесе урынбасары, җитәкчесе (1973 тән), берләшмәнең баш инженеры (1983 тән). 1986 дан Мәскәүдә: «Нефтеотдача» тармакара фәнни-техник комплексының ген. директоры урынбасары, «Сонотрак» нефть компаниясе контракты җитәкчесе (Алжир, 1992 дән), «ЛУКОЙЛ» нефть компаниясе» АҖдә нефть һәм газ чыгару буенча Баш идарә җитәкчесе, җитәкче урынбасары (1994–2002).

Дәүләт бүләге нефть һәм газ чыганакларында торба үткәргечләрнең эчке өслекләрен саклый торган катлам эшләгәне һәм сәнәгатьтә үзләштергәне өчен бирелә. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Лениногорск шәһәренең мактаулы гражданы (1995).

**ЛОБА́Ч ТАВЫ́**, Кама елгасы тамагына каршы Иделнең уңъяк ярында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 1,5–2 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Абс. биеклеге 136 *м*. 1991 елдан табигать тыюлыгы. Мәйданы 241 *га*. Өслеге Пермь системасы югары бүлегенең Казан (известьташ, доломитлар, гипс) һәм Татар (балчык, мергельләр) яруслары токымнарыннан тора һәм алар Идел сулары б-н өлешчә юылган антиклиналь җыерчыклар барлыкка китерә. Җыерчык үзәгендәге биек күтәрелгән известьташ катламы Иделнең кориолис көче тәэсирендә уңга авышуына зур каршылык күрсәткән, шул сәбәпле елга биредә калкулыкны кискен (туры почмак ясап диярлек) уратып уңга борыла һәм елганың юнәлеше көньяк-көнчыгыштан көньяк-көнбатышка үзгәрә. Л.т. Идел буе калкулыгының биегрәк булган платосыннан (180–220 *м*) көньяк-көнбатышта — биредә Иделгә коючы Карамалы елгасы үзәне б-н, ә төньяк-көнбатышта — Карамалы елгасының сул кушылдыгы үзәне (неоген чорының күл-елга утырмалары б-н күмелгән һәм рельефта иңкүлек ясый) б-н аерыла. Идел уңга авыша барып, кушылдыкның югары агымын кисеп үтә һәм Иделнең уңъяк ярында, Кама Тамагы пристане янында үзәнне тутучы неоген чоры балчыклары ачыла. Яр буйлап Татар ярусының балчыксыл-мергель катламнары һәм неоген чоры балчыклары б-н бәйле шуышма процесслар киң таралган. Тау түбәсенең һәр җирендә Татар ярусы конгломератларының җимерелү продуктлары — Урал чыгышлы чакматаш, кварц, кварцит, кварцлы комташларның яхшы шомарган чуерташ сибелмәләре таралган. Территориясендә археология ядкәрләре — палеолит заманына караган торулыклар һәм б.э.ның 1 нче меңьеллыгына нисбәтле авыллыклар бар. Гражданнар сугышы эзләре сакланган.



Лобач тавы.

Калкулык урмансыз, аның авыш сөзәклекләре сукаланган. Дала үсемлекләре өстенлек итә. ТРның Кызыл Китабына кертелгән үсемлек (кызыл гамбәрия чәчәге, известь мәкәсе, үпкә гентианасы, җәрәфи үлән) һәм хайван (гади кара елан, елга каракошы, кара башлы шаркылдык акчарлак, сары корташар, тимгелле йомран) төрләре бар.

*А.П.Дедков, И.И.Рәхимов.*

**ЛОБАЧЕ́ВСКИЙ** Николай Иванович (20.11.1792, Түбән Новгород ш. — 12.2.1856, Казан), математик, геометр, нәевклид геометрияне тудыручы, Казан ун-тының атказ. проф. (1841). Немец математигы М.Ф.*Бартельсның* укучысы.

Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә Г.И.Карташевский, И.И.*Запольский*, Н.М.*Ибраһимовта* укый. 1811 дә Казан ун-тын магистр дәрәҗәсендә тәмамлый, шунда ук эшли, адъюнкт (1814 тән), саф математика кафедрасының экстраординар профессоры һәм мөдире (1816 дан), ординар профессоры (1822 дән). 1822–25 тә физика-матем. бүлекчәсе деканы, 1827–46 да университетның ректоры, 1846 дан Казан уку-укыту округы попечителе ярдәмчесе.



«Н.И.Лобачевский портреты». Билгесез рәссам. Л.Д.Крюковның төп нөсхәсеннән. 19 йөзнең 1 нче яртысы.

1826 ның 7 февралендә Л. Казан ун-тының физика-матем. фәннәре бүлекчәсенә «Геометрия башлангычларын параллельләр турындагы теоремаларын катгый исбатлау белән бергә кыскача сурәтләү» («Сжатое изложение начал геометрии со строгим доказательством теоремы о паралелях») дигән хезмәтенең кулъязмасын тапшыра. Бу дата Евклид геометриясеннән аерылып торучы яңа геометрия системасының (к. *Лобачевский геометриясе*) туган көне һәм матем. фикер үсешендә борылыш пункты булып санала. Кулъязма, фәнни журналны оештыру кичектерелү сәбәпле, басылып чыкмый. Ул 1829–30 да «Казанский вестник» ж-лында басылган «Геометриянең башлангычлары турында» («О началах геометрии») хезмәтенең нигезен тәшкил итә. Л.ның шулай ук алгебра, ихтималлылык теориясе, астрономия, механика һәм физика буенча хезмәтләре билгеле.

Л. механика, гидростатика, гидравлика, математика һәм тәҗрибәләр физикасын, астрономияне дә кертеп, физика-матем. циклының барлык фәннәре буенча диярлек лекцияләр укый. Университет архивында Л.ның дәресләрдә һәм халык алдында укыган лекцияләре, ш.и. «Тәрбиянең мөһим яклары хакында» («О важнейших предметах воспитания», 1828) дигәненең тексты сакланган, анда ул тәрбиягә, белем бирүгә карата үз карашларын бәян итә. Аның тырышлыгы б-н ун-тта татарларны, кыргыз, калмык, башкорт, бурятларны укыту башлана; ун-тны ул җитәкләгән елларда күп кенә укытучылар Европаның фәнни үзәкләренә стажировкага җибәрелә, экспедицияләр, ш.и. Шәрекъ илләренә (анда яшәүче халыкларның тари-

хын, мәдәниятен һәм телләрен өйрәнү өчен) оештырыла. Гарәп-фарсы телләре каф. б-н беррәттән, төрки-татар, монгол, кытай, әрмән телләре белеме, санскрит теле кафедралары ачыла. Л. ун-т типографиясен чит телләр (гарәп, әрмән, калмык, монгол, санскрит, тибет) шрифтларының зур тупланмалары б-н тәэмин итүдә башлап йөри.

Фәнни-пед. эшчәнлеген Л. китапханәчелек эше б-н бергә алып бара (1825–35). Аның җитәкчелегендә ун-т китапханәсендәге кулъязмаларның беренче тасвирламасы эшләнә, ил эчендә һәм чит илләр б-н китаплар алышу фондларын комплектлаштыруның фәнни нигезләре булдырыла, бердәм китапханә каталогларын төзү башлана. Китапханә Казан халкына хезмәт итә башлый, җәмәгать китапханәсенә әверелә. 1834 тә Л. «Учёные записки Императорского Казанского университета» фәнни ж-лын чыгаруны оештыра (беренче номеры аның кереш мәкаләсе б-н чыга).

Университетның ректоры сыйфатында Л. күп кенә комиссияләр һәм ком-тлар эшендә катнаша. Төзелеш ком-ты әгъзасы (1822 дән) һәм рәисе (1825 тән) була. 1822–26 да ун-т бинасының классицизм стилендә эшләнгән фасады үзенең соңгы рәвешен ала (Воскресенская урамы, хәзерге Кремль урамы); 1830 елларда Л. җитәкчелегендә китапханә, анатомия театры, химия кабинеты, физика лаб-ясе, астрономия һәм магнит обсерваторияләре бина元лары, ботаника бакчасы оранжереясы, клиника, төрле хуҗалык корылмалары төзелә (арх. М.П.Коринфский).

Л.ның кызыксынулар даирәсе гаять күпкырлы. Россиядә сәнәгать һәм а.х. үсешенә ярдәм итү теләге б-н ул Казан икътисадчылар җәмгыятен төзүдә (1839) башлап йөрүчеләрнең берсе була һәм аның ике бүлеген җитәкли. Төбәкнең икътисадын өйрәнүдә, сәнәгать һәм а.х. җитештермәләре күргәзмәләрен оештыруда катнашып, докладлар б-н чыгыш ясап, Л. икътисад өлкәсендә профессиональ белемнең зарурлыгы, киң катлау яшьләр өчен һөнәри һәм сәүдә мәктәпләре оештыру кирәклеге турында әйтеп килә. Үзенең «Беловолжская слободка» дип аталган утарында (хәзер Чуаш Респ-касындагы Козловка пос.) ул хуҗалык итүнең алдынгы алымнарын кертергә тырыша (крепостной Россия шартларында аның башлангычлары бары тик югалтуларга гына китерә).

Л.ның оештыру таланты шәһәр өстенә килгән ике стихия казасы: Казанда ваба эпидемиясе (1830) һәм шәһәрнең шактый өлешен юкка чыгарган коточкыч янгын (1842) вакытында аеруча нык беленә; ректорның булдыклы җитәкчелеге аркасында ун-т зур югалтулар кичерми. 1830–40 елларда Казан ун-ты илнең иң яхшы уку йортларыннан берсе була.

Л.ның ректорлык эшеннән һәм матем. каф. мөдире вазифасыннан китү (1846) сәбәпләре бик үк ачык түгел. Уку-укыту округы попечителе ярдәмчесе булып билгеләнеп, ул ун-т эшләреннән бөтенләй читләштерелә. Л. гомеренең соңгы еллары бик авыр була. Сәламәтлеге һәм матди хәле начарая. 1852 дә олы улы, ун-т студенты Алексей туберкулёздан вафат була. Бөтенләй диярлек сукырайган Л. ун-тының 50 еллыгына багышланган җыентык өчен үзенең соңгы хезмәте «Пангеометрия»не әйтеп яздыра (1855).

Фәнни иҗатында үз чорын бик күпкә узып киткән бөек галим үзе исән вакытында танылу тапмый. Моңа бигрәк тә ФАнең акад. М.П.Остроградский тарафыннан язылган үтә тискәре бәяләмәсе сәбәп була. Бары тик Көнбатыш Европа математикларының хезмәтләре аркасында гына хәл бераз үзгәрә башлый.

Л. Мәскәү һәм Казан ун-тларының шәрәфле әгъзасы, Гёттинген Король Фәннәр җәмгыятенең мөхбир әгъзасы (1842) була, ул җәмгыять тарафыннан К.Гаусс медале б-н (1856, вафатыннан соң) бүләкләнә. 1893 тә Казан физика-матем. җәмгыяте инициативасы б-н Л.ның 100 еллыгы киң билгеләп үтелә; халыкара Н.И.Лобачевский фонды (1891 дә төзелә) акчасына Казанның үзәгендә урнашкан скверга галимнең бронза бюсты куела (1896, к. *Лобачевский Н.И. һәйкәле*), *Лобачевский Н.И. исемендәге халыкара премия* булдырыла. Л. исемен кече планета һәм Айдагы бер кратер, Казан ун-тының фәнни китапханәсе (1953 тән) һәм Казанның бер урамы йөртә. Л. яшәгән йортка (Казан ун-тының элекке механика корпусы бинасы, Кремль ур., 18) мемориаль такта куела. 1991 дә СССР МК тарафыннан *Лобачевский Н.И. исемендәге медаль* булдырыла.

Х е з м.: Полное собрание сочинений: В 5 т. М.–Л., 1946–51; Научно-педагогическое наследие. Руководство Казанским университетом: Фрагменты. Письма. М.–Л., 1976.

*Әд.:* Л а п т е в Б.Л. Н.И.Лобачевский и его геометрия. М., 1976; В а с и л ь е в А.В. Николай Иванович Лобачевский, 1792–1856. М., 1992; Г у д к о в Д.А. Н.И.Лобачевский: Загадки биографии. Н.Новгород, 1992.

*Б.Н.Шапуков.*

**ЛОБАЧЕ́ВСКИЙ**, кече планета № 1858. 1972 елда Кырым астрофизика обсерваториясендә астроном Л.В.Журавлёва тарафыннан ачыла һәм Н.И.*Лобачевский* исеме б-н атала. Л.ның Кояштан ераклыгы 2,5 тән 2,9 а.б. аралыгында үзгәрә. Кояш тирәли әйләнү периоды 4,4 ел.

**ЛОБАЧЕ́ВСКИЙ ГЕОМЕ́ТРИЯСЕ**, 1826 елда Казанда Н.И.*Лобачевский* тарафыннан төзелгән теория. Бу геометриянең нигезләре беренче тапкыр аның «Геометриянең башлангычлары турында» («О началах геометрии», «Казанский вестник» ж-лы, 1829–30) дигән язмасында басылып чыга. Л.г. барлыкка килүнең чыганагы булып параллельләр проблемасы — Евклидның «Башлангычлар» (б.э.к. 3 йөз) хезмәтендә күрсәтелгән параллельлек аксиомасы (бишенче постулаты) тора. Бу хезмәттә беренче тапкыр геометрия аксиомалар системасы (к. *Геометрия*) нигезендә төзеп бирелә, арасында параллельлек аксиомасы аеруча мөһим урынны алып тора: яссылыкта бирелгән туры өстендә ятмаган теләсә нинди нокта аша бу турыны кисеп үтми торган (бирелгән турыга параллель булган) бердәнбер туры үткәрергә мөмкин. Евклидның дәвамчылары бу расламаны башка аксиомалар ярдәмендә теорема кебек исбатларга мөмкин дип уйлаганнар. Мондый эзләнүләр ике меңьеллык буе дәвам итсә дә, уңышсыз тәмамланган, чөнки анык булмаган формада бишенче постулатка эквивалент раслама кулланылган. Бишенче постулат проблемасы физик фәзаның реаль чынлыкта ничек төзелүе турындагы сорау б-н тыгыз бәйләнгән булып чыга һәм немец галиме И.Кант хезмәтләрендә фәлсәфи яңгыраш таба: ул геометрик хакыйкатьләрнең килеп чыгышын танып белү теориясендә төп мәсьәләләрнең берсе дип исәпли.

Лобачевский Евклидның параллельлек турындагы расламасы калган аксиомаларның логик нәтиҗәсе түгел дигән фараз әйтә. Шуның өстенә, Евклид геометриясенең барлык башка аксиомаларын саклаган хәлдә, тик бишенче постулат урынына яңасын — аның капма-каршысын («яссылыкта бирелгән туры өстендә ятмаган теләсә нинди нокта аша бирелгән турыны кисеп үтми торган кимендә ике туры үткәрергә мөмкин») куеп, Лобачевский яңа геометрия булдыра. Бу очракта бирелгән турыны кисмәүче чиксез күп турылар булырга мөмкин. Шундый ук нәтиҗәгә немец математигы К.Гаусс (1818) һәм венгр математигы Я.Бойяи (1832) да килә.

Л.г.нең логик яктан каршылыксызлыгы мәсьәләсе Лобачевскийның вафатыннан соң, бу геометриянең модельләрен (интерпретацияләрен) башка теорияләр кысасында төзү юлы б-н хәл ителә. Шундый беренче модельне итальян математигы Е.Бельтрами Евклид фәзасында даими тискәре Гаусс кәкрелеге (псевдосфера) өслегендә төзи (1868). Турылар ролен бу өслекнең геодезик сызыклары уйный. Бу өслек бары тик локаль интерпретация генә булса да, ягъни Лобачевский яссылыгының бер өлешен генә чагылдырса да, Л.г.н танытуда зур психологик роль уйный. Л.г. проектив геометрия нигезендәге беренче интерпретациясен (иркле сандагы үлчәүләр өчен) 1871 елда немец математигы Ф.Клейн эшли, ул Евклид геометриясенең дә, немец математигы Б.Риманның эллиптик геометриясенең дә (сфера геометриясенә якын) проектив интерпретациясен күрсәтә. Клейн геометриягә төркемнәр ягыннан якын килүне тәкъдим итә, аның буенча һәрбер геометрия хәрәкәт ролен үтәүче һәм фигураларны үзара чагыштырырга мөмкинлек бирүче рәвеш үзгәртүләр төркеме б-н характерлана. Шулай итеп, нигезләрендә яткан элементларның характеры б-н генә түгел, бу геометрияләрдә хәрәкәт ролен үтәүче рәвеш үзгәртүләр төркеменең төзелеше б-н дә аерылып торган геометрияләр барлыгы ачыклана. Л.г.нең башка модельләре арасында француз математигы А.Пуанкареның конформик моделе дә киң танылу ала, ул аны комплексле үзгәрешленең автоморф функцияләре теориясен төзегәндә таба (1882). Л.г.нең математикадагы роле геометрик кысалар б-н генә чикләнми. Лобачевский үзе үз геометриясе алымнарын 200 дән артык интегралны исәпләгәндә, ш.у. астрономик үлчәүләр һәм реаль физик фәза төзелеше турындагы мәсьәләне хәл иткәндә куллана.

19 йөз ахырында математиклар алдына килеп баскан иң мөһим мәсьәләләрнең берсе — геометриянең аксиоматик нигезләнеше мәсь-

әләсе була. Бу эшне 1899 елда немец математигы Д.Гильберт үзенең «Геометриянең нигезләре» («Основания геометрии», М.–Л., 1948) дигән китабында төгәлли һәм бу хезмәт математиканың башка бүлекләрен үстерү өчен башлангыч була. 20 йөз башында Л.г. б-н махсус чагыштырмалылык теориясенең кинематикасы арасында тыгыз бәйләнеш урнаштырыла. Совет галиме А.А.Фридман хезмәтләре нәтиҗәсендә Л.г.нең космология өчен әһәмияте ачыклана (1922). Ул Эйнштейн тигезләмәләрен чишә һәм алардан Галәмнең киңәюе турында нәтиҗә чыгарыла, соңрак бу нәтиҗәне Америка астрономы Э.Хаббл тәҗрибәләр б-н раслый (1929). 20 йөз ахырында Л.г. һ.б. нәевклид геометрияләрнең физикада, механика, биология һ.б. табигыять фәннәрендә кулланылышын ачкан хезмәтләр дөнья күрә.

*Әд.:* Л о б а ч е в с к и й Н.И. Полное собрание сочинений: В 5 т. М.–Л., 1946–51; ш у л у к. Научно-педагогическое наследие. Руководство Казанским университетом: Фрагменты. Письма. М.–Л., 1976; Н о р д е н А.П. Элементарное введение в геометрию Лобачевского. М., 1953; К а г а н В.Ф. Лобачевский и его геометрия. М., 1955; Об основаниях геометрии. М., 1956; Ш и р о к о в П.А. Краткий очерк основ геометрии Лобачевского. К., 1964; Е ф и м о в Н.В. Высшая геометрия. М., 1971; Л а п т е в Б.Л. Геометрия Лобачевского, её история и значение. М., 1976.

*Б.Н.Шапуков.*

**ЛОБАЧЕ́ВСКИЙ Н.И. ИСЕМЕНДӘГЕ́ МЕДА́ЛЬ**, «Г е о м е т р и я  ө л к ә с е н д ә г е  к ү р е н е к л е  х е з м ә т л ә р  ө ч е н», СССР МК тарафыннан 1991 елда билгеләнә, һәр 5 ел саен үткәрелә торган халыкара конкурс нәтиҗәләре буенча жюри



Н.И.Лобачевский исемендәге «Геометрия өлкәсендәге күренекле хезмәтләр өчен» медале. Авторы Г.В.Богородская. 1991 елда гамәлгә кертелә.

карары нигезендә бирелә. Бу вакыйгага бәйләп, Н.И.Лобачевский исем. халыкара геометрик семинар һәм «Лобачевский укулары» дигән яшьләр фәнни мәктәп-конференциясе үткәрелә. Медаль 1 декабрьдә — Лобачевскийның туган көнендә, Казан ун-тының киңәйтелгән гыйльми советында тапшырыла. Медальдән тыш мактау дипломнары да бирелә.

Беренче Л.и.м. 1992 елда, Лобачевскийның тууына 200 ел тулу уңае б-н Казан ун-ты профессоры А.П.*Норденга* бирелә, ул аңа нормальләштерү алымнарын төзегәне һәм нәевклид фәзалар теориясенә багышланган хезмәтләре өчен лаек була. 1997 дә 2 медаль: француз математигы М.Громовка — батырулар һәм гиперболик төркемнәр теорияләре өчен һәм Россия математигы Б.П.Комраковка — Ли төркемнәре һәм бериш фәзалар теорияләре буенча тикшеренүләре өчен бирелә. 2002 дә медальгә дифференциаль һәм алгебраик топология буенча хезмәтләре өчен Кытай математигы Ш.Чжен Ю лаек була.

*Әд.:* В и ш н е в с к и й В.В. 200-летие Н.И.Лобачевского, его итоги и уроки // Тр. геометр. семинара. К., 1997. Вып. 23; Ш а п у к о в Б.Н. История премии и медали имени Н.И.Лобачевского // Тр. геометр. семинара. К., 2003. Вып. 24.

*Б.Н.Шапуков.*

**ЛОБАЧЕ́ВСКИЙ Н.И. ИСЕМЕНДӘГЕ́ ХАЛЫ́КАРА ПРЕ́МИЯ**, геометрия, башлыча, нәевклид геометрия өлкәсендәге күренекле фәнни казанышлар өчен бирелә торган бүләк. 1895 елда Казан физика-матем. җәмгыяте тарафыннан билгеләнә һәм һәр өч ел саен Н.И.*Лобачевский* фонды тарафыннан бирелә. Премия беренче тапкыр 500 сум күләмендә билгеләнә, аны Казан ун-ты профессоры А.В.Васильев (җәмгыятьнең рәисе, 1890–1906) рәислегендәге махсус комиссия карый. Конкурста катнашып та премия алмаганнар мактау хатларына лаек була. Беренче премия 1897 дә Норвегия математигы Софус Лига рәвеш үзгәртүләр төркемнәре теориясе буенча хезмәтләре өчен бирелә. Шуннан соңгы елларда премияне күренекле немец математиклары В.Киллинг (1900) һәм Д.Гильберт (1904) ала. 1906 һәм 1909 елларда, тәкъдим ителгән хезмәтләрнең берсе дә лаеклы дип табылмау сәбәпле, премия бирелми. 1912 дә 2 премия — Германия галимнәре Л.Шлизенгер һәм Ф.Шурга бирелә, беренче хезмәт 1909 да кичектерелгән була һәм ул җәмгыять тарафыннан алдан белдерелгән темага багышлана. 1915 тә премияне тапшыруга Беренче бөтендөнья сугышы комачаулый; Окт. рев-циясеннән соң Казан физика-матем. җәмгыяте эшчәнлеге туктатылып тора. 1925 тә әлеге җәмгыятьнең үтенече б-н премия яңадан тапшырыла башлый; 1927 дә ул немец математигы Г.Вейльгә, 1937 дә француз математигы Э.Катранга бирелә, яшь совет математиклары өчен махсус премиягә Саратов геометры В.В.Вагнер лаек була. 1947 дә СССР МС карары нигезендә Н.И.Лобачевский исем. премия СССР ФА карамагына күчерелә. Премия лауреатлары арасында А.Д.Александров, Н.Ф.Ефимов (СССР, 1951), А.В.Погорелов (СССР, 1959), Л.С.Понтрягин (СССР, 1966), Х.Хопф (Швейцария, 1969), П.С.Александров (СССР, 1972), Б.Н.Делоне (СССР,1977), С.П.Новиков (СССР, 1980), Г.Буземан (АКШ, 1983), А.Н.Колмогоров (СССР, 1986), Ф.Хирцебрух (Германия, 1989), В.И.Арнольд (РФ, 1992), Г.А.Маргулис (РФ, 1996), Ю.Г.Решетняк (РФ, 2001) һ.б. бар.

*Әд.:* Б у х ш т а б е р В.М., Н о в и к о в С.П. История премии им. Н.И.Лобачевского (к 100-летию первого присуждения в 1897 г.) // Успехи мат. наук. 1998. Т. 53, вып. 1; И з о т о в Г.Е. Казанское физико-математическое общество. К., 2003; Ш а п у к о в Б.Н. История премии и медали имени Н.И.Лобачевского // Тр. геометр. семинара. К., 2003. Вып. 24; Г е р а с и м о в а В.М. Указатель литературы по геометрии Лобачевского и развитию её идей. М., 1952.

*Б.Н.Шапуков.*

**ЛОБАЧЕ́ВСКИЙ Н.И.ҺӘЙКӘЛЕ́**, Казанда. Бөек рус математигының эшчәнлеге Казан ун-ты б-н бәйле булганга, һәйкәл аның шәхесен һәм хезмәтләрен мәңгеләштерү уңаеннан Кремль һәм Лобачевский урамнары кисешкән бакчада куела. 19 йөздән саклanып калган бердәнбер һәйкәл, ун-т корылмаларының архит-ра-сәнгать ансамбленә керә. Галимнең тууына 100 яшь тулу уңаеннан, аны кую карары 1893 елда кабул ителә. Шәһәр башлыгы С.В.Дьяченко һәйкәл кую идеясе б-н чыга, үзе үк шәһәр кеременнән 952 сум 71 тиен акча бүләк итә, бу театрның ике спектакленнән кергән акча була; Казан губерна земствосы 500 сум бүлеп бирә, студентлардан 105 сум акча җыела. Һәйкәл авторлары — скульп. М.Л. Диллон һәм арх. Игнатьев.



Н.И.Лобачевский һәйкәле. Бронза, гранит. Скульп. М.Л.Диллон, арх. Игнатьев. 1896.

1896 ның 1 сентябрендә, университет чиркәвендә литургия һәм панихида үткәрелгәннән соң, һәйкәлне ачу тантанасы була. Җыелучылар арасында университет советы әгъзалары, Казан физика-матем җәмгыяте, бюстны ясатучы комиссия әгъзалары һәм хөрмәтле кунаклар була. Нотык б-н С.В.Дьяченко, Казан ун-ты матем. профессоры Ф.М.Суворов, физика-математика җәмгыяте рәисе проф. А.В.Васильев, Түбән Новгород физика һәм астрономияне яратучылар түгәрәге рәисе С.В.Щербаков чыгыш ясыйлар.

Бюст 19 йөзнең 2 яртысы психол. скульптура традицияләрендә эшләнә. М.Л.Диллон ясалмалылыктан һәм тышкы купшылыктан качарга тырышкан. Башының җиңелчә иелүе, галимнең үз уйларына бирелүе, тирән җыерчыклар б-н ергаланган маңгай, кысылган иреннәре — болар барысы да уй-фикерләрнең тупланган чагын һәм фикер активлыгын күрсәтә. Галим гүя тирә-як мохиттан аерылган һәм тулаемы б-н фәнни идеяләр дөньясына кереп чумган кебек. Аның психол. халәте аша дәртлелеге, ирек сөючәнлеге һәм көчле темпераменты чагыла. Скульптор үзенең төп идеясенә яраштырып пластик чараларны уңышлы сайлый. Скульптура портреты тәэсир итү көче һәм форманың җентекле эшләнүе б-н аерылып тора.

Бюст турыпочмаклы, кубсыман нигездә торучы, шомартылган кара граниттан ясалган колонна сыман постаментка куелган. Поста-

ментта: «Математик Николай Иванович Лобачевский. 12.2.1856 ел. 63 яшендә вафат» дигән язма бар. Постамент бронза детальләр б-н бизәлгән: геометрия эмблемасы — өчпочмак, җәзбә һәм дәфнә агачы ботагы (1930 ның башларында юкка чыга һәм ярты гасырдан соң яңадан торгызыла).

*А.И.Новицкий.*

**ЛОБКО́В** Вячеслав Николаевич (16.3.1903, Воронеж губ., Богучар өязе Кантемировка а. — 6.12.1970, Казан), партия, адм.-хуҗалык хезмәткәре. 1919–25 елларда РКСМның Воронеж губернасы Острогож өяз ком-тында инструктор, бүлек мөдире, секретарь. 1925–43 тә Үзәк Кара туфраклы өлкәдә, Вологда, Барнаул шәһәрләрендә партия һәм хуҗалык эшендә. 1943–54 тә ТАССР ХКС рәисе урынбасары, КПССның Татарстан өлкә ком-тының 2 нче секретаре. 1947–51 дә РСФСР, 1947–59 да ТАССР ЮСлары депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*С.С.Елизарова.*

**ЛО́БОВ** Борис Иванович (8.1.1936, Омск өлкәсенең Черлак р-ны «Коммунист» с-зы), төгәл приборлар төзү өлкәсе белгече, техник фән. канд. (1982), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1980). 1964 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү авиация технологиясе һәм производствоны оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1967–68 дә Саратов технол. фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында. 1968–2003 тә Бөтенроссия чыгымнар билгеләү фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), фәнни-тикшеренү лаб-ясенең сектор башлыгы (1981 дән), аз тотылышлы сыеклыклар һәм газларның күләмен үлчәү алымнары һәм җиһазлары бүлеге башлыгы (1988–2003). 2004 тән Мәскәү үрнәк үлчәү җиһазлары төзүче «Прувер» пр-тиесенең әйдәп баручы белгече. Сыекчалар һәм газлар тотылышын көйләүче прецизияле генераторны гамәлгә куя. Л. җитәкчелегендә су һәм нефть продуктлары тотылышы махсус 2 дәүләт эталоны, ш.у. сыекча һәм газларның 36 эшче эталоны (халык хуҗалыгының төрле тармакларында гамәлгә кертелә) булдырыла. Үзара Икътисади ярдәмләшү советына (СЭВ) керүче илләр өчен норматив документлар (тотылыш күләмен билгеләү өлкәсендә күрсәтмәләр һәм стандартлар) эшләүдә катнаша (1974–87). Дәүләт бүләге кан күләмен билгеләүче электромагнитлы приборлар эшләгәне һәм, аларның серияле производствосын җайга салып, көндәлек мед. практикасына кертүгә өчен бирелә. Уйлап табуга 44 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль һәм ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Государственные эталоны России. М., 2000; Организация автоматизированного учёта нефти // Трубопроводный транспорт нефти. 2000. № 9 (автордаш); Способ и устройство передачи размера единицы расхода от эталонов рабочим средствам измерений // Измерительная техника. 2004. № 4 (автордаш).

**ЛО́БОВ** Василий Александрович (10.8.1912, Екатеринбург губ. Алапаевск пос. — 13.10.1972, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1958), проф. (1960). 1937 елда Пермь ун-тын тәмамлаганнан соң, Куйбышев пед. ин-тында укыта. 1941 елдан «Куйбышевнефтеразведка» трестында (Сызрань ш.), 1946 дан Көнчыгыш нефть эшкәртү һәм проектлау ин-тында геол. бүлекләре башлыгы (Куйбышев ш.); 1958 дән Куйбышев нефть сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-тында директор. Бер үк вакытта Куйбышев индустриаль ин-тының нефть геологиясе каф. профессоры (1950–60). 1962 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Геология ин-тында (ЦНИИгеолнеруд), нефть секторы мөдире. Л. Куйбышев өлкәсе терр-ясендә — нефть-газ, Татарстанда кристаллик нигез токымнары перспективасын бәяли. Аның җитәкчелегендә Татарстанда тирән һәм үтә тирән скважиналарны бораулау проекты эшләнә (1970–90 елларда тормышка ашырыла). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Волго-Уральская нефтегазоносная область: Тектоника. Л., 1956 (автордаш).

**ЛО́ГИНОВ** Виталий Павлович (20.3.1950, Казан), архитектор, ТАССРның атказ. архитекторы (1985). 1973 елда Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанның Ленин р-нында — архитектор, 1990 елда Казан шәһәренең баш архитекторы урынбасары, 1992 дә — баш архитекторы булып эшли. 1995 тән Казан хакимияте башлыгы каршындагы Баш архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары. 2006 дан «ВЕЛП» иҗат остаханәсендә, ТР Архитекторлар берлеге рәисе. Л. тарафыннан Казандагы күп кенә эре җәмәгать объектлары: «*Болгар*» мәчете, Иоанн Кронштадтский чиркәве, руханилар семинариясе һәм епархия идарәсе биналары (1991); *Татарстан Республикасының Зур концерт залы*, ТР Эчке эшләр министрлыгының адм. бинасы (2004–05), билет кассалары павильонын реконструкцияләү б-н бергә Казанның вокзал яны мәйданы (2004–05, барысы да Е.И.Прокофьев б-н бергә). «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексы (2005) проектлаштырыла. Л. — Ленин р-ны адм. мәйданы төзелешләре (1981) һәм Казанның төньяк-көнчыгыш өлешен детальләп планлаштыру (икесе дә Е.И.Прокофьев һәм А.И.Чебинев б-н бергә, 1986) проектлары авторы. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (2000). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Л.М.Мортазина.*

**ЛО́ГИНОВ** Георгий Павлович (9.4.1939, Чуаш АССРның Козловка р-ны Карамышево а.), биохимик, биол. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1966), «Росгипрозем» ин-тының Татарстан җир төзү экспедициясендә эшли (1966–1969). 1969 елдан Казан вет. медицинасы академиясендә. Хезмәтләре төрле биолигандалар кергән биоген металлар хелатларының физик-химик үзлекләренә, аларның биологик активлыгын һәм а.х. терлекләренең продукция бирүчәнлегенә тәэсирен өйрәнүгә карый. Л. хелат төзелешле яңа металл комплексларны — бакыр һәм кобальтның триптофанат һәм метионинатларын, протофер, феррокомп, феррокомп-2 һәм феррокомп-3 не тәкъдим итә. «Микроэлементларның хелат формаларын терлекчелектә куллану» («Исследование хелатных форм микроэлементов в животноводстве», 2005) уку ярдәмлеге авторларының берсе. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм 3 рационализаторлык тәкъдиме бар.

Хезм.: Перспективы применения хелатов биогенных металлов в животноводстве // Тр. 1 съезда ветврачей Республики Татарстан. К., 1996 (автордаш); Хелатные формы биогенных металлов в животноводстве. К., 2004 (автордаш).

*Әд.:* Казанская Государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**ЛО́ГИНОВА** Лидия Ивановна (27.2.1951, Казан), спортчы (волейбол), СССРның атказ. спорт остасы (1980). Спорт б-н 1964 елда 4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый (Казан), тренеры — Э.А.*Семёнов*. Свердловск пед. ин-тын тәмамлый (1978). СССР чемпионы (1976, 1978–79, 1981), СССР чемпионатында (1977), СССР халыклары спартакиадасында (1975, 1979) «Уралочка» командасы составында көмеш медаль ала. Европа (1975, 1977, 1979), Олимпия уеннары (1980) чемпионы, Дөнья чемпионатында (1978) бронза медаль ала (СССР җыелма командасы составында). 1974 тән Екатеринбург шәһәрендә яши, 1978 дән Свердловск пед. ун-тында укыта. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**...ЛО́ГИЯ** (грек. lо́gos — сүз, тәгълимат), кушма сүзләрнең фән, белем, тәгълиматны белдерүче өлеше (мәс., *геология, филология*).

**ЛОҖЫ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Зичә елгасының (Зәй елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 9,4 *км*, бассейнының мәйданы 39,1 *км²*. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы — Байрак авылы янында, тамагы — Түбән Лоҗы авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагынікы — 67 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 67%. Л.ның 2 дән алып 4,8 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 74 *мм*, ташу агымы катламы 52 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,005 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада суның күләме 0,49 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ЛОЗА́НОВ** Николай Николаевич (6.8.1904, Саратов ш. — 10.9.1977, Мәскәү), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1938), проф. (1938), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1966). 1927 елда Саратов ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач, Саратов Югары сулыш юллары физиологиясе фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1932 дән 1 нче Ленинград мед. ин-тын-

да, бер үк вакытта П.Ф.Лесгафт исем. Ленинград физик культура ин-тының көнкүреш сәламәтлеге клиникасында. 1937 дән Башкорт ун-тының оториноларингология каф. мөдире. 1939 дан Казан мед. ин-тында, бер үк вакытта 1939–50 елларда Казан ГИДУВында. Хезмәтләре кешенең бит, борын, чәйнәү аппаратындагы катнаш яраларны, колак, бугаз, борын авыруларын, вестибуляр функцияне комплекслы өйрәнүгә һәм дәвалауга карый. Л. 1943 тә ишетү юллары зарарланган вакытта пластик операция ысулын эшли һәм тасвирлый, борынның утлы корал яралары классификациясен төзи, 1956 да Казанда беренче тапкыр колак, бугаз, борын авыруларына диагноз кую өчен электроэнцефалография ысулын куллана. 1936 да ринопневмометр ясый. Казан оториноларингологлар җәмгыяте рәисе (1939–70). Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физиологические компоненты вестибулярной реакции. Уфа, 1938; Огнестрельные комбинированные ранения лица–носа, придаточных пазух и жевательного аппарата. К., 1945 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Н.Н.Лозанов (50-летию врачебной, научной и педагогической деятельности) // Казан. мед. журн. 1977. № 4.

**ЛОЗОВА́Я** Вера Владимировна (22.4.1948, Казан), биохимик, биол. фән. д-ры (1986), проф. (1989). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1975–2001 елларда РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, цитофизиология лаб-ясе мөдире (1983 тән), күзәнәк биологиясе бүлеге мөдире (1992 дән). 2002 дән АКШта (Иллинойс штаты). Хезмәтләре үсемлекләр физиологиясенә һәм биохимиясенә карый. Л. целлюлоза биосинтезының субстрат һәм гормональ регуляциясе принципларын эшли. Регенерация сәләте б-н аерылып торучы культураларда күзәнәк тышчасы составы үзенчәлекләрен билгели. Җитен сабагы тукымалары нигезендә, күзәнәк тышчасының дифференциация процессын өйрәнү алымын тәкъдим итә. Тамыр барлыкка килүне активлаштыручы олигосахариннарны ача.

Х е з м.: Особенности формирования клеточной стенки изолированными протопластами. К., 1990; Формирование клеточных стенок в тканях стебля растений льна-долгунца. К., 1990 (автордаш).

**ЛОЗО́ВСКИЙ А.** (чын фамилиясе һәм исеме Дридзо Соломон Абрамович) (16.3.1878, Екатеринослав губ., Александров өязе Даниловка а. — 12.8.1952), дәүләт, партия эшлеклесе, тарих фән. д-ры (1939). 1899 елда Н.А.Семашко һәм А.С.Кулеша тарафыннан оештырылган Казан с.-д. төркеменә әгъза булып керә. 1901 дән РСДРП әгъзасы. 1905–07 еллар рев-циясендә катнаша (Казан). 1906 ның июнендә кулга алына. 1908 дә Иркутск губернасына сөргенгә барганда чит илгә кача. 1909–17 дә эмиграциядә Женевада һәм Парижда яши. 1917 нең июнендә Россиягә кайта. 1917 нең июлендә ВЦСПС секретаре булып сайлана. 1918–21 дә — укучылар, соңрак тимерюлчылар профсоюзы җаваплы секретаре, профсоюзларның Мәскәү губерна советы рәисе. 1921–37 дә Профинтерн ген. секретаре. 1937–39 да Гослитиздат директоры. 1939–46 да СССР тышкы эшләр халык комиссары (министры) урынбасары, бер үк вакытта, 1941–48 дә, Совинформбюро башлыгы урынбасары, башлыгы. 1940–49 да ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбендә халыкара мөнәсәбәтләр һәм СССРның тышкы сәясәте каф. мөдире. СССР ҮБК әгъзасы. СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Рабочий контроль. П., 1918; Профсоюзные массы в Советской России. М., 1920; Анархо-синдикализм и коммунизм. М., 1924; Основные моменты в развитии международного профдвижения. М., 1924; Ленин и профдвижение. Л., 1925; За единство фронта и единство профдвижения. М., 1935.

*Әд.:* Л и т в и н А. Лозовский Соломон Абрамович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**ЛОКА́Й** Виктор Иосифович (8.5.1920, Краснодар краеның Усть-Лабинск ш. – 30.10.1997, Казан), җылылык энергетигы, техник фән. д-ры (1969), проф. (1969), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1971, 1978). 1944 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, моторлар төзү ф-ты деканы (1953–58), проректор (1958–63), турбомашиналар каф. мөдире (1965–91). Хезмәтләре суытыла торган югары темп-ралы газ турбиналарына карый. Газ турбиналы двигательдән чыгучы кайнар газ агымы җылылыгын үтилләштерүгә караган хезмәтләре Казан моторлар төзү ЖБдә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар. Октябрь Революциясе, «Почет билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Газовые турбины двигателей летательных аппаратов. М., 1991 (автордаш); Теплопередача в охлаждаемых деталях газотурбинных двигателей летательных аппаратов. М., 1993 (автордаш).

**«ЛОКОМОТИ́В»**, тимер юл транспорты һәм тимер юллар учреждениеләре, оешмалары эшчеләре һәм хезмәткәрләре, шулай ук уку йортлары укучылары профсоюзларының ирекле спорт җәмгыяте. «Л.» Бөтенсоюз спорт җәмгыятенең Казан советы 1936 елда оештырыла (рәисе — И.М.Тюрихов), 1961 гә кадәр Ирекле спорт җәмгыятенең Казан һәм Юдино р-н советларын үз эченә ала, алар 40 тан артык физкультура коллективын берләштерә. Казан тимер юлының «Л.» Юдино р-н советы рәисләре — О.Б.Вешняков, Г.Б.Маликов, Б.И.Рыжов. Горький тимер юлы Казан бүлегенең «Л.» Казан р-н советы рәисләре — Б.И.Рыжов (1961–65), М.С.Казаров (1965–77), В.В.Митялин (1977–79), Л.М.Антонов (1979–81), М.Т.Нугаев (1981–87), З.И.Ягналиев (1987–99, 1999 дан «Л.» Казан физкультура-спорт клубы башлыгы). 1963 тә Юдино «Л.» спорт коллективына Я.Юдин исем. СК статусы бирелә (рәисе — В.Т.Зайцев, 1967–99). «Л.» та үсеш алган спорт төрләре: бокс, чаңгы спорты, биатлон, җиңел атлетика, футбол, хоккей, өстәл теннисы, пауэрлифтинг (өч төрле көрәш), җилкәнле спорт, авыр атлетика, грек-рим көрәше. СССР, РСФСР, РФ, ТАССР, ТР, «Л.» Ирекле спорт җәмгыяте Үзәк советы, Горький тимер юлы спартакиадалары, Халыкара тимерюлчылар спорт союзы, Европа, дөнья чемпионатларында җиңгән һәм приз алган атаклы спортчылар — И.Н.Кондрашов, Ф.Закирова, М.М.Галиев, И.Г.Хәкимуллина, А.Р. һәм Р.Р. Низаметдиновлар, А.Н.Галимуллина (чаңгы), Е.В.Григорьева, В.Г. һәм Г.Г.Григорьевлар (биатлон), А.М.Андрианов, М.М.Акчурин (бокс), В.М.Колотов (футбол), Д.М.Шәймәрданов, А.А.Симцов, И.Л.Павлов, С.Н.Ишмулкин (җиңел атлетика), А.А.Мартьянов, А.И.Иванов (алкалы хоккей); тренерлар — Н.М.Ермолаев, А.И.Шибаев, Р.И.Мәхмүтов (чаңгы), В.А.Рылов, И.Я.Полтаржицкий (бокс), Г.А.Востоков (футбол), В.П.Машин (җиңел атлетика), И.П.Медведева (өстәл теннисы), С.Д.Миронова (аэробика, шейпинг). Зур спорт корылмалары: Горький тимер юлы Казан бүлегенең «Л.» физкультура-спорт клубы балалар спорт-сәламәтләндерү комплексы, «Л.» пляжы» спорт комплексы, Я.Юдин исем. стадион (Юдино посёлогы).

**ЛОКТИО́НОВ** Виктор Николаевич (16.9.1930, Самара өлкәсенең Богатов р-ны Виловатое а. — 9.1.1991, Казан), токсиколог, фармаколог, вет. фән. д-ры (1984), проф. (1986). 1954 елда Казан вет. ин-тын тәмамлый. 1954–57 елларда ВЛКСМның Совет р-ны секретаре, 1957 дән Казан вет. ин-тында; 1964–71 дә вет. ф-ты деканы урынбасары, 1988–91 дә фармакология һәм токсикология каф. мөдире. Хезмәтләре гербицидларның агулы үзенчәлекләрен өйрәнүгә һәм гербицид токсикозларны дәвалау һәм булдырмау ысулларын эшләүгә карый.

Х е з м.: Профилактика отравлений животных // Степные просторы. 1981. № 10; Ветеринарная токсикология. М., 1987 (автордаш); Окружающая среда и токсикозы животных. К., 1989.

*Әд.:* Н а б и е в Ф.Г. Профессор Виктор Николаевич Локтионов. К., 2003.

*Ф.Г.Нәбиев.*

**ЛОМА́КИН** Тихон Сергеевич (14.6.1915, хәзерге Мордва Респ-касының Инсар р-ны Казеевка а. — 26.8. 2002, Казан); хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация техникумын (1937), Казан финанс-икътисад ин-тын (1955) тәмамлый. 1937–49 елларда Казан авиация з-дында эшли: техник-механик, Пе-2 бомбардировщикларын җыю цехы, очышлар станциясе, заводның катнаш производстволар бүлеге башлыгы. 1950–54 тә КПССның Ленин райкомы, 1954–58 дә Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1958–70 тә Казан компрессорлар з-ды директоры. Л. җитәкчелек иткән чорда компрессорлар з-дының гамәлдәге цехларында техник реконструкция уздырыла һәм яңа цехлар төзелә, прогрессив техниканың күп кенә төрләрен — турбосуытулы (фреонлы, аммиаклы, һава ярдәмендә) компрессор машиналарын, төрле технол. газлар өчен махсус пешкәкле компрессорларны, югары куәтле үзәктән кугыч циркуляцион компрессорларны күпләп эшләү оештырыла; илдә беренче тапкыр винтлы компрессорлар җитештерүне үзләштерү башлана; продукция җитештерү 4 тапкыр арта. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, ике «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* 50 лет ОАО «Казанькомпрессормаш». К., 2001.

**ЛО́МАН** Александр Карлович (1810, Або ш., Финляндия — 25.12.1883, С.-Петербург), ар-

хитектор. 1838 елда СА тәмамлый (С.-Петербург). Мария исем. сарай төзелеше комиссиясендә архитектор ярдәмчесе. 1843 тән Казан губернасы төзелеш комиссиясендә, 1853 тә С.-Петербургка әйләнеп кайта. Л. проектлары буенча Казанда нигездә эклектика стилендәге 10 га якын торак йорт төзелә. Печән базары мәчете проекты авторы да Л. дип фаразлана (1845–49). 1848 дә Иске татар



А.К.Л о м а н. Печән базары мәчете. Казан. 1845–49.


бистәсендә Л. проекты буенча эклектиканың классицистик юнәлешендәге ике катлы (ш.и. антресольле ишегалды каты) йорт һәм ишегалдында каралтылары булган сәүдәгәр утары төзелә (тулысынча сакланган). Ул ш.у. Ә.М.Ямбикова (1848), Медведев (1848), М.И.Пичкасинская (1849), Е.Е.Шилов (1849), Е.О.Тальникова (1849), Н.П.Морозов (1850), А.Н.Булыгин (1850), А.Силантьев йортлары (19 йөз уртасы) проектлары авторы (сакланмаганнар).

*Әд.:* Ф е х н е р М. Великие Булгары, Казань, Свияжск. К., 1978; М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М.Мортазина.*

**ЛОМОВА́ТОВО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Каманың югары агымы буенда (якынча 5–10 йөзләр). Атама Ломоватовка елгасы (Кама елгасы кушылдыгы) исеменнән алынган. Археол. культура комплексы буларак, А.А.Спицын һәм А.В.Шмидт тарафыннан аерып күрсәтелә, атамасы 1950 елларда В.Ф.Генинг башкарган тикшерү эшләреннән соң беркетелә. Л.к. истәлекләре Ижевск һәм Пермь археологлары Р.Д.Голдина, А.М.Белавин тарафыннан өйрәнелә. Полом археол. культурасы тарихи-мәдәни комплексына якын. Фин-пермь һәм угор кабиләләре калдырган дип фараз ителә. 10 йөзнең 2 нче яртысында Ломоватовка кабиләләренең бер өлеше Урта Идел буена күчеп урнаша, болгар халкын һәм аның культурасын формалаштыруда катнаша.

Л.к. кабиләләре китмәнле игенчелек, терлекчелек, сунарчылык, балыкчылык б-н шөгыльләнә; тимер металлургиясе б-н таныш була. Л.к. халкы яшәгән терр-ядә баусыман һәм тараксыман бизәкләр төшереп эшләнгән йомры төпле керамик савытлар табып алына. Курган һәм чокырларга мәетләр җирләү үзенчәлекле ритуал буенча башкарыла. Татарстан терр-ясендә Л.к. истәлекләре Минзәлә р-нында табыла. Аның элементлары 9–10 йөзгә нисбәтле күпчелек болгар каберлекләренә хас. Танкеевка каберлегендә Л.к. һәм аңа якын Полом культурасына караган йөзләрчә кабер өйрәнелә. Каберләрдә әвәләп ясалган, тараксыман һәм баусыман бизәкләр төшерелгән йомры төпле керамик савыт ватыклары, кораллар, бизәнү әйберләре һ.б. табыла. Керамика, табыну әйберләре, мәет битлекләре Урал-Кама яны угор халыкларының культурасының башка предметлары б-н охшаш.



**Ломоватово культурасы**. Игем каберлегенең табылдыклар җыелмасы: 1 — алка, 2–5 — каеш бизәкләре, 6 — аел, 7 — асма бизәк, 8 — беләзек, 9–15 — ук очлыклары, 16 — җәя өстәмәсе, 17 — кылыч, 18 — сөңге очлыгы, 19 — балта, 20 — керамик савыт.

*Әд.:* Г о л д и н а Р.Д. Ломоватовская культура в Верхнем Прикамье. Ижевск, 1985; К а з а к о в Е.П. Культура ранней Волжской Булгарии. М., 1992.

*Е.П.Казаков.*

**ЛО́МОВКА** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 32 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 7 кеше (руслар) яши. 1678 дән мәгълүм. Халкы башта Зөя Успение монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, агач материаллары әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да 2 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 689 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 84 ир-ат; 1859 да — 296, 1897 дә — 345, 1908 дә — 354, 1926 да — 434, 1938 дә — 377, 1949 да — 201, 1958 дә — 187, 1970 тә — 193, 1979 да — 117, 1989 да — 28, 2002 дә — 12 кеше.

**ЛОНЩАКО́ВА** Тамара Ивановна (22.11.1936, Тамбов өлкәсенең Бокино а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1992). 1960 елда Казан химия технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бийск шәһәрендә оборона пр-тиесендә эшли. 1964 елдан Казан технол. ун-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1992 дән). Хезмәтләре нефть химиясе производствосының күптонналы икенче дәрәҗә продуктларын химик эшкәртү һәм максатчан куллануга карый. Л. алкадиеннар әверелешенең традицион булмаган типларын билгеле, олигомер кушылмалар, нефтеполимер сумалалар (резина катнашмасы модификаторлары, лак-буяу материаллары өчен элпә ясагычлар һ.б. композицияләр) алу процессларын эшли. Олефин һәм алкадиеннар аеруның эффектив ысулын, диен каучуклары һәм калдыкларының кислородлы полифункциональ олигодиеннарга (элпә хасил итүче материаллар җитештерү өчен чимал) әверелдерү алымын тәкъдим итә. Нефть химиясе производствосының калдык продуктларыннан юллар салу өчен модификацияләнгән күкертле битум алу рецептурасын һәм процессын эшли. Л.ның фәнни тикшеренү нәтиҗәләре «Түбәнкаманефтехим», «Кварт» АҖләрдә, С.М.Киров исем. «Ясалма каучук заводы» ФҖБдә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. ВДНХның көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Перспективы использования пиперилена: Темат. обзор. М., 1982 (автордаш): Нефтеполимерная смола сполак: Темат. обзор. М., 1994. Вып. 2; Термоокислительная деструкция каучука СКБ воздухом в растворе в присутствии кобальтовых солей органических кислот // Изв. вузов. Сер. химия и хим. технология. 2001. Т. 44, вып. 6 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЛОПА́ТИН** Олег Николаевич (7.5.1963, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук эшли. Хезмәтләре минералогия, кристаллохимия, геммология, зәркән ташларын эшкәртү буенча нанотехнологияләр куллану өлкәсенә карый. Минералларның физик-химик үзенчәлекләрен һәм ионлы-нурлы тәэсир нәтиҗәсендә аларның синтетик төрләрен модификацияләү технологиясен эшли. РФАнең Казан минералогия җәмгыяте рәисе (2011 дән). Казан ун-тының Геология һәм Казан Кремленең Табигыять тарихы музейләры кураторы.

Х е з м.: Кристаллохимия силикатов альпинотипных гипербазитов Урала и поисковые критерии хромитового оруденения. К., 1997 (автордаш); Геммология — наука о самоцветах // Соросовский образовательный журнал. 1999. № 5; Геологический музей Казанского государственного университета им. А.А.Штукенберга. К., 2004 (автордаш); Ионная имплантация минералов и их синтетических аналогов. Saarbrucker, 2011.

**ЛОПА́ТИН РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 144 *км*². Үзәге — Лопатино авылы (Пенза шәһәреннән 86 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 16,2 мең кеше, ш.и. 3 меңгә якын татар (2002). Иң зур татар авыллары: Селәү (1186 кеше), Иске Вершаут (793), Карлыган (753), Берлек (137). Район терр-ясендә татарлар 17 йөз ахыры —

18 йөз башында күренә башлыйлар, Пенза краендагы җирләр аларга хәрби хезмәт үтәгәннәре өчен бирелә. 1925 тә 10 мәчет була. Хәзерге вакытта Л.р.нда 4 мәчет: Селәү (1997 һәм 2000 дә ачыла), Иске Вершаут (1998), Карлыган (1999) авылларында эшли. 3 урта һәм 1 башлангыч мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. 2003 тән районда Татар мәдәнияте җәмгыяте (җитәкчесе Р.Р.Нәдершин) эшли. Л.р.нда шагыйрь М.Х.*Мазунов*, тел белгече, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Ш.Г.*Рамазанов* туган.

**ЛОПУША́НСКАЯ** София Петровна (16.3.1926, Украина ССРның Полтава ш. — 20.5.2008, Волгоград), тел галиме, филол. фән. д-ры (1976), проф. (1979), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996), РФ хөкүмәте каршындагы Рус теле буенча совет әгъзасы (1994 елдан). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, 1950–77 дә Казан пед. ин-тында укыта. 1977 дән Волгоград пед. ин-тында рус теле каф. мөдире. 1980 нән Волгоград ун-тында: рус филологиясе каф. мөдире, 1998 дән Рус теле тарихы фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: рус фигылен тел системасында һәм текстта өйрәнүнең теоретик нигезләре, 11–20 йөзләрдә аның семантик үсеше; рус әдәби теле һәм Түбән Идел диалектларының үзара йогынтысы.

Х е з м.: Очерки по истории глагольного формообразования в русском языке. К., 1967; Основные тенденции эволюции простых претеритов в древнерусском книжном языке. К., 1975; Развитие и функционирование древнерусского глагола. Волгоград, 1990.

*Әд.:* Кто есть кто в современной русистике. М.–Хельсинки, 1994.

**ЛО́СЕВ** Иван Платонович (3.1.1883, Волгоград өлкәсенең Арчадинск станицасы, хәзер Фролово ш. — 27.5.1963, Мәскәү), химик, проф. (1938), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе. 1914 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан коммерция уч-щесендә, 1917 дән урта мәктәп укытучыларын әзерли торган Казан югары курсларында укыта. 1919 дан Мәскәү вет. ин-тында. 1923–63 тә Мәскәү химия-технол. ин-тында (бүленеп: 1944–48 дә Мәскәү авиация технол. ин-тының нәметалл материаллар каф. мөдире), пластмассалар химиясе һәм технологиясе кафедрасының (1932–43) һәм СССРда беренче органик һәм элементорганик югары молекуляр кушылмалар технологиясе кафедрасының оештыручысы һәм мөдире (1948 дән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясе һәм технологиясенә карый. Л. винилль мономерлар сополимерлашуын, гади винил эфирлары һәм α-хлоракрил к-тасы кушылмалары полимерлашуын өйрәнүгә шактый зур өлеш кертә. Поливинилхлорид өчен пластификаторлар синтезлауның нәтиҗәле алымнарын эшли. Поливинилхлорид синтезлау мәсьәләләре буенча Л.ның фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсендә Россиядә бу полимерны сәнәгый җитештерүгә нигез салына. Аның җитәкчелегендә полиэфируретаннар, полиамидлар, полимочевина синтезлау, термочыдам полимерлар алу, ионалыштыручы сумалаларның төрле типларын булдыру эшләре гамәлгә ашырыла. Студент елларында Л. иҗтимагый хәрәкәттә катнаша. Крәстияннәр җыенында хөкүмәткә каршы чыгышы өчен бер ел Казан төрмәсендә утыра. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыяте президенты (1956–63). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение в химию искусственных смол и пластических масс. М., 1938 (автордаш); Технология систематических смол и пластических масс. М.–Л., 1946 (автордаш).

*Әд.:* С м и р н о в а О.В. Иван Платонович Лосев // Коллоидный журн. 1958. Т. 20, № 2.

**ЛОТФИ́** (1366, Һират ш., хәзерге Әфганстан — 1465/66, шунда ук), Урта Азия шагыйре. Иске үзбәк (чагатай) һәм фарсы телләрендә яза. Күпмедер вакыт Алтын Урда башкаласында яши дип фаразлана, Болгар шәһәрендә булгалый. Яшь чагында дөньяви фәннәрне өйрәнә, соңыннан суфичылык б-н мавыга, дәрвишләрчә яши. Шаһрух солтан кушуы буенча *Аксак Тимернең* шигъри биографиясен — «Зафәрнамә» («Җиңүләр китабы») дастанын яза башлый, ләкин әсәр язылып бетми кала (кулъязмасы сакланмаган). Л.ның «Гөл вә Нәүруз» (1411) исемле героик-романтик поэмасы фарсы шагыйре Җ.Табибның шул исемдәге поэмасына (1333) нәзыйрә рәвешендә иҗат ителә. Ике гашыйкның күп сынаулар үтеп кавышулары яктыртылган сюжет Л. тарафыннан гадел хөкемдар идарә иткән идеаль дәүләт турындагы фикерне дәлилләү өчен файдаланыла. Поэманың бер күчермәсе Казанда 1960 елларда табыла. Безнең көннәрдә Л.ның 4 мең шигъри юлы билгеле. Алар төрле жанрларда язылган (газәл, кыйтга, робагый, кыйсса); үзенең уй-хисләрен шагыйрь укучыга төрки телле халыклар фольклоры чаралары б-н җиткерә. Күп кенә шигырьләре халык җыры булып китә. 1914 тә Казанда Л. шигырьләренең беренче басмасы дөнья күрә. Л.ның иҗаты Казан ханлыгы чоры татар шагыйре Мөхәммәдъярга сизелерлек йогынты ясый.

Ә с ә р: Лирика. Гуль и Науруз. М., 1961; Девон. Гул ва Наврўз. Тошкент, 1965.

*Әд.:* А б и л о в Ш., М а к с у д о в а З. Лотфи Идел буйларында // Казан утлары. 1968. № 6; Р у с т а м о в Э.Р. Узбекская поэзия в первой половине XV в. М., 1963; Э р к и н о в С. Лутфий. Таш., 1965; М а л л а е в Н.М. Узбек адабиёти тарихи. Тошкент, 1965. 1 кит.

*Ш.Ш.Абилов.*

**ЛОТФИ́** (Лотфуллин) Гасыйм Фатих улы (16.4.1900, Царёвококшайск өязе Иске Өҗем а. — 3.6.1991, Казан), язучы, тәрҗемәче. 1937 елда Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый, 1937–41 елларда Казан ун-тында укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1943–49 да ТАССР Мәгариф министрлыгында, 1960 ка кадәр «Совет мәктәбе» ж-лында (бүлек мөдире) эшли. Беренче хикәяләре 1920 еллар ахырында «Безнең юл», «Мәгариф», «Ярыш», «Башлангыч мәктәп» ж-лларында басыла башлый. Л.ның «Тамчылар» (1947), «Шомырт» (1949), «Китап турында китап» (1952) җыентыкларына кергән хикәяләре һәм «Әнисәнең альбомы» (1949), «Канатлы дуслар» (1951) җыентыкларына кергән шигырьләре мавыктыргыч, алар балаларда кызыксыну, дөньяны танып белергә омтылу хисләре тәрбияләләр. Л. — урта мәктәп өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм методик әсбаплар авторы. Әдип А.П.Чеховның «Акмаңгай» («Белолобый», 1932) хикәясен, Е.Ильинаның «Дүртенче биеклек» («Четвёртая высота», 1953) повестен, Б.Полевойның «Без — совет кешеләре» («Мы — советские люди», 1950) хикәяләр җыентыгын, М.Горькийның «Әкиятләр»ен (1949), Дж. Лондон хикәяләрен татарчага тәрҗемә итә.

*Әд.:* Г ы й н и я т у л л и н а А.К. Татар совет язучылары. К., 1958.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**ЛОТФУЛЛА́** бине Галиулла, к. *Өммәти-Алматави*.

**ЛОТФУЛЛА́ ибн ГАТАУЛЛА́ әл-ӘЛМӘТИ́** (якынча 1840, хәзерге Нурлат р-ны Иске Әлмәт а. — 1910 га кадәр, Казан), каллиграф-хаттат, гравёр, ташка уеп бизәк ясаучы. Казан типолитографиясендә эшли. 1860 елларда Казанда татар телендә басылган дөнья литографик картасы (Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана), 1897 һәм 1900 елларда Казан ун-тының типолитографиясендә Ш.Хөсәенов акчасына басылган «Догалык» шәмаиле авторы. Күп кенә китаплар, ш.и. «Мәүлид китабы» (1861), «Аллаһы Тәгаләнең матур исемнәре» (1865), «Диван Ризаи» һ.б.ның кучереп яза. 1890 нан кабер ташларына уеп язу-бизәк төшерү б-н шөгыльләнә (үрнәкләре Ульянов өлкәсенең Зиябаш авылы зиратында сакланган; атаклы эшмәкәрләр Акчуриннар гаилә әгъзаларының каберләренә куелган ташлар). Хаттат анда «Лотфулла бине Гатаулла әл-Әлмәти» яки «Гамәлә Лотфулла әл-Әлмәти» («Лотфулла әл-Әлмәти гамәле») дип язып куйган.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М., Т а и р о в Н. Ташлар кисеп язучы бер оста // Татарстан. 2000. № 12; Ш а м с у т о в Р. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ЛОТФУ́ЛЛИН** Илдус Әнвәр улы (23.10.1938, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1985), проф. (1988). ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1993). 1963 елда Казан мед. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1965 тән 2 нче госпиталь терапиясе кафедрасында, 1986 дан каф. мөдире. 1967–68 елларда Судан Республикасында. Хезмәтләре йөрәк зәгыйфьлеген һәм ишемия авыруын дәвалау һәм булдырмауга карый. ТР Терапевтлар җәмгыяте рәисе (1986–2004), 1998 дән ТР Терапевтлар, кардиологлар фәнни җәмгыяте идарәсе әгъзасы. Уйлап табуга 1 патенты бар.

Х е з м.: Состояние гипоталамо-гипофизарно-надпочечниковой системы при экспериментальном инфаркте миокарда. К., 1982; Общие принципы диагностики и лечения неотложных состояний // Казан. мед. журн. 1988. № 1 (автордаш); Гнойные осложнения инфаркта миокарда // Терапевт. архив. 1991. № 9; Депрессия сегмента ST у больных нестабильной стенокардией (клинико-прогностическое значение). К., 2003.

**ЛОТФУ́ЛЛИН** Илья Зәйнулла улы (10.2.1920, БАССРның Туймазы р-ны Иске Туймазы а.), инженер-метеоролог, техник фән д-ры (1967), проф. (1985). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1941). 1941–70 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында

катнаша. 1970–81 дә Казакъстан Гидрометеорология һәм әйләнә-тирәне саклау фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1981–87 дә Казакъстан ун-тында каф. мөдире. Хезмәтләре атм. процессларын матем. модельләштерүгә карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новые методы гидродинамики по предвычислению состояния среды. Л., 1966; Новые методы предвычисления метеорологических полей. Л., 1967.

*Әд.:* Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

**ЛОТФУ́ЛЛИН** Минсәгыйт Хәйрулла улы (2.1.1950, Чирмешән р-ны Бәркәтә а.), вет. микробиологы, паразитолог, вет. фән. д-ры (1992), проф. (1994). 1972 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли. 1984–93 тә Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1993 тән Казан вет. медицинасы академиясенең паразитология каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. хайваннарының паразитар һәм йогышлы авыруларына диагноз кую, дәвалау һәм булдырмау ысулларын камилләштерүгә һәм яңаларын эшләүгә карый.

**ЛОТФУЛЛИН** Наил Сәет улы (9.1.1952, Уфа — 19.11.1992, шунда ук), нәкышьче, график. Уфа сәнгать уч-щесенең сәнгать бүлеген тәмамлый (1975). Уфадагы «андерграунд» төркеме лидеры (1980–87), «Инзәр» иҗат төркеме әгъзасы (1989–93); «Сары бия» иҗат төркеменә нигез салучыларның берсе. «Чыңгызхан» рәссамнар берләшмәсен оештыручы һәм җитәкчесе (1990–92). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). «Татарт» бөтентатар төбәкара күргәзмәсен башлап җибәрүче һәм оештыручыларның берсе (С.-Петербург — Казан, 1991).

Л. — Россия авангардында әйдәп баручы рәссамнарның берсе, Д.Д.Бурлюкның Уфа чоры иҗаты мирасына таяна; татар халкы сәнгате һәм Көнбатыш Европа нәкыше традицияләрен берләштерә. Аның әсәрләрендәге сәнгать теле портрет жанрына өстенлек биргән реалистик стилистика б-н авазлаш («Евгений Малютин», 1987; «Әби», «Малай портреты», икесе дә — 1980; «Һади абый», 1982; «Толик Маткин», 1983; «Тәрәзә янындагы кыз», 1986; татар мәдәнияте эшлеклеләре портретлары — «Шәйдулла Маннанов», «Шамун Фидаи», икесе дә — 1980; «Галимҗан Ибраһимов», 1981; «Мәҗит Гафури», 1983), пейзажлар («Төнге мосафир», 1978; «Авыл яме» 1984; «Суык көн», 1985 ; «Көймәле пейзаж», 1986), өлешчә натюрморт сериясе («Натюрморт», «Алтын шарлар б-н натюрморт», икесе дә — 1980). Л. ш.у. абстракт сәнгать теленә мөрәҗәгать итеп, бай хисле образлар чагылдырган картиналар сериясе тудыра («Җайлашу», 1988; «Яшерен караш», «Хач», икесе дә — 1989; «Рух медитациясе», «Тынычлыкны тою», икесе дә — 1990; «Шәрекъ композициясе», 1991; «Вакыт фәзасы», 1992 һ.б.). «Чыңгызхан» рәссамнар берләшмәсе төркеме җитәкчесе буларак, Л. дөньяви сәнгать үсешенең гомуми агымында барган татар авангард нәкыше идеясе концепциясен игълан итә. Л.ның «Чыңгызхан» картинасындагы Ак Җайдак декларатив образы төркемнең символына әверелә (1992). Л. иҗатының фәлсәфи концепциясе автопортретта — кояш түгәрәге фонында кулына бер бөтен икмәк тоткан кеше фигурасында («Кояш улы», 1989), көнчыгыш һәм көнбатыш башлангычлары синтезында («Манара», 1991), манара архит-расы образында («Омтылыш», 1989). Хәзерге тормыш драмасы кайвакыт гротеск б-н бирелгән аллегорик дөнья күренешләре чолганышындагы, язмыш б-н сүзсез низагтагы кешеләр образларында чагылыш таба («Тукай», 1986; «Инфанта», 1988; «Суга бару», «Кәбир», икесе дә — 1989; «Дүрт сеңел», «Гөлнара», «Сөембикә», барысы да — 1992). Л.ның график мирасында карандаш, тушь, гуаш техникаларында башкарылган 500 гә якын рәсем бар.

Республика (1974 тән), төбәк («Социалистик Урал», Төмән, 1979; «Курган», 1991), бөтенроссия (РСФСРның автономияле республикалары, өлкәләре, милли округлары рәссамнары, Мәскәү, 1989) күргәзмәләрендә, «Инзәр» (Уфа, 1989; 1990; Мәскәү, 1991) «Сары бия» (Мәскәү, 1989, 1991; Чиләбе, 1990) һәм «Чыңгызхан» (С.-Петербург, 1990; Казан, 1992) иҗади берләшмәләренең төркемле күргәзмәләрендә, «Татарт» төбәкара күргәзмәдә (С.-Петербург — Казан, 1991) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1992, 1993 (графика әсәрләре), вафатыннан соң — 2002, 2003 (Уфа).

Хезмәтләре Третьяков галереясендә һәм РФ Мәдәният министрлыгында (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда (Уфа), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Чиләбе өлкә картиналар галереясендә, Уфа сервис ин-тының «Academia» сәнгать галереясендә, БРның вәкаләтле вәкиллегендә (Мәскәү), Россия һәм чит илләрдәге хосусый тупланмаларда (Австрия, ГФР, Франция, АКШ) саклана. 2002 дә Уфада аның әсәрләреннән даими экспозиция булдырыла. БРның Л. исем. хәзерге заман сәнгате музее ачыла.

Ә с ә р.: Лирика: Сб. стихов. Уфа, 1993.


*Әд.:* В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г. Наил Лотфулла әсәрләре // Казат утлары. 1992. № 1; Г а я н о в З. Созвездие Наиля // Рампа. 1994. № 2; Х а л и м А. Цветы к мемориалу Наиля Лотфуллина // Аргамак. 1994. № 1; Наиль Лотфуллин. Живопись в собрании Башкирского государственного музея им. М.В.Нестерова: Каталог. Уфа, 2001; Наиль Лотфуллин. Живопись: Альбом-каталог. Уфа, 2004; «ВХ»: Спец. вып. Уфа, 2005. № 1; Башкортстан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ЛО́ЦМАНОВА** Галина Павловна (4.4.1944, Казан), хакимият хезмәткәре. Саратов югары партия мәктәбен тәмамлый (1981). 1962–85 елларда Казан электрон-хисаплау з-дында. 1985–96 да ТРның социаль тәэминат министры, 1996–2000 дә министр урынбасары. 1975–90 да ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛУБЯ́Н** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 39 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Лубян елгасы буенда. 2010 елда 1697 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 49%, руслар — 44,8%) яши. Урман хуҗалыгы техникумы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Чиркәү. 19 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да почта-телеграф бүлекчәсе, такта яру з-ды, юртак һәм эш атлары үрчетү з-ды, пассажирлар һәм йөк ташу (агач ташу өчен специальләшкән) пристаньнар, вак-төякләр кибете эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. 1938 дән 2004 кә кадәр Л. шәһәр тибындагы посёлок стату-

Н.С.Л о т ф у л л и н. 1. «Суга бару». 1989; 2. «Сукмаклары аерылган бакча». 1990; 3. «Чыңгыз хан». 1992.








сында була. Халык саны: 1859 да — 36, 1897 дә — 185, 1908 дә — 148, 1920 дә — 370, 1926 да — 620 (Гурьевка авылын да кертеп), 1938 дә — 1707, 1979 да — 3676, 1989 да — 2,2 мең, 2002 дә — 1,9 мең кеше.

**ЛУБЯ́Н** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Вятка елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 37,5 *км*, ТР чикләрендә 30 *км* га якын. Бассейнының мәйданы 273 *км*². Елга башы — Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы — Кукмара р-нының Лубян авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 75%. Л.ның 9 кушылдыгы бар. Иң зур сулы — Сәрәмәк елгасы (15,8 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*². Туенуы катнаш, якынча өчтән ике өлешен кар сулары алып тора. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язын кар эрегән вакытта түбәнге агымнарында елга көчле ташый, һәм якын урнашкан урман җирләрен кайвакыт су баса. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 116 *мм*, ташу агымы катламы 74 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,4 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен




Лубян елгасы.

уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада 2 буа бар. Су ресурслары хуҗалык-көнкүреш максатларда файдаланыла. Л.да елга гольяны һәм хариус (ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән) бар. Елганың 6 *км* озынлыктагы түбәнге агымы б-н аңа тоташкан 200 *м* киңлектәге урман зонасы табигать истәлеге (1989).

**ЛУБЯ́Н УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, ТР экология һәм табигать ресурслары министрлыгы карамагында. Кукмара р-нының Лубян авылында урнашкан.

1921 елда Лубян посёлогына күчерелгән урман кондукторлары әзерләү мәктәбе (1888 дән Уфа губернасының Минзәлә өязе



Лубян урман хуҗалыгы. Куакчыл наратлык.

Биклән авылында) җирлегендә ачыла. Башта күбрәк урман эшкәртү сәнәгате пр-тиеләре, 1970 еллардан урман хуҗалыгы өчен кадрлар әзерли. Укыту урман һәм урман-парк хуҗалыгы, бакча-парк һәм ландшафт төзелеше, урман хуҗалыгы менеджменты белгечлекләре буенча алып барыла. 2011 елга көндезге бүлектә 300, читтән торып уку бүлегендә 110 студент укый. Укытучылар коллективында 31 кеше эшли. 8 меңнән артык белгеч әзерләнә. Техникумда шагыйрь З.Нури укыган.

**ЛУГОВО́Й** посёлогы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кама елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 22 кеше (руслар) яши. 1921 дә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1938 дә — 172, 1949 да — 122, 1958 дә — 82, 1970 тә — 38, 1979 да — 21, 1989 да — 12, 2002 дә — 17 кеше.

**ЛУГОВО́Й** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 15 *км* көньяктарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1949 да — 204, 1958 дә — 93, 1970 тә — 60, 1979 да — 44, 1989 да — 21, 2002 дә — 12 кеше.

**ЛУГОВО́Й КО́МПЛЕКСЫ** (археол.) Алабуга шәһәреннән 1 *км* көньяк-көнчыгышта һәм *Алабуга шәһәрлегеннән* 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. Л.к. ядкәрләрен тикшерү 1938–40, 1946–48 елларда А.В.Збруева, 1943 тә П.П.Ефименко, 1959 да В.Ф.Генинг тарафыннан алып барыла. Таш һәм бронза гасырларга нисбәтле 4 туктаулык һәм 3 каберлектән гыйбарәт. Л.к. ядкәрләре Кама елгасының уңъяк ярындагы болынлыкның өске өлешендә урнашкан. Л.к. терр-ясендә борынгы заманнардан бирле халыкның тыгыз урнашуы Кама һәм Тойма елгалары арасында күлләр һәм ермаклар б-н кискәләнгән шактый зур (5x10 *км*) үзәнлек булып, аның балык, киек кошлар, төрле хайваннар, үләнле болыннар һ.б. байлыклары булу б-н аңлатыла. Л.к. истәлекләре саналган табылдыклар *Кама культурасына, Чиркәскүл культурасына, Ананьино культурасына, Кушнаренко культурасына, Казан яны культурасына* карыйлар. Ананьино каберлегендә 70 кабер тикшерелгән.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Приказанская культура. М., 1980; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

*Е.П.Казаков.*

**ЛУЗГИ́Н** Валерий Васильевич (14.7.1940, Хабаровск крае Николаевск-Амур ш. — 13.11.2005, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1993), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлый (1963). 1963–65 елларда оборона сәнәгате пр-тиесе инженеры (Казан). 1968–94 тә Казан пед. ун-тының филос. кафедрасында. 1994 тән Казан техник ун-тының филос. каф. профессоры. Хезмәтләре филос. фәне теориясе, антропосоциогенез теориясе, табигыять белеменең филос. мәсьәләләренә, социаль философиягә карый.

Х е з м.: Современные проблемы теории основного вопроса философии. К., 1985; Становление самосознания в процессе антропогенеза. К., 1989; Основной вопрос философии как историко-философская проблема. К., 1990; Основной вопрос философии и природа философского знания. К., 1994;

**ЛУ́ЗИН** Валерий Павлович (6.8.1939, Чиләбе өлкәсе Кыштым ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), геол.-минерал. фән. канд. (1977). 1967 елда Тау ин-тын (Свердловск ш.) тәмамлый. 1958, 1961–62 дә геол. экспедицияләрдә (Чиләбе өлкәсе), 1967–78 дә «Ураласбест» (Асбест ш.) комбинатында эшли, 1971 дән баш геолог. 1979 дан ЦНИИгеолнерудта, 1990 нан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Л. ТРдагы табигый һәм техноген руда булмаган минерал чималга, ш.у. химия производствосы калдыкларына комплекслы технол. бәяләү үткәрә. Уйлап табуга 20 дән артык патенты бар. Дәүләт бүләге ТРдагы металл булмаган файдалы казылмаларны эффектив куллануның яңа минерал.-технол. юлларын эшләгәне һәм тормышка ашырганы өчен бирелә.

**ЛУКА́** (Канашевич Лаврентий) (? — 1.1.1758, Белгород ш.), дин эшлеклесе, миссионер. Киев руханилар академиясен тәмамлый (1724). 1725 елдан монахлыкта, Мәскәүдәге Киев епархиясендә стряпчий. 1728 дән Мәскәү руханилар академиясендә, 1736 дан Петербург кадетлар корпусында укыта. 1737 дә — Устюг һәм Тотем, 1738–55 тә — Казан һәм Зөя, 1755 тән Белгород һәм Обоян епискобы. Миссионерлык эше б-н шөгыльләнә, чынында *Яңа чукындырылганнар конторасы* б-н җитәкчелек итә, яңа чукындырылганнар мәктәпләре ача. Ислам диненә карата гадәттән тыш дошман мөнәсәбәттә булуы б-н билгеле. Император Анна Иоанновнаның миссионерлык эшчәнлеген көчәйтүгә юнәлтелгән 1740 ел 11 сентябрь Фәрманы һәм Сенатның 1552 елдан соң төзелгән барлык мәчетләрне су-





М.М.Лукин. В.В.Лукницкий.

теп юк итүне күз алдында тоткан «Казан губернасында мәчетләр төзүгә юл куймау һәм губернаторларга һәм воеводаларга Мөхәммәд канунына кайтырга теләгән яңа чукындырылганнарны тикшереп тору турында»гы 1742 ел 19 ноябрь фәрманы чыгуның инициаторы. 1740–43 тә Казан төбәгендә Л. җитәкчелегендә 556 мәчетнең 418 е җимертелә. 1749 елгы янгыннан соң, бистәдә берничә гаиләнең чукынуын сәбәп итеп, Л. Казанның *Татар бистәсе* халкын башка җиргә сөрергә омтыла (мөселманнар һәм яңа чукындырылганнар аерым яшәргә тиеш була). *Казан руханилар семинариясен* үстерүгә зур игътибар бирә (Л. эшләгән елларда Россиядә иң яхшылардан санала). Татар фольклорында мөселманнарны җәберләүче Лука Каратун яки Аксак Каратун исеме б-н билгеле. Граждannar хакимияте инициативасы б-н, Казан татарларының *Батырша хәрәкәтенә* ярдәмгә күтәрелүеннән куркып, Белгородка күчерелә.

*Әд.:* Щапов А.П. Лука Канашевич епископ Казанский // Православный собеседник. 1858. Ч. 2; Благовещенский А. История Казанской духовной семинарии. К., 1881; Харлампович К.В. Материалы для истории Казанской духовной семинарии в XVIII в. К., 1903; Ислаев Ф.Г. Православные миссионеры в Поволжье. К., 1999.

*Е.В.Липаков.*

**ЛУКИ́Н** Александр Владимирович (22.1.1903, Феодосия ш. — 18.9.1991, Казан), ихтиолог, биол. фән. д-ры (1946), проф. (1949). Казан ун-тын тәмамлый (1931). Бөтенсоюз күл һәм елга балык хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан бүлеген оештыручы һәм аның беренче директоры (1932–62). 1962–84 елларда Казан ун-тының умырткалылар зоологиясе каф. профессоры. Хезмәтләре Урта Идел буе сулыкларында һәм Куйбышев сусаклагычында балык ресурсларын тикшерүгә һәм рациональ файдалануга карый. Л. Урта Идел мәрсин балыклары экологиясенең төп билгеләрен ачыклый, ТАССРда колхоз балыкчылыгы нигезләрен эшли, балыкларның үзгәртеп корылган сулык-сусаклагыч шартларына җайлашу закончалыкларын өйрәнә һәм төп кәсәбәчелек балыклары запасларының формалашу үзенчәлекләрен күрсәтә. Куйбышев сусаклагычында продуктив балыкны һәм азык ресурсларын арттыру буенча чаралар комплексын тәкъдим итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Основные черты экологии осетровых в Средней Волге: В 2 ч. К., 1947–49; Разведение карпа в колхозных прудах. К., 1950; Рыбное хозяйство Татарии и перспективы его развития. К., 1952; Куйбышевское водохранилище // Изв. НИИ озёр и речного рыбного хоз-ва. 1961. Т. 50; Рыбы Среднего Поволжья. К., 1971 (автордаш); Стерлядь Куйбышевского водохранилища. К., 1981 (автордаш).

*Әд.:* Кузнецов В.А. Александр Владимирович Лукин. К., 2002.

*В.А.Кузнецов.*

**ЛУКИ́Н** Анатолий Васильевич (19.7.1937, Витебск ш.) физик, техник фән. д-ры (2002), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997). Ленинград ун-тын тәмамлый (1961). «Гамәли оптика институты» ФҖБ Федераль дәүләт унитар пр-тиесендә эшли, 1978 елдан — сектор, 1983 тән — лаб., 1986 дан — бүлек, 1987 дән бүлекчә җитәкчесе, 1991 дән дифракцион, интеграль һәм асферик оптика фәнни-техник комплексы башлыгы. Хезмәтләре физик һәм гамәли оптикага, оптик голографиягә карый. Л. төрле типтагы газ бушанулы лазерлар плазмасында электроннарның тизлекләр буенча бүленүе фракцияләрен һәм аларны оптик приборлар төзелешендә куллануны тикшерә. Асфериканың барлык төрләрен контрольдә тоту мәсьәләләрен хәл итә. Голография алымнарын тармак пр-тиеләрендә гамәлгә кертә. ТР Дәүләт бүләге (1998) лауреаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Голографические методы контроля асферических поверхностей // Оптикомеханическая пром-сть. 1979. № 4 (автордаш); Изготовление и контроль асферической оптики. М., 1980 (автордаш); Синтезированные голограммы и их применение в оптическом приборостроении // Оптическая запись и обработка информации. Куйбышев, 1986; Синтезированная голограммная оптика // Оптический журн. 2002. Т. 69, № 12 (автордаш).

**ЛУКИ́Н** Анатолий Венедиктович (19.10.1906, Курск губ. Щигры ш. — 21.7.1968, Казан), геолог-нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). 1941 елда СССР Нефть халык комис-тының җитәкче хезмәткәрләр курсын тәмамлый. 1923 тән Курск өлкәсе һәм Төньяк Осетия АССР геол. оешмаларында эшли. Кама Тамагы (1941 дән), Шөгер (1942 дән) һәм Ромашкино (1946 дан) нефть разведкасы конторалары башлыгы, 1 нче номерлы разведка-бораулау конторасы директоры (1949 дан), «Татнефтегазразведка» тресты башлыгы урынбасары (1959–64). Татарстанда Шөгер, Яңа Елховой һ.б. нефть чыганакларын ачучыларның берсе. Дәүләт бүләге Ромашкино нефть чыганагын ачканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ЛУКИ́Н** Макар Михайлович (1905, Дон өлкәсе Новочеркасск ш. — 26.5.1961, Мәскәү), хуҗалык эшлеклесе, авиация моторлары төзүне оештыручы, инженерлык-авиация хезмәте генерал-майоры (1944). Соц. Хезмәт Герое (1945). 1935 тә Новочеркасск индустриаль ин-тын тәмамлаганнан соң, 16 нчы Союз моторлар з-дына (Воронеж ш.) эшкә җибәрелә; мастер, группа җитәкчесе, баш механик, директор (1937 дән) булып эшли. 1939–40 та СССР Авиация сәнәгате халык комис-тында. 1942–46 да 16 нчы з-д (Казан) директоры; бер үк вакытта (1946 дан) СССР авиация министры урынбасары. Соңрак СССР Дәүләт планы аппаратында, 1958 дән СССР МС-ның авиация техникасы буенча Дәүләт ком-ты рәисе урынбасары. Авиация сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә. Л. җитәкчелек иткән заводларда М-11, М-58, М-85, М-87, М-88, М-89 пешкәкле авиамоторларны серияләп җитештерү оештырыла; алдынгы технол. процесслар кертелә; авиация техникасының яңа үрнәкләре булдырыла һәм үзләштерелә. 1938–47 дә РСФСР, 1946–50 дә СССР ЮСлары депутаты. Биш Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы Л. исемен йөртә.

*Әд.:* Лобачёв А.А. Трудными дорогами. М., 1960; Рокоссовский К.К. Солдатский долг. М., 1980; По следам героических лет. Смоленск, 1983; Ларичева З. Лукин Макар Михайлович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2. Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЛУКНИ́ЦКИЙ** Всеволод Всеволодович (25.5.1845, Петербург губ. — 14.8.1917, Казан), хуҗалык эшлеклесе, генерал-лейтенант (1914). Дворяннар нәселеннән. Михаил артиллерия уч-щесен һәм Михаил артиллерия академиясен (С.-Петербург) тәмамлый. Охтино (Петербург губ.) һәм Шостка (хәзерге Украина Респ-касының Шостка ш.) дары з-дларында хезмәт итә. 1874 елдан *Казан дары заводында*: хуҗалык, ясалма продукция бүлекләре мөдире ярдәмчесе, ясалма продукция бүлеге мөдире, 1885–1917 елларда башлыгы. Л. проектлары буенча һәм аның җитәкчелегендә пр-тиедә киң колачлы 2 реконструкция (1885–88, 1893–94 тә) уздырыла, илдә беренче тапкыр пироксилиннан (нитроцеллюлозадан) төтенсез дары җитештерү технологиясе эшләнә һәм үзләштерелә. Эшчеләрнең хезмәт һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга зур игътибар бирә. Л. инициативасы б-н 1906 да завод каршында ирләр өчен техник класслары булган башлангыч мәктәп ачыла. 1916 да, үзәктән бирелергә тиешле ассигнованиеләрне көтеп тормыйча, эшчеләрнең хезмәт хакын арттыра. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң завод эшчеләр ком-ты б-н даими элемтә урнаштыра. 1917 нең 14 августында, заводта башланып, шәһәрнең зур өлешенә юкка чыгу куркынычы янаган куәтле янгын Л. тырышлыгы б-н сүндерелә. Янгын вакытында алган яраларыннан вафат була. 2, 3, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир; 1, 2, 3 дәрәҗә Изге Анна; 1, 2 дәрәҗә Изге Станислав, Ак Бөркет орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның Киров р-ныңдагы урамга Л. исеме бирелә, завод терр-ясендә аңа һәйкәл куела.

*Әд.:* Казаков В.С. 210 лет на службе Родине: Казанский пороховой завод. К., 1998.

**ЛУКОВСКО́Е ГОРОДИ́ЩЕ**, к. *Салатчы шәһәрлеге*.

**ЛУКЬЯ́НОВ** Владислав Георгиевич (25.8.1937, Чиләбе ш.), хор дирижёры, педагог, ТАССР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1979, 2008). 1975–87 елларда ТАССР Хор җәмгыяте идарәсе рәисе. 1960 та Казан консерваториясен хор дирижёрлыгы буенча (С.Казачков классы) тәмамлый. 1960–61 дә Казан пед. ин-тында, 1961 дән

Казан консерваториясендә (1990 нан хор дирижёрлыгы каф. мөдире, 1992 дән проф.), 1997 дән студентлар хорының, бер үк вакытта, 1960–2002 дә А.Алиш исем. Пионерлар сарае (хәзер А.Алиш исем. Балалар иҗаты үзәге) балалар хорының сәнгать җитәкчесе. Хор иҗатын пропагандалауга зур өлеш кертә. Хор коллективлары б-н Россиядә һәм чит илләрдә концертлар бирә. Хор өчен әсәрләр тупланмаларын, ш.и. «Яшь җәлилчеләр җырлары» («Песни юных джалильцев», М., 1976) җыентыгын төзүче һәм мөхәррире. Хорда җырлау осталыгы мәсьәләләренә караган мәкаләләр авторы. Шәкертләре арасында — хор дирижёрлары һәм педагоглар Р.Биктимерова, А.Бикчәнтәева, З.Гайсина, В.Губанов, М.Таминдарова бар.

Х е з м.: Фольклор на уроках музыки // Советская музыка. 1978. № 4; Хор, семья, школа // Клуб. 1982. № 24; Детское хоровое пение в Татарии // Музыка в школе. 1985. № 4; Как продолжить песнь? // Клуб. 1985. № 17.

**ЛУКЬЯ́НОВ** Иван Константинович (20.1.1889, Сембер губ., Буа өязе Ишеевка а. — 6.3.1952, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1932), проф. (1935), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1945). 1918 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1917–18 дә Көньяк-Көнбатыш фронтта, 1918–21 дә Көнчыгыш, Кавказ һәм Кавказ арты фронтлары госпитальләрендә хәрби табиб. 1921–26 да Чуаш АССР сәламәтлек саклау халык комиссары. 1926 дан Казан ГИДУВында: көнкүреш гигиенасы кафедрасында, 1935–48 дә көнкүреш гигиенасы һәм сәламәтлек саклауны оештыру, 1939–46 да эпидемиология каф. мөдире. Хезмәтләре трахоманы булдырмауга, су чыганакларының, туфрак, тау суларының сан. күрсәткечләренә, сулыкларның үзлегеннән чистаруына карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Трахома в Волжско-Камском крае. Чебоксары, 1925; О составе воды некоторых рек Татарской и Чувашской республик с санитарной точки зрения // Вопр. оздоровления Татарии. 1932. Вып. 2; О современной методике количественного определения углеводов // Сб. трудов Казан. ГИДУВа. 1935. Т. 4.

*Әд.:* Кафедра общей гигиены // Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина (1920–1990). К., 1990; Краткая чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2001.

**ЛУКЬЯ́НОВА** Резедә Габдрәшит кызы (19.7.1965, Әлмәт ш.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), геол.-минерал. фән. канд. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1987), ТатНИПИнефтьтә эшли, 2010 елдан Татарстан геологик-разведкалау идарәсендә. Дәүләт бүләге «Нефть чыганакларын эзләүдә алымнар комплексы эшләү һәм Татарстан Респ-касының көнбатыш өлешендә нефть перспективаларын бәяләү» хезмәте өчен бирелә.

**ЛУ́НДСТРЕМ** Олег Леонидович (2.4.1916, Чита ш. — 14.10.2005, Мәскәү), күренекле джаз музыканты, композитор, дирижёр, РСФСРның халык артисты (1984). 1921–47 елларда Харбин һәм Шанхай (Кытай) шәһәрләрендә яши. 1934 тә Харбинда 9 музыканттан торган үз оркестрын төзи (И.Лундстрем, В.Серебряков, А.Котяков, А.Гравис, З.Хазанкин, Г.Осколков һ.б.). Оркестр 1936 да Шанхайга күченә, анда ул зур бию залларында — «Мажестик» һәм «Парамаунт» болл-руммнарында уйный. Прессада Л.ны «Ерак Көнчыгышның джаз короле» дип атыйлар. 1944 тә Шанхай югары техника үзәген «инженер-архитектор» белгечлеге буенча, бер үк вакытта, скрипка классы буенча музыка техникумын тәмамлый. 1947 дә оркестры б-н СССРга кайта, яшәү урыны итеп Казан шәһәрен сайлый. Аның оркестрына Казан консерваториясе ректоры Н.Г.Җиһанов һәм Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе А.С.Ключарёв зур ярдәм күрсәтәләр.



О.Л.Лундстрем.

Л. 1953 тә Казан консерваториясен композиция (А.Леман классы) һәм симф. дирижёрлыгы буенча (И.Шерман классы) тәмамлый. Л. Казанда оркестр чыгышлары программасына совет композиторлары җырларын һәм татар халык музыкасы әсәрләрен кертә. А.С.Ключарёв («Самба») һәм А.Монасыйпов («Бегин») б-н актив хезмәттәшлек алып бара. 1956 да Л. Мәскәүгә күченә, анда үз коллективы җирлегендә төзелгән эстрада концерт оркестрын (Росконцерт системасында) җитәкли, оркестр СССРда иң күренекле джаз коллективына әверелә. Л. иҗаты А.Монасыйпов, Р.Белялов һәм респ-каның башка композиторларының музыка стиле формалашуына сизелерлек йогынты ясый.

Л. Татарстан б-н тыгыз иҗат бәйләнешләрен саклый. Ел саен аның оркестры Казанда һ.б. шәһәрләрдә чыгышлар ясый, «Джаз чаты» («Джазовый перекрёсток») һәм «Джаз-пикник» фестивальләрендә катнаша. ТР джаз сәнгате үсешендә Л. күренекле роль уйный. Аның Казандагы эшчәнлеге музыка тормышының куәтле стимуляторы була; Л. йогынтысында көчле джаз коллективлары барлыкка килә (В.Деринг һәм А.Василевский җитәкчелегендә). РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1998).

Аудиоязмалар: «Без яңадан бергә» («Мы снова вместе», 1967), «Кояшлы үзән серенадасы» («Серенада Солнечной долины», 1977), «Дюк Эллингтон истәлегенә» («Памяти Дюка Эллингтона», 1977), «Свинг стилендә» («В стиле свинг», 1986).

*Әд.:* Б а т а ш е в А. Советский джаз. М., 1972; Советский джаз: Проблемы. События. Мастера: Сб. статей. М., 1987; Ф е й е р т а г В. Джаз. XX век. СПб., 2001.

*А.Л.Маклыгин.*

**ЛУНЁВ** Александр Николаевич (30.11.1950, Пенза өлкәсенең Түбән Ломов ш.), авиация машиналары төзелеше өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (2006). 1974 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, машиналар төзү технологияләре каф. мөдире. Хезмәтләре авиация техникасы детальләренең катлаулы өслекләрен механик эшкәртүне автоматлаштыруга карый. Аэродинамик профильләрне шомарту юлы б-н детальләргә адаптив форма бирү технологияләре авторларының берсе. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Гибкие производственные системы в авиадвигателестроении. К., 1989 (автордаш); Адаптивное управление шлифованием пера крупногабаритных лопаток ГТД // Изв. вузов. Авиац. техника. 1998. № 4 (автордаш); Адаптивное формообразование лопаток шлифованием. К., 2002 (автордаш).

**ЛУНЁВ** Александр Тимофеевич (1.8.1949, Бөгелмә р-ны Ефановка а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), техник фән. канд. (2005). 1972 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Турбокомпрессорлар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, автомат проектлаштыру системалары (1986–93), үзәктән кугыч компрессорларны газодинамик исәпләү һәм сынау (1993) бүлекләре башлыгы. 100 дән артык төр компрессор эшләүдә катнаша (алар ТР һәм РФнең газ чыгару, нефть эшкәртү, энергетика һәм металлургия пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Дәүләт бүләге газ кудыру агрегатының көч җайланмаларында югары эффектлы алмаш агым өлешләрен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 1 патенты бар.

**ЛУНИ́Н РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* төньягында урнашкан. Мәйданы — 1704 *км*². 1928 елда оештырыла. Үзәге — Лунино посёлогы (Пенза шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 23 мең кеше, ш.и. 700 гә якын татар (2002). Татарлар күбесенчә Лунино посёлогында (250 кеше) һәм Синорово авылында (288) яшиләр. Татарлар анда 17 йөздә килеп урнаша, йомышлы татарлар бу җирләргә ныгытма сызыклары төзү һәм хезмәт итү өчен җибәрелә. Синорово авылы мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла; мәчет эшли.

**ЛУНЬЯ́К** Андрей Иванович (17.12.1881, С.-Петербург — 15.10.1957, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1946). Хәрби-мед. академиясен тәмамлаганнан соң (С.-Петербург, 1904), Казанда хәрби табиб булып эшли, 1906 елда запаска чыгарыла. 1907–12 дә Казан ун-тында. 1912–14 тә Ново-Александрийск а.-х. һәм урманчылык ин-тында (Польша), 1914 тән Хәрби мед. академиясендә (С.-Петербург), 1916 дан Пермь ун-тында физика-матем. һәм мед. ф-ты деканы, директор урынбасары, проф. (1917). 1924 тән Казан ун-тының техник химия каф. мөдире, 1926–28 дә ректор, 1929–36 да А.М.Бутлеров исем. Химия фәнни-тикшеренү ин-тында техник химия бүлеге мөдире. Бер үк вакытта, 1924–30 да Казан а.-х. һәм урманчылык ин-тында (1925–26 да ректор), 1930–35 тә Казан химия-технол. ин-тында органик химия каф. мөдире, 1936–52 дә Казан мед. ин-тында шул ук исемдәге каф. һәм махсус



А.Б.Луппов.



Р.А.Лурия.

лаб. мөдире. Хезмәтләре органик химиягә карый. Л. майлар рәтендәге альдегидларны фенол б-н конденсацияләү продуктларын (Рус физика-химия җәмгыятенең Н.Н.Зинин исем. бүләге, 1904), бер нигезле майлы к-та ангидридлары б-н галоидцинкорганик һәм галоидмагнийорганик кушылмалар реакциясен өйрәнә. Бөек Ватан сугышы елларында Казандагы госпитальләр һәм дәвалау учреждениеләре кытлык кичергән күп кенә медикаментларны лаб-ядә җитештерүне оештыра. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О продуктах конденсации альдегидов жирного ряда с фенолами // Журн. Рус. физ. хим. об-ва. Ч. хим. 1904. Т. 36/1; К постройке цементно-тукового комбината в Татарской республике. К., 1930 (автордаш); Перспектива химической промышленности в Татарстане. К., 1932 (автордаш).

*Әд.:* Абрамов В.С., Вильчинская А.Р., Фриновская В.А. Памяти Андрея Ивановича Луньяка // Журн. орган. химии. 1958. Т. 28, вып. 3/4; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЛУ́ППОВ** Анатолий Борисович (2.6.1929, Киров өлкәсенең Тужин р-ны Пачи а.), композитор, пианист, педагог, Мари АССР, РСФСР, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968, 1974, 1993), ТРның халык артисты (2009). Казан консерваториясен композиция (А.Леман классы) һәм фортепиано буенча (В.Апресов классы) тәмамлагач (1956), шунда ук эшли: композиция каф. мөдире (1969–91), проф. (1977). СССР Композиторлар берлеге (1959) һәм Россия театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1964). Төрле жанрдагы әсәрләр авторы.

Л. әсәрләрендә образлар диапазоны бик киң. Ул үзенә күтәренке, поэтик төсмерле лириканы һәм трагик пафосны, ихтыярлылыкны һәм шаянлыкны, драматик хәлне һәм фәлсәфи фикерләүне, кискен психол. кичерешләрне сыйдыра. Л.ның иҗат чыганаклары булып халык хикәятләре, легендалар, классик әдәбият, хәзерге заман һәм тарихи вакыйгалар тора. Композитор ш.у. татар поэзиясенә һәм прозасына (Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил, Г.Кутуй, Р.Кутуй, Ш.Галиев һ.б.) мөрәҗәгать итә. Л. — рус, мари һәм татар музыка сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Рус интонация материаллары нигезендә Фортепиано өчен квинтет, квартетлар, оркестр б-н тынлы уен кораллары өчен 2 камера операсы һәм күпсанлы концертлар кебек әсәрләр иҗат итә. Л. беренче мари балеты «Урман әкияте» («Лесная легенда») һәм «Мари каприччиосы» («Марийское каприччио»), мари халык көйләре нигезендә иҗат ителгән башка әсәрләр авторы. Композитор иҗатының аеруча зур өлеше татар халык музыкасы традицияләре б-н бәйле. Үзенең әсәрләрендә ул саф халык көйләрен — «Кара урман» (7 нче симфония), «Сабан туе», «Бишле бию», «Сикереп төштем», «Әллүки» («Татар каприччиосы») һ.б.ны файдалана. Композитор материалны эффектлы эшкәртеп, халык көйләренең яңача сәнгатьле мөмкинлеген ача. Әмма Л. өчен, бигрәк тә халык көйләренең интонация үзенчәлекләрен, хәзерге композиция чараларын, катлаулы ладотонлы, метроритмлы, фактуралы алымнар кулланып, берьюлы күрсәтә белү хас (тынлы уен кораллары өчен концертлар, симфонияләр, вокаль-симф. поэмалар). Ул проф. татар музыкасының жанр һәм стиль чикләрен шактый киңәйтә. Л. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча шул исемдәге беренче татар монооперасын һәм татар музыкасында беренче тапкыр Оркестр б-н тромбон өчен концерт иҗат итә.

Композитор татар балалар музыкасын үстерүгә зур өлеш кертә (1 нче һәм 2 нче «Балалар альбомы», «Фортепиано өчен 24 татар халык җыры эшкәртмәсе» циклы, Ш.Галиев шигыренә «Кояш нинди төстә?», М.Җәлил шигыренә «Батыр егет турында җыр» кантаталары һ.б.). Л. үзенең иҗаты б-н хәзерге тынлы (агач һәм җиз) һәм бәрмә уен кораллары репертуарын шактый баета. Аның пьесалары, сонаталары, ансамбльләре, концертлары пед. һәм концерт репертуарларына керә. Илдә 20 йөзнең 2 нче яртысы музыкасы өчен актуаль булган эстрада һәм акад. жанрлар чаралары һәм алымнарының үзара тәэсире тенденциясе Л.ны заманның күренекле композиторлары Р.Щедрин, А.Эшпай, С.Слонимскийлар б-н якынайта.

Композиторның әсәрләре Россиянең танылган башкаручылары: Россиянең халык артистлары А.Корнеев (флейта), З.Шахморзаева (скрипка), дирижёрлар Н.Рахлин, В.Дударова, М.Шостакович, Ф.Мансуров һ.б. программаларына кертелә. Л. әсәрләре Россиядә һәм чит илләрдә (Германия, Чехия, Польша, Югославия, Венгрия) фестивальләрдә һәм конкурсларда яңгырый. Күпләгән әсәрләре респ-каның һәм чит илләрнең үзәк музыка нәшриятларында басыла.

Л. пианист буларак үзенең әсәрләрен интерпретацияли (солист һәм ансамблист). Ул композиция буенча абруйлы педагог. Казан консерваториясендә аның классын 50 дән артык студент тәмамлый. Л.ның респ-када һәм Идел буе шәһәрләрендәге шәкертләре арасында танылган композиторлардан: Р.Кәлимуллин, Ш.Тимербулатов, М.Шәмсетдинова, С.Беликов (Татарстан Респ-касы), С.Маков, Г.Яшмолкин, Э.Архипова (Мари Респ-касы), А.Корепанов, А.Шабалин (Удмурт Респ-касы), М.Фомин, Г.Сураев-Королёв (Мордва Респ-касы), Ю.Григорьев, Н.Казаков (Чуаш Респ-касы) һ.б. бар.

Аның татар музыкасы теориясе проблемаларына һәм композиторлар белеме мәсьәләләренә багышланган байтак мәкаләләре Россиянең вакытлы махсус музыка басмаларында басыла. РФнең мактаулы югары проф. белем бирү педагогы, Мари АССРның Дәүләт (1973) һәм ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре лауреаты (1999).

Төп әсәрләре: опералар — Г.Кутуй повесте буенча «Тапшырылмаган хатлар» (1979) монооперасы, М.Цветаева шигыренә «Мәхәббәт, мәхәббәт...» («Любовь, любовь...», 1988), А.Блок шигыренә «Ят хатын-кыз һәм Шагыйрь» («Незнакомка и Поэт», 1992) камера опералары; балетлар — «Урман риваяте» («Лесная легенда», 1972), «Бүленгән бәйрәм», («Прерванный праздник», 1976), Муса Җәлил поэмасына «Сандугач һәм чишмә» (1974), М.Җәлил поэмасына «Джим», (1975), вокаль-симф. әсәрләр — В.Маяковский шигыренә «Казан» (1977), Е.Евтушенко шигыренә «Сходка» (1985) кантаталары; Р.Кутуй шигыренә «Соңгы төн», («Последняя ночь», 1944), «Хатирәләр» («Воспоминания», 1987), «Хәрбиләр йокысы» («Сны военные», 1969) поэмалары; симф. әсәрләре — 9 симфония (1963, 1987, 1989, 1990, 1991, 1993, 1995, 1997, 1999), төрле уен кораллары составы һәм оркестр б-н соло уйнаучы уен кораллары өчен 12 концерт, увертюралар («КамАЗның яшьлеге», 1973; «Чибәр егетләр», 1975; «Җиңү шатлыгы», 1984 һ.б.); «Татар каприччиосы» (1970), «Мари каприччиосы» (1972), «Никола триптихы» (2002), «Минем Татарстаным» (2004) симф. күренешләре, 6 вокаль цикл һ.б.

Хезм.: Воспитать творческую личность // Муз. академия. 1993. № 2; Пентатоника и современная композиция // Муз. академия. 1994. № 3.

*Әд.:* Артищева Р. Анатолий Луппов и марийская музыка. Йошкар-Ола, 1968; Егорова О. Рождение легенды // Советская музыка. 1973. № 10; Композиторы Российской Федерации: Сб. статей. М., 1982. Вып. 2; шул ук. Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

*Т.Г.Алмазова.*

**ЛУ́РИЯ** Александр Романович (3.7.1902, Казан — 14.8.1977, Мәскәү), психолог, РСФСР, СССР ПФАнең хакыйкый әгъзасы (1947, 1968). Р.А.*Луриянең* улы. 1918–23 елларда Казан ун-тының иҗтимагый фәннәр һәм мед. ф-тларында, бер үк вакытта Шәрекъ пед. ин-тында укый. 1921–23 тә Казан психиатрия клиникасында һәм Казан хезмәтне фәнни оештыру ин-тында эшли. 1924–41 дә Н.К.Крупская исем. Мәскәү коммунистик тәрбия академиясендә һәм Мәскәү дефектология ин-тында укыта. Бер үк вакытта, Мәскәү мед. ин-тын 1936 да тәмамлаганнан соң, 1936–41 дә СССР МФАсенең Нейрохирургия һәм неврология ин-тында эшли. Бөек Ватан сугышы елларында Чиләбе өлкәсе Кисегач шәһәрендә тернәкләндерү госпитален җитәкли. 1945 тән Мәскәү ун-тының нейропсихология һәм психофизиология кафедрасында, 1966 дан каф. мөдире. Хезмәтләре нейропсихология нигезләрен, баш миенең аерым урыннары зарарланганда югары психик эшчәнлек бозылуын тикшерүгә карый. Л. гомуми, балалар, мед. психологиясе һәм тарихи психология буенча хезмәтләр авторы. 1969 дан Халыкара фәнни психология советы вице-президенты. АКШ Милли ФА әгъзасы, чит илләр психология җәмгыятьләренең шәрәфле әгъзасы, Лейстер, Реймеген, Люб-

лин, Брюссель, Тампере, Ужалы шәһәрләре ун-тларының мактаулы фән д-ры. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Восстановление функций мозга после военной травмы. М., 1948; Высшие корковые функции человека и их нарушение при локальных повреждениях мозга. М., 1962; Мозг человека и психические процессы: В 2 т. М., 1963–70.

*Әд.:* Л у р и я Е.А. Мой отец А.Р.Лурия. М., 1994.

**ЛУ́РИЯ** Роман Альбертович (16.5.1874, Гродно губ. Брест-Литовск ш. — 22.10.1944, Мәскәү), терапевт, медицина д-ры (1902). РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1935). 1897 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Сембер губернасының Буа земствосында табиб, 1898 дән губерна земство хастаханәсендә эшли, бер үк вакытта Казан фельдшерлар мәктәбендә укыта. 1907 дән Германия, Швейцариядә командировкада. 1919 дан Гадәттән тыш тиф б-н көрәшү комиссиясе рәисе урынбасары. 1920 дә ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты коллегиясе әгъзасы. 1920–30 елларда Казан ГИДУВы директоры, бер үк вакытта 1 нче терапия каф. мөдире, проф. (1922). 1925 тә Германия, Голландиядә командировкада. 1929 да Утрехт, Амстердам шәһәрләрендә лекцияләр укый. 1930 дан 1 нче Мәскәү мед. ин-тының терапия кафедрасында. 1925–44 тә Мәскәү Үзәк табибләр белемен күтәрү ин-тының терапия каф. мөдире. Хезмәтләре ашказаны-эчәк һәм башка эчке авырулар мәсьәләләренә карый. Л. маляриянең әүвәлге һәм дәвамлы формалары килеп чыгышы механизмын ачыклый, беренче булып малярия авыруларын иммунобиол. принцип буенча классификацияли. 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 2 нче дәрәҗә Изге Станислав, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Отёчная болезнь: Клинические лекции. К., 1922; Болезни пищевода и желудка. М.–Л., 1935; Внутренняя картина болезней и иатрогенные заболевания. М., 1977.

*Әд.:* Р а х л и н Л.И. Профессор Роман Альбертович Лурия (к 100-летию со дня рождения) // Казан. мед. журн. 1974. № 2.

**ЛУЧ** посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 4 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 1343 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 60%, татарлар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — җәнлек үрчетү, кырчылык. Урта һәм музыка мәктәпләре, китапханә. 1931 дә нигез салына. Халык саны: 1938 дә — 42, 1949 да — 303, 1970 тә — 1490, 1979 да — 1454, 1989 да — 1441, 2002 дә — 1453 кеше.

**ЛУЧИ́НСКИЙ** Михаил Францевич (30.11.1900, Мәскәү — 4.1.1972, Казан), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1946), проф (1963). Казан ун-тын тәмамлый (1931). 1924 тән ТАССР Финанс халык комис-тында бүлек мөдире. 1927 дән Көньяк Казакъстанда Бюджет һәм финанс буенча округ планы рәисе. 1931 дән Казан ун-тында, бер үк вакытта ТАССР Госпланының секция мөдире. 1932–42 дә Казан финанс-икътисад ин-тының кредит, 1945–66 да акча әйләнеше һәм кредит кафедралары мөдире, исәп-ләү-икътисад ф-ты деканы. 1942–45 тә СССР Госпланы Татарстан конторасының Чистай бүлекчәсе управляющие вазифаларын башкара. Хезмәтләре 9–12 йөзләрдә Рус дәүләтендә акча мөнәсәбәтләре тарихына, акча, банклар һәм акча әйләнеше теориясенә карый. Банк һәм акча реформасының зарурлыгы турында Л. тарафыннан нигезләнгән идея 1947 елда тормышка ашырыла. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: По вексельному обращению // Труд и хозяйство. 1926. № 1; Три формы стоимости (А, В и С) на европейской территории СССР. К., 1941; Банковская и денежная реформа в СССР. К., 1946; Деньги на Руси IX–XII вв. К., 1958.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**«ЛУЧИ́СТОЕ»**, тары сорты. 1999 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Л.Г.Сәгъдиева, Н.Ш.Хисаметдинов, Х.З.Хәсәнов тарафыннан чыгарыла. Терлек азыгы өчен үстерелә торган сорт, соң өлгерешле, сөрлегүгә бирешми, яхшы тармаклана. Сабагы нәзек, 130–145 *см* га кадәр биеклектә үсә. Яфраклары эре, киң. Себеркәче җәенке, азрак салынкы. Бөртеге ачык сары төстә, ярым түгәрәк формада. 1000 бөртекнең авырлыгы 7 *г*. 1 *кг* яшел массасында 42 *мг* каротин, 54 *г* га кадәр шикәр, 37 *г* га кадәр беренчел протеин бар. Бу сорт 2003 елда Урта Идел буе төбәгендә чәчәргә рөхсәт ителгән.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**ЛУ́ШНИКОВ** Владимир Петрович (29.5.1914, Казан — 31.3.1985, шунда ук), инженер-химик, сәнәгый җитештерүне оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1971). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1937). 1937–39 елларда В.И.Ленин исем. химия з-дында остаханә башлыгы. 1939–53 тә В.В.Куйбышев исем. химия з-дында инженер-технолог, цех, производство башлыгы, баш инженер. 1953–58 дә 9 нчы фотожелатин з-ды директоры. 1958–82 дә Казан «Органик синтез» ҖБ директоры. Завод төзүне оештыручы. Л. җитәкчелегендә фенол һәм ацетон, газ кушылмаларын аеру, этилен окисе, полиэтилен, перекись инициаторлары, полиэтилен торбалар һ.б. җитештерү буенча проектта каралган егәрлекләр файдалануга кертелә; һәм социаль-мәдәни файдалану объектлары (Химиклар мәдәният йорты, йөзү бассейны, санаторий-профилакторий, 8 балалар комб-ты, 2 ял базасы, поликлиника һ.б., 150 мең $м^2$ торак) төзелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. 1967–82 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан урамнарының берсенә һәм Казан нефть химиясе көллиятенә Л. исеме бирелә.



В.П.Лушников.

*Әд.:* Т у т а е в М.З., А й т у г а н о в И.М. Объединение «Органический синтез». К., 1987; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ЛЫ́ВИН** Сергей Осипович (29.9.1923, хәзерге Питрәч р-ны Черемышево а. — 18.3.2000, Казан), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1960), ТАССРның халык рәссамы (1973), Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1947). Рәссамнар берлеге әгъзасы



С.О.Л ы в и н. «Май киче». 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

(1952). 1960–70 елларда Татарстанда әйдәп баручы пейзаж осталарының берсе. Л. сәнгатьтә үз темасын иртә таба, сугыштан соңгы тәүге әсәрләре — зур булмаган, табигый лирик пейзажлар: «Кечке Идел» (1947), «Идел. Дебаркадер» (1948), «Басу юлы» (1950). Соңрак ул тематик пейзаж серияләрен иҗат итүгә күчә. Аларның беренчесе — «Казанның архитектура истәлекләре», башлыча, 1956–57 еллар этюдларыннан барлыкка килә. Икенче





С.О.Л ы в и н. 1. «Татарстан киңлекләрендә». 1960; 2. «Язгы җыр», 1973. Икесе дә — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

зур сериясе 1960 елларда республиканың нефть р-ннарына йөргәндә языла: «Баулы–Бөгелмә юллары», «Баулыда» (икесе дә — 1961), «Нефть төбәге», «Бораулау җайланмасы янында» (икесе дә — 1963). Әлеге серияләр 1970 елларда да дәвам иттерелә. Л. иҗатындагы яңа күренешләр үз заманының иң яхшы индустриаль пейзажы булган «Татарстан киңлекләрендә» картинасында (1960) чагыла.

Тыныч композицияле, киң манзаралы пейзажга офыкка таба сузылган автострада тасмасы хәрәкәт тойгысы алып керә, лиризм б-н сугарылган эпик эчтәлек уңышлы берләштерелә, сәнгатьчә гомумиләштерү чарасы рәссамга нәфис һәм ышандырырлык табигать образын иҗат итәргә мөмкинлек бирә. «Май аенда» (1965), «Май киче» (1967), «Салкынайта» (1968) пейзажлары нәкышьнең бөтенлеге, тирән, шәхси интонацияле булулары б-н игътибарга лаек. 1970 елда рәссам пастель техникасында эшли, лирик пейзаж темасын үстерүен дәвам итә. «Монда Тукай үз җырларын җырлады» исемле зур нәкышь сериясен (1975–76) рәссам Г.Тукайның тууына 90 ел тулу уңаеннан шагыйрьнең балачагы үткән урыннарга барып туплаган материаллар нигезендә тудыра. Әлеге сериядәге күп кенә әсәрләрнең исемнәре Тукайның поэма һәм шигырьләрендәге юллар б-н аталган, һәм картиналар аларның нәкышьтәге чагылышы кебек кабул ителә.

Табигать үзгәрүчәнлеге, тыйнак матурлыгы һәм бөеклеге, халык тормышы б-н әзлексез бәйләнештә булуы — рәссам иҗатының нигезен тәшкил итә.

Республика (1947 дән), төбәк — «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1946; Волгоград ш., 1967; Ульянов ш., 1969; Горький ш., 1974; Казан, 1980, 1991; Чабаксар ш., 1985), бөтенроссия — «РСФСР автономияле республикалар рәссамнарының әсәрләре күргәзмәсе» (Мәскәү, 1952, 1954, 1955), «Советлар Россиясе» (Мәскәү, 1960) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казан (1959, 1967, 1973, 1977, 1983), Чаллы, Әлмәт (1973–74), Куйбышев (1983) шәһәрләрендә уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда; Чуаш картиналар галереясында (Чабаксар ш.) саклана. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1978). Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан, «Почёт Билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Выставка работ художника С.О.Лывина: Каталог. К., 1980; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**ЛЫ́ГИНА** Талия Зиннур кызы (9.10.1952, Удмурт АССРның Воткинск ш.), геолог-аналитик, геол.-минерал. фән. д-ры (2002), проф. (2006). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), ЦНИИгеолнерудта эшли, 2003 елдан директор урынбасары. Л. геол. тармагының лаб. хезмәте өчен 20 ләп норматив документ эшли. Руда булмаган файдалы казылмаларның 9 дәүләт стандарты үрнәген булдыруда һәм аттестацияләүдә катнаша. Россия Дәүләт стандарты эксперт-аудиторы (1993 тән), Россия Дәүләт стандарты техник ком-ты әгъзасы (2000 нән). Үйлап табуга 5 патенты бар. Металл булмаган файдалы казылмаларны эшкәртүнең яңа технологияләрен эшләгәне өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (2003). 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан: В 3 ч. К., 1999–2001 (автордаш); Аналитико-минералогическое сопровождение геологоразведочных работ на неметаллические полезные ископаемые // Разведка и охрана недр. 2003. № 3.

**ЛЫ́ЗЛОВ** Андрей Иванович (1655 тирәсе — фаразланганча, 1697), тарихчы, тәрҗемәче. 1675 елдан стряпчий чинында, 1677 дән стольник. Рус-төрек сугышында (1676–81), Кырым (1687, 1689) һәм Азов (1695–96) яуларында катнаша. Шул елларда Л. Кырым һәм Төркия тарихлары б-н кызыксына башлый. 1682 дә поляк теленнән М.Стрыйковский «Хроника»сының кайбер өлешләрен, 1686 да С.Старовольскийның «Төрек патшасы сарае» («Двор цесаря турецкого») дигән хезмәтен тәрҗемә итә.

Л. — мәгълүм «Скифия тарихы» («Скифская история», СПб., 1776) тарихи әсәренең авторы. Китап турында Л. үзе: «... төрле чит илләр тарихчылары мәгълүматлары, Россиянең дөрес тарихлары һәм хикәятләре нигезендә тупланды һәм язылды... Христос туганнан соң 1692 елда», — дип яза.

Хезмәт «Скифиянең аталышы, аның чикләре һәм Скифия халыклары, татарлар атамасы булган монгоиллар яки мунгаллар, Европага килгән әлеге татарлар турында» («О названии Скифии, и границах ея, и народах скифийских, монгоилах или мунгалах и прочих... и чего ради татаре прозвашаяся, и киих татар суть сии татарове, иже в Европу придоша») дигән бүлектән башлана. Л. русларны — «москва», украиннарны һәм белорусларны — «россияне», Көнчыгыш Европаның барлык күчмә кабиләләрен «татарове» дип атый.

Китапның «Казан шәһәренең башлангычы һәм халкы, соңыннан аның Мәскәүнең бөек падишаһлары тарафыннан бөлдерелүе» («О начале и населении града Казани и потом о разорении его московских великих государей») дип аталган 3 нче кисәгендә рус кенәзләренең Казанны яулау өчен озакка сузылган дәвамлы көрәше җентекләп тасвирлана, «аны тәмам басып алу һәм ул патшалыкны тулысынча буйсындыру» һәм Әстерхан ханлыгын яулау хакында сөйләнә.

Казан ханлыгы тарихына мөрәҗәгать итеп, Л.: «Казан патшалыгы борынгы заманнардан мәшһүрлеккә һәм кодрәткә ирешеп, Россия халкына гына түгел, күп кенә чит илләргә дә мәгълүм булган. Аның турында чит илләр тарихчылары һәм бөтен дөньяның елъязмачылары бертуктаусыз язганнар», — дип билгеләп уза. Поляк тарихчысы Александр Гвагния фикеренә таянып, ул: «Казан татарлары ... йортлар төзү һәм игенчелек буенча нык танылганнар һәм осталар ... сәүдәгәрләре һәм сәүдә кешеләре Мәскәү һәм фарсылар б-н эш йөртәләр», — дип яза.

Л.ның «Скифия тарихы» кульязма хәлендә үк Россиядә киң тарала (китапның 32 күчермәсе мәгълүм), ул кыпчак далалары (к. *Дәшти Кыпчак*), Алтын Урда, Казан һәм Әстерхан ханлыклары халкына, Кырым татарларына кагылышлы гаять зур проблемаларны өйрәнүдә үз әһәмиятен бүгенге көндә дә югалтмый. Н.И.Новиков тарафыннан 1776 да һәм 1787 дә нәшер ителә, кабат 1990 да тарих фән. д-ры Е.В.Чистякова мөхәррирлегендә басылып чыга.

*Әд.:* Ч и с т я к о в а Е.В. «Скифская история» А.И.Лызлова и вопросы востоковедения // Очерки по истории русского востоковедения. М., 1963.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**ЛЫ́КОВ** (Лыков-Оболенский) Борис Михайлович (1576, Мәскәү — 2.6.1646, шунда ук), кенәз, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе. 1594 елдан дәүләт эшендә һәм хәрби хезмәттә. 1602–04 тә — Брянск, 1618 дә Можайск шәһәрләрендә воевода. 1605–06 да Зур полк воеводасы, Ялган Дмитрий I янында кравчий һәм бояр. 1606–07 дәге И.И.Болотников кузгалышын бастыруда катнаша. 1608–10 да поляк илбасарларына каршы сугыша. 1610 да боярлар хөкүмәте («җиде бояр») әгъзасы, 1611–12 дә илбасарлар гарнизоны б-н Мәскәү Кремлендә «камалышта утыру» хәлендә була. 1620–22 дә Казанда воевода. 1619 да — юлбасарлык эшләре, 1623–28 дә — качакларны эзләү эшләре, 1628–31 дә — ямчылык, 1634 тә биштән бер өлеш һәм бурыч акчаларын җыю приказлары башлыгы. 1626 дан конюший. Бер үк вакытта Казан сарай идарәханәсен (1635–43), Себер приказын (1637–43) һ.б. җитәкли.

*Әд.:* К о р с а к о в а В.Д. Список начальствующих лиц в городах теперешней Казанской губернии. К., 1908; Б о г о я в л е н с к и й С.К. Приказные судьи XVII в. М.–Л., 1946.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛЫСЕ́НКО** Владимир Дмитриевич (29.10.1934, Краснодар краеның Армавир ш.), нефть чыганакларын эшкәртү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1973), проф. (1992). 1959 елда Грозный нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында эшли: 1962 дән проектлау методикасы секторы, 1964 тән нефть чыганакларын эшкәртүне проектлаштыру лаб-ясе мөдире, 1978 дән директор урынбасары, 1982 дән директор (бүленеп: 1967–78 дә Алжирда). 1996 дан Россия инновацион җылылык-энергетика компаниясенең Нефть чыганакларын эшкәртүне проектлау һәм камилләштерү фәнни-җитештерү үзәгендә башкаручы директор (Мәскәү). Хезмәтләре су кудыру шартларында нефть чыганакларын эшкәртүне исәпләү алымнарына, катламнарның нефть бирүчәнлеген билгеләү проблемаларына карый. Л. нефть чыганакларын эшкәртүнең адаптив системасын, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру юлларын тәкъдим итә. ТР, Удмуртия, Хасси-Месауд (Алжир) нефть чыганакларын эшкәртү проектлары Л. тәкъдим иткән методика буенча эшләнә. Үйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Адаптивная система разработки нефтяных месторождений // Нефтяное хоз-во. 1996. № 7; Инновационная разработка нефтяных месторождений. М., 2000; Разработка малопродуктивных нефтяных месторождений. М., 2001 (автордаш).

**ЛЫ́СОВ** Виктор Фёдорович (28.2.1928, Буа кантоны Уби а. — 17.5.2008, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1967), проф. (1970), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1983, 1993). 1950 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1963–69 да физиол. бүлеге мөдире, 1968–99 да физиол. каф. мөдире, бер үк вакытта, 1974–78 дә, вет. ф-ты деканы, 1978–98 дә проректор, 1999 дан каф. профессоры. Хезмәтләре а.х. хайваннары физиологиясенә, ашкайнату органнары эшчәнлегенә, нерв һәм эндокрин системаларның ролен ачыклауга карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Укыту процессына физиологияне өйрәнүнең яңа ысулын кертә. Дәреслекләр авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физиология молодняка сельскохозяйственных животных. К., 1977; Практикум по физиологии сельскохозяйственных животных. М., 1990 (автордаш); Физиология сельскохозяйственных животных. М., 2003 (автордаш); Физиология и этиология животных. М., 2004 (автордаш).

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993.

**ЛЫСО́В** Михаил Данилович (21.11.1932, Чистай ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1979), проф. (1981), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1960–62 елларда СССР Эчке эшләр министрлыгының Алабуга милиция мәктәбендә укыта. 1964–2004 тә Казан ун-тының җинаятьчелеккә каршы хокук кафедрасында. Хезмәтләре җинаять эшләре хокукы, мошенниклар берләшмәләре һәм пр-тиеләре, вазифаи җинаятьләр б-н көрәш мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ответственность за частно-предпринимательскую деятельность по советскому уголовному праву. К., 1969; Ответственность должностных лиц по советскому уголовному праву. К., 1972; Наказание и его применение за должностные преступления: Цель, эффективность, принципы индивидуализации. К., 1977.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**ЛЫСО́В** Михаил Иванович (21.11.1918, хәзерге Саратов өлкәсенең Синенькие а. — 19.3.1995, Казан), самолётлар төзү технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1960), проф. (1961), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1968, 1982). 1943 елда Казан. авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, очкыч аппаратларны җитештерү каф. мөдире (1956–87), бер үк вакытта проректор (1968–73). Хезмәтләре юка стеналы детальләрне пластик формалаштыруга, авиация производствосы өчен махсус технол. җиһазлар булдыруга карый. Уйлап табуга 34 авторлык таныклыгы бар. Октябрь Революциясе ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә

Х е з м.: Теория и расчёт процессов изготовления деталей методом гибки. М., 1966; Пластическое формообразование тонкостенных деталей авиатехники. М., 1983; Прикладная теория пластического растяжения с изгибом при сложном нагружении. М., 1991.

**ЛЫСОГО́РСКИЙ** Юрий Борисович (14.9.1930, Казан — 5.8.1988, шунда ук), график, китап рәссамы. Казан сәнгать уч-щесендә (1949–54, нәкышь бүлеге) һәм Эстония ССРның Дәүләт сәнгать ин-тында укый (1954–60, графика ф-ты). 1960–86 елларда Татарстан китап нәшриятында, бизәлеш буенча өлкән мөхәррир, штаттан тыш рәссам (1964 елдан). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1970).

1960 елларда гравюра өлкәсендә, индустриаль пейзаж һәм портрет жанрларында эшли: «Кохтла-Ярве шахтёрлары» сериясе (диплом эше, 1960, офорт, коры энә), «Дуслык трассасы» (1964, коры энә); «Гурий Плетнёв һәм Алёша Пешков» (1963, коры энә). 1960



Ю.Б.Л ы с о г о р с к и й. «Эшче патруль». И.Ионенко, И.Таһировның «Казанда Октябрь» китабына иллюстрация. Кәгазь, акварель, карандаш. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

елларның 2 нче яртысыннан рәсем ясау техникасына өстенлек бирә, күмер, сангина, пастель, акварель, тушь, карандаш куллана. Рәсемнәр сериясендә тарихи темаларны ача: Пушкин (1972–73, күмер, пастель, акварель) һәм Горький (1976–78, күмер, пастель, акварель) цикллары.

Л. Татарстанның 1960–70 еллар китап сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Китап графикларының яңа буын вәкиле буларак, иллюстрацияләр иҗат итү б-н бергә (1940–50 еллардагы кебек), Л. китапны бердәм ансамбль итеп карый, аның сәнгати бизәлешен тулаем башкара. Төп нөсхәләрне акварель, тушь б-н эшли. Л. балалар китабы өлкәсендә иҗат иткәндә аеруча тарихи әдәбият б-н кызыксына. «М.Җәлил» фотоальбомы (1966), И.Ионенко, И.Таһировның «Казанда Октябрь» («Октябрь в Казани», 1967), З.Дусаевның «Атаклы сәяхәтчеләр» («Замечательные путешественники», 1968), Х.Гарданов, И.Гомәрованың «Кызыл Йолдыз» (1975) китаплары бизәлеше буенча Мәскәүдә узган китап сәнгате конкурсында 3 нче дәрәҗәле дипломга, «Татарстан АССР тарихы» (1970) Казанда узган Республика китап сәнгате конкурсында 1 нче дәрәҗәле дипломга лаек булалар. Л.ның хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Красновидово авылындагы А.М.Горький музеенда һ.б.да саклана.

*Әд.:* Музей изобразительных искусств ТАССР: Путеводитель. К., 1970; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии. Живопись, скульптура, графика. М., 1978; ш у л  у к. Художники Советской Татарии. К., 1984; Музей А.М.Горького в Казани: Путеводитель. К., 1980.

*О.Л.Улемнова.*

**ЛЬВО́В** Дмитрий Михайлович (21.10.1850, Пенза өлкәсенең Керенский өязе Коповка а. — 1899 дан соң), хокук белгече, финанс хокукы д-ры (1893), статский советник (1888). Руханилар нәселеннән. Пенза руханилар семинариясен (1870), Казан ун-тын (1874) тәмамлый. 1875–77 елларда Харьков округ мәхкәмәсендә бүлекчә башлыгы, 1876 дан җинаятьчелек бүлеге секретаре ярдәмчесе булып эшли. 1877–99 да Казан ун-тында: профессорлык стипендиаты (1880 гә кадәр), доцент (1880–84), финанс хокукы кафедрасында экстраординар проф. (1884–93), ординар проф. (1894). Хезмәтләре финанс хокукына карый. «Кәсәбәчелек салымы һәм аны Көнбатыш Европа дәүләтләрендә һәм Россиядә гамәлгә кертү юллары» («Промысловый налог и методы его установления в западноевропейских государствах и в России», 1879), «Бүгенге финанс фәне тәгълиматы буенча варислык салымы» («Налог с наследства по современному учению финансовой науки», 1883), «Оброк бурычы, аның тарихы һәм гамәлдәге законнар» («Оброчная подать, её история и действующее законодательство», 1886) дип аталган һ.б. хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Очерк развития кассовых и контрольных учреждений в России за истекшее двадцатипятилетие. СПб., 1889; Поземельный кадастр. СПб., 1890.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ЛЬВО́В** Михаил Давыдович (чын фамилиясе һәм исеме Габитов Рәфкат Дәүләтша улы) (4.3.1917, хәзерге БРның Салават р-ны Нәсибаш а. — 25.1.1988, Мәскәү), шагыйрь. Рус телендә яза. 1941 дә Мәскәүдә А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945 тән Мәскәүдә яши. Л. шигырьләренең төп темасы — замандашлары тормышы, кеше язмышының кабатланмас булуы. Аның лирик герое — бай эчке тормышлы, бөек рухка ия шәхес. Л. иҗатына тормышны фәлсәфи кабул итү, кырыс батырлык б-н нечкә лиризмның үрелеп баруы хас. «Бүген яшим» («Живу сегодня», 1973), «Бирелгәнлек» («Одержимость», 1977), «Мин сезне яраттым» («Я вас любил», 1977), «Тәүлек буе» («Круглые сутки», 1980), «XX гасырда яшим» («Живу в XX веке», 1984), «Каршы хәрәкәт» («Встречное движение», 1984) җыентыклары авторы. С.Рәмиев, М.Җәлил, Ә.Исхак, Ш.Маннур, М.Садри, С.Хәким, Н.Дәүли, Ә.Давыдов, М.Хөсәен, М.Әхмәтгалиев һ.б.ның шигырьләрен рус теленә тәрҗемә итә. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Шигырьләр. К., 1971; Собрание сочинений: В 3 т. М., 1987–88.

*Әд.:* Г ә р ә й Р. Ул безнең үз шагыйребез // Казан утлары. 1972. № 12; Ә х м ә т җ а н М. Тормыш мизгелләре // Казан утлары. 1997. № 2; К о ч е т к о в В. Поэты военного поколения // Люди и судьбы. М., 1977.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ЛЬЯШ** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 124 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 70%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Льяш Пүчинкәсе исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1898 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1898 дә ачыла), тимерче алачыгы, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1495 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Кызыл Алан волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 328 ир-ат; 1859 да — 793, 1897 дә — 1186, 1908 дә — 1343, 1920 дә — 1242, 1926 да — 910, 1938 дә — 1006, 1949 да — 491, 1958 дә — 391, 1970 тә — 240, 1979 да — 168, 1989 да — 171, 2002 дә — 170 кеше.

**ЛЮБА́РСКИЙ** Евгений Леонидович (3.10.1930, Приморье краеның Шкотовский р-ны Соловейцев Ключ а.), ботаник, биол. фән д-ры (1969), проф. (1970). ТР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1992, 1996), Казан геоботаника мәктәбе вәкиле (1970 еллардан). Казан ун-тын тәмамлый (1953), шунда ук эшли, ботаника каф. мөдире (1974–99). Бер үк вакытта РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тында гражданлык хокукы белеме каф. профессоры. Хезмәтләре геоботаника, болынчылык һәм урманчылык белеменә, популяцион һәм сәнәгый ботаникага, гомуми экологиягә, экология хокукына карый. Л. вегетатив-хәрәкәтчел үсемлекләр экологиясен өйрәнә. Җир өсте — шуышма һәм озын тамырчалы үсемлекләрнең таралуында туфрак дымлылыгы режимының мөһим роль уйнавын нигезли, озын тамырчалы үсемлекләр популяциясендә плагиотроп тамырчалар эко- һәм фитотроплыгының статик чагылышын ачыклый. Вегетатив-хәрәкәтчел үсемлекләрнең үрчү һәм яңару органнарын, үсемлекләрнең тереклек формаларын, экологик факторларын оригиналь юл б-н классификацияли. Күп кенә үсемлекләрнең биоморфологик төзелешен, экологиядә геометрик модельләштерү алымнарын, «популяция кыры» алымын тәкъдим итә. Бөтенсоюз ботаника җәмгыятенең (1998 дән — Рус ботаника җәмгыяте) Казан бүлеген оештыручы (1959), аның рәисе (1972 дән), мактаулы әгъзасы (2003 тән). Казан ун-тының атказ. профессоры (2007).

Х е з м.: Экология вегетативного размножения высших растений. К., 1968; Ценопопуляция и фитоценоз. К., 1976; Структура ценопопуляций вегетативно-подвижных растений. К., 1984 (автордаш).

*Әд.:* Любарский Евгений Леонидович (к 60-летию со дня рождения) // Бот. журн. 1992. Т. 77, № 5; П о л у я н о в а В.И., И б р а г и м о в а К.К. Евгений Леонидович Любарский (к 70-летию со дня рождения) // Бот. журн. 2002. Т. 87, № 2.

**ЛЮБИ́МОВ** Николай Матвеевич (9.5.1852, Уфа — 20.2.1906, Казан), патологоанатом, медицина д-ры (1879), атказ. табиб (1905). 1875 елда Казан ун-тын тәмамлагач, шунда ук эшли, 1885 тән патологик анатомия каф. мөдире, проф., 1896 дан декан, 1905–06 елларда ректор, 1880 дә патологик анатомия кафедрасында бактериология лаб-ясенә, 1880 еллар башында патолого-анатомия музеена һәм университетның патологоанатомнар мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре лейкозлар, туберкулёз, ваба, чума, тифның патологик анатомияләренә карый.


Х е з м.: О туберкулёзных бациллах Kocha. К., 1884; Бактерии и влияние их на здоровье человека. К., 1887; Курс бактериологических методов исследования. К., 1888; О борофуксине // Мед. обозрение. 1888. № 3; Курс патологической анатомии. К., 1890; Об отношении организма к инфекции. К., 1898; К учению об острой лейкемии. К., 1906.

*Әд.:* П о д о л ь с к и й Н.С., П о р ы в а е в Н.Ф. Николай Матвеевич Любимов как учёный и общественный деятель // Архив патологии. 1956. № 5.

**ЛЮБИ́МОВКА** елгасы; к. *Кече Үләмә.*


**ЛЮБИ́МОВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 6 *км* төньяктарак, Тәтеш-Апас автомобиль юлы буенда. 2010 елда 15 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 353 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Кызыл Алан волостенда, 1920 дән ТАССРның Тәтеш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 19, 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 269, 1897 дә — 247, 1908 дә — 522, 1920 дә — 498, 1926 да — 419, 1938 дә — 510, 1949 да — 420, 1958 дә — 311, 1970 тә — 204, 1979 да — 134, 1989 да — 69, 2002 дә — 32 кеше.

**ЛЮ́БИН** Дмитрий Рафаилович (26.4.1880, Самара ш. — 9.5.1951, Казан), драма актёры, ТАССРның халык (1939), РСФСРның атказ. (1940) артисты. Сәхнә эшчәнлеген реаль уч-ще тәмамлаганнан соң, 1897 елда Самара шәһәр театрында башлап җибәрә, 1898–1905 тә Сембер, Оренбург, Владикавказ шәһәрләрендәге театрларда эшли. 1906–09 да Казан шәһәр театрында Н.И. Собольщиков-Самарин антрепризында, монда ул Великатов, Безсудный, Муров («Талантлар һәм баш иючеләр», «Кеше күп җыелган җирдә», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский) рольләрен уйный. Казан вакытлы матбугаты аның башкаруында Ямщик («Станция күзәтчесе», А.С.Пушкин повесте буенча), Солёный («Өч сеңел», А.П.Чехов), Антонио («Шейлок», У.Шекспир), Гуннар («Төньяк баһадирлары», Г.Ибсен) рольләрен уңай бәяли. Аннан соңгы елларда Ростов-Дон, Одесса, Новочеркасск, Саратов, Воронеж шәһәрләрендәге театрларда эшли. 1934 тән Казан Зур драма театрында. Элеккеге актёрлар мәктәбенең күренекле вәкиле буларак, Л. аеруча классик репертуардагы рольләрендә югары сәнгатьчәлеккә ирешүгә б-н аерылып тора. Фамусов («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Кнуров, Лыняев, Прибытков, Дулебов, Кучумов, Дудукин («Бирнәсез кыз», «Бүреләр һәм сарыклар», «Соңгы корбан», «Талантлар һәм аларга баш иючеләр», «Котырган акчалар», «Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Тычков («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), дон Саллюст («Рюи Блаз», В.Гюго) образларын гәүдәләндергәндә актёр тарихи чор күренешләрен, персонажларның үз-үзләрен тоту рәвешләрен, теге яки бу хәлләргә карашларын һәм аларны бәяли белүләрен төгәл һәм дәлилле күрсәтә. Тамашачылар каршына узган гасырларның социаль гомумиләштерелгән тирән мәгънәле образлары кабат «терелеп кайта» һәм төрле яклап ачыла. Үз чорының драматургик материалында урын алган рольләрне дә актёр ышандырырлык итеп оста башкара: Н.Ф.Погодинның «Балдан соң» (Адам Петрович) һәм «Аристократлар» (Бабкин), В.П.Катаевның «Чәчәкләр юлы» (Газгольдерның ире), А.Е.Корнейчукның «Платон Кречет» (Бублик) пьесаларында ул иҗат иткән образлар җылы юмор б-н сугарылган; Харитонов («Рус кешеләре», К.М.Симонов), Булавин («Газап чигеп йөрү», А.Н.Толстой романы буенча), акад. Писа-



Д.Р.Любин.






Д.Р.Л ю б и н:
1. Боцман («Оптимистик трагедия», В.В.Вишневский);
2. Булавин («Газап чигеп йөрү», А.Н.Толстой романы буенча) рольләрендә.

ревский («Намус законы», А.П.Штейн), миллионер Атабаев («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт) рольләренә дә тормышчан чынлык, рухи бөтенлек хас. 1914 тән Л. пед. эшчәнлек б-н шөгыльләнә, 1938 дән Казан муз. уч-щесендә актёрлык осталыгы дәресләре бирә. Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегенә нигез салучы һәм аның беренче рәисе (1939–41). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*



Л.З.Любовский.

**ЛЮБО́ВСКИЙ** Леонид Зиновьевич (24.2.1937, Украина ССРның Каменка ш.), композитор, педагог, ТАССРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1983, 1996), 1967 елда Казан консерваториясен композиция буенча (А.Леман классы) тәмамлый, шунда ук (2008 гә кадәр) композиция кафедрасында укыта. Л. композиторлык иҗатының күпләгән жанрларында уңышлы һәм нәтиҗәле эшли. Аны бигрәк тә масштаблы циклы композицияләр (симфонияләр, ораторияләр, инструменталь, вокаль һәм хор циклллары, театр музыкасы) җәлеп итә. Композитор заманны, аның җанлы хәрәкәткә бай пульсын, ургылып аккан тормыш агымын үткен һәм киеренке халәттә тоемлый. Бигрәк тә иҗатының бу үзенчәлекләре И.Франко шигыренә язылган Симфония ораториясендә, 3 нче, 4 нче, 5 нче симфонияләрендә кәтелмәгән композиция һәм сәнгати-идея чишелешләре аша ачык күренә, аларда үткән, хәзерге һәм киләчәк турындагы фәлсәфи уйланулар б-н тулган фаҗигале пафос чагыла. Л. әсәрләре арасында А.Сахаров истәлегенә багышланган Lacrimosa (зур симф. оркестр һәм орган өчен) үзенең гражданлык позициясе б-н үзенчәлекле. Виолончельләр, скрипкалар, фортепиано өчен язылган оркестр концертларында неоклассик һәм неоромантик үсеш юнәлешләре сизелә. Композитор иҗатында М.Җәлил шигырьләренә иҗат ителгән «Моабит дәфтәрләреннән» вокаль-симфоник әсәрләре һәм А.Твардовскийның «Хәтердә калганнардан» («По праву памяти») поэмасы буенча язылган «Телсез әрнүне сүзләргә әверелдерү...» («Немую боль в слова облечь...») кантатасы мөһим урын алып тора. Россия һәм чит ил шагыйрьләренең шигырьләренә тавыш һәм фортепиано өчен язылган вокаль циклларның тематикасы һәм образлар дөньясы төрле («Яңа гасыр» — «Новый век», «Сугыш җилләре» — «Военные ветры», «Торналар иле» — «Страна журавлиная», «Корея классик поэзиясеннән» — «Из корейской классической поэзии», «Шатлык» — «Радость»). Л. үзенең иҗатында гадәти булмаган уен кораллары составына мөрәҗәгать итә: ике труба, валторна, тромбон һәм туба өчен (беренче башкарылуы АКШта була) Brass Quintet (тынлы уен кораллары өчен квинтет); дүрт тромбон, фортепиано һәм бәрмә уен кораллары өчен (Саратов шәһәрендә 1 нче халыкара тынлы музыка фестивалендә беренче тапкыр башкарыла) «Босх триптихы»; инструменталь музыкаль чараларның каноник циклы формасы — Passionmusic (премьерасы Ленинград филармониясенең Зур залында була, 1990), дүрт бәрмә уен коралы өчен Дүрт классик фуга (Казанда «*Европа-Азия*» халыкара фестивалендә беренче тапкыр башкарыла, 2000). «Кыйссаи Йосыф» балеты Л.ның зур иҗат уңышы булып санала; 2001 дә Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә куела (Р.Харис либреттосы, Г.Ковтун хореографиясе). Автор бөтендөнья рухи мирасында мөһим урын алып торган сюжетка мөрәҗәгать итеп, хәзерге заман музыка техникасы чаралары б-н классик инструметарийны гына түгел, хәтта экзотик инструментарийны да кулланa, гомумкешелек дөньясында әхлакый проблемаларны кеше шәхесенең һәм югары, һәм түбән хисләре каршылыклары аша ачтырта. Балет музыка тәнкыйтьчеләре һәм тамашачылары тарафыннан югары бәяләнә; РФнең Дәүләт бүләгенә лаек була (2005). Композиторның әсәрләре концерт һәм пед. репертуарларга даими кертелеп тора, танылган музыкантлар тарафыннан Казанда, Мәскәүдә, Россиянең башка шәһәрләрендә, чит илләрдә (Литва, Эстония, Молдова, Польша, Болгария, Германия, АКШ, Япония һ.б.) еш башкарыла. Л.ның авторлык концерт программалары арасында Концертлар концерты (1995), 7 инструменталь соната (1998), А.Сахаров истәлегенә концерт (1989), Полифоник музыка кичәсе (2000), М.Тарасова, Р.Абязов, Л.Леонтьева, Ф.Хасанова, И.Коциньш, И.Гыйрфанов, Р.Скуратов һ.б. катнашында Симфоник концерт (2002) бар. Л. ш.у. үз әсәрләренең дирижёры, пианист-ансамблист, китаплар һәм мәкаләләр авторы буларак та билгеле. Л. әсәрләре Казанда һәм Мәскәүдә (3 нче һәм 4 нче симфонияләр партитуралары, «Кыйссаи Йосыф» балеты клавиры, вокаль цикллары һ.б.) кат-кат басыла.

Төп әсәрләре: Бергстедның шул исем. повесте буенча «Изге Йорген бәйрәме», («Праздник святого Йоргена», 1967) операсы; симф. оркестр өчен: 6 симфония (1965, 1976, 1979, 1983, 1990, 2004), Lacrimosa (1990), кече күләмле классик вариацияләр (1970), «Салон музыкасы» (1997), Симфониэтта (1964), симф. оркестр б-н фортепиано, виолончель, скрипка өчен концертлар (1968, 1972, 1985); хор һәм симф. оркестр өчен: И.Франко шигыренә Симфония-оратория (1970); А.Твардовскийның «Хәтердә калганнардан» («По праву памяти», 1987) поэмасы буенча «Телсез әрнүне сүзләргә әверелдерү» («Немую боль в слова облечь...», 1970) кантатасы; М.Җәлил шигырьләренә «Моабит дәфтәрләреннән» (1969) исемле вокаль-симф. сюиталар; хор өчен: Ф.Тютчев шигыренә «Табигать дөньясы» («Мир природы», 1971), Р.Харис шигыренә «Фикерләр» («Мысли», 1980); инструменталь камера әсәрләре: 1 нче, 2 нче кыллы квартетлар (1963, 2003), кларнет, фагот, фортепиано һәм бәрмә уен кораллары өчен дивертисмент (Кечкенә концерт, 1967), төрле уен кораллары өчен сонаталар, вариацияләр, сюиталар, пьесалар; тавыш һәм фортепиано өчен вокаль цикллар; җырлар; драма спектакльләренә, балалар өчен музыка һ.б.

Хезм.: Что есть музыка. К., 1993; Маленькая книжечка о Бахе (техника и философия И.С.Баха). К., 1994; Смысл фуги в западноевропейском музыкальном мышлении. К., 1996; Гармония и доброта // Казань. 1995. № 7/8.

*Әд.:* Гурарий С. Диалоги о татарской музыке. К., 1984; Кантор Г.М. Музыковеды Казани: Биобиблиогр. словарь. К., 2000; Композиторы Татарстана. М., 2009.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ЛЮ́БЧЕНКО** Владимир Ильич (20.3.1960, Казан — 22.10.1996, Мәскәү), химик физика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1991). 1981 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1984 дән Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Казан). 1990 нан берничә кече пр-тие җитәкчесе (Мәскәү). Хезмәтләре шартлаучан матдәләрнең яну теориясенә карый. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: Стационарная теория распространения неадиабатических волн горения в газовой смеси // Журн. физ. химии. 1987. Т. 61, № 4.

**ЛЮ́БЧЕНКО** Илья Сергеевич (16.5.1930, Воронеж ш.), химик физика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1985). 1954 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан моторлар төзү з-дының тәҗрибә КБда эшли. 1963 тән Казан. авиация ин-тында укытучылык эшендә, 1966 дан СССР ФА Химик физика ин-тында (Мәскәү), 1969 дан Рязань югары тыл һәм транспорт хәрби уч-щесендә, 1971 дән Бөтенсоюз электротехника ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Черноголовка штп.). 1973–92 дә Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан) лаб. башлыгы. Хезмәтләре яну, кабызып җибәрү, шартлау теорияләренә карый. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Математическое моделирование технологического процесса на ЭЦМ // Вестн. Моск. ун-та. 1963. № 2; Асимптотические решения в теории теплового взрыва // Докл. АН СССР. 1969. Т. 188, № 4; Тепловая теория зажигания реагирующих КВ // Успехи химии. 1987. Т. 61, № 2.

**ЛЮГДО́Н** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 12 кеше (удмуртлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1949 да — 113, 1958 дә — 81, 1970 тә — 77, 1979 да — 59, 1989 да — 29, 2002 дә — 27 кеше.

**ЛЮ́ЛИН** Виктор Васильевич (3.2.1932, хәзерге Рязань өлкәсенең Сасово ш. — 10.7.2000, Казан), җир төзү инженеры, РСФСРның атказ. җир төзүчесе (1981), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Мәскәү инженерлык-җир төзүчеләр ин-тын тәмамлый (1957). 1950–51 елларда Рязань өлкәсенең Пителинск р-нында, 1957–58 дә Казан җир төзү партиясендә эшли, 1958–61 дә ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгының җир төзүчелек отряды

башлыгы. 1961–69 да Татарстан җир төзүчелек экспедициясендә отряд башлыгы, 1965 тән җитәкчесе. 1969–75 тә «Росгипрозем» ин-тының Татарстан бүлеге башлыгы, 1975–91 дә «Волгогипрозем» ин-тының Татарстан ф-лы директоры. 1991–2000 дә «Республика җир-кадастр үзәге» унитар пр-тиесе директоры (1998 гә кадәр). Дәүләт бүләге Биектау р-нының «Чулпан» һәм Арча р-ның «Игенче» күмәк пр-тиеләре мисалында агроландшафтлы игенчелек системасын эшләгәне һәм җитештерүдә гамәлгә кертканe өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медаль, ТАССР, ТР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛЮПИ́Н** (Lupinus), кузаклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Терлек азыгы, сидерат һәм декоратив культура буларак үстерелә. Якынча 100, БДБда — 5 төре билгеле. Татарстан терр-ясендә 4 төре бар: гибрид Л. (декоратив үсемлек буларак үстерелә); күп яфраклы Л. (күпьеллык агулы дару үләне; болыннарда, кырлар, урман кырыйлары, юл буйларында очрый; үсемлекнең барлык өлешендә дә ачы һәм агулы алкаидлар: люпинин, люпинидин бар); тар яфраклы Л. яисә зәңгәр Л. һәм ак Л. (берьеллык төрләре). Электән берьеллык Л.ның орлыкларын ашамлык һәм терлек азыгы итеп кулланганнар. Л.ның барлык төрләре дә аксымга бай. 1 *кг* яшел терлек азыгында 0,09 азык берәмлеге һәм 12 *г* үзләштерелә торган протеин, силоста — 0,16 һәм 12, орлыкта 1,16 азык берәмлеге һәм 320 үзләштерелә торган протеин бар. Терлеккә ашату өчен алкалоидсыз ачы булмаган сортлары, ш.у. орлыкларында алкалоидлар 0,025–0,1% тан артык булмаган терлек азыгы сортлары (Л.ның 0,1–0,3% алкалоидлар булган сортлары силос итеп ашату өчен кулланыла) яраклы. Ачы Л. (1–2% алкалоидлы) бары тик яшел ашлама буларак кына үстерелә. Л. дым ярата, туфракка таләпчән түгел, ләкин сазлыклы һәм известькә бай туфракларда начар үсә. Казан губернасында Л. яшел ашлама буларак беренче тапкыр 1854 елда чәчелә, 1 дисәтинә җирдән сары Л.ның яшел массасы 3137–3880 пот, зәңгәр Л.ның — 2817–3819 пот тәшкил итә. Казан а.х. ин-ты һәм Арча р-нының Молотов исем. к-зының сорт сынау тәҗрибәләрендә яшел массаның уңышы 1954 тә — сары Л. 1 *га* дан 169 *ц*, зәңгәр Л. — 194 *ц*, 1955 тә — сары Л. — 270,3 *ц*, зәңгәр Л. — 362,5 *ц* тәшкил итә. Сидерат люпин пары җиренә чәчелгән арышның уңышы 7,1–35,5% ка арта. ТРда яшел ашлама буларак иң әһәмиятлесе — тар яфраклы Л. һәм сары Л. Тар яфраклы Л. — зәңгәр, шәмәхә, алсу, ак төстәге иссез чәчәкле. Орлыклары бөресыман, мәрмәр төсендә; абс. авырлыгы 160–200 *г*. Өлгергән кузаклары коңгырт сары төстә. Үсемлекнең биеклеге 1,5 *м* га кадәр җитә. Алсу чәчәкле сортлары тиз өлгерешле, сабаклары зәңгәр чәчәклегә караганда биегрәк. Сары Л. — комлы туфраклар өчен иң яхшы сидерат үсемлек, чәчәкләре сары, тәмле исле. Орлыклары түгәрәк — бөресыман, ике катлы, алсу, кара нокталы көрән яисә мәрмәр төсендә; абс. авырлыгы 130–150 *г*. 5°С темп-рада шыта, 9–11 көндә тишелеп чыга. Тар яфраклы Л. –9°С ка кадәр салкынга чыдам, ТР-ның төньяк районнарында да өлгерә, вегетация чоры кыскарак, яшел массасы күп була. Үзәк тамыр системалы. Сөрү катламын тирәнәйтү, фосфорлы һәм калийлы ашламаларны (1 *га* өчен 60–80 *кг*) күбрәк кертү отышлы. Иртә өлгерешле язгы культураларны чәчә башлагач, 5 көннән соң гадәти рәтләргә яисә тар рәтле ысул б-н чәчәләр (иң яхшысы җитен чәчкеч б-н); орлыкларның чәчү нормасы (1 *кг/га* исәбеннән): яшел ашлама яисә терлек азыгы буларак тар яфраклы Л. яки ак чәчәкле Л. — 200–250, сары Л. яисә ак Л. — 140–160; орлык өчен тоташ рәтле итеп чәчелгән тар яфраклы Л. — якынча 150, 2–3 *см* тирәнлеккә чәчелә. Яшел массаны 15–16 *см*, җиңел туфракларда 20–22 *см* тирәнлеккә көзге чәчүгә кадәр 30 көн алдан сөреп күмдерәләр. Сентябрь башында тулысынча өлгерә. 80–90 % орлыклары көрән төскә кергәч җыела, уңышы 1 *га* дан 16–18 *ц* чыга. Күпьеллык Л. язгы бөртекле культуралар чәчелгәннән соң чәчелә. ТР да ак Л.ның — «Дельта» (2001), тар яфраклы Л.ның — «Кристалл» (2004) сортлары районлаштырылган.



Зәңгәр люпин.

*Әд.:* А в р о в О.Е. Агротехника однолетнего люпина на зелёное удобрение в Татарии. К., 1957.

*И.Н.Афанасьев.*

**ЛЮТЕРАНЛЫ́К**, христиан динендә протестантлык юнәлешләренең берсе. Европада 16 йөздә Реформация нәтиҗәсендә барлыкка килә, М.Лютер (1483–1546) нигез сала. Протестантлыкның төп кануннарын, ш.у. «инану б-н тәүбәгә килү», ягъни Илаһка шәхси инану б-н генә үзеңне коткару мөмкин дигән үз доктринасыннан гыйбарәт. Л.ның тәгълимат чыганагы — Библия.

Л. руханилар катлавына Илаһ б-н кеше арасында изге арадашчылар итеп карауны кабул итми; *иконаларны* (Библия сюжетларына ясалган сурәтләр рөхсәт ителә), монахлыкны, изгеләргә һәм аларның череми саклаган сөякләренә табынуны кире кага; гыйбадәт кылуны гадиләштерә. Л. 2 йоланы: чукындыру һәм икмәк б-н шәраб кабуны таный, ләкин эч серен руханига ачып салып тәүбәгә килүнең бердәм позициясе эшләнмәгән. Оештыру структурасы: чиркәү — епархия — пробстволар (төбәкләрдәге приходларның эшчәнлеген күзәтүче оешмалар) — приход. Лютераннар чиркәвендә аерым әгъзалык кабул ителгән: анда гариза биреп керү (чыгу) каралган. Чиркәү әгъзалары күләме билгеләнмәгән акча түли. Дөньяда 192 Л. чиркәвенә берләшкән 75 млн. нан артык лютеран (күпчелеге Германиядә, Төньяк Европа илләрендә яши) исәпләнә; 50 млн. га якынын Бөтендөнья лютераннар берлеге берләштерә (үзәге — Женева ш.).

Россиядә 85 меңгә якын лютеран бар. Беренче лютераннар 1558–83 елгы Ливон сугышыннан соң пәйда була. Әсирлеккә төшкән немецлар (үз диннәрен иректе тоту хокукы б-н) Россия шәһәрләренә, ш.и. Казан краена (Казанда ш.у. гаиләләре б-н килеп төпләнгән сәүдәгәрләр, Казан гарнизоны хәрбиләре яши) урнаштырыла. Тарихи чыганакларда Казандагы лютераннар һәм аларның пасторы Скультет турында беренче хәбәрләр шушы чорга карый. Лютераннар җәмгате 1767 дә, бирегә полк рухание җибәрелгәч һәм изге Екатерина чиркәве төзелә башлагач барлыкка килә (аңа, башлыча, немецлар керә). 19 йөз башында Казанда 100 гә якын лютеран-немец гаиләсе яши, алга таба аларның саны даими үсә. 1897 дә уздырылган Беренче гомуми халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча, Казан губернасында 1384 лютеран исәпләнә. Лютераннар җәмгате Казанга реформат дини юнәлешен тоткан (протестантлыкның Л. төренә якын тора) немецлар килеп урнашу хисабына арта. 19 йөз башында реформатлар һәм лютераннар бер җәмгатькә — сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, укытучылар, чиновниклар һ.б. тупланган евангелие-лютеран җәмгатенә берләшәләр (К.К.*Клаус*, Х.*Крамп*, П.Ф.*Лесгафт*, Д.И.*Мейер*, К.Л.*Мюфке*, А.И.*Песке*, К.А.*Тон*, К.Ф.*Фукс*, А.К.*Шмидт*, Ф.И.*Эрдман* һ.б.). Казан җәмгате актив тормыш б-н яши, хәйрия эшчәнлеге алып бара. Россиядә 1917 гә кадәр эшләгән Евангелист-лютеран чиркәве уставы (1832) буенча приходлардан торган һәм күзәтүче оешмаларга (пробство) бүленгән консисториаль округлар төзелә. Казан җәмгате Мәскәү консисториаль округына керә. Россия империясенең Кануннар тупламасы Л.ны түзәрлек дин дип исәпли. Россиядә Евангелист-лютеран чиркәвенең хокукый хәле шактый тотрыклы була. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында хәл катлаулана: Германиягә теләктәшлек күрсәтүдә яки шымчылыкта гаепләнгән күп кенә лютеран-немецлар эзәрлекләүгә дучар ителәләр. 1917 дә Вакытлы хөкүмәт лютеран чиркәвеннән күп кенә чикләүләрне ала һәм дәүләт тикшерүеннән азат итә. Окт. рев-циясеннән соң Россиядә лютераннарның хәле начарая төшә, әмма рев-циядән соңгы беренче елларда һәм нэп чорында шактый яхшы була, чөнки совет хакимиятенең дингә каршы алып барган сәясәте иң элек Рус Православие чиркәвенә каршы юнәлтелә. 1920 еллар ахырында Л.ка хакимият басымы көчәя. 1920 нең ноябрендә ТАССР ҮБК Президиумы карары б-н лютеран чиркәве ябыла; евангелист-лютеран җәмгатенең күп кенә күренекле вәкилләре репрессияләнә.

Татарстанда лютераннар җәмгате 1970 еллар ахыры — 1980 еллар башында шәһәр тибындагы Урыссу посёлогына күчеп килгән немецлар арасында яңадан оеша, ләкин 1990 еллар башында ул яшәүдән туктый. 1990 да лютераннар җәмгате Казанда яңадан торгызыла, 1996 да аңа Менжинский исем. Мәдәният сарае комплексы составындагы кирха тапшырыла; 2000 нән ул «Казандагы

евангелист-лютераннарның Изге Екатерина кирхасы» исемен йөртә (к. *Санкт-Катарина кирхасы*). 2002 дә ТРда Россиянең Европа өлешендәге Евангелист-лютеран чиркәвенең Татарстан оешмасы (пробство) төзелә. 2004 тә ул 4 җәмәгатьне үз эченә ала. Казанда 500 гә якын, Татарстанда 3000 ләп немец (күпчелеге Чаллыда, ш.у. Әлмәт, Баулы, Түбән Кама шәһәрләрендә) яши. Әле 20 йөз башында Казан губернасында Л.та яңа юнәлеш — Ингрия евангелист-лютераннарының чиркәве барлыкка килә (нигездә, аның тәгълиматы башка лютеран чиркәүләре догмаларыннан аз аерыла). Хәзер Ингрия чиркәвенең Казан җәмәгатенә элек протестант чиркәүләрендә әгъза булып торган төрле милләт вәкилләре керә (гыйбадәт йорты П.Лумумба урамында урнашкан).

*Әд.:* Кречмар Г., Ратке Г. Евангелическо-лютеранская церковь в России, на Украине, в Казахстане и Средней Азии. СПб., 1996; Куриль О.В. Очерки по истории лютеран в России (XVI–XX вв.). М., 1996; Лиценбергер О.А. Евангелическо-лютеранская церковь и советское государство (1917–1938). М., 2000; Корнилов И.П. Протестанские организации в Республике Татарстан // Ислам и христианство в диалоге культур на рубеже тысячелетий. К., 2001; Современная религиозная жизнь России: Опыт систематического описания. М., 2003. Т. 2; Религии и религиозные объединения в Республике Татарстан: Справ. К., 2004.

*И.П.Корнилов.*

**ЛЮ́ТКИНО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 17 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Л.да Изге Гурий чиркәве, земство мәктәбе (1884 тә ачыла), кредит ширкәте, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3521,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 906, 1897 дә — 1145, 1908 дә — 1306, 1920 дә — 1374, 1926 да — 1559, 1949 да — 836, 1958 дә — 866, 1970 тә — 358, 1979 да — 54, 1989 да — 14, 2002 дә — 7 кеше.

**ЛЮЦЕ́РНА** (Medicago), кузаклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 36 төре билгеле, шуларның 20 се — күпьеллыклар. Берьеллыклардан колмаксыман Л. үстерелә. Күпьеллыклардан 2 төп төре таралган: сары Л. һәм зәңгәр Л. Җитештерүдә иң мөһим урынны алып торучы табигый яисә ясалма серкәләндерү нәтиҗәсендә булдырылган арадаш төрләр зәңгәр-гибрид Л., сары-гибрид Л., чуар-гибрид Л. ТР да киң таралган. Л.ның күпьеллык төрләре тамырның туфрак өслегеннән 3–7 *см* тирәнлектә урнашкан юан өлешеннән таралучы күпсанлы сабаклы зур куак барлыкка китерә. Аңардан яз көне һәм чабып алганнан соң үрентеләр үсеп чыга. Яфраклары өчләнгән, чәчәк оешмасы — чук, җимеше — күп орлыклы кузак, орлыклары вак (1000 данәнең авырлыгы — 2 *г*), бөресыман, сары-көрән төстә. Үзәк тамыр системалы, көчле үсемлек, тамыры 5 *м* га кадәр тирәнлеккә, җиңел туфракларда 10 *м* га кадәр җитә. Тамырларының төп өлеше сөрү катламында урнашкан. Нәзек тамырларында үскеннәр (бүлбе бактерияләре) бар, алар атмосферадан азот туплауга сәләтле. Симбиотик сәләткә ия булу сәбәпле, Л.ның тамырларында 150–200 *кг* азот туплана. Л. туфракның структурасын яхшырта, барлык культуралар, аеруча бөртеклеләр өчен яхшы элгәр санала.



Сары люцерна.

Басу чәчү әйләнешендә продукция бирүчәнлеге 1 *га* дан 50–60 *ц* печән (яисә 200–250 *ц* яшел масса) тәшкил итә. Орлык уңышы уртача 1 *га* дан 1 *ц*, уңай килгән елларда (чәчәк ату һәм җимешләнү вакытында кояшлы көннәрнең күп булуы зарур) 1 *га* дан 3 *ц* га җитә. Сугарулы җирләрдә яшел массаның уңышы 1 *га* дан 400–450 *ц* (яисә 100–110 *ц* печән) тәшкил итә. ТРда районлаштырылган сортлар: «Айсылу», «Татарская пастбищная», «Мөслимә». Л.ның корткычлары — люцерна ябалакчыгы, люцерна галлицасы, люцерна кандаласы һ.б.; авырулары — тутык, ончыл чык, таплылык.

*М.Ш.Лапина.*

**ЛЯ́НДО** Александр Матвеевич (12.1.1903, Николаев ш. — 20.10.1986, Казан), икътисадчы-финансист, икътисад фән. д-ры (1963), проф. (1965), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1973, 1978). 1921 елда Мәскәү сәнәгать-икътисад ин-тын тәмамлый. 1924–42 дә СССР Финанс халык комис-тында, 1938 гә кадәр Фәнни-тикшеренү ин-тында белгеч, сектор башлыгы урынбасары, 1938–42 дә фәнни хезмәткәр. 1942 дә Казанга эвакуацияләнә, Казан финанс-икътисад ин-тында финанс каф. мөдире, 1978 дән каф. профессоры; бер үк вакытта ТАССР Финанс министрлыгының фәнни консультанты. Хезмәтләре халык хуҗалыгының финанс балансына һәм пр-тиеләрнең финанс-кредит эшчәнлеген планлаштыруга карый.

Хезм.: Вопросы методологии и структуры единого финансового плана. М., 1932; Вопросы финансового баланса народного хозяйства. М., 1963.

**ЛЯ́ПИН** Зиннур (Гусейн) Хөсәен улы (1947, Баку ш.), контр-адмирал (1994). А.С.Попов исем. Югары радиоэлектроника хәрби-диңгез уч-щесен (Ленинград өлкәсе, Петродворец ш., 1970), Югары офицерлар классларын (Ленинград, 1975), Сов. Союзы Маршалы А.А.Гречко исем. Хәрби-диңгез академиясен (Ленинград, 1989) тәмамлый. 1970 елдан Кара диңгез флотында — корабль элемтәсенең хәрби часте (БЧ-4) командиры, корабльләр бригадасы, дивизиясе, Урта диңгез оператив эскадрасы элемтәсе, 1992 дән флотның элемтә башлыгы. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткәне өчен», «Хәрби казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**ЛЯ́ПИН** Николай Михайлович (29.9.1940, Кострома ш.), химик, химия фән. д-ры (2001), проф. (2004) ТРның атказ. фән эшлеклесе (2010). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), шунда ук эшли. 1978 елдан Казанда Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында (бүленеп: 1981–84 тә Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тының Ташкент ф-лында директор урынбасары), баш технолог (1997 дән), директор урынбасары (2002–2006). Хезмәтләре югары энергияле кушылмалар һәм алар нигезендә эшләнгән композицион материаллар химиясе һәм технологиясенә карый. Л. фуроксаннар классындагы югары энергетик кушылмаларны синтезлый, аларны барлыкка китерү һәм таркату механизмнарын тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә куркынычлылык ихтималы булган производстволарда куркынычсызлыкны тәэмин итү алымнары системасы һәм приборлары эшләнә, ату кораллары өчен дарыларның яңа буыны һәм аларны җитештерүнең җиңел үзгәртелүле энергия саклаулы репродуктив технологияләре булдырыла (ш.и. саклану срогы чыккан дарылардан). Махсус тематика буенча 7 монография, 200 дән артык мәкалә авторы. Уйлап табуга 120 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР МС (1990), РФ Хөкүмәте бүләкләре лауреаты (2000).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ЛЯ́ПИНА** Нәфисә Кәбир кызы (15.12.1933, БАССРның Кырмыскалы р-ны Сахай а.), нефтехимик, химия фән. д-ры (1983), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). 1955 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, Новоуфимск нефть эшкәртү з-дында эшли. 1956 дан СССР ФАнең Башкортстан ф-лы химия бүлегендә, 1961 дән РФАнең Уфа гыйльми үзәге Органик химия ин-тында, күкерторганик кушылмалар лаб-ясе мөдире (1967 дән), проф. (1986). Хезмәтләре табигый углеводородларның күкерторганик кушылмалары төзелешенә һәм үзлекләренә карый. Л. БДБ илләре һәм РФ чыганакларындагы нефтьнең 74 типтагы күкерторганик кушылмалар компонентлары составын билгели, нефтьтә һәм газ конденсатларында сульфоксидлар һәм сульфоннар булуын ачыклый. Татарстанның Архангельскски–Танай нефть-газ зонасы чыганакларындагы нефтьтә тиаксантеннар һәм элегрәк идентификацияләнмәгән бензо- һәм дибензотиофеннар таба. Күкерторганик кушылмалар концентратларын бүлү методикасын һәм нефть сульфоксидлары алу технологиясен тәкъдим итә. Тәҗрибә өчен нефть сульфидлары һәм сульфоксидлары партияләрен алуда, җитештерү процессын эшләүдә, сирәк мәгъдән элементларын экстракцион чистарту өчен гамәлгә кертүдә катнаша. Углеводород чималын өлешчә

һәм тулысынча демеркаптанлаштыру, ш.у. азот-, күкерт-, һәм кислородлы полифункциональ сульфидлар алып, нефть һәм газ эшкәртү з-дларында сульфид-селтеле агымнарны генерацияләү процессын эшли (сәнәгатьнең һәм а.х.ның төрле тармакларында кулланыла). Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, СССР ВДНХсының ике көмеш һәм бронза медальләре; БАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Современное состояние проблемы исследования органических соединений серы нефтей // Успехи химии. 1982. Т. 51, вып. 2 (автордаш); Химия и физикохимия сераорганических соединений нефтяных дистиллятов. М., 1984; Демеркантанизация карачаганакского и оренбургского газоконденсатов путём алкилтиометилирования и алкилтиилирования винилкетонов // Нефтехимия. 2002. Т. 42, № 5 (автордаш).


**ЛЯПУНО́В** Михаил Васильевич (30.9.1820, Түбән Новгород губ., Васильевск өязе Плетниха а. — 20.11.1868, Түбән Новгород губ. Болобоново а.), астроном. 1939 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казанның Икенче ир балалар гимназиясендә, 1840 тан Казан ун-тында эшли. 1850–55 тә Демидов юридик лицее (Ярославль ш.) директоры. Хезмәтләре планеталарны, Айны, астероидлар һәм йолдызларны күзәтүгә карый. 1842 дә Н.И.Лобачевский һәм Э.А.Кнорр б-н бергә Кояшның тулысынча тотылуын күзәтү өчен Пензага бара. Орион томанлыгын өйрәнү б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**ЛЯШКО́** Анатолий Дмитриевич (3.8.1930, Геленджик ш. — 26.11.2008, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1975), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1988, 1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли, хисаплау математикасы каф. мөдире (1975–98). Хезмәтләре матем. физика мәсьәләләрен чишүнең санлы алымнарына, фильтрлашу һәм сүрүләр теорияләренең нәсызыкча мәсьәләләрен матем. модельләүгә карый. Л. сызыкча мәсьәләләрнең Галёркин алымнарына охшаш алымнар б-н якынча чишелешләрен таба; эллиптик тигезләмәләр һәм пластиналар теориясенең нәсызыкча мәсьәләләрен чишүнең сумматор бердәйлекләр алымын нигезли; нәсызыкча операторлы-аермалар схемаларының коррективлыгы теориясен эшли; нәсызыкча нәстационар тигезләмәләр өчен аермалар схемасының төгәллеген бәяли.

Х е з м.: О некоторых вариантах метода Галёркина-Крылова // Докл. АН СССР. 1959. Т. 128, № 3; Метод прямых для квазилинейных эллиптических уравнений // Дифференциальные уравнения. 1972. Т. 8, № 5; Об исследовании проекционного метода для вырождающихся нестационарных уравнений // Дифференциальные уравнения. 2002. Т. 38, № 7.

ӨСТӘМӘЛӘР



Т.Я.Лапин.

**ЛА́ПИН** Трофим Якимович (9.5.1913, Уфа губ., Минзәлә өязе Яңа Троицкий а. – 24.3.1981, Свердловск ш.), Дан орденының тулы кавалеры (17.3.1944, 25.1.1945, 15.5.1946), гв. сержанты. Балта остасы булып эшли (Свердловск ш.). 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1 нче танк батальонында механик-йөртүче (46 нчы армия һәм 5 нче удар армиянең 2 нче гв. механикалаштырылган корпусындагы 37 нче гв. танк бригадасы). 2 нче, 3 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Украина, Яссы–Кишинёв, Дебрецен (икесе дә — 1944), Будапештны (1944–45) азат итүдә, Вена һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 31 гыйнварыннан 6 февральгә кадәр (танк экипажы дошманның 2 орудиесен һәм 9 пулемётын юк итә); Зур һәм Рече Лепетиха (Днепропетровск өлкәсе) авылларыннан 10–12 *км* төньяк-көнчыгыштарак Днепр елгасы янындагы Никополь плацдармын яулауда; 1944 нең 4 ноябрендә (дошманның сугыш кораллары складын, 2 пулемётын һәм 4 йөк автомашинасын юк итә) Фелшепаконь (Венгрия) торак пункты тирәсендә танклар рейды вакытында; 1945 нең 20 мартында (танк экипажы составында 3 миномёт, 4 пулемёт һәм сугыш кирәк-яраклары төягән 3 йөк арбасын юк итә) Насааи һәм Альмаш (Венгрия, Тата шәһәреннән 5–8 1 *км* төньяк-көнбатыштарак) торак пунктлары өчен сугышларда батырлык күрсәтә. 1945 елда демобилизацияләнә. Свердловск шәһәрендә төзелеш идарәсендә балта остасы булып эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Созвездия Славы. Свердловск, 1975; Солдатская слава. Свердловск, 1925; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**ЛАТЫ́ЙПОВ** Рөстәм Мәсгут улы (20.12.1947, Казан – 3.12.2011, шунда ук), эшмәкәр, композитор М.*Латыйпов* улы. 1971 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1972–80 дә Татгражданпроект, Казгражданпроект оешмаларында эшли. И.С.Бах иҗатына багышланган, 1998 елдан башлап, фортепиано, скрипка, альт, виолончель, флейта номинацияләре буенча ел саен уздырыла торган Республика конкурсының (2012 дән — халыкара) гамәлгә куючысы һәм меценаты. Конкурсларда 300 дән артык бала катнаша, 150 се лауреат һәм дипломант исеменә лаек була. Араларында абруйлы халыкара конкурслар лауреатлары, оста башкаручылар булып танылган музыкантлар бар (Т.Мөстәкыймов, С.Гуляк, З.Фәхразиев, А.Гыйбадуллина, К.Егорычев, М.Монасыйпов һ.б.). Конкурс яшь талантлардан И.С.Бах музыкасы аша чын музыкант шәхесе тәрбияләүгә хезмәт итә. Л. ш.у. татар композиторлары иҗатын, татар халык көйләрен, балалар өчен муз. әсәрләр туплап, нота басмалары нәшер итүче «Еникиева нәшрияты»н (1994) гамәлгә куючы да. Нәшер ителгән басмалар: «Фортепиано өчен җиңелчә эшкәртелгән йөз татар халык җыры (җыр текстлары белән)» (К., 1999), «Фортепиано өчен җиңелчә эшкәртелгән йөз утыз татар халык җыры (җыр текстлары б-н)» (К., 2005), татар композиторларының мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен язылган җырларыннан өч җыентык: «Кояшкай кайда йоклый?», «Балалар җырлары» (Г.Зәйнәшева шигырьләре), «Кил, Нәүрүз» (К., 1996, 2001, 2003) һ.б. Хор, вокаль һәм инстументаль музыка әсәрләре тупланган барлыгы 30 га якын җыентык. Л. тарафыннан Татарстан музыка мәдәнияте һәм белеме үсешенә зур өлеш кертелә.

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ТӨП КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
абс. — абсолют
авг. — август
адм. — администрация, административ
адм.-терр. — административ-территориаль
акад. — академик, академия
акц. — акционерлык
апр. — апрель
арх. — архитектор
архит-ра — архитектура
атказ. — атказанган
атм. — атмосфера
а.м. — атом массасы
а.х. — авыл хуҗалыгы
әзәрб. — әзәрбайҗан
башк. — башкорт
балетм. — балетмейстер
биол. — биология, биологик
вет. — ветеринария
б.к. — баш килеш
г-та — газета
б.э. — безнең эра
б.э.к. — безнең эрага кадәр
гарәп. — гарәпчә (гарәп теленнән)
гв. — гвардия, гвардияче
ген. — генераль
геогр. — география, географик
геол. — геология, геологик
геом. — геометрия, геометрик
гинекол. — гинекология, гинекологик
геоморфол. — геоморфология
гистол. — гистология
гыйн. — гыйнвар
грек. — грекча (грек теленнән)
губ. — губерна
дек. — декабрь
дис. — дисәтинә
д-р — доктор
ж-л — журнал
з-д — завод
зоол. — зоология
инстр-т — инструмент
илл. — иллюстрация
ин-т — институт
ингл. — инглизчә (инглиз теленнән)
исем. — исемендәге
ит. — итальянча (итальян теленнән)
к. — кара(гыз)
канд. — кандидат
к-та — кислота (исем янында)
К$^{о}$ — компания
кап. — капиталь (төзелеш)
каф. — кафедра
кв. — квадрат
к-з — колхоз
ком. — командир
ком-т — комитет
комис-т — комиссариат
комп. — композитор
комб-т — комбинат
конф. — конференция
коэф. — коэффициент
крист. — кристаллик
к/т — кинотеатр
күпл. — күплек (саны)
лаб., лаб-я — лаборатория
лат. — латинча (латин теленнән)
либр. — либретто
лингв. — лингвистика
макс. — максималь
матем. — математика, математик
мәс. — мәсьәлән
мед. — медицина
метеорол. — метеорология
минерал. — минералогия
миним. — минималь
мифол. — мифология
млн. — миллион
млрд. — миллиард
монгол. — монголча (монгол теленнән)
морфол. — морфология, морфологик
муз. — музыкаль
нем. — немецчә (немец теленнән)
неол. — неологизм
норм. — нормаль
нояб. — ноябрь
окт. — октябрь
Окт. рев-циясе — Октябрь революциясе (1917)
пасс. — пассажир
пед. — педагогика, педагогия, педагогик
пос. — посёлок
пр-тие — предприятие
проф. — профессор, профессиональ
псевд. — псевдоним
психол. — психология, психологик
публ. — публикация
райком — район комитеты
райсовет — район советы
ревком — революцион комитет
рев-ция — революция
реж. — режиссёр
рентгенол. — рентгенология
респ-ка — республика
р-н — район
сан.-эпид. — санитария-эпидемиология
сент. — сентябрь
с.-д. — социал-демократлар
симф. — симфоник, симфония
скульп. — скульптор
сов. — совет(лар)
с-з — совхоз
соц. — социалистик
социол. — социология, социологик
ст. — станция
стат. — статистика, статистик
стомат. — стоматология
т. — том
темп-ра — температура
терр. — территориаль
терр-я — территория
технол. — технология, технологик
төрки. — төркичә (төрки телләрдән)
ун-т — университет
ур. — урам
уч-ще — училище
фарм. — фармацевтика, фармацевтик
фармакол. — фармакология
фарсы. — фарсыча (фарсы теленнән)
фән. — фәннәр
февр. — февраль
физиол. — физиология, физиологик
филол. — филология
филос. — философия
ф-ка — фабрика
ф-л — филиал
ф-ла — формула
ф-т — факультет
фр. — французча (француз теленнән)
һ.б. — һәм башкалар
һ.б.ш. — һәм башка шундый
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок
ш.и. — шул исәптән
ш.у. — шулай ук
ш.у.к. — шулай ук кара
экз. — экземпляр

## ШӘҺӘР ИСЕМНӘРЕНДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР
(библиографиядә)

### Татар/рус телләрендә

А.-А. — Алма-Ата
Аш. — Ашхабад
Г. — Горький
Дүш./Душ. — Дүшәнбе/Душанбе
Ер. — Ереван
К. — Казан/Казань
Киш. — Кишинёв
Л. — Ленинград
М. — Мәскәү/Москва
М.—Л. — Мәскәү—Ленинград/Москва—Ленинград
Н. Новгород — Нижний Новгород
Наб. Челны — Набережные Челны
Новосиб. — Новосибирск
Од. — Одесса
П. — Петроград (Петербург)
Ростов н/Д. — Ростов-на-Дону
СПб. — Санкт-Петербург
Тал. — Таллин
Таш. — Ташкент
Тб. — Тбилиси
Фр. — Фрунзе
Хар. — Харьков

### Чит ил телләрендә

Amst. — Amsterdam
Antw. — Antwerpen
B. — Berlin
Balt. — Baltimore
Bdpst. — Budapest
Brat. — Bratislava
Brux. — Bruxelles
Buc. — Bucuresti
Camb. — Cambridge
Chi. — Chicago
Cph. — Copenhagen, Copenhague
Fr./M. — Frankfurt am Main
Gen. — Geneve
Hamb. — Hamburg
Hdlb. — Heidelberg
Hels. — Helsingfors, Helsinki
Ist. — Istanbul
L. — London
Los Ang. — Los Angeles
Lpz. — Leipzig
Mass. — Massachusetts
Melb. — Melbourne
Mex. — Me ̌xico
Mil. — Milano
Münch. — München
N.Y. — New York
Oxf. — Oxford
P. — Paris
Phil. — Philadelphia
Rio de J. — Rio de Janeiro
S.F. — San Francisco
Stockh. — Stockholm
Stuttg. — Stuttgart
W. — Wien
Warsz. — Warszawa
Wash. — Washington
Z. — Zürich

Башка шәһәрләрнең исемнәре кыскартылмыйча бирелә.

## БИБЛИОГРАФИЯДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР

әд. — әдәбият
әсәр. — әсәрләр
библиогр. — библиография
бюл. — бюллетень
вестн. — вестник
дис. — диссертация
докл. — доклад(лар)
журн. — журнал (лар)
зап. — записки
кис. — кисәк
кит. — китап
конгр. — конгресс
конф. — конференция
реф. — реферат
рец. — рецензия
т. — том
тәрҗ. — тәрҗемәче
төз. — төзүче
у. һәм е.к. — урыны һәм елы күрсәтелмәгән
хезм. — хезмәт(ләр)
чыг. — чыганак
экз. — экземпляр
энцикл. — энциклопедия

## АББРЕВИАТУРАЛАР

ААЖ — ачык акционерлык җәмгыяте
АЖ — акционерлык җәмгыяте
АКШ — Америка Кушма Штатлары
АТС — автоматлаштырылган телефон станциясе
БАССР — Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
БДБ — Бәйсез Дәүләтләр Берлеге
БР — Башкортстан Республикасы
БҮБК — Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты
ВАСХНИЛ — Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе (Всесоюзная академия сельскохозяйственных наук имени Ленина)
ВДНХ — Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (Выставка достижений народного хозяйства)
ВКП(б) — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ВЛКСМ — Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (Всесоюзный ленинский коммунистический союз молодёжи)
ВНИВИ — Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский ветеринарный институт)
ВНИИгеолнеруд — Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский институт геологии полезных ископаемых)
ВРК — Вакытлы революцион комитет (Временный революционный комитет)
ВЧК — Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (Всероссийская чрезвычайная комиссия)
ВЦСПС — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы (Всесоюзный центральный совет профессиональных союзов)
ГИДУВ — Табибләрнең белемен күтәрү дәүләт институты (Государственный институт для усовершенствования врачей)
ГЭС — гидроэлектростанция
ДОСААФ — Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту)
ЖБ — җитештерү берләшмәсе
ҖЧҖ — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КамАЗ — Кама автомобиль заводы
КБ — конструкторлык бюросы
КГБ — Дәүләт иминлеге комитеты (Комитет государственной безопасности)
КГҮ — Казан гыйльми үзәге
КОМУЧ — Учредительләр җыены әгъзалары комитеты (Комитет членов учредительного собрания)
КОМЗ — Казан оптик механика заводы
КП — Коммунистлар партиясе
КПО ВС — Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе (Казанское производственное объединение вычислительных систем)
КПСС — Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
КЭМСТ — Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе (Конструктивно-экспериментальная мастерская современного театра)
МК — Министрлар Кабинеты
МС — Министрлар Советы
МТС — машина-трактор станциясе
НГДУ — нефть һәм газ чыгару идарәсе (нефтегазодобывающее управление)
НКВД — Эчке эшләр халык комиссариаты (Народный комиссариат внутренних дел)
нэп — яңа икътисади сәясәт (новая экономическая политика)
ОГПУ — Дәүләтнең берләштерелгән сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление)
ОСОАВИАХИМ — Авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (Общество содействия авиационному и химическому строительству)
ПТУ — профессиональ-техник училище
ПФА — Педагогия фәннәре академиясе
РАХФА — Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе
РВС — Революцион хәрби совет (Революционный военный совет)
РМА — Россия Мәгариф академиясе
РМФА — Россия Медицина фәннәре академиясе
РОСТО — Россия оборона-спорт техник оешмасы (Российская оборонно-спортивная техническая организация)
РСДРП — Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (Российская социал-демократическая рабочая партия)
РСФСР — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ — Россия Федерациясе
РФА — Россия Фәннәр академиясе
СА — Сәнгать академиясе
СК — спорт клубы
СССР — Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТМР — төш магнит резонансы
ТР — Татарстан Республикасы
ТССР — Татарстан Совет Социалистик Республикасы
ТЭЦ — җылылык-электр үзәге (теплоэлектроцентраль)
ФА — Фәннәр академиясе
ФҖБ — фәнни-җитештерү берләшмәсе
ХКС — Халык комиссарлары советы
ХХС — Халык хуҗалыгы советы
ЦНИИгеолнеруд — Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (Центральный научно-исследовательский институт геологии нерудных полезных ископаемых)
ЧК — Гадәттән тыш комиссия (Чрезвычайная комиссия)
ҮК — Үзәк Комитет
ҮБК — Үзәк Башкарма Комитеты
ЭПР — электрон парамагнит резонансы
ЮС — Югары Совет
ЯАЖ — ябык акционерлык җәмгыяте

## ЗУРЛЫК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ КЫСКАРТУЛАРЫ

*А* — ампер
*а.б.* — астрономик берәмлек
*а.к.* — ат көче
*В* — вольт
*Вб* — вебер
*В·А* — вольт-ампер
*Вт* — ватт
*Гн* — генри
*Гц* — герц
*Гпа* — гектопаскаль
*Гс* — гаусс
*г* — грамм
*га* — гектар
*град* — почмакча градус
*Дж* — джоуль
*дБ* — децибел
*дал* — декалитр
*дптр* — диоптрия
*К* — кельвин
*кВт·сәг.* — киловатт-сәгать
*кал* — калория
*кар* — карат
*кг* — килограмм
*Кл* — кулон
*км* — километр
*л* — литр
*лк* — люкс
*лм* — люмен
*м.а.б.* — массаның атом берәмлеге
*м* — метр
*мг* — миллиграмм
*мин.* — минут
*мкм* — микрометр
*мм* — миллиметр
*Н* — ньютон
*окт* — октава
*Па* — паскаль
*рад* — радиан
*с* — секунд
°*С* — градус (Цельсий шкаласы буенча)
*сәг.* — сәгать
*см* — сантиметр
*т* — тонна
*Ф* — фарад
*Э* — эрстед
*эВ* — электронвольт
‰ — промилле

## КАРТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

(җәя эчендә бит саны күрсәтелә)

Т а р и х и   к а р т а л а р.
Казан губернасы (66), Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–1556 еллар) (75), Казан өязе (113), Казан ханлыгы (155), 1552 елда Казанның рус гаскәрләре тарафыннан камалышы (194), Козьмодемьянск өязе (414), Казан төбәгендә крәстияннәр кузгалышы (1773–1775 еллар) (524), Кырым ханлыгы (631), Лаеш кантоны (643), Лаеш өязе (644).

Р а й о н н а р ы н ң   а д м и н и с т р а т и в   к а р т а л а р ы.
Кайбыч районы (211), Кама Тамагы районы (227), Кукмара районы (555), Лаеш районы (645), Лениногорск районы (671).

## КАРТАЛАРДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
исем. — исемендәге
пос. — посёлок
р-н — район
с-з — совхоз
ш. — шәһәр
штп. — шәһәр тибындагы посёлок

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КАРТАЛАРЫНДА

**Торак пунктлар**

Татарстан Республикасы башкаласы - Казан шәһәре
Район үзәкләре

Төре буенча

ЛЕНИНОГОРСК — Шәһәрләр
КУКМАРА — Шәһәр тибындагы посёлоклар
*Тимәш* — Авыл тибындагы торак пунктлар

Яшәүчеләр саны буенча

10 000 һәм аннан артыграк
1000 нән 10 000 гә кадәр
500 дән 1000 гә кадәр
500 дән кимрәк

**Чик билгеләре**

Республика һәм өлкәләр арасында
Районнар арасында

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
1Р 241 — Төп автомобиль юллары һәм аларның номерлары
а, б — Башка төр автомобиль юллары:
а) түшәүле юллар
б) түшәүсез юллар

Елгалар
Сусаклагычлар

### ТАССР КАНТОННАРЫ КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Татарстан АССР 1921 елда
Татарстан Республикасы 2011 елда
Татарстан АССР кантоннары 1921 елда

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

### ӨЯЗЛӘР КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Россия империясенең 1890 нчы еллардагы губерналары
Өязләр

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

# Татар энциклопедиясенең фәнни мөхәрририяте

**Археология.** Ф.Ш.Хуҗин (рәис), А.Ә.Борһанов, Р.М.Вәлиев, Е.П.Казаков, А.Г.Ситдыйков.
**Архитектура.** С.С.Айдаров (рәис), Г.Н.Айдарова, Х.Г.Надыйрова, С.П.Саначин, Н.Х.Халитов.
**Астрономия.** Н.А.Сәхибуллин (рәис), Е.Е.Беляева, И.Ф.Бикмаев, Р.В.Заһретдинов, Н.Г.Ризванов.
**Биология.** А.А.Җәләлов (рәис), В.А.Бойко, В.И.Гаранин, Р.Я.Гыйльметдинов, Р.Х.Фәйзрахманова.
**География.** Ю.П.Переведенцев (рәис), А.Х.Газизуллин, Ю.А.Горшков, Э.П.Наумов, В.А.Рубцов.
**Геология.** Д.К.Нургалиев (рәис), У.Г.Дистанов, Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков, Р.Р.Хәсәнов.
**Дәүләт һәм хокук.** В.П.Малков (рәис), Н.В.Бахарев, Б.Л.Железнов, Г.И.Курдюков, И.Г.Тарханов, Р.Ш.Хафизов.
**20 йөзгә кадәрге Татарстан һәм татар халкы тарихы.** М.Г.Госманов (рәис), И.К.Заһидуллин, И.Л.Измайлов, Ф.Г.Ислаев, А.А.Литвин, Д.Г.Мостафина.
**20—21 йөзләр Татарстан һәм татар халкы тарихы.** И.Р.Таһиров (рәис), Р.К.Вәлиев, И.А.Гыйләҗев, Р.Р.Салихов, О.В.Синицын, Р.В.Шәйдуллин.
**20 йөзгә кадәрге татар әдәбияты.** Х.Й.Миңнегулов (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.К.Ганиева, Р.Ф.Исламов, Н.Ш.Хисамов.
**20—21 йөзләр татар әдәбияты.** Д.Ф.Заһидуллина (рәис), А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Р.Ф.Рахмани, Р.Г.Фәйзуллин, Р.М.Харисов.
**Икътисад.** Ф.Г.Газизуллин (рәис), В.П.Захаров, В.А.Мальгин, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев, Ә.Ш.Хәсәнова, В.В.Хоменко.
**Массакүләм мәгълүмат чаралары.** В.З.Гарифуллин (рәис), Е.С.Дорощук, Р.М.Нуруллина, Р.А.Ратникова.
**Математика.** М.М.Арсланов (рәис), А.М.Елизаров, Д.Х.Мөштәри, Э.В.Скворцов.
**Медицина. Сәламәтлек саклау.** М.К.Михайлов (рәис), Н.Х.Әмиров, В.Х.Фазылов.
**Музейлар.** Г.Р.Нәҗипова (рәис), С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташова, Р.М.Нургалиева, Л.И.Саттарова.
**Музыка.** Р.К.Абдуллин (рәис), В.Н.Горшков, В.Р.Дулат-Алиев, А.Л.Маклыгин, Ш.Х.Монасыйпов, З.Н.Сәйдәшева, В.М.Спиридонова.
**Педагогика, халык мәгарифе.** Ә.Н.Хуҗиәхмәтов (рәис), М.М.Гыйбатдинов, Җ.Г.Нигъмәтов, Ф.Ә.Шәрифуллин, И.Э.Ярмәкиев.
**Рус әдәбияты.** А.М.Сәяпова (рәис), Л.С.Ачкасова, В.В.Корчагин, Р.Ә.Мостафин, В.И.Шишкин.
**Сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә.** Ш.М.Вәлитов (рәис), И.Ш.Мостюков, Р.З.Рәхимов, И.Ш.Рахманкулов, К.Ф.Фәсхетдинов.
**Сынлы сәнгать.** Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова (рәис), А.Ә.Абызгилдин, Е.П.Ключевская, З.Ф.Гыймаев, Х.Г.Якупов.
**Театр сәнгате.** А.Г.Әхмәдуллин (рәис), М.Г.Арсланов, Ю.А.Благов, Д.Ә.Гыймранова, И.И.Илялова.
**Тел белеме.** М.З.Зәкиев (рәис), Л.К.Бәйрәмова, И.Б.Бәширова, Ф.Ә.Ганиев, Ф.Ш.Нуриева, Д.Б.Рамазанова.
**Терлекчелек. Ветеринария.** Р.Г.Госманов (рәис), А.М.Алимов, А.В.Иванов, Н.Н.Мөхәммәтгалиев, К.Х.Папуниди, М.Ш.Шәкүров.
**Техника һәм технология.** Ш.М.Чабдаров (рәис), Р.И.Әдһәмов, О.Ш.Даутов, И.М.Закиров, С.О.Мирумянц.
**Торак пунктлар тарихы.** М.И.Әхмәтҗанов (рәис), Д.Г.Мостафина, А.И.Ногманов, Р.Р.Хәйретдинов.
**Үсемлекчелек.** Г.Г.Җиһаншин (рәис), Е.И.Захарова, Ф.З.Кадыйрова, М.Л.Пономарёва, И.П.Таланов.
**Фәлсәфә һәм дин.** Р.М.Мөхәммәтшин (рәис), В.П.Козлов, Н.М.Мөхәррәмов, Р.Ә.Нәбиев, Р.М.Нугаев, Ф.М.Солтанов.
**Физик культура һәм спорт.** Х.Х.Шәйхетдинов (рәис), Р.А.Абзалов, А.Ш.Баһаветдинов, Н.Д.Бобырев, И.Г.Илдарханов, З.Н.Пантелеева, А.М.Яруллина.
**Физика.** К.М.Салихов (рәис), В.А.Голенищев-Кутузов, Ә.В.Ильясов, И.В.Овчинников, В.В.Самарцев.
**Фольклор.** Ф.И.Урманчеев (рәис), Л.Ш.Җамалетдинов, Х.Ш.Мәхмүтов.
**Хәрби эшлекләләр, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары.** А.А.Иванов (рәис), Н.Х.Булатов, И.И.Мостюков, В.Ф.Телишев, С.Н.Погодин, М.В.Черепанов.
**Химия һәм химия технологиясе.** В.П.Барабанов (рәис), Г.К.Будников, А.О.Визель, В.И.Галкин, Ф.П.Мадякин.
**Этнография.** Д.М.Исхаков (рәис), Р.Н.Мусина, С.В.Суслова, Р.К.Уразманова, В.И.Яковлев.
**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү буенча фәнни мөхәрририят.** М.З.Зәкиев (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Ф.Ә.Ганиев, Ф.Г.Гарипова, Р.М.Мөхәммәтшин, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, Р.Ә.Шакирҗанов, А.Г.Яруллина.

# Татар энциклопедиясе институты

Директоры — тарих фән. д-ры Р.М.ВӘЛИЕВ
Директорның беренче урынбасары — тарих фән. д-ры Р.В.ШӘЙДУЛЛИН
Директор урынбасары — тарих фән. канд. А.И.НОГМАНОВ
Гыйльми секретарь — тарих фән. канд. М.З.ХӘБИБУЛЛИН

*

Татар энциклопедиясенең җаваплы мөхәррире — тарих фән. канд. Г.С.САБИРҖАНОВ

## Бүлекләр

**Энциклопедия басмаларын татар telендә әзерләү бүлеге.** Мөдире — филол. фән. канд. А.Г.Яруллина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: В.Г.Габдрахманова, Л.К.Галиева, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Г.Зәкиева, Ф.Г.Камалетдинова, филол. фән. канд. Г.И.Каюмова, И.Г.Нигъмәтҗанов, Г.Х.Нургалиева, Р.И.Хәлиуллина; әдәби мөхәррирләр төркеме: житәкчесе — Ф.Ә.Шәрифуллин, 2011 елдан И.Х.Хәлиуллин; мөхәррирләр: Ф.Р.Бәдретдинова, Р.С.Вафина, С.С.Шәмси; корректор Ф.Г.Макарова.

**Биология, география һәм геология бүлеге.** Мөдире — а.х. фән. канд. Ф.Г.Борһанов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән. канд. В.Г.Бакирова, геол.-минерал. фән. канд. Э.Х.Рәхмәтуллин, О.В.Ерёгин, Л.Р.Камалиева, Р.Э.Рәхмәтуллин.

**Икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге**. Мөдире — Г.Я.Мәүлетова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: икътисад фән. д-ры Ф.С.Зыятдинов, а.х. фән. д-ры Ә.Х.Фазылҗанов, а.х. фән. канд. Р.Ә.Әсретдинова, икътисад фән. канд. М.Җ.Гаитов, И.Н.Афанасьев, С.Г.Белов.

**Иллюстрацияләр һәм картография бүлеге**. Мөдире — Ф.Ә.Ибраһимова, өлкән фәнни хезмәткәрләр: геогр. фән. канд. Г.Н.Булатова, Г.Р.Дәүләтьянова, Р.Г.Нурмөхәммәтов; фәнни хезмәткәрләр: Л.Н.Донина, Р.А.Фәсахова; фотограф Р.Н.Шакиров.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәният учреждениеләре бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. Р.А.Айнетдинов; өлкән фәнни хезмәткәр, филол. фән. канд. З.З.Гыйләҗев.

**Медицина, сәламәтлек саклау һәм спорт бүлеге**. Мөдире — биол. фән. канд. Р.Г.Исхакова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: пед. фән. канд. Н.Д.Бобырев, Л.Ф.Ильина; фәнни хезмәткәр Ф.Ф.Нуриева.

**Рус телендәге текстларны редакцияләү бүлеге**. Мөдире — пед. фән. канд. И.И.Барабанова, 2012 елдан С.А.Ярмөхәммәтова; редактор Р.Х.Нуриев; корректорлар: Ф.Ш.Әхмәтҗанова, А.Ш.Закирова, Л.Т.Нигъмәтҗанова.

**Табигать һәм техник фәннәр бүлеге.** Мөдире — биол. фән. канд. Г.Г.Осокина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: физ.-матем. фән. д-ры Р.Г.Усманов, В.Г.Абзалова, фәнни хезмәткәр Л.Р.Хәлилова.

**Тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге.** Мөдире — тарих фән. д-ры Р.В.Шәйдуллин; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. д-ры Е.П.Казаков, тарих фән. канд-тлары Л.М.Айнетдинова, Р.Х.Әхмәтҗанов, Р.Р.Батыршин, И.Р.Вәлиуллин, Е.Б.Долгов, Ф.Г.Кәлимуллина, Ф.Г.Миңнеханов, Р.Ә.Нәбиев, М.З.Хәбибуллин; өлкән фәнни хезмәткәр А.В.Климин.

**Тел белеме һәм әдәбият бүлеге**. Мөдире — филол. фән. канд. Р.Р.Мусабәкова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: филол. фән. д-рлары Ф.И.Урманчеев; филол. фән. канд. А.М.Ахунов, Л.Р.Әскәрова, Г.М.Габделхакова, Л.Т.Нигъмәтҗанова.

**Торак пунктлар тарихы бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. А.И.Ногманов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Р.Р.Ибраһимов, Х.Ә.Абдулкаюмов, С.А.Фәйзуллин; фәнни хезмәткәрләр: Э.В.Әбдрәхимова, Д.М.Васильев.

**Мәгариф һәм мәдәният бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. Е.П.Липаков; өлкән фәнни хезмәткәрләр: сәнгать фән. д-рлары Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Ф.Ш.Салитова, архит. фән. канд. Х.Г.Надыйрова, Ф.Ә.Әхмәтшина, Ю.А.Благов.

**Фәнни мәгълүмат хезмәте һәм библиография бүлеге**. Мөдире — Р.Ф.Шәрәпова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Э.Г.Сәйфетдинова, Г.Р.Садриева, Э.Т.Сибагатуллина; әйдәп баручы библиографлар: Р.М.Вовченко, Н.Ф.Мироновская.

**Фәнни методика һәм контроль бүлеге.** Мөдире — биол. фән. канд. И.Г.Кадошникова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән. д-ры Н.Н.Максютова, А.В.Гарзавина, Р.И.Гурьянова, Т.П.Жучкова, Л.М.Сәхапова.

**Фәнни нәшрият бүлеге.** Мөдире — техник фән. канд. Р.Р.Сәләхиев; программист Г.Х.Галимуллина; компьютерда җыючылар: Л.С.Касимова, Г.К.Кәримова, А.Б.Насыйбуллина, И.И.Насыйбуллина, Л.Р.Хисамиева.

* * *

**Бухгалтерия.** Баш бухгалтер Н.Г.Локманова, бухгалтер-икътисадчы А.Н.Вәлиева.

**Канцелярия мөдире** Г.Р.Вәлиуллина.

**Кадрлар буенча белгеч** Г.Н.Харисова.

**Маркетинг һәм хуҗалык эшләре бүлеге**. Мөдире — Е.С.Чиляков, хуҗалык бүлеге башлыгы Е.Н.Алькова, склад мөдире — З.Н.Таҗиева.

## ТЭ 3нче томының авторлар исемлеге

Р.К.Абдуллин, В.Г.Абзалова, Ш.Ш.Абилов, Г.Н.Айдарова, Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова, И.М.Айтуганов, И.Е.Алексеев, Е.П.Алексеева, Н.М.Алиев, А.М.Алимов, И.Ф.Алиуллов, Т.Г.Алмазова, В.Н.Анисимов, В.А.Анохин, Н.А.Антонова, В.А.Архипов, И.Н.Афанасьев, Н.И.Афанасьева, Е.В.Афонина, А.М.Ахунов, Р.М.Әминова, Н.Х.Әмиров, Р.Г.Әмирханов, Р.М.Әмирханов, Л.Р.Әскәрова, Р.Ә.Әсретдинова, Г.А.Әүхәдиева, К.А.Әхәтов, А.Г.Әхмәдуллин, Л.М.Әхмәдуллина, Л.Ә.Әхмәтҗанов, М.И.Әхмәтҗанов, Ф.Ә.Әхмәтшина, Р.С.Бакиров, В.Г.Бакирова, Р.Р.Батыршин, Г.А.Бәдретдинова, М.Ш.Бәдретдинова, Л.К.Бәйрәмова, И.Б.Бәширова, С.Г.Белов, Е.Е.Беляева, Е.А.Бердников, Т.В.Бизяева, В.Н.Бирин, Г.Н.Бирюлёв, Ю.А.Благов, Т.И.Благовещенская, Н.Д.Бобырев, В.Н.Богданов, В.Ф.Богоявленский, В.А.Бойко, В.П.Болдырев, А.Ә.Борһанов, Ф.Г.Борһанов, Р.Г.Бохараев, Ю.В.Брыков, Л.П.Бурмистрова, Г.П.Бутаков, Р.С.Вафина, Ә.Р.Вәлиев, Р.К.Вәлиев, Рамил М. Вәлиев, Рафаэль М. Вәлиев, Ф.Б.Вәлиев, Ф.З.Вәлиев, Р.М.Вәлиева, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Н.Б.Вәлитов, И.Р.Вәлиуллин, Б.М.Вәлишев, О.Г.Вербина, М.А.Верещагин, Р.Г.Власова, Р.С.Габәшев, А.Р.Габәши, Г.Г.Габделганиева, Х.Ә.Габделкаюмов, Г.М.Габделхакова, Э.В.Габдрәхимова, Р.Р.Габдуллин, Г.Н.Гаврилина, В.И.Гаврилов, А.Х.Газизуллин, М.Җ.Гаитов, М.В.Гайнетдинов, М.З.Гайнетдинов, Ә.М.Галиев, М.Ш.Галимова, А.С.Галявич, В.Х.Ганиев, Ф.Ә.Ганиев, Р.К.Ганиева, В.И.Гаранин, А.В.Гарзавина, Ф.Х.Гафурова, Х.З.Гаффаров, Р.С.Гәрәев, Г.Б.Гобәйдуллина, Т.В.Голубцова, С.Г.Гордиенко, О.Л.Горшевникова, В.Н.Горшков, М.А.Горшков, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, Е.И.Григорьев, Я.Я.Гришин, Ф.Ф.Гулова, В.И.Гуськов, Ф.А.Гыйбатдинов, И.Г.Гыйззәтуллин, Н.Г.Гыйззәтуллин, И.А.Гыйләҗев, Р.Я.Гыйльметдинов, Д.Ә.Гыймранова, С.И.Даишев, Г.Л.Дегтярёв, А.П.Дедков, У.Г.Дистанов, Е.Б.Долгов, Н.Ф.Домашов, Ю.Н.Дрешер, В.А.Евплов, М.С.Ежкова, А.М.Елдашев, А.М.Елизаров, С.С.Елизарова, О.В.Ерёгин, А.К.Жеребцов, Г.В.Жуков, Л.Ш.Җамалетдинов, Р.Ә.Җәләлиев, А.А.Җиһаншин, Ә.М.Закирҗанов, И.М.Закиров, Т.Р.Закирова, Г.Р.Заманова, М.М.Зарипов, Д.Ф.Заһидуллина, Җ.Г.Зәйнуллин, М.З.Зәкиев, Н.В.Звёздочкина, Р.М.Зелеев, Л.А.Зенитова, Ф.С.Зыятдинов, Р.Р.Ибраһимов, Ә.И.Ибраһимова, Ф.И.Ибраһимова, А.В.Иванов, Г.Г.Идиятуллина, И.Л.Измайлов, С.Ю.Измайлова, Г.Е.Изотов, И.Г.Илдарханов, М.И.Ильина, Н.Б.Ильинский, И.И.Илялова, Р.Н.Имангалиев, С.И.Ионенко, Р.Ф.Исламов, Г.Г.Исмәгыйлев, Д.М.Исхаков, Р.Г.Исхакова, Р.Р.Исхакова, С.Х.Исхакова, Э.А.Ишмаев, Н.М.Йосыпова, М.М.Кавиев, С.И.Кадошников, И.Г.Кадошникова, Е.П.Казаков, Л.Р.Камалиева, Б.А.Канеев, В.Д.Капитов, Н.П.Капитонова, И.Ю.Карпилова, Е.И.Карташёва, Ф.Г.Кәлимуллина, А.В.Климин, Е.П.Ключевская, И.К.Козин, Р.Ә.Колшәрипова, Е.Д.Кондратьева, Т.А.Кондратьева, М.Е.Королёв, Л.И.Корчагина, Б.И.Кочелаев, О.В.Краснов, Г.А.Кринари, В.А.Кузнецов, Н.А.Кузнецов, Е.В.Кузьмина, А.В.Лапин, М.Ш.Лапина, Е.В.Липаков, О.Д.Любарская, Ә.М.Мазһаров, Л.Г.Макарова, А.Л.Маклыгин, В.А.Максимов, А.В.Малёв, Б.З.Малкин, Р.З.Мансуров, В.И.Маркелов, Л.А.Мартынова, В.Г.Марфин, Е.С.Маслова, Л.И.Машонкина, Н.К.Мәҗитов, Г.Я.Мәүлетова, Х.Ш.Мәхмүтов, А.Х.Мәхмүтова, С.Н.Медведев, Х.Й.Миңнегулов, Г.Г.Миңнекәев, Ф.Г.Миңнеханов, Җ.С.Миңнуллин, Л.Җ.Миңнуллина, Н.В.Мироновская, М.К.Михайлов, Н.М.Морадымов, В.П.Морозов, Л.М.Мортазина, В.С.Мостафин, Д.Г.Мостафина, Л.В.Мошкова, А.Р.Мөдәрисов, И.М.Мөлеков, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Н.Н.Мөхәммәтгалиев, Р.М.Мөхәммәтшин, Ш.Н.Мулаянов, Р.Р.Мусабәкова, Г.С.Муханов, И.Н.Надыйров, Х.Г.Надыйрова, Т.М.Насыйров, Э.П.Наумов, Ф.Г.Нәбиев, К.А.Нәҗипова, Р.И.Нәфыйков, С.Н.Неуструева, А.З.Нигамаев, Л.Т.Нигъмәтҗанова, И.А.Новицкая, А.И.Новицкий, А.И.Ногманов, Д.Р.Нуретдинова, Р.М.Нуруллина, Г.Е.Осипов, Г.Г.Осокина, А.Н.Пашкуров, Ю.П.Переведенцев, С.Г.Персова, Н.Г.Петров, В.К.Половняк, Е.В.Порфирьева, Д.Б.Рамазанова, А.Р.Рахман, И.И.Рәхимов, Р.Э.Рәхмәтуллин, Э.Х.Рәхмәтуллин, С.И.Роднина, К.А.Руденко, Г.С.Сабирҗанов, Р.М.Сабиров, А.А.Сабитов, И.К.Сабитов, Ф.Ш.Салитова, И.Г.Салихов, К.М.Салихов, Р.Р.Салихов, Е.А.Сапаев, Г.М.Сафин, М.Г.Сафин, Т.Ф.Сафин, З.А.Сафиуллина, Ф.К.Сафиуллина, Ф.С.Сафиуллина, С.Г.Сафуанов, М.А.Сәйдәшева, Р.С.Сәйфуллин, А.М.Сәлахов, Р.Л.Сәхапов, Л.М.Свердлова, Ю.В.Сементовский, П.П.Сенаторов, Г.И.Середа, А.П.Ситников, А.С.Созинов, В.Д.Соловьёв, Р.Р.Солтанова, Т.Д.Сорокина, В.Ф.Сөләйманов, В.М.Спиридонова, З.А.Старицына, П.Н.Старостин, А.Ф.Степанов, Т.Ф.Степанова, А.Г.Субботин, А.И.Сурская, М.А.Сущенцова, А.С.Тайбинский, Р.И.Такташ, В.Ф.Тарасов, И.Р.Таһиров, М.С.Таһиров, В.Ф.Телишев, В.А.Тимесков, В.Г.Товстуха, И.Ф.Томаева, Д.Г.Тумашева, О.Л.Улемнова, О.Н.Урбанова, Ф.И.Урманчеев, Н.И.Усанова, Р.Г.Усеинова, Р.Г.Усманов, Ә.Х.Фазылҗанов, В.Х.Фазылов, Ф.К.Фәизов, Г.Р.Фәйзрахманова, Р.С.Фәссахов, К.Ф.Фәсхетдинов, К.Р.Фәтхуллин, Д.С.Фәхретдинов, Р.Г.Фәхретдинов, Л.А.Федотова, Н.Л.Фомичёва, С.А.Фролова, Н.Җ.Хаҗипов, В.Х.Хаков, Н.Х.Халитов, Р.Ф.Халитов, Н.Г.Ханзафаров, Ф.М.Харрасова, М.З.Хәбибуллин, Ф.С.Хәбибуллин, А.И.Хәбибуллина, Д.З.Хәйретдинов, Р.Г.Хәйретдинов, Р.Р.Хәйретдинов, Р.Х.Хәйретдинов, Г.Т.Хәйруллин, Җ.Ф.Хәкимова, Л.Р.Хәлилова, И.Х.Хәлиуллин, Л.Х.Хәмидуллин, А.Ә.Хәсәвнех, Р.Р.Хәсәнов, Н.Ш.Хисамов, Д.Д.Хисамова, Р.Х.Хөсәенов, Р.С.Цейтлин, Д.Э.Цыплаков, Г.А.Чмутова, В.А.Шагалов, Б.Н.Шапуков, Р.Г.Шаһиева, Р.В.Шәйдуллин, Р.М.Шәмсутов, Д.Р.Шәрәфетдинов, Ф.Х.Шәрәфетдинов, Р.Ф.Шәрифуллин, Л.Ф.Шәрифуллина, С.М.Шәфигуллина, В.А.Шевченко, Н.В.Шулаев, В.А.Яковлев, Э.З.Якупов, Т.С.Янькова, А.Г.Яруллина.

Тышлыкның макеты, «Биология», «Үсемлекчелек», «Ветеринария» бүлекләрендәге төсле иллюстрацияләр һәм таблицалар рәссам В.Е.Булатов тарафыннан эшләнде.
Махсус фотолар З.Г.Бәширов, Е.Г.Бычков, О.В.Ерёгин, И.М.Йосыпов, Р.Н.Шакиров тарафыннан әзерләнде.
Томда шулай ук Г.П.Бутаков, А.И.Галиев, М.Г.Гафуров, А.Г.Гаянов, Ф.С.Гобәев, В.А.Голенищев-Кутузов, Ш.Ф.Дәүләтшин, Д.Р.Йосыпов, В.Г.Марфин, М.М.Медведев, В.Ю.Соломахин, О.Г.Столова, А.Л.Яскович, И.В.Яценко архивларыннан һәм М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры (Р.И.Такташ), Г.Камал исем. Татар академия театры (Л.Г.Шакирҗанова), В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры (Ю.А.Благов) музейлары, Казан (Идел буе) федераль университеты Геология музее (В.В.Силантьев), В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе фотоархивы (Н.Г.Ризванов) фондларыннан алынган фоторәсемнәр һәм слайдлар файдаланылды.
Иске Казан фотографияләре А.И.Дубин, Г.В.Фролов коллекцияләреннән алынды.

Томның материалларын туплауда ТР Милли архивы (директоры Л.В.Горохова), ТР Тарихи-сәяси документларны саклау үзәк дәүләт архивы (директоры В.Г.Хәмидуллина), ТР Аудио-визуаль документлар үзәк дәүләт архивы (директоры С.И.Горохов). Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсе (директоры Е.Н.Струков), ТР Милли китапханәсе (директоры Н.А.Камбеев), ТР Милли музее (директоры Г.Р.Нәҗипова), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее (директоры Р.М.Нургалиева) хезмәткәрләре катнашты.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты бу томны әзерләүдә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ТР ФА Президиумына (Ә.М.Мазһаров), ТР буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәт территориаль оешмасына (рәисе В.П.Кандилов), ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә (Д.И.Ибраһимов), ТРның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә (Н.А.Никифоров), Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек (М.Г.Әхмәтов), Мәгариф һәм фән (А.Х.Гыйльметдинов), Мәдәният (А.М.Сибагатуллин), Сәламәтлек саклау (А.З.Фәррахов) министрлыкларына, Казан (Идел буе) федераль университеты (ректоры И.Р.Гафуров), Казан дәүләт консерваториясе (ректоры Р.К.Абдуллин), Казан дәүләт медицина академиясе (ректоры К.Ш.Зыятдинов), Казан дәүләт медицина университеты (ректоры А.С.Созинов), Казан дәүләт техник университеты (ректор вазифаларын башкаручы А.Р.Абруков), Казан дәүләт технология университеты (ректоры Г.С.Дьяконов), Казан дәүләт аграр университеты (ректоры Җ.И.Фәйзрахманов); ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (директоры К.М.Миңнуллин), Тарих институты (директоры Р.С.Хәкимов), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (директоры Е.М.Аксёнов), Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты (директоры М.Ш.Таһиров) галимнәренә һәм белгечләренә зур рәхмәтен белдерә.

Төрле вакытта Татар энциклопедиясенең 3 нче томын әзерләүдә: Ф.Т.Арсланова, Ф.З.Вәлиев, Ф.Г.Гарипова, Д.Ә.Гыймранова, В.К.Зыятдинов, А.Х.Мәхмүтова, Р.Ф.Халитов, М.Х.Харисов, Ә.М.Хисамова, Р.Ә.Шакирҗанов катнашты.

Текстларны компьютерда җыю һәм макетка салуда «Jahat Lab., KAI» лабораториясенең (җитәкчесе Р.Р.Имамов) Jahat™ программалар пакеты кулланылды.

**Татар энциклопедиясе:** 6 томда / Баш мөхәррир Ә.М.Мазһаров, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. — Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе, 2012. — **3 т.**: К–Л. — 716 бит, илл., карталар.

ISBN 978-5-902375-08-1

Татар энциклопедиясе — татар халкы һәм Татарстанның борынгы чордан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан беренче фәнни универсаль басма. Китапта 3190 мәкалә (1050 биографик), 1240 иллюстрация (745 төсле) урын алды.

**Tatar ensiklopediəse:** 6 tomda / Baş mөxərrir Ə.M.Mazharov, cavaplı mөxərrir Ğ.S.Sabircanov. — Qazan: «TR FAneñ Tatar ensiklopediəse institutı» dəülət uçrejdeniyese, 2012. — **3 t.**: K–L. — 716 b., ill., kartalar.

Tatar ensiklopediəse — tatar xalqı həm Tatarstannıñ borıngı zamannardan alıp bezneñ kөnnərgə qadərge tarixın həm yəşəyeşen yaqtırtqan tatar telendəge berençe universal’ basma. Tomda 3190 məqalə (1050 şəxeslərgə qarıy), 1240 illustratsiə (745 tөsle).

**Татар энциклопедиясе**

3 нче том

Китапны компьютерда җыю һәм макетка салу Татар энциклопедиясе институтының фәнни нәшрият бүлегендә башкарылды.

Басарга кул куелды 5.7.2012. Махсус кәгазьдә. Форматы 84×108/16.
«Петербург» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма табагы 75,18. Нәшер-хисап табагы 132,48.
Заказ

«ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты» дәүләт учреждениесе.
420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 56.
e-mail: info-ite@mail.ru

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.